*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*җитәкчелеге, бу сүзлекне бастырып чыгаруда*
*матди ярдәм күрсәткәннәре өчен,*
***Камил Алим улы Әбләзов, Равил Рифат улы Әбдрәшитов,***
***Илдар Камил улы Тугушев, Рөстәм Рафаил улы***
***Гыйльметдинов** һәм **Локман Камил улы Әбләзовларга***
*рәхмәтен белдерә*

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА им. Г. ИБРАГИМОВА

**Р. Г. АХМЕТЬЯНОВ**

# ЭТИМОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В ДВУХ ТОМАХ

II том

## М–Я

КАЗАНЬ • ИЗДАТЕЛЬСТВО «МАГАРИФ—ВАКЫТ» • 2015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һәм СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Р. Г. ӘХМӘТЬЯНОВ**

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ

ИКЕ ТОМДА

II том

**М–Я**

КАЗАН • «МӘГАРИФ — ВАКЫТ» НӘШРИЯТЫ • 2015

УДК 494.3
ББК 81.632.3
Ә 87

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Гыйльми советы*
*карары нигезендә басыла*

Россия Федерациясенең «Авторлык хокуклары һәм арадаш хокуклар турында»гы Законы белән саклана.
Китапка кергән материалларны тулысы белән яки өлешчә башка басмалар өчен файдалану, төрле,
шул исәптән электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки төшереп алу
авторлык хокукына ия булган затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела

**Редколлегия:**

К.М. МИҢНУЛЛИН, А.Ә. ТИМЕРХАНОВ (җаваплы редактор), М.Х. ВӘЛИЕВ

**Фәнни редактор**

Р.Т. СӘФӘРОВ

**Бәяләүчеләр:**

Д.Б. РАМАЗАНОВА, филол. ф. док., проф., ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ;
Ф.М. ХИСАМОВА, филол. ф. док., проф., Казан (Идел буе) федераль университеты

**Әхмәтьянов, Р.Г.**

**Ә 87** Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М—Я). — Казан: Мәгариф — Вакыт, 2015. — 567 б.
ISBN

Хәзерге татар лексикографиясендә этимологик сүзлек мондый киң күләмдә һәм чагыштырмача тулы шәкелдә беренче тапкыр нәшер ителә. Сүзлек авторның озак еллар дәвамында алып барган фәнни тикшеренү-эзләнү нәтиҗәләрен, аның бу өлкәдәге табышларын-казанышларын чагылдыра. Сүзлектә барлыгы 10300 чамасы сүзнең килеп чыгышы аңлатылган. Теркәлгән сүзләрнең зур күпчелеген төрки тамырлы берәмлекләр һәм татар теленең диалекталь лексикасы тәшкил итә. Нигездә фонетик яктан үзләштерелгән рус, шулай ук гарәп-фарсы алынмалары да чикләнгән күләмдә кертелгән.

Этимологик сүзлек – филологиянең барча тармакларына иң кирәкле ярдәмлек. Тарихчылар, этнографлар, сәнгатьчеләр һ. б. лар өчен дә ул файдалы белешмә чыганагы була ала. Киң катлам укучылар да монда татар сүзләренең тарихы хакында кызыклы мәгълүмат таба алачак.

Сүзлек, анда тупланган тел материалын мәктәпләрдә, югары уку йортларында уку-укыту программалары кысаларында файдалану өчен шулай ук зур мөмкинлекләр бирә.

ISBN

© Әхмәтьянов Р.Г., 2015
© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2015

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

id. – ibidem, ягъни «шул ук мәгънәдә»
op. cit. – opus citatum – (югарыдарак) күрсәтелгән хезмәт
әд. – әдәби тел
бор. – борынгы
г., гг. – гасыр, гасырлар
гом. – гомум, гомуми
дерив. – деривация
диал. – диалекталь
ирон. – иронияле
иск. – искергән, иске
йөкл. – йөкләтү (юнәлеше)
к. – карагыз
кайт. – кайтым (юнәлеше)
кит. – китаби сүз
көнб. – көнбатыш
көнч. – көнчыгыш
күп. – күплек сан
күч. – күчерелмә мәгънәдә
мәгъ. –мәгънәсендә, мәгънә һ.б.ш.
мәс. – мәсәлән
миф. – мифологиягә караган сүз
неол. – неологизм
сөйл. – сөйләм теле
тар. – тарихи сүз
төш. – төшем (юнәлеше)
тур. – турында
урт. – уртаклык (юнәлеше)
фольк. – фольклор әсәрләрендә кулланыла торган бердәмлек
фонем. – фонематик
хәз. – хәзерге
һ.б.; һ.б.ш. – һәм башка шундый
чаг. – чагыштырыгыз
ш. ук – шулай ук
шигъ. – шигъри сүз
ы. – ымлык
эвф. – эвфемизм
юг. – югары стиль
юн. – юнәлеш
← тамырыннан, тамыр сүздән
> үзгәрү юнәлеше яки телдән телгә күчү-алыну юнәлеше
>> арадаш формалар яисә телләр аша үзгәреп килгән
* реконструкцияләнгән яңгыраш
~ тәңгәл формалар (яңгырашлар) арасында куела
? «шулай микән» мәгънәсендә куела

### Телләр һәм сөйләшләр

абаз. – абазин теле
авар – авар теле
авест. – «Авеста» теле
адыгей – адыгей теле
аз. – азәрбайҗан теле
айну – айну теле
алабугат – татар теленең алабугат сөйләше
алб. – албан теле
алеут – алеут теле
алт. – алтай теле
ассур – ассур теле
әрм. – әрмән теле
әстр. – татар теленең әстерхан сөйләше
әфг. – әфган теле
башк. – башкорт теле
бәҗ. – бәҗәнәк теле
белорус – белорус теле
болг. – Идел буе болгар теле
болг. Д. яки Д. болг. – Дунай буе болгар теле
босн. – босния теле
бөре – татар теленең бөре сөйләше
брб. – татар теленең бараба диалекты
бур. – бурят теле
венг. – венгер (венгр) теле
вьет. – вьетнам теле
гаг. – гагауз теле
гар. – гарәп теле
гәй. – татар теленең гәйнә сөйләше

герм. – герман телләре
голл. – голланд теле
госм. – госманлы теле
груз. – грузин теле
даргин – даргин теле
дат – дат теле
дравид – дравид телләре
дөб. – татар теленең дөбъяз сөйләше
инг. – инглиз теле
ингуш – ингуш теле
индонез. – индонез теле
ир. – иран телләре
исланд – исланд теле
исп. – испан теле
ит. – итальян теле
к.-балк. – карачай-балкар теле
к.-калп. – каракалпак теле
кабарда – кабарда теле
каз. ар. – татар теленең казан арты сөйләшләре
каз. – казак теле
калм. – калмык теле
камас – камас теле
кар. – караим (карай) теле
карагас – карагас теле
карагаш – татар теленең карагаш сөйләше
карел – карел теле
кас. – татар теленең касыйм сөйләше
кет – кет теле
кмшл. – татар теленең камышлы сөйләше
койбал – койбал теле
ком. – комык теле
коми – коми теле
кор. – корей теле
котт – котт теле
көрд – көрд теле
кргл. – татар теленең каргалы сөйләше
кр.-тат. – кырымтатар теле
крш. – татар теленең керәшен сөйләшләре
кузн. – татар теленең кузнецк сөйләше
куман – куман теле
кумд. – куманды теле
кыпч. – кыпчак теле
кырг. – кыргыз теле
кыт. – кытай теле
лат. – латин теле
латыш – латыш теле
леб. – лебедин теле
лезг. – лезгин теле
лив – лив теле
литв. – литва теле
лобнор – уйгур теленең лобнор диалекты

м.-кар. – модва-каратай теле
макед. – македон теле
манси – манси теле
маньч. – маньчжур теле
мар. – мари теле (мар. Т. – мари теленең тау сөйләшләре, мар. Б. – мари теленең болын сөйләшләре, мар. кч. – мари теленең көнчыгыш сөйләшләре, мар. т.-кб. – мари теленең төньяк-көнбатыш сөйләшләре
минз. – татар теленең минзәлә сөйләше
миш. – татар теленең көнбатыш (мишәр) диалекты
молдав. – молдаван теле
монг. – монгол теле
морд. – мордва теле (морд. М. – мукшы, морд. Э. – эрзя)
нан. – нанай теле
негид. – негидал теле
нен. – ненец теле
нидерланд – нидерланд теле
ним. – нимес теле
нокр. – татар теленең нократ сөйләше
нуг. – нугай теле
орок – орок теле
ороч – ороч теле
осет. – осетин теле
пәһл. – пәһләви теле
перм. – пермь теле
пол. – поляк теле
прм. – татар теленең пермь сөйләше
прус – прус теле
пушт. – пуштун теле
рум. – румын теле
рус – рус теле
саам – саам теле
сагай – хакас теленең сагай диалекты
самод. – самодий телләре
санск. – санскрит
сарт – сарт теле
сары уйг. – сары уйгур теле
себ. тат. яки себ. – татар теленең көнчыгыш (себер) диалекты һәм сөйләшләре
селькуп – селькуп теле
сем. – семит телләре
серб – серб теле
серг. – татар теленең сергач сөйләше
слав. –славян телләре
слов. – словен теле
салар – салар теле
сол. – солон теле
сугд – сугд теле

т. я. – татар теленең тау ягы сөйләшләре
таҗ. – таҗик теле
талыш – талыш теле
тамил – тамил теле
таранчы – уйгур теленең таранчы диалекты
тат. – татар теле
тел. – телеут теле
телегу – телегу теле
тибет – тибет теле
тоф. – тофалар теле
тохар – тохар теле
төм. – татар теленең түбән сөйләше
төр. – төрек теле
төрки – төрки тел(ләр)
төркм. – төрекмән теле
тпк. – татар теленең тепекәй сөйләше
трбс. – татар теленең турбаслы сөйләше
туб. – татар теленең тубыл сөйләше
туба. – тубалар теле
тув. – тува (тыва) теле
тунг. – тунгус теле
тунг.-маньч. – тунгус-маньчжур телләре
угыз – угыз телләре
уд. – удэй теле
удм. – удмурт теле
уйг. – уйгур теле
укр. – украин теле
ульч – ульч теле
урал – урал телләре
урду – урду теле
урум – урум теле
үзб. – үзбәк теле
фар.– фарсы теле
фин – фин теле
фин-угор. – фин-угор телләре
фр. – француз теле
хак. – хакас теле
халаҗ – халаҗ теле
халха – монгол теленең халха диалекты
хант. – ханты теле
харәзем – Харәзем дәүләте теле
хатт – хатт теле
хетт – хетт теле
хива – Хива ханлыгында кулланылган тел
хорв. – хорват теле
һинд. – һинд теле
һинд-евр. – һинд-европа телләре
һинд-ир. – һинд-иран телләре
чех – чех теле
чеч. – чечен теле
чжуан – чжуан теле
чирк. – чиркәс теле
чув. – чуваш теле
чулым – чулым теле
чыгт. – чыгтай теле
шор – шор теле
шрл. – татар теленең шарлык сөйләше
шумер – шумер теле
эвен – эвен теле
эвенк – эвенк теле
элам – элам теле
эстон – эстон теле
эстр. – татар теленең эстәрлетамак сөйләше
эчк. – татар теленең эчкен сөйләше
ягн. – ягноб теле
яз. монг. – язма монгол теле
як. – якут теле
яп. – япон теле
яушт. – татар теленең яүштә-чат сөйләше
яһ. – яһүд теле

Кайбер телләрнең атамалары текстта кыскартылмыйча язылды (мәс., авар., рус., урду. һ.б.), ләкин тел турында сүз барганлыгын белдерү өчен нокта куелды.

**ТАТАР АЛФАВИТЫ**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Дд | Зз | Мм | Пп | Үү | Чч | Ьь |
| Әә | Ее | Ии | Нн | Рр | Фф | Шш | Ээ |
| Бб | Ёё | Йй | Ңң | Сс | Хх | Щщ | Юю |
| Вв | Жж | Кк | Оо | Тт | Һһ | Ъъ | Яя |
| Гг | Җҗ | Лл | Өө | Уу | Цц | Ыы | |

# М

**М** авазы төрки телләрдә еш кына **б** авазы белән чиратлаша (**б** > **м** да **м** > **б** да очрый). Тат. телендә бу авазга башланган сүзләрдә гарәп алынмалары зур урын алган.

**МАВЫК-У (мавыкты, мавыга)** «увлекаться», (Радлов II: 1992) «взяться за дело» ~ каз. *мауқ-* «язын жанланып китү, тернәкләнү, дәртләнү», к.-калп. *маўық-* «бик нык теләү» < бор. төрки **маңық-* «атлыгу» ← (ДТС: 337) *таŋ-* «тиз йөрү» > тат. диал. (себ.), нуг. **маң-** «ашыгу», уйг., чыгт. *маң-* «тиз-тиз йөренү, йөгерү» (ягъни *маңык-* > *маwық-* – бор. *маң-* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе, чаг. **ашык-у ← аш-у** һ.б.ш.).

Шул ук *маң-* фигыленнән **маңук, маңык** «тиз йөрү, ашыгу, чабулау күренеше» сүзе дә ясалган булган, шуннан тат. *маwык* (к. Ф. Сәйфи-Казанлыда **мавыклану** «мавыгып вакыт уздыру, бүтән эшкә карамау») ~ каз. *мауық,* к.-калп. *мавх* «борчылып әрле-бирле йөреш», кырг. *мооқ* «теләк, омтылыш» һ.б., к. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 176) *маңк*, каз. (ҚТДС: 232) *маңқы* «омтылыш».

**Маң-** фигыленең исем коррелянты («адым, керешү» мәгъ.) булган, шуннан к. **Манты-у,** башк. (БТДҺ: 229) *маңда-у* «җайлау».

Дерив.: **мавыгыл-у, мавыгыш-у, мавыктыр-у** (→ **мавыктыргыч**).

**МАВЫЛ [маᵒwы̆л], мағыл** (Будагов II: 201; Тумашева 1992: 146, 149) «шест; пересов (на ворота)» ~ башк. (БТДҺ: 230) *мауыл* «киштә». Чыгышы ачык түгел. Рус. (Аникин: 381) *маул* «чош сәрдек (настил), елга аша басма» сүзе татарчадан дип күрсәтелә.

**МАГА, магай** (себ, к. Аникин: 364) «балык тоту әсбабы – озын мурда» ~ селькуп., рус. диал. *магай* id. Чаг. тунгус. (ССТМЯ II: 520) *магдан* «вак балыкка куелган ятьмә».

**МАГАҖИ, мағазы** (ТТДС I: 296) «место хранения общественных запасов хлеба и других продуктов» ~ башк. (БТДҺ: 234, 241) *мәгәзин, мәгәзәй, мәңгәзәй, мөгәзәй, мүгәҗә* «иген амбары», каз. (ҚТДС: 236) *мәңгезей* ~ чув. *макаç, макаçа, макаçей, мокаçи, мокоçей* id. (к. Сергеев 1971: 85), удм. *магазэй* (к. Зверева: 110–115), мар. *магази, магаза* «орлык фондын саклау урыны» (Саваткова: 88) ~ нуг. *йэрмагазы, маңгазы* «көпкә, зимләнке; хөкүмәт казнасы», бор. тат. (Казан дәүләтендә) *магазы* «каравыл өе» (к. Ноғай халқ йырлары: 208), төр. *magaza, mahazin* «җирасты амбары; ашлык саклау урыны» (Redhouse: 718, 720, 723), гаг. *мааза, магазие* «нәүрәп» һ.б.; бу сүз рус сөйләшләрендә дә киң таралган: *магазей, магазейн, мангазина, мугазея* һ.б. (вариантлары күп, к. СРНГ, 17: 287–288). Төп чыганак – гар. *мăхāзин, мăхзăн* «мөлкәт саклау урыны». Бу сүз гар. *хзн* «саклау, саклыкка калдыру» тамырыннан, шуннан ук к. **Мәхзән, Хәзинә.**

Рус. *магазейн* тур. төрле карашлар бар: берәүләр аны Көнб. Европадан килгән (ә Европа телләренә, әлбәттә, гарәпчәдән) диләр (к. Биржанова, Войнова, Кутниа: 281–282); икенчеләр турыдан-туры Шәрыктән (татарчадан яисә төрекчәдән) диебрәк язалар (Шипова: 225). *Магазейн* сүзе рус телендә XVIII г. гына түгел, аннан элегрәк булган: «Иоанн I определил во всех городах иметь запасом на три года … магазейны» (Татищев: 277). Ләкин аңа кадәр Бату хан да шундый «магазиннар» оештырган (На стыке континентов и цивилизаций: 258). Чаг. ш. ук каз. *мәңгезей* «бик зур (ун мең сарыклык) абзар» (к. ҚТДС: 236). Гомуми азык запасы амбарлары ясау, әлбәттә, беренче дәүләтләрдә, б.э.к. III меңьеллыкта ук булган.

*Магаҗи* сүзеннән үзгә буларак хәз. тат. **магазин** «кибет, сатуханә» рус теленнән (рус. < фр.) килә. Һәм бу сүз дә гар. *мăхāзин* сүзенең бер чагылышы гына. К. Фасмер II: 554–555; Добродомов И.Г. Слова-путешественники. Русская речь, № 1, 1967; Федотов I: 339–340.

**Магазы ~ мәгәзәй** сүзе XIX г. 30 нчы елларында активлашып китә: патша хөкүмәте авылларда *магазей*ләр салдырырга һәм аларның ишек башына христианнарча миһербанлык билгесе – хач ясап куерга әмер бирә; татар-башкортлар моны христианлаштырырга маташу дип аңлаганнар; нәтиҗәдә «башкорт болаларының» соңгысы – 1835 елгы «восстание» килеп чыккан.

**МАГАРЫЧ, мыгарыйч** «магарыч (взятка, подарок за устройство дел, особенно продажи-покупки)» < рус., русчага төрки телләр аша гар. **Мәхариҗ** (к.) сүзеннән. Рус. *магарыч, магурец, могорец* һ.б. вариантлар тур. Аникин: 364–365.

**МАЕМ: маем килү, майымлау** «извергнуть съеденное (от переедания и т.п.); не переносить жирной пищи» ~ башк. (к. БҺҺ II: 167) *майымнау, майыннау* «бөгү; юлга чыккач кире кайту; элекке өенә кайту (сатылган мал тур.)». Ике тамырдан ясалган: 1) **майы** «кире кайткан нәрсә», 2) **май** халык этимологиясенчә **май** «организмдагы суда эреми торган матдә» сүзенә нисбәт ителгән.

Дерив.: **майым китерү, маемлат-у.**

**МАЕТ [маᵒйыйт], майт** (БТДҺ: 227) «состояние усталости; трудный; твёрдый» ← **май-, майы-** (к.) фигыленнән ясалган бор. (*-т*) нигез. К. ш. ук тат. **майыт-у** «рәхмәт әйтү (сый-хөрмәт өчен)».

**МАЕТ-У [маᵒйыйт-]** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «отблагодарить; отплатить», башк. (БТДҺ: 227) *майыт-* id., ш. ук «рәнҗетү» ← **май-у** (к.).

**МАЕШ-У [маᵒйыйш-]** (Й. Гиганов), диал. (БТДҺ: 240) **мәйеш-ү** «перегибаться, гнуться; отступать перед трудностями» ← **май-у, майы-у** (шул фигыльнең аерым мәгъ. алган урт. юн.).

Дерив.: **майышкак** (к. Тумашева 1992: 147) «бөгелүчән», башк. диал. *мәйшелдәк* «артык бөгелүчән, сыек, шыек», *мәеш* «кыеш, бөгелгән; яньчелгән» (→ **мәйшәй-** «бөгелү») һ.б.

**МАҖАР I** «большая телега, фургон», (Ә. Баян; БҺҺ III: 131) «басу арбасы» киң таралган сүз: кр.-тат., кар., к.-балк., ком., нуг. *мажҗар*, id. рус. *мажар* «сәүдә олавының кулавызы (юл күрсәтүчесе)», *мажара* «зур, авыр арба», «утын сату берәмлеге» (СРНГ 17; 297), калм. (Ramstedt 1935: 294) *madǯar* «арт күчәре аеруча озын, киң көймәле арба», укр. *мажары* «үгезләр җигелә торган арба», төркм. диал. (ТДГДС: 124) *мажҗар* «фургон» – сүзлекләрдә төрки *мажҗар* «мадьяр, венгр» сүзенә бәйләп аңлатыла (Фасмер II: 357), чаг. тат. диал. **мишәр арбасы** id. К. **Маҗар II, Мишәр.**

**МАҖАР II** «мадьяр, венгр» < төр. *macar* < венг. *magyar* – венгрларның үзатамасы.

**МАҖАРА** «приключение» < гар. *māǯārā* «маҗара, дөнья күрү» – *җрр* «сөйрәү, сөйрәлү, ышкылу, ягылу, катнашу» тамырыннан; *мажҗара* сүзе тат. әд. теленә төр. *macera* id. сүзеннән килә.

**МАЗА** «покой, спокойно-довольное состояние», диал. (Тумашева 1992: 142) «красота, пригожество» (**мазалы** «смазливый») > удм., мар. *маза* id., чув. *маса* «матурлык, ямь» ~ нуг., каз., үзб., төркм. һ.б. *маза, мазза* «маза; тәм», уйг. *мәзә* id., төр., фар. *meza, meze* «тәм-том; шаярту; җиңелчә исереклек» >> башк. диал. (БТДҺ: 226) *маҙа* «тәм, тәмләү; рәхәтлек» ~ гар. *mäzzä* id. *мзз* «суыру, имү; чөмерү» тамырыннан. Морд., рус. *мазый* «матур» төрки телләрдән (мөгаен татарчадан) булса кирәк (бу сүз м.-кар. сөйләшендә кулланыла). Гомумән, ир. телләрдән, к. авест. *mazanh* «тат, тәм».

Дерив.: **мазалы, мазасыз;** диал. **мазалан-у** (кире мәгъ. «азаплану»).

**МАЗАР** «чёртовы кулички, бог знает где» (*ни мазарыма киткәндер* «куда он запропастился»). Прибавляясь к существительным, образует парные слова с модальным значением уничижения того, что выражено основным словом, например: *эт-мазар* «собачонка какая-то (какая-нибудь)» ~ чув. *масар* id., ш. ук «теләсә нәрсә», мар. *мазар* id., ш. ук «күп кенә, шактый; никадәр (!)» ← тат. әд. *мәзар, мазар* «каберлек». Кайбер зиратларда һәртөрле корбанлык әйберләр (киндер һәм тире кисәкләре, тасмалар һ.б. агачларга эленеп торган, шуңа күрә алар кирәкмәгән төш, кирәкмәгән кемсә яисә нәрсә мәгънәсен алганнар, бу турыда к. Г. Ахмаров 1903: 17). К. ш. ук **Мәзар.**

**МАЗЛУМ** «угнетенный» к. **Мәзлум.**

**МАЗЫЙ** «бывший, прежний» (*мазый хөкүмәт* «бывшее правительство»), «прошедший» (о грамматическом времени) < гар. *māḍī* id., к. ГТРС: 250. Бу термин әдәби-мәдәни характерда.

**МАИП** (Будагов II: 202; ЗДС: 462), **мәйеп** «увечный, раненый» < гар. *mä'īb* «(тән) гаебе бар». Бу сүз төрки телләрдә киң таралган, к. үзб. *майыб*, уйг. *мәйеп* һ.б. «чулак, бәрелгән-сугылган». Күбесенчә **мәйеп булу** тәгъбирендә кулланыла.

Бу сүзнең чыганакка якынрак **мәгъюб** яңгырашы «гаепле, гаепләнүче» мәгъ. кулланылган.

**МАЙ I** «месяц май» < рус. < лат. Элекке әд. телдә төрекчәдән алып *майыс, майус* сүзен куллан-

ганнар, бу сүз турыдан-туры латинчадан (түбәндә «үстергеч фәрештә» исеме).

**МАЙ II** «масло, жир» ~ гом. кыпч., уйг. *май*, үзб. *мой*, төркм. *маай,* угыз телләрендә сирәк очрый, кор. телендәге *ma, mai* «май» белән чагыштырыла (Ramstedt 1935: 113; Räsänen 1969: 322). Ләкин, безнеңчә, кор. сүзе очраклы охшашлыкка ия.

Тат. сөйләшләрендә (миш.) **май** «бәби туе – бала туугa багышланган тантаналы мәҗлес» (к. Рамазанова 1997: 61–64), **бәби мае** «исем кушу мәҗлесе» (ДС I: 40), **маем** «кадерлем, җаным, фәрештәм» (мәс., к. Тарихи һәм лирик җырлар 1988: 278) яки менә җыр өзеге: *Йөзләрең тулган ай кебек. Үзең сары май кебек...* Татар халкы сөйгән кызын *сары май*га тиңләр дәрәҗәдә зәвыксыз микән ни? Юк, әлбәттә, *сары май* ул бор. кыпч. *Сары Умай* «гүзәл (к. **Сары**) Умай», ягъни бәбиләр һәм бала табучы хатыннар химаячесе булган алиһә, к. алт. диал. *Умай, Убай, Ымай, Май-энэ (инә)* id. (аның хакында әдәбият күп, к., мәс., Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири: 151–153, 166). Т. Ялчыголда (Рисаләи Газизә. Казан, 2014: 26) *сары май кеби, мөселман кардәшләреңә мөлаем улгыл.* Монда *сары май* зат, шәхес, югыйсә *мөселман кардәшләреңә сары май кеби мөлаем улгыл* булыр иде. *Умай* > тат. *Ŏмай, Ымай* > *май* күчеше фонетик җәһәттән табигый, мәгънәви җәһәттән шуның белән аңлатыла: мәҗүси карашлар буенча, яңа туган бәби өстендә **Аза** белән **Умай** көрәшә – Аза бәбине үтерергә, Умай саклап калырга омтыла, Умайга куәт бирер өчен майлы аш пешергәннәр, май исе (*таба исе*) чыгарганнар, рухлар хуш ис белән туклананалар дип уйланылган. Бу хакта моннан мең ел элек Ә. Бируни язып калдырган: «Харәзем әһелләре… явыз рухлардан саклану өчен аш исе чыгаралар…», «Хәз. көнгәчә таҗиклар, үзбәкләр, каракалпаклар, татарлар, төрекләр… рухлар май исе белән туклана дип уйлыйлар» (к. Кармышева: 147–175). Нугайларда да шул ырым булган (к. Ногайцы: 174–175). Себердә «*зираттан килүwенә май йеc тип май-әлwә кылатлар ... йеc чыксын дигән сүз булаты ... әрwахлар, рухлар иснәгәле тейеш, – диләр»* (Баязитова 2001: 197). К. ш. ук **Аза, Нумай, Умай.** ЭСТЯ VII: 13–14.

Диал. (ТТДС II: 217–218) **майбыр, майкуш** «кадерле(м)» сүзләре дә **май < умай** сүзе нигезендә ясалганнар.

**МАЙ III** (трбс.) «загиб; возврат (лишнего, переплаченного), сдача; согнутый (наоборот)» – **май II** тарафыннан хәз. телдән кысрыкланган бу сүз бик күп (башлыча диал.) сүзләрнең тамыры, тик иске ядкәрләрдә сирәк очрый; чаг. як. (Пекарский: 1514) *манјa-* «түләү» ~ ? кыт. *мэ(й)* «янгын сүндерү; бурычны түләү». К. **Маемлау, Маймак, Майрык, Майтару, Майткы, Майтояк, Майу, Майыт, Майыту, Майышу.** Бу рәткә караган бүтән сүзләр тур. Räsänen 1969: 322 (ләкин безнекеннән азрак).

**МАЙБАЛЫК** (П. Паллас) «черноспинка (рыба)», диал. (Арсланов 1988: 87) «сельдь» > калм. (Линдберг, Герд: 70) *ма-балык* id. **Май-** монда нинди мәгъ. икәнлеге аңлашылып бетми. Чаг. **Маймыч,** башк. (БТДһ: 227) *майма* «ташбаш, капкорсак».

**МАЙГАК** «самка марала» (КБ телендә «ана марал»), хәз. рус: (Аникин: 366) *майгак* id. ~ алт., тув. *тујуaq*, хак. *тију* id. Ясалышы буенча хөкем йөрткәндә, ниндидер *май-* фигыленнән һәм шуннан ук түбәндәге **майган** сүзе дә ясалган булса кирәк.

**МАЙГАН –** разновидность диких уток в Сибири (ЗДС: 464). Чаг. рус. диал. (Аникин: 368) *майхан* «аучы чатыры яки куышы» ~ тув. *таiууп*, тув., монг. *майхан* < маньч. *майкан* id., каз. (ҚТДС: 229) *майкан* «ашлык өеме; кирпеч киптерү лапасы». Тат. мәгънәсе *майканга бару* кебек тәгъбирләрдән килеп чыккан бугай (транзитив мәгъ. булган).

**МАЙМАК** (Н. Исәнбәт) «косолапый» ~ башк. (БТДһ: 227) *маймык* «йомшак; хәлсез» < гом. кыпч., уйг. *маймақ*, каз. *майпақ, майпаң*, тув. *майтақ* id. ← **майу** (к.).

К. ш. ук аз. *маймақ* «әле тоягы катмаган, тоягына басалмый торган бута (дөя баласы)», **маймыр** «чатан дөя». Көньяк Себ. рус һәм төрки сөйләшләрендә **маймак** «сырылган, тегелгән аякчу» сүзе бар. Аны кытайчага нисбәтлиләр икән (Аникин: 367). Безнеңчә, бу сүзнең кыт. сүзләренә дә, безнең **маймак** сүзенә дә катнашы юк, ә **пайпак** (к.) ~ *баймак* ~ *майпак* «оек» сүзләре рәтендә. **Маймак** яңгырашының әле «бармак» мәгъ. бар. Популяр яңгыраш инде, әйтәсе дә юк.

**МАЙМЫЛ, маймул,** гом. диал. **мәймүн** «обезьяна» ~ башк. (БТДһ: 227) *маймун, маймын, мәймүн* id. > чув. *маймăл*, удм., мар. *маймыл*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 173) *маймыл* < чыгт., к.-балк. *маймул* < куман., ком., кар., уйг., госм. *маймун* id. < гар.

*маймӯн* «Йәмәнле, Йәмән иленнән килгән (маймыллар Йәмәннән китерелгәннәр); бәхетле» (к. тат. хатын-кыз исеме – **Мәймүнә** «бәхетле кыз; Йәмән кызы»): **Йәмән** бәхетле ил дип исәпләнгән (чаг. рус. *Счастливая Аравия* – легендар ил) ← гар. *ймн* «бәхетле булу» (әмма фигыль тамыры беренчелме, ил атамасымы – ачык түгел). Маймыллар да «бәхетле халык» дип исәпләнгәннәр.

Бор. рус. *мамона* < лат. *mamona* > ит. *manina* >> инг. *monkey* «маймыл» сүзе *маймун* > *маймыл* белән тамырдаш булса кирәк.

Дерив.: **маймыллык; маймыллан-у** «кылану».

**МАЙМЫЧ,** диал. **маймуч**, (ТТДС I: 297; БТДҺ: 227) **майма, маймы, маймак, маймич** «малёк (рыба)» ~ башк. *маймыс, маймус,* як. *maіма, байба* id. тунг. (ССТМЯ I: 521–522) *майма, мальма, майгу, майагас* (барысы да як. сөйләшләреннән булса кирәк) балык төрләре. Ихтимал, **мармыш** (к.) белән баглыдыр. Гомумән, бу сүз формаларында контаминация очраклары бар (чаг. башк. *маймак* «маймыч» – тат. **маймак** «гарип; йомшак (тәнле)»).

**МАЙРЫК, майырык** (ТТДС I: 297; БҺҺ II: 167; БТДҺ: 227) «увечный; хилый; мягкотелый; неестественно согнутый» < гом. кыпч., алт., тув. *майырык,* уйг., чыгт. (Zenker: 804) һ.б. *майрук,* каз., алт. *мыйрык,* монг. *майыраг* id. ← тат., башк. **майыр-* (к. башк. – БТДҺ: 227 – *майырыл-ыу* «кайтарылу, бөгелү») < гом. кыпч., үзб. (ЎХШЛ: 175) *майыр-* «кәкрәйтү, бөгү; имгәтү» ← *май-, майы-* (к. **Май-у**) «кирегә бөгү»; бур. *майыр-* «кайтарып бирү; түләү» төрки телләрдән; к. ш. ук иске тат. (Будагов II: 202) **майра-у** «кыешаю» (← ***майыр** «кыеш»?).

**МАЙТАР-У** (ДС II: 136; ДС III: 109, әд. чыганаклар) ирон. «наделать дела», «загнуть; отбить атаку; делать наоборот», «платить долг работы (день работы за день)» ← **май-, майы-** (к. **Май-у**); гом. кыпч. характерда, к. каз., кырг. *майтыр-* «арыту; телләшү, тавыш күтәрү», кырг. *майтар-* «мактанчыкны урынына утырту» һ.б.

Дерив.: **майтарылу, майтарышу, майтарту.**

**МАЙТКЫ, мәйтке** «остроумный ответ на выпад; словесная игра-баталия (обмен колючими шутками-прибаутками)» < **майыткы ← майыт-у** (**майы-у** фигыленең йөкл. юнәлешеннән). К. **Аткый-маткый, Май-у.**

**МАЙТОЯК** (трбс.) «болезнь лошадей, при которой они не ступают на копыта» ← **майы тояк** булса кирәк, к. бор. төрки (ДТС: 335) *tajγuq* «кәкрәйгән; чатан, аксак» ← **майы-** (к. **Май-у**). Чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 227) *маймаңна-у* «бер аягын аяп атлау; йөргәндә бөгелү»; аз. (АДДЛ: 314) *мајтах* «аксак», *мајтымах* «аксау».

***МАЙ-У, майы-у** «загнуться назад; отказаться от решения, передумать; отступить перед трудностями» < гом. кыпч. характерда, к. каз. *май-, майы-* ~ бур. *май-, майа-* «(аяклар) бөгелү; аксау» < бор. төрки (Räsänen 1969: 322) *май-* «бөгелеп төшү һ.б.» – **май III** сүзенең фигыль коррелянты. К. ш. ук ЭСТЯ VII: 14–18.

**Май-, майы-** бик продуктив нигез, аның **маеш-у, майтар-у, маер-у** юн. формалары билгеле (к. аерым матдәләр), к. **Мает**, башк. (БТДҺ: 226–227) *майкылда-у, майлыш* < *майылыш* һ.б. Чаг. **Маемла-у.**

**МАКАБЕЛ** (К. Тинчурин) «составная часть общего стола (еды)» – шәкертләрдә < гар. *мӓқāбил* «партнёр», «аерым кешенең уртак чыгымга һ.б. керткән өлеше». **Макабел кертү** «взнос кертү».

**МАКАУ [маºқaw]** (ТТДС I: 298; БТДҺ: 227) «человек с плохой дикцией; глуповатый человек» > мар. *маха* «саңгырау» ~ каз. *мақау*, кырг. *макоо* «макау». Чаг. гар. *ма қawlӓ, ля кawwуl* «сөйләшә алмаучы»; чаг. ш. ук **Махау.**

**МАКЛАК** иск. (Ш. Камал һ.б. язучыларда) «маклак, хвалитель товара на базаре, посредник – знаток при покупке (особенно – лошадей)» ← **мақла-* «мактау» сүзеннән булса кирәк. Ләкин к. гар. *мӓғāллӓк* «маклак, арадашчы».

**Маклак** сүзе рус телендә күп дериватлар биргән: *маклачить, махлачить, маклевать, маклыжить* (к. Даль). Рус. *маклер* < ним. *Makler* бөтенләй бүтән сүз: мондагы охшашлык – очраклы.

Хәз. рус сөйл. телендә таралган *мухлевать* «сату-алуда, уенда хәрәмләшү» чув. диал. *мухлак* «маклак» сүзенә тоташа шикелле.

**МАКМАЛ** (Будагов II: 248; Тумашева 1992: 164) «толстая шёлковая ткань» ~ каз., к.-калп., кырг., үзб. *макмал* id. Л. Будагов буенча (II: 216) гар. *мӓхмӓл* «Мәккәгә Кәгъбәне тышлау өчен җибәреләә торган ефәк» – төп мәгънәсе «йөк» (к. **Хәмел**) сүзеннән. Киң таралган сүз.

**МАКСАТ** «цель, желанное» < гар. *mäķçad* id. ← *ķçd* «теләү» тамырыннан, шуннан ук к. **Касд.**

Дерив.: **максатлы, максатсыз; максатчан** һ.б.

**МАКСЫМА** (Хайрутдинова 1993: 122) «домашнее пиво (слитое в первую очередь)», (ТТДС I: 298) **маķсым** «брага без хмеля» (Гигановтан) > мар. диал. *максым*, удм. *максыма,* чув. *максăма* id. ~ каз. *маķсым* «ашлыктан ясала торган эчемлек», (ҠТДС: 230) «квас», кырг. *маķсым* «арпа ярмасыннан ясала торган әчкелтем эчемлек», адыг телләрендә *бахсыма, максыма* «буза» һ.б. гар. (> тат.) *mä'çӯm* «гөнаһсыз (мөзәккәр)», *mä'çӯmä* «гөнаһсыз (мөәннәс)» сүзләреннән (кеше исеме буларак та билгеле), к. каз., кырг. *маķсым* «ишан углы», *маķсыма* «ишан кызы», «изге хатын» ЭСТЯ VII: 18–19.

**Максыма** сүзен морд. Э. *максома* «ярдәм» сүзе белән чагыштыру дөрес түгел. Морд. сүзе Көнч. Европада киң таралган *макс* «өстәмә түләү» сүзеннән икән (Masing U. Akkadisches miksu in Osteuropa. Acta antiqua (Budapest) XXII, 1–4, 1974: 521–526.

**Максыма** «исерткеч булып исәпләнми, эчсәң дә гөнаһ түгел» була.

**МАКСЫМТАРАЙ** диал. «божья коровка (насекомое)» > мар. *максымтрай* id. Бу сүз камка тараканның диал. атамаларының – **максым** һәм **тарай** сүзләренең берләштерелүеннән пәйда булган. Ягъни кайбер урыннарда бу бөҗәкне **максым** «гөнаһсыз, мәгъсум» дип, икенче бер тарафларда **тарай** «түгәрәк-түгәрәк таплы тукыма» дип атаганнар. Бу атама әһелләре берләшкәч, уртак *максымтарай* килеп чыккан.

Бу бөҗәкнең *мәксым – мәгъсум* дип аталуы аның файдалы булуыннан – гөбләләрне, бүтән вак корткычларны ашап йөрүеннән һәм әкрен хәрәкәтләнүеннән, шунлыктан ук рус. *божья коровка* «Алла бозавы». Тат. **Алла бозавы** дип бик әкрен кыланучыларны атыйлар.

**МАКТАЛ, мактагал** «хвалебная песня, ода (в эпосе)», диал. **маķтаwыл (мактаwыл тойоķ)** «песня – восхваление жениха и невесты» (*Икегез дә пар килгәнсез, гөрләп гомер итегез* һ.б.) ~ каз. *маķтал, маķтан* «горурлык» ~ тув. *магадал* «дан җыры» (← *мағада* «соклану»), як. *махтал, махтабыл* «мактау», *мағадал* «соклану, сокланып җырлау» < монг. *мактагал* id. (*-гал* монг. кушымчасы). Тимергалин: 290. К. **Макта-у.**

Дерив.: **макталла-у, макталлы** (шуннан үзгәртеп **мактаулы** килеп чыккан).

**МАКТА-У** «хвалить» > мар., удм. *макта-*, чув. *мохта-* > *мухта-* гом. төрки, монг., тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 523) *маķта-*, яз. монг. *taγta-* id. чыгт., куман., алт., кырг., каз. (Радлов IV: 1993; Будагов II: 197–198 һ.б.) *маķ,* бор. төрки *таγ* «мактау, шаншәрәф» сүзеннән, к. ш. ук тат. (Утыз-Имәни 1986: 119) **маķчы** ~ каз. *маķшы* «мактанчык». Тамыры сугд. *т'γ* «дан, мактау» сүзеннән дип уйланыла (ДТС: 335), шуннан уйг. *магу* «дан», *мағут-* «мактау, данлау» ~ хак. диал. *магат-* «шәп эш итү», хак. *мағатта-* id. ясалган. К. ш. ук хак. *мах* «дан», *махтыг* «билгеле, мәгълүм», хак., уйг. *мағат* «бик шәп; һәйбәт», *маңат* «гадел, игелекле», тув. *мага-* «ләззәтләнү», *мағада-* «таң калу», *мағалығ* «бик шәп» һ.б. К. **Магалт-у.**

Бу материалдан чыгып, *макта-* < *магыт-а-* дип, ә **магыт* «дан» нигезе бор. **магы-* «данлау» фигыленнән, *мағ* тамырыннан дип әйтеп була. *Макта-у* < *макла-у* түгел! Ләкин *маг* тамыры үзе *магу*дан килеп чыкмадымы икән?

*Макта-у* фигыленең киң таралуы аның бор. дәүләтчелек термины булганлыгы белән аңлатыла. Федотов I: 364; ЭСТЯ VII: 11–13. К. **Маклак, Мактал.**

Дерив.: **мактал-у, мактан-у, макташ-у, мактат-у; мактанчык** һ.б.

**МАЛ** «имущество; товар; скот, скотина» > мар., удм. *мал*, чув. *мол* > *мул* < гом. төрки *мал*, төркм., як. *маал,* монг. *мал* (монг. диал. *мар*), фар. гар. һ.б. *māl* id. Күчмәннәрнең төп байлыгы терлек булганлыктан, бу сүзнең мәгъ. структурасы бик аңлашыла. «Товар» мәгънәсе (к. тат. *кызыл мал* «мануфактур товар») гадәттә ат белән бәйле (чаг. *табыр ~ tawar*), шунлыктан бу сүзнең элекке мәгънәсе дә «ат» булган дип уйлыйлар һәм кор. *mal* (*маль, моль*) «ат» белән (Рамстедт 1957: 190) яисә кыт. *ма* < бор. кыт. *mla* < *mra* (к. бирманча *mraŋ*) ~ тамил. *mä*, инг. *mare* «ат» сүзләре белән чагыштыралар (к. Новиков А. К истории и этимологии лошади в алтайских языках // Проблемы алтаистики и монголоведения. М., 1975: 36–58).

Гомумән, бу сүз бик бор. халыкара мәдәни тамырдан дип уйларга нигезләр бар (гар. теленнән дип раслау дөрес булмас). Беренчел чыганагы – тәүләп кыргый атны ияләштерүчеләр теле, дип уйларга мөмкин.

**Мал** сүзе югарыда күрсәтелмәгән күп кенә бүтән (тунг., слав., Кавказ һ.б.) телләргә дә кергән. К. ш. ук Радлов IV: 2035; Будагов II: 199; Räsänen 1969: 323; Walde-Pokorny II: 296; Федотов I: 361.

Дерив.: **малчы; малчылык; малбагар** (неол.); **малтабар;** гарәпчәдән: **мали, малия** «финанс».

**МАЛАЙ,** диал. (ДС III: 110) **малый** «мальчик», диал. «парень», иск. «слуга, лакей, официант» < рус. *мало́й, малый* (шулай дип элек русча фамильяр рәвештә хадимнәрне, хезмәтче егетләрне һ.б. да атаганнар, к. *добрый малый* «яхшы яшь кеше» һ.б.). Үзб., каз., кырг. *малай* «лакей» рус сәүдәгәрләре теленнән (бу мәгънә инг. *boy* «малай; хезмәтче» сүзеннән калька булса кирәк). Сүзнең тамыры рус һ.б. *мал* «кечкенә» һәм бу сүз тәүдә «вак мал, кәҗә-сарык» мәгъ. булган (ләкин этимологлар моны *мал* «терлек» сүзе белән чагыштыруга каршы). ЭСТЯ VII: 20–21 (рус сүзеннән булуына шик белдерелә).

Тат. сөйләм телендәге *малай, малайкай, малайкаем* «дустым» мәгъ. хатын-кызларга карата да әйтелә. К. **Малайшак.**

**МАЛАЙШАК** (ТТДС I: 299) «ребятишки, ребятня; сын-мальчик» < *малай-ушак*. К. **Ошак.**

**МАЛАЙ-ШАЛАЙ, малай-салай** «мальчуганы; ребята-негодники» – рус теленнән субституция булса кирәк (рус. сөйл. *малый-шалый* id.).

**МАЛАСНИК** (Тумашева 1961: 164) «сосуд для молока» < рус. диал. *молостник* (*молочник* түгел), к. ш. ук иске тат. **маластауный чүлмәк** (Г. Кандалый) ← рус. *молостав, молост* «туз белән уратылган чүлмәк» (Фасмер II: 646–647): җәен тиз генә әчемәсен өчен сөтле чүлмәкне юеш тузга яисә чүпрәккә төреп куйганнар.

**МАЛАХАЙ** (Радлов IV: 2037; БТДҺ: 228) «острая меховая шапка с наушниками» ~ чув. *мулахай, мулаххай* < *молахай* id., ш. ук «башлыклы кыска җилән» ~ каз., кырг. һ.б. кыпч. *малақай*, алт. *малаккай*, уйг. *малихай* ~ бур. *малғай* «малахай», тат. (к. махсус матдә) **мәгәләй < *мәкәләй ~ *мәләхәй ~ мәһәләй** «лачынчы-бөркетчеләрнең күн башлыгы һәм лачын, бөркет тырнагыннан саклангыч иңбаш вә җиң капламасы» < фар. *бäһлäи* (к. **Бияләй**) сүзеннән килә. Бу сүз тат. телендә һәм аның сөйләшләрендә күптөрле үзгәрешләр кичергән, күп яңа мәгънәләр алган, к. **Мәләчлек.**

*Мәһәләй* вариантына рус. диал. *махалай, махлай* һәм маньч. *махала* «малахай, шаман бүреге, кыйммәтле баш киеме (таҗ һ.б.)», калм. *махl* «томак бүрек» һ.б.ш. (к. Фасмер II: 262; ССТМЯ I: 322; Аникин: 370) тоташа. Бу этимологик полиплет матди мәдәният тарихына зур мәгълүмат бирә һәм шул ук вакытта күп сораулар да уята. Тамыр – төп сүзнең фар.-сугд. даирәсеннән бик бор. заманнарда (б.э. I меңьеллыгында ук) таралганлыгы ачык: ул як. теленә дә кереп өлгергән һәм чжурчжэнь иероглифик яз. телендә дә (*ma-hi-lah*) булган. Безнең өчен әһәмиятлесе шул – сүзнең иң киң тармакланышы – тат. телендә (биш аерым сүз!). Бу хәл татарларның элгәрләре матди мәдәният таратучылар булган, дигән нәтиҗәгә китерә.

Сүзнең велярлашуы (*мәләхәй > малахай*) кайда, нинди мохиттә булган – монысы табышмаклы мәсьәлә. Һәрхәлдә рус телендә (яки рус телендә генә) электән булмаган – моңа каз., кырг., уйг., маньч. һәм чжурчжэнь мисаллары дәлил.

Бор. фар. *мäһлäи, мäһлаи* гомумән киң мәгънәдә «яшергеч, өрткеч, каплагыч, гизләгеч» мәгъ. булган, шуннан «кул яшергеч» – бияләй, «баш яшергеч» – малахай, **мәләнчек** – акча яшергеч – эчке кесә һ.б. мәгънәләре тармакланган. Федотов I: 361–362 (монг. сүзе дип бара).

**МАЛГАТ-У** (брб., Тумашева 1992: 147) «отговаривать; убедить; гарантировать» < *мағалт-у* id., к. тув. *мага* «канәгатьлек», *магады < магалды* «ышандыру», алт. *магат* «шарт, сөйләшү». Монгол даирәсеннән булса кирәк.

**МАЛИК** «обладатель; хозяин» (*малик булу* «овладеть, удостоиться чего-либо», *талантка малик* «имеющий талант») < гар. *mālik* id. К. **Милек, Мөлек, Мөлкәт.** Будагов II: 199–200; ГТРС: 250.

**МАЛТ** (сәүдә, бәхәс термины, к. Тумашева 1992: 299) «договорились, что так; действительно» < **магалт;* к. **Малгат-у.**

**МАЛЮНКА** (ТТДС I: 299) «посудина вместимостью в 16–18 кг» < рус. диал. *малёнка* id. Ясалышы ачык түгел.

**МАЛУХА** (БТДҺ: 228), **малуқа** (ТТДС I: 299) «хлев (летний), летняя кухня» < рус. булса кирәк. Ачык түгел. Чаг. гом. тунг. *малу* «түр; кәзәнкә» (к. ССТМЯ I: 525) – шул сүздән рус. *малуха* ясала ала, ләкин Аникинда андый сүз юк.

**МАЛЬ** (ТТДС I: 298; БТДҺ: 228) «брусника» < удм. диал. *моль, моли,* коми. *моль* һ.б. «җиләк, нарат җиләге». (КЭСК: 173–174). Урманлы яклардагы җиләкләр атамалары фин-угор телләреннән алынуы гаҗәп түгел, к. **Көртмәле.**

**МАМА́** (ЗДС: 466) «мама, мать» – тат. теленең бер-берсеннән ерак сөйләшләрендә (Тумашева 1992: 147; Арсланов 1988: 87) «дәвәни, нәнәй» ~ уйг. диал., үзб. һ.б. *мама, момо* id., аз. (АДДЛ: 315, 321) *мама* «түти», *мәмә* «ана», гом. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 525) *māма* «дәвәни; карчык». Гомумән, *мама, момо, муму* һ.б. «әби, әни; ими-мәмәй» дөньяның барча телләрендә очрый торган яңгырашлар. ЭСТЯ VII: 25–28.

Төрки *ма́ма* рус. < фр. *мама* сүзеннән түгел инде.

**Мама** сүзе күп кенә телләрдә төрле изге рухларны да белдерә, к. шумер *мама, мами* «аналар химаячесе, кендек әбиләренең ярдәмче рухы», фар. *мама, мамак* «әни», *mamare* «кендекче әби», һинд-евр. *mama*, исп. *mamita* «Мәрьям ана», кечуа. (бор. Көньяк Американың мәдәни теле) *Мама Уаке, Мама Оклё, Мама Рауа, Мама Коро* «иң тәүге дүрт ана исемнәре», кор. *мама* «чәчәк авыруы рухы» һ.б. (күп мисаллар табарга була). К. МНМ II: 96. Чаг. **Мәмәй.**

Дерив.: **мамай, мамакай,** (ЗДС: 467) **мамау.** Чаг. **мамалыга.**

**МАМАЙ** – название одного из ногайских племён (имя исторического деятеля **Мамай** скорее из названия племени, а не наоборот). Чаг. каз. (ҚТДС: 231) *мама, мама ағаш, мамағаш* «ат бәйләү агачы, баганасы», «баш угыл». Мамай сүзенең «әзмәвер» мәгъ. булган. **Мамай аты** дип мамонтны (аның сөякләренә карап) атаганнар, к. **Мамонт.** Аникин: 372 (**мамай** рус. тискәре мәгъ. килә, ләкин рус. *Мамаева дорога* «киек каз юлы» кире мәгъ. була алмый).

Тат.-башкортларда **Мамай** дигән кеше исеме таралган булган һәм ул Мамай түрә исеменнән түгелдер.

**МАМАЛЫГА** «кукуруз оныннан пешерелгән күмәч» < рус. < молдав. *мамалыга* id. асылда төр. *mamalık, memelik* «мәмәй, мәмәйлек» сүзеннән.

**МАМАНАЙ** (ДС II: 136) «злодей», **мамай** «страшилище» ~ иске рус. *мамай, момай* «ташкурчак төре», укр. *мамай* «балбал, кыпчаклар калдырган таш сын» – бор. мифик баһадир исеменнән булса кирәк, тарихи **Мамай** исеме шуннан килеп чыккан. Татарларда **Мамай** дигән кеше исеме бар. К. **Мамай.**

**МАМКЫ** (Тумашева 1961: 170) «разновидность красного червя», (Тумашева 1992: 50) **мамке, мәмге** «водяная баня; горбунец» ~ башк. (БТДҺ: 241) *мәңкә* «күл корты» ~ рус. *мамка* id. Чаг. **Мәңкә.** К. Аникин: 372.

**МА́МОНТ** (тат. сөйл. **мамунт**) «мамонт». Бу сүзне XVIII г. галимнәре «себ. татарлары теленнән» дип язганнар. Ләкин сүзнең төгәл генә этимоны бүгенгәчә табылганы юк, төрле фаразлар гына бар, к. Фасмер II: 566; Эргис: 221–223; Аникин: 372–373.

**Мамонт** сүзенең чыганагын Себердән эзләү мамонт сөякләре борын-борыннан Себердән табылуы һәм китерелүе белән аңлатыла.

Бу сүз тат. **маманой ат* «бор. коточкыч зур (к. **Маманай**) баһадир аты» яисә к. тат. диал. (т. я., миш., без теркәдек. – *Р.Ә.*) **мын** «зур, юан» < чув. *мăн [мŏн]* «зур, кабарынкы» (чыгышы бик үк ачык түгел, к. Федотов I: 349) < бор. **муң*; шуннан бор. төрки *муң йунт* «зур ат» була ала (к. бор. төрки – ДТС: 349, *jont, jund, junt* «ат; мифик ат»). К. ш. ук эвенк. *маңи* «әзмәвер; җир иясе» (шуннан монг. *маңи-ут* «җир ияләре-әзмәверләр»). Хәер, мамонт сүзенең этимологиясе тур. фаразлар исәпсез күп. Күпчелек бу сүзнең тамыры Себернең фин-угор телләреннән эзли. Безнең шуны гына әйтәсебез килә: бу сүз себер татарлары теленнән таралса да гаҗәп түгел.

**МАМЫК** «хлопок; нежный пух», «хлопчатобумажный; пуховый», диал. «брачное ложе; подарки после первой ночи новобрачных» > чув. *мамăк*, мар. *мамык, момык, мӓмӗк*, удм. *мамык, мамъқ* «вата, пух» < гом. кыпч., чыгт., урта төрки *мамук,* чыгт. *мамуғ* id. («зөфаф ястыгы» мәгънәсе каз., к.-калп. телләрендә дә бар) ~ иске төркм. (Мухамедова 1973: 67) *банбукъ, баатук,* төркм. *памық,* бор. төрки (ДТС: 396), төр. *pamuk,* кр.-тат. *pambuk*, аз. *памбығ* рус. һ.б. *бамбук* сүзе белән гомоген (бамбук мамыгы зөфаф ястыгына түшәлгән). Чаг. ш. ук фар. *памба, памбаһ, пӓмбә* «мамык» > төр. *pembe* «йомшак»; иске фар. *пумба-һ* «мамык; мамык тукыма» >> рус. *бумага* «мамык тукыма» (шуннан *бумазея* > тат. *бумази, бумаҗи* id.), «кәгазь» (кәгазь иске мамык тукымадан эшләнгән). ЭСТЯ VII: 105–106 (төркм. *памык* матдәсендә).

Гомумән алганда, *памба//бамба* «мамыклы нәрсә, мамык» тамыры ономопоэтик халыкара сүз

булса кирәк, к. грек. *βομβυε, παμβαε*, ит. *bambagino,* лат. *bombacium* «мамык» ~ бур. *бамбагар, пүмпэгэр* «мамыклы, ялбыр, йонлач» ~ груз. *bumbul* «мамык, йон» һ.б. **Бамбук** сүзе үзе русчадан, ләкин русчага инг. теле аша Һиндстан телләреннән, ә Һиндстан телләренә төрки телләрдән килгән булырга мөмкин. Шунысы игътибарга лаек, Европа телләрендә ауслаут *-к* юк: *бамбу, бамбус* дип кенә әйтелә. Федотов I: 341–342.

**МАН** диал. (ТТДС II: 219) «с, вместе с» (тат. әд. **белән**) – бу сүзнең бүтән вариантлары (**мән, пән**) татар теленең төрле сөйләшләрендә очрый, бүтән төрки телләрдән башк., нуг. һәм каз. телләрендә дә кулланыла.

**Ман** (*мән, пан//пән, бан//бән*) һичшиксез *билән* «белән» сүзе белән гомоген. К. тат. диал. (ТТДС I: 311) **мынан** ~ башк., тат. диал. *менән* «белән» *бән ~ мӓн* варианты кыскалыгы белән уңышлы. К. Тумашева 1961: 170–186; Ахатов 1963: 153.

**МАНАП** «манап, представитель феодальной верхушки у казахов и киргизов» – татарларга бик билгеле сүз булган, чөнки татар шәкертләре, зыялылары манаплар акчасына кыргыз мәктәпләре ачып, татарча укытканнар. *Манап* сүзенең чыгышы төгәл билгеле түгел: Вамбери буенча, **манап** «кыргызларның бер бор. башлыгы, шуның нәселе – **манаплар**». Будагов II: 200; Räsänen 1969: 523. Манаплар тур. төрле энциклопедияләрдә һәрвакыт искә алына.

**МАНАРА** «минарет» < гар. *мӓнāрā, мӓнāрāт* «утлы маяк, манара, нурландыргыч», *nwp* «яктыру, нурлану, яктырту, ут, нур» тамырыннан; кайбер мөселман халкы телләрендә (к. ЗДС: 467) *мӓнар ~ минар* варианты актив кулланыла. Рус. *минарет* Европа телләре аша кергән. К. **Нур.**

Дерив.: **манаралы, манарасыз; манаралык.**

**МАНАС** «Манас, герой киргизского героического эпоса (самого большого в мире по объёму)» – асылда **маңач* > алт. *маңаш* > каз. *маңас* > кырг. *манас* (бер версия буенча) яисә *мамай → мамаш > манаш > манас* (икенче версия буенча). Икенче версия дөрес булса, бу геройның исеме тат. дастаннарында (к. ТХИ: Дастаннар 1984) **Алып Мәмшән ~ Мәмшән алып** һәм **Мешәк** (< **Мәмшәк**) **алып** булып та саклана, к. ш. ук **Алпамыш** < *Алып Маңаш* яисә *Алып Мамыш.* Хикмәт шунда: *Мамак, Мамыш, Мамшан* дигән эпик герой исеме угыз дастаннарында очрый. Бик ихтимал ки, бу исемнәрнең тамырдашы **Мамай** (к.) батырдыр.

**Мамыш би** атаклы **Барчын Салур ~ Барчын сылу**ның ире (к. Ögel: 268), **Барчын Салур** ул *Салур < Салавыр* (угыз) кабиләсеннән **Барчын** исемле кыз була. Кыпчаклар бу исемдәге **Салур** өлешен **Сулу** «сылу»га әвереләдергәннәр булса кирәк.

**Манас** сүзе татарларга күптән билгеле: ул эпосның тулырак, композицион эзлекле вариантын тәүләп язып алучылар татарлар – кыргыз мәктәбендә укытучылар була.

**МАНАТ** диал. (БТДҺ: 228) «рубль» < алт., төркм., аз. һ.б. *манат,* каз. (ҚТДС: 235) *мәнәт,* карагаш. (Арсланов 1992: 135) *манет* «акча берәмлеге, сум» сүзеннән булса кирәк; к. ш. ук рус. сөйл. *монет* «тәңкә; сум». Аз. сүзе дә, рус. *монета* сүзе дә лат. *Moneta* «рухлардыргыч алиһә (Юнонаның эпитеты)» сүзеннән. Бу сүз исә *топео* «рухландыру» фигыленнән: бор. Римда **Монета алиһә**гә багышланган гыйбадәтханә янында тәңкә сугу кярханәсе булган. Kluge: 638; Федотов II: 342 (чув. *манет, манит* «бер сум» сүзен киң таралган **манат** сүзенә баглый, хәлбуки чув. сүзе турыдан-туры рус теленнән булса кирәк).

**МАНГАЛ, маңгал** «передвижная печка для приготовления шашлыка» < гар. *мӓнқӯл* «күчерелеп йөртелмәле (мич)» сүзеннән киң таралган сүз (рус, Кавказ телләре һ.б.). К. **Мәнкул.**

**МАНГЫТ, манкыт** – название одного из племён ногайцев (также узбеков, казахов и др.); ругательное слово у некоторых татар. Кабилә-ыру атамасы буларак бу сүз Алтайдан башлап Кырымга кадәр күп төркиләрдә еш очрый; *мангут, маңгуд* дигән кабилә-ырулар монголларда, тунгус-маньчжурларда да билгеле (Султанов: 169); калмык телендә *шара (ак) мангт* «татар», *хара (кара) мангт* «казак һәм нугай». Нугайлар үзләрен XVI г. ук *мангит* дип атаганнар (Продолжение древней российской вивлиофики, ч. VIII, СПб, 1793: 195). Үзбәкләрдә *мангыт* кабиләсе XVIII г. башлап Бохара ханлыгында өстенлек иткән. 1923 елгы саналуда йөз мең маңгыт исәпләнгән (шуннан соң аерым **мангыт халкы** инде юк). Себ. татарларында да **маңгыт** кабиләсе булган; кырг. *маңгыт* – зур гәүдәле ау эте токымы.

*Мангын < мангу-д* монг. «*мангылар*» дигән сүз, башкортларда *маңгы* ыруы бар, эвенкларда *маңū*

«әзмәвер, дию, инсанашар һ.б.» (ССТМЯ I: 531). Рус. диал. *мангут* «янут (җәнлек)» – нигә шулай аталгандыр, билгесез (к. Фасмер II: 567). К. ш. ук МНМ II: 99–100. Гомумән, мангытлар тур. әдәбият ишле. К. **Маңгыз.**

**МАНДАША** (Будагов II: 200) «(гнилая) гуща» ~ башк. (БТДҺ: 228) *манташа* «шәре, (судагы) боз боламыгы», каз., кырг. *малташа* «суда эреп бетмәгән калдыклар» ← *малта шак* «су өстендә йөзгән тизәк, чүп (шак)»: *малта* < *манытлы* (к. **Ман-у**) «мангач калган эреп бетмәгән буяу» һәм к. **Шак I.**

**МАНИГЪ** иск. «препятствие, преграда» (к. Тукайда: *Юлда манигъ күрсәм тибәм дә аударам*) < гар. *māni'* id., ш. ук «тыю».

**МАНКОРТ, маңкорт** «недалекий и малодушный представитель нерусского населения СССР, России, всегда готовый отречься от родного народа, предать его национальные интересы ради (часто иллюзорных) благ; манкурт» – бу сүз, кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов әсәрләрендә кулланылып, шуннан таралган диләр. Шул автор раславынча, бор. *жужань (жуань-жуань)* халкында шундый әшәке гадәт булган имеш: әсирләрнең башына чи тиредән тирән капчык кидергәннәр, чи тире кибеп, бөршәеп, әсирнең башын әкренләп кыскан һәм аңын җуйдырган икән. Шуннан соң әсир зомбига – хуҗасы нәрсә кушса, шуны эшли торган хайвансыман җан иясенә әверелгән, ди. Һәм шулар **маңкурт** дип аталган, имеш. Жужань дәүләтен тикшергән Л. Гумилёв (к. аныкы: Тысячелетие вокруг Каспия: 162) мондый хәл бик мөмкин дип карый.

Икенче яктан, Җ. Киекбаев (1966: 113) башк. *манҡорот* «эшкә инмәгән (кеше)» сүзен русча *банкрот* сүзеннән дип бара.

Әгәр *манкорт* < *манкŏрŏт* < *маңкурут* булса, бу сүз монг. *-ут* күп. кушымчасын алган **маңкур* ~ монг. *маңгус* < *маңгуз* > башк. *мауыҙ, маңғыҙ* «(фольклор әсәрләрендә) явыз рух; әшәке, юньсез кеше» сүзе белән бердәй булырга мөмкин (*Мангус* һәм бу сүзнең күптөрле вариантлары тур. к. МНМ II: 99–100).

Дерив.: **манкортлык; манкортларча.**

**МАНКЫ, маншик** (Тумашева 1992: 148; БТДҺ: 228) «подсадная утка или муляж утки (у охотников); манок; чучело» < рус., әлбәттә. Рус сүзләре *манок, маншик*, диал. *манка* id. *манить* «кул изәп чакыру» фигыле нигезендә ясалалар.

**МАННИ** «манка (каша, крупа)» < рус. *манный* (< яһ. *манна* Библиядә сөйләнгәнчә, «күктән яуган татлы ярма» сүзеннән).

**МАНСА** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «корзина с пыльцой у пчёл» ~ башк. *манса* id., ш. ук (БТДҺ: 228) «бал икмәге, чыршын» < **мантча* id. *мант* сүзеннән булса кирәк. К. **Мант.**

**МАНТ** «пчельник» (Будагов II: 201), по-видимому, означало и «корзину» с пыльцой – обмотанную вокруг ноги пергу, к. каз., кырг. *мант* «ярага бәйләнгән бинт», *мәнт* «көмеш бизәкле билбау», һәр икесе фар.-таҗ. *банд, бӓнд* «бәй, билбау, коршау» сүзеннән, бу сүз исә һинд-евр. (бигрәк тә герм.) телләрендә киң таралган һәм рус теленә дә кергән *банд, банда, бандаж, бинт, бунт* сүзләре белән гомоген. К. ш. ук **Бишмәт.**

**МАНТАР, мынтыр** (Троянский II: 189) «гриб; вид гриба» ~ гаг., төр., к.-балк., кр.-тат. *мантар* id. < фар. *баңдар, бӓңддар* «наркотик, бәңле» (к. кырг. *маң*, чыгт. *бәң, баң* «наркотик үсемлек», к. **Паңгы**). К. иске уйг. *Ол мантар суви ким бу кузэдин ичип турур, мэниң илимтин аңа үлүк тэгэр, тэп тэди* «кем дә кем бу купыдан ул мантар суын эчсә, аңа минем гыйлемемнән өлеш тияр, дип әйтте» (к. Насилов: 88). Монда *мантар суы* – гөмбәдән сыгып алынган наркотик, сóма да, шулай ук эченә саф торсын өчен гөмбә салынган су да булырга мөмкин. Мантар элек-электән дезинфекция өчен кулланылган. Чаг. ш. ук к.-балк. *мантар* «киндераш, алабута». К. **Мындыр.** Будагов II: 256 (бу сүзне грек теленнән ди). ЭСТЯ VII: 29–30 (күп материал бирелә).

**МАНТЫЙ** (Радлов IV: 2020–2021) «манты, пельмени» ~ госм. *манты,* калм. диал. *манту,* монг. *мантуу*, уйг., бор. төрки *tantui* «мантый» < кыт. *мáньтоу* «парда пешерелгән күмәч» > тунг.-маньч. *манту* «күмәч, мантый» ~ тув. *манчы* id. К. ш. ук Будагов II: 200–20. Бу сүз рус теле аша да киң таралган. Рус теленә – төрки телләрдән. ЭСТЯ VII: 30–31; ССТМЯ I: 528–529.

**МАНТЫЙК** «логика, логичность; смысл», иск. «логика (как предмет обучения в медресе)» < гар. *mӓnṭīķ* «сөйләү рәте, сөйләм, мантыйк» ← *nṭķ* «сөйләү; суд ясау; прокурор хокукы алу»

тамырыннан, шуннан ук к. **Нотык,** иске тат. **мәнтака** «зона, округ (мәс., мәгариф яисә суд округы)».

Дерив.: **мантыйклы, мантыйксыз.**

**МАНТЫ-У,** (трбс.) **маңды-у**, **мандык-у** «поправляться (после болезни, кризиса); развиваться (пережив трудности)», себ. (Тумашева 1961: 164; Тумашева 1992: 14) **манта-у, маңда-у** «максатка якынлашу», **мантык-у** «ашкыну; ашыгу» ~ башк. (БТДҺ: 228–229) *мандыҡ-у* «манту, савыгу», *мантыҡ-у* «ашыгу; каушау», *манда-у* «мыштырдау; карарсызлану», *ман йулатма-у* «якын да җибәрмәү» (**ман** «адым»), каз. *манды-* «тизләтү, тиз эшләү» (> *мандым* «темп; эштәге энергия») – карлук телләреннән булса кирәк, к. уйг. *маңда-*, алт. *маңта-* «шәп хәрәкәтләнү, чабу», үзб. (ЎХШЛ: 176) *маңды-* «кинәнү, уңышка ирешү», тув. *манды-* «чәчәк ату, үсешү» һ.б. < *маңыт-у* «алга җибәрү, кызулату» сүзеннән була ала, к. себ. тат. (Тумашева), уйг., тув., алт. һ.б. *маң-* «кызу атлау; әрле-бирле йөренү, интенсив хәрәкәтләнү», *маң* «чабыш адымы; максат; үсешү; чәчәк ату». Будагов II: 198; Радлов IV: 2006–2009; ДТС: 337; ЭСТЯ VII: 31–34 (тәфсилле, ләкин тат.-башк. материалы китерелми).

Дерив.: **мандыр-у** «(эшне) алга җибәрү; кызулату, уңдыру». Чаг. **Мавык-у.** К. **Маңгыл ~ Мәлем.**

**МАН-У** «макать, красить в растворе» < куман., чыгт., бор. төрки (МК, ДТС: 336) *тап-*, төр., гаг. *бан-* id., нуг., каз., к.-калп., кырг. *мал-* «ману, батыру» – шуннан *малт-* «йөзү, су өстенә калку, батмау», нуг., тат. диал. (Арсланов 1992: 135) *малт-, малта-* «(балык тотканда һ.б.) бик әкрен генә ишкәк ишү», каз. *малта* «буяуны һ.б. эреткәндә эремичә калган калдыклар». Бу сүзләр белән **балата** һәм **мандаша** сүзләре гомоген. К. ш. ук **Манчы-у.**

*Ман-* сүзе кыт. *мак* «тушь, буяу; буйа-у» сүзе белән бәйле дип уйлыйлар (Gabain).

**МАНЧЫ-У** «макать; увлажнять» < кар., бор. кыпч. *манчы-, манч-* ~ угыз. *банг-* > чув. *поç-, пуç-* id. *ман-* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе.

**МАҢ I** (ЗДС: 468; БҺҺ II: 168) «ширинка; ворот рубахи; манжет» ~ тув., хак. *маңныг,* алт. *маңдыг* id. < уйг. *маңлыг* «маңлык, чигүле ефәк» < кыт. *маңлуң* «дүрт тәпиле ләү (аждаһа)» сүзеннән – Себер төркиләрендә, монг. һәм тунг.-маньч. халыкларында традицион бизәк шундый. Төркиләр (уйг. һ.б.) *маңлуң* сүзен *маңлык* дип аңлаганнар. К. бур. *магнал*, монг. *магнаг* < яз. монг. *тangпиү* «ләү сурәте чигелгән ефәк» (ССТМЯ I: 528).

**МАҢ II** (Тумашева 1992: 148) «мера, величина», «предел: один шаг до цели» ← бор. (ДТС: 336–337, 343) *маŋ* «адым» (*маң-* «атлау») мәгънәсеннән, к. **Манты-у.** Чаг. каз., кырг. *маң бас-* «тыныч һәм тигез атлау». Ихтимал, бор. *маң-* «атлау, кызу бару» тат. телендә дә саклангандыр: кызу, шәп баручы тур. (дөрес, малайлар телендә генә) сокланып, *мана гына!* дип сөйләгәнне ишеткәнем бар. К. **Маңлаш-у.**

Дерив.: **маңта-у** «чамалау». **Маң йөрү** «йөкле булу (хатын-кыз тур.)».

**МАҢГАЙ, маңлай, мангай** (Троянский II: 227) «лоб» ~ гом. кыпч., үзб., уйг. *маңлай,* башк. диал. *маңдай,* нуг., каз., к.-калп. *мандай* id., як. *маңнай, магнай* «башлангыч, башлык» ~ бур. *магнай, маңлай* «йөз, бит», бор. монг. *таŋlai* «маңлай; авангард (гаскәрдә)» (к. Поппе 1938: 405), сол. (тунг.) *манил, маңил* «маңлай» (ССТМЯ I: 530). К. ш. ук тат. диал. **маңгайча** «ат маңгаена куелган бизәк; тәңкәле түбәтәй; арба башы; бәби туена бүләк» (к. ДС III: 111; ТТДС I: 302; БТДҺ: 228–229) << кыт. *маңлуң* «ләү рәсеме төшерелгән ефәк» сүзеннән. Рус. диал. *магнай* «мыс» тур. Аникин: 365. К. **Маң I.**

Бор. төрки-монг. халыкларында ат башын, экипажның кузласын ләү-аждаһа рәсеме белән бизәү гадәте булган.

**МАҢГЫЗ, маwыз** («Заятүләк» дастанында) «нечистая сила; ведьма», сюда же, по мнению Урманчеева (1984: 133–138), **маңгуш** «сын Кидянхана, противник Ак-Кубяка» в эпосе «Аккүбәк», миш. (шрл.) **магыз** – ругательное слово (по сообщению И. Башировой) – төрки-монг. телләрендә бик билгеле, бер кире, бер уңай эпик персонаж атамасы, к. уйг. диал. (салар) (Тенишев 1964: 18–21, 64–66 һ.б.) *муңгыскарджах,* уйг. (Малов 1967: 99, 107–108 һ.б.), тув. *маңгыс*, як. (Эргис: 221–223) *моңус, могус, Ала-могус* «явыз рух», «убырлы карчык», башк. *маңгыз, мауаҙ* id., монг. *маңгас*, яз. монг. *тangуus* «адәмашар», бур. *маңгад, маңгадхай, маңгас* > рус. диал. (Аникин: 374) *мангад, мадгадхай* «эпик явыз рух» һ.б. Калмыклар һәм бурятлар *мангад* «шайтан» дип русларны һәм татарларны да атаганнар (Аникин, id.). Чаг. эвенк (ССТМЯ I: 531) *маңи* – әкияти баһадир, «җир иясе; йолдызлык атамасы». МНМ II: 99–100. К. **Мангыт, Мус.**

**Маңгыз** сүзе белән, ихтимал, киң таралган *Маңгушев* фамилия исеме баглыдыр, чөнки төркм.

*мангуш* – явыз рух атамасы. *Маңгуш* дигән кабиләыру атамалары да очрый (бу бер дә гаҗәп түгел – башкортларда *майган ыруы* бар ич). «Манас», «Идегәй» дастаннарында *мангуш* – актив герой, хәбәрче, аралаштыручы, илче һ.б. Бәлки бу кешенең хас исеме түгел, иҗтимагый терминдыр. Каз. *маңгаз* «бик көчле һәм олпат кеше».

МНМ (II: 99–100) китабында *мангут, мангат, мангат* сүзе дә **маңгыз** сүзенең бик күп вариантларының берсе итеп күрсәтелә һәм сүзнең тамыры ачыкланмаганлыгы әйтелә. К. **Мангыт.**

**МАҢГЫШЛАК** – название урочища в Башкортостане и известного полуострова в северо-восточной части Каспийского моря. Бу сүз нугай ядкәрләреннән дә билгеле (русчадан түгел). Аны Будагов (I: 259) буенча *мең қышлақ* сүзеннән аңлатып киләләр. Ләкин Мухамедова (1973: 133), М. Кашгарига сылтанып, бу топонимны *маң ғышлақ* «(карт) кучкар кышлагы» дип аңлата. Төрекләрнең бабалары – сәлҗуклар берара Маңгышлакта яшәгәннәр һәм алар, анда кышын җилләр-давыллар еш булгач, ул ярымутрауны *маңгуш аглагы* «шайтан (к. **Маңгыз**) аулагы (өлкәсе)» дип атаганнар, имеш (бу хакта төрек һәм нимес авторлары яза). *Мангышлак* сүзе VI г. ук билгеле һәм бу сүзнең төрки булмавы да ихтимал.

**МАҢКА** «сопли; (**маңка чире**) сап» > мар. *маңга* < гом. төрки *маңка, маңга* id. (Радлов IV: 2007), чаг. эвенк. *мунгги* «эрен», *мун-, муңи-* «эренләү, черү» (ССТМЯ I: 557). ЭСТЯ VII: 35–37.

**МАҢЛАШ-У** (ЗДС: 469) «приближаться к цели» ~ алт. *маңнаш* «йөгерешү, ярышу», *маңна-, маңла-* «төбәп бару». К. **Маң II, Маңыл.**

**МАҢРА-У, мәңрә-ү** (ЗДС: 468, 473) «блеять; кряхтеть», «мычать» ~ гом. төрки *маңра-, маңыра-, магра-* һ.б. id. ЭСТЯ (VII: 39–40) авторлары боларны тат. **мōңрō-у, муңра-у** (ЗДС: 481) һ.б. белән бер зур мәкаләдә бергә бәян итәләр. Шунда ук чув. *макăр-* «ялау» да бергә күрсәтелә. Безнеңчә, монда кимендә өч нигез аерып күрсәтергә кирәк. Бу тәкълиди сүзләрнең *м-* авазына башлануы генетик кардәшлекне күрсәтми, чөнки дөньядагы барча телләрдә дә, мәс., сыерлар һәм кәҗәләр *м-* авазына охшаш авазга башланган кычкырыклар чыгаралар. *-ра ~ -ыр, -рә ~ -ер* элементы исә күптөрле тәкълиди сүзләргә хас.

**Маңра-у** «мәэлдәү» һәм «ыңгырашу» бор. төрки (ДТС: 337) *taŋra-, taŋyïra-* id. сүзеннән үк килә. Бу сүз *мөгрәү*дән бераз үзгәрәк, *мы-аң* дигән авазны белдерә булса кирәк (хайваннар азапланганда, курыкканда шундый тавышлар чыгаралар).

**МАҢЫЛ, маңгыл** («Кәлилә вә Димнә» тәрҗемәсендә һ.б.), **маныл** (Оренбург) «дикая степная кошка (более массивная, чем домашняя, не приручается), манул» ~ уйг., алт., тув. *маңы, маңгы*, бор. төрки (ДТС: 336) *тапи* «кыргый мәче». Тат. һәм рус *манул* варианты монг. телләреннән булса кирәк, к. уйг *малун, мулун, маwыл*, кырг. *мады, мадыл*, бор. төрки *talun* «кыргый мәче», яз. монг. *тапиul* «маныл; сакчы, каравылчы» (> як. *манабыл* «сакчы, каравыл») ← тув., як., монг. *мана-, маңа-, маңна-* «каравыллап тору; әкрен генә бер урында йөренү», кырг. *маңы-* «йөренү, әкрен генә алга атлау, елышу», уйг. *маңгы-, маңгула-* «яшеренеп елышу». К. **Маң II.** Чаг. **Маңлаш-у.** Räsänen 1969: 326; Аникин: 376.

*Мангыл, маңыл* сүзе Азиядә киң таралган (Һиндстан телләрендә дә бар). Элек маңыл тиресе сәүдә әйбере булган (к. **Мәлем I**). Маңыллар сирәк очрый. Хәз. Татарстан җирендә һичкайчан булмаган бугай.

**МАР I** (ТТДС I: 300), **мара** (ТТДС II: 219) «могильный холм (размером с большой стог), оставленный древними народами» ~ морд., чув., рус. (к. Аникин: 376) *мар* id. бор. һинд-ир. халыклардан калган (к. санск. *мару* «кашлак, түбәлек») дигән фикер бар (Кондратьева: 85). Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 339) *тar* < санск. *mär* «дин мөгаллиме»: шуларның изге кабере дә **мар** дип аталырга мөмкин, чаг. **Кирәмәт.**

**МАР II** диал. (Будагов II: 196; Тумашева 1992: 148) «ныклы, саглам». Чаг. **мар I** (?).

**МАРÁ** диал. (к. ш. ук БТДҺ: 229) «дикая конопля» (к. **Тарма**) ~ диал. (ТТДС I: 307) *мŏра* id. < **мура* ~ чаг. рус. *мура*. Чаг. рус. *мара* ~ пол. *тara* «исереклек, саташу; иләс, өрәк» (киндерашның кайбер төрләре саташтыргыч); **мара-у* «саташтыру, миңгерәтү» фигыле дә булган, к. башк. *марама* «миңгерәткеч; миңгерәткеч үсемлек (шомырт чәчәге һ.б.)», к. БТДҺ: 229. Сүзнең чыгышы ачык түгел (безнеңчә, рус теленнән дип раслап булмый). Чаг. нуг. *мараула-* «миңгерәп, бәлтерәп йөрү».

**МАРАЗ,** диал. **марас** (Тумашева 1961: 165) «ложь» к. **Мәраз.**

**МАРАКЫ** диал. (миш., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «что-либо бросающееся в глаза, заметное» ~ добр. тат., гаг., төр. *merak*, аз. *мараг,* көрд. *meraq* «интерес, кызыксынып күзәтелгән нәрсә» ~ бор. төрки *maraq* «хәрби күзәтү пункты», уйг. *марақ* id. (*маракчы* «күзәтче»); гар. *мурāқиб* «күзәтүче, каравыл» сүзе белән чагыштырыла, ләкин. к. **Мара-у.** Räsänen 1969: 327.

Дерив.: **мараклан-у** «күзгә чалыну; еректан күренү».

**МАРАЛ** «марал» (Cervus elaphus) – «асыл болан» – каз., уйг., кырг., ком., төркм. һ.б. *марал*, кар. *маран*, төр. *meral* «марал; (кырг., төр.) ана марал», шор. *парал* id. ~ яз. монг. *maral* id. **мара-у** фигыле белән баглы аңлатыла (Аникин: 377) һәм монг. телләрендә ясалган дип уйланыла (*-л* кушымчасы). К. ш. ук Räsänen 1969: 327. Ләкин к. чыгт., фар., гар. (Будагов II: 221) *мäрал* «ана марал (рус. *лань*)» ди, ягъни бу сүз гар. булып чыга.

Элек мараллар безнең тарафларда да күп булган, тик кырып бетерелгән бугай. К. каз. *марал* «болансыман хайваннарның инәсе», *маралдай* «сылу һәм көчле (кыз)», *кер марал* «ата марал» (к. **Кыр**), *маралды* «мараллы җир», *маралшы* «марал асраучы, маралчы» (димәк, *мараллар* терлек итеп тә асралганнар» һ.б. (үсемлек атамаларында да **марал** сүзе еш очрый).

**МАРА-У** (Тумашева 1992: 148) «пасти скот» ~ уйг. *мара- (мари-)* «яшерен күзәтү, эзәрләү, сагалау», к.-балк. *мара-* «күзәтү», к.-балк., нуг. *мара-* «күз төбәү, төзәү; аулау», кырг. *мара-* «күз төбәү, корбанын сагалау (ерткычлар тур.)», к.-балк. *маraw* «ау киеге», *марачы, мараwчы* «аучы», чаг. ш. ук тат. диал. **мәрә-ү, мәрәлә-ү.**

*Мара-у* сүзен рус. диал. *мар* < монг. *мараа(н)* «киекләр тоз яларга килә торган тозлак» сүзе белән баглап карыйлар: *мара-у* «тозлак янында аңдып, сагалап утыру (аучы тур.)» булып чыга (к. Аникин: 376–377, шунда ук әдәбият). К. **Марал.**

**МАРҖА,** диал. (миш.) **майра** «русская женщина», башк. *мәрйә* id. > чув. *майра* «марҗа; дама (кәрттә)», мар. *марйа, марья* «марҗа, гомумән – үз милләтеңнән булмаган хатын-кыз» < рус. *Марья, Мария* «еш очраучан хатын-кыз исеме» (Егоров 1964: 127; Räsänen 1969: 328 һ.б.); бу сүз тат. теленнән каз., кырг., хәтта рус. теленең үзенә дә (*марджа, маржа* «рус хатыны», Казакстандагы руслар телендә – «казак яисә кыргыз хатыны») кергән. К. **Марҗабаш.**

**МАРҖАБАШ < марҗа башы** (ТТДС I: 300; БТДҺ: 229) «способ укладки снопов для сушки; седьмой сноп на шести снопах стеблем вверх» – букв. «голова русской женщины» ~ чув. *майра пуçĕ* id., мар. кч., удм. *марза* «марҗабаш, ослан», ләкин мар. *марьявуй* «марҗа + баш» – «наратбаш (үлән), кыргый торма». Гомумән, *марҗа ~ майра ~ марья* сүзе белән күп кенә кушма сүзләр, фразеологизмнар да ясала, к. башк. *мәрйә башы* «кылган», чув. *майра кепçи* – «марҗа көпшәсе» – көпшә төре, тат. **марҗакүз, марҗа башмагы, марҗа инәсе** – төрле үсемлек атамалары (к. ТТДС I: 600), **марҗа көянтәсе** «энә карагы (бөҗәк)» һ.б. К. Ашмарин VIII: 165–168; Саваткова: 90; Аникин: 377.

**МАРЗА** (БТДҺ: 229) «критерий, точность (в сделках)» ~ нуг., к.-балк. *марда* «чик; норма, доза», төр. *marda* «магарыч; күбрәк алган саен арзанрак сату», к.-балк. *марза* «эш күләме буенча түләү», ← фар. *мäрза* id. ← *мäрз* «чик; шарт» > төркм. (ТДГДС: 123) *мерз* «шарт».

**МАРКА** (Нагайбаки 1995: 130) «шестимесячный барашек», (Арсланов 1992: 136) «ранний приплод; первенец; любимый (дитя)» ~ башк. (БТДҺ: 229) *марҡа* «көзге куян баласы» (мәгъ. тарайган, күрәсең), нуг., каз. *марқа* «житлекмәгән (чага); иртәрәк туган; сөекле (кыз, угыл)», кырг. *марқа* «кинҗә, соңгы (зәгыйфьрәк) бала; бәрән», к.-балк. *марқа* «имезәк, имә торган колын (я бүтән терлек баласы)», хак. *марго* «эре туган бозау». К. ш. ук Будагов II: 196. Чыгышы безгә ачык түгел.

**МАРМЫШ** (к. Tabiƣət həm biologiə terminnarь: 16) «бокоплав (рачок)» ~ башк. диал. *мормош* «кармакка җим итеп кулланыла торган бөҗәк, коңгыз һ.б.ш.», ихтимал, фар. теленнәндер, к. көрд. *marmj [мармыж]* «сөлек, суалчан» < *мари мыж* «имгеч елан» (*мар* «елан», *мыж* «имгеч»). Рус. *мормыш* тур. к. Меркулова В.А. Мелкие заметки по истории и этимологии слов: мормышка // Этимология 1971. М., 1973: 183–185 (бу сүз тат. теленнән дип бара), Аникин: 392 (праслав. *mъrmyšь* сүзеннән ди, ул тәкъдирдә тат. сүзе русчадан алынма булып чыга). Чаг. **Маймыч.**

**МАРСЫК** (ТТАС II: 368) «гнилой пень», күч. «косный, упрямый в своём невежестве» ~ төр. *marsık* «кисәүбаш (янгыннан калган агач); негр». Арытабан ачык түгел.

**МАРТ** «март (месяц)» < рус. *март* < лат., асылда сугыш тәңресе *Марс* (ш. ук планета атамасы) сүзеннән.

**МАРУЛ** (Будагов II: 196; ЛТ; Тумашева 1992: 148), **марыл** «латук, салат (растение)» ~ төр. *marul*, к. ш. ук кар. *марор* «ачы бер яшелчә төре». Шәрык телләреннән булса кирәк.

Бу сүз хәзер кулланылмый.

**МАС** (Тумашева 1992: 148), иске тат. **маст** «пьяный» ~ башк. (БТДҺ: 229) *мас* «барыннан да канәгать, риза», тат., башк. **мәс** «бераз исерек» < фар. *маст, мӓӓст* «исерек, шат» < авест. *mazdä* «акылдар, хикмәт иясе; нирванада яшәүче, һәрвакыт шат» < һинд-евр. **mendh* «тыныч уй-фикергә талу» (>> рус. *муд-р* «акылдар, хикмәтче»). Кыпч. төрки телләрдә *мас, мес* «исерек». К. **Масай-у, Мәз.**

**МАСАЙ-У** «возгордиться, загордиться», диал. «радоваться» > мар. диал., удм. диал. *масай-* id., тат. диал. **мастай-у, мастык-у** «масаю» ~ кырг. *масай-у,* каз. *мастан-у, масық-у* id., ш. ук «уңышлардан баш әйләнү, исереп шатлану» ← үзб., уйг. < фар. *маст* «исергән, шатланган һ.б.ш.», к. **Мас, Мәз.**

**МАСАН: Масан батыр** «герой народных сказок» << тибет. *масаң* «бозаубаш» – бозау башлы мифик герой, к. **Бозау Ичәчән** – шундый ук герой. *Масаң* > монг. *Басаң* исеменнән бур. *Баһаң* яңгырашы аша рус. *пахан* «юлбасарлар башлыгы» сүзе килә. К. тибет. *масан, мабсан, мабцан* (шуннан ук алт. һ.б. *басаң* «үгез башлы герой» һ.б.) «таң иясе; еш кына карчык рәвешендә йөри». МНМ II: 122, 189. Чаг. **Мәстән.**

**МАСКАРА, маскар, масхара** миш. «шутка», к. **Мәсхәрә.** К. ш. ук каз. *масқар,* кр.-тат., кырг. *масқара* id.

Дерив. **маскарчы** (ЗДС: 469) «мәзәкчән, шаяртырга яратучан»; **масхарлау** «мыскыллау».

**МАТ: мат булу, матлану** (к. ТТДС I: 300–301) «парализоваться; замучиться; одуреть» < гом. көнб. төрки (Радлов IV: 2043), уйг. *мат,* үзб. *мот* < фар., гар. *мат* «үлгән, үлек, мәет; параличланган», шуннан ук шахматтагы **мат** (бусы бөтен дөньяга таралган сүз).

**МАТА, маты** «прочная ткань (на обивку); коврик для намаза» (Г. Ахунов телендә) < үзб., уйг. *мата* < гар. *mӓtā‘* «кыйммәтле тукыма төре» (к. ГТРС: 329). Күп телләргә таралган, мәс., каз., калм., рус. *мата*, төр. *matah, meta* id. һ.б. Рус. *маты* «физкультур күнегүләр өчен түшәк» сүзе дә асылда шул ук сүзгә кайтып кала. Будагов II: 195; Фасмер II: 580, 584.

**Мата** сүзен кыт. теленнән диючеләр дә бар.

**МАТАВЫК [ма°таwы̆ҡ]** «помехи, преграды; канительный, с помехами (о работе) ← **мата-у** (к.).

Дерив.: **матавыклы; матавыклан-у.**

**МАТАВЫЧ [ма°таwы̆ч]**, себ. (Тумашева 1992: 149) **матауыс** «шнур, шпагат» ~ як. *матаабыс* id. ← **мата-у**. Күрәсең, шактый бор. сүз.

**МАТАЙ** «мотоцикл» – тат. телендә ясалган. К. ш. ук башк. (БТДҺ: 229) *матасай, матат* id.

**МАТАЛАН-У** «возиться, бороться с помехами; быть заторможенным» > чув. *моталан-* > *муталан-* id. – **матала-у** (к.) фигыленең кайт. юн.

**МАТАЛА-У** (ТРС 1931; ДС I: 129) «помешать, затормозить» > чув. *мутала-* id. ← **мата-у** (к.) фигыленең ешайтулы формасы булса кирәк. Турыдантуры **мата** «корык, лассо» сүзеннән булуы шикле.

**МАТАЛ-У** (ДС III: 111) «встретить большие трудности, намучиться, намаяться» ← **мата-у**. Чаг. **Мәтәл-ү.**

**МАТА-У** (ТРС 1931; ДС I: 130; ДС II: 137; БТДҺ: 229) «мотать, замотать; путать; стреножить; держать скот в загоне; парализовать» > чув. (Ашмарин VIII: 227–280) *мота-, мута-* «тышаулау, кешәнләү (атны)», к. ш. ук башк. (БТДҺ: 242) *мәтә-* «атның дүрт аягын да тышаулау» < гом. кыпч. (нуг., каз., к.-калп., кырг. һ.б.) *мата-* «хайванны (терлекне) бәйләп салу; бөгү, бөгәрләү; сыер өчен көрәшү (үгезләр тур.)» бор. **мāт* (алт. *маат*, эвенк., эвен. *маут, мавут, мавунт, мату*) «аркан, корык, лассо (бер очы герле аркан – шуны хайванның аягына ыргытып, хайванны екканнар)» сүзеннән ясалган. Хак. *мата-*, алт. диал. *матта-* «җентекләп эшләү»

сүзе «бәйләп салып эшләү» кебек мәгънәдән булса кирәк, к. ш. ук тат. диал. **мата-у** «ярдәм итү» һәм «сырып алу, маталау» (Тумашева 1992: 149), бур. *мата-* «бөгү, бөгәрләү» һ.б. Гомумән, бу сүзнең мәгъ. шактый тармакланган, ләкин төп мәгънәсе *мат* < **mаwунт* «ярдәмендә (хайванны һ.б.) егу» булырга тиеш, чөнки шундый шөгыль төрки халыклар өчен меңьеллыклар буена актуаль булган.

**Мата-у** һәм аның дериватлары тат. әд. теленә гаммә телендә булганча адекват дәрәҗәдә кермәгән – моның сәбәбе шул: әд. телебез Урта Азиядә һәм Алтын Урда чорында чыгт. (дөресрәге Ясәви) теле тәэсирендә формалашкан.

Бор. **mаwунт* сүзенең тамыры, багланышлары ачык түгел. Турыдан-туры фар., гар. *мат, mаwт* «параличланган, үлгән, үлек» (к. **Мат**) белән чагыштыру (*мата-* фигылен шуннан чыгару) тарихи-этнографик җәһәттән бик шикле. Ләкин ихтимал ки, мәзкүр сүзләр бор. ностратик (дөресрәге – мәдәни лингвистик) катламнан киләдер. К. **Матавык, Матавыч, Маталан-у, Матала-у, Матал-у, Мәтәл-ү**. Тат. диал. **мутат-у** «сугыштыру» (ДС I: 135) < *матат-у* (чув. теленнән кире алынган булса кирәк). **Матау** сүзен «кулга алу (арест)» мәгъ. дә кулланылган. Каз. *матау* «бер-берсенә бәйләнгән ике ат яисә атлар төркеме – калым составына керә» (к. Будагов II: 197). К. түбәндәгене.

**МАТАШ-У,** диал. **мәтәш-ү** (К. Тинчурин) «безуспешно пытаться, возиться, валандаться» > чув. *маташ-*, *муташ-* id., удм. *маташ-*, *муташ-* id., удм. *маташ-* «бәйләнү; аяк чалу» (Насибуллин: 127), рус. *матошить* «беспокоить, приводить в смятение» (к. Фасмер II: 512) ~ кырг. *маташ-*, каз. *матас-* «бер-берсенә бәйләнү» ← *мата-у* сүзенең урт. юн.

Дерив.: **маташыл-у, маташтыр-у.**

**МАТӘМ** «траур, траурные дни» < гар. *mā-täm* id. (ГТДС: 254).

**МАТБУГАТ** «пресса, печать» < гар. *mäṭbū‘āt* id. (ГТРС: 253) ← *ṭб‘* «бастыру, нәшер итү», шуннан ук иске *табгханә* «типография, басмаханә».

**МАТДӘ** «вещество; статья (закона, словаря); параграф» < гар. *māddä* «материя, масса; дару; асыл; статья; укыту шәе» *мдд* «киңәйтү, сузу, язу» тамырыннан; шуннан ук иске **мәд** (*мәд хәрефләре*) «сузык аваз», **мәдәт** «ярдәм, кул сузу». Будагов II: 196.

**МАТКА** (ЗДС: 470) «верхний брус на остове крыши; матица» < рус. диал. (СРНГ 18: 31) *матка* сүзенең бик күп мәгънәләреннән берсе. К. **Матча.**

**МАТРАС** «матрас, матрац» < рус. < ним. *Matratze* id. сүзеннән, ә бу сүз ахыр чиктә гар. *mäṭrah* «гаскәриләрнең поход ятагы» ← *ṭрх* «ташлау, ыргыту» икән, к. Kluge: 604.

Гар. *ṭрх* тамырына иске тат. математик терминнар **тарых, тарх** «алу», **мәтарых** «тамыр алу, тамыр чыгару», **мәтрах** «кыскарту» (гар. түбәндә «матрасны төрү, төргәкләү») сүзләре тоташа.

**МАТРА-У** (ЗДС: 470) «онеметь», **матраш-у** «съёжиться» – тат. теленең киң ареалында (миш., себ.) фиксацияләнгән бу сүзләр монг. *матра-* «бөгелү, бөгелеп төшү, бөрешү» сүзенә тоташа, бу монг. сүзе исә *мата-* «бөгү, матау» сүзеннән. К. **Мата-у.**

**Матра-у** сүзе күбесенчә атчылыкка карый булса кирәк, к. ТТАС II: 373.

**МАТРУНӘ** «душица, вид душицы» < рус. *матрёха, матерника* id. диелә. К. **Мәтрүшкә.** *Матрёна* сүзенең тамыры-ясалышы азмы-күпме дәрәҗәдә ачык булса, *матерника* варианты аңлашылып бетми. Ихтимал, **мәтрүшкә** һәм **матрухә** аерым үсемлекләрдер.

**МАТУР** «красивый; видный; славный (о делах)», диал., башк. «упитанный; благовонный, сладкий», «мóлодец», «злой» (ТТДС I: 301; БТДҺ: 229) > чув. *матур, маттур*, мар., удм. *мотóр* id. көнч. төрки телләрдән соңрак (XIII г. алып) кергән, чөнки бу сүз, тат.-башк. даирәсеннән тыш, көнб. төрки телләрдә юк һәм аның фонетик йөзе дә (*а – у* сингармоник чылбыры) татарча түгел, аның иң якын параллеле хак. *матур, матыр* «баһадир; түрә; солдат» >> хант. *матур* «батыр, баһадир», к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 147) **маһатыр,** алт. *баатыр* ~ *маатыр*, *мэттыр*, тув. *маатыр, маадыр* id.; як. *могутур, мугутур* «мөһим, кямил», *муңутур* «һәйбәт» ← *мугута-* «өстен булу, (әйбәтлектә) чиккә җитү» ← *муң* «чик, мәрәй; шедевр» тамырыннан (Пекарский II: 1578; 1624, 1631–1632), чаг. хак. диал. *магат-* «яхшы башкару». Гомумән, *матур* сүзе бор. төрки, монг. һ.б. *bayatur* «баһадир, батыр» сүзенә тоташа шикелле. Ләкин, ихтимал, бор. этимон сүз *м-* авазына башлангандыр, ягъни **магатур* борынгырактыр. К. **Батыр, Баһадир.**

Шуның белән бергә, **матур** сүзенең бик бор. һинд-ир. алынма булу ихтималлыгы да юк түгел,

к. санск. *madhura* «баллы, сөекле, татлы» (к. *матур* сүзенең «татлы, хуш исле» мәгънәсен – ул каян килә? *Баһадир* сүзенә «хуш исле» ярашмый ич!). ЭСТЯ VII: 43–44.

**Матур, матура** «бизәкле кием» мәгъ. рус сөйләшләрендә дә таралган, к. СРНГ 18: 37–38. Чибәр кызны (шаяртыпмы) **матура** дип әйткәнне ишеткәнем бар.

Дерив.: **матурлык; матурай-у, матурлан-у.**

**МАТЧА,** диал. **матлича, машча, мачина** (ТТДС I: 302) «матица (потолка)» ~ башк. *матса* id. > мар. *матча,* чув. *мачча* ~ коми. *матича* һ.б. < рус.; рус. *матица* исә *мать* «ана» сүзеннән. К. **Матка.**

Дерив.: **матчалы, матчасыз; матчалык.**

**МАТЫ́** «полог; маты» (ДС II: 137), **мата** (к.) сүзеннән булса кирәк. Русчадан кире кайткан сүз булуы да ихтимал.

**МАТЫЙК, матыйга, матыйќа, матига, матуќ** (ЗДС: 370) «мотыга» < рус. *моты́ка, моты́га* сүзеннән шикелле: аның слав. параллельләре күп, к. Фасмер II: 665. Бүтән һинд-евр. параллельләре дә күп кебек, әмма бигүк ышанычлы түгелләр. Татарчасында -*ќ* булуы да, русчадан микән, дигән фикер уята.

Дерив.: **матукла-у, матыйкла-у.**

**МАХАН** (Х. Туфан; Тумашева 1992: 147) «мясо лошади (как предмет презрения со стороны христиан)», тат. диал., башк. (БТДҺ: 230) «блюдо из чистого мяса, подаваемое на пиру; жаркое (из цельной туши)» ~ чув. *маххан*, рус. *махан* «начар ит; ат ите», рус. диал. *мяхан* «сыер ите» < бур. *махан*, монг. *махан, махин, мах* < яз. монг. *mixan, miqan* «ит» ~ каз. *мықын* «ит; кабырга ите; кабырга», үзб., уйг. *биқин, бықын* «кабырга (ите)». Аникин: 381, 399.

**МАХАУ [ma°xaw]** «проказа, больной проказой» < уйг. *maxaw*, үзб. *махов* id. һ.б., к. ЭСТЯ VII: 44–46 (күп материал) К. **Макау.**

**МАХМЫР, махмур, макмыр** «головная боль, плохое самочувствие после опьянения (требующее дозы спиртного для снятия), похмель» ~ чув. *мохмăр* > *мухмăр,* мар. *мокмыр,* удм. *махмыр,* морд. *махмари* < гар. *мāх̣мӯр* «исерек, хәмер эчкән» ← *х̣мр* (к. **Хәмер**). Киң таралган сүз: барча мөселман илләрендә очрый, ш. ук гаг. *маамур*, алт. *пакпыр,* хак. *пахпыр* «махмыр». Räsänen 1969: 322; Саваткова: 92.

Рус. *бахмур* «махмыр» тур. төрле фикерләр бар, безнеңчә, ул да **махмур** сүзеннән. Икенче яктан, **махмыр** сүзен русча *похмель* (> тат. сөйл. *пахмил*) сүзеннән дип аңлату да очрый. Räsänen 1969: 322; Федотов I: 363–364.

Дерив.: **махмырлы** (эчемлек һәм кеше), **махмырсыз; махмырла-у.**

**МАХОРКА, махра** русчадан кергән сүзләр. Түбәндә Голландиянең *Амерсфорт* каласы исеме. Тимергалин: 454.

**МАХСУС, мәхсус** «специальный; специально» < гар. *мăх̣с̣ӯс̣* id. (ГТРС: 337), *х̣с̣с̣* тамырыннан, шуннан ук **хасс, хосус, хосусый, тәхсис** һ.б.

**МАҺИР,** диал. (Тумашева 1961: 164) **майхыр** «мастер; мастеровитый, способный» < гар. *мāһир* id. (ГТРС: 256); ш. ук **маһирә** «оста куллы хатын-кыз».

Дерив.: **маһирлык; маһирлан-у.**

**МАҺИТАП: маһитап гөле** «флокс» – кеше исеменнән булса кирәк, к. ш. ук **гатифә гөле, мәстүрә гөле** һ.б. Гомумән **маһитаб** < фар. «ай яктысы».

**МАҺ-МАҺ** – междометие для подзывания собак: шуннан **маһмаһ > маһмай > маэмай** «эт, көчек»; нindидер субстрат телдә *маһ* «эт» сүзе булган, күрәсең.

**МАЧ** «удача, везение» ~ нуг. *мас* id., ком., уйг. *мас*, үзб. *мос* «бап; туры килгән; тәңгәл» < фар. *мăс* id. К. ш. ук каз., кырг. *маш* id. Тат. варианты казакчаны (*маш*) «татарлаштыру» нәтиҗәсендә хасил булган. Тат. сүз мәгънәсенә рус. *масть* «кәртле уенда төстәш; туры килә» сүзе тәэсир иткән, ләкин рус. *масть* үзе Шәрык телләреннән булса кирәк.

**МАЧЫ, мацы** «кошка, кот» к. **Мәче.**

**МАШ I** диал. (М. Гафури) «чечевица; маш, вид гороха (тёмного цвета, мельче обыкновенного)» < фар. *мăш* > үзб. *мош*, каз. (ҚТДС: 237), к.-калп., төркм. *мәш*. Тат. *машны баш итеп күрү* мәкалендә очрый. Машны *ишәк борчагы* дип тә атыйлар.

**МАШ II** «башня, мачта, столб, на который влезают за призом во время сабантуя» ~ чув., к.-калп.

*маш*, каз. (ҚТДС: 237) *мәш* id. Бу сүзне рус. *мачта,* иске рус. *машта* (< нидерланд. *mast* id.) сүзеннән дип карарга мөмкин. Ләкин кулланыш үзенчәлекләре бу фаразга шик уята. Чаг. кырг. *маш* «физкультур күнекмәләр, шулар өчен җайланма» < фар.-таҗ. *машк* id. (к. **Мәш**).

**МАША,** диал. **мәшә** «щипцы, пинцет (для свеч)» < фар. *māшā* id. Күп төрки телләрдә очрый.

**МАШАЛЛА** «дает же Бог; слава Богу» < гар. *māшā Аллāһ* «Алла биргән нәрсә».

**МАШТАК** (Арсланов 1988: 87), диал. **мәштәк** (Тумашева 1992: 151) «низенький, недоразвитый» ~ башк. (БТДҺ: 229) *мастак* «кәрлә», нуг., к.-балк., ком. *маштак* «тәбәнәк буйлы» (шулай дип чечен-ингушларны да атыйлар); кайбер телләрдә бу сүз атларга гына карый: башк. *мәштәк* (> тат. диал. **мәчтәк**), к.-калп. *мәстек,* каз. *мәстәк*, калм. *мастг* «кечкенә һәм арык ат (яисә ишәк)» < фар. *пäстäк* «тәбәнәк» (← *пäст* «түбән»). Рус. телендә **маштак** «кечкенә, ләкин көчле ат» (Фасмер II: 586, автор калм. теленнән ди, ләкин дөресе татарчадан булса кирәк: *пастäк* > *мастак* > *маштак* – фар. > каз. > тат. күчешләре). К. **Мәштәк, Паст, Тәпәш.**

**МАЯ [ма$^{o}$йа]** «запас; капитал; яйцо-подкладыш» > чув., мар., удм. *мая* id. ~ гом. төрки *майа,* к.-калп. *майә, майе* (*мәйек* «йомырка»), үзб. *мойак, мәйәк* «мая; камыр башы, игәрче» < бор. харәзем., сугд. *madak* id. < бор. һинд. *maha dhana* «зур байлык, капитал» (*maha* «зур», *dhana* «байлык») сүзеннән; бу сүз безнең эраның беренче меңьеллыгында монг., тунг.-маньч. телләренә дә кергән, к. эвен. *mājā* «запас»; *māja-* «запаска калдыру» һ.б. (ССТМЯ I: 521). Бүгенге ир. телләрдә дә киң таралган. «Камыр башы, игәрче, чүпрә» мәгънәсе ком. һәм удм. телләрендә (*маял*) саклана. Башк. диал. (БҺҺ II: 166) *майаw* «мая» < **майаг*. Будагов II: 203.

**МАЯК [ма$^{o}$йак]** «маяк: ветка (на дороге)» ~ мар., удм. *маяк*, чув. *майак, майок, маньак* (к. Сергеев 1971: 85) id. ~ гом. кыпч. *майақ* «су юлы маягы»; еш кына рус теленнән дип хисаплана, рус телендә исә *маять* «кул изәү» сүзе нигезеннән дип раслана (Фасмер II: 586; Аникин: 382), ләкин бор. төрки (ДТС: 335), уйг. *tajaq* «юлда (кәрваннан) калган тизәк», *tajaqa-* «чик билгеләре кую, билгеләр калдыру», ш. ук башк. (БҺҺ II: 166) *майақ* «тау түбәсе» һ.б. фактлар **маяк** сүзен русчадан диюгә карата шик уята. Иске рус телчеләре (мәс., М.С. Тучков, к. аныкы: Военный словарь, I. М., 1818: 243) **маякъ** сүзенең татарчадан икәнлегенә шикләнмәгәннәр.

Дерив.: **маяклы, маяксыз; маякла-у** (юлны); (су юлында) **маякчы** һ.б.

**МАЯ-У [ма$^{o}$йаw]** (Н. Исәнбәт) «лепить, лощить керамическую посуду; делать сварку металла» (**майал** «сварка») ~ нуг. *майа* «чүлмәк ясау өчен мәте (үзле балчык)», *майала-* «сылау» ~ удм. *маялля-* id. Чаг. маньч. *maja* «күкшен» (ССТМЯ I: 520).

**МӘ** «на, возьми» ~ чув., удм. *ме [мэ]* ~ уйг., нуг., каз. *мә,* гом. төрки, гом. монг., гом. тунг.-маньч. *мэ*, үзб., таҗ., маньч. *ма,* бур. *маа*, бор. төрки *tah* id. халыкара аралашу процессында таралган; күрсәтү алмашлыгы *менә, мәнә* белән бәйле, к. Пекарский: 1542; ССТМЯ I: 519 һ.б. Чаг. рус. *на,* мар. *нä, нääй* «мә!».

**МӘГАРӘ [мәғәрә]** «пещера, грот» < гар. *мäғāра* id., **гар** (к.) сүзе белән тамырдаш.

**МӘГАРИФ [мәғәриф]** «просвещение, просветительство; образование» < гар. *мä'āриф* id. *'рф* «алдан белү (беленү); таң» тамырыннан, шуннан ук к. **Гарәфә, Мәгърифәт.**

**МӘГАШ [мәғаш]** иск. «зарплата, оклад, жалование» < гар. *мä'āш* id., *'йш* «яшәү» тамырыннан, к. **Мәгыйшәт.**

**МӘГӘЛӘЙ, мийәли** диал. (Тумашева 1992: 149) «охотничьи варежки, руковицы (кожаные или из шкур мехом внутрь» << фар. *бäһлäи* id. К. **Бияләй.**

**МӘГӘЛДӘК,** (Гиганов, ДС I: 138; ТТДС I: 302, 312, 316; Тумашева 1961: 156, 167, 169; Арсланов Л., канд. дис. авторефераты; Akb: 105) **мегәлдәк, мукятяк, мөгәлдәк, мүгәлдәк, мүгәлтәк, мүгәтәк > нүгәтәк,** себ. **мүгүрдәк, мүгүртәк,** миш. **мәгәдәк, мәдәк** «крытый свадебный экипаж, свадебная карета (в которой сидит невеста); двухколёсная телега, колесница» ~ үзб. (Будагов II: 265) *муңäдäк* «мәгәлдәк», *мәгәдәк* «экипаж түбәсе» (Радлов – IV: 2129 – шулай аңлата, дөресе «түбәле экипаж» булса кирәк), к. ш. ук манси. (< тат.) *мүкер, макер* «мәгәлдәкнең ачылмалы-ябылмалы

капкачы» (Räsänen 1969: 346). Бу югары рухи вә матди мәдәният билгеләрен белдергән үзенчәлекле сүз тат. телендә генә киң таралган һәм, безнеңчә, Алтын Урда монг. телендәге *möger terge* «ике тәгәрмәчле экипаж» (*möger* «тәгәрмәч», *tergen* «арба») сүзеннән яисә *mögertei täx* «тәгәрмәчле тәхет» сүзеннән дә була ала. Гомумән, туй мәрасимендә **кәләш** «хан кызы», *егет* – «ханзадә яисә бизадә». Туй экипажын *онова, он орва* «хан арбасы» дип атау мари һәм мордваларда сакланган. Татарчада *килен төшерү* тәгъбире киленне мәгәлдәктән төшерүдән (бу эш үзе бик тәфсилле мәрасим булган). К. Ахметьянов 1981: 88.

Казакларда **мүгәдәк** дип ярлы кешеләрне атаганнар, чөнки ярлылар ике тәгәрмәчле арбада күченеп-яшәп йөрергә мәҗбүр булганнар. Сүзнең шәрәфле мәгънәсе анда онытыла төшкән. Чөнки казаклар кәләшне мәгәлдәктә түгел, атка мендереп, ат (дөя) өстендә күчергәннәр.

**МӘГӘР** «всё же, несмотря на (известное из контекста); если; хотя; паче чаяния» > чув. *мехер,* мар. *мӓгӓр*, *магар* < гом. көнб. төрки, к. төр. *meger, meer*, куман. *magar*, бор. төрки (ДТС: 339) *mägär* һ.б. < фар.-таҗ. *мӓгӓр* id. < бор. фар. *мӓ ӓгӓр* «әгәр юкса; юк, әгәр» сүзеннән (Horn: 221; Räsänen 1969: 332). Төрки телләрдән күп күрше телләргә кергән.

**МӘГЪДӘН** «руда; сплав; металл» < гар. *мӓʻдӓн* (Будагов II: 241) id. Кеше исеме буларак **Мәгъдән** – «кыйммәтле металл».

Дерив.: **мәгъдәнче, мәгъдәнчелек.**

**МӘГЪЛҮБ** «побеждённый» < гар. *мӓғлӯб* id. ← *ғлб* «өстен булу» тамырыннан, шуннан ук **галәбә** «җиңү» (к. **Калабалык**), **галиб** «җиңгән, җиңүче» (иске телебездә еш очрыйлар) һ.б.

**МӘГЪЛҮМ** «известен; известно; известный» < гар. *мӓʻлӯм* id. ← *ʻлм* «белү, белеп алу» тамырыннан, к. **Гыйлем, Мәгълүмат.**

Дерив.: **мәгълүмлек; мәгълүмебез** «барыбызга да яхшы таныш», **мәгълүмегез** «сезгә билгеле булганча».

**МӘГЪЛҮМАТ** «информация; осведомлённость человека» (**мәгълүматлы** «осведомлённый, сведущий») < гар. *мӓʻлӯмāт* «мәгълүм нәрсәләр».

Дерив.: **мәгълүматлы** «эрудицияле», **мәгълүматсыз; мәгълүматлык** «энциклопедия; белешмәлек».

**МӘГЪНӘ** «смысл; значение (слова)», диал. **мәғәнә** id. Ләкин гар. *мӓʻнā* «мәгънә» берлек санда, ә *мӓʻāнӣ* – күп. санда («мәгънәләр»); аннары, тат. сөйл. **мәғәнә** «акыллылык, юнь» мәгъ. кулланыла (*мәғәнәле* «юньле, акыллы»); элек **мәгани** «лексик мәгънә» сүзе дә кулланылмакта булган (Будагов II: 243). К. ш. ук **Мәгънәви, Мән.**

Дерив.: **мәгънәле, мәгънәсез; мәгънәчек.**

**МӘГЪНӘВИ** «относящийся к смыслу, значению; семантический» < гар. *мӓʻнӓwӣ* id. К. **Мәгънә.**

**МӘГЪРИП, мәгъриб** «запад, западная страна; Запад (как культурно-историческое понятие); Магриб (арабские страны к западу от Египта)» < гар. *мӓʻриб* id. **гареп** (к.) сүзенең җыелма күплеге.

**МӘГЪРИФӘТ** «просвещение» < гар. *мӓʻрифӓт*, к. **Мәгариф.**

Дерив.: **мәгърифәтле, мәгърифәтсез; мәгърифәтче, мәгърифәтчелек.**

**МӘГЪРУР** «гордый собой, надменный» < гар. *мӓғрӯр*, к. ГТРС: 295. К. **Горур.**

Дерив.: **мәгъруурлык; мәгърурлан-у.**

**МӘГЪСУМ** «невинный (как младенец)» < гар. *мӓʻçӯм*, к. ГТРС: 296. Сүзнең мөәннәсе: **мәгъсума, мәгъсүмә.**

**МӘГЪТУФ** иск. связанное союзом (словосочетание), мәс., *һәм башкалар; шуның белән бергә; янә килеп*. **Мәгътуф** сүзе кыскалыгы белән кулланышта уңай һәм хәзер дә ярарлык. Гар. *мӓʻṭӯф* «юнәлтелгән» сүзеннән, к. ГТРС: 296.

**МӘГЪФУ** иск., кит. «достойный прощения (о поступках); помилованный (об осуждённых)» < гар. *мӓʻфӯ* id. **Гафу** белән тамырдаш. Бу сүз хәзер дә куллануга лаеклы (күп төрки телләрдә *мафу* id.).

**МӘГЪШУК** «любимый, тот, в кого влюблена» < гар. *мӓʻшӯk̦,* мөәннәсе – **мәгъшука** «гашыйк булган кыз, сөелгән хатын», к. **Гашыйк.**

**МӘГЫЗЬ [мәғӗз],** диал. **мәйез** «самое ценное в чём-либо; ядро (орехов, в особенности южных)» ~ башк. *мәйез* «йөзем» (БТДҺ: 241) < фар. *мӓғз* «ми, чикләвек төше», рус. *мозг* «ми» белән тамырдаш. ГТРС: 297.

**МӘГЫЙШӘТ [мәғишәт]** кит. «жизнь; быт; житьё-бытьё, существование» < гар. *мӓʻӣшӓт* id., **мәгаш** сүзе белән тамырдаш. ГТРС: 297.

**МӘГЫЙШӘТЧЕ** иск. «религиозный реформатор, сторонник приведения религиозных установлений в соответствие с современными условиями жизни» – «Дин вә мәгыйшәт» (XX г. башы) дигән татар журналы исеменнән.

**МӘД** «гласный (звук); прилив», «нотки (в голосе)» < гар. *мӓдд* id., *мдд* «сузу, озайту» тамырыннан, шуннан ук к. **Матдә, Мәдәт, Мәдид.** ГТРС: 298.

**МӘДӘ** (Тумашева 1992: 149) «(добрый) знак, признак» < каз. *медеу,* кырг. *медөө* «билге; өмет, ышаныч, рухи терәк» ~ яз. монг. *mede-* «белү, сизенү», гом. тунг. *мэдэ-* «белү, сизенү», маньч. *мэдэ, мэдэчэ* «билге; хәбәр» (ССТМЯ I: 563–564). Каз. *medew* яңгырашыннан атаклы альпинистик үзәк **Медео** атамасы килә (каз. сүзенең «тау үткеле» мәгънәсе булган).

**МӘДӘНИ** «культурный, цивилизованный» < гар. *мӓдӓнӣ* id. ← *мдн* «шәһәр, кала булу» тамырыннан. К. **Мәдәният.**

Дерив.: **мәдәнилек; мәдәничә.** К. **Мәдинә.**

**МӘДӘНИЯТ** «культура, цивилизация» < гар. *мӓдӓнийӓт* id. К. **Мәдәни.**

Дерив.: **мәдәниятле, мәдәниятсез, мәдәниятче** «мәдәният хезмәткәре».

**МӘДӘТ,** (ЗРС: 377) **мидәт** «помощь, поощрение, поддержка» < гар. *мӓдӓд* id. *мдд* «(кул) сузу» фигыленнән. К. түбәндәгене.

**МӘДИД** «название стихотворного размера; удлинённая строка в стихе» < гар. *мӓдӣд* «озынайтылган». К. **Мәдәт.**

**МӘДИНӘ** «город, поселение городского типа» < гар. *мӓдӣнӓ* id. **Мәдинәи мәхрүсә** «Мәдинә шәһәре» (сүзгә-сүз «саклана торган шәһәр»), **Мәдинәи мөнәүвәрә** «Мәдинә шәһәре» (сүзмә-сүз «нурлы шәһәр»). **Мәдинә** исеме исә «мәдәниятле» мәгъ.

**МӘДИЯ** (Гиганов) «род ракушек, употребляющихся как пуговица или побрякушка на одежде» < төр. *mediye, midiye* «мидия, диңгез кабырчыгы төре».

**МӘДРӘСӘ** «медресе, школа (в особенности – религиозная)» < гар. *мӓдрӓсӓ* «дәрес бирелә торган урын». К. **Дәрес, Мөдәррис.**

Дерив.: **мәдрәсәле, мәдрәсәсез.**

**МӘДХИЯ [мәдхийә]** «ода; восхваление» < гар. *мӓдхийӓ* id. ← *мдх* «мактау, данлау». Шуннан ук тат. диал. **мәдех**, башк. (к. БТДҺ: 240) *мәҙех* «үлгән кешене мактап искә алу (йоласы)», *мәҙих* «данлы, мактаулы, һәйбәт» һ.б.

Кешенең җеназасында **мәдех әйтү** бор. төрки халыкларда да булган.

**МӘЕЛ [мәйёл],** диал. (Тумашева 1992: 170) **пәйел** «склонность, характер, нрав» ~ чув. *пил*, мар. *пиал, пиӓл*, удм. *мыль,* морд. М. *мяль* ~ гом. кыпч. *мейил*, башк. (БҺҺ II: 102) *бәйел,* кырг. *бейил*, гаг. *майыл*, уйг. *мәйил*, үзб. *майил* «мәел; теләк; кәеф» < фар. < гар. *мāʼил* «мәеллек, авыш, авышлык» сүзеннән (Räsänen 1969: 323). Бу сүздән диал. **мәйле** < **мәелең** «ярый, хуш, ихтыярың» сүзе ясалган.

Дерив.: **мәелле,** иск. **мәеллек** («наклонение» – русчадан калька булган).

**МӘЕТ [мәйёт]** «мощи, тело умершего» < гар. *мӓййит* «үлгән, үлек» ← *мwт* «үлү, вафат булу» тамырыннан. Шуннан ук к. **Мат.**

**МӘҖБҮР** «вынужден; под нажимом» < гар. *мӓҗбӯр* id. К. ш. ук **мәҗбүри** «каршылыксыз үтәлергә тиешле», **мәҗбү́рән** «теләр-теләмәс, көчләнеп, үз иркеңнән башка», **мәҗбүрият** «чарасызлык, мәҗбүрилек» – барысы да гарәпчәдән. К. **Җәбер.**

Дерив.: **мәҗбүрлек.**

**МӘҖЛЕС** «меджлис, собрание; парламент; общество в сборе» < гар. *мӓҗлӣс* id. ← *җлс* «утыру» тамырыннан. Будагов II: 211–212.

Дерив.: **мәҗлестәш; мәҗлесле, мәҗлессез.**

**МӘҖНҮН** «человек не от мира сего; юродивый» < гар. *мӓҗнӯн* «үзенә җен ияләшкән, җенле» сүзеннән; ләкин тат. телендә бу сүз төп мәгънәсе буенча түгел, атаклы «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастаны буенчарак билгеле; анда **Мәҗнүн** – хыялый гашыйк. Будагов II: 212.

Дерив.: **мәҗнүнлек, мәҗнүнлән-ү.**

**МӘЗ: мәз булу, мәз бетү** «быть в эйфории, в экстазе» ~ башк. (БТДҺ: 226) *маз булу* id., каз.

(ҚТДС: 234) *мәз* «рәхәт, шатлык; кызык» < фар. *маст* «исерек; чиктән тыш шат» сүзеннән. К. **Масай-у.**

**МӘЗАР,** диал. **мазар** «кладбище (старое, заброшенное или языческое, например, марийское)» ~ чув. *масар,* мар., удм. *мазар*, рус. (Фасмер II: 557; СРНГ 17: 292–294) *мажары, мазары, мазарки* < гом. кыпч. *мазар,* нуг., кар., гаг. *мэзар, мезар*, төр. *mezar* < гар. *мăзāр* «зират; зыярат; килеп йөрү пункты», **зиярәт** (к.) сүзе белән тамырдаш. К. ш. ук себ. (Тумашева 1961: 164) **масарат < мәзарат** «галәмәт, могҗиза; изге зат кабере» < фар. *мăзāрăт* «каберлек; төрбә» (к. Будагов II: 226), иске тат. **мәзарстан** «зират». К. **Мазар.**

**Мәзар, мазар** тур. бай әдәбият бар, к. Аникин: 366.

**МӘЗӘК** «шутка, потеха; анекдот; анекдотичный, нелепый (о человеке)» ~ чув. *месек* «шаян, шук» (к. Сергеев 1968: 42), мар. *мäзак, масак* (Саваткова: 90), удм. *мазак* (Алатырев 1977: 6) «мәзәк» ~ башк. (БҺҺ II: 178) *мәҙәк,* каз., к.-калп., кырг. *мазақ,* уйг. *мәзәк* id. һ.б. < гар. *мăзāх* «көлкеләр», *мӯзāх* «көлке», к. ш. ук гар. *мăззāх* «көлкече, кызыкчы».

**Мәзәк** сүзенең «анекдот» мәгънәсе соңрак карарлашкан.

Дерив.: **мәзәкле, мәзәксез; мәзәкчел.**

**МӘЗИН** «муэдзин (служитель мечети, который громко призывает к совершению намаза), дьякон» > чув. *месин* < уйг. *мәзин* < гар. *му’ăҙҙин* «азанчы» (**Азан** сүзе белән тамырдаш).

**МӘЗКҮР** «вышеупомянутый» < гар. *мăҙкӯр* id. ← *зкр* «искә алу», шуннан ук **зикер > зекер** «хәтердә тоту; дога төре». ГТРС: 301.

**МӘЗЛУМ** «угнетённый, подверженный гнёту (мужчина)» < гар. *мăẓлӯм* id. (**золым** сүзе белән тамырдаш); к. ш. ук **мәзлумә** «җәберләнгән, рәнҗетелгән (хатын-кыз тур.)». ГТРС: 301.

**МӘЗМУН** «содержание (слов, произведения)» < гар. *мăḍмӯн* id. ГТРС: 302. К. **Зәмин.**

**МӘЗҮН** иск. «получивший официальное разрешение (заниматься чем-либо); выпускник учебного заведения» < төр. *mezun* [*мäзун*] id. < гар. *мă’ҙӯн* > иске тат. **мәэзүн** id. (ГТРС: 342).

**МӘЗҺӘП** «секта; направление в религии» < гар. *мăҙһăб* id. асылда «юл». ГТРС: 303; Будагов II: 220.

**МӘЙ** «вино; хмельные напитки» < фар. *мәй, май* << авест. *madhu* (Platts II: 1103) id. К. ш. ук тат. *мәйханә (килү)* «тәртипсезлек» < фар. *мăйхāнә* «кабак, бар».

**МӘЙДАН** «площадь, майдан; арена; сабантуй» < фар. *мăйдāн* id. < авест. *тaiдуäпа* «урталык» һинд-евр. **medh-yo* «урта» тамырыннан (хәер, *майдан* сүзенең килеп чыгышы тур. иранистлар арасында да уртак фикер юк: кайберәүләр *мăйдан* ул «җыелышып мәй эчә торган урын» диләр). **Мәйдан, майдан** сүзе барлык төрки-монг., слав., финугор, семит, Кавказ, Һиндстан һ.б. телләрендә исәпсез күп мәгъ. очрый, к. Качалкин А.Н. Слово *майдан* в истории русского языка // Этимологические исследования по русскому языку. Вып. VII. М., 1972: 86–92; Мурзаев 1984: 358–359; Аникин: 367.

**МӘК** «мак» < рус.; шуның белән бергә тат. диал. **макы** (ТТДС I: 298), мар. *макэ, макы* (Саваткова: 88), удм. диал. *мäкĕ* (Насибуллин 1978: 127), чув. *макăнь, мăкăнь* «мәк» бу сүзнең рус теленнән чит-үзгә чыганактан да килүен күрсәтә. Төп чыганак – грек. *михун (μηχων)* id. – Кара диңгез буенда урнашкан бор. бер кала исеменнән. Ихтимал, бор. болгарлар бу сүзне Азов буйларында яшәгәндә җирле халктан яки греклардан үзләштергәннәрдер.

Мәкнең төрләре, үзлекләре, төрле заманнарда, төрле халыкларда ничек бәяләнүләре һәм кулланулары тур. зур мәкалә-пассаж Ф.Д. Закировның «Агулы үсемлекләр» (2010) китабында бирелә. Мәкнең йөздән артык биологик төре һәм төрчәсе бар. Шулардан берсе – Papaver somnifecum – гына наркотик матдәләр, әфьюн алу өчен файдаланыла.

**МӘКАЛӘ** «статья» < гар. *мăқāлă* id., төп. мәгъ. «сөйләм» ← *қлл* «сөйләү».

**МӘКАЛЬ** «пословица» < гар. *мăқāл* id. ← *қлл* «сөйләү, әйтү» тамырыннан. К. **Мәкалә.**

**МӘКАМ** «способ чтения Корана нараспев» ~ гом. көнб. төрки *мақам* id. < гар. *мăқāм* «урын, изге урын, чин, дәрәҗә, тон» (к. Будагов I: 246) ← *қмм* «урын алу» тамырыннан, шуннан ук **Кыйммәт.** Сүзнең семантикасына бор. гадәт буенча утырышта «дәрәҗәңә күрә урын алу» тәэсир иткән:

кешенең сөйләү тоны да дәрәҗәсенә күрә төрлечә була. Мәдрәсәләрдә *мәқам* – аерым укыту фәне булган, мәкам курсын үткән кеше *қари* була алган. К. **Мөгам.**

**МӘКӘ** диал. (Тумашева 1992: 150) «хитрость, обман» ~ хак. *мике,* алт. *меке, мэкэ*, тув. *меге* < яз. монг. *meke* > эвенк. *мэкэ* id. (ССТМЯ I: 566). Будагов II: 274. Сөйләшләрдә **мәкә** актив кулланыла: шуннан (ЗДС: 472) **мәкәлә-ү** «алдау», **мәкәче** «хәйләкәр».

**МӘКӘЙ** «галла на ореховом кусте; шишка» (к. Avьl xụçalьƣь həm urmancьlьq atamalarь: 80; ТТДС I: 313), иске тат. **мәкәй** «чёрная краска для окрашивания кожи» < кыт. **mak* «тушь; кара кара»: кара буяуны чикләвек орысыннан сыгып алалар; к. ш. ук башк. *мәкә* «үзеннән кара кара алына торган үлән». К. **Ман-у.**

**МӘКЕР** «коварство» < гар. *мäкр* id. К. ш. ук диал. (ТТДС I: 313) **мәкәр** ~ каз. *мекер* «хитрый» < гар. *мäккāр* «хәйләкәр (кеше)».

Дерив.: **мәкерле, мәкерсез; мәкерчел.**

**МӘКИНӘ** «пóлова, мякина; труха» ~ чув. *мекине,* удм. *макня* id. < рус. *мякина* < *мягкина* «йомшак кибәк» сүзеннән (*мягкий* «йомшак», *мять* «изү» фигыленнән).

Дерив.: **мәкинәле, мәкинәсез.**

**МӘККӘ** «Мекка», шуннан **Мәккә кына(сы)** «хаҗ кыначы, бальзамин», **Мәккә бодае** «кукуруз» (**Мисыр бодае** дип тә әйтелә), к. Тумашева 1992: 149; ТТДС II: 229. К. **Мәккәй.**

**МӘККӘЙ** «кукуруза» < фар. *мәккәи* «Мәккәдән килгән, мәккәле» сүзеннән. К. каз. (ҚТДС: 238) *меке жүгері*, үзб. *макка жухори*, төркм. *мекгежөвен* «Мәккә тарысы». Мәккә тирәсендә аеруча зур башаклы игеннәр үсә дип күзаллаудан (чынлыкта кукуруз культурасының таралуына Мәккәнең катнашы юк). К. югарыдагыны.

**МӘКРӘ** иск. «отпавший (крещёный татарин, вновь возвратившийся в ислам)» < иске тат. *мөкрәһ* id. < гар. *мукраһ* «ярым гөнаһлы» ← *крһ* «дошман күрү, җирәнү» тамырыннан, чаг. дини лексикада **мәкруһ** «ярамый торган эш».

**МӘКТӘП** «школа», иск. «начальная школа» < гар. *мäктäб* «контора, яза торган урын» сүзеннән, *ктб* «язу» тамырыннан. Шуннан ук **китап, көтепханә, кятиб, мәктүп.** Н.К. Дмитриевның «Мектебе и медресе (очерки по методике преподавания русского и родного языков в национальной школе)» (М., 1954) китабында **мәктәп** сүзенең мәгънәсе гарәпчәгә туры килмәгәнлеген күрсәтеп, бу сүзне «плод недоразумения», ди. Ләкин *мäктäб* «язарга өйрәнү урыны» мәгъ. ислам илләрендә күптәннән килә.

Дерив.: **мәктәпле, мәктәпсез; мәктәпче.**

**МӘКТҮП** «письмо» < гар. *мäктӯб* «язу, язылган нәрсә» ← *ктб* «язу» тамырыннан. К. **Китап.**

Иске әд. телдә **мәктүбат** «корреспонденция».

**МӘКЯН** «место жительства; место в иерархии, чин, степень» < гар. *мäкāн* id. К. Будагов II: 249. Мөселман илләрендә бу сүз «прописка» мәгъ. кулланыла.

**МӘЛ I** «момент; удобное время» ~ чув. *мал, мел* id. ~ уйг. *мәл* id. < *мәхәл* (к.) сүзеннән.

**МӘЛ II** диал. «толк», **мән** сүзеннән үзгәргән (к. ТТДС I: 313).

**МӘЛӘК** «ангел» < гар. *мäлäк* id. **Малик, мәлик** сүзләре белән тамырдаш. Будагов II: 253 (мәләкләрнең классификациясе бирелгән).

**МӘЛӘКӘ** «способность, сноровка, смекалка», «практика» (Җантурин: 394) ~ чув. *мелеке* «елгырлык», кар. *мелаха* «һөнәр», төр. *meleke* «мәләкә; өйрәтелгәнлек; остарганлык; өйрәнгән һөнәрең» < гар. *мäлäкä* «ия булганың, үзләштерелән сыйфат» ← *млк* «ия булу, ияләү» тамырыннан, шуннан к. **Мәлик, Милек, Мөлек** һ.б. (тат. телендә егермеләп сүз). Бу тамыр бор. Мисыр телендә дә булган.

Дерив.: **мәләкәле, мәләкәсез.**

**МӘЛӘЧЛЕК** (Остроумов 1876: 103), диал. (ТТДС I: 313, 314) **мәләнчек, мәрәчлек** «шапочка под платок, повойник» ← **мәлән* «күн башлык», к. ш. ук **мәләкәй** «күн күпчек, күн каплама» < **мәләнкәй.* Боларның этимоны фар. *бäһлä-и* «каплавычлар» сүзе булса кирәк, к. **Бияләй, Малахай. Мәләчлек**нең тасвирламасын к. Григорьев А.Н. Иптяш Долговка иптяшлярчя җазыу // Киңәш, 8. V. 1928; Баязитова 1986: 144 (рус. *волосник* сүзеннән димәкче).

**МӘЛГАМЬ, мәлгамә** «состав для придания блеска изделиям» < гар. *мӓлғам, мӓлғамӓ* id. ← *лгм* «тирәнтен буяу, чыеп буяу» тамырыннан; рус. *амальгама* («көзге ясауда кулланыла торган буяу») << гар. *ӓл-мӓлғамӓ.*

**МӘЛГУНЬ [мәлғүн]** «проклятый» > рус. (Даль) *мельгун* «легкомысленный человек» < гар. *мӓл'ӯн* «ләгънәтләнгән». К. **Ләгыйнь.**

**МӘЛЕМ I: мәлем тун** «женская доха», к. башк. (БТДҺ: 240) *мәлем* «селәүсен», нуг. *мӓлим,* каз. *мәлĕн,* (ҚТДС: 235) *мәлĕ, мәнĕл* «кыргый мәче төре, маңыл» < монг. бур. *мануул*, бор. монг. *tapuul* > рус. *манул, мануль, мамуль* id. монг. **мана-ул, *манағул* «аңдып, саклап торучы» сүзеннән, к. **Маңыл.**

Дала кыргый мәчеләре элек күп булган һәм тиресе өчен ауланылып, кырып бетерелгән. Нұрмағамбетов: 82.

**МӘЛЕМ II: Мәлем хуҗа** – имя знаменитого святого, могила которого – место поклонения башкир, татар и чувашей. Бу исем *Балын гозя, Балимеры* дигән русчалаштырылган топонимнарда чагылыш тапкан. Балимеры чув. *Палым ырӑ* «Балым ару (изге)» тәгъбиренә тәңгәл киләә. Мөстәкыйль Болгар дәүләте заманнарында яшәгән ул затның исеме *Мөгаллим* булган бугай. К. ТЭС: 61 («Балынгузское городище» дигән матдәдә).

**МӘЛЕС** (БТДҺ: 240; Оренбург татарларында да очрый) «порода овец» (точнее не сказано) ~ каз. *мәлеш* «салынкы (зур) койрыклы сарык токымы», (Будагов I: 254) *мелишь* «рус сарыгы» (ягъни «куй түгел»), *мелешь* «игез бәрәнли торган сарык», к.-калп. *мәлши, мәлиш* «сарык (куй түгел)», үзб. (ЎХШЛ: 178) *мәльш* «каракүл сарыгы», кырг. *малыш* «сарык һәм куй кушылгагы» ~ төр. *melez, meliz* «кушылгак, метис» ~ фар. *мӓлӓс* «әчкелтемтөчкелтем; кушылгак».

**МӘЛҖЕРӘ-Ү** «обессилеть, одряхлеть; впадать в маразм» ~ башк. *мәлйерә-ү* id. – **мәлҗе-ү** (> башк. *мәлйе-ү*) «хәлсезләнү» фигыленең *-рә* морфемасына «киңәйтелгән» варианты. Бу фигыльләр күпчелек төрки телләрдә теркәлмәгән. Гомуми закончалыклар буенча фикерләгәндә, *мәлҗе-* < **мәлче- ~ бәлче- (> бәлчерә-), балчы- (> балчыра-), былчы- (>былчыра-)* һ.б.ш. фигыльләр рәтеннән килеп чыккан. К. ш. ук **Бәлшәй-ү, Мәлке-ү.**

Дерив.: **мәлҗерәл-ү, мәлҗерән-ү, мәлҗерәш-ү, мәлҗерәт-ү; мәлҗерек.**

**МӘЛИК** «владетель; владелец; правитель; царь, царёк» < гар. *мӓлик* id., ш. ук «старшина һ.б.» (аерым титулларда, к. Будагов II: 253); сүзнең мөәннәс төре **мәликә**. К. **Милек, Мөлкәт, Мөлек.**

**МӘЛИКӘТУТАЙ** (БҺҺ II: 143) «божья коровка» – **мәликә** «патшабикә» + **тутай** «бикә», бөҗәкнең чуар-бизәкле канатына карап бирелгән атама. Чаг. каз. (ҚТДС: 235) *мәлек татай, мәлкĕ тотай* «балалар уены атамасы» («кул өзү» дип аңлатылган).

**МӘЛКЕ-Ү** (БТДҺ: 241) «раскисать; подтаять» ~ себ. (Тумашева 1992: 24) **мәлке-ү** > *мәлге-ү* «быть зыбким, колыхаться под ногами (о болоте)», **мәлкелдә-ү** ~ каз. *мелкĕлде-ү* (к. Будагов II: 253) id. ~ **былкылда-у ~** *балкылда-у* һ.б.ш. фигыльләр рәтеннән, *мәл < бәл ~ бал* тәкълиди тамырының *-ķ* детерминантына беткән тармагыннан. К. **Балкы-у** һ.б., **Мәлҗерә-ү.**

**МӘЛЛӘ** «льняной, бледно-жёлтый (о волосах); альбинос» < каз., чыгт., төркм. *мәллә*, үзб. *малла* id.; к. ш. ук тат. (?) **мелле** «буланая лошадь», диелә (Будагов II: 253).

**МӘЛХӘМ,** (ТТДС I: 313) **мәлхам** «мазь; пластырь» < гар. *мӓлхӓм* id. > рус. диал. (Фасмер II: 564) *мальхан* id., ахыр чиктә грек. *μαλαγμα* «авыртуны җиңеләйтә торган дару; мәлхәм» сүзеннән.

**МӘМӘЙ > мәми** «сладкая еда», **мәммә** «кашица для младенцев», «хлеб» (в детском языке) ~ чув. *мамма, мемме* id. < гом. төрки (Радлов IV: 2118, Пекарский: 1551, Ашмарин VIII: 1871–225) *мӓмӓ* «ими, имчәк» ~ төр. диал. *memek, memük* id. Барлык телләргә хас ономопоэтик сүз, к. тунг.-маньч. *мэ̄мэ̄* «әни», *мэмэ* «ими; мәми», маньч. *мэмэ* «имезүче хатын» һ.б. (ССТМЯ I: 567). Вокатив формасы *мәмәй, мамай* кыпч. телләрендә очрый; каз., к.-калп., уйг., хак. *мәммә, мам, мамаа* һ.б. «мәми». ЭСТЯ VI: 61–63.

**МӘМӘЧ** «липкая жидкость под корой» < **мәмә-ч, мәмә-кәч, мәммә-кәч** «татлы бутка» сүзеннән, әлбәттә. К. **Мәмәй.**

**МӘМГЕ, мәмке, мәнге** (Тумашева 1992: 150) «водяная блоха, горбунец (излюбленная наживка

удильщиков)» ~ рус диал. *мамчы, мамга, момга, монга* id. (себ. тат. сөйләшләреннән булса кирәк, к. Аникин: 372) ~ як. *мäніä, менкä*, *maria* «селәүчән, балык җиме» һ.б., к. **Мәңкә.**

**МӘМЕР I** «блаженное состояние; эйфория» ~ башк. *мамыр* id. ~ чув. *мимĕр, нимĕр*, мар. *немыр*, удм. (Насибуллин: 130) *нэмър* «мәмәч; татлы бутка». «Рәхәтлек хәле ~ татлы бутка» мәгъ. күчеше бу сүзнең дериватларында күренә, к. мар. *мäмĕрлĕк ~ нäмĕрлĕк* «мәмерлек, нирвана», тат., кырг. **мәмерә-ү** > **мәмрә-ү**, башк. (БТДҺ: 228) *мамыра-у* «рәхәтлеккә бирелү», тат. (ТТДС I: 313) **мәмертәп пешү** «изелеп пешү» ~ к.-балк., кырг. *мамур, мамыр* «мәмер, рәхәт», нуг., каз. *мамыр* «симергән, симереп авырайган». Башк. (БТДҺ: 228) *мамырҫын, мамыршин* «йомшак, мамык кебек» сүзенә карaганда, **мәмер < мамыр** нигезе монг. телләреннән шикелле, ләкин к. **Мәмер II.**

**МӘМЕР II, мамыр** (Тумашева 1992: 148–150) «богатый, обильный; обилие» ~ нуг. *мәмир* «оста, булдыклы», кар. *мэмир* «җитешле (тормыш)», уйг. *мәмур* «администратор», «төзек» һ.б. < гар. *мäʻмӯр* (> иске тат. **мәгъмур**) «төзек, уңай (торлак), яшәлгән, эшкәртелгән (җир)» ← *ʻмр* «яшәп тору, утрак тормышта яшәү», шуннан ук к. **Гомер, Гыймарәт.**

**МӘМЕРҖӘ** «пещера, грот; подземные ходы, лабиринт» ~ башк. *мәмәрйә* (ш. ук *мәмерек,* к. БТДҺ: 241) id. < гар. *мäмуррийä* id. ← *мрр* «әйләнеп агу, борылгалау», к. **Моржа.**

**МӘМЕЧ** (БТДҺ: 24, гәй.), **мәнәс** «самый младший; коротыш», **мәмеш** «неумелый». Чаг. иске тат. киң таралган исем **Мамич, Мамиш** «төпчек». Чаг. **Бәпеч, Бәбчек.**

**МӘМЛӘКӘТ** «страна, государство; владение; Родина» < гар. *мäмлäкäт* id. ← *млк* «ия булу, биләү», шуннан ук к. **Малик, Мәлик, Милек, Мөлкәт** һ.б.

Дерив.: **мәмләкәтле, мәмләкәтсез. Мәмләкәт** һәм аның дериватлары хәзер бераз искергән.

**МӘМЛҮК: мәмлүкләр** «мамлюки» гарәп илләрендә (Мисыр, Сурия һ.б.) XIII–XVI гг. дәүләт башында торган төрки телле хәрби оешмалар (аларның соңгылары «чиркәс» дип аталсалар да, төрки-кыпчак телле булганнар, к. Velidi: 179–180). Мәмлүкләр составында бик күп кыпчаклар – бор. татарлар да булган.

Асылда **мәмлүк** < гар. *мäмлӯк* «чура кол, чураш, сатып алынган > яллы гаскәри» дигән сүз, *млк* «ия булу» тамырыннан, к. югарыдагыны. Рус. *мамелюк* Европа телләре аша шул ук гар. теленнән. Мәмлүкләрнең иң атаклы солтаннары Бибарыс һәм Каетбай – саф төркиләр. Алар монголларга да, хәчтерүшләргә дә бирешмәгәннәр.

**МӘМНҮН** «очень довольный, считающий себя обязанным отблагодарить» < гар. *мäмнӯн* id. ← *мнн* тамырыннан, к. **Миннәт.**

**МӘН I** «толк; значение, смысл (слова)», диал. **мәне** < гар. *мäʻнā* «мәгънә» сүзеннән, к. ш. ук каз. *мән,* нуг. *мәне*, уйг. *мәнә* «мән»; бу сүзнең *мәнсез* ~ нуг. *мәнесиз*, уйг. *мәнесиз* «ахмак, мәгънәсез» дериваты киң таралган.

**МӘН II** иск. (Г. Тукай һ.б.) «человек, лицо» < гар. *мäн* id. ГТРС: 313.

**МӘН III** кайбер себ., миш. сөйләшләрендә: «с, вместе с», к. **Ман.**

**МӘН IV** иск. «ман, единица измерения веса» < ир. *мäн, ман* id. (киң таралган сүз). К. **Батман.**

**МӘНДӘ** (Balint: 170) «слуга; батрак» < **бәндә** (булса кирәк). Чаг. иске рус. *человек* «хезмәтче» мәгъ. Хәз. (ЗДС: 473) **мәндә** «кеше, бәндә» ~ каз., кырг. *менде* id.

**МӘНҖӘНИКЪ** гар. (М. Гафури) «камнемёт (в древности)» < гар. *мäнжäнӣк* «таш аткыч корал» < грек. *μαγγαηιχου* «зур җәя» сүзеннән дип исәплиләр, к. EJ VI: 405–406. Мәнҗәникъны Мөхәммәт пәйгамбәр дә (VII г.) кулланган, дип язалар.

**МӘНЗИЛ** «время бездействия; стоянка; время года» (*кыш мәнзилендә* «кышын авыл хуҗалыгы тукталган чорда»), ш. ук иске тат. **мәнзәләт** «юлчыларның тукталышы һ.б.» < гар. *мäнзил, мäнзäлäт* id. һ.б. ← *нзл* «тукталып тору» (к. иске тат. *нәзел, нәзлә* «томау, борын тыгылу»). К. **Минзәлә.**

**МӘНИ** «сперма» < гар. *мäнӣ* id.

**МӘНКУЛ, мәнкуль** «движимое, движимость», иск. «взятое из другого автора; цитированный»

(**мәнкулат** «цитата; пассаж из другой книги») < гар. *мäнķӯл, мäнķӯлāт* id. ← *нķл* «күчерү» тамырыннан. К. **Мангал, Нәкыль.**

Фразема: **гайре мәнкул** «күчемсез (милек)».

**МӘНТӘШ** (Тумашева 1992: 150) «быстро гниющий (о дереве)», «гниль дерева (как лекарство при ранениях)» ~ башк. (БТДҺ: 241) *мәндәш* «нарат кайрысы» < рус. *мендач, мендаш, менда, мянда* «сазда үскән нарат» < фин. *täntü* «чыршы». Аникин: 383–384.

**МӘНФӘГАТЬ [мәнфәғәт]** «интерес; резон; толк, польза» < гар. *мäнфäʿäт* id.

**МӘҢГӘР** – название большого населенного пункта к северу от Казани – кабилә атамасымы? К. каз. *мәңгер, мәңгәр* – кабилә атамасы, чаг. монг. *маңхар* ~ эвенк. *маңкар* «кашка; пеләш», тув. *маңан, маңган* >> рус. (Аникин: 314) *магин* «чал; мәллә; аксыл чәчле (яшь булса да)». Хәер, төрки, монг. телләрендә бүтән охшаш сүзләр дә бар.

**МӘҢГЕ** «вечный; вечно, никогда» > чув. *менкĕ,* мар. *мäңгĕ* id. < гом. кыпч., к. каз. *мәңгĕ,* к.-калп. *мәңги,* кр.-тат., уйг. *мәңгү, мәңү* < бор. төрки (Радлов IV: 1082, 1584) *мäңгү, бäңгү,* угыз. *бәңгү,* бор. төрки (ДТС: 342) *meŋgü, meŋigü, beŋgü, beŋigü* id.; икенче бер эзлекле линия – чыгт., алт. *мөңку,* тув. *мөнге* ~ бур. *мүнхэ,* монг. *мөнхө, мүнху, мүнку, мөңке,* калм. *tönkö* id., к. ш. ук як. (Пекарский II: 1558, 1626) *мäңä* «мәңге» – бор. кыт. *man kö* «ун мең ел (яшь)» сүзеннән дип исәпләнә (к. Räsänen 1969: 334), шуннан ук хәз. кыт. *вань цуй* > яп. *банзай* «ун мең ел узса да, һичкайчан (онытмам, чигенмәм һ.б.)».

Дерив.: **мәңгелек; мәңгеләш-ү (→мәңгеләштер-ү).**

**МӘҢКӘ** (ТТДС I: 316; БТДҺ: 241) «рыба-наживка» ~ чув. *менкĕ* «селәү, селәүчән». Чаг. бор. төрки (ДТС: 341) *meŋ* «җим». Räsänen 1969: 334 (уйг. *bäŋ* «кыргый кош-корт, балыкларны миңгерәйтеп аулау чарасы – киндераш орлыгы» сүзе белән багламакчы). К. ш. ук ЭСТЯ VII: 53–54 (арытабангы әдәбият китерелә). К. ш. ук **Мәмге.**

**МӘР** (Тумашева 1992: 150) «сок дерева» ~ башк. диал. (БТДҺ: 241) *мәре* «сыек балчык», *мәре-ү* «җепшү», *мәрет-ү* «җепшетү; сыегайту». Ачык түгел.

**МӘРАЗ,** (Dobr. II: 443–444) **maraz,** «болезнь, недуг» < гар. *мäрад̣* id. ← *мрд̣* «авыру булу», к. ш. ук иске тат. **мәризъ** «авыру, чирле, сырхау». ГТРС: 319, 320.

**МӘРАСИМ** «церемониал, обряд, установившийся порядок» < гар. *мäрāсим* «рәсмилек, рәсми тәртип».

**МӘРӘ I** (Будагов II: 221), **мәрәй** (Радлов II: 2092; «Тел ярышы» 1910: 47–48; ТТДС I: 314; БҺҺ II: 180 һ.б.) «цель, мишень для тренировочной стрельбы; круг или ямка на земле, куда стараются попасть в играх по метанию (мяча, палочек и т.п.)» > чув. *мере* «мәрә таягы; аткы», *мерей* «аткы» < гом. кыпч., к. каз. *мере, мерей, мәрәй.* кырг. *мерей, мәрәй* «максат; бәхет, мач», каз. (ҚТДС: 237), к.-калп., үзб. (ЎХШЛ: 179) *мәр* «мәрәй, финиш; максат, шарт», аз. (АДДЛ: 322) *мәрә* «чокыр мәрәй», *мәрә-мәрә* «мәрәйле уен», каз. диал. *мерай* «дан, мәргәнлек даны» һ.б., икенче үсеш линиясе – кырг., алт. *мөрөй*, уйг. *мөр, мөрәй* «мәрәй; приз; максат, сәмәрә, отыш», хак. *морий, мөрий* «ярыш»; фонетик үсеш линияләре **мүәрәй* < **муарай* яңгырашына тоташа, к. тув. *мөрей* «ярыш, мәрәй», *мөөрей* «пари, ядәч, бәхәс». К. **Мәрәлә-ү, Мәре-ү, Мәргән.** Вильяминов-Зернов 1963: 214–215; Räsänen 1969: 334–335.

Мәгъ. үсеше җәһәтеннән бу сүздә «мишень > җирдәге уен түгәрәге > финиш > максат» һәм «мишень > атуда ярышу > гомумән ярышу > отыш > дан» һәм «бәхәс» линияләрен аерырга мөмкин. Болар бор. төрки җәмгыятьләр өчен актуаль һәм хас булган шөгыльләр вә хәлләр.

**МӘРӘ II** (ТТДС I: 314; БТДҺ: 241) «медлительный (человек)» – **мәрәлә-ү** (к.) сүзеннән кире сүзьясалышы нәтиҗәсендә килеп чыккан булса кирәк; «төзәү ~ әкрен кылану» мәгъ. күчеше нуг., к.-балк. *мара-* «озак, җентекләп (мылтык һ.б.) төзәү» һәм *мараў* «сүлпән, әкрен» сүзләрендә дә күзәтелә (тат. *мәрә* < *марау* дип фаразларга да мөмкин, ләкин бу шикле фараз булачак; әмма бу сүзләрнең алтаистик бор. тирәнлектә тамырдаш булуы ихтимал (к. түбәндәрәк).

**МӘРӘКӘ** «потеха, забава; шуточное представление» > чув. *мереке, мерекке*, мар., удм. *мäрäкä, марака* id. ~ каз. *мереке* «туй җыены», аз. (АДДЛ: 322) *мәрәкә* «җыен, җыелыш», уйг. *мәрикә* «сугыш, көрәш мәйданы; җеназа мәрасиме; кампания», кырг. *маареке* «бәйрәм җыены; ярышлар,

финиш» < фар. *мә'рәке* «җыен; арена; кәмитчеләр һ.б. тамаша күрсәткән мәйдан» < гар. *мә'ракә* (> иске тат. **мәгърәкә**) «тамаша һ.б.ш. мәйданы».

Бу сүз тат., башк. телләрендә киң таралган (к. ш. ук *мәрәкәче* «комедиант, шомакай»), ләкин әд. телдә сирәгрәк кулланыла. Федотов II: 354 (**мәрәкә** һәм **маракы** сүзләрен бутый, хәлбуки бу сүзләр аерым – үзгә тамырлардан киләләр).

**МӘРӘЛӘ-Ү** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «делать что-либо очень тщательно и медленно», (БТДһ: 241) «ковылять (?)» – безнеңчә, **мәрә I** сүзеннән (ату коралын төзәгәндә аеруча игътибар һәм кабаланмаучанлык таләп ителә), тик, ихтимал, тат. телендә дә **мәрә-ү** «ук, мылтык төзәү» фигыле булгандыр, шуннан ешайту формасы буларак *мәрә-лә-* сүзе ясала ала.

**МӘРВӘРИТ [мәрwәрит]** «красный коралл» к. **Мәрҗән.** Рус. *Маргарита* исеме белән нигездәш.

**МӘРГӘН, миргән** «меткий (стрелок), снайпер», (Троянский II: 213) **мәрган** «охотник» > чув. (Сергеев 1968: 42) *меркĕн*, мар. *мäргäн, марган, мардан,* удм. (Насибуллин: 127) *мäрган, мардан* «миргән; аучы» (*мäрдан* > *мардан* варианты **мәрдан** (к.) сүзе тәэсирендә килеп чыккан) < гом. кыпч., алт., төркм. һ.б. *мерген, мергäн, мэргэн*, уйг. *мәргән*, хак. *мирген [миргән]* «мәргән; аучы», як. *мэргэн, бэргэн* ~ бор. монг. *mergen* «мәргән; акыллы, акылдар» ~ эвен. *миргэн* «акыл», эвенк. *мэргэ* «мәргән; оста, акыллы» һ.б. күп сүзләр (к. ССТМЯ I: 571); бу сүзнең фигыль нигезләре дә шәйләнә, к. алт. диал. *мäргä-* «оста булу» ~ эвен. *мэргэ-, мөргэ-* «уйлау, өйрәнү» һәм хак. *мирге-*, тув. *мерге-* «аткы, таяк ату», алт. диал. *пäргү* «мәргән»: бу сүзләрдән **мәр//мäр** тамыры булганлыгы күренә.

**Мәргә-** нигезе бор. төркиләшкән тунгус кавеме *меркит* (монг. **мэрки-т* «мәргәннәр») һәм рус. елъязмаларында искә алынган *берендей* < бор. төрки **бэрэнтэй* < **бэргэнтэй* (монг. «акыллылар, осталар») этнонимнарында да чагыла дип уйлыйлар. К. **Мәрә I, Мәрәлә-ү, Мәре-ү, Мизгел.** Будагов II: 224; Räsänen 1969: 335. Рус. *мергень* «мәргән» тур. Фасмер II: 600; рус. диал. *морген* «тәҗрибәле аучы» тур. Аникин: 385, 391 (шунда ук әдәбият); ЭСТЯ VII: 57–58.

Дерив.: **мәргәнлек;** диал. **мәргәнче** «оста аучы»!

**МӘРДАН** иск. «муж, мужи (важные, настоящие)» < фар. *мäрдāн* id. (төп мәгъ. «егетләр»). Шуннан ук **мәрданә** «егетләрчә». Будагов II: 223.

**МӘРДӘС** «браво; спасибо; молодец!» ~ себ. (ДС I: 137) **мәртәс,** чув. *мертес, морттес* id. < фар. *мäрд аст, мерд аст* «егет ул» тәгъбиреннән, к. нуг., к.-калп. *мерт,* төр. *mert* «ир-егет; асыл егет» < фар. *мäрд, мäрт* id. (шуннан *мäрдä* «осталык, егетлек» сүзе дә ясала, *мäрдäш* «аның осталыгы!» дип әйтелә һәм *мәрдәс* шуннан да килеп чыга ала). «Шаһнамә» (Ә. Фирдәүси) әсәрендәге *Мәрдәс* патшаның *мәрдәс* «афәрин» сүзенә катнашы юк.

**МӘРҖӘН,** диал. **миржән,** себ. (Тумашева 1992: 150) **мәрцен** «кораллы; бусы; бисер» ~ башк. *мәрйән, мәрйен* id. > чув. *мерчен*, мар., удм. *мäрзäн, марзан* id. < гар. *мäрҗāн* < арамей. (яһ. теленең бор. диалекты) *marganîda* < грек. *μαργαρίτης* «энҗе, мәрҗән» – шуннан рус., лат. > *маргарита* «чәчәкле бер үсемлек һәм кеше исеме» > гар. > тат. **мәрвәрит** «энҗеле чәчәк» сүзе дә килә (к. Фасмер II: 573). Кайбер тикшеренүчеләр, грек сүзе үзе сем. телләреннән алынган диләр (Kluge: 598). **Мәрҗән, Маргарет, Мәрвәрит** исемнәре дөньяда киң кулланыла; элек алар кол балаларына кушылган (Zenker: 835).

**МӘРКӘП, мәркәб** иск. «поэтически-мечтательное состояние», «верховое животное (лошадь, осёл, верблюд)» < гар. *мäркäб* id., ш. ук «затлы һәртөрле экипаж, мәгәлдәк һ.б.». Гомумән, абстракт мәгънәгә тартым, тамыры *ркб* «җыелма булу», шуннан иске тат. (төрки телдә киң таралган). **Мөрәккәп** «катлаулы, җыелма составлы; махсус язу карасы». Будагов II: 224.

**МӘРМӘР** «мрамор; мраморный» < грек. *μάρμαρος* «төзелеш ташы» сүзеннән киң таралган; татарчасы гарәпчәдән булса кирәк.

**МӘРТ** «летаргия», диал. (Остроумов 1876) **мәрет** «һуштан язу» > удм. *нарт* «летаргия» < фар. *мäрд* «үлем; мәрт» (рус. *мерт-в-* белән тамырдаш). к. ш. ук каз., кырг. *мерт* «мәрт; каза».

**МӘРТӘБӘ** «раз; крат; чин, степень, высокая степень» < гар. *мäртäбä* id. Кайбер төрки телләрдә бу сүзнең кыскарган варианты – уйг. *мәртә*, каз., кырг. *мерте*, үзб. *марта* «тапкыр, рәт» кулланыла, бу вариант тат. телендә дә очрый һәм гар. *мäртäб* вариантыннан килә. Будагов II: 221–222.

Дерив.: **мәртәбәле, мәртәбәсез** (кеше).

**МӘР-Ү, мәре-ү** диал. (ТТДС I: 314; БТДһ: 241) «вышивать; вязать на спицах узоры, обшивать по

краю ткани, чтобы не измызгалось» – безнеңчә, тат., башк. телләрендә генә һәм тәүдә «челтәр үрү; җеп божрасын кулларда уйнатып, төрле бизәкләр ясау» мәгънәсендә булган (шундый уен бор. халыкларда киң таралган була). **Мәр-ү** сүзенең *мәре-ү, мәрә-ү* вариантлары да очрый, к. ш. ук **Мәрәлә-ү.**

Рус. *мерёга, мерёжа* «сиҗә, челтәрле тукыма» сүзе белән охшашлык очраклы булса кирәк.

**Мәр-ү** бик бор. сүз булырга мөмкин, к. **Мәрәй, Мәргән.**

**МӘРХӘМӘТ** «милость, милосердие» (**мәрхәмәтле** «милостивый») < гар. *мäрхäмäт* id. ← *рхм* «ягымлы булу» тамырыннан. Шуннан ук **Мәрхүм, Рәхим, Рәхмәт**.

**МӘРХҮМ** «покойный, покойник, почивший» (**мәрхүмә** «покойная, покойница») < гар. *мäрхӯм, мäрхӯмä* id., id. ← *рхм* «ягымлы булу» (үлгән кеше турында яхшы ягын гына сөйләү) тамырыннан.

**МӘРЧЕН** (ЗДС: 474) «бузина». Бу сүзнең төгәл-анык параллелен тапмадык, әмма якынча охшаш сүзләр бар: добр. (Dobr. I: 299) *berčimek, percimek,* төр. *mercimek* ~ фар. *merdümek* – кузаклы бер үсемлек, лат. *bens culinarus* һәм аның яшькелт яисә кызыл вак борчагы. Будагов (I: 222) төр. *мерджемек* «чечевица» ди. К. ш. ук диал. (ТТАС II: 621) **мәрҗән агачы** рус. «бузина красная» диелгән.

**МӘСӘЛ** «басня» < гар. *мäҫäл* «мәсәл, мисал, кыйсса, гыйбрәтле хикәя» **мәсәлән, мисал** сүзләре белән тамырдаш; *мәсәл* сүзе кайбер телләрдә (төрки *mesel*) «мәкаль», кайбер телләрдә (аз., кр.-тат.) *масал* «әкият» мәгънәсендә килә. К. **Тәмсил.**

**МӘ́СӘЛӘН** «например» < гар. *мäҫäлäн* «мисал итеп». К. **Мәсәл, Мисал.**

**МӘСИХ: мәсих итеге (читеге)** «сапоги для совершения намаза» < гар. *мäсӣх* «помазание; намазанный; мессия (помазанный на пророчество)». Шулай дип Гайса пәйгамбәрне дә атыйлар.

**МӘСКӘҮ** «Москва; московит» < бор. рус. *Московo, Московь* «Мәскәү» (елгасы һәм шәһәре) сүзеннән, бу сүз бор. *Москы* (елгасы) сүзенең төш. килеш формасы (Фасмер II: 660).

**МӘСЛӘК** «внутреннее убеждение; принцип» < гар. *мäслäк* id. ГТРС: 325. Бу сүзнең дериваты **мәсләксез** «принципсыз» киңрәк кулланыла.

**МӘСЛИХӘТ** «рекомендация; рекомендуется (предикатив); желательно» < гар. *мäҫлихäт* id. **Солых** сүзе белән тамырдаш. Будагов II: 236.

**МӘСТ I** иск. «пьяный, пьян; несознательный» < фар. *мест, мäст* id. К. **Масай-у, Мәз.**

**МӘСТ II,** диал. **мист** «сафьяновые сапожки (с невысоким каблуком), которые выделывали в Казани с древних времен на вывоз» (к. Баттал: 170) ~ башк. *мисте* (БҺҺ II: 171) ~ кырг. *маасы, маасты, мәсти,* төр., көрд. *test, мэст* (Будагов II: 228), к.-балк. *месси* «күн оек», каз. *мес, меси* «сарык тиресеннән эшләнгән читек», нуг. *мес*, к.-калп. *мәси*, аз. диал. (АДДЛ: 323) *мәс, мәст* «сәхтиян аякчу» id. Бу сүзне каз., к.-калп. *мес*, уйг. *мәйсә*, кырг. *меш* һ.б. (к. **Мис II**) «кәҗә тиресе; кәҗә күне, кәҗә» белән чагыштыру фонетик җәһәттән шик уята. Тире, күн атамасы хайван атамасыннан чыгуы бик табигый һәм еш очрый, ләкин күн атамасының аякчу атамасына әверелүе дә мотлак түгел (һәм, гомумән, сирәк очрый). Шулай ук **Мәсих (итеге)** белән чагыштыру да шикле. Räsänen 1969: 336 (тулы түгел).

**МӘСТӘН, мастан (мастан карчык)**, **мустан** «ведьма» ~ к.-калп. *мәстан* id., кырг. *мастан, мыстан,* үзб. *мастон,* калм. *мустан,* тат. диал. (Арсланов 1988: 88) **мускортка** id. «Гүр углы» дастанында *мастан* «мәстән» һәм **Чанбил мастан** – «Шамбала, һәрбер теләгең үтәлә бара торган тылсымлы ил». Маньч. *мус, могус, мас* «пәри, җен» сүзенә тоташа. Төрки халыкларда ничектер **мавыз** (к. **Маңгыз**) сүзе нигезендә ясалган сүз булса кирәк. Казакларда *мыстаң кемпир* «салават; аллыгөлле кәҗәләре, сарыклары булган карчык, ул аларны яңгырдан соң сава». МНМ II: 189; Куфтин Б.А. Календарь и первобытная астрономия киргиз-казахского народа // Этнографическое обозрение. № 3–4. М., 1916.

**МӘСТӘР,** диал. **мистәр,** «смета; графлённая конторская книга; что-либо, состоящее из ряда параллельных прямых линий» (ДС I: 132), **мәчтәр** «полка»; «лежень саней» (ДС I: 137) ~ башк. *мистар* (к. БТДҺ: 232 *мистарлау* «теләсә ничек тегү») < фар. *местäр* «графалап сызу өчен җайланма,

линейка» < гар. *мāстāр* «туры параллель сызыклар җөмләсе» **сәтыр** (к.) сүзеннән. Будагов II: 230–231.

Дерив.: **мәстәрлә-ү** «смета төзү; кәгазь битен графалап чыгу».

**МӘСТРИК, мәстерик** (ЗДС: 475) диал. «шишка хвойных деревьев», «твёрдый нарост на дереве, твёрдый гриб» ~ хак. *мистiрiк* id., арытабан *мичiр, миҷiр* «каты сөял, оры; кире, тыңлаусыз» < *мирiр* id., ш. ук «бирчәйгән», *мирттiг* «биртле» ← *мира* «бирт, яраның инде бетәшкән эзе» һ.б. К. **Бирт.**

Шул ук сүзләр – *бирт ~ бәрт* сүзенең дериватларыннан Төньяк Кавказ татарларындагы **мычыгыш** «ингуш, чечен» сүзе килеп чыга бугай, к. хак. *миргең* «кире, тупас; биречле» һ.б. Хак. һ.б. Себер төрки телләрендә сакланган кайбер сүзләрне омоним гар., фар. сүзләре кысрыклаганнар (мәс., бу очракта **миржән** «мәрҗән» кысрыклаган).

**МӘСТҮРӘ: мәстүрә гөл (гөле)** «растение с цветами, закрывающимися на ночь» < гар. *мāстӯра* «качына, бөркәнә торган кыз» сүзеннән – халык этимологиясенчә **Мәстүрә** дигән кеше исеменә нисбәт ителгән.

К. ш. ук миш. (ЗДС: 471) **мачтура** «борчаклы гөл, борчак үләне».

**МӘСХӘРӘ**, диал. (ТТДС I: 314) **мәсҡәрә,** ш. ук (ТТДС I: 309) **маскар, масхар, маскара, масхара** > удм. *маскар, маскара* < гом. кыпч., төр. *масҡара*, төркм. *масғара* «высмеивание, издёвка; посмешище» << гар. *мāсх̣ара* id. *схр* тамырыннан, к. **Сихер**. К. ш. ук тат. диал. **маскарчы, маскарцы, масхарачы** ~ удм. *маскарчи* «комик, клоун, насмешник» (к. Алатырев 1976: 148–149). К. **Маскар, Мыскыл.**

**Мәсхәрә** сүзен Һарун әр-Рәшид заманында яшәгән (828 елда үлгән) Әбү әл-Әтәхийя дигән дәрвиш гамәлгә керткән дип язалар.

Рус. (< фр. < ит.) *маскарад* сүзен дә гар. *мāсх̣ара, мāсх̣арат* сүзеннән диләр (к. Будагов II: 230; Kluge: 602), шуннан ук рус. *маска* < фр. *masque* < ит. *maschera [масхера]* (фр. телендә ауслаут *-р* төшеп калучан).

Дерив.: **мәсхәрәле, мәсхәрәсез; мәсхәрәлә-ү; мәсхәрәче.**

**МӘСЬӘЛӘ, мәсәлә** «вопрос, проблема; задача» < гар. *мāс'āлā* id. ← *с'ал* «сорау» тамырыннан, к. **Мәсьүл, Саил, Сөаль.**

**МӘСЬҮЛ** кит. «ответственный» < гар. *мāс'ӯл* id. ← *с'ал* «сорау» тамырыннан. К. **Сөаль.**

Дерив.: **мәсьүллек;** иске **мәсьүллә-ү; мәсьүлият** – гарәпчәнең үзеннән.

**МӘТ** (ТТДС I: 315) «косноязычный, туповатый» ~ добр. тат. *matй, matuw*, үзб. (ЎХШЛ: 180) *мәтув* id. ~ төр. *matuh* id. < гар. *мā'тӯħ* «дебил» ← *'тħ* «тилемсә булу».

**МӘТӘЛӘ, митәли** (ЗДС: 475, 480) «дорогая посуда» < гар. *муṭаллā* «алтынланган, алтын бизәкле». К. **Теллә.**

**МӘТӘЛ-Ү** (Радлов IV: 2103) «упасть от подножки; перекатываться, кувыркаться» ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 180) *мәтәлә-* id. < диал. **матал-у, матала-у** id. ← **мата-у** (к.). К. **Мәтәлчек.**

**МӘТӘЛЧЕК** «кувырок; сальто-мортале» ← **мәтәл-ү. Мәтәлчек ату** «сальто ясау». Чув. *мекĕлчек* «мәтәлчек» *мекĕлт* тәкълитеннән дип уйланылган.

**МӘТЕ** «вязкая глина (кирпично-красного цвета)», диал. (Тумашева 1992: 145) **ләте** «дуен» – ниндидер фин-угор теленнән (ләкин күрше фин-угорларда юк), к. морд. *мода* «балчык, җир», фин. *muta* «ләм, лай». К. ш. ук **Нәште.**

**МӘТЕН** «основной (аутентичный) текст произведения» < гар. *мāтн* id.

**МӘТКӘ** «русская жена (нерусского); русская женщина (вообще)», ругательство в отношении несдержанных женщин ~ башк. *мәткә* id., ш. ук «чикерткә» (БТДҺ: 242), чув. *матка* «ир хатыны» < рус. сөйл. *матька* id., ш. ук «ана, әни».

Башк. сүзлекләрдә әйтелгән «чикерткә» мәгъ. бигүк дөрес түгел, дөресрәге «әнә карагы» (к. **Марҗа көянтәсе, Көянтәле марҗа** ~ рус. *коромысло* – бөҗәк тур.).

**МӘТРҮШКӘ,** диал. **мәтрүш,** (ТТДС I: 301) **мәтрүнә** «душица» < рус. сөйл. *матрёшка* (ш. ук *маткина душка, матрёна, матрёнина душка*) > чув. *матрушке,* мар. *матрушка* id. Бу үсемлек балаларга бик шифалы исәпләнә һәм шунлыктан аны «бер ананың җаны» (*матрёна* «күпбалалы ана»), бер ана үлгәндә шул үсемлеккә әверелгән, дигән легенда бар, к. Фасмер II: 582; Егоров 1964: 129.

Шуның белəн бергə бор. төрки (ДТС: 338) *matridus* «шифалы үлəн төре» искə алына.

**МƏҮКƏЙ [мəwкəй]** диал., башк. (БТДҺ: 242) «плохой, невоспитанный (о мальчиках и девочках)» << монг. *мағухай* id.

**МƏҮСИМ [мəwсим]** иск. «сезон; благоприятная пора» < гар. *мäwсим* id., тəүдə кəрапларның һəм кəрваннарның юлга чыгу вакытын билдергəн һəм *wсм* «билге, тамга; билгелəү» тамырыннан килə.

**Мəүсим** сүзе Европа теллəренə үтеп кергəн: исп. *monzon* > фр. *mousson* > рус. *муссон*; ним. *Monsun* «җилкəнле кəрапларга уңай җиллəр; муссон», к. Фасмер III: 17; Kluge: 630.

Дерив.: **мəүсимле** (үз вакытында эшлəнгəн), **мəүсимсез.**

**МƏҮСҮЛ [мəwсүл]** иск. «относительное местоимение», иске əд. (ГТРС: 346) «тоташкан; тоташтыргыч», тар. «аргыш пункты, мəнзил», шуннан төр. *Мусул* (> рус. *Мосул*) шəһəренең атамасы килə (шунда элек почта станциясе булган). К. **Муслин.** Будагов II: 264.

Грамматик термин буларак бу сүз хəзер дə бик уңайлы булыр иде.

**МƏХАРИҖ** «издержки, расходы» < гар. *мäхāриҗ* id. – *мäхраҗ* (> тат. *мəхрəҗ*) «чыгым» сүзенең күп. формасы, к. ГТРС: 337. К. **Магарыч, Харижи, Хəраҗəт, Хəреҗ.**

**МƏХƏББƏТ, мөхəббəт** «любовь» < гар. *мухäббäт* id. ← *хбб* «сөю, телəү» тамырыннан, к. **Хуп.**

Дерив.: **мəхəббəтле, мəхəббəтсез** һ.б. (икенчел дериватлар).

**МƏХƏЛ** «место в ряду, удобное положение, уместность; момент» ~ чув. *мехел*, мар. *мäгäл, магал* id. шуннан к. **Мəл I** (чаг. чув. *мехелсĕр* ~ тат. **мəлсез** «вакытсыз, уңайсыз») < гар. *мäхäл* id. (к. Будагов II: 215) *хлл* «урын алу, урынлы булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Хəл I.** К. **Мəхəллə, Хəлəл.**

**МƏХƏЛЛƏ** «махалля, приход мечети» < гар. *мäхäллä* «урынчылык, урындагы, төбəктəге бүлекчə» сүзеннəн. К. **Мəхəл.** К. ш. ук иске **мəхəлли** «төбəктəге, җирле» (ГТРС: 339).

**МƏХБҮС** «арестант; сидящий в тюрьме» < гар. *мäхбӯс* id. ← *хбс* «тоткын булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Хибес, Хибесханə.**

**МƏХДҮМ** «сын священника» – «рухани углы» (**мəхдүмə** – «рухани кызы») < гар. *мäхдӯм, мäхдӯмä* id. id.

**МƏХЗƏН** «тумба со шкафчиком (в медресе)» < гар. *мäхҙäн* id. К. **Магаҗи.**

**МƏХЛУК [мəхлүк]** «тварь», күч. «непонятливый, неловкий, равнодушный ко всему человек» > чув. *мехлюк* (Сергеев 1968: 42), мар. *мäхлöк* (Исанбаев 1978: 20), удм. диал. *мехлук* id. < гар. *мäхлӯӄ* «мəхлук; җан иясе» – **халык** (к.) сүзе белəн тамырдаш. К. ш. ук иске. **мəхлукат** «барча җан иялəре».

**МƏХРҮМ** «лишён, лишённый» < гар. *мäхрӯм* id. **Харам** (к.) белəн тамырдаш.

Дерив.: **мəхрүмлек; мəхрүм булу (калу).**

**МƏХСУЛ** «продукт; (в математике) производное» < гар. *мäхҫӯл* id.; к. ш. ук **мəхсулат** «все произведенное, вал» (к. ГТРС: 337), *хҫл* «барлыкка килү» тамырыннан, к. **Тəхсил, Хасил.**

**МƏҺƏР,** диал. **мəəр** (Тумашева 1992: 149) «махр, свадебный подарок жениха будущей жене» < гар. *мäһр* id. (к. Будагов II: 270), **мөһер** (к.) сүзе белəн тамырдаш булса кирəк (гарəплəр фарсы теленнəн алганнар).

**МƏЧЕ**, диал. (ТТДС I: 302) **мачы, мацы** «кошка, кот» > чув. *мачă* (Сергеев 1978: 40, *мачă кăрьăк* < миш. *мачы корьык* «мəчекойрык үлəне» сүзендə), мар. (Исанбаев 1978: 19) *маче*, удм. *мачы* < гом. көнб. кыпч. *мачи, мачы* (СС *мачу*) id. ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 177) *машы* «песи баласы», *мача* «ана ишəк», каз. (ҚТДС: 177) *мəш*, чыгт. (Будагов II: 195) *мачэ* id., фар. *маче* «кəнтəй», себ. **мəцикə, мəчкə > мəшкə** «бəти, бəрəн» (к. Тумашева 1961: 151, 170), каз. *мəшке* «такса (кечкенə буйлы, озынча гəүдəле ау эте)» һ.б. ~ грек. *ματζα* «мəче» – барысы да һинд-евр. **mäther* «ана» сүзенə кайтып кала. **Мəчелəр** – үрнəк аналар.

**МƏЧЕН, мичен: мичен елы** «год обезьяны», **мичен сəгате** «час обезьяны» к. **Бичен. Мичен, мəчин, бичен йолдызлыгы** тур. МНМ II: 110.

**МӘЧЕТ** «мечеть» > башк. *мәсит,* чув. *мечӗт,* мар., удм. *мä̈чет* < гар. *мäсҗид* (> тат. **мәсҗед**) «сәҗдә кыла торган урын» сүзеннән. Рус. *мечеть* (> чув. диал. *мичет*) татарчадан булса кирәк (к. Фасмер II: 613), хәер, *мäчит, мәчит* һ.б.ш. яңгырашлар күп телләрдә (уйг., Балкан, Иран һ.б.) очрый.

**МӘЧКӘЙ,** диал. (себ.) **мәцкәй** «обжора; злой дух; алчный» ~ башк. *мәскәй, мискәй, мәсёкәй, мисекәй* (к. БТДҺ: 232) id., үзб. (ЎХШЛ: 182) *мечкай,* каз., к.-калп., кырг. *мешкей,* кырг. *мечкей,* нуг. *мешкейил* (< *мешкей йэл*: *йэл* «рух, җен, пәри»), гаг. *мечик* «җен баласы» ~ иске тат. (Будагов I: 312) **пәчик** «җенләнү», **пәчикләнмәк** «котыру» ~ башк. (БТДҺ: 242) *мәсих* «өй иясе» – ауслаут *-х* монда **мәсих** (к.) сүзе беләп буталудан. **Мичен, Бичен, Бичура** (к.) сүзләре белән тамырдаш. ЭСТЯ VII: 58–59.

Рус телендә «башкорт хикәяте» дип язылган стилизацион «Кузы курпяч» әсәрендә **М***ескяй карчык* – тылсымчы изге зат булып гәүдәләндерелә, ләкин бу чын фольклор образына каршы уйдырма гына.

**МӘЧКӘҮ [мәчкәw]** (ТРС 1966) «силок»; «флажкование» ~ башк. (БҺҺ II: 170, 180–181; БТДҺ: 232–242) *мәскәү, мискәү* «мәчкәү, тозак; балитәк, бөрмә» ~ як. *мэһэй* < *мэсэй* «тоткар, киртмә, комачау». Бу сүздән Башкортстандагы *Мәскәү* дигән берничә авыл һәм ыру атамасы килә.

**Мәчкәү** сүзенең чыгышы ачык түгел; ихтимал, **мичә-ү** фигыле белән тамырдаштыр. К. **Мичәү.**

**МӘШ: мәш килү** «оживленно заниматься чем-либо» < диал. **мәшек** (**мәшеклән-ү** «мәш килү») ~ уйг. *мәшиқ,* кырг. *маш, машык,* каз. *машық,* к.-калп. *машкы,* үзб. *машқ,* төр. *teşk* «күнегүләр; күнекмә ясау» < фар. < гар. *мäшқ* id. (> иске тат. **мәшқ** «матур язу дәресе», к. ГТРС: 340). К. **Маш.**

**МӘШӘ, мәшәлә** «возня» < иске әд. (ГТРС: 340) **мәшгалә** «занятость» < гар. *мäшғалä* id. ← *шгл* «эшләү, хәстәрләү» тамырыннан, шуннан ук к. **мәшгуль, шөгыль.** Чаг. төркм., каз. *машғала, машқала* «хуҗалык», төр. *meşgale* «эш, хезмәт» һ.б., әлбәттә, гарәпчәдән.

Дерив.: диал. (ЗДС: 475) **мәшәкәлә-ү** «кемгәдер эш табу, кызыксындыру» (*мәшәкать* сүзе белән контаминация), **мәшәлән-ү** «маташу».

Сөйләшләрдә тагын **мәшмәшә** «буталчык эш, ыгы-зыгы» сүзе очрый. Бу да гар. сүзе, ләкин бөтенләй үзгә бер тамырдан.

**МӘШӘКАТЬ** «лишние хлопоты; затруднения, лишние дела» < гар. *мäшäққат* id. ГТРС: 342.

Дерив.: **мәшәкатьле, мәшәкатьсез; мәшәкатьлән-ү.**

**МӘШГУЛЬ [мәшғүл]** «занят; занятый (делом)» < гар. *мәшғӯл* id. ← *шгл* «эшләү, кылу», к. **Шөгыль.** Дерив.: **мәшгульлек.**

**МӘШЕК** иск. «бурдюк», диал. (ТТДС I: 306) **мәшәк** «капчык, тире капчык» ~ башк. диал. (БТДҺ: 232) *мишәк,* үзб. *мешик, машк,* к.-балк. *машок* «күн капчык, толын» ~ көрд., фар. *teşk, teşke* id., к. ш. ук үзб., кырг. *меш* (каз., к.-калп. *мес*) id., таҗ. *меш* «кәҗә», төр., фар. *мешин* «кәҗә тиресе». Бу сүзләрнең рус. *мешок* (← *мех*) сүзенә катнашы юк, әлбәттә, ләкин бор. һинд-евр. теле тәңгәлендә *мәшек* һәм *мешок* тамырдаш булырга да мөмкин. Чаг. ш. ук **Мәст, Мәшкә IV, Мәшик.** ЭСТЯ VII: 69–71.

**МӘШКӘ I,** диал. (ТТДС I: 315, БТДҺ: 231) **мәшкәк, мишке, мешкәк**, себ. (Тумашева 1992: 150–152) **мәшкә, мишкә, мишкәләк, мишкәйәк** «гриб; гриб-трутовик» > мар., удм. *мä̈шкä, мä̈шкä̈к* ~ алт. *мешке,* алт. диал. *пешке* < тув. диал. *бешкä,* хак. *миске* «ку гөмбә; каен орысы; бөке» гадәттә мар. һ.б. *мекш* «агач череге» сүзе белән чагыштырыла, ләкин (үзе фин) А. Йоки (Joki 1952: 90–91) бу чагыштыруны кабатламый. Себ. **мәшкә** «бәти, бәрән; нарат күркәсе», **йир мәшкәсе** «гөмбә» (к. Тумашева, Op. cit.; Будагов II: 234) – бу сүзләр себ. **мәцикә** «бәрән», **мәстрик, мәцрик** «нарат һ.б. күркәсе» белән чагыштырылганда, сүзнең төп мәгънәсе «яңа туган бәрән» түгелме икән, дигән фикер туа, бу мәгънә исә «мәче һ.б. баласы; мәче» (к. **Мәче**) белән гомоген. ЭСТЯ VII: 59–60.

Башк. (> тат. диал.) **бәшмәк** «мәшкә, гөмбә» **мәшкәк > бәшкәк** вариантыннан үзгәреп килеп чыккан.

Дерив.: **мәшкәкле, мәшкәклек.**

**МӘШКӘ II** (ТТДС I: 315; БТДҺ: 242) «цинга» – ачык түгел, ихтимал, **мәшкә I** белән баглыдыр.

**МӘШКӘ III** (Тумашева 1992: 151) «жир» ~ кырг. *мешке* «май; күбек май». Ачык түгел. Чаг. **Мәшкә IV.**

**МӘШКӘ IV** (Тумашева 1992: 151) «ягнёнок» ~ рус. диал. (Аникин: 379) *маська* «сарык». Чаг. **Мәшек.**

**МӘШРИКЪ** «восток, восточная сторона» < гар. *мāшриķ* id., *шāрķ* (к. **Шәрык**) «көнчыгыш» сүзенең җыелма күплеге.

**МӘШРУТИЯТ [мәшрутийәт]** иск. «конституция» (бу сүз XX г. башларында бик актив кулланылган) < гар. *мāшрӯṭийāт* id., **шарт** (к.) сүзе белән тамырдаш. ГТРС: 341.

**МӘШТӘК** (ЗДС: 476) «низенькая (женщина)» ~ каз. *мәстек* «тәбәнәк ат, маштак; тәбәнәк (кеше)». К. **Маштак.**

**МӘШҺҮР** «знаменит; знаменитый» < гар. *мāшһӯр* id. ← *шһр* «атаклы булу» тамырыннан, к. **Шөһрәт** (ГТРС: 342).

**МӘЭЛДӘ-Ү** «блеять» – типик *-елдә//-ылда* аффиксы ярдәмендә **мәә** ымлыгыннан. К. төр. *meletek.* Параллельләре барча төрки телләрдә бар һәм *м-* яки *б-* авазына башлана.

**МӘЭМӘЙ [мә’мәй]: мәэмәй итү** «побить (младенца)» – *мамай* «балаларны куркыткыч образ» (*мамай килә!*). Бу сүзнең атаклы Мамай сәргаскәр исеме белән бигланышы шикле. Чаг. *Маэмай.* Гомумән, ачык түгел.

**МӘЭЮС [мә’йүс]** «очень печальный, опечаленный; отчаявшийся» < гар. *мā’йӯс* id. ← *й’ис* «өметсез булу». К. **Яс.**

**МЕДАЛЬ,** сөйл. **мидал** «медаль» ~ башк. *миҙал* id. Рус һәм гом. Европа сүзе, асылда *металл* белән бердәй. Kluge: 610.

Сөйл. телендә *видал, кәҗәдә мидал* дигән шаян әйтем бар (лаексыз кешене күтәрү, мактау тур., күз алдында кәҗәнең иягендәге тәлләре тотыла).

**МЕДЕР: медер-медер** – подражание тихому и неторопливому разговору. Шуннан **медердә-ү** «тыныч кына нәрсәдер сөйләү, сөйләнү». Гом кыпч. сүзе булса кирәк. Тат.-рус. сүзлекләрдә **межмеж, межелдә-ү, межелдек** кебек **медер-медер** мәгъ. сүзләр китерелә. Без ул сүзләргә җанлы сөйләмдә дә, әдәбиятта да мисал очратмадык бугай.

**МЕКЕР-МЕКЕР, мекел-мекел, мики-кики** – имитативы короткому блеянию коз. Төрки сүзлекләрдә теркәлмәгән. Болардан ясалган **мекердә-ү, мекелдә-ү** фигыльләренә охшашлар бар: ним. *meckern, mecken*, лат. *miccire* һ.б. id.

**МЕЛ** «мел». Бу сүзне без мәктәптә (1940 нчы елларда) **мыйыл** дип үзгәртеп әйтә идек. Һәм хәзер дә техник *мел*ны (рус сүзен) шулай әйтүчеләр бар.

**МЕЛЕ, мелек** «молодь рыбы, моль, малёк, мальки» русчадан дип карала. к. ЗДС: 476. Ләкин **мелтәй, мелтке** вариантлары (ЗДС: 477) id. тәгаен русчадан түгел. Чаг. төр., гар. *мāлā*, лат. *mille* «бик күп, ыбыр-чыбыр» һ. б. ш.

**МЕЛОДИК** «мелодический» – фр. теленнән турыдан-туры яисә төр. теле аша (анда *melodic* id.) күчерелгән, *-ик* кушымчасына беткән термин сыйфатлар рәтендә тора. Шуңа тамырдаш *мелодика, мелодия, мелодрама* кебек сүзләр рус теленнән кергән.

Бу сүзләрдәге *мелод-* нигезе грек. *melos* «җыр» һәм *oide* «җырлау, көйләү» сүзләреннән гыйбарәт кушма сүз. Kluge: 612. Соңгы – *oide* сүзенә **Ода** «мактау көе, мәдхия» тоташа.

**МЕЛТ: мелт-мелт** – подражание подёргиванию губ (при готовности заплакать), миганию свечи и т.п. к. **Мөлдерә-ү, Пелт.**

Дерив.: **мелтелдә-ү.**

**МЕЛТЕК** (ТТАС II: 379) «замухрышка» – ачык түгел; чаг. башк. (БТДҺ: 50) *биртек* «бахыр; боек; кыерсытылган» (к. **Бирт-ү**), яки рус. *винтик* сүзеннәнме?

**МЕН** (ЗДС: 476–477) «недостаток, дефект» к. **Мөн.**

Дерив.: **менәш-ү, менләш-ү** «җитешсезлек күрергә тырышу, артык талымлау», **менцеклә-ү** «төпченү», **менчел** «шикләнүчән» һ.б.

**МЕНӘ,** диал. **мына, мона, мәнә, мени** «вот; вот это» (**менә-менә** «вот-вот»), миш., себ. **менәкә,** гом. тат. сөйл. **менәтерә, менәтерәк, менәтерәкә** ~ гом. кыпч. *менā,* ~ башк. *бына, мына,* уйг. *муны*, үзб. *мана*, кырг. *мына,* бор. төрки *bина, тина, тинě, тини* (ДТС: 348) < *bи па* id. (*на, не* бор. күрсәтү алмашлыгы).

**МЕНГӘШ-Ү** «сесть вдвоём на одну лошадь» ~ уйг. *мингәш-,* кырг. *мěнгес-*, төр. *bingeş-* ~ бор.

төрки (ДТС: 344) *miŋäš-* id. **Мен-ү** сүзеннән, әлбәттә, ясалышы ачык түгел.

**МЕНГЕ** «верховой, для езды верхом (о лошади, осле и т.п.)» < гом. кыпч. *минги*, бор. төрки (ДТС: 344) *mingü* id. К. **Мен-ү.**

**МЕНДӘР,** диал. **миндәр** «подушка; основа передка телеги» > чув. *минтер,* мар. *мындер*, удм. *миндэр* id. ~ нуг. *миндер* «күпчек», ком. *минне* «кечкенә ястык» (ләкин Дагстан телләрендә *миндар* «мендәр»), кар. *миндэр, мындэр* «кушетка», гаг. *мендер, миндер* «диван», төр. *minder* «аслык; ияр мендәре» һ.б. гадәттә *мен-* < *мин-* «менү» һәм монг. *дэрэ* «мендәр» сүзләреннән гыйбарәт дип аңлатыла (Егоров 1964: 134; ЭСТЯ VII: 66–67), ләкин к. каз. *мӗндәр* «кабер ташы; салдау, кимә тукталу урыны; трап» (ҠТДС: 249) < фар. *бäндäр* «порт, салдау; кимәләр салдауга терәлә торган урынга куелган мендәр». Фар. сүзе төрки телләрдә *мин-* «менү» сүзенә бәйләп аңлатылган булса кирәк.

**МЕНЛА** «молодой мулла» к. **Мулла.**

**МЕН-Ү** «взбираться, взобратся наверх; садиться, сесть верхом на животного» < гом. кыпч., үзб., уйг. *мин-*, як. *минн-*, угыз. *bin*, алт. *мүн-*, тув. *мун-*, бор. төрки (ДТС: 344, 353) *mün-, min-* id. бор. **мүин-* id. булса кирәк, к. Räsänen 1969: 338. К. ш. ук Будагов II: 359–360; ЭСТЯ VII: 63–66.

Дерив.: **менел-ү, мендер-ү,** диал. **менгез-ү.** Төрки телләрдә (к. Будагов II: 259-260) *мин-* ~ *бин-* нигезенең тагын берничә кызыклы дериваты бар. К. **Менгәш-ү, Менге.**

**МЕҢ** «тысяча» < гом. кыпч., уйг., үзб., госм., чыгт. *миң*, нуг., каз., к.-калп. диал. *мың*, алт., хак., тув. *муң* (> себ. **мӧң,** к. Тумашева 1992: 153), угыз. (төр.) *biŋ, bin* >> чув. *пин*, бор. төрки *biŋ* «мең», *biŋa* «мең кешедән торган хәрби бүлек» (ДТС: 105) > уйг. диал. *пың* «мең», як. *муң* «йөз» ~ монг., гом. тунг. *миңган,* бор. төрки *miŋ, miŋig* «мең» маньч. *миңгаха* «бик күп вак төерле үлән» атамасы белән чагыштырыла (ССТМЯ I: 569), к. ш. ук монг. диал. *mjaŋ, mjäŋ* «мең». *Мең* < *миң* сүзенең төрле яңгырашларда таралуы аның бор. бер көчле дәүләттә-империядә еш кулланылуыннан киләча. Чаг. ш. ук як. *муң* «чик, соң» (*мең* < *миң* «иң зур сан»?). ЭСТЯ VII: 67–69.

Дерив. – саннар өчен регуляр. Төрки халыкларда *мең-* ~ *миң* ~ *мың* – *муң* дигән кабилә-ыру атамасы бар, к. Әхмәтҗанов 2002: 104–132.

**МЕР-МЕР** – подражание лёгкому мурлыканию ~ төр. *mir-mir* id. Күрәсең, гом. төрки сүз. Тат. халык телендә *мер-мер* тәкълите *мыр-мыр* тәкълитеннән бик ачык аерылса да, язучылар аларны бутыйлар (чөнки русча *мур-мур* «мер-мер» (хәлбуки *мыр-мыр* түгел!). **Мерелдә-ү** дә **мырылда-у** түгел.

**МЕСКЕН** «бедняжка; жалкий, бедный, несчастный» > чув. *мӗскӗн*, мар. кч. *мыскынь*, удм. *мискинь* id. < гар. *мискӣн* «мескен, юаш, сүзсез, карусыз» сүзеннән, тамыры *скн* «тыныч, әкрен, юаш булу» (шуннан **сәкинә** «тыныч холыклы кыз» исеме килә).

Дерив.: **мескенкәй, мескенчәк; мескенәй-ү, мескенлән-ү; мескенлек.**

**МЕШӘК, мәшәк, мишек** (Тумашева 1992: 151; ТТДС I: 316) «кошка, кот» ~ үзб. *мышык, мишиг, мушук, пишәк, пышык, пышай* (ЎХШЛ: 184, 219), кырг. *мышык*, нуг., каз., к.-калп. *мысык,* уйг. *мөшөк* id. Räsänen 1969: 337 (бүтән вариантлар китерелә). **Песи** сүзе белән гомоген.

**МЕШИК** (ЗДС: 477) «кожаный мешок», **меши** (Будагов II: 35) «эшкәртелгән сарык тиресе» ~ төркм. *мәшик, мешик* «күн су капчыгы», төр. *meşk* «тулун, тулум, тире су капчыгы» < фар. *мешк* id. Рус. *мешок* сүзеннән түгел. Радлов IV: 2114; Мухамедова 1973: 133; Özön: 524.

Без бу сүзне «рус. *мешок* белән бутамагыз» дип алдык. Су каплары, капчыклары корылыклы якларда яшәгән төрки халыклар өчен бик актуаль булган, чөнки аларны атка, дөягә йөкләү җайлы. К. **Мәшек, Мис II.**

**МИ,** диал. **мийә, мейә, мый** (ТТДС I: 304, 310), **мөйә** (Тумашева 1992: 153–154) «мозг; родничок (у младенца)» – бу сүз төрки телләрнең һәрберсендә дә гадәттән тыш вариантчыл, к. чув. *миме, мимикки, нимикки, виме, ниме, мине* (Сергеев 1971: 88), башк. *мӗй, мӗйӗ, мыйы* ~ уйг. *мәйә, мәңи, миңи*, чыгт. *миңä, миңгä*, үзб. *мийә, майна, мәйнә, мәйин*, бор. төрки (ДТС: 340, 342) *meji*, *meŋä, meŋi,* аз., төр. *beyin* һ.б. Татарчасына иң якыннары каз. *ми*, к.-калп., ком. *мий* (язылышы буенча татарча да *мий* булырга тиеш, чөнки *мийӗ* – *мисе* түгел); нуг. *мый,* к.-балк. *мыйы* мишәрчәгә якын. К. ш. ук алт., кырг., тув. *мее, мää, мээ*, як. *мэйи, мэйш* һ.б. Алтай диалектларындагы *пää, пее* «ми» фин. *pää,* венг. *fei, fö* «баш» сүзен хәтерләтә, ләкин бу очраклы булса кирәк; авест. *mazga* «ми,

мәгызь» (к. **Мәгызь**) сүзен *мий* белән чагыштыру да тәвәккәл адым; Рясянен буенча, беренче вариант *bäŋi* (Räsänen 1969: 70), к. ш. ук ЭСТЯ II: 106–107.

**МИДӘ, мигъдә** «желудок» < гар. *ми‘дä* id. (ГТРС: 257). Бу сүз **аш казаны** тәгъбиреннән мәдәнирәк.

**МИДӘ-Ү, мәдә-ү, миңдә-ү, минтә-ү** (ЗДС: 471, 479) «падать от изнурения, ослабления, голода, болезни» ~ каз., кырг. *меңде-* id., уйг. *мәнди-* «аңсыз хәрәкәтләр ясау, йокыда хәрәкәтләнү; аңгырап калу», алт. *меңде-* «ашыгып аңгыраю, нишләргә белмәү» һ.б. гом. төрки **мәңлä-* булса кирәк. К. **Миңгерә-ү.**

**МИЖА** «межа» < рус., шуннан ук. чув. *миша, мише* id. Рус сүзе һинд-евр. **med* «урталык» тамырына тоташа (шуннан бик күп халыкара терминнар ясалган).

**МИЗАН**, диал. **мисан** «весы; месяц октябрь», диал. «паутина» < гар. *мӣзāн* id. (Будагов II: 273); *Мизан көне* «Кыямәт көне» (кыяматтә адәмнәрнең гөнаһларын һәм савапларын чагыштырып үлчәү көне) – гар. *йаум äл-мӣзāн* сүзеннән калька; гөнаһларны һәм савапларны кыяматтә үлчәү тур. күзаллаулар бор. Мисырдан ук килә һәм *мизан* сүзе дә бор. Мисыр теленнән.



Кыяматтә гөнаһларны үлчәү. Бор. Мисыр рәсеме

Чаг. каз. *миза,* кырг. *мийзам, мыйзам* «мизан, көзен һавада очып йөрүчән үрмәкүч тозагы», еш кына *мыйзам* «низам, закон» сүзе белән бутала.

**МИЗГЕЛ** «один из чередующихся моментов времени; определённый момент» – гом. кыпч. *мезгил*, башк. *миҙгел,* уйг. *мәзгил* «мизгел, мөддәт, фасыл; аралык», төркм. (ТДГДС: 126) *меҙгел* «аш вакыты» һ.б. барча мәгънәләрендә гар. *мäнзил* (> тат. *мәнзил,* ГТРС: 315) сүзенә тәңгәл; мөгаен, бор. төркиләр бу сүзне метатезалап үзләштергәннәрдер: *мәнзил* > *мәңзил* > *мэзгил* > тат. *мизгел.* Будагов II: 227.

Гар. *мäнзил* (*нзл* «чиратка, рәткә тезелү; баскычлану» тамырыннан) «ямылчылык» (озын юлда ат алмаштыру, ял алу станцияләре теземе һәм бер станция) мәгъ. булган һәм аның «почта, почта станциясе» мәгъ. дә бар. *Мәнзил* > *мәзгил* күчешенә кр.-тат. *мäзги-*, каз. *мезге-* «төзәү; төртеп күрсәтү» (< бор. төрки **мэргэ-*, к. **Мәргән**) сүзе йогынты ясаган булса кирәк. К. **Минзәлә.**

Дерив.: **мизгелле, мизгелсез.**

**МИКЪДАР** «размер, количество, доза; мера, соотношение» < гар. *миқдāр* id. **Кадәр** сүзе белән тамырдаш.

Дерив.: **микъдарлы, микъдарсыз; микъдарла-у.**

**МИЛ I** «миля» < гар. *мӣл* < лат. *mille* «мең (мең сажин, мең колач)» сүзеннән бор. заманнарда таралган. Рус. *миля* – Көнб. Европадан килә.

**МИЛ II** диал. «дрожжи из хмеля» ~ башк. диал. (БТДҺ: 232) *мин* < рус. *хмель* сүзеннән.

**МИЛАДИ, миляди** «христианский – от рождества Христова (о летоисчислении)» < гар. *милāдӣ* «туган көнгә бәйләнешле», *милāд* «туган көн» ← *млд* «туу, тудыру» тамырыннан (шуннан ук **Мәүлүд**). **Милади** сүзе **һиҗри**гә каршы куела: *һиҗри* «Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күченүенә бәйле». Аннары *милади* ел кояш елы буенча, ә *һиҗри* – ай елы буенча исәпләнә.

**МИЛӘҮШӘ [миләwшә],** диал. (Арсланов 1988: 87) **меләwиш** «фиалка» ~ ком. *мелевше*, кар. *мäнäвшä*, төр. *menekşe* id. (*meneviş* исә терпентин агачының чәчәге вә җимеше) < фар. *бäнäфшä* < пәһл. *vanawša* id. (Paul: 53). Чаг. **Гөнәфшә.** Татарларда кеше исеме буларак кулланыла; әд. телдә – русчадан калькалаштырып – «фиолетовый» (төс) мәгъ. кулланылу очрый. **Мәләwши < менәwши** варианты гарәпчәдән килә (гар. моделендә ясалган фарсы алынмасы).

**МИЛӘШ,** диал. (ДС III 151) **мәләш, мүлиш**, себ. (Тумашева 1992: 152) **миләц < миләч** «рябина» ~ башк. (БТДҺ: 231 һ.б.) *милеш, мелиш,* ш ук *миҙәш* > каз. *митес*, төркм. (< тат. булса кирәк) *мелеш,* чув. (Ашмарин IX: 209, X: 79; Сергеев 1971: 98) *пилеш, пүлеш, пүлиш* ~ алт. *пеле, пäлä* һ.б. id. – фин-угор телләреннән бор. алынма, к. удм. *палязь,* коми. *пелысь*, мар. *пилзе, пизле*, морд. *пизёл, пизыль* (> тат. диал. – ТТДС I: 601 – **пизел**) ~ фин. *pihlaji* < **pislaja* «миләш». Тат. диал. (ТТДС I:

304) **миләйеш** яңгырашы фин-угор **милә̄ш* яңгырашыннан.

Дерив.: **миләшле; миләшлек.**

**МИЛЕК** «собственность, имущество; владение» > мар. (Исанбаев 1978: 30) *мелык* «усадьба» < гар. *милк* id. (ислам дөньясында киң таралган сүз) ← *млк* «ия булу», шуннан ук **малик, мәлик, мәмләкәт, мөлек, мөлкәт.** Диал. (ЗДС:478) **миләкло-ү** «куе урманлы яисә сазлыклы җирне чәчүлеккә әвереләдерү» тарихи җәһәттән кызыклы.

Дерив.: **милекле, милексез; милекче, милекчелек.**

**МИЛЕНЧӘ, милцә, мил'ча, мил'ынча** һ.б.ш. (ЗДС: 476, 478) «мельница» < рус. Күп сөйләшләрдә очрый. Моның хикмәте бар: XVI г. башлап рус хакимияте Идел-Урал регионындагы халыкларга тегермән корырга рөхсәт итмәгән. Авыл янында тегермән булса, аның хуҗасы гадәттә урыс булган. Нәтиҗәдә тегермәнчелеккә баглы күп кенә сүзләр тат. һ.б. Идел буе халыклары телләренә рус теленнән кергән (мәс., **куласа,** к.) Ләкин кире тәэсир дә булган: кайбер тегермәнчелек терминнары (мәс., **кавыз,** к.) тат. теленнән рус сөйләшләренә кереп калган. Чаг. ш. ук диал. (ЗДС: 478) **милек** «тегермәнче (рус. “мельник”)». Монда **милек, милекче** сүзләренең тәэсире бар бугай.

**МИЛЕС** диал. (трбс., к. мәкаль: *Урыс барда милес бар*) «милость, добрые отношения между людьми» ~ башк. (БТДҺ: 231) *милыҫ* (ләкин дөресреге *милеҫ* түгелме икән?) id. < рус., әлбәттә.

Мөстәкыйльлек юкка чыгу нәтиҗәсендә татар-башкортлар арасында тупаслык, шәфкатьсезлек күренешләре дә булгалаган, русларда исә андый хәлләр азрак булган булса кирәк.

Дерив.: **милесле, милессез.**

**МИЛЛӘТ** «национальность, народ, нация» < гар. *миллäт* id. Шуннан **милләтпәрвәр** «патриот», **милләтпәрәст** «милләтче» – һәр икесе фарсычадан. К. түбәндәгеләрне.

Дерив.: **милләтче, милләтчелек.**

**МИЛЛИ** «национальный» < гар. *миллӣ* id. ← *млл* «халык булу» тамырыннан.

**МИЛЛИЯТ [миллийәт]** «национальность» в значении «национальная принадлежность» < гар. *миллийäт* id. К. ГТРС: 260.

**МИЛЛЕК**, диал. (ТТДС I: 86) **бинек, пинек,** (ЗДС: 149) **винек, виник,** ш. ук **миннек, минек** һ.б. (к. БТДҺ: 231) «веник (банный)» ~ чув. *милĕк, милкĕ, мĕлкĕ* (Сергеев 1971: 88), мар. *веньык, виник, выльык, мыньык* (Гордеев I: 209), удм. *вэник, веник* id. < рус. *вейник, веник.*

Сөйләшләрдә **миллек** сүзен «печән» мәгъ. куллану бар (кайбер урманлы якларда печән урынына – миллек).

**МИЛТӘ, мелтә** (ЗДС: 476) «махсус филтә» – «фитиль», иске тат. (к. «Мирас» № 9, 2000: 18, XVIII г. шагыйре Габдессәлам шигырендә *Мылтыгымның мелтидер ташкынасы* дигәндә) **мелти** – бор. мылтык филтәсе. К. **Билтә, Мылтык, Филтә.** Элегрәк мылтык филтәсе урынына чакмак кулланганнар, к. **Чакмак.**

**МИМ** – название арабской буквы م, употребляемое в различных фразеологизмах, мәс., *әлифне күрсә, таяк дир (дияр), мимне күрсә, чукмар (чумар) дир (дияр)* – сәвәтсез кеше тур. мәкаль; *уң битеңдә миң, иренеңдә мим* (мимгә охшаш буялган төш, ш. ук көяз-кыланчык кыз тур.). К. ш. ук **Ләм-мим.**

**МИМЕЧ** диал. (ЗДС: 479) «мастер, техник» ~ башк. *мимес* id. < рус. *немец* (рус сөйл. дә *немец* «мастер» бар). Ләкин тат. диал. **мимеч** «кәрлә» бүтән сүз булса кирәк, чөнки нимесләр бер дә кәрлә түгел, буйчан халык.

**МИН** «я» – башк., хак., як. *мин*, гом. кыпч., алт., тув. *мен*, уйг. *мән*, үзб. *ман*, угыз. *бен, бән* (алт. диал. *бин*) ~ чув. *эпĕ* ~ монг. *би* id., тунг.-маньч. *би* «мин», ләкин төрләнештә *мин-* (супплетив тамыр), к. ССТМЯ I: 79. Бор. төрки *bän, men, min* (ягъни барча бүгенге вариантлар бар).

*Мин* сүзе бор. **эм-эн* сүзеннән: *эм* ашарга теләүченең үзен белдерүе (барлык телләрдә диярлек кабу-ашауны белдерүчән *ам//әм, ым* ымлыгы бар), *-эн* берлек белдерүчән морфема; угыз. *бән* – икенчел. К. **Без I.** ЭСТЯ II: 129–130 (*биз* «без» тур.); ЭСТЯ VII: 47–51.

Дерив.: **миндәге, минлек, минминлек, минчелек.** Төрләнештә **мин** нигезе нык үзгәрә – төрләнеш формалары редукцияләнә: **миңа, миңә** < **мингә**, **миңарга** < *мингарыга* (*-гары* – бор. *ҡары* «кул; тараф» сүзеннән, шунлыктан сингармонизмга буйсынмый).

**МИНӘЗ, менәз,** («Тел ярышы»: 75, 142–143) **мәнәз** «образ; образ жизни, привычка» ~ башк.

(БТДҺ: 230) *менәҙ* «холык», каз. *мĕнәз, минәз* «кәеф; холык», уйг., үзб. (ЎХШЛ: 179, 183) *минәз, мәңгиз* «характер; охшашлык», уйг. *мәңиз* «йөз; образ» < бор. төрки (ДТС: 340–342) *meŋgiz, meŋiz* «йөз; кыяфәт» ~ урта төрки, чыгт. (Мухамедова 1973: 73) *беңиз* «йөз төсе» > төр. *beniz* id. (к. **Биңзә-ү**) һ.б. ← *мәң ~ бәң* (к. **Миң**) тамырыннан. ЭСТЯ VII: 54–57.

Башк. (БТДҺ: 72) *бәҫ* «көч, хәл; кадер» << **бәңиз* булса кирәк, к. СС *tejiz* «йөз, бит» (Zajączkowski 1961: 110; анда күп кенә бүтән бор. төрки мисаллар китерелә). Хак. *миис* «йөз, бит».

Дерив.: **минәзле** «охшаш, кебек» ~ башк. *менәҙле* «сәер холыклы, чыгымчыл».

**МИНЗӘЛӘ** – название реки в Татарстане и города на ней < иске гар. *mänzil, mänzilä* «(кәрванның) тукталыш урыны; ике ямыл арасы; почта; кичү, сукай», «ел вакыты» сүзеннән булса кирәк. Чыгт. *мэнзил,* төр. *menzil* киң кулланышлы сүз, шуннан *мэнзилчи* «почтмейстер», *мэнзилханә* «почта станциясе; мотель» һ.б.ш. сүзләр ясалган (к. Будагов II: 257). Хәз. гар. *mänzil* «квартир; айның билгеле фазасы (“станциясе”)» ← *нзл* «төшү, килеп урнашу» тамырыннан. **Минзәлә** сүзенең төрки түгеллеге *-нз-* тезмәсеннән үк күренеп тора.

Тарихи җәһәттән Минзәләнең кайсы чорда «станция» булганлыгы ачык билгеле түгел. **Мәнзелханә** «сәүдәгәрләрнең тукталыш урыны» сүзе И. Гиганов сүзлегендә теркәлгән. *Минзәлә Багдадтан ерак бит* мәкале «башкаладан читтә һәртөрле законсызлыклар җәзасыз кала» мәгъ. (*Багдад* – хәлифәлекнең башкаласы булган).

**МИННӘТ** «упоминание о сделанном благодеянии; упрёки, попрёки (за неблагодарность)» < гар. *миннäт* id. ← *мнн* «кыскарту, кыска (якын) тоту» тамырыннан; шуннан ук иске тат. **мәмнүн** «бик риза, (кешедән) бик канәгать». Будагов II: 256; ДТС: 344.

Дерив.: **миннәтле** «кешегә үзенең кылган яхшылыгын исенә төшерүчән», **миннәтсез; миннәтдар.**

**МИҢ,** диал. **мим, мәң** (Тумашева 1992: 152; БТДҺ: 231) «родинка (тёмное или красное пятно на коже человека)», диал. «румяна» (*миң сөртү* «румяниться») > чув. *мин*, мар. *мең*, удм. *мен* < гом. кыпч., тув., алт., як. *мең [мәң]*, алт. диал., чыгт., төркм., уйг. *мәң* «миң; йөз төсе», хак. *миң*, алт. диал. *мӧң* «йөз, кыяфәт» ~ угыз. (кр.-тат., аз., госм.) *бәң*, төр. *ben* «миң», көрд. *beng* «кыяфәт; кәеф, мәел» һ.б. Тикшеренүчеләр манси. *бäң* «йөз, бит», коми. *бан* «йөз» ~ удм. *бам* «яңак, бит» сүзен дә төрки телләрдән дип уйлыйлар.

Төп вариант. *мәң* < монг. *мэнгэ*, бор. монг. *menge* (тибет теленнән дип уйланыла): Тибетта *мэнгэ* – «миң»нең тугыз төре аерым каралган, шулар һәм **мөҗәл** (к.) буенча кешенең язмышын юраганнар (к. Абаев Н., Жамбалдагаев Н. Тибетская медицина: как быть здоровым // Азия и Африка сегодня. № 8, 1989: 55–56; Жуковская Н.Л. Категории и символика традиционной культуры монголов. М., 1988: 94–95). *Миң* бәхет билгесе булып исәпләнгән, шуннан татар исемнәрендәге **Миңле-** «бәхетле». ЭСТЯ VII: 51–53.

*Миң* < *мәң* > *бәң* продуктив сүзьясагыч тамыр, шуннан **биңзә-ү** (к.), **миңзә-ү** «охшау», **минәз, менәз** (к.) «образ, кыяфәт, гадәт», себ. **биңзат, биңзәт** «матур» (к. Тумашева 1992: 44). К. Радлов IV: 1584, 1588, 2080, 2130; Räsänen 1969: 70, 334; Федотов I: 359.

Дерив.: **миңле, миңсез.**

**МИҢГЕ, миңке** (**аңгы-миңге** парлы сүзендә, сирәгрәк аерым да кулланыла) «бессознательный; растерянный, оглушённый» << монг. *мэңгүй, мэңигүй* «мисез» (*мэңи* «ми»), к. каз. *мәңгү* id. Икенче яктан к. **Миңгерә-ү.**

**МИҢГЕР** (ТТДС I: 306; БТДҺ: 232, һәр ике фиксация Гәйнә якларыннан) «обруч; оборка» < фар. *бäндгир* «коршау, бәйләвеч, түгәрәк кайма» булса кирәк; рус. *менкер* < як. *мäңгäр* < эвенк. *мэнгэр, мэңгир, мэңир* «курҗын; сумка; төргәк» (к. Аникин: 570) сүзеннән булуы (мәгънәви җәһәттән) шиклерәк.

**МИҢГЕРӘҮ [миңгерәw]** «оглушённый, обалделый», «гнусавый» ~ башк. (БТДҺ: 232) *миңгерәү* id. ← **миңгерә-ү** (к.).

**МИҢГЕРӘ-Ү**, **миңрә-ү, мәңгерә-ү** «оглушаться; почти терять сознание, обалдеть; растеряться вконец» > чув. *минĕре-, минре-* ~ каз. *мәңгĕре* < бор. кыпч. **мәңги-рә-* (*-рә* киңәйткече) ягъни **миңге-ү* < *мәңги-* «аңгыраю» фигыленнән, к. башк. *миңкә-ү* ~ як. *мэңий-* «шашып калу», тат. (ТТДС I: 306) **миңгет-ү**, башк. *миңгәт-ү* > чув. *минкет-* «аптырату; азаплау», күренеп тора ки, **минге- ~ *миңгә-* фигыленең йөкл. юн. К. ш. ук (ДС II: 112; БТДҺ: 232) **миңдә-ү, миңнә-ү** «хәлдән таю, алҗу» > чув. *минтев* «арыклана башлаган, йончыган», кырг. *меңнә-, меңнәәр-,* каз. *меңде-* «ару, йончу,

миңгерәү», алт. *меңде-,* (Радлов IV: 2083) *мäңдä-,* хак. *миңде-,* як. *мэңдэ* «ашыгу, кабалану, шашу», уйг. *мәңдә-* «аңсыз хәрәкәтләнү» ~ бор. монг. *mengde-* >> эвенк. (ССТМЯ I: 568–569) *мэндэл-* «шашып калу, миңгерәү» һ.б. К. ш. ук башк. *миңсе-ү* < *минчеге-ү* ← *миңче-ү, миңчек-ү* «йончу» (к. БТДҺ: 232). Барлык мәзкүр фигыльләрнең уртак тамыры итеп ком. *маң* (*маң бол-*) ~ тув. *мең, мäң,* як. *меник,* монг. *мэнег,* яз. монг. *meneng* «хәтерсезлек, миңгерәүлек; хәтерсез, миңгерәү» ~ кыт. *бань* (?) id. сүзен күрсәтергә мөмкин. К. ш. ук каз., к.-калп., төркм. *мең, мәң*, фар. *мäң* «миңгерәү хәле». *Меңгерә-ү* < *мэңгирә-* > *мәңгерә-* нигезе уйг. *мәң*, каз., к.-калп. *мең, мәң* «баң, гашиш» < фар. һ.б. *мäң* «миңгерәү: наркотик киндераш» сүзеннән дә (к. ЭСТЯ VII: 54) килеп чыга ала. К. ЭСИЯ 4: 81–82.

Морфологик җәһәттән *миңгерә-ү, мәңгерәү* сүзләренә бигрәк тә як. *мэнэрки-* «миңгерәү, тилерү, тыелгысыз кыланчыклану һәм чәбәләнү, истерикада булу (Төньяк Азия халыкларында күзәтелә торган авыру)», *мэнэрик* «истерикалы, бума авырулы, бума өянәге еш булучан» > рус. *менерики, менерячить, меряченье* (Аникин: 384–385) сүзләре охшаш. Ләкин *миңгерә-ү, мәңгерә-ү* фигыленең «истерика тоту» һ.б.ш. мәгънәләре юк.

**Миңгерә-ү** сүзе **аңгыра-у, каңгыра-у, саңгыра-у** һ.б.ш. кайбер сүзләр моделендә ясалган.

Дерив.: **миңгерән-ү, миңгерәш-ү, миңгерәт-ү; миңгерәүле.**

**МИР I [мир′]** «мир, сельская община» ~ чув. *мир*, мар., удм. *мер* id. < рус. *мир* id. (ахыр чиктә бор. ир. *миһер* < *миçра* «килешү рухы» сүзе белән тамырдаш); бу сүз Идел-Урал регионында рус административ термины булганлыктан таралыш алган. К. **Айзар-Байзар.**

**МИР II [мир-]** в составе имён (мәс., *Миргали, Миргаян, Мирхәйдәр*) иск. *мир* «башлык» < фар. *мӣр* < гар. *äмӣр* сүзеннән, к. **Әмир.** Кайбер тәгъбирләрдә **мир** русчаданмы, фарсычаданмы икәнлеген белү дә мөшкил. Будагов II: 272–273 (тәфсилле).

**МИРАН** (ТТДС I: 304) «заяц» < мар. *мераң* id.; М. Рясянен фикеренчә, бу сүз бор. монг. *tören, morin* «ат» сүзеннән (шуннан ук рус. *мерин* «алаша», к. Фасмер II: 604), бу сүз исә бор. кыт. *mra'*, бор. кор. *muraŋ* сүзе белән чагыштырыла, к. Новиков К.А. К истории и этимологии названия лошади в алтайских языках // Проблемы алтаистики и монголоведения. М., 1975: 36–55; Гамкрелидзе, Иванов: 549–550.

**МИРАП, мираб** иск. «староста в селе» < фар., түбәндә – сугарулы җирләрдә су бүлүче *мӣри аб* «су әмире». **Мирап** сүзенең (төрки телләрдә бозылган) *мурап, морап* «староста» варианты бар.

**МИРАС** «наследие» ~ чув. *мĕрес,* удм. *мерас* id. < гар. *мӣрāç* id., к. ГТРС: 262.

**МИРЕКӘЙ** (БТДҺ: 323) «припадочный; припадок» < рус. *менерики, мерячение* к. Аникин: 384–385 (асылда як. теленнән). К. **Миңгерә-ү.**

**МИРЗА** «интеллигент; мурза» к. **Морза**. К. Будагов II: 273; ГТРС: 262.

**МИС I** (ТТДС I: 305), **мисы** диал. «самка; коза, бурдюк из козьей шкуры» ~ башк. *мыс* id. > удм. *мес* ~ каз., к.-калп. *мес*, кырг. *меш* ~ фар.-таҗ. *меш* «кәҗә; кәҗә тиресе; мис» сүзеннән. Чаг. **Мәст.**

**МИС II** «металлический сосуд, кастрюля» > чув. *мис*, мар., удм. *мес* < гар., фар. *мес* «бакыр, җиз» сүзеннән: к. диал. **мискин** id. (ТТДС I: 305) < бор. *мискүн* (*күн* < *гүн* «савыт; казан», к. **Чәйгүн**); тат. диал., чув., удм., мар. *миска* рус теленнән, ләкин рус сүзе тат. алынмасы нигезендә ясалган (мәгънәсе татарчага тәңгәл).

Бор. рус. (Срезневский II: 153) *миса* «мис» ~ гот. *mes*, ним. *miss* «җиз савыт» лат. теленнән киләләр (гар.-фар. сүзләре дә шуннан бугай). Будагов II II: 227; Özön: 539.

**МИСАЛ** «пример, предмет сравнения» < гар. *миçāл* id. ← *мçл* «мисал; китерү, чагыштыру» тамырыннан, шуннан ук **Мәсәл, Мәсәлән, Мисле, Тәмсил.** ГТРС: 262.

**МИСВӘК [мисwәк]** «зубочистка, щётка» < гар. *мисwāк* (гар. сүзе үзе каяндыр алынган) «мисвәк; үзеннән мисвәк ясала торган агачсыман үсемлек» ~ башк. (БТДҺ: 242, 232) *мәсүәк, мисүбәк* үзләреннән мисвәк ясала торган үлән атамалары, каз. (ҚТДС: 237) *мәсүәк, мәсиүек* id. Нұрмағамбетов: 83.

**МИСЕК** иск., әд. «мускус» к. **Мөшек.**

**МИСЛЕ** «вроде, как, наподобие» < **мисл-ĕ** < урта төрки *мисл-и* «аның (шуның) мисалы» < гар.

*миҫл* «мисал, охшашы» ← *мҫл* тамырыннан, к. **Мәсәл, Мәсәлән, Мисал.**

**МИСРАГ** «полустишие (повторяемое два раза)» < гар. *миҫрāʻ* id., асылда «ике канатлы ишекнең бер канаты». ГТРС: 263.

**МИСЫР, мысыр** «Египет» < гар. *Миҫр* id., асылда «зур шәһәр, күп шәһәрләр, өлкә» ← «Каһирә һәм аның тирәсе».

Дерив.: **мисырлы** «Мисыр кешесе»; **мисри** «Мисырда укып кайткан кеше», чаг. **бохари**. Идиома **Мисыр бодае** «кукуруза», чаг. **Мәккә бодае** (к. **Мәккә**).

**МИХНӘТ** «тяжёлый, неблагодарный труд; трудности, испытания» < гар. *михнӓт* id. ←*мхн* «сынау, сыналу» тамырыннан. Кайбер төрки телләрдә (үзб., к.-калп. һ.б.) *мехнат* «хезмәт» мәгъ. кулланыла – бу Совет чорыннан калган (рус. *труд* сүзеннән калькалаштырылган) һәм этимологик җәһәттән дөрес түгел.

Дерив.: **михнәтле, михнәтсез; михнәтлән-ү.**

**МИХРАП, михраб** «ниша в стене мечети, указывающая направление на Каабу» < гар. *михрāб* «михрап, аванпост, авангард» сүзеннән, *хрб* «сугышчан булу» тамырыннан, к. **Хәрби**. Будагов II: 214.

**МИҺЕР** «любовь, доброта, милосердие; солнце (в поэзии)» < фар. *меһр* id. (к. Будагов II: 270), ш. ук **Митра** «кояш һәм изгелек тәңресе» (аның тур. к. МНМ: 154–158). К. түбәндәгене.

Дерив.: **миһерчелек** ~ себ. (Тумашева 1992: 151) **мигерцелек** «шәфкать, миһербанлык». К. **Айзар-Байзар, Мир.** К. түбәндәгене.

**МИҺЕРБАН** «любовное отношение, сострадание; ласковость» < фар. *меһрибāн, меһрбāн* «миһер белән караучан; кояш кебек шәфкатьле» сүзеннән (*меһр* «миһер» + *бāн* «караучы»). К. **Миһер.**

Дерив.: **миһербанлы, миһербансыз; миһербанлык; миһербанлан-у.**

**МИЧ,** диал. **пич** «печь» ~ башк. *мейес* id. < рус. *печь* id. Бу сүзнең чув., мар., удм. телләрендә булмавы гаҗәп. Безнеңчә, алар рус *мичен* үзләштермәгәннәр, иске, бор. типтагы мичләре белән яшәгәннәр (бу хакта рус язучылары, мәс., С.Т. Аксаков язып калдырган). Татарларның иске тип (туры морҗалы) мичләре **чувал, супа, уша** дип аталган (төрле җирдә төрлечә).

Тат. диал. **бичәш** (ТТДС I: 89) < рус. *печище* «өйдән аерым торган мич».

Дерив.: **мичле, мичсез; мичче.**

**МИЧӘҮ [мичәw]** «запряжка цугом», **мичә-ү** «впрягаться гусём» (к. Будагов II: 272) ~ башк. *нисәү, минсә-ү* «запрячь в пристяжку» (БҺҺ II: 183; БТДҺ: 235), тат. диал. **мичән** «ике якка җигелгән» (ТТДС II: 224), тат. әд. **мичәп** id. (бу сүз үзе бер нигез булып аңлашыла, чөнки *мичә-ү* фигыле үзе онытыла төшкән, ә бүтән төрки телләрдә бөтенләй онытылган) ~ чув. *пычав, пичев*, мар. *пецӧ* «мичәү», *пече* «мичәү аты» ~ ком. *мечев, минчав*, төркм. *мечев*, үзб. (ЎХШЛ: 185) *мычев* «буксирга алу», каз. *мешеў* «артта калган, мичәүгә мохтаҗ», к.-калп. *мешеў* «мичәү»; к. ш. ук аз. (АДДЛ: 326) *минҗәр* «кер элү бавы» (*м*-вариантларның бор. этимоны) сүзләреннән тыш, рус. *бечев, бечева* «мичәү арканы» һәм бор. төрки (Ибне Мүһәнна сүзлеге) *бәчаку* (Мелиоранский: 52) «аркан, бау» сүзе, аннары удм. *бечоло* «мичәүләп» сүзе карый, к. ш. ук абаз. *бачу* «буксир».

Бу сүзнең тамыры ачык түгел. Фар. *бӓнд* «бау, мичәү бавы (бу сүзнең мәгънәләре күп)» сүзеннән булырга мөмкин. Чаг. ш. ук **Мәчкәү.**

Тат. диал. **бичәвәй** «бурлак арканы» < рус. *бечевой* «мичәүләп» дигән сүздән (ягъни рус теленнән кире кайткан сүз). К. Аникин: 128 (сүзнең этимологиясен Дыбо *ачкан* димәкче, хәлбуки без аны А. Дыбодан күп элек күрсәткән идек, к. Ахметьянов 1989: 120–121).

Дерив.: **мичәүле; мичәүләп, мичәп** (бу сүз «мичәү аты» мәгъ. очрый).

**МИЧЕН: мичен елы** «маймыл елы» к. **Бичен**.

**МИЧКӘ,** диал. **мүчкә, мүцкә, пичкә** (Тумашева 1992: 156; ТТДС I: 341) «бочка» ~ чув. *пичке*, мар. *пэчкэ, пэцкӓ* (Упымарий: 180), удм. *бечке, бекче* id. ~ башк. *мейескә* (БТДҺ: 230), к.-балк. *бечке* id. бор. рус. *бъчка* сүзеннән куманнар заманында ук алынган.

**МИШӘ** (ЛТ I: 252), диал. **мешә** «мелкий лес; лиственный лес» ~ башк. *мөйәшә, мәшә, бешә,* аз. *мешә,* төр. *tişe*, көрд. *bĕşe, tĕşe* «урман; имән урманы; карурман» < фар. *bĕşa* «урман, карурман» < авест. *vareşa* id. (Horn 1893). Татарстандагы **Мишә** елгасы, ихтимал, **мишә** сүзе белән бәйледер.

**МИШӘР** «мишар, один из представителей татар-мишарей» ~ чув. *мишер*, удм., мар. *мешер*, рус. *мишар, мещеряк, мещера, можар* id. Бу сүз тур. шактый (йөздән артык) махсус хезмәт бар, әмма ап-ачык этимология юк. Күпчелек тикшеренүчеләр *мишәр* һәм *маҗар* < *манчар, *мәнчәр* > *мещера* сүзләрен бердәй дип баралар, ягъни *мишәр* < *мещера* (фин-угор кавеме) атамасыннан диләр. К. Ахмаров 1903; Мухамедова 1972; Махмутова; Nemeth J. Magyar und mišer // Acta Orientalica. XXV. F. 1–3. Budapest 1972: 294–299; Әхмәтьянов Р. Кайда соң син, Мишәрстан // Мирас, № 4, 2000.

**МОГҖИЗА** «чудо, чудеса» < гар. *муʻҗизä* id. ← *ʻҗз* «аптырашта калу, зәгыйфьләнү». Шуннан ук к. **Гаҗиз.**

Дерив.: **могҗизалы, могҗизасыз; могҗизачы.**

**МОГТӘБӘР** «уважаемый, видный» < гар. *муʻтäбäр* id. ← *ʻбр* тамырыннан, к. **Игътибар.**

Дерив.: **могтәбәрле, могтәбәрсез.**

**МОГЫЛ [мŏғŏл]** «круглая шишка, округлая опухоль» ~ чув. *мăкăл,* мар. *мыгыл, мыгыль* ~ фин. *tukula* id., удм. *мугыл* «тупа» ~ як. *мöгöлчöк,* монг. *мокольчок* «шар» һ.б.ш. образлы-тасвири сүзләр рәтеннән (Егоров 1964: 180), к. **Мок I, Мокай, Мокыт, Мүкләк.** Чаг. калм. *мугалзуур* < **моғулҗағур* > як. *моғолдьуор* «тупа мөгез» (Иванов 1993: 211). Шуннан (монголчадан) **Могылҗар** «Мугоджары – Уралның дәвамы булган сөзәк таулар өлкәсе» сүзе килә.

**МОК I,** диал. (Гиганов; Радлов IV: 2171; Тумашева 1992: 152) **муķ** «тупой; бессловесный, смирный; бестолковый» ~ каз. (Будагов II: 265–266) *муķ, муғ*, ком. *мукъ*, кырг. *моķоķ,* алт. *моķо* id., ш. ук. «комсыз». Гом. алтаистик ономопоэтик тамыр, к. **Мокай, Мокыт, Мүкләк.**

Дерив. (диал.) **моķа-у, моға-у** «тупаслану; тупару; аңгыраю»; **мокый** «аңгыра һәм юаш» һ.б.

**МОК II** (БТДҺ: 233) «гниль; труха; болезнь (повальная)» < гом. төрки **муķ,* к. **карамык, кызамык, сарымык** һ.б. сүзләрнең компоненты **мык < мук** булса кирәк.

**МОКАЙ, мокый, мыкый** (ДС III: 113; ТТДС I: 306, 310; БТДҺ: 233) «тупица; невежда; подхалим» ~ мар. *мокай, мукай,* чув. *мăха, муха* ~ монг. (Rona-Tas 1972: 103) *moqa* id. һ.б. (параллельләре Себер телләрендә бик күп, к. **Мүкләк**). К. **Мок I, Моктан-у, Мокыт.**

**МОКСЫЛ [мŏķсŏл], муķсум** (Тумашева 1992: 153, 155) «рыба муксун» ~ рус. (Аникин: 393) *муксун, максун, моксун* «бөкре гәүдәле балык төре (Себергә хас)» Аникин буенча, рус һәм тат. телләренә ханты теленнән кергән, рус теле аша бөтен Себер телләренә таралган. Ләкин хант. *măksəŋ, mŏxsəŋ, тиksəŋ* һ.б. «моксыл» сүзенең ясалышы – тамыры аңлатылмый. Шунлыктан тат. сүзе хант. яки рус теленнән алынган дип раслап булмый. Тат. нигез *моķ, муғ* (к.) тамырыннан закончалыклы рәвештә ясала ала (*моķсыл ~ моķсым* «аңгырарак, сантый» сүзе бар яисә була ала). К. **Мок I.**

**МОКТАН-У** (Г. Кандалый; ТТДС I: 306) «жить в нужде» ← **мокта-* фигыленең кайт. юн., ә ул фигыль исә **мокыт** сүзеннән (*мокыт-а-* > *мокта-*) дип уйларга мөмкин; чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 233) *мŏкŏра-у* «моктану».

**МОКЫТ [мŏķŏт]** «тупица, неумеха; имя фольклорного героя-тупицы, блиставшего, однако, своеобразным остроумием» ~ мар. *мокыт*, мар., удм. *могыт* ~ як. *моғотох,* монг. *моғотаķ* «мокыт; сүлпән» (к. Пекарский: 1577). Морфологик җәһәттән **мокы-т** «аңгыралык» тат. диал. **мокы-, мŏķа-, мŏға-** (Тумашева 1992: 152), кар., каз. *мŏķа-,* кырг., алт. (Радлов IV: 2121) *моķо-* ~ монг. *мохо-, моху-* ~ эвенк. *муку-* (к. ССТМЯ I: 552–553) «тупару → аңгыралану» фигыленнән (*-т* бор. сүзьясагыч кушымча), бу фигыль исә *мŏķ* < *муķ* < *моķ* (к. **Мок I**) «тупа → аңгыра» сүзеннән. К. **Мокай, Мүкләк.**

**МОН-,** диал. **мын-** – супплетивная основа местоимения **бу** в склонении «этот», а также в словах, образованных от **бу.** Русчага тәрҗемә иткәндә түбәндәге мәгъ. бирә: *моның* < *монның* «этого», *моны* < *монны* «это, этого, эту», *моңа* < *монга* «этому, этой», *моннан* «отсюда», *монда* «в этом месте», ш. ук *мондый* < *мондай* «такой», диал. *мондайын* «такой уж» һ.б.ш. Бу нигез белән тат. теле башк. теленнән бераз аерылып тора: *мон-* гом. кыпч. вариантына (*мун-*) якын, башк. *бын-* исә угыз вариʼанты *бун-*нан килә. К. ш. ук **Менә.**

*Мон* < *мона* < *муна* < *бу-на: на* бор. күрсәткеч алмашлык, ул кыпч. һәм угыз килешләр төрләнешендә дә асемантик морфема *н-* буларак (мәс., *өй-е-н-нән, өй-е-н-дә*) саклана. К. **Бу.**

**МОНАР** «туманное небо; низкие облака, мгла»; сирәгрәк «мираж» ~ гом. кыпч. *мунар* id., кырг. *му-*

*нарык* ← *мунар-* «томан йомгакланып куеру» фигыленнән; бу сүзнең «чишмә» мәгъ. дә бар: бор. төрки (ДТС: 345; Боровков 1963: 224) *mïŋar* ~ кар. *мынар*, кр.-тат. *бунар* (**Татар Бунары** – «Татар Чишмәсе» – Украинада бер шәһәрчек), төркм. *мүңер*, иске төрки ядкәрләрдә (к. Мухамедова 1973: 82) *быгар, бынар, бынаар* «кое», төр. *pınar* «зур чишмә»; сүзнең тарихи нигезе – *муна-, мана-* «болгану, кайнау», к. уйг., калм., монг. *манан* «таман», *манар-, манара-* «томанлану» (Номинханов 1975: 281). Чаг. **Мондыз.**

**МОНАСТЫРЬ** «монастырь» – хәз. әйтелеше русчадан; халык телендә *манастир, манастыр* дип сөйләнелеп килгән, к. төр. *manastır* – грек теленнән (**монах** сүзе дә шуннан).

**МОНАУ [мŏнаw]** диал., ш. ук **монаwы,** (ТТДС I: 303) **менау** «вот этот» (всегда с предметной соотнесенностью, в устной речи) < *мŏна бу(л)* (> *мона wыл*) сүзеннән. Чаг. **Анау.**

**МОНГОЛ [мангол]** «монгол» – бу сүз шундый әйтелештә русчадан алынган; саф татарча ошбу халык *могыл, маңгул* дип атала һәм монголча *мун гоол* «төп агым, зур агым» дигәннән (к. Бимбаев Р. Монгольско-русский словарь: 114), бу сүзнең бүтән этимологияләре дә бар: *Мон гоол* «Мон үзәне», *моң қоол* «үҗәт кул (колонна)», *моң коол* «куркусыз кул (колонна)», бор. төрки *tonqul* «акылсыз» һ.б. (к. Doerfer G. Name der Mongolen bei Rašid ad-Din // CAJ, v. XIV, 1–3, 1970: 68–77). К. ш. ук Будагов II: 264–265; Räsänen 1969: 340.

Тат. һәм бүтән кыпч. телләрендәге күпсанлы монг. сүзләре башлыча Чыңгыз хан империясе корылудан элек үзләштерелгәннәр: монгол һәм төрки халыклары меңьеллыклар дәвамында үзара тыгыз аралашып яшәгәннәр.

Дерив.: **монголча [мангулча]; монголлык [мангуллык].**

**МОНДЫЗ [мŏндŏз]** иск. «бурный поток, бурное общественное движение» (к. Г. Камалда *Аурупада күренә бер мондыз...*), диал. «весенняя распутица» ~ куман. (Räsänen 1969: 344) *munduz* «ахмак, куптарай», бор. төрки (ДТС: 349; Боровков 1963: 341) *munduz* «таулардан төшкән ташкын», ш. ук «шашкын ахмак». Бу сүз *балдыр ~ балдыз, йолдыр ~ йолдыз, кондыр ~ кондыз* кебек сүзләр рәтендә булса, аның *-р*лы варианты себ. (Тумашева 1992: 156) **мүндер, мүнсер (мүнзер)** «бозлы яңгыр», башк. (БТДҺ: 233) *молдор* «ташкынлы яңгыр», алт. *мундур* «туфан», төр. *muntar* «көчле агым», ш. ук хак. *мондыл-* «шаулап ташкынлану», уйг., монг. (Будагов II: 257) *мӧндүр*, хәз. монг. *мөндөр* «бозлы яңгыр» сүзләре булыр. Ихтимал, бор. төрки (ДТС: 247–248, 352–353) *тип-* «адашу, юлдан язу, азу», *тип ~ түп* «зыян, җитешсезлек тамырыннандыр. ЭСТЯ (VII: 79) авторлары *-злы* (*мондыз ~ мундуз*) вариантын белмәгәннәр бугай, анда кырг. *мөндүр* һ.б. тур. гына сөйләнелә һәм әдәбият китерелә.

**МОНЧА, монтак, мончак, мунцак** һ.б. (ЗДС: 481, 487) – күбесенчә Себердә һәм Барабада – «так, такой, такой степени». Бу формалар (әлбәттә *бу ~ мун* нигезеннән) күп төрки телләрдә очрый һәм бор. әд. төрки телләрдән үк килә, к. (ДТС: 124, 348) *bunča, munčaq*, *munday, muntay* id., id. (азаккы нигезләрдән **мондый** сүзе килә).

**МОҢ** «мелизм в музыке; печаль; вдумчимость» < гом. кыпч., чыгт., уйг., үзб., алт., як. *муң*, бор. төрки (ДТС: 124, 346, 350) *buŋ, tïŋ, muŋ* «хәстәр; кайгы; кичеренеш»; угыз телләрендә *buŋ* (төр. *bun*) «картлык; картайганлык» мәгъ. очрый; тат., башк. телләрендә мәгънә үзәге булып, «авырлыкның кичерелеше, музыкада белдерелүе» тора. Гом. төрки *муң, буң,* урта төрки, чыгт. (Радлов IV: 1809) *буң*, як. *буң, муң* «кыенлык, тыгызлык; соңгы чик», ш. ук алт., тув. *муң* «мок, мокыт» сүзләре белән бердәй булса кирәк. Будагов II: 266; Räsänen 1969: 344; ЭСТЯ VII: 83–87.

Гаҗәбрәк ки, чув. телендә **моң** ~ *муң ~ буң* сүзенең рефлекслары күренми. Монг. телләрендә дә гомумән ш. ук хәл: бур. *мунхяа-*, эвенк. һ.б. тунг. (ССТМЯ I: 557) *муңна-* «азаплау» төрки телләрдән алынмалар.

**Моң** сүзенең элекке, бор. төрки мәгънәләре хәз. тат. кайбер дериватларда, фраземаларда чагыла, к. себ., башк. (Тумашева 1961: 167; БҺҺ II: 172) **моң түгел** «бигүк кирәк түгел», тат. **моңсыз** «гамьсез» (<< бор. төрки – к. ДТС: 351 – *buŋusuz* id.) һ.б.

**Моң <** *муң* бор. заманнардан бирле (бигрәк тә бор. төрки яз. телләрдә, к. ДТС: 124–125, 350–351) бай деривациягә ия: **моңлы** (> мар. *муңло* һ.б., к. Исанбаев 1978: 45), **моңсыз** (музыкаль мәгъ.); **моңай-у, моңлан-у** (бу сүзләрдән **моң** нигезеннән сыйфат мәгънәсе сизелә); **моңла-у; моңсу;** себ. (Тумашева 1992: 152) **моңкак** «күп хәсрәт күргән» (бу сүзнең нигезе фигыльгә тартым);

крш. (ТТДС I: 308) **моңғый** «моңлы (көй)»; төрле сөйләшләрдә **моңчыл; моңдаш** «кеше хәсрәтенә керүчән». К. ш. ук БТДҺ: 233 (бүтән дериватлар да бар).

**МОРАТ, морад** «цель; намерение, желание» < гар. *мурāд* id. Будагов II: 220–221.

**МОРТ I, мурт, мурут** (Тумашева 1992: 153) «ус, усы» < үзб. < фар. *мурт, мурут* id.

**МОРТ II** диал. (Төньяк Башкортстан) «удмурт» < удм. *мурт* «кеше; удмурт».

**МОРДАР** «стервец, сволочь; мародёр; поганый» < фар. *мурдāр* id. (ГТРС: 379), *мурд* «үләксә» сүзеннән.

**МОРҖА**, диал. (ЗДС: 484, 490) **мөрҗа, мөрҗә, мөрзә, мөрйә** «печная труда», диал. «печь, ламповое стекло», күч. «отдельное хозяйство» ~ чув. *мăррье, мурье*, удм. *мурьё, мурнӓ*, мар. *мурийа, мурна, мурля, вурня* ~ башк. *мөрйә*, каз. *муржа* һ.б. < фар. *мӯрӣ-чэ* «керәч торбачык» ← *мури* «торба» > чыгт., үзб., урта төрки (к. Радлов IV: 2193) *мури* «торба, юллык, җир асты юлы» < гар. *мурийӣӓ* id. > тат. диал., башк. диал. *мөрилә*, чув. диал. *муриле, мăриле* һ.б. (Сергеев 1971: 87), мар. *мурля* «төтен торбасы». К. ш. ук тат. диал. (ДС III: 113) **мира, мийра, мыйра,** каз. диал. (ҚТДС: 242–243) *мор, морышак* «мөрҗә, юллык», уйг. *мора, мура* «труба» һ.б. Бу сүзнең кайбер вариантлары **быргы** (к.) сүзенең вариантлары белән буталган. Кайбер сөйләшләрдә (ТТДС I: 307) *мөрҗә* «җылыткыч мич, кан (торбалары, юллыклары идән астыннан үткән мич)».

**Морҗа, мөрҗә** сүзен рус. диал. *мурья* «морҗа, юллык» сүзеннән дию (Räsänen 1969: 345) дөрес түгел; рус сүзе үзе тат. сөйләшләреннән булса кирәк, к. Будагов II: 262, 263; Тимергалин: 325. К. **Мәмерҗә.**

Дерив.: **морҗалы, морҗасыз; морҗала-у.**

**МОРЗА, мырза, мурза** «татарско-башкирский дворянин, в период XVII–XX веков – прослойка татарской аристократии, приобщённой к русской культуре – из них выходили многие деятели татарского просвещения» (к. Ислам в татарском мире. Казан, 1997, статьи Р. Хайрутдинова, А. Ногманова; Ислаев Ф. Чабаталы морзалар // Идел, № 6, 2000: 20–23) > удм., мар. *мурза, мырза*, чув. *мăрса* < нуг., каз., кырг. *мурда, мырза* id. фар. *мирза* << *эмир задә*; к. **Мирза**. XIX г. *мирза* «интеллигент» һәм *морза* сүзләре мәгънә буенча аерымланган.

Кара халык телендә *морза, мырза* төрле мәгънәләр алган, к. башк. *мырзам* «әфәндем» (ироник мәгъ.), «иреңнең энесе»; кар. *мирза, мурза* «наиб, наместник», җунгар һәм калмык ханнары каршындагы түрәләр дә *мурза* дип аталган (Räsänen 1969: 345). Гомумән, *мирза ~ морза* тур. әдәбият ишле. Рус. *мурза* тур. Аникин: 396.

*Мирза > мырза > мурза > мŏрза* күчешләре алынма сүзне сингармонизмга буйсындыру, *м-* тәэсирендә иренләшү һәм татарча *ŏ*лаштыру (*у > ŏ*) процесслары белән аңлатыла.

**МОТЛАК** «обязательный», **мотлака(н)** «обязательно» < гар. *мутлақ, мутлақāн* id., id. ← *тлқ* «кискен таләп итү» тамырыннан, к. ГТРС: 279. К. ш. ук **Талак II.**

**МОХЕР [мах'эр]** «пух ангорских коз и изделие из него» < рус. < төр. < гар. *мухаййар* «кәҗә мамыгы» (*хӣр* «кәҗә») сүзеннән.

**МОХИТ** «среда; единое водное пространство земного шара, гидросфера» < гар. *мухӣт* id. ← *хwт* «урап алу» тамырыннан, шуннан ук **Ихата.** К. ГТРС: 423.

**МОХТАҖ** «нуждаться, в нужде, нуждающийся» < гар. *мухтāҗ* id., к. **Ихтыяҗ, Хаҗәт.**

Дерив.: **мохтаҗлы, мохтаҗсыз** (сирәк кулланылалар); **мохтаҗлык, мохтаҗлан-у.**

**МОЧАЛ** «двенадцатилетний животный цикл годов» к. **Бүлҗәл, Мөчәл.**

**МОШКЫ [мŏшкŏ]** диал. (ТТДС I: 307) «конопля» < морд. *мушко, мошко* id., ихтимал, рус. *мочка* id. сүзеннәндер.

**МӨӘННӘС** «женский род (в грамматике)» < гар. *мӯ'äннäс* id. Чаг. **Ниса.**

**МӨБАРӘК** «благословенный, августейший» < гар. *мубāрäк* id., к. **Бәрәкәт, Тәбрик.**

**МӨГАЕН [моғайын]** «скорее всего; наверняка; наверно» < гар. *му'аййäн* «билгеле, ап-ачык, күренеп тора» ← *ғйн* «күрү, билгеләү» тамырыннан, к. **Тәгаен.**

**МӨГАЛЛИМ** «учитель (средней школы)» < гар. *му'аллим* id. ← *'лм* «белү, беленү» (шуннан ук бик күп сүзләр, к. **Әләм, Галәм, Галим, Гыйлем, Тәгълим** һ.б.); мәәннәсе – **мөгаллимә. Мөгаллим** сүзе XX г. азакларында пассивлаша башлады.

Дерив.: **мөгаллимле, мөгаллимсез; мөгаллимлек.**

**МӨГАМ [моғам]** (Тумашева 1992: 152) «плясовой мотив, веселая музыка» < үзб., уйг., аз. һ.б. *муғам* < гом. кыпч., уйг. *мукам* «көй» – Шәрык музыкасы терминологиясендә бик билгеле сүз (гар. *муқам* «көйләү» сүзеннән) нишләптер тат. сүзлекләргә кертелмичә кала. К. **Мәкам.**

**МӨГАМӘЛӘ [мөғәмәлә]** «отношение к кому-либо; обхождение» < гар. *му'āмäлä* id., ш. ук «финанс мөнәсәбәтләре; ришвәт» ← *'мл* тамырыннан, к. **Гамәл, Гамил.** Будагов II: 240.

Дерив.: **мөгамәләле** «әдәпле, илтифатлы»; **мөгамәләсез**. Иске тат. **мөгамәләче** «менеджер».

**МӨГЕЗ [мөгөз],** диал. **нөгез,** себ. (Тумашева 1992: 154) **мөйөс, мөңөс** «рог, рога; роговой» < гом. кыпч., ләкин күп вариантлы яңгырашларда: башк. *мүгеҙ*, каз. *мөйөз, мүйёз,* к.-калп. *мүйиз*, кырг., к.-балк. *мүйүз*, кар. *мювюз, мүңүз, мүйүш, муңуз*, куман., алт. *мүүз* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 352, 354) *tügüz, tüŋüz*, уйг., үзб. *мүгүз, мүңүз* id. Шулай итеп, тат. варианты уйг. һәм бор. төрки вариантларыннан килә; угыз (*б*-) линиясендә: гаг. *буңуз*, төркм. *буйнуз*, төр. *boynuz, boyŋuz*; як. *муос* һ.б., чув. *майрака [мӧйрака]* ~ монг. *törgü* < *töŋürgü* һ.б.; нигез яңгыраш веляр **мойуңургу* «мөгез» вариантыннан булса кирәк. Räsänen 1969: 347; Будагов II: 266; ЭСТЯ II: 244; Иванов 1993: 70.

Дерив.: **мөгезле, мөгезсез; мөгезлән-ү, мөгезләш-ү** «сөзешү»; **мөгез-мөгез.**

**МӨГЕЗБОРЫН** «носорог» – русчадан калька; рус сүзен икенчеләй калькалаштырып **борынмөгез** дип тә язгалыйлар. Югыйсә бу хайванның искедән килгән тат. атамасы – **Кәркәдән** (к.).

**МӨГРӘП** диал., ш. ук (ЗДС: 130, 483, 496, 538, 540, 545) **нөгрәп, нәүрәп, бөгәрәп, пугарап, пугрип, мукерәп** һ.б. «погреб» < рус. (рус сүзе исә *гребать* «казу» белән тамырдаш).

**МӨГРӘ-Ү, мөңгерә-ү, мөгөрә-ү,** «глухо мычать (о коровах)» – гом. төрки *мүңгүрэ-, мүгүрэ-, мүүрэ-* id. исемләшкән **мөңгер <** *мүңгүр* (к.) имитативыннан. К. ш. ук (ССТМЯ I: 546–547) монг. бур. *мөөрэ-* < яз. монг. *mögöre-, mögöri-*, тунг. *моро-, мура-, мэрэ-* «мөңгерәү, ажгыру, бакыру». Федотов I: 340; Иванов 1993: 212.

Дерив.: **мөгрән-ү, мөгрәш-ү, мөгрәт-ү; мөгрәвек.**

**МӨДИР** «заведующий» < гар. *мудūр* id., к. **Даир, Идарә.**

**МӨЕШ [мөйөш]**, диал. (ТТДС I: 316; БҺҺ II: 173) **мөгөш,** себ. (Тумашева: 154–155) **мөгәш,** (ЗДС: 476, 478, 483, 488, 489) **мейеш, мийеш, мийүш, мөйәшә, мүwуш, мүгеш, мүүш > мүш** һ.б. «угол (чаще всего – изнутри) дома» ~ к.-балк., кар. *мүйүш*, кар. *мийүс, мувус*, каз., к.-калп. *мүйеш, мүйис,* ком. *мүйүш, муйус*, нуг. *муйис* id. К. ш. ук каз. *мүйіс*, кар. *мивиз, мүңүз, мювюз* «тышкы почмак, мыс», ягъни *мүйүш* «күпер», *мүйүз* «мөгез» сүзләре уртак нигездән шикелле. Чаг. *мөгез* һәм тув. *мыйыс* «мөгез» һ.б. Монда фонетик тәңгәллекләр кыенлык тудырмый, әмма, безнеңчә, «*мөгез*» белән «*мөеш*» төшенчәләренең бор. бердәйлеге шикле. Хәер, к. чыгт. (Будагов I: 266) *ул тажның кырык мүнүши бар ирди, тикмә бер мүңүшендә бер улуг гәүһәр урнамыш ирди* дигәндә **мүңүш** «мөгезчек» шикелле. К. **Мөяшә, Нүвеш** Räsänen 1969: 344–345; ЭСТЯ VII: 80–82.

М. Рясянен бу сүзне бор. **tuŋul* «болын, елга борылышы» сүзе белән чагыштыра, ләкин себ. *мөйәшә*, **мүәшә** (к.) варианты бу фикергә каршы. Чаг. **Мөңгер II.**

Дерив.: **мөешле, мөешсез; мөешлек.**

**МӨҖӘЛ, мөчәл, мочал** «удобное для совершения (чего-либо) или предопределённое время» (*мөҗәленә күрә әҗәле* «смерть придёт в своё время»), диал., иск. (ГДС II: 156) «двенадцатилетний цикл» ~ уйг. *мүчәл*, кырг. *мүчөл*, каз. *мошул*, нуг., каз. *мүшөл* һ.б. «уникеллык хайван циклы, шул циклның бер елы, чираттагы елы; мөддәт» ~ төркм. *муче* id., кырг. *мүчө-* «үзеңнең мөҗәлдәге (билгеле бер хайван исеме белән аталган) туган елыңа җитү», ягъни 12, 24, 36, 48, 60, 72, 84 һ.б. яшькә җитү (кеше шуларның берсендә вафат була дип исәпләгәннәр). К. Захарова И.В. Двенадцатилетний животный цикл у народов Центральной Азии // Новые материалы по древней Средневековой истории Казахстана. Алма-Ата 1960: 33–66; ЭСТЯ V: 91; МНМ II: 144–146. К. **Мөчәвел, Мөрчәл.**

Каз. *мүшел* «нәкъ утыз көнлек унике айдан соң яңа елга кадәр калган берничә көн» (тат. «нардуган атнасы, нардуган көннәре)».

**МӨҖАВИР** «завхоз мечети; охранник святых мест и памятников» < гар. *муҗāwир* «изге урыннарда, мәчет янында хөҗрәдә яшәүче», төп. мәгъ. «күрше». Шунысы кызыклы ки, чувашларда *мӑчавӑр* – иң югары рухани дәрәҗә, хәз. көндә рәсми «милләт башлыгы».

**МӨЗАКӘРӘ** иск. «(научное или учебное) обсуждение спорных вопросов» < гар. *муӡāкāра* id. – **зекер** сүзе белән тамырдаш. Будагов II: 220.

**МӨЗӘККӘР** «мужской род (в грамматике)» < гар. *муӡāккāр* id. ← *ӡкр* «ир булу», шуннан ук *ӡакир* «ир» һ.б.

**МӨЙТӘН** – название рода у сибирских татар и башкир ~ башк. ш. ук *муйтел, муйтен, мыйтан,* каз. *татар мүйтен,* к.-калп. *митан, муйтан,* үзб. *муйтан, муйтән.* Бу атама тур. төрле фаразлар бар: гадәттә бу сүзне фар. *муй тан* «йонлач тән» сүзеннән дип аңлаталар (һәм чыннан да Үзбәкстандагы *муйтән*нәр йонлачлыгы белән аерылып торалар), ләкин чынлыкта бу атама **матиен** «угарит кабиләсе» сүзеннән дигән фикер бар (Толстова 1984: 173–178). Угаритлар Ассириядә (хәз. Төньяк Гыйракта) яшәгәннәр, бик йонлач булганнар (чаг. рус. *ассирийская борода*).

Төрки фольклорда **Мөйтән би** дигән хөкемдар тур. төрле сөйләкләр бар. Шуларның берсе – башкортларның үсергән кабиләсе вәкиле **Мөйтән**нең Чыңгыз ханга бүләк алып барып, Җаек һәм Сакмар үзәннәрен биләүгә ярлык алып кайтуы турында (к. Башкорт халык иҗады, II, Өфө, 1997: 15–64–165, 386). Мөйтән бинең нәселе – шәҗәрәсе дә төрлечә тәгърифләнә: *Мөйтән би Туксаба угланы*, Мөйтән би бәҗәнәкләрдән чыккан, Мөйтән би Майкы би белән дус (кайбер риваятьләрдә дошман) булган, диелә. Мөйтән бигә багышлап макталлар, эпик әсәрләр иҗат ителгән. К. Әхмәтҗанов 2002: 9; Әхмәтҗанов 2009: 44–45, 49–50. Тарихи әсәрләрдә Мөйтән би тур. мәгълүмат юк диярлек.

**МӨКӘЧ,** себ. (ЗДС: 483) **мөкцөк** «слегка горбатый»; «опухоль на суставах» К. **Бөкәч, Бөкрәч.**

Бу сүзнең дериватлары активрак кулланыла: **мөкәчлә-ү, мөкчәй-ү** ~ себ. (ЗДС: 488) **мүксәй-ү** «бөкчәю»; чаг. диал: (прм.) **мөкриҗлән-ү** «(буыннар) кәкерәеп шешү» < *мөкрәчлән-ү ~ бөкрәчлән-ү.* Чаг. түбәндәгене.

**МӨКЛӘШКӘ, мүкләшкә** «выпуклость вместо рогов», (ЗДС: 483) «выступающие концы брёвен в грубом срубе» (очевидно, переносное значение). К. **Муклашка, Мүкләк.**

**МӨЛАЕМ [мөләйем, мөлайы̆м]** «мягкий в обращении с людьми, миловидный» < гар. *мулāйим* id. ← *лйм* «йомшак булу». ГТРС: 366.

Дерив.: **мөлаемлык; мөлаемлан-у.**

**МӨЛДЕ, мөлек,** (Будагов II: 253; ТТДС I: 309, 318; БТДҺ: 230, 235) **мөнөк, менек; мәле, меле, мөлө, мөлөкәй** «мулёк (рыбка-наживка)» ~ рус. *моль, мольва, мулёк* һ.б. (күп вариантлар, к. Фасмер II: 648–649).

**МӨЛДЕРӘМӘ [мөлдөрәмә]** «переполненный (жидкостью – о сосуде)» ← **мөлдерә-ү** (к. **Мөлдер-мөлдер**).

**МӨЛДЕР-МӨЛДЕР [мөлдөр-мөлдөр]** имитатив течению слёз, а также мерцанию в своей полноте (о капле, о переполненных жидкостью сосудах) ← **мөлт** (к.). Уйг. теле оригиналь: *мөлдүр* «барлык, җәен яуган боз: үтәкүренмәле, сөзген» *мөлдүрлә-* «мөлдерәү».

Дерив.: **мөлдерә-ү, мөлтерә-ү** – гом. кыпч., к. каз. *мөлдӗре-*, кырг., алт. *мөлтүре-* «мөлдерәү, чиста булу (су тур.)».

**МӨЛЕК [мөлөк]** иск. «владение, государство; империя» (к. Будагов II: 253), «имущество (которым владеют по закону), поместье, земли» < гар. *мулк* id., к. **Милек, Мөлкәт.**

**МӨЛКӘТ** «(всё) достояние, (всё) имущество», иск. «право владения» < гар. *мулкāт* id. **мөлек** < *мулк* сүзенең җыйма күп. формасы ← *млк* «биләү» тамырыннан, к. **Милек.**

Дерив.: **мөлкәтле, мөлкәтсез; мөлкәтлән-ү.**

**МӨЛЛӘТ,** диал. (ТТДС I: 302) **мелләт** «срок действия родительских обязанностей; родительские обязанности» < яз. **мөһләт, миһләт** «кичектереп тору, мөддәт» < гар. *муһлāт* id., к. ГТРС: 436.

Фразема: **мөһләт бир-ү** «бурыч түләүне кичектерү, гомумән – бурычлының хәленә керү»; **мөлләтне (мөһләтне) үтәү** «аталык-аналык бурычын үтәү».

**МӨЛТ: мөлт-мөлт** – имитатив (образное слово) о переполненных слезами глазах, а также о переполненных сосудах ~ гом. төрки, монг., тунг. *мэлт: мэлт-мэлт* id. К. ССТМЯ I: 537. К. **Мөлдер.**

**МӨЛТӘЛ: мөлтәл батыр** «имя героя сказок – богатырши» (к. ТХИ: Әкиятләр II: 211–215) – татар халкында киң таралган балалар әкияте: батыр йөрәкле кызый җиде абыйсын эзләп китә; чуваш халык эпосында шундый сюжетта кызый түгел, малай. Татар әкияте – элекке зур эпостан гадиләштерелгән һәм тарихи мәгънәсе югалган вариант. Чаг. **Мөйтән.**

**МӨМКИН** «можно, возможно; допустимо; возможный, допустимый» < гар. *мумкӣн* id. *мкн* «урын, төш; мөмкин булу» тамырыннан, шуннан ук иске тат. **имкян** «хәл, рәт», к. ш. ук **Мәкян.** Дерив.: **мөмкинлек**; **мөмкинчелек.**

**МӨМТАЗ** иск., кит. «выделяющийся чем-либо определённым», «шакирд, выделяющийся активностью, выдумкой и т.п.» < гар. *мумтāз* id. ← *мтз* «привилегияле булу; аерылып тору».

**МӨН I** диал. (к. Будагов II: 255) «бульон, суп», башк. *мөн* «туклыклылык; сөтле аш; рәт» < *мӱн, мөң, тїп* < бор. төрки (ДТС: 352) *тӥп, bӥп* «аш, өйрә», «акча байлыгы».

**МӨН II** (ЗДС: 476; башк.), **мен** «дефект; скрытый порок, недостаток» ~ ком. *мин*, каз. (Будагов II: 255) *мын*, кырг. *мун, мүн*, төркм. *мүүн, муйн*, бор. төрки (ДТС: 352–353) *тӥп*, (Мухамедова 1972: 82) *бүн* id., бор. төрки (Clawson: 347) *bӥіп* id. һ.б. ЭСТЯ VI: 88–89 (тат., башк. тулысынча китерелмәгән, *муң* «моң» сүзе белән чагыштырыла: безнеңчә, бу раслама исбатка мохтаж).

Дерив.: **мөнсез** «шелтәсез». Бүтән дериватлар **мен** вариантында.

**МӨНӘҖӘТ, мөнаҗат** – жанр духовных песен, духовное песнопение (один читает и поет текст, другие хором поют рефрен); «исповедь, исповедальный рассказ» (к. Будагов I: 255) < гар. *мунāҗāт* id., төп мәгъ. «котылу җыры» ← *нҗw* «котылу» тамырыннан.

**МӨҢГӘЧӘЙ, мүңгәцәй** (Тумашева 1992: 156; ЗДС: 489) «трясогузка» – *мөңгә, мөнкә, мөңке* «артын сикертүчән» сүзеннән иркәләү-кечерәйтү формасы *мөңгә-чәй ~ мөңгәчәк* дигәннән (кошчыкның русча атамасы да шул мәгъ). К. **Мөңке, Мөңке-ү.**

**МӨҢГЕ, меңге** (ТТДС I: 304) «деньга, деньги» << бор. төрки *төңип*, яз. монг. *tönggün* (> хәз. монг. *мөңгө*) «көмеш; акча» < кыт. *tĕn gün* «саф көмеш» (ССТМЯ I: 570), к. ш. ук бор. төрки *тӥп* «акча, капитал», рус. диал. *мунга* «акча, сәмән» (Аникин: 394). Гомумән, бу сүз киң таралган.

**МӨҢГЕР I: мөңгер-мөңгер [мөңгөр-мөңгөр]** – имитатив глухому мычанию (коров) ~ гом. төрки, монг. *мүңгүр, мүгүр, мүүр ~ мөөр* id. К. **Мөгрә-ү**.

**МӨҢГЕР II [мөңгөр]** «ограждение с горловиной, куда пригоняли дичь при облавной охоте» < чыгт. *мүңгүр* (Котби) id. Чаг. **Моң.**

**МӨҢКЕ [мөңкө]** «уросливый, норовистый» ~ каз. *мөңкі* id. монг. *мүнгүй* «менгесез (ат тур.)» булса кирәк, к. түбәндәгеләрне.

Дерив.: **мөңкетәк** < *мөңкечәк* «егып төшерүчән; яшь ат» < **мөңке-чәк.**

**МӨҢКЕТ [мөңкөт]** (Тумашева 1992: 156; ЗДС: 483) «пескарь» ~ каз. (ҚТДС: 243, 247) *мөңке* «сазанның кечкенә төре», *мүнгір,* төркм. *мүңкүр* «Каспий диңгезендәге бер балык төре». **Мөңке-ү** «сикеренү (хайван, балык тур.)» сүзе белән баглыдыр, к. **Мөңке.**

**МӨҢКЕ-Ү, мөңге-ү, мөнгет-ү мүңге-ү** (Тумашева 1992: 153–154, 156; ЗДС: 483, 488) «встать на дыбы или вскидывать зад, чтобы сбросить седока, всячески сопротивляться (о лошади)» ~ каз. *мөнкі-* id. ← монг. *мүнгүй* «менгесез, мендермәүчән (ат. тур.)» ← *мүн-* «менү». Чаг. бор. төрки (ДТС: 535 һ.б.) *bїп-, тїп-, тӥп-* «күтәрелү, менү» һ.б. К. **Мен-ү.**

Дерив.: **мөңкүчән** «егып төшерүчән (ат. тур.), **мөнгетчәк** id. К. югарыдагыны.

**МӨРӘҖӘГАТЬ [мөрәҗәғәт]** «обращение (к кому-либо)» < гар. *мурāҗā'ат* id. ГТРС: 381.

**МӨРҖӘ** к. **Морҗа.**

**МӨРИТ** «мюрид, адепт духовного главы – муршида» < гар. *мурӣд* id.

Дерив.: **мөритлек.**

**МӨРТӘТ** «отступник, ренегат» < гар. *муртӓд* id. Будагов II: 222; ГТРС: 380.

Дерив.: **мөртәтлек, мөртәтлән-ү.**

**МӨРЧӘЛ, мөлчәр, мөрчил** (Сборник материалов… 1941: 159, 175, 305) «порядок следования боевых отрядов» ~ чыгт. *мүрчал* «кирмән башнясы, дежурдагы каравыл», кырг. *мөлчөр* «гаскәр җыелырга тиешле урын һәм вакыт» һ.б. < **бүлҗәл** (к.). Будагов II: 262.

**МӨРШИТ** «муршид, духовный глава организации мюридов» < гар. *муршид* id., төп мәгъ. «алдан баручы, юлбашчы». ГТРС: 380. Мөәннәсе – **мөршидә** «оештыручы хатын-кыз».

**МӨСАФИР** «человек в пути; человек на чужбине (по делам)» < гар. *мусāфир* id., к. **Сәфәр.**

Дерив.: **мөсафирлык; мөсафирханә;** сөйл. **мөсафирчы** «командировкага җибәрелгән кеше».

**МӨСЕЛМАН [мөсөлман]** «мусульманин» < фар. *муслимāн* < гар. *муслим* id. ← *слм* «тыныч һәм акыллы булу», шуннан ук **ислам** (к.), **сәламәт** һ.б. Dobr. II: 512.

Дерив.: **мөселманлы, мөселмансыз; мөселманлык.**

**МӨТӘВӘЛЛИ [мөтәwәлли]** «член совета прихода мечети» < гар. *мутӓwӓллӣ* «дини тәшкиләтләрнең багавылы», төп мәгъ. «хириссыз». Будагов II: 209.

**МӨТӘК**, диал. (ТТДС I: 302) **метәк** (ТТДС II: 222, 232) **метеч, мәтәч**, башк. (БТДҺ: 236) **мөтик, мөтәк** «бита, большой козон; альчик вообще» ~ чув. *мӗтӗç* id.; себ. (Тумашева 1992: 154) **мөцөк адышу** «төз атуда ярышу», чув. *мăчăк* «мөтәк». Чаг. рус. *битюг, битюк* «зур гәүдәле ат токымы; ат ашыгы» (этимологиясе ачык түгел, фаразлар гына бар, к. Фасмер I: 164), чаг. ш. ук рус. *биток* «аткы кузна».

**МӨФ** (К. Тинчурин) «даровой; бесплатно; демпинг» < фар. *муфт, мофт, мүфт*, (Будагов II: 244) *мӳфг*, көрд. *mift, mifte* id. Уйг. *мупт, мупты* ~ каз. *мут, муфт* id.

**МӨФТИ** «муфтий, региональный глава мусульман» < гар. *муфтӣ* «хәл кылучы» (сыйфат мәгъ.), «фәтва бирүче». К. **Фәтва.** Будагов II: 244.

**МӨХАЛЬ** «затруднительно; затруднительный» (в значении «невозможно, невозможный» в деликатном выражении); «нелёгкий; маловероятный» < гар. *мухāл'* id.

**МӨХӘРРИР** «редактор» < гар. *мухаррир* id., «хаталардан азат, хөр итүче», к. **Хөр.**

Дерив.: **мөхәррирлек; мөхәрририят** (< гар.).

**МӨҺЕР [мөһөр]** «печать, штемпель», иск. «девственность» < фар. *мүһр, мүһре, муһра* «мөһер; изге яисә шифалы йомры таш; мөһерле (кашлы) йөзек; дисбе»; бу сүз төрки телләрдә төрле мәгънәләр алган, к. башк. **мөр** «нарат күркәсе» (БТДҺ: 235). К. Будагов II: 270.

Дерив.: **мөһерле, мөһерсез; мөһерлә-ү.**

**МӨҺИМ** «важный, требующий серьёзного отношения» < гар. *муһимм* id. ← *һмм* «кирәкле, әһәмиятле булу», шуннан ук к. **Әһәмият, Һиммәт.**

Дерив.: **мөһимлек.**

**МӨҺЛӘТ** «отсрочка» к. **Мөлләт.**

**МӨЧӘ**, диал. (Троянский һ.б., иске язылышта) **мөҗә,** (Тумашева 1992: 153–154) **моца, мөйә,** (ЗДС: 484) себ. **мөхцө, мөцә, мөцәй** «часть тела, конечность; таз; доля, кусок из туши, сваренный на пару» < гом. кыпч. *мүчә*, к. алт., чыгт. *муча, мүче, мүчӓ,* уйг. *мүчә* (> нуг., каз., к.-калп. *мүше, мүшө,* башк. *мөсә*), кырг., төркм. *мүчө,* хак. *мөчү*, як. *мүсэ, мүһэ* ~ бур. *мүсэ*, хәз. монг. *мөч* ~ сол. (тунг., к. ССТМЯ I: 560) *мусу* id. Себ. тат. **мөцәй,** башк. *мөсәй* бор. вариант түгел, ә фар. *мүчә-и* «мөчә итеп билгеләнгән» сүзеннән (гомумән, *мүчә* «мөчә» сүзе ир. телләрдә киң таралган һәм ул төрки телләрдән алынган булса кирәк), к. көрд. *тиçе* «өлеш; эш хакы».

**Мөсә** < *мүчә* төрки, монг. һәм тунг.-маньч. халыкларында киң таралган бор. традицион гадәт – суелган киекнең яки терлекнең бер өлешен беренче килгән кешегә, хәергә, мәгънәсе төгәл билгеләнгән бүләккә бирү белән баглы. Тулаем пешерелгән терлек итен утыз ике, унике, егерме дүрт яки сигез **мөчә**гә аерулар билгеле (корылтайда катнашкан «делегатлар» санынча). К. Будагов II: 262, 264.

**Мөчә** сүзенең этимологиясе ачык түгел, тик шунысы бар: бик ихтимал, бу сүз *оча < уча < угуча* (к. **Оча**) сүзе белән баглыдыр: *муча* һәм *ууча* сүзләренә махсус уртак мәгънәләр хас. Ихтимал ки, *муча, мүчә* < **муг-уча* (парлы сүз). Ш. ук *мөчә*

< *мөчәл* (~ *мӧчүл*) була ала: *унике мөчә* төшенчәсе бар, чаг. **мөчәл** – уникееллык, төр. *tüçe* «мөчәл, бүлҗәл» К. түбәндәгене.

**Мөчә** сүзе хәз. әд. телдә сирәк кулланыла һәм деривациясе дә юк. Кайбер төрки телләрдә *мүчеле-,* төркм. *мүчөлә-* «суелган терлекне бүлгәләү (уникегә бүлү)» һ.б. дериватлар очрый. ЭСТЯ VII: 90–91.

**МӨЧӘВЕЛ [мөчәwĕл]** иск. (К. Насыйри) «двенадцатилетний (*или* шестидесятилетний?) цикл < могн. **töčegül* (булырга тиеш), чаг. тув. *мөчүлге* (монда тат. *ө* белән тув. *ө* бер үк авазны белдермиләр, бөтенләй үзгә авазлар өчен кулланылалар), яз. монг. *möcelge, mөcilgen* һ.б. «мөҗәл». Әлбәттә **мүчә** < **мӧчә* нигезеннән, чаг. **мөчә.** К. **Мөҗәл, Мүлгәр.**

**МӨШЕК, мисек, миск** «мускус» < фар. *мүшк,* гар. *миск* id. < лат. *мускус* «тычкан; җофар» (русча аны «мускусная крыса» дип тә атаганнар, чөнки лат. сүзе рус. *мышь* «тычкан» белән тамырдаш). Ә. Бируни (Соч. IV: 810–811) язганча, «мөшек [Урта Азиягә] Һиндстаннан һәм төркиләрдән китерелә», мөшекнең яхшысы – Кытайныкы, аннары татарныкы, кыргызныкы». **Мөшек** сүзе белән *мускул* сүзе (лат. *muskula* «тычканчык») тамырдаш.

**МӨШКӘ,** (ТТДС I: 304) **мешкә** «деревянный желобок для засыпки зерна на мельнице; желобок для воды» ~ башк. (БТДҺ: 236) *мөшкә, мөшкәт, мөйәшә* id. – ачык түгел. Рус теленнән кебек, ләкин рус. тәңгәл сүз табылмады. Чаг. төр. *müšker* «кратер».

**МӨШКӘЧ, мөшкәш** (миш., ЗДС: 484–485) «рахит; рахитик», «боль в животе; согнувшийся от боли в животе» < фар., таҗ. *муче-и-кäҗ* «кәкрәйгән арка (мөчә)». К. **Мөчә** һәм **Кәҗ.**

Дерив.: (Рамазанова 2013) **мөшкәчле** (шунда *мөшкәчне* дәвалауда кара халык ысуллары тур.).

**МӨШКЕЛ, мөшкил** «трудно; трудный, неясный, запутанный» > мар. *мүшкүл* id. < гар. *мушкил* id. **Шәкел** белән тамырдаш.

**МӨШТӘРИ** кит. «участник сделки; подписчик (газет, журналов); подписант (договора); планета Юпитер» < фар. < гар. *муштäрӣ* id. ГТРС: 428.

**МӨЭМИН [мө’мин]** «правоверный мусульманин» < гар. *му’мин* id., төп мәгъ. «ышанычлы кеше, имин зат», **әманәт, иман, имин, тәэмин** сүзләре белән тамырдаш. ГТРС: 429.

**МӨЯШӘ [мөйәшә], мүәшә** (Тумашева: 154–155; ЗДС: 483, 488) «угол дома» < **мүгәшә*. Себ. тат. сөйләшләрендә генә теркәлгән бугай. **Мөеш** (к.) белән баглыдыр, ләкин ясалышы (азактагы *-ә*) аңлашылмый.

**МУАФИКЪ** «соответственен; соответствующий» < гар. *муwāфиķ* id. ← *wфķ* «тәңгәл; тәңгәл булу» тамырыннан, шуннан ук **Иттифак, Тәүфикъ.**

**МУГ, муķ** иск. «тупой и жадный» (Будагов II: 264–265) ~ каз., к.-калп., үзб. *муķ* id. К. **Мок, Мокыт.** Ләкин *мук* сүзе фар.-таҗ. *муг* «Зәрдүшт дине рухание, маг» сүзеннән дә була ала.

**МУЕЛ [муйы̆л]** «черёмуха (в особенности её дерево)» ~ каз. *мойыл*, уйг. *мойул* id. монг. сүзе булса кирәк, к. бур. *мойһон,* монг. *мойсун* < иске монг. *tojulsun* «муел». К. ш. ук **Мыер.**

Дерив.: **муеллы; муеллык.**

**МУЕН [муйы̆н]** «шея» < нуг., каз., к.-калп., алт., хак. *мойун*, гом. угыз, уйг., к.-балк., ком., к.-калп. диал. *бойун*, үзб., каз. *бойын, буйын* id. – бор. төрки **моой* [> як. *моой,* чув. *муй, мăй, мый, мыйă* (Сергеев 1971: 86)] «муен» сүзеннән (*-н* – тән әгъзасы атамаларына ялганучан кушымча, к. **борын, буын, куен, ирен, яурын**), к. ш. ук госм. *бой* «муен» (шуннан *бой* «буйсынган кабилә»). К. тунг.-маньч. *мойе, моңон* < *монгон* һ.б. «муен» (ССТМЯ I: 546). Ихтимал, бу сүз тәүдә «муенса» мәгъ. булгандыр. ЭСТЯ II: 80–82.

**Муен** продуктив сүзьясагыч нигез, к. регуляр ясалмалар – **муенлы, муенса, муентык,** аерым нигезләр – **Боендырык, Буйсын-у, Муенчак.**

**МУЕНЧАК** «ошейник» – *муен* сүзеннән, әлбәттә. Ләкин **муен** сүзенең тәүге мәгъ. «муенчак» булырга мөмкин, ягъни **муенчак** «кечкенә муен».

**МУЗИКӘН, мызикән, мызукан** (ТТДС I: 310), **музекен** (БТДҺ: 237) (Г. Тукайда *Кулларында музикән, Шул музикән уйнаганда Ишми ничек түзәйкән?*) «гармун» > мар. *музекан, музыкан,* удм. *музикан, мүзкан* id. (Исанбаев 1978: 45, Насибуллин: 128). Күрәсең, бу сүз тат. телендә формалашкан аерым лексема булган һәм рус. диал.

*музыкаль* (XIX г.) «гармун» сүзеннән. Бу сүз исә *музыкальный инструмент* тәгъбиреннән кыскартылган.

**МУЙНАК** «белошейка (о собаках)» < *муены ак.*

**МУКЛАШКЫ, муклашка** [*к*] «кулак (как орудие наказания)» < чув. *муклашка* id., к. **Мөкләшкә, Мүкләк.**

**МУКЧА** «сумочка» к. **Букча.**

**МУЛ** «обильно, обильный» < гом. кыпч., уйг., үзб. *мол,* угыз., чыгт. *бол* «мул; киң; батыр» (к. Радлов IV: 1669) ~ фар., көрд. *bol* «җитәрлек; җитте», һинд. *mol* «байлык, хак, кыйммәт» – халыкара киң таралган сүз, к. ЭСТЯ II: 184–185.

Дерив.: **муллык; му́лча; муллан-у.**

**МУЛАТА,** (ТТДС I: 309) **муллата** диал. «грязь» < гом. төрки (к.-балк. һәм хак. телләрендә фиксацияләнгән) *балата, малата, маллата* «тире иеләү өчен сасы боламык» сүзеннән булса кирәк (чув. теле аркылы), к. **Мандаша.** *Мулата* сүзе рус. *болото* сүзеннән дип тә уйлыйлар, ләкин ул тәкъдирдә *-лл-* геминациясе аңлатылмый.

**МУЛКАЧ** диал. «заячий мех» < чув. *мулкач, молкач* «куян» < тат. диал. (< миш.) *малкач* «мал баласы, малкай; колын» булса кирәк. Ләкин к. ш. ук эвенк. *мулкан* «яшь болан», *мулкачан* «яшь болан үгезе», *малкан* «яшь кыргый болан», *муннукан* «куян» (ССТМЯ I: 555, 556). Федотов II: 362 (удм. теленнән дип исбатламакчы, ләкин удм. телендә охшаш сүз юк).

**МУЛЛА** «мулла – глава прихода и мечети» > мар., удм. *молла* «каһин» < гадәттә гар. *mäwlā* «төбәктәге хуҗа, вәлилек иясе» сүзеннән дип аңлатыла һәм мәгънәсе дә туры килә: Төркиядә һ.б. *молла* «судья»; ләкин *мулла* сүзенең вариантлары мәзкүр аңлатмага сыеп бетми: иске тат. *мелла, менла* «яшь мулла; муллалыкка кандидат». К. ш. ук иске тат. (< фар.) *дәмулла, дәмула* < фар. *даи мулла* «мулла-практикант; мулла ярдәмчесе; дин укытучысы» (Будагов I: 550), *мәүлана* «муллалык итмәгән мулла; галим мулла, абруйлы интеллигент». Төркиядә – Җәләлетдин Руминең кушаматы (татарларда *мәүлана* дип бик укымышлы изге хатыннарны да атаганнар), шуннан тат. < төр. **мәүләви** «Җ. Руми тарикате кешесе»? «дин галиме» һ.б. К. ГТРС: 346.

Иске рус. *молна* < тат. диал. *молна* «мулла, закон укытучысы» (к. Будагов II: 251) сүзеннән булса кирәк.

**МУЛЬ** (ТТДС I: 309), **мүл** (БТДҺ: 238) «перевозка леса по рекам (особенно небольшим) самотёком, не составляя плот» < рус. *моль* id. Башк. *мөлөм* id. (БТДҺ: 235) < рус. *мóлем* «муль белән». Рус сүзе үзе фин-угор телләреннән булса кирәк. Чаг. ш. ук рус. *моль* > башк. *мөлө* «вак балык», удм. *моля* «комкорсак балык».

**МУНЧА**, диал. **монча, мынча, минча** «баня» ~ башк. *мунса,* чув. (Сергеев 1971: 89) *молча, мулча, мунча*, мар., удм. *мунчо* id. < иске рус. (Срезневский II: 159) *мовьница* «мунча» сүзеннән күптәнге алынма; төрки һәм бүтән күрше телләргә (нуг., каз., к.-калп. *монша*, үзб., уйг., төркм. *монча*) **мунча** сүзе татарчадан кергән булырга тиеш, тик мар. диал. (Саваткова: 92) *момоца, номоца* турыдан-туры рус. *мовьница*дан. ЭСТЯ VII: 73–74.

**Мунча** сүзенең фонетик вариантлары бик күп; бу хәл рус телендә дә вариантлар (паронимнар) булуы белән аңлатыла; алт., хак. *мылча* < рус. диал. *мыльница* булса кирәк (Егоров 1964: 135), к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 154) **мыльца, мульца, муйца, муйылца, мольца**. Бу вариантлар *мунча* < болг. *мун чан* «зур чан» сүзеннән дигән фаразны кире кагалар. К. Räsänen 1969: 337; Тараканов: 91.

Болгар һәм Казан дәүләтендә мунча (гарәпчә) *хәммам* дип аталган.

**МУНЧАК** «ожерелье из монет», «бусы; коралл, жемчуг» ~ башк. (БТДҺ: 237) *мунсак* id. < бор. төрки (ДТС: 346–348), уйг. *топčиq, типсиq, топсаq* id., ш. ук «бөти, әмәйлек» ~ госм., төр. *bončиq* > рус. *бунчук* «үзенә ат (тәүдә – як) койрыгы тагылган томар (жезл)» (к. Фасмер I: 242), куман., чыгт. *bипčиу* «байрак төре» ~ калм. *montsag* «бизәлештә чуклар, шарлар һ.б.» ← (Ramstedt 1935) бор. *тип, топ* «кыйммәтле таш белән бизәлгән байрак төре». Бу сүз халык аңында **муенчак** белән буталган, хәлбуки **муенчак** һәм **мунчак** икесе ике тамырдан.

Рус. *мунчак* «ясалма асылташ» тур. Аникин: 395 (бик тәфсилле, шунда ук библиография).

**МУНЧАЛА,** диал. **мунцала** «мочало» ~ чув. *мунчала*, мар. *мочыло, мацала* (Иванов, Тужаров: 127), удм. *мучоло, минчала*, башк. диал. *муйсала, муйчала* (БТДҺ: 236) < рус. *мочало* > тат. *мутча-*

*ла* > *мунчала* (рус. шартлаулы *ч* татарча *-тч-* яисә *-нч-* дип кабул ителгән, чаг. ш. ук *калача* > *каланча*); бу сүзне **мунча** сүзенә нисбәт итү (Тараканов: 91) дөрес түгел. Шулай ук удм. *бун* «мунчала» сүзе дә үзе генә *мунчала* сүзенә нигез була алмый.

**МУРДА** «морда (рыболовная снасть)» ~ башк. *мурҙа,* чув. *мурта, морда*, мар. *морда*, удм. *мурда* id. рус. теленнән, рус теленә исә фин-угор телләреннән, к. удм. *мерда*, фин. *merta* «мурда» (Toivonen II: 341). К. ш. ук **Нәрәтә.** Фасмер II: 653; Аникин: 391 (шунда ук әдәбият).

**МУРТ** «ломкий, хрупкий; дряблый» ~ чув. диал. (Ашмарин VII: 274) *морт* «ку», *морт-* «муртаю» < гом. кыпч., к. ком., кырг., каз., к.-калп. *морт,* алт., төркм., хак. *порт* id. < **борут* ~ **морут* булса кирәк, к. **Муры-у.** Чаг. **бурсы-у.** К.-балк. *морт* «күгәрек» икенчел мәгъ. К. түбәндегене.

Дерив.: **муртай-у.**

**МУРТЫК** (ДС I: 135; БТДҺ: 237) «ломкий, хрупкий» ~ чув. (Ашмарин VIII: 274, 320) *мортак, муртак, мăртăк* ~ алт. *бортык*, алт. диал. *портык* һ.б. id. ← *морт-* > *мурт-, борт-* «черү, күгәрү, муртаю» → башк. (БТДҺ: 237) *муртығыу*, чув. *муртăх-*, алт. *бортых-* «череп муртаю» (**мурт-у** → **муртык-у** сүзләре тат. телендә дә булырга тиеш). К. ш. ук шор. (Радлов IV: 1269, 1272) *порд-* «зәгыйфьләнү, картаю; муртаю», алт. диал. (тел.) *порты-* «күгәрекләнү». Räsänen 1969: 341; Федотов I: 363 (мар. *мортияш* «муртаю» татарчадан ди). ЭСТЯ VII: 118–120.

**МУРЫ-У, мурай-у, мура-у** (ЗДС: 487) диал. «стать трухлявым и обрасти мхом» ~ каз. (ҚТДС: 242–243) *мору* «черү, уалу, караю», «агачны бөгемләү өчен суга салып кайнату». Чаг. манси. *tur-, tor-* «уалу» ~ һинд. *murr-* «уалту» һ.б., к. Абаев 1981: 85.

**МУС: мус кортка** «персонаж, соответствующий Бабе-Яге (в сказках)» – *мышыз* ~ *маңыз* (к. **Маңгыз**) сүзе белән тамырдаш булса кирәк. Чаг. ш. ук себ. һәм әстр. татарларында *мустан* ~ *мастан* ~ үзб. *мустон* ~ калм. *мустан* id. Монг. телләреннән бугай. МНМ II: 189. Чаг. т. ук **Масан.**

**МУСАВИ** кит. «иудейский, еврейский; иудей» < гар. *мусāwӣ* id. Муса пәйгамбәр исеменнән, ягъни Мусага ияручe дигәннән. Будагов II: 263.

Муса пәйгамбәр (рус. *Моисей*, яһ. *Мошеһ* һ.б.) яһүди, христиан һәм мөселман дини риваятьләрендә бик гыйбрәтле хәлләрдә күрсәтелгән.

**МУСЛИН** «муслин, тонкая ткань» < төр.-гар. *муҫӯл-ин* «Мусул (Мосул) шәһәрендә эшләнгән», к. Будагов I: 264. К. **Мәүсүл.**

**МУСТАН** (карчык) к. **Мәстән.**

**МУТ** «жуликоватый» ~ чув., удм., мар. *мут* «хәйләкәр; мут», удм. *мот* «шаян, наян» < рус. *мот* «типтереп йөрүче байбәтчә» сүзеннән. Федотов I: 363. Тат. телендә бу сүз продуктив сүзьясагыч: **мутлану, мутлашу, мутлык.**

**МҮК,** диал. **нүек** (Бәетләр 1960: 80), **мөх** (Тумашева 1992: 154) «мох» < рус. (бор. рус. *мъх* id., шуннан *мшистый* «мүкләнгән» һ.б.).

Дерив.: **мүклә-ү > мүклән-ү** (күч. мәгъ. дә бар); **мүкләч; мүкле.**

**МҮКӘЙ, мүкә,** диал. **мөкәй, бүкәй, бүкә** (БТДҺ: 62) «на четвереньках» (**мүкәйлә-ү, мүкәлә-ү** «ходить на четвереньках» активрак кулланыла») ~ **мүкәй-ү, бүкәй-ү** фигыле дә бар ~ алт. *бӧкӧй-, пүкäй*, як. *бӧкӧй-, бүгүй-* ~ бор. монг. *bokei-* «иелү; мүкәю» (Поппе 1938: 123), уйг. *мүқ-,* каз. *бӧкӧңде-*, кырг. *бӧкӧңдӧ-* «иелеп йөрү», *бӧкӧң* «бөкре» һ.б. *бӧк, бүк* (к. **Бөк**) тамырыннан. Чаг. **Бөкчәй-ү.**

Дерив.: **мүкәйлә-ү**, (ТТДС II: 231) **мөкәчлә-ү < мүкәчлә-ү.**

**МҮКЛӘК,** диал. **мукла, муклак** (к. ТТДС I: 308) «комолый, безрогий» ~ чув. *мăкка, мăкла*, мар. *мугыла*, удм. *мугло, муглок, моклок,* башк. диал. (БТДҺ: 232) *мӧғӧлӧй, мөгөлөй* ~ каз. *мокул* (к. Радлов IV: 2121) ~ маньч. *мохоло, моқто, моқту* (ССТМЯ I: 552–553) «мүкләк» ~ рус. *моклок* «сөякнең беленеп чыгып торган төше», бур. *мухар* «мүкләк», *муха-муха* «мүкләк баш белән сөзү хәрәкәтенә тәкълит» һ.б. *мук* «тупа» тәкълиди тамырыннан. К. **Мокыт, Мөкләшкә, Муклашкы.**

Гомумән, *мүкләк* < *мүкел-әк* (*-әк* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы) булырга тиеш, сүзнең ясагыч нигезе **мүкел* < *муқыл* < гом. төрки *моқул* булып чыга. К. чув. *мăкăл, мукал, муклак* «түмгәк, кискә, төпсә, тубыр», *мăклăк* «тупа очлы», *мукка* «мүкләк сыер», *муклака, муклашка* «тубыр, зур шеш, йодрык» (> тат. диал., башк. диал. – БТДҺ: 236 –

**муклашка** «киез тыгынчык, йодрык»), к. Ашмарин VIII: 257–303.

**МҮКТӘРГЕ** «лунь; вид цапли», башк. (БТДҺ: 238) «кобчик» (?) ~ үзб. *бўктарги* id., каз., к.-калп. *бөктерги*, төркм. *бөкдерги*, яз. монг. *bögtürge* «бөктәр, аркага асылган капчык» (мүктәрге кошы сазда балык сагалап басып торганда аркасына биштәрләп зур капчык таккан затка охшаш). К. **Бөктәр.**

**МҮЛЧӘР** диал. (кас., себ., к. Тумашева 1992: 196) «мера; вес; пропорциональность; срок» ~ чыгт., фар. һ.б. (Будагов I : 289) *мулҗар, булҗар* «гаскәрләрнең җыелу пункты һәм яуга чыгу вакыты» ~ чыгт. һ.б. (Будагов II : 262) *мурчал, мурчил* «кальганың, кирмәннең турасы – (гадәттә унике) башнясы; гаскәрләрнең урнашу, парадка тезелү, билгеле пункттан үтү тәртибе» тамырдаш. Гадәттә *бүлҗәл ~ бүлҗәр* һ.б. монг. телендә *болҗа-, болҗу-* (> як. *болҗуо-*) «вакытын һ.б. билгеләү» сүзеннән дип карала. Бу сүз бер караганда монг. *бол-* «табу, булдыру» тамырыннан шикелле. Ләкин *мурчал-* варианты сүзнең тамыры **бөреҗ** (к.) < *бурҗ* түгелме икән дигән фикергә китерә. **Бурҗ** сүзенең «кальга почмагы» һәм «унике тарафның берсе» һ.б., һ.б. мәгънәләре бар ич. Унике тигез тараф почмакларда тоташа. Шуннан *бурҗа- ~ мулҗа-* «почмаклар ясау, почмакларга тукталу фигыле, шуннан (бор. төрки яки бор. монг. әд. телләрендә) *булҗар ~ булҗал ~ мулҗар* «тукталыш, тукталыр (урын, почмак)» сүзе ясалган дип уйларга нигезләр бар. Рус. ул тукталу почмаклары «стоянки зодиакальных звезд» дип атала.

Арытабан **унике мөчә** (тән әгъзалары) тәгъбире дә шуннан килә, шуңа нисбәтле (ягъни *мөчә < мөчәл*) дип уйларга нигез бар. Космологик күренешләрне кешенең тән әгъзаларына тәңгәлләү бор. кешенең фикерләвенә хас нәрсә икән. К. **Мөчә, Мөчәл.**

Бу «унике ай ~ уникееллык цикл ~ унике мөчә ~ унике кальга мөеше (башнясы)» системасы төрки, монголларга, **бөреҗ** сүзенең мәгънәләренә караганда., Якын Шәрыктән шактый бор. заманнарда (мәс., манихеизм дине аша) кергән булса кирәк.

К. ш. ук каз. *мөлшер* «чама», кырг. *мөлчөр* «билгеләнгән (барып җитәсе) урын» һ.б.

**МҮЧКӘ I** сөйл. «злая, много лающая, низкорослая собака» < рус. *моська* id. **Мүчкә** дип гадәттә күп тиргәшүчән хатыннарны да атыйлар.

**МҮЧКӘ II** (ЗДС: 489) «низкорослый» (рус. *моська* сүзенә сылтанылган), себ. (туб., Будагов II: 261) **муцькя** «мүкләк» ~ каз. *мүшкө* id., *мөшке* «савым сыер». Будагов «корова невзрачная, но дающая много молока» ди. **Мүчкә I** белән чагыштыру һич тә кабул ителерлек түгел, безнеңчә. Мүкләк сыерлар тәбәнәк булалар, ләкин нишләп аларны этләр белән чагыштырырга мөмкин? **Мүчкә II** сүзенең рус теленнән алынган булуы да ихтимал, ләкин үзгә бер рус сүзен – этимонын эзләп карарга кирәктер. Ихтимал, русларда сыерларга еш кына бирелә торган (шаян) *муза, музька* (*му-у* тәкълиди сүзеннән) кушаматыннандыр. Татарча да **мүчә** дигән сыер кушаматы бар (**түчә-мүчә** диләр).

**МЫГЫРДА-У** «ворчать» – **мыгыр (мыгыр-мыгыр)** тәкълиди сүзеннән, бу сүз исә тәкълиди *мың* тамырыннан (*ык-мык, мык-мык*, чаг. ш. ук *бык-бык* ямьсез сөйләү тәкълите).

**МЫЕК [мы̆йы̆к]** «ус, усы» > мар., удм. *мыйык*, чув. *мăйăх* < гом. кыпч. *мыйык,* үзб., уйг. *мийиқ,* угыз. (ш. ук тат.) *быйык,* аз. диал. *быық* < бор. төрки (ДТС: 105) *bïδïq*, як. *бытык, мытык*, шор., алт. диал. *мыйгак, мыйнак* < *мыйы-ак* id. фигыльдән ясалган нигез булса кирәк. Ихтимал, каз., к.-калп., кырг., үзб. *мурт, мурут* «мыек», нуг. *мурт* «мыек очы, бөтереп, очлайтып куелган мыек» сүзе дә *мыйык* белән тамырдаштыр. Кайбер төрки телләрдә «мыек» мәгъ. аерым сүз юк – бу төркиләрнең бер өлеше мыексыз-сакалсыз булуы белән аңлатыла. Тикшеренүчеләр, шуңа нигезләнеп, *мыек* < **мыд-ык* сүзен фар. *муй* < *муд* «мыек, төк» сүзе белән чагыштыралар, к. тунг. (эвен.) *бодуруқа* «мыек». *Мыйык* сүзен бор. монг. *bužigir* «бөдрә» сүзе белән чагыштыру (к. ССТМЯ I: 103, ЭСТЯ II: 304), безнеңчә, дөрес түгел.

Дерив.: **мыеклы, мыексыз; мыеклач, мыекчан.**

**МЫЕР [мы̆йы̆р]** диал. «орех, орешник» ~ чув. *мăйăр, мăйăрă, мурă, муйăр, мурьă* (Сергеев 1971: 86) ~ венг. *mogyoro* «чикләвекчек», к.-балк. *маяр* «чикләвек». **Муел** (к.) сүзе белән чагыштырыла (Рясянен), ләкин к.-балк. варианты бор. кыпч. чагыштыруны шик астына куя. Тат. сүзе чувашлар белән күрше яшәгән якларда гына кулланыла.

**МЫЖ** – подражание гулу множества насекомых в одном месте (**мыж кил-ү** «шуметь, жужжать, кишеть – о насекомых и т.п.», күч. – о лю-

дях), шуннан **мыжгы-у** «мыж килеп тору, туктаусыз сукрану», ш. ук **мыжлау, мыжылдау** һ.б. К. **Мыжык I.**

**МЫЖЫК I** «брюзгливый; брюзга; копуша» < диал. *мыжгык, мыжгак* id. *мыжгы-* фигыленнән; бу сүзләрнең вариантлары күп: башк. диал. *мызык* «капризлы», *мыжмык, мыжбыр, мыжгыр, мыжмыр* һ.б. (БТДҺ: 238). К. **Мыж.**

**МЫЖЫК II** диал. «вид рыбы (чёрного, тёмного цвета, легко ловится, но её не едят) – **мыжык I** «әкрен хәрәкәтләнүчән» сүзеннән булса кирәк. Чаг. ш. ук башк. *мыжы* ~ кырг. *мыжың*, үзб. *миҗиқ* «рахитик».

**МЫЗ-У,** себ. (Тумашева: 157) **мыц-у (мыцы-у**?) «жеманно слегка улыбаться» ~ хак. *мызай-* id. Гомумән, *мыз* тамырының дериватлары төрлечә: башк. *мызла-у* «балку, ялтырау, ялтырап күренү» (*мызлат-у* «күзләрен ялтырату»), каз. (Будагов II: 227) *мызыл-* «ялындырып елмаю», хак. *мызыцна-* id. К. як. (Räsänen 1969: 338) *tiči-* «көлемсерәү» ~ монг. *misige-* «шат кыяфәттә булу». Алт. эпосында (Маадай-Кара: 65):

*Тӧзӱ бӱрлӱ бай агажым*
*Мызылаган мында турды*

Ягъни «түзе бөреле [тоташ яфраклы] *байагачым* нурланып алдымда торды».

**МЫЙК** – имитатив звукам, издаваемым мелкими животными, пойманными зайцами, а также ворчанию бессильных.

Дерив.: **мыйк-мыйк, мыйкыл-мыйкыл; мыйкылда-у, мыйкылдат-у, мыйкылдык.** Бу сүзләргә охшаш имитативлар чув. телендә күп: *мăйк, мăйăк* «мыйк, чыйк»; *мăкалтат-, мăйкăлтат-* «мыйкылдау», *мăкăл, мăкăлт, мăкăльт* куян һ.б. хайваннарның кискен хәрәкәтләренә, тыпырчынуларына тәкълит һ.б. Башк. *мыйҡылда-* «ялтырау».

**МЫЙМЫЛ: мыймыл-мыймыл** – имитатив движениям, претендующим на грациозность, а также угодливость – бу сүз гом. кыпч. характерда, әмма сүзлекләрдә теркәлми, тик кырг. *мыймыңда-* «кымтырыклау» теркәлгән.

Дерив.: **мыймылда-у; мыймылдык**. К. ш. ук диал. **мимелдә-ү** ~ чув. *мимĕлтет-* «ирен кыймылдату».

**МЫК** иск. (Будагов II: 272) «гвоздь» ~ нуг., каз., кырг. һ.б. *мық* < фар. *mīx̱* > төр., ком. *мых* «кадак, зур кадак, чөй, винт, болт һ.б.». Бу сүздән төрки телләрдә күп кенә сүзләр ясалган, к. **Мыкты, Нык.**

**МЫКТЫ** «крепкий, здоровый, крепко сбитый» ~ башк. (БТДҺ: 238) *мыҡлы* id. < кырг., каз. *мықты* «кадаклы, кадак белән беркетелгән, какшамас» (~ төр. *mıhlı* «ныклы, кадакланган») сүзеннән, **мык** (к.) нигезеннән.

Бор. заманнарда кадак сирәк кулланылган (аз булган), шунлыктан «кадак белән беркетелгән > аеруча ныклы» мәгъ. күчеше пәйда булган.

**МЫЛҖЫ, ымылҗы** (ТТДС I: 310, 526) «угодливый; податливый; мягкотелый, слишком легкий (о тесте)» – онопоэтик (образлы) сүз булса кирәк, һәрхәлдә шундый тамырдан: *мылҗы* < **мылчы* (сүз уртасындагы *-җ-* < *-ч-* була) ← ***мыл**. Шуннан башк. (БТДҺ: 238–239) *мылый-у* ~ *мыййыл-у* «тиктәскә елмаю; ярамсакланып елмаю-көлү» ~ як. *мылай-* «киң елмаеп тору (күренү)»; каз. *мылжы-у*, кырг. *мылҗы-* «кирәксезгә сөйләү» < *мылчы-у* id. (булса кирәк); каз. *мылжың, мылжың* «мәгънәсез ягымлы, ялагай» ~ к.-калп., кырг. *мылҗың* «күп сөйләүчән, лыгырдык, телдәр». К. **Мылҗыра-у, Мылҗы-у.** Чаг. **Мызы-у.**

**МЫЛҖЫРА-У** диал. «излишне размягчиться», **мылҗы-у** (к.) сүзенең *-ра-* морфемасына «кинәйтелгән» формасы. Чаг. **Мәлҗерә-ү**, ш. ук **былчыра-у** һ.б.ш.

**МЫЛҖЫ-У** диал. «сильно размягчиться; быть мягкотелым» < *мылчы-у* (к. **Мылҗы**).

Дерив.: **мылҗык** «йомшак холыклы, еларга гына торган».

**МЫЛТЫК** «ружьё; винтовка», иск. «фитильное ружьё» ~ гом. кыпч., төркм. *мылтық*, уйг., үзб. *милтиқ,* алт., тув. *мултық, мултуқ,* алт. диал. *пултуқ* һ.б. id. (Радлов IV: 2198, 1379; Joki 1952: 222–223), иске тат. (XVIII г.) *милтек, милтик* бор. чыгт. *милтä оқ, милтäли оқ* «филтәле ук» сүзеннән: бор. мылтыкта тәүдә *милтә, мелтә* – филтәгә ут токандырылган, ул филтәне мылтык көбәгендәге тишеккә якынайтып, дарыны шартлатканнар һәм ядрә көбәктән атылып чыккан. Тат. **мылтык ату** тәгъбиреннән күренгәнчә, **мылтык**ның төп мәгънәсе «атылган нәрсә» (ягъни «ату коралы» түгел!). Атыла

торган нәрсә исә – **ук.** Бу фикерләрне, асылда, Рясянен (Räsänen 1969: 337) дә әйтә. К. **Билтә, Милтә, Филтә.**

Гаҗәп рәвештә күрше чув., мар., удм. телләрендә *мылтык* сүзе юк, «мылтык» мәгъ. *пычал* < рус. *пищаль* сүзе кулланыла. ЭСТЯ (VII: 93–94) **мылтык** тур. озын мәкаләдә бу сүзнең рус. *винтовка* белән багланышын карый (*винтик* сүзеннән түгелме икән, имеш).

Тат. **агач мылтык** тәүдә, ихтимал, арбалетны белдергәндер. Рус. *мултык, мултых* (Себер төрки телләреннән) тур. Аникин: 394.

Дерив.: **мылтыклы, мылтыксыз; мылтыкчы** («аучы» мәгъ.).

**МЫНДЫР** (А. Троянский 1860: 95–130) «гриб; толстый, с телесами» (о человеке) ~ чув. *мăнтăр* id. мар. *мындыр* «гамьсез; муллык, байлык», *мундыра* «йомгак», *мундыр лу* «бот сөяге» ~ башк. (БТДҺ: 239) *мындырыҡтай* id., кар. *мантыр* «юан, симез»., кырг. *мандыр* «эре» ~ төр. *tantar* «гөмбә», бор. уйг. *мантар суви* «гөмбәле су» (бор. текстта, татарчалаштырыбрак әйткәндә «Рәсүл: ул мантар суы, кем бу чүлмәктән эчеп торыр, минем гыйлемдән аңа өлеш тияр», к. Насилов 1974: 88). Ул **мантар суы** – наркотик булган булса кирәк, шуннан чыгып *мантар* < фар. *бäңдар* «наркотик (составында наркотик булган)». Наркотик гөмбә төрләре күп кенә (к. **Паңгы**).

Әйтеп үтү кирәк ки, Мөхәммәт пәйгамбәрнең наркотиклар белән эш итүе бик шикле: ул һәртөрле исереклеккә каршы булган.

Тат., чув., мар. *мындыр* сүзенең формалашуына, ихтимал, чув. *мăн*, бор. төрки *мун* «зур, юан, дәү» сүзе катнашлык иткәндер. К. **Мантар.**

**МЫРАК** диал. (ДС I: 135) «морошка (ягодное растение)» ~ башк. (БТДҺ: 239) *мыраҡ* id. < *мŏраҡ* < манси. *морах* id. чаг. ш. ук эвенк. *мороңо, бороңо* (ССТМЯ I: 547) id. Рус. *морошка* ← **морох* id. К. Аникин: 392.

**МЫРАУ [мы̆раw]** – подражание ворчанию кошки (*мыраула-у* «громко ворчать – о кошке», *мыраужан* «кот», *мыраубикә* «кошка») – чыгышы ачык аңлаешлы тәкълиди сүз (*мыр-мыр иту* һ.б.). Әд. телдә **мер-мер** белән бутала.

**МЫРКЫЛ-МЫРКЫЛ** – имитатив хрюканию: «хрю-хрю». Дерив.: **мыркылда-у; мыркылдык.**

**МЫРЫЛДА-У** «сердито ворчать» – песиләрнең ачуланып (ләкин бик кычкырмыйча) аваз чыгаруыннан, *мыр-мыр (мырыл-мырыл) килүеннән*. Вариантлары күп.

Дерив.: **мырылдаш-у; мырылдык.** К. ш. ук әд. ясалма **мырмырый.**

**МЫС [мы̆йс]** «мыс, вдающееся в водное пространство часть суши» – фәнни (географик) телдә русчадан, әлбәттә, әмма рус теленә бу сүз – рус диал. *маяс, мыс* ~ Себер төрки (тув. һ.б.) *мыйыс* << бор. төрки *tüŋüz* < **tüŋürgü* «мөгез» сүзеннән, аның «озынча табигый объект» мәгънәсеннән булса кирәк, к. Аникин: 382, 398. Каз. *мүйiс* «мыс; борылыш, почмак» дип бирелә (~ тат. **мөеш** id.). Чаг. себ. (Тумашева 1992: 157) **мыска карату** «(мөгезгә карап?) фал ачтыру» (мөгез сырлары буенча юрау гадәте булган).

**МЫСКАЛ** «золотник, мера веса в 4,68 грамма; одна десятая единицы *ҡадаҡ*» > чув. *мăскал*, удм., мар. *мыскал* < гом. көнб. төрки, фар., көрд. һ.б. *мысҡал, мисҡал* id. гар. теленнән таралган, семит телләрендәге *çҡл, шҡл* «көмеш» тамырыннан. Әмма үлчәү микъдары үзе шумерча *дарик* диелгән берәмлеккә барып тоташа икән, к. Velidi: 123–124.

Дерив.: **мыскаллы; мыскалла-у, мыскаллан-у.**

**МЫСКЫЛ** «издевательство» > мар., удм. *мыскыл*, мар. диал. *мускул,* чув. *мăшкăл* < гом. кыпч. *мысҡыл*, ком. *мысғыл* id. < тат. диал. **мускар, мыскар,** кар. *мысхыр, мысхыра* «мәсхәрә» сүзеннән (Будагов II: 231; Егоров 1964: 131) үзгәргән булса кирәк; икенче версия буенча, гар. *мудхик* (> тат. *мозхик* к. ГТРС: 271) «мәзәкче» сүзеннән (к. Räsänen 1969: 337), ләкин, ул тәкъдирдә *-ыл* каян килә? *Мыскыл* < *мыскыр* Шәрык мәзәкчеләренең кыпчаклар арасына килеп тамаша күрсәтеп йөргәнлегенә дәлил. К. ш. ук **Мәрәкә, Шамахай.** Рус. *скоморох* «бор. профессиональ мәзәкче һәм клоун» сүзе дә гар. *мәсхәр-мәрәкә* яисә *сахир-мәрәкә* (*сахир* «сихерче, фокусчы») сүзеннән дигән фараз нигезсез түгел.

Дерив.: **мыскыллы, мыскылсыз; мыскылла-у, мыскылчы.**

**МЫШАЯК** «мышьяк» > мар. *мушньак* (Упымарий: 126) < бор. үзб. *муш йағы* «күсе (үтерү) даруы» сүзеннән (*йағ* «май; мазь; дару», тәбегә куел-

ган май тур. әйтелгән булырга мөмкин). Рус сүзе татарчадан булса кирәк.

**МЫШ (мыш-мыш)** – подражание сопению ~ чув. *мăш (мăш-мăш)* (к. Ашмарин VIII: 317, 324–325), мар., удм. *мыш (мыш-миш)* ~ гом. төрки *мыш* id.

**МЫШКЫЛДА-У** «сопеть, шумно дышать (от физического напряжения)» гомуми модель буенча **мыш** тәкълиди сүзеннән, к. чув. *мăшăлтат-*, *мĕшĕлтет* «мышкылдау; мыштырдау» һ.б. (чув. телендә бу бапта сүзләр күп кенә). К. **Мышык-мышык.**

Дерив.: **мышкылдаш-у, мышкылдату; мышкылдак.**

**МЫШТЫМ, моштым** «тихоня (который отнюдь не глуп или забит)», «тихонько»; иск. (М. Гафурида …*хәзрәт үзенең моштымнары белән…*) «скрытный телохранитель знатного лица» < үзб. < фар. *муштум, муштук* id. ← *мушт* «йодрык», к. Redhouse: 801–802.

**Мыштым** сүзе Урта Азиядә укып кайткан шәкертләр теленнән таралган. **Мыш, мушт** «йодрык» каз. актив кулланыла (**муштла-у** «туктау» бездә дә бар).

**МЫШТЫР (мыштыр-мыштыр)** – подражание медлительной и мелкой физической деятельности, работе ~ чув. *мăштăр (мăштăр-мăштăр)* id. Ш. ук **мыштыр** «әкрен кыймылдаучан (кеше)» һ.б.

**МЫШТЫРДА-У** «медленно (сопя) что-либо делать; медлить с работой» ~ чув. *мăштарта-* id. **Мыштыр** сүзеннән. К. ш. ук **мыштырдавык, мыштырдык** ~ мар., удм. *мыштырдык,* чув. *мăштăркка, мăштăртăх* «мыштырдык кеше» һ.б.

**МЫШЫК**, диал. **лышык: мышык-мышык**, диал. **лышык-лышык** – имитатив тихому плачу с сопением; чув. телендә *мăшăк-мăшăк* бу хәлдә селкенеп хәрәкәтләнүне белдерә.

**МЫШЫР** диал. «ягоды рябины, рябина» ~ иске тат. **мычыр** (Будагов II: 212), себ. **мӧчӧр, мыцыр** (Тумашева 1961: 167, 169) «миләш; шадра», башк. *мышыр, мышар* (БҺҺ II: 118) «миләш». Ачык түгел, фин-угор *пизыл* «миләш» сүзе белән бердәй булуы ихтимал, к. **Миләш.**

**МЫЯ [мы̆йа]** диал. (ЗДС: 488) «солодковый корень» ~ нуг., каз., кырг. *мыйа*, ком. *мийа*, чув. *мăйан* ~ төркм., төр. *bиyan, boyan* һ.б.ш. id. К. ЭСТЯ VII: 91.

# Н

**Н** авазы тат. телендә анлаутта башлыча алынма сүзләрдә очрый һәм кайбер очракларда бор. төрки *й*- авазыннан килә.

**НАБАТ** «тревожный бой барабанов, колоколов, набат» < рус. *набат* id. ~ бор. рус. (Срезневский II: 261) *набат* «зур бакыр барабан» < төр. (госм.) *нäвбäт* id. < гар. *нäwбäт* (> тат. *нәүбәт*) «каравыл алмаштыру» сүзеннән (к. **Нәүбәт**): каравыл алмаштыру моментында зур барабаннар кагылган – бу тантаналылык өчен эшләнгән, к. Zenker: 921 (тәфсилле аңлатма); Будагов II: 294; Фасмер III: 34.

**НАГАЙБӘК** «этнографическая группа крещёных татар» – шул исемдәге авыл (Башкортстан, Бакалы районы) исеменнән булса кирәк, к. Никольский 1920: 286; Нагайбаки 1991. Гомумән, **Нугай** (к.) сүзенә тоташа. К. Шакуров: 119–120.

**НАГАЧ, нагачы, нагаҗы** (Хәлфин), себ. **нәгәзе** «сородич» (так называют родственников матери её дети, а также детей женщины, вышедшей замуж в другую деревню, в её родной деревне) ~ чыгт. *нагачы*, бор. төрки *паүаӡ̌у*, башк. (БТДҺ: 242) *нагасы,* каз., к.-калп. *нагашы*, бор. монг. *паүаčи* id. (Räsänen 1969: 348) ~ хәз. монг. *нагац*, бур. *нагаса* id. Бу сүзне **анага ача* сүзеннән кыскарган дип уйлыйлар, к. бор. төрки *аčа* (ДТС: 4) «канкардәш». Будагов II: 288; Рамазанова 1991: 160.

**НАДАН** «невежда, неуч» < фар. *нäдāн* «белексез, белемсез» (*нä* юклык префиксы, *дāн* «белү». Гом. көнб. төрки *надан*, үзб. *нодон* id. Тат. теленнән күрше чув., фин-угор телләренә дә (диалекталь лексикага) кергән.

Дерив.: **наданлык; наданлан-у.**

**НАДУЛАП** (Г. Газиз; Будагов II: 276) «тротуар (в старой Казани – дощатый)», себ. **набулат** «пóлок» < бор. рус. *надолобь, надолбы* «баганалар өстенә салыңган юл, озын күпер» – *долбить* «багана кагу» сүзеннән, к. Фасмер III: 38.

**НАЖДАК** «точильный камень, наждак» < бор. төрки (ДТС: 360) *nižday* «беләү». Рус теленә каян кергәндер – билгесез. Төрки сүз дә каяндыр алынма.

Дерив.: **наждаклы, наждаксыз; наждакла-у.**

**НАҖАГАЙ, наҗакай, нәҗәгай, назагай, назгай** (БТДҺ: 343), **нажағый** (ЗДС: 492), **нацағай, начағай** (Тумашева 1992: 158) «зарница, сполохи», «надоедливый дух» (ТТДС I: 320) ~ каз. *найзағай* (Радлов III: 636) id. бор. XIII г. монголларында теркәлгән *натигай* (Марко Поло), *начигай* (монгол текстлары) «җир-ана» рухы атамасының дәвамы; *натигай* бер үк вакытта яшен алиһәсе дә (ул җирдән чыга һәм җиргә керә дә; шунлыктан бор. төркиләр яшен аткан җирне изге дип санаганнар, авырудан терелер өчен шунда ятып аунаганнар). Хәз. бур. диал. *нитүгэн* вариантыннан чыгып, *натигай* сүзен **Үтәгән** (к.) сүзе белән бердәй дип карыйлар (Банзаров: 266–269; МНМ II: 674–675). Каз. варианты **найза***, нәйзә* «кыска сөңге, сәгать угы» сүзенең контаминацион тәэсирендә барлыкка килгән. *Наҗагай уйный, наҗагай кебек* тәгъбирләре татарларда әле күптән түгел **наҗагай** җанлы кемсә, рух итеп күзаллануын күрсәтә. Бор. монг. сүзенең монгол халыкларының үзләрендә онытылып та татарларда (дөресреге – нугайларда булырга тиеш) һәм казакларда саклануы монголларда ламаизмның көчәю белән аңлатыла. К. **Аҗаган, Назыгыш, Сазаган, Үтәгән, Ялагай.**

**НАҖУМ, нәзюм, нәз'ум, нәҗим** (ДС I: 142; ДС III: 120; ТТДС I: 318, 320, 322) «навоз, назём» < рус. *назём* «ашлау тиресе» (*на землю* «җиргә» тәгъбиреннән). **Нәҗүм балыгы** – ашалмый торган кара балык төре.

**НАЗ** «нега» (*назлы* «нежный» – только о человеке), «жанр песни раставания с родными местами у рекрутов и невест» (К. Насыйри әкиятләрендә, к. ш. ук Исәнбәт Н. Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре // КУ, № 11, 1966: 141–151) < фар. *нāз* id. К. **Наза, Нәзек.**

**НАЗА** диал. «нежный (преимущественно о девушках)» < фар. *нāзäһ* «гыйффәтле (кыз)». Иске тат. (ГТРС: 439) **назнин, назәнин** id. дә

фарсычадан. 1930–1940 елларда «Наза» дигән җыр популяр иде.

*Наза, наза,*
*Наза матур кыз бала,*
*Стахановчы егетләр*
*Сөя торган замана.*

**НАЗАР, нәзар** кит. «взгляд; точка зрения» < гар. *нӓẓāр* id. Шуннан ук иске **назари** «теоретик», **назария, назарият** «теория». К. ГТРС: 454–455. К. түбәндәгеләрне.

**НАЗАРӘТ, нәзарәт** «ведомство» < гар. *нӓẓāрат* id. ← *нẓр* «карау, багу».

**НАЗИР, назыйрь** «старшина; министр, делопроизводитель» < гар. *нāẓир* id. Будагов II: 278, 287; ГТРС: 440.

**НАЗИРӘ, назыйрә** кит. «подражание (известному произведению, автору)» < гар. *нāẓира* id. К. югарыдагыларны.

**НАЗЫГЫШ** (ТТДС I: 318) «зарницы» – *назагай//нажҗагай* (к.) сүзеннән, ләкин ничек ясалганлыгы аңлашылмый. К. **Нажҗагай.**

**НАЗЫМ** «слова песни; вирши; духовные стихи» < гар. *нӓẓм* (> тат. *нәзым*, ГТРС: 456) «тезмә, энҗе тезгесе; шигырь, назым». Бу сүз төрки телләрдә «шигырь, поэзия» мәгъ. киң таралган (мәс., ком., к.-балк. *назму* «шигырь», уйг. *нәзм* «поэзия» һ.б.). К. Будагов II: 287.

Дерив.: **назымлы, назымсыз; назымла-у.**

**НАИБ** «наместник (правителя)» < гар. *нā'иб* id. ← *нwб* «алмаштыру» тамырыннан, шуннан ук к. **Набат, Нәүбәт.**

**НАЙ, нәй** «най, флейта (деревянная, среднеазиатского типа)» < фар. *нӓй,* үзб., таҗ. *най, ной* «курай; камыш».

**НАЙНАМАЗ, нәйнамас** (Тумашева 1992: 158) «коврик для намаза» < **йайнамас, йәйнамас** (Op. cit.: 74) < фар. *җаӣ нӓмāз* «намаз урыны» (**җай** «урын»); тат. диал. **намазҗәй** (к. ТТДС I: 318) < фар. диал., төр. *намазҗай* ш. ук. «намаз урыны» дигәннән.

*Җайнамаз > йайнамаз > найнамас* күчешләрендә тат. теленең кайбер сөйләшләренә электән хас *й- > н-* күчеше (к. **Наян, Ниргә**) бик ачык күзәтелә.

**НАКАЗ** «наказ» < рус. (рус. *казать* «күрсәтү»).

**НАКАЛ** «напряженность, накал (страстей)» < рус. (рус. *калить* «кыздыру»).

**НАКАРӘ, накра, нақарь, нақыра** (Гиганов) «литавры; металлический барабан» ~ гом. кыпч., төр., чыгт. *нақара*, бор. тат. *нақара* (шуннан – **нақарагы**) < гар. *нӓқр, нӓқараӓ* id. (гарәп телендә дә төрлечә), к. ГТРС: 456. Бор. рус. *накра* «барабан», рус. диал. *нагара* «керәч барабан» тур. к. Фасмер III: 36, 40.

**НАКАТ** «накат» < рус. (рус. *катать* «тәгәрәтү»).

**НАКЫС** (ТТДС I: 322) «скудный, недостаточный (о средствах, материале для чего-либо)» ~ башк. *накыҫ* id. < гар. *нӓқҫ, нақӣҫ* id., ш. ук «дефект» (ГТРС: 440, 457), **ноқсан** сүзе белән тамырдаш. **Накыс** сүзе төрки телләрдә төрле мәгъ. очрый, һәм тат. телендә дә (норматив сүзлекләргә кертелмәсә дә) һәр җирдә еш кулланыла (мәс., *накыс уңыш,* «Кызыл таң», 31.VIII.1996).

Дерив.: **накыслык; накыслан-у.**

**НАЛ** (Троянский) «шпоры; подкова» < гар. *нӓ'л* id. (> иске тат. **нәгыль** «дага; ката», ГТРС: 454). Бу сүз төрки һ.б. телләрдә киң таралган. Урта гасырларда *на'л* салымы дип хәрби салымны (≈ төрки **тояк хакы**) атаганнар. Бу сүз контрибуция акчасы (акча берәмлеге) мәгъ. булган, к. Sumer 1983: 105–108; Velidi: 303. К. **Барнагыл, Нәгълин, Нәлбәк.**

**НАЛӘ** кит. «жалобная песня; стон» < фар. *нāлӓ* id., к. ш. ук иске *налиш* id. < фар. *нāлиш* (*налидāн* «елау, үксү»). Будагов II: 278–279.

**НАМ** «имя, название, титул (человека)» < фар. *нāм* < авест. *nāma* «исем, мөрәҗәгать; адрес, титул» ~ санск. *naman* < һинд-евр. **jenmen* (?); рус. *имя (имен)* сүзе белән тамырдаш (ә **намә** белән тамырдаш түгел). Будагов II: 279; Kluge 2002: 646 (*нам ~ ним* тамырыннан бик күп хәз. терминнар ясалуы күрсәтелә).

**НАМАЗ** «намаз, молитва с ритуальными движениями» < фар. *нӓмāз* < пеһл. *nemaǯ* ~ сугд. *nm'č,* авест. *nemanh* id.

Намаз гамәле ислам диненә бор. фарсылардан кергән булса кирәк һәм төрки халыкларга да ул исламгача мәгълүм булган.

Дерив.: **намазлы, намазсыз** (фарсыча **бинамаз** да диелә); **намазлык; намазчы**. К. **Найнамаз.** Себ. (Тумашева 1992: 157) **намастигәр (< намаздигар)** һәм **намасшам (< намазшам)** сүзләре турыдан-туры фарсычадан киләләр.

**НАМӘ** «письмо; что-либо написанное (для чего)» – широко используется как словообразовательная морфема < фар. *нāме* < бор. фар. *пāмак* «язу, китап»; бор. төрки, монг. *нат, ном* «китап; изге китап, закон» < сугд. *пwт* (ДТС: 360–361) сүзе дә *намә* белән баглы. Кайберәүләр (Баскаков, Малов) *ном* сүзен *намус* белән баглыйлар.

**НАМӘГЪЛҮМ** кит. «неизвестный» < фар. *нāмä'лӯм* (гар. *мä'лӯм* сүзе нигезендә ясалган).

Дерив.: **намәгълүмлек.**

**НАМӘХРӘМ** кит. «чужой для семьи, посторонний (при которых женщинам нельзя было показываться с непокрытой головой)»; ш. ук «допустимый для заключения брака (не родственный)» < фар. *намäхрäм* «харам түгел, харамга исәпләнми».

Дерив.: **намәхрәмлек.**

**НАМЗӘД** «кандидат» < фар. *нāмзäде, нāмзäд*, к. ГТРС: 441.

**НАМУС,** диал. **намыс** «честь, достоинство (человека); честность» ~ чув. *намăс*, удм., мар. *намус, намыс* < гар. *нāмӯс* id. < грек. *ηομος (ηομ-ος)* «закон». Атаклы француз марксисты П. Лафарг (Язык и революция. М., 1930: 20) бу сүзнең тәүге мәгънәсе «бау», шуннан «бау ярдәмендә җир үлчәү» > «төгәллек» > «гаделлек» мәгъ. килеп чыгуын яза. Рус. *номос* «закон» (Срезневский II: 466) турыдан-туры грек теленнән кергән.

Гар. сүзлекләрендә *намус* сүзен, «әдәп-хәя» мәгънәсендә алып, *нмс* «яшеренү, оялу» тамырыннан дип карыйлар. Ләкин бу – ясалма этимология булса кирәк. Федотов II: 366.

Дерив.: **намуслы, намуссыз; намуслан-у,** иске **намускяр** («бигрәк тә намуслы кеше»).

**НАН** кит. «хлеб (вообще)», диал. «лепёшка (среднеазиатского типа)» < каз., к.-калп., кырг., уйг. *нан*, үзб., таҗ. *нон* (үзб. диал. *нан*) < фар. *нāн* id. < бор. ир. *пап* id. > удм., морд. > рус. диал. *нян, нянь* «икмәк, ипи». Түбәндә бу сүз «күмеп пешерелгән» (чаг. **Күмәч**) дигән сүз икән. К. Оранский: 95–107; Аникин: 403.

**НАНЫМ, наный** (ТТДС I: 319) «слово ласкового обращения (к младшим)» ~ к.-балк. *наным* id., *йаным* < *җаным* (*й-* > *н-*) булса кирәк. Бор. кыпч. сүзе. К. **Нәни.**

**НАР I** «верблюд (одногорбый)» < гом. көнб. төрки *нар* < фар. *нāр* id. К. **Наркөмеш.**

**НАР II** «гранат (фрукт)» < фар. *нāр* id. Федотов II: 367.

**НАР III** «(адский) огонь» < гар. *нāр* id. К. **Нур.**

**НАРАЗЫЙ** кит. «недоволен; недовольный» < фар. *нāрāḍӣ* «риза түгел».

Дерив.: **наразыйлык; наразыйлан-у.**

**НАРАСЫЙ, нараси, нарасидә**, диал. (ДС III: 118) **нараста**, себ. (Тумашева 1992: 172) **нәрәситә** «невинный ребёнок, кроткое существо; ребёнок до пяти лет» ~ чув. *нараста*, мар. (Иванов, Тужаров: 137, Саваткова: 100) *нäрäштä* id. < фар. *нāрāси, нāрāсӣдä* id. (> гом. көнб. төрки *наристе* һ.б.). Бу сүзнең төрки һ.б. телләрдә киң таралуы суд процедурасы белән бәйле булса кирәк (**нарасидә** судка тартылмый); сүзнең ясагыч нигезе – фар. *расӣдäн* «үсеп җитү» (*нā-рāсӣд-ä* «үсеп җитмәгән»), рус. *расти* сүзенә тамырдаш. Федотов II: 367.

Дерив.: **нарасыйлык.**

**НАРАТ** «сосна» > чув. *нарат* ~ к.-балк., ком. *нарат* < монг. *нарад* «наратлар» *нара (нара-сун)* < *нара-н* «кояш агачы, кояш ярата торган агач» сүзеннән, к. ш. ук як. диал. *нурат*, бур. *нархун, нарахунь* «нарат»; монголларга күрше халыкларда **нарат** сүзе юк, ул кыпчак төрки телләренә Алтын Урда чорында төзелеш агачы атамасы буларак таралган булырга тиеш (**нарат**ны таләп итүчеләр – монголлар була). К. Räsänen 1969: 350; Федотов II: 368.

Дерив.: **наратлы, наратсыз; наратлык.**

**НАРДУГАН** (Троянский II: 253) «праздник солнцестояния» (*кышкы нардуган* – «зимний нардуган, святки», *җәйге нардуган* – «летний нардуган, зелёные святки»), у некоторых групп крещёных татар **нардуган** «удлинённый месяц, начинающийся с 25 октября (каждый месяц считался по 30 дней, последний был удлинённый)», к. Гаврилов 1876: 22–26 > чув. *нартăван, нартукан,* удм. *нартуган,* мар. *нардуган*, морд. *нардван, нардава,*

*нардукан* id. ~ төр. диал. *мартуфал, мунтувар, мартавал* (Çау 1993: 61–66) < фар. *нäрд-у-фал* «нәрд уены ысулы белән күрәзәлек итү» («нәрд һәм фал») сүзеннән: нәрд уенында уенчы махсус савыттан (чүлмәктән) билгеле чиккә кадәр саннарның берсе язылган шакмак ала һәм нәрд тактасында шул са́нча йөреш ясый; нардуган уенының төп өлешендә – йөзек салыш уенында катнашчыларның берсе яисә икесе төнге уникедә бәкегә барып су алганнар. Ул суда **шүлгәннәр** кайта дип уйлаганнар (**шулгәннәр** исә киләсе елда ни булачагын белеп тора), ул суны махсус чүлмәккә, чиләккә койганнар һәм шуңа катнашчылар (гадәттә яшь кызлар) үзләренең исемле йөзекләрен салганнар. Шуннан соң, гадәттә арада иң гөнаһсыз – иң кече кыз чиләккә салынган йөзекләрне кармап алган һәм шунда әйтелгән мәкаль яисә җыр эчтәлеге йөзекнең иясенә япсарылган. Әстерхан мишәрләрендә тәүдә әлеге иң кече кыз шундый такмак әйткән:

*Нардуганым нард булсын,*
*Эче тулы нур булсын.*
*Нардуган кевен кем күләсә,*
*Шул бәхетле яр булсын!*

Шундый уен әрмәннәрдә дә булган. Русларда бу уен *куляш* дип аталган. Нардуган җырлары, такмаклары, мәкальләре аерым жанр хасил иткәннәр. Җәйге нардуганда йөзек урынына чүлмәккә чәчәкләр салганнар, һәрбер чәчәк төренең махсус юралышы булган h.б. Шуны әйтергә кирәк, *нәрд* сүзе үзе дә түбәндә бер чәчәк атамасы, к. **Нәрд.**

**Нардуган** тур. этнографик әдәбият бик бай. К. Ахметьянов 1977 (СФУ № 2); Баязитова 1995: 57–64; Баязитова 1998: 25–35.

**Нардуган** сүзен монг. *нар* «кояш *туган* (көн)» дип (чув. этимологы В.Г. Егоровча) аңлату дөрес түгел, әлбәттә.

**НАРДУГАТ** (Гаврилов 1876) «последний удлиненный месяц года (конец ноября – декабрь)» **нардуган** сүзеннән, ләкин ясалышы аңлашылып бетми. К. **Нардуган.**

Татар халык календаренда һәр ай утыз көнлек булган, соңгы айга **нардугат атнасы** (ул һәр ел тигез булмаганга) кушылган.

**НАРКӨМЕШ** «сулема; аппретура» ~ чув. *наркăмăш, маркăмăш* (Сергеев 1971: 90), мар. *наргумыж* «мышаяк» < фар. *маргемуш* «тычкан үтерү даруы» – *мäрг* «үлем», *муш* «тычкан» сүзеннән (Ашмарин 1923: 243), безнеңчә, **нар көмеше** – дөя дәвалау өчен *көмеш* сулема (төсе буенча бу агуны **көмеш** дип атаганнар). **Наркөмеш** тире-күн эшкәртү өчен дә файдаланылган. Федотов I: 368.

**НАРЫН** (Тумашева 1992: 158) «борщ» к. **Нәрен.**

**НАРЫНЧА, нарыйнҗа** «вид цветка (который олицетворял весну и молодого парня, которого, повидимому, приносили когда-то в жертву воде), купальница (растение с большими желтыми цветками)» ~ мар. *нарынзы, нарынче* «сары» (*нарынзывуй – нарынчабаш* «алтын туй чәчәге (үсемлек)», *нарынзы кек* «шәүлегән (сары төсле кош)» < «нарынча киек» (к. Саваткова: 99), Ф. Баязитова язып алган материаллар (*нарыйнча*/*нарыймҗа*га багышланган җырлар) буенча фикер йөрткәндә, **Нарынча** – җимчәчәк бәйрәмендә төп персонаж булган. Ләкин бу бәйрәмнең (гомумән, яз бәйрәме) детальләре ачык түгел. К. Татар диалектологиясе буенча материаллар. Казан., 1978: 31 h.б.

*Нарыйнча* < фар. *нāринҗ*, гар. *нāранҗ* «әче әфлисун» (> бор. рус. *наранжа, наранзи* id., к. Фасмер III: 43); фар. (> төр.) *нарин* «сылу (егет)», фар.-гар. сүзеннән фр. *orange* «әфлисун» (шуннан рус. *оранжевый, оранжерея*) сүзе килә. Күрәсең, фар. **наринҗа** белән бәйле ниндидер мифологемалар булган. Гомумән, бу сүзнең чыгыш-тамыры да бик ачык түгел.

**НАРЫ-У, нарвы-у** (ТТДС I: 319) «настояться; упреть»; күч. «вздремнуть; перебеситься» ~ мар. *нары-* id. Ачык түгел (диалектологик сүзлектә мордва телләреннән диелә).

**НАС** кит. «(знаменитые) люди; род человеческий» < гар. *нāс, äн-нāс* id. К. **Ниса.**

**НАСАРИ** тар. «христианин» < гар. *нäçāрӣ, нäçāрā* id., түбәндә рус. *назаряне* дигән кавем, к. Будагов II: 285.

**НАСБАЙ, насвай,** себ. (Тумашева 1992: 157) **назыбай** «толчёный и смешанный с некоторыми добавками табак для жевания или насыпания в ноздри (у татар в XX веке уже не употреблялся)» ~ башк. (БТДҺ: 243) *насбый, насывай,* каз., кырг. *насыбай*, үзб. *носвой* id. Л. Будагов (II: 277) фикеренчә, рус. *носово́й (табак)* сүзеннән: борын тәмәкесен куллану элекке рус казакларында киң таралган булган (гомумән, бу гадәт Кавказ аша Шәрык

илләреннән килә). Ләкин А.С. Аникин Л. Будагов фаразын кире кага.

**НАСИЛА, насилый, начылый, начилә, нәсилә** (ЗДС: 493, 494, 496) диал. «еле, с трудом» ~ башк. (БТДҺ: 249) *насыла, нәселә, нәслә* id. – тат. сөйләшләрендә киң таралган. Бу сүзне диалектологлар русча *на силу* тәгъбиреннән дип аңлаталар. Ләкин монда шикләнерлек урын бар: русларда *насилу* сүзе бик киң кулланыла микәнни? Аннары китерелгән сүзләргә нигез булырдай төрле гарәп һәм фарсы сүзләре дә табыла, мәс., фар. *насилах* «көчсез, хәлсез, коралсыз хәлдә» һ.б. Безнеңчә, фар. (яисә берәр гар.) сүзе халык аңында русчага нисбәт ителгәндер.

**НАСКИ, насук** «носки» < рус. (рус. *носить* «киеп йөрү» фигыленнән).

**НАСТРУК, настырук** «наструг, струг» < рус.
Дерив.: **наструкла-у.**

**НАСЫЙП** «суждено; доставшийся на долю, суженый» < гар. *nāçиб* id., к. ГТРС: 460.

**НАСЫР** диал. «чаяние; проблеск удачи, счастья и т.п.» ~ башк. (БТДҺ: 243) *наçыр* id.< гар. *нäçр* «ярдәм; уңыш, алгарыш, җиңү» сүзеннән фар. һәм төр. телләрендә мәгънәсе бераз үзгәреп килеп чыккан. Тамыры – *нçр* «ярдәм итү», шуннан ук иске тат. **носрат** «җиңү, уңыш», **насыйр** «ярдәмче, ярдәм итүче».
Дерив.: **насырлы** «эше уңучан», **насырсыз.**

**НАХАК** «напраслина; неверно, ложно» > чув. *нехак*, мар. диал., удм. диал. *накак, нахак* id. < фар. *нāхаķ* «хак түгел».
Дерив.: **нахакка; нахаклык.**

**НАЧАР,** диал. (себ., миш.) **нацар, надзар** «плохо; плохой» > чув., мар., удм. *начар* id., мар. диал. *незер* «ярлы» (Саваткова: 100) < фар. *нäчāр* (үзб., таҗ. *ночор*) «чарасыз; бернәрсәсез». Төрки телләрдә киң таралган сүз (башк. *насар*, каз. *нашар* id.).
Дерив.: **начарлык; начарлан-у, начарай-у.**

**НАЧИЗ** (Троянский) «обесцененная вещь; ничто» ~ нуг., каз. *нашиз* < фар. *нāчӣз* id. (*нā чӣз* «берни түгел»). ГТРС: 446–447.

**НАШМАК** «головной убор невесты в виде широкой ленты, прикрывающий лоб и лицо (остаются видными только глаза); вуаль; покрывало» > удм., мар. *нашмак*, чув., кар., төркм., төр., бор. төрки (Изысканный дар… 1978: 309) *йашмак* id. *йаш*- «яшеренү» сүзеннән (*й*- > *н*-). К. **Яшер-ү.**

**НАЯН [наᵒйан]** «плутоватый; шаловливый; лентяй» > чув., рус. диал., морд., мар., удм., коми һ.б. *наян,* як. *наяан* «наян; көшкел» < бор. тат. *найан* ~ алт. *ньайан, йайан, йайаан* «шәһитләрнең тынычсыз рухы» сүзеннән (*й*- > *н*-) к. ш. ук **Заятүләк, Чая, Шаян.** Рус сүзе тур. Аникин: 405 (*надан* сүзеннән дигән фараз китерелә, ләкин бу дөрес түгел). Ахметьянов 1981: 24–25.
Дерив.: **наянлык, наянлан-у.** Рус телендә *наян* нигезеннән күп сүзләр ясалган: *наянка; наяный, наянливый, наянистый, наяноватый; наяниваться.*

**НӘ I** «что» – китаби телдә очрый, к. **Ни I.**

**НӘ II** «не; ни» < фар. *нä, на* (> таҗ. *но*); әд. телдә тиңдәш кисәкләрдә генә кулланыла (*нә җил, нә буран*). Халык телендә һәм барлык кыпч. телләрендә **нә** һәм **ни** күптән ачык аерылмыйлар. Хәлбуки бу сүзләрнең берсе төп төрки, икенчесе фарси. К. **Ни II.**

**НӘБИРӘ,** диал. (Тумашева 1992: 158; БТДҺ III: 244) **нәбәрә, нәвәрә, нәмәрә, нимәрә** «внучка; (реже) внук» ~ уйг. *нәбирә,* кырг. *небире*, үзб. *нәбӗрә, невара, нәбәрә* (ЎХШЛ: 351) < фар. *нäбӣрä* (ГТРС: 453) < иске фар. *newade* < бор. фар. *napāt* < һинд.-евр. **nepōt* «җиян» – төп мәгъ. «җитлекмәгән» булган, к. Фасмер III: 68 (бор. рус. *нетии* сүзе тур.).

**НӘВЕМ [нәwӗм]: нәвем базары** иносказательно «сон» – гар. *нäwм* «йокы» сүзеннән; бу тәгъбир элек еш очраган (Исәнбәт I, 1990: 42).

**НӘГӘР** «дружка (жениха на свадьбе); тамада (ТТДС I: 244)» < фар. *нäвкар, нäвгар* id., ш. ук «кучты (корал йөртүче)» > кар. *нэгер, нäгäр* id. Фар. сүзе исә монг. *нөгүр*, бор. монг. *nökür* (хәз. монг. *нөхөр*, бур. *нөхүр*) «дус, иптәш; якын хезмәтче» сүзенең халык этимологиясенчә (*нäв* «яшь, яңа» сүзе тәэсирендә) бозылган варианты. Мәзкүр монг. сүзе төрки телләргә турыдан-туры кереп киң таралган: тат. **нөгәр** (> чув. *нӗгер*), **нүгәр, нүңәр** (Тумашева 1961: 176) ~ каз. *нөгөр, нөгер,* уйг., алт., кырг. *нөкөр,* к.-балк., ком. *нёгер* «хәрби дус; дус

хезмәтче; хан сакчысы» һ.б. > иске рус. *нукер* «хан сакчысы», хәз. рус. *нохор, нукур* «дус» (к. Аникин: 411) – төрлерәк мәгъ. һәм төрле телләрдән.

Монг. сүзе үзе бор. *nöküger* формасыннан, **nökü* > бур. *нүх* «дус, иптәш; дус кыз (!)» тамырыннан (*-ger* зат атамасын ясагыч кушымча), чаг. тунг. *нэкӯ(н)* «эне, сеңел» (ССТМЯ I: 617–618) бу сүзнең исә *эне* < *ини* < *йэни* сүзеннән булуы ихтимал. Ягъни ахыр чиктә **нәгәр** ~ **нөгәр** төрки сүз булып чыга. Ләкин, әлбәттә, бу фараз тәфсилләп нигезләүгә мохтаҗ. К. ш. ук **Нәкә.** Сафаров: 62.

**НӘГЪРӘ [нәғрә]** «грозный крик, окрик» < гар. *нäʻра* id., ш. ук «дәрвишләрнең ритуаль кычкырыклары» (Будагов II: 287).

**НӘГЫЗЬ [нәғёз]** «качественный, фирменный, подлинный» < фар. *нäʻз* «нәгызь, шәп, гаҗәеп; җиңел сөякле» (Будагов II: 288), к. ш. ук нуг., каз., к.-калп., кырг. *нағыз* «чын, сыйфатлы» һ.б. (төрки телләрдә еш очрый).

**НӘГЫЛЬ, нәгълин** («Нәһҗел Фәрадис» әсәрендә) «райские туфли (~ туфля)», «босоножки (босоножка) для хождения по горячему песку в пустыне» ~ каз. диал. (ҚТДС: 248–249) *нағли* – «самавыр табасы яки аяклары» < гар. *нäʻл, нäʻлин* id., гомумән – «олтан; дага». К. **Нал, Нәлбәк.** К. ГТРС: 454. К. ш. ук **Барнавыл > Барнау.**

**НӘДЕРБАШ, надырбаш** «мокрец (трава)» – ачык түгел.

**НӘЗАКӘТ** «изящество; деликатность» < фар. *нäзāкäт* id. (ГТСР: 454).

**НӘЗБЕРЕК** «привередливый» < фар. *нāзӯвāрак* id. – *нāзӯвāр* «талымлы» сүзенең иркәләү-кечерәйтү формасы. **Назувар** сүзе исә *нāзӯ* «ана песи (назлы хайван)» сүзеннән ясалган нигез («ашамлыкка песи шикелле сак килүчән»).

Дерив.: **нәзберекле; нәзбереклән-ү.**

**НӘЗЕК** «тонкий» < уйг. *назик, назук* «нәзек, нечкә, сөйкемле» сүзеннән, *наз* тамырыннан (к. Будагов I: 277). Икенче бер фараз буенча, фар. *нāзук, нāзик* < бор. төрки *naivaziki* < санск. *naivasika* «фәрештә» (к. ДТС: 354–355) сүзеннән. Ул тәкъдирдә тат. *нәзек* турыдан-туры бор. төрки телдән була ала, к. тат. диал. (миш.) *нәзек* «җәйге нардуган, аяу көннәре» (Паасонен материалларыннан). К. ш. ук каз. *нәзĕк,* кар., к.-калп., уйг. *нэзик, нәзик*, төр., ком. *назик* «нечкә; четерекле».

Дерив.: **нәзеклек; нәзеклән-ү, нәзегәй-ү.**

**НӘЗЕР,** диал. **нәдер** > мар. *надыр* «обет, обещание; дар (деньгами)» < гар. *нäẓр* id. Будагов II: 282; ГТРС: 456.

Дерив.: **нәзергә; нәзер әйтү (итү).**

**НӘЗНӘЙ** «герой сказок – трикстер» – китапларда *незнай* дип «русчалаштырып» бирү дөрес түгел, к. авар. *назнай, нäзнäй* – көлкеле әкият герое (Дагестанские народные сказки: 63–70) – ниндидер бер Шәрык теленнән (чаг. фар. *наз-у-наи* «мактанырга омтылыш»: **Нәзнәй** – әкиятләрдә мактанчык герой).

**НӘЙЗӘ** «стрелка часов», диал. (ДС I: 139) **найза** «копьё, пика, штык» < фар. *найзä* id. (Будагов II: 298) – рус. *нож* «пычак» белән тамырдаш (к. Фасмер III: 84).

**НӘКӘ, негә, некә, нике, нөгә, нөкө** (ЗДС: 494, 497, 498, 499) «бракосочетание». Фонетик җәһәттән бу сүзләр **никях** сүзеннән килә алмый. Безнеңчә, алар тат. < монг. *нәкәр, нүгәр, нүкәр* «якын дус, дружинник», ш. ук «зәүҗә, зәвеҗ» сүзеннән. К. **Нәгәр**. Чаг. ш. ук түбәндәгене.

**НӘКӘС** «пухленький, соблазнительный; полненький (чаще о девушке); увалень, лодырь (о парне)» ~ иске тат. (Троянский) **накәс** «килбәтсез» ~ чув. *накас* id. *нахас, неккес* «ялкаурак» (к. Сергеев 1968: 44), мар., удм. *накас* «азгын» ~ кр.-тат., кар., уйг., кырг. *накәс, нәкәс* «түбән, кабахәт» һ.б. < фар. *нāкäс* «кеше түгел». Күп телләрдә бар. К. ш. ук ГТРС: 441; Федотов II: 365–366.

**НӘКӘ-Ү** (Тумашева 1992: 158) «настоятельно просить» ~ башк. (БТДҺ: 244) *никә-ү* id., *нәкәлә-ү* «белергә тырышу, ныклап сорану, кат-кат сорау», алт. *неке-, нäкä-* «эзәрләү», тув. *неге-* «таләпләү» < монг. *нэкэ-* id., к. Räsänen 1969: 352. Чаг. **Ныкы-у.**

**НӘКЪ [нәк]** «точно; как раз, именно» ~ каз., к.-калп., кырг. *нақ,* уйг. *нақ, нәқ,* үзб. диал. (ЎХШЛ: 189) *нақ* id. иске әд. *нәкыть* < гар. *нäқд* «төгәл (акча санаганда); кулдагы акча» сүзеннән дип уйларга мөмкин (К. Насыйри телендә *нәкыть* «нәкъ», к. ГТРС: 457); ләкин фар. һәм ягн. (сугд.) телләрендә дә *наһ, наһах* «нәкъ» (ЯТ: 290), бу исә

күрсәтү алмашлыгыннан. Һәрхәлдә **нәкъ** – алынма, нечкә сузык *-ә-* соңыннан каты тартык *-қ* килүе дә шуны күрсәтеп тора. ЭСТЯ VII: 96 (этимологиясен ачык калдыра).

**НӘКЫЛЬ** «догма; подражание, праформа» (к. мәкаль: *Акыл нәкыльдән өстен* «логика выше догмы») < гар. *нäқл* «күчерү, күчергеч, кичерү» > үзб. *нақл* «эчтәлекне сөйләү (дәрестә), риваять» һ.б. ГТРС: 457.

Дерив.: **нәкыльче; нәкыльчелек, нәкълән** (< гар.).

**НӘКЫТЬ** иск. «наличные деньги» (шуннан: *нәкыть вакытны саклый*) < гар. *нäқд* id. (ГТРС: 457) – ислам илләрендә киң таралган сүз, шуннан *нäқдäн* «кулдан (акча бирү)». К. **Нәкъ.**

**Нәкыть** сүзе бор. рус. *ногата* «вак акча (бәрәмлеге)» сүзендә чагыла дип уйлыйлар (Фасмер III: 79).

**НӘКЫШЬ** «резьба (по дереву), орнамент, узор (на бытовых изделиях)» ~ башк. *нагыш*, нуг., кар., каз., к.-калп. *нагыс*, уйг. *нәқиш* h.б. id. < гар. *нäқш* id. (шуннан **нәққаш** «бизәкче»). К. Будагов II: 290–291.

Дерив.: **нәкышьле, нәкышьсез; нәкышьлә-ү; нәкышьче, нәкышьчелек.** К. түбәндәгене.

**НӘКЫШЬБӘНДИ** «суфийское братство, распространенное и среди татар» – фар. *нäқшбäнди* id. ← *нäкшбäнд* «бизәкче, рәссам»: бу тарикать шулар арасында формалашкан. Гомумән **нәкышьбәнди** – интеллектуаль динче, мулла-фәлән түгел.

**НӘЛӘТ**, ш. ук **нәгъләт, нәгаләт** «проклятие; проклятый» (БҺҺ II: 181, 184) < әд. *ләгънәт* < гар. *лäʻнäт* сүзеннән (к. **Ләгънәт**). *Нәләт* татар телендә килеп чыкмаган, к. каз. *нәлет*, кар. *налет, нәлет*, к.-балк., ком. *налат*, кырг. *наалат*, уйг., үзб. диал. *нәлат, нәләт* (ЎХШЛ: 192) id. Күрәсең бу сүз гарәпчәдән алынган чорда ук метатезаланган.

**НӘЛБӘК** (әстр., Г. Минский) «металлическое блюдце» ~ ком. *налбеки* id. < фар. *нäʻлбäкӣ, нäʻлибäк* «ваза, чәчәкләр яисә яшелчә (*бäкл*) савыты» – *нäʻл* < гар. *нäʻл* «нал, олтан, кутәрмә, дага, түгәрәк металл кисәге» сүзеннән, к. **Барнагыл, Нал, Нәгыль.**

**НӘМӘ** «вещь, штука» к. **Нимә.**

**НӘМӘРСӘ** «штука; вещица» < уйг. *нәмәрсә* id. < бор. төрки *neŋ ärsä* «ни булса шул» > *nemärsä* «ни булса да» (ДТС: 358). К. **Нәрсә, Нәстә.**

**НӘНӘЙ,** (ЗДС: 495) **нәнәү** < вокатив от **нәнә** (Тумашева 1992: 158), **нинә** (ДС II: 143) «бабушка по матери» ~ кр.-тат., төр., аз. *нәнә, нинә* id., төр., аз. (Будагов I: 293) «сөт анасы». Бөтен дөньяга билгеле ономопоэтик сүз, мәс., удм. *нэнэ*, груз. *нана*, индонез. *nenek* «нәнәй», кыт. *няннян* «кендек әбисе», (МНМ I: 658) «бәби бүләк итүче алиһә», «императрица», фар. *нэнэ*, санск., шумер. *нана* «ана; әби алиһә» h.б. Чаг. **Наный.**

**Нәнәй** сүзенең «күз карасы» мәгъ. дә бар (ДС II: 145; БТДҺ: 247).

**НӘНИ** «малютка; малюсенький»; бу сүзне интернациональ *нана//нәнә* (к. **Нәнәй**)гә япсарып кына котылып булмый һәм ул төрки телләрдә төрле вариантларда очрый. Ихтимал, диал. *нан* < *йан* < *җан* сүзеннәндер. Чаг. себ. (Тумашева 1992: 158) **нәнә** «бәби» ~ төр. *nenne, nenni* «бишек җыры», фар. *нäнү* «бишек». Шул ук вакытта *нәни* < *наный* < *онаный* «оныкның баласы» да була ала. к. **Онык.**

**НӘНКӘ** «нанка (вид толстой хлопчатобумажной ткани)» < рус., гомумән – Кытайдагы *Нанкин* шәһәре исеменнән; к. ш. ук мар. *нанке* «нарынҗа төс(тәге)».

**НӘРӘТӘ, мәрәтә** (ДС I: 142; БҺҺ II: 184) «нерёт, нерёта» ~ чув. *нерет, нерете*, мар. диал., удм. диал. *нäрäтä* id. – рус сүзе кебек үк, бор. бер фин-угор теленнән, к. фин. *merta* «нәрәтә, мурда». Үзб. диал. (к. ЎХШЛ: 192) *нәрәтә* id. < тат. Фасмер III: 65; Аникин: 404 (рус. диал. *нарта* «нәрәтә» тур.).

**НӘРЕ** (ЗДС: 495) «вот там, вон» < уйг. *рәри*, үзб., кырг. *нари* id. Төр. *nere* «ни җир?» h.б. *Нә* сүзеннән булса кирәк.

**НӘРЕН** «ряска» (к. Иванова: 140) < диал. (Тумашева 1961: 171; ДС I: 140) *нарын* «ит һәм яшелчә турап пешерелгән өйрә» сүзеннән булса кирәк: нәренле су өйрәгә охшаш. Каз, кырг., үзб., аз. *нарын,* уйг. *нарин* «ит ваклап салынган аш-сый нигъмәте» (ҚТДС: 252) < фар. *нāрӣн* «яңа чыккан, йомшак, яшь» (к. Будагов II: 277).

**НӘРКӘМӘС** «полынь-эстрагон» (к. Иванова: 130), «герань душистая» (ТТДС I: 601) >

чув. *наркамас* id. ачык түгел. **Наркөмеш** (к.) белән чагыштыру аңлатмага мохтаҗ. Чаг. ш. ук добр. тат. (Akb: 133) *narkatış* < *нәһер камыш* (*нәһер* «елга-күл») «баш түндергеч исле камыш төре».

**НӘРКИС, нәркәс, нәргис** «нарцисс (растение)» < фар., гар. *нäркūс* < лат. *narcissus* ~ грек. *ηαρκισσος* id. Бу сүз гар. һәм фар. телләренә кабат-кабат кергән; **нәрҗис** < гар. *нäрҗūс* варианты да бар (ГТРС: 459). Сүз грек теленә ниндидер субстрат телдән калган (Kluge: 646), **наркоз** сүзе белән тамырдаш. **Нарцисс** дигән мифологик зат тур. МНМ II: 201, 202.

**НӘ́РСӘ** «что», **нәрсә́ (нәрсәкәй)** «вещь» – корреляция, по-видимому, произошла в татарском языке < гом. кыпч. *нерсé*, уйг. *нәрсә*, үзб. *нарса* «нәрсә» < бор. төрки *nersä* < *ne ersä* < *neŋ ersä* «ни (дә) булса» (ДТС: 358) тәгъбиреннән, шуннан тагын **нәмәрсә** (к.) һәм **нәәрсә* > **нәәссә* > **нәстә, ниәстә** сүзләре дә килә (бу сүзләр тат. телендә стилистик җәһәттән аерымланалар); иске тат. *нәснә* < төр. *nesne (нäснä)* бүтәнчәрәк хасил булган. **Нимә** сүзе дә үзгәчә ясалган. К. **Ни.**

Дерив.: **нәрсәлек.**

**НӘСӘП** «свойственные отношения; свойственник (человек из рода жены или мужа)», диал. «родственник» (ТТДС I: 324) < гар. *нäсäб* id., к. Будагов II: 283 (бик тәфсилле аңлатма). Тат. *нәсел-нәсәп* дигәндә беренче сүз «канкардәш», икенче сүз «кода ягы» мәгъ. аңлашыла, ләкин гар. **нәсәб** сүзендә андый аерма юк. **Нисбәт, нисби** сүзләре белән тамырдаш.

**НӘСЕЛ** «родственник; родственный; порода» < гар. *нäсл* id. ГТРС: 459.

Дерив.: **нәселле, нәселсез; нәселлек; нәселләш-ү; нәселдәш; нәселдәнлек, нәселчелек.**

**НӘСЕР** «стихи в прозе; эссé (литературный жанр)» < гар. *нäçр* id. ГТРС: 459.

Дерив.: **нәсерче.**

**НӘСИХӘТ** «наставление, назидание» < гар. *нäçихäт* id. ГТРС: 460.

Дерив.: **нәсихәтче, нәсихәтчелек.**

**НӘ́СТӘ** «что», **нәстә́, нәстәкәй** «вещь, предмет; человечек», к. **Нәрсә.**

**НӘТИҖӘ** «вывод; рузультат» < гар. *нäтūҗä* id. ← *нтҗ* «килеп чыгу; токым бирү, уңыш бирү».

Дерив.: **нәтиҗәле, нәтиҗәсез; нәтиҗәлә-ү.**

**НӘҮБӘТ [нәwбәт]** «очередь; (очередной) отпуск» < гар. *нäwбäт* id. ← *нwб* тамырыннан, шуннан ук к. **Набат, Наиб.**

Дерив.: **нәүбәтле, нәүбәтсез; нәүбәтләш-ү.**

**НӘҮМИЗ [нәwмиз],** диал. (ДС I: 139) **намиз, намид**, себ. (Тумашева 1992: 157) **намыт** «обескураженный, лишённый надежд» < фар. *нäwмūд* «өметсез хәлдә», ГТРС: 465.

Дерив.: **нәүмизлек; нәүмизлән-ү.**

**НӘҮРӘП** «погреб» < диал. *мәүрәп* < *мүгрәп* < рус. *погреб*; чув. *нухреп,* мар. *нӧреп* id. татарчадан булса кирәк. К. **Мөгрәп.**

**НӘҮРҮЗ [нәwрүз], нәүруз, науруз** «навруз, день иранского нового года (23 марта)» ~ чув. *норӑс, нурас, нарс* (болг. теленнән) id. ~ гом. кыпч. *науруз, наурыз*, уйг. *нәуруз*, үзб. *навруз* һ.б. < фар. *нäw рӯз* «яңа көн (яңа бәхет)» сүзеннән; шуннан **нәүруз гөле** «примуласыман гөл» (Урта Азиядә ул нәүруз көненә чәчәк ата); **Нәүрузбикә** Нәүруз бәйрәмендә юраулар өчен сайлана торган гөнаһсыз чибәр кыз, шуннан чув. *нарс пиге* > *нарспие* > *нарспи* id. Яңа ел бәйрәмендә «Нәүрузбик» сайлау Төньяк Кавказ төркиләрендә билгеле.

**Нәүрүз** тур. этнографик әдәбият чиксез күп; төрекчә бер китап «Nevruz» (Ankara 1995) 346 сәхифәле, һәм мондый китаплар бер генә түгел; андый хезмәтләр X г. бирле язылып килә (мәс., Гомәр Хәйям шундый бер китап язган). Будагов II: 293–294; Durduyeba A. The place of the Nevruz festivale in turkman folklore // Eurasien Studies, № 14, 1998. P. 108–124.

**Нәүрүз бәете** тәгъбиреннән **бәет** жанр атамасы килеп чыккан. **Нәүрүз (Яңа ел) гүзәле** сайлау гадәте бор. Шумерда, моннан биш меңь еллар элгәре үк булган (к. Нахмедов 1989: 55–62).

**НӘФӘКА,** диал. **нәфка, нәпке** (ДС I: 142; Тумашева 1992: 172) «иждивение; издержки на пропитание (подопечных лиц); алимент» < гар. *нäфäķа* id. ← *нфķ* «алмаштыру» тамырыннан, шуннан к. **Монафикъ, Нифак.** к. Будагов II: 290.

Дерив.: **нәфәкале, нәфәкасез.**

**НӘФЕЛ** «благодеяние (в дни религиозных праздников)» < гар. *нäфл* id. Дини телдә

ш. ук «фарыздан тыш булган гыйбадәтләр, изге эшләр».

**НӘФЕС,** диал. **нәфсе, нәпес, нәпсе** «безотчётное желание; вожделение» > мар. (Исанбаев 1978: 13) *нäпсе*, чув. (Сергеев 1971: 91) *непсĕр* id. < гар. *нäфс* id. Продуктив сүзьясагыч нигез: **нәфесле, нәфесләнү** һ.б.

**Нәфес** асылда «кайнар сулыш» ← *нфс* «сулыш алу» тамырыннан, шуннан ук гар. > иске тат. **нәфәс** «сулыш», **тәнәфес** (к.) һ.б. Рус. *небеса* «күкләр» – асылда «болытлар» шул ук тамырдан, диләр.

**НӘФЕТ** иск. «состав для горения в лампах», к. Максуди шигырендә:

*Нәфт улынды хикмәт илә анда су,*
*Нәгә янар нәфт илә, күргел, раку*
(ягъни – «юл фонаре»).

Гомумән бу сүз фар. *нäфт* «җир мае» сүзеннән таралган, шуннан ук **нафталин, нифте.**

**НӘФИ** иск. «грамматическая форма отрицания» < гар. *нäфӣ* id. ← *нфй* «кире кагу, фаш итү». Элекке (революциягә кадәрге) тат. теле дәреслекләрендә **нәфи фигыль** – фигыльнең **-ма//-мә** кушымчасы белән белдерелгән формасы. Бик җайлы термин.

**НӘФИС** «изящный» (**нәфисә** «изящная») < гар. *нäфӣс, нäфӣсä* id., id. *нфс* «матур булу» тамырыннан, к. иске тат. **нәфасәт** «гүзәллек» һ.б. ГТРС: 461–462.

Дерив.: **нәфислек; нәфислән-ү.**

**НӘФРӘТ** «ненависть; отвращение» < гар. *нäфрäт* id. ГТРС: 462.

Дерив.: **нәфрәтле** (мәс., караш); **нәфрәтсез; нәфрәтлән-ү.**

**НӘШТЕ, ләште** (ДС I: 127; ДС II: 145, Тумашева 1992: 195, 158) «слой красноватой глины» – Урал-Себер якларындагы рус сөйләшләрендә *няша* «лай, дуен» (Аникин: 413–414), мар. (Упымарий: 137) *нэнчэ* «былчырак, мәте, дуен», коми. *няша* «ташкыннан калган балчык катламы», чаг. ш. ук **мәте ~ ләте** (к. **Мәте**). Рус телендә дә, тат. телендә дә бу сүзләр фин-угор субстраты (бор. пермь) мирасы. К. КЭСК: 202.

**НЕЧКӘ** «тонкий, утончённый», «мягкий, палатальный (о звуках)» – в тат. и других тюрк. языках имеет великое множество вариантов произношения. Тат. диал. вариантларының изолинияләре барча бүтән күрше һәм төрки телләргә керә, к. анлаутлары буенча:

– тат. *нечкәк, нецкә* ~ башк. *нескә* «нечкә» ~ мар. (Саваткова: 101, 103) *нĕжгä* «нечкә; зәгыйфь», *нечкы* «иркә» ~ *ничке*, хак. *ніске*, тув. *ниничке* һ.б. «нечкә»;

– тат. (ЗДС: 806) *энечкә, эчкә ~ эчекә* > (ЗДС: 743) *чекә*;

– тат. (ЗДС: 249, 250) *йецкә, йиңичкә* ~ нуг. *йиңишке,* чыгт. *йинчä* «нечкә»; бор. төрки (ДТС: 261–262) *jinčkä* «нечкә, юка, тар»;

– тат. *җинечкә, җенечкә ~ каз. җеңішке, жинжә, җиңжу*, кыр. *җинҗә*;

– чув. *çанçе* (< болг. **җинҗә*) > мор. *синзе, се́нзä* «нечкә»;

– алт. *чичкэ, чишкэ* >> башк. диал. (БТДҺ: 276) *сес, сескә*;

– як. *синньгэс* «нечкә, юка, нәзек»;

– себ. тат. (Тумашева 1992: 62, 80) *ицкә, ицке,* уйг. *инчкә, иничкә, инчикә*, үзб. *ингичка,* кар. *инцке*, төркм. *инче*, куман. (Радлов I: 1422, 1445) *инцке*, төр. *ince* «нечкә, юка» һ.б.

Гомуми фонетик закончалыклар буенча бор. прототип – **йәничкә* «нечкә, юка» шәйләнә. Бу нигез, күрәсең, *йәнч-, йәнич-, йәнчи-* «яньчү, чүкеп юкарту» сүзеннән. Бу **йәнчи-* исә *-чи//-чы* кушымчасына беткән (чаг. *арчы-, борчы-, йомчы-, типче-, төпче-*) типик гом. төрки нигезләрнең берсе. Димәк, *йәнчи*-нең тамыры **йән-*.

Бу **йән* тамыры тур. төрле фаразлар булырга мөмкин. Уйг. (Будагов I: 13) *инчкә* «Конфуций тәгълиматы» сүзе бар икән. *Йән* тамыры кыт. *ин, инь* (*инь-ян* тур. тәгълиматтагы) «хатын-кызлык сыйфаты» түгелме икән? ЭСТЯ I: 363–365 (безнекенчә түгел). К. **Яньче-ү.** Чаг. **Җиңел.**

Дерив.: **нечкәлек; нечкәлә-ү, нечкәлән-ү, нечкәр-ү.**

**НИ I** «что; то (частица с указательно-определённым значением)» ~ хак. *ни,* башк. *нәй* < гом. көнб. төрки *не (нэ, нә)* < бор. төрки *neŋ* «әйбер, шәй; байлык; нинди дә (ни дә) булса», *neğü* «ни, ничек» (ДТС: 360–361) < бор. гом. төрки **jeŋü* >> алт. диал. (куманды) *дьу, чу, чүү, чугы,* тув. *чү, чүве* «ни, нә́рсә; нәрсә́», *че* «нә, ни» (чаг. тув. *ол чедип келген че* ~ хак. *ол сидĕп килген ни* «ул ничек килеп җиткән?»), *чүге, чиге* «нигә?», *чеже* «ничә?», як. *си* «ни» (*си буолбат?* «ни булмас?») һ.б. Чув. *мĕн, мен* «ни» < чув. диал. *нĕм, нем* < бор. төрки *нәң.*

Төрки телләрдә *н-* вариантының өстенлек итүе бор. бер абруйлы телдә *й-* > *н-* күчеше еш очраганлыгыннан булса кирәк. К. Будагов II: 297–298 (бу сүз кулланышы тур. – бик тәфсилле). ЭСТЯ VII: 96–99.

Бор. **je*, **jeŋü* сүзен тат. *йә, җә* ~ гом. төрки *йэ, җэ* «ярый» сүзе белән чагыштырырга мөмкин. К. **Нигә, Ник, Нитәккем, Ничә, Ничек.**

**НИ II** – частица усиления к вопросительным формам и конструкциям < *ни, ние* (чаг. рус. *ну и что?*). К. мәкаль: *Өй салуның ние бар – чутлыйсы да мүклисе.*

**НИ III** – частица отрицания, только в паре (ни …, ни …), «ни…, ни…» мәс., *ни ул, ни мин* «ни он, ни я» – кайберәүләр рус теленнән дип уйлыйлар (В.В. Радловтан башлап), ләкин *нә... нә...* дә шул ук мәгъ., ә ул исә тәгаен фар. теленнән. **Ни** яңгырашы закончалыклы рәвештә бор. яз. төрки *нэ* < фар. *нä.*

**НИБАРЫ** «всего лишь» < **ни-е бар-ы** < (*ни-е бар*)*-ы*; *нибары* үзе дә бербөтен итеп карала ала, шуннан: **нибары-сы.**

**НИБУЧ** диал. «небось» < рус. (русчада *не бойся* «курыкма» сүзеннән).

**НИГАҖӘП** «неудивительно; может и…» < **ние гаҗәп.**

**НИГӘ** «зачем, почему, к чему» < *ни-гә* ~ гом. кыпч., уйг., үзб. *негä, нега* id. К. **Ни I.**

**НИГЕЗ** «основание, фундамент» > чув. *никĕс*, мар., удм. *никĕз, негызь* < гом. кыпч., уйг., үзб. *негиз*, каз., кырг. диал. *неңиз* «нигез; табигать байлыклары» (Будагов II: 299), үзб. диал. *нәгиз* «чыгыш, нәсел, җәвер», бор. төрки һәм угыз., ш. ук Себер төрки телләрендә бу сүз күренми, ш. ук гар.-фар. алынмасы да түгел.

**Нигез,** безнеңчә, **ниргә** сүзе белән тамырдаш, к. **Ниргә.**

Дерив.: **нигезле, нигезсез; нигезлә-ү, нигезлән-ү; нигезләш-ү.**

**НИГЪМӘТ,** диал. **нигамәт** «яства; стол», «общее благосостояние» < гар. *ни‘мäт* id. ГТРС: 447.

**НИЗАГ** «распря, распри, конфликт» < гар. *низā‘* id. ГТРС: 448.

Дерив.: **низаглы, низагсыз; низаглаш-у.**

**НИЗАМ** «порядок; дисциплина; система» < гар. *ниẓāм* id., **назым** (к.) белән тамырдаш (Будагов II: 286–287). Шуннан **низамнамә** (< фар.) «устав».

Дерив.: **низамлы, низамсыз.**

**НИК,** диал. **нәк** «почему» ~ кар., куман. *нäк* id. – куман теленнән булса кирәк; В. Радлов (III: 670) фикеренчә, бор. төрки *nägä* «ничә» сүзеннән кыскарган (дөресреге: *нэңкэ* > *нэңк* > *нэк*); *нилĕк* > **нилк* > *ник* булырга да мөмкин.

**НИКАХ, никях** «бракосочетание» < гар. *никāх* id. ← *нкх* «өйләнү».

Дерив.: **никахлы, никахсыз; никахла-у, никахлан-у, никахлаш-у.**

**НИКРУТ** «рекрут» < рус. сөйл. *некрут* id. (**рекрут** сүзеннән); к. ш. ук чув., мар. диал., удм. диал. *никрут.* Бу сүз элекке фольклорда киң кулланылган.

**НИЛ** иск. «синька для глаз» ~ чув. *нĕл* < фар. *нил, нила* (шуннан ук исп. > ним. һ.б. *lila* → рус. *лиловый*, к. Kluge: 576), ахыр чиктә һинд. телләреннән, к. Будагов II: 299. **Нил** елгасы атамасына катнашы юк.

**НИ́ЛЕКТӘН** «отчего, с чего» < гом. төрки *неликтен* id., к. ш. ук тат. **нидән** < гом. төрки *нэдэн* id. (к. **Ни I**). **Нилек** сүзе үзе генә кулланылмый.

**НИЛЕТ, нилит** «тесьма, лента для каёмки», (ЗДС: 498) «косоплётка» < ним. *Inlett* «каймалык тасма» > төр. *inlet* id. Тат. теленә рус сөйләшләре аша кергән булса кирәк. Төп мәгъ. «аеруча тыгыз тукылган тукыма» булган, к. Kluge: 441.

Диалектологик сүзлектә бу сүз русча *лента* белән чагыштырыла.

**НИЛҮФӘР** «водяная лилия; донник» ~ чув. *илепер* id. < фар. *нӣлӯфäр* «лотос» ~ гар. *нӣнӯфäр* id. (Будагов II: 299).

**НИ́МӘ**, диал. **нә́мә** «что», **нимә́, нәмә́** «нечто; вещь» (Будагов II: 293) ~ хак. *ниме,* гом. кыпч., алт. *нäмä, нэмэ*, уйг. *нимә, нәмә*, үзб. *нема, нама* id. < бор. төрки *nemä* (ДТС: 358) id. < *neŋ te (ta), neta* < *neŋta* «әйбердер, нидер» мәгъ. булган.

**НИМЕ́С,** диал. **нимеч, мимеч** (**мимеч борчагы** «фасоль төре») «немец» < рус. (рус. *нем* «сөйләшми торган, телсез» сүзеннән), бу сүз тат. теленнән

кире закончалык буенча *немúс* яңгырашында бүтән (кырг., каз., үзб., уйг.) телләргә дә күчкән. К. ш. ук чув. *нимĕç, нимĕч* «нимес», *нимеç пăрчи* «мимеч борчагы» (Сергеев 1971: 143; Саваткова: 100), удм. *немыч, немысе атас* «күркә». *Нимеч* язылышы «Җәмигъ әт-тәварих»та теркәлгән – димәк татарларга XVII г. бирле билгеле. **Мимеч, Нимеч** дип оста кешене дә атыйлар (ТТДС I: 305) – бу XVIII–XIX гг. Россиядә һәртөрле техниклар нимесләрдән булу белән баглы. XIX–XX гг. әд. телдә **нәмсә** язылышы булган.

Хәз. әд. телдә **не́мец** дип язу, безнеңчә, акланып бетми: **нимес** яңгырашы күп кенә фразеологизмнарда һәм топонимнарда да саклана (мәс., Башкортстанда **Нимесләр** авылы – анда хәзер татарлар яши). Өстәвенә русча **не́мец** сүзендә кимсетү («телсез» дию) саклана. Без бу китапта һәрдаим **нимес** дип язабыз, кайбер бүтәннәр дә шулай яза.

Типологик җәһәттән күрше халыкны «телсез», «сакау» һ.б. дип атау киң таралган күренеш. Ләкин татарларга бу – хас түгел.

**НИМҖАН** диал. «мифическое полуживое существо (которое оживает только ночью)» < фар. *нӣмҗāн* «ярты җан» (*нӣм* «ярты»). К. **Нимтән.**

**НИМТӘН** иск. (Будагов II: 299) «половинник (мифическое существо, имеющее только одну ногу, одну руку, один глаз)», чаг. **Ниснас, Шүрәле, Ярымтык.** Азиядә киң таралган бу образ бор. гадәт буенча, кешенең бер аягын, бер кулын сындырып, бер күзен чыгарып җәзалау яисә корбан итүнең чагылышы булып тора. Реальлектә имгәтелгән һәм кырга чыгарып ташланган нимтәннәрнең исән калу ихтималы бик аз булган. Төркиләрнең килеп чыгышы тур. легендаларның берсендә бер нимтән малайның ана бүрегә өйләнүе, шуннан төрки кавем үрчүе тур. сөйләнелә һ.б. К. **Ниснас.**

**НИНДИ** < диал., башк. **ниндәй** «какой, который» < *ниендәй*; тат. һәм башк. телләреннән тыш, бу сүз кар. телендә генә, бүтән телләрдә (шул исәптән кыпч. төрки телләрендә дә) *қандай* кулланыла. *Нинди* сүзенең элекке яз. телләрдәге этимологик тәңгәле *нетӓк*, к. **Нитәккем.**

**НИРГӘ** «венец сруба; учтивость, правила поведения» (Будагов II: 298; ТТДС I: 320–321), диал. **нергә** «сруб фундамента, основание; взаимный подарок и порядок обмена подарками брачующихся сторон во время свадьбы», диал. **миргә** > башк. диал. (БТДҺ: 231) *миҙгә* «фундамент», иске тат. *ниргә* «дивар, стена; тәртип» (Ногман: 98–99), крш. *ниргә* «рәт; тәртип» (*ниргәсез* «тәртипсез, рәтсез, юньсез» (к. Balint: 147) > чув. *нирке* «ниргә, рәт», мар. *нэргэ* «чират; кизү чире» *нэргэн (нергең)* «рәтеннән, турында», удм. *нерге* «рәтендә, чутында; гадәт, кебек» (Алатырев: 149–150); белгечләр (М. Рясянен, В.И. Алатырев) бу сүзне тат. теленнән таралган һәм бор. тат. *йәргә, йәркә (йәркә-сурәт)* > мар., удм. *йерке* ~ кар. *йэргэ, йэргя* «рәт, тәртип» сүзеннән дип карыйлар (*й-* > *н-: йэргэ* > *нэргэ*); *й-* > *н-* күчеше Идел-Урал регионы телләреннән башлыча тат. телендә (ә шуннан читтә хак. телендә һәм алт. сөйләшләрендә) күзәтелә. **Йэргэ* нигезенең гом. төрки чагылышы – тат. диал., иске әд., уйг., чыгт. *җәргә* «хәрби тезем (*җәргә-җәргә* «рәт-рәт») > чув. *çерке* «кәртәләр, чошлар рәте» ~ тув. *черге* «дәрәҗә, иерархия», бур., як. *сэргэ* «ат бәйләү баганалары рәте (бу шәй белән күп кенә мифологемалар, йолагадәтләр баглы)». К. ш. ук *эргә* «ян; нигез; стена».

Гомумән, *йәргә//җәргә//нэргә//эргә* төрки телләрдә киң таралмаган, шунлыктан аны бор. фин-угор алынмасы дип уйлыйлар, к. эстон. *järk*, фин. *järki* «рәт, тәртип».

*Ниргә* белән *нигез* сүзе бәйле булса кирәк, ләкин багланышларның фонетик җәһәте ачык түгел (*нэргэ* > *нэгрэ* > *нэгир* > *нигез* булала). Удм. телендә Н.И. Смирнов (1890: 46) *негырь* «гаилә, нигез» сүзе бар дип яза, ләкин бу мәгълүмат хәз. сүзлекләрдә чагылмый, расланмый. К. **Җәргә, Эргә.**

Дерив.: **ниргәле, ниргәсез** (төрле мәгъ.); **ниргәлек.**

**НИСА** иск. «женщина» < гар. *нисā'* id. Чаг. **Мөәннәс, Нас, Инсан.**

**НИСБӘТ** «отношение, соотношение (величин)» < гар. *нисбӓт* id. ← *нсб* «нисбәт итү, туры китерү, тәңгәлләү» тамырыннан, шунна ук к. **Мөнәсәбәт, Нәсәп,** иске тат. **мәнсуп, мәнсүб** «табигъ, җөмләсенә кергән» һ.б., к. түбәндәгене.

Дерив.: **нисбәтле, нисбәтсез; нисбәтән; нисбәтлә-ү.**

**НИСБИ** «относительный» < гар. *нисбӣ* id., к. **Нисбәт.**

Дерив.: **нисбилек; нисбиләш-ү.**

**НИСНАС** фольк. «мифическое существо – половинник; вид обезьян» < фар. *неснас* id. ~ гар. *нисф ән-нāс* «кешенең ялтысы». *Ниснас*лар тур.

иске (фар., госм. һ.б.) әд. әкият һәм мәсәлләрдә сөйләнелә. К. **Нимжан, Нимтән.** Ögel: 193.

**НИТӘККЕМ, нитәкки** кит. «так как; поскольку дело обстоит так» < чыгт., госм. *нэтäк ки (ким)* «нинди ки, шулай ки», к. бор. чыгт. *нäтäг* «шуның кебек» (Боровков 1963: 228) < *нэ тэг* «ни тиак»; бу тәгъбир гом. төрки характерда, к. кар. *нэтяк*, бор. төрки *netäg* (ДТС: 351) >> як. *сити* «нәкъ шулай» һ.б.

**НИ́ТКӘН** «что за (оказия)» ← **нит-ү.** К. түбәндәгене.

**НИТ-Ү** глагольное местоимение «делать что-то» ~ төр. *net-, neet-* id. һ.б. *нә (ни) ит-ү* тәгъбиреннән гаплология. Чаг. **Нишлә-ү.**

**НИҺАЯТЬ [ниһайәт]** «наконец» – гар. *ниһā-йäт* «оч, соң, ахыр, азак» сүзенең тат. телендә алган мәгънәсе. К. иске тат. **ниһайә** «соң, азак» (шуннан **ниһаясез** «чиксез»)

**НИФАК** «притворство, обман, лицемерие; междоусобная борьба (обвиняя друг-друга в неискренности)» < гар. *нифāķ* id.

**НИФТЕ, нифет** сөйл. «нефть» – рус сүзенең закончалыклы үзгәртелеше (*е > и, ĕ* – эпентеза), рус сүзе < төр. < иске фар. *нäфтä* сүзеннән, беренчел чыганыгы – аккад. *напату* «янучан» (к. Вассоевич А.Л. О происхождении слова «нефть» // Природа, № 8, 1978: 159–160). К. **Нәфет.**

**НИЧӘ,** диал. **нинцә** «сколько» < бор. төрки *neŋčä* «ни кебек» сүзеннән (мәгънәсе дә үзгәреп); к. кар. *неча*, башк. *нисә*, нуг., каз., к.-калп. *неше*, кырг. *нече, нечен*, уйг. *нәччә* ~ тув. *чеҗе* «ничә?». Угыз телләрендә *неҗе, ниже* «ничек?» мәгъ. кулланыла. К. **Ничек.**

**НИЧЕК** «как, каким образом» < гом. кыпч. *нечик* (нуг., каз., к.-калп. *нешик*), уйг. *нечүк* < бор. төрки *nečük* «ничек; нилектән» (ДТС: 356), бор. *neŋ* «ни» сүзеннән, ясалышы ачык түгел.

**НИЧУ** сцйл. «не́чего» < рус., к. ш. ук чув. *неччу*, мар. *неччо*, удм. *нечо* id. Тат. сөйләшләрендә **ничаwа** id.

**НИШАН** «знак (отличия), медаль; знак обручения; знамение, признак; мишень» ~ кар. *нишан, нисан*, уйг. *нишан*, үзб. *нишон*, гаг. *нышан* < фар. *нишāн, нешāн* «нишан, эз; әләм, герб; гәрәү (залог)», к. Будагов II: 284–285. Рус. *мишень* < *нишан* тур. Фасмер II: 630. К. түбәндәгене.

**НИШАНА** «знак на дорогах, на границе и т.п.» – шуннан диал. *нишана* – сөйкемсез кеше, «тәре баганасы» (к. ДС II: 143; БҺҺ II: 183; БҺҺ III: 145) < фар. *нишāне* id.

**НИШАТЫР** «нашатырь» – гар. *нишāдир* id. сүзеннән таралган дип исәпләнә (ләкин төбендә гар. сүзе түгел), к. төр. (госм.) *nişadır, nişadur*, кырг. *ношадур* id. Рус. *нашатырь* билгесез төрки чыганактан. Будагов II: 284; Фасмер III: 51. Хәз. әд. телдә **нишатыр** сүзе кулланылмый, аның урынына русча **нашатырь** дип язалар, хәлбуки тат. **нишатыр** рус теленнән алынмаган.

**НИШЛӘ-Ү** «что делать; что-то делать» < *ни эшлә-ү.*

**НИЯЗ [нийаз]** «радение» (в парном слове **намаз-нияз** «моления и радения») < гар. *нийāз* «тырышлык» (Будагов II: 298); Иске себ. **ниязчылык, ниязчыламак** «дингә, мәчеткә дип акча сорау, теләнү» (шунда ук).

**НИЯТ [нийәт]** «намерение» > удм. *нет* «теләк» << гар. *ниййäт* «ният» ← *нwй* «мәрәйгә төзәү, ниятләү».

Дерив.: **ниятле, ниятсез; ниятлә-ү, ниятлән-ү.**

**НОГМАН: ногман чәчәге** «анемона» < гар. *ну‘мāн* «чишмә». Ләкин **ногман чәчәге** турыдан-туры «чишмә» мәгънәсеннән түгел, ә *Ногман ибне Мунзир* дигән кеше исеменнән, ди Ә. Бируни (к. Бируни 1974: 576). Рус. *анемона* << фр. *anemone* булса кирәк: *anemone* (чәчәкле үсемлек) бор. лат. һәм грек телләрендә дә булган, тик аның да чыганагы бәхәсле. Будагов II: 288; Kluge: 43.

**НОГЫТ [нŏғŏт], нугыт** «нут; бобовник, фасоль»; **ногыт салу** «гадание на бобах» > чув. *нухăт* «ногыт салу», мар. *ногыт* «ногыт», *ногыт пурса* «ногыт борчагы» < иске тат. (Троянский II: 256) *нухуд*, каз. (ҚТДС: 258) *ноқыт,* башк. *ноқот,* (БТДҺ: 246) *нуқта,* госм. *нохуд*, уйг. диал. (Радлов III: 693–694) *ноқуд*, бор. монг. (Поппе 1938: 259) *nōxūd*, бор. төрки (ДТС: 361) *nuqud* «ногыт, төрек борчагы» ~ бор. рус. (Срезневский II: 462; Фасмер III: 86)

*ногуть, нохоть* «борчак (төре)» < фар. *нохуд, нухуд* «ногыт» < *нуһ ғуд* «тугыз борчак» булса кирәк: ногыт кузагында тугыз борчак булучан; ногыт салып юраудa тугыз шакмаклы такта кулланыла (һәрбер шакмакка – күзәнәккә аерым мәгънә салына). Федотов I: 371–372.

Дерив.: **ногытчы** «ногыт белән юраучы».

**НОКРАТ,** диал. (ТТДС I: 321–322) **нукрат, нуграт** «река Вятка; серебряная монета» ~ чув. *нухрат, нăхрат* «борынгы тәңкә» ~ үзб. *нуқра* «көмеш», кырг. *нукура* «саф көмеш», уйг. *ноқрә*, төр. *nukre* «көмеш кисәге» < гар. *ṇуқрāт* «көмеш кисәге; котыйчык; кесә» (к. Әхтәри кәбир: 1101) – асылда «түгәрәк күмәч (келиндер)» булган булса кирәк (көмеш божра бор. Шәрык илләрендә патшалык, монархлык билгесе булган). К. ш. ук **Нукрат.** Кайбер телчеләрнең (Әхмәтҗанов М. Нократ иделе // Шәһри Казан, 15.I.1991) **Нократ** елгасының атамасы рус. *Новград* сүзеннән килә, чөнки елганың башларында Новгород биләмәләре булган дип баруы ышандырмый, чөнки тарихи мәгълүматларда Идел Болгарының төньягында «көмеш болгарлар» булуы тур. әйтелә. Räsänen 1969: 355; Федотов I: 375; Гарипова 1998: 385–389 (бик тәфсилле).

**НОКСАН** «недостаток, дефект» < гар. *нуқҫāн* id. ← *нқҫ* «кимчелекле булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Накыс.**

Дерив.: **ноксанлы, ноксансыз.**

**НОКТА** «точка» < гар. *нуқṭа* id. ← *нқṭ* «таплау, чәчрәтү» тамырыннан.

Дерив.: **ноктaлы, ноктасыз; ноктала-у.**

**НОКЫР** (ТТДС I: 321), **ногыр, лŏкŏр** (к. Юсупов 1971: 228–229) – так называют казанских татар татары-мишари Закамья.

Безнең мәгълүматлар буенча, бу сүзнең *клугур* варианты да бар. Гомумән, ачык түгел. *Ногыр* сүзен бор. төрки **оногур** этнонимына бәйләү (З. Вәлиди) җитәрлек нигезләнмәгән.

**НОТЫК [нŏғŏт]** «речь, выступление» < гар. *нуṭқ* id.

**НОЯБРЬ,** сөйл. **нуябер, наябер** «ноябрь» < рус. < лат., асылда «тугызынчы ай» дигән сүз (к. **Декабрь**).

**НӨГӘР** «один из помощников жениха во время свадьбы» к. **Нәгәр.**

**НӨКТӘ** «недомолвка, тонкий намёк, затаённый смысл» < гар. *нүктӓ* id. ← *нкт* «сөңгене җиргә кадау» тамырыннан (шул кыланыш белән ризасызлыкны яисә мыскылны белдергәннәр).

Дерив.: **нөктәле** (сүз), **нөктәсез**.

Яз. телдә **нокта** һәм **нөктә** сүзләрен бутау күзәтелә (мәс., башк. әд. телендә **нөктә** «нокта»).

**НӨР, нŏр** (к. ГТРС: 321) «облик» ~ чув. *нĕр [нөр]*, к.-балк. *нюр [нүр]*, як. *нюр, н'ур* id. < бор. монг. *nigür* «йөз» (бор. монг. телләреннән гом. төрки алынма) < бор. төрки **йигүр*?

**НӨРЕ [нөрө]** «личинка насекомых» ~ башк. (БТДҺ: 245; Башкирская диалектология: 115) *нор, нур, мыр,* чув. *нăрă* «нөре; коңгыз», төркм. *мөрмөҗек* «һәртөрле бөҗәкләр»; к. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 320) **нерлә-ү, нөрлә-ү** «күп санда һәм тигез үсү (балалар тур.)» – димәк, *нөр, нөре* төп мәгъ. «бөҗәкләрнең бергә торган кортлары», гомумән «бер үк яшьтәге, бергә торган балалар»; ихтимал, *нөр* «йөз» сүзе белән бердәйдер (кызыклы аналогия: рус. *личинка ← лик* «йөз»). Чаг. рус. диал. *ныргa* «вак балык, маймыч» (к. Аникин: 412). Гомумән, бу сүз фин-угор телләреннән булса кирәк, к. удм. *нумыр,* коми. *номыр* «корт, нөре», к. КЭСК: 194.

**НУ I** сөйл. «но (союз)» < рус.; чув., мар., удм. *ну, но* id.

**НУ II** ы., сөйл. «ну» < рус.

**НУГАЙ** «ногаец», диал. «народный бард, исполнитель эпосов» < гом. төрки *ногай* id. Алтын Урда түрәләреннән берсе – Чыңгыз ханның онык оныгы *Ногай, Нокай* исеменнән XIII г. бирле этноним булып киткән; асылда бу сүз монг. *нокаи, ногай* «эт» (**Ногай** ≈ «этбай»). *Нугай (ногай, ногой)* дип Урта Азия халыклары татарларны да атыйлар. К. Будагов II: 295; Аникин: 411.

XVI–XIX гг. дәвамында нугайлар күпләп татарлар, башкортлар һәм чувашлар составына кергәннәр. Аларда эпос-дастан башкару гадәте саклaнып килгән.

Шуны әйтергә кирәк, татарлар белән нугайларны калмыклар да бутыйлар, һәр икесен *мангт* «мангыт» дип атыйлар. К. Ногайцы 1988.

**НУЖА,** (ТТДС I: 321) **нужна** «нужда, бедность» < рус. *нужа, нужда* id.; рус әд. телендәге

**нужда** варианты чиркәү-славян теленнән, к. Фасмер IV: 88–89.

**Нужа** (~ чув. *нуша*) барча Идел-Урал телләрендә киң таралган. Федотов I: 375–376.

Дерив.: **нужалы, нужасыз; нужалан-у.**

**НУК** (ТТДС I: 321) «внук» < рус. диал. *унук* (к. **Онык**) id. К. ш. ук тат. диал. **нука** «внучка» < рус. диал. *унука.*

**НУКРАТ, нукырат** (ТТДС I: 322) «хлев; амбар (часто двухэтажный, соединённый с хлевом)» – ачык түгел, рус сөйләшләреннән булса кирәк (к. рус. *нагóрод* «абзарлар һәм амбарлар берләштерелгән каралты»). Гар. *нуқрат* «зимлянке» сүзенә баглау, арадаш сүзләр юклыктан, ышандырмый.

**НУКТА** «недоуздок, оброть» > мар. *нукта*, удм. *нюкта*, морд. *новта*, чув. *нăхта, нăкта, нăктав* id. < гом. кыпч. *ноқта,* кырг. *ноқто,* к.-балк. *нуқта* ~ чыгт. *нухта*, төркм., хак. *нохта* һ.б. id. < бор. монг. *noγta, noγtu* id. < кыт. *luŋtuu* id. (к. Ramstedt 1935: 278), шуннан турыдан-туры сары уйг. *лохта, лоқта*, маньч. (ССТМЯ I: 504) *лоңта, лоңту* «нукта, йөгән». *Нукта* < *ногта* фар. һ.б. телләргә дә үтеп кергән. Räsänen 1969: 354; Федотов I: 372 (тәфсилле аңлатма); ЭСТЯ VII: 99 (күп кенә параллельләр китерелә).

Дерив.: **нукталы, нуктасыз** (к. мәкаль: *Нократ нуктасыз – чыга да ычкына*); **нуктала-у.**

**НУМАЙ, нюмай** (ЗДС: 500) «много, обильно», диал. (Арсланов 1988: 97) **уммай** ~ чув. *нумай, нуммай, номай* id., нуг., кар. *номай* «күп, мул; күбрәк булсын!», үзб. (ЎХШЛ: 198) *номай* «мул», *нӯмай, мумай* «көтелмәгән бәхет, байлык», каз., к.-калп. *нобай* «мул; муллык» – бор. төрки *Умай* (к.) «бәхет алиһәсе» сүзеннән, аның бор. төрки *Йумай* < *Һомай* вариантыннан (сүз башында *й-* > *н-* тур. к. **Нашмак, Ни, Ниргә**). Федотов I: 375 (бик фәкыйрь аңлата).

**НУЯН [нуйан]** «нойон, военачальник в Золотой Орде» < монг. *нойон* < кыт. *лао йе* «хөрмәтле ир кеше; оста» сүзеннән. Себер телләрендә киң таралаган. К. ССТМЯ I: 495, 604; Poppe 1955: 155; Аникин: 409. Яз монг. *nojan* «кенәз; яубашы; шахмат короле» мәгъ. кызыклы.

**НҮВЕШ [нүwĕш]** диал. «угол дома» < *мүweш* id., к. **мөеш.** Бу **нүвеш** сүзе теркәлгән миш. сөйләшләрендә бер төркем сүзләрдә *м-* > *н-:* **нурда** < *мурда,* **нүwуз** < *мүwез, мүгез* (к. **мөгез**), **нүгәдәк** < *мүгәдәк* һ.б., к. ЗДС: 500.

**НҮШӘР** «обильный иней; длительный дождь, ливень» ~ башк. (БТДҺ: 128) *йүшә, йүшәр,* кырг. *нөшер* (> каз., к.-калп. *нөсер*) id. Ачык түгел. *Й-* > *н-* күчеше тат. сөйләшләрендә төрки сүзләрдә булучан. Чаг. үзб. (ЎХШЛ: 198) *нөш* «көчле яшеллек», *нөш ур* «нүш ору» – «шәбәеп яшәрү (бигрәк тә агачлар тур.)». Чув. (Ашмарин III: 263) *нөсер* «аҗаган» тат. сөйләшләреннән булса кирәк.

**НЫГЫ-У** «крепнуть, окрепнуть» ← **нык** (к.); ясалышы **бай- → байа-, ий- → ийе-** һ.б. (аз продуктив) модельдә.

Дерив.: **ныгын-у, ныгыт-у** (шуннан берничә сүз ясалып, актив кулланыла: **ныгыткыч, ныгытма** һ.б.).

**НЫҖЫ, ныжы** (ТТДС I: 322), **неҗе** (ДС III: 118) «большой чирей; злой дух» ~ мар. (Саваткова: 95) *мыж, мужо* «авыру рухы, зәхмәт».

**НЫК** «крепко, крепкий» > мар. *нык*, чув. *нăк, нăх* < гом. кыпч. *нық* id. Г. Рамстедт (Ramstedt 1935: 276) яз. монг. *niγta* > бур. *нигта*, эвенк. *никта* «пөхтә, төгәл, җентекле» сүзе белән чагыштыра һәм моны бүтән тикшеренүчеләр дә кабатлый. Ләкин монда семантик хилафлыклар да юк түгел. Хәер, хәз. монг. сөйләшләрендә *нягт* «пөхтә» белән бергә *нях, ниг* «таш; нык» сүзе дә бар. **Нык** сүзе (иске сүзлекләрдә **нуқ**) төрки телләрдә бүтән чыганактан да килә ала, к. **Нықла-у, Ныклы**. Räsänen 1969: 353; Федотов I: 371; ССТМЯ I: 637.

Дерив.: **ныгай-у, ныкла-у;** к. **Ныкы-у, Ныкта-у.**

**НЫКЛА-У** «крепить» (преимущественно в форме **ныклап** «крепко, хорошенько») – **нык** сүзеннән; бу сүзнең ясалышы, ихтимал, тат. диал. (добр. һ.б.) **мыкла-у** «кадаклау» сүзе тәэсир иткәндер (к. **Ныклы**).

Дерив.: **ныклан-у, ныклат-у.**

**НЫКЛЫ** «крепкий» – **нык** сүзенең исем мәгънәсеннән шикелле, ләкин андый мәгъ. үзе теркәлмәгән. **Ныклы** сүзенең ясалышына диал. **мыклы** «кадаклы» ← **мық** «кадак» (фарсы сүзе) тәэсир ясаган. Чаг. **Ныкта-у.**

**НЫКТА-У** (**ныкда-у** дип языла ала), **ныка-у, ныга-у** (Будагов II: 290) «закрепить», диал. «повторять (назидательно, чтобы запомнилось)» ← **нык** (к.). **Ныкта-у** варианты каз., кырг. телләреннән алынган булса кирәк, чөнки гом. кыпч. (шул ук мәгъ.) *нықла-* нигезе кулланыла.

**НЫКЧА** «крепкий, крепенький (о человеке)» ~ башк. *нықса* id. – **нык** сүзеннән **какча** (к.) моделендә ясалган.

**НЫКЫ-У** «настаивать» < диал. (ТТДС I: 322) «плотно набивать; уплотнять; давить, надавить» ~ гом. кыпч. *нықы-,* хак. *ныхы-*, үзб. (ЎХШЛ: 198) *нуқу-, ниқи-*, к.-калп. *нуқы-, нуқыр-* id. ← **нык** (к.).

Дерив.: **ныкыш-у** «үз дигәнендә тору, үҗәтлек күрсәтү»; башк. (БТДҺ: 246) *ныкыт-ыу; ныкымыш, ныкыш.* Тат. диал., башк. диал. (БТДҺ: 246) **ныш-у** «ныку» < **ныгыш-у** булса кирәк.

**НЫУ [ны̆w], нŏw, нау** (ТТДС I: 321; Тумашева 1992: 159; ЗДС: 493) «заливной луг, долина (с обильной травой); равнина», иск. (Будагов I: 293) «сенокос, пора сенокошения» ~ каз., к.-калп. *ну, нув*, кырг. *нуқ* id. (к. ш. ук «куе – үсемлек, урман һ.б.») < яз. монг. *піуи, пиуи*, хәз. монг., бур. *нуга* «ныу, тугай» > эвенк. *нугу* id. (к. ССТМЯ I: 608).

# О

**Ŏ** авазы тат. телендә гом. төрки *у (и)* авазыннан килә һәм тулы вариантында беренче ике иҗектә генә әйтелә. Дүртенче иҗектә ул бөтенләй мөмкин түгел.

Бу аваз тат. теленнән тыш башк., чув. һәм эзлексез рәвештә каз. телендә кулланыла.

**ОЕК [ŏйŏķ]** «чулок, носок» > чув. *ăйăх* < бор. кыпч., төркм., төр., уйг. *уйуķ* id., к. себ. *уйуķ,* нуг., каз. *уйыķ,* чыгт., ком. *уйуķ* «пима, киез итек», бор. төрки (ДТС: 608) *ujuq* «киез оек» ~ чыгт. *уг,* алт., хак. *ук*, камас. *ооķ* id. Күпчелек төрки телләрдә юк. Мәгъ. һәм яңгыраш үзенчәлекләре бу сүзне табышмаклы итә, морфемик составы буенча *уй-уķ* яки *уйу-ķ,* к. себ. (Тумашева 1992: 225) **йуй-,** тув. *уй-* «тегү, сыру, чигү», як. *үй-* «ике кисәкне берләштереп тегү». Кайбер тикшеренүчеләр бу сүзне монг. *ойимосун* «оек» белән чагыштыралар (к. Räsänen 1969: 511). Әгәр беренчел мәгъ. «киез оек» булса, *ойык – ое-к-* фигыленнән. К. **Оеш-у, Ойы-у.** К. ЭСТЯ I: 581.

Дерив.: **оеклы, оексыз; оеклык; оекчан; оекбаш.**

**ОЕРША [ŏйŏрша]** «сгусток, клубок» ← **ŏйыр-* «оешкан хәлгә китерү» ← *ŏйы-, ой-* «өстәү, охшау, берләштерү» фигыленнән (к. **Ое-у**). Чаг. ш. ук диал. *оерчык [ŏйŏрчыķ]* «шар итеп катырылган киндераш орлыгы».

Дерив.: **оершалы, оершасыз; оершалан-у.**

**ОЕ-У I [ŏйŏ-]** «онеметь; задремать; свернуться (о молоке)» < гом. төрки *уйы-, уйу-* < бор. төрки *иди-, иди-* > тув. *уду-* > хак., шор. *узу-* id., бор. яз. уйг. *уты-* id. (ЭСТЯ I: 579–581). Тат. телендә башлыча «әчеп куеру» мәгъ. кулланыла; «кансырап хәрәкәтсезләнү» мәгъ. шуннан күчерелмә. Әмма «йоклау» мәгъ. беренчел булса кирәк, к. як. *уу* ~ бор. төрки (ДТС: 603) *u, uv* «йокы». Шуңа охшаш сүзләр фин-угор телләрендә дә бар: мар. *омо* «йокы», *омал-* «(буыннар) оюу; (сөт) оюу», морд. *удомс-* «йоклау» һ.б. Чаг. **Ойы-у II.**

Дерив.: **оет-у, оеткы**. К. **Оеш, Оеш-у.**

**ОЕ-У II [ŏйŏ-]** «свёртываться (о крови, молоке), отекать (от непрерывного сидения, лежания и т.п.); задремать» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *уйы-, уйу-,* башк. *ойо-,* төркм. *уйа-* id. ~ урта төрки *уй-* «(сөт) оюу» һ.б. бор. төрки (ДТС: 606–607) *uji-* < *идї-* «йоклау» белән гомоген булса кирәк. Төрле фаразлар тур. ЭСТЯ I: 574–576, 579–581.

**Ойы-** бик продуктив нигез, к. **Оеш, Оеш-у** һәм аларның икенчел нигезләре.

**ОЕШ [ŏйŏш]** «в виде сгустка, сгустком» – *ойы-* фигыленнән (к. **Ойы-у**).

**ОЕШ-У [ойош-у]** «образовать сгусток; организоваться» ~ каз. *ŏйыс-* id., нуг. *уйыс-* «(сөт) оюу; охшау, тәңгәлләшү», к.-калп. *уйыс-* «йон керешү (киез һ.б. басканда)», госм. *уйуш-* «охшашу; ризалашу» – бүтән кыпч. телләрендә табылмады, аның каруы үзб., уйг. *уйуш-,* төр. *иуиş-* «берләшү», димәк тат. **оеш-у** уйг. яисә төр. теленнән – дөресрәге, әд. чыгтайчадан.

*Ŏйŏш-* нигезе *ойы-у* фигыленнән дә, *ой- < уй-* «бер-беренә җайлашу» фигыленнән дә урт. юнәлеш буларак ясала ала. Төр. һ.б. угыз., кр.-тат., кар. *уй-* < бор. төрки *иδ-, ud-* «җайлашу, иярү; рифмалаштыру һ.б.ш. тур. к. ЭСТЯ I: 573–574. К. **От-у, Уйдырма.**

**Оеш-у**ның дериватлары – **оешма** һәм **оештыр-у**; уйг., кыпч. *уйушма, уйуштур-* безнекенә охшаш мәгънәдә, төр. телендә бу сүзләр икенчерәк мәгънәдә: кр.-тат., төр *иуиşта* «тән оюу» һ.б.

**ОҖМАХ** > башк. *ожмах,* мар., удм. *узьмак,* тат. диал. **җомах** (Г. Толымбай), **ŏчтŏмак** (ТТДС I: 330) «рай» ~ чув. *çатмах, ăçтăмах* (күп вариантлар к. Ашмарин III: 337, IV: 74–78) ~ Котбидә *учтмах, уштмах* «оҗмах; күк» ~ бор. уйг. *уштимах*, *uštmah* < сугд. *'wsrtm'x* (к. ДТС: 617) id. Ләкин сугд сүзе үзе төрки телләрдән булырга мөмкин, шуңа күрә М. Рясянен бу сүзне гом. төрки *уч-* «очу» сүзеннән ди (Räsänen 1969: 509), хәер, бу этимология бик юраулы. Чыгт. *уҗмак* «оҗмах, күк», төркм., госм., чыгт., алт. *учмах*, нуг., каз., к.-калп. *җумах, җумаķ,* кырг. *уҗмак, учмак*, чув. диал. (Ашмарин V: 70) *йăмах*, куман. *уймаķ* «оҗмах» – икенче сүзләр. Безнеңчә, *оҗмах* < бор. чыгт. *уҗалтмаг* «югарылык; югары күтәрү», *уҗал-* «күтәрелү», *уҗа-* «күтәрү (бигрәк тә абстракт, рухи мәгънәдә)» ← фар. *awҗ*

«күтәрелеш, алгарыш» (к. Исхаков 1961: 227–228), к. үзб. *авж олмақ* «үсеш алу». ЭСТЯ I: 614.

Дерив.: **оҗмахлы** (к. мәкаль: *Орышкан оҗмахлы, тиргәгән тамуглы*).

**ОЗ [ŏз]** диал. (Добруҗа татарларында) «расстояние; значительное расстояние», к. әкият башламында *аз китте, оз китте* ~ төр. *az gitti, uz gitti, dere, tepe, düz gitti* «аз китте, күп китте, елга, түбә, төз (дала) китте» (шуңа охшаш башламнар азәри, гагауз, кырым-татар фольклорында да очрый) < гом. төрки **уз*, к. гаг. *уз*, хак., як. *ус, уз* «аралык; озынлык; тигезлек» – чув. *вăрах* «озак», *вăрăн* «озын» сүзләренә караганда һәм монг. *урту* «озын» сүзен дә исәпкә алганда, бор. төрки **ур* (безнеңчә, **урғ*) тамырыннан килә.

Бу тамыр нигез шактый продуктив: к. **Озай, Озай-у, Озак, Озакый, Озат-у, Оза-у, Озын,** к. Будагов II: 130–131.

**ОЗАЙ** (ТТДС I: 325, БТДҺ: 247) «один за другим беспрерывно; в течение; расстояние, промежуток» – бу сүз башк. *оҙай* < *одай-,* каз. *ŏдайы* < к.-калп. *удайы,* кырг. *удаа,* алт. *удаан* «бер-бер артлы; дәвамлы; эзлекле, әкренләп» ← **уда-** «әкренәйтү, сүзу, җайлау» ~ гом. монг., эвенк. (ССТМЯ I: 248) *уда-* «әкренәйтү, тоткарлану» сүзләреннән, ягъни **оз** тамырыннан турыдан-туры ясалмаган, тик *ŏз* < *уз* сүзенең контаминацион тәэсирендә формалашкан. **Уз** һәм **уда** тамырларының гомогенлыгы да бәхәссез түгел.

Дерив.: тат. (Башкортстан газет-журналлары телендә) **озайлы** < башк. *оҙайлы* «дәвамлы». Төр. *uzay* «галәм киңлеге, фәзасы» – неол.

**ОЗАЙ-У** «удлиняться (например, о днях)» < *оз-ай* < *уз-ай* id. «**оз < уз** булып китү» нигезеннән (к. **Оз**), чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 242) *ŏзар-* < нуг., каз., к.-калп., кар., кырг., хак. һ.б. *узар-* «озаю». ЭСТЯ I: 570–572.

Дерив.: **озайт-у.**

**ОЗАК** «долго, долгий», диал. «далёкий» > мар. *узак*, гом. төрки (Радлов I: 1756) *узак* «озак; озын; ераклык» ~ чув. *вăрах, вырах* «озак» – бор. *уз* сүзенең кечерәйтү формасы (чаг. рус. *далековато, далёконько*) яисә *узоқ* «ерак ук» сүзеннән.

Дерив.: **озаклы, озаклык, озакла-у.**

**ОЗАКЫЙ** иск., диал. «давнишний, прошлый» < бор. төрки (ДТС: 375) *ozaγï, ozaqï, uzaqï* «асый, мазый, күптәнге» *oz-* «узу» сүзеннән һәм татарча *узакы* булырга тиеш иде, ләкин *озак, оза-у* сүзләре тәэсирендә *ŏ* белән әйтелә башлаган.

**ОЗАН,** диал. (Тумашева 1992: 161) **ŏсан, усан,** (Радлов I: 1756) **узан**, «тетерев; самец тетерева – косач», (Будагов I: 139) **усан** «тетеря», **кара усан** «косач», **усан** «шершень» ~ башк. (БТДҺ: 248) *оҙан* «көртлек» < угыз., төркм. *узан, озан, узанчы* «җырчы, дастанчы, халык шагыйре, бард», чыгт. *узан, усан* «чәчмә җыр (шигырь булмаган текстны җырлау; прозаик дастаннарны, бигрәк тә “Угызнамә”не көйләп башкару)», төр. (к. Будагов I: 131) *ozan, uzan* «гитарада уйный-уйный җырлаучы, мәзәкләр сөйләүче; дастанчы»; күч. мәгъ. «кычкырынып йөрүчән тыйнаксыз кеше» ← «дастан башкару». **Озан** – ата көртлекнең язын озак итеп «җырлавыннан» шулай аталган (чаг. **Телмәрҗен**). Шөпшәнең *озан* дип аталуы да аның бызылдавыннан була ала.

*Озан* угызча *уз-ан,* ягъни «җырлаган, җырлаучы» чыгт. *уз-, -уза* «дан җырлау; мактау, мактану» фигыленнән. Бу фигыль тат. **өзләү,** башк. *өҙләү, оҙлау* «кай (к. **Кай**) белән эпос башкару» сүзе белән тамырдаш булырга мөмкин. К. Räsänen 1969: 518. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 569–570) *озан* сүзен бор. төрки *uz, ūz* «оста» сүзе белән (шикләнебрәк) чагыштыра. Озаннар тур. угыз телләре филологиясендә әдәбият гомумән күп кенә. К. **Коркыт.** Күрәсең, алар бор. татарлар арасында да булганнар.

**ОЗАН-У** (ДС I: 146) «растягиваться (во весь рост)» < гом. төрки (уйг., госм., алт. һ.б.) *узан-* id., ш. ук «табу, булдыру; ышану, бирелү» (Радлов I: 1759) *оза-у* < *уза-* фигыленең кайт. юн., к. ш. ук чув. *ăсан-* «озатылу».

**ОЗАТ-У** «сопровождать, сопроводить, проводить (гостя)» > чув. *ăсат-* < гом. төрки *уза-т-* «озайту, озынайту, озату, тоткарлау» (Радлов I: 1762); бу сүзнең *оз* < *уз* сүзеннән килеп чыкканлыгы ачык булса да, ясалышы һәм мәгъ. үзенчәлекләре табышмаклы. Тат. *(җеп) озату* «киләптәге яисә күшәдәге җепне буйлык итеп сузу» *оза-у*ның «сузылу» мәгънәсеннән. *Кунакны (кызны) озату* да «сөйләшүне сузу, озак итү» мәгънәсеннән булса кирәк. *Озат-у < узат-у* тур. бик тәфсилле Будагов I: 130–131. «Җеп, бау сузу» мәгъ. борынгыдан килә, к. як. *уһат-* id.

**ОЗА-У** «долго продолжаться; заставлять себя долго ждать» < гом. төрки *уза-* ~ як. *уһаа* id. *оз* < *уз* «озын» сүзеннән, к. **Оз.**

**ОЗЫН [ŏзŏн]** «длинный» < гом. төрки *узун, узын* (к. Радлов I: 1768) ~ чув. *вăрăм* < болг. **уырың* бор. *уз ~ ур* «озынлык» сүзеннән, як. *уста* «озынлык, озын як» < бор. төрки **узун-ы* (Пекарский III: 3080–3082), алт. *узун* «озынлык» бор. *уз* сүзеннән, аның фигыль вариантыннан (?) булса кирәк; ләкин *көнозын* дигәндә *озын* бор. *оз* < *уз* сүзенең инструменталь килеш формасына охшап китә. К. Будагов II: 134; ЭСТЯ I: 171.

Дерив.: **озынлык, озынай-у** (һәм аның икенчел дериватлары), **озынча.**

**ОКТЯБРЬ,** сөйл. **үктәбер** «октябрь» < рус. < лат., асылда «сигезенче ай» дигән сүз (к. **Декабрь**). Бу сүзнең **үктәп** варианты гарәпчәдән.

**ОК-У (окты, огу)** (Радлов I: 1606; Тумашева 1992: 159) «слышать, услышать; слушаться; понимать; запомнить (услышанное)» < гом. кыпч. (кайбер телләрдә теркәлмәгән), алт., уйг., чыгт. *уқ,* хак. *оқ-* id. < бор. төрки (ДТС: 613) *uq-* «аңлау» ~ бор. монг. *uqa-* «ишетү; тыңлау; аңлау». Бу сүз ничектер *уқы-* < *оқы-* (к. **Укы-у**) белән баглы булса кирәк. ЭСТЯ I: 584–585.

**ОЛАК** (ДС II: 146) «далёкий» ← (Тумашева 1992: 160) **ола-у** «ераклашу». К. **Олак-у.**

**ОЛАК-У (олакты, олагу)** «уходить и пропасть без вести, запропаститься» ~ башк. (БТДҺ: 250) id., ш. ук «адашу» < брб. (Тумашева 1992: 215), үзб. (ЎХШЛ: 265) *улақ-, ула-* «бушка йөрү, юкка мавыгу, тинтерәү; олагу», себ. «арттырып сөйләү», ком. *ула-* «азыну». Арытабан ачык түгел. Бик ихтимал, **ола-у** «ераклашу, ераклаштыру» белән гомогендыр. Будагов (I: 152) *олақ-* < *аулақ-* ди. Чаг. **Аулак.**

Дерив.: **олагыш-у, олактыр-у.**

**ОЛАН, ылан** «дитятко, малыш; братец» ← иске тат. *ŏлан* < *улан* «асылзат егет; шаһзадә, принц» сүзеннән поэтик-иркәләүле атама, к. **Углан.**

**ОЛАТА I,** себ. (ЗДС: 503) **оллата, олатай** «дед (родной), дедушка». Башк. әд. *олатай* id. тәэсирендә таралган булуы ихтимал. Әлбәттә, *олы ата ~ олыата* тәгъбиреннән кыскарып килеп чыккан, к. **Олы.** Тат. сөйләшләрендә (Уралда) *оланай, өләнәй* «дәвәни» сүзе дә очрый, бу башк. *оләсәй* id. < *оло әсәй* сүзенә охшашлы.

**ОЛАТА II** (ЗДС: 503) «достигая, вплоть до; начиная с (данного пункта)» – **олат-у** нигезенең хәл фигыль формасы. К. **Ола-у.**

**ОЛАУ [ŏлаw]** «подвода; воз; караван телег или саней» > чув. *лав* < *ăлав* «олау, арба», мар. *ула* «олау» (*улазу* «олаучы») < гом. кыпч., к. к.-балк. *улоў* «транспорт», каз. *лау, ылау,* уйг. (кыпч. телләреннән) *улав* «олау» < бор. төрки (ДТС: 608) *ulaγ* «олау аты; ямнар арасында йөри торган почта транспорты», ш. ук «ялгау, ямау; бер-берсенә аллыартлы бәйләнгән атлар теземе» < *ula-* «ялгау, тезү» < (безнеңчә) **uγla-* id., к. тув. *угла-* «тоташтыру; юнәлтү» (к. **Ола-у**). К. ш. ук кырг. *улоо* «баш-башы төйнәлгән төш, бәй».

Бор. төрки *ulaγ* сүзенә чыгт., уйг. (Будагов I: 152), тув. *улақ* «почта аты; алмаш ат», госм., аз. (АДДЛ: 395) *улах*, фар. *улаг,* көрд. *улақ* «ишәк, дөя кебек кәрван хайваны», куман., госм. *улақ* «чапкын; ямылчы» сүзе тоташа.

Бор. *ulaγ* сүзенең бор. монг. тәңгәле *ulaγa* олау һәм олаучыны да, олау атын да белдергән, шуннан бор. төрки *ulaγa* «хәрби ат, хәрби олау аты» ~ хәз. як. *улага* «нәрсәнең дә булса артындагы, чираттагы шәй; күрәсең, *улага ~ улаг ~ улақ* олауны гына түгел, аргышны, ямыл системасын да белдергән (к. **Аргыш**).

Монг. *улага* > кыпч. **улаwа* вариантына рус. *лава* «бер-бер артлы килеп һөҗүм итү» сүзе дә тоташа, дип язалар. Гомумән, бор. төрки-монг. сүзе Евразиянең бик күп телләренә (һинд-ир., Кавказ, слав., фин-угор һ.б.) үтеп кергән һәм аның тур. күп язылган, к. Räsänen 1969: 512; Doerfer II: 102–107; ЭСТЯ I: 574, 587–589; Федотов I: 326–327.

Дерив.: **олаула-у; олаулы.** К. **Ола-у, Олаучы.**

**ОЛА-У I** (Остроумов 1876: 129; ТТДС I: 326; Тумашева 1992: 326; БТДҺ: 250), трбс. **үлә-ү** «присоединять; надставлять; удлинять; прибавить; привязать один к другому в ряд» < гом. кыпч., уйг., чыгт., госм., алт. һ.б. *ула-* (к. Радлов I: 1676–1678) «тоташтыру; дәвам итү, тезү; бармак төртеп күрсәтү; юнәлтү» (мәгъ. җәһәтеннән охшаш очрак: **кушу** «ялгау, күрсәтү, әмер бирү»), безнеңчә, бор. төрки **угла-* id., к. уйг. *улла-*, тув. *угла-* «бер линиядә тоташтыру; юнәлтү» ← *уг, угу* «юнәлеш»; к. ш. ук алт. *уула-* «юнәлтү; күрсәтү» > хак. *ула-* id.

**Ола-у** төрле тат. сөйләшләрендә шактый продуктив нигез: **олат-у, олаш-у** «тоташу», **олашык** «тоташкан» һ.б. Нигез мәгънә кырг. *улоо* «башбашы төйнәлгән, бәйләнгән төш, төен, бәй» ~ бор. төрки (ДТС: 608–609) *ulaγ, ulïγ* «төен, бәй, тоташма» сүзендә ачык чагыла. К. ш. ук Будагов I: 151.

**ОЛА-У II** диал., башк. **оло-у** «выть; непрестанно плакать» ~ **ула-у** сүзенең гади филициясе түгел, чөнки тат. телендә дә **олы-у** варианты бар.

**ОЛАУЧЫ [ŏлаwчы̆]** «подводщик», «ямщик» > мар. *улазе* «ямщик» ~ бор. гом. төрки **улагчы* id.; тарихта төрле мәгънәләргә ия булган, к. кырг. *ылоочу*, калм., монг. *улачи, улаачин* «олауда ниләр барлыгын гүаһлап баручы хәбәрче кеше, комиссар», бур. > рус. диал. *улачи, улачен* «олау станциясе; ямчылар яши торган авыл; ерак араларга йөрүче почтальон» һ.б. Монгол хөкемдарларының махсус *улагчылары* булган. Velidi: 489; Фасмер III: 158; Аникин: 582.

Бор. монг. *улаачин* сүзенә **лачын** ~ башк. *ыласын* «бик әйбәт ат; чабышкы» (к. **Лачын**) сүзе дә тоташа бугай: монгол курьерларының пайзаларында (к. **Пайза**) лачын сурәте булган (Хара-Даван, к. На стыке...: 117).

**ОЛБАН, олпан** (Будагов I: 153) «отлогий, некрутой» < фар. диал. *улубан* «киң горизонтлы, зур мәйдан күренеп тора торган» сүзеннән булса кирәк.

**ОЛГАШ-У** (ДС I: 254) «подвергаться (болезни)» ~ башк. (БРС 1996: 471) *олғаш-* «күтәрелү», башк. диал. (БТДҺ: 250) «аралашу; кирәк булу; өлгерү, җитешү; дучар булу; ябышу, укмашу (?)» – чаг. **олаш-у,** төр. (һ.б.) *ulaşmak* «җитү, җитешү, өлгерү» һ.б. **Олгаш-** < **улгаш-* (бу фонетик вариант хәз. төрки телләрдә юк шикелле) бор. **ол-* < *ул-* фигыленең *-ға* морфемасына киңәйтелгән (*улаға-*) вариантыннан, яисә (ихтималрагы) тув. телендә сакланган *уғла-* «юнәлтү, олау» (к. **Ола-у**) сүзеннән метатеза (*уғла-* > *улға-*).

Дерив.: **олгашын-у** (*болытка олгашынган таулар*…), **олгаштыр-у.**

**ОЛГЫН, ŏлғон** (ТТДС I: 326) «многоопытный, маститый» ~ төр. *olgun*, бор. төрки (ДТС: 366) *olγun* id. – угыз. *ол-* < бор. төрки *ol-* «җитешү» фигыленнән. Бу фигыльне гом. төрки *бол-* «булу; өлгерү» фигыленең угызча үзгәргән варианты дип аңлаталар, к. **Ул-у.**

Дерив.: **олгынлык; олгынлан-у.**

**ОЛПА** (БТДҺ: 251) «почтенный; величавый; видный, крепкий» – **олпат** (к.) сүзе белән баглы, әлбәттә. Бу сүз башк. телендә кире сүзьясалыш юлы белән **олпат** сүзеннән ясалган булса кирәк (монда **олы** сүзенең контаминацион тәэсире юк түгел).

**ОЛПАК** «подушка на основе верблюжьей шерсти» ~ каз. (ҚТДС: 254) *ŏлпақ,* кырг. *улпақ ~ урпақ* id., к. **Өрпәк.**

**ОЛПАТ** «солидный, серьёзный» ← башк. *ŏлпат* < каз. диал., кырг. *улпат* id.; бор. кыпч. сүзе ниндидер *-пат* кушымчасы ярдәмендә *олы* сүзеннән ясалган кебек, ләкин чынлыкта уйг. *үлпәт* «дуслык, компания; әңгәмәдәш, дус» < гар. *үлфӓт* «дуслык, әңгәмәдәшлек» > иске тат. *өлфәт* «әңгәмәдәшлек; әңгәмәдәш» (**Өлфәт** дигән газет та булган, к. Әдәби сүзлек: 193) сүзенең халык этимологиясенчә үзгәрүеннән килә, к. ш. ук кырг. *үлпөт*, к.-калп. *үлпет,* каз. диал. *үлпәт* «дуслар компаниясе; 30–40 кешелек ир-ат береге» (ҚТДС: 361), *үлпеттĕ* ~ башк. *олпатлы* «олпат, хөрмәтле; җитди әңгәмәдәш булырлык», үзб. *улфат, үлфәт* «дус» (ЎХШЛ: 382), каз. *ŏлпатан* «бөтенесе бергә» һ.б.

**ОЛТАН** «подошва обуви, подмётка» > мар. *ултан, утан*, удм. *ултон* ~ каз. *ŏлтан* < гом. кыпч. *ултан, ултаң*, алт. *ултан, ултам, ылдаң*, алт., уйг. диал. *ултаң* (к. Радлов I: 1699–1700) id., чыгт. (XV г.) *ултаң гӧн* «калын күн», бор. төрки (ДТС: 609; Clauson: 131) *uldaŋ, ulduŋ* > тув., хак. *улдуң*; як. *уллуң* «олтан». Авазлар составы буенча төркм. *олтаң*, ком. диал. *ортан*, тув. *ултуң* һәм иске тат. (Будагов I: 83) *ŏлдуан* id. аерылып тора. Тув. һәм як. сүзләре «чирек (адымның дүрттән бер өлеше), фут» мәгъ. кулланыла (ш. ук тат. **табан** id.).

**Олтан** сүзе, безнеңчә, бор. **ултанғы* «өстенә басып йөргеч» сүзеннән һәм *ултан-* «өстенә басу, таяну» ← *улта-* «аяк астына салу, аяк асты итү» фигыленнән. К. **Олтар-у.**

**ОЛТАР-У** «ставить подмётку, снабдить подмёткой; обувать, обуть» ~ башк. (БТДҺ: 251) *олтар-* «җөен эчтә калдырып тегү», нуг., каз., к.-калп., кырг. *ултар-*, хак. *ултур-*, тув. *улдур-, улдура-*, як. *уулар-* id. **улта-, *улту-* «катлам аерылу, катлам хасил булу» фигыленең йөкл. юн. Тат. диал. (ДС I: 143) **олтыра-у** «тузып, тетелеп бетү, какшау» < **олты-ра-**, к. бор. төрки *uldï-* «аяк табанының тиресе кубалаклау, атның дагасы төшү» (ДТС: 609); *улта-, улту-* фигыле исә уйг., чыгт. *ул*, үзб. диал.

(ЎХШЛ: 269), бор. төрки (ДТС: 608) *ul, (uul)*, хәз. монг. *ул* ~ бор. монг. *ula* > эвенк. *ула* «табан; нигез; төп» тамырыннан (әмма ясалышы бигүк ачык түгел), к. Räsänen 1969: 512; ЭСТЯ I: 449–451; ССТМЯ II: 257. К. **Олтырак, Олы, Утыр-у.**

**ОЛТЫРАК [ŏлтŏрак]** «стелька» > мар. *утрак*, удм. *ултырак, ултрак* id. < бор. кыпч. *ултарыk,* алт. *ултурак*, каз. *ылтырақ,* нуг., каз., ком. *ултарақ* id. *ултар-, ултур-* «олтару» фигыленнән. К. югарыдагыны.

**ОЛУГ** «великий (о чине); высокочтимый» < чыгт., уйг. һ.б. *улуғ* < *уллуғ* id. К. **Олыгай-у, Олы.**

Дерив.: **олуглык.**

**ОЛЫ [ŏлŏ]** «старший; большой, великий; важный» < гом. кыпч., госм. *улу,* каз., төркм. *улы,* кырг., як. *улуу,* тат. диал. (Гиганов; Тумашева 1992: 160) **ŏллŏ,** (ЗДС: 503) **ŏллы,** үзб. диал. (ЎХШЛ: 268) *уллы,* нуг., ком., к.-балк. *уллу* id. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 593–594) бу сүзне бор. төрки, чыгт. **ул* «зур, күп» сүзеннән ди һәм тат. диал. (к. ТТДС I: 451) *олла-* ~ госм. *ула-* «күбәю» һ.б. кайбер шундый фигыльләрне мисал итеп китерә. Бор. төрки *ул* «күп, масса» сүзе булганлыгы шиксез – бу сүз фигыль ясагыч *-ла* һәм сыйфат ясагыч *-лы (< -лыг)* кушымчалары нигезендә ята (чаг. *каенлык* << *каен-ул-уг* ≈ «каен күп + сыйфат кушымчасы *уг*»). Ләкин, безнеңчә, *ŏллŏ* < *уллуғ* варианты беренчел мәгънәдә килә һәм сүзнең тамыры – *ул, уул* «өлкән кешеләр утыра торган урын – махсус ястык», к. бор. төрки *ulla-* «хөрмәт күрсәтү, *ul*га утыру (ДТС: 610). Чаг. **Утыр-у.** Рясянен да (Räsänen 1969: 513) сүзнең тамыры бор. төрки *ul* «фундамент» дип күрсәтә. К. **Олтар-у.**

Дерив. киң: **олло** (себ., ЗДС: 503) «тәүге бала», **оллата** «дәвәти» (~ башк. *олатай* id.), ш. ук **олинә; олло-кары** «өлкәннәр»; **олғон, олгын** «хөрмәтле», **олоқла-у** «олуглау, олы дип хөрмәт итү» һ.б. (башлыча себ. сөйләшләрендә); әд. телдә **олылык; олыла-у; олысымак.** К. ш. ук Будагов I: 157.

**Олы** сүзенең катнашлыгында ясалган фраземалардан тат. диал. **ŏлŏ көн** «якшәмбе; пасха», каз. *ŏлыстың ŏлы күнě* «нәүрүз» (Кенесбаев: 630), хак. *уллюкүн, үлүкүн, улуг күн* «бәйрәм», тув. *улуг хүн* «якшәмбе», бор. төрки *uluγ bačaγ* «ураза», *uluγ bačaγ kün* «ураза гаете» (*bačaγ, bačaq* манихей һәм христиан уразасы, к. ДТС: 76) һ.б., һәм шуннан ук күрше телләрдәге калькалар: чув. *мăн кун* «зур көн», мар. *мун кун, куго кече*, удм. *бадзым нунал,* морд. Э. *ине чи*, морд. М. *очыжи* – барысы да «зур көн» – «пасха»: бу сүз христианлык белән бәйле (рус. *воскресенье* – Гайсә пәйгамбәрнең үлгәч тагын бер көнгә терелүе). Димәк, бор. татарларның бер төркеме христианлыкның бер мәзһәбендә (ихтимал, несторианлыкта) булганнар (бу хәл мөселманлыкны кабул иткәнче булырга мөмкин) һәм күршеләргә дә йоктырганнар. К. **Олыгай-у.**

**ОЛЫГАЙ-У [ŏлŏғай-], олгай-у** «стать старым, пожилым; входить в преклонные лета» < гом. кыпч., уйг., үзб., чыгт., бор. төрки һ.б. *улғай-, улуғай-* id. ← *улуғ* (к. **Олуг, Олы**); уйг., үзб., чыгт. телләрендә бу сүз конкрет, матди «үсү; зураю» мәгъ. кулланыла.

**Олғай** сүзендә кыпч. телләрендә закончалыклы рәвештә редукцияләнгән *-ғ-* авазы саклануы кызыклы.

Дерив.: **олыгаеш-у, олыгайт-у** «олы, карт дип исәпләү» мәгъ.

**ОЛЫК [ŏлŏқ],** диал. (ДС I: 234) **ылук** «луг» ~ чув. *улăх,* удм. *улыг,* мар. *улыk, олыk, алыk* «болын» рус. *луг* «болын» яисә *лог* «уйсулык» сүзеннән булса кирәк; *улык мари* русчага «луговые мари» дип тәрҗемә ителә (Иделнең сул ягы – түбән тигезлекле җирләр күз алдында тотыла). Чаг. ш. ук тат. диал. *уйлык* «тигез түбәнлек». Фин-угор телләрендә дә (удм.) *ул* «түбәнлек». Монда халык этимологиясенә урын бар.

**ОЛЫН [ŏлŏн]** диал. «ствол дерева; ручка (инструмента), полотняная часть узорного полотенца, грунт вышивки; подушка телеги; копчик; хребет, спинной мозг» ~ башк. (БТДҺ: 250) *олон* id. < бор. төрки (ДТС: 366) *olun* «кәүсә; сабак». **Йөлен** (к. **Йөлә, Йөлен**) сүзе белән тамырдаш булса кирәк. Чаг. **Улак.**

**ОЛЫС [ŏлŏс]** «большая область, страна, владение» < гом. төрки *улус* id. к. **Улус**. Бу сүз хәз. көндә әдәбиятта ошбу рәвештә язылса да – бу хәл гом. төрки сүзне ясалма татарчалаштыру гына, чөнки татар гом. халык телендә мондый әйтелеш булмаган. Гомумән, мондый «яңа» татарчалаштыруларга (чаг. ш. ук *угор* > *угыр* һ.б.) без каршы: алар тарихны бозып күрсәтә башлый.

**ОМА [ŏма],** (Тумашева 1992: 154, 160, 164, 225; ЗДС: 680) **умма, өммә, өммәлә(й)** «совершенно не, совсем не, нисколько» к. **Өмә.** Гомумән, ачык түгел.

**ОМБЫ [ŏмбŏ]** «река Омь», название рыбы ~ каз. *Умбы* «Омь»; чаг. иске тат. **умпы** «таран» (Шпилевский 1877: 29). К. **Умбы.**

**ОМСЫН-У [ŏмсŏн-],** диал. **ымсын-у** «обнадёжиться, (напрасно) надеяться на скорое исполнение вожделенного желания» ~ башк. *ымһын-,* чув. *ăмсăн-, ăмсан-* «кызыгу» < гом. кыпч., к. кар., кырг., чыгт. һ.б. *умсун-*, госм. *умсан-* id. ← **умсы-, *умса-* «өметләнү» (чаг. **җирсә-ү, суса-у** һ.б.) ← гом. кыпч., гом. угыз. *ум* «алгы як»; *ум-* «өмет итү; омтылу», бор. төрки (ДТС: 611) *ит-* «ышанып көтү». К. ш. ук алт., хак. *умзан-* «омтылу». Күрәсең, **омсын-у** һәм **омтыл-у** уртак тамырдан киләләр.

**Омсын-у** фигыле контаминацион-маргиналь охшаш сүзләргә бай: тат. **ымсын-у** «ихтыярсыз ымлау» ← **ым** (к.); чув. *хăмсăн-* «омсыну» (Сергеев 1971: 54) < тат. диал. **қŏмсын-у** «комсызланып карау» (булса кирәк); алт. *амза-*, як. *амсай-, амтан-* ~ бур. *амһа-*, маньч. (ССТМЯ I: 38–39) *амсула-* «татып карау» һ.б. ЭСТЯ I: 596; Федотов I: 83 (тат. сүзен искә дә алмый).

Дерив.: **омсыныл-у, омсындыр-у;** башк. (БТДҺ: 405–406) *ымтаныу, ымшаныу* «омсыну» фонетик дивиацияләр булса кирәк (башк. теле дивиацияләргә бай).

**ОМТЫЛ-У [ŏмтŏл-], ынтыл-у** «устремляться; порываться; стремиться» > чув. *ăнтăл-* id. < гом. кыпч., к. нуг. *ымтыл-*, башк. (БТДҺ: 405) *ымдыл-*, каз., к.-калп. *умтыл-*, кырг. *умтул-*, уйг., үзб. *интил-* id. һ.б. ← **ынты- ~ унту-* «омтылышлы булу», к. алт. *умту-* «тотырга тырышу, тоту», кырг. (Радлов I: 1172) *омтун-* «ташлану». Бу сүзнең кызыклы паронимы тат. диал. (Будагов I: 102) **ымтырыл-у** ~ каз. *ымтырыл-* «омтылу, күтәрелү, ташлану» ← **ынтыр-, *ымтыр-* фигыленең фонетик варианты я ниндидер *ын-* (һ.б.ш.) фигыленең йөкл. юн. Ул **ын- ~ ун- ~ ум-* фигыленең төп мәгънәсе ачык түгел. Ихтимал, ул уйг., кр.-тат., госм., бор. төрки *ум-*, *умы-* «өметләнү» фигыле белән бердәйдер (формаль назардан, *ум-* вариантыннан *умтыр-*, ә *умы-* вариантыннан уйг. *умыт-* «өметләндерү» ясалуы табигый). Чаг. **Ымсын-у.** ДТС: 611–612; ЭСТЯ I: 654; Федотов I: 85.

Безнеңчә, чув. *ăмăрт-* «ярышу» < иске тат. **ымтыр-**, ә чув. *ăмăртăл-* «омтылу» < тат. **ымтырыл-** (чув. телендә метатезаланган).

Дерив.: **омтылын-у, омтылыш-у, омтылдыр-у; омтылыш.**

**ОН,** диал. (ДС II: 147) **ŏм** «мука» < гом. кыпч., уйг., алт., чыгт., гом. угыз. *ун*, төркм., бор. чыгт. (Мухамедова 1973: 182) *уун, ушун* id. М. Рясянен буенча, *у-, уш-* < *уғ-* (к. **У-у**) фигыленнән (*у-ғын, уғын* яисә *уғ-ғын*). Бу фикер тат. диал. **ŏм** ~ үзб. диал. (Будагов I: 158) *ум* < *у-ым* яисә *уғ-ум* варианты булуы белән дә ныгытыла (чаг. **агын ~ агым, явын ~ явым** һ.б.ш.). Чув. *çăнăх* «он» < **йŏнŏк* < **уйн-ук* < **уғн-уқ* (яки бүтәнчә) фонетик үзгәрешләр нәтиҗәсе булса кирәк.

Räsänen 1969: 514; Федотов II: 95–96; Кажибеков: 232.

Дерив.: **онла-у, онлан-у; онлата; онлы, онсыз; онлык; онча, ончы, ончык, онаш;** к. **Онтак, Ончыл.**

**ОНТАК,** диал. **онта, онты,** (Радлов I: 1639, 1645–1546) **ундақ** «мучная *или* мучнистая пыль» < гом. кыпч., алт. *унтақ,* хак. диал. *уннак* «он итеп төелгән» ← *унта-* «он итеп төю» > тат. диал., башк. **онта-у** «төеп он ясау». Монда *-т-* аңлашылып бетми: *онта-* < *онла-* (*унта-* < *унла-*) күчеше диссимилиция көчле үсеш алган телләрдә генә була ала, тат. андый түгел.

**ОНТЫЙ** себ. (Тумашева 1922: 160; ЗДС: 504) «мягкие валенки» < рус. *унты, унто* «тиредән, күннән эшләнгән төрле озын аякчу, йон тышкары мехлы итек һ.б.ш.» (Аникин: 585; Россиянең төньягында һәм бөтен Себердә таралган сүз икән) < эвенк. *унта* «мехлы аякчу». Бу сүз тур. күп языла, ләкин тат. варианты искә алынмый.

**ОНЧЫЛ [ŏнчŏл]** «мучнистый» – әд. телгә хата яңгыраштa кергән: *ончыл* тел мантыйгына күрә «он яратучан», ә рус. «мучнистый» мәгъ. *онсыл* булырга тиеш (чаг. *сусыл* һ.б.ш.). Ләкин *ончыл корт* дигәндә **ончыл** – дөрес.

**ОНЫК [ŏнŏқ]** «внук», **оныка** сирәк «внучка», диал. **нук, нука,** (ТТДС I: 321–322) **мынук** «внук, внучка» (подразделяются не очень последовательно) ~ мар. *уныка,* венг. *unoka* id. куман. *unuc* «онык», кар. *унук*, тув. *унуқ* «токым», «өч яшьлек» (к. Потапов Л.П. Очерки народного быта тувинцев. М., 1969: 326, 339), төркм. *овнуқ* «өлеш» ~ тунг. телләрендә *нэкун, нокун, нукун* һ.б. (бик күп вариантлар, к. ССТМЯ I: 617–618) «җиян (сеңленең улы); онык; энекәш», монг. *нуган* «угыл; токым». Мәзкүр сүзләр *онык* < рус. *внук, нука* < рус. диал. *внука* дип гади генә аңлату белән канәгатьләнергә

мөмкинлек бирмиләр; киресенчә, рус сүзләре куман яисә бор. бер төрки теленнән дә була ала: рус. *ынук, ынука* (диал. *унук*) сүзләренең этимологияләре бигүк ышандырырлык түгел. О.Н. Трубачёвның «История славянских терминов родства» (М., 1959: 73–76) китабында рус. (гом. слав.) *унук* һинд-евр. **aĥn* «җәт, бор. баба» сүзеннән, шуның киреләмәсеннән диелә. Бу киреләмә («дәвәти» мәгънәсенең «онык» мәгънәсенә әверелүе) үзе сирәк очрый торган күренеш (һәм, гомумән, бармы икән әле?). Аннары О.Н. Трубачёв *внук* сүзенең ясалыш моделен дә күрсәтми. Шуңа күрә Фасмер (I: 328–329) *внук* сүзенең этимологиясен аныксыз калдыра.

Татарча *онык-оныка* сүзләре, *тудык-тудыка* сүзләре рәтендә (моделендә); к. ш. ук *чулык* «оныкның баласы», *юлык* «чулыкның баласы» – барысында да бор. төрки *-ук* кушымчасы (бор. *уг, уķ* «нәсел; кавем») бар. Чаг. ш. ук башк. диал. *оноķта-у* «кушу, ялгау, дәвам итү» (БТДҺ: 252).

Халыклар тыгыз аралашканда нәсел-нәсеп терминнары ят телләргә дә күчә; төрки нәсел-нәсәп атамаларын гар., фар., Кавказ, слав. телләрендә еш очратырга мөмкин; төрки телләргә *кода, кодагый* кебек алынма сүзләр күптән хас. Һәм славяннарның төркиләр белән аралашуы нәсел-нәсәп терминнары үтеп керерлек дәрәҗәдә булган. Шунлыктан без *онык*, *оныка* сүзләрен төп төрки дип исәплибез.

Рус теле буенча хезмәтләрнең берсендә дә *внук ~ унук* сүзенең төрки алынма булу ихтималы каралмый, чөнки, беренчедән, *унуķ* гом. төрки сүз түгел, икенчедән, рус телчеләре гомумән төрки телләрдән алынмаларга кырын карыйлар. Безнеңчә, *унук* сүзенең төрки телләрнең күпчелегендә онытылган булуы бер дә гаҗәп түгел: нәсел-нәсәп атамалары төрки телләрдә бик чуар, үзгәрешле, хәтта якын телләрдә дә алар кискен аерымланган булырга мөмкин (чаг. тат. *ана* ~ башк. *әсә*, лексикасы татарныкына бик якын булган чув. телендә нәсел-нәсәп атамалары бөтенләй үзгәчә һ.б.). К. ш. ук **Нука.**

**ОНЫТ-У [онот-]**, диал. **омот-у, умут-у** (к. Тумашева 1992: 225) «забывать» < гом. кыпч., уйг., угыз. *унут-*, бор. төрки (ДТС: 612) *unut-, unït-*, нуг. диал., каз., к.-калп. *умыт-*, хак. *умут-*, тув. *унт-* > *ут-* «оныту» формасы буенча бу сүз бор **уну-, *уму-, *уңу* > башк. диал. (к. БТДҺ: 252) *ŏңŏ-* «онытылу, онытылып китү» фигыленең йөкл. юн., шул *уну-* > *ŏнŏ-* фигыленең *ŏнŏн-* (кайт. юн.) формасы К. Насыйри сүзлегендә дә күренә (ЛТ I: 46).

*Уну-, уңу-, уму-* вариантлары уртак **умңу-* нигезеннән киләләр, к. эвенк. (һ.б. тунг.) *омңо-* «оныту» (күп фонетик вариантлары бар, к. ССТМЯ II: 47). *Омңон-* > *омон-* «оныту» (әлеге фигыльнең кайт. юн. болг. телендә кулланылган, шуннан мар. *мунт-, монт-* < *омонт* «оныту» һәм чув. *ман-* < *мант-* «оныту» сүзләре килә. К. ш. ук як. *умун-, умнат-* «оныту».

Алт. *унту-*, хак. диал. *уңду-* «оныту» формалары ничек тәшкилләнгәнлеге ачык түгел.

Бур. *унта-*, монг. *умта-, уңта-* > як. *оңто-* «төләрү, йокымсырау» сүзеннән чыгып *омңо-* тамырын бор. гом. төрки *у-*, фин-угор *ум-, ом-* «йоклау» тамыры белән кардәш дип уйлыйлар. Рамстедт 1957: 175; Räsänen 1969: 514; ЭСТЯ I: 597; Федотов I: 342.

Дерив.: **онытыл-у, онытыш-у, оныттыр-у;** диал. (әкиятләрдә) **оныткы** (дару, агу).

**ОҢГЫ [ŏңғŏ]** «отверстие, трубка для вставления топорища, рукоятки, ручки, черенка; основа наконечника копья и т.п.», (Исәнбәт II: 835) «отверстие в костях» ~ башк. (БҺҺ II: 187; БТДҺ: 252) *оңго, оңķа* «чалгы ямавы; оңгы» < гом. кыпч., к. каз. *уңғы*, кырг. *уңгу* «оңгы; бораулангaн тишек һ.б.ш.» ~ чув. *ункă*, удм. диал. *уңго,* мар. *оң, оңго* «элмәк; балдак, күгән, тупса (шарнир)» ~ бур., эвенк. (ССТМЯ II: 278) *унги*, маньч. *унгин* «оңгы». Федотов II: 281 (тат., башк. сүзләрен искә дә алмый). Ахметжанов: 54–55; 82.

Күрәсең, **оңгы < уңку** бик бор. (һәм хәзер дә кирәкле) сүз. Ихтимал, ул **умыртка** (к.) сүзе белән тамырдаштыр.

**ОҢКЫТ I [ŏңķŏт], оңгыт:** *Кош яманы оңгыт, ил яманы маңгыт* мәкалендә *оңгыт* «өке» булса кирәк (**маңгыт** исә XVI г. искиткеч эзлексез, акылсыз сәясәт йөрткән нугай кабиләсе), диал. *оңкыт, оңкот* «надан мәҗүси кеше» (бу сүзләр күп чыганакларда китерелә). Чаг. алт., тув. һ.б. Себер төркиләрендә *оңгут* «шаманизм диннәрендәге төрки кеше», «шаманистик тәре, кош шикелле пот», «Себер төркиләрендә, тунгусларда һәм аеруча монгол халыкларында киң таралган санәм», *онгон* сүзенең күп. формасы. К. Зеленин Д.К. Кулы онгонов в Сибири. М.–Л., 1936 (калын гына китап); МНМ II: 256; ССТМЯ II: 21; Аникин: 425.

Ул *онгут, онгоннар* тур. күп материал җыелса да, сүзнең этимологиясе томанлы булып кала.

**ОҢКЫТ II [ŏңķŏт]** (ЗДС: 504) «обжора, человек, который много ест». Чаг. рус. (Аникин: 425)

*унгун, огон* «явыз рух». **Оңкыт I** белән баглы булса кирәк.

**ОП-: оп-озын** «предлинный», **оп-олы** «превеликий», **оп-очлы** «преострый» кебек сүзләрдә фар. бәйлеге -*ба*- ярдәмендә ясалып, бик кыскарган нигез, төп өлеш күзәтелә: *озын-ба-озын* > *озып-озын* > **оп-озын,** *олы-ба-олы* > *олып-олы* > **оп-олы** һ.б.ш. **Озып-озын, олып-олы** сүзләре сөйләшләрдә (мәс., трбс.) күзәтелә.

**ОПТЫ [ŏптŏ]** «язь (рыба)», себ. (Радлов I: 1156; Тумашева 1992: 103) **ōпту** «плотва (рыба); хитрец; притворщик» ~ алт., шор. *опту,* тув. *оптуг* «хәйләкәр, ике йөзле» ← алт., тув. *оп* «хәйлә, рия, икейөзлелек». Будагов I: 796.

**ОРАН,** себ. (Радлов I: 1653, брб.) **уран** «боевой клич; призыв» ~ каз. *ŏран,* чыгт., уйг., бор. төрки *уран,* алт., кырг., калм. *уран, ураан* id., к. ш. ук төр. диал. *oran* «оран; марка», алт. ш. ук «күмәк җыр, гимн» (*ураанда*- «бергә җырлау», к. Баскаков I: 121) – монг. телләреннән булса кирәк, к. яз. монг. *uri* «чакыру; кычкырып дога кылу» һ.б. ЭСТЯ I: 601–602.

Дерив.: **оранла-у; оранчы, оранчыл.**

**ОРГА-У, оргы-** диал., (ТТДС I: 327) «размножаться»; «родить; забеременеть», «заставить родить» ~ башк. (БҺҺ III: 148; БТДҺ: 252, 259) *орғо-, өргә-, өргө-* «үрчү, ишәю» < бор. төрки **uruү-a-* id. (бу фигыль тат.-башк. даирәсендә генә сакланган); аның каруы бу сүзнең дериватлары киң таралыш алган, к. тат. **ŏргачы, оргацы, оргац** (Будагов I: 125; ТТДС I: 327; Тумашева 1992: 161), башк. *орғас* (БТДҺ: 252) «инәк, теше (бигрәк тә яшь терлек тур.)» < гом. кыпч., чыгт. *урғачы* (нуг., каз., к.-калп. *урғашы*), кырг. *урғаачы* id. ~ калм. *urүäätši* «оргачы; ана»; бик күп телләрдә һәм яз. ядкәрләрдә *урагут* «хатын», к. Räsänen 1969: 512; ЭСТЯ IV: 603–604. К. **Орлык, Өргә-ү, Ыру.**

**ОРЛЫК [ŏрлŏк]** «семя; семена» > мар. *урлык,* удм. диал. *ырлык, урлык*, чув. *вăрă, вăрлăх* < гом. көнб. кыпч. *урлуқ, урлық* < *урулық* id. Каз., к.-калп., кырг. телләрендә бүтән мәгънәдә: *уруwлық, уруwлуқ* «ырулы, ыруга нисбәтле» < бор. төрки *uruүluq* «аксөяк, асылзат», *uruүluq* «орлыклык» (ДТС: 615) – *uruү* «орлык; ыру» сүзеннән. К. **Ыру.** Федотов I: 109–110.

Дерив.: **орлыклы, орлыксыз; орлыклык; орлыклан-у.**

**ОРМЫТ [ŏрмŏт]** (ТТДС I: 328) «остатки рода, отродье (в положительном значении)» ~ башк. *ŏрмŏт* «туган як» (?, к. БТДҺ: 252). Ачык түгел. Гомумән, гом. төрки *ur* «орлык, ыру» тамырыннан, әлбәттә.

**ОР-У** «бить с размахом» < гом. төрки *ур*-, як. *уур*-, чув. *вăр* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 137) *uүur*- «ору, сугу; салу һ.б.ш.». ЭСТЯ I: 599–601; Федотов I: 107.

*Ор*- шактый продуктив нигез: иске тат. **орыш** «удар, җәң», яңа терминологиядә **орынма, орын-у** (геометриядә), к. **Орын-у, Орыш-у.**

**ОРЧЫК [ŏрчŏқ]** «веретено», «ось мельничного камня» < гом. кыпч., чыгт., үзб. *урчуқ* (башк. *орсоқ,* нуг., каз., к.-калп. *уршуқ, уршық*), хак. *оорчых*, төркм. *огурҗақ,* бор. төрки *aүuršaq, oүuršaq* «орчык» (ДТС: 24, 365) >> себ. (брб. һ.б.) *аурдзық, аурцык, аурчык* (Радлов I: 14; Тумашева 1992: 32) ~ бор. монг. *oүurčuq* (Поппе 1938: 108) ~ венг. *orso* id.; к. ш. ук госм. *ағырсақ, ағырҗақ, ағыршақ* «орчыкбаш, таякка утыртылган йомры таш һ.б.» (*ағыр* «авыр» сүзеннән), бур. *ээрсэх* «орчык», *ээрэ*- «эрләү». Шулай итеп төрки һәм монг. телләрендә «орчык» мәгъ. сүзләр төрле тамырлардан, ләкин *-чык//-чук, -чек//-чүк, -чак//-чәк* кушымчасы ярдәмендә ясалалар. Шуңа бәйле рәвештә төрле «орчык»ларның мәгънәсе төрлечәрәк. Тат. телендә кайбер сөйләшләрдә **орчык** дип тегермән ташының теңгелен, ягъни күчәрен дә атыйлар. Гомумән, тат., башк. *орчык* < *урчуг* сүзенең тамыры тур. конкрет сүз әйтү кыен, монг. *орчи-х* «әйләнү» белән охшашлык очраклы булса кирәк (бу сүзләрне бәйләүгә фонетик һәм морфологик закончалыклар комачаулый). Ләкин монг. *ор*- < төрки **огур*- «әйләнү, бөтерелү» сүзеннән булуы ихтимал (тик андый сүз беркайда да теркәлмәгән, шуңа охшаш *ӓгүр*- «әверү» генә бар), чаг. **Бөтерчек.** ЭСТЯ I: 418–419.

**ОРЫ [ŏрŏ]** «свищ, отверстие с желваком (на дереве)», диал. (ЗДС: 684) **оро** «колодец», «углубление», диал. (Тумашева 1992: 226, 230) **уру** «шеш, оры», **үрү** «бөер төере; шеш» < гом. төрки *ур* «шеш, оры», тув. *ору* «шеш чокыры», *уру* «агач орысы» ~ гом. монг., гом. тунг. *ур* «оры» (ССТМЯ II: 281); «шеш» һәм «шеш чокыры» бер сүз белән белдерү бик табигый. Чаг. **Ур.**

**ОРЫН I [ŏрŏн]** (ТТДС I: 240) «клык; зуб, который выпирает из дёсен (находится вне ряда

зубов)» ~ башк. *орон* «ат тешләре» (*орон* «кешнәү» диелә, к. БТДҺ: 253), **оры** (к.) сүзе белән баглы булса кирәк, к. монг. *урун* «оры». К. түбәндәгене.

**ОРЫН II, орон** (ЗДС: 505) «(прямая) дорога в стороне от большой дороги» ~ каз. *урун* «яшерен»; *урғун* «яшерелгән өлеш», *урунды* «яшерен рәвештә». К. **Урынтын.**

Башкортстанда **Орынды** дигән яшеренеп, тирән үзәндә утырган бер авыл бар. ЗДС (: 505) **орынды** «муксун балыгы» дип күрсәтә, ләкин Орынды авылы Агыйделгә якын торса да, аны «балыкчылар авылы» дип булмый.

**Орын, орынды** сүзенең «тәҗрибә өчен үзенә ашлык чәчелгән җир кишәре» мәгъ. бар.

**ОРЫН-У [ŏрŏн-]** «задеть, задевать; прикасаться», диал. (Тумашева 1992: 161) «возиться; копошиться» < гом. кыпч., (фонетик вариантлары белән) гом. төрки (Радлов I: 1660) *урун-* «орыну, тию һ.б.», күп кенә телләрдә (к.-балк., кырг., уйг.) «нык тырышу (бәргәләнү); ташу; тәҗрибә ясау» мәгъ. кулланыла. Әлбәттә, **ор-у** < *ур-* сүзенең кайт. юн.

Дерив.: **орыныш-у, орындыр-у.** К. **Орынчык.**

**ОРЫНЧЫК [ŏрŏнчык]** (ТТДС I: 320), **орынчак, орончык** «трудности, хлопоты; помехи», «мелководье, место, где быстрое течение по мелкому или узкому месту; мыс» ~ башк. (БТДҺ: 252) *оронсоҡ* «мәшәкать; кирәк-ярак», каз., к.-калп. *урыншаҡ* «бәйләнчек (кеше)», уйг. *урунчак* «тырыш, инициативалы» – барысы да (к.) **орын-у** < *урын-, урун-* id. фигыленең төрле мәгънәләреннән. К. ш. ук тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **орынты, орынды** «тәҗрибә өчен чәчеп каралган җир», башк. (БТДҺ: 252) *орҙомша* «сал бүрәнләрен беркеткеч бастырык, аркылы бүрәнә; гомумән кирәк-ярак» – рус. *ромша, ронжа* «үзара беркетелгән чаналар» (төрки телләрдәнме?).

**ОРЫШ [ŏрŏш]** «война, бой; битье» ~ башк. *орош* id. < гом. кыпч., уйг., үзб. һ.б. *уруш-* id. ~ чув. *вăрçă, вăрăç* < болг. **вŏрŏж̌* > мар. *вырсэ, вурсо, вырсы* id. Федотов I: 111.

Дерив.: **орышчан, орыш-сугыш** (парлы сүз).

**ОРЫШ-У [ŏрŏш-]** «журить, пожурить» < гом. кыпч. *уруш-* «сугышу», к.-балк., ком. *урыш-* (> нуг. *урыс-*) «тиргәү, сүгү». «Йомшак тиргәү» (к. мәкаль: *Орышкан оҗмахлы, тиргәгән тамуклы*) мәгъ. тат.-башк. телләрендә генә. Гомумән, *уруш-, урыш-* «сугышу, тиргәү, орышу» *ур-* «ору» фигыленең урт. юнәлешеннән, к. үзб., уйг. *уруш-* ~ чув. *вăрç-* «сугышу». Федотов I: III.

**ОС** диал. «сознание; память» (*истә-оста юк* «совсем забыл»), чув. *ăс [ŏс]* < гом. төрки (һәркайда сирәк) *ус, уз* «сәләтле, тәҗрибәле», як. *уус,* бор. төрки, төр. *uz, us* id., *us-* «уйлау» (ДТС: 612, 620). Чаг. яз. монг. *uran* «осталык». К. Будагов I: 129; ЭСТЯ I: 606; Мухамедова 1973: 182; Федотов I: 88–89 (*ис* < *эс* сүзе белән бутый).

**Ос** сүзенең тат. диал. **уш** сүзенә катнашы юк.

**ОСКЫТ-У [ŏскŏт-]** (ТРС: 1966) «подстрекать; разъярять», ниндидер *осқы-* фигыленнән, чаг. **Өстер-ү.**

**ОСТА** «мастер» > мар., удм. *уста, усто*, чув. *ăста* id., удм. *усто* «шәп» < фар.-таҗ. *усто* < гар. *устāҙ* id. К. **Остаз.**

Диал. **остачы** (ТТДС: 329) >> мар. (Исанбаев 1978: 15) *устаз'е* «специалист» тат. телендә тәшкилләнгән сүз. Федотов I: 9–92 (тәфсилле).

**ОСТАЗ** «наставник» < гар. *устāҙ* id. К. ш. ук **остазбикә > остабикә.** Будагов I: 136.

**ОСТЫХАН [ŏстŏхан], өстүан, ыстуан** (в различных транслитерациях старых написаний арабскими буквами) «кумир; кумирня», иск. (Г. Кандалый) «предмет поклонения, возлюбленная», себ. (Тумашева 1992: 161) **ŏстŏған** «труп» < чыгт. < фар. *үстухани-будә* «буддистларның мәет кую урыны – зират төре (мәетләр күмелмәгән, ачык килеш ятканнар, аларны ерткыч кошлар һ.б. ашап бетерә торган булган)», к. ш. ук уйг. *устухан, истуған* «оссуарий; җимеш тошы; нәсел буыны; сөякләргә карап юрау» (к. Будагов I: 41).

Мәетләрне махсус урыннарда ачык калдыру йоласы монголларда һәм буддист төркиләрдә XX г. кадәр дәвам иткән. Себер татарлары бу йола белән таныш булганнар. Идел-Урал регионында исә **остыхан** сүзенең «зират > изге җир > санәм» мәгънәсе өстенлек иткән, шул нигездә «сөйгән яр» мәгъ. дә килеп чыккан һәм **Стуани//Өстуани** дигән фамилия дә пәйда булган.

**ОТ-У I** «выиграть (в игре)» > чув. *ăт-, ут-,* удм. (Насибуллин: 73) *ут-, ыт-, ът-* id. < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., төр. һ.б. *ут-,* үзб. *йут-*, төр. *yut-* id. Бу сүзне гадәттә (Будагов II: 139; ЭСТЯ I:

609; Федотов I: 93) **от-у II** белән бердәй нигездән дип карыйлар һәм бер матдәдә бирәләр. Безнеңчә, **от-у I** һәм **от-у II** сүзләренең гомогенлыгы шикле. Чаг. чув. *вăлт-* «уенда хәрәмләшү; серен белү» < **улт-*. *От-* < *ут-* сүзенең кыскалыгы, ә мәгънәсенең киңлеге һәртөрле фаразларга урын калдыра. М. Рясянен (1969: 517) **от-у** сүзен **отыры** (к.) сүзе белән баглый. ЭСТЯ I: 509 (Э.В. Севортян *отыры* сүзендә *от-* аерым тамыр ди).

Дерив.: **отыл-у, отыш-у, оттыр-у** һәм **откыз-у** (диал.) ~ бор. төрки (ДТС: 619) *utuz-* id.; **отыш, оттырыш** һ.б.

**ОТ-У II** «перенимать; запомнить (сказанное, показанное)» < гом. кыпч., гом. көнб. төрки *ут-* id. < бор. төрки (ДТС: 605, 606, 617) *yt-, ud-, иδ-, uz-* «иярӱ, бер-бер артлы килү» > уйг. *ут-* id., шуннан себ. (Тумашева 1992: 161) **ŏта** «рәттән». Шул ук тамырдан гом. угыз., кр.-тат., кар. *уй-* «җайлашу, иярӱ, туры килү; рифмалашу», к. **Оеш-у, Уйдырма.**

Дерив.: **откыр**. Диал. (ТТДС I: 329) **откы** «коткы, котыру», **ŏткŏт-у** «котыру» сүзләренең **от-у II** сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел.

**ОТЫРЫ [ŏтŏрӹ], отор, утыры** (ТТДС I: 329; Тумашева 1969: 161; БТДҺ: 255; ДС II: 148) «наперекор, напротив; все более; против; навстречу», себ. «заусенец; загиб» > мар. *утыр* (Упымарий: 231) *утыр-утыр*, удм. (Насибуллин: 73) *ытыр, утър, ытыры* id. < гом. кыпч. *утру, утуру*, алт., тув. *удуру, удура*, хак., тув. *удур*, уйг. *уттур*, бор. төрки (ДТС: 618–619; Боровков 1963: 333; Будагов II: 111; Zajączkowski 1961: 301) *utru*, сары уйг. *олтур-* id., бор. төрки, уйг. һ.б. *утур-, уттур-* «очрашуга бару, каршыга бару» сүзенең бор. хәл фигыль формасы (**утра, утура** варианты да шуны күрсәтә), әлеге фигыль исә бор. *ут-* < *улт-* «очрау, туры килү» (чаг. **От-у I**) фигыленең йөкл. юн. (*ут-тур-*) булса кирәк, к. себ. (Тумашева 1992: 227) **утку-** «аяксып тору, барасы-йөрисе килү» ~ алт. *утку-* «каршы чыгып алу», *утку* (Радлов I: 1708) «килгән кунакка багышланган тәбрик сүзе (еш кына – шигырь)», як. *утар* «каршы тору», *утарыы* «отыры»; *ут-* < *улт-* фигыленең исем коррелянты да булган кебек, к. кар. *уткары* «каршыга».

**Отыры** сүзе тур. күп кенә язылган, к. Хабичев М.А. К структуре первичных корней в урало-алтайских языках // Вопросы изучения языков и литератур народов Карачаево-Черкесии. Черкесск, 1967: 63–66; Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. Казань, 1983 (Ф. Фасеев һәм Р. Әхмәтьянов мәкаләләре); ЭСТЯ I: 610–611.

Дерив.: **ŏтŏрла-у; ŏтŏрлаш-у; оторчылык, ŏтŏрсылык** (Тумашева 1992: 161; БТДҺ: 255).

**ОФЫК [ŏфŏк]** «горизонт» < гар. *уфк* id. ← *äфк* «ил гизү».

**ОХША-У,** диал., башк. **окша-у** «походить, быть похожим» < гом. кыпч., к. кар. *охша-, окша-, ухша-*, куман., уйг. *окша-,* уйг., чыгт., кр.-тат., төркм., аз. (Радлов I: 151–152, 1002–1005) *охша-*, шор. *ошка*, алт. *ошко-*, нуг., каз., к.-калп. *укса-* < бор. төрки (ДТС: 364, 370, 374) *oγša-, oqsa-, oxša-* «охшау; ошау» ← бор. төрки (к. Боровков 1963: 233), уйг. *огуш, огус* «нәсел, буын; зат, төр» (*огша-* < *огуш-а-*), ягъни **охша-у** асылда, «нәселенә тарту, нәселен хәтерләтү» булып чыга, к. ш. ук тув. *уксаа-,* як. *усаа-* «нәселенә тарту» ~ бур. *угсаа, угсага* «чыгыш, нәсел» (мәгънәви җәһәттән чаг. алт. *кöкле-* «охшау; нәселенә, тамырына тарту» ← *кöк* «тамыр; нәсел»).

**Огуш** нигезе исә тув., як., монг. һ.б. *уг, ук* < бор. төрки *oγ, oq* (к. **Ук II**) «токым, зат, чыгыш» һәм бор. төрки (ДТС: 372), чыгт. *oš, uš* «инде, менә; нәкъ» тамыр морфемаларыннан гыйбарәт булса кирәк: *ок уш* «заты шул, нәкъ үзе, үзе инде».

**Охша-у** сүзе үзе тат. әд. теленә иске тат. (чыгтай) теленнән кергән, шуның «саф» кыпч. фонетик варианты **оша-у** < *уша-* ~ нуг., каз., к.-калп. *уса-* икенчерәк мәгъ. («өнәү, ярау») алган. Гомумән, «охшау > ошау» мәгъ. күчеше күп телләрдә күзәтелә (мәс., инг. *like* сүзенең семантикасында һ.б.). Будагов I: 118; Пекарский: 2987; ЭСТЯ I: 419–420 (иске төрки *ок* ~ *ог-* «бердәй; шул үзе» сүзеннән диелә, бу безнең әйткәнгә хилаф түгел).

**Охша-** һәм **оша-** тат. телендә бик продуктив нигезләр: **охшаш-у; охшат-у; ошат-у I** («яратып китү, үз итү» мәгъ.), **ошат-у II, охшаш < охшашлы** (< гом. кыпч. *укшаш, уксас* һ.б.), диал. (ТТДС I: 332) **ошаклы, ошаулы** «охшаш»; **ошамаган** «ярамаган, начар»; **ошаусыз** «килбәтсез» һ.б.

**ОЧ,** диал. (себ., миш.) **оц** «острый конец, острие; конец, торец, один из концов; оконечность» < гом. кыпч. *уч* (башк. *ос,* нуг., каз., к.-калп. *ŏш, уш*), төркм. *ууч* ~ чув. *вěç* id. һ.б. (гом. төрки характердагы сүз). Төбендә ике яки өч иҗекле нигездән булса кирәк. Төрле чагыштырулар һәм фаразлар тур. ЭСТЯ I: 61–612; Федотов I: 119–120.

Дерив.: **очлы, очсыз; очлык** (төрле мәгъ., бу сүзнең «мөчә» мәгъ. русча *конечность* сүзеннән уңышсыз калька); **очла-у** (төрле мәгъ.), диал. (Тумашева 1992: 161) **оца-у** «очлау, очлы итү», **очкары, оцкары, оцғары** «иң очта, иң очка; көчкә, очын-очка ялгап кына (запассыз яшәү тур.)». К. **Чорма.**

**Уч, уж** сүзе төрки дәүләтләрдә «чик, чигәрә посты, кирмәнчек» мәгъ. кулланылган, тат. торлагында (авылда һ.б.ш.) **түбән оч, югары оч** тәгъбирләрендә шул мәгъ. чагыла.

**ОЧА** «крестец, задок; нижняя часть спины; ляжки», (Будагов I: 116) «верхняя часть бараньего бедра» > морд. Э. *уця* «бөкре; арка» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг., бор. төрки *уча* (башк. *оса,* нуг., каз., к.-калп. *уша*), төркм., госм. һ.б. угыз. *ужа* «оча», нуг. *уша,* к.-балк. *уча, уца* «түшкә», тув. *ужа* «оча, куй очасы, көрдек», як. *уса* «савыр», сүзнең палаталь варианты да бар: тат. (к. Радлов I: 1327, 1721) **өчә** «арт сан» ~ үзб. (ЎХШЛ: 27) *өчә* «иңбаш», к. ш. ук чув. *вĕче* > мар. *вĕцӓ, вĕцӓлү* (*лү* «сөяк»), мар. Б. *выца, выцалу* «оча сөяге», алт. диал. *удьа,* як. *удьунах, ужунах* «оча» һ.б.; бу сүзнең «тантаналы табында кунакларның дәрәҗәсенә карап бирелә торган ит өлеше» мәгъ. булган; борынгырак яңгырашы – бор. монг. *иуиča* (> бур. *ууса,* монг. *ууц*) > тунг. (ССТМЯ I: 290) *ууса* «оча, савыр; мөчә»; борынгырак мәгъ. – «табыш белән кайтып килгән аучыны иң беренче очраткан кемсәгә тиешле өлеш» (к. Радлов I: 1722; Вайнштейн 1961: 128–130). **Оча** < *уча* < *уғуча,* ихтимал, **уңуча* ~ **умуча* >> *мүчә* «мөчә» сүзе белән бердәйдер, к. **Мөчә.** Гомумән, сүзнең ясалышы юраулы. Федотов I: 120–121; Ögel: 215–216; 371–372.

Дерив.: **очалы; очалык.** Чаг. **Чалкан.**

**ОЧАН I** (ТТДС I: 329), себ. (ЗДС: 507–509) **оцан**, каз. ар. **очок** «цистит», «вздутие живота (у детей); паралич задних ног овец», башк. (БТДҺ: 253) *осан* «опущение живота»; ачык түгел. Ихтимал, **очык** (к.) сүзе белән баглыдыр.

**ОЧАН II** «парусная лодка (небольшая)» < гом. кыпч., к. каз. *ŏшон*, к.-калп. *ушан* < куман., төркм., чыгт., госм., бор. төрки (М. Кашгари) *учан* «ике җилкәнле кимә», бор. рус. (1182 елда теркәлгән) *учан* «елга кимәсенең бер төре» (рус ядкәрләрендә бу сүз соңыннан еш кына очрый). Ике җилкәнле булгач, *очан* < *учан* угызча *учан* «оча торган, очкыр (канатлы)» дип тәгърифләнергә мөмкин. Ләкин к. каз. *ушан,* кырг. *учан* «очсыз-кырыйсыз (диңгез тур.), каз. (ҚТДС: 357) *ŏшан* «ераклык». Чаг. ш. ук Будагов I: 16; Фасмер IV: 179.

**ОЧКАЛАК** «белка-летяга» ← **очкала-у** (к. **Оч-у**). Бу сүз русчадан калька түгелме икән? Гомумән, тат.-башк. тел даирәсендә **очкалак ~ оскалак** төрле мәгъ. очрый: «тиктормас, очынгыч»; «ябалак кар», «камка» (к. БТДҺ: 253) һ.б., к. **Очкылык.**

**ОЧКАТ** (Будагов I: 115) «жимолость», себ. (Тумашева 1992: 227) **уцкат** «козья жимолость» ~ башк. (БТДҺ: 253) *осҡат* «аю баланы» < **өч кат** < *уч кат*: **ҡат** «җиләк, җимешчек», чаг. **Карагат, Кызылгат.** Мәзкүр үсемлекләрнең җиләклеге өч өлештән тора. Каз. (Будагов I: 138) *ушқат* «куак» – төгәл түгел, ҚТДС (: 365) буенча, *үшқат* «кабыгы өч катлы агач».

**ОЧКЫЛЫК [ŏчқŏлы̆қ],** диал. (трбс.) **очқалақ** «икота» ~ башк. *осҡолоҡ* id. – төп мәгъ. «күренмичә очып йөрүчән пәри, җен», **очкалак тоту** нәтиҗәсендә кешенең сулышы бозыла, имеш.

Дерив.: **очкылыкла-у.**

**ОЧКЫН [ŏчқŏн], оцкын** «искра» ~ башк. *осҡон* id.; диалекталь сөйләмдә **очкын** ~ *оскон* төрле мәгъ. очрый: «көл, кибәк», «очынгыч, кыйланчык» һ.б., к. БТДҺ: 253. Чаг. чув. *вĕçкĕн* «очынучан; очык».

**ОЧЛЫК [ŏчлŏқ]** «конечность (рука, нога)» – бу сүз русчадан әд. телдәге уңышсыз калька (чөнки халык телендә **очлык** «нәрсәнең дә булса очына куела торган әйбер», мәс., *чыбыркы очлыгы*). Ихтимал, тат. телендә рус. «конечность» мәгъ. **очалык** сүзе булгандыр (**оча** – түшкәнең кунакларга бүлеп бирелә торган өлеше), шуны дөрес аңламау нәтиҗәсендә **очлык** сүзе пәйда булган.

**ОЧЛЫПЫЙ [ŏчлŏпы̆й]** (А. Расих) «вязаная шапка, верхняя часть которой откидывается назад или в сторону» < рус. диал. *слепой (слепая шапка)* id.

**ОЧРА-У [ŏчра-]**, диал. **ŏчŏра-** «встретить; встречать» < гом. төрки *учура-*, башк. *ŏсŏра-,* кр.-тат., кырг., чыгт. *учра-* (Радлов I: 1727, 1231), бор. төрки *učra-* (ДТС: 604) > нуг., каз., к.-калп. *ушра-* id. бор. төрки *учур-* > тат. диал. **очыр, ŏчŏр,** башк. (БТДҺ: 254) *ŏсŏр* «чор; очрак, момент» нигезеннән (ЭСТЯ I: 296–297), к. ш. ук монг. *учир,* бур. *ушар* «очрак; нигезләмә», маньч. *учара-* «очрашу» һ.б.

*Очора-* нигезен *очор-а-* дип таркату беренче карашка бик табигый күренсә дә, шикләнерлек фактлар да бар: себ. *уцура цыҡ-* «каршы чыгу» дигәндә фигыль *уцур-*, ә бу фигыль исә **уцу-* фигыленең йөкл. юн. шикелле, к. ш. ук эвенк. *учик* «очрак; хадисә; язмыш, өлеш» (ССТМЯ II: 296–297). Мәгънә мөнәсәбәтләрен удм. *учыра-* «вакытында килү; атып тидерү; очрашу», *учыр* «момент, очрак», *учырак* «ә дигәнче, тиз генә» (тат. теленнән) сүзләре ачыклый төшә. К. **Чор.**

**ОЧСЫЗ [ŏчсŏз]**, диал. **оссыз** «дешёвый, дешево» – **очыз** сүзеннән халык этимологиясе нигезендә кабат таркатылган – гүяки **оч-сыз**. К. **Очыз.**

**ОЧ-У**, диал. **ŏц-у** «летать; улетать; падать с высоты» ~ чув. *вĕç-* < гом. төрки, бор. төрки *иč-* > башк. *ŏс-,* кар. *уц-*, нуг., каз., к.-калп., тув. *уш-*, хак. *ус-*, алт. диал. *үч-*, хак. диал. *учу- (учуды)* id., себ. *ŏц-* «очыну, шаяру» (Тумашева 1992: 161). ЭСТЯ I: 612–613; Будагов II: 117.

**Оч-** бик тә продуктив нигез: диал. **очалак** «һавада үзеннән-үзе очып йөри торган (җансыз нәрсәләр тур.)», **очанак** (ТТАС II: 484) «ярсынучан, кызу холыклы», **очын-у** «мактанып, горурланып кылану» (шуннан – **очынгыч, очындыр-у** һ.б.), **очкыч, очучан, очучы, очыргыч, очыш** һ.б. К. **Очкалак, Очкылык, Очык I, Очык II, Чорма.**

**ОЧЫЗ [ŏчŏз]**, диал. **осыз** «дешёвый» < уйг., чыгт., кр.-тат., госм., ком. *учуз*, к.-балк. *уцуз* «арзан (киң мәгънәдә); эчтәлексез, игътибарга лаексыз», төр. *ucuz*, бор. төрки (ДТС: 605) *učuz* «бик аз гына; юк дәрәҗәдә; җиңелчә; кыйммәтсез; арзанлы», *učuz-jenik* «юк кына». М. Рясянен (Räsänen 1969: 509) бу сүзне монг. *ucir* «момент, очрак; сәбәп» сүзе белән чагыштыра. Һәрхәлдә сүзнең тамыры **уч*. Ихтимал ки, *уč-uz* < **uc-ur* «тузан; очык» сүзеннәндер.

**ОЧЫК I [ŏчŏк]** (Троянский I: 94, һ.б. чыганаклар), себ. **оцыҡ** (Тумашева 1992: 161–162) «охвостье, мякина» < гом. кыпч. *учыҡ, учуҡ* (> башк. *осоҡ,* нуг., каз., к.-калп. *ушыҡ, ŏшыҡ*), хак. *учух* һ.б. id. ← *уч-* «очу» сүзеннән. Гомумән, бор. ясалма, к. венг. *ocsu* «очык» (бор. төрки теллләрдән). Чаг. ш. ук чув. *вĕçенчĕк* «очык, онтак» ~ тат. **очынчыҡ** id., ләкин төп мәгъ. «очынучан кеше, мактанчык».

**ОЧЫК II [ŏчŏҡ], оцоҡ** (ЗДС: 508) прм., себ. «оч, чәч очы; бала йон» – күрәсең, **оч** сүзеннән, кечерәйтү формасы. К. каз. *ушыҡ* id.

**ОЧЫК III [ŏчŏҡ]: оцык** «болиголов» («ислекәй, түндербаш» диелгән, к. ЗДС: 508). Бәлки **очыҡ утыдыр**, ягъни, **очык IV** – «ирен шешү»не дәвалау чарасы»дыр. Чаг. ш. ук себ. **оцогот** «сары чәчәкле бер үсемлек; гөлбадран, албидрә».

**ОЧЫК IV [ŏчŏҡ]**, миш. (к. ЗДС: 801) **ычык,** себ. **ŏцык** «цистит; воспаление, сыпь и т.п., появившиеся вследствие внутренней болезни» < гом. төрки *учук,* бор. төрки (ДТС: 603–604) *učuγ, učγuq* id. > башк. *ŏсŏҡ,* нуг., каз., к.-калп. *ушыҡ* id. һ.б. *Оч-у* сүзе белән бәйле, к. тат. (ЗДС: 508) **оч** «чуан», каз. (ҠТДС: 358) *ушпа* «очма, кәҗә-сарык чире». Бор. төрки *učuγ-jelpek* «бизгәк, очык-җилпек» – ихтимал, «очып килеп кунган чир» мәгънәсендәдер, төр. (Будагов I: 117) *учуҡ, учыҡ* «герпес; берәр авыру-чирдән ирен ярылу» һ.б.

**ОШАК** (Будагов I: 137; ТТАС II: 490; Тумашева 1992: 162) «сплетня; клевета, донос», диал. (кас.) **үши'**, башк. диал., тат. диал. *ушаҡ* «әләк», *ушак* «вак; бала-чага» (*малайшак* < *малай-ушак*, к. ТТДС I: 299) ~ кырг., чыгт. *ушаҡ,* нуг., каз., к.-калп. *усаҡ* «вак; вакчыл, вакчыллык; вак акча», төр., аз. *ушаҡ,* хак. *узах* «вак бала», бор. төрки *ušaq* «вак, вак акча», *ušaq söz* «вак сүз; гайбәт», *ušal-* «ваклану», *ušat-* «ваклату» ← төркм., бор. төрки (ДТС: 617) *uš-a-* «ваклану, вакка әверелү», **uš* «вак кына» сүзеннән, *у-у* белән тамырдаш булса кирәк. ЭСТЯ I: 617–618.

Дерив.: **ошакла-у; ошакчы; ошакчыл.**

**ОША-У** «нравиться», диал. «походить, быть похожим на кого» < гом. кыпч. *уша-* id. < *ухша-, уҡша-*, к. **Охша-у**.

Дерив.: **ошат-у.**

**ОЮ** к. **Ое-у II.**

**ОЯ [ŏйа]**, диал. (Троянский II: 333) **йуйа** «гнездо» ~ чув. *йуйа, йăва, йăвва* (к. Ашмарин V: 40, 48) < гом. кыпч., алт., тув. *уйа*, бор. кыпч. *йува*, угыз. *ува, йува* (Радлов I: 1628, 1785), як. *ууйа* ~ монг. *уйаға* «ая; тукталыш урыны», к. ш. ук кар. *уйа* «оя», *уйал-* «оялау», уйг. *уйа* «гар, мәгарә; оя» *уй-у* фигыле белән бәйле. К. **Уй II**. Räsänen 1969: 51.

Дерив.: **оялы, оясыз; ояла-у.**

**ОЯЛ-У [ŏйал-]** «стыдиться» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг., төркм., төр. һ.б. *уйал-* id. **уйа-* «хурлыкка калу» фигыленең төш. юн., Э.В. Севортян бор. **уй* «оят» сүзеннән ди (ЭСТЯ I: 576–577), ләкин сүзнең этимологиясе катлаулырак, к. куман. *ugial-* «оялу» ← **угйа-* < *огуй-а-* > **owуй-а*, шуннан ком. диал. *йувал-* «оялу»; диал. **ойан-у** фигыле дә бар, шуннан **ойанык** «оялырлык» (без теркәдек. – *Р.Ә.*) > себ. **ойаң** «оялчан» (Тумашева 1992: 159); бор. төрки *ujal-* белән беррәттән *ujad-, ujaб-, ujat-* «оялу» (ДТС: 607). К. **Оят, Уфтан-у.**

Дерив.: **оялыш-у, оялт-у, оялдыр-у** (затланышсыз мәгъ.); **оялыш.** К. **Оялчан.**

**ОЯЛЧАН [ŏйалчан],** диал. **ойалчак, ойалчык** «стыдливый» ~ башк. *ойалсан, ойалсыҡ* id. < гом. кыпч., алт. *уйалчаң, уйалчаҡ* id. (к. Радлов I: 1630–1631) – **оял-у** (к.) сүзеннән булса кирәк, ләкин төп юнәлештәге (***ойа-**) фигыленнән дә (**ойалчан**) булуы ихтимал, к. себ. (Тумашева 1992: 159) **ойаң** «оялчан».

Дерив.: **оялчанлык; оялчанлан-у.**

**ОЯҢ [ŏйаң]** «суставный ревматизм» ~ башк. (БТДҺ: 249) *ойан* id., ш. ук «оешкан, оеш» һ.б. **ойы-у** фигыленнән булса кирәк. Каз. *ӧйаң,* к.-калп., кырг., алт. һ.б. *уйаң* «йомшак; кыюсыз» сүзе белән уртаклыгы шикле (к. ЭСТЯ I: 577).

**ОЯТ [ŏйат]** «стыд, постыдное дело» < гом. кыпч., уйг., алт., чыгт., төркм. һ.б. *уйат*, куман. *ugat, *ugyat*, бор. чыгт. (Боровков 1963: 230–232) *owут, уwут, огут,* уйг. (Радлов I: 1162) *обут, убут, увут* id. < бор. төрки **огйут* < *огуй-ут//огуй-ат* id. ← **огуй-* «оятлы булу» фигыленнән (безнең фараз); бор. кыпч. сүзләрнең тамыры **уг ~ ув* (һ.б.) исем (Э.В. Севортян) яки сыйфат (безнеңчә) тамырдан. Ягъни **ойат** < *уйат* бор. *-т* исем ясагыч кушымча ярдәмендә фигыльдән ясалган сүзләрнең берсе. К. **Оял-у.**

**Оят** сүзенең варианты *owут* сүзеннән **уфтан-у** (к.) фигыле ясалган, к. угыз. *утан-* ~ чув. *вăтан-* «оялу», як. *саат* < **ужат* «оят» һ.б. ЭСТЯ I: 161–163, 609–610 (*утан-* сүзе тур.).

Дерив.: **оятлы, оятсыз; оятлан-у, оятла-у**. Тат. сөйләшләрендә *оят* > *йат* күчеше нигезендә **ятлы, ятсыз, ятла-у** дигән яңгырашлар да очрый. Чув. *ятла-* «тиргәү, сүгү, оятлау» тат. (миш.) сөйләшләреннән булса кирәк, тик Федотов (II: 505) бу чув. сүзен *ят* (< *айыт*) «исем, ат» сүзенә нисбәтли.

# Ө

**Ө** – тат., башк., чув. һәм (эзлексез рәвештә) нуг. вә каз. телләрендә гом. төрки *ү* урынына килә торган үзенчәлекле аваз. Ул гадәттә беренче иҗектә һәм тик үз ишеннән соң килгәндә генә икенче һәм өченче иҗекләрдә очрый.

**ӨВЕМ [ŏwŏм], өwәм** диал. «копна снопов» (Халиков 1981: 77, 120) – *өй-ү* белән бәйле (аның **өw-ү** вариантыннан) булса кирәк, дөресрәге **өwем**дер.

**ӨЕК-Ү (өекте, өегү)** «толпиться, стоять кучей (об овцах), сбегаться за сукой, спариваться (о собаках)» < гом. кыпч. *үйүк-* (каз. *уйуқ-*, к. Радлов I: 1634) id. *өй-* < *үй-* (к. **Өй-ү**) фигыленең интенсивлык формасы.

Дерив.: **өегеш-ү** («совокупляться», ди Будагов I: 169); к. **Өйкем.**

**ӨЕР [өйөр],** диал. (Тумашева 1992: 39, 328) **әwĕр, үwĕр, үүр** «небольшое стадо; табунок, гурт; банда, свора» < гом. кыпч. *үйүр*, каз. диал., алт., хак. *үүр*, як. *үөр,* тув. *өөр* < уйг., бор. төрки (Радлов I: 1180, 1817; ДТС: 622; Clauson: 112) *ögür, ügür* ~ монг. *үгүр* id., кайбер мәзкүр телләрдә (хак. алт., тув.) «яшьтәшләр төркеме, группа» мәгъ. йөри (негатив мәгънәләре юк). К. Будагов I: 168; ш. ук Räsänen 1969: 369).

Мар. кч. (Упымарий: 235; Исанбаев 1978: 18) *урӧ* «өер» алт. *үүрä, үүрү* id. сүзләрен хәтерләтә, тат. теленең бор. сөйләшләреннән алынган булса кирәк. К. **Өер-ү, Өй-ү I.**

Дерив.: **өерле.**

**ӨЕР-Ү [өйөр-]** «завихрить, закрутить; собирать косяк в кучу (о жеребце-вожаке)» < гом. кыпч., чыгт. *үйир-, үйүр-* < (чыгт., уйг.) *үгүр-,* бор. төрки (ДТС: 382) *ögür-* «бору, борылдыру» < **öй-гүр-* id. ← **öй-* «әйләнеп тору» (шуның йөкл. юн.); бу фигыль мәгънәсенә аның дериватларында бор. *үй-* < *үг-* «җыю, өю» фигыле дә контаминацион тәэсир ясаганлыгы күренә. Шулай, мәс., **өер <** *үйүр, öйүр* (к. **Өер**) сүзе **өй-** тамырыннан да, *үй-* < *үг-* тамырыннан да ясала ала. Будагов I: 168.

Дерив.: **өерел-ү, өереш-ү, өерт-ү; өермә ~ өерелмә; өерткеч;** башк. (БТДҺ: 256) *өйрелмәк, өйөрсөк, өйөрөм* һ.б.

**ӨЗ** иск. «род горлового пения (с жалобно-минорными звуками)» < бор. төрки (тув.) *үз* id. К. **Өзел-ү II, Өзлә-ү** һәм түбәндәгене.

**ӨЗӘЛӘН-Ү** «выражать (голосом) сокрушения, переживания» ~ башк. (БТДҺ: 255) *өззәлән-ү, өҙәлән-еү* id. ← **өзә, *өззә* «дулкынландыргыч авазлар», чаг. **Өз.** К. ш. ук башк. диал. *өззәләт-еү* «(эт) өстерү (өсләтү)».

**ӨЗӘҢГЕ**, диал. (Тумашева 1992: 53, 228) **изәңгү, үзәңгә** «стремя; подножка экипажа», диал. (ДС I: 254) «обойма колеса (вероятно по внешнему подобию)», (ТТДС I: 184) **йөзәңге** «бублик, баранка» < гом. кыпч., к. башк. *өҙәңге,* каз. *үзеңгĕ,* к.-калп., кар., ком., к.-балк. *үзеңги*, кырг. *үзөңгү*, чыгт., уйг. *үзәңгә*, алт. *үзӧңӧ*, тув. *езеңги*, як. *исэнэ* һ.б. «өзәңге (атка менү җайланмасы)», бор. чыгт. (Боровков 1963: 337) *үзäңү* «баскыч» бор. **үзән-* «күтәрелү» фигыленнән булырга тиеш, бу фигыль *үзә-* фигыленең кайт. юн., ул (төп) фигыль исә *үз* < *öз* < *öрг* «югарылык, биек төш» исеменнән ясалган булса кирәк. Чаг. иске тат. **үзә, үзрә** (к.) һ.б. «өстенә, өстендә».

Тат. **йөзәңге** варианты, гаг. *йӧзеңги* һәм чув. *йăрана (< йӳрäнä < йӳрäнгӳ)* сүзләре белән беррәттән бор. *йӧр ~ дьӧр < дӧӧрг* (безнеңчә) тамыры булганлыгын күрсәтә. К. ш. ук монг. *дүрүгэ < дүрэңә*, эвенк. (ССТМЯ I: 226) *дүрэки*, сол. *дурэңки* «өзәңге» (бор. төрки телләрдән).

Өзәңгене (һәрхәлдә бүтәннәргә бинисбәтән) төркиләр уйлап тапканнар, к. Кызласов И.Л. О происхождении стремян // Советская археология, № 3, 1973: 24–36). Моны **өзәңге** < *үзäңги* (һ.б.) сүзенең бик күп күрше телләргә алынганлыгы да күрсәтә, к. ЭСТЯ I: 623–625; Федотов I: 185–186 (әдәбият күрсәтелә).

Фонетик җәһәттән *өзәңге* ~ чув. *йăрана* ~ сол. *дурэңки* мисаллары, беренчедән, *-р > -з* күчешенең чагыштырмача яңалыгын, икенчедән, алт. *дь-* авазының бик борынгыдан килгәнлеген күрсәтәләр.

**ӨЗБЕ [өзбө], өзве** «звено; одна из частей целого; пуговица четок» < гар. *уḍw* id. сүзеннән, ләкин **өз-ү** (к.) сүзе тәэсирендә ясалган булса кирәк; к. ш. ук төр. *uzuv, uzvu* «өзбе; тән органы», *uzviyet* «организм».

**ӨЗВИ, öски** (Линдберг, Герд: 63–64) «разновидность стерляди». Чаг. **Өзбе** (?).

**ӨЗЕК I [өзөк],** диал. [Тумашева 1992: 228) **үзүк** «одна из четырёх войлочных частей, служащих крышей юрты; крыша» << бор. төрки (ДТС: 376) *öčük* «кыек, түбә».

**ӨЗЕК II [өзөк]** «разрыв; разорванный конец; распутица (время, когда не могут применяться ни сани, ни телеги)» ← **өз-ү** сүзеннән, әлбәттә. Төрки телләрдә *үзүк* төрле мәгъ. кулланыла. Чаг. **Өзлек.**

Дерив.: **өзекле, өзексез; өзеклек** («кризис» һ.б.ш. мәгъ.).

**ӨЗЕЛ-Ү I [өзөл-]** «разорваться; прекращаться, прекратиться» ← **өз-ү** (к.).

**ӨЗЕЛ-Ү II [өзәл-]** «сокрушаться, переживать» – дөресе **өзәл-ү** булса кирәк, к. бор. төрки (ДТС: 629–630) *üzäl-* «газаплану» ← *üzä-* «кичерену» ← *üz* «нәфрәт»; тәүдә – көчле хис». Бу **үзә-* фигыленең ешлык дәрәҗәсе **үзә-лә-* сүзеннән тат. *өзәлән-ү* сүзе ясалган бугай, к. кар. *öзялэнь-* «колау, егылу; һөҗүм итү; якынлашу, омтылу; кайгыру, өзәләнү». Бор. *üz* «нәфрәт» сүзе тув. һ.б. *үз* «кай белән көйләүнең бер төре» сүзе белән бердәй булса кирәк (дастан башкарган телмәрчеләр нәфрәт хисләрен *өз* тавышы белән белдергәннәр). Чаг. төр. *özen* «хәстәр, тарышчанлык, өзәләнү», *özen-* «хәстәрләү». К. **Өзлә-ү.**

**ӨЗЛӘ-Ү** (Н. Исәнбәт) «исполнять горловое пение (одно из видов, а именно то, которое выражает сильные чувства)» диал. *өз* < (тув.) *үз* «кайның бер төре».

**Өзлә-ү** белән беррәттән, ихтимал, *өз-* ~ *үз-* «көчле хисле җырлау» (**өз** исеменең фигыль коррелянты) да булган булса кирәк һәм **өзел-ү II** шуннан да ясала ала. К. төр. *üzüntü* «өзенте, көчле кичереш».

**ӨЗЛЕК I [өзлөк]** (ТТДС I: 551) «место разрыва» < ***өзгелек** яисә (ТТДС I: 551) **өзеклек** сүзеннән килеп чыга ала.

Дерив.: **өзлексез.**

**ӨЗЛЕК II [өзлөк]** (ТТДС I: 551; ТТДС II: 402) «повторная болезнь, рецидив болезни» < **Өз** (к.), **Үз** (к.) «шайтан, яман чир; авыру, чир рухы» сүзеннән булуы бик ихтимал. Икенче яктан, әлбәттә, **өзел-ү** ← **өз-ү** сүзләре нигезендә ясалуы (яки контаминациясе) гаҗәп түгел (мәс., **өзлек < өзүлек** һ.б.). К. **Өзлек-ү.**

**ӨЗЛЕК-Ү (өзлегү, өзлекте)** «вторично заболеть после сравнительного выздоровления; заболеть после родов» ← диал. **өзөл-** id. сүзенең интенсивлык формасы, к. төр. *үзүл-,* башк. *өзлөкһөн-,* каз. *үзлүк-* бор. төрки *üzel-* (DLT I: 195) «өзлегү», к. ш. ук Будагов I: 133. Чаг. чув. *вĕрĕл-* «өзлегү». **Өз-ү I** сүзенә катнашы юк шикелле. Чаг. **Өзел-ү II, Өзлек II.**

Дерив.: **өзлегел-ү, өзлектер-ү.**

**ӨЗ-Ү** «рвать, порвать» < гом. кыпч., уйг., чыгт., гом. угыз., бор. төрки *үз-*, төркм. *үй-, үйз-*, себ. (Дмитриева 1981: 170) *öйс-*, сары уйг. *йуз-* < **үйүз-* id. **үй-, *үйү-* фигыленең йөкл. юн.; к. ш. ук алт. диал., хак. *үс-* «өзү» һ.б. Радлов I: 1889, 1901; Будагов I: 134; ЭСТЯ I: 621–622.

**Өз-** бик продуктив нигез: **өзел-ү, өзеш-ү, өздер-ү; өзек, өзем, өземтә,** диал. **өзенте; өзген, өзгенлек** (чаг. **бөлген, бөлгенлек**); **өзмә.** К. **Йөзем, Өзлек, Өзлек-ү.**

**ӨЙ,** диал. (ТТДС I: 556; Тумашева 1992: 28, 67, 163, 228; Дмитриева 1981: 193) **үй, әү, ĕү, ү**, иске тат. (XX г. башларына кадәр) **өйү** «дом, жилище», диал. «проушина топора», «квадрат (в играх детей)» < гом. кыпч., уйг., чыгт., госм. *үй* id. Бу кыска гына сүзнең фонетик вариантлары гадәттән тыш күп: алт. *үй, үй, үк, үк, ух, үх, уң, уу, уг* (к. Баскаков 1972: 261), тув. *öг, öö* ~ уйг., төркм. *öй*, бор. төрки (ДТС: 623) *üjüv, eb, ef, ev* «өй» һ.б. Бу яңгырашларда, гомумән, ауслаутта гом. төрки, уйг. *-й* һәм угыз-миш. *-w* линияләрен аерырга мөмкин. Угыз-миш. линиясенә төр. *ev* ~ кр.-тат. *ew*, бор. төрки *eb* > хак. *иб* һәм чув. *ав* (*авлан-* «өйләнү» сүзендә) < миш., себ. *әү* һ.б. карыйлар. Хак. диал., уйг. диал. (Радлов I: 1308) *öп* «өй» икенчел булса кирәк. Иске тат. *өйү* [*өйew*] ~ кар. *йүw* < *үйүw* ~ чыгт. *эйү, үйү* һ.б. (к. Будагов I: 163–165) бу сүзнең тәүдә ике иҗекле (ихтимал, **үйүг*) булганлыгын күрсәтә шикелле.

Кайберәүләр (Н.А. Баскаков һ.б.) *өй* сүзен **өй-ү** фигыле белән баглы дип карыйлар. Безнеңчә, бу шикле фараз. Дөресрәге кыт. *in, i* «ил чигендәге кальга, Бөек Кытай диварының бер үҗәге (вышкасы, бастионы)» сүзе белән баглап булыр иде кебек. Чаг. кыт. *ин коу* «кальга авызы», *ин мынь* «кальга капкасы; кальгалар». Поливанов Е.Д. К этимологиии слова *үй, öй* «дом, юрта» // Труды лингвистического

сектора Узбекской НИИ Культурного строительства, I. Вып. II. Ташкент, 1934. К. ш. ук Будагов I: 105–106; Räsänen 1969: 34; Баскаков 1966: 29; ЭСТЯ I: 513–515; Кажибеков: 239.

Дерив.: **өйле, өйсез; өйлек, өйчек** («кечкенә өй» ~ башк. *өйсөк* «өйчек, куыш; ши́на; кош тозагы», к. БТДҺ: 256); кушма сүзләр составында: (ТТДС I: 522; ЗДС: 690; БҺҺ III: 149) **өйкәртә, үкәртә** «ишек алды», (Тумашева 1969: 164, 228; БҺҺ III: 149 һ.б.) **өйгеше, ү кеже, үдөгө** «хатын, бичә». К. **Өйлән-ү.**

**ӨЙКӘ-Ү** (ДС I: 254) «тереть, натереть (рукой)» < гом. кыпч., к. башк. *өйгә-,* к.-калп. *үйке-,* кырг. *өйқө-* id., к. ш. ук башк. (БТДҺ: 256) *өйкәлән-еү* «сыену (иркәләнеп), кыланчыклану», *өйгәү* «сөял, өйкәлгән төштә чыккан чуан». Ниндидер *үй ~ өй ~ өг* тамырыннан, чаг. төркм. *үве- ~* тув. *өге-* «өйкәү» һ.б. (ЭСТЯ I: 618–620). К. ш. ук **Өйрә.**

**ӨЙКЕМ** «группа» ~ башк. (БТДҺ: 256) *өйкем ~ өймәк* **өйәк-ү** һәм **өй-ү** сүзләреннән ясалган нигезләр (**өйкем < өек-ем**).

**ӨЙЛӘ** «полдень; полуденная молитва, обедня» < гом. көнб. төрки (кар., чыгт., госм. һ.б., к. Радлов I: 1801) *үйлä < ödläk* «вакыт, көн», чаг. тибет. *öd* «яктылык», шумер. *ud* «өйлә; көн», бор. төрки *öd-kün* «көн уртасы». *Өйлә ~ ödlä* һ.б., күрәсең, **төнлә** моделендә ясалган. Чаг. ш. ук алт., чыгт. (Радлов I: 1869) *үдä*, яз. монг. *üde* «өйлә», як. (Пекарский: 3192) *үтä* «көнлек юл азыгы». **Өйлә ← өйлә намазы** тур. к. Çagataj 1957: 231–239; ЭСТЯ I: 516–517.

**Өйлә** сүзе дини лексикага карый, ләкин ул исламгача булган диннәрдән калган шикелле.

**ӨЙЛӘН-Ү,** диал. (миш., себ.) **үлән-ү, әүлән-ү** «жениться», сирәгрәк «выходить замуж» (букв. «обзавестись домом») < гом. кыпч., уйг., төркм. *үйлен-* id., угыз., кр.-тат., бор. төрки *evlän-* >> чув. *авлан-* id. Чаг. гом. кыпч. *үйли,* госм. *äвли* «өйләнгән». К. **Өй.**

Дерив.: **өйләнеш-ү, өйләндер-ү.**

**ӨЙРӘ,** диал. (ТТДС: 560; БТДҺ: 363 һ.б.) **үрә,** (ДС III: 62) **ирә, ири** «суп, похлёбка (с крупой, лапшой, вермишелью)» < (нуг.) *үйре* < уйг. диал., чыгт., алт., хак. *үгре*, бор. төрки (ДТС: 623) *ügrä* «өйрә, умач, онаш» >> як. *үөрэ*, кар. *иврe*, хак. диал. *үгүрэ* > һ.б. id. бор. **үгүрәг* «уынты, умач» сүзеннән булса кирәк, ул сүз исә *үгүр-* «уу, уылдыру» ← (кырг.) *үк- ~* уйг. *өг-*, хак. *үү- ~* башк. (БТДҺ: 255) *өгөү (өк-) ~* бор. монг. *ügü-*, бор. төрки (ДТС: 622–623) *ügi-, ügü-* (>> төркм. *үви-*) «уып ваклау», шуннан себ. (Тумашева 1969: 163) **өгел-ү** «уалу, тузанга әверелү». Чаг. **Өйкә-ү.** Räsänen 1969: 369; ЭСТЯ I: 324–325.

Дерив.: **өйрәле** («ярлы» мәгъ.), **өйрәсез, өйрәлек** (к. *Ходайның фәрманы – тавык түккән ярманы; Буткалык дип тора идем, Өйрәлек тә калмады,* такмаза).

**ӨЙРӘН-Ү**, диал. **үрән-ү,** миш. **өрән-ү, эрән-ү** «научиться» ~ чув. *вĕрен-* id. < гом. кыпч. *үйрен-*, башк. *өйрән-,* башк. диал. (БТДҺ: 363) *үрән-,* кр.-тат. *үйрән-,* кар. *öрäн-,* госм., чыгт. *өйрäн-, öгрäн-,* уйг. *үгрен-,* алт. *үгрен-* < бор. төрки (ДТС: 380) *ögren-* id. Иске тат. **үгрән-ү** варианты XX г. башларына кадәр актив кулланышта була. К. ш. ук кырг. *өйрөн-,* төркм. *өврен-,* тув. *өөрен-,* як. *үөрэн-,* ләкин куман., уйг. *әүрән-* «өйрәнү, белү» ← бор. *öгрә-* «белемле булу» ← *öк-* «уйлау, белем алу» ← *ö-* «белү» (к. ЭСТЯ I: 496–498); ягъни *өйрән-ү* бор. **өйрә-* < **үгрә-* фигыленең кайт. юн. булып чыга, к. ш. ук **Берүк, Үгет, Үкен-ү, Үрдәк.**

Бор. *үгрә- ~ öгрә- ~ әүрә-* фигыленең бүтән юнәлешләреннән Әбүлгази телендә төш. юн. *үгрүл-* (Будагов I: 146–147) һәм **өйрәт-** << **үгрәт-** (к.) сүзләре генә сакланган. Төп фигыль үзе һәм урт. юн. әлегәчә билгеле түгел. Төрле формалар тур. ш. ук Федотов I: 118.

Дерив.: **өйрәнел-ү, өйрәнеш-ү, өйрәндер-ү;** к. **Өйрәнчек.**

**ӨЙРӘНЧЕК** «ученик, обучающийся; предназначенный для обучения, тренировки, учебный» < гом. кыпч. *үйренчик* (каз., к.-калп. *үйреншик*) < (алт.) *үгренчик* «шәкерт; өйрәнчек». *Кыланчык, чукынчык* ясалыш моделендә.

**ӨЙРӘТ-Ү**, диал. **үрәт-ү**, миш. **өрәт-ү, эрәт-ү** < гом. кыпч. *үйрәт-*, башк. *өйрәт-,* башк. диал. *үрәт-*, кырг. *өйрөт-*, госм., чыгт. *өйрäт- < огрäт-* һ.б. (к. Радлов I: 1174, 1200), куман., уйг. *әүрәт-*, бор. төрки (ДТС: 38) *ögret-, ügret-* id. Иске тат. **үгрәт-** варианты XX г. башларына кадәр актив кулланылган. К. ш. ук төркм. *өврет-*, тув. *өөрет-* һ.б. «өйрәтү»; чув. *вĕрент-* «өйрәтү» ← *вĕрен-* «өйрәнү»; *өйрәт-*, күренеп тора ки, бор. *өйрә- << *үгрә-* фигыленең йөкл. юн., к. **Өйрән-ү.**

Дерив.: **өйрәтел-ү, өйрәтеш-ү, өйрәтен-ү** «өйрәтергә теләп кыбырсу», **өйрәттер-ү; өйрәтке**

(«укытучы ярдәменнән тыш берәр нәрсәгә өйрәтә торган дәреслек» һәм «күнегү, күнекмә» мәгъ. сирәкләп кулланыла); **өйрәткеч; өйрәтмә́** («тәгълимат» мәгъ.) рус. *учение* сүзеннән калька, **өйрәтүче** һ.б.

**ӨЙ-Ү I,** диал. **өйе-ү** (к. ЛТ I: 68), **ү-ү** (миш., себ.) «собирать в кучу» < гом. кыпч., уйг. *үй-*, чыгт. *үгү-* (Радлов I: 1810) id., кырг., чыгт., алт. *ү, үү-* «җыю», хак., шор. *үг-*, чыгт., бор. төрки (ДТС: 623) *ÿk-, üg-* «җыю, туплау». Шуннан бор. төрки (ДТС: 623–624) *ükül-* «күбәю, ишәю», *ükil-* «туплам» һ.б. Материаллардан күренгәнчә, борынгырак вариант *үкү-* булган (шуннан *үгү-* > *үг-* һәм *үкү-* > *үк-*), бу фигыль исә *үк* исем сүзеннән («өем, таучык» мәгъ. булган булса кирәк) килә. Шундый фаразлардан чыгып, шактый мантыйклы рәвештә кайбер тюркологлар *өй-* фигылен һәм *өй* «торак» сүзен гомоген (фигыль-исем синкретизмы) дип карыйлар (Н.А. Баскаков, А.Н. Кононов). Чөнки урманлы якларда колгалардан, чошлардан *өелгән* конуссыман өйләр киң таралган булган. Шулай да, безнеңчә, бу чагыштыру белән ашыгып мавыгырга кирәкмәс. Чаг. **Өй-ү II.** ЭСТЯ I: 620–621; Кажибеков: 239.

Дерив.: **өел-ү, өеш-ү, өйдер-ү; өйгеч ~ өйдергеч** (машина); тат. диал., башк. **өйөк** «өелебрәк торган»; **өем; өймә** (шуннан **өймәлә-ү → өймәләмә**, к. ТТДС: 403) һ.б. К. **Өер, Өер-ү, Өялә-ү**. Чаг. **Өянке, Үкеш.**

**ӨЙ-Ү II** (Тумашева 1992: 164; БТДҺ: 256) «рассказывать (сказки); загадывать загадки и т.п.» ~ төр. *öy-* «төрле кызыклы сүзләр сөйләү»; *öykü* «хикәя». Чаг. тунг. (ССТМЯ II: 250–251) *уй-* «бәйләү, тезү, оештыру». Ш. ук. **өй-ү әй-ү** (к.) сүзенең фонетик деривациясе дә булырга мөмкин.

**ӨКӘ-Ү** иск. «хвалить, расхваливать» (чаще в форме совместного залога **өкәш-ү** «хвалить друг друга – о муллах»), **өке-ү** иск. «почитать, отзываться с хвалой» < уйг. *өгү-*, бор. төрки, госм. *ög-, ök-* id. ДТС: 379–380; Будагов I: 148 һ.б.

**ӨКЕ [өкө],** диал. (Тумашева 1992: 163, 228) **өгө, үгү** «филин», «перо филина на шапке» ~ чув. *ухĕ*, мар. *уҥӧ, уҥо,* удм. *ыгы* < гом. кыпч. *уки, үкү,* үзб. *укки,* уйг. *үкә,* хак., тув. *үгү,* алт. *үкү, үккү,* төр. *öğü, üğü,* бор. төрки *ühi, ügi* (ДТС: 622–623) id. тәкълиди сүздән (кошның кычкырыгыннан), чаг. ним. *Uhu*, төр. *puhu* «өке». Өкенең төрки халыкларда «хикмәтле» кош булуы тур. к. Ögel: 357–358.

**ӨЛӘ-Ү** (к. Баязитова 2001: 194) «делить, распределять» < гом. төрки (алт., хак., чыгт., бор. уйг., каз. диал.) *үлә-*, кырг., себ. (Радлов I: 1849) *үлӧ-*, бор. төрки (ДТС: 624) *ülä-* id. К. ш. ук төркм., төр. диал., алт., иске төрки (ЭСТЯ I: 627–629) *üle-* «өлеш; пай; хәер, садака». Бу (фигыль һәм исем) нигезләрнең тамыры бор. уйг. *ül, öl* «кисәк, өлеш; үлчәм; язмыш» дип исәпләнә, шуның фигыль коррелянты *ül-, öl-* «билгеләү, өләшү» сүзе дә булган диелә, к. кырг. *лӧк* «тиешле өлеш», як. *үлэх* «заказ; мөддәт; шартнамә» ~ як. *үлүк*, тув. *үлүг* «өлеш». Чув. *валем* «өлеш» сүзенең гом. төрки параллеле – башк. (БТДҺ: 258) *өләм* < **үләм* «бүленгән өлеш». Чув. *валĕ* «өлеш, кыйсем» сүзе *валь* < **үл* сүзенең 3 зат тартым формасы дип исәпләнә. Чув. телендә бу тамырдан *валли* «(кем, нәрсә) өчен, «(кемгә, нәрсәгә) була» сүзе ясалуы кызыклы (к. Федотов I: 98–99). **Өлә-ү < үлә-** һәм аның дериватлары тур. күп язылган. К. **Өләш-ү, Өлеш, Өлте, Өлтерә-ү, Үлчә-ү.** Чаг. **Өлгән.**

**ӨЛӘШ-Ү** «разделить, распределить» < гом. кыпч., гом. төрки *үләш-, өләш-* (> алт., кырг. *үлӧш-*, нуг., каз., к.-калп. *үлэс-*, кырг. *үлӧс-*), як. *үллэс-,* чув. *валеç-, вальаш* < болг. **wәләш-* id. *үлә-* (к. **Өлә-ү**) фигыленең урт. юнәлешеннән (төп фигыльдән киңрәк таралган һәм мәгъ. дә үзгәрә төшкән). Будагов I: 151; ЭСТЯ I: 628–629; Федотов I: 98–99.

Дерив.: **өләшел-ү, өләшеш-ү, өләштер-ү.**

**ӨЛГӘН** «бог-творец» (так сказать, «рабочий бог», который по приказу верховного бога *Тәңре* создал землю и людей и т.п.) < алт. *Үлген, Үлгäн*. *Өлгән* сүзе әд. телдә борынгыдан тәнәйтепреконструкцияләп кенә кулланыла. Тат.-башк. сөйләшләрендә бармы икән – билгеле түгел. Һәрхәлдә себ. сөйләшләрендә булуы бик ихтимал. Сүзнең чыгышы тур. к. **Өлә-ү.** Чаг. **Өлкән.**

Алт., шор., бур. һ.б. *Ульгень, Ӱлген, Улгэн* – югары тәңре яки тәңреләрнең берсе тур. МНМ II: 546–547. Бу мифик зат тур. бик төрле, хәтта каршылыклы сөйләкләр бар икән. Аларда *өлгән* еш кына *әрлик* (к. **Әрлик**) белән бергәләшеп яки каршылашып эш итә. Аларның мөнәсәбәтләре башк. «Урал батыр» эпосындагы Урал һәм Шүлгән арасындагыларга охшап китә. *Үлген* сүзенең чыгышыясалышы төгәл генә билгеле түгел дип язалар.

**ӨЛГӘШ-Ү**, диал. (ТТДС II: 403) **өлкәш-ү** «достичь, достигать; успевать, сделать во-время» – бу фигыль тат. һәм башк. телләрендә генә булса кирәк,

һәм ул нининдер ***өлгә-ү < үлгә-** фигыленең урт. юн. дип уйларга мөмкин, к. тув. *үүлгет-* «яңалык эшләү, майтару, тоҗыру» (шуннан *үүлгедик* «акция, инициатива, кирәкмәгән активлык»), як. *улуһуй-* < *улусөй-* «өлгәшү, омтылу; мавыгу; булдыру»; бу сүзләр тув. *ууле-* «язмыш; талант; нәтиҗә, эш», як. *улэ, улä* «эш, шөгыль, хәрәкәт» ~ яз. монг. *üile, üil* «иҗади эш», гом. тунг. *улä, уйлэ, уилэ* «эш, хезмәт», фигыль мәгъ. «эшләү, ясау» (к. ССТМЯ II: 266) сүзләре белән тамырдаш булса кирәк.

**Өлгәш-ү** ← ***өлгә-ү** сүзен **өлгер-ү** белән турыдан-туры баглау фонетик законнарга хилаф. Тик, ихтимал, *өлгәш-* < *өлгәреш-* үзгәреше булырга мөмкин. К. **Өлгер-ү.**

Дерив.: **өлгәшел-ү, өлгәшен-ү, өлгәштер-ү.**

**ӨЛГЕ I [өлгө]** «часть оконного переплёта, стекло части окна», диал. (ТТДС I: 553) «вышитый кусок ткани для нашивания на одежду; вышитый конец полотенца» > чув. *ĕлкĕ,* мар. кч. *улгö* id., ш. ук «портрет» ~ госм. *öлгу, улку*, бор. төрки (ДТС: 624) *ülgü, ülkü* «чама, үлчәм; шартнамә» ← *öл-, ул-* «бүлгәләү, өләшү» (к. **Өләш-ү, Өлеш**). Чаг. бор. төрки *ÿlgü* «мизан йолдызлыгы». К. ш. ук **Өлге II.**

Дерив.: **өлгеле, өлгесез** (мәс., тәрәзә), **өлгелек, өлгелә-ү.**

**ӨЛГЕ II [өлгө]** «образец; выкройка, модель» < гом. кыпч., үзб. *улги*, кырг., уйг., алт., урта төрки (Боровков 1963: 338) һ.б. *улгу,* хак. *улгу, улгэ*, уйг. *улгә* id., хак. *улгу* (*улгу-чаргы* парлы сүзендә) «чакыргы, лозунг» ~ төр. *ülkü* «идеал, югары максат» һ.б. Бу сүз гомумән **өлеңге** (к.) сүзеннән килә, ләкин аңа **өлге I** сүзенең дә контаминацион тәэсире көчле. Räsänen 1969: 520.

Дерив.: **өлгеле** «үрнәкле».

**ӨЛГЕР [өлгөр]** «ловкий; расторопный, оперативный» – тат., башк. телләрендә генә бугай. Бу сүз **өлгер-ү**гә семантик якынлыкта булса да, аннан чыгарылалмый, морфологик җәһәттән турыдан-туры **өл- < ул- < уйл-* фигыленнән (*-гер,* чаг. **елгыр, үткер** һ.б.ш.) булса кирәк. К. **Өлгер-ү.**

Дерив.: **өлгерлек; өлгерлән-ү.**

**ӨЛГЕР-Ү [өлгөр-]** «успевать, успеть; поспевать, поспеть» > чув. *ĕлкĕр-* id. < гом. кыпч., уйг. *улгур-*, каз., к.-калп. *улгер-* id. < **өл- < ул- < уйл-* «ясау, булдыру» (к. **Өлгәш-ү**) фигыленең йөкл. юнәлеше булса кирәк; шуның белән бергә, тат. сөйләшләрендә **өлгә-ү** (< **улук-ә-*) «булдыру» фигыле дә бар шикелле. Räsänen 1969: 520; Федотов I: 148.

Дерив.: **өлгерел-ү, өлгерт-ү; өлгерткеч** неол.

**ӨЛГЕТ [өлгөт]** сөйл. «льгота» < рус., әлбәттә.
Дерив.: **өлгетле, өлгетсез.**

**ӨЛЕҢГЕ [өлөңгĕ],** диал. (ТТДС II: 389) **элеңге** (халык этимологиясенчә ← *эл-у*) «занавес снаружи, вывешиваемый в случаях наличия в доме покойника; образец» (к. *Язу язган җегетләргә бүгенге Язу үлчәр өчен булсын өлеңге.* Дәрдемәнд. Исә җилләр 1980: 146), «мунча альяпкычы», «вуаль» (ТТАС III: 706), «фата» (Будагов I: 155) ~ төркм. *улүңңү* «өлге» < бор. төрки (ДТС: 615) *uruŋgu, uruŋu* ~ бор. монг. *orunγa* «байрак; билге»; төбендә тибет. *roŋgo* «билге» сүзеннән (Ramstedt 1935: 289). Бу сүз төрки телләрдән слав. һ.б. телләргә дә киң таралган, к. венг. *roŋgy* «(бизәкле) тукыма кисәге», рус. *хорунга* («Казаки … преклонили перед Пугачевым *хорунгу*… к. Н. Дубровин. Пугачев и его собщники, т. III. СПб, 1884: 242) «байрак», бор. рус. *хорюговь, хоругы* «байрак», *хоронгви* «эскадроннар», пол. *choragiew* «байрак», *chorazy* «хорунжий» ← иске слав. *хорѫгы* «байрак»; рус. *хорунжий* << бор. төрки *horuŋči* «байракчы» (к. Фасмер IV: 269), бор. төрки *urungu* «беренче сугышчы» (Donuk: 106) һ.б. һунн заманнарыннан ук килә булса кирәк, чөнки бу сүз тарих дәвамында тагын берничә тамыр сүзгә тармакланган: хак. *улгу-чаргы* «чакыру, оран» ~ алт. *улгер,* тув., бур. һ.б. монг. *улгэр, улигэр* «батырлар тур. эпос (яшь буынга *өлге*)», тат., башк. *өләң, үләң*, каз., к.-калп. *улаң, улең* «эпик характердагы җыр»; як. *олоңхо* «эпос» сүзе дә шул *уруңу* сүзеннән булса кирәк. Ихтимал, **оран** сүзе дә бор. *оруң* сүзенә кайтып каладыр. К. **Үләң.**

**ӨЛЕШ [өлөш]** «часть, доля» > чув. (Сергеев 1968: 17) *ĕлĕш*, мар. *улуш* id. < гом. кыпч., уйг., госм., төркм. (һ.б. угыз) *улуш* id. ← **ул-, улу-* «өлешләү» (к. **Өл-ү**) к. ш. ук себ., гом. кыпч. *улэш* (> каз., к.-калп. *улес*), кырг. *улöс* һ.б. «өлеш» ← **улә-ү** (к.). ЭСТЯ I: 627. *Өлеш* мәгъ. **өлек** сүзе дә бар бугай (һәрхәлдә **өлеклә-ү** бар). К. КБтә:

*Баят, бирмешеңнән миңа кыл өлөк,*
*Күңлем булсын тере, ә нәфсем үлек.*

К.**Өлкә.**
Дерив.: **өлешле, өлешсез; өлешлә-ү.**

**ӨЛКӘ** «область» < гом. кыпч. *улкэ, öлке*, кырг. *öлкö*, госм. *öлкä* «өлкә, ватан, мәмләкәт; икъ-

лим», бор. монг. *ölke* «икълим», бор. төрки *ölki* id. (Räsänen 1969: 371) ← уйг. *үлүк* «өлеш, пай» (к. Радлов I: 1851) < бор. төрки (ДТС: 625) *ülük, ülüg* > тув. *үлүг,* як. *үлүк, үлү* «өлеш» сүзеннән булса кирәк (<**үлүк-әк*), сүзнең тамыры *үл-, үлә-*, к. **Өлә-ү**. ЭСТЯ I: 629–630.

**ӨЛКӘН,** диал. (БТДҺ: 250) **олҡан** «старший; взрослый», диал. «большой», (ТТДС I: 553) «значительно» > чув. *ӗлккен* «великолепный; пышный; важнецкий» < гом. кыпч., төркм. (ТДГДС: 181) *үлкен*, нуг. *үйкен*, кырг. *үлкөн,* үзб. *улкан* «өлкән», алт. (Баскаков 1966: 163) *үлген* «зур; озак» һ.б. < **үлүкә-гән* яисә **үлүкәйгән* булса кирәк, к. каз., к.-калп. *үлкей-* «үсү, зураю; картаю» ← ***үлүк** «зур; карт», к. ш. ук башк. *өлкәйеп йәшәү* «кыенлык кичереп яшәү» (БТДҺ: 257) – бәлки хата аңлатмадыр, дөресе «картаеп китү»дер.

**Өлкән, өлкәй-** сүзләренең чыгышы гомумән юраулы. Тат., башк. *олҡан* вариантын каз., к.-калп. *улуқан*, госм., төркм. (к. Радлов I: 1694) *улуққан* ~ як. *улахан, улаххан* «зур, биек, олы» сүзләре белән чагыштырырга бөтен нигезләр бар. Ләкин *өлкән* < *ӑлкан* ~ гом. төрки *үлкән* < *улқан* дип фаразлау да ышандырмый. Ихтимал, *өлкән* < *үлкән* һәм *ӑлкан* < *улкан* сүзләре бор. төрки кушма (к. Sumer 1992: 274) *ulu qañ* ~ *ulu han ata* «нәселдә, ыруда иң олы яшьтәге кеше» сүзеннәндер (бу фараз палаталь һәм веляр вариантлар булуын аңлата, к. бор. төрки *qañ* = *қань* «зур ата – ыру башлыгы»). К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 624) *üklä-* «зураю, күбәю» – шуннан *үклән* > *үлкән* ясала ала. Гомумән, барыбер монда шикләнергә урын кала.

**Өлкән** < *үлкән* сүзен алт., хак. һ.б. *Үлген, Үлгөн, Үлкен* > бур. *Үлгэн* «яралтучы тәңре; өлкән, зур» (к. **Өлгән**) сүзе белән чагыштыруны да юкка чыгарып булмас (к. Федотов I: 148). ЭСТЯ I: 630 (төрле фаразлар китерелә).

Дерив.: **өлкәнлек, өлкәнәй-ү.**

**ӨЛКӘР** «созвездие Плеяд, Плеяды» > чув. (Ашмарин III: 12, IV: 102) *ӗлкер, елкер* < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *үлкәр*, алт., хак., тув. *үлгәр*, як. *үргэл* < бор. төрки (ДТС: 625) *ülkär* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 379) *ülger* id., хак. *үлкер* «Өлкәр; Күрпәч (Курбутсан, Хормустан, Орион)» йолдызлыгын атыйлар, к. Бутанаев В.Я. Представления о небесных светилах в фольклоре хакасов // Учёные записки Хак. НИИЯЛИ, 1976: 236–237). Алт. сөйләшләрендә *Үлгәр* һәм *Үлгән* «иҗатчы тәңре» сүзләре бутала һәм бу хәл, **Өлкәр** һәм алт., хак. һ.б. *Үлген, Үлгән* (к. югарыда) сүзләре тамырдаш түгелме икән, дигән фикер уята. Л. Базен (к. Bazin L. Les noms turcs et mongols de la constellation des Plejades // Acta Drientalia, t. X. f. 3. Budapest, 1960: 294–297) *өлкәр* < *үлкәр* сүзе *үл-* «бүлү, бүлгеләү» (к. **Өлеш-ү**) сүзеннән дип бара.

Тат. сөйләшләрендә **Өлкәр** сүзе популяр түгел – аның урынына **Иләк йолдызы** диләр. Башк. (БТДҺ: 257) *Өлкән йондоҙ* («Өлкәр» – халык этимологиясе буенча шулай аталган. Каз. *Үркер* «Өлкәр» варианты да икенчел булса кирәк.

**ӨЛПӘК** «птичье перо на головном уборе (как украшение)» к. **Өрпәк I.**

**ӨЛТЕ [өлтө],** диал. [Тумашева 1992: 164) **өлтек** «часть треснутой поверхности, часть треснутого плоского предмета» < бор. *өлет-ек* < **үлүт-үг* «чатнату, өләшү» (к. **Өл-ү**). К. монг. *үлтү-* «чәрдәкләнү» (төрки телләрдән булса кирәк). К. түбәндәгене.

**ӨЛТЕРӘ-Ү [өлтөрә-]** «рассыпаться в любезностях; лебезить» ~ каз. *үлтүре-, үлдүре-*, кырг. *үлдүрө-*, як. *үлтүрүй-* «вак кисәкләргә, өлтеләргә бүленү» ~ тат. диал. (Тумашева 1992: 229) **үлтрәү** «картаю, картаеп алҗу» (*үлтү-рә-*) сүзеннән, к. ш. ук монг. *ültüre-, ültürge-* «таркалу; өлтеләргә бүленү» (Poppe 1972: 99), к. ш. ук тув. *үлдүре-* «таркалу; көпшәкләнү».

***ӨЛ-Ү** «распределять; разделить» – бу сүз тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *өлү* ~ як. һ.б. *үлүү* «участок, өлкә» сүзендә чагыла. К. **Өлә-ү.**

**ӨЛФӘТ** «единодушие; общение (дружеское); внимание (к человеку)» < гар. *үлфәт* id. К. ш. ук **Олпат.**

**ӨМӘ** «помочь, выполнение трудоемкой работы сообща в порядке взаимопомощи (с односельчанами и т.п.); субботник» ~ чув. (Сергеев 1971: 91) *виме, ниме, нүме, мүме, мимме,* мар. (бөтен сүзлекләрендә дә бирелә) *вимӓ, вүмӓ, бүмӓ, мүмӓ, үме,* удм. *веме* (> тат. диал. – ТТДС I: 77 – **бемә**) ~ каз. *үме*, хак. *öме* «өмә; бергәләшеп», уйг. *өм* «бергәлектә, дәррәү», алт. *öмö* «киңәш», иске тат. (Будагов I: 158) **өмәйемәк** < **өмә йыймак?** «ярдәмгә чакырмак», **өмәләмәк** «үзара сөйләшеп-килешеп (законга хилаф рәвештә) бүлешмәк» ~ каз. *үмелеү* «бергәләшеп эшләү». Трбс. сөйләшендәге **өммә**

«өмә» варианты **өм- < үм-** дигән фигыль булган дип уйларга нигез калдыра, к. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 268) *уммай-җуммай* «бергә-бергә». Чаг. яз. монг. *ӱтӱ-ǰi* «җыелышу», тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 272) *умун, омо, ому* (вариантлар күп) «бер; бергә». Нұрмағамбетов: 126–127.

**ӨМӘК** (ЛТ; ТТДС I: 553) «маковка; головка лука и т.п. с семенами» – рус. *мак* сүзеннән яисә турыдан-туры грек теленнән; чаг. чув. *макӑнь*, бор. рус. *маконь* < грек. *макон* id.

**ӨМЕТ [өмөт]** «надежда» ~ иске тат. **үмид** < гар. *умӣд* id. Бу сүз белән беррәттән төр. теленнән алынган **умут** (төрки *ум-* тамырыннан) «өмет» сүзе дә кулланылган.

**Өмет** продуктив сүзьясагыч нигез: **өметлән-ү, өметлә-ү, өметле, өметсез** һ.б.

**ӨММӘТ** «сообщество мусульман, умма» < гар. *уммӓт* id. ← *умм* «аналык (ана булу), нигез, чыгыш» сүзеннән. Бу сүздә матриархат тәэсире сизелә. К. **Өмми.**

**ӨММИ** иск. «неграмотный, не умеющий читать и писать» < төр. *ümmî* < гар. *уммӣ* «анадан тума; анадат туган килеш калган, укымаган» ← *умм* «ана булу, аналык һ.б.», к. югарыдагыны.

**Өмми** < *умми* төрки телләрдә киң таралган булган, к. каз. (ҚТДС: 42–43) *әмбі, әми, әмі* «надан, укымаган» ~ тат. (ЗДС: 81) **әмәкәй** «ахмак, надан; беркатлы»? Ләкин хатын-кыз исемнәрендә очраган **өмме-** «анасы, иясе, тудыручысы» мәгъ., мәс., *Өммекамал* «кямиллек иясе кыз», *Өмменур* «нур иясе кыз», *Өммеһани* «кунакчыллык иясе» кебек һ.б. (әлбәттә, бу исемнәрнең тарихи эчтәлеге дә була).

**ӨН I** «голос, звук (единичный)», диал. «влияние на окружающих (о личности)» < гом. төрки *үн* id. (Радлов I: 1819), кырг. *үүн*, төркм. *үйн*, кр.-тат. *ын*, аз. *ин* id., төр. *ün* «өн, дан». Нуг., каз., кырг. *ың* «тавыш» (к. *ыңгырашу*) белән чагыштыру (Севортян, к. ЭСТЯ I: 625–626) дөрес түгел. *Өн* < *ӯн* < **öгун* id. *ö* (тәкълиди) тамырыннан булса кирәк. К. **Өндә-ү, Эндәш-ү.**

Дерив.: **өнле, өнсез.**

**ӨН II** «явь», диал. (эчк.) **өң** < гом. төрки *үн, үң* (төр. *öп*) «өн; күз алды; ал як» сүзеннән; к. диал. *өн керү* «айну» (ДС I: 254), Будагов I: 148–149; TS: 168. К. **Өң.**

**ӨН III** «нора; берлога» – дөресе *ён* булырга тиеш, чөнки гом. төрки *ин* < бор. төрки (ДТС: 209) *in, jin, jın* ~ чув. *йӗнӗ* «өн, кын», к. ш. ук төркм. *һин, хин* id. Чув. *йӗнӗ* < *кын, кыны* булырга тиеш, шуннан *ин* дә *кын* яңгырашыннан түгелме икән, дигән сорау туа. Ләкин гом. төрки (чув. теленнән тыш) *к-* > *й-* күчешенә мисаллар юк диярлек; *өн* сүзендә сузыкның иренләшүе башк., тат. диал. *өң-ү* «казып керү» сүзе тәэсирендә барлыкка килгән булса кирәк.

**ӨНӘ-Ү** – употребляется в отрицательной форме: **өнәмә-ү** – «терпеть (кого, что), мириться с существованием (кого, чего)» < диал. (Тумашева 1992: 160) **ŏна-** < гом. төрки (Радлов I: 1640–1641) *уна-* < бор. төрки (ДТС: 612) *ипа-* «килешү, ризалашу» сүзеннән (палатальләшкән), чаг. төр. *опа-* «хуплау, рөхсәт бирү, килешү». К. Насыйри буенча, *өнә-, ŏна-* «ризалык тавышы бирмәк» (ЛТ I: 45) *өн-, ŏн-* «тавыш, өн» сүзеннән. Бу раслама өстәмә дәлилләргә мохтаҗ. Будагов I: 160.

**ӨНДӘ-Ү** «взывать; приглашать», диал. «подавать голос; извещать» < гом. төрки *үнде-, үндә-* < бор. төрки (ДТС: 625–626) *ündä-* «чакыру, тавыш бирү» ~ төр. *ümle-* «кычкырып чакыру» ← (гом. төрки) *ün* «өн, аваз». *Өндә-* нигезенең тат. *ĕндә-, индә-* ~ төркм. *индә-, иннә-* варианты бар, шуннан к. **Эндәш-ү** > **дәш-ү.** Бу вариант бор. төрки ядкәрләрдә дә очрый һәм бор төрки (төркм.) *үйндә-, үйндәт-* вариантыннан килә, ягъни

**үйн* → *үйнлә-* > *үйндә* → *индәш-* > *эндәш-*
«өн, аваз» «өндәү» ↘ *үндәш-* > *өндәш-*

булган. К. **Өн I.** Будагов I: 100–101; Мухамедова 1973: 105–106.

Дерив.: **өндәү** «кунакка (туйга) чакыру»; **өндәүле** «чакырулы»; **өндәм; өндәмә** «лозунг» фигыль юнәлешләреннән **өндәт-ү** генә кулланыла бугай. К. түбәндәгене.

**ӨНДӘҮ [өндәw]** «лозунг, взывание»; **өндәү җөмлә** – XX г. ясалган.

**ӨНЕГӘТ [өнөгәт]** (в сказках) «работа по обету (например, работа у сирот, стариков); сказочная птица, выполняющая работу по желанию хозяина» < монг. *унагат* «хезмәтчеләр» (*унаган* «хезмәтче» сүзенең күп. формасы). Чаг. **Өн-ү.**

**ӨННӘ** (ЗДС: 512) «бабушка (своя родня)» < *өлинә, олинә* < *олы инә.* Себердә һәм Уралда бу сүз

➛

күптәннән килгәнлегенгән **өннәкә, өннәш** «дәвәнисенең исеме кушылган кыз бала» сүзе күрсәтә шикелле. К. **Олы** һәм **Инә.**

**Олинә** сүзенә параллель башк. *оләсә* < *оли әсә* сүзе (**әсә** «ана») дә бар. *Өннә, олинә* дип сөйләүчеләр башкортлар белән бергә аралашып, кодалашып яшиләр.

**ӨН-Ү** (ЗДС: 512) «притязать». Бу Себердә теркәлгән сүз кыпч., үзб., уйг. телләрендә киң таралган *үндүр-* «ныкышып сорап алу; төрле юллар белән тырышып булдыру» сүзенең төп формасы булса кирәк, к. бор. төрки (ДТС: 385) *ön-* «пәйда булу; үсү; юнәлү, җитү» → *öndür-* «үстерү, булдыру, күтәрү, чыгару һ.б.» мәгъ. киң кулланылышлы сүзләр булган.

**ӨҢ** «передняя сторона; фактура меха» < гом. төрки *öң, үң* < бор. төрки (ДТС: 385) *öŋ* «төс, төсмер; алгы як» сүзеннән, к. ш. ук як. *öң* «уңдырышлы; төс, төсмер; чел, мездра»; *öнчöх* «түтә», төр *öп* «алгы як; киләчәк». К. **Үң,** чаг. **Уң.**

**ӨҢГӘЛ** «холка (лошади)», иске тат. (Будагов I: 150) **өнгән, унгән,** себ. (Тумашева 1992: 229) **үмгән,** чыгт. *үмңән, öмгäн* бор. төрки (ДТС: 385, 625) *ümgän, ötgän* id. *өң, үң* «алгы як» сүзеннән булса кирәк, к. ш. ук үзб. *öмгәй, умгай* «күкрәк» (ЎХШЛ: 201), кырг. *öмгöк*, хак. диал. *омых* «ат күкрәге». К. **Өңер, Үңер.**

**ӨҢГЕР [өңгөр]** «промоина (на крутом берегу, в земле и т.п.); боковая выемка» ~ башк. (БТДҺ: 626) **өңгөр** «мич куышы» < гом. кыпч., уйг., хак., алт., тув. *үңгүр, үңүр*, бор. төрки (ДТС: 626) *üŋür* «өңгер, грот, гар, мәмерҗә» *өң-* < *үң-* «казып керү» фигыленнән, к. ш. ук Мурзаев 1986: 577. К. түбәндәгене.

**ӨҢЕР [өңөр]** диал. «прорезь воротника, ворот» к. **Үңер.** Чаг. **Өң.**

**ӨҢЛЕ [өңлө]** диал. «видный собой; внушающий видом доверие». К. мәкаль: *Ат алсаң өңле булсын, сарык алсаң йөңле булсын.* Әд. әсәрләрдә кешенең *усал өңе, өркеткеч өңе* (яки – *өне*), *җанландыргыч өне* дигән тәгъбирләр очрый. Монда **өң – өн** микән, аерым сүз микән, **үң** (к.) сүзе белән бердәйме икән, әйтү кыен.

**ӨҢ-Ү** «делать, сделать углубление, промоину (о воде)» < гом. кыпч. *уң-* < бор. төрки (ДТС: 626) *üŋ* «казып керү; тишек тишү» сүзеннән. К. ш. ук як. *оң-* «чоку; куптару; казып керү һ.б.» (шуннан бик күп сүзләр ясалган). Чаг. эвенк. (ССТМЯ II: 280) *уңулу* «чокыр», яз. монг. *ongүurxai* «тишек, өн». К. **Өңгер.**

**ӨР,** диал. **ор: өр (ор) яңа** «совершенно новый; с иголочки», себ. **ŏра** (Тумашева 1992: 160) «совершенно» ~ чув. *вĕр, вăр* id. (Ашмарин V: 309, 357) < алт., хак., тув. *үр, үүр* id. ш. ук «күптән; күп (заманнар)» < бор. төрки *üг* «күптән» (ДТС: 626), к. хак. *үрбе, аспа* «азмы-күпме». Мондагы мәгъ. үзгәрешләре аңлашылып бетми («күптән > бөтенләй»?).

**ӨРӘК** «призрак; неспокойная душа умершего» ~ чув. *ĕрех* (тат. *өрәгем купты* ~ чув. *ĕрехем вĕçрĕ* «очты»), чаг. як. *үöр* «өрәк, явыз рух». Себ. **әүрәк, аурак** «өрәк» < гар. *әрвах,* ягъни *өрәк* һәм *әүрәк* икесе тамырдаш түгел, үзара контаминациягә генә кергәннәр. Алт., хак. *öрöкен* (< монг.) «хатын-кыз рухы, коты» сүзенең *өрәк*кә мөнәсәбәте дә ачык түгел.

**ӨРӘН** диал. (ДС I: 55; Тумашева 1992: 164) «твёрдое семя, ядро (ореха)» ~ алт. *үрен*, тув., бур. *үрэ(н)* «төш, орлык», монг. *öрöл* «кыргый чия» ← *öр*, *үр* «төш» тамырыннан, чаг. **Орлык, Өрек.**

**ӨРӘҢГЕ,** диал. **өргә** (к. ТТДС I: 554) «клён, вид клёна» ~ чув. *вĕрене,* уйг. *үрәңги*, куман. *үрге* id. < монг. *үрэңхи* «ак (үзагачлы) агач», *үрэң* ~ бор. төрки (ДТС: 627) *üriüŋ, jürüŋ* «ак төсле». Чаг. **Чаган. Өрәңге** сүзеннән *өяңке* сүзен чыгаруга (Егоров 1964: 52) без бик шикләнеп карыйбыз.

**ӨРГӘ** диал. (ТТДС I: 554), «стена; фундамент» ~ хак., тув. *öргээ* «сарай, зур бина», алт. диал. (Баскаков 1966: 142) *öргүö* «әкият героеның торагы», бор. төрки (ДТС: 388) *örgi-* «бина кору», *örgin, örgün* «тәхет» ~ бур. *ургöö(н),* монг. *öргöö* < бор. монг. *örgüge, ergüge* «сарай, ирәк» > рус. диал. *урга* «хәрби тукталыш, ирәк, стан; чатыр» (Аникин: 587). Монголиянең башкаласы Улан-Батырның элекке исеме **Урга** була. Чаг. фар. *öурең* «тәхет». К. **Өрлек.**

**ӨРЕ [өрө]** «навар; плёнка на поверхности супа» ~ алт. *öремä, үремä,* тув. *öреме, öрöме*, як. *öрүмä* (Пекарский: 1967), *үрүмэ* ~ бур. *öрмэ*, монг. *öрйме* < шор. *öрүңмä, үрүңмä,* маньч. *оромо, ороку* «өре» ← *оро-* «чырышу, чыр, өре пәйда булу» (ССТМЯ II: 288), чаг. чув. *вĕр-, вĕре-* «кайнау» <

болг. *өр-, *өрә-. *Өре* < бор. *үрүг «каймак» булса кирәк. А. Йоки (Joki 1952: 251) камасси. *öretä* «өре» сүзен угыз., уйг., чыгт. *өру* «үрә; үргә» сүзеннән ди.

**ӨРЕК I [өрөк]** «абрикос; урюк» < уйг., төр. диал. *өрүк, урук* «өрек; тошлы җимеш» (кайчакта – «чия, шәфталу», хәтта «кедр күркәсе») < бор. уйг. *әрүк*, бор. төрки (ДТС: 182) *erük, erüg* id., үзб. диал. *өрик, орик*, кырг. *өйрүк*, госм., чыгт., аз. *äрик* (Радлов I: 76, 1174, 1223), ком., к.-балк., каз. *эрик* «өрек». Рус. *урюк* «кипкән өрек» төрки телләрдән. К. **Өрән, Өрет.**

**ӨРЕК II [өрөк]** «хвастун» к. **Өрек-ү II.**

**ӨРЕК-Ү I (өректе, өрегү)** «сильно испугаться, пугаться; в страхе терять самообладание» > мар. кч. *үрк-* (Исанбаев 1978: 20) < гом. төрки *үрк-*, бор. төрки *һürk-, һürük-* (к. Поппе 1938: 192), чыгт. *һүрк-* (к. Ясәви Ә. Дивани хикмәт. Казан, 1912: 164), як. *үрт-, үргäр-* ~ бур. *үрге-*, монг. *үргэ-* (Пекарский: 3171, 3175) id. эвенк. *һурбул-* «куркып, паникада качу» һ.б.; чув. *ĕрĕх-* «чыгымлау (ат тур.)» < тат.; *үр-үк-* **һүр-* фигыленең интенсивлык формасы (*үр-к-*) булса кирәк. Чаг. **Өр-ү II**. ЭСТЯ I: 635–637.

Дерив.: **өркәк, өркет-ү.**

**ӨРЕК-Ү II [өрөк-]** «хвастаться; хвастовство», ш. ук (себ., ЗДС: 513) **өрөк** «хвастун». Тат. теленә якын телләрдән параллельләрен тапмадык, тик бор. төрки (ДТС: 379, 382) *ögir-, ögür-* «шатлану, горурлану»; шуннан **ögürük-* «мактана төшү, артык мактану» һәм **ögürük* «мактаныч; мактанчык» сүзләре ясала алган һәм безнең мәзкүр сүзләр килеп чыккан.

*Ögür-* сүзе, күрәсең, бор. төрки *ög-* «мактау» фигыленнән, к. кр.-тат. (Dobr. III: 3) *ögunmek* ~ төр. *ögünmek* «мактану». Кр.-тат. *ög-* сүзе юк бугай, әмма төр. *öv* < **ög* «мактау». Шуннан арытабан к. **Үк, Үкеш-ү, Үктәм.**

Борынгылыктан бирле *ök* > *yk, ög* > *öv* яңгырашында омонимнар яшәп киләләр, тик аларның төптән омоним булмаганлыклары билгеле. Тамырлары исә тарих караңгылыгында калган.

**ӨРЕТ [өрөт]** диал. (Исәнбәт II: 297) «потомство» ~ башк. (БҺҺ III: 150) *өрөт* «орлык» < *үрүт* бор. *үр* «орлык» сүзенең бор. күп. формасыннан, к. **Өрән, Өрек.**

**ӨРКӘЧ, үркәч** «горб верблюда; гора на горе» < бор. чыгт. *өркäч* ~ к.-балк. *ёркеч,* нуг., каз., к.-калп. *өркеш*, кырг. *өркөч*, үзб. *үргәт, ургач*, төркм. *өркүч*, аз. *һөркүч*, госм. *өргүч* id., алт. *өркөш* «өркәч; шаман төңгеренең калкулы ягы» ← *үр-* < *өр-* (к. **Үр**) сүзе белән баглы, ләкин турыдан-туры **үр-кәч** дип нәтиҗәләргә ашыгу ярамас, к. бор. төрки (МК I: 129) *örkü* «үркәч».

Дерив.: **өркәчле, өркәчсез.**

**ӨРЛЕК [өрлөк]** «балка, матица» > мар. *урлук, ўрлĕк*, удм. *ырлык*, рус. диал. *урлюк* id. ~ себ. (Тумашева 1992: 165) **өрлөк түбә** «кыек түбә (яссы түбәгә каршы куеларак)», **өрлек** «кыек, өй кыегы», (Будагов I: 316; Радлов I: 1340) *һурлук, урлук, урлік* «кыек, түбә» ~ каз. (ҚТДС: 362) *урлĕк, ерлĕк* «өрлек», к.-калп. *өрлик* «мачта», чув. (Ашмарин IV: 28) *урлĕк* «тирбәлчек – юан бүрәнәгә аркылы салынган такта (аның ике башына ике кеше утыра)», *вĕрлĕк* «кәртәлек, жирда», чыгт. (Радлов I: 1218, 1232) *өрлäк,* төркм. *өрлүк* ~ алт. диал. *өрлää* < *өрлäгä* «мачта, байрак баганасы; байрак», алт. (Баскаков 1972: 238) *өрөги, өрөгү* «югары, югаргы; корбанлык». Китерелгән сүзләр арасында фонетик нисбәтләр бигүк закончалыклы түгел, мәгънәви нисбәтләр дә шикләнергә урын калдыра. Räsänen 1969: 532; Федотов I: 118–119 (**өрлөк** ул **үр** < *өр* сүзеннән ди, ләкин нәкъ шушы фараз фонетик закончалыкларга хилаф). ЭСТЯ I: 549 (материалы ярлы һәм *өрлек* ← *өөр* «үр» дип бара, бу безне ышандырмый). Чаг. ш. ук як. *үрдүк* «югары; биеклек»; рус. *урлюк, урлюшник* тур. Аникин: 589–590.

Дерив.: **өрлекле, өрлексез; өрлеклек**, сөйл. **өрлектәй** «буйчан һәм таза (яшь егет яки кыз тур.)».

**ӨРПӘ,** диал. **өрпе, өрфе** «волоски на перьях, пушинка; длинные волосы на шерсти (встающие дыбом)», чаг. диал. **өреш-ү** «кабару, күперү» (ДС I: 255) – күрәсең, бу сүзләр **өр-* тамырыннан, к. ш. ук каз. *өлпе*, кырг. *өлпө* «мамык йон», башк. *өлпәк* «өрпәк» (БҺҺ II: 191). *Өрпә* сүзенең үзеннән киңрәк таралган варианты – тат., башк. **өрпәй-** < гом. кыпч. *үрпей-*, кырг. *үрпөй-*, кар. *өрпäй-* «кабару, күперү, үрә тору (йон, төк тур.), тырпаю, төрпәю» (ДТС: 627). К. **Олпак, Өрпәк I.** *Өрпәй-* сүзе тур. ЭСТЯ I: 637.

**ӨРПӘК I** «пушистый, распушённый» < гом. кыпч. (каз. һ.б.) *үрпек, үрпäк* «таралмаган, өрпәйтелгән (чәчләр)», каз. *өлпа*, к.-калп. *улпа*, кырг. *улпак ~ урпак* «өрпәк», алт. *улбүрек* «бизәнү-ясану

әйбере буларак өке каурые», бор. төрки (ДТС: 627) *ürpäk* «өрпәк». Чаг. ш. ук себ. **өрбөлтәк** «өрпәк; элпә» (Тумашева 1992: 164) ~ бур. *урбэлгэ* «өрпә».

**ӨРПӘК II** «пуховый платок (с крупными ячеями), ажур» (к. ТТДС I: 554) тат. диал. **өрелпәк** (без теркәдек. – *Р.Ә.*), себ. *һүрәи бәк* «нашмак, өртмәк, килен ябуы» (Будагов II: 313) ~ үзб. диал. *өрипәк* «яулык» (ЎХШЛ: 204), аз. *өрпәк* «өрпәк». Бу сүз берничә сүзнең контаминациясе бугай: 1) *өрпәк* «өрпәйгән, мамыклы», 2) *өретмәк* «ябынгыч, каплавыч», 3) фар. диал. *һурипак* «зонтик, кояштан каплангыч» (*һури* «кояш нуры», *пак* «каплангыч») яисә *һорипак* < *хорипак* «хур кызын каплагыч». Чаг. ш. ук **Өрфия II.**

**ӨРПЕ [өрпө]** «соска; отверстие в соске» (ТТДС I: 554) ~ башк. (БҺҺ II: 192) *өлпө* «лепкә», каз. *үрүп*, кырг. *үрп* id. Ачык түгел.

**ӨРТ-Ү, өрет-ү** «покрывать, скрывая что-либо» < гом. төрки *өрт-* (*үрт-* түгел!), бор. төрки *ört-, örüt-* (ш. ук юн. формалары: *örtül-, örtün-, örtür-, örtüš-*, к. ДТС: 389) ← **өр* – Будагов I: 123; ЭСТЯ I: 552.

**ӨРҮ** (Тумашева 1992: 165) «поздно, потом» ~ чув. *вара* id., ш. ук «азак, аннары; соң». Этимологиясе ачык түгел.

**ӨР-Ү I** «дуть» ~ чув. (Егоров 1964: 52) *вĕр-* < гом. төрки *үр-* < *үwĕр-* < *үфĕр-, үфгĕр-* id. (*үф-гер-*: *-гер* тәкълиди тамырлардан фигыль ясагыч кушымча), к. к.-балк., ком., аз., үзб. диал. *үфүр-*, чыгт. *җүр-*, хак. *үбүр-*, шор. *үгүр-* (Радлов I: 1810) һ.б.

**Өр-** продуктив нигез: **өрел-ү, өрдер-ү; өрелмә, өрелмәле, өргеч;** себ. **үрүк** «өреп кабартылган» (Радлов I: 1833). К. **Өфер-ү.**

**ӨР-Ү II** «лаять» ~ чув. *вĕр-* < гом. төрки *үр-*, алт., хак., шор. *үбүр-,* төркм. *үйр-,* тув. *ээр-,* чыгт. *һүр-* id. Күп телләрдә ш. ук бор. төрки (ДТС: 627) *ür-* «исү» һәм «һауһаулау» омонимнар (к. Егоров 1964: 52) ләкин бу нигездә очраклы күренеш: һәр икесе *-гĕр* < *-гүр* кушымчасы ярдәмендә, ләкин төрле тәкълиди сүзләрдән ясалган: беренчесе *үф* сүзеннән, икенчесе *үһ, һү-ү* (озак монотон эт өрүенә һ.б.ш. тәкълид) сүзеннән. **Өр-ү II** дән **өрек-ү** килеп чыккан булуы ихтимал: тәүдә *өр-* < *үр-* < *үһ-гүр-* терлекләрнең куркынып эһелдәүләрен белдергән булса кирәк.

**ӨРФИЯ I [өрфийә]: өрфия тәңкә** (ТТАС III: 291; ТТДС I: 554; ТТДС II: 404) «монета или (чаще) имитация монет из жести для монисты» < һинд. *рупий, рупия* «тәңкә» (к. БРС 1996: 486). Бу сүзнең Идел-Урал регионына кайчан һәм ничек кергәне ачык түгел, тик ул Оренбург тирәләрендә таралган сүз.

**ӨРФИЯ II [өрфийә]** «тюль; белая ткань для невесты», **өрфәк, өрпәк** (ТТДС I: 554) id. ~ үзб. (ЎХШЛ: 204) *рөпәк, өрипәк* id. < фар.: *руипак* id., төп мәгъ. «пакь йөз», **Өрфия II Өрфия I** тәэсирендә шундый яңгыраш алган.

**ӨС I** – по существу неправильное написание слова **өст** «верх; верхняя одежда» < гом. төрки һәм бор. төрки *üst*. Ф. Исхаков фикеренчә (к. **Ал, Арт, Ас**), < *үсту* < *үсну* < *үсүн-ү* үсешендә бор. **үсүн* ~ хак., тув. *үзүн* «өске як, үсү ягы (?)» сүзеннән килеп чыккан, бу *үсүн* ~ *үзүн* исә **үс-* ~ **үз-* «каплау» фигыленнән (чаг. **Өсәк**) ясала ала, к. Будагов I: 135–136; ЭСТЯ I: 638–639. Элек (гарәп шрифтында) **өст-баш, өсткә, өстке** дип язганнар һәм дөрес эшләгәннәр. Латинчага һәм кириллицага күчкәч *өs, өс* дип кенә язу орфографиянең фәнни нигезләреннән чигенү (имеш, «халыкча») булган. Чаг. – рус орфографиясендә авазларның *әйтелмәгәннәрен* язу бик күп: ләкин бу хәлне «төзәтергә» өндәүчеләр юк.

Дерив.: **өсле**, **өссез**, парлы сүзләрдә: **өсте-башы** (**өсе** түгел?), **өсте-асты** һ.б. К. **Өстәр, Өстә-ү, Өстен.**

**ӨС II, өсс** – междометие для натравливания собак, «усь!» Бу сүз шартлы. Аның физиологик нигезләре юк бугай, чөнки этләрне төрле телләрдә төрлечә «өстерәләр, өсләтәләр». Рус сүзе белән охшашлык – аваздашлык (*өс* ~ *усь*) очраклы түгел. К. **Өстер-ү.**

**ӨСӘК** «крыша котла, лари; ларь с крышкой» ~ башк. (БТДҺ: 260) *өсәк* «бура, келәт өлеше», *өҫәк* «иген бурасы» ~ чув. диал. *ăвсак* «зур капкач», монг. *үсэгэ* (> бур. *үһээ*) «түшәм, капкач». Чаг. **Өс I.**

**Өсәк** сүзе гомумән рус. *сусек* сүзеннән дә килә ала, к. чув. *ăс-* «сосу», *ăса* «соса», *ăсла* < рус. *сусло, ăслан* < рус. *суслон.* Ләкин мондый күренеш – сүз башындагы *с-* авазының югалуы – тат. теленә хас түгел, аннары рус. *сусек* > тат. *сусик* булыр иде.

**ӨСТӘК** «добавка» < гом. кыпч., уйг. *үстек, үстәк* < бор. төрки (ДТС: 627–628) *üstäk* id. ← *üstä-* «өстәү», к. **Өстә-ү.**

**ӨСТӘЛ** «стол» > мар. (Исанбаев 1978: 3), удм. *үстел,* чув. *сĕтел* < рус. *стол* id., тәүге мәгънәсендә «җәймә, ашъяулык» ← *стелить* «җәю» сүзеннән. Себ. тат. *үстел, үстөл,* каз., кырг., алт. һ.б. *ӱстӧл, остол,* шор. *истәл* рус теленнән мөстәкыйль рәвештә алынганнар (к. Федотов II: 47), чөнки русча *стол* кебек җиһаз төркиләрдә булмаган, төркиләр keләмгә, сәкегә, идәнгә утырып ашаганнар. Урта Азия телләренә *стол* сүзе XX г. гына кергән (һәм үзгәртелмичә языла).

Дерив.: **өстәлле, өстәлсез; өстәллек; өстәлчек.**

**ӨСТӘР** диал. «покрышка с внешней стороны», (ТТДС II: 405) «верхняя часть нагрудника» – **астар** сүзенә кире аналогия – антоним буларак татар телендә килеп чыккан (**астарлау**га каршы **өстәрләү** сүзе дә бар). Тамыры **өст,** әлбәттә.

**ӨСТӘРӘ, өстара,** (Гиганов) **үстара**, диал. (Тумашева 1992: 161) **остара** «бритва» < фар. *остоpe* id. күп төрки телләрдә очрый.

**ӨСТӘ-Ү** «прибавить; добавить» > мар., удм. диал. *үсте-,* чув. *сĕте-* < гом. кыпч. *үсте-* (кырг. *үстӧ-*) < бор. төрки *üste-* id. *üst* «өс, өске як» сүзеннән, әлбәттә. *Үсте-* сүзе уйгур һәм угыз группаларында кулланылмаган (һәм Э.В. Севортян бу сүзгә тукталмаган), ләкин аның дериватлары очрый.

**Өстә-ү** сүзенең паронимы буларак ***өстәр-ү** сүзе дә булган, к. удм. (Насибуллин: 143) *үстäр-* ~ мар. *үштäр-, үстäр-* «өстәү»; чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 628) *üstär* «өстен булу». Удм. *устол* «өстәмә, өстәк» сүзе удм. теленең үзендә ясалган булса кирәк. К. ш. ук **Өстәк, Өстәр.**

**Өстә-** продуктив нигез: **өстәл-ү, өстәш-ү, өстәт-ү; өстәү** (исем мәгъ.), **өстәлмә, өстәмә,** диал. **өстәлә-ү** (~ төр. *üstele-*) «өстәп тору».

**ӨСТЕН [өстөн]** «превосходящий, превосходный» < гом. кыпч. *үстүн* ~ төр. *üstün* < бор. төрки (ДТС: 628) *üstün* «өстен; өсте белән, өстеннән» (*өст* ~ *үст* сүзенең инструменталь килеш формасы). Нұрмағамбетов: 128.

Дерив.: **өстенлек** (рус. *превосходство* сүзеннән калька булса кирәк).

**ӨСТЕРӘ-Ү [өстөрә-]** «тащить, волочить; тянуть» < *сөтрә-ү* < уйг., үзб. *судрә-* «сөйрәү» сүзеннән (этимологик дублет, к. **Сөйрә-ү**), к. мар. *шудыра-, шӹдӹра-* «өстерәү» < болг. **сүдĕрә-* id.

Чув. *сĕтĕр- (сĕдĕр-)* «өстерәү» сүзе болг. сүзеннән нык үзгәргән (тартыкка беткән фигыльгә әверелгән). Шунысы күренеп торса да, Федотов (II: 47) тат. *өстер-* (? андый яңгыраш юк та бугай) чув. теленнән димәкче.

**Өстерә-** продуктив нигез: **өстерәл-ү, өстерәт-ү; өстерәлчек** ~ чув. *сĕтĕренчĕк* «сукбай; җенси азгынлыкка бирелмеш» (*өстерәл-ү* «азгынлыкка бирелеп йөрү», ихтимал, рус. *волочиться* сүзеннән калькадыр).

**ӨСТЕРТЕН [өстөртĕн]** «поверхностно» – **астыртын** сүзенә аналогия рәвешендә ясала.

**ӨСТЕР-Ү [өстөр-]** «науськивать» – дөресрәге диал. **өскер-ү** (**өсс-кер-:** *-кер* тәкълиди сүзләрдән фигыльләр ясагыч кушымча), паронимнары да күп: **үскет-ү** (ДС II: 256), **үслә-ү** (ДС I: 230) «өскерү», башк. *һөслә-ү, һөсләт-ү* id., (БТДҺ: 260) *өҫкөт-өү* «котырту» ~ чув. *ĕскĕрт-* «өскерү, өскертү», мар. (Упымарий: 230) *уськыр-, усыклэ-*, удм. *ускыт-, иска-* (төрки телләрдән, әлбәттә) – тат. *өсс*, башк. *һөсс* ~ хак. (Радлов I: 1877) *үс* – этләрне өскерү ымлыгыннан, к. Ашмарин IV: 138, V: 330. К. **Өс II.**

**ӨТӘЛӘ-Ү** «палить, опаливать», тат. диал., башк. (к. БҺҺ III: 151; БТДҺ: 161) ш. ук. (төп мәгънәдән тыш) «линять; быть облезлым, оборванным, изнуренным» ~ чув. (Ашмарин V: 381) *вĕтеле* «өтү, өтәләү» ← тат., башк. *өт-*, чув. *вĕт-* «өтү» фигыленең кабатланулы интенсивлык формасы.

Дерив.: **өтәлән-ү** «яраргa тырышып каударлану; өлтерәү»; **өтәләгән** «өтелеп өзгәләнгән, ертмачланган»; **өтәләт-ү.**

**ӨТӘ-Ү** диал. (трбс.) «толкать, теснить» ~ кырг., хак *үтä-, үтэ-* id., тув. *үдэ-*, як. *үтэй-, үтүрүй-* «этү-тарту».

**ӨТӘЧЛӘ-Ү** «кое-как опаливать» ← **өт-ү** (к.), чаг. **ермачла-у ← ер-у, төрмәчлә-ү ← төр-ү;** шулай итеп, монда *-ачла//-әчлә* игътибарсыз үтәү мәгънәсен бирә торган аффикс шәйләнә.

Дерив.: **өтәчлән-ү, өтәчләт-ү.**

**ӨТЕ [өтө],** диал. (ТТДС II: 405) **өтек** «утюг» < гом. кыпч. (кар., ком., нуг. һ.б.) *үтү, үти* (кайбер телләрдә теркәлмәгән), аз., төр. *ütü* (> лезг. һ.б. Кавказ телләрендә *үтү*) < бор. төрки (ДТС: 629) *ütük* id. Тат. *үтүк, үтек* варианты Алтын Урда уйгурчасыннан да, рус теленнән дә килә ала, рус

теленә исә бор. төрки *үтүг вариантыннан кергән, бу сүз бор. төрки (ДТС: 629) *üti-* «үтекләү (өтеләү)» *üt-* сүзе белән гомоген булса кирәк (ЭСТЯ I: 641). **Өте** тат. теленең үзендә **өтке** формасында ясала алыр иде: бу аләт тәүдә кием җөйләре өстеннән йөртеп бетләрне өтү өчен кулланылган.

Ком., нуг. *ийтүв* варианты икенчел (борынгылыкны чагылдармый).

**Өте** ~ *өтөг* сүзе кыт. теленнән алынган дигән фикер дә бар. Бор. төркиләр бу аләтне кытайлардан үзләштергән булуы ихтимал, әмма бөтен ясалышы белән бу – төп төрки сүз.

Дерив.: **өтелә-ү.**

**ӨТЕР [өтөр]** «запятая» < гом. кыпч. *үтир*, кырг. *үтүр*, төр. *ötre* «өтер, заммә (яки даммә – гарәпчә язуда иренләштерү хәрәкәсе)» < бор. төрки *ötürü* «шуның өчен ки, шуны искә төшереп» (хәл фигыль) сүзеннән, бу форма исә бор. төрки (ДТС: 393) *ötür-* «искә төшерү, искәртү, белдереп кую» фигыленнән. Будагов I: 111 (*өтүрү* сүзен *отыры* сүзе белән бутый); Zenker: 111.

**Өтер** < *үтүр* сүзенең бүтәнчә (алынма, төрки түгел) дип аңлатулар да очрый. Чыннан да к. гар. ʾ билгесе-хәрәкәсе *өтрэ, үтрä, үтäрä* дип әйтелә. Ләкин бу төр. теленнән алынма булса кирәк.

Дерив.: **өтерлә-ү** «гарәпчә язылган текстка хәрәкәләр куеп чыгу (иске телдә)», **өтерче** «корректор (шаян телдә)».

**ӨТЕРЕК [өтөрěк]** (Арсланов 1988: 90) «небылица (как жанр фольклора)», себ. (Тумашева 1992: 231) **үтерек** «ложь; хвастовство» ~ башк. (БТДҺ: 261) *өтөрөш* (< **өтөрөкче*) каз. *öтěрěк,* чыгт., үзб. диал. (ЎХШЛ: 205) *öтүрүк, öтрүк, үöтрүк, öтирык* «ялган», к.-балк. *ётюрюк*, кырг. *öтүрүк* «ялган, алдаштыру, юкны сөйләү» < госм., төр. *öturük* «арттырып сөйләү» ← *öttür-* «мактану, этәч булып кычкыру (күч. мәгъ.)» ← *öt-* «(этәч) кычкыру, сайрау; җырлау» ~ бор. төрки (ДТС: 391–392), бор. монг. *öt-* «аваз салу» һ.б. (к. ш. ук ЭСТЯ I: 556–557, тат. **өтерек** < *öтүрүк* тур. әйтелми).

Тат. телендә закончалыклы яңгыраш **үтерек** (к. **Үтрек**), ләкин бу сүз «үтерелгән» мәгъ. аңлашылгач, гиперсынылышлы **өтерек** пәйда булган. **Өтерек ~ үтерек ~ үтрек** иске ядкәрләр телендә еш кына «ялган, алдак» мәгъ. очрый, фольклор жанры атамасы буларак тат. телендә генә бугай.

**ӨТЕРГЕ [өтөргě]** «долото» < гом. кыпч. *үтүргү* (каз. *үтěргě*) id. – тат. диал. *өтөр-* «тишек тишү» (к. Радлов I: 1344, Balint 1988) << бор. төрки (ДТС: 229) *ötür-* «бораулап яисә өтереп тишек тишү»; чаг. хак. *үте-,* тув. *үттэ-* «өтерү» ← *үт* < бор. төрки *üt, üd* «тишек»; як. *үүт* «тишек, ярык», *öтöрү* «үтәли».

Дерив.: **өтергелә-ү**.

**ӨТӘ-Ү** диал. «толкать вперёд», бор. кыпч. (хак., кырг.) *үтэ-* «бораулап тишү» сүзеннән үзгәргән булса кирәк. Гомумән, *өтә-у* сүзекүрсәтелгән мәгъ. тат.-башк. телләрендә генә очрый бугай.

**ӨТИ** «оборванный (о конце ткани и т.п.)» < *өтей* < *өтәй* id. ← **өт-ү.**

**ӨТҮ [өтөw]** (Хайрутдинова 1993: 25) «лепёшка из кислого теста» ~ чув. *вěтү, вěтěв* id. (Сергеев 1971: 59) ← *вěтě* «вак».

**ӨТ-Ү**, диал. (Арсланов 1992: 140) **өйěт-ү** «палить, опаливать» ~ чув. *вěт* - < гом. кыпч. *үт-,* каз. *үйт-,* к.-балк. *үйүт-,* нуг. *уйыт-* id. ← бор. төрки *үң-, уң-* (?) «өтелү» (фигыльнең йөкл. юн.). Егоров 1964: 53; ЭСТЯ I: 640–641.

**Өт-** продуктив нигез: **өтел-ү, өтеш-ү, өттер-ү; өтек.** К. **Өтәлән-ү, Өтәчлә-ү, Өти.**

**ӨФ, өфф** – имитатив выпусканию изо рта сильной струи воздуха (на огонь, на горячую еду и т.д.) < гом. кыпч. *уф, уф* id., чаг. рус. *пфуй* id., ним. *Pfiff* «сызгырык».

**ӨФЕ [өфө]** название города Уфа и реки **Уфа, Уфимка** (тат. **Өфе иделе**). Бик табышмаклы топоним. Гомуми закончалык буенча шәһәр исеме елга исеменнән булырга тиеш, әмма топонимикада киресенчә булган очраклар да билгеле. **Өфе иделе**нең электән шулай аталуы аның югаргы агымында **Уфалей** дип аталуы белән дә дәлилләнә кебек. Ләкин интервокаль *-ф-* авазы җирле халык (башлыча башкортлар) теленә хас түгел, өстәвенә башкортлар һәм татарлар елганың үзен **Каридел < Кара Идел** дип атап килгәннәр. Шул фактлардан чыгып фикер йөрткәндә, *Уфа ~ Өфе* субстрат телдән, мөгаен угор телләреннән калма булырга тиеш кебек. Һәм чыннан да венг. телендә шуңа охшаш сүзләр бар.

Икенче бер мәсьәлә – **Өфе** яңгырашының килеп чыгышы. Бу яңгыраш бор. рус. (шәһәр исеме буларак) *Уфы* вариантыннан була ала (җирле топонимнарга күп. кушымчасы кушу руслар гадәтендә

булган). Шулай ук **Өфе < *Үфе** һәм рус. *Уфа* < ***Үфә** вариантлары элекке ***Үфәй** вариантыннан килүе ихтимал: Каридел буйларында башкортларның **Үпи, Үпей, Үпәй** кабиләсе яшәп килгән һәм бу этнонимның төрки этимоны билгеле түгел.

*Уфа* сүзен һинд-евр. *ира* ~ *ufa* «су, елга» сүзенә нисбәт итү (Фасмер IV: 859, О.Н. Трубачёв өстәмәләре) семантик җәһәттән дә, тарихи җәһәттән дә нигезләүгә мохтаҗ (мәс., нишләп Каридел генә «елга», бүтән елгалар елга түгелме? һ.б.).

Ниһаять, **Уфа** һәм **Уфалей** сүзләренең төрки *упа* һәм *упалы* «уба» һәм «убалы» (к. **Уба**) сүзләреннән килүе дә ихтимал (*б* ~ *п* ~ *ф* тәңгәллекләре себ. тат. сөйләшләрендә, ш. ук ханты, манси телләрендә очрый). Кариделнең башыннан азагына кадәр яр убалары очрый.

Күрше халыклар *Уфа* ~ *Өфе* сүзен бездән алганнар: мар. *Ўпы*, удм. *Упа* id. Рус. *Князь Уфимский* XVI г. башында телгә алына (Матвеев 1980: 270–272).

Дерив.: **Өфеле ~ Уфалы.**

**ӨФЕР-Ү [өфөр-]** «дуть ртом; погасить свечу, лампу и т.п.» < гом. кыпч., госм. һ.б. *үфүр-* < *үфгүр-* id. *өф* < *үф* тәкълиди сүзеннән ясалган, *өфер-* нигезеннән **өр-ү I** (к.) килеп чыккан.

Дерив.: **өферт-ү.**

**ӨЧ** «три» ~ башк. *өс* < гом. төрки, бор. төрки *üč, ǖč* >> чув. *виҫ, виҫĕ, виҫҫе* id. Шуннан арысы ачык түгел.

**Өч** продуктив нигез: регуляр ясала торган **өчәү** (< бор. төрки *üçägü*), **өченче, өчле, өчлек** кебек сүзләрдән тыш, **өчкел** «өчпочмак», **өчәм** «өченче» сүзләре дә бар. ЭСТЯ I: 641–642.

**ӨЧЕН [өчөн]**, диал. **өцөн, үцүн, үцин** (Дмитриева 1981: 194) «для, ради; из-за» ~ башк. *өсөн*, нуг., каз., к.-калп. *үшин, үшүн* < гом. кыпч., угыз., уйг. (ДТС: 622) *üçün* id.

Бу сүзнең ясалышы вә тамыры тур. фикерләр төрле: Радловча, *уч-ун* (*уч* «оч» сүзеннән), Зәйнәп Коркмаз буенча, бор. *уч* «сәбәп» сүзеннән (Korkmaz Z. Zür Ableitung der türkischen Postpoziten *uçın, üçün, için* // UAJ, XXXIII, 2, 1961: 98), Э.В. Севортян буенча, бор. **үч-* дигән фигыльдән (ЭСТЯ I: 642–643). К. ш. ук Räsänen 1969: 169, 509 (*ич* «эч» сүзеннән ди). К. ш. ук Щербак 1987: 90–92.

**ӨЧКАТ** «жимолость» (Будагов I: 115) – *өч кат* «өч бөртек орлык» сүзеннән.

**ӨШӘН-Ү** «относиться с волнением, подозрением, со страхом; переживать что-либо неотвратимое» < бор. төрки **үшән-*, к. төр. *üşen-*, аз. (АДДЛ: 401) *үшән-* id., *үшәнчил* «сакчыл». К. **Үшән**. Чаг. **Өшәнчек.**

**ӨШӘНЧЕК** «постельные принадлежности в составе приданого» ~ каз. (ҚТДС: 363) *үсеншік* «эш кораллары өчен тире яисә күн капчык», уйг. *күшәнчүк* «урын-җир әйберләре, җәймән». Чаг. бор. төрки *ešün-* һәм *köšün-* (икесе дә) «ябыну, өртенү», *ešü-* һәм *köšü-* «ябу, өртү» (ДТС: 186, 319). Күрәсең, монда ике фигыль контаминациясе бар, өстәвенә к. **өшән-ү** («Тел ярышы» җыентыгында *Кызлар өшәнеп-өшәнеп өшәнчек әзерлиләр* мисалы китерелә). Гомумән, бу сүзнең этимологиясе ачык түгел.

**ӨШЕ-Ү [өшө-]** «мёрзнуть, зябнуть» < гом. кыпч., уйг., төркм. һ.б. *үшү-* (> нуг., каз., к.-калп. *үси-, үсĕ-*, алт., тув. *үжү-* > хак. *үзү-*) id. төр. һ.б. *үшә-, үшә-* варианты да билгеле. Чув. *шăн-* «туңу» < **өшөн-* булса кирәк (Федотов I: 444). *Үшү-* нигезе як. *үлүй-*, иске монг. *ülü, üli* «өшү, туңу» сүзләре белән чагыштырыла (*л* ~ *ш*).

Дерив.: **өшен-ү** (сирәк кулланыла), **өшет-ү**; диал. (ТТДС I: 556) **өшөк** «туңган, туң» < бор. төрки (ДТС: 628) *üšik* «суыклар» > үзб. (ЎХШЛ: 271) *ушық, үшүк*, нуг., каз., к.-калп. *үсик* id. ЭСТЯ I: 644–645.

**ӨШКӘЛЛЕК** (Г. Ахунов һ.б.) «шкалик; рюмка» < рус., әлбәттә. Рус. *шкалик* 0,6 л. күләмендәге сыеклык үлчәме.

**ӨШКЕ [өшкө]** «инструмент для обработки стен отверстия; совок» >> мар. *вашкы* id. < гом. кыпч., бор. чыгт. *үшкү*, төркм. *үшгү* id. (Мухамедова 1973: 186), аз. *үшкү* «дрель» (АДДЛ: 401), *үшкүл* «без» ~ кырг. *үшкө*, каз. *үски, үскө* «өшке», *үскі біз* «зур без» (ҚТДС: 363) бор. (ДТС: 628) *üš-* «бораулап тишү» фигыленнән, к. **Өшке-ү.** ЭСТЯ I: 643–644.

**ӨШКЕР-Ү [өшкөр-]** «нашёптывать заговоры и дунуть с брызгами слюны» ~ нуг. *үскир-* id. Бу сүз төбендә гап-гади тәкълиди фигыль: уйг., төркм., алт. *үшкүр* «чыжылдау; һүш итү», кар. *үшкүр-* «төчкерү», кырг. *үшкүр-* «уфыру» һ.б. *үш, һүш* тәкълиди сүзеннән. ЭСТЯ I: 645.

**ӨШКЕ-Ү [өшкө-]**, диал. **өшкә-ү** «прочищать стенки отверстия, трубы и т.п.» – себ. *өшө-* < себ., уйг., кырг. *үшү-* id. бор. төрки *üš-* «бораулау» (ДТС:

628) фигыленең интенсивлык формалары. Räsänen 1969: 523; ЭСТЯ I: 643–644.

Дерив.: **өшкел-ү, өшкет-ү.** К. **Өшке.**

**ӨЯЗ [өйәз]** «уезд (административная единица в царской России)» < рус. *уезд* «атта йөреп идарә итәрлек территория» ← *ездить* «атта йөрү» сүзеннән (Будагов I: 165; Фасмер IV: 150).

**ӨЯК [өйәк]** «подбрюшница, подбрюшный мех; кусок шкуры с живота» << чыгт. *өйәк,* алт. *өйөк* id. бор. кыпч. *үйәк*, иске тат. *үwәк* < бор. төрки *ükäk* «почмак башня, бөреҗ; сандык» ← *ük-* «бергә җыю, берләштереп тору» сүзеннән булса кирәк, к. Будагов I: 165; ДТС: 623; Фасмер IV: 144.

М. Рясянен хезмәтләрендә мар. *вäйä, вайа, вяя* «илтер кырпу, кайма» сүзе тат. **үйәк** сүзеннән диелә, ләкин Гордеев (II: 78) моңа каршы, мари сүзе Урал телләре лексикасына карый ди.

**ӨЯЛӘ-Ү [өйәлә-]**, диал. (ТТДС II: 403) **өймәлә-ү** «валиться, лежать в поваленном виде» ~ башк. (БТДҺ: 257) *өйәнә-ү* id., каз. *уйеле-*, чаг. себ. *өйәтә-ү* «җайсыз ятып, оешу» (Тумашева 1992: 164), башк. *өйәҙә-ү* «торалмыйча яту» < тув., бур. *үйэдэ-* id. ← (алт.) *үйэ* «буын». Ш. ук *өй-ү* сүзенең тәэсире дә сизелә. **Өй-ү, Өянәк, Өянке.**

**ӨЯНӘК [өйәнәк]** «паралич суставов, падучая болезнь» ← диал. *өйән* id. сүзеннән, чаг. башк. *өйәнә-ү* «өяләү». Сүзнең тамыры *өйә* ← бор. төрки *үйэ* «буын». К. **Өялә-ү.**

**ӨЯНКЕ [өйәңке]** «ветла, толстая талина». БТДҺ (: 257) буенча, **өйәңке** «раскидистое дерево, куст» һәм гүяки **өйән-ү, өйәнә-ү, өйәлә-ү** «таралып яту; ябалдашлы булу» сүзеннән. **Өйәнке** сүзе аеруча Идел-Урал регионына хас һәм күп фонетик вариантларда очрый: тат., себ. (Радлов I: 1579, 1816) *ӗйәнкӗ*, *үйәңе*, ш. ук *ийәнке, йәнке* > мар. (Упымарий: 232; Саваткова: 179; Исанбаев 1978: 23) *үйӓнгэ, уйанге*, чув. (Сергеев 1968: 17) *енккӗ*, каз. *үйенкі* id. Тат. диал. (ДС III: 43) **бәнке** чув. **ванккӗ* < миш. (ДС II: 238) **үвәңке** вариантыннан булса кирәк; Башкортстан мишәр сөйләшләрендәге *йанкы* варианты да күрше телләрдән «әйләнеп кайткан» бугай. Бу сүзнең кыскартылган вариантлары да бар: (ДС II: 257) *үәк* ~ мар. *үвӧ, үэ, үйэпу* (*пу* «агач»); (ЗДС: 242–243) **йәнке** «сәрви», **йәңче** «өянке», **йәңке** «талның бер төре». Räsänen 1969: 520 (бик аз).

Вариантларның күплеге алынма сүзләргә хас. *Өянке*, безнеңчә, бор. кыпч. **үйән куа* < монг. *удун куа* «тирәк гүзәл» (*удун* «зур агач», *куа* < кыт. *хуа* «чәчәк; гүзәл кыз») сүзеннән, к. алт. диал. *өөн* «байтирәк, ыру агачы; күләгәсендә эпик батырлар ял итә торган агач», калм. *удун* «ырудан берүзе калган геройның (Җик Мәргәннең) бишеге эленгән агач», *удун куа* «шул геройның анасы үзе» (к. МНМ II: 632–633), к. **Чураш.**

Өянке агачы татарларда ыру агачы буларак һәр йортта сөеп үстерелгән. Агачны гүзәл хатын-кыз итеп күзаллау күп мифологик системаларда (хосусан, Кытайда, хараппа культурасы ядкәрләрендә) очрый.

# П

**П** авазы тат. телендә сүз башында башлыча алынма һәм кайбер тәкълиди сүзләрдә кулланыла. Кайбер төрки сүзләр (*пай, пычак, пеш-ү* һ.б.) угыз, себ. диалектларыннан һәм уйг. теленнән килә.

Тат. сөйләшләрендә *пи*гә башланган күп кенә сүзләр – русчадан алынмалар. Без аларның күбесен сүзлеккә алмадык.

**ПАДА** диал. (З. Бәшири) «крупный рогатый скот» < чыгт. *пада* id. < фар. *па̄да̄* < *па̄йда̄р* «аяклы, аягы бар» (шуннан калька: *аяклы мал* «сыер заты», хәлбуки «аяксыз» терлек татарларда юк та). *Пада* сүзе Урта Азия һәм Казакстан төрки телләрендә киң таралган.

**ПАДИША** к. **Патша.**

**ПАЕТ [пайы̆т]** миш. (ТТДС I: 331–332; ТТДС II: 242) «сарай; хлев; навес» ~ рус. *поветь* id. (к. Фасмер III: 293–294), ләкин рус сүзенең ышандырырлык этимологиясе юк (*ветвь* «ботак» сүзеннән дигән фараз бар).

**ПАҖМА,** диал. **паҗбы, паҗум, пәҗмә** (ДС II: 151), **паз′ма** (ТТДС I: 331) «усадьба; ка́рда» ~ чув. *паçма, паçӑм* id. рус. диал. *пазьмо, позьмы, позмище* «сөрүлек җир» сүзеннән дип карала (к. Сергеев 1980: 112). Ләкин рус сүзенең этимологиясе бигүк ачык түгел: В. Даль *позём* «тирес; сөрү» сүзеннән ди, ләкин бу сүздән ничек *пазьмо* сүзе ясала ала – аңлатылмый.

*Пазьма* фар. *па̄и зäм(ин)* «җир өлеше» сүзеннән дә була ала. Чаг. ш. ук мар. *паз* «печәнлек пае» (Иванов, Тужаров: 151).

**ПАЗ** «паз» к. **Бәҗ.**

**ПАЙ** «пай, доля», (Будагов I: 311) «участь» < угыз., уйг. *пай* id. ш. ук «уен кубы, уен сөяге, домино тубырчыгы», чыгт. *пай*, фар. *пай, пой* дип хан табынындагы кешеләрнең дәрәҗәсенә карап өләшенгән мөчәләрне – түшкә өлешләрен дә атаганнар, кемгә (нинди ыру-кабилә вәкиленә) түшкәнең нинди өлешләре бирелергә тиешлеге турында махсус инструкция-җәдвәлләр языла һәм таратыла торган булган (бу хакта Рәшидетдин һәм Әбүлгази хезмәтләрендә дә язылa), к. ш. ук Ögel: 371–372.

Хәз. төрки телләрдә **пай** сүзе рус теле аша кереп рус телендәге мәгънәләрдә кулланыла. Рус теленә исә бу сүз төр. яисә иске тат. теленнән кереп калган, шуннан **паёк** (> тат. **пайук**) «хәрби хезмәттә солдатларга яисә, азык-төлек накыс булганда, эшләүчеләргә тигез бүленеп өләшелә торган ризык» сүзе ясалган, к. Тучков: 24; Фасмер III: 187; Аникин 2000: 431–437.

Төрки *пай* (> тат. диал. **бай**) сүзенең чыгышы төрлечә аңлатыла: кайберәүләр кыт. теленнән диләр, икенчеләр фар. *бећ, бәћ* «өлеш, кертем» сүзеннән бор. заманнарда ук алынган (чаг. әрм.-кып. *behlä-* «өлеш кертү») диләр. К. ш. ук **Баек, Бай II, Байтирәк.**

Дерив.: **пайлы, пайсыз; пайчы; пайчылык; пайла-у, пайлаш-у** (*ике эт бер сөякне пайлашмый* дигән мәкальдә); **пайлык.**

**ПАЙБЫ** (ЗДС: 516) «корзина пчеловода, бортника» < рус. (Аникин: 437) *пайба, пойва* «кәрзин». Аникин манси теленнән дип исбатлый (чаг. сүзен искә алмый). Гомумән, бу сүз Себердә киң таралган.

**ПАЙЗА** (Н. Исәнбәт һ.б.) «золотая или серебряная дощечка с надписью, выдаваемая правителями тюрко-монголов как верительная грамота» < иске тат., чыгт., уйг. һ.б. *пайза, байза, байса* id. < кыт. *бай-цзы* id. Будагов I: 312–313; Velidi 1981: 239.

**ПАЙМА, пуйма** (миш., к. ТТДС: 331, 334; ТТДС II: 251; ЗДС: 516) «раз, разок; гнездо, выводок; группа» (*яшь егетләр паймасы*) мәзкүр чыганакларда русчадан диелгән, конкрет рус сүзе күрсәтелмәгән. Ихтимал, рус диал. (Даль һ.б.) *поймо, пойма,* ш. ук *поймище, поёмные (пойменные) луга* «субасар болыннар» күз алдында тотылгандыр. Фонетик җәһәттән тат. сүзләре русчадан алынган булуы бик бап килсә дә, мәгънә ягы шикләнергә урын калдыра. Чаг. фар. *пäйма, пäймуда* «үлчәүле; беркадәр» → төр. *peymai* «үлчәүле; үлчәнгән бер өлеш, группа». Конкрет икърарга килергә арадаш сүзләр җитенкерәми.

**ПАЙПАК,** диал. (Тумашева 1992: 40, 167) **байбак, баймак, байпак,** «войлочные сапоги (с кожаной головкой)» ~ башк (БТДҺ: 261) *паймак,* нуг., каз. *байпак,* кырг. *пайпак,* үзб. *бойпоқ* һ.б. id. < фар. *пайпак* «аяк киеме, аякчу»; бу сүз күп телләрдә очрый. Рус. диал. *байбак, пайнак, пайпак* «киез оек, пайпак» тур. Аникин: 109, 437.

**ПАКАРАЧ (**миш., ТТДС I: 332) «молх (земноводное животное, похожее на ящерицу)» < морд. *пакапрясь* «бакабаш?»; **пакарач** – бака да, кәлтә дә түгел, бөтенләй башка хайван.

**ПАКИЗӘ** «чистоплодная женщина; девственница» < фар. *pākizä* id. < *pāk-e-zän* «хатыннарның пакь булганы».

**ПАКУС [-к-], пакуй** «покос, валок (скошенного сена и т.п.)» ~ башк. (БТДҺ: 35) *бакуй* id. < рус. *покос* id., **пакуй** формасы, ихтимал. рус сөйләшләрендәге берәр варианттандыр.

**ПАКЫЧ [-к-], пукач, пакысь** (ТТДС I: 332; Зимасов: 76; ЗДС: 517) «пакость» (гом. слав. сүзе, ләкин чыгышы бик үк ачык түгел, к. Фасмер III: 189) < рус.

**ПАКЬ** «чистый, пречистый; чистенький; безгрешный» > мар. (Упымарий: 155) *пак, пок* < фар. *pāk*, санск. *pakk* ~ бор. фар. *pavaka*, пәһл. *pakih* һ.б. id. Һинд-ир. сүзе, дини телдә киң кулланылучан. Platts: 218; Paul 1893: 62.

Дерив.: **пакьле, пакьсез; пакьлек; пакьлә-ү, пакьлән-ү,** к. **Пакизә.**

**ПАЛ** (ТТДС I: 332) «гадание (по книге); предположение, гипотеза» ~ уйг., кырг. *пал* id. < гар. *фа'л* (к. **Фал**). Бу сүз уйг. теленнән таралган булса кирәк.

Дерив.: **палла-у; паллы.** К. **Паллама.**

**ПАЛАС** «ковер, палас», «дерюга» ~ башк. *балаç, палаç* id. > мар., удм., рус., чув. *палас,* мар. *палаш* «палас; җәймә» < фар. *палас, пäлас, пелас* «иске келәм; тупас тукыма».

**ПАЛАЧ** «палач» < рус. *палач* < госм. *палачы* ← *пала, пäлä* «җәллад балтасы, зур пычак». Ш. ук сүздән рус. *палаш* «киң кылыч» < венг. *palas* id. Фасмер III: 191.

Дерив.: **палачлык; палачлан-у.**

**ПАЛЛАМА** «предсказание; оценка; гипотеза». Бу сүздә ике тарихи нигез чагыла: **фаллама** (к. **Фал**) һәм кр.-тат. **пааллама** «баһалама, бәяләмә» (к. **Бәя**).

**ПАЛЬТО, пәлтә** «пальто» ~ башк. диал. *бальтә* id. < рус. < фр., ахыр чиктә < исп. Фасмер III: 194, Kluge: 676.

Дерив.: **пальтолы, пальтосыз, пальтолык.**

**ПАЛЯК [пал'ак]** (ТТДС I: 332), диал. (БТДҺ: 70, 264) **бәләк, пәләк** «солдатик (насекомое)» < рус. *поляк* id., төп мәгъ. «поляк, Польша кешесе». Кызыл тараканны милләт атамасы белән атау киң таралган күренеш, к. **Кырымзау,** рус. *прусак* һ.б. Үз чиратында немесләр дә тараканны *Schabe* «славян» дип атыйлар.

**ПАН** «пан, господин (в Польше, Украине)» < бор. төрки (авар.) *паган, баган* «мәҗүси рухани – традицион гадәт-йолаларны саклаучы» сүзеннән, к. **Бага.**

**ПАНА** диал. (*Ата-ана балага пана,* диләр) «крыша над головой; укрытие, убежище; защита» < иске тат. *пäнаһ* (ГТРС: 472) < фар. *пäнāһ, пенāһ* id. Урта Азия һәм Казакстан төркиләрендә киң таралган сүз (каз. *пана,* кырг. *паана* id.).

**ПАНАЕР [па°найы̆р]** иск. «гуляние, прогулка; народное гульбище по случаю (вне календарных праздниклв)» ~ кр.-тат. *panayır* id. < грек. πανηγυρις «җыелышып (җиңүчеләрне һ.б.) котлау». Тат. теленә бу сүз төр. теленнән кергән. Бу сүз белән рус. *панегирик* сүзе тамырдаш (Dobr. III: 23).

**ПАНСКИ, фәнески** диал. «фабричный (о трикотажных товарах)» < рус. арготизм *панский* id. («Польшада эшләнгән» мәгъ.).

**ПАҢГЫ** (ТТДС I: 335), **пәңге** (ТТДС II: 257) «вид гриба; гриб (вообще)» < морд., мар. *пáңга, пáнго, понго* id. ~ манс., хант. *paŋx, pinko* «гөмбә; чебен гөмбәсе» > рус. *панга* id. Бу сүзне фар. *бäң, баң* «наркотик киндераш орлыгы, гомумән наркотик; тилебәрән» < авест. *baŋxa* «ниндидер бер үсемлекнең наркотик суты» белән чагыштыралар һәм һинд-евр. **spong* нигезеннән дип карыйлар. Balazs J. The hungarian shamans technique of trance Induction // Popular beliefs and folklore tradition in Siberia. Budapest, 1968: 53–75; Аникин: 438–439

(арытабангы бай әдәбият күрсәтелә); ЭСИЯ II: 83–84).

Тат. **паңгыбаш** «наркоман» сүзе игътибарга лаек.

**ПАПА I, папай** (ЗДС: 519) «хлеб (в детском языке)» ~ рус диал. *папа*, төр. *papa, papara* «мәми», ним. *Pappe*, лат. *pappa* «бутка» һ.б. Халыкара сүз, бәбиләр теленнән. К. **Пәпә**.

**ПАПА II** (ТТДС I: 333) «бабочка, птичка; насекомое» ~ удм., рус. диал. *папа* id. Бәбиләр теленнән.

**ПАПАДИЯ** «садовая ромашка (с крупными цветами)» < госм. *пападийа*, төр. *papatya* «камилла, пападия» сүзеннән, бу сүз исә грек. *παπδια* «поп хатыны» дигәннән (Радлов IV: 1207; Steuerwald: 734). Рус. *ромашка* сүзе дә грек. *ромей* «византияле» сүзеннән килә. Византия грекларында пападия чәчәге белән бизәнү гадәте булган.

**ПАПАЙ, папый** (ТТДС I: 333; ТТДС II: 243) «простейший головной убор, колпак» – бу сүз ахыр чиктә фар. *пāпāи* «папалар, грек монахлары кия торган баш киеме» сүзеннән һәм *папаха* сүзе белән тамырдаш. Грек., лат. һ.б. *папа* «монах, рухани» – «атакай» киң таралган сүз, к. Фасмер III: 200.

**ПАПИРОС,** сөйл. **папирус,** иск. **фифирус** «папироса» < рус. Рус. *папироса* id. тәүдә юка кәгазьне генә белдергән, шундый кәгазьгә тәмәке төреп тарта башлаганнар, шуннан соң *папироса* кәгазеннән махсус «шүреләр» – «гильзалар» ясый башлаганнар. Папирос гильзасына фильтр өстәү XX г. икенче яртысында гына гамәлгә керде.

Рус. *папироса* рус. *папи́рус* «камыш төре; шуннан ясалган язу кәгазе» сүзе белән нигездәш, икесе дә лат. *papyrus* id. сүзеннән. Бу сүзнең төп нигезе – бор. Мисыр. *па-пэр-аға* «фиргавенгә тиешле» тәгъбире. Махсус Нил камышыннан кәгазь ясау фиргавен монополиясе булган. Сүзнең тарихи нигезе *пәр-ага*дан гар. *фирагаун* «фиргавен» сүзе килә. Шул ук чыганактан рус *фараон*. **Папирус** белән **фиргавен** тамырдаш сүзләр: Kluge: 678.

**ПАР I** «пар» < рус. *пар*, укр. *пара* id. *преть* «пожу» сүзеннән дип исәпләнелә (Фасмер I: 203). Бу сүзне *парылда-у* фигыле белән тамырдаш дип раслау да бар. «Пар» мәгъ. төп төрки сүз – **бу** < *буғ, бухур.*

Дерив.: **парлан-у, парла-у.**

**ПАР II** «пара» < рус.; рус теленә исә немесчәдән кергән.

Дерив.: **парлы, парсыз; парлаш-у; парлы-парлы; пардаш.**

**ПАРАҖ** диал. (ТТДС I: 333) «привет, теплое слово» < гар. *фӑрӑҗ* «җиңеллек, шатлык».

**ПАРӘ** «часть, кусочек чего-либо», тар. «мелкая монета (1/40 пиастра); взятка» < фар. *пāрӑ* id. ~ пәһл. *pārak* «данә» ~ авест. *pāra* «бурыч», бор. һинд. *pāra* «калдык». Көнб. төрки телләрдә киң таралган сүз (Будагов I: 309). Paul: 62–63; Тимергалин: 368–369.

Продуктив нигез: **парә-парә**, к. **Парча, Пәрәкәндә.**

**ПАРЛАК** «блестящий, великолепный (о достижениях)» < төр., төркм., кар. (һ.б. угыз) *парлаҡ* id. ← *парла-* «ялкылдау, ялтырау», к. ш. ук себ. (Дмитриева 1981: 174) **парлыҡ-у** «ялтырау, балку» ← (госм.) *парыл* «ялтырак»; тат. диал. (Сүнчәләй) **парылда-** «ялтырап җилфердәү», госм. *пар, пӓр* дөрләүгә тәкълит, «дөр» (Будагов I: 308). Мәгъ. җәһәтеннән чаг. рус. *блестеть → блестящий.*

Дерив.: **парлаклык; парлаклан-у.**

**ПАРНИ́К** (ТТДС II: 243; БТДҺ: 262) «чайник, заварник» < рус. диал. *па́рник* id.

**ПАРТӘК** (Тумашева 1992: 168) «бросовая, заболоченная земля; сено, скошенное с бросовой земли» < фар. **партӓфт* id., *партафтан* «ташлау» фигыленнән, к. үзб. *партов* «партәк».

**ПАРТИЯ** «партия» < рус. < фр. *partie* id.

**ПАРФИЗ** тар. «ямская обязанность, ямщина» < рус. *форфоз* (< ним.) id. (Остроумов 1892).

**ПАРЧА** «кусочек; образец; отрез на платье; ткань для платья – парча» < фар. *пāрчӓ* id. ← *пāрӓ* (к. **Парә**). Zenker: 160–162; Будагов I: 308. Бу сүз Шәрыктә киң таралып, тукыма төре мәгъ. слав. телләренә дә кергән.

**ПАС I** (Тумашева 1992: 168–169) «широкие сени, веранда; пол *или* потолок, перекрытие». К. **Паст.**

Дерив.: **пас-йек** «колаша, ырмау» (парлы сүз). К. **Бәҗ.**

**ПАС II** (*Мин пас инде, диде генерал.* Х. Туфан) «пас, возглас, означающий признание поражения (особенно в игре)» < төр. *pas, pes* < фар. *бäс* «җитте, җитәрлек».

**ПАСТ** диал. (ДС II: 151) «навес; подполье сеней» < фар. *паст, пäст* «ас, түбәнлек, түбән җир» (к. ш. ук мәкаль: *Югарының пасты бар, үр менгәннең касты бар.*) > каз., уйг. *пәс* «түбән (төрле мәгъ.)».

**ПАСТАУ [паᵒсtaw]** (ТТДС II: 243) «все вместе; гуртом, копом» < иске тат. (Будагов I: 309) *пастау, паста* ~ төр. *pastal, pastav* «тәлгәш; тукыма; тукыма (ш. ук тәмәке яфраклары) урамасы яисә дәстәсе (бер-бер өсле җәеп куелган тупламы)» ~ рус. *постав* «постау дәстәсе». Л. Будагов буенча, венг. теленнән. Венг. телендә исә ним. *Woelstof* «йон тукыма, постау» сүзеннән булуы ихтимал. К. ш. ук **Постау.**

**ПАСХА́** «Па́сха» (христианнарда Иисус – Гайсә пәйгамбәрнең үтерелгәч терелеп күккә ашкан көне, язгы бәйрәм) < рус. *пасха* < грек. *πασχα* < яһ. *фасха* «дәрт, омтылыш; күтәрелеш» ~ гар. *фисķ* > тат. *фиcкы* (иске телдә **фиcкы-фәсәт** «азгынлык, дуамаллык»).

**ПАТАКА, пайтака, пәтәкә** миш. (ТТДС I: 334, 335) «круг родственников» < фар. *пāйдаштһа* «өлешчеләр, өлешкә керүчеләр» ← *пайдашт, пайдашти* «өлешче, өлеше булган зат» ← *пай* «өлеш» (к. **Пай**) булса кирәк.

**ПАТПАЛЧЫН** «лесная фея» ~ мар. *ший пүй патпалчын, пампалче* «әкияттәге урманчы кыз» ~ тув. *пат-патбалчын, пал-палпалчын,* алт. *пампам-палчын* «лесной хан, хозяин лесных духов» (Гребнев 1950: 145; Тыва улустың чогаалы. 1979: 24) < кыт. *фан фансяниш* «сөрәндә аю киемендә роль уйнаучы кяһин» (к. Яншина: 45–48).

Гомумән, **патпалчын** татарларда таралмаган сүз. Ләкин мар. теленә ул татарлар аша гына кергә алган. Димәк, бу сүз элек татарларда да киң билгеле булган (бу сүзне мәҗүсилек калдыгы дип муллалар тыйган булса кирәк). Кытайда *фанфан сяниш* – күп актёрлар катнашлыгында үткәрелгән театраль сабантуй, анда балалар да актив роль уйнаган (бишәр йөз кыз уйнаганы билгеле).

Һ. Такташның атаклы **Урман кызы** шигыре асылда мифологик *патпалчын* образын чагылдырса кирәк (чаг. – **урман иясе** образы бар).

**ПАТРАУ [паᵒtraw]** «потрава; штраф за потраву лугов» < рус., әлбәттә. Рус сүзе *травить* «кыргычлап яки махсус агу белән бетерү» фигыленнән.

**ПАТСАНКА, патсанкы** (ТТДС I: 243–244, БТДҺ: 262) «подсанки (дополнительные сани для перевозки брёвен на санях» < рус., әлбәттә.

**ПАТША,** иск. **падишаһ** «царь» ~ башк. *батша,* чув., мар., удм. *патша* < фар. *пāдишāһ, пāдшāһ* id. < бор. фар. *pati šah* «тәхеттәге шаһ» сүзеннән (Platts: 214, 216); икенче бер версия буенча, грек. *βατησα [батиса]* «патриарх» сүзеннән, фар. варианты халык этимологиясеннән килә. К. ш. ук Paul: 60.

Төр. *паша*, ком. *пачча* «башлык, начальник» сүзе дә шул ук *падишаһ* сүзеннән. К. Räsänen 1969: 377.

**Патша** продуктив нигез: **патшалы, патшалык, патшала́рча.**

**ПАТЯКАЙ, пайтакай** (ТТДС I: 334) «камка», «солдатик (насекомое)» < фар. *пайāдäк* «җәяүле солдат; пехота»; камкаларны гаскәргә охшату күп телләрдә очрый, к. **Кырымзау, Паляк.**

**ПАЧА** миш. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «гребешок петуха» < төр. *paça* < фар. *пāчä* (< *пāйчä*) «әтәч балагы (аякка үскән каурыйлары)» сүзеннән (мәгънәсе үзгәргән).

**ПАЧАС** «посконь, пенька» ~ чув. *пачас, палчас*, мар. *пачаш, патсаш* (Упымарий: 161), *потяш* (Саваткова: 124), удм. *пачаш* (Насибуллин: 132) id. < рус. *подчёс* id. Иске тат. (Троянский) *пачамак* «көнҗәлә талку» бүтән фаразларга да урын калдыра. Чаг. **Баса, Пәҗе.**

**ПАЧЫШКА, бачышка** диал. (крш.) «поп» ~ чув. *паччăшка* id. < рус. *батюшка* «атакай, поп».

**ПАШЛЫК** диал. (брб., уйг., к. Радлов IV.2: 1203; Тумашева 1992: 170) «старуха; супруга» ~ (Радлов IV.2: 1559) *пашлых* «гаилә башы (ире) булган хатын», таранчы. *башлыķ* «хөрмәтле карчык». К. ш. ук алт. *пастыķ,* хак. *пастаƨ, пастаƨҷы* «гаилә башлыгы». Гомумән, тат. < уйг. сүзенең мәгънәсе «ир хатыны, гаиләле хатын» кебегрәк була.

**ПӘВЕФКӘ [пәwĕфкә], пауфка, пуфка, бофка, буфка** (БТДҺ: 262; ТТДС I: 334; ТТДС II: 244) «пуговка, большая пуговица» < рус., әлбәттә. Элек

татар-башкортларда эре төймә урынына ялау белән тияк кулланылган.

**ПӘЕЛ [пәйѐл]** (Тумашева 1992: 170) «настроение; желание» ~ чув. *пил,* мар. *пиӓл* id., ш. ук «бәхет» < уйг. *пәйел* id. > башк. (БТДҺ: 69) *бәйел*; бу сүзне **мәел** сүзеннән аерырга ярамастыр, ләкин *м > б > п* күчешләренең гарәп алынмасында күзәтелүе гадәти хәл түгел, аерым аңлатма сорый.

**ПӘЕЧ [пәйѐч], пәйеж, пәйец** (ЗДС: 523) «накипь на посуде; короста», **пәйеж** «пенка на бульоне», **пәйес** «засохшая грязь на одежде» ~ төр. *payız*, фар. *пайиз* «юешлек».

Дерив.: **пәечлән-ү** «кутырлар барлыкка килү», **пәечле** «касмаклы; кутырлы».

**ПӘҖӘ-Ү, пәже-ү,** (ЗДС: 522–524) **пәзә-ү, пәнҗе-ү,** (Зимасов: 75) **пәждерә-ү**, башк. (БТДС: 64) *беже-у* «подгнить; залежаться, смягчаться» ~ рус. (Даль) *пазгать, паздерить* «теткәләү». Ниндидер өченче бер чыганактан (фин-угор телләреннән) булса кирәк.

**ПӘҖЕ, пәҗи [пәҗей]**, (ТТДС I: 241, 244, 255) **пази, пажи, пәзи** «пенька, конопля от женских особей этого растения (худшего качества, чем **баса**)», башк. *бәжей, бәзей, сары бәжей* (БҺҺ II: 202) ~ морд. *пазе* «баса»; чаг. кабарда. *бацэ* «ябага, язгы йон». Табышмаклы сүз: бор. куман-кыпч. теленнән булса кирәк. Ул чагында бор. рус. **пеньжа*, рус. *пенька* < бор. фар. *bäŋgä* < «наркотик; киндераш» (к. Фасмер III: 233) сүзеннән. Киндераш элек-электән наркотик матдәләр әзерләү өчен дә кулланылып килгән. Ахыр чиктә *пәҗә* һәм *баса* сүзләре бор. һинд.-ир. телендәге бер үк сүздән килүе ихтимал, к. бор. һинд. *bhaŋdas* «киндераш» ~ **bhandsa* > авест. *baŋha* id. К. **Баса.**

**ПӘЙГАМБӘР [пәйғәмбәр], пигамбәр [пиғәмбәр]** «пророк» > чув. *пихампар, пихемпер*, мар. *пиамбар, пиамбер* «пророк; божество – помощник верховного бога»; в чув. «повелитель волков» < фар. *пӓйғāмбӓр* «илче» ← *пӓйғāм* «әмер күндерү, боерык, ярлык, идарәчедән хәбәр» < бор. ир. *paitigata* «әмер әйтү» (Paul: 77). К. ш. ук Егоров 1964: 163. К. **Пәйда.**

**ПӘЙДА** «появившийся» (употребляется только в составе устойчивых словосочетаний) < фар. *пӓйда, пейда* < бор. ир. *paiti dayä* «уйланылган нәрсә, проект һ.б.» (Platts I: 298), **пәйгамбәр** сүзе белән өлешчә тамырдаш.

**ПӘЙНИР** (Җантурин: 76) «вид сыра» < фар., төр. *peynir* «сыйр» ~ рус. *панир, паныр* «әрмән сыйры» << бор. фар. *pänir* id. Будагов I: 320; Фасмер III: 197.

**ПӘКӘНӘ, пәкинә, бәкәлә** (ЗДС: 109, 523) «низкорослый, но юркий коротыш» ~ каз. (ҚТДС: 269) *пәкене*, уйг. *пәкәнә, пакинәк, пака, пакар,* үзб., таҗ. *пакана* id.; чаг. чув. *покана, пукане*, мар. *поганя* «курчак; кәтүк». Фар. сүзе булса кирәк. Чаг. фар. *пайк* «йөгерүче хезмәтче, хәбәрче, паж» → *пайканэ* «пайк кебек (елгыр)».

**ПӘКЕ,** (ЗДС: 523) **пәкке,** себ. (Тумашева 1992: 170) **пәги** «складной ножик, перочинный нож», иск. «нож для строгания стрелы» ~ башк. *бәке* id. > чув. *пекĕ, пеккĕ*, мар. *пакэ, пӓкэ,* удм. диал. *баки, бӓкĕ* ~ кар., каз., к.-калп. *пәки*, чыгт., уйг. *пәки*, үзб. (ЎХШЛ: 211) *пәкки*, төркм. *пәәки*, урта төрки *беки* < *паки, паку* id. >> миш. (ТТДС I: 338) **пике** «сөннәтләү өчен махсус пәке» (к. ш. ук мәкаль: *Мөселманлык ике – комган белән пике*; **пике келәве** «тантаналы сөннәтләү мәҗлесе»). *Пәке ~ пике* вариантлылыгы бу сүзнең бор. кыпчаклык заманнарында алынганлыгын күрсәтә. Җизнинең кайнешкә пәке бүләк итү йоласы да бор. аучылык гадәтләренә ишарәли. Будагов I: 310; Мухамедова 1973: 71; Федотов I: 412.

**ПӘКРӘ,** диал. (ТРС 1966) **бикрә** «стерлядь» ~ мар. *пикре,* удм. *бекра,* иске тат. (Паллас) *бекра*, чув. *пакра,* иске чув. *бекря* (к. Сергеев 1971: 127) ~ к.-калп., төркм., чыгт., тат. диал. *бекире*, каз. *бекѐре*, кырг. *бекрӓ* id. ~ калм. *bekr* «балык (гомумән)», төркм. *бекре* «кыйммәтле балык төре», каз. *мекіре,* к.-калп. *мекре* «мәрсин балыгы» – бу киң таралган сүз мәдәни терминнардан – *пәкрә* бор. сәүдә малы булган. Чыгышы ачык түгел (к. ш. ук **Багры**), Ramstedt 1935: 41; Линдберг, Герд: 61–62; ЭСТЯ II: 108.

**ПӘКТӘ** (ЗДС: 523) «хлóпок; вата», брб. **пакта** «хлопковое растение» < үзб. *пахта* < фар. *пāхта, паһта* «мамык, мамык үсемлеге». Räsänen 1969: 378.

Урта Азиядә яшәгән татарларда **пахта** бик таныш һәм актуаль сүз, чөнки анда халаекны *пахта җыярга* җәлеп итәләр.

**ПӘЛӘЙ** (ЗДС: 523, Кавказ, Әстерхан якларында) «широкое и длинное женское платье» < аз., төр. < фар. *палай, палан, палад* «ат менеп йөрү өчен бизәкле киң (атның җилкәсеннән алып койрыгына кадәр җитәрлек) ябу», кайбер очракларда ияр һ.б. *пәләй* астында калдырылган. Будагов I: 310; Özön: 684.

**Пәләй** бик кыйммәтле – аристократлар ат өстендә йөргәндә кия торган кием булган.

**ПӘЛӘС, пәләч** (миш., ЗДС: 523) «слабенький, вялый, еле живой (но не умирающий)». Бу сүзне **бәләче** дип уйлавы бик табигый, ләкин **бәла** сүзен **пәлә** дип әйтү мишәрләрдә юк. Чаг. иске төр. (Будагов I: 310) *палаз, пулаз,* хәз. төр. *palaz* «кош (бигрәк тә каз-үрдәк) бәпкәсе», күч. «мыегы да чыкмаган үсмер».

**ПӘН** (себ., ЗДС: 524) «по (чему), по поверхности» – **белән** (к.) сүзенең варианты дип күрсәтелә.

**ПӘНЕС, пәнеске, пәныскы** (ЗДС: 524) «вид ручной вязки из шерсти», *пенесне белән җамау* сүзенә караганда «бәйләмләп эшләнгән тукыма (оекфәлән генә түгел)». Бу сүзләр Татарстанның төньяк-көнб. (Дөбъяз районында) теркәлгән, күрше мари сөйләшләрендә дә бар. Сүзлекләрдә рус. *панский* (← *пан* «поляк») сүзеннән дип күрсәтелә. Ихтимал, ул тирәдә сөргенгә җибәрелгән поляклар яшәгәндер. Чаг. **Пански.**

**ПӘНГЕ, пән'е** (ЗДС: 524) «сорт грибов, употребляющихся в засушенном виде» ~ бор. төрки (ДТС: 94) *bengä* «наркотик, банг». Чаг. рус. *пенька* «киндераш (төре)» – ш. ук наркотик. Бу сүзләр **Паңгы** (к.) белән нигездәш, к. ЭСИЯ II: 83–84.

Бу **пәңге** белән тат. диал. (ЗДС: 110) **бәңке, бәңге** «өянке» сүзе контаминацияләнә бугай (пәңге өянкедә үсә).

**ПӘНҖӘРӘ** иск. «окно, окошко над дверьми», диал. (ЗДС: 532) **пинҗара, пинҗәрә** «сени с окном» < фар. *панҗарэ, пӓнҗӓрэ* «болдыр тәрәзәсе», сүзмә-сүз «биш өлге».

**ПӘНҖЕКИ** «пятирублёвка (монета или бумажная купюра)» < фар. *пӓнҗӓки* id. ← *пӓнҗ* «биш» (гом. һинд.-евр. сүзе, рус. *пять* белән гомоген). К. түбәндәгене.

**ПӘНҖЕШӘМБЕ**, диал. (Тумашева 1992: 170, төрле сөйләшләрдә очрый) **пәйшәмбе** «четверг» < фар. *пӓнҗ шӓмбе* «бишенче шәмбе»: *пӓнҗ* «биш»; *шӓмбе* тур. к. **Шимбә**. К. югарыдагыны.

**Пәнҗешәмбе** – китаби телдән килә; гади сөйләмдә ешрак **атнакич** сүзе кулланыла.

**ПӘПӘ, пәппә** (ЗДС: 24) «гусёнок, утёнок; младенец, не умеющий говорить, но болтающий» ~ халыкара ономопоэтик тамырдан. Чаг. **Әпә.**

**ПӘР** «чёрная краска для окрашивания дублёных шкур» < фар. *пӓрз* «порошок; корым».

**ПӘРӘВЕЗ [пәрәwӗз]**, диал. (Вәлиди II: 377) **пәрwәзә** «паутина» < фар. *пӓрwӓзӓ, пӓраwӓзӓ* «очып йөрүче, очучан» (очкыр пәрәвезләр күз алдында тотылган) ← фар. *пӓрwāз* «очыш»; к. иске тат. **пәрваз кылу** «очып китү, югарыда очу» һ.б. Будагов I: 315. Чаг. ш. ук төркм. *паравуз*, үзб. (ЎХШЛ: 208) *паравыз* «кайма».

**ПӘРӘГӘН** диал. (Турбаслыда: *Пәри кызы пәрәгән, Башын пәри тараган, Тараса да үрмәгән, Инәсе дә күрмәгән...*) «фея, эльф» < бор. төрки (Gabain 1950: 60) *pärikän* «королева фей» – сугд теленнән булса кирәк, **пәри** (к.) сүзе белән тамырдаш.

**ПӘРӘКӘНДӘ, пәракянда, праканда (китерү)** иск. «разбрасывание, разбрасывать», диал. (Зимасов 75, 77) **поракан, пыракай, праканҗа** «разбросанный, разгромленный» < фар. *пӓрӓканда* «өлешләп тарату, парә-парә итү», к. **Парә.** Тимергалин: 371.

**ПӘРӘМӘЧ**, диал. (ДС III: 120, 127, 132) **пирәмәч, пәрәмәчә, пәрәпәч, перепеч, пирипис**, (Тумашева 1992: 171) **пәрәмец**, (ТТДС II: 73) **бүрәмәч**, (ЗДС: 545) **пүрәмәч** «ватрушка; круглый пирог с мясом (характерной чертой которого было то, что чуть виднелась мясная начинка)» ~ башк. *бәрәмәс,* (БТДҺ: 264) *пәрәмәç,* чув. (Ашмарин X: 84) *пүремеç, пүремеçе,* удм. *перепеч*, мар. (Иванов, Тужаров: 162, Саваткова: 118) *перемец, пермец* id. > рус. *пермяч, перемяч* «пончик» (Аникин: 445) – сүзнең төп нигезе *бөгүрәмәч* булса кирәк: *бөгүр//богур* «йомры нәмәрсә; бөер», *-мач//-мәч* – ашамлык атамаларын ясагыч кушымча (чаг. **куырмач, токмач, умач** һ.б.). Чаг. чыгт. *буғрамач* «умач төре», *буғра* «тукмач төре», имеш, легендар **Буғрахан** исеменнән (к. Будагов I: 261). **Пәрәмәч ~ пүрәмәч** вариантларында анлаут *п-* авазына караганда, бу сүз иске уйг. яисә угыз диалектларыннан калган.

Хайрутдинова 1993: 37; Федотов I: 461 (этимологиясен ялгыш юнәлештә эзли).

**Пәрәмәч < бәйрәм ашы** дип аңлату фонетик закончалыкларга хилаф.

**ПӘРӘМИ** (ТТДС I: 352) «дружище (о подруге)» < **бәгырь ами:** *ами* (к. **Амиткә**) «дус, җаным; җан; сулыш, тын» монг. һәм тунг.-маньч. телләрендә киң таралган сүз, к. ССТМЯ I: 34–35, 37. **Пәрәми** сүзе үзе чув. сөйләшләрендә ясалган парлы сүз булса кирәк (*б-* > *п-* күчеше шуны күрсәтә), ләкин безгә чув. сүзлекләрендә очрамады. Ихтимал, **пәрәми** болг. сөйләшләреннән үк киләдер.

**ПӘРӘНҖӘ** «паранджа» < фар. *фӓрӓнҗи* < бор. ир. *paranya* «канат» сүзеннән (Абаев I: 420). К. **Пәрдә, Пәри.**

**ПӘРВАЙ** «воспитание; воспитанность» (**пәрвайлы** «тәрбияле», **пәрвайсыз** «тәрбиясез», **пәрвай кылу** «тәрбияләү, багу, асрау») < фар. *päрwāй, päрwō* «кайгырту, хәстәрләү» < сугд. *prw'уδ, prwyst* «эзләү, сорау, хәстәрләү» (ЯТ: 303). Будагов I: 315.

**ПӘРВАНӘ** «бабочка, летящая на огонь» (как поэтический образ «трепетная душа – безнадёжно влюблённый») ~ төр., фар. *пӓрванэ* id., төп мәгъ. «очкалак» ← *пӓр* «очыш». Тарих дәвамында фарсы һәм төрки телләрдә бу сүз бик күп күч. мәгъ. алган: поэтик планда *пәрванә (күңел)* «өметсез гашыйк күңеле», сәяси лексикада «хәбәрче, информатор; вәзир», ш. ук «шатлыклы хәбәр; пичәт, мөһер; ышаныч кәгазе» һ.б. Будагов II: 315. Хәз. төр. телендә *pervane* «пропеллер, кимә винты, маховик» һ.б.ш. мәгъ. кулланыла. Тимергалин: 371.

Дерив.: **пәрванәче, пәрванчы** «баш секретарь; Урта Азия төрки дәүләтләрендә баш хәрби министр».

**ПӘРГӘЛ** «циркуль кожевников» < фар. *пӓрг'āр* id., к. үзб. (ЎХШЛ: 213) *пәрйәр, паргар*, көрд. *pergel, pergäl* id. ~ төр. *pergel* «циркуль; план, проект һ.б.ш.» (*pergellemek* «алдан чамаламак»).

***ПӘРГИС** (Тумашева 1992: 171, **пәргислән-ү** «ураза тоту») «христианский пост; диета» < уйг. *пәрһиз* ~ төр. *perhiz* < *pehriz* < фар. *пӓһрез ~ пӓһриз ~ пӓрһиз* «пәрһиз, курку-хәвефләнү нәтиҗәсендә нидән булса да тыелып тору күренеше». Будагов I: 315.

Дерив.: (Гигановча) **пяргислик** (женси мәгъ.) «нәфесен тыю, тыелу».

**ПӘРДӘ** «занавес; регистр (в музыкальных инструментах)» > мар. *пӓрдӓ* (к. Исанбаев 1978: 31), тат. диал. **фәрдә** ~ каз. диал. *перне* (Аманжолов: 398), уйг. *пәрдә* < фар. *пӓрдӓ* < бор. ир. *parna* «пәрдә; канат» (*parr-* «очу», чаг. рус. *парить*). К. **Пәри.** Будагов I: 314.

Дерив.: **пәрдәле, пәрдәсез; пәрдәлек, пәрдәлә-ү, пәрдәлән-ү.**

**ПӘРИ,** диал. (ТТДС I: 340, ТТДС II: 248) **пири, пире, пир** «пери, черт и т.п.» (наиболее часто употребляемое название невидимых духов, в целом **пәри** – не очень сильный дух-проказник, однако в некоторых говорах этому слову придается значение злого духа, нечистого, в литературных произведениях наоборот – значение обольстительной красавицы, русского *пéри*) ~ башк. *бәрей, пәрей* > мар. (Исанбаев 1978: 48) *парий*, удм. *пери́*, тат. диал. **фәри** > чув. *хвери, хӗвери* id. – каз. *пері*, гом. кыпч. *парий, пэри*, уйг. *пәри*, төр. *peri* < фар. *перӣ, пӓрӣ* «пәри; пәрәгән, гүзәл» (к. Будагов I: 316) < авест. *pairika* id., төп мәгъ. «очучан, очкалак» – **фәрештә** (к.) сүзе белән тамырдаш вә мәгънәдәш. Бу сүз ир. телләреннән төрки телләргә бор. заманнардан бирле (к. **Пәрәгән**) кат-кат кергән.

Дерив.: **пәрилек; пәриләч-ү** («иркәләнеп киреләнү» мәгъ.); **пәризат.**

**ПӘРИШАН** «расстроенный, расстроен; разгромленный, разгромлен» ~ башк. диал. (БТДҺ: 71) *бәрәшән* id., ш. ук. «чамасыз» < фар. *перишāн, пришāн* id., к. ГТРС: 474.

Дерив.: **пәришанлык, пәришанлан-у.**

**ПӘРМӘПӘР, пәрмә-пәр** «яростно, с криками – о перебранке, споре». Асылда кураз, әтәч сугыштыру термины, к. фар. *пӓр-бӓ-пӓр* «канатка канат» – сугышучы әтәчләр тур.

**ПӘТ** (м.-кар.) «ян»: **пәтендә** «янында; рәтендә» – «около» – чув. *пат, пачӓ* «яны», каз. (ҚТДС: 271) *пәт* «тышлык; күңел; көч, куәт». **Бит** белән бердәй булса кирәк. Ләкин фар. теленнән дә була ала.

**ПӘТЕР** (Тумашева 1992: 171), **питер** (ЗДС: 533), ш. ук диал. **бәтер** «булочка (из пресного теста)» ~ каз. (ҚТДС: 60. 270) *бәтір*, кырг. *патир*, аз. *фәтир* id., үзб. *пәтир, патир* id., ш. ук «төче камыр» < гар. *фаṭир* «фитыр күмәчләре», к. **Питрач, Фитыр.**

**Пәтер** сүзе белән кешелек тарихында төрле чорларда (XIX г. кадәр) дөньяның төрле почмакларында күзәтелгән күренеш – елга, диңгез иясенә яшь кызларны корбан итү (аяк-кулын бәйләп ыргыту) баглы: бор. Мисырда **фатир** дип Нил елгасы рухы – крокодил Хапигә елына бер тапкыр (су соңгы чиккә җитеп кимегәндә) корбан ителгән кызны атаганнар. Соңрак яшь кызны тәмле күмәч – **пәтер** белән алмаштырганнар. К. Сказки народов жарких стран. Минск, 1999: 167.

**ПӘТРӘ** (ТТДС I: 357), **пәтери** (ТТДС II: 256) «подволока, чердак, пространство между крышей и потолком» < удм. диал. *петра* «амбар алды, чардак» (булса кирәк). Ләкин удм. сүзенең дә этимологиясе ачык түгел. Түбәндә рус сүзе түгелме икән.

**ПӘТРӘҮ, пәтерәү, патрау** (ТТДС II: 243, 256) «штраф за потраву; потрава», чаг. ш. ук (ТТДС I: 334) **паттрау** «недоношенный» < рус.

**ПӘХЛӘВӘ [пәхләwә]** «пахлава, слоёный пирог» төр. *pahlava, baklava* id. ← гар. *бақл* «кузак».

**ПӘҺЛЕВАН [пәhлĕwан],** диал. (ЗДС: 518) **палуwан,** (ТХИ: Әкиятләр I: 263) **пәлвән** «силач, богатырь» < фар. *пäһлäwāн* < бор. фар. *pälhäwan* < *pärδäwan* «парфяннар» (безнең эра башларында Иранда өстенлек иткән кавем – *пәрфу* атамасыннан, к. иске тат. *Пәһлу, Бәһлу ибн Сам* «ирани халыкларның җәте – бор. бабасы», к. ЛТ I: 114). Paul: 75. К. **Балбан.**

**ПӘЦЕ** себ. (ЗДС: 525) «маленький ребёнок», **пәшә, пәшкә** «ягнёнок, овечка; неумелая девочка» ~ себ. рус. *пашка* «болан бозавы» < манси. *пасыг, pāši, pāišg* id.; рус. *пешка* «яшь бозау» < хант. *pešo, peši* id. h.б. (к. Аникин: 443–444, 447). Бу сүзләрне себ. тат. **пәшәкә, бәшәкә** ~ рус. *бяшка* «сарык, бәрән» сүзләреннән аерырга сәбәп юктыр. Барысы да тат. *пәш-пәш, бәш-бәш, бәшә-бәшә* ~ рус. (Даль) *бяш-бяш* (сарык чакыру ымлыклары) белән баглы бугай. Моның ише сүзләр төрки, фар. телләрендә еш очрый.

Төрки халыкларда кечкенә балаларны бәтигә, бәрәнгә, тайга охшатып, яратып атау сирәк түгел. Көчеккә, бозауга охшату кире мәгънәләрдә була (к. рус. *щенок, теленок* h.б.). Чаг. **Пәшә.**

**ПӘЧ, пәчт** – имитатив смачному, но лёгкому удару.

Дерив.: **пәчнәт-ү (< пәчләт-ү)** «тиз-тиз генә штамп, мөһер сугып алу; җәһәт кенә имза салып алу».

**ПӘЧ-Ү** «поймать удачу, выиграть в чём-либо; *в непереходном значении* неожиданно везти и достаться» ~ чув. диал. *пач-* id. М. Рясянен буенча, бор. төрки **пäз-* «патшалыкка сайлангач, тәхет алдында бию» >> *бие-* сүзеннән, к. **Бие-ү.**

**ПӘШӘ, пәшкә** (себ., ЗДС: 525) «овечка, козочка; недотёпа» ~ рус. диал. *бяша, бяшка* «бәрән», *бяш-бяш* – сарыкларны чакыру ымлыгы, *бя-бя* – сарыклар мәәлдәвенә тәкълит. К. ш. ук рус. *пашка, пешка* «болан бозавы», ханты теленнән. Аникин: 447 (бай әдәбият күрсәтелә). Чаг. **пәце.**

**ПЕЛ,** диал. **пыл** «телеса, туша», «большой кусок мяса; мускул, мускулатура» ~ башк. (БҺҺ III: 152) *пел, пелле* «көр, симез» < фар. *пил, пиле* «кокон; тән егәре; батарея» сүзеннән булса кирәк. К. **Пелләү.**

**ПЕЛӘГӘ** (ТТДС II: 244) «(стекляная) посуда» < рус. *фляга* «шешә төре, солдат шешәсе» < ним., к. Фасмер IV: 200.

**ПЕЛӘМӘ** (Толымбай) «племя, порода (скота)» < рус. *племя* id.

Дерив.: **пеләмәле, пеләмәлек.**

**ПЕЛӘШ** «плешивый; плешь» < рус. *плешь*. Чаг. ш. ук удм. (Wichman) *pileš* id.

Дерив.: **пеләшлек; пеләшлән-ү.**

**ПЕЛДЕРИШ** (ТТДС II: 244) «пёрышко; игрушка-пропеллер из пера» < иске фар. *пäлиндар* «бумеранг; ыргытыла торган пычак» (*пäлиндариш* «аның пәлиндары»).

**ПЕЛЛӘ-Ү** «освежевать тушу» – **пел** сүзеннән. Чаг. *пеллән-ү* «көрәеп җитү (терлек тур.)», к. ТТДС I: 335.

**ПЕЛПЕЛ I** (ЛТ I: 113) «вид перца» < гар. *филфил* id.

**ПЕЛПЕЛ II** (ТТДС II: 244) «лампа-коптилка, мигалка» < ***пелт-пелт**, тәкълиди ясалма. К. **Пелт.**

**ПЕЛТ –** подражание внезапным мелким звукам и движениям: *пелт итү* «мигнуть», *пелт-пелт*

*итү* «мигать (о лампе), внезапно озариться, вспомнить»; **пелтек** «мигалка (о лампочке, сигнальном светофоре)», *пелтелдә-ү* «мигать неровно» ~ чув. *пӗлт* id. Чаг. **пылт.** К. **Пелпел II.**

**ПЕРӘННЕК,** диал. **перәнлек** «пряник, пряники» < рус. (рус. *прян-ый* «татлы, баллы» сүзеннән ясалган). **Перәнлек** дигәндә халык этимологиясенчә кабаттаркалыш күзәтелә.

**ПЕРӘШКӘ** «пряжка (на ремне)»; «запряжка с двумя лошадьми» < рус. *пряжка.* Бу сүзнең тагын берничә төрле мәгънәсе бар: ат ашату вакыты; колхозда хезмәт көне; атның туктамыйча бара торган аралыгы (25–30 км), к. ТТДС I: 335. Бу мәгънәләр рус сөйләшләрендә дә бар. Будагов I: 313.

**ПЕРЕС, прес** – междометие, которым отгоняют кошек, «брысь!» – типологик характердагы сүз булса кирәк (сүзлекләрдә сирәк бирелә). Ихтимал, *барыс, барс* сүзе белән тамырдаштыр.

Тәфсилле аңлатмалар белән (татарча вариантларны да искә алып) удм. *прис, прыс* һ.б., мар., чув. *прыс, пăрис*, рус. *брысь* һ.б. песиләрне куу ымлыгы тур. Максимов С.А. Комментарий к карте «кошка» // ДАУ I: 145–154. Максимов бу сүзне төптән ымлык дип исәпли һәм *барс* һ.б.ш.белән чагыштырмый.

**ПЕСИ [пĕсĕй],** диал. **песәй, печәй** «кошка, кошечка; сережки у ивы» ~ башк. *бесей, бесәй,* чув. диал. *пăси*, чыгт. *писи* ~ бур. *биихэй* < *биисэй*, үзб. диал. *пьшәй* (ЎХШЛ: 219), ком. *бишев*, тат. диал., үзб., уйг. *мешәк* (ДС II: 138), *мышак*, уйг. *пүшүк, мүшүк*, кырг. *пишек* > каз. *писек*, чыгт., госм. *пишик*, каз. *мышық* ~ фар. *пушек, пошек*, көрд, *пишик* һ.б. (ир. телләрендә вариантлары күп), гар. *бас* id. < бор. Мисыр. *баст* «изге песи; песи тәңре». Бу сүзнең төрле вариантларына *пес-пес* (песи чакыру ымлыгы) тәэсир иткән, к. ш. ук инг. *puss-puss*, һинд. *biss-biss*, рус. *кис-кис* (шуннан *киска* «песи») һ.б.ш. ЭСТЯ VII: 109–112. Удм. *пис'ай, писэй, писи* ~ мар. *пысий, псий* «песи, мәче» < тат. һәм удм. *пис'-пис'* ~ мар. *пси-пси*, ш. ук *писикай* һ.б. (бик күп вариантлар) тур. Максимов С.А. Комментарий к карте «кошка» // ДАУ I: 145–154. К. **Мәче.**

**Песи** сүзе белән күп кенә фразеологизмнар (үсемлек атамалары һ.б.) ясала. *Тал песие*, ихтимал, фар. *гурбāн бид* (*бид* «тал») сүзеннән калькадыр.

**ПЕСНӘК** «синица» ~ башк. *беснәк* > чув. диал. *пĕснек*, тат. диал. **песләк** (~ удм. *пислэг*), *пыснай* id. > мар., удм. *писник* id. Рус. *мясник* «песнәк; итче» сүзеннән булса кирәк (Будагов I: 316): песнәкләр ит ярата һәм алъяпкычлы ит сатучыга охшатыла. Шул ук вакытта коми. *пыста, пыстӧг, пистӧг* «песнәк» һ.б. бу сүзнең фин-угор тамырлары да бар дигән фикергә урын калдыра (Алатырев 1976: 129). Сафина 2006: 47–48.

**ПЕСТӘ** «фисташка» < уйг. *пистә* ~ төр. *fıstık* id. Рус һәм бүтән Европа телләрендә дә охшаш сүзләр бар (Фасмер IV: 197). Тат., уйг. сүзе һичшиксез шуларга кардәш, ләкин конкрет чыганагы билгеле түгел. Урта Азия һәм Иран телләрендә бу җимеш бүтәнчәрәк тә атала.

**ПЕСТЕЛ, пестер, пестермай** (к. ТТДС I: 336) «малыш; недоросль; неумелый» < рус.? К. рус. диал. (Аникин: 446) *пестерь* «юньсез кеше».

Дерив.: **пестелчек** «үсмәгән, чибек, кәрлә». Чаг. рус. *пестунчик* «бик иркә бала».

**ПЕТӘЙ, пети** (ТТДС II: 245), **пыт'и** (ЗДС: 549) «соски (женской груди)» – мордва телләреннән дип исәпләнелә (миш. сөйләшләрендә киң таралган).

**ПЕТЕК, петекей** (ТТДС II: 245), **бетеки, бечеки** (ТТДС I: 81–82), **петик** (БТДҺ: 262) «маленький, малюсенький» – киң таралган ономопоэтик тамырдан, к. **Печтек.**

**ПЕЧӘ** диал. «женщина, имеющая четырёх и более детей» (Арсланов 1976: 3–71). Чаг. (эчк., ЗДС: 528) **пецә тун** «корама тун»: күп балалы хатыннарны яман күздән, шайтаннар шәреннән саклау өчен корама кием кидергәннәр. **Печә** сүзе үзе *Бичә* белән бердәй булса кирәк. Чаг. ш. ук **Печкә.**

Бор. төркиләр дүрт һәм күбрәк егет үстергән аналар каберенә махсус сынташ куйганнар.

**ПЕЧӘН,** диал. (ТТДС I: 35–36) **пичин**, **песчән, песин** «сено», (прм.) **печин** «трава» ~ башк. *бесән,* ком., кар., к.-балк. *бичӓн*, әрм.-кыпч. *бичен*, нуг., каз., к.-калп. *пишен*, төр., үзб., уйг. *пичән, пичан*, алт., шор. *пичен*, алт. диал. *пыҗан*, кырг. диал. *пычан* «печән» һ.б. *печ-//пыч-* (к. **Печ-ү**) фигыленнән ясалган дип уйланыла (Будагов I: 245; ЭСТЯ II: 161), ләкин сүзнең кайбер вариантлары бу расламага карата шик тудыра, к. себ. (брб.) **пичан** «утлак», (Старчевский) **пэцаал, пэцаwыл** «болын», уйг. *пичән* «запас деталь», *пичан* «печән», чув. *пиҫен* «гөләп, гөлҗимеш», мар. *пилчен, пилсен, писен,*

*писан* «печән; билчән». Бигрәк тә *пичан* яңгырашында сингармонизм сакланмавы аңлатма сорый. Чаг. ш. ук бор. монг. *ebesün* ~ чыгт. *өбүсүн* «печән, курмы». К. **Печәнәк.** Диал. сүзлекләрдә (ЗДС: 528–529) **печин** сүзенә беткән бик күп үлән атамалары күрсәтелә. **Печән** сүзе төрле фразеологизмнарда кулланыла.

Дерив.: **печәнле, печәнсез; печәнлек** – 1) печәнгә ярарлык; печәнгә махсус калдырылган җир кишәрлеге; 2) кышлык печән өелә торган махсус каралты, абзар башы һ.б.

**ПЕЧӘНӘК** диал. «травинка, былинка» (без теркәдек. – *Р.Ә.*) ~ аз. *бичәнәк, бичәнәх* «печәнлек, чабынлык» (АДДЛ: 80). Чаг. үзб. (ЎХШЛ: 218) *печәк* «чырмавык (үлән)». Тат. сүзе закончалыклы һәм аңлашыла, аз. сүзе аңлатмага мохтаҗ.

**ПЕЧЕНЕГ** (татарча публикацияләрдә дә шулай языла) «печенег». Русчасы ул халык белән күп сугышкан бор. (X г.) руслар теленнән үк килә. Хәз. кр.-тат. һәм төр. телләрендә (к. Dobr. III: 40) *peçenec.* Ләкин иске төрки һәм гар.-фар. чыганакларында *баҗанак, бәҗәнәк,* к. Kurat 1937. К. **Бәҗәнәк.**

Русларда *Кто к нам с мечом придёт, от меча и погибнет* «кем безгә кылыч янап килсә, үлеме кылычтан булыр» мәкале баҗанаклар теленнән алынган диләр. Баҗанакларны византиялеләр белән бергәләп куманнар кырып бетергәннәр.

**ПЕЧКӘ** «женщина из родственников мужа; свекровь» (к. Остроумов 1892, Balint: 149, Рамазанова 1991: 106), *печкәчә(й)* «каенсеңел» (ТТДС I: 336–337), чаг. чув. *пичче* «агай, тагай». Ачык түгел.

**ПЕЧМӘН** «веснянка (коллективный выход весной и в начале лета на поля с ритуальными молениями)» (к. Материалы по татарской диалектологии 1978: 18) рус теленнән булса кирәк. Чаг. мар. (Саваткова: 135; Тараканов: 88), *пысман, пěсмäн*, удм. *бисмянь, бесмен* «мижа, кишәрлек». К. **Пештемә.**

**ПЕЧТӘН, печтәл** «непрошеная помощь; посещение кого-либо без приглашения» (активнее употребляется *печтәнлән-у, печтәллән-у* «предлагать помощь без особой надобности; явиться без приглашения») < рус. *фискал* «ревизор», «XVIII г. игенчеләргә киңәш биреп йөрергә билгеләнгән чиновник» сүзеннән; (асылда *фискал* «салым җыючы», соңрак «хөкүмәтнең яшерен агенты» мәгъ. кулланылган латин сүзе).

**ПЕЧТЕК**, диал. **печтик, печěк, пеҗеки** (ДС II: 152; ДС III: 125) «мало, маленько» ~ чув. *пěчěк, пěчěкке, пěçěкçе, пчик, пăча* һ.б. (Сергеев 1971: 97), удм. *пичи* id. ~ сарт. (үзб. диал.) *бича*, кырг., алт., тув. *биче, бичи, бичик,* як. (Пекарский: 481, 606, 647) *бичикан, бычык, бычыкан* < монг., бур. *бичихан, бисихан*, хәз. монг. *бяцхан*, икенче яктан – көрд. *bečik* id. Чаг. **Печ-ү.**

**ПЕЧ-Ү,** диал. **пец-ү** «кастрировать», диал. (ТТДС I: 337) «обрезать; кроить (одежду), наметить размеры» < гом. кыпч., уйг. *пич-* (башк. *бес-,* нуг., каз., к.-калп. *пиш-, биш-*), кырг., угыз., ком., кр.-тат., кар. *бич-* id. К. **Пыч-у.**

**ПЕШЕ,** диал. (Тумашева 1992: 173) **пешек, пешкен** «гибкий и прочный; опытный; зрелый; спелый» > мар. *пěсě, пысы* «булдыклы» < башк. *беше,* нуг. *пиши,* уйг. *пишшик,* каз. *пысық,* к.-калп. *писық,* кырг. *бышық* (> каз. диал. *быжық*), бор. төрки (ДТС: 106) *bïšïγ, bïsïq*, тув. *быжыг,* шор. *пышы, пышыг,* хак. *пызыг,* як. *бусуу*, төр. *pişkin* id. һ.б. (к. Радлов IV: 1319, 1323). Асылда **пеш-ү** фигыленнән, бу сүзнең мәгъ. структурасында бор. заманда кайбер материалларны (чыбык, туз, кабык) кайнатып ныклы һәм сыгылмалы итү эше чагыла. К. **Пешек-ү, Пеш-ү I, Пыш-у.** Будагов I: 159.

**ПЕШЕК** «место покраснения кожи от жары, лёгкого ожога», диал. «сваренный» ← *пеш-ек*, чаг. *ерык* < *ер-у, кылык* ← *кыл-у, төзек* ← *төз-у* һ.б.

**Пешек** продуктив нигез: **пешекләү, пешекче** һ.б. К. Будагов I: 259. К. **Пеш-ү.**

**ПЕШЕК-Ү (пешекте, пешегү)** «покраснеть от жары, огня и т.п.», диал., башк. «париться, уплотняться» – **пеш-ү** фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе, чаг. кырг. *бышык-* «чыныгу; тәҗрибә алу».

**ПЕШКӘК** «поршень пахталки, мутовка» ← **пеш-ү II.** К. **Пыш-у.** К. ш. ук кырг. *бишкек,* нуг., каз., к.-калп. *пискек* «пешкәк», алт. *пышкы* id. (Будагов I: 260).

**ПЕШНӘ** «пешня» < рус. *пешня* id. ← *пеш-, пих-* «төртү, төртеп тишү», һинд.-евр. тамырларыннан. К. **Пыш-у.**

**ПЕШТЕМӘ:** (крш., к. ТТДС I: 338) **пештемә куу** «изгнание злых духов из полей после весеннего сева» (сохранилось у крещёных татар) – чәчүләр

беткәннән соң басуда факел яндырып явыз рухларны куу. Бу бор. мәҗүси йола бәлки руслардан һәм фин-угорлардан киләдер. Н. Исәнбәт **пештемә** дигән балалар уены тур. яза һәм **пештеме?** сүзеннән дип үзенчә аңлата. Гомумән ачык түгел.

**ПЕШ-Ү I** «вариться, свариться; печься, покраснеть от жары; созревать» ~ башк. *бёш-*, кар., ком., к.-балк. *биш-*, нуг., каз., к.-калп. *пис-,* уйг., чыгт., госм., төркм. *пиш-,* чув. *пиҫ-,* алт. *пыш-,* тув., кырг. *быш-*, хак. *пыс-* «пешү» (кайбер телләрдә ашамлыкка карата әйтелми: рус. «вариться, печься» мәгъ. икенчел булса кирәк) < бор. төрки (ДТС: 103, 105–106, 397) *biš-, bïš-, piš-* «пешү». Бу сүзнең дүрт төп варианты булу аның алынма булуына ишарә; өстәвенә як. *бус-* «пешү», бор. төрки *bïšur-, büšär-* «пешерү» вариантлары да бар. Чаг. сугд. *pwγš-, pč-*, Памир телләрендә *pač:pux* (үзгәрешле тамыр) < бор. ир. *pač-* < һинд-евр. *pek-* «яндыру, пешерү» (ЯТ: 301, 310; Абаев I: 488). Шулай итеп, тат. *пĕш-* һәм рус. *печь (пёк)* тамырдаш булса кирәк.

Дерив.: **пешен-ү** (диал.); **пешер-ү** һәм **пештер-ү** (аерым мәгънәләрдә); к. **Пеше, Пешек-ү.**

**ПЕШ-Ү II** к. **Пыш-у**.

**ПИГАМБӘР** к. **Пәйгамбәр.**

**ПИЖАМА** «пижама» << инг. *pijama(s)* < һинд. *päjäta, payjata* < фар. *пайҗамӓ* (Фасмер III: 259; Kluge: 731) «аяк каплагыч» – озын чабулы яисә озын итәкле күлмәк; шуннан ук себ. (Тумашева 1992: 174) *писма* «күлмәк итәгенә тегелгән өстәмә тасма» сүзе дә килсә кирәк.

**ПИЛМӘН,** диал. **пилмин** «пельмень, пельмени» < рус. *пельмень* < морд. *пель нянь* «колаксыман ашамлык» (*пель* «колак», *нянь* «ипи, нан»); барча төп фин группасы телләрендә шул ук сүзләр, шунлыктан рус. *пельмень, пельнень* сүзен фин теленнән дип тә, удм., коми телләреннән дип тә (к. Аникин: 444) аңлаталар. К. ш. ук (ЗДС: 532) **пирмән, пирмәнке** «пилмән төре».

**ПИМА** «валенок, валенки» < рус. *пимы* < коми. *пим, пими* самод. телләреннән, к. Joki 1952: 134; Аникин: 447–448 (бик тәфсилле).

**ПИМБЕ** (Будагов I: 326) «зяблик (птица)» < мар. *пембе* id. Ихтимал (хәтта, мөгаен, дип әйтергә дә ярыйдыр), иске тат. **пәмбә** – төр. *pembe* «җете ал» сүзеннәндер, к. төр. *pembe sığırçık* – рус. «розовый скворец». **Пимбе** пәмбә төстә була.

**ПИНӘ, пәнә** (ЗДС: 524, 531–532) «обида, обвинение в адрес кого» – сүзлекләрдә рус *пéня* «штраф» сүзеннән дип аңлатылучан. Ләкин тат. сүзенең мәгънәсендә дә, яңгырашында да (бигрәк тә **пәнә́** вариантында) русчадан булуына шик тудырырлык моментлар бар. Ихтимал, тат. *пинә – пәнә,* аз. диал. *пеһанә, пеһнә* < төр., фар. *bahane, behane* «сылтау, сылтану» сүзеннәндер. К. **Баһанә.**

Дерив.: **пинәлә-ү, пәнәлә-ү** «үзеңнең унышсызлыгың, бәла-каза хәле өчен кемнедер гаепләү, үпкә белдерү», З. Бәшири телендәге **пинәү** сүзе рус. *пенять* сүзе тәэсирендә ясалган булса кирәк. Монда чыннан да рус теленең катнашлыгы юк түгел.

**ПИНҖӘК, пинжәк** «пиджак» ~ мар. *пинжäк,* удм. *пинжак*, чув. *пиншак* id. рус. диал. *пинжак* < рус. әд. *пиджак,* бу сүз исә < инг. (Фасмер III: 259) *pea-jacket* «кыска пальто».

**ПИНЗЕ, пинсе** сөйл. «пенсия» ~ удм. *пэнза* id. < рус. *пенсия* << лат. *pensio* «түләү» (Фасмер III: 232). Чаг. иске рус. *пенсион*, көнб. Европа телләрендә *пенс* – вак акча берәмлеге.

**ПИПАРАТ** (Н. Макаров) «струнный музыкальный инструмент типа гитары», «музыкант на свадьбе» («Нагайбаки» 1995: 103) < уйг. *пипа, пипарат* < маньч. *фифари* (күп. формада) < кыт. *пипа* «дүрт кыллы кубыз» < тибет. *pi wang* id. (ССТМЯ II: 300). Бу сүз кыт. теленнән маньч. теленә, маньч. теленнән монг. телләренә, шуннан уйгурчага, шуннан тат. теленә кергән. Гомумән, халыкара сүз: инг. *pipe* «сыбызгы», лат. *pipare* «сызгырту» һ.б.

**ПИПИ** диал. (Хайрутдинова 1993: 16; БТДҺ: 264), **пәпәй, папай** «мелкая лепёшка», «хлеб (в детской речи)» ~ ком. *папай* ~ рус. *папа* id. Чыгышы ачык түгел. Гомумән ономопоэтик сүз, к. мар. *пäп* «тавыкның ак ите», *пипи* ~ чув. *папка* «тал бөресе» һ.б.ш. (балалар телендә).

**ПИР I** иск. «почтительное название ишана-мюршида; войсковой священник» (М. Хуснуллин), тар. «старец; глава монахов; старшина ремесленников» (к. Будагов I: 325) < фар. *pīр* id. К. **Кимпер.**

**ПИР II,** к. **Пире.** *Ир түгел, пир* дигән мәкальдә очрый. **Пир** монда «карт, ямьсез» мәгънәсендә дә,

«пәри, җен» мәгънәсендә дә аңлашыла алган, ике мәгънәле булган. Күбрәге шаярып әйтелгән.

**ПИРАКЛАТ**, **пирахлат** (ЗДС: 532) «перекладина (в стройке)» < рус., әлбәттә.

**ПИРӘСӘ, пирасә** (Тумашева 1992: 174), **пирәцә** (ЗДС: 532) «женская тёплая куртка, женский выходной плащ» < фар. < гар. *фäрäжё, фäрäҗиййä* «кешелек хатын-кыз җиләне». Шуннан ук иске рус. *ферязь* «хатын-кыз җиләне». Будагов I: 782. К. ш. ук **Бәрәҗә.**

**ПИРӘШ** (Троянский I: 256), **пираш** (Будагов I: 324) «пиво, брага»: юраулы сүз: төр. *bira* яки мар. *пир, пуйыр, пүрӧ*, морд. *пуре* «пирәш, сыра» сүзләреннән ясалуы ихтимал. Чаг. ш. ук *первач* «самогонның өсте, иң чиста өлеше» (ләкин **пирәш** сыра төре генә).

**ПИРЕ,** (ЗДС: 532) **пир** «злой дух, который дразнит тем, что все делает наоборот (особенно на дорогах – указывает не то, а совершенно другое направление, читает молитвы с конца и т.п.)» ~ башк. *бир* id. – **пәри** (к.) сүзенең этимологик дублеты булса кирәк (*пире < пәри > пәрей*). Ш. ук бор. төрки (ДТС: 398) *prät* < санск. *preta* «җен» сүзеннән килү ихтималы да юк түгел. К. **Бир.**

*Мин сөйлимен перегә, пире сөйли кирегә* дигән мәкальдә, гадәттә ул кире кешегә карата әйтелсә дә, пиреләр кеше әйткән сүзләрне кирегә – азагыннан башлап кабатлыйлар икән, дигән ышану ята. Бу хакта к. **Шекә.**

**ПИРЕС** иск. «вид толстой шёлковой ткани» (из неё шили тюбетейки) < рус. сөйл. *перс* «фарсыдан килгән» сүзеннән булса кирәк. Чаг. **кытат, манчистыр, фырансуз.**

Татарларда *перс* сүзе электән кулланылмаган, **фарсы** дигәннәр.

**ПИРИЯЗ [пирийәз], пирәйәз** (БТДҺ: 263), **пирез** (ТТДС I: 340) «мера площади земли: по одним данным 75 сотых, по другим – 40х40 саженей» (в целом разница небольшая) ~ удм. (Кельмаков 1977: 58) *пэрэз* id. < рус. *переезд* id. (*гон* дип тә аталган).

**ПИРТА** (ТТДС I: 340) «женское нагрудное украшение» < рус. диал. *передá* id. ← *перёд* «алгы як» (исем).

**ПИРУК** (Хайрутдинова 1993: 36) «пирог» < рус., ләкин рус сүзе төрки телләрдән, к. **Бөйрәк.** Башк. (БТДҺ: 56) *бөйөрөк* «вак бәлеш».

**ПИС** иск. «отвратительный» < фар. *пес, пис* «әшәке; махау» < пәһл. *pēsak*, авест. *paesa* «чуар йөзле» (Paul: 79). **Пис, пес** яз. төрки телләрдә киң таралган сүз: уйг. *пес*, төр. *pis* һ.б. Рус. *пёстр* белән тамырдаш. Шул ук бор. төрки < авест. *paēsa* «пис, чуар таплы» сүзеннән рус. *пёс* «ата эт» – асылда «бериш акка чуар таплы (эт)» сүзе килә, к. рус. *псовая* «акка кара таплы ала». Фасмер III: 249.

Дерив.: **пислек** «әшәкелек», **пислән-ү** һ.б.

**ПИТЛА** (ТТДС I: 340 һ.б.), **битла** (БТДҺ: 50) «дверная петля» < рус., әлбәттә. Рус. *петля* үзе «элмәк, ялау» дигән сүз (шуннан *петлица* «элмәк рәвешендәге бизәк»); элек ишекләрне элмәккә элеп кенә япканнар. Фасмер III: 252.

**ПИТЛӘ-Ү** (Тумашева 1992: 174) «запереть, запирать» – турыдан-туры «бикләү» сүзеннән түгел, чөнки к. нуг. *пите-* «бикләү». Гомумән, **бик** белән баглы булса кирәк.

**ПИТРАЧ**, диал. (ТТДС I: 240, ТТДС II: 249) **питырач, питырац, питырас, питырка**, башк. > тат. **битрас, питрас** «колобок, пышка; хлебец (круглой высокой формы); грудный мускул лошади» ← *фитыр* (к.), фитыр мәрасимендә төче камырдан күмәч (ритуаль камыр ашы) пешерүдән калган. К. **Пәтер.**

**Питрач** (һ.б.) сүзенең сингармонизмның беренче законына буйсынмавы аның кушма сүздән килеп чыкканлыгын, ә *ә* > *и* күчеше бор. кыпч. телләреннән үк килгәнлеген күрсәтә (*ә < э < и*), бор. этимон. **пәтир ачысы* (**ачы** «камыр» мәгъ.) булырга тиеш. Хайрутдинова 1993: 22–23 (тәфсилле аңлатма).

**ПИЧӘТ** (ТТДС I: 342, гомумән һәр төштә очрый), **печәт** «печать; обои» ~ чув. *пичет*, мар. *пецат, печат*, удм. *печет* «мөһер, пичәт» < рус., ләкин рус. *печать* ~ пол. *piecez [пиченц]* бор. төрки телләрдән булырга тиеш (к. Добродомов 1974: 29). Чаг. алт. диал. *пичик*, хак. *пичиг,* монг. *бичиг,* як. *бичик* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 103) *bitig* «язу, язма» ← *bit-, biti-* «язу» ← бор. кыт. **pjet-* «пумалачык (иероглиф язу әсбабы)». К. **Бетек, Бөти.** Федотов I: 438.

Дерив.: **пичәтле, пичәтсез; пичәтлә-ү, пичәтлән-ү.** Безнеңчә, **пичәт** сүзен һәм аның

дериватларын **басма, бастыру** һ.б. сүзләр урынына активлаштыру мәгъкуль (чөнки ул сүзләр артык күпмәгънәле).

**ПИШ** иск., жарг. «фаворит, клеврет ишана – первый шакирд; главарь среди шакирдов в медресе» (шуннан *Бүген пиш, иртәгә пис* дигән мәкаль калган) < фар. *пӣш* «ал, алгы як; алдынгы».

Дерив.: **пишлек; пишәй-ү** «беренче, узаман булып китү (булдым дип уйлау), үзен әллә кемгә кую». Бу сүзләр элекке мәдрәсә шәкертләре телендә кулланылганнар.

**ПИШЕН, бишин** (ЗДС: 136, 535) «полдень; чуть после обеда» ~ гом. кыпч., үзб. *пишин* id. < фар. *пēшӣн* «(өйләдән) алдарак». Будагов I: 325.

Иске әд. **пишеннәр** «җәтләр, бабалар, элекеләр».

**ПИШКАДӘМ** иск. «первый шакирд в медресе, помощник ишана (иногда таковым оставался всю жизнь); кандидат в преподаватели медресе». В современном Иране и Турции – «кандидат наук» < фар. *пēшкадӓм* «беренче адым; алдан атлаучы». Будагов I: 325.

**ПИШКӘШ** кит. «маленький подарок уважаемому лицу (не взятка)» < фар. *пēшкӓш* id.

**ПИЯЗ [пийаз],** себ. **пияс** «сладкий лук (белый, крупный)» < фар. *пийāз* id. Урта Азия төрки телләрендә киң таралган. Себердә **пыйаз** – гомумән «суган».

**ПИЯЛА, пиала** (в отличие от **пыяла**) «фарфоровая чаша, чашка определённой формы» < фар. *пийāлӓ* «чынаяк, бокал; чикләвек оячыгы» < лат. *phiala* «киң төпле тустаган, эчемлек савыты» < грек. *πυελος* «чынаяк, тустаган һ.б.ш.». Räsänen 1969: 385; Kluge: 700; Тимергалин: 375–376.

Шул ук сүзгә рус. *фиалка, фиолет* сүзләре тоташа.

**ПЛЕН [пл'эн]** «плен, пленение» < рус. *плен* ~ бор. рус. *полон* id. Рус телендәге тулысузыклы (полногласный) вариант бор. уйг. (Радлов IV: 1280) *полун*, бор. төрки (ДТС: 123) *bolun, bulun,* «әсир; әсиргә төшү» сүзенә бик охшаш, өстәвенә к. як. *булуон* «әсир», *молуон, молоон* «шау-шу, паника» (бу сүз бор. төрки **болгун* «болганыш» сүзеннән килеп чыга ала), *болуонна* ~ «Кутадгу билик»тә, Котбидә *болна-* «әсиргә алу». Шулардан чыгып, рус сүзе дә төрки теллəрдән дип уйлаучылар бар. Ләкин рус. *полон ~ плен* тәңгәллеге бу сүзләрнең бор. слав. теленнән килгәнлеген күрсәтә һәм шунлыктан бор. төрки *полун//болун* сүзе үзе көнч. слав. телләреннән (Күктүрк дәүләте заманнарында ук) алынган дип тә уйлыйлар, к. Menges 1987: 233–240. Һәрхәлдә куман. *болон,* иске тат. *пулын* «әсир» бор. русчадан булуы бик ихтимал. Иске тат. *болна-* ~ рус. *полонить* сүзләренең үзара субституция мөнәсәбәтендә булуы да мөмкин.

**ПОДАУКА, подаукы, пыдаука,** себ. (ЗДС: 543) **путафка,** ш. ук татарчалаштырылган форма (трбс.) **подаулык,** рус. аерым варианттан ЗДС: 546) **пыдавик** «пудовка» < рус. диал. (СРНГ 33: 107–110) *пудовик, пудовка* һ.б. (күп вариантлар) «бер пот сыешлы чиләк», ш. ук «бер пот орлык чәчәрлек җир», «бик авыр нарасый» һ.б. Урта Идел регионында киң таралган: чув. *пӑтавкка,* мар., удм. *пудовка* «бер потлык савыт» һ.б. К. **Пот I.**

**ПОКРАУ [пŏкraw]** «Покров день (1 октября)» ~ чув. *пукрав*, мар. *покро*, удм. *пукро, пукрол* id. < рус., әлбәттә. К. Фасмер III: 189. Башк. (БТДҺ: 36) *бакрау* id. Рус. *покров* – «Мәрьям ана яклавы (*покровительство*сы). Даль.

**ПОЛ** «монета» к. **Пул.**

**ПОЛТЫРАК [пŏлтŏрақ]** «отвисающий буклями (о женских волосах)» ← диал. *полтыра-у* «баеркасы белән асылынып тору» (**полтырату** – шулай асылындыру) сүзеннән. Тәкълиди тамырдан булса кирәк.

**ПОЛЫН [пŏлŏн],** иске тат. **пулын** «пленный из гражданского населения, полоняник» < рус. *полон* булса кирәк. К. **Плен.**

**ПОПУГАЙ, папугай** «попугай». Европада киң таралган бу сүз ахыр чиктә (фар. теле аша) гар. *баббаға̄* id. сүзеннән килә. Kluge: 678.

Тат. теленә *попугай* рус теленнән XX г. гына кереп активлашып киткән. Аңарчы **тутый** (к.) сүзе кулланылган.

**ПОРАК: порак оны** «гарнец» («часть муки, которая отдаётся мельнику» – собственно «мучная пыль, которая оседает на стенах») ~ мар. *пырак, пурак*, башк. диал. *пŏрақ* «тузан, чәчәк серкәсе;

тузанлы», удм. *бурак* «җитен тузаны» (к. БҺҺ II: 195; Саваткова: 130; Насибуллин: 108), чув. *пăрах* «көнҗәлә тузаны» ← алт. *пур*, кырг. *бур*, хак. *пыр* «пәрәвезгә кунган, үсемлекләр өстендәге һ.б. тузан», хак. диал. *пырын* «корым» һ.б. (к. Добродомов И.Г. Загадочная параллель: *бур (бор)* орхонских надписей и *боръ (< бъръ)* Повести временных лет // Turcologica, к семидесятилетию акад. А.Н. Кононова. Л., 1976: 241–246).

Безнеңчә, бу сүзне рус. (гом. слав.) *прах: порох* һәм фар. (> тат.) *барут* «дары» сүзләре белән дә чагыштырырга мөмкин: дары ясауда кулланыла торган селитра иске каберләрнең янтыкларына куна һәм элек шуннан себереп-кырып алынган; к. ш. ук көрд. *порак* «поташ (калий карбонаты)», уйг. *пурақ* «яман ис, ис». К. **Порхыт-у.** К. ш. ук **Борак I.**

**ПОРАМЫШ, прамыш (йоннопрамыш)** «шөпшә» (ТТДС I: 349), чаг. **пордаш** «коңгыз» (Остроумов 1892). Ачык түгел.

**ПОРХЫТ-У [пŏрхŏт-],** диал., башк. **бŏрхŏт-у** «поднять пыль (о дуновении, ударе), обдать пылью» ← диал. *порхы-у, порых-у* «күтәрелү (тузан тур.)» ← *пор* «куе тузан». К. **Порак.**

**ПОС** «морозная пыль в воздухе, лёгкий пар» ~ башк. (БТДҺ: 263) *пŏс* «он очынтысы», чув. *поас* «бәс», *пăс [пŏс]* «пар, җиңел томан; ис» (к. Ашмарин IX: 146, 149, 254), мар. *пуш, пыш* «ис, сөрем; пар, бу», удм. *бус, быс, бүс* «томан, пар, төтен», коми. (КЭСК: 42) *бүс* «томан», рус. диал. *бус* «пос, вак томан» < ком., алт., хак., тув., чыгт., госм. *пус*, бор. кыпч. (әт-Төхфәт 1978: 287) *bus* «томанлы, төтрә», ихтимал, *бор < бур* тамырыннандыр (*бур > буз > бус*?). Гомумән, һәр ике сүз ономопоэтик тамырдан булса кирәк (чаг. *порых ~ пырых, пош ~ пыш* һ.б.). Һәрхәлдә *поскы-у* фигыле һичшиксез *пос* сүзе белән бәйле. Räsänen 1969: 90 (бик тәвәккәл чагыштырулар китерә).

**Пос** продуктив нигез: шуннан бор. төрки *pusar-* «посару, послану» (МК II: 78) > чув. *пăсар-* «ис чыгару» → тат. диал. **бŏзара,** чув. *пăсара,* мар. *пушара,* удм. *бызара* «сасы көзән; сасы сусар» сүзе килә. К. **Поскак, Поскы-у.**

**ПОСКАК** «дождь с мельчайшими каплями» ~ башк. *быҫҡаҡ, боҫҡаҡ* id. > мар. (Исанбаев 1978: 27) *пускак* id. ← диал. *поска-у* «пос чыгару, пос (хасил) булу» сүзеннән.

**ПОСКЫ-У** «тлеть, моросить» к. **Пыскы-у.**

**ПОСТАЛ** иск. «посталы» ~ добр. (Dobr. III: 66), төр. *postal* «калын кунычлы тупас аяк киеме, аякчу» < фар. *постагал, пустагал* «тире куныч», «йоны өскә калдырылып тегелгән тире итек» ← *пуст* «тире» (**постау** белән багланышы ачык түгел). Тикшеренүгә мохтаҗ. К. Радлов IV: 1191. Рус. сүзе тур. Фасмер IV: 341–342 (фар. *пуст* сүзеннән ди; гипотетик *подстол < подстелить* сүзеннән дә чыгаралар, бәхәсле сүз).

**ПОСТАУ [пŏстаw],** диал. **пустаw** «тонкое сукно», «плис», (Троянский I: 256) «немецкое сукно» ~ башк. *бостаw, бустаw* id.> чув. *пуҫтав, постав,* удм. *пустол* (*л > в),* мар., удм. *посто* id. < рус. *постав* «урамалы (киндер һ.б.ш.) тукыма» (XVI г. руслар нугайларга «тугыз постав сукна» җибәрәләр, к. Продолжение древней российской вивлиофики: 321) ~ венг. *poszto* «постау», *pastal* «постау кисәге», табышмаклы сүз: В.Г. Егоров буенча, тув. *пӧс-даавы* (> себ. *постаwы*) «тукыма тавар» сүзеннән (Егоров 1964: 168): *пӧс* «бүз», *даавы* < бор. төрки *tabı* «тукыма» > бур. монг. *даабу* < кыт. *да бу* «күк тукыма» (*постау* шул төстә була). К. **Пастау.** Рус. *даба* тур. Аникин: 175. К. ш. ук **Пастау.**

**ПОС-У** «прятаться от преследователя, сесть в засаду, сидеть в засаде» > удм. *пыс-* < башк. *бŏс-,* нуг. *пыс-*, госм. (һ.б. угыз.), бор. төрки (ДТС: 398) *pus-*, каз., чыгт., аз. *бус-* һ.б. (Радлов IV: 1385, 1864) id. К. ш. ук себ. (ЗДС: 538) **пōзу** «качу, күченеп китү, күздән югалу», урта диал. **пос булу** «тынып калу, тынын да чыгармау». Räsänen 1969: 90 (бик тә төрле сүзләр китерелә).

*Пŏс- < пус* продуктив нигез: **поскын, постырма** (кыпч. телләрендә параллельләре очрый).

**ПОТ I** «пуд» ~ башк. *бŏт,* чув. *пăт*, мар. *пут*, удм. *пут, пуд* id. < рус. (һинд-евр. тамырларыннан). К. **Подаука.**

**ПОТ II** «идол» < уйг. *пут* < бор. төрки (ДТС: 129) *but* ~ фар. *бут* < һинд. *Будда*. Буддизм динендә Будда һәйкәлләрен кою изге эш санала, гыйбадәтханәләрдә күпсанлы Будда сыннары куела. Төрки буддистлар да булган, бу сыннар хәтта Әстерхан тирәләрендә табыла).

К. ш. ук тат. **потханә** < фар. *бутхāнә* > бор. рус. (Срезневский IV: 28) *бутхана* «мәҗүси гыйбадәтханә».

**Пот I** белән омонимлыктан качу өчен **пут** яңгырашын нормалаштырасы иде.

**ПОЧКАК** «кожа с лапок зверья; остатки, вырезки шкуры (после шитья шубы)», себ. **бӧчқақ** «хайванның бот тиресе», **почкак** «пошыйның бот тиресе» (ДС I: 36; Тумашева 1992: 176), Уралда *почкак, пычкак* «ат сыйрагы тиресе – киез итек табанына (башк. *босқақ* – чаңгы табанына) беркетелә» (к. ТТДС I: 343; БҺҺ II: 52) < уйг. *пучқақ* «почкак; мәчесыман вак хайваннарның тиресе», каз., к.-калп. *бушқақ*, кырг., к.-балк. *бучқақ* «сыйрак; җәнлекләрнең аяк тиресе», тув. *бышкак* «почкак» (каз., к.-калп. *пушқақ, пушпақ* вариантлары да бар); кайбер телләрдә бу сүз икенчерәк мәгъ.: кар. *бучқақ, бучхах*, ком. *бучғақ,* чыгт. (Радлов IV: 1863–1864) *бучқақ* «почмак, кырый» бор. чыгт. (Боровков 1963: 112) *бучғақ* «яр; кырый», бор. төрки (МК; ДТС: 119) *bučγaq* «почмак, кырый; өлкә; хайванның аяк тиресе – шуннан аякчу ясыйлар» һ.б. (чаг. к.-балк. *бучхақ* «балак; почмак»).

**Почкак** сүзе һичшиксез **почмак** һәм **почык** сүзләре белән бәйле, ләкин бу бәйлелек катлаулы һәм тикшерелмәгән. Ихтимал, *почкак* < *почык-ак*. Әмма үзб. *бурчак* «почмак» ← үзб., төркм. *бурч, бурҗ* «бөреж, кальга почмагы» (к. **Бөреж**), чаг. ш. ук фар. *бурчгаһ* «кальганың һ.б. почмак турысы». Һәм, гомумән, **почкак** сүзе шул фар. сүзеннән дә килеп чыга ала. Гомумән, *почкак ~ почмак* мөнәсәбәтләрендә контаминацияләр зур роль уйнаган. К. **Почмак, Почык.**

**ПОЧМАК** «угол» ~ чув. *пĕçмех*, мар. (Упымарий: 169) *пусьмак* < уйг. *пучмақ,* башк. диал. *босмақ,* алт. диал., чыгт. *бучмақ,* каз. *пушмақ* «почмак, урам чаты», *пушпақ* «сыйрак тиресе, почмак; тупик, урам чаты», формаль бор. **пучу-мак *бучумак* сүзеннән, **бучу-* фигыленнән; чаг. кар. *бучақ,* ком. *буччак*, госм. *буҗак* >> чув. *пĕçек*, мар. *пусак* «почмак» һ.б. Бор. **бучақ* < *буччақ*мы яисә *бучғақ* < *бучақ-ақ*мы? К. **Почкак, Почык.**

**ПОЧЫК [пŏчŏқ]** «половина; полпуда; курносый, коротконосый» ~ башк. *босок* «пешкәк; почык (борын тур.)», чув. *пăçăк, пăçăх* < уйг., чыгт. *пучуқ,* гом. кыпч., гаг. *бучуқ* «ярты», төр. *bučuk* «өстәмә, ярты», каз., к.-калп. *пушық,* бор. төрки (ДТС: 105) *bïčuq* «ярты», (Радлов IV: 1862) «ярым» бор. төрки *buluŋčuq* «ярты», *buluŋ* «ярты» (*buluŋ batman* «ярты батман», к. ДТС: 124) сүзеннән булса кирәк. К. Räsänen 1969: 85.

**ПОШАМАН, пошайман** > мар. *пушаман* «переживание по поводу случившегося, сожаление, раскаяние», гом. кыпч. *пушайман*, кырг. *бушайман, бушман, пушман* < фар. *пāшӣмāн* (Будагов I: 318). Бу сүз, төрки телләргә күптән үк кереп, төрле вариантларда очрый (кырг. *бушман, бушайман* һ.б.) һәм, ихтимал, *пошайман* варианты бор. фар. яңгырашын чагылдырадыр, к. ш. ук төр. *pişman*, көрд. *pojman [пожман]* «пошаман» һ.б. < бор. фар. *patiš mana* «төшенке уйда» (Paul: 69); Räsänen 1969: 386.

**ПОШКЫР-У [пŏшқŏр-]** «фыркать» к. **Пышкыр-у.**

**ПОШ-У** «огорчаться, переживать» ~ башк. *бош-* id., чув. *пăш-* < уйг. *пуш-* id. (Радлов IV: 1389) ~ к.-балк., ком., кар., чыгт. *буш-*, бор. төрки *buš-* id. (Боровков 1963: 112; ДТС: 127–128). Бу сүзнең дериватлары ешрак кулланыла, к. тат. **пошын-у, пошыргалан-у, пошыр-у** (Будагов I: 282; ТТАС һ.б.). ДТСта күп кенә бүтән дериватлар күрсәтелә.

*Пош-* < *пуш-* нигезен таҗ. диал. *пушидан* «көю, пыску» (нигезе *пуш*), фар., көрд. *пуш, пуши* «коры үлән, кау, ку» белән чагыштырырга мөмкин. Күп кенә төрки телләрдә *пуш-, буш-* фигыле теркәлмәгәнлектән, аны алынма дип уйларга нигез бар. Räsänen 1969: 70.

**ПОШЫЙ, поши**, диал. **мышый, миши** «лось» ~ башк. *мышы* id. > мар. диал. *мыший* ~ чув. *пăши* < мар. *пучо, пучы, пӱчӧ* «болан» ~ удм. *пужей*, манси. *пааши*, коми. *пэж* «яшь болан» > бор. рус. *пыжь* id. (Егоров 1964: 152), шуннан хәз. рус. *пыжик* «яшь болан тиресе». К. **Пыштыр.** Аникин: 461–462.

**ПОШЫК-У (пошыкты, пошыгу)** «заторопиться» ***пош-у** фигыленең интенсивлык формасы. Чаг. ш. ук **ашык-пошык**. Бор. төрки *buš-* «ашыгу» (DLT II: 12), монг. *бушуу* «тиз, җитез».

**ПӨСКЕР-Ү [пөскөр-]** «брызгать ртом» < (кар.) *пүскүр-* id. < **пүрүс-күр-, пүрс, пүрүс* тәкълиди сүзеннән. Чаг. диал. *пөскерт-ү* «җәһәт кенә куып җибәрү».

**ПӨХТӘ** «аккуратный» < фар. < *пухтä, пухтэ* id. төп. мәгъ. «пешкән; өлгергән, пеше» ← *пухтан* «пешү» (һинд-ир. тамыр сүзе).

**ПРАВУР, прубыр** (ЗДС: 540) «проворный, быстрый в действиях» – «елгыр, өлгер» < рус.

*проворен* бугай. Бу сүз (җирле яңгырашларда) күрше чув., фин-угор телләрендә дә кулланыла.

**ПРАКӘНДӘ** иск., кит. «разбросано, в беспорядке (о книгах, о вещах в помещении)» < фар. *пāрäкундä* «парәләргә бүлгәләп, парә-парә итеп» сүзеннән. Бу сүз фар. телендә хәзер сирәк кулланыла; элек тат. теленнән күрше телләргә дә таралган һәм хәзер төрле тат., башк., мар. сөйләшләрендә очрый: *пракәндә булу, пракәндә итү* һ.б. Чаг. **Пәрәкәндә.**

**ПРАН, пыран, быран** (ЗДС: 145, 547) «очень; совершенно; совсем» ~ хак., алт. диал. *пран, пыран* id. Себер төрки, монг. телләреннән булса кирәк.

Дерив.: **пыранный** «бөтенләй» < **пыранлай.**

**ПРАУЛЫК [пра$^{o}$wлы̆к], пыраулык** диал. «переулок» ~ мар., чув. *пралук, пролок*, удм. диал. (Насибуллин: 136) *пэрэулка* id. < рус. *переулок* id.

**ПРИДАН** диал. «приданое» < рус.

**ПРОМ, порам** диал. (Тумашева 1971: 145) «много, обильно», чаг. хак. *прай* «күп, мул; бөтенесе».

**ПУДАЕК [пудайы̆к], подайык** «вид птицы (из сказки)» < кырг. *буудайык,* чыгт., үзб., бор. төрки *буғдайық* id. (төр. мәкальдә: *Эт түрәсе кумайык, кош түрәсе бугдайык*). Чаг. рус. *потатуйка* (этимологиясе ачык түгел, к. Фасмер III: 343). *Бугдайық* «бөркетләр патшасы» угыз кабиләсе *чавулдур*ның герб кошы булган, к. Ögel: 219, 364. К. ш. ук себ. тат. (Будагов I: 284, 321) **пудайчык** «лачын, бөркет», чыгт. *буғдайнақ* «Һомай кошы», ихтимал, иске төрки, монг. *богда, бугда* «Будда (кошы)» сүзеннәндер. Мәзкүр кошның читлектә мәһабәт рәвештә утыруыннандыр.

**ПУЙГАТ** диал. «беременная» (Тумашева 1992: 183), асылда «буйы кат», чаг. як. *хат* «көмәнле».

**ПУЛ I,** диал. **пүл** иск. «монета», диал. «кон, деньги на кону» ~ башк. (БҺҺ II: 50) *бол «*байлык; акча», удм. *пöл* «өстәк» < гом. көнб. төрки *пул, пол* «акча; мал-туар», чыгт., бор. төрки, төркм. «тәңкәнең биштән бер өлеше» (Радлов II: 1371–1372), каз., кырг. *бол, бул* «байлык; бәя», рус. диал. *пул, пуло* «вак акча» («мелкая татарская монета», Фасмер III: 404), фар. *пӯл* < грек. *фолла, фоллис* яки бор. грек. *οβολος* «вак акча; драхманның алтыдан бер өлеше» сүзеннән. Räsänen 1969: 387.

**ПУЛ II** (ТТДС II: 252) «полок, лавка в бане», фар. *пул, пол* «күпер; ләүкә» сүзеннән булса кирәк. К. **Болдыр.**

**ПУЛАТ** «палата, представительное жилище, сооружение», диал. (ТТДС II: 252) «полати» ~ чув. (Ашмарин IX: 276) *пулат, полат*, удм. *полать* < рус. диал. *полата, полати*. Тат., чув. сүзләре рус теленең *о*лаштыручан сөйләшләреннән алынган.

**ПУМАЛА** «помело» > чув., мар., удм. *пумала* id. < рус. Рус. сүзе *помести* «себерү» фигыленнән.

**ПУНАФ** диал. (ЗДС: 542, шрл.) «рулон (бумаги), свёрток, кипа, охапка». Ачык түгел. Чаг. рус. *понява* «озын итәк», ш. ук «яулык, урама, ябулык, пәрдә» һ.б., к. Даль: 505.

**ПУРКИ** «нахлебник, приживал» < төр. *purki* id.

**ПУСТ** иск. «шкура; выделанная шкура» (к. Будагов II: 235) < фар. *пуст* id. Чаг. ш. ук чув. *пус, пуст* «тиен (акча)». Элекке телебездә *пуст* актив кулланылышта булган, к. **Җилпуч, Пустал.**

**ПУСТА, поста** (ТТАС II: 533) «пустошь, невозделанная (заброшенная) земля» ~ венг. *puszta* «буш дала». Бу сүз рус. *пуст*, *пустой* сүзеннән түгел, ә рус сүзе шуннан килеп чыккан шикелле. Башк. (БҺҺ II: 152) *постиш* < рус. *пустыш* > каз. (ҚТДС: 242) *пошташ* «тындырыр өчен, парга калдырылган җир»; рус. *пустошь* «торлаксыз җирләр» (рус. *пуст* тамырыннан күп сүзләр ясалган, к. Даль). Монда чагыштырырлык сүзләр күп: бор. төрки (ДТС: 113) *bos, boš, bōš* «буш», фар. *бустан* «торлактан читтәге бакча» ← *буст* id. һ.б.

**ПУСТАЛ** диал. (Тумашева 1992: 179) «сгиб обуви между подъёмом и голенищем» < рус. *постолы* («сандалии из сыромятной кожи») ~ гом. слав. *постол* һ.б.ш. < төр. *postal, pustal* «яничәриләр кигән башмак» (Будагов II: 321) – *post, pust* «тире, күн» сүзеннән. К. **Пуст.**

**ПУТА** «широкий пояс, карниз дома (снаружи)» > мар. (Упымарий: 161) *пота* «кушак», удм. *путо* < гом. кыпч. *пота,* башк. *бута,* кырг. *пото, бото* «пута; киң шарф» ~ госм. *фота* «буй-буй бизәкле тукыма», төр. *futa* «алъяпкыч, чигүле билбау», фар., иске төр. *fota* > укр., иске рус. *фотá* «туйда кәләшкә кидерелә торган киң бөркәнчек»

> хәз. рус. *фатá*. Төбендә һинд сүзе булса кирәк (к. Фасмер IV: 187). Рус. диал. *путо; путы* «пута» сүзе дә бар (*путы* «тышау» сүзе белән бутамаска!). Иске тат. *фута (мәхәббәт футасын багла билгә…* Утыз-Имәни).

**ПУТАЛ** «поталь, сусальное золото», башк. *бутал* «металл төсле буяу» < фар. *муталла* «алтынланган» ← *ṭиллā* «алтын» (сүз гарәп теле нигезендә ясалган, ләкин аның тамыры фарсыча), чаг. госм. *путалумба (< путал-умбра)* «сары буяу» (к. Радлов IV: 1360). Рус. *поталь* грек теленнән дип хисаплана (Фасмер III: 343), ләкин грек сүзе үзе фарсычадан булса кирәк. К. **Теллә.**

**ПУТМАР I, путемар**, диал. (ТТДС I: 310, 346) **муйтымар, мыйтымар,** в XVIII веке (Крюкова Т.А. Коллекция П.С. Палласа по народам Поволжья // Сборник музея антропологии и этнографии АН СССР, Т. XII. М., 1949: 158) **бутьмар, муйтемар** «амулет, обычно носимый на перевязи через плечо у женщин» < *буй томар* «буйга, гәүдәгә асыла торган томар», к. **Томар.**

Үзбәк һәм таҗикларда *куштомар, култыктомар* һ.б. томарлар булган, к. Ершов Н.И., Широкова З.А. Альбом одежды таджиков. Душанбе, 1969: 25 һ.б.

**ПУТМАР II, путемар**, диал. (ТТДС I: 342, 347) **покмар** «шкаф для посуды, верх которого служит кухонным столом» ~ чув. *путнар,* удм. *бутьмар,* морд. *потмар* id. Чув. ш. ук «сәке; табигый чикләре булган урман кишәре» (Ашмарин X: 49). Табышмаклы сүз: рус. *поднары* сүзеннән дип аңлату мәгънәсенә тәңгәл түгел.

**ПУФ** – подражание шумному выдоху – типологик тәкълиди сүз (дөньяның барлык телләрендә бар).

Дерив.: **пуф-пуф; пуфла-у, пуфылда-у.**

**ПУШКА** «пушка» < рус. < ним. *Buhsa, Buchse* «мылтык» сүзеннән дип карала (Фасмер III: 415); *пущать* «ыргытып җибәрү» сүзеннән дигән фараз да бар (ул вакытта *пушка* < *пущка* сүзенең тәүге мәгънәсе – «туп, ядрә»). Ниһаять, к. бор. монг. *вии* < кыт. *пао* «пушка» (ССТМЯ I: 35–36) Алтын Урда монголларындагы **пууһ* «пушка» сүзеннән рус сүзе дә килеп чыга ала, чаг. ш. ук төр. *buş* «пушка». Әйтергә кирәк, XIV–XVII гг. дөньяда иң яхшы пушкаларны төрекләр ясаган.

**ПҮЛӘН** «полено» < рус. (рус телендә *пламя, полымя* «ялкын», *пылать* «ялкынлану» сүзләре белән кардәш дип карала, к. Фасмер III: 308). Чаг. ш. ук чув. *пуленке* «пүлән».

**ПҮНӘТӘЙ** «понятой» < рус. (XIX г. ук кергән).

**ПҮПӘЛӘ-Ү** «калякать; говорить с трудом (из-за незнания языка или болезни)» ~ чув. *пупле-* «әңгәмәләү, гәп сату», мар. *попаш* «әйтү, сөйләү», *попылаш* «юкны сөйләү». Тат. сүзе мар. яки чув. теленнән булса кирәк. Чув., мар. сүзләре Урта Азия телләреннән бор. алынма булырга мөмкин, к. уйг. *бапла-* (үзб. *бопла-*, кырг. *бапта-*) «оста сөйләп алдау; нәрсәне дә булса шәп эшләү». К. **Бап.**

**ПҮЧТӘК** «пустяк, пустяки» < рус.

**ПЫЖЫ-У, пожы-у** «преть; тлеть; киснуть; смягчаться (от залежности)» ~ башк. *быжы-* id. ← **пыж (пыж-ж)** тәкълиди сүзеннән (**пыж-ж-** яки **пыжжы-**), к. **Пышлык-у.** Чаг. **Пәҗе-ү.**

Бу сүз тат. теленең үзендә *ж* авазы урын алгач килеп чыккан булса кирәк.

**ПЫЛАУ [пы̆law]** «плов» < фар. *пилав, палов* id. Будагов I: 318. Рус сүзе төрки телләрдән бугай. Бу сүзне грек. *полиав* «күпкомпонентлы» сүзеннән дигән фикер бар. Имеш, аны Искәндәр Зөлкарнәйн солдат ашы итеп тәкъдим иткән ди.

**ПЫЛТЫРА-У** «рассеяться, растрепаться» ← *пылтыр* ← *пылт//пелт* тәкълиди сүзеннән.

**ПЫР,** диал. **фыр: пыр туз-у** «быть разбросанным; бурно возмущаться» ~ чув. *пăр*, гом. кыпч. *пыр* id. Шуннан ук *пыр-пыр (очу)* «тиз-тиз канат кагу», *пырыл-пырыл (килү)* «очу, канат кагу тур; пропеллер әйләнүе тур.» ← *пырыл*; **пырылда-у, пырылдык.** Гом. төрки характердагы сүз. К. ш. ук **Пыран.**

**ПЫРАН I** «в разгромленном виде» > удм. *бырон* «һәлакәт», шуннан ук **пыран-заран, пыранла-у** «шаулап тиргәнү (хатын-кыз тур.)». **Пыр** тәкълиди сүзеннәндер, чаг. ш. ук фар. *феран, фераран* «бар көчкә качып».

**ПЫРАН II** к. **Пран.**

**ПЫРГЫ** «насос» < **пырғы-ғы* ← диал. **пыргы-у** «фонтан булып сиптерү», **пыргы-т-у** «агым

ясау». Тәкълиди нигездән, чаг. **Пыр, Пырых** һ.б.ш. Тат. теленең үзендә барлыкка килгән.

**ПЫРДЫМ** «такт, порядочность (в разговоре)» < рус. *пардон* (?, чаг. *пырдымсыз* – рус. *беспардонный*). Чаг. ш. ук фар. *пордейн, пордайун* «тайярлык белән тулы, бик тә әдәпле».

Дерив.: **пырдымлы, пырдымсыз.**

**ПЫРЫХ: пырых итү, пырых-пырых көлү** «прыскать (от едва сдерживаемого смеха)» – тәкълиди сүз. К. ш. ук **пырхылда-у** шул ук мәгъ., **Пыргы.**

**ПЫСКЫ-У** «шипеть (о сырых дровах в огне); гореть с дымом (о лампе); тлеть» ~ башк. *быскы-* id. ← *пысс* төрки телләрдә киң таралган тәкълиди сүздән; чаг. **Поскы-у.**

**Пыскы-** продуктив нигез: **пыскый (лампа)** «сукыр лампа»; **пыскыт-у** «тәмәке тарту» һ.б.; диал. **пыскылда-у.**

**ПЫТ** – подражание треску, **пыт-пыт** – подражание отрывочкам-трескам мотора; шуннан төрки телләрдә күп кенә тәкълиди характердагы сүзләр ясала; тат. **пытырт, пытыр-пытыр, пытырда-у; пытырдык** «мотоцикл»; **пытылда-у** «бытылдау» һ.б., каз. *пытырла-*, үзб. *питирла-* «пытырдау». К. түбәндәгене.

**ПЫТЫМЫР** «человек, который всё время говорит про себя; дух, который говорит в тишине» ~ башк. (БҺҺ III: 46) *бытымыр* id. ← **Пыт** (к.).

**ПЫТЫР-У** диал. (ТТДС I: 350), дөресрәге **пӧтра-у** «взбаламутить» ~ чув. *пӑтра-*, мар. *пудра-* (*пудран-* «болгану») id., морд. *бутрав* «болганчык» ~ төркм. *пытра-* «тузу, таркалу». К. ш. ук чув. *патранчӑк*, мар. *пудранчык* «болгавыр» < тат. **пӧтранчык*. Гом. төрки нигездән булса кирәк.

**ПЫЧАК,** диал. **пыцак** «нож»; *п*-варианты: каз., к.-калп. *пышақ,* алт. *пычак*, уйг. *пичақ,* үзб. *пичоқ,* хак. *пычах*, төр. диал. *pіcak, pıcak*, *б*-варианты: куман., ком. *бичақ,* башк. *бысақ,* кырг., чыгт., госм., алт. диал. *бычақ,* тув. *биҗек*, як. *быһак*, бор. төрки (ДТС: 104) *bïčaq* id. ← *пыч-, быч-* «кисү», бор. вариант **бычғақ* булырга тиеш. К. **Пыч-у.**

**Пычак** сүзе барча күрше телләргә (рус теленә төрле яңгырашларда ике тапкыр, к. Аникин: 447) кергән.

**ПЫЧКЫ** «пила» > удм. *бычкы, бызгы, пъскъ* (Насибуллин: 135), мар. *пыс'ке, пичке* (Исанбаев 1978: 40), чув. *пӑҫкӑ* (чув. диал. *пычӑкӑ, пӑчӑк*) < гом. төрки *бычкы* id.; *п*-варианты: нуг., каз., к.-калп. *пышкы*, үзб. диал. (ЎХШЛ: 221) *пычқы,* *б*-варианты: башк. *бысқы,* кырг., алт. *бычқы,* төр. *bıçkı,* бор. төрки *bïčqu* (к. Боровков 1963: 105), *bïčуu* (ДТС: 105) «пычкы; кылыч» ← *пыч-, быч-,* к. **Пыч-у.**

**ПЫЧРАК** «грязный; грязь» ~ башк. *бысрақ* id. < к. **Былчырак**, ш. ук **Пычра-у.**

**ПЫЧРА-У** «загрязниться» < *пылчыра-*, к. себ. (ДС I: 151) *пылчақ* ~ тув. *былчак* «чиләнеп торган; пычрак», каз. *былшық (< былчық)* «күздәге эрен», үзб. *билчилла-моқ* «былчырау, баткаклану». Сүзнең тамыры бор. төрки *бал//был* «сазламык; сыеклык», шуннан *балчы-//былчы-* «сазлану, балчыклану» (шуннан *балчы-ғ* «балчык; пычрак»), арытабан *балчы-ра-//былчы-ра* фигыле ясалган (*-ра* көчәйткеч кушымча, к. *җәй-* → *җәйрә-, кый-* → *кыйра-* һ.б.). *Былчыра-* > *пылчыра-* бор. уйг. тәэсирендәге телләрдә пәйда булган. К. ш. ук **Пычыргы.** ЭСТЯ VII: 102–105.

**ПЫЧТЫР: пычтыр-пычтыр** – подражание хлюпанию, звукам работы с водой ← *пыч//пач* тәкълиди тамырыннан, к. ш. ук **пачтыр, пычтыр-пычтыр, пычтырдау, пычтырдык** (к. ТТАС) һ.б.

**ПЫЧ-У,** диал. (Тумашева 1992: 173, 181) **пыц-у, пец-ү,** (ТТДС II: 255) **пыс-у** «пилить, резать; кроить» ~ башк. *быс-ыу* id. < гом. төрки *быч-, бич-, пыч-, пич-* (дүрт фонетик вариантта) «кисү, кисеп чыгу» (гомуми мәгънә); Э.В. Севортян буенча, бу сүз **бы-чы-** (алт. *бычы-*) вариантыннан редукцияләнеп килеп чыккан (к. ЭСТЯ II: 158–161) һәм асылда бор. *бы-, би-* «кисү» (*би* «үткен нәрсә») сүзенә интенсивлык кушымчасы *-чы//-чи-* ялганып ясалган нигез. Тат. әд. телендә палаталь *печ-* һәм веляр *пыч-* мәгънәләре шактый кискен рәвештә аерымлана (к. **Печ-ү**). Бу хәл һәм, гомумән, әлеге дүрт фонетик вариантның таралыш үзенчәлекләре тарихи җәһәттән аңлату сорый. К. ш. ук **Без II, Беләү.**

Дерив.: **пычыл-у, пычыш-у, пычтыр-у;** к. **Пычак, Пычкы.**

**ПЫЧЫРГЫ** «загноение, гнойная рана, гнойный лишай» < диал. *пылчыргы* id. *пылчыра-//былчыра-* фигыле белән тамырдаш, к. **Пычра-у.** Башк.

(БТДҺ: 67) *бысылқы, бысылдақ* «чиләнеп торган, күбекле» һ.б.ш. Чаг. ш. ук бор. монг. *bilčirqai* «биз, пычыргы» (төрки телләрдән), чув. *пыччи, пыччă* «пычыргы».

**ПЫШ (пыш-ш), пош** – подражание звукам струи воздуха, күч. шёпоту; шуннан күп кенә сүзләр ясала: **пыш-пыш** (сөйләшү), чаг. **пыш-пыш, пышкыр-у ~ пошкыр-у; пышык-пышык** (елау) һ.б. (к. ТТАС II: 565). **Пыш ~ пош** тәкълиди сүзе (һәм охшашлары) барча төрки телләрдә очрый һәм бүтән телләрдә дә бар, чаг. **Пуф.**

**ПЫШАТАН** (ТТДС II: 351) «лапти из обрезков кожи, шкуры» к. **Пыштыр, Пышым.**

**ПЫШКЫЛДА-У** «сопеть, посапывать (носом); шипеть». Прицеипта бу сүз **пышкыл, пышкыл-пышкыл** тәкълиди сүзеннән ясалган булырга тиеш, ләкин ул гипотетик сүз беркайда да теркәлмәгән бугай. ***Пышкыл** нигезе **пыш** тәкълиди тамырга мөнәсәбәтле.

**Пышкылдау** нигезенең гом. кыпч. параллельләре дә бар, ләкин бүтән төрки тел сүзлекчеләре дә андый сүзләргә игътибар итмиләр.

**ПЫШКЫР-У, пошкыр-у,** диал. **фышкыр-у** «фыркать; пыхтеть» > удм. диал., мар. *пышкыр-,* башк. *бошқор- – пыш, пош* һ.б.ш. тәкълиди сүзеннән, бу сүз исә киң таралган (төрки, фин-угор телләрендә еш очрый). Кр.-тат. (Dobr. III: 52–53) *pısqır-,* гом. кыпч. *пышқыр-,* каз., к.-калп. *пысқыр-,* төр. *fişkır-* «пышкыру» бер яктан *мыш-мыш, мышкылда-у* сүзләренә, икенче яктан диал. *пых-пых, пыхылда-у*ларга ялганып китә. Чаг. ш. ук рус *пыхать, пышать, пыхнуть, пыхтеть* «еш-еш, тавышландырып сулыш алу». К. түбәндәгеләрне.

**ПЫШЛАК** «брынза, овечий сыр», күч. «хилый (от значения “рассыпчатый”)» > мар. *пышлак,* чув. *пăшлак* «пешеп бетмәгән, өлгермәгән; хәлсез, зәгыйфь» < гом. кыпч. *пышлақ,* алт. *пуштаг,* тув. *пыштақ,* хак. *пыслак,* алт. диал. *пыстак,* башк. *бышлақ* ~ монг. *бислаг,* калм. *башлиг.* Ачык түгел. Чаг. каз. диал. *пыш болу* «өлгермичә калу» (ҚТДС: 273). ЭСТЯ II: 162 (Э.В. Севортян **пыш-у** сүзе белән багламакчы). Рус. *бышлак, быштак, пыштак* тур. Аникин: 462; ЭСТЯ VII: 122–123.

**ПЫШЛЫК-У (пышлыкты, пышлыгу)**, диал. **пышык-у** «преть; задыхаться» ← *пышы-у, пыжы-у* (к. **Пыжы-у**) фигыленнән интенсивлык формасы, чаг. чув. *пăчă* «бөркү», *пăчăх* «пышлыгу; пыжу», *пăчлан-* «бөркүләнү», үзб. *бижғи-* «пышлыгу». Тәкълиди тамырдан.

**ПЫШТЫР, поштыр** «кожаные онучи» < **пошый тире.* Чаг. **Ыштыр.**

**ПЫШ-У**, диал. **пеш-ү** «взбалтывать, взбивать (кумыс), сбивать, пахтать (масло)» ~ гом. кыпч. *быш-*, башк. *беш-,* уйг., алт. *пыш-*, алт., тув. *быш-* > алт. диал. *пиш-, биш-* һ.б. id. Ихтимал, ир. *pix-, pax-* id. ~ рус. *пахтать* сүзе белән тамырдаштыр.

**ПЫШЫМ, пошым, пышый, пышыт** (ТРС II 2007: 170; БҺҺ II: 195) «обувь с кожаной подошвой и матерчатым верхом» ~ рус. *поршни, поршень* id. сүзе белән тамырдаш.

**ПЫЯЛА** «стекло, стеклянный» < фар. *пийāлä* «фарфор савыт; пыяла савыт, чынаяк» сүзенә тоташа. К. **Пияла.**

Дерив.: **пыялалы, пыяласыз** (төрле мәгъ.); **пыялалан-у** (күз тур. «хәрәкәтсезләнү») һ.б.

# Р

**Р** авазы сүз башында гом. төрки телдә кулланылмаган һәм тат. телендә дә соңрак кына кулланыла башлаган (аерым сөйләшләрдә XX г. рус теленнән алынган сүзләр тәэсирендә генә карарлашкан).

**РАББЕ, раббы** «господь» < гар. *рабб* «раббе; тәрбияче» ← *рбб* «тәрбияләү». Шул ук тамырдан яһ. *раввин* «рухани» сүзе ясалган.

**РӘВАН, раван, рауван** кит. «прошедший, ушедший» (*рәван заманнар* «кайткысыз үтеп киткән заманнар», *рәван гомер* «тиз үтеп киткән гомер», диал. рәвеш мәгъ. «быстренько, немедленно» (*рәван тотып* «приниматься за дело сейчас же») < фар. *päwān* id., бор. ир. *raw-* «агып китү, тиз агу» нигезеннән. Төрки телләрдә *päwan, pawan* сүзе төрле мәгъ. кулланылып килгән, к. Будагов I: 597; ҠТДС: 275. К. **Рәвеш.**

Фразема: **рәван җан** «үлгән кешенең үз йортына, өенә кайтып йөри торган җаны, өрәк» (күч. мәгъ. «бик арык кеше; үлмеш затларның тынгы тапмаган рухы тере кешеләрнең тормышына тыгылулары тур. күзаллаулар борын-борынгыдан килә, к. шумер. *этемму* «рәван җан»; к. **Зая**); **рәван юл** «ачык юл, барып җиткәнче тукталышсыз юл», «хәерле юл сезгә» мәгъ. дә кулланыла. Иск. тат. әд. **рәwан булу** «озын юлга чыгу», ш. ук «үлү».

**РАЗ I** иск., кит. «тайное желание; исповедь; сокрытая правда о чём-либо» < фар. *раз* id. **Рази агяһ** «беленгән сер». **Разыңны сөйләү** «сер; сереңне сөйләү».

**РАЗ II** сөйл. «если так, то…» ← рус. сөйл. *раз* id. Шарт фигыльне көчәйтү өчен әйтелә, мәс., *раз башлагансың икән, тәмамла!*

**РАЗЕ**, **рәҗе, рәҗи, рәйе** (ЗДС: 550, БРҺ) «разве». **Рәйе** яңгырашы әлбәттә, турыдан-туры русчадан түгел, ә тат. сөйл. **рәҗе**дән килә (*җ* > *й*). Кызыклы күренеш.

**РАЗЫЙ** «согласный» (в отличие от *риза* «согласен») к. **Риза.**

**РАМАЗАН** «месяц рамазан » < гар. *рамäḍан* id. (түбәндә – «эссе ай»).

**РАПАТ** – топоним – название татарской деревни (Западный Башкортостан) и горы около села Темяс (Восточный Башкортостан) ~ себ. тат. (Будагов I: 584) **рибат** «кышлау (зимовка)» ~ каз., кырг. *ырабат*, уйг. *рабат, рауат*, бор. төрки (ДТС: 476–477) *rabat, ribat* < гар. *räbāṭ, рибāṭ* «кәрвансарай; юллар чаты» ← *рбṭ* «төйнәү, чатлаштыру».

**Рабат** сүзе Евразия һәм Африкада киң таралган топоним, мәс., Мәскәүнең *Арбат* районы (к. Добродомов И.Г. Рабат // Тюркология, 1992, № 2: 46–54), Мароккода *Рабат* шәһәре, Кырымдагы *Арабат* кырачлыгы һ.б.

Безнең *Рапат* турыдан-туры гар. сүзеннән түгел, ә бор. рус. (к. Фасмер III: 502) *ропать* «мәчет, мәҗүси гыйбадәтханә» сүзеннән (бу сүз исә Византия грекчасындагы ῥαπάτιον вариатыннан) булса кирәк. Ләкин *рапат* (интервокаль *-п-*) варианты уйг. яки себ. тат. сөйләшләрендә дә килеп чыга ала.

Башк. сөйләшләрендә (БРС 1996: 512, БТДҺ: 407) *рапат* «кирт, бирт», *ырапат* «агач куышы, агач орысы» тәүдә «юл чатындагы юламан (юл күрсәтүче) шалашы» булган бугай. Бу сүзләр дә уйг.-себ. вариантларына ишарәлиләр. К. ш. ук Фасмер III: 502.

**РАС** «верно; верный, правильный» > мар. *рас, раш* id. < фар. *раст* < бор. ир. *rasta* id. ~ лат. *restus, rectus* «туры, төз» (һинд-евр. **reg* «турылау, көндерү, режимлау» тамырыннан). К. Будагов I: 586.

Дерив.: **раслык; расла-у; раслама.**

**РАСХУТ** сөйл. «расход, расходы» ~ мар., удм. *роскот, раскот*, чув. *расхот* id. һ.б. < рус.

**РАУДА [раºwда]** (ЗДС: 351) «перекладина в комнате» – удм. сүзе булса кирәк.

**РАУЗА [раºwза]** иск. «райский сад; цветник», күч. «город Медина, где находится могила пророка Мухаммеда», к. Ясәвидә (107 хикмәт):

*Ният кылдым Кәгъбәгә –*
*Хак Мостафа раузага…*

**Рауза** сүзе турыдан-туры гар. *rawḍa* «гөлбакча, изгеләрнең, бигрәк тә Мөхәммәт пәйгамбәрнең кабере» сүзеннән. Шул ук мәгъ. бу сүз барча мөселман халыклары телләренә, шуннан грек теленә, аннары лат. теленә һәм барча Европа телләренә алынган (монда хәчтерүшләрнең Шәрык походлары роль уйнаган. Шуннан бик күп яңа нигезләр – рус. *роза, розан* ясалган. Рус., укр., Д. болг. *рожа* «ямьсез кызыл бит» (ш. ук авыру атамасы) да шуннан икән.

Гар. *rawḍa* нигезенең күп. формасы *рийāд*, шуннан кеше исеме **Риазетдин** (**Разетдин** дип кыскартыла). Гомумән исә бу сүз иран телләрдәге *raoč* «нур» (к. рус. *луч*) тамырыннан килә диләр. Будагов I: 599; Фасмер III: 495; Kluge: 770–771; Тимергалин: 377–378. К. түбәндәгене.

**РАУШАН [paᵒwшан], рушан** «ясный, светлый, лучезарный» < фар. *rawшäн, rawшāн* < авест. *raočanh* «якты көн» (Platts I: 665): *raoč* (~ рус. *луч*) «нур». Тимергалин: 380.

**Раушан(а)** ялгызлык исем буларак бик бор. заманнарда ук кулланыла башлаган, Искәндәр Зөлкарнәйннең (б.э.к. IV г.) чибәр хатыны – фарсы мәликәсе **Роксана** ~ асылда тат. **Раушана,** шуннан гарәпчәләштерелгән **Раушания**. Шул ук бор. ир. *raoč* сүзенә **Рөстәм** исеме дә тоташа («нурлы баһадир» мәгъ. булган).

**РАШКЫ,** диал. **ырашкы** «мокрый снег (осенью); осенние заморозки» ~ мар. *рашкэ* «карлыяңгырлы көн, көн бозылу», чув. *рашкă* «рашкы» (Ашмарин X: 285). Ачык түгел. Ихтимал, бор. рус теленнәндер, чаг. рус. *разить* ~ чув. *раш латтар* «юкка чыгару (игеннәрне)».

**РАШТУА [paᵒштуwa]** «рождество» < рус. ~ чув. *раштав,* мар. *рашта* id. Рус. *рождество* – Гайса (Иисус) пәйгамбәрнең туган көне бәйрәме, Тукай әйткәнчә, «рус мәүлүде». К. Фасмер III: 493.

**РӘ** – не очень большая (50–60 км длиной) река в Западном Башкортостане. Бу елга атамасы бор. ир. ядкәрләрдән билгеле *Ра, Рау* «агым, идел, Идел-Волга» сүзенең «адашы» түгелме икән? **Рә** Ыкка коела, **Ык** исә шулай ук (к. түбәндә) «агым» дигән сүз.

**РӘВА [рәwa]** иск. (в жаргоне шакирдов) «позволительно, неплохо, можно и …» (мәс., *мәхәббәткә дәва – кыз урласаң, рәва*) < фар. *рäвā* < авест. *rauuah* «ирек, иркенлек» ~ рус. *равн-//ровн-* (*равен, равно, ровно* һ.б.) «тигезлек, тиңлек» һинд-евр. **reu* тамырыннан, шуннан ук герм. *ruum* «киңлек», лат. *rūs* (*ruus*) «авыл җире» һ.б., к. Kluge: 747.

Сүз уңаеннан: *рус* сүзен лат. *rūs* «авыл җире, авыллык» дигәннән дипраслауны телчеләр яратмый.

**РӘВЕЗ, ривиз** иск. «ревизские сказки» < рус. Элек 10–12 ел саен бер тапкыр ревизия ясап, ирзатлар санын исәпкә алып, шуларның мәгълүматлары (*сказки*) буенча җирләрне кабаттан бүлешкәннәр.

**РӘВЕШ [рәwĕш]** «образ (действия); наречие; вид» < фар. *рäwиш* «агым; йөреш; йөреш-торыш». К. **Рәван, Рә.** Будагов I: 599; Platts I: 603, 605.

Дерив.: **рәвешле, рәвешсез; рәвешчә.**

**РӘГЫЯТЬ [рәғийәт]** «подданный; райя, неосновное население государства» < гар. *ра'ийäт* id., төп. мәгъ. «көтү, талпа», **Ригая** сүзе белән (к.) тамырдаш. Будагов I: 593, 594.

**РӘДД, рәдде** кит. «опровержение; отрицание, отказ» < гар. *радд* id. (Будагов I: 591). К. ш. ук иск. **Рәддия** «рәдд итүгә багышланган хезмәт, нотык; юридик яклау». Бу сүзләрне кайтарасы иде.

**РӘДИФ** «редиф, слово в стихе, повторяемое после рифмующихся слов» < гар. *радūф* id. түбендә «ат өстенә икенче кеше булып атланган солдат; иярчен» (Будагов I: 591).

**РӘЕШ [рәйĕш]** «наряд; наряды; украшения (на зданиях и т.п.), отделка», чув. *эреш*, мар. *ĕрĕш* id. < фар. *āрāйеш* id. ← *āрāстāн* «бизәнү; төзәтенү», *раст* «рас» сүзе белән тамырдаш (Paul: 4).

Дерив.: **рәешле, рәешсез; рәешлән-ү.**

**РӘЗЕ, рәже, әрәйе** диал. (Махмутова: 248; ТТДС I: 517) «разве» к. **Разе.**

**РӘИС** «председатель» < гар. *ра'ūс* id. ← *ра'äсä* «башчылык итү» ← *ра'с* «баш».

**РӘЙХАН** «базилик» (душистое растение) < гар. *райхāн* id. ← *рwх* «сулыш; хуш ис, җиләс җил» тамырыннан, шуннан ук к. **Рәхәт, Рух.**

**РӘКӘГАТЬ [рәқәғәт]** «цикл определённых словословий и движений в намазе» < гар. *ракä'āт* id.

← *рк‘* «баш иеп сәламләү», шуннан *рөкүгъ* «баш ию жесты».

**РӘКЫМ** «любой письменный знак (буква, цифра, ноты и т.п.)» < гар. *рақм* id. Будагов I: 595.

**РӘКЫС** «танец» < гар. *ракҫ* id. Тимергалин: 376.

**РӘМЕЛ** иск. «гадание камушками; вид стихотворной стопы» < гар. *рамл* id. Тимергалин: 379.

**РӘНЕК, рәң** (ГТРС: 486) «оттенок», диал. (ТТДС I: 554; БТДҺ: 417) **эрәнке, өрәнке** «приличный вид» ~ чув. *ĕренкĕ, йĕренкĕ, йеренке* id. < фар. *рäң, раң* «төс». Төрки телләрдә еш очрый, к. Özön: 708; Федотов I: 155–156.

**РӘНҖЕ-Ү** «оскорбиться», диал. «быть раненым» ← иске *рәнеҗ* (себ. *рәнец,* к. Тумашева 1992: 182) «каргыш, үпкә, кинә» < фар. *рäнҗ* «яра; газап; кешегә яра ясау» (санск. теленнән). К. ш. ук (ТТДС II: 258) *рәнҗү* «авыру; яралы».

**Рәнҗе-** продуктив нигез: **рәнҗеш-ү, рәнҗет-ү, рәнҗеш; рәнҗүле, рәнҗүсез.**

**РӘСӘЙ, Рәчәй** иск., диал. «Россия; страна, государство» (без бәләкәй чакта надан халык «дөньяда күп *рәчәйләр* бар» дип сөйли иде; ихтимал, бу мәгънә бик борынгылыктан киләдер). Рус. *Рассéя* (гади сөйләм әйтелеше) сүзеннән. Кайбер рус тикшеренүчеләре рус *Россия* топонимы *Русь* «рус иле; руслар» сүзе белән баглы түгел, дип тә язгалыйлар. Гомумән, *рус, Русь, Россия* сүзләренең чыгышы-ясалышы бәхәсле (тикшеренүчеләрнең күпчелеге бу сүзләрне бор. варяг ~ швед теленнән дип баралар, к. Аникин: 467–468). К. ш. ук Фасмер IV: 855. К. **Урыс.**

**РӘСЕМ** «рисунок, изображение; контур; план (действий)» < гар. *расм* id. *рсм* «рәсемләү» тамырыннан, шуннан (гар. теленнән турыдан-туры) **рәсме хат** «язу рәвеше»; **рәсми** «официаль» (→ **рәсмият**), **рәсмән** «официаль рәвештә». К. ш. ук **Мәрасим, Рәссам, Тәрсим.** К. ГТРС: 487; Будагов I: 592; Özön: 708–709.

Дерив.: **рәсемле, рәсемсез; рәсемлә-ү; рәсемче.**

**РӘССАМ** «художник; рисовальщик» < гар. *рäссāм* id. К. югарыдагыны.

Дерив.: **рәссамлык, рәссамчылык.**

**РӘСТӘ** иск. «сведение счётов; закрытие счёта» < фар. *рäстä* id., төп мәгънәсе «котылыш». Özön: 709.

Фразема: **рәстә кылу** «эшләрне (постны) тапшыру».

**РӘСҮЛ** «пророк, посланник Бога» < гар. *расӯл* id. ← *рсл* «хәбәр итү; күктән төшү, яву». Шуннан ук к. **Рисалә.**

**РӘТ** «ряд; раз; толк, возможность», диал. **эрәт** ~ чув. *ĕрет*, мар. *рäдэ,* удм. *рäт, рад* id. Бу сүз артында ике этимон тора: рус. *ряд* һәм добр. тат. *рәт, рәәт, рәһәт* «җиңел, кулай, рәхәт» (к. **Рәхәт**). **Рәт** сүзенең продуктив нигез булуы да шуның белән аңлатыла, к. **рәтле, рәтсез, рәтлә-ү, рәттән**. Чаг. добр. тат. *retlen-, ratlan-* «ял итү, юнәю, рәтләнү», төр. *rahatsız* «тынычсыз, рәтсез»; нуг., каз., к.-калп., үзб. диал. (ЎХШЛ: 225) *рет*, кырг. *ирет* «рәт» һ.б. татарчадан булырга мөмкин.

**РӘФӘНДЕ** «Рефанды» – название старинного селения на севере Башкортостана – иске тат. («Мәҗмугыль-хикәят» телендә еш очрый) **рәвенде** (*рәwәнде, рәwәндә*) «сәяхәтче, юлаучы, юлчы» сүзеннән булса кирәк: тәүдә шунда *рәвәндәләр өе* – кунакханә булгандыр (чаг. **Рапат**). *Рәвәндә* үзе фар. *рäwäндä* «узгынчылар» сүзеннән килеп чыккан. К. **Рәван.**

**РӘХӘТ** «наслаждение; блаженство; удобно, легко; удобный, легкий; счастливый» > мар., удм. *рäкäт*, чув. диал. *раххать* (Сергеев 1971: 54) < гар. *рāхäт* id. ← *pwx* «җиләс җил исү, ял итү» тамырыннан, шуннан ук к. **Рәйхан, Рух, Тәравих.**

**РӘХИМ** «милость» < гар. *рахӣм* id. ← *рхм* «йомшару»; шуннан ук **Мәрхәмәт, Рәхмәт.**

**РӘХМӘТ** «спасибо; благодарность» > мар., удм. *ракмат, рахмат*, чув. *рехмет, ĕрехмет* id. *Рәхмәт*, гомумән, «рәхимлелек, рәхимле ярдәм» дигән сүз, «изге теләк әйтем» мәгънәсе *сиңа Алланың рәхмәте булсын* дигәннән эллипсис. Чаг., үлгән кеше тур. «*Алланың рәхмәтендә булсын*» диләр.

Дерив.: **рәхмәтле, рәхмәтсез.**

**РӘШӘ**, диал. (ТТДС I: 391) **эрәжә, эрәшә, әрәшә** «марево, сизая дымка (на горизонте); мираж» > мар. *рäшä, ĕреше, эрежä,* удм. *ӧрешо, решо* id. Н.И. Ашмарин буенча, рус. *ржа* «коры томан»

сүзеннән (шуннан ук тат. диал., башк. *ыраша, ыржа* «рәшә» (к. ДС II: 251; ДС III: 198; БТДҺ: 407). Ләкин немес тюркологы Б. Шернер күрсәтүенчә (к. CAJ, V. XVI, № 3, 1972: 234), тат., башк. *рәшә* фар. *раш* «су ялтыравы» (дөресрәге *рашһа* «су ялтыраулары») сүзеннән дә килеп чыга ала.

**РӘШМӘН** (трбс.), диал. **эрәшмән, әрешмән** (к. Ватаным Татарстан, 7.2.1995) «вид паука» ~ чув. (Сергеев 1971: 62) *ĕрешмен, йерешмен, решме* < мар. *эҥгĕрäшмäн, эҥгерäмшäн, эҥгырамыш* id., ш. ук «үрмәкүч тозагы». Чаг. ком. *эришме* «йөгән, тезген»; фар. *рūсмāн* «паром арканы» > госм. *rešta* > серб., рус. диал. *решма* «йөгән». Räsänen 1969: 389.

**РИВАЯТЬ [риwайәт]** «предание» < гар. *рuwāйäт* «хикәяләү, кыйсса» ← *рwй* «сөйләү». Шуннан ук тат. **рави** < гар. *рāwu* «хикәяче».

**РИГАЯ [риғайә]** «соблюдение (законов), уважение (к старшим)» < гар. *ри'āйä* id. ← *р'й* «көтү көтү; сабыр итү» тамырыннан. к. **Рәгыять.** Будагов I: 594 (тәфсилле).

**РИДВАН, ридуwан, ризыwан, ризwан, ырындуван** (ЗДС: 551, 799) «крытая телега» < рус. *рыдван* «көймәле зур арба» (XIX г. киң таралган булган) < ним. *Reisbahn* «сәяхәт арбасы» Бу сүз күп телләргә алынган.

**РИҖА** иск., кит. «нижайшая просьба» < гар. *рäҗā* id. **Риҗа итү** «үтенеп сорау» (еш кына дәрәҗәле, югары торган кеше, үзен гүяки түбән куеп, шул сүзне кулланган).

**РИЗА** «доволен (малым)», «согласен» < гар. *риḑа* id. *рḑй* «канәгать булу» тамырыннан.

Дерив.: **ризалы, ризасыз; ризалык; ризала-у, ризалат-у, ризалаш-у.**

**РИЗЫК (ризкы)** «хлеб насущный» > мар. *резык, рэзык, рызыҡ* < гар. *ризҡ* id. < пәһл. (бор. ир.) *ročik* «көнлек азык». К. **Рыскал, Ураз, Ырыс.**

Дерив.: **ризыклы, ризыксыз; ризыклан-у.**

**РИСАЛӘ** иск. «трактат» < гар. *рисāлäт* «озын хат», асылда «җибәрелгән (нәрсә)», к. **Рәсүл.**

**РИСВАЙ [рисwай]** «позор; опозоренный» < фар. *рäсwā'и, русwā'и* id.

Дерив.: **рисвайлы; рисвайсыз; рисвайлан-у.**

**РИШВӘТ** «взятка, мзда» < гар. *ришwäт* id.

Дерив.: **ришвәтле; ришвәтчелек.**

**РИЯ [рийа],** диал. **ырыйа** «лицемерие» < гар. *рийā'* id. ← *ра'й* «күрү, күренү».

Дерив.: **риялы, риясыз; риялан-у; риячы; риячыл**.

**РОБАГЫЙ** «рубаи (стихотворение, строфа из четырёх строк, обычно по схеме рифмовки *ааба*); любовная песенка» < гар. *рубā'ū* «дүртле, дүртлек; робагый» ← *рб'* «дүрт булу» тамырыннан.

**РОЗА** «роза» (цветок, растение), а также популярное женское имя собственное < *роза* – Европа телләреннән, к. **Рауза.**

**РОТА** «рота (воинское подразделение)». Бу рус хәрби терминын еш кына төр. *orta* «урта, яничәриләрнең хәрби берлеге» (хәз. рус. *рота* белән *батальон* арасындарак булган) белән чагыштыралар, шуннан килә диләр. Әмма кайбер рус телчеләре моны кире кага. Һәрхәлдә *урта* дигән хәрби берәмлек татарларда һ.б. төркиләрдә *orta* булган (ул берәмлекнең кухнясы бер «уртак» була). Чаг. **Урда, Уртак.**

**РӨХСӘТ** «позволение, разрешение» > мар. диал. *руксäт*, чув. диал. *ĕрескет* id. < гар. *руҳ̣ṣат* id. ← *рҳ̣ṣ* «арзан, җиңел, мөмкин булу».

Дерив.: **рөхсәтле, рөхсәтсез.**

**РӨШДИ** «средний (о школе); семилетний (об образовании)» < гар. *рушдū* ← *ршд* «уртача булу».

**РӨШДИЯ** «средняя школа (в XIX – начале XX века), обычно светская в отличие от **медресе**» < гар. *рушдийä* id.

**РУДА, рауда** (ТТДС I: 354) «шест для развешивания одежды и т.п.» ~ башк. (БТДҺ: 407) *ырауҙа, ырыуҙы, урҙа* id. Ачык түгел. Алынма сүз булса кирәк, чаг. мар. *рудä* «үзәк».

**РУМ** тар. «Византия; византиец» < гар. *рӯм* id. < грек. Будагов I: 599.

**РУМИ** тар. «византийский; византиец» < гар. *рӯмū* id. Асылда грек. *ромэй* «римле» сүзеннән.

**РУХ I** «дух» < гар. *рӯх* id. ← *pwx* «җиңелчә җил (исү)» тамырыннан, шуннан ук к. **Әрвах, Рәйхан,** шуннан ук **рухан, рухлы, рухсыз** һ.б. «Җил ~ рух; күренми торган җан иясе» мәгъ. күчеше интернациональ характерга ия, к. **Җил.**

**Рух-** продуктив нигез: **рухлан-у, рухлы, рухсыз** һ.б. К. **Рухани, Рухи.**

**РУХ II** «мифическая птица огромных размеров (питается слонами)» < гар. *рӯх̣* id. Асылда **Рух I** белән бердәй дип карала.

**РУХАНИ** «духовный; представитель духовенства» < гар. *рӯхāнӣ* id. К. түбәндәгене.

**РУХИ** «духовный; душевный» < гар. *рӯхӣ* id. К. **Рух.** Дерив.: **рухилык,** рус. *духовность с*үзенә тәрҗемә итеп ясалган.

**РЫСКАЛ,** диал. (Остроумов 1976: 109, ТТДС I: 354) **рискал, ырыскал** «счастье, удача; судьба, участь, доля» ~ чув. (Сергеев 1971: 54) *ăрăскал, ăраскал, рăскал* id., мар. (Упымарий: 185) *рыскал* «бәхет» ~ каз., к.-калп. *ырыскал* id. фар. диал., көрд., төркм. *рызгари* < фар. әд. *рӯзг'āр, рӯзг'āрӣ* > иске тат. *рузгяр* «язмыш; көнкүреш; замана» сүзеннән (к. Будагов I: 598). К. ш. ук үзб. *рузгяр,* к.-калп. *рузигәр* «көнкүреш кирәге; көндәлек тормыш», төр. *rüzgâr* «һава хәле; җил» һ.б. К. **Ураз, Ырыс.**

# С

**С** авазы тат. телендә һәртөрле позициядә бор. төрки төркет теленнән килә һәм алынма сүзләрдә дә чыганак телдәге *с* авазы саклана. Башк. телендә (кайчакта гар.-фар. сүзләрендә дә) *с*- > *һ*-. Түбәндә шуны истә тотарга кирәк – башкортча яңгырашлар күрше удмурт, мари телләренә үтеп кермәгән.

**САБА I** «кожаная посуда; бурдюк для кумыса», диал. «маслобойка» < гом. кыпч., алт. *саба*, кырг. *сабаа* ~ монг. *саба*, башк., бур. *һаба* id. (кайбер телләрдә мәгъ. үзгәрешләре күзәтелә). Классик *саба* тур. к. Будагов I: 682. Чаг. ш. ук тув. *сава*, монг. *сав* «савыт; аналык». Хак. диал. *сабан* «савыт», каз., к.-калп., кырг., уйг. *сапал*, үзб. *сопал* «(керамик) савыт-саба». Гомумән – ачык түгел. Рус. диал. *саба* «күн капчык», *сабан* «гөбе», *хаба* «савыт» тур. к. Аникин: 469, 599; ЭСТЯ VII: 126–127.

**САБА II: саба җиле** «зефир, мягкий ветерок» < гар. *сӓбā'* «көнчыгыш җиле», **Саба** «легендар бәхетле ил» сүзеннән (чаг. рус. *Царство сабейское*). Саба иле (Гарәп ярымутравының хәз. Йәмән җирендә була) V г. каты корылык афәтендә юкка чыга, халык шәһәр-авылларны ташлап китә. Шулай итеп **саба җиле** «әйбәт язгы җил» мәгъ. анахронизм ул. **Саба бикәсе** «кадерле кунакбикә» – Саба иленең мәликәсе Бәлкыйсь. Аның Сөләйман пәйгамбәрне күрергә килүе хакында яһүди, христиан, мөселман дини әдәбиятында риваятьләр бар.

**САБА III** (ш. ук **Сабай**) – название крупного исторического населенного пункта в Татарстане – рус тарихи документларында искә алынган **сабакуляне** дигән (һәм хәз. Саба тирәләрендә яшәгән) кавем-кабилә атамасыннан. **Сабакуляне** сүзе көнб. Себердәге **Сафакүл** топонимын да хәтерләтә, ләкин конкрет мәгълүматлар бу атамаларны үзара багларга җитенкерәми. Хәз. **Байлар Сабасы** – соңрак килеп чыккан атама булса кирәк. Чаг. башк. **байлар** – кабилә атамасы (Ык һәм Сөн бассейнында яшәгәннәр, әмма аларның реаль башкорт булганлыгы бик шикле, чөнки **байлар** кабиләсе (ас кабиләсе) төрекмәннәрнең **йомут** тармагында да бар. **Байлар** сүзе монда халык этимологиясе булса кирәк, чынлыкта бу тирәләргә көньяктан атаклы **байаут** төрки-монг. кабиләсе үтеп кергән бугай. **Байаут** монголчадан тәрҗемәләгәндә **байалар** (**байлар** түгел).

**САБА IV** (Тумашева 1992: 182) «молоки рыбы» – А.Е. Аникин фикеренчә (Аникин: 469; 498), рус. диал. *саба* «акмай түпрәсе (остатки вытопленного жира)» << нен. *саб* сүзе белән бердәй булуы ихтимал. Чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 368) *һаба* «елгакүлнең иң күп сулы, тулы чагы, ташу чоры (нәкъ шул чорда балыклар уылдык чәчә)».

**САБАК I** «стебель», миш., себ. (ТТДС I: 355, Тумашева 1992: 182) «ушки пуговиц, серёг и монет для монист» < гом. кыпч. *сабаҡ* «сабак (үләннең үзәге)», башк. *һабаҡ* id., ш. ук (БТДҺ: 368) «тәлгәш; нәсел, буын; тезген; саплам», нуг., каз., к.-калп., төркм. *саба* «кәтүк, кәтүккә уратылган җеп», үзб. (ЎХШЛ: 228–229) *сабаҡ, савах* «(гомумән) җеп», *сапаҡ* «кавын-карбызның озын сабагы, үркәне», уйг. *сапаҡ, савағ* «сабак, тәлгәш», к.-балк. *сабаҡ* «кукуруз чәкәне», төр. *sapak* «ботак, тармак, бер яры киткән нәрсә» ~ чыгт. (Будагов I: 619) *сапағ* «сабак», *сапаҡ* «төп юлдан аерылган юл» – шуннан төр. *sapak* «акылдан сапкан» һ.б. – барысы да **сап/сап-** тамырыннан (к. **Сап, Сап-у**).

Чув. *сапак, сапака* (Федотов II: 13) «җиләк чеме; кузак; тезе; сәдәп, төймә, төре; алка, сырга» мәгънәсе буенча да, морфемикасы буенча да тат. **сабак** сүзенә тәңгәлләшми, ул ниндидер **сәбәк, *сәбәгә* сүзеннән булса кирәк, ләкин бу вариант үзе ***сабак, *сабака** яңгырашыннан була ала, к. тув. *савак* «чәкүшкә; кечкенә сап һ.б.ш.». **Сабак** сүзе белән себ. (Тумашева 1992: 183) **сабал, сабалаҡ** «тармак, тәлгәш» гомоген булырга тиеш.

Дерив.: **сабаклы, сабаксыз; сабаклан-у; сабаксыл** (неол.). К. **Сабак II**. Аерым мәгъ.: тат. (ТТДС I: 355; Тумашева 1992: 182) **сабакла-у** «саплау; энәгә җеп кертү» – гом. кыпч. *сапла-* (кырг., каз. *сапта-*) id.

**САБАК II** (ТТДС I: 355) «голенище; пришиваемая (не основная) часть полотенца» – **сабу** сүзенең «өстәп тегү, өстәп беркетү» мәгънәсеннән турыдан-туры ясалган; чаг. ш. ук башк. (БТДҺ: 368, 372) *һабитек* «сабылган кунычлы итек» (ул сүзлектә «ат тиресеннән йон ягын тышка калдырып

нәзек каеш җеп белән тегелгән итек» диелә, ләкин бу – тарайтылган мәгъ.), *һап* «чарыкның (тире катаның) тукыма өлеше» – һәр ике очракта да гом. төрки *сап* сүзенең «киемнең өстән беркетелгән өлеше» булганлыгы чагыла. Һәм рус. *сапог* «итек» сүзенең төрки (бәҗ.) **сапаг* «аерым куныч; (аерым кунычлы) итек» сүзеннән икәнлеге (к. Фасмер III: 559) ачыграк шәйләнә. К. **Сабак I.** Räsänen 1969: 401–402.

**САБАК III** «школьный предмет; домашнее задание; то, что проходили» < гар. *сăбăķ* «сабак, үткән дәрес; кабатлау дәресе» ← *сбķ* «үтү, узу, иң алга үтү» тамырыннан. Шул ук тамырдан иске тат. **сабикъ** «элекке (мәс., рәис, башлык, хөкүмәт)».

**САБАН** «плуг; яровые культуры» (**сабан ашлыгы** «яровая культура») > мар., удм., морд., рус. *сабан*, чув. *сапан* < гом. кыпч., башк. *һабан,* төр. *сабан* id., ш. ук «җир сөрү; сөренте», к.-калп. «салам» (бу вариант **саман** сүзенә тартым), куман. *saban* «сөрелә торган җир; җирнең бер өлеше», М. Кашгарида *сбн* «тимер төрәнле сука һ.б.» < бор. төрки (ДТС: 478) *saban* «сөрү; сабанга һ.б.ш. җигелгән пар үгез», уйг., кр.-тат., госм., аз. *сапан* «сабан» һ.б. Бу сүзнең һәр телдә диярлек күпмәгънәлелеге күзгә ташлана, к. ш. ук мар. *сабан* «утын кисү өчен җайланма – дүрт аяклы бүрәнә» (тат. *кәҗҗә,* рус. *козлы* id.), рус. диал. *сабан* «җылым төяп йөртү өчен зур чана; элеккечә такта яру җайланмасы – дүрт биек аяклы корылма» (Даль); Л. Будагов (I: 695) *сабан ~ сапан* сүзенә ике мәгъ. бирә: «сабан» һәм «зәңгәрт, сапкан», ягъни «сабан» һәм кр.-тат., аз., төр. < фар. *сапан, сапанд* «зәңгәрт» сүзе белән бердәй дип карый; безнеңчә дә, бу бик ихтимал: **сабан** үзе аска каратылган мәнҗәникъка (катапультага, ташаткычка) охшаш; аның төрәне – мәнҗәникъ кашыгы. *Сапан* < *сапанд* фарсы сүзенә охшаса да, **сабган** варианты бу сүз төбендә төркичә нигездән дигән фикергә юл куя; к. ш. ук **Сап-у.** Мухамедова 1973: 142; ҚТДС: 276–277; Нұрмағамбетов 1985: 99–100; Федотов II: 13. Сабан төрләре тур. Н. Халиков 1995: 50–52; Аникин: 469; ЭСТЯ VII: 127–128; Steuerwald: 797 (*сабан* «сабан» һәм *сапан* «мәнҗәникъ, катапульта» сүзләрен ул да бергә карый); Тимергалин: 386 –387.

Дерив.: **сабандаш, сабанчы, сабанчылык; сабанла-у** һ.б. Идиоматика: **сабан туе** (> **сабантуй**) дигәндә **сабан** – «сөрү» (**сабантуй** бәйрәме тур. зур әдәбият бар), **сабан тургае** дигәндә **сабан** «сөрелгән, игелгән кырлар». **Сабан ашлыгы** «язын чәчелә торган ашлык». **Сабанчы** «крестьян, игенче».

**САБА-У** «трепать, бить, стегать палочкой шерсть (для разбивания комков)» < гом. кыпч. *саба-*, башк. *һаба-,* як. *сабаа-,* угыз., уйг., үзб. *сава-* id. (хәз. сүзлекләргә сирәк алына), ш. ук «селтәнеп сугу» ~ яз. монг. *saba-*, хәз. монг. *сава-,* бур. *һаба-,* эвенк. (ССТМЯ I: 51) *саба-* «селтәнү, селтәнеп сугу; канат кагу» һ.б. **Чәпче-ү** (к.) белән тамырдаш булса кирәк. Шуннан ук бор. чыгт., угыз., төр. *savaş-* «сугышу», *savaş* «сугыш, җәң». Башк. һәм бур. *һаба-* уртак (*с-* > *һ-* күчеше булган) чыганактан. Боровков 1963: 257; Räsänen: 391; ДТС: 492; Мухамедова 1973: 142–143 (этимологиясен дөрес булмаган юнәлештә эзли); Номинханов 1975: 259; ЭСТЯ VII: 127.

Дерив.: **сабала-у** (~ рус. диал. *сабанить*, к. Аникин: 470); **сабавыч** (~ уйг. *савигуч* һ.б. гом. төрки) «йон тетү өчен махсус корал».

**САБЫЙ** «ребёнок младшего возраста (но не младенец), ребёнок до 12 лет» < гар. *çабū* id. Элек бу сүзнең бүтән гар. формалары да кулланылган: **сабыя** «сабый кыз», **сыйбйан** «сабыйлар».

Дерив.: **сабыйлык; сабыйлан-у** һ.б.

**САБЫН,** диал. (м.-кар.) **сабынь** «мыло» ~ башк. *һабын* id. > удм. диал. *сабын*, мар. *шавынь, шовынь*, морд. *сапонь* < болг. **сабын'* > чув. *сопăнь* > *супăнь* < бор. төрки **сабуни*, безнеңчә, бор. фар. *соибун* «югыч тамыр (кер китәрә торган күбекле тамыр – бертөрле үлән)» сүзеннән. Бу сүз бор. заманнарда бөтен Евразиягә таралган: гар., фар. *çāбӯн*, лат. *sapo*, фр. *savon*, алт., кырг. *самын*, монг. *сабаң* һ.б. к. Федотов II: 64. Гадәттә бу сүз кельт телләренә нисбәт ителә, к. ним. *Seife* «сабын» тур. Kluge: 838.

**САБЫР** «терпение; терпеливый, спокойный, степенный» ~ башк. диал. (БТДҺ: 368) *һабыр* id.> мар. (Упымарий: 185) *савыр* «тәүфикъ», чув. *сапăр* «юашлык, тынычлык, тәрбиялелек; сабыр», удм. (Насибуллин: 136) *сабър* «сабыр, тыныч», морд. М. *савор* «әкрен, тыныч»; тат. *сабырлы* сүзеннән *-лы* кушымчасы кыскарып килеп чыккан, исем мәгъ. гар. *çабр* «сабыр, түземлек» сүзеннән. Федотов II: 13–14.

Дерив.: **сабырлы, сабырсыз; сабырлан-у, сабырсызлан-у** һ.б.; **сабырлык; сабыр ит-ү** фраземасы ССта ук теркәлгән: *sabor eter.*

**САВАЛ [са$^{о}$wал]** диал. (Тумашева 1993: 187) «закат; время захода солнца» < гар. *зăwал* id. Чаг. **Сәвәл.**

**САВАП [са$^{o}$wап], сәвап** «божественное воздаяние за молитвы, богоугодные деяния, благородные поступки и т.п.» ~ башк. *һауап* id. > мар. *суап,* чув. *сăвап* id. < гар. *çäwāб* «савап, бүләк» ← *çwб* «кайту, түләнү». ГТРС: 514; Федотов II: 19–20.

Бу (киң таралган) **савап** сүзеннән тыш икенче **савап** < гар. *çawāб* «дөрес гамәл, дөреслек» сүзе бар, ул икенче бер тамырдан, к. ГТРС: 494.

Дерив.: **саваплы, савапсыз** (гамәл һ.б.).

**САВЫЛ [са$^{o}$wы̆л]: савыл кыстыру** (ТТДС: 355) «льстить, говорить комплименты» ~ чув. *савăл* «агач чөй, кыек тубырчык», *савăл хĕстĕр-* «савыл кыстыру» (чаг. *салпы ягына салам кыстыру* шул ук мәгъ.). Бу сүзне кем кемнән алганлыгын әйтү кыен. Һәрхәлдә тат. сөйләшләрендә ул чувашлар белән аралашып яшәүче татарлар телендә очрый.

**САВЫМ I [са$^{o}$wы̆м],** диал. (ТТДС II: 276; БҺҺ II: 233) **сәwем** «чисменка – счёт ниток в пряже (мотушке), единица счёта ниток (три или четыре нитки, такой счёт имеет значение при тканье бёрдами)» ~ башк. *һауым* > мар. *сом*, чув. *сум* id.; удм. *сомында* < тат. **саумында** «шулчаклы, шулчама».

М.Р. Федотов (II: 61–62) чув. *сум, сом* «савым» сүзен, чув. *сум* «сан» сүзе белән тиңләп, Дунай болгарлары теленнән калган һәм слав. телләренә дә кергән *сам* «сан, хисап» сүзенә баглый. Ул тат. сүзен искә дә алмый. Хәлбуки чув. *сум* < *сом* «җеп исәбе» мәгъ. һичшиксез тат. **саwым** сүзеннән килә, киресенчә була алмый. **Саwым** исә бор. төрки (ДТС: 476–486; Боровков 1963: 260–261 һ.б.) *sa-, saq-* «санау» сүзеннән ясалган (*saqїm* > *sayїm* «санау берәмлеге» үзе теркәлмәгән, ләкин *saqїš* «сан, санак, санау берәмлеге» күп тапкырлар очрый; к. ш. ук бор. *sayu* «ашлык үлчәү берәмлеге»). К. **Савым III. Савым I** сүзенең татарчадан таралганлыгы татар теленең күрше халыклар теленә көчле һәм борынгыдан килгән тәэсире вә татарча сөйләшүче илатның матди мәдәнияте дә электән югарырак булуы тур. сөйли.

**САВЫМ II [са$^{o}$wы̆м]** «подарок, который приходящие на свадьбу гости приносили в чётном числе, на похороны – в нечётном числе» (к. Я.Д. Коблов. Религиозные обряды и обычаи татар-магометан // ИОАИЭ, XXIV, вып. 6. 1910: 543), к. ш. ук ТТДС II: 259–260, себ. (Тумашева 1992: 187) **сауым, сауын** «туй бүләге» < ***саwғым, *саwғын** id., к. **Сауга.**

***САВЫМ III [са$^{o}$wы̆м]** – тарихи ядкәрләр буенча, болгарларда **саум** «8,5 грамм чамасы (≈ ике мыскал) көмеш». **Саwым I** белән бердәй булса кирәк, әмма моның ышандырырлык багланышы табылмады. **Сум < сом** сүзенең болгарча язылышы гына булырга мөмкин (иске язмаларда гом. төрки *о* авазын гарәпчә язылышта او – ике хәреф белән белдергәннәр).

**САВЫР [саwы̆р], сауры [саwры̆]** «ягодица; круп» > удм. диал. *саур* «кожа, шкура, сделанная из кожи крупа коня» < гом. кыпч. *саwур* ~ *саwыр* (> кырг. *соор*) < бор. төрки (Поппе 1938: 319; ДТС: 481) *sayrї,* куман., госм. һ.б. (Радлов IV: 276) *сағры,* уйг., үзб. *сағри,* як. *саары* һ.б. «савыр; (атның) савыр тиресе». Гомумән, бөтен дөньяга таралган төрки сүзләрнең берсе, к. **Саурый, Шигрин**. Будагов I: 614; ЭСТЯ VII: 142; Тимергалин: 388. Рус диал. *саври* «ияргә тагыла торган күн кисәкләре» тур. Аникин: 471.

**САВЫР-У [са$^{o}$wы̆р-]** «приливать (о крови), затекать» (исем фигыль мәгъ. «кровоизлияние; затёк») ~ төр. *savur-* «җәелдерү, тарату яисә бер якка ишерү; эчтән тышка чыгару» < бор. төрки (ДТС: 492) *savur-* «җилгәрү, суыру; чәчелдерү, тарату», к. **Суыр-у II**. Будагов I: 693; Рәхимова: 91–92.

**САВЫТ [са$^{o}$wы̆т]** «посуда; сосуд; вместилище; одеяние» (диал. **аяк савыты** «обувь»), иск. (әле К. Нәҗми әсәрләрендә дә очрый) «броня, латы, панцирь» > чув. *савăт* «ашамлык һ.б.ш. савыты» < гом. кыпч. *саwыт* (> кырг. *соот*) < бор. төрки (ядкәрләрдә теркәлмәгән) **сағут* > үзб. *совут, соғут* «савыт; кыяу». Башк. *һауыт* «савыт», (БТДҺ: 374) *çауыт, һауыт* «пычаклы тозак». Уйг. *савут* һәм төр. *savut* башлыча «кыяу (броня, шайман һ.б.ш.), корал» мәгъ. кулланыла, аз. (АДДЛ: 355) *сафуд* «кумта, шкатулка», *сафут* «салам эшләпә». Бу сүзнең *-б-, -п-* варианты – иске тат. (Троянский I: 566) *сапуд* ~ бор. рус. (Срезневский III: 534) *съпудъ* «савыт» ~ алт. (Баскаков 1966: 145) *сабыт* «чиләк». Сүзнең төп, чыганак мәгъ. «шлем; кыяу» булганга охшый. О. Прицак буенча (к. аныкы Bolgarische Etymologien // UAJ, XXIX, 3–4; 1957: 200–214), сүзнең тамыры – бор. кыт. *say* «металл чүлмәк». Ком. *сағ* «2,5 литр» ~ бор. төрки, чыгт., уйг. (Будагов I: 614; Поппе 1938: 319; ДТС: 481) *sayu* «16,5 литр», уйг. ш. ук «үлчәү тәлинкәсе», төр., бор. төр. («Мөхәммәдия» телендә) *сағ* «ашлык үлчәү берәмлеге». Räsänen 1969: 393–394; Федотов

II: 4 (**савыт** сүзен **саба** һәм **сәбәт** сүзләре белән бутый); ЭСТЯ VII: 131–132.

Дерив.: **савытлы, савытсыз.**

**САГА, сака,** диал. (ТТДС I: 510–511; Тумашева 1992: 183 һ.б.) **сағай, сакай, шаға, шақа, шакай** «бабка, козон; бита в игре в альчики» ~ башк. *һаҡа, һаҡы,* чув. *саха* < гом. кыпч., чыгт., уйг., төркм. һ.б. (Радлов IV: 241) *сақа,* калм. *шаға,* бур., кырг. *шағай,* тув. *шаңай,* як. (Пекарский: 2421) *сыағай* ~ сол. (ССТМЯ II: 56) *сааха,* маньч. *саj-ха* ~ яз. монг. *šaxan, šaγaj, sıγaj* һ.б. (к. Räsänen 1969: 440) id. К. ш. ук **Шәмәй.**

Бу сүз (кайбер семантик дивиацияләре белән) төрки-монг. телләреннән күп күрше телләргә дә таралган, к. рус. диал. *шагайка* «сака», *сак, сака, саквы* «бөк (ашыкның бөкресе өскә карап ятуы)» һ.б., к. Аникин: 476 (әдәбият күрсәтелә); ЭСТЯ VII: 151–162.

**САГАЙ-У** «настораживаться, насторожиться» ~ башк. *һағай-у* id. – тат. телендә ясалган шикелле, **сақ I** тамырыннан. Бүтән төрки телләрдә бу *сақ* сүзеннән *-ай* кушымчасы ярдәмендә ясалган фигыльләр икенчерәк мәгънәдә: к.-балк. *сағай-* «уяну», уйг. *сақай-* «сәламәтләнү, савыгу» һ.б.

Дерив.: **сагаеш-у, сагайт-у.**

**САГАЛА-У** «подстерегать, подстеречь» < гом. кыпч. булса кирәк, к. башк. *һағала-,* каз., кырг. *сағала-* id. **Сак I** тамырыннан, ясалышы бигүк ачык түгел. Ихтимал, элекке **сағы-* ~ алт. (Баскаков 1972: 245) *сақы-* «көтү, сагалау» фигыленең ешайтулы формасыннандыр.

**САГАЛДЫРЫК**, диал. (ТТДС II: 261; ЗДС: 554) **сакалдырык, сакалтырык** «подгубник (часть уздечки); бородка топора; подвязка для платка (нередко украшенная блёстками, монетами)», «подвязка для нижнего платья без рукавов у женщин», себ. (Радлов IV.1: 213) **сағалдрық, сакалтрық** «привески на шапке невесты» һ.б. (бүтән охшаш мәгъ. дә бар), башк. (БТДҺ: 368) *һағалдырыҡ* – гом. кыпч. *сақалдырық* id. *сақал-дырық,* ягъни «сакал, ияк асты» сүзеннән кебек. Ләкин к. каз. *сағa, сақа* «детальләрнең тоташу урыны» һәм асылда *сака+лдырык* булуы ихтимал, ягъни монда төп нигез *сакал* түгел, **сақа**; чаг. **күзелдерек** < *күз +елдерек,* **муендырык** < *муен-дырык,* **табандырык** < *табан-дырык* (к. **тәбәлдерек**) һ.б., чаг. үзб. (ЎХШЛ: 228) *сағалдырық* «балык яңагы, саңак», бор. төрки (ДТС: 486) *saqalduruq* «бүрек бәйләвече, колакчын бавы (ефәктән ясала)» ~ хәз. монг. *сагалдрага* «каптырма, сакалдырык».

**САГАН** (ТТДС II: 260) «кастрюля» ~ каз., кырг. *саған* «калай табак». Чаг. *савыт* < *сағыт*. Нұрмағамбетов: 100.

**САГАНАК** (әстр.) «буря, дождь с сильными порывами ветра» ~ чыгт., кр.-тат., төр. *saganak, sayganak, zaγanaq* < төр. диал. (Будагов I: 684) *сажҗанақ, саңанақ* «давыллап яуган диңгез буе яңгыры, бора», куч. мәгъ. «афәт» төр. *sac- [саҗ-]* «чәчелдерү» сүзеннән булса кирәк. *Саҗ-* > *сай-* нугай тибындагы төрки телдә була ала. Гомумән бу сүз угыз телләрендә ясалган бугай.

Радлов сүзлегендә (IV.1: 261–262) **сағанақ** дигән биш омоним күрсәтелә.

**САГЛАМ** «здоровый (душой и телом)» < уйг. *сағлам,* төр. *sağlam* id., шуннан ук кр.-тат., кар. *сағлам* id. бор. төрки *saγ* «сау» сүзеннән. К. **Сау.**

**САГРЫЙ** «обработанная дорогая кожа» к. **Саурый.**

**САГЫЗ** «жевательная сера, резина и т.п.» ~ башк. *һағыз* ~ гом. кыпч. *сағыз* < бор. төрки, госм., кр.-тат., куман. һ.б. *сақыз,* алт. *саңыз, сақҡыз°,* хак. *саас,* як. *ыас* «сагыз, сумала», «мастика» (Будагов I: 614) < бор. төрки **saŋqız* < *saŋ* тамырыннан, к. алт. диал. *саң* «агач чәере», чув. *сухăр, сохăр* < болг. **сағыр* «сагыз, чәер». *Сагыз* сүзе төрки телләрдән күп телләргә кергән. Räsänen 1969: 396; Федотов II: 70; ЭСТЯ VII: 169–171 (чув. сүзләре искә алынмаган).

Дерив.: **сагызлы, сагызсыз; сагызлан-у** һ.б.

**САГЫЗАК** «оса; шмель» ~ башк. *һағызаҡ,* хак. *саасхах,* тув. *шаашкак,* к.-балк. *сасқы* «сагызак, шөпшә; чуар чебен». Күп төрки телләрдә юк (яки теркәлмәгән), шунлыктан тамыры ачык түгел. К. **Шөпшә.**

**САГЫМ** «мираж; марево; проекция» < гом. кыпч. *сағым,* нуг., ком. *сағын,* хак. *шағың* id. < бор. төрки *saqïm* id., к. бор. төрки *saqïγ* «мираж, күренгән иллюзия; өрәк», *saqı-* «юк нәрсә күренү, галлюцинация», *saq-* «уйлау, исәпләү, күз алдына китерү» (ДТС: 488). К. **Сагын-у.**

**САГЫН-У** «вспомнить, вспоминать; тосковать, грустить о ком-то, о чём-то»; (ТТДС II: 260) «пред-

ставить себе» < гом. кыпч., хак., алт. һ.б. *сағын-,* уйг. *сағын-, сеғин-,* ком. *сағун-* ~ башк. *һағын-* ~ як. *ағын-* < бор. төрки (ДТС: 486) *saqïn-* «уйлау, фикерләү; теләү, хыяллану; кайгыру, кичерену; хәстәрләнү, хәстәр күрү» > госм. (Радлов IV: 248) *сақын-* id., бор. төрки *saq-* > хак. *сақ-, сах-* «уйлау» фигыленең кайт. юн., бу фигыль исә бор. гом. төрки, монг., тунг.-маньч. *sa-* «уйлау, фикерләү, санау, белү» фигыленең интенсивлык формасы (*sa-q-*) булса кирәк (к. ССТМЯ II: 49–51). *Сагын-у,* шулай итеп, асылда бор. «уйлану; хәтерләү» мәгъ. фигыльнең окказиональ кулланылышыннан килә. Мәзкүр төп мәгънә тат. диал. (ТТАС II: 613) **сагынмаклык** «истәлек, хәтердә калырлык (нәрсә)» сүзендә дә чагыла. Ш. ук к. иске тат. (Будагов I: 688) *сағы сағмақ* «үлгәнне хәтерләп елау» (к. ш. ук **ыгы-зыгы**). Чаг. алт. *сакы* «көтеп тору; сакта тору». Башк. *һағын-* һәм як. **һағын-* > *ағын-* «сагыну» нигезләре гомоген. К. **Сагыныч, Сагыш, Саен, Сан, Сан-у.** Будагов I: 687–688; ЭСТЯ 2003: 144.

**Сагын-** төп мәгъ. күрше мар., удм. телләренә дә кергән.

Дерив.: **сагынгыл-у, сагыныш-у, сагындыр-у** һ.б.

**САГЫНЫЧ** «тоска (по ком, по чём)» < гом. кыпч. *сағыныч* (> башк. *һағыныс,* нуг., каз., к.-калп. *сағыныш*) < бор. төрки *saqinč* id. (димәк бу сүз борынгыдан килә). К. **Сагын-у. Сагыш.**

Дерив.: **сагынычлы** (сәлам).

**САГЫР** диал. (Тумашева 1992: 187) «глухой» ~ нуг., кырг., кар., төркм., госм. *сағыр* (Радлов IV: 267), гаг. *саар* id. төптә сыйфат фигыль (*-р*) булса кирәк (ягъни *сағыр* < *саңгы-р*). К. **Саңгырау.** ЭСТЯ VII: 145–146.

**САГЫШ** «тоска» ~ башк. *һағыш* ~ чув. *шохăш, шухăш* «уй, фикер» < гом. көнб., кыпч., куман., алт., тув. *сағыш* «уй; акыл; хәстәр», хак. *сағыс* «акыл», төр. *sağış* «санау, теркәү, исәпләү» < бор. төрки *saqïš* «исәп, санау» (к. Боровков 1963: 155; ДТС: 486) ← *saq-* «уйлау» фигыленнән ясалган исем (*-ш*). Чаг. ш. ук алт. *сақы-* «көтеп тору». **Сагыш** сүзенең үзенчәлекле мәгъ. тат. телендә килеп чыккан булса кирәк. Будагов I: 687; Räsänen 1969: 395–396; Федотов II: 465; ЭСТЯ VII: 144.

Дерив.: **сагышлы, сагышсыз; сагышлан-у;** диал. **сагышла-у** «ныклап уйлау; хәстәрләү».

**САДА** иск. «шакирдская песня, шакирдский хор» < гар. *ṣадā* «аваз, яңгыравык». ГТРС: 495.

**САДАК** «сосуд для стрел» к. **Сайдак.**

**САДАКА, сәдака** «милостыня; дружеское подношение» < гар. *ṣадāқа* id. ← *ṣдқ* «тугрылык; дуслык» тамырыннан, шуннан ук иске тат. **садыйк** «тугрылыклы», **садакать** «тугрылык», к. **Тәсдикъ.**

**САДӘ** «простой; простодушный» < фар. *cāдä* id. К. **Сатамай.**

Дерив.: **садәлек; садәләш-ү, садәләштерү.**

**САЕК-У (саекты, саегу)** «мелеть» – диал. (Тумашева 1992: 183) **сайы-у** «сай булып китү» фигыленең интенсивлык формасы. Чаг. чув. (Ашмарин XI: 4) *сайам* «сай төш» (татарчадан). Чаг. ш. ук диал. **Яяр-у.**

**САЕН [са$^{о}$йы̆н],** диал. (Урал, себ., к. БТДҺ: 266) **сайы,** себ. (Тумашева 1992: 183) **сай** «еже-, каждый (раз)» > мар., удм. *сайын* < гом. кыпч., башк. *һайын,* алт., хак., төркм. *сайын*, уйг. диал. *сайин*, үзб. *сойин*, алт. диал. *зайын* (!) < бор. төрки (ДТС: 481–482) *sajïn, saju* «һәр, һәрбер; саен» ~ себ. (Тумашева 1977: 145, Тумашева 1992: 183), хак. *сай,* төркм. (ТДГДС: 154) *саайы, сайы, сайу* «саен». Бу сүз (ахыр чиктә гом. төрки) чыгт. *сай,* госм., гаг., төр., төркм. *саайы, сайы* «сан; исәп» сүзеннән килә, ләкин ясалыш ысулы һәм мотивациясе төгәл аңлашылып бетми, чөнки төрле фаразлар бердәй дәрәҗәдә ышандырырлык. Безнеңчә, *сайын* яңгырашы элекке *сай* (к. **Сай II**) «рәт, тезем» сүзенең инструменталь килеш формасы. Бүтән версияләр бор. *sa-*, соңраккы *sajı-* «санау» сүзеннән булырга мөмкин (ягъни **сай-у** «санап» хәл фигыленнән).

Тат. (т.я., крш.) сөйләшләрендәге (ТТДС I: 358, 386) **сайран, сәйрән > сәрән** ~ чув. *сайран > саран, сейрен > серен* «саен, һәрбер» болг. телдәге **сай-ран** «сайдан, рәттән» (*сай* «рәт, тезем») сүзеннән килсә кирәк. К. **Саерга-у.**

Һәрхәлдә **саен** һәм **сайран ~** *сәрән* сүзләре бор. төрки, бор. монг., бор. тунг.-маньч. *sa-* ~ кыт. *шань ~ сань* «уйлау; санау» тамырына тоташалар, к. **Сагын-у, Сагыш, Сан, Сана-у, Сая-у** һ.б. Будагов I: 617–618; Радлов IV: 291, 294–295; Gabain 1951: 138; Ашмарин XI: 6; Егоров 1964: 186.

**САЕРГА-У [са$^{о}$йы̆рға-],** (Тумашева 1992: 183) **саирға-у** «ставить в ряд; разобраться, разбирать, приводить в соответствие» – бор. төрки **сай-у, сайы-у** (к. **сай-**) «рәткә тезү» фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе (*-рға* кушымчасы!).

**САЕСКАН [саºйы̆сқан],** диал. (ТТДС I: 355–356, 361, 384) **саwысқан, сал'ускан, саwысан, сәйескән, сәwескән** иске тат. (Троянский I: 620) **сағыскан,** бик үзенчәлекле «Әчтерханча» (Арсланов 1988: 91) **саwырысқан** – гом. кыпч., каз., к.-калп. *сауысқан,* ком. *савусган,* нуг. *савысқан,* үзб. (ЎХШЛ: 228) *савускан, савусхан, загизгон*, алт. *саңысқан*, хак., тув. *саасқан*, бор. төрки (Поппе 1938: 319; ДТС: 481) *sayïzγan, sayzïγan*, төркм., төр., чыгт. *сақсаған,* башк. (БТДҺ: 369) *һайысқан, һайытқан, һайыхқан* id. – З. Мухамедова (1973: 144) фикеренчә, төркм. һ.б. *сақырда-мақ* «(саескан) шакырдау» фигыле белән тамырдаш. Ягъни *сакыр//шакыр* тәкълидн сүзеннән ясалган нигезгә киң билгеле һәм хайван атамалары ясаучан *-қан* аффиксы ялганып пәйда булган, һәм бор. төп яңгырашка тат. диал. **саwырысқан** якын булып чыга. Бу яңгырашның азагы *-ысқан* элементын уйг., фар. *заг, заған* «саескан, чәүкә» сүзенә охшатырга мөмкин (*саwырысқан* < *сагырсқан* < **сагыр заған* «шакырдавык чәүкә»?). Һәрхәлдә *сағызған* < *сағырған* < **сақырқан-* тамыры *сақыр* булуы бик ышандырырлык, к. мар. *шогертен, шагäртен* «саескан» – болг. (-*r*-) телдән, мәс., **сакырткан* вариантыннан. Саескан атамасында бу кошка хас авазлар бергәлеге булу бик табигый рәвештә киң таралган, к. венг. *szarka*, фин. *harakka,* рус. *сорока* һ.б. Як. *саҗағай* << монг. *сагаҗигай,* бур. *шаазгай* «саескан» < бор. монг. **сағар җигай* (*җигай* «кош») сүзеннән булса кирәк. Кайбер төрки телләрдә саескан атамасы *чак//чик* тәкълиди сүзеннән: чув. *чакак*, к.-балк. *чыкынчик, чыкынҗик*. Шулкадәр тавышчан кошның атамасы ул чыгарган авазлардан булмавы гаҗәбрәк булыр иде. Räsänen 1969: 396; ЭСТЯ VII: 166–169; Сафина 2006: 33–34.

**Саескан** сүзенең вариантлары *р* > *з* (киресенчә түгел) икәнлегенә дәлил: *сағыр-* > *сағыз-*.

**Саескан** (һ.б.ш.) сүзе төрки телләрдән күрше телләргә дә кергән: морд. *сезьган*, укр. *саксаган, саескан,* рус. (Аникин: 489) *саускан* id. һ.б.ш.

**САЖИН** «сажень» < рус. Мар. *сажин, шажен,* чув. *сажин, шаршăн, шашин,* удм. *сажем* өлешчә тат. теле аша таралган. Чаг. ш. ук чув. *шаршан*, мар. *шăшан* «әрдәнә» (Саваткова: 198). Рус. *сажень* тур. к. Романова 1975: 58–60. Федотов II: 436.

**САЗ I** «болото» < гом. кыпч., чыгт. *саз*, алт., хак. *сас,* башк. *һаҙ* id. Ком., к.-балк., каз., к.-калп. телләрендә башлыча «балчык, мәте (сары балчык)» мәгъ. кулланыла, ләкин төп мәгъ. татарчада сакланган, чаг. чув. *шор, шур*, венг. *sar* «саз, сазламык» < болг. **сар* (< **сäрг*) id. Башк. диал., тат. диал. (БҺҺ II: 300; Тумашева 1992: 227; ТТДС I: 513) *шар* «куе камышлык, таллык, үткесез урман» сүзе дә болг. (яисә шуңа иш) телдән дигән фикер бар. К. **Саз II.** Федотов II: 462; Гарипова 1998: 101–103; ЭСТЯ VII (2003): 146–147.

Дерив.: **сазлы, сазсыз; сазлык.** К. ш. ук **Саза, Сазамык, Сазан, Сазанак, Саза-у, Сазламык.** Башк. телендә бу сүзнең сәер генә дериватлары теркәлгән (к. БТДҺ: 369): *һаҙамат, һаҙамырт, һаҙмат, һаҙыран* – барысы да «сазламык» мәгъ.

**САЗ II** «флейта; музыкальный инструмент вообще; поэзия» < чыгт., уйг., госм. *саз*, төркм., гаг. *сааз* «курай (флейта)» – асылда «камыш < камышлык ~ сазлык», чаг. ш. ук төркм. *сааз* «шүре», төр. *saz* «камыш», үзб. *соз* «камышлы саз» һ.б. К. **Саз I**. Будагов I: 613; ЗДС: 35 (кызыклы этнографик мәгълүмат китерелә).

**САЗА, сазы** «болото» ~ башк. (БТДҺ: 369) *һаҙы.* **Саз I** сүзе белән гомоген, әлбәттә. Чыгышы-ясалышы ачык түгел.

**САЗАГАН** (әстр.) «смерч; дракон» ~ башк. (БТДҺ: 368–369) *һаҙаған* «ажаган, елдырым; җен, убыр» < бор. кыпч. *сазған, сазаған*, СС *saxagan* «аждаһа» ~ кр.-тат., кар., төр. *sazagan* «аждаһа рәвешендә ясалган очырткыч» < бор. төрки **saryaγan* > венг. *sarakany, sarkany* (1193 елда теркәлгән) > словен. *šarkan,* рум. *sărcan*. Бу сүз тур. күп язылган, к. Gombosz: 178, Курышжанов: 183; Добродомов 1974: 11–19; Нұрмағамбетов: 101–102; Палло М. Реальная основа заимствованного слова *sarkany* «дракон» // Исследования венгерских учёных по чувашскому языку. Чебоксары, 1985: 98–106. Украинадагы елга һәм шәһәр атамасы *Харьков* бор. венг. сүзе **һarakaw* «сазаган» сүзеннән килә, имеш. Рус.диал., укр. *шараган* «аждаһа» < венг.

Дерив.: **сазаган туе** «аҗаган, елдырым», ул **шәүлегән туе** дип тә атала.

**САЗАМЫК** «болотистый» к. **Сазламык.**

**САЗАН** «сазан» < гом. кыпч., төр. һ.б. *sazan*, чув. *сăзан*, төркм. *саазан,* башк. *һаҙан* һ.б. төрки > рус. *сазан* (рус теленнән күп телләргә таралган); рус. диал., укр. *шаран*, укр. диал. *саран* «сазан» бор. болг. теленнән (шуннан ук *сазан*: *-р-* > *-з-*),

**саз I** сүзе белән баглы булырга тиеш (сазан – саз балыгы). К. ш. ук диал. (ЗДС: 556) *сайсан* «сазан». Räsänen 1969: 406; Федотов II: 32–33; ЭСТЯ VII: 147–148.

**САЗАНАК** «багульник (растение)» < бор. **сазғана* «саз үсемлеге, саз үләне» (*-ғана//-кана* – үсемлек атамалары ясагыч кушымчасы). Принципта ***сазганак** варианты да булырга мөмкин.

**САЗА-У** «сильно стареть (особенно в относительных значениях); побледнеть, пожелтеть; поблекнуть» ← **саз** «саргайган камыш төсендәге» (к. **Саз II**) сүзеннән булса кирәк *(саз-а-)*, к. диал. җырда: *Карага – саз атыңны син җигәрсең...* (Материалы 1974: 223).

**Саза-у** фигыленнән бигрәк аның сыйфат фигыль формасы **сазаган** ~ башк. *һаҙаған* «кияүгә чыгар яисә өйләнер вакыты узган» сүзе киңрәк билгеле.

**САЗЛАМЫК, сазлавык [сазлаwы̆к]** «небольшое болото; болотистое место; болотистый» ~ башк. *һаҙаламыҡ, һаҙҙауыҡ, һаҙлауыҡ* id. – **саз** сүзенә *-лаwыҡ//-ләwек* аффикслары ялганып ясалган сүзләрдән, чаг. шул модельдә **гөрләвек, күлләвек, шарлавык, ярлавык** һ.б. **Сазамык** вариантында чир-чор, былчырак-баткак атамалары ясагыч *-мык* кушымчасы күренә.

Дерив.: **сазламыклы, сазламыксыз; сазламыклан-у** һ.б.

**САИЛ** иск. «просящий милостыню, нищий» < гар. *сā'ил* «сораучы, хәерче» – *сәаль, мәсьәлә* сүзләре белән тамырдаш. Тат. *саилче* id. сүзе этимологик җәһәттән дөрес түгел (*-че* – артык).

**САИН** тар. «особо почитаемый; уважаемый» < кр.-тат., төр. *sayın* id. Төр., бор. төрки *sayı = sajı* «сан (түбәндә хәрби демократия дәверендә исәп-кә-санга кергән сугышчы берәмлеге)» сүзеннән. *Саин* яңгырашы монг. телендә килеп чыккан. Батый ханны *Саин хан* дип тә атаганнар. Бу Батый ханның ләкабеме, чинымы дигән мәсьәләдә тарихчылар арасында бәхәс бара. Кайберәүләр *саин* «мәрхүм» мәгънәсендә, Батыйны үзе үлгәч кенә шулай атаганнар дип тә әйтәләр. Бу хакта к. (авторы күрсәтелмәгән) «Посмертный титул Бату хана» // Восточный свет, № 2, 2005 (берничә абруйлы тарихчының фикерләре китерелә). Каз. поэтик телендә *сайын* «туган, җанга кадерле» (*сайын дала* диелә).

**САИРГА-У** (Гиганов, шуннан Тумашева 1992: 183) «разбирать по частям» ← *сай-ырға* – булса кирәк: *-ырға//-ырка* аффиксы ярдәмендә *сай* «яхшырак нәрсә» тамырыннан (к. **Сайла-у** һ.б.).

**САЙ I** «мель, мелкий» < гом. төрки *сай*, башк. *һай,* төркм. *саай* «сай; сай җир», чыгт., уйг., алт., хак., тув. телләрендә ш. ук «вак таш, вак ташлык; елганың төбендә ташлары күренеп торган һәм суы тиз аккан урыны», каз., кырг. «киң елга юлы, киң генә тау елгасы».

Бу сүзнең морфологик вариантларына тат. *сайлавык*, тат. диал., каз., кырг. **сайыз,** *сайаз,* үзб. *саёз* «киң сайлык» ~ каз., чыгт. *сайыр*, чув. *сайӑр*, монг. *сай, сайр* «чуерташ», *сайир* «ташлы үзән», чув. диал. *сайӑм* «сай төш» (Ашмарин XI: 4 – тат. сөйләшләреннән булса кирәк) һ.б. керә. Чаг. ш. ук хак. *сайра-* «саегу» ~ бор. төрки (ДТС: 481–482) *sajram* «сай төш» һ.б., Будагов I: 617; Радлов IV: 219; Räsänen 1969: 394; Мухамедова 1973: 143; Мурзаев 1984: 491–493; Гарипова 1998: 103–105; ЭСТЯ VII: 150–152.

**Сай** сүзен башк. (БҺҺ II: 197) *сай* «ләм, сүсем; ике тау арасы» белән чагыштыру бигүк дөрес түгел, чөнки башк. сүзе *чай* яңгырашыннан килә; гом. төрки (башлыча угыз телләрендә) *чай* > *җай, зай* «елга» сүзен дә *сай* белән бердәй дип (Г. Саттаров, М. Зәкиев) раслап булмый. К. **Саек-у.**

Төр. *sığ* «сай» сүзенең, ш. ук уйг. *сай* «тигез комлык» сүзенең дә *сай* сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел.

Дерив.: **сайлык;** диал. **саяр-у.**

**САЙ II** (ТТДС I: 357) «ряд; строка (лаптей); настил; гать» > мар. *шой* id. ~ хак., алт. *сай* «рәт», кырг. *сай* «мылтык көпшәсенең эчке сыры, винты», чув. (тат. булса кирәк) *сай, шай, сахай* «сынган сөякне кузгалмаслык итеп беркеткеч җайланма; сай, чабата юкәсе», к.-балк. *сай* «өлеш, өлте», каз. *сай* түбәтәйнең түбәсен тәшкил иткән дүрт өлешнең берсе» һ.б. (гомумән, сирәк очрый) – себ. *сай* «рәт, сан, саен» сүзе белән гомоген булса кирәк.

Тат. теле даирәсендә бу сүз шактый продуктив нигез, к. **Сайгак, Сайгау**, к. ш. ук **Саен, Саерга-у.**

**САЙБЫР** (Тумашева 1992: 182) «ходкий; иноходь», (ЗДС: 556) **сайпар** «редкий» ~ хак. *сайбыр,* алт., каз. *шайбыр* «уңган (кеше)» ~ маньч. *сайбуру,* яз. монг. *saibur* id. бор. монг. *saji bir* «бәхетле, уңышлы; яхшы холыклы» сүзеннән (к. Räsänen 1969: 395). ЭСТЯ VII: 154.

Дерив.: (Будагов I: 694) **сайбырламак** «йомшак юырту», (Тумашева 1961: 187) **сайбырлашу** «икәүләп атка атлану, менгәшү».

**САЙГАК I** (Троянский I: 220; ДС II: 165–166) «половица; накат; ограда (из кольев); ряд балок» > удм., мар. *сайгак* «аркылагач, өрлек» (Кельмаков 1977: 58), чув. *сайхах* «кәртәлек (жердь)», мар. *шайгак* «сайгак» ← тат. диал. **сайга**- «кәртәлек тезү; рәткә, рәттән тезү» ← тат. диал., чув. *сай* «рәт, тезем, сан» (к. **Сай II**) ← *са*- «санау; уйлау» тамырыннан, к. башк. (Катаринский) *һайғал*- < *сайгал*- «тезелеп яту, тигез тезелү», гом. тат. **сайгау** (исем фигыльнең исемләшүеннән) «сайгак, тезмә» ~ башк. *һайғаҡ, һайғау* id., id. Идел-Урал регионына хас сүз. К. ш. ук тув., төркм. *сайғар*- «тәртипкә китерү; таслап салу; сайлау», төркм. *сайхал* «әдәп, рәт, юнь», алт. *сайыргач, сайрач,* шор. *сайлағ* «атлама, шикмә, сайгау», алт. диал. *сайлан*- «рәттән тору» (к. Радлов IV: 221, 226, 228), ком. *сайғоҡ* < *сайғаwыҡ* «чош (салам түбә өстенә куелган басырыкларның берсе)». ЭСТЯ VII: 149–150 (гом. төрки *сай*- «чәнчү» тамырына кайтарып калдырыла, безнеңчә, бу шикле).

Каз., к.-калп. *сайғаҡ* «кабер өстенә кагылган колга; суел (махсус сугыш күсәге)», хак. *сайхах* «чагу, әләк» һ.б.ш. – икенче сүз; каз., кырг., алт. *сай*-, як. *саай*- «кадау, казык кагу; чәнчү» фигыленнән.

**САЙГАК II** «сайгак, сайга» < гом. кыпч., тув. һ.б. *сайғаҡ,* төркм. *ҫайғаҡ* id.; тат. диал. (ТТДС: 358) *сайгак, сайаҡ* «тиктормас, йөремсәк, сукбай» ← (алт.) *сайа*- «таркау йөрү, таралып китү, сирәгәю» фигыленнән булса кирәк (*сайа-ғаҡ* > *сайғаҡ*). К. **Саяк II.** Рус. *сайга* тур. Аникин: 475 (бай әдәбият күрсәтелә; бор. төрки *saj* «үләнсез коры дала» сүзеннән түгелме икән, дигән фикер әйтелә). ЭСТЯ VII: 153.

Сайгаклар элек Идел-Җаек аралыгында, Казакстанда да күпләп яшәгән.

**САЙГАК III** (ЗДС: 556) «овод» ~ каз., к.-калп. *сайғаҡ* id., каз. ш. ук «кабергә кадалган колга» ← гом. төрки *сай*- «чәнчү». К. **Сайгак I, Сәнәк.**

**САЙДАК,** диал. **садаҡ, саудаҡ** (Тумашева 1992: 183, 186), **сагайдаҡ** «колчан» < гом. кыпч., алт. *садаҡ,* чыгт., төркм. *сағдаҡ,* уйг. *сағыдаҡ,* кырг., алт., тув., як. *саадаҡ,* башк. *һаҙаҡ* һ.б. (гом. төрки сүз) > рус. *саадак, сагайдак, сагадак, сайдак*, *саандак* һ.б. бор. рус. *савдак*, мар. *шовыдак* «ук савыты; ук яки җәя савыты». Безнеңчә, тат. диал. **санай** < *саңай* «җәя» сүзе белән бәйле: **саңайдак, *саңаwдаҡ* < **саңагдак* сүзеннән булса кирәк. Чаг. ш. ук абаз. *сағындаҡ* «ук; ук һәм җәя». Һәрхәлдә бу сүздә *-дак* кушымчасы барлыгы бик ихтимал.

Бу сүз тур. күп язылган. Монг. *саадаг* (> бур. *һаадаг* > башк. *һадаҡ*) «сайдак» *сааха*- «ук ату» сүзеннән дип уйланыла, ләкин бу бик шикле. Тарихчы Л.Н. Гумилёв буенча, *сагайдак* сүзе һунн телендә итекне белдергән, чөнки укларны итеккә тыгып йөргәннәр (к. кет телендә *saadi* «итек»). Безнеңчә, бу фараз да ышандыргысыз. К. ш. ук Räsänen 1969: 393; Uray-Köholmi 1960: 293–297; Menges 1972: 55–69; Добродомов 1981: 70–88; Аникин: 4775; ЭСТЯ VII: 140–142.

**САЙКАЛ** (Г. Тукайда: *И күңлемнең сайкалы* – бала тур.) «центр души» ~ Харәземдә *сәйқәл* «үзәк», Котби телендә, кырг. *сайкал* «көзге» < төр. < гар. *сайқал* «ышкып ялтырату» (к. Будагов I: 716), к. ш. ук төркм. *сайкал* «әдәп, юнь, тәрбиялелек», каз. *сайқал* «җиңел йөрешле җитез хатын» һ.б., ихтимал, монда төрле сүзләр беришле яңгыраштадыр. Нұрмағамбетов: 102.

**САЙЛА-У** «выбирать, отбирать лучшее» > мар., удм. диал. *сайла*-, чув. *сойла*- > *суйла*- id. < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., үзб., госм. һ.б. *сайла-,* башк. *һайла*- id. ← гом. кыпч., төркм. һ.б. (> мар.) *сай*, чув. *сайӑ* «яхшы, иң яхшы» ~ төр. *saygı* «аеруча яхшы дип исәпләү, аеруча хөрмәт» ← *say*- «санлау; хөрмәтләү һ.б.ш.». К. ш. ук төркм. *сайла*- «сайлау; чүптән арындыру, чүпсезләү» < иске төрки *сайла*- id., алт., шор. *сайла*- «эрбет чикләвеген чистарту».

Кайбер төрки телләрдә (себ., к. Тумашева 1992: 183) *сайла*- «рәткә тезү, тәртипкә китерү» ← **сай II** (к.). Гомумән, **сайла-у** төрле юллар белән һәм гом. төрки *сай(ы)* сүзенең төрле мәгъ. килеп чыга ала. Радлов IV: 227, 229, 230; Мухамедова 1973: 143–144; Федотов II: 54 (чув. *сайӑ* «яхшысы, яхшырагы» белән *суйла*- арасында бәйләнеш сизелми, бу хәл аларның ике чыганактан килгәнлеген күрсәтә); ЭСТЯ VII: 154–155.

Дерив.: **сайлау; сайлан-у** (һәм аның дериватлары: **сайланмыш, сайланчык** һ.б.; **сайлаш-у, сайлат-у**; диал. **сайландык ~ сайлантык** «сайлап алганнан соң калганы»; **сайланма** (неол.).

**САЙРАН, сәйран** диал. «один из парных половинных духов» (к. **Тайран**) < тибет. *seyran* id. К. ш. ук

уйг. (Малов 1967: 38*) сейшин* һәм *тейшин* «ике изге фәрештә». К. башк. *сайран* «сыңары туганда үлгән игезәк».

**САЙРА-У** «петь (о певчих птицах); краснобайствовать» < гом. кыпч., уйг., чыгт., шор., хак. һ.б. *сайра-,* башк. *һайра-* «сайрау; шыкырдап чутылдау һ.б.ш.» < бор. төрки (ДТС: 481) *sajra-* «сайрау; юкны сөйләү»; Котбидә *булбул мәңизлик [кебек] сайр этсәңән...,* димәк *сайра- < сайр-а-*; чыгт. (к. Räsänen 1969: 395) *sajra, sajrı, sajruu* «сандугач» (моннан чыгып фикер йөрткәндә, *сайра-у* «сандугачлану» кебегрәк була). М. Кашгари буенча (DLT II: 357, III: 194) *sayra-* фигыле *sajık* «хыялый» нигезеннән, к. Ә. Ясәвидә (49 хикмәт) Аллага гашыйк кеше *Язын-кышын былбылайын валәһ булып [мавыгып], Сайы-рай-у Шахдин шахка [ботактан ботакка] кунар, дуслар.* Монда *-рай* аффиксы *аңгырай-, миңгерәй-* кебек сүзләр белән чагыштырганда беленә. Монг. *саир-ха* «мактану» ← *сай* «яхшы шәп» < кыт. *сань, шань* «яхшы, шәп» дип аңлатыла, к. ССТМЯ II: 5. Чыннан да, ихтимал, *сайра-, сайыра-* бор. төрки, чыгт., госм. (Радлов IV: 288 һ.б.) *сайа-, сайы-* «мәрхүмнең фазыйләтләрен мактау» сүзенең интенсивлык формасыдыр, чаг. *җәй-ү → җәйрә-ү, чәч-ү → чәчерә-ү* һ.б. Чаг. монг., госм. к. **Сайла-у. Саин** «хөрмәтле», *сайы* – «мактау» ← *сай* «яхшы, шәп».

Дерив.: **сайрал-у** (күч. мәгъ.), **сайран-у, сайраш-у, сайрат-у; сайрар (кош)**, диал. (ТТДС I: 358) **сайран** «сайрар, сайраучы». ЭСТЯ VII: 155.

**САЙСА** (ТТДС I: 358) «ухаб, рытвина, ямина (на дороге)», чаг. башк. (БТДҺ: 266) *сай* «ике тау арасы» < **чай* (к. **Чай**). **Сайса < чайча** булса кирәк, ягъни бу сүз башк. теленнән сирәк алынмаларның берсе.

**САК I** «осторожный; бдительный; охрана» > мар., удм. *сак* id. < гом. кыпч. *сақ,* башк. *һақ* < уйг., чыгт., хак., угыз., бор. төрки *saγ* «тере; сәламәт; бөте́н» > гом. кыпч. *саw* «сау». Шулай итеп бор. бер сүздән кыпчак телләрендә ике сүз – **сак** һәм **сау** этимологик дублет килеп чыккан. Чаг. ш. ук чув. *сыхӑ* «сак», *сывӑ* «сау» (бу сүзләр чув. теленә кыпч. – бор. тат. теленнән алынганнар).

**Сак** нигезенең фигыль коррелянты да бар, к. иске шигъ. мәкальдә: *Егет дигән сүз алынган егәрдән, Егет булсаң, сакын артка чигәрдән.* Гомумән, бу сүз бор. *са-* «санау, уйлау» тамырыннан булса кирәк.

**Сак** бик продуктив нигез: **сакла-у, саклык, сакчыл** һ.б. Мәзкүр дериватлар төркиләргә күрше телләргә дә (фин-угор, Кавказ һ.б.) алынган. К. **Сагай-у, Сагала-у, Саклау, Сакчы, Сау.** Будагов I: 688–689; Федотов II: 77–78; ЭСТЯ VII: 156–157.

**САК II** (**бук-сак** парлы сүзендә) «навоз» ~ як. *саах* id., ихтимал, бор. төрки *сағ, сақ* «балчык» белән бердәйдер (к. **Савыт**).

**САК III: колакка сак, сакбай** «глуховатый» – бор. төрки **саңк* нигезеннән, к. **Саңгыра-у.**

**САКА I** «бита (в играх с метанием палок, козонков и т.п.)» к. **Сага.**

**САКА II: сака кошы** «щегол», (РТС 1931) «щеглёнок» ~ төр. *saka kuşu* «купшыл» (Carduelis carduelis) ~ иске тат., себ. (Тумашева 1992: 183) **сақа** «интендант; маркитант» < госм., төр. *saka, sakka* «ярдәмче гаскәри (интендант һ.б. хезмәтендәгеләр)» – аларның формасы сары төсләрдә булган. Хәз. Төркиядә *saka* «өйдән-өйгә йөреп сату итүче». Түбәндә гар. теленнән кергән сүз: *сиқ* «җәлеп итү» тамырыннан.

**САКА III,** диал. (Тумашева 1992: 183) **сағау, сақау** «мыт (болезнь скота, выражающаяся в опухле шеи, гноении ушей, слюнотечении)» > чув. (Ашмарин XI: 16) *сака, сакав*, удм. *сакаул*, башк. *һақа, һақау* id. < гом. кыпч., чыгт. (к. Радлов IV: 243) *сақа*, *сақау, сағау* id., гомумән – «муен шеше» ~ чыгт., госм. *сақақ, саңақ,* кырг. *сағақ* «икеле ияк; зоб», к. ш. ук тат. (ТТДС II: 261) **сақа** «сарык, кәҗәләрнең ияк асты сыргасы» > мар. *сага > сога* «әтәч сакалы», алт. диал. *саңат, саңыт* «колак асты бизе; муен шеше» – бор. **санқ* тамырыннан, к. **Сакау, Саңак**. Räsänen 1969: 396.

**САКАЛ** «борода», күч. «бородка топора, ключа и т.п.» ~ башк. *һақал* id., ш. ук (Руденко С. Башкиры. М., 1955: 182) «нагрудное украшение женщин, состоящее из многорядного сбора монет либо из горизонтального ряда разноцветных полос» < гом. кыпч., уйг., алт. һ.б. *сақал*, төркм. *сағғал, сақғал, саққал* ~ яз. монг. *sakal* > хәз. монг. *сахал* > бур. *һахал* «сакал», к. ш. ук сол. (ССТМЯ II: 56) *сағала*, маньч. *салу* id. Гомумән, бу сүзнең фонетик вариантлары күп һәм ул күп күрше телләргә дә кергән, к. Федотов II: 69 (чув. *сохал > сухал* id. тур.). Башк.

*һақал* һәм бур. *һахал* уртак (*с-* > *һ-* күчеше булган) чыганактан килә. ЭСТЯ VII: 164–166.

*Сакал* (гомуми закончалык буенча) < *саккал* < *саңкал,* безнеңчә, тәүдә «ияктәге чәчсыман йон» мәгъ. булмаган – моны башк. (ш. ук тат. диал.) «муенга, ияк астына тагылган хатын-кыз бизәнчеге» мәгъ. күрсәтә: хатын-кыз чын сакал тагып бизәнсә, бик сәер булыр иде, чөнки бизәнү әйбере функциясе буенча хатын-кызлыкны белдерергә тиеш. Төркологлар фикеренчә, *сакал* < *саккал* монг. телләреннән алынган (*сак* һәм *-кал* аффиксы), әмма нәкъ менә типик монгол – сакалсыз кеше. Бор. монг. *саккал* < **саңкал, саң* «күпкатлы муенса, бергә киелгән күп муенса» сүзеннән, шундый муенса үзенчәлекле «календарь» – көмәнгә узудан саклану максатында «хәтәр» көннәрне билгеләү өчен дә кулланыла алган (этнографик әдәбиятта күренгәнчә, шундый муенсалар төрле халыкларда очраган); к. ш. ук төркм. (ТДГДС: 154) *сақақ* «авыз ябулыгы»; ~ бор. төрки (ДТС: 486) *saqaq* «ияк асты» эвенк. (ССТМЯ II: 61–62) *саң* «кирт, киртләү», эвен. *һаңун* < *саңун* «киртле агаччык; календарь» ~ кыт. *саң* «чут (чыбыкчыкларга тезелгән төймәләрдән гыйбарәт хисаплау әсбабы)». Һәрхәлдә **саң* тамыры беленеп тора, к. **Саңақ** (формасы – төзелеше белән бизәнчек «сакал»га охшаш сулыш органы), кырг., чыгт., госм. *саңақ* > *сағақ* «икеле ияк» > башк. *һағақ* «балта сакалы; катмарлы агач гөмбәсе», каз. *саға* «тамак, бугаз; кылыч яки хәнҗәр сабы (аңа үтерелгән дошманнарның саны киртләп билгеләнгән)» < **саңға* (?). К. ш. ук **Сака III, Сагалдырык, Сакау, Сакалтай.** Räsänen 1969: 396; Eren: 350–351 (безнеңчә); ЭСТЯ VII: 164–165 (төрле фаразлар китерелә).

Дерив.: **сакаллы, сакалсыз; сакалбай.** К. түбәндәгене.

**САКАЛТАЙ** «бородатый, бородач», диал. (ТТДС II: 261) «нагрудное украшение женщин» << монг. *сақалтай* «сакаллы» (*сакал* монда «муенса; түшлек», к. башк. *һақалта* «муенса».

**САКАТ,** диал. **сақыт** (Ставрополь татарларында, к. ш. ук Арсланов 1988: 91) «увечный; повреждённый (об органах тела)» ~ к.-балк., ком. *сакат*, төр. *sakat, sakıt* < гар. *сäқаṭ* id. Гомумән, көньяк төрки телләрендә еш очрый. К. **Сикыт.** Будагов I: 615.

**САКАУ [са$^{o}$қаw],** тат. диал. (Тумашева 1992: 183) **сағау** «косноязычный», (ТТДС II: 261) «немой» > мар. *сакау* id., *шага, шога* (Упымарий: 365) «сакау; тотлыгучан» < гом. кыпч., башк. *һақау,* төркм. *сакаw* id., чаг. удм. (< тат.) *сакаул*, каз. *сакау*, кырг. *сақоо* «колыннарда булучан муен шеше» < (сары уйг., госм.) *сақағы, сақагу*, иске монг. *сақагу* «сака (муен шеше), маңка чире», к.-балк. *сақав* «маңка авыруы» h.б. **саңгырау** (к.) сүзе белән тамырдаш булса (ә бу бик ихтимал), бор. **саңқа-ғу* яңгырашыннан. К.-калп. *шақалма* «сакау авыруы» оригиналь вариант. К. **Сака**. Чаг. **Сакал**.

Элекке заманнарда, күрәсең, муен җыерчыкланып, маңкалап чирләү киң таралган булган һәм шуннан кеше сакаулана торган булган. К. Räsänen 1969: 397). Федотов II: 18; ЭСТЯ VII: 161–162.

**Сакау** сүзе күп күрше телләргә кергән (мәс., абаз. *сакау* «ат чире»).

Дерив.: **сакаулык, сакаулан-у.**

**САКДУШ** (әстр.) «доверенное лицо при заключении брака, а также при обрезании; кум, крёстный отец» ~ төр. (Будагов I: 614, 687) *сақдуш, сағдыж, солдут* id. (бу сүз барча Кавказ телләрендә диярлек «бүтән халыктан булган дус» мәгъ. очрый). «Мөхәммәдия» китабында (XV г. төрекчәсендә) Мөхәммәт Хәдичәгә өйләнгәндә «*Әбү Бәкер Иденде сани әснайн*, *Камәр сагдыч, күйәгү шәмсе кәүкин*» диелә. Төрекләр үзләренең хәз. диал. *sagduç* сүзен туйда кияүнең уң ягында утыручы дусты дип аңлаталар, к. Räsänen 1969: 393. Ләкин монда әгәр *sag* «ун як» булса, *-duç* элементы аңлашылмый кала. Бор. төрки (ДТС: 480) *saγdïč* «тугры дус», *suγdïč* (ДТС: 517) «кышкы мәҗлес». Безнеңчә, *сағдыч* ~ *суғдыч* «якын дус» **сугди** сүзеннән: сугдлар белән төркиләр озак гасырлар дәвамында бергәрәк яшәгәннәр: сугдлар утрак, төркиләр күчмән булганнар. Тарихи әдәбиятта бор. төркиләрнең бик теләп бүтән халыклар, бигрәк тә сугдлар белән кодалашулары тур. әйтелә (шундый гамәлкылыклар нәтиҗәсендә сугдлар X г. азагына төркиләшеп бетәләр, әмма бик күп төркиләр ирани телләргә күчеп, гарәпләшеп, этник йөзләрен югалталар; бу хакта З. Вәлиди күп язган).

**САКЛА-У** «охранять; беречь, приберечь» (мар., удм. *сакла-*), башк. *һақла-* < гом. кыпч. *сақла-* id. **сак I** сүзеннән. Исемләшкән исем фигыль *саклау* (> мар. *сакла,* к. Исанбаев 1978: 25) «кисү тыелган урман; сагалау; каравыл; әманәт» > чув. *сыхлав* id. киң таралган. К. **Сак I.**

Дерив.: **саклан-у, саклат-у, саклаш-у; саклавыч, саклагыч** h.б.

**САКМА** миш. «пограничная военная дорога (вдоль реки Пьяна)», *сакма урам* «улица с канавами» ~ рус. *сокма* > *сакма* «сакма; арба эзе; сукмак», кр.-тат. (Будагов I: 710) *соқма* «таулардагы зур юлдан билгесез урыннарга аерылып киткән сукмак» ~ каз. *соқпа,* башк. *һуқма йул* «сукмак» ~ уйг. *сохма* «сукмак», ш. ук «балчыктан ясалган (дивар, өргә)» ← *соқ-* «сугу» сүзеннән дип уйланыла (Фасмер III: 547; Menges 1961: 111). Әгәр шулай булса, миш. *сакма* рус теленнән кире алынма булып чыга. Миш. *сакма яка* «алмаштырмалы яка» < *сапма яка* (к. **Сап-у**), ягъни бөтенләй бүтән нигездән. К. **Сукмак.** Аникин: 476–477.

**САКМАЛ** диал. (Оренбург) «стадо овец с ягнятами» ~ рус. диал. *сакман, сакмал* ~ каз., хак. *сақпан* id., кырг. *сақман* «бәрәнле сарыклар төркемен саклаучы», үзб. (ЎХШЛ: 229) *сақман* «сакчы, каравыл», каз. (ҚТДС: 279) *сақпан* «игенгә төшкән кошларны куркытучы җайланма», уйг. (Будагов I: 615) *сақман* «зәңгәрт, сапкан» ← **сақ** (к. **Сак**). Аникин: 479.

**САКСАВЫЛ [саºқсаwы̆л]** «саксаул» < чыгт. *саксаwыл* < *саксағыл* id. ← уйг. *зак, сак*, монг. *заг, узаг* «саксавыл; яфраксыз чүл агачы» (Номинханов 1975: 291) тамырыннан булса кирәк, к. як. *сахса, сахсай* «коргаксыган; чытырман». Рус. *саксаул* тур. к. Дмитриева Л.В. О некоторых заимствованиях в тюркских языках // Языки народов Сибири. М., 1980: 85–86. Гомумән, *саксаwыл* – монгол сүзе, к. Аникин: 506–507.

**САК-СОК, Сак белән Сок** «две мифические птицы, в которые были превращены два брата по неосторожному проклятию матери, которой надоели вечные ссоры братьев между собой; вид реальной птицы» (М. Гафури. Сайланма әсәрләр, II, 1953: 65) ~ башк. *һақ* «йокычан ябалак, чыелдык ябалак», чув. *сак-сук* «сак-сок» (к. Трофимов Г.Ф. Бытование пеита сак-сук // Чуваши Приуралья. Чебоксары, 1989: 112–123). Бу сүз (сүзләр) тур. тат. филологиясендә күп кенә фаразлар язылды. Безнеңчә, *сак* һәм *сок* тур. легенда ахыр чиктә һиндләрнең *шака* һәм *шука* дигән ике гандһарва (индуизмда ярымилаһ) хакындагы легендасына тоташа. Ул гандһарваларны парлашып җырлау белән мавыкканнары өчен Индра тәңре каргап, *шака (< шарика, шарак, сарика)* «майна кошы» һәм *шука* «тутый» дигән кошларга әверелдергән (ошбу кошлар, кешедән отып, сүзләр әйтә алалар), к. Das Papagaienbuch. Berlin, 1981: 14–15, 297, 326; Бакиров 2008: 31–32 (**Сак-сок** риваятенә охшаш мисаллар китерә).

Идел-Урал регионыннан тыш, чаг. фар. *сак* һәм *сакхәр* яки *хаз-баз* (Хайател-хайван II: 32–33) кошлары тур., алт. *юзаак* һәм *юзак*, кыт. *шэнь-шан*, кырг. *сэйнэк-кукук* тур. легендалар һ.б. – шул мотивны кабатлыйлар.

**САКЧЫ** «охранник; караульный» < гом. кыпч. *сақчы* (> башк. *һақсы,* нуг., каз., к.-калп. *сақшы*) id. – гом. төрки характерындагы сүз, к. бор. төрки (ДТС: 486) *saqčï* id. – бор. *сақ* «каравыл; каравыл мөддәте, ике сәгатьлек вакыт арасы (тәүлекнең уникедән бер өлеше)» сүзеннән. Ул бәлки гом. алт. *са-* «санау; уйлау» фигыленнәндер. Бу сүзнең борынгылыгын чув. *сыхчӑ, сыхча* «химаяче фәрештә» (к. Ашмарин XI: 121–124) ~ чув. *суксо, шукчо* «фәрештә» сүзе дә раслый. Бу сүз бор. заманда «галиҗәнаб» мәгъ. булган, к. бор. рус. *сагчий* «сановник», к. Фасмер III: 543.

Себ. (Тумашева 1992: 184) **сақчы** «өч япьле сәнәк», ихтимал, бор. сакчылар («часовойлар») тотып торган корал атамасыннан киләдер.

Дерив.: **сакчылык.**

**САКЫ, сакь** (*-а-,* ләкин *-қ* түгел) иск. «улика, юридический довод» < төр. *sak* < гар. *сакк* id. К. **Сака II.**

**САКЫЙ** «виночерпий» < гар. *сāқӣ* id. ГТРС: 497. Бор. поэзия телендә бу сүз бик актив кулланылган. Хәз. себ. (ЗДС: 557) **сақы** «су ташучы». К. **Сака II.**

**САЛ** «плот» ~ башк. *һал* id. < гом. төрки *сал,* бор. төрки (ДТС: 482) *sal* > як. *аал* «сал; эченә салам тутырылган толыннар өстенә тезелгән такталардан торган йөзмә күпер» ~ чув. *сулӑ* < *солӑ* < болг. **салы* > мар. *шал, шалы* > *шоло* id. ~ бур. *һала, шала*, тув. *шалаа* «сайгау, сал», бур. *салаа* «салдау» һ.б. К. ш. ук мар. *салке* «сал», алт. *салтым, салтың* «идән, сайгау», тув. *салдак* «сал» һ.б. *Сал* сүзе монг. телләрендә дә очрый һәм венг. теленә һ.б. да кергән. Башк. *һал* ~ бур. *һала*, як. **һаал* > *аал* «зур кимә, сал, кәрап» уртак чыганактан килә. Радлов IV: 343; Räsänen 1969: 397. Рус. *сал* «кечкенә сал» тур. Аникин: 478; ЭСТЯ VII: 177.

*Сал* сүзенең тамыр бәйләнешләре ачык түгел (чөнки ихтималлыклар күп), чаг. **Салдау, Саллы, Сал-у.**

**САЛА I** «ряд ветвей (по кругу или по вертикали); отроги гор; кисть руки с пальцами; ряд добавочных строк при плетении лаптей», «приток реки» (Будагов I: 689; видимо – «ряд притоков») ~ башк. *һала* id. < гом. кыпч., алт., шор., уйг., як. һ.б. *сала*, кырг., алт., тув., монг. һ.б. *салаа* «улак, колаша», *салаға* «тармак яки тармаклар рәте, бармаклар, бармак аралары; елга кушылдыгы һ.б.», каз. (ҚТДС: 280) «тезелеп киткән вак арыклар – буразналар арасы» (төрле телләрдә аерым мәгъ. үзенчәлекләре бар) < (хак. диал., монг.) *салага* id., чаг. ш. ук чув. *сула* < *сола* < *сала* «саңак; беләзек, манжет, ишек янагы». Räsänen 1969: 397 (кумд. *salaγa* «бармак» сүзеннән башлый). Радлов IV: 349–351; Пекарский: 2036; Гарипова 1998: 105–106. К. **Салабаш, Салаш.** Рус. *салаир* «таучагыллы җир» < төрки *сала йир* тур. Аникин: 478–479 (шунда ук **сала** сүзе тур. әдәбият); ЭСТЯ VII: 177–178.

**САЛА II** диал. «село» < гом. кыпч. *сала* id. кыпч. телләрендә XIV г. бирле билгеле (мәс., Котби телендә). Бор. рус теленнән булса кирәк, к. Бушаков В.А. Термины, обозначающие селения и крепости, в топонимике Крыма // СТ № 2, 1985: 28–30; Добродомов 2008: 198–200.

Кайбер тат. телчеләре, ш. ук Егоров (1964: 176) бу сүзне рус сүзе түгел димәкчеләр. Уйг. < гар. *сäра* «авыл». Федотов II: 7–8.

**САЛАБАШ** (М. Гафури, гомумән еш очрый) «ряд связок льна, хмеля или коры липы, положенных в воду (озеро, пруд и т.п.) для мочения» ~ башк. *һалабаш* id. Ачык түгел. Ихтимал, **сала I** белән бәйледер. Диал. *саламбаш* id. халык этимологиясеннән булса кирәк.

**САЛАВАТ [ca°лаwат]** «восхваление пророка Мухаммеда», иск. «амнистия» < гар. *ṣalāwāt* id. Бу сүз төрки телләрдә төрле күч. мәгъ. алган, к. кырг. *салабат, салават* «бөеклек, олпат; рухи биеклек, явызлыкны оныта белү» (чаг. тат. *үткән эшкә салават*) һ.б. **Салават күпере** (сөйләшләрдә **салават** кына!) «Алланың гүзәллек билгесе» мәгънәсеннән килсә кирәк. Бу сүз монг. *солоңут* ~ алт. *солоңгу* «салават» урынына килгән (к. **Солан**).

**САЛАВЫЧ, Салагыш** название деревни в Агрызском районе Республики Татарстан < мар. *салауз (йумын салауз)* «тәңренең мәсьүл фәрештәләренең берсе» (Paasonen 1939: 203) << бор. төрки *jalavač* ~ *jalafar* «илче, адвокат; пәйгамбәр». Мар. теленә болг. теленнән кергән. К. **Ялавач.**

**САЛАК, салакай** (ТТДС I: 359) «вялый, грязнуля» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 267, 370) *салақы, һалақа, һалақы,* каз., кырг., уйг., як. *салак* ~ *салаң* «сәлкәү, гамьсез», төр. *salak, sallak* «ахмак кыяфәтле», *salla-* «барысына кул селтәп, тик йөрү» ← ***сал** ономопоэтик тамырыннан, к. **Салпы, Сәлен-ү** һ.б. К. ш. ук монг. *салаң, салан, салангай* «салак». Räsänen 1969: 997; ЭСТЯ VII: 178–179.

**САЛАМ** (башк. *һалам*) «солома» < гом. кыпч. *салам* бор. заманнарда ук русчадан төрки телләргә кергән сүз. Räsänen 1969: 397.

**САЛАМТОРХАН** «герой сказок – бедняк, разбогатевший благодаря хитрости своей кошки (либо лисы)» («кота в сапогах» в европейских вариантах), күч. «хитрый хвастун» < *салам турқан* «салам ефәк» сүзеннән: *турқан* «ефәк», к. **Турка. Саламторхан** дигәндәге *-х-* авазы бу сүзнең болг. теленнән таралганлыгын күрсәтә шикелле.

Дерив.: **саламторханлык.**

**САЛАМАТ I** (Г. Толымбай) «кнут (с ремнём в конце); палка с хлопушкой» ~ башк. (БТДҺ: 267) *саламат* «бик озын чыбыркы». Чаг. ш. ук мар. *cáла, caлó, cóла*, удм. *сюло* «чыбыркы». К. **Саламат II**. Федотов II: 8.

**САЛАМАТ II** (ТТДС I: 359) «болтушка; саламата (мука, зерно, крупа, зажаренные на сале)» ~ башк. (БТДҺ: 267) *саламат* «уч төбе кадәрле генә җәймә» ~ каз., алт. *саламат*, төркм. (ТДГДС: 155) *саламатыр*, аз. (АДДЛ: 358) *сәләмә* «саламат», як. *саламаат, һаламаат* «майда кыздырылган ит, балык һ.б.» (к. ДСЯЯ: 202, 226). Бу сүз, ихтимал, каз. (ҚТДС: 105–106) *жаламат, жаламык* «бутка», алт. *дьалама, чалама, йалама* «бауга тезелеп пешерелгән ит кисәкләре – тәңреләргә корбанлык», гомумән «явыз рухлардан саклагыч лента (аңа төрле төстәге тукымалар асыла)», тув. *салбак* «төрле бизәкләр асылган һәм корбанлык урынын уратып, казыкларга беркетелә торган бау», хак. *чалама, чалаңма* «шаман тасмасы» < бор. төрки **җалаңма* id. сүзләренә баглыдыр. К. ш. ук **Саламат I.**

Бу чагыштыруларда фонетик кыенлыклар бар: 1) *җ-* >> *с-*, бу күчеш як. һәм мар. телләрендә генә булала, һәм, димәк, *саламат* (рус-слав. вариантлары *саломат, соломать, саламаха*, к. Фасмер IV:

549) мар. яисә як. теленнән булып чыга, ләкин тарихи җәһәттән бу хәл мөмкин түгел; 2) *саламат(а), саламатыр* вариантларындагы соңгы *-т, -та, -тыр* «элементлары» аңлатуга мохтаҗ. К. **Шалама.**

Ихтимал, *саламат* < **цаламат* < **чалама-т* ~ *җалама-т* бор. монг. диалектларыннан таралгандыр.

**САЛАТ I** иск. (Насыйри I: 230) «солод» < рус. (рус. *сладкий* «татлы» сүзе белән тамырдаш).

**САЛАТ II** «салат» < рус. < фр. (Фасмер III: 549) яки ним., ахыр чиктә – ит. *insalata* «тозлаган» (*sal* «тоз») сүзеннән, к. Kluge: 781.

**САЛАЧА,** диал. (тпк.) **саласа** «волокуша; дроги» < башк. (БТДҺ: 267, 370) *саласа, һаласа, һалаша* id. – **сала I** сүзеннән (**сала-ча**) булуы бик ихтимал (аның «чошлар, ботаклар тезмәсе» мәгънәсеннән, к. Типекәй якларында «*ике каенны ботаклы көенә кисеп атка йигәләр дә, саласа була анысы»*, к. ТТДС II: 261).

Рус. *салазки* төрки **салаҗа < салача** нигезеннән булса кирәк (рус сүзенең канәгатьләндерерлек этимологиясе юк, к. Фасмер III: 548). Һәрхәлдә тат. **салача** сүзен рус. *салазка* сүзеннән чыгарып булмый. К. **Сәнәскә** (аерым сүз). Тат. диал. (ЗДС: 592) **сылызы** «салача» – ялгыш язылыштыр.

**САЛАШ** (Х. Госман телендә) «нары, лежанка на ветвях деревьев», (Халиков 1981: 83) «сарайчик для инвентаря», (ДС II: 161) «шалаш», (ТРС 1931: 258) «палатка», (Гордлевский 1927: 9) «молельня» ~ төр. (Будагов I: 702; Steuerwald: 792) *salaş* «яшелчә кибете; тукталыш урыны, шалаш» – **сала I** белән баглы булса кирәк, к. алт. (Баскаков 1972: 245) *салач* «бармак; бармаклар теземе». Чаг. **Салача,** к. **Шалаш.**

**Салаш** сүзен рус. *шалаш* сүзенә кайтару фонетик җәһәттән акланмый (тат. һәм төр. телләрендә *ш* > *с* күчеше юк; андый күчеш нуг., каз., к.-калп. телләрендә бар, ләкин тат. һәм төр. сүзләренең нуг. яки каз. теленнән алынуы бик шикле, каз. телендә андый сүз теркәлмәгән дә).

Рус этимологик сүзлекләрендә *шалаш* венг. теленнән алынма диелә. Безнеңчә – төрки телләрдән.

**САЛДАУ I** (Илеш р-ны, Башкортстан) «мостки у реки, озера» ~ үзб. *салдов [салдоw]* «паром», төркм. (ТДГДС: 155) *салдоv* «бурлак арканы» (дөресрәге «паром арканы» булырга тиеш), шор. *салдам, салдым* «салдау», «елга аша салынган агач», тув. *салдақ* < *салдаг* «сал», *салдам суг* «кичү» – **сал** (к.) сүзеннән, ясалышы ачык түгел. К. монг. *салдаг* «сүтелмәле күпер», *салда-* «салда йөзү» – күпмәгънәле **сал, сала** «аеру, аерылу, таркау, таркалу, сүтү һәм җыю» тамырыннан, к. **Салак.** К. **Салдау II.** Räsänen 1969: 398 (бик аз гына); Eren: 352.

**САЛДАУ II** (ТТДС II: 261) «острога, пика для ловли рыбы» > мар. (Исанбаев 1978: 42) *салдау, салда* id., рус. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *салда* id. – башк. *салдау, һалдау* id., *һалтау* (БҺҺ II: 200) «аю сөңгесе». **Салдау I** белән баглы (метонимик мәгъ. күчеше; эре балыкны ыргакка эләктерү өчен күперчек ясаганнар, күперчектән торып аулау **салдау** дип атала башлаган, бу мәгъ. ау коралына күчкән.

**САЛИБ** иск. «крест» < гар. *ҫалӣб* id. ← *ҫлб* «терәү, терәтү». Шуннан ук **сальбия** (к.) «шалфей (үсемлек)» – чәчәге хачсыман булганга бугай; *салиби* «хәчтерүш, тәре йөртүче» һ.б. (бу *ҫлб* тамырыннан берничә халыкара таралыш алган сүз ясалган).

**САЛКЫ** (**элке-салкы** парлы сүзендә) «вяло; ни шатко, ни валко» < гом. кыпч., к. башк. *һалқы,* каз. *салқы*, кырг. *илкий-салкый,* төр. *salkı* id. ~ чув. *салху* «күңелсез; кәефсезчә, кәефсезлек». Федотов (II: 10) бу сүзне **сағын-у** (к.) сүзе белән багламакчы. К. **Салак.**

**САЛКЫН,** себ. (Тумашева 1992: 84) **салғым** «прохладный; холодный; мороз» (в ряде говоров «прохладный, прохлада», а в значении «мороз» употребляется слово **суык**) > удм. *салқын, салқым*, мар. диал. *шолкын, солкын*, чув. (Ашмарин XI: 177–178) *солхӑм* > *сулхӑм, сулхӑн* < гом. кыпч. *салқын, салқым*, куман. *salkun*, уйг., үзб., чыгт. *салқин*, алт., тув., як. *салғын,* башк. *һалқын* «салкын, салкынча; (көчсез) җил» ~ монг. *салхи, салхиин*, бур. *һалхин*, иске монг. *salkin* id., эвенк. (< як.) *салгин* «һава, тын» ~ бор. төрки (ДТС: 483) *salqïm* «салкын» һ.б. як. телендә сакланган *салкы-* «җилләү» сүзеннән ясалганнар, *сал//тал* тамырыннан (к. **Җил**) *салқын* < *салқығын* «җилле», **салкы** «җил исеп алу», ләкин һәр телдә боларның мәгънәләре үзара керешкән, буталган. Пекарский: 2044, 2053–2054; Räsänen 1969: 398; ССТМЯ II: 58; Федотов II: 60–61; ЭСТЯ VII: 182–183. Рус. диал.

*салгун* «сүрән көн» тур. Аникин: 479. Фар. *салҗин* тур. Doerfer I: 341. Гомумән, **салкын ~ салкым** сүзе төрки телләрдән күп кенә күрше телләргә үтеп кергән һәм ул телләр тур. хезмәтләрдә искә алына. Башк. *һалҡын* һәм бур. *һалхин* уртак чыганактан. Чаг. **Салкы, Салпы**.

Дерив.: **салкынлык; салкынча́** һәм **салкы́нча; салкынай-у, салкынлан-у; сап-салкын** < ***салкын-ба-салкын.**

**САЛЛА-У** (ДС III: 134) «тяжело нагружать» < гом. кыпч., к. ком., төркм. *салла-,* төр. *salla-* «аркага йөкләү; үлчәүгә салу» – ***сал** «авырлык» нигезеннән, к. **Саллы.** Төрки телләрдә икенче бер **салла-у** «селкетү, тибрәтү; болгау» киң таралган (к. **Сәлен-ү**). М. Рясянен (Räsänen 1969: 398) чув. *сулла-, солла-,* мар. *шалла-* «ташлау» сүзен шул *салла-* нигезенә нисбәтли.

**САЛЛЫ** «весомый, полновесный» ~ төр. *sallı* «иләмсез зур» ← **сал* «зур авырлык» – гом. төрки **сал** тамырының исәпсез мәгънәләренең берсе булса кирәк, к. **Салла-у, Салмак.**

**САЛМА** «салма – кусочек тонко скатанного теста, который кладётся в суп вместо лапши» > чув., мар. (Саваткова: 141) *салма* < гом. кыпч. *салма,* башк. *һалма* id. ← **сал-у** (к.). Кыпч. телләрендә **салма** дигән нигез күптөрле (мәс., каз. телендә – ҚТДС: 281–282 – җиде төрле) мәгъ. очрый. ЭСТЯ VII: 183–184.

***САЛМАВЫР [са$^{о}$лмаwы̆р]** > башк. (БТДҺ: 371) *һалмауыр* «что-либо громоздкое, тяжёлое; большая дубина; мальчик на побегушках» – төп мәгъ. «сапан-мәнҗәникъ ташы» булса кирәк («йөгереп торган йомышчы малай» мәгъ. шуннан килеп чыга ала), к. кырг. *салмоор* «зәңгәрт; шакул», бор. төрки (ДТС: 482–483) *salïŋu, salŋu* «зәңгәрт». Сүзнең тамыры – **сал-у** (аның «ыргыту, ату» мәгънәсеннән булса кирәк), чаг. **Салмак.**

Дерив.: башк. *һалмауырҙа-у* «ату, ыргыту (мәс., ташны)» – тәүдә «зәңгәрт ярдәмендә ату» булган.

**САЛМАК** «степенный; неторопливый» < диал. (ТТДС I: 360) **салмаҡлы** сүзеннән эллипсис, к. диал. **салмаҡ,** башк. (БТДҺ: 370) *һалмаҡ* «авыр, авырлык», чув. (< тат.) *сулмак < солмак ← сулмаклă, солмаклă* «авыр, салмак, саллы» < гом. кыпч., уйг. *салмаҡ* «авырлык», *салмаклы* (кырг., каз. *салмақты*) «салмак, салмаклы» һ.б. **Салмаҡ** сүзе кыпч. телләрендә күптөрле мәгъ. очрый, мәс., каз. (Радлов IV: 374) *салмақ* «салым; терәк», кырг. *салмаҡ* «кыенлык, авырлык; җәбер» һ.б. Сүзнең беренчел мәгъ. «үлчәүгә салынган авырлык, гер» булган (әлбәттә, **сал-у** фигыленнән), моны сәер генә (төрки нигез, фарси кушымча) уйг. *салмаҡдар* «зур авырлыктагы; олпат» сүзе дә күрсәтә шикелле. К. **Салмавыр.**

Дерив.: **салмаклык, салмаклан-у;** диал. (Тумашева 1992: 184) **салмакла-у** «(үлчәүгә салып) үлчәү», **салмаклан-у** «(үлчәүдәге гер һәм йөк шикелле) тирбәлеп тору».

**САЛПАК** (ТТДС I: 360), **салпан** «вялый; ленивый, но злой» < гом. кыпч., к. башк. *һалпаҡ, һалпан,* кырг., госм. *салпаҡ, салпаң, шалпаң,* нуг., уйг. *салпаң*, ком. *салпан*, алт. *салбаҡ* «салпы, сүлпән» ~ тув. *салбаң* «җилдә селкенеп, җилфердәп торган; салынып торган», кырг. *шалпаң* «шәлперәйгән» һ.б. ← **салп-ы-, салп-а-** фигыленнән, к. **Салпы.**

**САЛПЫ, салбы,** себ. (Тумашева 1992: 184) **салбыҡ** «отвислый, вислый», диал. (ДС I: 161) **салпы** «ленивый; вялый» < гом. кыпч., к. башк. *һалпы, шалбыҡ,* нуг., каз., к.-балк., төркм. *салпы*, кар., ком. *салпу*, уйг., госм. *салпа, салпаҡ* «салпы, сүлпән; мәлҗерәгән» ~ бур. *һалбуу, салбуу*, монг. *салбуу* «салпы». Гомуми модель буенча **салп-ы-г ← *салп-ы* «салпаю» ← *шалп,* (нуг., каз., к.-калп. телләрендә сакланган) *салп* «төшеп, йомшак кына бәрелү авазына тәкълит» сүзеннән, к. Худайкулиев 1962: 91; ЭСТЯ VII: 184–185. Ахыр чиктә *сал* «хәлсез асылыну, бушак булу, селкенеп тору, җилфердәү» онопоэтик тамырыннан. К. **Салак, Салкы, Салпак, Сал-у, Сәлберә-ү, Сәлкәү, Сәлпән, Сәлпе, Шалапай.**

Дерив.: **салпылык; салпай-у, салпылан-у;** кушма сүз: **салпыколак,** башк. *һалпуш, һалпыш* «сәлкәү, мыштыр, мыштырдык». Гом. төрки, монг. дериватлары бик күп.

**САЛПЫР, салбыр** «неопрятный; небрежно одетый; в лохмотьях; вялый, медлительный» ~ башк. *һалбыр* ~ чув. *шалпар* «бушак, салынкы (кием-салым тур.)» < гом. кыпч. *салбыр, салпыр* «салпы киемле» ← *салп* тәкълиди тамырыннан, к. **Салпы**. Чаг. **Сәлпе, Сәлперә-ү.**

Дерив.: **салпыра-у, салбыра-у** «салынып тору» ~ гом. кыпч. *салпыра-, салбыра-* id. (бу сүз *салпыр, салбыр* нигезеннән киңрәк таралган); **салпырлан-у.**

**САЛТ** диал., иск., **салтаң, салтак** «холостой; без семьи» ~ башк. (БТДҺ: 371) *һалтан* id. < чыгт., каз., төр., уйг. һ.б. *салт* «йөксез; бары тик», уйг. **салтаң** «йөксез». Чув., мар. *салтак* «солдат» сүзе дә шуннан булса кирәк (ул тәкъдирдә бу сүз аларга тат. теленнән кергән). «Буйдак > солдат» мәгъ. күчеше **казак** сүзендә дә күзәтелә. Чаг. ш. ук төр. *saltık* «рыцарь, өйләнмичә, дин өчен сугышып йөрүче» (атаклы **Сары Салтык** тур. эпик әсәрләр дә бар). **Сал(т)** нигезе монг. телләрендә бик продуктив: *салта-* «аеру; ялангачлану», *салданг* «ыштансыз», *салдан* «чалт (болытсыз)». Чаг. **Шалтан.**

**САЛТАНАТ** «царское величие и великодушие» к. **Солтан.**

**САЛУ** (**чана салуы**) «раскат, рытвины, ухабы, углубления на санной дороге (особенно к весне)» ~ чув. *солу, сулу*, мар. (Упымарий: 267) *шало, шоло* id. тат. *суалу* «иңү, төшү» (к. **Суал-у**) сүзеннән булса кирәк, к төр. *soğulmak* «елга кимәле иң түбән дәрәҗәгә төшү». *Суалу* > *салу* күчеше һәр ике сүзнең сирәк кулланылуы шартларында бик мөмкин. Чаг. ш. ук рус. диал. *сало* «бозланган кар, бозлак» – тат. теленнән булуы ихтимал.

Дерив.: **салулы, салусыз** (юл); **салула-у** «кыегаеп салуга төшкәләү (чана тур.)».

**САЛ-У** «класть, ложить, положить; снять (с себя) одежду; бить с размаху» (остальные многочисленные значения – преимущественно связанные казуальные и метафорические) < гом. төрки *сал-* (чув. *сул-* < *сол-* < *сал-*) «салу» һәм **сал* (чув. диал. *сол* > *сул*) «авырлык» (к. **Салла-у, Саллы**). Бу сүзнең тәү мәгънәсе «йөк» булуы бик ихтимал, тик ул чагында «киемеңне салу, төс салу һ.б.», ягъни «нәрсәдән дә булса азат яисә мәхрүм булу» мәгънәсе икенче бер сүздән булырга мөмкин (ТТАС II ике омоним *сал-у* бирә), к. монг. *сал-, салу-, сала-* «нәрсәдән дә булса арыну; аерылу» ~ эвенк. һ.б. *салу* id. (ССТМЯ II: 58–59). Әмма *сал-у* «бәрү» мәгънәсе «кую» һәм «өстеңнән ташлау – кием салу» мәгънәләрен берләштерә (ДТС: 482). Гомумән, *сал-* төрки телләргә аеруча хас иң бор. (беренчел) тамырларның берсе. Чаг. ш. ук угыз *сал-* >> чув. *сол-* > *сул-* «селкетү, тирбәтү» (к. **Сәлен-ү**). Будагов I: 190–191 (тәфсилле); Федотов II: 57; ЭСТЯ VII: 173–177.

*Сал-* иң продуктив сүзьясагыч нигезләрнең берсе: **салын-у, салыш-у, салдыр-у** сүзләренең дериватлары һәм к. **Салма, Салмак, Салым, Салын-у, Салыш-у.**

**САЛФЕТКА,** диал. **салфиткә,** (ТТДС I: 364) **сарфиткә,** (ЗДС: 59) **салфит** «салфетка» < рус., сүз нигезе *салфет* ит. *salvietta* «кунак табыны» сүзеннән (Фасмер III: 551), ахыр чиктә **салют** сүзе белән тамырдаш (Kluge: 782). Тат. **сарфиткә** вариантында **сарпинкә** (к.) сүзе белән буталу сизелә.

**САЛЫМ** «обложение, налог», диал. «порция» ~ башк. *һалым* id. ← *сал-у* фигыленнән; *сал-ым* нигезе төрки телләрнең төрлесендә төрле мәгънәдә: чув. *сулӑм* < *солӑм* «авырлык; бәрү; салым-налог; чык төшү; кәрт салу-күрәзәләү һ.б.» (Ашмарин XI: 175), каз., кырг. *салым* «кертем, әманәткә, кассага салынган сәмән», төркм. *салым* «вакыт, момент, форсат», алт. *салым* «закон; язмыш, тәкъдир; порция», тув. *салым* «язмыш; талант; кертем», хак. *салым* «чык» һ.б. «Налог» мәгънәсендә уйг., үзб. телләрендә *салиқ,* кырг. *салык* < *салыг* сүзе кулланыла (иске тат., чыгт. **салық** id.).

**САЛЫН-У** «быть положенным; отвиснуть, провисать; надеяться на своё какое-либо особое качество; предаваться (порочным наклонностям)» ~ чув. *сулӑн-* < *солӑн-,* башк. *һалын-* id. **сал-у** сүзенең төрле мәгънәләреннән. К. **Салыш-у.**

**САЛЫШ-У** «помогать ложить»; күч. «предаваться (порочным наклонностям); симулировать (болезнь и т.п.)» ~ башк. *һалыш-у* id. – күч. мәгъ. *башын (күңелен) (нәрсәгә) салу* «аеруча мавыгу яисә игътибар итү» тәгъбирендәге мәгънәдән килә (шуннан ук – **салын-у**).

**САЛЬБИЯ, салбия** иск. «шалфей (растение)» < гар. *ҫалбийӑ* id. К. **Салиб.**

**САМАВЫР [са$^{o}$маwы̆р],** диал. (ЗДС: 560) **самар, самарау, самрау** «самовар» ~ каз. *самауыр, самаурын* id., кырг. *самоор* «самавыр, чәйханә» һ.б. Рус *самовар* сүзеннән дип карала, ләкин рус сүзе үзе Ерак Көнч. телләрендәге *самаыр* «самавырсыман савыт» сүзеннән дип тә уйланыла. Самавырга охшаш су җылыткыч Кытайда да электән булган (к. **Самар**). Чаг. ш. ук фин. *сампу* «һичтуктаусыз бутка пешереп, ташып тора торган тылсымлы казан», шуннан рус. *сампувар* > *самовар* сүзе килә, диләр.

**САМАЙ I** «самый; уже подросший, не маленький» ~ чув. *самăй*, удм. *самой*, мар. (Иванов, Тужаров: 198; Саваткова: 141) *самай* id. Бу сүзнең Идел-Урал телләрендә таралганлыгы игътибарга лаек; тат. *самай шәп чагы* кебек тәгъбирләрдән булса кирәк. Түбәндә, әлбәттә, рус сүзеннән (*сам* «үзе» дигәннән ясалган).

**САМАЙ II** диал. (ДС I: 158; Тумашева 1961: 188; Арсланов 1988: 91) «висок, косички на висках (как признак девственности)» < гом. кыпч. (ком. һ.б.) *самай,* кырг. *саамай,* башк. *һамай,* башк. диал. (БТДҺ: 374) *һаумай* id., кр.-тат. *samaŋ*, хак. *саңмый,* тел. *сабай* һ.б. Башк. һәм хак. вариантларына караганда, *саң* тамырыннан (к. **Саңак**): ихтимал, **саңмуй*дыр. К. ш. ук калм. *самг, самаг* «толымчык». Räsänen 1969: 399; ЭСТЯ VII: 198 (җавапсыз калдыра).

**САМАЙЛАН-У, самыйлан-у** (ТТДС I: 361) «дурить» ~ башк. (БТДҺ: 371) *һамайлан-у* id. – **самай I** сүзеннән булса кирәк. Чаг. ләкин диал. (ЗДС: 560) **самау** «иркен, буш».

**САМАК** диал. (Г. Рәхим 1923; Мөхәммәтҗанов: 155–159) «песня-увещевание, напевная речь» ~ мар. *шамак, шомак*, чув. *сăмах, самах* «сүз; юкбар сүз». Г. Рәхим бу сүзне гар. *сăмā‘* «ишетү, тыңлау» сүзе белән бәйли. Безнеңчә, **самак̡ < сарк̡амак > сармак̡,** к. **Сармак**. Чаг. башк. (БТДҺ: 368) *һағамак̡* «самак».

**САМАН I** «саман, сырцевой кирпич (из глины, смешанный с соломой)» < гом. кыпч., төр., уйг. *саман* «саман; салам», бор. төрки (ДТС: 483) *saman* «салам» < (тув.) *сабаң, саваң* id., к. каз., к.-калп. *сабан* «салам». Рус. *саман* тур. Аникин: 480; ЭСТЯ VII: 186.

**САМАН II** диал. (Будагов I: 703: **саман юлы** [**саман угрысы (карагы) юлы** дип тә атала] «млечный путь». Легенда буенча, бер кыз (егет) зөфаф кичәсенә ятагы өчен кырдан салам урлап кайтканда, арбасының ике ягыннан *саманы* – саламы коелып калган, ди. К. МНМ II: 424. **Саман** «салам» тур. к. югарыдагыны.

**САМАР** «большая чаша, таз», «самовар» (ТТДС I: 361) ~ башк. (БТДҺ: 37) *һамар* «сыңар тоткалы агач савыт» – бу сүзне рус. *самовар* сүзеннән дию дөрес түгел, к. каз., к.-калп., кырг., чыгт., төркм. *самар* «зур озынча табак; кечкенәрәк күл» (к. Будагов I: 634, 691), **Самар, Самара** елгасы исемен дә шуңа бәйлиләр (Фасмер III: 552), ләкин бу гидроним **Сакмар, Сакмара** белән чагыша. К. ш. ук маньч. *самара* «самар, зур табак», *самаран* «керамик табак» (ССТМЯ II: 99). Тат. диал. **самарау** варианты чыннан да рус. *самовар* тәэсирендә пәйда булган булса кирәк. Нұрмағамбетов: 103–104 (артык күп фаразлар китерә).

**САМСЫРА-У** диал. (РТС 1931; ДС II: 162) «быть не в духе; изнуряться» ~ башк. *һамһыра-, һамтыра-* id. > мар. (Исанбаев 1978: 18) *самсырга-* «сырхау» ← (кырг.) **самсы-,* ~ башк. *һамсы-у, һансы-у* – «йончу»; алт. *самзыл-* «самсырау», бор. төрки (ДТС: 483) *samsït-* «җәберләү; йончыту», маньч. *самси-* «таркалу, таркаулану», *самсирэ-* «тар-мар ителеп, таркалу, таралып качу» (к. ССТМЯ I: 60) һ.б. – сүзнең ясалышына караганда, **сам* тамырыннан. К. ш. ук каз., төркм. (ҚТДС: 283) *самсык,* к.-калп. *самсам* «ахмак» һ.б. Räsänen 1969: 399. Чаг. **Сандыра-у**.

**САМУР** «соболь» («Идегәй»дә) ~ кар., гаг., төр. һ.б. *самур* < гар. *сăмӯр* id. (хәер, бу гарәпчә сүзнең чыгышы да ачык түгел), фар. *сăмӯр* id.

**САН I** «число; числительное, номер» ~ башк. *һан* id. < гом. төрки *сан* < төркм., бор. төрки *san* «сан» ~ болг. **сам* (> венг. *szat;* чув. *сом* > *сум;* болг. *самчы,* шуннан бор. рус. *самчий* «эконом, санчы», к. Фасмер III: 554) ← бор. гом. төрки *са-* «уйлау; белү; санау» (бор. төрки *sa-* «исәпләү, хисаплау», к. ДТС: 478–487).

Бу сүзнең берничә тармак мәгънәсе дә бар. Себ., нуг. *сан* «күп», каз., кырг., төр. *сан* «ун мең; йөз мең»; к. ш. ук **Савым, Саен, Сан II, Сан-у, Сана-у.** Räsänen 1969: 390, 400; Левитская 1976: 9–13; *сан* нигезенең дериватлары тур. Будагов I: 692–693 (тәфсилле һәм мәгълүматлы). Федотов II: 61–62; ЭСТЯ VII: 187–189.

**САН II** «авторитет, почёт; приличие» (к. *сансыз* «әдәпсез») < гом. кыпч., уйг., төр. (һәр телдә сирәк кулланыла) *сан* > удм., мар. *сан*, чув. *сон, сун* «сан, хөрмәт» – **сан I** сүзенең аерым мәгъ. кулланылышы (аналогиясе: рус. *почёт* «санау; хөрмәт»). Рус. *сан* «дәрәҗә» (шуннан *сановник*) төрки телләрдән дип исәпләнелә.

**САН III** «всё тело, стать; бедро, ляжка, нижняя часть тела» < гом. көнб. төрки *сан,* төркм. (ТДГДС:

156) *саан* id. Ихтимал, себ. *саң* «ян як» сүзе белән тамырдаштыр. Гомумән – ачык түгел. ЭСТЯ VII: 188–189.

**САНА, сәнә –** частица, означающая просьбу; «пожалуйста, -ка» ~ башк. *һана//һәнә,* башк. диал. *саны//сәне* (*-чәле* тәэсирендә), нуг., кр.-тат., угыз. *сана//сәнә (сэнэ),* чув. *сам, сама* id. Күп төрки телләрдә юк. Грамматик тикшеренүләрдә төрлечә аңлатыла: *сана < са-ң ла* (Хангилдин, Покровская); *< са-ң, а!* (Баскаков 1952: 478); *< сән, а* (Будагов I: 639) ягъни, соңгы *а//ә* авазы ымлык дип карала. Безнеңчә, монда конверсия: үтенеч кисәкчәсе *сана//сәнә* тат. диал. (миш.) *сана, саңа*, чув., гаг., кар. *сана*, кырг., төркм., уйг. *саңа* «сиңа» сүзеннән (чаг. сөйл. *кара сиңа!; була ди менә сиңа!; бирде ди сиңа!*). *Сана!* «уйла» сүзеннән дигән фараз да бар.

**САНАЙ** диал. (Будагов I: 616; Тумашева 1992: 185) «лук (оружие)»; бүтән телләрдә ачык-аян параллельләре юк; к. башк. *Һанай батыр* (Башҡорт халыҡ ижады. Әкиәттәр III, 1978), тат. **Санай батыр** (Васильев М.А. Памятники татарской народной словесности. Казань, 1924) – әкият герое (һәм әкият исеме); чаг. мар. *шана пӗл, шанан, шонан пыл, сонан пыл, сонар пыл* «салават күпере» (*пыл, пӗл* «күпер»), *Сонар* – әкияттәге батыр. Ихтимал ки, *Санай ~ *Санар ~ Санан* бор. реаль баһадир яисә мәҗүси изге зат исемедер. Тимергалин: 393.

**САНАК** «посох пастуха со счётом скота» (ТРС 1966) ~ каз., к.-калп., кырг., тув. *санак* «исәп-хисап; халык санын алу» ← **сана-у**. *Санак* сүзе «компьютер» мәгъ. тәкъдим ителә.

Дерив.: **санаксыз** (**сансыз-санаксыз**) «исәпсез-хисапсыз», **санакла-у** «берәмләп санау».

**САНАМЫШ** «считалка (в детских играх)» – тат. телендә генә; әлбәттә *сана-у* фигыленнән.

**САНАТ** «вельможа, член российского сената» ~ чув. *çанат* id. – рус. *сенат* сүзеннән (ахыр чиктә < лат.). **Сенат** – бор. Рим дәүләтендә киңәш органы булган.

**САНА-У** «считать по порядку; счесть; считать за (кого)» < гом. кыпч., уйг., алт., тув. һ.б. *сана-,* башк. *һана-* id. ~ монг. *сана-* > бур. *һана-* «уйлау, фикерләү», як. *санаа-* «уйлау, ниятләү» һ.б. *сана-* нигезенең беренче мәгъ. *сан* сүзеннән (*сан-а-*), икенче мәгъ. икенче чыганаклардан килсә кирәк. Башк. *һана-* һәм бур. *һана-* уртак чыганактан килә. К. ш. ук **Сан-у.**

**Сана-** кыпч. телләрендә бик продуктив нигез: **санак, санамыш, санау, санаулы, санаусыз** һ.б.ш.

**САНӘМ, санам** «идол, кумир» < гар. *ҫанӓм.*

**САНДА** (бигрәк тә **анда-санда** сүзендә), диал. (ЗДС: 737) **чәндә** «изредка; поодиночке» ~ каз. диал. (ҚТДС: 284, 366, 381) *санда, чанда, шанда* «сирәк, анда-санда». Бу сүзләрдә *ч-* авазы очраклы түгел, ул оригиналдан – фар. *чанд, чӓнд,* «ничә; бераз» сүзеннән, к. ш. ук төр. *çend* «берничә». Төп яңгырашы *чӓндтӓ* булган; *санда* яңгырашы халык этимологиясе буенча **сан** сүзенә нисбәтләүдән пәйда булган. Ихтимал, *сан* сүзенең «күп» мәгънәсе дә фарсыдан киләдер.

**САНДАЛ I,** себ. **сандала** «наковальня, основание наковальни», диал. «сидение, стул» > мар., удм. *сандал*, мар. (Упымарий: 183, Алатырев 1976: 27) *шандал,* чув. *сонтал, сунтал* «сандал» < гом. кыпч., төркм. *сандал,* башк. *һандал* id. ~ к.-калп., кырг., уйг., үзб. *сандал* «астында күмер янып җылытып тора торган тәбәнәк өстәл» < фар. *санд-дан* «сандал аслыгы, сандал урыны» (*санд* «сандал», *-дан* – төрки *-лык//-лек* мәгъ. кушымча), к. Радлов IV: 304–305.

*Сандал < санддан* сүзе фар. теленнән барча күрше телләргә таралып күп төрле мәгъ. алган. «Урындык» мәгъ. көнч. төрки һәм монг. телләрендә таралган (к. Räsänen 1969: 400), төр. сөйләшләрендә бу сүзнең егермеләп аерым мәгъ. бар (Zenker: 574). К. ш. ук Фасмер III: 555–556; Kluge: 784.

**САНДАЛ II** «румяна, красная краска» > чув. *сантал, сентел*, мар., удм. диал. *сандал* (к. Алатырев 1976: 26) «куе кызыл буяу; купорос», рус. *сандал* «кыйммәтле агач, язу карасы» (Жукова Л. Сандал // Юный техник, № 2, 1972: 36) < төр., фар. *сандал* «үзеннән кызыл буяу да алына торган кыйммәтле, хуш исле һәм ныклы агач – фернамбук агачы дип тә атала» < санск. *candana* > бор. төрки *čindan, čintan* «сандал агачыннан ясалган тәхет» (к. ДТС: 149–150). Фар. *санд, сандӓ* «тимерче сандалы» сүзе дә шул һинд-дравид сүзенә кайтып кала. К. **Сандал I, Сандали.** Федотов II: 63.

**САНДАЛИ** «сандалия, сандалии» < рус. < грек., к. Фасмер III: 556. Ахыр чиктә бу сүз «*сандал* агачыннан ясалган» дигәннән.

**САНДУГАЧ,** диал. **сандыгаш, сандлуғач** һ.б. «соловей» (бик күп күч. мәгъ., к. ЗДС: 560) > мар., удм. (Исанбаев 1978: 21, Насибуллин: 136) *сандугас',* чув. диал. *шантукаç, сантукаç* id. < чыгт., уйг., кар. *сандугач,* башк. *һандуғас,* бор. төрки *sanduwač,* алт. диал. *сандыгач, сандыгаш,* каз. *сандуғаш*, Котбидә *зандаwач,* к.-балк. *санвач* һ.б. id. сугд. *zntwčh* «татлы авазлы» сүзеннән (к. Clauson: 837) булса кирәк. Тат. телендә чагыштырмача соңгы алынма икәнлеге икенче иҗектә *-у-* булуыннан күренә. ЭСТЯ VII: 190–192; Сафина 2006: 47–48.

Алт. диал. *сандык* «сандугач» (Радлов IV: 307) *сандыгач* id. сүзеннән кыскартылган булуы ихтимал.

Дерив.: **сандугачлы, сандугачсыз; сандугачлык.**

**САНДЫК,** диал. **сондык** ~ башк. *һандыҡ* > мар. *сандык, сондык* «сандык», *шондык, шандык* «тәмәке кумтасы», удм. *сандык*, чув. *сантăк, сунтăх* «сандык, әрҗә, киштә» < гом. кыпч., госм. *сандыҡ,* чыгт., уйг. *сандук*, госм. *сандыҡа* «сандык; таш сандык» < фар., гар. *сандуҡ* id., һинд телләреннән таралган (Крачковский: 353). Рус. *сундук* < төрки (СС) *sunduk* id. Тат. диал. *сŏндŏк* варианты рус теленнән кире алынма булуы ихтимал. Räsänen 1969: 401; Федотов II: 63.

**САНДЫРАК** «бред; тот, кто говорит чепуху, бред» (*саяк-сандырак* «бестолковый врун», к. ТТДС I: 357) < гом. кыпч. *сандыраҡ* id., себ., каз. ш. ук «таркау; таркалган, сибелгән», ком. *сандырыҡ* «сандырак; тиле шуклык», госм. *сайдырыҡ* «юкны сөйләүче», *сандыраҡла-* «юкны сөйләү» (Радлов IV: 230) һ.б. К. **Сандыра-у.**

**САНДЫРА-У**, **сәндерә-ү** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «болтать чепуху; одряхлеть, лишаться ясности мысли из-за старости» ~ башк. (БТДһ: 371) *һамтыра-у, һандыра-у* id. ~ каз. *сандыра-* «юкны сөйләү, фантазиягә, хыялга бирелү», чув. *сунтăрка-* < *сонтарка-* «мәлҗерәү» ~ төркм. *сандыра-,* монг. *сандра-* «аптырап, мәлҗерәп төшү; паникага бирелү» ← *сандыр* (> башк. *һандыр*) «юләр, саташкан» ← *санд, сант* «таркау», *сант-* «таркалу һ.б.» К. башк. *һанйы-у, һанты-у* «ушсызлану, хәтерсезләнү». К. ш. ук төр. *sanrı* «галлюцинация», бор. төрки *sanrï-* «өлтерәү, кабалану», *sanruš-* «үзара юкны сөйләү», *sandïrïš* «шау-шу» (к. ДТС: 484; ССТМЯ I: 61). К. **Сантый.** Räsänen 1969: 400–401; ЭСТЯ VII: 235–236 (каз., кырг. *сендел-,* бор. төрки *сәндирә-* «мәлҗерәү» һ.б. китерелә, ләкин веляр вариантлардан каз., кырг. *сандал-* id. кына искә алына).

Тат. **анда-санда** дигән парлы сүздәге *санда* < монг. *сандах* «таралып яту».

**САНҖАГ** (ДС II: 163), **санчак** (ТТДС II: 263) «брошка» << аз. *санҗаг* id. Китаби телдән. К. түбәндәгене.

**САНҖАК** диал. «область в Румынии, где живут (вместе с ногайцами, крымскими татарами) татары-переселенцы из Поволжья» < төр. *sancak* «өлкә; губернатор; байрак» (*sanç-* «байрак кадау, чәнчү» сүзеннән) > рус. *санджак* «Госманлы Төркиядә өлкә», *санчак* «идарәче, урынбасар», к. Будагов I: 637; Фасмер III: 552.

**СА́НКИ,** диал. **сәнки, сәки** (к. Махмутова: 248–249) «считай, что; как будто, якобы; предположим; дескать, мол» ~ ком. *сайки*, төр., аз., гаг. *санки* id. < *сан ки*, к. **Сан-у.**

**САНТЫЙ,** диал. **сандый** «глупец, придурковатый» ~ башк. *һандый, һантый, һантыр* id. ← **санты-, *санды-* «саташу, юләрләнү, иләсләнү» фигыленнән, к. төркм. *сандығ* «галлюцинация», к.-балк. *сант*, каз., к.-калп. *санда* «юньсез фантазия, юк сүз», ком. *сант* «апатия, мәлҗерәгәнлек», кар. *санд-* «саташу», каз. (Радлов IV: 305) *сандал-* «һуштан яза язу» ~ калм., монг. *санда-* > бур. *һанда-* «таркаулану, таркалу» һ.б. *Сант, санд* тамырының чыгышы безгә ачык түгел. К. **Сандыра-у.**

**САН-У, саны-у** иск. «считать за, счесть» ~ чув. *сон-* > *сун-* < болг. *сан-* > мар. *шан-* «сану; теләү, уйлау» (Иванов, Тужаров: 269–270) < угыз. *саан-, сан-* «сану» ← бор. төрки *са-* (> чув. *со-, су-*, як. *ваа-х* > *анна-х*) «уйлау, чамалау, санау» сүзенең кайт. юн.: *са-н-*, к. **Сагыш, Сан, Сана-у** һ.б. Мухамедова 1973: 146–147; Федотов II: 53, 62; ЭСТЯ VII: 12–126. Элекке әд. телебездәге **сана-у** белән **сан-у** аермасын оныттыру әйбәт түгел.

**САҢ I** (Будагов II: 402) «одна сторона, одна из сторон (одно из ушей)», диал. (ЗДС: 561) **саңкай** (← *саң*) «саңгырау». К. **Саңгырау.**

**САҢ II** диал. «птичий помёт» ~ госм. *саңҡ,* бор. төрки *saŋ* id. һ.б., Räsänen 1969: 421.

Дерив.: каз. *саңғы-* ~ монг. *саңга-* «кәк итү».

**САҢАК** «жабры», диал. «бородка топора; метёлка растений, кисть» (ТТДС I: 365) ~ тат. диал., к.-калп. *сағақ,* СС *sagak* «саңак», башк. *һағаҡ* «бүлтәеп асылынган нәмәрсә; саңак», нуг., каз. *саңғақ* ← *саңға-у* «сулыш алу» ← **саң-*. Күрәсең, тотылган балыкларның саңаклары хәрәкәтләнүеннән. Чаг. ш. ук нуг. *саңлав* ~ каз. *саңылау* «ярык; саба авызы» һ.б. Чаг. **Сака, Сакал.** ЭСТЯ VII: 140 (тәфсилле).

**САҢГЫРАУ [са$^{o}$ңғы̆раw]** «глухой» ~ башк. *һаңғырау* > мар. (Упымарий: 192) *соңыра, содра*, удм. диал. (Насибуллин: 133) *соңро*, чув. диал. *сантрав* id. < гом. кыпч. *саңраw, саңғыраw* «саңгырау, чукрак» ~ бор. төрки (Радлов IV: 288) *саңрағу* «саңгырау», бор. чыгт. (Поппе 1938: 147) *saγrau, saγır, saqır* id., к. ш. ук себ., каз. *саңыр*, нуг., төркм. *сағыр,* төр. *sagır,* гаг. *саар* «саңгырау», госм., чыгт. *саңғы* «аптыраштa калган, башы томган; туңган, туң» (Радлов IV: 302), тув. *саңга* «ачыгавыз», тат. диал. (ЗДС: 51–57) **сак, сакбай** «саңгырау». Бу сүзләрнең тамыры – **саңқ* «туң, томган» мәгънәсендәрәк булса кирәк. Шуннан *саңкы-, *саңгы-* фигыле ясалып, шуның интенсивлык формасы **саңгы-ра-у* «саңгыраулану» килеп чыккан һәм, ниһаять, исем фигыль булып, *саңгырау* пәйда булган (чаг. *Аңгырау, Кыңгырау, Яңгырау.* ЭСТЯ VII: 145–146. Чаг. ш. ук **Сакау, Сандырак, Сантый.**

**САП** «рукоятка; черенок» ~ башк. *һап* id. < гом. төрки *сап* «сап, сабак» (Радлов IV: 400) ~ таҗ. диал., ягн. *sappa* «сап, тармак». *Сап* сүзенең « япь, тагылган бау, киндерә, җеп һ.б.ш.» мәгъ. дә бар (чаг. *энәгә җеп сапла-у*), ләкин төп мәгънә «ботак, тармак», гомумән – «кәүсәдән, төп юлдан аерылып читкә киткән нәрсә» булырга тиеш: *сап* исеменең фигыль коррелянты *саб-у* «читкә аерылып китү, читләшү» (чаг. *юл сабу* «каршыга килгән юлчы җиңел үтсен өчен, юлдан бераз чыгып тору»). К. **Сабак, Сап-у.** ЭСТЯ VII: 195–196.

**САПСАН** «сапсан, вид ястреба» < рус. *сапсан* < башк. *сапсан* «елгыр, чапчан, сапсан (бу кошның җитез һәм манёврчан булуыннан)», себ. (Тумашева 1992: 234) **цапцаң** < гом. кыпч. *чапчаң* «елгыр, җитез», уйг. *чапсан* «җитез» ← *чапса-* «ташлану, ыргыту». К. **Чәпче-ү.**

**САП-У (сабу, сапты)** 1) «отойти в сторону (чтобы пропустить встречного)», «уходить от основного пути, от правды и т.п.», 2) «вдевать нитку в ушко иголки», 3) «приделать, прикрепить выдающуюся деталь к корпусу, к основной части», «надевать» – М. Рясянен (Räsänen 1969: 401–402) бу мәгъНәләрне төрле аерым сүзләр итеп күзаллый, ләкин, безнеңчә, алар бер үк мәгънәнең төрле чагылышлары гына.

Беренче мәгънәлектә *сап-* кыпч. һәм угыз телләрендә таралган (Радлов IV: 401–402), шуннан *сабыш-у* «салыну, салышу, әверелү» (чаг. тат. *сарыга сабышу*) килә; к. ш. ук чув. *сап-* > *суп-* «хәлдән таю, азап чигү; бер тарафка китү» һ.б. (күп кенә үзенчәлекле дериватлары бар, к. Ашмарин XI: 187–188), *сып-* «сабу, ялгау». Икенче мәгънәлек барча төрки телләрдә, ләкин сирәк кулланыла. Өченче мәгънәлек башлыча тат. *сап-* һәм чув. *сып-* сүзләрендә чагыла. Шунысы кызык, бу мәгънә нигезендә тат. диал. (ДС II: 162) *сапма* «читек; кәвеш» һәм бор. болг. *сапаг* > рус. *сапог* «итек» сүзе ясалган (к. Фасмер III: 559). Төркм., к.-калп. *сап-* «иген игү» сүзе дә шул ук тамырдан бугай. ЭСТЯ VII: 197–198.

*Сап-* фигыле *сап* исеменең коррелянты-тамырдашы булуы бик ихтимал. Федотов II: 64; ЭСТЯ VII: 197–198.

**САР, сары** диал. «сарыч (птица)» к. **Сарыч.**

**САРАВЫЧ [са$^{o}$раwы̆ч]**«платок, надетый козырьком над глазами» > удм. диал. *сарауц* id. < тат. диал. **сырауц** (Радловтан – Тумашева 1992: 197) > **сылавыч** (ТРС 1992) «женский головной убор, в который вкладывается коса; тесьма для волос – налобник», **сарауц** (Тумашева 1992: 188) «головной убор с позументами, который надевают старухи» > миш. **салауц** id., башк. (БТДҺ: 372) *һарауыс* «чигелгән янчык» ~ нуг. *сылауш* «накидка в форме косынки с опускающимся сзади концом» диелгән (к. Ногайцы 1988: 128–131) ~ каз. *сарапшин* «ат кылыннан тукылган челтәр», кырг. *сарапчы* «күзлек», хак. *сарапчы* «кузыр, козырёк» ~ яз. монг. *sarabčin* «кузыр, япма» > як. *чарапча, чарапчы,* эвенк. *сарапчу* id. > рус. *черапча, чарапча* «күзне артык якты кояштан (мәс., карлы тауларда) саклар өчен кылавын күзлек». Икенче яктан кр.-тат. *saraγyç* < бор. төрки (ДТС: 488) *saraγuč*, чыгт. *саракуч* – хатын-кызларның катлаулы баш киеме < фар. *сäрагош, сäракуч* > гар. *сäра̄қӯҗ* id. Бу сүзнең фонетик вариантлары вә дериватлары хәтсез күп һәм таралышы да бик киң (слав. телләренә дә үтеп кергән). Будагов I: 624 (фар. –

Урта Азия *сәракучы* тәфсилләп тасвирлана); Räsänen 1969: 402, 428; Номинханов 1975: 132; Субракова: 44; Аникин: 656. Кайбер тикшеренүчеләр (к. ССТМЯ I: 65) *сарапчы* һ.б.ш. (*-п-* белән килгән) вариантларын *саравыч* белән бәйләмиләр, аерым сүз дип карыйлар. Тат. диал. (ЗДС: 592) **сылаугыч** «толымса» халык этимологиясе буенча килеп чыккан сүз. Чаг. **Сар-у.**

**САРАЙ** «дворец; сарай» < фар. *сäрай* < иске фар. *сäраи* «сарай, бина» ← авест. *thraiti* id., *thra-, ðra-* «төзү» (Platts: 650) ~ рус. *строй*. **Сарай** сүзе фар. теленнән дөньядагы барча телләргә диярлек таралган (Россия телләренә – рус теле аша да). Рус. *сераль, серайль* «хәрәм сарае» фр. теле аша төрекчәдән килә. *Сарай* – хуҗалык корылмасы мәгънәсендә тат. телендә дә – русчадан. Иске әд. телебездә мәһабәт, рәешле бинаны *сәрай* дип, әлеге хуҗалык корылмасын *сарай* дип атап, аермалы итеп язганнар. Без дә шулай язу тарафдарыбыз. Рус. *сарай* тур. Аникин: 483 (әдәбият күрсәтелә).

**САРАН** «скупой, скупо» > чув., мар. *саран*, башк. *һаран* id. < гом. кыпч., алт., уйг. (Радлов IV: 317) *саран* id., себ. тат. **сараң** «саран; аз ашаучан, ашүтмәс, чирләшкә», алт., уйг. *сараң*, як. *араң* «чибек, чирләшкә, тиле», каз. диал. *сараң* «саңгырау» һ.б. (к. ЭСТЯ VII: 202–203). Бу сүз, ихтимал, **сара-* фигыль нигезеннәндер, к. тат. диал. (ДС II: 162) *саранчык* «саран» (чаг. *мактанчык, төрләнчек, чукынчык* һ.б.). Радлов IV: 366; ДТС: 488.

Дерив.: **саранлык; саранлан-у.**

**САРАНА** «сарана, саранка, лилия» («зур суганлы үсемлек, урманлы якларда очрый») > чув., мар., рус. *сарана́* ~ бур. *һараана* < монг. *сараана, сараанаг,* яз. монг. *sarana, sirana* id., к. ш. ук як. *сардаңа, сардага* > рус. диал. *сардина* «сарана төре», рус. диал. *сахарана* id. Төбендә бу сүз *сары кана* > *сарыгана* (*ҡана* «үлән, кыяк һ.б.ш.», к. **Кана-у**) булган, чаг. себ. (Тумашева 1992: 186) **сарғай** < *сарыҡай* «сары чәчәкле сарана» (гадәттә сарана шәмәхә яки кызыл чәчәкле булучан), башк. *һарана,* башк. диал. (БТДҺ: 372) *һарғымсаҡ* «сарана». Räsänen 1969: 403; Федотов II: 17; Аникин: 484 (арытабангы бай әдәбият күрсәтелә).

Сарана кайбер төрки кабиләләрнең еллык азык балансында, бигрәк тә бор. заманнарда, зур роль уйнаган, хәтта **сарана айы** > тат. диал. **саранай** дигән ай исеме (май-июнь) булган. К. ш. ук **Сарымсак.**

Дерив.: **сараналы; сараналык.**

**САРАНЧА** «саранча; саранчук» > рус. *саранча* < бор. кыпч. **сарынча* (*ы* > *а* тат. теленә хас), к. осет. (< кыпч.) *sarinca* «саранча» (к. Абаев I: 291), куман. *sarynčka*, урта төрки *саранчыҡа, saryγča* «чикерткә» һ.б. (Räsänen 1969: 404) – *сары* сүзеннән булса кирәк; ш. ук *сары анча* тезмәсеннән дә килеп чыга ала. Мухамедова 1973: 147. Рус. *саранча* тур. Аникин: 484–485; ЭСТЯ VII: 212–213 (күп материал китерелә).

**САРАТАН I** «верблюдка (насекомое)» < *сары атан* (к. **Атан**) дип аңлатылучан, ләкин диал. *саратан чикерткәсе* – чикерткәнең бер төре – тәгъбирендә **саратан –** ай исеме (июнь-июль). К. **Саратан II.**

**САРАТАН II** к. **Сәратан.**

**САРАФАН** «сарафан» < рус. (интервокаль *-ф-*), ләкин рус сүзе үзе төрки телләрдән. Гадәттә (рус этимологлары) бу сүзне төр. *serapa* < фар. *сäр-упай* «баштанаяк (озын күлмәк)» сүзеннән дип тәгърифлиләр (бүтән бер фар. сүзеннән – *serapa* «затлы кием» сүзеннән диючеләр дә бар, к. Фасмер III: 561), ләкин бу этимология азактагы *-н* авазын аңлатып бетерми. Шунлыктан, безнеңчә, рус. *сарафан* < болг. *сарыван* < фар. *сäрбанд* «баш бәйләвече; озын яулык» сүзеннән дә була ала. К. **Сарпат, Сарпинка.**

Башк. (БҺҺ II: 288) *һарапан*, чув. *сарахван, сараппан*, мар. *сарапан* «сарафан; хатын-кыз күлмәге» рус һәм тат. телләреннән таралган булырга тиеш. Рус. *сарафан* һәм аның модификацияләре тур. к. Мусина 1978.

**САРБАЗ** иск. «авантюрист; канатоходец» < фар. *сäрбаз* id. – сүзмә-сүз «баш + уен» > «башы белән уйнаучан».

**САРБЫСАН, сармысан** (Тумашева 1992: 186) «пушка» < фар. *ḍарбäзäн* id. ← *ḍарбä* «бер сугу» + *зäн* «бәрү». К. **Зарбә.**

**САРГАЙ-У** «пожелтеть, желтеть», башк. *һаргай-* < гом. кыпч., уйг. һ.б. *сарғай-, сарғар-* < *сарығ-ай-, сарығ-ар-* id. Бу сүздә бор. кушымча *-ғ* сакланган (бор. төрки *sarïγ* «сары»). К. **Сары.**

**САРДАР** иск. «профессиональный военный; боевик; военачальник» < фар. *сäрдар* id. сүзмә-сүз «башлык». Бу термин XIX–XX г. башларында Вәисевләр хәрәкәтендә актив кулланылган.

**САРКЫТ, саркым** «остаток пиршества; сыворотка» ← **сарык-у** (к.); гом. кыпч., уйг. *сарқыт* id. < **саврукыт* >> рус. *сыворотка* дигән фикер бар (И.Г. Добродомов). **Саркыт** сүзенең этнографик мәгъ. тур. Будагов I: 626.

**САРМАК I** диал. «речистый», «песня-наставление молодожёнам (в особенности – невесте)», башк. (БҺҺ II: 288) *һамақ, һармақ, һағамақ* «такмак; такмаза» ~ төркм. *саргамак* «тапшыру; заказ бирү» ← **сар* (> башк. *һар*) «речитатив; үгетләү сүзе». К. **Самак**, **Сарна-у.**

**САРМАК II** арготизм. (Г. Теләш) «деньги» – *сары* сүзеннән булса кирәк, к. рус. диал. *сара́, сары́* < төрки *сары́* (< *сары алтын*). Фасмер III: 559–562.

**САРМАН I** диал. (Тумашева 1961: 188) «лемех плуга» ~ чув. *сарпан,* нуг. *сарапан* id. Чаг. фар. *сäрбäнд* «сука башы».

**САРМАН II, Сәрмән** – название реки и сельского района в Татарстане – нуг., каз. *сарман* ыругы исеменнән булса кирәк (Сәрмән бассейны ыруг биләмәсе булган), андый очраклар күп кенә, к. **Байкы, Зилаер, Өсән.** Ул ыруг, хосусан, Г. Ибраһимовның «Казак кызы» хикәясендә искә алына. XV–XVI гг. Сарман буйларында нугайлар яшәгән. **Сарман** сүзе гомуми мәгъ. фарс. *сарбан* «дөяче» (*сар* «дөя») яисә бор. *сармат* (скиф) этнонимын хәтерләтә. К. ш. ук төр. *sartan* «зур гәүдәле, олы» (шул сүздән булса кирәк, **Сарман** – Чыгтай ханның угылларыннан берсе). Алт. миф. (к. Маадай-Кара: 116, 463) **Сарыйман** «кояшның тәүләп күренгән иле». Шулай итеп *Сәрман* < *Сарман* бик төрлечә аңлатыла ала. Чаг. ш. ук **Сарманай** – элекке бер ай исеме.

**Сарман** гидронимы тат. халкында шул исемдәге көй-җырга мөнәсәбәттә бик билгеле. *Сарман, сарыман* дигән топонимнар Казакстанда да бар.

**САРМА-У** диал. «обвивать» **сар-у** (к.) сүзенең интенсивлык формасы.

Дерив.: **сармал-у, сармат-у, сармаш-у.**

**САРМАША** (Будагов I: 685) «плющ (растение)» ← **сарма-у** ← **сар-у**. Ясалышы ачык түгел.

**САРНА-У** «оплакивать с причитаниями» (**сарнау** «плач; жалобная песня») < гом. кыпч. *сарна-* id. (кайбер телләрдә гомумән «җырлау», «сайрау») ← себ. (Тумашева 1992: 186), гом. кыпч. **сарын** «матәм җыры», алт., тув., хак. *сарын* «боек җыр», алт. диал. (Баскаков 1972: 244) *саарын* «җыр, такмак» ← **саар-* > башк. *һар* «речитатив», к. **Сармак.** ЭСТЯ VII: 211–212 (күп материал китерелә).

**САРПАТ, сарпыт, сарфат**, диал. (Н. Исәнбәт; ТТДС I: 363) «приличный вид; аккуратность» << фар. *сäрбäнд* «яулык, баш бәйләгеч» (*сäр* «баш», *бäнд* «бәйләвеч, яулык»), к. чув. *сурпан, сорпан, сарпан* > *шарпан, сараппан,* мар. *сарпан* > *шарпан* «тасмал, башка яулык итеп урала торган сөлге», куман. *sarpan* «ашъяулык», бор. кыпч. *сарбан, сарапан* «чалма» (Räsänen 1969: 409; Курышжанов: 184), себ. тат. **сарабат** > хант. *saravat* «сәйләннән белән чигелгән кашбау» (Прыткова: 231); күрәсең, *сарбат* < *сäрбäнд* > *сарбан; сәрбанд* «рәешле яулык» сүзенең *сарпат* «әдәп» мәгънәсен алуы шуның белән аңлатыла ки, хатын-кызның яланбаш йөрүе әдәпсезлек, мәдәниятсезлек саналган; шундый җыр бар: *Чыкма тышка яланбаш, Язык булыр – ярамас, Яланбаш йөргән кызларга Бер егет тә карамас.* Ихтимал, бу сүзгә *зарафәт* «матурлык» сүзенең контаминацион тәэсире бардыр.

Дерив.: **сарпатлы, сарпатсыз**.

**САРПИНКА, сарпинкә, сарфинкы, сәрпинкә, сәрфинкә** «сарпинка (клетчатая ткань для платков, салфеток и т.п.)» < рус.; рус сүзе, М. Фасмер (III: 563) буенча, Волгоград тирәсендәге **Сарпа//Сарепта** бистәсе атамасыннан килә. Тик, рус сүзенең нигезендә фар. *сäрбäнд* «баш яулыгы» сүзе ятуы да ихтимал, к. диал. (ЗДС: 568) **сәрәпин, сәрпин** «баш яулыгы; тукыма төре».

**САРТ** «сарт, дореволюционное название городских узбеков», диал. «гомосексуал» ~ башк. *һарт, сарт, һартай* «башкортларның бер ыруы исеме», «саран, карун» < гом. төрки *сарт* «сарт» < санск. *sarthavaha* «сәүдәгәр, кәрванчы» (к. Бартольд II: 286, 327), к. уйг. *сартпау* «кәрванчы», башк. *һаркаш* < фар. *сарткаш* «саран; кәрванчы», монг. *сартаул* «мөселман», *сартакту* «мөселманча» һ.б. К. **Сат-у.** Будагов I: 612; Аникин: 487.

**САРТЫН, сәтен, сәтә** диал. (Махмутова: 227) «для; из-за; по; ради» < гом. көнб. төрки *сартын* < уйг. *сарытын,* уйг., аз. *сарыдан* «яктан, җәһәттән, өчен». К. **Сары II.**

**САРУ [саºрЫ̆w]** «изжога» ~ башк. *һарау,* алт. *сару,* тув. *сарыг,* кырг. *сарна* ~ бур. *шара* id. Чаг.

башк. *һарыу* < *сарыw* «сидек». *Сару,* хәер, *сары (сары су)* сүзеннән дә булала.

**САР-У** «облеплять; наматывать, обматывать», башк. *һар-* < гом. төрки *сар-, сары-, сару-,* тув. *шары-* id. ~ чув. *сыр-, сăр-* «кием (бигрәк тә чолгау һ.б.) кию». Будагов I: 685; Радлов IV: 314, 321, 324; Räsänen 1969: 402; Федотов II: 76; ЭСТЯ VII: 201–202. К. **Сыр-у.**

Дерив.: к. **сарыл-у, сардыр-у**, диал. (ТТДС I: 363) **саргыч** «чолгау». Чаг. **Саравыч.**

**САРУТ** «пырей (и некоторые другие растения, к. ТТДС I: 602) > мар. (Исанбаев 1978: 24) *сарот*, башк. *һарут* < *сары ут*, ләкин к. чув. *шурути* «сарут» – сүзмә-сүз «саз уты». Чаг. каз. *ак ут* «сарут» (сарутның тамырлары аксыл сары була).

**САРЫ I** «жёлтый» > мар. *сар, сары, сарэ*, удм. *сари* «сары» (ат тур. гына), башк. *һары* id. < гом. кыпч. *сары* < бор. төрки *sarïγ, sariγ* id.; чув. *сар, сарă* «сары, матур» – татарчадан; алт. диал. *саары* < **сагарыг* – ниндидер **саг* тамырыннан булса кирәк. Төркм. *сары, саары* тур. Мухамедова 1973: 147–149 (бик тәмләп сөйли).

**Сары** сүзе гом. төрки планда бик продуктив сүзьясагыч нигез – шуннан тат. **саранча, сарут, сарымсак, сарымык** «сары авыруы» һ.б. К. ш. ук **Саза-у, Саргай-у.** Будагов I: 685–686; Федотов II: 15–16; ЭСТЯ VII: 206–208.

Дерив.: **сарылык; сарылан-у. Сары май** тур. к. **Май II.** Себ. *сары цац* «бичура хатыны» тур. МНМ: 173.

**САРЫ II** диал. (Тумашева 1992: 186) «сторона; в (определённую сторону)» (*ул сары да бу сары; ике сары* – фразеологизмнар) < гом. кыпч. (куман., кар.), алт., чыгт. *сары*, уйг., үзб., төркм. *сари* (төркм. ш. ук *сери*) < бор. төрки (ДТС: 488) *sarï, sarïqa* id., алт. диал. (Баскаков 1972: 75) *саары* (*сары, зары, за, зьа, са, сҗа, се*) «юнәлештә», кар. *сарын* >> удм. *сярен* «өчен», хак. диал. *сари* «бер як, ян як» – Рясянен (Räsänen 1969: 403) бу сүзне *сыңар* сүзе белән бәйли (*сыңары* > *сäры*?). К. ш. ук Будагов I: 613; ЭСТЯ VII: 208. К. **Сартын.**

**САРЫК** «овца», диал. (ДС II: 162) «ягнёнок-самка» ~ башк. *һарыҡ,* чув. *сорăх* > *сурăх,* мар. *шорык* < *шарык* < болг. **сарыҡ* < гом. кыпч. *сарыҡ* < **сагрыҡ* «савыла торган сарык» (савылмый торган сарык – *куй*дан аеру өчен әйтелгән) ← *саг-* «саву» сүзеннән. Чаг. «Идегәй» телендә **саурык бия** «савыла торган бия, кымыз биясе» < *сагрык* (*бәйә*). К. ш. ук уйг., төркм. *саглык* «сарык»; каз. *сарыҡ* «куй токымы» дип кенә әйтелә. Чаг. **Саулык.** Сарык саву элек киң таралган булган, к. **Пышлак.**

Гомумән, *сарык* сүзе киң таралмаган – ул кайбер кыпч. телләрендә (кырг., к.-балк.) теркәлмәгән (аларда *куй* сүзе генә билгеле). Тик тат. телендә дә бу «яңа сүз» дигән нәтиҗә белән (Мусаев: 89–91) килешеп булмый. Ш. ук М. Рясяненның (Räsänen 1969: 403) *сарык* сүзен *сар-у* фигыленнән дип раславы да нигезләнмәгән. *Сарык* сүзе койрыклы сарыклар (куйлар) да, койрыксызлары да асралган халыкта килеп чыккан, андый халык исә утрак төркиләр – татарларның турыдан-туры бабалары була. Федотов II: 66 (этимологиясе сай); ЭСТЯ VII: 209–210 («этимология билгесез» диелә, безнеңчә, җитәрлек дәрәҗәдә билгеле).

Формаль җәһәттән **сарык <** *сагрыҡ* < *саглыҡ* (*л* > *р*) яисә бор. **саг-ры-* фигыленнән, к. тат. диал. *(кан) саw-у ~ саwыр-у.*

**САРЫК-У (сарку, сарыкты)** «вытекать из щелей, через стенку», башк. *һарыҡ-*, тат. диал. (ТТДС I: 382) **сырык** ~ чув. *сăрăк-, сăрăх-* < гом. кыпч., госм. *сарҡ-*, урта төрки *sarq-* < бор. төрки (ДТС: 492) *savruq-* «сарку; агып чыгу, агу; дулкынлану», төр. *sark-* «агымланып хәрәкәтләнү, үтеп керү», к.-балк. *сарҡ-* гомумән «агу, агып яту», чыгт. *сарыҡ-, сарҡ-* «асылынып тору» һ.б. бор. **савур-* «агып үтү, агу» сүзенең интенсивлык формасы. К. **Саркыт, Сыкра-у.** Элекке тат. телендә *саркыра-* ~ каз., як. *сарҡыра-*, монг. *саркира-* «әкренләп сарку» фигыле дә булган (к. Räsänen 1969: 404). Федотов II: 31; ЭСТЯ VII: 203–204.

**САРЫМСАК** «чеснок» > мар., удм. *сарымсак,* башк. *һарымһаҡ* < гом. кыпч., урта төрки *сарымсаҡ* ~ яз. монг. *sarımsag* id. (Räsänen 1969: 404), шор. *сарымзаҡ,* гаг., госм. *сарымсы* «саргылт» сүзләре белән чагыштырыла, ләкин СС *sarmısak, saramsak, sarmusak,* ком., бор. төрки *самурсаҡ,* к.-балк. *сарысмаҡ* вариантлары бу сүз *сарыс-, сарсы-* «сасу, кискен ис аңкыту» ~ төр. *sarsmak* «тетрәндерү» сүзеннән дә була алуын күрсәтә. Бәлки сүзнең беренчел нигезе *сар-ымса-* «сар (үләксә) исенә ия булу»дыр, к. **Сар.** Räsänen 1969: 404; ЭСТЯ VII: 210–211.

**САРЫН: сарын сарна-у** (ЗДС: 564) «пять частушек». К. **Сарна-у.**

Дерив.: (Гиганов) **сарынце** рус. «певчий».

***САРЫП** диал. (себ.) «удар; чеканка; строгость» (**сарыпла-у** «ставить печать, полностью закончить; оформлять, оформить; сочинить мотив к тексту», **сарыплы** «талымлы, талымчан», к. ТТДС I: 364) ~ чув. *сарăп* «зыян, зарар» < гар. *ḍарб* «бер сугып алу» (к. ш. ук иске тат. **зарб** «бәрү; тапкырлау», **зарбә <** гар. *ḍарбă* «бер сугу»). К. **Сарбысан.**

**САРЫЧ** «сарыч, канюк (птица)» ~ рус. *сарыч, сарыча* id. < кыпч. *сарча, сарыча* «кечкенә сар (сары)» сүзеннән. Тат. диал. **сар** > башк. *һар* < гом. кыпч., алт. *сар, сары*, чыгт., як. *сар*, калм., яз. монг. *sar, sart, säärt* (Räsänen 1969: 402) «лачын, карчыга; зур тилгән» бор. төрки *sär* < *saŋır* «үләксә» сүзеннән булса кирәк (*сар кошы* «үләксәгә килүчән кош» → *сар*). К. **Сасы.** ЭСТЯ VII: 199–201.

Төрки телләрдә *сары, сарыча* дип бүтән берничә кошны да атыйлар, мәс., тат. диал. (ТТДС I: 364) **сары** «сандугач».

**САРЫЧЫН I** (Ш. Камал) «Царицын (Волгоград)» – бор. миш. (куман-кыпчак) *сарыцын* «саргылтым» сүзеннән. Шулай дип куманнарны (ком төслеләрне, ягъни сары чәчлеләрне) атаганнар, мөселман куманнар шул яклардан Шәрыкка китеп, анда хәчтерүшләр (тәре йөртүчеләр) белән көрәштә актив катнашканнар. Шулар атамасыннан рус. *сарацин* < урта гасыр латинчасынча *saraceni* «хәчтерүшләрнең дошманнары, сугышчан мөселманнар» сүзе, ш. ук гар. *саржийă* < *саргийә* «сарациннар, саргыллар» сүзләре килә (монда мишәрләрнең бор. заманнарда ук *-ғ-* урынына урта *-г-* авазы белән сөйләүләре чагыла). К. Räsänen 1969: 404.

Тарихи әсәрләрдә сарычыннар тур. күп язылган.

**Царицын** атамасын шул шәһәрдә Иделгә койган *Царица* («патшабикә») елгасы исеменнән чыгаралар. Ләкин бу соңгы этимологизация. Ихтимал, ул елга элек **Сарысу** яки **Сарыча** дип аталгандыр (аның сулары саргылт). К. түбәндәгене.

**САРЫЧЫН II** (ТТДС II: 220) «желтоватого цвета; перга, пыльца», ш. ук (ЗДС: 563) **саршын** id. бор. тат. (куман) *сарычын* «саргылт» сүзеннән. К. ш. ук **Чаршын**.

**САСУН, сосым, сосын, сусым, сусын** (ЗДС: 564, 578, 586) «жеребёнок, телёнок; мясо телёнка» < рус. *сосун* «имезәк». Кайбер яңгыраш халык этимологиясенчә «сосу»га нисбәт ителгән.

**САСЫ** «вонючий» < диал. **сассық,** башк. *һаҫыҡ* id. ← тат. **сасы-,** башк. *һаҫы-* «сасу» фигыленнән, к. гом. кыпч., угыз., үзб. *сасық* «сасы» һәм *сасы-, сассы-* «сасу», бор. төрки (ДТС: 490) *sasïγ* «сасы», *sasu-, sasï-* «сасу» < тат. диал. (Зимасов: 81), уйг. диал., ком. *сарсы-* < (кырг.) *саңырсы-* «сасы һәм пычрак булу» ← чыгт. *саңк,* бор. төрки *saŋ* «кош (бигрәк тә ерткыч кош) ашы калдыгы, тизәк» (к. Будагов II: 403; ДТС: 485) сүзеннән. Чаг. ш. ук тув. *саң* «арча яндырып төтәсләү йоласы», уйг. *сарсағ, сарсығ* «әшәке», *сесиқ* «сасык», чув. *шăршă, шăрăш, шăш* «ис», ком. *сарсы-* «ашалып бетмичә калып, черү», як. *асах* «юеш һәм черек». Кайбер телләрдә (угыз, бор. төрки) *сарсық, сарсығ* «тупас һәм көчле» мәгъ. килә (к. Räsänen 1969: 405), тәр. *sars-* «тетрәү, калтырау» һ.б. Бу сүзләрнең тамыры, ихтимал, үзгәдер. Федотов II: 451 (чув. *шăрш* нигезендә *-р-* «кертелгән аваз» ди, ләкин бу дөрес түгел – монда ул аваз борынгыдан килә).

Дерив.: **сасылык, сасылан-у;** фигыльдән – **сасыт-у.** ЭСТЯ VII: 213–214 (этимология сайрак).

**САТАМАЙ, сатай, сатый** диал. (ТТДС I: 365) «недотёпа» – ачык түгел. Ихтимал, фар. (гар. нигездә) *сāдāй* «садәлек, беркатлылык» сүзеннәндер, к. себ. *сата, сатә* «аңгыра; беркатлы» (Тумашева 1992: 186) < фар. *садэ* id. К. ш. ук **Сантый.**

**САТАШ-У** «бредить» > мар., удм. (Алатырев 1976: 142) *саташ-* id., башк. *һаташ-* id. ~ нуг. *сатас-,* каз. *шатас* «буташтыру» < бор. төрки *satγaš-* «чатлашу, буталу» ← *satγa-* «чатлы итү, чатлашу» (к. ДТС: 490). Гомумән, *саташ-у* «зиһен буталу» төрки телләрдән тат. телендә генә диярлек: бүтән телләрдә бу фигыль бик төрле мәгъ. очрый: госм., аз. *саташ-* «очрашу, адашу, һуштан язу; шаяру; янау», кар., ком. *саташ-* «җанга тию, бәйләнү», башк. (БһҺ II: 288) *һаташ-* «сабышу», чаг. *саташ-* «борчу» һ.б. төп. фигыль *сатга-* да шулай ук күп мәгънәле (ДТС I: 490 өч омоним *satγa-* күрсәтә: «таптау, кимсетү»; «кисешү»; «бурыч-түләү эшләрен башкару»). Бу хәл сүзнең чыгышын томанлы итә. К. Räsänen 1969: 405.

Дерив.: **саташыл-у; саташтыр-у.**

**САТИН** «сатин (вид ткани)» < рус. < фр. *satin* < гар. *зайтӯнӣ* id. ахыр чиктә кыт. *Цзяодун* шәһәре исеменнән, к. Фасмер III: 565. К. ш. ук **Зәйтүн.**

**САТЛЫК** «вещь, предназначенная для продажи» ~ башк. *һатлыҡ* id. < **саткылык** яки **сатулык**

булса кирәк. Бор. төрки (ДТС: 491) *satïγlïq* id. сүзеннән турыдан-туры килгән булуы да ихтимал (әйтергә кирәк, *sat-* тамырының дериватлары элек хәзергедән күбрәк булган). «Сатылган, хыянәт иткән» мәгъ. икенчел булса кирәк. К. **Сат-у.**

**САТ-У** «продавать, продать», күч. «предать» (исемләшкән формада **сату** «сәүдә, товар») > удм. диал. *сат-,* чув. *сот-* > *сут-* «сату», мар. *сату* «товар», башк. *һат-ыу* < гом. кыпч., уйг., угыз. һ.б. *сат-* (к. Радлов IV: 1375) id., чыгт. *сатығ,* тув. *садыг* «сату эше, кибет, магазин», як. *һатыы* > *атыы* (Пекарский I: 198) «товар; хак; сәүдә, сату» – этимологлар бу сүзне чыгт., уйг., бор. төрки *sart* < бор. һинд. *sartha* «кәрван, сәүдә; сәүдәгәр» (к. **Сарт**) сүзеннән килә дип уйлыйлар. Төрки телләрдән бу сүз күп күрше телләргә алынган, мәс., абаз. *сату* «сәүдә» (*сатучы* «сәүдәгәр»), венг. *szatocs* «сатучы» һ.б. Башк. *һатыу* һәм як. *һатыы* вариантлары уртак чыганактан килә. Будагов I: 683; Räsänen 1969: 405; Федотов II: 67–68; ЭСТЯ VII: 214–215 (этимология үзгә).

Дерив.: **сатыл-у; сатын-у** («анаңны сатыйм» дип сүгенү»); **сатыш-у; саттыр-у;** диал. **саткын** «сатуга билгеләнгән» (к. **Сатлык**); **сатулаш-у; сатучы.**

Идиоматик тәгъбирләреннән **сатып алу** «акча түләп алу» сәерсендерә, тик шуңа охшаш тәгъбирләнеш бүтән төрки телләрдә һәм монг. телләрендә дә (*худалдан авах: худалдан* «сатып», *авах* «алу») күзәтелә, бор. төрки телләрдә дә (ДТС: 490–491) *satïb al-* id. Күрәсең, моның тәүге мәгъ. «сату һәм алу» (ягъни «сәүдәләшү») булган. *Сатып ал-* тәгъбиренең эчке мантыйксызлыгын өнәмәүчеләр шул мәгъ. иске тат., кар. **сатнал-у, сатын ал-у** ~ төр. *satın al-*, чув. *сотын* > *сутын ил-* фраземасын кулланалар (*сатын* < *сатыгын* булса кирәк), к. Ә. Ясәви телендә *саткын алу*: *[Кол-Хуҗахмәт] җанын биреп саткын алды көймәклекне* (94 хикмәт). Ш. ук. **сатым алу** тәгъбире дә бар. Безнеңчә, иң яхшы вариант шул – **сатым алу.** Тат. әд. телендә дә **саткып алу** тәгъбирен кулланырга була. К. түбәндәгене.

**САТУАН,** (Akb: 75–86) **satuwan** «распродажа» < бор. төрки < фар. *сартаwан* «сәүдәгәрләр». К. **Сат-у.**

Дерив.: **сатуанла-у** «күпләп сатып алу».

**САУ [саᵒw]** «здоровый, целый; не больной» ~ башк. *һау* id. < гом. кыпч. *сау,* кырг. *соо* < уйг., чыгт., угыз. һ.б. *саг,* тув. *саа*, бор. төрки (ДТС: 480) *saγ* «сау; яхшы, әйбәт», «саф, чиста»; «уң» > гом. кыпч. һ.б. *саҡ* (к. **Сак**). Бу күзаллау чув. *сывӑ* «сау, исән» һәм *сыхӑ* «сак» сүзләренең параллельлегеннән дә килеп чыга. К. ш. ук яз. монг. *saγ* «сак», калм. *саг* «саклык, уяулык» һ.б. Räsänen 1969: 395–396; Федотов II: 73–74; ЭСТЯ VII: 132–137.

Дерив.: **саулык, саусыз**. **Сау** сүзенең дериватлары күптәннән бирле күрше фин-угор телләренә кергән: мар. *шу* «сау», *шулык* «саулык» < чув. диал. *су, сулӑх*; мар. *шушыр* < *сусыр* ~ удм. *сӧсыр* < болг. **саусыр* «саусыз» (болг. сүзе үзе кыпч. алынмасы нигезендә ясалган). Фразема: гом. кыпч. характердагы **сау бул** – шуннан **саубуллаш-у** (күрше телләргә дә алынган).

Тат. **савык-у** «сәламәтләнү» сүзе электә **сау-у** «сау булу» фигыле булганлыгын күрсәтә (**савык-** нигезе шуның интенсивлык дәрәҗәсе булса кирәк).

**САУБУЛЛАШ-У [саᵒwбуллаш-]** «прощаться», букв. «сказать друг-другу: будь здоровым». Тат. телендә ясалган һәм күрше телләргә алынган яки калькалаштырылган, к. чув. диал. *сывпуллаç-* id.

**САУГА [саᵒwға]** иск. «подарок, дар» < чыгт., уйг. *сауға* id. < монг. *сагуга* «бирнә» > кырг. *соога* «табыштан бер өлеш – бүләккә бирелә». К. ш. ук үзб., уйг. *савға, соға* «бүләк». Ихтимал, кыт. *са-хуа* «бүләк» сүзеннәндер. Шул мәгъ. икенче сүз *сәүгать* гарәпчәдән булса кирәк, к. Будагов I: 616, 647; ЭСТЯ VII: 273–275; Из глубины столетий: 145.

**САУЛЫК [саᵒwлы̆ķ]** «ярка; молодая овца (не моложе трёх лет)», себ. (Тумашева 1992: 186) «самка (овца, коза, корова)», башк. *һаулыҡ* «теше сарык» < гом. кыпч. *саwлыҡ* id., к.-балк. *саулуҡ* «савым, савыла, саудыра торган», сары уйг. *сағлыҡ* «савым сарык», бор. кыпч. *saγlaq, saγlïq* «савым кәҗә яисә сарык», бор. төрки (ДТС: 481) *saγlïq* «саулык; сарык»; к. ш. ук уйг. *сағлиҡ* «сарык» (яңгырашы икенчел). Щербак 1961: 112. К. **Сарык.**

**САУМАЛ [саᵒwмал]** «дойная кобыла» < *са-wын мал* булса кирәк; хәер, *саумалы* сүзеннән дә ясала ала; чаг. каз. *саумал*, як. *саамай* «бер тәүлек кенә торган кымыз», башк. *һаумал* «сәрен кымыз» ~ кырг. *саамал* id., төр. *sağmal* «савын, савыла торган» ~ яз. монг. *sayamal* «сөт», бигрәк тә «бия сөте» > рус диал. (Аникин: 511) *сумал* «сөт кушылган кымыз». Һәрхәлдә *сау-* < *саг-* тамырыннан. К. **Сау-у.**

**САУРЫЙ [саºwрыйй]** (Будагов I: 614), **сауры,** диал. **саурын** «отделанная кожа (крупа коня); круп» ~ башк. *һауырый, һауыр* «ял; савыр, арт сан (атныкы, сыерныкы); ат яки сыер савырыннан ясалган (кызыл төсле) күн», себ. **сауры, сағры** «арт сан, савыр» (к. Тумашева 1992: 186) > удм. *сарвыл, саурыл* «ат савыры», рус. диал. *сары* «коневые сапоги», *савры* «тибенге» (Даль) < гом. кыпч. *саwры, саwру* < гом. төрки, бор. төрки *sayrï* «атның савыр тиресеннән эшләнгән күн» (к. ДТС: 481), *сууры* (к. Räsänen 1969: 393), уйг. *сағра* id. һ.б., к. ш. ук **Соран I;** рус. *сагиры, сагыры* «су үтмәслек махсус итек», *шагиры* «иләнмәгән тиредән эшләнгән аякчу», *шагири* «күн оек» (< эвенк. *шагирал* id.), *сáры* «ат тиресеннән тегелгән якут итеге» (к. Аникин: 472, 487, 683). ЭСТЯ VII: 142–144.

Бөтен дөньяга билгеле бу сүзнең күп кенә (төркиләргә күрше) телләрдә этимологик дублетлары гамәлдә. Тат. телендә алар алты: *савыр, саурый, саурын, соран, шигрин, шагрень*; рус телендә дә ким түгел.

**Савыр** башлыча тән әгъзасын, сирәгрәк күнне белдерә; **саурый** башлыча күнне, сирәгрәк тән әгъзасын, **саурын** «ат күнен», **соран** «мөгезле терлек күнен» белдерә. **Шигрин** революциягә кадәр рус теленнән «затлы күн» мәгъ. *шагрень* сүзеннән үзгәреп кергән, **шагрень** – шул мәгънәдә (асылда французчадан) революциядән соң кулланыла. К. **Шигрин.**

**Саурый** формасы үзе **саwырың* (чаг. госм. *шагырын, сагырың*) яңгырашыннан һәм бор. монг. *сагари(н)* «соран» сүзеннән булса кирәк (к. Пекарский: 2110–2111): бу сүз тунг.-маньч. телләрендә дә (эвенк. *сäри, һари, шаурал* «аякчу, чарык», маньч. *сарин* «савыр күне») киң таралган (к. ССТМЯ II: 66) һәм анда монг. теленнән дип уйланыла. К. ш. ук рус. *савры* иярнең ике ягыннан асылындырып куелган күн кисәкләре (Аникин: 471, бай әдәбият күрсәтелә). К. кырг. *соору* «савыр, саурый», *соорун* «оча (аучы табышының аудан кайтканда беренче очраган авылдашына бирелә торган өлеше, гадәттә савыры)» < **саwырын* id. Әгәр бу сүз *саwыр* < *сағыр, сағры* сүзенең инструменталь килеш формасы булса, *саwыр* төптә «оча» мәгъ. була һәм, ихтимал, монг. *сага-* «тарту» фигыленнәндер (к. тат. *тарту* < *тартыг* «кәләшкә бүләк»). К. **Оча** (бүләкләү гадәте тур.). Чаг. **Чарык.** ЭСТЯ VII: 142–144.

**САУСАК [саºwсак]** иск. «ряд пальцев руки; рука с раздвинутыми пальцами» ~ кр.-тат. *savsaq* «йодрык», каз. *саусақ* «бармак» (дөресе «кул чугы») ← (?) *сауса-* «(ара калдырып?) рәткә тезелү (сугышчылар турында)» ← (?) төр. *san* «аерымланган». Чаг. төр. *savaş-*, куман. *sauvaš-* «(бергә бер) көрешү, сугышу». К. **Саба-у.** Räsänen 1969: 406.

**САУТИ [саºwти]** иск. «звуковой (метод обучения)» < гар. *ṣawtī* id. ← *ṣawt* «аваз, өн». Тат. мәдәнияте тарихында *осулы саутия* дип аталган метод өчен көрәш җәдитчелектә, яңарыш хәрәкәтендә зур роль уйнаган. **Саут, саутия** һәм **саутият** («пропедевтик фонетика») сүзләре шул чорда актуаль булган.

**САУ-У [саºw-]** «доить; натирать кирпич в порошок», башк. *һау-,* чув. *су-, сыв-* id. < гом. кыпч. *саw-* < гом. төрки (уйг., төркм., госм., тув., хак.) *сағ-* > кырг., алт. *саа-*, як. *сыа-* ~ *ыа-* ~ монг. *саа-, саға-* «саву». Як. *ыа-* < *һыа*, бур. *һаа-* һәм башк. *һау-* «саву» нигезләре уртак (*с-* > *һ-* булган) чыганактан. М. Рясянен бу сүзне фин-угор *saga-* «алу» белән чагыштыра. Федотов II: 53–54 (тәфсилле); ЭСТЯ VII: 137–140.

**Сау-у** «сөтне сыгып чыгару» сүзенең *кан сау-у* тәгъбирендәге *сау-у* сүзенә мөнәсәбәте безгә ачык түгел.

**Сау-у** продуктив нигез: **савым** «бер савуда алынган сөтнең күләме», **савын** < *саwғын* «савыла торган»; к. **Саулык, Саумал, Сарык.**

**САФ I** «чистый, без примесей» < гар. *ṣāф* id. ← *ṣфw* «чиста булу» тамырыннан. ГТРС: 503.

Дерив.: **сафлык; сафла-у, сафлан-у.**

**САФ II** «ряд; шеренга» < гар. *ṣафф* id. ← *сфф* «рәткә тезелү» тамырыннан. ГТРС: 503.

**САФА (кәеф-сафа; сафа сөрү** тәгъбирләрендә) «эйфория; беззаботное времяпровождение» < гар. *ṣафā'* id. – **саф I** сүзе белән тамырдаш.

Дерив.: (бик сирәк) **сафачылык;** иск. **сафадар** «буш вакыты күп кеше» (фарсычадан).

**САФСАТА** «болтовня, софизм; демагогия» < гар. *сäфсäṭа* id. < (грек.) *софистика.*

Дерив.: **сафсатачы, сафсатачылык.**

**САФУРА**: **сафура бураны** «женский гнев». **Сафура** гар. «көзге сарылык; ләкин мәзкүр идиома ул сүздән түгел, ә Муса пәйгамбәрнең көнчел хатыны *Сафура* – Тәүраттагы *Циппора* исеменнән.

**САХИП, сахиб** «обладатель, владетель; совладетель; собеседник» ← *ṣхб* «бергә ия булу», шуннан **сахабә** «Мөхәммәт пәйгамбәрнең якын дусты, яраны»; **сөхбәт** «дусларча сөйләшү», к. **Сәүмәт.**

**САХРА,** себ. (Тумашева 1992: 183) **сакра** «широкая степь; ширь» (к. ш. ук **Сәхрә**) < гар. *ṣахрā'* «кыялы чүл, Сахара чүле». Тат. телендә **сахра, сәхрә** поэтик лексикада кулланылучан.

**САХТӘ** иск. «поддельный, фальшивый», себ. (Тумашева 1992: 188) **сәктә** «незакономерный; непредвиденный, неожиданный» < фар. *сāх̮тä* «ясалма». Уйг., үзб. *сахта* «ялган исем белән йөрүче».

**САЧ** «волосы» – фольклор (җыр) теленә бу сүз Алтын Урда уйгурлары теленнән кергән. К. **Чәч.**

**САЧТАРАШ** «парикмахер», «парикмахерская» – дөресе **сачтәрраш** – фар. телендә төрки **сач** (к.) һәм **тәрраш** (к. **Тәрәш**) сүзләреннән ясалган (**тара-у** фигыленең катнашы юк).

Дерив.: **сачтарашлык, сачтарашханә.**

**САЧУ** иск. «подарки невесте во время свадьбы в виде монет» ~ чыгт., төр. *sačuq, sacıq* id. ← *sac-* «чәчү», к. **Чәчү.**

**САЯ I [саᵒйа]** (ЗДС: 555) «одежда из шерстяной ткани – плащ с оборками (видимо, женский)». Чаг. төркм. *сай, сайы* «иң яхшы, сайланган», аз., төр. *say* «иң яхшы», «яхшы (кеше), хөрмәтле» < монг. *сай, сайн*, бор. монг. *sajin* «яхшы; асыл» һ.б. Чаг. ш. ук чув. *сайă*, мар. *сай* «сәламәт, яхшы, асыл» һ.б. (безнең бу чагыштыруларда ачыклыйсы моментлар бар). К. ЭСТЯ VI: 148 (анда тат. сүзе китерелми).

**САЯ II [саᵒйә]** иск., диал. «тень; сень» < фар. *сāйä* id., бу сүз мөселман төркиләренең барысында да очрый һәм киң кулланыла, к. иске тат. **сайәсендә** «аркасында, нәтиҗәсендә; ярдәмендә». Элегрәк, **сайә** халык телендә, сөйләшләрдә дә киң кулланылган булса кирәк, к. удм. *сай, саюл* «күләгәле урын, ышык».

**САЯЗ [саᵒйаз]** диал. «широкое мелкое место, мель» к. **Сай I.**

**САЯК I [саᵒйак]** «бродяга»; диал. (ТТДС I: 357–358) **сайғак** «любитель ходить к родным и знакомым», (ТТДС II: 260) «бредущий; приблудный; склонный отбиваться от стада, от дома (о скотине)» > чув., мар. (Иванов, Тужаров: 195; Саваткова: 198) *сая, саяк, сояк* id., ш. ук «көтүчесез терлек» ~ каз., төркм. *сайақ,* башк. *һайаҡ* «ялгыз утлаучан (терлек)» һ.б. бор. (алт., к. Баскаков 1972: 244) *сайа-* «сирәк булу» фигыленнән, к. **Сайгак**. К. ш. ук миш. **сайгак** «куаклык» (диелә, к. ТТДС I: 358), асылда «сирәк урман» булса кирәк. К. түбәндәгене.

**САЯК II [саᵒйак]** (Тумашева 1992: 183) «редкий; поодиночке» (**сирәк-саяк** гом. тат.), башк. *һайаҡ* < гом. кыпч., уйг., төркм. һ.б. угыз. *сайаҡ* «ялгызак; сукбай; көтүчесез, башлыксыз», нуг., ком., к.-балк. телләрендә «эшлексез, азгын», алт. *сайаҡ,* хак. *сайах* «сирәк» ← *сай-, сайа-* «сирәкләнү, сирәгәю; таркау һәм сирәк булу»; к. ш. ук каз. *сайдак* «ялгыз», кырг. *сайаң* «бик сирәк». К. **Саяк I, Сайгак.** Räsänen 1969: 395 (тунг., кор., фин. телләреннән параллельләр таба).

**Сайак** сүзе төрки телләрдән бүтән телләргә дә кергән, к. авар. *саяҡ* «тәртипсез йөрүчән».

**САЯК III [саᵒйак]** диал. «ложь; пустословие», (ТТДС I: 357) «бестолковый» ~ чув. *суйа* < *сойа* ~ мар. (Иванов, Тужаров: 268; Саваткова 1981: 198) *сойа* < *сайа, сайак, шая, исойа,* удм. (Насибуллин: 147) *шойак* «алдак, әләк» ~ алт. диал. (Баскаков 1972: 244–245) *сайаҡ, сайгак,* хак. *сайғах* «әләк, бөһтан», төр. *saya-* «җеназада мәрхүмне мактау» ← **сай-,* **сайы-* икәнлеге күренеп тора, әмма сүзьясагыч фигыль итеп бор. тат. (?) **сай-* > чув. *суй-* (< *сой-* < *сай-*) «алдау, ялгану» карала; к. хак. *сайға-, сайха-, сасха-* (бор. тат. **саҙға-*) «рәнҗетү», к.-калп. *сай-* «күп сөйләү; әләкләү», чаг. каз. һ.б. *сай-* «чәнчү» һ.б. ЭСТЯ VII: 150 (безнеңчә, артык материал бирә).

Федотов (II: 54) чув. *суя* «ялган, әләк» сүзен рус. *всуе, суе* «юкка (сөйләү)» белән чагыштыра, ләкин бу фараз ышандырырлык түгел.

**СӘБӘП** «причина; предлог; юридический повод» (к. Будагов I: 618) < гар. *сäбäб* id. ← *сбб* «сәбәпле булу» тамырыннан. ГТСР: 514.

Дерив.: **сәбәпле, сәбәпсез; сәбәпче.**

**СӘБӘТ I** «клетка, ларь; воронка» (к. Троянский; Будагов I: 620; Тумашева 1992: 187) ~ чув. *семет* «бүрәнкә» ~ каз. (ҚТДС: 277, 291) *сабет, сәбет,* к.-калп., кырг., төркм. *себет,* кар., гаг., төр. *sepet* «ипи савыты» > рус. *сапетка* «күн, тире

белән тышланган кәрзин» < фар. *сāпäд* (> үзб. *сават, сабат*) «кәрзин». Нұрмағамбетов: 105–106.

**СӘБӘТ II** (Тумашева 1992: 187) «лошадь-коренник (в тройке)» < рус. диал. *заводь* id. (*водящая*).

**СӘБЗӘ** (К. Тинчурин) «овощ» < фар. *сäбзä, сäбзи* id. ← *сäбз* «яшел; яшеллек» >> чув. *симĕс* «яшел». Рус. *сабза* «киптерелгән йөзем» < төрки < фар. тур. Аникин: 470.

**СӘВӘЛ [сәwәл]** (Дмитриева 1981: 180) «красиво одетый, порхающий»; (Тумашева 1993: 88) «красивые места; широкие (безлюдные) долины» < гар. *зäwāл* «буш (җирләр)» сүзеннән булса кирәк. Гадәттә *зәвал* «бушлык, бетү» мәгъ. кулланыла, ләкин күчмәчеләр күзендә буш җирләр – өметле ау җире һәм көтүлекләр. Чаг. **Савал.**

**СӘВӘЛӘЙ [сәwәләй]** «ряженый (под Новый год); потешник», диал. (ТТДС I: 384, 520) **сәбәләү, сәвәнәй, шабалаң, шәбәләй, шәбәләү** id., «человек в одежде до земли», (МТД 1978: 49) *сефелей* «озын кием», башк. (БТДҺ: 388) *һәмәләй, һәмәндәй* «әзмәвердәй зур кеше (колга атламаларга басып атлап йөргән кеше)», *һәүәнәй* «Баба-яга», к. ш. ук (ЗДС: 565) **сәwәнәй** «ямьсез кыяфәтле кеше», «клоун», **сәбәләүдәй** «килешсез озын күлмәктән», **сәwәнәйле** «кием алмаштырып уйнау». Минем җыйган материаллар буенча, **сәвәләй** «зурлар киеме киеп атлый алмаган бала», **шәбәләү** «мәзәкче». Якын төрки телләрдә бу сүз юк бугай. Күрше теллләрдән мар. (Исанбаев 1978: 48) *сäвлäй* «сәвәләй» тат. теленнән алынган.

**Сәвәләй** сүзен хак. (Катанов 1888; Будагов II: 404; Унгвицкая: 64–66) *сiвäлдäi, сибәлдәй, сибильдей, хара шивильдей* «сихерче, җадучы» сүзе белән бердәй дип карасак, бу сүзләр бор. мәҗүсилектән килә дип уйларга мөмкин. Чаг. ш. ук тунг.-маньч. (Василевич) *səwən, šəwən, həwən* «шаманның ярдәмчесе».

Башкортстанда һәм Татарстанда берничә **Сәвәләй** авылы бар. Чаг. ш. ук эвен., эвенк һ.б. тунг. (ССТМЯ II: 135) *сэwэн, сэwэки* һ.б. (күп вариантлар) «аю рухы – тәңренең ярдәмчесе; аю булып бию». Чаг. **Сибел.**

**СӘВӘТ [сәwәт], сәвад** иск. «грамота; грамотность» ~ каз., кырг. *сабат*, үзб. *савод* id. < гар. *сäwāд* «кара; язу карасы; каралама, сәвәт» ← *cwd* «кара булу» тамырыннан, к. ш. ук **Сәүдә.**

Бу сүз Башкортстанда әле 1930–1940 нчы елларда актив кулланылышта иде. Мең ел буе сәвәтле татар халкында *сәвәт* сүзенең онытыла төшүе (аның урынына *грамота* кулланылу) гаҗәп!

Дерив.: **сәвәтле, сәвәтсез.**

**СӘВЕЛ I** (Г. Галиев) «соболь». Рус теленнән булса кирәк. Рус теленә кыпч., госм., кр.-тат. *самур, сäмүр* сүзеннән үзгәреп кергән дип уйланыла, к. Сетаров: 21–22. К. **Самур.**

**СӘВЕЛ II: сәwелем, сәүлем** (әстр., к. ЗДС: 569) – слово обращения снохи к золовке: элек татар гаиләләрендә киленнең каенсеңлесенә эндәшү сүзе. **Сәwелем** < миш. **сәүгелем** ~ төр. *sevgülüm, sevüglüm, sevüglügum* (*sevgü* «сәүге, сөю хәле») сүзеннән булса кирәк. Ягъни **сөеклем** сүзенең мишәрчә-угызча варианты. К. бор. төрки (КБ; ДТС: 497–988) *seviglig* «сөекле», *sevig, sevüg* «сөю; сөйгәнең» һ.б. К. **Сөй-ү.**

**СӘВЕР [сәwĕр]** «апрель (точнее 22 апреля – 22 мая) < гар. зодиакаль календарь буенча *çäwp* «үгез» сүзеннән. Хәз. календарьларда рус. *телец* сүзеннән тәрҗемә итеп **үгезбозау (ае)** дип язып куялар (әйтмәкче, «үгез бозау» мәгъ. бездә кыскарак сүзләр дә бар). Мин шәхсән бу русчадан тәрҗемәләнгән атамаларда политик бер эчкерлелек күрәм: гүяки татарлар, руслар әйтмәсәләр, зодиакаль календарьны белмәгәннәр булып чыга…

Зодиакаль календарь системасы тур. күп язылган.

**Сәвер** аен сөйләшләрдә **сабыр ае** дип тә атыйлар икән, к. ЗДС: 553. Бу – **сәвер** сүзенең бозылышы булса кирәк, әмма мөстәкыйль бер сүз булуы да ихтимал.

**СӘВИТ I [сәwит]** (ТТДС I: 384); **сәwитем** «моя подруга, подруженька», сүзлекләрдә рус. *советчица* «киңәштәш (ахирәт)» сүзеннән дип аңлатыла. Ләкин ник русча сүзне кыскартып әйтәләр икән? Дөресрәге – төр. һ.б. *seviyet* «тугрылык, тиңдәшлек; ахирәт» < гар. *сäwийäт* «тиңдәшләр» түгелме икән? Чаг. тат. иске әд. **сәwийә** «тәңгәллек, тигезлек» һ.б.

Икенче җәһәттән к. бор. төрки (ДТС: 498) *Sevit* «Венера, Зөһрә» – «чибәр кыз» мәгъ. сүз дә булган. Шуннан *сәwитем* «чибәрем» була алган…

**СӘВИТ II [сәwит]** сөйл. «совет; сельсовет». Элегрәк, XX г. беренче яртысында татар авылларында һәр төштә шулай әйтелгән.

**СӘГАДӘТ** «счастье» < гар. *сä'āдäт* id. Еш кына **бәхет-сәгадәт** диелә. ГТРС: 515.

**СӘГАТЬ [сәгәт]** «час; часы» > чув. *сехет,* мар. *сäгäт, сагат, шагат* ~ төркм., к.-балк., кар., ком. *сағат*, каз., кырг., госм., алт. һ.б. *саат*, үзб. *соат* id. < гар. *сā'āт* id. ← *cw'* «казык» сүзеннән: кояш сәгатенең унике казыгының берсе күз алдында тотылган. Федотов II: 38–39 (башк. мисалын китерә, тат. сүзен белми).

Элекке тат. телендә *сәгать* вакыт берәмлеген генә белдергән, вакыт үлчәгеч инструмент *сәгатьләмә* дип аталган, к. **Сәтләмә, Сәтлек.** Тимергалин: 400–401.

Дерив.: **сәгатьле, сәгатьсез; сәгатьче; сәгатьләп** (мәс., эшләү, түләү һ.б.)

**СӘДӘП,** диал. **садап** «перламутр, пуговица (из перламутра)» < гар. *çадäф* > тат. **сәдәф** «перламутр». Шулай итеп, тат. әд. телендә *сәдәп* һәм *сәдәф* – этимологик дублетлар (к. ТРС 1931: 257, 263).

**СӘЕЛ [сәйёл]** диал. (Гиганов; Будагов I: 617; Тумашева 1961: 195; ТТДС I: 384) «веселье; весёлый; праздник летнего солнцестояния – начала *челлә*», «вёдро», (Дмитриева 1981: 180; Тумашева 1992: 187) «открытый (красивый) вид местности, живописный; лесное озеро» ~ каз., к.-калп., кырг. *сейил*, уйг., төркм. *сәйил, сәйлә* «яз бәйрәме, сабантуй; һавага чыгып йөрү» < уйг. *сәйир* id. < гар. *сäйр* id. К. **Сәер, Сәйран.**

**СӘЕР [сәйёр]** «странный; чудной», диал. (ТТДС I: 384) «интересный» > чув. *сейĕр,* мар. *сäйыр*, удм. диал. (Кельмаков 1977: 59) *сайэр* «сәер; кызыклы; көлкеле» ~ нуг. *сейир* «гаҗәеп», ком. *сейир* «аяз һәм тын һавалар», к.-калп. *сәйер* «сәйран» < гар. *сäйр* «һава сулап йөрү» ← *сйр* «тамаша кылу, кызык өчен йөрү» тамырыннан, шуннан ук к. **Сәйран, Сәйяр, Сәйяра.**

**СӘЕТ** «сеид, потомок пророка Мухаммеда; духовный глава татар» (к. Будагов I: 654) < гар. *сäйид* id. ГТРС: 516; Тимергалин: 402 (тәфсилле).

**СӘҖДӘ** «поклонение, преклонение; молитва» < гар. *сäҗдä* id. ← *сҗд* «гыйбадәт кылу, баш ию» тамырыннан (шуннан ук *мәчет < мәсҗид,* хатынкыз исеме *Саҗидә* һ.б.). Бу сүз күбесенчә **сәҗдә кылу, сәҗдәгә китү** (намазда башыңны иеп тәсбих әйтү) составлы фигыльләрендә очрый.

**СӘЙЛӘН** «бисер, бисеринка» > чув. *селем* «энҗе» < фар., гар. *сäйлāнӣ* «Цейлон утравыннан килгән (энҗе)» сүзеннән, к. Zenker: 532. Цейлон утравын континенттан аерып торган Полк бугазында энҗе күп табыла. К. **Ләйсән.**

**СӘЙРАН** «прогулка; место прогулки – красивая местность» < фар. *сäйрāн* id. ← гар. *сäйр* «тамаша кылып йөрү», к. **Сәер.**

**СӘЙЯР [сәййар]** «передвижной (театр); труппа» < гар. *сäййāр* «күченеп йөрүче». К. **Сәер.**

**СӘЙЯРА [сәййара]** «планета» < гар. *сäййāра* «планеталар», сүзмә-сүз әйткәндә «йөрүчәннәр» – урыннары нигездә үзгәрми торган йолдызлардан үзгә буларак, планеталарның күк йөзендәге торышы гел үзгәреп тора, алар «йөри». Чаг. *планета* – латинча «очучан».

**СӘКӘЛ** «пежина, пучок волос у копыта коня» ~ чув. *сакăл,* мар. диал. *сакыл*, башк. *һәкәл*, каз. *шекел* id. ~ бор. чыгт. (Räsänen 1969: 408) *sekül*, аз. *сәкил*, төркм. *секкил* «ат аягындагы ак тап, ак йоннар», кырг. *секелек* «баланың маңгай чәче, чупае», монг. *саглага* «сәкәл; чук», *сагсаг* «чачаклы-чуклы» һ.б. (күп дериватлар), монг. диал. (Rona-Tas 1964: 168–169) *sagalak, sagalga* «сәкәл», *segeldereg* «ат дирбиясендә кыска каеш бау; чук». К. ш. ук госм. *шақақ,* төр. *seki* «сәкәл, чук, чупай». Ачык түгел. Räsänen 1969: 408; Федотов II: 6; ЭСТЯ VII: 226–227 (тат. һәм башк. параллельләре китерелмәгән). К. **Сагалдырык.**

**СӘКЕ,** диал. **сике, сәйке** (ТТДС I: 384) «нары; ровная, широкая доска для настила и других работ», башк. *һике* id., ш. ук «савыт-саба өстәле» ~ чув. *сикĕ*, мар. (Упымарий: 254; Иванов, Тужаров: 271, Саваткова: 198–200) *шугы, шäгы* «сайгау; зурат, күтәртеп ясалган кибән аслыгы», «алтарь, корбанлыклар куела торган өстәлчек», чув. *сакы* «уша», морд. М. *шяке* «юылган җепне ураткыч, шүргеч» ~ кр.-тат. *seke*. каз. *сәкі* «диван», аз. *сәки*, кырг., төркм. *секи* «сике, тапчан; яссы өсле чыгынты; балчыктан өелгән сәке», төр. *seki* «сүтун (колонна) төпсәсе, пьедестал; терраса», бор. төрки (ДТС: 494) *sekü* «сәке» ~ көрд. *seku* «таш сәке; платформа; сәхнә һ.б.ш.» – чыгышы бәхәсле сүз: берәүләр бу сүзне фар. *сäңки* «таш, таштан ясалган» сүзеннән дип уйлыйлар, икенчеләр тунг.-маньч. > як. *сäктä, сäксä* «аска җәелә торган нәрсә, ястык

һ.б.ш.» (к. Пекарский: 2150–2154) сүзләре белән чагыштыралар; к. чув. *сакси* «сәке» (Ашмарин XI: 23, ләкин бу сүз тат. *сәкесе* сүзеннән булуы ихтимал), венг. (Gombocz: 181) *szek* «урындык; өлкә (!)». Räsänen 1969: 408; Федотов II: 5–6; ЭСТЯ VII: 224–225.

Дерив.: **сәкеле, сәкесез; сәкелек.** *Сәке ~ сике* «как (ашамлык) үлчәү бирәмлеге» кызыклы.

**СӘЛ, сәлә** (ТТДС I: 385) «легко; нетрудно; лёгкий» < иске тат. **сәһел** > чув. *сахал, сахӑл*, мар. *шагал, шӓгӓл, шӓхӓл* < фар., гар. *сәһл* «җиңел; кулай» ← *сһл* «җиңел булу; тигез булу», шуннан ук иске әд. **сәһлән** «җиңеллек белән».

Иске тат., каз., к.-калп., уйг. һ.б. *сәл* «бераз, чак кына, әз генә» сүзе дә мәзкүр гар. сүзеннән булса кирәк, ләкин к. як. *сэл, сӓл* «уртача җиңел, сирәк» (бу сүзнең гарәп-фарсыдан алынуы мөхаль). ГТРС: 531; Федотов II: 18–19 (тәфсилле).

**СӘЛАМ [сәләм]** «привет, салям» > мар., чув., удм. *салам* ~ каз., кырг., уйг. *салам* һ.б. id. < гар. *сӓлāм* id. ← *слм* «исән-сау, бөтен; тыныч холыклы (булу)», шуннан ук к. **Сәламәт, Ислам, Мөселман, Тәслим.**

Федотов (II: 8) бүтән төрки телләрдә дә *салам* варианты барлыгыннан чыгып, чув. *салам* татарчадан түгел димәкче (ул тат. вариантын искә дә алмый), ләкин мар. диал. *сӓлӓм, шӓлӓм* вариантлары бар.

Удм. телендә *салам* «бүләк, күчтәнәч» мәгъ. дә кулланыла. Тат. орфографиясендә **сәлам** дип язу гарәпчә язылышны чагылдыра һәм орфографик традициядән килә. Будагов I: 632.

Дерив.: **сәламлә-ү,** диал. **сәламлек** «кеше аша җибәрелгән бүләк, күчтәнәч». **Әс-сәламү галәйкүм** «сезгә тынычлык (телим)» дигән мәгъ. тәгъбир.

**СӘЛАМӘТ [сәләмәт]** «здоровый (не больной)» < гар. *сӓлāмӓт* «исәнлек-саулык», тат. сыйфат мәгънәсе **сәламәтле** сүзеннән эллипсис буларак килеп чыккан. **Сәламәт** – барча мөселман халыкларында очрый торган сүз. Тамыры тур. к. **Сәлам.**

Дерив.: **сәламәтлек; сәламәтлән-ү.**

1960–1970 нче елларда атеизм, «искелеккә каршы көрәш» бигрәк котырынган елларда бер мәлне Башкортстан радиосында берәү **сәлам, сәламәт** сүзләре, имеш, «сөннәтләнгән» дигән сүз һәм, димәк, *әссәламү-галәйкүм* «син сөннәтлеме?» дигән сүз була, дип сөйли иде. Чыннан да, мәзкүр сүзләрнең гарәпчә шундый фигураль мәгънәсе бар, ләкин аны күптән белмиләр инде.

**СӘЛӘМӘ** «оборванный», «старый, засохший, беспорядочный», диал. (ЗДС: 199, 777) **зәләмә** «сәләмә», **салама, шалама** «сәләмә; иске, җимерек» > чув. *селеме* «йолкыш» ← **сәлә-, *сала-* «асылынып, тузылып, җимерелеп төшү» фигыленнән (*сәлә-мә < сала-ма*, чаг. *әләмә-сәләмә, алам-салам, алама-салама*), к. мар. (Иванов, Тужаров: 273–274) *шӓлӓ* «тузгыган», *шӓлӓн-, шалан-* «тузгу», *шӓлӓт-* «туздыру, тузгыту», чув. *салан-* «ватылу-җимерелү», *салат-* «туздырып ташлау» һ.б. гом. төрки **сал* «җимерек, ертык, тузгын, салынкы» тамырыннан, к. тат. (ЗДС: 566–567) **сәлгә** «сәләмә», к. кырг. *салай* «салынып төшкән», төр. *sele-serpe* «сәләмә» һ.б.ш. Федотов II: 9.

**СӘЛӘТ** > мар., мар. диал. *сӓлӓт*, башк. *һәләт* «способность» < тат. кит. **сәләхият** < гар. *ṣалāхийӓт* «яраклылык, максатчанлык, максатка ярашлылык» сүзеннән ← *ṣлх* «ярашу» тамырыннан, шуннан ук к. **Солых.**

Дерив.: **сәләтле, сәләтсез** (ш. ук **сәләхиятсез**).

**СӘЛӘҮ [сәләw]** диал. (ТТДС I: 385) «тесёмка, оставляемая под длинным платком (тастар)», чаг. мар. *шӓлӓ* «сәлам; сәлам билгесе итеп тапшырыла торган бер баерка сүс, ефәк җеп һ.б.». Гомумән – юраулы.

**СӘЛБӘГӘЙ, сәрбәгәй** (ЗДС: 566, 568) «жидкий, с тонкими стеблями и веточками и с малым количеством листьев (о травах на лугу)» ~ каз. *сербә-* «тырпаеп тору»; алт., тел., шор. *сарбай-, сӓрбӓй-* «артык киң як-якка җәелү» < монг. *сарбайи-* «төрле якка ботак җибәрү», *сарбаң* «ябалдашлы, киңгә җәелгән күп ботаклы», к. Räsänen 1969: 403. Әлбәттә; *сарп, салп//талп//чалп//шалп* тәкълиди тамырыннан. К. түбәндәгене.

**СӘЛБӘЛТӘК, сәлбелтәк** (ЗДС: 566) «сильно качающийся; качающийся даже при приложении малых сил», чаг. **сәлберә-ү, шәлперә-ү** һ.б. Чаг. **Салын-у, Сәлен-ү** һ.б.

**СӘЛБЕРӘ-Ү** «вянуть» ← *сәлбер* ← *сәлп* тәкълиди сүзеннән, к. **Сәлпе, Шәлпер.**

**СӘЛБИ** «отрицательный» < гар. *сӓлбӣ* id. ← *слб* «талап алу; юкка чыгару» тамырыннан.

**СӘЛЕН-Ү** «качаться, покачиваться» ← ***сәл-** < гом. төрки *сал-* (> чув. *сол-, сул-*) «селкетү,

җилфердәтү», *сал* «җилфердек» тәкълиди сүзеннән; к. гаг., төр. *salın-* «селкенү», кырг., үзб. һ.б. *салаң* «салбыр», кар. *салла-* «селкетү», *саллав* «веер», бор. төрки (ДТС: 482) *sal-* «селтәү; шаманнарча бию» һ.б. Палаталь вариант тел. (Räsänen 1969: 409) *sälmänčik,* «таганчык», алт. *säläŋdä-* «атыну» һ.б. сүзләрдә күзәтелә. Чаг. ш. ук **сәңгелдәк, чәңгелдәк,** к. түбәндәгене. К. гом. тат. **салкы, салпы, шалпы** һ.б. (бик күп сүзләр).

**СӘЛЕНЧӘК, сәленгеч, сәленеч, сәлли** һ.б. (күп вариантлар, к. ЗДС: 567) «колыбель, люлька; качели» ~ төркм. *салланңыч, салланчак*, төр. *salıncak* «бишек, тирбәлгеч». Гом. төрки сүз, ләкин күп сүзлекләргә кертелмичә кала. К. **Сәлен-ү, Сәли, Силә**.

**СӘЛҖУК** – представитель древнего тюркского племени – по-видимому от имени древнего вождя. Бу сүзнең монголча күп. формасы *сәлҗугут, салйаугут*, башк. *салъйуһут, салъйут, һальйут*, кырг. *шулҗуыт* һ.б. тат., төрки, монг. тарихи ядкәрләрендә еш очрый. Күньяк Урал регионына **сәлҗугутлар, сәлҗукыйлар** – сәлҗук токымнары (алар Төркияне нигезләүчеләр буларак киң билгеле) ничек килеп урнашканлыгы бигүк ачык түгел. Кырым тат. составында булган *сиҗуутлар* да шул ук *сәлҗигутлар* бугай.

Сәлҗук үзе хәзәрләрдә хәрби хезмәттә булган **Дукак** исемле бер бинең углы икән. Әтисе үлгәч, би булган Сәлҗук (*Сәлчук* «силчык») Хәзәр ябгусы (хан урынбасары) белән конфликтка керә, хәтта ябгуны аттан бәреп төшерә. Шуннан ул, бөтен кушыны, мал-мөлкәте белән качып, Харәземгә барып урнаша. Анда ул, йөз яшькә җитеп, 994 елга кадәр яши. Аның угыллары аталары нигезләгән империяне Диҗлә елгасы буйларына кадәр киңәйтәләр. К. ш. ук **Чалчут.** Velidi: 183–185 һ.б. (сәлҗукыйлар тур. зур әдәбият бар).

Шуны өстик – кайбер тарихи мәгълүматларга караганда, Сәлҗук Ибне Фадланга очраган «күзәркиннең» кияве, димәк, болгар патшасы Алмушның баҗасы булган. XVIII г. Уралда *Салзаут волосте* искә алына.

**СӘЛИ, сәләй, сәлли** (ЗДС: 567–570) «пружинная колыбель», чаг. ш. ук **сәленмә, сәленгеч, сәленчек, сәленчәк, сәлгелдәк, сәңгелдәк, сәңгелтәк,** себ. **цәлгенцәк, цәнгелцәк**, арытабан чылаштырылып (ЗДС: 738) **чәңгелдек, чәңгелтәк, чәңгелчек** «сиртмәле бишек», «кое сиртмәсе», **сел** тәкълиди тамырыннан төрле сөйләшләрдә ясалганнар. Чаг. **Чиңгелчәк.**

Бу сүзләрнең параллельләре бүтән төрки телләрдә күренми, чөнки «бишек, сәлли» мәгъ. сүзләр сүзлекләрдә начар чагылдырыла.

**СӘЛКӘҮ [сәлкәw]** «вялый, ленивый; слабый, хилый» > мар. *сälкäу*, чаг. төркм. *салланңыч* «бишек», *салланчак* «таган», башк. *һәлкәү* id. ~ каз. *селкеу* < *салқау* id. *салқа-* «сәлкәүләнү» фигыленнән, *салқ* тәкълиди сүзеннән, бу сүз исә *сал* тәкълиди нигезенә *-қ* детерминанты ялганып ясалган; к. тат., каз., госм. һ.б. *салкы*, үзб. *салқа, солқа* «зәгыйфь, сәлкәү» (к. Радлов IV: 361), чув. *салху* «күңелсез, сагышлы, сәлкәү», к.-балк. *сал* «сәлкәү», госм. *сулку* «йомшак, черек» һ.б. (төрки телләрдә хәтсез мисаллар табыла). К. **Салкын, Салпы, Сәлпе.**

**СӘЛКЕН-Ү, силкен-ү** «плясать, делая движения наподобие журавля, пытающегося взлететь» (фольклористик әдәбиятта, хаталанып, **селкен-ү** дип язалар), «превратиться в образ животного (о кудесниках, шаманах и т.п.)» ~ алт. *селкин-*, каз. *сәлкін-, селкін-* «кош кебек кагыну; очарга әзерләнү (зур кошлар тур.); очып китү», бор. төрки (ДТС: 482) *sal-* «шаманча бию» һ.б. Бор. шаманизмнан калган сүз, *җилкен-у* белән тамырдаш.

Рус телендә генә сакланып калган «Алдар и Зухра» башкорт эпосындагы изге хатын *Зухра* этенә *силкин, этем, силкин,* дип әйткәч, эт «селкенә» һәм аның тәненнән ярма коела. Асылда (халык иҗатыннан алынган мотив булса) *силкин* дип әйткәч, хезмәткәр эт коштай очып китеп, сихерле сыйлы дәстерхан алып килергә тиеш иде (к. руслардагы *скатерть-самобранка*). *Силкен* – сүзен аңламау эпостагы поэтик мотивның ямьсез бозылышына китергән (кунаклар эт бетен ашыйлар була).

**СӘЛПӘН, сәлпәң** «медлительный; рыхлый (туловищем); неповоротливый» ~ башк. *һәлпән* id., ш. ук (БТДҺ: 387) «тырай тибеп йөрүче, авыл буйлап эшсез йөрүче». К. **Сәлберә-ү; Сәлпе.**

**СӘЛПЕ, сәлпек, сәлпә** «неповоротливый, вялый (о языке в значении невыразительный)» ~ чув. *селĕп, селпү, селпу* id., венг. *selyp* «сәлпе, сәлпән» сүзенә караганда, шактый бор. сүз. Әлбәттә, **салпы** вариантыннан палатальләшкән (**салп** нигезеннән, **сал** тәкълиди тамырының *-п* детерминанты булган тармагыннан). Федотов II: 36.

Дерив.: **сәлпелән-ү; сәлперә-ү (> сәлберә-ү) → сәлперәк** «шиңеп асылынган». К. **Сәлпән.**

**СӘМА** шигъ. «небеса» < гар. *sämā* id. Шуннан **сәмаwи** «күкләргә хас».

**СӘМАК** диал. (ДС I: 17) «спусковой крючок ружья, затвор» ~ кырг., алт. *самык* id. < рус. *замóк* id. Бу сүз чув. теле аша таралган булса кирәк (*з-* > *с-*).

**СӘМӘН** «денежные средства» > чув. *семен* «байлык», башк. (БТДҺ: 388) *һәмән* «акча; байлык», мар. *саман* «яшәү шартлары» < гар. *çämän* id. бор. Мисыр. *çмн* (сузыклары билгеле түгел) «көмеш» сүзеннән.

**СӘМӘРӘ** «плод, плоды (в разных значениях)» < гар. *çämära* id.

**СӘМИХ** «камедь, прозрачная смола» < гар. *çамғ* id. Бу сүз гарәпчәдән нык үзгәргән. К. ш. ук удм. *сюмык* «бокал, рюмка, чынаяк; пыяла» – болг. теленнән (Смирнов 1890: 46), төр. *zamk* «җилем, келәй».

**СӘМРӘҮ [сәмрәw], сәмер кош** ← тат. кит. **сәмруг** «сказочный двухглавый орёл, сказочная огромная птица» > мар. (Исанбаев 1978: 48) *сäмрык кайык*, башк. *һәмрәү, самрау* ~ каз. *самурық*, к.-калп. *суймурық*, кырг. *семирук, зумурук* id., нуг. *сумырай* «бәла-каза рухы» < фар.-таҗ. *семург, симург, синмург* < авест. *saenomereүo* «әкияти каракош»; *mereүo* > хәз. фар. *марғ, мурғ, мäрғ* «кош», *saeno* тур. төрле фикерләр бар: «билгесез бер кош» (Абаев 1965: 116), «бөркет; эт» (Рыбаков 1988: 442–443), «дөньяга *сома* ~ *һаума* эчемлеген алып килгән беренче кош» (бу кош образында төрки фольклордагы язмыш кошы – *ат башындай алтын кәккүк* образы охшаш), «изге бәхши кош» (к. Рапопорт: 62–63). К. ш. ук бор. слав. *семаргл, симаргл* – мифик кош атамасы да *сәмрүг* < *сәммург* < *сәйна мург* сүзеннән килсә кирәк. **Сәмрәү** сүзен гадичә *сийаһ мург* «кара кош» дип тә аңлаталар. К. ш. ук МНМ II: 436–437; Тимергалин: 405.

Тат. фольклорында **сәмрәү** яхшы да, яман да түгел, гадәттән тыш зур гәүдәле кош кына. Ләкин бу сүз белән Россия гербын атаганда аңа кире мәгънә салынган (*сәмрәү* ~ царизм). Башк. фольклористикасында *самрау кош*ка «бор. башкортларның баш тәңресе» кебегрәк мәгънә салулар – ясалма, фольклорда да, тарихи ядкәрләрдә дә реаль нигезе булмаган раслама.

**СӘМСӘВЕР [сәмсәwер], сәмсәүр** (Тумашева 1992: 188) «меч» ~ каз. *симсар, семсер* < уйг. *шәмшәр, шәмшир* < фар. *шамшир* id. ~ төр. *şimşir* «бүк агачы; туры кылыч». Шәрыктә бик билгеле сүз.

**СӘН** иск., диал. «ты» < чыгт. *сән*. К. **Син.**

**СӘНӘ** иск. «год» < гар. *sänä*.

**СӘНӘГАТЬ [сәнәғәт]** «промышленность» < гар. *çанā‘ат* «сәнәгать», «һәртөрле һөнәрләр» сүзеннән ← *çн‘* «эшләү, ясау» тамырыннан. К. ш. ук **Сәнгать, Сонгый.**

**СӘНӘК,** диал. (ЗДС: 374) **синәк** «вилы» < гом. кыпч., чув. *сенек, сәнәк* > башк. *һәнәк* id. Тат. сөйләшләрендә бүтән фонетик вариантлар да киң таралган: к. (ЗДС: 574) **синәк,** нокр. (> удм.) **саник,** мар., удм. (Упымарий: 288; Иванов, Тужаров: 274; Саваткова: 200; Насибуллин: 147) *шеньык, шäньык, шаньык* (< *шайнык*); к. ш. ук кырг. *сенек* «корып каткан тармак, ботак; ике япьле сәнәк» < уйг. *сәйнәк* id. < гом. төрки **сайнақ* id. < *сайна-* ← *сай-* «чәнчү, үткәрү», к. кр.-тат., кырг., каз. *сай-* «үтәли чәнчү» һ.б.

К. ш. ук кас. **сини’, синик,** кар. *синак,* морд. М. *цянго,* морд. Э. *сянго* «сәнәк», ихтимал, **сәнгәк,* **сәнге* шикелле формалардандыр. чаг. тат. (Тумашева: 183) **сайғак** «кигәвен» ← **сай-* «чагу, чәнчү» һ.б. Федотов II: 36–37; ЭСТЯ VII: 236–237. К. ш. ук **Сыяу.**

Дерив.: **сәнәкле, сәнәксез; сәнәкче** – 1918–1920 елларда Совет хакимиятенә каршы сугышучы.

**СӘНӘСКӘ, чәнечкә, чәнисә** (ТТДС I: 501), **сәнескә** (БТДҺ: 293) «салазка, сани, которые тянет человек», русчадан булса кирәк, к. рус. *саночки, санице* «чаначык». Чаг. **Салача** (ләкин монда контаминация генә).

**СӘНӘТ** иск. «документ» < гар. *sänäd* id. Иске әд.-фәнни телдә бик кулланылышлы сүз булган, *снд* «таяну, терәтү» тамырыннан, шуннан ук **иснад** «дәлилләр теземе, хәдиснең чыгышы-чыганагы тур. мәгълүматлар».

**СӘНДЕРӘ** «полати», диал. (ДС II: 171; ДС III: 145) «плоская крыша на столбах (для сушки сена, снопов и т.п.)» > башк. *һәндерә* «баскыч» ~ чув. *сентре, сентрей* һ.б. (к. Сергеев 1971: 106), мар. *сендыра, шӧлдравал, сäндра, селдыра, сӧндра* һ.б.

(к. Исанбаев 1979: 86–87, 97), удм. *сэндра* «сәндерә». К. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 386, 389) *сүндерә, сүндәрә* id.; каз. *сәндіре* «лапас» (ҚТДС: 290) татарчадан алынма булса кирәк. Бик бәхәсле сүз: М. Рясяненның бу сүзне русча *средник* (яисә рус. диал. *средна*) «матча» сүзеннән дип күрсәтүе *сәндерә* сүзенең мәгънәләрен дә, фонетик вариантларын да аңлатып бетерми. Ш. ук. төр. *мусандыра* «сәндерә» сүзе дә фонетик җәһәттән караганда *сәндерә* сүзенең чыганагы булалмый. Тик төр. *son-durma* «дивардан тышка караган зур, озын балконсыман корылма» (*son-* «сону» сүзеннән) генә бераз уйландыра. Федотов II: 37–38.

**СӘҢ I** (ТТДС II: 279) «хорошо, отлично, великолепно (как модальное слово)» ~ каз. (ҚТДС: 290) *сәң, сән* id.; башк. (БТДҺ: 372) *һаң* «әйе; ну». Монг. сүзе булса кирәк, к. монг. *сейн* «яхшы, шәп; әфәнде» > төр. *sayın* id. Татарларда *сәң* – арготизм, жуликлар, караклар телендә кулланылган.

**СӘҢ II** (ЗДС: 568, себ.) «табачный дым; налипшая грязь (особенно в трубке); плесень», иске тат. (К. Насыйри һ.б.) *зәң* < фар. (Будагов I: 607) *зәң* «тут, тутык». К. **Зәңгәр**. Чаг. **Зин.**

**СӘҢГӘР** «завал; баррикада» < фар. *сäңгäр* id. Будагов I: 638.

**СӘҢКИ: сәңки (чәңки) елан** «змея – дух болезни (в заговорах)», к. Н. Исәнбәт. Мырауҗан батыр. Казан, 1975: 127–128. Ачык түгел. Ихтимал, **зәңги елан** «кара елан» сүзеннәндер. К. **Зәңги**.

**СӘПИ** диал. «скорняк; дубильщик» ~ кр.-тат. *sepi* «тире пеләү», төр. *sepi* «тире иеләү эше», алт. *cеп* id. чаг. **сип.**

**СӘРАТАН** – название зодиакального знака и месяца – «рак» к. **Саратан.** Тимергалин: 395.

**СӘРӘПИН, сәрпин**, **сарабан, сарапан, сарапи** (ЗДС: 562, 568) «вид ткани», **сарапинка, сарбинка** «алъяпкыч; алъяпкыч өчен тукыма төре» (рус теле аша) һ.б. барысы да фар. *сäрбäнд* «баш яулыгы» һәм *сäрупай* «баштанаяк (кием)» сүзләренең контаминацион чагылышлары бугай. К. **Сарафан, Сарпат, Сарпинка.**

**СӘРБӘГӘЙ** (ЗДС: 568) «редкий; вторично выросший (о траве на выкос)» ~ каз. *сербегей* id. ← *серби* «тырпаеп тору», алт., шор. һ.б. (Räsänen 1969: 403) *sarbaj-* «таралып, ботаклары тырпаеп үсү» ~ монг. *sarba-ji* «төрле якка ботак җибәрү» һ.б. > як. *сарбай-* id. Чаг. **Тырпай-у.**

**СӘРВИ [сәрwи], сәрби** «кипарис», күч. «стан красавицы» < фар. *сäрwӣ* «кипариска охшаш», *сäрw* «кипарис», к. Будагов I: 627.

**СӘРВИНАЗ [сәрwиназ]** иск. «красавица (подобная кипарису)» < фар. *сäрwинāз* id. «Сәрвиназ» дигән танылган көй дә булган.

**СӘРГАСКӘР** «главнокомандующий, полководец» < фар. *сäр-и ‘аскäр* «гаскәр башы» (фар. *сäраскäр* дип укыла) > төр. *serasker* > рус. *сераскир*. Фасмер III: 603.

**СӘРГӘРДӘН** «растерянный, в смятении; блуждающий, не находящий себе места» < фар. *сäргäрдāн* «башы әйләнмеш». Фар. *сәр* «баш» сүзе күп кенә кушма сүзләр составында килә, к. **Саравыч, Сарафан, Сарбаз, Сардар, Сарпат, Сәргаскәр, Сәркәтип, Сәркәш, Сәрмая, Сәрсән, Сәрхуш** һ.б., к. Будагов I: 623.

**СӘРГЕ** иск. «выставка; полка, полки (в магазине)» ~ төр. *serge* «күргәзмә», *sergin* «җәеп салынган (тавар)» һ.б. ← *ser-* «җәю, җәеп салу, яткызу, яткыру». К. түбәндәгене.

**СӘРДӘ, сәрдәнә** диал., башк. **сәрәтә** «сныть; анчоус» > чув. *серте, сетре, сетера*, мар. *середа, седера,* удм. *сарда* < фар. *зäрдä, зäрдäнä* «зәгъфран, рәваҗ – гомумән үзеннән сары буяу алына торган үсемлек». Будагов I: 608. К. ш. ук тат. диал., удм. *шäрдä* «сәрдә» (Потанин Г.Н. У вотяков Елабужского уезда // ИОАИЭ II, Казань, 1980) ~ мар. *серетан* id.

Бу сүз Болгар дәүләте заманнарында ук Урта Азиядән килгән һөнәрчеләр теленнән калган – вариантлар күплеге аның бик бор. алынма булуы белән бәйле. К. **Зәрдә, Сәртәк, Чәрнәй**. Räsänen 1969: 412 (шикле параллельләр китерә); Федотов II: 38 (этимологиясен белми).

**СӘРДЕК, сәрлек** (трбс.) «полати; настил (из тонких жердей), жердь под потолком для вывешивания одежды», диал. (Туймазы) «гать» – чаг. чув. *сарлăк* «сайгау» ← *сар-* < *сäр-* «җәю, тезү», к. мар. *сäр-, сар-, -шäк-, шар-,* чув. *сар-* «җәеп салу, тезеп кую» ~ төр. *ser-* «җәеп салу», к. **Сир-ү.** Чаг. аз.

(АДДЛ: 359) *сәрдик* «мичкәнең, казанның һ.б. тактадан ясалган капкачы». К. **Сәрге.**

**СӘРЕН, сәрин** (С. Сүнчәләй, А. Расих; ДС II: 171, 258; ТТДС I: 386; Арсланов 1988: 42) «свежий» ~ кар., кр.-тат., алт. диал., *серин, сэрин,* аз. *сәрин,* төр. *serin, selin*, хак. *сирен, сӧрӧн, серääн*, алт. *сэрӱӱн, сäригун*, як. *сäриин, сӧрӱӱн* < яз. монг. *serigün* «(сиздерерлек) салкын». К. ш. ук хәз. монг. *сэрүүн*, тунг. (ССТМЯ II: 145–146) *сэрүн* «салкынча; сәрен» ← монг. *сэр* «йомшак җил », *сэр-* «җил исү». ЭСТЯ VII: 244–245. Чаг. **Сиз-ү.**

**СӘРЕНҖЕ, сарынҗы** (Г. Исхакый) «цветастая ткань», себ. (Тумашева 1992: 188) **сәринди** «буйбуй, аллы-гөлле киҗе-мамык тукыма», **сәрәнде, сәринде** «Урта Азиядәгечә бишмәт тегү өчен буй-буй тукыма» ~ чыгт. (Будагов I: 627), төркм. (ТДГДС: 595) *серинда* «хатын-кыз киеме өчен тукыма», уйг., бор. кыпч. *серәнҗи* «салават күпере», үзб. диал. *сәрингә* «сәренҗе» < фар. *сари-и һинди* «сәренҗе», төп. мәгъ. «һинд сарие» (*сари* Һиндстан хатын-кызлары уранып йөри торган бизәкле тукыма кисәге). К. ш. ук кырг. *сарынҗы* «бишмәт төре». **Сәренҗе** сүзенә охшаш иске **сәрәнҗан** «өс киеме» сүзе бөтенләй үзгә – фар. «баштанаяк» дигән сүз.

**СӘРКӘТИБ, сәркәтип** «секретарь» < фар. *сäркāтиб* id.; төп. мәгъ. «баш кятиб, баш секретарь», *сäр* «баш, башлык», *кāтиб* «секретарь, кятип».

**СӘРКӘШ** (ТТДС II: 278) «своенравный и упорный» ~ башк. диал. id., ш. ук (БҺҺ II: 231; БРС һ.б.) «җигелә торган үгез; үзсүзле; гел алдан йөрергә, башлык булырга яратучан кеше», башк. *һәркәш* «сөзгәк; сугышуга өйрәтелгән (хайваннар тур.)» ~ госм., уйг., үзб. һ.б. *сәркәш* id. < фар. *сäркäш* «көтү башлыгы (кәҗә, тәкә); баш күтәрүче» – номиналь мәгъ. «баш сузучы» (*сäр* «баш», *кäш* «сузучан»). Чаг. **Сиркә.**

**СӘРМАЯ [сәрмайа]** «капитал, денежные средства для начала дела» < фар. *сäрмāйä* id.–«баш мая».

**СӘРМӘ-Ү** «пощупать рукой; украсть», **сәрмәлә-ү** «искать ощупью» ~ үзб. (ЎХШЛ: 234) **сәрмә-** id. һ.б., к. **Сирмә-ү.**

Дерив.: **сәрмән-ү, сәрмәт-ү.**

**СӘРСӘН** «нервный, нетерпеливый» (Ш. Манур) ~ башк. *сәрсәңке,* чув. *çерсен* id., уйг. *сәрсан* «ыгы-зыгыдан арыган» < фар. *серсам, сäрсам* «баш авыруы», *серсем, сäрсäм* «кыргыйлашкан, юләрләнгән». Redhouse: 1005.

**СӘРТӘК, сәрдәк** диал. (Тумашева 1992: 195) «морковь» < фар. *зäрдäк* id. сүзмә-сүз «алтын тамыр». К. **Сәрдә.**

**СӘРХӘТ** иск. (Гиганов сүзлегендә *сярьхядъ*) «граница (страны, области)» < фар. *сäрхäдд* id. (фар. *сäр* «баш, төп», гар. *хäдд* «хәт; чик, чигәрә»; чаг. иске тат. *ходуд* «чикләр» < гар. *худӯд* һ.б.). Төр. *serhat* «аеру линиясе» икенче бер сүз: *ser* «баш» + гар. *hatt* «линия; хат, язу» һ.б. Гар. *хдд* «чикләү» һәм *хтт* «язу-сызу» аерым тамырлар.

**СӘРХУШ** «пьяный; пьяница» < фар. *сäрхош* id. – «башы кәефле», «башы хуш».

**СӘТ** диал. (ЗДС: 568–569) «пульс; момент; удачный момент» > мар. (Исанбаев 1978: 28) *сат, сады* «момент» ~ каз., к.-калп. *сәт* «момент; бәхет» < миш., төркм. *сәәт*, төркм. (ТДГДС: 163) *саат* «сәгать» сүзеннән.

**Сәт** продуктив сүзьясагыч нигез, к. диал. **сәтлек** «шундук, моментында; пульсы бар», **сәтлексез** «пульссыз», к. ТТДС: 385–386. К. **Сәтләмә.**

**СӘТЛӘМӘ** (З. Бәшири) «карманные часы; протекание жизни» < диал. *сәгәтләмә* «часы» > чув. *сехетлеме* (к. Сергеев 1968: 56), мар. диал. *сäгäтлäмä, сагатлама* id. һ.б. иске тат. теленнән; каз. *сағатлама* id. – барысы да иске тат. *сәгатьлә-ү* «сәгатен билгеләү» сүзеннән булса кирәк.

**СӘТЫР, сатыр** «строка (написанного)» < гар. *сäт̣р* id. (к. Будагов I: 628); бу гар. сүзен грек. *һистор* «билге, хәбәр» (шуннан *история* «тарих») сүзеннән дә, санск. *sutra* «шигырь, шигырь юлы, җеп» сүзеннән дә чыгаралар.

Элек хат язганда *түбәндәге сатырларымда* дип хәбәр яза башлаганнар.

**СӘҮГАТЬ [сәwғәт]** «подарок (за благополучное возвращение домой; за благополучную сдачу экзаменов) – гар. сүзе шикелле язылса да, бөтенләй башка сүз. К. **Сауга**. ЭСТЯ VI: 273–275.

**СӘҮДӘ [сәwдә]**«торговля; тесное общение» ~ башк. *сауҙа, һауҙа* id. < гар. *сäwдā* (*cwд* «кара булу» тамырыннан), «кара көю; көнчелек, дәрт»

сүзеннән; фар. телендә бу сүз «мал табу белән мавыгу, милек дәрте» мәгънәсендә активлашкан; төрки телләрдә *сәүдә* «дәрт» (*гыйшык сәүдәсе* «гыйшык дәрте, көнчелекләр һ.б.»), «якыннан аралашу; бәйрәм» (к. кар. *сӓwда* «бәйрәм итү») мәгънәләрен алган; к. ш. ук Ә. Ясәвидә *Сабырлы кеше «ахирәттә Алла белән сәүдә кылгай»*.

*Сәүдә* < *сӓwда* сүзен бор. фар. *сууд* «файда, табыш» сүзеннән дә чыгаралар. Ләкин бу фараз фонетик җәһәттән нигезләнмәгән.

**Сәүдә** продуктив сүзьясагыч нигез: **сәүдәче, сәүдәләмәк** һ.б. К. Будагов I: 642, к. түбәндәгене.

**СӘҮДӘГӘР [сәwдәгәр]** «торговец, купец» < фар. *сӓwдāг'āр* «сәүдә итүче».

**СӘҮМӘТ [сәwмәт], зәүмәт** (Гаврилов 1891: 22–26) «новогоднее празднество, один из обрядов новогоднего цикла» < гар. *сућүмӓт* «ук атыш, ук атып юраулар» сүзеннән булса кирәк: Яңа ел бәйрәмендә гарәпләрдә дә һәртөрле юраулар, шул хисаптан югарыга ук атып аның очышына, кая төшүенә карап юрау гадәте булган. Бор. гарәпләрдә **сәһүмәт** «ук атып юрау» өчен махсус изге уклар (**сәһем** «ук») булган.

**СӘҮРӘК [сәwрәк], сәүрек, сәwерек** (Тумашева 1992: 188), **сәүряк** (миш., к. ДС I: 172) «молодой конь; юнец, подросток», **сәүрәwек** (ТТДС I: 386) «молодая липа, молодая кора» ~ башк. диал. (БҺҺ II: 298; БТДҺ: 388) *сәүрек, һәүрек, һәүрәк, һәүрик* «өергә җибәрелмәгән яшь айгыр; нәселгә калдырыла алмаган айгыр; алаша»; күч. «булдыксыз кеше», *һәүәркә* «булдыксыз хатын» ~ каз. (Катаринский) *сәүрук* «4–5 яшьлек айгыр», *сәүрiк* «өергә җибәрелмәгән айгыр», *сәwүрәк* «начар йөрешле айгыр», каз., кырг. (Будагов I: 58, 645, 693) *сауруқ, сэврук* «печтерергә билгеләнеп тә печтерелми калган айгыр» < төр. (угыз.) *savruk, savuruk* «эшкә яраксыз, юньсез; ташландык» ← *savur-* «ташлау, ыргыту; ирекккә җибәрү; җил белән җилгәрү» (к. **Суыр-у II**) ← *sav-* «сугу, кизәнү, куу». Кыпч. телләрендәге *сәүрек* < *саурық* һ.б. төр. теленнән түгел, бор. бер угыз сөйләшеннән булса кирәк. Кайбер сүзләр (мәс., башк. *һәүәркә* < *сәүәркә*) кыпч. телләренең үзендә ясалган). К. **Саба-у.**

**СӘҮРЕ [сәwрĕ], сәүрә, сәwерә** (ТТДС I: 384; ТТДС II: 386) «туесок для молочных продуктов»; «берестяное ведро» < удм. *сарба, сарва ~ савра* id. Чаг. рус. диал. *сарга* (Аникин: 485–486) «шеле, нәрсәдер үрү өчен агач кабыгы тасмасы (бик төрле типта була)». Фин-угор сүзе бугай.

**СӘҮЧЕ [сәwчĕ],** диал. **савцы** (Будагов I: 693) «посредник; пророк» < чыгт. *саучы* «сәүче; илче, хәбәрче» < бор. төрки *sabčı, savčı* «илче, хәбәрче, пәйгамбәр» ← *sab* «сүз, нотык; язма хәбәр, хат; кыйсса, тарих», (ДТС: 478, 491–492) *sav* «әмер; хәбәр»; төбендә кыт. сүзе булса кирәк. Һуннарда *чопчи* «имче, күрәзә» булган (Гукасян 1981: 81); чаг. ш. ук бор. монг. *ǯabuči* «илче, яучы» >> мар. *савуш, сагуш, сӓүс* «кияү егете», угыз. *саужы*, төркм., үзб. *саучы* «яучы» (ләкин *сәүче* белән *яучы* бердәй түгелдер!). Будагов I: 693; Мухамедова 1973: 171–172; ЭСТЯ VII: 128–129. К. **Чавыш.**

**СӘФӘР I, сафәр** «месяц сафар (мусульманского лунного календаря)» < гар. *ҫафӓр* id., к. Будагов I: 701. **Сәфәр** – икенче ай, *ҫфр* «буш булу» тамырыннан, шуннан ук *сифр* «нуль; цифр».

**СӘФӘР II** «путешествие (с определенной целью); поход» < гар. *сӓфӓр* id. ← *сфр* «юлга чыгу» тамырыннан, шуннан ук *мөсафир*.

**СӘХӘР** «завтрак до зари (во время поста рамазана)» < гар. *сӓхӓр* id. ← *схр* «таң беленү» тамырыннан (Будагов I: 622).

**СӘХИФӘ** «страница (книги)» < гар. *ҫахӣфӓ* id. ← *ҫхф* «яңа сүз әйтү» тамырыннан.

**СӘХНӘ** «сцена» < гар. *ҫахнӓ* id. << грек. *ςχηνη [skene]* id. >> рус. *сцена*. Фасмер II: 816; Kluge: 901.

**СӘХРӘ, сахра** «простор; лоно природы» < гар. *ҫахрā'* id., төп мәгънәсе «кыя, кыялар», шуннан ук *Сахара* (чүл атамасы), к. **Сахра.**

**СӘХТИЯН [сәхтийан], сахтыян, сактайан** «сафьян, качественно выделанная тонкая кожа» << фар. *сӓхтийāн* > рус. *сафьян* ~ ним. *Saffian* (төр. теленнән). Фар. сүзен *сӓхт* «ныклы» сүзеннән дип уйлыйлар, ләкин бу фикер бәхәсле, к. Фасмер III: 566.

**СӘЯСӘТ [сәйәсәт]** «политика» < гар. *сӓйāсӓт, сийāсӓт* «политика; администрация; административ чаралар» (к. Будагов I: 653) ← *сwс* «идарә итү» тамырыннан. Шуннан ук **сәяси** «политик».

**Сәясәт** продуктив сүзьясагыч нигез: иск. **сәясәтле** «кырыс, чара күрүчән», **сәясәтче, сәясәтчелек, сәясәтлек**; Башкортстан татар матбугатында һәм хәз. башк. телендә **сәясмән** «политик (кеше)».

**СӘЯХӘТ [сәйәхәт]** «путешествие» < гар. *сäйāхäт* id. ← *cwx* «сәяхәт итү» тамырыннан, шуннан ук иске *сәййах* «сәяхәтче»; дериватлары: **сәяхәтче, сәяхәтчелек,** к. түбәндәгене.

**СӘЯХӘТНАМӘ [сәйәхәтнамә]** «дневник путешествия, записи путешественника, путевые заметки» < фар. *сäйāхäтнāмä* id. (*сәяхәт-намә*), гар. *сäйāхäт* + фар. *нāмä.*

**СЕБӘ, зебә** «ложное ребро» к. **Сөбә.**

**СЕБЕР** «Сибирь» – Рәшидетдин тарихнамәсендә (XIII г. азагы) бер кабилә-өлкә һәм шундагы шәһәр исеме буларак *Сибир* искә алына; Рәшидетдиндәге һәм рус елъязмаларындагы *Ибирь и Сибирь* иле татарча *Эбер-Себер, Эбер-Чебер, Ыбыр-Чыбыр* «вак халык» сүзенә бик тәңгәл; Себер татарларында хәзергәчә *Сыбыр* – бор. кечкенә буйлы мифик халык тур. сөйлиләр икән (Исхаков 1992). Фин-угор этнонимикасында *сипыр* дигән угор (ханты-мансиларның ата-бабалары) кабиләсе билгеле. Шул этнонимны бор. төрки *сабир, савир* кабиләсе атамасы белән бәйлиләр (угорлар төркиләшкән дип уйланыла). Савирлар V г. Урал белән Алтай арасында яшәгәннәр (к. Мольнар: 19). Византия чыганакларында *гунно-савирлар* яки *гамак-савирлар* искә алына. *Гамак* дигәне төрекмәнчә *ғамақ* < кыпч. *қамгақ* < *каңгак* «биек тәгәрмәчле арба» (к. Чичуров: 49–50, 74–78; 88, 96). Хәзәрләрнең дә *сабир* дип аталуы билгеле h.б. (к. Velidi: 92, 27, 404). Гомумән, *Себер ~ сабир* чагыштырылуы, күп кабатланса да, юраулы.

**Себер** этнонимы тур. да күп язылган, к. Фасмер III: 616; Язык земли Сибирской // Правда 1978, 9 октябрь; Аникин: 493–494 (күп кенә әдәбият күрсәтелә, ләкин болар моңарчы язылганнарның кечкенә бер өлеше); Тимергалин: 410.

Шуны әйтергә кирәк, Урта гасырларда язылган бай төрки әдәбиятта һәм дастаннарда **Себер** < **Сибир** сүзе очрамый диярлек. Шунлыктан хәз. тат. **Себер** сүзе русчадан алынган булу ихтималы да юк түгел. Бор. татарлар Себер якларын бүтәнчә атаганнар бугай.

Дерив.: (себер татарларында) **себерлек** «Себер кешесе», **себерче.**

**СЕБЕРКӘЧ** «метлица, пучок колосьев» < **себеркекәч** (булса кирәк). Ихтимал рус. *метлица* ← *метла* сүзләре тәэсирендә ясалгандыр. К. **Себерке.**

**СЕБЕРКЕ** «метла», диал. (миш., себ.) «борона», **себертке** «себерке; ат тырмасы» < гом. кыпч. *сибиртки* ← *себерт-* < *сибирт-* «себертү» сүзеннән; ләкин интерконсонант *-т*-сыз вариант та бор., к. бор. чыгт., төр. *süpürgü* «себерке». К. ш. ук хак. *сібіркі* (нәкъ татарча әйтелә). К. **Себер-ү.**

**СЕБЕР-Ү** «мести, подметать», диал. «вытереть» (миш., себ., к. ТТДС II: 265; Тумашева 1992: 189) «бороновать» < гом. кыпч., к. башк. *һебер-,* кар., ком., алт. *сибир-, сибүр-,* хак. *сібір-,* чыгт. *сипур-,* уйг., чыгт., госм., аз. h.б. *сүпүр-* < бор. төрки (Радлов IV: 848; ДТС: 501, 517) *sipir-, süpür-* id. > венг. *söpör-, seper-* «себерү» < бор. төрки **сирбиир-*, к. тув. *ширвиир-* «себерү». **Себер** нигезенең веляр параллеле – каз., кырг. *сыпыр-,* алт., хак. *сыбыр-* «себерү, бөтенләй куып чыгару (китү)» ~ тат. **сыпыр-у** (к.). Ошбу сүзләрнең тамыры *сарп*// *сäрп*//*сырп*//*сирп* – каты ышкылуны белдерүчән тәкълиди сүз тагын берничә гом. төрки сүзгә нигез булган һәм үзе дә фигыль мәгъ. кулланылган, шуннан чув. *шăпăр, шăппăр,* мар. *шӗвӗр* < болг. **сĕбĕр, *сĕбĕрĕг* > венг. *seprö, söprö, söprü* ~ як. *сиппир*, яз. монг. *sigür*, бур. *шэрбүүр* < **сэрбигүр* «себерке». Рясянен (Räsänen 1969: 437), *себер-* һәм *сыпыр-* нигезләренең гомогенлыгын таныган хәлдә, алар чыгт. *sür-* «себерү» сүзеннән (арытабан *чүп-*?) димәкче була бугай. Ләкин ул чыгт. сүзе **сирпү-* > **сүрпү-* сүзеннән үзгәреп килеп чыккан шикеллерәк. Будагов I: 653; Федотов II: 447 (төрле сүзләрне бергә куша); ЭСТЯ VII: 359–360.

Дерив.: **себерелү** (күч. «азып-тузып йөрү»), **себеренү, себерешү, себертү; себерма́,** (Тумашева 1992: 184) **себергән** «җәяүле (буран тур.)» h.б. К. **Себеркәч.**

**СЕВӘЗ** [в] диал. (миш., ТТДС I: 366) «пятистенный дом с коридором по середине» < рус. диал. *связь* id. (СРНГ IV: 59).

**СЕЗ** «вы» < гом. төрки *сиз, сэз* < **эсирг* > чув. *эсир* id. *эс* «син» сүзенең күп. (яки икелек) формасы (безнеңчә, чув. *эс* борын-борынгы төрки яңгырашны саклый); бу бор. **ис//эс = сың//сең (-ис-иң)** кушымчасында саклана, мәс., *барасың* < *бар-а(й)-ыс-ың* «бара синең», *киләсең* < *кил-ә(й)-ес-ең* «килә синең»; исем – сыйфат төрләнешендә;

*матурсың* < *матуры-с-ың* «матур синең», *тересең* < *тере-с-ең* «тере синең». Башк. *һеҙ* һәм як. *эһ-* < **һэс-* «сез» уртак чыганактан килә. К. **Син.** ЭСТЯ VII: 232–234, 254–256.

Ихтимал, боерык фигыль формасының 3 зат кушымчасы *-сын//-сен* составында да *-с, -эс* «син» сүзеннән киләдер.

**СЕЛӘГӘЙ** «слюна» < гом. кыпч., хак., алт. *силегей, силекей*, башк. *һеләгәй,* тув. *шилегей*, аз. *селик* id. ~ эвенк. һ.б. (ССТМЯ II: 426) *силэксэ*, маньч. *силэнги* һ.б. (күп вариантлар) «селәгәй, сыек лайла, мәмәч»; күп төрки телләрдә *-ү-* вариант: чыгт. (Радлов IV: 831) *сүләгәс,* үзб. *сулак, сулакай,* уйг. *шөлгәй* id. ~ як. (Пекарский II: 2396) *сүлүгäі, сүлäгäі* «сүл» ~ монг. *шил үсүн,* бур. *шүлүсү* «селәгәй». Чаг. ш. ук фин. *sülke, sylki,* морд. *сельге* «селәгәй; төкерек», удм. *сялзём* «төкерек», госм. *салја* < грек. *ςαλιον* «селәгәй» (Радлов IV: 359), рус. *слюна* ~ латыш. *slienas* id. Күренгәнчә, күп телләрдә «селәгәй, төкерек» мәгъ. сүзләр охшаш – *сл ~ сил ~ сүл* тамырыннан килә.

Чув. *сӗлеке* «селәгәйле», мар. (Исанбаев 1978: 17), удм. (Насибуллин: 137) *сӗлӓгӓй* «селәгәй» тат. теленнән булса кирәк. Федотов II: 40–41; ЭСТЯ VII: 250–251.

Дерив.: **селәгәйле, селәгәйсез; селәгәйлән-ү.**

**СЕЛӘҮ [сĕләw], селәүкәй, селәүчән, сөләү** (ТТДС II: 265; ЗДС: 570; БТДҺ: 275, гомумән киң таралган) «червяк – наживка для удочек» к. **Суалчан.**

**СЕЛӘҮСЕН [сĕләwсĕн],** диал. **селәүчен** «рысь» < гом. кыпч., к. башк. *һеләүһен,* куман., каз. *силеусүн,* ком. *силевсин,* к.-балк. *сүлөүсүн,* кырг. *сүлөөсүн* (һәр мәзкүр телдә вариантлы) < яз. монг. *silügüsün* id. Бу бор. яңгыраштан тагы ике вариант үзгәреп килеп чыккан: тат. диал. **сүләwес** ~ чув. *çүлевӗç* ~ хәз. монг. *шилүүс;* тат. диал. (Ә. Еники) **сүлән** ~ маньч. (ССТМЯ II: 85) *силүн, шулүн* «селәүсен». К. ш. ук үзб. *силовсин*, уйг. *силәвсин, сүләйсин, сүләйсүн*, алт., тув. *шүлүзүң* «селәүсен» һ.б. Федотов II: 147–148; ЭСТЯ VII: 257–258 (тулы түгел).

Монг. телендә *silügüsün* сүзе *silügün* нигезенең җыелма күп. формасы. Чынгыз хан империясендә *силäwсүн* «премьер-министр» – «бикләр биге» (Velidi: 233).

**СЕЛЕК-Ү (селкү, селкә, селекте), селке-ү (селки)** «трясти; качать; махнуть» < гом. кыпч., алт., уйг., үзб. *силки-,* башк. *һелке-,* хак., тув. *силги-,* як. *илги-* id. ~ төр. < бор. төрки (ДТС: 500) *silk-* «селкү» ~ монг. *силги-* < бор. монг. *silge-* «дерелдәү», (Поппе 1938: 320) *selge-* «дулкын бәрү, чәпчү» һ.б. *сил//сәл//сәл* тамырына *к-* детерминанты ялганып ясалган нигездән; к. ш. ук тув. *селеңке-* «селкетү», кырг. *селк эт-* «селкенеп алу», кор. *silluk-silluk, silgit-silgit* дерелдәү, калтырау, селкенүләрне белдерә торган тәкълиди сүз (к. Ramstedt 1949: 233). Башк. *һелке-, һелк-* һәм як. *илги-* < **һилки, илк-* < **һилк* нигезләре гомоген: *с-* > *һ-* күчеше булган чыганактан киләләр. ЭСТЯ VII: 259–260.

Дерив.: **селкенү, селкетү;** диал. **селкенчәк** һ.б. **Селкенү** < гом. төрки *силкин-* «кубылу, бер кыяфәттән икенче кыяфәткә әверелү (мәс., кешенең бүрегә әверелүе)» мәгъ. кулланылучан. ССТМЯ II: 83. Чаг. **Сәлкен-ү.**

**СЕЛТӘ-Ү** «махнуть, махать (рукой)» < гом. кыпч., чыгт. һ.б. *силтэ-* (> каз. *сӗлтэ-, сӗлте-,* башк. *һелтә-*), кырг. *шилте-* id., ш. ук «кул белән күрсәтү» – *силт//сәлт* тәкълиди тамырыннан (ул *сил//сәл* тамырына *-т* детерминанты ялганып ясалган), чаг. **селек-ү.** Бу фигыльнең үзенчәлекле варианты – тат. (миш.) *селдә-* ~ чув. *сӗлт-,* к.-балк., кар. *силдэ-* «селтәү; ыргыту, ташлау». Федотов II: 42; ЭСТЯ VII: 260–261.

Дерив.: **селтән-ү, селтәт-ү**, диал. **селтәк** «ташландык» (шулай дип элек кызлыксыз кызларны хурлаганнар).

**СЕЛТЕ,** диал. **селде** «щёлочь» ~ башк. *һелте* id. ~ чув. (Сергеев 1971: 106) *сӗлтӗ, сӗлӗт, сӗлкӗш, сӗлтӗк* «селте», *сӗлкӗт, шӗлкӗш, шӗлтӗш, шөлтөш* «су сеңдергән язгы кар», мар. *сылтэ вүд* «селте су – селте» ~ гом. кыпч., чыгт. *силти* «селте» (каз. *сілті* «кислота»), алт. *шылты* «түпрә, түп», *шилти* «каен суты» ~ монг. *шүлт* «селте» < яз. монг. *šültä* ~ калм. *šültü* «селте» ~ эвенк. *силту, һилти* > як. *силти* «каен үзеге черегеннән ясалган сеңәл – эчемлек һәм тире иеләү сыекчасы итеп файдаланыла», к. ш. ук к.-балк. *зылды* «карбызның һ.б. йомшагы; кәс; таркау, сәлкәү». Гомумән, бу тунг.-монг. даирәсеннән алынма булса кирәк.

Федотов II: 41–42; Аникин: 701, 709 (рус. диал. *шильта* «каен суы» һәм *шульта* «чәй итеп кайнатыла торган черек каен үзәге» сүзләренә параллель итеп күп кенә рус. диал., бур., тунг. сүзләре китерелә).

**СЕМ I** «тихий; притихший (в печали)» ~ чув. *сӗм* «сем», *сӗм варман* «карурман», тат. диал. (кас.)

**сәм** «сем» ~ хак. диал. *сым* «сем» (Радлов IV: 675) ~ калм., бор. монг. *sem* «сем; тын гына» (к. Поппе 1938: 320) > хәз. монг. *сэм, сем* id., тунг. *сим-сим* «тын гына» һ.б. (ССТМЯ II: 88). К. ш. ук **Шым.**

**Сем** нигезеннән аның дериваты **семәй-ү** (> башк. *һемәй-у*) «уңышсызлыктан кайгырып тын калу», шуннан **семәйт-ү** «зурга өметләнгән, шәпләнгән, мактанган кешене уңышсызлыкка очратып боектыру» киңрәк кулланылалар. К. Зимасов: 86.

**СЕМ II** – река Сим ~ башк. *Эҫем,* бор. төрки (ДТС: 500) *sim* «чик, чигәрә» сүзеннән булса гаҗәп түгел, чөнки бу (гомумән, турыга сузылган һәм уң як ярлары текә вә биек булган) елга чик итеп билгеләү өчен бик тә уңайлы.

**СЕМӘК** «заострённый верх шлема (с отверстием для **ялау**); кран, носик» ~ башк. (БҺҺ II: 289) *һемәк* «төтәткеч», нуг. *симек, сүмек* «семәк; чөмәк» (к. **Чөмәк**).

**СЕМГЕР-Ү, семкер-ү** себ. (ЗДС: 571) «сморкаться» ~ бор. яз. төрки *sümkür-. simkür-* id. ← төркм., бор. төрки, чыгт., госм. һ.б. ← *сүмүл* «маңка» ← **сум-*. **Сеңгер-ү.** Räsänen 1969: 437.

Дерив.: себ. (ЗДС: 571) **семкерек** «маңка».

**СЕМЕ** диал. (Тумашева 1992: 189) «куча навоза; островок твёрдой земли посреди болот» < рус. диал. *земь* id. (к. Фасмер II: 93).

**СЕМЬЯ,** сөйл. **семийә, чемийә** «семья, домочадец, домочадцы» ~ чув. *çемье,* мар. *семия*, удм. *с'эмйа* id. (мар. ш. ук «гаиләле», к. Саваткова: 144) < рус. *семья* «гаилә; токымнар». Бу сүзнең Идел-Урал регионында таралуына рус административ идарәсе сәбәпче булган.

Дерив.: **семьялык** (биологиядә).

**СЕНТЯБРЬ,** сөйл. **синтәбер** «сентябрь» (к. мәкаль: *Синтәбердә син дә бер, мин дә бер*) < рус. < лат. (асылда «җиденче ай» дигән сүз). Диал. (ТТДС I: 268, 278) **синтәп, синәп, сәнтәп** id. русчадан түгел, Шәрык телләреннән (тик, ахыр чиктә, барыбер латинчадан), к. гар. *сäптäм* «сентябрь». **Найәп, үктәп** «ноябрь, октябрь» (ЗДС: 575, 679) сүзләре дә русчадан түгел, гарәпчәдән.

**СЕҢ: сең туу, сеңер туу** (миш. ЗДС: 571–572) «припухать (о жилах, мускулах) от длительной работы», «завязываться – о жилах». Бу бездә бер тапкыр гына чагылган *сең* < гом. төрки **сиң* «ярымсыек һәм сузылучан субстанция»не белдергән булса кирәк, к. диал. **сеңер-ү** ← *сең-ур-, суң-әр-* «сеңәлләнү; сыегаю», **сеңел-ү** «эрү, таркалу», **сеңәрт-ү** ← **сеңәрт-* «сеңгә булу», **сеңгәк, сеңгәләк** «баткаклы, сазлыклы төш», **сеңгәлцек, сеңелцек** «баткаклык, сазлык», к. кар., нуг. *сиңге-* «сыеклану» һ.б. **Сеңер** (к.) сүзенең дә **сең** ~ *син* тамырыннан булуы, ш. ук **сеңел** (к.) «яшь кенә кыз яки егет» төбендә «буыны сыек, катмаган» мәгъ. сүздән булуы ихтимал (гом. төрки *сыңил-* сүзенең бүтән төгәл этимологияләре күренми шикелле). К. ш. ук **Сеңәл, Сеңел.**

**СЕҢӘЛ** (Будагов I: 681; ДС I: 162) «раствор, гель; жижа», диал. (ЗДС: 571) «жидкий; редкий», **сеңел** «жидкий», себ. (Тумашева 1992: 250) **шеңкән** id. ~ чув. *шăнкал* «известь сеңәле», мар. *шеҥӓл* «сыек» < гом. кыпч. *сиңäл, сиңәл* «сыеклатылган» ~ бор. чыгт., бор. монг. (Поппе 1938: 323) *sınken* «сыек», яз. монг. *singgen,* бур. *шэнгэн* > эвенк. *шиңэн* id. (ССТМЯ II: 387, 426). К. югарыдагыны.

**СЕҢГЕР-Ү**, диал. (Зимасов: 83) **сөңгөр-ү** «высморкаться» < гом. кыпч., уйг., үзб. *сиңгир-,* башк. *һеңгер-* (каз. *сиңбир*), хак. *сыңыр-,* тув. *сиңмир-*, госм. *сүмкүр-* id. ← *сиң-, сэң-, сүң-* «борын аша һава бөркү» тәкълиди фигыленнән (< *сиң-кир-, сиң-күр-* > *сүңкүр-*), к. төр. *sümük*, як. *сы̄ң, сы̄ңк* «маңка», бор. төрки (DLT III: 387) *seŋregü* «маңкалы». Чаг. ш. ук (Радлов IV: 2068) алт., кырг. *чыңыр-* «чыңгырдау, мыркылдау, сеңгерү» ~ чув. *шăнкар-* «сеңгерү» һ.б. К. **Семге-ү, Чөңгер-ү.** Федотов I: 445; ЭСТЯ VII: 353–355.

**СЕҢЕЛ, сеңгел** дип тә әйтәләр, **сеңле, сеңне,** себ. (Тумашева 1992: 190) **сиңне** «младшая сестра, сестрёнка» < гом. кыпч., уйг., үзб., ш. ук бор. төрки *сиңил, сиңли,* башк. *һеңел, һеңле* һ.б. (төрле төп варианттан тайпылышлы яңгырашлар тур. к. ЭСТЯ 2003: 265–266) id., чув. *шăллăм, шăнкăлăм* «энем, энекәш», мар. *шаля, шольо* «энекәш»; як. (ДСЯЯ: 227) *һиңил* «яшь, өйрәнчек, башлангыч». Гомумән, ачык түгел, к. Покровская 1962: 32–33; Егоров 1984: 90; Рамазанова 1991: 54–55; ЭСТЯ VII: 265–267.

Дерив.: **сеңелдәш, сеңелкәш** ~ **сеңелкәч** һ.б.

**СЕҢЕР,** диал. **сеңгер** «сухожилие; вены», диал. (ТТДС I: 368) «резина; худощавый и жилистый» > мар. (Исанбаев 1978: 137, 149) *сĕҥĕр*, удм.

(Насибуллин: 17) *сиңыр, сыңыр, сънър, шънър* ~ чув. *шăнăр* «сеңер» (төп мәгъ.), удм. *сыңгыр* «түземле, сеңерле» < гом. кыпч., уйг., үзб., чыгт., алт., бор. төрки (ДТС: 500) *siŋir* «сеңер; кан тамыры» > төр. *sinir* «сеңер, нервы»; к. ш. ук башк. *һеңер,* кар. *сыңыр,* як. *иңиир* «сеңер». М. Рясянен (Räsänen 1969: 423) бу сүзне *сең-ү* (к.) фигыле (аның гом. төрки параллельләре) белән баглый. Чаг. ш. ук **Сыйрак**. Федотов II: 444–445. Башк. *һеңер* һәм як. *иңиир* < **һиңиир* вариантлары гомоген. К. **Сең, Сең-ү.** ЭСТЯ VII: 267.

Дерив.: **сеңерле, сеңерсез;** диал. **сеңерлән-ү** «күңелдән катгыйлану», добр. *sïŋïrlentek* «нервылану, ачулану».

**СЕҢ-Ү** «впитываться; уходить в землю; усваиваться» > мар. *шӹҥ-, шың-* «сеңү; сыю» < төр. *sin-,* төрки, бор. төрки (ДТС: 500) *siŋ-*, як. *иң-,* башк. *һең-* id.; чаг. чув. *шăн-* «туңу; юкка чыгу», хак. диал., шор. *сың-* «сеңү, үтеп керү, сыю» (к. Радлов IV: 622) ~ яз. монг. *singge-,* монг. *шиңгэ-,* бур. *шэңгэ-,* маньч. *сиэгэ-* «сеңү, бату»; аз. (АДДЛ: 364) *сыңыр-* «сеңдерү», чыгт. (Поппе 1938: 334) *singer-*, алт. диал. *сүңүр-* «сеңдерү» һ.б. Чаг. **Сый-у.** Башк. *һең-* һәм як. *иң-* < *һиң-* уртак (*с-* > *һ-* күчеше булган) чыганактан киләләр. ЭСТЯ VII: 260–263.

Дерив.: **сеңдер-ү**, иске тат. (Будагов I: 656–657) **сеңгер-ү** «аңлату». К. **Сеңәл**.

**СЕР** «тайна, секрет» < гар. *cирр* id. > гом. кыпч. *сыр.*

Дерив.: **сердәш; серле; серләш-ү**. Кушма сүз: **сертотмас**.

**СЕРӘЙ-Ү** «одиноко торчать» ~ башк. *һерәй-,* кырг. *серей-,* кырг., хак., тув. *сырай-* ~ монг. *сэрийх* id. Чаг. **Сырган.**

**СЕРӘҢКЕ** диал. «спички» < рус. диал. *серянка* id. Бу сүз Себердә киң таралган һәм төрле телләргә кергән, к. уйг. *сәрәңгә* «шырпы» (хәз. шырпы Себер, Урта һәм Үзәк Азиягә Россиядән килгән). Чаг. ш. ук як. *сиäрä*, эвенк. *шарама, серама* һ.б. «шырпы» < рус. *сера* (к. ССТМЯ II: 72).

**СЕРКӘ I,** диал. **сергә** (ТТДС: 367) «гнида; плесень, цветень; цвет, серёжки (хлебов)» > мар. (Саваткова: 219) *сӧркä, сырка, шырка, шӧрха* «башак серкәсе», *шаргинчэ, шаргэнчэ, шаргэньэ* «бет серкәсе», удм. *сюрел* «чәчәк, башак серкәсе», *серел* «бет серкәсе», чув. *шăрка* һәм башк. *һеркә* – һәр ике мәгънәдә (безнеңчә, бу ике мәгънәнең бердәйлеге шик тудырмый: бет серкәсе дә беренче карашта башак серкәсенә зурлыгы, төсе, кылчыкка – чәчкә тезелеп торуы белән бик охшаш була), к. ш. ук венг. *serke,* морд. Э. *сярко,* морд. М, *сярхка,* коми *серов* «бет серкәсе» < гом. төрки *сиркэ* (каз. *сӗркә,* тув., хак. *сиргэ* һ.б.) id. ~ бур. *шэрхэ* «бет», монг. *сиркэ* «кызыл бет» һ.б. к. Räsänen 1969: 423; ЭСТЯ VII: 268–270.

*Серкә* < *сиркэ* сүзе **сырга** (к.) > рус. *серьга* сүзе белән бәйле. Сүзнең тамыры ачык түгел; тат. диал. (себ.) **серлә-ү** «коелу, агып тору» сүзен *серкә* белән бәйләү бик тәвәккәл адым. Шулай ук аны фин-угор сүзе дип билгеләү дә (КЭСК: 251) шикле. **Серкә –** продуктив сүзьясагыч нигез: **серкәлән-ү** (үсемлек тур.), **серкәлә-ү** (кеше тур.), **серкәле.**

**СЕРКӘ II** «уксус» > мар. *сырка* (Упымарий: 197), рус. диал. *сирка* < гом. төрки (Радлов IV: 704) *сиркä* < фар. *сиркаһ* id., сүзмә-сүз «сарымсак исе» булса кирәк. Башк. *һеркә* «серкә; әче бал» үзенчәлекле мәгъ. ия. Räsänen 1969: 423.

**СИБЕЛ** «длинное одеяние»? (Башкортстанда без язып алганча *сибелен сүрәгән,* нәкъ шул сүзтезмәне диалектологлар *сефелен сүрәгән* дип язалар, к. МТД 1978: 49), к. кырг. *себил* (*себил тон*) «пуля үтмәслек кием», уйг. *сепил* «кальга, форт». Икенче яктан, минем сорашканыма *сибел тун* «чанада озак юлда барганда киелә торган тун» диделәр, һәм к. төр. *sebil* ~ гар. *сäбӣл* «озын юл».

**СИГЕЗ** «восемь» < гом. төрки *сэкиз, сэккиз* < бор. төрки *sekkiz* (ДТС: 494) ~ башк. *һигеҙ,* чув. *сакăр, саккăр* (Ашмарин XI: 19), як. *агыс* ~ сары уйг. *сакыс* < *саккыз* id., безнеңчә, бор. *сэҡ козу* «язын туган бәрән» сүзеннән (ашыкның сигезенче почмагы-мөеше шулай аталган), к. монг. *сэгсэг* «язгы бәрән». Чаг. *тугызак* ← *тугыз*. **Тугыз** < *ток козу* «көзен туган бәрән, ашыкның тугызынчы мөеше». К. **Кузы.** Ахметьянов 1988; Räsänen 1969: 408; Федотов II: 6–7; ЭСТЯ VII: 225–226.

Дерив. – саннар өчен регуляр.

**СИДЕК** «моча» ~ башк. *һиҙек* < гом. кыпч. *сидик* < *сий-дик* яисә *сид-ек* id., к. **Сий-ү.**

**СИҖӘ** «вид ткани» (к. ТХИ: Бәетләр 1963: 93) ~ рус. *сичный* «тыгыз (тукыма)» < уйг., үзб. *зич* «еш, тыгыз».

**СИЗЕК, сизүк, сизик** «опоек» (Будагов I: 628), **шижик** «двухлетний баран» (Тумашева 1992: 189, 250). Ачык түгел.

**СИЗРӘ-Ү,** диал. **сидрә-ү** (ДС III: 138) «редеть, стать прозрачным (о ткани)» << бор. төрки *sедrä-* id. (ДТС: 494). К. **Сирәк.**

**СИЗ-Ү** «почувствовать, почуять, чуять» > чув. *сис-,* башк. *һиҙ-* ~ хак. *сис-* (*сизег* «сизем»), төркм. *сииз-* < гом. төрки *сэз-, сӓз-* < бор. төрки *sēz-* ~ монг. *сэр-* > як. *сэр- (сэрэй-)* id. Бу фигыльнең исем коррелянты *сес//сӓс* алт. сөйләшләрендә билгеле. К. ш. ук удм. *сазь* «уяу, аек», *сэзь* «сизгер» Räsänen 1969: 413; Федотов II: 52; ЭСТЯ VII: 221–222.

*Сиз- < сэз- ~ сэр-* продуктив тамыръясагыч нигез, шуннан к. **Зирәк, Сәрен, Сирмә-ү, Сискән-ү.** К. Clauson: 860–869; ССТМЯ II: 145.

Дерив.: **сизел-ү, сизен-ү, сизеш-ү, сиздер-ү; сизгер; сизгеч**; **сизем,** диал. **сизге, сизек.**

**СИКӘ** (ТТДС II: 267; БТДҺ: 276), **сикә бал** (Зимасов: 81) «хлебина, перга», **ситә** (ТТДС II: 268) «соты» ~ башк. (БТДҺ: 276) *сикә* «чыршын», (БТДҺ: 377) *һита, һитә* id. < рус. *сыта* «баллы катнашма; сикә» сүзеннән яисә шуның белән гомоген. *Сикә ~ ситә* тәңгәллеге гаҗәп, ләкин бик мөмкин.

**СИКӘЛТӘ,** диал. **сикелтә, сикәлте** «ухаб; трамплин» ~ башк. *һикәлтә,* чув. *сакӑлта, сикелте, саккӑлта, саң калтӑк* һ.б.ш. (Сергеев 1968: 104) id. Бор. тат. **сикел-, *сәкел-* «сикерелү» яисә *сик-* «сикеренү» фигыленнән ясалган (*сикел-те* яисә *сик-елте*). К. **Сикер-ү, Сиртмә.**

**СИКЕР-Ү** «прыгать, прыгнуть» < гом. кыпч. *сэкир-, сӓкир-* (к. Радлов IV: 441–442), башк. *һикер-, һигер-,* хак. *сигӗр-,* үзб. *сәкрә- (сакра-),* уйг. *сәкри-* < бор. төрки *sekri-* id. (ДТС: 494) ← чув. (< бор. төрки) *сак-,* төр., бор. төрки *sek-,* госм. чыгт. (Радлов IV: 441) *сӓк-,* як. *эккирээ-, һэккирээ-* «сикеренү, бер аякта сикерү; бию», *эккэлэ-* «койрык болгау (эт тур.)» һ.б., к. ЭСТЯ VII: 222–224.

*Сикер- < сиккер- < сэккир-* яңгырашыннан, ягъни *сик- < сэк-* «сикеренү» сүзенең йөкл. юнәлешеннән, бу форма исә «бертапкырлык» мәгъ. биргән. Уйг. *сәкри- < сәкрә-* икенче төрлерәк – *-рә-* киңәйткеч кушымчасы ярдәмендә ясалган. *Сик- < сэк-* фигыленең төш. юн. *сикел- < сэкил-* сүзеннән *сикәлтә ~ сикәлте < сикелтә, сикелте* (һ.б.ш.) ясала.

*Сик- < сэк-* фигыле образлы-тасвирлы сүздән булырга мөмкин: к. тат. диал. *чикерт-чикерт, сикерт-сикерт,* чув. диал. *сик-сик* – сикеренүгә тәкълит. Яңгырашы буенча чув. *сик-* тат. теленнән (э > *и*), әмма чув. телендә бу сүзнең дериватлары бик күп (татарчада аз). Тат. диал. (ЗДС: 566) **сәген-** «атыну», **сәкәнлә-ү** «бер аякта сикерү» чувашчадан булса кирәк. Федотов II: 48–49.

**СИКСӘН** «восемьдесят» ~ башк. *һикһән* < гом. кыпч. *сэксэн,* чыгт., госм., уйг. *сәксән,* бор. *seksün* < *sekkiz un* (DLT I: 437) «сигез ун», чаг. тат. диал. **сигезән** (ДС I: 162), алт. *секиз он* ~ чув. *сакӑрвуннӑ* «сиксән». К. **Сигез.** Чаг. **Туксан.** ЭСТЯ VII: 220–221.

**СИКЫТ** (БҺҺ II: 209), диал. (трбс. һ.б.) **чикыт** «хилый; увечный, калека» (о детях), «мытарства» ~ удм. *секыт* «кыенлык, кыен». Чаг. тат. диал. (Ставрополь) *сайкат,* нуг., ком., к.-балк. һ.б. *сақат* «чибек, чирле» < гар. *сӓқаṭ* «дефектлы, бозык». ГТРС: 518; Тимергалин: 414.

**СИЛ I** «сель, горный поток; наносы» > башк. *һил* id., ш. ук (БҺҺ II: 290) «елга утравы» < гом. төрки, бор. төрки, бор. монг. *sel,* госм., кырг., уйг. *сил,* төркм. *сиил* < гар. *сӓйл* «агым, ык, сил» (Räsänen 1969: 408). Бу сүзнең фин-угор тамырларын күрсәтү (Камалов: 42) нигезсез. Тимергалин: 414.

**СИЛ II,** диал. (ТТДС: 369, 512) **шил** «тихий; успокоенный; ослабленный (о буре)» < гом. кыпч. (нуг., каз., к.-балк.) *сел,* (к.-балк.) *сёл* «тыныч; тынган»; «исән-сау». Чаг. **Сәл, Шил.**

**СИЛ III** диал. «туберкулёз» ~ як. *сэллик,* эвенк. *сэлли* id. Ачык түгел.

**СИЛӘ** «пружина; рессора» < диал. **силлә** id.; чаг. диал. (ТТДС I: 385) **сәли, сәлли, сәлей** «бишек», чув. *селле-* «селкетү»; *силлев* «селкенү (исем)». *Силә* сүзен рус. диал. *сила* «көшле арбаның озын агач аратасы (ул рессор ролен үти)» сүзеннән дип аңлату да бар. К. **Сәлен-ү.** Федотов II: 49–50.

**СИЛӘЗӘН** (ЗДС: 574) «селезень», «наёмный певец во время свадеб и т.п. торжеств». Русчадан түгел бугай, чөнки рус. сүзлекләрдә *селезень* сүзенең юньле этимологиясе бирелми. Татарлар арасында ул сүз мишәрләрдә һәм Уралда теркәлгән, ягъни киң таралган булган. К. уйг. *чиләзин, чилиҗын,*

*силәсүн* «ата үрдәк». Чаг. фар. > төр. (Özön) *silezen* «тәкмәч атучан, тибешкәк» (*sile* «сальто», *zen, zan* «атучы, бәрүче»): бу сүз үрдәкләрнең җим эзләп су төбенә томшыклары белән үрелгәндә артлары вертикаль күтәрелүен дә белдерә. Үрдәкләрнең кайбер төрләре көйләп сызгыра да белә һәм рус. *свистун* дип атала).

**СИЛСИЛӘ** «блестящая нить (как украшение); родословная, генеология; иерархия, инстанция» < гар. *силсилä* id. Будагов I: 633; Тимергалин: 414 (тарикать имамнары силсиләсе тур.).

**СИМӘЛӘК, симнәләк** (Будагов I: 657; Тумашева 1992: 190) «лайка; порода мелких собак» ~ башк. *һепәләк, һәпәләк* id. < фар. *сäгипäлäк* «бәйле эт» (*сäг* «эт», *пäлäк* «бәй, бау, шнур»).

**СИМӘН: симән көне** «Семёнов день» < рус. (Мәхмүтов: 91).

**СИМӘНӘ** сөйл. «семена» ~ чув. *симене,* мар. *семенä,* удм. *семена* id. < рус., әлбәттә. Чаг. ш. ук **симәнке, симечке, чимешке** «ашала торган көнбагыш» < рус. *семянки, семячко* id., id.

**Симәнә** сөйләшләрдә продуктив нигез: **симәнәле, симәнәлек** һ.б.

**СИМЕЗ** «жирный, упитанный» < гом. кыпч., госм., чыгт., уйг., алт. *семиз,* урта төрки *семүз* id. < бор. гом. төрки **сәмирг* id. *сәмир-* «симерү» фигыленнән, к. чув. *самăр* «симез», *самăр-* «симерү». Башк. *һимеҙ* һәм як. *эмис* < *һәмис* < *сәмиз* гомоген үзенчәлекле сүзләр. Räsänen 1969: 529; Федотов II: 11–12; Мухамедова 1973: 150; ЭСТЯ VII: 227–230.

Дерив.: **симезлек; симезлән-ү.**

**СИМЕР-Ү** «жиреть» < гом. кыпч., госм., чыгт., уйг., алт. һ.б. *сәмир-,* башк. *һимер-* ~ төр., көнч. төрки *semiz-* id. бор. төрки **сәм, *сәмә* «юан, симез» тамырыннан, к. бор. монг. *semeǯi* «эч мае» (Поппе 1938: 320), эвен. *хәмәх* < *сәмәх* «эч мае» һ.б. Räsänen 1969: 409; Федотов II: 11–12 (тәфсилле); ЭСТЯ VII: 230–232.

**СИМСИМ** «сезам» < төр., гар. *симсим*. Чаг. **Синсән.** Тимергалин: 414 (тәфсилле).

**СИН** «ты» < гом. төрки *сән*, башк. *һин,* чув. *ĕс, эс* id. К. **Сез.** Кызыклы тәңгәллекләр: тунг.-маньч. *си* (төрләнештә *син-*) «син, синеке», фин. *sinä* «син». Башк. *һин* һәм як. *эн* < **һэн* уртак чыганактан килә. ЭСТЯ VII: 232–233.

**СИНӘК** иск. (в словаре Троянского **сиври синәк** «острый *синәк*» – вид комара, видимо – особо крупный комар») ~ кар. *синақ*, чыгт. *сиңек, siŋäk, siŋgak,* төр. *sinek,* алт. *сиек, сеек,* тув. *сеек* ~ *сääк* «москит, кигәвен», ш. ук «бал корты» ~ чув. *шăна* «чебен». ЭСТЯ (VII 264–265; тат. сүзе күрсәтелмәгән) мәзкүр сүзләрне тунг.-маньч. *синкэ* «коңгыз» белән чагыштыра, *сиң* «зең, чың» тәкълиди сүзе белән баглы дип яза. Ихтимал, тат. диал. (ЗДС: 571) **сеңгәләк** «чикерткә» сүзе дә **синәк** белән баглыдыр). **Сиври** сүзе тур. к. **Сөйре**.

**СИНСӘН, синсин** иск. «состав для освежения рта» ~ төр. *sensen, sensing* гар. теленнән таралган сүз (Европа телләрендә дә очрый). Чаг. лат. *ginseng* id. (асылда бер үсемлек). К. **Симсим.**

**СИҢА** «тебе» – бу сүзнең сингармонизм законына хилафлыгы аның бор. уйг. теленнән килгәнлеген – «әдәби» сүз икәнлеген күрсәтә; югыйсә халык сөйләм телендә *сиңә,* башк. *һиңә* < *сиңгә* id. «Сиңа» мәгъ. сүзләр төрки телләрдә еш кына гомумән кагыйдәләргә буйсынмаучан, к. гом. кыпч. *саңа,* каз. *саған,* кырг. *саға* «сиңа», әмма бу телләрнең барысында да *сан* «син». **Сиңарга, сиңәргә** вариантлары стилистик мәгънәгә ия.

**СИҢГӘР, сиңгер** (Тумашева 1992: 190) «мыс; отрог горы» > чув. *сиңкер* «кальга; тайгы – урманны егып салган хәрби киртә», чыгт. *сäңир* «ныгытма», каз. *сеңгір* «тау тезмәсе», ком. *сянгер*, нуг. *сенкер* «окоп; тайгы», фар. *сäңгäр* «вал; кальга», авар. *сангар* «тайгы», лезг. *сенгер* «ныгытма, вал; ур», кырг. *сеңир* «үләнле тау» (төп мәгънәдән ерак киткән очрак) < бор. төрки (ДТС: 495) *seŋir* «тау борыны; тайгы; дивар очы» һ.б. М. Рясянен монг. *сэгэр* «сырт» сүзе белән бәйли (Räsänen 1969: 410, к. ш. ук Владимирцов: 250–251). Безнеңчә, бу сүз кр.-тат. *sıŋır,* госм. *синор* «чик, чигәрә» сүзе белән бердәй һәм грек (Бактрия греклары) теленнән – *ςυνορον* «чик, чигәрә» сүзеннән килә, шуннан ук төр., гаг. *синор, сынар, сыңыр* «чик» һ.б., чөнки *сиңгер* сүзенең төп мәгъ. «тау сыртына урнашкан чик ныгытмасы». Бу (безнең) этимология, әлбәттә, тәфсилләрәк исбатлауны сорый. Һәрхәлдә *сиңгер, сингәр* сүзе тат. телендә электән килә һәм тәүдә чик ныгытмасын белдергән. Чаг. ш. ук башк. *Һиңгәр*

«Башкортстанда бер тау», тат., башк. *сеңрән* «ыру һәм берничә авыл исеме». Будагов I: 638; ЭСТЯ VII: 237–238; Аникин: 519.

**СИП** (ДС I: 163; ТТДС I: 370) «прибавка, добавка», диал. «подарок; подарок жениха», себ. (Тумашева 1992: 190) **сип < сэп** «приданое», кайбер сөйләшләрдә (Зимасов: 82) «польза от лекарства, полезный компонент лекарства» > чув. *сип* id. < гом. кыпч., алт., үзб. *сеп, себ [сэп, сэб]*, уйг. *сәп,* башк. *һип* «бирнә» < бор. төрки (ДТС: 496) *sep* id. һәм *sep-* «бирнә әзерләү» ~ як. *сэп* «корал-ярак, инструмент; җенси орган», *эп* «өстәмә, өстәмә бирү» < **һэп*. Этнографлар күрсәткәнчә*, сэп* тәүдә кәләшнең егетенә биргән ау һәм сугыш коралын белдергән. Бүтән мәгънәләр – к. кар. *сеп, себь, сэп* «ярдәм», хак., тув. *сеп* «елга кушылдыгы», госм. *сäп* «тире иеләү составы» һ.б. – икенчел. К. ш. ук калм. *seb* «килен алып килгән мөлкәт». Чув. *сапла-* «сипләү, ямау», *саплăк* > мар. *саплык* «ямаулык» сүзләренә караганда, *сап (< сәп)* «өстәмә; ямаулык» сүзе булган. К. **Сиплә-ү.** Федотов II: 14; ЭСТЯ VII: 239–240 (кайбер телләрдә *сеп-* фигыле бар диелә).

**СИПКЕЛ** «веснушки» < гом. кыпч., чыгт. *сэпкил*, уйг. *сәпкә, сәпкәл*, башк. *һипкел,* яз. монг. *sebkil* (хәз. монг. *сэбэх > сэбх*) id. *сип-у* (к.) фигыле белән тамырдаш, к. венг. *szeplö* «сипкелле». Күрәсең, *сип-* фигыле белән беррәттән *сип (< сэрп)* «сибелгән нәрсә, таплар һ.б.ш.» сүзе (исем) булган (*-кил* төс атама сыйфатлар ясагыч кушымча).

Дерив.: **сипкелле; сипкеллән-ү.**

**СИПЛӘ-Ү** «подновить, починить (по частям), подправить» ~ башк. *һиплә-* ~ чув. *сапла-* (< *сәплә-*) id., ш. ук «ямау» ← *сип* < *сэп* < *сәп* тамырыннан (к. **Сип**). *Сэплэ- ~ сэптэ-* «сипләү» фигыле күп төрки телләрдә очрый.

Дерив.: **сиплән-ү, сипләш-ү.**

**СИП-Ү (сибү, сипте)** «сыпать, рассыпать; брызгать, поливать» < гом. кыпч. *сеп- (сэп-)*, башк. *һип-,* урта төрки, уйг., аз. һ.б. (к. Räsänen 1969: 410) *säp-, sep-* id. Кайбер төрки телләрдә (һәм бор. төрки) очрамый; чув. *сап-* < болг. **сәп-* > мар. *сäп-, шäп-* «сибү, чәчрәтү; чәчү». *Сип- < сэп- < сирп-, сэрп-* (к. **Сирпе-ү**) булса кирәк, к. төр. *sep- < serp-* «сирпү». Федотов II: 12; ЭСТЯ VII: 240–241.

Дерив.: **сибел-ү, сибеш-ү, сиптер-ү, сибәлә-ү; сибердек; сипкеч, сиптергеч.**

**СИРА, сирә** (ТТДС I: 370), **сыйра** (ТТДС II: 370, 378) «ряд; раз, еще раз, повторно» < гом. кыпч., угыз., үзб. *сыра, сыйра, сира,* төр. *sıra* «рәт, тезем, тезмә; тәртип; чират; заманы (тәртип белән килгән мәл, үз вакыты)» – угыз (мәс., гаг.) телләрендә бик продуктив сүзьясагыч нигез. Уйг., к.-калп., кырг., үзб. *сира* (үзб. диал. *сра*) «бөтенләй, тәмам» сүзе дә шуннан (*сира да* «бер тапкыр да > һич тә > бөтенләй» тәгъбиреннән эллипсис). Чыгышы ачык түгел, к. нуг. *сыдыра,* ком. *сыдра* «рәт» (к. **Сәтыр** ~ *сутра*); алт. диал. *сырай* «бөтенләй»; гар. *ҫираһ* «параллель (сызыклар)» – **сира** боларның һәркайсыннан килеп чыга ала. ЭСТЯ VII: 414 (төрки сүз диелә, ләкин безне ышандырмады). Рәсәнен (Räsänen 1969: 419) аз. *syra* «рәт» сүзен грек. *σερα* id. сүзеннән ди.

**СИРАТ** «мост тоньше волоса над адом, через который люди должны проходить в Судный день» < гар. *ҫирāṭ* «күпер, басма; таш юл» (< лат. *strata* «таш юл; олы юл»). Лат. сүзе Шәрыктә Рим империясе чорында киң таралган (Петрушевский: 71).

**СИРӘ** «жизнеописание (в особенности пророка)» < гар. *сира, сийäрат* id. ← *сйр* «бару, йөрү» тамырыннан. Иске тат. **сирәт** «биография».

**СИРӘК** «редко, редкий» ← диал. (Тумашева 1992: 190; ЗДС: 575) **сирә-ү**, ш. ук **сирәй-ү, сирел-ү** «становиться редким; редеть», чаг. ш. ук **сир-ү**. Барча бу сүзләргә бүтән төрки телләрдә параллельләр бар: башк. *һирәк,* нуг., каз., к.-калп., ком., к.-балк. һ.б. *сийрек,* төркм., төр. *seyrek,* гаг. *сиирек,* аз., куман. *säjräk* ~ монг. *сейрэг,* яз. монг. *seyreg, seyrig,* бор. төрки (DLT I: 477) *seδrek* ← (ДТС: 494) *seδrä-* «сирәгәю, сирәкләнү, сирәү, *сизрәү» > гом. кыпч. *сийрә-, сәйрә-* id. Әгәр бу фигыль типик *-ра//-рә* кушымчасына бетеп ясалган булса, сүзнең тамыры **set-//*seδ-* > монг. *сий* – «сирәкләнү». К. ш. ук чув. *сайра-* «сирәкләнү», *сайра* «сирәк», хак, *сайрах*, монг. *саарах* «сирәк» һ.б. Räsänen 1969: 407; ЭСТЯ VII: 270–271; Федотов II: 5.

Дерив.: **сирәклә-ү** (һәм аның юнәлешләре); **сирәкләп; сирәклек,** диал. **сирәкле, сирәгенчә** һ.б.

**СИРВӘЛӘ, силвәрә** (ТТДС II: 267) «девичьи шаровары» < гар. *сирwāл, сäрāwūлāт* ~ фар. *сäрwāлһа, сервāлһа* id. *сäрwāл, сервāл* «чалбар» сүзенең күп. формасы. *Сирвәлә, сäрwал* һәм *камис* «кыска күлмәк» (к. **Камис**) мөселман кызларының классик киеме. К. **Чалбар.**

**СИРГӘК** диал. (ТТДС I: 370) «живой (о характере), темпераментный, чуткий» ~ каз. *сиргәк*, хак. *сиргек,* төр. *serkek,* куман. *sergek,* чыгт., уйг. *сäргäк* id. ← уйг. *сәрги-*, кырг., алт. *серги-* «уяу булу»; параллель рәвештә монг. *сэргэг,* яз. монг. *sergeg, sergek* «аек, уяу, сизгер сакланучан» (> бур. *һэргэг* id.) ← хәз. монг. *сэргэ-* «йокламау, уяу булу» ~ эвенк. һ.б. (ССТМЯ I: 145) *сэри-* «уяну, уяу булу». **Сиз-ү** белән тамырдаш, к. чыгт. *сäзгäк* «сизгер, зирәк» < **сәргäк.* Räsänen 1969: 412–413; Clauson: 843, 850; ЭСТЯ VII: 259 (*серги-* сүзе тур. гына).

**СИРЕЛ-Ү** «раздвигаться (о ветвях в чащобе); рассеиваться (о тумане и т.п.)» > чув. *сирĕл-*, төп чув. *сарăл-* < **сәрел-* «тирә якка таралу, таралып бетү; юкка чыгу; киңәю, җәелү» ← *сир-* (к. **Сир-ү I**). Чаг. **Сирәк.**

**СИРЕНЬ,** сөйл. **сирин** «сирень» < рус. *сирéнь,* рус. диал. *сырень* < ним. диал. *sirene, syringe* id. лат. *syrinx, syringa* «көпшә, шүре» сүзеннән (чөнки *сирень* ботагының үзәген чыгарып, шүре ясыйлар) дип аңлатыла, к. Фасмер III: 626–627. Безнеңчә, *сирин* < кыт. *сы линь* «дүрт лепелдәк, сирень» сүзеннән (чөнки, беренчедән, сирень Кытайдан таралган, икенчедән, сирень чәчәге дүрт лепелдәкле, арада сирәк кенә биш лепелдәкле була).

**СИРКӘ** (БТДҺ: 277), диал. (Арсланов 1988: 92) **серкә** «кастрированный козёл, ведущий овечье стадо», тар. «стадо овец, ведомый одним козлом» > башк. (БТДҺ: 295) *сәркә* «маймыч» ~ каз., к.-калп., кырг., алт., төркм. *серке,* үзб. *серка,* уйг. *сәкә* < *сәркә,* чыгт. *сäркä* «сиркә». М. Рясянен бу сүзне иске монг. *serke* (> калм. *serk*) «сиркә», тунг. *сиру* «көтү башы үгез» ~ фин. *härkä* «печтерелгән болан үгезе» сүзләре белән бәйли (Räsänen 1969: 412). Аникин (: 517) рус. *сыркэн* «печтерелгән тәкә» монг. *сэрхэн,* бор. монг. *serke* сүзеннән ди. Чаг. ш. ук фар. *сäргаһ* «баштан (алдан) баручы», бор. төрки *serkär* «юлбасар» < фар. *serkâr* «башлык, юлбашчы, эш башында торучы» һ.б. Чаг. **Сәркәш.** ЭСТЯ VII: 247.

**СИРМӘ-Ү** (Троянский I: 574), **сәрмә-ү** (М. Гафури һ.б.) «ощупывать; схватить, хватать, воровать» ~ башк. *һәрмә-ү* id.< гом. кыпч. *сәрмә-* «кул сузып тоту, тотып алу һ.б.» (төрле телдә мәгъ. төсмерләре бар) < бор. төрки *serme-* «балык сөзү» (к. DLT II: 349) – ләкин бу төп. мәгъ. түгел, к. бор. уйг. *sermemiš suttin kaymak* (Clauson: 853) «сөт өстеннән каймак җыеп алмыш». Безнеңчә, *сирмә-* < *сәрмә-* > *сәрмә-* нигезе бор. гом. төрки **сәр-* «сизү, капшау» фигыле белән тамырдаш (к. **Сиз-ү**), шул фигыльнең кабатлану формасы (*сәр-мә-*, чаг. *кар-у* һәм *карма-у, көр-у* һәм *көрмә-у*). К. **Сир-ү II.** ЭСТЯ VII: 264.

**Сирмәү** ~ **һәрмә-ү** сүзенең дериватлары башк., каз. һәм к.-балк. телләрендә күп. К.-балк. *сермеш* «сугыш, якалаш», *сермеш-* «сугышу» үзенчәлекле.

**СИРПЕ-Ү** «слегка дёргать, трясти; откидывать лёгким движением; брызгать легким взмахом; взглянуть (и быстро отводить взор)» < гом. кыпч. *сәрп-, серп-,* төркм. *серп-*, госм., чыгт. *сäрп-* (Радлов IV: 472), алт. *серпи-* id., үзб. *серпа-,* башк. *һирпе-* «селтәнү» һ.б. *сэрп* тәкълиди сүзеннән, к. кырг. *серп эт-* «күз сирпү». Чаг. ш. ук тат. диал. (Balint: 139) *сиру* «селкетү». К. **Сип-ү.**

**Сирпе-ү** фигыленең дериватлары үзеннән активрак тат. **сирпел-ү** «чәчелү, таралу; талпыну» (К. Тинчурин), чув. *сирпен-у* «чәчелү, сибелү», *сирпет-у* «чәчү; тарату (мәс., өемне)», *сирпĕнчĕк* < *сирпĕлчĕк* «чәчрәгән тамчы» һ.б. (бу чув. сүзләре тат. сөйләшләреннән алынган), к. Ашмарин XI: 155; ЭСТЯ VII: 247.

**СИРТМӘ** «журавль колодца»; «рессора», «оцепь» (Троянский I: 573) ~ башк. (БҺҺ II: 290) *һиртмә* «пружина, силә» < диал. **сийертмә** < **сигертмә** (ТТДС I: 369) < **сикертмә** (ДС I: 163) id. ← *сикерт-* ← *сикер-* (к. **Сикер-ү**), к. чув. *сике, сикмерчĕк, сикелте, сиктерме* – барысы да «сиртмә», башк. (БҺҺ II: 211) *сиртке, сирткес, сирткеш* «кое сиртмәсе» һ.б. К. ш. ук мар. диал. *сиртмä* «сиртмә». Шулай итеп, бу сүз Идел-Урал регионына хас сүзләрнең берсе.

**СИР-Ү I** «раздвигать (ветки в лесу)» (Х. Госман) > чув. *сир-* «актарып ташлау, җәю; сиру» < гом. төрки *сәр-, сäр-* > чув. *сар-* «җәелдерү, җәю» (к. Räsänen 1969: 411). К. ш. ук мар. *сäр-, шäр-* > *шар-* «җәю, сиру», үзб. (ЎХШЛ: 234) *сәр-* «керләр элү». К. **Сәрдек, Сирел-ү**. Федотов II: 14–15 (тәфсилле); ЭСТЯ VII: 242.

**СИР-Ү II** «мочиться (только о животных)» ~ башк. *һир-* id. К. **Си-ү.**

**СИС** (Тел ярышы: 135) «голос, голоса; звук, шум» < гом. кыпч., төркм., гаг. *сэс, сес*, аз., үзб. диал. (ЎХШЛ: 235) *сäс,* төр., кар. *сäс* >> чув. *сас*

«аваз, тавыш; хәбәр-хәтер», каз. *сес* «мактау, дан». Ихтимал. **Сискән-ү** белән тамырдаштыр. Будагов I: 628; ҚТДС: 292–293; ЭСТЯ VII: 249–250 (тат. сүзе искә алынмаган).

Дерив.: **сисле, сиссез; сислә-ү.**

**СИСКӘН-Ү** «вздрогнуть; испугаться» > чув. *сискен-* < гом. кыпч. *сескен-, сэскэн-, сäскäн-,* уйг. (Радлов IV: 488) *сәскән-* id. беренче карашка **сискә-* < **сэскä-* фигыленнән кебек, ләкин к. каз., кырг. *сес* «куркыту, буш янау сүзе», *сескен-, сезген-* «куркыну», *сесте-* «куркыту», *сестен-* «сискәнү». Ихтимал ки, бор. *sezik-än* «сизенү» ← *sezik-* «сизенү, сизенүчән булу, сизенеп тору» ← *sez-* «сизү» сүзенең интенсивлык формасыннан, к. ДТС: 298–299; Clauson: 860–869 һ.б. R-вариант: себ. (Тумашева 1992: 190) **сирән-ү** << төр. *sirken-, sirkin-* «сискәнеп уяну». К. **Сәрен, Сәрсән, Сиз-ү, Сис.** ЭСТЯ VII: 250.

**СИТӘ** к. **Сикә.**

**СИ-Ү** (дөресрәге **сий-ү** булыр иде) «мочиться» < гом. кыпч., алт., уйг., үзб., госм. һ.б. *сий-,* башк. *һей-* < бор. төрки (ДТС: 499–501) *siδ-, sid-, sit-* ~ чув. *шăр-* < болг. **сĕр-, *сир-*. Чаг. ш. ук монг. *сари-, шээ-* «сию», бор. монг. *sigesün* ~ тунг. (ССТМЯ II: 392–393) *чикэн* «сидек». К. **Сидек.** Федотов II: 448; ЭСТЯ VII: 256–257.

Бу сүз түбәндә тәкълиди тамырдан булырга тиеш, чаг. рус. *ссать* id.

**СИХӘТ** «нормальное здоровье; целебное воздействие» < гар. *çиххäт* id. ← *çхх* «сау-сәламәт булу» тамырыннан; шуннан ук иске **сахих** «бозылмаган, сау».

Дерив.: **сихәтле; сихәтлек; сихәтлән-ү.**

**СИХЕР, сихыр** «колдовство; чары» < гар. *сихр* id. ← *схр* «сихерләү», шуннан ук **сихри**, иске тат. **(мө)сахир** «сихерче» – гар. телендә ясалган сүзләр.

Дерив.: **сихерле, сихерсез; сихерлә-ү, сихерлән-ү; сихерче, сихерчелек.**

**СИШӘМБЕ,** диал. **чишәмбе** «вторник» ~ башк. *шишәмбе, шишәмбә* < фар. *сешäнбä* id. («атнаның өченче көне» дигән сүз: *се, сä* «өч», *шäнбä* «атнаның бер көне»). К. **Шимбә.**

**СИЯТ [сийат]** (Идегәй 1988: 522) «украшения упряжки, саней на свадьбе»; «набор (дорогих) украшений (на одежде)» < диал. (ДС II: 171) **сәйәт** «сәгать», к. **Сәгать.** XIX г. чылбырлы сәгать тагып йөрү һ.б. байларча киенү галәмәте булган. Яки фар. *зиһат* id. ← *зиһ* «бизәнү, бизәү тасмасы».

**СКРИПКА, эскерипкә** «скрипка» < рус. (*скрипеть* «чыңгылдау, шыгырдау» сүзеннән). **Скрипка** дип языла, тик фольклорда һәрдаим *эскерипкә* диелә – рифма, ритмика шундый әйтелешкә корыла.

**СОГЫН-У [сŏғŏн-]** «вложить себе в рот большие куски; жадно есть; объедаться» < гом. кыпч., уйг., алт. *сугун-*, к.-калп., үзб. *сугын-,* каз. *сŏгын-,* башк. *һоғон-* һ.б. id. ← гом. кыпч., алт., уйг. һ.б. (Радлов IV: 750) *суқ-,* хак. *сух-* «тыгу; кидерү»; бу сүз тат. сөйләшләрендә дә үзгәрешсез яңгыраштa очрый, мәс., *атка йөгән сугу* (~ *согу)* диелә. К. ш. ук як. *угун-* «тыгу, пулга өлеш салу» < **һук-*. К. **Сук-у II.** Чаг. **Сон-у.**

Дерив.: иске тат. **согындыр-у**, башк. *һоғондороу* «кунакның авызына тыгу» – янәсе, аеруча кунакчыллык билгесе (к. ДС II: 165; БРС: 735 һ.б. чыганаклар), *соғалан-у* «ашыгып ашау»; (ТТДС I: 371) **соганак** «гуҗ, күп ашаучан (кеше)» (бу сүзнең «аждаһа» мәгъ. дә бар).

**СОЕРГАЛ [сŏйŏрғал]**, **сөергәл** тар. «жалованное за службу поместье» < монг. *суйургал, сойургал* id. ← *суйурқа,* бор. төрки (ДТС: 508, 513) *sojurqa-, sujurqa-* «бүләкләү, шатландыру» ~ чыгт. (Будагов I: 616–617) *саурга-* id., бигрәк тә «зур җир мәйданы, төбәк, өлкә һ.б. бүләк итү». *Сойорғал* бирү системасы Чыңгызхан империясендә киң кулланылган, к. ш. ук Будагов I: 658; Тимергалин: 422. Бу сүз күп телләрдә очрый.

Бор. *sujurqa-, tsujurqa-* сүзен бор. кыт. *цы-, дзы-* «ана мәхәббәте, ана шәфкате» сүзеннән дип уйлыйлар, к. ДТС: 583.

**СОК** «жадный или восхищённый взор, взгляд; жадный до еды»; себ. (Тумашева 1992: 191) **соқ** «вор», **сох** «жадный: обжора», диал. ш. ук «сглаз» > удм. *сук,* удм. диал. (Насибуллин: 137) *суд*, мар. (Упымарий: 195) *сут* ~ чув. *сăхă* «комсыз; сок» < гом. кыпч., к. башк. *һоқ,* каз. *сŏк* «киеренке караш», кырг. *суқ* «явыз рух төре», нуг. *сық,* куман. *суқ* «комсыз», уйг., бор. төрки (Радлов IV: 517) *соқ* «комсыз; көнчел», үзб. *суқ* «күз тию» һ.б. Räsänen 1969: 426; Федотов II: 34–35.

**Сŏк < суқ** сүзенең гом. кыпч., уйг., үзб. *суқлан* (> кырг. һ.б. *суктан*) «соклану» дериваты еш очрый.

**СОЛ** «способность, искусство в трудных операциях» (Будагов I: 717), диал. (ЗДС: 592) «секрет, порядок, лад» ~ чув. *сăл*, мар. (Упымарий: 194) *сул* < (нуг.) *сул* id., ихтимал, *ысул* сүзеннәндер. Федотов II: 22.

Дерив.: **соллы; соллан-у.**

**СОЛАК** (Арсланов 1988: 92) «уключина», **сулау < сōлау** (Тумашева 1992: 191–192) «крючок, затвор», *сōла-* «запереть (затвором)», үзб. (ЎХШЛ: 240) *солақ, солағ* «чәкүшкә», к.-калп. *солақ* «силә, рессор». Тат. *сōла-* фигыленә караганда, ниндидер *сō-* тамырыннан, чаг. кыт. *со́* «йозак; хибесханә» (шуннан уйг. *сола-* «кулга алу», *солақ* «төрмә»). ЭСТЯ VII: 302 (тат. сүзләре китерелми). К. **Солау, Сулык**.

**СОЛАҢ** (ТРС 1992), **сōлаңғыр** (Тумашева 1992: 191) «радуга зимой» ~ алт. *солонга, сүлүңги,* уйг. *солан,* шор. *сүлäңи* < монг. *soluŋga* «салават күпере; сары ас, коланык» > рус. диал. *солонгой* «көзән, ас, коланык». Тат. *солаңгыр* < *солоңға қур* (к. **Кур** «җәя») булса кирәк.

Монг. *солуңга*, эвенк һ.б. тунг. телләрендәге *солоңго* > *һолоңго* > *холонго* > *колонго* «коланык; солаңгыр» сүзеннән булса кирәк. Салават күперен озын торыклы сарылы-кызгылтлы ас дип күзаллаганнар. Бәлки ул асны кыт. миф. *чулуңванга* «күк аждаһасы»на тиңләштергәннәрдер. Чөнки *солонго* < *чолонга* кыт. *чжу-луң-ван* «күк ләве, таң аждаһасы» сүзеннән килә ала, к. **Чулпан, Чулпы.** ССТМЯ II: 109, 332, 405; Аникин: 503 (бай әдәбият китерелә); ЭСТЯ VII: 203. Гомумән, *солан* һәм *коланык* сүзләре үзара баглы, ләкин ничек – ачык түгел. К. **Коланык.**

**СОЛАУ [сŏлаw]** (ЗДС: 576, брб.) «крючок дверной» – «элгеч, бик» ~ уйг. *сулағ* id. К. **Солак, Сулык**.

**СОЛДАТ [салдат],** иске тат. сүзлекләрендә **салдат** «солдат» ~ башк. *һалдат* ~ мар., удм. *салдат* «солдат; үлән төре» (к. Насибуллин: 136), чув., мар. диал. (Саваткова: 141) *салтак* < рус. *солдат* < ним. *soldat* < ит. *soldato* «яллы гаскәри» (*sold* «ял, түләү; акча» < лат. *solid* «коемланган акча; хөкүмәт акчасы; җитди» >> рус. *солид-ный* «җитди, могтәбәр, олпат»). Фасмер III: 709–710; Kluge: 855.

Дерив.: **солдатлык; солдатка** (ш. ук русчадан).

**СОЛТАН** «султан; принц, принцесса» < гар. (гомумән сем.) *сулṭāн* «югары хакимият, власть (шәхес түгел)» сүзеннән фар. һәм төр. телләре аша мәгънәсе үзгәреп килеп чыккан; күп очракларда *солтан, солтания* «патша кызы» мәгъ. кулланыла. Будагов I: 633.

Гар. *сулṭāн* гомумән *слṭ* «тел остасы булу» тамырыннан килә, шуннан ук *салтан, салтанат* «патшаларча булу; патшалык, егетлек һ.б.», иске тат. *салитә* «кискен, каты, әмма бик урынлы, дөрес сүз, кыланыш» → **салитәле** «бик дөрес сүзле» һ.б. килә. Гомумән бу сүзләр, халыкара киң таралыш тапканнар. к. рус. *салтан, султан* – төрле мәгъ. нигезләр.

**СОЛЫ [сŏлŏ]** «овёс» > чув. *сăлă, сĕлĕ* ~ мар. *шўльӧ* ~ башк. *һōлō* < гом. кыпч. *сулу, сулы*, кырг. *сулуу*, төркм., үзб. *сулы, сүли, сүле* (ТДГДС: 164), алт., хак., тув. *сула* ~ калм. *сули* «солы», монг. *сули* «кылганның бер төре»; СС *suul urme* «солы» һ.б. (к. Joki 1952: 274). Бу сүзне монголчадан дию (Räsänen 1969: 432) мәгънәви җәһәттән ышандырмый, фонетик җәһәттән дә бу фараз аксый: алт. һ.б. *сула* дигәндә *-а* һәм палаталь вариантлар (чув. *сĕлĕ=сөлө* ~ төркм. *сүли*) да аңлатылмый. Федотов II: 41; ЭСТЯ VII: 349–350 (тамыры билгесез ди).

Дерив.: **солыча** (үлән төре).

**СОЛЫХ [сŏлŏх]** «примирение, мир; согласие (после споров и т.п.)» < гар. *ṣулх* id. ← *ṣлх* «яхшы мөнәсәбәттә булу; яхшыру», шуннан ук к. **ислах, мәслихәт, сәләт < сәләхият**; кеше исемнәре: **Салих, Салиха, Мөслих, Мөслиха** һ.б. Будагов I: 703.

**СОМ** (ЗДС: 576–577) «опухоль без нарыва, желвак (обычно на бедре»), **сōм** «сплошной, кругловатый кусок». Чаг. **Савым I.** К. **Сум II**.

**СОН-У,** иске тат. (Радлов I: 1747) **осын-у** «протянуть (руку); предлагать, подносить; всунуть, всучить; совать, всовывать» ~ башк. *һон-*, каз. *усын-*, кырг. *усун-* < гом. кыпч., гом. төрки (Радлов IV: 762) *сун-* < бор. төрки *su-n-* ← *su-* «озайту, сузу, тарту» (фигыльнең кайт. юнәлеше, к. ДТС: 512, 514); чаг. монг. *суна-* «сузылу» → *сунаа-* «озайту, сузу» < бор. монг. *sunuya-* id. ~ тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 126–127) *сӯн-* «озынаю, сузылу» һ.б.; чув. *сĕн- [сөн-]* «көчләп бирү, үгетләп тәкъдим итү» *сŏн-* вариантыннан палатальләшкән (димәк, бу сүздә тат. һәм чув. телләренең уртак тарихи компонентының борынгылыктан килгәнлеге күренә), к. ш. ук мар. *шĕн-, шун-* id. Будагов I: 713;

Федотов II: 43; Räsänen 1969: 432 (Рясянен буенча, *сон-* < *сун* – Урал-Алтай сүзе); ЭСТЯ VII: 335–336.

Дерив.: **соныл-у, соныш-у, сондыр-у.**

**СОҢ,** диал. **суң** «конец (события, действия); поздно; после, затем» < гом. төрки *соң* (төр. *son,* башк. *һуң*) < бор. төрки *son, soŋ* id. (кайбер телләрдә исем мәгъ. юк); чув. һәм як. телләрендә булмаган. Сүзнең этимологиясе табышмаклы; маньч. *соңқо, соңкон, соңку* «эз, эзәк, сукмак; үрнәк, күчерге» сүзе белән чагыштырыла (семантик аналогиясе: рус. *след – послед – последний – следствие* һ.б.); икенче яктан, к. тат. диал. **суң**, үзб. (ЎХШЛ: 240) *соң* «сул» ~ тув. *соңгу* «төньяк; көнчыгышка караганда сул як – төньяк, көнгә караганда – арт як, күләгәле як». Бор. *соң-* фигыле дә булган бугай. Будагов I: 711; ЭСТЯ VII: 308.

**Соң** бик актив сүзьясагыч һәм фразаясагыч нигез (к. Махмутова: 231): **соңай-у, соңар-у, соңгы, соңын, соңыннан, соңынтын** һ.б.; к. **Соңгылык, Соңра.**

**СОҢГЫЛЫК [сŏңғ̆олы̆қ]** «послед» ← ***соңгы** «соңгылык», к. тув. *соңгу* id., ихтимал, **соң-* фигыленнәндер, к. бор. төрки (ДТС: 508) *soŋиq* «азак, ахыр, соң». Һәрхәлдә *соңгылык* «бала чүбе, бала кабы» *соңгылык* «соңгы булу» белән бердәй түгел. К. **Соңра.**

**СОҢРА**, диал. **соңыра** «потом, затем» < чыгт., уйг. *соңра* (> госм., төр. *sonra, sora* > к.-балк., ком. *сора*) id. Чаг. бор. төрки (ДТС: 508) *soŋra-* «кичектерү, соңгарак калдыру». *Соңра* сүзе **тышра, эчрә, үзрә** кебек сүзләр моделендә ясалган булса кирәк, ә бу модельнең эчке структурасы бигүк ачык түгел (*-ра* биредә ~ чув. *ра* – бор. урын-вакыт килеш кушымчасы дип кенә хәлдән чыгып булмый). К. **Соң.**

**СОРАН I** (Остроумов 1872: 114) «сыромятная необделанная кожа»; вообще «толстая обделанная кожа» ~ чув. *сăран [сŏран],* мар. (Иванов, Тужаров: 207) *сӳран,* удм. *сурон, сыран, сърон, сүрон* «сыйфатлы күн» – бик бор. сүз, к. Дагстан телләрендә *сурон, соран*, венг. *szirony* id. Ихтимал, **саурый** (к.) сүзе белән гомогендыр, к. кырг. *соорун* «оча, мөчә; саурый». Федотов I: 30 (монг. *сур* «каеш» сүзе белән чагыштыра).

**СОРАН II,** (Тумашева 1992: 192) **сөрән** «хамелеон». Чаг. диал. **сорхантай, сөрхәнтәй** «юньсез хәйләкәр». К. **Сөрән II.**

**СОРАУ [сŏраw]** «вопрос» – исемләшкән **Сора-у** (к.).

**СОРА-У,** гом. диал. (төрле сөйләшләрдә) **сура-у** «спрашивать; просить» < гом. төрки (к. Радлов IV: 765) *сура-* ~ монг. *сура-* (> бур. *һура-*) «сорау; белешү», кайбер шивәләрдә «мәгълүм итү» ← ***сур** тамырыннан булса кирәк, шуның фигыль коррелянты **сор- < сур-** «сорау» (бу сүз дә киң таралган).

Күп телләрдә (кырг., уйг., монг. > фар.) *сурак, сураг, сурах* «тикшерү; сорау алу» **сора- < сура-** нигезе белән баглы булса кирәк. Бур. *һура-* һәм башк. *һора-, һура-* вариантлары гомоген. Чув. телендә *сура-, сур-* сүзләре (чагылышлары) күренми (*шăра-* «эзләү» сүзен мин *сора-* белән кардәш дип исәпләмим). К. **Сор-у.**

Дерив.: **сорал-у, соран-у** («хәер эстәү» мәгъ. күп төрки телләрдә очрый), **сораш-у, сорат-у** (һәркайсы үзенчәлекле мәгъ. кулланыла). Будагов I: 707–708; ДТС: 509; ССТМЯ II: 129; ЭСТЯ VII: 309–311.

**СОРГАВЫЛ [сŏрғаwы̆л]** «арьергард, задний дозор» < монг. *сурғағул* id., ш. ук «өйрәнчек» ← *сурга-* «өйрәтү, үгетләү» (*соргавылга* яшь-җилкенчәк куелган).

**СОРКА, сөркә** «конура для сурка» < рус. *сурка* id. К. **Суыр.**

**СОРНАЙ** «большая, длинная труба – музыкальный инструмент» > чув. *сăрнай, сурнай, сырнай,* мар. (Исанбаев 1978: 45) *сорнай, сурнай* «волынка» ~ башк. *һөрнай* < фар. *сурнай* «сорнай» (сүзмә-сүз «туй быргысы»: *сур* «туй; туйга чакыру», *най* «көпшә, курай, быргы»). Бу фарсы сүзе киң таралган, к. рус. *сурна, зурна* «быргы, курай һ.б.», к. Фасмер II: 807; Федотов II: 31–32.

**СОРТ [сōрт],** сөйл. **сурт** «сорт» < рус. < ним. < лат. *sortis* «табыш, табышлы товар» сүзеннән.

**СОР-У** иск. «спрашивать, просить» (к. Тукайда «*бурыч сорганыбыз бардыр*») < чыгт. *сур-* «сорау; белешү, өйрәнү» (Поппе 1938: 116, 328), куман., госм. *сор-* (Радлов IV: 542) id. ~ бор. монг. *sur-* «сорау» һ.б. Чаг. ш. ук бор. монг. *suraγ* «яңалык, яңа хәбәр», хәз. монг. *сураг* «хәбәр-хәтер», тув. *сураг* «хәбәр; риваять, сөйләк». *Сур-, сура-* сүзләре нәкъ менә *сураг* сүзеннән килеп чыга ала (гадәттәгечә

түгел), ә бу сүз исә иске фар. *suraq* «белге; аяк эзе; эзләү-тикшерү» сүзе белән игез булырга тиеш, к. чыгт. *сура-* «сынау» һ.б.

**СОРЫ I [сŏрŏ],** диал. (себ. һ.б.) **сор** «серый» ~ башк. *һӧрӧ* > чув. *сăр, сăрă*, мар. *сур, суро*, удм. *сур* < гом. кыпч., уйг., як. *сур,* төркм. *суур* «соры, тычкан төсендәге», *суур* «кыйммәтле көмешсу – соры төстәге каракүл», бәҗ. теләндә *suru* «соры, саргылт» булуы билгеле. К. **Суыр.** ЭСТЯ VII: 336–337.

**СОРЫ II: сорыкорт** «трутень» ~ башк. *һӧрӧгорт, һӧрӧ ҡӧрт,* чув. *сăр; сăр хурт, сăрă,* мар. *сури, шури,* (Упымарий: 194) *шүрэ-мукш, шырэ,* удм. *зыры, зърмъш, зърмъш, ъзъри, узыри* «соры корт» (к. Насибуллин: 71). М. Рясянен (Räsänen 1969: 433) бу сүзне **соры** төс белән бәйли, ләкин безнеңчә, бу хата, чөнки соры кортлар соры төстә булмый. Безнеңчә, фин-угор сүзе. К. ш. ук Федотов II: 29.

**СОРЫК [сŏрŏк], сорых** (Тумашева 1992: 191) «двух-, четырёхвесёльная большая лодка» < рус. *струг, струга* id. (к. Фасмер III: 782–783).

**СОСА,** диал. **суса** «шпулька, ткацкий челнок» ~ башк. *һӧҫа,* чув. диал. *аса, сăса;* удм. *сусо*, коми. *суса* (КЭСК: 267), мар. > удм. *шуша* (Насибуллин: 149); мар. диал. *сопс*, хант. *supăs* id. Ихтимал, бор. тат. **суп-са,* к. каз. *субаҡ, собаҡ* «шүре» ← **суп* id. Чаг. уйг. *соза* ~ кыт. *со, со цзы* «соса». Әгәр бу сүз кытайчадан булса, уйланырга урын күп. ЭСТЯ VII: 339.

**СОСЛАН,** диал. **сосла** «суслон» ~ чув. *ăслан, сăслан*, мар. *сусла* һ.б. < рус.; рус. *су-слон* «терәтелгән» (Фасмер III: 810).

**СОС-У** «черпать» ~ башк. *һӧҫ-,* чув. *ăс-, сăс-* < гом. төрки (хак., алт., төркм.) *сус-*, уйг., тув. *ус-* id. Кыпч. телләрендә сирәк очрый. ЭСТЯ VII: 338.

*Сос-у* < *сус-* фигыленә рус. *сусло* «куассыман сыеклык» (> тат. *сосла*, к. ТРС 1992) сүзен бәйлиләр (Фасмер III: 810).

**Сос-** продуктив нигез: **соскы, соскыч** һ.б.

**СӨБӘ,** диал. (матур әдәбияттан алынган материаллардан) **зебә, зөбә, себә,** себ. **сүмӧ,** (Тумашева 1992: 190) **симә** «ложное ребро; нижнее, несомкнутое ребро» ~ башк. *һебә,* каз. *сүбе,* кырг. *сүбөө,* алт. диал. (Радлов IV: 850–853) *сүбää,* тув., хак., алт. *сүме, сүмү* id. бор. чыгт., бор. монг. (Поппе 1938: 239) *sübe* «атның сөбәсе» < яз. монг. *sübege* «кабырга, ян», *sübegen* «сөбә», хәз. монг. *сүврэг* id. *сүвээ* > бур. *һүбөө* «күкрәк читлегенең ян ягы», эвенк. *сувин* «сөбә» һ.б., к. Номинханов 1975: 92; ССТМЯ II: 117. Монгол сүзе булса кирәк; гомумән – ачык түгел. *Сөбә ~ һебә* көрәш-ярышларда җиңүчеләргә бүләк итеп бирелгән. Башк. *һебә, һөбә* һәм бур. *һүбөө* уртак чыганактан. ЭСТЯ VII: 340–341.

**СӨБХАНАЛЛА** «восхищаюсь» – междометие при виде чего-либо прекрасного < гар. *субхāн Аллāһ* «Аллаһ (һәр кимчелектән) пакь».

**СӨГЕЗЛИН [сөгөзлин]** «дождевой червь» (ТТДС I: 387). К. башк. (БТДҺ: 280) *сөгәзлин, сөгәлҗән, сөгәлсән* һ.б.ш. id. Ачык түгел. **Суалчан** сүзе тәэсирендә ниндидер бүтән сүздән үзгәргән. Чаг. мар. *шукш,* морд. *сукс* ~ саам. *suoksa* «суалчан», к. Räsänen 1969: 420.

**СӨЕК [сөйөк]** диал. «ласка, милование» – шуннан дериваты **сөекле,** диал. **сәwеклĕ** < бор. төрки (ДТС: 497) *seviglig* «сөекле, сөелгән» ~ чув. *савăк* «сөенеч, шатлык, рәхәтлек», *саваклă* «сөекле; шатлыклы»; нуг., к.-калп. *сүйикли,* кырг. *сүйүктү* һ.б. «сөекле». К. **Сөй-ү.**

**СӨЕН-Ү [сөйөн-],** диал. **севен-, сәвен-** «радоваться, ликовать» ~ башк. *һөйөн-* < угыз линиясендә *сәwен-, сәвен-, сәбин-,* гом. кыпч., уйг. линиясендә *сүйүн-* id., асылда «шатлыктан үз-үзеңне чәбәкләп сөю» дигән сүз. **Сөйөн-** < *сүйүн-* продуктив сүзьясагыч нигез: **сөендек** («сөенү сәбәбе» мәгъ.), **сөенеч, сөенечле** һ.б., к. ш. ук **Сөенче.** К. **Сөй-ү.**

**СӨЕНЧЕ [сөйөнчĕ]** «радостная весть», диал. (ДС III: 136) **севенче** «подарок за хорошую весть» ~ башк. *һөйөнсө,* чув. *савăнчăк,* төркм. (ТДГДС: 164) *сөвүнҗи*; гом. кыпч. линиясендә: нуг., каз., к.-калп. *сүюнше, сүйүнши,* к.-балк. *сюйюмчю*, кырг., ком. *сүйүнчү,* уйг. *сүйүнчә* id. Бу сүз күрше телләргә дә кергән, к. мар. *сүнзы* «терлекләр бала китергәч әйтелә торган сүз, шунда балаларның колакларын боралар» (Саваткова: 150); бор. рус. *сеунчь* «җиңү хәбәре; җиңү хәбәрчесе» (шуннан *сеунщик, сеунчевать*), к. Сороколетов: 255–256.

*Сөенче* тат. тулысынча *колак сөенчесе* диелә; **сөенче** тәүдә кеше, гамәл кылучы (Nomina agentis) һәм гадәттә хәрби булган, иске тат. (Гиганов)

*сөйөнцө* «возвеститель мира». Тамыры, әлбәттә, *сөй- < сүй-,* к. **Сөй-ү.**

**СӨЗӘК I,** (ДС I: 174) **сөсәк** «затяжная болезнь; зараза» ~ к.-калп. *сүзәк*, кырг. *сүзөк* «тиф» < уйг. *сүзүк < сөңзәк* «венерик авыру». Арытабан безгә ачык түгел.

**СӨЗӘК II**, (ДС III: 146) **сүзәк** «пологий» ~ башк. *һөҙәк,* чув. *сӗвек, сӗврек* id. Арытабан ачык түгел.

**СӨЗЕК I [сөзөк],** диал. **сөзген,** (Тумашева 1992: 195) **сүзүк** «прозрачный» < гом. кыпч., к. куман., ком., бор. төрки (Clauson: 861) *süzük* id. ← *süz-* «сөзү», к. **Сөз-ү II. Сөзек** яки **сөзген** сүзләрен сөйләшләрдә «үтә күренмәле» мәгъ. кулланалар һәм бу бик урынлы. К. түбәндәгеләрне.

**СӨЗЕК II [сөзөк],** (ЗДС: 578) **сөdөк** «то, что выцеживается; гуща, результат выцеживания», сөйләшләрдә киресенчә – «сөзелеп чистартылган (сыеклык)». Себ. (ЗДС: 587) **сүзүк** «саф, сөзелгән (сыеклык)». Сөйләм телендә **сөзген** «чиста, үтәли күренмәле, үтәкүренмәле» (к. **Сөзек I**). Моның омонимы **сөзген** «игътибар белән, сөзеп һәм туптуры (карау, караш турында)» кайсы фигыльдән икәнлеге бигүк ачык түгел. Ш. ук **сөзет** һәм **сөзелтә** сүзләре дә ике мәгънәле булып калалар. Иң уңышлы кулланыш мәгънәләре «сөзгәннән калган чагыштырмача каты масса». **Сөзмә** сүзе ашамлык атамасы буларак рус теленә дә кергән – *сюзьма.* Тат. телендә **сөзелте, сөзелдек** сүзе дә бар. Чаг. ш. ук **Сөземтә.** К. **Сөз-ү II.**

Бу сүзләр бүген төрки телләрдә дә очрый.

**СӨЗЕМТӘ [сөзөмтә], сөзелте, сөзенте** «то, что остаётся после выцеживания», күч. «результат; вывод» неол. булса кирәк. Башк. *һөзөмтә* id. татарчадан бугай. К. **Сөз-ү II.**

**СӨЗМӘ** «сюзьма (молочный продукт)» – гом. төрки характердагы сүз.

**СӨЗ-Ү I** «бодать» < гом. кыпч. *сүз-*, куман., гом. угыз., хак., алт. *сүс-*, башк. *һөҙ-,* бор. төрки (ДТС: 518) *süs-* id. ЭСТЯ VII: 269–370.

Дерив.: **сөзеш-ү, сөздер-ү; сөзгәк.**

**СӨЗ-Ү II** «процеживать, цедить, ловить рыбу бреднем» ~ башк. *һөҙ-* id. < гом. төрки (Радлов IV: 841–844) *сүз-* id., тув. *сүз-* «суда йөрү», үзб. *сүз-, сүз-* «йөзү» ~ чув. *сӗр- (сөр-)* «сөзү (рус. “цедить, бродить рыбу”)» ~ калм. *шүр.-* «сөзеп чистарту» һ.б. ~ тат. диал. *сөр-* (к. **Сөр-ү**) id., монг. *сөрө-, сөр-* «җилгә, агымга каршы бару». Будагов I: 646; Räsänen 1969: 438–439; Федотов II: 44–45; ЭСТЯ VII: 342–344.

Дерив.: **сөзел-ү, сөзеш-ү, сөздер-ү; сөзге, сөзгеч; сөзенте;** к. **Сөзек; Сөземтә, Сөзмә, Сөрәкә.**

**СӨЙКӘЛ-Ү** «прислоняться (к человеку)» ~ башк. *һөйкәл-,* диал. **сөйкә-ү** (башк. *һөйкә-ү*) «сөяп кую» фигыленең төш. юн. К. **Сөя-ү.** ЭСТЯ (VI: 345) икенче бер (төркм., тат., к.-калп., төркм., үзб.) *сүйке-* «ышку» сүзен китерә.

**СӨЙКЕМ [сөйкөм],** «миловидность, обаяние» < гом. кыпч. (нуг., каз., к.-калп.) *сүйким,* (кырг., ком.) *сүйкүм,* башк. *һөйкөм* id., к. ш. ук кырг. *сүйгүн* id. **Сөй- < сүй-** тамырыннан, ясалышы ачык түгел (*сөек-ем* булса кирәк, ягъни **сөек-ү** дигән фигыль булгандыр).

Дерив.: **сөйкемле, сөйкемсез** һ.б.

**СӨЙЛӘ-Ү**, диал. (күп төбәкләрдә очрый) **сүлә-ү** «говорить (продолжительно), вести речь» < гом. кыпч., уйг., угыз. һ.б. *сөйлә-, сөйлә-,* к.-балк. *сөле-,* башк. *һөйлә-, һөйҙә-* < бор. төрки (ДТС: 512) *sözlä* > төркм. *ҫөзле-*, алт. *сөстө-* һ.б. ← *сөз-* «сүз» < **сөөз*, к. хак. диал. (Радлов IV: 583) *сөөлә-*, тув. *сөгле-* «сөйләү». Ихтимал, *сүз < сөз < сөөz < сөгүз*, ягъни **сөг* нигезенең күп. формасыдыр. Кайбер төрки телләрдә *сүзлә- < сөзлә-* кулланылмый, ул мәгънәдә бүтән сүзләр килә (мәс., чув. *кала-*, үзб. *гапир-*, хак. *чоохта-*). Будагов I: 651; Мухамедова 1973: 153; ЭСТЯ VII: 318–319.

Дерив.: **сөйлән-ү, сөйләш-ү, сөйләт-ү; сөйләк, сөйләм, сөйләш** һ.б. (икенчел дериватлар да күп кенә).

**СӨЙМӘН**, иске тат. (Радлов IV: 594) **сүкмән, сукман** «пешня» > мар. *сүмен, сүймӓн,* каз. *сүймен* id. Ачык түгел.

**СӨЙРӘ-Ү,** диал. **сүрә-ү** «волочить, тащить» < гом. кыпч. *сүйрә-,* кырг. *сүйрө-,* башк. *һөйрә-* < уйг. диал., үзб. *сүдрә-* id. < **сүдүр-э-* бор. *сүт- < *сүд- ~ *сүб- ~ сүз-* «сөйрәлдерү» фигыленең *-рә* киңәйткече (дәвамчанлык форманты) ярдәмендә ясалган формасы, к. алт. *сүзүр-,* хак. *сөзир-, сөзүр-, сөзір-,* тув. *сөдүр* >> мар. *шүдер-,* чув. *сӗтӗр-* «сөй-

рәү». Чаг. **Өстерә-ү.** Федотов II: 47; ЭСТЯ VII: 346–347.

Дерив.: **сөйрәл-ү, сөйрәт-ү; сөйрәтмә ~ сүрәтмә; сүрәтке,** диал. (ТТДС II: 282) **сүрәклә-ү** ~ алт. (Баскаков 1966: 150) *сүректе-* һ.б.

**СӨЙРЕ [сөйрө]** (ДС I: 173), диал. (Тумашева 1992: 192) **сүйрү, сүре, сүрек, сүгри** «длинный и остроконечный (стержень с острым концом); конусообразный» < гом. кыпч., к. нуг., к.-калп. *сүйри, сүйир,* каз. *сүйĕр, сүйрĕк,* төркм. *сүйрүк, сүйрик,* кар. *сүврү, сиври*, уйг. *сүври,* чыгт., төр. *sivri,* алт. *сүгрү*, як. *сүрүн* ~ чув. *сĕвĕр, шĕвĕр* id. урта төрки *sübi,* госм. *сүбү,* бор. монг. *sibüge* «без; оч» белән чагыштырыла (к. Räsänen 1969: 438), чаг. ш. ук яз. монг. *sobuүur* ~ эвенк. (ССТМЯ II: 118) *сувэрэ* «очлы тау; сөйре» ~ алт. (Баскаков 1966: 150) *сүри, сүгри* «калкулык; очлы тау башы; кыяларның очлы кырый-ярчыклары». Будагов I: 650; Федотов II: 456; ЭСТЯ VII: 252–253. К. **Сөрек, Сүрә I, Сүрек, Черки.**

**СӨЙСӘ-Ү** диал. «любоваться, смотреть с любовью, желать погладить» ~ каз., кырг. *сүйсе-, сүйсін-* id. К. **Сөй-ү.**

**СӨЙСЕН [сөйсөн]** (ЗДС: 579) «напитки и сладости, принесённые из дома жениха в дом невесты» ~ башк. *һөйһөн* id. Бу сүз халык этимологиясе буенча бор. монг. *šigüsün* «гаскәри азык-төлек» сүзеннән үзгәртелеп пәйда булган бугай. К. чыгт. < монг. (Будагов I: 675) *шусун* «хәрби порцион (азык-төлек)». Туй терминологиясендә асылда хәрби булган терминнар кулланылу төркиләрдә типик күренеш. К. **Сусын.**

Шуның белән бергә **сөйсөн** сүзенең бүтән этимологиясе дә булырга мөмкин, к. кыт. (МНМ I: 412) *суйсин* «Зөһрә йолдызы; туйда кәләшне атау сүзе».

**СӨЙ-Ү,** диал. (күп төбәкләрдә, ләкин диалекталь сүзлекләрдә тулысынча теркәлмәгән) **сү-ү, сеw-ү, сәү-ү** «любить; похлопывать, поглаживать в знак любви». Тат. телендәге ике төп вариант төрки телләрдәге ике төп линияне чагылдыра: *-й* (уйг.-кыпч.) линиясендә *сүй-, -б > в > w* (бор. уйг.-угыз.) линиясендә *сәб-, сәв-, сәw-* id. Бу ике линиянең икесе дә кулланылу куман., хәз. уйг. һ.б. телләрдә дә күзәтелә.

Чув. *сав-* «сөю, шатлану, сөенү» миш. **сәү-** вариантыннан килә (һәрхәлдә шуңа баглы). Будагов I: 651–652; Räsänen 1969: 406–407; Боровков 1963: 264–265; Федотов II: 3 (тунг.-монг. параллельләре китерелә, ләкин, безнеңчә, алар бик ышандырырлык түгел); ЭСТЯ VII: 219–220.

**Сөй-, сәү-** бик продуктив нигезләрнең берсе: **сөел-ү, сөен-ү (!), сөеш-ү, сөйдер-ү; сөйдергеч** һ.б., к. **Сөек, Сөенче, Сөйкем, Сөйсә-ү.** Чаг. **Сөя-ү.**

**СӨКӘ** «верша, сачок для ловли рыбы», себ. (Радлов IV: 796–797) **сүкä, сүйкä** «рыболовная морда» > чув. *сĕке* id. ~ каз. *суке, сукә* id. < (яз.) монг. (Поппе 1938: 336) *sigükü* «сөзгеч, фильтр» ← *sigü-* «сөзү»; к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 195) **сүгән** «мурда, сөкә» ~ башк. (БТДҺ: 382) *һүгән*, алт., хак., тув. *сүген, сүгäн* id. ← *сүг-* «сөзү». Мәзкүр монг. һәм төрки тамыр сүзләр тамырдаш булырга тиеш. Чаг. **Сөңгөт**. Рус. диал. *суган, соган, цуган, шуган* (< шор., чулым. *сүген*) «сөкә, сөгән» тур. Аникин: 509 (тат. сүзләрен искә алмый). ЭСТЯ VII: 370–371.

**СӨКӘТ** «чучело» < диал. **сөлкәт, сөлтәк**, (ТТДС: 383) **сүлтәкә ~ сүлкәтә** «кыяфәтсез; койрыксыз, бөкре» ~ каз. *сөкет, сөлекет* «әшәке кыяфәт; оят», уйг. *сөлтәк*, төркм. *сөлтүк* «кыяфәтсез», ләкин үзб. (ЎХШЛ: 242) *сүлкәт* «олпат кыяфәтле» (бәлки дөресе «дәү һәм ямьсез»дер). Ачык түгел. К. **Шөкәт.**

**СӨЛӘЙМАН: сөләйман балыгы** «лосось» – лат. *salmo-n* > гар. *салмун* id. сүзеннән татарчалаштырылган. Югыйсә бу балык атамасының Сөләйман пәйгамбәр исеменә кагылышы юк шикелле.

**СӨЛГЕ [сөлгө],** диал. (ДС III: 137) **селе** «полотенце» > чув. *сĕлкĕ* ~ башк. *һөлгө,* (БТДҺ: 379) *һөлөңгө,* каз. *сүлгі,* гом. кыпч., үзб. (ЎХШЛ: 243), төркм. *сүлги,* кырг. *сүлгö, сүлгүр* id. ← тат. диал. (Balint 1988: 141) *сөл-* ~ каз., кар., чыгт., төр. һ.б. *сил-,* чув. *шăл-* «сөртү; себерү» ~ яз. монг. *sili-, sile-*, тунг.-маньч. (ССТМЯ II: 84) *силки-, силку-* id. М. Рясянен (Räsänen 1969: 421) бу сүзләргә фин. *silittää-* «сөртү; юу» сүзе дә тамырдаш дип карый. Уйг. *сул-* «итне сөяктән аеру» сүзенең мәзкүр тамырга кагылышы ачык түгел. Чаг. ш. ук **Сулык.** Федотов II: 440–441.

**СӨЛЕК [сөлөк]** «пиявка» ~ чув. *сĕлĕк, сĕлĕх, сĕлкĕ,* мар. *сүлык, сулык,* удм. *сүлүк, сульык* ~ гом. кыпч., уйг., төркм. һ.б. *сүлүк,* башк. *һөлөк,* алт., яз. монг. (Поппе 1938: 487) *šülük,* төркм. (ТДГДС: 205) *шүллүк,* кырг. диал., үзб., уйг. *зүлүк* id., чаг. ш. ук

аз. *зәли*, фар. *залу* «сөлек». Räsänen 1969: 436; Федотов II: 41.

Бу мәдәни сүзнең (медицина әйбере атамасы) чыгышы ачык түгел. Ихтимал ки, ул бор. төрки (ДТС: 517) *sülük* «гаскәри, хәрби; офицер» сүзеннән (күч. мәгънәдә) килеп чыккандыр, к. тат. **сөлек кебек** ~ төр. *sülük gibi* «бик күркәм вә сәламәт (егетләр тур.)» – «офицер кебек», чаг. **ыспай** < *сипаһи* «гаскәри, офицер». Бор. төрки *sülük* – махсус күнекмәләр үткән ярсулы сугышчы-яугирне белдергәндер һәм судагы сөлекләр шуларга охшатылгандыр. КБтә *сүлүг* хәрби атны да белдерә шикелле:

*Йэгү, кү, мингү ат – айгыр, сүлүг*
*Булардыйн чыкар, һәм йүҙүргү күлүг,*

ягъни «менге атлар-айгырлар, сөлекләр болардан (күчмәләрдән) чыга, шулай ук йөк атлары – күлекләр дә». Фар. *залу* һ.б. бу тәкъдирдә контаминацион компонент кына булала. ЭСТЯ VII: 351–352.

Бор. төрки *sülük* «яугир һ.б.» *sü, süü* «гаскәр, яу» сүзеннән, к. **Ил-сү.**

**СӨЛТӘР,** диал. **сөлдә,** (ТТДС I: 387) **сөлдәр** «скелет; привидение; контур, каркас» > удм. *сульдэр* «картина, рәсем» ~ башк. *һөлдә* «скелет» < гом. кыпч., к. каз. *сүлде, сүлдер,* кырг. *сүлдөр* «сөяксанак; скелет», ком. *сулдур*, төркм. (ТДГДС: 156) *сулдар* «силуэт; контур», к.-балк. *сүлдэр* «хәрби амуниция, аркылы-торкылы каешлар», тув. *сүлде* «герб» < монг. *сүлдэ, сүлдэр* «химаяче рух; бор. бабаларның байракка күчкән рухы», калм. *sülde* «әләм, байрак», *süldr* «язмыш» һ.б. < бор. монг. *sügülde, sügülder* «ат яки як койрыгыннан ясалган чук; чуклы байрак, кутаз» < бор. монг. *segül* «койрык» (к. Ramstedt 1935: 340). Банзаров: 79–80; 274–275; Окладников: 143–144.

Башк. *һөлдә* < *һүлдә* һәм бур. *һүүлдэ* «сөлдә, калдык» уртак чыганактан. К. **Шәлтәү. Сөлтәр** сүзе, гомумән, Чыңгыз империясе чорында таралган булырга тиеш.

**СӨМ** «ощущение; наитие» (**сөм тою** «чувство общей атмосферы, настроения окружающих») ~ башк. *һөм*, чув. *сĕм [сөм]* ~ мар. (Упымарий: 195) *сүм, сүн, шүм, шүн* «сизгерлек, сизүчәнлек; йөрәк, күңел» (бу сүз удм. *сюлем,* коми. *сьӧлӧм* «күңел, җан, рух» сүзе белән дә чагыштырыла, к. КЭСК: 270) ~ манси. *сим, шим, шым* «күңел». Идел-Урал региональ сүзе, ихтимал, фин-угор телләреннән киләдер. Федотов II: 43.

Бу сүзнең киң таралган дериваты – тат. **сөмсез,** башк. *сөмçөҙ, һөмһөҙ* ~ чув. *сĕмсĕр* > мар. *шӹмшӹр* (шуннан калька *шүмдымо*), ш. ук (Упымарий: 196) *сумзыр, сүмсер, сүмүсер, сомсора, сүмер* «нахал; тактсыз, әдәпсез». Бу сүзне **сөмсер** (к.) белән бутау очраклары бар, әмма ул бөтенләй бүтән сүз.

**СӨМӘЙ-Ү** «утихнуть в подавленном настроении» к. **Семәй-ү.**

**СӨМБӘ, сөмбе** (ДС I: 173; Тумашева 1992: 192) «шомпол» ~ каз., к.-калп. *сүмбе,* кырг. *сүмбө,* уйг. *сүмбә,* төркм. *сүмме* id., чаг. алт. *сүме, сүмä,* монг. *сумун* «шомпол; ук». Рус. *шомпол* сүзе белән охшашлыгы очраклы булса кирәк. ЭСТЯ VII: 355.

**СӨМБЕЛ [сөмбөл], сөнбел [сөнбөл]** «гиацинт; кудряшки, кудри (красавицы)» < гар. *сүнбүл, сүмбүлä* id. Кырг. *сумбул чач* «кара бөдрә чәч» һ.б. төрки телләрдә еш очрый. К. **Сөмбелә.**

**СӨМБЕЛӘ, сөмбәлә,** (Гиганов; ТТДС: 387) **сүнбүлә, сөнбәлә** «созвездие Девы; месяц Девы (22 августа – 21 сентября); сентябрь» < гар. *сүнбүлä* «сөмбел көннәре, сөмбеллек» ← *сүмбүл* «башак, бәрчә, себеркәч» < шумер.-аккад. *šubultum* id. Мөселман халыкларында *сүмбүл, сүмбүлä* сүзләренең мәгънәләре күп кенә, к. Zenker: 520; Будагов I: 637; Solonen: 30.

Тат. сүзлекләрендә **сөмбелә** «август» дип шәрехләү иске (хәзергедән 13 көнгә соңарып килгән) календарь системасыннан калган, хәз. календарь буенча **сөмбелә**нең 2/3 өлеше сентябрьгә тия. Көньяк илләрдә сөмбеләнең башы (беренче числасы), безнең якларда сөмбеләнең соңгы көне – уңыш һәм кызлар бәйрәме (**кыз сырасы**). Ул бәйрәм **Нәүрузе мизан** дип тә аталган, к. Будагов I: 243–244.

**СӨМСЕР [сөмсөр], сөм-сер,** диал. **сөр-сөм** «бодрый дух, самообладание» ~ башк. *һөмһөр,* ком., к.-балк. *симсир* ~ калм. *сүм-сүр, сүр-сүм* id. – **сөм <** *сүм* һәм **сөр** (к.) < *сүр* сүзләреннән гыйбарәт парлы сүз. Башлыча, тат. *сөмсере коелу* ~ калм. *сүр-сэмсән алдх* (*алдх* «ычкыну, ычкындыру») кебек тәгъбирләрдә очрый.

Бу парлы сүзнең беренче компоненты фин-угор телләреннән килсә кирәк, к. **Сөм,** ләкин к. монг. һ.б. *сүмэ* «җан; кыяфәт».

**СӨН –** название реки в Татарстане и Башкортостане – ачык түгел; бу гидронимны бор. *сүнну*

«һунн, гунну» сүзе белән бәйләү (Н. Фәттах, Г. Саттаров) үтә дә проблемалы. Чөнки **сюнну**лар Үзәк Азиядә яшәгәннәр һәм шул исемдәге кабиләләрнең Сөн буйларына килеп җиткәнлеге тур. мәгълүматлар юк (һәм гомумән дә, андый хәл булган тәкъдирдә ни өчен нәкъ менә – Сөн, берәр зуррак елга алар исеме белән аталмаган?). *Сүннү*ләр Европага килгәндә инде *һүннү* (*һунн, гунн*) дип аталганнар (*с* > *һ* күчеше бор. халыклардан тунгусларга хас булган).

Бәлки **сөн** тарихта атаклы *үсүн* кабиләсе исеменнәндер – бу фараз (к. Әхмәтҗанов 2002: 158) ышанычлырак. К. **Өсән.**

**СӨННӘТ** «священное предание, излагающее слова и деяния пророка Мухаммеда как образец и руководство для каждого мусульманина» < гар. *сүннӓ*$^{т}$ «гадәт, йола, түрә, заң». К. **Сөнни.** Тимергалин: 418.

Дерив.: **сөннәтле, сөннәтсез** (сүгү сүзе буларак та кулланыла); **сөннәтлә-ү; сөннәтче.**

**СӨННИ** «суннит; суннитский» < гар. *сүннӣ* «сөннәткә бәйле». **Сөннәт** һәм **сөнни** сүзләре тур. к. Будагов I: 637, 639–640. Мөселман татарлар – сөнниләр.

**СӨҢГЕ [сөңгө]**, диал. (Тумашева 1992: 195) **сүңкү** «копьё, пика» > мар. *сүнгӧ* (Насибуллин: 14), башк. *һөңгө* < гом. кыпч., чыгт. *süŋgi, сүңгү* < бор. төрки *süŋgü, süŋü, süŋük* (к. DLT III: 368, ДТС: 516–517) > уйг. *сүңүк* id., к. ш. ук чув. *сĕнĕ, сăнă* «сөңге, чәнечке» бор. төрки *süŋüš-, süŋiš-* «сугышу» ← **süŋ-* «сугыш алып бару» ← *sü-* «сугыш булу», *sü* «гаскәр». К. Räsänen 1969: 437; Федотов II: 25; ЭСТЯ VII: 355–356. К. **Сөңгөт.**

**СӨҢГЕТ [сөңгөт]** (Тумашева 1992: 192) «острога» – *сөңгө* < *сүңгү* сүзенең монголча формасыннан (*сүңгү-т*) булса кирәк.

**СӨР I** «вяленое мясо» ~ башк. *һөр*. К. **Сөрсе-ү.**

**СӨР II** «бодрость, сопротивляемость ко внешним воздействиям; внушительность» (**сөрсез** «күңелсез», **сөрсе-ү** «нык каушау, сөреме коелу», к. ДС I: 173) ~ башк. (БҺҺ II: 295) *һөр* «кот» < гом. төрки (уйг., алт., чыгт., як. һ.б.) *сүр* «җан, өрәк, санәм, кыяфәт, гайрәт, сөр» ~ монг. *сүр* «мәһабәтлелек», «иләмсез караш» (к. Пекарский: 2401–2402), як. *үөр* «өрәк, явыз рух». Гомумән, *сөр* < *сүр* сүзенең мәгънә үзенчәлекләре һәр телдә күпкырлы. К. **Сөмсөр, Сөрем II, Сөренҗегән**. К. Алексеев: 128–136.

**СӨРӘКӘ** (ДС III: 146) «бредень» ~ чув. *сĕреке*, мар. *шүрӓкӓ, шӧрӧке* id. ← **сөр-ү II**. Тат. сүзе бор. чув. теленнән булырга мөмкин (хәз. чув. булса, **сөрәгә** булыр иде).

**СӨРӘН I** «весенний языческий праздник изгнания злых духов и смены огня; тревожно-угрожающий крик» ~ башк. *һөрән,* чув. *сĕрен,* удм. *сүрен* id. < гом. кыпч. *сүрән* «хәрби кычкырык», кырг. *сүрөөн* «ярыш кычкырулары», чыгт., уйг. (Радлов IV: 597, 812, 816; Будагов I: 642) *сүрӓн, сүрүн* «сөрән салу; ике каршыдаш гаскәрнең җәң алдыннан кычкырышуы» ← **сөр-ү I** (Егоров 1964: 189).

**Сөрән** < *сүрән* тат. телендә дә, күрше вә кардәш телләрдә дә төрле яңа мәгънәләр алган. Диал. сүзлекләрдә *гәзиз сөрән* «сабантуй», *сөрәнгә йөрү* «кунак булып йөрү», *сөрән ае* «июнь» күрсәтелә, к. ш. ук мар. *сүрәм, шүрәм* «бәйрәм», «аерым бер рух атамасы» һ.б. Федотов II: 45.

**СӨРӘН II** диал. «страшный видом, дух, призрак» < алт. *сүрӓн*, хак. *сүрүн* һ.б. id. **сөр** сүзеннән. Шуннан (Тумашева 1992: 192) **сөрән** (ш. ук **соран**) «хамелеон».

**СӨРГЕ [сөргө],** (ЗДС: 580) **сөргөч** «струг и т.п. для очищения деловых стволов дерева от коры, шкур – от мездры» ~ башк. *һөргө,* ком. *сюргю*, каз. *сүргі,* кырг., алт., тув., һ.б. *сүргү* id ~ төр. *sürgü, sürek* «сөрелгән җирне тигезли торган тырма», «сылагыч», алт. *сүргү* «пуляны сөрүче заряд». К. ш. ук тоф. *сүргүш*, як. *үс, үүс* «сөрге». Бу вариантларның кайберләре рус сөйләшләренә дә кергән, к. Аникин: 513.

**СӨРГЕН [сөргөн]** «ссылка; массовое изгнание, угон» (к. мәкаль: *Сөрген белән алган мал кугын белән китә, ди*) ~ гом. кыпч., төр. *sürgün,* башк. *һөргөн* id. Күчмәчелек чорында бу сүз зур-зур малтерлек көтүләрен дә белдергән. Сүзнең *сөрек* ~ *сүрүк* һ.б. вариантлары да бар, к. ҚТДС: 303.

Дерив.: **сөргенче, сөргенләү** һ.б.

**СӨРГЕТ [сөргөт]** – название города Сургут. Төр. *sürgüt* «сөрелү, куылу» сүзенә караганда, татарча «сөрген урыны» мәгъ. булган.

**СӨРГӨБӘТ** диал. (Тумашева 1992: 192) «полярное сияние; дух огня» < **сөргөлбәт*, к. алт. (Алтай кеп-куучындар 1994: 293, 399) *сургулјын* «күкнең кызыл катында яшәүче кыз тәнре: салават күпере аның алтын сиптергегече. Шул сиптергечтән ул җиргә «тере суы» сибә». К. ш. ук **Сүрәбәт.**



**Сөргөбәт** Төньяк Себер халыклары белән аралашып яшәгән Себер татарларына таныш күренеш булган.

**СӨРЕК [сөрөк],** диал. (Тумашева 1992: 192, 196) **сөйрек, сүйрү, сүрек, сүрех** – название разных осетровых рыб (стерлядь, севрюга и т.п.), иске тат. **сюрик, сюриик, сюрюк** (Паллас язмалары, к. Линдберг, Герд: 63–65) ~ чув. *сĕврек*, рус. *севрюга*, рус. диал. *шеврига, шеврюга*, серб. *шеврлюга, шурег,* румын. *северинга*, венг. *serek*, калм. *сүрлик, чүгүрлүк* һ.б. Бу *сөйрек* < **сүйүрүк* «очлы» сүзе белән билгеләнгән балык Көнч. Европада борынборыннан сәүдә әйбере булган, күрәсең.

**СӨРЕМ [сөрөм]** «угар; запашок дыма; газ» > чув. *сĕрĕм*, удм. *сурым, сүрĕм*, мар. *шӗрем* id., башк. *һөрөм* «корым; сөрем» – Идел-Урал регионына хас сүзләрдән. *Сөр* «сасыган ит һ.б.ш.» белән бәйле, к. **Сөрсе-ү. Сөрем** сүзен **сөр I** мәгъ. куллану да очрый (*сөреме коелган*).

**СӨРЕНҖЕГӘН [сөрөнҗĕгән],** диал. (ТТДС I: 367) **серенҗегән** «одряхлевший» < *сөрен җуйган.* К. **Сөр II.**

**СӨРЛЕК-Ү (сөрлегү, сөрлекте)** «спотыкаться; споткнувшись, тащиться» < гом. кыпч. *сүрлүк-* (каз. *сүрлик-*, к.-калп. *сүрник-*, кырг. *сүрдүк-,* башк. *һөрлөк-* һ.б.) id., нуг., ком. *сурлик-* «кинәт шуышу, шуышма булу» һ.б. **сөр-ү I** сүзенең интенсивлык формасыннан (чаг. *ату – атлыгу, тоту – тотлыгу, язу – язлыгу*).

**СӨРМӘ** «мазь, крем, сурьмило», «сурьма (химический элемент)» < бор. кыпч., уйг., госм., чыгт. һ.б. *сүрмә,* башк. *һөрмә* id., (бу сүзнең мәгънәләре күп) тат. *сөр- (күзгә сөрү)* < гом. көнб. төрки *сүр-* «сөртү, ышкып буяу» фигыленнән. *Сөрмә* < *сүрмә* күп күрше телләргә кергән (мәс., рус. *сурьма* һ.б.). Чаг. ш. ук хак. *сүртке* «сөрмә». Радлов IV: 829; Будагов I: 645.

**СӨРСЕ-Ү [сөрсө-]** «провонять, иметь запашок; залеживаться; засидеться в девках», «покрываться копотью» (ЛТ I: 204) ~ башк. *һөрһө-* > морд. диал. *сүрсĕ-* id. < гом. төрки *сүр-сү-* «каклау, ыслау; төтендә тоту» ← гом. төрки (каз., уйг., кырг., үзб. һ.б.) *сүр-* «какланган ит; исләнгән тире» тамырыннан; бу тамырның фигыль коррелянты да булган булса кирәк, к. тув. *сүр-* «тире иеләү», ком. *сүр* «иеләнгән тире», каз. *сүрүк, сүрік* «йомшак кара сәхтиян» (Будагов I: 645; ҠТДС: 294–295), башк. *һөр ит* «какланган ит; сөрсегән ит» (БҺҺ II: 205). Чаг. ш. ук чув. *сăс [сŏс, сыс]* «сасыган ит», *шăршă* «сасы» (< **сŏрсŏ?*). К. **Сөрем (< сөр-ем).**

**СӨРТ-Ү,** диал. **сөрөт-ү** «вытирать, вытереть» ~ башк. *һөрт-* < гом. кыпч., гом. төрки *сүрт-,* бор. төрки *sürt-* ~ бор. монг. *sürč-* id. (Радлов IV: 825; Поппе 1938: 176; ДТС: 518) гом. төрки *сүр-* «сөрү» сүзенең йөкл. юн.

*Сөрт-* < *сүрт-* продуктив сүзьясагыч нигез: тат. **сөртен-ү** *(абыну)*, диал. **сөртенгеч** «сөлге», **сөртке** «шырпы сөрмәсе», **сөрткеч** һ.б.

**СӨРХӘНТӘЙ, сорхантай, хөрсәнтәй** «дурачок, всегда бессмысленно радостный» < фар. *хурсăндăи* «шаталак; сөрхәнтәй» ← *хурсăнд* «шат, көләч».

**СӨР-Ү I** «гнать; гонять; пахать землю; мазать», диал. «тереть; сметать колосья, плоды и т.п. с черенков (*барысы да бер чыбыктан сөрелгәннәр*) һ.б.» ~ башк. *һөр-,* чув. *сĕр,* мар. *шүр-* < гом. кыпч., гом. төрки *сүр-* (Радлов IV: 527, 810), бор. төрки *sür-* (ДТС: 517–518), як. *үүр-* id. < бор. төрки **сүүр-,* ихтимал, **сү-* «дошманны куу, сугышу» тамырыннан булса кирәк.

*Сөр-* < *сүр-* фигыле төрки телләрдә иң күп мәгънәле һәм иң продуктив сүзьясагыч нигезләрдән: тат. диал. **сөрү** < гом. кыпч. *сүрү* < бор. төрки (ДТС: 518) *sürüg* «көтү, табыр»; тат. **сөрген;** к. ш. ук **Сөрән, Сөрлек-ү, Сөрмә, Сөрт-ү** һ.б., к. Räsänen 1969: 437; Федотов II: 43–44. Иске әд. телдәге мәгънәләре, дериватлары тур. Будагов I: 643–645 (бик тәфсилле); ЭСТЯ VII: 365–368 (өч омоним *сүр-* дип карала).

**СӨР-Ү II** диал. «ловить рыбу бреднем» ~ чув. *сĕр-* (*сөр-*) ~ мар. *шүр-* < бор. гом. төрки **сӯр-* булса кирәк; ихтимал, **сөр-ү I** белән бердәйдер. Чаг. монг. *сӧрӧ-* «агымга каршы бару».

**СӨТ** «молоко» ~ башк. *һөт,* чув. *сĕт [сөт]* < гом. төрки *сүт*, бор. төрки (ДТС: 518) *süt*, төркм. *сүйт* ~ самод. *siüt* id. < бор. гом. төрки **süüt* ~ монг. *sün* < *süün* ← *sü* id. (*sǖ-n* берлек, *sǖ-t* күп. формасы), к. ш. ук маньч. *сун* «сөт» (< монг., к. ССТМЯ II: 126). Шулай итеп, *сөт* < *сүт* сүзенең бор. монг. алынмасы булуы ихтимал (моңа өстәмә дәлил: тат. сөтне **сөт агы** (**сөт-агы** парлы сүз?) дип әйтү бар. К. бор. төрки (ДТС: 48) *aqï* «байлык, муллык; нигъмәт». Икенче яктан, гом. төрки *сөт* < *сүт* төп форма булып, ул монг. телләрендә халык этимологиясе буенча гына *sü* тамырыннан дип тә аңлашыла алгандыр, к. ягн. *xšift* << авест. *xšvipta* «сөт» яисә бор. һинд. *svitna* «ак; сөт» ~ рус. *свет* «якты; ак нур», асылда «сөт төсендәге нәрсә (?)» һ.б. Як. *үүт* < *һүүт,* бур. *һүүн*, **һүүт* ~ башк. *һөт* < *һүт* id. уртак чыганактан киләләр (*с-* > *һ-* күчеше булган кавем теленнән). Радлов IV: 834; Räsänen 1969: 438; Федотов II: 46; ЭСТЯ VII: 346–348.

*Сөт* < *сүт* төрки телләрдә йөзләрчә дериват биргән нигезләрдән (к. Mandoky-Kongur: 250–254); **сөтләч, сөтлаш** сүзләренең параллельләре барча кыпч. телләрендә очрый һ.б. К. **Сөтлегән, Сөчек.**

Дерив.: **сөтле, сөтсез; сөтләч.**

**СӨТЛЕГӘН [сөтлөгән]** «молочай (растение)», «бодяк полевой» < гом. кыпч. *сүтлүген* (> башк. *һөтлөгән,* каз. *сүттиген*, нуг. *сүтликен,* кырг. *сүтмүгөн*), госм. *сүдлүгән, сүдлигән* id. < *сүтлү кана* «сөтле үләнчел үсемлек» (к. **Кана-у II**). ЭСТЯ VII: 347–348 (аңлатмасы бирелми).

**СӨХБӘТ** «разговор по душам; общий семейный совет родственников» < гар. *ṣухбäт* «дусларча сөйләшү; дуслык» ←*ṣхб* «дус булу» тамырыннан; шуннан ук ислам илләрендә киң таралган сүзләр – **сахиб** – төрле титуллар атамасы, «әфәнде, галиҗәнаб һ.б.ш.», **сахабә** – «Мөхәммәт пәйгамбәрне исән чагында күреп ислам динен кабул иткән кеше» һ.б. Будагов I: 684, 696. К. **Сүбәт.**

Дерив.: **сөхбәтле, сөхбәтсез;** башк. (БТДҺ: 282) *сөхпәтһеҙ* «килбәтсез, килешсез».

**СӨЧ** (Радлов IV: 592) «грех, проступок; косвенная вина; подозрение (при судебном разбирательстве)» < кр.-тат., аз., госм. һ.б. *суч, суҗ* (> нуг. *шүш*) id. < бор. төрки (ДТС: 512) *suč* «ялгышлык» < кыт. *цзуй цзы* id., шуннан бор. төрки парлы сүз *suj-jazuq* «гөнаһ, язык; гаепле эш», *tsuj-erinč-ajïγ qïlïnč* (өч синоним бергә, к. ДТС: 583) «гөнаһ кылмыш». Кытай суд системасы бор. төркиләргә үрнәк булган. Будагов I: 641; ССТМЯ II: 121; ЭСТЯ VII: 339.

Дерив.: **сөчле** «гаеп эштә шикләнелгән; гаепле; берникадәр хатасы булган».

**СӨЧЕК [сөчөк], сөчө** «слащавый», күч. *сөчек тел* «слащавая речь» ~ башк. *сөсө* id. < чыгт., госм. һ.б. *сүчүк*, бор. төрки (ДТС: 518) *süčük, süčik* «татлы; сөчек» ← *süči-* «татлы булу» ← *süt-si-* «сөт тәмен хәтерләтү, тәме сөткә охшау» (татлы ана сөте күзалланган булса кирәк), к. себ. (Тумашева 1992: 126) *сүцүк* «сут, сок». К. **Төче.** Будагов I: 641; Räsänen 1969: 434; ЭСТЯ VI: 345.

Дерив.: **сөчеклек,** башк. дериватлары тур. к. БТДҺ: 282.

**СӨЯК [сөйәк],** диал. (ТТДС I: 366, 388) **сеwек, сүәк,** себ. (Тумашева 1992: 192) **сөөк,** (Дмитриева 1981: 184) **сүөк** «кость, кострика; род» (к. әйтем: *Үз каным, үз сөягем*) < гом. кыпч. *сүйәк, сүйәк,* кар. *сүwäк,* чыгт., госм. *сөйүк* (хәз. төр. бу сүз кулланылмый) < бор. төрки (ДТС: 511) *söŋük* id. > чыгт. *сөңäк, сөңүк, сүңүк*, уйг. *сөнүк*, аз. *сөмүк*, төркм. *сүңк,* чув. *шăнă, шăмă,* башк. *һөйәк* «сөяк»; к. ш. ук алт., тув., хак. *сөөк,* як. *уӊуох, омуох* id. һ.б. ← **сөң-,* **сүң* «җилеген суыру». К. иске тат. кит. **сөңгәк** «сөяк», чаг. төр. *sömük* «сөяк», *sömür-* «җилек суыру». Тәүдәрәк *сөяк* < *söŋügek* дип җилекле сөякләрне генә атаганнар, күрәсең, чаг. бор. монг. *sime-* «җилек суыру», *čimügen* «бот сөяге». Будагов I: 650 (тәфсилле); Räsänen 1969: 437; (күп мисаллар китерә) Мухамедова 1973: 154; Федотов II: 443; ЭСТЯ VII: 357–359.

Тат. **аксөяк** сүзендә **сөяк** сүзенең «нәсел-ыру, зат» мәгъ. чагыла.

Дерив.: **сөякле, сөяксез; сөякләч.**

**СӨЯЛ [сөйәл], сөйән, сеwәл** «мозоль, бородавка» ~ башк. *һөйәл,* чув. (Сергеев 1968: 89) *шăклă, шăкльă, шĕкĕллĕ* «сөял», мар. *шыгыле* «бәкәл сөяле» > удм. диал. *шĕгĕла, шогыльо* «сөял» (Насибуллин: 149) < гом. кыпч. *сүйәл* (нуг. *шүйел*) < бор. төрки, уйг. *сөгäл* ~ монг. *сөгэл* id. К. ш. ук алт., кырг., хак., калм. *сөөл,* хак. *сүүл,* госм. *сийил*, урта төрки *sigil* һ.б. id. Бу сүзне Рясянен (Räsänen 1969: 429) фин. *syyla, sypla* «сөял» белән чагыштыра. Безнеңчә, *сөйәл* << *сөгäл* сүзен бор. төрки (ДТС: 499, 517) *sökel, sökäl* «авыру», *sügül* «сөял» сүзе белән бәйләргә кирәк. Бор. телләрдәге параллельләре тур. Clauson: 820; ЭСТЯ VII: 367–368, 321 (төркм. *сөкел,* аз. *сөкәл* «авыру» сүзен *сөял* белән чагыштырмый).

**СӨЯМ [сөйәм]** «пядь» < гом. кыпч. *сүйәм* (күп телләрдә онытылган), уйг. *сүйәм,* башк. *һөйәм* id. ~ кырг., алт., тув., монг. *сөөм* < бор. монг. *sögem, sögüm, sügem, sügüm* id., як. *сүөм* > эвенк. *суум, сээм, сэмэ* һ.б. Пекарский: 2398, ССТМЯ II: 125; Колесникова: 14–116. Кырг. *сөөм* имән бармакны белдерә һәм **сөям** берәмлеге шуннан килә дип уйларга мөмкин; икенче яктан, бур. *һөөм* < *сөөм* үкчәне, үкчә киңлеген белдерә. К. ш. ук як. *сөмүйә* «имән бармак».

Чув. *сĕвем* «шәлкем; бер метр чамасы җеп үлчәме» сүзе миш. **сеwәм* id. яңгырашыннан булса кирәк. Федотов II: 40 (чув. сүзен тат. теленнән алынма дими).

**СӨЯН [сөйән],** диал. (ДС I: 172) **сөйәм**, иске тат. (Троянский I: 586) **суим** «ободранная липа» > удм., мар. *суем, суём* id. ~ башк. *һөйән* id. ~ каз. (ҚТДС: 302) *сүйен* «шикмә» (рус. «тонкие перекладины под кровлю крыши»). Ачык түгел, фин-угор телләреннән булуы ихтимал.

**СӨЯ-Ү [сөйә-]** «прислонить; приставлять, упирать во что» ~ башк. *һөйә-ү* < гом. кыпч. *сүйә-* (кырг. *сүйө-*), уйг. *сүйә-* id. бор. **сүй* тамырыннан (*сүй-ә-*) булса кирәк, чаг. шор. *сөйгä, сөйбä (< сөймä)* «колга; байраклы колга» (Радлов IV: 566, 569); к. ш. ук як. *өйөө-* «сөяү», *өйөн-* «сөялү»; чув. диал. *сөрөн-, сүэн-, сөн-* «сөялү» (Т.Я. Чуркин материаллары).

*Сөйә-* нигезе белән **сөйкә-** < гом. кыпч. *сүйкә-* тамырдаш (*сөйәл-* һәм *сөйкәл-* паронимнар), ләкин бу тамырдашлык эзлекле рәвештә күренми; кырг. *сөйкө-* һәм *сүйкө-* «сөртү» мәгъ. ЭСТЯ VII: 316–318.

**СТАКАН** «стакан» < рус., рус теленә исә төрки телләрдән (бик ихтимал ки, бор. татарчадан), к. бор. рус. *дьстоканъ, дъстакан* ~ тат. диал. *дустакан, дустаган,* тат. әд. *тустаган* ← *тустак*. Сүзнең төрки чыгышы ачык булуына карамастан, рус этимологлары аны ним. яки бор. фар. теленнән һ.б. дип «исбатларга» маташалар. К. Фасмер IV: 856 (өстәмәләр һәм төзәтмәләр бүлекчәсендә). К. **Тустаган, Тустак.**

**СТАЯ [стайа]** диал. (Вәлиди I: 151) «сторона, направление» < чув. *çтайа* «кая»; к. ш. ук диал. (миш.) *кŏчта, кычта* «кайда?» < чув. *хăçта* id. Бу сүзләр чув.-миш. контактлары зонасында таралган.

**СУ,** диал. **сŏw** «вода; река, водоём» < гом. кыпч. *сyw [сyw-ы]*, башк. *һыw,* кырг. *суу*, уйг., угыз. *сув, суб,* тув. *суг,* хак. *сух*, кар. *суй*, алт. (Баскаков 1972: 247–248) *су, суу, суг, сүү, сүүк*, бор. төрки *sub* – иң бор. форманы тәнәйтү читен. Чаг. ш. ук бор. монг. *usu, usun* «су», *usu-* «агу» (*usuba usun* «тамды су», Поппе 1938: 368). Төрки-монг. *су ~ усу* тамырын кыт. *шуй,* (диал.) *суй* «су, елга» сүзе белән гомоген дип уйлыйлар. Чув. *шыв* «су» < болг. **сыw.* Як. *уу* < *һуу* ~ бур. *уһуу* ~ башк. *һыу* уртак чыганактан (бер өлеше төркиләшкән, бер өлеше монголлашкан тунгус халкы теленнән). Будагов I: 705–706; Федотов II: 465–466; ССТМЯ II: 329; Гарипова 1998: 106–107; ЭСТЯ VII: 325–327.

*Су-* төрки телләрдә иң продуктив нигезләрдән**:** **сула-у, сулык, сусыл**; к. **Сугар-у, Сусын, Сыек.**

Су, сулыклар – мифологиядә еш очрый торган объектлардан; **су анасы** һәм **су атасы**, **су иясе** образлары барча төрки халыкларда (бигрәк тә кыпчакларда) очрый; **сусылу** образы татар-башкортларда гына булса кирәк. Диал. **суwәсе** «су иясе», **сумийә** «су иясе» кебек вариантларда бор. фонетик яңгырашлар һәм күчешләр чагыла (к. ТТДС I: 374, 376).

**СУАЛ-У** (Тумашева 1992: 197–193) «ухудшаться (о зрении); уменьшаться (о молоке в вымени коровы), перестать доиться» ~ башк. *һыуал-,*чув. *сывал-, сывăл-,* каз. *суал-,* уйг., госм. *соғул-,* чыгт. (Радлов IV: 756) *суғал-, суғул-,* бор. төрки (ДТС: 509, 513; Боровков 1963: 276) *soqul-, soɣul-* id., ш. ук «җиргә сеңү; елга-күл кимәленең иң түбән дәрәҗәсенә җитүе» ← **соқ- ~ *суқ-* фигыленнән (мәгъ. төгәл генә билгеле түгел); к. ш. ук кырг., алт., хак., тув. *соол-,* як. *уол-* < *һуол-* «суалу». К. **Суалчан.** Федотов II: 74 (тат.-башк. сүзләрен белми).

Дерив.: **суалкы** ~ башк. *һыуалҡы* «сөте савылмый башлаган», диал. (ТТДС I: 373) **суwалка, суwалкы, суwалма** «язгы ташкыннан калган һәм җәен корып-кибеп бетә торган күлләвек». К. ш. ук **Салу.** ЭСТЯ VII: 278–279.

**СУАЛЧАН,** диал. (ТТДС I: 373) **сывал'чан, суwалҗен** «дождевой червь, червяк» > мар. *сöсан* < гом. кыпч. *суwалчан,* к. кар. *сывалцан,* нуг., каз., к.-калп. *суалшан*, кырг. *соолчан* < бор. төрки **soɣulčan* > төр. *soğulcan, solucan* id. бор. төрки *согул-* «җиргә кереп бетү» фигыленнән, к. **Суал-у.** Радлов IV: 531–532; Räsänen 1969: 425; Redhouse: 1026–1027; ЭСТЯ VII: 279–281 (бик күп фонетик вариантлар күрсәтелә). Чаг. **Селәү, Селәүчән.**

**СУАР, сувар** «название древнего города и, возможно, племени в древней Булгарии» – еш кына

бор. **сабир, сибир** һәм **субар** этнонимнары (һуннарга якын кабиләләр) белән баглыйлар, ләкин, безнеңчә, бу бәхәсле. **Суар** сүзе хәз. Татарстандагы **Шәмсуар, Нырсуар, Янцевар** авыл атамаларына керә (Юсупов 1971: 273). Velidi: 170–173, 404; Аникин: 493–494 (хаклы рәвештә *Сибир ~ Сабир ~ Субар* сүзләрен чагыштыруларга шик-шөбһә белдерә).

**Суар** сүзен **чуваш** этнонимы белән баглау да ышанычлы түгел.

**СУБАЙ I** «свая» < рус., ләкин *свая* сүзеннәнме, иске рус. *забой* «субай» сүзеннәнме? К. ш. ук чув., ком. *субай* id.

**СУБАЙ II,** диал. (ТТДС I: 373) **субагай** «молодая и стройная; сохранившая фигуру – о женщинах», иск. «бесплодный» ~ гом. кыпч., алт., хак. *субай*, тув. *сувай*, як. *субай, сыбай, субан, суман* < бор. монг. *subai* < **субаѓай* «кысыр» > калм. *субхай, сувха* «ике елның берендә буазлый торган терлек». К.Д. Номинханов (1975: 246) буенча, монг. *суба-* «ике елның берендә, ел аша пәйда булу» фигыленнән (түбендә кыт. сүзенә охшый), к. ш. ук ком., кырг. *субай* «озын; озынча; нәзек-озын», аз. *субай* «буйдак»; төр. *subay* «офицер» (?). Тат. *субаѓай* варианты иң бор. яңгырашны чагылдыра (ул, күрәсең, Алтын Урда монг. теленнән килә). Räsänen 1969: 431; ЭСТЯ VII: 324–325 (**субай** һәм **сыбай** сүзләрен бутый).

К.-балк. телендә *субай-* «сылулану, сылу булу» фигыле бар.

**СУГАН** «лук, луковица» > чув. *сухан*, удм. *сугон*, мар. *шоган,* башк. *һуѓан* < гом. чыгт. *соѓан* (к.-балк. *сохан*), чыгт. (Радлов IV: 513) *сойѓан,* бор. төрки *soγan, soγun,* СС *sorgan,* алт. *согоно,* алт. диал. (Радлов IV: 520) *сокына,* тув. *сонгуна, согуна,* бор. монг. *sonγina* id. Л.В. Дмитриева һ.б. фикеренчә (1979: 166–168), кыт. *tsung* «суган» сүзеннән. Рус. *согуна* «суган төре, татар суганы» тур. Аникин: 499 (бай әдәбият күрсәтелә). Федотов II: 69; Гаффарова 2007: 98; ЭСТЯ VII: 276–277.

Дерив.: **суганлы, сугансыз; суганча́** һ.б.

**СУГАНАСТЫ, суганасы** (ТТДС I: 374) «водяной, хозяин воды» – бу сүздә, **су** сүзенең бор. яңгырашы **суғ** сакланган, дип уйлау беркатлылык булыр иде: нишләп ул сакланыр икән? Өстәвенә *-т-* авазы да аңлатуга мохтаҗ. Безнеңчә, **суған-** өлеше бор. *су ханы ~ су қаны* тәгъбиреннән киләдер.

**СУГАР-У, суар-у** «орошать, оросить», «поить» ~ башк. *һыўѓар-* < гом. кыпч., бор. төрки *суѓар-,* (Боровков 1963: 276) *cywap-,* төр. *suvar-* id., ш. ук бор. төрки (ДТС: 515) *suvγar-* «(ат) эчерү» ← **су; -гар// -гәр** аффиксы бор. төрки (Боровков 1963: 239) *отѓар* «утлату» һәм **җилгәр-** (к.) сүзләрендә дә күренә.

Дерив.: **сугарыл-у, сугарт-у; сугарулы, сугарусыз.**

**СУГЫМ** «скот, назначенный на убой; забой скота» > мар., удм. *сугым, сугум* (Насибуллин: 137), чув. *сухӑм,* башк. *һуѓым* id. < гом. кыпч., алт., хак. *соѓым, соѓум,* чыгт. *соқум* id. ← *соқ-* < *соѓ-* «сугу, сую»; тат. **сугым** – эш, шөгыль, **сугымлык** – терлек. К. **Суй-у, Сук-у.** Рус *согум* «сугымлык ат» тур. Аникин: 499 (әдәбият).

Дерив.: **сугымлык.**

**СУГЫШ** «война; драка» > мар., удм. *согыш,* башк. *һуѓыш* < гом. кыпч. *соѓыш* (нуг., каз., к.-калп. *соѓыс*), алт., тув. *соѓуш,* бор. уйг. *soquş* ~ як. *oγus* id. әлбәттә, *суқ-* < *соқ-* фигыленнән, к. Räsänen 1969: 426.

**СУГЫШ-У** «драться; воевать» < гом. кыпч. *соѓыш-* (нуг., каз., к.-калп. *соѓыс-,* башк. *һуѓыш-*) ← *сук-* < *соқ-* «сугу» фигыленең урт. юнәлешеннән аерым, үзенчәлекле мәгънә алган.

**СУД [сут]** «суд» < рус. Тат. бу сүз күп кенә дериватлар һәм фразеологизмнар биргән.

**СУЕЛ [суйы̆л]** «дубина (утыканная гвоздями)» ~ башк. *һуйыл,* каз. *сойыл,* кырг. *сойул,* уйг. *сойла* id. ~ төр. (Будагов I: 715) *сойманты* «юан таяк». Чаг. себ. **сойыр, соир** ~ калм. *sör* «зур кадак, болт» (Ramstedt 1935: 335).

**СУЕР [суйы̆р]** «глухарь (птица)» ~ башк. *һуйыр* ~ монг. *сойр* > бур. *һойр* id.

**СУЗ-У,** себ. **сос-, сус-** «растягивать, тянуть (увеличивать в длину или долготу)» < гом. кыпч., төркм., уйг. һ.б. *соз-,* чыгт., уйг. диал. *сооз-,* уйг., үзб. *чоз-,* башк. *һуҙ-* id. Чаг. башк. *һуйҙай-,* тат. (к. Ф. Әмирхан I: 300) *сузай-у* «озын гәүдәле булып тору яки китү» ← **суйыз* < **сойуз* «сузылган буйлы, озын» – **сойуз-* «сузу, озынайту» фигыленең исем коррелянты; тамыры **сой* булырга тиеш, бор. төрки телләрдә *сӧз-* сүзе юк. ЭСТЯ VII: 282–283; Будагов I: 708.

**Суз-** < *соз-* продуктив сүзьясагыч нигез: юн. формаларыннан тыш, тат. диал. **сузан** «ябык озын буйлы» (ДС III: 141), **сузыл-у** «кул сузу», **сузым, сузынкы** һ.б., **сузык** (аваз) гар. *мәд* сүзеннән калька булса кирәк.

**СУЙЛАК** (ТТДС I: 374) «лентяй; лежебока» < (кырг.) *сойлаҡ* id. ← кырг., алт. *сойло-,* уйг., хак. *сойла-,* тув. *сой-* «корсакта шуышу». Чаг. маньч. (ССТМЯ II: 104) *cojō-* «боргалану; бөгәрләнү; суйлаклану».

**СУЙ-У** «резать (скот); обдирать кору (дерева)» ~ башк. *һуй-* < гом. төрки *сой-,* бор. төрки *soj-* id. < **coг-* > гом. төрки, бор. төрки *soq-* «сугу, чабу, сую, чәнчү» (к. Радлов IV: 519–522; ДТС: 507–508 һ.б.).

Терлекнең башына сугып яисә чәнчеп үтерү гадәте борын-борыннан килгән, шунлыктан «*сугу* > *сую*» мәгъ. күчеше бәхәс тудырмый. Шулай ук «*сую* > *тунау*» да аңлашыла. Әмма монда фонетик һәм морфологик үзгәрешләр барышы конкрет материал белән җитәрлек күзалланмый: бор. **coг-* фигыле сакланмаган. Шунысы кызыклы ки, бор. сүзлекләрдә *сой-* «сую»ның «тунау» мәгънәсе генә бирелә. Бу хәл исә бу *сой-* аерым бер тамыр түгелме икән дигән фикергә урын калдыра.

Һәрхәлдә, *суй-* «терлек бугазлау» < *coг-> сук-* «сугу» бәхәссез, к. гом. төрки (Радлов IV: 519) *соҡ-* «сугу, сую, чәнчү», хак. *сох-* «сугу; сую» һәм гом. төрки (Радлов IV: 513) *сой-* «сую, сугу» ~ монг. *сох, сохи-* «сугу» һ.б. Будагов I: 715; Räsänen 1969: 425; Федотов II: 70; ЭСТЯ VII: 283–285.

**СУК: сук бармак** «указательный палец» < гом. кыпч., чыгт. (Поппе 1938: 301) *suq barmaq* id.

**СУКА, сукабаш** «соха» ~ башк. *һука, һуҡабаш,* чув. *суха, сухапуҫ,* мар. *сога, шога, шога-вуй, шага, шагавуй* (Упымарий: 190; Иванов, Тужаров: 267; Саваткова: 193–194), морд. М. *сока*, морд. Э. *соки*, гом. кыпч., уйг. *соҡа,* кырг. *соҡо* ~ укр., Д. болг. *соха* «сука, чата», литв. *šaka* «ботак» сүзе белән чагыштырыла (Фасмер III: 729; Гамкрелидзе, Иванов 1984: 690); рус. *сохатый* «пошый, болан» сүзенең нигезе *соха* «тармаклы мөгез» дә шул ук *соха* белән бердәй дип уйланыла; к. ш. ук ягн. *шох, шоха* «зур мөгез; ботак, чат» > фар. *шäһ* id. Ихтимал ки, *сука* < *соҡа* < *шаха* үзе «пошый» мәгъ. булгандыр, шуннан **сука башы** – «пошый башы» – «сука төрәне» метафорик аталмадыр.

**Сука** сүзе төрки телләргә (кыпчакларга) IX–XI гг. кергән булса кирәк. Чыганагы бор. герм. телләре дә булырга мөмкин, к. гот. *hōha* < **soha* «сабан». Г. Громов (к. аныкы. Сельскохозяйственная техника и этнические традиции // СЭ, № 3, 1976: 98–113) буенча, Идел-Чулман халыклары *соха* һ.б. сүзен рус теленнән алган дип карау хата, чөнки бу сүз биредә иске чыганакларда б.э. I меңьеллыкта ук билгеле. К. ш. ук Räsänen 1969: 426 (*сука* сүзен рус теленнән дип күрсәтә). Фасмер III: 729 (бик күп әдәбият күрсәтелә); Федотов II: 68–69; Kluge: 786–787 (*сука* сүзен бор. герм. *suga, sok* «чучка, дуңгыз» белән чагыштыра).

**Сука** продуктив сүзьясагыч нигез: **сукала-у, сукачы** һ.б.

**СУКАЙ, сухай** «пологий спуск к реке; косой брод» (Г. Кашшаф) – чаг. рус. (бурлаклар телендә) *сухая (вода)* «Иделдәге сайлык, сай урыннар» (Даль); икенче яктан к. төр. *su kayısı* «сөзәк елга яры» ~ башк. (БТДҺ: 380) *һуйҡай* «уйсулык, иңкүлек», тат. (ЗДС: 584) **суйбак, суйкак** «сөзәк».

Ашказар елгасына коя торган **Сухайля** елгасы атамасы **сукайлы** сүзеннән булса кирәк.

**СУКАРДАК** (ДС II: 167; ТТДС I: 375) «вид дикой утки» – ачык түгел, ләкин *-дак* морфемасына беткән кош атамаларының берсе (чаг. **кашкалдак, үрдәк**). Чаг. каз. *сұксыр, соқсур,* кырг. *суксур* ~ рус. (Аникин: 477–478) *саксан, соксун* «киң томшыклы кыр үрдәге төре», рус. «пеганка» диелә.

**СУКБАЙ** «бродяга; бродячая собака» ← *сук, сок* «комсыз караш», «алдакчы, хәйләкәр» (Тумашева 1992: 193) + *бай* (татарларда эт кушаматларына компонент) сүзеннән (тәүдә иясез этне белдергән).

**СУКМАК** «тропа, тропинка» > чув., удм. *сукмак*, мар. *сокмак*, морд. М. *сухмак*, башк. *һуҡмаҡ* < гом. кыпч. *соҡмаҡ,* үзб. *сукмоқ,* каз., к.-калп. *соҡпаҡ,* уйг., кырг., төркм. *соҡма* һ.б. «сукмак» тәүдә тау битләвендәге уенты сукмакларны – кәҗә сукмагын белдергән, к. тув. *сыҡпаҡ* «тау битләвендәге сыр, уенты», *суктак* «елга ярындагы дулкыннар “суккан” уенты», як. *ахпа* < *сахпа* < *соҡмак* «чокыр; юлдагы сырлар һ.б.», алт. *согынты* «сугынты, тау битләвендәге сырлар һ.б.». Рус. диал. *сокма* «сукмак; бурлак сукмагы һ.б.» (Даль) – төрки телләрдән.

*Сукмак* < *сокмак сук-* < *сок-* «сугу» сүзеннән, чаг. рус., укр. *шлях* «юл» < ним. *schlag* «сугу». Уйг. *сохма* «балчык сугып эшләнгән дивар; сукмак».

Төр. *sokak, sukak* ~ гар. *zoqaq* һ.б. «урам, тыш» сүзенең *сукмак* < *сокмак* сүзенә бәйләнеше ачык түгел. К. **Сакма.** Räsänen 1969: 426; Федотов II: 56.

**СУКМАН** (ДС I: 166) «позумент с шёлком; лапти без обор», **сукма** (Тумашева 1992: 193) «золочёная тесьма» ~ төр. *soktan* «төрекмән чүәге», чыгт. (Будагов I: 710) *соқман* «сәхтиян оекбаш». Асылда, бу сүз *соқ-* «киеп алу» сүзеннән һәм хатын-кыз ыштанының балак очын бәйләү өчен тагылган ука киндерәсе һәм шуңа иш чүәкне бергә белдергән. Рус. *сукман* тур. Фасмер III: 798–799.

**СУКНО, сукна** «сукно» < рус. Рус. *сукно* сүзе исә гом. слав. сүзе, *сук-* тамырыннан, к. Фасмер III: 799.

**СУКРАН-У, сукыран-у** «ворчать, сокрушаться» ~ башк. *һуқран-, һуқыран-,* к.-балк. *соқуран-,* төр. *sokran-* һ.б. тат. (Тумашева 1992: 199) **сокра-у** ~ госм. (Радлов IV: 523) *сокра-* «туктаусыз сөйләнү» – асылда «чурылдап, шырылдап агу» < *сорқыра-у* id. сүзенең кайт. юнәлешеннән, к. каз. *шорқыра-,* кырг. *шоркура-* «чурылдап агып яту», *шорқур-а-* ~ *сорқур-а-* ← **сорқур* нигезеннән, **сорқ* тәкълиди сүзеннән, чаг. ш. ук **сыкра, сыкра-у.**

Дерив.: **сукраныш-у, сукрандыр-у.**

**СУКТА** (Хайрутдинова 1993: 105–106) «колбаса из фаршированного мяса с крупой» > чув. *сукта, сутта, сотта,* мар. *сокта* < гом. кыпч. *соқта* (СС *soxta*), бор. төрки (ДТС: 507, 509) *soqtu, soγut* «колбаса» ~ эвенк. *силукта, сулукта* «эчәк» (к. ССТМЯ II: 85). К. Менгеснең (к. Menges 1961: 111) бу сүзне гом. төрки *сок-* «сугу» сүзеннән дию ышандырып бетми. Федотов II: 57; ЭСТМЯ II: 85.

**СУК-У I (сукты, сугу)** «ударить, бить» < гом. төрки *соқ-,* башк. *һуқ-,* як. *ох-* id. һ.б. < бор. төрки (ДТС: 508) *soq-* «сугу; кискәләү, тапау» < **соғ-* > *сой-*, к. **Суй-у** (булса кирәк). **Киндер сук-у** дигәндә аркаулыкны кылыч белән *сугып* тыгызлау күз алдында тотылган. Будагов I: 710–711; ЭСТЯ VII: 286–292.

Дерив.: **сугыл-у, сугыш-у, суктыр-у; сугылма** һ.б. К. **Сугым, Сугыш, Сукмак.**

**СУК-У II** (аерым тәгъбирләрдә генә саклана) «надевать, вдевать; втыкать, воткнуть; внести, вносить; входить» (*йөгән сугу, ай шәүләсе – яктысы сугу*, к. ТТДС II: 270; *рәсемгә сугу* «фотога төшерү», к. ТТДС II: 274; гом. тат. **санга сугу** «исәпкә кертү» һ.б.) < бор. төрки (ДТС: 508) *soq-* «сугу, кертү; кадау, кадату». Ихтимал, **сук-у I** белән баглыдыр. К. **Сукман, Сүкмән.** ЭСТЯ VII: 292–296 (тат. сүзе китерелми).

**СУКЫР** «слепой» > чув. *суккăр,* удм. диал. *сокър,* мар. *сокыр,* морд. М. *сокор* id. < гом. кыпч. *сокыр, сокур,* башк. *һуқыр* «сукыр», чыгт. (Будагов II: 404) *соқур* «корыган елга, кое һ.б.ш.; көчен җуйган ат», бор. монг. (Поппе 1938: 324) *soqar* «сукыр», алт. *соқар, соғыр,* үзб. диал. *суқир* «сыңар күзле»; бор. төрки (ДТС: 508) *soqar* «мүкләк; пеләш», як. *соххор* «сукыр; тукыманың сул ягы» ~ монг. *соххор* < *сохгор* «сукыр» ← *сох* «так, җитешсез, сыңар», к. ш. ук алт. диал. *соқлун-* «сукыр булу», монг. *сохло-* «сукырайту», *соххатга-* «бер күзен чыгару», эвенк. (< монг.) *сокор-* «сукыр», *сокото* «сукыр, кылый», эвен. *чоқан-* «бер күзне йомып, ук, мылтык төзәү» һ.б. (тунг. телләрендә киң таралган тамыр, к. ССТМЯ II: 404). Räsänen 1969: 426 (Рясянен *сок* тамырын фин. *sokea* «сукыр» сүзе белән чагыштыра). К. ш. ук Федотов II: 55–56; Аникин: 213 (рус. диал. *зокор* «сукыр йомран» тур. әдәбият китерелә); ЭСТЯ VII: 297–298.

*Сукыр* < *соқур* сүзе кайбер ир., Кавказ һ.б. телләргә дә таралган, ләкин угыз телләрендә үз түгел.

Мар. *сокыр кольа*, удм. *сокър шыр* id. (Насибуллин: 137) тат. **сукыр тычкан** сүзеннән калькалар. Төр. *sokur* «сукыр тычкан» кыпч. телләреннән алынма булса кирәк.

Дерив.: **сукырлык; сукырай-, сукырлан-у; сукырларча.**

**СУЛ** «левый» < гом. төрки *сол,* төркм. *соол,* башк. *һул* (як. юк) id.; тат. диал. **суң** «сул» *уң* сүзенә аналогия-охшату буларак килеп чыккан булса кирәк, әмма иң бор. вариантны (**соң*) чагылдыруы да ихтимал (ул чагында *сул* < *сол* < **соң-ул*). Гар. *шул* «сулагай» төрки телләрдән булса кирәк. Сөйләм телендә *сул* дивиатив сүзьясагыч нигез, к. диал. (ДС III: 141; ТТДС I: 376) **султый, султык, сулахман** «сулагай». К. **Сулакай.** Радлов IV: 548; Будагов I: 712–713; Левитская 1970: 267; Мухамедова 1973: 152; ЭСТЯ VII: 299–302.

**СУЛАГАЙ, сулакай** «левша» > чув. *сулахай*, мар. *солагай, шолагай, шалагай* < гом. кыпч., төркм. *солақай*, к.-балк., хак., кырг., алт. *солағай*, чыгт., госм. *солақ,* башк. *һулағай* < бор. монг. *soluγai* «сул; ялгыш» > эвенк. *салагай* «сул» (ССТМЯ II: 57), к. ш. ук хәз. монг. *солгой, солгай*, бур. *һалгай*

«сул кул; сулагай». К. **Сул.** К. ш. ук Егоров 1964: 193; Федотов II: 58.

**СУЛАК, сулау** (ЗДС: 585) «уключина, дужка, скоба» ← бор. төрки *sola-* «чылбырлау, чылбырга бәйләү, йозаклау» ← кыт. *so* «йозак» (к. ДТС: 506, 508), к. **Солак, Сулык.** ЭСТЯ VII: 302–303.

**СУЛАМЫК** «увлажнённый (о земле, участке)» ← *сула-у* «сулы итү» һәм чир-авыру, начар нәрсә атамаларын ясагыч **-мык (< -мук)** аффиксы ярдәмендә ясалган. Чаг. **Боламык, Карамык, Кызамык.**

**СУЛА-У** «дышать, дышать с шумом» ~ чув. *сывла-, сүле-* > мар. *шүлэ-* < чыгт. *сола-* < бор. **соғла-* id. **соғ* ~ калм. *suү* «тирән сулыш (авазы)» сүзеннән, тәкълиди тамырдан.

Диал. **сулы-у** (*сулу кабыну* һ.б.), башк. *һулы-* < гом. кыпч., алт. *солы-,* госм. *солу-* «сулау» вариантының (шуннан **сулыш**) ясалышы ачык түгел; чаг. ш. ук алт. диал. *соол-* «авыр сулау» (Радлов IV: 549). Räsänen 1969: 426; Федотов II: 74–75; ЭСТЯ VII: 303–304.

**СУЛКЫЛДА-У** «вздрагивать при рыданиях, всхлипывать» ← ***сулкыл** тәкълиди нигезеннән, к. тәкълиди **сулык-сулык (сулқ-сулқ) итү** «сулкылдау» – гом. кыпч. **сол* тәкълиди тамырының *-қ* детерминантына беткән тармагыннан, к. каз. *солқ* «калтырау, дерелдәүгә тәкълит», *солқылда-,* кырг. *солқулда-,* башк. *һулқылда-* «сулкылдау, чәпчү» һ.б., к. Радлов IV: 554 (һәм арытабан), к. ш. ук тат. сөйл. **сулқы-у** (К. Тинчурин) «бер тапкыр калтырап алу», башк. (БТДҺ: 381) *һулқылдақ* «пружина, силә».

**Сулк < солк** тамырының **сулау** сүзенә катнашы булырга мөмкин.

**СУЛПЫ, сулпык** «деформированный; увечный (о теле человека, о человеке)» ~ башк. (БТДҺ: 381) *һулпы, һулпық* «рахитның өченче стадиясе» диелә – чаг. ш. ук *султық* (**сукыр-султық** парлы сүзендә) «гарип»; кыпч. телләрендә төгәл параллельләре юк шикелле, ләкин к. монг. *сулбагар* «зәгыйфь», *сулбай-* «зәгыйфьләнү», *сулда-* «артык зәгыйфь булу» ← *сула* (тунг.-маньч. *соло, сула*) ~ бур., башк. *һула* «бик зәгыйфь; рахитик, рахит» – барысы да (монг.) *сул* «буш, бушак, зәгыйфь» тамырыннан (к. ССТМЯ II: 107–108); арытабангы бәйланышлары ачык түгел. Як. *солбоңуй-* «хәлдән таю» монг. телләреннән. **Сул-у** яки **сүлпән** сүзләренең контаминацион тәэсире бар булса кирәк.

Дерив.: **сулпай-у (→ сулпайт-у), сулпайыш** «деформация».

**СУЛТЫЙ** «неумеха; левша» к. түбәндәгене.

**СУЛТЫК** (**сукыр-султык, сулагай-султык** парлы сүзләрендә) «парализованный» ~ каз. *солтақ* «чатан-чулак; параличланган» ← *солта-,* к. кырг. *солдо-, солдой-* «карышып, тартышып кату; параличлану». К. **Сулпы.**

**СУЛ-У,** диал. **сулы-у** «блекнуть, вянуть» < гом. кыпч. *солы-,* кырг. *солу-*, башк. *һулы-,* кыпч. диалектларында һәм уйг., алт. *сол-* госм. *солу-*, тув. **соол-* (*соолдур-* «үләнне кайнатып сулдыру» сүзенең нигезе) < бор. төрки *soүul-* (к. **суал-у)** ← ниндидер **со-* тамырыннан булса кирәк. *Solu-* нигезе бигрәк тә төр. телендә кулланышлы: *solgun, soluk* «сулган, төсен җуйган», *soldurmak* «сулдыру» һ.б. Як. *уол-* «кибеп бетү». ЭСТЯ VII: 298–299; Аникин: 421 (рус. < як. *олба, олбут* «иске үзән, иске елга юлы» – кипкән күл тур.).

Бу сүзләр семантик җәһәттән дә, бүтән җәһәтләрдән дә *сулы-у* ~ **сула-у** (к.) сүзе белән охшаш. Әмма логик эзлеклелек белән конкрет бәйланышларны билгеләү кыен.

**СУЛЫК I** «водоём» ← **су** (к.); бу сүз күп телләрдә очрый һәм төрле мәгъ. кулланыла; к. диал. (ТТДС II: 276) **сыулық** «водосточная труба» һ.б.ш. Рус. *сулак* «арык, канау» (< төрки) тур. Аникин: 508.

**СУЛЫК II** (Тумашева 1992: 194) «псалия, железная часть удила» < гом. кыпч. *сулық, сулуқ,* төр. *suluk zıncırı* id., каз. (ҚТДС: 297) *сулык* «чиләк кылавы», хак. *суглух* «йөгән» (*суглух сух-* «сулык сугу, йөгән кидерү», кырг., алт. *суулуқ* «йөгән, сулык» ← тат. диал. *суқ-* < *соғ-* «йөгән һ.б. кидерү» сүзеннән (Будагов I: 714), к. төр. *sok-* «кидерү, шудыру һ.б.», ком., к.-балк. *соқ-* «скрипкада уйнау» һ.б. – гом. төрки *суқ-* < *соқ-* сүзенең төрле мәгънәләреннән булса кирәк. Чаг. ш. ук **Солак.** ЭСТЯ VII: 334–335.

**СУЛЫК III,** диал. (ТТДС II: 272) **суллык** «карниз; доска или лестничное устройство, поддерживающее толстую соломенную крышу по краям», «полоса, которая разделяет узоры (термин вышивки)» ~

кырг. *солык, солук* «рам», *соло-* «рамлау». Чаг. ком. *солғу* «кыршау, чәмбәр». Чаг. **Сулак, Сулык I.**

**СУЛЫК-У I (сулыгу, сулыкты)** «всхлипывать; тяжело дышать (с одышкой)» ~ башк. *һулыҡ-* id. – **сулы-у, сула-у** фигыленең интенсивлык формасыннан. К. ш. ук тат. диал. (Akb: 71), төр. *solık* – авыр сулау авазы, кырг. *солуқ* «тыналыш», *солуқ-* «тын алу».

**СУЛЫК-У II** «сильно вянуть» ~ башк. *һулыҡ-* – **сул-у** фигыленең интенсивлык формасы.

**СУЛЫМ** (Остроумов 1972: 115; Balint 1988: 143) «заснеженный (о дороге)» < чув. *сулӑм, сулӑмлӑ* «авыр (кышкы юл)» ← *сул-* «салу»; чаг. тат. *кар салган юл*.

**СУЛЫШ** «дыхание» ~ башк. *һыулыш,* чув. *сывлӑш* «һава, сулау, тын» ← тат. диал. *сулы-*, башк. *һыулы-, һулы-* һ.б. «сулау», к. **Сула-у.**

**СУМ I** «рубль», диал. (Тумашева 1992: 191) «форма (для литья)», «брус», (Гиганов) «дебелый» < гом. кыпч. *сом* «сум, бөтен, бөтен кисәк, кәбәрә», алт., хак., тув. *сом* «форма; килбәт; мәҗүси тәңре гәүдәләнеше буларак тупас кына кеше рәвешендә юнылган агач кисәге» (к. Радлов IV: 562 һ.б. чыганаклар), кырг., үзб. *сом* «килешле-килбәтле, таза (егет)», каз. *сом* «авыр, точ», башк. *һум* «сум» һ.б. **Сум**ның акча мәгънәсе бор. «тоташ кисәк (алтын яки көмеш), вакланмаган» сүзеннән, **сум** элек зур акча булган: «сом – ике колаклы көмеш коелмасы, ул 20 динарга тиң» (Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде: 88). К. ш. ук диал. (Тумашева 1992: 194) һ.б. *сумла-у* ~ тув. *сомна-,* кырг. *сомдо-,* як. *умна-* «тупас формага китерү», госм. *сомун* «түгәрәк ипи, каравай; түгәрәк металл кисәге» (Радлов IV: 565), бор. төрки *son, sun* «каре, терсәк озынлыгы» < кыт. *цунь* ≈ 3 см; *sun altïn* (ДТС: 514) ≈ төр. һ.б. *som altın* «тоташ кисәк алтын; сум алтын». Бу мәгълүматлардан чыгып фикерләгәндә, *сум* < *сом* – кыт. теленнән шикелле, әмма к. фар.-таҗ. *сумб, сунб* «тояк, түгәрәк» (әйтмәкче, төрки *туйақ* «тояк» сүзенең акча берәмлеге мәгъ. дә булган), к. ш. ук **Савым.** Шулай итеп. *сум* < *сом* сүзе берничә сүзнең контаминациясеннән гыйбарәт булса кирәк. К. **Суматан.** Федотов II: 61; ЭСТЯ VII: 304.

**СУМ II: сум ит** «ляжка; сплошной однородный кусок мяса» – **сум I** белән бәйле шикелле, ләкин к. **Сом.** ЭСТЯ VII: 304–305.

**СУМ III** (Тумашева 1992: 194) «руль; корма» ~ эвенк. һ.б. тунг. *сомна, сумна* «чалка очы, көймәне ярга беркетү арканы» (ССТМЯ II: 125).

**СУМАЛА**, диал. **сымала, ысмала,** (ТТДС I: 375–376) **сулама** «смола, смоль» ~ чув. *сӑмала*, бор. кыпч. (СС һ.б.) *samla, samala* id. рус. теленнән бор. алынма. Федотов II: 23–24.

**СУМАТАН, суматам** (Тумашева 1992: 194) «грубо обделанный, неотёсанный» < каз. *сомда-м* ← *сомда-* «тупас форма бирү», к. **Сум I.**

**СУМГА** (Гиганов; Тумашева 1992: 194) «пустырь; жилище в пустыре; хижина, келья» < гар. *ҫаwмӓʻа* «монастырь» (Будагов I: 713).

**СУМГЫЛ** диал. «наряды; нарядный» ~ башк. *һомғол* «нәзакәтле, зифа буйлы» ~ себ. (Будагов I: 649) *сум* «фигура, сын», чаг. кырг. *шумбул (тон)* «Кытай чиновнигының форма киеме».

**СУМИЯ [сумийә]** (ЗДС: 986) «злой дух рек и озёр» < гар. *сумӓййӓ, сумийӓ* «мандрагора, агулы үсемлек». **Су иясе** түгел.

**СУМСА** «ливерный пирог», башк. диал. (БҺҺ II: 200, 217 һ.б.) *самбуса, сәмбүлсә,* гомумән, тат., башк. телләрендә бу сүзнең фонетик вариантлары бик күп (к. Хайрутдинова 1993: 28) ~ үзб. *самбуса, сомса* < фар. *сӓмоса* < *сӓңбӯсӓ* «сумса, очпочмак» (*сӓң* < *си-ӓң* «өчле», *бӯсӓ* «почмак, кырый»); к. ш. ук каз., кырг., госм. > рус. *самса* «сумса». Тат. **өчпочмак** (к.) сүзе, ихтимал, фар. сүзеннән калькадыр.

**СУН,** себ. (Старчевский) **суун** «самка оленя, лося» < алт. *суун* «марал», бор. төрки (ДТС: 503) *sïγun* «иркәк марал» ~ монг. *соғо* «сун»; к. ш. ук госм., бор. чыгт. һ.б. ядкәрләрдә *сыгын*, госм., уйг. *сугун* «болан, марал һ.б.ш.», к. Räsänen 1969: 415. Рясяненнан соң бу сүз тур. күпләр язганнар. ҚТДСта (: 299) *суын* «иң яхшы ат» дип бирелү – хата. Рус. *сыгын* тур. Аникин: 516.

**СУНА: сигез суна** (М. Гафури), диал. (миш., перм.) **сына, суна** «вид дикой водоплавающей птицы; гагара; вид уток» < гом. кыпч., чыгт., угыз. *сона,* башк. *һуна,* кырг. *соно* id., ш. ук «кигәвен», каз. диал. *сона* «сырга» (ҚТДС: 295), үзб., төркм. *сона,* төр. *suna, süne* «матур ана үрдәк», үзб. *сона*

«кигәвен», чулым. *сууна,* чыгт. *сунақ,* монг. *сона, соно* «эре (яшел башлы) кигәвен, чикерткә» (к. Räsänen 1969: 415). Төп мәгъ., безнеңчә (уйг.) *сона, суна, зона* «фирүзә (матур яшел таш һәм шуның төсе)». Шуннан *сигез суна* «муенында сигез яшел тап булган кош – гагара», шуннан *сигез* сүзе төшерелеп **суна** «су кошы, үрдәк» килеп чыккан. ЭСТЯ VII: 306–307 (*соно, сонор* «үрдәк төре» һәм *сона, сунак* «кигәвен» аерым матдәләр).

**СУНАР** «охота (по пороше)» ~ башк. *һунар* > чув. *сунар,* удм. *сунэр* id., мар. *сонар* «киек» < гом. кыпч. *сонар*, як., кырг. *сонор* «кырпак кар; көзге яңа яуган кар» ← монг. *сонин,* як. *сонун* «яңа, яңа нәрсә» ~ себ. (Тумашева 1992: 191) **сōōны** «яңа (кеше); чит, ят». К. ш. ук ССТМЯ II: 111; ЭСТЯ VII: 307–308.

**СУНЫК-У** диал. (Будагов; Радлов; Тумашева 1992: 194) «грустить». Ачык түгел. Чаг. төр. *sonuk* «буявы уңган» ← *son-* «буявы уңу».

**СУПА, соп** диал., иск. «широкая печь во дворе» ~ үзб. *сопа* id., кырг. *супа* «бакчадагы, ишегалдындагы балчык сәке», төр. *soba, supa* «мич, кан».

**СУР** «рог, труба, горн» < гар. *ҫӯр* id.

**СУРАЙ-У, сурык-у (сурыгу, сурыкты)** «вытягиваться, вытянуться, расти (при одновременном похудании), стоять торчком» ~ кырг. *сорой-* «тырпаю», *сорогой* «арык һәм озын буйлы» < монг. *сорогай* id. ← *сору, шоро* «шеш, колга, кыздыру өчен чыбык». К. ш. ук к.-балк. *сурахай* «жираф». Räsänen 1969: 468.

**СУРАХ** (Н. Воробьёв) «состав для выведения волос» < фар. *сӯрāх̧* id.

**СУРӘТ [сүрәт]** «рисунок, изображение, образ», «карикатура» > башк. *һүрәт,* чув., мар. һ.б. *сүрет, сүрäт* id. < гар. *сӯрат* id. ← *cwp* «рәсемләү» тамырыннан, шуннан ук к. **Тасвир**. Әд. телдә беренче иҗектә *у* язылу гарәпчә язылыштан килә. Федотов II: 71.

Дерив.: **сурәтле, сурәтсез; сурәтлә-ү.**

**СУРГЫЧ, сŏргŏч** «сургуч, состав красного цвета для печати» ~ төр. *сургуч* «шәлкем, кәкел, чук» < *сургуч* < *савургуч* ~ *саравыч* ди Будагов (I: 624, 707). К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 514) *surqač, surquč* «пычак һ.б.ш. сабын эшкәртү өчен лак, сумала». Фасмер III: 806 (тат. сүзе үзе русчадан димәкче). Räsänen 1969: 433 (рус сүзе татарчадан ди).

Дерив.: **сургычла-у; сургычлы.**

**СУСАК** «ведро для очистки колодца», «рыболовное устройство в виде ведра с длиной рукояткой» ~ төркм., чыгт., госм. һ.б. *сусақ* > рус. *сусак* id. (Дмитриева 1981: 544). Чаг. (Тумашева 1992: 192, 242) **суцакла-у, цуцакла-у** «сай суда йөрү» – күрәсең «сусак белән балык тоту» мәгънәсеннән.

**СУСАР** «куница» ~ чув. *сăсар,* башк. *һуҫар, һыуһар* < гом. кыпч. *сусар*, кырг., к.-балк. *суусар,* алт. *сузар, суузар*, куман. (Радлов IV: 239) *саусар,* госм. *саңсар, сансар, самсар* ~ монг. *саусар, суусар, субсар* ~ фар. *сусмар* id. Кайбер телләрдә төлкене, каманы, бурсыкны һ.б.ш. белдерергә мөмкин. Чыгышы ачык түгел. Räsänen 1969: 393; ЭСТЯ VII: 192–193.

**СУСЫН I** «то, что подаётся жаждущему; напиток», күч. «вино» < гом. кыпч. *сусун, суусун*, кар. *сувсун*, тув. *сухсун,* башк. *һыуһын* < монг. *усусун* «сулар, һәртөрле су» (*-сун* «гомуми күп. кушымчасы»).

**СУСЫН II** «вид подати в Казанском государстве». Тат. ярлыкларындагы **сусун, сүсүн, шусын** «сый; рәсми кунакларны сыйлау өчен салым» бор. монг. *siasun, šigasun, šigüsün* «гаскәри азык-төлек, (гаскәри азык өчен) сарыклар» сүзеннән (к. Vásáry. Susun und süsün // AO, Budapest, XXXI, 1. 1977: 51–60); ЭСТЯ VII: 328–330. К. ш. ук **Сөйсөн.**

**СУТ** «сок» ~ башк. *һут* id. < монг. *усу-т* «сулар» сүзеннән. К. **Суткак.**

**СУТКАК,** диал. (Тумашева 1992: 194) **супқақ** «очень влажный; болотистый» – монг. *усут* «сулар» сүзе белән бәйле. К. **Сут.**

**СУТУН, сүтун, сутүн** иск., кит. «колонна»; «колонка в газете» ~ төр. һ.б. төрки әд. *sütun* id. < фар. *сутӯн* id. Элек киң кулланылган сүз.

**СУТУНКА, сатунгә, сутунга** (Тумашева 1992: 186, 195; ЗДС: 586) «толстое бревно» диелә, дөресрәге рус. *затонка* «суда озак яткан бүрәнә, бигрәк

тә имән» – андый бүрәнәләр черемәүчән, алардан ясалган агач материалы матур төстә була (русча *мореный дуб* та диелә).

**СУТЫЙ** «одна сотая гектара (мера земли)» < рус., әлбәттә. Идел-Урал регионы телләрендә шушы яңгырашта киң таралган.

**СУУН** «марал» к. **Сун.**

**СУФИ** «аскет, мистик, суфий», күч. «святоша» < гар. *çӯфӣ* id. ←*çwф* «йон» сүзеннән диләр (суфилар йон **хирка –** плащ киеп йөргәннәр). Ләкин госм. төр. *sofu, sofi* «суфи, мистик» грек. *çoφια, çoφoς* «акылдар» сүзеннән дип тә аңлатыла (Радлов IV: 560). Будагов I: 709; Тимергалин: 424.

Дерив.: **суфилык, суфичылык; суфилан-у.** Чаг. **Сыпы.**

**СУФРА, сөфрә** (ГТРС) «скатерть, стол» < гар. *сүфра* id. (Будагов I: 629). Бу сүз төрки телләрдә киң таралган, к. **Сыбра,** төркм. (ТДГДС: 159) *супра, супро, суфра ~ сурфа* «эскәтер», төр. *sufra, sofra* id.

**СУХТА** (Г. Тукай) «семинарист, ученик медресе; религиозный фанатик, не считающийся с условиями современности» < кр.-тат. *сохта,* төр. *softa, suhta* > нуг., каз. һ.б. *соқта, суқта* id., уйг. *сухта* «энтузиаст». Төбендә фар. *сӯх̣тӓ* «көйгән, янган; ялкынлы мәхәббәте булган» сүзеннән. Социаль җәһәттән *сухта* «дәрәҗәле руханиларның хезмәтчесе һәм шул руханиларга бирелгән хәер-садакадан өлеш алып яшәүче» (шуннан к.-калп. *соқта* «кәрт уенында – валет»). Сухталардан көлгәннәр. Диал. (ЗДС: 585) **сукта** «иренең өченче ир туганы» сүзе дә **сухта** белән бердәй булса кирәк.

**СУЫК** «холод; холодный» ~ башк. *һыуыҡ* id., к. **Суы-у.**

**СУЫН,** себ. (Тумашева: 191) **сōōны** «чужак, из чужого племени; пришелец» ~ башк. *һыуын,* к. ш. ук себ. *суын* ~ башк. *һыуын* «бер ыру исеме». Чаг. монг *suunit* ~ кыпч. *suunlar* – бер кыпчак ыругы, к. Velidi: 252. Каз. (ҚТДС: 299) **суын** «бик яхшы ат», «суын аты» микән?

**СУЫР** «сурок; байбак» ~ чув. *сăвăр,* башк. *һыуыр* < гом. кыпч. *суыр, суур,* уйг. *сувур,* уйг., үзб. һ.б. *суғур* «суыр, йомран» ~ бор. төрки *soɣur* «куян»? (DLT I: 494; ДТС: 507). Рус. *сурок* сүзенең нигезе дә төркичәдән. Räsänen 1969: 393; Федотов II: 20–21; Фасмер III: 808.

**СУЫР-У I** «втягивать в себя; вытащить, выдергивать (гвоздь)» < гом. кыпч. *суыр-, суур-*, тув. *сывыр-* < чыгт. *суғур-*, төркм. *суғыр-,* башк. *һыуыр-* id. Кайбер төрки телләрдә (төр., кырг. һ.б.) *сор-* (тат. диал. *сур-*) яңгырашында очрый, к. ш. ук яз. монг. *sor-, soro-* > бур. *һоро-* «суыру». ЭСТЯ VII: 281–282.

Дерив.: **суырыл-у** («ябыгу» мәгъ. дә очрый); **суыргыч.**

**СУЫР-У II** «провеивать» (чаще в форме понудительного наклонения **суырт-**) ~ чув. *сăвăр-,* башк. *һыуыр-* < гом. кыпч. *суыр-,* к.-балк. *суур-,* кар., кр.-тат., төр., гаг. һ.б. *саwур-, савур-* ~ бор. төрки (ДТС: 493; Поппе 1938: 213) *sawur-* > үзб. *совур-* «суыртү, иләү, җилгәрү», алт., хак. *собыр-* id., каз. (ҚТДС: 288) *сауыр* «өермә», (Аманжолов: 407) *сӧбыру* «тегермәндә тарттыру» ~ монг. *сабир-* «җилгәрү» һ.б. Räsänen 1969: 39; Федотов II: 21; ЭСТЯ VII: 275–276.

**СУЫТ** диал. (Тумашева 1992: 195), **сувут** (Будагов I: 713) «осока; злак» – ихтимал, дөресе – *сүwĕт,* к. төр. *söğüt* «тал; тал яфрагы; тар гына хәнҗәр», кр.-тат., уйг. диал. *сөгүт, сүгүт* > төркм., чыгт. *сөвүт* «тал» һ.б., к. ЭСТЯ VII: 313–314 (тат. сүзе китерелми).

**СУЫ-У, соуы-у,** себ. (Тумашева 1992: 193) **суа-у** «охладеть, остыть» – шуннан к. **суын-у**, **суык** «холод» һ.б. – < бор. төрки (ДТС: 507) *soyu-, soyï-* «суу», *soyun-* «суыну», *soyut-* «суыту», *soyïq, soyuq* «суык» һ.б. Бу сүзләрнең параллельләре барча төрки телләрдә бар: кырг., алт., тув. *соо-, соон-, соок,* чув. *сивĕ-, сивĕн-, сивĕт-, сивĕ,* башк. *һыуы-, һыуын-, һыуыт-*id. id., як. *уох* «суык», үзб. *совуқ,* чыгт. *саwуқ* (Боровков 1963: 257) «суык» (шуннан **суыклык; суыгай-у, суыклан-у** һ.б.ш. кебекләр) **со* тамырыннан. Чув. *сивĕ* < **сыйвы* < **соwуғ* < **соғуғ.* **Суы-** < *соғ-ы-* сүзен *су* сүзе белән баглау нигезсез. Будагов I: 714; Федотов II: 47–48; ЭСТЯ VII: 272–273.

**СҮБӘТ, сүбет** (ДС III: 146; ТТДС I: 388; ТТДС II: 280–281 һ.б.) «пир по случаю рождения ребёнка», себ. «совет перед свадьбой» < гар. *çухбäт* «сөхбәт, сөйләшеп утыру».

**СҮВЕРҮ [сүwĕрү]** себ. (ТХИ: Дастаннар 1984: 31) «гора Сумеру – мифический центр мира» – һинд телләреннән бөтен дөньяга киң таралган сүз, к. МНМ I: 311–312; Сагалаев: 64–66.

**СҮГӘН** (Тумашева 1992: 195) «морда (рыболовная снасть), поставленная на быстрине» ~ башк. (БТДҺ: 382, 392) *һүгән, һеүән, сеүән,* алт., хак. *сүген, сүгӓн* id. ~ бор. төрки (Боровков 1963: 273) *сүкӓн* «кәрзин». Рус. диал. *суган, цуган, уоган, шуган* < шор., чулым. *сүген* «сүген» тур. Аникин: 509 (тат.-башк. сүзләрен искә алмаган). Чаг. **Сөкә.**

**СҮЗ** «слово» < гом. төрки *сӧз* (> алт., хак. *сӧс*, себ. тат. **сӧс > сүс,** башк. *һүҙ,* як. *ӧс*) «сүз, сөйләм» < бор. **сӧр* «сөйләшү, гәп; әкият, мәзәк һ.б.ш.» (к. уйг. диал. *сӧрчек*, төркм. *сүрчек* «әкият» > алт., төркм. *чӧрчӧк* id.), к. ш. ук чыгт. *sӧz* «рөхсәт; вәгъдә; хәлне аңлату» (Поппе 1938: 373; чаг. тат. **сүз бирү**). К. **Сөйлә-ү**. Будагов I: 645–646; ЭСТЯ VII: 315–316.

Дерив.: **сүзле, сүзсез; сүзлә-ү;** себ. **сүсмәкер** «сүзчән» һ.б.

**СҮК** «овсяная каша; крупа овсяная, запарная» (к. Будагов I: 647); «молокообразная жидкость, изготовленная из семян конопли» (ТТДС: 337) < чыгт., бор. төрки *сӧк* «кибәктән арчылган тары» ~ монг. *сӧг* «тары; борай ярмасы һ.б.ш.» < кыт., кор. *sok* id. (Räsänen 1969: 429). К. ш. ук ҚТДС: 296 (*сӧк, сүк*нең төрләре тур.), уйг., кырг. *сӧк* «кыздырылган тары ярмасы» һ.б. К. **Сүкәмәч.** ЭСТЯ VII: 319.

**СҮКӘМӘЧ** «густая каша, которую берут на дорогу (её можно резать и есть руками)» > удм. *сукомеч* id. < *сүк әнәчә* (к. **Әнәчә**); бу сүз **-мәч** аффиксына беткән ашамлык атамалары калыбына кертелгән.

**СҮКЕ, сукы** «гробница; могила святых» (Тумашева 1992: 195; Радлов; Будагов һ.б.) < бор. төрки (ДТС: 510) *sӧki* «элекке, борынгы (изгеләр тур.)».

**СҮКЛҮН, сүлүн, сөлән** иск. «фазан» < чыгт. *сӧклүн*, бор. төрки (ДТС: 511) *süglin, süglün, sӱvlin* >> СС *sӧvlun* >> к.-калп. *сүвлүн* id. К. ш. ук чыгт., төркм. *сүлгүн,* төркм. *сүүлүн, сүйлүн* һ.б. бор. поэзиядә көн символы булган бу кош атамасы – түбендә бик күңелсез нигездән, к. бор. (Боровков 1963: 278–279) *сүкли-, сүклү-* «кыздыру, куыру» ~ чыгт. (Радлов IV: 799) *сүкүлӓ-,* бор. уйг. *sӧgla-* id. Ләкин бу фигыль нигезенең тамыры *сүкү ~ сӧг* ни белдергәнлеге ачык түгел.

**СҮКМӘН, сүгмән** (Будагов I: 648; Тумашева 1961: 193; Тумашева 1992: 195) «чекмень; армяк из верблюжьего сукна; сермяга» ~ мар., удм. *сукман*, чув. *сӑхман* «тула; зыбын», морд. М. *сумань* «зыбын», рус. *сукман* «сукна кафтан яки сарафан», бор. рус. *сукманъ* «тула», Д. болг. *сукман* «җиңсез йон күлмәк» слав. сүзе дип тә исәпләнелә (к. Фасмер III: 798–799), ләкин А.Е. Аникин (2000: 510) бу сүзне төрки алынма булырга тиеш дип карый. Шул ук вакытта ул рус сүзе чув. *сӑкман, сӑхман* сүзеннән дигән фаразга һәм *чикмән* белән тамырдаш дигәнгә дә хаклы рәвештә каршы.

*Сүкмән*, ихтимал, бор. төрки (ДТС: 510) *sӧktӓn* «каһарманнарга бирелә торган атама» сүзе белән тамырдаштыр: ул «батырлар киеме, броня» дигәннән була ала – төркиләрдә калын йон тукыма яисә сырган саклагыч киемнәр традициядә булган. Чаг. ш. ук төр. *sokman* «биек итек төре».

**Сүкмән** һәм **чикмән** сүзләре аваздаш һәм мәгънәдәш булсалар да, тамырдаш яки кардәш түгелләр, чөнки болар арасындагы аваз аермалары аваз күчешләре закончалыкларына хилаф. Гомумән *сүкмән* (тат. диал. *сукман*) табышмаклы сүз булып кала.

**СҮК-Ү (сүгү, сүкте)** «ругать, бранить» < гом. төрки, бор. төрки *sӧk-* id. (к. Радлов IV: 571; ДТС: 510), төр. *sӧv-* ~ башк. *һүк-,* бор. монг. *sӧge-* id. Төрки телләрдә (к.-балк., уйг., бор. төрки, төр., алт., тув. һ.б.) тагын *sӧk-* «сүтү, җимерү, вату» фигыле очрый, безнеңчә, бу фигыль шул ук *сүк- < сӧк-* «сүгү» белән бәйле, чаг. тат. диал. **сүт-ү** «сүгү; тиргәү», к. **Сүт-ү**. Боларның уртак тамыры (тув.) *сӧ-* «сүгү; кырку; сүтү», к. ш. ук чыгт. *сӧг-* «сүгү» ~ монг. *сөө-, сөгө-, сөхө-* «сүгү; хырылдау». ЭСТЯ VII: 314.

Тат. диал. (ДС I: 174) **сүкелә-ү** «сүгү» < *сүккелә-ү*, к. диал. (гәй.) **сүкке** «сүгеш» (ТТДС I: 309).

**СҮЛ** «сукровица»; (Радлов IV: 830) «гной» < гом. кыпч. *сӧл,* башк. *һүл* id. ~ монг. *сӧл* «сүл; күзге яшь үлән». Калганы ачык түгел. Чаг. шор. (Радлов IV: 1111) *шүлү* «агач суты». ЭСТЯ VII: 321–322.

**СҮЛПӘН** «вялый, вяло» ~ башк. *һүлпән* > мар. кч. *сүлпӓм* ← **сүлпә, *сүлпе*, к. госм. *сүлпүк* «сүлпән», *сүлпү-* «йомшару, сәлперәю», чув. *сулкке* «ахмак», шор. *шүл-* «зәгыйфьләнү», к.-балк. *сӧл* «зәгыйфь, сүлпән» һ.б. тәкълиди тамырдан (*сүл-п*). Чаг. **Салпы** һ.б. Радлов IV: 833, 834.

**СҮН-Ү** «затухать, потухнуть», диал. (ДС II: 172) «замедляться; уснуть; умереть» < гом. төрки *сөн-, сүн-,* башк. *һүн-* ~ бор. монг. *söne-* «сүнү», *sönü-* «сүндерү», төркм. *сөөн-* «сүндерү», госм., бор. төрки *söjün-* «юкка чыгу», к. ш. ук венг. *szün-* «сүндерү», эвенк. *сии-* «сүндерү». Räsänen 1969: 511; Федотов II: 70–71; ЭСТЯ VII: 322.

Дерив.: **сүндер-ү; сүнек** (бу сүзнең омонимы **сүнек-ү** венг. теленә кергән: *súnik-* «сүнегү»).

**СҮРӘ I** диал. «стержень; зацепной палец» < бор. төрки (ДТС: 519) *süwrä* «очлы (таяк)». К. **Сөйре, Сүрек.**

**СҮРӘ II** «сура, одна из 114 глав Корана» < гар. *сӯра* id., төп. мәгъ. «баскыч» ← *cwp* «менү, күтәрелү».

**СҮРӘБӘТ** «дух вроде лешего» (ТТДС I: 377, 388), **сүwәрмәт** «неумеха» ~ башк. (БТДҺ: 383) *һүрәпәт* «шапшак» – **сөргөбәт** (к.) сүзе белән контаминация булырга тиеш, к. (Зимасов: 83) **сөрхүәт** «нәләт төшкән». Мәҗүси мифологиядән.

**СҮРӘГӘ** «севрюга, стерлядь», диал. (ДС II: 172) **сүрек** «чөгә» ~ чув. *сĕврек* id. (*сĕврекке* «шүре»), уйг. диал. *сүрүк* «чөгә» (Радлов IV: 816). К. **Сөйрә, Сүрә I, Сүрек**.

**СҮРӘКӘ** (ТТДС: 390) «женский головной убор (у кряшен) – угловатый (с двумя рогами) чехол поверх платка» – ихтимал, рус. *соро́ка* id. сүзеннәндер; к. ш. ук мар. *шүр,* удм. *сүр,* морд. *сюра, сюро* «мөгез».

**СҮРӘН** «недостаточно горячий; без энтузиазма» ~ башк. *һүрән, һүрәнке* id. > мар. *сӱрäн* «тачка, пешеп җитмәгән» ← **сүр-ү** фигыленнән, ясалышы ачык түгел; чаг. тат. *сүренке* ~ чув. *сӳрĕнкĕ, сүренкĕ* «сүрән», *сӳрĕк* «сүлпән».

**СҮРЕК I** «стерлядь» ← *сүр-* < *сүвĕр-* «очлы булу» сүзеннән, к. себ. (Дмитриева 1981: 184) *сүрәт-* «очлы итү» ~ бор. төрки (ДТС: 519) *süvrit-* id. К. **Сөйре, Сүрәгә.**

**СҮРЕК II** «стержень» ~ төр. *sürgü* id., ш. ук «болт, винт» ← *sür-* «сөрү; ишерү». Чаг. **Сүрә I.**

**СҮРЕЛ-Ү** «остыть, охладеть (төрле мәгъ.)» ~ чув. *сӳрел-* id., ш. ук «айну», мар. *шӧрĕл-* «сүрелү», ш. ук «сүтелү». *Сүр-* ~ *шӧр-* (к. **Сүр-ү**) фигыленең төш. юнәлешеннән (аерымрак мәгънә алган). Федотов II: 71–72.

**СҮРҮ [сүрĕw]** (Троянский I: 573) «наволочка» ~ чув. (Ашмарин XI: 227) *сүрү* «астар, эчлек». Ачык түгел. Радловтагы (IV: 816) *сүр-, сөр-* «мендәргә сүрү кидерү» фигыленең реальлеге шик уята.

**СҮР-Ү** «отговорить; охладить, умерить (пламя печи)» ~ чув. *сүр-, сĕвĕр-* «сүрү, сүрән итү», мар. *шӧр-* «сүтү; (винтны) кирегә бору; сүрү» (к. Иванов, Тужаров: 283; Саваткова: 216) – моннан башк. *һүр-* «сүрү» һәм «толымны һ.б. сүтү» бер үк сүзнең төрле мәгъ. икәнлеге күренә, чаг. ш. ук удм. *сӧр-* «вату, бозу, яраксыз итү һ.б.» ← төрки *сӧр-* < **сӧ-гүр-* id. Бу сүзне як. *сӧрӯн* ~ монг. *сөрүүн,* бор. монг. *särigün* «салкынча» сүзе белән бәйләү (Егоров 1964: 199), безнеңчә, ышандырып бетми. **Сүр- < *сүвĕр-** Идел-Урал (Идел-Чулман) региональ сүзе, бүтән төрки телләрдә күренми. Мәгәр к. бор. төрки (ДТС: 498) *sevrä-, sevrit-* «бетерү, җую; сүрү; сирү»? К. **Сүрән, Сүрел-ү.**

**СҮС** «волокна, кудель, прядь», диал. (ТТДС I: 390) «кострика» ~ чув. *сүс* id. К. **Сүсән.**

**СҮСӘН** «метлица, овсяница», «тимофеевка», (ЗДС: 589) «осока; полевица белая», (Будагов I: 646) «митлага» ~ чув. *сӳсен* id., төр. *süsen, susan* ~ лат. *susam* «кыяклы лилия; көнҗет; кылыч уты». Будагов буенча, фар. *сӯсэнь* id. сүзеннән, ләкин к. уйг. *сәүсән* «зәңгәр чәчәкле лилия». Федотов II: 72 (*сүс* сүзе белән чагыштыра).

**СҮТ-Ү** «распарывать, пороть», «расплетать, развивать» (Троянский I: 566) ~ чув. *сүт-*, *сĕвĕт-*, мар. *шүт-* < гом. кыпч. *сӧт-* id. Киңрәк таралган *сӧк-* «сүтү» сүзе белән тамырдаш. Ихтимал, *сүр-* сүзе дә шулар белән тамырдаштыр һәм аларның уртак тамыры *сӧ-*дер (*сӧ-р-, сӧ-т-* һәм *сӧ-к-*). Чаг. монг. *сүйтгэ-* «юк итү». ЭСТЯ VII: 319–320.

Дерив.: **сүтел-ү, сүтеш-ү, сүттер-ү; сүтек;** диал. **сүтек-ү.**

**СЫБАЙ** диал. «конный, всадник», себ. (Тумашева 1992: 197, 254) **сыпайы, ысбайы** «ыспай, тәрбияле, килешле» ~ башк. *һыбай, һыбайлы* «атка атланып; атлы», кырг., төркм. *сыпайы* «әдәпле, хәялы; гаскәри; атлы гаскәри» < фар. *сипаһи* id.

<< авест. *späda, spädha* «атлы гаскәри; асылзат»; к. ш. ук үзб. *sipah, sipahi* «солдат; тыйнак; ыспай», төр. *sipahi* «гаскәри; госманлы дәүләтендә аерым төр гаскәри (атлы казак, үз аты һәм коралы белән армиягә килүче)»; чаг. семантик аналог; фр. *cavalier* «атлы гаскәри; кавалер». Абаев I: 479; TS: 1206; Будагов I: 53. К. **Ыспай.**

**Сыбай** сүзенең **субай, субагай** (к.) сүзенә катнашы юк.

**СЫБРА** «кожаная скатерть», **сыпра** (Тумашева 1992: 196–197) «кожаный ток для молотьбы» ~ нуг. *сыпыра* «тәбәнәк өстәл», к.-калп. *сыпыра* «тире куна», үзб. *супра,* каз. *сыпыра* (ҚТДС: 307) «тире җилпуч, он иләгәндә, кул тегермәне тартканда аска салынган тире», уйг. *супура* «суфра; сыпра» һ.б. < гар. *сүфра* «тире ашъяулык», к. **Суфра.** Чаг. ш. ук тат. диал. **сыпыра** «тигез».

**СЫБЫЗГЫ,** диал. **сымызгы, чыбызгы** һ.б. «свисток; свистулька; свирель» < гом. кыпч. *сыбызғы,* үзб. *сивизга, сивизға,* алт. *сыбыскы,* бор. төрки (ДТС: 502; Räsänen 1969: 414) *sïbïzγu* id. (гомумән, вариантлары күп) < *сыwызгы* < **сығызгы* < **сығырғы,* к. алт., хак. *сығыртқы, сықыртқы* «сыбызгы» (к. Радлов IV: 609, 610, 618), к. ш. ук кырг. *сыбызгы-* ~ як. *сыбыргаа-* «чыбыркы селтәгәндә сызгыру авазы чыгару», тув. *сығырға* «шәүлегән». Сүзнең тамыры *ссы, ссыф* – сызгыру авазына тәкълит, шуннан *ссы-гыр-//ссыф-гыр-* фигыле ясалган, шул фигыльдән *сыwғырғы* > *сыбызғы* исеме (*-ғы* исем ясагыч аффикс) һәм *сыwғырғы-* > *сыбызғы-* фигыле (*-ғы-, -га-* фигыль ясагыч аффикс) ясалган. К. **Сыгыр-у, Сызгыр-у.** ЭСТЯ VII: 379–382.

**СЫГЫЛ-У** «сжиматься, быть сжимаемым и упругим; прогибаться, гнуться, но после снятия нагрузки выпрямляться» ~ башк. *һығыл-* id. – **сык-у** (к.) сүзе нигезендә тат. телендә барлыкка килгән сүз.

Дерив.: **сыгылдыр-у; сыгылмалы.**

**СЫГЫН-У** «прибегать к защите; уповать на кого», (ДС I: 167) «забыться; замкнуться в себе» < чыгт., уйг., төр. һ.б. *сығын-* «сыю, сыену», бор. төрки (ДТС: 502) *sïγïn-* «ярдәм эстәү» ← *сығ-* «сыю; сыгу». К. Будагов I: 700. К. **Сый-у, Сык-у.**

**СЫГЫР-У** (Тумашева 1992: 198), сөйл. ш. ук. **сыйғыр-у, шыйғыр-у** «свистеть» ~ чув. *шăхăр-* id. < гом. кыпч., алт., төркм., аз., тув. һ.б. *сығыр-* < *ыссы-ғыр-* id. *ысс, ыссы* – сызгыруга тәкълит сүзенә бик билгеле *-гыр* кушымчасы ялганып ясалган фигыль, к. ш. ук каз. *ысқыр-* «сызгыру», нуг., тув. *сығы* «сызгырык» һ.б. Чаг. ш. ук **Сыбызгы, Сызгыр-у, Сыерчык.** Бу сүзләрнең уртак тәкълиди тамырыннан бер очракта гади сызгыру мәгъ., икенче очракларда «кызгандыргыч» мәгъ. сүзләр ясалган. ЭСТЯ VII: 383–387 (бик күп төрле материал китерелә).

**СЫГЫТ** «плач (на похоронах, на поминках), жанр плача – элегия» < гом. кыпч., алт., хак., бор. төрки (Радлов IV: 619; ДТС: 266) *sïγït* id., к. ш. ук тув. *сыгыт* «кайның (тамак төбеннән көйләүнең) бер төре» ← *сығы* «сызгырык» сүзенең монг. күп. формасы яисә бор. **сығы-* «елау, сыктау» фигыленнән билгеле *-т* кушымчасы ярдәмендә ясалган исем. Рус. *сыгыт* (< тув.) тур. Аникин: 516. К. **Сыгыр-у, Сыкта-у, Ыгы-зыгы.** ЭСТЯ VII: 390–391.

**СЫДЫР-У, сызыр-у** «сдирать, сделать сдирающий удар кнутом, плетью» < гом. кыпч. *сыдыр-,* башк. *һыҙыр-* < бор. төрки (ДТС: 502) *sïδïr-, sïdïr-* «сыдыру; кырку, йолку»; як. *сырдыр-* «сыдыру» сүзенә караганда, **сыдыр-у** < *сырдыр-у* бор. **сыр-* «суелдырып сөртү» фигыленең йөкл. юн., чаг. госм. *ысыр-* «тешләп алу, сыдыру, чыю». Чув. *сăтăр-* «сыдыру» тур. Федотов II: 34; Räsänen 1969: 414 (монг., маньч. телләреннән бигүк ачык булмаган параллельләр күрсәтә). ЭСТЯ VII: 391–392. Чаг. ш. ук **Шыер-у.**

Дерив.: **сыдырыл-у, сыдырыш-у, сыдырт-у; сыдырткы, сыдырткыч** (зур щётка).

**СЫЕК [сы̆йы̆к],** диал. **шыйык** «жидкий; слишком гибкий; слабый (о человеке)» < гом. кыпч., алт., уйг. *суйуқ* ~ тув. *сууқ,* хак. *суух,* төр. *sıvık,* башк. (БТДҺ: 397) *шыйық, һыйық* ~ чув. *шĕвĕ* «сыек, сусыл» < бор. төрки (ДТС: 516) *suvuq* «сыек, шыек» ← **suvu* «су кебек булу» фигыленнән, к. шуннан ук төр. *sıvı-* ~ чув. *шĕв-, шу-* «сыеклану, сыегаю», бор. төрки *sıvış-* id. һ.б. Бур. *шииг* «сыек» төрки телләрдән. К. **Су.** Федотов II: 456 (әдәбият күрсәтелә); ЭСТЯ VII: 332–333 (*суйу-* «сыегаю» матдәсендә).

Дерив.: **сыеклы, сыексыз; сыеклык; сыегай-у, сыеклан-у, сыекла-у; сыекча́.** К. **Шыек.**

**СЫЕН-У [сы̆йы̆н-]** «искать и находить прибежище, защиту и т.п.» ~ башк. *һыйын-,* кр.-тат. *сыйын-* id. – **сый-у** (к.) фигыленең кайт. юн. Асылда

(ясалышы буенча гына түгел, ихтимал, тарихи филиация буларак та) **сыгын-у** (к.) сүзе белән бердәй.

Дерив.: **сыеныш-у, сыендыр-у.**

**СЫЕР [сы̆йы̆р]** < гом. кыпч. *сыйыр,* башк. *һыйыр* < чыгт., госм. *сығыр,* уйг., үзб. *сигиръ* id. < бор. төрки (ДТС: 502) *sïyïr* «сыер; үгез (!)» ~ төркм. (ТДГДС: 165) *сығыр* «эш үгезе», к. ш. ук кар., каз. диал. *сыыр* «сыер». Бик бәхәсле сүз: кайберәүләре аны каз. *суын*, себ. (брб.) **суун** ~ төркм. *сугун* < бор. төрки (ДТС: 503) *sïγun* «иркәк марал» һ.б. белән (бу сүз тур. бай әдәбият бар, к. Аникин: 516) чагыштыралар, икенчеләр *сау-* < *сағ-* «саву» нигезеннән диләр (Räsänen 1969: 414; Мусаев 1984: 26). **Сыер** сүзе кайбер төрки телләрдә сирәк очрый, бу мәгъ. **инәк** (к.) сүзенең параллельләре кулланыла. Аз. диал. (АДДЛ: 363) *сығыр* «урманда яшәүче ерткыч хайван» – сәер сүз, ихтимал, *сыер* < *сыгыр* белән тамырдаш түгелдер. ЭСТЯ VII: 383–384.

**СЫЕРЧЫК [сы̆йы̆рчы̆к]**, диал. (ДС II: 232 һ.б.) **чыйырчық, шыйырчық** «скворец» < иске тат. (Будагов I: 700) *сығырчық, сығырчақ* < бор. төрки (ДТС: 502) *sïyïrčïq, sïyïrčuq* > башк. *сыйырчық, шыйырсық* ~ төр. *sıgırcık*, хак. *сығыржҗақ* ~ үзб. *чуғурчиқ,* госм. *чоғуржуқ* id. ← **сыгыр-у** (к.) сүзеннән. **Сыерчык** сүзенә охшаш сүзләр күрше телләрдә дә еш очрый: чув. *шӑнкарч, шӑнкарчӑк* (Сергеев 1971: 151–152 – бу сүзнең унлап вариантын китерә) «сыерчык», мар. *шыңгыртыш, шыңгырчык, шырчык*, удм. *сырчик, шырчик* «сыерчык» ~ коми. *сырчик* «сиртмәкойрык» һ.б. Рясянен (Räsänen 1969: 415) бу сүздә төрле-төрле тамыр контаминациясен күрә. Соколов 1967: 189–190; КЭСК: 269; Федотов II: 445; ЭСТЯ VII: 387–390.

**СЫЗ,** диал. (Тумашева 1992: 198) **сыс** «ноющая боль; мозжение» ~ алт. *сыс,* госм. *сызы,* кр.-тат. *сизи* id. Шуннан тат., гом. кыпч. *сызла-у* > башк. *һыҙла-у* һ.б. (Радлов IV: 660, 663). К. **Сызла-у.** Чаг. монг. *сир* «сызлау (күренеше)», тув. *сыртыла-* «сызлау», монг. (Номинханов 1975: 171) *шарх, шарха* «җәрәхәт, яра». Чаг. **Сыз-у I**.

**СЫЗА, сызак** «буерак» < төр. һ.б. *сызак* id. ← *сыз-* «сарку» (к. **Сыз-у I**); ягъни *сыз-ак* «төбеннән су саркып торучан кул, озын чокыр»; к. ш. ук каз., кырг. *сыз* «суткак, дымлы җир». Гарипова 1998: 108.

**СЫЗГАН-У,** диал. (ДС I: 167) **сыган-** «засучивать (рукава, подол)» ~ башк. *һыҙған-,* алт. *сыскаң-, сыскың-, сыскын-,* хак. *сыхсан-, сыхсар-* id. ← *сыхса-* < *сысха-* (метатеза) «ялангачлау» < **сызға-* ~ тув. *сырға-* id., к. ш. ук чув. *шӑнкарт-* < *шӑркант-* «сызгану», каз. *сырый-* «ялангач йөрү», тат. диал., каз. *сырға-* «лайлалы шома булу», алт. диал. (Будагов I: 698; Баскаков 1972: 249) *сырканчык, сырзанчак* «чалбар балагы (сызганыла торган өлеше)», бор. төрки (ДТС: 506) *sïtγa-* «сызгандыру, сызгану» һ.б. Бүтән кыпч. телләрендә *сызган-у* сүзе юк шикелле.

*Сыган-* варианты бор. төрки (ДТС: 502) *sïγan-* (каз. *сыбан-*) вариантыннан килә, бу фигыль исә (госм. һ.б.) *сыга-* «ялангачлау, сыйпау, шомарту» (к. Радлов IV: 615) фигыленең кайт. юн. Гомумән, *сызған-* < *сырған-* > *сыҙған-* > **сыйған-* > *сыған-* һ.б. К. Räsänen 1969: 414. Бу сүзләрнең тамыры **сыр* «ялангач, киеме, кабыгы суелган», чаг. **Шыр.**

**СЫЗГЫР-У,** диал. **сырғыр-** «свистеть» < гом. кыпч. *сызғыр-* (каз., к.-калп., кырг. ш. ук *сызыр-*), башк. *һыҙғыр-,* үзб. *чизғир-,* чулым. *сыкыр, сыққыр-* һ.б. (к. Радлов IV: 610–619) id. Бик гади генә *ыссыр-ғыр-, сыр-ғыр-* рәвешендә *ысс, сысс* ымлыгынан яңадан-яңа, репродуктив рәвештә ясала, к. каз. *ысқыр-*, чыгт. һ.б. *сығыр-* > чув. *шӑхӑр-* «сызгару» < *ссы-ғыр-*. К. ш. ук **Сыбызгы, Сыгыр-у.** Федотов II: 451–452; ЭСТЯ VII: 383–387.

**Сызгыр-у** продуктив сүзьясагыч нигез, шуннан **сызгырак** «бүрекле чыпчык», **сызгырык** «бер сызгыру», **сызгырткыч** һ.б.

**СЫЗЛА-У** «ныть, остро болеть» > удм. *сызла-,* мар. диал. *сызла-, сӗслӓ-* (*сӗслӓн-* «сызлану», к. Исанбаев 1978: 18) id. < гом. кыпч. *сызла-* (башк. *һыҙла-,* каз., к.-калп., кырг. *сызда-*) id. ← *сыз,* к. **Сыз I**. Федотов II: 33–34 (тәфсилле); ЭСТЯ VII: 393–394.

**СЫЗЛЫК** диал. (Тумашева 1992: 196; Будагов I: 716) «конопатка (орудие для конопачения)». Ачык түгел.

**СЫЗМА** «широкорядный (об агрокультурах)» – **сыз-у II** сүзеннән булса кирәк.

**СЫЗ-У I** «гореть, таять с шипением; ныть, болеть; издавать протяжный, тональный звук (о скрипке)» < гом. кыпч. *сыз-,* башк. *һыҙ-* id. ~ чув. *шӑр- (шӑран-)* «кыздырыла торган май эрү; көйрәү, сызу һ.б.». Бу сүздә асылда ике тамыр булырга да мөмкин, к. урта төрки *сыз-* «эрү (май

тур.)», төр. *sız-* «сарку, үтеп керү; сөзү; сөзелү; чөмерү; исерү», алт., хак., тув. *сыс-* «сарку» һ.б., к. Räsänen 1969: 420; ЭСТЯ VII: 394.

**Сыз-** продуктив сүзьясагыч нигез, к. себ. **сыс-гыр-** < бор. төрки *sïzγïr-,* (ДТС: 506) *sïzγur-* «май эретү» > госм. *сызыр-* һ.б. тат. әд. **сыздыр-у** «скрип-када уйнау; музыкаль инструментта шәп уйнау», **сызгыч** «кәман, җәя». К. ш. ук **Сыз, Сыза, Сызыл.**

**СЫЗ-У II** «чертить; чиркнуть», күч. «убегать» < гом. кыпч. *сыз-* ~ башк. *һыҙ-,* уйг., үзб. *чиз-,* госм., бор. төрки (Радлов IV: 663, 667; Радлов III: 2148; Räsänen 1969: 420; ДТС: 147, 151) *čiz-* id. Чаг. чув. *çыр-, çӗр-* «сызу; сөрү». Бу фигыльнең исем коррелянты – тат. диал., к.-балк. *сыз* «сызылган нәрсә, сызык, чый, язу» (к.-балк. *сызла-* «сызу»). ЭСТЯ VII: 392–393.

*Сыз-* нигезе бор. төрки *чыз-* < **чырг-* сүзеннән килеп чыкса*,* ул сүз **чый** (к.) белән тамырдаш булуы ихтимал.

**Сыз-** бик продуктив сүзьясагыч нигез: **сызгы, сызгыч, сызма, сызык, сызым** һ.б.

**СЫЗЫК I** «черта, линия» ← **сыз-у II**.

**СЫЗЫК II** «шкварки» ~ башк. (БТДҺ: 383) *һыҙҙыҡ,* кырг. *сызыҡ,* хак. *сызых* id. ← **сыз-у I.** К. **Сызыл.**

**СЫЗЫЛ** «шкварки; отруби» > чув. *сăсăл*, мар. *шушыл, шышыл* id. < **сыз-гыл* id. ← **сыз-у I.** Федотов II: 33 (сүзнең этимологиясен фин-угор телләреннән эзли, тат. сүзен белми).

**СЫЙ** «угощение», диал. «почёт; уважение» > чув. *сăй*, *сий*, удм., мар. *сий*, башк. *һый* id. < гом. кыпч., алт., хак., төркм. һ.б. *сый* «сый; бүләк; хөрмәт» монг. *суй, сүй* «калым» сүзе белән чагыштырыла (Räsänen 1969: 41), чаг. үзб. *сийла-* «хәлгә керү, хөрмәт итү». Федотов II: 21–22; ЭСТЯ VII: 394–396.

Дерив.: **сыйлан-у, сыйлаш-у, сыйлат-у, сыйла-у; сыйлы, сыйсыз;** диал. **сыйлык** (*шыйлык* белән чагыштырыла) һ.б.

**СЫЙГА** иск. «грамматическое спряжение глагола» к. **Сыяк.**

**СЫЙНЫФ** «класс (общественный)» < гар. *ṣинф* id. ← *ṣнф* «бүлү, классификацияләү» тамырыннан (шуннан иске тат. **тәсниф** «классификация»).

**Сыйныф** сүзен «мәктәп классы» мәгъ. куллану дөрес булмас, **класс** «класс» булып калсын иде. Ягъни татаарчада ике мәгънә – ике сүз булсын

Дерив.: **сыйныфчылык; сыйнфый** (гар. теленнән үк килә).

**СЫЙПА-У** «гладить; ласкать поглаживанием» < гом. кыпч. *сыйпа-,* башк. *һыйпа-,* каз., к.-калп., уйг. *сипа-,* куман., алт. *сыба-, сиба-,* хак. диал. *сыйба-* ~ тув. *суйба-* id. ЭСТЯ VII: 396.

Дерив.: **сыйпал-у, сыйпан-у, сыйпаш-у.**

**СЫЙР** «сыр» < рус., русчада гом. слав. тамырыннан, к. Фасмер III: 819 (бик күп әдәбият күрсәтелә). Тат. **сыйр** дип язу **сыр** сүзеннән аеру өчен кирәк.

**СЫЙРАК,** диал. (Остроумов 1872: 117) **сыйырак** «голень; берцовая кость» < гом. кыпч. *сыйраҡ,* башк. *сираҡ, һираҡ* id. ~ төркм. *сыңраг, сыңыраг, сырнаҡ* id., ш. ук «тояк» ← (аз., к. АДДЛ: 364) *сыңыр* «сыйракның төп өлеше; сеңер», к. ш. ук тув. *сыырғаҡ* «беләзек сөяге» ~ бур. *шиира* «сыйрак; сеңер», алт. *шыйраҡ* «бәкәл сөяге» һ.б. К. **Сеңер.**

**СЫЙ-У** «вмещаться; умещаться», диал. «впитаться; проникать» ~ башк. *һый-* < гом. кыпч. *сый-* < уйг., төркм., чыгт., госм. һ.б. *сыг-* ~ алт., хак., тув. *сың-* id. Чаг. ш. ук уйг. (Радлов IV: 606) *сыҡ-* «сыю» >> чув. *сăх-* «сеңдерү, сеңү». К. **Сең-ү, Сеңәл, Сыгын-у, Сыен-у.** ЭСТЯ VII: 382–383.

Дерив.: **сыеш-у, сыйдыр-у; сыем, сыеш** һ.б.

**СЫЙФАТ** «качество», «имя прилагательное» < гар. *ṣифăт* id.

Дерив.: **сыйфатлы, сыйфатсыз; сыйфатла-у; сыйфатчы** (авыл хуҗалыгында эшнең һәм продукциянең сыйфатын тикшерүче – гадәттә колхозларда була торган вазифа).

**СЫКРА** «недержащий мочу» (ТТДС I: 379) ~ башк. (БТДҺ: 384) *һыҡыра* «саран» < **сырҡыра-г* ← *сыркыра-* «саркып тору», к. **Сыкра-у.**

**СЫКРА-У** «брюзжать; выражать сильное недовольство; постанывать от боли» ~ башк. *һыҡра-, һыҡыра-* < башк. диал. (БТДҺ: 386) *һырҡыра-, сырҡыра-* id. ~ ком., каз., к.-калп., төркм., төр. диал. *sırkıra-* ~ як. (Пекарский: 2035) *саркыра-* «саркып тору» ← (үзб.) *сарқи-, сирқи-* «челтерәп агу; тук-

таусыз зарлану» – ахыр чиктә тәкълиди тамырдан, к. **Саркы-у.** Чаг. **Сукран-у.** ЭСТЯ VII: 418.

Дерив.: **сыкран-у, сыкраш-у; сыкраш;** к. **Сыкра.**

**СЫКТА-У** «(беззвучно) плакать» < гом. кыпч., алт., тув. *сыкта-*, үзб. диал. *сиқта-,* башк. *һыҡта-* id. ← **сыгыт** (к.): *сыгыт-а-* > *сыкта-*, к. бор. төрки (ДТС: 503) *sïγta-* id. К. ш. ук як. *ытая* «елау». Räsänen 1969: 415.

Дерив.: **сыкташ-у, сыктат-у;** тат. диал. (Тумашева 1992: 196) **сыктак** «елак».

**СЫК-У (сыкты, сыгу)** «выжать, выжимать»; диал. «вжимать, уплотнять», диал. (Тумашева 1992: 196) «сжать, сжимать» < гом. кыпч., алт., госм. һ.б. *сыҡ-*, уйг., үзб. *сиқ-*, чыгт. *сығ-* ~ як. *ыҡ-* «сыгу; кысу» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 333) *šika-, šiγa-* «кысу». Бу сүзнең исем коррелянты – кр.-тат., нуг., төр., үзб. *сыҡ* «тыгыз сыенган». Чаг. **Сыгыл-у.** Räsänen 1969: 415–416; ДТС: 505; ЭСТЯ VII: 396–398 (шунда ук *сыт-у* турында да).

Дерив.: **сыгыл-у, сыктыр-у; сыгымта; сыгынты.**

**СЫКЫ,** (ТТДС I: 140; БТДҺ: 140) **зыкы** «густая, тяжелая пороша; пороша, которая бывает в особенно холодные и одновременно тихие дни; тихий, безветренный холод» һ.б. ~ башк. (БҺҺ II: 74, 223, 296; БТДҺ: 289, 384) *зәһеү, сыҡы, һыҡы* id. ~ чув. (Ашмарин XI: 289) *сăк, сăкă, сăхă* «вак кына кар», «шудырмый торган карлы кышкы юл», гом. кыпч. сүзе булган, к. абаз. (< кыпч.) *сыха* «кырпак кар; зыкы; җяяүле буран». Гомумән бу сүз, бик ихтимал, фар.-таҗ. *заһ, заһи* «сыкы; дымлылык» сүзенә тоташа бугай, к. тат. диал. **зыкы** «мәте, суткак балчык», **зык (зыкы) салкын (суык)** «көчле суык» һ.б.

Сүзлекләрдә тагы **зыкы(н) чыгу, зыкыга тию** һ.б.ш. тәгъбирләр (ТТДС I: 140) очрый – боларда сүз нигезе гар. *зäһм, зиһм, зäһим* «авыр ис, тир исе» сүзеннән булса кирәк, к. к.-калп. *зыкым шыкты* «бик нык арыдым», кырг. *зыкым чыкты* «авыр хәлдә калдым» (*зäһим* > *зыкым* дигәч, төркиләр, халык этимологиясенчә, сүзнең нигезе **зыкы** икән дип аңлаганнар).

**СЫЛ** (ТТДС: 379; БТДҺ: 289) «дрожжи, приготовленные путём квашения высевок в воде (куда могут капать выжимки хмеля)» – ачык түгел; чаг. рус. *сало* id. (бу сүзнең күп мәгънәләренең берсе).

**СЫЛА** «судак» ~ башк. *һыла,* каз., к.-калп. *сыла,* чув. *шăла* > мар. *шыла* id. ~ үзб. *силә*, төркм. *сииля* һ.б. ~ венг. *süllö* id. сүзенә караганда, бор. Идел-Урал регионы сүзе. В.Г. Егоров буенча, бор. (фин-угор?) *сул* >> *шăл* «теш» сүзеннән (**сыла** – тешләч балык, к. Егоров 1964: 333), ләкин М.Р. Федотов (II: 441) бу этимологияне кабатламый. ЭСТЯ VII: 257.

**СЫЛА-У** «гладить (больное место), массировать; замазывать (глиной и т.п.)» < гом. кыпч., хак. диал. һ.б. (Радлов IV: 652) *сыла-*, уйг., үзб. *сила-,* башк. *һыла-* id. < **сывла-* < чыгт., госм. (к. Радлов IV: 672–673) *сывала* «сылау, сыйпау» ← госм. *сыва* «штукатурка» ~ як. *сыбаа*, монг., тунг. *сиба, сива* ~ венг. *szivaj* «балчык, мәте»; бу нигез үзе дә фигыль булып килүчән, к. төр. *sıva-* яз. монг. *šiba-, šaba-*, тунг.-маньч. (ССТМЯ II: 74) *сива-* «сылау». Бу сүз белән бор. төрки (ДТС: 515; Боровков 1963: 276) *suva-, cywa-* «сылау» гомогенмы икән – әйтүе кыен. ЭСТЯ VII: 399–440.

Дерив.: **сылан-у, сылаш-у, сылат-у; сыланма** (исем һәм сыйфат, к. ТТДС I: 379).

**СЫЛТАУ [сы̆лтаw]** «повод, предлог» ~ башк. *һылтау* < гом. кыпч. *сылтау [сылтаw]* > чув. *сăлтав* ~ як. *сылтах* ~ монг. *шалтаг,* бор. монг. *siltaγ* id. **Сылтау** сүзе, шулай итеп, бор. *сылтағ* id. сүзеннән закончалыклы фонетик үзгәрешләр соңында пәйда була алган кебек, **сылта-у** (к.) фигыленең формасы да була ала.

Дерив.: **сылтаулы, сылтаусыз.**

**СЫЛТА-У** «отговариваться; находить предлог; ссылаться на» < гом. кыпч. *сылта-,* уйг., үзб. *силта-*, як. *сылта-, сыылта-,* башк. *һылта-* «сылтау, сәбәбен, акламасын табу» ~ монг. *силта-*, маньч. *сылта-* «сүз әйтеп котылу» һ.б., к. ш. ук к.-балк. *салта-,* алт. *шылта-,* монг., бур. *шалта-* «бәйләнергә сәбәп эзләү». К. **Шелтә.** Пекарский: 2450; Räsänen1969: 416; ССТМЯ II: 85; Федотов II: 231.

Дерив.: **сылтан-у, сылташ-у, сылтат-у.** К. **Сылтау.**

**Сылта-у** сүзе белән беррәттән иске чыгт. (Котби), куман., сары уйг. *тылта-,* бор. төрки (ДТС: 567) *tïlta-, tïlda-* «сылтау, сылтану» сүзе дә бар. Төрки телләрдә *т* ~ *с* күчеше юк, ләкин кыт. *тс* авазы бер очракта *с-*, икенче очракта *т-* белән субституцияләнергә мөмкин. Шуннан чыгып, *сылта-* ~ *тылта-* фигыленең төбендә кыт. алынмасы ята

дигән фикергә киленә. Гадәттә исә *сылта-* фигылен монг. телләреннән таралган дип уйлыйлар.

**СЫЛУ [сы̆лы̆w]** «стройная (красавица), красавица (вообще)» ~ башк. *һылыу*, каз., үзб., алт. *сылу, сулу* < алт. диал., хак. диал. *сылығ* < бор. төрки (ДТС: 503) *sïlïγ* «сылу кыяфәтле; мәһабәт» ~ хак. *сiлiг* < бор. уйг., госм. *силик* «чиста, матур» һ.б. нинидидер *сы//си* тамырына *-лыг//-лиг* кушымчасы ялганып ясалган сүз. **Сылу** < *сылығ* дигән фараз өстәмә дәлилләр сорый. Тат. этимологиясендә *сылу* < *сылығ* < **сынлыг* (к. **Сын**) дип аңлатыла. Räsänen 1969: 421 (*сол-, сөл-* «сөртү»дән димәкче); ЭСТЯ VII: 258–259 (аңлатма безнеңчә түгел).

Дерив.: **сылулык; сылулан-у.**

**СЫМАК, сыман**, диал. **сымал** «подобный» < гом. кыпч. *сымаҡ, сыман*, башк. *һыман, һымаҡ*, уйг. *симан,* үзб. *симон,* алт., хак. *сыман, зыман, зыбан* id., ш. ук «сыйфатны киметү кисәкчәсе». Һичшиксез *-сыл, -сым* (*аксыл, аксым, күксел* һ.б.ш.), *-су (алсу)* < *-сыг* кушымчалары белән тамырдаш. Чаг. кар. *сыман* «күренеш, җәһәт, як», кырг. *сымал* «охшашлык» (*сымалдан-* < *сымаллан* «охшау»). Фигыль ясагыч *-сы//-се* кушымчасы (*авырсы-, авырсы-н-, авырсы-т-*) да шул ук сериядән: тамырлары *сы* «охшашлык; охшау» сүзеннән булса кирәк, к. себ. **сын** «кебек, шикелле» (Тумашева 1992: 197). К. **Сын.**

**СЫМБАТ** «телосложение», эпоста «внушительный облик», диал. (ТТДС II: 274) **сыпат** «облик» ~ башк. (БТДҺ: 385) *һыпат,* каз., кырг., уйг. *сумбат, сымбат* id. Кайбер сүзлекләрдә гар. сүзе дип тәгърифләнә (к. Будагов I: 701, 704). К. **Сыйфат.**

**СЫМРАК** (Гиганов; Троянский), диал. **цымарыҡ** (Тумашева 1992: 197, 244) «рожок для кормления младенца», башк. *һымраҡ* id., ш. ук *сымраҡ* «мөгез быргы» (Будагов I: 635) ~ кырг. *чыңыроон, чымыроон* «мөгез быргы» >> чув. *шăхран* «дары савыты буларак мөгез».

**СЫН** «стан; корпус, вид (человека)» ~ кр.-тат. *sın* > мар. *сăн* < гом. төрки *сын,* башк. *һын* «сын, буй; образ; һәйкәл» (бу мәгъ. бигрәк тә көнб. кыпч. телләрендә еш очрый; көнч. төрки телләрдә (к. Радлов IV: 628, 692) «тау сырты». Бу сүз кыт. теленнән дигән фикер бар (бу тур. к. Федотов II: 24–25). Чаг. монг. *сынжҫ, шынжҫ* «сын». ЭСТЯ VII: 401–403.

**Сын** продуктив сүзьясагыч нигез: тат. диал. (Махмутова 1978: 222; Тумашева 1992: 197) **сĕннĕ, сынны, сынлы** > чув. *сăнлă, сăлнă* > мар. (Саваткова: 151) *сылны, сĕлнĕ* «кебек; охшаш» (~ кырг. *сындуу* «матур; охшаш», каз. *сынды,* башк. *һынды* id.); тат. < гом. кыпч., үзб. диал. *сынчы* (себ. *сынцы*) «сынаучы; күрәзә», башк. *һынсы*, нуг., каз., к.-калп. *сыншы* id., себ. **сынцыл** «кызыксынучан» (Тумашева 1992: 197). К. ш. ук **Сына-у, Сылу.**

**СЫНА-У** «испытывать, наблюдать» > чув. *сăна-* (Ашмарин XI: 261), чув., мар. *шына-* < гом. кыпч., урта төрки *сына-,* уйг., чыгт., бор. төрки *sïna-* «сынау; күрәзәләү һ.б.» ← тат. диал., каз., кырг., төркм. һ.б. *сын* «күрәзәләү, сынау күренеше» *сын* «образ, кыяфәт» белән бердәй булса кирәк. Räsänen 1969: 417; ЭСТЯ VII: 403–406.

Дерив.: **сынал-у, сынат-у** («үзеңнең зәгыйфь ягыңны сиздерү, белдерү» мәгъ.); **сынау** «имтихан» (бу сүз татарчадан төрек теленә дә кергән), **сынак** «сынап күзәтү», **сынамыш** «билгеләр буенча юрау».

**СЫН-У** «ломаться, сломаться» < гом. кыпч., гом. төрки *сын-* (башк. *һын-,* кайбер телләрдә *сыын-*) ← бор. төрки (ДТС: 502–503) *sï-*, уйг., госм. (Радлов IV: 602, 629; Боровков 1963: 270) *сы-*, хак. *сыы-* «вату, бозу, җимерү» фигыленең кайт. юн. (йөкл. юн. *сыт-*, к. **Сыт-у**). Будагов I: 704–705; ЭСТЯ VII: 371–377.

Дерив.: **сыныл-у, сындыр-у;** диал. **сынык-у (сыныгу)** «өзгәләнү, күп урыныннан сыну», **сындыргыч; сынык** һ.б.

**СЫҢАР,** диал. **сыңгар** «один из пары; подобие чего-либо» ~ башк. *һыңар* ~ гом. кыпч. *сыңар,* уйг., үзб. *сиңар, сиңгар, сиңгари,* кырг. *киңир*, алт. *саңар, саңир,* тув. *саар,* бор. төрки (ДТС: 504) *sïŋar* «сыңар; ике якның берсе; ярты; бер як юнәлеш» ~ як. *аңар* «сыңар», *аңы* «өлеш, як; ике тармакның берсе». Бу сүзне бик төрлечә аңлаталар, к. Будагов I: 689; Радлов IV: 207, 622, 631; Пекарский: 115, 117; Räsänen 1969: 417; Мухамедова 1973: 155; Җәләй: 1953: 60; ЭСТЯ VII: 406–407. Бик ихтимал ки, *сыңар* < *сынгары* (*сын* «бер як»).

Дерив.: **сыңарла-у, сыңарсыз;** башк. *һыңартай, һыңарсай* «чәнчә бармак».

**СЫП** (трбс.) «звено цепи; часть плетня между двумя кольями» ~ башк. *сып* «читән» < рус. *сцеп*? Чаг. ш. ук нуг. *сып* «сап, ботаклары боталган

кәүсә», төр. *sıpa* «ас ягы өчаяк шикелле күчерелмәле багана» < фар. *sepa [сепа, сеһпай]* «өчаяк». Ихтимал, *сып* – «күчерелмәле читән, койма баганасы»дыр, шуннан «читәннең бер торыгы» мәгъ. килеп чыга. Элек күчерелмәле баганаңы зур булмаган агачның җәпләшкәле ботакларын бер яссылыкта тигезләп кисеп ясаганнар. Räsänen 1969: 418.

**СЫПКА, сыпкы** (ЗДС: 593) «грязь, слякоть» < рус. *зыбка* id. (булса кирәк).

Дерив.: **сыпкалы, сыпкылы** «пычрак, шапшак».

**СЫПТЫР-У** «хлестать; быстро и жадно есть» ~ башк. *һыптыр-* id. ← **сып-,** к. **Сыпыр-у.**

**СЫПТЫРЫНКЫ** (ЗДС: 593; норматив сүзлекләргә дә кертеләә) «с виду скромный, вроде скромный, скромничающий (но в сущности полный желаний и намерений)» ← ***сыптыр-у** (югарыдагы **сыптыр-у** түгел). Чаг. каз. *сыптығыр* «аккурат, җыйнак; ябык», *сыптай-* «ябыгу» һ.б.

**СЫПЫ, сыпый** (ТТДС I: 381), диал. (ТТДС II: 269) **сопо** «малоежка; привередливый» ~ башк. (БТДҺ: 385) *һыпы* «әчми торган; туй чәе» – **суфи** (к.) сүзеннән килүе ихтимал, к. чув. *сăпă [сыбы]* «назланучан, кыстатучан». Чаг. ш. ук **сыпыйым** «соң дәрәҗәдә чисталыкны яратучы».

**СЫПЫЛ-У** «вылезать из ткани – о нитках» ← **сырпыл-у** (к.).

**СЫПЫРТ-У** «быстренько удалиться, убегать» ~ төркм. «тунау; суеп алу», күч. «урлау, чәлдерү». Кр.-тат. *sıpırtmaq* «фырлату, нәрсәне дә булса болгап иргыту» – **сыпыр-у** (к.) фигыленең йөкл. юнәлешеннән, әлбәттә (аффектив – күч. мәгънә).

**СЫПЫР-У** «разглаживать ладонью; проводить (щёткой) очищающие движения по поверхности чего-либо», күч. «очистить – съедать без остатка всё, что подано» < гом. кыпч. *сыпыр-, сыппыр-, сыптыр-* «сыпыру, себерү» ← **сып-* < **сырп-* «сыйпау, сыйпап тигезләү» – *сырп* тәкълиди тамырының фигыльләшкән формасыннан, шуннан ук к. **Сыйпа-, Сырпа**. Кыпч. һәм алт.-саян шивәләрендә, монг., тунг. телләрендә *сырп* тамырыннан тармакланган исәпсез күп тамыр-нигезләр табыла, к. алт., хак., шор. *сыба-,* куман. *сыпа-* «шомарту, сыйпау», каз. *сыпанда-у* «койрык белән (бөҗәкләрне куып) селтәнү» һ.б.ш., к. Радлов IV: 668–670.

**СЫР** «одна из параллельных чёрточек, линий, полос, гофр» > мар., удм. *сыр [сър]* id., башк. *һыр* id., ш. ук «бизәк, бидәр» < гом. кыпч., гом. төрки *сыр* (чув. *сăр*), уйг., үзб. *сиръ* ~ монг., калм. *шир* «буяу, буялы бизәк; лак, киноварь (җете кызыл буяу)» ~ маньч. *сирбэ* id. кыт. *tsi* < *tsir* «сандал, иннек» сүзеннән, к. бор. төрки (ДТС: 505) *sïr* «кытайлар йөзләрен буйый торган буяу»; бу мәгънә **сыр-у** (к.) белән контаминацияләнгән. Räsänen 1969: 418; ССТМЯ I: 95; Федотов II: 28–29; ЭСТЯ VII: 409.

Дерив.: **сырлы, сырсыз; сырла-у, сырлан-у;** иске тат. **сырчы. Сыр** сүзе **шар II** белән бердәйме икән – әйтүе кыен.

**СЫРА I** «пиво» ~ башк. *һыра* id. > чув. *сăра*, мар., удм. *сыра* < гом. кыпч. *сира*, каз. диал. (Аманжолов: 406) *сыраб*, каз. *serap* < фар. *сäраб* «куе шәраб, куе чәй, сөзекләндерелмәгән катнашма» булса кирәк (шуннан ук **сироп**). Бу сүзне төркм., үзб. һ.б. *ширә* < фар. *ширä* «сут, сок» сүзеннән дә, санск. *sura* «әчемлек төре» сүзеннән дә чыгаралар (Егоров 1964: 183; Räsänen 1969: 418, 447; Федотов II: 29, 30). К. удм., коми. *сур*, венг. *sör*, хант. *сар* «сыра» – бор. һинд.-иран телләреннән (Гордеев 1985: 75). К. ш. ук ЭСТЯ 2003: 413–414 (бик аз гына).

**СЫРА II** диал. «раз» к. **Сира.**

**СЫРАҖ** «норичник (растение)» – иске төр. *sıraca otu* id., *sıraca* «золотуха (балаларның йогышлы чире, аны сыраҗ белән дәвалаганнар)». Чаг. ш. ук уйг. *сираҗ* > кырг. *сырач* «җилем, шереш» – алынма сүз (ауслаут *-җ*).

**СЫРГА** «серьга» > чув. *сăрка, шăрка,* мар. *сырга, сэргэ*, морд. М. *сорга* id., удм. *сырга* (*сырга жильы* «сырга чылбыр») «тузганак» < гом. кыпч. *сырга,* чыгт. *асирга,* чыгт., уйг., үзб. *исирга* (>> коми., рус диал. *исерга*), төркм. *ысырга,* алт., хак. *ызырга,* як. *ытарга, ыдарха,* башк. *һырга* һ.б. id. (Радлов I: 542, 1398; Пекарский: 3842: 328). Бор. сәүдә әйбере атамасы буларак, бу сүз Европага да киң таралган, к. бор. рус. *усерязь, усергу,* бор. герм. *üseregü* «сырга, алка»; хәз. рус. *серьга* – төрки телләрдән (к. Grundriß 1901: 361). Гомумән, чыгышы ачык түгел. К. **Серкә I.** Чаг. **Сыр-у**. Федотов II: 31. ЭСТЯ 2003: 415–417 (безнеңчә түгел).

**СЫРГАВЫЛ [сы̆рғаwы̆л]** (ТТДС II: 275; ЗДС: 594–595; фольклор әсәрләрендә очрый) «длинный, высокий шест для состязаний по влезанию, а также для наблюдений свысока (в старину – в военном деле)» ~ башк. *һырғауыл*, каз., к.-калп. *сырғауыл* id. (бүтән телләрдә теркәлмәгән бугай). Ясалышы буенча монг. сүзе. Чаг. **Сырга-у, Сыргый.**

**СЫРГАН** тар. «маленькая крепость, отдельное укрепление, башня» ~ чыгт. (Будагов I: 626) *сырған* «башня». К. югарыдагыны.

**СЫРГАНАК I,** диал. (ТТДС I: 603) **сырғы, сыргак** «облепиха» ~ башк. *һырғақ, һырғанақ* ← *сыргы-у* < *сырык-у,* к. **Сыр-у II.** Чаг. **Аксыргак, Сырлан.**

**СЫРГАНАК II** (Будагов I: 698) «горка, каток (для катания)», ш. ук «раскат на зимней дороге» ~ башк. (БТДҺ: 385–386) *һырғалақ, һырғанақ,* каз., к.-калп. *сырғанақ, сырғалақ* «тайгак; сырганак» ← кырг., ком., каз., к.-калп. *сырғала-, сырғана-,* үзб. *сирин-, сирған-* «таю; шуу» ← тат. *сырға-,* кыпч. *сырғы-* «шуу; тайгак булу». Хәз. тат. телендә **сырганак II** кулланылмый бугай. К. түбәндәгене.

**СЫРГА-У** (Будагов I: 698) «скользить; кататься с горки или по льду» < гом. кыпч. *сырға-, сырғы-,* уйг., үзб. *сирға-, сирған-* «шуу, шуып төшү; баганадан шуып төшү», уйг. *сирил-*, төр. диал. һ.б. *сыр-* «шуу». Гом. алтай тамырыннан, к. тунг. (ССТМЯ I: 96–97) *сирун, һирун-* «шуып төшү, шуу». Чаг. **Сыргавыл II.** ЭСТЯ I: 409–410.

**СЫРГЫ, сыргый** (Будагов I: 698; Тумашева 1962: 107) «поперечина, жердь ограды», **сырык** (*сырықтай* сүзендә, к. ТТДС II: 25–26) «матица, балка; шест» ~ башк. (БТДҺ: 386) *һырғый, һырык,* каз. *сырғы,* гом. кыпч., алт., госм. *сырық,* үзб. (ЎХШЛ: 239) *съйрық,* төркм. *сыырық* < бор. төрки (ДТС: 505) *sïruq* «чош, кәртәлек; багана» > монг. *ширук* «багана, колга» һ.б.ш. К. ш. ук хак. *сырақ,* аз. (АДДЛ: 364) *сырығ* «сырык; колга» (рус. «шест для сбивания плодов с дерева» диелгән), чыгт. (Будагов I: 627) *суруғ* «чатыр терәге, баганасы». ЭСТЯ VII: 421–422 (тат. *сыргы, сыргый* ~ башк. *һырғый* варианты искә алынмаган).

Себ. (Рамазанова 2001: 86 һ.б.) **цыргый, сыргый,** ш. ук башк. *һырық* сүзләренә караганда, **сырыг* ~ **сырыгуг* «үзенә нәрсәдер эленә торган колга» мәгъ. булган һәм, ихтимал, **сыр-у ~ сар-у** (к.) белән баглыдыр. К. **Сырык.**

**СЫРЛАК** (Тумашева 1992: 197) пронизывающий ветер, пронизывающе ветреный» ~ башк. (БТДҺ: 385–386) *һырғақ, һырғанақ, һырқат,* каз. (ҚТДС: 308) *сыран* «каты суык», алт. (Баскаков 1966: 151) *сыргын* «ызгыр җил», тув. *сырын* «җил агымы, сырлак» ~ яз. монг. *siɣurɣan* > *suurɣan* > бур. *шуурган* > рус. диал. *шурга, шурган* «көчле салкын җил; җил-давыл», к. ш. ук эвенк., эвен. *сиүин, сиүир* «өермә, каты җил», ихтимал, *ссыг-* сызгыруга тәкълит сүзеннәндер. К. **Ызгыр.** ССТМЯ II: 119; Аникин: 508; 710.

**СЫРЛАН, сырлыган,** (ЗДС: 793) **шырлан** «липучка (растение)» ~ башк. (БТДҺ: 386) *һырлан, һырлыған* ~ мар. (Исанбаев 1978: 24) *сырланге* < тат. диал. *сырлангы* id. ← **сыр-у, сар-у** (к.).

**СЫРЛАН-У** «капризничать; кривляться; заставлять упрашивать» – *сырпалан-у* сүзеннән кыскарган.

**СЫРПА** «виляющий; стелющийся» – тат. телдә сакланган бор. сүз, к. як. *сырбай-* «койрык болгау; сырпалану» ~ монг. *сирба-*, бур. *шарба-, шарва-*, эвенк. *сирбай-*, маньч. *сирбаша-* id. (ССТМЯ II: 94–95). К. **Сырлан-у.**

**СЫРТ** «спина, спинной хребет (животного); горный хребет» < гом. төрки *сырт* (башк. *һырт,* үзб. *сиртъ,* тат. диал. *сырыт,* як. *сыырт*) «сырт; тышкы як», угыз диалектларында «ике тау арасы» (икенчел мәгънә) < **сыр-ыт* бор. **сыр-* «рәттән тезелү (тәүдә – бау тур.)» фигыленнән, чаг. **Сыр-у.**

*Сырт* сүзе рус теленә, рус теленнән бик күп бүтән телләргә ороним буларак кергән (Мурзаев 1982: 30). Räsänen 1969: 419; Федотов II: 32; ЭСТЯ VII: 418–420.

**СЫРТЛАН** «гиена» < чыгт., бор. кыпч., госм. *сыртлан*, уйг. *сиртлан* id. < *сырт-лаң* (Рамстедт 1957: 201): *сырт* («буй-буйлы» мәгъ.) сүзеннән. Тәүдә юлбарысны белдергән булса кирәк, к. каз., кырг. *сырттан* «бүребасар эт; мифик елгыр эт». ЭСТЯ VII: 420.

**СЫР-У I** «облепить; обступать» ~ башк. *һыр-,* чув. *сӑр-* id. – гом. төрки характерда, һәрдаим

**сыр-у II** һәм **сар-у** белән бутала. Федотов II: 29; ЭСТЯ VII: 410–412.

Дерив.: **сырлык-у, сырык-у, сырыш-у;** к. **Сырганак, Сырлан.**

**СЫР-У II,** диал. **сыры-у** «обшивать; стегать», диал. «обвивать» < гом. төрки *сыр-, сыры-,* уйг. үзб. *сири-,* як. *сирий-,* башк. *һыры-, һыр-* id. Федотов II: 76; ЭСТЯ VII: 410–411 (тәвәккәл мисаллар да китерелә). Чаг. **Сар-у, Сырт.**

Дерив.: **сырыл-у, сырдыр-у; сырма, сырмак** «фуфайка, сырылган бишмәт һ.б.ш.», бу сүз күп телләрдә очрый һәм бор. заманнардан бирле килә, к. *sïrmaq* «ишәк менү өчен ияр (эчерге)», к. ДТС: 505 һ.б.

**СЫР-У III** «мести, намести сугробы» ~ башк. *һыр-,* төр. *sıra-* ~ монг. *сигур-, шигур-* id. Югарыдагылар белән гомоген шикелле.

Дерив.: **сыргын, сырынды** (буй-буй «сырылган» кар өемнәре). Чаг. **Сырт**.

**СЫРХАВАТ [сы̆рхаwат]**, **сырхабат** (Будагов I: 625; ТТДС II: 275 һ.б.), **зырхаwат** (ЗДС: 596) «рожа (болезнь); опухоль; долго не заживающие кожные болезни» ~ чув. *сăрхават* id., башк. (БТДҺ: 386) *сырхыуат, һырҡыуат, һырҡауыт,* ш. ук (БТДҺ: 391) *сырхәмбәт* «аз ашаучан, сәлкәү» ~ удм. *суркубат, сыркубат* «экзема, кызамык» (*суркубат турын* «бака яфрагы») << фар. *сорхи бāд* (к. Будагов I: 625 һ.б.) «кызамык», сүзмә-сүз «начар кызыллык». ТТДС (I: 603) **сырхуwат** «сары мәтрүшкә» < *сырхау ут* дип аңлата; безнеңчә, бу дөрес түгел. К. **Сырхау.**

**СЫРХАУ [сы̆рхаw]** «хворь, болезнь» < гом. кыпч., к. башк. *һырҡау, сырҡау,* ком. *сырҡав,* каз. *сырқау,* кырг. *сырқоо* id. К. **Сырха-у.**

Дерив.: **сырхаулы, сырхаусыз; сырхаула-у; сырхаулык** һ.б.ш.

**СЫРХА-У** «хворать» ~ гом. кыпч. **сырқа-* id., шуннан ком., каз. *сырқыра-* ~ башк. *һырҡыра-* «сызла-у», конкрет мәгъ. «саркып тору, аккалау (мәс., сүл, эрен тур.)»; чаг. **сыкра-у**. Себ. **сырға-** (к. ЗДС: 594) «авыру» нигезе бор. уйг. телендә *ысырға-, ысырқа-* «эсселек кичерү» (рус. сөйл. «температурить») кебек сүздән дә килеп чыга ала. Чаг. ш. ук **сырхават.** Монда, күрәсең, төрле сүзләр контаминациясе күзәтелә. Ни өчен тат. телендә *-х-*? Бу билгегә караганда, тат. сүзләре – алынма. ЭСТЯ VII: 417–418 (күп параллельләр китерелә).

**СЫРЫК** (ЗДС: 596) «жердь» ~ төр. *sırık,* кр.-тат. (Dobr. III: 594) *сурық, сорық,* бор. төрки (ДТС: 505) *sïruq* id. ~ монг. *sirug, şurag, сураг* id. К. **Сырган, Сыргы.**

**СЫТ-У** «задавить, сплющить» < гом. кыпч. (кайбер телләрдә сирәк кулланыла) *сыт-,* башк. *һыт-* id. ← бор. төрки (ДТС: 502) *sï-* «сындыру» (к. ш. ук **Сын-у**), ягъни *сы-* фигыленең йөкл. юн. К. **Сык-у.**

Дерив.: **сытыл-у, сытыш-у, сыттыр-у; сытык; сыткы** (сытып эрене чыгарыла торган чабырчык).

**СЫЧКАН** (ЗДС: 596) «мышь» – бу чыгт. теленнән килгән (һәм элекке әд. телдә киң кулланылган) вариант безнең диал. җанлы сөйләмдә дә бар икән. К. **Тычкан.**

Бу сүзнең төр. телендә *sıcan* варианты актив. Будагов (I: 621) кр.-тат. *сычыул* вариантын да күрсәтә.

**СЫЯК [сы̆йак]** (ТТДС II: 289) «внешний вид; военная форма; хорошая одежда» ~ кр.-тат. *siyak,* каз., кырг. *сыяқ* «үрнәк, форма, күренеш», иске тат. **сыйга**, төр. *sıyag, sıyga* «сыйга, фигыль төрләнеше үрнәге; металл эретеп салу өчен керамик савыт» < гар. *ҫийāғ* «форма (төрле мәгъ.), манера; мәсьәләне хөкемгә куйганда тәртип, пункт; китапның башламларга һ.б. бүленеше», *ҫийāғат* «пунктлау, номерлау; бәбде-бәҗвин, хәрефләрнең сан кыйммәтләре буенча хисап чыгару» һ.б.

**Сыяк** сүзеннән иске тат., каз., кырг. һ.б. төрки телләрдә киң кулланышлы **сыяклы** ~ *сыякты* «формалы, кебек, шикелле» сүзе ясалган. Будагов I: 653; Räsänen 1969: 421.

**СЫЯУ [сы̆йаw]** (ДС II: 176; ТТДС I: 369, 379) «кочедык, коточик (инструмент для снятия лыка с дерева и для плетения лаптей)» ~ кр.-тат. *sayaw* «зур энә», к.-балк. *сояў, саяў* «киез тегү өчен сөяк без». И.М. Отаров (1978: 64) буенча, *сай-* «чәнчү, тишү» сүзеннән, к. ш. ук кырг., каз. *сойаw* «киезгә эре тишекләр тишү өчен таякчык» һ.б. ~ як. *сойуо* «тыгыз төеннәрне чишү өчен чөшле сыман корал» < бор. монг. *sojuγa* «ерткыч хайваннарның азау теше», ш. ук «марал мөгезе» һ.б. К. ш. ук **сәнәк** (< *сәйнәк*). Будагов I: 714; Аникин: 499–500.

# Т

**Т** авазы төрки телләрдә элек-электән һәр позициядә очрый. Тат. телендәге *т-* бор. төрки телдән үзгәрешсез килә. Төп тат. лексикасында сүз башында килү җәһәтеннән *т-* беренче урында.

**ТА I: та//тә, да//дә** кисәкчәсе (вариантлары кушымчаларныкы шикелле) – текстлардан тоташ язып алынган мәгълүматлар күрсәткәнчә, тат. телендә иң кулланышлы сүз икән. Гом. төрки характерда, **тагы(н)** сүзе белән бәйле, к диал. **тагын//тәген, дагын//дәген, та//тә, да//дә** (*килде дәген китте* һ.б.ш.). Рус. *да (да и)* кисәкчәсе белән охшашлык очраклы дип исәпләнелә. К. **Тагын.**

**ТА II** иск. «чтобы; до (от) самого» < фар. *tā* id. (~ рус. *до*).

Бу сүз нигезендә ясалган **таки, та ки** рус. «для того чтобы» киңрәк кулланылган. **Та кыямәт** – «кыяматкә кадәр» – элекке әд. телдә актив кулланылган фразеологизм.

**ТАБА I** «сковорода» > мар., удм. *таба,* чув. *тупа, топа* (Сергеев 1971: 72) id. < гом. кыпч. (һ.б. угыз) *таба, тава* id., чыгт., госм. < фар. *tābä, tāwa* «таба; тигель» ← *täб* «эсселек; кыздыру; ут» (~ авест. *täpa*, санск. *tap*), к. фар. *tābäи* «типше (төба төре)»; каз. (ҚТДС: 311) *табадан* < фар. *tābäдан* «таба аслыгы». Төрки телләрдә бор. (исламга кадәрге) алынма. Радлов III: 983; Platts I: 303; Räsänen 1969: 451; Тимергалин: 429.

Дерив.: **табалы, табасыз; табалык; табачá**; себ. **табакца, табаца** «чынаяк аслыгы». К. **Тәбә.**

**ТАБА II, табан** «к, по направлению» < гом. көнб. төрки *таба, табан* (ш. ук нуг. *табаған,* ком. *табалык*), бор. төрки (ДТС: 525, 526, 533, 534) *tapa, taba, tabaru* «таба» ~ каз., к.-калп., уйг., төркм. *таман* «як, тирә; таба». Этимологиясе бәхәсле сүз: Н.К. Дмитриев (1940: 89) һәм А.Н. Кононов (1980: 202–203) *таба* сүзен *тап-у* (табу) фигылленнән дип карыйлар, к. каз. (ҚТДС: 311) *табай* «таба». Ләкин уйг. һ.б. *таман* варианты аңлатылмый кала. Г. Рамстедт (1957: 74) *таба* сүзен бор. *ta* «тегe» + (кыт. алынмасы) *pa, ba* «урын, төш» сүзләреннән тора дип карый һәм бу фараз бор. *табару, табага (безнең табага), табан* кебек формаларны да аңлата ала. К. **Табантын.**

**ТАБАК** «чашка; лист (жести, бумаги)» < гом. кыпч. *табақ,* госм. *табақ,* төркм. *таабақ,* хак. *табах*, уйг. *тавақ,* госм. *табақа* ~ монг. *табага* «табак» < гар. *ṯабӓк̱* «табак», *ṯāбāк̱* «кирпеч» ← *ṯбк̱* «яссы, җәенке булу». К. **Тепке.**

Сүзлекләрдә (Räsänen 1969: 451; Redhouse: 1073) бу *табак* сүзенең һәрдаим гар. алынмасы итеп күрсәтелүе безне ышандырып бетерми. *Табак* сүзе гарәпчәдә генә түгел, фар.-таҗ., Һиндстан, Индонезия телләрендә дә бар. Бурят телчесе Н.А. Хазуев (1978: 59) бур. *табаг* «тәлинкә» сүзен тибет. *тха-паг* сүзеннән ди. Каз. *тайпақ* «таба» варианты да гар. алынмасына охшамый. Гомумән, бу сүз чыгышы томанлы мәдәни лексика җөмләсенә кертелергә тиеш. К. **Табан I.**

**Табак** продуктив сүзьясагыч нигез: **табакла-у, табаклы, табакча, табакчы, табак-табак** һ.б.

**ТАБАЛА-У** «порицать, позорить; злорадствовать; зря осуждать» > чув. *топала-* > *тупала-* id. ← диал. (ТТДС I: 390) **таба (таба җасау)** «хурлык» < гом. кыпч. *таба*, уйг. *тапа* «хөсетләнеп шелтәләү» (рус. «превышение меры порицания, наказания») ~ фар. (Будагов: 339) *таба, табаһ* «бетерү, җимерү; хәрабә» → *табаһкяр* «җимерүче» ~ төр. *tebah* «җимерелгән» һ.б. Räsänen 1969: 451.

Дерив.: **табалаш-у, табалат-у.**

**ТАБАН I** «ступня; подошва», диал. (ДС I: 175) «пятка», күч. «полозья, плоская опора», **уч табаны** «ладонь» һ.б. < гом. кыпч., уйг., хак., алт., төр. *табан* < бор. төрки (ДТС: 524) *taban* (башлыча) «аяк табаны, олтан», аз. *таабан*, төркм. *даабан* id., тув. *даван* «мөчә (аяк-кул)», *таван-гай* «аяк табаны» > як. *табағай* «чәңгәл, ерткыч җәнлек тәпие»; фонетик дивиацияләр: үзб. *товон, тәвон*, уйг. диал. *тапан*, алт. *табаш* «табан» һ.б. к. ЭСТЯ III: 110–112. Чув. *топан* > *тупан*, мар. *таван* «чана табаны» мәгъ. тат. теленнән алынганнар. Гомумән, бу сүз күп кенә күрше (Кавказ, Балкан, Шәрык) телләренә дә кергән (к. Э.В. Севортянда). Монг., калм. *tabag, tabaγ* id. сүзе төрки *табан* белән гомоген, ләкин алынма булмаска да их-

тимал. Э.В. Севортян В.Е. Егоровка ияребрәк *табан* сүзен *тап* имитативына баглый, ягъни бу сүз **тапта-у, тапылда-у** фигыльләре һ.б.ш. белән гомоген булып чыга. Безнеңчә, бу нәтиҗә ашыгыбрак ясалган. К. **Табан II.** Räsänen 1969: 462; Федотов II: 249.

Дерив.: **табанлы, табансыз; табанлык; табанча; табанла-у** «табан озынлыгы белән үлчәү»; (Г. Тукайда) **табан-табан.**

Гомумән, **таба, табак** һәм **табан** сүзләре тамырдаш булырга да мөмкин, к. фар., төр. диал., гар. һ.б. *тава* ~ *даба* ~ *дабба* «елгалар кичәр өчен түгәрәк кимә» (к. Никитин А. Хождение за три моря. М.–Л., 1958: 209).

**ТАБАН II,** ш. ук **табан балыгы** «карась; лещ; окунь» (барчасы яссы балыклар), к. Будагов I: 327–328; Радлов III: 963. Тат.-башк. даирәсеннән тыш, төрки телләрдә күренми. Мар. сөйләшләрендә *таван* id. < тат. Чаг. удм. *табан*, рус диал. *табани* «җәймә күмәч, тәбикмәк».

Бу сүзне бүтән сүзләр белән тәгаен генә чагыштыру мөшкел.

**ТАБАНЛА-У I** (Х. Туфан) «зашагать, пойти пешком» ← **Табан I.**

**ТАБАНЛА-У II** «табанить, приставать к берегу, гребя вёслами против течения; грести одним веслом для маневрирования при приставании к берегу». Тат. сүзе **табан* ~ төр. *taban* «кимәне бору, боргалау өчен махсус яссы кыска ишкәк» нигезеннән. Аникин (: 518–519) рус. *табанить, таванить* сүзенең төрки нигездән булуын таный, әмма конкретлаштырып әйтә алмаган.

Мәзкүр **табан** сүзе **Табан I** белән бердәй булса кирәк.

**ТАБАНЛЫК, табанлыг** иск. (Радлов 1908: 1–40) «чиновник», (Будагов I: 327–328) «мостовщина» – асылда «урынбасар» мәгъ. булса кирәк, к. төр. *taban* «нигез, таяныч», *tavan* «сайгау, идән-түшәм; чин»; чаг. ш. ук *табун, табунан* «монгол хөкемдарларының кияүләренә бирелә торган чин вә гонван» < кыт. *тайбоо* «олуг химаяче» (к. Аникин: 519–520). К. **Тайбуга, Тайчи.**

**ТАБАНТ-У** (Ш. Бабич) «направлять; направить стопы (?)» – бу яки моңа охшаш фигыльне без сүзлекләрдән тапмадык. Ихтимал, шагыйрь үзе ясаган сүздер. Чаг., ләкин рус. диал. *табанить* «кимәне ишкәк белән идарә итү» – төрки телләрдән, к. **Табан II.**

**ТАБАНТЫН, табатын** (ТТДС II: 283) «по направлению, к … *или* от …» – тат. теленең үзендә **түбәнтен, югартын** һ.б.ш. сүзләр моделендә ясалган булса кирәк. К. **Таба II.**

**ТАБАНЧА, табәнчә** (Тимергалин: 439) «пистолет, револьвер» ~ ком., кар., кырг., каз., үзб. һ.б. *тапанча, табанҗа* (> нуг., каз. *тапанша*), төр., аз. (Будагов I: 734) *табанҗә, тапанчә* id. Сүзлекләрдә (Рясянен сүзлегендә дә) фар. *табанчэ, тäпанчэ* «пистолет» (ш. ук «сугып җибәрү») сүзенә нисбәтләнә.

Бу сүзне **табанча** (к. **Табан**) сүзеннән аеру өчен **табәнчә** дип язу хәерле.

**ТАБӘКА [табәқа]** «сословие» < гар. *ṭабäқа* id., ш. ук «кат, катлам». Будагов I: 734.

**ТАБГАЧ** тар. – название Китая в тат. сочинениях XVIII–XIX веков. Асылда бор. төрки кавем. К. **Тәвәкәч**. Türkler II: 941.

**ТАБИГАТЬ [табиғәт]** «природа; нрав» < гар. *ṭабӣʻат* id. (барча мөселман телләренә алынган сүз) ← *ṭбʻ* «куллану, сеңдерү; үзләштерү; күнектерү, иләштерү» тамырыннан. К. **Матбага, Матбугат, Табигъ, Табигый, Табигыйн**.

Дерив.: **табигатьле; табигатьче** «табигать фәннәре белгече», **табигатьчелек.**

**ТАБИГЪ** «подданный; крепостной (крестьянин); принадлежащий к …» – бу гар. сүзенә төрки *тапуг* бик охшаш һәм алар еш кына буталыша. Будагов I: 378 (киңрәк аңлатыла). К. **Табигать.**

**ТАБИГЫЙ [табиғи]** «естественный, природный; естественно» < гар. *ṭабӣʻӣ* id. К. **Табигать.**

Дерив.: **табигыйлык; табигыйлан-у, табигыйлаш-у.** Иске әд. **табиган, табган** «табигатенә күрә» *табигый* сүзеннән гар. телендә ясалган рәвешләр. Ш. ук иске әд. **табигыя** фар. изафәсе юлы белән ясалган сүзләрдә **табигый** мәгъ. килә.

**ТАБИГЫЙН** «последователь; табиин – один из представителей того поколения мусульман, которые не видели пророка Мухаммеда, но застали его сподвижников» < гар. *тāбӣʻӣн* id. Рус. *табин* < чыгт. *табиин* тур. к. Фасмер IV: 6.

**ТАБИКМӘК** к. **Тәбикмәк.**

**ТАБИП, табиб** «лекарь, врач» < гар. *ṭабūб* id. *ṭбб* «дәвалау» тамырыннан, шуннан ук **Тыйп.**

Дерив.: **табиплык;** диал. **табипчы; табипчылык.**

**ТАБУГ** «поклон, приветствие поклоном» < бор. төрки *tapıγ, tapuγ* «хезмәт» ← *tap-* «табыну, хезмәт итү», к. **Табын-у**. Будагов I: 719–720.

Дерив.: **табугчы,** к. КБтә: *тапугчы – тапугчы турур, белгүлүг* «табугчы ул табугчы инде, билгеле».

**ТАБУТ** «гроб» < гар. *тāбӯт* id., ш. ук «сандык, әрҗә; көймә (этимологиясе бәхәсле, төп. гар. сүзе түгел). Чув. *тупӑк* < *топӑк* «табут» ничек килеп чыкканлыгы ачык түгел. Будагов I: 329; Федотов II: 249–250.

Дерив.: **табутлы, табутсыз; табутла-у.**

**ТАБЫЛ-У** (ТТДС I: 392) «собираться; воссоединиться» ← **тап-* «очрау; тап килү». **Тап-у I** дән түгел, икенче бер сүз.

**ТАБЫЛЧЫК** «найдёныш» (Исанбаев 1978: 10) – мар. телендә теркәлгән бу тат. сүзе тат. сүзлекләрендә юк. Әлбәттә, **табыл-у** сүзеннән.

**ТАБЫН I** «стол для гостей; группа гостей; общий стол семьи», диал. (ТТДС I: 392, БҺҺ III: 164) «табун» < гом. кыпч. *табын* < чыгт. *табун* id. М. Рясянен буенча (Räsänen 1969: 543), монг. *табун* «биш» сүзеннән (ат өере дүрт бия һәм бер айгырдан гыйбарәт) дип исәпләнә. Икенче бер фараз буенча, монголлар *биш төрле* малны – ат, дөя, сыер, сарык, кәҗәләрне «бишлек» дигәннәр. Ләкин к. **Тап I: табын** «тап булып» (инструменталь килеш) сүзеннән исемләшкән булуы ихтимал.

Тат. сөйләшләрендә (ш. ук күрше телләрдә) *табун* яңгырашы да (Радлов III: 978; ТТДС I: 392) бар, ләкин бу вариант рус теленнән (рус теленә исә кр.-тат. яки Кавказ төрки телләреннән кергән), чөнки тат. сингармонизмы законнары буенча икенче иҗектә *-у-* килми.

Иске сүзлекләрдә (казанча) *табун* «дүрт кешелек дирбия», Дагстанда «40–50 данә», төр. телендә «учак ягу чокыры» мәгъ. күрсәтелә (Будагов I: 328) һ.б. Рус. *табун* (төрки телләрдән иканлеге) тур. Аникин: 519–520 (шунда ук тиешле әдәбият).

Дерив.: **табындаш, табынлык, табынчы** («официант»), **табынчылык**. К. түбәндәгене.

**ТАБЫН II** – название башкирского племени (это племя занимало территории в радиусе 100 километров от г. Уфы) – күп төрки халыкларда билгеле кабилә; атама үзе **Табын I** «биш, бишлек» белән бердәй булса кирәк (монг. саннары белән аталган төрки кабиләләр тагын берничә, мәс., *найман* – монг. «сигез»). Чаг. ләкин нуг., кр.-тат. *tabın* «кабилә; нәселдәшләр» һ.б. гар. *тāби'ӯн* «табигъләр, бер үзәккә бәйләнгәннәр» дип аңлатыла.

**Табын** кабиләсе Казан дәүләте белән бәйләнештә торган. Уфа шәһәре *табын* кабиләсе җирендә булган, Казан тирәсендә дә *табыннар* яшәгән (к. Гарипова 1998: 371–372), тик алар нугай булган бугай. К. Әхмәтҗанов 2002: 330–340.

**ТАБЫН-У** «преклоняться, поклоняться; чтить» < гом. кыпч. *табын-* < чыгт., уйг., бор. төрки (ДТС: 533, 535) *tapïn-, tapun-* «табыну, хезмәт итү (итенү)» ← уйг., госм., бор. төрки *tap-* «хезмәт итү» ~ *tap* «теләк, ихтыяр, мәел» (?), к. ш. ук бор. чыгт. (Поппе 1938: 338) *tap, tapı* «канәгать, таман» ~ монг. *таб-* «риза, канәгать булу» һ.б. к. **Табуг.** Räsänen 1969: 462.

Дерив.: **табынылу-у, табындыр-у**; диал. **табынчык** «ялагай, юмакай».

**Тап** тамырының гар. *табғ* «басылу, бастырылу» сүзләре белән охшашлыгы очраклы булырга тиеш. Шулай ук бор. төрки *tap-* «табу, табып алу» белән бердәйлеге дә (к. Будагов I: 719–720) исбатлауга бик мохтаҗ.

**ТАБЫР** «лагерь (на хлебном поле), место отдыха и водопоя скота» > чув. *тапӑр* id. ~ төр. *tabur* «батальон; оешкан төркем; каре́; хәрби лагерь», госм., кр.-тат. *табур* «арбалар белән тирәләнгән хәрби лагерь, табор» ~ вегн. *tábor* > рус. *та́бор* id. Бор. төрки **табғур* сүзеннән дип карала, к. **Тапкыр.** Будагов I: 720; Фасмер IV: 6–7; Федотов II: 173.

Дерив.: **табырлы, табырсыз; табырла-у** («үләнне кара җиргәчә ашап бетерү»); **табырлан-у.**

**ТАБЫРА, табра,** диал. (ДС III: 50) **дабра** «тавро, клеймо (на лошадях)» – татарчадан тыш төрки телләрдә юк. Рус. *тавро* сүзеннән дип тә әйтеп булмый, рус сүзе үзе төрки **тугра** сүзеннән дип аңлатыла (Аникин: 521). Безнеңчә, *табыра* сүзе фар. *таб, тап* «ут, эссе, көйдерү» сүзеннән ясалган, к. тат. диал. **табыра** «басу» (ДС I: 125), ихтимал – «үләне, саламы яндырылган җир».

**ТАБЫСКА** (ТТДС II: 284) < **табычка** «щепка» ~ башк. (БТДҺ: 299) *табыҡ* id.; һәр ике сүзнең

тамыры ~ тат. диал., башк. **тап** (к.). **Табычка** сүзе **йомычка** сүзе моделендә ясалган булса кирәк. Ш. ук ***тапчык-ак** (к. **Тапчык**) яки **табыкча** формасыннан да ясала ала.

**ТАВАР [тawap]** «фабричные ткани», (Будагов I: 382) «шелковая материя, атлас» ~ к.-балк., уйг. *табар, тавар* «ефәк; тавар», бор. төрки (ДТС: 526, 542; Clauson: 442) *tabar, tavar* «байлык, әйберләр; кирәк-ярак», алт. *табар* «товар; атлы гаскәр». Бу сүзнең «сәүдәгәр олавы» мәгънәсе булган, шуннан бор. рус. *товар* «олау, сәүдәгәр олавы», шуннан *товарище* «зур олау», *сотоварище* «олаудаш» > *товарищ* «иптәш» (к. *товарка* «иптәш хатын»), к. Елкина Н.М. К этимологии слова *товар* // Этимологические исследования по русскому языку. 2. М., 1962). Гомумән, *тawap* ~ **туар** сүзләре бер нигездән (к. **Туар**). К. Сергеев 1980: 96–108; Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 114–117) **тавар ~ табыр** сүзләре (аларның гомогенлыгы шикле) тур. төрле бәхәсләр булуын күрсәтеп үтә. Тик *табур* < *табқур* дигән версияне (к. **Тапкыр**) ул искә дә алмый. К. ш. ук Räsänen 1969: 451–452; Федотов II: 161–162; Мухамедова: 85 (төркм. *довар*, төр. *davar* «сарык көтүе» сүзен китерә).

Дерив.: **таварлы, таварсыз; таварлык; таварлан-у; таварчы, таварчылык.**

**ТАВАРЫН-У [тawapы̆н-]** (Ф. Әмирхан, Казан шәһәре татарлары телендә) «следить (за объектом интереса); примеряться; прикидывать» ← **тawap-, тawyp-** «әзер булу; ярашу» фигыленең кайт. юн., гом. кыпч. характерда булса кирәк, к. кырг. *тоору-* «каравыллау, күзәтү; чамалау», тув. *таарыш-* «ярашу; ошау» (?). Чаг. бор. төрки (ДТС: 526–527, 542–543) *tabran-, tavra-, tavran-* «хәрәкәткә килү, актив мөнәсәбәттә булу; тырышу, омтылу; ашыгу» < **tayra-, tayran- (tayuraq* > *tayraq* > *tavraq* «тизгер, өлгер, тирак») һ.б. Арытабан Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 112–113) угыз телләреннән һәм бор. ядкәрләрдән җыйган бай материал китерә (ләкин тат., кырг., тув. сүзләрен белми): төр. *davran-*, төркм. *даабыра-, дабра-, дабран-, давран-*, үзб. (ЎХШЛ: 76) *дабрын-, даврын-, дыбрық-,* уйг. (Räsänen 1969: 453) *tawra-, tawran-* «чабу, йөгерү; ашыгу; кужу; актив хәрәкәткә әзерләнү; коралга тотыну һ.б.ш.» Азагында ул бу фигыльләрне **тап** тамырыннан дип белдерә. К. **Тапырык, Тәперән-ү.**

Тат. сүзе Казанда гына сакланган булса кирәк. Шунлыктан аның әйтелешен дә төгәл билгеләп булмый (ихтимал, *тawapын-* түгел, *тawырын-, тawpын-* һ.б.дыр ул).

**ТАВИС [та°wис]** «пава, павлин» < гар. *ṭāwис* < грек. *ταώς* id.

**ТАВЫК [та°wы̆қ]** «курица» < гом. кыпч., чыгт. *тawық* (> кырг. *тооқ*), уйг. диал., төр. *tavuk,* үзб. *товуқ* < чыгт. *тäхäқу, тағуқ* бор. төрки (ДТС: 536) *taqayu, taqïyu, taquq, tayïqu* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 341) *taqıya* > хәз. монг. *тахиа, тахя* > алт. *тақаа* id.; тув. *таақ, дагаа*, хак. *таах, тагах, таңах* – үзенчәлекле фонетик линияләр; уйг. *тоху* аз. *тойух, тŏух, тöух* id. аерым бер вариант; чув. *чăхă* < **тыхы* уйг. вариантыннан килә шикелле; венг. *tyik* «тавык» та чув. варианты белән гомоген.

Бу сүзнең тамыры ачык түгел. Л. Җәләйнең (Җәләй 1953: 22) **тавык** сүзе *тау* < *таг* сүзеннән дип фаразлавы кызыклы, ләкин исбатлаудан ерак тора. Räsänen 1969: 457; Мухамедова 1973: 85, 159; Федотов II: 406.

Аерым әйтерлек деривациясе юк.

**ТАВЫЧ [та°wы̆ч]** һәм **[та°вы̆ч], тәбеч, тәбич** (ТТДС II: 284 һ.б.) «большая чаша» – «зур табак, табынга аш куя торган табак» < рус. *ставец* id. (*ставить* «кую» сүзеннән). Хайрутдинова 2000: 15.

**ТАВЫШ [та°wы̆ш]** «голос, звук; шум-гам» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *тawыш, тавуш, тауш* (> нуг., каз., к.-калп. *таус, таўыс*), алт. *табыш* > хак. *табыс* ~ кырг. *дабыш, добуш*, тув. *дааш* > як. *тыас* id. ~ каз. *даус, дабыс* «матәм елаулары; үлгәннән соңгы дан» ~ гар. *дäwäш* (төрки телләрдән булса кирәк). Тув. *дагжа-* «тавышлану» сүзеннән чыгып, бор. **дағыш* вариантын чыгарырга мөмкин, ләкин бу вариантның икенчел булуы бик ихтимал. Гомумән, *тавыш ~ дawыш* һ.б. күп күрше телләргә кергән.

Безнеңчә, **тавыш <** **тawылч ~ *дawылч,* ягъни **Давыл** (к.) сүзе белән гомоген (бу фараз барча этимологик принциплар белән яраша, әмма эзлеклерәк исбатлауга материал җитенкерәми). Будагов I: 721; Радлов III: 774–776; Räsänen 1969: 453.

Дерив.: **тавышлы, тавышсыз; тавышла-у, тавышлан-у; тавышчан.**

**ТАВЫШКАН [та°wы̆шқан]** (**тавышкан елы** тәгъбирендә), гом. тат. (Троянский I: 46; ЛТ I: 7) **таушан, тушан** «тушканчик; кролик» (хайван атамаларын бутау тат. сүзлекләрендә еш күзәтелә) < гом. кыпч., төр., аз., гаг. *тawшан* «куян», чыгт., уйг. *тawышқан*, кар. *давсан, дафсан, тафшан*, госм. (Будагов I: 747) *давшан*, аз. *даушған* «куян; тавышкан»

< бор. төрки (ДТС: 526, 542–543) *tabïčγan, tavïčγan, tavïšγan, tavušγan* «куян», (Clauson: 447) *duwušaγan* < **taγulčaγan* id. (безнең тәнәйтү). Бу сүзнең икенче бер үсеш линиясе – Д. болг. *dvalan* ~ бор. монг. *taγulaj, taulaj, taolaj* > алт. диал. *толай, тулай,* як. диал., тув. *толлай* > рус. (Аникин: 529–550) *талай, толай, толуй* «Себер куяны; Себер тау куяны». Сүзнең бор. нигезе **тағул* < **такул* < **такағул* «сикерүчән» ← *тақ-* «сикерү» – бор. төрки-монг. сүзе (к. Аникин: 573, шунда бай әдәбият китерелә), к. чыгт. (Будагов I: 338) *тауш-* «сикереп йөгерү; чабу» < **тағуш-*, чаг. эвенк. *туксаки* «куян» (> рус. диал. *туксак* id.) ← гом. тунг.-маньч. *токса-, тукса-* «сикереп бию, сикереп йөгерү» (ССТМЯ II: 208, бик күп материал китерелә, әмма төрки-монг. параллельләре билгеләнмәгән). **Тагул-* нигезен бор. монг. *tauli-* «чабу» яисә кыт. *tao* «куян» сүзләре белән дә чагыштыралар. К. ш. ук Räsänen 1969: 453; Фасмер IV 129.

Рус. *тушкан, тушканчик* турыдан-туры тат. теленнән булырга тиеш: Идел-Урал регионында **тавышкан (> туышкан > тушкан)** дигән кимерүче хайван очраштыргалый (ләкин ул, беренчедән, сирәк күренә, икенчедән, аның практик әһәмияте юк – шунлыктан аны гадәттә белмиләр). **Тавышкан** – арт аякларында сикереп хәрәкәтләнүче озын койрыклы җәнлек, аның ике төре бар: **тушкан** һәм **тушканчык** (кечерәк төре). **Таушан, тушан** яңгырашлары иске әд. телдән кергән булса кирәк. Чаг. ш. ук **Ялман.**

**ТАВЫШ-ТАЛКЫН,** (ТТДС II: 284) **тавыш-талғын** «дрязги, распри» – бу парлы сүздә икенче компонент **талкын < талкы-ғын** «кабатлану (тиргәш-талаш тур.)», к. **Талкы-у.**

**ТАГАЙ I** «дядя по матери» (к. Тумашева 1992: 199; автор бу сүзне «корал» дип аңлата, ләкин ул китергән тексттан күренгәнчә кеше, кемсә тур. сүз бара) < кырг., уйг., алт., үзб., төркм. һ.б. *тағай* id.; **тагай** белән **җиян** аеруча якын мөнәсәбәттә торганнар: тагай җиянен тәрбияләргә, һәртөрле ярдәм күрсәтергә тиеш булган, к. **Тай II** ш. ук мәгънәдә. **Тагай,** безнеңчә, **тай аға(й)** сүзеннән. **Тай** һәм **ағай** синонимнар булган. **Тай < тагай** дип аңлату да бар. К. Покровская 1961: 47–52; Курышжанов 1970: 194–195.

**ТАГАЙ II** (Радлов IV: 196) «оружие» < алт. диал. һ.б. *тағай* «пычак, хәнҗәр» << авест. *taeγa* «үткер (нәрсә)» > фар. *тега, тиғ* «очлы кылыч» (к. Joki 1979: 65: бу сүз хант.-манси телләренә дә кергән икән).

**ТАГАН**, диал. **даган** «качели; козлы (для пилки дров), треног; шиш; таган, таганок» > чув. *такан*, мар., удм., морд. М., рус. *таган*, мар. диал. (Упымарий: 28) *даган* id. ~ төркм. *тааған,* хак. диал. *таххан* < бор. уйг. *тақан* id. (> иске тат. **такан** «дар агачы») ~ бур. *тағаан* «таган, таккыч» ← **так-у** (к.); к. ш. ук иске тат. (ТТАС III: 19) **такак** «берничә элмәкле дар». Чаг. **Дага.** Рус. *таган, таганок* тур. Аникин: 521–522 (бу сүз грек теленнән таралган димәкче, без бу фикергә кушылмыйбыз). К. ш. ук Федотов II: 165 (рус теленнән күрше телләргә таралганлыгын әйтә).

Дерив.: **таганлы, тагансыз; таганлык; таганла-у;** идиома: **таган асты** «яшьләрнең уен үткәрү урыны» (к. ТТДС II: 284 һ.б.). Бу мәгънә шуннан чыккан: ике таган (өчаяк) төзеп, шуларның өстенә аркылагач куеп, шуңа бер бауның ике башын беркеткәннәр һәм чәңгелдәк (сәленчәк) ясаганнар. Шунда атыну белән бергә төрле уеннар да уйналган.

**ТАГАР** иск. «грубый сосуд из лыка и т.п.», диал. «дощатый сосуд для рассады» ~ чыг., фар. һ.б. *тағар* «чирәп таст; тире кап, сумка һ.б.» (к. түбәндә). Будагов I: 361; Будагов II: 397 (*тағар* дигән авырлык берәмлеге тур. сөйли): Төркестанда өч тагар – бер батман; Кавказ тарафларында тагарның авырлык кыйммәте товарына карап, мәс., 1 тагар арпа – 30 пот булган), Рясянен (Räsänen 1959: 454) буенча, *тагар* ~ монг. *дағар* «киндер капчык» (төп мәгънәме?). К. түбәндәгеләрне.

**ТАГАРАК,** (ДС I: 176) **тагырак** «деревянное корыто; кормушка» ~ башк. (БТДһ: 299–300) *тағара, тағрақ, тағырау, тағырақ, тағрал, тағран, тағрау* «кәрәз элү өчен таяк; кәрәз рамы» – күрәсең, тәүдә «бал кортларын ашату урыны» ~ үзб. *тағора,* кырг. *тағырақ* «тагарак», төркм. (ТДГДС: 166) *тағара* «керәч купы, тәлинкә», кырг., каз. диал. *дағара* «тас, ләгән» ← кырг. диал., уйг., чыгт., госм. *тағар* «тагарак; зур мис; кап; ияр арты капчыгы һ.б.» (к. Радлов III: 796), алт., хак., тув. *тäр*, бор. төрки (ДТС: 526) *taγar* «капчык; капчык тегүгә китә торган тупас тукыма», госм., төр. *dağar* «күн капчык», «көтүче сумкасы (төп һәм күч. – үсемлек атамасы мәгъ.); зур балчык чүлмәк; дөя йөге – авырлык берәмлеге» ~ фар. *тағар* «капчык, янчык» ~ индонез. *takar* «чүмеч» һ.б. – халыкара, ин-

тернациональ сүзләрнең берсе. Räsänen 1969: 454; ЭСТЯ III: 120–122 (бездә күрсәтелмәгән күп телләр вә мәгънәләр китерелә, ләкин тат.-башк. материалы бездәгедән күпкә азрак). Рус. *тагар* «чыпта, палас», *тагарнина, тагарник* «чыбык-чабык һ.б.ш.», *тар* «икмәк янчыгы» тур. Аникин: 522, 533). Чыгт. *тағар* «ашлык салымы», «79,8 килолык берәмлек» тур. Velidi: 290, 308.

Барча мәгънәләргә уртак сема: «ашамлык савыты». **Тары < таарығ** сүзе белән гомоген түгелме икән? К. ш. ук **Тагарчык.**

**ТАГАРЧЫК,** «сумка из шкуры шерстью наружу» ~ добр. (Dobr. III: 270) *taγarcıq* id. ~ бор. чыгт. *дағаржуқ,* төр., аз. *тағаржуқ,* төркм. *тағарчық* «күн янчык». К. **Тагар.** Мухамедова 1973: 84.

**ТАГАТ-У** (Тумашева 1992: 199; БТДҺ: 299) «разрушать (сделанное), расплетать, рассеять» ~ нуг. *тағат-*, кр.-тат., төр. һ.б. угыз. *daγıt-* «тарату» ← *daγı-,* төркм. (> к.-калп.) *дағы-* «таралу; бетү; тәмамлану»; бу фигыльнең бүтән юнәлешләре дә очрый, мәс., госм. *тағал-* «зиһен таралу» (Будагов I: 726), төр. *dağınık* «таралган, сибелгән» ← **dagın-* «таралу» һ.б. ЭСТЯ III: 119–120 (тәфсилле, башк. мисалы күрсәтелми). Боровков (1963: 281, 283) *тағыл-* «таралу» һәм *тақыл-* «сүтелү» сүзләрен аерым-аерым бирә. Чаг. **Тарка-у.**

**ТАГУ** (Тумашева 1992: 199 һ.б.) «помеха, препятствие» < *таңғу* «тышау, тышаулау». К. **Таң-у II.**

Дерив.: **тагыл-у** «абыну» (ЗДС: 600).

**ТАГУН** «чума (болезнь)» < гар. *ṭāʻун* id. Чаг. ш. ук монг. > эвенк. (ССТМЯ II: 155) *тахул, такул* «эпидемия». Бу (гар. һәм монг.) сүзләрнең бердәйлеге шикле.

**ТАГЫ, тагын**, себ. (Тумашева 1992: 195–196) **таа, тағa,** диал. **дагы** «ёще; ёще раз; к тому же» > мар. диал., удм. диал. *тагы*, морд. М. *тага*, морд. Э. *таго* id. < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 79) *дахы*, (БҺҺ III: 188) *тәген*, нуг., куман., уйг., хак. *тағы*, кырг., каз. *тақы*, каз., к.-калп., ком., к.-балк., төркм. *дағы*, тув. *дағын*, як. *даа* һ.б. «тагы; хәер» < бор. төрки (ДТС: 536) *taqï* id. ← *тақ* (к. **Так-у**) фигыленнән ясалган сүз, чаг. ш. ук монг., бур. *дахин* «тагы, тагын, кабаттан» ← *даха-, дага-* «иярү; тагылу»; тунг. *даки, дахи* «тагы, тагын, яңадан» ← маньч. һ.б. *дахи- ~ даху-* «кабатлау» һ.б. (ССТМЯ I: 191–192). Чув. *тата* «тагын» < тат. **тагы да.**

Бор. төрки *тақы* < *таққы,* ә *тақын* < *таққын* булса кирәк. *Такы* сүзенә тагы **тәкый** (к.) һәм **дәхи** (к.) сүзләре кайтып кала. Өстәвенә, **да//дә, та//тә** кисәкчәсе (тат. диал. **дагын//дәген** варианты күрсәткәнчә) шул ук **такы, такын** сүзләреннән килә, к. бу хакта Шараф: 238; Räsänen 1969: 497; Мухамедова 1973: 159; ЭСТЯ III: 122–124.

**ТАҖ** «венец, корона» < фар., гар. *тāҗ* < бор. фар. *taga, taka, thag* (Крачковский: 359; Platts I: 304). Будагов I: 330.

**ТАҖИК** «таджик» к. **Тази.** Татарларга бик билгеле булган бу этноним тур. төрле фикерләр бар. Шуларның берсе тур. Будагов I: 330 (тәфсилле; *таҗик* сүзен *таҗ* сүзеннән чыгара). Бор. Казанда *тәзик* дип Урта Азия сәүдәгәрен атаганнар.

**ТАЗ** «шелудивый; лысый; парша» > морд. М. *таз* «кычу» < гом. кыпч., чыгт., уйг. *таз,* бор. төрки *taz* «таз; кырчын» ~ угыз. *даз* id. < **тāрг,* к. венг., бор. монг. *tar* «таз; шома; чәчсез-үләнсез», монг. *тарағай* «кырчын; кырчынлы» > тат., як. *тарағай* «таз кеше» ~ тунг. *тарака* id. (Пекарский: 2564); көнч. төрки телләрдә *тас* «таз» варианты икенче бер сүз – **тас** «яман кол» сүзе белән буталган (к. **Тас II**). Радлов III: 915, 925; Räsänen 1969: 467; ЭСТЯ III: 124–125.

**ТАЗА** (Троянский I: 305) «чистый; здоровый, сильный» > себ. тат., чув. *таса*, удм. (Насибуллин: 139) *таза*, мар., морд. *таза*, мар. диал. (Иванов, Тужаров: 214) *тäжä* id. < гом. кыпч. *таза* (кар. *тэзэ*) < фар. *тāзä* (үзб., таҗ. *тоза*) «таза, саф, йөгерек (агымсу тур.)» – *тāхтāн* (таҗ. *тохтан*) «йөгерек, чабу, ашыгу, омтылу» фигыленең нигезе (Platts I: 304, 306). Федотов II: 179–180.

**Таза** сүзе Идел-Урал телләрендә бик актив һәм киң мәгъ. кулланыла: **тазалык** (~ чув. *тасалăх*), **тазар-** һәм **тазарт-, тазала-** һәм **тазалан-** сүзләре барысында да бар.

**ТАЗЗИТ** «пигалица» (С. Хәким) ~ удм. *тэзык* id. Ачык түгел.

**ТАЗИ, тазый** иск. «быстроходный, борзый»: **тази ат** «лошадь арабской породы (отличающаяся быстрым бегом и неутомимостью)», **тази эт** «борзáя» ← фар. *тāзӣ* «шәп, елгыр; гарәп, гарәп затлы», *тāзик* «гарәп каны булган зат (кеше, ат); таҗик» ← *тāхтāн* «чабу, омтылу, атлыгу» фигыленең

нигезе **tagt* > **taǯ* ~ **taz* сүзеннән. К. **Таза.** Тимергалин: 432.

**ТАИФӘ** «род; группа родственников; класс людей» < гар. *ṭā'ифä* id. *twф* «әйләнү» тамырыннан; шуннан ук *тәwaф* «кемгә дә булса барып кайту, аралашу; хаҗ вакытында Кәгъбә тирәли әйләнеп чыгу» > себ. (Тумашева 1992: 205) **тауап** «(гыйбадәт буларак) түгәрәк ясап әйләнеп йөрү». Махсус терминологиядә **таифә** – «кәрап, очкыч экипажы (командасы)».

**ТАЙ I** «жеребёнок от одного года до двух лет», диал. (ТТДС I: 284–285) «жеребёнок» < гом. төрки (Радлов III: 765) *тай,* аз. *дай (дайча)*, як. *тый* id.; *тай* сүзе дөя һәм үгезләр токымына да караган (к. Будагов I: 732; БТДҺ: 300). Чув. *т'ыха, тăйха, тиха, тике* «тай» < *тайқай* ~ монг. *тайиқай*, бур. *дааган* id. (*-кай* ~ *-қан//-ган* иркәләү кушымчалары). Венг. *csikо* «тай» сүзе дә шул рәттән булса кирәк. Чаг. себ. (брб.) *тайчақ,* (Радлов III: 765, 770) *тайдзақ, тайзақ* «тай, тайчык». К. **Тайлак I.** Räsänen 1969: 455; Федотов II: 237. Рус. (< тат.) *тай* тур. Аникин: 523.

Дерив.: диал. **тайлы, тайсыз; тайла-у** «колынлау».

**ТАЙ II** (ТТДС I: 293), **тайы** (Будагов I: 552) «дядя, дядька, человек, который по древнему тюркскому обычаю брал на воспитание сына своей сестры», «тётя, тётка, тетушка» < гом. кыпч., к. кырг., үзб. (ЎХШЛ: 355) *тай,* төркм. *даайы,* як. *таай* id., ш. ук «ана ягыннан нәсел-нәсәпнең гомуми атамасы» (к. **Тагай I, Такай**). Госманлы империясендә **дайы** – биләмә (колония) идарәчеләренең атамасы (аларның кызы яисә бирәр кыз кардәше солтан сараенда әманәт буларак тотылган), Төркиянең үзендә (бигрәк тә яничәриләр телендә) *дайы* дип һәртөрле начальникларны хөрмәтләп атау гадәттә булган (чаг. хәз. рус. *шеф* «остаз, җитәкче һ.б.ш.»). Гарәп илләрендә *дайы* «губернатор» мәгъ. кулланылган. К. Будагов I.

**Тай** сүзе кыт. *тайши* «хөкемдарның остазы, тәрбиячесе», *тайцзы* «тәхет варисы», *тайҗы* «династиянең нигезләүчесе» һ.б. сүзләре белән чагыштырыла: мәгънә структурасы җәһәтеннән бу сүзләр төрки **тай ~ тайы** сүзенә бик туры килә: төркиләрдә тәхет варисы булып патшаның кыз кардәшенең улы (ягъни хөкемдарның үз токымы түгел) исәпләнгән. Кыт. *тай*, гомумән, «зур, олы, олуг». ЭСТЯ III: 127–129; ССТМЯ: 151–152. К. **Тайчи.**

**ТАЙБУГА** тар. – титул сибирских князей у татар. Тәүдә бер кеше исеме булган. К. **Тайчи.**

**ТАЙГА I [тайга]** «тайга, (преимущественно хвойный) лес в Сибири» < рус. *тайгá* id. Рус сүзе үзе себ. тат. теленнән алынган, ләкин төбендә монг. сүзе дип исәпләнә, к. Аникин: 523–929. Безнеңчә, ихтимал, кыт. *тай ха* «зур үсентелек» сүзеннән таралгандыр.

Дерив.: **тайгалы, тайгасыз; тайгалык.** Чаг. түбәндәгеләрне.

**ТАЙГА II [та$^{о}$йға]** (Тумашева 1992: 200) «болото». Чаг. алт., чулым. *тайға, тайыға* «тоташ урман арасыннан аерылып күренеп торган ялангач (вак үләнле, мүкле) зур, биек тау». Тат. һәм алт. сүзләрендә уртак момент – «үләнлек, агачсыз мәйдан (зур сазлыкларда агачлар үсми диярлек)». К. түбәндәгене.

***ТАЙГЫ [та$^{о}$йғы]** «знаки, метки на деревьях в лесу для обозначения пути, тропы» – «зур урманда адашмас өчен агачларга салынган тамга-кирт, юнылган урын һ.б.» ~ рус. (Аникин: 525) *тайгыз, тайгыс* id.

Дерив.: (Тумашева: 200) **тайгыла-у** «агачларны киртләп тамгалау».

**ТАЙКАН** (Тумашева 1992: 200) «борзая, охотничья собака» ~ каз., алт. диал. *тайқан*, чыгт. *тайған*, бор. төрки (ДТС: 528) *tajɣan,* яз. монг. *tajıɣan* > калм. *tääɣan* id. Будагов I: 339; Räsänen 1969: 456; ССТМЯ II: 152; Аникин: 523.

**ТАЙЛАК I** «верблюжонок по второму, третьему году» (Будагов I: 331) < гом. төрки *тайлақ* (күп телләрдә хәзер онытылган), аз. (АДДЛ: 166) *дайлаг, дайғул* id. Zenker (: 594) буенча, бу сүз асылда «тайга охшаш; йөгәнсез» дигән мәгъ.

**ТАЙЛАК II** (себ., ЗДС: 601) «большой желоб для источника, ключа» – *тай улак* «зур улак» булса кирәк. Теләсәң-теләмәсәң дә кыт. *тай ~ дай ~ да* «зур, дәү» сүзе искә төшә. Шул ук компонент югарыдагы сүздә дә булса, ул *тайлак < тай ылак* (к. **Ылак**) булырга тиеш. Һәм **тай I** сүзе шулар рәтендә **тай колын** сүзеннән кыскарган булса да гаҗәп түгел.

**ТАЙПЫЛ-У** «отклониться» ← диал. *тайпы-* «тайпылдыру» фигыленең төш. юн., **тай-** нигезеннән

(к. **Тай-у**). *Тайпыл-, тайпы-* сүзләре тат.-башк. даирәсендә генә очрый. К. **Тайчан-у.**

Дерив.: **тайпылыш-у, тайпылдыр-у; тайпылыш.**

**ТАЙРА** «родословная; круг родственников» (ТРС 1966). Бу сүзнең барлыгы шик уята: бәлки ул гом. кыпч. *тайпа* < гар. *ṭā'ифä* > тат. әд. **таифә** сүзедер. Яки **даирә** (к.) сүзеннәндер.

**ТАЙРАН, тайраң, сайраң, сыйраң** (Тумашева 1992: 196, 200) «дух-половинник; калека» (бу сүзләр себ. *Сыйыр мүнгән сыйраңнашып, тай мүнгән тайраңнашып,* дигән типсәү – туй такмагыннан беленә) << тибет. (МНМ II: 535) *тхеүранг* (*theuraŋ*) һәм *çеүраң* «бер аяклы, бер куллы, бер күзле парлы табигать рухлары» (чаг. **Ярымтык**); бу сүзләр каз., кырг., монг. һәм тува мифологиясендә дә очрый (*тэрэң, тыйраң*). Күрәсең, мәҗүси тат. мифологиясендә популяр булганнар. К. ш. ук уйг. (Малов 1967: 37) *теішин* һәм *сеішін* берсе табигатьне, берсе кешеләрне яралткан ике илаһи зат». Кырг. эпосында *тәрән, терен* Тибет батыры, Күгэтэй мәргәннең дошманы. *Тайрак* «чатан дөя», *тайра-* «чатанлап йөгерү».

**Тайраң** һәм **сыйраң**нарның аяклары берәр генә булгач, алар атка һ.б. икәүләшеп атланалар икән дигән мифологема бар. *Тайраңнашу* ~ *сыйраңнашу*, димәк, «меңгәшү».

Тибет-монг. *тэрэң*нәре үгезгә, сыерга һ.б. гадәттә менелмәгән хайваннарга менеп йөриләр.

**ТАЙРАҢНА-У** диал. «бег-соревнование пар, связанных ногами вместе» – ике малайның, берсенең сул аягын икенчесенең уң аягына ашык тәңгәлендә бәйләшеп, шундый ук парлар белән ярышып йөгерү (сабантуй номеры) ~ каз. *тайраңда-у* id. К. югарыдагыны.

**ТАЙ-У** «поскользнуться; ускользать»; күч. «удрать» < гом. төрки (Радлов III: 766–767) *тай-* id. Чаг. чув., мар. *тай-, тӓй-* «бөгү, ию» (бу сүз мәзкүр телләрдә ифрат продуктив нигез). К. Будагов I: 733; Федотов II: 163.

Дерив.: **таел-у, таеш-у, тайдыр-у; тайгак, тайгалак, тайганак;** к. **Тайрыл-у, Тайчан-у.**

**ТАЙЧАН-У, тайчын-у** «уклониться» ← *тайчы-* «читкә тайдыру» фигыленең кайт. юн., *тай-* нигезеннән (к. **Тай-у**). *Тайчын-, тайчы-* сүзләре тат.-башк. даирәсендә генә: каз., к.-калп. *тайсал-* «тайчану»ның ясалышы икенчерәк булса кирәк (*тайчан-* > *тайшал-* булырга тиеш иде).

**ТАЙЧИ** (до XIX века сохранялось как имя собственное) – «княжич» – себ. татарларында административ берәмлек башлыгы атамасы булган һәм монг. *taiǧi* < кыт. *тайцзы* «башлык» (*тай* «зур, бөек; остаз») сүзеннән. Монг., маньч. *тайҗи* «изге рух». Бу сүз тур. зур әдәбият бар, к. Аникин: 526; МНМ II: 109.

Көньяк Урал регионында таралган *Тайчин, Тайсин* фамилияләре шул *Тайчи* исеменнән булса кирәк.

**Тайчи** сүзе белән калм. *тайша* һәм иске себ. **тайбуга** (← яз. монг. *taibuu* < кыт. *тайбао*) титуллары тамырдаш, ләкин бердәй түгел (кыт. *тай* + төрле сүзләрдән киләләр). **Тайбуга** Себердә ялгызлык исеме буларак та билгеле. ССТМЯ I: 152. **Тай** (кардәшлек термины) тур. Räsänen: 454, 455, 456.

**ТАЙЯР [та°ййар]** «готов, проворен, проворный (в деле)» < гар. *ṭаййāр* id., «очып торучан» ← *ṭӣр* «очу» тамырыннан.

Дерив.: **тайярлык; тайярлан-у.**

**ТАК I** «нечет» < гом. көнб. төрки (Радлов III: 777) *тақ* ~ фар. *тäқ* id., ир. сүз булса кирәк (Юдахин). Чыгт., төркм. *тәк, тәәк* «ялгыз; тәү» сүзенең *тақ* сүзенә багланышы шикле. К. **Така.**

**ТАК II** диал. «пустота; небытие; пустое пространство» (*такка таяну* «юксыллыкның чигенә җитү; бөтенләй юкка өмет итү») ~ каз., кырг., алт., госм. һ.б. *тақ* id. (Радлов III: 778) < бор. төрки *taq* «юксыллык» (к. Gabain 1950: 338; ДТС: 350, 536), к. ш. ук тат. *таксы-у* «бетүгә якынлашу», *тақсық* «бетүгә якынлашкан (азык-төлек тур.)». К. **Таксы-у, Такыр.**

**ТАК III** – имитатив стуку (производимому деревянными предметами) ~ гом. төрки, монг. һ.б. (барча телләрдә, хәтта имитативларга ярлы рус телендә дә очрый торган **так** һәртөрле кискен бәрелү-сугылу авазларын белдерүчән тәкълиди сүз. К. рус хәрби җырында:

*Так, так, так говорит пулемётчик,*
*Так, так, так говорит пулемёт.*

Чаг. **Такыл II, Такыр II.**

Дерив.: **так-так, так-ток,** к. **Токыл-такыл, Так-у.**

**ТАК IV** «а́рка; полукруг или острый угол верхней части окна, двери и т.п.» < фар. *tāķ* id. Күп телләрдә очрый. Номинханов 1975: 143.

**ТАКА, тақы, тәқә** (БТДҺ: 304 һ.б.) «совершенно, совсем» (**такы ялгыз** «совершенно одиноко» һ.б.ш.) ~ үзб. *тоқа* «бер генә, ялгыз». **Так I** белән баглы булса кирәк. К. ш. ук монг. *таг* «така».

**ТАКАЙ** «тётушка» к. **Тай II.**

**ТАКАТЬ, тәкать** «терпение (в напряжённом положении)», диал. (ТТДС I: 125, 440) **дахат, тәхәт** < гар. *ṭāķat* id. ← *ṭwķ* «чыдау» тамырыннан.

**Такать** – продуктив нигез: **такатьле, такатьсез; такать тоту** «чыдап тору».

**ТАКМАЗА** – фольклорный жанр – рифмованый детский потешный рассказ, иногда – дразнилка ~ кырг. *тақмаза* id., төр., кр.-тат. *тапмаджа*, төркм., үзб. (ЎХШЛ: 245) *тапмача* «табышмак» сүзеннән **такмак** (к.) тәэсирендә үзгәреп килеп чыккан. Бу сүз формалашуындагы *ч* > *җ* > *з* күчешләре мишәр сөйләшләрендә була алган.

Дерив.: **такмазалы, такмазасыз; такмазала-у; такмазачы.**

**ТАКМАК** «частушка; песенка для пляски» (**такмак әйтү** «хором исполнять такие песенки, под такт которых и пляшут»), «прибаутка» > чув., мар., удм. *такмак* id. < гом. кыпч., к. нуг., ком. *тақмак*, каз., к.-калп., алт. *тақпақ,* хак. *тахпах* «такмак; мәкаль, табышмак». В.В. Радлов (III: 793–794) буенча, тат. **такмак** сүзенең «табышмак» мәгъ. өстенлек иткән. Гомумән, бу сүз тат. **такы → тақымақ** ~ уйг. *тақимақ* «кабатлау; тагу, рифмалау» формасыннан килә. К. ш. ук иске чув. (< тат., әлбәттә) *такмак* «кобаҗыр, туйда хуҗаларны рифмалап мактау» (к. Прокопьев: 14–15).

Чув. һәм мар. *такмак* «чәрмә, туйга барганда ашамлыклар һ.б.ш. салып алып барыла торган букча» сүзе дә татарчадан һәм ул **так-у** сүзеннән матди әйбер мәгънәсендә турыдан-туры ясалган. Федотов II: 166–167. Добр. сүзлегендә *taqtaq* «үлгән кешене сагынып җырлау» дигән сәер аңлатма бирелә.

Дерив.: **такмаклы, такмаксыз; такмакла-у; такмакчы.**

**ТАКСЫ-У** «оскудеть» – **так II** сүзеннән, чаг. *бур → бурсы-у, җик → җиксе-ү, как → каксы-у, көң → көңсе-ү* һ.б.; мисаллардан күренгәнчә, *-сы*//*-се* кушымчасы тискәре, негатив характеристикалы күренешләрне белдерүчән сүзләр ясауда кулланыла.

Дерив.: **таксыл-у, таксыт-у; таксык** (бетүгә йөз тоткан, к. мәкаль: *Бар чагында каксык, юк чагында таксык*).

**ТАКТА** «доска; кусок материи, предназначенный для сшивки» > чув. *такта* < гом. төрки (Радлов III: 802) *такта* id., ш. ук «эскәмия, урындык, тапчан», хак., тув., госм. *тахта* «күпер» < фар. *такта, тахта* «идән, күпер; такта» бор. һинд *тахта* «киселгән, юнылган, шомартылган» сүзеннән (Platts I: 313). К. **Тәхет. Такта** сүзе мөселман динендәге барча халыклар телендә очрый. Рус. *такта* «көймәдә утыргыч» тур. к. Аникин: 527; Федотов II: 166 (бик ярлы).

**ТАКТАБАШ** (ЗДС: 602) «сени, крыльцо; односкатная крыша» < төр. *tahtapoş* < фар. *таһтапош, таһтапуш* «такта түбәле (корылма)»: *таһта* «такта» + *пош ~ пуш – пушыдан* «каплау» фигыленең нигезе. Eren: 391.

Тат. сөйләшләрендә **тактай**, каз. *тақтай, тақтаи* «тактадан ясалган» сүзе очрый. Ул фарсыдан үзгәртмичә алынган: анда *таһта* – исем (материал) мәгънәсендә генә, ә «тактадан ясалган» мәгънәсе *тактаи* сүзе белән бирелә.

**ТАК-У (тагу, такты)** «прицепить, привязать» < гом. төрки (Радлов III:778) *тақ-,* алт. *таң-,* уйг., каз. *така-* id., төркм., угыз. *дақ-*. Чаг. **таң-у** «бәйләү; тагу». Будагов I: 334; Мухамедова 1973: 156–159; ЭСТЯ III: 129–130.

Дерив.: **тагыл-у, тагын-у, тагыш-у, тактыр-у; тагылма, таккыч** һ.б. К. **Такым.**

**ТАКЫ** (ТТДС I: 395) «скудно, скуден». **Таккы** яңгырашыннан булса кирәк, к. **Таксы-у**; к. ш. ук **Такы-токы.**

**ТАКЫЛ I,** диал. (Троянский) **тагыл** «инструмент для обеспечения ровности, прямизны при изготовлении проволоки, при резании полос и при строгании», «узор (у ювелиров)», диал. (БҺҺ III: 164) «рубанок; наструг» > мар., удм. *такыл* id. ~ кар. *тақыл* «ярыклы герләр тезү (асу) өчен сүрек», тув. *тағлы* «такыл (көмешчеләрдә)». Таралышына караганда, бу сүз төрки булырга тиеш. Гомумән – ачык түгел. Чаг. **Талык.**

Дерив.: **такылла-у** – «тигез-туры итеп кую, кисү, телү» һ.б. (к. Будагов I: 333, 727).

**ТАКЫЛ II: такыл-такыл** – имитатив стукам, а также резкой болтовне – **так (тақ-тақ)** имитативыннан. Күп төрки телләрдә очрый. К. **Такы.**

**ТАКЫЛ III** (ТТДС I: 395; БТДҺ: 301) «хороший, хорошо; вполне здоров» ~ нуг., к.-балк. *тақыл* «иң яхшысы», төр., кр.-тат. *taqıl* «кадәр, чаклы; иң яхшысы». Ачык түгел.

**ТАКЫМ I** «группа; набор» < кр.-тат., чыгт., госм. һ.б. *тақым* id., уйг. *тақым* «тезем; архипелаг» **тақ-у** фигыленнән (к. Радлов III: 787–788). Гар. *ṭāқим* «комплект» (төрки алынма) сүзе нигезендә *ṭқм* «җигү; киендерү» тамыры пәйда булган.

**ТАКЫМ II** «шпоры (у колена)» < гом. кыпч. *такым* «тез бөгелеше». Ачык түгел.

**ТАКЫР I** «гладкий, ровный (о дороге); без растительности (о поверхности земли); скудный» > чув. *такăр*, мар., удм. *такыр* id. удм. (Кельмаков 1977: 59) *такър бусь* ~ мар. (Иванов, Тужаров: 214) *тäкӹр пасу* – «такыр басу», морд. М. *такор* < гом. кыпч., алт. *тақыр*, уйг. *тақир* id. < *тақ қыр* яки бор. *так-ыр* (**тақ-* «бетү» фигыленнән була ала) **тақ** «юксыл, җетек» сүзеннән, к. **Такы-токы.**

**Такыр басу** «алмаш басу, бер елга чәчелмичә сөреп калдырылган басу» *тақ* (ягъни «парсыз, җөп түгел») сүзеннән булса кирәк. **Такыр басу** сүзенең Идел-Урал регионында таралуы игенчелек культурасын таратуда татар халкының хәлиткеч ролен күрсәтә. Ләкин мар. *тагыр* варианты турыдан-туры татарчадан түгел, чувашчадан.

Räsänen 1969: 457, 470; Федотов II: 165–166 (тат. **такыр** сүзе чувашчадан, ә чу. сүзе бор. гом. төрки *тәкир* «тигез» сүзеннән димәкче; ләкин чув. *такăр – тагыр* дип әйтелә һәм тат. теленә дә шул яңгыраштa керер иде; ә тат. *такыр* > чув. *тагыр* гомуми закончалык буенча чув. телендә интервокаль тартыкларның яңгыраулашуыннан килә).

Дерив.: диал. **такырак, такырлы, такырсыз (такыр** сүзенең исемләшкән формасыннан); **такырлык; такырла-у, такырлаш-у, такырлат-у.**

**ТАКЫР II: такыр-такыр, такыр-токыр** – имититив звукам, производящим негружёной телегой по твёрдой сухой просёлочной или каменистой дороге – гом. төрки сүздер, к. добр. (Dobr. III: 273) *taqır* (дериватлары белән), төр. *takır* id., шуннан **такыр-да-у** һ.б.

**ТАКЫ-ТОКЫ** (ТТДС I: 395), **такы-тыкы** «скудно; еле сводя концы» – **такы** (к.) сүзенә аллитерацион **токы** сүзен тагып ясалган. Бу тагылма мөстәкыйль сүз булырга да мөмкин, к. **Токын.**

**ТАКЫ-ТЫКЫ** – имитатив прерывистым стукам – **так-ток, так-тык** тәкълиди сүзләр нигезендә ясалган.

**ТАКЫ-У** (ТТАС III; БТДҺ: 301) «повторять одно и то же (назидательно)» ~ гом. төрки *тақы-* ~ монг. *таqи-, тахи-* «кабатлау» (к. **Тагы**) һ.б. (гомумән сирәк) тәкълиди *так (//тык//тук//тӧк)* сүзеннән, фигыль – аның исем дип фараз ителгән формасыннан, чаг. **Туқы-у.**

**ТАКЫЯ [таᵒқыйа],** диал. **тайка, тайика, тайха** (ТТДС I: 394; ТТДС II: 285) «венок; венец, девичья шапка (различных видов)», диал. «тюбетейка» > мар., удм. *такйа, такия, такъя,* чув. *тохйа* > *тухйа* < гом. кыпч., госм. һ.б. *тақыйа* «такыя, түбәтәй, шлем» < фар. < гар. *ṭāқийā* «такыя, түбәтәй» ← *тwқ* «әйләндереп алу». Бу тамыр үзе фар. *тāқ* «так, гөмбәз» сүзеннән (к. **Так III**).

**Такыя** сүзе гомумән бик киң таралган, аның рефлекслары күп телләрдә очрый (мәс., рус. *тафья* «опричник кәпәче»). К. **Тукыя**. Будагов I: 335; Радлов III: 789; Räsänen 1969: 457; Федотов II: 259.

**Такыя** продуктив нигез: **такыялы (кыз)** «кызлыклы кыз, яшь кенә кыз»; **такыябаш** «испәрәк»; **такыячан.**

**ТАЛ I** «ива», диал. «гладкий ствол»; «пучок; веточка» < гом. төрки (Радлов III: 875) *тал* «тал, таллык; чыбык; чем; бөртек», төр. *dal* «тармак, тармакланыш», *tal* «ботакча, тармакча», бор. төрки (ДТС: 158, 528) *dal* «тармак», *tal* «тал» ~ санск. *dal* «бөре; үсенте; чем, тәлгәш, җилпәзә», индонез. *tal* «җилпәзә яфраклы пальма», гар. *ṭалх* «акация». Бу охшашлыклар очраклы микән? Чаг. **Тәлгәш.** Рус. диал. *тал* (шуннан *таль, талы, талина, тальник* «таллык») тур. Аникин: 527–528.

**Тал** продуктив нигез: **таллы, таллык**, диал. (ДС I: 177) **талла-у** «бөртекләү». Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 130–131) «тал агачы» һәм *тал* (к. **Тал II**) «тармак, чем, ябь» икесе ике тамырдан димәкче.

**ТАЛ II** диал., иск. «пучок, (искусственная) веточка, перо на головном уборе, на девичьей шапке (у татар в отдельных местностях, обычно у казахов)» к. **Тал I.**

Кызлык, өйләнмәгән егет булу билгесе итеп баш киеменә каурый (к. **Өке**) беркетү күп халыкларда (мәс., нимесләрдә) булган. **Тал** сүзенең мәгънәсе онытыла төшкән шундый җыр бар:

*Тал бер генә, тал бер генә,*
*Тал бер генә була ул.*
*Җан җараткан, күңел тарткан*
*Җар бер генә була ул.*

Әлбәттә, тал агачы бер генә булмый. Монда бөтән тал тур. сүз бара.

Бу тал йөртү гадәте, ихтимал, кошларны күзәтү нигезендә тугандыр: язын кайбер кошчыклар пардаш табу өчен томшыклаларына кечкенә каурыйчык, ботакчык кабып йөриләр, бүтән иштәшләренә тәкъдим итәләр икән: «Әйдә, оя корыйк», янәсе. Андый кошларның кыланышы оя кору өчен гадәттәгечә материал ташудан аерылып тора икән.

**ТАЛАЙ (бер талай)** «значительное количество» ~ башк. (БТДҺ: 301) «гел, һәрвакыт; байтак» < гом. кыпч., уйг. *талай* «байтак; күп кенә; берничә», чыгт. *талай* «шактый күп; бик күп»; бу сүзне Г. Рамстедт (1957: 73) бор. төрки (ДТС: 528–529) *talaj, taluj* «океан, диңгез» ~ калм. *dalaa,* бор. монг. *dalaj* id. сүзе белән чагыштыра. Морд. *талай,* удм. *талай* «күптән үткән, күптәнге» тат. сөйләшләреннән булса кирәк (татар гомумхалык һәм әд. телендә **талай** сирәк кулланыла). Федотов II: 167 (чув. *талай* «диңгез» мәгъ. ди). К. **Дала.**

Монг. империясендә *далай диваны* «гомумхалык диваны» инже диванына (киңәшенә каршы куелган, к. Velidi: 238.

**ТАЛАК I** «селезёнка» > чув. *талак* < гом. кыпч. *талақ,* угыз. *далақ,* төркм. *даалақ* ← бор. төрки (ДТС: 528) *tal,* уйг. *тал,* як. *таал,* төр. *tahal* id. Бу сүзне фонетик җәһәттән гар. *ṭихāл, ṭухāл* «талак» (ЛТ II: 7) сүзеннән дип әйтеп була, ләкин нишләп төркиләр – терлек анатомиясен бик яхшы белүчеләр – бу сүзне гарәпчәдән алырга тиешләр икән?

*Талак* сүзен алт. *телүүн* < монг. *дэлүүн* < яз. монг. *delüün, deligün* ~ маньч. *дэл'ахун* «талак» белән чагыштыру фонетик-морфологик җәһәттән нигезләүгә мохтаҗ. Räsänen 1969: 457; Федотов II: 167–168; ЭСТЯ III: 137–138; Eren: 103.

Дерив.: диал. **талакла-у**, к. **талаулау.**

**ТАЛАК II** «развод (супругов)» < гар. *ṭалāқ* id. ← *ṭлқ* «ирекле, азат булу» тамырыннан. Мөселманлык (шәригать) нигезендә киң таралган. Будагов I: 738 (тәфсилле).

Дерив.: **талаклы, талаксыз; талакла-у.**

**ТАЛАК III** «колики; ящур; падучая болезнь» < *талғақ* (к. **Тал-у**) булса кирәк, гомумән, бу сүзнең мәгъ. ачык түгел (к. БТДҺ: 302). Чаг. **Талак I.**

Дерив.: **талакла-у** (ТТДС I: 305) «хәлсез аунап яту; үлү».

**ТАЛАН** «случайный успех, везение; талан» ~ чув., мар., каз. (ҚТДС: 315), хак., чыгт., төр. *talan* «мач, бәхет» id. бу сүзне күп очракларда (як. һ.б. Себер телләрендә) рус теле аша таралган дип, ә рус сүзе чыгт. *талан* (**талан-тараж**) «талап алынган мал, талау» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан дип карыйлар, к. Федотов II: 168; Аникин: 529 (күп авторларны искә ала). Безнеңчә, **талан** «бәхет; уңыш; (каз.) абруй» **талан** «талау» белән бердәй түгел. Монда кискен мәгънә үзгәлекләре ярылып ята. Дөньяда һичбер халык талап алынган малны «уңыш, бәхет» дип карамый. **Талан** сүзе *таңла-у* «сайлау, сайлап алганда мач килү» сүзеннән яисә кыт. теленнән (бор. кыт. *tai laŋ* «зур өлеш»?) булырга мөмкин.

*Талан* рус телендә шактый абстракт мәгъ. сүз, андый сүзләр бүтән телләргә тиз генә алынмыйлар. Бур., як., эвенк. *талааң* «бәхет, уңыш» (эвенк. телендә шактый дериватлы: *таллань, талачич* «уңышлы рәвештә», *талалкан* «бәхетле») рус теленнән түгел, борынгылыктан киләләр. Һәм ССТМЯ II: 157 дә бу сүзләрне рус сүзеннән дип күрсәтми.

**ТАЛАУ [таᵒлаw]** диал. (ЛТ I: 122) «падучая болезнь у скота» < гом. кыпч. *талаw*, каз. *талақ,* алт., шор. (Радлов III: 891) *талғақ* id. *Талак* һәм *талау* – паронимнар: беренчесе *талган* сүзеннән, *тал-у* фигыленнән, икенчесе *талла-у* фигыленнән, к. **Тал-у.**

**ТАЛА-У I** «грабить; терзать; ругать» > мар., удм. *тала-*, мар. *тола-,* чув. *тола-, тула-* < гом. төрки (Радлов III: 878, 880) *тала-*, бор. төрки (ДТС: 528) *tala-, talï-* id. ~ бор. монг. *tala-* id. (Поппе 1938: 338). Габен (Gabain 1950: 337) *tala-* «җимерү, кыйрату», ә *tali-* «талау» дип аера; угыз. *дала-*, төркм. *даала-* «тешләп өзгәләү» булса, бу фигыльне *тал, дал* < *даал* «җепсел, сеңер, тармакча» сүзеннән (*тал-а-* һәм *тала* «сеңерләргә; җепселләргә аеру») дип фаразларга мөмкин. К. монг. *талла-* «бүлешү; кисеп алу», *таллага* «талау күре-

неше» ~ төр. *dalla-* «бүлгәләү» (Будагов I: 336). Räsänen 1969: 458; Федотов II: 244–245; ССТМЯ II: 159 (эвенк., монг. *тала-* «талау» эвенк. һ.б. *тагди-* «тартып алу, тартып чыгару» белән чагыштырыла); ЭСТЯ III: 135–137. Чаг. **Тала-у II.**

**Тала-** бик продуктив нигез: **талаш, талашлы, талаш-у, талан-у, талат-у** (юн. формалары аерым мәгъ. алган), иске тат. *талан* «талау күренеше» (> удм. *талан* id.) ~ уйг. һ.б. *талан* id.

**ТАЛА-У II** диал. «сдирать кору; обстругать; выдирать». Моннан илле еллар элек мин Башкортстанның Илеш районы балта осталары телендә *бүрәнә талау* сүзен ишеткәч, тәүдә гади *талау* сүзенең метафорик кулланылышы дип уйлаган идем, ләкин бераздан төп мәгънә шул – «каезлау» дигән фикергә килдем. Бу **тала-у** < **талла-у** «ялангачлау» ул. К. төр. *dal* «ялангач; бизәлешсез, бизәксез». Бу сүздән төр. телендә характерлы тәгъбирләр ясалган: *dal fes* «бизәксез-нисез фәс, кәпәч», *dalkavuk* «чалма нигезе булып хезмәт итә торган каты кәпәч», күч. мәгъ. «бернинди фазыйләте дә булмаган кеше»; *dalkılıç* «кылычын кыныннан чыгарган, ялангачлаган кеше», күч. мәгъ. «волонтёр, үзе теләп хәрби эшкә катнашучы»; *daltaban* «яланаяк» һ.б. К. ш. ук Dobr. I: 501.

Бу **тала-у I** һәм **II** икесе дә **талла-у**дан, аларның тамыры **тал** төбендә ни икәнлеге бигүк ачык түгел: *тал I* «ялангач кәүсә, ялангач тармак»мы яисә *тал II* «сүс, каурый»мы? Бу ике тамыр бер бор. нигездәнме, аерым-аерым тарихи тамырларданмы?

**ТАЛАШ** «ссора» – бик закончалыклы рәвештә **тала-у** фигыленнән кебек, ләкин менә иске әд. телдә *тәлаш* «сабырсызлык» < гар. *ṭälāš* «сабырсызлык, талашу» бар.

**ТАЛӘП** «требование» < гар. *ṭaläб* id. ← *ṭлб* «сорау, эзләү; өйрәнү» тамырыннан, шуннан ук **талиб** «студент», **талибә** «студентка».

**Таләп** продуктив нигез: **таләпле, таләпсез, таләпчән.**

**ТАЛГЫН** «неспешно, неспешный» > мар. (Упымарий: 201) *талгын* «урта тизлектә» ← **тал-**, к. **Тал-у.** К. төр. *dalgın* «уйга талга хәлдә».

**ТАЛИГА, талигъ** «звезда счастья; созвездие, под которым родился определённый человек; судьба; счастье» < гар. *ṭāли‘a, ṭāлu̧‘* id., к. Будагов I: 728; Тимергалин: 433.

**Талига** продуктив нигез: **талигалы, талигасыз.**

**ТАЛИР: талир тәңкә** – талер, австрийская монета с изображением Марии Терезии, распространённая в России в XVIII веке: её дарили любимым девушкам ~ мар. (Упымарий: 201) *тальэр тәңгә*, чув. *талер тенке* id. татарчадан булса кирәк. Тимергалин: 434; Зварич: 163–165.

**ТАЛКАН** «толокно; жареная мука» < гом. кыпч., алт., уйг. *талкан* id., алт., хак. *талған* (кайбер телләрдә бүтән күч. мәгъ. бар), тув. *далган* ~ каз., чыгт. (Будагов I: 337; Räsänen 1969: 438) *талқа-* «утта кыздыру, куыру» сүзеннән; к. ш. ук монг. *талкан* «талкынган, вакланган, төелгән», бур. *талхан* «он; икмәк», эвенк. *талган, талганэ* «он; ипи, коймак», маньч. *тала-* «ипи, коймак һ.б.ш. пешерү». *Талкан* сүзен ССТМЯ (II: 157) авторлары кыт. *тань цзянь* < бор. кыт. *tan k'an* «җәеп куыру» сүзе белән чагыштыралар.

**Талкан** сүзенең рус. *толокно* белән тарихи бәйләнешы юк. Рус. диал. (< төрки) *талкан, толкан* «талкан» тур. к. Аникин: 529–530 (шунда ук әдәбият). Гомумән, **талкан** сүзе төрки телләрдән күп күрше (фин-угор, ир., Кавказ) телләргә кергән.

**ТАЛКЫ** «кожемялка; орудие для ломки конопли; время ломки конопли» < **талкы-гы**. Бу сүз күп телләргә кергән. к. рус. (Аникин: 530) *тальки, толки*. К. **Талкы-у.**

**ТАЛКЫ-У** «мять, ломать лён», күч. «повторять одно и тоже» ~ мар. *тул-, тулы-* < *тол-, толы-* < болг. **талы-* < бор. төрки *talgı-* (к. бор. *talgïš-* «тула басышу», ДТС: 529) > алт., як. *талқы-*, тув. *далгы-* ~ монг. *талхи-* «талку; тире иеләү; бер нәрсәне (сүзне күп кабатлау)» бор. **талк-* «йомшарту; талку» фигыленнән.

Бу фигыльдән ясалган **талкы** < **талқыг* (> тув. *далгыг*) > кырг. *талқуу*, гом. кыпч., алт., як., уйг. һ.б. *талкы* ~ бор. монг. *talkin*, эвенк. *талки*, маньч. *талгику* һ.б. «тире йомшарткыч» киңрәк таралган; чув. *тыла* < болг. **тылһа* > венг. *tilo*, мар. *толэ* «талкы» чувашларның болгарларга мөнәсәбәте барлыгын күрсәткән дәлилләрнең берсе (бу сүзләрдәге *а* > *ый, и* һәм *ы* > *а, э* **талкы** сүзенең бүтән рефлексларында күзәтелми). Федотов II: 266; ССТМЯ II: 158. Гомумән, *талк* тамыры ностратик характерга ия, чаг. рус. *толкать, толочь*.

Дерив.: **талкын-у** (күч. мәгъ. «бер генә төрле эштә, шөгыльдә булу»), **талкыш-у, талкыт-у; талкыш.**

**ТАЛМА** «падучая болезнь; эпилепсия» < гом. кыпч. *талма* id. ← **тал-**, к. **Тал-у.**

**ТАЛП** – имитатив колыханию плоского предмета на ветру и т.п., а также обвисанию – асылда, төрки телләрдә иң күптармаклы *йал//дьал//дал//тал//чал//сал* тамыр имитативының *-п* бабыннан (детерминативыннан); вә шуннан *далп-//дьалп-//далп-//талп-//чалп-//салп-* тамырларына даир күп кенә мисалларны бу китаптан табарга мөмкин.

Дерив.: **талп-талп** (сирәк очрый), себ. (Тумашева 1992: 201) **талбаңна-у** «киң булып селкенеп тору», **талбрак (талбырак)** «иске-москы, ертык-портык», **талбыйа** «балыкның суын саркыту өчен көймә өстендә ясалган улак; сәләмә», **талбык** «озын колаклы», **талбыр** «йонлы, йонлач», ш. ук **талбыра-у** «йонлач кыяфәттә булу». К. **Талпын-у.**

**ТАЛПА** «толпа, часть стада» [татар телчеләре бу сүзнең русныкы икәнлегенә шулкадәр ышаналар ки, хәтта диалектологик сүзлекләргә дә кертмиләр, хәлбуки рус телендә бу китаби характердагы сүз – *толпа* 1627 елдан гына билгеле (к. СРЯ 1963: 562) һәм аның ышандырырлык һинд-евр. этимологиясе дә юк]. *Талпа* сүзе миш. сөйләшләрендә еш кына очрый; к. (ТТДС I: 254) *Талпа-талпа куйлар...;* (Татар халык җырлары 1965: 254) *Талпа-талпа күгәрченне Өерәдер карчыга.*

Безнеңчә, *талпа* иске маңгыт (Алтын Урда татарлары), нуг., тат. һ.б. телләрдәге *талба* «группа, өер; клика» сүзеннән килә (к. Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде: 109, 152; Олеарий: 450). Бу сүз исә кырг. *талба, далба, талбаа, далбаа* «киек кошларны алдатып якынлаштыру өчен муляж» ~ к.-калп. *далбай* id., аз. *далвә* «көртлекләрне алдатып якынлаштыру өчен сөлге» (к. Биялиев: 12–26; АДДЛ: 167) ~ монг. *далба* «маска; төркем» сүзеннән. Хикмәт шунда – төрки һәм монголлар дошманны алдату өчен карт-коры яисә әсирләр төркемен хәрби бүлек кебек тезеп, сугыш мәйданына куйганнар (бу хакта күп чыганаклар сөйли). К. ш. ук эвен. *далба* «бер яклы шалаш, лапас», маньч. *далба*, чжурчжэнь. *tähh leh pä läh* «бер як, кабырга» (ССТМЯ I: 193).

Ихтимал, *талпа* ~ *талба* ~ *талма* сүзе чыгт. *тама* < *талма* «оккупацион гаскәр» сүзе (к. Рашид ад-дин. 1952: 54) белән баглыдыр.

Рус. *толпа* бор. рус сүзен иске слав. *тлъпа,* чех. *tlapa*, словак. *tlupa* сүзләре белән чагыштырып, гом. слав. сүзе дип карыйлар (Фасмер IV: 74), әмма «гом. сл.» сүзенең бор. һунн яисә авар теленнән алынган булуы ихтимал.

Төрки *талба* һәрхәлдә **талта** белән тамырдаш, к. **Талта.**

**ТАЛПАН** «клещ» > чув. диал. *талппан* id. ~ башк. диал. (БҺҺ III: 189) *тәлпән* id., каз. диал. (Аманжолов: 408) *талпан* «кандала», хак. *табаңга, табылға* < **талбыға, *талбаңга* «талпан». Чаг. башк. диал. *талпан*, кырг. *талпаң, талпагай* «авыр хәрәкәтле һәм яньчелгән гәүдәле». Гомумән, **талпан** сүзенең чыгышы бигүк ачык түгел. К. **Талпы, Тарпан.**

**ТАЛПЫ** диал. «широкий и плоский». Чаг. монг. *далбай-* (← төрки *талпай-*) «яссы, киң булу», *далбан* «яссы, киң».

**ТАЛПЫН-У** «махать крыльями; порываться; стремиться» > чув. *талпӑн-,* мар. *талпын-* < гом. кыпч. *талпын-*, каз. диал., төркм. һ.б. *далпын-,* бор. төрки *talpın-* id. ← гом. төрки *талпы-*, як. *талба-,* монг. *далба-* «канат кагу; кул болгау» (ш. ук *талп эт-*) фигыленең кайт. юн. К. **Талп.** Räsänen 1969: 459.

Дерив.: **талпыныш-у, талпындыр-у; талпыныш.**

**ТАЛТА** (З. Бәшири), диал. (ДС I: 177) **талда** «защита; утешение», ~ кр.-тат. *talda* «явым-төшемнән ышык; күләгә; химая» > чув. диал. *талта* < гом. кыпч., чыгт., госм., аз., үзб. *далда*, кырг. *далдаа* «ышык, пана, калкан; химая, таяныч» < яз. монг. *dalda* (> бур. *далда*) «яшеренү урыны, яшеренеп күзәтү пункты» ← монг. *дал-* < **тал* «яшерү, каплау» сүзеннән (шуннан ук *далба* < *талба* > *талба*, к. **Талпа**); к. ш. ук төр. диал. *dulba,* төр. *dulda* «ышык, ябу, япма», эвенк., эвен. һ.б. *далда* «бер яклы шалаш; ышыклык, яшерү һәм яшеренү урыны» һ.б. (күп сүзләр, к. ССТМЯ I: 194); як. диал. *далла, далда* «кыргый болан аулаганда кулланыла торган җайлама: ике чаңгыга беркетелгән тишекле калкан – аучы шуның артына яшеренеп һәм тишектән күзәтә-күзәтә боланга шул җайланманы шудырып якынлаша» (к. Романова, Мырьева, Барашков: 168). Монг., бур., як. *дал* «кәртә, кура» *дал-* «яшерү» сүзенең исем коррелянты булса кирәк. **Талта** исем нигезенең дә фигыль коррелянты бул-

ган. XVI г. татар шагыйре Максудидә: *...бер өртек* [өртү] *сез мәңа виреңез, та далданаем мән аңа.* К. ш. ук чыгт., аз. (Будагов I: 549) *далдаламак* «аркага яшерү, каплау», каз. *далдала-* «икейөзлеләнү». Чаг. **Талпа, Тал-у.** Räsänen 1969: 131; ЭСТЯ III: 138–139 (тат. сүзләре китерелми).

**ТАЛТАЙ-У** (Н. Исәнбәт) «растопырить ноги, стоять с широко расставленными ногами» ~ каз., кырг. *талтай-* id., калм. *taltä-* «киң булу; авызны киң ачу» < монг. *талтайи-* id., үзб. *талтай-* «кәперәю». **Талта** нигезеннән ясалган сүзләр каз., кырг. телләрендә күп. К. ш. ук як. *даллай-* «аякларны аерып басу яки колач җәю»; чыгт. *далдагай* «бик озын канатлы кош» < монг. *далдаѓай* «бик җәенке» ← иске монг. (Räsänen 1969 131) *daldaji-, taltaji-* «киң һәм ерак булу».

**ТАЛ-У** «ослабляться от усталости», диал. (ДС I: 177) «падать в обморок» < гом. кыпч., алт., хак., уйг. һ.б. *тал-,* як. *таал-,* тув., гом. угыз. *дал* id., чыгт. *тал-,* төркм. *даал-,* госм., кр.-тат., гаг. *дал-* ш. ук «суга чуму, чумылу; төшү». Бу сүзнең исем коррелянты – кырг. *дал* «аптырамыш; башы түнгән», Räsänen 1969: 457; Э.В. Севортян (ЭСТЯ III): 133–134 (мәзкүр сүзлекләрдә **талу** сүзенең кайбер дериватлары күрсәтелми).

**Тал-** продуктив нигез, к. **Талау** (исем), **Талма, Талчык-у, Талык-у.**

**ТАЛЧЫК-У (талчыкты, талчыга)** «утомиться, переутомиться» < гом. кыпч. *талчыҡ-* (> башк. *талсык,* нуг., каз. к.-калп. *талшыҡ*) id., хак. *талҗых-* «һуштан язу» һ.б. ← ***талчы-** «һуштан язу, һуштан язардай ару» – **тал-у** (к.) фигыленең интенсивлык формасы. К. ш. ук түбәндәгене.

Дерив.: **талчыгыл-у, талчыгыш-у, талчыктыр-у.**

**ТАЛЫК** (БТДҺ: 302) «чурка, щепка и т.п., положенные под бревно и т.п. для приведения в строго горизонтальное положение; шина, накладываемая при переломе костей» < **таңлык < таңғылыҡ.**

Дерив.: (башк. телендә генә): *талыҡла-* «талык салу, тигезләү, җайлап урнаштыру». Тат. һ.б. **таҡыл** (к.) сүзе, бик ихтимал, **талыҡ** сүзеннән метатезадыр. Икенче яктан, **такыл < *таңкыл** (*-кыл*// *-кел, -гыл*//*-гел* һ.б.ш.) да була ала һәм шул нигездән дә (ш. ук метатеза юлы белән) **талык** килеп чыга ала. Һәр очракта сүзнең тамыры бер – **таң-,** к. **Таң-у I.**

**ТАЛЫК-У (талыкты, талыгу)** «умориться, уставать; ослабляться» – **тал-у** (к.) фигыленең интенсивлык формасы.

Дерив.: **талыктыр-у**; диал. (Тумашева 1992: 201) **талғын-у < талыгын-у.**

**ТАЛЫМ** «требовательность (к объектам потребления); избирательность» < **тал-* «сайлау» фигыленнән, к. себ., алт., хак., аз. *талла-,* алт., кырг. *талда-,* чув. *далда-,* каз., бур. *талға-* «сайлау; талымлау; сеңерләргә, җепләргә аеру; анализлау»; сүзнең тамыры як. *тал-* «сайлап алу» (шуннан *талба* < *талма* «талым», *талым* «зиннәт» мәгъ.); себ. **таңла-у** сүзенең себ. *тал-ла-у*га катнашы юк (к. **Таңла-у**).

**Талым** бик продуктив нигез: **талымла-у; талымлы, талымсыз; талымсак, талымчан; талымчы** һ.б.

**ТАЛЬЯН [таºл′йан]** «тальян, вид гармоны» < *итальян* сүзеннән рус телендә килеп чыккан дип исәпләнә. Ләкин *тальянка, тальян* аеруча тат. теленә хас (**тальян** үзе шул көенчә рус телендә кулланылмый да бугай).

**ТАМ I: там ярты** «точно наполовину» < гар. *тāмм* «тулаем, тәмам» сүзеннән булса кирәк. Төрки телләрдә *тал* «там, бөтенләй» сүзе дә бар, к. ЭСТЯ III: 132.

**ТАМ II** диал. (Тумашева 1992: 201) «стена; глиняное, саманное или каменное сооружение; небольшой склеп на могиле» < гом. кыпч., чыгт., уйг., үзб. һ.б. *там* < бор. төрки (ДТС: 526, 529) *tam, tayam* «стена; түбә», бор. чыгт. (Боровков 1963: 283) *там* «стена; өй; киртә» ~ төр. *dam* «кыек, түбә; өй; хибесханә» (к. Redhouse: 270). К. ш. ук каз., к.-калп., кырг. *там* «балчык өй, стена, дивар; зират». Бу сүзне кор. *tam* «стена, дивар» белән чагыштыралар; бор. ир. *dam* «өй» (~ лат. *dom* > рус. *дом*) белән чагыштыру да бар; ниһаять, **там,** безнеңчә, иң ышандырырлыгы – гом. төрки *там* «йомарланган балчык кисәге» (к. нуг., ком. *там* «тамган сыеклык эзе, тап») сүзе белән баглы, чөнки озак гасырлар буенча Үзәк һәм Урта Азиядә төрле корылмаларны шундый балчык йомарлагыннан салып килгәннәр (һәм әле дә салгалыйлар). К. **Там-у.** Будагов I: 337; Нұрмағамбетов: 114–115.

**ТАМА** – ногайский род, представители которых жили в Казани в XV–XVI веках – бор. чыгт.

(Рәшидетдин һ.б.) *тама, тәма* «оккупацион гаскәр». **Тама** ыруы үзбәкләрдә дә бар (Султанов: 165–176). Чаг. **Тамъян.**

**ТАМАК I** «горло; устье (реки)» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг. *тамақ,* хак. *тамах*, гом. угыз. *дамақ* id. < бор. төрки (МК; ДТС: 530) *tamγaq* «тамак; азык» ← бор. *там-* «йоту» сүзеннән, к. эвен. *там* «йоту, эчкә суыру» (ССТМЯ II: 158). **Тамак** сүзен чыгт., госм. < фар. *димаг* «аңкау; ми; борын; кәеф» сүзе белән чагыштыру да бар. Räsänen 1969: 460; ЭСТЯ III: 140–142.

**Тамак** – продуктив нигез: **тамаклы, тамаклык, тамакса** (бизәнү әйбере), **тамакча** (җигемлек детале). К. **Тамаксау.**

**ТАМАК II** (ЗДС: 604) «еда; обед» ~ каз., алт. һ.б. *тамақ,* төркм. *дамақ,* кырг. *тамаг* һ.б. «ашамлык» (бу мәгъ. беренче булып килә). Бу сүз төрле чит сүзләр – *димаг, табақ* һ.б. белән контаминациягә кергән. Будагов I: 376; Мухамедова 1973: 85.

Дерив.: **тамаклан-у; тамаклык.**

Ихтимал ки, *тамак* сүзләренең берсе төрки, берсе гарәпчәдән булып, тарих дәвамында алар буталанып беткәндер.

**ТАМАКСАУ** «любитель поесть» – асылда *тамаксыw* ← *тамаксы-* «тәмләп ашарга теләү» фигыленнән (*ы* > *а*). **Тамак** нигезе монда «ашамлык».

**ТАМАН** «впору, нормально» > чув. (Сергеев 1968: 65), мар., удм. (Кельмаков 1977: 139) *таман*, мар. диал. *тӓмӓн*, удм. диал. (Насибуллин: 139) *тамам* id. ~ нуг., ком., тув. *таман* < бор. төрки (Радлов III: 1004) *тамган* id., эвен., эвенк. *таман* «бәя, хак» ← *тама-* «түләү» сүзе белән бәйле. Бу сүзне гар. *тӓмам* (к. **Тәмам**) сүзеннән диючеләр бар, к. Будагов I: 37

**Таман** сүзе төрки телләрдә сирәк очрый (күпчелек телләрдә теркәлмәгән), ул омонимнар – Урта Азия һәм Үзәк Азия телләрендәге *таман* «табан, юнәлештә» һ.б.ш. белән кысрыкланган булуы ихтимал. Гар. *ṭамӓн* «таман» сүзе үзе төрки телләрдән булса кирәк. Чаг. ш. ук төр. *daman* «киемнең кысып торган кырые».

**Таман** продуктив нигез: **таманла-у, таманлык, таманча**, диал. **таманысы < тамансы** «җитте, ялыктырды, туйдырды» һ.б.

**ТАМАР: тамар табак** «чаша, сделанная из корневищ дерева» – **тамыр** сүзе белән бердәй булса кирәк, кр.-тат., к.-калп., төркм., төр. *tamar, damar* < бор. төрки (МК, ДТС: 529) *tamar* «тамыр» id. З. Мөхәммәдова буенча, бу угыз телләренә хас вариант (Мухамедова 1973: 160). Фар., көрд телләрендә дә *тамар* «кан тамыры, сеңер, мускул». К. **Тамыр.**

**ТАМАША** «зрелище; суматоха, переполох; диковина» > чув. (Сергеев 1968: 120) *тамаша, тамашша, тӑмаша, тумаша*, мар. (Иванов, Тужаров: 211; Исанбаев 1978: 45) *тамаша*, (Саваткова: 164) *томаша, тымаша, тумаша* id., удм. (Тараканов: 93; Насибуллин: 140) *тумашо, тумошо* «кызык, көлке» < гом. кыпч. *тамаша* < фар. *тӓмāшā* «тамаша» < гар. *тӓмāш* ← *мшй* «йөрү, хәрәкәт итү» тамырыннан, к. Будагов I: 376; Федотов II: 169.

**Тамаша** сүзе тат. телендә (һәм бүтән төрки телләрдә) күп мәгъ. алган продуктив нигез: **тамашалы, тамашалык, тамашачы** һ.б.

**ТАМБАЛ** диал. «женские кожаные штаны» (к. БҺҺ III: 165) ~ кырг. *дамбал* «кальсон». Чаг. эвенк. *табака, тамбака* «хатын-кыз өс киеме» (ССТМЯ II: 159).

**ТАМБУР,** диал. **дамбур** «род вышивания на пяльцах» < рус. *тамбур* «түгәрәк кыса; кысага (киергегә) тарттырылган чигүлек әйбер (тукыма, күн)» ← төр. *tambur* «барабан, төңгер» ← фар. *тӓнбӯр* «кыллы музыкаль инструмент (аның резонаторы түгәрәк була)». Чаг. төр., рус. һ.б. *тамбурин* «музыкаль инстумент төре».

**ТАМГА** «тамгá, клеймо, тавро; знак рода» > мар., удм. *тамга* «имза» ~ чув. *тамха, тӑмха, тумха* > *томха* < гом. кыпч. *тамға* (ком. *тамңа*, кар. *тымға*) «тамга; тап; баҗ; мөһер, пичәт» < гом. төрки *тамға,* төр. *damga* < бор. төрки (ДТС: 530) *tamγa* id., к. ш. ук алт., тув. *таңма* «пичәт, тамга; нуян кәнсәсе» ~ монг. *тамага* «пичәт» һ.б. (күп телләрдә очрый). К. бор., фар., сугд. *dagmä* «тамга, көйдереп ясалган билге» ← фар. *dag* (авест. *dagħa*) «көйдерү, көек; тамга» > бор. төрки (ДТС: 158) *daγ* «көйдермә тамга» ~ чыгт. һ.б. *даг* «җан көеге»; ш. ук бор. төрки (ДТС: 537) *taγla-* «тамгалау», *tamdur-* «яндыру, көйдерү». Гомумән, *тамга* сүзе бик бор. заманда (б.э. башларында яисә элегрәк тә) ир. телләрдән төрки телләргә (ихтимал каткат) кергән сүз булса кирәк. Zenker: 309; Будагов I: 729–730; Räsänen 1969: 460; Doerfer II: 554–565; Platts I: 337, 501; Федотов II: 246; Аникин: 531

(шунда ук бай әдәбият күрсәтелә). Тимергалин: 432–433.

**Тамга** продуктив нигез: **тамгала-у; тамгалы, тамгачы** һ.б. К. **Тамгаханә.**

**ТАМГАХАНӘ** «таможня» – Алтын Урда тат. телендә ясалган булса кирәк. Рус. *таможня* татарча *тамгаханә* сүзеннән калька.

**ТАМИН** «страховка, страховой взнос» (иске дини-мәдрәсә лексикасында бик билгеле сүз); «амортизация» ~ төр. *temin* id., гар. *тä'мӣн* id. сүзеннән үзгәреп килеп чыккан (*имин* сүзе белән тамырдаш).

**ТАМУК** сөйл.*,* **тамуг, тәмуг** «ад, преисподняя» ~ чув. *тамăк* > мар. *тамык* < гом. кыпч., уйг. *тамук, тамык* < бор. төрки (ДТС: 531) *tamuγ, tamu* > уйг., госм. *тамы, таму,* бур. *тама,* хак., монг., калм. *там*, алт. *таам* id., кайбер телләрдә – «чокыр, зиндан» (Радлов III: 1001–1002). Бор. төрки *tamula-* «бөяү, буа буу» сүзләренә караганда, *tamu* «буа» мәгънәсендә дә булган; тат. **тәмуг** яңгырашы иске уйгурчадан булса кирәк. Гомумән, *тамуг* сүзен сугд. теленнән дип уйлыйлар (к. Федотов II: 169–170), ләкин фонетик һәм морфологик җәһәттән монда аңлатылмаган моментлар кала.

**ТАМ-У** «капать» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *там-* > гом. угыз. *дам-* «таму»; бу сүзнең исем коррелянты – бор. кыпч., чыгт. *там,* аз. *дам* «тамчы» (к. Будагов I: 729; Радлов III: 992). Исем мәгънәсеннән бор. төрки, чыгт. *тамла-* «тамчылау», шуннан **тамлаг* «тамчы» > чыгт. *тамла,* угыз. *дамла* >> чув. *томла, тумла* «тамчы».

**Там** «таму, тамчы» тамырын, безнеңчә, *там* «балчык йомарлагы» ~ чув. *тăм, тăн* «балчык» сүзе белән чагыштырырга мөмкин. М.Р. Федотов (II: 190) бу сүзне бор. төрки, алт., кырг. һ.б. *той,* як. *туйо* «балчык» сүзенә нисбәтли, ләкин алай булса фонетик аңлатма читенлекләргә дучар була. К. **Тамчы.** ЭСТЯ III: 139–140.

**ТАМЧЫ** «капля» < гом. кыпч. *тамчы* (башк. *тамсы*, нуг., каз., к.-калп. *тамшы*), аз. *дамчы* < бор. кыпч. *тамчық* «кечкенә там (сыек балчык йомарлагы)» сүзеннән. К. **Там-у.**

Дерив.: **тамчылы, тамчыла-у, тамчылан-у.**

**ТАМЪЯН [таºмйан]** – название древнего ногайского рода, вошедшего в состав татар и башкир. М. Әхмәтҗанов (2002: 165–170) бу этноним бүтән беркайда да очрамый ди. Ихтимал, **тама** (к.) этнонимы белән тамырдаштыр (фар. **тамайан* «тамалар»).

**ТАМЫЗ-У** «накапать, капнуть» < диал. *тамгыҙ-у* id. **там-у** фигыленең үзәнчелекле мәгънә алган йөкл. юн. (төп мәгънәсеннән **тамдыр-у** формасы ясала). Чаг. хак. *тамыс-* «ут кабызу».

Дерив.: **тамызгыч; тамызым.**

**ТАМЫР I** «корень; жила, кровеносный сосуд» < гом. кыпч. *тамыр* (ком. *тамур*), уйг. *тамыр, таамар, тамар*, госм. һ.б. угыз. *дамар*, тув. *дамыр* < бор. төрки (ДТС: 530) *tamar, tamur, tamïr* id. ~ чув. *тымар*, як. *тымыр* id. ~ монг. *тамир* «артерия; көч, гайрәт», эвенк. (ССТМЯ I: 182) *тимэр* «аорта». Чыгышы ачык түгел (к. ЭСТЯ III: 143–144). Бор. төрки **тар-мыр* «таралган, тармакланган нәрсә; тармакланыш» сүзеннән диган фикер бар. К. **Тамар.** Räsänen 1969: 460; Федотов II: 266.

**Тамыр ~ тамар** сүзе күрше телләргә (Балкан, Иран, Кавказ һ.б.) алынган.

Дерив.: **тамырлы, тамырсыз; тамырлык; тамырлан-у; тамырча, тамырчык** һ.б.

**ТАМЫР II** «близкий друг» ~ каз. *тамыр, тамур*, кырг. *тамыр* id. Будагов I: 739. Рус. *тамыр* тур. Аникин: 531. **Тамыр I** сүзеннән аермыйлар.

**ТАНА** «тёлка (по второму году)» < гом. кыпч., чыгт., уйг. *тана,* төр. *tana, tene, dana*, госм., гаг. *дана*, төркм. *таана* id. << бор. ир. (авест.) *daenu* «сыер», к. чув. *тына, тăна* ~ мар. *туна* «тана» ~ бор. болг. **тыйна* > венг. *tino* «яшь үгез». Räsänen 1969: 410; Мухамедова 1973: 160–161; Федотов II: 267; Eren: 106.

Сыер терлегенә кагылышлы сүзләрнең бор. һинд-ир. телләрдән килүе **һәүкәш, һәш** һәм **түгәнәй** сүзләрендә дә күзәтелә.

**ТАНАК** диал. «ствол; скелет; дерево без листьев» (к. **Элә-танак**) ~ чув. *тона* > *туна* id. М. Федотов бу сүзне гом. көнб. төрки *тән* < гар. *тäн* сүзе белән бәйли, ләкин бу аңлатма фонетик закончалыкларга хилаф. **Танак** >> чув. *тона* > *туна* уникаль төрки сүз. Ихтимал, ***таңгақ** «ат бәйләү баганасы» сүзеннәндер, к. **Тана-у, Таң-у I.** Федотов II: 147.

**ТАНАП** «танап, мера площади ≈1/6 гектара» (бу сүз тат. телендә актив кулланылган, К. Насыйри

һ.б. телендә очрый) < иске тат., чыгт., кырг., төркм. һ.б. *танап, танаб* «аркан (бигрәк тә ау эшендә кулланылганы), җир үлчәгеч бау, озынлык үлчәме (бер квадрат танап ≈ 17 сутый), җир мәйданы үлчәме» (ул төрле төбәктә төрлечәрәк булган, к. Будагов I: 741). Бу сүз «бүтәннәрне ауга эләктерүче елгыр, хәйләкәр кеше» мәгъ. дә кулланылган һәм гар. *ӓṭнāб* «тирмәне ныгыткыч баулар» (*ṭунуб* «ныгыткыч бау» сүзенең күплеге) дигәннән, *ṭнб* «тирмә утырту, (күчмә тормышта) килеп тукталу» тамырыннан килә.

Озынлык үлчәме атамасының җир мәйданы үлчәме атамасына әверелүе тат. һ.б. телләрдә еш күзәтелә, к. **Карыш, Сажин, Таяк.**

**ТАНАУ [таᵒнаw]** «ноздря», тат. диал., башк. «нос; морда» < гом. кыпч. *танаw* (кырг. *таноо*) < бор.чыгт. (Ибне Мүһәнна) *танаг,* нуг., алт., тув. *танаķ* «танау, борын эче» ~ яз. монг. *tanaγa* id. > алт. *таана*, хак. *танаа*, як. *таныы*, эвенк. һ.б. тунг. *танäһун* < монг. **танагасун* «ике борын тишеге, танау» (к. ССТМЯ II: 161). Чув. *тона* > *туна*, алт. *тана*, төркм. *таана* id. аерым тармакны тәшкил итәләр.

**ТАНА-У** (Тумашева 1992: 202) «отдыхать» ~ башк. (БТДһ: 304) *танат, таңат* «янган атны андыз суы эчереп ашатмыйча бәйләп кую» ← **таңа-у* «ат бәйләү», к. себ. (Тумашева 1992: 202, 207) **таңы-у, тәнәү** «(ат) бәйләү», башк. диал. (БТДһ: 348–349) *тәнлә-ү* «берничә сабакны бергә бәйләү» ~ алт. (Баскаков 1972: 251) *таңы-*, чыгт. (Будагов I: 335) *таңа-*, гом. кыпч., уйг. һ.б. *таң-*, төркм. *даң-* «бәйләү, төйнәү, тышаулау», алт. *таң* «бәй, тышау» сүзеннән (тәфсилле бәянын к. ЭСТЯ III: 145–146, шунда ук әдәбият күрсәтелә, тик. Э.В. Севортян тат.-башк. мисалларын күрсәтмәгән).

**Таң** тамыры белән тюркологлар *таңла-у* «сайлау» сүзен дә баглыйлар. Тат. диал. **тәнә-ү, тенә-ү** «ял итү (иген басуы тур.)» *таңау* > *тәңәү* сүзенең күч. мәгънәсе түгел, бүтән тамырдан, ләкин *таңа-у* белән контаминациягә кергән булса кирәк.

Тат. диал. (себ. һ.б.) *тагу* «комачау, киртә» < *таңгу* < *таңгы-у* «бәйләү». К. **Таң-у.**

**ТАНДЫР** (Тумашева 1961: 197) «глинобитная печь» ~ каз., кырг., үзб. *тандыр, тәндер* «нан пешерелә торган балчык мич» < гар. *тäннӯр* id. Бу төр мич безнең салкын якларда эшкә ярамый, шунлыктан сүзнең мәг. дә үзгәргән, к. себ. (Тумашева 1992: 202) **тантыр** «учак, мич учагы», иске тат. (Дамаскин сүзлеге, к. СТ № 2, 1980: 59) *тянур* «учак уты». Нұрмағамбетов: 115–116.

**ТАНСЫК** «желанный; ожидаемый с нетерпением, редкостный» ~ башк. *таньыķ,* чув., *тонсӑх* > *тунсӑх*, мар. *томсык, тансык*, удм. *тунсык* «охотно желаемый» < гом. кыпч. *тансыķ*, тат. диал. (Тумашева 1992: 202) *таңзыķ, таңсыķ* «тансык, теләп көтелгән, сагынылган» < бор. төрки (ДТС: 532–533) *taŋsuq* «гаҗәеп; гадәттән тыш», (Gabain 1951: 337) «затлы, тансык» > уйг., үзб. *тансиķ,* аз. диал. *даңсыг,* ләкин төр. *tansık* «таң калырлык, гаҗәеп», *tansık dramı* «курчак театры (шуның бер төре)» ~ яз. монг. *tangsug*, хәз. монг. *тансаг* «сөенеч, шатлык» һ.б. < бор. төрки *таңсы-* > башк. *таңçы-у* «гаҗәпсенү, таңга калу; сөенеп гаҗәпләнү», башк. (БТДһ: 305) *таңһыу* «(гаҗәпләнеп) шак катучан; аптыраучан, ушсыз» ← *таң* «гаҗәеп», к. **Таң.** Räsänen 1969: 461; ССТМЯ II: 164; Федотов II: 248 (бик аз мәгълүмат бирелә). К. ш. ук **Тан-у.**

Дерив.: **тансыклы, тансыксыз; тансыкла-у.**

**ТАНТАНА** «торжество» < гар. *ṭанṭанӓ* id. ← *ṭнн* «яңгырау, шау».

Дерив.: **тантаналы, тантанасыз; тантаначылык.**

**ТАН-У** (Троянский II: 23) «не признавать обвинения, притворно удивляться обвинению» > удм. *тан-,* мар. *тан-, тон-,* чув. *тон-* > *тун-* id. < тат. диал. (С. Сүнчәләй телендә), кар. *таң-* «гаепләүгә гаҗәпләнү» ~ гом. кыпч., уйг., чыгт. *тан-,* куман., чыгт. (Будагов I: 727) *таң-,* аз. *дан-*, төр. диал. (TS III: 989–995) *daŋ-, taŋ-*, төркм. *дән-* «гаҗәпләнү, таң калу» – **Таң II** (к.) сүзенең фигыль коррелянты. К. ш. ук аз. (АДДЛ: 17–18) *даңга, даңгаз* «тыңлаусыз, юньсез», *даңсы-* «сүзеннән кайту». ЭСТЯ III: 217–218 (Э.В. Севортян *ң* > *н* күчешендә нииндидер хилафлык күрә). Федотов II: 246.

Деривациясе юк, чөнки деривbooтив формалар **таны-у** сүзенең дериватларына омоним булыр иде.

**ТАНЫК** «свидетель; справка» < гом. кыпч. *таныķ, тануķ,* төр. *danık, tanık*, чыгт., уйг., бор. төрки (ДТС: 532) *tanuγ, tanuq* ~ чув. *тынӑ (а > ы)* id. Бу сүз күрше телләргә дә кергән, к. венг. *tanu* id. һ.б. – төркиләрнең иң бор. юридик терминнарыннан берсе; әлбәттә, **таны-у** (к.) фигыленнән. Шунысы кызыклы ки, чув. телендә **таны-у** сүзенең тәңгәле *танӑ-* > *тунӑ-,* ягъни монда *а* > *ы* күчеше юк. Димәк, фигыль үзе инде (*а* > *о* > *у*) кыпч. (бор.

тат.) теленнән алынган дип уйларга мөмкин. Федотов II: 267. Рус. *танук* «имче», *таник, таника* «белгеч, ат танучы һ.б.ш.» (< тат.) тур. Аникин: 532 (әдәбият китерелә).

Дерив.: **таныклык; таныкла-у (→ таныклан-у, таныклат-у)** «раслау (мәс., имзаны)».

**ТАНЫП** «река Танып» – сәеррәк яңгырашлы бу атама герм. телләрендәге *Дануба* «Дунай» сүзен хәтерләтә (монда ихтимал булган аваз күчешләре дә ышандырырлык), к. ш. ук лат. *Danuvi-us* «Дунай». Гомуми этимологик фикер буенча, бу гидроним скиф (ир.) *danu ab* «саркынты су, тармаклы елга» сүзеннән (бу характеристика да Таныпка бик таман), шуның нигезендә *Дон, Днепр, Днестр* һ.б. гидронимнар да ясалган дип карала, к. Фасмер I: 552–553. *Дунай* – төр. *Tuna* һәм бу вариант бор. төрки телләрдән килсә кирәк.

Башкорт этнонимикасында **танып** ыруы тур. сүз куертыла, ләкин бу атаманың реаль эчтәлеге бик томанлы (ниндидер тарихи ыру-кабилә тур. түгел, «Танып буе кешеләре» тур. сүз баруы мөмкин).

**ТАНЫ-У** (Троянский II: 23) «узнать; признать»; (мәс., *хәреф тану*) «познать» >> мар. *туне-* id. < гом. кыпч. *таны-*, кырг. *тааны-*, төр. телендә *danı-* «белешү», *tanı-* «тану» аерымлана, бор. төрки (ДТС: 531–532) *tanu-* «хәбәр итү, белдерү». Гомумән, бу фигыль төрлечә яңгырашларда барча төрки телләрдә очрый. Чув. *тынӑ* «танык» сүзенә караганда, **тынӑ-* «тану» сүзе булган. Мар. *туне-* бик продуктив нигез һәм ул чувашчадан дип әйтеп булмый.

Г. Рамстедт (1957: 132) бу сүзне тунг. *тä-, таг-* «белеп алу, тану» тамыры белән чагыштыра. ССТМЯ (II: 149) авторлары ул тунг. тамырын гом. төрки *тап-* сүзенә баглыйлар (**таны-** һәм **тап-** фигыльләре тамырдаш булып чыга). **Таны-** фигылен фар. *dān-*, пәһл. *daan-* «белү, белеп алу» сүзе белән чагыштыру да бар (к. Федотов II: 267; Eren: 393–394).

Ихтимал, удм. *туна-* «күрәзәләү», мар. *тун* «билге» сүзләре бор. төрки телдән киләдер. Будагов I: 731; Радлов III: 825; Räsänen 1969: 461.

**Таны-** бик продуктив нигез: **таныл-у, таныт-у, таныш-у** һ.б. К. **Танык** (бу сүз үзе шактый продуктив нигез: **таныкла-, таныклы, таныклык, таныкчы** һ.б.), **Таныш.**

**ТАНЫШ** «знакомый» > мар., удм. диал. *таныш,* чув. диал. *тунӑш* id. < гом. кыпч., алт., тув. *таныш* (> нуг., каз., к.-калп. *таныс*) id. Гом. кыпч. *танышлы* «таныш, танылган, таныла торган» сүзеннән эллипсис. К. **Таны-у.**

Дерив.: **танышлык, танышлаш-у.**

**ТАҢ I**«заря, рассвет» ~ башк. *таң, таңаҡ* < гом. төрки *таң,* гом. угыз., тув. *даң, дан* ~ як. *тыҥ* id. Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 144) бу сүзне бор. төрки *taiŋ* «эңгер», *saŋ, seŋ* «таң» сүзләре белән чагыштыра. К. ш. ук уйг. *čaŋ* «таң» (ДТС: 139) – ләкин бу чагыштырмача соңгы (уйгурча «Угызнамә» дастанында килеп чыккан) сүз.

Безнеңчә, тат. һ.б. *таң ату* сүзенә эвенк. *гарпа-,* эвен. *гарпу-,* бор. монг. *xarbu-* «ук ату; кояш чыгу» сүзе мәгънәви параллель (к. ССТМЯ I: 142). Киң таралган кыт. мифы буенча, чыгар алдыннан кояш *сянь* дигән күлдә коена; явыз ләү (аждаһа) аны чыгу белән йотмакчы була, ләкин каһарман ләү – *Чжу люң ван* явыз аждаһаны *атып ега* һәм кояш исән-сау чыга. Ихтимал, **таң** *Чжу люң ван* (> **Чулпан**)ның икенче исемедер һәм тат. һ.б. *Таң-чулпан* сүзе асылда парлы сүз **Таң-Чулпан** булса кирәк (кояш һәм аны сагалаучы вә саклаучы ләү-аждаһалар тур. к. Яншина: 392–394 һ.б.). Бор. төрки (манихей) текстларда **Таң тәңре** тур. әйтелә. **Таң тәңресе** образы барча халыклар мифологиясендә очрый (мәс., һинд мифологиясендә *Ушас ~ Ушинас*, лат. *Аврора* һ.б.). Мондый образ поэтик фикерләүдә яңадан-яңа формада килеп чыгып тора (мәс., рус. *Иван-Заря*). Тат., башк. һ.б. экиятләрендәге **Таңбатыр**, алт. экиятләрендә **Таң-заган, Таң-Саган** («таң бабай») образы һәм аның маҗаралары күп җәһәттән әлеге кыт. мифын хәтерләтә (**Таңбатыр** җир астына кереп патша кызын коткарып чыга). Шушы фактлар яктылыгында Н.А. Баскаковның (1987: 73) **таң** сүзен кыт. *таң, даң* «таң» сүзеннән диюе шактый ышандырырлык. **Таң атты**, димәк, «Таңбатыр аждаһаны атты» дигән сүз. К. ш. ук **Таң II.**

Дерив.: **таңсу** (төс). К. **Таңак.**

**ТАҢ II** «удивлён; восхищён» (сирәк, мәс., мәкальдә: *Бай хатынына ялчы таң*), гадәттә **таң кал-у** «изумиться; удивиться» идиомысында, ш. ук себ. (ДС I: 181) **таң** «сосредоточенно», (Будагов I: 727) *таң-маң* «в растерянности», миш. (ТТДС I: 404) **таң тешү (төшү)** «сглазиться» ~ удм. (Алатырев 1959: 59) *таң* «гаҗәпләнү; могҗиза» < гом. кыпч., алт., чыгт., госм. һ.б. *таң* – гаҗәпләнү ымлыгы (к. Радлов III: 804), уйг. *таң* «гаҗәеп», куман., бор. төрки (ДТС: 171) *taŋ* «могҗиза», төр. диал. *daŋ, taŋ* «аптыраш; гаҗәеп», *daŋča, danča*

«гаҗәп!» (к. TS II: 989–995), аз. диал. (АДДЛ: 171) *дан (кәлмәк)* «таң (калу)» һ.б. < төркм., хак., алт. диал. *тааң* «гаҗәп; белмим бу ни». К. ш. ук мар. (Саваткова: 155) *таң* «ягымлы кыяфәт» ~ себ. **таң** «матур, гүзәл» (чаг. җырда: *Таң таң ата*...).

**Таң II** сүзенең киң таралган бер мәгънәви вә фонетик тармагы тат. диал. **таң** «әллә ...» (*таң кем* «әллә кем») ~ хак. һ.б. *таң* id. (*таң пар, таң чох* «әллә бар, әллә юк») > алт., тув., чув., мар., морд. Э. *та, тä* id., (чув. *та кам* «әллә кем», *тахçан* «әллә кайчан», *тахăшĕ* «әллә кайсы» һ.б. бик күп сүзләр, к. Сергеев 1971: 121; мар. *та гышак* «кайдадыр; әллә кайда», *тама* «әллә ни» һ.б.; морд. Э. *таков* «каядыр; әллә кая», *такосо* «кайдадыр, әллә кайда» һ.б.), к. Ашмарин 1898: 207; Левитская 1976: 37.

**Таң II** тамырыннан төрки телләрдә тагын берничә киң таралган нигез ясалган, к. **Дан, Тан-у, Таңак, Таңгыр-у, Таңлан-у, Таңла-у, Таң-у, Таңчы.**

**ТАҢАК, таңнак** диал. (себ., БҺҺ II: 240) «утренняя заря; восток» ~ алт. (Баскаков 1972: 250) *таҥаҟ* «гаҗәеп матур; күңелчәк; мөлаем кыяфәт», төр. (TS II: 989–995) *daŋak, taŋak* «гаҗәп, сәер нәрсә», бор. төрки (Gabain 1950: 337; ДТС: 532) *taŋaγ* «аптыраш; имәнү» ← *таң* «аптырашта; гаҗәпләнгән хәлдә» (к. **Таң II**) сүзеннән булса кирәк, ләкин халык этимологиясендә **таң I** сүзенә нисбәтләнгән.

**ТАҢГАН, таңкан** (ДС I: 181; Тумашева 1992: 202; БТДҺ: 305) «чугунный заварочный чайник» ~ үзб. (ЎХШЛ: 78, 247) *даңқа, таңка* id., төр. *tanka* «чүлмәк аягы; аяклы чүлмәк» ~ яз. монг. *daŋха,* калм. *daŋхеп* «чуен күкшен» – кытайчадан. Рус. *танха, танга* «чан, казан; табак» тур. к. Аникин: 532. Чаг. **Дага.**

**ТАҢГУ, тағу** диал. (себ.) «препятствие, помеха» < ***таңыгу** ← **таң-у** (к.). Чаг. төркм. *даңы* «бәй, төен, бау». Чаг. **Таң-у.**

**ТАҢГЫР-У, таңгырга-у** (Будагов I: 727; Тумашева 1992: 202) «удивляться, изумиться» ~ каз., кырг., алт. *таңырка-* < бор. төрки (ДТС: 532) *tanïrqa-* id. > чыгт. (Г. Нәваи) *таңгыз-, таңгызга-* id. ← **таң II**. К. ш. ук тув. *даңгыр-* «ант итү», *даңгыраҟ* «ант».

**ТАҢЛАЙ** «твёрдое нёбо» ~ нуг., к.-калп., үзб., төркм. *таңлай* (> каз., кырг. *таңдай*), як. *таҥалай,* башк. диал. *таңғай* id. < монг. *таңалай* id. Ачык түгел.

**ТАҢЛА-У** «счесть за диво; восхищаться» ← **таң II** (к.).

Дерив.: **таңлан-у** «гаҗәпләнү» < бор. төрки (ДТС: 532–533) *taŋlan-* id. >> чув. *тĕлĕн-, тĕлен-* id. к. Räsänen 1969: 461.

**ТАҢ-У I** (иске тат.; Тумашева 1992: 202), **тәң-ү, тәңә-ү** (ЗДС: 618) «связать, завязать» < гом. кыпч., к. кар., кырг., уйг., чыгт. (Будагов III: 335), алт., хак. *таң-,* үзб. *тоң-,* як. *тыҥ-,* гом. угыз. *даң-* һ.б. (к. ЭСТЯ III: 145–146) «бәйләү, урату; тигезләп төяү; тигезләү; җайлап урнаштыру, төргәкләү» – бор. кучмәчелек заманнарында бик актуаль эш-хәрәкәтләрне белдергән. К. **Тагу, Талык, Тана-у, Таңгу.** К.-калп. *таңғыл, тәңгіш* «тирмәнең бер канатын икенчесенә бәйләгеч бәй», каз. *таңғыш* «тирмә таякларын бәйләгеч киндерә һ.б.» ← **таңгыч.**

Дерив.: диал. **таңыл**, (ЗДС: 606) **таңылчак** «төенчек». **Таңыл** сүзе монг. *таңуул* id. сүзеннән булса кирәк, к. рус. *тангаур* «тышау төре».

**ТАҢ-У II** (С. Сүнчәләй) «удивиться» ~ кр.-тат., госм. *даң-* id. **Таң II** (к.) сүзенең фигыль коррелянты.

**ТАҢЧЫ** (Г. Тукайда *Кайда Фәрһад илә Мәҗнүн? Мин аларның таңчысы*) «поклонник, почитатель» ← **Таң II.**

**ТАП I** «пятно, точка», диал. «щепка, колышек, камешек, которые ставят как обозначение точки отсчёта» < гом. төрки *тап* id. ~ гом. монг. *таб* «заклёпка» ~ кор. *tap* «йомычка» (Рамстедт 1957: 256) һ.б.

Төрки-монг. телләрендә *тап* яңгырашының мәгънәләре бик күп һәм аларны бер-берсеннән чыгарып була. Мәс., нуг., уйг. *тап* «буразна, эз; бер карыш җир» сүзе җир чиген белдергән **тап** сүзеннән килеп чыга ала. К. **Тап II, Тапчык, Тәп.**

**ТАП II** «точно; как раз, именно» < гом. кыпч., алт., чыгт. *тап* id. *Тап бул-, тап кил-* «очрау; туры килү» тәгъбире дә шул ук телләрдә очрый (Радлов III: 945). Чаг. ш. ук чув. *лап* «тап, нәкъ, тач».

**ТАП III** – имитатив, обозначающий топот, бой молотка, пинок и т.п. – гом. төрки *тап* id. (к. Рад-

лов III: 955) ~ монг. *дап* id. Барча телләрдә охшаш сүзләр бар, мәс., рус. *топ, хлоп,* инг. *tap, stamp* һ.б. *Тап* тәкълиди тамырыннан **тапыл, тапылт, тапыл-топыл, тапыр, тапырт, тапыр-топыр** тәкълиди нигезләре һәм **тапылда-у, тапырда-у** тәкълиди фигыльләре ясала. К. **Тапа-у, Тапырык, Тапта-у, Туп, Тып, Тәбе.** Räsänen 1969: 462.

**ТАП IV** сирәк «группа лошадей с одним жеребцом во главе» < гом. кыпч. *тап* id., ш. ук «класс, категория; мәшек (тренировка)» – тәүдә атларның яшь һәм җенес буенча аерымланган төркемен белдергән булса кирәк. К. ш. ук чув. *тап, тапӑ* «җәйге нардуган бәйрәмендә яшьләрнең аерым группасы; ат табы; сәйран» (Фокин: 165–192).

**ТАПАС (**К. Насыйри) «топаз; крупные бусы и т.п. шаровидные украшения». Рус сүзен татарчадан дип уйлыйлар, чөнки бүтәнчә аңлатмасы юк. Смит: 222–223.

**Тапас** сүзе тат. телендә киң кулланыла. Бәлки ул төр. *topaz* «минерал төре» (> ним. *topas* һ.б. id.) сүзеннәндер.

**ТАПА-У** «отбивать косу; измельчать, фаршировать (овощи)», диал. «топтать» > морд. М. *тапа-* id. гом. төрки **тап** тәкълиди сүзеннән (аның **тап-па* вариантыннан булса кирәк). Гомумән, **тапа-у** һәм **тапта-у** нигезләре тат. һәм башк. әд. телләрендә генә аермачык аерымлана бугай.

**Тапа-** продуктив нигез: **тапагыч; тапал-у, тапат-у,** диал. **тапама.**

**ТАПКЫР I** «находчивый; остроумный» < гом. кыпч. *тапҡыр*, уйг. *тапҗур* id., әлбәттә, **тап-у** фигыленнән.

Дерив.: **тапкырлык. Тапкыр II** дән ясалган дериватларга омоним булырлык сүзләр **тапкыр I** дән ясалмый.

**ТАПКЫР II** кыек килешләрдә*:* «(определённое) место; то, что рядом; в ряду чего», төп формада: «раз, -жды; -крат; -кратный» > мар. *тапкыр,* чув. *тапкӑр, тапхӑр* id., ш. ук «период, момент» < бор. монг. *dabxur* (> хәз. монг. *давхар*) «рәт, кат; этаж; тапкыр; икеләтүле һ.б.». Мәгъ. буенча хөкем йөрткәндә, бор. монг.-тунг. *дап-* ~ төрки *дьап-* «ябу, өстен каплау» тамырыннан, к. як. *дьапта, дьаптал* «катлам; ябу, өстәр», эвенк. *дапкар* «катлам; ямау», *дапкур* «тапкыр» һ.б.; *-җур* морфемасы төрлечә аңлатыла ала: гом. төрки, монг. һ.б. *җур* «кор, түгәрәк» мәгънә ягыннан иң бап килгәне (ягъни тәүдә монг. **дап җур* яисә **дапта җур* «ябулы (бикле) түгәрәк» булган). Монг. күпсанлы сүзләрдә *давх-* «икеләтелгән; өсте-өстенә куелган» нигезе шәйләнә. Мар. сөйләшләрендәге (Исанбаев 1978: 28; Саваткова: 15 һ.б.) *тапыр, тӓпыр* «тапкыр (төрле мәгънәләрендә)» бу сүзнең Урта Идел якларына күптән керүен күрсәтә.

**Тапкыр** сүзе күпчелек кыпч. телләрендә юк диярлек. Аның каруы бу сүз угыз телләрендә күпмәгънәле: госм. (Радлов III: 953–954, 978, 980) *тапҗур, табғур* «коршау, текмә читән; рәт, линия; бер линиягә тезелгән атлар (яки бүтән эш терлекләре)», (Sumer 1983: 78–79) *tabkur, dapkur* «ияр күпчеге, ияр өстенә салынган мендәрчек; гаскәр сафы (шеренга)», шулай ук «лагерь тирәли түгәрәкләп тезелгән арбалар, та́бор» (*табы́р ~ та́бор* сүзен дә шуннан дип уйлыйлар). К.-балк. *тапҗур* «терраса, битләүгә уелган террасаларның берсе» – икенчел булса кирәк. Кр.-тат., төр. *tabur* «хәрби олау, олау арбалары белән уратылган хәрби лагерь» угыз телләренә хас күренеш – *-г-* авазының төшеп калуы нәтиҗәсендә килеп чыккан. Монгол һәм угыз төркиләренең бай хәрби практикасы нәтиҗәсендә *дап җур* «икеләтелгән (ике тезем) арбалардан яисә вакытлы киртәләрдән гыйбарәт булган сакланыш корылмасы» төрле мәгъ. алган. Чыгтай монгол империясендә *табҗур* дип шәһәр төзеклеге өчен алынган салым аталган (Velidi: 302). «Мәртәбә, тапкыр» мәгънәсе дә чыгт. телендә – Урта Азиядә барлыкка килгән, к. үзб. *топҗир* ~ төркм. *допҗир, тапгыр* id. К. **Табыр.** Минорский В.Ф. Tabqur//tabor // Acta Orientalia XII. Budapest 1961: 27–34; ССТМЯ I: 197; Федотов II: 174–175.

Дерив.: **тапкырлы; тапкырла-у** (ш. ук исемләшкән мәгъ. **тапкырлау**), шуннан **тапкырчыгыш** (неол.) һ.б. математик гыйбарәләр. **Тапкырлап чигү** тәгъбире кызыклы (монда «тапкырлау билгеләре тезү» күз алдында тотыла).

**ТАПТА-У** «топтать; задавить; травить», диал. «отбивать косу», «молотить» > чув., мар. *тапта-* «таптау», ләкин чув. *топта- > тупта-* «чалгы тапау» (шулай итеп, чув. теленә тат. сүзе ике тапкыр алынып, этимологик дублет килеп чыккан) < гом. кыпч., уйг., хак., алт. *тапта-* ~ к.-балк., чыгт. һ.б. *тапла-*, монг. *тавла-* «таптау», ш. ук бур. *дабта-*, монг. *дапча-, дапша-* ~ эвенк. *тавит-*, эвен. *тават-* «чүкү, тапау; яньчү» (к. ССТМЯ I: 149) һ.б. Гомумән, *тапа- ~ тапта-* сүзләренең параллельләре һәм паронимнары күп һәм алар, әлбәттә, **тап** ~

*тып* (һ.б.ш.) тәкълиди тамырлардан килә. Рус. *топтать* төрки сүзгә бинисбәтән ясалган (рус телендә дә *тап, топ* һ.б.ш. тәкълиди сүзләр бар). Федотов II: 174 (**тапта-у** белән **типсә-ү**не чагыштыра).

Дерив.: **таптал-у, таптан-у, тапташ-у, таптат-у; тапталыш** (бу сүзләрдән тагын күп кенә икенчел дериватлар ясалган). К. **Таптау.** Шунысы игътибарга лаек – бор. монг. телендә үк – *dabxurla-* «икеләтү, кабатлау».

**ТАПТАУ [таºптаw]** «земля, которую часто топчут; поле на выпас скота осенью» (к. мәкаль: *Үсәсе чәчәк таптауда да үсә*) – тат. теленең үзендә **тапта-у** сүзеннән исемләшкән. Бу сүз әзәлдән бирле утрак игенче халык булган татарларда утраклыкка караган яңа сүзләр вә төшенчәләр ясалу мисалы буларак кызык. Ихтимал, ул ш. ук мәгъ. **таптаулы** сүзеннән эллипсистыр. Чаг. **такыр басу, такырлау.**

**ТАП-У (табу, тапты)** «находить, найти; добыть» ~ чув. *туп-* < *топ-* < гом. төрки *топ-* < гом. төрки *тап-,* тув. *тып-* id. *тап* «нокта, момент» сүзенең фигыль коррелянты булса кирәк, к. як. *тап-* «мәрәйгә тидерү; уңышлы эш итү». М. Рясянен төрки *тап-* тамырын монг. *тава-* һәм хәтта фин. *tapaan, tavata* «табу» сүзләре белән (к. Räsänen 1969: 462), ССТМЯ (II: 140) исә тунг.-маньч. *таг-, тақа-* ~ яз. монг. *taγa-* «белеп алу, табышмак җөмен табу» белән чагыштыра. Будагов I: 719; Федотов II: 248. Кайбер төрки сүзлекләрдә *бала табу* дигәндәге *тап-* аерым нигез итеп алына.

**Тап-** бик продуктив нигез: **табыл-у, табыш-у, таптыр-у, табыш; тапкыр I** һ.б. (бу сүзләр күрше телләргә дә кергәннәр һәм аларның гом. кыпч. һ.б. параллельләре дә булучан), **табышмак.**

**ТАПЧАН** «топчан, широкая скамейка, на которой можно лежать; кушетка» < бор. төрки (ДТС: 534) *tapčan, tapčaŋ* «йөзем җыйганда файдаланыла торган өч аяклы табурет» ~ монг. *табцан* «тәхет, тау тәңгәле», бор. уйг. *tavčaŋ* < кыт. *tao čaŋ, dao čaŋ* «ятак; Будданың изге эскәмиясе» – һинд. *bodhimanda* id. сүзеннән ярымкалька. К. ш. ук к.-балк. *табчан* «тапчан», кр.-тат., добр. *тапшан, тапцан* «агач эскәмия», кар. *тапчан* «җир идән, идән тактасы» һ.б. Рус. *топчан* < тат. булса кирәк. Аникин: 554 (шунда әдәбият та күрсәтелә).

**ТАПЧЫК** «щепка; колышек» – **тап I** сүзеннән («билге өчен куелган агач яки таш кисәге» мәгънәсеннән). К. **Тап I, Тәп.**

**ТАПШЫР-У** «поручать; передавать; вручать» < гом. кыпч., чыгт., уйг., госм. *тапшыр-* (ног., каз., к.-калп. *тапсыр-*), уйг., бор. төрки (ДТС: 535) *tabšur-,* бор. төрки (ДТС: 534) *tabčur-* id. *тап-* тамырыннан булса кирәк, к. тув. *тып-* «табу», *тыпсыр-, тывысыр-* «тапшыру», алт. *табыштыр-* «тапшыру; олаштыру, ялгау».

**ТАПЫР** – имитатив топоту: **тапыр-тапыр** имитатив монотонному, **тапыр-топыр** немонотонному топоту; имитатив звукам пляски. К. **Тап II.** Чаг. **Тыпыр**.

Дерив.: **тапырда-у,** башк. *тапырла-у, тапырта-у* (шуннан арытабан *тапырдық, тапырдавық* һ.б.), тат. диал. (ТТДС I: 398) **тапырла-у** «таптап пычрату».

**ТАПЫРЫК,** диал. (ТТДС I: 398) **тапырын** «вечно торопящийся (и неуспевающий), импульсивный, нетерпеливый» ~ алт. *табырақ,* хак., уйг. *табрақ*, бор. төрки (күп чыганакларда) *tawraq*, төр. диал. *dabrak* «темпераментлы, тизгер» < бор. төрки (ДТС: 542) *tavra-* ~ төр. диал. *tavrı-* «бик ашыгу; һай-һулап тотыну, керешү, дәррәү кузгалу, бик актив булу», шуннан ук үзб. диал. (ЎХШЛ: 76) *дабрың-, дабрын-* «усал карау», *даврын-*, кр.-тат. *давран-*, төр. *davran-, dabran-* «актив эш итү; көрәшкә, эшкә күтәрелү; тиз-тиз хәрәкәт итү», төр. диал. «коралга тотыну», бор. төрки (ДТС: 543) *tavrat-* «хәрәкәткә китерү; тибрәтү» – күрәсең **тибрәт-ү** (к.) белән нигездәш; чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 207) **тәперән-ү** «йөренү, кызу-кызу йөрү» < ***тапыран-у.** К. **Таварын-у.**

Беренче карашка **тапырык, тапырын** «тапыр-топыр килү, түземсезләнеп тору» сүзеннән шикелле һәм Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 112–114) шулай дип аңлата да. Ләкин дөрес эзләкләп барганда алай түгел: **тапырык ← тапыр-у < тапры-у < тапра-у** булып чыга. Әлбәттә (һәрхәлдә татар сүзендә), **тапыр** имитативының контаминацион тәэсире дә юк түгел.

Дерив.: **тапырыклык; тапырыклан-у.**

**ТАР** «узкий; тесный» > удм. диал., мар. диал. *тар, тор* id. ~ гом. төрки (Радлов III: 835) *тар* id., к.-балк. *тар* «тарлавык», урта төрки *таар,* як. *таар, туор*, төркм. *даар* «тар». Будагов I: 721; Räsänen 1969: 463; ЭСТЯ III: 146–147.

**Тар** продуктив нигез: **тарлык, тарлавык, тарчылык; тарай-у, тарлан-у, тарык-у, тарлык-у** һ.б. тат. (себ.) сөйләшләрендә *тар* сүзенең фигыль

коррелянты *тар-* (< *таар-*) «тар булу» теркәлгән (ЗДС: 609). К. **Тарык-у.**

**ТА́РА** «тара, всё то, во что кладётся, завёртывается товар» – Европа телләреннән килә, анда исә гар. *ṭарх, ṭархāт* «чигерү, алып бер якка кую», ягъни «товарны исәпкә кертмәү» сүзеннән икән. К. Kluge: 906.

Элекке татар мәктәбендә *тарх, тәрех* «математик алу гамәле» (рус. «вычитание») сүзе кулланылган. Тик совет власте урнашкач бу уңышлы терминны диффуз күпмәгънәле *алу* сүзе белән алыштырганнар. *Тәрех, тарх* сүзенә **матрас** (к.) сүзе дә тамырдаш.

**ТАРАВЫЛ [таºрawы̆л]: таравыл карт** в сказках, в эпосе – «мудрый сто- и трехсотлетний старец, к которому за советом обращаются ханы» < монг. *таргаул, тарғағул* «хәрби диспетчер» ← *тарға-* «тарату; юл чатында юл күрсәтү». К. **Тара-у.**

**ТАРАГАЙ: татар-тарагай** (башк. телендә) «татарин гололобый» – Алтын Урда чорында монголларның «татарларны» (төркиләрне) кимсетү сүзе (чөнки монголлар «татарларның» какулларын кискән булганнар); к. монг. > як. һ.б. *тарагай* «пеләш, таз», к. **Таз**. ССТМЯ II: 167; Аникин: 200. К. **Татар.**

**ТАРАЗАЙ** (БТДһ: 305; Юсупов 1979: 63) «сноповозка (длинная телега, на которой, положив в ряд, возят снопы с поля на гумно)» < фар.-таж. *дäрāзӣ, дäрāзгāһӣ* «озын арба» ← *дäрāз* «озын; озак» – шуннан иске тат. **дираз** «озак, дәвамлы», к. ГТРС: 111; Будагов I: 554.

БТДһ дә бу сүз Мияс якларыннан язып алынган дип кенә күрсәтелә; ул яклар халкының шактый өлеше – татарлар, элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгәннәр.

**ТАРАЗЫ,** (Будагов I: 313) **тәразу,** (Тумашева 1992: 203) **тарас** «уровень; нивелир, ватерпас; весы, безмен», «созвездие весов» > удм. *тараза* «Орион йолдызлыгы, Җәббар», мар. *тараза* «айның тулган вакыты», *тараза, таража* (Упымарий: 202) «хәтәр вакыт», чув. *тараса* «көянтәле үлчәү; кое сиртмәсе», башк. (БТДһ: 350) *тәрәс* «бизмән тәлинкәсе» ~ гом. кыпч. *таразы,* ком. *терезе*, каз., к.-калп. *тәрези* һ.б. id. (барча төрки телләрдә рефлекслары бар); бор. төрки (МК) *tarazu,* (ДТС: 536) *tarazuq* «үлчәү; тигезлек». Кавказ телләрендә *täräz, teraz* id. тур. Абаев III: 266. Рус. *тереза* «таразы» тур. Фасмер IV: 46.

Киң таралган һәм күп мәгъ. алган бу сүзнең чыгышы ачык түгел; сүзлекләрдә ул фар. теленнән таралган диелә, к. фар. *таразу* «үлчәү», көрд. *teraz, terazi, terazu* «үлчәү; авырлык тигезлеге; ризалашу» (< гар. *тäрāḍӣ*); соңгы мәгънә контаминацион характерда булса кирәк.

Безнеңчә, рус. *тараса, тарасы* «дошман кальгасын камаганда кулланылган каланча» сүзе дә төрки *тараза, таразы* сүзеннән килә. Будагов I: 347; Zenker: 274; Räsänen 1969: 463; Федотов II: 178.

**ТАРАК** «гребешок, расчёска» < гом. кыпч., алт., төр., чыгт. *тарақ* ~ як. *тараақ,* тув., бор. төрки (МК; ДТС: 537) *tarγaq* id. Чув. *тура* < *тора* < болг. **тараһ*. К. **Тара-у**. Räsänen 1969: 464; Федотов II: 250–251.

**ТАРАКАН,** диал. (Радлов III: 839) **тара** «таракан» ~ мар., удм. *таракан* < гом. кыпч. *тарақан* id. Күпчелек төрки телләргә бу рус теленнән кергән, рус телендә (ш. ук пол., укр.) *таракан, торган, тораган* чув. *таракан [тараган]* «таралып качучан» сүзеннән дип карала (Фасмер III: 20–21), бу чув. сүзе исә *тар-* < **тäр* «таралып качу» фигыленнән (~ бор. төрки *tez-, täz-* id.); мар. *тäрäлäн*, себ. (ЗДС: 620) **тәрәгән, тәрәкән** «таракан» борынгылыктан да, рус теленнән дә килә ала. Räsänen 1969: 463; Федотов II: 177–178; ДАУ I: 140–143.

Китерелгән этимология беренче карарга ышандыргыч булса да, кайбер сораулардан хали түгел. *Таракан* сүзе гомумән «бөҗәк» мәгъ. булган, к. **Камка таракан.** Радлов варианты югарыда китерелгән (гадәти) этимологиягә ятышмый һәм **таракан** сүзенең чыгышы бөтенләй үзгә-көтелмәгәнчә булуы ихтимал.

**ТАРАЛГЫ** «кольцо, к которому прикрепляются концы нескольких (более двух) ремней (обычно в упряжи)», «кольцевидное утолщение в стебле растения, от которой ответвляются побочные веточки» ~ башк., каз., к.-калп. *таралғы*, кырг., уйг. *таралға* id. (аерым телләрдә бу сүзгә төрле бүтән мәгънәләр дә бирелә). Әлбәттә, **тарал-у** сүзеннән. Рус диал. *таражник* id. ниндидер бор. төрки телдән.

**ТАРАЛ-У** «распространяться; разваливаться, рассыпаться» > удм. (Насибуллин: 139) *тарал-* id.

< гом. кыпч. *тарал-* id., *тара-* фигыленең төш. юн. К. **Тара-у II.**

**ТАРАМЫК** (Шура, № 3, 1908: 67) «отпрыск; ответвление (рода)», «сухая жила» (Радлов III: 845) ← *тара-* (к. **Тара-у**). Башк. *тармыт* (күрсәтелгән мәгънәдә) монг. теленнән (< *тарамууд* id.) булса кирәк, ягъни **тарамык**тан килеп чыкмаган.

**ТАРАМЫШ** «сухожилие» < гом. кыпч. *тарамыш* (ног., каз., к.-калп. *тарамыс*) id., уйг. *таримуч* «тарамыш, вак кан тамырлары» *тара-у* фигыленнән, ләкин ничек килеп чыкканлыгы билгеле түгел. «Грамматика… алтайской миссии» авторлары (1869: 23) алт. *тарамыш* «тарамыш» сүзен *тарам-аш* (*-аш* – кечерәйтү кушымчасы) дип аңлаталар, к. алт., бор. төрки (Радлов III: 845) *тарам* «тарамыш; елга дельтасы». Безнеңчә, *тара-мыш* < *тарама-гыч* сүзе тәүдә чәчүргеч тасманы, сүсне белдергән – андый тасма кайнатып киптерелгән сеңердән эшләнгән, чаг. **Чәчүргеч.**

**ТАРАТ-У** «распространять, рассеивать, рассеять» < гом. кыпч. *тарат-* id. **тара-у II** фигыленең йөкл. юн.

**ТАРАУ [та°раw]** «разбросанный» – **тара-у II** фигыленнән сыйфатлашкан исем фигыль. Күптәннән килә, к. кырг. *тарау* ~ монг. *тарагу, таруу* «сирәк тармакланган; тарау».

**ТАРА-У I** «расчёсывать (волосы); вычёсывать (лён и т.п.)» ~ чув. *тора-* > *тура-* id. < гом. кыпч., уйг., чыгт., алт., төр. *тара-*, төркм., төр. диал. *дара-, даара-*, бор. төрки (ДТС: 536) *tara-* id. бор. төрки, монг. *тар* ~ фар. *тар* «төк, кыл, йон» сүзеннән (тәүдә бу сүз йон арасындагы мамыкны белдергән булса кирәк)».

Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 147–149, 150–152) **тара-у I** һәм **тара-у II** сүзләре икесе ике тамырдан димәкче, ләкин без катган шулай дип әйтерлек нигезләр күрмибез. К. ш. ук Räsänen 1969: 464; Федотов II: 250.

**Тара-у** продуктив нигез: **тарал-у** (чәч тур.), **таран-у, тарат-у, тараш-у,** к. **Тарак.**

**ТАРА-У II** диал. (Тумашева 1992: 203) «разбрестись, рассыпаться» < бор. төрки (ДТС: 536) *tara-, tar-* «(дошман явын) таркату, тар-мар итү»; икенче фигыль *tar* исеменнән фигыльләшкән булса кирәк. К. **Тарка-у.**

**Тара-у** продуктив нигез: к. **Тарал-у, Тарат-у, Тарау.**

**ТАРАФ** «направление; сторона» < гар. *т̣араф* id. (күплек формасы **этраф**). **Тараф** продуктив нигез: **тарафчы, тарафлы, тарафсыз** һ.б. К. түбәндәгене.

**ТАРАФДАР** «сторонник, приверженец» < фар. *т̣арафдāр* id.; ләкин бу сүз татар теленең үзендә дә ясала алыр иде.

Дерив.: **тарафдарлык.**

**ТАРАШ** (БТДҺ: 306) «конопля» – фар. *тӓрāш* «тукыма туку өчен сүс» сүзеннән булса кирәк, к. **Тәрәш.**

**ТАРАШКЫ** (ТТДС I: 399, БТДҺ: 306) «град; дождь со снегом» – ихтимал, рус сөйләшләреннәндер. К. рус. сөйл. *дрожки* «калтыраткыч (суык)».

**ТАРБАГАЙ I** (Будагов I: 348; Тумашева 1992: 203; ЗДС: 608) «растопыренный; щеголь; ветрогон» ~ к.-калп., кырг. *тарбагай-,* башк. (БТДҺ: 306) *тарбаҡай* «тырпаеп торган» ← тат. диал. (Будагов; Тумашева), каз., к.-калп., кырг. һ.б. *тарбай-* «тырпаю, җәелү; тармаклы булу», к. башк. (БТДҺ: 306) *тарбаҡ* «тиктормас», *тарбыҡ* «тармаклы, тармачлы»; себ., каз. *тарбый-* «тарбаю», тув. *дарбай-* «тырпаю; үпкәләү» һ.б. Арытабан (ТТДС I: 434; ТТДС II: 311; БТДҺ: 345) **тырбак, тырбык, тырбайчык** «тәкәббер, көяз», **тырбай-у** «көязлән-ү» һ.б. Тасвири имитатив *тарп* тамырыннан, к. **Тырпа.**

**ТАРБАГАЙ II, тарбакай, тарбаган** (БТДҺ: 306) «лягушка, вид лягушки» (видимо, «пёстрая лягушка») ~ маньч. *тарбака, тарбахи* «чуар бөркет» һ.б. чуар хайваннар. **Тарбаган** (к.) белән тамырдаш. Монда «чуар» мәгъ. бер нигез контаминациясе сизелә, чаг. *таз ~ тар.*

**ТАРБАГАН** «тарбаган (полосатый суслик)» ~ ног., каз., к.-калп., уйг., тув., як. һ.б. *тарбаған,* уйг. *тарбуған* «тарбаган» < монг. *тарбага(н)* id. Кайбер телләргә бу сүз рус теленнән таралган булса кирәк. *Тарбагай ~ тарбаган* вариантлары булу (*-н ~ -й*) монг. сүзләре өчен характерлы. ССТМЯ (II: 167–168) авторлары маньч. *тарбака, тарбахи, тарбага* «тарбаган; чуар бөркет» сүзләреннән чыгып, монг. *тарбалжа* «урман бөркете» сүзен дә бер үк тарихи лексемага кертәләр. Морфологик җәһәттән кара-

ганда, сүзнең ясагыч нигезе себ. (Тумашева 1992: 203) **тарбай**- «көяз булу, көязләнү (< чуарлану)». Шулай ук гом. төрки *тарбай-* «тырпаю; тарбану» сүзеннән дә ясалырга мөмкин (к. Сетаров: 23). Нұрмағамбетов: 116–117; Аникин: 535–536 (бай әдәбият китерелә, ләкин тат.-башк. сүзләре искә алынмаган). К. югарыдагыны.

**Тарбаган** исеменнән Көньяк Казакстандагы **Тарбагатай** (монг. «тарбаганлы») топонимы ясалган.

**ТАРБАН-У** (ТТДС: 399), **тарбаңла-у** «сучить ногами (о младенцах); перебирать передними ногами в воздухе (о лошади); копаться ногой в земле» – гом. кыпч. *тарбан-* id. *тарба-* «тырпаеп хәрәкәтләнү» фигыленнән. Образлы сүз (*тарп* тәкълитеннән), к. **Тарпан.**

**ТАРБАСА** (ЗДС: 608) «большие ворота» < фар. *дäрвāзä* id.

**ТАРГЫЛ** «красно-чёрный; красный с чёрными полосами или пятнами» (*таргыл сыер* «чёрно-красноватая корова», *таргылташ* «гранит») < гом. кыпч. *тарғыл* id. < *тар-гыл(т)* id. бор. *тар* «таз; чуар» сүзеннән булса кирәк, к. Nemeth: 80–84 (венг. *tarka* «чуар» тур.). К. **Тарлан I.**

**ТАРИКАТЬ [таºрикәт]** «духовное усовершенствование у суфиев и мюридов», сүзмә-сүз «пути (совершенствования)» < гар. *ṭарӣқат* id. ← *ṭарӣқ* «юл» (бу сүз үзе дә иске тат. телендә кулланылган, к. ГТРС: 543, язучылардан мисаллары белән) – *трқ* «юл белән бару» тамырыннан. К. ш. ук иске тат. **тарика** «ысул белән, итеп»: *шул тарика* «шулай итеп». Төр. *tarikat* «дәрвишләр оешмасы, орден».

**Тарикать** дип ш. ук рухи камилләшүнең дүрт баскычыннан (**шәригать** һәм **мәгърифәт** баскычларыннан соң) өченчесен – танып белү методикасын атаганнар. Шуннан соңгы баскыч **хакыйкать** дип аталган. К. Ә. Ясәвидә:

*Шәригатьнең базарыны сәйран кылдым,*
*Мәгърифәтнең бостанында җәулан кылдым*
(атта йөрдем),
*Тарикатьнең пишгяһында тайран кылым*
(залында очып өрдем)
*Хакыйкатьнең ишегене ачтым, дуслар.*

Дерив.: **тарикатьче, тарикатьчелек.**

**ТАРИЛКӘ** диал. (трбс.), ш. ук (ЗДС: 621) **тәрилкә, тәринкә, тәриңкә** «тарелка» ~ чув. *тарилкке* id. (к. Федотов II: 179), к. **Тәлинкә.**

**ТАРИФ** «тариф» < рус. Ләкин асылда бу сүз төр. *tarif* < гар. *тä'рӣф* (к. **Тәгъриф**) сүзеннән килә.

Дерив.: **тарифлы, тарифсыз; тарифла-у** (чаг. рус. *тарификация*).

**ТАРИХ** «история; дата» (к. бәетләрдә: *Тарих мең дә сигез йөздә фәләненче сәнәдә*) < гар. *тāрӣх̮* id. *ррх̮* «дата кую; елъязма язу» фигыленнән. Иске тат. **тәварих** «тарихлар; хикәя, хикәят» – *тарих* сүзенең күп. формасы. Будагов I: 332.

**Тарих** продуктив нигез: **тарихлы** (иске) «даталы», **тарихчы; тарихтагы.**

**ТАРКАЛ-У** «рассеиваться, расходиться; разлагаться» < гом. кыпч. *тарқал-,* гом. төрки *тарқа-* «таркалу; таркату» фигыленең төш. юнәлешеннән. К. **Тарка-у.**

**ТАРКАТ-У** «разлагать, разложить; рассеивать» < гом. кыпч. *таркат-* id. ← *тарка-*, к. **Тарқа-у.**

**Таркал-у** һәм **таркат-у** тат. телендә күп дериватлы сүзләр: **таркалдыр-у** һәм **таркатыл-у; таркалыш, таркатыш; таркалма́, таркатма́** һ.б., бигрәк тә махсус өлкәләрдә.

**ТАРКАУ [таºркаw]** «рассеянный; разрозненный» – *тарка-у* фигыленең сыйфатлашкан исем фигыль формасы.

**ТАРКА-У, тарға-у** (Тумашева 1992: 203; БТДҺ: 306) «рассыпаться, разлагаться, разбрестись», «разбрасывать, рассеять» < гом., кыпч., уйг., алт. *тарқа-*, як. *тарға*, төркм. *дарға*, аз. диал. *тара-*, *дары-*, бор. төрки *tar-, tara-* (Боровков 1963: 287; ДТС: 536), монг. *тара-* «таркау, аеру», ә *тар-* варианты бор. **тар* «йон, мамык; таркау нәрсә» сүзенең исем коррелянты булса кирәк (к. **Тара-у I**). Будагов I: 723–724; ЭСТЯ III: 150–151.

*Тарка-* фигыленең юн. формаларыннан тат. телендә *таркал-* һәм *таркат-* кына кулланыла; нуг., каз., к.-калп. телләрендә *таркас-* < *таркаш-* «таркалышу» да очрый; бор. төрки телләрдә *tarqan* (кайт. юн.) формасы да бар. К. **Таравыл.**

**ТАРЛАН I** (ТТАС III: 44) «чёрно-пятнистый, сивый с жёлтыми пятнами (о лошади)» ~ каз., кырг., чыгт. *тарлан* id., ш. ук «ау кошының бер төре», калм. *tarlu* «тарлан», хак. диал. *тырлан* «божыр» ← **тар* «каралы чуар», к. **Таргыл.** Чаг. **Тарбагай, Тарбаган.**

**ТАРЛАН II** (ТТАС III: 44) «участок, где раньше было хлебное поле; заброшенное поле» > мар. диал. *тарлал* «ышна (төпләнгән урман урыны)» < каз., куман., бор. төрки *tarlan* id. < *tarıγ-la-γan* (к. Clauson: 538, 541). К. **Тарлау, Тары.**

**ТАРЛАУ [таºрлаw],** диал. **тырлаw** «пашня; участок поля», диал. (ДС I: 179; ДС III: 163; БҺҺ II: 239) «огороженное пастбище, выгон» < гом. кыпч. *тарлаw* < *tarıγ-la-γu*; к. ш. ук кр.-тат., төр., аз. (Будагов I: 331), гаг. *тарла, дарла* «тарлау» (кыпч. телләреннән булса кирәк).

Гомумән, **тарлаw** – исемләшкән исем фигыль, к. ш. ук хак. диал., чыгт. *тарлаг* бор. төрки (ДТС: 538) *tarlaγ, tarïγlaγ, tarïγlaγu* «сөрелгән җир», нуг. *тарылав* «тарма; ябай тары»; мар., манси. (Kannisto 1912: 205) *тарлаw* «басу». К. **Тарлан, Тарма, Тары.**

**ТАРМА** (ТТАС I: 339; Тумашева 1992: 203; БТДҺ: 307) «дикорастущая конопля», чаг. ш. ук башк. *тараш* «тарма; агач гөмбәсе»: бу сүзләрнең уртак тамыры **тар <** *тары* < *тарыг* «тары, иген» шикелле, ләкин мәгъ. җәһәтеннән монда тикшеренү сорала. *Тарма* сүзен уйг. диал. *тарма* «игелгән киндераш» (*ма* – кыт. – «киндераш») сүзеннән дип, ә **тараш**ны – *тар ашы* (чаг. *киндераш* < *киндер ашы*) дип карасак, *тар* «киндер» сүзе бар кебек күренә. Тув. *тарымал* «чәчелгән», ләкин **тарма** нәкъ ябай (чәчелмичә үскән) киндерашны белдерә. Чаг. бор. һинд *darbha* «сусле кыргый үлән төре» (к. Ригведа I: 449). Чаг. ш. ук алт. диал. (Баскаков 1965: 126) *тарма* «сихер», кырг. *дарым* «әфсен-төфсен».

**ТАРМАК** «ответвление; отрасль» > чув. диал. *тармак* «очлы боз», мар. *торма* «тармак; тырма» < гом. кыпч., уйг. *тармаҡ,* үзб. *тармоқ* id. < бор. төрки (ДТС: 538) *tarmaq* «елга һ.б. тармагы», «чәңгәл». Радлов (III: 872–873) буенча, *тарамак* ~ *тарамык* дигәннән, к. **Тара-у. Тармак** сүзе угыз телләрендә юк бугай. Чаг. **Тармач, Тырпа** һ.б.ш.

Дерив.: **тармаклы, тармаксыз; тармаклан-у, тармакча.**

**ТАР-МАР, тармар** «разгром» < фар.-таҗ. *тāр-у-мāр* «җеп һәм чырымта (итү)» сүзеннән.

**ТАРМАЧ** диал. «обрубленная ветка; сук; сосулька» – **тармакча** сүзеннән булса кирәк. *Тарамач* булырга да мөмкин. К. ш. ук диал. (ЗДС: 608, 621) **тәрмәз, тәрмәч** «тәлгәш», **тәрмәц** «ярь».

**ТАРНАЙ** (ЗДС: 608) «ступа, ступка» < фар. *дāри-нāй* id. сүзмә-сүз «агач-көпшә». Чаг. (ЗДС: 163) «**дарана** кебек шешү» – гөбе кебек шешү.

**ТАРНАУ [таºрнаw]** (Будагов I: 331) «канализация; водопровод» ~ чыгт. (Бабурнамә. Казан, 1857: 3) *тарнау* «акведук, су юлы», каз., к.-калп. *тарнау* «(яндаулары түшәүле) канау» һ.б.

**ТАРПАН** «тарпан, вымершая лошадь юго-восточной Европы и Казахстана» («*тарпаны* ростом против средней лошади, только круглее, … саврасые и голубые… головы их больше… чем у киргизских лошадей, на лбу имеют западины», к. Рычков: 147) < гом. кыпч. *тарпаң, тарпан* «тарпан; начар йөрешле ат» ← (каз., к.-калп., кырг.) *тарпы-* «алгы аяк белән тибү; алгы аяк белән карны казып үлән табу» фигыленнән, *тарп//талп* тәкълиди тамырыннан (к. **Тарбан-у**). К. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 399) **тара-у, таран-у** «тибенү», хак. *тарбаңна-* «әтәчләнү», каз., к.-калп. *талпаңла-, тарбаңла-* «алпан-тилпән йөрү», як. *тарбаа-* «тырнау, тырнашу», *тарбан-* «тырнану» һ.б.

*Тарпан* сүзе бөтен дөньяга таралган, к. Räsänen 1969: 465, Epstein: 410–416; Аникин: 537.

**ТАРСЫМАЛ, тарцымал, тарчымал** (Будагов I: 331; Тумашева 1992: 203) «утюг, вид утюга» < фар. *дäрзимäл, дäрзмал* id. (*дäрз, дäрзä* «җөй», *мал* – «сөрткеч, үтүкләгеч, ышкыгыч» мәгъ. морфема, чаг. **Тастымал**). *Тарсымал* дип ташчыларның махсус калагын да атаганнар.

**ТАРТАЙ, тартар** «коростель» > мар., удм. *тартай* (к. Исанбаев 1978: 21) < гом. кыпч., чыгт. *тартай, тартар*, хак. *таарт* id. Тәкълиди сүз (бу кошның кычкырыгына охшатудан).

**ТАРТАНАК, тартынак** иск. «вес; весы» – әлбәттә, *тарт-у* «билгеле бер авырлыкта булу» (к. җырда: *Алтын алка авыр тарта – Алты мыскалдан арта*) сүзеннән. К. Вашари: 101. Чаг. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 252) *тәртәнәк, тартанаг* «үрмәкүч (< пәрәвез)».

**ТАРТКЫ** «гребок (на току); подпруга» ← *тарт-у*, әлбәттә. Төрки телләрдә *тарткы* төрле мәгъ. очрый, мәс., төр. *tartkı* «ышкы». Чаг. ш. ук уйг. *тартка* «тешсез тырма, тарткы».

**ТАРТМА** «ящик», баштан «выдвижной ящик» > чув., мар., удм. *тартма* id., тат. телендә ясал-

ган сүз булса кирәк, кырг., үзб. *тартма,* нуг., каз., к.-калп. *тартпа* «тартма» < тат. Бүтән төрки телләрдә *тартма* «тартып чишелә торган бөрмә бавы; шундый детале булган аякчу (йомшак итек һ.б.)», чаг. төр. *çezme* «итек» ← *çez* «тартып чишү». К. **Тарт-у.**

**ТАРТУ** «подарок жениха (*или* со стороны жениха) невесте» < гом. кыпч. *тарту,* кырг. *тартуу* «җәлеп итү; сый, сыйлау; бүләк; матур көй» ~ чыгт., уйг. *тартиқ, тартиғ* id., бор. төрки (ДТС: 537) *taratγu* «бүләкләр», *tartuq* «хәраҗ» (к. Радлов III: 861–865), *тару* «әҗер, түләк, бүләк» (к. Боровков 1963: 289).

*Тарт-у* фигыле белән баглы.

**ТАРТ-У** «тянуть; тащить» < гом. төрки *тарт-* > угыз. *дарт-* < *таарт-* < *тарыт-*, бор. төрки (ДТС: 537) *tarït-* id. бор. **тар-* «тар итү» фигыленең йөкл. юнәлешеннән булса кирәк, к. тунг. *тäркал-* «тарту»; морд. М. *таргамс* «тарту»; тат. һәм бүтән төрки телләрдә *тарт-, дарт-* (тув. *тырт-*) фигыле бик күп күч. мәгъ. (к. Радлов III: 857) һәм дериватларга ия (кыпч. телләрендә киң таралганнары *тартык, тарткыч, тартылыш, тартым, тартыш, тартыш-у* һ.б.), к. ш. ук **Тарткы, Тартма, Тарту, Тартык, Тартын-у, Тәртә, Түтәл.** Будагов I: 722–723; ЭСТЯ III: 154–157; Федотов II: 254.

*Тегермән тарту* дигәндә бор. җайланма – тегермән ташын валга уралган озын аркан ярдәмендә әйләндерү чагыла: ул арканны валдан сүтелеп беткәнче атлар, ишәкләр һ.б. ярдәмендә тарттырганнар (шул ук вакытта валга икенче аркан урала барган, беренче аркан сүтелеп беткәч, тарту көчен тиз генә икенче арканга кушканнар). К. «Хөсрәү вә Ширин»дә «*Күлек* (эш аты) *бер йөк яисә тегермән тартсын*».

**ТАРТЫК** «согласный (звук)» ← **тарт-у**; бу грамматик термин гарәпчәдән калька (чаг. ш. ук **Сузык**). Тат. телендә *тартык* сүзенең бүтән мәгънәләре дә теркәлгән: «оялчан, тартынучан» (ЛТ I: 4), «тотлыгучан» (Тумашева 1992: 204). Бүтән төрки телләрдә дә *тартык* сүзенең аерым мәгънәләре бар, мәс., уйг. *тартуқ* «бирт (камчы тартканнан калган эз)», бор. төрки (ДТС: 539) *tartïγ* «киндерә», «җыен, җыелыш».

**ТАРТЫЛЫШ** «тяготение; тяга (к чему)» *тартыл-у* фигыленнән XX г. 20 нче елларында рус. *(всемирное) тяготение* сүзеннән калька буларак активлашкан.

**ТАРТЫМ, тартымлы** «похож; сходно; похожий; сходный» ← **тарт-у**, **тартым** сүзенең регуляр мәгънәләре (мәс., *бер тартым* тәмәке, йөк һ.б.) *тарт-у* фигыленең аерым мәгънәләреннән килә.

**ТАРТЫН-У** «стесняться» < гом. кыпч., уйг. һ.б. *тартын-* id. ← *тарт-у*. Регуляр ясалма буларак **тартын-у** «берүзе тәмәке тартып йөрү».

**ТАРТЫНЧАК** «стесняющийся, застенчивый», «упрямый» (к. себ. **тартынцак** «оялчан», **тартындзак** «чыгымчы») – бу мәгънәләр гом. кыпч., уйг. телләрендә (*тартынчақ* сүзендә, әлбәттә) дә очрый. К. **Тартын-у.**

**ТАРТЫШ** «перетягивание каната», иск. «борьба» – беренчел мәгъ. *тартыш-у* «бер-береңне тарту» фигыле тәэсирендә килеп чыккан, икенче (иске) мәгъ. төр. *tartış* «көрәш» сүзеннән килә.

**ТАРТЫШ-У** «дёргаться; подвергаться спазмам» (регулярное значение «тянуть, дёргать друг-друга») ← **тарт-у;** *тартыш-у* сүзенең аерым мәгънәсе, ихтимал, фар. телендәге *кäшиш* сүзеннән калька булса кирәк.

**ТАРУ I** диал. «хлеба; поле» ~ бор. тат. (Котби), алт. *тару,* кырг. *таруу* id. < бор. төрки *тарығ* id. К. **Тары.**

**ТАРУ II: тару бул-у** «быть супругом кого-либо». К. **Тары-у.**

**ТАРХ, тарых** иск. «вычитание (в арифметике)». Иске тат. кулланылган бу мәдәни терминны совет власте елларында шактый тупас (чөнки чиктән тыш күпмәгънәле) *алу* (рус. «взятие») сүзе белән алмаштырганнар. Гар. телендә *ṭарх (← ṭрх)* «алу, чигерү», *ṭарахä* «товарны үлчәгәндә аның төрү-каплау әйберләре авырлыгын исәпкә алу». Шуннан ук рус. *тáра* < ним. яки ит. *tárah* «товарның савыты, кабы – чүбе» сүзе килә. Kluge: 906.

Гар. *ṭрх* «алып ташлау» тамырыннан күп кенә бүтән сүзләр дә ясалып, кайберләре киң таралыш алганнар; **мәтрух** «ташландык; алынмыш, алына торган сан» (мәс., 5–3=2 тәгъбирендә 3) тат. телендә дә кулланылган. Безнең элекке математик терминология хәзергедән байрак вә кулайрак булган.

**ТАРХАН,** диал. **тәрхан, тәрхән** «тархан (представитель сословия, свободного от налогообложения);

беззаботное состояние; крестьянское сословие в XVIII–XIX веках» < бор. төрки (ДТС: 538–539) *tarqan, tarxan* «бер титул; югары катлам кешесе», хәз. төрки телләрдә *тарқан, тархан, тәрхан, дарқан* ~ монг. *дархан, дарқан* «тимерче; оста; тархан», бор. (Velidi: 293–294) *tarhan, tarxan* «дәүләт кешесе».

Татарларда Казан дәүләте чорында *тархан* «салымнардан азат (кеше); диван әһеле» XVI г. Иван IV тарафыннан бетерелгән. Шуның белән бу сүз дә «кануло в лету» дип яза М. Федотов (II: 239–240), ләкин тарханнамәләр башкорт феодалларына, рус хөкемдарларына XVIII г. кадәр бирелгән, шул чорда Уфа губерниясендә 650 тархан була (к. Шафиков Г. Крючья под ребро. Уфа, 1993: 21–25). *Тәрхан* дигән чыгтай кабиләсе дә булган (Радлов III: 854) һәм Д. Исхаков та шул исемдәге кавем-кабилә Казан дәүләтендә булган бугай дип яза (к. аның: К вопросу об этносоциальной структуре..., 1995: 98). К. ш. ук Скворцов 1976: 79–86; Максутова Г. Тархан // Фән һәм тел, № 1. Казан, 2003: 14–17; Дмитриев 1986: 341–354 һ.б.

*Тархан* сүзе Евразиядә күп телләрдә очрый (башлыча төрки телләрдә таралган) һәм бу сүз тур. исәпсез күп язылган. Ләкин этимологиясе һаман ачыкланмаган (бу җәһәттән ул *батыр ~ баһадир* сүзенә охшаш). Э.В. Севортян күрсәткән әдәбият (ЭСТЯ III: 151–154) публикацияләрнең бер өлеше генә. С.Г. Кляшторный һәм В.В. Лившиц (1971: 121–146) күрсәткәнчә, *тархан* сүзенең сугд телендә *trγw'nt (таргуант)* варианты булган. Әгәр бу дөрес булса, *тархан* сүзен кыт. теленнән дип раслау (киң таралган фикер) дөрес түгел. Кайбер телчеләр бу сүзнең параллельләрен һинд-евр. телләрендә табалар һәм хәтта һинд-евр. вә алт. телләреннән дә борынгарак чыганактан килә дип исәплиләр (к. Менгес: 154).

*Тархан* сүзенең бор. төрки телләрдә *тӓркӓн, түркӓн* «хатын-кыз тархан, ханча, патшабикә» дигән варианты булган (к. Мелиоранский: 85). Будагов I: 349; Шапшал: 302–316. Рус. *тархан* тур. Аникин: 178; ЭСТЯ III: 151–152; Doerfer II: 460–474.

Дерив.: **тарханлык, тәрханлык, тәрханчылык** (бусы «иркенчелек» мәгъ. кулланылучан); **тарханнамә.**

**ТАРЫ,** диал. (ТТДС I: 124) **дары**, себ. (Тумашева 1992: 204) **тарық** «просо» < бор. төрки *tarıγ* «ашлык, икмәк, тары; игенчелек» ← *tarı-* «иген игү, ашлык чәчү» ~ тув. *тьары* – id., бор. чыгт. (Боровков 1963: 287) *тар-* «иген игү, җир эшкәртү» – ихтимал, ниндидер **тāр* < **тағар* сүзеннәндер (чаг. аз. диал. *даары* «тары»), к. бор. төрки *taraγ* > тув. *тара, дара* «иген, тары».

Кыпч. телләрендә һәм закончалыклы рәвештә угыз телләрендә *дары* варианты өстенлек итә (кайбер кыпчак халыклары бу сүзне угызлардан алган булса кирәк). *Тары* ~ ком. *тари* варианты (*т-*), гомумән, киң таралган (к. **Тару**); *тарық* варианты үзб., уйг. *тариқ, териқ* (ш. ук *тарығ, тариғ*) «тары, иген» сүзләреннән килә. Чув. *тыр, тырӑ* «иген», венг. *dara* «ярма» төрле бор. төрки телләрдән.

Себ. (Тумашева 1992: 203) **таран** «тары, ашлык» варианты < алт. *таран* < *тараан* < *тараған* < монг. *тариган* id. сүзеннән. *Тари-* «чәчү, игү» барча монг. һәм тунг.-маньч. телләрендә дә актив кулланылышта (к. Дамдинов: 53–54; ССТМЯ II: 168). Бүтән мәгълүматлар тур. ЭСТЯ III: 157–159; Федотов II: 168; Гаффарова 2007: 63–78 (бик тәфилле). Рус. диал. *тара* < тув. *тараа* «куырылган тары» тур. Аникин: 533. К. **Тарлан, Тарлау, Тару.**

**ТАРЫЗ** иск. «образ действия; модель; манера» < гар. *ṭарз* id. ГТРС: 543.

**ТАРЫК-У (тарыкты, тарыгу)** «счесть обременительным, лишним» < гом. кыпч. *тарық-*, төркм. *дарық-* id. тат. диал. һ.б. (Тумашева 1992: 204) **тар-, тары-** «тар булу; тараю» фигыленең интенсивлык формасы. ЭСТЯ III: 147. Тат. мәгънәсе *күңел тарыгу* дигәннән эллипсис.

Дерив.: **тарыгыш-у, тарыктыр-у.**

**ТАРЫ-У I** «встречать невзначай (на пути); попасть (в беду) и т.п.» ~ ком. *тары-,* нуг., каз., к.-калп. *дары-,* кырг. *даары-* «(җен) кагылу; тару», аерым тәгъбирләрдә «(мәрәйгә) тию» ~ як. *таары* «юлагай, узып барышлый», *таарый-* «юл уңаеннан кереп чыгу» < яз. монг. *daγari-* (> хәз. монг. *таара-,* бур. *дайра-*) > эвенк. (ССТМЯ I: 168) *таарuj-* id. Чаг. **Тары-у II.** Будагов I: 547 (*дарымак* формасын бирә); Räsänen 1969: 133 (аз материал).

Дерив.: **тарыл-у, тарыт-у.**

**ТАРЫ-У II** (Тумашева 1992: 204) «приближаться; распространяться» << бор. монг. **daγar-, *daγarı-* «якынлашу, тию» ← **daγa-,* к. гом. тунг.-маньч. (бик күп дериватлары, к. ССТМЯ I: 187–188) *даға* «якын», *дағари-* «камыт тию, яралау (!)». Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 149–150) бу фигыльләргә төркм., аз. *даара-* «чабып килеп һөҗүм итү» сүзен дә, **тары-у I** фигылен дә терки.

**ТАС I,** иск. (ЛТ I: 5) **таст,** диал. **тач** «таз, тазик» < фар. *таст, ташт, тешт* < авест. *tasta, tashta,* таҗ. диал. *точ, тач* ~ гар. *тāс* «тас, купы, агач табак» – киң таралган мәдәни сүз (к. ш. ук рус. *таз,* ним. *Tasse,* фр. *tasse,* ит. *tazza* һ.б.).

**ТАС II: тас булу** (ЛТ I: 120) «замучиться; быть в смятении; опозориться» ~ бор. төрки (МК, ДТС: 539) *tas* «бик начар нәрсә», төркм. *тас* «(нинди) була язу» (к. Мухамедова 1973: 162), куман., бор. чыгт. (Ибне Мүһәнна) *tas* «югалмыш, беткән», кар., ком., к.-балк., аз. *тас* «хур (булу); югалту», хак. *тас-тарау* «җыйнаксыз», уйг. *тәс* «кыен хәл».

Бу сүзне гадәттә монг. *тас, тасу* «бөтенләй инде» сүзе белән чагыштыралар (к. Räsänen 1969: 465, ш. ук Ramstedt 1935). Безнеңчә, бу сүз бор. һинд. *dasu, dasyu* «арий булмаган җирле халык; кара кол; бер кастага да кермәгән кеше; үтерелергә хөкем ителгән, ләкин тере калдырылган кол» сүзеннән килә. Гом. кыпч. *тас булу* «хур булу», ихтимал, шуннан: бор. закон буенча, җыелу урынына – бүлҗәлгә килмәгән яугир, хәтта бөтен хәрби бүлкәләр (частьләр) үлемгә хөкем ителгәннәр.

Төрки халыкларда киң таралган *таз кол* (к. ТХИ: Дастаннар, 1984: 56) асылда, *тас кол* ул: бу очракта *таз* (чәчсез, чәче кырылган һ.б.) сүзе белән контаминация сизелә. Таслар, тас коллар үзләрен саклау өчен елгырлык, ярамсаклык, шулай ук хәйләкәрлек тә күрсәтергә тиеш булганнар. Тас колларның *трикстер* (хәйләкәр, елгыр) булуы бөтен дөнья фольклорында билгеле (к. МНМ II: 260–261). **Тас** һәм **таз** сүзләренең буталуына шул да ярдәм иткән: төркиләрдә һәм монголларда әсирләрнең, яман колларның чәчләрен кырганнар (хәер, бу гадәт бүтән халыкларда, мәс., русларда да булган), к. хак. *тас* «кол» һәм *тас* «таз», монг. *тас-таракай* «хур ителгән кеше». Һинд-ир. телләрендә *das* «кол, хезмәтче» бик продуктив тамыр, к. ЭСИЯ II: 285–288.; Kluge: 14. Славяннарда андый коллар *смерд* дип аталган.

**ТАС III** «хищная птица; хищник» (в составе сложных слов): себ. (Тумашева 1992: 199, 201) **таскәрә** «шыртлака», **тилгәнтас** «челән»; башк. *тазбөркөт* «акбаш бөркет», *тазкутан* «челән» (бу сүзләрдә *таз* дип язу халык этимологиясеннән килә) ~ тув. *тас* «мәетләрне ашаучы кош (элекке Монголия һәм Тувада мәетләрне күммичә аерым урыннарда ерткычларга ашарга калдыру йоласы булган)», *даъс* «каракош», хак. *тас-ары* «шөпшә» ~ бор. монг. *tas* «каракош» ~ сол. *тасах,* маньч. *таса, тасха* «юлбарыс», уйг. диал. *қорултаз* «бөркет», бур. *тас-шубуун* «бәрән бөркете, бәрәнкарак», ССТМЯ II: 169–170. К. **Таскара.**

**ТАСВИР [таºсwир]** «описание; образ» < гар. *тāçwӣр* id., к. ш. ук **тасвират** «описание (как отглагольное имя – название процесса)» < гар. *тāç-wӣрāт* id. ← *çwр* «рәсем ясау, сурәтләү» тамырыннан, шуннан ук к. **Сурәт.**

**Тасвир** продуктив нигез: **тасвирла-у, тасвирлы** һ.б.

**ТАСКАК,** диал. (Тумашева 1992: 199, 204; ТТДС I: 394; ЗДС: 611) **тақсақ, тазак, тахсах** һ.б. «подставка на столбиках; навес с плоской крышей; строительные леса», диал. «настил на ветвях или на коротких ножках» ~ башк. (БТДҺ: 300, 308) *таҙғаҡ* «агач башында җәнлек күзәтү өчен ясалган урын», *тасҡаҡ* «лапас; балыкчы кимәсендә өстәлчек (ут яндыру урыны), асмалы лампа калпагы (тәлинкәсе)» > мар. (Исанбаев 1978: 30) *таскак* «таскак; трибуна; аслык», удм. *таскак* «төзелеш күперчекләре» ~ алт. (Будагов I: 805–806), хак. *тасқақ* «лапас; аслык; савыт-саба киштәсе; корбанлык терлекнең тиресе, сөякләре куела торган аслык» (к. ш. ук Радлов III: 919, 926), хак. *тасхах*, тув. *дазчақ* «киштә» һ.б. Гомумән, чыгышы безгә ачык түгел.

Башк. диал. *талғаҡ* «аучы таскагы» < *таҙғаҡ* (кире аваз күчеше).

**ТАСКАРА** «гриф» ~ башк. *таҙғара,* кырг., уйг. *тасқара* id., үзб. *тасқара, ташқара* «каракош; шөкәт», хак. *тазғара* «бөркет», тув. *даас- қара* «каракош шикелле кара (бөркет тур.)» һ.б. *тас* < *тағыз* (?) «ерткыч» сүзеннән; **кара** өлеше кош исемнәрендә төсне түгел, бүтән нәрсәне белдерә булса кирәк, к. башк. (БҺҺ II: 238) *таҙһара* ~ маньч. *тасҗари* «бөркет» (к. ССТМЯ II: 169–170), к. ш. ук хак. *тасха* «ябалак» ~ маньч. *тасха, тасһа* «юлбарыс» ← монг. *тас* «ерткыч; юлбарыс». К. **Тас III.**

**ТАСЛА-У** «сложить аккуратно; отёсывать» ~ башк. *тәçлә-, тәçтә-, тәçтәрҙә-*, чув. *тасла-* id., Босния серб диалектында (Радлов III: 920) *тасла-* «таш таслау» ← слав. *тёс* «тасланган нәрсә (агач, таш)» сүзеннән диелә. Ләкин к. монг. *тасла-* «таслау; тасмалар ясау, телгәләү», *тасда-* «ермачлау» һ.б. (**тас* тамырыннан) күп сүзләр һәм төр. *tasla-* «таслау; сурәтләү» → *taslak* «схема, проект» сүзе дә бор. төрки **тас* тамыры булгандыр дип уйларга юл калдыра.

**ТАСМА** «лента, тесьма; тонкий ремешок» < гом. төрки *тасма*, як., каз. *таспа* ~ гом. монг., тунг.-маньч., фар. һ.б. *тасма* id. киң таралган мәдәни сүз, к. рус. *тясма, тесьма, тасма*, ш. ук. удм., мар. *тасма*, мар. *тäсмä, тäшмä* (Упымарий: 203; Иванов, Тужаров: 216) id. һ.б. Евразиядә күп телләрдә очрый.

**Тасма** сүзе яңгырашы белән төрки сүзгә *-ма* кушымчасы ярдәмендә ниндидер *тас-* яки *тасы-* фигыленнән ясалган сүзгә охшый, чаг. **Тасла-у**. ССТМЯ (II: 164) авторлары маньч. *тасма* ~ яз. монг. *tasama* (> бур. *таһама*) сүзен ороч. *таппирасу* «шәлтәү (үзенә элмәкләр, кын, кесә һ.б. тагылган каеш билбау)» сүзе белән чагыштыралар. **Тасма** сүзе фар. теленнән дигән фикер дә бар (бу тур. к. Аникин: 538); өченче бер фикер буенча **тасма** грек. *δεςμα* «каеш, тасма» сүзеннән (Бактрия грекчасыннан таралырга мөмкин). Будагов I: 333.

Дерив.: **тасмалы, тасмасыз; тасмала-у; тасмалан-у; тасмалык.** Тат. сөйл. **тасма тасу** да, рус. *тесёмка* сүзе дә халык этимологиясенә кызыклы мисаллар: бу сүзләр электән килми.

**ТАСМАЛ** (ДС III: 151), **тастмал** (ЗДС: 611) «длинный вышитый платок молодых девушек и женщин» к. **Тастымал.**

**ТАСРАЙ-У, тасырай-у** «вытаращить глаза (в испуге, в ожидании чего)» < гом. кыпч. *тасрай-, тасырай-,* хак. *тазрай-,* кырг. *тарсай-* «тасраю; кабару, күперү» тәкълиди тамырдан (← **тасыр*) булса кирәк. К. башк. (БТДҺ: 308) *тасрый, тасрыҡ, таҫыр* «акайкүз». Чаг. **Тасыр.**

**ТАСТАР** «длинный ритуальный платок невесты, который вышивают одиннадцать подруг невесты в ночь *таңкучат*» (к. Бәшири: 94; ЗДС: 610–611) > чув., морд. *тастар* < гом. кыпч. *тастар* id. (бүтән – күч. мәгъ. дә очрый, мәс., ком. *тастар* «тюль») < фар. *дäстāр* «чалма, яулык». Будагов I: 557; Егоров 1964: 233.

Тастар киеп киленнәр йөри башлаган, к. туйда

*Башкаема тастар сардыгыз,*
*Яулыгымны кая куйдыгыз?*

дип кияүгә чыгарга теләмәгән кыз җырлаган. К. ш. ук *тастарлы кыз хәстәрле* (яки киресенчә *хәстәрле кыз тастарлы*) дигәннәр, ягъни тастарны алдан әзерли башлаганнар.

**ТАСТЫМАЛ,** диал. (ЗДС: 611) **тастимал, тастыман, тастамал** «полотенце (вышитое); полотенце для украшения окон и дверей» < гом. кыпч. *тастымал*, иске тат. (ЛТ I: 252) *дастымал* < фар. *дäстмāл* «кул сөрткеч». **Тастымал** сүзеннән кыскарып **тасмал** (к.) сүзе дә килеп чыккан. себ., иске тат. (Räsänen 1969: 466) **тастырмал** варианты фар. *дäстрӯмāл* «кульяулык» (сүзмә-сүз «кул һәм йөзне сөрткеч») сүзеннән.

**ТАСЫЛ,** диал. (ДС I: 195) **тәсел** «сноровка, особый навык, умение» ~ башк. *таҫыл, таһыл, таһауыл*, үзб., төркм. *тасыл*, каз. *тәсел* «тәртип, ысул, юл», тув. *дазыл* «тамыр; тасыл; эш-әхвәлнең асылы», алт., себ. (Тумашева 1992: 85) *тазыл* «тамыр». Төрки сүз булса кирәк. Киң таралган дериваты **тасыллы, тәселле** «оста, соллы». Чаг. монг. *дасал, дасгал* «тасыл» ← *даса-* «күнегү».

**ТАСЫР** – имитатив шуму, грохоту с треском ~ башк. *таҫыр* id. Чаг. як., монг., тунг. (ССТМЯ II: 169) *тас* «тасырдап; тасырт итеп». *Тас* < *тарс* булса кирәк.

Дерив.: **тасырт** (бер тапкыр кыштырдау яки шатырдауга тәкълит), **тасыр-тасыр, тасыр-тосыр** (мәс., кинәт чабып киткән ат, сыер һ.б. тур.); **тасырда-у** → башк. диал. (асылда, тат., к. БТДҺ: 308) *тасырҙык* (дөресе – **тасырдык**) «аны-моны уйламыйча гамәлгә керешүчән»; **тасырдаш-у, тасырдат-у.** Чаг. төр. *tasırtı* «курку, хафа, шом».

**ТАТ I** (Н. Исәнбәт һ.б.) «вкус; сладость» ~ чув. *тута* < *тотă* < гом. кыпч., уйг., чыгт., госм. *тат,* төркм., аз., гаг. *дат* id. (к. Радлов III: 898) < бор. төрки *tāt* < *taγat* id. (бу вариант «Угыз каган» дастаны телендә очрый). Будагов I: 720; Федотов II: 257.

**Тат** продуктив нигез: **татлы, татсыз.** К. **Тату, Таты-у, Тәте-ү.**

**ТАТ II** диал. (ДС I: 180) «пятно» к. **Татыр.**

**ТАТ III** «тат (название персоязычной народности в Дагестане); чужеземец» ~ «этническая группа персов; самоназвание персов в областях, где они составляют меньшинство» < бор. һинд.-ир. *dágdhä* «утка табынучы» (сүзмә-сүз «утчы, изге ут яндыручы» ← *dah* «яндыру»). К. ДТС: 514, 540; Фасмер IV: 26; Оранский 1979: 44 һ.б.

Кайбер татар телчеләре һәм тарихчылары **тат** сүзеннән **татар** сүзен чыгармакчы булалар. Ләкин **татар** сүзе тәүләп Ираннан еракта – Көнч. Монголия һәм Маньчжуриядә теркәлгән. Һәм мәгъ.

буенча да **тат** сүзе **татар** этнонимына нигез булырдай түгел. К. **Татар.**

Татлар Кырым ханлыгында аерым хәрби группа тәшкил иткәннәр. Будагов I: 330.

**ТАТ IV** (ЗДС: 612, себ.) «жалоба, донос (на обидчика)» < уйг., үзб. *дад, dād, дод* id., «ярдәмгә чакыру, каравыл!» < фар. *dād* id. Элекке әд. телебездә дә кулланылган. Будагов I: 545.

**ТАТАБИ** – название древнего народа, жившего в Маньчжурии – к. **Татар.**

**ТАТАВЫР [таᵒтаwы̆р]**иск., «подпруга, татаур» (к. Даль) ~ башк. *татауыр* id. < бор. монг. *tatayur* «тарткы; тарткыч, тартучы, пружина» > хәз. эвенк. *татоор* «киң каеш», хәз. монг. *татуурга* «киндерә, татавыр» һ.б. Себер телләрендә төрле вариантларда очрый, монг. *тата-у* «тарттыру» сүзеннән, *тарт-у* белән гомоген. К. **Татау.** ССТМЯ II: 171; Аникин: 540–541 (әдәбият китерелә, тәфсилле).

Бор. рус. *татаур* «бизәкле аел; баяр билбавы» чинны белдерә торган билбау буларак Алтын Урда хөкемдарларыннан күчерелгән.

**ТАТАКАЙ** диал. (ЗДС: 612) «дед, дедушка», ш. ук **татакау** һ.б. ← *тата*, к. **тата абый** > **татабый** «самый старший брат». Тат. халкының ниндидер компонентыннан кергән сүз. Гомумән, *тата ~ дада* күп телләрдә очрый торган кавем-кардәш атамасы (мәс., рус телендә дә бар).

**ТАТАР** «татарин; татары; татарский», диал. «муж жены» ~ гом. төрки *татар* – хәзер бөтен дөньяда бердәй мәгъ. кулланыла.

**Татар** этнонимы турында йөзләрчә мәкалә вә китап нәшер ителгән (иң күләмлеләреннән берсе – Podhorodecki I. Tatarzy. Warszawa, 1971. 405 s.). Шулар арасында гөман-фараз төсендә булганнары да, кистереп «менә шулай ул» дип язылганнары да бар. Ләкин бу этнонимның чыгышын – тәүдә кайсы телдә һәм ниндирәк мәгъ. ясалганлыгын без әле дә төгәл генә белмибез. Бу хакта аерым азмы-күпме уңышлы фаразлар гына бар, тик фәнни тәнкыйтьне күтәрерлек уңай раслама юк. Мәсьәләгә яңа фактик материаллар гына ачыклык кертә ала, тик алар сирәк табыла.

Ошбу этноним яз. ядкәрләрдә беренче тапкыр VIII г. башларында Күлтәгин (Күлетәгин «данлы шаһзадә») батырга багышланган руник язулы поэмада **утыз татар** кавеме турында әйтелгәндә калкып чыга. Ул әсәрдә шул кавем вәкилләренең Беренче Күктүрек каганнарының җеназасына килүе бәян ителә, җеназалар исә VI г. урталарында була. Димәк ки, VI г. һәм аннан шактый элек тә татар (һәрхәлдә **утыз татар**) этнонимы бик билгеле булган.

Руник яз. ядкәрләрендә **утыз татар**ларның VII г. тугыз угызлар белән союздаш һәм күктүрекләргә дошман булуы әйтелә. VIII г. башларындагы вакыйгалар искә алынганда инде утыз татар кабиләсе әйтелми, аның урынына **тугыз татар** дигән кавем атамасы килеп чыга. 720–740 нчы еллар араларында **тугыз татар**лар һәм **тугыз угыз**лар Күктүрек хакимиятенә каршы кузгалыш оештыралар. Ниһаять, 745 елда боларга уйгурлар да кушылып, Күктүрек дәүләтен җимерүгә ирешәләр һәм шул территориядә (хәз. Монголиянең үзәк вә көнч. өлкәләрендә) атаклы уйгур каганлыгы пәйдә була (аңарчы уйгурлар Үтәгән илендә – хәз. Монгол Алтае, Кангый – Хангай тауларында яшәгән булалар). Бу бор. уйгур дәүләте составында татарлар үзидарә белән файдаланганнар һәм аларның хөкемдары **апа тәгин** дигән титулга ия булган (пәһл. телендәге манихей җәмәгате язмасы, 825–830 нчы еллар). 842 елда Кытай яз. ядкәрләрендә дә **дада**, **дадань** халкы тәүләп искә алына.

Ул чорда татарлар уйгурлар белән бергә бик тыгыз аралашканнар. Уйгурларның югары катламы манихей динен кабул иткәч, татарларда да бу дин тарала барган булса кирәк.

Уйгур-татар дәүләтен 845 елда Енисей кыргызлары тар-мар итә. Төрки халыклар тарихында иң зур фаҗигаларның берсе булган бу вакыйга нәтиҗәсендә татар төрле якларга тузгытыла: аның бер өлеше көнчыгышка чигенә, ә зуррак төркемнәре көнбатышка күченәләр. IX–X гг. татар атамасы Хотан-сак яз. ядкәрләрендә (хәз. Кытайның Синьцзян-Уйгур провинциясендә, к. Кляшторный 1987: 33–36.), аннары «Худӯд әл-ʻаләм» («Дөньяның чикләре») дигән атаклы фар.-гар. әсәрендә искә алына. Шул ук чорда татарларның бер төркеме Иртеш буйларында Кимәк дәүләтен оештыруда катнаша (кайбер авторлар кыпчакларның көчәюенә шулар төп нигез булган дип саный).

Тузгытылган татарларның бер өлеше үз теләге белән яисә әсир булып хәз. Тувага һәм хәз. Хакасия җирләренә дә килеп утырган булса кирәк. Бу хакта кайбер руник язулар гүаһлык итә. Тувада *Хербис баары* (сырты) дигән җирдә табылган руник ядкәрдә менә нәрсә язылган: «*Минем ир-атым* (каһарман исемем) *Күлүг игә*, минем атам ил башы

*Ыңгал үгә*, миңа егерме җиде яшь булганда, мин үз илем тугыз татар өчен...» Бу язма X–XI гг. карый (к. Сердобов: 481).

Бу урында әйтергә кирәк: хәз. рус телле әдәбиятта еш кына бор. **татар** монгол булган дип язалар. Әгәр **тугыз** (һәм **утыз**) **татарлар** монголча сөйләшкән булсалар, нишләп аларның үзатамалары төркичә. Нишләп алар төркичә эпитафия язып куялар һәм нишләп аларның исемнәре (*күлүг* «данлы», *ыңгал* «сәвәтле, грамоталы») төркичә соң?

Татар этнонимы искә алынган икенче бер руник ташъязма Уйбат елгасы буенда Хакасиядә табылган. Хакас галиме И.Л. Кызласов фикеренчә, бу ташка *Татарның иле игә (ия, рух) өчен (корбан итеп) бирер; игебез (игенебез) сакланыр* язылган һәм Татар исемле илбашының басу иясенә корбан чалып игеннәренең уңачагына өмет баглаганлыгын белдерә (к. Кызласов 1987: 21–32).

Бу язмадан бор. Хакас-Енисей кыргызлары дәүләтендә (IX г.) **татар** сүзе бик билгеле, үз булганлыгы күренә. Гомумән, бор. язмалардагы **татар** сүзе монголларны белдерә диярргә хәлиткеч дәлилләр юк. Чыңгыз хан дәверенә кадәрге мәгълүматларда – Кытай чыганакларында монголларны **мэн** дип, татарларны **дада** дип ачык аерып язалар (к. Lovıs Hambis: 43–44). Төрки галимнәре күптәннән бирле бор. татарларны төркиләр дип язалар (к. Губайдуллин: 131–142). **Утыз татар**, **тугыз татар** дигәннән, кайбер чыганакларда **Сәкиз татар** «сигез татар» кабиләсе дә булган диләр (к. Фәхретдинов 1996). Тик руник төрки язмаларда бусы («сигез татар») очрамый бугай. Гомумән исә, бор. төрки этнонимнарда саннар еш кулланыла: әйтелгән *сигез татар, тугыз татар*га параллель рәвештә *сигез угыз, тугыз угыз; тугыз уйгур, ун уйгур* һ.б. еш кына очраган. Бу кабиләләр, күрәсең, үзләрен бер системага кертеп караганнар. Мондый хәл исә аларның кайчандыр бер дәүләт составына караганлыгыннан түгелме икән?

Шуларга охшаш атамалар монгол халыклары этнонимикасында да очрый. **Найман** дигән монголда һәм, күбесенчә, төркиләрдә очрый торган кабилә-ыру атамасы монголча «сигез» дигән сүз. Нәкъ найманнарны гарәпләр «татарлар» дип тә атаганнар. Бу кызыклы факт безнең фикерне куәтли, әмма татар һәм монгол сүзләре буталу күптәннән килгәнлеген дә әйтү зарур. Тикшеренүчеләрнең күпчелеге бу *сигез, тугыз, утыз, ун* сүзләрен кабиләләр санын күрсәтә дип уйлыйлар: тугыз татар димәк тугыз ырудан торган татар кабиләсе берлеге – союзы. Ләкин, шуның белән беррәттән, болардагы саннар елгалар исәбен күрсәтә дигән фикер дә бар: утыз татар – «утыз елга буен биләгән кабиләләр союзы» булып чыга.

Ничек кенә булмасын, без ошбу саннар кабиләләр санын күрсәтә дию ягында. Һәрхәлдә **утыз татар** тәгъбире татар кабиләләр союзының киң булуын күрсәтә шикелле.

**Татар** этнонимының сан белән төрләндерелгән вариантларынан тыш, төс белән төрләндерелгәннәре дә була: кытайлар **ак татар, кара татар** һәм **кыргый** (яисә **урман**) **татарлары** бар дип язганнар. Кытай чыганакларында ак татарлар *шато* кабиләсенең бер өлеше дип әйтелә. Шато кабиләсе исә VII г. Тянь-шань регионында яшәгән һәм өлешчә христиан булган төркиләр (к. Гумилев 1994: 165–170).

**Кара татар**лар дип монголларны атаганнар. **Кыргый татар**лар Себердә яшәгән. Якут легендаларында якут халкы бабаларының бор. берсе **Татар тайма** исемле. Бу фактлар **кыргый татарлар** чыннан да булган дигән фикергә этәрә.

IX г. **татар** кавеме атамасы гарәп тарихчысы Гәрдизинең кимәк федерациясе оешуы турында кыскача хәбәрендә күренә: анда **татар** шаһзадәләренең берсе бу федерацияне оештыручы буларак аңлатыла (бу хакта Бартольд, т. VIII 1973: 43–44; Гумилёв 2002: 225–227).

XI–XII гг. татар исеме инде бик күп ядкәрләрдә искә алына. М. Кашгари (XI г.) татарларны төркиләр рәтенә кертә, «әмма аларның үз телләре дә бар» ди. Монысы нәрсәне белдерә – ачык кына аңлатылмый. **Татар чүлләре** дип М. Кашгари хәз. Җунгарияне атый булса кирәк: анда, бигрәк тә Турфан тирәсендә, кыргызлардан качып килгән татарлар чыннан да күп булган.

XIII г. **татар** сүзе иксез-чиксез күп ядкәрләрдә һәм төрле мәгънәләрдә очрый: аларны карап чыгу өчен калын бер том язарга туры килер иде. Тик без түбәндәге кызыклы фактка игътибар иттерәсебез килә: XIII г. башларында хәз. көньяк-көнч. Казакстанда көчле мәҗүси дәүләт корып, монголлар белән дә, Харәзем империясе белән дә көрәш алып барган Күчлүк ханның мөселман исеме Кадыйр булган һәм аны Кадыйр-татар дип атаганнар. Димәк, ул чыгышы белән татарлардан булган. Аның ата-анасы ислам динен алып, Күчлүк (көчле) исемен гарәпчә эквиваленты Кадыйр белән алмаштырганнар. Ләкин Кадыйрның кул астындагы төркиләр мөселманлыкка күчәргә теләмәгәннәр һәм Кадыйрга да элекке мәҗүси исеменә кайтырга туры килгән.

Чыңгыз хан заманындагы монгол чыганакларына күрә, Монголиядә **алухай**, **алчи**, **дутаут** һәм **чаган** дигән «татар» кавемнәре булган. Бераз соңрак, XIII г. азагында атаклы тарихчы Рәшидетдин татарларны сортлап күрсәтә: **татар-тутуй**, **татаркултуй**, (кайбер транскрипцияләрдә, күчермәләрдә *тутуй* белән *кулгуй* берләштерелеп *тутукулуй* дип язылган) **татар-алчи**, **татар-чаган**, **татаркуин**, **татар-терат**, **татар-баркуй**. Шул ук вакытта Рәшидетдин XIV г. башларында бөтен «иске дөньяда» (Хитай, Һинд вә Синд, Чин һәм Мачин, Кыргыз, келар һәм башкорт илләрендә, Дәште Кыпчакта һәм аннан төньяк өлкәләрдә, гарәпләрдә – Сириядә, Мисырда һәм Мәгърибтә) төркиләрнең **татар** дип атала башлаганлыгын хәбәр итә. Анынча, бу күренешнең сәбәбе – татарларның аеруча көчле, күренекле, данлыклы булуларында: төркиләр еш кына үзләрен татар дип атаганнар, чөнки татарларның данына уртак булырга теләгәннәр.

Бор. монгол исемлегендә дә, Рәшидетдин исемлегендә дә ешрак кабатланган татар кавемнәре ике генә – **алчи татар** һәм **чаган татар**. **Алчи** (**алчын**) сүзе бүгенгә кадәр казак һәм үзбәкләрдә билгеле булган кабиләләр союзының (Кече җүзнең) атамасы. **Чаган татар** сүзенә килгәндә, бу Кытай чыганакларында да күп тапкыр искә алынган (к. югарыда) **ак татар** тәгъбире белән бердәй булса кирәк (*чаган* монголча «ак»). *Ак ~ чаган* сүзе төрлечә тәгърифләнә.

Гомумән, «ак» мәгъ. сүзләр этнонимиядә бик киң таралган: славяннарда **бело**руслар, **ак** хорватлар билгеле; шулай ук элекке язмаларда **ак** һәм **кара** болгарлар искә алына. Чувашларда **шуры чываш** «ак чуваш» этник группасы бар, нугайлар да **ак** һәм **кара** группаларга бүленә һ.б. (к. ш. ук. **Иштәк**, **Мангыт**). **Ак** сүзе төрле очракта төрлечәрәк мотивлана; **шуры чувашлар** халыкның раса билгеләренә ярашканлыктан шулай аталганнар, ә алардан аерымланган **кывак (күк) чувашлар** күк җилән, күк күлмәк яратканнар. *Белорус* сүзе *Белая Русь* дигәннән, ә бу исә «Алтын Урдага ясак түләмәгән Русь» дип аңлатыла (*белый* сүзенең «ясаксыз, салымсыз» дигән мәгънәсе булган). Шуның шикелле **ак татарлар**ның һәр очракта *ак йөзле* кавем булуы шарт түгел.

Кытай чыганакларында тагын **цзинь дада,** ягъни «алтын татарлар» кабиләсе искә алына. Алар хәз. Маньчжурия тирәләрендәрәк яшәгәннәр. Төрки һәм фарсыча чыганакларда «алтын татарлар» турында ләм-мим сүз юк. һәм аларның ни өчен «алтын» булуы да ачык түгел (шуның кебек үк «көмеш болгарлар»ның көмешлеге нидән гыйбарәт икәнлеге дә бигүк аңлашылмый). Ихтимал, әлеге **алчин** татар дигәндә **алтчин** – төркичәгә **алтын** «алтын» сүзенең монголча чагылышыннан килеп чыккандыр.

Тарихи әдәбиятта Чыңгыз хан татар кавемен «кырып бетергән» дигән сүз мәктәп дәреслекләрендә дә, төрле псевдотарихи әсәрләрдә дә еш очрый. Ләкин Чыңгыз хан үз кавеменең (бөрҗәгиннәрнең) әзәлге дошманы булган Буир-нур татарларын гына кырган. Дөрес, Буир-нур өлкәсе (хәз. Кытай Маньчжуриясенең төньяк-көнбатышында һәм Монголиянең төньяк-көнбатышындагы җирләр) татар кавеменең *ана йорты,* оешып аерым этнос формалашкан территория булган бугай. Ләкин аерым татар кабиләләре VII–IX гг. ук ишәеп, ул (табигый җәһәттән фәкыйрь) җирләрдән китеп, бөтен Үзәк Азия буйлап киң таралган булганнар. Бу хакта К.А. Аблязов «Историческая судьба татар» дигән китабында (130–140 нче һ.б. сәхифәләр) бик тәфсилләп яза. Үзәк Азиядә Хупнхэдан башлап Җаекка кадәр булган территориядә я тегендә, я монда татар дәүләтләре оеша торган булган.

Урта Идел регионында **татар** сүзе, нигездә, X г. бирле билгеле булса кирәк, чөнки нәкъ шул чорда кимәк-кыпчак кабиләләре бу җирләргә күпләп үтеп кергәннәр, ә кимәк союзында татар кавеме төп союздашларның берсе булган. Кимәк федерациясендәге татарларның төркичә сөйләшкәнлегенә шикләнмәскә мөмкин, чөнки бу союздагы бүтән кавемнәр төрки булгач, татарларның нинди дә булса бүтән телне (гәрчә андый тел булган булса да) саклап калуы бик шикле. Ник дигәндә, кимәк федерациясен төзегән кавемнәр бик тиз үзара кершеп, ассоциацияләнешеп бетәләр. VIII г. беренче тапкыр искә алынганнан соң, алар тарихи ядкәрләрдә бөтенләй күренмиләр, соңрак (X–XIII гг.) тик **кимәк** һәм **кыпчак** сүзләре генә торып кала.

X–XII гг. Урта Иделдә татар этнонимы гомумән билгеле булса да, үзләрен татар дип атаучылар булдымы икән – бусы бәхәсле. Ниндидер бер төрки телдә сөйләшкәннәрнең үз телләрен татар теле дип атау факты XIII г. бирле теркәлә: шул чорда язып алынган фольклор материалларында – мәшһүр «Codex Cumanicus» китабында ул. Бу китапның телен лингвистик җәһәттән караганда да «бор. татар теле» дип күрсәтергә хакыбыз бар. Ул тел мишәр диалектына охшаш, әмма караим теленә аеруча якын дип карала.

XIV г. Алтын Урданың төп территориясен – хәз. көнб. Себер, Казакстан, Көньяк Урал, Урта һәм

Көньяк Идел буйларын, Дон һәм Кубан бассейнын бергә алып – Татария (Тартария) дип атау халыкара кулланышка кергән. Һәм үзләрен татар дип атаучылар да аз булмаган. Төньяк Кавказдагы кайбер төрки, хәтта төрки булмаган кабилә-кавемнәрнең XIX г. башларында руслар тарафыннан һаман татар дип аталуы юкка түгел. Чиркәс-адыгей телләрендә **тәтәр** «җирле төрки, карачай-балкар яисә нугай» сүзе белән беррәттән **казан** «Идел-Урал татары» булуы да шуны күрсәтә.

Бүтән җирләрдә дә **татар** этнонимы бу чорда күп очраган. Мәс., шул ук Аксак Тимер бер **кара татар** кабиләсен Анатолиядән Урта Азиягә күчергәнлеге билгеле (к. Будагов I: 329; Sumer 1992: 181). Төрле «татар» төркемнәре тур. З. Вәлиди (Velidi 1981) китабында күп материал китерелә.

Көнч. Европада татар сүзе, гомумән, кимендә X г. бирле билгеле булса да, аның киң таралуы монгол яулары белән баглы: Чыңгыз хан, аның уллары һәм оныклары төп монголларны монгол дип, монгол гаскәрләренә кушылган һәм гадәттә төп гаскәр алдыннан барган сугышчыларны татар дип атаганнар (чөнки башта ул гаскәрләр Чыңгыз хан тарафыннан буйсындырылган кайбер татар кабиләләре кешеләреннән гыйбарәт була, тик соңрак ул татар гаскәрләренә күптөрле бүтән төркиләр, хәтта төрки булмаган кавемнәр, мәс., кайбер руслар да кушылган). «Безнең» татарларга бу атама шул монгол гвардия гаскәре (кәшиктәннәре) тарафыннан алга куелган татарлардан йогып калуы турында тарихчылар XIII г. бирле язып киләләр (к. Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций. М., 1996: 305–307; Исхаков, Измайлов 2007). XIII г. урталарында монголлар үзләренә ияргән барча халыкларны татар дип кимсетеп атаганнар. Татар-башкорт сөйләшләрендә **татар-тарагай** «татар тазбаш» бу монгол гадәте буенча әсирләрнең какул чәчен (кәкелен) бәйләп кую яисә бөтенләй кисеп алудан килә. Башы такыр кырылганлык – чит (монгол түгел) кабилә-кавемнәрдән булган хәрбиләр билгесе булган. Монголлар үзләре андыйларга кимсетеп караганнар һәм русларның **гололобый татарин** тәгъбире монголларның **татар тарагай** дигәненнән калька. Башкортларда әле без бәләкәй чакларда шундый такмак бар иде:

*Татар, татар, тарагай,*
*Кермә безнең арагай,*
*Кысылырҫың, үләрҫең,*
*Биш тәңкә акса түләрҫең.*

Ихтимал, монгол яуларына катнашкан башкортларның кәкеле кыркылмагандыр.

Әлеге такмакка каршы татар малайлары башкорт малайларын үчекләп:

*Башкорт, башкорт, барагай,*

дип башлап шул ук такмазаны кабатлыйлар иде. **Барагай** монголча «симез» дигән сүз. Шулай ук татар сөйләм телендә **урыс-улак**, **урыс-улагай**, **урыс-унтагай** сүзләре билгеле. **Урыс-улак** яки **улагай** дигәне «урыс-олаучы» (димәк урыслар монгол хакимияте чорында олаучылыкта йөргәннәр) дигән сүз. **Унтагай** монголча «юлбасар»: бу характеристика X–XVI г. дәвамында урыс кимәле юлбасарушкуйникларның Идел һәм Чулман буе халыкларын талап вә кырып йөрүләренә ишарә итсә кирәк.

Бу **тарагай, барагай, улагай, унтагай** (шулай ук **кыргыз-кырагай** «кырларда гизүче», шуннан – **кыргый**) сүзләре Алтын Урда чорындагы «халыкларга» мөнәсәбәтләрне гаҗәеп тәфсиллек белән чагылдыралар: монголлар үзләре – хаким халык, алар тәнкыйтьтән өстен һәм буйсынулы халыклар да бер-берсенә монгол күзе белән караганнар!

Ләкин «олы ага» монголлар озак тантана итмәгәннәр: Алтын Урда төзелеп илле ел да үтмәгән, монголлар үзләренең тарагай-барагайлары тарафыннан йотылып, ассимиляцияләнеп беткән.

Алтын Урда һәм Казан дәүләте чорларында әд. әсәрләрдә **татар** сүзләренең кимсетүле мәгънәдә бирелүе әлеге монголлар күзеннән һәм дә монголларга карауның чагылышы булса кирәк.

Ләкин XIV г. азагы – XV г. башларында **татар** сүзе Алтын Урданың төп (үз) илатына карата кулланыла башлый. Испан сәяхәтчесе Руй Гонсалес де Клавихо үзенең Аксак Тимерне күреп сөйләшергә барганлыгы хакындагы язмаларында Татария дип фәкать Алтын Урданы гына атый (Урта Азия Татариягә керми) (к. аныкы Дневник путешествия в Самарканд ко двору Тимура. М., 1990.) Шул ук заманда (Клавиходан өч дистә ел соңрак) язылган «Бабахан дастаны»нда «Татар шәһәре» әкияти ил кебек гәүдәләнә. XV г. Бәлх (Төньяк Әфганстан) төрки шагыйре Атаи **Татар иленнән** ataклы мөшек килгәнлеген билгели: сүз җофар турында бара, җофар исә Идел бассейнында гына яши. Бу фактлар Алтын Урда илатын **татарлар** дип атау урыслардан гына килмәгәнлеген күрсәтә. Шунысы мөһим ки, Алтын Урда таркалуга барган Идегәй заманында Алтын Урда этносы – бор. бер төрки телле татар теле формалаша башлый. Тик бу процесс үсеш алмый һәм Идегәй үтерелү белән таркала. Хәз. татар халкы икенчерәк нигезләрдә формалаша.

Шулай күзаллаганда Ә. Кәримуллинны (к. Татары. Этнос и этноним. Казань, 1988; Язмыш, яз-

мыш. Казан, 1996: 390–397) бик аптыраткан мәсьәлә – Алтын Урда татарлары версияләренең күплеге (татарлар, нугайлар, комыклар һ.б.) белән хәз. татар атамасының мәгънәсе арасында каршылык җиңел хәл ителә.

Урта Азиядә XVI г. төзелгән даими 92 төрки кабилә исемлегендә (ул исемлек соңыннан күп тапкырлар кабатланган) татар кабиләсе һәрвакыт искә алына (к. Султанов: 66–77). Алтын Урда татарларына параллель рәвештә угыз кабиләләре арасында да әледән-әле татар дигән кабилә-кавемнәр искә алына. Мәс., XVI г. Шамда **татар-алилү** ыруы яшәгән (к. Sumer 1992: 105).

XIX г. башында төрекмәннәрнең йомут кабиләсенә караган ырулардан **күчүк татар** һәм аңа буйсынулы *татар ыруы* булган. Икенче бер мәгълүматлар буенча, XVII г. ул татарларның **Меру (Мары)** тирәсендә үз билеге булган һәм ул аларны Аксак Тимер хәз. Төркиядән XIV г. күчергән була (Бартольд II: 616–617). XVIII г. урталарында татар этнонимы турында язган П.И. Рычков татар-монгол атамаларының күптән буталганлыгы, төрки халыклар арасында XVIII г. **татар** сүзе ниндидер начар халыкка күрсәтүе, әмма Идел-Урал татарлары үзләрен татар дип атасалар да, бүтән төркиләр аларны нугай яки казак дип атаулары турында яза (к. аныкы: Топография Оренбургской губернии: 46).

XIX г. рус әдәбиятында Идел-Урал һәм Кырым татарлары гына түгел, кайбер Кавказ халыклары – комыклар, карачай-балкарлар, азәрбайҗаннар һәм Көньяк Себер халыклары – хакаслар, шорлар һәм алтайлар да татар дип атала башлыйлар (хакаслар һәм шорлар бүгенгә кадәр үзләрен татар дип аташтыралар). Хәер, руслар гына түгел, Европа халыклары да ул чорда төрекләрдән тыш барлык төрки халыкларны татар дигән гомумиләштерелгән исем белән атыйлар; *нугай татарлары, кыргыз татарлары, Кытай татарлары* (уйгурлар) һ.б. дигән тәгъбирләр еш очрый. Төрки халыкларның һәм телләренең гомуми атамасы *төрек-татар шивәләре* (рус.: турецко-татарские наречия) була. Бу атама чит илләрдә хәзергә кадәр очрый. Мәс., Ирандагы күптөрле (башлыча угыз) төркиләре турында татар шивәләре, төрек-татар кавемнәре дип язгалыйлар. Хәз. фар. телендә дә *шиваһаи турки-татар* (*тәтәр*) диелә.

Инде **татар** сүзенең лингвистик чыгышына күчик.

Кайбер чыганакларда татарлар элегрәк кыт. **шивей** дип аталган дигән фикер үткәрелә. Беренче чиратта шивейләрнең һәм тәүге татарларның яшәгән урыннары бер булуы күзәтелә. Шивейләр үзләре **кумоси** һәм **киданә** дигән тунгус-маньчжур халыклары белән кардәш булганнар. Ләкин аларны төркиләр тарафыннан билгеләнгән өч **тотык** (губернатор) идарә иткән. Гомумән, шивейләр биш төрле: көньяк шивейлар (алар егерме биш кабиләгә бүленә), төньяк шивейлар (тугыз кабиләгә бүленә), бо шивейләр (тагын төньяктарак), шэньмода шивей һәм зур шивейләр. Аларның территориясе хәз. Якутиядән Маньчжуриягә кадәрле җирләр була. Бу җирләрдә бор. заманнардан бирле тунгус-маньчжурлар яшәгән һәм шунлыктан булса кирәк В.В. Радлов заманында бор. татар-тунгус вә маньчжурлар кардәш дип язып чыккан. Кайбер тикшеренүчеләр татар сүзендәге *-р* авазын маньчжур күплек кушымчасы *-ра*ның калдыгы дип күрсәтәләр (ягъни элек ***тата-ра*** «татарлар» сүзе булган, имеш). Бу фараз файдасына тагын шундый дәлил китерелә: кайбер монгол сөйләшләрендә **татари**, **татыр** «сакау» ~ нанайча **татари** «тырылдавык» һ.б. Ягъни татарлар та-та-та дип торучылар, яисә татылдаучылар, тәтелдекләр. Ләкин бу монголча булмаган сүзне башкача да аңлатып була: «сакау» – димәк туган теле монголча булмагач, монгол телендә акцент белән сөйләшүче. Шулай уйлаганда бу сүз – бор. татарларның монгол булмавына гына дәлил (чаг. рус. *немец* «телсез, сөйләшә белмәүче».) Танылган тюрколог, тарихчы В.В. Бартольд бор. татарлар монгол да, төрки дә түгел дигән карашта торган.

Тарихта беренчеләй билгеле татарлар Көнч. Монголия һәм Төньяк-Көнб. Маньчжурия регионында яшәгәч, аларның тәүге ватаннары да шунда дип уйларга ярый. Әгәр бу фикер дөрес булса, **татар** сүзенең этимологиясен тунгус-маньчжур һәм монгол телләреннән эзләү дә табигый.

Ләкин татар сүзенең чыгышын тунгус-маньчжур телләреннән эзләү ышандырырлык нәтиҗәләр бирми. Дөрес билгеле бер фаразга нигез булган сүзне һәрвакыт табып була, ләкин менә тарихи конкрет дәлил буларак сүзләр табылмый. Мәс., эвенк. *татаар, татигар* «укыту, өйрәтү; укытылган, өйрәтелгән (мәс., солдат)»; кайбер бүтән тунг.-маньч. телләрендә *татари* «теге яктагы; аръяк» (ССТМЯ II: 160–170). Мәзкүр сүзләрнең һәр икесе этноним буларак яраклы, алардан татар этнонимы ясалуы ихтимал, тик бу ихтималлык конкрет дәлилләргә бик мохтаҗ.

Татар сүзен аңлатып бирүгә тырышу XII г. бирле билгеле. Мөселманлаштырылган легендаларда Яфәс оныгы татар-төрек һәм монгол дигән *туграй*

(иң бор.) *бабаларның* атасы (легенданың кайбер вариантларында татар һәм монголлар **түрек баба** угыллары). Бу легендаларда этнонимнар «Алладан бирелгән», һәм шуңа күрә аңлатуга мохтаҗ түгел.

Европа халыклары татар сүзен антик мифологиядәге **тартар** «җир асты патшасы» белән бутаганнар (бүгенгә кадәр кайбер телләрдә **татар**ны **тартар** дип атап язалар).

А. Халиков татар сүзе «очлы һәм җиңел ук»ны белдерә дигән әрмән чыганагын күрсәтә (Халиков 1992). XIII г. монголлар татар сүзе белән кызыксынучыларга бу сүз тәүдә елга исеме булган дип аңлатканнар. Тик татар елгасының кайдалыгы күрсәтелмәгән.

Европада һәм Россиядә XVIII–XIX г. татар сүзен аңлату өчен бик күп фаразлар әйтелә. Бөтенләй диярлек нигезләнмәгән булганлыктан, аларның күпчелеген искә төшерү дә күңелсез. Кызганычка каршы, шундый сәвәтсез «этимологияләр» бүгенгә кадәр пәйда булгалый. Мәс., Р. Корбангалиевнең «Ватандаш» журналында (№ 9, 2007: 184–204) «Башҡорт тарихының көҙгөһө» дигән пырдымсыз мәкаләсендә «*татар* – монгол гаскәрендә авангард – дошман көчен *татып караучы*» дип аңлатыла.

Гомумән, **татар** сүзенең этимологияләрен өч группага бүлеп карарга мөмкин:

а) алтаистик (төрки-монгол-тунгус телләренән чыгып),

б) ирани (фарсы, сугд),

в) сино-тибет (кытайча яисә тибетча) этимологияләр.

А л т а и с т и к  э т и м о л о г и я л ә р. Татар сөйләшләрендә **татар** «ир, гаилә башлыгы» дигән сүз. Бу бик кызыклы фактны төрлечә аңлатып була. Мәс., ул нинди дә булса бор. татарларның килеп җирле хатыннарга өйләнүеннән калган булырга мөмкин. Шулай ук ул мари теле тәэсирендә барлыкка килә ала: мари телендә мари сүзе милләт атамасын да, ирне дә белдерә (мондый мәгънә структурасы күп кенә халыкларда очрый).

И р а н и  э т и м о л о г и я. Бу очракта киң таралган версия – **татар** сүзенең **тат әр – тат кешесе, тат ир** тәгъбиреннән килеп чыгуы турында фараз игътибар үзәгендә тора. Кайбер тикшеренүчеләр төрки этнонимда *-ар* компоненты сүз азагында еш очравына игътибар итеп – мәс., *авар*, *хазар*, *болгар*, *сувар*, *кабар* (Төньяк Кавказда яшәгән бор. бер кавем) һ.б., бу компонент бор. төрки *әр* «ир, гаскәри, батыр» сүзеннән килә, дип уйлаганнар (Ф.И. Гордеев, Д.Е. Еремеев һ.б.) һәм татар сүзен дә шундый *-әр* ярдәмендә ясалган рәтендә караганнар. Сүзнең тамыры **тат** – үзе дә Евразиядә киң таралган этноним. Ул бор. төрки яз. ядкәрләрдә дә еш очрый һәм, М. Кашгари билгеләгәнчә, ирани телле кешеләрне белдерә.

Бер карашка шактый ихтималлы булып күренгән бу фараз (*татар* < *татәр*) җентекләбрәк, уйлабрак караганда бөтен кызыклыгын югалта. Беренчедән, мәзкүр сүзләрнең *әр* «ир» сүзе ярдәмендә ясалганлыгы бер очракта да тарихи яз. мәгълүматлар белән расланмый. Хәз. көндә *-ар* булып беришле яңгыраган бетемнәр төрлечә килеп чыккан булса кирәк. Ягъни монда очраклы охшашлык булуы бик ихтимал.

Икенчедән һәм иң мөһиме – татарларның (алар кайда гына вә нинди генә булмасын) *татлар* белән аеруча бәйләнышы турында бер генә тарихи, этнографик һ.б. мәгълүмат та күренми (к. югарыдарак).

**Татар** сүзе тәүләп руник ядкәрләрдә VIII г. башларында теркәлгән. Ләкин ул язмаларда VI г. вакыйгалары турында сүз бара. Димәк ки, **татар** этнонимы VI г. күптән билгеле булган. **Тат** сүзе исә тәүләп шул ук төрки чыганакларда «чит ил кешесе, бигәнәй» мәгънәсендә VIII г. искә алына. **Тат** ул кавем-кабилә атамасы түгел, бер кеше, социаль катлам вәкиле. **Тат** сүзе бүгенге көнгә кадәр Якын Шәрыктә еш очрый. **Тат:**

1) Дагстанда ирани телле бер халык;

2) көньяк-көнч. Иранда фарсыларның үзатамасы;

3) көрдләр телендә – «гарәп», XIX г. Кырымда һәм Төркиядә **тат** дип яһүдиләрне һәм җәнвәләрне (генуизларны – итальяннарны) атаганнар, чыгт. язмаларда **тат** – монах, патша сараенда хезмәт итүче (чит ил кешесе), яллы гаскәри, чыгышы билгесез кеше, бабул. «Дәдә Коркыт» китабында **тат** – мөселман миссионеры. Шулай итеп, бер контекстта да **татар** белән **тат** «чагышмый», бергә туры килми.

Күп кенә мәгълүматлар **тат**ларның ирани (фарсы яки сугд) телендә сөйләшүенә ишарә итә. Һәм **татар** сүзен **тат әр**гә тартып, А. Халиков үзенең «Татар этнонимы турында» мәкаләсендә (к. Мирас, № 5, 1992) М. Кашгари, имеш, татарлар фарсы телендә сөйләшәләр дип язган ди. Хәлбуки М. Кашгарида андый сүзләр юк. Анда «татарлар төркиләр, тик аларның тагын үз телләре дә бар» диелә, әмма үз телләренең нindилеге хәбәр ителми. Бу «үз телләре» дигән сүз үзәктән ераграк төрки телне дә белдерергә мөмкин. М. Кашгари тик **татлар** турында гына фарсы телендә сөйләшәләр ди (кызганычка каршы, А. Халиковның бу хатасы кабатлана да башлады, к. Исхакова 1992: 89–95).

**Тат** этнонимының, әйткәнебезчә, кырым татарларына гына кагылышы бар: анда **тат или** (тат иле) дигән группа һәм **тат-туфәңчи** дигән гаскәри груһ булган (*туфәңчи* «мушкетёр», *туфәң* «бор. авыр мылтык, пушка»). *Тат*ларның тәгаен ирани халык булуы тур. З. Вәлиди (Velidi: 114, 214) ассызыклап яза. Хәз. төр. телендә *тат* «төрки түгел» мәгъ. кулланыла.

Сино-тибет телләреннән кергән дигән фараз. Безнең карашыбызча, **татар** сүзенең бор. яңгырашы **тартар** (бу яңгыраш, әлбәттә, лат. телендәге **тартар** «җәһәннәм, җирасты тәмугы» сүзе белән баглы түгел – монда очраклы охшашлык кына). Сүзнең тамыры – бор. төрки **тар** «кабилә башлыгы, би, кенәз» (ул **тархан** һәм бор. **тарым** «би хатыны, бикә» сүзләрендә сакланган). Шул титулдан **тартар** «башлыклар башлыгы, кенәз кенәзе, патша, император» сүзе ясалган, чаг. Төркиядәге *бәгләр бәг (бәгләри бәги),* фар. *шаһиншаһ, мобедан-мобед,* гар. *әмир әл-үмәра* һ.б., төрки **хакан**, **каган** сүзен дә күпчелек тарихчылар **ханхан** сүзеннән дип карыйлар.

Тарихи җәһәттән, безнеңчә, фараз түбәндәгечә нигезләнә: Л.Н. Гумилёв (1993: 14–15) **жужань** (**жуан-жуан**, **руан-руан**) дәүләтенең иң көчле чагы Датань хан заманында булган ди. **Датань** дигәнебез Кытай иероглифлары белән **жуань** телендәге сүзне белдерергә маташудан килеп чыккан. Кытайлар үз телләрендә булмаган ауслаут *-р* һәм *-л* авазларын *-нь* белән алмаштырганнар һәм еш кына *-д* вә *-т* авазларын да бутаганнар. Шуларны искә алып фикер йөрткәндә, *Датань*нең чын исеме *татар* яки *тартар* булып чыга, һәм сүзнең шәхес исеме түгел, титул булуы да ихтимал. Менә шул **Датань-Татар** патшаның табигъларын-рәгыятен дә күрше халыклар **татар** дип атый башлаганнар булса кирәк. Шундый фараз **татар** сүзенең элек-электән бик төрле кабилә-кавемнәрне белдереп килүен дә аңлата: жужань империясе бик төрле халыкларны берләштергән булган ич!

Бор. («маньчжур») татарлар һәм алар белән чордаш вә күршелектә яшәгән **татаби** һәм **татань** дигән халык атамаларының охшашлыгы, ай-һай, очраклы микән? Бу этнонимнар да әлеге Датань-татар патша исеме белән баглы булса ни гаҗәп.

Бор. **тар** титулы бор. кыт. **тар, дар** «зур; өлкән башлык; олы» сүзеннән (классик кыт. *да* «зур» шуннан килә). Кыт. теленнән бу сүз күрше кабилә-кавемнәргә дә титул буларак күчкән. Безнең эра башларыннан бирле кытайлар үз сүзләрен үзләре танымый башлаганнар. Хәер, **дада** «татар» сүзе «өлкәннәр өлкәне» дип тә аңлатыла алган (әмма монда иероглифлар икенчерәк).

Кайбер рус галимнәре, мәс., Н.А. Баскаков, безнең татар атамасы бор. төрки-монгол кавемнәрендәге татар этнонимы белән турыдан-туры бәйләнмаган, ә Чыңгыз ханның оныгы – мәшһүр Нугай нойонның атасы – Татар исеменнән дип расламакчы булганнар. Төрки дөньяда кеше исеменнән килеп чыккан этнонимнар очрый (нугай, үзбәк һ.б.), ләкин ул очракның билгеле тарихи аңлатмасы – нигезе була. Әлеге Татарның исә безнең татар халкы тарихына катнашы юк, ул Урта Идел регионында хакимлек итмәгән һәм гомумән күренекле шәхес булмаган.

Н.А. Баскаковның татар сүзенең беренче мәгънәсе «илче, курьер» булган дигәне дә ышандырырлык түгел. Дөрес, XIV г. башлап XX г. кадәр Госманлы империясендә һәм Иранда шундый термин булган. Төрки телнең бик тәфсилле Редхауз сүзлегендә **татар:**

1) татар халкы; бер татар; 2) курьер, бигрәк тә хөкүмәтнең җаваплы курьеры, шуннан *татар чыкармак* «җаваплы курьер, илче җибәрү», *татар калпагы* (Сәйф Сараида *татар бүрке* – курьерларының махсус баш киеме), *татар кәдхуда*сы «дәүләт юлларының сакчысы», *татарчык* – кечкенә курьер; курьер быргысы; черки (аның безелдәве курьер быргысы безелдәвенә охшашлыктан) диелә (к. ш. ук төр. *tatarı* «хат ташучы күгәрчен»). Хәз. Төркиядәге

*Истанбулдан килә татар,*
*Сөңгесен ул күккә атар*

дигән җыр-такмак та югары әйтелгәнгә ишарә. Ләкин бу очрактагы татар сүзе һичшиксез – татар дигән кавем-кабилә кешеләренең (ихтимал, Алтын Урдадан күченеп киткәннәрнең) Шәрыктә курьер булып хезмәт итүеннән килә. Иранда ниндидер «татар»лар яллы гаскәри булып та хезмәт иткәннәр. Алар кыска җиңле махсус «татар күлмәге» белән билгеле булганнар.

Татар этнонимының Урта Идел – Көньяк Урал төбәгендә таралыш тарихы безнең карашка түбәндәгечә.

Бу этноним Идел Болгары дәүләте оешкан заманда ук биредә билгеле булган: дөньяда татарлар барлыгын тәүге болгарларның союздашлары хәзәрләр дә, актив аралашкан күршеләре – бәҗәнәкләр, узлар һәм кыпчаклар да яхшы белгәннәр. Тик үзләрен татар дип атаучылар IX–XIII г. Болгарда сирәк булган булырга тиеш: көнчыгыштан һәм көньяк-

көнчыгыштан (мәс., Күчлүк хан дәүләтеннән) килгән сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр, ихтимал, сатлык әсирләр, очраклы кешеләр һ.б. Бу чорларда реаль татарлар – татарча сөйләшүчеләр – үзләрен чит ил кешеләре алдында болгар дип таныткannar, ә ил эчендә, чын болгарлардан аеру кирәк булганда, **биләр**ләр дип атаганар.

Монгол яулары чорында һәм шуннан соң татар этнонимын куллану ешайган, ләкин аның эчтәлегенең статусы тотрыклы булмаган. Ләкин «Codex Cumanicus» материалы күрсәткәнчә, татар телен **татар теле** дип атау XIII г. азагыннан ук башланган! Димәк, татарларга этнонимны руслар биргән дигән сүз дөрес түгел. Шул ук вакытта чын татарлар арасында да татар этнонимын кире кагучылар һәрвакыт булган. Ләкин XIX г. азагына татар җәмәгатьчелеге бу атаманы тулысынча кабул иткән һәм хәтта бу этнонимны өнәмәүчеләр (Р. Фәхретдинов, кайбер башкорт зыялылары һ.б.) да бу уртак атама белән килешергә тиеш тапканнар. Һәм Дәрдемәнд болай дип язган:

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме?*
*Кеше үз исемен инкяр итәрме?*
*Татарлыкта татар углы татармын.*
*Татар түгел димә – башың ватармын.*

Әмма XX г. азагында татар исемен алмаштырырга теләүчеләр тагын күренә башлады. Бигрәк тә татар этнонимын болгар этнонимы белән алмаштыру идеясе популяр (бу идеяне Ә. Кәримуллин, өлешчә М. Зәкиев, М. Глухов кебек филолог һәм тарихчылар да яклап карадылар).

Бу мәсьәләдә безнең фикер шушыдыр: татар атамасы инде карарлашкан һәм аны тик бик мөһим сылтау белән генә алмаштырып булыр иде. Андый сылтау күренми. Инде бу этнонимның «дөрес түгеллегенә» килгәндә, «дөрес булмаган» этнонимнар дөньяда бер бездә генә түгел, әмма ул дөрес түгеллекләр һәрвакыт нисби була. Тарихчы Равил Фәхретдиновның *татар* этнонимын алмаштыру идеясенә берничә тапкыр рәддия язуы юкка түгел (к. Türk yurdu, № 7, 1993 һ.б.).

Күрше халыкларда таралган башкортча, нугайча һ.б. **татар**, марича (татар сүзе белән беррәттән) *тадар*, *тодар*, чувашча *тодар*, *тудар* (язылышта *тотар*, *тутар*) сүзе *татар* лексемасының этимологиясен ачыкларга берни дә бирми – алар соңрак русча *татарин* сүзе тәэсирендә таралганнар. Алардагы фонетик вариантлар – һәр телнең үз фонетик закончалыклары буенча *татар* нигезенән килеп чыкканнар һәм аларда ниндидер аеруча борынгылык сакланган дип уйларга нигез юк. Чувашча *тудар* тагын «сакау, эпә» дигән сүз; ул татар этнонимыныннан килеп чыкмаган, ә **тут-тыт** – «тотылу» сүзе белән баглы булса кирәк. Һәрхәлдә бу сүздә дә **татар** сүзенең бор. мәгънәсе сакланган дип уйлау дөрес булмас.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп узыйк – Казан дәүләте чорында гына түгел, Рус империясе шартларында да күрше халыкларның башта мөселманлыкка, мөселманлык аша татарлыкка чыгулары, татар исемен алулары дәвам иткән. Бу процесс уртак тормыш рәвеше һәм тулысынча тиңхокуклык шартларында татарларның чагыштырмача мәдәнирәк булуы белән генә аңлатыла. Татар этнонимы гуманлырак менәсәбәтләр, сабырлык, тәртип билгесе дә булган. Бу хакта революциягә кадәрле рус әдәбиятында да күп материал табып була.

Татар этнонимы гына түгел, **татар теле** тәгъбире дә бәхәсле булып чыкты. Кайбер кардәш төрки республикаларда (кимендә) XIII г. бирле килгән иске татар теле – ул татар теле түгел, **төрке тел** дип игълан итәләр.

Татар этнонимы V г. бирле билгеле. **Татар теле** конкрет билгеле тел (безнең төрки тел) буларак XIII гасырдан гына аермачык күзәтелә (әлеге «Codex Cumanicus» теле). Бу чорда ук татар теле – үзендәге гарәп-фарсы лексик элементлары белән баетылган һәм бор. руник ядкәрләр теленә якын торган, күрше кыпчак телләреннән аермалы буларак, бор. төрки консонантизмны бозмыйча саклаган көнб. кыпчак теле, үзенең үсешкән яз. варианты булган тел. Татар яз. теле тик XVI г. гына килеп чыккан дигән раслама (мәс., С. Брукның 1982 елда нәшер ителгән популяр «Народы мира» китабында бар) татар халкы тарихына хилаф ул. Татар теле баштан ук яз. тел катнашлыгында формалаша һәм анда гомумтөрки эталон элементларының күплеге нәкъ шуның белән аңлатыла.

*Татарский язык* – татар теле һәм *татарское письмо* – татар язуы дигән тәгъбирләр XIV г. башлап рус документларында һәм рус тарихи ядкәрләрендә еш очрый һәм алар башлыча безнең татар халкына карыйлар. Дөрес, татар телендә дип тәгърифләнгән кайбер язмалар татар халык теленнән нык кына аерылалар – аларда чыгтай (Урта Азия төркисе) һәм угыз (госманлы) элементлары, гомумхалык телендә үзләштерелеп бетмәгән гарәп-фар. сүзләре еш очрый. Ләкин аларның гамәлдәге укылышы татар вокализмына буйсындырылган ич!

Татарның үз язма-әдәби теле электән килгәнлеген инкяр итүчеләр бик мөһим тагын бер мо-

ментны күздән ычкындыралар. Соң бит ул татар телендә дип билгеләнгән төрле документлар, төрле әдәби-нәфис әсәрләр чыннан да татар халкы җирлегендә туган, аларны башлыча **татарлар** өчен башлыча **татарлар** язган! Язмачылык культурасы, укучылар һәм язучылар тупланмалары, мәктәпләр, мәдрәсәләр челтәре Идел-Урал регионы халыклары арасында иң беренче булып татарларда барлыкка килгән һәм бу татарлыкның бер атрибуты да булган. Һәм XVIII–XX гг. мәгърифәтчелек хәрәкәтен тудыручы, башкаручы һәм күрше халыкларга да таратучылар этник татарлар булганнар. Һәм ул чорлардагы әдәби-язма тел лингвистик җәһәттән нинди генә характерда булмасын, ул **татар халкының әдәби теле булган, бүтәннәрнеке түгел.**

Хәер, лингвистик характеристикаларга килгәндә дә монда татар сүзен алып ташларлык урын юк. Элекке татар әдәби-язма телендә язылган ядкәрләрдә һәрвакыт диярлек гомумхалык татар теленә яисә аның аерым җирле вариантларына (мәс., себер яки мишәр сөйләшләренә) генә хас булган фонетик, грамматик яисә лексик үзенчәлекләр табып була. Ягъни шулар буенча да, бу тәгаен татар теле дип, билгеләп була. Мәс., XV г. язылган «Могҗизнамә» китабында аерым татарчалык элементлары күп.

Дөрес, иске яз. татар теле, әйткәнебезчә, халыкчан булу җәһәтеннән нык аксаган. Ләкин бу аксауны арттырып, купайтып күрсәтергә ярамый (совет власте елларында публицистик әдәбиятта «муллалар кара халык аңламасын өчен юри халыкка аңлашылмаган телдә язганнар һәм сөйләшкәннәр» дип раслаулар еш очрый иде). Чөнки, беренчедән, үсешкән язма-әдәби тел сәвәтсез массалар теленнән һәрвакыт аерылып тора. Икенчедән, элеге «Codex Cumanicus»тан алып XX г. кадәр «иске» татар әдәбиятында демократик телдә язылган әсәрләр, сәхифәләр очрап торган. XVII г. инде саф татарча язылган Мәүла Колый әсәрләре пәйда була, XVIII г. азагында Таҗетдин Ялчыгол «Рисаләи Газизә» әсәрен махсус татарча яза, XIX г. беренче яртысында Г. Кандалый саф татарча яза һ.б. Өченчедән, татар зыялылары тышкы төрки дөнья белән араны өзмәскә, барча төркиләргә аңлаешлы телдә язарга тырышканнар. Дүртенчедән, татар әдипләре гасырлар буенча чарланган язма-әдәби телнең тәгъбирлелек мөмкинлекләрен, стилистик чараларны, лексик һәм фразеологик җәүһәрләрне сәнгатьчә сөйләм тудыру, катлаулы фикерләрне, абстракт төшенчәләрне белдерү өчен файдаланырга омтылганнар. Тик татар әдәби-язма телнең массалар теленнән аерылып калуына төп сәбәп – милли дәүләтчелекнең булмавы дисәк тә ялгышмабыз.

Гомумән, татар теленең Урта Идел – Көньяк Урал регионында оешуы, таралуы вә үсешүе IX–X гг. башлап XX г. башларына кадәр һәрдаим көчәю юнәлешендә булган. Бу үсеш процессына хәлиткеч ударны марксизм-ленинизм гыйлеме белән коралланган совет власте гына ясаган.

Шуны да өстик: XX г. үзләрен татар дип атап килүчеләр сигез төркем: Себердә өчәү (хакас, алт. – кара татар, чулым төркиләре), Әфганстанда бер төркем, Иран, Кырым, Румын һәм Идел-Урал татарлары. Аникин: 539; Dobr. III: 300–301; Тимергалин: 439–444.

Дерив. (хәз. тат.): **татарлы, татарсыз; татарлык; татардагы; татарлардагы; татарларча; татарлардай; татарлан-у, татарлаш-у (→ татарлаштыр-у); татарча (→ татарчалаштыру-у, татарчалык); татарчадагы (-ча); татарчалап, татарчалатып: татарчы (→ татарчылык)** һ.б. 1920 нче елларда Татарстан автономияле республикасында **татаризация** – эш кәгазьләрен татарча язарга омтылып карау булган, ләкин ул бик тиз сүнгән. Сирәк кенә **татаризм** – рус, чуваш һ.б. телләрдә «татар теленнән алынган сүз, тәгъбир һ.б., татарчалык» сүзе кулланыла. **Татар бүреге** «колакчынсыз тирән бүрек». К. С. Сәраида:

*Ни хаҗәт башыңа таҗе-мәшаих?*
*Татар бүркен киеп дәрвиши булгыл.*

**Татар** сүзе (латинча язылган) күп кенә үсемлек һәм хайван атамаларында очрый.

**ТАТАР-МОНГОЛ** «татары и монголы», **монгол-татар** «монголы и татары (древние, центральноазиатские)» – рус теленнән таралган сүзләр. Элекке тарихи-иҗтимагый лексиконда да, ш. ук Азия вә Европа яз. телләрендә дә андый тәгъбирләр кулланылмый.

**ТАТАРСТАН** «страна татар» < фар. Бу сүз XIII г. бирле (М. Кашгарида бар) төрле географик мәгъ. кулланыла. Төркия тарихчылары *Tatarstan, Tataristan* дип Балхаш күленең көньягындагы киң өлкәне (Кытай Уйгурстанын да кертеп) атыйлар. К. **Татар.**

**ТАТАУ I [taºtaw]** (Будагов I: 330) «крепкая извозная лошадь». Чаг. түбәндәгене.

**ТАТАУ II [taºtaw]** диал. (БТДҺ: 309) «что-либо стягивающее, затягивающее: бинт на рану;

матерчатый ремень или поясной платок, в который завёртываются деньги, документы и т.п.» [хәзер күптән очрамый бугай]. К. мәкаль: *Гаиләдә без алтау, бер-беребезгә татау*. Ләкин каз. (ҚТДС: 321) *татау* «комачау, киртә», (Катаринский) «кытыр» К. **Татавыр.**

**ТАТБИКЪ** иск. «применение» – башлыча *татбикъ итү* «тиешле яки кирәк җирдә куллану» тәгъбирендә – гар. *tāṭbīq* «җайлаштырып ябу» сүзеннән. К. **Тепке.**

**ТАТЛЫ** «сладкий, сладостный» < гом. кыпч. *татлы* (кайбер башк., каз., кырг. сөйләшләрендә *татлы*, ләкин бу яңгыраш әд. нормага керми), алт. *татту* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 541) *tataylaγ, tatïγlïγ* id. **Тат-** тамырыннан ясалган күпсанлы сүзләрнең иң популяры-кулланышлысы шушы бугай. Кайбер телләрдә **татлы** сүзе исемләшеп, билгеле берәр төр ашамлыкны яки десерт мәгъ. белдерә, к. Dobr. III: 301.

Дерив.: **татлылан-у** (сөйл. телендә еш кына **татлану** дип кыскартыла, ләкин бу нормага керми), **татлылаш-у, татлылык**; кушма сүзләр составында: **татлытамак, татлытамыр** (берничә үсемлек атамасы) һ.б.

**Татлы** сүзенең антонимы буларак **татсыз** сүзе пәйда булган. Бу сүзнең дә дериватлары бар: **татсызлык; татсызлан-у** һ.б.; фразема: **татсыз аш, татсыз хәят (тормыш); татсыз яшәү (тормыш)** һ.б.

**ТАТРАН: татран тамыр** «дикий хрен» (Armorika rusticana) ~ нуг., кар. *татыран* id. *таты-у* фигыленнән (к.), ягъни «аппетит кузгаткыч» була; димәк, *татран* «аппетит»; **татран тамыр** дип төрле дару үләне тамырларын атыйлар, к. кырг. *татыран* «тау үләненең бер төре». Ихтимал, **татыр** белән дә баглыдыр.

**ТАТУ** «дружно, мирно, в согласии между собой» > чув., мар., удм. *тату* id. < гом. кыпч. *тату*, кырг. *татуу* id., кырг., хак. (к. Радлов III: 906) *татуу* «дуслык, иминлек, тыныч», ком. *тату* «тәмле, татлы», бор. төрки (Ясәви) *татуғ* һ.б. «ләззәтле, татлы» *тат-* «тәм сизү, тәм табу» фигыленнән. К. **Тат I, Таты-у.** Федотов II: 181.

Дерив.: **татулык; татулан-у, татулаш-у.**

**ТАТЫЛДА-У** «лепетать (о детях); быстро и много говорить (о женщинах)» – **татыл* тәкълиди нигезеннән, *тат (тат-тат)* тәкълиди тамырыннан. К. **Тәтелдә-ү.**

**ТАТЫМАЛ I** диал. «опытный; бывалый; умелый» < монг. *татымгал* id. дип исәпләнә. К. аз. (АДДЛ: 164) *дадамал* «белдекле, татымал», *дада-* ~ монг., тунг. (ССТМЯ I: 170–171) *тат-, тати-, тату-* «өйрәнү, күнегү», *таты-у* (к.) сүзе белән чагыштырыла.

**ТАТЫМАЛ II** (ТТДС I: 402) «достаточно большой, чтобы почувствовать вкус (о еде)» < *татыма-лы* сүзеннән.

**ТАТЫР** «осадок, привкус минералов в воде» ~ башк. диал. (БҺҺ II: 243) *татра* > мар. (Упымарий) *татыр* «известь» (*татыран вӱд* «известковая вода») < гом. кыпч. *татыр* «өстенә тоз утырган җир, тозлак» < бор. төрки (ДТС: 541–542) *tatïr jer, tatïrlïγ jer* «балчыксыл тигез җир» ← себ. (Тумашева 1961: 199) *тат* (>> чув. *том* > *тут*) «тап», каз., хак., алт. *тат*, тув., каз. *дат* «тут, тутык». Ләкин *тат* сүзеннән *татыр* сүзе төрки телләрдә түгел, тунг.-маньч. телләрендә ясалган булса кирәк, к. эвен. *татара* «татырлы». Чаг. ш. ук диал. *татырга, татырлаwык* «тозлак», бор. чыгт. *tatır su* «тутыклы су» (к. Поппе 1938: 97).

Дерив.: **татырлы, татырсыз; татырлык, татырлан-у.**

**ТАТЫ-У** «пробовать на вкус; переживать вкус, чувства и т.п.» < чыгт., уйг. һ.б. (к. Радлов III: 900–905) *тати-, таты-* id.; күпчелек төрки телләрдә *тат-, дат-* id. ~ угыз., монг. *дада-* «тату; кичерү; күнегү». ЭСТЯ III: 162–164. К. **Тат, Тәте-ү.**

**Таты-** продуктив нигез: **татым, таттыр-у, татыт-у** һ.б.

**ТАУ I [taᵒw]** «гора», диал. (Будагов I: 726) «лес» < гом. кыпч. *таw* < уйг., үзб., хак., бор. төрки *тағ* > угыз. *дағ, дааг* id. ~ як. *тыа* «урман, тайга» бор. монг. *dabaγ* «үткел» ~ эвенк. *даw-у-*, эвен. *даw-а-* «үткелдән үтү, кичү» сүзе белән чагыштырыла (Котвич 1962: 41), чаг. тат. сөйл. *тау мену, тау төшу*. Чув. *ту* ~ алт., кырг. диал. *туу* «тау» < *тыw* < *таw* булса кирәк. ЭСТЯ III: 117–119; Федотов II: 240.

**Тау** продуктив нигез: **таулы** «таулары күп; тауда яшәүче», **таулык, таучы** һ.б.

**ТАУ II [taᵒw]** (ДС II: 65; ТТДС I: 402; Balint: 104; ЗДС: 612) «поздравление; спасибо; завеща-

ние, доброе напутствие», «распитие спиртного на свадьбе; тост» ~ чув. *тау, тав, таву* ~ удм. *тау* «рәхмәт» (*тау карыны* «тау итү, рәхмәт әйтү»), мар. (Упымарий; Иванов, Тужаров: 209 һ.б.) *тау, таво, тагу* «рәхмәт, рәхмәт әйтү» ~ каз. *тау* «энергия; саулык», абаз. (< төрки), кар. *табу, табув, таба* «рәхмәт белдерү» ~ госм. *дау* «уенда йөреш, чират; пулны (ставка) икеләтү; отыш, тост, сәламәтлеккә эчү», лезг. (< төрки) *тау, тав* «кияү егет өендә аерым туй», госм. *tau*, төр. *tav* «бөтен, бердәнбер, мәртәбә, тапкыр; эчү (тост әйтү) чираты; мөмкинлек», *tau etmek* «түгәрәктә эчү»; чыгт., аз. (Будагов I: 338) *тау, тов* «чират: сый кайтару» < фар. *туа, ту, тай* «бер тапкыр»? Өзён (Özön) сүзлегендә госм. *dav* «тау» фарсычадан диелә. Госм. һәм тат. *тау (дау) сиңа (сана)* дип төбәп тост әйтү булган (шуңа каршы госм. *ašp olsun* дигәннәр), к. Zenker I: 249. К. ш. ук нуг., каз., куман. *таус-* (< *tawуш-*) «исәнлекккә эчү» (Радлов III: 776). К. **Ташлама.**

Бу кызыклы сүзнең этимологиясе ачык түгел: шуңа охшаш сүзләр гар., фар. һәм монг. телләрендә очрый. Мәс., монг. *тав* «тынычлык, иминлек», фар. *daw* «уенда йөреш, көрәштә бәреш чираты», гомумән, «кирәкле, уңайлы период, момент, процесс». Räsänen 1969: 467 (гар. сүзе ди); Федотов II: 161 (бу хезмәтләрдә материал бездәгедән ярлырак). Чаг. ш. ук **Тахан.**

Дерив.: иске әд. (Ясәви) **таула-у** «багышлау, бүләк итү»: *пәйгамбәр, «өммәтем» дип, миһре таулар* (миһербанлыгын күрсәтер).

**ТАУЛАК [таºwлак̡]** (ЗДС: 612) «без шерсти; голый; кожаные в клеточку штаны» төр. *tavla, table, tablak* «тигез өслек, шашка тактасы, урам сатучыларының күчерелмәле өстәлчеге; киң күн өслек, күн җаймә» < лат. *tabula* «тигез өслек, такта» ← *tabu* «өслек». Бу латин сүзе Европа телләрендә хисапсыз күп сүзләргә тарихи нигез булган, к. рус. *табель, таблетка, таблица, табло.* К. ш. ук иске тат., төр. *тавла* «шашка уены».

**ТАУРАН-У [таºwран-]** «поспешать» < уйг. *tawran-* id. Räsänen 1969: 493. К. **Таварын-у.**

**ТАУСА-У [таºwса-]** (себ., Тумашева: 205) «ослабляться; израсходоваться (о силах и т.п.)» ~ каз. (Будагов I: 731) *тауyса-* id., төр. *tavsa-* «зәгыйфьләнү, (эшләр, кәсепләр һ.б.) начарлану». Фонетик җәһәттән үзенчәлекле кр.-тат. (Dobr. III: 309) *tawsi-,* к.-балк. *тауус-,* куман. *tavus-,* чагт. *tawус-,* уйг. *таѓус-,* һ.б. «бетүгә бару; зәгыйфьләнү» < монг. *dayus-* «бетүгә китерү». Räsänen 1969: 454.

Дерив.: **таусал-у, таусан-у, таусыт-у.**

**ТАУШАЛ-У [таºwшал-]** «измызгаться, протереться (о частях одежды); ослабеть, постареть», диал. (Н. Баян) «разволноваться» ← диал. ***тауша-*** (ш. ук **таушар-, таушарыл-у**) «начарлану, юкару» (чаг. диал. **таушак** «таушалган»). Бу фигыль чыгт. (Zenker I: 250; Радлов III: 988) *тawуш, тавуш* «зәгыйфь, арык, нечкә, юка» сүзеннән килә, бу исем сүз исә үз чиратында бор. кыпч. **тaw* < **таѓ* «так, беткән» нигезеннән ясалган (яки шуның фигыль коррелянты булган) **тaw-*, **тawы-* фигыленнән, шуннан ук гом. кыпч. *тawыс-, тawус-,* хак. *тоос-* «кулланып бетерү; ахырга җиткерү» < **тawш-* id. (ягъни бер очракта гадәттәгечә омонимнар ясалган: **таw-ыш** *-ш* аффиксына беткән исем һәм **таw-ыш-** *таw-ы* фигыленең урт. юн.). Чаг. ш. ук чыгт. (Будагов I: 338, Zenker: 250) *тawуш-* «хәлдән тайганчы йөгерү, чабу, сикерешү», *taušat-* «куып, арытып аулау». К. **Тауса-у.**

**ТАУШАН [таºwшан]** к. **Тавышкан.**

**ТАХАН** (Будагов I: 82) «ровная сторона альчика, ровный бок» ~ хак. *тах,* кырг. *таа*, төркм. *товха*, каз. *дауа, тауа* ~ яз. монг. *tanxai* > монг. *тawк̡ай* (к. Владимирцов: 255) > маньч. *тава* һ.б. Һәрхәлдә тат. телендә монголчадан булса кирәк. Рус. диал. *таган* id. төрки телләрдән, к. Фасмер IV: 29; Räsänen 1969: 451.

**ТАХИЛ** «питьё по случаю крупной сделки, обновки или праздника» ~ кар. *тахыл, тахил,* аз., чыгт. *тахил*, госм. *тäхил*, төр. *tahıl* «иген уңышы, уңыш бәйрәме» сүзеннән булса кирәк (гомумән, гар. *дäхл* «керем, файда»). К. Будагов I: 330.

Монг. телләрендәге *тахил* «бәйрәм һ.б. корбаны» (← *тахи-* «корбан бирү») сүзе дә тат. *тахил* сүзенең чыганагы булала, ләкин бу вариант шиклерәк.

Дерив.: **тахиллә-ү** «шатлыкка эчү».

**ТАЧ** диал., (ЗДС: 623) **тәч** «точь-в-точь; сплошь; совсем» (к. Максютова: 110; Махмутова: 241) ~ башк. *тас, тәс* id. – чаг. монг. *тас* «бөтенләй». Чаг. ш. ук башк. *лас,* чув. *лач* «тач». Ихтимал ки, монда ике сүздер.

**ТАЧКА** «сырой, непропечённый (хлеб)» ~ чув. *тачка, тачăка, лачка* id., *лач* «лач, ләч, тачка». **Тач**

< *лач* һәм *тачка* < *лачка* Идел-Урал телләренә хас *л-* > *т-* күчешләрен чагылдыралар.

**ТАЧКЫ-У, тачкыла-у** «перемешивать (с маслом, водой); месить», (ТТДС I: 400) **тасҡы-у** «измять» ~ башк. (БТДҺ: 308) *тасҡы-* «май язу», *тасҡа-* «майны (суык суда) йомарлау» < бор. төрки (к. ДТС: 531) **tančqï-, tančγala-, tančqïla-, tančula-* «өзгәләп чәйнәү» ← *tanču* «кисәк, өзенте». Арытабан ачык түгел.

**ТАЧРАННА-У** (ЗДС: 613) «ходить с длинными голыми ногами». Чаг. ш. ук **тайранла-у, тайранлаш-у.** К. **Тайран.**

**ТАЧЫЛДА-У, тачкылда-у** (Balint: 105; ТРС II 2007: 328) «чавкать; хлюпать». Гомуми кагыйдә буенча **тач** тәкълиди сүзеннән. К. **Тач.**

**ТАШ** «камень» < гом. кыпч. *таш* (нуг., каз., к.-калп. *тас*), төркм. *дааш,* як. *тааш* < бор. төрки **таал* >> чув. *чол* > *чул* id., бор. монг. *čilaγun* > монг. *чулуун* «таш» һәм гом. тунг. *ǯоло* «таш», ш. ук. кор. *тол* «таш» сүзләре белән чагыштырыла, к. Будагов I: 724; ЭСТЯ III: 167–169; ССТМЯ I: 263; Федотов II: 421–422.

**Таш** сүзен кайбер этимологлар *тыш* < *таш* сүзе белән бердәй дип баралар. Чаг. ш. ук **Чаллы.** Гомумән, **таш** продуктив нигез: **ташак** (тестикула), **ташлы, ташлык**. К. **Ташбака, Ташбаш, Ташкуран, Ташла-у, Ташы-у.**

**ТАШБАКА** «черепаха» < гом. кыпч. *ташбаҡа, таш баҡа* (нуг., каз., к.-калп. *тас баҡа, тасбаҡа*), уйг. *ташпаҡа*, төркм. *ташбаққа, ташпаққа* id. Бу сүз ташбаканың кабырчыгы таш кебек каты булганнан, бигрәк бор. төркиләрдә, кытайлар үрнәгендә, һәртөрле истәлекле баганалар, нишаналар кую өчен таштан зур ташбака сыны ясау гадәтеннән булса кирәк (к. Киселёв 1962: 65–67; Zieme: 254–258). Тимергалин: 445.

Ташбака ком. *таҡалы бака: таҡа* «баш сөяге». Шуннан чыгып, рус. *черепаха* сүзен төрки. *чәрәп бака* тәгъбиреннән дип уйларга гына кала: рус. *череп* «баш сөяге; чирәп (керамик) чүлмәк» төрки телләрдә дә киң таралган (к. **Чирәп).**

**ТАШБАШ** «головач; пескарь (рыба)» > чув., мар. *ташпаш* (Исанбаев 1978: 22, Сергеев 1978: 66). Диал. *ташбый* «ташбаш» халык телендә яңа ясалма булса кирәк. Әлбәттә, *таш баш* сүзеннән.

*Ташбаш* дип аңлаусыз һәм тыңлаусыз кешеләрне дә атыйлар.

**ТАШКУРАН** «камнеломка (растение)» ~ төр. *taşkıran (otu)* id. Кайбер очракларда бу үсемлек *ташъяргыч* дип тә атала (ихтимал, русчадан калька), ләкин *ташкуран* дип аталу юкка түгелдер: *ташкуран* дип алт. телендә ташлы тауларда яшәүче кыргый кәҗәсыман хайванны (рус. *каменный козёл*) атыйлар. *Ташкуран* үләне шуларның яраткан ризыгы. К. **Куран.**

**ТАШЛАМА I** «льгота, уступка» сәүдәгәрләр теленнән – *ташла-у* сүзеннән булса кирәк – аның «бәяне төшер» мәгънәсеннән, чаг. сөйл. *ташла!* «тукта, җитәр».

**ТАШЛАМА II:** диал. (ТТДС I: 403) **ташлама айак** «круглый ковш» > мар. *ташлама корка* «бәйрәмнәрдә күзеннәт сыра яки әче бал тутырыла торган чүмеч (аны соңгы тамчысына кадәр эчеп бетерергә кирәк булган)», *ташлама кече* «пасханың соңгы көне», *ташла-* «тулып ташу» ~ чув. *ташлама* «бәйрәмдә барча мәҗлестәшләр берәр телем кисеп ала торган калач», *ташла-, ташлат-* «бию» – барысы да тат. *таш-у (ташып чыгу)* сүзеннән ди Рясянен (Räsänen 1969: 466). Әгәр аның сүзе дөрес булса, *ташлама* < **ташулама*, чув. *ташă* «бию» < тат. **ташу*. Ләкин чув. этимологлары бу аңлатма белән килешмиләр, аларча, чув. *таш, ташă* «бию» тәкълиди сүздән килә (к. Егоров 1964: 233–234, Федотов II: 182). Безнеңчә, *ташлама* сүзе бор. **таштлама-* ← бор. төрки (ДТС: 257) *tayšut* «шигырь уку, декламация» ← *tayıš* «такмак» сүзләренә тоташа, к. кырг. *ташта-* «бию-җырның бер номерын башкару» > каз. *таста* «мәҗлестә үз өлешеңне эчеп бер җыр җырлау». Шулай итеп, *ташлама* << **тағшутлама.* Чув. *ташă* «бию» < бор. **тағышыг*; нуг., каз., куман. *таус-* «исәнлеккә эчү» ← **тағыш-* «тау итү» булса кирәк. Чаг. **Тау II.**

**ТАШЛА-У** «бросать, бросить» < гом. кыпч., уйг., чыгт., төр. һ.б. *ташла-* (кырг. *ташта-*, каз. *таста-*), аз., төркм. *дашла-* id. *Таш* сүзеннән дип исәпләнә (тәүдә *ташла-у* «таш ату»). Ләкин *ташла-* «тышка чыгару» (бор. *таш* «тыш») сүзеннән дә була ала. ЭСТЯ III: 171.

Бу сүзнең актив кулланылышлы дериватлары күп: **ташлан-у, ташлат-у, ташлаш-у; ташлак, ташландык** һ.б.

**ТАШ-У (таша),** диал. **ташы- (ташый)** «переливаться через край; заливать берега (о реке)» < гом. кыпч., уйг., чыгт., төр. һ.б. *таш-* (нуг., каз., к.-калп. *тас-*), төркм. *дааш-*, аз. *даш-* id. гом. төрки *таш* «тыш» сүзе белән баглы («ташка ~ тышка чыгу»), к. ЭСТЯ III: 169–170.

**Таш-** продуктив нигез: **ташкын** (гом. төрки характердагы сүз), **ташу** «су басу», **таштыр-у** һ.б.

**ТАШЫ-У (ташый)** «таскать, возить; нести, носить» < гом. кыпч., уйг., чыгт., госм. (Радлов III: 935–936) *ташы-* (нуг., каз., к.-калп. *тасы-*), төркм. *даша-*, төр. диал. *дашы-* id. Э.В. Севортян һ.б. (к. ЭСТЯ III: 170–171) *таш* «тыш» сүзеннән диләр; безнеңчә, бу *таш* сүзеннән дә килә ала. Һәм, гомумән, аерым бер тамыр булырга да мөмкин.

**Ташы-** продуктив нигез: **ташыл-у, ташын-у, ташыт-у, ташыш-у** (барча юн. формалары кулланыла).

**ТАЮ** к. **Тай-у.**

**ТАЯК [таºйак̡]** «палка» < гом. көнб. төрки (Радлов III: 816; ДТС: 527) *тайак̡,* чыгт. *тайаг,* аз., төр., кр.-тат. *дайак̡,* чув. *туйа* < *тойа* ~ мар. *тоя* < бор. *tajaγa* id. Бор. яңгыраш яз. монг. *tajaga*, бор. рус. (Срезневский) *тояга*, серб.-хорв. *tojaga* «таяк» сүзләрендә дә чагыла. Тамыры, әлбәттә, **тайа-** (к. **Тайа-у**). ЭСТЯ III: 126–127; Федотов II: 259–260. Рус. *таяк* (< тат.) тур. Аникин: 543.

**Таяк** продуктив нигез: **таякла-у, таяклы, таякчы** «җитәкләп йөртүче», **таякчык** (микроб төре) һ.б.

**ТАЯН-У [таºйан-]** «опираться» > чув., мар. *таян-* id. ← **тая-у** (шуның кайт. юн., төп юн. формасыннан ешрак очрый), Федотов II: 182.

**Таян-** продуктив нигез: **таянгыч, таяндыр-у; таяныч**. К. **Таянчык.**

**ТАЯНЧЫК [таºйанчы̆к̡]** «скот, который родственники дарят невесте в момент, когда она сходит со свадебного экипажа у дверей жениха» (Ахмаров 1907: 28) > чув. *таянчăк* (шулай ук – *таян* id.) ~ башк. (БТДҺ: 300) *тайансык̡,* уйг. *тайанчук̡,* үзб. *тайанчик̡, тойанчик̡* «таяныч, терәк», чыгт. (Радлов III: 817–818) *тайанчак̡* «сөңге терәгән урын (сөңгене җиргә терәү – бор. гореф-гадәт буенча үз фикереңне әйтергә теләү»)» ← *тайан-* «таяну».

М.Р. Федотов (II: 183) чув. *таян, таянчăк* сүзләренең этимологиясен ерактан – монг. *тайи-* «корбан бирү» сүзеннән эзләп маташа. Хәлбуки *таян – таянчык* сүзеннән кире сүз ясалыш нигезендә генә килеп чыккан (эллипсис).

**Таянчык** туры мәгънәдә – кәләш мәгәлдәктән төшкәндә таяна торган мал, фигураль мәгънәдә – киленнең мораль таянычы булган.

**ТАЯ-У [таºйа-]** «подпирать» < гом. кыпч., алт., уйг. *тайа-*, төркм., аз., төр., гаг. *дайа-* id. бор. **тай-* фигыленең *-ага* киңәйтелгән формасы (к. ЭСТЯ III: 125–127). Ихтимал, **тай* дигән исем дә булгандыр. К. ш. ук Будагов I: 732–733.

Дерив.: **таяу** (к. мәкаль: *Ир бала ата-анага таяу*); **таят-у**. К. **Таяк, Таян-у, Таянчык.**

**ТӘБӘ** «яичница, омлет» < диал. (ДС I: 193) **тәбия** id. ~ башк. *тәбейә* id. тат. сөйләшләрендә камыр ашы, «кекс», кайбер сөйләшләрдә (Хайрутдинова 1993: 37) **тәбәгый** id. < фар. *тāбāӣ* «табада пешерелгән» (фар.-таҗ. *тāбӑ, таба* «таба», к. **Таба**). Чаг. **Тәбикмәк.**

**ТӘБӘЛАЯК [тәбәл′айак]** «черви (масть карт)» к. **Тәвә.**

**ТӘБӘЛДЕРЕК** «педаль (ткацкого станка); подножка (вагона)»; диал. (ДС I: 193) «намордник (телят); слега» < (ДС III: 147) *табандырык̡* «педаль», (башк.) *табалдырык̡* «бозау (һ.б.) борындыгы», нуг., кр.-тат. *tabaldırık* «мунчада киелә торган агач ката» ~ каз., к.-калп., кырг. *табалдырык̡* «тәбәлдерек; тупса», хак. диал. (сагай, койбал, к. Радлов III: 968) *табалдрык̡* «олтырак; олтан», к.-балк. *тебеңнък̡* «иярнең бер өлеше», рус. (Даль) *тебенек* «ияр канаты», хак. *тебёнҗек* «өзәңге». Бу бер-берсенә керешә торган сүзләрнең уртак элементы – яфрак формасындагы яссы әйбер. *Тәбәлдерек* < *табалдырык* < *табандырык* күчешләре бик аңлашыла (*табан* сүзеннән), әмма йөгән яисә иярнең бер детале булу безгә бик аңлашылып бетми. Ихтимал, бу сүзләрдә контаминация күренеше бардыр (к. **Тибенге**).

**ТӘБӘНӘК,** диал. (ДС III: 147) **тәбәшәк, тәбешәк,** (ТТДС I: 436; Тумашева 1992: 205) **тәбәкәй, тәбәй, тәбешек** «низкий, низенький», (ЗДС: 618–628) **тәмәш, тәмәшәк, тәптәк** ~ башк. *тәпәшәк, тәпәш,* башк. диал. *ләпәшәк, ләпәш* id., себ. (брб., к. Дмитриева 1981: 186) **тäбäн** «тәбәнәк; түбән, түбәнгә», **тäбäчäк** «лапас» ~ кар. *тёбеньги, тибэнги* «тәбәнәк; түбәнге», удм. *табанак* «тәбәнәк буйлы»

< тат. (ЛТ I: 3) **табанак,** үзб. диал. (ЎХШЛ: 244) *таванақ* id.

Бу сүзләрдә дә контаминация бар. **Тәбәнәк** < *тәбән-әк* (*-әк* кечерәйтү кушымчасы) ← *тәбән* < *тәпән* < бор. уйг. *тәги пәнд, тәгү пәнд* «төбе түбән» (*тәк* «төп», *пәнд* «аскы, түбән») сүзеннән, к. *түбән; тәбәшәк* < *тәбәш-әк* ← *тәбәш* < *тәпәш* < бор. уйг. *тәги пәст (паст), тегү паст* ш. ук мәгънәдә (фар. *пäст* «түбән, тәбәнәк» сүзе тат. диал. *паст* «тәбәнәк болдыр» һәм *бәштәк* < *мәштәк* «тәбәнәк буйлы ат» сүзләрендә дә чагыла). *Ләпәшәк* ← *ләпәш* вариантында фин-угор тамыры *лап* (к. **Лап**) «түбән» сүзенең тәэсире бар. К. **Тәпән, Түбән.**

**ТӘБӘНӘ КУГА** – имя красавицы в эпосе (ТХИ: Дастаннар 1984: 32–33, 35) < алт. *тäмäнä* < *тäңäнä* < тув. *Ак Тевене*, ш. ук *даңына, даңгына* ~ бур. *дангина* < санск. *dakini* «дөнья гүзәле; фәрештә» һәм алт. *куа, қуга* << кыт. *хуа* «чәчәк; гүзәл кыз» сүзләреннән гыйбарәт тәгъбир. Татар эпосында *Куа ханым, Куга ханым* үзе генә дә әкияттәгедәй гүзәл хатын мәгъ. кулланыла. Бу сүз ш. ук *юха* < *ләw хуа* «аждаһа гүзәл» сүзе составында да бар.

Һинд мифологиясендә *däkini* < **dänkini* Кали дигән алиһәнең җарияләреннән берсе, бик усал, хәтта явыз, ләкин изгелеккә авышлы рух. Тибет буддизмында бу рух трансформация кичергән һәм фәрештә мәгъ. кулланыла башлаган (МНМ I: 348). Себер төркиләрендә бу образ киң таралган.

**Тәбәнә** бор. төрки (ДТС: 160) < санск. *divini* «алиһә» сүзеннән дә килеп чыга ала. Ләкин аның мәгънәсе «гүзәл кыз»га бик бап түгел.

**ТӘБӘРЛЕК** (Тумашева 1992: 206) «шнурок из савана долго жившей старухи, который привязывают на руку маленькому ребенку» < гар. *тäбäррук* «мөбарәк нәрсә, изге комарткы» > кырг. *табарик, теберик,* уйг. *тәбәррүк, тәвәррүк* «изге, хөрмәтле; мөбарәк». Чаг. ш. ук тат. **тәбәрәк (тәбәрек) догасы** «эченә дога салынган бөти» һ.б. – гар. *брк* «бәрәкәтле, уңыш бирүчән, газиз» тамырыннан. К. **Тәбрик.**

**ТӘБӘССЕМ** (Ф. Әмирхан һ.б. язучыларда) «ироническая, кривая усмешка», кр.-тат *tebessüm* id. < гар. *тäбäссум* id. ← *бсм* «авыз еру, хәйләле көлү».

Дерив.: **тәбәссем итү** «көлкегә алу; (ачусыз гына) көлкегә калдыру, көлкегә ббору», гар. телендә ясалып иске тат. алынган **бәсим** «елмаеп торучы» (ялгызлык исеме буларак та кулланылган).

**ТӘБӘТ, дәвәт** (Гиганов, Троянский) «шашки» < рус. *доведь* «шашка уены (аның төп максат дамкага чыгу булган төре)». Бу сүз төрки (гомумән Себер) телләрендә киң таралаган. К. Аникин: 187–188.

**ТӘБЕ,** диал. (ЗДС: 619) **тәпе,** (Радлов III: 1110, 1120) *тäпäі, тäбäі* «мышеловка, небольшой капкан» ~ чув. *тапă, тапкăч* id. (< тат. *тәпе, *тәпкеч*), башк. (БТДҺ: 349) *тәпе* ← *тәп, тап* тәкълиди сүзеннән, к. **Тәпә-ү**. Räsänen 1969: 474; Федотов II: 172.

**ТӘБЕР** (ТТДС I: 435) «еще раз» < чув. *тепĕр, тепре, тепĕрев* (> мар. *тäпĕр, тапыр*) id. < тат. *тагы бер*, ди Федотов II: 208. Ләкин Н. Исанбаев (1978: 28) фикеренчә, чув. *тепĕр*, мар. *тäпĕр* < *тапыр* << гом. кыпч. **тапқыр** (к.) һәм бу аңлатма тарихи җәһәттән дөресрәк: монг. *дабкур* сүзенең «кабатланган дога, келәү» мәгъ. бар. Ниһаять, чаг. гар. *дäwр* «әйләнә; ашамлыкны, эчемлекне мәҗлестәшләр бер-берсенә сонып әйләндерү».

**ТӘБЕРСЕН, тәберсе, тийәберсен** (к. ТТДС I: 435; Нагайбаки. Казань, 1995: 85, 111–113) «языческая молитва; языческое моление» – табышмаклы сүз. Аны тат. «тәңре бирсен» тәгъбиреннән дип аңлату (Ф. Баязитова һ.б.) өстәмә детальләр сорый: ихтимал, керәшен (каратай) *тәйре бирсен* (мәҗүси дога) сүзләреннәндер. Ләкин бүтәнчә аңлатулар да мөмкин, к. чув. *тепрешим* барча мәҗлестәшләр бер икмәктән телем телеп алу, бер табактан ашау йоласы – *тепре* «тагын бер тапкыр» сүзеннән (к. **Тәбер).**

**ТӘБЕЧ, тәбич** (ЗДС: 615–161) «глубокая, средних размеров чаша» < рус. *ставец* id. (булса кирәк).

**ТӘБИКМӘК** (ТТДС I: 436) «блин; тонкая лепёшка; вид тонкого пирога» < *таба икмәк*, әлбәттә. Еш кына **табикмәк** дип әйтелә һәм языла да, к. ТТДС I: 390; БТДҺ: 299.

**Тәбикмәк** һәм **табикмәк** вариантларына аерым мәгънәләр салу, безнеңчә, иртәрәк, чөнки бу сүзләр төрле урынчылыкларада төрле ашамлыкларны белдерәләр. Гомумән, диффуз мәгънәле, киң таралган бер сүз.

**ТӘБРИК** «приветствие, одобрение» < гар. *тäбрӣк* id. ← *брк* «котлы булу» тамырыннан. К. **Бәрәкәт**.

Дерив.: **тәбриклә-ү, тәбрикле** һ.б.; **тәбрикнамә.**

**ТӘВӘ I: тәвә кош(ы)** «страус» к. **Дөя**. Тәвә кошын дөя белән чагыштыру антик заманнардан килә. К. түбәндәгене.

**ТӘВӘ II [тәwә], дәвә [дәwә]** (ТТДС I: 89, 314) «верблюд» ~ уйг. диал. *тәвә*, тув. *теве* < бор. төрки (ДТС: 557) *tevej, devej*, төр. *deve* һ.б. (бик күп вариантлар, к. ЭСТЯ III: 313–315) id., иң бор. вариантка уйг. *тоги* < бор. кыт. *токи* якын булса кирәк, чөнки барча бүтән вариацияләр шуннан чыга ала, к. ш. ук **Дөя.**

Тат. телендә **тәвә** варианты, башлыча, **тәвә кошы, тәвәкош** тәгъбирендә очрый; бу тәгъбир күптәннән килә, к. рус. *девякушъ* «тәвә кошы» < кр.-тат., төр. *deve kuş, devekuş* id. Гомумән, бу кошны «дөя кошы» (башы дөянекенә охшап торган кош) дип атау барча Евразия телләрендә күзәтелә: ул кошның лат. атамасы *Struthio camelus* асылда «тәвә кошы» дигән сүз, к. ш. ук бур. *тэмээн шубуун*, кыт. *тоцзū* һ.б. шундый ук фразеологик атамалар.

**Тәвә ~ дөя** сүзенең монг. телләренә хас *тэмээн, тэмиэн* варианты тат.-башк. даирәсендә дә билгеле булган күрәсең, к. миш. (ТТДС II: 313–314) **тәбәлайак, тәвәтояк** «черви (кәрт тамгасы)» – *тәбәл* < *тәбән* монда монг. диал. *тэбээн* «дөя» сүзеннән килә. К. ш. ук башк. кабиләсе **тамъян <** *тәмийән* асылда «дөячеләр» мәгъ. булган булса кирәк. К. ш. ук Федотов II: 211; Аникин: 574–575 (рус *тывен, тымен, тюя* сүзләре тур.).

**ТӘВӘКӘЧ I [тәwәкәч]** иск. «погонщик верблюдов» ~ кырг. *төөкөч* id. Чаг. төр. диал. *devekeş* id. ← *deve* «тәвә, дөя». Мантыйк буенча **тәвәкәч** «дөя колыны» (**тәвәкәч** дип туйда йомышка йөгерүче малайны да атыйлар).

**ТӘВӘКӘЧ II [тәwәкәч]** – название села в Центральном Башкортостане. Бу авыл исеме, ихтимал, бор. *табгач ~ тавгач* дигән халык исеменнәндер. Табгач дип элек татарларны атаганнар: Башкортстандагы микротопонимнар һәм микроэтнонимнар арасында бик борынгылары – кайчандыр Үзәк Азиядә яшәгән төрки һәм монгол кабиләләренең атамалары очрый.

Табгачлар З. Вәлиди (Velidi: 41) һәм Л. Лигети (Лигети: 107–117) буенча да сяньби теленә якын телдә сөйләшкәннәр. Сяньбиләрне З. Вәлиди төркиләр дип карый. Алар хәз. Монголия җирләрендә һәм күрше өлкәләрдә яшәгәннәр.

**ТӘВӘККӘЛ [тәwәккәл]** «решительный; рисковый; рискованный», иск. «риск» (*тәвәккәл* хәз. мәгъ. *тәвәккәлле* сүзеннән эллипсис) < гар. *täwäkkäl* «тәвәккәллек» сүзеннән. Мар. *тäүкäл* «елгыр, оста» (к. Исанбаев 1978: 10), чув. *теветкел* «тәвәккәллек» сүзләре татарчадан булса кирәк (*тәвәккәл ~ тäүкäл ~ теветкел* нигезенең дериватлары да өч телдә бердәй: чув. *теветкеле-* «тәвәккәлләү», *теветкеллӗ* «тәвәккәлле» һ.б.). К. **Вәкил.**

**ТӘВЕР [тәwĕр]** «в добром здравии» (ТТАС III: 207 «җен-пәригә, юк-барга ышанучан» дигән сәер аңлатма бирелгән), диал. (ДС I: 175) **тавыр, таврык** «җиңел холыклы, кызу кеше» ~ каз. *тәуiр* «яхшы, юньле», иске каз. *тауур* «тәвер, сап-сау» < фар. *даур* id., гарәпчәдә дә *таур* «образ; кыланыш; әхвәл; яхшы әхвәл, гаҗәеп шәп». Шулай итеп, *тәвер,* һичшиксез, гар.-фар. сүзләре даирәсеннән, ләкин конкрет кайсысыннан икәнлеге билгеле түгел. Будагов I: 409.

**ТӘВЕШ [тәwĕш], түвеш [түwĕш]** диал. «собирание, сбор», (активрак кулланылышта **әвеш-тәвеш, әвеш-түвеш** парлы сүзендә) «сборка; выборка, сборный» < бор. төрки (ДТС: 548–549) *tegiš* «үзгәреш», чыгт. (Будагов I: 418) *тэкиш-* «җыю», *тэкшир-* «берләштерү» ~ тат. диал (ЗДС: 165) **дәвеш, дәвешләмә** «табада пешерелә торган катлаулы ашамлык» < **тэгиш*, к. төр. (YTS: 63, күп вариантларда) *degšurmek, dögšurmek* «туплау, җыю; классификацияләү; төркемләү», төр. *devširme* «парламент; армиягә балалар җыю (элегрәк – буйсындырылган халыклардан); җиләк-җимешне сайлап җыю» һ.б. барысы да бор. төрки (МК) *tev-, teg-* «сайлап алу, сайлап җыю» нигезеннән. Бор. төрки *дегиш-, дейиш-* «үзгәрү, алмашыну» һ.б.ш. тур. Мухамедова 1973: 87. Чаг. **Ти-ү.** К. түбәндәгене.

**ТӘВЕШЛӘМӘ [тәwешләмә],** (БТДҺ: 176, 351) **кәүешләмә, кәwәшләмә, дәweш, дәwешләмә** (Хайрутдинова 1993: 35) «вид пирога без дна» – бу сүзләрдәге анлаут тартыкларның кайсы беренчел икәнлеген билгеләү читен; тат. телендә *т* > *к* очраклары да, тәгаен *т* > *д* да бар, к. **Дәвеш.**

**ТӘВ-Ү [тәw-]** (ЗДС: 616, брб.) «обижать слабого (о мальчиках)» < уйг. *тәг-* «тию» (**ти-ү** сүзенең «рәнҗетү» – бигрәк тә балаларга карата әйтелгән – мәгънәсе бар). К. **Ти-ү.**

**ТӘГАЕН [тәғәйён]** «определённо» < гар. *тә-ʻаййин* «тәгаен, билгеләнгән» ← *ʻйн* «билгеләү» тамырыннан. К. **Мөгаен.**

Дерив.: **тәгаенле; тәгаенлә-ү.**

**ТӘГАМЬ [тәғәм]** «еда, яства» < гар. *ṭаʻāм* id. Будагов I: 737. К. **Тәм.**

Дерив.: **тәгамьле, тәгамьсез; тәгамьлән-ү.**

**ТӘГАНӘ [тәғәнә]** (ТТДС I: 314)**: әдәм тәганәсе** «подонок» < гар. *ṭаʻāнā* «хурлаулар» (к. **Тәгънә**).

**ТӘГӘЙМӘТ** (Радлов IV: 72) «войлочный ковёр», Гиганов сүзлегендә **тякьяметь** «холст с узорами (бизәкле, төрле төсле калын тукыма)», **тякмять** «кожаный пояс», хәз. себ. (Тумашева 1992: 206) **тәкәмәт, тәкмәт** «киң билбау» ~ башк. (БТДҺ: 348) *тәкиәмәт кейеҙ* «буялган йоннан сугылган киез», кырг. *текемет (қур)* «бизәкле билбау, бил каешы», каз. *текәмәт* «бизәкле чуар юрган; корама юрган», (Катаринский) *текемет* «бизәкле киез» > рус. (Фасмер IV: 36) *текеметь* «корама келәм», үзб. (ЎХШЛ: 248–249) *такайман, тәкәмәт, тәкийәмәт* «бизәкле киез» < фар. *тāқййā-е-бāнд* «аслык палас; түгәрәк палас (утыру өчен)»: *тāқййā* «түгәрәк» (к. **Такыя**), *бāнд* «бәйләмләнгән, үрелгән нәрсә».

**ТӘГӘР, тигәр, тәгәй** (ЗДС: 616) «круг, колесо» ~ кр.-тат., госм. *тäгäр, тäкäр*, төркм. *тигир* id. Тат. **тәгәр** сүзенең үзе генә кулланылуы шик астында (ләкин бик мөмкин), әмма бу сүзнең (һәм аның фонетик модификацияләренең) күпсанлы дериватлары теркәлгән, к. иске тат. (Троянский I: 343) **тәкәрәк** «тәгәрәүчән нәрсә» < **тәкәр-әк** ~ кырг., госм. һ.б. *тегерек* id.; тат. диал. (ЗДС: 616–618) **тәңәр-ү**, (ТТДС I: 436) **тәгәрлә-ү, тәгәрнә-ү,** (ЗДС: 617) **тәкәрләт-ү**, башк. *тәңәрлә-ү* «тәгәрәү» ~ каз. *тегерле-*, госм. *тäкäрлä* id. һ.б., себ. (Тумашева 1992: 206, 209, 220–221) **тәгәрцек, тигәрчек** «тәгәрмәч», башк. (БТДҺ: 248–249) *тәңәрсәк* ~ каз. *тегершiк* id.; себ. (Тумашева, Op. cit.: 204, 207) **тәгәрек, тигәрәк** «түгәрәк», төр. *tekerlek* «тәгәрмәч». Бу сүзләрнең **түгәрәк** (к.), **түгәрлә-ү, түгәрчек** ~ ком. *дёгерчик* һ.б. вариантлары да бар. Шулай итеп, сүзнең *тәгәр ~ тигәр ~ түгәр* яңгырашлары абайлана. *Тәгәр < *тэгэр > тигәр* вариантлары тат. теле өчен характерлы, аңлаешлы күренеш, әмма **тэгэр ~ тöгэр > түгәр* (*э ~ ö*) тәңгәллегенең генезисы юньләп хәл ителмәгән мәсьәлә, к. **Тәкернә-ү, Тирә, Түгәрәк.**

**Тәгәр** < *тэкәр < тэңкәр* «түгәрәк» белән беррәттән **тәгәр-** < *тэкәр- < тэңкәр* дигән фигыль дә булган, к. венг. (< төрки) *teker-* «әйләндерү», *tekere-* «тәгәрәү», к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 206) **тәгәрек** «түгәрәк» (**тәгәр-ек: -ек** фигыльләрдән исем ясагыч кушымча).

Бу сүзләрнең барысының да тамыры **тәк < тәңк** «әйләнә, түгәрәк» (**тәңк** варианты башк. мисаллардан күренә); бу сүздән төрки телләрдә исәпсез күп сүзләр ясалган, к. **Тәгәрә-ү, Тәгәрмәч, Тәгәч, Тәкмәк, Тәкмәч, Тегермән, Тик, Тирә, Түгәр.** Будагов I: 367–368; ЭСТЯ III: 178 (аз мәгълүматлы).

**ТӘГӘРӘ-Ү** «катиться» ← **тәгәр** (к.): **тәгәр-ә-**. Ихтимал, монда фар. *тäк авäр* – «тәгәрәтү» сүзенең контаминацион тәэсире бардыр. Ләкин фарсыда да *тäк* «түгәрәк» төрки сүздер. Бу фигыль, башлыча, тат.-башк. даирәсендә кулланыла.

Дерив.: **тәгәрәш-ү, тәгәрәт-ү; тәгәрәгеч, тәгәрәткеч** (уенчык).

**ТӘГӘРМӘЧ** «колесо» < **тәгәрмәгәч** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) id. < *тәгәрмикәч, *тәгәрмәй-кәч* «кечкенә *тәгәрмәч*» сүзеннән, к. диал. (ТТДС I: 436) **тәгәрмәй, тәгәрми** «тәгәрмәч; арбачык», каз. *тегiрмеш* id. һ.б. << бор. төрки (ДТС: 548, 550) *tekermi, tegermi, tegirmä* «түгәрәк, алка» (*-mi, -ma* морфемасы аңлашылып бетми, ихтимал, ул аерым сүздер) > төр. *tegermi, deyirmi* «математик түгәрәк, әйләнә», *degermi* «түгәрәк; хачсыман дүрткел», төркм. *дегирми* «тәгәрмәч» һ.б. күп телләрдә.

Шунысы характерлы ки, *тәгәрмәч, тәгәрмәгәч* яисә *тәгәрмәй* сүзләре, бор. төрки һәм тат. теленнән тыш, бүтән кыпч. телләрендә юк; бу факт башк. *тәгәрмәс, тәңәрмәс* сүзенең тик тат. теленнән генә килә алганын күрсәтә. Тат. *тәгәрмәч* сүзе үзе дә берәр аерым төбәктән (ихтимал, миш. сөйләшләреннән) таралган, чөнки Казан татарларында «тәгәрмәч» мәгъ. **көпчәк** сүзе кулланыла (*арба көпчәге* һ.б.); чув. телендә «тәгәрмәч» урынына *кустäрмач* (тат. *тәгәрмәч* сүзеннән ярымкалька) һ.б.

Диал. (ЗДС: 616–617) **тәгәрмә, тәкермәч** «тәгәрмәч», әлбәттә, **тәгәр-, тәкәр-* фигыленнән (тик ясалышы ачык түгел); аның исем коррелянты – **тәгәр**, к. аз. *тәкәр*, төр. *teker* «тәгәрмәч», тат. диал. (ТТДС I: 436; Тумашева 1992: 206) **тәгәрцәк, тәгәрцек,** башк. (БТДҺ: 349) *тәңгәрсәк* ~ нуг. *тегершик,* каз. диал. (ҚТДС: 327) *тегершiк* «кечкенә тәгәрмәч», госм., чыгт. *тäкäрлäк* id. һ.б. ясалган. К. **Тәгәр, Тәкернә-ү, Тегермән**. ЭСТЯ III: 172, 178 (төркм. *дегирми-* «тәгәрми» сүзе тур., аз мәгълүматлы).

Дерив.: **тәгәрмәчле, тәгәрмәчсез; тәгәрмәччек; тәгәрмәчлек, тәгәрмәчлә-ү.**

**ТӘГӘРЧЕК**, (ЗДС: 618) **тигәрчәк** «колёсико; тележка (детская)» ~ каз. (ҚТДС: 95, 326) *дігіршік, тегершік,* нуг. *дегершик* id. һ.б. к. **Тәгәр.**

**ТӘГӘЧ,** (ТТДС I: 436–437; Тумашева 1992: 208) **тәwәч, тегәц, тигәч, тигәц,** (ЗДС: 617) **тәкәчә** «кружка, деревянная чаша, чашка, кадка, корзина – все круглые сосуды» < гом. кыпч., к. башк. (БТДһ: 347; БҺҺ II: 144) *тәгәс, тигәс*, нуг., каз. *тегеш*, үзб. (ЎХШЛ: 249) *тәкәш* «тирән агач тәлинкә», алт. (Баскаков 1972: 252) *тегилегеч, теглегеч* «түгәрәк савыт» < *тәклэк-эч, тэклэк-кэч* ← **тэклэк** «түгәрәк». Тамыры *тэк* < *тэнк* «түгәрәк», к. **Тәгәр, Тәүлек. Тәгәч < *тэңкәч > тигәч**. Хайрутдинова 2000: 15.

**ТӘГЪБИР** «выражение; толкование; предположение», «рассуждение, суждение» < гар. *тә'бūр* id. ← *'бр* «ясалу, әверелү; хисаплау, исәпләү» тамырыннан, шуннан ук **Гыйбарәт, Гыйбрәт, Игьтибар.** К. ш. ук диал. (Зимасов: 95) **төштәгабир** (**тәгабир** «тәгъбирләр») «төш юраулыгы (китап)».

Дерив.: **тәгъбирле** «тәҗрибәле; зирәк, тапкыр», **тәгъбирсез** «дуамал, уйлап-нитеп тормаучан»; «санга сукмаучан»; **тәгъбирлә-ү** «төшенү, аңлау», «фикерне, төшенчәне аңлату, белдерү», «багу, күрәзәлек итү» → **тәгъбирнамә** «төш юрау китабы», **тәгъбирче** «багучы, күрәзәче; киңәшче; информатор, комментатор».

**ТӘГЪЗИЯ [тәғзийә]** «траурное воспоминание (об умерших на войне); посещение и утешение вдов и родных погибших» < гар. *тә'зийә* id. ← *'зw* «сугышу» тамырыннан, шуннан ук иске тат. **гази** «сугышта җиңүче», **газәват** «дин өчен сугыш».

**ТӘГЪЛИМАТ** «учение; концепция» < гар. *тә'лūмāт* id. ← *'лм* «өйрәнү» тамырыннан, к. **Галәм, Галәмәт, Галим, Голәма, Гыйлем, Мәгълүмат, Мөгаллим**.

**ТӘГЪНӘ** «критическое рассмотрение; поправка; выговор» < гар. *ṭа'нā* id., к. **Тәганә.**

**ТӘГЪРИФ** «определение; выражение; пояснение» < гар. *тә'рūф* id. ← *'рф* «аңлату, яктырту» тамырыннан. Шуннан ук интернациональ **тариф** сүзе килә.

Дерив.: **тәгърифлә-ү** «билгеләү; сөйләп аңлату; тасвирлау, сурәтләү»; **тәгърифче, тәгърифнамә** «белешмәлек, билгеләгеч (китап)».

**ТӘГЪТИЛ** «каникулы; отпуск» < гар. *тә'-ṭūл* id. ← *'ṭл* «рәттән чыгу; туктатылу; эшсез калу; ярлы булу» тамырыннан, шуннан иске тат. (Г. Тукай һ.б.) **гаталәт** «ялкаулык; эштән баш тарту; юньсезлек». К. ш. ук **Әтәмби.**

**ТӘДБИР** «(эффективный, продуманный) приём, средство» < гар. *тāдбūр* id. ← *дбр* «астыртын, арттан хәрәкәт итү», шуннан ук иске әд. **дәбир** «тәҗрибәле чиновник, үзе алга чыкмыйча, дәүләт эшләрен башкаручы; хуҗасына баш булган хезмәтче, кол; Меркурий (мифологик образ һәм планета)». Будагов I: 346, 552.

Дерив.: **тәдбирле** «тәҗрибәле, актив (җитәкче тур.)».

**ТӘҖЕ,** диал. (шрл.) **тяжы** «тяж» < рус.; шуннан ук чув. *тевĕш, терш, черш* һ.б. id. Рус. сүзе *тяга* «тарту» сүзе белән тамырдаш.

**ТӘҖЕЛ** (ТТДС I: 441) «срочно, срочный» < гар. *тā'җūл* «ашыгычлык, тизлек» сүзеннән (*тәҗел* сүзе үзе татарчада *тәҗелле* дигәннән эллипсис), *'җл* «ашыгу» тамырыннан, шуннан ук иске тат. *гаҗил* «тәҗел».

**Тәҗел** продуктив нигез: **тәҗелләнү, тәҗелләү** (Я. Емельянов), **тәҗелле** һ.б.

**ТӘҖРИБӘ** «опыт» < гар. *тāҗрибā* id. *җрб* «татып карау, сынау» тамырыннан. Чаг. ш. ук иске тат. **тәҗриби** «тәҗрибәле». К. **Җәриб.**

Дерив.: **тәҗрибәле; тәҗрибәсез** «тәҗрибәсе булмаган» һәм «тәҗрибә ясамыйча»; **тәҗрибәлә-ү; тәҗрибәче** һ.б. Иске телдә **тәҗрибәкяр** «тәҗрибәләр үткәрүче» сүзе булган.

**ТӘЙ** (ТТАС III: 211) «одна сторона двухстороннего мешка для навьючивания» – «курҗынның (хөрҗеннең) бер ягы; шундый ук авырлыкта булган йөк (рус. «противовес»)», диал. **тай** «парлы борысларның берсе» ~ чув. *тай* (< *тәй-* ?) id., *тай кĕсье* «тулы кесә; зур кесә» ~ гом. кыпч., чыгт., уйг., аз., төр. *тай*, төркм. *таай* «тәй; сыңар; курҗынның бер ягы; тиңдәш; төргәк, тюк», төркм. *даай* «ярты», үзб. диал. *той, тойпақ* «төргәк» < фар. *тай* id. Бу сүз киң таралган (Кавказ телләрендә дә еш очрый) һәм аерым телләрдә күп аерым үзенчәлекле (күч.)

мәгънәләр алган (мәс., каз., к.-калп. *тай* «99 килограммлы үлчәү берәмлеге»). Zenker: 250; Будагов I: 339; ҚТДС: 313; Räsänen (FUF XXIV, 1937: 257) бу сүзгә венг. *táj* «каршы; каршы як» сүзен дә нисбәт итә); рус. *тай, тайка* «төргәк, тәй» тур. Фасмер IV: 10.

Фразеологизм: **ике тәйле** «тиң ихтималлы, тегеләй дә, болай да булырга мөмкин; шикле». К. **Тәе.** Чаг. **Тән, Тиң.**

**ТӘЙЗӘ** иск., **тей, тейчау** (крш., ЗДС: 625) «женщина из родни старше говорящего» ~ төр. *teyze*, бор. угыз. *dayıze* id. *tay* ~ *day* «тай, тае» (к. **Тай II**) сүзеннән, Räsänen 1969: 454, 455–456 (күп вариантлар).

Т. Текин буенча, **тәйзә** < *тайза* < *тай әҗә* (к. **Әчә**) сүзеннән икән. Ләкин тат. **тейчау** варианты аңлашылмый.

**ТӘЙКӘ –** определённое положение (одно из положений) альчика; альчик, утяжелённый свинцом; утяжелённый (вообще)» к. **Тайка**. *Тай* > *тәй* сүзеннән булса кирәк.

**ТӘЙПӘК** (БҺҺ II: 271) «мелкий, неглубокий» чаг. **Җәйпәк.**

**ТӘК I** сөйл. «так, так значит» < рус. *так*.

**ТӘК II** диал. «так просто; впустую» к. **Тик**. К. ш. ук **Тәккә.**

**ТӘКА** (Садыкова 1985: 100) «очень уж; совсем; даже» ~ башк. (БТДҺ: 301, 344, 348) *тақа, тақы, тықы, тәкә,* каз. (ҚТДС: 314) *тақиқ, такый* «анык, төгәл» < гар. *тäхқӣқ* (> **тәхқыйк**) «чынлыгын тикшерү», тат. әд. телендә «чыннан да, чынлап» мәгъ. кулланылган, к. ГТРС: 602. Тат., башк. диал. сүзләр элекке гар. (хәзер сүзлекләргә кертелми) *тäхäққақ* «тикшерелгән, чынлап» сүзеннән дә килеп чыга ала.

**ТӘКАТЬ** «терпение» к. **Такать.**

**ТӘКӘ** «козёл, баран» > чув. *така [тага]* > мар. (Иванов, Тужаров: 214; Саваткова: 156) *тага, тäгä*, удм. (< тат.) *така* id. < гом. төрки *тэкэ* id. ~ бор. монг. (Поппе 1938: 267) *teke, tekke* > хәз. монг. *тэк, тэх*, бур. *тэхэ* ~ тунг.-маньч. (ССТМЯ II: 230) *тэхэ* «кыргый кәҗәсыманнарның иркәге». Төркм. *тәккә* «көтү башлыгы булган тәкә»; гомумән «шәп егет», ш. ук кабилә атамасы. Чаг. **Кучкар.**

Сүзнең тәүге яңгырашы **тәккэг,* к. бор. төрки (Zenker) *täkäv* ~ каз. *дегаү, дегәү* «тәкә» (каз. сүзе угыз-кыпч. катнаш сөйләшләрдән). Бу сүз күп күрше телләргә кергән, к. фар. *такка, тäккä*, көрд. *teke* «көтү тәкәсе, сәркәш». Будагов I: 366; Федотов II: 163–164. Рус. *тек, тыкен* «тәкә, кыр кәҗәсе» тур. Аникин: 544, 574 (бай әдәбият күрсәтелә).

Дерив. ярлы. К. **Тәкәдән, Тәкәли.**

**ТӘКӘББЕР** «гордый; спесивый; чван» > чув. (Сергеев 1969: 60) *теккепĕр,* мар. (Исанбаев 1978: 10; Гордеев 1973: 39) *тäкäбер, тäкäмбер, такабыр* id. – иске тат. **тәкәбберле** сүзеннән эллипсис, бу сүз исә **тәкәббер** < гар. *тäкäббүр* «горурлык, зурлану, киберләнү (исем)» ← *кбр* «зур булу», шуннан ук к. **Кибер, Тәкбир.**

Дерив.: **тәкәберлек; тәкәберлән-ү.** Халык этимологиясендә мәзәк рәвештә **тәкәгәбер** «тәкәббер».

**ТӘКӘДӘН** иск., диал. «выбранная и т.п. жертва» *тәкә* сүзенең корбан хайваннарга нисбәт ителүеннән килә: **тәкәләрне** атарга яраган.

**Тәкәдән** дип коллектив уеннарда авыр, хурлыклы рольне уйнарга тиеш кешене атаганнар; таяк тотышта иң аста калган малай **тәкәдән** («көтүче») була.

**ТӘКӘЛИ,** (ТТДС I: 437) **тәкә** «вид пирога (в виде рогов); рожок, рожки» – **тәкә** (к.) сүзеннән (яисә киресенчә булмадымы икән? **Тәкә < тәккә** бор. заманда тәкәләргә хас булган мөгезне белдергән булуы ихтимал).

**ТӘКӘМӘТ** «узорчатый пояс» к. **Тәгәймәт**.

**ТӘКӘРЛЕК** (Троянский I: 341 һ.б. күп чыганакларда) «пигалица; чибис; трясогузка» ~ башк. (БТДҺ: 347) *тәгәрәк, тәгәрлек, тәгәрлүк* > чув. *текерлĕк, текерлү, тетерлĕк* һ.б. (к. Федотов II: 206), мар. (Исанбаев 1978: 21) *тагарля* «чибис». Бу сүзнең тат., башк. сөйләшләрендә бүтән мәгънәләре дә бар (к. ТТДС I: 437; БТДҺ: 348) «сипкелле» (*тәкәрлек күкәе шикелле* дип тә әйтелә), «мөгезле әкәмтөкәм» (**тәкә** сүзенең контаминацион тәэсиреннән), «мәрхүмне искә алу мәҗлесе» (гар. *тäкäррур* «кабаттан искә алу» сүзеннән юри бозылган булса кирәк). Чаг. гаг. *текир*, төр. *tekir* «кара чуар (мәче); чутырлы», *tekir ördeği* «кара чуар кыр үрдәге төре».

Икенче яктан к. иске тат. (Троянский I: 343) **тәкәрәк** «тәгәрәүчән; тырпылдык» ~ төр. *tekerlek* «түгәрәк; йомры».

**ТӘКӘРМӘЧ, тәкермәч** (ТТДС II: 314) «кружочки (картошки, колбасы)» – **тәгәр, тәкәр, тәкер** «түгәрәк; тәгәрмәчсыман нәрсә» сүзенә ашамлык атамаларын ясагыч *-мач//-мәч* кушымчасы ялганып ясалган. К. ш. ук диал. (ЗДС: 617) **тәкернә-ү** «тәгәрәү». К. **Тәгәр, Тәгәрмәч, Тәкернә-ү.**

**ТӘКӘТ** (БТДҺ: 348, «төньяк-көнбайыш», ягъни тат. сөйләшләреннән) «способ действия, (духовная) сила, терпение» < **тәкать** (к.) сүзеннән булса кирәк, ләкин монда бүтән бер сүзнең контаминацион тәэсире дә бар бугай. К. төр. *tekit* < гар. *tä'кӣд* «ныкышу, кат-кат эш итү».

Дерив.: **тәкәтсез**.

**ТӘКЕЛДӘ-Ү** (К. Нәҗми) «говорить так-так-так; без умолку болтать» < *такылдау* (к.)

**ТӘКЕН-Ү** (ТТДС II: 437) «спотыкаться» ~ чув. *такăн-* id. Чаг. кырг. *текил, текиреҥ* «сикереп-сикереп хәрәкәтләнеш (мәс., тышаулы ат тур.)», каз. *текекте-* «сикереп йөгерү (кат-кат сикерүдә ярышу)». Федотов II: 165.

**ТӘКЕРНӘ-Ү** (ЗДС: 617) «катиться (неровно); кататься на плоскости (на земле, на полу), кувыркаться» ~ төр *tekerle-* «тәгәрәү; тәкернәү» (гомумән, бу сүз күп мәгънәле) ← *teker* «тәгәрмәч». Чаг. тат. диал. **тәгәрләт-ү** «тәгәрәтү». К. **Тәгәрмәч.**

**ТӘ́КИ** «так и; несмотря ни на что, всё-таки» ~ удм., мар. *таки,* чув. *такки* id. < рус. *так и, таки.*

**ТӘККӘ, тиккә** «напрасно; без резона» < гом. кыпч. *текке, тәккә* id. ← *тәк, тәк* (к. **Тәк II**).

**ТӘКМӘР, тәкмәч** «кувырок» ~ башк. *тәкмәр, тәкмәс* id. – тат.-башк. даирәсендә генә булган бу сүзләр, һичшиксез, *тәк* «түгәрәк, дүңгәләк» тамырыннан, ләкин ясалышлары ачык түгел. К. **Тәгәрмәч.**

**ТӘКРАР** «повтор, повторение» < гар. *тäкрāр* id. ← *крр* «кабатлау» тамырыннан. К. **Кәррә.**

Дерив.: **тәкрарла-у, тәкрарлан-у.**

**ТӘКСЕ, тиксе, тәксем, таксым** (Юсупов 1985: 181–182; Башҡорт диалектологияһы: 178) «до (чего)» бор. *тәгзи* < *тәгри* id. сүзеннән (*р* > *з*), к. **Тәре, Тире.** Веляр вариантлар аңлатуга мохтаҗ.

**ТӘКЧӘК, тәкцәк** (брб., Тумашева: 206; ЗДС: 617) «внутренний угол, уголок» ~ кырг. *текче* «асылмалы киштә», каз. *текше* «тау битендәге кечкенә тигезлек» (каз. сүзлекләрендә күп мәгъ. күрсәтелә) ← кырг. һ.б. *тек, тäг* «киштә» (фар. сүзе булса кирәк, к. **Так**).

**ТӘКЪВА [тәқwa]** «богобоязненный, благочестивый» < гар. *тäқwā* id ← *wқй* «үз-үзеңне саклау».

**ТӘКЪДИМ** «предложение, то, что предлагается» < гар. *тäқдӣм* id. ← *қдм* «адым ясау; юл башлау» тамырыннан, шуннан да иске тат. **мөқаддәм** «элек, элегрәк», **қадәм** «беренче адым».

**ТӘКЪДИР** «судьба, предопределение» < гар. *тäқдӣр* id. ← *қдр* «алдан билгеләү; санау; санап, исәпләп кую» тамырыннан, шуннан ук к. **Кадәр, Кадир, Кодрәт,** иске **Мөкаддәр** «язмышлар язылган илаһи такта».

*Тәкъдир* сүзе фонетик үзгәрешләр кичереп күрше телләргә дә кергән: чув. (Сергеев 1968: 68) *тахтăр* «нужа, кыенлык», мар. *тактыр* id.

Дерив.: **тәкъдирлә-ү, тәкъдир итү** «тиешле бәя бирү; язмышын хәл итү».

**ТӘКЪЛИДИ** «подражательный» (*тәкълиди әсәр* «подражательное произведение», *тәкълиди сүз* «подражательное слово, имитатив») < гар. *тäқлӣдӣ* id., к. **Тәкълит.**

**Тәкълиди, тәкълит** лингвистик терминнарын Җ. Вәлиди тәкъдим иткән булган; тик 30 нчы елларда бу терминны юкка чыгарып, русчадан ямьсез, уңышсыз калька – **аваз ияртеме** сүзен керткәннәр. Хәлбуки **аваз ияртеме** яки **ияртем** дигәннән дә барыбер (махсус аңлатмасаң) берни дә аңлашылмый. Сүз ясалу мантыйгы буенча исә **ияртем** ул «ияртелгән төркем»!

Әдәби телдә **тәкълидия** «ияреп, охшатып (кайчакта сатирик тонда) язылган әсәр», мәс. Тукайның «Яңа кисекбаш» поэмасы. **Тәкълидия** дип иске үлчәмнәр белән язылган шигырьне дә атыйлар.

**ТӘКЪЛИТ, тәкълид** «подражание, подражательное слово» < гар. *тäқлӣд* id. ← *қлд* «охшау, кәпләнү, ияру» тамырыннан.

Элекке әд. телебездә *тәқлид* – әдәби жанрларның бер төре.

**Тәкълит** продуктив нигез: **тәкълидән** «ияреп, охшатып», **тәкълитче, тәкълитчән** (Ш. Бабич). К. **Тәкълиди.**

**ТӘКЪРИЗ** «литературное толкование, разбор, анализ произведения» < гар. *тӓқрӣḍ* id. **Тәнкыйть** сүзеннән аермалы буларак, **тәкъриз** уңай бәяләмәне, мактауны да белдерә ала. Шунлыктан элек *тәнкыйть вә тәкъриз* дип язганнар.

**ТӘКЪСИР, тәкъсыйрь** – слово обращения к старшим по рангу, к учителю. Катлаулы юл белән гар. *тӓқṣир* «кимчелекле» (*қṣр* «кимчелекле булу») сүзеннән килеп чыккан: тәүдә мөрәҗәгатьче **мин тәкъсир** дип үзен атаган («мин, кимчелекле, мөрәҗәгать итәм» мәгъ.). Ләкин сүзнең төп мәгънәсе онытылгач, **тәкъсир** сүзе мөрәҗәгать ителүчегә нисбәтләнгән. Әкәмәт!

**ТӘЛ I** (Тумашева 1992: 206; БТДҺ: 348) «точно; точка»; *тәл бул-* «встретить, наткнуться» ~ чув. *тĕл* «урын, төш, өзенте», *тĕл пул-* «тәл булу» (?, монда фонетик закончалыкларга хилафлык та юк түгел). Каз. *тел* «бердәнбер» < *тәл?*

*Тәл* сүзенең бүтән төрки телләрдә параллельләр күренми, ихтимал ки, ул болг. сүзедер. Чув. *тĕл* гом. төрки *түш* > *төш* сүзе белән чагыштырыла, к. Федотов III: 214.

*Тәл* сүзеннән себ. **тәлек-ү** «кинәт очрау», башк. *тәлләү* «төбәү» фигыльләре ясалган.

**ТӘЛ II, тәл, тил** (Арсланов 1992: 147; ЗДС: 632) «проволока, кисть веточек» < гом. кыпч., гаг. *тәл*, госм., аз. (Радлов III: 1080) *тӓл*, төр. *tel* «тәл, алтын җеп; ука; кыл; чук; каурый һ.б.ш.» ~ чыгт., уйг., бор. төрки (Радлов III: 875), чув. *тал* «җеп; бер тотам, бер учма» ~ яз. монг. *del* «ял» > эвенк. *дэл, дэлин* id. (к. ССТМЯ I: 231). К. ш. ук Zenker I: 305.

*Тәл* сүзен *тал* (к. **Тал**) сүзе белән чагыштыру мөмкин кебек булса да, шикле. *Тәл* сүзенең «ука, алтын җеп» мәгънәсе игътибарга лаек; чаг. гар. *тӣл,* фар., көрд. *тәл* «җеп, киндерә, кыл, бәрчә». К. **Тәлгәш, Тәллетәвеч.**

**ТӘЛӘГӘЙ:** в форме притяжательности во фразе **тәләгәе (-м, -ң) тигез** «у него (меня, тебя и пр.) нет забот, всё налажено, на мази» ~ кырг. *телегейн тегиз (~ тең)*, каз. *телегей-теңiз* (дөрес язылмаган) id., аз., кырг. *телегей, telägäj*, хак. *тилекей*, тув. < монг. *делегей* «киң дөнья; киңлек» > як. *дӓлӓгӓй, делегей* «киң» ← *делей* «киңәю» ~ монг. *дэлгэ-* «киңәю» ← *дэл* «ерак, киң», *зэл-* «киң җәю, киңәйтү һ.б.». Räsänen 1969: 135, 471–472 (бүтән күп кенә мисаллар китерелә). К. **Тәләкә I.**

**ТӘЛӘЙ** «счастье; призвание» > чув. *телей, талай* < уйг. *тәләй,* төркм. *тәлей* id., ш. ук «язмыш» ~ гом. кыпч. *талай,* кырг. *таалай*, гар. *ṭāли‘* «бәхет йолдызлыгы (зодиактагы йолдызлыкларның берсе)» сүзеннән дип уйлыйлар (Räsänen 1969: 458; Федотов II: 206–207).

**ТӘЛӘК** диал. «амбар или сенник на столбах; сооружение, нижний этаж которого конюшня или коровник, верхний – летнее жильё или амбар» ~ үзб. (ЎХШЛ: 249) *тәләк* id., чыгт. *телек [тӓлӓк]* «магазин булып хезмәт итә торган сәндерә» (к. Будагов I: 372) ~ каз., к.-калп. *телек* «амбар» (шуннан к. *Олы Тәләк* – Уфадан 50 км көнчыгыштарак урнашкан зур авыл исеме) < монг., тув. *тэлгэг, дэлгэк* «таскак» > эвенк. *дэлкээн, дэлкэгэн,* нан. *дэлэңку* «тәләк, баганалар өстенә салынган амбар», монг. *дэлгэ-* «җәеп салу, күргәзмәгә кую» сүзеннән. ССТМЯ I: 233. К. ш. ук як. *тел, тӓл* «җәелгән нәрсә, палас» һ.б., *тӓллӓх* «җәймән, урын-җир».

**ТӘЛӘКӘ I** (ТТАС III: 217; ТТДС I: 438; ТТДС II: 315) «вертушка (у калитки и т.п.); засов; закрутка; валёк (у плуга), отвал плуга; человек маленького роста» ~ башк. (БҺҺ III: 189; БТДҺ: 348) *тәләкә, теләкә* «келә; авызлык божрасына эләктерелә торган тияк, кәс тактасы» и т.п. – бу сүзнең күп мәгънәлелеге аның этимологиясен кыенлаштыра. Мәгънәләрнең күпчелеген «беркеткеч деталь» дип гомумиләштереп, аны гар. *тӓ‘лӓқа* «бәйләгеч, беркеткеч» (к. **Тәләкә II**) сүзеннән булуын чамалап була. Ләкин нишләп гарәп сүзе – әйбер атамасы шундый киң таралыш алды икән. Аннары, китерелгән мәгънәләрне «әйләнә торган нәрсә» дип тә гомумиләштереп була (ш. ук сүзтезмәләрдә: *тәләкә күкәе* «күп кабатланган нәрсә», *тәләкә кыздыру* «бер нәрсәне күп кабатлау, артык әһәмият биреп сөйләү», *тәләкә коңгыз* «су өстендә әйләнеп йөри торган коңгыз төре»), шул ук вакытта *тәләкә* сүзен каз., к.-калп. *телеген* «ике тәгәрмәчле арба», чыгт. *тлкин* (сузыклары ачык түгел, к. Будагов I: 374) «арба төре», чыгт. (Радлов III: 1086) *тӓлгӓн* «агач хәрби машина», чулым. (алт. диал., к. Радлов III: 1070) *тӓргӓн* «түгәрәк; тәгәрмәч», монг. *тэрэг* «шүрегә җеп урагыч тәгәрмәч; арбачык», *тэргэн, тэрэгэн, тэлэгэ(н)* «арба» – шуннан кр.-тат. һ.б. кыпч. телләре аша рус. *телега* сүзе дә килә (Фасмер IV: 37–38). К. ш. ук ССТМЯ I: 238.

Рус. *телега* сүзенең төрки < монг. этимоннары турында К.Г. Менгес (1979: 137–145) бик тәфсилләп яза. Аныңча, (С. Муратовка сылтанып) бор.

монг. *teligen* < **teg-li-gen, teg-li-ken* «тәгәрмәччек» бор. төрки-монг. *тәк* < *тәг* «түгәрәк, әйләнә» тамырыннан ясалган (бу тамырга гомумән бик күп сүзләр тоташа, к. **Тилгән**).

**Тәләкә ~ тәләгә** сүзе белән хак. *тилекей*, тув. *делегей* «киң дөнья, түгәрәк горизонт» сүзе баглы булса кирәк. Тат. *тәләгәе тигез* «(аның) дөньясы тигез» тәгъбирендә дә шул ук сүз күренә. Чаг. **Тәликә, Тәләгәй.**

**ТӘЛӘКӘ II, тәләке** (ТТДС II: 438; БТДҺ: 348) «клевета; злоба; издевательства» < иске гар. *тäʻ-лäķ* «үртәшү, үртәү» (шуннан *тäʻлäķӣ* сатирик; мыскыллы») ← *ʻлķ* «бәйләү, баглау, баглы булу» тамырыннан, шуннан иске тат. **галәка** «багланыш, мөнәсәбәт», **тәгъликъ** «бөти, хәситә асу; гарәп хәрефләрен үзенчәлекле язу төрләренең берсе (хәрефләрне күбрәк кушылдырып язу)» һ.б.

**ТӘЛӘФ** «разбазаривание, расточительность; приведение в негодность дурным обращением» < гар. *тäлäф* id. Будагов I: 374.

**ТӘЛГӘШ, тәлкәш,** (к. ДС II: 194), диал., башк. (БҺҺ II: 271; ТТДС II: 315) **тәлгә, тәлге** «гроздь; кисть; бахрома» < **тәлкәч, тәлкә-, тәл* (к.) сүзенең кечерәйтү формалары. Фонетик үзенчәлеге (*ч* > *ш*) буенча нуг. теленнән дип уйларга мөмкин, ләкин нуг. андый сүз безгә мәгълүм түгел.

Дерив.: **тәлгәшле, тәлгәшсез; тәлгәшлән-ү.** Диал. (ЗДС: 615) **тәгәлдәш** < **тәлгәдәш** «бәрчә, букет».

**ТӘЛИКӘ** (XIX г. текстларында) «тележка (двухколесная)» ~ кр.-тат. *taleke,* нуг. *таьлийке [тәликә]* «кырандас, тарантас», төр. *talika* «көймәле җиңел арба» – төр. язылышына карганда, бу сүз гар.-фар. даирәсеннән килә, ләкин М. Өзённең бик зур гар.-фар. алынмалары сүзлегендә (Özön 1997: 813) андый сүз юк. Ихтимал, **тәләкә** (к.) сүзе белән баглыдыр.

**Тәләкә, тәликә** сүзләре мисалында һәм яңгырашлары, һәм мәгънәләре бик охшаш сүзләрнең дә еш кына бөтенләй үзгә-башка чыганактан килү ихтималы бик ачык күренә.

**ТӘЛИНКӘ** «фарфоровая или металлическая тарелка», техникада «диск» < рус. диал. *талерка* (шуннан арытабан **тарелка** → тат. **тарилкә**) < *талер* ← ним. *Teller* «тәлинкә» < ит. *tagliere* «коштабак, үзендә ашамлык турагыч табак» ← лат. *taliare* «юну, турау, нечкәртү». Шул нигезгә *талия* «кысык бил» сүзе тоташа, к. Kluge: 904, 911. К. ш. ук **Тарилкә.** Фразема: **тәлинкә тоту (ялау)** «ялагайлану, ярарга тырышу». Русча тәгъбирдән калька булса кирәк, чаг. рус. *блюдолиз* «ялагай» һ.б.

**ТӘЛКЫЙНЬ [тәлķин]** «толкование; проповедь муллы у могилы покойного после его погребения», себ. (Тумашева 1992: 201) **талкын** «кабер өстендә җырлана торган җыр» < гар. *тäлķӣн* id. Үзб. телендә бу сүз (к. ЎХШЛ: 245) гомумән «җыр, көй» мәгъ. алган.

Себ. татарларында бу сүз мәҗүси төрки йола рухында аңлашылган; төркиләрдә, ш. ук һуннарда мәрхүм турында аны аклап-мактап эпик җыр җырлау булган (мәс., Аттила үлгәч, шундый тәлкыйнь – озын җыр җырлаганнар, ул җырның латинчага тәрҗемәсе дә сакланган).

Дерив.: **тәлкыйньлә-ү, тәлкыйньче.**

**ТӘЛЛӘТӘВЕЧ [тәлләтәwĕч]** «вальдшнеп; зуёк» ~ башк. (БҺҺ II: 273; БТДҺ: 350–351) *тәтәлтәүгес* «бытбылдык», *тәтелдәүес, тәтелдәүек* «яңгыр чыпчыгы» ~ чув. (Сергеев 1968: 68–69) *телле* «шәп чаба торган ниндидер бер кош» < *тәлле тәвеч* < *тәлле тавис* «башы чуклы тавис» (диал. *тәвес, тәвис* «тавис»), к. **Тәл.** К. ш. ук удм. *таллибош* < тат. **тәллебаш**, удм. *талливай* «тәлле кикрик» (*вай* «әтәч кикриге») – һәр икесе «тәлләтәвеч» мәгъ. Башк. вариантлары халык этимологиясе нигезендә («тәтелдәү»гә нисбәтләп) килеп чыккан (хәлбуки *тәлләтәвечләр* «тәтелдәмиләр»). К. түбәндәгене.

**ТӘЛЛЕТОРНА,** диал. **тиллеторна** «вид птицы, похожей на журавля», аны төр. *telli balıkcı* һәм *telliturna* дип атыйлар. Камышлар арасында кузгалмыйча (балык аңдып) торганы өчен шулай аталган. Кеше-кара якынлашканда да үзен камышлар аркасында күрмәсләр дип, ул хәрәкәтсез тора бирә. Шунлыктан игътибарсыз кешене **тиле торна**, дөресе *тилле торна* атыйлар. Чөнки аның баш түбәсендә *тәл ~ тил* бар. К. **Тәлләтәвеч.**

**ТӘЛПӘК** сирәк «узбекская шапка (без наушников)» < уйг. *тәлпәк,* үзб., каз., кырг. *телпак, телпек [тәлпәк]* «колакчынсыз бүрек» < *кәлпәк*, к. **Калпак.** Будагов I: 374.

**ТӘМ** «вкус; удовольствие» (*тәм табу* «находить удовольствие (в чём)») < иске тат. (ЛТ I: 7)

*тәғым* > чув. *техӗм* id. < гар. *ṭа‘м* «ашау, тату» тамырыннан. Будагов I: 375.

*Тәм* һәм аның дериватлары күрше фин-угор телләренә дә таралган: мар. *тӓм, там* «тәм», *тӓмлӗ, тамлӗ* «тәмле»; удм. (Насибуллин: 139) *тӓмжэ тодънъ* «тәм тату» һ.б. Федотов II: 210 (тат. сүзләрен искә дә алмый һәм *дәм* сүзе белән бутый).

Дерив.: **тәмле, тәмсез; тәми; тәмлә-ү, тәмәйт-ү;** диал. (Будагов I: 375) **тәмшән-ү** һ.б. (икенчел дериватлар).

**ТӘМАМ** «закончено; окончательно, совершенно» < гар. *тӓмāм* id. ← *тмм* «тулы, төгәл булу» тамырыннан. Шуннан ук иск. **тамм** «бөтенләй; бөтен, тулы куәтендә», **тәммәт** «эпилог, соңгы сүз (китапта)».

Дерив.: **тәмамла-у; тәмамлык** (грамматикада).

**ТӘМӘКЕ,** диал. (Радлов III: 1130, 1120) **тәмәкү** «табак» < госм. *тамаку,* гом. кыпч. *тәмәкә, тамақа, тамеки* һ.б. (һәрвакыт *-м-* белән), төркм. *тәммәкә*, фар. *тӓнбакӯ* һ.б. (күп телләрдә). Бу сүз тат. теленә Шәрыктән килгән (рус. *табак* исә ним., фр. телләреннән). Ахыр чиктә ул Гаити утравының индиан телләренең берсеннән (тайно) таралган (к. Kluge: 902).

Мар., удм. *тамак, тамаки, тӓмӓк* < тат., чув. *тапак* < рус., чув. *тамкӑ* << алт., хак. *тамкы* һ.б. аерым бер чыганактан, к. Räsänen 1969: 459. Тунг.-маньч. *дамга*, яз. монг. *tamakin* «тәмәке» тур. к. ССТМЯ I: 195. К. ш. ук Тимергалин: 454 (бик тәфсилле).

Дерив.: **тәмәкече, тәмәкечелек; тәмәжник** (русчаданмы?).

Шәрык илләрендә тәмәке тарту гөнаһка исәпләнми. Татарларда электән катган тыелган (к. М. Колыйда: *Шайтан шөгыледер, бел, тәмәке*). Русларда да XVIII г. кадәр тыелган булган.

**ТӘМӘЛ** иск. (Будагов I: 377) «основание (деревни, крепости); постоянное место жительства; происхождение» < төр., кр.-тат. һ.б. *temel* < грек. *temelion* id. Бу сүз хәз. тат. теленә дә бик ярап куяр иде (чөнки **чыгыш** сүзе артык күп мәгънәле).

**ТӘМБӘЛ** (ДС I: 194) «лентяй» < уйг., төркм. һ.б. *тәнбәл,* төр. *tembel* id. үзб. (ЎХШЛ: 281) *тәммәл* «сөмсез, тупас» һ.б. < фар. *тӓмбӓл* id. Гомумән – ачык түгел.

**ТӘМДӘК** (Тумашева 1992: 206) «тамга, бирка» ~ алт., хак. *темдек, тӓмдӓк,* тув. *демдек* «билге, значок» < бор. төрки **temläk* (←*temlä* «билгеләү, бикләү», к. ДТС: 551) >> рус. *темляк* «кылыч кынына тагылган билгелек, чук». Рус сүзен тат. *тәмлик* сүзеннән дип аңлату (Фасмер IV: 40) бик төгәл түгел, чөнки беренчедән, андый сүз безгә очрамады, икенчедән, татарча **тәмләк** булыр иде. Гомумән, *тәмдәк* варианты, әлбәттә, **тәмләк*тән килеп чыккан (башкортчарак вариант). Сүзнең тамыры – **тәм* < **тэм* «билге итеп бәйләнгән элмәк, киндерә». Чаг. **Тимгел, Тимрәү.** Рус. *темляк* (күпмәгънәле сүз) тур. Аникин: 545.

**ТӘМИЗ** кит. «чистый, опрятный; добротный, добротно; качественный; безупречный, безупречно» ~ добр. *temĭz*, төр. *temiz* < гар. *тӓмӣӣз* «сайланып алынган; аеруча сыйфатлы». К. Будагов I: 378.

Дерив.: **тәмизлә-ү** «кондициягә җиткерү; яхшылап редакцияләү».

**ТӘММУЗ** иск., кит. «июльская жара» < фар. *тӓммӯз* id., төр. *temmuz* «июль» (Шәрыктә үзенчәлекле Сурьяни – Сурия календареннән гарәп теле аша таралган сүз).

**ТӘМСИЛ** «употребление, сравнение; краткая притча в литературном произведении», «сравнительный оборот (в грамматике)» < гар. *тӓмҫӣл* id. **мисал** сүзе белән тамырдаш.

**ТӘН** «тело» < фар. *тӓн, тан, тӓне* < авест. *tanu* id., к. Абаев III: 261. Бу сүз гар. теленә дә кергән.

Дерив.: **тәнле, тәнсез; тәнчек** (рус. *тельце* сүзеннән калька).

**ТӘНӘ I, тәна** (ТТДС I: 438, миш.) «вот то» ~ алт. (Баскаков 1972: 74) *тене, тени,* уйг. *тәнә, тана* id. < *тә+на* (кушма сүз; тәфсилле аңлатманы к. Махмутова: 238–239). **Тә, та** барча телләрдә диярлек билгеле булган күрсәтү алмашлыгы, к. **Теге.**

**ТӘНӘ II, тәнәй, танай** (ЗДС: 618; БТДҺ: 349) «младенец; обращение к младшим» каз., кырг. *тана, танай* «акыллы» (чаг. тат. сөйл. **акыллым** – балаларга эндәшү сүзе) < фар. *дана* «акыллы», *данайи* «акыллы булып туган». Хәер, мәзкүр тат.-башк. сүзенә чыганак булырлык бүтән сүзләр дә бар, мәс., төр. *tena* < фар. *тӓнһā* «бердәнбер (бала һ.б.)» яки гом. һинд-евр. *dhenu* «имезәк». К. **Тана**.

**ТӘНӘЙ-Ү, тәнә-ү, тинә-ү** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «отдыхать, восстанавливать силы (о поле,

о женщине после родов)» << монг., тунг. *тэний-* «бөгелгәч тураю, аякка басу» ← *тә̄н, тә̄ң* «тигез, туры» сүзеннән (к. ССТМЯ II: 235). Кр.-тат., төр. телләрендә *dene-* «сынау; аермасын белү», *denel-*, *denen-* «сыналу», *denet* «фәнни тәҗрибә», *deney* «эксперимент» сүзләре дә *тәнә-ү* белән гомоген шикелле. Чаг. башк. (БТДҺ: 348) *тәңклә-ү* «тигезләү, турайту, таслау». К. ш. ук **Тана-у, Тинә-ү.**

Дерив.: **тәнәйт-ү** «торгызу, реконструкцияләү» – ошбу китапта бу сүз шул мәгъ. кулланыла.

**ТӘНӘФЕС** «перерыв; перемена < гар. *тәнәффус* id., гомумән «сулыш алу» ← *нфс* «сулыш алу». К. **Нәфес.**

**ТӘНДЕ-Ү, тәне-ү,** себ. (Тумашева 1992: 206) **тәнде-ү, тәне-ү** «скитаться; бездельничать; блуждать» < гом. төрки *тэнти-, тэни-* id. К. ш. ук добр. *tent-, tenti-, tentik-* «аптырап әйләнгәләп йөрү». Уйг., алт. *tänä-*, тув. *тент-*, монг. *тэну-* һ.б. «бушка, тик йөрү» Räsänen 1969: 479. К. **Тинтәк.**

**ТӘНКӘР** иск. «конкурс, отбор», «приёмные экзамены» < гар. *тäнкäр* id. Казан мәдрәсәләрендә XIX–XX гг. **тәнкәр** уздырыла торган булган.

Дерив.: **тәңкәрлә-ү** «сайлану; талымлау» (к. ТТАС III: 222).

**ТӘНКЫЙТЬ** «критика (особенно – литературная)» < гар. *тäнкӣд* id. ← *нкд* «кимчелекне күрсәтү».

Дерив.: **тәнкыйтьчән, тәнкыйтьчел; тәнкыйтьче; тәнкыйтьлә-ү** һ.б.

**ТӘҢӘ-Ү** диал. (ЗДС: 618) «аккуратно уложить, завязывать» ~ башк. *тәңклә-*, каз. *теңде-*, кырг. *теңе-* һ.б. id. ← башк. *тәңк*, каз. *тең*, кырг. *тәң* «кием-салым, ястык һ.б. төргәге», «төрү тәртибе»; уйг. *таң-, тәң-* «бәйләү, баглау; тагу». Чаг. **Тагу, Таң-у I.**

Чув. *тенкĕл* < тат. **тәнгел* «күчәр» ← *тәң-* «бәйләү» булса кирәк.

**ТӘҢГӘЛ** «соответствует, корреспондирует», диал. (Рамазанова 1984: 110; ТТАС III: 239) «ровная долина», себ. (Тумашева 1992: 211) **тиңәл** «тиң»; тат. теленең күп кенә сөйләшләрендә **тәңкәл** «табурет; терраса» > чув. *теңкел, тенкĕл* id., мар. (Упымарий: 204, 209; Саваткова: 163) *тäңгал* «янында, тирәсендә» (*тäңгäл тол-* «тап булу»), *теңгыл, тöнгыл* «эскәмия», удм. (Насибуллин: 139, 142) *тäңгäл* «вертикаль», *тэнгыл* «стена буендагы сәке» һ.б. ~ каз., кырг. диал., төркм. *деңгел* «тиң, бердәй» (*деңгей* «кимәл», *деңгек* «шобага»), тув. *деңкел* «кимәл, тиңлек» < монг. *тэңкэл* «тигезлек, тиңлек, симметрия» (*тэң-кэл*) гом. төрки, монг. *тэң* «тиң» сүзеннән. Чаг. ш. ук эвенк. *тэңкэл* «ике як яр», *тэңкил* «тиңнәр» һ.б. Федотов II: 207 (материалы аз).

**ТӘҢКӘ** «монета; рубль» > удм. *тенке, танка*, мар. *тäнга* ~ бор. тат. (Мөхәммәдьяр телендә, XVI г.) **дәңге** > чув. *тенкĕ*, мар. *теңге, тэнгы*, удм. *тэнкы* ~ чыгт., уйг. *тәңгә,* алт. *тäңкä, теңке*, каз., төркм. *теңге* ~ монг. *тэңкэ* «тәңкә, сум; көмеш тәңкә» (төрле төбәкләрдә бу сүзнең мәгъ. үзенчәлекләре бар), фар. *тäңге, тäңгä,* иске монг. *teŋge* «көмеш тәңкә» һ.б. Гомумән, бу сүз Азиядә бик киң таралган, охшаш сүзләр Һиндустан ярымутравындагы телләрдә дә очрый. Сүзнең чыгышы бәхәсле, күпчелек этимологлар аны иске фар. *данаг* < бор. фар. (грекча язылышында) *δαναχη* «тәңкә» сүзеннән дип карыйлар; индонез. *tanggah* – «бор. фарсы тәңкәсе» < фар. *даңги гаһ* «гади (йөрештәге) тәңкә» (шуннан ук иске монг. *tengah* «металл акча, тәңкә») дип аңлатыла; урта гасырлар фар. телендә *dang* «дирһәмнең дүрттән бер өлеше» (к. Поппе 1938: 138), *daneg, danake, danik* – төрле өлкәләрдә төрле тәңкәләр. **Тәңкә** һәм **тиен ~ тин** сүзләренең багланышы бик шикле.

Иске тат. **дәңге, дәңгә** рус. *деньга* сүзенең чыганагы булган булса кирәк; рус теленнән бу сүз русларга күрше күп кенә телләргә кергән (мәс., фин. *tenke,* эстон. *teng* һ.б.). Будагов I: 381; Фасмер I: 499; Doerfer II: 587–589; ЭСТЯ III: 180; Федотов II: 207–208; Аникин: 181 (бу китапларда арытабангы мул әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **тәңкәле; тәңкәлек.**

**ТӘҢРЕ** «бог, тенгри» ~ гом. кыпч. *тэңир, тэңири*, к.-балк. *тәйри*, уйг. *тәңри* «тәңре», алт. *теңери* «күктәге, Алланыкы», хак. *тигĕр* «күк» ~ монг. *тэңэр, тэңри, тэңэри* «күк; тәңре». Бу сүзнең веляр варианты да киң таралган: чув. *турă* < *торă* < болг. **торы* ~ төр., аз., төркм., кар. *таңры*, як. > тунг. *таңара, таңгара* «тәңре; икона» (к. ССТМЯ I: 162). Алт. *теңери* «күк», ә *танары* «тәңре». Тув. *тээр адам, чер ием* «тәңре атам, җир анам» диелә. Бу сүз тур. фикерләр бик төрле (к. Федотов II: 252–253). Безнеңчә, якут филологы Н.К. Антоновның (1971: 123–127) *тэңри* < *таң эри* «таңбатыр» дигән фикере игътибарга лаек. Бор. Кытай чыганакларында хәз. Алтай тирәләрендә

*po teng-ninig-li* «җир тәңресе» таулары булган (Die chinesischen Nachrichten zur Geschichte der Ost-Türken: 42), моны *Бор (бур) таңның эри* дип аңларга мөмкин. Палаталь һәм веляр вариантлар булу *таң эри* «таң ире» тәгъбиренең бер телләрдә палаталь (*эри* – доминанта сүз), икенчеләрендә веляр (*таң* – доминанта сүз) яңгыраштa булып берегүеннән килә. **Тәңре** сүзен кыт. *thiān* «күк», *thiānlu* «күк акылы» дип аңлату да бар, к. Будагов I: 370. М. Рясянен буенча (Räsänen 1969: 474), төрки *тэңри* < кор.-кыт. *thjen li* «язмыш тәңресе». **Тәңре** < *тэңри* сүзе хакында бүтән фаразлар тур. к. Жубанов, Ибатов: 314–337; МНМ II: 500–501.

Дерив.: **тәңречелек.** К. ш. ук **Тәре.** Чаг. түбәндәгене.

**ТӘҢСӘЛ-Ү, тәңзәл-ү** (Тумашева 1992: 207) «вставать на дыбы (о лошади)», **тәңзәлт-ү** «качать; колебать», себ. (Будагов I: 370) **тиңсәлмәк** «чайкалу, тулкыну», **тиңсәү** «җиңелчә дулкынлану, тирбәлеш», **тиңсәлдермәк** «тибрәтү, тирбәтү», аннан күпкә алданрак нәшер ителгән Гиганов сүзлегендә *тинсәләмен* «колебаюсь».

Бу сүзне бор. төрки (ДТС: 551–552) *teŋ-, teŋi-, teŋil-* «югары күтәрелү, очып китү» (шуннан *teŋäk* «күк; һавалар», *teŋit-, teŋtür-* «һавага җибәрү, очыру») сүзе белән чагыштырып карарга ярыйдыр. Әгәр бор. төрки **тәң* «болытлы күк» кебек сүз табылса, бу мөмкин. Шул *teŋil*-фигыленнән бор. төрки *tenälgün, tenälgüč* ~ төр. һ.б. ядкәрләрдә (к. Мухамедова 1973: 167) *дүләңңәч, дөвленгеч, делүгеч* «тилгән» сүзе ясалган. К. **Тилгән.** Чаг. **Диңгез.**

**ТӘП I** «щепка; колышек или камень и т.п., которые ставят на землю при планировке участка, замерах земли», «положение альчика стоймя, при котором игра считается ничейной», «игра, которая состоит в быстрейшем выщёлкивании шашек из шашечной доски» (к. ТТДС I: 437) < башк. *тап* id. ~ бор. монг. *tab* «тәп, чөйкадак, заклёпка», маньч. *таба* «тәп». ССТМЯ I: 149.

**ТӘП II: тәп-тәп** – подражание быстрым шагам маленького ребёнка, частым, но несильным ударам твёрдым предметом по твёрдому. К. **Тап: тап-тап.**

Дерив.: **тәпелдә-ү,** к. **Тәпи.**

**ТӘПӘН** «кадочка; бочонок мёда» > мар. *тäпäн* id. ~ каз. (ҚТДС: 328) *тепем* «тәгәч, агач савыт» < бор. уйг. *тәги пәнд* «төбе җәенке (савыт)» сүзеннән (*тәг* «төп», *пәнд* «җәенке, яссы, лапакай»): тәпәннең төбе авызыннан киңрәк булучан. К. **Тәбәнәк, Тәпәреш.**

**ТӘПӘРЕШ** диал. «коротыш, сморчок» ~ башк. (БТДҺ: 350) *тәпәрез, тәпәриз* id. < уйг. < фар. *тәги пәрһиз* «ачлык, ураза тоту нәтиҗәсе» сүзеннән (*пәрһиз* «ураза; аскетлык») булса кирәк. Чаг. каз. *тепеpiш* «кыенлык, авырлык». Кр.-тат. *tepĭreš, tepreš* «сәхрәдә гизү» < гар. *teferrüc* id. дип аңлатыла, к. Dobr. III: 322.

Башкортстанда **Тәпәреш** дигән берничә авыл бар. Аларның аталыш мотивациясе билгесез.

**ТӘПӘ-Ү, тәпәлә-ү** «мелко, но резко бить, мелко рубить; тяпать» ~ башк. (БТДҺ: 349) *тәпе-* – *тәп-тәп* тәкълиди сүзе нигезендә (ихтимал, рус сүзе тәэсирендә) килеп чыккан. Иске тат. (Радлов III: 948) *тäнё-*, госм., аз. *тәпәлә-* «башка сугу» ← *тәпә* «баш түбәсе». Чаг. ш. ук **Түбә → Түбәлә-ү.**

**ТӘПӘЧ** «боёк цепа» ~ башк. (БҺҺ II: 272) *тәпәс, тәпес* «тәпәч, чабагач» ← **тәпә-ү**. Бу сүзнең ясалышында да рус сүзләренең (*дубец, тяпа* «чабагач тәпәче» һ.б.) тәэсире сизелә шикелле. К. ш. ук мар. *топец* «тәпәч» ~ чув. *тăпач, тăпаçă* «чабагач». Федотов II: 193.

Дерив.: **тәпәчле; тәпәчлек, тәпәчлә-ү.**

**ТӘПИ** диал., башк. (БТДҺ: 349) **тәпәй** «ножка ребёнка; лапа, лапка (кошек, собак)» – *тәп* тәкълиди сүзеннән; гомумән, шуңа охшаш сүзләр бөтен дөньяда билгеле: алт. *табаш*, як. *табагай*, монг. *тавхай*, гом. герм. *tappe,* ним. *Tatze* ~ ит. *zampa*, рус. *лапа* һ.б. (Пекарский III: 2510)

Дерив.: **тәпилә-ү; тәпи-тәпи** (йөрү).

**ТӘПКЕ, тяпка** (ЗДС: 607, 619) «тяпка, мотыга» < рус. булса кирәк.

Дерив.: **тәпкелә-ү.**

**ТӘПСЕРЛӘ-Ү, тәпсенлә-ү** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «дотошность; дотошно объяснять или проверять» < әд. **тәфсирлә-ү.** К. **Тәфсир.**

**ТӘРӘЗӘ,** диал. (ДС III: 155; ТТДС I: 439; Ногман: 101; Тумашева 1969: 207, 211 һ.б.) **тәрзә, тәрәз**, миш. **тирәз, тирәзә,** себ. **тәрәчә, тәрәс, тирәс**, иске тат. **дәрицә** «окно» ~ башк. *тәрҙә* **>** *тәҙрә* < гом. кыпч. *тэрэзэ* (кар. *тэрэджэ* > *тэрэдзэ* > *тэрэзэ*), төркм. (ТДГДС: 77) *дереч̧е, дережҫе [дэрэҗә]* < фар. *дäрӣчä* «кечкенә ишек, тәрәзә, төннек»

(*дäр* «ишек» сүзенең кечерәйтүле вариантыннан) > төр. *deriçe* id.

Бу сүзнең үзенчәлекле вариантлары – чув. (Сергеев 1971: 149) *чүрече [чүрэҗә], түрече, төрече,* мар., удм. *төрзä* < болг. **төрэҗә* < **торажҗа* < кар. *таражҗа* турыдан-туры бор. кыпч. сөйләшләреннән. Гомумән, бу сүз кыпчак-куманнарның Иртеш буйларында яшәгән чорларында Урта Азия телләреннән алынган, к. кырг. *дарча, дарыча* «кечкенә тәрәзә, төнлек», алт. (Радлов III: 1063) *тäрäзä* «төрмә (!)», куман. *тереč* «балкон», «Йосыф китабы»нда *дәрәҗә, дәрчә* «тәрәзә» < уйг. *деризә,* үзб. *дераза, дарча,* үзб. диал. *дәричә, дарича, тәрәчә* «тәрәзә». Кыпчак телләреннән бу сүз күрше (фин-угор, Кавказ һ.б.) телләренә дә кергән.

Фонетик үсеше сүзнең хакас-алтай тибындагы консонантизмга (сүз башында барча тартыкларның саңгыраулашуы, ә интервокаль позициядә яңгыраулашуы) ишарә итә; *-ч-* > *-җ-* > *-з-* үсеше исә мишәр тибындагы шивәдә пәйда булган. Zenker I: 1866; Räsänen 1969: 475; Абаев I: 627; Федотов II: 428; ЎХШЛ: 84.

Дерив.: **тәрәзәле, тәрәзәсез; тәрәзәлә-ү; тәрәзәчек.**

**ТӘРӘККЫЙ, тәрәккыят** «прогрессивный; прогресс; развитие» < гар. *тäраққӣ, тäраққийāт* id., к. Будагов I: 350. Бу сүз элекке әд. телдә киң кулланылган.

**ТӘРӘП** «очёски льна; кудель» (бу сүз диал. **тәрәплә-ү** «тәрәшләү»; **тәрәпәч** < *тәрәп агач, тәрәпагас, тәрәп такта* «каба, тәрәшле каба» һ.б. тәгъбирләрдән – к. ТТДС II: 316; БТДҺ: 350 – күренә) < рус. диал. *трепь, терёб* id. (*тәрәплә-ү* ≈ *теребление*). Татар тукучылыгы лексикасында рус сүзләре еш кына очрый.

**ТӘРӘТ** сөйл. «омовение; испражнение» < уйг. *тәрәт* < гар. *ṭаһāрат* (к. **Тәһарәт**). Бу сүз, күрәсең, татарларга Алтын Урда чорында таралган.

**Тәрәт** продуктив нигез: **тәрәтлән-ү, тәрәтле, тәрәтсез** һ.б.

**ТӘРӘЧ** «тресь, треска» < рус. *тресь*. Асылда – «йомычка», к. Фасмер IV: 100.

**ТӘРӘШ** «мочка (льняная), пучок льна или шерсти; пакля; шерстобитка; чага (гриб)»; иск. «средство для удаления волос» (к. ЛТ I: 126) > мар. (Исанбаев 1978: 43) *тараш, тäраш* < уйг., үзб., төркм. *тараш* «тәрәшләү, юну, кыргычлау, чистарту» < фар. *тараш* «тәрәшләү; юну» < авест. *thwareš* id. (Platts: 315), к. ш. ук кырг., үзб. *тараша* «йомычка; щётка», төр. *taraz olmak* «тетелү, тәрәшләнү», (БТДҺ: 306, 350) *тараш* һәм *тәрәш* (бердәй мәгъ.) «киндераш; каен гөмбәсе; энәкарак», төр., гаг. *тараш* «камыл», *тараз* «көнҗәлә чүбе» һ.б. К. **Тәрәшле.**

**ТӘРӘШЛЕ,** иск. (Радлов III: 843, 1064) **тарашлы** «мочка льняная» тәүдә «чистартылган» мәгъ. булган булса кирәк; ш. ук *тәрәшлек* < *тарашлык* сүзеннән дә була ала. Гомумән, **тәрәш** < *тараш* һәм *тәрәшле* < *тарашлы* сүзләренең тарихи мәгъ. үсеше аңлашылып бетми. Һәрхәлдә *тараш* «тарау (нәтиҗәсе)» сүзе белән турыдан-туры багланмаганнар, ә фар. *тäрāш* сүзеннән киләләр.

**ТӘРБИЯ [тәрбийә]** «воспитание; культура (поведения; обработки продуктов)» ~ башк. *тәрбейә* < гар. *тäрбийä* id. Будагов I: 348.

Дерив.: **тәрбияле, тәрбиясез; тәрбияләү; тәрбияче** һ.б. (**тәрбия** – тат.-башк. телләрендә иң киң кулланылган гар. сүзләренең берсе).

**ТӘРЕ I** диал., **тире** (ТТДС I: 438; Юсупов 1979: 182; БТДҺ: 318, 350) «до (чего)» ~ чув. *тери* < чыгт. *тэгру*, як. *диэри* id. ← бор. төрки *teg-* «тию, җитү» сүзеннән.

**ТӘРЕ II** «христианский крест; икона» (*тәре баганасы* «икона на дорогах»), диал. (м.-кар.) **тәйре** ~ к.-балк. *тейри* «бог неба, гром» < бор. кыпч. (> алт., шор.) *тäгрі* id. (к. Радлов III: 846) < гом. төрки монг. *тэңри* (к. **Тәңре**). **Тәре** сүзе мар., удм. һәм чув. сөйләшләрендә дә (сүгенү сүзе буларак) кулланыла.

**Тәре < тәйре** сүзе тат. теленә христиан кыпчаклардан (Алтын Урда дәверендә шундыйлар да булган) килеп кергән. К. **Тәрегәр.**

**ТӘРЕГӘР, тәргәр** «главный священник у тюрок-язычников» (к. себ. *...Хатыны патша булып, үс халкына тәрё биреп, үлкән тәргәр булды...* к. Радлов. Образцы IV: 411; Д. Тумашева монда *тәре* «дару», *тәргәр* «табип» дип аңлата, хәлбуки «үз халкына *дару биру*» гайре табигый сүзтезмә, бөтен халык авыру булалмый ич!) < бор. төрки *täŋrikär, teŋrikän* (к. ДТС: 552) «баш рухани»; кырг. (к. Будагов I: 546) *тэргэр* исә < фар. *дарук'ар (дарукяр)*, чыннан да, «аптекарь, имче». Бу сүзне себ.

татарлары элекке *тәңрекән* мәгъ. аңлаганнар булса кирәк.

**ТӘРҖЕМАН** «переводчик (при переговорах), толмач, драгоман» < гар. *тäрҗӯмāн* id. < Мисыр гар. *тäргимāн* > иске төр. *дәргиман* > рус. (фр. теле аша) *драгоман* id. К. **Тәрҗемә.**

Дерив.: **тәрҗеманчы** (атаклы «*Тәрҗеман*» газета позициясендә торучы).

**ТӘРҖЕМӘ** «перевод (текста)» < гар. *тäрҗäмä* < *тäргäмä* id. ← *ргм* «яңгыравык, кайтаваз» тамырыннан, к. ш. ук иске тат. **мөтәрҗәм** «тәрҗемә ителгән», **мөтәрҗим** «тәрҗемәче» (икесе дә гарәпчәдән). К. **Тәрҗеман, Тәрҗемәи-халь.** Будагов I: 348–349 (бу сүзләр асылда яһ. теленнән таралган ди).

Дерив.: **тәрҗемәче, тәрҗемәчелек.**

**ТӘРҖЕМӘИ-ХАЛЬ** «биография, автобиография» < фар. *тäрҗимäи халь* id. (гар. сүзләреннән фарсыча ясалган).

**ТӘРКИП, тәркиб** иск. «чернила», «состав; смесь; фразема» < гар. *тäркӣб* id. Будагов I: 351.

**Тәркип** сүзе иҗтимагый-сәяси мәгъ. кулланылмаган һәм *состав* сүзен өлешчә генә алмаштыра.

**ТӘРСӘНӘ** тар. (Гиганов сүзлегендә һ.б.) «арсенал» < гар. *дāр äс-ҫанā‘а* «остаханә, сәнәгатьханә» сүзеннән; шуннан ук фр. *d'arsenal* (французлар *д-* авазын үзләренең *d'* кисәкчәсе итеп уйлаганнар һәм ул *d'*не ташлагач *arsenal* > рус. *арсенал* килеп чыккан). Чаг. төр. *tersane* «верфь». Kluge: 62.

**ТӘРСИМ** «общий чертёж, абрис; краткая обрисовка» < гар. *тäрсӣм* id. к. **Рәсем.**

**ТӘРТӘ** «дышло, оглобля», диал. (ДС II: 195; БҺҺ II: 273 һ.б.) **тәртнә** < *тәртәнә*, иске тат. *тарта* > мар. *тарта* > *торта*, чув. *торта* > *турта*, удм. *турто* id. ← *тарт-*. К. ш. ук каз. (ҚТДС: 190) төркм. *дәрте* id., себ. (Тумашева 1992: 207) **тәртнә**, эчк. (ТТДС I: 439) **тәртмә** «кечкенә чана». К. Радлов III: 860; Федотов II: 254 (тат. *тарта* сүзен искә алмый). К. **Тәртешкә.**

**ТӘРТЕШКӘ** (ДС I: 195) «кочерга, черенок кочерги», к. ш. ук **тәртешке** «гребок на току» (ТТДС I: 439), **тәртүшкә** «кочерга» (ТТДС I: 439; Тумашева 1961: 211), **тәртәшкә** «укрюк» (ДС II: 196) ← *тарт-у*, әлбәттә; к. ш. ук чув. *турчка* < *торчка* < **тартышка, *тартышкы* «кисәү, тәртешкә» (Федотов II: 254).

**ТӘРТИП** «порядок, режим работы» < гар. *тäртӣб* id. ← *ртб* «тәртипкә китерү, тезү, катлау» тамырыннан, шуннан ук **мәртәбә**, иске тат. **рүтбә** «иерархия, чин».

Дерив.: **тәртипле, тәртипсез; тәртиплән-ү; тәртипчел** һ.б.

**ТӘСБИХ** «восхваление Аллаха (повторением одних и тех же выражений); чётки» < гар. *тäсбӣх* id. ← *сбх* «туктаусыз мактау; (хыялда) йөзү» тамырыннан. К. **Дисбе.**

**ТӘСЕ** диал. (Тумашева 1992: 207–208) «корма лодки; челнок (в ткачестве)» < фар. *дäстӣ* «руль; кулса» ← *дäст* «кул» (чаг. **Тастымал**); к. ш. ук башк., тат. (БТДҺ: 350; ТТДС II: 350) **тәсәй** «уенчык» < фар. *дäстһаи* «уенчыклар (кулчыклар)». Чаг. **Тәте.**

**ТӘТӘЙ I, тәтә** (Рамазанова 1991: 164–165; БТДҺ: 351) «двоюродная тётя», иск. (Г. Тукайда) «проститутка» ~ нуг. *тäтäй* «әби; дәвәни», каз. *тәте* «апа», уйг. *тәтәй* «мадам; бикә» ~ удм. *татай* «апа», морд. *тядяй, тядякай* «анакай, әнкәй» һ.б. – ымлык нигезеннән ясалган сүзләр (шуның шикелле, әмма ирзатларны белдерүчән сүзләр дә төрле телләрдә очрый, мәс., тат. диал. (ЗДС: 622) **тәтә** «әти, дәвәти» ~ чув. *тете* «абый; агай», рус. *тятя* «әти»). Федотов II: 209–210.

**ТӘТӘЙ II** «игрушка» к. **Тәти.**

**ТӘТӘЛ, тәтәле** (ТТДС I: 440; ТТАС III: 232) «поплавок или грузило невода; невод» ~ чув. *тетел,* мар. (Упымарий: 224) *тэтэлэ* «җылым төре».

**ТӘТЕ, тәтек** «курок» ~ нуг., к.-балк., кырг. *тетик*, төр. *tetik* id., ш. ук «күчәр, кендек; шкворень; механизм өлеше, шөреп»; чаг. ш. ук тат. диал. **тәтек** ~ чув. *татӑк* «кисәкчек, кисәкчә; деталь». Гар. *тäтäк* «тәте» < төр. Чаг. фар. *дäсти, дäстäк* «кулса», *дäстик* «кулчык». Федотов II: 180–181 (чув. *татӑ, татӑк* «тәте, тәтек» сүзен **тет-ү** < *тит-* сүзе белән баглый, безнеңчә, бу нигезсез фараз).

**ТӘТЕК,** диал. (ЗДС:63) **титек** «маленький ростом, но ловкий, юркий», чыгт., төр. *tetik* id., уйг.

*тәтик*, бор. төрки (ДТС: 56) «зирәк, уңган» ← *tet-* «каршылыкларны җиңү».

**ТӘТЕР** (трбс.) «рослый и неуклюжий (при небольшой голове)» ~ бор. төрки (ДТС: 254, 264) *tetir, titir* «кәрван дөясе (токымы)»?

**ТӘТЕ-Ү** «достаться (о хорошем, завидном)», тат. диал., башк. (Арсланов 1988: 94; БТДҺ: 350), **тәте-ү,** каз. *тәте-* (уйг. *тәти-* «(нәрсәнедер) эшләп һ.б. карау, тоту» < **таты-у** (к.). Күрәсең, тат. телендә палатальләшү процессында ясалган яңа тамыр. Ихтимал, монда уйг. *тати-мақ* «тату, кичерү» фонетик вә мәгънәви транзитив форма ролен үтәгәндер. Чаг. ш. ук төр. *dedik* «дигән, аталган» яисә *degdik* «тигән».

**ТӘТИ, тәтәй, тәтә, тәттә** в детском языке «игрушка-побрякушка; куски фарфора, цветного стекла; красивый, яркий, цветистый», «цветок» ~ чув. *тетте, чечче* id.; каз. *теттей, титтей*, тат. диал. (ДС III: 99) **титек** «кечкенә генә». Балалар телендәге ономопоэтик сүз (мисаллары күп телләрдә табыла).

**Тәти** сүзе ироник мәгъ. өлкәннәргә карата да кулланыла (мәс., *тәти егет, тәти кыз* һ.б.ш.).

**ТӘҮ [тәw]** «начальный, первый» < бор. төрки (Радлов III: 1014, 1028) *тäг,* уйг. *тәк*, кырг. *тек, тәк* «чыгыш; нәсел; төп». Бу сүзне префикс итеп куллану күзәтелә: **тәүбилге, тәүтапкыр** һ.б. (рус. *пре-* урынына).

Дерив.: **тәүге; тәүләп** (→ **тәүләпке**).

**ТӘҮБӘ [тәwбә]** «раскаяние; покаяние» > мар. (Исанбаев 1978: 48) *тäубä* << гар. *тäwбä* id. Бу гар. сүзенең тәүдәрәк төрки телләргә кергәне – кырг. *тобо* ~ чув. *тупа* > удм. *тубо*, морд. *тоба* «ант; тәүбә». Федотов II: 248–249.

Дерив.: **тәүбәле, тәүбәсез; тәүбәлә-ү** (барысы да сирәк очрый), **тәүбәче, тәүбәчел.**

**ТӘҮЛЕК [тәwлĕк]** «период времени; сутки», диал. (ТТДС I: 441) «год; годовщина» > мар. кч. *тäулук* ~ каз., к.-калп. *тәулик, тәулĕк*, чыгт. (Радлов III: 1127) *тäвлук* id. Чув. *тавлăк, тавăк, талăк* «тәүлек (көн һәм ел тәүлеге)» > мар. (Саваткова: 153, 156) *тäлык, талык, талук* «ел тәүлеге» бор. тат. теленнән булса кирәк, тат., башк. *тәүлек* исә бор. кыпч. **тәулик* < **тәглик,* **тәглүк* «түгәрәк» сүзеннән (чаг. тат. сөйл. *ел түгәрәге = ел тәүлеге*), к. үзб. *тевлиг* «чагарак» (к. ЎХШЛ: 247). Хак. *теглек,* алт. *теглек, тегилек, теглегеч* «түгәрәк». Сүзнең тамыры **тәү* < **тәг* «түгәрәк; нуль (!)» сүзеннән. к. ш. ук себ. **тәүлә-ү** «һавада әйләнеп йөрү», **тәүләгән, тәүләткән** «тилгән». К. **Тәгәрмәч, Тилгән.** Егоров 1964: 229; Räsänen 1969: 468; Федотов II: 168–169 (тат. теле материалы дөрес бирелми).

Дерив.: **тәүлекле, тәүлексез; тәүлекләп.**

**ТӘҮМӘК [тәwмәк]** (ЗДС: 623) «габарит», **тәүмәклек, тәүмәле, тәүмәлле, тәүмәлеге** «величиной с…», **дәүлек, дәүмәлек** (ЗДС: 116–117) «үлчәм». **Тиң ~ тәң** һәм **дәү** тамырларының контаминациясеннән килеп чыккан сүзләр булса кирәк. Чаг. каз. (ҚТДС: 86) *дәүлең* «хәл; чама».

**ТӘҮФИКЪ [тәwфик]** «благочинность; благонравие» < гар. *тäwфӣқ* «тәүфикъ, гармония» ← *wфқ* «тиешле, ярыйсы дип табу, хуплау, килешү» тамырыннан, шуннан ук к. **Иттифак, Муафикъ.**

**Тәүфикъ** продуктив нигез: **тәүфикълы, тәүфикъсыз, тәүфикълан-у** һ.б.

**ТӘҮХИТ, тәүхид [тәwхит]** «единобожие, догмат о единственности и единстве Аллаха» < гар. *тäwхӣд* id.

**ТӘХЕТ** «престол» < фар. *тахт, тäхт, тахта* «тәхет, диван, пьедестал» бор. ир. *takh* «чабу, кисү, юну, шомарту» фигыленнән ясалган (Platts: 313, 318); **тәхет,** асылда, *такта* һәм *тахта* сүзләре белән бердәй.

**ТӘҺАРӘТ, таһарәт,** диал. **тарәт, тәһрәт, тәрәт** «ритуальное омовение; ритуальная чистота» < гар. *ṭаһāрат* id. ←*ṭһр* «чистарту, пакьләү» тамырыннан. К. **Тәрәт.**

Дерив.: **тәһарәтле, тәһарәтсез, тәһарәтлән-ү; тәһарәтханә.**

**ТӘШВИШ [тәшwиш]** «смущение, беспокойство» < гар. *тäшwӣш* id.

Дерив.: **тәшвишле; тәшвишлән-ү.**

**ТӘШКИЛ** «формирование, составление» < гар. *тäшкӣл* id. *шкл* «формага китерелү» тамырыннан, шуннан ук к. **Шикел**, иске тат. **тәшкиләт** «учреждение; оешма».

Дерив.: **тәшкиллек; тәшкиллән-ү; тәшкилче.**

**ТӘЭМИН [тә'мин]** «обеспечение» < гар. *тä'-мūн* id. *äмн* «ышанычлы булу» тамырыннан, шуннан ук **Әманәт, Әмин, Иман, Имин, Мөэмин** һ.б.

**Тәэмин** нигезеннән гар. > тат. **тәэминат** сүзе ясалган.

**ТӘЭСИР [тә'сир]** «влияние; впечатление» < гар. *тä'çūр* id. ← *äçр* «эз, мөһер калдыру» тамырыннан, шуннан ук к. **Әсәр.**

Дерив.: **тәэсирле, тәэсирсез; тәэсирлән-ү.**

**ТӘЯН [тәйән], тәйен** (ТТДС I: 437; ТТДС II: 314; Тумашева 1992: 206; БТДҺ: 347) «совсем; всегда, то и дело; каждый раз», **тәйән-тәйән** «раз за разом» – **тәгаен** (к.) сүзеннән булса кирәк. К. ш. ук төр. *tayın* «билгеле, билгеләнгән».

**ТЕГӘРҖЕП,** тат. диал., башк. **тегәрйеп** «суровая нитка» < иске тат. *дигәр җеп* «катылган, көчәйтелгән, икеләтелгән җеп» сүзеннән: *дигәр* «икенче; өстәмә, аеруча, супер» < фар. *дигäр* «икенче тапкыр; икенче, бүтән; супер-, өстәмә». Шунысы кызык ки, татарлар соңрак аны *тегәр җеп* дип аңлаганнар (*текмәс җеп* буламы инде?) һәм татар сүзен күрше халыклар шул мәгъ. калькалаганнар: чув. *çĕлен çип* «тегәрҗеп» (*çĕле-* «тегү, җөйләү»), мар. (Иванов, Тужаров: 248) *ургумшүртö* «тегәрҗеп»: *ургум* «тегем», *шүртö* «җеп». Бу мисаллар тат. теленең борынгыдан килгән абруе, тәэсирчәнлеге турында сөйли. К. **Тигәлбар.**

Тат. кием-салым, тегү-чигү лексикасында фар. сүзләре (**бишмәт, мәсти, әдеп, сарпан, тастымал, шал, шәл** һ.б.), шулай ук фар. теленнән калькалар (*чигү* ~ фар. *кашидан* һ.б.) борынгыдан, VI–X гг. бирле килә.

**ТЕГЕ,** диал. (Дмитриева 1981: 187) **теги, тиги** «то, тот, вышеупомянутый; известный общающимся» ~ хак. *тiгi,* кырг., алт., чыгт. һ.б. *тиги, тига* (кыпч. телләрендә сирәк очрый) id. < бор. **тики* < *ти-ки, тэ-ки* id. (алт. диал.) *тэ*, гаг., аз. *та*, төр. *dee,* бор. монг. *te,* тунг. (Рамстедт 1957: 74) *та, тей, тейе* «теге; әнә» һ.б. (*та//тэ* тамырыннан бик күп мисалларны к. ССТМЯ II: 165–167, 204); төрки телләрдә (каз., алт. һ.б.) *ту//тү* «теге». Гомумән, бу тамыр дөньядагы барча телләрдә бар һәм балалар тәтелдәвеннән килсә кирәк, к. фин-угор *та//тä* (морд. *тя, те*) «теге, әнә, бу», рус. *та, то* һ.б. (к. Махмутова: 238–239), фин. *tuo* «теге», гот. *tojo* ~ санск. *tasya* «бу» һ.б. Мар. *тывэ, тэвэ* «менә, әнә», *тыганьэ* «тегенди, шундый» бор. тат. теленнән булырга мөмкин. К. **Тәнә, Тегеләй, Тегенә, Терә.**

**ТЕГЕЛӘЙ** «туда; таким образом; сомнительно, сомнительный» > мар. (Упымарий: 219) *тыгылай, тыглай* «тәк кенә, сәбәпсез; бозым, тегеләй (итү)», удм. (Насибуллин: 139) *тигълай* «болай (тегеләй) генә, гомумән» < *теге-ләй*. Бүтән төрки телләрдә сирәк очрый.

**ТЕГЕНӘ, тегнә, текнә** (Троянский I: 346) «әнә теге» ~ кырг. *тигине* ~ бор. монг. *tegüni, tūni* «тегенә» (к. Владимирцов: 196). Бу сүз татарчада һәм монголчада үзгәчә ясалган булса кирәк: тат. *тегенә* (*-нә, -на* күп кенә күрсәтү алмашлыкларына өстәмә: *ана//әнә, мона, тәнә* һ.б.; сүз *нә* < *нәң* «ни, нәрсә» сүзе белән бердәй).

**ТЕГЕРМӘН** «мельница» < (дөресе) диал. **тәгермән** id. Бу сүз тат.-башк. сөйләшләрендә гаҗәп күп вариантлы: Урал сөйләшләрендә **тигәрмән ~ тәгәрмән** (*и ~ ә*) пары бар; ул **тәгәрмән* яңгырашыннан килә; **тегермән** < бор. төрки (Поппе 1938: 344, 353; ДТС: 548) *tegirmän*, шуннан ук чыгт. *тäгирмäн, тäкирмäн, тäкäрмäн, тäкүрман*, үзб. *тегирман*; **тигермән** (Тумашева 1992: 208; БТДҺ: 315) < *тэгирмäн* сүзеннән тат. (*э* > *и*) варианты; **тәүермән** (Тумашева 1992: 206) < чыгт. *тäгүрмäн* – типик кыпч. (*-г-* > *w*) варианты; **тегермин** (гәй, к. ДС I: 182) «тегермән» ~ **тәгәрми, тәгәрмәй** (Башкортстанның Яңавыл авылында без теркәдек. – *Р.Ә.*) «тәгәрмәч» < бор. төрки (ДТС: 548) *tegerti* «түгәрәк, тәгәрмәч»; **декермән** (Троянский I: 534) «тегермән» искечә язылыш кына булса кирәк яисә угыз телләрендәге *дäгирмäн, дäкирмäн* «тегермән» (төр. *tegirmen* «тегермән; герле сәгать») сүзенең чагылышы.

Миш., башк. диал. (ТТДС I: 414) **тирмән, тирмин** ~ к.-балк. *тирмен, термен,* кар. *тэрмэн, термянь,* алт. *тäрмäн, тääрбäн*, хак. *тирбэн,* тув. *тээрбе* һ.б. ~ (миш.) *тийĕрмән*, кар. *тэйирмэн* < *тэгирмáн* «тегермән; зур тәгәрмәч» – аерым тарихи изоглосса.

Гомумән, тәүдә *тэгирмäн* «зур тәгәрмәч» (к. нокр. сөйл. **тигермән** «тегермән ташы») – *тэгир-, тэкир-* (тат. диал. *тәкер-*) ← *тэкир-* (тат. диал. *тәкер-*) «әйләнү» сүзеннән (к. **Тәгәрмәч**) *тэг* «түгәрәк» (к. **Тәүлек**) тамырыннан: аның «зур тәгәрмәчле арба» мәгъ. булган (кырг. *тегирмен җек-* «тегермән җигү», гомумән «җигү»). Бу сүз күп күрше телләргә кергән. К. **Тәгәрмәч**. Будагов I:

367–368; Räsänen 1969: 469; Clauson: 486; ЭСТЯ III: 172–173, 176–178.

**Тегермән** продуктив нигез: **тегермәнче, тегермәнлек. Тегермән тарту** тур. к. **Тарт-у.** Чув. *арман* < *авăрман* < **әwермән* «тегермән» – **тәгирмән** сүзеннән калька. Чув. *авăрман авăрать* «тегермән әйләнә» ~ тат. диал. **тәкермән тәкерә** id.

**Тегермән** сүзенең тарихы махсус тикшеренүгә мохтаҗ. Монда азаккы **-мәй ~ -ми ~ -мән ~ -мин** аерым бер сүз булган (гөманымча – фар. *байн* «бәйле, баулы», к. **Бәйнә-бәйнә**).

**ТЕГҮ** к. **Тек-ү.**

**ТЕЕШ-Ү [тĕйĕш-]** (Тумашева 1992: 208) «браться за, начинать (дело)» – тәүдә «ук атуда ярышу» булган ← **тей-, тәй-** «тию, тидерү». К. **Тий-ү.**

**ТЕЗ** «колено» < гом. кыпч., уйг., бор. төрки *тиз* (*tiz*, к. ДТС: 564), госм. *диз*, төркм. *дииз, дыыз,* алт., кырг., каз., үзб. (Радлов III: 1383) *тизә, тизэ* id. ~ чув. *чĕр* < **тĕр* id. Һичшиксез **терсәк** (к.) сүзе белән тамырдаш. *Тер* < *тир* тамырын як. *түсүргäс* «тез» (к. Пекарский: 2926) ~ монг. *türei* «кыныч» сүзе белән дә чагыштыралар. К. ш. ук хак. *тĕзэк* ~ як. *түсэх, түһэх* «тез, тезләр», хак. диал. *тĕзэнэк* «тез, бер тез». Бу форма *тез* < *тиз* сүзенең тәүдә икелек санын белдергәнлеген күрсәтә (**тӣ-з* < **тэг-из* > бор. кыпч. **тәwиз* > як. **түүс* > *түс* ?). Räsänen 1969: 482; ЭСТЯ III: 336.

Аерым дериват: **тезлән-ү**.

**ТЕЗГЕ, тезгеч** «нить, шнур, на которую нанизывают (в частности – рыбу)». К. **Тез-ү.**

**ТЕЗГЕН,** иск. (Троянский I: 529) **дезгин** «узда, уздечка», «вожжи, повода» ~ гом. кыпч., уйг. *тизгин*, төркм., к.-калп., төр., аз. *дизгин*, алт. *тискин*, як. *тескин*, уйг. диал. *тэзгэн* id., к.-балк. *тизгин* «тезем, рәт; юл, сәтыр (текстта)», Котбидә *тäзгин* ~ көрд. *däzgin* id. Чаг. чыгт. *тизгäк* «бер-берсенә бәйләнгән дөяләр рәте» (Радлов III: 1399). К.-балк. һәм чыгт. мисалларыннан чыгып, бу сүзне *тез-ү* ~ *тиз-* сүзеннән дип карарга мөмкин, ләкин фар. *дäст* «кул» сүзе нигезендә дә ясала алган.

*Тезген* < *тизгин* төркиләрдән күрше халыкларның телләренә дә кергән (мәс., рус. диал. *чизгины*). ЭСТЯ III: 220–221 (Э.В. Севортян бу сүзне *тез-* < *тиз-* фигыле белән бәйләми). Аникин: 661.

Дерив.: **тезгенле, тезгенсез; тезгенлә-ү** һ.б. (күч. мәгъ.).

**ТЕЗЕ** (Н. Исәнбәтнең мәкальләр җыентыгында), **тезә** (ТТДС II: 292) «нашейное украшение с подвесками; богато украшенное монисто, ожерелье» ~ чыгт. *тизик*, төр. *dizi*, *дизик,* (Мухамедова 1973: 90) *дүзүк*, тув. *тизиг,* бор. төрки (ДТС: 564) *tizig* id. ← *tiz-* «тезү». Чаг. ш. ук төркм. *дүзүм* «җепкә тезелгән тезем».

**ТЕЗМӘ** сүзгә-сүз «низка» ← *тез-ү*. **Тезмә** «тезү эше» сүзе күп кенә конкретлаштырылган мәгъ. ия, к. диал. (ЗДС: 625) **тезмә** «чәчкап», «түшәм, бастырма»; «текмә, койма», «матча кашагасы», «исемлек». Болар өстәвенә әд. телдә тагын төрле терминологик мәгънәләр, мәс., «шигъри текст», «үзара баглы сүзләр рәте» һ.б. ясалган. Фән әһелләре мондый күп мәгънәлелектән качу юлын табарга тиешләр иде. Бүтән төрки телләрдә алай түгел.

Дерив.: **тезмәле** (күпмәгъ. сүз), **тезмәсез** (ш. ук күпмәгъ.); **тезмәлә-ү, тезмәлән-ү** һ.б. **тезмә сүз** «шигырь».

**ТЕЗМӘЛЕ, тезелмәле** «можно *или* должно составляться в ряд, нанизываться» – **тезмә** сүзеннән түгел, **тез-ү** һәм **тезел-ү** (йөкл. юн.) сүзләре нигезендә ясалган сүзләр. Күбесенчә гади сөйләмдә.

**ТЕЗ-Ү** «ставить в ряд; нанизывать» < гом. кыпч., чыгт., уйг. *тиз-*, чыгт. *тизэ-*, угыз. *диз-*, хак. *чĕс-* һ.б. ~ чув. *тир-* id.; сүзнең исем коррелянты да бар: харәзем. *тиз* «тезем; көй» (к. ЭСТЯ III: 218–220). Räsänen 1969: 482; Федотов II: 235.

Чув. *тир-* «тезү, энә күзләү, кадау, үрү» сүзе *тез-* < *тиз-* белән баглы булмаска да мөмкин, ул тат. *тир-ү* «тезү» сүзенә охшаш, ә бу сүзнең вокализмы аны *тез-* < *тиз-* белән багламый. Шулай ук **тез-ү** һәм **төз-ү** сүзләрен баглау да фонетик законнарга хилаф.

**Тез-ү** бик продуктив нигез: **тездер-ү, тезел-ү, тезеш-ү; тезгеч, тезем,** диал. **тезмәк** (бу сүзләр күпмәгъ.). К. **Тезге, Тезген, Тезе, Тезмә, Тезмәле.**

**ТЕК I** (ЛТ I: 129), диал. (Троянский I: 533) **дек** «вертикально, стоймя; альчик, стоящий стоймя; крутой, крутизна» ~ гом. кыпч., чыгт., уйг. һ.б. (Радлов III: 1347) *тик* «туры, тек; ачык», төр., төркм. *dik* «туры; үткен очлы; текә»; көрд. *tîk* «биек, текә; тек; туры». Коми. *dik* «тек ашык» төрки телләрдән булса кирәк. Бу күпмәгънәле тамырдан күп кенә гом. төрки нигезләр ясалган, к. **Текә, Текә-ү, Тек-ү.** ЭСТЯ III: 224–226.

**ТЕК II** сөйл., диал. «дык» (частица утверждения и убеждения, «да ведь», «да, но») – ачык түгел. Ихтимал, русчадандыр.

**ТЕК III** – имитатив-подражание частым мелким ударам (*тек-тек басу* «стучать каблучком по полу, тротуару», *тек-тек* – о тиканиии часов, швейной машины и т.д.) – тәкълиди тамыр.

Дерив.: **текел-текел; текелдә-ү.**

**ТЕКӘ,** диал. (Троянский I: 129) **текәк, декәк** «круто, крутой, крутизна» > мар., удм. (Насибуллин: 142) *тыка, тыга, тӗкӓ* < гом. кыпч. *текә, тикә, тикә* < уйг. *тиккә,* үзб. *тикка,* төркм. *дике* < *тик-кӓк* «кадалучан, кадалган» *тик-* «туры кадау» сүзеннән, к. ш. ук гом. төрки *тик* «текә» ~ кор., кыт. *чик*, монг. *чикэ, чихэ* «текә; туры» > алт. *чике* id. һ.б. К. **Тек, Текәк.**

Дерив.: **теп-текә; текәлек; текәлән-ү.**

**ТЕКӘК** (Гиганов) «виноград (как растение)» << төр. *dikek* «виноград сабагын күтәртеп кую җайланмасы» ← *dik-* «кадау, казык утырту». К. түбәндәгене.

**ТЕКӘ-Ү, тегә-ү** «вперить (взор), прислонить; воткнуть перпендикулярно к поверхности» ~ каз. *тікә-, тіке-*, кырг. *тике-* id. < *тик-ке-* (*-кӓ* фигыль ясагыч аффиксы) **тик** «тек» сүзеннән.

**Текә-** продуктив нигез: **текәл-ү, текәш-ү, текәт-ү** һ.б.

**ТЕКМӘ,** диал. **текмәк, текмә читән** «тын», диал. (ТТДС I: 405) «сушилка сена; сруб для погреба; частокол, штакетник; калитка между двумя дворами» > чув. *тӗкме, тӗкмек,* удм. (Алатырев 1976: 144) *тыкме* id. ← *тек-* < *тик-* (к. **Тек-ү**), к. куман. (Радлов III: 1351) *тікмӓ* «кадап куелган; казык; багана».

*Текмә* сүзенең чув. (болг.?) *чикме* варианты да Идел-Урал телләрендә киң таралган: мар. (Упымарий: 222; Иванов, Тужаров: 265; Саваткова: 185–186) *цыкма, цикма, цӗкмӓ* «текмә, читән» > удм. диал. (Насибуллин 1978: 146) *чыкма* id. Бу сүз элегрәк шәһәр, кальга, кирмән ныгытмасын белдергән, к. мар. *Цикмӓгӓрмӓн* «Козьмодемьянски кирмәне» – элекке болгар кальгасы, *цикмӓнай, цикмӓныш* «курык (тау ягы) марилары» («кальга ягы»). К. ш. ук **Шикмә.**

**Текмә** продуктив нигез: **текмәлә-ү, текмәлек** һ.б. Идел-Урал регионыннан тышкы телләрдә *тикме* сүзе «чигү» мәгъ. (ком., к.-балк.) очрый. Төр. *dikme* «бастырып куелган, тек басып торган» һ.б.

**ТЕК-Ү** «вперить взор (*күз тегү*); воткнуть, поставить (знамя)», «шить» < гом. төрки *тик-*, угыз. *дик-*, чув., алт. диал. *чик-* (*т-* > *ч-*) «кадау; чәнчү; вертикаль яисә перпендикуляр кую» (ш. ук «вертикаль», «перпендикуляр» мәгъ. дә очрый, к. **Тек**), «тегү», к. Будагов I: 418; ЭСТЯ III: 226–228 (Э.В. Севортян бу сүзне ике нигезгә бүлеп бирә). Федотов II: 417–419.

**Тек- < тик-** төрки телләрдә күпмәгънәле һәм күп дериватлар биргән сүз. Тат., башк. **тегү, тегел-ү, тегем, тектер-ү, тегемче, тегеш, тегеш-ү.** К. **Текмә.**

Бор. монг. *čiki-* ~ тунг. *чикив-* «тыгу, кадау», ихтимал, төрки *тик-* белән тамырдаш булса да, чув. *чик-* сүзенә баглы түгел.

**ТЕЛ** «язык», «язычок (как деталь)» < гом. төрки *тил,* гом. угыз. *дил,* уйг. диал. (Радлов III: 1223), бор. төрки (ДТС: 566) *tıl*, як. *тыл* id. һ.б. үзенчәлекле вариантлар тур. к. ЭСТЯ III: 228–230. Безнеңчә (Э.В. Севортян бу тур. бер сүз дә әйтми), *тӗл* < *тил* ~ фин-угор. *kēle* ~ бор. монг. *kele(n)*, инде күптән әйтелгәнчә, уртак чыганактан булырга тиеш (к. КЭСК: 149) һәм мәдәни сүзләр җөмләсенә керә: бу сүз аңлашырга, хәбәрләшергә теләүне белдергән һәм хәтсез заманнардан бирле төрле (ш. ук кардәш булмаган) телләрдә сөйләшүчеләр очрашканда беренче сүз буларак, Евразиянең урман һәм урман-дала зонасында киң таралган (*к* ~ *т* вариантлашуы төрле зоналарда очрый). К. ш. ук **Кәләш, Килен.** Яз. телләрдә *тел* < *тил* тур. Будагов I: 371–372 (бик тәфсилле).

Тат. сөйләшләре даирәсендә *тел//кел* параллельлеге ярылып ята, к. *телә-ү//келә-ү, телмәр// келмәр* һ.б. Дөрес, монг. *кэл* варианты белән төрки *тил* варианты арасында закончалыклы фонетик тәңгәллек юк, ләкин шундый киң таралган тамыр «закончалыксыз» да үзгәрергә мөмкин. Әйтмәкче, *тил* сүзен *ти-, тә-* «әйтү, дию» сүзеннән чыгып аңлатуларда да фонетик эзлеклелек ригая ителми.

Чув. *чӗлхӗ* < болг. **тӗлгӗй ~ тӗлгәй ~ телкәй*? (*әй, телкәйләрең* дип әйтү татарча сөйләмдә дә кулланышлы).

ССТМЯ (II: 180) төрки *til ~tıl* сүзен эвенк. *тил-* «аңлау» белән чагыштыра.

**Тел** бик продуктив нигез: регуляр дериватлар – **телле, телсез, телче, телчән, телчек** (боларның арытабангы деривациясе дә булучан). К. **Телә-ү,**

**Телгәч, Телдәк, Телдәр, Телмәгәй, Телмәкәр, Телләш-ү, Телмәр, Телмәт, Тылакый, Тылкы-у, Тылмач, Тылтык.**

**ТЕЛАВЫЗ [tĕлаwы̆з]** (крш., ЗДС: 636) «манера говорить; речь» ~ угыз. (төр.) *dil-ayız* сүзеннән булса кирәк, чөнки **авыз** сүзенең «сөйләм» мәгънәсе кыпч. телләрендә юк., төр. телендә актив кулланыла: *ağız* «сөйләм; диалект».

**ТЕЛАЗАР** (ЗДС: 628) «страстный спорщик; тот, кто неуместно перечит». Беренче карашка «тел(е) азар» шикелле, ләкин к. фар. *дилазар* «телазар, күңел болгаткыч» (*дил* «күңел, тил», *азар* «азаплагыч», к. **Азар**). Ясәвидә *Күңле катыйғ [каты] дилазардан Хода бизәр* (1 хикмәт).

**ТЕЛӘК** «желание» < гом. кыпч. *тилэк* < бор. төрки (ДТС: 560–561) *tiläk* id. (күпсанлы фразеологизмнары барысы да КБтән алып күрсәтелгән) > угыз. *диләк* (төр. *dilek*) id. Бу сүз дә фар. *дел, дил* > төрки *тил* «күңел, теләк» сүзе тәэсирен кичергән бугай, к. **Телә-ү.**

Дерив.: **теләкле, теләксез, теләктәш**; иске тат. **теләкчә** «гариза»; **теләкче** һ.б. (китерелгән сүзләрнең дериватлары). Фразеологизмнарыннан **теләккә килү** «җенси дәрт уяну» үзенчәлекле.

**ТЕЛӘН-Ү** «попрошайничать < гом. төрки *тилән-*, төркм. һ.б. угыз. *дилен-* id. Бу сүзнең тат. диал. (ЗДС: 626), гом. төрки «дога кылу» мәгъ. бар. ЭСТЯ III: 233.

Бу фигыльнең дериватларыннан бигрәк тә **теләнче** < гом. төрки *тиләнчи* > угыз *диленчи* күзгә ташлана. Шуннан **теләнчелән-ү, теләнчелек.** Диал. **теләнчек, теләнчәк** ~ каз. *тіләмсәк* «теләнүчән» (ләкин бор. төрки – ДТС: 560 – *tilämsin-* «нидер әйтергә теләү»).

**ТЕЛӘҮ [tĕләw]** диал. (ТТДС I: 406) «языческое моление» – **телә-ү** фигыленең исемләшкән формасы. Чаг. ш. ук **келәү** һәм **келә-ү.**

Дерив.: **теләүлек** «пот, санәм, мәҗүси табыну предметы; фетиш».

**ТЕЛӘ-Ү** «хотеть; молиться» < гом. төрки *тилә-, тилә-* (угыз. *дилә-*) ← *тел* < *тил* (к. **Тел**). Гомумән, *телә-* < *теллә-* < *тиллә,* к. «Мөхәммәдия»дә *тилләк* «җиңгән батырның теләге». Будагов I: 372–373; ЭСТЯ III: 231–233. Кайбер телләрдә (уйг. һ.б.) *тили-* формасы да бар.

Дерив.: **теләт-ү, теләш-ү** (*карга теләген теләшкән сандугач* тәгъбире бар), **теләк, телән-ү, теләнче** һ.б.

**ТЕЛБИСТӘ < тел бистәсе** «краснобай»: бу сүздә *бистә* «сәүдәгәр, кырыктартмачы (товарын мактаучы) < шәһәрнең сәүдә урыны» (к. **Бистә**). Чаг. морд. Э. *кель парго* «тел тартмасы (кәләш алып килгән бүләкләр тартмасы); телбистә, телдәр (кеше)», к. Евсевьев 1931. Шуның белән бергә төр. *dilbeste* < фар. *дилбäсте, delbäste* «күңел баглаган; гашыйк» сүзе дә искә төшә.

**ТЕЛГӘЧ** (ТТАС III: 74) «агитатор в пользу кого-либо (неодобрительное)» – формасы буенча *тел-* («сөйләү?») фигыленнән. Гомумән – ачык түгел. Чаг. чув. *чĕлхеç* «сихерче».

**ТЕЛДӘК** (Троянский I: 358), себ. **тылдак** «речистый» ← **тел//тил**. Ясалышы ачык түгел. КБ телендә *тилдәм* «телдәк» сүзе бар.

**ТЕЛДӘР** «бойкий на язык; склонный пререкаться» – фар. теленнән кергән *-дар//-дәр* кушымчасы ярдәмендә **тел** сүзеннән, к. ш. ук төр. диал. *тылтар* id.

**ТЕЛЛӘ** «золотая монета; золото как знак богатства» < гар. *ṭиллā* (к. Будагов I: 375, 738). К. **Путал.**

**ТЕЛЛӘШ-Ү** «препираться» **теллә-ү** (кулланылмый торган) фигыленең урт. юн.; күптәннән килә, кырг., каз. *тилде-,* хак. *тĕллә-, тĕлләс-* «телләшү» к. як. (Пекарский: 2935) *тыллас-* «хәбәрләшү; сүз әйтешү» ← *тыл* «тел, сүз, хәбәр, вәгъдә, әмер».

**ТЕЛМӘГӘЙ** (Будагов, Радлов III: 1417) «речистый» – безнеңчә, **телмәкәр** сүзеннән. Бу сүз тур. бүтән фикерләр дә бар (ЭСТЯ III: 229).

**ТЕЛМӘКӘР** «тот, кто работает чаще языком» – **эшмәкәр** (к.) сүзенә онтоним итеп ясалган сүз булса кирәк.

**ТЕЛМӘР** диал. «речь, доклад», диал. (Тел ярышы: 94) «литератор; мастер слова» < бор. кыпч. **тилмәр*, к. алт., кырг. *тилмәр* «кошлар телен аңлаучы кеше; телдәр, телбистә» ~ бур. *хэлмэри* «тәрҗемә, аңлатма» – бу сүзнең үзеннән бигрәк дериваты киң таралган: башк. *телмәрсе* «оратор», тат.

*телмәрче* «кош сайравын тыңлап, “аңлатып” бирүче күрәзә», башк. *телмәрйен* «(сайраучы) бака» ~ бор. монг. (Х г.) *kelmerčin,* иске монг. *kelemürči* «тәрҗемәче; аңлатучы», калм. *келмерчи*[н] «әкиятче, дастанчы» >> **тылмач** (к. **Тылмач**). Шулай итеп, төрки *тилмәр* ~ монг. *кэлмэр, кэлмэри* «озын нотык, кошлар (бакалар) сайравы», күренеп тора ки, төрки *тил, тыл* ~ монг. *кэл, кэлэ* «тел» сүзеннән параллель рәвештә ясалган; *-мэр* ~ *-мэри, -мүри* морфемасы безгә аңлашылмый. Ихтимал, гом. төрки *-ма//-мә(мэ)* сыйфат ясагыч кушымчасының борынгырак варианты **-мар//-мәр* булгандыр, чаг. иске монг. *kelemerči,* уйг. *кәләмәрчи* «тәрҗемәче, телмәрче». Лигети Л. Табгачский язык – диалект сяньбийского // Народы Азии и Африки, № 1. 1969: 107–117. Кара Д. Книга монгольских кочевников, М., 1972: 9; Менгес 1979: 147. К. түбәндәгене.

**ТЕЛМӘРҖЕН,** диал. (Тел ярышы: 53) **телмәрчен** «лягушка, вид лягушки» < бор. **тилмэрҗин* < *тилмэрчин* «дастанчы, телмәрче» (чаг. калм. *кэлмэрҗин* id.) > башк. (БТДҺ: 348) *телмәрйен, тәлмәрҗен, телмәрйән* (бу вариант халык этимологиясен чагылдыра). Гомумән, бу сүз монгол телләрендә килеп чыккан (төрки *-чи* ~ монг. *чин*). К. **Телмәр.** «Дастанчы > бака» мәгъ. күчешенә аналогия – **озан** «дастанчы > ата көртлек».

Башк. (БТДҺ: 84, 348) *дәлбе, дәлбәрйен, тәлбаҡа, тәлбеш* һ.б. вариантлар җирле сөйләшләрдә пәйда булганнар. Тат. (халык этимологиясенчә) **телмәрчән** «телмәр сөйләүчән» дип аңлату да бар.

**ТЕЛМӘТ** «бойкий на язык» ← *тел; -мәт, -бәт* кушымчасы, ихтимал, фар. *-мäнд* ~ «*чан//чән*» кушымчасыннан киләдер, ул чагында **телмәт** < төрки-фар. *тилмәнд* «телчән». К. ш. ук фар. *дилбäнд* «тәрҗемәче».

**ТЕЛ-Ү** «разрезать; резать на полосы; резать (острым ножом)» < гом. төрки *тил-*, угыз. *дил-*, чув. *чĕл-* id. Бу сүзнең исем коррелянты – кырг. *тил* «телем». Тамыр багланышлары ачык түгел. Räsänen 1969: 480; ЭСТЯ III: 230–231; Федотов II: 410.

Дерив.: **телен-ү, телдер-ү; телем** һ.б.

**ТЕМИ** «корысть» < диал. **тәмйы* < *тәмгы.* Чаг. фар. *тäмä* «комсызлык», *тäмäн* «комсызларча» ← гар. *ṭаммā‘* «комсызлык» һ.б. К. **Тәмгы.**

**ТЕНТЕ-Ү** «обыскивать» < гом. кыпч. *тинт-*, алт. диал. (Радлов III: 1362–1363) *тинти-*, төркм. *тинте-*, к.-балк. *тинд-*, ком. *тюнт-, түнт-* id. М. Рясянен (Räsänen 1969: 481) бу нигезне *jintü-* > *ǯintü-* (к. **Җентек**) сүзе белән чагыштыра; к. ш. ук тув. *чинди-* хак. *нĕнди-* «тентү», як. *чинчи-, чинчү-*, алт. *шинҗи-* ~ монг. *синҗи-* «тикшерү» (Пекарский: 3620). Бу чагыштыруларда фонетик «гадәтсезлекләр» бар, әмма бөтенләй үк мөмкин түгел дип әйтеп булмый. К. **Чемчен-ү.**

**ТЕҢ, төң, түң** (ЗДС: 627, 645, 665) «небольшое возвышение посреди болот» ~ башк. *түң* id. ~ кырг., тув. *дөң* «калкулык» һ.б.ш. күп очрый. Чаг. **Түмгәк**.

**ТЕҢЕЛ, тәңел** (Тумашева 1992: 208) «ось, шпенёк (ножниц)» ~ кар. (Радлов III: 1055) *тäңгил, тэнгил*, чув. *тĕнел*, чув. диал. *тенкĕл* ~ гаг., төр. *dingil* ~ бур. *тээлк*, иске монг. *tenggelig* id. (к. ЭСТЯ III: 235–236) ← (төр. диал.) *dink, denk* «тегермән ташының күчәре; таш цилиндр»; к. ш. ук удм. диал. (Кельмаков 1977: 53) *дынгыльк* «теңел; күчәр», *тингыли* «тәгәрмәч», мар. *тенгĕл* «күчәр», венг. *tengely* «күчәр», бор. төрки *tiŋil-* «әйләнү» (Gabain 1950: 341). Шулай итеп, бор. төрки **тиңк* «цилиндр» һәм «әйләндерү, әвәләү» исем-фигыль тамыры булган, шуннан *тиңкил-* (төш. юн. ясалган, моннан исә – **тиңкилиг* «күчәр» сүзе (шул формадан монг. һәм удм. сүзләре килә). *Тиңгил* шул *тиңкилэг* сүзеннән булса кирәк (кабаттаркалыш һәм редукция). К. ш. ук Федотов II: 216–217 (материалы аз). Чаг. **Тәләкә I.**

**ТЕҢКӘ** «нерв, нервы; нервный тик» – бу сүзнең аерым билгеле фигыльләр белән генә кулланылуы аның этимологиясен билгеләүгә комачаулый: чув. *тĕнке, тинке* «көч, куәт» (*тинке кăлар* «теңкә чыгару» – «хәлдән тайдыру»), *тинкелен-* «теңкәләнү» – «көчәнү, азаплану», *тинкер-* «теңкәрү» – «текәлү»), кырг. *диңкэ, дэнкэ, тэнке* «көч-куәт, түзем» (*диңке ҁуру-* «теңкә кору»), каз., к.-калп. *діңге,* ком. *динке* «куәт, гайрәт; нерв», үзб. *тиңка*, уйг. *тиңкә* «хәл» (*тинка ҁур-* «теңкә кору»), төркм. *тиңкеңи дикмек* «текәлеп карау», к.-балк. *тинке, тюнке* «көч, хәл» (ш. ук аерым тәгъбирләрдә). Чаг. калм. *тэңкэ* «көч, куәт», алт. диал. *тäңкі* «чирдән терелеп, көч алу» ~ монг. *тэнхэл, тэнхээ* «көч-куәт». Икенче яктан, к. фар. *тäңк* «киеренке хәл». Гомумән, *теңкә* сүзенең этимологиясе томанлы булып кала. Федотов II: 232–233.

**ТЕПКЕ, тепте** (ТТДС II: 295; БТДҺ: 313), иск. **тыпкы** «совершенно, совсем (похожий)» ~ төр.,

кр.-тат. *tıpkı* id.< гар. (Özön: 866) *ṭибқ* «охшаш, ярашлы; копия» ← *ṭбқ* «тыгыз, тигез, төгәл ябу». Бу күпмәгънәле тамырга тагын төрле сүзләр, шулардан тат. теленә дә кергән *табикъ, мөтәбикъ* «үзенә ярашлы», *татбикъ* «яраштырып куллану; сылтау», *табақ ~ тәбәқ* «капкач, табак», *табәқа* «(сыйнфый, иҗтимагый) катлам; класс» сүзләре дә карый.

**ТЕРӘ** частица «вот» < болг. **те-рә* «тегендә» (булса кирәк), чаг. ш. ук гом. тунг.-маньч. *тар, тэр*, гом. монг. *тэр* < *tere* «менә; әнә». ССТМЯ I: 164–167. Диал. **терәкә > терәк** сүзендә *-кә* аерым күрсәткеч кисәкчә, к. себ. (Тумашева 1992: 166) *менәкә* «менә»; бу *кә* < **кӧ* булса кирәк, к. чув. *ку* < *кү* «бу, бит» ~ үзб., уйг. *ку, кү* id. Ягъни *терәкә* < *терә кү, менәкә* < *менә кү*.

**ТЕРӘК** «опора; упор» < гом. кыпч., уйг. *тирэк*, бор. төрки (ДТС: 562) *tirgük,* үзб. диал. *тиргак* ~ төркм. *дирег, диирег,* төр. *direk* id. Бу сүзнең туры нигезе *тирэ-* түгел, *тиркэ-* булса кирәк, к. **Теркә-ү.**

**ТЕРӘҮ [тĕрәw]** «наклонная опора» < гом. кыпч. *тирәw* < бор. төрки (ДТС: 561) *tirägü* «багана, терәү» ← *tire-* «терәү» фигыленнән. Гомумән, бу сүз тат. теленең үзендә кабаттан ясалырга мөмкин (**терә-ү > терәү**). К. **Терә-ү.**

Дерив.: **терәүле, терәүсез; терәүлә-ү; терәүлек** (материал; бу сүзнең мәҗүси «корбанлык» мәгъ. бар).

**ТЕРӘ-Ү** «подпирать; припереть (к стене)» > чув. *тĕре-* < гом. кыпч., алт., уйг. *тирә-, тирэ-,* угыз. *дирэ-, дирә-,* үзб. диал. (< төркм.) *диирә-,* як. (Пекарский III: 2679) *тірä-, тіäрä-*, бор. төрки (ДТС: 561–562) *tire-* id. Э.В. Севортян фикеренчә, бор. фар. *tir* < *tigra* «ук; мачта; сайгау һ.б.» сүзеннән (ЭСТЯ III: 238–240). Бу фаразны инкяр итеп булмаган кебек, исбат итеп тә булмый. Безнеңчә, *терә-* < *тирә-* < *тигрә-* «нык тиеп тору» фигыленнән *тәг-, тиг-* «тию, җитү» тамырыннан (чаг. *җәй-* → *җәйрә-, көй-* → *көйрә-* һ.б.ш.). Чаг. ш. ук тунг. *тирэ-* «стенага терәү, бастыру, кысу, терәтү» (ССТМЯ II: 187–188). К. **Теркә-ү.** Будагов I: 414; Федотов II: 220.

Дерив.: **терәл-ү, терәш-ү, терәт-ү; терәтке, терәткеч.**

**ТЕРЕ** «живой, бодрый», **терек** «живой (физиологически)» > мар. *тыре* ~ хак. *тĕрĕг,* чув. *чĕрĕ* < гом. кыпч. *тири, тирик,* угыз. *дири, дириг* < бор. төрки (ДТС: 562) *tirig* id. ← *tir-, ter-, tiri-* «яшәү» (төрле формалар тур. к. ЭСТЯ III: 240–242). К. **Тер-ү.** Федотов II: 434.

Дерив.: **тереклек, терелән-ү; терелек; терeләй.** К. **Теремек, Терлек, Тернәк, Терчә.**

**ТЕРЕКӨМЕШ [тĕрĕкөмөш], теркөмеш** «ртуть» (буквально «живое серебро») ~ башк. *терегөмөш* > мар. (Упымарий: 221) *тыркүмĕш*, удм. (Насибуллин: 142) *тьркьмьш* id. ≈ чув. *чĕрĕкĕмĕл* id.; «терекөмеш» (татарчадан калька); мар. *илыше вуд* «терекөмеш» – сүзмә-сүз «тере су»; хак. *тірiг мӧӧн суғ* «терекөмеш», әкияти «тере суы» (*мӧӧн* < яз. монг. *mönggün* «көмеш»); фар. *симаб* (*сим* «көмеш», *аб* «су») һәм монг. *мөнгөн үс* «терекөмеш» сүзмә-сүз «көмеш су» ~ чаг. иске тат. һ.б. **күнә суы** (к. **Күнә**).

Фар. *симаб* иске тат. һәм бүтән яз. төрки телләрдә кулланылган. Федотов II: 414.

**ТЕРЕМ** «терем, теремок (в сказке)». Дәреслекләрдә **терем, терем, теремкәй,** *теремдә кемнәр яши* диелгән әкият сүзләре китерелә. Бу сүзләр русчадан алынган шикелле, ләкин к. төр. *darım evi* «төрекмән өе», төркм. *därim* «төрек тирмәсе», к. Räsänen 1969: 133.

Бу сүз **тирмә** (к.) белән тамырдаш, ләкин (*тәк-* «тирү, җыю» тамырыннан») икенче төрле (*-м* кушымчасы ярдәмендә) ясалган булса кирәк. Рус этимологик сүзлекләрендә *тéрем* сүзенең этимологиясе бәхәсле (күптөрле фикерләр әйтелгән), к. Фасмер IV: 47 (кыпч. *tärmä* «хатын-кыз тирмәсе» сүзеннән килү ихтималын да күрсәтә).

Гомуми закончалыклар буенча, бу сүзнең саф тат. яңгырашы **тирем** булырга тиеш. Андый сүз бар, ләкин икенчерәк мәгъ.: «бер тапкыр җыелган җиләк-җимеш күләме».

**ТЕРЕМЕК** «живой, подвижный, бодрый» ← **тере,** әлбәттә; *-мек* морфемасы *карамык, кызамык* һ.б.ш. сүзләрдәге *-мык* < *амык* белән бердәй булса кирәк. Ягъни **теремек** тәүдә тискәре сыйфатны белдергән булса кирәк.

**ТЕРЕСКӘК** «выступ назад на задних ногах животных» < *терс-кәк,* к. **Терсәк.**

**ТЕРИТ** (ТТДС I: 407; БҺҺ II: 246) «раз, -жды, -крат; третья часть» ~ чув. (Сергеев 1968: 70) *терит,* мар. (Гордеев I: 278) *дырет,* удм. *тьрит, терит* id. < рус. *треть* «өчтән бер», *третицею*

(Даль) «өч тапкыр» сүзләреннән килсә кирәк. Гомумән – эшне өчкә бүлеп эшләүдән.

**ТЕРКӘ-Ү** «приставить так, чтобы касалось; пристроить, прицеплять; составлять из деталей; регистрировать, записать» (к. ТТАС III: 31) < гом. кыпч. *тиркә-* id., уйг. *тиркә (тиркимәк)* «эләктерү; теркәү», кырг., кр.-тат., каз. *тирке-* «бер-бер артлы тезеп баглау, бәйләү (мәс., кәрвандагы дөяләрне)», чыгт. (Радлов III: 1372–1373) *тиркäш* «рәттә булу, рәттә йөрү», төр. диал. *tirke-* «терәү» – **терә-** < *тирä-* нигезеннән, әлбәттә, ләкин ничек ясалганлыгы бик үк ачык түгел (ЭСТЯ III: 237–238; Э.В. Севортян тат.-башк. сүзләрен искә алмый). Чаг. **тез-ү, тирге.**

Дерив.: **теркәл-ү, теркәт-ү; теркәмә; теркәвеч ~ теркәгеч; теркәлеш.**

**ТЕРКЕ,** диал. (Тумашева 1992: 209) **терге** «молодая сосна, молодой сосняк» ~ башк. (БТДҺ: 329, асылда тат. сөйләшләреннән) *төркө* id. < фин-угор, к. мар. (Упымарий: 221) *тырке,* удм. (Насибуллин: 142) *тьркь* id., мар. *тöрке,* хант. *tegәr* «чыршы». Осет. *tägär* «чаган, өрәңге» белән чагыштыру (Абаев 1981: 87), безнеңчә, шиклерәк. Алт. (Баскаков 1972: 260) *тьурук* «кедр» << *дьурук* белән чагыштыру да фонетик җәһәттән тайгаклы.

Дерив.: **теркелек.**

**ТЕРКЕШ** к. **Тиркеш.**

**ТЕРЛЕК** «домашний скот, скотина» < **терелек** дип кенә аңлату кифая түгел: асылда бу сүз бор. төрки (Zenker; ДТС: 562) *tiriglik* «яшәү; яшәрлек мал-туар» ~ госм., төр. *dirilik* «пенсиягә чыккан яничәриләргә бирелә торган көн итәрлек мал-мөлкәт» кебек сүзләрдән килә. К. тат. (ТТДС II: 295–296) **терлек** «бирнә», **терлек-карман, терлек-тару, терлек-торош** «иген игеп, мал асрап гадәтчә яшәү хәле, көн итеш», (ТТДС I: 407–408) **терлек-тырыш, терлек-хәлмән** «мал-туар», **терлек-әрбир** «бирнә составындагы өй җиһазлары» (**карман, хәлмән** сүзләре тур. к. **Карман II**). К. **Тере.** Velidi: 293.

Дерив.: **терлекче, терлекчелек.**

**ТЕРНӘК** күч. «опора» ~ к.-балк. *тирнек* «тырыш», каз. *тірнек [тĕрнәк]* «үтә яшь, яшь кенә» сүзләреннән чыгып, **тернәк** сүзен **тере**, **теремек** (к.) сүзләре белән баглы дип уйларга мөмкин, к. ш. ук **тернәкле** «кыю; яшь көенчә өлгергән» (к. ТТДС II: 108); ләкин **тернәкле** сүзенең «хәле ныклы, хәлле» мәгънәләре (к. ТТАС III) бор. төрки (ДТС: 553–555, 563) *ternäk, tirnäk* «союз, оешма; җәмәгать, община» сүзләрен хәтерләтә. Бу сүз кр.-тат., төр. *dernek* «оешма», *derniş-* «җәмгыять булып оешу» нигезләрендә дә чагыла.

Дерив.: **тернәкле, тернәксез; тернәклән-ү.**

**ТЕРПӘК, тырпак** (БТДҺ: 314, 345) «вид лошади вроде иноходца», «ход такой лошади» – чаг. бор. төрки (ДТС: 554) *terk* «тиз, шәп»? К. ш. ук **тырпыл-да-у.**

**ТЕРПЕ,** диал. (БТДҺ: 314) **төрпө** «терпуг, скобель» ~ к.-балк., кырг. *түрпү,* аз. *төрпи,* төр. *dürpü,* (Будагов I: 554) *дöрпи, тöрпү* «тупас игәү» (кайбер телләрдә «пычкы», «кытыршы тиреле балык»), тув. *дүрбүү* «рашпиль, кечкенә игәү» ← *дүрбү-* «игәүләү, ышкылу» ~ бор. төрки (ДТС: 581) *törpig, törpigü* «игәү» ← *törpi-* «шәүләү». Бор. *-pi* кушымчасына караганда, **tör-* «тырнашып ышку» тамырыннан. Рус. *терпуг* ниндидер бор. төрки телдән булса кирәк. Фасмер IV: 49. К. **Төрпә.** Чаг. **Керпе.**

**ТЕРСӘК** «локоть» (ш. ук озынлык үлчәү берәмлеге мәгъ. «аршин»), диал. (Радлов III: 1377, Будагов I: 350; Тумашева 1992: 209) «ячмень в глазу» ~ башк. *терһәк* id.; к. ш. ук (Тумашева 1992: 209) **терескәк,** каз. (Радлов III: 1383) *тилäрсäк* «терсәк», бор. төрки (ДТС: 563; DLT III: 424) *tirsäk, tirsgek* «терсәк» ← (кырг.) *тирсий-* «чыгынты булып тору; төрле шеш чыгу», к. ш. ук угыз. *дирсәк* «терсәк», тув. *дискек* «тез». Рясянен (Räsänen 1969: 477, 481) урта төрки *tirsgäk* «күздәге арпа» һәм «кул терсәге» сүзләрен аерым-аерым матдә итеп яза.

Каз. вариантыннан чыгып, бу сүзне *терә-ү, терәл-ү* сүзенә нисбәт итү очрый (В.В. Радлов, А.М. Щербак), ләкин төп мәгънә – «тәндәге чыгынты» һәм сүзнең тамыры **тир* «терсәк, тез», к. нуг. *тирей-, тирәй-*, тат. *тертәй-* «төер булып чыгып тору», к. бур. *тэрзэгэр* «чыгынты; бүлтәймәле». К. **Тез.**

Дерив.: **терсәкле** (мәс., урындык), **терсәксез; терсәклек** «култыкса»; **терсәклә-ү, терсәкләш-ү.**

**ТЕРТӘЙ-Ү** «выпирать из-под платья; выступать углом» – *терт* тәкълиди тамырыннан, < *төртәй-ү* дип тә фаразларга мөмкин. К. **Терсәк.**

***ТЕР-Ү** (к. *тер-ел-* «становиться живым; вылечиться», *тергез-ү* «оживить, оживлять» – **тер-ү** фигыленең төш. һәм йөкл. юн.) < бор. төрки (ДТС:

562) *tir-* «яшәү, яшәп тору», шуннан гом. төрки *тири* < *тириг* > тат. **тере, терек** (к. **Тере**), угыз. *дири*, к. ЭСТЯ III: 240–242 (Э.В. Севортян архетип **тиир-* яисә **тиири-* булырга тиеш ди). Ихтимал, бор. *тиир-* < *ти-ир-*, ягъни ниндидер *ти* «яшәү, хәят» сүзеннән ясалган фигыль. Чаг. тунг. *тӣван-* «яшәү, яшәп тору, имин яшәү һ.б.» (ССТМЯ II: 174–175) **тив-* тамырыннан.

***Тер-** продуктив нигез: к. **тере, терек, теремек, терлек** һ.б. К. **Терчә.**

**ТЕРЧӘ** «живой, подвижный, шустрый» (преимущественно о детях и женщинах) < *теречә* (Г. Бәширов). Бу сүзнең *терчән* варианты да очрый һәм ул **тер-чән* «яшәүчән» дип тә аңлатыла ала (к. **Тер-ү**). Элекке терминологик тәҗрибәләрдә *терчә ~ живчик* тәңгәллегеннән чыгып, аңа «сперматозоид» мәгъ. биреп караганнар.

**ТЕТ, тыт** «лиственница, вид лиственницы» < **телт* < **тилт* булса кирәк, к. XVIII г. тат. *telagatsch* «тыт» (И. Паллас язып ялганча); к. ш. ук як. *тит*, бор. төрки (ДТС: 569) *tit* id. Чаг. **Терке.**

**ТЕТРӘ-Ү, тетерә-ү** «трястись, дрожать» < гом. кыпч., гом. төрки (Радлов III: 1391) *титрä-, титирä-*, як. (Пекарский: 2690) *тітігірä-,* чув. *чĕтре* ~ яз. монг. *čičire-,* бур. *чічірэ-* id. < бор. **тиртиргирä-* id. *тиртир* «дер-дер, тер-тер» имитативыннан. ССТМЯ II: 401; Федотов II: 417.

Дерив.: **тетрәл-ү, тетрән-ү** (шуннан актив кулланышлы **тетрәндергеч**), **тетрәт-ү; тетрәвек** «сазламык; дерелдәвек», **тетрәк** (мәс., тавыш).

**ТЕТ-Ү** «рвать в клочья; трепать; расщипать» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *тит-*, угыз. *дит-*, төркм. *дүйт-*, кырг. *тыт-*, чув. *тăт-* < бор. төрки (ДТС: 563–564) *tit-* «тетү, өзгәләү» ~ төр. *tift-* «тетү, йолку» (шуннан *tiftik* «кәҗә мамыгы»), к. Açıkgöz 1984: 137–188. Гомумән, бу сүз дә тәкълиди тамырдандыр. ЭСТЯ III: 321–323.

Дерив.: **тетел-ү** (күч. «тузу, таушалу»), **теттер-ү** («күңел ачу» мәгъ. биегәндә чыккан тузанны теткеч белән йон теткәндә бик куе тузан чыгуга охшатудан килә); **теткеч** (корал, җайланма), **тетмә** «тетергә алынган йон».

**ТЕФТӘ, тефта** (ТТДС I: 604; Иванова: 36) «донник (растение)» < фар. *тифта* «пластырь, олтырак» (бу үсемлек олтырак итеп файдалануга уңайлы) ← *тифт-* «тетү».

**ТЕШ** «зуб; зубец» < гом. кыпч. *тиш*, угыз. *диш* (төркм. *дииш*) < бор. гом. төрки **тиил* id., к. чув. *шăл (< чыл < *чĕл < *тĕл < *тӣл*) «теш». Räsänen 1969: 481; ЭСТЯ III: 242–244; Федотов II: 440 (тик бу автор чув. *тăл* сүзен иң беренче чиратта гом. төрки *шыш, шиш* «шеш, шомпол» белән чагыштыра, без бу фикергә каршы түгел).

Дерив.: **тешле, тешсез; тешә-ү** «теш алмаштыру; инструмент тешен үткерләү» һәм аның юн. формалары; **тешлә-ү (→ тешләт-ү); тешлән-ү** (төрле мәгъ.); **тешләч**. **Теш әни, төш әни** (ЗДС: 629–630, 648–649) бәбинең беренче тешен тәүләп күргән хатын-кыз (аңарга бүләк бирелә). К. ш. ук **Сыла, Тешләк, Шешәк.**

**ТЕШЕ,** диал. (ТТДС: 435) **тышы** «самка (домашних животных)», иск. «самка; женщина» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *тиши*, алт. *тижи, тыжы*, хак. *тӗзӗ, тызы*, як. *тысы ~ тыһы*, угыз. *диши*, тув. *дижи* id. < бор. төрки (ДТС: 563–569) *tiši, tïšï* «хатынзат». Бу сүз тур. күп язылган, к. Räsänen 1969: 482; Clauson: 560; ЭСТЯ III: 244–245 һ.б. Этимологиясе бәхәсле: кайбер телчеләр *теше* < *тиши* < *киши* «кеше» диләр, икенчеләр бор. һинд. *dariši* «кыз, хатын-кыз» сүзеннән чыгаралар һ.б. Без дә бер гипотеза өстик: *тиши* < *тыши* < кыт. *тàңши* «кергелектәге бикә» (рус. «госпожа в приёмной») – бу гипотеза палаталь һәм веляр вариантларның янәшә килүен яхшы аңлата (бер очракта веляр беренче иҗек, икенче очракта – палаталь икенче иҗек).

Дерив.: **тешекәй** (к. ТТДС II: 296).

**ТЕШЛӘК** «упорно молчаливый, не открытый, не желающий объясняться (преимущественно о детях)» ← **тешлә-ү**, к. *ирен тешлә-ү* «әйтер сүзеңне әйтмәү». Чаг. башк. *тешегү* «үпкәләп сөйләшү», *тешек, тешекмә* (һ.б. вариантларда) «тешләк» (к. БТДҺ: 314–315).

**ТИБӘН: тибән энә, темән энә** (Арсланов 1988: 95; БТДҺ: 315), тат.-нуг. (Арсланов 1912: 145) **тебен ейне** «большая игла; шорная игла» < гом. кыпч. *тәбән,* чыгт. *тибән*, үзб. (ЎХШЛ: 250–255) *тәмән, тебәнә, тована, түвәнә,* кырг. *темене*, тув. *тевене*, хак. *тибе ӗңе, тибе ӗне*, *тибинге*, каз. (Будагов I: 413) *тәбин ийне.* К. бур. *тэбэнэ*, иске монг. *tebene* > хәз. монг. *тэвнэ* ~ тунг. *тэмэ*, маньч. (ССТМЯ II: 235) *тэмэнэ улмэ* (*улмэ* «энә») «тибән энә» < уйг. *тәвә ийнә*, монг. *тэмэн ийне* «дөя энәсе» (к. Номинханов 1975: 260). Тат. теленең

үзендә үк (к. ЗДС: 166) *дәмән I* «дөя», *дәмән II* «тибән». Бу сүз күрше телләргә кергән, мәс., рус. диал. *тебеня* «тибән», к. Аникин: 543 (этимологиясе бирелми). К. **Дәмән, Тәвә.**

**ТИБӘР-Ү** «оттолкнуть, отпинать» < гом. кыпч. *тәбәр-* < *тәбә бәр-* «тибә бирү» булса кирәк. Ш. ук **тибер-ү** формасыннан да (*-е-* > *-ә-*) килеп чыга ала.

Дерив.: **тибәрен-ү, тибәреш-ү.**

**ТИБӘТ** (ТТАС III: 90) «детская рубашка; пелёнка», удм. (Насибуллин: 142) *тәбәт, тәбет* id. ~ миш. тат. (Kecskemeti-Paasonen 1965) *кірән [кипĕн]* «биләүсә, бала чүпрәге» ~ чув. *кипкĕ,* хак. *кип* «күлмәк» < гом. төрки *кәп, кәп* «форма, кипкер» сүзеннән. Күрәсең, *тибәт* < **кибәт.*

**ТИБЕЗ: тоз-тибез** (ТТДС I: 416) «аппетитность; аперитив» ~ к.-калп. *тәбиз* «аппетит, теләк» < бор. төрки (ДТС: 553) *tepiz* «тозлак; көнчелек, азгын теләк» ~ монг. *дабусун* «тоз, тозлылык».

**ТИБЕН** «тебенёвка (питание скота на подножном корму зимой)», «зимнее пастбище» < гом. кыпч. *тәбин* id. ← *тәп-* «тибү». Рус. *тебеневать* тур. Аникин: 543 (бай әдәбият күрсәтелә).

**ТИБЕНГЕ** «шпоры на ногах у куриных», «кожаная полоска, прикрепляемая к седлу, чтобы колени всадника не раздражали кожу лошади; тебенёк, тебеньки» ~ гом. кыпч. *тәбинги* (башк. – БТДҺ: 315 – *тибенгел,* кырг. *тәбĕнгĕ*), төр. (Sümer 1983: 76–77) *depingi, tepengü*, уйг. *тәбингү*, чыгт. *тәбәнәк* һ.б. – чапрак өстенә яисә ат янтыгына туры-дан-туры ябыла торган төрле формадагы һәм төрле материалдан эшләнгән ябуча – ат тәнен җәрәхәтләнүдән, ә сыбай киемен ат тире белән керләнүдән саклый. К. Будагов I: 341. Рус. *тебенёк* тур. Фасмер IV: 35; Аникин: 543.

**ТИБЕН-Ү I** «пинать (без причины, со злости и т.п.); ходить на подножном корму (о птицах); тебеневать» ← **тип-ү** сүзенең кайт. юн.

**ТИБЕН-Ү II** миш. (ТТДС I: 409) «стремиться; приниматься за, начинать» ~ кар., ком., к.-балк. *тебин- [тәбин-]* «омтылу; көрәшкә күтәрелү; тибрәнү» ~ чув. *тапăн-* < **тәбен-* «тибенү, башлау». Бу сүзнең кайбер мәгъ. «тибү» белән контаминациягә кергән булса да, безнеңчә, төптән аерым тамырдан – *тип-* «барабан сугып көрәшкә күтәрү» фигыленнән, к. к.-балк. *теб- [тәп-]* «хәрәкәт итү». *Тибен-* < *тәбин-* сүзенең көнб. кыпчакларда гына булуы игътибарга лаек. К. **Илтибәр, Тибрә-ү, Тип II.**

**ТИБЕРЧЕН-Ү** «дрыгать ногами (о детях); бурно сопротивляться» – **тыпырчын-у** (к.) сүзе тәэсирендә **тип-ү** сүзеннән ясалган. Морфемик составына карап хөкем иткәндә, ниндидер ***тиберче-ү** фигыленең кайт. юн. Ләкин андый төп фигыль юк шикелле.

**ТИБРӘЛ-Ү** «качаться; покачиваться» ← **тибрә-ү** (төш. юн.). К. **Тирбәл-ү.**

**ТИБРӘН-Ү** «качаться, закачаться; задвигаться, начинать двигаться» (к. җырда: *Тибрәнде телем, әйтергә Сүзләрне табалмадым*) ← **тибрә-ү** (кайт. юн.). Югарыдагы фигыльдән үзгә буларак, **тибрән-ү** < *тәбрән-* төрки телләрдә киң таралган: гом. кыпч. *тебрен-, тебирен-* «хәрәкәтләнү, хәрәкәткә килү», башк. (БТДҺ: 315) *тиберән-* «тырышу», себ. (Тумашева 1992: 207) **тәперән-,** кр.-тат., госм. *тäпрäн-* «әрле-бирле хәрәкәтләнү», угыз. (төр., төркм. һ.б.) *deprenmek* «ярсыну, тетрәнү» (шуннан *deprente* «җир тетрәү») ~ чув. *тапран-* «омтылу; керешү, тотыну», к. Мухамедова 1973: 164. К. түбәндәгеләрне.

**ТИБРӘТ-Ү** «закачать; задвигать; шевелить, зашевелить» ← **тибрә-ү** (йөкл. юн.). К. **Тибрә-ү.**

Дерив.: **тибрәтке, тибрәткеч; тибрәтел-ү, тибрәттер-ү.**

**ТИБРӘ-Ү, тиберә-ү** «качать, колебать, приводить в движение», диал. (Тумашева 1992: 209) «отправиться в путь» < гом. кыпч. (Радлов III: 1113, 1407), чыгт., алт. *тебре-, тебрä-*, кр.-тат. *тäпрä-,* угыз. *тебре-, дәпрә-,* хак. *тибĕрә-* «хәрәкәткә килү, хәрәкәткә китерү» һ.б. < бор. төрки (ДТС: 546) *tebrä-* «хәрәкәтләнү; калтырау; ялкынлану, чир таралу» (→ *tebranigli* «хайван, җан иясе») >> чув. *тапра-* «кузгалу; кыймылдау; кискен омтылу».

*Тирбә-* нигезе күп телләрдә бор. заманнардан ук метатезаланган **тирбә** ~ *тәрбә-* һ.б. вариантта да кулланыла, к. **Тирбә-ү.**

Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 201–202), бу сүзнең этимологиясе белән кызыксынган бүтән күп кенә галимнәрнең фикеренә дә таянып, гом. төрки *тәбрä-* < *тәпрä-* фигылен иске төрки *тäп-* «хәрәкәткә өндәү авазы» һәм *тәп-, тäп-* «хәрәкәткә килү, куз-

галу, башлау, керешү, тотыну» сүзләре белән баглый (к. **тибен-ү** «омтылу», әмма Э.В. Севортян бу сүзне, аның фикере файдасына булса да, искә алмаган). **Типрә-ү, тибрә-ү (← тип-ү),** гомумән, *-рә* киңәйткеченә беткән бер төркем фигыльләр рәтендә, чаг. *җәй-ү → җәйрә-ү, көй-ү → көйрә-ү, кый-у → кыйра-у*. Ләкин бор. фигыль *тәп-, täп-* «хәрәкәткә килү» гом. төрки *тәп-* «тибү» белән бердәй булаламы соң? Безнеңчә, монда «тибеп хәрәкәткә китерү» мәгънәсе ята дип фаразлау артык тәвәккәллек булыр иде.

Безнеңчә, *тип* < *тәп* тамыры тат. диал. *тип* (к. **Тип III**) < бор. төрки *тәп-, täп-* «хәрби барабан, сигнал барабаны» сүзеннән, аның фигыль мәгънәсеннән: бор. төркиләрдә *тәп* сүзеннән «барабан кагу – сәфәргә чакыру – хәрби сәфәргә кузгалу – гомумән массакүләм гамәлгә керешү һ.б.ш.» мәгъ. фигыль бик җиңел ясала алган (таралган исем – фигыль конвергенциясе). Бу фараз түбәндәгечә нигезләнә (к. ш. ук **Тип-ү**).

**Тибрә-** < *тәпрә- ~ дәпрә-* яңгырашында тәүдә тотрыклы *-п-* булганлыгы күренә. Бу *-п-* авазының саклануы аның тәкълиди сүз булу хасиятеннән килә; төрки телләрдә төбендә-чыгышында тәкълиди характерда булмаган сүзләрнең дә тәкълиди сүз калыбына керүе күзәтелә. Бу очракта да шундый хәл булган: *тәп* «барабан» сүзе «барабан кагу авазы» (чаг. хәз. тат. **дөп-дөп, тыбыр-тыбыр**) хөкеменә кертелгән.

Аннары шунысы да бар: гом. төрки *тәп* «барабан» үзе мөгаен сем.-фар. *тәпир* < *тәпил* < *табл* < *табул* (һәр яңгырашка конкрет мисал табып була) < аккад-шумер. *табаллу* «хәрби барабан» сүзеннән киләдер (к. **Давыл**). Һәм *тәпрә-* < *тәпирә-* сүзе турыдан-туры *тәпир* < **тәппир* «барабан» сүзеннән дә бик җиңел ясала алган (ягъни бу очракта *-рә-* киңәйткече бар дигән югарыдагы фараз кирәксезгә чыга).

Төрки *тәпрә-, тәбрә-* сүзе күп күрше телләргә үтеп кергән, к. иске монг. (Поппе 1938: 427) *tebre-* «хәрәкәт иттерү», Кавказ телләрендә *тебре-* id. еш очрый. К. ш. ук **Илтибәр.** Федотов II: 173–174.

**Тибрә-ү** фигыле үзе хәз. тат. телендә сирәк кулланыла, ә аның юнәлешләре – ешрак (шунлыктан алар югарыда аерым күрсәтелде). Һәм **тибрә-ү** фигыленең үзеннән ясалган сүзләр дә аз.

**ТИГӘЛӘЙ** (Тумашева 1992: 209) «(в эпосе у богатыря) широкий потник» ~ кырг. *тегелей*, үзб. (ЎХШЛ: 79) *дәгәләй* «кыйммәтле тукыма, шул тукымадан эшләнгән бүрек яисә җөббә, җилән» < монг. *дэгэлэй* id. > рус. (Фасмер IV: 35) *тегиляй* «кыска җиңле, биек якалы җилән (хәрби форма булган)».

Киң таралган сүз: чыгт. *däglä,* калм. > *degle* (Ramstedt 1935: 85), эвен. һ.б. (ССТМЯ I: 231) *дэкэли,* рус. диал. *дели, дыгилей* «аркалык». Бу сүзнең нигезе төр. *tegel,* монг. *dekele* «тупас кына тупчып тегелгән сырма», *tegel-* «тупчып тегү» – шуннан төр. *teğelti* «тигәләй, чапрак, тирлек» (к. Sümer 1981: 83–85, бик тәфсилле); Аникин: 192–193; Аблязов I: 398. К. **Җилән.**

**ТИГӘЛБАР** (к. БТДҺ: 315) «настойчиво, многократно» < фар. *dīгäрбāр* «тагын бер тапкыр, каткат». К. **Тегәрҗеп.**

**ТИГӘНӘ** «корыто (для теста), кормушка» > мар. *тäгäнä* (**тәгәнә** варианты тат. телендә дә бар), *тагына*, чув. *такана* < гом. кыпч., к. куман. *тäгäнä*, кырг. *тегене*, каз. *тегәнә* һ.б., осет. *тэгэнэ*, груз. *тэгана, тэгани* «тигәнә, тагарак»; сүзнең редукцияләнгән варианты – уйг. *тәгнә, тәңлә, тәңңә*, үзб. *тигнә, тигна*, кар., госм., аз. *тәкнә* >> венг. *teknö, tekenö* «тигәнә, тагарак, ушат һ.б.ш.», госм. «судно». Чаг. ш. ук эвенк. *такэн* «дөмбәскә, түмәр; улак», монг. *тэкэң* «түмәр». Тигәнә бүрәнә кисәгеннән уеп ясала. Будагов I: 367; Räsänen 1969: 470–471; Федотов II: 165 (бернинди дәлилсез бор. чув. **täkänäy* вариантыннан ди).

Дерив.: **тигәнәле; тигәнәлек.**

**ТИГӘНӘК,** (иске сүзлекләрдә) **тикәнәк**, диал. (ЗДС: 165, 168, 616, 624, 691) **тәгәнәк, тегәнәк, тийәнәк, дәгәнәк, дегәнәк**, «лопух; чертополох» < гом. кыпч. *тәгәнәк,* шор., чулым. (Радлов III: 1031) *тäгäнäк,* башк. *тегәнәк, дегәнәк* ~ төркм. *дигенек, дикенек*, id., алт. *тегенек, тäгäнäк* «гөлҗимеш», хак. *тiгенек* «тигәнәк» (*тĕгән* «ылыс; чыршы») һ.б. < *тәкән* > **Тикән** (к.), к. Будагов I: 369. Рус. *тегенек, тёгенек* – чәнечкеле үлән төре – Кавказ телләреннән. Чув. *тикенек, тикенет* (< тат.) тур. Федотов II: 227–226 (тат. сүзен искә дә алмаган).

Кайбер очракларда бу сүз үзгәчәрәк мәгънәдә кулланыла, к. тат. диал. (ЗДС: 616, 624, 631 һ.б.) **тәгәнәк, тегәнәк** «роза, розасыман тикәнле үсемлекләр», **тийәнәк** «чәнечкеле түгәрәк орлыксалы бер үсемлек» һ.б., төр. *değenek, değnek* «чәнечкеле таяк, очлы таяк, кыйнау таягы».

Дерив.: **тигәнәкле, тигәнәксез; тигәнәклек.**

**ТИГӘРӘК** (ЗДС: 631) «окружность, окрестность» ← *тигәр* ~ *тәгәр* нигезеннән. К. **Түгәрәк.**

**ТИГЕЗ** «ровный; равен, равный» ~ башк. *тигеҙ* > чув., мар. диал., манси. *тикĕс*, удм. *тегыз* < гом. кыпч. *тэгиз* < бор. төрки **тэңиз* «тиңләр; ике тиң» сүзеннән (к. **Тиң**).

Шуның белән бергә ком., к.-балк. *тегиш [тэгиш]* > нуг., к.-калп. *тегис* «тигез» сүзе дә бар һәм ул бор. *тэңиш* «тиңәшкән, тиңешкән» сүзеннән, ягъни уртак тамырдан үзгә нигез булса кирәк; аны бур. *тэгшэ*, калм. *тэгш* < бор. монг. *tegsi* > тунг. *тэгши*, маньч. *тэқши* (к. ССТМЯ II: 226) «тигез» ~ куман., уйг. диал. *тäкси*, каз., хак. *тэкси* «үлчәүдә тигез, тиң» сүзе белән (к. ш. ук **тикшерү**) чагыштыралар, к. Räsänen 1969: 471; Федотов II: 228.

**Тигез** сүзенең деривациясе тат. телендә бик күп: **тигезле, тигезсез (тигезле-тигезсез** парлы сүзе дә бар): **тигезлек** (бик төрле мәгъ.**); тигезлә-ү, тигезлән-ү, тигезләт-ү, тигезләш-ү** һ.б. һәм боларның дериватлары.

**ТИГЕН,** диал. (ТТДС II: 297) **тийен**, (Тумашева 1992: 206) **тэгин** «бесплатный, даровый» < гом. кыпч., уйг. *тэгин*, уйг., төр., чулым. (Радлов III: 1033) *тäгiн,* хак. *тигiн*, төр. *tekin*, төркм. *дегин, декиин*, бор. төрки (ДТС: 547, 550) *tegin, tekin, tekün* «тиген, бушлай» ← тат., башк. *тэк, тик,* хак., тув. *тик* «ноль; юк, тиен» (к. **Тәккә** «юкка») сүзенең инструменталь килеш формасы. К. ш. ук алт. *теген, тегин* «гади (кеше)», төр. *tekin* «буш җир (чүл һ.б.)».

**Тиген** сүзегең карарлашкан дериватлары юк, окказиональ дериватлары гына булырга мөмкин, мәс., *тигенлеккә тиген лә ул* һ. б. ш., чаг., ләкин түбәндәгене.

**ТИЕЛ [тийёл]** тар., (Будагов I: 423–424) **тийул, тиулат** «пожалованные за заслуги участки земли; далекие земли, осваиваемые тарритории». Бабур *тиңул, тинул* дип яза һәм «пенсиягә чыккан хәрбиләргә үз гомеренә бирелгән кишәр» мәгъ. куллана. Һәм фар. *тиул* да шул ук мәгънәдә, ягъни **тиел** мирас итеп калдырылмый. З. Вәлиди буенче (Velidi: 293), *tiyül, tıyul* бор. төрки телләрдә үк кулланылган сүз, ул Казан дәүләтендә билгеле булган. Чаг. як. *тäгил, төгүл; төңүл, түңүл* «чират, тәртип; бер тапкыр». Чув. *тивлет* «байлык» сүзе дә, ихтимал, **дәүләт** сүзеннән түгел, бор. **тиүләт** сүзеннәндер. Чаг. **Тиген.**

**ТИЕН I [тийён],** диал. (Тумашева 1992: 209) **тииң** «белка» < гом. кыпч., алт., шор., як. *тиин, тийын*, госм., уйг. *тийин, тәйин*, тув. *дииң*, төр. *değin*, бор. төрки (ДТС: 548–549) *tejiŋ, teŋin* id., *tegiŋ, täkiŋ* «кеш», к.-балк. *тийин* «асның бер төре», *тыйын* «эчек, мех» ~ манси. *lεin*, хант. *täŋkә*, эвенк. *деңке, диңке* «кеш» (к. Räsänen 1969: 470). ЭСТЯ III: 180–181.

*Тийён* сүзенең акча берәмлеге мәгъ. барча Идел-Урал һәм күрше телләрдә дә очрый: мар., морд. *ур* «тиен (җәнлек; акча)», удм. *коньы* «тиен (җәнлек; акча)», рус. *векша* (< *вѣкъша*) «тиен; акча берәмлеге» (к. Фасмер I: 287) һәм бу хәл бор. Болгар дәүләте законнарыннан бирле килә (к. Халиков 1976: 104). Хәз. рус *белка (< бълъка)* «тиен (җәнлек)» тәүдә «тиен (акча берәмлеге)» мәгъ. йөргән һәм *бел-ый* «ак» сүзеннән, ягъни тат. *акча* < *ак-ча* сүзеннән калька: **бел-ка** (тат. *-ча* ~ рус. *-ка* – кечерәйтү кушымчалары), к. Проценко 1981: 167–168; ЭСТЯ III: 180–181; Тимергалин: 467.

Кайбер телчеләр *тиен* сүзен *тәңкә* сүзе белән бәйлиләр, к. Мухамедова 1973: 169–170. Бу бик шикле. Рус. диал. (< төрки) *тинка* «түләгән чорындагы тиен» тур. сөйләгәндә А.Е. Аникин (: 546) бор. төрки **degiŋ* (?) «тиен» сүзен хант.-манси *lεin* һ.б. id. белән чагыштыруны да кире кага.

Күп кенә тат. сөйләшләрендә *тиен* «җәнлек», *тин* «акча» аерымланган һәм бу *тин* тат. теленнән күрше һәм кардәш телләргә, шулай ук таҗ.-фар., Төньяк Кавказ һ.б. телләргә үтеп кергән. Рус. диал. *тин* (шуннан *полтинник* «илле тиенлек») «тәңкә, сум» сүзе дә тат. теленнән булса кирәк.

**Тиен, тин** продуктив нигез (бигрәк тә акча берәмлеге мәгъ.): **тиенле (тинле), тиенлек (тинлек), тиенсез (тинсез**, мәс., *бертинсез*), **тиенче** «тиен аулаучы» һ.б. Без **тиен** (җәнлек) һәм **тин** (акча берәмлеге) сүзләрен аеру ягында: элекке бер сүздән ике яңгырашлы ике сүз пәйда булу – закончалыклы хәл.

**ТИЕН II [тийён], Тиин** (Кара Тиен Йосынчы**)** – в эпосе «Идегей» имя отрицательного героя, якобы укравшего любимую дочь Тамерлана < бор. төрки *tegin* «принц» (ДТС: 547); аның тискәре каһарман булуы ислам мәдәниятенең мәҗүси төрки мәдәниятенә яхшы карамавы белән бәйле. Төрки халыкларда Аксак Тимернең кызын урлау тур. күп кенә легендалар бар, әд. әсәрләр язылган.

**ТИЕН-Ү [тийён-]** «достичь достатка чего-либо, иметь что-либо в изобилии» ← **ти-ү** (аның «өлешеңә туры килү» мәгънәсеннән), к. бор. төрки (ДТС: 547) *tegin-* «теләгеңә (югары дәрәҗәгә һ.б.ш.) ирешү» *teg-* «тию, житү» сүзенең кайт. юн. Чаг. ш. ук диал. (ТТДС II: 297) **тиеш-ү** «тиенү».

Дерив.: **тиенел-ү, тиенеш-ү, тиендер-ү.**

**ТИЕШ [тийёш] < тиешле** «должен, соответствует; касается; надлежащий, причитающийся» > мар. *тийыш, тийышлы* < гом. кыпч. *тийиш, тийишли* (нуг., каз., к.-калп. *тийис, тийисли*), уйг., үзб. *тегиш, тегишли* һ.б. < бор. төрки *tegiš, tegišli* id. һ.б. (к. ДТС: 548) ← *teg-* «(өлешеңә һ.б.) тию» сүзеннән, к. **Тий-ү.**

Чув. *тивĕç* «тиеш, бурыч; хокук һ.б.», *тивĕçле* «тиешле», *тивеç-* «(өлешеңә) тию» сүзләре тат. теленең миш. сөйләшләреннән килә (*г* > *w* – миш.-угыз линиясе). К. Федотов II: 226.

Себ. (Тумашева 1992: 207) **тәңиш** «тиеш» *ти-* < *тәг-* сүзеннән борынгырак *тәң-* «тию» вариантыннан.

**Тиеш < тиешле** тат. һәм бүтән кыпч. телләрендә аерым тәгъбирләрдә төрле мәгъ. ия: «кардәш, нәсел», «бәя, хак», «булса кирәк», «тәртиптә; тәртиптәге, гадәттәге» (к. тат. **тиешсез** << бор. төрки *tegišsiz* «тәртипсез, әдәпсез»), **тиеш** хәбәрлек сүз мәгъ. дә киң кулланыла (**-рга//-маска тиеш**, **-у//-ү тиеш** һ.б.).

Дерив.: **тиешле, тиешсез** (ш. ук **тиешле-тиешсез** – парлы сүз), **тиешлек; тиешенчә, тиешчә**. К. **Тиеш-ү.**

**ТИЕШ-Ү I [тийёш-]** (Тумашева 1992: 210) «быть должным, обязательным, надлежащим» ← **тий-ү** фигыленең урт. юнәлешеннән, тәүдә «һәркемгә кагылышлы булу» мәгъ. булган. Чаг. **Тееш-ү.**

**ТИЕШ-Ү II [тийёш-]** «снять (вернее – сменить) одежду». Диалектологик сүзлекләрдә һәм иске яз. ядкәрләрдә **тиш-ү (тишмәк)** дип кыскартыла торган бу сүз аерым лексема ~ угыз. (төр. һ.б.) *deyiş-, degiş-* «алмаштырылу; үзгәрү; (киемне) салу» ← бор. угыз., монг. **тэг-, дэг-* «киемне салу < үзгәрү» тамырыннан килә.

**Тиш-ү** < *тиеш-ү* фигылен **чиш-ү**нең бер варианты дип карарга ярамастыр. Төр. телендә *degiş-* бик продуктив сүзьясагыч нигез. Аның исем коррелянты *degiş* «алмашу; үзгәрү» тат. **әвеш-тәвеш** парлы сүзендәге *тәweш* белән гомоген.

**ТИҖАРӘТ** «торговля, коммерция» < гар. *тиҗāрат* id. ← *тҗр* «сәүдә итү», шуннан ук иске тат. **таҗир** «сәүдәгәр», к. ГТРС: 546–547.

**ТИЗ** «быстро, живо» < гом. кыпч. *тэз, тиз,* госм. *тэз,* төркм. *тииз,* хәз. төр. *tez* «тиз; кызу; иртүк, алдан ук, вакытыннан элек», чыгт. *тäз*, кар. *тäйиз, тäйз* «тиз», уйг. *тэзик* «тизген» һ.б. фар. *тūз, тэ̄з* id. сүзеннән хисапланыла (к. Радлов III: 1102, 1104, 1397; Räsänen 1969: 477), фар. сүзен исә бор. ир. тамырларга нисбәтлиләр (Platts: 351). Шул ук вакытта бор. төрки (ДТС: 1554, 557) *tez-* (~ чув. *тар-* < *тäр-*) «чабу, йөгерү» һәм *terk* «тиз» сүзләре дә бар. Аларның фар. сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел.

Тат. диал. (ДС II: 181; ТТДС I: 410) **тизгер** һәм **тизген** «җитез» сүзләре элек *тиз-* «тиз эш итү» фигыле булганлыгына ишарә.

**Тиз** продуктив нигез: **тизлек; тизлә-ү, тизлән-ү, тизләнеш, тизләт-ү; тиз-тиз** (күп төрки телләрдә очрый); **тиз бул!** ~ төр., аз. *тез ол!* һ.б. К. **Тиздән.**

**ТИЗӘК** «помёт; кизяк» < гом. кыпч. *тэзэк,* уйг. *тезәк,* госм., аз., кр.-тат., алт., шор., чыгт. (к. Радлов III: 1103; Боровков 1963: 295) *тäзäк,* к.-балк. *тезгек, тазгек* «тизәк, тирес» < безнеңчә, *киз-гәк* < *кэзгэк* ← **кэз-* «яргалану, кисәкләргә аерылу» (к. **Кизәк**) фигыленнән. А.Е. Аникин (: 288) рус. *кизик, кизек* вариантларын (*ти-* > *ки-*) рус телендә килеп чыккан ди (һәм бүтән авторларга да сылтана), ләкин *к-* > *т-* төрки сүзләрдә дә очраштыргалый. К. **Тизге.**

**ТИЗГЕ** (Г. Ибрагимов) «ровный с надтреснутой поверхностъю» ~ тув. *дески,* як. *дэхси* ~ монг. *дэргэ* «тигез (һәм өсте чатнаган)»; чаг. ш. ук морд. Э. *теръгев* «койкасыман». Ихтимал, бор. *кәз-* > *киз-* (к. **Кәз**) «өлтеләнү, яргалану» (тигез өсле ләм утырмасы тур.)» сүзеннәндер. К. **Тизәк.**

**ТИЗГЕР** «быстрый, расторопный» – тат. телендә генә булса кирәк. Ясалышы буенча ***тиз-ү** фигыленнән (ул фигыль конкрет теркәлмәгән).

Дерив.: **тизгерлек; тизгерлән-ү.**

**ТИЗДӘН** «скоро, вскоре» ← **тиз** (к.) сүзеннән үзенчәлекле ясалма, к. ш. ук **тизлектә** id.

**ТИЙР-Ү** (Тумашева 1992: 210) диал. «собирать (мелкие плоды, ягоды)» – к. **Тир-ү.** Гомумән, бу сүзнең дөрес язылышы әд. телдә дә *тийр-ү* булырга тиеш кебек.

**ТИЙ-Ү (тию)** – этимологик һәм морфологик принциплардан чыгып язганда шулай, чөнки **тий-ә** диелә, *ти-и* түгел!), себ. (брб.) **тәй-,** «касаться; трогать; посягать; воздействовать; попасть в цель; достаться на долю», себ. (Тумашева 1992: 208) **тәү-**

«попадать; трогать», (Дмитриева 1981: 187) *тäң-(тәң-)* «тию», башк. *тей-* id. Бу вариантларның төрлесе төрле ареаллардан килә: 1) **тей- < тий-** < гом. кыпч. *тий-, тэй-*, як. *тии-* ~ чув. *тив-*; 2) *тәү-* < *тэw-* бор. Себер ареалыннан; 3) *тәң-* ~ хак. *тэң* бор. хак. ареалыннан; болардан тыш төркм., тув. *дег-,* төр. *deg-,* аз. *дәй-,* госм. *дей-* һәм үзб., уйг. *тәк-, тэк-, тик-* «тию» һ.б. барысы да бор. төрки (к. Räsänen 1969: 468–469; Gabain 1950: 339; Боровков 1963: 292; ДТС: 546–549), диффуз *täg-//teg-//teŋ-* «тию, җитү» (бик күп дериватлары билгеле) тамырыннан фонетик җәһәттән закончалыклы рәвештә киләләр. К. ш. ук Радлов III: 1343; Будагов I: 419–420; ЭСТЯ III: 173–175; Федотов II: 226.

**Тий-** << *тэг-* (һ.б.) тат. телендә дә, бүтән төрки телләрдә дә иң продуктив сүзьясагыч тамырларның берсе; регуляр деривациядә: **тиел-ү, тиен-ү** (к.), **тиеш-ү, тидер-ү,** ш. ук **тигез-ү, тигер-ү** (йөкл. юнәлешенең аерым формалары мәгънәви җәһәттән бераз аерымлана). К. **Тәре I, Тиеш, Тикмә.**

**ТИК I,** диал. **тәк** «без дела; без причины; так просто», (ТХИ: Әкиятләр I: 183) «даром, без оплаты» > чув. *тĕк*, мар., удм. *так* id. < гом. кыпч. *тек [тэк]*, алт., куман. (Радлов III: 1014), бор. чыгт. (Боровков 1963: 295–296) *тäк,* хак. *тик,* төр. (YTS: 62) *dek, tek* «тыныч, сүзсез; хәрәкәтсез» һ.б. **тик II** белән бердәй – бер сүз, әмма аннан аермалы буларак, **тәк** вариантына ия. К. **Тиген.**

Дерив.: **тиккә** ~ хак. *тикке.*

**ТИК II** союз «но, только; только лишь; лишь бы; пусть; однако, вот только» > мар. диал. *тэк, тик* < гом. кыпч. *тэк,* алт., куман., госм. һ.б. (Радлов III: 1014–1014) *тäк* < бор. төрки (ДТС: 550) *tek* id. ~ чыгт., кар., төр., аз. һ.б. *тэк, тәк* «берүзе, бер генә, ялгыз; так» һ.б.

**Тик I** һәм **Тик II** һичшиксез бер үк тамыр сүздән, мәгънә үсеше «бер > бер генә төрле (*тик тору*) > хәрәкәтсез > сәбәпсез, ләкин һ.б.» булса кирәк. Чаг. ш. ук **Тиген.** К. Räsänen 1969: 470; ЭСТЯ III: 185 (Э.В. Севортянда материал һәм анализ бик ярлы); Федотов II: 211, 212 (ике сүз).

**Тик** (I, II) продуктив нигез: **тиккә, тәккә** (~ гом. кыпч. *тэккэ*); **тиктән-тик**, диал. (ТТДС II: 411–412, 438) **тикләй > тиклей > тикли, тикәй** «юкка». К. **Тикмә, Тиктәс.**

**ТИК III,** диал. **тәк,** иск. **дәк, дик** (к. Мөхәммәдьярда: *Мәрдәнәләр дик биленңне баглагыл*) «как, словно, наподобие» (хәз. телдә фольклор әсәрләрдә, җырларда гына кулланыла) < чыгт. *тик, тэк,* госм., аз. *тәк,* төр. *dik,* чыгт. *дәк* һ.б. id. < бор. төрки (ДТС: 546) *teg* id. – бор. *teŋ* сүзеннән аерымланган яисә борынгырак варианты *tenk* яңгырашыннан, к. ЭСТЯ III: 184–185, Clauson 1972: 475.

Бу сүз бор. чорларда ук аффикска әверелгән: тат. **-тай//-тәй, -дай//-дәй, -тый//-ти, -дый//-ди**, диал. **-тай//-тәү, -дау//-дәү** < чыгт., уйг., госм. **-таг//-тэг, -даг//-дэг** > алт. диал. *-тыг//-тиг, -дыг//-диг* – чагыштыру аффиксы, шуннан тат., кр.-тат., төркм., төр. һ.б. **-тайын//-тәйен, -дайын//-дәйен,** тат. **-тыйын//-тĕйĕн, -дыйын//-дĕйĕн** (к. *андыен, мондыен, шундыен* кебек күрсәткеч алмашлыклар) кебек **-тай//-тәй** һ.б.га беткән сүзләрнең инструменталь килеш формалары ясалган.

**ТИКӘЙ** (ТТДС II: 298; БТДҺ: 316) «постоянно, то и дело; грубый, непритязательный» – **дихай** (к.) сүзе белән бердәй булса кирәк. Шул ук мәгъ. (ЗДС: 632) **тикләй** (← **тик**) сүзе дә бар.

**ТИКӘН** (*Гөл тикәнсез булмый* дигән мәкальдә һ.б.), иск. (Будагов I: 369) **тикәң** «колючка» < гом. кыпч., уйг. *тикэн, тикән,* угыз. *дикэн, дикэн* id. < бор. төрки (ДТС: 558–559) *tikän, tikkän* «тикән, тигәнәк, тигәнәкле үсемлек» ← *tik* «кадау, чагу». К. **Тек-ү; Тигәнәк**. Мухамедова 1973: 87–88.

Дерив.: **тикәнле, тикәнсез; тикәнлек. Тикән** сүзе күп фитонимнарда очрый **каба тикән, кара тикән, Мисыр тикәне** «акация», **пәйгамбәр тикәне** «бөрлегән», **тикән уты** «аю табаны» һ.б. (Л. Будаговта һәм К. Насыйри хезмәтләрендә **тикәнле** үсемлекләрнең бик күп төрләре күрсәтелә).

**ТИКЕ, тәке** (ТТДС I: 411; 437) «до (чего)» ~ алт., уйг., чыгт. (Радлов III: 1033) *тәги, тәгин* < бор. төрки (ДТС: 547–559) *teg, tegi, tegin, teginč, tegün, teki* id. Тат. сүзе бор. төрки сүзнең соңгы, борынгырак вариантының дәвамы; бүтән төрки телләрдә очрамый диярлек (кыпч. телләрендә юк). Тамыры *teg-* «тию, барып җитү» (к. Щербак 1987: 87). ЭСТЯ III: 182–184. К. **Тәре I, Тире, Тикле.**

**ТИКЛЕ** «до (самого)», диал. **тәй** (сирәк), **тәке, тәклĕ, тикĕ, тикләй > тиклей > тикли, тиклем, тин, тиң, тиңĕлтĕ, тиңĕн, тиңĕнтĕ, тиңĕтĕ, тиңкĕ, тиңлĕ, тиңнĕ, тиңлĕк, тиңнән, тийĕн, тийĕнтĕ, тийĕнтĕн** (к. ТТДС I: 410–416, 437) ~ башк. (к. БТДҺ: 316–318, 337, тат. сөйләшләрендә булмаган вариантлар) *тиксе, тиксем* id.; к. ш. ук «Мәҗмугыль-хикәят» телендә *дәк, дәкĕн, дикĕн* «тикле»

~ госм., төр. *değin, deyin,* нуг. *дейим,* аз. *тейин, тейин*, төр. *değinçe* «тикле, хәтле», себ. (Тумашева 1992: 210) *тикру* ~ уйг., чыгт. (Радлов III: 1030) *тегру*, бор. төрки (Боровков 1963: 294) *тäгру* ~ кар., к.-балк. *дэри, дäри, дäйирä, тäгри,* як. *диэри* ~ чув. *терĕ, тери [тэрĕ, тэри]* ~ тат. диал. **тәре** id.

Гомумән, бу сүзнең вариантлары исәпсез күп. Аларның уртак тамыры *тәй//тәң//тәк* ~ бор. төрки (ДТС: 546–548) *teg, tegi, teki* «тикле», ш. ук *tegin, teginč* id. ниндидер бер **исем**нән килә (ЭСТЯ III: 184–185), ул исем **тий-ү** (к.) белән тамырдаш булса кирәк.

К. ш. ук Федотов II: 208.

**ТИКМӘ** «всякий; простой (человек)» < бор. төрки (ДТС: 548; Боровков 1963: 293) *tegmä*, *тäгма*, угыз. (Мухамедова 1973: 87) *дегме* (төр. *değme*) id. ← бор. төрки *teg-* «тию, очрау» фигыленнән булса кирәк.

**ТИКТӘС (тиктәстән)** «беспричинно» < *тиктәс* < бор. кыпч. *тәк-тәрс* барысы «тик карышып кына» (*тәрс* «кире», к. **Тирес**).

**ТИКТОМАЛ (тиктомалга, тиктомалдан)** «ни с того, ни с чего» < *тик тормалы* > чув. *тĕк-тăмал, тĕк-тăмалăх, тĕк-тăмалках* id. (к. Ашмарин XIX: 20). Диал. сөйләмдә **тыптымал, тŏптŏмал** яңгырашлары халык этимологиясенчә **тып-, топ-** иҗекләрен көчәйткеч аллитератив кисәкчә дип аңлаудан килеп чыкканнар. К. ш. ук **Токтомалга.**

**ТИКШЕ** (Насыйри), **тәкше** (Тумашева 1992: 206) «ровный, равный» ~ хак. *тикшĕ, тексĕ* «тоташ бергә алып», кырг., алт. *текши* «тоташтан, һәммәсе; тигез, тиң»; каз. *тексi, текшi*, куман. *teksi* «тоташтангы, (гомуми) тигез, тиң» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 345) *tekši* «тигез, гадел» һ.б. К. ш. ук тув. *дески < декси* «тигез, тиң». Чаг. чыгт. (Радлов III: 1025) *тäкшä-* «тигезләү; уңыш җыю (тоташ алу)» < **тäкишä-*. Сүзнең тамыры **тәң* «тиң» дип уйларга мөмкин.

**Тикше** сыйфатыннан гомуми закончалык буенча *тикшер-* «тоташ тигезләү; тиңләштерү» ясала ала. К. түбәндәгене.

**ТИКШЕР-Ү,** сөйл. **тишкер-ү, тәкшер-ү** «разбираться, разбирать дело; исследовать» > чув. *тикшĕр-*, мар., удм. *текшыр* һ.б. id. < гом. кыпч. **тәкшир-,* к. кырг. *текшер-*, каз., к.-калп. *тексер-,* үзб. *текшир-,* уйг. *тәкшүр-* һ.б. id. Будагов (I: 417–418) фикеренчә, **тәкиш* ~ төр. *değiş* «үзгәрү, алмашыну, алмашу» сүзеннән йөкл. юн., к. бор. төрки (ДТС: 548) *tegiš* «алмашыну», *tegšür-* < *tegištür-* «алмаштыру», *tegšüt* «алмашу, алмаш». Ш. ук тат. (миш.) **тишкер-** > чув. *тишкер-* «икърар итү, тану; тикшерү; яхшы белү» ~ кр.-тат. *тишкәр-*, нуг. *тешкер-* «тикшерү» (бу сүз бүтән бер тамырдан да була ала). Гомумән, «тикшерү» һәм «алмаштыру» мәгънәләренең бердәйлеге шик уята. Бәлки берсенең **тиңәштер-ү**гә катнашы бардыр.

Бор. *tegiš* «алмашыну» исә бор. *teg-, täg-* «әйләнү» фигыленнән дә (к. **тәгәр, тәгәрә-ү**) сүзеннән дә була ала. К. ш. ук тат. **Тәвеш** ~ төр. *deriş* «алмаш».

**Тикшер-** нигезенең морфологик җәһәттән **тәкше-* яки **тәңиш-* нигезеннән була алуы *-ч, -ш* авазларына беткән фигыльләрнең йөкл. юн. формалары **-ыр//ер** < *-ыр//ир* кушымчасы ярдәмендә ясалучанлыгыннан да күренә, чаг. *кач-* → *качыр-у, төш-* → *төшер-ү* һ.б.ш.

Дерив.: **тикшерел-ү, тикшерен-ү, тикшереш-ү, тикшерт-ү, тикшерендер-ү** «тикшеренергә рөхсәт яки мөмкинлек бирү»; **тикшерттер-ү; тикшерелеш; тикшерүче; тикшерүчән** һ.б.

**ТИЛ I** диал. «душа; помыслы, мысли, мнение» (к. мәкаль: *Тилемдәге телемдә*) < фар. *дӣл* «күңел».

Дерив.: **тилхат** «расписка».

**ТИЛ II: тил (тилү) булу** «быть иждевенцем» (к. мәкаль: *Теле татлы бозау ике инәгә тил булыр* «телёнок со сладким языком будет сосать двух маток») ~ кырг. *тел (эки энеге тел)*, як. *тиил* «ике сыерны (инәне) имүче бозау (яшь терлек)» ~ монг. *tel* id., к. ш. ук тув. *тел* «ике инәне имеп үскән», каз. (ҚТДС: 321) *тел өсу* «бик тиз үсү», тув. *тел ыяш* ~ башк. *тил ағас* «куш агач», кырг. *тел* «янәшә ике нәрсә». Гомоген мәгъ. фигыль *тил-ү*нең исем коррелянты, к. **Тил-ү.** Räsänen 1969: 471.

*Тил, тилү* сүзе белән рус. *тель, теля* «бозау» сүзе тамырдаш булуы бик ихтимал (бу сүз славяннарга һуннардан калырга мөмкин).

**ТИЛӘСКӘҮ [тиләскәw]** «придурок, дурашливый» – *тиләскә-ү* (к.) фигыленең исемләшкән формасы.

**ТИЛӘСКӘ-Ү** (ДС II: 182) «дурить» ~ гом. төрки параллельләре юк. Ачык түгел. Әлбәттә, *тиле* сүзе белән гомоген. Ихтимал, бу сүздә чув. телендә актив кулланышлы *-шка//-шке* кушымчасы вариантлы чагыладыр, к. **Тилбәшкә.**

**ТИЛБӘ** «глупый; шатун (о скотине)» < гом. кыпч. *тэлбэ, дэлбэ*, чыгт. (Радлов III: 1389) *тилбä*, алт. диал. *тилби* «тилбә; әйләнчек авыруы (терлекләрдә)», бор. төрки (Боровков 1963: 296) *тäлwä*, (ДТС: 551) *telwä* «тиле», як. (Пекарский: 687) *дäлби* «бигрәк тә, чиктән тыш», каз., төркм. *делбе* «котыру авыруы», башк. (БТДҺ: 316) *тилбә, тилбегән* «тилберән орлыгы» – *тиле* < *тэли* сүзеннән сирәк очрый торган *-ба//-бэ* кушымчасы ярдәмендә ясалган (ЭСТЯ III: 214–217). К. **Тиле.**

Дерив.: **тилбәлек; тилбәр-ү** (Будагов I: 514).

**ТИЛБӘШКӘ** «дуралей» – **тилбә** сүзенә *-шкә* (иркәләү-кечерәйтү) кушымсачы ялганып ясалган, чаг. *Кәкрешкә, Көмешкә, Тәртешкә,* ш. ук **Кырмыска.**

**ТИЛБЕРӘН,** диал. **тилбәрән, тилебәрән,** (ТТДС I: 604) **тилебәлән, тилемилән**, (Будагов I: 422) **тилүрәңге** «белена» ~ башк. (БТДҺ: 316) *тилбегән, тилмерән, тилмерлән, тилбиҙән* (*р* > *ҙ!*), *тилбүлән* (*тилбә үлән*) һ.б. (күп вариантлар) – рус. *белена* сүзе белән баглы булса кирәк, к. алт. *бэлэ, пэлэ* «балан; тилберән». Рус сүзе күп телләргә таралган халыкара сүзләрдән берсе, к. Kluge: 123. Тат., башк. әд. **тилебәрән** дип язу халык этимологиясеннән килә: имеш, тилберәнне ашап бәрәннәр тилерә! Хайваннарның агулы үләннәргә карата инстинктив сизгерлеге яки иммунитеты бар, алар тилберән орлыгын ашамыйлар бугай. Тат. әд. нормага без диал. (трбс.) **тилберән** яңгырашын тәкъдим итәбез – шулай итсәк әлеге ялгыш этимологиядән дә котылабыз. Нәкъ шул яңгыраш күрше телләргә дә алынган: чув. (Федотов II: 230) *тилпĕрен*. К. ш. ук диал. **тилерән** < *тиле өрәңге* «тилберән» (тилберәннең яфрагы өрәңгенеке шикелле).

**ТИЛГӘН, тилегән**, диал. (ДС II: 202; ДС III: 168; ТТДС I: 442; Тумашева 1992: 208, 210, 220) **тилгәткән, түлгән, түлегән, теүлегән, теүләткән, тәүелгән, тәүләткән, төйлегән, түллегән, түрлегән, түлгән** һ.б. «коршун» ~ башк. (БҺҺ II: 255; БТДҺ: 315, 325) *тийҙегән, төйлөгән, төйләгән, төлөгән* һ.б.– бүтән төрки телләрдә дә ш. ук күп вариантлы кош атамасы (аның мәгънәсе дә конкрет тикшергәндә төрлечәрәк булырга тиеш): хак. *тигĕлген,* алт. *тэлгэн, тейлеген* (Радловта *тäjläгäн*), чыгт. (Радлов III: 1529) *түjläгäн, түläгäн,* ком. *түлүген,* госм. *түläк, дүläк* «тилгән». Кайбер төрки телләрдә бу сүз бөтенләй бүтән кошны белдерә: кырг. *телиген* «бәләкәй лачынның иркәге» (>> мар. *түлеген* «лачын»), шор. *тäглäгäн* «бөркет». Иң үзенчәлекле вариант тув. *дээлдиген* «тилгән». Кайбер телләрдә тилгән бүтәнчә атала, мәс. чув. *хăлат*, төр. *şaylak* һ.б.

Бу сүз гомумән бор. төрки *тэгил-, тэңил-* (к. як. *тäгäліі-* «әйләнә ясау») «әйләнә ясау, әйләнеп очу» сүзеннән, тик шуның төрле дериватларыннан һәм модификацияләреннән булырга тиеш, к. алт. диал. *тäлигäн* «һавада әйләнүчән; тилгән». Бор. төрки (ДТС: 552, М. Кашгаридан) *teŋälgüč, teŋälgün* «карчыгасыман кошчык» ← *tenäl-* «күтәрелү» сүзе дә контаминацион тәэсир ясагандыр, дип уйларга кирәк. К. ш. ук каз. *түйүл-* «туп-туры аска ыргылу (ерткыч кош тур.)», бор. төрки, бор. уйг. *tilgän* «тәгәрмәч, әйләнчек». К. **Тилгәнтас.** Gabain 1950: 341; Räsänen 1969: 469.

**ТИЛГӘНТАС, тастилгән** (Тумашева 1992: 210) «коршун, вид коршуна» – **тас** монда монг. *тас* «бөркет, зур каракош» дигәннән. К. **Тас III.**

**ТИЛЕ** «глупый и страстный» > чув. диал. *тилĕ,* мар. (Исанбаев 1978: 11) *теле,* (ихтимал) *тале* id. < гом. кыпч. *тэли,* куман., кар., алт., угыз. (Радлов III: 1083, 1678) *дäли,* уйг. *дәлли* «ахмак; батыр, дәртле; беркатлы», иске чыгт. (Боровков 1963: 117) *дäлү* ~ бор. төрки (ДТС: 551) *telü* «җенле», төркм. *тәәли* id., *дәәли* «җенле, дуамал; фидакяр», уйг. *дәл-,* кырг. *дел* «шашкын», *тели* «әйләнчек авыруы», хак. *телĕк* «аңсыз, аңгыра». Тат. *тиле,* ком. *тели,* төр., кр.-тат. *deli, däli, dälü* «чамасыз зур, чамасыз көчле (үсемлекләр, ш. ук табигать күренешләре тур.)» мәгънәсе күрше телләрдә дә кабатлана: морд. *дурак куяр* «тиле кыяр, кабак», кабарда *жыгделэ* «агач тилесе» – «чаган».

*Тиле* < *тэ̄лиг* сүзен бик төрлечә аңлатырга мөмкин.: алт. диал. (Радлов III: 1083–1084) *тäлі-* «тинтерәү, каңгырау» (← *тэг* «түгәрәк»?) сүзеннән дә, шор. (Радлов III: 1081) *тäл-* «илһам алу (шаман тур.)» сүзеннән дә, бор. төрки *tel-* «акылдан язу; игътибарсыз кылану» (к. ДТС: 550) фигыленнән дә (бу варианты Э.В. Севортян яклый, к. ЭСТЯ III: 214–217). Безнеңчә, бу сүз бор. ир. *тэв* < *дэв* «дию, җен» алынма сүзеннән дә ясалырга мөмкин: **тэвли* «диюле, җенле» (бу фараз «исәр, юләр» һәм «гадәттән тыш зур» мәгънәләрен дә аңлата). Чаг. ш. ук **Тилбә.**

**Тиле** сүзе продуктив нигез: **тилелек; тилеләнү, тилер-ү**, к. **Тиләскә-ү, Тилбә, Тилбәшкә, Тилберән, Тилемсә.** Шулардан *тилер-* сүзе чув., мар. телләренә алынган, к. Федотов II: 229.

**ТИЛЕМСӘ** «глуповатый, дебильный» – тиле сүзенә *-мсә* кушымчасы (чаг. *җылы → җылымса, тулы → тулымса*) ялганып ясалган.

**ТИЛКЕН** «порыв ветра» – чаг. *җилкен-ү* һ.б. имитатив нигезләр. **Тилкен** сүзенең ясалышына **тиле** сүзе тәэсир иткән булса кирәк.

Дерив.: **тилкенлә-ү** (тилкенләп искән җил), **тилкенләй** (ТТАС III: 98) «бер омтылыш белән»; **тилкен-тилкен** «кинәт-кинәт». Чаг. **Тилпен-ү.**

**ТИЛМЕР-Ү** «томиться, страдать, быть в острой нужде; смотреть с надеждой» ~ чув. *талмăр-* (< болг. **тәлмер-*), *тилмĕр-, тĕлмĕр-* (< тат.), чув. диал. (Сергеев 1971: 127) *тимĕр-* (чаг. себ. *тĕмĕр-* id.), мар., удм. *тэлмир* < гом. кыпч. *тәлмир-* (каз. *тэлмĕр-*) «тилмереп карау», уйг. *тәлмур-,* гом. угыз. *дәлмир-* һ.б. (к. ЭСТЯ III: 186–187). М. Рясянен (Räsänen 1969: 472), бор. төрки (МК II: 179) *telim telmirdi* «күп тилмерде» сүзеннән чыгып, сүзнең тамыры бор. төрки *telim* «күп» дип бара; ихтимал, **telim jer-* «күп елау» (к. чув. *йер-* «елау»). Ләкин к. к.-калп. *телмий-* «тилмерү» бүтән фаразларга да юл ача, к. ш. ук алт. диал. *тилби* «көчле теләк; көчле ихтыяҗ» *тилбилäн-* «тилмерү» (к. Радлов III: 1389), иске тат. **тилбәр-ү** «тилбәләнү» (к. Будагов I: 564). Федотов II: 229.

Дерив.: **тилмерел-ү, тилмерен-ү, тилмереш-ү, тилмерт-ү.**

**ТИЛПЕН-Ү** «несильно махнуть крыльями; колебаться, отряхиваться» (Радлов III: 1388) «порываться» – күрәсең, *тилпе-* (фиксацияләнмәгән) фигыленең кайт. юн.; һичшиксез, тәкълиди тамырдан (**тилп-тилп; тил//тәл//тал* тәкълиди тамырының *-п-* детерминантына беткән тармагыннан), чаг. *тилбер < тилпер.* Чаг. як. (Пекарский: 2627) *талыбыр-, тäлiбiрä-, тäлiбрä-* «калтырау, тетрәү».

Дерив.: **тилпенеш-ү, тилпендер-ү.**

**ТИЛ-Ү, тиле-ү** «приучать сосать другую матку (преимущественно о телятах)» – бу сүз башк. сөйләшләрендә (к. БҺҺ II: 171) һәм татар дастаннары телендә (Идегәй 1988: 195 һ.б.) очрый < гом. кыпч. *тели-*, як. *тилий-* id., төр. *tel-* «бозауны анасына имәргә җибәрү» һ.б. < бор. төрки (ДТС: 550) *tel-* id. (аның исем компоненты тур. к. **Тил**). К. ш. ук кырг. *телки*, алт. *телкин* «ана коралай», алт. *телди* «сыер, кәҗә һ.б.ш. имчәге», *телде- (< телле-)* «имчәк үсү».

**ТИЛЦАМ** (Тумашева 1992: 210) диал. «потихоньку, не спеша; обдуманно, обстоятельно» < фар. *дилҗам* id. (*дил* «күңел, уй» **-җам** аффикс). Чаг. иске тат. **хәтерҗам** «хәтердән чыгармаучан».

Деривация (тик Себердә генә): **тилцамлы** (кеше); **тилцамла-у.**

**ТИЛЧӘ** «золотуха; болезнь (опухоль) желез» > чув. *тилче, тилçе,* удм. *тэльсе*, мар. *телеза* «тилчә, рак» < гом. кыпч., к. к.-балк. *телче*, нуг., каз. *телше* id.; чыгышы ачык түгел, башк. *силсә < *силчә ~ чилчә* «сифилис, тилчә» сүзеннән дип фаразларга мөмкин, бу гипотетик сүз үзб. *сил* < фар. *селл* «туберкулёз» нигезеннән булуы ихтимал. **Тилчә** яңгырашы *чилчә* вариантыннан дистант диссимиляция нигезендә ясала ала. Федотов II: 230 (бик ярлы).

Әшәке сүз әйтүчегә каргыш итеп *телеңә тилчә тисен (чыккыры)* тәгъбирендә **тилчә** ~ кр.-тат., төр. *telçe* «тимер шырпы, тимерчыбык кисәге» булырга мөмкин. Чаг. ш. ук. төр. *delice* «тиле бодай (бик ачы бер чүп үләне)».

**ТИМ** (Тумашева 1992: 210; БТДҺ: 317) «время, момент; до момента чего» ~ хак. *тим* id., фар. *дәм* сүзеннән бор. кыпч. шивәләре аша (*д- > т-*) кергән. К. **Дәм.** Күбесенчә **тим-тим** формасында кулланыла.

**ТИМГЕЛ, тимкел** «пятно (на теле)» к. **Тимрәү.**
Дерив.: **тимгелле, тимгелллән-ү.**

**ТИМЕР** «железо; железный» > чув. *тимĕр* < гом. кыпч., алт., куман. һ.б. (Радлов III: 1133) *темир, тäмир,* хак. *тимĕр*, уйг., чыгт. *темур, тәмүр* < бор. төрки (ДТС: 551) *temir, temür* ~ угыз. *дәмир, демүр*, бор. чыгт. (Поппе 1938: 436) *demür* ~ уйг. диал. *тöмүр,* бур. *түмэр* «тимер; тимер деталь», яз. монг. *temür,* хәз. монг. *төмөр* һ.б. (күп телләрдә очрый) id., барча телчеләр фикеренчә, бор. кыт. *тэ мур* «тимер әйбер» сүзеннән, к. Räsänen 1969: 232; ЭСТЯ III: 188–190; Федотов II: 231–232; ССТМЯ II: 235 һ.б. Кайбер тәгъбирләр тур. к. Будагов I: 377–378; Тимергалин: 468.

Дерив.: **тимерле, тимерсез; тимерлә-ү, тимерлән-ү; тимерче, тимерчелек, тимерлек** «тимерче алачыгы» сүзе борынгыдан килә: (ДТС:551) *temürlük* «тимер эретү урыны». К. **Тимерказык, Тимеркүк.**

**ТИМЕРКАЗЫК (йолдызы)** «Полярная звезда» < гом. кыпч., чыгт. (Будагов I: 377–378) *темир*

*ҡазыҡ, темүр ҡазыҡ* id. (бу казыкка күктәге мифологик атлар бәйләнгән була, к. *Җидегән йолдызлыгы* һ.б.) < бор. төрки (ДТС: 298) *temür qazïŋuq* id. Чаг. төр. *demir mih* «тимер кадак», чув. *тимĕр шалча*, алт. *Алтын ҡазыҡ* ~ монг. *Алтан гадас* id. Аникин: 297–298 (рус. *Кол-звезда* тур.).

**ТИМЕРКҮК** «тёмно-сивый (о лошади)» – букв. «цвета синего железа» ← **тимер + күк**, әлбәттә. Бу тәгъбир күрше телләрдә калькалаштырылган, к. чув. *тимĕркăвак,* удм. *корт кук*, мар. *кыртнигӧк* id. (удм. *корт*, мар. *кыртни* «тимер»).

**ТИМЕР-ТОМЫР** «всякие железки, металл»: бу парлы сүздә икенче компонент **томар** «тимер корал (ук, сөңге һ.б.)» белән бердәй булуы ихтимал.

**ТИМЛӘК, тәмләк,** (Троянский) **тәмлик,** (Тумашева 1992: 206) **тәмдәк** «ремень на ручке кнута; тесьма с кистью на шпаге» ~ алт., хак., тув. *темдек* «билге, галәмәт; тамга, чук, металл билгелек». Кырг. *темгек* «биркада сызык, чый; чин: иерархиядә бер баскыч». Рус *темляк* < тат. Аникин: 545 (күп рус материалы китерелә). К. түбәндәгене.

**ТИМРӘҮ [тимрәw],** сөйл. **тимерәү,** диал. (себ., к. Радлов III: 1317) **тәмрәү** «лишай (на коже)» > чув. *тимре, тимĕре, тимĕрел,* мар. (Исанбаев 1978: 18) *темырау* id. (чув. *тимĕрел* < тат. **тимрәле, *тимĕрәле,* к. каз. *тĕлмәр* < *тĕмрәлĕ* «рожа – авыру») < гом. кыпч. *тэмирэw,* хак. *тиберее, тимірӧ, тимирӧ*, сагай. *тирбе* < бор. төрки (МК; ДТС: 551) *temrägü* «тимрәү» – төр. диал. *demregü* ← бор. **temre-* «тимгелләнү» сүзеннән; төркм., төр. *демрев* – кыпч. телләреннән, төр. *temriye, temregi, дӓмрӓйи* (к. Радлов III: 1137) вариантлары да бар; к. ш. ук алт. *темирүү* «тимрәү».

Тат. диал. **тимрәтке** ~ гом. кыпч. *тэмирэтки* (каз. *тӓмірӓткӓ,* Радлов III: 1133), уйг. *тәмрәткә*, төр. диал. *demretkü* һ.б. ← **temret-* «тимрәтү», ягъни **temre-* фигыленең йөкл. юнәлешеннән.

Л. Будаговтан (I: 377) алып этимологлар бу сүзне **тимер** < *temir* сүзенә нисбәт итәләр (к. ЭСТЯ III: 190). Безнеңчә, бу дөрес түгел – *тимрә-* < *temre-* фигылен *тимгел* < гом. кыпч. *тэмгил* «тап, тимрәү эзе» сүзеннән аерырга ярамый. Бу сүзләрнең уртак тамыры алт. *тем* «билге; бирка», бор. кырг. **тем-* «билгеләү, тамгалау» (шуннан кырг. *темгек* «билге итеп ясалган кирт»), к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 206) **тәмдәк** ~ алт. *темдек*, тув. *демдек*, монг. *тэмдэг, дэмдэг* «билге, тамга, табра; ырым; намус» ~ маньч. *тэмгэ* id. (к. ССТМЯ I: 233). Димәк, *тимрә-* < *тэмрэ* < *тэмир-э-* «тап, тимгел төшү» чыннан да **тэмир* нигезеннән, ләкин бу тамыр *тимер* < *тэмир* – металл атамасы белән бердәй түгел – ул *тэм* тамырыннан (*тэм-и-р* булса кирәк), к. алт. *темис* < **тэмиз* тиренең йонсызланган төше < **тэмирг*. К. **Тәмдәк.** Федотов II: 232; Рамазанова 2013: 305–307 (күп материал китерә).

**ТИМСАХ** «крокодил; крокодиловый (о коже)» < гар. *тимсāх* id. Будагов I: 277.

**ТИМТЕН-Ү** (Будагов I: 422) «колебаться», (ТТАС III: 100) «стараться по мере сил; напрягаться», уйг. *дәндә-, дәнди-* «гадәтләнү» ~ башк. (БҺҺ II: 249) *тимтәл-еү*, алт. *тэмтин-, темтен-* «ярышта алга чыгу, ярышу (ат тур.)», төр. *temtin-* «көчергәнү», **тимте-* < **temti-* «талпыну, күтәренкелек кичерү, очыну» сүзенең кайт. юн., к. як. *тэмтэй-* «рухлану; югары күтәрелү» ← бор. төрки *teŋ-* «югары күтәрелү» (к. ДТС: 551–552). Гомумән, бу чагыштырулар шик астында.

**ТИН I** диал. «копейка» (в отличие от **тиен** «белка») ~ гом. кыпч., үзб., фар.-таҗ. *тин* id., к. **Тиен.**

Дерив.: **тинлек.**

**ТИН II** (ЗДС: 633) диал. «хәзер генә, бергә» < чув. *тин* id.

**ТИНАС** (ТТДС I: 462) «подвязка обуви; стяжки чулков» – чув. *тынас* id., чув. филологлары (к. Федотов II: 267–268) фикеренчә, гом. төрки *тӓң-* «бәйләп кую» сүзе белән бәйле. Ләкин к. мар. (Упымарий: 220) *тыҥас* «тәгәрмәч».

**ТИНӘК** (Тумашева 1992: 211) «заразная болезнь; припадок» < *тинә-ү,* (ЗДС: 618) **тәне-ү** «һуштан язу; бер урында әйләнү (авырудан)». К. **Тинтәк, Тинтерә-ү.**

**ТИНӘ-Ү** «испытывать; доводить до кондиции» к. **Тәнәй-ү, Төнә-ү II.**

**ТИНТӘК,** диал. **тәнтәк, тинти** «неспокойный дурак», диал. (Тумашева 1961: 200) «просто так» < гом. кыпч. *тентек [тэнтэк]* «ахмак, тинтәк; сукбай», себ. тат., каз. (ҚТДС: 328) *темнтек* «әйләнчек авыруы», (Будагов II: 398–399) *тентек* «җинаятьче, сукбай», чыгт., кр.-тат. *тӓнтӓк,* як. *тэнтик, тӓнтік* id. ← себ. (ЗДС: 618) **тәнде-,**

**тәне-,** гом. төрки *тэнтэ-, тэнти-* «әйләнчек авыруы белән авыру; бер урында әйләнү; тик йөрү» фигыленнән. К. алт., кырг. *тинти-*, төркм. *тенте-* «әйләнеп йөрү, тик йөрү» ~ калм. *dendi-* «аптырау, каңгыру», монг. *dendüji-* id. һ.б. (сүзләр күп). Чаг. фар. *дәнд* «тинтәк» (< төрки).

*Тинтәк* < *тэнтэк* ← *тэнтэ-* белән параллель рәвештә себ. *тинәк* «өянәк» (к. **Тинәк**) ~ алт., тув. *тенек* «идиот, алйот, наян» ~ як. (Пекарский: 2634) *тäнiк*, бур. *тэнэг,* калм. *тенг* «ахмак; юкка йөремсәк» ← уйг. *тен-, тән-, тени-, тәни-* «адашып йөрү», уйг. диал., алт. (к. Радлов III: 1057–1058) *тäнä-, тäнi-, тини-* «юкка йөренү, каңгыру» ~ монг. *тэнэ-, тэнү-* id. сүзләре дә бар. *Тэнтэ-* һәм *тэнэ-* фигыльләре уртак тамырдан, әлбәттә, ул тамыр – уйг. *тән-*, төркм. *дәән-*, алт. *тäн-, теен-* «юкка әйләнеп йөрү» < бор. чыгт. (Боровков 1963: 298) *тäн-* «алдашу» ~ хак. *тин* «бераз баш әйләнгән хәлдә булу» булырга тиеш. Gabain 1950: 167; Räsänen 1969: 473. К. **Тинтерә-ү.**

**Тинтәк** продуктив нигез: **тинтәклек; тинтәклән-ү.**

**ТИНТЕРӘ-Ү,** (ЗДС: 618) **тәнтерә-ү** «терять рассудок, сбиться с толку» ~ гом. кыпч. *тэнтирә-*, каз., хак. диал. (Радлов III: 1363) *тiнтрä-*, тув. *тендири-*, як. (Пекарский: 263) *тäмтäрии-* «тик йөрү; каушау; абынгалау, каңгыру», алт. (Радлов III: 1057) *тäнтĕр-* «абынгалау; каңгыру» ← **тäнтиг* «башы әйләнгән».

Кырг. *танты-* «ниҗиттене сөйләү», *тантыры-* «тинтерәү», *тантыт-* «тинтерәтү» сүзләренең веляр рәттәлеге табышмаклы: ул сүзләр бор. вариантны чагылдырамы яисә велярлашу нәтиҗәсеме икән? Гомумән, **тинтерә-ү** фигыленең ясалышы ачык түгел, тамыры, әлбәттә, *тэн* «баш әйләнү», к. **Тинтәк.** Чаг. **Диңкү.**

Дерив.: **тинтерәт-ү**; (ЗДС: 618) **тәнтәрәк, тәнтерек** «глупенький» (иркәләү мәгъ.). Диал. (ЗДС: 633) **тинтереп** «көчләп», **тиндрәкләп** «тилереп».

**ТИҢ** «равен; равный; друг», «вместе одновременно» ~ чув. *тан* < болг. **тәң* id. > мар. (Иванов, Тужаров: 215 һ.б.) *тäң* > *таң*, чув. (< тат.) *тин* id. (өченче мәгъ.) < гом. төрки, гом. монг. *тэң, тäң*, угыз. *дэң, дәң* id. – барча этимологлар күрсәтүенчә, бор. кыт. *têng* «тиң, бердәй; үлчәү» сүзеннән (Gabain 1950: 340). Ихтимал, себ. (Тумашева 1992: 211) *тиң* «ике агачтан торган сөйрәтке» сүзе дә шул тамырдандыр (шуннан себ., урта диал. **тиңә-ү** «төяү», иске тат. **дәң** «төгәл» сүзләре дә килергә мөмкин). Төрек телчеләре үзләренең *denk* «тиң» сүзен фар. теленнән алынган диләр. Будагов I: 421 (күп сүзле); Räsänen 1969: 473; Федотов II: 170–171.

*Тиң* < *тэң* төрки телләрдә киң мәгънәле һәм бик күп дериватлар биргән тамырларның берсе (к. ЭСТЯ I: 191–193): **тиңле, тиңсез, тиңлек, тиңлә-ү, тиңдәш,** диал. (Тумашева 1992: 211) **тиңәл, тиңләк** «тигез», **тиңгеләй** «яшьтәш» һ.б. К. **Тәңгәл, Тиңә-ү, Тиңгел, Тиңен, Тиңгенәй.**

**ТИҢӘШ** диал. «верный друг, кореш» ~ башк. диал. *тиңкәш,* мар. (Иванов, Тужаров: 215) *тäңäш* «дус егет» << уйг. *тäңäш* «яшьтәш; иш» (к. Радлов III: 1044) < *тәң-әш* «тиң-иш» булса кирәк.

**ТИҢӘ-Ү** диал. «быть равным, равняться» << бор. төрки (ДТС: 551–552) *tenä-* id. Бу сүзнең урт. юн. – тат., башк. **тиңәш-ү** «тиң килү» < бор. төрки *teŋäš-* (ДТС: 551–552) «тиңләшү» > уйг., болг. *тәмәш-* > мар. диал. (Саваткова: 187) *тäңäш-* > чув. *танаш-* һ.б. киң таралган. К. ш. ук себ. **тиңәл-ү** «тиңләшү». К. **Тиң.**

**Тиңәш-ү ~ тәңәш-ү** сүзенең мар. параллеле *таңас-* бик киң һәм төрле мәгъ. кулланыла: «чагыштыру, ярышу»; *таңаш* < *тәңәш* «дус, тиңдәш» сүзе дә бар һ.б.

**ТИҢГЕЛ, тиңел, тиңкел** диал. «определённое место» (**тиңелендә, тиңгелендә** «в определённом месте») < **тиң-кел* < **тэңкил* «тирә, нәрсәгә дә булса тиң урын» сүзеннән. Чаг. тув. *деңгел* «кимәл».

**Тиңгел** нигезеннән **тиңелте, тиңелтен** кебек бәйлекләр ясалган.

**ТИҢГЕНӘЙ** диал. «член девического союза из двенадцати девушек одного поколения» ← *тиңгенә* (*тиң* «дус, ахирәт» сүзенең иркәләү формасы).

Бор. төркиләрдә һәм кытайларда 8–15 кыз бергәләшеп, бер-берсен «карендәш» дип йөртү гадәте булган (к. Л.Н. Гумилёв 1993: 74). Татар **тиңгенәйләре** бер-берсенең туенда катнашырга килешкәннәр һәм кыз чакларында бертөсле киенгәннәр. К. **Көмәй.**

**ТИҢЕН** «с, величиной с, вровень с» – **тиң** сүзенең (к.) инструменталь килеш формасы. **Тиңеш** нигезеннән шул ук мәгъ. диалекталь **тиңенте, тиңентен** һ.б. (Рамазанова 1984: 109; Садыкова 1985: 96; Хайрутдинова 1985: 97) бәйлекләр ясала.

**ТИҢСӘ-Ү** себ. (Будагов I: 371) «волноваться» (**тиңсәү** «зыбь») – **тиңес-ә-ү** «диңгез кебек булу» сүзеннән, к. себ. *тиңгес* ~ башк. диал. (БТДҺ: 317) *тиңкес* «диңгез». К. ш. ук *тиңсәл-ү* (Гиганов) рус. «колебаться» сүзенә эквивалент (к. Тумашева 1992: 211).

**ТИП I** (ТТДС I: 412) «подпор воды; обратное течение (во время половодья)» ~ чув. *тапӑ* < болг. **тәп* id. **Тип-ү (тибү)** белән бердәй булса кирәк, к. ш. ук каз. (ҚТДС: 324) *тәпі* «типкен, тип». М. Федотовның (II: 173) чув. сүзен мар. *таве* «кое» белән чагыштыруы бөтенләй гайре табигый, ләкин аның алт. диал. (Радлов III: 1123) *тäбүү* «су култыгы» белән чагыштыруы игътибарга лаек.

**ТИП II** «односторонний плоский барабан, бубен» ~ ком. *теп*, кар. *даф, дэф, таф*, каз., к.-калп., үзб. (ЎХШЛ: 81) *дәп*, аз. *дәф, дэф*, таҗ., фар. *дафф*, фар., көрд. (к. Будагов I: 560) *дäф*, төр. *def, tef* id. Безнеңчә, фар. *тäбл*, гар. *ṭабл* id. (*ṭаббāл* «барабанчы») нигезеннән, к. уйг. диал. *тебил* «литавра» һ.б. < аккад. *tabállu* «хәрби барабан»; шул ук сүздән к. **Давыл, Тибрә-ү.** К. ш. ук уйг., әрм. һ.б. *дап* «зур барабан» (гомумән бу сүз барча Кавказ телләрендә, Һиндстанда һ.б. киң таралган). К. **Типсә-ү.**

**ТИП III [т′ип]** «тип» < рус. < фр. *type* < лат. *typus* < грек. τυπος «эз, сугу эзе». К. **Типик.**

**ТИПИК** «типичный» – турыдан-туры фр. теленнән (анда *tipique* «типик»).

**ТИПКЕ** «удар ногой», «побои, пинки», сөйләшләрдә һәм башка төрки телләрдә бик күп күч. мәгъ. К. **тәпке, типкен** һ.б. Әлбәттә, **Тип-ү** (к.) фигыленнән.

Дерив.: **типкелә-ү, типкелек** һ.б.

**ТИПКЕН** «побои»; техникада «обратный удар»; «прилив моря; паводок весной», «ловкий, добычливый (о ловчих птицах)» һ.б. төрки телләрдә параллельләре күп түгел шикелле.

Дерив.: (Тумашева: 211) **типкенцәк** «чәңгелчәк»; **типкендә йөрү.**

**ТИПСӘ-Ү** «петь песни, нарочито издеваясь над женихом (чтобы не зазнался) во время свадьбы» (совершенно неверно у Тумашевой – 1992: 211 – о том, что якобы **типсә-ү** «восхваление жениха»), брб. (ДС I: 194) **тәпсә-ү** «игры во время свадьбы» ~ к.-балк. *тепсе-* «бию; биюнең бер элементын башкару», як. *тэпсии* «якут халык уены, милли биюнең бер элементы» ~ бор. монг. (< төрки) *däbsägü* «бию».

Бу сүз бер үк вакытта «үчегү, мыскыллау» һ.б. мәгъ. дә алган, к. бор. төрки (ДТС: 553) *tepsa-, tepzä-* «көнләшү», (Боровков 1963: 299) *тäпсä-* «көнләшеп ачулану» >> каз. *тепсе-* «тынгы бирмәү». Бу сүзне халык этимологиясенчә *тәп-* «тибү» сүзенә дә нисбәт иткәннәр, к. алт., кырг. *тепсе-* «таптау, өстенә басу; юк итү», уйг. *дәпси-* «таптау; сугу, тибү». Ләкин КБтә этимологик бәйләнышларны ачыкларга ярдәм иткән шундый юллар бар:

*Тәбизлик болур бу капугда öкүш,*
*Тәбиз кайда эрсә токуш ул, уруш...*
*Сэниңдә улугуң сэни тәбсәгәй,*
*Сэни отка итгәй, öз итлүр, тәгәй* һ.б.

Ягъни «**Тибезлек** күп булыр сәрайда шактый; **тибез** кайда, шунда сугыш-талаштыр. Кем олырак синнән, ул сине **типсәр,** сине утка этәр, көйсен дип эстәр». Димәк, *тәпсә-* < *тәбизә-* ← *тәбиз* «көнчелек». **Типсә-ү**нең ротацияле параллеле М. Әхмәтҗанов нәшер иткән «Түләк китабы» (Әдәби мирас, № 4, 1997: 15–33) текстындагы *дибрә-ү* «биеп җырлау» ← *дәбирә-* ← *дәбир* ~ **тәбир.* Бу **тәбир-*не без бор. төрки *тәбил* «сугыш барабаны» сүзе белән чагыштырабыз. Арытабан к. шул ук «Түләк китабы»нда *дыбса-у* «биеп җырлау» ← (каз.) *дыбыс* «тавыш, көй», хак. *тапса-* «бию-җырлау» ← *табыс* «тавыш» һ.б.ш. параллельләр. К. **Давыл, Тибрә-ү**. Чаг. **Купса-у.** К. Poucha: 174.

**ТИПТӘР,** (Радлов III: 1114) **тäптäр** – этнографическая группа татар в Приуралье. *Типтәр, тәптәр* дип элекке рәсми «Башкирия» җирләренә читтән килеп утырган игенче-терлекчеләрне атаганнар. Соңрак сүз этник атама – гүяки аерым халык исеме булып киткән (мәс., Ризаэтдин бине Фәхретдин, Г. Ибраһимовлар аны шул мәгъ. куллана). Ләкин русча документлардагы *тептяри из татар, тептяри из мишарей, тептяри из вотяков, тептяри из черемис, тептяри из башкир* сүзләре үзләре генә дә типтәрләрдә бердәм этнос билгеләре булмаганлыгын, моның табәкә-сословие атамасы икәнлеген күрсәтеп тора. Үзләрен милли табигъләк яссылыгында *типтәр* дип атаган кешеләр сирәк булган, хәзер бөтенләй юктыр инде (тик *авылның типтәр очы* дигән тәгъбир очрый, әмма аның төп мәгънәсен аңламыйлар да).

Типтәр сүзенең этимологиясе – килеп чыгышы һәм тарихы ачык. Бу сүз түбәндә грек. *διφθερα* «тире; яры; пергамент; язу» (шуннан ук *дифтерит* «тире чире») сүзеннән. Бу сүз Якын Шәрыкка безнең эрага кадәр ук таралган һәм фар. телендә *дәфтәр, дифтар* мәгънәсен һәм формасын алган. Фар. теленнән ул бор. уйг. теленә *тәбтәр* яңгырашында алынган (бор. төрки яз. телләрдә сүз башында *д-* кулланылмаган) һәм шул яңгыраштa Чыңгыз хан империясе кәнсәләрендә *тәбтәр, тәптәр* «исемлек; суд карарлары язылып бара торган кенәгә» мәгъ. киң таралган. Хосусан *кӧкӧ тәбтәр* «күк дәфтәр» – монгол идарәчеләр телендә «салым түләүчеләр исемлеге» мәгъ. киң кулланылган (Бартольд I, 1963: 454). Тат. телендә XIV–XV гг. *тәбтәр, тибтәр* «исемлек» сүзе белән беррәттән турыдан-туры фар. теленнән алынган *дәфтәр* «язу дәфтәре, кенәгә» сүзе дә йөри башлаган. Укымышлы кешеләр бу вариантларның асылда бер сүз икәнлеген шундук сизеп алганнар. XVI г. әрмәнчә язулы кыпчак телле документларда *tiftar, diftar* «кенәгә, документ» (к. Tryjarski 1987).

XVII г. татарча рус документларында (Хисамова 1990: 108) *дәфтәр* «исемлек, реестр». Ләкин *типтир* варианты да онытылмаган һәм яңа мәгънәләр ала башлаган (Ахмаров 1908). Мәгърифәтче әдип Г. Гафуров-Чыгтайның «Тутам» дигән публицистик хикәятендә (XX г. башы) бер баб «Зат (исемле) хаҗиның нәсел *типтәре* (шәҗәрәсе)» дип атала. Димәк, *типтәр* сүзе, *дәфтәр*дән аермалы буларак, «шәҗәрә» мәгънәсен дә алган булган.

*Типтәр* сүзенең аерым мәгънәләренең берсе «исемлек, чират, тәртип, закон» Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында ук килеп чыкканлыгы турында Н.И. Ашмарин тәфсилләп язган (к. Ашмарин 1921). Ул да чув. *типтер* «тәртип» (*типтерле-* «тәртипкә салу») сүзен *дәфтәр* сүзеннән дип күрсәтә. К. Насыйриның «Ләһҗәи татар» сүзлегендә *тибтәр* «пөхтә, җыйнак, тәртипле», *тибтәрле* «җыйнак, әдәпле, тәртипле» ~ хәз. чув. сүзлекләрендә *типтер [типтәр]* «бирка, исемлек, чират, тәртип», *типтерлĕ* (типтәрле) «тәртипле».

Алтын Урда документларында исә *дәфтәр* «закон, указ; исемлек, реестр» хан әмерләре язылып куелган кенәгә һ.б. (к. Березин: 126).

*Типтәр* сүзе башта башкорт җирләренә бөтен исемлек, командалары белән килеп утыручыларны белдергән һәм шул сыйфат белән *типтәр* дигәне *бобыль* (< тат. *бабул*) «үз белдеге белән каяндыр килеп җир эшкәртә башлаган кеше» һәм *тархан* «ниндидер хөкүмәт законы – әмере белән килеп җир биләгән йомышлы кеше» сүзләренә каршы куелган. Мәзкүр мәгънәдәге *типтәр* XVIII г. башларында киң кулланышка кергәч, белдекле патша түрәләре А.И. Тевкелев һәм И.К. Кирилловлар бу сүзнең *дәфтәр* сүзе белән бердәйлеген махсус аңлатып язып калдырганнар (Материалы по истории России, т. I. Оренбург, 1800: 106). *Типтәр* термины транзитив *типтәрле* сүзеннән кыскарган булса кирәк, бу хакта түбәндәге факт сөйли: мари телендә *тептер* «исемлек; тәртип» һәм башкорт җирләренә килеп башкортларга исемлек буенча иҗарә хакы түләүчеләр *тептерля* «исемлекле» һәм исемлек буенча түгел, аерым түләүчеләр *тептердыме* «исемлексез» дип аталган (к. Ученые записки МарНИИЯЛИ, т. I. Йошкар-ола, 1948: 126).

Д. Рамазанова *типтәр* сүзенең *дәфтәр* белән тамырдашлыгын, XIX–XX г. беренче яртысына караган барча публикацияләрдә һәм XVII г. документларында ук *девтярский ясак* сүзе булганлыгын, бу сүз 1693 елгы бер документта *тептярский ясак* булып әверелгәнлеген, аннары *окладной тептяр, ясашный тептярь* терминнары килеп чыгуын эзмә-эз тикшереп аныклады (к. анықы Функционирование терминов *мещеряки, башкиры, тептяри* в Западной Башкирии // Исследование языка древнеписьменных памятников. Казань, 1980: 142–157).

XX г. *типтәр* сүзенең элекке мәгъ. онытыла төшкәч, тикшеренүчеләрне «типтәрләр – кемнәр соң алар» дигән сорау кызыксындыра башлаган.

К. Уйфальви дигән кешенең (Известия императорского русского географического общества, вып. 1. СПб., 1877: 119) «Башкиры, мещеряки и тептяри» дигән мәкаләсендә типтәрләрнең татарлашкан гетероген халык булуы хакында әйтелә. Башкорт дип язылганнарның күпчелеге чын башкорт булмаганы, ә *типтәр* яисә татар яисә мишәр булуы белдерелә. «В Бурсянском улусе Оренбурской губернии живут до 50000 чистых башкир, которые с пренебрежением смотрят на остальных и полагают, что этих последних совершенно ошибочно называют башкирами», диелә.

Е.С. Филимоновның «Что такое тептяри?» (Труды пермской ученой архивной комиссии, вып. II. Пермь, 1893: 51–56) дигән мәкаләсендә типтәрләрнең аерым табәка булуы аермачык әйтелә һәм *тептяр* сүзе Казан ханлыгы заманнарыннан ук килә, *типтәр*ләр хәрби оешма әгъзалары булганнар, брб. татарлары «Казачество составында хезмәт иткән мишәрләрне *тәптәр (тептер)* дип атыйлар», диелә. Е.С. Филимоновның бу кызыклы мәгълүматлары шуның белән дә раслана: хакаслар, үзләрен

*тадар* дип атаган хәлдә, татарларны *казак* дип атыйлар. Казан ханлыгында *казак* дип солдатны атаганнар. Регуляр гаскәрләр, күрәсең, *дәфтәр-типтәр казаклары* (рус. *реестровые казаки*) дип аталган (төр. телендә дә *defter açtak* «күңелле яки ялланмыш солдат җыю»). 1832 елда хәз. Башкортстан территориясендә «типтәр кантоны» оештырылу *типтәр* сүзенең хәрби термин булуына да дәлил.

Шулай итеп, барлык фактлар *типтәр* сүзен тәүдә «исемлек, реестр, кенәгә» мәгъ. йөргәнлеге һәм *дәфтәр* сүзеннән килеп чыкканлыгы хакында сөйли. Сүзнең төрки телләрдә тармаклануын түбәндәге шәкелдә күрсәтеп була:

| I | II | III | IV | V |
|---|---|---|---|---|
| Бор. грекча > | Ир. телләрдә (фар., сугд.) > | Бор. төрки (ДТС: 159) > | Алтын Урда һәм Казан дәүләтендә > | XVII гасырдан тат., чув. һәм мар. |
| *διφϑερα* «тире; пергамент» | *defter, difter* «пергамент, кәгазь, дәфтәр» | *däptär, däftär* «исемлек, реестр, кенәгә», бор. монг. *тэптэр* «реестр» | *дәфтәр* «дәфтәр», *типтәр*// *тәптәр* «исемлек, беркетмә, акт; кенәгә» аерымлана | *тептер (тэптэр)*, *типтәр* «исемлек, чират; закон, тәртип; дәфтәр», *тептерлы* «исемлеккә кертелгән» |

К. ш. ук каз. (XIX г.) *типтэрь* «дәфтәр, кәгазь төргәге» (к. Будагов I: 561).

Системага салып әйткәндә, *дәфтәр* һәм *типтәр* сүзләренең этимологик дублет икәнлеге:

1) бу мәсьәлә белән кызыксынган тикшеренүчеләрнең XVIII г. бирле шуны раслап килүе;

2) бу дублетлыкның тарихи мәгълүматлар белән тулысынча ярашуы, аңлатыла алуы;

3) аның мәгънәви вә фонетик үзгәреш-үсеш закончалыкларына туры килүе белән зур ихтималлыкта раслана.

Шуңа да карамастан, адәм баласы үз интересларына кагылса, ике икең дүрт икәнлеген дә шик астына ала бит – *типтәр* этнонимының *дәфтәр*дән килеп чыкканлыгына шик белдерүчеләр дә табылган.

Бу шик-шөбһә А.Х. Юлдашевның 1950 елда язылган «Язык типтерей» дигән кандидатлык диссертациясендә бәян ителә. Аннары, халык арасында электән *типтәр* сүзен *типмәк* фигыле белән бәйләп аңлату булган: имештер, *типтәр* «тибелгән халык». Икенче бер шундый халык этимологиясе буенча, *типтәр* сүзе – *тип тәре*не сүзеннән: типтәрләр христианлаштырудан баш тартканнар, үз авылларына куелган тәре баганасын тибеп аударганнар да Башкортстанга качканнар. Я, шундый этимологиягә ышанып буламы? Әмма ләкин башкорт тарихчысы А.З. Әсфәндияров үзенең күпсанлы публикацияләрендә халык фантазиясен «фәнчә» нигезләргә тотына: имеш, *типтәр* сүзе *типтерү*дән үзгәргән (башкортлар *типтереп* яшгәннәр мени?). А.З. Әсфәндияровның төп максаты – типтәрләрне башкорт составына кертеп карау. Мондый карашка «Сборник статических сведений по Уфимской губернии» (т. I. Уфимский уезд. Уфа, 1898) китабы да юл калдырылган. Анда «благодаря тесному сожительству и одинаковой религии мещеряки вполне слились с башкирами», «эта смесь народностей составило сословие тептярей», «окончательно разделить эти народности не удалось» дип язылган (91 биттә). Тик бу сүзләр бигүк дөрес түгел: типтәрләр составында төп өлешне Казан татарлары тәшкил иткән, мишәрләр азрак, ә «чи башкортлар» алардан да азрак булган.

А.З. Әсфәндияров тигез җирдән түмгәк чыгарса да, шул түмгәккә абынучылар очраштыргалый.

Типтәрләр турында махсус китап язып нәшер иткән Р.И. Якупов (к. аныкы: Тептяри. Этносоциальный феномен и научная проблема. Уфа, 1998: 120 һәм таблицалар) күп кенә чыганакларны анализлап, *типтәр* сүзенең *дәфтәр* сүзеннән килеп чыгуына кискен каршы килмәгән хәлдә, *дәфтәр* > *типтәр* фаразында татар теленә хас булмаган аваз күчешләре барлыгына аптырый.

Бу бик урынлы аптыраш. Чыннан да, хәз. тат.р теленең үзендә *дәфтәр* сүзенең *типтәр* булып үзгәрүе мөмкин түгел: тат. телендә нигездә сүз башындагы *д-* саңгыраулашмый (*дулкын ~ тулкын, диде ~ тиде* кебек вариантлашулар аерым сөйләшләргә генә хас); беренче иҗектә *ә* > *и* күчеше дә тат. теленең Идел-Урал өлкәсендәге үз тарихында башкарылмаган, ә бор. төрки диалектлардан ук килә (моңа дәлил – э > *и* күчешенең хак. телендә дә күзәтелүе).

Әмма мәсьәлә монда җиңел чишелә. Әйтелгәннәрне (к. таблицаны) кабатлыйк: *дәфтәр* варианты тат. әд. теленә турыдан-туры фар. әд. теленнән кергән, *типтәр* исә бор. уйг. яз. теленнән килә. Бор. уйг. (X–XIII гг.) *тэптэр* – бор. фар. теленнән «кенәгә, исемлек, реестр» монг. теленә дә кереп, Алтын Урда һәм гомумән Чыңгызхан әуладлары

дәүләтләрендә киң таралыш тапкан сүз. Тат. теле тарихында беренче иҗектәге э- авазы *и*-гә әверелгән (бу күренеш хак. теленә дә хас) һәм шул закончалык буенча *тэптәр* сүзе *типтәр* булып киткән. Ягъни төптә бер үк чыганакка кайтып калсалар да, *дәфтәр* һәм *типтәр* сүзләре тат. гомумхалык теленә икесе ике юлдан күптәннән килеп кергәннәр. Аларның мәгъ. аермалары да булган: *дәфтәр,* башлыча, мәдрәсә, уку-язу әсбабы, *типтәр,* иң беренче чиратта, «реестр» һәм, шунлыктан, русча «реестровые казаки» булган, мишәрләр татарча *типтәрле казаклар* һәм шуннан кыскартылып *типтәрләр* дип кенә атала башлаганнар.

Кайбер (бигрәк тә Себер) тат. сөйләшләрендә *дәфтәр*не хәзер дә *тәптәр* дип атыйлар. Бу күренеш бор. кыпчактан ук килә (бор. кыпч. сөйләшләрендә сүз башында *д*- кулланылмаган).

Гомумән, *тәптәр – типтәр* вариантларының булуы үзе бу сүзнең тат. телендә һәм бор. заманда барлыкка килүенә ишарә: бу пар (*тәптәр – типтәр*) борынгыдан килгән *бәр-бир, кәбәк-кибәк, кәбән-кибән, кәрәк-кирәк, кәртә-киртә, әнәй-инәй* кебек парлар рәтендә тора.

Дөрес этимологияләрнең шундый үзенчәлеге бар: алар файдасына яңадан-яңа материаллар табылып кына тора. **Дәфтәр* >> *типтәр* аңлатмасы да шундый этимологияләр рәтенә керә.

Р.И. Якупов китабында көтелмәгәндә *типтәр теле* турында сүз куертыла. Моннан соң инде *типтәр этносы* турында сөйләргә бер генә адым. Бу башкорт телче вә тарихчылары өчен бик характерлы нәмәрсә: дөньяда аерым *мишәр* этносы бар дип игълан иттеләр ич!

Хәлбуки үзләрен «мин типтәр» дип атаучылар, ихтимал, булса да, әлбәттә, бу милләт мәгънәсендә әйтелми. Югарыда әйткәнебезчә, типтәрләр составында төркиләр генә түгел, фин-угорлар (чирмешләр, арлар-удмуртлар) да булгач, нинди тел берлеге турында сүз булырга мөмкин? Бигрәк тә бүгенге көндә. Хәз. татар һәм башкортларның күпчелеге *типтәр* дигән сүзне дә белми. Р.И. Якупов типтәр теле турында «үз күзәтүләрем буенча әйтәм» ди. Менә мин дә үз шәхси күзәтүләремне ифадә итә алам: алтмыш ел буе (бала чактан бирле) этник мәсьәләләр белән кызыксынган хәлемдә, гаҗәпләнүемә каршы, миңа бер генә тапкыр – моннан алтмыш еллар элек – «сез татар түгел, сез типтәр» дигән сүзне ишетергә туры килде. Диалектологик экспедицияләрдә йөргәндә дә миңа «без татар (яки башкорт) түгел, типтәр» дигән кеше очрамады бугай. Бу мәсьәлә буенча студентлар белән сөйләшкәндә, аларның берсе дә үзен типтәр дип атамады. Тик кайберәүләр генә «безнең авылда типтәр очы бар» дию белән чикләнделәр, шуннан артыкны әйтә алмадылар. Шунысы һаман характерлы – «башкорт» дип аталган татар авылының бер «очы» яисә, аңа күрше исемдәш авыл, мәс. – *түбән Хансөяр* башкорт, *югары Хансөяр* исә, иске хәтер буенча, типтәр дип калырга мөмкин, әлбәттә, әмма ул күрше «оч»лар яисә авыллар бер үк телдә сөйләшә. Һәм гомумән, Башкортстан татарлары телендә уртак диалектизмнар бар, ләкин алар типтәрлек белән баглы түгел: һичкайчан «типтәр» булмаган авылларда да шул ук тел!

Аерым типтәр теле булмаганлыгы Р.И. Якуповның үзенең элегрәк язылган «Тептяри и историография вопроса» дигән мәкаләсендә китерелгән материаллардан бик ачык күренә (к. Этнологические исследования в Башкортостане. Уфа, 1994: 85–101, к. ш. ук Решетов А.М. Материалы по этнографии народов Поволжья в Санкт-Петербургском филиале архива РАН // Op. cit.: 75–84).

**Типтәр** дигәннәрдән тел вә гореф-гадәтләр җәһәтеннән Урал артында бер группа аерылып тора. XIX г. бу группаны С.М. Рыбаков җентекләп тикшергән. Аның публикацияләрендә әлеге типтәрләрнең башкорт телендә сөйләшкәнлеге әйтелә. Аның фикеренчә, *типтәр* сүзе сукбайны белдерә, к. Рыбаков С. Очерк быта и современного состояния инородцев Урала // Наблюдатель, № 7–8, 1895 (*типтәр* сүзе турында 305 биттә); С.М. Рыбаков Музыка и песни уральских мусульман с очерками их быта. СПб., 1897 (типтәрләр турында махсус бүлекчә бирелгән). Бу аңлатманы ул каян алгандыр – әйтелми. Гомумән, ул Урал арты типтәрләренең килеп чыгышы да үзенчәлекле булса кирәк. Ләкин Уралның бу ягындагы «типтәр сөйләшләренең» (шунда дип әйтергә яраса) берсе дә башкорт теленә азмы-күпме сизелерлек якын түгел. XIX г. беренче яртысында 250 меңләп типтәр арасында 66 мең башкорт булуы билгеле (к. Кузеев Р.Г. О характере присоединения народов Волго-Уральского региона к русскому государству и некоторые вопросы их средневековой истории // Этнолингвистические исследования в Башкортостане. Уфа, 1994: 71). Ләкин бу башкортлар (әгәр чынлап башкорт булсалар да) компакт группа тәшкил итмәгән хәлдә, бик тиз татарлашкан дип уйларга бөтен нигезләр бар.

Тагын кайбер бүтән фикерләр: Г.Ф. Ковалёвның «Русская этнонимия» китабында (Воронеж 1982: 58) *типтәр* сүзе бор. рус диалектларында очрый

торган *тепьра* этнонимы белән чагыштырыла (ләкин бу чагыштыруның реаль нигезе күрсәтелми); М.Р. Федотов (II: 234) чув. *типтер* «бирка, таякка язылган билге – кирт» һәм *типтер* «типтәр» сүзләренең бердәйлегенә шикләнми; ТЭС (: 573) **типтәр** сүзенең этимологиясе «анык түгел» дип, бу сүзнең ачык-аян тарихын арытабан да болгатырга урын калдыра; Фасмер (IV: 44) өчен мәсьәлә ачык: *типтәр* һәм *дәфтәр* – гомоген сүзләр; З. Вәлиди (Velidi: 291) дә нәкъ шул фикердә. К. **Типтирлә-ү.**

**ТИПТЕР-Ү** «гулять; вести разгульную жизнь» – собственно «заставлять плясать ~ пинать» (к. **Тип-ү**) – тәүдә бу сүз «туйда егетне-кияүне биетү» мәгъ. булса кирәк: булачак кияүне биетеп карау бор. булачак ханны биетеп карау йоласыннан күчерелгән булса кирәк. Ш. ук элек аулакта кызларны биетеп карау гадәте дә булган. Гомумән, **тип-ү** < *тәп-* сүзенең «бию» мәгънәсе борынгылыктан килә, к. тув. *девиг* «көрәш алдыннан бию, биешү (*тибек*)».

**ТИПТИК, типтәк** (Тумашева 1992: 211) «малюсенький; чуть-чуть; даром», **типә-тик** (ТТДС I: 413) «даром, без причины» < **тип-тик, тип-тиген,** к. ш. ук мәгъ. башк. (БТДҺ: 318) *тип-тибез, типтиләмәгә.* Бу очракларда **тип < *тик бә** (к. кереш өлешен).

**ТИПТИРЛӘ-Ү** (ТТДС I: 413) «старательно делать что-либо, делать как следует», **типтирсез** «невоспитанный» – бу сүзләр ***типтир** «тәртип, юнь, рәт» сүзләреннән ясалган, ул сүз исә чув. яки мар. теленнән урап кайткан: тат. *типтәр* > чув. *типтер [типтәр]* > тат. **типтир**. Күрәсең, **типтир** нигезе татарлашкан чув. яисә мари группаларында кулланыла. Гомумән, гом. тат. *-ә-* урынына икенчеөченче иҗекләрдә *-и-* кулланылу очраклары татарлашкан бүтән этник группаларда күзәтелә, чөнки төп тат. телендә ачык (иреннәрне ерыбрак әйтә торган) э аваз булмаган, ул авазны татарлар (рус алынмаларында да) *и* авазы белән субституциялиләр.

**ТИП-Ү (типте, тибү),** себ. **тәп-** «пинать, лягать, лягнуть, лягаться; плясать; биться, пульсировать (о сердце); захватывать жертву (о хищных птицах); устроить гнездо (о любых птицах)», күч. «красть, стибрить» < гом. кыпч., чыгт., алт., тув., як. *тэп-*, хак. *тип-*, уйг. *тәп-*, угыз. *дэп-, дәп-* id. ~ чув. *тап-* id. (һәрбер төрки телдә бу сүзнең үзенчәлекле мәгъ. бар). Тув. телендә *теп-* һәм *деп-* тамырлары төрле дериватлар биргән.

**Тип-** фигыленең исем коррелянты **тип** (к.) «агым суның киресенә агуы, отпор» тат., чув. телләрендә генә бугай (к. ш. ук чув. *тап, тапă* «су ташу»). Федотов II: 171–172.

**Тип- < тэп-** төрки телләрдә иң продуктив тамырларының берсе: тат. **тибел-ү, тибен-ү, тибеш-ү, типтер-ү** (һәр юн. формасы киң вә күп мәгънәле, соңгысы тур. к. аерым матдә); **типке** «кыйнау, сугу; сугу эзе»; **типкен**; **типкеч** «типтерүче», к. **Тибәр-ү, Тибен, Тибенге, Тибеш, Типкенцәк.**

Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 195–196) **типсә-ү** (к.) сүзен дә **тип- < тэп-** тамырыннан дип тәгърифли, ләкин тышкы охшашлыкка карамастан, **типсә-ү,** безнеңчә, бөтенләй бүтән тамырдан килә. **Тип-ү** сүзе тик контаминацион тәэсир генә ясаган.

**ТИПЧАК** «типчак (вид травы)» < рус., бүтән күрше телләрдә дә ш. ук. Бу сүз мөгаен төрки телләрдән, ләкин конкрет этимоны билгеле түгел.

**ТИПЧЕ-Ү** «стегать; наметывать» < хак. *типчі-, типсі-,* гом. кыпч. *тэпчи-* (башк. *типсе-*, ком., кырг. *тепчи-,* нуг., каз., к.-калп. *тепши-, тепше-*), уйг. *тәпчи-,* аз. *тәфҗи-* << бор. төрки (МК, к. ДТС: 546) *tevči-, tefči-* id. ← *tev-* «(шешкә) тезү» – ихтимал, *тип- < тэп-* фигыленнәндер (*-чы//-чи* фигыль ясагыч аффиксы ачык билгеле). Тув. *депши-* «тишү; типчү» ш. ук «алга китү», *депшилги* «прогресс» күч. мәгъ., әлбәттә.

**ТИПШЕ** (трбс.) «поднос», себ. (ЗДС: 620, 627) **тепше, тепши** «вид небольшого корыта» ~ кырг. *тепши* «зур булмаган агач ялгаш», кр.-тат., төр. *tersi* «типше», ком., к.-балк. *тепси* «түгәрәк өстәл; куелган ашамлыклар», бор. төрки (ДТС: 557, МК) *tevši* «типше, бәләкәй өстәл» ~ монг. *tebš, tevs* «типше». Гомумән, бу сүзнең яңгыраш яки мәгъ. җәһәтеннән читкәрәк киткән вариантлары күп: каз. (Катаринский) *типеш* «киң табак, зур тәлинкә», (ҠТДС: 324) *тәпенше* «таба», нуг. *тепшек* «тәлинкә», уйг. *тәбиш, тапиш, тәпиш,* чыгт., аз. (Будагов I: 340) *тәбиш* «савыт; кадәх; котыйчык», төр. *tebis* «зур стакан», ком. *табс, тапс* «кечерәк типше». Рясянен буенча (Räsänen 1969: 469), урта төрки *tävši* id. кыт. теленнән.

Ихтимал, китерелгән сүзләргә рус. диал. (Аникин: 181) *депше, депша* «нәрсәне дә булса өстән каплау өчен тире», яз. монг. *depse* «чапрак, ат ябуы» ~ хәз. монг. *дэвсэ-* «җәю» сүзләре гомогендыр. К. ш. ук як. *дэпсэ, тэпсэ ~ лэпсэ* «ияр өстенә чахул».

**Типше** һ.б. вариантлар күп күрше телләргә дә алынган. Удм. *типши,* рум. *tepsie* һ.б.

**ТИР** «пот» ~ чув. *тар* «тир, ял (яллау)» < болг. **тәр* > мар. (Иванов, Тужаров: 216; Саваткова: 156) *тӓр* «яллану хакы» ~ гом. кыпч., алт. *тер,* хак. *тир* «тир», уйг., госм., чыгт. (к. Радлов III: 1059) *тӓр* «тир», тув. *дер* «тиф». ДТС (: 555) авторлары да *tēr I* «тир» һәм *tēr II* «яллану хакы», Федотов та (II: 176) *тар I* «тир» һәм *тар II* «яллану хакы» сүзләрен аерым-аерым карыйлар, ләкин болай аеру кирәксез, чөнки икенче мәгъ. «тир хакы» тәгъбиреннән килә (бу тур. Clauson: 528, ЭСТЯ III: 203–204).

**Тир –** продуктив нигез: **тирлә-ү, тирле, тирсез, тирчән.** К. **Тирлек.**

**ТИРАК** (ТТДС: 413; Тумашева 1992: 211) «энергичный; аккуратный; деловой» < бор. төрки (ДТС: 566) *tïyraq* «көчле, батыр; илче» ← *tïyra-, tïyda-* «көчле булу, көчләнү» (к. ш. ук Вәлиди II: 706); бор. чыгт. (Мелиоранский: 85) *тӓғраг* «каты». Морфологик җәһәттән чыгып, сүзнең нигезе **tıyr; *tıyır* дип уйларга мөмкин. Чаг. **Чирак.**

**ТИРАРАЙ** «божья коровка (золотистого цвета, мельче обыкновенной)» < мар. *трай, трай-трай* id. (бу сүз каз. ар. сөйләшләрендә марилар белән татарлар күрше яшәгән төбәктә теркәлгән).

**ТИРӘ** «окрестность, место вокруг чего, обрамление» ~ чув. *тавра* < болг. **тәwрә* ~ бор. төрки (ДТС: 549) *tegirä* «тирә, тирәли» ← *tegir-* «әйләнү» фигыленнән (*teg* «түгәрәк») хәл фигыль формасы («әйләнә, әйләнеп»), к. ш. ук чыгт. *тиңрә, тиңрү,* шор. (Радлов III: 1038) *тӓгрӓ*, төркм. *дегре*, төр. *tekre, devre*, к.-балк. *тийре* «тирә, тирәли» һ.б. (ЭСТЯ III: 178–179). Гомумән, бу сүз кыпч. телләрендә спорадик рәвештә очрый. Будагов I: 419; Егоров 1964: 227–228; Федотов II: 163 (тат. **тирә** сүзен искә дә алмый).

**Тирә** продуктив нигез: **тирәлә-ү, тирәли [тирәлӗй < тирәләй], тирәле, тирәлек** һ.б. К. **Тирәч.**

**ТИРӘК** «тополь; осокорь; любое дерево»; (Троянский I: 303) «узор, рисунок дерева», диал. «священное дерево» (к. ш. ук **Байтирәк**) > чув. *тирек,* мар. диал. *тирӓк* ~ хак. *тирек* гом. кыпч., алт., тув. *терек*, кар. *теряк, тэрах, тэрэх, дирэк, дэрэк, дирак* «тирәк», уйг. *дарак, дирак* «тирәк; усак», *тәрәк, тарәк* «биек агач», төркм. *дерек*, кырг. *дарак* «утыртылган агач» < фар. *дӓрахт, дирехт* «агач» (рус. *дерево* белән тамырдаш). Егоров 1964: 252–253; Räsänen 1969: 475; ЭСТЯ III: 205–207.

*Тирәк* сүзен *терә-* < *тирә-* «терәү» фигыленнән дип карау бөтенләй нигезсез. Тат., башк., кырг., үзб. һ.б. халыкларда таралган *Ак тирәк – күк тирәк* такмагы ике ыру-кабиләне белдерә.

**Тирәк** продуктив нигез: **тирәкле, тирәклек; тирәклә-ү** (чигү төре).

**ТИРӘН** «глубокий» < гом. кыпч., тув. *тэрэн, тӓрӓн,* башк. *тәрән,* кр.-тат., куман., алт. *тӓрӓң,* уйг., бор. төрки (Боровков 1963: 300; ДТС: 300) *teräŋ, täriŋ, teriŋ,* төркм. (ТДГДС: 171) *териин*, төркм. *дериң* > гом. угыз. *дерин* (к. Мухамедова 1973: 168) id., як. *дириң* «тирәнлек, тирән төш». Чув. *тарӑн, тавӑрӑн* «тирән» < болг. **тәwӗрӗн* id. сүзләренә караганда, безнеңчә, бу сүз чув. *тавӑр-* < **тәwӗр-* < бор. төрки *тӓгир-* (к. **Тегермән**), (Боровков 1963: 294) *тӓгрү-* «әйләндерү, бөтерелдерү» фигыленнән килә һәм төп формасы *тэгиргинги* ~ *тэгрүгинги* «әйләнгечле бөтерелмәле, өермәле» булган: елгадагы бөтерелмәләр чоңгыллар, тирән төшләр өстендә пәйда булучан. Чаг. ш. ук тунг. *дэрэн* «агымсу башы» (ССТМЯ I: 237). Räsänen 1969: 475; ЭСТЯ III: 208–209; Федотов II: 178–179 (бу авторларның барысы да **тирән** сүзенең параллельләрен санау белән чикләнәләр).

Дерив.: **тирәнлек, тирәнге; тирәнлә-ү.**

**ТИРӘЧ** «оправа, околыш» ← **тирә,** ясалышы ачык түгел (**тирәчә́** дигәннәнме?).

**ТИРӘЯК [тирәйәк], тирайак** (ТТДС I: 298; БТДҺ: 318) «прозрачные, либо чёрно-стеклянные конфеты в палец длиной, которые прежде продавали бродячие торговцы (были действенным средством против дизентерии у детей)» < **тирьяк** (к.). Бу сүз татар-башкортларда халык медицинасы тарихы өчен кызыклы.

**ТИРБӘЙ** (ТТДС: 413), **тырпай** (ТТАС III: 199) «нормально-упорядоченное положение в хозяйстве» > чув. *тирпе, тирпей* «тәртип, кот, чисталык» << гар. *тӓрбӣʻ* «квадратура, дүрткә бүлү; керемне тигез дүрт өлешкә (куллану, запас, салым түләү, эш хәрәкәте өлешләренә) бүлү» сүзеннән; к. ш. ук төр. *terbi* «дүрткелләү; дүрт сәтыры да бар рифмалы шигырь төре».

**Тирбәй** сүзе гарәп прототибыннан бик ераклашкан – күрәсең, ул бор. (IX–XII) гг. үк кергән; *ә* > *и* күчеше дә шуны күрсәтә (*тәрбәй* варианты да бар).

**ТИРБӘ-Ү** «качать; шевелить; волновать» – **тибрә-ү** (к.) сүзеннән метатеза; *тәбрә-* > *тәрбә-* > *тәрвә-* күп төрки телләрдә очрый һәм шул шәкелдә күрше телләргә дә үтеп кергән, к. мар. (Иванов, Тужаров: 212–214; Саваткова: 155–157) *тара-* < *тарва-* < *тäрвä-* «аралау, аерып бару (мәс., куе биек үләнне); дулкынлату (мәс., күл өстен)», *тарван-* < *тäрвäн-* «кузгалу, кыймылдау; берәр эш-гамәлгә керешү, тотыну», *тäрвäлт-, тäрвäт-* «кузгату; тию; башлау, керешү, тотыну». Федотов II: 173–174.

Дерив.: **тирбәл-ү, тирбән-ү, тирбәт-ү; тирбәлеш** һ.б.

**ТИРГӘ-Ү** «бранить, ругать»; диал. (ДС I: 185) «привередничать», (Тумашева 1992: 211) «проверять; собирать; выбирать; испытывать» ~ башк. *тиргә-* «тиргәү, сүгү», (БТДҺ: 318) «карау, тикшерү», *тиргәү* «тәртип» ~ чув. (< тат.) *тирке-* «талымчан булу; бракка чыгару; начар ягына игътибар итү; ураза тоту», удм. (Насибуллин: 142) *тэрга-* «тиргәү, тәнкыйтьләү», мар. *терга-* «тиргәү; тикшерү», мар. диал. (Саваткова: 158) *тәргä-* «тикшерү, сорау алу, таләп итү» ~ кар., чыгт., куман. (Радлов III: 1070–1073) *тäргä-* «карап чыгу; тентү», чыгт. *тиргä-* «карап чыгу, тикшерү, сорашу, инкяр итү, тыю; игътибар итү», нуг., каз., к.-калп. *терге-* «хөкем тикшерүен үткәрү, сорау алу», уйг. *тәргә-, тәрги-,* кырг. *терге-* «сөйләү; бер сүз урынына икенче сүз куллану (хатыннар телендә)», төркм. *дерге-, дерңе- [дәрңә-]* «тикшерү» һ.б. (кайбер төрки телләрдә юк); үзб., уйг. *тергав, тәргәү* «хөкем тикшерүе» кыпч. телләреннән.

Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 209–210) бу сүз турында «калдык (ягъни төп мәгънәсе онытылган) сүз» дию белән чикләнә. Безнеңчә, бу сүзнең төп мәгънәсе «хәрби һ.б. сәфәргә солдат җыю, хәрби комиссия» булган һәм *тәргә-* гом. төрки *тәр-* «тезү; җыю, оештыру» тамырыннан; тәүдә **тәриг, *тәриң* «хәрби комиссия» исем сүзе, шуннан *тәрңә-, тәргә-* сүзе ясалган. Китерелгән барча мәгънәләр шул семантик ноктага илтә (башлык яки башлыклар төркеме яугирләрнең физик, әхлакый һәм рухи якларын бер-бер артлы тикшергән, кайберләрен кире каккан һәм шул юл белән хәрби бергәлек комплектланган), к. ш. ук алт. диал. (Räsänen 1969: 475) *тäргä-* «әзерләнү», тув. *тергин* «сайланмыш; бик һәйбәт», *терги-* «беренче булу, иң яхшы булып чыгу, хакимлек итү», төр. *derge-* «җыю; оештыру», *dernek* «оешма» (< **deriŋäk* ← **deriŋ-äk* «гаскәрчек»), бор. төрки *terig* «җыелыш» һ.б. К. **Тернәк.**

Төркиләрнең бик бор. заманнардан бирле хәрби хәзерлеккә, хәрби оешмаларга зур әһәмият бирүләре, (шуның нәтиҗәсендә I–XI гг.) зур уңышларга ирешүләре бөтендөнья тарихында эз калдырган күренеш. К. **Тирге, Тир-ү.** Будагов I: 414; Федотов II: 236–237.

**Тиргә-ү** продуктив нигез: **тиргәл-ү, тиргән-ү, тиргәш-ү, тиргәт-ү** һ.б.

**ТИРГЕ** диал. (гәй., ТТДС I: 438) «комплект, гарнитура (чаще о посуде) как свадебный подарок» ~ башк *тәрге* «корыт киптерү өчен өстәл» > чув. *тиркĕ, тирĕк* «мис, купы, тәлинкә». Мар. (Иванов, Тужаров: 219) *теркы* «тәлинкә, табак», удм. (Тараканов: 93) *тэрки, тэркы* «аш савыт-сабасы» < чыгт. *tärki* «бүләкләр тезелгән такта, өстәл», иске кыпч. *tergi*, кр.-тат. *tirki* «өстәл» < бор. төрки (ДТС: 554) *tergi* «аш өстәле», *tergu-ajaq* «аш савыт-сабасы», *tergü* «өстәлгә куелган ашамлыклар» ← бор. төрки, госм. һ.б. *ter-* «җыю, тезү, тирү». Бор. *тәрки, *тәрәк* сүзе түбәндәге мәгънәви-фонетик группаларга да нигез булган:

– тат. (ЗДС: 620) **тәрге** «тәлгәш; бәйләм, букет», төр. *tergi*, аз. (Будагов I: 35) *тәрги багы*, тув. *dergü, дергү* «ияргә әйбер бәйләп тагу өчен беркетелгән махсус киндерә», рус. *торока* id. (рус. сүзе бор. чыганагында **төргүкä* кебегрәк булган бугай; иренләшкән сузыклы вариант *-ги//-ки* кушымчасының *-гү//-кү* вариантының регрессив ассимиляциясе нәтиҗәсендә килеп чыга); бу сүзне Рясянен аерым бирә;

– алт. диал. *тäрги, тәрги* «корбанлыклар өчен өстәл, таскак» ~ *тирке* «мәҗүси корбанлык өстәле» һ.б.;

– иске тат. **дәрге** < төр. *dergi* «әдәби түгәрәк; әдәби җыентык», хәз. мәгъ. «журнал», ш. ук «оешма»;

– хак. *тиргі* «атка һ.б. йөкләү өчен махсус каешлар»;

– тув. *дәригле-, därigla-* «җыю, юлга әзерләү», *däriglän-* «әзерләнү»;

– як. *тәриэбэ* «тирге», *тәрий-* «җыю, оештыру»; һ.б. Räsänen 1969: 475; Sümer 1983: 81–82; Федотов II: 235.

Тат. диал. (ТТДС I: 407) **теркәү, теркеү** «кызның үзе әзерләгән сөлге, чаршау, кием-салым, савыт-саба, бирнәсе» сүзе асылда шул ук *тирге* булса кирәк, тик ул **теркә-ү** сүзе тәэсирендә үзгәргән. Бу сүзләрнең нигезе хак. *тир-, тәр-,* каз., кырг., бор. төрки *ter-* «җыю, төрү» һ.б. К. **Тир-ү.**

**ТИРЕ,** диал. (Тумашева 1992: 207) **тирә̆, тәрә** «шкура, кожа (живого существа)» > чув. *тир, тирĕ* < гом. кыпч. *тәри,* куман., кр.-тат., уйг. (Радлов III: 1061, 1064) *тäри*, алт. *тäрä*, як. *тирии, тэрии, тириэ,* бор. төрки *teri,* угыз. *дәри* (аз. *дәри*), хак. *тээр, тээри* id. Э.В. Севортян фикеренчә, бу сүз ниндидер бор. фигыльдән ясалган (ЭСТЯ III: 207–208). Федотов III: 234–235.

**Тире** продуктив нигез: **тиреле, тирече, тиречек.**

**ТИРЕ-ЯРЫ,** диал. **тире-җары** «сырьё для выделки» сүзендәге *йары* < *йагры* (к. **Яры**) «чи тире» *йаг* тамырыннан, шуның шикелле *тире* < *тәри* дә **тәг* тамырыннан булырга мөмкин.

**ТИРЕС** «навоз», диал. (ТТДС I: 413) «обратная сторона, изнанка; непослушный, строптивый; ошибочный; не так, как надо», себ. (Тумашева 1992: 211) **тирĕс** «север» ~ башк. *тирĕҫ, тирҫ* «эчке як; тизәк» > чув. *тирĕс* «төньяк», «кире; тирес», мар. *терĕс, тереш, терыс* «тирес» < гом. кыпч., алт., чыгт., урта төрки *терс, тäрс* (нуг., к.-калп. *терис*, каз. *терĕс*) «кире як; капма-каршы», уйг., алт. (Радлов III: 1076) *тäрс* «кире, аркылы, каршы; сулга, көнчыгышка; тирес» ~ монг. *тәрс* «(кемгә, нәрсәгә) каршы», уйг. *тәрса* «тирес, киреләнүчән; христиан», *тәрс, тәс* «кыенлыклы» < фар. *тарса, тäрса* «дошман; христиан», чаг. ш. ук бор. төрки (Әбү Хәйям) *tärsa* «яһүди»; к. ш. ук төр., көрд. *ters* «кыек, кире, тискәре, тупас; тизәк, тирес». «Дәдә Коркут» китабында *Дирсә [Дәрсә] хан* – угызларның конфликтлы бер ханы (дошман түгел). А.К. Боровков (1963: 14) фар. *tersa, tersak* «христиан; монах» *tersidan* «курку» сүзеннән (ягъни «куркыныч») дип яза.

Кайбер сүзлекләрдә (көрд, чуваш сүзлекләре) бу сүзнең «кире, тискәре» һәм «тизәк, тирес» мәгънәләре аерым сүз итеп бирелә, ләкин болай аерырга нигез юк: «дошман як > кире, тискәре > әшәке, пычрак > тирес» мәгънә үсеше бик мөмкин һәм очрый да.

Татарстанда һәм кайбер бүтән күрше өлкәләрдә очрый торган *Тирсә* гидронимы *тирес* < *тәрс* < **тәрсә* белән баглы булса кирәк («төньяк елга; динсезләрне аерып торган елга»), к. **Тиресаяк, Тискәре.** Будагов I: 349–350; Räsänen 1969: 476 (*тирес* < *тәрс* сүзен фар. *тäрса* белән багламый), Федотов II: 236 (**тирес** сүзен *тизәк* сүзе белән чагыштыра); Тимергалин: 469.

**Тирес** продуктив нигез: **тиресле, тиреслек, тиреслә-ү, тиреслән-ү** «киреләнү».

**ТИРЕСАЯК [тиресайак]** «чёрт, бес; чомга (птица)» ~ башк. (БҺҺ II: 249; БТДҺ: 318) *тиреҫайак* id. ~ мар. диал. (Исанбаев 1973: 21) *тирсайак* «гагара» (аның аяклары чыннан да *тирескә* – артка караган – гомуми демонология буенча, шайтаннарның берәр әгъзасы тискәрегә, артка караган була; Урал телләре семьялыгы мифологиясендә тәңре диңгез төбеннән җир кисәге алып чыгарга кушкач, гагара тыңламаган, ә үрдәк тыңлаган һәм җир кисәге алып чыккан, к. В.В. Напольских. Миф о возникновении земли в прауральской космогонии... // Советская этнография, № 1, 1990: 65–74). Чаг. ш. ук гом. тат. сөйл. **тирес бит** «әшәке кеше; шайтан – артка караган битле зат»; каз. диал. (ҚТДС: 330) *теріс табан* «шайтан баласы» һ.б.ш.

Шул ук «тиресаяк»ны башкортлар (к. БТДҺ: 166) *күтайақ* дип тә атыйлар.

**ТИРКЕШ, теркеш** «колчан» – гадәттә фар. *тир* «ук» һәм төрки *кәш, кäш* «ук савыты, тиркеш» сүзләреннән гыйбарәт дип аңлатыла (к. Добродомов 1981: 70–89); бу сүзнең ян мәгънәләре бар: тат. диал. *теркеш* «пыяла савыт футляры» (Шарифуллина 1991: соңгы фотога аңлатма), каз. *тĕркĕш, тĕркĕс* «төрән, сука шырты», көрд. *tırkeş* «тиркеш; укчы (!)».

**ТИРЛЕК** «бельё; потник» < гом. төрки *тәрлик,* госм., чыгт. (Радлов III: 1059) *тäрлик,* угыз. *дәрлик* < бор. төрки (МК; ДТС: 555) *terlik* «тир өчен киелгән кием» (К. **Тир**). Бу сүз монг. (*тәрлэг, тәрлиг* «милли бизәкле кием») һәм рус (урта гасырларда *терлик* «феодалларның парад киеме») телләренә дә кергән (бу тур. бай әдәбият бар, к. Аникин: 545–546). Sümer 1983: 45–46, 88–89.

**ТИРМӘ** «юрта» ~ тув. *терме, тербе,* хак. *тääрбä, тээрбэ* «тирмә», нуг. *терме үй* id., кырг., калм., монг. *терме,* уйг. *тәрмә* «киез өйнең каркасы, аерым канатлары», кырг. һ.б. *терме* «җыйма» ← *тер-* «тирү, кисәкләрдән җыю» сүзеннән. Куман. *тäрмä* «хатын-кыз өе (тирмәсе)» сүзе нигезендә рус. *терем* «матур өй» (гом. слав. параллельләре бар) сүзен дә *тәрмэ, *тәрим* (> төр. *derim*, төркм. *дирим*) «җыйма өй, тирмә» сүзеннән дип карыйлар (Г. Рамстедт һ.б.). Ләкин рус һ.б. сүзен грек. *τερεμκοк* «торак, өй» сүзенә дә нисбәт итәләр (Фасмер IV: 47). *Тирмә* үзе татарларда күптән кулланылмый, ләкин аның аерым детальләренең атамалары (алар тур. к. Будагов I: 163–164 *үй* «өй» сү-

зендә), мәс., **кирәгә, уык** хәзер дә еш кына очрый. К. **Тир-ү.** Тимергалин: 469.

**ТИР-Ү** диал., (Тумашева 1992: 207) **тәр-ү, тийр-ү** «собирать (по штуке), расставлять; отбирать» < гом. кыпч., алт., тув. *тер-*, уйг. *тәр-*, угыз. *дәр-*, хак. *тир-, тәәр-* id., бор. төрки (ДТС: 553) *ter-* «җыю; тезү; назым төзү», тув. *дери-*, як. *тәрий-* «җыю, оештыру; (сугыш сәфәренә, ауга) җыену» (к. алт. *терге-, тäргä-* «юлга җыену»), чув. *тир-* (< тат.) «энә күзләү; чәнчү; тирү, тезү, үрү», уйг. *тәр-* «дөге утырту (берәмләп)», бор. төрки (Радлов III: 1060) *тäр-* «чүпләп, җыю». Будагов I: 415; Räsänen 1969: 475; ЭСТЯ III: 204–205.

Бор. төрки **тәәр-* «рәткә (кадап, утыртып) тезү; рәткә тезеп сайлау» бик продуктив нигез булган, шуннан к. **Дәрге, Дирбия, Тиргә-ү, Тирге, Тирмә.** Хәз. тат. **тир-ү** сирәк очрый (башлыча диалекталь сөйләмдә кулланыла).

М. Федотов (II: 235) чув. *тир-* сүзен гом. төрки *тиз-* «тезү» белән чагыштыра.

**ТИРЬЯК [тирйак]** «териак, лекарство-противоядие; вид растения (цикорий)» > мар. (Упымарий: 224) *тәрийак* id. ~ ком., к.-балк. *тирьек* «әфьюн» һ.б. (күп төрки телләрдә очрый) < фар. *тәрйāк*, гар. *тирйāк* «тирьяк» < грек. *θηριακον* «елан-чаян агуына каршы дару» > лат. *theriacит*. К. **Тирәяк.** Будагов I: 353; Фасмер IV: 48; Тимергалин: 466.

Сүзнең «әфьюн» мәгънәсе әфьюн ярдәмендә авырту-әрнүләрдән качудан килә.

**ТИСКӘРЕ** «обратная сторона; север; неуступчивый, непослушный» > чув. *тискер,* удм. *тискäри,* мар. *тескаре* id. < гом. кыпч. *тәскәри* < *тәрскәри* id. ← *тәрс* «кире, дошман» (к. **Тирес**) сүзеннән («тирескә таба»), к. ш. ук кырг. *тескери*, уйг. *тәскәри* «тискәре», хак. *тискер* «тискәрегә, эчке ягын әйләндереп», *тискертĕн* «төньяктан». Федотов II: 237.

**Тискәре** нигезеннән **тискәрелек, тискәрелән-ү** дериватлары ясалган.

**ТИТАК** «ковыляние» (*титакла-у* «ковылять; быстро идти, припадая на одну ногу») < *тыйтак* < диал. *тайтак* ~ кырг. *тайтак̧* «аеры аяклы (кеше)», аз. (АДДЛ: 370) *тайтах* «аксак», *тайта-* «аксау» ← *тай-* (к. **Тай-у**). К. ш. ук каз. *тайтаңда-у* «сикереп чабу; масаю»; мар. *титак* «гаеп, ялгыш, юлдан язу» *титак* сүзеннән күч. мәгъ. булса кирәк.

**ТИТАРАЙ, тиратай**, диал. (ТТДС I: 124, 126) **дандурай, дилдарай** «дурачок» < *тилетарай* (*-тарай* – диал. зурайту кушымчасы), ягъни «үтә тиле, бик тиле».

**ТИТӘМ** (в сказках) < **тилтәм** тар. «посыльный и личный секретарь хана» < фар. *дилдäм* «фикердәш, бер карашлы» яисә *дилтäне* «сер саклаучы» сүзеннән булса кирәк (к. диал. *тил* < *дил* «күңел, эчке фикер»). Чаг. ш. ук монг. *титэм* «таҗ; чин» ш. ук фарсычаданмы?

**ТИШЕН-Ү** диал. «раздеваться» **чишен-ү**нең фонетик варианты гына түгел, к. **Тиеш-ү II.**

**ТИШ-Ү I** «продырявить; сделать дыру; отверстие» < гом. кыпч. *тәш-,* алт., куман., уйг., чыгт. һ.б. (Радлов III: 1105–1106) *тäш-, теш-,* угыз., тув. *дэш-, дәш-* id., бор. төрки (ДТС: 1553) *teš-* < **teeš-* (к. уйг. диал. *тәәш-*) id. (кайбер төрки телләрдә юк) *тиш-* < *тәш-* сүзенең *-л* варианты угыз телләрендә (*дәл-, дәл-*, ш. ук Котбидә *тил-*) очрый. К. ЭСТЯ III: 185–186, 210–212.

**Тиш-** продуктив нигез: **тишек, тишел-ү** (аерым мәгъ. «шытып чыгу»), **тишем, тиштер-ү, тишкеч,** диал. **тишәwеч** һ.б.

**ТИШ-Ү II** диал. «сменить одежду; снять верхнюю одежду» к. **Тиеш-ү II.**

**ТИЯК I [тийәк]** «палочка или мелкая кость вместо пуговиц (которая вдевается в **ялау**); палочка для зацепления узла» > удм. *тиёк* «тияк; кармак сабындагы алка» ~ к.-балк., төркм. диал. (ТДГДС: 330) *тиек* «төймә», кырг. *тээк* «тияк», хак. *теек* «ат бәйләү баганасы», алт. *тегеек* «ыргак, багур», төр. *degek, devek, tegek* «мәктәптә кулланыла торган күрсәткеч таяк»; тув. *деек*, монг. *дэгэгэ* > эвенк. (ССТМЯ I: 230) *дэгэ* «тияк»; ~ бур., монг. *тээг* «аркылаш, эшерге, төймә» ← монг. *тээ-,* тунг. *тэв-* «өстәрләү, өю; йөкләү» ~ тат. диал. (ТТДС I: 411) **тийә-ү** «салу, тутыру; түшәү, җәю» (**төя-ү** түгел!). Чаг. **Тигәләй.**

**ТИЯК II [тийәк]** (Тумашева 1992: 210) «кобылка (насекомое)» ~ хак. *теек* «саранча» – дөресе рус. «богомол» – «суфи чикерткә» (алгы тәпиләрен дога кылган кебек авызы янында тотканга шулай аталган) < рус. *дьяк* «түбән дәрәҗәдәге поп» (грекчадан, к. Фасмер I: 560). Чув. (Федотов II: 227) *тияк* «дьяк». Сүзнең «суфи чикерткә» мәгъ. рус телендә килеп чыккан.

**ТИЯР: тиярен алу (бирү)** «брать (давать) свою достойную цену» – тарихи сүз, к. бор. төрки (ДТС: 548) *tegir* «бәя», төр. *değer* «хак, кыйммәт, абруй» (*değerli* «хөрмәтле»).

**ТОБА** диал. (ТТДС I: 416 һ.б., киң таралган сүз) «плёс; омут» ~ башк. (БТДҺ: 80, 319, 332) *доба, тоба, туба* «упкын; чокырга җыелган су; тугай» ~ чув. *тăпа,* мар. (Исанбаев 1978: 26) *тува,* морд. Э. *дуба* «тоба, елганың киңәеп, күл сыман булган төше», *томка* «тирәнлек», *томбака* «баткыллы», рус. *туба* «елга белән тоташкан дугай» (шуннан *Ахтуба* «Иделнең зур параллель агынтысы», каз. Фасмер IV: 113), каз. (ҚТДС: 347) *тыма* «тар култык».

**ТОБРА,** диал. **тобыра, дорба, төбрә** «торба, мешок с провизией, навешиваемый на голову лошади и из которого лошадь может есть стоя в упряжке» (*Тобра төбен иснәмичә ат туймас,* дигән мәкаль бар) ~ башк. *төбрә*, башк. диал. (БТДҺ: 81), каз., к.-балк. *дорба*, кырг. *дорбо* (язылышлары бердәй булса да, тат., башк. *дорба* белән каз. һ.б. *дорба* әйтелеше бердәй түгел), госм. *tobra,* куман. *topra,* нуг., кр.-тат. һ.б. *dorba,* төркм. *тоорба* «гомумән киндер сумка». **Торба** варианты тат. сөйл. дә очрый. Бабур телендә **түбрәк** варианты бар бугай, к. Будагов I:: 384. Фар. *tobra* id. сүзеннән килә дип исәпләнә. Аникин: 554–555 (әдәбият күрсәтелә).

**ТОГЫ [тŏғŏ]** (Тумашева 1992: 212) «осётр» ~ Паллас буенча, себ. *таго, того*, аз. *того*, нан. *туги* (к. Линдберг, Герд: 60, 62, 64) һ.б. id. Сүзнең киң таралуы аның сәүдә шәе булуыннан.

**ТОЕК [тŏйŏк]** «стих, в котором рифма составляется из омонимов» < чыгт. *туйуқ, туйуғ* id. ~ як. *тойуқ* «җыр» ← *туой-* «җырда мактау; импровизацияләү». Будагов I: 411; Бертельс I: 57. Моннан башка диал. (ЗДС: 637) **тойоқ** «бөтен; өзлексез» сүзе дә бар. К. ш. ук алт. *туйуқ сöс* «кыеклап әйтелгән сүз» ← *туй-* «яшерү». Тимергалин: 470 (**тоек** мисалы китерә). Чаг. **Туй-у.**

**ТОЖРАЙ-У, тозрай-у** «выпучиться, блестеть (о глазах); смотреть во все глаза» ← ***тожыр, *тозыр**, к. тув. *дозура-* «ялтырау». Чаг. тат. *тозкүз* «елтыр күзле (кеше тур.)».

Дерив.: **тожраеш-у, тожрайт-у.**

**ТОҖЫ [тŏҗŏ]** (ДС III: 152; ТТДС I: 420) «чистый, аккуратный», башк. ~ (БҺҺ III: 173) *тŏжŏ* «җитез», чув. *тăчă* «точ» (?). Гомумән, ачык түгел. К. **Тожыру.**

**ТОҖЫМ [тŏҗŏм], тоҗын [тŏҗŏн]** «длинная паутина» ~ башк. (БҺҺ II: 267) *тызым* «ук кереше». Чаг. чув. *тăс-* «тарту, җеп һ.б. тарттыру». Чаг. **Чыжым.**

**ТОҖЫР-У [тŏҗŏр-]** (ТТДС I: 421) «намудрить; якобы выполнять работу» ~ кар. *туджур-, тудзур-* «агач ую, уеп бидәр ясау; авыр мәсьәлә чишү» – *тоҗы* < *туҗу* (к. **Тоҗы**) «сәнгатьчә эшләнгән» сүзеннән.

**Тоҗыр-у** ~ башк. (БТДҺ: 320) *тозор-оу, тойзор-оу* сүзенең «сугып җибәрү, тондыру» мәгъ. дә бар. Ихтимал, монда ике сүздер. Ләкин «осталарча эшләү»нең ироник мәгъ. дә үсеш алырга мөмкин. Чаг. *булдыргансың!* «тоҗыргансың, кыйраткансың».

**ТОЗ** «соль; вкус» < гом. кыпч. (Радлов III: 1502) *туз* «тоз; тәм» ~ башк. *тоҙ,* төркм. *дууз*, як. *туус* < бор. төрки (ДТС: 594) *tuz, tuuz* < **тушуз* ~ чув. *тăвар, тŏара* (Ашмарин XIII: 41) «тоз». Бу сүзне еш кына монг. *дабу, дабу-сун* «тоз» сүзе белән чагыштыралар (мәс., Räsänen 1969: 505), ләкин Э.В. Севортян әйткәнчә, бу чагыштыру «перспективасыз» (к. ЭСТЯ III: 288–289). *Тууз* < **тоор* ниндидер бер бор. сүзнең күп. формасы булса кирәк. Федотов II: 183–184 (чув. сүзен тунг. *туру, туру-кэ* «тоз» сүзләре белән чагыштыра). Мухамедова 1973: 176.

**Тŏз** продуктив нигез: **тозлак, тозлы, тозлык** һ.б. К. ш. ук **Тозчы.**

**ТОЗАК** «силок; петля» < гом. кыпч., чыгт., уйг., алт. *тузақ (тōзақ),* төркм., тув. *дузақ,* бор. төрки (ДТС: 594) *tuzaɣ, tuzaq,* як. *тусах* id. һ.б. гом. төрки ← уйг. *туз* ~ тат. һ.б. *тур* «кош аулау челтәре» (к. **Тур**), к. Räsänen 1969: 502; ЭСТЯ III: 289–290. Ш. ук вакытта *тŏзақ* < *тузақ* < **тус-ғақ* булырга да мөмкин, к. **Тус-у**. Рус. *тузак* «тозак» тур. Аникин: 560.

**Тозак** продуктив нигез: **тозаклы, тозакчы.**

**ТОЗГЫ [тŏзғŏ]** иск. «хлеб-соль, предлагаемый высоким гостям» – дәрәҗәле кунакларга тәкъдим ителгән икмәк-тоз (к. Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде: 31, 187, 304) < кыпч., бор. төрки (ДТС: 594) *tuzɣu* id. Формасы буенча **туз-* фигыленнән, мәгъ. буенча *туз* «тоз» сүзе

белән бәйле. *Тозгы* < *тузгу* сүзе иске тат. телендә еш кына очрый.

**ТОЙБЫ [тŏйбŏ],** себ. (Тумашева 1992: 213) **тойба** «скрытый; осмотрительный» – «астыртын, хәйләкәр» ~ башк. (БТДҺ: 321) *тойпо* id., алт. *тойабу* «маскировка». Н. Исәнбәт буенча, **тойбы** «яшеренгән төштән атучы мәргән» булган. Кыт. сүзе булса кирәк, к. монг. *туйпу* «кирпеч дивар, Бөек Кытай диварлы» < кыт. *tüj-рü* id.

**ТОЙГАР** себ. (Гиганов) «жаворонок» ~ төр. *tuygur, tuygar* – **тургай** (к.) сүзе белән бердәй.

**ТОЙГЫ [тŏйғŏ]** «чувство; восприятие; чутьё» ← *той-* (к. **Той-у**). Төрки әд. телләрдә киң таралган, бигрәк тә төр. *duygu* киң кулланыла һәм ишле деривациягә ия.

Дерив.: **тойгылы, тойгысыз; тойгылан-у** һ.б. (киң кулланылмаганнары бар).

**ТОЙГЫН [тŏйғŏн],** иске тат. (Троянский һ.б.) **толғун, тулғун** «белый сокол» ~ гом. кыпч., чыгт. (Будагов I: 410) *туйғун, тойғун,* госм. (Радлов III: 1142, 1784) *тоiған, дуiғун* id., ш. ук «иң кечкенә ау кошы; карчыгачык» һ.б.ш. Э.В. Севортян фикеренчә, төр. *дуган* < *доган* «ак лачын» сүзе белән бердәй түгел. Будагов I: 410; ЭСТЯ III: 248.

**ТОЙ-У [тŏй-]** «почувствовать, чуять; осязать, воспринимать; догадываться» < гом. кыпч., чув., уйг., чыгт. *туй-*, угыз. *дуй-* < бор. төрки (ДТС: 584–585) *tuj-* id., кайбер төрки телләрдә сирәк очрый яисә аерым мәгънәләрдә генә (төр. *duy-* «ишетү»). Тәүдә бу сүз «тыныч кына күзәтү һәм колак салу, сиземләргә тырышу» мәгъ. булган булса кирәк. ЭСТЯ III: 290–292; Федотов II: 241.

**Той- < туй-** бик продуктив нигез: **тоел-у, тоен-у** (сирәк), **тойдыр-у** (*тоймасаң, тойдырырмын мин сине!*), **тоем,** диал. (Тумашева 1992: 112) **тŏйсŏн-у**, к. **Тойгы, Тойгын.**

**ТОК, токчай** «мешок» ~ башк. *тоҡ, тоҡсай* < башк. диал. *толҡ* < гом. төрки *тулуҡ, тулукчай* id., к. **Толык.**

**ТОКАН-У** диал. «зажигаться, загораться» ~ башк. *тоҡан-* < **тоткан-у,* к. тат. диал. (прм.), башк. (БТДҺ: 324) *тотан-у* «токану», уйг. *туташ-*, төр. *tutuş-* «янып китү», тат. диал. (Г. Минский, к. Совет Татарстаны, 11.V, 1980) *тотандыр-у* «токандыру». К. тат. диал. **тотқа-у** (к. ТТДС I: 420) «тотып тору, тотып алу; тоткарлау». *Тоткан-у* турыдан-туры *тотан-у*дан килә алмый, чөнки бу позициядә *-т-* > *-ҡ-* мөмкин түгел.

**ТОКМАН** к. **Толыкман.**

**ТОКМАЧ,** диал. **тукмач** (к. Хайрутдинова 1993: 75–76) «лапша» ~ башк. *туҡмас, тŏҡмас* > чув. *тăкмаç,* удм., мар. *тукмач, тукмача*, рус. диал. *тукмачи* id. < бор. чыгт. **токмач*? Бу сүзнең кыпч. параллельләре юк, бүтән телләрдәге параллельләре – аз., төр. *tutmaç*, алт. диал. (Баскаков 1972: 257–258) *тутмаш, тутпаш* < бор. төрки (ДТС: 592) *tutmač* «тукмач». Тат. вариант **тукы-у** фигыленә нисбәт ителеп, халык этимологиясе нигезендә килеп чыккан, ә төп – бор. вариант **тутмач** «салма» мәгъ. булган һәм *тут-* «тоту» фигыленнән ясалган булса кирәк (к. Räsänen 1969: 502); *-мач* ашамлык атамалары ясагыч билгеле аффикс.

Дерив.: **токмачлы, токмачсыз; токмачлык.**

**ТОКТОМАЛГА, тыптомалга** (ДС III: 162) к. **Тиктомалга**. Ләкин бу вариантның бүтән тамырлары да бар бугай: к. бур. *тогтомал* «һәрдаим».

**ТОКЫМ [тŏҡŏм],** тат. диал. (миш.) **тŏхŏм, дŏкŏм** «порода (скота); круг родственников, род; потомство», диал. «семя» > мар. *тукым,* чув. *тăхăм* ~ гом. кыпч. *туҡум,* нуг., каз., к.-калп. *туҡым* id., уйг., үзб. *тухум*, чыгт., госм. ~ угыз. *тохум, дохум,* себ. (Тумашева 1992: 213) **тоғум** «орлык, йомырка» < фар. *тухм* << авест. *taoxтan* «йомырка». Räsänen 1969: 497; Федотов II: 201–202.

Дерив.: **токымлы, токымсыз.**

**ТОКЫН [тŏҡŏн]** (ТТДС I: 417; БҺҺ II: 251) «глухой (без окон); клетушка (для скота); без шва (о варежках и чулках)» < *толкын* < *толыкын* «толык рәвешендә», к. **Толык.**

**ТОЛ** «вдовствующий, вдовствующая, являющийся вдовцом (вдовой)» ~ чув. *тăлăх [тŏлŏх]* < болг. **тŏлŏҡ, *тулуҡ* > мар. кч. *тулык, тылык, тŏлŏк* id. < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт. һ.б. (Радлов III: 1464), бор. төрки (ДТС: 585) *tul,* угыз. *дул* id. – бор. мәгъ. «сөкәт, вафат ирнең сурәт-сыны (тол хатын ярты ел шул сөкәткә табынып яши торган булган)»; арытабан борынгыча *тул* «киекнең, терлекнең ярмыйча салдырылып алынган тиресе»,

шундый тиредән сөкәтләр эшләнгән һәм һәртөрле каплар, капчыклар, янчыклар һ.б. ясалган. *Тул* үзе *тӯ-л* < *туг-ул* «бикле, көпләнгән» дип аңлатыла. К. **Ток, Толас, Толча, Толыкман, Толым, Толын, Толып, Тулак, Тулпар.** Покровская 1961: 76–77; ЭСТЯ III: 292; Федотов II: 189.

Дерив.: **толлан-у, толлык;** идиоматика: **тол гамәл** «буш эш; онанизм».

**ТОЛАС** (Тумашева 1992: 212; ЗДС: 638; БҺҺ II: 251) «холостой; онанист; тряпьё; тупой, бескультурный» < гом. кыпч. **тулас* < **тулаз*, к. башк. *толаç, толаһ,* кырг. *тулас* «сөкәт; җыйнаксыз, тәртипсез», бор. төрки (ДТС: 585) *tulas* id., бор. төр. *tulaz* «тол» (к. ЭСТЯ III: 292). ДТС бу сүзне «бледный» дип аңлата, тик, безнеңчә, бу – хата (мондый аңлатма бер текстка гына нигезләнгән). К. ш. ук көрд. (< төрки) *tulazi, tulayi* «зина; иске-мосқы»; *tulaze* «зиначы».

*Толас* < *тулаз* ясалышына караганда, бор. **тул-а-* «тол булу, тол калу, толга-сөкәткә карап яшәү, юк белән шөгыльләнү» фигыленнән ясалган (*-з* бор. фигыльдән исем ясагыч билгеле аффикс). К. **Тол, Толга.**

**ТОЛГА** диал. (ТХИ: Дастаннар 1984: 312) «туловище, тело» ~ каз. (Радлов III: 1473) *тулға* «тән, фигура; әфәнде», к.-калп. *толға,* каз., кырг. *тулға,* кырг. *таштулға* «сөкәт, тол; таш сын» ~ тув. *тулгу* «киселмәгән, ярылмаган (тире); тол» (*тулгуяқ* «толкай, толгынай»), бур. *тулгу* «тол» ← *тол* «сөкәт». К. **Тол.**

**ТОЛЫК [тŏлŏк]** «мешок для соли (из снятой чулком шкуры)» < гом. кыпч. *тулуқ,* к. к.-балк., уйг., алт. *тулуқ* «чи бөте́н тиредән эшләнгән капчык», уйг. *тулуқча, тулуқчай* «кечерәк толык, ток, токчай», нуг., каз., к.-калп. *тулық* «тоташ (кисмичә) салдырылган тиредән эшләнгән кымыз тогы», кар. *тулувъ* «тире савыт», төркм. (ТДГДС: 174) *туллуқ, тулломо* «су капчыгы», каз. (ҚТДС: 91) *долық* «зур күн чиләк» (кое чистартканда коедан лай, баткак алу өчен кулланыла икән), аз. диал. (АДДЛ: 196) *дол,* аз. *тулуғ* «күн чиләк» ← бор. төрки *тул* «тоташлый салдырылган тире». *Тулуқ* сүзе тур. к. Molnar A. An agricultural termin an old uighur description of Hell // Acta Orientalia (Budapest). T. XXXIV; f. 1–3. 1980: 163–170). Чаг. чув. *тăлăх* < болг. *тŏлŏх, тŏлŏк* > мар. *тулык* «тол (толык киеп йөрүче ир яисә хатын)». К. **Тол, Толыкман, Толым, Толып, Тулак.**

**ТОЛЫКМАН [тŏлŏкман]** «очень большой мешок (для перевозки домашней утвари, постельных принадлежностей); большой кусок, глыба» – **толык** яисә **толым** нигезенә **-ман** зурайту кушымчасы ялганып ясалган, к. монг. *тулумкаан* > эвенк. *тулумкан* «бозауның тоташ тиресеннән эшләнгән капчык» (ССТМЯ II: 212) ← *тулум* «толык», к. түбәндәгене. К. ш. ук Аникин: 562–563.

**ТОЛЫМ [тŏлŏм]** «коса (волос)» ~ нуг., каз. *тŏлым,* к.-калп. *тулым,* үзб. *толим* «чәч баеркасы», куман., каз. (Радлов III: 1198, 1469, 1470) *тулум,* алт., хак. *тулуң* «толым; чигә толымы», чыгт. *толун* >> мар. *тылым,* чув. *тăлăм* «баерка» (рус. «клочок невыстриженных волос человека или шерсти на овце, оставленный как примета») < бор. төрки (МК I: 371), кар., госм., төркм. *тулум* «күн капчык; юл капчыгы; йөзмә күпер салу өчен кулланылган капчык» << чыгт. *тулуғум* id. < *тулуқ-ум* < **тулуқ-уң* > *тулуқ-ун* >> *тулун* id. ← *тул* «тоташлый салдырылган тире». К. ш. ук сол. *толма*, маньч. *тулума* «эченә һава тутырылып, йөзмә күпер салу өчен кулланылган тире капчык» (ССТМЯ II: 212). Шулай итеп, *толым* асылда «тире, күн капчык» дигән сүз; хикмәт шунда – ирле хатыннар (хәзер – Тувада) һәм шаманнар толымнарын махсус капчыкка салып йөрткәннәр, к. Моллова М. Тюркские слова *tulım, tololaq, yez, qapsa* в Codex Cumanicus. СТ № 2, 1989: 34–50. К. ш. ук бур. *тулам, туулмаг* «тире капчык».

*Толым* < *тулум* һәм *тулун* сүзләре тарих дәвамында күп мәгъ. алган һәм төрки телләрдән күп күрше телләргә үтеп кергән, к. Будагов I: 725; Räsänen 1969: 497–498; Федотов II: 188. Рус. *тулунья* «әрбет чикләвеге җыю өчен тире капчык» тур. к. Лебедева, Сафьянов: 109. Рус. *тулым, тулум* «валун» (тире капчыкка охшашлыгыннан), *тулун* тур. к. Аникин: 562, 564 (шунда ук әдәбият). К. **Толымбас, Толып.**

**ТОЛЫМБАС [тŏлŏмбас]** «тулумбас, вид (турецкого) барабана» < төр. *tulumbaz – tulum* «шубыр (эченә һава тутырылган тире капчык һәм шуңа беркетелгән сыбызгыдан гыйбарәт музыкаль аләт, әсбап) уйный торган музыкант» (монда «уенчы → уен әсбабы» мәгънәви күчеше күзәтелә, андый күчеш мисаллары күп кенә). **Тулумбаз** сүзе үзе фар. телендә ясалган (*-баз* «уен, уенчы» морфемасы шуны күрсәтә). *Тулум* исә төрки, к. **Толым.** К. диал. **тулумбы** «тоташлый салдырылган тире». Аникин: 563 (рус. *тулунбасить* «йодрыклау» тур.). К. түбәндәгеләрне.

**ТОЛЫН [tŏlŏн]** «мешок для воды у верблюжьих караванов» к. **Толым.**

**ТОЛЫП [tŏлŏп]** «тулуп», диал. (к. ТХИ: Әкиятләр II, 1978: 257) **тылуп** (гарәпчә язылыштан ялгыш күчереш, дөресе – **толоп**) «мешок» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 321) *толоп* «бозау тиресенә салам тутырып эшләнгән сыер алдагычы; ярмыйча туналган тире һәм шул тиредән ясалган әйбер», кр.-тат., кар., *тулуп* «саба; күрек», алт. шор. *тулуп* «тоташлый салдырылган тире, шундый тиредән (ш. ук аяк тиресеннән) эшләнгән капчык, янчык һ.б.» ~ гом. кыпч., уйг., үзб., төр. һ.б. (к. Радлов III: 1469–1470) *тулум* id. (к. югарыда) *тулуп* > *тулум* булса кирәк, к. төр. *tulumba* «тире савыт; тире мичкә, бигрәк тә янгынчы мичкәсе». Һәрхәлдә сүзнең тамыры *тул* «тоташлый салдырылган җәнлек, хайван тиресе» (к. **Тол**). **Толып**, шулай итеп, «эре бәдәнле хайванның (мәс., аюның, пошыйның) тоташлый салдырылган тиресеннән эшләнгән тун» булган. К. удм. *тулуп* «тол, ятим (**тул** – сөкәт белән яшәүче)»; рус. сөйләшләрендә *тулуп* «толык; табут; пот, санәм» – төрле (бигрәк тә Себер) төрки сөйләшләреннән (Аникин: 563–564), иске рус. *tollyp* «нугай куйлары тиресеннән эшләнгән тун, мехы эчке ягында» (к. Ларин: 187). Бу сүз рус теле аша күп телләргә таралган; мар. *тулып, тылып,* удм. *тулуп* рус теленнән дә, тат. теленнән дә кергән булырга мөмкин. Чув. *тăлăп* «толып» сүзен М. Федотов (II: 189) русчадан дип яза, безнеңчә, алай кистереп әйтеп булмый. Юналеева 1982: 52–55 (бик тәфсилле). Рус. *тулун, тулуп* һәм *тулым* сүзләренең төрки булуы һәм тамырдашлыгы тур. Аникин: 562–563 (бик күп әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **толыплы, толыпсыз; толыпчан.**

**ТОМ I** диал. (ТТДС I: 417) «совершенно (о темноте, о невежестве и т.п.)» ~ чув. *тăм* id. ~ бор. төрки (Радлов III: 1520) *тум-* «күз йому» – күрәсең бор. онопоэтик тамырдан, аның гомуми мәгънәсе «караңгылык; караңгылану, каплану». Шуннан башк. (БТДҺ: 322) *тŏмбат* «томансу (көн)», *тŏмŏҡ* «болганчык, тоныk», *тŏмра* «тынчу», тат. диал. **тŏмар-у** «караңгылану, болытлану», **тŏмарык** (алт. *тумарык*) «томан», алт. *томай*, хак. *тумай* «йомыкый; караңгы, томанлы». К. **Дөм, Тома, Томан, Томау, Томса, Тон, Тон-у.**

**ТОМ II** в парном слове **им-том** «знахарское лечение» (*им* «лечение, знахарство» и *том*) ~ монг. *дом* id. Чаг. ш. ук чув. *йăм [йŏм]* id. Як. *дом* – рухларны чакыру ымлыгы (шаман *дом-дом-дом* дип чакыра).

**ТОМА I** «совершенно, отроду» (*тома сукыр; тома юкны сөйләү,* Г. Толымбайда, к. ш. ук ТТДС II: 301) < *тума* id. ← **ту-у** (к.). Чаг. *шома* < *шума.* **Тома II** һ.б.ш. сүзләр контаминацион компонент буларак тәэсир ясаган.

**ТОМА II: тома балавыз** «прополис» ~ чув. *тăпа [тŏба]* id. Гомумән бу сүз «бөтенләй ябулы, көпләнгән, караңгы һ.б.ш.» мәгънәләрдәге ономопоэтик *тŏм* < *тум* тамырыннан булса кирәк; һәрхәлдә бу символик яңгырашның тәэсире юк түгел, к. **Томак, Томау, Томра-у, Томса, Төм.** Ихтимал, **том-у** яисә **томы-у** фигыле дә бардыр, к. диал. (ТТДС II: 301) **томол-у** «төтеннән һ.б. буылу»; мондый фигыль исә **том** тамырыннан ясала ала. К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 212) **томуын** «яшерен рәвештә, яшертен».

*Тŏма ~ тŏба* сүзләре **тŏмпа* (чаг. **Тумпа**) сүзенең чагылышлары да була ала. К. **Томала-у.**

**ТОМАГА** «закрытый шлем воина, а также охотничьих птиц» ~ гом. кыпч. булса кирәк, к. кырг. *томого,* үзб. *тумаға* «томага, томак» < яз. монг. *tomuγa* «башлык, кәпәч», төр. *tomağa* «аучы кошның аягына бәйләнгән агач шар» (икенчел мәгъ. булса кирәк). **Томаға < тумаға** нигезе **томак < тумак** (к.) сүзеннән ясалган, киресенчә түгел. Будагов I: 406.

**ТОМАЙ** (БТДҺ: 322, тат. сөйләшләреннән) «необщительный» ~ алт., хак., шор. (Радлов III: 1240) *томай, тумай* id. Чаг. уйг. (Радлов III: 1524) *тумлы-, тумла-* «томсару, томанлы һәм салкын булып китү». К. **Томса.**

**ТОМАК** «колпак (Рамазанова 2001: 134); чехол, надеваемый охотничьим птицам на голову во время их траспортировки к месту охоты» < гом. кыпч., к. каз. *тŏмаҡ,* үзб., уйг., кырг. *тумаҡ* id., төркм. диал., үзб. *тумоҡ* «колакчынлы бүрек» ← **тома-, том-* < **тума-, тум-* «тоташ каплау, көпләү» фигыленнән (к. түбәндәгене). Чаг. ш. ук маньч. (ССТМЯ II: 196) *томархон* «томак». Рус. диал. *тумак* «колакчынлы бүрек» тур. Аникин: 264–265.

**ТОМАЛАК** (Тумашева 1992: 212) «мошка» – төп мәгъ. «сукыр, күзе томаланган» булса кирәк,

чаг. тат. **сукыр чебен** ~ башк. (БТДҺ: 381) *һуҡыр себен* «ләпәк, вак чебен». **Томалак чебен** тезмәсеннән икенче сүз төшерелгән. К. **Томала-у.**

**ТОМАЛА-У** «закрыть, заткнуть (отверстие) наглухо» < гом. кыпч., к. каз., алт., куман. (Радлов III: 1528) *тумала-* «томалау, биләү, чолгау» ← **тома < тума** «каплавыч; тыгын, бөке».

Дерив.: **томалан-у, томалаш-у, томалат-у. Томалан-у ← тома** «капланган» сүзеннән дә ясала ала, чув. *тăмалан-* «(чәчләр) билтәләнү; тончыгу» сүзен М. Федотов чув. *тăмала-* «тетү» сүзенә бәйлый, ләкин бу сүз *тăрмала-* сүзеннән (*-р-* редукцияләнгән), ә *тăмалан-* «томалану, тончыгу» тат. теленнән алынма.

**ТОМАН** «туман» < гом. төрки *туман* «томан; караңгылык; буран», чув. *тăман*, хак. *тубан*, угыз. *думан* id. – Э.В. Севортян бор. төрки **тум* «каплау, караңгылау, карангылык» (к. **Том**) тамырыннан димәкче (ЭСТЯ III: 295–296). Гадәттә, киң таралган *туман* сүзен бор. ир. *dumnan, dvanman* «томан, төтен» сүзенә (аның чагылышлары ир. телләрдә шактый, к. Абаев I: 383) нисбәт итәләр. Федотов II: 191.

Дерив.: **томанлы, томансыз; томанла-у, томанлан-у; томансу.**

**ТОМАНА** «тёмный, совершенно неграмотный; недалёкий», диал. (ТТДС: 418) «тыныч кына, сүзсез, семәеп-боегып» башк. (БТДҺ: 321, асылда татарча) *тома, томала, томана* ~ чув. *тŏмана* «байгыш, ябалак», мар. *тымана, тумна* «ябалак» – рус. сөйл. *тёмна, тёмная* «сукыр; ябалак, байгыш» сүзеннән булса кирәк (*томана* сүзе, Идел-Урал регионыннан тыш, төрки телләрдә юк). Тат. телендә бу сүзнең мәгънәсенә **тома I** сүзе тәэсир иткән. Федотов II: 191 (рус теленнән дими).

Дерив.: **томаналык, томаналан-у.**

**ТОМАР I** «свиток (завёрнутый в футляр)», «жезл», «амулет – бумага с записанной молитвой, завёрнутая в кожаный треугольник и носимая при себе» < кырг., уйг., үзб. һ.б. *тумар* id. (*бой тумар, мойунтумар, култуктумар, куштумар* һ.б. төрләре тур. к. Ершов, Широкова: 25 һ.б., шунда ук рәсемнәре); к. ш. ук көрд. *tomar* «кәгазь урамасы; язып бару өчен кенәгә; исемлек, типтәр», фар. *тумар* id. ~ госм., аз. *тумар* «кәгазь урамасы; баш хәреф; бер башы калынаеп торган калай цилиндр» (к. Zenker: 327, 611) < гар. *ṭ̣ӯмāр* id. грекчадан (Будагов I: 753; бүтән авторлар да бу сүзне грек теленнән дип күрсәтәләр, к. Бируни 1995: 598). Чаг. ш. ук бур. *дагумари* «галстук; томар».

**Томар** тур. күп язылган. К. Räsänen 1969: 487; ТТДС I: 342, 347; Мухамедова 1973: 140; Валеев 1976: 248.

**ТОМАР II,** диал. (ТТДС I: 418) **томарчык** «стрела с тупым концом или шариком вместо острия (для охоты на белок, а также применяемая как детская, учебная)», «бутон цветка, головка лука» ~ алт. *томар,* уйг. *томур* id. Бу сүз төрки телләрдән рус теленә дә кергән һәм аның төп чыгышы тур. төрле фикерләр әйтелә: Штейниц (: 280–282) рус сүзен татарчадан ди; Абаев (III: 299–300) бор. һинд *tomara* «атыла, ыргытыла торган сөңге» сүзенә кайтарып калдыра; Аникин (: 552) бор. ир. *taumara* «кулдан атыла торган ук» сүзенә тоташтыра. К. ш. ук Фасмер IV: 859 (О.Н. Трубачёв искәрмәләре белән).

Безнеңчә, *томар* < (башк. диал.) **тумар** сүзенең чыгышы ерактан түгел – ул **тум** (к. **Тумпа**) ономопоэтик тамырыннан, к. кар., төр. *tomruq, tomuruk* «чәчәк томарчыгы», ком. *томпур* «бөре» һ.б. К. **Тумалак.** В. Радлов (III: 1236) **Томар I** һәм **II** сүзләрен бер итеп карый.

Дерив.: **томарлы, томарсыз; томарлан-у.**

**ТОМАС** (Тумашева 1992: 212) «пасмурный, облачный» ~ башк. (к. БТДҺ: 322, 336) *томбат, томпаҫ, тумбат, тумбаҫ,* күч. «астыртын, аз сүзле» – нигез яңгырашы **тумбаз* булса кирәк, *том* < *тум* «бөркүле, ябулы, томалаулы» тамырыннан, әлбәттә. К. түбәндәгене.

**ТОМАУ [tŏmaw], тымау** «насморк» – ***тома-у** «(борын) тыгылу» дигән фигыльдән исемләшкән – гом. кыпч. *тумаw,* кырг. *тумоо;* тат. диал. (миш., к. ДС I: 192) **тŏнау** «томау», себ. (ДС I: 187) **томарау** «томаулау»; бор. төрки (ДТС: 585) *tumaγu* > уйг. *тумаг,* үзб. *тумоғ,* госм., чыгт. *думаγу,* төр. *duma, dumağı, tumağı* ~ төркм. *дүмев, думав, тумав* (кыпч., телләреннән), тув. *думуу,* як. *тумуу,* хак. *тымо* һ.б. (к. ЭСТЯ III: 325–326) «томау». Тамыры – **тум** «бөркәүле, томалаулы», к. **Томала-у, Томас.**

Дерив.: **томаулы, томаусыз; томаула-у.**

**ТОМБА, томбак** «ботало (кругляк из тряпья, насаженный на длинную палку, употребляемый для того, чтобы загнать рыбу в снасти ударами по воде)» < *тумпа, тумпак* (к.).

**ТОМРА,** диал. **тŏмŏра** «мгла; тёмный, пасмурный» ~ башк. (БТДҺ: 322), к. **Томра-у.**

**ТОМРА-У, томыра-у [тŏмŏра-]** «выглядеть тёмным, тихим и бездонным (о небе и о воде); делаться пасмурным, хмурым»; **томрап тору** «выглядеть спокойным и сильным (о девушках и лошадях)», **томрай-у** «помрачнеть (о человеке)», себ., алт. (Радлов III: 1520) *тумарыҡ* «томрау, томанлы», хак. *тумара, тунара* «йокылы», як. *тумарый* «баш тону», *тумара* «агачсыз саз; куе томан һ.б.ш.». Күрәсең, *том* < *тум* «бөркәүле; капланган, томанлы» тамырыннан төрлечә юллар белән ясалган һәм үзара контаминациягә кергән сүзләр. К. **Томас, Томра, Томса, Томырык.**

Охшаш сүзләр һинд-евр. телләрендә дә бар: бор. һинд. *tumra* «көчле, юан, зур» ~ лат. *tumor* «шешенке», *tumere* «шешенү» һ.б.

**ТОМСА, төмсә** (ДС III: 157, 165) «мрачный, хмурый; хмуро молчаливый, необщительный, замкнутый» > чув. (Сергеев 1971: 23) *тăмса, тăмсай* «сүзсез ахмак» ~ каз. *тŏмса* id.; чаг. ш. ук тат. диал. (ТТАС III: 116) **томсыҡ** ~ уйг. *домсаҡ* «томса». Чаг. аз. *доңсу-* «томсару, кайгыда тынып калу». *Томса* < *тумса* ~ *тумсыг* нигезе *тумса-//тумсы-* фигыленнән ← *том* < *тум* «бөркәүле, капланган; томанлы» тамырыннан булса кирәк» К. **Том I, Томра-у, Томырык,** чаг. **Томай, Томыш-у** һ.б. (ономопоэтик *том* ~ *тум* ~ *тŏм* тамырыннан).

Дерив.: **томсакай** > чув. *тăмсака* «сүзсез һәм зиһенсез» (ләкин холыксыз түгел); **томсалык, томсалан-у.**

**ТОМСАЙ-У, томсар-у** «хмуро или обиженно замолчать», **төмсәр-ү** «помрачнеть» ~ каз. *тумсар-, түмсер-,* кр.-тат. *tomsar-*, уйг. *домсай-, домсар-* һ.б. охшаш мәгъ. К. **Томса, Томсык.**

**ТОМТАЙ-У, тумтай-у** себ., трбс. һ.б. «выпукло выступать (обычно о больших объектах)»; Рясянен бу сүзгә махсус тукталып, аны төрки, тунг., фин телләренә уртак лексемалар рәтенә кертә, к. Räsänen 1969: 499. Чаг. **Тумпай-у.**

**ТОМШЫК [тŏмшŏҡ]** «клюв», күч. «морда, харя» ~ уйг., чыгт., бор. төрки *tumšuq, tumšıq*, алт., тув. *тумчуҡ,* хак. *тумзух* id., каз., госм. (Радлов III: 1240) *томшуҡ* «томшык; калку борын» ← *тум, тумб* «тумпа нәрсә». К. **Томыш.** Räsänen 1969: 499.

**ТОМЫР-У [тŏмŏр-],** диал. (Остроумов 1972: 125; ДС I: 190) **тумыр-у** «перерубить, перепилить на большие куски (дерево и т.п.); расколоть сильным ударом; ударить тяжёлым предметом, бросить с размаху» ~ башк. *тумыр* < гом. кыпч. (кайбер телләрдә начар сакланган), алт. *томыр-, томур-* id., бор. төрки (МК; ДТС: 574) *tomır-* «тумран ясау, агачны түгәрәкләп кисү» ← *том, томб* «йомры нәрсә» (к. **Тумпа**) тамырыннан; к. ш. ук төр. *tomruk*, к.-балк. *томуроу* «зур агач кисәге, тумран, түмәр; бүрәнә». К. **Тумран, Түмәр.** Räsänen 1969: 487.

**Томыр-** продуктив нигез: **томырыл-у, томырыш-у.**

**ТОМЫРЫК [тŏмŏрŏ́ҡ]** «спёртый; тихий и глубокий (о водоёме); омут» < диал. *тŏмарык* < себ., алт. *тумарык* (Радлов III: 1520) «караңгы, томансу» ← *тумар-* «караңгылану, томанлану» ← *тум* (к. **Том I**). К. **Тымызык.**

**ТОМЫШ [тŏмŏш]** (Троянский I: 372) «переносица» ~ як. (Пекарский: 2811–2813) *тумул* «тау кашлагы, тау борыны», *тумус, томус, тумса, тумусах* «томыш; томшык, борын» < бор. төрки **тумул* < *тум-ул* ← *тумб* «тумпайган нәрсә; томшык». **Томшык** сүзенең этимоны *томыш-ыҡ* < *тумуш-уҡ* рәвешендә дә, *том-чыҡ* < *тум-чыҡ* рәвешендә дә булала. К. ш. ук як., алт. *тумук* «имезлек борыны (төймәсе)», госм. (Радлов III: 1238) *томуш-* «берберсенең борынын чистарту (кошлар тур.), үзб. (ЎХШЛ: 263) *тумуш-, тумшай-* «үпкәләшеп, борын салындырып утыру». Госм. һәм үзб. сүзләре бор. **тум-* «томшыклы булу» фигыленнән.

Чув. (Ашмарин XI: 245–246) *сăмса* «томшык, борын», *сăмсак* «борынсыман калкулык» сүзләренең *томшык* сүзенә кагылышы юк – алар яз. монг. *samsa* «танау» белән гомоген, к. Федотов II: 24.

**ТОН I [тōн]** «тон» < рус. < ним. < лат. *tonus* «тон, тонус», асылда «думбыра кылының киерелеше» сүзеннән. Төрки телләрдә дә охшаш сүзләр бар.

**ТОН II [тŏн]** (Рамазанова 2001: 129) «первенец; ребёнок сразу после рождения», диал. (ТТДС I: 419) **тŏнчык** «первенец; первый сын» ~ кырг., уйг., хак. *тун*, тув. *дуң, дун* «тон, баш угыл; чын; ихлас», бор. төрки (МК) *ton* «беренче; асаба; атасы урынына каласы» (шуннан бор. төрки ханнарының атаклы бер киңәшчесе – *Тоньюкук* «беренче хәзинә» – исеме килә, к. Кляшторный С.Г. Тоньюв-

кук – Ашидэ Юаньчжэнь // Тюркологический сборник. М., 1966: 202–204). К. бор. төрки (ДТС: 586) *tun beg* «тәүге ир», *tun oγul* «беренче угыл», *tun* «беренче, тәүге». К. ш. ук тат. диал. (ЗДС: 699) **тонык,** уйг., аз. *туңҗү, тунҗуқ* «тәүге бала». К. **Тонгыч.**

**ТОНАН-У, тунан-у** (себ., ЗДС: 639) «облачиться (в военную, боевую форму)» ~ төр. *dunan-* «кораллану» (төр. сүзенең деривациясе киң) ← *dun* «тун, көбә». Күрәсең, **тун** < *тон* сүзенең тәүге мәгънәсе «хәрби кием» булган. К. **Тун.**

**ТОНГЫЧ [тŏнғŏч]** «первенец» ~ кар. *туньгуц, туңгуч, туңгыч,* үзб. (ЎХШЛ: 381) *тоңғыч, тоңғич, туңгич,* каз. *туңгут* «беренче угыл» >> к.-балк. *тюньюч улан* «беренче углан», каз. (Будагов I: 380, 403) *туңгуш,* чыгт. (Бабур телендә) *туңгуҗ* «беренче угыл», тув. *туңгуш* «беренчел тапкыр балалаучы», як. *тунуй* id. «гыйффәтле кыз» < монг. *туң-, туңга-* «беренче бала булу (туу)», *тунғағ* «беренче бала», калм. *туңгу* «бер генә балалы (хатын)» һ.б. Рясянен (Räsänen 1969: 500) бу сүзләрне алт. диал. *туңгақ* «томаланган, бөкеләнгән» сүзе белән чагыштыра, к. алт. (Будагов I: 808) *туң* «бала тапмаган хатын». Гомумән, монда беренчел мәгънәне билгеләү авыр.

**ТОНДЫР-У [тŏндŏр-]** «закинуть; ударить» ← **тон-у II** («башы тонырлык итеп сугу, бәрү» сүзеннән килеп чыккан).

**ТОН-У I** «отстояться (к. *Су болганыр да тонар, ил болганыр да тынар*, мәкаль); стать как стеклянные (о глазах)» < гом. кыпч. (күпчелек кыпч. телләрендә дериватлары гына кулланыла) *тун-* «сөзгеп, үтәкүренмәле хәлгә килү», тув. *дун-*, үзб., уйг. *тинъ-* «төпкә урыту, чүпләнү (савыт төбе тур.)» < бор. төрки *tun-* «тынычлану» ← *tu-* «ябу, тоткарлау» фигыленең кайт. юн. (к. ДТС: 584, 586). К. ш. ук бур. *туна-* «төпкә утыру», бор. монг. *tunqä-* «сөзү» (Поппе 1938: 354). К. **Тонык, Тонык-у.**

**Тон-у I** продуктив нигез: (су) **тондыр-у,** к. **Тонык I, Тонык-у I.**

**ТОН-У II** «глохнуть; закладывать нос; терять сознание, ясность чувств и мысли» < каз., чыгт., алт., хак. *тун-*, алт. *туң-* «ябык, бөркү, тынчу булу» бор. *туң//тум* (к. **Том I**) тамырыннан. **Тон-у** < *тун-у I* һәм *тон-у* < *тун- II* еш кына буталалар, ләкин ДТС (536) боларны аерып күрсәтә.

**ТОНЧЫК [тŏнчŏк],** (Старчевский) **тунцукъ, тунчук,** диал. (ДС I: 192) **тынчык** «затхлый» ~ нуг. *туншық* id. < бор. *тунчуғ* > тат. *тынчу [тынчыw]* id. ← *тынчы-* < тат. диал. *тончы-* < бор. *туңчу-, туңчы-* «тынчу» ← *туң-* фигыленнән кабатлану, дәвамлы булу формасы. К. **Тон-у II. Тончык-у.**

**ТОНЧЫК-У (тончыгу, тончыкты)** «задохнуться» < гом. кыпч. *тунчық-, тунчуқ-* (нуг., каз., к.-калп. *туншық-* id.) «тончыгу» ← *туңчу-* «тынчу» фигыленең интенсивлык формасы.

**ТОНЫК-У I (тоныгу, тоныкты)** «становиться прозрачным (о воде)» – **тон-у I** фигыленең интенсивлык формасы.

**ТОНЫК-У II (тоныгу, тоныкты)** «оглушиться» ← **тон-у II** фигыленең интенсивлык формасы.

**ТОПА, топ** диал. «крепкий; сплошной, неразделанный» ~ (БҺҺ II: 253) – шуннан диал. (ТТДС I: 444) **төпкүтәрә** «тулаем, бөтенләй; тик торганда».

**ТОРА I,** (брб., ЗДС.: 640) **торацык** «город», тар. «небольшая крепость, укреплённое языческое святилище», тар. **тура** «передвижное защитное ограждение» (к. Греков, Якубовский: 473) «башня» (күрәсең, шуннан ук **тура** – шахмат фигурасы) – бу сүз Себер халыкларында киң таралган, к. алт., монг. *тура* < бор. төрки (ДТС: 587) *tura* «ныгытылган торак» ~ тунг. (ССТМЯ II: 219–221) *тура, туру* «багана, мачта; шаман агачы; манара; колга (чум төнлегеннән чыгып торган махсус озын кәртәлек)» ~ як. *туру,* тунг. *тора, тŏра, турум* «пот, санәм, торараш». Бу сүзне төрки *тур-* «тору» сүзеннән дип аңлату бик тә беркатлы. Төбендә *тура* ~ *туру* (ихтимал **тураw*), рус монастырьлары шикелле ныгытылган гыйбадәтханәне белдергән һәм ул гыйбадатханәдә мәҗүси пот торган (к. **Тораташ**). Хәз. Башкортстан территориясендә ике **Боратау** билгеле – аларның түбәсендә кирмән калдыклары бар. Уфа шәһәре дә элек *Тора кала, Имән кала* һ.б. дип аталган дигән легендалар бар. Ниһаять, **Кандыра** күленең атамасын төбәктәге эзтабарлар **Хан тŏра,** ягъни «хан кирмәне» сүзеннән дип баралар һәм чыннан да бу күл эчендәге ярымутрауда кальга калдыклары табыла диләр. К. ш. ук Тимергалин: 482.

*Тора* < *тура* сүзенең чыгышы ачык түгел: маньч., бор. төрки *тура* «бруствер; бáлка» (к. Räsänen 1969:

500; Clauson: 531) яки санск. *тару* «агач, тирәк» (к. Чернецов: 125) сүзләре белән чагыштырулар безне канәгатьләндерми.

**ТОРА II: тора ят** к. **Торачы.**

**ТОРАК** «жилище» ← **тор-у.** Кайбер төрки телләрдә *турақ, дурак* «тукталыш», алт. *тургақ* «юл чаты; юл чатында булына торган адаштыргыч рух». К. **Торлак.**

**ТОРАТАШ** «каменная статуя» – *тора ташы.* К. **Тора.**

**ТОРАЧЫ,** (ЗДС: 640–673) **торачи, торәчәй, тырачәй, тыраш** «предок четвёртого поколения по женской линии», «далёкий родственник», чаг. **тора ят** id. (рассматриваемый с точки зрения законности брака) ← **тŏра** < (кырг.) *тобура* ~ монг. *тогура* «онык-онык-онык» (*баба-токым* линиясе киредән кабатлана). Гомумән, **-чы//-чи, -ча//-чә** кушымчасына беткән нәсел-нәсеп терминнары монгол телләреннән килә бугай.

**ТОРБА** «труба (печная)» к. **Труба.**

**ТОРБАК, торбақ, торбоқ** (ЗДС: 640) «тёлка», **турбақ** (ЗДС: 659) «телёнок вообще; двухлетняя тёлка, тёлка до отёла», ш. ук *торбы* id. (барысы да себ.) ~ башк. *торпақ, торпы* «бер яшьтән зуррак бозау», каз. *торпақ,* кырг. *торпоқ,* хак. *торбақ,* алт., тув. *торбаг, дорбаг, торбог* > рус. диал. (Аникин: 500) *торбак* «яшь бозау», *торбóк* «икенче яшькә чыккан бозау». Әгәр *торпақ* белән тамырдаш булса, башк. *торпо, торпы*, тат. *турпы, торбы* сүзенә параллельләр күп: хәз. монг *тором* < бор. төрки (ДТС: 578) *torum* «бута, дөя баласы», *torum* «икенче яшьтәге бозау» һәм бор. монг. *torum* «бута, дөя колыны» ~ хәз. төр. *dorum* «бута», чыгт. *турум* «ике яшьлек колын». Бу сүзләрне Мухамедова (1973: 172) иске төрки *торумчах* «ике яшьлек дөя баласы» һәм Көнб. Анатолия төр., төркм. *тоорум ~ догурум* «ике яшьлек колын» сүзләре белән, арытабан, бор. төрки *toɣur-, doɣur-* «тудыру» сүзләре белән баглый. Безнеңчә, монда бер яктан *торбак* ← *торбы* рәтендәге сүзләрне *торум ~ турум* белән, икенче яктан ул *торумны тогурум* белән ышанып багларга арадаш сүзләр җитенкерәми. **Торп* тамыры нишләп *торум*нан килеп чыккан икән?

Мәгънәви җәһәттән монда шикләнерлек урын юк. Чаг. ш. ук чыгт. (Будагов I: 387) *тор* «бозау», арытабан рус һ.б. *тур* «бор. Евразия далаларында яшәгән һәм кырып бетерелгән кыргый сыер-үгез». К. **Туры II.**

**ТОРГА** себ. «вид толстого шёлка» к. **Турка.**

**ТОРГАК** тар. «пост охраны», «стан» – сүзмә-сүз «стоящий; стойкий»; название рода (к. Будагов I: 388). Гадәттә *яткак-торгак* дигән парлы сүз («вакытлыча ятыла һәм аягүрә йөреләә торган төш») составында килгән. **Торгак** постта тик торган кешене – хәрбине дә белдергән (рус. *постовой* кебегрәк булган). К. бор. төрки (ДТС: 587) *turɣaq* «сакчы» ← *tur-* «тору».

Дерив.: **торгакла-у** «эш буенча төп торак-торлактан еракта тәүлекләп яту, куну-төнү (мәс., ерак көтүлектә, ерак басу торгагында һ.б.)». Алт. сөйләшләрендә *тургақла-у* «берәр урынга җен ияләшү» ← *торгақ* «җирнең, урынның иясе (җене)», к. Алтай кеп-куучындар 1994.

**ТОРКЫЛДА-У [тŏркŏлда-]** «курлыкать (о журавлях)» < **торыйк-ылда-у: торыйк-торыйк** торналар авазына тәкълит.

**ТОРКЫЛЫ [тŏркŏлӹ]** диал. «вдоль» < **торкы-лай,** к. нуг., каз., к.-калп. *турқы,* кырг. *турқ, турқу* «кәүсә; торык, сырт; буй». К. **Торык.**

**ТОРЛАК** «постоянное жильё; жилище; населённый пункт, куда возвращаются постоянно» (в отличие от *кышлак* < *кышлаг* «зимовка», *җәйләү* < *йайлаг* «летовка» и т.п.) ~ гом. кыпч., уйг. *турлақ,* алт., хак. *турлаг* id. ← *тор-* < *тур-* (к. **Тор-у**), бу сүздә **-лак//-ләк < -лаг//-ләг** үзенә күрә бер кушымчага әверелгән. Хәз. телебездә **торак** һәм **торлак** сүзләре буталана; тат. сөйләшләрендә *торlaw* «торлак» сүзе булган, шуннан чув. *тăрлав* «торлак; тәртип; нәтиҗә» (!). Бу сүзләр *тор* < *тур* дигән исем булганлыгына ишарә итә шикелле (к. **Тор-у**), к. алт. *турла-* «билгеле бер көтүлектә тору» (Баскаков 1972: 257).

**ТОРМА,** диал. (Тумашева 1992: 213) **тŏрŏп** «редька», (ДС I: 187) **тŏрба** «хрен» ~ кар., к.-балк. *турма,* венг. *torma,* монг. *тором* id., каз. *тŏрŏп* «торма, шалкан» < фар. *турма, турб, турп* (> госм. *turp, turup*) id. Räsänen 1969: 501. Бор. төрки (ДТС: 587–588) *turma* «корбан ашы», *turmïq* «дару төре» бүтән бер сүз бугай.

Венг. сүзе бор. кыпч. (куман) теленнән булса кирәк.

**ТОРМЫШ [тŏрмŏш]** «жизнь; житьё-бытьё; семейная жизнь» (*тормышка чыгу* «выйти замуж») > чув. *тăрмăш* id. < гом. кыпч., уйг., үзб. *турмуш* (нуг., каз., к.-калп. *турмыс*), төркм. *дурмуш* id. Бу сүз бор. әд. телдән таралган. К. **Тор-у.**

**Тормыш** продуктив нигез: **тормышлан-у** «тормышка чыгу, хатын алу», **тормышлы** «гаиләле», **тормышсыз, тормышчан** (рус. *жизненный* сүзеннән калька булса кирәк).

**ТОРНА** «журавль» ~ мар. *турна, турня, тыртня*, чув. *тăрна, тăрне, тăрньа* < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *турна*, угыз. *дурна,* як. *туруйа* < бор. төрки (ДТС: 588) *turuŋaja quš* ~ монг. *тогрун, тугарун, туграгун, тогоригун* < яз. монг. *toγuriγun* һ.б. ~ эвенк. (ССТМЯ II: 193) *токоров* «торна». К. ш. ук удм., коми. *тури,* венг. *daru* < *taro* id. Бу сүзне *тур-* «тору» нигезенә кайтаруга (ЭСТЯ III: 301–302) хаҗәт юк, чөнки бу кош атамасы тәкълиди сүздән (к. **Торкылда-у**) килеп чыккан, чаг., кор. *turum*, бор. ир. *zurana*, ним. *Kranich* (шуннан *кран* сүзе дә килә), бор. инг. *cornoc*, бор. герм. *trani* «торна» (Kluge: 534) – барысы *турр* ~ *тугур* ~ *курр* һ.б.ш. тәкълитләрдән.

**Торна** һәр телдә диярлек күч. мәгънәләр дә биргән продуктив нигез: **торналы** (саз), **торнакай** (> чув. *тăрнаккай*), **торнай** «озын буйлы арык кеше; акылга таман буйчан кеше», **торнабаш, торнакүз** (к. ДС III: 233, ТТДС I: 605; БТДҺ: 323) төрле үлән атамалары (к. түбәндәгене). Räsänen 1969: 500; ЭСТЯ III: 301–302; Федотов II: 199.

**ТОРНАВЫК [торнаwы̆ӄ], тырнаwык** (ТТДС I: 605) «торнабаш үләне», **торна** сүзеннән, ясалышы аңлашылмый.

**ТОРПЫЧА [тŏрпŏча],** (Троянский I: 295) **турбучы** «вьюшка навивальная, дуплянка» ~ удм. диал. *турбуча* id. < рус. сөйл. *трубица* id. (к. Радлов III: 1330) – *труба* сүзеннән ясалган. Рус. телендә *трубица* гомумән, күпмәгънәле сүз һәм шуннан ук тат. (ТТДС I: 419) **топырча, торбоча**, башк. (БТДҺ: 338) *турбиса* «тәгәрмәч бүкәне», аннары (ДС III: 158) **торпоча** «трубкасыман токмач, макарон» сүзләре дә килә.

**ТОРПЫША [тŏрпŏша], торыпша,** (ТТДС I: 420) **торыпца, торыпча,** (ЛТ I: 136) **турпуш** «полог, покрывало лошадей для защиты от стужи, когда они стоят запряжёнными зимой» ~ чув. *тăрпăша* id. < рус. *торбище* id. – рәсми мәгъ. «зур *торба*» сүзеннән. Рус. *торба* исә төрки *торба* ~ *тобра* ~ тат. **тобра, тубра, тубыра** < ир. *tobra* «атның көндәлек азык капчыгы» (аны атның башына кидерәләр һәм ат шунда баскан килеш ашап тора ала, к. мәкаль: *Тобра төбен иснәмичә ат туймый,* ягъни «күпме салсаң да ашап бетерә»). Башк. (БТДҺ: 338) *турба, турбы* «тобра» русчадан кире алынма.

Рус. сүзе конкрет алганда кр.-тат. (Радлов III: 1463) *торба* «букчай, токчай, чунтай; тобра» сүзеннән булса кирәк. Бу сүз бор. заманнарда ук киң таралган булган, к. бор. монг. (Поппе 1938: 131) *tubra* «кәгазь капчыгы». К. **Тобра.**

**ТОР-У** «вставить, стоять; выстоять; жить, обитать», имеет ряд служебных значений общетюркского характера ~ чув. *тăр- [тŏр-]* < гом. төрки *тур-,* угыз. *дур-* «тору; тукталу» – бу сүз бор. күчмәнчелек заманнарында бик тә актуаль булган, шуның өчен аның дериватлары да исәпсез күп һәм бу фигыль нигезендә берничә грамматик кушымча да ясалган (к. ЭСТЯ III: 296–301), бу дериват вә кушымчалар әле барланып та бетмәгән. *Тор* < *тур* исеме дә («тукталыш пункты») булган бугай, к. **Торлак.** Будагов I: 744–746.

**Тор-**уның регуляр дериватлары да тармаклы: **торыл-у, торын-у, торыш-у**, йөкл. юн. формалары **торгыз-у, тордыр-у,** диал. **торлык-у** «артта калу», **торым** «яшәү»; **тора** формасы (хәз. зам., 3 зат, берлек) ике аерым мәгъ. ия: «гыйбарәт, кәш» һәм «бәясе»; **торганы** формасы «тоташ, тулысынча» мәгъ. кулланыла һ.б. К. **Торак, Торгын, Торлак. Тормыш, Торыш, Тырыш-у.** Федотов II: 195.

**Тор- < тур-** нигезеннән **-дыр//-дер, -тыр//-тер** хәбәрлек кушымчасы ясалган; икенче *-дыр* – йөкл. юн. кушымчасы да шул ук нигездән дигән фараз бар, к. Кузнецов 1985: 36–41.

**ТОРЫК [тŏрŏк]** (ЛТ I: 138) «пролёт; продольный размер; стан, туловище (рассматриваемое по габариту), спина животного; жердина», диал. (Остроумов 1892) «расстояние между столбами» ~ башк. *тороҡ,* чув. *тăрăх [тŏрŏх]* id., каз. *тӧрық* «озынлык», чыгт. *туруқ* «буйга», кырг., уйг. *турқ,* бор. төрки (ДТС: 588) *turq* «озынлык үлчәме», бор. монг. *turug* «озынлык», *tur* «тиренең арка үзәге», к. ш. ук нуг., к.-калп. *турқы*, к.-калп. *тӧрқы* «буй-сын» (к. **Торкылы**), тув. *дургу* «озаклык», *дурт (узун-дурту)* «озынлык; үлчәм», *дурт-сын* «буй-сын» һ.б. Арытабан бигүк ачык түгел. **Аркылы-торкылы <**

**аркалы-торыклы.** Мар. *тореш* «аркылы» *торык* < *турык* белән баглы булса кирәк.

**ТОРЫК-У (торыгу, торыкты)** «простаивать; слишком долго стоять» – **тор-у** фигыленең интенсивлык формасы.

**ТОРЫМТАЙ [тŏрŏмтай]** «копчик; перепелятник (птица)» < гом. кыпч., к. нуг., каз., к.-калп. *турымтай,* кырг., чыгт. *турумтай,* үзб. *турунтай* id. < бор. төрки (ДТС: 589) *turumtaj* «кечкенә карчыга (дербник)» < бор. монг. *turumtaj* (к. Räsänen 1969: 500).

**ТОРЫШ-У [тŏрŏш-]** «помогать в борьбе», «сопротивляться, упорствовать» ← **тор-у** «стоять вместе». К. **Тырыш-у**

**ТОСКА-У,** диал. (Х. Сарьян) **төскә-ү** «устремить взгляд; прицеливаться» ~ башк. *тосҡа-* id., ~ нуг., каз. *тусқа-* «юнәлү» ← *тус* «юнәлеш» (шуннан иске әд. *тусында* «турында»). Монг. *тусгах* «атып тидерү» ← *тус-* «аткан нәрсә тию». Тув. *доска-* «билгеләү, тәгаенләү; фикер юнәлтү»; *доос-* «тәмамлау» икенче сүз бугай. Чаг. **Туш килү?**

Дерив.: чыгт. (Будагов I: 394) *тусқаwул* «тоскавыл, дозор, каравыл». Мар. *тусар-* «күз ату, караш ташлау» тат. микән?

**ТОТАМ** – дөресрәге **тотым** «пядь; горсть» < гом. кыпч., уйг., госм. һ.б. *тутам, тутум, тутым,* бор. төрки *tutam*, *tutum* id. ← *tut-* «тоту».

**ТОТАНАК I** «(эпилептический) припадок» ← *тот-* > *тут-* тамырыннан (к. *тотанагы тота* тәгъбире бар); **тотан-ак <** *тутан-ак* ← (төр. диал.) *tutan* «эпилепсия рухы» сүзеннән.

**ТОТАНАК II** «ручка, держалка» ← *тутан, тутаган* «тота торган (нәрсә)» сүзеннән кечерәйтү формасы. К. төр. *tutamak* «тоткыч, тотка; ярдәмче; терәк; кадак», *tutanak* «беркетмә; шаһитлык, гуаһлык». К. **Тотнак.**

**ТОТАШ,** диал. **тŏтŏш** «беспрерывно; сплошной, сплошь» > чув. *тăташ [тŏташ],* мар. (Упымарий: 214) *тутыш* «һәрвакыт» < уйг., госм. *туташ* «бөтен; терәлеп торган; тоташ» ~ бор. төрки (ДТС: 592; Боровков 1963: 314) *tutašї* «терәлеп торган, өзлексез, мәңге» – *tut-* «тоту» тамырыннан, ләкин ясалышы ачык түгел. *Тотыш* < *тутуш* варианты Себер төрки телләрендә очрый, к. тув. *тудуш* «тоташ». Федотов II: 200–201.

**ТОТАШ-У** «соединиться, смыкаться, примыкать» < гом. кыпч., уйг. *туташ-* (нуг., каз., к.-калп. *тутас-*) «тоташу; янып китү, токану» (к. тат. җыр: *Су таша, су таша, Йөрәккә ут тоташа*). Гомумән, **тоташ-у <** *туташ-у* элекке **тота-* < **тута-* фигыленнән шикелле, бу фигыль, әлбәттә, *тут-* «тоту» тамырыннан булала.

**Тоташ-у** продуктив нигез: **тоташыл-у, тоташтыр-у** һ.б.

**ТОТКА,** диал. **тоткы [тŏтқŏ]** «ручка, держалка; крепёж, скоба» ~ чув. *тытха, тăтха* < гом. кыпч., уйг. *тутка* id. ← *тут-* «тоту», **тоткы** варианты тат. теленең үзендә ясалган.

**ТОТКАВЫЛ [тŏтқаwы̆л]** «стражник (ворот); привратная охрана; дозор», иске тат. *тотка-мак* «тоту, тотып алу, тотып тору» фигыленнән (к. **Төткәз-ү**), *-аwыл* < *-ағул* (хәрби-административ терминнар ясагыч) кушымчасы ярдәмендә ясалган.

**ТОТКАК** «припадок; схватка (родовая)» < гом. кыпч., уйг. *туткақ* < бор. төрки (ДТС: 592) *tutγaq* «тоткак; тоткавыл» ← *тут-* «тоту». *Тотқақ* сүзе **торгак** (к.) кебек үкниндидер рух мәгъ. булган.

**ТОТКАР** «препятствие, помеха» (*тоткарлык* id. сүзеннән эллиптик ясалыш булса кирәк) > мар. *туткар* < бор. тат., тат. диал. **тотка-у** фигыленнән, бүтән телләрдә *тоткар* һәм *тотка-у* фигыльләре сирәк очрый. Тик. к. төркм. *тутарык,* төр. *tutarak* «тоткар; тотанак». **Тотка-** фигыле тагын *тоткан-у* < **токан-у** сүзендә чагыла. *Тотка-* < *тутук-а-* «тотык итү» сүзеннән булса кирәк. Монг. *тотгор* «тоткар» төрки телдән.

Дерив.: **тоткарлык; тоткарла-у** һ.б.

**ТОТКЫН [тŏтқŏн]** «узник» < гом. кыпч., уйг., госм. һ.б. *тутқун* id. (кайбер телләрдә бу сүзнең бүтән мәгъ. бар); ясалыш мәгъ. буенча бу сүз «тоту күренеше», шунлыктан монда эллипсис булган булса кирәк (мәс., *тоткын корбаны* → *тоткын*).

**ТОТЛЫК-У (тотлыгу, тотлыкты)** «заикаться» < гом. кыпч., госм. (Радлов III: 1491) *тутлуқ-* (каз., кырг. *туттуқ-*) < *тутул-уқ-,* ягъни *тотыл-у* фигыленең интенсивлык формасыннан: к. уйг. *тутул-,* чув. *тытăн-,* бор. төрки *tutun-* «тотлыгу».

**ТОТРЫК [tŏтрŏқ] , тотырык** «устойчивость» ~ уйг. *тутруқ* «түзем, тотрык» < бор. төрки (ДТС: 542) *tutruq* «терәк» – асылда кыпч. телләрендә сакланган *туттурук* (ком. *тутдуруқ*) «тигез; беркеткеч, цемент; аккургаш» (кургаш элек таш корылмалардагы блокларны тоташтыру, беркетү өчен кулланылган) сүзеннән ← **тотырак** варианты (~ нуг., каз. *тутрақ, тутырақ* id.) фонетик модификация буларак кыпч. телләрендә килеп чыккан булса кирәк; чув. *тăтăр, тăтăрка* «куәт; тотрык» тат. сөйләшләреннән алынма булырга тиеш (чөнки төп чув. «тоту» – *тыт*-!).

Дерив.: **тотрыклы, тотрыксыз; тотрыклык; тотрыклан-у.**

**ТОТ-У** «держать, взять в руки, охватить», күч. «обводить по краям, обрамлять; придерживаться, соблюдать; хранить, беречь; содержать; ловить; израсходовать» < гом. кыпч., алт., хак., тув., уйг., чыгт., госм., як. һ.б. < бор. төрки (ДТС: 591–594) *tut-,* чув. *тыт-* «(кулга) тоту» ← бор. төрки *tu-* «тоткарлау, киртәләү, ябу» (шуның йөкл. юн.). **Тот-** < *ту-т-* тәүдә коллектив ауны һәм ау кагыйдәләрен (алар шактый катлаулы була) белдергән – хәз. барча төрле мәгънәләр шул үзәк мәгънәгә илтә. Радлов III: 1480; Будагов I: 742–744; Räsänen 1969: 465; Федотов II: 268–269.

**Тот- < тут-** гадәттән тыш продуктив нигез: **тотыл-у, тотын-у, тотыш-у, тоттыр-у; тоткыз-у;** диал. **тоткыр;** к. **Токан-у, Тотак, Тотам, Тоташ, Тоташ-у, Тотка; Тоткавыл; Тоткак, Тоткар, Тоткы, Тоткын, Тоткыч, Тотык, Тотын-у, Тотырык, Тотыш-у.**

**ТОТЫК [tŏтŏқ]** тар. «пленный (которого должны выкупить); задержанный» < бор. төрки (ДТС: 592–593) *tutuɣ* «заклад; әманәт» ~ хак. *тудыг* «тоту, тоткарлау; арест». Шул ук мәгъ. чыгт. һ.б. *тутақ, тутсақ,* госм. *туту* сүзләре дә билгеле. Әлбәттә, *тот-* < *тут-* (к. **Тот-у**) фигыленнән, к. Будагов I: 742–723.

Бор. төрки телләрдә **тутуқ, тутуғ,** ш. ук **тутуң** бөтенләй үзгә – «идарәче урынбасар» мәгъ. кулланылган, к. Velidi: 54 (ләкин бор. төрки *тутуң* сүзен кыт. теленнән алынма дип тә карыйлар). Хәз. тув. *тудуг* «төзелеш» ← *тут-* «төзү» («киртәләү, киртә кору» мәгънәсеннән, к. тат. *киртә, читән һ.б.ш. тоту*).

**ТОТЫН-У [tŏтŏн-]** «держаться за что-либо» (регулярное значение), «взяться за..., приниматься за (дело), начинать действовать (определённым образом); израсходовать» < гом. кыпч., уйг., угыз. һ.б. *тутун-* < бор. төрки (ДТС: 593) *tutun-* ~ чув. *тытăн-* id. ← гом. төрки *тŏт-* < *тут-* id. (к. уйг. *тут-* «тоту, тотыну»).

Дерив.: **тотыныл-у, тотыныш-у, тотындыр-у; тотынгыч.**

**ТОТЫШ-У [tŏтŏш-]** «конаться, решать вопрос по жребию (собственно “держать друг-друга”)» – **таяк (сөлге) тотышу** тәгъбиреннән эллипсис: таяк, сөлге кебек озын бер нәрсәне бер-бер артлы тотамлыйлар да, иң соңгысы булып кем *тота*, шул җиңгән (сайланган), шуңа тиешле булып чыга. Мондый шобаганы **тотыш, тотышлы, тотышкы** дип тә атыйлар.

**ТОЧ I** «с большим удельным весом; ядрёный; увесистый» ~ башк. *тос* id. – **точ II** белән бердәй булса кирәк: бронза бик «точ» була.

**ТОЧ II**, **туч** (ЗДС: 662) «бронза», диал. «(нечто) с большим удельным весом», себ. (Тумашева 1992: 213, 220) **точ** «сталь», **туц** «бронза» ~ башк. (БҺҺ III: 183; БТДҺ: 323) *туч* «гади металл (корыч түгел)», *тос* «бакыр төсле» < гом. кыпч., бор. төрки, бор. монг. *tuč* «бронза», госм., кр.-тат. *дуч* «җиз, бронза» < фар. *тунч* «бронза; кургашын», к. ш. ук удм., чув., мар. *туй, той* «бронза», тунг. *тӯӡа* «кургашын» (к. ССТМЯ II: 205). Гомумән, бу сүз төрки телләр аша күп телләргә таралган. К. Räsänen 1969: 499; Федотов II: 241 (чув. *туй* < *той* сүзен тат. *точ* < *туч* белән багламый).

**ТОШ** «ядро (ореха)» ~ мар. *туш*, удм. диал., коми. *тусь* id. Безнеңчә, *тош* фин-угор телләреннән кергән һәм **төш II** сүзе белән гомоген түгел. **Төш** сүзе «тош» мәгънәсендә ялгыш язылып киткән.

**ТОЮ** к. **Той-у.**

**ТОЯК [tŏйақ]** «копыто» > мар. диал., удм. диал. *туйак* < гом. кыпч., уйг. *туйақ* < бор. төрки (ДТС: 585) *tujaɣ* «тояк; тырнак», төр., төркм. *тойнақ, туйнақ, дойнак,* төрки (Zenker: 328) *tujnaɣ,* чыгт. (Радлов III: 1424; Поппе 1938: 239, 354) *туйна-* «тибү», *tujnaq* «тояк», *tujlaqcı, tujlaqucı* «тибешкәк (ат)», тув. *дуюг,* тув. диал. *туйуң, туйуг,* алт. *туйгақ* «тояк» (*туйла-* «сикерү; тибешү»), хак. *туйгах*, шор. *тыгақ,* як. *туйах, туньах* «тояк» һ.б. ~ монг. *туурай,* бор. монг. *turun, turaɣun* «тояк».

Күренүенчә, сүзнең тамыры *туй-* ~ *тур-* «тибү, тибенү», чаг. **Турак.**

Урта гасырларда **тояк < туйақ** «хәрби салым, контрибуция» мәгъ. кулланылган (ягъни «ат тоягы хакы»).

Дерив.: **тояклы** (фәнни термин) ~ бор. төрки (ДТС: 584) *tujuγluγ,* **тояксыз.**

**ТОЯН, туян** кит., себ. «монгольский священник» ~ бор. төрки (ДТС: 572) *tojïn, tojun* – монг. *тойн* < кыт. *dâu-ńin* «лама; изге карт; монах»; к. рус. киң таралган *тойон* Себер халыкларында «староста, кечерәк башлык», к. Аникин: 549). Мәҗүси уйгурларда *туйун* «мәҗүси (буддист) рухани». Шуннан *туйунана* «тойон кебек, тойоннарча». Бу сүз тур. әдәбият ишле.

**ТОЯНА [тŏйана],** (ЗДС: 670) **тыяна** «автоматически, бессознательно» > чув. *тăяна* «җиңел эш, уйламыйча да эшләнә торган эш» (к. Сергеев 1978: 68), мар. (Упымарий: 210) *туяна* «миңгерәгән хәл» ~ куман., алт. *туйана, тыйана*, чулым. *түйäнä* «ачык рәвештә, яшермичә», Рясянен буенча, (Räsänen 1969: 497) *туй-* «тою» фигыленнән, ләкин, безнеңчә, бу аңлатма шикле. К. ш. ук каз. (ҚТДС: 342) *туянадай* «җыйнак, тыйнак». К. югарыдагыны.

**ТӨБӘК,** диал. **түбәк** «поворот реки; определённая местность; среднее подразделение» ~ чув. *тĕпек* «кәкел, кикел; баш түбәсе; калкулык, аклан», к. к.-калп., каз. *түбек* «бишек төбенә беркетелгән савыт; мәдәни үзәкләрдән ерактагы торак», кырг. *түпөк* «кәкел, кикел; чук» (*түпөй-* «кабарып шешеп тору») *төп* < *түп* сүзеннән булса кирәк, к. кырг. *түп* «төп, түбән җир; ыру». Шуның белә бергә чаг. каз. (ҚТДС: 342–343) *түбәгі, түбек* «байракчы, ту бәге» сүзе төрлечә уйларга урын калдыра.

**ТӨБӘЛ** к. **Түбәл.**

**ТӨБӘ-Ү** «направить (острие, палец, взор); нацелить (оружие)» ~ к.-балк. *тюбе-* id. Төрки телләрдә сирәк очрый.

**ТӨБЕЛДӘ-Ү [төбөлдә-]** (ТТАС III: 240), диал. (Тумашева 1992: 214) **төбөр-ү** «отогнать, гнать; отбить атаку; идти обратно (о печном дыме)» < бор. төрки (ДТС: 598) *tüpür-, tüpir-* «җил исү, җилләү», *tüpi, tüpü* «җил-буран». Чаг. бор. монг. *debi-* > тунг. *дәва-* «җилпү, җилпенү, талпыну», *debigürde-* «төтенне һ.б.ш. куу» (к. ССТМЯ I: 228).

**ТӨБЕТ [төбөт]** «мастиф (собака тяжеловесной породы); овчарка-волкодав» ~ каз., нуг. *төбет*, кырг. *дөбөт* id. < бор. төрки (ДТС: 598) *Tüpüt* «Тибет, Тибет халкы» сүзеннән (Тибет этләре бик зур, эре булалар һәм аларны көтүләрне саклау өчен кулланганнар; тик алар ачык далаларда үрчемәгәннәр). К. **Дебет.** Тув. *төбет* «кызыл таплы карасу эт (мондый этләрдән шайтаннар да курка, имеш)». Бор. төрки *Түбүт* «Тибет», кыт. *тху бод* «баш бод»; *бод* – тибетлыларның үзатамасы. К. Зайцев А.Н., Кузнецов Б.Н. О названии Тибет // Топонимия Востока. М., 1969: 185–196.

**ТӨГӘЙ, теwәй** (БТДҺ: 314, 324) «двойная нитка в ткачестве» < фар. *дуһаи* id. (*ду* «ике»).

**ТӨГӘЛ** «точно; точный; законченный» > мар. *түгäл, тĕгäл* id. ~ чув. *тĕкел* «җөп, пар » < гом. кыпч. *түгәл* (башк. *теүәл,* к.-калп. *түwәл,* кырг. *түгөл*), уйг. *түгәл,* чыгт. *түкäл*, бор. чыгт. (Поппе 1938: 352) *tügel* «тулы, тулысынча» (к. ш. ук Радлов III: 1331, 1535), бор. төрки (ДТС: 595) *tükäl* «тулы, тулысынча; кямил» < бор. төрки **төкäр* «җитәр, бетте, тәмам» ~ бор. монг. *tögüz, tegüs,* хәз. монг. *төгс,* калм. *tögüs* (к. Владимирцов: 154) «төгәл» (*r* ~ *z*) ← гом. төрки *тукä-* «тәмамлау» ← *түк* «тәмам, бөтен», к. **Төгә-ү**. К. ш. ук алт. *түгäзä*, як. *түгүсү, түксү* «төгәл, бөтен; бөтенләй, бетереп», госм. *дүйүз-* «җитлеккән, мөстәкыйль; өлгергән, егетләрчә», тув. *дөгер-,* калм. *töker-* «төгәлләү, тәмамлау»; тув. *түң* «сумма; нәтиҗә», *түңнәл* «төгәл нәтиҗә» һ.б. Чаг. **Төң**.

Күренүенчә, бор. төрки *төкäр* «төгәл; җитәр» сүзенең *-з* варианты монг. телләренә үтеп кергән һәм шунда яхшырак сакланган; моның сәбәбе – **төгәл-ү < түгäл-** фигыле булу. К. **Төгәл-ү, Төгән-ү, Төгәт-ү.** Будагов I: 401–402; Федотов II: 213.

**ТӨГӘЛ-Ү**, диал. **төгән-ү** «кончаться, завершаться» < гом. төрки, к. уйг., чыгт. хак. һ.б. (Радлов III: 1537) *түгäл-*, угыз. *дукäл-* id. ← *төгә-* < *тукä-* (фигыльнең төш. юн.). Чаг. ш. ук чув. *чĕкел-* «матураю, яхшыру». К. түбәндәгеләрне.

**ТӨГӘН** «некий, такой-то» (обычно в парном слове **фәлән-төгән** «якобы то и то») – гом. кыпч. булса кирәк, к. кырг. *палан-түгөн*, к.-калп. *пәлен-төлен,* уйг. *пәлән-түгән* һ.б. id. Чаг. алт. *төгүн* «алдак».

**ТӨГӘТ-Ү** диал. «закончить, завершить, довести до конца» ~ башк. (БТДҺ: 327) *төкәт-ү* < гом.

кыпч. *түгәт-* id. ← *түгә-*, к. **Төгә-ү.** Мар. *түган-, түгат-* «төкәнү, төгәтү» < тат.

Дерив.: **төгәтел-ү, төгәтен-ү, төгәтеш-ү, төгәттер-ү.**

**ТӨГӘ-Ү** диал. (ТТАС III: 242; Тумашева 1992: 214) «закончить, завершить; похудеть» ~ башк. (БТДҺ: 327) **төкә-ү** «ваз кичү» < гом. төрки, бор. төрки (Радлов III: 1242; ДТС: 595) *tökä-, tükä-,* уйг. *түгү-, түги-* «бетү, тәмам булу; җиту, тулу» (күчемле фигыль мәгъ. кулланыла). Бу фигыль үзе *түк* «бөтен, тулы; тәмам» сүзеннән, к. диал. **текмә-тек,** (ЛТ I: 143) **түкмә-түк,** тат., башк. (ТТАС III: 241; БҺҺ II: 256) **төкмә-төк** «төп-төгәл, тулысынча»; моның фигыль коррелянты да бар: көнчыгыш төрки (Zenker: 325) *tükmek* «бөтен булу; тәмамлану, азагына җиту», *tük* «төгәл, чын» ← *төк* «билгелелек, төгәллек». К. **Төгәл, Төгәл-ү, Төгән-ү, Төгәт-ү.** Будагов I: 401–402.

**ТӨГЕР [төгөр]** иск. (К. Насыйри) «металлический поднос» ~ чув. *тĕкĕр [төгөр]* ~ венг. *tükör* «(металл) көзге» ~ бор. рус. *тикр,* чиркәү слав. телендә *тикъръ, тикьрь, тыкъръ, тыкърь* «көзге» – М. Фасмер (IV: 57) бу сүзне **түгәрәк** (к.) сүзенә нисбәтли. Бор. кыпч. (Котби телендә) *түгүр* «поднос». Федотов II: 213 (тат. сүзен белми).

**ТӨЕЛ-Ү [төйөл-]** «связываться узлом; спутываться» ← *төй-*, к. **Төй-ү I.** К. ш. ук (ЗДС: 643) **төйөл-ү** «чәчәү», «бөреләнү» гомоген сүзләр. **Төел-ү** (**төе-ү**нең төш. юн.) сүзе дә актив кулланыла, бу инде бүтән нигез.

**ТӨЕН [төйөн]** «узел; свёрток» < гом. кыпч. *түйүн, түйин*, миш.-угыз линиясе буенча *түwĕн* ~ кар. *тювюн, тивин*, төр. *düküm, düvün, düğüm,* чув. *тĕвĕ* id. ← тат. *төй-,* тат. диал. *ту-* < *түг-* «төйнәү, төенләү» тамырыннан, к. **Төй-ү I.** Будагов I: 411; Федотов II: 210–211.

**Төен** продуктив нигез: **төенле, төенсез; төенлә-ү** > **төйнәү** (к.); бигрәк тә **төенчек** > мар. *түйĕнчĕк, түнчĕк*, башк. *төйөнсөк* ~ гом. кыпч. *түйүнчүк, түйүнчик* (нуг., каз., к.-калп. *туйиншик,* кырг. *түйүнчөк*) киң таралган.

**ТӨЕН-Ү [төйөн-]** сирәк «подавиться» ← *төй-,* к. **Төй-ү II.**

**ТӨЕР [төйөр]** «комочек, комок; связка» < гом. кыпч., к. нуг., каз., к.-калп. *түйир*, каз. *түйĕр* < уйг., чыгт. *түгүр* id. ← *түг-* «төйнәү» (к. **Төй-ү II**). Ясалышы ачык түгел. Чаг. **Төер-ү.**

Дерив.: **төерле, төерсез; төерчек; төерлән-ү.**

**ТӨЕР-Ү [төйөр-],** диал. **түвер-ү, түwер-ү** «завязать узлом конец нитки; образовать утолщение при прядении; закреплять булавкой» < **төйгер-ү,** ягъни **төй-ү II** фигыленең үзенчәлекле йөкл. юнәлешеннән.

Дерив.: **төерел-ү; төерт-ү;** диал. (ТТДС I: 442, 450) **төйөрем, түwерем > түрем** «җеп, бау уртасындагы (тормозлау өчен яисә кирәксез) төен, төйнәлеш», күч. «көмән» (→ **түремәй-ү** «көмәнле булу»); диал. **төерек** «төерелгән; күптөерле».

**ТӨЗ I** «прямой, прямо; вертикально, под прямым углом; правильный; исправный; строгих правил (о человеке); метко» > чув. диал. *тĕс* id. < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., бор. төрки (ДТС: 602, һ.б. чыганаклар) *tüz,* госм., аз., төркм., үзб. (ЎХШЛ: 93) *дүз, дүүз,* башк. *төҙ* «төз; тигез (дала); чын, дөрес; хакыйкый; тәүфикълы» һ.б.ш. (к. ЭСТЯ III: 309–313), сүзнең мәгънәләр спектры һәр телдә үзенчәлекле.

Себ. (Тумашева 1992: 216) **төс < төз** «урман; дала, тигез җир» < каз. диал., хак., алт. *түс* «тигез; төз; дала, тигезлек»; к. ш. ук чув. *түс* «кыргый (хайван)» < нуг. *түз* «кыргый дала; кыр».

Гом. төркет *түз* < *түүз* (> тат. диал. **түwез**) «тигез дала» сүзен кайберәүләр (Räsänen 1969: 508; Э.В. Севортян – ЭСТЯ III: 312) чув. *түрĕ* «туры, төз» сүзе белән чагыштыралар, ләкин бу дөрес түгел; чув. сүзе тат. **туры** сүзеннән килә (бу сүзләрнең деривациясе тулысынча тәңгәл). Мар. (к. Саваткова: 163) *тӧр* «тиң, тигез; туры, төз; дөрес» (ш. ук *тӧрем* ~ тат. **төзәм**) төрки *түз* сүзеннән булуы ихтимал. Чөнки, чыннан да, **төз** < *түүз* бор. гом. төрки **түүрг* «төз» сүзеннән булса кирәк.

Дерив.: **төзле, төзсез; төзәй-ү, төзләү** (деривациясе бар), **төзәк**; к. **Төзәм, Төзә-ү, Төзген, Төзек, Төзе-ү.**

**ТӨЗ II,** себ. (Тумашева 1992: 216) **төс** «лес, степь; равнина» ~ гом. кыпч. *түз* id. ~ чув. *түс* «киек; кыргый җирләр». К. **Түз I.**

**ТӨЗӘМ** (ТТДС I: 442; БТДҺ: 325): **төзәм җир [йĕр]** «ровное место, ровная низменность; способ кладки снопов; голова одного снопа на комель другого» (к. Халиков 1981: 77–79) ~ аз. диал. *дүзәм* «тигез җир» – кырг. *түзем*, каз. һ.б. *түзең*, аз. *дүзән* «тәртип, билгеле бер тәртиптәге» сүзе белән

чагыштырыла (ЭСТЯ III: 312). Безнеңчә, бу чагыштырма аңлатуга мохтаҗ. К. **Төз, Төз-ү.**

**ТӨЗӘ-Ү** «нацелить ружье», диал. (к. БТДһ: 325) «приводить в порядок; украшать» > чув. *түсе-* id. < гом. кыпч. *түзә-, түзä-* (кырг. *түзө-*), алт., хак., уйг., чыгт., бор. төрки (Радлов III: 1581) *түзä-* «тигезләү, төзәтү, аңлату», госм., аз. *дүзә-*, кр.-тат. *дүзе-* «тәртипкә салу» ← *төз* < *түз* > *дүз* (к. **Төз**) нигезеннән ясалган фигыль.

**Төзә-** бик продуктив нигез: юн. формалары **төзәл-ү, төзән-ү, төзәт-ү** – һәрберсе аерым үзенчәлекле мәгъ. ия (к. ТТАС III: 244–246), **төзәш-ү**. Бу фигыльләрнең параллельләре кыпч. һ.б. төрки телләрдә дә бар. К. Егоров 1964: 266; Федотов II: 223.

**ТӨЗГЕН [төзгөн]** «правильно построенный; симметричный; гармоничный» ~ кр.-тат. (Dobr. I: 549) *tüzgün,* төр. *düzgün* «тәртипле, тәртиптә», төркм. *дүзгүн* «кагыйдә, устав, закон» ← *төзе-* < *tüz-* > *düz-*, әлбәттә. Чаг. **Төзек.**

Дерив.: **төзгенләү; төзгенлек** һ.б. терминологиядә *төзген өчпочмак (күппочмак)* һ.б.

**ТӨЗЕК [төзөк]** «исправный; благоустроенный» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *түзүк* id., ш. ук «тәртип, кагыйдә; тәртипкә, кагыйдәгә буйсынучан» (к. Радлов III: 1584) ← *түз-* «төзү». К. **Төз, Төзе-ү.**

**ТӨЗЕ-Ү [төзө-]** «строить; составлять» ~ кар. *түзү-* id. Барча бүтән төрки телләрдә *түз-* > тат. диал. **төз-** (*төзә* дип сөйлиләр) id. **төз** < *түз* сүзенең фигыль коррелянты (Räsänen 1969: 508).

**Төзе-** продуктив нигез: **төзел-ү, төзеш-ү, төзет-ү** (диал. **төздер-ү**), **төзем,** к. ш. ук **Төзек.**

**ТӨЙМӘ,** миш. **темә, түмә** «пуговица» < гом. кыпч. *түймә* (кырг. *түймö*) < уйг., чыгт. *түгмә* ← *түг-*, бор. төрки (ДТС: 595) *tüg-* «төю, төйнәү» фигыленнән. Бу сүзнең исем коррелянты чув. *тү, тĕвĕ* «төен» рәвешендә сакланган. **Төймә** сүзе тат. теленең үзендә дә ясала алган, к. җыр: *Кызлар кызыл киядер, Җефәктән төймә төядер* (ТХИ: Кыска җырлар 1976: 178). Элекке заманнарда төймәләр төен рәвешендә булган һәм киндерәдән, нечкә каештан һ.б. ясалган. Миш.-угыз линиясендә *тү-, тĕв-* «төю, төенләү», *түмә* > чув. *тумме* «төймә» ~ куман. *түүмä,* төркм., төр. *дүгме,* төр. *döyme* һ.б. ЭСТЯ III: 308; Мухамедова 1973: 176; Федотов II: 260–261. К. **Төй-ү II.**

Дерив.: **төймәле, төймәсез; төймәлә-ү.**

**ТӨЙНӘ-Ү** «завязывать узлом» < гом. кыпч. *түйнә-* id. (ләкин бу нигез дериватларда гына күренә) < *түйүн-ä-* id. *түйүн* < *түгүн* «төен» сүзеннән, әлбәттә.

**Төйнә-ү** продуктив нигез: **төйнәл-ү, төйнән-ү, төйнәш-ү, төйнәт-ү, төйнәлеш** һ.б. икенчел дериватлар күп. **Төйнә- < түйнә-** фигыленең төрки телләрдә киң таралган, ләкин тат. сирәк очрый торган дериваты – башк. *төйнәк* «көнҗәлә» ~ гом. кыпч. *түйнәк* (кырг. *түйнөк*) – сарыкларның эчәгенә җыелып «төйнәлгән» йон йомгагы һәм шуның нәтиҗәсендә пәйда булган авыру.

**ТӨЙРӘ-Ү** (Тумашева 1992: 214) «прикалывать; закрепить узлом нитки (при шитье); захлестнуть конец нитки» < гом. кыпч. *түйрә-,* үзб. *түйра-* id. һ.б. **төй-ү** «төенләү» сүзенең кабатланулы интенсивлык формасыннан (аффикс *-ра//-рә*, к. **Җәйрә-ү**) һәм *түйүр, түйир* «төер» сүзеннән дә ясала ала.

**Төйрә-** продуктив нигез: диал. (ДС III: 153; Тумашева 1992: 214) **төйрәwец > терәвец, дерәвец** «булавка, кадама» (гом. кыпч. *түйреwүч*) (нуг. *түйрегиш,* каз. *түйревĕш* id.). Гигановта *тюйряуцъ* id.

**ТӨЙТӘ** диал. «дробилка» к. **Түтә.**

**ТӨЙ-Ү I** «многократно бить в одну точку; толочь в ступе» > мар., удм. *туй-* < гом. кыпч., уйг. *түй-* < уйг. *түг-,* чыгт., бор. төрки (ДТС: 579) *tög-* «төю, ашлык суктыру». Бу сүзнең миш., угыз линиясендәге варианты тат. диал. **тĕв-, тү-** > чув. *тĕв-, тү-,* төркм. *түв-,* гаг. *дүү-*, төр. *döv-* «төю; тукмау». Гомумән, *төг-* тамыры тунг.-маньч. *дуг-, дув-* «төю, ашлык суктыру» сүзе белән чагыштырыла (ЭСТЯ III: 270–272). Федотов II: 260.

Дерив.: **төел-ү, төеш-ү, төйдер-ү; төйгеч.** К. ш. ук **Дөге; Төйтә > түтә, Төяк, Тү.**

**ТӨЙ-Ү II** (миш., себ. һ.б.) «завязывать в узелок» < гом. кыпч. *түй-* < уйг. *түг-* < бор. төрки (ДТС: 595) *tüg-* «бәйләү, төю» ~ алт. *тү-, түң-* ~ тув. *дүң-* (*дүңгү* «бәйләвеч»), чув. *тĕвĕ* «төен» < *түйгү* id.; миш.-угыз. линиясендә миш. *тү-,* чув. *тĕв-, тү-,* төркм. *дүв-,* тув. *түү-, тү-* «төю, бәйләү», ләкин тув. диал., төр. *дүй-* (кыпч. телләреннән булса кирәк), *düg-* id. К. ш. ук як. *түм-* (< *түң-*) «төйнәү», *түмүк* (< **түңүг*) «төен», *түмүл-* (< *түңүл-*) «төелү, төйнәлү» (чаг. тат. *төел-ү* «тамакка, үңәчкә утыру»). К. Räsänen 1969: 503;

ЭСТЯ III: 307–309 (як. мисаллары китерелми). **Төй-ү II** сүзен кайбер сүзлекләрдә **Төй-ү I** белән бер матдәдә карыйлар, ләкин бу дөрес түгел.

*Төй-* < *түй-* < *түг-* продуктив тамыр, к. **Төел-ү, Төен, Төйнә-ү, Төер, Төйрә-ү, Төймә, Төйтә > Түтә, Түлә-ү, Төнтек.**

**ТӨК** «волосок, шерстинка; короткая, редкая шерсть» ~ чув. *тĕк* < гом., кыпч., уйг., алт. *түк* < бор. төрки (ДТС: 595) *tüg* > госм., кр.-тат., төркм. *tüj*, тув. *дүү*, як. *түү* id. ← бор. төрки *tü* «төк; кавырсын; хайван тәнендәге йон; хайван төсмере», «ат төсмере» (к. МК III: 207). *Төк* < *туг* нигезе **тү-* «йон үсү» фигылennән булырга мөмкин, шуннан ук *тү-р* «төр» һәм *түс* < *түсү* < *тү-си* (к. **Төс**). К. **Төлә-ү, Түлә-ү II.** Räsänen 1969: 503; Федотов II: 212.

**Төк** продуктив нигез: **төкле, төкләч, төксел, төксем, төкчә**. К. **Төксе.**

**ТӨКӘН-Ү, төгән-ү** «закончиться; исчерпаться» > чув. *тĕкен- [төгән-]* «зәгыйфьләнү, бетерену», мар. (Упымарий: 222) *түгäн-, тĕгäн-* «кием тузып бетү, таушалу» ← тат. диал. **төгә-ү** (к.) фигыленең кайт. юн. К. гом. кыпч., алт. *түгән-*, кырг. *түгөн,* төркм. *түкән-*, чыгт. (Радлов III: 1243) *төкүн-* «төкәнү».

Дерив.: **төкәндер-ү; төкәнмәс (бетмәс-төкәнмәс)** һ.б.

**ТӨКЕ [төкө]** диал. «бляха, металлический кружочек (как знак)» к. **Төкле, Төкләче.**

**ТӨКЕР-Ү [төкөр-]** «плевать» < гом. төрки (Радлов III: 1531, 1596, 1600–1601) *түкүр-,* куман. *түпкүр-,* чыгт. *түфкүр-* id. – *түф, тефү* ымлыгына фигыль ясагыч *-кур, -кыр* кушымчасы ялганып ясалган (чаг. *а-кыр-, ба-кыр-, чоң-гер-* һ.б.ш.), к. ЛТ I: 129. Чаг. үзб. *туфла-* «төкерү».

Дерив.: **төкерек, төкерел-ү, төкерен-ү, төкереш-ү, төкерт-ү.**

**ТӨКЛӘЧЕ** диал. (трбс.) «одна из женщин, готовящих невесту к свадьбе (сегодня конкретные обязанности неясны)» ~ мар. *туглачы, тугулачы* «кодагый; кайнана», *туглар, тугылар* «кода» һ.б. (күп фонетик вариантларда, к. Räsänen 1969: 225; Иванов, Тужаров: 226, 229), удм. *туклячи, тү’лäчи, тиклäчи* (ш. ук күп вариантларда, к. Вопросы удмуртской диалектологии, Ижевск 1977: 59, 72, 93), чув. *тăхлачă* «кодагый» ← *тăхала-* «киленгә махсус аеллы билбау кидерү» ← *тăхă* «махсус аеллы билбау, туй билбавы» < гом. кыпч. (нуг., каз., ком.) *тоға,* төр. *toka,* бор. төрки (ДТС: 397) *toqu* «махсус аел; чәч бизәге – металл түгәрәк», кырг. *тогоо* «аел; божра» ~ тунг. (ССТМЯ II: 192) *тохон* «махсус төймә». К. ш. ук бур. *туулга* < *тогулга* «аккургаш; кургаш төймә-амулет», *туулга хадалган* «кияүгә аккургаш төймә тагу», *туулгатай басаган* «аккургашлы кыз-каләш»; хәтта *туулгын дуун* «аккургаш җыры» да булган (чаг. **Тулгау**), к. Галданова: 131–159.

Ошбу материаллардан күренгәнчә, тат. телендә дә **төке** «махсус аел» сүзе булган, к. ш. ук башк. (БҺҺ II: 256) *төкө* «ат күкрәгендәге шеш (ат күкрәгенә куелган металл аел эзе)».

Әмәйлек (амулет) итеп кызлар, балалар һәм атларга төрле аеллар, аеллы билбаулар, түшлекләр беркетү барча халыкларда әзәлдән бирле билгеле. Төрки халыкларда *тоқа, тоқу* һ.б. явыз көчләрдән саклагыч итеп кызлар ыштаны – сирвәлә балагына һ.б. беркетелгән, бәрәкәт һ.б. символы булган. Тат. **төкле аяк < төкеле аяк,** ягъни балагына төке беркетелгән (кәләш-киленнәр) аягы була.

М. Рясянен (Op. cit.) мар., удм. сүзләрен чув. теленнән таралган димәкче. Ләкин аларның бер өлеше (*тулар, тулачи* «кода, кодагый» вариантлары) гына чувашчадан була ала, калганнары (бигрәк тә удмурт вариантлары) бор. мәҗүси тат. теленнән кергән.

Башк.-тат. фольклорында очрый торган *Төкләç* ~ *Төкләч бабай* (каз., к.-калп. *Түктеш*) «сихерче» образы асылда *төкләче* < *түкләчи* булып, соңрак кына «төкле-сакаллы» булып аңлашыла башлаган. Нигез вариант – *газиз кирәмәт баба Туглас* (аның тур. Кадыйр Галибик «Тәварих»ында сөйләнелә). Федотов II: 203–204 (бик аз).

**ТӨКЛЕТУРА [төклөтура]** «полярная сова», «шмель» ~ чув. *тĕклĕ тура* «балаклы ябалак; шөпшә» ~ хак. *түктĕг аар*, тув. *дүктүгары* «төкле бал корты» – «төклетура» >> себ. (Тумашева 1992: 214) **төктуар** «шөпшә» (*аар, ары* «бал корты», к. **Әрә**) сүзеннән, к. ш. ук үзб. *тукли ари*, каз. *түктĕ ари* «шөпшә». Мәгънәви параллель – миш. *йонны прамыш* «төклетура» (ДС III: 67). **Төкле тура, төкле турак** варианты халык этимологиясенчә «төкле аяк» буларак аңлашылуыннан, к. **Турак I.** Федотов II: 213–214 (аңлатуы бигүк дөрес түгел).

**ТӨКСЕ [төксө]**, диал. **төксә, төксү, төксөк, төксем** «хмурый, хмуро; неприветливый, неприветливо» > чув. *тĕксĕм* id. ← *төксе-у* «бала йоны

чыгу» фигыленнән, *төк* тамырыннан, к. каз. *түксĕ-*, к.-калп. *түксий-* «чыраен сыту», кырг. *түксүй-* «йөнтәс йөзле булу; ачулану», ләкин к. эвенк. *тӯксу* «болыт; болытлы» (ССТМЯ II: 208).

**ТӨК-Ү** «толкнуть (тяжёлым предметом); бодать», диал. **төкә-ү** «подтолкнуть», «упирать» ~ чув. *тĕк-* «төнү, тию», мар. *түк-* «төкү, тию, терәтү» (*түк, түкӧ* «мөгез») ~ коми. *тувкы-, тувк-* «төкү»; чаг. мар. *түкнäш-* ~ үзб. *тукнаш-* «тиеп китү, бәрелешү». Төрки телләрдә сирәк очрый торган бу сүзләр тәкълиди характерда булса кирәк (к. **Тукы-у, төк итү** ~ монг. *дүг* «мөгезгә мөгез бәрелү авазы» һ.б.), ләкин фин-угор телләре тәэсирендә активлашкан булырга мөмкин. Чаг. башк. (БТДһ: 327) *төкөлдәт-ү* «тукылдату» һ.б. Федотов II: 211–212 (бу автор *төке* ~ *тĕк* сүзе гом. төрки *тәг-* «тию» белән бәйле ди, безнеңчә, бу дөрес түгел).

**Төкө-, төкә-** нигезе продуктив: **төкет-ү, төкәт-ү** «терәтеп кую, терәтү (мәс., бер бинаны икенчесенә)». Башк. (БТДһ: 326–327) *төкө* «терәк аслык», *төкөмә, төкөтмә* «янкорма», *төкәл-* «терәлү» һ.б. актив кулланыла.

**ТӨЛ II** (**төш-тел** парлы сүзендә) «сон, дрёма» к. **Төлер-ү, Төш.**

**ТӨЛ II, төлĕ** диал., иск. «линька (птиц); линяющий» (*төл ябалак кебек* «тихо, как линяющая сова», әйтем) < бор. төрки *tülüg* «ябагалы». К. **Төлә-ү.**

**ТӨЛӘ-Ү** (ДС I: 196) «линять; иметь оборванный вид» < бор. төрки (ДТС: 506) *tülä-* id. Гомумән, күп телләрдә очрый, бор. *tü* (к. **Төк**) «йон, төк, ябага» сүзеннән. К. **Түләк II**. Будагов I: 403.

**ТӨЛЕК I [төлөк]** диал., башк. **түлек** (**азык-төлөк, азык-түлек** «продукты питания») «фураж» < *түллук*, к. **Түл.**

**ТӨЛЕК II [төлөк]** «дремота со сновидениями (в нездоровом состоянии)» к. **Төш.** К. түбәндәгене.

**ТӨЛЕР-Ү [төлөр-]** диал., (ТТАС III 250, 287) **түлĕр-ү** «дремать, задремать (сидя)» ~ чув. *тĕлĕр-* id. ← **тĕл [төл]* «йокымсырау хәле; төш», *тĕлĕк [төлөк]* «төш» < бор. төрки *түүл* «төш; йокы». К. **Төл I, Төш.**

Мар. диал. *түлĕк* «летаргия» сүзе бор. болг. теленнән булса кирәк; чаг. ш. ук эвенк. *толкин* «төш», маньч. *толги-* «төш күрү» (ССТМЯ II: 195); калм. *tölgə-* ~ монг. *tölge-* «күрәзәләү» сүзен Г. Рамстедт тат. *төлөр-ү* белән чагыштыра (Ramstedt 1935: 406). Rona-Tas 1972.

**ТӨЛКЕ [төлкө]** «лиса, лисица» < гом. кыпч. *түлку,* хак. *түлгү*, нуг., каз., к.-калп. *түлки*, чыгт., уйг., бор. төрки *тилку, түлки*, төркм., госм. *тилки* ~ чув. *тилĕ,* госм. (Будагов I: 565) *дилки* һ.б. «төлке»; чаг. эвен. *дилки, дилики* «ак ас».

Безнеңчә, бу сүз тибет. *тулку, тюлькю* (к. Буддизм. М., 1992: 247) «бер тәннән икенчесенә күчеп йөргән җанның чираттагы тәне (гадәттә – хайван төре)» сүзеннән. Көнч. Азия илләрендә **төлке** – пәриләрнең күренмеш кыяфәте һәм бу төлкеләр тур. бик күп сөйләкләр, әкият, хикәяләр бар. Татар дастаннарында (ТХИ: Дастаннар 1984: 69) төлке аждаһа кыяфәтенә кереп йөри һ.б. Аз. (АДДЛ: 392–393) *түлү, түлүңкү, түлүңки* «хәйләкәр; карак» икенчел булса кирәк. Федотов II: 229; Räsänen 1969: 480 (этимологиясен ачык калдыра).

Дерив.: **төлкелек; төлкелән-ү; төлкече** (аучы).

**ТӨМ** «совершенно (тёмный)» ~ башк. (БТДһ: 327) *төмә,* чув. (Федотов II: 215) *тĕм, тĕме* id. ~ рус. *темь, тьма* сүзенә охшаш, ләкин к. **Дөм**. Төрле сүзләр контаминациясе булса кирәк.

**ТӨМӘН** «тьма; десять тысяч», диал. «область» < гом. төрки, монг., эвенк. < бор. төрки *tümän* id. Тат. **төмән төрле** «гаять күп төрле» тәгъбире бор. төрки (ДТС: 596–597) *tümän türlüg* сүзеннән килә.

**Төмән** < *түмäн* гом. тунг.-маньч. *туман* id. сүзе белән чагыштырыла (к. ССТМЯ II: 212–213), к. ш. ук монг. > фар. *туман* – зур акча берәмлеге (10 000 динар), к. Бартольд V: 570–571. Гомумән, *төмән* < *тумэн* сүзен кыт. теленнән дип уйлыйлар, ләкин бу телдә канәгатьләндерерлек этимон күренми. Чаг. бор. төрки (ДТС: 595) *tük miŋ* «мең».

**Төмән** сүзе Алтын Урдада административ берәмлек (ун мең яугир куярлык өлкә) мәгъ. йөргән, шуннан Мордовиядәге **Темников** һәм Себердәге **Тюмень** шәһәрләренең исемнәре килә. К. ш. ук себ. (Рамазанова 2001: 119) **төмән** «өлкә».

Рус. *тьма, темь* «ун мең; исәпсез күп» бор. төрки телләрдән килә, к. Аникин: 576–577 (шунда ук **төмән, туман** сүзләре тур. бай әдәбият күрсәтелә). Федотов II: 215.

Тат. **төмән** дигән этнографик группа – Мордовиядәге Төмән (рус. *Темников*) мишәрләре (алар хәзер төрле өлкәләрдә очрыйлар).

**ТӨН** «ночь» < гом. төрки *түн* < як., бор. төрки *түүн* > угыз. *дүн*, төркм. *дүйн, дүин* id. (к. ЭСТЯ III: 315–316) монг. *түнэ* «караңгы» сүзе белән чагыштырыла (Пекарский: 2893).

Чув. телендә «төн» мәгъ. төп сүз *çӗр [счөр]*. Бу факт *төн* < *түн* сүзенең төрки телләрдә соңрак, *көн* < *күн* сүзенә рифмалашарак килеп чыкканлыгын күрсәтә шикелле; чыгт. һ.б. (к. Радлов III: 1549) *түнä* «кичәгенәк; элекке» > тат. диал. (ДС I: 182; ДС III: 153) **тенә, төнә, тенәкөн** «кичәгенәк», ихтимал, беренчел мәгънәгә (чыгт. *түн-* «караңгылану») якындыр. К. ш. ук Мухамедова 1973: 177–178.

**Төн** продуктив нигез: **төнге, төнгелек, төнен, төнлә, төнле, төнсез** «төн җитмичә», к. **Төнә (көн), Төнәк, Төнә-ү, Төнтек.**

**ТӨНӘ, төнәген** диал. (ТТДС I: 443) «вчера; прежний (день)» < куман., чыгт., кар., хак. диал. *түнä*, кар., ком. *түнэгүн*, к.-балк. *түнэнэ*, «Kelür-name» телендә (СТ № 3, 1972: 102) *tunakun,* иске угыз. (Мухамедова 1973: 90) *dünägün*, төркм. *дүйнәән* id. Ихтимал ки, *төнә* < *көнә* < фар. *куһнä* «иске, элекке» (к. **Көнәген**). Ул вакытта *төн* < *түн* сүзе дә ир. телләрдән (сугдчаданмы) булып чыга. Гаҗәп рәвештә, тунг. телләрендә дә *тинэвэ, тинугэ* һ.б. (бик күп вариантлар) «кичәгенәк, төнәген; былтыр», к. ССТМЯ II: 183–184.

**ТӨНӘК,** диал. **төнек** «место, где ночуют (можно ночевать)», күч. «квартира, дом, жильё». Бу сүз төрле җирдә төрле мәгънәле: тат. диал., башк. «тавыклар кунып, төн уздыра торган урын» ~ төр. (Радлов III: 1599) *түнäл* «төрмә, караңгы урын», иске угыз. *tünek* «бүлмә», төр. *tünek* «ат абзары», төр., төркм. *düynek* «ритуал яки бәхәс буенча зиратта төн уздыру урыны» һ.б. К. тат. мәкаль: *Төнәргә төнәге булмаган кешегә кыз бирмиләр.*

Дерив.: **төнәклә-ү** «тиешсез (махсус билгеләнмәгән) урында куну, төнлә йоклау».

**ТӨНӘТ-Ү** иск. (Троянский I: 377) «обмануть, провести» ← **төнә-ү II.**

**ТӨНӘ-Ү I** «переночевать; садиться на шест (о курах)» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *түнä-* id. ← *түн* «төн». К. **Төнәк**.

Дерив.: **төнәче** «төнәү урыны», **төнәт-ү** «кич кундыру».

**ТӨНӘ-Ү II** «настаиваться (о бродильном составе)» – безнеңчә, бу сүз асылда себ. *тинә-ү* «сынау, үзгәреш кичерү» ~ төр. *dene-* id. белән бердәй, тик **төнә-ү I** тәэсирендә яңгырашын үзгәрткән, к. диал. (ТТДС I: 443) *төнәр-ү* «төнәү, әчеп чыгу», **төнәрт-ү** «әчетү».

Дерив.: **төнәт-ү, төнәрт-ү; төнәтмә** һ.б.

**ТӨНБОЕК [төнбӧйӧк]** яки **[төмбӧйӧк],** себ. (к. Тумашева 1992: 212; Будагов I: 407) **тӧмкыйык, тумғуйук** «водяная лилия, кувшинка» ~ башк. (БТДҺ: 81) *домбойоҡ,* алт. *тумғуйаҡ* «су чикләвеге (үлән)» ← иске тат. *тумғы-,* себ. *думғалы* «чуму». Сүзнең төп нигезе *тӧмга-* < *тумға-, тумқа-* «чуму» → *тумғай* «төнбоек» → *тумғай-аҡ* (*тумғай* сүзенең иркәләү-кечерәйтү формасы). Тәүдә кайбер су үсемлекләренең төнгә суга яшеренүеннән; **төнбоек** варианты халык этимологиясе буенча бу үсемлекнең чәчәкләре **төнгә** таба ябылуыннан чыгып ясалган (төнен боек).

**ТӨНДЕК [төндөк]** (ТТАС III: 292) «отверстие в стене чёрной избы» (а также затычка этого отверстия) ~ башк. *төндөк*, каз., кырг. һ.б. *түндүк* «тирмәнең чагарагын каплагыч киез». Каз. сүзлекләрендә *түндүк* сүзе *түнүк* «төннек»тән аерым күрсәтелә. К. **Төннек.**

**ТӨНИ, төней** (ТТДС I: 443; ТТДС II: 320) «стёганые валенки; толстые тёплые чулки», башк. (БТДҺ: 341) *түни, түней* id. < рус. диал., коми. диал. *тюни* «резин кәвеш; төни»; чаг. рус. *чюни, чуни* «кәвеш төре». Аникин: 577, 676.

**ТӨНКАТА** «всю ночь», **төнқатар** «ночной дежурный; охранник». Бу сүз беренче карашта **төн** һәм **кату** сүзләреннән тора кебек. Ләкин к. чыгт. (Будагов I: 381) *түнқатар, түнқутар, түнқыйтар* «төнге дежур, төнге дежурлык» **төн** һәм гар. *катар* ~ *кыйтар* «рәт, чират, дежурлык» (к. **Катар**) сүзләреннән гыйбарәт. **Төнқата, төнката** халык этимологиясе буенча ясалган сүзләр. К. ш. ук Velidi: 13.

**ТӨНЛӘ** «ночью» < чыгт., уйг. *түнлä*, бор. төрки (ДТС: 597) *tünlä* id. > кырг. *түндө* һ.б. (гомумән сирәк очрый). **Төн белән** сүзеннән ясала ала (*төн илә* > *төнлә*).

**ТӨНЛЕК [төнлөк]** «достаточный для проведения ночи» ← **төн,** әлбәттә. Кайбер сүзлекләрдә бу сүзне **төннек** белән бутыйлар. Себ. **төннөк, төңлөк** (к. Тумашева 1992: 215) «баз, идән асты»

**төнлек** мәгънәсеннән һәм башк. *төндөк* «баз төннеге» сүзеннән контаминация.

**ТӨННЕК [төннөк]** «дымоход в стене (обычно – бани) под потолком», себ. (Тумашева 1992: 220–221) *түннүк, түңнүк* «дымоход юрты» > мар. *түнүк, түнӗк, төнөк* һ.б. (күп вариантлар) ~ чув. *тӗнӗ* «күзәтү тәрәзәсе, төннек, юллык» ~ нуг., к.-калп. *түңлик,* каз. *түндӗк,* кырг., алт. *түндүк,* каз. диал., тув. *дүндүк,* уйг., чыгт., кр.-тат. (Радлов III: 1554) *түнлүк,* як. (> эвен., к. ССТМЯ II: 214) *түннүк*, бор. чыгт. (Поппе 1938: 278) *tünglük* «төннөк; кечкенә тәрәзә», үзб. (ЎХШЛ: 265) *түндук* «төтен юлы – түшәмгә уелган зур тишек», *түйник* «дивардагы төннек» < бор. төрки (ДТС: 595) *tügnük* id. һ.б.

Бор. заманнардан XX г. кадәр тирмәләрдә, чумнарда, куышларда, ш. ук балаганнарда (балчык, саман өйләрдә) төтен түшәмгә уелган, түшәмдә калдырылган тишектән чыгып торган һәм тишек белән бәйле ырым-йолалар да килеп чыккан (мәс., теләгеңне төннеккә кычкыру, татарларда – **төннек бәйрәме** – шәгъбан аеның 15 ендә төнлек ~ төннек тыгынын урлау, к. Будагов I: 409). Нуг., каз. телләрендә мәзкүр сүзләр төннекне төнгелеккә каплый торган киез кисәген дә белдерә. Хак., алт. телләрендә ул «йорт, төтен (гаилә, салым салу берәмлеге)» мәгъ. дә йөри. *Төннек* сүзе тат. *төтенлек* сүзеннән дә килеп чыга алыр иде һәм гом. төрки *түнлүк* дип билгеләп, *түн* «төн» сүзенә дә нисбәт итәләр, ләкин к.-калп. *түңлик* һәм бор. (к. Räsänen 1969: 505) *tügünük* вариантлары сүзнең этимологиясе катлаулырак булуын күрсәтә. Бер фараз буенча, *түңлүк* кыт. *tieŋ lu* «өй яктырткыч, өй шәме» сүзеннән үзгәреп килеп чыккан, имеш. К. **Төндек, Төнтек.** Федотов II: 216.

**ТӨНТӘЙ-Ү** «замкнуться в себе, ни с кем не общаться; быть мрачным, нелюдимым» **төнт, төнте** нигезеннән, чаг. башк. (БТДҺ: 328) *төң берүзе (төң-берүзе?)* «ялгызын һәм аралашмыйча» ~ к. кырг. *түнт* «төнтек» → *түнтөй-* «караңгы булу (урман тур.). Төн < түн* тамырыннан булып чыга. Чаг. ш. ук маньч. *туңги* «төнтек» (ССТМЯ I: 224).

**ТӨНТЕК [төнтөк]** «замкнутый, неразговорчивый (и не умный)» – ***төнте-ү** фигыленнән шикелле. К. **Төнтәй-ү**. Чаг. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 215) **төңкөш** «төнтек», **төңкө-ү** «өю, сөмсезләнү». Рус. (Даль) *дюндик* «мескен генә бәләкәй кеше» < тат. булса кирәк.

**ТӨҢ I** (ЗДС: 645–645) «полностью; целиком», «совсем», сөйл. **төң-бөтен** «әзер һәм бөтен (әйберләр җыемы тур.)», крш. (Balint: 120) **töñ** «rauhreif», ягъни «әзер дияргә мөмкин». К. түбәндәгене.

**ТӨҢ II: төң, төңәк, дөңчөк** (ЗДС: 645), **төң, төңкө, дөңкө** (БТДҺ: 328) «узел, тюк» ~ к.-балк. *тюнке, тюңке* «бар байлыгыңны җыйган төен, зур төен» < куман. ***түңкә** > бор. рус. (Аникин: 576) *тюм, тюнь* «төң, төңкә». Рус. *тюк* сүзе дә бор. кыпч. **түңк** сүзеннән булса кирәк. К. Фасмер IV: 134 (бор. төрки **tǖk* сүзеннән ди).

Дерив.: **төңкә-ү < төңәк-ә-ү** фигыле булган бугай, к. (Тумашева: 213; ЗДС: 645) **төңгәт-ү, төңгөт-ү** «нык итеп бәйләү, төргәкләү», **төнкәк, төңгәк** «төенчек, зур төен»; **төңкәлә-ү** «бәрәңге төбен өю, күчләү».

**ТӨҢГЕР [төңгөр],** диал. **дөмбер** «бубен», иск. «шаманский бубен» > мар. *түмӗр, түмбӗр* «бубен, барабан» < алт., хак., чыгт., бор. төрки (Радлов III: 1543) *түңүр, түңгүр*, як. *дыңыр, тыңгыр, дүңгүр, дүгүр*, тув., яз. монг. һ.б. *düngür* id. Рус. *дюнгюр* «шаман төңгере» тур. Аникин: 194 (шунда ук арытабангы әдәбият).

**Төңгер** < *түңгүр* сүзе имитатив тамырдан ясалган булса кирәк; тат. сөйл. (к. мәкаль: *Туй үткәч дөмбер нә?*) **дөмбер** «туй барабаны» **дөмбердә-ү** фигыленә нисбәтләнеп аңлатылган. К. ш. ук **дөңгелдә-ү, дөңгердә-ү** һ.б.ш.

Төрки һ.б. халыклардагы **төңгерләр** бик хикмәтле-төрле билге-тамгаларга бай булганнар; алар тур. зур этнографик әдәбият бар.

**ТӨҢЕЛ-Ү [төңөл-], төңү** «сделав круг, падать вниз (о стреле и. т. п.)», күч. «раздумать, отказаться, пойти на попятную» ~ гом. кыпч. *түңүл-* тик соңгы мәгъ. генә. Чаг. **Түңел-ү, Түңкә.**

**ТӨҢКӘН** (Мәрҗани 1989: 317) «дунган, дунганы-мусульмане, говорящие на диалекте китайского языка».

**ТӨП** «дно; основание; комель, пень; коренной» > мар. диал., удм. диал. (Насибуллин: 141) *түп, тып*, чув. *тӗп* id. < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт. һ.б. *түп* < бор. төрки (ДТС: 598) *tüp* < **tüüp* > төркм. *дүйп* > гом. угыз. *дүп,* төр. *dip* ~ иске монг. (Поппе 1938: 357) *tübe* id., к. ш. ук бур. *түб* «үзәк», монг., калм. *төв* «үзәк, урта». Будагов I: 383; ЭСТЯ III: 317–319; Федотов II: 217–218.

Тат. гомумхалык һәм әд. телендә **төп** сүзенең күп кенә яңа мәгънәләре үстерелә (к. ТТАС III: 254–257), шулардан яңа дериватлар ясала: **төпле, төпсез** (һәр икесе күпмәгънәле); **төплек; төплә-ү, төплән-ү; төпләгеч; төпләм;** диал. **төпчә, төпчәк** һ.б. К. **Төбәк, Төпкә, Төплә-ү, Төпләк, Төпсә, Төпчек, Төпче-ү.**

**ТӨПКӘ,** диал. **төпкәк** «большой пень» – бу сүз **төп-, *төпе-* фигыле булганлыгына ишарә, чыннан да, диал. сөйләмдә *төбө-ү* «төпкә омтылу, төпченү» сүзе очрый (окказиональ ясалышмы?).

**ТӨПКҮТӘРӘ** (ЗДС: 646) «все вдруг, разом; одним рывком» (бу сүз әд. әсәрләрдә дә очрый) ~ үзб. *тўп-кўтара* (парлы сүз: *тўп* «төркем, туп булып», *кўтара* «күчерәрәк, күчереп» ← *кўтар* – «күчерү») «кинәт бергә талпынып». Үзб., уйг. *кўтар-, көтәр-* «бергәләшеп күчерү» < **költär-* «җигелдерү». К. **Күлем.**

**ТӨПЛӘК** диал. (БТДҺ: 328) «топляк, бревно, ствол в реке, озере» – бу сүз тат.-башк. диал. *төплә-ү* «төпкә тарту, төпкә китү» сүзеннән дә ясала ала һәм рус сүзен халык этимологиясенчә аңлаудан да килеп чыга алган.

**ТӨПЛӘ-Ү** «переплетать книгу; ставить (новое) дно; кочевать лес» – тат. телендә **төп** (к.) сүзенең мәгънәләреннән ясалган сүз; соңгы мәгъ. «урманның төпләрен генә калдыру» мәгънәсенең «төпләрен дә бетерү» булып әверелүеннән булса кирәк.

**ТӨПСӘ** «корешок (книги, листа)» – асылда, «төп (нәрсәнең дә булса төбе) утыртыла торган нәрсә», к. үзб. *дупсә* «йомры төпле чүлмәк кавын-кабак утыртыла торган махсус җайланма» (ЎХШЛ: 92).

**ТӨПЧЕК [төпчөк]** «самый младший, последний ребёнок; окурок» ~ башк. *төпсөк* > чув. *тĕпчĕк* id. (Федотов II: 218) ← **төп** (к.) сүзенең кечерәйтелү формасы. Тат. телендә ясалган булса кирәк. Диал. (ЗДС: 646) **төпцөк** «иң эчке кием, хатын-кызның коену күлмәге».

**ТӨПЧЕ-Ү [төпчө-]** «выкапывать корень», күч. «дотошно расспрашивать, выведывать, выпытывать, разузнавать, расследовать» > чув. *түпче-, тĕпче-,* мар. *түпчы-, түпчэ-* id. Идел-Урал регионында гына таралган бу сүз **төп** (к.) тамырыннан ясалган, ихтимал, шуның фигыль коррелянты булгандыр, к. башк. *төпсө-* id., башк. диал. (БТДҺ: 329) *төпөш-өү* «сорашу; төпчү» ← ***төп-өү**. Федотов II: 218.

Дерив.: **төпчен-ү, төпчеш-ү, төпчет-ү; төпчемә** (элегрәк «тикшеренү» мәгъ. кулланылган).

**ТӨР** «разновидность, вид, сорт» < гом. кыпч. *түр,* угыз. *дүр* id., тув. *түрү* ~ монг. *дүри* «кыяфәт, чырай; чалым». Бу **төр** < *түр* сүзе тат.-башк. даирәсендә генә шул килеш актив кулланыла, бүтән төрки телләрдә аның дериватлары, бигрәк тә *түрлүг* (~ бор. төрки *törlüg*) «төрле» еш кына очрый. Тат., башк. *түрлә-ү* «тыштан бизәү» сүзеннән чыгып, кайбер тикшеренүчеләр **төр** сүзе астында ике тамыр сүз ята дип тә уйлыйлар, к. İnan I: 268–273; ЭСТЯ III: 327–329; Федотов II: 219–220.

Дерив.: **төрдәш; төрле** (> чув. *тĕрлĕ*, удм., мар. *түрлĕ, турлы, түрлö*), **төрсез; төрлә-ү, төрләг-ү** (күп мәгъ., к. ТТАС III: 263); **төрләнчек; төрлек** (грамматик термин), **төрлеклән-ү; төрчә, төрчек.**

**ТӨРӘН** «лемех, сошник» > чув. (Ашмарин XV: 80, 114) *тĕрен, трен* «төрән; җир бүлешүдән соң калган кештәк» < гом. кыпч. *түрен, түрән* (кайбер кыпч. шивәләрендә теркәлмәгән), куман. (Радлов III: 1448) *туран* «төрән». Урум. *сурӓн* id. (к. Муратов С.Н. Материалы по говорам тюркоязычных греков // Краткие сообщения народов Азии. М., 1963: 181) халык этимологиясе буенча (*сур-* «сөрү» сүзенә нисбәтләп) пәйда булган вариант булса кирәк. Федотов II: 219–220 (бик аз сүз әйтелә).

Дерив.: **төрәнле, төрәнсез; төрәнлек.**

**ТӨРБӘ** «склеп, мавзолей» ~ иске тат. (<төркм.) *дөрбә* < гар. *түрбӓ, түрбӓт* «төрбә» ← *трб* «туфрак» тамырыннан; ГТРС: 621. К. ш. ук фар. *төрбӓт* «төрбә».

**ТӨРГЕ [төргө], төргөн** (ЗДС: 646) «раз, крат (о приёме гостей)» к. **Төркен.**

**ТӨРЕК I [төрөк]** «турок», иск. «тюрк» – бор. төрки, чыгт. һ.б. *түрк* «төрки» сүзенең татарча кинәйтелүеннән (икенче *ө = е* – интеза). Бор. язмаларда *türk* «кабиләләр союзы», «көчле», «иң, бик» (*türk jigit* «иң-иң егет, егетлегенең иң шәп чагы»), гомумән тәүдә бу сүз «кульминация, зенит, иң көчле чак, үзәк» мәгъ. булган (Clauson: 542–543), к. кырг. *түрк* «иң көр, иң симергән (терлек тур.)», *түркүк* «тирмәдә үзәк багана», *эрк-түрк* «ирек һәм көчлелек». Сәгадәт Чагатай фикеренчә (к. аныкы:

Einige Ellipsen in türk dialekten // UAJ, XXIX, 3–4, 1957: 233), *türk* этнонимы *türk sir* «иң көчле, үзәк сир» тәгъбиреннән эллипсис – ул чагында төрки халыкларның бор. гомуми атамасы *sir = сир, сыр* булган һәм бу сүзне бор. лат. *ser* «Кытай чигендә бер халык», соңрак «Кытай» сүзенең нигезе дип уйларга мөмкин. Кайбер тикшеренүчеләр *Сыр дәрья* («сырлар дәрьясы») гидронимын да шуннан чыгаралар.

**Түрк** сүзе кимендә V г. ук этноним термин булып китә һәм VI г. Евразиядә (тәүдә – Алтайда) *түрк (көк түрк)* каганаты пәйда булгач халыкара таралыш ала. Бу сүзнең төрле халыкларда шул чорда язылышлары (лат. шрифтына күчерелгәндә) – кыт. *t'uət kiwət*, гар. *trk*, грек. (Византиядә) *tourkoi*, бор. сири (Сурия) телендә *turkae*, санск. *turuşka*, пракрит. (Һиндстан) *turukka*, фар. *turk*, сугд. *twrk*, тибет. *dru-gu*, хотан-сак телендә *ttrruki* (к. Кляшторный 1965: 20). Рус яз. ядкәрләрендә *торк, торъци* XI г. бирле билгеле (шундый аерым бер кабилә булган): ул заманнарда «*төрки* халыклар» дигән төшенчә булмаган. IX–X гг. *түркман, түркмӓн* дигән этноним пәйда була: аны фар. *түрк мӓнанд* «түркә охшаш» яисә *түрки-иман, түрки-аман* (чаг. бор. рус. *туркоман*) «иманга килгән түрк» дип тәгърифлиләр (Sümer 1992: 60). **Төрек < түрӗк < түрк** сүзенең этимологиясенә керешүчеләр күп кенә, ләкин ышандырырлык аңлатмалар юк диярлек. К. **Төркем, Төрки.** Türkler II: 49–52.

**ТӨРЕК II [төрөк], төрүк** (ЗДС: 647) «вдруг, быстро» < рус. *вдруг* «кинәттән». Чаг. чув. *тăрук, трук* id.

**ТӨРЕКМӘН [төрекмән]** «туркмен», миф. **Төрекмән баба** – хозяин водоёмов; башкортларда берничә **төрекмән ыруы** бар. Сүзнең чыгышы тур. к. **Төрек.**

**ТӨРЕПКӘ [төрөпкә]** сөйл. «курительная трубка» < рус. *трубка* id.

**ТӨРКЕ [төркө]** иск. (Гигановта **тюрку**) «простонародный» – бу мәгънә элегрәк мөселман төркиләре арасында киң таралган булган, к. төр. *türkü* «халык җыры; саф төрекчә җыр». Соңрак татарларда **төрке** «гарәп хәрефләре белән төркичә-татарча язу, язма» мәгъ. кулланылган (**төрке тану** «укыйяза белү»). Асылда **төрке** < гар. *түрки* «төрки» булса кирәк.

**ТӨРКЕМ [төркөм]** «группа» > чув. *тĕркĕм* < гом. көнч. кыпч., чыгт., уйг. *түркүм* (нуг., каз., к.-калп. *түрким, түркĕм*) «төркем», кырг. диал. *дүркүн*, к.-калп. *дүркин* «талпа, группа, отряд», бор. төрки (ДТС: 581, 599) *törkün, türkün* «ыру, кабилә» ~ тат. диал., башк. диал. (Тумашева 1992: 221; БҺҺ II: 266; БТДҺ: 342) *түргүн, түрген, түркүн, төрген*, як. *төркүт* «киленнең, кәләшнең барча туган-тумачасы, туган авылы; аның үскән йортына кунаклый бару йоласы» ~ каз., алт. *төркүн,* уйг. диал. *түргүн*, хак. *төргүн* id. ~ монг. *төрхөм, төркүм*, бур. *түрхэм* «үз нәселләрең, нәсел-нәсәбең», бур. *түрбэл* «атаң йорты; нәсел-нәсәп». Соңгы сүз **түр* тамырын аерырга мөмкинлек бирә шикелле, чаг. ш. ук чув. *тĕркĕн* «группа белән; җыйнау» ← **тĕрк* < **түрк* «җыен»?

*Төркем ~ төркен* сүзен төрлечә – *төрек* < *түрк* сүзе белән дә, *түрә-ү* «туу» фигыле белән дә чагыштырырга мөмкин, ләкин ышанычлы этимология әлегә юк. Räsänen 1969: 494 (чагыштырулары төгәллексез һәм юраулы). İnan II: 268–272.

**Төркем** продуктив нигез: **төркемдәш, төркемлә-ү, төркемлән-ү, төркемле, төркемчә, төркемче, төркемчелек, төркем-төркем** h.б.

**ТӨРКЕТ [төркөт]** «тюркут, тюркуты» < бор. монг. *түркүт* «түрекләр, төркиләр» сүзеннән; хәз. фәнни әдәбиятта **төркет** «*р ~ л*» төркиләреннән (гомумтөрки *-ш* урынында *-л* авазын, *-з* урынына *-р* авазын кулланылучылардан) тыш төркиләрне билдерә. Әйтергә кирәк, ул «*р ~ л*» төркиләр, гомумән, борынгырак булганнар, ләкин хәзер алардан тик чувашлар гына калган (болай дип әйтү дә әле шартлы). Төркетләр, гомумән, яңарак, «яшьрәк».

**ТӨРКИ** «тюрк; тюркский», диал., башк. «старотатарский» < чыгт. *түрки* < гар. *түркӣ* «төрки, түрекләргә мөнәсәбәтле» сүзеннән таралган; фар. телендә төркиләрне *түркан* дип тә атыйлар һәм Урта Азиядә шул атамалы төрки кабилә дә бар. Тат. әд. телендә **төрек** «Төркия төркисе» һәм **төрки** сүзләрен аеру XX г. гына карарлаша. Соңгы елларда (XX г. азагында) **төрки** яки **түрк** сыйфатыннан аермалы **түрек** (< бор. төрки *türk*) сүзе дә кулланыла. К. **Төрек**. Будагов I: 351.

Дерив.: **төркилек; төркичә; төркиләш-ү.**

**ТӨРКИЯТ [төркийат]** «тюркология» – гар. телендә ясалган сүз: *түркийāт* ← *түрки* ← *түрк*. К. **Төрек.**

Дерив.: **төркиятчы.**

**ТӨРМӘ,** (Троянский I: 88; БТДҺ: 260 һ.б.) **өтөрмә, өтөрмән** «тюрьма» ~ чув. *тĕрме*, удм. (Насибуллин: 100–141) *түрмä*, мар. (Иванов, Тужаров: 239) *тöрмä* id. < рус. *тюрьма* – бор. төрки телләрдән булса кирәк, к. алт. диал. *түрмä*, кырг. *түрмö*, алт. диал., як. *түрбä, түрбэ* «төрмә» – ихтимал, *түрбэ* «төрбә» сүзеннән үзгәргәндер (к. Räsänen 1969: 506–507). Ләкин мәзкүр төрки сүзләр рус теленнән таралган булуы да бик ихтимал. Тат. **өтөрмән** ~ манси. *түрмäн* вариантлары каян, ничек килеп чыккан? Бәлки, иске этимология – рус. *тюрьма* < ним. *Türmen* «башнялар, төрмә вышкалары» дөрестер, к. Фасмер IV: 137; Федотов II: 220–221 (**төрмә** сүзен **төр-ү** сүзеннән димәкче).

**ТӨРМӘЧ, төрмәчә** (**төрмә** дип тә әйтелә, ләкин бу ямьсез), **төрмәк** «вид пирога; варенье и т.п. завернутые в блин» – гом. төрки характерда, к. аз. (АДДЛ: 208) *дүрмәз* «төрмәч», бор. төрки (ДТС: 599) *türmäk* «сыйр катыш икмәк» (Кашгари шулай аңлаткан) һ.б. ← *tür-* «төрү».

Тат. икенче бер **төрмәч** «тәртипсез буталып төргәкләнгән әйберләр» (шуннан **төрмәчлә-ү** «тәртипсез бутап төрү»). Монысы да **төр-ү** сүзеннән, әлбәттә.

**ТӨРПӘ, төрпе,** диал. (ТТДС I: 420) **торпа** «колючий (взгляд), колкий (о словах)» < **дорфа** (к.) булса кирәк. Чаг. ләкин, бор. төрки (ДТС: 580) *törpigü* «эре тешле игәү» (→ рус. *терпуг*), *törpi-* «юнгычлау».

**ТӨРРӘ, дөррә, терря** – междометие для отогнания овец ~ чув. *тĕрре* id. Ихтимал, бор. бер телдә бу сүз гомумән сарыкны белдергәндер.

**ТӨРТ-Ү** «ткнуть; толкнуть», диал. (ТТАС I: 445) «макнуть» < гом. кыпч., алт., хак., уйг., чыгт. *түрт-,* гом. угыз. *дүрт-* id., бор. төрки (ДТС: 599) *türt-* «сөртү»; чув. *тĕрт-* «төртү; аяк терәү» ← себ. (Тумашева 1992: 216) **төр-ү** < бор. *tür-* «этү» фигыленең йөкл. юн. К. ЭСТЯ III: 328–330 (Э.В. Севортян күп кенә мәгъ. китерә, ләкин алар барысы да метафорик, экспрессив һ.б. характерда, мәс., тат. *акча төртү* «ришвәт бирү»). Чаг. ш. ук **Өтер-ү, Төр-ү**. Федотов II: 222.

Дерив.: **төртел-ү, төртен-ү** («чукыну» мәгъ. дә бар), **төртеш-ү, төрттер-ү; төртенчек; төртмәле; төртке, төрткеч, төртек; төртмән** (майсыз күмәч, коймак – кунакларга кайтырга кирәклекне белдерү өчен пешерелгән).

**ТӨРҮ** диал. «незначительные подарки невестке; недорогое угощение сватьям» (дарятся и даются с целью испытания характера) ~ башк. (БТДҺ: 330) *төртмән, төрткө,* төр. *dürü* id. – «төреп», ягъни көтелмәгәндә эшләнгәнлеге өчен шулай аталган. Күрәсең, бик бор. гадәт. Чаг. **Чәчү**.

**ТӨР-Ү** «свёртывать, складывать; обёртывать», диал. (ТТДС I: 445) «мотать»; «засучивать» ~ чув. *тĕр-* id. < гом. кыпч., алт., хак., уйг., чыгт. *түр-,* төркм. *дүйр-,* аз. диал., госм., тув. *дүр-,* бор. төрки (ДТС: 598) *tür-,* як. *түүр-* id., кайбер телләрдә тагын «өемгә салу, төяү», «урау, чорнау» мәгънәләре бар, шул нигездә бу сүзне *төй-* < *түй-* «бәйләп кую, төйнәү» сүзе белән тамырдаш дип карарга мөмкин, ләкин *төр-* < *түр-* < миш. *түwер-* «төерү» дип фаразларга ярамас. Чаг. ш. ук **Төрт-ү** (ихтимал, бор. ике – *түр I* һәм *түр II* фигыльләре булгандыр).

**Төр-** продуктив нигез: **төрел-ү, төрен-ү, төреш-ү, төрдер-ү** (барча юн. мәгъ. актив кулланыла), **төргәк** (< бор. төрки *türkäk*, тәүдә «шнур» мәгъ. булган), **төрем** (*бер төрем тәмәке*) һ.б. К. **Төрмәч.** Рус. *тюрик, тюрюк* «кәтүк, шүре; төргәк, букчай» төрки телләрдән булса кирәк (к. каз. *түрик* «сызганылган», төр. *dürük* «төргәк» һ.б.). Будагов I: 389; Егоров 1964: 247; Räsänen 1969: 506; ЭСТЯ III: 319–321; Федотов II: 219; Фасмер IV: 137; Аникин: 577–578.

Гомумән, **төрөк* < *түрүк* «төрү үзәге, үзәк» дип карап, *төрек* сүзен дә «төрү» фигыленә бәйләп була, ләкин әлегә – эчтәлексез фараз гына. Тик шуны әйтергә кирәк: күчмәчелек заманнарында төрү-сүтү гамәле көндәлек тормышта гаять зур роль уйнаганлыктан, шул мәгънәдәге сүзләрнең киң һәм төрле (шул хисаптан абстракт мәгънәле) деривация бирүе бер дә гаҗәп түгел.

**ТӨС** «цвет, масть; вид, образ, облик», диал. (ТТДС: 445) «фото, фотография» > чув. *тĕс, түс*, мар., удм., морд. М. *түс* id. < гом. кыпч., уйг., чыгт. *түс* id. бор. *tü-sü* «төсе, төге» ← *tü* «төк, төс, төсмер» сүзеннән (Clauson: 433), к. **Төк.**

**Төс** сүзенең чагыштырмача яңалыгы аның кайбер төрки (угыз һ.б.) телләрендә юклыгыннан яисә сирәк кулланылуыннан да күренә. Тат. телендә **төс** – иң кулланышлы һәм продуктив нигезләрнең берсе: **төсле, төссез, төслә-ү** (төсен, кыяфәтен хәтерләү) һ.б., к. **Төс-буй, Төсмер. Төссез** сүзе күрше телләрдә калькалаштырыла: удм. (Насибуллин: 14) *түстэм*, мар. *тусдымо* «төссез» һ.б. Федотов II:

222–223 (*төс* < *түс* сүзен монг. *тӧс* «охшашлык» белән чагыштыра).

**ТӨСБӘТ** (ЗДС: 647) «безобразный, некрасивый < фар. *түсибӓд* «начар төс» яки тат. *төсе бәт?* (к. **Битәр).**

**ТӨС-БУЙ** «облик, лицо и стан» > удм. *тусбуй* id. < **төс** һәм **буй.**

**ТӨСМЕР [төсмөр]** «масть; подобие по цвету, облику» – бүтән кыпч. телләрендә юк; чув. *тĕсмĕр* «төсмер», ш. ук *тĕшмĕрт-, тĕсмĕрт-* «хәтерләргә тырышып текәлеп карау» < тат., к. Федотов II: 223. *Төсмер*, ихтимал, *төс-нөр* парлы сүзеннәндер, к. диал. (ТТДС I: 321) **нөр** «кыяфәт» ~ к.-балк. *нюр* id. (к. **Нөр**). Чув. *тĕсмерт-* < тат. **төсмерт-* ← **төсмерә-?* Чаг. **Үсмер.**

**ТӨТӘП** «склад тела, стан» к. **Түтәп.**

**ТӨТӘС** (ДС III: 238) «дымянка лекарственная (растение); окуривание» < бор. төрки *tütsüg, tütsük* «хуш исле шәм, төтәсләү шәме» (ләкин монда фонетик үзгәрешләр аңлашылып бетми); к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 601–602) *tütüz-* > госм. *дүтүз-* «төтәсләү», госм. (Радлов III: 1574) *түтсүлӓ-*, тат. диал. (ТТДС I: 445) *төсә-ү*, (К. Нәҗми) *төслә-ү* id., сөйләшләрдә *төтәслә-ү* > *төтәчлә-ү* id. К. **Төтә-ү.**

**ТӨТӘ-Ү** «дымиться» < гом. кыпч. *түтә-,* алт., хак. *түдӓ-, түдә-,* нуг., уйг., госм. *түт-,* бор. төрки (ДТС: 601) *tüt-* id. ~ ир. *dud* «төтәсләгеч; хуш исле төтен» (к. **Тут II**) сүзеннән. Бор. йолаларда хуш исле төтеннәр куллану зур роль уйнаган. К. **Төтәс, Төтен, Төтрә, Төтрә-ү.**

**ТӨТЕН [төтөн]** «дым» < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *түтүн*, төркм. *түүтүүн* алт., хак. *түдүн, түдүң* «төтен», кр.-тат., госм., кар. *түтүн* «тәмәке» (Будагов I: 385, к. укр. *тютюн* id.) – бу мәгънә, ихтимал, борынгырагыдыр (к. **Төтә-ү**) ← бор. төрки *tüt-* «төтәү» сүзеннән (ихтимал, **түтгүн* формасыннандыр). Чув. *тĕтĕм* «төтен» ~ тат. сөйл. **төтем** id. ← болг. (?) *төт-* «төтәү». К. **Төтәс, Төтә-ү, Төтрә.** Räsänen 1969: 507; Федотов II: 224–225; Мухамедова 1973: 178.

*Төтен* < *түтүн* сүзе бор. төркилек заманнарыннан бирле (хәтта як. телендә дә) салым түләү берәмлеген белдергән (к. ДТС: 601; татарларда – Сәхипгәрәй хан ярлыгында, к. Вестник 1925: 31 һ.б.).

Чув. *тĕттĕм* «караңгы, караңгылык» сүзе **төтен**нән түгел, **төп-төм* (к. **Төм**) сүзеннән.

**Төтен** (гомумән) < ***төткен** булырга мөмкин. *Төт* < *түт* тамырына һинд.-ир. *du-du*, фар. *дуд* һ.б. «төтен, төтәсләгеч» охшаш һәм гомоген булса кирәк. К. ш. ук рус. *дым* «төтен» ~ гом. һинд.-евр. сүзе.

Дерив.: **төтенле, төтенсез; тетенлә-ү.**

**ТӨТЕ-Ү [төтө-]** (ЛТ I: 136), «түзү; чыдау» ~ башк. (БТДҺ: 330, 331) *төт-, төтө-* «түзү; чыдау» к. **Төткер-ү.**

**ТӨТКЕР-Ү [төткөр-], төткәр-ү, төткәз-ү** «бережно употреблять так, чтобы хватало до намеченного срока» ← тат. диал., башк. **төте-ү, төт-ү** «озакка җитү», чув. *тăтха-* ~ тат., башк. **төткә-** «янда булу, үзендә саклану» → **төткәт-ү, төтәт-ү** «төткерү» һ.б. (к. ТТДС I: 445; БТДҺ: 330–331). Ачык түгел. Ихтимал, **тот-у** белән баглыдыр.

**ТӨТРӘ,** диал. **төтөрә,** (ДС II: 202) **түтерә** «изморось; дождь мельчайшими каплями в туман; сплошной редкий туман» ~ чув. *тĕтре, тĕтĕре,* мар. *тутрӓ, тĕтĕрӓ,* удм. *тутĕрӓ* «томан, төтрә», мар. *тутĕр-, тĕтĕр-* «төтәсләү» < төрки (госм.) *түтүр-* «төтенләү, төтен чыгу» < **түтүг-үр-* id. **түтүк, *түтүг* «сыек төтен» ← *түт-* «төтәү» (к. Упымарий: 218–222; Иванов, Тужаров: 239; Насибуллин: 141; Федотов II: 223–224); **төтөрә** < **түтүрәг* ← *түтүр-* булса кирәк. **Төтрә** сүзенең параллельләре бүтән телләрдә сирәк очрый.

**ТӨФӘЙЛИ** к. **Туфәйли.**

**ТӨФӘК, төфәң** «ружьё; мелкокалиберная пушка», **туфаң** (ЛТ I: 141) «пушка» ~ аз., госм. *түфәң, түфәк, түәк,* кр.-тат. *түфәнк* «мылтык» (бу сүзләр тур. тәфсилләп – Будагов I: 362–363), фар. *дуфек, тӧфаң,* көрд. *тифиң, тыфың* «мылтык, төфәк» ~ бор. рус. *тюфяк* – фар. теленнән дип исәпләнә (к. Фасмер IV: 138, ГТРС: 621), ләкин бу дөрес түгел, к. бор. төрки (МК; ДТС: 388) *tüväk* «пневматик ау коралы» («тал яисә бүтән агач кайрысыннан ясалып, балчык тубалакларны чыпчыкларга өреп ату көпшәсе») – күрәсең, *туф* ымлыгыннан. Чаг. себ. (Тумашева 1992: 214) *төбәк* «зур кәтүк». Төп формасы **туф-ә-ңки* булган булса кирәк. Тимергалин: 476.

**ТӨЧЕ I [төчө]** «пресный; слащавый», (ДС II: 227; ДС III: 190; ТТДС I: 506) **чөче, чөчө, цөце**

«слащавый; приторный» ~ башк. *сөсө* «төче; үтә юмакай», *сөчөк* «төче, ялагай (тел, сүз тур.)» < гом. кыпч., к. кырг., уйг. *чүчү* «төче, чөчек», каз., к.-калп. *түши, түшү*, чыгт. (Радлов III: 1575) *түчи*, (Поппе 1938: 101) *čüčük,* төр. *сüсü* «төче», *süçü* «шәраб» ~ болг. (Ибне Фадлан) *сүҗү* «татлы эчемлек» < *sütsig* «сөттән ясалган, сөтсыман» ← *sütsi-* «сөт тәмен хәтерләтү» (к. Bang 1948: 35–37). К. **Сөчек, Төче-ү, Төчлегән.** К. ш. ук түбәндәгене.

Дерив.: **төчелек; төчелән-ү, төчер-ү.**

**ТӨЧЕ II [төчө]**, диал. **чөчө** «почечуй; волчанка; кожная болезнь, продолжающаяся годами» > чув. *чĕчү, чĕчĕ, чүчү*, мар. *чүчи, чүчү, чучу*, удм. *чучи*, морд. *сучэ, цуцэ* (< миш. *цөцө*) id. – **төче I** белән бердәй яисә тамырдаш булса кирәк (ихтимал, бәбиләрдә сыер сөте саясендә пәйда була торган диатез күренешләреннәндер). Чаг. диал. **чөчөк** «сөт касмагы» (ТТДС: 506), уйг. *чүчү-* «бераз эчү; сыеклану; пычыргылану».

**ТӨЧЕ-Ү [төчө-],** диал. **чөчө-ү** «опресняться, становиться слащавым» ~ башк. *сөсө-* < бор. *сүтси-* «сөт тәмен хәтерләтү» сүзеннән. К. **Төче.**

Дерив.: **төчет-ү** (диал. **чөчөт-ү**), **төчөтке ~ чөчетке** «горчица; сыл, салат (ашлык оны)» ~ нуг. *шүшитки* «горчица».

**ТӨЧКЕР-Ү [төчкөр-],** башк. *сөскөр-* < тат. диал. **чөчкөр-ү** «чихнуть, чихать» ~ к.-балк., алт., уйг. *чүчкүр-*, нуг., каз., к.-калп. *шүшкир-, шүшкĕр-* id. – *тчү, чсү* ымлыгына *-кур ~ -кĕр* аффиксы ялганып ясалган фигыль; угыз телләрендә «төчкерү» мәгъ. *асҗыр- > аксыр-* (һәм аның фонетик вариантлары) кулланыла.

Дерив.: **төчкерен-ү, төчкереш-ү, төчкерт-ү; төчкерек.**

**ТӨШ I** «сон, сновидение» < гом. кыпч., уйг., чыгт., алт. *түш* (> нуг., каз., к.-калп., хак. *түс*), кр.-тат., угыз. *дүш* < бор. төрки (ДТС: 596, 600) *tül ~ tüš, tüül ~ tüüš* > төркм. *дүйш, түйш,* як. *түүл* id. < бор. гом. төрки **түүлгү* (булса кирәк), һәрхәлдә *төш* < *түш* < *түүш* < **түүлч* үсеше ачык күзаллана; *түүлч* < *түүлҗ* < *түүлг* булуы бик ихтимал. Арытабан ачык түгел.

Бор. яз. телләрдәге кебек, тат. телендә дә *-š* варианты да, *-l* варианты да саклана, к. **төл, төлек**, һәм хәтта ике вариант парлы сүз хасил итә: **төш-төл (күрү), төл** сүзенә аерымрак мәгъ. бирелә (к. **Төлер-ү**). Шундый хәл тув. телендә дә күзәтелә: *дүш-дүл* «төш-төл». Күрше чув. телендә *тĕл (тĕлĕк)* варианты гына бар һәм, ихтимал, тат. *төл* чувашчадан яисә болг. теленнән киләдер.

**Төш** < *түш* һәм *төл* < *түл* күп тюркологларның игътибарын җәлеп иткән сүз, к. Räsänen 1969: 507; ЭСТЯ III: 323–324 (тат. **төл, төлек, төлер-ү** сүзләре искә алынмый); Rona-Tas 1972: 226–236 (Рона-Таш та тат. сүзләрен белми); Федотов II: 214–215 (кыскача гына яктыртыла).

Дерив.: себ. һ.б. диал. (Тумашева 1992: 216) **төшә-ү** «төш күрү» (< *түшә-* id. күп төрки телләрдә очрый), **төшлән-ү; төшлек** («төш юрау», шуннан **төшлекче** «төш юраучы»; без белгән бер төшлекче карчык бар иде: ул кешеләрнең кием әйберен астына салып йоклый да, күргән төшен әйбер иясенә сөйли һәм аның теләгәнен юрый иде).

**ТӨШ II** «полдень; наивысшее положение солнца в данный день» < гом. кыпч., уйг., чыгт., алт. *түш* (нуг., каз., к.-калп., хак. *түс*), тув. *дүъш, дүүш* «төш вакыты», бор. төрки (ДТС: 600) *tüš* «төш вакыты; тукталыш урыны» ~ бор. монг. *düli*, венг. *del* id. **Төш III** белән бердәй булса кирәк.

Дерив.: **төшсез** «төш вакыты җитмичә»; **төшке; төшкелек**, **төшлек** иск. «көньяк» һ.б.

**ТӨШ III** «место, точка» < гом. кыпч., уйг., чыгт. (Радлов III: 1508) *түш*, төр. *düş* «төш; каршы як; юнәлеш ягы» ~ чув. *тĕл* «төш, урын; вакыт ноктасы, чак» (чув. телендә бик продуктив нигез, к. Ашмарин XV: 28–38). Төрки телләрдә шул ук мәгъ. *туш* (> нуг., каз., хак. *тус*), угыз. *душ*, төркм. *дууш* (ш. ук «очрау ноктасы») сүзе (к. **Туш II**) дә бар һәм этимологлар бу *түш* һәм *туш* сүзләрен бер сүз дип карыйлар, к. Räsänen 1969: 501; ЭСТЯ III: 303–304; Федотов II: 214. Ләкин *туш* > *түш* палатализациясе гомумән мөмкин булса да, мәс., угыз телләре өчен характерлы түгел. Безнеңчә, **туш** сүзе монда контаминацион тәэсир генә ясаган, *төш* < *түш III* исә *төш* < *түш II* белән бердәй һәм аның төп мәгънәсе – «тукталу яисә борылу урыны, ноктасы», к. себ. (Дмитриева 1981: 192) **түшин** «тукталыш», диал. (ТТДС I: 446) **төшек аш** «төшкелек, тукталыштагы аш». *Төш* < *түш,* ихтимал, *түңүш* (к. **Түн-ү**) сүзеннәндер, к. тув. *дүъш* ~ як. *түс* «конуссыман өем». К. **Төңел-ү** «югары атылган нәрсә әйләнеп төшү».

**Төш III** сүзенең регуляр деривациясе юк, чөнки ул башлыча тотрыклы тезмәләрдә генә кулланыла.

**ТӨШ IV** «ядро, ядрышко (ореха и т.п.)» > чув. *тĕш* id. ~ бор. төрки (ДТС: 600) *tüš* «җимеш»?

Бик ихтимал, бу очраклы охшашлыктыр. Тат. сөйләшләрендә бу мәгъ. **тош** (к.) сүзе кулланыла һәм, гомумән, омонимик этәренеш законыннан чыгып, шул вариантны әд. нормага әверелдерергә кирәктер (**төш коралы** түгел, ә **тош коралы** һ.б.ш.). Федотов II: 225.

**Төш IV** сүзенең дә регуляр дерив. юк диярлек.

**ТӨШӘМЕЛ** иск. (КБтә очрый, иске тат. тарихчылары) «чиновник», иске тат.-монг. (Velidi: 296) *tüşimel* «чиновник в сфере финансов» > бор. рус. (Аникин: 573) *тушемил* «чиновник, мәэмүр, түрә», уйг. (Будагов I: 396) *тӱшумал* ~ монг. *тусмал, тосмал* «финанс министры, ханның керемнәре белән эш итүче баш түрә». К. ш. ук як. *тӱсӱмäт*, тув. *дүъжүмет* «рәсми кунак, югары дәрәҗәле түрә, чиновник» һ.б. Бу сүзне монг. *туши-* «йомыш тапшыру» сүзеннән чыгаралар, ләкин Будагов аны монг., маньч. (кытайчадан) *тусу* «керем, доход» сүзеннән ди. Рясянең да шул фикердә. К. Räsänen 1969: 507.

**ТӨШЕК-Ү [төшөк-], түшек-ү** (себ., ЗДС: 216, 222) «привыкать». Ачык түлек.

**ТӨШЕН-Ү [төшөн-]** «понять; понимать» < гом. кыпч. *түшүн-* (нуг., каз., к.-калп. *түсĕн-, түсин-*) id., чыгт., себ. (Радлов III: 1590) *түшүн-* «бер фикергә килү, аңлап алу», к.-балк. *түшүн-* «ихнану», угыз., төр. *düşün-* «уйлау, фикерләү» – асылда *төш-* < *түш-* «төшү» фигыленең кайт. юн. (к. ЭСТЯ III: 335–336), к. үзб. *туш-*, уйг. *чүш-, түш-* «аңлап алу; фикер тирәнлегенә төшү». Чаг. бор. төрки *ök-, ög-* «аңлау» > чув. *ук* «төшү» (чув. сүзе беренчел мәгънәне саклаган). К. **Төш-ү.**

Дерив.: **төшенчә**; **төшендер-ү.**

**ТӨШКЕН [төшкөн]** «грустный; упадочнический» ~ гом. төрки *түшкүн* id., тарихи мәгъ. «сугышта аттан егылган әсир», к. Радлов III: 1587–1591.

**ТӨШ-Ү** «спуститься, сходить, слезть» (много переносных значений) < гом. кыпч. *түш-* (нуг., каз., к.-калп., алт. диал., хак. һ.б. *түс-*), угыз. *дүш-* id. < бор. төрки (ДТС: 600) *tüš-* < алт. диал. *түүш-* (тув. *дүъш-*) id. ниндидер **тү-* фигыленең урт. юнәлешеннән (яисә, әгәр **түүл-* булса) төш. юнәлешеннән үзгәргән. Будагов I: 396–397 (тәфсилле); ЭСТЯ III: 330–332 (Э.В. Севортян алт. *түүш-* яңгырашын белмәгән); Федотов II: 225 (чув. *тĕшĕр-* < тат. *төшер-*, ләкин М.Р. Федотов моны танымый); Рамстедт 1957: 53, 140 (алтаистик планда чагыштыра).

**Төш-** < *түш-* төрки телләрдә иң кулланышлы фигыльләрдән (ул модифакатор фигыль буларак та киң билгеле), к. тат. **төшел-ү, төшер-ү** (< *төштер-ү*); **төшек** «төшкән җимеш», **төшем** «дивиденд» (ш. ук **төшем килеш**); **төшенке**; **төшмән** «җәндә, сугышта аттан егылган кеше» һ.б. К. **Төшен-ү; Төшкен.**

**ТӨЯ [төйә]** (ЗДС: 642) «верблюд». Бу сүзнең күп вариантларының берсе. К. Аникин: 574 (рус. диал. *тывен* тур.). К. **Дөя.**

**ТӨЯК I [төйәк],** миш. **түәк** (**wак-түwәк** дигәндә) «мелочи; беспокойства» ~ монг. *тӧбӧг* id.

**ТӨЯК II [төйәк]** «родная земля, родное общество» (әйтем: *таянган төягем* «земля, на которую я опираюсь») ~ нуг., каз. *түйәк* «ындыр табагы», к.-балк. *түйек* «ашлык сугу» ← *түй* – «төю». К. ш. ук каз. (ҚТДС: 86) *дәүек*, төркм. *дөвек* «ашлык бастыру».

**Төяк** сүзе күчмә төркиләрнең дә үз иткән төбәкләре булганлыгы тур. сөйли.

**ТӨЯ-Ү (төйи** < диал. **төяй, төяү)** «навьючить; грузить, нагрузить» ~ чыгт. (Радлов III: 1546) *түйä-*, кырг. *түйӧ-* id. ш. ук «туплау, җыю» – төрки телләрдә сирәк очрый торган бу сүз тат. диал., чув., гом. кыпч., як. һ.б. **тийә-** «төяү» сүзе белән бердәй булмаса кирәк. *Төйә-* < *түйә-* «өеп, тәртип сакламыйча төяү», *тийә-* «тәртип белән төяү»; кр.-тат. *tüye-* «төю, төенләп» (к. *төй-ү*). Чаг. монг. *тэгнэ-, тэңнэ-* «тигезләп төяү» ← *тэг, тэң* «тиң». К. **Тияк.** Räsänen 1969: 504; Федотов II: 227 (*төйә-* һәм *тийә-* икесе бер сүз дип карыйлар).

**Төя-** продуктив нигез: **төягеч** (машина); **төял-ү, төян-ү, төят-ү, төяш-ү** һ.б.

**ТРУБА** «труба» < рус. < лат.; *труба* хәз. техник терминологиядә кулланылса, аның этимологик дублеты *торба* көнкүреш әйберләренә карата кулланыла (*мич торбасы, самавыр торбасы*), к. ш. ук чув. *тăрпа* «лампа куыгы; торба», мар. *турба* «торба» һ.б. К. **Төрепкә.**

**ТРУЙЧЫН, труйсын,** (ТТДС II: 303) **труйсы** «Троица, Троицын день» (50–51-е дни от Пасхи) < рус.; **труйчын** бәйрәменә мәҗүси һәм христиан та-

тарлар үзләренчә мәгънә салганнар, аны **Аяу** (к.) бәйрәме белән тиңләгәннәр.

**ТУ I,** себ. (Тумашева 1992: 219) **туу, туw** «бесплодная, яловая; откормленная на убой (о кобылах)» ~ башк. *тыу* id., башк. диал. (БҺҺ III: 270; БТДҺ: 346) «чәчми үскән башсыз иген; тол (ир, хатын); кысыр чәчәк; буш; сазаган (ир, хатын)» < гом. кыпч. *ту, тув,* алт., кырг. *туу,* хак. *тоғ, туғ* «ту; аборт» – монг. *табиғу* id. ← *таба-* «азат итү, бурычтан бушату» белән чагыштырыла. Гомумән, ачык түгел.

Дерив.: к. **туак, тугар-у, туча.**

**ТУ II,** себ. (Тумашева 1992: 220) **туу** «знамя (большое, видное издали)» > мар. (Упымарий: 210) *ту* < гом. кыпч., алт. *ту, туу, тув* (асылда аермалар язылышта гына), башк. *тыу, ту*, иске тат., уйг., чыгт., госм. һ.б. *туғ,* тув. *туқ* < бор. төрки (ДТС: 584) *tuγ, tuиγ* ~ монг., маньч. һ.б. *ту, туғ* id. < бор. кыт. *tuk*, урта гасыр кытайчасындагы *dú, dao* «байрак, билге». Бу сүз тур. әдәбият ишле, к. Радлов III: 1421, 1425, 1429; Будагов I: 398 (тәфсилле); Владимирцов: 159; Ramstedt 1957: 409; Clauson: 398 (кыт. *dok* вариантыннан ди); ССТМЯ II: 202; Donuk 1988: 88 һ.б.

**Ту, туғ** «байрак» нигезендәге характерлы идиомалар: **сабан туы** «сабантуй байрагы», **ту казан** «хәрби мәҗлес, сугыш, җәң алдыннан сыйлану», **ту киңәш** «җәң алдыннан командирлар киңәше».

Төр. телендә *tuγ* «тулга (шлем) түбәсенә беркетелгән әләм (ялау)» – ул хәрбиләрнең дәрәҗәсенә күрә төрлечә булган һәм бу сүз хәрби дәрәҗә атамаларында компонент буларак кулланыла.

**ТУА: туа ят** «родственник по предкам пятого-шестого поколений» ~ башк. (киресенчә) *тыуа* «оныкның баласы; үрчем». К. ш. ук каз. (ҚТДС: 340) *туаңат* «нәбирәнең баласы – үзеңнән туган бишенче буын». **Ту-у** – бор. төрки (ДТС: 584) *tu-* «ябу, чикләү» (к. **Тугым**) сүзеннән булса кирәк. Бу **ту-** белән **ту-** «бала табу» сүзләренең үзара мөнәсәбәте ачык түгел. Туа ятлардан кыз алырга, аларга иргә чыгарга ярамаган.

**ТУАК** «выкидыш; аборт» ← **ту I** («буш, нәтиҗәсез»). Бу сүзнең бүтән мәгъ. очрый: «уйнаштан туган» яисә «ирсез бала тапкан».

**ТУАН** (Тумашева 1992: 216) «плотина» < уйг. *туған*, үзб. *туғон* id. ← **туг** (к.). Каз. (ҚТДС: 332) *тоған* «зур арык» мәгъ. үзенчәлекле.

**ТУАР,** диал. (ДС III: 152) **тывар,** (ТТДС I: 422) **туғар** «скот; скотина» < гом. кыпч., уйг. *туар, тувар,* кырг., алт. *тубар,* гом. угыз. *давар, даwар* һ.б. (ЭСТЯ III: 114) «туар; яшь терлек; үрчемгә әзер яшь терлек» – электән бирле (к. Будагов I: 741) **тавар** ~ **таwар** «товар» сүзе белән гомоген дип карала, ләкин монда күп кенә сораулар килеп туа. Чаг. **Туара I.**

Тат. телендә **туар** башлыча **мал-туар** парлы сүзендә очрый, шуңа охшаш бор. *ed-tavar* (ДТС: 162 һ.б.) «тере һәм тере түгел мөлкәт» дип аңлатыла (*ed* тур. к. **Әйбер**).

**ТУАРА I** (ТТДС I: 421) «наземные плоды картофеля, яблочки» ← **ту-у** булса кирәк, ясалышы аңлашылмый.

**ТУАРА II** «вид творога» к. **Тура II.**

**ТУБА I** (Тумашева 1992: 216) «раскаяние» ~ куман., кырг., уйг. *тоба, тооба* < кырг., уйг. *тауба* id. > чув. *топа* > *тупа* «ант». Гар. *täwбä* «тәүбә» сүзеннән булса кирәк. Федотов I: 248–249.

**ТУБА II, тубар** «утолщённый конец кости; утолщение на конце клюва птиц» ~ рус. диал. *туба* «томшык». Чаг. **тубыр.** К. **Алатуба.**

**ТУБА III** (Г. Тукай телендә) «райское (мировое) дерево» < гар. *тӯбā* id. К. мәкаль: *Туба агачына кунып сайрау* «говорить о чём-либо крайне восторженно, напыщенно». Ислам мифологиясендә *туба агачы* – баштүбән үскән агач – «Мөхәммәдия» китабында тасвирлана.

**ТУБАЛ** «кузовок, круглое лукошко», диал. (Тумашева 1992: 216) «круглый футляр, тубо» ~ башк. (БҺҺ II: 259) «тире савыт; карыннан ясалган савыт» > чув. *тупал*, манси. *topal* «тубал» < иске тат. (Гиганов 1804) *дулап* (рус. «поставец» диелә), *тулаб* «озын цилиндр рәвешендәге су савыты» (М. Ивановның «Татар хрестоматиясе» китабында шул исемендәге шигырьдә) ~ төр. *dolab, dolap* «цилиндр; түгәрәк шкаф» < фар. *доли аб* «су савыты» (ди Будагов I: 573); к. ш. ук көрд. *dolav* «орчык; вал», *dolče* «цилиндр формасындагы казанчык». *Тул* < *тол* «вал; чүлмәкчеләр чыгыры; чыгырда эшләнгән чүлмәк» төп төрки сүз булса кирәк, к. үзб. *дол* «тегермән ташы; озын барабан; әйләнмәле цилиндр, вал», бор. монг. *tolui* «диск; тәлинкә; түгәрәк көзге» ~ тунг.-маньч. *толи* id. (ССТМЯ II: 195). К. **Тулга, Тулгак, Тулган-у.** Шуның белән

бергә гар. *тубал, тубул* «зур кәрзин, тубал» сүзе дә бар. Гарәпләр төркиләрдән алганмы, юкса төркиләр алардanмы? Яки очраклы охшашлыкмы?

**Тулап > тубал** метатезасы **тубалак** «шар» сүзенең контаминацион тәэсиреннән килеп чыккан.

**ТУБАЛАК I** (ЗДС: 650) «вид пахучего растения, благовонная трава, гвоздика» ~ төр. *topalak*, (Будагов I: 385) *топалыķ* «тубалак; һинд сөмбеле». Чаг. **Тубалак III.**

**ТУБАЛАК II** себ. (ЗДС: 650) «угощение после свадьбы для тех, кто работал в организации свадьбы, а также для желающих угоститься». Чув. *туйтупалан* сүзенә караганда, мәзкүр сүзнең **Тупалан** яңгырашы да булган. Чаг. төр. *topalak, topalan* «зур түгәрәк төргәк», *toparlak* «зур йомгак»; үзб. *тўполон* «шау-шу, ыгы-зыгы». Гомумән, **тубалак** сүзен төрлечә аңлатырга мөмкин.

**ТУБАЛАК III, тумалак** «шарик на шапочке ребёнка (для отвода сглаза); шар; шаровидный» «вид растения» (у К. Насыри «гвоздика») > чув. *тупалак* «канәфер», нуг. *топалак* «хушисле борчак» ~ төр., кр.-тат. *tupalak* «үзеннән төймәләр, талисманнар ясала торган чикләвек» (к. Будагов I: 742), кар., чыгт., госм. *тумалак, тумбалак*, кырг. *томолоķ* «шарсыман, түгәрәк, йомры; шар» һ.б. ← (нуг., кар. һ.б.) *топал, тобал* «йомры, шарсыман очлык; шар, йомарлак, йомгак» – *туп* < *топ, томп* тамырыннан, к. **Туп, Тупал.**

Бу сүзнең төрле чәчәк, үсемлек атамасы булуы шундый үсемлекләрнең күзсендерүдән саклагыч итеп файдаланылуыннан булса кирәк.

**ТУБЫК** «коленная чашечка; лодыжка» (в разных говорах по-разному) > мар. (Исанбаев 1978: 17) *товык* «тез капкачы» < гом. кыпч. *тобыķ, тобуķ,* уйг., тув. *тобуķ,* кырг., алт. *томуķ,* хак. *томых*, хак., алт. диал. *томаķ, томах* «тубык, бәкәл сөяге», чыгт., госм. *тобык*, госм., төр. *topuq, topuk*, бор. төрки (ДТС: 569) *topïq* «тубык; тез; үкчә; шар, туп» ← *топ* «туп, тумпаеп торган нәрсә»; чаг. ш. ук як. *табык, тамыķ* ~ *тобуķ* «тез бөгеме» ~ маньч. (ССТМЯ II: 189) *тобго* «тез, тубык», алт. *тобого* «түгәрәк шеш», бур. *тобхо* «түгәрәк кабарынкылык, үкчә һ.б.ш.» К. **Тубырчык, Тупак.**

Дерив.: диал. **тубыклан-у** «тезләнү».

**ТУБЫЛГЫ,** (ДС II: 260; ТТДС I: 145; ЗДС: 650) **тубылгай, тубылгый, тубылдык** «таволга (растение)» – бармак юанлыгы матур һәм каты сабагы булган күпьеллык үсемлек, шуннан кирәкле таякчыклар (боргычлар һ.б.), уклар, уенчык савытлар һ.б. ясаганнар ~ башк. (БТДҺ: 332) *тубылға*, чув. *тупӑлкан*, *тупӑлхӑ*, *тупалхӑ* «тубылгы», *алӑл тӑпӑлхи* «ишек күгәне» (тубылгыдан ясалгангамы?), морд. *дуболго,* удм. *тубылгы,* мар. *тоболго,* «тубылгы, нугай камчысы (нагайка)» – бу соңгы мәгъ. тубылгыдан камчы сабы ясаудан килә ди К. Насыйри (ЛТ I: 11–12), мар. (Упымарий: 205; Исанбаев 1978: 23) *товылго* «волжанка (вид мелкой ивы)» диелгән < гом. кыпч. *тобылғы,* кырг. *тобулғу* «тубылгы», төр. *tabulga* «кызылтал» < бор. төрки (ДТС: 569–575) *tobulγaq,* (Р. Рәхмәти-Арат) «кипарис», *topulγaq* «мирт», як. *тобулуоскай* «тубылгы; зелпе» – барча бу сүзләрнең нигезе себ. (Тумашева 1992: 213) **тōбыл: тōбыл агацы** «тубылгы». Шуннан ук **Тубыл** елгасының атамасы килә диләр. Кайбер тат. сөйл. (ТТДС II: 303) **тубылғы** «тупыл» – әлбәттә, ялгыш атама.

Бу сүзнең беренче иҗектә *-а-* булган варианты киң таралган: чыгт. *табулғу,* кырг. *табылғы,* уйг. *табылķы*, алт. *табылғы,* шор. *табылķа,* госм. *тапылға, табулға* ~ бор. төрки (Clauson: 441) *tavılqu, tavılγuč* ~ монг. *табилха* – төрле үсемлек атамалары. Ниһаять *-л-* > *-р-* вариантлары да бар: ком. *табурғу*, тат. (к. Насыйри сүзлегендә) **тәбәрхун** < госм. (Zenker: 252) *teberhun,* фар. *тубурхан* «тубылгы; чыбыркы сабы; (кызыл төстәге) эстафета таягы; куе кызыл төс; эстрагон», к. ш. ук бур., монг. *табилгана, тавилга(на)*, яз. монг. *tabilxa* «тубылгы» һ.б. (күпмәгънәле сүз).

**Тубыл** < *тобул* тамырының чыгыш-ясалышы караңгы. Морфологик җәһәттән нинидидер *тобул-* фигыленнән (**топ-* тамырыннан) шикелле, чаг. башк. (БТДҺ: 332) *тубылғы-у* «куерып үсү», гүяки **туб-ыл-у**дан. Будагов I: 328; Räsänen 1969: 452; Жаримбетов: 160; Федотов II: 251; Дмитриева 1980: 63–64 (сүзнең тамыры **tabi* ди). К. ш. ук рус. (Аникин: 520) *табурка* «кечкенә ныклы агач деталь» (күптөрле аерым мәгъ. күрсәтелә).

**ТУБЫР** «желвак (на ноге лошади); уплотнение на теле; плотная шишка (на стволе дерева)» ~ башк. *тубар* id. < гом. төрки сүз булса кирәк, к. шор., хак. *тобыр* «кыска, йомры (нәрсә)», каз., үзб. *тобыр, тобур* «туплам, тупар» һ.б. К. түбәндәгене.

**ТУБЫРЧЫК,** диал. (Будагов I: 384, 742; Радлов III: 1515; Тумашева 1992: 216) **тубырцык, тубырцык** «кусок (спиленного и т.п.) дерева как под-

кладка, клинышек» > чув. *тупăрчăк,* мар. диал. *тувырчык* id. < гом. кыпч., к. башк. *тубырсыҡ* id., куман. (Радлов III: 1224) *топурчаҡ* «йомры, түгәрәк», каз. *тобыршық, тобуршуқ,* тув. *довуршақ,* шор., хак., алт. диал. *тобырчыҡ* «терескәк, терлекнең арт аягы бөгемендәге төер, тубыр» ~ кырг. *тобурчаҡ* «(ява торган) боз», як. *чуорчах, чүөччäх* ~ монг. *тогурчаг* > *тоорцок* «тубалак, тумалак; тубырчык» һ.б. ← *тубыр* < *тобур* (к. **Тубыр**) тамырыннан, әлбәттә. Чаг. себ. (Тумашева 1992: 216) **тубырцын** «ашык, тубык». Тат. (ТТДС I: 242) **тубырсыҡ, тупырсыҡ** «йомры һәм нык гәүдәле (балалар һәм кызлар тур.)» сүзе дә икенчерәк төрле ясалган булса кирәк (монда *-сык* кушымчасы кечерәйтү кушымчасы *-чык*ның фонетик варианты түгел). Ләкин монда контаминацияләр бар.

**Тубырчык ~ тубырчак** нигезеннән кыскарып **Тупчак** (к.) һәм диал. **турчык** «цилиндрсыман деталь» сүзләре ясалган (к. Аникин: 557–558, рус. *торсык* тур). Шуны да әйтик – *тубырчык* сүзенә охшаш нигезләр (мәс., **тубылчык, тупырсык** һ.б.) барысы да тамырдаш түгел.

**ТУГ** иск. «запруда, кляп и т.п., всё то, что прекращает или тормозит течение, движение» < үзб., уйг. *туғ, тоғ* id. К. **Тугнак**. Чаг. түбәндәгене.

**ТУГА** (БТДҺ: 332) «кольцо (в роли пряжки), простейшая пряжка» < каз., кырг. һ.б. *тоға* < бор. төрки (куман., төр.) *toqa, toka* id. К. ш. ук к.-балк. *тоғай,* чув. *тăха* «каеш каптыргычы». Räsänen 1969: 485.

**ТУГАВЫЛ [тугаwы̆л]** диал. «аллитерационный стих; сказка, рассказываемая таким стихом для детей» < **тулгаwыл**, к. **Тулга-у**. Чаг. тув. *тоол* < монг. *тоол, тогол, тууль* < бор. монг. *toγul* «тугавыл; эпос».

**ТУГАЙ** «поёмный луг, тугай» < гом. кыпч. *тоғай* «тугай, әрәмә, тугайдагы урман», кырг., алт., чыгт. (Радлов III: 1147, 1158) *тоғай, тоқай* «елга буендагы, елга утрауларындагы урман» < монг. *тохой, тоқой* > эвенк. *тоғой* «елга бөгелеше; терсәк; дугай» ← *тохи-, тоқи-* «бөгелү»; к. к.-балк. *тоғай* «түгәрәк, алка, әйләнә, ярымәйләнә һ.б.ш.»

Бу тамырдан бор. *тоқай* > *туқай* «җәя» сүзе дә килә. К. ш. ук **Тугым.**

*Тугай* сүзенең «елга бөгелеше» мәгъ. тат. сөйләшләрендә дә бар бугай, башк. *туғайлан-у* «(елга) бөгелү», к. мар. (Упымарий: 205) *тоғай* «елга култыгы», чув. (Сергеев 1968: 73) *тухай* «тоба» < тат. К. **Дугай.**

Бу сүз тур. күп язылган, к. Будагов I: 398, 808; Räsänen 1969: 485; ССТМЯ II: 190; Мурзаев 1984: 559, 561; Аникин: 558.

**ТУГАЛАК, туғылаҡ** (ЗДС: 651, 652, 654) «с кругленьким телом, полный» ~ башк. *туғалаҡ*, каз. *тоғалаҡ*, кырг. *тоголоҡ* «шарсыман» ← кырг. *тоголо-* «тәгәрәү, тәгәрәтү» ← **тоға*. Чаг. **Туган II, Тугар II, Тугач, Түгәрәк**.

Кыргызларда *тоголоҡ молдо* «юан мулла» дигән мәшһүр чичән булган.

**ТУГАН I** «родной (брат или сестра); младший (брат или сестра)» > удм., мар., морд. *дуган, туган,* чув. *тăван*, мар. (Саваткова: 163) *туан* id. < гом. кыпч., алт. *туған, тувған, тууған* id. (мәгъ. үзгәрешләре бер-берсеннән чыга һәм аларны аерым күрсәтү әллә ни бирми), төркм. (һ.б. угыз) *доған* «бертуган» һ.б. (ЭСТЯ III: 245); *ту-* < *тоғ-* белән баглы, ләкин бу сүзне һич кенә дә турыдантуры *туган* – үткән заман фигыль формасы белән бәйләргә ярамый, к. уйг. *туққан*, үзб. *туғқон* «туган», ягъни сүз *туғ* һәм *қан* морфемаларына бүленә. Ихтимал, бу сүз бор. төрки **тоғ* «абый яисә эне» (к. төр. диал. *dog* id., бу тур. ЭСТЯ III: 246) сүзенә монг. *-қан* ~ тат. *-кай* иркәләү кушымчасы ялганып ясалгандыр, к. морд. *дугай, дуги* «туганкай, сеңелкәш» (< бор. төрки).

Будагов I: 748; Покровская 1961: 43–47; Räsänen 1969: 483; Федотов II: 183; Рамазанова 1991: 146–148 (бу әсәрләрнең берсендә дә тирән этимология юк).

**Туган** продуктив нигез: **туганлы, туганлык, туганлаш-у, тугандаш, туганнарча, туганчыл** һ.б., башк. *туғанаҡ* «гомумән туган-кардәш хөкемендәге кеше».

**ТУГАН II, туғаң** «вид сокола» < уйг. *тоған,* чыгт. *тоғаң,* бор. төрки (ДТС: 571) *toγan* > төр. һ.б. угыз. *dogan,* добр. *toğan* «лачын; кыю, батыр». Рясянен (Räsänen 1969: 483) чыгт. *тойғын, туйғар* (к. **Тургай**) сүзләре белән чагыштыра.

Бу сүзне эмиграциядәге кайбер татар-башкорт егетләре фамилия итеп алганнар, мәс., *Зәки Вәлиди-Тоган (Туган).*

**ТУГАНЫЙ** «невестка с золовкой в отношении друг-друга» (Рамазанова 1991: 128) < *туганай* (туган сүзенең эндәшү формасы).

ЗДСта (: 651) **туганай, тугани, туганый** яңгырашларына төрле мәгънәләр бирелә. Гомумән, **туганый** сүзе катлаулы, төрле нигезләрдән контаминацияләнгән булса кирәк. К. югарыдагыны.

**ТУГАР I** (ЗДС: 651) «животное». **Туар** (к.) белән бердәй бугай.

**ТУГАР II: тугарлан-у** (Тумашева 1992: 217) «округляться», (ЗДС: 651) «катиться». Чаг. **дүңгәләк, түгәрәк** һ.б. (шуларның веляр варианты булса кирәк).

**ТУГАР-У,** гом. диал. **туар-у** «распрягать» > мар. (Иванов, Тужаров: 225) *тугар-* (Саваткова: 164) *туар-,* чув. *тăвар-,* хант. *тоwар-* < гом. кыпч. *туғар-, тувар-, туар-*, чыгт., каз. (Радлов III: 1159), *тоғар-,* каз. диал. *доғар-,* кырг. *тоғор-* «тугару; үз бурычыңны бүтәнгә тапшыру; азат булу» ← *ту* «буш, азат» (к. **Ту I**); венг. *tobart-* «тугару» < болг.

Räsänen 1969: 483; Федотов II: 184 (бу авторларда без биргән аңлатма юк).

**Туғар-** продуктив нигез: **тугарыл-у, тугарын-у** (аерым үзенчәлекле мәгъ.), **тугарыш-у, тугарт-у.**

**ТУГАЧ,** диал. (ЗДС: 651, 654) **тукач,** (Тумашева 1992: 217) **туғац,** (Рамазанова 2001: 133) **тоғач,** (Арсланов 1988: 95) **тоғаш** «сушки, бублики» ~ каз. (ҚТДС: 332) *тоғаш*, кырг. *тоқач*, уйг. *тоғач, тоқач* id. < бор. төрки (ДТС: 577) *toquč* «көләчә». Аръягы ачык түгел.

**ТУГНАК** (Гиганов; Тумашева 1992: 217), (Будагов I: 399) **туғанак** «засов; заслонка, защёлка» < уйг. *туғанақ,* уйг., гом. кыпч., чыгт. *тоғанақ* «киртә, эшерге; бау башындагы зур төен (берәр ярык, тишек аша үтмәсенгә)» ← *туған, тоған* «нинди дә булса хәрәкәт юлындагы киртә, бөке һ.б.» ← бор. төрки, иске тат. *tuγ* «киртә, бик һ.б.». К. **Туан, Туг, Туга.**

**ТУГРА** (Будагов I: 737) «печать монарха (состоящая из замысловатой монограммы из арабских буквенных начертаний)» < бор. төрки (МК; ДТС: 584) *tuγraγ* «хан мөһере; фәрман; тугра». Бу сүзне төрлечә аңлаталар: берәүләречә (Zenker: 600), бор. төрки *тургай* «торгай, торсын, булсын», икенчеләрчә, уйг. *туғра* «туры, дөрес» сүзеннән имеш. Төркиләрдә **туғра** сүзенең гарәпчә эквиваленты *тäwқи‘* сүзе дә кулланылган (к. Будагов I: 400), бу сүз исә *вакыйга* белән тамырдаш, шуннан чыгып фикерләгәндә, Т. Ценкер фаразы кабат искә төшә. Ләкин төр. *tugra, tura* «тугра; ефәк корты курчагыннан алынган беренчел ефәк йомгагы; катлаулы вензель; спираль; камчы» (ягъни бик конкрет мәгъ. сүзләр), бор. төрки *tuγraγlan-* «хәрби ат алу (яшь солдат тур.)» – «хәрби камчы алу»мы? К. Мухамедова 1973: 175. **Тургай** сүзе белән чагыштыру да очрый (тугра очкан кош рәвешендә языла). Добр. (Dobr. III: 373) *tugra* сүзенең *tura, tugraq, taraq* (?) вариантларын күрсәтә. **Тугра** дип тәңкәләрнең язусыз тарафын да атаганнар.

Дерив.: **тугралы, туграсыз;** иске тат. **туграwи, туграи** «династиягә баглы; династияне, зат-нәселне нигезләүче» (**туграwи ата** «шәҗәрә башындагы ата», **туграwи ана** «шәҗәрә башындагы ана»).

**ТУГРЫ** «верный, преданный, правильный» < чыгт. *тоғры, тоғру,* угыз. *доғру,* уйг., үзб. *туғри, туғра,* башк. *тоғро, туғыры* һ.б. «туры». К. **Туры.**

Дерив.: **тугрылык;** иске тат. **тугрыла-у;** Л. Будагов (I: 747–748) башк. (?) *туғрымақ* «дөресләп тикшерү» һәм шуннан ясалган *туғрылтмақ* «дөресләмәк» фигыльләрен китерә.

**ТУГЫЗ** «девять» < гом. кыпч. *тоғыҙ* < *тоғуз,* башк. *туғыҙ,* гом. төрки *тоғуз, тоқуз, тоққуз, доқуз* < **токург* id. > чув. *тăхăр* id., к. ш. ук рус. *тахъръ* «тугызлык; дистә» (Срезневский III: 929) болг. теленнән.

Безнеңчә, бу сүз бор. *тоқ козу* «көзге бәрән» (к. *сэк қозу* «язгы бәрән» > *сэккиз* «сигез») сүзеннән: шулай дип ашык сөягенең тугызынчы почмагын – мөешен атаганнар (гомумән, һәр мөеш-чыгынты берәр терлек-хайван исеме белән аталган – бу хәл монгол халыкларында яхшырак сакланган); балалар ашык сөягенең мөешләрен атап, санарга өйрәнгәннәр. Һәрхәлдә, *сигез* һәм *тугыз* сүзләренең бер модельдә ясалганлыгы бәхәссез, к. Ахметьянов 1988.

**Тугыз** сүзе төрки халыкларда күпмәгънәле: туй бүләкләренең саны (һәм төре дә) тугыз булган һәм бу сүз белән гомумән туй бүләкләре комплектын, тугыз көнлек бор. атнаны атаганнар; турфан уйгурларында *тоқуз* «сансыз; тугыз яшьлек», як. *тогусун* «тугыз» (Пекарский: 2713). К. **Тугызак, Туксан.**

**Тугыз** сүзе тур. төркиятта күп язылган, к. Будагов I: 750 (тәфсилле), ЭСТЯ III: 255–256 (шунда ук әдәбият); Федотов II: 202–203.

**Тугыз** – «тылсымлы» саннарның берсе һәм саннар арасында аеруча продуктив нигезләрдән: **тугызлы, тугызсыз; тугызлык** (төрле мәгъ.)**; ту-**

**гызла-у**; аерым мәгънәгә ия сүзтезмәләр: **тугыз-бармак** (ТХИ: Әкиятләр I: 266) явыз рух-юлбасар исеме; **тугыз комалак** (~ госм., аз. *доқурҗин* ~ төр. *dokurcun*) ике уенчы түгәрәк тактадагы унсигез уемга сиксән бер (9 × 9) ташны билгеле бер кагыйдә буенча урнаштыруга корылган уен (һәрбер ташның үзенең билгесе һәм исеме булган); **тугыз-төймә** – «акылга таман»; **тугыз турка** «кабарып торган катлы-катлы кием», «киная һәм мыскыл итүне аңламаучан кеше»; **тугыздан калган тукаби** «иң соңгы бала». **Тугыз < токуз** сүзеннән бор. төрле этнонимнар ясалган: **токуз окуз, токуз огул, токуз татар, токуз уйгур** һ.б.

**ТУГЫЗАК, тугзак** «столетний (о человеке), одинокий в старости» ~ к.-балк. *тоғузақ* «тугызынчы; тугызлык», каз., үзб. һ.б. *тоқузақ, туқузақ* – найман кабиләсенең бер ыруы; әкияти батыр яки әби исеме, кырг. *тоғузақ* «үз балаңны сатып алу» (балалары үлә барган кеше явыз рухларны алдар өчен үз баласын сатып алгандай булып кыланган – урамнан, тәрәзәдән кертеп алган һ.б.). *Тугызак-*, *туғыз* < *тоққуз* сүзеннән, әлбәттә, ләкин ясалыш мотивлары аңлашылып бетми.

**ТУГЫЗЛЫК** – комплект свадебного подарка у тюркских народов (состоящий из девяти предметов)». К. Карагёз Х. Старинный обычай татарского заручения свадьбы // Забвению не подлежит. Казань, 1992: 227.

**ТУГЫЛА-У, тугла-у** «взбалтывать (ложкой), размешивать» ← **тугы-у, тукы-у** (ДС II: 158; ДС III: 159) id. сүзенең интенсивлык формасы < чыгт. *тоғу-*, уйг. диал. *тоқы-* id. **Тукы-у** (к.) белән бердәй булса кирәк. Räsänen 1969: 483 (чулым. *тоғла-* «туглау» сүзен кырг. *тоғолоқ,* каз. *доғолақ* «йомры; тулымга» сүзләре белән чагыштыра, безнеңчә, бу дөрес түгел).

Дерив.: **туғым** «терлек өчен боламык» (БТДҺ: 333, асылда татарчадан); **туглавыч.**

**ТУГЫМ I, туғын,** (ЗДС: 17, 652) **дуғым, тугун** «обойма; обод колеса», диал. «карусель» > мар. *тогым*, удм. (Насибуллин: 140) *тугъм,* чув. *тукăн* «тәгәрмәч тугымы» < гом. кыпч., үзб., уйг. *тогун* (> нуг., каз., к-калп. *тоғын*) id., каз. *тоғун* «тирмә төннегенең коршавы, тирәче» ~ монг. *тохом* «тугым» ← *тохо-* «иярләү; ияр каешын атның корсагыннан уратып бәйләү» < бор. төрки **тоқу-* «уратып алу» булса кирәк. К. ш. ук маньч. (ССТМЯ II: 192) *тохоро* «тугым». Чаг. *дугуй* «бөҗра, тәгәрмәч». Як. *токай-* «бөгелү, бөгелгәләнү» һ.б. Чаг. түбәндәгене.

Дерив.: **тугымлы, тугымсыз; тугымла-у.** К. ш. ук **Тогалак, Тугар.**

**ТУГЫМ II, тукым** «потник (лошади)» < гом. кыпч., к. нуг., каз. *тоғым*, кырг., алт. *тоқум* ~ яз. монг. *toqum* id. ← алт. һ.б. *тоқы-*, уйг. (Радлов III: 1149–1150) *тоқу-* «ат аркасына тугым салу» ~ монг. *тохо-,* яз. монг. (Поппе 1938: 448) *toүu-, toqu-,* тунг.-маньч. *тохо-, току-* «тукым салу, тукымлау, иярләү». Рус. диал. *тукум* «тукым» тур. Аникин: 562 (шунда ук әдәбият).

**ТУГЫШ,** (Тумашева 1992: 213) **тōғуш** «годовалый лосёнок; годовалый козлёнок (оленёнок)» ~ тув. *тош* < *тоош* «бер яшьлек марал» ~ төр. диал. *doүuş* «кечкенә колаклы кәҗә»; бу сүзнең параллельләре рус (Себер) сөйләшләрендә яхшырак сакланган: *тогуш, токуш, тугаш, тыгаш* «бер яшьлек пошый», к. Аникин: 548–549 (А.Е. Аникин бу сүзне **тукал, туклы** сүзләре белән чагыштыра һәм ахыр чиктә *ту-, туғу-* «тудыру» сүзенә кайтарып калдыра). Безнеңчә, **тугыш туклы** (к.) сүзе белән тамырдаш һәм бор. төрки *toq* «мүкләк, мөгезсез» тамырыннан ясалган.

Тат.-башк. **тугыш** дигән ялгызлык исемнәре (антропоним, этноним) еш кына очрый.

**ТУДЫК** «двоюродный» < гом. кыпч. *туудуқ* (нуг., каз. *туўдық*) id., кырг. *туунду* «икенчел». Кайбер төрки телләрдә бу сүз хатын-кызларга гына карый; тат. бу очракта *тудыка* сүзен кулланалар (Рамазанова 1991: 86, 151–152, тәфсилле). Мөгаен, *ту-у* фигыленнәндер. Чаг. **Тума.**

**ТУЕЗ [туйыз]** «береста; берестяное ведёрко» ~ башк. *төйөҫ* < рус. *туез, туйис* < коми. **тойис* «туз савыт» ← бор. перм. *toj* > удм. *туй* «туз». Рус теленнән бу сүз бик күп Себер телләренә таралган (к. Аникин: 560–561, шунда ук бай әдәбият китерелә). **Туз** сүзе белән турыдан-туры бәйләнмаган булып чыга. К. ш. ук Лыткин: 176–180.

Мәзкүр авторлар тат., башк. мисалларын искә алмыйлар. Хәлбуки тат. *туйыз,* башк. *туйыҙ* ~ каз. *тойаз* «туз» ~ бур. *туйсэ* һ.б. этимологияне тагын да тирәнәйтә торган мисаллар. К. **Туз.**

**ТУЗ I** «туз» < рус. < фр. < лат. *duos* «икеле» сүзенә кайтып кала, к. Фасмер IV: 115.

**ТУЗ II** «береста», диал. **туйыз** id. (к. **Туез**) < гом. кыпч., чыгт., уйг. *тоз*, алт., чыгт., бор. төрки (Радлов III: 1207) *тос* id. < бор. төрки (ДТС: 579) *toz* «туз; җәя савыты, садак», к. ш. ук чулым. *тус*, як. *туос* ~ монг. *тоос, тоус* һ.б. «туз», госм. *toz* «тупыл» ~ бор. төрки *toyraq* «тупыл» (? к. Räsänen 1969: 492). Безгә калса, *туз* < *тоз* сүзе бор. **торс* «каен орысы» сүзеннән дә булырга мөмкин, к. кырг. *тоз* «каен орысы». Чаг. **Тустак.**

Бор. Шәрыктә язу материалы буларак *тууз* киң билгеле булган, бу сүз тузны да, бүтән кайбер агач кайрыларын да белдергән (к. Бируни 1995: 598). Г. Хәйям әсәрләрендә *туз* «агач юкәсеннән ясалган бинт». *Туз* кәгазь урынына Алтын Урдада, бор. Русьтә һ.б. кулланылган, шуннан *тузга язу* тәгъбире килә диләр.

**ТУЗАН** «пыль» > чув. *тусан*, мар. *тозан*, удм. *тузон* < гом. кыпч. *тозан, тозаң* (кырг. *тозоң*) «вак тузан» (**чаң** «эре куе тузан»нан үзгә буларак), алт., шор., хак. *тозун, тозын* «тузан», тув. *доозун* «тузан йомгаклары» ~ монг. *тоғураг* «тузан» һ.б. Бор. этимон – **тоозғун* < **тоғур-ғуң* «тузан булып күтәрелгән (нәрсә)» булса кирәк, *туз-* < *тооз* < **тоғур-* «сүзеннән», к. **Туз-у, Туфрак.**

Федотов II: 255 (тат. сүзен искә алмый, чув. *тусан, тосан* (?) сүзен *тос-ан* (ягъни чув. телендә) ясалган дип аңлата, ә мар. һәм удм. сүзләрен «төрки телдән» дип кенә характерлый).

**ТУЗГАНАК** «одуванчик», чаг. башк. *туҙғаҡ, туҙғаҡбаш* id. (БТДҺ: 333 һ.б.) ~ уйг., к.-калп., чыгт. *тозғақ* < бор. төрки *tozγaq* «чәчәк мамыгы; камыш чәчәге». Тат. *тузғанақ* < *тузғын-ақ* булса кирәк, к. **Тузгын.**

**ТУЗГЫН** «растрёпанный; разворошенный; беспорядочный» *тузғы-у* фигыленнән дә, *туз-у* фигыленнән дә ясала ала.

**ТУЗГЫ-У** «растрепаться (на ветру); взъерошиться; подняться (о пыли чего-либо на ветру)» ← *туз-у*; *тузгы-у* фигыленең параллельләре бүтән төрки сүзлекләрдә күренми. Гомумән, *тузгы-* < *тузык- (тузыгу).*

**ТУЗ-У** «подняться (о пыли); растрепаться; изнашиваться (об одежде); вспылить, разгорячиться, скандалить» (последнее значение чаще употребляется в составе идиомы *пыр туз-у*) > чув. *тус-*, удм. *туз-*, мар. *тоз-* id. < гом. кыпч., чыгт., уйг. *тоз-* < бор. төрки *toz-* > алт. *тос-* id. Бу фигыльнең исем коррелянты кар., кырг., каз., к.-калп., госм., бор. төрки *toz* < (Gabain 1950: 343) *tooz-* «тузан, порошок» киң таралган. Безнеңчә, *тоз-* < *тооз-* **towur-* < *toγur* // *тоғур-* «туфрак булу» (**tobur* «туфрак; тузан») сүзеннән, *тоғ* (к. Радлов III: 1158) «тузан, туфрак» тамырыннан. Федотов II: 255–256.

Кайбер кыпч. телләрендә (к.-балк., ком.) *тоз-* күчемле фигыль: «туздыру».

**Туз-** тат. телендә аеруча продуктив нигез: **тузыл-у, тузын-у, тузыш-у (пыр тузыш-у), туздыр-у,** диал. (ТТДС I: 423) **тузымтык** «чүпрәк-чапрак» һ.б.; к. **Тузан, Тузганак, Тузгын, Тузгы-у.**

**ТУЗЫК, тусык** (Тумашева 1992: 219) «изношенный» ~ кырг. *тозуқ* ← *туз-* < *тоз-*. К. **Туз-у.**

**ТУЙ** «свадьба; торжество» < гом. төрки *туй* < *той* (угыз. *дой*) id. бор. төрки (ДТС: 572) *toj* «тантана, сыйлану», ш. ук «ирәк (ставка, резиденция)», «талпа», «шәһәр» һ.б. Бу сүз «туй» мәгъ. күп күрше телләргә (монг., фин-угор һ.б.) кергән. Шул ук вакытта кайбер төрки телләрдә (мәс., төр.) бу сүз сирәк кулланыла. Будагов I: 754.

*Туй* сүзенең чыгышы бик үк ачык түгел. Аны *туй-у* һәм *тук* сүзләре белән баглау (к. ЭСТЯ III: 251–253) өстәмә дәлилләр сорый. Räsänen 1969: 414, 488; Федотов II: 241–242; рус. диал. *той* тур. Аникин: 549; Тимергалин: 479 (кызыклы мәгълүматлар).

**Туй** продуктив нигез: **туйла-у, туйчы.**

**ТУЙРА, туера** (ЗДС: 654, гомумән киң таралган) «дуб, молодой дуб; кустарник, ростки деревьев; кора липы; пень, пенёк с ростками; гриб-трутовик; жёлудь» > чув., мар. (Вершинин: 568) *тойра, туйра,* удм. *туйыро* «яшь имәннәр; карт агач төпләреннән үсеп чыккан бәбәкләр» ~ чыгт. *турақ,* бор. төрки (ДТС: 571) *toγraq* «тупыл», *toγraγu* «сумала», безнеңчә, **торaңгы** (к.) сүзе белән тамырдаш һәм бор. **тоғ* «сумала» сүзеннән килә, к. Әхмәтьянов 2001: 210.

**ТУЙ-У** «насытиться» < гом. кыпч., уйг. *той-,* угыз. *дой-,* уйг. диал. *тод-,* тув., як. *тот-* < бор. төрки (ДТС: 569–572, 578) *tod-, toj-, tot-, toδ-* > хак., шор. *тос-* id. Бу фонетик вариантларның бор. уртак нигезе **tor-* булса кирәк, к. чув. *тăран-* «туену» ← **тăр-* «тую». Бор. **tor-//тор-* нигезе, үз чиратында, бор. *to-//то-* «бөялү; буылу» сүзеннән булса кирәк, шуннан ук к. **Тук, Тукта-у, Тул-у.**

К. Будагов I: 749; ЭСТЯ III: 251–253; Федотов II: 195–196 (шуларда ук – әдәбият).

Дерив.: **туел-у, туен-у, туеш-у; туйдыр-у** (бу нигезләрдән күп кенә икенчел нигезләр ясала).

**ТУК I (тук-тук) –** подражание стуку (чаще употребляется в редупликативной форме) – дөньядагы барча телләрдә очраучан тәкълидизи тамыр (чаг. рус. *тук*, индонез. *tuk* «тук»); татарча йомшаграк тукылдауны **түк** *(түк-түк)* дип тә атыйлар; гомумән, *тук* тәкълидизи сүзе *так (так-так), тык (тык-тык), тек (тек-тек)* тәкълидизи сүзләренә аваздаш, гомоген һәм өлешчә мәгънәдәш: боларда ниндидер зур бер каты нәрсәгә кечкенә бер каты нәрсә бәрелү авазы белдерелә.

*Тук//так//тык//тек* тәкълидизи тамыры этимологик чагыштырулар өчен ышанычсыз материал, чөнки бу сүзләр һәр телдә, һәр чорда яңадан барлыкка килә алалар, чаг. рус. *тук-тук* һ.б. Әмма бу тамырдан (тамырлардан диярге була) ясалган сүзләрнең кайберләре этимологик тотрыклы, мәс., **тукылда-у, тукылдык** (тат. **Тукылдык** ~ чув. *Тукăлтăк* дигән әкият персонажы да бар) шундыйлар.

**Тук** тамырына **тукы-у** фигыле (һәм аның дериватлары) тоташа.

**ТУК II** «сыт, сытый; полный, тучный (о колосьях)» > мар. *ток* < гом. кыпч., уйг. *тоқ,* гом. угыз. *доқ,* як. *том* ~ чув. *тутă* id. – бор. төрки һ.б. *toq- ~ tog- ~ tot-* «тую» фигыленең (к. **Туй-у**) исем коррелянты яисә бор. **to-* «тук булу» фигыленең үзеннән ясалган, к. ЭСТЯ III: 251–252. Рус. *тук* (шуннан *тучный* «симез») «көрлек, май» сүзе белән охшашлык очраклы булса кирәк.

Дерив.: **туклык, туклан-у; тугай-у.**

**ТУКАЛ** (ТТДС II: 305) «комолая, безрогая; младшая жена (при многожёнстве)»; мондагы сәер мәгъ. күчеше шуның белән аңлатыла: иң яшь хатын **бичә** (беренче хатын) һәм **чичә** (икенче хатын) алдында мөгезсез сыер кебек ярдәмсез кала, к. бу тур. Радлов III: 1148 (чаг. ш. ук **Тукмык**). Гом. кыпч.: нуг., к.-балк., каз., уйг. һ.б. *тоқал*, кырг. *тоқол* «мөгезсез» сүзе бор. төрки (ДТС: 576) *toq* «мөгезсез» < кыт. *tu* < *thog* «мүкләк» тамырыннан, монг. телләрендә ясалган булса кирәк, к. монг., бур. *тугал*, монг. *тукул* «бозау» >> як. *тугут ~ тубут* «болан бозавы» ~ эвенк. *тукучэн* id., рус. диал. (Аникин: 560) *тугут* «болан бозавы; болан бозавы тиресеннән эшләнгән бүрек», к. ш. ук (Будагов I: 572) *доғал, доқмал* «башына ук урынына шарчык куелган ук сабагы». Pritsak: 208–214.

К. **Тугыз, Тугыш, Туклы, Тукмык.**

**ТУКАН I** (Ахмаров 1907: 18) «цапля» < *кутан* id., к. каз. *тоқан ~ қотан* (*көк қотан*) id. чыгт. (Будагов II: 85) *қотан* «бабакош» ~ монг. *хутан*, маньч. *қотан* id. >> венг. *guden* id. (Gombocz: 71–73).

**ТУКАН II** (Будагов I: 486) «чижик (игра)» – **тукан I** сүзеннән микән.

**ТУКАНЛА-У, туканна-у** (ТТДС I: 421) «ходить на четвереньках», (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «бегать, прыгая то на одной, то на другой ноге», башк. (БТДҺ: 334) *туканна-* «бер бату, бер калку» ***тунка** сүзеннән, к. диал. (ЗДС: 657) **туңканна-у** «мүкәләү, бүкәйләү». Чаг. ш. ук тунг. (ССТМЯ I: 213) *доколо-,* монг. *доголо-* «чатанлау». К. **Туңкай.**

**ТУКАТ-У** (З. Бәшири) «снимать порчу» < чув. *тука ту* «дога кылу; сихерләү» (к. Ашмарин Н.И. Материалы для исследования чувашского языка. Казань, 1898: 105).

**ТУКЛЫ** (Будагов I: 399; Тумашева 1992: 217) «овца, которая ещё не ягнилась, ярка» (ТТДС II: 305) «годовалый (о любом виде скота)» < гом. кыпч., к. нуг., к.-калп., ком., төркм. *тоқлы*, уйг., гаг., төр., аз. *тоқлу, тоғлу*, тув. *тоғду,* каз. *тохто, туқту, тоқты,* кырг. *тоқту* < бор. төрки (ДТС: 577) *toqlu* «алты айлык бәрән; көзге бәрән», безнеңчә, **тукал** сүзе белән тамырдаш, к. рус. диал. (Аникин: 539) *тохтун* «бер яшьтән ике яшькә кадәрге бәрән, кучкар» (яз. монг. *tuyul* «бозау» сүзе белән чагыштырыла). Сүзнең тамыры – бор. төрки *тоқ, тоғ ~* бор. кыт. *thog* «мүкләк; әлегә мөгезсез». З. Мухамедова (1973: 170) урта төрки *тоқлы, тоқли < тоқлуқ < токлуғ* сүзен *тоқ* «тук» сүзеннән димәкче. Безнеңчә, мондый аңлатма семантик җәһәттән ышандырырлык түгел, чөнки каз. сөйләшләрендә *тоқ* үзе генә дә «мөгезсез бәрән» дигән сүз, к. **Тугыз, Тугыш, Тукал.** К. ш. ук Räsänen 1969: 485.

**ТУКМАК** «колотушка; дубинка» (төрле мәгъ. тур. к. ТТДС I: 421; Тумашева 1992: 217) > мар., чув. *тукмак, токмак* id., ш. ук «тупа (очы йомры)» < гом. кыпч., уйг. *тоқмақ* (нуг., каз., к.-калп. *тоқпақ,* алт. *токпоқ,* кырг. *тоқмоқ*), тув. *докпак ~* бор. төркм. (Мухамедова 1973: 88–89) *доқмақ,* хәз. төркм. *тоқмақ* < бор. төрки (ДТС: 576) *toqïtaq* id.,

ш. ук «агач чүкеч» ← *toqı-* «сугу, бәрү, тукылдау, чүкечләү», к. **Тукма-у, Тук II, Тукы-у.** Рус. *тукмак* (< тат.) тур. Аникин: 561 (шунда ук әдәбият). Федотов II: 242 (чув. *тукмак* сүзенең төп – нәкъ татарчада – мәгънәләреннән тыш «бүре» мәгънәсен күрсәтә, ләкин бу мәгънә *тукмак хүрě* «тукмак койрык» сүзтезмәсеннән килә; **тукмак** сүзен М.Р. Федотов *тукма-у* фигыленнән ясалган дип карый, к. ш. ук Будагов I: 400. К. **Тукын-у**).

Дерив.: **тукмаклы; тукмакла-у, тукмаклан-у.**

**ТУКМА-У** «бить, лупить, дубасить» ~ башк. (БТДҺ: 334) *туҡма-* «шаку; аркадан сөю» – тат.-башк. даирәсендә генә бугай, **тукы-у** (к.) сүзенең интенсивлык дәрәҗәсе.

Дерив.: **тукмал-у, тукмат-у;** диал. **тукмар** «тукмак» ~ каз., к.-калп. *тоқпар* id.

**ТУКМЫК, токмык** (ДС I: 186) «младшая жена (при многожёнстве)» – асылда «мөгезсез (> ярдәмсез) яшь терлек» (чаг. ш. ук **Тукал**), к. тат., башк. (ТТДС I: 417; БТДҺ: 320, һәр ике теркәлеш Гәйнәдән) **тŏқмык, тŏқмŏқ** «мүкләк; тупыйк; тупас», башк. диал. (БТДҺ: 320) *тоҡмаҡ,* себ. (Тумашева 1992: 217) *туқмақ* «мүкләк; тупас» сүзе дә **туқмық, токмақ** сүзенең халык этимологиясенчә үзгәртелеше булса кирәк.

**Тоқмық < туқымық** < **tŏқамуқ:* **-амук** һәртөрле авыру-чирләрне, аномаль организмнарны белдергән формант (аерым сүз буларак та билгеле), сүзнең тамыры *тŏқ < туқ < тоқ* «мөгезсез; тупа, очлыксыз» күп тат.-башк. диал. сүзләрендә очрый, к. (БТДҺ: 320–321) *тоҡан, тоҡын* «тупас; аңгыра», *тоҡол* «койрык сөяге, коймыч», *тоҡор, тоҡос, тоҡош, тоҡтой* «көтек, кыскартылган; кыска буйлы» һ.б. К. **Тугыш, Туклы.**

**ТУКРАН,** сөйл. **тукыран** < (ДС III: 159, 160) **тукыркан, тумырка** «дятел» > мар. (Исанбаев 1978: 21) *токран,* чув. *тăхран, тăкрон* id. ← **туқырт-у* < **токурт-* «тукылдату» ← **тоқур-* < **тоңқур-* «тукылдау» ← *тоңқ* тукран тукылдатуына имитатив сүзеннән, к. ком. *тонқ тонқ* «тукран», к. **Тук II.**

Әлеге **тоңкур- > тоңкыр-** (**-кур- > -кыр** имитативлардан фигыль ясагыч кушымча) фигыленнән тукранның үзгә атамалары да ясалган: тат. диал. (ДС III: 189), башк. **тумыртка < туңыртка** (к. БТДҺ: 336) ~ алт. *тоңыртқа,* тув. *тоорға* ~ хак. *тобырғы* (*-б-* монда икенчел); себ. (Тумашева 1992: 217) **туқыртма > туғыртма.**

*Тоңқ* тәкълиди сүзеннән бүтән фигыльләр һәм шулардан тукран атамалары да ясалган: як. (Пекарский: 2726, 2730) *томсоғоі, тоңоғос* «тукран» ← *тоңсуі-* «тукылдату», чаг. монг. *тоңшуул* «тукран» ← *тоңшу-* «тукылдату» һ.б. Федотов II: 204; ССТМЯ II: 193, 198.

**ТУКРА-У, тукыра-у** диал. «остановиться по пути, задерживаться» ~ каз. *тоқыра-* id. **Тукта-** < *туғыт-а-* нигезе *туғыт* исеменнән ← *туғ-* «бөяү, бөялдерү». Шул ук фигыльдән **тоғ-ық-ра-* нигезе ясалырга мөмкин. К. **Туг, Тугнак.**

**ТУКСАБА,** диал. (к. Тумашева 1987: 38–51) **туксыба, туқсыбай** «один из родов сибирских татар, род башкир; боевой клич башкир» ← название половецкого племени и имя одного эпического героя в древности < уйг., чыгт. (Будагов I: 398) *туқсаба* «полковник; прапорщик», төркм. (к. Гараджаев: 13) *тоғсабай, туқсабай* «полковник; бор. бер хәрби дәрәҗә» – бор. төрки *tuү* «байрак» (к. **Ту I**) сүзе нигезендә ясалган хәрби чиннарның берсе, *туғсипаһи* «байрак тоткан атлы-сыбай» дигәннән (к. **Сыбай**), чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 584) *tuүčï* «байракчы», Хива ханлыгында *туқсаwыл* «югары чин», төр. *tuğbay, tuğgeneral, tuğkomutan* – төрле югары чиннар. Аерым чин атамаларының кабиләкавем атамасына әверелүе бүтән очракларда да күренгәли (чаг. **Эчкен**). Бор. яз. («Аккүбәк» дастанына баглы) ядкәрләрдә куманнарның **туксаба** кабиләсе «татарлардан чыккан» дип язылган. Ул туксаба кабиләсе Чыңгыз ханга барып баш игән һәм Бату хан гаскәрләренә кушылып яңадан Көнч. Европага килгән вә башкортлар составына кергән булса кирәк. Башкортстанда һәм Алтайда Аккүбәк тур. сакланган сөйләкләр, эпос өзекләре шуның белән баглы.

**Туксаба** сүзенең бүтәнчә аңлатмалары да очрый, тик алар дөрес түгел кебек.

**ТУКСАК** «припадающий на одну ногу при ходьбе» < гом. кыпч. *тоқсақ* id. ← ***токса-** «сикереп хәрәкәтләнү» ~ эвенк. (ССТМЯ II: 209) *туқса-* id., чаг., каз. (Радлов III: 1155) *тоқсаі* «аксак» һ.б. К. **Тавышкан**.

Дерив.: **туксакла-у.**

**ТУКСАН** «девяносто» ~ башк. *тоҡһан* < гом. төрки *тоқсан* (> *тохсан, доқсан, дохсан*) < *тоққуз он* «тугыз ун»; к. як. *тогус уон* ~ чув. *тăхăр вуннă* > *тăхăрвун* id. *Туксан* < *тоқсан* сүзендә икенче

иҗектә *-а-* сингармоник чылбырлар законына буйсынарак килеп чыккан.

Деривация – саннар өчен типик. Татарларның кайбер этник төркемнәрендә, казакларда һ.б. **туксан** ~ *тоқсан* – елның дүрттән бер өлеше, «туксанкөнлек» (ул ел фасылларыннан беразга аерылган).

**ТУКТАВЫЛ [туқтаwыл], туктагул** «стоянка; привал» ← *тукта-у*, чаг. як. *токтобул* «туктавыл» (монг. телләреннән, к. түбәндәгене). Räsänen 1969: 485.

**ТУКТА-У** «остановиться; перестать» < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., угыз диал. *тоқта-* (алт., кырг. *токто-,* як. *тогто-,* к.-балк., аз. *тохта-,* тув. *доктаа-,* чув. *тăхта-*) id., ш. ук (чув.) «көтеп тору», (төр.) «озак яшәү» ~ яз. монг. *toγta-, toγtu-* «бер төштә ныгыну; өелү, ясалу» ~ тунг.-маньч. *токто-* «хәрәкәтсез калу; төпкә утыру; ныгу, карарлашу» (к. ССТМЯ II: 193–194). К. Насыйри буенча, *тукта-у* < *тутка-у* (к. **Тот-у**), ләкин бу фараз дәлилләргә мохтаҗ.

Сүзнең тат. диал. (ТТДС I: 425), башк. *туқра-, туқыра-,* каз. (Радлов III: 1152) *тоқра-,* кырг. *тоқоору-* варианты да бар. Күрше телләрдә бу сүзнең юн. формалары очрый (удм., мар. *туктал-* «тукталу», удм. *дуктът-* «туктату», к. Насибуллин: 113). Räsänen 1969: 485; Федотов II: 204 (Радлов материалларын кабатлыйлар). Гомумән, бу сүзнең этимологиясе җентекләп тикшерүгә мохтаҗ.

**Тукта-** продуктив нигез: **туктал-у, туктат-у; тукталып.** Бор. төрки (< монг.) *токтағул* > *туктагул* «карар; тукталыш» сүзе Урал регионында берничә авыл исеме. Чаг. монг. *toγtaγal* «поход тәртибе».

**ТУКЧЫН: тукчын ат** (Котбидә) «злонравная лошадь; лошадь-дракон» ~ як. *дохсун* «котырынкы, котырган» ~ яз. монг. *doxšin* «кыргый» >> бур. *дошхон* id. ~ маньч. (ССТМЯ I: 213) *доқсин* «явыз» – тибет теленнән булса кирәк, к. МНМ I: 391 (монг. *докшит* < тибет. *drags-gsed* «явыз палач»).

**ТУКЫЛДА-У** «стучать (о дятле)» к. **Тук II.**
Дерив.: **тукылдаш-у, тукылдат-у; тукылдык.**

**ТУКЫН-У** кит. «задевать (интересы, честь)» < чыгт., үзб. *тоқын-,* уйг., чыгт. *тоқун-,* бор. төрки (ДТС: 576) *toqïn-* «тию, тукыну» ~ кр.-тат., кар. *тоқун-,* аз. *тохун-,* төр., гаг. *докун-* «тию; бәрелү; тидерү, бәрдерү» һ.б. (ЭСТЯ III: 256) ← *туқы-* < *тоқу-* «бәрү». К. ш. ук Радлов III: 1150, 1702. К. **Тукы-у.**

**ТУКЫ-У** «ткать; плести; ритмично ударять (в частности – бердом), повторять (многократно)», чыгышы буенча *туқы-у* «тукылдату» сүзе белән бердәй, күрәсең, уйг. һ.б. *тоқу-* < бор. төрки (ДТС: 576–577) *toqï-, toqu-* «сугу, суккалау, тукылдату; казык кагу; тукылдау, дөпелдәү, чүкечләү; бәрү, вату; тию, тукылу, тукыну», *toqı-* «тукыма туку» һ.б. һичшиксез *тук (тук-тук)* тәкълиди тамырыннан (чаг. рус. *стук, стукать, стучать, тукать,* ним. *tuckern* «тукылдау» һ.б.). К. **Токмач, Тук I, Тукмак, Тукма-у.**

**ТУКЫЯ [туқыйа]** (Остроумов 1892 һ.б.) «головка, шишка (семян) лука», (Balint: 104) *takja* «семенные стебли лука» – **такыя** (к.) сүзеннән булса кирәк. **Тукыя** варианты чув. диал. *тухъя* < *тохъя* id. сүзеннән алынма булуы ихтимал. Суганның орлыклык көпшәләре башындагы гонҗә такыяга охшатылган. Чаг. **Такыя.**

**ТУЛ** иск. «боевая лошадь» < чыгт. *тул* id. К. **Тулпар.**

**ТУЛА I**, диал. (ТТДС II: 306; Баязитова 1995: 99–100) **тулақ** «сукно домашнего производства», иск. (ЛТ II: 15) **тулақ** «онучи, портянки» ~ чув. (Сергеев 1971: 122) *тăла, тăлла* «тула» < иске тат., чыгт. (Радлов III: 1192) *толағ* «чолгау, ыштыр», ком., төркм. һ.б. угыз., төр. *dolaq,* аз. *долағ* «тула оек, ыштыр һ.б.ш.» ← гом. угыз. *дола-* «чолгау, урау; тулгау» ← гом. төрки *тол* «әйләнү, урау, урату», к. **Тулгак, Тулга-у, Тулма**. Мухамедова 1973: 89; ЭСТЯ III: 259–260; Федотов II: 187–188.

Дерив.: **тулачы, тулачылык,** сөйл. **тулайық < тула оеқ**.

**ТУЛА II:** (Тумашева 1992: 217–218) **тула йауын, тулуқ** «бурный дождь, дождь с градом» < уйг. диал. (Zenker: 611) *tola* ~ төр., аз., тув. *толу, долу*, төркм. > каз. (ҚТДС: 91) *долы*, уйг. диал. *тоолы, толуқ,* бор. төрки (ДТС: 573) *tolï* id. Чыгышы ачык түгел, к. Мухамедова 1973: 172; ЭСТЯ III: 280–281 (татар сүзе күрсәтелми). Чаг. башк. *тулыш-у* «кызып китү», каз. *долу* «гасаби, нервылы».

**ТУЛАЕМ [тулайы̆м]** «оптом, целиком» > мар. *толайым, тулайым* id. К. **Тулай.**

**ТУЛАЙ** «всё, взятое вместе; оптом, целиком», иск. (Будагов I: 404) «сборище, собрание; восклицание, которым собирают своих», себ. (Тумашева

1992: 217) **тулай**, (Дмитриева 1981: 84, 189) **толай** «барлыгы», **тулайын < толайын** «киресенчә; кире сәбәбеннән», **тулайынан < толайынан** «кирәгеннән» ~ хак. *толай* «аймак; компания», *толайы*, төр. *dolay* «тирә-юнь; әтраф; урау, вираж; әйләндереп, уратып алынган мәйдан», *dolayı* «тирә-як; әйләнә-тирә; сәбәбеннән; турында; шартлар нәтиҗәсендә», тув. *долгандыр* «тирәли». Бу мисаллардан күренгәнчә, **тулай < ****тулгай*, ягъни *тулга-* < *толга-* (к. **Тулгау II**) сүзенең күп дериватларының берсе һәм тәүдә камап алынган киекләрне яки терлекләрне белдергән булса кирәк, «сәбәбеннән, турында, өчен» мәгънәсе «тирәли» мәгънәсеннән килә (к. тат. сөйл. *утын тирәли сөйләшү = утын турында сөйләшү*). Монг. *туулай* «тулай» төрки телләрдән.

**Тулай** сүзенең исем мәгънәсеннән себ. **тулайын** «тулысынча» (**тулы** сүзенә катнашы юк) **тулай** сүзенең инструменталь килеш формасы ясалган. Бу **тулайын** тат. сөйләшләрендә **тулайым** яңгырашын алган.

*Тула́ем* – рус телендә дә бар (Фасмер II: 117; Аникин: 562) һәм анда татарчадан алынган **тулай** сүзенең «творительный пад. ед. ч.» дип аңлатыла. Алайса тат. сүзе русчадан әйләнеп кайткандай була: рус. **тула́ем >** тат. *тулаем?* Ләкин **тулайым < тулайын** булу ихтималы зуррак.

**ТУЛАК I** (*ат арыса – тулак, ир арыса түләк* мәкалендә, к. ш. ук БТДҺ: 335), **тула** «чучело жертвенной лошади, которое ставилось на могилу; чучело телёнка для вызывания молока у коровы без телёнка; скатерть, покрывало из шкуры» < гом. кыпч. *тулаҡ* «сөкәт», төр. *doluk* «толык, тулак» ← *тул* «ярмыйча салдырылган тире», к. **Тул**. Кыпчакларда һәм алардан күрмәкче мордваларда да кабер өстенә тулак кую тур. Контарини (XIII г.) да яза. К. **Толык**.

**ТУЛАК II: тай-тулак** сүзендә «жеребёнок, который резвится; несерьезная молодёжь» < **туйлак,** к. кырг. *туйлаҡ* «тулак, колынчак» ← *туйла-* «тиккә чабып йөрү, уйнаклау» ~ аз. (АДДЛ: 387) *туйламағ* «йөгермәк» һ.б. (*туй* < *той* сүзенә катнашы юк). Чаг. төр. *toy* «тәҗрибәсез, яшь».

**ТУЛГА** (Тумашева 1992: 217) «треножник; подставка на трёх ножках» ~ як. *дулға*, алт., эвенк. һ.б. *тулға* < бур. *тулга,* монг. *тулга(н)* < яз. монг. *tulγa(n)* «өчаяк, таган; терәү һ.б.ш.» ← *tul-* «таяну, терәлү, терәтелү». Рус. диал. *тулуган* «тулга» тур. Аникин: 562 (шунда бу сүз тур. шактый бай әдәбият күрсәтелә); чаг. **Тулка.** Ramstedt 1935; Räsänen 1969: 468.

**ТУЛГАВЫЛ [тулғаwы̆л]** «песня-рассуждение; речь героя в эпосе (в стихотворной форме, в отличие от рассказа автора-исполнителя)» ~ кырг. диал. *толгоол* id. Тоташ шигырь-назымнан гыйбарәт дастанны да (мәс., «Идегәй»не) *тулгавыл* дип атаганнар. Гомумән, бу сүзне *эпос, дастан* сүзләренең синонимы дип тәгърифләргә мөмкин. Этимологиясенә караганда ← **тулга-wыл** предмет түгел, зат, **тулгау** (к.) башкаручы. Ләкин фольклорда «жанр атамасы» ~ «шул жанрны башкаручы» семантик алмашынучанлыгы еш очрый. Өстәвенә, **тулгаwыл** сүзен «тулганып йөрү, маҗаралар» дип аңларга мөмкин. Чаг. бур. *туулга дуун* «аккургаш җыры – туй җыры». К. **Төкләче.**

Дерив.: **тулгавылла-у** «тулгавыл әйтү», **тулгавылчы.**

**ТУЛГАК,** диал. **тулғаw** «родовые схватки» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *толғаҡ* (кырг. *толғоҡ*) < бор. төрки *tolγaq, tolγaγ* < *тулға-* < *толға-* < бор. төрки *tolγa-* «эч борылып авырту», «бору; колак итенә (алканы) борып кертү» (к. ДТС: 573); чаг. ш. ук алт. *толғаҡ* «борылма, борылмалы», тув. *толғаҡ* «борыт; кәтүк». К. **Тулга-у.**

**ТУЛГАН-У** «извиваться; крутиться; ворочаться» (все в переносных значениях) < гом. кыпч. *толған-* id. (күп сүзлекләрдә «кайгыру» дип кенә аңлатыла) ← *тулға-* < *толға-* «әйләнеп чыгу» (к. **Тулга-у**); кайбер сөйләшләрдә **тулгал-у, тулгат-у** юн. формалары да очрый.

**ТУЛГАУ [тулғаw]** «песнь-речь; рассуждение в форме песни» (к. Исәнбәт III: 64) < гом. кыпч. *толғаw* id. («тарихи җыр» дип тә тәгърифләнә) < гом. кыпч. *толға-* (кырг. *толго-,* ком. *толгъы-*) id. чыгт. (Будагов II: 751), каз. *толға-,* төркм. һ.б. *долға-* «шигырьдә мактау; әкияттә шигырь сөйләп, җыр җырлап алу», кырг. к. ш. ук «уйлап хөкем чыгару», як. *толҡуй* «фикер, идея» һ.б. К. **Тулгавыл, Тулгак.**

Бу сүз **тулга-у** (к.) белән гомоген булырга мөмкин («*әйләндерү* > фикер йөртү»). Икенче яктан, к. монг. *тоғул* > тув. *тоол* «әкият, эпос» (*толға-* < *тоғулға-* булырга мөмкин).

**ТУЛГА-У** «вертеть, крутить» (ТТАС III: 160), «колебаться, волноваться под ногами – о болоте»

(Тумашева 1992: 217), иск. «поворачивать» (Ясәвидә: *Тугры әйтсәм игре юлга буйнын (муенын) тулгар...* 13 хикмәт) < гом. кыпч., уйг., чыгт. *толға-* (кырг. *толго-*) «әйләндерү; бораулап кертү» < бор. төрки (ДТС: 573) *tolγa-* «урау, боргалау, бору, борып кертү» > тув. *долға-* id. ~ угыз., кр.-тат. *дола-* id. (к. Räsänen 1969: 486; ЭСТЯ III: 359), М. Рясянен һәм Э.В. Севортян *толға-* > *долға-* һәм *дола-* вариантларын бер үк сүз дип карыйлар. Безнеңчә, алар тамырдаш булса да, төптән аерым булырга мөмкин. *Толға-* «әйләндерү» борынгырак *тол-* «әйләнү; чорнау» сүзеннән ясалган булса кирәк (чаг. *болга-, чолга-, тарка-* һ.б.). К. **Тула, Тулай, Тулгак, Тулган-у, Тулма.** Кайбер төрки телләрдә бу нигез, мәс., тув. *долға-,* хак. *толға-,* аеруча күп дериватлар биргән.

**ТУЛКА** (Г. Толымбай) «втулка колеса», (Будагов I: 404) **дулға** «каска, шлем, шишак» ~ башк. *тулҡа* «втулка, чөй», төр. *тулга, тугулга,* чыгт. *таулга, дагулға, дабулға,* уйг. *дуйулға,* каз., монг. *дулҡа, долҡа, толға,* каз. диал. (Аманжолов: 714) *тулыған* id., аз. (АДДЛ: 203) *дулғу* «тегермән куласасының тулкасы»; чаг. рус. *тулка*, морд. *туло, тулкаа,* удм., коми. *тул* «тулка; кадак, кадак эшләпәсе». Рус. *втулка* я үзе төрки телләрдән, я **тулка** белән охшашлыгы очраклы булса кирәк (рус этимологик сүзлекләрендә фикерләр төрлечә).

*Тулка, тулга,* ихтимал, *тулға* «өчаяк; куыш каркасы» белән гомогендыр («шлем ~ куыш» мәгъ. күчеше була ала). К. **Тулга.**

**ТУЛМА** «голубцы», буквально «нечто завёрнутое» ~ төр. *dolma, dolman* «урама; ябынча», гаг. *долма* «хатын-кызларның киң изары (кушагы)» ← *дол-* «чорнау, урау, урату», к. **Тула.** Төр. сүзеннән рус. *долиман* «хәрби плащ (плащ-палатка)» сүзе килә, к. Фасмер I: 525.

**ТУЛПА** диал. (м.-кар.) «толстый, коренастый, крепкий» ~ чув. *тӑлпан* id., башк. (БҺҺ III: 180) *тулпанлы* «кыска юан кеше», каз. *тулпан* «гәүдә, бәдән», үзб. (ЎХШЛ: 259) *толпаҡ* «юан, шешмән (кеше)». Калганы ачык түгел. Чаг. **Тул-у.**

**ТУЛПАК, тулфак** (ТТДС II: 308) «металл серебристого блеска» ~ башк. *томбаҡ* «латунная монета; блестящий купол» (к. БҺҺ II: 252) ~ рус. *томпак* «җиз төре» < фр. *tombac* < малай. *tombaga* «җиз, бакыр» (Фасмер IV: 76), тат. сүзе рус-евр. линиясеннән түгел, бүтән чыганактан булса кирәк.

**ТУЛПАР, толпар** миф. «крылатый конь; пегас» < гом. кыпч., уйг. *тулпар,* хак. *тулбар* «хәрби ат, сугыш аты», к.-балк. ш. ук «җитез; батыр, герой» ← *тул пар* < *тул пард* (яисә фар. *тули пард*) «хәрби ат-юлбарыс (барыс)» сүзеннән: чыгт. *тул* «яуга хәзерләнгән ат» + *пар, пард* (ир. телләрдән) «барыс, юлбарыс, пардус (кулга өйрәтелгән гепард)». К. ш. ук төркм. *тулпар* «кечерәк гәүдәле нык ат», алт. диал. *тулбар* «начар ат» (? ялгыш түгелме икән), күп мәгъ. к. Радлов III: 1465, 1467, 1475; Räsänen 1969: 444. Аксак Тимернең кучтылары (тәнсакчылары) юлбарыс тиресенә төрелгән атларда йөргәннәр (к. На стыке континентов...: 218). Тимергалин: 480.

**ТУЛ-У** «наполняться; быть полным, наполнять собой» ~ чув. *тул-* id. < гом. кыпч., уйг., чыгт. һ.б. *тол-,* як. *туол-,* угыз. *дол-,* төркм. *доол-* id. Бу фигыльнең исем коррелянты да билгеле: төр. *tol* «тулы» ~ тат. диал. **тул* id. (*тул-ла-у* фигылендә, к. ДС III: 159; ТТДС I: 475), к. ш. ук **Тулпа.**

*Тул-* < *тол-* бор. **тоо-* фигыленең төш. юн. дип карала: ул фигыльдән *туҡ* < *тооҡ* «тук, туйган» һәм *туй-* < *той-* < *тоғ-* «тую» фигыле дә килә дип карыйлар. ЭСТЯ III: 257–259; Федотов II: 243.

**Тул-** продуктив нигез: диал. **тулык-у** «нык тулу», **тулын-у, тулыш-у, тултыр-у > тутыр-у**, **тулман** (Тумашева 1992: 217)**, тулымса, тулынкы** һ.б. К. **Тулы.**

**ТУЛЫ** «полный» < гом. кыпч., уйг. *толу* (нуг., каз., к.-калп. *толы*) id. < бор. төрки (ДТС: 573) *tolu* < (чыгт.) *толуғ* > каз., кырг. *толуҡ* ~ тат. диал. (ТТДС I: 425; Тумашева 1992: 218) **тулыҡ, тулуҡ,** (Зимасов: 96) **туллык** id. Шуннан **тулыксы-у** «тулып ташу» фигыле ясала, к. «Идегәй»дә: *Тулыксыган киң Идел...*

Бу сүзнең тат. диал. (себ. һ.б.), башк. **тула** ~ кырг., алт. *толо*, чыгт. *тола* «тулы» вариантлары да бар. Ул вариантның ясалышы ачык түгел. Һәрхәлдә бу вариант та *тул-* < *тол-* фигыленнән.

**ТУЛЬ** иск. «географическая долгота»: **туле гарби** иск. «западная долгота (по меридиану)», **туле шәркый** «восточная долгота (по меридиану)», к. ГТРС: 549. Болар гар. *тул'* «озынлык; меридиан» сүзе һәм *гареп* вә *шәрык* сүзләре нигезендә фарсыча ясалган тәгъбирләр. Меридианнар буенча үлчәмне «озынлык, җәйрәү» сүзе белән атау лат. *longitudo* id. сүзеннән килә һәм бор. Рим-итальян географлары тарафыннан кертелгән. Хәз.

тат. **озынлык, киңлек** географик терминнары рус теленнән калька. Гомумән алганда, лат. сүзе **озаклык** сүзенә тәңгәл килә, чөнки географик **туль** сәгатьләр һәм минутлар белән үлчәнгән, тик соңрак кына **градус** сүзе кертелгән.

**Туль, тул** сүзен К. Насыйри һ.б. революциягә кадәрге галимнәр киң кулланганнар (бу сүз госманлы телендә дә шул яңгыраштა кулланылган һәм төр. телендә кулланылып килә).

**ТУМ** «река Томь; город Томск» – җирле телләрдән.

**ТУМА** диал. (Рамазанова 1991: 148–149) «отпрыск, потомство; родственник третьего-четвёртого поколений», (Тумашева 1992: 218) «родной», (ТТДС I: 425–426) «уроженец», әд. «доморощенный, отроду» ~ башк. «яралгы», «уйнаштан туган, никяхсыз туган» < гом. кыпч. *тума* ш. ук күп мәгънәле: «ерак кардәш; еллык үрчем; тумыштангы һ.б.» ~ уйг., үзб. *туғма* «тумыштан», төркм. *доғма* «угыл-кыз», хак. *туңма*, тув. *дуңма* «алпай (энекәш яки сеңелкәш)» һ.б. К. **Тумак.** Кайбер телләрдә «беренче бала» мәгъ. сиземләнә, ихтимал **тон** (угыл) сүзенең тәэсиредер.

**ТУМАК I** «помесь, метис, гибрид», (ТТДС I: 426) «незаконнорождённый», «растущий самосевом», махсус мәгъ. «помесь зайца-беляка и зайца-русака» ~ башк., к.-балк. *тума* «тумак», *тумаҡ* «мөгезсез (сыер); ахмак», рус. *тумак* «малахай; тумак», *тума* «тумак» тур. Аникин: 564–565.

**Тума** һәм **тумаҡ** сүзләренең мәгънәләре еш кына тәңгәлләшә; аларның мәгънә структурасы үсеше катлаулы – монда тикшерәсе нәрсәләр күп: ни өчен «уйнаштан (законсыз) туган» һәм «сеңелкәш, туганкай» мәгъ. килеп чыккан? Чаг. ш. ук **Туган.**

**ТУМАК II,** диал. **тумага** иск. «жезл; палка с шаром на конце» ~ төр. *tomak, tomağa* id. Чаг. **Томар.**

**ТУМАН** тар., хәз. әд. «туман, денежная единица (в 10000 динаров в древности)» Бу күптөрле мәгъ. алган сүздән рус. *тьма* «бик күп; уң мең» сүзе дә килә (яки калька) дип уйлыйлар. К. ш. ук **Төмән.** Будагов I: 406; Аникин: 579 (гомумән, әдәбият күп).

**ТУМАР** «чурбан; кочка» ~ башк. (БТДҺ: 335) *тумар* «түмгәк» < гом. кыпч., к. каз., к.-калп. *томар* «түмәр», кырг. *томар* «зур булып тумпайган» һ.б. ← *том, томп* онопоэтик тамырыннан. **Томар** (к.) белән баглы түгел. К. түбәндәгене.

**ТУМПА** «округло-выпуклый», диал. (Тумашева 1992: 218) **тумпалак** «чурбан», гом. диал. **тумпаҡ** «выпуклость», **тумпаҡай** «карапуз» ~ гом. кыпч. *томпаҡ,* кырг. *томпоҡ,* төркм. *томмаҡ* «юан, шешмән, тумпа» һ.б. *тумп//томп* тәкълиди сүзеннән, *тум//том* «калкып, бүлтәеп, шешеп торган нәрсә» тамырыннан (шуннан рус. диал., тат. диал. һ.б. *тумак* «сапка утыртылган шар; күсәк, йодрык»), каз. *төмпе* «түмгәк» һ.б.ш. К. **Түмгәк.**

*Тумпа* сүзеннән бигрәк аның дериваты **тумпай-у** ~ уйг. *думбай-* «шешенкеләнеп, йомрыча кабарып тоту (чыгу)» киң таралган. Чаг. ш. ук тат. диал. (Гиганов), башк. *тумтай-й* «тумпаю», *тумтык, тумпык* «тумпак».

**ТУМРАН** «нераскалываемый чурбан» ~ гом. кыпч. *томран* id. ← тат. (ТТАС III: 164) **тумра-, тумыра-** < *томра-*, бор. төрки (ДТС: 574) *tomru-* «тумран итеп кисү» → кар., госм., чыгт. һ.б. *томруҡ* «түмәр, кискә; бүрәнә; агач богау», «түгәрәкләп киселгән агач; тукыя, гонҗә» ← кырг. һ.б. *томур-*, бор. төрки (ДТС: 574) *tomur-* «агач төпләү», «тумранлау; тумран ясау», «томыру» > тув. *домур-* id. К. ш. ук тат. *тумар* «түмәр», *тумарык* «кечкенә томар» ← *тумар-, тумыр-* «түгәрәкләп кискәләү» һ.б. (к. Радлов III: 1519–1520).

Бу сүзләрнең этимологик тамырдашлыгы ачык булса да, морфологик бәйләнешләр тикшерелмәгән. *Тумран* бор. төрки (ДТС: 574) *tomrum* «тумран, агач богау» сүзеннәнме (> *тумрам* > *тумран?*) яисә угыз телләреннән алынганмы (*-ан* кушымчасы!). *Тумар* сүзе ничек ясалган?

Сүзләрнең тирәнге тамыры – гом. төрки *том// тум* «түгәрәк, шешенке калкулык» бик күп сүзләрдә чагыла, к. **Томшык, Томыр-у, Тумырка, Түмәр, Түмгәк.**

**ТУМТАЙ-У** к. **Томтай-у.**

**ТУМТАРАКАЙ** «врассыпную (о бегущих от противника)» ~ каз., кырг. *тымтыракай* id., бор. монг. *tamtararixu, tamtarıxu* «вату, кыйрату» тәкълиди сүздән булса кирәк.

**ТУМЫРКА** (ДС I: 190) «дятел» ~ башк. *тумыртҡа* < (алт.) *томуртка* id. *томур-* «агачны чәрдәкләү» сүзеннән. К. **Тумран**.

**ТУН** «шуба», иск. «свадебная одежда» < гом. төрки *тон,* уйг. диал. *тоон*, кайбер чыганакларда (Ценкер, Будагов) *тоң,* угыз. *дон,* төркм. *доон* «кыйммәтле кием», чув. *тум* «гомумән кием; рәешле кием», «бизәкле тукыма» (к. Ашмарин I: 133). Гадәттә санск. *thauna* «кыйммәтле кием» сүзеннән дип карала (Малов, Рясянен һ.б.), ләкин бу этимологиягә шикләнеп караучылар да бар (к. ЭСТЯ III: 262–264). М. Федотов (II: 238) чув. *том//тум* «кием, костюм» < бор. төрки **don* < иске кыт. *twan* «озынча кием» сүзеннән дигән фикерне куәтли. Будагов I: 753; К. ш. ук Аникин: 565–566 (шунда ук әдәбият); Тимергалин: 480.

**Тун** продуктив нигез: **тунлы, тунлык**, к. **Туна-у.**

**ТУНА-У** «сдирать шкуру; ограбить» ~ нуг., к.-калп. *тона-*, алт., кырг., як. *тоно-* id., ләкин каз., чыгт. *тона-*, угыз. *дона-*, тат. диал. (к. Тумашева 1992: 214) **тōна**- «кием кию» ← *тон* «тун». Угыз телләрендә бу фигыльнең төрле юнәлешләре кулланыла.

*Туна-у* «тунын куптару» (ЛТ II: 15) мәгънәсе сүз ясалышы җәһәтеннән *кер, сатып алу, (урман) төпләү, чүпләү* кебек абсурд сүзләр рәтендә тора. Э.В. Севортян фикеренчә *туна-у* сүзенең көтелгән «тунлы итү» мәгънәсенә кире мәгънә алуы «метафорик нигездә» барлыкка килгән (ЭСТЯ III: 164–165). К. ш. ук Räsänen 1969: 488.

**ТУНГУС** «тунгус». Бу сүз, әлбәттә, русчадан. Ләкин шунысы кызыклы: бу сүзне нен. (< селькуп.) *tınkos* «татар кешесе» сүзеннән чыгаралар: селькупча *tın* «татар». Аникин: 566–567.

**ТУҢ** «мёрзлый; мерзлота» < гом. төрки *тоң*, угыз., тув. *доң* id. ~ чув. *тăм* «суык; чык» ~ тат., башк. *туң-* < гом. төрки *тоң-*, угыз. *доң-* «туңу». Бу сүзләр бор. исем-фигыль конверсиясенә ачык мисалларның берсе (к. ЭСТЯ III: 265–267). К. ш. ук Räsänen 1969: 488; Федотов II: 190.

**Туң** һәм **туң-** төрки телләрдә продуктив нигезләр: **туңлы, туңлык** («наданлык» мәгъ. бар); **туңдыр-у**; к. **Туңгак**.

**ТУҢГАК, туңгалак** «наст; твёрдая мёрзлая поверхность (дороги)» > мар. *тоңгоҗ* «сөмсерәгән (тән өлеше)» ← *туң-* «туңу». Кайбер төрки телләрдә (каз., к.-калп.) *тоңғақ* «туңучан, өшүчән».

**ТУҢГАТА, туңката** «глыба, ком глины, цементированные льдом» ~ чув. (Сергеев 1971: 129) *томката, тоңката, туңката* «тумар, түмәр», мар. *тоңгата, таңгата* «каты; төпсә» ~ тунг. (ССТМЯ I: 217) *донгото* «туңган; туң; туңгак». *Туң* < *тоң* сүзе белән бәйле булса кирәк. Федотов II: 247 (тат. сүзен һәм тунг. параллельләрен белми).

**ТУҢГЫЗ, дуңгыз** диал. (ЗДС: 173; Тимергалин: 153) «боров (надстройка)» – өй түбәсе чатыры, эшкәртеләгән бүрәнәләрнең, чошларның баш-башларын бер-бер өсле куеп ясалган корылма, шуның өстенә өртү-каплау материалы (салам, кабык) җәелгән ~ мар. (Вершинин: 78) *доңгыз* id. Бу сүз, күрәсең, рус. *боров* id., төп мәгънәсендә «ата дуңгыз (аның сырты югарып күтәрелә)» сүзеннән калька. Чаг. **Дугыз.**



**ТУҢКА** «необожжённый кирпич, кирпич-сырец (в засушливых областях здания нередко строят из необожженного кирпича, которые стоят столетиями)», иск. «шлак», диал. (Akb: 38) *toñka kılış* [туңка кылыч] «бик авыр кылыч» ~ нуг. *тоңға* «чуен», каз., кырг. *тоңқа, тоңқо* «металл банка», тув. *доңға* «кувшин, күкшен» һ.б. Төп мәгъ. «начар коелган чуен» булса кирәк. Гомумән, *тоңка-* бор. төрки металлургия термины.

**ТУҢКАЙ** диал. «на карачках» ~ каз. *тоңқай,* кырг., алт. *тоңқой,* тув. *донгай* «башны җиргә тидереп, артны күтәреп иелеп», як. *тонгой-, тӧнкӧй-,* хак. *тонхар-* «туңкаю, түңкәю». Рясянен буенча (Räsänen 1969: 488), монг. *tonga-ji* «намаздагыча иелү» сүзеннән. К. ш. ук ком. *тонко* «бөкре». К. **Туңкай-у, Түңкә.**

**ТУҢКАЙ-У** «встать на карачки; упасть (головой вниз)», күч. «протянуть ноги» < гом. кыпч. (к.-балк., кр.-тат., каз., кырг., алт.) *тоңқай-, тоңқой-*, хак. *тоңхай-* «тәкмәрләү; иелү; мәтәлү», бор. төрки *doŋγaj-* > тув. *тоңғай-* «иелү-бөгелү, туңкаю» ~ яз. монг. *tongγuj-* > хәз. монг., бур. *тонгой-* «туңкаю», эвенк. *тонкоj-, тоңкорго-* «туңкаю», *тоңо-* «ию, бөгү» һ.б. (к. ССТМЯ II: 197) ← бор. төрки, монг., тунг.-маньч. **тоңка* «ашыкның билгеле бер (авып, мәтәлеп) торышы», к. каз. *тоңқалан-* «баштүбән егылу», *тоңқанда-* «мүкәләү» ← *тоңка*; ком., к.-балк. *тоңқу* «бөкре; бөкрәйгән», кырг. *оңко-тоңко* «тәкмәч-бөкмәч; ашыкның бер торышы» (> тат.

*уңкы-туңкы*). К. ш. ук уйг. *доңгаķ* «бөкре», *тоңкай* «сыер ашыгы». Сүзнең тамыры символик имитатив *тоң* «тумпа, бөкреле һ.б.ш.» булса кирәк. К. **Туңкай, Түңкә.** Räsänen 1969: 488.

**Туңкай-** продуктив нигез: **туңкаел-у, туңкаеш-у, туңкайт-у** һ.б. **Туңкай** сыйфат-рәвеш мәгъ. дә очрый (*туңкай тору* диелә).

**ТУҢКАЛАК** диал. (Тумашева 1992: 219) «четырёхстенный (дом)» ← *туңка* «яндырылмаган кирпеч» (?).

**ТУҢ-У** «мёрзнуть, замёрзнуть, замерзать» < гом. төрки *тоң-,* угыз., тув. *доң* id., к. ЭСТЯ III: 267. К. **Туң, Туңгак, Туңгыл.**

Дерив.: **туңыл-у, туңыш-у, туңдыр-у** (→ **туңдыргыч, туңдырма); туңгылы, туңгысыз; туңгылык**. Себ. (Рамазанова 2002: 124) **туңра-у** «туңдыру» аерым үзенчәлекле нигез: **туң-у** сүзенең дәвамлы интенсивлык формасы.

**ТУП I** «мяч; ядро; пушка; стадо; тесное сборище; тесная группа (скота)» ~ чув. *тупă* id. < гом. төрки *топ* id. – төрки телләрдә иң продуктив тамырларның берсе, асылда *тумп* (к. **Тумпа**) тәкълиди-образлы тамырыннан.

Бу тамырдан бик күп нигезләр ясалган, к. **Тубалак, Тубык, Тубыр, Тубырчык, Тупа, Тупак, Тупар, Тупас, Туплан, Тупла-у, Тупса, Тупчак, Тупчы-у, Тупый, Тупыйк** һ.б. (аерым төрки телләрдә бүтән дериватлар да аз түгел, к. Юдахин 750–754; Redhouse: 1181–1183). *Туп* < *топ* һәм дериватлары төркиләргә күрше халыклар телләренә дә таралган (мар., удм., морд. *топ, туп* «уен тубы», фар., көрд һ.б. *топ, туп* «пушка, туп» һ.б.). Федотов II: 249; Тимергалин: 481.

**Туп** үзе генә дә регуляр деривациягә бай: **туплы, туплык** (төрле мәгъ.), **тупчы, тупчак, тупчык** һ.б.

**ТУП II** (Тумашева 1992: 219) «сушёная кора тальника для получения отвара-дубителя» < рус. *дуб* «имән; тире иеләгеч сыекча», к. Аникин: 268 (рус. *туп* «каен кайрысының сеңгәле» < тат. < рус.).

**ТУП III** – имитатив, означающий глухой удар, звук такого удара мягким толстым предметом по твёрдому (*туп-туп* – о звуках бега босого ребёнка) ~ гом. төрки *туп, топ* ~ рус. *топ* id.

**Туп** продуктив нигез: **тупылда-у, тупылдык, тупыр-тупыр, тупырда-у** һ.б.

**ТУПА** «тупой (о режущих инструментах)» < *тумпа* (интервокаль *-п-* < *-пп-* < *-мп-*) булса кирәк; к. ш. ук рус. *туп, тупо, тупой* һ.б. – тәкълиди тамырдан. Тат. диал. **тупуй** «аңсыз» < рус. *тупой* (ДС III: 160).

Дерив.: **тупар-у, тупай-у**. К. түбәндәгеләрне.

**ТУПАК,** (Троянский II: 6) **тупан** «тупой, круглый (о конце колющих инструментов, вообще – о верхушке длинных предметов)» < гом. төрки, к. госм., чыгт. (Радлов III: 1221) *топаķ* id. – әлбәттә, **туп, тумп** тамырыннан, ләкин ясалышында сораулы моментлар бар. Беренче карашка **туп-аķ – туп** сүзенең кечерәйтүле формасы кебек, ләкин икенчел караштa *тупа-* дигән фигыль булганлыгы, шуннан **тупа-ķ** сыйфаты ясалган булуы мөмкин. Чаг. **Тупас.**

**ТУПАЛ** диал. «округлая опухоль (белого, нормально-телесного цвета); ком» ← **туп** (ихтимал, **тупķал* < **топķал*): бу сүз башк. сөйләшләрендә актив сүзьясагыч нигез – шуннан *тупалаķ* «шар; түгәрәк икмәк, буханка», *тупалсай* < *тупалчай* «бугаз алмасы, богардак» һ.б. к. БТДҺ: 337. К. ш. ук төр. *topalak* үсемлекләрнең түгәрәк җимешлекләре, аерым үсемлек атамалары, чаг. **Тубалак, Тупар.**

**ТУПАР I** диал., башк. (БТДҺ: 337) «кругляк, шарик (необязательно правильной формы), круглый плод» < **тумпар** id. ← **туп ~ тумп**, к. **Тумпа.** К. түбәндәгене.

**ТУПАР II** иск. «группа, небольшой отряд (всадников, кавалеристов)» < гом. кыпч., нуг., к.-калп., төркм., гаг. *топар*, каз. *топыр*, уйг. *топур* id. ← **туп <** *топ* (к. ĶТДС: 335). Төп яңгыраш **томпар* булырга тиеш.

Дерив.: **тупарлы** «атлы төркемле»; **тупарла-у;** диал. **тупарлак** «талпа» ~ төр. *toparlak* «түгәрәк сан; хәрби арба күкрәге; тәртипсез, җәргәсез хәрби төркем». Чаг. **Тубалак** (к. **Тупал).**

**ТУПАС** «грубый, неуклюжий; тупой» < гом. кыпч. *тупас, топач* id.. Чаг. төркм. *топаз* (> каз., башк. *тупай*) «сыер-үгезнең ашык сөяге», төр. *topuz* «күсәк, йомгак яки шарсыман шәй; кисап, күсәк», төр., кр.-тат. диал. (Dobr. III: 360) *topuz, tompız, tompuz* «саплы шар сыман сугыш коралы, махсус күсәк, кисап», чыгт. (< фар.) *топазы* «тимер күсәк» һ.б. *Тумп, туп ~ туп* (к. *Туп*) тамырыннан

булса кирәк, к. Räsänen 1969: 489. Чаг. ш. ук **Тампа, Тупак, Тупар-у, Тупыйк.**

Рус. *туп, тупой* сүзләренең тат. **тупас** сүзенә турыдан-туры тәэсире юк бугай. Рус сүзләре төрки (тат.) теленнән дә кайбер фин-угор, һинд-евр. телләреннән дә килә ала. Чаг. ш. ук рус. *дубасить.*

Дерив.: **тупаслык; тупаслан-у** һ.б.

**ТУПСА** «шарнир; порог или подоконник» ~ башк. *тупҫа, тупһа,* гом. кыпч. *топса* «бусага» һәм «шарнир (ишекне, тәрәзәне һ.б., ш. ук төрле капкачларны төп элементка, яңакка, савыт яндавырына беркеткеч әйбер)» сүзенең моңаргы ышандырырлык этимологиясе тәкъдим ителмәде. Бу сүз элекке ишек, капкач һ.б.ларның түбәндәгечә беркетелешендә аскы һәм өске арапаларны белдергән, к. рәсемне.




Ишекне һәм ачылмалы тәрәзәне борынгыча беркетү

Ягъни **тупса** < *топса* ул **туп** < *топ* кереп утыра торган уенты һәм шундый уентылы деталь дигән сүз. **Туп** бу очракта ишек һ.б. ның терәк элементының ике башына ясалган (яисә беркетелгән) шарсыман өлеш мәгънәсендә булган. Бор. кыпч. сүзенең тамыры гом. төрки *туп* < *топ,* әлбәттә.

**Тупса** сүзенең «бусага» мәгънәсе икенчел.

**ТУПЧАК** (И. Хәлфиннең «Чыңгызнамә» җыентыгына кушымта сүзлегендә) «охотничья лёгкая лошадь» ~ уйг. (Радлов III: 1230, 1233), чыгт. *топчаҡ* «түгәрәк кенә матур ат», уйг. *тобычаҡ* «көчле, зур ат», каз. (ҠТДС: 331) *тобышаҡ* «әйбәт йөрешле аргамак», кырг. *тобурчаҡ* «һәйбәт хәрби ат», Г. Нәваиның ат атамалары сүзлегендә («Мөхәкәмәт әл-лөгатәйн»дә) *топучак* (**аргумак** «аргамак» белән рәттән куела) – ат төре, «токымлы ат» > иске монг. *tobičaq* «көнб. илләрдән китерелгән ат токымы» ~ иске фар. *топучаҡ* id., к. Doerfer II: 601–603; Sümer 1981: 99; Менгес 1979: 145–146 (шунда ук арытабангы әдәбият, әмма тат. сүзе искә алынмый).

Себ. сөйләшләрендәге (Тумашева 1992: 219) **тупцык** «кыска буйлы (ат)» һәм башк. (БТДҺ: 337) *тупсан ат* «кыска аяклы ат (токымы)» сүзләренең **тупчак** сүзенә нисбәте ачык түгел. Бик ихтимал, тат. диал. һәм башк. диал. сүзләре **тупчак** < *тобырчаҡ* сүзенә бинисбәтән **туп** тамырыннан ясалганнардыр.

*Тобурчак* сүзе исә, күрәсең, **тубыр** < *тобур* нигезеннән *-чаҡ* кечерәйткеч кушымчасы ялганып ясалган һәм тәүдә «ыкчам һәм елдам (ат)» мәгъ. булган.

Бор. заманда Киев кенәзләренә хезмәт иткән төрки **топчак (топчаки)** кабиләсе атамасын да әлеге ат токымы терминыннан дип уйлыйлар, к. Фасмер IV: 80–81 (тат. сүзе искә алынмый). Бу **топчак** этнонимы ясалышында **кыпчак** сүзенә охшашлыгы игътибарга лаек. Чаг. ш. ук **Тукчын.**

**ТУПЧУ, тупцу** (Тумашева 1992: 219) «конечность (рука, нога)» ~ башк. (БТДҺ: 338) *тупсыу* «сөякнең йомры башы» << уйг. *топчуғ* id. ← *топ* «туп».

**ТУПЧЫ,** диал. **тōпцы** «узелок», чаг. кырг. *топчу*, уйг. *топча, топчу*, алт. *топчы* > яз. монг. *tobči* > эвенк. *топчи* «төймә» (к. ССТМЯ II: 199) ← уйг. *топчуғ* «сөякнең һ.б. юанайган башы». К. түбәндәгене.

**ТУПЧЫ-У** «завязывать конец нитки узлом» ~ башк. *тупсы-* id. ← бор. **туп-* < **топ-* «төен ясау, туп кебек итү» фигыленнән булса кирәк. Чаг. ш. ук **Тупчы.**

**ТУПЫ** миш. (ТТДС I: 427) «пюре или творог с конопляным семенем» < морд. *топо, топьо* «эремчек төре» < ир. *tōp, tōpī* «каймак, эремчек» (Joki 1973: 330).

**ТУПЫЗЛЫК** «лапчатка (растение)» (к. Соболева Л.С., Крылова И.П. Зелёная аптека Татарии. Казань, 1990: 62) ← нindидер **тупыз** (сүзлекләрдә теркелмәгән). Чаг. башк. (БТДҺ: 339) *тупыс* «тырнаксыз яки киселгән бармак». **Туп** тамырыннан булса кирәк.

**ТУПЫЙ** (ТТАС III: 169; ТТДС I: 427), **тупы** (Ф. Сәйфи-Казанлы) «вид шапки без наушников» ~ башк. (БҺҺ II: 263) *тупый* «кияү егетнең туй бүреге», кырг. *топу,* үзб. *түппә, түппи* «түбәтәй», уйг. *топә* «бүрек» һ.б. **Туп** тамырыннан булса кирәк.

Дерив.: **тупыйбаш** (ЗДС: 658) «бөҗәк төре».

**ТУПЫЙК** «с округлённо-тупым концом» ← *тупайыҡ,* к. башк. (БТДҺ: 337) *тупай-* «очы йомры

булу», *тупай* «ашык сөяге; йомры башлы сөяк». К. **Туп.**

**ТУПЫЛ** «тополь» < рус. булса кирәк.

**ТУПЫРДА-У, тупырдат-у** «(неритмично) притоптывать, перестукивать (о многих разом)» ← **тупыр-тупыр** – подражание частому перестуку множества людей (в твёрдой обуви), копыт ← *туп-туп* «перестук одиночного лица ногой, копытом». Бу сүзнең каз. һ.б. *топыр* «талпа», *топырла-* «өер булып тору-йөрү»гә бәйләнешы бар. Гомумән, төрки телләрдә сүз башында *т* ~ *д,* сүз уртасында *п* ~ *б* еш килгәнлектән һәм өстәвенә сузыклар да алмашынып торганлыктан, **тупыр** нигезенең вариантлары хәтсез: **топур, топыр, тобур, тыпыр** һ.б.

Идиома: **тупырдатып бала тап-у** «бер-бер артлы бала табу (хатын-кызны мактап һәм хуплап әйтелә)». Бу тәгъбир *тупырда-у*га ничек тоташадыр, аңлашылып бетми. Чаг. түбәндәгене.

**ТУПЫРСЫК** (ЗДС: 438) «толстенький, здоровый и подвижный (о ребёнке)», **тупырсы** «толстенький и здоровый» ← **тупырсы-у** ← **тупыр, *тубыр* «итләч йөз», к. диал. **тубырсын** «итләч йөзле». Чаг. **тубырчык, тубырчын** «тәбәнәк юан» һ.б. К. **Тубыр, Тубырчык** һ.б.ш.

**ТУР** «сеть, сетка; сетчатка глаз; сетчатый узор» < гом. кыпч., уйг., чыгт., төр., көрд., монг., бор. төрки (ДТС: 578) *tor* < *toor* id., ш. ук «кош аулау челтәре; тозак» < бор. **тоғур* id., к. як. *доғур*, монг. *догор* «тур, ау челтәре». *Тор* > *тур* сүзенең төрле аерым мәгъ. тур. к. Zenker: 319, 606; Будагов I: 387; ҚТДС: 336–337. К. **Турла-у.**

Дерив.: **турлан-у** «яшь белән тулу (күзләр тур.)». К. Румыния татарлары җыры:

> *Һәрбер халыкның үз җыры,*
> *Үз телендә җырлана;*
> *Тыңлаганда үз җырыңны*
> *Күз яшлары турлана* (к. Dobr. III: 365–366).

**ТУРА I** (ТТДС I: 428; Хайрутдинова 1993: 97; БҺҺ II: 264) «творог, сметана и т.п. с окрошкой, ягодами», «пастила ягодная» < тат. диал. (Хайрутдинова 1993: 95) **туара** id. ~ чув. (Сергеев 1971: 122) *тора, тăвара* «сырок», мар. (Саваткова: 155) *тара, туара, тугара,* удм. (Насибуллин: 140) *туара* «тура», ш. ук «түгәрәк эремчек күмәченә охшаш чәчәкле үсемлек (“эт борчагы, мальва”)», к. Куклин: 22–25. Тат. диал. (крш., к. ТТДС I: 422) **туғарук** «пышлак, эремчек» рус. *творог* сүзеннән дип карала, ләкин аның төп төрки сүздән килүе дә мөмкин, к. хак. диал. *тубрақ, тубараг* >> рус. *творог* (к. Räsänen 1969: 490; Рясяненның бу фикерен кайбер рус этимологлары да яклый); к. ш. ук чув. *торақ, торах* > *турах*, мар. *торых* < бор. төрки, чыгт., к.-калп., төр. *toraq, torak* «пышлак, сыйр төре һ.б.ш.», төркм. *дорақ* «тозланган эремчек», көрд., фар. *торақ* «пышлак» ~ венг. *túro* «эремчек, эркет». Иске монг. *tarax* > маньч. *тара* > рус. диал. (Аникин: 533, 534, 554) *тар, тара, тарка* – катыктан ясалган төрле ашамлыклар, башлыча «эркет, эремчек» һ.б. (к. ССТМЯ II: 167) **тура** белән гомоген микән, аңлашылмый. **Тура** << **тоғаруғ* дип фаразлаганда да сүзнең тамыры-ясалышы томанлы (ниндидер **тоғ* тамырыннан булса кирәк). Бор. ир. (Авеста) *turaii* «тура» сүзенең катнашы шикле. К. **Тур, Турта, Түгәрәк.** Мухамедова 1973: 175–176; Федотов II: 184, 525; Аникин: 536–537 (рус. *творог* сүзен төрки телләрдән диюгә каршы).

Дерив.: **туралы** (ашамлык төре, З. Бәшири).

**ТУРА II** (ЗДС: 659) «город» к. **Тора.**

**ТУРАЙ (батыр)** – сказочный персонаж < ног., к.-калп. *торай*, кырг. *торопай* «чучка, дуңгыз баласы» > ком. *торай* «бала, бәби» < монг. *торой* < *тора-ай* «кабан баласы» (Räsänen 1969: 490) < бор. монг. *torui* id. ~ як. *тороку, тороху* «кабан». Чаг. калм., монг. *tur* «яшь терлек көтүе»; монг., бур. *тураг, турхаг* «эре гәүдәле (хайван, терлек)».

«Кабан яисә дуңгыз баласы» > «гомумән бала» мәгъ. күчеше **чучка** сүзендә дә күзәтелә. Чучканың әкият герое булып китүе бор. мәҗүси төркиләрнең бер кавеме башлыча дуңгызчылык белән шөгыльләнүеннән.

**ТУРАК I** (трбс., без теркәдек. – *Р.Ә.*): **тәпи-турак** «пешком, пешим ходом» («җәяүләп, җәяүле, тәпи-тәпи, тәпиләп») сүзендә «аяк, тәпи» > чув. диал. *тура, турак* «аяк, тәпи» ~ кырг. (Радлов III: 1446) *тура* «ат тоягы астындагы йомшак ит, тояк арты» – калм. *tura* «тояк» < яз. монг. *tuγurai, turaγun* «тояк». Ramstedt 1935: 182; ССТМЯ I: 218. К. **Төклетура.**

**ТУРАК II: турак уты** (ТТАС III: 170) «толокнянка; укроп» ~ төр. *dorak otu* «кандала үләне» – **тура, турак** (эремчек төре) сүзеннән булса кирәк; бу үләнне турага – эремчеккә турап салалар. Мухамедова 1973: 175–176.

**ТУРАКЛА-У** «раскромсать; разрубить на мелкие части» – бор. ***турак** «пүлән, туралудан килеп чыккан өлеш» сүзеннән, к. чув. *турат, торат* < *торак* (← *тора-*) «тармак, ботак» (чаг. *бота-у* → *ботак*). М. Федотов (II: 251) чув. сүзен **тора-у** «тaралдыру» сүзенә нисбәт итә, ләкин бу фараз бик ышандырырлык түгел. **Туракла-у** сүзе **тура-у** сүзенең интенсивлык формасы дип тә карарга мөмкин.

Дерив.: **тураклан-у, тураклат-у; тураклагыч.**

**ТУРА-У** «нарезать, крошить; сечь; рубить (врагов)» > чув. *тура-* < гом. кыпч. *туўра-* < чыгт., уйг., хак., шор. *тоғра-* < бор. төрки (ДТС: 571) *toγra-* id. > тув. *доора-* «урталай яисә аркылыга кисү», як. *туора-* «аркылы чыгу, аркылыга кисү» << хак. *тоғыра-* «турау, аркылыга кисү» ← *тоғыр* < *тоғур* «аркылыга, аркылы». Бу сүз фигыль мәгъ. дә йөргән (к. алт., хак. *тоор-* «кисү, киртү»), шуннан *тоора-* > тув. *доора* «аркылы, аркылыга кисеп» (*тоғур-а*). К. **Тургач, Туры I**. Räsänen 1969: 484; ЭСТЯ III: 248 (безнеңчә түгел); Федотов II: 251.

**Тура-** продуктив нигез: **турал-у, тураш-у, турат-у; турам; турамá, турагыч,** к. **Туракла-у** һ.б. Чаг. **Турбас – Турбаслы.**

**ТУРАҢГЫ, тораңгы** «тамариск, вид тополя» ~ каз. *тораңғы, тораңғыл, тураңғы* «зәңгәрсу яфраклы тупыл (Populus diversifolia)», чыгт. *тураңға* «усак төре» ~ монг. *to(γu)rai* «элмә» (Räsänen 1969: 484)? Үзб. *тураңғил* «сумалалы», кырг. *тоора* «кара тирәк». Гадәттә **туйра** (к.) белән чагыштырыла.

Сүзлекләрдә **тораңгы** «хөрмә; әфлисун» сүзе күрсәтелә. Аның чыгышы безгә ачык түгел.

**ТУРАЧ** «турач (птица семейства фазановых)» < чыгт., төр. (Будагов I: 346–347) *тураж, дурраҗ* id. Фар.-гар. теле даирәсеннән, к. Özön: 179. Тәүләп Бабур тасвирлаган.

**ТУРБАСЛЫ** –название речек, урочищ и нескольких населённых пунктов в Башкортостане – мар. *турбаслы, торбаслы*, чув. *турпаслă* «йомычкалы» ← мар. *турбас, торбас,* чув. *турпас* «йомычка» сүзләреннән булса кирәк. Легенда буенча, авыл корырга җир, уңайлы урын эзләп урманлыкта йөргән кешеләр бер елгачыкта яңа гына юнылган йомычкалар агып килүен күрәләр һәм, агым үренә барып, бер аланда бүрәнә юнып (өй салып) торган кешеләрне күрәләр. Шуннан болар белән бергәләп шул урында авыл коралар һәм авылны да, елгачыкны да **турбаслы** «йомычкалы» дип атыйлар.

Агып килгән йомычкалар буенча агым үрендә кемдер барлыгын белү-байкау мотивы алтайлы-куманды төркиләрендә (к. Баскаков 1972: 133) һәм японнарда *сусаноо* турындагы легендада (МНМ I: 113) билгеле. Ихтимал, бүтән төбәкләрдә дә бардыр.

Әйтергә кирәк, хәз. ул Турбаслы авылларында башлыча татарлар яши. Әмма **Турбасты** вариантына караганда, элегрәк башкортлар да булгандыр.

*Турбас* нигезенең үзен тел. *тормыш,* як. *туорпас* «кискә, бүләк» белән чагыштыралар.

**ТУРГАЙ** «жаворонок», диал. (Себер, Урал төбәкләрендә) «воробей» > удм. *турагай, тюрагай,* морд. *торкай* «тургай» ~ гом. кыпч., уйг., чыгт. *торғай,* башк. *турғай,* «тургай; чыпчык», гомумән – «вак кош төре» (шуннан **бузтургай** «дала тургае», **сибә тургай** «кечкенә купшыл», **ҡара тургай** «сыерчык», кырг. *жол тургай* «тай сыерчыгы», *молдо торгой, сопу (=суфи) торгай* «тургайның бер төре» һ.б., к. Будагов I: 744), ләкин госм., чыгт. (Радлов III: 840, 1184) *торағай* «карчыга төре; бекас», бор. чыгт. (Поппе 1938: 407) *torγai* «сыерчык», алт. *сары торко* «шәүлегән, сары тургай», хак. *торғай, торғойах* «сабан тургае», тув. *торға* «тукран» ~ монг. *тоғай* «төрле вак кош атамасы», к. ш. ук госм., бор. төркм. *доргай* «чыпчык» һ.б. Чув. *тăри* «тургай; сандугач» > мар. (Саваткова: 169) *тыри* «җаным, җанашым», (Иванов, Тужаров: 232) *торей, тырей, тŏрей* «тургай» < бор. төрки (ДТС: 579, 587) *torïγa, turïγa* «тургай». Барча вариантларның уртак нигезе **торуғай: -ғай//-қай* «кош» (чаг. **Карчыгай** һ.б.), *тору* сүзенең мәгъ. ачык түгел. М. Федотов (II: 198) буенча, чув. вариантының элгәре – **тăврий.*

М. Рясянен госм., чыгт. *туйғар, тойғар*, госм. *дуйғар* «чыпчык» сүзен *турғай* < *торғай* сүзеннән метатеза дип бара (Räsänen 1969: 490).

**Тургай** < *торғай* сүзе төрки телләрдән күп күрше телләргә үтеп кергән, мәс., рус. диал. (Аникин: 556) *торгай* һ.б. Морд. фольклорда *Торгай* легендар батыр (бу сүзнең «лачын» мәгънәсеннән булса кирәк).

**ТУРГАЧ** («Идегәй») «перекладина, подставка для охотничьих птиц» < *тургы агач* яки *тугыр агач*, к. иске *турғы* ~ каз., кырг. *туур* < *туғур* < чыгт. (Радлов III: 1163, 1432, 1445) *тоғур* id. – ихтимал бор. *тоғур* «аркылаш» (к. **Тура-у, Туры I**) сүзеннәндер.

**ТУРКА** «толстая шёлковая ткань», (к. мәкаль: *Туйга барсаң туеп бар, турка туныңны киеп бар*), «зерно на рынок», себ. (Тумашева 1992: 123, 214 (*Катыбаны қурласам, тон-тōрғадан кийәрмен* дигән эпик сәтырлар «хәтфәне яратмасам, бийләр тунын һәм ефәк кием киярмен» мәгъ. була) **тōрға** «дорогая шёлковая ткань» < гом. кыпч., хак. *торқа*, кырг., алт. *торқо*, *торғун* id., ш. ук «көбә өчен тукыма», уйг., чыгт. *торғо, турғу* «кәгазь документларны саклау өчен кулланыла торган чуар тукыма», уйг., алт. *торқо* «ефәк; ефәк тукыма», *қыл торқа* «кытай җитене (тупас һәм нык була)» к. Будагов I: 388–389 → к.-калп. *торқо* «җепсел, сүс», чыгт. *торғу, торқа* «кызыл сүсле киндераш», төркм. (ТДГДС: 173) *торқа* «зур капчык, кәрван капчыгы»; хак. *торғы*, тув. *торгу*, каз. *торғун* ~ монг. *торгон* «ефәк» ~ эвенк. *тоорғаа,* як. *торго* «тукыма» һ.б. (ССТМЯ II: 199), бор. төрки (ДТС: 578) *torqu* «ефәк». К. **Саламторхан.**

Кайбер тюркологлар (Рамстедт, Поппе һ.б.) бор. төрки *торқу* > *торғу* сүзенә рус. *торг* «сәүдә» (гом. слав. параллельләре белән) ~ эстон. *turg*, фин. *turku* «базар» сүзләрен нисбәтлиләр. Фасмер (IV: 82) бу гипотезага шикләнеп карый. Әлеге гипотеза файдасына шуларны да әйтергә була: тат. (к. ТТАС II) **турка** *(бодай* һ.б.*)* «базарда сатуга әзерләнгән (бодай һ.б.)», мар. кч. (Исанбаев 1978: 31) *торга* «кечерәк чатыр (< сәүдәгәр чатыры?)». Элекке заманнарда төрки сәүдәгәрләрнең төп шәйләре-товарлары ефәк тукымалар булган һәм рус. *торго* «ефәк, ялтыр җепле тукыма» шуннан, к. Аникин: 556 (бу сүзнең рус *торг* сүзенә нигез булуы кире кагыла). Иске рус. (Даль) *белотурка* «экспортка китә торган чиста бодай» сүзе дә безнең фаразны куәтли. Тувада (Тыва тоолдар, 6. Кызыл 1963: 159–160) кытай сәүдәгәрләре *кара торгу тон (тун)* белән сәүдә итәләр. Аз. (АДДЛ: 208) *дүргә, дүркә* «ефәк төргәге». К. **Туркан.**

**ТУРКАН** (нокр., ЗДС: 659) «вид насекомого вроде таракана» – ихтимал, бор. төрки *турқан* «чуар ефәк» сүзеннәндер, к. хәз. каз. (ҚТДС: 337) *торғын-торқа* «кыйммәтле кием-салым, парад киеме». Чаг. ш. ук. *камка таракан* «күзмәкүз», асылда **камка** «ефәк төре». К. югарыдагыны.

Тарихта атаклы *Таркан катун* – Харәзем ханбикәсе билгеле. Ихтимал, бу сүз хас исем түгел, титул булгандыр. Чаг. каз. *қыз-жібек* «кыз-ефәк», атаклы принцесса, бу сүз гомумән «принцесса» мәгъ. булган.

**ТУРЛАН-У** «покрасоваться; погордиться своей красотой» (к. мәкаль: *Тутый турланыр, турланыр да, аягын күреп хурланыр*). К. **Турла-у.**

**ТУРЛА-У** «украсить; очищать от пятен» и т.п. ~ гом. кыпч., уйг. *торла-*, кырг. *тордо-* «ямау; төзәтү, матурлау; болытлардан арындыру» < *тавурла-?* К. кырг. *тавурла-* «бизәү», алт. (Баскаков 1965: 27) *тавурлан-* «балку».

Ихтимал, **тур** сүзе белән баглыдыр. К. ш. ук **түрлә-ү**.

**ТУРЛЫК** (ЗДС: 659) «полог из камыша» (рус. *турлушка*) ~ каз. (Будагов I: 164, 369; Катаринский) *туурлық,* хәз. каз. *туырлық,* кырг. *туурдуқ* «тирмә кирәгәсе өстенә ябыла торган вертикаль ябу, гадәттә калын киез», чыгт. *турлуғ* «тирмә эчен бүлә торган чаршау (төрле материалдан була ала)». Чаг. төр. *torluk* «тур (к.) ясарлык; кыргыйлык; күмер яндыручы; балчык өй» > рус., укр. (Аникин: 570) *турлук* «җылы читән абзар», «түбәсез киң абзар». Гомумән, *тур* < *тōр* < *тоғур* «балчык яки камыш һ.б. дивар, эргәлек; читән, челтәр» сүзеннән шикелле. Ышанып әйтергә материалыбыз җитми. Һәрхәлдә **турлык** ул **торлак** түгел бугай. Чаг. **Турла-у.**

**ТУРМАН** иск. (Будагов I: 389) «снаряжение; прибор, сбруя» ~ каз. *тȯрман*, кырг. *турман*, к.-калп., ком. *ер-турман, ертурман* («ияр-турман») id. – ихтимал, **тур** сүзе белән бәйледер. Л. Будагов бу сүзне тат. *дурман* < фар. *дәрман* «ат даруы» сүзе белән чагыштыра.

**ТУРПЫ (туган-турпы, туган-турпак** сүзләрендә) «родственник; молодое поколение» к. **Торбак.**

**ТУРСАЙ-У** «надуться (обижаться)» < гом. кыпч., к. башк. *турһай-,* нуг., каз., хак. *торсай-,* алт., кырг. *торсой-* «күбенү, шешеп кабару» ← *турс* < *торс* «агач шеше» тамырыннан (к. **Тустак**); к. башк. (БТДҺ: 339) *турһы-у* < *турсы-у* «турсаю; кабарыну», к.-балк. *торсуқ-* «үпкәләп киреләнү» ← *торсу-* «күбенү». Монг. *дорсой-* «турсаю» төрки телләрдән. К. **Турсык.**

**Турсай-** продуктив нигез: **турсайыш-у**, (авызын, иренен, ияген) **турсайт-у; турсайган** һ.б.

**ТУРСЫК** «кожаный ларец; кузовок; небольшой мешок (из цельноснятой кожи мелких животных)» ~ чыгт. *турсуқ,* гом. кыпч. (нуг., к.-калп.) *торсық*

«саба», кырг., алт. *торсуқ* id., ш. ук «терескәк, терлекнең тубыгы, тез кабарынкылыгы; ору», тув. *дорз* «шешек; тырыс», *дорзуқ* «тез турысы кабарынкылыгы; турсык», алт. диал. *торсоқ* «кабарынкы (сөял)» ← *торсы-* «кабарып, бүлтәеп чыгу» фигыленнән, к. башк. *турһы-у* < *турсы-у* «турсаю» (к. **Турсай-у**), алт. диал. (Баскаков 1972: 255) *торсо-* < *торс-а-* «сөялләнү, кабарып чыгу», каз. (Радлов III: 1189) *торсуі-* «шешенү, күбенү, күперү». К. **Тустак.** Будагов I: 388. Рус. *торсук, торсык, турсук* «турсык, йөк капчыгы; бүрек төре; күн янчык, бурдак» тур. Аникин: 557–558, 571–572 (бик тәфсилле).

Төр., иске тат. (Максуди: 89) **дугырчык** «янчык» ~ бор. монг. *toγurčaγ* «чәчкап, чәч бөтеркәсе» > хәз. монг. *тоорцог,* бур. *тоорсог* «дүрт өлештән торган (өлешләр аерылып күренә) баш киеме», *турсыкка* да, *тубырчыкка* да катнашы юк бугай.

**Турсык** < *торсук* төрки телләрдән күп күрше телләргә кергән; рус. *торсук*, *турсук* «турсык» тур. Аникин: 557, 571 (бик күп әдәбият күрсәтә, *торс* тамырын һәм *торсы-, торса-* фигылььләрен искә алмый).

**ТУРТА** «отстой; вытопки» < гом. кыпч. *торта,* кырг. *торто,* алт., шор. *тордо, торда,* госм. *торту,* үзб., таҗ. *дурда* id. һ.б. (Räsänen 1969: 490), төр. *tortu* «утырма, юшкын; турта; куныk» мәгъ. Этимологиясе, гомумән, ачык түгел. К. ш. ук көрд. *tort* «түпрә». Хайрутдинова 1993: 92.

Дерив.: **турталы, туртасыз.**

**ТУРТАЙ** (БТДһ: 339) «бурдюк» << монг. *торстай* «турыслы» булса кирәк, к. **Турсык**. Чаг. диал. (трбс.) **туртай-у** «үпкәләү, чырайны сыту» ~ **Турсай-у** (к.).

**ТУРТЫЙ** (ТТДС I: 428) «дурачок, простяк (говорящий напрямик, не задумываясь)» – рус. сөйләшләреннән булса кирәк, к. Даль сүзлегендә (*дур* тамырыннан ясалган исәпсез күп сүзләр белән беррәттән) *дурандáй, дуры́нда* «тилемсә, беркатлы» һ.б.ш. Чаг. ш. ук чув. *туртăй* «тутый (кош)» (*-р-* монда интертеза).

**ТУРУК I** «вдруг» (Г. Кандалый; сөйләм телендә киң генә таралган сүз) < рус., әлбәттә. Бу сүзне **туры ук** дип тә аңлаткалыйлар. Ләкин к. чув. *тăрук* «кинәт; дәррәү» ~ мар. *трук,* удм. *турак* id.

**ТУРУК II** (Зимасов: 96) «направление». **Туры** сүзеннәнме икән, әллә гар. *ṭуруқ* «төп юнәлеш, барасы юл» (*ṭрқ* «юлда булу» тамырыннан) микән? Чаг. иске тат. **турук** «катгый инструкция».

**ТУРУН I** «спорынья» (БТДһ: 339 «арыш атаһы» дип аңлата). **Турун** сүзендә икенче иҗектә *-у-* килү бу сүзнең алынма яисә кушма сүз булуы тур. сөйли.

**ТУРУН II, торын** «внук, правнук» – бор. болг. (Иделдә дә, Дунайда да) *турун,* рус ядкәрләрендә *трунъ* (1230 елда) – шаншәрәфле титул ~ хәзәрләрдә (грекча язылышта) *τουδοῦος,* бор. төрки (ДТС: 584, 593) *tuduŋ, tutuŋ* «өлкә идарәчесе» (бу сүз бик күп составлы исемнәрдә, титулларда кулланыла). К. ш. ук төр. *torun* «онык, ике яшьлек дөя». Фасмер IV: 108; Хаков 1972: 31.

*Турун,* шулай итеп, болг. сүзе, ул кыт. *to-thoŋ* титулының чагылышы (шуннан ук к. **Туян)**. Тат. әд. теленә бу сүзне махсус рәвештә соңрак М. Җәлил һ.б. язучылар керткән. Чув. телчеләре (Егоров, Федотов) Чувашстанда күп кенә топонимнарда очрый торган *тăрăн, тăрăм* компонентын әлеге *турун* сүзенә нисбәт итәләр (Федотов II: 196–197), ләкин бу бик шикле чагыштыру.

**ТУРЫ I** «прямой; прямо» ~ каз., к.-калп. *туўры* < чыгт. *тугры* > уйг. *тогри*, кар. *дугуру,* төр. *doğru,* угыз. *doγru*, гаг. *доору* < бор. төрки (ДТС: 571) *doγru* «туры; дөрес» ~ тат. диал. (Тумашева 1992: 219), башк. *тура, турай,* иске башк. (к. Будагов I: 747), ног., к.-балк., ком., кырг. *туура [туwра]* «туры» ~ алт. *тура* «аркылы; иң; диаметр», хак. *тогыра* «каршы, туры (нәкъ каршында)», *туры* < *тугры* < *тогуру* һәм *тура* < *тугра* < *тогура* вариантлары булу бу сүзнең бор. *тогур-* (> хак. *тогыр-*) «аркылы кисү; турау» сүзенең (к. **Тугры**) хәл фигыль формасыннан лексикалашкан булуына өстәмә дәлил (к. **Тура-у**). ЭСТЯ III: 249–251 (нигездә безнекечә, тик Э.В. Севортян арытабан китеп **тогыр-* фигылен бор. төрки *toγ-* «югары күтәрелү» сүзе белән баглый).

Чув. *тӳрĕ* ~ мар. *töре, торе, тöр* «туры, дөрес, тугры» болг. теленнән булса кирәк; сүзнең палатальләшүе *-j-* тәэсирендә була ала: *тугры* > **туйры* > *тӳрĕ*. Федотов (II: 263) бу сүзне гом. төрки *тӳз* «төз» сүзе белән чагыштыра, ләкин бу дөрес түгел: чув. *тӳре* һәм тат. *туры* сүзләренең төрләнеш һәм сүз ясагыч парадигмалары тулысынча бердәй (мәс., тат. *туры килү* ≈ чув. *тӳрĕ килӳ*).

**Туры** продуктив нигез: **турылык, турыла-у, турыдан-туры** һ.б., диал. (Зимасов: 96) **турык** «юнәлеш». К. **Турында.**

**ТУРЫ II** «гнедой (о лошади)» > чув. *турă,* мар. *тор,* удм. *тöри* id. < гом. кыпч. *торы,* кырг., к.-балк. *тору,* госм. *тору, дору,* хак. диал. *торыг,* тув. *доруг,* бор. чыгт. (Поппе 1938: 213) *toruq,* чыгт., бор. уйг. (Gabain 1950: 42) *toruγ* id. Бу сүзнең кр.-тат. *тор,* хак. диал. *тоор,* төркм. *доор* варианты беренчел дип карала, к. ЭСТЯ III: 268–269; Федотов II: 251–252. Элек (һәрхәлдә татарларда) *туры ат (> турат)* – җигем атлары токымы булган. Чаг., һинд.-евр., рус. *тур* < *тоур* < сем. *thōr, tōra* «кыргый үгез», ш. ук «җигүлек үгез»: турлар *туры* төсмердә булганнар.

Туры ат тигез ачык кызгылт җирән төстә, ләкин ялы һәм койрыгы кара була. Бу төсмер бик матур саналган.

**ТУРЫНДА, турысында** «о, об» ~ искечә *туг-рында* (ш. ук *ул, шул, бу* сүзләре белән килгәндә – *турыда*), башк. *турала, тураһында, турыла,* тат. сөйл. *турыннан, турыларында* (стилистик үзенчәлек белән), каз. *туралы* һ.б. – *туры* сүзеннән (аның «күрше, каршы як» мәгъ.). «Турында» мәгъ. сүзләр төрки телләрдә бик төрлечә бирелә, тат. телендә дә төрлечә: *хакында* (*ул, шул, бу* сүзләре белән) *хакта*, иск. *бәянында* һ.б. Тат. вариант чыгт. *тоґрында, тоґрысында*, уйг. *тоґрисида, тоґрида,* төркм. *доґрусында, доґруда* сүзләре тәэсирендә карарлашкан, тат. сөйләм телендә *тур, турда* вариантлары да билгеле (*бу тур сөйләштек*).

Бор. төрки телдә делиберaтив мөнәсәбәтләр төшем килеш белән генә белдерелгән – тат. сөйл. *нәрсәне сөйләү (уйлау)* һ.б. шуны дәвам итә. Ләкин бу форма китаби тел өчен җитәрлек түгел, шунлыктан махсус бәйлек кирәк булган. К. Ахметьянов 1989 (керештә).

**ТУСМАЙ** (Тумашева 1992: 219) «дёготь» < *туз мае.*

**ТУСНАК** («Сиражел-қолүб», 1553), диал. **тоснак**, иске тат. **тюшняк** (История Татарии... 1937: 165) «домовой раб» > мар. диал. *тошнақ* id., удм. диал. (Тараканов 1985: 502) *тусноқ* «сукбай», ком. *туснақ* «төрмә; арестант» (> авар. *туснак* id.), кар. *туснақ, туснах* «әманәт, тотык; арест» > рус. (экзотизм) *туснак* «заложник» (Материалы по истории Башкирии: 19, 21) ← тат. диал. *тус-* < уйг., алт. *тос-* «тоткарлау» сүзеннән. К. **Тустыр-у.**

**ТУСРЫЙ** диал. «широколицый» ~ башк. (БТДҺ: 339) *тусрай* id. < фар. *тāстрӯй* «табак битле».

**ТУСТАГАН, тустыган,** диал. (ДС II: 78, 190; ДС III: 32; Хайрутдинова 2000: 47–48) **дустаған, дустыған, тустукан, тустакан** «глубокая (обычно деревянная), но небольшая чаша, стакан», (ЛТ: 12) «чаша для питья вина» < гом. кыпч. *тостақан*, к. каз. *тостаға,* чыгт. (Радлов III: 1211; Боровков 1961: 168–169), нуг. *тостақан,* кырг. *тостуқан* id. (әлбәттә, бу сүзнең бүтән төрле савытны белдергән очраклары да бар); рус. *достаканъ, дъстакан* «стакан» (к. Срезневский I: 715) тат. теленнән булса кирәк. К. ш. ук тув. *достаган* «кабарынкы-йомры».

Добруҗа сүзлеге (Dobr. III: 367) авторлары фикеренчә, алардагы *tastigay, tostagay, tastaqan ~ tostaqan* «тустаган, стакан» сүзе элекке төрки (кр.-тат.?) *tos-toqay* «түп-түгәрәк» сүзеннән, шуннан ук *tostoqaj* «түгәрәк тояклы ат», *tostıqay* «түгәрәк коңгыз» төре, нигезе *tokay* «алка, түгәрәк», к. **Тугай.**

Бу сүзнең икенче варианты тат., башк. (ДС II: 90; БТДҺ: 339) **тустақ,** *туҫтақ* «коштабак, агач чүмеч» < алт. *тостақ,* тув. *достақ* «кабарынкы-йомры, бүлтә», кырг. *тостоқ, тостоғой,* нуг. *тостақай* «акайган (күз)» (әйтергә кирәк, *тустак күз* тәгъбире тат. сөйләшләрендә дә очрый).

Безнеңчә, *тостакан* һәм *тостак* сүзләре бор. **тоста-* «бүлтәеп, бүселеп тору» фигыленнән (*тоста-қан* һәм *тоста-қ*), бу фигыль исә *тос* < *торс* «агач (бигрәк тә каен) орысы» сүзеннән (шундый орыдан савыт уйганнар), к. хак. *торс, торш* «агач орысы». К. **Турсай-у.**

**ТУСТЫР-У** «подержать ребенка над горшком (чтобы он помочился, опорожнился)», «подставить чашку» < гом. кыпч., к. кырг., кар. *тостур-* id., уйг. *тостур-* «тустыру» ← *тос-* ~ чыгт. (Будагов I: 394) *тос-,* үзб. *тўс-* «тустыру» сүзенең йөкл. юн.

Бу *тос-* исә каз., к.-калп., алт. *тос-* «аңду, каравыллап тору», кырг. *тос-* «аяк чалу», уйг. *тос-* «киртәләү, бөяү, тоткарлау, туктату», чыгт. (КБ) *тос-* «форсат көтеп тору» < яз. монг. *tos-, tosu-* «юлда очрату; очрашу өчен көтеп тору; юлын кисү» сүзе белән бердәй, к. Räsänen 1969: 490 (бәбине **тустыру, тусу** мәгънәләрен искә алмый). К. к.-калп. *тостыр-* «көттерү, чакырып чыгару».

**Тус-у** фигыленнән тат. диал., башк. **тосқа-у, төскә-ү** «озак итеп (мылтык һ.б.) төзәү» ~ монг. *тусгах* id. ясалган. Чаг. **Туснак.**

**ТУСЫН: тусын кебек** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «здоровенный», «неуправляемый» < төр. (Zenker: 608) *tosun* «яшь үгез» ~ төркм., уйг. *тосун* «кулга өйрәтелмәгән, дулап китүчән (терлек)»,

бор. төрки (ДТС: 578) *tosun* «тыелгысыз, дуамал» – төбендә «яшь як үгезе», «шактый үскән үгез бозау» (к. Clauson: 478) дигән сүз. Чаг. төр. *tos* «төкеш, мөгез белән бәреш».

**ТУТ I** «тутовник, тутовое дерево» < чыгт., фар.-таҗ. һ.б. *тут, туд* << санск. *tūda* id. (Platts: 341).

**ТУТ II** (ТТДС II: 309; ЗДС: 660–661) «благовоние; свежесть» ~ кар. *тут* id. Бу сүзнең дериваты **тутла-у** «кыш көне кардан, суыктан агару (юылган кер тур.)» сүзе киңрәк билгеле (*тутлат-у* «яхшырак агарту өчен махсус чиста кар өстенә җәю»). Фар. *дуд* «төтәс, төтәсләү; хуш ис» сүзеннән. Чаг. тат. диал. (Тимергалин: 483) **тут исе** – туңда киптерелгән кер исе.

**ТУТ III** «ржавчина» ~ мар. (Упымарий: 208) *тото* id. < гом. кыпч. (кайбер телләрдә теркәлмәгән) *тот* ~ яз. монг. *tot* id. Бу сүзнең фигыль коррелянты **тут-* < **тот-* сүзе дә булган, шуның интенсивлык формасы **тут-ык-у** (к. **Тутык-у**). К. шук **Тут IV. Тут III** сүзен **тат** (к. **Татыр**) сүзе белән дә тәңгәлләштерәләр. К. Федотов II: 256.

**ТУТ IV** «загар (на лице); веснушки» ~ чув. *тут, тутă* id. ~ алт. *тот,* төркм. *туту* «карачманлык». **Тут III** белән бердәй булса кирәк.

Дерив.: **тутлы, тутсыз; тутла-у.** К. **Туткыл, Тутлык-у.**

**ТУТА** (чаще встречается в форме вокатива **тутай**) «старшая сестра (не обязательно родная, единокровная); благородная девушка» > мар. (Исанбаев 1978: 9) *тотай* «кайнигәч, хатынның апасы» < нуг., к.-балк., кр.-тат. *тотай* «затлы нәселдән» (*тотай қыз* «кенәз кызы», *тотай хатун* «кенәз хатыны»). < монг. *тоотай* «санлы, хөрмәтле» ← *тоо* «сан». Тимергалин: 482.

*Тута* сүзен *түтә* белән чагыштыру (Räsänen 1969: 502) дөрес түгел: бу сүзләр арасында мәгънәдәшлек очраклы. К. **Туташ.**

**ТУТАШ** «барышня, мисс, мадемуазель» < нуг. *тоташа* «тутача»; төр. *tutač* > *tutaş* тат яисә нуг. теленнән кергән булса кирәк, к. Çagatay 1962: 17–34. К. **Тута.**

**ТУТКЫЛ** «участки пигментации на лице (от постоянного пребывания под солнцем или у беременных женщин)» < *тот-кыл: тут* < *тот* (к. **Тут IV**) сүзенә төс атамалары ясагыч *-қыл//-ғыл, -кел//-гел* аффиксы (чаг. *тимгел* < *тәмгил* һ.б.) ялганып ясалган.

Дерив.: **туткыллан-у, туткыллы.**

**ТУТЛЫК-У (тутлыкты, тутлыгу)** (ТТДС I: 430) «почернеть, потемнеть (о поверхности чего-либо)» ← *тут-* (к. **Тутык-у**) фигыленең дәвамлы интенсивлык дәрәҗәсе. К. **Тут IV.**

**ТУТЫ** сөйл. «то-то» ~ мар. (Саваткова: 162) *тоты* id. < рус. *то-то.*

**ТУТЫЙ** «попугай» < фар. *ṭūṭī* < санск. *тоту* id. күп төрки һәм монг. телләрендә очрый, к. Номинханов 1975: 196. Чув. *туртăш* < *тутый кош* тур. Федотов II: 254. Рус. *дутыш* «күгәрчен токымы» сүзен дә тат. **тутый кош** сүзеннән уйлыйлар.

**ТУТЫК-У (тутыкты, тутыгу)** «заржаветь» < ***тут-** фигыленең (к. **Тут III**) интенсивлык дәрәҗәсе. Шул (онытылган) фигыльдән **тутык** «тутыккан төш» сүзе дә ясалган.

Дерив.: **тутыктыр-у** (фигыльдән); **тутыклы, тутыксыз** (исемнән). Чаг. **Тутлык-у.**

**ТУТЫР-У** «заполнять, заполнить; наполнять, наполнить» < диал., башк. *тултыр-у* ← **тул-у** фигыленең йөкл. юн. К. **тул-у, тутырыл-у, тутырыш-у, тутырт-у.**

**Тутыр-** продуктив нигез: **тутыргыч, тутырма**, диал. (ДС II: 191) **тутыруқ** «тәмам тулы».

**ТУТЫЯ [тутӹйа]** «цинковая мазь для глаз; квинтэссенция; цинк» < гом. кыпч. *тотуйа* «купорос; тутыя» < фар. *тотуйа* id. < санск. *tuttha* «купорос», к. Бируни IV: 326–327.

**ТУ-У [тӹw-]** «родиться; рождаться», миш. (ЗДС: 662), себ. (Рамазанова 2001: 140) «родить» < гом. көнб. кыпч. *туw-,* уйг. *тоғ-, тоқ-,* бор. төрки (ДТС: 570) *toɣ-,* тув. *доо-* id. Көнч. кыпч. (каз., к.-калп., кырг.), уйг. диал., алт., үзб., хак., кр.-тат. *туw-* «тудыру», угыз. *доғ-* id., чув. *ту-* «ясау, итү». Бу фигыльгә бик охшаш сүзләр тунг.-маньч., кор. һәм фин-угор телләрендә очрый, к. Räsänen 1969: 483; ЭСТЯ III: 245–247 (Э.В. Севортян *туw-* < *тоғ-* тамырының *тоң-, туң-* варианты бар ди һәм аны *туң* > *тоң* «беренче бала» тамыры белән чагыштыра); Федотов II: 241. Рясянең бор. төрки *toɣ-* «туу»ны «аякка басу» мәгънәсеннән ди һәм барча

Урал-Алтай (кор. телен дә кертеп) лексикасында параллельләрен таба.

**Ту-** бик продуктив нигез: **тудыр-у, тудырт-у,** к. **Туган, Тума, Тумак** һ.б. *Туар* сүзен дә *ту-* < *туг, тоғ* нигезенә нисбәтлиләр.

**ТУФАН** «потоп; всемирный потоп (по священным писаниям)» < гар. *ṭӯфāн* id., төбендә «уйравык, чоңгыл» ← *ṭwф* «тирәли әйләнеп йөрү» тамырыннан (шуннан ук, *ṭавāф* «хаҗ кылганда Кәгъбәтулла тирәсендә әйләнеп йөрү»). К. **Таифә.**

**ТУФРАК,** диал. **тупрак, туфырак** «почва; пахотная земля», диал. «пыль» < иске уйг. *тофрақ* ~ кар., куман., чыгт., уйг., госм. һ.б. (к. Радлов III: 1226) *топрақ,* нуг., каз., к.-калп. *топырақ,* кырг., ком., к.-балк. *топурақ,* алт., чыгт. *тобрақ, тобурақ* > төр., бор. төрки (ДТС: 579) *topraq* «туфрак, җир; тузан; тузанлы, былчырак» ← *topra-* «тузанланып кибү (җир тур.)» ~ башк. *тупра-* (*тупран-ыу* «пычрану», к. БҺҺ II: 263) ~ тув. *довура-* фигыленнән. К. ш. ук як. *тобурақ* «яуган боз; тузан», тув. *довурақ* «җир; тузан; былчырак» ~ бур. *тоброг* «тузан», иске монг. *toburaγ, tobaraγ, toγuraγ* (вариантлары күп) «тузан» < *тобура-г,* к. алт. («кара татар» диалектында) *тобурул-* «тузан тузу», тув. *добура-* «тузан туздыру». Бор. *тобура-* «тузан тузу» фигыле *тобур ~ тоғур* «тузан, җир» (к. кырг. *топур*, монг. диал. *тоарай* id.) исеменнән, ә ул сүз гом. төрки *тооз* «тузан» белән бердәй (*тобур* > *тобуз* > *тооз*), к. Владимирцов: 210. *Тобур ~ тоғур* «тузан» нигезе, үз чиратында, (таранчы) *топа* ~ монг. *доба* «җир, балчык, тузан» сүзе белән чагыштырыла. Чаг. ш. ук чыгт. (Радлов III: 1158), бор. төрки (ДТС: 570) *toγ-* «тузан тузу; тузан» (ихтимал, **тоб-уг-* сүзеннән). Шулай итеп, **тоб* → *тобуг-* → *тобуғур* > *тобур* → *тобура-* → *тобурақ* > *туфрақ.*

Тат. *туфрак* үз мәгъ. Алтын Урда уйгурлары теленнән килә; тат. әд. телендә **тупрак** варианты «территория, ил җире» мәгъ. (**тупракчы** «территориаль автономия тарафдары») кулланылып килгән, ләкин тат. әд. телен вульгарлаштыру чорында (XX г. 20–30 нчы еллары) бу дифференциация оныттырылган.

Чув. *тăпра* «туфрак» болг. **тŏпраħ* < **топраг* вариантыннан килеп чыккан, ләкин чув. *тупрас, тăпрас* «туфракса» бор. тат. теленнән булса кирәк. Räsänen 1969: 489; Федотов II: 194 (бу авторларда тирән этимология бирелми). К. түбәндәгене.

**ТУФРАКСА,** диал., себ. (Радлов III: 1233–1234) **тобрақса** «подволока, рассадник, завалина»; сүзнең формаль мәгъ. «туфрак савыты» (*-са* савыт, кием, оя атамаларын белдерә торган кушымча, к. **Тупса**) ~ башк. *тупрақса,* – татар-башкорт даирәсендә генә. Чув. *тăпрас* < болг. **тŏпраħса* < тат. *тупрақса*; мар. (Упымарий: 210, 213) *тувраш, тупраш, тупырас, тувыраш* «түшәм; нигез туфраксасы» > удм. (Насибуллин: 141) *тупъраш* «туфракса»; фонетик закончалыклар буенча тат. *тупракса* > болг. **тупракса, *тупраħса* > чув. *тăпрас [тŏпрас]* > мар. *тупраш* > удм. *тупъраш.* Димәк, болгарлар бу сүзне татар (кыпчак) теленнән алганнар булып чыга. Бор. болгарларның төп торак төре – тирмәләр булган (бу хакта Ибне Фадлан да яза), туфракса исә буралы өйләргә өелә. Болгарлар туфраксаны һәм буралы торакны җирле төркиләрдән – бор. татарлардан үзләштергәннәр. Татарлар, димәк, болгарлар килгәнче үк Урта Идел регионында яшәгәннәр! Әйтергә кирәк, башкортлар да **тупракса** сүзен татар теленнән алганнар (югыйсә *тупрақһа*) булыр иде.

**ТУЧА** «еще не родившая (о коровах, овцах, козах)», диал. (ДС I: 192) **түчә** «дважды телившаяся корова» ~ башк. *тыуса* id., кырг. *туйча* «әле колынламаган өч яшьлек бия», үзб. (ЎХШЛ: 262) *тувча, тухчә* «бер яше тулган бәти», каз., к.-калп. *туўша* id. **ту** «кысыр, кысырга калдырылган» сүзеннән булса кирәк, к. **Ту I.**

**ТУШ I,** диал. (Будагов I: 395) **тōш**, (ТТДС I: 451) **туш, түш,** (ТТАС III: 180) **туыш** «наледь» ~ башк. (БҺҺ II: 259, 265) *төш, туш, түш, тыуыш* id. > удм. диал. (Насибуллин 1978: 141) *түш* id. ~ бор. төрки, алт., хак. (ДТС: 579; Радлов III: 1207, 1217) *тош* > *тос,* тув., монг. *дош, дожаң* ~ бур. *тошо, тошон* > алт. *тожон* «туш; боз каплаган җир, кишәр»; хак. *тошла-, торсла-* «тушлау, бозлану; сөялләнү». Соңгы мисал *туш* < *тош* < *торш, торс* дигән фаразга юл ача. К. ш. ук нуг. *тосап,* каз. *тусап, тŏсап* «туш» < фар.-таҗ. *турши-аб* «су сөяле» (?). К. ш. ук Пекарский: 2750.

**ТУШ II** (ЛТ I: 139), диал. **тушы** «момент, место (встречи, схождения)», «встреча» ~ алт., чыгт. (Боровков 1963: 316) *туш* ~ бор. төрки (ДТС: 590), фар., көрд. *tuş* > хак., нуг., к.-калп., як. *тус,* каз. *тŏс,* тув. *душ,* төркм. *дууш* «юнәлеш; каршы як; вакыт, момент» (кайбер сүзлекләрдә «вакыт, момент» һәм «каршы як, юнәлеш» мәгъ. омоним сүз-

ләргә бүлеп бирелә). Тат. әд. телендә **туш II** сүзе XVII г. бирле (к. Хисамова 1981: 140) *туш килү, туш булу* һ.б. составлы фигыльләрендә генә очрый һәм шул җәһәттән **дуч: дуч килү, дуч булу** сүзенә бик охшаш.

*Туш* (исем) белән беррәттән *туш-* «очрау» (к. ш. ук тув. *дос-* «каршылау») фигыле дә бар һәм шуннан тат. (ЛТ I: 139) *туш* сүзе белән *түш > төш* «урын» һәм чув. *тĕл* «очрашу урыны» сүзләрен бердәй дип карыйлар. Безнеңчә, бу дөрес түгел: **төш** «урын; нокта» һәм **туш** «урын; очрашу нок-тасы» сүзләрен бер тарихи-лексик берәмлек дип исәпләргә түбәндәге фактлар комачаулый: 1) бу сүзләрнең төп мәгънәләре тәңгәл булса да, мәгъ-нә структуралары тәңгәлләшми (*туш-* сүзенең фи-гыль коррелянтында «очрашу» мәгънәсе бар, *төш* сүзенең андый коррелянты юк һ.б.); 2) *төш* сүзе-нең чув. *тĕл* тәңгәллеге бар, бу факт *төш << түл* сүзенең борынгылыктан бирле палаталь әйтелешен дәлилли; 3) *төш* һәм *туш* сүзләренең валентлыгы бердәй түгел (тат. *туш килү, туш булу* бар, әмма *төш килү, төш булу* һ.б. юк). **Туш** сүзе револю-циягә кадәрге әд. тат. телендә еш кулланылган: **тушмасында, тушында** (**тушын**, хәтта **туш**) татар тарихчылары (Һ. Атласи һ.б.) телендә «турында» мәгъ. очрый. Будагов I: 394–395 (*төш, түш* һәм *туш* сүзләрен бергә карый); ЭСТЯ III: 304–306.

**ТУШНА** (ЗДС: 662) «тоска, грусть» ~ бор. төр-ки (МК, ДТС: 591) *tušna-* «дулкынлану, кичеренү». Шулай итеп, рус. *душно* сүзенең монда катна-шы юк!

**ТУЯН [туйан]** иск. «тойон, монгольский князь» < кыт., к. Аникин: 549–550.

**ТҮ** (ДС III: 168, гомумән киң таралган) «пше-но» ~ куман. (Радлов III: 1421, 1423) *туу*, к.-балк., төркм. һ.б. *түй* id. < уйг. (Радлов III: 1539) *түгі* «чистартылган дөге» ~ куман. *тү, түві* «дөге» (к. Räsänen 1969: 503). К. **Дөге.**

**ТҮБӘ** «верхушка, вершина; крыша, макуш-ка» > чув. *тупе,* мар. *тувӓ,* морд. *тĕбя* id. < гом. кыпч. *төбә,* кырг., алт., як. *төбө, дөбө* < бор. төрки (ДТС: 579–580) *töbü, töpü* ~ эвенк. һ.б. (ССТМЯ II: 128) *дувэ, дугээ, дуэ* «түбә; оч; елга башы», маньч. *дубэ, дубэн* «түбә, оч; елга тамагы» һ.б.

Бу сүзнең себ. (Тумашева 1992: 205) **тәбә** ~ кр.-тат., аз. *тәпә*, үзб., уйг. *тепә, теппә*, гом. угыз. *дэпэ, дәпә* «түбә, калкулык» варианты да киң та-ралган; гомумән, вариантлары күп, к. ЭСТЯ III: 297–299.

*Төбэ ~ тэбэ* сүзе фар.-таҗ. телләре даирәсендә дә киң таралган һәм күпсанлы топонимнарда оч-рый. Шунлыктан бу сүзнең чыгышын-этимонын да билгеләү кыен; *ö ~ э ~ ә* чиратлашуыннан чыгып, төп яңгыраш **түöппä* булгандыр дип фаразларга мөмкин. Будагов I: 384; Радлов III: 1269–1271; Му-хамедова 1973: 163; Федотов II: 262–263.

Дерив.: **түбәле, түбәсез; түбәлек;** һ.б. К. **Түбә-гәй, Түбәтәй, Түбәлә-ү, Түбәлдәк.**

**ТҮБӘГӘЙ** диал. (Төньяк Башкортстан, без тер-кәдек. – *Р.Ә.*) «с белой звездочкой на лбу (о корове)» < **түбәлкәй**, к. башк. (БТДҺ: 340) **түбәл** «түбәгәй» ~ каз. *төбел*, кырг. *төбөл*, үзб. (ЎХШЛ: 261) *төбәл, тувәл, тевәл* «терлек маңгаендагы ак тап» – **түбә** < *төбэ* (к. югарыда) сүзе белән баглы булса кирәк.

**Түбәл** < *төбәл* байтал (бия) элекке кыпчаклар-да (кыргыз, казакларда һ.б.) корбанлык булган, к. İnan: 122.

**ТҮБӘЛ, төбәл, төбәләк** «жертвенная лошадь (кобыла)» к. югарыда.

**ТҮБӘЛӘ-Ү** «снабдить крышей; сделать навер-шие (стогу и др.)», сөйл. «бить по макушке» ~ гом. кыпч. *төбәлә-* (еш кына *төбеле-* дип языла) id. ← *төбэ* «түбә». Чаг. **Тәпәлә-ү.**

Дерив.: **түбәләт-ү, түбәләш-ү** «сугышу, бәр-гәләшү»; **түбәләш** «сугыш (вак-төяк)». **Түбәләмә́** «конус, чүмәлә кебек өелгән».

**ТҮБӘЛДӘК** «(коническое) навершие; конус» < **түбәлек тәк** (**тәк** «түгәрәк», к. **Тәү**) булса кирәк.

**ТҮБӘН** «нижний, низкий; вниз» < гом. кыпч., чыгт. *төбән, төбән* id., уйг. *төвән* << бор. төрки (ДТС: 580) *töpün* «түбәнгә» > хак. *төбүн, төбĕн*, тув. *төвүн, дөвүн*, кырг., алт. диал. *төбөн* id. ~ тат. диал. (Тумашева 1992: 220) **түмән** < үзб. (ЎХШЛ: 261) *төмән*, көнч. кыпч. *төмэн*, кырг. *төмөн* id. гадәттә, *түп* «төп» сүзеннән диелә (Räsänen 1969: 493). Ләкин бу фараз фонетик закончалыкларга ярашып бетми. К. ш. ук Будагов I: 383–384.

Дерив.: **түбәнле, түбәнлек; түбәнтен** < (к.-балк.) *төбентин*; **түбәнчелек; түбәнәй-ү, тү-бәнлә-ү** (*түбәнләп бару*)**; түбәнсен-ү, түбәнсет-ү.**

**ТҮБӘТӘЙ,** (ТТДС I: 436) **тәбәтәй,** (ТТДС II: 323) **түбәкәй** «тюбетейка, ермолка» ~ башк. *түбәтәй*

id., башк. диал. (БТДҺ: 340) «материядән тегелгән хатын-кыз башлыгы; самавыр калфагы» > чув. *түпеттей* (экзотизм буларак), удм. диал. *түбäтäй,* мар. (Исанбаев 1978: 33) *тöвäтäй, тöбäтäй* «түбәтәй» – *түбә* < *тöбэ* сүзеннән монг. телләрендә ясалган: *тöбэ-тэй* «түбәле, түбәлек» (ш. ук *тöбэл-тэй* дә булырга мөмкин, к. **Түбәл**). Чаг. кр.-тат., чыгт. *тöпä* «мехлы бүрек (Кырым бүреге)», үзб. *туппи, дуппи* «түбәтәй».

**ТҮБЕР** «остатки; осадки» к. **Түпер.**

**ТҮГӘ –** междометие, которым гонят, зовут, отгоняют корову (конкретизация передаётся интонацией) к. **Түгәнәй.**

**ТҮГӘНӘЙ** «бурёнушка, ласкательное называние коровы» < бор. төрки *tüge, tügä* > төркм. *түве*, госм. *дүвэ*, аз. *дүгэ, дүйэ* «тана башмак». Clauson: 478; ДТС: 595. Бу нигез ир. телләрдән булса кирәк (*ду-* «ике яшьлек»?). **Түгә-нәй** дигәндә **нәй** аңлашылып бетми.

К. сыер затын чакыру ымлыгы *түбан-түбан, түгәй-түгәй, тывай-тывай, түңәй-түңәй, түгән-түгән*; куу ымлыгы **түгә** (*һәш, түгә, көтүгә!* диләр).

**ТҮГӘР, түңәр** «(правильный) круг, колесо» – Әбүлгази язмаларында махсус аңлатылган бу сүздән себ. **түгәрлән-ү** «тәгәрәү, йомарлану», **түгәрцәк, түңәрцәк** «әйләнчек» (ДС I: 184, 199; Тумашева 1992: 221) һәм башк. *түгәрлән-еү* «бөгәрләнү», *түгәрләт-ү* «тәгәрәтү», *түгәрел-ү* «әйләнү, уратылу» (к. БТДҺ: 340, 341) (к. ш. ук **туғарлан-у** «йомарлан-у», **туғалак < туғарлақ** «йомарлак», к. Тумашева 1992: 217) сүзләре ясалган; к. ш. ук төр. диал. *döğer, döver* «йомры, йомарлак» бу сүздән, төр. галиме Б. Өгәл буенча, бор. угыз кавеме *tüger, döger* атамасы, уртак мәгънәсе буенча «туплам» булып килә. Ахыр чиктә бу сүз *tüg* ~ *tög* «төен, төйнәү» тамырыннан (ди, к. Ögel 1993: 336–337). Ләкин, безнеңчә, *түгәр* < *тöгер* < *тäwгäр* < *тәңгäр,* к. **Тәгәр.** К. **Түгәрәк.** Чаг. **Дүңгәләк, Түңкә.**

**ТҮГӘРӘК,** диал. (Зимасов: 94) **төгөрик** «окружность, круг; окрестность», башк. *түңәрәк*, башк. диал. (БТДҺ: 340, 341) *түгерик, түңерек, түмәрәк* > чув. *түкерек* id. < гом. кыпч. *тöгэрэк*, кырг. *тöгөрöк*, каз. *тöңѣрек*, ком. *дёгерек* «түгәрәк», тув. *тöгерик* ~ монг., бур. *тöхэриг, тöхриг* «түгәрәк, әйләнә; тәңкә, тугрик (Монголиянең төп акча берәмлеге)», як. *тöгүрүк, тöгүрүмтэ* «түгәрәк, йомры» ← *тöгүрүй-* (к. Пекарский: 26116) *тöгүрүi-* «тәгәрәү, аунау; әйләнү». **Түгәрәк** сүзенең фигыль нигезе тат. телендә дә бар: к. диал. (Balint: 126) **түгәрә-ү** ~ к.-балк. *тёңере-* «түгәрәү, түгәрәкләнү», ком. *дёгере-* «тәгәрәү» ~ монг. *дүгрэ-* «тирәли әйләнү».

**Түгәрәк** < *тöгэрэк* варианты белән рәттән тат. (Тумашева 1992: 209) **тигәрәк** ~ кырг. *тегерек* варианты да бар.

**Түгәрә-** фигыль нигезе аңлаешлы рәвештә **түгәр** (к.) < *тöгэр* исем нигезеннән ясалган. **Тигәрәк ~ тәгәрәк** исә **тәгәрә-ү** сүзенең контаминацион тәэсирендә килеп чыккан. Як. *тöгүүр* «әйләнеч, урау» (< *тöгэ-wүр* < **тогэ-гүр*?) һәм *тöкүнүй-* «тәгәрәү», *тöкүнүк* «түгәрәк» сүзләренә карагандa, аларның тамыры **тöг ~ *тöк ~ *тöкэ > *түэкä* булса, шуннан **тöгэк* ясалса, *тöгәр тәгәр *тöгэкэр* вариантлары аңлашыла кебек.

Дерив.: **түгәрәкле, түгәрәксез; түгәрәклә-ү, түгәрәклән-ү; түгәрәкче** («һәвәскәр оешма катнашчысы» мәгъ.); **түгәрәкләп. Түп-түгәрәк < **түгәрәк-бә-түгәрәк.***

Монг. *тугрик* < монг. *тöгрöг* < яз. монг. *tögürig* «түгәрәк; тугрик» сүзен Аникин (: 559) чув. *тӗкӗр* (к. **Төгер**) «түгәрәк көзге» сүзе белән чагыштыра.

**ТҮГӘРҮК** (ТТДС II: 323) < **тугарук ~ туwарук, тыwарук, тwара, туара** (Хайрутдинова 1993: 95) ~ чув. *тăвара, тора* «творог; сырок». К. ш. ук **Тура.**

Бу сүз рус теленә кереп-чыгып йөргән сүзләрдән: **туарук** (урта *-к* белән) һичшиксез русчадан, ләкин рус сүзе (аның **тварог** варианты да бик билгеле) төрки телләрдән дигән фикер бар (к. Фасмер IV: 31), чаг. венг. *turo* «түгәрүк» **тура < туара** сүзенә охшаш сүзләр төрки телләрдә очраштыргаласа да, алар эзлекле бер үсеш линиясенә тезелмиләр. Ихтимал, себ. **тугарлан-у** «йомарлану» сүзенең тамыры **туғар* эремчек йомарлагын белдергәндер (к. **Түгәр**) һәм *туғар-* «йомарлау» фигыле булгандыр, шуннан инде **туғарығ* < **туғаруғ* «йомарланган (эремчек)» сүзе ясалгандыр. Ләкин моны исбатлыйсы бар.

**ТҮ́ГЕЛ,** диал. **те́гел,** (миш. һәм Чүпчә татарларында – тат. теле массивының ике аерым ягында, к. ТТДС I: 454) **тәгел,** м.-кар. **тигел** «не, не является (употребляется в постпозиции)» < гом. кыпч., уйг. диал., чыгт. *түгүл* > к.-балк. *тюйюл, тюл*, куман. *devül* ~ бор. тат. (Максудида) *дәңел, деңел,* иске тат., чыгт. *дәгел, дәкел, тäгил,* госм. *дэйил*, иске угыз. *тäгүл,* төркм. диал. *тәгил, дәйил, деел,* төркм. *дәәл* һ.б. (к. ЭСТЯ III: 213–214). М. Кашга-

ри аңлатуынча, бор. төрки *тегүл* (*tegül)* аргу төрки диалектындагы *дааг ол, ҙааг ол* сүзеннән үзгәргән. Хәз. тюркологлар бу аңлатманы җитди дип уйламыйлар. Кононов буенча (к. анықы Этимология слова *дегил* «не есть» // Советское востоковедение IV. 1949: 97–101), *түгел* < *түгүл* < *дьүгүл* < бор. төрки **дьоқ ол* «юк бул» сүзеннән. Ләкин бу аңлатма да бигүк дәлилле түгел (ул шор., хак. диал. *чогул* «түгел; юк» очрагына гына нигезләнә). Г.П. Мельников исә (к. анықы К этимологии отрицания *tegül* // СТ, № 4, 1970: 57–66) *түгел* < *тәгүл* сүзен бор. төрки *teg*- «тию» сүзенә бәйли. Безнеңчә, төп вариант *тәгүл* < **тәңкол* бор. төрки **тәнк* «буш, ноль, юк, әһәмиятсез» сүзеннән, к. **Тиген, Тик, Тикмә.** К. ш. ук Мухамедова 1973: 165–166.

**Түгел** сүзеннән **түгеллек** сүзе (ярдәмлек исем) ясала.

**ТҮГҮ** к. **Түк-ү.**

**ТҮЗ** диал. (ТТДС I: 448; БТДҺ: 341) «место разветвления (стволов дерева); устье реки; переносица», «кочерыжка; твёрдый стебель; скелет» (*Картлар сүзе – кәбестә түзе,* мәкаль; *түз генә калган* «остался только стебелек»), «основание, пьедестал» < бор. төрки (ДТС: 582) төр. *töz* «тамыр, нигез; асыл» > уйг., төр., алт. (Баскаков 1972: 124) *төз, төөз*, тув. *дөс [дөс]* хак. *төс* «нигез», хак., алт. диал. *төс* «берәр урынның даими рухы, шайтаны, бетмәс-үзгәрмәс субстанция» (рус телендә бу *тёс*лар тур. зур этнографик әдәбият бар). Алтын Урдадан калган яз. ядкәрләрдә *түзен* «аристократия, асылзатлар; дәүләт нигезе» < бор. уйг. *tözün* id. (к. Räsänen 1969: 495). Гомумән *түз* < *төөз* < **төңүз* «төпләр, төплек» булса кирәк, ләкин соңрак бик абстракт «үлми торган җан, берәр затның төп рухы, заяны» мәгънәсен алган. İnan I: 268–273 (*түрә-ү* сүзе белән чагыштыра).

**Түз** сүзеннән **түзлек** «умарта төре; чырак элү өчен чатлы ботак» сүзе ясалган. Себ. төрки телләрендә *төс* ~ *төз* бик продуктив сүзьясагыч нигез.

**ТҮЗ-Ү** «терпеть, выносить» > чув., мар. *түс-* < гом. кыпч., чыгт. *төз-* < бор. төрки **tör-* > венг. *tür-, turui-* id. (к. Федотов II: 265). Бор. төрки *töz-* «ак булу» дип аңлатыла (МК буенча ДТС: 583), ләкин бу аңлатма шикле. Безнеңчә, бу фигыль *түз* < *төз* «үзгәрмәс нәстә, үзгәрми тору» (к. югарыда) белән бер тамырдан булырга мөмкин.

Дерив.: **түзел-ү, түзеш-ү, түздер-ү; түзгесез, түзмәле; түзем,** диал. **түзмер.**

**ТҮКӘН** (ТТАС III: 286; БТДҺ: 341) «коротыш; карапуз», «ванька-встанька» < диал. **түңкән** id., ш. ук «яңа гына атлый башлаган бәби», к. каз. (Будагов I: 403) *түңкәндә-* «түкәнләү, егыла-тора йөрү»: Чаг. **түн-ү, түң-ү.**

Дерив.: **түкәнлә-ү, түңеш** «кыланчык» (?).

**ТҮК-Ү (түкте, түгү)** «пролить, проливать» < гом. төрки (к. Радлов III: 1242) *төк-*, як. (Пекарский: 2754) *тох-*, чув. *тăк- [тŏк-]*, угыз. *дөк-* id. ~ яз. монг. *tügü-* «таралу». Будагов I: 401; Räsänen 1969: 492–493; Федотов II: 186–187; ЭСТЯ III: 273–274.

Дерив.: **түгел-ү, түген-ү, түгеш-ү, түктер-ү; түгем** «чуен һ.б. кою»; **түгенте** (*түгенте су* «агып җыела торган су»).

**ТҮЛ,** диал. (ТТДС I: 448) **түлĕ** «готовность быть оплодотворённым или оплодотворять; растущие яйца в утробе курицы» < гом. кыпч. (Радлов III: 1260) алт., хак., тув., уйг., чыгт. *төл,* бор. төрки (ДТС: 579) *töl, tööl* «үрчүчәнлек; яшь буын; туар; чага; балалау чоры», угыз. *дөл* «түл; балалау, бала табу (хайванат тур.), токым; җенси органнар һ.б.ш.» (к. ЭСТЯ III: 274–276) ~ монг. *төөл* «еллык үрчем» > бур. *түл* id. Бу сүзнең *төш* ~ *дөш* дигән вариантлы да бар. Гомумән, бәхәсле сүз (к. Räsänen 1969: 493; Федотов II: 261; Мухамедова 1973: 173), тат. *түлĕ* ~ мар. *түлӧ*, к.-балк. *тёлю* «түл» варианты борынгырак вариант булырга мөмкин. Чаг. **Түлә-ү.**

**Түл** продуктив нигез: **түл-ле** «күп балалы, бала табучан» (*бүдәнәдәй түлле бул* – килен төшергәндә әйтелгән теләк), **түллә-ү** «бала табуга әзер булу; үрчү» > чув., мар. *туле-* id. Чаг. **Түлә-ү.**

**ТҮЛӘ, җиртүлә** «землянка для окота овец» ~ Добруҗа (Akb: 163) *töle,* каз. диал. (ҚТДС: 331) *төле*, каз. *төлө*, үзб. *тўла*, аз. *төвлә, төйлә* id. Чаг. төр. диал. (YTS: 72) *döllek* «куйлар кузыйлаган җир» ← *döl* «түл»; себ. (Тумашева 1992: 220) **түләгә** «саулык бәрән». К. **Түл.** Чаг. **Түлә-ү, Түләк**.

**ТҮЛӘК I** диал. «уплата; штраф» < чыгт. (Радлов III: 1261) *төләк* ~ тув. *төлег,* id. Гом. төрки сүз. К. **Түлә-ү.**

**ТҮЛӘК II** диал. (трбс.) «тихий, скромный, кроткий», «ягнёнок» ~ чув. *түлек* id. < чыгт. *түләк*, кырг. *түлүк* id.; бор. төрки (ДТС: 579) *töläk,* төр. (Мухамедова 1973: 173) *дөлек, төлек* «хәрәкәтсез; тыныч», *tüläk* «йон кою чоры», тат. диал.

(Тумашева 1992: 220) **түләгә** «бәрән» ~ хак. *тӧлеге*, алт. *тӧлӧгӧ* id. ~ монг. *тӧлӧг* «бер яшьлек бәрән» (йонын алмаштыру чагы), бор. монг. *tölgen* id. һ.б. К. ш. ук уйг. *төллә-* «йон алмаштыру» ~ кырг. *түлӧ-*, алт. *тӧлӧ-* һ.б., төр. диал. (YTS: 71) *dölek* «тыныч, ышанычлы», төр. *dülenmek* «тынычлану» ~ яз. монг. (ССТМЯ I: 223) *dölügen* «тын, тыныч», к. Будагов I: 403–404. К. **Төлә-ү, Төш.**

Бу сүздә, күрәсең, ике аерым сүзнең контаминациясе бар: бер яктан, **түлә-* > госм. *дүлә-* «тынычлыкта калу (йонын, каурыен алмаштырган хайванат кебек)», икенче яктан, **түләк** < *tӧläк* «яңа туым; бәрән» һ.б. Räsänen 1969: 504; Rona-Tas 1972; Номинханов 1975: 209; Федотов II: 261. Рус. *тулугун, тулюгун* «түләк» (< монг.) тур. Аникин: 562.

**ТҮЛӘК III** – имя героя одноимённого эпоса (к. **Заятүләк**). Ихтимал, **түләк II** сүзеннәндер. Ләкин. к. аз. (АДДЛ: 292–293) *түләк, түлән* «хәйләкәр, оятсыз», *түләнмәк* «оятсызлык кылу», *түлү, түлүңкү, түлүңки* «хәйләкәр; карак». **Түләк** образында хәйләкәрлек чалымнары да юк түгел.

**ТҮЛӘМӘ** «сибирская язва (опухоль горла у скота)» ~ кырг., каз. *түлеме, түлӓмӓ* id. ← бор. төрки *tüg* «төен» сүзеннән булса кирәк. Рус. *туляремия* сүзенең чыгышы ачык түгел.

**ТҮЛӘ-Ү** «платить, уплатить» > чув., мар. *түле-* < гом. кыпч., алт., хак., чыгт., уйг., тув. һ.б. (Радлов III: 1260–1261) *тӧлә-*, алт., кырг. *тӧлӧ-* ~ монг. *тӧлү-* бор. төрки (шор теләндә сакланган, к. Радлов III: 1260) *тӧл* «түләк (рус. “уплата”)» сүзеннән (*тӧл-ä-*), к. бор. төрки (ДТС: 579) *tölä-* «түләү», *töläč* «бәясең, чыгымын һ.б. түләү». *Тӧл* тамыры гом. төрки *түл* < *тӧл* < *тӧӧл* (к. **Түл**) сүзе белән бердәй булуы бик ихтимал, к. бор. төрки *tölä-* «бәрәнләү, бәрән бирү», к. тат. диал. (ТТДС I: 448) **түлә-ү < түллә-ү** «балалау, бала табу». Икенче яктан, чув. *тĕвĕле-* «төенләү, түләү» сүзе бор. гадәтне – бурыч билгесе итеп киндерәне һ.б. төйнәп куюны хәтерләтә. Ихтимал, *тӧл* < **тӧгүл* «төен, түл төене» сүзеннәндер. Räsänen 1969: 504; Федотов II: 261.

Дерив.: **түлән-ү, түләш-ү, түләт-ү.** К. **Түләк I.**

**ТҮМӘР, түмәркә** (Г. Бәширов) «пень, чурбан» ~ башк. (БТДҺ: 83) *дүмбәр, дүмәр* > чув. диал. *түмер*, мар. (Гордеев 1973: 44) *томер, томерка* < гом. кыпч., к. **Тумар.** *Том//тӧм* тамырыннан, к. **Түмгәк.**

**ТҮМГӘК** «пень (замшелый, старый); кочка» имеет много вариаций с едва уловимыми смысловыми особенностями (ДС II: 79, 80; ДС III: 54, 169; ТТДС I: 122; БТДҺ: 81–83, 341–342) **гөмбәк, дүмгәк, дүңгәк, түңгәк, түңкәк** һ.б. ~ каз. *дӧңбек, дĕңгәк, діңгек,* ком. *тёңгек,* алт. *тӧңкӧк,* төр. *tümbek* һ.б. «түмгәк; бүлтә, тумпа, кабарынкы» ~ чув. (Сергеев 1971: 129) *тумхах, тункаx, тăмхах, тонкак, тонхак* һ.б. «түмгәк», төр. *tümsek* «калкулык; түмгәк». Сүзнең морфологик составы буенча хөкем йөрткәндә, **тӧм-, *тӧң-* яки *тӧң* онопоэтик тамырыннан ясалган *тӧңкä-, тӧңүкä-, тӧмүкä-* «тумпаеп тору» фигыленнән; *тӧм-* фигыленнән дигән фараз файдасына тат. диал. **дөмгәк** «сазлык» шәһадәт итә. К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 213–220) *түң, туң, тоң* «сазлык эчендә калку җир; түмгәк, түмгәклек» ~ алт., хак. *тӧң, тоң*, каз., кырг., уйг., бор. төрки (Радлов III: 1731–1732) *дӧң* «кечкенә калкулык» ~ чув. *тĕм, тĕмĕ* «түмгәк» һ.б. барча телләрдә була торган *тум//том, тумб//томб, тумбул//томбыл* ономопоэтик тамырыннан, к. **Тумпа.** ЭСТЯ III: 279–281; Федотов II: 215, 245 (бу китапларда аңлатмалар биредәгедән тәфсиллерәк).

Дерив.: **түмгәкле, түмгәксез; түмгәклек; түмгәклән-ү.**

**ТҮН I** диал. (Г. Минский; әстр.) «путина» < рус. *тоня* «җылым; җылым белән балык тоту чоры; җылым салына торган урын» – гом. слав. сүзе, к. Фасмер IV: 77. Бу сүзне кр.-тат., төр. *ton, tun* (балыгы) ~ гар. (к. Kluge: 916) *тинн*, грек. *thun* «тунец» сүзе белән бутарга ярамас: *тун балыгы* Әстерханда тотылмый.

**ТҮН II** «задняя сторона, зад (*түнгә тарту* «тянуть назад») – **түн-ү** (к.) фигыленең исем коррелянты. К. **Түң, Түң-ү**

**ТҮНДӘК** «кадка для цветов; клумба; табурет», (ТТДС II: 324) «ступица колеса», «колодочный улей» – **түмгәк** сүзенең фонетик вариантларының берсеннән «югарылатып» килеп чыккан. К. **Түмгәк.**

**ТҮНДЕРБАШ** «болиголов (растение)» – «баш түндерү»дән. Ихтимал, русча атамасыннан калькалашкандыр.

**ТҮНДЕР-Ү: баш түндер-ү** «морочить голову» ← **баш түнү** «караңгылану, томанлану – аң, һуш» – түбендә «баш әйләнү», к. **Түн-ү.**

**ТҮНДИ КӨН, түндикен** (ТТДС I: 449) «понедельник (в пятидневной старинной неделе)» < чув. *тӳнти, тунти кун*. Болг. теленнән (асылда «туган көн» мәгъ.).

**ТҮНЕЛ-Ү, түңел-ү** «отказаться, отвратиться» ← **түн-ү, түң-ү.** К. **Төңел-ү**.

**ТҮНИ** (Тумашева 1992: 220) «совсем, совершенно» < рус. *втуне* «бөтенләй юкка».

**ТҮНТӘРМӘ** (ЗДС: 665) «рулет со слоем семян конопли» – *түнтәр-ү* (к.) «баш әйләндерү, исертү» сүзеннән булса.

**ТҮНТӘР-Ү, түңтәр-ү, түңгер-ү** «опрокинуть», «ставить вверх дном; перевернуть, свергнуть» ~ добр. *tönter-* id. << гом. төрки, алт., чыгт. *төңтäр-*, хак. *түңдер-*, бор. монг. (Поппе 1938: 339) *tüngеr-*, бор. төрки (ДТС: 580) *töŋdär-* id. ← *түн-, түң-* < *төн-, төң-* (аның «әйләнеп төшү» мәгънәсеннән, к. чув. *тун-* «әйләнеп төшү, түңкәрелү» → *тунтер-* «аудару, мәтәлдерү, дөмектерү»). К. ш. ук госм. *дӧндäр-*, аз. *дөндәр-* һ.б. «түнтәрү». Чаг. **Түңкәр-ү**, к. **Түң.** ЭСТЯ III: 276.

**Түнтәр-** продуктив нигез: **түнтәрел-ү** (шуннан **түнтәрелеш** «кискен барылыш»), **түнтәрен-ү** «котыру» мәгъ., **түнтәреш-ү, түнтәреш** һ.б. **Түнтәр** (диал.) «кире як, чүрә, тискәре» ← **түнтәрлә-ү** «аударып ташлау» сүзләрендә кире сүз ясалыш күзәтелсә кирәк, ягъни фигыль нигезе (*-тар//-тәр* кушымчасына беткән йөкл. юн. формасы) соңыннан исемгә әверелгән.

**ТҮНТЕК** диал. «отказник; быстро отказывающийся, бросающий дело» – **түн-ү** сүзеннән. Чаг. **Төнтек.**

**ТҮН-Ү,** сирәк **түң-ү** «падать (лицом вниз); впасть (в определённое состояние); превратиться; отвращаться; идти назад; махнуть рукой (потеряв надежду)» ~ чув. *тун-* < куман. һ.б. (Радлов III: 1249, 1733), кар., кырг. *төн-*, чыгт. *төң-* «кирегә әйләнү, кайту, дүнү» (к. **Дүн-ү**), төркм. (Мухамедова 1973: 1973) *дөөн-* «түнү». Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 271) сигез вариант *тун-, дун-, төн-, дөн-* һәм *түң-, туң-, дүң-, дуң-*нәрне карап, монда төптә ике фигыль бар дипраслый. Чыннан да, монда тамыр сузыгы ике төрле булуы юкка түгел. Ләкин тат. телендә көтелгән закончалыклы *төң-* яисә *дөң-* вариантлары юк. Федотов II: 262 (тәфсилле).

Дерив.: **түнел-ү, түнеш-ү, түндер-ү, түнек-ү; түнек**, к. **Түн II**. Чаг. ш. ук **Түңел-ү.**

**ТҮҢ** (Тумашева 1992: 220; ЗДС: 639, 645, 657, 665) **тоң, төң, туң** «холм; кочка; комель (рубленого топором ствола)», **түң** ш. ук «түгәрәк савыт төбе», «төп як»; төрки телләрдә иң продуктив характерлы тамыр булса кирәк, аның монг. һәм фин-угор. телләрендә дә параллельләре бар. Әлбәттә, мондый тамырның фигыль коррелянты да билгеле. К. тат. телендә генә:

| исем нигездән | фигыль нигездән |
|---|---|
| *түң < төң > дөң > дөм* «түгәрәк кабарынкылык, түмгәк» | *түң- > тун- < төң- > дөң-* «йомылу, өелеп аву» |
| *түңек-, түнек-, төңек-* | *түңел-ү* |
| *дөмек-* һ.б., | *түңеш-ү; түңеш > түнеш* |
| *түңкә- > түңкәй-* | *түңтәр-ү > түнтәр-ү* |
| *түңкә > түңкәл-ү* | *түңлә-ү* |
| *түңкәй-ү, түңкәр-ү* | *түңкә-ү, түңкәр-ү,* |
| *түңкәч* | *түңкәк > түмгәк* |
| *түкән < түңкән* һ.б. | |

Бу сүзләрнең веляр вариантылары азрак, без аларны санап тормадык. Ш. ук гом. төрки параллельләрен дә санамадык. Бу сүзләр охшаш тамырлар һәм нигезләр (алар бихисап) белән тәэсирләшеп контаминацияләргә кергәннәр. К. түбәндәгеләрне.

**ТҮҢЕЛ-Ү** «отказаться, передумать» < чыгт., уйг. (Радлов III: 1543) *түңүл-*, як. (Пекарский: 2773) *тӧнүн-, тӧңүн-* < бор. төрки (ДТС: 580) *töŋül-* һ.б. id., әлбәттә *тун-, түң-* фигыленнән. Чаг. **Түңкәр-ү.**

**ТҮҢКӘ** «перевёрнутый (вверх дном, корнями вверх и т.п.)» ← *тун, түң*. К. ш. ук монг. *түңкэ* «агачның түңе, түң ягы». К. **Түңкәр-ү.**

Дерив.: **түңкәй-ү** «туңкаю; дөмегү, бетү» (к. ТТДС I: 451) ~ як. *тӧңкӧй-* id. Чаг. **Туңкай-у.**

**ТҮҢКӘР-Ү** «опрокинуть; перевернуть вверх дном (посуду), кантовать» < гом. кыпч., чыгт. *төңкäр-*, кырг. *төңкөр-*, алт. *кӧнкӧр-*, як. *түңнэр* һ.б. id. Чаг. **Түнтәр-ү.** *Түңкәр-ү* сүзе тат. телендә *түңкә* сүзеннән килеп чыга ала (*түңкә-р-*), ләкин гом. кыпч. һ.б. *төңкäр-* фигыле *төң-* «кире әйләнү һ.б.» (к. **Түн-ү**) фигыленең йөкл. юн. һәм тат. сүзе шуннан дип уйларга кирәк.

Дерив.: **түңкәрел-ү (→ түңкәрелеш** «революция»**), түңкәрт-ү.**

**ТҮҢКӘЧ** «малыш, едва начинающий ходить (падающий на каждом шагу); ванька-встанька» ← *түн-ү* (булса кирәк). Чаг. ш. ук алт. (Баскаков 1972: 256) *тöӊеш, тöӊöч, тöӊöжöк* «түмгәк, тиле». К. **Түң.**

**ТҮП I** – имитатив шагам и падению ребенка, едва начинающего ходить» (**түп итү** «егылу – бала тур.»).

Дерив.: **түп-түп (итү); түпелдә-ү**. Чаг. **Түпәй.**

**ТҮП II**, **түпе** (ТТДС I: 447) «выжимки, жмых; крошки» < гом. кыпч., үзб. (ЎХШЛ: 262) *тöп,* нуг., кырг. *топ* id. ~ бур. *тобог* «чүп». Чаг. үзб. *турп* «түп». Бу тамырдан күп кенә сүзләр ясалган, к. **Түбер, Түпер, Түпрә, Чүп, Чүпрә, Чүпрәк.**

**ТҮПӘЙ** – имитатив падению малолетнего ребенка на ходу ~ башк. (БТДҺ: 329, 337) *төпәй, тупай* id. – **Түп I, Туп III** ономопоэтик сүзләреннән ясалма булса кирәк. Ләкин к. фар. *дупак* «ике аяклы; аягына басып йөри башлаган нарасый», башк. *түпәйә* – бер ыру атамасы (*Тугыз түпәйгә бер акыл* дигән мәзәк мәкаль бар), каз. *топай,* кырг. *топой* «бәкәл сөяге».

Дерив.: **түпәйлә-ү;** фразема: **түпәй булу.**

**ТҮПЕР, түбер** (ТТДС: 288–289) «остатки, очёски, жмых; спитая заварка и т.п.» ~ башк. (БТДҺ: 324, 342) *төбөр, түпер* «мамык калдыгы; түпрә; камыл; түмгәк; агач төбе (бу соңгы мәгъ. – **төп** сүзе тәэсирендә), *түпер* «дебет калдыгы; түпрә», каз. *түбір,* к.-калп. *түбир* «камыл; төп; тамыр». К. **Түпрә, Чүпрә, Чүпрәк.** Себер сөйләшләрендә еш кына бер үк авылда *түбер ~ түпер ~ чүпер* «түпер», шуннан **түберәк ~ түперәк ~ цүперәк ~ цеперәк** «чүпрәк» дип сөйләшәләр (к. Баязитова 2001: 163–166). *Түпер ~ түбер ~ чүпер ~ чүбер* вариантлары бор. төрки шивәләрнең Себер сөйләшләре шикеллесендә барлыкка килеп, төрле вариантларда бүтән төрки телләрдә карарлашкан булып чыга. Ошбу факт себ. тат. сөйләшләре иң бор. төрки телләргә якын дигән фикергә илтә. Бүтән хәз. төрки телләрдән *т ~ ч* тәңгәллегенең еш очравы чув. телендә күзәтелә.

**ТҮПРӘ** «осадок вина». Бу сүзне **түп** һәм **түпер** сүзләреннән аеру кыен. Шул ук вакытта **чүпрә** сүзеннән дә аерылмый, әлбәттә. Ихтимал, **түпрә** болг. **түберә* «төптә, төптәге» сүзеннән киләдер һәм гом. төрки *чöпүрә* сүзенең борынгырак вариантыдыр. *Тöп > түп* һәм *түп > төп* тамырлары төптән аерым булырга тиеш, ләкин кайбер ясалмаларда алар контаминацияләнгәннәр, күрәсең. К. югарыдагыны.

**ТҮР I** «место против двери; почётное место в комнате (красный угол); внутренность» > мар., удм. *тöр* < гом. төрки, бор. төрки (Радлов III: 1249) *тöр*, бор. төрки (ДТС: 580) *tör, törä* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 353) *töre* id. Будагов I: 387; Räsänen 1969: 494.

Күп кенә телләрдә бу сүз *түр* < *тöр башы* тәгъбирендә килә.

Дерив.: **түрле** (*ишекле-түрле* сүзендә һ.б.), **түрлек, түрлә-ү** «түргә узу, карьерага омтылу».

**ТҮР II** диал. «орнамент, бордюр верхней кромки стен» > мар. *түр, тěр,* чув. *тěр, тěрě* «чигеш, үрнәк, бизәк» < гом. кыпч. (каз., кырг., алт.) *түр* id. ~ каз. (Будагов I: 387) *түвер, түр* «чигешле баш киеме». Тат. *түwер* булган. Чаг. **Тур, Турла-у.** Räsänen 1969: 506; Номинханов 1975: 261 (каз., кырг. *түр* сүзен калм., монг. *дүр, дүри* «йөз, кыяфәт, форма» белән чагыштыра), Федотов II: 219 (бөтенләй урынсыз рәвештә *тирәк* һәм *тур* «челтәр» сүзләре белән чагыштыра).

Дерив.: **түрлә-ү** «диварларны бизәү», **түрләмә** «дивар чаршавы» һ.б. (ТТДС I: 150 бу сүзләрне **түр I** сүзенә нисбәт итә, ягъни «түр башына эленгән бизәкле тукыма» булып чыга).

**ТҮРӘ** «чиновник, начальник», иск. «судья», диал. (Тумашева 1992: 221) «старший брат мужа» > чув. *түре*, мар. *тöрä*, удм. *тере, тöрö, тöро* id., ш. ук «туйбашы» < гом. кыпч. (нуг., каз., кар.) *төрә*, кырг. *төрө* «түрә» < уйг., чыгт., госм., шор. (Радлов III: 1250–1253) *тöрä* «принц; асылзат; патша чиновнигы»; кайбер телләрдә (к.-балк., ком., кар., бор. чыгт.) *тöрä, төрә* «суд, закон; гадәт, йола», бер төркем телләрдә (к.-калп., госм., уйг.) бу сүзнең һәр ике мәгънәсе дә очрый. Өченче мәгъ. – тув. *тöре*, уйг., бор. төрки (ДТС: 581) *törü* ~ гом. монг. *төрө* «идарә, тәртип; туй тәртибе» борынгырак булса кирәк: *түрә* ← *түрәче* (лексик эллипсис) «закончы» мәгъ. күчеше бор. кыпч. сөйләшләрендә барлыкка килгән. А. Донук буенча (Donuk: 85–87), *төре* сүзе бор. төрки кавеме табгачларда III г. «кагыйдә, закон» мәгъ. йөргән. К. ш. ук Будагов I: 390–391 (бик тәфсилле, *түрә, түрә-ү* һәм *түркен* сүзләре бердәй нигездән булса кирәк ди); Räsänen 1969: 495; Номинханов 1975: 119–120; Федотов II: 263–264 (тәфсилле).

Дерив.: **түрәлек, түрәлән-ү.** Туй йолаларында **түрә, түрәлә-ү, түрәле** тур. ЗДС: 666.

**ТҮРӘ-Ү** (ДС III: 168–169) «родить; творить; производить», «умножаться» < гом. кыпч. **төрэ-* (к. кар. *тёря-*, кырг. *төрө-*, каз. диал. *дүре-*) id. ~ уйг., чыгт. (Радлов III: 1255) *töре-*, тув. *төрү*, як. *төрөө-,* хак. *төрі-,* бор. төрки (ДТС: 581) *töri-,* төркм. *дөре-* ~ бор. монг. *törü-,* хәз. монг. *төрэ-,* бур. *түрэ-* «түрәү; түрәтү» (ягъни төп юн. белән йөкл. юн. бергә килә) ~ тунг. *дэрүү*, маньч. (к. ССТМЯ I: 237) *дэрибу-* «башлау; башлану». К. ш. ук төр. *türe-* «кинәт килеп чыгу», *türet-* «җитештерү» > тат. (яңа телдә) **түрәт-ү** id., башк. (БТДһ: 342) *түрәргәле* «вакыты җитеп туган». Бу сүз, ихтимал, **түркен** (к.) белән тамырдаштыр. К. **Түрем.** ЭСТЯ III: 283–284. İnan I: 268–273 (**түз** белән чагыштыра). Төр. телендә *түрә-* фигыле күптөрле яңа терминнар ясау өчен кулланыла.

**ТҮРЕК** – название древних тюрков в литературе. К. **Төрек.**

**ТҮРЕМ** диал. «толстый (в одном месте); беременная» (*түрем башак* «полный зёрнами колос») ← диал. **түрĕ-, түри-* (к. ДС III: 168–169) «бала табу» (*түрә-ү* фигыленең борынгылыктан килгән фонетик варианты, к. **Түрә-ү**) булса кирәк. Хәер, *түрем* < миш. *түwерем* «төерем» сүзеннән дә килеп чыга ала. К. **Төер-ү.**

Дерив.: **түремәй-ү** «юанаю, авырга узу» (ДС I: 161, 169); диал. *турымай-у* id. варианты аңлатмага мохтаҗ (ихтимал, *туыр-ым?*).

**ТҮРКЕН, түрген, түргүн** диал. (Тумашева 1992: 221; ЗДС: 666–667) «отчий дом невесты, женщины; обычай посещения отчего дома после выхода замуж» ~ башк. (БТДһ: 342) *түркен,* добр. *törkĭn* id. ~ гом. төрки *түркүн, төркүн,* бор. төрки (ДТС: 581) *törkün* «кәләшнең, киленнең нәсел-ыруы, туган йорты» – бик бор. сүз һәм төшенчә, к. як. *төркүт* «түркен йоласы». К. **Төрген, Төркем.** Чаг. **Түрә-ү.**

Дерив.: **түркенлә-ү** «ата-ана йортына махсус килеп, үз кирәген алып китү»; **түркенчәк** (башк. *түркенсәк*) «ата-ана йортына еш килүчән».

**ТҮТӘ I (түтә-се, түти < түтә-й)** «тётя», «старшая сестра» (к. Рамазанова 1991: 35–36, 39–41) рус. *тётя* һәм *тута (← тутай)* сүзләренең контаминациясе. Диал. *тәтәй* һәм *түтек* сүзләре дә шул юл белән ясалганнар. *Түткәй* < *түтекәй* < *түтикәй* – иркәләү формасы. Нәсел-нәсеп терминнары өчен аеруча вариантлылык һәм яңа формалар, кабаттаркалу, контаминация күренешләре хас. Чаг. **Тута.**

**ТҮТӘ II,** диал. (Ш. Маннур) **төйтә** «тыльная, обратная сторона топора, ножа, а также приклад ружья» ~ башк. *төйтә*, *төйҙә* < нуг. *түйде* ~ төр. (Zenker: 441) *döğdü, düğdü, dövdü,* чув. *тӳрте* id. Ачык түгел. Бәлки **төй-ү** фигыленнәндер.

**ТҮТӘ III** (*Арка җиркәйләрдән болан үтә, Арка җирдән юллар түтә, дип*. С. Кудаш китергән җыр.) диал., башк. «прямая (дорога по гребню горы), прямая линия между двумя точками на местности» < уйг., үзб. (ЎХШЛ: 262) *төтә*, каз. *төте,* кырг. *төтө* < яз. монг. *döte* id., маньч. *дутэ* «туры сукмак» < *дуғутэ* id. ← **tuk, tuq* «дамба» (к. ССТМЯ I: 219). Бу сүз төбендә Бөек Кытай диварын белдергән дигән фикер бар.

Мар. (к. Упымарий: 218) *түткĕн* «түтә, туры» тат. сөйләшләреннән булса кирәк. К. ш. ук як. (Räsänen 1969: 495) *tötölüj-* «ашыгу, түтәләү».

**ТҮТӘЛ** «грядка, ров между грядками», диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «часть земельного участка» > мар., чув. *тӳтел* < бор. кыпч. *татуул* < *татаwыл* (нуг. *татавыл,* ком. *татавул*) «канау, түтәл ерынтысы, кечкенә арык» < уйг. диал. *тартаwыл* id. ← *тарт-* «туры чокыр казу» (хәз. уйг. *чөнәк тарт-* «түтәл казу»), төбендә «тартылган шнур буенча казу» сүзеннән. К. чыгт. (Радлов III: 860) *тартау* < **тартаул* «канал» ~ яз. монг. (Поппе 1938: 343, 447) *tataal* «арык», *tatuul* «туры елга; канау» һ.б. Сүзнең фонетик үсеше *тартаwул* > *татул* > тат. **тәтүл* > *түтәл* (тат. телендә палатальләшү һәм *ә-ү* > *ү-ә* сингармоник чылбырларның үзгәрү нәтиҗәсе).

Дерив.: **түтәллек, түтәллә-ү.**

**ТҮТӘНӘ** (ТТАС III: 290) «особенно крупный (о скотине)» ~ каз. *төтен* «кинәт», *төтенше* «аеруча», кырг. *төтөн* «аеруча», төркм. *төтен* «очрак». Гомумән, ачык түгел. К. түбәндәгене.

**ТҮТӘП** (ТТАС III: 290), **төтәпле** (ТТАС III: 270), **тутәппел** (ЗДС: 661) «могутный, сильный (телом и духом)» ~ каз. *төтеп* «кару, каршы тора алучанлык», к.-калп. *төтепки* «чыдам, түзем», кырг. *төтөп* «иркен яшәү хәле». Гомумән, ачык түгел.

**ТҮТӘРӘМ** (ТТАС III: 290) «четверть, четвертинка; одна шестая десятины; 400 граммов» (измерительные значения являются эллипсисами от прежних названий мер и площади, и веса: *түтәрәм җәриб* и *түтәрәм балбатман*), к. **Җәриб** һәм **Батман**) > мар. (Исанбаев 1978: 14) *тӧтӧрем* «дүрттән бер өлеш» < болг. **түәт-әр-әм* > чув. *тăваттарам* «дүртенче (өлеш)». Шунысы кызык ки, чув. телендәге *түтерем (җир)* тат. теленнән алынган! К. болг. эпитафияләрендә *түәт, туат* «дүрт» < гом. төрки *төрт* id.

**ТҮТЕК** «дудка, дудочка» (к. БТДҺ: 342) ~ чув. *түт* id. кырг. *түтүк,* аз. *түтәк,* чыгт. *түтä* (к. Радлов III: 1571–1572), үзб. (ЎХШЛ: 93) *дүүдик* «флейта»; иске угыз., төр. *düdük,* төркм. *түйдүк* id. > мар. *түтүк* «көтүче быргысы һәм шуның тавышы», удм. *тутэктон* «түтек» һ.б. киң таралган имитатив тамырдан (к. ш. ук рус. *дуд-ить, дудка,* ним. *tuten, dudeln* «түтек кычкырту» һ.б.ш.). Егоров 1964: 267.

**ТҮТҮРҮШ** (ТТАС III: 290) – слово ругательства – собственно «гомосексуалист» < үзб. *кутфуруш, кусфуруш* «күт сатучы».

**ТҮФӘЙЛИ** «блюдолиз, человек, любящий ходить в гости; незваный гость» < гар. *ṭуфайлӣ* id. ← **Туфәйл** дигән бер гар. исеменнән, имеш, к. Будагов I: 737. Бу сүз мөселман төрки телләрендә очрый.

**ТҮФӘНК, түфәң** иск. (Будагов I: 363–364) «ружьё восточного производства» ~ төр., кр.-тат., аз. *töfenk* id. < фар. *түфäнк* id. диелә. Безнеңчә, үзб. һ.б. *тупанчә* id. (к. **Табанча**) белән тамырдаш.

**ТҮШ I,** диал. (ДС I: 182) **тĕwĕш, түвĕш** «плоскость груди; женская грудь» > чув. *түш* < гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 582) *töš,* угыз., төркм. *дӧӧш* ~ монг. *дӧш, дӧӧш,* як. *түӧс* һ.б. id. (кайбер икенчел мәгънәләре дә бар, к. ЭСТЯ III: 286–287) < фар. *dōš* < авест. *daoš* ~ һинд.-евр. **dous* «түш, ике кул арасы» (Pokorny: 226), к. **Түш II.** Räsänen 1969: 495; Федотов II: 265.

Дерив.: **түшелдерек, түшле, түшлек**. К. **Түшти.**

**ТҮШ II** «полевая наковальня» ~ алт. диал. *тӧжи*, кырг., тув. *дӧжү* id. Ихтимал (Э.В. Севортян буенча), **түш I** белән бердәйдер. Бигүк ышандырмый.

**ТҮШӘ** (ЛТ I: 140) «дорожная провизия» < фар. *түше* id., ш. ук «багаж» – чаг. бор. төрки (ДТС: 583) *tözi, tözü, tözügü* «барчасы бергә».

**ТҮШӘК** «перина, матрац, тюфяк» > чув. *түшек*, мар. *түшäк, тӧшак*, удм. *тушак, түшäк* < гом. төрки *төшәк* (нуг., каз., к.-калп. *төсек*, хак. *төзек*, алт. *төжӧк*, тув. *дөҗөл* һ.б.) id. < бор. төрки (ДТС: 582) *töšäk* «ятак» һ.б. *түшә-* < *төшә-* фигыленнән, ләкин бу фигыльдән киңрәк таралган (күп күрше телләргә кергән, к. ЭСТЯ III: 335). Рус. *тюфяк* «түшәк» сүзенең конкрет кайсы телдән кергәнлеге ачык түгел. Федотов II: 265–266; Аникин: 578.

Дерив.: **түшәкле, түшәксез;** иск. **түшәкче** (зөфаф кичәсенә түшәк җәюче).

**ТҮШӘМ** «потолок» > мар. (Упымарий: 209) *тӧшäм, түшäм* id. – **түшә-ү** фигыленнән тат. телендә ясалган.

**ТҮШӘМӘ** «настил» ~ төр. *döšeme, düšeme* «түшәмә, түшәлгән нәрсә, юллык, келәм һ.б.» ← **түшә-ү.** К. **Түшә-ү.**

**ТҮШӘ-Ү** «стелить (постель и т.п.)» < гом. кыпч., чыгт., уйг. *төшә-* (нуг., каз., к.-калп. *төсе-,* кырг. *төшӧ-*) < бор. төрки (ДТС: 582) *töšä-* > аз. *дӧшә,* госм., кр.-тат. *түшä, дүшә-,* төркм. *дүше-* id. ~ монг. *түш-* «таяну». К. ш. ук хак. *тӧзӧ-, тӧзä-* < алт. диал. *тӧсä-* «түшәү». Ясалышы буенча хөкем йөрткәндә, **түш* ~ **төш* тамырыннан (бу сүз **түш II** белән бердәй түгелме икән?). Будагов I: 395–396; Räsänen 1969: 495; ЭСТЯ III: 333–334.

Дерив.: **түшәл-ү, түшән-ү, түшәш-ү, түшәт-ү;** к. **Түшәк, Түшәм, Түшәмә.**

**ТҮШТИ, түштей** (ТТДС I: 451; БТДҺ: 343) «нагрудник; нагрудное украшение (у женщин)», «женщина с пышными грудями» – ясалышы буенча монгол сүзен хәтерләтә, һәрхәлдә монг. *дӧштэй* «түшле» сүзе бар.

**ТЫГУ** к. **Тык-у.**

**ТЫГЫЗ** «тесный, плотный; тугой; туго набитый» > чув. *тăкăс* < гом. кыпч. *тыгыз,* башк. *тыгыҙ,* ком., хак., алт. *тығыс,* уйг., үзб. *тиғиз,* төркм. *дықыз,* төр. *tıkız* < бор. төрки **тықырғ,* к. чув. *тăвăр* «тыгыз, тар», аз. *тығрақ,* кырг. *тығырчық* «тыгыз гәүдәле, базык» – сүзнең тамыры себ. (Ту-

машева 1992: 223; ЭСТЯ III: 339), каз., алт. һ.б. *тыңҡ, дыңҡ* «каты, ныклы, тыгыз» (к. **Дыңгыч**), к. ш. ук тув. *дыгыш* «тыгыз», *дыгыш-* «тыгызлану», як. (Иванов 1993: 223–224) *тыйыс, тыньыс* «каты, кырыс; тыгыз» ← **тыг-, *тыңь-* «тыгызлау, тыгызлану». К. **Тыкырык.** Räsänen 1969: 492; Федотов II: 16, 187 (чув. *тăвăр* «тыгыз» сүзен **тар** сүзе белән чагыштыруы дөрес түгел).

Дерив.: **тыгызлы, тыгызсыз; тыгызлык; тыгызай-у, тыгызлан-у, тыгызлаш-у**, чув. *тăкăскă* «тыгыз, тупа» < тат. **тыгызгы** сүзе булганлыгын күрсәтә.

**ТЫГЫН** «пробка, затычка; кляп; затор; узкий, тесный» < гом. кыпч., к. каз., к.-калп. *тығын,* уйг., үзб. *тиқин,* төр. *tıkanık, tıkalı* id. (төр. сыйфат мәгъ. генә) – **тыңк** (к. югарыда) «каты, ныклы» сүзенең инструменталь килеш формасы булса кирәк; ш. ук *тыҡ-* фигыленнән дә ясала ала: *тыҡ-ҡын > тыҡын > тыгын*; чаг. төр. һ.б. *tıkaç* «тыгын, бөке».

Дерив.: **тыгынла-у; тыгынчык** (бу сүзнең күч. мәгънәләре «бөке», «төннек» тур. ТТДС II: 310).

**ТЫГЫН-У I** «жадно и много есть, обжираться» – **тык-у** (к.) сүзенең кайт. юнәлешеннән мәгънәсе үзгәреп килеп чыккан, к. **Тыгын-у II.**

**ТЫГЫН-У II** (кrш.) «одеваться, надевать на себя» ~ чув. *тăхăн* ~ як. *таңын-* id. – **тык-у** (к.) сүзенең кайт. юнәлешеннән. Якут мисалы бу сүзнең күптән үк килеп чыкканлыгын дәлилли. Федотов II: 202 (тат. мисалын белми).

**ТЫЖАР** (Räsänen 1969: 477) диал. «нужная вещь, нужное действие, дело» – чаг. башк. (БТДһ: 343) *тыжыу* «мыжыгу, тыгылу» (бу сүзнең дериватлары да китерелә), *тызыу* «тырнау, ышку».

**ТЫЙЛЫК-У (тыйлыкты, тыйлыгу), тилык-у** (ТТДС I: 412, 430; БТДһ: 343) «стихнуть, утихнуть», «затормозить» – **тый-у** (к.) сүзенең интенсивлык формасы. Башк. *тыйлыҡ* «бастырык; тормоз» **тыйлык-у** сүзеннән кире сүзьясалышы буенча килеп чыккан.

Дерив.: **тыйлыктыру.**

**ТЫЙНАК** «сдержанность», иск. «тормоз», ~ каз. *тиянақ* «терәк; кирәкле чик», к.-балк., гаг. *тыйнаҡ* «бөя, буа, дамба; тормоз», кар. «полиция, төрмә; арест» һ.б. Әлбәттә, *тый-* нигезеннән, к. **Тый-у.** Нигез формасы **тыйанак** булса кирәк (*-анак* кушымчасы, чаг. *тигәнәк*, *тотанак, чыганак* һ.б.). Дерив.: **тыйнаклы, тыйнаксыз; тыйнаклан-у.**

**ТЫЙ-У** «запрещать; удержать, сдержать», диал. (ТТДС: 431) «закрыть ход» < гом. кыпч., алт. *тый-,* уйг., үзб. *тий-,* төркм. *дый-* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 565–566) *tïδ-, tïd-* > иске уйг. *тыд-, тыз-* >> хак. *тыс-* id. < бор. **тыр-*. К. чув. *тыры-* «дыңгычлау, төеп тыгу», *тырык* «бик, тыгын». М. Рясянен **тыр-* тамырын чув. *чар-* һәм *чыда-у* сүзләре белән чагыштыра (Räsänen 1969: 477), ләкин бу дөрес түгел (чөнки чув. *чар-* < тат. *чәр-*, к. **Чәрек,** ә *чыда-* < *чыңда-*, к. **Чыда-у**).

Дерив.: **тыел-у, тыен-у, тыеш-у, тыйдыр-у;** к. **Тыйлык-у, Тыйнак.**

**ТЫКА-У** «вталкивать» ~ гаг., төр. *tıka-, tıqa-*, аз. *тыха-*, тув. *тыгы-* id. К. **Тык-у.**

Дерив.: **тыкан-у** «төренү, катлы-катлы киенү».

**ТЫК-У (тыкты, тыгу)** «засунуть, совать; затыкать, воткнуть» < гом. кыпч., алт., госм. (Радлов III: 1300) *тыҡ-*, үзб., уйг. *тиқ-* id. тат. диал. һ.б. **тык** «тыгыз, ныклы» сүзе белән коррелянтлык мөнәсәбәтендә, к. тат. диал., гаг. **тыќа-** *(тыҡ-а-)* «ябу, бикләү, бөяү», алт. (Радлов III: 1303) *тыҡта-* «тыклау, тыгынлау; ныгыту». К. ш. ук кар., төр., гаг. *тыкач,* үзб. *тиқач* «тыгын, бөке» < *тыҡ-ҡач* (*-кач* кечерәйтү кушымчасы). Будагов I: 361–362; ЭСТЯ III: 337–340.

**Тыҡ-** продуктив нигез: **тыгыл-у, тыгын-у, тыктыр-у;** к. **Тыгын, Тыгын-у, Тыкчын-у**. Чув. *тăкăл-* «тыгылу» < тат. (чув. *тăк-* «тыгу» сүзе юк).

**ТЫКШЫН-У, тыкчын-у** «вмешиваться (в дела других)» ← **тыкчы-* «көчләп тыгу» фигыленең кайт. юн. Чаг. ләкин төр. *tıkış-* «бергә тыгылу» → *tıkışın-* «тыкшыну». *Тыкчын-у* һәм *тыкшын-у* төрлечә ясалганнар. *Тыҡшын- < тыҡышын-.*

**ТЫКЫРЫК, тыкрык,** диал. **тығырык** «переулок; тупик» > мар. (Упымарий: 219) *тӹгӹрӹҡ* < гом. кыпч. *тығырыҡ,* чыгт. (Радлов III: 1347) *тигириқ,* үзб. диал., төркм. (ЎХШЛ: 86) *дыгырыҡ* «тыкырык; кыска урам», кар. id. ш. ук «өн», к.-балк. id., ш. ук «начар гына өй, тар йорт; ярык» ← **тыҡыр- < тыҡҡы-р-* «тараю, кыскару» *тыҡ* «кыска, тыгыз» тамырыннан. Чув. *тăкăрлăк* < тат. **тыҡырлыҡ* «тыкырык» сүзе *тыҡыр* «тар җир» сүзе булганлыгын күрсәтсә кирәк. Гомумән – ачык түгел. Федотов II: 187 (**тыгыл-у** сүзе белән чагыштыра).

Диал. **тыкырык** «арт капка» (ТТДС I: 432), **тыкырык** – уен төре (ТТДС II: 310) төп мәгънәдән килеп чыккан булырга тиеш.

**ТЫЛ [тъ̆йл]** «тыл» < рус. Ләкин рус. (гом. слав.) *тыл* сүзенең ышандырырлык этимологиясе юк. Тик төрле фаразлар гына бар. Шуларның берсе – *тыл-* < бор. төрки (болг.) **тыл* < бор. төрки **тал* > төр. *dal* «яурын, арка, арт» ~ монг. *дал*, эвенк. *далу* «калак сөяге; арт» (ССТМЯ I: 195).

Бу фаразның нигезе шул: бор. төрки телләрдә *а ~ ы* тәңгәллеге булган һәм аның калдыклары-чагылышлары чув., тув., як. һ.б. телләрдә бүгенгәчә очрый. К. **Талта.**

**ТЫЛКЫ-У** «переворачивать пищу во рту языком», «пытаться сосать грудь или вымя» (к. ЗДС: 670) – бор. *тыл* «тел» сүзеннән, әлбәттә. Әмма ясалышы ачык түгел. Чаг. ш. ук *тылакый* (Г. Ахунов) «сөйләнчек» – ш. ук ясалышы тикшерелмәгән. К. **Тел, Тылмач.**

**ТЫЛМАЧ,** диал. (Тумашева 1992: 208, 210) **телмәц, тилмәц** «красноречивый; толмач, переводчик» ~ кырг. *тилмеч* (нуг., каз., к.-калп. *тилмэш*), төр. *dilmaç,* алт. *тилмäч, тилбäч,* хак. *тилбəс,* чулым. *тилбäц,* уйг. *тилмәҗи* < **тилмәрчи* id. *тилмәр* «телмәр, кошлар һәм чит тел сөйләмен аңлатучы» сүзеннән, к. **Телмәр.**

*Тылмач* ~ куман. *тылмац* варианты бор. **тылмарчы* вариантыннан булса кирәк, к. як. *тылбаасчыт* ← бор. төрки *тылмачы* «тылмач» (к. Иванов 1993: 235), шунысы игътибарга лаек: уйг., ком. *тилмач,* к.-балк. *тилманч* < аз. *дилманҗ,* төркм. *дилмаач* «тылмач» сингармонизмга буйсынмыйлар. Димәк *-мач* < *марч* ~ *манч* аерым бер сүз тамыры. Чув. *тăлмач*, һичшиксез, татарчадан (Федотов II: 189–190).

Рус. *толмач* яңгырашы бор. рус. *тълмачъ* < бор. төрки **тылмачы* сүзеннән (*ъ* > *о*). Слав.-рус. варианты Көнб. Европа телләренә дә кергән (мәс., венг. *tolmács*, ним. *Dolmetscher* һ.б.). К. ш. ук Аникин: 551 (шунда ук – әдәбият).

**Тылмач – толмач** тур. бик күп язылган. Э.В. Севортян (ЭСТЯ III: 233–235) бу сүзне урынсызга уйг. *тилимчи* «тәрҗемәче» сүзе белән чагыштыра һәм, гомумән, сүзнең чыгышын ача алмаган. Бик күпләр кебек, ул да бу сүздә *-мач//-мәч* аффиксын күрә, хәлбуки бу сүздәге *-мач//-мәч* бөтенләй үзгә мәгънәдә һәм аның чыгышы да үзгә (*-мач* < *марч* < *марчы*). *Дилманч* ~ *тилманч* вариантындагы *-н-* < *-л-* < *-р-* булырга тиеш, ягъни ул икенчел аваз. **Толмач ~ тылмач** сүзенең этимологиясен бор. монг. *kälämürči(n)* «тәрҗемәче» тирәсеннән эзләргә кирәклегенә томанлы ишарә К. Менгеста (Менгес: 147) гына табыла. К. ш. ук Федотов II: 189–190; Тимергалин: 485; Nemeth J. Die Geschicte des Wortes *tolmacs* Dolmetscher // Acta Orientalia VIII. s. 38; Jyrkankallio P. Zur Etymologie von russ *tolmač* // Studia Orientalia. XVII, № 8; Eren: 112–114.

**Тылмач** продуктив нигез: **тылмачла-у, тылмачлы, тылмачлык** (*тылмачлык итү*) – барысы да гади сөйләмдә.

**ТЫЛСЫМ** «волшебство; колдовство, чары» ~ гом. көнб. төрки *тылсым, тилсим* id. < фар. *ṭилисм* > төр *tılısım, tılsım* «тылсым» < гар. *ṭилăсм* «юкны бар итеп күрсәтү, гипноз, күз буу» < грек. *télesma* «образ; мистерия» ← *telos* «нишан, мәрәй; максат». Европа (һәм рус) телләрендәге *талисман* «тылсымлы әйбер, әмәйлек» гарәпчәдән алынган. К. Räsänen 1969: 478; Kluge: 904 h.б. (бу тур. күп язылa). Гаг. *тылсым* «өрәк, күренгән җен» мисалы төп мәгънәгә якын.

Дерив.: **тылсымлы, тылсымлы-у, тылсымчы.**

**ТЫЛТАК, тылтык** «косноязычный» (к. Тумашева 1992: 222) ← бор. *тыл* «тел». Ясалышы ачык түгел.

**ТЫМА: тыма балаwыз** «прополис» (ДС III: 162) ~ чув. *тăпа* id. Ачык түгел. К. **Тома II.**

**ТЫМАТ,** (ТТДС: 418) **тŏмат** «аккуратно» ~ чув. *тăмат* «тымат, тыйнак» < гар. *и'тимāд* «әзерлек» булса кирәк, к. **Ыкчам.**

Дерив.: **тыматлы** «тыйнак, әдәпле, юньле» > мар. (Упымарий: 220) *тыматлэ* id.

**ТЫМЫЗЫК,** диал. (ТТДС: 432) **тымырсыҡ,** (ДС I: 192) **тŏмарсыҡ, тŏмарыҡ** «тихий; молчаливый; спокойный» ~ башк. (БТДҺ: 344) *тымырҫыҡ, тымырһыҡ* «коры суык; томанлы, салкын» ← *тымырҫы-у* < *тŏмырҫы-у* «эссе яки салкын тынлык» ~ башк. диал. *тымырҫын,* кырг. *тымызын* «тымызык» һ.б. ← *тум, тым* (чув. *тăм*) «җилсез суык; җилсезлек» тамырыннан, к. **Тымык. Тымызык < тŏмызык < тŏмырыҡ** дип (*р* > *з*) фаразларга ярый, к. **Томырык.**

**Тымызык** сүзенең вариантлары күп булган кебек, мәгънә төсмерләре дә күп. Тик бу сүз әд. телдә актив кулланылмый.

**ТЫМЫК** (ТТДС I: 432), диал. **дымыķ** «тишина; тихий, спокойный», башк., каз., к.-калп., алт. *тымыķ* id. ~ мар. *тымык* «тыныч, тын, тымык», *тымык-тымык* «бик тымызык», *тып-тымык* «бөтенләй тын» ← *тым* «тынычлык, тынлык» (*тым-тым* «бик тымызык, бик тын») (к. Упымарий 220–221) ~ хак. *тым, тымы* «тымызык; тынлык, тын», кырг. *тым* «сүзсез», куман., алт. (Радлов III: 1342) *тым* «сүзсезлек», себ. (Тумашева 1992: 222), куман., алт. *тымы-* «сүзсезләнү, тынып калу» (к. ш. ук каз. *тымы-* > *тым-* «тыну»), төркм. *дым-* «тыну, шыму» һ.б. Шулай итеп, *тым* → *тымы-* → *тымы-ķ* (шикелле; шунысы игътибарга лаек, ошбу сүзләр һәм аларның дериватлары мари телендә яхшырак сакланган). ЭСТЯ III: 340–341.

**Тым** тамырын, әлбәттә, **тын < тың** тамырыннан аерып булмый, к. **Тын.**

**ТЫН I** «дыхание; пар изо рта на морозе; воздух», диал. «сознание, дух; жизнь, душа» > мар., удм. *тӹн* < гом. кыпч., уйг., алт., хак., тув. *тын*, чув. *тăн* < бор. төрки (ДТС: 566) *tïn* «сулыш; җан, яшәгәнлек; һуш, аң» < (як.) *тыын* «тын, пар, рух, төннек» (к. Пекарский: 2948). Тат., башк. һ.б. *тын алу* «сулау; ял итү» бор. төрки телләрдән үк килә. К. **Тын II, Тың.** ЭСТЯ III: 341–345 (бик тәфсилле).

**Тын** сүзенең «минут» мәгъ. дә очрый (мәс., *бер тын карап тору* һ.б.ш.). **Тына-у** «сулау, тын алу» *тынар тыны юк* «җансыз нәрсә» тәгъбирендә чагыла.

**ТЫН II** «тихий, тихо» ~ нуг., ком. *тын* id., к.-балк. *тын* «тынлык» < бор. **тыңын* «тыңлап торарак» сүзеннән; бу сүзгә **тын I** нең контаминацион тәэсире шиксез (*тын алу* тәгъбирен *сулыш алу* дип тә «тынычлык алу» дип тә аңлатып була). К. **Тын-у, Тыныч.** Будагов I: 739–741 (тәфсилле).

Дерив.: **тынлык, тып-тын**; диал. **тына-у** «тын булып китү», **тындык** (ЗДС: 672) «тыныч хәл (шуннан **тындыклы, тындыксыз; тындыклан-у** һ.б.), **тынга утыру** «яңа ел төне уртасында бәке янына утырып читтән килгән аваз-тавышларны тыңлау» (чана тавышы тәүләп ишетелсә – ел уңышлы, эт өрсә – ел тынычсыз булачак, ди. К. ЗДС: 671); монда, күрәсең, шүлгәннәр белән аралашу тур. сүз бара, к. **Шүлгән.**

**ТЫН III** (ТТАС III: 183) «целинный, долго не засеваемый (о земле)» ~ ком. *тын*, к.-калп. *тың* id., кырг. *тың* «сәп-сәламәт, тап-таза, теремек; әйбәтләп ял иткән, гайрәтле». Ачык түгел. Бәлки ул тәүдә «сыйфатлы; чын» мәгъ булгандыр, к. тат. диал. (м.-кар., к ТТДС I: 432) **тын** *йефәк* «кыйммәтле асыл ефәк» ~ удм. *дун маржан* «чын мәрҗән, рубин», *дин* «саф; сөзген; бәя» ~ коми. *дон*, манси. *тин* «бәя» (КЭСК: 95).

**ТЫНА, тынап** диал. (ДС III: 162; ТТДС I: 432–433; БҺҺ II: 268 һ.б.) «раз, -жды» (чаще всего в выражении *бер тына* «один раз, однажды») – *тын-у* (к.) (һәм диал. *тына-у*) сүзенең хәл фигыль формасы, чаг. чув., мар. *кан-* «ял итү; тыну» → *кана* «тына, тапкыр» (татарчадан яисә калька).

**ТЫН-У** «затихать, успокоиться; умолкать» < гом. кыпч., уйг. диал. *тын-*, чув. *тăн-*, уйг., үзб. *тин-*, аз. *дин-*, төркм. *дыын-* id. ~ алт., хак., тув. *тын-* «сулыш алу, сулау» ~ төр. *tın-* «сулау авазы чыгару» < бор. төрки (Поппе 1938: 102; ДТС: 567) *tın-* «сулау, тын алу; ял итү; тыну, тынычлану». «Сулыш алу > тыну > ял итү» мәгъ. күчешләре киң таралган типологик күренеш. Шулай ук *тын* һәм *тын-у* сүзләре дә, һичшиксез, гомоген. Бу сүзләр белән *тың* сүзе дә баглы булуы бик ихтимал, к. бор. төрки (МК III: 356) *ting* «тын; тик». Шулай итеп, һәрхәлдә халык этимологиясе кимәлендә, *тын* «сулыш; тын, сүзсез; тың, тыңлану», *тын-у* һәм *тың* сүзләре бер тамырдан. Бу караштан мар. сүзләре өстәмә дәлил: *тым, тың* «тынычлык, тынлык». Räsänen 1969: 478; Федотов II: 193; ЭСТЯ III: 341–345.

**Тын-** продуктив нигез: **тынык-у (тыныгу)** → **тыныктыр-у, тыныш-у, тындыру: тынгы** (→ **тынгысыз** һ.б.). К. **Тыныч, Тыныш.**

**ТЫНЧЫ-У** «застаиваться; тухнуть, протухать; стать затхлым» ~ башк. *тынсы-,* кырг., к.-балк. *тынчы-* «тып-тыныч калу; бераз ислəнү» > нуг., к.-калп. *тыншы-* «тынычлану». Бу сүз, асылда, ике сүзнең контаминациясе: **тынчы-** ← **тын-** (аның интенсивлык формасы) һәм **тŏнчы-** (к. **Тончы-у**).

**ТЫНЫЧ** «спокойный; мирный» > чув. *тăнăç* > мар. (Упымарий: 220) *тыньысь* < гом. кыпч. *тынч, тыныч* (> нуг., каз., к.-калп. *тыныш*), уйг., үзб. *тинч* «тыныч» > төр. *dinç* «салмак, көчле, нык, сәрин» < **тын* тамырыннан булса кирәк. Гомумән, ясалышы ачык түгел, әмма, әлбәттә, *тын-у* фигыленнән.

**ТЫНЫШ** сирәк «остановка; успокоение» (это слово более известно по фраземе *тыныш билгесе*

«знак препинания») ← **тын-у** (регуляр деривация буенча), нуг. *тыныс* «тыныш» тат. теленнән булса кирәк.

**ТЫҢ I** диал. (Тумашева 1992: 223) «крепкий, крепко; сильный, сильно; очень» ~ алт., хак. *тың* id. К. ш. ук тат. диал. **тың-у, тыңы-у** «кату, катылану».

**ТЫҢ II** «подслушивание (разговоров на предмет гадания в новогоднюю ночь); слух» < бор. төрки (ДТС: 568) *tïŋ* «аваз; тың», (Радлов III: 1308) *тың* «чеңләү, чыңлау» – *чың* сүзе белән тамырдаш булса кирәк. К. ш. ук **Тын, Тын-у.**

**Тың** сүзеннән бигрәк аның деривaты **тыңла-у** > чув. *тăнла-* < гом. кыпч. *тыңла-,* алт., хак. *тыңна-* > алт., кырг., каз., башк. диал. *тыңда-,* кар., үзб. диал., төркм., аз. диал. *диңлә-,* төр. *dinle-* ~ бор. төрки (ДТС: 568) *tïŋla-* киң таралган. Севортян 1962: 24–25; Räsänen 1969: 478; ЭСТЯ III: 236.

**Тың**, гомумән, продуктив нигез: **тыңчы** «махсус тыңлаучы; шпион» (< бор. төрки *tıŋčı* id.); **тыңчыл** «күндәм» (чаг. рус. *послушный*).

**ТЫҢКЫШ** «гнусавый, говорящий в нос» ~ башк. *тыңҡау* id., каз. (Радлов III: 1309) *тыңқа-* «сөйләнү, лыгырдау», *тыңқый* «дыңгычлап тутылган». Гомумән, *тыңкыш* ← **тыңкы-* «борын тыгылу» сүзеннән булса кирәк. Арытабан ачык түгел. Чаг. **Тын I** («сулыш» мәгъ.).

**ТЫП** – имитатив не очень сильной поступи, откуда далее **тып-тып** – подражание поступи, топоту (младенца), **тыпыл-тыпыл, тыпыр-тыпыр** – имитативы не очень громкому топоту, пляске, **тыпылда-у** «плясать на месте; выплясывать; делать притоп; плясать в валенках», **тыпырда-у** «отбивать дробь в пляске; топотать». Бу сүзләр (к. ш. ук *тап, туп*) чув. телендә бар һәм гом. кыпч. характерда, чаг. төр. *tıpır-tıpır, tıpırdı, tıpırtı.* К. **Тыпырдык, Тыпырчын-у.**

**ТЫПЫРДЫК** «быстро перебирающий ногами; нетерпеливый; чечетка (в пляске)», ш. ук *тыпырдавык* ← **тыпыр-у* һәм *тыпырда-у* фигыльләреннән. К. **Тып.** Мар. *тывырдык* «бию элементы» < тат.

**ТЫПЫРЧЫН-У** «быстро, нервно перебирать, сучить ногами; трепыхаться» – сирәгрәк очрый торган **тыпырчы-у** (ш. ук мәгъ.) фигыленең кайт. юн. Тамыры, әлбәттә, *тып* имитативы (шуннан **тыпыр* исем сүзе ясалган булса кирәк). К. кырг. *тыбырчыла-*, үзб. *типирчила-* «тыпырчыну» һ.б. (гомумән, *тып ~ тäп* имитативы һәм аның дериватлары гом. төрки характерга ия). Чаг. **Тиберчен-ү.**

**ТЫР, тыр-р** – имитатив шуму трещотки, моторов, а также быстрому бегу мелкими шагами, откуда далее **тыр-тыр** – подражание шуму моторов и быстрой беготне и т.п., **тырыл-тырыл** – подражание шуму моторов, **тырылда-у** «шуметь (о моторах, о пропеллере и т.п.)», **тырылдык** и **тырылдавык** «издающий шум (о моторах и т.п.); бегущий взад и вперед мелкими шагами». К. **Тыракай, Тыракла-у, Тырпылда-у.**

**ТЫРАКАЙ** «бег вприпрыжку (прыгая попеременно на каждой ноге)» ← **тыр** (к.). **Тыракайла-у** «сикерә-сикерә йөгерү».

**ТЫРАКЛА-У** шул ук **тыракайла-у.** Әлбәттә, **тыр** тамырыннан.

**ТЫРАНЧА** «минога (рыба)» < төр. *trança* id. (әд. телдән кергән махсус алынма; татарларның төп массасы яшәгән өлкәләрдә бу балык очрамый).

**ТЫРМА I** «грабли; борона» > мар. (Исанбаев 1978: 38) *тырма,* чув. *тăрма* (чув. телендә бу сүз башлыча *тăрмала-* «тырмалау, тырмачлау» фигыленең нигезе буларак билгеле) < диал. **тырмау** «тырма». Бу сүз иске уйг. телендә барлыкка килгән булса кирәк, к. каз., к.-калп. *тырма* «тырма» ~ хәз. әд. уйг. *тирма, тирна* «тырма» ~ чыгт. (Радлов III: 872) *тарма* id. К. ш. ук кырг. *тырмоо* < *тырмаw* «кул тырмасы». К. **Тырмавыч.**

Дерив.: **тырмалы, тырмала-у**, диал. **тырмачла-у** «аннан-моннан һәм тупас тырмалау, ерткалау».

**ТЫРМА II** – единица измерения длины ниток основы – 4 аршина – **тырма I** (к.) сүзеннән булса кирәк (җепне тырмага урап үлчәгәннәрме?).

**ТЫРМАВЫЧ [ты̆рмаwы̆ч], тырнавыч** (ТТАС III: 197) «грабли; вид граблей» > чув. *тăрмавçă* ~ гом. кыпч. характерга ия: к.-балк., ком. *тырнавуч,* нуг. *тырнавыш,* кырг. *тырмооч* >> хак. *тырбос,* алт. *тырмууш,* тув. *дырбааш* һ.б. (к. ш. ук к.-балк. *тырқавуқ,* кырг. *тырнооқ*) id. ← **тырма-у** һәм **тырна-у** фигыльләреннән. Шунысы характерлы, хак. һәм тув. вариантлар кыпч. телләреннән килә.

**ТЫРМА-У** «сгребать; бороздить (туповатым концом)» ~ кырг., алт. диал. *тырма-, тырба-,* алт. диал., як. *тарба-,* гом. угыз. *дырма-* > тув. *дырба-* «тырнау». **Тырма-у** һәм **тырна-у** фигыльләре тат. (һәм башк.) телләрендә генә аерымлана, бүтән телләрдә шуларның берсе генә (я *тырма-*, я *тырна-*) кулланылучан. *Тырма-* һәм *тырна-* нигезләре уртак *тырың-а-* сүзенә кайтып кала (ягъни алар бер-берсеннән килеп чыкмаганнар). ЭСТЯ III: 345–349 (Э.В. Севортян, безнеңчә, бу сүзләргә катнашы булмаган кайбер сүзләрне дә китерә; һәм, аның фаразынча, *тырма-* фигыле бор. **тыр-* «тырнау, ерту» фигыленең ешайту формасыннан гыйбарәт). Федотов II: 198–199.

Дерив.: **тырмал-у, тырман-у.** К. **Тырмаш-у.**

**ТЫРМАШ-У** «копаться (острым предметом, не лопатой); стараться (не имея эффектных средств)» > чув. *тăрнаш-, тăрмăш-* < гом. кыпч. *тырмаш-* (нуг., каз., к.-калп. *тырмас-*) «җир тырнап югары менү, тырмашу» (кайбер сөйләшләрдә *тырнаш-* дип тә әйтелә) < бор. төрки (ДТС: 569) *tırmaš-* «тырнашу» > гом. угыз. *дырмаш-* «(тау битләвеннән) үрмәләү» һ.б. *тырма-* фигыленең урт. юнәлешенең аерым мәгънә алуыннан килә. Федотов II: 199.

**ТЫРНАК,** диал. (Тумашева 1992: 223) **тыргак, тырмак** «коготь; ноготь», «зуб граблей и т.п.» < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт. *тырнак* (кырг. *тырмак*) id. < бор. төрки (ДТС: 569) *tïrŋaq, tïrïŋaq* ~ як. *тыңырах* < бор. төрки **тырынгак* «тырнау коралы» ← **тырын-* «тырнану; тырнак белән казыну» ← **тыр-* > чув. *чĕр-* «тырнау» сүзеннән. К. ш. ук чув. *чĕрне,* як. *тыңырах* < *тырыңах,* алт. (Баскаков 1972: 259) *тыргак,* алт., кырг. *тырмак,* угыз. *дырнак*, тув. *дырбак* «тырнак» (бу вариантлар барысы да икенчел). К. **Тырна-у.**

Дерив.: **тырнаклы, тырнаксыз; тырнакла-у** «тырнак белән эләктереп алу» һ.б.

**ТЫРНА-У** «царапать, когтить» < гом. кыпч. *тырна-* id. < *тырын-а-* id. бор. **тырын* «тырнак» сүзеннән ← *тыр* ~ *тар* имитатив тамырыннан, ул тамыр барча телләрдә очрый, к. рус. *др-ать* ~ санск. *drnati* «тырнау, тырнаклау» ← һинд.-евр. **der-* «тырнап яру», индонез. *toreh-* «киртү, тырнау» һ.б. К. ш. ук **Тырма-у**. Räsänen 1969: 465; Федотов II: 416–417; ЭСТЯ III: 348.

**Тырна-у** продуктив нигез: **тырнал-у, тырнан-у, тырнаш-у, тырнат-у; тырнагыч.** К. **Тырнак.**

**ТЫРПА,** диал. **тырпы, тарпа** «оттопыренный; стоящий торчком» ~ рус. диал. *тырба* «ашыкның басып тору хәле» ~ эвенк., эвен. *дарпин, дарпир* «казык, багана, текмә һ.б.ш.» (к. ССТМЯ I: 200) ~ башк. (БҺҺ: 345) *тырпак* «тәгәрмәч теше». Бу сүзнең үзеннән бигрәк дериваты билгелерәк: тат., башк. **тырпай-у** ~ хак. *тарбай-* ~ бур. *дарбай-* «тырпаю, кабару».

**ТЫРПЫЛДА-У** «трепыхаться; беспорядочно шевелить руками и ногами (о младенце)» < гом. кыпч. *тырпылда-,* кырг. *тырпыра-* ~ тув. *дырбаңна-* һ.б. ← (каз., кырг.) *тырп* «кискен хәрәкәт» тәкълиди сүзеннән, бу сүз исә *тыр* тамырының *-п-* тармагыннан, к. **Тыр, Тырт. Тырпыл-тырпыл** сүзе дә бар бугай.

**ТЫРТ –** подражание движению, резкому изменению направления: *тырт-тырт йөгерү* «бежать неровными движениями», **тыртай-у** «вдруг изменить решение» и т.п. Гом. төрки тәкълиди тамырдан. Чаг. **Дерт.**

**ТЫРЫС** «берестяный кузовок» ~ чув. *тăрăс* id. – **тŏрŏс* < *турс* «каен агачының орысы, бүлтәймәсе» сүзеннән булса кирәк, к. **Турсык**. Чаг. рус. (Аникин: 571–572) *турсук* «тырыс». Федотов II: 197 (бу сүзне **туез** сүзе белән бәйли).

**ТЫРЫШ** «старательный, старательно; упорный, упорно» > чув. *тăрăш,* мар. *тырыш* < гом. кыпч. *тырыш* (нуг., каз., к.-калп. *тырыс*), уйг. *тириш,* чыгт., алт. *туруш* > госм. *дуруш* id. ~ тат. диал. **тырышлы** < *тŏрышлы* < бор. төрки *турушлы* «үз урынында, позициясендә тора торган» ← *тŏр-у* < *тур-у* (к. **Тор-у**). **Тырыш**,димәк, *белеш, калыш, килеш* һ.б. сүзләр рәтендә. К. **Тырыш-у.**

Дерив.: **тырышлык, тырышман, тырышчан.**

**ТЫРЫШ-У** «стараться» > чув. *тăрăш-,* мар. *тырыш-*, удм. *тырш- (тыршон-)* < гом. кыпч. *тырыш-* (нуг., каз., к.-калп. *тырыс*) < (алт., чыгт.) *туруш-* «тырышу, каршылык яки түземлек, үҗәтлек күрсәтү» (урт. юнәлешенең төп юн. мәгъ. кулланылуы) ← *тор-* < *тур-* «тору», к. тат. **сүзендә тор-у; торыш-у** (Н. Исәнбәт) «каршылык күрсәтү». Гомумән, бу сүз күптәннән килә, к. «Мөхәммәдия»дә *Турушур ничә талипләр, укылыр гыйльме шәригать.* К. Егоров 1964: 239.

Дерив.: **тырышкак** (~ каз. *тырысқақ*) «үҗәт, үзсүзле».

**ТЫТ, тет** «лиственница» ~ алт., хак., чув. *тыт* < бор. төрки (ДТС: 569) *tït* id. ~ манси. *tēt, tät*, хант. *texət*, селькуп. *titi*. Бу сүз төптә фин-угор сүзе булса кирәк, к. Hajdu: 257.

**ТЫЧКАН,** иск. **сычқан,** диал. (ТТДС II: 362) **чышқан,** себ. **цыцкан** «мышь» ~ башк. *сысҡан,* кырг., к.-балк., алт. *чычҡан* > ног., каз., к.-калп., шор. *шышкан*, уйг. *чичқан, чачқан, сичқан* ~ угыз. *сычан* < бор. төрки (ДТС: 502) *sïčγan* id. Этимологлар (Егоров, Рясянен) бу сүзне гади генә *тычкан ~ сычкан,* ягъни *тыч- ~ сыч-* фигыленнән дип карыйлар. Ләкин бу фараз нигезләүгә мохтаҗ. Чув. *шăши* «тычкан» сүзенең дә ясалышы ачык түгел. Безнеңчә, *тычкан < сычкан* ~ як. *чыңгыркан, чыңыр, чыңырыккан*, эвенк. *чэңирэкээн* «тычкан» ← гом. төрки *-қан//-ған* кушымчасына беткән һәм гадәттә хайван атамалары булган сүзләрнең берсе (тәүдә **сыңырчкан* булган), чаг. кырг. *сары чычкан* «йомран», *арыс чычкан* «ак ас». Һәм әд. норма итеп **чышкан** варианты алынса, мәдәнирәк булыр иде.

М. Кашгари (МК I: 206) бор. *сыжған* «тычкан» сүзен *сыжғыг ан* дип тә аңлата (тик *сыжғыг* сүзе аңлатылмый).

**ТЫЧКАНЧЫК** «мыт (болезнь скота, при которой под кожей образуются воздушные пузырьки)», «опухание мускул от удара» ← **тычкан**. Шунысы кызык: *мускул* < лат. *musculus* сүзе дә төп мәгъ. «тычканчык (кечкенә тычкан)» дигән сүз.

**ТЫЧ-У** «испражняться» ~ кырг. *чыч-*, госм., чыгт. *сыч-,* үзб., уйг., иске чыгт. (Поппе 1938: 115) *čiš* > каз. *шыш-,* башк. *сыс-,* алт., шор., хак. *сыс-* id. Калганы ачык түгел. Ихтимал, тәкълиди тамырдандыр.

**ТЫШ** «внешняя сторона, внешность», «сверх, кроме того» < гом. кыпч., алт. *тыш* (ног., каз., к.-калп. *тыс*), госм. *дыш* ~ иске тат. («Мәҗмугыльхикәят») *таш* < уйг., бор. төрки (ДТС: 539), чыгт. *таш* (> хак. *тас*), төркм., аз., төр. *daš,* уйг. *дааш* id. һ.б. ~ чув. *тол (> тул),* аз. *дал* < бор. **талч* id. Тунг.-маньч. *тулиин, тулги, тулэ* һ.б. (күп вариантлар, к. ССТМЯ II: 211) «тыш, тышкы як» сүзе белән дә чагыштыру фонетик җәһәттән нигезләүгә мохтаҗ. Венг. *túl* «(шуннан) тыш» сүзе тур. да шуны әйтергә кирәк.

*Тыш ~ таш* «тыш» нигезе *таш* «минераль токым» сүзе белән бердәй булуы ихтимал. К. **Чык-у.** Будагов I: 736; Räsänen 1969: 466; ЭСТЯ III: 164–166; Федотов II: 243–244.

**Тыш** продуктив нигез: **тышкары, тышкы, тышлы, тышла-у**, иске тат. **ташра**, **тышра** «тышка» һ.б. **Тышка чыгу** тәгъбире үзенчәлекле мәгънә алганлыктан, *тышкары чыгу* (*чыгам* һ.б.) дияргә кирәк.

**ТЫШАУ [тъ̆шаw],** диал. **тŏшау** «путы, оковы» – **тыша-у** фигыленең исемләшкән формасы (әмма борынгыдан килә, к. бор. төрки *tušaγ* > куман., чыгт., госм. *тушақ,* к. Радлов III: 1511). К. ш. ук төркм. *душақ* ~ тув. *дужақ* «тышау» һ.б. Бу сүз күрше телләргә дә кергән, к. монг., бор. монг. *tušjaa*, *тушаа* «тышау». Тат. диал. *тыршау* «тышау» икенчел. К. **Тыша-у.**

Дерив.: **тышаулы, тышаула-у, тышаусыз**.

**Тышау (тастымал) кисү** «бик читен эшне хәл итү». Каз. (Будагов I: 396) *тусау кесүү* «ике судлашучы кеше бий [монда – судья] каршында махсус арканның ике башыннан тотканнар да ныклап тартканнар, шунда бер битараф кеше арканны кайчы белән кискән һәм бәхәс хәл ителгән, бетте дип исәпләнгән. Бу рәвештә бәхәсне хәл итү гадәттә нәүрүз бәйрәмендә башкарылган һәм **тышау** (татарларда **тастымал**) **кисү** эшен кечкенә малай яки кызчык башкарган. Тастымал кисүчегә бүләк бирелгән.

**ТЫША-У, тоша-у** диал. «надевать путы, путать» < гом. кыпч. *туша-* (> ног., каз., к.-калп., хак. диал. *туса-,* хак. *туза-,* каз. *тŏса-*), төр. диал. (һ.б. угыз) *duša-, doša-* id. ← бор. төрки (ДТС: 590) *tuš* «аел; буын» < **тулч, тулж*, к. чув. *тăлă [тŏлы]* < **тул-уғ* «тышау». Бу сүз төркиләрдән күрше телләргә дә кергән, к. бур. *туша-* «тышау, тышаулау». Тат. **тыша-у** үзе сирәк кулланыла, аның урынына **тышаула-у** диелә (чаг. **бора-у** урынына **бораула-у**). ЭСТЯ III: 306; Федотов II: 188.

**ТЮК** «тюк» < рус., ләкин рус теленә төрки телләрдән кергән, к. тат. диал. (Akb: 9) *tük tösekte, tük yastıklar üstine bašin salip ..., tük kapcike* һ.б., алт. *тьук, дьук* «йон, төк, мамык». **Тюк** элекке фаразча **йөк** сүзенә түгел, **төк** сүзенә карый һәм тәүдә күләмле «йон-мамык капчыгын» белдергән.

# У

**У** авазы төп тат. сүз нигезләрендә беренче икеөч иҗектә генә кулланыла; кайбер сөйләшләрдә ул гомумән юк: *у* дип языла, *ыw* дип укыла. Кагыйдә буларак, тат.-башк. *у* гом. төрки *о* авазыннан килә, ләкин гом. төрки *у* авазыннан килгән очраклар да бар.

**У I, уы, ыw** «злокачественная опухоль» (*аягына у чыккан*, Исмаил, Дүртөйле районы, Башкортстан), «яд» (к. Будагов I: 106), «лекарственное растение» (в фразеологизме *бүре уы* – название лесного растения – волчье лыко, к. Вәлиди II: 419) ~ каз. *у* «дару», ләкин гом. кыпч., үзб. (ЎХШЛ: 266) *уw, ув* ~ тув., хак. *оо* «агу», уйг. *оға ~ агу* сүзеннән дип уйланыла (Мухамедова 1973: 53). К. ш. ук **Уа.**

**У II** (ТТДС: 451; Тумашева 1992: 223; Будагов I: 106) «он; тот» < гом. төрки *у, о* id. **Ул** сүзенең ошбу варианты тат. Урал һәм себ. сөйләшләрендә очраштыргалый. Ул башк. телендә тулы парадигмасы белән килә (ягъни *у, уны, уның, уга, унан, унда, уныкы* һ.б.). Бу (тарихи җәһәттән борынгырак) вариант чыгт. һәм кайбер иске тат. яз. ядкәрләрдә дә төрлечә кулланыла (кайберләрендә кыек килешләрдә **ан** нигезе белән алмаштырыла). Räsänen 1969: 356.

**УА [уwа], уы [уwы̆]** (ТТАС III: 293) «рахит», (ЗДС: 676) «горб» ~ башк. (БҺҺ II: 313) *ыуа* «шеш» ~ удм. *у* «грыжа» һ.б. < гом. кыпч. *уaw* «агу» < *ағу* (? к. ЭСТЯ I: 67). К. **У I.**

Бу *у, уа, уы* сүзе белән беррәттән тагы башк. *ыу*, к.-балк., каз., кырг. *ув, уў [уw]* «үрмәкеч авы, пәрәвез» сүзе дә бар. Бу омонимнарның үзара мөнәсәбәте ачык түгел.

**УАЛА-У** «тереть, растирать; мять» ← *у-у* (бу фигыльнең интенсивлык формасы) ~ каз., к.-калп. *уwала-у* id.

**УБА,** диал. (Тумашева 1992: 162, 224; ТТДС I: 451) **ōбō, убы** «(насыпной) холмик; яма, нора», (ДС II: 203) «логово» > удм. (Насибуллин: 142) *убо* «түтәл», мар. (Исанбаев 1978: 25) *вова, воба* «баз, өн» һ.б. гом. кыпч., к. кр.-тат. (Будагов I: 107) *оба* «очлы түбәле һәм әйләнәсе чирек чакрымнан бер чакрымга кадәр булган калкулык – ул аерым урын яисә авыл билгесе булучан» < монг., маньч. һ.б. *обо, оба* (> каз., к.-калп., к.-балк., кырг. *оба, обо*, хак. *обаа*, тув. *оваа*), бур. *обоо, обоон*, яз. монг. *обиуап* һ.б. «уба». Чаг. тибет. *огбон* «гыйбадәт кылу һәм табыну тавы». Аерым тауларга – убаларга табыну һәм шул тауга гыйбадәтханә ясау киң таралган булган; тау булмаганда ясалма тау ясаганнар. К. Традиционная культура народов Центральной Азии 1986: 74–84; 112–131 (Л.Л. Абаев һәм Е.А. Окладников мәкаләләре).

**Уба <** *оба* сүзе төрки һәм күрше телләрдә, гомумән, киң таралган һәм ул күп икенчел мәгънәләргә ия (ЭСТЯ I: 400–401). Э.В. Севортян тат., башк. *уба* сүзенең «чокыр, баз (бигрәк тә элекке корылма, өй урынындагысы)» сүзен *оба* тамырыннан аерым, *убу* (к. **Уп-у**) сүзенә нисбәт итмәкче. Безнеңчә, «калкулык, өем» һәм «чокыр, баз» мәгънәләре үзара нисбәтле: өем өяр өчен баз казырга кирәк ич! Монда контаминация бар: карстлы төбәктә (Уфа тирәләрендә) элекке өй урынын (базын) да, көтмәгәндә *убылып* пәйда булган чокырны да **уба** диләр.

Угыз төркиләрендә, ш. ук Кырымда, Төньяк Кавказда *оба,* (төркм.) *оовба* дип «зимләнкене, ярлауга өн ясап корылган торакны», аннары «тирмәне, тирмәләр төркемен – авылны» һәм хәтта «(тирмәләр тезелеп утырырлык) тигезлекне» дә атыйлар. К. Мухамедова 1973: 134; Dobr. II: 539–540 (ике **оbа** күрсәтелә: 1) «туфрак, таш өеме», 2) «туплам, җәмгыять»).

**Уба <** *убы* сүзенә күп топонимистлар *Уфа ~ Уфы ~ Өфе* елга һәм шәһәр исемен баглыйлар. К. башк. диал. *упа,* бор. төрки (Малов II: 101) *опа* «корбанлык урынында ташлар өеме». К. Räsänen 1969: 356. ССТМЯ II: 4; Аникин: 415.

**УБЫР** «ненасытный оборотень-людоед; дух ненасытности» (к. *убырлы* «тот, в которого вселился дух ненасытности, обжорства») > удм. *убир* «убыр, адәмашар, вампир», мар. *вувер,* мар. диал. *увер* «убырлы карчык» < гом. кыпч. *обыр, обур ~* уйг., угыз. һ.б. *обур* «убыр, явыз рух, сихерче һ.б.». Элек-электән бу сүз *уп-у* фигыленнән (аның сыйфат фигыль формасыннан) дип карала; к. чув. *вупăр, вопăр* «явыз рух, убыр», *вупкăн, вопкăн* «авыру,

чир рухы; убыр» ← *вуп-* «афәт-бәла китерү (явыз рухлар тур.)» (к. Ашмарин V: 269–273). Мар. *опкын* «убыр, адәмашар», *опкалаш* «убырланып ашау» (Идел-Урал төрки телләреннән) сүзе дә бу фаразны раслый. К. ш. ук ЭСТЯ I: 465; Гордеев II: 152–153 (бик тәфсилле); МНМ II: 578.

*Убыр* сүзе элек-электән рус. *упырь* (гом. слав. *упир* һ.б.) сүзе белән чагыштырыла һәм рус сүзе төрки телләрдән (бор. татарчадан) алынган дип карала. Ләкин рус филологлары бу сүзләрнең охшашлыгы очраклы дип карыйлар, к. Фасмер IV: 165; Федотов I: 131–132.

Дерив.: **убырлы; убырлан-у** «күп ашау».

**УГАН** иск. (Г. Утыз-Имәни, Г. Кандалый) «господь, бог (обобщённо)» < чыгт. (Будагов I: 140) *оған,* бор. төрки (ДТС: 603, 607) *Uγan, Uγan-täŋri* «илаһ, тәңре» ← *u-* «кодрәтле һәм түземле булу».

**УГАТА** (ТТДС: 452; БТДҺ: 352) «особенно; чрезмерно» > мар. (Упымарий: 140) *огата, огатак*, удм. *уката,* чув. диал. *ухата* < гом. кыпч. *оғата* (> кар. *оғата*, каз., к.-калп. *оғада*, кырг. *оғоло*) < *уғатай* (к. башк. *уғатай*) «бигрәк тә, аеруча; бигрәк инде, үтә китеп, үтә киткән» < бор. монг. *oγtai, oγtu* > хәз. монг. *огоот* «бөтенләй» ← *огоо* «күп, күбрәк» > тув. диал., хак. *оғаа, уғаа* «бик тә». ЭСТЯ I: 410–411 (без бу китапта китергән кайбер мисаллар юк).

Мар. *угатак* < тат. *угата ук* булса кирәк.

**УГЛАН** тар. «княжич» (**эч углан** «гвардеец»), диал. (ТТАС III: 294) «отрок; сын» < чыгт., уйг., угыз һ.б. *оғлан* (> *углан* варианты рус., каз., к.-калп. телләрендә дә очрый) ← *оғыл, оғул* (к. **Угыл**). *Оғлан* < *оғулан*, ләкин бу нигезнең ясалышы ачык түгел: *-ан* морфемасы сирәк очрый (чаг. *ир* → *ирән*). Ул, ихтимал, фар. күп. кушымчасы *-ан* (чаг. *яран* «ярлар») белән бердәйдер.

**Углан** < *оғлан* тарихта бик эчтәлекле сүзләрнең берсе, ул төрле вариантларда, төрле илләрдә төрле иҗтимагый мәгънәләргә ия булган, к. **Олан, Улан**. ЭСТЯ I: 411–412 (тат. сүзе искә алынмый); Аникин: 580, 582.

**УГЛАП, углаб** (Будагов I: 141) «бревно, подпирающее крышу (в глинобитных домах со слабой стеной), центральный опорный столб в треугольнике стропила» – Л. Будагов фикеренчә, бу сүз **уык** (к.) «тирмә түбәсендәге радиаль шикмәләрнең берсе» сүзеннән, ягъни **уыклау* нигезеннән булып чыга. Бу кызыклы фараз өстәмә материалга мохтаҗ. Кызганычка каршы, хәз. телдә **углап** сүзе кулланылмый һәм аның күрше вә кардәш телләрдәге параллельләре табылмый.

Кайбер русистлар *углап* сүзеннән рус. *охлуп, охлупень* «углап» сүзен чыгаралар. Әгәр бу дөрес булса, рус сүзе болг. теленнән (*ķ* > *х*): Болгар осталарының Үзәк Россиядә биналар төзеп кәсеп итүләре билгеле. Ләкин М. Фасмер (III: 176) рус. *охлуп* сүзенең татарчадан (гомумән төрки телдән) булуын катган кире кага (әмма аның үз этимологиясе дә уңышлы түгел).

**Углап** сүзе рус. *оглобля* «тәртә» белән гомоген булса кирәк, к. тув. *оглаңай* «тәртә»; рус сүзе *глоба* «озын кәртәлек, озын багана» сүзеннән диелә (Фасмер III: 117–118), ләкин чех. *ohlobne* нәкъ «углап».

**УГРА-У** иск. (ТТАС III: 294) «встретить на пути», «подвергнуться (беде)» Котби телендә (Zajączkowski 1961: 114) «пытаться, попадать в положение» < чыгт., угыз. *угра-* < *уғура-* id., бор. төрки (ДТС: 363) *oyra-* «юнәлү; җыелу; җыену» ← угыз., бор. уйг. *уғур, оғур* (> кр.-тат., ком., к.-балк. *оғур,* кар. *оғыр*) «очрак; уңайлы очрак; язмыш; юнәлеш; мач, котылыш» сүзеннән. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 564–565) *уғур* < *оғур* нигезен *оң* «уң» сүзеннән ди, безнеңчә, *уķ* ~ *уғ* «юнәлеш» яки «очрау, очрашу, очрату ноктасы» сүзеннән (хәер, монда төрлечә уйларга урын бар).

**Угыр** < *оғур* нигезеннән иске тат. **угрында** (к.) «турында; сәбәбеннән; максатында» бәйлеге ясалган булган. К. **Угыр II.**

**Угра-у, угыр** һәм **угрында** сүзләре иске (XX г. башларына кадәрге) әд. телебездә искеләр теленә пародия, стилизация максатларында гына кулланылган. Ләкин алар башкорт диалектларында хәзер дә кулланыла шикелле (к. БТДҺ: 352).

Дерив.: **уграш-у, уграт-у**, диал. **уғрыл-у** «кыенлыкларга очрау».

**УГРЫ** иск., диал. (Тумашева 1992: 226) **ур, уры, ōгур, ōугры,** (ТТДС II: 327) **уғыр** «вор» < куман., иске тат., Котби (Zajączkowski 1961: 114) *oγry* < гом. көнб. төрки, бор. төрки *оғры, уғру* ~ башк. (БТДҺ: 247, 352) *оғоро, уғры,* чув. *вăр, вăрă* id. ~ кыпч. *уwры, уры* id. (Федотов I: 109).

Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 412–413) хаклы рәвештә төп вариант *уғыр* < *оғур* дип саный, бу сүзнең фигыль коррелянты *оғур-* > як. *уор-* «урлау» сүзе дә бар икән. Бу сүзләрнең тамыры **оғ-,* яисә, безнеңчә, **о-* булырга тиеш (*о-ғур*, чаг. **елгыр,**

**үткер** һ.б.ш.), ләкин бу фаразны исбатларга материал җитенкерәми.

Шушы туры линияле фаразлардан тыш, бүтән бер фараз да яшәргә хаклы: *угыр* < *огур* икенче бер *огур, угур* «уңайлы очрак» (к. ЭСТЯ I: 564) сүзеннән кире сүз ясалышы буенча пәйда булган: *угур* «уңайлы очрак» → *угурла-* «очрактан файдалану, урлау» → *угур-* «урлау». К. ш. ук **Урла-у, Урынтын.**

**УГРЫНДА** иск., кит. «о, об, относительно (чего)» < госм. *угурунда* (төр. *uğrunda, uğruna, uğurda*) ← *угур* сүзенең «мөнәсәбәт, бәйләнеш» мәгънәсеннән. Чаг. каз. *угыр* «рәт, юнь; урын», төркм. *угур* «юл» ~ бор. төрки (ДТС: 363) *oγruγ, oγruγ* «юллар чаты; максат, карар, теләк». Чаг. каз. **угыр** «рәт, юнь; урын», төркм., төр. *uğur, uğru* «мәсьәлә; очрак». К. **Угра-у, Угыр.**

**Угрында** сүзе хәз. телдә бөтенләй кулланылмый.

**УГЫЗ I** «молозиво» (к. Хайрутдинова 1993: 87–88) ~ диал. (ДС III: 170, ТТДС: 524) **убыз, увыз, ывыз, ыwыз,** миш. (Будагов I: 162) **уwыз**, себ. (Тумашева 1992: 163, 254) **ōус, уыз, ыуыз, ыуыс** ~ башк. *ыуыҙ* > чув. *ăвăс, увăс, ывус, ус* (төп чув. *ĕнери, ырри, ыра,* к. Ашмарин IV: 115) < гом. кыпч. *уwыз, уwуз,* кырг. *ууз,* хак. *оос* << (ДТС: 365) *oγuz* > уйг. (Радлов I: 1620) *угус* id. Бу сүз вариантлылыгы белән аерылып тора: бор. һәм урта төрки телләрдә (чыгт. һ.б.) *aγuz* > *avuz* варианты еш очрый (к. Räsänen 1969: 9), аз., төр. телләрендә ш. ук *ayuz, ağız, aaz* «угыз» һ.б. (к. ЭСТЯ I: 405–407; Э.В. Севортян чув. вариантларны анализламый). Башк. (БТДҺ: 410) *ыуыҙ* «яшь, бала, үсеп җитмәгән» варианты **уғыз** сүзе **уғыл** белән тамырдаш түгелме икән, дигән фикергә китерә; тув. *аа* «угыз», *аазы* «угызы» кызыклы, ләкин бу соңрак килеп чыккан күренештер.

Сүзнең *-r (-р)* вариантлары исә шулай ук күп төрле: чув. *ĕнери* < *ĕне ырри* «инәк (сыер) угызы» (*ырри – ыра* сүзенең тартым формасы), *ыра* (> мар. *йыра*) исә монг. телендә сакланган (Поппе 1938: 362) *uγraq,* яз. монг. *uγuraγ* > хәз. монг. *ураг* «угыз» белән гомоген (аффикс *-ay,* чаг. ш. ук як. *урах ~ уоcах* id.). Кайбер телләрдә (каз., хак., як. һ.б.) бу сүзнең «йомырка сарысы» мәгънәсе дә бар. Безнеңчә, *балавыз* сүзе дә *бал угызы ~ агузы* сүзеннән килә. Бор. болг. телендә **йура* «май сызыгы» булган, шуннан мар. *йыра,* рус. диал. *юрага,* венг. *iro* «май түбере (май эреткәч, савыт төбендә калган өлеше)» сүзләре килә (к. Фасмер IV: 592). Ихтимал, бу сүз дә **угыз** сүзе белән бәйлыдыр.

Бу **угыз** сүзе белән **угыз II** арасында бәйләныш ачык түгел (төрек филологлары һәм тарихчылары монда бәйләныш юк дип баралар). Һәрхәлдә бор. заманда ук икесе бер төрле – *oγuz* дип язылган (к. ДТС: 365), икесендә дә бор. күп. кушымчасы *-z* < *-r* сакланган. Әмма сүзләрнең тамырлары юраулы.

**УГЫЗ II** «огуз» (вначале древнеуйгурское племя, затем – название мощной ветви тюрков – предков современных туркмен, турок, азербайджанцев, гагаузов) < гом. төрки *огуз* < *огург.* Бу этнонимның килеп чыгышы тур. фикерләр төрле. Төрки тарихи мифологиядә бор. **Угыз хан** һәм аның угыллары хакында дастаннар (*угызнамәләр*) мәшһүр. Гомуми фаразлар буенча, **уғыз < оғуз > ғуз > уз** (тарихта шундый вариантлар да киң билгеле) төбендә бор. төрки *оқ* «ук; кабилә» сүзеннән, к. Sümer 1992: 13–14, 67–68 һ.б. (шунда ук төрле фаразлар да китерелә). **Угыз хан** тур. ш. ук МНМ II: 240.

**УГЫЛ** юг., иск. «сын, отрок», в более старом стиле «сын или дочь» без различия: *ир угыл* «сын», *кыз угыл* «дочь». **Угыл** сүзенең тартымлы төрләнештә берлек санда **углы** диелүе чыгт. теленнән килә (иҗек азагында *-г*). Гом. төрки *угыл* < *огыл* < *огул* «угыл, ул» бор. төрки *ог ~ оқ* «нәсел, токым; бала» (к. **Ук II**) тамырыннан булса кирәк, ясалышы ачык түгел, к. як. *ого* «бәби». *Угыл* нигезенең кыскару этаплары *ŏwул* > *ыул* > *ул* кебек диалекталь сүзләрдә күренә. Чув. *ывăл* < *ыwыл* тат. сөйләшләреннән булса кирәк. Räsänen 1969: 358; ЭСТЯ I: 411; Doerfer II: 78–81.

**Угыл** нигезеннән тат. диал. (ЗДС: 639) **уғлақ, улақ** (к. ш. ук **ылак**) «һәрнинди хайван баласы» һәм **углан** (к.) сүзләре ясалган. **Угыл** һәм **углан** нигезләре тат. телендә һәртөрле фономорфологик модификацияләргә бай: *угылчак ~ угланчак, угылчык ~ угланчык.* **Угыл-ушак, углан-ушак** һ.б., к. Будагов I: 141. Рус. *улан, углан* тур. Аникин: 580, 582.

**УГЫР I** неол. «угор (этноним)». Хәз. тат., башк. һ.б. төрки телләрдә бу сүз юк; рус. *угор* (→ *угрин*) сүзләре бор. лит. *unguras* «венгр//венгер» сүзеннән исәпләнә; гомумән бу сүз бор. төрки этноним *һунгур ~ онугур* «ун угыр» сүзеннән дип карала, *угыр* < *огур* исә *угыз* < *огуз* сүзенең *р ~ л* телләрдәге варианты. К. Фасмер IV: 147 (тәфсилле, күп әдәбият). К. **Угыз.**

**УГЫР II** иск., кит. «момент; точка; благоприятный случай, удачный момент», «предмет обсуждения, разговора» < бор. төрки (ДТС: 364) *oγur* «вакыт, чак», «әхвәл, шартлар», «очрак», «алмашу» ~ төр., аз. һ.б. (Будагов I: 140) *огур* «очрак, язмыш; бәхет, уңыш», *огур-* «бәхетле булу, бәхеткә тап булу» ← *ог* «(уңай) нокта».

Дерив.: **угырлы, угырсыз; угры. урла-у.**

**УДАР** «удар» < рус. (төбендә *дар* ← *да-ть* «бирү» нигезеннән). Бу сүздән ясалган **ударник** сүзе дә тат. телендә киң кулланылды.

**УДМУРТ** «удмурт; удмуртский» рус теле аша удм. *удмурт* ~ *одмурт* ~ мар. *одо марий* «уд кабиләсе кешесе» сүзеннән; татарлар удмуртларны *ар* дип атаганнар, ләкин удмуртлар белән янәшә яшәүчеләр *мурт* дип тә атыйлар (Р. Нуретдинов). Черных 1980: 49–52.

**УЕ [уйы̆], уек [уйы̆ķ]** (ЗДС: 678) «низменное место» – кыпч. һ.б. төрки телләрдә киң таралган сүз: каз. *ойық* «тәндәге уелган төш, чокырчык», кр.-тат. *oyıq*, төр. *oyuk* «кискен уелган төш» һ.б. К. **Уй II, Уй-у.**

Дерив.: **уеклы; уеклап.**

**УЕЛ [уйыл] –** название тат. народной песни и мотива к нему – Казакстандагы *Уйыл* елгасы исеменнән. Анда ярминкә уздырыла булган, к. башк. (БҺҺ III: 193) *уйыл дебете* «тетелмәгән кәҗә мамыгы, дебет», *уйыл* «киң уйсулук» < **уйгыл* (*-гыл* кушымча) ← **уй II** (к.). Ихтимал, тат. «*Уел*» – татар сәүдәгәрләре чыгарган көйдер, чаг. **Эрбет** көе!

**Уел** (көе) сүзен «уйлану» дип тә шәрехлиләр (һәм шулай да була ала – этимологик җәһәттән хилафлык юк, әмма конкрет дәлилләр дә юк). Ләкин **Уел** ярминкәсе **Уел** (русча *Уил* дип языла) елгасы исеменнән, елга атамасы исә **уй II** (к.) сүзеннән булса кирәк. Чаг. ш. ук монг. *ойл* «гирдап, су өермәсе».

Ниһаять, *уйыл* сүзе тат. диал. **уйылы** нигезеннән (яки шуңа параллель каз. нигезеннән) булырга да мөмкин, к. диал. *уел* (к. югарыда) «түбән җир».

**УЕН [уйы̆н]** «игра» < гом. кыпч., алт., хак. *ойын*, ком., кыргъ., чыгт., уйг., гом. угыз. *ойун* < бор. төрки (ДТС: 366 һ.б.) *ojun* «уен; ярышу; бию, тансы; музыка; көлке» ← иске уйг., як. *oj-* «уйнау һ.б., сикерену» ~ монг. *ой-* «качу». Бу тамыр сүзнең исем коррелянты себ. сөйләшләрендә сакланган: *бер көндә балалар ой кылып йатыр икән алтын ашык пилән...* (к. Радлов, Образцы… IV: 275). Чув. *вӑйӑ* «уен» < **уйгы* < **ойгы, *өйгү* (?) яки М. Рясянен буенча, **öjiγ* сүзеннән. **Уйын** < *ойын, ойун* үзе **ойгун* сүзеннән булса кирәк (ягъни монда *-гун* кушымчасы роль уйнаган), к. як. *ойуун* «(сикеренеп камлаучы) шаман».

Төрки телләрдән тыш *ой (< *ойу ?)* бор. монг. *oǯo, oǯi* «үбешү; флирт» сүзе белән чагыштырыла. *Уен < ойун* сүзенең төрки телләрдәге мәгънәләре көрд. *oyin [ойин]* сүзендә ачык чагыла: «чират, уендагы йөреш» (чаг. тат. *уен кәрт* «козырь кәрт»), «җәргәдәге (стройдагы) тәртип; кыяфәт, образ; тамаша; могҗиза; әкәмәт, мәрәкә; шаян, шаяру», к. ш. ук як. *ойуу* «сикерену», *ойуун* «шаман; бөтерчек», тунг. *эви-* «уйнау», *эвин* «уйнау» (к. Räsänen 1969: 359) – ләкин бу соңгы чагыштыру фонетик җәһәттән нигезләүгә мохтаҗ. Гомумән, **уен** сүзенең бор. төп мәгъ. дә аңлашылып бетми. ЭСТЯ I: 435–437; Федотов I: 104–105.

**Уен** бик продуктив нигез: **уенлы, уенлык**; **уенчы, уенчак,** иске тат. (Гиганов) **уйынак, уйнак**; к. **Уенчык, Уйна-у** (һәм аның дериватлары).

Бор. *уй-* < *ой-* фигыленең юн. формалары да булырга тиеш, тик алар хәзергә теркәлмәгән, танылмаган. Ихтимал ки, *ой* «уен», «фикер» һәм «батынкылык» – барысы да бер тарихи оядандыр, без тик борынгыларның яшәү шартларын, фикер үзенчәлекләрен һ.б. белеп бетермибез.

**УЕНЧЫК [уйы̆нчы̆ķ]** «игрушка» ~ башк. *уенсыҡ,* нуг., каз., к.-калп. *ойыншық,* ком. *ойунчақ,* төркм., төр., аз., үзб. диал. *ойунҗақ, ойунчақ,* гаг. *ойунҗäк* id. Рус. *игрушка* сүзе белән эчке семантик структур охшашлыгы күзгә ташлана; төрки сүз, ихтимал, бор. төрки *ойун* «бөтерчек» сүзеннәндер (ул тәкъдирдә рус. *игра → игрушка* төрки телләрдән калька!). ЭСТЯ I: 437 (Э.В. Севортян тат. һәм башк. сүзләрен искә алмый).

**УҖАР** «ярый, яростный; злой; ярость, злость» ~ башк. (БҺҺ III: 192) *ужар* id. ~ чув. *вушар* «карышык, кыек катламлы (үзагач тур.); кире, үҗәт; кирәкмәгәнчә гайрәтле». Ачык түгел.

Дерив.: **уҗарлы; уҗарлан-у.**

**УҖАУ [уҗаw]**, диал. (ТТДС I: 452), «поварёшка, половник» ~ чув. *вӗҫ, вӗс, вӗчев, вӑчав, уҫав* «пешкән ит өчен агач табак; уҗау, чүмеч» ~ башк. *ужау*, башк. диал. (БҺҺ II: 274) *ыжау, ижау*, каз. *ожау,* кыргъ. *оҗоо* ~ як. *удьаа, ужҗаа, уйабул* «чү-

меч»; «Хөсрәү вә Ширин»дә: *Беләсең – шәмчырак нур ала җәүдән, Ләкин җәү сүндерә, ташса уҗаудан*, ягъни бор. яктырткычның эч мае, яу салына торган савыты *уҗау* дип аталган, шуннан чыгып *уҗау* < *ут җавы* «яктырткыч өчен билгеләнгән май савыты» дип фаразларга мөмкин. Räsänen 1969: 509 (материалы аз).

**УҖЫМ** «озимые, озимь» ~ чув. *уҫăм* «уҗым; басу; басу мәйданы», удм. *озьым, узьым,* мар. *озым, азым, ойзым, озим* < рус. *озимь* (*о зиме* «кышка таба чәчелгән ашлык»). Гордеев I: 57.

Дерив.: **уҗымлы, уҗымсыз; уҗымлык**.

**УҖЫ-У** (т.я., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «доходить до апогея, совершенства, кондиции» ~ башк. (БТДҺ: 352) *ужыҡ-у, ужғы-у* «тулып яту; күп булу».

**УЗАК, уҗак** (Г. Камал) «напарник» ~ башк. (БТДҺ: 352) *уҙаҡ*. Төрекчәдән булса кирәк. Курчак театрында *ҡуҗаҡ* «башлык», *уҗак* «иярчен» (яки киресенчә була).

**УЗАМАН** «вожак (в игре); ведущий, выдающийся» – халык этимологиясенчә, **уз-у** (к.) фигыленнән. Ихтимал, иске тат., төр. *uzman* «оста, специалист» сүзеннәндер (бу сүзнең тамыры *уз* < *ууз* «осталык, булдыклылык» һ.б.ш. тур. ЭСТЯ: 569–670). К. **Ус.**

**УЗ-У** «опередить; перегнать; проходить (мимо); (*авырга узу*) забеременеть» < гом. кыпч., уйг., алт., чыгт. *оз-* id., сары уйг. *йоз-*, хак. *ос-* «үткән заманда булган булу» һ.б. Моңа мәгънәдәш һәм аваздаш, ләкин фонетик законнар буенча чагышмый торган сүзләр бар: иске каз., куман. алт. шор. (Радлов I: 1710) *уда-* «көтү; озау; узу», бор. чыгт. (Боровков 1963: 233) *одар-* «уза; узган, үткән булу». Räsänen 1969: 367. ЭСТЯ I: 425.

Гомумән продуктив нигез: **узын-у, узыш-у,уздыр-у** (һәркайсы үзенчәлекле мәгъ.); **узгын; узгынчы.** К. **Узаман.**

**УЙ I** «мысль; намерение, желание» > чув., мар. диал. *уй* < гом. кыпч. *ой* < (төркм.) *оой* ~ бор. уйг. *ot, od* «уй; үз-үзеңне белешү» ~ монг. *ой, ойун* id., к. ш. ук як. *өй*, калм. *ö;* тат. диал. (без. теркәдек. – *Р.Ә.*) **уйы** (*уйысы* диелә) < бор. **ойу*, булса кирәк, шуннан к.-балк. *уй* (югыйсә бу телдә *о* > *у* күчеше булмаган). К. **Уян-у, Уяу,** к. **Уй-у**. Räsänen 1969: 357; ЭСТЯ I: 428; Федотов II: 270.

Дерив.: **уйлы, уйсыз; уйла-у, уйлан-у, уйлаш-у, уйлат-у; уйчан,** себ. **уйгыр** (~ алт. диал. *ойгор*) «уйчан; уйлап табучан»; бу сүзләрнең кайберләре күрше фин-угор телләренә дә кергән (мәс., удм., мар. *уйла-,* к. Насибуллин: 142).

**УЙ II** (ТТДС I: 452) «поле (на низменности); выбоина; выемка, углубление, глубь» ~ чув. *уй, ой* «басу» < гом. кыпч., алт., хак., чыгт., уйг., төркм. һ.б. *ой*, бор. төрки, төркм. *оой* id. ~ монг. *ой* «урман» ~ эвенк. *һой* «сазлык, тундра». Бу сүзнең фигыль коррелянты *уй-* < гом. төрки *ой-* «ую» (к. **Уй-у**) Räsänen 1969: 358; ЭСТЯ I: 425–428; Федотов II: 269–270. К. **Уе, Уел, Уйсу, Уйчы, Уяз.**

Әйтергә кирәк ки, диал. сөйләмдә **уй II** нигезеннән ясалган сүзләр күп кенә, мәс., себ. (Тумашева 1992: 224–225) **уйас (< уйаз), уйбас, уйык, уйыргак** – барысы да төрле уйсулык, болын төрләрен белдерә, башк. (БТДҺ: 352–353) *уйаҙ* «ике тау арасы», *уйаҙсыу, уйалыҡ, уйамҡыр, уйамыр, уйасыҡ, уйғылды (< уйғыллы), уйҡаз, уйҡыл, уйҡылды, уйма, уймаҡ, уйпа, уйпат* (к.), *уйсыл, уйтүбән, уйтыҡ, уйыра* һ.б. К. ш. ук **Уйдым.** Күрәсең, һәр төбәктә **уй** тамырыннан үзләре белгәнчә сүз ясаганнар һәм уйсу урыннарның аерым төрләрен тәгърифләргә омтылганнар.

**УЙГАТ-У** иск. (әд.) «пробудить (чувства, сознательность)» – бор. төрки *ойғат-* id. бор. *ойға-* < *озға-* һ.б. «уяу булу, уя тору» сүзеннән. Шуннан ук бор. төрки һ.б. *ойған-,* иске тат. *уйған-у* «уяну» фигыле дә ясалган. **Уйгал-у, уйгаш-у** кебек (гомуми закончалык буенча көтелгән) юн. формалары табылмый. Чув. телендә дә *вăрат-* һәм *вăран-* («уят» һәм «уян») юнәлешләре генә бар. Räsänen 1969: 357; ЭСТЯ I: 429–432; Федотов I: 108. К. **Уяу.**

**УЙГАШ** (ТТДС II: 329) «ладный; рифмованный», себ. (Тумашева 1992: 18, 224) **уйгашлык** «подобие» < гом. кыпч., к., башк. (БТДҺ: 249) *ойҡаш* «охшаш», кырг. *уйкаш*, нуг., каз., к.-калп. *уйкас* «уйгаш, таман» ← **уйҡа-, *уйға-, *уйғу-* «туры китерү» ← гом. төрки *уй-* «ярашу» (к. **Ое-у**).

Тат. **уйгаш-у** «туры килү, муафикъ булу» һәм **уйгаштыр-у** «җайлаштыру, туры китерү» фигыле дә бар, тик сирәк очрый.

**УЙГУР** «уйгур, представитель уйгурского народа» – бор. төрки этноним, тюркологиядә бик төрлечә аңлатыла (димәк, гомумән ачык түгел), к. Наджип 1988: 80–86. Тат. **уйгыр** дип язу – кирәксез

«үзләштерү» (өстәвенә себ. **уйғыр** «уйчан, уйлап табучан» сүзе белән бутала).

**УЙДЫК, уйдым** (Вәлиуллин: 9; ТТДС I: 452) «углубление на склоне горы; неглубокая впадина; падь» – **уй-у** (к.) фигыленнән булса кирәк, ясалышлары аңлашылып бетми (чаг. **Белдек, Калдык, Постык**), ихтимал, **уйыт-ык > уйдык, *уйыт-ым > уйдым* (ягъни *уй-у* фигыленең йөкл. юн. булган **уйыт-* сүзеннән) ~ каз., алт. *ойдық, ойдым* id., id. К. **Уел.** Бу сүзнең «берәр нәрсә күп булган урын» мәгъ. икенчел булса кирәк.

**УЙДЫРМА** «выдумка» ← **уйдыр-у** «уйландыру» сүзеннән була ала, к. ш. ук кр.-тат. *уйдур-* «уйлап чыгару; алдаштырып күндерү», төрки *uydur-* «туры китерү, җайлау; рифмалаштыру; күндерү» ← бор. төрки (ДТС: 606) *ud-, иδ-* «җайлашу; ияру, ышану; буйсыну; шигырь чыгару; оештыру». К. ЭСТЯ I: 573–754.

Бу материалдан күренгәнчә; **уйдырма** сүзе угыз телләреннән (сузык аваз характерын үзгәртмичә) алынган булуы да ихтимал. К. **Уй-у II.**

**УЙМА** «вырез (на ткани и т.п.); полукруглая стамеска» ← **уй-у**, әлбәттә. Ләкин диал. **уйма-у** «уеп алу (зур итеп)» – **уй-у** фигыленең интенсивлык формасы. К. **Уймыр.**

**УЙМАК** «напёрсток» > мар. *оймак* < гом. кыпч., чыгт. *оймақ,* алт. диал. *ойбақ, ӧймӓк* id., каз. (Радлов I: 986–987) *оiма, оiмақ* «уймак; уйма». Бу сүзнең ясалышы һәм тамыры да табышмаклы булып кала: *уймаклы* (ягъни «*уелган* чокырчыклары булган») *бармакса* тәгъбиреннән эллипсис дип уйларга мөмкин. Räsänen 1969: 359; ЭСТЯ I: 433 (Э.В. Севортян себ. һ.б. *ой-* «тегү» фигыленнән дигән фикерне куәтли, к. **Оек**).

**УЙМЫР** «полукруглая стамеска», диал. (ДС I: 201) «бурав» > удм. *уймыр* id. ← *уй-у* (к.). Сирәк кулланылучан *-мыр//-мер* аффиксы бу сүзнең борынгылыгына гуаһ. Әлеге эш коралы хәзер **уйма** дип дә атала.

**УЙНАК** «игривый; неустойчивый (о лодке)» < гом. кыпч. *ойнақ* < бор. төрки (ДТС: 366) *ojnaq* id., ш. ук «кыланчык, җилкенчәк, җилбәзәк». Кайбер телләрдә (к. Радлов I: 975) *ойнақ* «уен мәйданы». К. түбәндәгене.

Дерив.: **уйнакла-у.**

**УЙНА-У** «играть», диал. «плясать» < гом. кыпч., уйг., чыгт., бор. төрки һ.б. *ойна-* id. < *ойун-а-,* к. **Уен**. Чув. *выла-, вылля-, выльа-* «уйнау» < *вӓйла-, вӓйӓла-* микән, яисә < **ойла-, *ойула-* яки гом. төрки *уйна-* < *ойна-* сүзеннән үзгәреп килеп чыкты микән – әйтүе кыен; як. *ōйнō-, ōйјō-* «уйнау; сикерү» монг. *оi-* «тайчыну; янтаеп калу» сүзе белән чагыштырыла (к. Пекарский: 1796–1806). ЭСТЯ I: 435–436; Федотов II: 136–137.

**Уйна-** продуктив нигез: **уйнал-у, уйнаш-у, уйнат-у** һ.б., к. **Уйнак, Уйнаш.**

**УЙНАШ** «блуд» < бор. төрки (ДТС: 366) *ojnaš* «җиңел холыклы хатын» ← *уйна- < ойна-*, к. **Уйна-у.**

**УЙПАТ, уйбас, уймат** (ЗДС: 677–678) «низина, пониженное место в рельефе». Ихтимал *уйыпаст* парлы сүзеннәндер (к. фар. *паст* «түбән төш»). К. каз. (ҚТДС: 259) *ойпаң, ойпас* id. К. ш. ук **Уй, Уй-у, Уймыр.**

**УЙРА-У** «образовать мелкие водовороты, воронки на поверхности (о реке, потоке)», «оседать» (к. ЗДС: 678–679) – **уйыр-а- < *ойур-а-* булса кирәк, **уй-у** (к.) фигыленнән. Чаг. диал. (ЗДС: 679) **уйыргаķ** «уйсулык».

Дерив.: **уйрал-у** (*Уйралып, уйралып ага Уралдагы елгалар,* җырдан); **уйравык** «сай чоңгыл, су, елга һ.б.ш. өстендәге бөрәнкә; чоңгыллана торган».

**УЙСУ** «пологая низина, понижение; пониженный (о местности)» ← **уй II.** Төп нигездән үзгә буларак, *уйсу (уй-су)* сүзе һәр төбәктә кулланыла.

**УЙСЫН** – название древнего народа, предположительно отюреченные ираноязычные племена ~ хәз. каз., нуг., *уйсун* – вак кабиләләрнең берсе. Бу сүз башк. *үсәргән < үсәңнәр* кабилә атамасында булуы ихтимал. **Уйсун** сүзен кыт. *вусун* этнонимы белән чагыштыралар. К. Türkler I: 776–781.

**Җик мәргән** тур. сөйләнелгән риваять вусуннар тур. да сөйләнелгән. К. **Үсәргән.**

**УЙ-У I** «делать углубление, выкопать, выдолбить выемку (с округлыми краями)» < гом. төрки (к. Радлов I: 969–970) *ой-*, төркм. *оой-* id., ш. ук «уйлану» (!). Төрки телләрдә һәрдаим «төшү» > «уйлау, уйлану», к. **Төшен-ү, Үкен-ү.** Бу хәл бор. бер модельдән килсә кирәк. Гомумән, бу **Уй I –**

**Уй II – Уй-у** сүзләре арасында бәйләнешләр һичшиксез бар. Будагов I: 167;ЭСТЯ I: 428–429.

**Уй-** гадәттән тыш продуктив нигез: **уел-у, уеш-у, уйдыр-у** (бу сүзнең «уйландыру» мәгънәсе *уеңны уйдырып сөйлә* тәгъбирендә дә сизелә); исемнәр: **уем, уеш; уючы;** к. **Уел, Уйдык, Уйдым, Уйма, Уймыр;** сыйфатлар: (диал.) **уйык,** башк. *уйпат*, к. **Уяз, Уярла-у**. М. Рясянен (Räsänen 1969: 359) рус. *ваять* сүзен төрки *уй-* < *ой-* белән бәйли.

**Уй** һәм **уй-** сүзләренең мондый продуктивлыгы күчмәнче халык – бор. төркиләр өчен җир өслеген – рельефны белүнең актуальлеге белән бәйле булса кирәк.

**УЙ-У II,** (Тумашева 1992: 225) **уйу-у** «следовать», «слушаться» ~ кр.-тат., кар., төркм., гом. угыз. *уй-* < бор. төрки (ДТС: 605, 620) *ud-, uδ-, uz-* «иярү; (кемнең) тәэсиренә бирелү». К. **Ойы-у II.** Чаг. **Ола-у I.**

Дерив.: себ. (Тумашева 1992: 224) **уйғашлық** «охшашлык, иярғәнлек». Бор. телдә *ud-* һ.б. бик продуктив сүзьясагыч тамыр булган.

**УЙЧЫ, уйчыл** (Исәнбәт III: 79, 368) «склонный пребывать в оврагах, долинах, углублениях (о зверях)» – ш. ук аучылар, гомумән кешеләр тур. әйтелә. **Уй II** «түбән җир» сүзеннән. **Уйчы, уйчыл** сүзләре аучылык һәм күчмә тормыш актуаль булган чорлардан калган.

**УК I** «стрела; грядиль, рало (сабана, плуга, вероятно, по контуру)» < гом. төрки *оқ* ~ чув. *ух, ухă, охă* id. (к. Радлов I: 988; Ашмарин III: 341, 344). К. ш. ук монг. диал., эвен. һ.б. *ок, ох* «ритуаль ук». Лобнор төркиләрендә *оқ* сүзенең фигыль коррелянты *оқ-* «ату» сүзе дә бар, к. Будагов I: 143; ЭСТЯ I: 437–438; Федотов II: 296–297; Тимергалин: 488–489.

Бор. төрки халыкларда *уқ* < *оқ* «кабилә, үзәккә буйсынган кавем» мәгъ. кулланылган, чөнки каган вассалларына берәр ук биргән, аларга ярашлы җәясе үзендә калган (Sümer 1983: 20).

Дерив.: **уклы, уклык** (к. мәкаль: *Бай бер йотлык, батыр бер уклык*), **укчы**. К. **Уклау, Уктал-у.** К. ш. ук **Охша-у.**

**УК II,** после слов, оканчивающихся на переднерядный гласный либо на мягкий согласный – **үк** – частица «также; тот же; даже; всё-таки; уже; довольно-таки» < гом. төрки *оқ* һәм (алгы рәт сузыклы сүзләрдән соң) *öк* id. Бу сүзнең тат. сөйләшләрендә (Чувашстанның мишәр авылы Урмай төбәгендә) **ак//әк** ~ чув. *ах//ех*, мар. (Гордеев I: 66) *ак// äк, ах//äх*, ш. ук каз. *ақ//әк* варианты бар (бу вариант төрки телләрдә *оқ//öк* кисәкчәсенең еш кына кушымча кебек кулланылуыннан килеп чыккан).

Кайбер шивә һәм телләрдә – хак., чув. – бу кисәкчә аеруча еш кулланыла, бу хәл кайбер тат. сөйләшләрендә дә очрый (мәс., Казанда 1906 елда авторы күрсәтелмичә нәшер ителгән «Ахыр заман ишаны» китабында).

Тат. сөйләшләрендә (без теркәдек. – *Р.Ә.*) бу сүзнең *ука, укы* варианты бар, к. ш. ук к.-балк. *оқуна-* «ук//үк» (бу тур. ЭСТЯ I: 438–439; *ақ//әк, ах// ех* варианты искә алынмый). Тат. *ук//үк* мәгъ. удм. *уга*, морд. *гак//гяк* кисәкчәсе кулланыла.

Г. Рамстедт (1935: 446) *ук//үк* < *ок//öк* сүзен шул ук мәгъ. кор. *-ok, -uk* кисәкчәсе белән чагыштыра, ләкин, гомумән, сүзнең чыгышы бик томанлы, чөнки ошбу кисәкчәнең аерым мәгънәләре ифрат күп һәм абстракт характерда.

**УКА** «позумент, (Радлов I: 1668) галун; серебряная или (реже) золотая нитка» > чув. *ука, ока*, мар. *ока* id., морд. М. *ока,* рус. *окка* «алтын әйбер» ~ гом. кыпч. *оқа*, кырг. *оқо* «ука» < төр. *oka* «көмеш тәңкә» < госм. *оққа* «400 дирһәм һәм шундый авырлыктагы үлчәү берәмлеге (1,282 кг)» < бор. грек. *ћукка* > гар. *'уққа* «тәңкәле таҗ; йөзек кашы» (шуннан *'ақиқа* > тат. *ғақыйқа* «бәби чәче»). *Ока, око* үзара якын мәгъ. слав. телләрендә дә киң таралган. Гиганов 1804 (рус. *уха* – тат. *уқа*); Радлов I: 998. Алтын яки көмеш тәңкәләрне баш киеменә һ.б. беркетеп тезү тур. «Ногайцы»: 128; Redhouse: 898 һ.б.; Федотов II: 272 (бик ярлы мәгълүмат бирелә).

Дерив.: **укалы, укалау** «ука белән чигү яисә ука беркетү»; *Ука* сүзенең махсус җепне дә белдергәнлеге җыр сүзләреннән беленә: *Ак ука белән сар' ука Күгәрченгә тозакка* һ.б.; *Укаң коелмас әле* мәкалендә *ука*ның тәүдә тәңкәне белдергәнлеге саклана.

**УКЛАУ [уқлаw]** «скалка» < гом. кыпч. *оқлаw* (каз., к.-калп. *оқтаў*) < бор. төрки (ДТС: 369) *oqlaγu* «йомры», төрле яз. чыганакларда *оқлағу,* төркм. *оқлов*, аз. *охлов*, аз. диал. (АДДЛ: 348) *охлуғ* «уклау», төр. *oklaği, oklava* «уклау, цилиндр» ← (чыгт. һ.б.) *оқла-* «тигез өслектә тәгәрәтү» ← *оқ* «ук»: ук сабын шомарту һәм төзәйтү өчен аны тип-тигез таш өслектә озак кына тәгәрәткәннәр; чаг. фар. *тири-наан* (*тир* «ук», *наан* «нан камыры») «камыр угы – уклау». Шулай итеп, **уклау** ←

**ukla-u* «ук ясау» фигыленнән. Räsänen 1969: 360; Мухамедова 1973: 135; ЭСТЯ I: 441–442.

**УКРА** «личинка овода под кожей коров; изъян деловой шкуры (в кожном деле)» > мар. (Исанбаев 1978: 22) *укра* id. < нуг., каз., к.-калп. *оқыра,* ком., кырг. *оқура* id. < чыгт. (к. Будагов I: 144) *оқра, уқра* «чүлмәк», к. каз. *оқра қурды* «тире астындагы оя – чүлмәк корты – укра». К. ш. ук чув. *ăхра, ыхра,* мар. *охыра* «сарымсак, суган», үзб. (ЎХШЛ: 201) *оқрә* «эчтәлек, нәрсәнең дә булса эчендәгесе». Каз. (ҚТДС: 260) *оқалақ* «укра» аерым сүз бугай. Гомумән, ачык түгел.

Рус. *угорь (угри)* «сипкел; укра» сүзе белән охшашлык – очраклы.

Дерив.: **укралы, украла-у** «укралы булып китү».

**УКСЫМ, уксын**, диал. (Будагов I: 145) **үксүн** «дикий чеснок (его луковица); луковица вообще» > мар. кч. *уксым*, чув. *уксăм, оксăм* ~ себ. (Тумашева 1992: 163) **осқом**, башк. (БТДҺ: 250) *оқсон, осқон,* алт. *усқум, усқун*, шор. *оқсум* «кыргый сарымсак», хак. *ухсум, усхум* «суган» < бор. уйг. *usqun* «сарымсак; суган» < грек. (Бактрия) телендәге *оксинос* «әче җимеш, әчелек; оксид» сүзеннән; бу сүз төр. *eşqun, eskin, uşkun* һ.б.ш. яңгырашларда яңадан кергән (к. Christos Tzitzilies: 201); Türk dili, № 432 (1987): 315–336. Рус. *усхум* «сарымсак» тур. Аникин: 594 (әдәбият күрсәтелә).

**УКТАЛ-У** (к. Будагов I: 143) «стремительно нападать» ~ башк. *уқтал-* << каз. *оқтал-, оқтан-,* кырг. *оқтол-* «уклану, ук кебек атылу», алт., тув. *оқтал-* id. ← ассимиляция үсешкән телләрдә *оқта-* < *оқла-* «ук ату, укка тоту». К. **Ук, Уклау.**

**УКУ** «учение, учёба; чтение» к. **Укы-у.**

**УК-У** (диал., м.-кар. сөйләшендә: *Кодәй тәлә, угсаң иде, Жаңырны бирсәң иде* – мәҗүси дога) < иске тат. («Хөсрәү вә Ширин») **уқ-** > себ. (Тумашева 1992: 159) **ōқ- (ōғу)** «слушать, внимать; понимать, разуметь» < бор. төрки (ДТС: 613) *uq-* «аңлау», уйг. *ух-* id. ~ каз., кырг., алт., хак. (Радлов I: 1666) *уқ-* «тыңлау». Чаг. **Укы-у.**

Дерив.: **уклама-у** (ЗДС: 679) «тыңламау; ишетмәү», **уқмас** «кире, үҗәт», **оқмасай-у** (ЗДС: 582) «саңгыраулану». Элекке заманнарда балалар үлә барса, чираттагысына **Укмас** дип исем кушканнар, шуннан **Укмас** дигән авыл исеме һәм шуннан **Укмасый** фамилиясе (танылган балалар шагыйре) чыккан.

**УКУБА** (ЗДС: 679) «окоп». Диалектологик сүзлекләрдә гадәттә русчадан диелә. Ләкин азактагы *-а* авазы бу фаразга бик көчле чик куя. Асылда бу сүз, мөгаен, Мөхәммәт пәйгамбәрнең, Мәдинәдән ерак түгел *Укуба* тавында ур «окоп» казып, Мәккә мөшрикләренә каршы сугышуыннан булса кирәк.

Тат. гади сөйләмдә рус. *окóп* сүзен **акуп** дибрәк әйтәләр.

**УКШЫ-У,** себ. (Тумашева 1992: 225) **укцы-у** «издавать звуки и делать непроизвольные движения при позыве на блевание, при стошнении» < (кырг.) *оқшы-* > нуг., каз., к.-калп. *оқсы-* id.; төбендә **оқчы-* булырга тиеш, нуг., к.-калп. *оғы-*, алт. диал. (Радлов I: 993, 994) *оқы-*, тув. *оғу-* «косу; укшу» фигыленең дәвамлылык формасыннан (*оқ-чы-*, чаг. *борчы-, кырчы-, типче-*); к. ш. ук бор. төрки (МК III: 254) *uqı-* «укшу», үзб., таҗ. *uq, oq* «укшу хәле» – тәкълиди сүз булса кирәк (*оқ-оқ иту*).

Дерив.: **укшыт-у.** Мар. (Упымарий: 227; Саваткова: 175) *укшунчыкта-, укшынча-, уксынза-* «укшу» сүзләре тат. **укшын-у, укшынчак** сүзләре булганлыгын күрсәтә.

**УКЫ-У** «читать (исходное – громко читать), учиться» > удм. *уке-,* мар. *окэ-* «уку», чув. *ухă-, укă-, ух-* «дога кылу» < гом. кыпч. *оқы-,* куман., кырг., госм., чыгт., төркм. *оқу-, оқа-* id., бор. чыгт. (Боровков 1963: 235) *оқı-,* уйг. (Радлов I: 1008) *оғы-* «чакыру» >> чув. *вула-* «уку»; «уку → өйрәнү» мәгъ. күчеше фар. *хандăн* сүзендә дә күзәтелә һәм иске мәдрәсәләрдә уку методын – бер сүзне күп тапкырлар кычкырып кабатлауны чагылдыра. Морфологик җәһәттән *уқы-* < *оқы-* < **оққур-* «тыңлату» булырга тиеш, ничек тә *уқы-* нигезе *уқ-* «аңлау; тыңлау» (к. **Ук-у**) сүзе белән баглы; к. ш. ук (Радлов I: 991–996) уйг. һ.б. *оқ, оқы* «кычкырык, аваз; дан, данлау, дан җырлау; игълан», шуннан *оқа- (оқ-а-)* «чакыру» (чаг. алт. *қычқыр-* «кычкыру; китап уку»), чаг. яз. монг. (Поппе 1938: 365) *иqа-* «аңлау», тунг. *огат-* «җырлау».

«Тыңлау» һәм «әйтү» мәгънәләренең керешүе *уқ* < *оқ* тамырының бик борынгылыгы тур. сөйли.

Дерив.: **укыл-у, укын-у, укыш-у, укыт-у; укучы, укытучы; укымалы, укыгысыз**, сирәк **укыштыр-у** һ.б. Чув. *укăт-* «кирәген бирү, тиргәү, тукмау һ.б.» < тат. сөйл. «иманын *укыту*» id. тәгъбиреннән эллипсис, к. Федотов II: 273; Räsänen 1969: 359–360.

**УКЪЯНУС [укйанус]** иск. «энциклопедия, всеобъемлющий словарь» < төр. *okyanus* id. < грек. *Ωκεανός* «океан (сүзләр океаны)». Будагов I: 145.

Революциягә кадәр берничә тат. **укъянус** нәшер ителгән.

**УЛ I,** диал. (ДС III: 121) **ŏwыл,** (Тумашева 1992: 163) **ŏул, уул** «сын» ~ к.-балк., каз., к.-калп. *ул,* нуг. *увыл [уwыл],* кырг., алт. *уул,* алт., хак., тув. *оол,* як. *уол* < бор. гом. төрки *огул* «бала-чага, балалар». К. **Угыл, Уыл, Уылдык.**

Дерив.: **уллы, улсыз, уллык** (*уллыкка алу*). Рәсми стильдә **фәлән улы** дип язу, гомумән, шыксызрак, традиция буенча **углы** дию хәерлерәк һәм мәдәнирәк.

**УЛ II** «он; тот (то, та)» (в ряде форм склонения и словообразования заменяется супплетивной основой *ан-*) < гом. кыпч., алт., уйг. *ол*, як. *оол* ~ кырг., алт. диал. *ал* id. ~ чув. (Ашмарин III: 165) *вăл, вăлă, вул, ву, у, о* «ул» ~ себ., башк. (диал.) *у* < үзб. диал., кр.-тат., каз., ком., төр. һ.б. *о* (к. ЭСТЯ I: 444–446), кор. *ol* «нәкъ шул» сүзе белән чагыштырыла. Гомумән, этимологиясе катлаулы сүз. Чув. *ун, он* ~ тат. *аның*, *ул* (*ун чухлĕ* «ул чаклы, аның чаклы» һ.б.), ягъни бу сүздә тат. һәм чув. телләрендә генетик уртаклык бар. Федотов II: 106 (чув. *вăл* вариантының крш. сөйләшләрендә дә *выл* яңгырашында кулланылуына игътибар итә).

**УЛАК I** «колода, корыто, жёлоб» – кыпч. (каз., нуг.) *олық* id., ләкин тат., башк. яңгырашы каз., уйг. *олақ* ~ бор. кыпч. («Шәҗәрәт әл-әтрәк») *alaq, ulaq* «бассейн, терлек сугару хәвезе», кр.-тат., госм., як., бор. төрки (ДТС: 366) *oluq,* чыгт. (Радлов I: 1024; Будагов I: 141) *оғлуқ, оғлуғ* «улак, кечкенә канал, бәҗ» (**оғ* тамырыннан) сүзеннән. Чув. *валак, волăк, вулак* ~ мар. *валак* ← мар. (Иванов, Тужаров: 25) *вал*, мар. кч. *вол* ~ венг. *valu* «улак, тагарак». ЭСТЯ I: 451–453 (Э.В. Севортян **ол* тамырыннан ди), Федотов (I: 99, 130) бу сүзне чув. *вулă, волă* «көбәк, көпшә» ~ башк. *ŏлŏн* < бор. төрки *olun* «кәүсә» (к. **Олын**) сүзләре белән бәйли. Гомумән, сүзнең этимологиясе юраулы: *иу- ~ оу* тамырының мәгъ. ачык түгел. Ихтимал, *оқ ~ оу* «юнәлеш» сүзеннәндер: *оглақ* «(су агымын) юнәлткеч» ← *огла-* «юнәлтү», к. **Ук I, II.**

Дерив.: **улаклы, улаксыз; улакла-у** «улак рәвешенә китерү».

**УЛАК II, уланшак** (себ., яүшт. ЗДС: 679), «сын; ребенок», (Гиганов) «козлёнок» ~ төркм. *овлоқ,* куман., чыгт., уйг., төр. һ.б. *оғлақ* «кәҗә бәрәне, бәти», тик шор телендә һ.б. кайбер сөйләшләрдә генә «угыл, ул, бала»; бор. телләрдә үк (ДТС: 363) *oγlaq* «бәти» һәм *oγlaγu* «йомшак, нәфис; иркә һ.б.ш.». Җәди = Кучкар йолдызлыгын *оулақ* дип атау бор. телләрдән хәз. төр. теленә кадәр дәвам итә. Күрәсең, тәүдән үк *углақ < оглақ < огул-ақ* «кечкенә» бәтиләр атамасы булган: бәтиләр бүтән йорт хайваннарына караганда балаларга күбрәк охшыйлар – тавышчанрак, хәрәкәтчәнрәк, кыюрак булалар. К. ш. ук **Углак, Ылақ.** Räsänen 1969: 358.

**Уланшақ** варианты **улан-ушақ** парлы сүзеннән бугай.

**УЛАН** «улан (воин лёгкой кавалерии в русской армии XVIII–XIX веках.)» < ним. *Ulan, Uhlan* id. төр. *oğlan* сүзеннән таралган (к. **Углан**). Фасмер IV: 158. Төр. *oğlan* «углан» дип яшь яничәрине атаганнар. **Уланнар** тур. русча тарихи энциклопедияләрдә тәфсилләп язылa.

**УЛА-У I** «выть, завывать» – тат. теленең үзендә *у-у* тәкълиди сүзеннән ясалган (*уу-ла-,* чыгт. *бызла-, гөҗлә-, гырла-, жула-, жуылда-*), тат. диал. (ТТДС I: 326–327), башк., каз. *ŏлы-у, ŏлŏ-у* < гом. кыпч. *улы-, улу-* ~ яз. монг. *uli-*, чыгт. (Поппе 1938: 363) *ulu-* «улау» икенче бер модель буенча ясалган. Räsänen 1969: 275; Федотов II: 273.

Дерив.: **улаш-у, улат-у** һ.б.

**УЛА-У II** (миш. ЗДС: 680) «быть обильным, многочисленным; быть бурно растущим». Сүзлектә китерелгән мисалларны тәкълиди *ула- (< у-ла-)* «уу дип аваз салу» сүзеннән дә чыгарып була: күч. мәгъ. бу сүз «мул булып китү» мәгънәсеннән дә алала (чаг. *бүресе улады* «бик зур уңышка иреште»). Ләкин бу *ула-у* бүтән сүздән бугай.

Дерив. (себ.) **улам** «күп итеп, еш кына» (*уламы белән* «күпләп»), **уламлы** «артыгы белән».

**УЛА-У III** (ЗДС: 680) «чактыру» < **уыла-у,** к. **У, уы.**

**УЛҖА,** (ЗДС: 680) **улца,** (Тумашева 1992: 162–163) **ŏлҗа, ŏлца** «военная добыча, трофей» < куман. *olǯä,* ком., к.-калп., кар., чыгт. *олҗа*, кырг. *олҗо,* каз. *олжа,* чыгт. *олча*, тув. *олчо,* башк. *улйа* һ.б. < яз. монг. *olǯa* (хәз. монг. *олзо*$^{н}$) «табыш, аслам, улҗа» > тунг. *олǯи* «әсир» ← *ol-* «табып алу». Räsänen 1969: 360; ЭСТЯ I: 446–447; ССТМЯ II: 13; Сафаров: 69.

**Улҗа** < *олҗа* сүзенең кайбер телләрдә (ком. һ.б.) «хатын, кәләш» мәгъ. булуы игътибарга лаек; к. ш. ук алт. *олдьйог, олйо* «әсир; богау».

Дерив.: **улҗалы, улҗасыз; улҗалык; улҗала-у.**

**УЛҖАР, үлҗәр** (Котбиның «Хөсрәү вә Ширин»ендә) «весть, приказ о походе, извещение о войне» ~ чыгт. (Будагов I: 153) *олҗар ~ öлҗäр* id., ш. ук «мобилизация» ← *олҗа-, олча-* «хан алдында тезләнеп тезелү». Монг. сүзе булса кирәк. Чаг. **Уҗар.**

**УЛТАРА** (*ни ултара, ни пултара* яки *ни ылтара, ни пылтара* «ни так, ни сяк, не делится») «пополам», диал. (ТТДС I: 456) **уртара** id. Аңлашылмый: **урталай** сүзеннән үзгәргән дип раслап булмый. Бәлки рус. *ни литра, ни полторы* кебек бер сүздән бозылгандыр

**УЛ-У** иск. «быть» < угыз. (кр.-тат., төр., аз. һ.б.) *ол-* (< *вол-* < гом. төрки *бол-*) id. *Бул-у* фигыленең артык күп мәгъ. булуын искә алып булса кирәк, төрки телләрдә язучылар XII г. башлап һәр җирдә *ул-* < *ол-* фигылен кулланып килгәннәр; тат. әд. телендә *ул-* XX г. башында да бик актив кулланылган. Ләкин бу *ул-у* халык теленә кереп урнашмаган. Хәлбуки *ул-у* фигыле еш кына саф тат. морфологик парадигмасында килгән (*улган, улырдай, улырлык* һ.б. угыз телләрендә юк). *Ул-у* һәм *бул-у* сүзләренең (мәгънәләрен аерып) кулланырга омтылышлар (бер үк текстта һәр икесен, ләкин төрлерәк мәгънәдә куллану), мәс., З. Һади әсәрләрендә сизелә, ләкин алар дәвамын-үстерелешен тапмаган. Хәз. телдә *ул-у* иске телгә стилизация өчен кулланыла. К. **Бул-у.**

**Ул-** < *ол-* < *вол-* күчешләренең реальлегенә тат. диал. (ТТДС I: 329) *улҗал* << *булҗал* (к. **Бүлҗәл**) мисалы да ышандыра: бу очракта да *у-* < *ву-* < *во-* < *бо-*. ЭСТЯ II: 185–188 (тат. *ул-у* каралмаган).

Дерив. юк диярлек. Грамматик формалары *бул-* фигыленекенә тулысынча тәңгәл түгел: мәс., *улдык* (**улдык-ым** ~ *улдыгым, улдыкы ~ улдыгы* һ.б.) «булу хәле» формасына тәңгәл **булдык** кулланылмаган (**булдык** сүзе тат. телендә бөтенләй үзгә мәгънәдә, икенче бер сүз).

**УЛУС** «улус, административная единица; стойбище (в Сибири); страна, государство (в XV–XVI веках.)» – кайбер әдәбиятта *олыс* дип языла, ләкин сөйләм телендә чагылыш тапмый. К. куман., алт., уйг., чыгт., госм. (Радлов I: 1696–1697) *улус* «кабиләләр берлеге», кар., уйг. *улуш* «халык, милләт», бор. төрки (ДТС: 611) *uluš* «торлак, торган җирең» ~ монг. (> тув., хак.) *улус, улс* «ил; халык, кешеләр» ~ монг. диал. *улур* «өлкә», маньч. (сол.) *олор, олур* «халаек» (к. ССТМЯ II: 16), чаг. үзб. (ЎХШЛ: 268) *улуз* «як, тараф». Дж. Клоусон (Clauson: 153) фикере буенча, *улус* сүзе монголчадан таралган, монг. телендә исә төрки *улуш* сүзеннән диләр. Кайбер телчеләр (к. Бертагаев 1951; ЭСТЯ I: 592) *улус* сүзенең бер варианты итеп нуг., каз., к.-калп., кырг. *улут* > *улт* > *ӯлт* «милләт, халык; дәүләт» сүзен күрсәтәләр, ләкин, безнеңчә, бу сүз гар. *әүлад* сүзеннән дә булырга мөмкин (һәрхәлдә монда *с* > *т* күчеше аңлашылмый). Безнеңчә, хакыйкатькә якут филологлары тәкъдим иткән этимология якын: *улус* < *улу ус* < *улу уз* «олы союз; олы киңәш, олы килешү» (бу фаразны семантик җәһәттән **улус** сүзенең «киңәш, җыелыш; кәрт уенында бер кулда барча корольләр булу хәле» мәгъ. булу куәтли), к. Антонов: 102. Рус. *улус* тур. Аникин: 583 (шунда ук арытабангы бай әдәбият күрсәтелә); гар., фар. һ.б. чыганакларда *ӯлӯс* сүзенең кулланылышы һәм мәгънәсе тур. к. Будагов I: 88–89.

XVI г. тат. телендә *улус* «ватан» мәгъ. кулланылган, Казанның соңгы якчылары «үзебезнең *улусы*быз өчен үләбез» дип әйткәннәр. Соңыннан *улус* сүзе әд. телдә сирәгрәк кулланыла башлаган һәм аны тәнәйтү тәҗрибәләре дә уңышка ирешмәгән. Шунлыктан бу сүзнең деривациясе дә юк диярлек.

**Улус ~ улуш** сүзе, төрки телләрдән алынып, элекке укр. һ.б. слав., ш. ук Балкан телләр союзы телләрендә дә кулланылган. Тик рус *волость* сүзен төрки **улус** сүзеннән чыгару акланмый, чөнки рус сүзе закончалыклы рәвештә *власть ~ владеть* сүзләре белән тамырдаш.

**УМ** диал. «передняя часть туши; передок» ~ чув. *ум* id. М.Р. Федотов (I: 280) бор. төрки *öŋ* «алгы як» сүзе белән чагыштыра. К. ш. ук **Умрау.**

**УМА** «брюшина, матка» ~ монг., бур. *уумай* id. **Умай** сүзеннән булса кирәк.

**УМАЗА** (ТТДС I: 451; БҺҺ III: 193) «чревоугодник; не постящийся», иск. «диета» ~ каз. *оңаза* id., нуг. *оңаза* «катарның бер төре – һәрдаим тулы булмаса, ашказаны авырту». Чаг. бор. төрки (ДТС: 611) *ит* «ашказаны бозылуы».

**УМАЙ: Умай ана** «покровительница родов, роженицы и младенца в языческой мифологии

тюрков; добрый дух-покровитель» ~ кырг., каз., алт., шор., үзб. диал. *умай*, бор. төрки (ДТС: 611) *umaj* «соңгылык; Умай ана»; чыгт. *умай* «һавада оялый торган кош» мәгънәсе бу сүзне ир. *һумай (кош)* сүзеннән дип уйларга мөмкинлек бирә (к. **Һомай**). Төрки телләргә бу сүз (һәм образ) бик бор. заманнарда – б.э.к. кергән булырга тиеш. **Умай** сүзе тат. телендә *ӧмай > ымай > май* күчешләрен кичергән, к. **Май II;** тат. сөйл. **нюмай** (к.) «күп; муллык» сүзе дә шуннан булса кирәк. МНМ II: 547. Абрамзон С.А. Рождение и детство киргизского ребёнка // Сборник музея антропологии и этнографии, т. XII. М., 1949: 81–85; Потапов Л.П. Умай – божество древних тюрков // Тюркологический сборник 1972. М., 1973: 265–286; İnan I: 396–398.

**УМАК** (Ж. Вәлиди) «компания; завсегдатай какого-либо места встреч для времяпровождения; компанейский (человек)» ~ уйг. *ӧмәк* id. Төрки телләрдә *умаҡ ~ омаҡ* яңгырашында берничә сүз йөри: к.-балк., уйг. *омаҡ* «купшы; мөлаем, чибәр»; хак., тув. *омаҡ,* алт., кырг. *омоҡ* «теремек, терчә», лобнор. *омак, омоҡ* «горур», нуг. *омаҡ* «булдыксыз; тик йөрүчән»; чыгт. *омаҡ* «нәсел, зат, фамилия», як. *омуҡ* ~ эвенк. *омук, омог* ~ калм. *omg* «кавем, ыру; чит ыру» < бур., монг. *омог, обог, обуг,* яз. монг. *omuγ, obuγ* id. (к. Аникин: 425). Тат. **умак** мәгъ. җәһәтеннән уйг. сүзенә якын, ләкин веляр яңгыраштa; бүтән мәзкүр сүзләр яңгыраштa тат. сүзенә бик бап, ләкин мәгънә җәһәтеннән читтәрәк. К. ш. ук Будагов I: 158; Räsänen 1969: 361; ЭСТЯ I: 452–453; ССТМЯ II: 18.

Дерив.: **умакчы; умакчыл.**

**УМАР** диал. (Будагов I: 158) «река Обь». Аникин (I: 416–417) Обь тур. озын гына матдәсендә бу вариантны оныткан.

**УМАРТА,** диал. (Будагов I: 158) **умарда**, (ДС II: 147) **ӧмурты**, (ДС I: 135; ДС III: 11 һ.б.) **мурта** «улей, борть», **марта** (Гобәйди), диал. (ТТДС I: 300, 309) **марта, мурта,** себ. (Тумашева 1992: 225) **умо̄рто̄** «пчела» ~ удм. *уморта* «бүкән умарта», мар. (Упымарий: 143) *омарта,* чув. (Сергеев 1968: 40) *марта* «умарта» ~ каз., кырг. диал., уйг. *омарта* «умарта, киләк» (татарчадан булса кирәк) ~ абаз. *мартан* «умарта; кәрзин».

Яңгырашы буенча **умарта** икенчел, *мурта* < **омурта* элгәргерәк; чаг. рус. диал. *бортя* «чолык», *бортень* «буш умарта» (чаг. тат. *сыерчык умартасы = оясы*); рус. сүзләре гом. слав. характерда, к. пол. *barc,* чех. *брт* «умарта». Әмма тат. *умарта* < **омурта* сүзен русчадан дип раслауга фонетик киртәләр бар: рус. *борть* (бор. рус. *бърть, боръть*) > төрки **бӧрт* > тат. **бүрт* > **мурт* булыр иде, хәлбуки андый төрки вариантлар беркайда да теркәлмәгән. Рус-слав. һәм тат.-кыпч. (абазин сүзе кыпчакчадан) вариантлары уртак бер чит чыганактан килүе дә мөмкин. Бу сүзне бор. һинд-ир. *martgan, murdan* «кешеләр, халык» сүзеннән дә чыгаралар (умарта – бал корты күче халыкка охшатыла: шуннан мордва, удмурт этнонимнары ясалган).

Дерив.: **умарталы, умартасыз; умарталык.**

**УМАЧ** «затируха; похлёбка с клёцками» > мар. (Исанбаев 1978: 35) *умач* ~ башк. *умас*, ком. *увмач*, каз., к.-калп. *умаш, умаҡ*, кырг. *омоч*, үзб., таҗ. *умач, омач*, төр. *otac* < *oγtac* id. ← *oγ-* «уу» (*-мач* – ашамлык атамалары ясагыч кушымча). Тат. диал. (ТТДС I: 451) **умаҡ** «вак кабартма» ~ төр. *oğmak, oğtaç* «умач төре» – **умач** сүзенең паронимы (*-мак* аффиксы да ашамлык атамалары ясалуда кулланыла). Хайрутдинова 1993: 76–77.

Дерив.: **умачлы, умачсыз; умачлык.**

**УМБЫ** (Урал, без теркәдек. – *Р.Ә.*) «торфяник; мощное, большое болото» ~ башк. (БТДҺ: 251) *омбол* «чоңгыл; баткаклык», нуг., к.-калп. *омба, омбы* «көрт», каз. *Умбы* – Омски каласы (Будагов I: 158). Бу сүзнең **Обь** һәм **Омь** елгалары атамасына катнашы булса кирәк. К. **Умар.**

**УМРАУ [умраw], умырчау, умыра** «ключица»; (Тумашева 1992: 225) «верхняя часть груди» < гом. кыпч.: каз. *омырау,* нуг. *омырав,* к.-балк. *омурау,* ком. *омурав,* кырг. *омуроо* id., алт. *омуру,* хак. *омырыг* «умрау; умыртак, сын» < **омуруг* ~ **омуругу* ~ яз. монг. *omuruγun* «умрау», к. ш. ук төркм. *омурдан* «кулбаш»; чув. *ăмăр* ~ хак. диал. *омыр* «хайван (башлыча – ат) күкрәге»; чув. (Ашмарин IV: 39–41) *ăмра, ŏмра* «ат күкрәге» татарчадан булса кирәк. Төр. *om* «сөякләрнең тупак очы», *oma* «бот сөяге», *omur* «умырткаҗың бер сөяге», *omurga* «умырткалык», *omuz* «умрау» (*-z/-з* вариантлы тат.-башк. даирәсендә генә юк, ул барча кыпч. һәм угыз телләрендә очрый).

**Умыраw,** бүтән бик күп очраклардагыча, төбендә исем фигыль – **умыра-у* сүзеннән булса кирәк, аның төп мәгъ. «(сөякләр) тоташу, күкрәк читлеген хасил итү; гомумән тоташтыру, тоташтыргыч һ.б.ш.» булган һәм бу фигыль *умыр* < *омург* «(сөякләр) тоташмасы, күкрәк читлеге» (> *омуз*)

сүзеннән ясалган (*омур-а-*), үз чиратында *омур* < **омурғ* бор. гом. төрки *ом* «сөякнең йомры башы; ике сөяк тоташкан төш», ш. ук. «ике сөяк тоташу» сүзеннән ясалган, к. **Умыртка, Умыр-у.**

Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 453–455) *ум* < *ом* тамыры гом. төрки *öң* һәм *оң* «алгы як, уң» сүзләре белән контаминациягә кергән дип исәпли. К. ш. ук Räsänen 1969: 361–362; Федотов I: 82–83.

**Умрау** сүзенең реаль деривациясе юк диярлек.

**УМЫЛ: умыл уты** (ТРС 1966: 340) «змееголовник» – ачык түгел. Чаг. рус. *омела* – агачларда үсә торган паразит үлән; чаг. ш. ук каз. (ҚТДС: 261) *омал* «ревматизм».

**УМЫРЗАЯ [умы̆рзайа]** «подснежник», кайбер сөйләшләрдә «горицвет» ~ башк. (БТДҺ: 204, 254, 361) *ҡумырзыйа, умырҙайҡ, умырзыйа, үмәрзайа, үмәрзәйә* – Урал артында (Г. Теләш), Урал регионында (БТДҺ: 74, 76–77) *гөмөр(ө) зайа* дип атала (чәчәге бик тиз коелучан булуыннан дип аңлатыла), к. ш. ук нуг. *öмирзайа* «утчәчәк». Безнеңчә, *гомере зая (чәчәк)* дип аңлату – халык этимологиясе. Сүзнең этимоны фар. *хумри* (> кырг. *кумры, кумуру*) «җете кызыл чәчәкле үлән» сүзе белән бәглы булса кирәк (*хумри зиаһ* «кыр ут чәчәге», фар. *зиаһ* «кыр, ялан»).

**УМЫРТАК, умырткак** «позвоночник». Башкортстан тат. сөйләшләрендә теркәлгән бу сүз уникаль булуы белән кызыклы. Ихтимал, бор. болг. шаһзадәсе *Омуртағ* исеме белән гомогендыр. **Умырткак** яңгырашы яңа – тат. телендә килеп чыга ала.

Гом. төрки планда **умыртак** сүзе **умырт-ак,** ягъни **умырт** нигезенең кечерәйтү-иркәләү формасы булса кирәк. Соңрак ул икенчел мәгънәләр алган. К. түбәндәгеләрне.

**УМЫРТКА** «позвонок», **умыртак** «позвоночник» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг. һ.б. *омуртқа* (нуг., каз., к.-калп. *омыртқа*), хак. *омыртха, омырха*, чулым. *омырға,* төр. диал. *omurγa* id. кайбер телләрдә (кр.-тат., кар., төркм. һ.б. к. ЭСТЯ I: 463) *оңурға* вариантына ия. Бу хәл *умрау* һәм *умыртка* сүзләренең гомогенлыгына шик уята. Ләкин, һәрхәлдә икенчел кимәлдә булса да, бу сүзләрнең этимологик мөнәсәбәтлелеге шиксез. К. **Умрау.**

**УМЫР-У** «отламывать, откусывать большими кусками» > мар. (Упымарий: 143) *ӧмыр-* < (нуг., к.-калп.) *омыр-*, кырг. *омур-* id. Гом. кыпч. сүзе. Гомумән, ачык түгел (**ом-* фигыленең йөкл. юн. дип фаразларга мөмкин).

Дерив.: **умырыл-у, умырышу-, умырт-у.**

**УН** «десять» ~ чув. *вуннӑ, воннӑ* < болг. *wан* ~ гом. төрки *он* < *онн* id. ~ тунг., кор. *он* «йөз». Räsänen 1969: 362; ЭСТЯ I: 455; Федотов I: 130–131 (төрле фаразлар китерә).

Дерив.: **унлы; унлык; унсыз** (*сәгать унсыз*); **унна́рча, унар** (шуннан: **унарлы, унарлык; унарлап** һ.б.); **унлап; унлат-у** һ.б. икенчел сүзләр.

**УҢ** «правый; лицевой (о стороне); успешный (о делах); передняя сторона, перед» (*күз уңында* «күз алдында») < гом. төрки *оң,* як. (Пекарский: 3020) *уңа, ума* id., чув. *ум* «ал як» – иң «төп төрки» сүзләрнең берсе. Бүтән телләрдә аның бәхәссез параллельләре табылмый диярлек: мар. *оҥ* «күкрәк» төрки телләрдән. ЭСТЯ I: 456–461 (Э.В. Севортян *öң* «үң» сүзен *оң* сүзенең соңрак килеп чыккан палаталь варианты итеп карый, к. **Өң**).

**Уң-** продуктив нигез: диал. **уңал-у, уңар-у; уңлы, уңлык; уңагай** (*сулагай*ның антонимы). Төрле мәгъ. һәм дериватлар тур. Будагов I: 149–150.

**УҢАЙ,** диал., башк. **уңгай > ŏңгай > ыңгай** «попутный; положительный; удобный, лёгкий (о труде и т.п.)», «направление», «по (дороге)» > чув. *ункай, ӑнкай, ӑмкай* (кайбер чув. сөйләшләрендә аффикска әверелгән) id., мар. (Упымарий: 145 һ.б.) *оҥай* «кызыклы», «җай; уңайлы, җайлы», удм. (Насибуллин: 150) *ъңгай* «даимән, беруңай» < гом. кыпч., алт., уйг. *оңай*, кырг. *оңой*, хак. *оой* < бор. төрки (ДТС: 367–368) *оңа, оңај* «җиңел; дөрес; Юпитер планетасы» – әлбәттә, *уң* < *оң* сүзеннән, тәүге варианты **оңқай* (**қай* «юнәлеш, юнәлгән тарафың») булса кирәк.

**Уңай** продуктив нигез: **уңайлы, уңайсыз; уңайлык, уңайсызлык; уңайла-у;** кайбер төрләнеш формалары лексикалашкан: **уңайга, уңаена, уңаеннан** һ.б.

**УҢАШ-У, уңыш-у** (ЗДС: 681) «согласовать (с другими)» (к. парлы **киңәшү-уңашу**, ш. ук **киңәш-уңаш**) ← **уңа-у* фигыленең урт. юн., **уң** тамырыннан; к. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 460) **уңышма-у** «килешелмәү; уңышсыз, уңайсыз килеп чыгу», үзб. (ЎХШЛ: 203) *уңыш-,* каз. (ҚТДС: 260) *оңыш-, оңыс-* «уңашу».

**УҢГАН** «дельный; уродившийся, хороший (о хлебах)» – бу сүздә *уң-у*дан сыйфат фигыль фор-

масы белән **уңгын** (төр. һ.б. *оңгун*) сыйфат сүзенең контаминациясе күзәтелә. Диал. **уңгыл,** (ЗДС: 681) **уңны** «уңган, булдыклы».

**УҢКЫ** «кольцо у коновязного столба (к которому можно привязать несколько лошадей)», күч. «объединённый участок поля и луга, принадлежащий нескольким хозяевам» – кайбер сөйләшләрдә (к. ТТДС: 460) **уң** дип халык этимологиясенчә кыскартылган, шуннан **уңдаш, уңдашлык** «уртакка эшләү» > мар. (Упымарий: 145) *оң, оңго* «әлмәк; үзенә берничә тәңкә тагылган бөҗра», *уңгы, оңгы* id., ш. ук (к. Саваткова: 157) «күршеләр союзы», чув. *ункӑ*, каз. *уңқы* «уңкы; утырган кешеләр түгәрәге; бөҗра» > башк. диал. *ӧңгӧ* «чалгы беркеткеч бөҗра», чаг. **Оңгы**.

**Уңкы** сүзен гар. *ʻунқ* «бөҗра» сүзе белән чагыштырып карарга мөмкин: к. ш. ук каз. *оңқай*, кырг. *оңқо* «ашыкның тик тору хәле» < фар. *ʻанкāʼ* (? к. Räsänen 1969: 514); к. Федотов (II: 281) төрле фаразлар китерә (тик тат., башк. сүзләрен белми). Венгер һәм фин галимнәре бу сүзне санск. *oñko* «әлмәк» белән чагыштыралар – шуннан ук фин. *onki* id. диләр. Безнеңчә, **уңкы** һәм **оңгы** сүзләре контаминациягә керешеп, төрле мәгънәләр пәйда булуына китергән.

**УҢТЫЙ** (ТТДС I: 455) «правша; удачный; нормальный, ожидаемый, успешный» ~ каз. *оңтай*, кырг. *оңтой* «уңайлы барыш, уңайлы очрак» ← **уң.** Чаг. **Юлтый.**

**УҢ-У I** «удаваться (о предприятии); уродиться» > мар. *ун-, уң-, им-* < гом. кыпч., уйг. *оң-* id. ~ чув. *ӑн-, ӗн-, ӳн-* (?) id. *уң* сүзенең фигыль коррелянты; к. ш. ук төр. *on-* < бор. төрки (ДТС: 367) *oŋ-* «хәлләр яхшыру, авырудан терелү». Федотов I: 84 (тат., башк. параллельләрен китерми).

Дерив.: **уңдыр-у; уңыш.** Күп телләрдә **уңган** < *оңған* «булдыклы», **уңмаган** < *оңмаған* «булдыксыз» лексикалашулары очрый. К. **Уңган.**

**УҢ-У II** «блекнуть, терять свежесть цвета» < гом. кыпч., уйг., тув. *оң-* < бор. төрки (ДТС: 367) *oŋ-, oŋuq-* id. Гом. төрки характерда, к. ЭСТЯ I: 460–461. К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 386) *öŋ-*, уйг. *өң-* id., алт. диал. (Радлов I: 1026) *оң* «сулган», *оң-* «юкка чыгу».

**Уң-у I** һәм **уң-у II** күп телләрдә омоним булып килә, бу хәл алар бер тамырдан түгелме икән, дигән фикер уята.

**УП** (Старчевский) «гумно, место молотьбы (со специальной дорожкой для вола) ~ каз., кырг. *оп* id. ~ бор. төрки (МК, ДТС: 368) *ор* «авыл хуҗалыгы эшләрендә вал». Юдахин буенча, фар. сүзе.

Дерив.: **уп баганасы; уп үгезе** күч. мәгъ. «төп эшне башкаручы» (элек ашлыкны үгезләр белән бастырткannар). Ихтимал **упуч** (к.) сүзе дә **уп**тан киләдер.

**УПЛА-У** (к. **Сууплар батыр** – әкият герое) к. **Уп-у.**

**УПРАК: упрак-чапрак** (дигән парлы сүздә) «лохмотья, старая одежда и т.п., употребляемая для накидывания на скот в стужу и т.п.» К. чыгт., үзб. (Будагов I: 192) *упрак, уфрак* «ертык кием-салым» ← бор. төрки (ДТС: 368) *opraq, orpaq, ofraq* «иске-москы» ← бор. төрк. *opra-, obra-* > чыгт. *обра-*, кр.-тат. *упра-* «ерткалану, өзгәләнү, кискәләнү (кием тур.)». Räsänen 1969: 363 (тагын төрле төрки телләрдән параллельләр китерә).

КБ телендә *обрақ, упрак* «обмундирование» мәгъ. кулланылган. Кайбер бор. телләрдә (куман. һ.б.) *opraq* «гомумән кием, кием өлеше». Бор. төрки телләрдән бу сүз бүтән телләргә дә кергән, мәс., венг. *apro* «кием өлеше».

**УП-У (упты, убу)** «проваливаться; всасывать в себя» (беренче мәгънә асылда *җир убу* сүзеннән эллипсис, ләкин бу хәл онытылган) < гом. кыпч., алт. *оп-*, төр. *ор-, ир-,* як. *уоп-,* чув. *вуп-* < бор. төрки (ДТС: 368) *ор-* «йоту» һ.б. монг. *уу-*, тунг. *уw-* «эчү, суыру» белән чагыштырыла (к. ЭСТЯ I: 464–465). Этимологлар *уп-* < *оп-* тамыры белән *үп-* < *öп-* тамырдан (к. **Үп-ү**) бердәй дип тә карыйлар, ләкин, безнеңчә, мондый раслауга нигезләр җитми. Сүзнең исем коррелянты бар: каз. *оп* «асты куыш төш, куышлык».

**Уп-** продуктив нигез: **убыл-у; упкын** ~ чув. *вопкӑн, вупкӑн* «убыр, явыз рух»; **убыр** ~ чув. *вопӑр, вупӑр*; диал. (Тумашева 1992: 225) **упкаҗ** (~ кырг. *опқоқ*) «тирән сазлык», диал. (Akb: 71) **упла-у** «берьюлы йоту», (ТТДС I: 455) **уплык-у** *(уплыкты, уплыгу)* «эчкә батып керү (терлекнең тән әгъзалары тур.)» һ.б. **Уптым, иләһи** фразеологизмы рус. «провалюсь на месте, (если)» сүзеннән калька.

**УПУТ, упыwыт** (ЗДС: 681) «рейс, однократная езда (туда и обратно); отрезок рабочего времени» – бу сүзләр бер-берсеннән ерак урыннарда теркәлгән. Күрәсең, элек алар киңрәк таралган булгандыр (аларның нигездә бердәйлеге шик уятмый).

ЗДС авторлары бу сүзләр рус. *путь* дигәннән дип күрсәтәләр, ләкин, әгәр алар русчадан булса, *обвод* яки *обход* сүзләреннән килүе ихтималлырак. Чаг. ш. ук **Уп.**

**УПЧЫ, гупчы, вупчы, бубчы** (к. ДС III: 40), **вас'ы, восе, вусе, высе** (миш. ЗДС: 148, 150) «вовсе, совсем» ~ чув. *вуçĕ*, мар. (Гордеев II: 245) *гупче, бубча,* удм. *восе* id. – әлбәттә, русчадан.

**УПЧЫ-У** диал. (трбс., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «морщиться (о плёнке над жидкостью), перекисать» < (алт.) *опчы-* «бөрешү» ← **оп-* фигыленең кабатланучанлык формасы, тик ул фигыль конкретлаштырылмаган.

**УР** «глубокая канава, ров (в частности – вокруг крепости)», «дренажный канал в болотистой местности» (Ә. Баян), диал. (ТТДС: 456) «ложбина с крутыми берегами» > чув. *ур*, мар. *ор, ур*, удм. *ур* < гом. кыпч., чыгт. (Радлов I: 1046) *ор*, хак., уйг. *ора* id. «ясалма чокыр; чокырлы вал», кар. *Ор* «Кырымдагы Перекоп муентыгы һәм шәһәрчеге (кальгасы)» ~ мар. диал. (Упымарий: 147; Саваткова: 108) *ор* «җир өеме белән генә уратылган кальга» һ.б. ~ *ур* «чокыр; ачыклык, казынты»; бу сүзнең фигыль коррелянты да бар: хак. *ор-*, як. *ороо-, оруо-,* чув. *вар-* «канау яки канал казу». К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 161–163) **ōрō, ора, оро**, к.-балк. *уру*, алт. *оро* «чокыр, баз», хак. диал. *оры*, төркм. *уры*, чыгт., үзб. (ЎХШЛ: 269) *ора, ору*, каз. *ура* «бәрәңге, яшелчә, орлык һ.б. саклау өчен мөгрәп», бор. төрки (ДТС: 371 һ.б. чыганакларда) *oru* «зиндан (җир астындагы)» һ.б. шул *ор-* фигыленнән ясалган булса кирәк. К. **Урай, Урык.** Räsänen 1969: 364; Мухамедова 1973: 181; ЭСТЯ I: 466–468; Федотов II: 283; Нестеров 1980: 66–73; Гарипова 1998: 110–111.

**УРА** «ура!» (возглас, с которым идут в атаку) ~ рус., укр. һ.б. слав. *ура*, ним. *hurra, hurrah*, инг. *hurrah, hurray* һ.б. М. Фасмер (IV: 106) иске нимес теленнән чыгара; ләкин күп кенә этимологлар бу сүзне төрки-монг. телләреннән килгән диләр (к. төр. *ur, ay* «ор, әй»; төрки-монг. *уран* (як. *урä*) «оран; сөрән», тат. *ура!* – «дошманның флангларын урап һөҗүм ит»). Гомумән, Европа телләрендә бу сүз XVIII г. гына активлашкан, к. Kluge: 428.

**УРАЗ** (Будагов I: 120) «счастье», «языческий бог счастья» ~ чыгт. *ураз*, гом. кыпч. *ороз* «язмыш, бәхет, кот», төр. *oraz* «кот» < бор. фар. *роз* «көн, кояш; бәхет; бәхет тәңресе» сүзеннән, к. ш. ук **Рызык, Рыскал, Ырыс.**

«Бәхет тәңресе» буларак, элегрәк (XIX гасыргача) *ураз* сүзе антропонимиядә еш кулланылган, шуннан *Уразай ~ Рузай, Уразбакты, Уразкилде* ш. ук *Килдураз*) *Уразман* «бәхетле», *Уразмәт (< Уразмәмәт < Уразмөхәммәт)* һ.б. хәзер фамилияләрдә саклана торган исемнәр килә. Хатын-кыз исемнәре арасында *Уразбикә, Уразгөл* һ.б. очрый. *Уразлан (< Уразлы олан?), Уразланбик* исемнәре дә булган (Д.Б. Рамазанова мәгълүматлары) һәм шуннан рус. *Руслан < Еруслан* исеме дә килә. Рус. *разгильдяй* «ялкау; сөрхәнтәй» сүзен Алтын Урда чорындагы *Уразгилдей* исемле кешегә нисбәтлиләр (Попов 1957: 35). Топонимикада **Уразлы** дигән авыл, елга-күл исемнәре очрый. **Урыссу** дигән зур авыл атамасы **Уразсу** дигәннән һ.б.

Күп кенә хезмәтләрдә иске кыпч. *урус* исемен (берничә *Урус хан* билгеле) **рус** сүзенә нисбәтлиләр, ләкин, безнеңчә, бу исем *уруз < руз, роз* «көн, бәхет» сүзеннән булырга тиеш (рус сүзе исә бүтәнчә аңлатыла). К. ш. ук түбәндәгене.

**УРАЗА** «мусульманский пост, ураза» < фар. *рӯзä, рӯзе* «ураза», «көнлек». Будагов I: 598–599.

**УРАЙ I** «вал со рвом» < **ур айы*, к. чув. *ай* «ас, аскы як»; бу сүз – *ай* тат. телендә дә булган, к. диал. **урманай** «урман асты (ышыгы)». К. **Ур.**

Бу сүзне тув. *уургай* «ям, бунт (иген, ашлык саклау өчен баз)» сүзе белән дә чагыштырырга мөмкин, ләкин **урай** – хәрби объект булган, моны төрле төбәкләрдәге *урай* «ныгытма, кальга» мәгъ. топонимнар күрсәтә (мәс., Татарстанда *Троицкий Урай, Урай* дигән татар, чуваш авыллары һ.б.). Рус. диал. *урай* «дугай, елганың элекке юлыннан калган кәкре күл яки култык» сүзе дә шуннан шикелле, чаг. каз. *урañкай* (ҚТДС: 355) «махсус кечкенә (бер кешелек) өй, зимләнке».

**УРАЙ II** «вихор на макушке», «специально сделанный чуб, султан, укреплённый на темени боевой или парадной лошади» < гом. төрки: каз., алт. *орай*, кырг., як. *орой* < монг., бур., калм. *орой* «тау түбәсе; шлем семәге» < яз. монг. *oroi, horai* «түбә». Номинханов 1975: 81; ЭСТЯ I: 473; ССТМЯ II: 334; Аникин: 428.

**УРАК I** «серп» < гом. кыпч. *орақ* < бор. төрки (ДТС: 370) *orγaq* > себ. (Тумашева 1992: 163) **орғақ** id. К. **Ур-у.**

**УРАК II** (Тумашева 1992: 163, 226) «тропа (едва заметная), звериная тропа» к. **Урык-Сурык, Урык II.**

**УРАЛ** «горы и река Урал», (у писателя XVIII в. Муслими) «климатический пояс» (перевод перс.-араб. слова **икълим** «один из историко-климатических областей Старого света»). Елга исеме буларак **Урал** XVIII г. бирле генә кулланыла, этимология өчен тау (тәүдә бер тау сырты, соңыннан – гаять зур тау системасы) атамасы гына кызыклы. Бу топоним тур. йөзләрчә мәкалә һәм пассаж язылган, әмма уртак фикергә киленгәне юк. Күпчелек төрки *урал* < *орал* «урама, билбау» сүзеннән дип уйлый, чөнки рус чыганакларында Урал таулары күп тапкырлар «каменный пояс» дип аталган һәм сүз төрки (тат., башк.) теленнән калька булуы бик ихтимал. Фасмер IV: 166; Матвеев 1961: 25–30; Ястребов 1979: 163–171; Аникин: 586–587 (бай әдәбият күрсәтелә); Ромбандеева 1987: 271–274 (*Урал* сүзен манси теленнән димәкче).

Башк. **Урал батыр** исеме, әлбәттә, икенчел, чагыштырмача яңа тәгъбир. **Урал батыр** дастаны асылда монг. халыкларының *Кэзэр ~ Гэсэр* (к. **Гизәр**) дигән эпосының бер чагылышы – алардагы уртак моментлар шул фикергә китерә. К. Munkacsi B. Der Kaukasus und Ural als Wurtel der Erde // KSz. 1900, N 1. Моңарчы әйтелгән фаразларга шуны өсти алабыз: нугай җырларында *Урғал* «Урал» << бор. монг. *oruγal* «билбау»! Урал тирәсендә яшәгән күп халыкларда Урал тавы «таш» мәгънәсендәге сүз белән белдерелә: коми. *Из,* нен. *Пэ,* хант. *Кеw,* манси. *Нор* шундыйлар. К. тат. җырында: *Безнең яклар таш Урал, шаулап ага ташулар*. К. ш. ук Мурзаев 1984: 579–580.

**УРАМ** «улица» > чув. *урам, орам*, мар. *урам, урем*, удм. диал. *урам* id., морд. М. *орам* «җыелыш, мәйдан» < гом. кыпч., үзб., чыгт., уйг. *орам*, кырг., алт. *ороом* «урам», кырг. ш. ук «артбакча, сулык читендәге куе куаклыклар» (чаг. **Урай**), хак. *ором* «кальга, кирмән», госм., үзб. диал. *урам* ~ бор. чыгт. (Боровков 1963: 9) *урам* «квартал; торлак, шәһәрчек», бор. төрки (ДТС: 370, Малов I: 438) *uram* «урам», каз. (Радлов I: 1052) *орам* «биләмә» һ.б., к. ЭСТЯ I: 601 (Э.В. Севортян беренчел мәгънә итеп «шәһәрчек, утрак яшәү урыны, колония» дип күрсәтә), иске фар. (Очерки истории культуры Средневекового Ирана: 235) *урам* «почта станциясе, ямыл», нуг. диал. (В.А. Мошков) *орам* «капка» һ.б. **Ура-у** сүзеннән булырга мөмкин, ягъни беренчел мәгъ. «ямылчылык системасында бер *урап* кайтырлык ара → ямыл станциясе». Кадим заманнарда ямыл станцияләре ныгытма, кирмән рәвешендә булган, «капка» мәгъ. шуннан килә (чаг. **Кабак**). Барча мәгънәләренең ретрофокусында **урам** сүзенең элгәре **уғрам** «очрашу урыны» (к. **Угра-у, Угыр**) сүзе дә шәйләнә. Ләкин конкрет алганда андый сүз безгә билгеле түгел. Федотов I: 284 (материалы бай түгел); Нұрмағамбетов: 94 (төрле фаразлар китерә). Гомумән, бу бор. тарихи сүзнең этимоны ачылмаган.

Дерив.: **урамлы, урамсыз; урамчы; урамчык.**

**УРАН** – этноним группы татар на юге Пермской области – бу кабиләнең Харәземнән килгәнлеге ачык билгеле: **ураннар – каңлы** кабиләсенең бер өлеше (гомумән *оған* этнонимы антик ядкәрләрдән үк мәгълүм) XIII г. башларында Харәзем шаһларына каравылчылык хезмәтендә булган, к. Velidi: 161, 344 (әйтергә кирәк, З. Вәлиди ураннарны «башкортлар арасында яшиләр» ди, ләкин «башкорт» дими). Уран-Гәйнә сөйләше аерым лексик үзенчәлекләре белән аерылып тора. Тарихта танылган харәземшаһ Мөхәммәтнең әнисе (шулай ук атаклы) Түркән хатын уран кабиләсеннән дигән фикер бар (В.В. Бартольд), тик икенче бер версия буенча ул, **баяут = баяулар** (утраклар) кабиләсеннән (Velidi, Op. cit.: 432). Ураннар, Мөхәммәт шаһ тар-мар ителгәч, «иштәкләр арасына» килеп сыенганнар (Әбүлгази). Хәзер **уран** һәм **иштәк** атамалары синоним диярлек, к. **Иштәк.**

**УРАУ I [ураw]** (Тумашева 1992: 226) «куплет, строфа» ← **ура-у** (булса кирәк).

**УРАУ II [ураw], ураулы** «окружной (о пути)» ← **ура-у**; к. ш. ук чув. *ура* «җеп урамасы», к. Федотов II: 284.

**УРА-У** «наматывать, заворачивать; окружать; огибать; сходить, съездить (туда и обратно)» < гом. кыпч., төркм., хак., тув., үзб. *ора-,* алт., кырг. *оро-,* уйг. *ору-* < монг. *оро-* < яз. монг. *oruγa-* id. Räsänen 1969: 364; ЭСТЯ I: 469.

Дерив.: **урал-у, уран-у, ураш-у, урат-у; урама; урагыч; ураулы.** К. **Урам, Урау I, Урау II**.

**УРГЫ-У** «бить ключом; фонтанировать» < гом. кыпч. *оргу-* (каз. *оргы-*) «ургу, сикерү», як. *оргуй-* «кайнау» (Пекарский: 1861) ~ монг. *урги-* «ургылу», *уркил-* «кайнату».

Дерив.: **ургыл-у** (удм. *ургыл-ыны*), **ургылыш**; диал. **ургыл** «табигый трамплин; юлдагы үр».

**УРДА** «орда, государство кочевников», диал. (Башкортстан) **урда** «таган, таганок (над костром)» ~ башк. *урҙа* id., ш. ук «өйдә әйберләр элеп куя торган колга, матча, өрлек» ~ гом. төрки *орда, ордо* (кыпч., чыгт., уйг., хак. телләрендә), *ōрду, орду, орту* (бор. чыгт. һәм угыз телләрендә) «сарай; дәүләт үзәге; зур дәүләт; армия». КБ телендә бер урында *орду* «амбар, келәт», бүтән бор. телләрдә «резиденция; сарай». Гомумән, тарих дәвамында бу сүз (ДТС: 370), Евразиянең күп телләренә кереп, исәпсез күп яңа мәгънәләрдә кулланыла. Шулардан берсе – *урду* (теле) «Пакьстанның дәүләт теле».

Г.Ф. Благова буенча (Благова 1975: 9–20), *урда* < *орда* һәм тат. *урта* < гом. төрки *орта* (к. **Урта**) гомоген сүзләр. Болар рәтендә, безнеңчә, *уртаҡ* < *ортак* (к. **Уртак**) сүзе дә тора, к. түбәндәгеләрне:

– яз. монг. *ordun*, хәз. монг. *ордон* «урда»; монг. диал. *ордуң* «урта»;

– тат. диал. (ЗДС: 506, 684) *ōртан, ōртамыҡ, уртан,* гом. төрки *ортуң* һ.б. «урта, уртадагы»;

– тат. *уртаҡ* < гом. төрки *ортаҡ,* бор. төрки (ДТС: 373) *ortaq, ortuq* «иптәш, кәсептәш», *ortaqï* «уртадагы»; урта гасырларда (Velidi: 309–311, 445) *ortaq* «сарайның сәүдә оешмасы», шуннан соң гомумән «сәүдә компаниясе» («сәүдә компаниясе» > «иптәш» мәгъ. кучеше рус. *сотоварище* > *товарищ* сүзендә дә күзәтелә).

**Урда < орда** төрки телләрдә (тат.-башк. сөйләшләрендә, к. ш. ук ДТС: 370) «җәнлек өне (чокыры)» мәгъ. дә кулланыла. Безнеңчә, бу сүз бор. төрки ядкәрләрендәге (Velidi: 18; Kırzaoğlu: 4; Ögel: 150) *ortaγ* һәм *kürtaγ* (Вәлиди буенча *ortak* һәм *kürtak*) дигән бор. төрки бер үзәк атамасы булган булса кирәк. Бу тауларның кайда булганлыгы тур. бәхәсләр бара. Танылган кытай тарихчысы Сыма Цянь (б.э.к. II г.) буенча, хәз. Төньяк Монголиядә (нәкъ бор. уйгурлар яшәгән төбәкләрдә) «Җир тәңресе тавы» һәм «Күк тәңресе тавы» булган (к. История татар 2002: 387). Ул тауларда, Үзәк Азиядәге гадәт буенча, казып-чокып җир куенында эшләнгән сарайлар, гыйбадәтханәләр-урлар булгандыр (чаг. мәшһүр Дуньхуан мәгарәсе), к. **Ур.** Будагов I: 124; Фасмер III: 150; ЭСТЯ II: 470–472. Мәзкүр сүзнең чув. телендәге үзенчәлекле мәгъ. турында к. Михайлов: 131; Димитриев 1959: 53; Федотов I: 59 (чув. *арта* < рус. *орда, ордынская овца* «куй» тур.)

Русча әдәбиятта *Казанская Орда* дигән тәгъбирне очратырга туры килә: бу фәнни караштан дөрес түгел – Казан ханлыгы күчмә түгел, утрак халык дәүләте булган һәм ул *урда*, *орда* дип тә аталмаган. Рус. сөйл. *орда* «мәҗүси халык (вәкиле)» һәм *орда* «күпбалалы гаилә» тур. Аникин: 97, 427.

Дерив.: **урдалы, урдасыз.**

**УРДЫК** (ТТДС I: 455) «стул, табурет; нары, кровать» – **урындык** (к.) сүзеннән булса кирәк.

**УРДЫН** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «ткацкий станок» ~ бор. төрки (ДТС: 614) *urdun* «сандал, эш урыны». К. **Ындыр.** Чаг. ш. ук диал. (ЗДС: 684) **урынтыҡ** «киндер урыны». Монда контаминация бар.

**УРЛА-У** «красть, своровать» < гом. кыпч., алт. *урла-* (кырг. *уурда-*) id. – шуннан тат. диал. *ŏрла-* id., закончалыклы яңгыраш, *урла-* исә бүтән кыпч. телләренннән кергән.

**Урла-** сүзе төрлечә килеп чыга ала: 1) тат. диал. (Тумашева 1992: 212, ДС I: 203) *ур, уры* «карак, угры» сүзеннән, чаг. чув. *вăрă* «карак» → *вăрла-* «урлау», тув. *оор* «угры» > *оорла-* «урлау»; 2) ком. *уру*, хак. *оғыр* «урлау күренеше» → *оғырла-* «урлау», 3) бор. төрки (ДТС: 363–365) *oγur* «форсат, ысул, әмәл, хәйлә» → *oγurla-* «форсаттан файдалану; урлау» (> уйг. *оғурла-* id.). ЭСТЯ I: 412–414; Федотов I: 119 (рус. *вор* сүзен дә чувашчадан ди; бу хакта бай әдәбият бар).

**УРМАН** «лес», (Тумашева 1992: 226) «ель» < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *орман* < бор. төрки (ДТС: 371) *orman* «урман», чув. *вăрман* «урман; агач; аклан» Э.В. Севортян буенча (ЭСТЯ I: 472–473), тохар. *or* «агач, утын» сүзенә *-ман* кушымчасы ялганып ясалган. Ләкин к. «Төхфәт әз-зәкия»дә (1968: 268) *аарман* «зур ябалдашлы агач», *аарманлык* «урман, урманлык» (димәк, *урман – әрәмә* охшашлыгы очраклы түгел). Безнеңчә, *урман* < **аурман* < *ағурма*^н^//*эгүрэмэ*^н^ < *агуу үрэмэн* «зур тайгы урман» сүзеннән булса кирәк (к. Ахметьянов 1980: 87–95), к. монг., эвенк. *аги, агуу, айу* һ.б. «зур, киң җәелгән» һәм тунг.-маньч. *урэ* «таулык, урман; урманлы таулар» (к. ССТМЯ I: 13, II: 289). Чаг. башк. диал. (БТДҺ: 127) *йурмә* «куе урман»; *урман,* ахыр чиктә, **әрәмә, әрем** һәм **имән** (үзара якын кардәш) сүзләре белән тамырдаш; к. ш. ук маньч. *эрэмун* «әрем» (к. ССТМЯ II: 467).

*Орман* сүзен тохар теленнән чыгару тарихи вазгыятькә дә ятышмый: бай топонимик тәҗрибәгә ия булган төркиләр нишләп «урман» мәгъ. сүзне утрак тохарлардан алырлар иде икән?

Бу сүзне угор (ханты-манси) телләрендәге *ур маң* «калкулыклардагы сазламыксыз әйбәт урман»

(*ур* «тау» сүзеннән) дип аңлату да (к. И. Ромбандеева. Названия разновидностей гор в мансийском языке // СФУ №4, 1987: 271–274) күп сораулар тудыра: нәрсә ул *маң*? Нишләп бор. төрки язмаларда ук *ortan* сүзе бар? Әгәр ул угор телләреннән алынма булса, ни өчен бор. төрки *urtaŋ* түгел? К. ш. ук Аникин: 590 (арытабангы әдәбият күрсәтелә). Гомумән, *урман, орман* сүзләре күп күрше телләргә үтеп кергән.

Дерив.: **урманчы, урманчылык; урманлы, урмансыз; урманлык.** К. түбәндәгене.

**УРМАНАЙ** диал. (Урал) «деревня, хутор у самого леса, в лесу» < чув., мар. *урман айы* «урман асты».

**УРНА-У** (ТТДС I: 456; Тумашева 1992: 226) «помещать; помещаться, занять место» < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *орна-,* кырг. *орно-* < бор. төрки (Боровков 1963: 237; ДТС: 371) *orna-* id. ← гом. төрки *урын* < *орун* (к. **Урын**). *Урна-у* бик борынгыдан килә (ләкин тат. теленең үзендә дә ясала алган булыр иде) һәм төрле (тат. телендә булмаган) мәгънәләргә ия, мәс., алт. (Баскаков 1972: 236–237) *орна-, орно-* «урыннан алу, алмаштыру»; бу сүз монг. һәм тунг.-маньч. телләренә дә киң таралган, к. ССТМЯ I: 19; Будагов I: 129

Дерив. (к. ССТМЯ I: 456): **урнал-у, урнат-у;** төп фигыльдән киңрәк кулланылучан **урнаш-у**; иске тат. **урнак** (< бор. төрки *ornaq* < *ornaγu*).

**УРНАШ** (ТТДС I: 456; ТТДС II: 330; БТДҺ: 356; Кашафутдинов: 32–35) «посиделки с угощением вскладчину; языческое моление с ритуальными явствами; яства, блюда на посиделках и т.п.; доля, вклад в общий котел» < **урын аш.** К. **Урын II.**

**УРНЫК-У (урныгу, урныкты)** (ТТДС I: 456) «встать на своё место; устроиться» – бу фигыль бор. **урын-у** дигән фигыль булган дигән фикергә китерә (шуннан интенсивлык формасы **урн-ық-**), бу **урын-** < *орун-* исә **олур-ун-* «үзенә утыру урынын алу» сүзеннән ясалган булган. К. **Урын I.**

**УРПАН** «глазомер», **урпанла-у** (Будагов I: 121) «приблизительно оценить величину, размеры, качества и т.п.» ← иске тат. (К. Насыйри) **урпан** «ат маклеры» << фар. *aҳурбāн* «ат белгече (тышкы кыяфәтенә карап атның сыйфатын әйтеп бирүче)». Тат. (миш.) *урпан*нары бөтен Рәсәйдә танылган булган.

М.Р. Федотов (I: 287) *урпанла-* «чамалау», *урпанлан-* «кемнән дә булса шикләнү, шик астына алу» сүзен **арба-у** (к.) белән бәйли, ләкин монда ышандырырлык мәгънәви бәйләныш күренми. М.Р. Федотов үз фаразын мар. *арпанла-* «искәрү» сүзе белән чагыштырудан чыгара, күрәсең, ләкин ул мар. сүзе бер генә ядкәрдә дә юк (ул сүз хәтта үтә тәфсилле Ф.И. Гордеевның мари теленең этимологик сүзлегендә дә теркәлмәгән) һәм аның яңгырашын вә мәгънәсен дөреслисе бар. Безнеңчә, әлеге чув. сүзе тат. теленнән алынган.

**УРСАЙ, урсий, урсәни** (ТТДС I: 456; ТТДС II: 330) < **урыс анай, урыс әней** «крёстная мать», **үрсәти < урыс эти** «крёстный отец» (у кряшен) – бу сүзләрдә *урс-*, әлбәттә, **урыс** (к.) сүзеннән. Һәм алар билгеле бер чорда керәшеннәрдә һәр туган баланың *урыс әнисе, урыс әтисе* булырга тиеш дип, куелуы турында шаһитлык итәләр.

Урыс илатының шул рәвешчә татарларны контрольләп торуы керәшеннәргә генә карамаган. Күп кенә төбәкләрдә һәр зур татар авылы янына кечкенә булса да бер урыс авылы утырту гадәттә булган. Шәхсән мин шундый ике авылны яхшы беләм: хәз. Башкортстанның Юрмаш буе татар авылларын контрольләү өчен Баран һәм Куян дигән ике кечкенә урыс авылы куелып, тегермәнче һәм тимерче шулардан билгеләнә иде. Бу авыллардан утыз километр көньяктарак урнашкан Көмәрле дигән зур башкорт авылы янында да бер егерме өйлек балыкчылар авылында руслар яши иде...

**УРТ,** себ. (Радлов I: 74; ДС I: 9; Тумашева 1992: 32) **аурт, ауртқы** «внутренняя часть щеки; дёсны» > удм. *урт* < гом. кыпч. *урт, уwырт,* алт. *уурт,* төркм., үзб. *оwурт,* госм. (Радлов I: 74) *аwурт,* төр. *avurt,* төр. диал. *urd* «урт». К. ш. ук аз. *урут,* як. *омурт* id. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 407–409) бу сүзне *оп-* «убу» (к. **Уп-у**) сүзеннән димәкче, ләкин к. яз. монг. (Поппе 1938: 108) *aγurči-ba* – чыгт. *aurtladı* «уртлады; эчте», димәк борынгырак яңгыраш **аҕурт*, шуннан сингармоник чылбырларга туры китереп, *оҕурт* > *оwурт* > тат. **уырт > урт** килеп чыккан (*а – у* > *о – у* чылбырлар күчеше төрки телләрдә еш күзәтелә). Югарыда китерелгән **ауртқы** варианты *аурт-* дигән фигыль дә булганлыгын күрсәтә шикелле.

Тат., башк. телләрендә кѳтелгәнчә *ŏрт* яңгырашы юк, андый яңгыраш тик каз. телендә бар. Тат. телендә, күрәсең, *урт* элгәрге *уырт* яңгырашыннан кыскарган. Гомумән, *аwырт* < *аҕурт*,

ихтимал, бор. монг. **агур-ут* «яңаклар» ← бор. төрки *йагур* «ике яңак, авыз» (чаг. чув. *çăвар* < **җаwыр* < **йагур* «авыз») сүзеннән киләдер. Монда, әлбәттә, ачыклыйсы урыннар күп. Һәм бүтәнчә фаразларга да урын бар. Räsänen 1969: 9.

Дерив.: **уртлы, уртсыз** (биологик терминнар); **уртла-у** (шуннан – **уртлам**).

**УРТА** «середина, средний» < гом. кыпч. *орта*, гом. төрки *орта, орту*, тув. *ортаа*, як., кырг., алт. *орто*, уйг. (Радлов I: 1073) *орду*, чув. *вăта* id.; бу сүзнең метатезаланган *отра, отру* яңгырашлары да бар (к. Räsänen 1969: 365; ЭСТЯ I: 473–475), к. **Утра-у.**

*Урта* < *ортан* < *ортаң* «уртадагы, үзәктәге» формасы соңрак килеп чыккан, к. **Уртанчы.** Федотов I: 112–113.

Дерив.: **уртача; урталы, уртасыз; урталык; уртала-у** «урталай булу», шуннан **урталайын > урталай;** диал. **уртачы** «арадашчы, адвокат»; **уртамык** «начарга тартым». *Урта кул* тәгъбирендә *кул* төрки-монг. хәрби традициясендә «колонна» – түбәндә *кool* «үзән; фарватер» (к. **Кул II**): *урта кулга* картрак сугышчыларны куйганнар, *урта кул* атака өчен түгел, дошман һөҗүменә каршы, майтару (оборона) өчен тәгаенләнгән; чаг. үзб. (ЎХШЛ: 202) *ўрта қўл* «урта бармак».

Төр. *orta* «яничәриләр полкы» сүзеннән рус. *рота* сүзе килеп чыккан дигән фикер бар (к. Радлов I: 1064). Хәз. рус этимологиясендә бу фараз кире кагыла. **Урта, уртак** һәм **урда** бер нигездән дигән фикер дә бар.

**УРТАК** «общий», диал. «община» < гом. кыпч., уйг., алт., хак., угыз., урта төрки *ортақ,* ш. ук «сәүдәгәрләр кәрваны; компаньон; иптәш» (к. Будагов I: 122–123; «кәрван >> иптәш» мәгъ. күчеше төрки **аргыш** һәм рус. *товарищ* сүзләрендә дә күзәтелә); яз. монг., чыгт. телләрендә (Поппе 1938: 271) *ortaq* «компаньон» мәгъ. бердәнбер сүз; Чыңгыз токымнары дәүләтләрендә бу сүз – дәүләт сәүдәчеләрен белдергән; чув. *вăртах* һәм *уртакçă* туйда төрле җаваплы кешеләр («кода-кодача», «туйда бүләк өләшүче», «кияү егете», к. Прокопьев: 13–15), шундый ук «туй мәгънәләре» керәшеннәрдә дә булган (к. Федотов I: 112), бор. төрки (ДТС: 371) *ortaq, ortuq* «иптәш»; **уртак** сүзен «авылдаш, иптәш» мәгъ. куллану кышкы нардуган йолаларында да теркәлгән (к. ТТДС II: 330) – бу хәл, безнеңчә, татар халкы составына кергән уйгур-үзбәк компонентыннан килсә кирәк. ЭСТЯ I: 476–477 (Э.В. Севортян бу сүзне бор. **орта-, *орту-* фигыленнән дип исәпли); Velidi: 124–125, 309–311. К. **Урда, Урта, Уртан.**

Дерив.: **уртакчы; уртакла-у**. К. **Уртакчыл.**

**УРТАКЧЫЛ**, (Будагов I: 122–123) **уртакшыл**, себ. (Тумашева 1992: 163) **ōртакцыл** «перпендикуляр; перпендикулярный» – ясалма термин булса кирәк, югыйсә гом. тат. телендә **уртакчыл** «уртаклап, уртакка эш итүне (мәс., сату-алуны) яратучан» мәгъ. кулланыла. Ләкин **уртакчыл** «перпендикуляр» сүзен ясаучылар **уртак** сүзенең «урта, уртадагы» мәгънәсен белгәннәр, күрәсең. Һәм бу кызыклы факт.

**УРТАН** (ТТДС II: 331), себ. (Тумашева 1992: 163, 227) **ōртан > уртан** «средний (о детях и т.д.)» < гом. кыпч., алт. *ортан*, кырг., алт. *ортон*, тув., бор. төрки (ДТС: 371) *ortun*, хак. *ортын* «уртанчы», каз., к.-калп., тув. *уртан* ~ як. *ортоку* id. **Урта** < *орта* сүзенең инструменталь килеш формасыннан булырга тиеш. ЭСТЯ I: 477 (тат. сүзләре искә алынмаган).

Дерив.: (Тумашева 1992: 226) **уртаңгы**, диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **уртанла-у** «уртаклау». К. **Уртанчы.**

**УРТАНЧЫ** «средний» < гом. кыпч. (к.-калп. һ.б.), үзб. *ортанчы* (> башк. *уртансы,* нуг., каз., к.-калп. *ортаншы*) id. – түбәндә **уртанчык** < бор. **ортанчуг* яңгырашыннан (балаларга карата әйтелгәнлектән, **-чык** иркәләү кушымчасы булган) ← **уртан** < *ортан*, к. югарыдагыны.

**УРТЫН** (ТТДС I: 56) «скрытно, тайно» ~ чув. *вăрттăн* id., к. **Урын II, Урынтын.** Будагов I: 123 (Ялгыш **уртын** сүзен **өрт-үгә** нисбәтли).

**УР-У** «жать», диал. (ДС I: 203) «стричь», (Радлов I: 1650) «косить» < гом. кыпч., уйг., алт. *ор-*, бор. төрки (ДТС: 370) *or-* ~ чув. *выр-* ~ тат. диал. (ДС II: 205) **ура-**, кар., кр.-тат., угыз. *ора-* id. Шумер. *ur-* «урып алу» сүзе белән чагыштыру бик тә тәвәккәллек булыр иде. ЭСТЯ I: 468; Федотов I: 136.

Дерив.: **урыл-у, урыш-у, урдыр-у**; себ. һ.б. **урынты** «камыл», **ургыч;** диал. **урынты** «игене урып алынган кишәр, басу». К. **Урак.**

**УРШЫ-У** диал., (трбс., без теркәдек. – *Р.Ә.;* БТДҺ: 357; ТТДС I: 457) **уржы-у, урчы-у** «пустив ростки, вянуть; размягчаться (о картофеле)» – *ор-, ур-* «үрү, үсенте җибәрү» тамырыннан булса кирәк.

**УРЫК I,** (Минзәлә һ.б., без теркәдек. – *Р.Ә.*) **ŏрŏк** «еле заметная тропа». Бу сүз себ. (к. Тумашева 1992: 226) **урақ** «хайван эзе», хак. *оргах*, хак. диал., шор. *орақ* id., алт. *орық,* тув. *оруқ,* як. *орох* «сукмак» < бор. төрки (ДТС: 372) *orıq* «сукмак» сүзе белән бердәй булса кирәк (к. Räsänen 1969: 364); чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 363–364) *oγraγ ~ oγruγ* «бөгелеш, батынкылык, сыртлавык».

**УРЫК II** диал. (Башкортстан, без теркәдек. – *Р.Ә.*) «направление». Югарыдагы **Урак I** белән бердәй булуы ихтимал, ләкин к. бор. төрки (Боровков: 238) *оруқ* «закон, төп юл» мәгъ. булган. Сүзнең тамыры – бор. төрки **ор-* «юнәлтү», ш. ук «очрашу урыны». К. **Урак II.**

Дерив.: **урыксыз (йөрү)** «юлсыз», ш. ук «вакытсыз; плансыз».

**УРЫК III: урык-сурык** «урывками, спорадически» ~ башк. *урык-һурық*, чув. (к. Федотов II: 301) *урĕк-сурĕк* «сәлкәү, игътибарсыз», тув. *ууруқ-суурук* «урык-сурык, төрле вакытта».

Чув. (Федотов II: 285) *урăм-сурăм* < *орăм-сорăм* «котырынкы; котыру рухы» сүзе дә ничектер **урык-сурык** сүзе белән баглы булса кирәк (М. Федотов тат. сүзен белми бугай, ул чув. сүзен гар. *хăрăм* «әрәм, хәрәм» сүзе белән багламакчы).

Барча китерелмеш **урык** сүзләренең тамырдаш булуы ихтимал.

**УРЫН I** «место; лежанка, ложе; служебное место» < гом. кыпч. *орун, оруун,* каз., к.-калп., чыгт. *орын* ~ алт., тув., як., монг. *орон,* к. ш. ук куман. *оруу*, алт. *ору*, монг. *оро* id., яз. монг. *oran* id. Бу сүзне Э.В. Севортян бор. төрки *or-* «кую, салу» сүзеннән дип бара. Безнеңчә, **урын** < *орын* < *орун* < *олур-ун* < *олур-гун,* ягъни *олур-* «утыру, утырту» сүзеннән, к. **Утыр-у.** Чув. *вырăн* «урын» болг. теленнән, әмма болг. теленә кыпч. телләреннән килүе ихтимал.

**Урын** сүзенең «хезмәт урыны, дәрәҗә» мәгънәсе шуннан килә: күп кенә тарихи-этнографик хезмәтләрдә күрсәтелгәнчә, элекке хәрби-феодаль җәмгыятьләрдә һәр мәсьүл кешенең хан, би табынында-киңәшендә аерым билгеләнгән урыны – «утырыр җире» булган, «фәлән кабилә вәкиле ханның уң ягыннан дүртенче урын» һ.б.ш. К. **Байтирәк, Мөчә, Оча.** ЭСТЯ I: 477–478; Федотов I: 137–138; Аникин: 428–429 (рус. диал. *орон* «сәке» тур.); İnan I: 241–254.

Дерив.: **урынлы, урынсыз; урынлык;** диал. **урынча**. К. **Урна-у; Урындык; Урнык-у.**

**УРЫН II,** диал. (ТТДС I: 455–459; БТДҺ: 356) **урыйн, урин** «тайный, секретный (о словах, сообщениях); тайна, секрет», (ТТДС I: 328) **ŏрŏн, ŏрын** «секретно, тайно; наедине, с глазу на глаз» ~ каз. (Будагов I: 129) *урун (сӧз)*, нуг. *орын*, кырг. *орун* (К. Юдахин моны *орун* «урын, төш» матдәсендә бирә, ләкин бу дөрес түгел), төркм. *огрын*, төр. *oğrun* «яшерен рәвештә, угрыларча» ← *угры, огры* (бу сүзнең инструменталь килешеннән); тат. диал. **урыйн > урин** яңгырашы *угрый-ын* ← *угрый* «угры» (китаби-диалекталь) вариантыннан, к. нуг. *урый* «угры».

**Урын II** сүзенең үзеннән киңрәк таралган варианты (ТТДС I: 456, 457, 528) **уртын < урынтын, ыртын** «яшертен, яшеренчә» > чув. (Сергеев 1971: 57) *вурттăн, вăрттăн, вуртăн* id. К. ш. ук **Урнаш < урын аш.**

Федотов I: 112 (*вăртăн* сүзенең этимологиясен фин-угор телләреннән эзли һәм төрки-тат. сүзләрен бик начар белә). К. **Угры.**

**УРЫНДЫК** «стул, сиденье, скамья», (Тумашева 1992: 226) **урынтық** «нары» ~ каз. *орындық,* кырг., уйг. *орундуқ* «урындык», нуг. *орындық,* төркм. (диал.), к.-балк. *орундуқ,* ком. *орунлуқ* «карават» ← **урын < орун**.

**УРЫНТЫН** «тайно» к. **Урын II.**

**УРЫС** «русский; христианин» ~ мар. *уруш, ыруш, руш*, чув. *вырăс*, удм. *җуч* id. ~ гом. кыпч. *орус, урус* (һ.б. телләрдә охшаш яңгырашта) «урыс». Кайбер хезмәтләрдә **Урус** дигән төрки исемне «урыс» дип тәгърифләү очрый, хәлбуки бу дөрес түгел: элекке яз. ядкәрләрдәге *урус* дигән кеше исеме **Ураз, Уроз, Уруз** «бәхет тәңресе»ннән килә (к. **Ураз).** Федотов I: 138–139.

Идел-Урал регионында **урыс** һ.б. сүзләр белән ясалган фразеологизмнар үзара калькалаштырылган, мәс., тат. **урыс атнасы, урсатна** ~ мар. *рушарня,* чув. *вырсарни*, удм. *җуч арня* «якшәмбе» һ.б. **Урыс** сүзе белән ясалган егермеләп фразеологизм БТДҺдә китерелә.

Дерив.: **урыслы, урыссыз; урыслык; урыслаш-у, урыслан-у; урысча;** к. **Урыс-улак.**

**УРЫС-УЛАК** (БТДҺ: 358 һ.б. чыганакларда) «разные русские» < монг. *орус-улаг(а)* «олаучы урыс» (Алтын Урда чорында күп урыслар олаучылыкта хезмәт иткәннәр).

**Урыс** сүзе белән ясалган тагын берничә парлы сүз бар. Алар тискәре мәгънәле.

**УС** (Тумашева 1992: 227) «мастер; кузнец» ~ кырг., уйг., чыгт., бор. төрки (ДТС: 620) *ūz* > алт., хак., тув. *ус*, як. *уус* ~ төркм. һ.б. (Мухамедова 1973: 182) *ууз* «мастер; кямил, осталарча эшләнгән», аз. (АДДЛ: 394) *угуз* «белгеч» ← *уг* ~ *уқ* «аңбелем» (?). З. Мөхәммәдова бор. заманда *Ууз* исемле оста яшәгәнлеге тур. легенда китерә. Чаг. **Ос.** ЭСТЯ I: 569.

Дерив.: иске тат., госм. **узман** «мастер; специалист; фокусчы».

**УСАК** «осина, осиновый» ~ чув. (Ашмарин IV: 35, V: 398; Сергеев 1971: 53) *ăвăс, увăс, вус, выс, выcă, ĕвĕс, ус* ~ гом. кыпч. *осақ* < себ. (ДС II: 43) **аусақ** < себ. (Радлов I: 82), алт. *апсақ,* шор. *аспақ* ~ бор. ним. *Aspa* (хәз. ним. *Espe*), латыш. *apse*, литв. *apuse* ~ рус. *осина* (← *ос-ина*) id. Гомумән, китерелгән (һәм монда китерелмәгән) материалдан күренгәнчә, ике филиацияне аерырга мөмкин: берсендә **-р-* (*п*) сакланган (шуңа тат. **усак** та керә), икенчесе – чув., ш. ук хак. диал. *ос,* рус. *ос* – ул **-р-* сакланмаган.

**Усак** сүзенең таралышыннан чыгып, һинд-евр. телләреннән алынган дип уйлыйлар. Бу агачның таралышы, бик ихтимал ки, сонгый сәбәпләр – махсус утырту һ.б. нәтиҗәсендә киңәйтелгәндер – усак агачы белән төрле ышанулар, легендалар баглы (к. Фәтхиев Ф. Усак яфраклары шаулавында... // Өмет, Уфа, 1997: № 66; к. ш. ук МНМ II: 266–267). Һинд-европалыларның сугыш кораллары усактан ясалган һ.б. ЭСТЯ I: 607–608; Гамкрелидзе-Иванов II: 940; Федотов I: 80–81 (арытабангы әдәбият китерелә).

**УСАЛ I** «злой; лихой, крутой», диал. (миш., к. Һ.Такташта: *Син гомереңне усал исем белән... чикләдең*) «нехороший, недобрый» > чув. *усал*, мар., морд. *осал* «явыз, яман» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *осал*, тув. *озал*, үзб., к.-балк., аз. *усал* «зәгыйфь, ялкау, кәй; начар»; чыгт., уйг., к.-балк. *осал*, кырг. «начар»; кр.-тат., ком. (диал.) *осал* «юаш (!)». Исем мәгънәләре: чув. *усал*, иске чыгт. – иске монг. (Поппе 1938: 271) *osal* «хаталык», фар.-таҗ. *усал* «фетнә», як. *осол*, *оһол* «афәт; каза; игътибарсызлык; кинәтлек» > эвенк. (ССТМЯ: 29) *оһол* id. ~ яз. монг. *osul* «игътибарсызлык» (ССТМЯ II: 29) һ.б. (к. ш. ук **Ушал**). Бор. төрки (ДТС: 616) *usajuq, usal* «гамьсез», *usan-* «гамьсезләнү» сүзләреннән чыгып, сүзнең ясагыч нигезе *уса-* < *оса-* «ялыгу; гамьсезләнү» дип карала (ЭСТЯ I: 479–481); к. ш. ук төр., бор. төрки (ДТС: 616) *us-* «дип уйлау; ялгыш уйлау». К. як. *осой-* «ябыгу, начарлану», эвен. *ус* «явызлык, начар». Гомумән, бу сүзнең тарихы-этимологиясе катлаулы; *-л* кушымчасы (исем-сыйфат ясагыч) монг. телләренә аеруча хас. Räsänen 1969: 365–366; Doerfer 1968; ЭСТЯ I: 606–607; Федотов II: 290.

Дерив.: **усаллык; усаллан-у, усаллаш-у, усаллат-у;** (ТТДС I: 457) **усалла-у; усалсыз** («явыз ниятсез», мәс., мыскыллау яки сүгү тур.). К. **Усан-у, Ушал.**

**УСАЛ-УНТАГАЙ** «всякие злодеи» ~ тув. *озалонтақ* «хәвефле кеше». Монг. теленнән.

**УСАН-У** (Тел ярышы: 134) «запечалиться, пригорюниться; оскорбляться» ~ кар., аз., төр., бор. төрки (Будагов I: 139; ДТС: 616) *usan-,* телеут. (Радлов I: 1139) *осан-* «күңелсезләнү, җиләү». ЭСТЯ I: 608–609 (тат. сүзе искә алынмый). Чаг. **Усал.**

**УСМА** (Н. Воробьёв) «состав для окрашивания волос» – ачык түгел. Чаг. рус. *усма* «буялган күн».

**УСТАН** (Будагов I: 139), **усты, устыға** (Тумашева 1992: 227) «основание печи; шесток (кузлык, мич авызы)» – **устуған** «мәетләр куела торган сарай» (Тумашева, Ор. cit.) сүзе белән бердәй: бу сүз себер татарлары арасында кайчандыр зәрдүшт дине яисә буддизм таралганлыгы тур. сөйли, чөнки нәкъ шул диннәр буенча мәетләрне күммәгәннәр, ә махсус кирпечтән эшләнгән урыннарда яндырганнар (шуннан «мич казнасы», «махсус учак урыны» мәгъ. килә) яисә махсус киртәләнгән урынга илтеп ташлаганнар һәм аларны ерткыч кош-кортлар, җәнлекләр ашап бетерә торган булган (Монголиядә һәм Тувада бу гадәт-йолалар XX г. кадәр дәвам иткән). «Мич» һәм «мич казнасы» мәгънәләре бор. *устуханнарда* мәетләрне яндыру белән баглы.

**Устуган** сүзе Иранда һәм Урта Азиядә «атәшханә – изге ут янып торган махсус корылма» мәгъ. озак вакыт сакланган, к. **Остохан.** Гомумән, бу сүз иске фар. *устухон* «сөякханә» сүзеннән, аның тамыры *асту, усту* – гом. һинд.-евр. сүзе, к. авест. *asti*, бор. һинд. *asthi* ~ грек. *όςτεον*, лат. *ōs, ossis* «сөяк» (→ лат. *ossuarium* «оссуарий, мәетнең сөякләре куела торган әрҗә») ~ рус. *кость*; себ. тат. **усты** варианты бор. фар. теленнән килә микән, әллә *устуган* сүзеннән кыскартылма микән – әйтүе кыен. Бируни 1995: 478–480.

Дерив.: **устанлык.**

**УСТЫН** диал., иск. «сооружение – кубический четырёхугольник из брёвен, крепких досок, подпирающее потолок и крышу здания, домика со слабыми стенами»; «станок ткача в комнате; комната для ткача» ~ каз (ҚТДС: 264) *үстiн* «кыек терәткече, кыек атламалары» < *усутун* ~ *сутун* «сутүн» сүзеннән булса кирәк. К. **Сутун.** Чаг. ш. ук **Устан.**

**УСЫР-У** «пердеть» < гом. кыпч. *осыр-, осур-*, кырг. *оосур-*, як. *утур-* id. < *ос-гур-* id., ш. ук «пошкыру, сеңгерү» *осс* тәкълиди сүзеннән.

**УТ I** «огонь» < гом. кыпч. *от* < бор. төрки (ДТС: 372) *ot, ōt*, як. *уот*, төр. *od, ot*, төркм. *оот, од*, чув. *вот, вут* (бу вариантлар бернинди дә яңа мәгълүмат бирми), яз. монг. *od* һ.б. id. Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 483–484) бор. *ot-* «өтү» сүзен дә *от* сүзенә тамырдаш итеп китерә, ләкин, безнеңчә, бу шиклерәк.

Мисаллардан күренгәнчә, *ут* << *оот* ниндидер бор. сүздән кыскарган. Этимологлар **ут I** һәм **ут II** сүзләренең кардәшлеге тур. сүз ачмыйлар, ләкин, безнеңчә, аларның бердәйлек – гомогенлык ихтималы юк түгел (**ут** «үлән; утын» була ала). Räsänen 1969: 366; Федотов I: 133–134.

Дерив.: **утлы, утсыз; утлык;** диал. **утлач;** неол.: **утчык, утчыл**. К. **Утын, Учак.**

**УТ II** «трава, сено», компонент в названиях трав ~ чув. (Ашмарин III: 325–328; IV: 37; Сергеев 1971: 133) *ут, утă, увтă, ывтă, ăвăт, ăвтă, вытă* «печән» < гом. кыпч. *от*, гом. төрки, бор. төрки (ДТС: 372–373) *ot,* тув. *оът* «ут, үлән; печән» ~ яз. монг. *ota* «дару үлән». Бор. һ.б. телләрдә *от* сүзенең «дару» һәм «агу» мәгъ. бар. К. ш. ук як. *уот-* «терлекне симертү».

**Ут II** сүзе дә ниндидер бор. бер сүздән кыскарган – моны чув. һәм тув. вариантлары күрсәтә. Räsänen 1969: 366 (*от* «ялкын» сүзен озын *ō,* «үлән» сүзен кыска *o* белән яза). ЭСТЯ I: 481–483; Федотов II: 294–295.

**Ут < от** төрки телләрдә иң продуктив тамыр нигезләрнең берсе: тат. **утлы, утсыз** (бу сүзләр сирәк кулланыла); **утлык** (гом. кыпч. параллельләре бар); **утла-у** (шуннан – **утлау, утлак, утлавык**), диал. (ДС II: 206) **утса** «абзарда печән саклана торган урын». К. **Утар, Ута-у, Утачы, Утлык-у.**

**УТАМАН** (әстр.) «костровой». Кайберәүләр бу сүзне «ут аман булсын» дигәннән дип аңлаталар. **Атаман** сүзе дә шуннан диләр. К. **Атаман.**

Без андый аңлатмага шикләнеп карыйбыз. Бәлки элекке төрле группаларның **атаманы** да, **утаманы** булгандыр (элекке заманнарда, бигрәк тә явымтөшемле көннәрдә, төрле юлаучыларга ут саклау проблема булган ич). Ут саклау өчен җаваплы кеше **ут агасы** дип тә аталган (хәер, бу сүзне «ут – үлән, печән – өчен җаваплы кеше» дип тә аңлаталар).

**УТАР** «загороженное пастбище; загороженные угодья (без жилья); пасека», иск. «хутор, имение (помещика)» > мар. *отар*, удм. *утор* «утар», чув. *учар, отар* «умарталык; хутор» < гом. кыпч. *отар*, кырг., алт., як. *отор*, тув. *одар* «утар; авылдан ерак торган утлавык; гомумән үләнле җир, утлак» ~ яз. монг. *otar* id.; Г. Рамстедт фаразынча, рус. *хутор* сүзе дә ошбу сүздән (Ramstedt 1935: 29). К. ш. ук Будагов I: 109; Velidi: 287.

**Утар**, күрәсең, **ут** «үлән» сүзеннән, ләкин ясалышы ачык түгел; бик ихтимал, *ута-* < *ота-* (к. **Ута-у**) «утлату» фигыленнән, *утар җир* < *отар йәр* «утлатырлык җир» сүзеннән эллипсистыр. Räsänen 1969: 367; ЭСТЯ I: 487–488; Федотов II: 294–295. Рус. *отара* «сарык көтүе» төрки телләрдән, тик конкрет чыганагы билгесез. Фасмер III: 169.

**УТАУ I [утаw]** (Тумашева 1992: 227) «шалаш (на поле, в пути); ложе новобрачных» < гом. балк. *отаw* (к.-калп. *отоw,* кырг. *отоо*) «зөфаф тирмәсе; зөфаф кичәсе өчен әзерләнгән махсус бүлмә», нуг., уйг. *отаw* «кечкенә тирмә, юл яисә көтүче тирмәсе» < бор. төрки (ДТС: 373) *otaγ* «куыш, тирмә; чатыр» ~ яз. монг. *otuγ* «зур учак; балаган, шалаш» > хәз. монг., бур., эвенк. *отог* id. > рус. (Себ.) *отоги, атог, отог* «кышын кола яланда куну – йоклау урыны – калау, учак янында ясалган пана, талта, ышыклык» һ.б., к. ш. ук хак., тув. *одағ,* алт. *оодағ* «учак; юлчыларның ял урыны» һ.б.

Себ. (Тумашева 1992: 162) **ōду,** алт. *оду* «алачык», *одоӊ* «учак; ирү, тукталыш» ~ уйг. диал., угыз. (> кар., кр.-тат.) *ода* «кунак бүлмәсе, зөфаф бүлмәсе; гомумән зиннәтле бүлмә» аерым *-д-* линиясен тәшкил итә; к. ш. ук як. *отуу* «шалаш; учак», төр. *oda* «канцелярия, кабулханә һ.б.ш.»

Иске тат. (М. Гафури һ.б.) **утаҡ,** каз., чыгт., уйг. диал., госм. *отаҡ* «читән өй, шалаш» *-ғ* > *-ҡ* линиясеннән. Шулай итеп, тат. телендә бер тарихи лексик берәмлекнең өч филиациясе бар, бүтән төрки телләрдә дә шул ук хәл – ике яки өч вариант табыла. Гомумән, ошбу сүзнең фонетик вә мәгъ. вариантлары бик күп, к. ЭСТЯ I: 284–287 (ничек

кенә тәфсилле булмасын, Э.В. Севортян да барча вариантларны исәпкә алып бетермәгән: тат. **оду** һәм **утак** искә алынмый).

**Утау** < *отаг* < **отагу* сүзен *оот, оод* «ут» нигезеннән дип уйлыйлар; чаг. чыгт., кырг. диал. *оттақ, отток* «тирмә» << *отлаг* «учак урыны» (*-лақ* < *-лаг* билгеле урын-төшне белдерүчән кушымча: **қышлақ,** диал. **язлак** һ.б.ш.). Гомумән, бу сүз тур. күп язылган: Будагов I: 119; Joki 1955: 249; Räsänen 1969: 139; Doerfer II: 68; ССТМЯ II: 28; Аникин: 432, 596; Ногайцы 1988: 231 (туй-зөфаф тирмәсе *отав*ның сызымы-рәсеме бирелә); Добродомов 2008: 226–228.

**Утау** тат. телендә хәзер сирәк очрый, аның деривациясе һ.б. онытылган. Башк. (БТДҺ: 358) *утау йебе* «утауның ишеген бикләгән ефәк бау – кәләшнең кызлыгы символы, аны яшь кәләш каенсеңлесенә бүләк иткән».

**УТАУ II [утаw]** (ТТДС I: 458) «стерня», (Будагов I: 110; Тумашева 1992: 227) «осот, заячья капуста» – общее значение: «хорошая для скота трава» ← *ута-* < (алт.) *ота-* «утлау» сүзеннән; **отазы* > кыпч. **отаwы* > рус. *отава* «яхшы үләнле көтүлек; яхшы үскән үлән» > тат. диал. (ТТДС I: 458; Тумашева 1992: 227) **утаwа, утабы** id. (русчадан кире алынма).

Рус этимологлары рус. *отава* сүзенең төрки телләрдән килүен кире кагарак, төрле фантастик этимологияләр коралар.

**УТА-У** «полоть» (исемләшкән исем фигыль буларак **утау [утаw]** «прополка») > мар. (Исанбаев 1978: 37–38) *отау* «утау эше», удм. (Насибуллин: 142) *уданы* «утау» < гом. кыпч., чыгт., уйг., төр., бор. төрки (ДТС: 373) һ.б. *ота-*, хак., кырг. *ото-*, алт. диал. *одо-* һ.б. «утау», төп мәгъ. «утлау, үлән өзү, печән чабу» ← *ут* < *от*, к. **Ут.** К. ш. ук каз., к.-калп. *отақ* «чүп үләннәр». К. Севортян 1962: 14.

Деривациясе – регуляр.

**УТАУЛА-У [утаwла-]** «кияүләп йөрү» сүзе бар. Мөгаен, **Утау I** сүзеннән, к. каз. *отау* «әле генә башка чыккан яшь гаилә»; иске каз. телендә «җиткән кызга махсус эшләнгән тирмә» (к. Г. Ибраһимов, «Казак кызы»).

**УТАЧЫ (**төрке телендә) «врач, знаток целебных трав» < бор. төрки (ДТС: 373 һ.б. чыганаклар) *otačï* id. *ota-* «үлән белән дәвалау» сүзеннән, к. ЭСТЯ I: 482. К. **Ут II.**

**УТЛЫК-У (утлыкты, утлыгу)** «спадать от недоедания (о боках у животных)», диал. (ТТДС I: 458) «проголодаться после тяжёлой работы, ходьбы и т.п.» – бу гом. төрки фонда оригиналь фигыль, бор. төрки **от-,* **огт-* «утлау, көтүдә йөрү» сүзе (фигыль) булганлыгына ишарә итә шикелле (*ут-лык-* «аеруча утлыйсы килү», чаг. *атлык-у* ← *ат-у, җитлек-ү* ←*җиту, йотлык-у* ← *йот-у* һ.б.). Чаг. аз. (АДДЛ: 348) *отухмаг* «тәүләп үлән ашый башлау (яшь терлек тур.)».

**УТРАК, утырак,** «оседлый» ← **утыр-у** (к.). Кайбер тыйбби хезмәтләрдә **утрак** – утыру органы – рус. «седалище» сүзеннән калька булса кирәк (дөресрәге **утырмаклык**).

**УТРАУ [утраw]** «остров», диал. (Тумашева 1992: 227) **утрач,** гом. диал. **утыраw** ~ каз. *отрау* id. – күп. төрки телләрдә юк, шунлыктан Радлов (I: 1709) бу сүзне рус. *остров* сүзеннәндер дип тә язган. Ләкин бор. төрки (ДТС: 374) *otruγ, oturuq* «утрау» мондый фаразны бөтенләй юкка чыгара (киресенчә – рус сүзе төрки телләрдән түгелме икән әле?). Тат., башк. *утрау* сүзенең параллельләре башлыча Себер төрки телләрендә: алт. диал. (Радлов I; 1116; Баскаков 1972: 235, 237) *оттыраг, одру, одруу, оттырайы,* хак. *олтурух, олтырых* ~ себ. (брб.), алт. диал., хак., госм. *орталық, ортолық*, тув. *ортулуқ* һ.б. «утрау». Тат. *утрач* (к. югарыда) < кар. *отрац, отрач, отраш, отураш, отлач*, куман. *otrač,* бор. кыпч. *otrač, utrač* аерым бер линияне тәшкил итә. Гомумән, бу сүзнең тамырыясалышы томанлы: *урталык* варианты халык этимологиясе нигезендә туган. Joki 1955: 245; Räsänen 1969: 387; Федотов (II: 295 ап-ачык татарчадан алынма – чув. *утрав* «утрау» сүзен русчадан алынган ди: тат. һ.б. төрки параллельләрне бөтенләй белми). Рус. *ольтарак, ольтарик* «утрау» ~ яз. монг. *oltorok* «архипелаг», бур. *олтирог* «утрау, архипелаг» тур. Аникин: 423 (*утрау* < **ултыраг* сүзен *урта* < *орта* сүзе белән баглауның шикле икәнлеген билгели).

Элекке заманнарда безнең күчмәнче бабалар еш кына аерым-аерым җәелгән шыйлыкларда ачык һавада *корлар* оештырып – яшь группалары буенча төркемләшеп утырыша торган булганнар (коры яклардагы озын, аяз җәйләр моңа уңай шартлар тудырган). Безнеңчә, бик ихтимал ки, **утрау** < *ултыр-агу* «утыру – табын урыннары» сүзеннән, ягъни сулыктагы утраулар табын киезләренә охшатылган. Хәз. тат. сөйләшләрендә дә, мәс., яландагы

җиләкле урынны «утрау» дип атау очрый. Башк. сөйләшләрендә (Җ. Киекбаев) *утрау* «таулы җирдә тигез урын, җәйләү өчен уңай җир». К. **Утырач, Утыр-у.**

**УТЫЗ,** себ. **утыс** «тридцать» < гом. кыпч. *отыз,* башк. *утыҙ,* кырг., к.-балк., кар., кр.-тат., гом. угыз. *отуз,* уйг. *оттуз,* чыгт. *олтуз* ~ кырг. диал. *олтус* id. М. Рясянен буенча (к. Федотов I: 113–114), гом. төрки *олтур-* «утыру» сүзе белән тамырдаш, чаг. себ. (Тумашева 1992: 163, 225) **ōлтуз-** > *ултус-* «утырту» ← бор. төрки *ол-* «утыру» (к. **Утыр-у**). Хикмәт шунда: элекке төрки, кидань, монг. җәмгыятьләрендә югары киңәш органы (ханнан башка) утыз кешедән гыйбарәт булган һәм алар махсус киездә-шыйлыкта утырып мәҗлес корганнар. Бу хакта төрле мәгълүматлар шаһитлык итә. Мәс., 442–445 нче елларда һуннарның башлыгы **утыз яраны** белән христианлыкка чыга, диелгән (Гукасян 1981: 79); бор. төрек-сәлҗукларда күчмәче һәм хәрби берек – **оҗақ** утыз кешедән торган (Гордлевский I: 86–87); тунг.-маньч. *кусун, гусин* «идарә, көч, хакимият» бор. монг. *ғучин* < *ғурчин* «утыз; утыз зат» сүзеннән (ССТМЯ I: 175) һәм **көч < күч** сүзе дә шуннан дигән фараз бар; монг. дәүләтләрендә (ш. ук бор. грекларда да!) төп киңәш органнарында һәрвакыт утыз әгъза булган һ.б.

*Утыз* < *олтуз* сүзенең борынгырак яңгырашы, безнеңчә, **олтурғы* ~ *олтурғ,* шуннан чув. *вăтăр* «утыз». Тат. **утырдаш**, ихтимал, бор. *утыр* «утырыш, киңәш» сүзеннән үк киләдер.

Як. *отут* «утыз» һ.б. кайбер вариантлар этимологиягә әлләни өлеш кертмиләр (як. телендә *-з* > *-с* > *-т* күчеше соңрак килеп чыккан). К. ш. ук ЭСТЯ I: 489 (Э.В. Севортян М. Рясянен фаразына каршы, ул *олтуз* варианты диссимиляция юлы белән *оттуз* яңгырашыннан килеп чыккан димәкче, ләкин төрки телләрдә мондый диссимиляциянең аналоглары юк).

Дерив.: саннар өчен регуляр; элек **утызлы** «утыз шәм көчендәге» керосин лампасы бар иде; **утызлык** «утыз сумлык (акча)» хәзер кулланылмый.

**УТЫН** «дрова» < гом. кыпч. *отун* (нуг. *отын*), алт., хак., кр.-тат., госм., төркм. *дун, одуң, оодуң*, алт. диал. *одын, одың* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 374) *otuŋ* id. һичшиксез *ут* < *от* < *оот* тамырыннан, аның фигыль мәгънәсеннән (ди Э.В. Севортян, к. ЭСТЯ I: 441–442); чув. *вотă* > *вутă* ~ як. *оттук* «утын» үзара гомоген булса кирәк. К. ш. ук Räsänen 1969: 366; Федотов I: 134.

Дерив.: **утынлы, утынсыз; утынлык; утынчы.**

**УТЫРАЧ, утырац** (Тумашева 1992: 227; ЗДС: 686) «остров, полуостров, заросший кустарником; луг (обрамлённый чем-либо)» – **утрау** (к.) белән нигездәш булса кирәк. Ләкин к. кырг. *отураақ* «үлән-ут күп-куе була торган урын» ← *от* «үлән»?

**УТЫРДАШ** «собеседник» – **утыр-у** (к.) сүзе белән баглы. К. ш. ук **Утыз**.

Дерив.: **утырдашлык.**

**УТЫР-У,** (Троянский I: 127) **ултыр-мак,** себ. (Тумашева 1992: 163, 225) **олтур-у, олтыр-у, олт-у > улт-** «сидеть, садиться» < гом. кыпч., к. башк. *ултыр-*, нуг. *олтыр-,* кр.-тат., кар., куман., уйг., чыгт., гом. угыз. *олтур-* id. ~ бор. төрки (ДТС: 366, 367) *oldur-* «утыру», *olta-* «утырту» ~ алт. *олтар-* ~ себ. (Тумашева, Op. cit.) **олтуз-у, ултус-у,** алт. *олтыс-* «утырту». Барча бу вариантлар бор. төрки **ол-* «утыру» ~ *ол* «утыру, утырышу өчен махсус киез, кәвер; утырыш; киңәш; җыен» тамырыннан киләләр, ләкин мәгънәви-морфологик структуралар төрлечәрәк. Төрки телләрнең күпчелегендә бик иртә (к. ДТС: 374; ЭСТЯ I: 489–492) *-л-* авазы төшерелеп, *ōтыр-* < *ōтур-* варианты йөкл. юн. икәнлеге дә онытылган булса кирәк. Рясянен (Räsänen 1969: 361) бүтәнчә аңлата: *ултыр-* < *олтур-* < **olutur* «утырып кал; утыра тор» ди.

Чув. *лар-* (< **ŏлар-*) ~ тув. *олур-*, як. *олор-* «утыру» сүзе дә тәүдә *ол-* фигыленең йөкл. юнәлешеннән булса кирәк; чаг. як. *олох* «урын; урындык», *олорт-* «утырту» < бор. төрки (ДТС: 366) *olγur-, olγurt, olγut-* id. > *олут-* > себ. (к. югарыда) *олт-, улт-* «утыру». Төрки телләрдә йөкл. юн. формасының төп юн. мәгънәсен алуы – киң таралган күренеш. Чаг. ш. ук **урын < олур-ун.**

Дерив.: **утырыл-у, утырыш-у,** төрле мәгъ. **утырт-у; утыргыч,** төрле мәгъ. **утырма,** төрле мәгъ. **утырыш** һ.б. тагын егермедән артык нигез сүзе. К. **Утрак, Утырдаш, Утырышчы.** Чаг. **Утрау.**

**УТЫРЫШЧЫ** «заседатель» – рус теленнән калька. Совет заманында **халык утырышчылары** килеп чыккан.

**У-У** «растереть; мять; стирать (белье и т.п.)» < гом. кыпч. *уw-*, башк. *ыу-,* төркм., госм. *ов-, оғ-, ув-,* хак., алт., тув. *уғ-* id., ихтимал, бор. **ууғ-* яки **ооғ-,* бор. төрки ядкәрләрдә үк (ДТС: 619) *uv-* яңгырашы бар. К. ш. ук чыгт. (Радлов I: 68) *ау-, уа-,*

*уга* «уу, угалау». Гомумән, *у-* < **оог-* төрки телләрдә иң продуктив тамырларның берсе – аның һәр төрки телдә диярлек ике-өч фонетик варианты һәм нык үзгәргән дериватлары очрый (к. ЭСТЯ I: 01–403, ләкин анда да фонетик вә морфологик деривациянең бер өлеше генә яктыртыла). К. **Әвәлә-ү, Вак, Валчык, Ват-у, Он, Ошак, Умач, Ушак, Үкәлә-ү.**

Синхроник дерив.: **уыл-у, уын-у, уыш-у, удыр-у; уала-у** (→ **уалану-** һ.б.).

**УФ, уф-у** – междометие, выражающее состояние напряжения, вздох – гом. кыпч., күрәсең (сүзлекләрдә теркәлми).

Дерив.: **уфла-у, уфылда-у, уфыр-у** һ.б.

**УФА, Өфе** «город Уфа» (рус. *река Уфа* тат. һәм башк. башк. телләрендә **Караидел,** *Кариҙел* дип атала) – тат., башк. телләре өчен характерлы булмаган *-ф-* авазы бу сүзнең алынма икәнлеген күрсәтә. К. **Өфе.**

**УФАЛЛА, ухалла** (ТРС; ЗДС: 687) – название ручной двуколки (тележки), возникшей, по-видимому, в 40-х годах ХХ столетия. Гомумән, аны ешрак *уфалла арбасы* дип атыйлар. Күренеп тора ки, бу сүз *уф, Алла!* дигән кушма ыплынтан килә (бүтәнчә аңлатмасы юк шикелле). Хәзер бу сүз кулланылмый бугай. Бу сүз ХХ г. «ядкәре» буларак сүзлекләргә кертелеп килә.

**УФТАН-У, офтан-у** «сожалеть о содеянном, сокрушаться по поводу своих ошибок и т.п.» < чыгт., иске уйг. һ.б. *уфтан-* id. < бор. уйг. **овтан-* < *обутан-* «үзеңнән оялу» ← *овта-* < *обута-* «оятлау» (кайт. юн.); бу фигыль исә чыгт. (Боровков 1961: 230–233) *ӧвут, огут,* бор. төрки (ДТС: 603, 619) *ubut, uvut* «оят, гарьлек» сүзеннән (к. ш. ук Мухамедова 1973: 180); бу сүз, ихтимал, *ойат* < *уйат* (к. **Оят**) сүзе белән бердәйдер (хәер, Э.В. Севортян бу фаразны кире кага).

*Овутан-* фигыленең икенче бер үзгәрешләр филиациясе – ком. (< аз. диал.), төркм., төр., гаг. *утан-* «оялу, уңайсызлану», к. ЭСТЯ I: 609–610.

Бу угыз линиясенең бер чагылышы – чув. *вăтан-* «оялу» булса кирәк, тик М. Федотов (I: 113), М. Рясянен эзеннән барып, чув. сүзен бор. төрки *ud, иб* «оят» сүзенә турыдан-туры кайтарып калдыра. Халык этимологиясендә **уфтан-у** сүзен **уф** ымлыгына бәйләү очрый (*уф-ф та уф-ф дип уфтана* дигәндә бу бик ачык чагыла).

Дерив.: **уфтаныл-у, уфтаныш-у, уфтандыр-у; уфтанчык.**

**УХ** ы. «ух» < рус. булса кирәк.

Дерив.: **ухла-у, ухылда-у.**

**УХА** «уха» < рус., гом. слав. сүзе, к. Фасмер IV: 177–178.

**УЧ,** диал. **уц** «ладонь, горсть» ~ чув. *уç, уçă, ывăç, ывçă* id. < гом. кыпч.: башк. *ус*, көнб. кыпч. *уwыч*, нуг., каз., к.-калп. *уwыс,* кырг., алт. *ууч, уучи,* алт. диал. *ооч* > алт., шор. *ош, оош* > хак. *оос* id. Икенче бер линия: себ. (Тумашева 1992: 33) **ауыц** ~ кр.-тат., уйг. *авуч,* госм. *абуч*, төр., аз., чыгт. (Будагов I: 115; Поппе 1938: 47) *ауч, ауҗ,* үзб. диал. *һавуч* «учлам» ~ бор. төрки (ДТС: 70–71) *avuč, awut, avut* id.; көтелмәгәнчә (ДТС: 14, 16) *adut, aбut* варианты да бар. Шуны әйтергә кирәк, күпчелек очракларда бу сүз «учлам» мәгъ. килә, «кул табаны» мәгъ. башлыча тат., башк. телләрендә.

Г. Рамстедт (1957: 118) төрки *awуч* < *абуч* сүзен иске монг. *aбiča* сүзеннән монг. *aбi-* «алу» фигыленнән дип язган, шуннан соң еш кына аның этимологиясе кабатлана (к. Räsänen 1969: 3; ЭСТЯ I: 409–410). Ләкин *adut* варианты бу фаразга каршы. Ихтимал, ул бүтән тамырдандыр? К. ш. ук Федотов I: 469 (гадәтенчә, тат. сүзен искә алмый).

Дерив.: **учлы, учсыз; учлык (бер учлык); учла-у** (бу сүзнең параллельләре төрки телләрдә «тоту» мәгъ. киң таралган: каз. диал. *ӧшла-у* > себ. **ошла-у** «тоту, алу», к. Тумашева 1992: 162); **учма** (бу сүзнең ясалышы ачык түгел: *уч-* «тотамлау» дигән фигыль булмадымы икән, ди Э.В. Севортян); **учмарла-у** ~ башк. *усмарла-у* (к. ТТДС II: 333; БТДҺ: 358) «учка алып карау, йомарлау» ← **учмар,* ш. ук *уч-* дигән фигыль булганлыгын белдерә шикелле.

**УЧАК,** диал. (себ., миш.) **уцак, уцак̡** «очаг, костёр; горнушка, загнетка; шахта, рудник» ~ чув. (Сергеев 1971: 60) *учах, вучах, вочах, вычах, мучах*, мар. (Иванов, Тужаров: 25) *вазак, вазака,* мар. Т. *вацак*, удм. *учог, мучог, очаг* id. < гом. кыпч., уйг., чыгт., бор. төрки, бор. монг. (Поппе 1938: 262) һ.б. *očaq* (> башк. *усаҡ,* нуг., каз., к.-калп. *ошаҡ,* кырг. *очоҡ*) «учак; мич», кр.-тат., кар., гаг., аз., төр. һ.б. угыз. *очаг, ожаҗ* (төр. *ocak*) «учак, ут урыны; мич, әүсәк; тимерче алачыгы; шахта, кян» (төр. телендә ш. ук «плантация; клуб; династия; ясле;

верфь; яничәриләр оешмасы һ.б.ш.») > ком. *ожъақ, ожақ* «өй, гаилә; учак», к.-балк. *оджак* «мич торбасы, элекке турыга ачык морҗа» << (төркм.) *оожъак* << (алт.) *оочақ,* (Баскаков 1972: 236) *оочаң* «учак» ~ тув. *оҗуқ,* хак. *очых*, як. *осох* < бор. төрки (ДТС: 362) *očiq, otčiq* «учак, мич». Чыгт. *očaq* сүзенең (к. Радлов I: 1042–1136; Поппе, Op. cit.) «учак» мәгъ. белән беррәттән «мәхбүсләрнең муенына кидерелә торган тимер коршау» мәгъ. бар – ул тәүдә «коршаулы тимер өчаяк» мәгънәсеннән көчерелгән булса кирәк (тат. һәвәскәр этимологиясендә – Радлов буенча – **учак** сүзен **үчаяк** «өчаяк» нигезеннән дип фаразлау юкка түгел). Чаг. ш. ук алт. *от ajaқ* «учак».

**Учак** – халык тарихын ачык чагылдыра торган сүзләрнең берсе. Күрәсең, ул *ōтчақ ~ ōтчуқ* – утны, ут иясен иркәләп атау сүзеннән килә (чаг. хәз. тат. *җылыкай*). Типологик рәвештә ут – мифик зат, җан иясе, рух итеп күзалланган. Бор. төркиләрнең тимерчелек белән актив шөгыльләнүе **учак** сүзенең «шахта, рудник» мәгъ. чагыла; сәлҗукларда *ожақ* «утыз гаилә берлеге» – бор. төркиләрдә утызлык – иҗтимагый оешмаларда популяр сан булган (к. **Утыз**).

*Учак* < *очақ* сүзе төрле мәгъ. төркиләр белән күрше барча халыклар теленә кергән. Фин-угор телләренә ул төрле чыганаклардан (болг., тат., рус.) берничә тапкыр алынган. Рус. *очаг* бәҗәнәк теленнән булса кирәк (ауслаут *-г* шуны күрсәтә, чаг. *печенег*). Гордлевский I: 80–100; Räsänen 1969: 356; Мухамедова 1973: 135; ЭСТЯ I: 422–425; ССТМЯ II: 29; Федотов I: 134–135; Аникин: 434.

Дерив.: **учаклы, учаксыз; учаклык.**

**УЧАР** «рынок, рыночная площадь; место разветвления» < гом. кыпч., к. ~ башк. *усар* «зур, тармакланган гаилә; күп балалы гаилә», ком. *очар*, ног., каз. *ошар* «ир-ат җыелып утыра торган урын», чыгт. (Будагов I: 116) *учар* «базарчык», кар. *очар* «бигәнәй, читтән килеп урнашкан кеше (< базарчы)», иске ядкәрләрдә *učar* «базар» < фар. *вачар* (>> венг. *vasar*) «базар урыны, базар чаты» (к. Räsänen 1969: 357). Оренбург тат. сөйләшендә **учар** «посёлок» (безнең мәгълүмат. – *Р. Ә.*).

Дерив.: **учарлы** «күп ботаклы»; **учарлан-у** «ботаклар саны арту».

**УШ I** «сообразительность; память» > мар. (Упымарий: 230; Саваткова: 223) *уш ~ ŏш ~ ыш* id. **Һуш** (к.) сүзеннән булса кирәк, әмма бор. төрки (Й. Баласагуни, к. ДТС: 613) *uquš* «акыл, уш» сүзеннән дә килеп чыга ала (*уқуш* > **угуш* > **ŏwыш* > *уш*). Чаг. себ. (Тумашева 1992: 159) **ŏқ-** [*огу*] < бор. төрки *иq-* «аңлау, тыңлау».

Дерив.: **ушлы, ушсыз**. Рус. сөйл. *ушлый* «елгыр-зирәк» тат. теленнән микән, әйтүе кыен.

**УШ II,** (Нуртдинов: 97) **ŏш** «лось-самец; медведь-самец» (у Нуртдинова, вероятно, неточно) < удм. *ош* ~ коми. *öš, öšk,* мар. *ушкыж, үшкүз* «үгез» ~ көнч. тохар. *okso*, авест. *uxšan* «үгез» (һинд-евр. телләрендә киң таралган сүз). ЭСТЯ I: 213; Гамкрелидзе, Иванов II: 937; Kluge: 662 (һинд-евр. телләрендә бу ниндидер бор. бер телдән алынма булса кирәк ди).

**УШ III** иск. «вот; вот значит» < бор. төрки (ДТС: 372, 617) *oš, uš* «бу, менә бу», *oši* «ошбу» > себ. (Тумашева 1992: 162) **ŏшу, ŏшы,** башк. *шо* «шушы». К. **Ушандак.** ЭСТЯ I: 492–494.

**УША** (ТТДС I: 459; ТТДС II: 333; БТДҺ: 360), крш. (Balint, Й. Мухаметшин) **uča, үшә** «лавка-скамейка у самой печки; уступ основы печи, на котором можно сидеть, ставить для просушки обувь и т.п.» – чув. *уша* «мич; мич казнасы», мар. (Упымарий: 231; Саваткова: 177) *уша* «уша; куна433 тактасы», чув. диал. (Paasonen 1903: 96) *užaj jubizem* «уша баганалары» ≈ тат. **пияш баганалары**, чув. *улча юпи* id. Димәк, *улча* > *уча* > *уша* (бу вариантларда тюркологларның башын катырган *-лч* > *-ш* күчеше бик ачык күренә). Сүзнең тамыры – гом. төрки, монг. *ул, ол* «нигез, аслык, төпсә», к. үзб. (ЎХШЛ: 269) *уул* «тандыр (алачык мичe) фундаменты, казнасы», *-ча* – билгеле кечерәйтү кушымчасы. К. ш. ук **Ушабаш.**

Фразема: **уша башы** ~ чув. *уша пуççи* шул ук «уша».

**УШАБАШ** (ТТДС II: 333) «отгадчик в игре с прятанием колец» – «йөзек салыш уенында гөрләүче» – **уша башы** сүзеннән: күрәсең, ул уенчы ушада, уша башында утырырга тиеш булган. К. диал. (БТДҺ: 360) **ушабаш** «мич казнасының чыгып торган өлеше».

**УШАК I** (ТТДС I: 459; БТДҺ: 360) «клевета; донос» – **ошак** (к.) сүзенең гәй. сөйләшендә генә теркәлгән бу вариантының **ушакланыш** «ошакчы» дериваты игътибарга лаек (күрәсең, **ушакланышы** сүзеннән эллипсис).

**УШАК II** иск., диал. «мелкий, измельчённый», «мелочь» ~ уйг., чыгт. һ.б. *ошақ* id., чыгт. *ошаг*, төр. *uşak* «вак; вак-төяк», «бала-чага», «вак хезмәткәр» һ.б., к. **Ушал-у.**

**УШАЛ I** иск. «тот, упомянутый» – бик искечә язылган әсәрләрдә очрый. Ә. Ясәвидә:

*Ушал казый барча илне разый кылса*
*Разыйлыктан оҗмах өен алыр, имеш*
(84 хикмәт һ.б.)

Бор. төрки (ДТС: 373) **ушал** юк, аның урынына *ošul*. К. **Шул** һәм **Ушандак.**

**УШАЛ II** диал. (м.-кар.) «явыз рух, усал», «су җене». Аның нәкъ менә «су җене, су иясе» булуы бу сүзнең асылы бор *усу ал ~ ушу ал* «су алы (җене)» түгелме икән дигән фикергә китерә (к. **Су** һәм **Ал II**). **Ушал** яңгырашы *ушалны утырт ушага* дигән әйтемдә дә чагыла. **Усал** сүзенең этимологиясе бик төгәл түгел. Һәм **усал**мы, **ушал**мы беренчел икәнлеген әйтү дә кыен: *с ~ ш* корреспонденциясе бор. төрки телләрдә үк очрый.

**УШАЛ-У** (себ., ЗДС: 688) «раздробляться, распадаться на мелкие куски» ~ чыгт. *ошал-* id. ← *ош-* > каз, *ос-* «ваклау; кискәләү» һ.б.

**УШАНДАК** иск. «таким образом, как-то, а также» < чыгт. (Будагов I: 137) *ушандақ, ушандӓк, ушандаг* id. – хәз. сүзлекләрдә күренми; бор. уйг. *ушан тәг < ушал тәг* «шуның кебек» сүзеннән, к. тат. диал. (миш.) **шал, ушал** «шул» (к. ТТДС I: 511 һ.б.). *Ушал < ошал < ош ал* сүзеннән яисә, бор. сингармоник чылбырга җайлаштырылып, *ош ол* сүзеннән (ЭСТЯ I: 493), к. **Уш II.**

**УШАТ** диал. (ТТДС II: 333; БТДҺ: 360) «ушат, деревянное ведро» (с «ушками») < рус., к. ш. ук чув. *ушат* id. (Ашмарин III: 353). Бу сүзнең киң таралуына аның рус һөнәрчеләре тарафыннан эшләнеп сатылуы сәбәпче булган.

**УШКЫН** диал. (Баязитова 1986: 212) «группа людей; семейство» ~ чув. *ушкан, ошкӑн*, мар. *ушкын* «группа, берләшмә, союз, җәвер (нәсел-ыру береге)» ← мар. *уш- (ушаш)* «берләштерү, группалау; кушу». Шулай итеп, **ушкын** сүзе мар. теленнән килә шикелле. Әмма мар. *уш-* нигезеннән ясалган барча сүзләр тат.-төрки сүзьясалыш модельләрендә: *ушын- (ушнаш)* «кушылу», *уштар-* «беректерү», *ушык* «берек, кушык», *ушым, ушем* «союз, берлек; беркетелү төше» һәм хәтта *уш* «куш» → *ушлан-* «кушлану». Кыскасы, *уш* сүзе **куш** сүзенә һәр тарафтан тәңгәл. Ләкин тат. *қ-* > мар. *ø* (нуль аваз) бүтән мисалларда очрамый! Чув. *ушкӑн* тур. Федотов II: 353 (тат. сүзен дә, мар. сүзен дә белми). К. түбәндәгене.

**УШНА** (ТТДС II: 333) «крестовина, мотовило» – тат. **әвернә** белән бер модельдә **уш-* нигезеннән ясалган, бу **уш-* мар. телендә «кушу, ялгау» мәгъ. саклана (к. югарыдагыны). Әвернә, ушна җеп кату, җеп кушу өчен файдаланыла.

**Ушна** сүзенең «кыр тычканы» мәгъ. дә бар. Моның мотивациясе безгә мәгълүм түгел.

**УШТАЛ, оштал** себ. (ЗДС: 688) «оглобля саней» ~ як. *уостал*, эвенк. һ.б. *оштол* «чанага тормоз сала торган махсус таяк» һ.б.ш., рус. *остол* id. Бу сүз тур. озын аңлатмасында Аникин (: 430) аның тат. **уштал** белән бердәйлегенә шик белдерә һәм этимологиясен ачык калдыра. К. ш. ук Räsänen 1969: 430.

**УЫ,** себ. (Тумашева 1992: 101) **ӯу** «яд» ~ гом. кыпч. *уw*, башк. (БҺҺ III: 216) *ыу, ыуа,* алт., тув., хак. *оо* «агу» һ.б., к. **У.**

**УЫК** «стрелолист (растение); радиальный» (к. Иванова 1990) ~ иск. (Идегәй 1988: 98) **увық** «тирмә түбәсен тотып торган чош, колга (алар чагаракка радиаль рәвештә беркетеләләр)» < гом. кыпч. *уwық, ууқ* id. (рус. *унина* диелә) < бор. **уңуқ* id. Чаг. ш. ук төр., уйг. диал. (к. Радлов I: 993) *ооқ* «күчәр; үзәк». Диал. (ЗДС: 679) **ук** «ике ярым метрлы юнылган таяк» – асылда **уык.** К. Будагов I: 143.

**УЫЛ** «детва пчёл» < *угыл < огул*, к. госм. *угул* «умарта күче», *угыл ырусы* «бал корты анасы» (к. Будагов I: 141). К. **Угыл, Уылдык.**

**УЫЛДЫК,** себ. (Радлов I: 1700–1701) **ултык** «икра» ~ башк. *ыуылдық*, (БТДҺ: 410) *ыуылдырық, ыуылтық, ыуылтырық* – төп мәгъ. бу сүз «балыкның уылдык капчыгы» булган, к. чыгт. (Радлов I: 1016) *огулдуруқ* «күкәйлек, аналык», ләкин кыпч. телләрендә бу сүз бүтәнчәрәк мәгъ. алган: нуг. *увылдық,* к.-калп. *уылдырык*, к.-калп. *уылдық, уылдырық,* кырг. *улдуруқ* «уылдык», төркм. (ТДГДС: 137–138) *оvулдуруқ, оглон туруқ* «уыл-

дык», күч. мәгъ. «яшь кенә» һ.б. Формаль җәһәттән сүз болай аңлатыла: *огул ~ угыл* (бу сүзнең «умарта күче; балык орлыгы укмашы» кебек мәгъ. бар) + *-дуруқ//-туруқ* (бу кушымча һәртөрле кидерелә торган нәрсәләрнең атамаларын ясый). Димәк, **уылдырык < огулдуруқ** «угыллар-балалар җыенына кидерелгән нәмәстә, капчык», бу мәгънә тора-бара шундый капчыкның эчендәгесе «уылдык массасы» мәгънәсен алган. Һәм, әлбәттә, *огулдуруқ > огулдуқ*. К. төр. *oğulduruk* «аналык».

Чув. *вăлчă* «уылдык» << бор. төрки (ДТС: 364) *oγulčuq* «аналык» очрагында да шуңа охшаш мәгънәви үзгәрешләр булган: *oγulčuq* бу очракта «кечкенә угыл» түгел, ә *oγul čoγ* сүзеннән – *čoγ* «урама, ыштыр». Федотов I: 107.

**УЯ [уйа]** «дочь старшего брата матери, которая старше говорящего» («женское» соответствие слова **тагай**) – тат. теленең периферияль сөйләшләрендә (м.-кар., әстр., себ.) таралган бу сүз гом. төрки характерга ия, к. Рамазанова 1991: 67 («Мордва-каратаи» җыентыгында). Алгы рәт сузыклы вариант – төр. *üye* h.б. угыз телләрендә таралган. К. ш. ук Щербак 1970: 127; ДТС: 607 (*uja* гомумән «кардәш»).

**УЯЗ [уйаз], уйас** диал. (Остроумов 1976: 131, ТТДС I: 452–453; Тумашева 1992: 224) «низменный (о местности)» < гом. кыпч. *ойаз* id., башк. (БҺҺ III: 192–193) *уйаҙ* «уйсулык; ике тау арасы» ← *ой* «уй, түбәнлек» (к. **Уй II**), ясалышы ачык түгел.

**УЯУ [уйаw]** «бдительность» – **уйа-у* «уяу, өнендә булу» фигыленең исемләшкән-сыйфатлашкан формасы. Шул ук фигыльдән **уян-у, уят-у** юн. формалары ясалган һәм алар барча төрки телләрдә (билгеле фонетик вариантларда очрый). Бор. төрки (ДТС: 362–363) *oduγ ~ одuγ* «уяу»; *odul-, odun-* «уяну», *odγur-* «уяту».

**Уйа-** нигезе үзе беркайда да теркәлмәгән бугай, ләкин ул **уйа-н-у, уйа-т-у** сүзләре шул фигыльнең кайт. һәм йөкл. юнәлешләре булуга шик юк.

*Уйа-* < *ойа-* < *ойга-* < *одуа-* «уяу булу» бор. **од//ор* тамырыннан, к. чув. *вăран-* << **оран-* «уяну», *вăрат-* << **орат-* «уяту». Әле **од//ор* тамырының мәгънәсе ачык түгел, *уй* < *ой* «уй» сүзе белән бәйлау бигүк ышандырырлык түгел (к. ЭСТЯ I: 429–432). Räsänen 1969: 357; Федотов I: 108. Иске тат. формалар тур. Zajączkowski: 115.

# Ү

**Ү** авазы тат., башк. телләрендә гом. төрки *ö* авазыннан килә. Ул аваз хәз. кириллек әлифбада кайбер төрки телләрдә *ө* дип языла, без ошбу сүзлектә элекке *ö* хәрефен үзгәртмәдек, чөнки ул *ө* тат. *ө*гә тиңдәш түгел, бүтәнчәрәк әйтелә.

**ҮӘС** (Тумашева 1992: 228), **овәс** (ЗДС: 501) «овод (мелкий)» < бор. төрки (ДТС: 382, 393) *öväz, öjäz* «черки», төр. *ivez, üvez* «кигәвен». Чаг. **Үпрә.**

**ҮГӘР** (ЗДС: 688): **үгәр ылан** «очень подвижный ребёнок» ~ рус. *ýгорь* – бик хәрәктчән балык төре (*угря в руках не удержать* дигән мәкаль дә бар). Ләкин бу чагыштыруга шикләнерлек урын кала: тат. **үгер** яңгырашында булырга тиеш иде. Рус. *огарь* – «хәрәкәтчән кыр үрдәге төре» сүзеннән дә килә ала.

Тат. телендә **үкәр** дигән су кошы булган бугай: Башкортстанда Караидел буенда, сазламыклы елга-күлләр арасында утырган **Үкәрле** дигән авыл бар һәм к. чыгт. (Будагов I: 143) *уқар*, Бабур телендә *гуқар*, бур. диал. *ухара* «ләкләк, торнасыман бер кош»; як. *үкэр* «биек камыш, күрән» ~ эвенк. *укар* «торна»; рус. диал. (Аникин: 381) *укар* «көе сиртмәсе» ~ төр. *okar* «зур күлбога, су үгезе (озын аяклы бер кош, гадәттә камышлыкта балык сагалап тора)», Радлов (I: 993) буенча, *окар* «челән».

**ҮГЕЗ** «бык» < гом. кыпч. *öгүз* (башк. *үгеҙ,* нуг., каз., к.-калп. *öгиз*), уйг., чыгт., угыз. *öкүз,* үзб. *хукиз*, уйг. диал. *һöкүз* ~ чув. *вăкăр*, венг. *ökör, ewker* (болг. теленнән) «үгез», монг. *үхэр,* як. (Поппе 1938: 37) *üker* «үгез, сыер (мөгезле эре терлек)», к. ш. ук алт. (Баскаков 1966: 142) *үңүс, öңүс* «ата аю»; *-р* фонетик вариантка, ихтимал, тат. диал. (эчк, к. ТТДС I: 207) **қуғыр** «үгез» якындыр, к. тунг. *һукур*, монгор. (монг. диал.) *fuguor* < **pügüör*. Бу мәгълүматлар **үгез** сүзен **үкер-ү** белән чагыштыруның (Г. Алпаров) нигезсезлеген күрсәтәләр. Ш. ук *үгез* < *öкүз* һ.б. һинд.-евр. (тохар) телләреннән китереп чыгару да нигезсез (төрле бәхәсләр тур. к. ЭСТЯ I: 521–523; тат. диал. **қуғыр** мисалы китерелми). Төр. *oyuz* варианты да бар, к. Eren 314–316. К. ш. ук бур. *үрхэр* «үгез» (бу бөтенләй оригиналь вариант). Федотов I: 105–106.

Дерив.: **үгезле, үгезсез;** диал. (ДС I: 256) **үгезәк** «үгез бозау».

**ҮГЕТ** «наставление» > чув. *үкĕт*, мар., удм. *öгыт* id. < гом. кыпч. *öгүт* (каз., к.-калп. *öгит*) < бор. төрки (ДТС: 382) *ögit* id. ← *ög-* «уйлану, уйландыру» (> башк. *өк-* id.). сүзеннән, к. ш. ук төркм., төр. диал. *öwүт* «киңәш, үгет; җәзалау» һ.б. (к. ЭСТЯ I: 500–501) һ.б. (күп телләрдә бар), бор. төрки *-т* кушымчасы ярдәмендә ясалган. К. **Үкен-ү.** Федотов II: 299 (бик ярлы).

Дерив.: **үгетле, үгетсез; үгетлә-ү; үгетче.**

**ҮГИ, үгәй** «неродный (об одном из родителей), сводный (о братьях и сёстрах), не свой, а мужнин или женин (о детях)» > мар. кч. (Исанбаев 1978: ) *öгäй,* чув. (Сергеев 1968: 76) *укей* < гом. кыпч., чыгт., уйг., угыз. *öгәй* (кырг. *öгөй*, төркм. *öвей*. кр.-тат., аз. *öгәй*), бор. төрки (ДТС: 379) *ögäj,* хак., алт. *ööй, öй* id. һ.б. (мәгъ. үзенчәлекләре тур. к. ЭСТЯ I: 405–406) электән бирле монг. *үгэй, үгэ* «юк, мәхрүм» сүзе белән багланышта аңлатыла, к. яз. монг. (Поппе 1938: 373–374) *ügei* «ярлы; мескен»; к. ш. ук төр. диал. *üvegü* «үгәй» ~ яз. монг. *ügegü* «юксыл; байлыксыз»; бур. *үггүй* «ятим; анасыз» (*-гүй* ~ төрки *-сыз* мәгъ. кушымча) һ.б. Чаг. башк. (БТДҺ: 361) *үк йәтим* «үксез ятим».

Дерив.: **үгиле, үгисез; үгилек (үгәйлек); үгисет-ү (үгәйсет-ү).**

**ҮДЕР** (ТТДС I: 556) «поминки» < гар. *witr* «хәтерләү» (шуннан **витер намазы**). Гадәттә *витер* дип әйтелә. Будагов II: 303. ЗДС (: 689) **үдер** сүзен русчадан дип билгели, тик нинди сүздән икәнлеген күрсәтми.

**ҮҖӘТ** (Троянский I: 89) «упрямый; ожесточённый» < гом. кыпч. (ком.) *öҗәт* > каз., к.-калп. *öжет* id. < бор. төрки (ДТС: 376) *öčüt* «үчләшү» >> себ. (Тумашева 1992: 231) **үцәт** «үҗәт» (*-ц-* < *-ч-* > *-җ-*); к. ш. ук тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **үҗәр** < уйг. *öҗәр-* > кырг. *öҗөр* «үҗәт, тырыш». **Үҗәт** < *үчәт* < *öчәт* сүзе бор. *үчә-* < *öчә-* «үч булу» фигыленә бор. *-т* ялганып ясалган, к. югарыдагы **үгет**. Биредәге *-ч-* > *-җ-* тур. к. **Үҗеклә-ү.** ЭСТЯ I: 559, к. **Үч.**

Л. Будагов (I: 313) һәм аңа ияреп М. Ногман да (Ногман: 102) **үҗәт** сүзен гар. *хуҗҗәт* «исбат, дәлил» сүзеннән дип язганнар, хәлбуки бүтән төрки телләрне карарга кирәк иде! К. **Үчәш, Үчәш-ү.**

Дерив.: **үҗәтлек; үҗәтлән-ү, үҗәтләш-ү.**

**ҮҖЕКЛӘ-Ү,** диал. (ТТДС I: 105, 409) **ижекләү-ү, үчә-ү** «дразнить, поддразнивать» < *үч*, диал. *өйч* «үч» сүзеннән; *ч* > *җ* күчеше элекке *үйч* варианты тәэсирендә барлыкка килгән (*-йч-* > *-җ-*) булса кирәк (чаг. **Үҗәт**). **Үчеклә-ү** вариантында *-ч-* саклану бу сүзнең морфемик составы онытылмаган тирәлектә кулланылганлыктан килә. **Ижеклә-ү** варианты халык этимологиясеннән киләдер.

**ҮЗ I** «сам, особа; свой, свойский; близкий (мәс., *үз кеше* дигәндә)», күбесенчә тартымлы формада кулланыла: **үзем, үзебез, үзең, үзегез, үзе, үзләре** < гом. төрки *öз,* төркм. һ.б. *ööз [ōз],* як. *үөс,* чув. *вар* ~ монг. *öр [өр, өрө]* id. Урал-Алтай телләрендәге бүтән кайбер сүзләр белән чагыштырулар – к. ЭСТЯ I: 506–508 – бигүк ышандырырлык түгел. К. ш. ук Räsänen 1969: 376–377.

**Үз** гадәттән тыш күп дериватлы нигез: **үзенә, үзенчә, үзлә-ү, үзләш-ү, үзләштер-ү, үзлек, үзлегеннән, үзчел** һ.б. һәрберсе продуктив нигезләр; **үз-** сүзьясагыч префикс буларак бихисап сүзләрдә очрый, аларның күп кенәсе рус. сүзләрдән калька (алардагы *сам-, само-* һ.б. урынына кулланыла); **үзагым, үзаң, үзәшчән** һ.б.ш. Фразеологизмнар да шактый күп: **үз алдына, үз дигәне (белгәне), үз итү, үзенә башка, үзенә күрә, үз-үзенә, үзеннән-үзе, үз-үзеннән** һ.б. Хәз. төр. телендә *öz-* префиксы ярдәмендә йөзгә якын сүз ясалган. К. **Үзәк, Үзән, Үзгә.**

**ҮЗ II** диал. «лучшая часть чего; середина, основа». Севортян бу сүзне **Үз I** бабында, аның бер мәгънәсе итеп карый. Чаг. кр.-тат. *öz* «чиста, катнашсыз».

**ҮЗ III** диал. «свойство сгущаться, быть клейким, не рассыпчатым». Күбесенчә **үзле** «ябышкак» сүзе составында килә. Бу **үз** аерым бер тамыр бугай.

**ҮЗ IV: үз чире** «душевная болезнь; эпилепсия» – *үз* < *öз* (к. **Үз II**) сүзенең «нервы; җан; рух» мәгънәсеннән, к. алт., үзб. (ЎХШЛ: 210) *үзүт* «җан, үлгәннәрнең һавада очып йөри һәм хәтта гаиләнең берәр әгъзасына керә торган зыянлы җаны» < бор. төрки (ДТС: 395) *özüt* «җан; асыл; гасабилык рухы».

**ҮЗӘК**, себ. (Тумашева 1992: 165, 230) **öзöк, үсәк,** (Димитриева 1981: 170) **өйсäк** «стержень; центр; долина; нутро; душа», (в выражении *үзәк көю*) «пищевод; трахея», себ. «ось телеги», диал. (ТТДС I: 557) «отборный (о волокнах льна или конопли)», «центральный» < гом. кыпч., хак., алт. *öзәк,* башк. *үҙәк,* уйг., үзб., угыз. *öзәк, ööзәк,* алт., кырг. *öзöк* «үзәк», ш. ук «үзән» < бор. төрки (ДТС: 395) *özäk* «тарлавык; кан тамыр; үзән», әлбәттә, *үз* < *öз* сүзеннән деминутив (*үз-әк* булып тат. теленең үзендә дә ясала алыр иде). К. **Үз II**. Чув. *васак* «үзәк» < болг. **wәзәк* < чыгт. *öзәк;* чаг. төп. болг. *wәр* < *öр* (к. **Үз I**). ЭСТЯ I: 509–510; Гарипова 1998: 117–119.

Дерив.: **үзәкле, үзәксез; үзәклек.**

**ҮЗӘН,** диал. **өзән**, себ. (брб.) **үзöн** «долина; река между горами» < гом. кыпч., хак., угыз. *öзән,* кырг., алт. *öзöн,* үзб. (ЎХШЛ: 203) *öзәң* «үзән», хак. диал. *öзöн* «кәүсә; үзәк» ~ чув. *васан* < болг. **wәзән* < кыпч. *öзäн*, **ööзäң* id. – әлбәттә, *үз* < *öз* (к. **Үз I**) нигезеннән, ләкин ясалышы ачык түгел. Төр. *öz* «чишмә, инеш»; алт., кырг., каз. телләрендә *öзек, öзöк* «елгачык» һәм *öзен, öзöн* «үзән» аерымлана. Ихтимал, *үзән* < *ööзәң* < **öгүзәң*, к. бор. төрки (ДТС: 382 һ.б. чыганакларда) *ögüz, öküz, ööz* «елга, ташкын; муллык, күплек». Чаг. тат. диал. (себ.) **өйсäн** «үзән» ~ алт. диал. *öйзöм* «уйсулык». Рус. *узень* «елга тармагы; күп кенә елгаларның атамасы» тур. Фасмер IV: 155; ЭСТЯ I: 510.

Дерив.: **үзәнле, үзәнсез; үзәнлек.**

**ҮЗӘРӘ** иск., кит. «относительно, о, об; по причине» к. **Үзрә.**

**ҮЗБӘК** «узбек» – закономерное татарское отражение самоназвания узбеков **öзбәк, ўзбек*. Гомуми караш буенча, хәз. **үзбәк** этнонимы Алтын Урда ханы **Үзбәк** исеменнән, ә гомумән бу сүз **öзү бәрк* «асылы, үзе ныклы» тезмә сүзеннән, имеш, к. Будагов I: 131–132.

**Үзбәк** этнонимы бөтен үзбәк халкына карата XX г. гына кулланыла башлый, шуңа кадәр бу сүз күчмәче һәм авыл-кышлак үзбәкләрен генә белдергән. Шәһәр үзбәкләрен исә **сарт** (к.) дип атаганнар.

**ҮЗГӘ** «иной, обособленный; отличный от; чужой» < гом. кыпч. *öзгә,* уйг., үзб., угыз. *öзгә,* куман.

(Радлов I: 1304) *özgä*, бор. төрки (ДТС: 395) *özgä* > алт., тув. *öске, аскä*, алт. диал., кырг. *öзгö* һ.б. «үзгә» – *үз* < *öз* сүзенең юнәлеш килеш формасыннан лексикалашкан булса кирәк (к. ЭСТЯ I: 506–508), чаг. *баш → башка, үң → үңгә,* ләкин бүтәнчәрәк тә килеп чыгу ихтималы бар.

**Үзгә** продуктив нигез: **үзгә-башка** (парлы сүз), **үзгәлән-ү, үзгәләт-ү; үзгәлек; үзгәгә**, диал. (ТТДС I: 556–557) **үзгәлчә, үзгәлчи** һ.б. К. **Үзгәр-ү.**

**ҮЗГӘР-Ү** «изменяться, измениться» < гом. кыпч. *öзгәр-* id. *үзгә* < *öзгә* сүзеннән бик аңлаешлы рәвештә (*-р* кушымчасы) ясалган һәм ясагыч нигезеннән активрак кулланыла торган сүз.

Дерив.: **үзгәрел-ү, үзгәрен-ү, үзгәреш-ү, үзгәрт-ү; үзгәргеч, үзгәрмеш** һ.б.

**ҮЗДӘН** иск. (Н. Исәнбет) «еретик; некий тюркский пророк, якобы покончивший жизнь самоубийством после прочтения Корана, увидев, что ислам лучше его учения» ~ к.-балк. *ёзден* «уздень, мәдәниятле кеше, интеллигент; кенәз, би, морза», кар. *эздэн* < *öздэн* «үзаллы зат» (*öз бий* «мөстәкыйль би») ← *үз* < *öз* сүзеннән, ясалышы ачык түгел. Кыпч. *öзден* > *узден* сүзе Төньяк Кавказда киң таралган, шуннан рус. *уздень* – экзотик социаль термин (рус. «местный феодал, князёк»).

**ҮЗЕ** «он сам» – алмашлык функциясеннән тыш, ярдәмлек мәгъ. дә кулланыла һәм рус. «к тому же» дигәнгә туры килә. К. **Үз I.**

**ҮЗЛЕ** «клейкий (о тесте), вяжущий (о глине)» < гом. кыпч. *öзли, öзлү* (сүзлекләрдә сирәк очрый), госм. *öзлү* «тулы кыйммәтле; җиләкле, сутлы» ← гом. көнб. төрки (Радлов I: 1298, 1305) *öz* «нәрсәнең дә булса иң кыйммәтле состав өлеше, иң сыйфатлысы» ~ чув. *вар* < **ör* id. К. **Үз I, III.**

**ҮЗЛЕК** «свойство, особенность» ~ гом. кыпч. *öзлик, öзлүк* (сүзлекләргә сирәк кертелә) id. Бүтән телләрдә *öзлүк* бүтән мәгъ., мәс., бор. төрки *özlüg* «тере зат, хайван», «маймыч», *özlük* «токымлы (ат тур.)».

**ҮЗРӘ** иск. «на, над; в, по всему; о, относительно; сообразно», себ. (Тумашева 1992: 165) **өсәрә** «сообразно; соответственно; к лицу, подходящий; как-то раз» < чыгт., уйг., иске угыз. *үзрә* id. бор. төрки **üz* «өс, өске як» (шуннан ук *үст*) һәм шуның фигыль коррелянты *üz-* «өстә булу» нигезендә ясалган сүзләрнең берсе, к. ш. ук иске тат. (Котби), чыгт., бор. төрки (ДТС: 629; Боровков 1963: 336–337) *üzä* «өстенә, янына; нигезендә» > як. *үөһэ* id. **Үзрә – үз** нигезеннән, **үзәрә – үзә** нигезеннән *-ра* кушымчасы ярдәмендә ясалган, чаг. шундыйлардан **соңра, тышра, эчрә**. Гомумән, **үзрә** һәм **үзәрә** синоним булсалар да, мәгънәләрендә һәм кулланышларында аермалыклар да юк түгел; **үзәрә** исем итеп тә кулланыла – **үзәрәсенә, үзәрәсеннән, үзәрәсендә** диелә; кайбер ядкәрләрдә очрый торган **үзәр** һәм **үзәре** (шуннан **үзәрендә** «турында») нигезләре **үзәрә** сүзеннән кире сүзьясалышы буенча барлыкка килгәннәр булса кирәк. Чаг. ш. ук чыгт. (Боровков 1963: 337) *үзäки* «өстәге», *үзäлä* «өстеннән, өстән», (Будагов I: 132) *үзәр-, үзүр-* «(сайлап) күтәрү, югары мендерү». Räsänen 1969: 526–524; Мухамедова 1973: 183; ЭСТЯ I: 622–623 (тат. диал. **өзәрә > өсәрә** беркайда да искә алынмаган).

**ҮЗҮК, үдзүк** (Тумашева 1992: 228) «крыша» << бор. чыгт. (Поппе 1938: 17) *öčük* id. К. ш. ук үзб. *учак (< үчәк)*, каз. *йүшек* «түбә, тау башы».

**ҮЙ-Ү** (ЗДС: 689) «петь, воспевать» < бор. төрки **öй-*, к. төр. *öykü* «хикәя, әкият». Чаг. төр. *öv-* < *öğ-* «мактау». К. **Өй-ү II.**

**ҮК I** к. **Ук II.**

**ҮК II: берүк** «пожалуйста; не забудь» «бер уйла» дигән сүзтезмәдән килә, к. бор. төрки (ДТС: 378–382) *ög-, ök-* «уйлау, фикерләү». Аның исем коррелянты *ög ~ ök* «уй, фикер; хәстәр», ш. ук «(хәстәрләүче) ана, әни» мәгъ. кулланылган. Бу исем һәм фигыль тамырыннан бор. телләрдә бик күп сүзләр ясалган булган, тик аларның күбесе тарих дәвамында бүтән сүзләр белән алмаштырылган. Тат. телендә *ög ~ ök* тамыр сүзенең дериватларыннан түбәндәгеләр сакланып килә:

**үгет** < бор. төрки *ögüt ← ögü-* яки *öggü-* «акыл бирү»;

**үкен-ү** < бор. төрки *ökkyn-, ökün-* «уйлану» ← *ökü-* яки *ökkü-* «уйлау»;

диал. **үктер-ү** «аңдыру, уйлап эш итәргә кушу» – *үк-* < *öк-* фигыльнең йөкл. юн. формасы;

иске әд. **үктәм** < бор. төрки *ögdäm* «акыллы һәм горур»;

**өйрән-ү ~ үрән-ү** һәм **өйрәт-ү ~ үрәт-ү** сүзләре – бор. *öгрә-* «акылга утыру» фигыленең кайт. юн. һәм боерык фигыль формалары;

**үги** < *үгәй* сүзе монг. телендә *өггүй* «акылсыз; анасыз» рәвешендә төрки алынма *өг* сүзеннән ясалган; аның төрки **үксез** < *өлсүз* сүзеннән калька булуы ихтимал. К. **Үгәй, Үгет, Үкен-ү, Үксез, Үктәм.**

Бор. *ög, ok* һәм *ög-, ök-* сүзләренә омоним (ихтимал, тарихи тамырдаш) итеп бор. төрки *ög-* «мактау» сүзе дә китерелә. Бу сүздән иске тат. (Тукайда бар.) **үкеш-ү** «макташу» килә. Ихтимал, шуннан ук тат. диал. (себ.) **өй-ү, үй-ү** «(мактап) җырлау» сүзе дә киләдер. Бүтән төрки телләрдән к. төр. *öv-* «мактау, данлау» (күп дериватлары белән) < бор. *ög-*. К. ш. ук **Өрек-ү II.**

**ҮКӘ** (ЗДС: 689) «младший барт» ~ кырг. *öke*, үзб. *ўка* id. ләкин чыгт., үзб. диал. *өкә* «сеңелкәш». Ихтимал бор. *ög* «акыл, уй» тамырыннандыр: *ög-kä-m* «акыллым»?

**Үкә** сүзе Себер һәм Урта Азия татарларында кулланыла.

**ҮКӘЛӘ-Ү** (ДС I: 256), **үкә-ү** (ТТДС II: 406) «разминать ладонью, растирать, обвалять» ~ каз. *үк-* id. Чаг. башк., каз., кырг., үзб. *уқала-*, нуг., ком., төркм. *увкала-* id. ← *ув-, ов-, ог-* «уу».

**ҮКЕЛ** (Баязитова 2001: 24; БТДҺ: 361) «посажёный (отец, мать – свадебный термин)» – каз., кырг. *өкил* «вәкил», к.-балк. *өкүл* «яклаучы, адвокат» (к. **Вәкил**) сүзеннән. К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 204) *өкүлата* «вәкил ата». Бу сүз каз. теленнән таралган.

**ҮКЕН-Ү** «раскаиваться, сожалеть о случившемся» > чув. *үкĕн-*, мар., удм. *өкын, үкын-, үкĕн-* d. < гом. кыпч.: нуг., каз., к.-калп. *өкин-*, кырг., к.-балк., ком. *өкүн-, өгүн-*, уйг. *өкүн-, өгүн-* id., ш. ук «зарлану» ← бор. төрки (ДТС: 378–379) *ökün-* id. ← **öök-* < **ogük-* «уйлану, нык уйлау» ← *ök-* > чув. *үк-* «төшү; төбенә төшү» («төш-ү» > «уйлау» мәгъ. күчеше, к. **Төшен-ү**). Кыпч. телләрендә интервокаль *-к-* гадәттә *тартык+к* урынына килә, шунлыктан **үкен-** < **өккүн-* < **өгүкүн-* дип уйларга кирәк. К. ш. ук **Үгет, Үктер-ү, Берүк.** ЭСТЯ I: 523–524; Федотов II: 298–299.

Дерив.: **үкенел-ү, үкенеш-ү, үкендер-ү; үкенеч** (< бор. төрки *okünč* h.б.) ~ себ. (Тумашева 1992: 228) **үгеч** «кайгы».

**ҮКЕР-Ү,** себ. **үгер-ү** «реветь» > мар., удм. *өкыр-*, чув. *ухĕр-* id. < гом. кыпч.: нуг., каз., к.-калп. *өкир-*, кырг., к.-балк. h.б. *өкүр-, өгүр-* id. < *ө-кур-* (*-қыр* – аваз белдергән тәкълиди сүзләрдән фигыль ясагыч кушымча).

Дерив.: **үкерен-ү, үкереш-ү, үкерт-ү.** Себ. **үгер-ү (< үкер-ү)** гомумән «тавышлану, кычкыру; чакыру» мәгъ. кулланыла, к. Тумашева 1992: 228.

**ҮКЕ-Ү** иск. (к. Тукайда: *Ишан-ишәк үкешер, Үкемәктә мәгънә бар*) «восхвалять, горячо одобрять» < чыгт., госм. h.б. *өк-, үк-* < бор. төрки (ДТС: 378) *ög* > төр. *öğ-, öv-* «мактау». К. **Үктәм.** Будагов I: 145–146.

Дерив.: **үкеш-ү.**

**ҮКЕШ, йүкеш** (Мөхәммәдьярда, Максудидә h.б. иске авторларда) «много, масса (чего)» < чыгт. *үкүш* ~ як. *үгүс* id. ← (ДТС: 623) *үк-* «өю» (к. **Өй-ү**). Ягъни, **үкеш** «өем» дигән сүз; к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 623) *ükil* «туплам, җыен» (ләкин *үкил* > *үкеш* дип раслап булмый). Будагов I: 145–146.

**ҮКСӘ** «омела» < төр. *ökse* «үксә; үксәдән алына торган җилем» (ул җилем белән кош тоталар) < грек. *ἰξός (үкос)* id. Будагов I: 145. **Үксә** «парлак чәчле чибәр хатын-кыз, пәри» мәгъ. дә йөргән. Ул үсемлеккә кельтлар изге дип табынганнар. К. МНМ II: 254.

**ҮКСЕЗ,** диал. (ДС III: 214) **өксёз** «(полный) сирота» > мар., удм. *өксыз* id. < гом. кыпч., к. башк. *үкһеҙ*, нуг., каз., к.-калп. *өксиз, өксёз [өксіз]*, кырг., к.-балк., төр. *өксүз* «үксез; анасыз» ← бор. төрки *ök, ög* «тәрбияләгән ана» – ихтимал *ök, ög* «акыл, уй» сүзе белән бердәй тамырдандыр, чаг. хак., шор. (Радлов I: 1190) *өксүс* «акылсыз». Кр.-тат. телендә *öklĭ* «ата-аналы». Чаг. **Үги.** ЭСТЯ I: 521.

**ҮКСЕ-Ү** «громко рыдать; всхлипывать» < гом. кыпч.: нуг., каз. *үкси-, үксĕ-*, кырг., алт. *өксө-* id., үзб. *өкси*, *окси-* «боегу; җәберсенү» бор. төрки *ög, ök* «уй, искә төшерү» сүзеннән булса кирәк. Э.В. Севортян (1960: 302) *үксе-* < *өксү-* нигезен бор. *ök, ög* «ана, әни» сүзеннән ди (**ögsü-* әнисен юксыну?). Ләкин *үксе-* h.б. тәкълиди сүздән дә ясала ала (*үксе-* < *үкес-* ~ *үкер-* ? h.б.).

**ҮКТӘМ** «гордый; хранящий своё достоинство» < гом. кыпч., уйг. h.б. *өктәм* < бор. төрки (ДТС: 379, 381) *ögdäm, ögtäm* id. ← *ög, ök* «акыл, фикер», *ög-* «мактау» (бу тамырлардан күп сүзләр ясалган). К. ш. ук төркм. *өкдөм* «батыр, куркусыз», к. ЭСТЯ I: 518–519 (тат. сүзе искә алынмый).

**ҮКТЕР-Ү** диал. (трбс.) «внушить, внушать, уговаривать, уговорить» ← иске тат. (Будагов I: 147) *үкмәк* «үтенү, димләү, үгетләү; ярдәмгә чакыру» < бор. төрки *ök-* «уйлау, уйлану» (к. **Үкен-ү**). К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 228) **үгеч < үкеч** «кайгы» – турыдан-туры *үк-ү* фигыленнән булса кирәк.

**ҮКЧӘ** «пята, пятка; задняя часть каблука» < гом. кыпч., госм., уйг., үзб. диал. *өкчә*, башк. *үксә*, кырг. *өкчө,* нуг., каз., к.-калп. *өкше,* төркм. *өкҗе* «үкчә; табан» ← урта төрки *өк, өг* ~ калм. *öög* < *ögeg* id. ш. ук «фундамент, аслык», үзб. диал., чыгт. *өк* «колонна, багана» (к. Радлов 1178–1187). Будагов I: 145; Мухамедова 1973: 138–139 (бор. телләрдә «эшерге, келә» мәгъ. булган ди); ЭСТЯ I: 520–521.

Дерив.: **үкчәле, үкчәсез, үкчәлек.**

**ҮЛӘБӘТ** миш. (ЗДС: 690) «хилый, нездоровый» > мар. (Вершинин 2011: 407) *öläмäт* id. Ихтимал, төрки-фар. *öläрмäнд* «үлемгә калдырылган» сүзеннәндер.

**ҮЛӘЙ** (Тумашева 1992: 228) «седая старуха» (аңлатмасы төгәл үк түгелдер шикелле, дөресрәге – «чал төшкән, төсе уңган – теләсә нинди чәч тур.») ~ алт. (Баскаков 1966: 142) *öлö* «ак таплы, аксыл чуар», тув. *öле* «аксыл, аксыл күгелҗем; чал, чаларган», каз. **өлег* «буз, агарган» (*өлегзы-* «бузару, сазару» фигыленең нигезе) – арытабан ачык түгел. Һәрхәлдә **үл-ү** белән бәйләнмаган.

Без бу сирәк очрый торган сүзне ул *үлү, үлем* белән бәйләнешле түгеллеген күрсәтү өчен алдык. Югыйсә **үләй** «чал карчык» диеп аңлатылгач, татарларда карчыкларга «үләсе зат» дип әйтәләр, дип аңлашылырга мөмкин.

**ҮЛӘКСӘ** «падаль; остатки» > чув. *үлексе*, мар. *öläксä*, удм. *öлексы* < гом. кыпч. *өләксә*, башк. (БТДҺ: 361) *үләкҫә, үләҫкә, үләкһә*, кырг. *өлөксө, өлүксе,* уйг. *өлүксә* id. ← *өл-* «үлү». Кайбер тикшеренүчеләр (к. Рамстедт 1957: 121; Цинциус 1969: 297–307) бу сүздә *-ксä* кушымчасын күрәләр. Ләкин бүтәнчә дә булырга мөмкин: безнеңчә, **үләксә** < *өлүксә* «үлек савыты» ягъни монда һәртөрле сыешлыкларны белдерүчән *-са//-сә* кушымчасы гына бар. Бор. төркиләрдә үлекләрне-мәетләрне табутка салып агачка асып куйганнар яисә зуррак елгага агызып җибәргәннәр (к. **Кабырчык**). Шундый табут яисә мәет куелган таскак **үләксә** < *өлүксә* дип аталган, соңрак, әлеге гадәт онытылгач, бу сүз мәеткә күчерелгән булса кирәк.

Дерив.: **үләксәлек** «үләксәләр илтеп куела торган чокыр»; себ. (Тумашева 1992: 228) **үләкцен** «кәнтәй» сүзе дә, ихтимал, **үләксәчен* сүзеннәндер.

**ҮЛӘН,** диал. (ДС I: 216) **үләм,** себ. (Дмитриева 1981: 170, 193) **өйлäң, үләң, үлөң** «трава; лист» < гом. кыпч. *өлән, өләң*, чыгт. *öläң*, кырг., алт., як. *öлөң* «үлән; сазламык үләне (аеруча)» < бор. төрки (ДТС: 383) *öläŋ* «чирәмлек» > тув. *өлең* «күрән», яз. монг. *öleŋ, ölen* «йомшак куе үләнлек» һ.б. чыгт., тув., бор. төрки *öl, ööl* > як. *үөл* «сусыллык, дым; дымлы» сүзеннән (Gabain 1950: 323). К. ш. ук төркм. диал. *һөлөң* «куе үләнлек» ← *һүл, һөл* «сусыл, дымлы». Чув. *ухлем, ухлӗм* «сарут, курмы үлән; чүп үлән; учак» сүзендә дә бор. *-һ-* саклана бугай; чув. *валем, валӗм* «бер кочак печән» үзенчәлекле рәвештә мәгънәсе тарайган вариант. чаг. ш. ук **Үл-су**. ЭСТЯ I: 527–528.

Дерив.: **үләнле, үләнсез; үләнлек; үләнсел** (дала, урын), **үләнчел** (хайван).

**ҮЛӘҢ, өләң** «эпическая песня» ~ уйг. *өләң*, каз., к.-калп. *өлең*, кырг. *өлөң* id., бор. чыгт. (З.-М. Бабур билгеләгәнчә, к. аның *Гаруз рисаләсе* – Трактат об арузе, 1972) *öläңгä* «туй җыры» ~ як. *өлөңгө* «эпос» (рус. *олонхо* дип бирелә) – безнеңчә, **өлеңге** (к.) сүзе белән бердәй (тәүдә «батырлар тур. гимн; үрнәк образ» мәгъ. булган).

**ҮЛӘТ** «мор; моровая язва» > удм. (Насибуллин: 13) *öлет* < гом. кыпч. *өләт, өләт*, кырг. *өлөт* < чыгт. *өлүт* id. *өл-* «үлү» сүзеннән бор. *-т* кушымчасы ярдәмендә ясалган (*өлүт* > *өләт* күчеше сингармоник чылбырлар үзгәреше белән аңлатыла), к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 383–384) *öläk* «үлек», *ölüt* «үтерү, үтереш; үләсе кеше».

**ҮЛДҮ** (Тумашева 1992: 220) «кылыч; сөңге» ~ алт. (Будагов I: 154) *ӱльдӱ* «кыска кылыч», чаг. ш. ук чув. *вӑлта*, төр. *olda* «ыргак; кармак». Арытабангысы ачык түгел.

**ҮЛ-СУ** «(лечебная) роса; святая вода» ~ чув. *вил-шыв* id. Бу сүздә *үл* чыгт. (Будагов I: 150) *үл, өл* «зур су, буа» белән бердәй булса кирәк, к. **Үлән.**

**ҮЛ-Ү** «умереть, умирать», диал. (ДС II: 256) «вянуть, блекнуть» < гом. төрки *өл-* < бор. төрки *öl-* < *ööl-* id., к. себ. (Дмитриева 1981: 170) **өйл-** ~

чув. *вил-* «сөмсезләнү; үлү» < болг. (эпитафияләрдә бар) *wил-* < **өйл-* < *өөл-*. ЭСТЯ I: 525–527; Федотов I: 122–123.

Дерив.: **үлеш-ү; үлеш; үле, үлек, үлем, үлемтек.** К. **Үләксә, Үләт, Үтер-ү.**

*Үл-* < *өл-* < *өөл-* нигезе ностратик тамырлар рәтеннән карала, к. венг. *öl-* «үтерү, сую», удм. *вий-* < **вил-*, манси. *ääl-*, хант. *wel-* «җәнлек, киек тоту», һинд.-евр. *ol-, ole-* «юк итү». Ләкин төрки *өөл-, өйл-* вариантлары ностратик фаразга хилаф шикелле. Ихтимал ки, бу тамыр сүз бор. **өө-, *өй-* «юк булу» фигыленең төш. юнәлешедер.

**ҮЛЧӘҮ [үлчәw]** «весы» – **үлчә-ү** фигыленнән исемләшкән.

**ҮЛЧӘ-Ү,** диал. **үлцә-ү** «измерять, взвешивать, замерять» ~ < гом. кыпч., уйг., төркм. *өлче-,* нуг., каз., к.-калп. *өлше-,* башк. *үлсә-,* кырг., алт. *өлчө-* ~ аз., госм., бор. чыгт. *өлч-* >> чув. *виç-* id. бор. **өл* «өлеш» тамырыннан, к. бор. кыпч. *ölüč, öläč* «үлчәм». ЭСТЯ I: 529–530; Федотов I: 125–126.

Дерив.: **үлчән-ү, үлчәш-ү, үлчәт-ү; үлчәм;** диал. **үлчәк.**

**ҮМӘ** (Будагов I: 158) «мошонка» ~ каз. *омә, ома* «күкәй» (рус. «шулята» диелгән). Чаг бор. төрки (ДТС: 384) *öт* «ыштан» >> чув. *йĕм* ~ монг. *өмдөн* id. ~ яз. монг. **emü-s* «кием». Федотов I: 195 (әдәбият китерелә). Тат. **үмә** < **үмәк* «ыштанчык» булса кирәк.

**ҮМӘЗ** (ТТДС I: 558) «налёт на зубах» ~ башк. (БТДҺ: 362) *үңәҙ* id. «авыз гөмбәчеге, үмәз, тел агы, тилчә», кырг., алт. *өңөр,* як. *өңүр, өңүс* «савытсаба яндавына ябышкан юеш касмак, лайла һ.б.ш.» ~ алт. диал. *өңөр,* монг. *өңгр, өңгүр* «эчке органнардагы лайла», к. ЭСТЯ I: 538 (М. Рясянен буенча, бу сүз монг. телләреннән; ләкин *-р-* вариантлар төбендә төрки сүзләр!). Э.В. Севортян татар сүзен искә алмаган.

**ҮНЕ, үн** (Будагов I: 799) «кәүсә; сабак» ~ алт. *өөн* id.

**ҮН-Ү** (Тумашева 1992: 229) «вырасти; прорастать; уродиться; размножаться» ~ башк. диал. *үнә-* (БТДҺ: 362, *үнәмә* «үсү» сүзендә), *үн-* < гом. кыпч., чыгт., уйг., тув. һ.б. *үн-* «үсү, уңу (иген тур.), яңа буын туып үсү», к. ЭСТЯ I: 530–532 (тат. сүзе искә алынмаган).

Тат., башк. телләрендә бу сүз *өн-* яңгырашында булырга тиеш иде, ләкин алай булмаган (ихтимал **өн** дигән бүтән омонимнардан качынылгандыр).

Дерив.: **үндер-ү** «уңыш алу, яңа буын үстерү»; күч. «файдага ирешү (мәс., сәүдәдә)». Тув. *үнүк* «яшь терлек, үрчем» сүзеннән чыгып, без рус. *внук, унук* (> тат. **онык**) «балаңның баласы» сүзен дә төрки телләрдән кергән булырга мөмкин дип карыйбыз (к. **Онык**).

**ҮҢ** (*юл үңе* сүзендә, ш. ук *Үнәре үңгә тарта, холкы түңгә тарта* мәкалендә) «передняя сторона, направление, перёд; то, что перед глазами» < гом. кыпч., чыгт., уйг., тув. һ.б. *өң* < бор. төрки (ДТС: 385–387) *öŋ* «үң; йөз төсе, йөзлек һ.б.», к. ЭСТЯ I: 532–536 (Э.В. Севортян монда ике аерым исем нигезен һәм бер *өң-* «алгарак бару, алга елышу» нигезен аерып карый). Уйг. (Радлов I: 1205) *өңү* «каршы як» *өң* сүзенең өченче зат тартым формасы булса кирәк. Бор. төрки яз. телләрдә *öŋ* һәм хәз. төр. телендә *ön, önk* бик продуктив нигез. Чаг. ш. ук **Ум, Уң, Үңгә, Үңер.**

Дерив.: (Тумашева 1992: 162, 229) **өңнү** «үзенчәлекле төстәге; аеруча яхшы», **үңки** «нәкъ үзе».

**ҮҢӘЧ**, диал. (ДС II: 253; ТТДС I: 558) **өмәч, үмәч,** себ. (Радлов I: 1204) **өңөц,** (Тумашева 1992: 165) **өңәч** «пищевод; передняя часть шеи» < гом. кыпч. *өңәч* (> башк. – БТДҺ: 362 – *үңәс, үмәс,* нуг., каз., к.-калп. *өңеш*), кырг. алт. *өңөч*, алт. *өөч, өч,* тув. *өөш* «үңәч», ш. ук «тын юлы»; күч. «торба, труба», як. *үөс* (Пекарский: 1953) *өңүс, үңүс* «йокы артериясе, шаһ тамыры» < уйг. *өңгәч*, иске тат. (Будагов I: 150) **үңгәч** ~ бор. төрки (ДТС: 387) *öŋüč* «үңәч» һ.б. *öŋ ~ öт* тамырыннан; *өңкәч* (кечерәйтүиркәләү формасы) сүзеннән, к. ЭСТЯ I: 536 (төр. диал. *ötük* < *öŋ-ük* «үңәч» мисалын китерә). Чаг. ш. ук **Үңер, Үңерәш.**

**ҮҢГӘ** (ТТДС I: 562; БТДҺ: 362), диал. (Будагов I: 149; Тумашева 1992: 229) **үңкә** «другой, иной» < гом. кыпч. *өңгә,* кырг. *өңгө,* төркм. *өңңө,* бор. төрки (ДТС: 387) *öŋi* һ.б. id., Э.В. Севортян буенча (ЭСТЯ I: 537–538), бор. *өң-* «үзгәрү» (?) фигыленнән, ләкин, безнеңчә, монда тамырның фигыль булуы мотлак түгел: **үңгә <** *өңгә* **башка**, **үзгә** сүзләре моделендә **үң <** *өң* «күз күремендәге төс, аерым төс» сүзеннән дә ясала ала. *Үң* < *өң* «бер як; юнәлеш, аерым юнәлеш» сүзе тур. к. ш. ук Цинциус 1984: 48 (*өң* < **pһöŋ* ~ кор. *pöŋ* дип аңлата, шунда *өңгә* сүзен дә китерә). К. **Үң.**

Дерив.: **үңгәлек; үңгәр-ү; үңгәчә, үңгәлинчә** (к. ТТДС II: 409).

**ҮҢЕН** (Мөхәммәдьяр һ.б. әдипләр телендә) «другой, иной» < уйг., бор. төрки (ДТС: 385–387) *öŋi, öŋin, öŋün* «үзгә, аерым» *öŋ* «аерым төс, буялыш» сүзенең аерым формалары булса кирәк, к. **Үңгә**. ЭСТЯ I: 534–535.

**ҮҢЕР** (Тумашева 1992: 229; БТДҺ: 362), **өңөр** (ТТДС II: 405) «передний разрез рубахи», **үңгер, үңер** (ТТДС I: 569; ТТДС II: 409), **үңүр, үңәр, үңгәр, өңгәр** (Троянский, ЛТ һ.б. иске сүзлекләрдә) «часть одежды между концами воротника спереди; нечто вроде бабочки артистов; щегольская завязка из цветных тёсем, шнурков; большая брошка под подбородком и т.п.» ~ каз. *үңѐр* «үңер (анатомик мәгъ.)», (ҠТДС: 264) *өнерше* «яка чылбыры, үңгер», кырг. *өңүр* «чигүле изү», к.-калп. *өңир* «изү, чигүле кайма» ~ тув. *өңгүр* «җете төстәге» (← *өң* «төс») үзб. (ЎХШЛ: 204) *өңнир* «чигүле итәк, чабу» ~ алт., шор. (Радлов I: 1313–1314) *ӧмӱр, ӧбӱр* «тун изүе» ← *үң* < *өң* «алгы як» (к. **Үң**). К. **Үңерәш**. ЭСТЯ I: 538–539 (төрле фаразлар китерелә). Башк. *иңер* id. бу тел өчен характерлы булган гайре тарихи дивиативлык нәтиҗәсе (**иң** сүзе тәэсирендә ясалган).

**ҮҢЕРӘШ, үңерәс, өңөрәш** (БТДҺ: 258, 362), ш. ук **үңереш** «трахея, бронхи» < **үңер эче** булса кирәк. К. ш. ук башк. *үңгәрсәк* «трахея». К. **Үңәч.**

**ҮҢ-Ү** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «изменяться в цвете, терять яркость цвета, поблекнуть» < бор. төрки (ДТС: 386) *öŋ-* id., монг. *өңгүй-лэ* «уңышлы булу». *Үң-* ~ *уң* (*өң-* ~ *оң-*) вариантлылыгы бор. яз. телләрдә үк күзәтелә. Тат. телендә *уң-у* («удаваться») сүзе белән омонимлыктан качарак, **үң-ү** сүзен активлаштырырга кирәк. К. **Уң-у II.**

Дерив.: **үңел-ү**; башк. (БТДҺ: 362) *үңкеү* «хәлсезлектән, картлыктан агарып беткән (карт-коры тур.)» – ихтимал, **үңек-ү* формасыннандыр.

**ҮПӘ,** (Будагов I: 107) **үбә** «белила для лица; пудра» < гом. кыпч. (каз., кырг.), чыгт. *опа,* алт., шор., ком. *оба,* бор. төрки (ДТС: 603) *ubu, opo* id. ~ яз. монг. *ou, ow, owa,* монг. *оо* ~ маньч. *уфа* id.; аны дөге онынна (Владимирцов 1929: 210), акбурдан (Радлов I: 1155, 157), кургаштан (МК) ясаганнар. Кытайчадан булса кирәк ди Дж. Клоусон (Clauson: 56).

**ҮПӘЧ** «смачный поцелуй» < диал. *үпекәч, үбүкәч* ← **үбү,** к. **Үп-ү**.

Дерив.: **үпәчлә-ү** «ашкынып үбү» (үбүче кешенең ихласлыгында шикләнүне белдерү төсмере белән әйтелә). Чаг. ш. ук диал. **үпәк-чүпәк** «һәртөрле үбешүләр».

**ҮПКӘ I** лёгкое (орган дыхания)» > чув. *упке* < гом. кыпч., чыгт., уйг., бор. төрки (ДТС: 387) *öpke* id., каз., к.-калп., хак. *өкпе,* алт. *ӧкпӧ* һ.б. id., ш. ук «кабырга» – ихтимал, бор. (төр.) *öк* «үпкә» тамырыннандыр, к. ЭСТЯ I: 541 (бу сүзнең бик күп вариантлы булуы күрсәтелә).

**ҮПКӘ II** «обиженность, ропот» > мар. *öпкы, öпкä,* чув. *упкев* < бор. төрки (ДТС: 388, 394) *öpkë, övke* id., әлбәттә, **үпкә I** сүзеннән – сүзлекчеләр бу сүзләрне берләштереп аңлаталар (к. Троянский I: 83; Радлов I: 1310 һ.б.), к. тат. **үпкә кабару** «үпкәләү». ЭСТЯ I: 540–541.

Дерив.: **үпкәлә-ү** (мар. *öпкäлä-,* удм. диал. – Насибуллин: 131 – *опкэлъны* id.), **үпкәләш-ү, үпкәләт-ү; үпкәләш, үпкәче**. К. ш. ук диал. **үпкә-сапка** «һәртөрле үпкәләшләр» > мар. *öпке-сапка* id.

**ҮПРӘ, үперә** (ТТДС II: 407) «комар; мошка» ~ чув. *упре, öпре* id. Федотов (II: 300) буенча, мар. *увра, ěвыра, вěра* «ләпәк, сукыр чебен» сүзеннән. Ләкин моңа охшаш сүзләр марилардан ерак төрки телләрдә дә очрый, к. төр. *ibre* «энә, без, чаккыч, чагучан бөҗәк» һ.б.ш. К. **Үәс.**

**ҮП-Ү (үпте, үбү)** «целовать» < гом. кыпч., уйг., госм. *öп-* id., бор. төрки (ДТС: 387, 393) *öp-, öv-* «убу, суыру, йоту» һ.б. нигезендә этимологлар *үбү* ~ *убу* (*öп-* ~ *оп-*) сүзләрен бердәй дип уйлыйлар, чаг. ш. ук себ. әкиятендә: *Ул егет бер күлнең суын аузына үбеп алады, икенце күлгә аппарып куяды* (Радлов, Образцы… VIII: 366). Гомумән *үп* < *öп, уп* < *оп* тәкълиди сүздән булса кирәк (к. **Уп-у**), чаг. **Чуп итү** һ.б. ЭСТЯ I: 539–540.

Дерив.: **үбел-ү, үбеш-ү, үптер-ү; үбеш;** диал. **үбек, үпәч.**

**ҮР** «возвышение, плоскогорье; высокое место» > мар. *öр* < гом. кыпч., гом. төрки *öр* ~ алт. *ӧрӧ,* шор. *урӓ,* чув. *вир* (к. Ашмарин V: 236–238) «үр; дала, өс», *вире* «үргә, тауга менеш»; кайбер телләрдә (к. ЭСТЯ I: 542–544) *öр, öрең* «тәхет» (!), *öрү* «ясалма калкулык, өем» һ.б. Бор. төрки (ДТС: 388) *örgi-* «төзү, кору», *örgin, örgün* «тантаналы корыл-

ма, тәхет» һ.б.ш. Э.В.Севортян *үр* < *өр* исем нигезен *өр-* «үрү, югарыга үсү» фигыле (к. **Үр-ү**) белән гомоген дип карый.

**Үр** продуктив нигез: **үрлә-ү, үрләт-ү, үрлек**. К. **Үрә, Үрә-ү I, II, Үрләч, Өркәч.**

**ҮРӘ** «стоя прямо» < гом. кыпч. (к.-балк. *ёре*), хак., алт., чыгт., уйг. *öрä,* кырг., алт., уйг., як. *өрө* id., ш. ук «югары», бор. чыгт. (Боровков 1963: 250) *өрү тур-* «үрә тору» һ.б. бор. *öр-* «үрләү» фигыле белән баглы. К. төр. *örü* «корылма, дивар; үрә, текә», бор. төрки (ДТС: 390) *örü* «югарыда». Чаг. **Үр.**

**ҮРӘН: үрән колагы** (Вәлиди I: 199), диал. (ТТДС II: 408) **үрән калагы** «вид круглой и большой ракушки». Чаг., башк. (БТДҺ: 24) *арамғолаҡ* «кабырчык; йөрәк колакчыгы», кырг. *өрөөн* «тәннең, кабырчыкның ярты ягы (сыңар капкачы)». Бор. төрки (МК) *örän* «һәрнәрсәнең яман пары, начар сыңары» ~ аз. (АДДЛ: 351) *өрән* «начар як». Гомумән, ачык түгел. Мухамедова 1973: 139.

**ҮРӘПЧЕ-Ү** (трбс.) «встать на дыбы (о лошади)» ~ башк. *үрәпсе-*, (БТДҺ: 363) *үрәкһе-, үрәпке-* id. ~ кырг. *өрөпкү-* «учащённо биться от возбуждения (о сердце)» диелгән – **үрә-ү I** (к.) белән гомоген, чаг. башк. *үрәк ~ үрәп ~ үрәт* «үрәпчүчән». Тат. **үрәпче-ү** «кинәт ярсып китү, карышып пыр тузу» мәгъ. киңрәк кулланыла. Каз. *өрекпу* «үпкәсе кабару, ярсуыннан сулышы кабыну», *өрепку* «ярсынып күтәрелү» – ш. ук күчерелмә мәгънәләрдә.

**ҮРӘ-Ү I** (БТДҺ: 363) «подниматься против течения (о ежегодных миграциях рыб)» ~ **үрлә-ү** id. (ТТДС II: 408, дөрес аңлатылмаган). Әлбәттә, **үр** (к.) тамырыннан.

**ҮРӘ-Ү II** (Тумашева 1992: 229) «звать кобылу (о жеребце)» < **үгрә-ү, үңрә-ү** id. (характерлы аваз салу) ← гом. төрки *öгүр* – атларның эндәшү, чакыру авазы, тәкълиди тамырдан.

**ҮРӘЧӘ** «отвод, грядки, нащипы саней и телег (обычно сплетённые из верёвок между двумя брусьями); нахлёстки» ~ башк. *үрәсә* id. > чув. *урече,* мар. *öрäчä,* удм. *ырача, орача, арача* «үрәчә; үрәчә кәртәлеге (борысы); чананың буй аратасы» < гом. кыпч. (ком. һ.б.) *öрече, öрүче* (> нуг., каз. *өреше*) id. «эре челтәр», кырг. *өрөчө ~ өрөҗө* «эре квадратлы бизәк төре, кирәгә киезе» ← тат. ***үрә*** (теркәлмәгән) < гом. кыпч. *öре, өрә,* кырг. *өрө, өрөө*, төр. *öre, örü, örgü*, бор. төрки (ДТС: 391) *örüg* «(баудан һ.б.) үрелгән (нәрсә), бау аркалык, үрелгән яндавыр һ.б. (бер-берсеннән троплар рәвешендә чыга торган күп мәгънәләрдә)», «катлаулы тышау» (шуннан башк. – к. БТДҺ: 363 – *үрәлә-ү* «тышаулау»), к. ш. ук төр. *örek* «бау кирәгә (тирмәнең вертикаль яндавырларын хасил иткән бау челтәр, вакытлы тирмәләргә куела, даими яндавыр-кирәгә исә таяклардан төзелә)», чув. *ĕревĕч* «үрәчә», диал. (Ашмарин IV: 19–20) *уретти* «күре кысасының аскы һәм өске горизонталь тупсаларының берсе», як. *өрөсө ~ өрөһө* «рәшәткә; күкрәк читлеге». Э. Пекарский (III: 1962) бу сүзне турыдан-туры тат. **үрәчә** сүзе белән чагыштыра. Китерелгән барча сүзләрнең тамыры, әлбәттә, *үр-* < *өр-* «үрү», к. ЭСТЯ I: 546. К. ш. ук Räsänen 1969: 374; Федотов II: 300–301 (материалы бик аз һәм этимологиясе сай).

**Үрәчә** сүзе, шулай итеп, күчмәчелектән утраклыкка күчкәндә мәгънәсе тарайган сүзләрнең берсе. Чаг. **Үреш I.**

Дерив.: **үрәчәле, үрәчәсез** (чана, арба тур.); **үрәчәлек; үрәчәлә-ү.**

**ҮРГЕ-Ү** (Радлов I: 1839; ДС III: 216) «успешно развиваться; умножаться; плодиться» ~ чыгт. (Будагов I: 123) *үрки-, үрги-* id., кырг. *өргү-* «ял итеп, көчәю, хәлләнү» – **Үр-ү II** (к.) белән баглы булса кирәк (ихтимал ки, *үрек-* < *өрүк-* «үрегү, үргү» – *үр-* < *өр-* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе).

Дерив.: **үргел-ү, үргет-ү** («юнәтү, булдыру» мәгъ. кулланыла); **үрген** (?), **үргенте,** башк. (БҺҺ II: 280) *үргенде* «курпы, үсентеләр; үрчем, артыш, табыш».

**ҮРДӘК** «утка» < гом. кыпч., төр. *ördäk*, хак., шор. *ортäк*, алт. *öртöк,* кырг. *өрдөк,* төркм. *өөрдәк*, бор. төрки *hördäk* «үрдәк», як. *үрдүкäн, өрдүкäн* «чүрәгәй» сүзен Г. Рамстедт (к. JSFOu 55, 1951: 93) бор. **öр-* ~ эвенк. *һур-,* маньч. *фура-* һ.б. (ССТМЯ II: 352) «чуму» сүзеннән ди. Ләкин башк. *өйрәк,* кырг. *үүрөк*, бор. кыпч. *äврäк,* тув. *өдүрек,* бор. төрки (ДТС: 377) *ödiräk* «үрдәк» бу фаразны шик астына куя. Хак. диал., тув. диал. *өдрäк* «үрдәк төре – сызгырак үрдәк», В. Радлов (I: 1284) фикеренчә, *өт-* «сайрау, сызгыру» сүзеннән. Бүтән төрле фаразлар тур. ЭСТЯ I: 547–548; Eren: 316–317.

Башк. диал. (БТДҺ: 256) *өйөрҙәк* һәм үзб. (ЎХШЛ: 24) *әвирдәк* яңгырашларына караганда, беренчел сүз *өгүрдäк* «кулга иyләштерелгән кош»

булырга тиеш, к. госм. (Zenker: 127) *ögür* «кулга ияләшкән; гадәти» < **öggür* «уйлаучан, күндәм». Хикмәт шунда: үрдәксыман кошлар бик тиз ияләшәләр (һәм тиз кыргыйлашалар). Чаг. (*-дәк* кушымчасы) **бизгәлдәк, кашкалдак.** Шул ук **өйердәк** һәм **әвердәк** яңгырашлары бор. гом. төрки *ӓгүр* «әверү, әйләнү» фигыленнән дә ясалган була ала: үрдәкләр (бигрәк тә кыр үрдәкләре) су төбенә житәр өчен баштүбән «әверелеп», артлары гына су өстендә күренгән хәлдә озак-озак торгалыйлар. Мондый үзенчәлекле кыланыш үрдәкләргә генә (яисә аеруча үрдәкләргә) хас бугай.

Себер халыкларында (шул исәптән кайбер төркиләрдә дә), билгеле булган этнологик легенда буенча, тәүдә дөньяда тик тоташ океан-су һәм һавакүк кенә булган, ди. Шуннан Тәңре үрдәкне яралткан. Үрдәк су өстендә йөзеп йөргән дә, күкәй салырга урын булмагач, су төбенә кадәр чумгалап, томшыгы белән балчык өеп бер түмгәк ясаган, шунда күкәй салган. Барча континентларны һәм утрауларны шул үрдәк-демиург ясаган һәм жирдәге хәятны үрдәк барлыкка китергән булып чыга. К. ш. ук **Энжеле үрдәк.**

Көнб. Себер татарлары аучылык белән күп шөгыльләнгәч кыр үрдәкләренең егермеләп төрен аералар, мәс., **аккацы, икәүборын, кашкалдак, күгәл, кылгойрык (кылкойрык), майган, царәгәй (чүрәгәй), цыплай, цыплак, цупыртык, чомга ~ чумга, чумгалак ~ чумгыл, зәңгәрбаш, яшелбаш** һ.б. **Үртәклә-ү** «кыр үрдәген ауларга йөрү» дигән махсус фигыль, **үртәкцел** «үрдәк аулаучан» дигән исем-сыйфат бар.

Үрдәк-демиург тур. к. Давлетшин (1992: 217–219); МНМ II: 681.

**ҮРЕЛ-Ү** «сягать, тянуться, чтобы схватить; вытянуться, чтобы увидеть» ← **ур-** (к. **Үр-ү II**) фигыленең төш. юнәлешеннән (**үрел-ү** «ишелү» белән бутамаска!).

**ҮРЕШ I** (ДС I: 257) «разводы саней» – асылда «үрәчә». К. **Үрәчә.**

**ҮРЕШ II** (БТДҺ: 363), диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **өрөш** «ближнее пастбище, куда гоняют скот вечером после дойки; сильно пересечённая местность (встречается и как название ряда населенных пунктов)» < гом. кыпч. *өрүш,* нуг., каз., к.-калп. *öрис,* к.-балк. *ёрю, ёрюм* «авыл якындагы утлак, көтүлек», төр. диал. (YTS: 169) *örü, öri, ürü,* аз. (АДДЛ: 350–351) *өрән, өрәнә* «көтүлек болын», бор. төрки (ДТС: 391) *örüš* «күтәрелеш, битләү», *ör-* «күтәрелү» (к. **Үр, Үрә**) сүзеннән булса кирәк. К. тат. диал. (ЗДС: 694) **үр-ү** «таралып утлау (битләүгә таралу)». Хәз. каз. *өріс* киң мәгънәле: «көтүлек, үреш; электрик кыр; күзкүреш, караш киңлеге; туган-тумача, нәсел-ыру» һ.б.

**ҮРКӘН** (ТТДС I: 559) «плеть, длинный стебель таких растений как тыква, дыня, огурец и т.п.» < гом. кыпч.: кар., кр.-тат. *öркӓн,* нуг., каз. диал. *өркөн* id., каз. *өркен,* төркм. *үркен, öркэн* «пәрәвез, озын бау», хак. (Бутанаев 1990: 96) *öрген* «атларны кырда кышлату өчен ныклы казыкка бәйләнгән озын бау» (чаг. чув. *үркен* < тат. теленнән – «20 м ара үлчәме»): ат казык тирәсендәге үләнне ашап бетергәч аны икенче «үркәнгә» күчергәннәр; кырг. *öркөн, öркен* «өлеш; бәхет»; төр. *örük, örk* «тышау», *örken, örgen, örkün, örgün* «аркан; дилбегә», тув. *öрген* «казык», як. *öргөн* «озын каеш; радиус, туры сызык», *öргүүр* «ат бәйләгеч казык» һ.б., күрәсең, бик бор. термин (бор. төркиләр атларын кырда кышлатканнар). Федотов I: 117 (**үркән** сүзен төр. *урган* «аркан» белән чагыштыра).

И.Г. Добродомов (к. СТ № 6, 1976: 12) чув. *вĕрен* (> мар. *вӗрӓн*) «аркан, озын бау; 10 сажин киңлеге, 80 сажин озынлыгы жир үлчәме» сүзеннән һ.б. чыгып, рус. *верига* «аскет диндарлар тагып йөри торган авыр чылбыр, гомумән – гомер буе күтәреп йөрткән авыр йөгең» сүзен дә болг. **вериг* < *örig* сүзеннән ди. Каз. диал. *өргөн, өркөн* «нәсел-нәсәп» күч. мәгъ. булса кирәк.

Бор. төрки (ДТС: 388) *örgen örüldi* «бау ишелде, үрелде» сүзеннән шәйләнгәнчә, *үркән* < *örken* **үр-ү** < *ör-* фигыленнән ясалган, ләкин монда хәл ителәсе сораулар бар: ни өчен кыпчакча *-к-?*

**ҮРЛӘТ-Ү** диал. «дуть на огонь (чтобы разжечь); заводить автомашину», к. **үрлә-ү** (к. **Үр**) сүзенең йөкл. юнәлешеннән булса кирәк.

**ҮРЛӘЧ** «холмистый» ~ башк. *үрләс* id., башк. диал. (БТДҺ: 363) *үрҙәш, үрләш* «подъём в гору (по дороге)» ← **үр** (к.), ясалыш моделенә аналогия: *кырлач, итләч, майлач.*

**ҮРМӘ** (ТТДС I: 560; БТДҺ: 363) «плеть, плетёнка; всё то, что изготовляется плетением; плетёный, вьющийся вверх (о растениях)» ~ гом. кыпч., угыз. һ.б. *öрмӓ,* кырг., алт. *öрмö* id. ← *үр-* < *öр-* «үрү, иш-ү» (к. **Үр-ү**). К. **Үрмәк, Үрмәлә-ү.**

Дерив.: **үрмәле.**

**ҮРМӘК** (Тумашева 1992: 230; БТДҺ: 363) «циновка; дорожка-палас; плетёнка» < гом. кыпч. *өрмәк*, үзб. (ЎХШЛ: 205) *öрмак* id., ш. ук «туку станы». К. **Әрмәк, Үрмә, Үрмәкүч.**

**ҮРМӘКҮЧ,** диал. (ЗДС: 87, 693) **әрмәнүч, үрмәкәч, үрмәкчә, үрмәнче, үрмәкчен; үрмәчәк** «паук» ~ башк. (БТДҺ: 363) *үрмәкес, үрмәксен, үрмәксәү, үрмәксе*, каз., к.-калп. *өрмекши*, нуг. *өрмекшин*, кырг. *өрмөкчү*, бор. чыгт. (Поппе 1938: 405) *örtükci* «үрмәкүч» ← гом. төрки *өрмәк, өрмүк*, бор. төрки (ДТС: 391) *örüt* «үрелгән тукыма; пәрәвез» ~ каз. *өрмек* «вертикаль туку станы» сүзеннән. К. ш. ук диал. (ДС I: 258) **үрмәкчә, үрмәчә** «пәрәвез», тув. *ээримчүк* «үрмәкүч», төр., аз. (Будагов I: 127) *өрмәчәк* id. һ.б.

**Үрмәкүч** сүзенең сингармоник чылбыры (*ү – ә – ү*) татарча түгел: бу вариант соңрак балалар телендә пәйда булган: *-күч* бөҗәк атамаларында очрый торган элемент, к. диал. **күчмәкүч** «камка таракан» һ.б. Гомумән, **үрмәкүч** сүзе төрки телләрдә бик вариантлы: кр.-тат., кар., госм. *өрүмҗәк,* бор. төрки (ДТС: 391) *örümčäk,* уйг. *өргәмчи*, бор. чыгт. *өрүмҗик,* хак. (Радлов I: 1226, 1228, 1243) *өрүнмәҗәк,* уйг. диал. *өргәмчи,* хак. *ирěмҗěк,* үзб. диал. *өргәмчěк* – күренгәнчә, гом. төрки *өр-* «үрү, туку, ишү» фигыленә нисбәтләнгән сүзләр. себ. (Тумашева 1992: 85, 89) **йөрмәүеч – йөрү**дән. К. ш. ук **Юрьгәмеш**.

**ҮРМӘЛӘ-Ү,** (ЗДС: 693) **үрмәкәйлә-ү** «карабкаться» ~ каз. *өрмеле-*, кырг. *өрмөлө-*, чыгт. (Радлов I: 1242) *өрмөлä-* id. бор. *өрмä* «бау баскыч, кыяга менү өчен ныклы челтәр» (к. **Үрмә**) сүзеннән булса кирәк. Ләкин к. диал. (Ф. Кәрим I: 165) **үрмә-ү** «үрмәләү» ← *үр-ү* < *өр-* «үрләү» сүзенең ешайтулы формасы. Гомумән, төрки телләрдә *өр-* «үрү, ишү» һәм *өр-* «үрләү, үргә менү» сүзләренең дериватлары контаминацияләнүчән.

Дерив.: **үрмәләш-ү; үрмәләт-ү; үрмәләч** (кошчык атамасы), **үрмәләгеч.**

**ҮРНӘК,** диал. **үрник** «пример, образец; узор, шаблон узора» ~ башк. (БТДҺ: 363) *үрәнәк* < төр., угыз. *өрнәк*, *йүрнәк*, кырг. *өрнөк* id. Будагов (I: 127) заманыннан бирле әрм. *orinak* < пәһл. *örenk* id. сүзеннән дигән фикер йөри, к. Haydar Ediskun 1968: 186–192; анык ук Sayın Emin Bayraktaroğluna açık mektüp // Dil yazıları, Ankara, 1974: 76–78; ЭСТЯ I: 549–550. Ләкин М. Рясянен (Räsänen 1969: 375) бу версияне кабатламый. Безнеңчә дә, **үрнәк** төп төрки сүз, к. башк. (БТДҺ: 363) *үрнәк* «бизәк; әвернә (!)» < **әwернәк*; к. ш. ук ком. *өрнек* «курпы, үсенте; ябае (коелган игеннән шытым)» ← *өр-* «үрү, шытып чыгу» (к. **Үр-ү).** Этимоны **өргүннәк* «үсентеләрнең берсе» яисә «күп бөҗраларның («вензельләрнең») берсен (-*нәк* күпләп булучан нәрсәләрнең берсен белдерүчән кушымча) була ала.

**Үрнәк < өрнәк** күрше телләргә дә алынган. Гар. *урник* «үрнәк» кыпч. әд. теленнән.

**ҮРСӘЛӘН-Ү** «метаться в сильном раздражении» ~ башк. *үрһәлән-*, каз. *өршелен-* < **өрчелен-* id. *үрт* < *өрт* «үлән яну; янгын» сүзеннән булса кирәк, к. ком. *өрчүк-*, *өрчү-* «үрсәләнү (кычудан, авыртудан); ялкынлану». К. **Үрт.**

**Үрсәлән-,** күрәсең, я миш. *урцәлән-*, я башк. *урсәлән-* id. вариантыннан. **Үрчәлән-* < *өрчәлән* исә ← **өрт-чү-* (-*чү*//-*чи* > *чě* ешайткыч фигыль кушымчасы). Башк. әд. *үрһәлән-* тат. теленнән «тәрҗемә» (югыйсә **үрсәлән-ү < үрчәлән-ү** нәкъ менә «башкорт сүзе»). **Үрсәлән-ү**не икенче тарафтан да аңлатып була; добр. тат. *örselemek* «тәртипсез кылану», *örsenlemek* «үрсәләнү» ← *örsen* «талашлы», төр. (Будагов I: 124) *үрсäлмäк* (безнең транскрипция, Л. Будаговта гарәп хәрефләре белән язылган) «тузан чыгару, тузан кагу» (моны төрлечә аңларга мөмкин) ← **үрсä-* ? К. төр. *ärs* «сандал; тимерче учагы?»

**ҮРТ** «пожар», иск. «поджигание, выжигание перезимовавшей травы весной (для лучшего роста молодой травы)» < гом. төрки, бор. төрки *ört* id., (Zenker I: 116) *ort* «куз, тере күмер» ← **өрүт,* **орут,* к. төр., монг. *өр-* «яну», төр. диал. *ор* «ялкын» (ЭСТЯ I: 550–551). К. **Үртән, Үртә-ү, Үрсәлән-ү.**

**ҮРТӘКӘ** иск. («Зыятүләк белән Сусылу») «идол в виде горного козла» ~ кырг. *өртеке* id., сүзмәсүз «үр тәкәсе». Кыргыз аучылары ауга чыкканда тәкәсыман курчак алганнар: «*үртәкәсен салып куенына, мылтыгын асып муенына*» диеләә. **Тәкә** кыяфәтендәге тәңреләр тур. к. **Кучкар.**

**ҮРТӘН** (Бәетләр 1960: 62, башк.) «горелое место в лесу, на лугу и т.п.» < гом. кыпч.: к.-балк., нуг. *өртен* «үрт; үткән елгы үләнне яндыру», ком. *өртен, ортäн,* каз., к.-калп., алт., тув. *өртең [өртәң]* «янгын, пожар; янык» ← *өрт*, к. **Үрт.**

**ҮРТӘ-Ү** «дразнить; специально раздражать кого», диал., башк. «сжечь дотла» < гом. кыпч., чыгт.

һ.б. *өртэ-,* уйг. *өртә-,* кырг., алт. *өртө-* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 389) *örtä-* «үртәү, үчекләү; чүп яндыру» ~ монг. *өрдэ-* «яндырып җибәрү» (төрки теллэрдән) ← *өрт-* (к. **Үрт**). Һәр төрки телдә бар.

Дерив.: **үртәл-ү, үртән-ү, үртәш-ү; үртәгеч, үртәвеч.**

**ҮР-Ү I** «плести (сетку, лапти, плетень), ткать (вручную, без приспособлений циновку, дорожку и т.п.)» < гом. төрки *өр-* < *өөр-* id. мәгънәсенә күрә бик тә бор., неолит заманнарыннан калган, шуны исәпкә алганда тат. диал. **җүр-ү** < бор. төрки *йөр-* «күп япь белән ишү» сүзе белән гомоген булырга тиеш, чаг. диал. **үрмә-ү, йүрмә-ү, җүрмә-ү** «аннан-моннан типчү; берничә япьтән ишү» – **ур-у, йүр-ү** сүзенең интенсивлык формасыннан (к. **Җүрмә**). Бор. һәм төр. (ДТС: 388–389; Stenerwald) *är-* бик продуктив тамыр.

**Үр- I** тат. телендә дә продуктив нигез: **үрел-ү** (*үрелгән каеш*), **үреш-ү, үрдер-ү; үрем, үреш,** диал. **үрге, үргеч** (к. **Чәчүргеч**). К. **Үрәчә, Үрмә, Үрмәк, Үрмәкүч, Үрмәлә-ү,** чаг. **Үрнәк.**

**ҮР-Ү II** «подрастать (во множестве), подниматься вверх (о ростках)» < гом. кыпч., бор. төрки (ДТС: 388) *ör-* «үрү; күтәрелү», каз. диал. (ҚТДС: 266) *өр-* «йокыдан тору» – мөгаен *өр* «калкулык, текәлек» (к. **Үр**) сүзенең фигыль коррелянтыдыр (к. ЭСТЯ I: 542–544), к. тат. диал. (ДС I: 258) **үр-,** каз., кырг., төр. диал. *ör-* «көтүлеккә чыгып таралу (терлекләр тур.)» – бор. төрки көтүлекләр үрләрдә, тауларда булган. Чаг. **Үреш II.**

Шулай ук бу сүзнең (һәрхәлдә «үсеп чыгу» мәгънәсендәге **үр**үнең) бор. монг. яисә тунг.-маньч. телләреннән алынма булу ихтималы да юк түгел, к. госм. (Радлов I: 1827) *үрä-* «күпләп үсү», хәз. монг. *ур*, бур. *урэ* < яз. монг. *üre* < *hüre* «орлык; ашлык», тунг. *урил* < *һурил* < *фурил* < *пурил* «орлык; бала» (к. ССТМЯ II: 357).

Дерив.: **үрдер-ү** (махсус рәвештә, мәс., иртәрәк үстерү өчен); **үрген, үренте** (бу сүзләр **үрге-ү** фигыленнән дә ясала алалар). К. **Үрә, Үрге-ү, Үрел-ү, Үрче-ү**. Чаг. ш. ук **Үрә-ү I, Үрмәлә-ү.**

**ҮРЧЕ-Ү** «размножаться; плодиться, расплодиться» ~ башк. *үрсӗ-* id. < кырг. диал., уйг., чыгт. *өрчи-,* нуг. *өрши-,* каз., к.-калп. *өршӗ-,* кырг., к.-балк. ком. *өрчү-* > каз. диал. *өршү-* ~ чув. *ӳрче [үрчэ-], ӗрче [ерчэ-]* id. Мар. *öрч-, öрчы-, öрчä-,* удм. *öрсё-* «үрчү, таралу» (тат. теленнән дә, чув. теленнән дә).

Бу сүзнең беркадәр гайре табигый вариантлылыгы монда төрле сүзләр контаминациясеннән түгелме икән, дигән фикер тудыра. К. аз. (АДДЛ: 400) *үрә-мәк, үрүшмәк*, төр. *üretek* «үрчү».

**Үрчӗ-** < *өрчи-, өрчү-* гомумән *өр-* «үрү II» фигыленең интенсивлык формасы, к. башк. *үрү-* «үрчү»; ләкин тат. диал. (ТТДС I: 560) **үрчет-** «үртәү», ком. *өрчү-* «чир кискенләшү; ярсыну», каз. (Радлов I: 1241) *өршү-* «ярсынып сөйләү» сүзләрен *үрчә-* < *үртә-* һ.б. (к. **Үртә-ү**) сүзләреннән дә чыгарып була.

Монг. *үржи-* «үрчү» төрки телләрдән булса кирәк. Будагов I: 123; Егоров 1964: 66; Räsänen 1969: 374 (**үрче-ү**не *үр* < *өр* «үр, калкулык» сүзеннән чыгара); ЭСТЯ I: 552.

Дерив.: **үрчеш-ү, үрчет-ү; үрчем** (һәм икенчел дериватлар).

**ҮРШӘН** (Гиганов; Будагов I: 124) «ласка, ластвица; хорёк», **үрцән, үрчән, йүрүшә, йүршән** (ЗДС: 260, 694) ~ чув. *үрçе*, хак. *урсен*, себ. (Радлов I: 1842) **үртäн** «ак ләтчә». Ачык түгел.

**ҮСЕРГӘН** – название одного из башкирских племён (земли их располагались на юго-востоке исторической Башкирии), диалект которых близок к татарскому языку ~ башк. *үçергән, үçәргән* id. < (безнеңчә) нуг. *үйсүңнәр, үйсиннәр*, каз. *үйсүңдәр*, к.-калп. *үйшүңңәр* кабиләсе атамасыннан (метатеза). *Үйсүңнәр* сүзе үзе танылган кыпч. *үйсүң, усүң* кавеме атамасыннан (күплек). З. Вәлиди буенча (Velidi: 408, 424, 433), **үсүннәр** – төркиләшкән тухриләр (тохарлар), германнарга якын һинд-европалылар. Алар б.э.к. V–IV гг. аксыл чәчле, зәңгәр күзле булганнар һәм Балхаш күленең көньяк-көнч. тарафларында яшәгәннәр (к. Гумилёв 2004: 259); гомумән, *үйсүң* сүзе – кытайча атама (к. Фасмер IV: 173). К. **Уйсын.**

**Үйсүннәр** б.э. беренче меңьеллыгында тәмам төркиләшеп беткәннәр һәм XII–XVI гг. бөтен монгол-татар биләмәләренә таратылганнар. Аларның төп токымнары казаклар дип исәпләнә. Соңгы үйсүннәрнең иң зур ыругы **җалаер**лар күп төрки халыклар, шул хисаптан себер татарлары составына да кергән (шулардан Касыйм татарлары арасында яшәгән атаклы тарихчы Кадыйр Галибик чыккан). *Җалайыр* сүзе хәз. Башкортстанның көньяк-көнбатышындагы **Зилаер** елгасы (һәм районы) атамасында (башк. **Йылайыр**) чагыла. Бу **җалаер** сүзе асылда монгол этнонимнарының берсе һәм, күрәсең, җалаерлар асылда төркиләшкән монголлардан

киләләр. К. ш. ук Султанов: 168–169; Исхаков, Измайлов 2007: 157–158.

**Үсергән** һәм **җалаер** сүзләренең тарихында этник тарихның да никадәр катлаулы булганлыгы шәйләнә.

**Үйсүң** этнонимы хәз. Башкортстанның көнбатышындагы **Сөн** һәм **Өсән** гидронимнарында да чагылыш таба бугай.

**ҮСМЕР** «подросток; подростковый» < уйг. *өсмүр* id.; көнч. кыпч. телләрендә нишләптер *-п-* килеп чыга: нуг. *өспүр, өспир*, кырг. *өспүрүм*, каз. *өспірім*, к.-калп. *өспирим* «яшь буын».

**Үсмер,** күрәсең, *басмыр, кысмыр, төсмер, түзмер* кебек сүзләр моделендә *үс-* < *өс-* фигыленнән ясалган.

**ҮС-Ү,** себ. (Дмитриева 1971: 170) **өйс-ү** «расти, вырастать; умножаться» < гом. төрки, монг. *öс-,* башк. *үҫ-,* хак. диал. *ööс-* id. ~ яз. монг. *ösü-,* тунг. *исэв-,* маньч. *фусэ-* «үсү» (мәгъ. структурасы үзгәрешсез килә); чув. *ус- (ӳс-)* < тат. булса кирәк. ЭСТЯ I: 552–553; Федотов II: 301–302.

Дерив.: **үсен-ү, үсеш-ү, үстер-ү** (һәркайсы аерым үзенчәлекле мәгънәләргә ия); **үсем, үсемлек; үсенте** h.б. К. **Үсмер.**

**ҮТ** «желчь» ~ чув. *вӑт* < гом. төрки *öт* id., бор. төрки (МК I: 35) *öt* «ачылык, үт», хак. *үт* «үт, үт куыгы», як. *үөс* id.

Дерив.: **үтле, үтсез; үтлә-ү** (күп ашаудан ашказаны эшләми башлау).

**ҮТӘ** «чрезмерно, очень», **үтә, үтәли** «насквозь», **үтәдән-үтә(гә)** «насквозь до конца» – бу сүзләрнең беренчесе гом. кыпч. характерда һәм *өт-* **үт-ү** (к.) фигыленең хәл фигыль формасыннан лексикалашкан, калганнары тат.-башк. сөйләшләрендә формалашканнар (к. Махмутова: 225). К. ш. ук иске тат. (ЛТ I: 48) *үтә* < төр., бор. төрки *öte* «теге якта», төр. *öteki* «теге яктагы».

**ҮТӘГӘН I** (ДС II: 256) «крохаль; утка-свистунка» < бор. төрки **öteken* «җырлаучан» ← бор. төрки, угыз. *öt* «җырлау, көйләү»; чаг. чув. *автан* < болг. **әwтән* > мар. *äптäн* «әтәч», чув. *авӑт-* «чакыру, кикрикүкләү». Чаг. ш. ук төр. *ötleğen* «(җырлаучы) черки». К. Федотов I: 28.

**ҮТӘГӘН II** – часто встречающееся собственное имя (имя человека, топоним) < бор. төрки (ДТС: 393) *ötükän* (*ötüken jer, ïduq, ötükän jïš*) «изге, бик билгеле бер урын», соңыннан билгеләнгәнчә, Хангай тауларында бер өлкә – төркиләрнең ана ватаны булып та исәпләнгән (*ötü kän* «иске, бор. Кангый» сүзеннән, *Кангый* < *Хангай* исә әкияти мәгъ., к. **Каңгый**), якутларда *Этүгэн*, *Үтүгэн Хаан* «урман иясе, аю рухы», «тәмуг» (Нюргун Боотур... 1975: 42); кырг. *өтөгөн* «аю». Бу сүз монголларга төрки телләрдән кергән булса кирәк – соңгы гасырларда монг. *Этүген эхе* «Үтәгән ана» – җир яки ут анасы; ул еш кына *алтан делхий* «алтын җир; алтын өлкә» сүзе белән алмаштырыла; бур. *идуган, итуган, удаган, утаган* «хатын шаман, имче карчык, әпче карчык», бор. Европа сәяхәтчеләреннән монголларда П. Карпини *итога*, Джон Мандевилль *Натигай*, Марко Поло *Начигай* дигән рухны искә алалар һәм бу сүзләр **Этүгән ~ Үтәгән** белән тәңгәлләштерелә. ДСЯЯ: 272; Банзаров 1955: 266–269; Czegledy: 55–69; Жуковская: 24–36; МНМ II: 674 (сүзнең чыгышы күрсәтелми); Velidi: 108–110.

**ҮТӘ-Ү** «исполнять долг» < гом. кыпч., гом. төрки *өтә-, өтү-, өдү-, өөдү-* «үтәү, бурыч түләү, ышанычны аклау»; (Радлов I: 1264) «дога кылу» (к. ш. ук Ә. Ясәвидә *Дәрвишләрнең холкы мордар: үтәмәс дога*), тув. *үдэ-* «кушылып җырлау» h.б. **үтә-ү** сүзен бор. төрки *öt-, öte-* «җырлау, көйләп (мәҗүси) дога кылу» сүзе белән бәйләргә нигез тудыра. Ләкин Малов (1954, сүзлекчә) *ötä-* «дога кылу, җырлау» һәм *үтä-* «үтәү» сүзләрен аерып бирә. ЭСТЯ I: 505–506 (Э.В. Севортян **үтә-ү** сүзе белән **үтен-ү** сүзен баглап карый, ләкин бик ышандырырлык түгел). К. **Үтләш-ү.**

Дерив.: **үтәл-ү → үтәлеш; үтәш-ү, үтәт-ү;** диал. (ДС I: 259) **үтәүче** «чират буенча йомышка йөрүче»; **үтәк** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «үтәлергә тиешле бурыч», чаг. төр. *ödek* «штраф»; чаг. **Үтәмеш, Үтәш** – элекке кеше исемнәре (ихтимал, нииндидер иҗтимагый титулларны белдергәндер).

**ҮТЕМЛЕ** «ходкий (о товаре); авторитетный, веский (о слове)» > чув. *витӗмлӗ* id. < гом. кыпч. *өтимли, өтүмлү*, каз., к.-калп. *өтимди*, кырг. *өтүмдүү* ~ уйг. *өтүмлиг* h.б. id. ← **үтем** < бор. төрки *өтүм* «үтем, үтү күренеше» (бу сүз тат. телендә сирәк кулланыла). **Үтемсез** сүзе дә гом. кыпч. һәм гом. уйг. характерга ия. Федотов I: 128. К. **Үт-ү.**

**ҮТЕН-Ү** «обращаться с просьбой, просить о чём-либо» < гом. кыпч. *өтӗн-, өтин-, өтүн-,* кар. *отэн-*, уйг. *өтән-* h.б. < бор. төрки (ДТС: 393)

*ötün-* id., КБтә – «хисле итеп сөйләү» ← бор. **öт-, *öтa-* (?) «тәфсилләп сөйләү, аңлату», к. бор. төрки (ДТС: 391) *öt* «киңәш; үгет» (фигыльнең исем коррелянты). Ихтимал ки, бу сүз бор. төрки (ДТС: 186, 391) *öt-, et-* «җырлау, сайрау; хисләнеп сөйләү» белән бердәйдер – төрки телләрдә «җырлау – өндәү – чакыру» мәгъ. күчешләре бар (чаг. *әтәч* **чакыру**, к. ш. ук **җыр ~ җар**), к. (бор. тат. сөйләшләреннән) удм. *öтьыны (öт-)* «чакыру, дәшү» (дериватлары шактый күп). Чув. *витĕн-* «үтенү» (> мар. *витн-, витĕн-*) болг. теленнән. К. ш. ук төр. *öd* «кагыйдә; иҗтимагый йола» < *öt* → *öde-* «үтәү». **Үтен-ү** һәм к. **үтә-ү,** шулай итеп, гомоген булуы ихтимал. Төрки *öт-* монг. *öч-* «аңлату; үтенү» сүзе белән чагыштырыла, монг. яңгырашы я *-т-* > *-ч-* күчеше нәтиҗәсе, я *öтчи-* (*-чи* фигыль нигезләрен киңәйткеч морфема, к. *кыр-у* → *кырчы-у, үр-ү* → *үрче-ү* һ.б.) формасыннан килә, к. удм. (< бор. төрки?) *отчаны (отча-)* «чакыру, өндәү, җыю». К. **Үтләш-ү.** ЭСТЯ I: 557–558; Федотов I: 127.

Дерив.: **үтенел-ү, үтенеш-ү; үтендер-ү; үтенеч,** к. **Үтеч, Үтрек.**

**ҮТЕР-Ү** «убить» < иске тат., башк. *үлтер-еү,* себ. **үлтүр-ү** id. – **үл-ү** (к.) фигыленең йөкл. юнәлешеннән *-л-* редукцияләнеп килеп чыккан (чаг. **китер-ү < килтер-ү, күтәр-ү < күлтәр-ү, утыр-у < утлыр-у**); *öтир-* кайбер кыпч. телләрендә дә очрый; уйг. *öтүр* id., чув. *вĕлер-* ~ як. *öлöр-* «үтерү», күрәсең, бор. бер формадан. К. **Үл-ү.**

Дерив.: **үтерел-ү, үтереш-ү, үтерт-ү; үтереш; үтергеч.**

**ҮТЕЧ,** миш. **үтец** «заем, долг» (**үтечкә** «в должок», обычно о долгах незначительных, обыденных), «прокат» < гом. кыпч., к. башк. *үтес*, куман. *öтүнц*, чыгт., бор. төрки (ДТС: 393) *ötünč* «үтеч; үтенеч», төр. *ödünç* һ.б. (к. Радлов I: 860, 1266–1267) беренче карашка **үтеч < үтенеч** кебек, ләкин чыгт. (Поппе 1938: 103) *öntüč,* кар. *öткюнч*, бор. төрки (ДТС: 392–393) *ötinč, ötkünč, öütkünč* «үтеч»: монда *künč* «бәя; бәяләү» (сугд сүзе түгелме икән?) Ягъни *үтеч* < бор. төрки (ДТС: 393) *ötüg* «үтенеч» + *künč* «бәяле нәрсә» булып чыга. Чаг. **Үтә-ү.** ЭСТЯ I: 505–506. Мухамедова 1973: 141 (төркм., төр. телләреннән мисаллар китерә).

**ҮТИ (үти-үти)** – междометие подзывания уток, ш. ук «утёнок» – рус сөйләшләреннән булса кирәк, к. чув. *ут-кăвакал* «үрдәк-каз». Рус. *ут-* тамыры һинд.-евр. телләренә уртак **hanәt* нигезеннән, к. ним. *Ente,* бор. һинд. *äti* һ.б. «үрдәк», к. Kluge: 246.

**ҮТКЕЛ** «проход, перевал», (Гиганов) «брод» ~ каз., кырг. *өткәл, öткел,* чыгт. (Будагов I: 111) *öткäл, откүл* id., ш. ук «кичү» *үт-* < *öт-* «үтү» фигыленнән төрлечә ясала ала. Күп гасырлар дәвамында туктаусыз диярлек тау-чагыллар кичеп яшәгән төрки халыкларда мәзкүр мәгъ. бүтән сүзләр дә бардыр. Башк. *үткеүел* «хәтәр үткелдә дежур торган кулавыз» монг. телләреннән шикелле.

**ҮТЛӘШ-Ү** диал. (к. Радлов I: 1867) «ссориться, судиться, обращаться к людям за разбором» ~ бор. төрки (Clauson: 59) *ütleš-, üdleš-* id. *üt, üd* «закон, кагыйдә» сүзеннән. К. ш. ук **Үтә-ү.**

**ҮТРЕК, үтерек** (к. ТТДС: 551; БҺҺ II: 281–282) «ложь, неправда; фантазия; художественный обман» < гом. кыпч.: каз., к.-балк., кырг. *öтүрүк*, чыгт. *öтрүк, отүрүк,* иске үзб. (ЎХШЛ: 205) *öтүрүк, үöтрүк*, яз. ядкәрләрдә *öтрүк* id. (к. Räsänen 1969: 376), бор. төрки (ДТС: 629) *ütrük* «хәйләкәр». К. **Өтерек.**

**ҮТ-Ү,** себ. (Дмитриева 1981: 171) **öйт-ү** «проходить, пройти; проникать; иметь сбыт (о товарах); быть достаточно острым» ~ чув. *вит-* id. ~ гом. кыпч., алт., уйг., угыз. *öт-* < *ööт-* «үтү; гомер үткәрү, яшәп яту» ~ бор. төрки (ДТС: 391) *öt-* «үтү», бор. тат. (Колшәриф телендә) **үт-ү** «гафу итү» (чаг. *кич-ү* ~ фар. *гаштан* «үтү; кичерү») һ.б. Бу фигыльнең исем нигезе дә билгеле: бор. төрки, урта төрки (Радлов I: 1259; ДТС: 366–367) *öt, öd* «вакыт; заман; закон; үткел». Будагов I: 112; ЭСТЯ I: 554–555; Мухамедова 1973: 138, 141; Федотов I: 127 (чув. *витер-* «үткәрү» > мар. *витер-* id. тур.; гомумән, чув. *вит-* < болг. **wит-* «үтү» булса кирәк).

Дерив.: **үтел-ү, үткәр-ү** (үзенчәлекле йөкл. юн. формасы); **үткен, үтмәс** (кисү кораллары тур.); **үткер** (төрле мәгъ.). **Үтә, Үтемле, Үткел.**

**ҮТҮК, үтек, үте** «утюг» > мар. (Исанбаев 1978: 31) *öтык,* удм. (Насибуллин: 143) *учуг* id. **Үтүк** яңгырашы русчадан булса кирәк, гомумән исә бу сүз төрки телләрдән таралган, к. **Өте.** Фасмер IV: 177; ЭСТЯ I: 641; Аникин: 596–597.

Дерив.: **үтүкле, үтүксез; үтүклә-ү.**

**ҮЧ,** диал. **үц** «месть, мстительность, ненависть» ~ башк. *үс* id. > удм. *öсь, öч* «үч, кинә» <

гом. төрки *өч* < *ööч,* үзб. диал. *ҳөч* ~ каз. *өш,* як. *өс* һ.б. id. Чув. *вĕчĕ, вүчĕ*, каз. *өш* ~ мар. *үчӧ* «үч» *өч* тамырыннан ясалган (ягъни борынгырак яңгыраш түгел). ЭСТЯ I: 559.

Дерив.: **үчле, үчсез; үчлек; үчләш-ү.** К. **Үҗәт, Үчәш, Үчәш-ү, Үчек-ү.**

**ҮЧӘШ** (ДС I: 259), диал. (Тумашева 1992: 231) **үцәш** «упрямый; капризный, злобствующий» > удм. *öчес* id. < гом. кыпч., чыгт. *öчеш*, алт., кырг. *öчөш*, тув. *öҗеш*, хак. *öчес,* як. *öсöс* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 376) *öčäš* >> төр. *öceş* «үчегүчән, ярсулы һ.б.ш.» ← (чыгт. һ.б.) *öčä-,* алт. *öчö-* ~ чув. *вĕче-, вĕчче-* «үчләнү, үчләшү» (к. Федотов II: 121) фигыленнән ясалган исем сүз. К. **Үчәш-ү.**

**ҮЧӘШ-Ү** (ДС I: 259) «злобно упрямиться, упорно противодействовать» > мар. *үчäш-*, удм. (Насибуллин: 131) *öчäш-* «каты бәхәсләшү, үчәшү» < чыгт., бор. төрки (ДТС: 376) *öčäš-*, төр. *öceş-* id. бор. төрки *öčä-* > алт., кырг. *öчö-* >> башк. *үсә-* «явызларча шатлану, үчегү; үчләшү» фигыленең урт. юнәлешеннән. К. **Үч, Үчәш.**

**ҮЧЕКЛӘ-Ү** к. **Үҗеклә-ү.**

**ҮЧЕК-Ү (үчекте, үчегү)** «питать мстительность, ненависть» < чыгт. формасыннан караганда, **үч-у* «үч алырга теләү» фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе, әмма *үч-* < *öч-* фигыле үзе беркайда да теркәлмәгән. К. **Үч.**

**ҮЧЕР-Ү** (ТТДС I: 561) «уничтожить; разорить; свести на нет» – асылда «утын сүндерү» булса кирәк, к. **Үч-ү. Үчер-ү** халык этимологиясендә **очыр-у** белән бутала.

**ҮЧТЕКИ, үчтекәй** «игра с малышом, подкидывая его вверх» ~ чув. (Ашмарин III: 225–226) *үтике, үчеки*, мар. *учи-учи, учики-учики,* удм. *уть-уть* id. Бу (сүзлекләргә сирәк алына торган) сүзнең таралыш ареалы мәзкүр халыкларның озак гасырлар килен алышып, кыз бирешеп яшәүләренә гуаһлык итә.

Чыгышлары буенча алар тәкълиди характерда.

**ҮЧ-Ү** (ТТДС I: 562) «потухать» < гом. төрки *öč-* id. (к. Räsänen 1969: 368). Бу фигыль үзе сирәк очрый, әмма аның йөкл. юнәлешендәге формасы тат. **үчер-ү** (к.), диал. (Тумашева 1992: 231) **үцер-ү** ~ үзб. *учир-*, каз., к.-калп. *өшир-*, уйг., кырг. *öчүр-* «сүндерү» киңрәк билгеле. ЭСТЯ I: 559–560. К. **Үчер-ү.**

**ҮШӘ,** диал. **үчә** «тесло; коловорот (орудие для проделывания крупных отверстий)» – чыгышы ачык түгел. К. **Өшке.**

**ҮШӘН,** диал. **үчән** (?) «вялый, ленивый (о лошади)» > мар. *öшäн* id., төр. *üşen* «үшән»; чаг. **Өшән-ү** (?).

Дерив.: **үшәнлек; үшәнлән-ү.**

# Ф

**Ф** авазы тат. телендә башлыча гар., фар. һәм рус (Европа) алынмаларына хас һәм алынмалык билгесе булып тора. Ләкин ул кайбер төп төрки сүзләрдә дә очрый: беренчедән, ымлыкларда (*уф! пуф, фи!*) һәм тәкълиди сүзләрдә (*фыр-фыр, фрр, фыс-фыс* һ.б.), икенчедән, Алтын Урда уйгурчасыннан кергән сүзләрдә (*туфрак, яфрак*, диал. *җиффәр-ү* һ.б.).

**ФАҖИГА** «трагедия, трагический случай» < гар. *фāҗи‘а* id. ← *фҗ‘* «аянычлы булу» тамырыннан, шуннан ук иске тат. **фаҗигъ, фаҗигый**. ГТРС: 626.

Дерив.: **фаҗигалы, фаҗигасыз; фаҗигалык.**

**ФАЗЫЙЛӘТ, фазиләт** «благо; достоинство» (хәз. тат. әд. телендә шул мәгъ. бүтән сүз юк!) < гар. *фāḍӣлäт* id. ← *фḍл* «югары сыйфатта булу» тамырыннан, шуннан ук иске тат. **фазыйль, фазыл.** ГТРС: 622–623.

Дерив.: **фазыйләтле, фазыйләтсез** һ.б.

**ФАЙДА** «польза, выгода; интерес» > мар., удм. *файда, пайда*, чув. *пайта* id. < гар. *фā’идä* «файда; табыш».

Дерив.: **файдалы, файдасыз; файдалан-у;** иске тат. (Будагов II: 779) **файдачы, файдачылык.**

**ФАЛ** «гадание», диал. «знак, знамение» < гар. *фāл* id. К. ш. ук **Пал.**

Дерив.: **фаллы;** иске тат. **фалбин** < фар. *фāлбӣн* «күрәзә».

**ФАМИЛИЯ** «фамилия» < рус. < лат.; лат. телендә тәүдә *familia* «өй коллары җөмләсе» булган, шуннан «гаилә» мәгъ. алган.

Дерив.: **фамилияле, фамилиясез**; иске тат. (XIX г.) **фамиль** ← рус. *фамильный.*

**ФАНЕР, фанир** «фанера (строительный материал)» < рус. < ингл. яисә ним. теленнән (үзгәреп) кергән, ахыр чиктә фр. *fournir* «товарны төреп, савытлап җибәрү» фигыленнән (шуннан ук рус. *фурнитура* «җибәрелгән җиһаз, кием-салым кабы, толыкманы, вак-төяк детальләре»). Фасмер IV: 185.

**ФАНИ** «преходящий, суетный, тленный (мир)» < гар. *фāнӣ* id.

Дерив.: **фанилык.**

**ФАРАЗ** «предположение; гипотеза» < гар. *фäраḍ* id. Иске тат. **фаразан** «предположительно, гипотетически; положим, что» < гар. *фäраḍан* id. ← *фрḍ* «чамалау; билгеләп кую», шуннан ук к. **Фарыз.**

Дерив.: **фаразлы, фаразсыз; фаразла-у.**

**ФАРСИТ (фарчит): фарсит итү** «вести себя разнузданно; тратить много средств для показухи» < рус. *форсить* id. ← *форс* «шәпләнү, мактаныч» < фр. *force* id. Фасмер IV: 203.

**ФАРСЫ** «перс» < гар. *фāрс* < бор. ир. (б.э.к. I меңьеллык башыннан бирле билгеле) *pars, parsik* этнонимыннан, тәүге мәгънәсе төгәл билгеле түгел. Бу сүзләрнең күп вариантлары бар һәм алардан тарих дәвамында исәпсез күп сүзләр ясалган. *Парс*тан гарәпчәләштерелгән *фарс → фрс* тамырыннан ясалган күп кенә сүзләрдән тат. телендә *фарис* «атлы, сыбайлы», *фирасәт, фирәсәт* «хәйлә-мәкер; оста сәясәт» кулланылган. Төп ир. *пäрс ~ пәрс* нигезеннән, грек һ.б. Европа телләреннән алынып, рус. *перс, Персия, персик* «шәфталу (җимеш)» һ.б. сүзләр кулланыла, алар тат. теленә дә үтеп кергәннәр. Фасмер IV: 184.

Дерив. **фарси; фарсыча** һ.б.

**ФАРЫЗ** «обязательный; обязательно (в функции сказуемого)» < гар. *фäрḍ* id. К. **Фараз.** Будагов I: 783–784.

**ФАСИКЪ** «развратный, беспутный; нечестивый» < гар. *фāсиķ* id. ← *фсķ* «типтерү, артык иркенәю» тамырыннан, шуннан ук иске **фисыкъ** «юньсезлек күренеше», **фисҗы фәсәт** «тәртипсез бунт», **фисҗы фирәсәт** «явыз политика» һ.б.ш.

Мәзкүр сүзләргә ахыр чиктә яһ. *песах*, рус. *пасха* (христианнарның дини бәйрәме) сүзләре тамырдаш (сем. телләренә уртак тамырдан). **Пасха** «иркенәю» – уразадан чыгу бәйрәме.

**ФАСЫЛ** «время года» (*елның дүрт фасылы* «четыре времени года»), иск. «глава, раздел; статья»

< гар. *фäҫл* id., түбәндә «кат, этаж; катлам һ.б.ш.». К. **Тәфсил.**

**ФАТИР** «временная (наёмная) квартира» < рус. диал. *фатер, фатир, хватир* id. > чув. *хваттер, хăваттер* һ.б. (Сергеев 1971: 139), мар. *пачер* (Исанбаев 1978: 30), удм. *патер* id.

**Фатир** сүзен «квартир» мәгъ. куллану урынсыз вә сәвәтсез, чөнки бу ике сүзнең үз аерым мәгънәләре бар.

**ФАТИХА** «благословение (на дело, на дорогу)» < гар. *фāтихä* «башлангыч; юл башы» ← *фтх* «юл башлау» тамырыннан.

Дерив.: **фатихалы, фатихасыз** (эш); **фатихачы.** К. **Фәтех.**

**ФАХИШ** «скверный; блудный, блудник» < гар. *фāхиш* id. К. ш. ук **фахишә** «уйнашчы хатын», иске тат. **фахшәт** һ.б.ш.

Дерив.: **фахишлек; фахишлән-ү.**

**ФАШ** «разоблачение» < фар. *фāш* id. Будагов I: 779. Дерив.: **фашла-у** «фаш итү».

**ФӘГЪФУР** иск. (К. Насыйри телендә), (Тимергалин: 497) **фагфур, багбур** «фарфор» < фар. *фäгфӯр* id. Бу фар. сүзен Будагов (I: 787) санск. *баг* «тәңре» һәм *пур* «угыл» сүзләреннән гыйбарәт һәм Кытайдагы фарфор эшләнә торган бер өлкәнең атамасы дип аңлаткан. Ягъни **фарфор** «тәңре углы» булып чыга. Будагов әлеге өлкәнең хәзер ничек аталганлыгын, кайдалыгын әйтмәгән (әйтә алмаган). Хәлбуки фарфор фар. тулырак әйтелештә *фарыгфур* дип атала. Димәк Будагов аңлатмасы дөрес түгел. Тик дөресен без дә әйтә алмыйбыз (белмибез). **Фарфур** сүзендәге *фур* һинд. *пур* «шәһәр, кала» булса кирәк. Ә *фарыг* ни?

**ФӘКАТЬ [фәқәт]** «только лишь» < гар. *фäқаṭ* id.

**ФӘКЫЙРЬ [фәқир]** «бедный; бедняк» < гар. *фäқӣр* id. К. ш. ук тат. диал. **фақыр** «бичара, мескен». К. **Бахыр.** Будагов I: 787 (сүзнең төрле тарихи мәгъ. күрсәтелә).

Дерив.: **фәкыйрьлек, фәкыйрьчелек; фәкыйрьлән-ү, фәкыйрьләш-ү.**

**ФӘЛӘК** «рок» < гар. *фäлäк* «күк йөзе, күкләр; язмыш» (кешенең язмышы күктә язылган дип ышанудан). К. ш. ук иск. **фәлякәт** «көтелмәгән аянычлы хәл». Будагов I: 788.

**ФӘЛӘН** «такой-то, тот-то; некий, некто; имярек» < гар. *фäлāн, фулāн* id., төп мәгъ. «әлеге, билгеле» < грек. *φαλλος* сүзеннән дип уйланыла. **Фәлән-төгән** тур. к. **Төгән.** К. ш. ук **фәлән-фәсмәтән,** себ. (Тумашева 1992: 171) **пәлән-пәстеүән** «фәлән-төгән» (боларның тагылмалары безгә ачык түгел).

**ФӘЛСӘФӘ** «философия» < гар. *фäлсäфä* id. < грек. *φιλοσοφια* id. К. ш. ук иске **фәйләсуф** «философ».

Дерив.: **фәлсәфәче; фәлсәфәлә-ү; фәлсәфи** гар. теленнән килә.

**ФӘН** «наука» < гар. *фäнн* id. ← *фнн* «төрләнү, тармаклану» тамырыннан. К. ш. ук **фәнни** < гар. *фäннӣ* id. Иске **фөнүн** «фәннәр» дә гарәпчәдән.

Дерив.: **фә́нчә; фәннилек.**

**ФӘРӘВАН [фәрәwан]** «полное счастье и свобода; изобилие» (мәкаль: *Дөнья – кәраван, гомер – фәрәван*] < фар. *фäрāwāн* id. Будагов I: 782.

**ФӘРӘЗӘ,** (Тукайда һ.б.) **фәрәҗә** «длинная рубашка у священнослужителей, надеваемая при богослужении» ~ төр. *ferace* id. Чаг. рус. *ферязь* id. < грек., к Фасмер IV: 180; Будагов I: 783. **Фирәзә** белән бутамаска!

**ФӘРӘЗӘН, фирзән,** диал. (ЗДС: 525) **пәрсәнт** «ловкость в делах; сообразительность; хитрость; удобный момент» – төп мәгъ. «шахматта вәзир (ферзь булу)» сүзеннән булса кирәк. К. гар. *фирзāн* «ферзь, вәзир». Монда төрле сүзләр контаминациясе күзәтелә.

**ФӘРЕШТӘ,** диал. **фирештә, пәрештә** «ангел» > чув. *пирĕште, пирĕшти* һ.б. (барча көнб. төрки телләрдә бар) < фар. *фäриштä, фириштä* id. < авест. *fra ashta, fra ishta* «илче ярдәмчесе». Platts II: 779; Федотов I: 434.

**ФӘРЗӘНД,** себ. (Тумашева 1992: 171) **пәрсәнт** «отпрыск, сын или дочь» < фар. *фäрзäнд, ферзенд* id. < бор. фар. *fra-zanti* «балалар». ЭСИЯ: 3: 55.

**ФӘРМАН** «повеление» < фар. *фäрмāн* id. < бор. ир. *fra-mana* «команда». Иран һәм фарсыларга карата *фирман* диелә. Platts II: 779; ЭСИЯ 3: 55.

Дерив.: **фәрманлы, фәрмансыз; фәрманла-у.**

**ФӘРРАШ** иск. «уборщик (обычно из бедных шакирдов) в медресе, он же парикмахер и т.п.» < гар. *фäррāш* id. Будагов I: 781–782 (сүзнең тат. мәгънәсен күрсәтми, бүтән, асыл мәгънәләре «сарайда жыештыручы; тәртип саклаучы офицер»).

**ФӘС** «феска» < төр. *fes* id. Төньяк Африкадагы Фәс шәһәре атамасыннан.

**ФӘСЛЕГӘН** иск., (Будагов II: 785) **фусилиянъ** «базилик (вид растения)» ~ добр. (Dobr. III: 45), төр. *fesleğen, fesilgen, pesleğen, pesilgen* һ.б. «хуш исле рәйхан». Шул ук **базилик** сүзенә тоташа.

**ФӘТВА [фәтwа]** «решение высшего религиозного авторитета» < гар. *фäтwā* «хәл итү, мәсьәләне чишү» ← *фтw* «хәл итү», шуннан ук к. **Мөфти.** Будагов I: 780. Тат., башк. сөйләшләрендә **фәтwә** «хәлиткеч чара, адым, файдалы акция».

Дерив.: диал. **фәтwәле, фәтwәсез** «ныклап уйланган – уйланмаган»; **фәтwәче.**

**ФӘТЕХ** «открытие, новооткрытие» < гар. *фäтх* id. ← *фтх* тамырыннан, шуннан ук иске **фатих** (мөәннәсе **фатиха**) «ачучы, яулап алучы» һ.б. күп сүзләр, *Фәттах, Мифтах, Мәфтуха* исемнәре, *Фәтхел*гә башланган исемнәр килә.

**ФӘХЕШ** «блуд; проституция; непотребность» < гар. *фäхш* id., к. **Фахиш.**

Дерив.: **фәхешлек, фәхешлән-ү; фәхешханә** (фар. телендә ясалган сүз).

**ФӘҺЕМ** «проницательность, понятливость; доходчивость» < гар. *фäһм* id. Шуннан иске **фәһим** «фәһемле».

Дерив.: **фәһемле, фәһемсез; фәһемлә-ү.**

**ФЕВРАЛЬ, фиврал, фибрал** «февраль» < рус. < лат., асылда «чистарыну ае» дигән сүз (бор. Рим календарында февраль – соңгы ай).

**ФЕТНӘ** «мятеж, бунт», сөйл. «возмутитель спокойствия, беда (о человеке)», иск. «красавица (как предмет споров)» < гар. *фитнä* «явызлык» ← *фтн* «начар хәлгә дучар булу» (чаг. иске тат. **мәфтүн** «онытылып сокланган, башы-күзе әйләнгән»).

Дерив.: **фетнәле; фетнәчел; фетнәчелек.**

**ФИГЫЛЬ** «действие; поступок; глагол (часть речи)» < гар. *фи‘л* id. *ф‘л* «эшләү, ясау, эш итү» тамырыннан. Шуннан күп кенә сүзләр ясалган. Бу тамырның продуктивлыгыннан чыгып, гарәп поэтикасында вәзен атамаларын (аларның саны йөзгә якынлаша) шул фигыльнең дериватлары рәвешендә бирәләр: **фагыйль, фагыйлүн, фагыйләт** һ.б. сүзләр шундый формула итеп кулланыла.

Дерив.: **фигыльле, фигыльсез; фигыль-шөгыль.**

**ФИДА** «самопожертвование, самоотверженность» < гар. *фидā’* «йолым, фида»; шуннан ук тат. < гар. **фидаи** «үз-үзен корбан итүче; партизан». К. **Фидакяр.**

**ФИДАКЯР [фидак'ар]** «самоотверженный» < фар. *фидак'āр* id. («фида кылучы»). **Фидакарь** дип язу дөрес түгел.

Дерив.: **фидакярлык; фидакярлан-у.**

**ФИКЕР** «мысль» < гар. *фикр* id.

Дерив.: **фикерле, фикерсез; фикерлә-ү;** (сирәк) **фикерче.**

**ФИЛ** «слон» < гар. *фӣл* id. < санск. *pil* id. < Һиндстанның җирле телләреннән. Мар., чув. *пил* id., әлбәттә, санск. теленнән түгел, татарчадан.

**ФИЛТӘ,** диал. **пилтә** «фитиль» > мар. *пэлта*, удм. *пильта* id. < фар. *фалита* < гар. *фäтӣлä, фäтӣл* «филтә, җеп үреме» сүзенең җыйма күплеге, *фтл* «эрләү, бәйләмләү» тамырыннан. Татар сүзе русчадан түгел. Рус. *фитиль* < төр. булса кирәк. Фасмер IV: 197. К. **Билтә, Мылтык.**

**ФИРАСӘТ** «(тонкая) политика; козни» < гар. *фирāсäт* ← *фрс* «фарсыларча эш итү». Фарсылар нечкә, хәйләкәр сәясәтче булып исәпләнгән.

**ФИРГАВЕН [фирғәwĕн]** «фараон (монарх в Древнем Египте)» < гар. *фир‘awн* id. ← бор. мисри. *пэриға* «фиргавен». К. **Папирус.**

**ФИРКА** «партия» < гар. *фирқа* «аерымланган төркем» ← *фрқ* «аерымлану» тамырыннан, к. **Әлфирак.**

Дерив.: **фиркалы, фиркасыз** (XX г. башларында актив кулланылган сүзләр).

**ФИРҮЗӘ, фәйрүзә, фирәзә** «бирюза», **фиренже** (ЗДС: 697) «монисто, блёстка» < фар. *фӣрӯ-*

*зä, пӣрӯзä* id. < авест. *pairi roačanh* «нур чыганагы; җиңү бәйрәме». Platts: 785; Фасмер I: 167–168. Икенче бер аңлатма буенча рус. *бирюза* < фр. *pierre turquoise* «төрек ташы» сүзеннән. К. Смит: 453.

**ФИТРӘТ, фәтрәт** дини «промежуток времени между двумя пророками, в особенности между Иисусом и Мухаммедом; междоусобица, безвременье» < гар. *фäтрат, фитрат* id. ← *фтр* «(хакимият) зәгыйфьләнү, бушау».

**ФИТЪРӘТ** (ГТРС: 631), **фытрат** «природное свойство, естество; природная особенность» ~ төр. *fıtrat* id., ш. ук «тумышы белән» (к. тат. әд. әйтем *фытраттан гали* рус. «велик от рождения») < гар. *фиṭрат* id. ← *фṭр* «бар итү». Шуннан ук **фитыр.** Асылда **фытрат** мисырча *фṭр ~ птр* «Нил елгасының иң саеккан вакыты (килү)». К. **Ифтар, Пәтер, Фитыр.**

**ФИТЫР, фытыр, фитра** «разговение»; халык телендә «хәер-садаканың бер төре» < гар. *фитр* id., к. **Пәтер, Фитърәт.**

**ФОНАРЬ** «фонарь» < рус.; гади сөйләмдә күптән **фанар** булып яңгырый, к. ш. ук төр. *fenar* id. < грек. Фасмер IV: 202.

**ФОРМА,** сөйл. **фурмы** «форма» < рус. < лат. Фасмер IV: 203.

Дерив.: **формалы, формасыз; формалаш-у (формалаштыр-у).**

**Форма** сүзеннән күп кенә халыкара терминнар ясалган: **формаль, формат, формация, деформация, трансформация, формула, формуляр** – болар барысы да хәз. тат. әд. телендә кулланыла.

**ФОРСАТ** «удобный момент, возможность» < гар. *фурçат* id. ← *фрç* тамырыннан (төп мәгънәсе ачык түгел, гар. телендә алынма сүз булса кирәк). **Фәрасәт** (к.) сүзенә бәйләнешле түгел.

Дерив.: **форсатлы, форсатсыз.**

**ФӨРЬЯД [фөрйат]** «стенания» < фар. *фүрйāд, фирийāд* «каравыл кычкыру» – бор. ир. сүз.

**ФРАНЦУЗ,** сөйл. **фырансуз** «француз; французский, французского производства (о тканях)» < рус. *француз, французский* < фр. *français* (к. Фасмер IV: 206). **Француз, Франция** сүзләре бор. герм. кабиләсе **франк** атамасыннан, шуннан иске тат., төр. **фәрәнги** «европалы, Европага караган» (фар. теле аша таралган).

**ФУ** ы. «фу». Рус теленнән булса кирәк. Ләкин охшаш ымлыклар күп телләрдә очрый: рус. *фу, фуй,* ним. *pfuj* һ.б.

**ФУТА** иск. «шёлковая накидка» < төр. *futa* < фар. *fūtä* «бизәкле ябынча (су кергәндә киелгән)». Räsänen 1969: 147. К. **Пута.**

**ФЫР, фыр-р** – междометие и звукоподражение, обозначающие быстрое вращение, быстрое трепыхание и т.п. К. **Пыр.**

**ФЫРТ** «щегольской; щеголеватый, франтоватый» – гар. *фарт, фирт* «артыкчалык; алга сикереп чыгу, күренергә тырышу» сүзе тәэсирендә микән? Чаг. ш. ук рус. *фарт* «купшылык, шапләнү», *фартовый* «шапләнеп кыланучан» һ.б. 2005 нче елгы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә **фырт** рус. *фарт* сүзеннән килә диелгән», безнеңчә бу шиклерәк. Рус. *фарт* тур. Фасмер IV: 186 (нимесчәдә диелә).

# Х

**Х** авазы башлыча алынма сүзләрдә кулланыла, ләкин кайбер сөйләшләрдә (бигрәк тә Уралда һәм Себердә) актив рәвештә гом. төрки *ķ* урынында килә.

**ХАДИСӘ** «явление; случай, происшествие, событие» < гар. *xāдиçä* id. ← *xдç* «булу, очрау; булганны сөйләү» тамырыннан. К. Будагов I: 510. К. **Хәдис.**

**ХАДИМ** «слуга» (**хадимә** «служанка») < гар. *ẋāдим, ẋāдимä* id. К. **Хезмәт.**

**ХАДУК I, хатак** (ЗДС: 697, 699) «крытый экипаж (для новобрачных на свадьбе)» < рус. *ходок* диелгән. Ләкин к. каз. (ҚТДС: 180) *ķадаķ* «арба яки чана көймәсе; көймәле арба-чана» ~ Урта Азиядә (Будагов II: 4, кайсы телдә икәнлеге ачык әйтелмәгән) *ķата* «барьер», бор. (ДТС: 401, 437) *qadaγ, xadaγи* «яклау, ышыклау». К. **Катау.**

**ХАДУК II** «ходок, представитель населения, обращающийся от имени кого-либо коллектива к властям» < рус. *ходок* id., төп мәгъ. «йөрүче» ← *ходить* «йөрү, юл йөрү».

Диал. сөйләмдә (ЗДС: 697) рус. диал. *ходок*тан алынган **хадук** «тарантас» сүзе теркәлгән.

**ХАЖ** «хадж » < гар. *xäҗҗ* id. ← *xҗҗ* «барып күрү» тамырыннан. К. **Хаҗи.**

**ХАҖӘТ,** диал. **хәҗәт, ķәҗәт** «потребность, необходимость» < гар. *xāҗäт* id. ← *xwҗ* «кирәк булу» тамырыннан; шуннан ук **Ихтыяҗ**, **Мохтаҗ.** К. ш. ук **Әҗәт**. Будагов I: 510.

Дерив.: **хаҗәтле, хаҗәтсез; хаҗәтлек; хаҗәтханә; хаҗәтлән-ү** (иске сүз). К. **Әҗәт.**

**ХАҖИ** «хаджи» – **хаҗ** сүзеннән фарсы телендә ясалган сүз.

**ХАЗАР** к. **Хәзәр.**

**ХАЗЫЙРЬ [хазыйр′]** «присутствующий» (**хазыйрун** «күз алдында булучылар, шаһитлар») < гар. *xāḍир (xāḍирӯн)* id. К. **Хә́зер.**

**ХАИН** «предатель» < гар. *ẋā'ин* id., к. **Хыянәт.**

**ХАЙВАН [хаºйwан]** «животное» > мар. (Исанбаев 1978: 20) *хайван, кайван* < гар. *xäйwāн* id. К. ш. ук кит. **хайванат** «хайваннар дөньясы; хайваннар күп урын» < гар. *xäйwāнāт* id.

**Хайван** продуктив сүзьясагыч нигез: **хайваннарча, хайванлык, хайванчылык, хайванлан-у** һ.б.ш.

**ХАК** «правда; цена», «право» < гар. *xäķķ* id. ← *xķķ* «дөрес булу» К. **Нахак, Хакыйкать, Хокук, Тәхкыйк** – тамырдаш сүзләр. К. иске тат. **Хаķķ** «Аллаһ».

**Хак** продуктив сүзьясагыч нигез: **хаклы, хаксыз; хакла-у** һ.б.ш.

**ХАКАН** «каган» к. **Каган.**

**ХАКИМ** «владетель; правитель» < гар. *xāким* id. ← *xкм* «идарә итү; хөкем итү, хөкем чыгару; диагноз кую» тамырыннан, шуннан ук **хәким** «врач; акылдар, хикмәт иясе», **хөкем, хөкүмәт.**

**ХАЛ** иск. «родимое пятно; небольшое пятно на лице (иногда девушки наносят специально для красоты)» < фар. *xāл* id. > тат. диал. (себ., ЗДС: 381, 384) **ķал,** каз., кырг. һ.б. *ķал* id. Бу сүзгә баглап төрле ырымнар, сөйләкләр бәян ителә.

Дерив.: **каллы; калы, калый,** ш. ук **ķалбай, ķалбигә, ķалчаķ, халчах** «халлы бала». Ырым буенча, халлы балага халы бетсен өчен мәзкүр сүзләрнең берсе белән эндәшергә кирәк дип ышанганнар: *калысы wөтсөн өцөн кырыхынацы «син Калы» тиф йөрөтәтеләр.* Рус *Колчак* < тат. (?) **калчак** фамилиясенең дә әлеге **ķалчаķ** сүзеннән булуы ихтимал.

**ХАЛАЕК [хаºлайыķ]** «разный люд; сборище; население, состоящее из разных национальностей» < гар. *ẋалā'иķ* «халыклар» сүзеннән. Төр. *halayık* «җарияләр; гаиләдә барча хатыннар». К. **Халык; Халик** иск. «бар итүче».

**ХАЛАТ** «халат» < рус. < иске тат., төр., чыгт. < гар. *xил'ат* (к. **Хилгать**) id. сүзеннән. К. Будагов I: 536.

**ХАЛӘТ** «состояние, положение» < гар. *хāләт* id. К. **Халь.**

**ХАЛИ** (*Бәндә хатадан хали түгел* дигән мәкальдә һ.б.) «лишён, свободен (от груза и т.п.)» < гар. *х̣āлӣ* id. Будагов I: 527.

**ХАЛИС** «чистенький; совершенно чистый; без примесей», диал. «только лишь» < гар. *х̣āлиҫ* id. ← *х̣лҫ* «начарлыктан азат итү», шуннан ук иске һәм диал. (Тумашева 1992: 21, 116) **халас ~ ҡалас** «начарлыктан азат, гөнаһсыз», **мөхлис** «гөнаһлардан азат». К. **Әләшә, Ихлас.**

**ХАЛХА: халха монгол** – название основного населения Монголии, одного из монгольских народов. Бу сүз – монголча *халха*$^{н}$ – асылда **калкан** (к.) сүзе белән бердәй, к. Горелик 2004.

**ХАЛЫК** «народ; нация; население» ~ чув. *халăх,* мар. *халык, калык* id. < гар. *х̣алҡ* id. (күп. формасы – *х̣алāʼиҡ*) ← *х̣лҡ* «яшәү, туу; ярату» тамырыннан, шуннан ук **әхлак, мәхлук, холык** һ.б.; к. **Халаек.**

Дерив.: **халыклы; халыкчан; халыкчы, халыкчыл; халыклаш-у** һ.б.

**ХАЛЬ** «положение; условия» < гар. *хāл'.* Бу сүз сүзлекләрдә аерым бирелми, **хәл** белән бутала. Хәлбуки күп кенә сөйләшләрдә *халь* дип аермачык әйтелә.

**ХАН I** «хан» >> коми. *ҡан* > удм. **кун* «хан, хөкемдар». Бу сүз Урта Идел-Урал регионында тат. теле формалашканчы ук таралган булган, к. чув. *хун < хон, хум < хом* «хан», мар. *хон, он*, морд. *он* «патша», удм. *кун* «дәүләт», венг. *hат* «хан арбасы, мәгәлдәк». Гомумән, тат., башк. *хан* чыгт. һәм монг. телләреннән килә (кыпчакча – *ҡан*). Титул буларак **хан** бөтен дөньяга билгеле.

*Хан ~ ҡан* һәм *хаҡан ~ ҡаған* сүзләре тур. әдәбият зур, ләкин конкрет нәтиҗә юк. Күпчелек этимологлар *хан* сүзен кыт. *куан* «идарәче» сүзеннән дип карый. Икенче версия – авест. *аnһи* «башлык, әфәнде» сүзеннән (Platts: 485). К. Будагов I: 527–528; Doerfer III: 1967: 123–173; Федотов II: 357; Аникин: 253–254.

**Хан** продуктив сүзьясагыч нигез: **ханзадә** «принц яки принцесса» (< фар.), **ханбикә, хани, хания, ханчá, ханлык,** иск. **ханыш** «хан кәләше». К. **Хантама, Ханым, Хатын.**

**ХАН II** иск. «изучающий определённую дисциплину или книгу» (мәс., *сарыфхан, исагуҗихан*) < фар. $x^{w}$*āн* id.

**ХАНӘ** «помещение (чаще – в сложных словах)» < фар. *х̣āнä* id. Будагов I: 528.

**ХАНӘВЕЗ [ха$^{о}$нәwĕз]** «вид атласной ткани» ~ рус. *канаус*, ком., к.-балк. *ҡанаwат*, фар. *ҡанāwӯз* «киндер шикелле тукылган ефәк тукыма» – чыгышы ачык түгел. Фасмер II: 178. Төньяк Кавказ телләрендә *канаус, канауз* «канал» < фар. *кянхаwыз* «казылган хәвез (буа)» сүзеннән.

**ХАНӘДАН** «династия; дәрәҗәле нәсел» (К. Тинчурин) < фар. *х̣āнäдāн* id. **ханә** сүзенең «династия» мәгънәсеннән (чаг. рус. кит. *дом* «династия әһелләре»). Будагов I: 528.

**ХАНӘКӘ I, ханәкәи, каникә** «замужняя женщина ханского рода», **ханәкә солтан** «княжна, девица ханского происхождения, принцесса» ~ кырг. *каныкей* < **ханыйкәй* id. *хани, ханый* «хан затыннан» дигәннән булса кирәк, икенче яктан к. ш. ук **Кәникә** < монг. *ханкэн* (азаккы *-н* төшерелүчән) id. Будагов I: 527–528. К. ш. ук **Кәникә.**

**ХАНӘКӘ II, ханәгәй** иск. «монастырь (для престарелых и больных)» < фар. *х̣āнг'āһ, х̣āнег'āһ*, ш. ук *х̣āнҡāһ* (к. Будагов I: 528) «өй-урын» кебегрәк мәгъ. сүз.

**ХАННА** диал. (МТД 1978: 103) «главарь чертей» < гар. *х̣аннāс* id. – Иблиснең кушаматы, «чигенүче (Аллаһны искә алганда)» мәгъ.

**ХАНТАМА** (ТТДС II: 335) «горячее желание, вожделение», (Тинчурин; Исәнбәт II: 210–211) «кураж, самохвальство» ~ к.-калп. *ҡамтама* id. < *хан тәмгы* («ханлыкка, өстенлеккә дәгъва итү») сүзеннән. К. Ә. Ясәвидә: *Хантамғылыҡ берлә юлга кермәң, дуслар* (41 хикмәт).

Дерив.: **хантамалы, хантамасыз** «дусларча ачыктан-ачык (сөйләшү, нәчәлник һәм куласты кешеләр тур.)»; **хантамасын салу** «бөтен ихтыярын салу», **фантамага ~ хвантамага калу** (к. ЗДС: 696) «аптырашка яки гаҗәпкә калу» (*хантама > хвантама > фантама* чув. теленә хас).

**ХАНЫМ** «дама» < бор. төрки **ханым** «хан хатыны» (чаг. *бигем* «би хатыны» > *бием, тарым*

«тархан хатыны» һ.б.) ~ төр. *hanım, hanım* «хөрмәтле хатын-кыз (ягъни кызларга карата да әйтелә)».

**ХАРАМ** «грех; греховный» < гар. *хӓрāм* id. К. **Әрәм, Мәхрүм, Хәрәм.**

**ХАРАП**, диал. **хәрәп** «прямо беда; всё пропало; ужасно; очень» > удм. *карап*, мар. *кӓрӓп, кӓрап* id., чув. диал. *харап* «бик; бик тә» (Сергеев 1971: 78) < гар. *х̣арāб* id. К. **Әреп, Хәрабә, Хәрби.** К. Будагов I: 530.

Тат. телендә дә, мар., удм. телләрендә дә бу сүз составлы фигыльләр ясалуда актив кулланыла. Кире мәгъ. сүзнең «шәп, бик» мәгъ. алуы *хәтәр* сүзендә дә күзәтелә.

**ХАРИҖИ** иск. «иностранный; заграничный; инородец» < гар. *х̣āриҗū* id. ← *х̣рҗ* «чыгу» тамырыннан, к. **Хәреҗ**.

**ХАРИТА** иск. «карта (географическая) < гар. *х̣арūт̣а*, грек. *χαρτεs*, лат. *charta* «кәгазь»; арытабан – «хартия» (Тимергалин: 511), «карта». К. **Кәрт.** К. Фасмер II: 203; Kluge: 473. Кайбер тел тарихчылары **калта** < *халта* «сумка» сүзен дә **харита** сүзеннән үзгәргән диләр. Түбендә бор. мисыр сүзе.

**ХАС** «свойственно», иск. **хасс** «особый, избранный» (*хас оч* «хазовый конец»), диал. «точно» (*хас, хәс* «точно как, очень похож на…», *хә́стә* «точь-в-точь; вылитый») < гар. *х̣аҫҫ* id. ← *х̣ҫҫ* «аеруча билгеләү, чиста булу» тамырыннан. Шуннан ук к. **Махсус, Тәхсис, Хасият, Хәс.** Будагов I: 525.

Дерив.: **хаслык;** фразема: **хас булу.** К. **Хасла-у, Хыйсса.**

**Хас** сүзе элекке һәм бор. терминологиядә киң кулланылган: **хас исем** «ялгызлык исем» (гар. *исмул-хасс* тәгъбиреннән күчерелгән); **хас хаҗиб** рус. «тайный советник» дигәнгә туры килә.

**ХАСИЛ, хасыйль** «возникший из...», иск. «результат; урожай» < гар. *хāҫил'* id. Иске телдә китаби тәгъбирләрдә киң кулланылган: **әлха́сыйль (әл-хасил)** «кыскасы, кыскача әйткәндә»; **хасыйле масдар** «исем фигыль», **хасыйле гамәл** «математик гамәл нәтиҗәсе – сумма, өлеш һ.б.» К. **Мәхсүләт, Тәхсил.** Будагов I: 511.

Дерив.: **хасиллек; хасиллән-ү.**

**ХАСИЯТ [хасийәт], хассият,** диал. **хәсият** «свойство; особенность», диал. «секрет, секреты (ремесла); смысл; толк; толкование, толки; объяснение (случая, поведения кого-либо)» ~ башк. (БТДҺ: 368) *хәсейәт* id. < гар. *х̣аҫҫийӓт* id. ← *х̣ҫҫ* «аеруча сыйфатта булу» тамырыннан, к. **Хас.**

**Хасият** сүзеннән башка охшаш мәгъ. **хассасият** «нечкәлек, нечкә үзенчәлек» сүзе дә булган (шул ук *х̣ҫҫ* тамырыннан) һәм **хасият ~ хәсият** сүзенең кайбер мәгъ. шуннан килә.

Дерив.: **хасиятле, хасиятсез; хасиятлек; хасиятлән-ү.**

**ХАСЛА-У** (ТТДС I: 461–462) «специально предназначать» (шуннан **хаслан-у** «тырышып омтылу») **хас** сүзеннән. Кайбер сөйләшләрдәге (ТТДС I: 461 һ.б.) **хасла-у** «зыян китерү», **хаслык** «зыян, үч» һ.б.ш. *кас, каст* сүзенең рефлекслары. К. **Каст.**

**ХАСТА**, диал. **хәстә, каста** «хронически больной» < фар. *х̣астӓ* id.

**Хаста** продуктив сүзьясагыч нигез: **хасталан-у; хасталык, хастаханә** һ.б.

**ХАТ** «письмо; строка», иск. «почерк», «документ, указ» > удм. *кат* «закон», чув. *хот* > *хут* «кәгазь» (болг. теленнән, к. Смирнов 1890: 46) < гар. *х̣ат̣т̣*; к. ш. ук тат. әд. **хаттат** «күчереп язучы; каллиграф» < гар. *х̣ат̣т̣āт̣* «язучы, күчереп язучы». Будагов I: 534.

Дерив.: **хатсыз; хатлаш-у** «хат алышу»; фразема: иск. **хатти шәриф** рус. «высочайший указ».

**ХАТА** «ошибка» < гар. *х̣ат̣ā'* id.

**Хата** продуктив сүзьясагыч нигез: **хаталан-у, хаталы, хаталык, хатасыз** һ.б.ш. К. **Хатая.**

**ХАТАЯ [хатайа]** диал. «извините, ошибаюсь (ошибся)» ~ башк. (БТДҺ: 366) *хатайа* «хәтта, бик» < гар. *х̣ат̣иййӓ* id. Бу сүзнең кулланылышында русча *хотя* сүзенең тәэсире сизелә.

**ХАТИРӘ** «воспоминание; память (о ком, о чём)» < гар. *х̣āт̣ира* id. – **хәтер** белән тамырдаш.

**ХАТЫН,** диал. **қатын** «женщина; жена» < уйг., чыгт. *хатын, хатун* > гом. кыпч. *қатын* < бор. төрки *qatun, xatun* «бикә, хан хатыны» сугд. *xwatĕn* «хуҗабикә; хатын-кыз» сүзеннән дип исәпләнелә; икенче версия буенча, *хатын* < *хантун* «хан бичәсе» (ләкин *-тун* өлешенең чыгышы томанлы).

**Хатын** сүзе төрки телләрдән күрше телләргә кереп киң таралган: монг. *хатун, хатан*, монг. *хатаң*,

эвенк. һ.б. *катун* «баһадирның, хөкемдарның хатыны», бор. рус. *катуна* «хатын» (Срезневский II: 1199) һ.б.

Шунысы игътибарга лаек: Себер телләрендә бу төрле паронимнар биргән: алт., шор., хак. һ.б. *қат* «хатын, теше, инәк», алт. *кадыт* «хатын», як. *хатый, хатын* «хатын-кыз», *хотун* «түрә хатыны» (Пекарский: 3406–3408, 3535). Будагов I: 524; Räsänen 1969: 156; Аникин: 272 (бай әдәбият күрсәтелә).

**Хатын** продуктив нигез: **хатыннарча, хатынлык, хатынша, хатын-кыз.**

**ХАФА** «беспокойство; обида» < гар. *ҳафā'* id.

**Хафа** продуктив нигез: **хафалан-у, хафала-у; хафалы** һ.б.

**ХАФИЗ: Коръән хафиз** «выучивший Коран наизусть» < гар. *хāфиẓ* id. ← *хфẓ* «яттан белү; хәтердә саклау». К. **Абыз.**

**ХАХЫЛДА-У** «хохотать» – **ха-ха** ымлык вә тәкълиди сүзеннән.

**ХАЧ** «крест» < төр. *хач* ~ авар. *ханч* id. Әрм. теленнән дип уйланыла, к. Zenker: 380. К. **Хәчтерүш.**

**ХАШИЯ [ха°шийә]** иск. «заметки (объяснения, толкования) на полях книги; поля (книги, тетради)»; күч. «шпаргалка» < гар. *хāшийā* id. Элекке китапларда хашияләр бик еш очрый.

Дерив.: **хашияле, хашиясез; хашиялә-ү.**

**ХӘБӘР** «весть, известие», в грамматике – «сказуемое» > мар. диал., удм. диал. *кабар, кäбäр* ~ чув. *хапар, хыпар* id. < гар. *ҳабäр* id. ← *ҳбр* «белешеп тору», шуннан ук иске **әхбарат** «хәбәрләр, яңалыклар; мәгълүмат», **мөхбир** «журналист, корреспондент». Будагов I: 529; Федотов II: 381.

Дерив.: **хәбәрле, хәбәрсез; хәбәрлек** (грамматик термин); **хәбәрлә-ү, хәбәрләш-ү; хәбәрче; хәбәрчелек.** К. **Хәбәрдар, Хәбәрнамә**.

**ХӘБӘРДАР** «осведомлён; извещённый, осведомлённый, сведущий, компетентный» < фар. *ҳабäрдāр* id. – гар. *ҳабäр* + фар. *дар.*

Дерив.: **хәбәрдарлык**.

**ХӘБӘРНАМӘ** «извещение, сообщение письмом» < фар. *ҳабäрнāмэ* id. – гар. *ҳабäр* + фар. *намэ.*

**ХӘБӘР-ХӘТЕР** «ве́сти (о чём-либо); слухи, молва» – **хәбәр** (к.) һәм **хәтер** (к.) сүзләреннән гыйбарәт парлы сүз.

**ХӘБЛӘ, хәбелә** «вид обложения в Казанском государстве», безнеңчә, болг. **хәбәлә* < гар. *қабāлā* «кабалә, шартнамә», к. **Кабалә.** Бу сүзне гар. *хäблā* «бау, аркан» сүзенә дә баглыйлар.

**ХӘВЕЗ [хәwĕз]** «искусственный водоём (в зоне пустынь и сухих степей), хауз» < гар. *хäwḍ* id. >> **кавыз** (к.). Иске тат. **хәүзә** «бассейн, елга бассейны» сүзе дә гарәпчәдән, шуннан к. **Кауза.**

**ХӘВЕФ [хәwĕф]** «опасность, риск, угроза неудачи» < гар. *ҳawф* id.

Дерив.: **хәвефле, хәвефсез; хәвефлек; хәвефлән-ү** һ.б.

**ХӘДИС** «хадис, предание о словах и деяниях пророка Мухаммеда» < гар. *хадӣҫ* id. ← *хдҫ* «әңгәмә кору» тамырыннан. К. **Хадисә.**

**ХӘЕР [хәйĕр]** «добро, благо; милостыня», в значении союза и модального слова «хотя, хорошо еще, что...» < гом. кыпч., уйг., угыз. *хайыр, хайр* (> нуг., каз., кырг. *кайыр*), уйг. *хәйр* id., кайбер телләрдә «ярый, хуш», «хуш, сау бул», төр. *hayır* «юк, алай түгел» һ.б. < гар. *ҳайр* id. Төрки телләрдә бу сүз күп мәгънәле.

Дерив.: **хәерле** (> удм. *кайырлы*), **хәерсез; хәерлек**; к. **Хәердога, Хәерхаһ, Хәерче, Хәйрия.**

**ХӘЕРДОГА** «благопожелательная молитва» < гар. *ҳäйр äл-ду'ā* «доганың изгесе» кебегрәк мәгънәдән. Антонимы – **бәддога.**

**ХӘЕРХАҺ** «благопожелательный, доброжелательный» < фар. *ҳайрх̮ʷāҺ* id. (*х̮ʷāҺ* «теләк, теләүче»).

Дерив.: **хәерхаһлык, хәерхаһчы; хәерхаһлы.**

**ХӘЕРЧЕ** «нищий; просящий милостыню» > мар. (Гордеев 1973: 33) *кайырче*, чув. (Сергеев 1968: 77) *хайăрçă* id., к. ш. ук кырг. *кайырчы*, уйг. *хәйрчи* id. К. **Хәер.**

Дерив.: **хәерчелек; хәерчелән-ү.**

**ХӘЗӘР, хазар** «хазарин» – бор., инде үлгән халыкларның берсе.

Хәзәрләр турында XIX г. алып күп кенә язылса да, хәзәр теленнән ялгызлык исемнәр һәм титуллар гына билгеле. Этноним үзе бор. яһүди, гарәп, фарсы, рум (Византия), әрмән чыганакларында *х* авазына башланса да, рус. һ.б. чыганакларда *к* белән язылган, мәс., бор. рус. *козаръ*. Хәзәрләр яһүди динендә булгач, ялгызлык исемнәре күбесенчә яһүдичә. *Каган ~ хакан, бәк тархан, шәд* титуллары төркичә. Икенче бер титул *большщ* «каган ярдәмчесе» ~ тат. диал. *булышцы* булса кирәк. Бер кәникә (хан кызының) исеме *Цицак* – нәкъ миш. *цицәк* диярлек; бер тәгин (принц) исеме *Барысбәк* һ.б. Хәзәрләр, күрәсең, мишәрләр, себер татарлары, ш. ук карачай-балкарлар, хәзер башлыча Литвада һәм Кырымда сакланган караимнар кебек цылаштырып сөйләшкәннәр. Караимнар яһүди динендәләр һәм хәзәрләрнең калдыклары булып исәпләнәләр. Аларның теле миш. сөйләшләренә бик якын.

Татарларда, удмуртларда, казакларда ш. ук караимнарда бор. көчле вә залим халык *әләнгәсәрләр, аланксарлар* турында сөйләкләр сакланган һәм монда алан-хазарлар турында сүз бара дип уйлыйлар. Аланнар – бор. бер Төньяк Кавказ халкы, хәз. осетиннарның элгәрләре булса кирәк. Алар хәзәрләр белән союздаш булганнар, күрәсең. Бор. бер чыганакта *хазарик* һәм *булгар* бертуганнар диелә.

Бор. чыганакларда хәзәр теле «төрки тел», «бор. болг. теленә якын» һәм, хәтта «төрки түгел» дип тә язылган. Кайбер тарихчылар соңгы расламаны күтәреп алалар. Ләкин хәзәрләрнең һәрхәлдә идарәче кавеме төрки булганлыгы шик уятмый шикелле.

Угыз төркиләрен берләштерүче Сәлҗук хан Хәзәр илендә тәрбия алган, шунда хәрби хезмәттә булган. Ошбу факт та хәзәрләрнең төркилегенә бер дәлил.

*Хазар, хәзәр, козар, касар* этнонимының чыгышы юраулы. Кайбер тарихчылар (мәс., Гумилёв) «бу төрки сүз түгел» дисәләр дә, охшаш төрки сүзләр табыла, мәс., башк. *ҡаһар* (< *касар*), алт. *казар* «явыз әзмәвер төре» һ.б. З. Вәлиди (Velidi: 415) хәзәрләрнең төрки атамасы *сувар* булган ди.

Гаркави А.Л. Сказания еврейских писателей о хазарах. СПб., 1874; Артамонов М.И. История хазар. Л., 1962; Гумилёв Л.Н. Открытие Хазарии. М., 1966 (шуннан соң күп тапкыр нәшер ителгән); Плетнёва С.А. Хазары. М., 1986; Golden P. Khazar Studies. Budapest, 1980; Гмыря Л.Б. Хазары на Кавказе һәм Петрухин В.Я. Хазарский каганат и его соседи (ике мәкалә дә История татар. Казань, 2002 китабында. Шунда ук арытабангы әдәбият күрсәтелә).

**ХӘ́ЗЕР I** «сейчас; теперь» < гар. *ҳāдир* id. (к. **Хазыйрь);** чув. диал. *хасӑр* (Сергеев 1968: 78), мар. *казыр, кäзыр* id. татарчадан булса кирәк.

**ХӘЗЕ́Р II** «готов, в готовности» < гар. *хāḍир* id. (тат. телендә басым үзгәргән). К. ш. ук чув. *хатĕр*, мар. Т. *хäдĕр* «хәзе́р, әзер; инструмент; кирәк-ярак; әйбер» (Саваткова: 180) болг. теленнән. К. **Әзер, Хәзрәт, Хозур.**

Дерив.: **хәзерле, хәзерсез; хәзерлек; хәзерлән-ү, хәзерлә-ү.**

**ХӘЗИНӘ** «клад; сокровище» < гар. *хазӣнä* id. ш. ук «казна; магазин; мылтыкның үзәк өлеше» ← *хзн* «өю; саклау» фигыленнән, к. **Казна, Магаҗи, Магазин, Мәхзән**.

**ХӘЗРӘТ** «господин; хазрат (может ставиться как перед титулом или именем, так и после; чаще при обращении к духовенству)» < гар. *хäḍрат* «хәзрәт, хөрмәтле кеше; арада булучы; мөһим нәрсә, мөһим зат» ← *хдр* «аеруча булу; әзер булу» тамырыннан, шуннан ук к. **Хә́зер, Хәзе́р, Хозур.** К. Zenker: 384.

**ХӘЙКӘ** (ТТДС I: 461–463; БҺҺ II: 284; БТДҺ: 367) «нашейное украшение; венец, венчик» – ачык түгел. Чаг. **Әкәй.**

**ХӘЙЛӘ** «хитрость» > чув. *хайла*, мар. *кайла, кäйлä* id. < фар. *хӣлä, һӣлä* < гар. *хӣлä* id. К. ш. ук **хәйләкәр** «хәйләгә оста кеше» < фар. *хӣлäк'āр* «хәйлә эшләүче»; удм. *кäлэкэр* «нәзберек кеше» татарчадан булса кирәк.

Дерив.: **хәйләче; хәйләлә-ү.**

**ХӘЙРАН, хайран** «удивлён, смущён; удивительно» < гар. *хäйрāн* id. ← *хӣр* «аптыраашта булу; күз камашу» сүзеннән; шуннан ук иске тат. **хәйрат** «гомуми аптыраш».

**ХӘЙРИЯ [хәйрийә], хәйрият** «благотворительность» < гар. *ҳайрийäт* id. К. **Хәер.**

**ХӘЛ I** «положение, состояние; мощь, сила» ~ чув. *хал*, удм. *кал*, мар. *кал, кäл, ал* (Упымарий: 20, 65) id. < гар. *хāл'* id. К. **Халь.**

Дерив.: **хәлле, хәлсез; хәллән-ү.**

**ХӘЛ II** «решение» < гар. *хäлл* id.

**ХӘЛӘЛ** «праведный; законный; разрешенный», күч. «супруг, супруга» < гар. *хäлāл* id.

**ХӘЛВӘ [хəлwə]** «халва» < гар. *хäлwä* id. Будагов I: 520. К. **Әлбә.**

**ХӘЛВӘТ [хəлwəт]** «уединение (для благочестивых размышлениеий)» < гар. *ҳалwäт* id. Будагов I: 597.

**ХӘЛИФӘ** «халиф, глава всех мусульман» < гар. *ҳалӣфä* id. ← *ҳлф* «(кемнең) вазифасын башкару» тамырыннан, шуннан ук к. **Хәлфә.**

Дерив.: **хәлифәле, хәлифәсез; хәлифәлек, хәлифәт** (< гар.).

**ХӘЛФӘ** иск. «учитель в начальной школе; ассистент преподавателя» < гар. *ҳалӣфä* «урынбасар» сүзеннән мәгъ. үзгәреп ясалган. Чаг. ш. ук. төр. *kalfa* «өйрәнчек, оста ярдәмчесе», госм. «солтан сараенда хезмәтче кызлар башында торган хатын; балаларны өйдән мәктәптән, мәктәптән өйгә йөрткән кеше»

Дерив.: **хәлфәле, хәлфәсез; хәлфәлек.**

**ХӘМӘЛ** «овен (зодиакальное созвездие); название месяца по зодиакальному календарю (22 марта – 21 апреля)» < гар. *хäмäл* «бәрән», себ. *әмәл* < *хәмәл* – яз башы бәйрәме, к. Баязитова 2001: 220–222; Рамазанова 2001: 128.

**ХӘМЕР** «спиртное, водка и всё то, что опьяняет» < гар. *ҳамр* id. ← *хмр* «әчеп чыгу; хәмер булу» тамырыннан, шуннан ук **Махмыр.** *Хмр* тамыры бор. мисыр *hmd* тамырыннан килә.

Дерив.: **хәмерле, хәмерсез; хәмерче.**

**ХӘНҖӘР** «кинжал» < гар. *ҳанҗäр* < ир. *ҳänger*. Киң таралган сүз, шуңа рус. *кинжал* сүзе дә кайтып кала, к. Одинцов Г.Ф. Из истории тюркизмов в русской оружейной терминологии // СТ, № 5, 1983: 14–25.

**ХӘРАБӘ** «развалины, руины» < гар. *ҳарāбä* id. ← *ҳрб* «кыйралу» тамырыннан. К. **Харап.**

Дерив.: **хәрабәле; хәрабәлек.**

**ХӘРАҖ** иск. «харадж, поземельный налог» < гар. *ҳарāҗ* id., к. **Хәреҗ.**

**ХӘРАҖӘТ** «расходы; вложения, финансирование» < гар. *ҳарāҗäт* id., к. **Хәреҗ.**

Дерив.: **хәраҗәтле, хәраҗәтсез; хәраҗәтлән-ү.**

**ХӘРӘКӘ** «харака, надстрочный или подстрочный диакритический знак в арабском» < гар. *хäракä* id. К. **Хәрәкәт.**

Дерив.: **хәрәкәле, хәрәкәсез** (текст); **хәрәкәлә-ү** «хәрәкәләр куеп чыгу».

**ХӘРӘКӘТ** «движение» < гар. *хäракäт* id., шуннан ук к. **Хәрәкә.** *Хрк* «кыймылдау, кымырдау» тамырыннан.

Дерив.: **хәрәкәтле, хәрәкәтсез; хәрәкәтлән-ү; хәрәкәтче**; **хәрәкәтчел, хәрәкәтчән.**

**ХӘРӘМ** «тыелган; изге; мәчеттә изге урын; хатын-кыз бүлмәсе; хатын» < гар. *хäрам* барча шул мәгъ. Шул сүздән фр. теле аша рус. *гарем* «хатын-кызлар бүлмәсе, өе» килә. **Хәрәм** сүзе **харам** сүзеннән гар. телендә үк аерымланган. Бу сүзнең мәгънәләре күп булып, төрле телләргә кергән. Будагов I: 515.

Дерив.: **хәрәмлә-ү, хәрәмләш-ү** «уенда хәйләләү»; **хәрәмлек** һ.б.

**ХӘРБИ** «военный» < гар. *хäрбӣ* ← *хрб* «ярсу, кыйрату» тамырыннан, шуннан ук *хәрб* «сугыш; талаш», к. **Әреп.**

**ХӘРЕҖ,** диал. төрле аерым мәгънәләрдә (к. ТТАС III: 384; ТТДС I: 223, 461) **харыч, җареҗ, җарыж**, «повседневные необходимости», «расходы; дань, налог» ~ башк. (БТДҺ: 367) *хәрез* «матди мөмкинлек; юл азыгы, юл акчасы» < гар. *ҳарҗ* id. ← *ҳрҗ* «акча чыгу» сүзеннән, шуннан ук к. **Хәраҗ, Хәраҗәт, Мәхариҗ > Магарыч.**

**Хәреҗ** сүзе элекке заманнарда «юл азыгы» мәгъ. актив кулланылган. Гомумән исә бу сүз урта фар. *һараха, һарага* < арамей. *һалака* ~ аккад. *илку* «җир өчен түләү-салым» сүзенә тоташа, к. Абу Йусуф ал-Куфи. Китаб ал-Харадж. СПб., 2001: XXVIII.

Рус. *харчи* < *хәреҗ* тур. Отин Е.С. К истории и этимологии слова *харчи* // Этимологические исследования по русскому языку. Вып. VI. Изд. МГУ, 1968: 114–134. Рус. *харчи* сүзеннән *харчевать* «юлда, вакытлыча туклану», шуннан *харчёвня* «юл өстендәге ашханә» сүзе ясалып, татарча ул **хәрчәүнә** булып кайткан.

**ХӘРЕФ** «буква» < гар. *хäрф* id. ← *хрф* «төрләндерү; боргалау» тамырыннан.

**ХӘСИС** (әд. һәм диал., к. Нуртдинов: 73) «подлец; подлый» < гар. *ẋасӣс* id. К. Будагов I: 533.

**ХӘСИТӘ,** диал. **хәсилә, хәсилтә, каситә, касидә** (ТТДС I: 224, 464; ТТДС II: 153, 338) «амулет в форме четырёхугольного или треугольного карманчика, пришиваемого к широкой тесьме», диал. «монисто» – болг. теленнән (*ķ > х, д > т*), гар. *ķаṣӣдä* (к. **Касыйдә**) «махсус шигъри формадагы мактау җыры» сүзеннән: бор. гадәтчә кызлар үзләренә багышланган мактау шигырен бөти итеп йөрткәннәр.

**ХӘСРӘТ,** диал. **хәсерәт, ķәсрәт** «горе, беда», күч. «никудышный человек», (БТДҺ: 368) «слишком, очень даже» > мар. (Исанбаев 1978: 12) *кäсрäт* < гар. *хäсрäт* «кайгы».

Дерив.: **хәсрәтле, хәсрәтсез; хәсрәтлән-ү.**

**ХӘСТӘ́ I** «больной, хворый» к. **Хаста.**

**ХӘ́СТӘ II, хәс** диал. (ТТДС II: 338) «точно как; как-будто; будто бы, якобы» < **хас та** (к. **Хас**).

**ХӘСТӘР**, себ. (Тумашева 1992: 122) **ķастәр** «мера, мероприятие; усердие, рачение; забота» < фар. *хāсдāр* «теләге булган; омтылышлы (кеше)» > чув. *хастар* «тырыш, булдыкды, сәләтле» (чув. сүзенең мәгънәләре фарсычанлыкына якынрак) Федотов II: 313–314.

Дерив.: **хәстәрле, хәстәрсез; хәстәрлә-ү, хәстәрлән-ү; хәстәрчелек; хәстәрчел.**

**ХӘТ** «предел, край» (*хәттин аш-у* «переходить все пределы, быть чрезмерным») < гар. *хäдд* id. ← *хдд* «чик кую» тамырыннан. К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 126) **ķәткә йетү** – *хәткә җиту* – «балигь булу».

*Хәт* сүзеннән тат. актив кулланыштагы **хәтле** (бәйлек) һәм **хәтсез** «чиксез» сүзләре ясалган.

**ХӘТӘР,** диал. **ķәтәр** «опасный, опасно» > мар. удм. *кäтäр, катар,* чув. *хатар, хатер* id. (Бу сүз барча мәзкүр телләрдә «бик тә, гаять» мәгъ. дә кулланыла, к. Сергеев 1971: 78) < гар. *ẋаṭар* id., к. **Хәтер.**

Дерив.: **хәтәрле, хәтәрсез (→ хәтәрсезләндер-ү); хәтәрлән-ү; хәтәрлек** һ.б.

**ХӘТЕМ** «поминки» < гар. *ẋатм* «соңгы нокта, бетем» ← *ẋтм* «бетерү, тәмамлау» (асылда «түгәрәкләү») тамырыннан, шуннан ук әд. **хатимә** «йомгаклау, эпилог». К. Будагов II: 524.

**ХӘТЕР** «память; самосознание; достоинство личности» < гар. *ẋāṭр* «хәтер; сак булырга кирәклек» ← *ẋṭр* «сак булу; истә тоту» тамырыннан, шуннан ук **хәтәр** «куркыныч», **хәтәрле** «куркынычлы», шуннан эллипсис буларак **хәтәр** сыйфаты килеп чыккан. К. **Хатирә.** Будагов I: 525–526.

Дерив.: **хәтерле, хәтерсез; хәтерлә-ү.** Идиомалар: **хәтер калу, хәтерен калдыру, хәтерен саклау.**

**ХӘТТА** «даже» < гар. *хäттā* id.

**ХӘТФӘ,** диал. **ķәтфә** «бархат; плис» ~ гаг., төр. һ.б. *kadife* ~ кабарда. *ķәдабә* id. Чаг. тув. *канихве* < **канифә* «хәтфә, камка» ~ хак., тув. *канфа, хаңма, каңма* «хәтфә, камка» ~ монг. *ханфу* < кыт. *han-fou* id. Икенче яктан фар. *кимһа, камһа* «камка» < кыт. *gimhua* id. Шулай итеп **хәтфә** һәм **камка** сүзләре үзара тоташкан ике алынма тамырдан киләләр. К. Аникин: 257.

**Хәтфә гөле** ~төр. *kadife çiçeği* < гар. *ķаṭӣфä* «бәрхет гөле» (ләкин бу сүз гарәпнеке түгел).

**ХӘҮЗӘ [хәwзә]** иск. «бассейн; пруд» к. **Хәвез.**

**ХӘЧТЕРҮШ** «незадачливый хвастун» < әрм. *хачакруц* «тәреле, хачлы; тәре йөртүче» сүзеннән булса кирәк (Болгар һәм Казан дәүләтләрендә әрмәннәр дә яшәгән), к. чув. *Качикруш паттăр* – әкият батыры исеме.

**ХӘШӘП** иск. «бестолочь, охломон» < гар. *хäшäб* «кискә, түмәр, утын». Бу сүз иске шәкертләр жаргонында кулланылган. Иске төрки *хәшәб* «агач башмак».

**ХӘШӘР** иск. «помочь, ополчение» < гар. *хäшäр* id. К. **Хәшәрәт.**

**ХӘШӘРӘТ** «гад, гадина» > мар. *хäшäрäт* id. < гар. *хäшäрāт* «бөҗәкләр җыены», *хäшäрат* «җыен, җыелыш» ← *хшр* «җыелу, җыю; ташыту», шуннан ук к. **Мәхшәр, Хәшәр.**

**ХӘЯ [хәйа]** «стыд; приличие» < гар. *хäйā’* «хәя, яшәү кагыйдәсе» ← *хйй* «яшәү» тамырыннан. Шуннан ук **хәят** «яшәү, тормыш, җанлылык».

Дерив.: **хәялы, хәясыз** (киң кулланыла).

**ХӘЯТ [хәйат]** < гар. *хäйāт* id. ← *хйй* «яшәү» тамырыннан, к. **Хәя.**

**ХЕЗМӘТ** «труд; услуга» > мар., удм. *кизмат, кызмат,* удм. *хӗзмäт,* чув. *хӗсмет* id. < гар. *х̣иӟмäт* id. ← *х̣ӟм* «хезмәт итү, эш күрсәтү» тамырыннан, шуннан ук **Хадим.**

Дерив.: **хезмәтче**; **хезмәтчел; хезмәтләндер-ү**. Идел-Урал регионында тат. **хезмәтче** (башк. *хезмәтсе*) > мар., удм. *кызматче* «батрак». К. түбәндәгене.

**ХЕЗМӘТКӘР** «слуга; служащий» < фар. *х̣иӟмäтк'āр* id. (*х̣иӟмäт, х̣идмäт* «хезмәт» сүзе нигезендә ясалган). Мәгънәсе бераз аермалы булган **хезмәтчән** сүзе дә бар (**хезмәт иясе** дә диелә).

**ХЕТ,** диал. **хыть, хуть** «хоть» ~ чув. *хуть*, мар. *хыть, хоть*, мар., удм. *коть* < рус. *хоть*, к. Махмутова 1978: 243. Рус. *хоть* «теләсәң ки» мәгъ., *хотеть* «теләү».

**ХИБЕС** иск. «заключение (в тюрьму), арест» < гар. *хибс* id. К. ш. ук **хибесханә** «алдан бикләп тоту урыны» < фар. *хибсхāнä* id. К. **Мәхбүс.**

**ХИКӘЯ [хикәйә]** «рассказ; повесть» < фар. (< гар.) *хикāйä, хикāйäт* id., шуннан ук **хикәят** «повесть», *хкй* «сөйләү, хикәяләү» тамырыннан (башкорт филологлары **хикәя** һәм **хикәят** сүзләрен аералар һәм бу тарихтагыча дөрес тә).

**ХИКМӘТ** «мудрость, потайной смысл», диал. «хитросплетения» < гар. *хикмäт* id. *хкм* «буталчыкны хәл итү, чияләнгән төенне чишү; нәтиҗә чыгару» тамырыннан, шуннан ук **Әкәмәт, Хаким, Хөкем, Хөкүмәт** һ.б.

Дерив.: **хикмәтле, хикмәтсез; хикмәти.**

**ХИЛАФ** «противоречит; противоречащий (чему); недопустимый» < гар. *х̣илāф* id.

Дерив.: **хилафлы, хилафсыз; хилафлык.**

**ХИЛГАТЬ [хилғәт]** «почётное платье; халат» < гар. *х̣ил'ат* id., к. Будагов I: 536 (тәфсилле аңлатма). Шуннан ук **халат** сүзе дә килә.

**ХИЛЕ, хәйли** иск., диал. (Арсланов 1986: 52; ЗДС: 162) **гыйлы, хыйлы** «изрядно; много» ~ нуг., ком. *хилы* < фар. *х̣äйлӣ* id. ← *х̣äйл* < гар. *х̣айл* «табыр, талпа».

**ХИМАЯ [химайә]** «защита, покровительство, охранение» фар., гар. *химāйä* id. ← *хмй* «яклау».

Дерив.: **химаяле, химаясез; химаяче, химаячелек.**

**ХИНГӘЛ** «хинкал» к. **Иңкәл.**

**ХИНЗИР** иск. «свинья, свинина» < гар. *х̣инзӣр* id.

**ХИРКА** «дервишское одеяние; лохмотья» < гар. *х̣ирк̣а* id.; хирка төрләре тур. к. Будагов I: 532 (тәфсилле, кызыклы мәгълүмат).

Дерив. **хиркалы** «хирка кигән», күч. «дәрвиш».

**ХИРЫС** «корысть; (недоброе) желание» < гар. *хирс̣* «көчле теләк; хирыс» ← *хрс̣* «үтә сакчыл булу» тамырыннан (**Харис, Харрас** «сакчы» исемнәре шул ук тамырдан).

Дерив.: **хирыслы; хирыслык; хирыслан-у.**

**ХИС** «чувство» < гар. *хисс* id.; шуннан ук **хиссият** «хисслелек» ← *хсс* «сизү, тою».

Дерив.: **хисле, хиссез; хислән-ү; хисчән.**

**ХИСАП** «счёт; отчёт» > чув. *хисеп* id. < гар. *хисāб* id.

**Хисап** – продуктив сүзьясагыч нигез: **хисапла-у; хисаплы, хисапсыз** һ.б. К. **Исәп.**

**ХИТЛАН-У, хыйтлан-у** «замучиться; переживать невзгоды», «зря стараться» < болг. *хыйтлаң-* id. *хыйтт* < гар. *к̣ахт̣* «ачлык; йот; корылык» сүзеннән, к. чув. *хыт [хыйт]* «авырлык, кыенлык» (бу сүз *кытă* < *к̣аты* сүзе белән контаминацияләнгән), *хытлан-* «кытлану» һ.б. К. **Кытлык.**

*Х* авазы тат. телендә һәрвакыт каты әйтелгәнлектән, **хыйтлан-у** дип (хәреф арттырып) язуның хаҗәте юк.

**ХОДА́ВӘНДӘ [хŏдаwәндә]** «о боже милостивый (употребляется при уповании на Бога как восклицание при жалком зрелище, событии, а также при виде необычайной красоты ребёнка, девушки и т.д.)» < фар. *х̣удāwäндӣ, х̣удāwäндäн* id., *х̣удāwäнд* «үзе яшәүче, үзе булучы» (*х̣ӯд* «үзе» һәм *äwäнд* «килүче, торучы, яшәүче»). К. **Хода.** Будагов I: 530.

Тат. сөйләшләрендә һәм хәз. әд. телдә дә **ходабәндә** дип әйтү һәм язу очрый. Ләкин фар., төр. һ.б. чыганакларның берсендә дә *худабäндä* дип язылмаган һәм язылмый. Элекке (революциягә

кадәрге) әдипләребез дә бу сүзгә **бәндә** сүзен кыстырмаганнар.

**ХОДАЙ, хода** «Бог, Всевышний» < фар. *ḫудā, ḫудāй* id. < бор. ир. *qa-dhata* ~ санск. *sva-dhita* «үз законын булдыручы, үзе бирүче» (Platts: 487). Бу сүз төрки телләргә бик бор. заманнарда ук кергән, к. алт., тув. һ.б. *қудай* «мәҗүси тәңреләрнең берсе». Гомумән, *ходай* < *худай* барча мөселман халыклары телләренә *Аллаһ* сүзенең синонимы буларак таралган. К. Joki 1952: 205.

**ХОЗУР** «достойно лицезрения, восхищения видом; лицезрение знатного лица» < гар. *ḫуḍур* id. К. **Хазыйрь, Хәзер, Хәзрәт.**

**Хозур** продуктив нигез: **хозурлан-у, хозурлы. Хозурында** «алдында, катында, каршында», *Аллаһ хозурында, солтан хозурына керү.*

**ХОЛЫК** «нрав» < гар. *ḫулқ* id. ← *ḫлқ* «ясау, төзү» тамырыннан. Шуннан ук **Әхлак, Мәхлук, Халык.**

**ХОНСА** «гермафродит» < гар. *ḫунҫā* id. К. Будагов I: 538.

**ХОРАФАТ** «предрассудок; суеверие; ересь» < гар. *ḫӯрāфāт* «юк-барга ышанулар», *ḫурāфā* ← *ḫрф* «акылы юк, акылдан язу». *Хāдиҫел-ḫӯрāфāт* – Хурраф дип аталган бер бәндәнең үзенең җеннәр арасында яшәгәнлеге турында сөйләгәннәре (барон Мюнхаузен сөйләгәннәре шикелле әкиятләр). Будагов I: 531.

Дерив.: **хорафатчы, хурафатчыл.**

**ХОРТУМ** «хобот (слона)» < гар. *ḫурṭӯм* id. Гомумән, бу гарәп сүзе түгел.

**ХОСУС** «(особое) отношение» (**хосуста, хосусында** «относительно кого, чего») < гар. *ḫуҫӯҫ* id.; шуннан *ḫуҫӯҫӣ* > тат. **хосусый.** К. **Махсус, Хас.**

**ХӨҖРӘ** «келья» < гар. *ḫуҗра* id.

**ХӨКЕМ** «решение суда; суждение; режим» < гар. *ḫукм* id. ← *ḫкм* «авыр мәсьәләне чишү» тамырыннан, к. **Мәхкәмә, Хаким, Хәким, Хикмәт, Хөкүмәт**.

Дерив.: **хөкемле, хөкемсез; хөкемдар; хөкемче.**

**ХӨКҮМӘТ** «правительство» < гар. *ḫукӯмäт* id. К. **Хаким, Хөкем.**

**ХӨЛЛӘ** иск. «шёлковый халат» < гар. *ḫуллä* id.

**ХӨР** «свободный» < гар. *ḫурр* id. ← *ḫрр* «азат итү» тамырыннан. Шуннан ук **мөхәррир** «(хаталардан) азат итүче». К. ш. ук **Ихтыяр, Хөррият.**

Дерив.: **хөрлек.**

**ХӨРӘСӘН** «неустойчивый и ленивый (человек)» – Н. Исәнбәт буенча *Хөрәсән ялкавы* – Хөрәсән (*Хорасан*) илендә укып кайткан шәкертләр кушаматыннан. *Хөрәсән* < фар. *Ḫурāсāн* топонимы бор. фар. *hwara sanna* «кояшлы җир, кояшка караган» сүзеннән. Иранның көнчыгышы күз алдында тотылган. Будагов I: 530.

**ХӨРМӘ** «финик» < фар. *ḫурмā* id. > рус. *хурма.*

**ХӨРМӘТ** «уважение» < гар. *ḫурмäт* id. **Хәрәм** белән тамырдаш.

**Хөрмәт** продуктив нигез: **хөрмәтлә-ү; хөрмәтле, хөрмәтсез.**

**ХӨРРИЯТ [хөррийәт]** «свобода, полноправие» < гар. *ḫуррийäт* id. Ләкин гар. телендә бу сүз үзе бездәгечә киң кулланылмый. Төрки телләрдә бу сүз күптөрле оешмалар, газет-журналларның атамасы буларак билгеле. К. **Хөр.**

Дерив.: **хөрриятче** хөррият оешмасының актив әгъзасы; «Хөррият» дигән газет һ.б. хезмәткәре.

**ХӨРТИ, хөрт** «плохо, неважно» < фар. *ḫурд* id.

**Хөрти** – продуктив нигез: **хөртилән-ү, хөртилек (хөртлек)**; диал. **хөрт-ү** > **хөтү** «начарландырып җибәрү» (Кандыра, Башкортстан).

**ХӨСЕТ [хөсөт]** «злодеяние от зависти» < гар. *ḫäсäд, ḫусуд* id. ← *ḫсд* «көнләшү, көнчелек кылу».

Дерив.: **хөсетле, хөсетсез; хөсетчән, хөсетче; хөсетчелек.**

**ХӨТБӘ** «проповедь» < гар. *ḫуṭбä* id. ← *ḫṭб* «мөрәҗәгать итү» тамырыннан, шуннан ук *ḫаṭӣб* > тат. **хатип, хатыйп** «дингә өйрәтүче, вәгазь сөйләүче», *ḫиṭаб* > тат. **хитап** «обращение».

**ХӨТНӘ** «полушёлковая ткань, кутня» < болг. **хөтнә, *хүтнә* ~ төр. *kutni, kutnu*, к.-балк. *қутуне* < гар. *қуṭн, қуṭнӣ* id. – киң таралган халыкара сүзләрдән, к. ит. *cotone*, инг. *cotton*, ним. *kattun* id. һ.б. Гар. сүзлекләрендә *қуṭнийä* «хөтнә» сүзен *қṭн* «урнаштыру; урнашу» тамырына нис-

бәтлиләр. Фасмер II: 434–435; Kluge: 478; Аникин: 336, 763.

**ХРАМ** «храм» < рус. Рус телендә бу сүзнең тулы сузыклы (полногласный) *хором* (*хоромы*) «зиннәтле зур сарай» мәгънәсендәге пардашы-тамырдашы да актив кулланыла.

Фасмер (IV: 265, 273) *храм, хоромы* сүзенә багышланган зур мәкаләләрендә бу сүзләр тур. төрле фаразлар китерә, тик гар. *äxpāм* «яшерен гыйбадәтханә» (*хәрәм* сүзенең күп.) сүзен искә алмый. Хәлбуки **храм** сүзе нәкъ *äxpāм*нан булса кирәк. Чөнки бор. христианнарның гыйбадәтханәләре яшерен булган.

**ХРИСТИАН** «христианин» – асылда тат. теленең үзендә ясалган сүз, чөнки рус. *христиан* мондый формада кулланылмый (*христианин* диелә, күп. – *християне*, ә *христиан* формасы **християне** сүзенең *родительный падеж*ы). Рус. *христиан-* нигезе – грек. *χριστιανος* «христиан», төп. мәгъ. «үзенә май ягылган» дигән сүз.

Татарлар озак заманнар дәвамында *христиан* сүзен кулланмаганнар, аның урынына *насари* дигәннәр. К. ш. ук **Крестьян. Христиане ~ крестияне** сүзләре тур. рус. лингвистикасында күп язылган.

**ХУАТ, хуwат, хыwат** (ЗДС: 703–704) «хорошо; мощно; удачно; мощный, удалой» – диал. сүзлектә гар. сүзе дип бирелгән. Ләкин бу сүзнең мишәрләрдә генә кулланылуы һәм мәгънәсе үзенчәлекле булуы аның **куәт** (к.) сүзеннән үзгәреп килеп чыгышына шикләнеп карарга мәҗбүр итә. Рус. *хват* «шәп, көчле, будыклы» сүзеннән түгелме икән (к. Лермонтовта: *Полковник наш рожден был хватом, Слуга царю, отец солдатам…*).

**ХУҖА,** себ. (Тумашева 1992: 136) **куца** «хозяин, владелец, владетель», диал. (себ. һ. б. ш.) «господин, мистер; дядя», «невидимый дух – хозяин объекта», (ТТДС I: 462) «муж» ~ башк. *хужа*, чув. *хуҫа, хоҫа* ~ мар. *хоза, оза, озя* (< болг. *ьоз'а*), удм. *кузе, кузё*, рус., коми. *ко́зя* «хуҗа, явыз рух; ия», морд. *козя* «бай (кеше)» < фар. *x̧ʷāҗӓ* < бор. ир. *xwaǯa* «хуҗа, ия, биләүче», бик күп телләргә кергән һәм күп мәгънәләр алган сүз. Идел-Урал телләрендәге мифологик мәгънәсе аерым игътибарга ия. Рус., морд. Э. *кузя, кузька*, коми. *кузь* «өй иясе, бичура, шүрәле» сүзе дә **хуҗа** сүзеннән булса кирәк (гадәттә, бу сүзне грекчадан килгән *Кузьма* исеме сүзеннән дип аңлаталар). Төркиядә, Урта Азиядә һ.б. *хоҗа ~ hoca* башлыча «әфәнде, карый; җитәкче; остаз, профессор һ.б.ш.» мәгъ. кулланыла, бу мәгънә тат. сөйләшләренә дә кергән (**Хуҗа Насретдин** дигәндә **хуҗа** шундый мәгънәдә). Будагов I: 539–540 (бик тәфсилле аңлатма); Федотов II: 371 (әдәбият күрсәтелә). Рус. *хозяин* тур. Аникин: 618–619, 765. Рус. *кузькина мать* тәгъбире тур. Добродомов И.Г. // Русская речь, № 1, 1990.

Дерив.: **хуҗалы, хуҗасыз; хуҗалык** һ.б., к. **Хуҗай.**

**ХУҖАЙ, хаҗәй** (ТТДС I: 462) «хозяйство» > манси. *кусяй* «хуҗа, ия» < фар. *x̧ʷāҗāй, x̧ʷāҗāгӣ* «хуҗалык, хуҗа булу». Рус. **хозяй (→ хозяй-ство, хозя-ин, хозяй-ка, хозяй-ничать)* сүзе татарчадан булырга тиеш (хәлбуки рус этимологиясендә мәзкүр сүзләр һәрдаим чувашчадан дип тәгърифләнә).

**ХУМ** «огромный горшок, кувшин (для хранения зерна, запасов воды)» < фар. *x̧ӯм, x̧ӯмб* < авест. *xumbha* id. (Paul: 99–100). Чаг. **Комган.**

**ХУП** «хорошо, ладно; прекрасно» < фар. *x̧ӯб* ~ сугд. *γwb* id. (к. ЯТ: 362) ~ пәһл. *khwap*, авест. *hvapa* < *huapa* ~ санск. *su-apas* «матуррак» (Platts: 495).

Дерив.: **хупла-у, хуп-мәхуп** (ироник хуплау сүзе).

**ХУР I** «унижен, оскорблён; считается никудышным (употребляется только в связанных сочетаниях)» ~ чув. *хур, хор,* удм. *кор*, мар. *ор* < *хор* < фар. *x̧ʷāp* «ярлы, мескен» < авест. *qwar, kwar* ~ санск. *swar* id. к. Platts: 403. Икенче бер версия буенча, фар. *хор* < авест. *xaδru*, к. Paul: 109; Будагов I: 541; Федотов II: 360 (күп төрки телләрдән мисаллар китерелә).

Дерив.: **хурлык; хурла-у, хурлан-у.**

**ХУР II** «гурия, райская дева» < гар. *хӯр* id. ← *xwp* «кара күзле булу» тамырыннан.

**Хур II** сүзе гадәттә **хур кызы** тәгъбирендә кулланыла.

**ХУРАЗ** «боевой петух» к. **Кураз.** Асылда грек сүзе, к. Будагов I: 533.

**ХУТ I** «созвездие кита»; название зодиакального месяца «рыба» (21 февраля – 22 марта) < гар. *хӯт* < грек., к. **Кит.**

**ХУТ II** сөйл. «ход» ~ чув., мар. һ.б. *хут* < рус. (гом. слав. сүзе).

Дерив.: **хутлы** «яшы йөри, йөгерә торган», **хутсыз;** фраземалар: **хутка китү; эш хутта** һ.б.

**ХУШ** «хорошо, добро; приятный (о расположении духа)», модаль сүз мәгъ. «до свидания; прощай, пока» < фар. *х̣ӯш, х̣ōш* < бор. ир. *γwš* «яхшы хәбәр; сөенеч» (к. ЯТ: 363). Фар. телендә *хуш* сүзе нигезендә күп кенә кушма сүзләр ясалган һәм алар төрки телләргә таралган, к. Будагов I: 541–542.

Дерив.: **хушлык** (мәс., *күңел хушлыгы өчен* дигәндә); **хушлан-у** «канәгатьләнү», иске **хушла-у; хуш** «сау бул» ← *хуш калыгыз (булыгыз)* дигәннән эллипсис. К. түбәндәгеләрне.

**ХУШАВАЗ [хушаwаз], хушавыз [хушаwы̆з]** «жанр песни-оды (исполняемой главным образом на свадьбе)» < *хуш аwаз* һәм *хуш авыз* (буталган). К. **Куштан.**

**ХУШАМӘТ, хушамад, хушамят** (Старчевский 1893: 35; ГТРС: 668) «добро пожаловать; лесть, комплимент» ~ төр. *ħoşamedi* id. < фар. *х̣ӯш āмӓдӣ* «хуш килдегез, хуш киләсез» һәм *х̣ӯшāмӓд* «комплимент» сүзләреннән (төрки телләрдә фарсыча ике сүз берләшкән). Чаг. ш. ук уйг. *хушамәт* «комплимент», каз. *кошамет* «тантаналап каршылау» К. **Кушамат I.** Будагов I: 542.

**ХУШБУЙ** «духи; одеколон» > мар. *кушбуй*, удм. *кушвой* id. < фар. *х̣ӯш бӯй* «хуш ис».

**ХЫЗЫР, хизыр** (**Хизыр пәйгамбәр**) «Хизр, Хидр – мифический пророк». *Х̣идр* дигән могҗизалы зат тур. легендалар Шумер-Аккад заманнарыннан (б.э. кадәр ике мең ел элек) булган. Шумерча бу сүз «яшел кеше; мәңге яшел» мәгъ. дә булган.

Татарларда *Хызырильяс* ~ төр. *ħederillez* бербөтен изге зат кебек күзаллана. Тарих чынбарлыкта Хызыр һәм Ильяс исемнәре аерым ике чыганактан киләләр (**Ильяс** – яһүдичәдән). Әмма Якын Шәрыктә **Һарут** һәм **Марут** (к.) тур. сөйләкләрне Хызыр һәм Ильяска нисбәтләгәннәр. Хызыр турындагы риваятьләр мөселманнар арасында киң таралган.

Мәңге яшәр Хызыр тур. бихисап хикәятләрнең берсенә нигезләнеп, без «Илдусның беренче сәяхәте» дигән озын поэма-повесть язган идек. Ул балалар газетында басылып чыкты, тик аны китап итеп чыгара алмадык. Хызыр турында элегрәк (XX г. башында) язылган икенче бер – кечерәк поэма да бар, тик ул сатирик планда (бер сукбай үзен Хызыр дип игълан итә).

Шумерча *Хиӡр* «мәңге яшел» сүзе бик бор. *киӡр ~ киçр ~ кифр* «кедр (агачы)» сүзеннән килә дип уйлыйлар. Шуннан ук **Кипр** утравы атамасы һәм латинча *купр-ум* «бакыр» сүзләре килә (элек Кипрда бай бакыр мәгъдәне учаклары булган). Шумерлар, үз якларында әйбәт төзелеш агачы үсмәгәч, озын, юан бүрәнәләрне Ливан аша Кипрдан китерткәннәр.

*Хызыр* тур. күп язылган. Мәс., төрекчә *Milli folklor* журналының бер (2002, № 54) санында гына өч мәкалә бар!

**ХЫР: хыр-хыр** – подражание хрипу, хрипению. Күрәсең, халыкара тәкълиди сүз.

Дерив.: **хырыл-хырыл; хырылда-у, хыр-хырла-у** һ.б.

**ХЫШ: хыш-хиш** – подражание тяжёлому дыханию (без взрывов и хрипов), звукам перед кашлем (но не звука кашля). *Х* авазын әйтүдән килеп чыккан.

Дерив. **хышылда-у.** Чаг. ш. ук **гыжылда-у.**

**ХЫЯЛ [хы̆йал]** «мечта; грёзы» < гар. *х̣айāл* «уй, планнар; хыял»; шуннан ук *х̣айāлӣ* > тат. **хыялый** «фантастик; фантазёр; акылдан язган, шашкан». Будагов I: 544; ГТРС: 668.

Дерив.: **хыяллы, хыялсыз; хыяллан-у; хыялыйлык; хыялыйлан-у;** сөйл. **хыялчан.**

**ХЫЯНӘТ [хы̆йанәт]** «измена, предательство; вероломство» < гар. *х̣ийāнӓт* id. ← *хwн* «хыянәт итү», шуннан ук **Хаин** (к.).

Дерив.: **хыянәтче, хыянәтчел, хыянәтчелек; хыянәтлек.**

# һ

**һ** авазы төп төрки телләрдә фонема белдермәгән; ул гар. вә фар. алынмалары белән кергән һәм тат. теленең төп сүзлегендә кайбер ымлыкларда вә тәкълиди сүзләрдә очрый (мәс., *һау-һау, һе, һи*).

**һАВА [haºwa]** «воздух» (**һавалар** «погода») < гар. *һäwā'* «һава; җенси дәрт, инстинкт; тәкәбберлек, минминлек». Будагов II: 316. К. **һавалан-у.**

Дерив.: **һавалы** «тәкәббер, масаючан».

**һАВАЛАН-У** «воспарить (мыслью, духом); возгордиться (бездумно)» < иске тат. *һawaилан-у* id. ← *һawaи* «хискә бирелүчән» < гар. *һäwā'ū* id. ← *һäwā'* «һава». Будагов II: 36.

**һАЙ** – междометие, выражающее сожаление < төр., фар., бор. төрки (ДТС: 197) *һай* id. Будагов II: 311. **һай-һу** «төрле кычкырыклар» сүзе < фар. Ләкин төрки телләрнең үзендә дә охшаш ымлыклар бар: тат. *һай-һай, ай-һай*; як. *һай* «терлекләрне куу ымлыгы». Чаг. *әйдәү* ~ *һәйдәү*.

**һАЙТ** – междометие, которым пугают пугливых и гоняют скот – тат. теленең үзендә *айт* ымлыгыннан (ш. ук мәгъ.) килеп чыккан, к. чув., мар. *айт* id.

**һÁМАН**, диал. **әмән, аман** «всё ещё» > чув. *хаман* < фар. *һämān* «шул ук; һаман» – *һәм* сүзе нигезендә ясалган. Тат., башк. *һаман* сүзе төптә *һаман саен* тәгъбиреннән эллипсис. Будагов II: 314.

**һАТИФ** «гений, ангел-хранитель, ангел-вдохновитель» < гар. *һātиф* «кычкырып тәбрикләүче; вөҗдан авазы». **һатиф** сүзе Г. Тукай, Ш. Бабич әсәрләрендә поэтик мәгънәдә кулланыла.

**һӘВӘС [һәwәс]** «влечение, желание» < гар. *һäwäс* id. *һwc* «тою, хис итү» тамырыннан. К. **Әвәс, һәвәскәр.**

Дерив.: **һәвәсле; һәвәслән-ү** һ.б.

**һӘВӘСКӘР** «любитель; самодеятельный» < фар. *һäwäск'äр* id.

Дерив.: **һәвәскәрлек** һ.б.

**һӘЙ** «гей (возглас)» чаг. **һай.**

**һӘЙКӘЛ** «памятник, статуя» < гар. *һäйкäл* «һәйкәл; гыйбадәтханә» << шумер. *haj kal* «үлгәннең өе», икенче бер версия буенча «зур өй».

**һӘЙһАТ** – восклицание горестного удивления, «погибель» < гар. *һäйһāт* id. Л. Будаговта (II: 317) бу сүзнең мәгънәсе дөрес бирелмәгән.

Алтын Урда Аксак Тимер тарафыннан җимертелгәч, татарлар **һәйһат** дип Урта вә түбәнге Идел һәм Дон бассейнындагы буш калган җирләрне атаганнар.

**һӘЛАК** «погибель, гибель», диал. (ЗДС: 704), **һаләк, һал'ак, һайлак, һәлак, һәләк** «очень» < гар. *һäлāк* id. К. **Әләк, һәлакәт.**

**һӘЛАКӘТ** «бедствие, гибель» < гар. *һäläкäт* id. ← *һлк* «һәлак булу» тамырыннан. Төбендә һинд. *hark* id. сүзеннән.

**һӘМ** «и (союз)» < фар. *һäм* id., к. **һәммә.** Будагов II: 314.

**һӘМИШӘ** «всегда» < фар. *һäмūшä* < авест. *hamatha* id. Platts: 1235.

**һӘММӘ** «все вместе» < фар. *һäмä, һäммä* «бергә җыюлы» бор. ир. *ham* ~ бор. һинд. *sam* «бергә» (~ слав. *сон* > *со* > *с*) сүзеннән килә. Абаев I: 134.

**һӘР**, диал. **әр** «каждый» > чув. *хар*, мар., морд. М. *äр, эр* id. < фар. (к. Будагов II: 312–313) *һар, һäр* < бор. ир. *haruva* < *haurva* ~ бор. һинд. *sarva* id. Абаев I: 48. К. **һәргиз.**

**һӘРГИЗ** «всегда, каждый раз» < фар. *һäр гэз: гэз ~ гиз* «тапкыр, мәртәбә». Бу тәгъбир кире җавапта «булыр әле, ашыгыч түгел» мәгъ. кулланыла.

**һӘҮКӘШ [һәwкәш]** «бурёнушка, бурёнка (корова)», себ. (Тумашева 1961: 232) **әүшкә** id. (в детском языке) < фар. *г'āw, г'āwäк* «сыер, һәүкәш» ← һинд.-евр. **gwou* «сыер, сыер заты» (шуңа рус.

*говядина* «сыер ите» һәм *гов-но* «сыер тизәге» сүзләре тоташа). К. ш. ук тат., башк. *һәү-һәү* «сыерны чакыру ымлыгы» (ихтимал ки, бу сүз фар. теленнән түгел, бүтән һинд.-евр., мәс., скиф яисә тохар телләреннән калгандыр). Тат. **һәүкәш < һәүкәч** (*-кәч* иркәләү кушымчасы), к. түбәндәгене.

**ҺӘШ** – слово, которым гоняют коров ~ ком. (Будагов I: 400) *хац-хац* id. < фар. *г'āwэш* «начар сыер» (*-эш* «начарайту» кушымчасы) яисә *һәү, эш!* (гом. төрки *эш* «китү, итү, качу») сүзләреннән. К. **һәүкәш.**

**Һәш, түгә** ымлыгының икенче өлеше дә фарсычадан. к. **Түгә, Түгәнәй.**

**ҺЕ** – междометие, выражающее понимание слов собеседника: «ага; ну; во как» ~ фар., төр. һ.б. *һа, һә* id.

**ҺИҖРӘТ** «переселение, эмиграция» < гар. *һиҗрат* ← *һҗр* «аерылып, ташлап китү; күченү», шуннан ук **мөһаҗир** «эмигрант». К. **Һиҗри.**

**ҺИҖРИ** «начинающееся со дня переселения пророка Мухаммеда из Мекки в Медину – о летоисчислении (конкретно – с 622 г. христианской эры)» ← *һҗр*, к. югарыда. Шуннан **һиҗрия** «һиҗри ел исәбе». Будагов I: 311–312.

**ҺИНДИ** «индийский; индиец» < гар. *һиндӣ* id. ← *Һинд* (елга һәм ил атамасы), шуннан ук **Һиндстан** < фар. теленнән. **Индия** варианты рус һәм Европа телләреннән.

**Һинди** дип элек Һиндстанда укып кайткан зыялыларны да атаганнар (чаг. **бохари** «Бохарада укып кайткан»).

**ҺИЧ,** диал. **ич** «никак; никакой возможности» (чаще употребляется в составе сложных отрицательных местоимений в качестве морфемы отрицания: **һичкем** «никто», **һични, һичнәрсә** «ничто», **һичбер** «ни один, ни разу» и т.п., много слов) < фар. *һӣч* id., к. Будагов II: 317.

**ҺОМАЙ, һөмәй** (дип тә әйтелә, сүз китап теленнән кергәнлектән, аны төрлечәрәк укыганнар) «мифическая птица счастья, которая гнездится и выводит птенцов в воздухе; на кого падёт её тень, тот будет счастлив; её могут видеть только абсолютно безгрешные люди» (к. Ялчыгул Т. Рисаләи Газизә. Казан, 2001: 179) < фар. *һумāй, һумāйӯн* «мифик бәхет кошы», бу кошның сурәте тәхет артлыгында ясала торган булган һәм ул һәр патшаның химаячесе булып исәпләнгән. Бу бор. ир. мифологема төркиләргә б.э. I меңьеллыгында ук үтеп кергән, к. **Умай.** Славяннарга ул шул заманнарда яисә шуннан да элек кергән булса кирәк, к. рус. һ.б. слав. телләрендә *Гамаюн* – кодрәтле мифик кош.

**ҺӨДҺЕД [һөдһөд]** «удод» < фар. < гар. *һудһуд* id. бу кошның характерлы авазына карап аталган.

**ҺӨҖҮМ** «нападение» < гар. *һуҗӯм* id.

Дерив.: **һөҗүмче; һөҗүмлә-ү** (сирәк кулланылалар).

**ҺӨНӘР,** диал. **өнәр** «ремесло, профессия», удм., мар. *öнер, үнäр, онер*, чув. *ĕнер* id. < фар. *һунäр* < авест. *hunara* id. К. ш. ук тат. **һөнәрмән** < фар. *һунäрмäнд* «һөнәр белүче, специалист».

**Һөнәр** продуктив нигез: **һөнәрле, һөнәрсез, һөнәрче** һ.б.

**ҺУНН, һунну** «гунн, хунн (название древнего народа)». Татарча һәм күп халыкара чыганакларда шулай языла. К. Гумилёв 1960; БРЭ 8: 160–161 (бай әдәбият), к. ш. ук **Сөн.**

**ҺУ-ҺУ** – благочестивое восклицание дервишей и очень религиозных людей; хәз. сөйл. телендә – **һу!** – гаҗәпләнүдән яки сокланудан кычкырып җибәрү ымлыгы – мөселман мистерияләрендә әйтелгән *һу!* ымлыгыннан, к. Özön: 331. Гар. *һӯ* «ул (Аллаһ)» сүзеннән.

**ҺУШ** «ясное сознание, способность реально оценивать ситуацию и происходящее» < фар. *һӯш* id. К. ш. ук **Уш.**

Дерив.: **һушлы, һушсыз** (киң кулланыла торган сүзләр); **һуш китү, һушы кичү** һ.б.

# Ц

**Ц** авазы гом. төрки *ч* урынында тат. теленең миш. һәм Себер сөйләшләрендә (башлыча бер үк сүзләрдә) очрый һәм һәр очракта бор кыпчак-куман теленнән килә: бу аваз тагы кар., к.-балк. телләрендә, кырг. сөйләшләрендә, төрки телләрдән тыш монгол телләрендә очрый. Аның бор. төп чыганагы бәхәсле. Төрки һәм монг. *ц*ылаштыруының генезисы аерым дигән фикер бар. Шулай ук куман теленең *ц*ылаштырган тел булуы да шик астына алына.

Биредә *ц*га башланган сүзләрнең татар сөйләшләрендә *ч*-вариантлары булмаганнары гына китерелә.

**ЦАККАН, цахқан** (Тумашева 1992: 233) «ловкий, бойкий: боевой» < уйг. *чаққан,* үзб. *чаққон* > каз., к.-калп. *шаққан* id. ~ төркм. (ТДГДС: 192) *чақғал* «тиз генә» (*чақғалла-* «тизләтү»). Бу сүз чыгт., аз., төр. *чакын, чаккын* (к. Будагов I: 460–461), аз. диал. *чаххын* «чакмак чаткысы, яшен; елгыр» кебек сүзләрнең бер варианты булса кирәк. Тамыры *чак-*, к. **Чак-у.**

**ЦАЛГАК** (Тумашева 1992: 232) «возбуждение, нервное состояние; клевета» ~ төр. *çalkak* «баш чайкаучан (ат); тынычсыз» ← *çalka-* «селкетү, чайкау». К. Будагов I: 463.

Бу сүз ахыр чиктә **чалкак, чалкан** сүзләре белән (к. түбәндәрәк) тамырдаш бугай.

**ЦАЛУ** (Тумашева 1992: 232) «изображение дочери Ульгеня («бога-творца») в виде куклы» ~ алт. *чалу, чалду,* шор. *шалу, шалыг, салыг* < бор. көньяк төрки **чаллыг* «сурәт, рәсем; курчак». Бу сүз төңгер уртасына урнаштырылган кечкенә кеше сурәтен-курчагын белдергән, кайбер очракларда төңгер үзе дә **чалу** дип аталган. Һәртөрле **чалу**лар тур. бай әдәбият бар, к. Иванов 1979: 13, 17, 24, 47, 74 һ.б.

**Цалу** сүзенең гом. тат. тәңгәле **чалу** икенчерәк мәгънәдә, к. **Чалпу.**

**ЦАР** (себ., ЗДС: 707) < *чар* «рабочий (обычно холощёный) бык» ~ чулым. *цар,* шор. *шар*, тув. *сары*, алт. *чар*, калм. *цар* ~ бур. *сар,* монг. *шар* < бор. монг. *čar* id. Чаг. себ. рус. диал. (Аникин: 644–646) *чар* «чар» ~ эвенк. *чар,* бор. монг. *ǯari* «кыргый болан» һ.б. Räsänen: 100. Аникин бай әдәбият күрсәтә, ләкин тат. сүзен күрсәтми.

Чаг. ш. ук каз. *шар* «тояклы хайваннар таптаган урын», «карт үгез». К. **Шар II?**

**ЦАРЫЦКЫ, царцыга** (себ., ЗДС: 707) «сверчок». Күренеп тора ки, *цар* < *чар* ~ *цыр* < *чыр* тәкълиди сүзеннән. *Царцы-* < *чарчы* фигыле булган, күрәсең. Чаг. **Чарылда-у, чәрелдә-ү.**

**ЦАТКЫЛ** (ЗДС: 707) «развилка, развилина (дорог и др.)» ~ кырг. *чатқал* id. ← монг. *чатгал, цатгал* «юллар чаты; төрлечә тармакланган үзәннәр» сүзеннән. Шуннан Кыргызстандагы **Чаткал** таулары, **Чаткал** елгасы һәм районы атамасы пәйда булган. Чаг. **Чатал.**

Бу сүз, *-қал* > *-қыл* кушымчасына караганда, монг. телләреннән килә.

**ЦӘК** (Тумашева 1992: 236) «месть; долг» << уйг. *чәк* «талон; квитанция төпсәсе; шобага, жирәбә», «җек, сынган төш; җөй», каз. (ҚТДС: 368) *чек* «билге, тамга», *чек тастау* «шобага салу», төр. *çek* «таякчык; чек». Бу сүзнең килеп чыгышы түбәндәгечә: кешегә әҗәткә акча биргәндә һ.б. бер таякчыкны сындырганнар да, бер башын әҗәткә бирүчегә, икенче башын казыйга калдырганнар (һәм, күрәсең, таякчыкка бурыч шартларын язып куйганнар); бурыч түләнгән мәлдә таякчыкларны тоташтырып караганнар һәм утка ташлаганнар; мондый таякчыклар раслама, ышаныч билгесе сыйфатында бүтән күп кенә очракларда да кулланылган.

**Цәк ~ чәк** сүзе үзе фар. теленнән булса кирәк (әмма төрки телләрдә дә шуңа охшаш сүзләр бар); фар. теленнән ул Һиндстан телләренә, аннан инг. теленә кергән һәм шуннан рус. *чек* рәвешендә кулланыла. Будагов I: 481; Фасмер IV: 324; Velidi: 121 (**чәк** сүзенең Сәлҗук дәүләте чорында таралганлыгы тур.); Kluge: 796 (ним. *Scheck* < инг. *cheque* ~ фар. *čäk* – ихтимал, төрки телләрдән ди һәм бу сүзнең гар. теленә *sakk* яңгырашында фар. теленнән алынуы тур. яза).

**ЦЕНЕ, чен** (Тумашева 1992: 238) «фарфоровый» < уйг., чыгт., төр. *çini* < фар. *чӣнӣ,* гар. *çӣнӣ* «кытайныкы» ← **чин** «Кытай» – асылда Кытайдагы

*Цзинь* династиясе (XII–XIII г.) атамасыннан. Кытайны *Чин* дип атау шул чорда бөтен дөньяга таралган, к. **Чин вә Мачин**. Бор. рус. *чини* «чынаяк; фарфор» < төр. *çini* id. (к. Фасмер IV: 298, 363), хәз. (XIX г.) себ. рус. сөйләшләрендә *ценина* «фарфор тәгәч, чынаяк һ.б.» – ихтимал себ. тат сөйләшләреннәндер (*-ина* рус кушымчасы, әлбәттә), к. Аникин: 631. К. **Чынаяк**.

**ЦӨМӘЛДЕ** (ЗДС: 715) «муравей» к. **Чүмәлә, Чүмәлде.**

**ЦҮР** (Тумашева: 242) «шпулька» – **шүре** (к.) сүзе белән чагыштырыла. Аникин (: 577–578) бу *сür* сүзен рус. *тюрик* «шүре (приспособление для намотки пряжи)» белән чагыштырып карый.

**ЦЫГЫТ** (ЗДС: 718) «приданое» ← себ. , миш. *цык-* «чыгу» булса кирәк.

**ЦЫМ** (ЗДС: 719) «засеянная, специально ухоженная трава, лужайка» ~ кырг. *чым*, каз. *шым*, үзб., уйг. *чимъ*, төр. *çim* id., ш. ук «чирәм; торфлык». Räsänen 1969: 111 (**чәмән** сүзе белән чагыштыра).

Фразеологизм: **цым салу** «майның уннарында зиратка барып каберләрне чистарту, догалар уку һ.б.».

# Ч

**Ч** авазы тат. телендә бор. төрки телләрдән үзгәрешсез диярлек килә. Хәлбуки кайбер төрки телләрдә бу аваз нык үзгәргән, чаг. башк. *ч > с*, нуг., каз., к.-калп., тув., шор. телләрендә *ч > ш*, чув. телендә күп кенә очракларда *ч > ç [сч]*. Рус теленнән кергән сүзләрдә гади сөйләмдә *ч < с, сч, ц* күзәтелә: *весь > вич, счёт > чут, царь > чар.*

**Ч** авазына тат. телендә бик күп тәкълиди сүзләр башлана (без барысын да алмадык).

**ЧАБАВЫЛ [чаᵒбаwы̆л]** (Будагов I: 451), себ. (Тумашева 1992: 232) **цабул** «гонец, курьер; почтарь» < гом. кыпч., к. башк. *сабауыл*, к.-балк. *чабывул*, кырг. *чабуул*, чыгт., төркм., аз. һ.б. *чапаул, чапуул*, каз., к.-калп. *шабуыл*, төр. (> көрд., фар.) *çapavul, çapul* һ.б. «хәрби сәфәр; атлы рейд; атака, һөҗүм» (төрле телләрдә төрлечәрәк) ← *чап-* «чабу». «Курьер» мәгъ. төрки телләрдә **чабар, атчабар, чабарман, чапкын** сүзләре (һәм аларның закончалыклы фонетик вариантлары) кулланыла.

**Чабавыл** сүзе тарихта иң беренче теркәлгән төрки сүзләрдән берсе: кыт. чыганакларында *Шабалио* дип исемләнгән хан (VI г.) хакында аңар ата-анасы данлы [*чаблы*] дип ат кушкан, ләкин чынлыкта ул *чабаул* «юлбасар, баскынчы, бүре» дип сөйләгәннәр, имеш, чөнки бу хан бик сугышчан булган (Гумилёв 1993: 57). Бу мәгънә **чабавыл** сүзенә бик бап килә.

**ЧАБАГАЧ,** диал. **чабагыш,** (ДС I: 156; ДС II: 218, 228, 233) **сабагач, чабагач, шабагач, шәпагач,** (Халиков 1995: 90) **субагач,** крш. (Balint: 97) **čubaγač** «цеп (для молотьбы)» ~ башк. (БТДҺ: 295, 368, 400) *сабағач, сыбағач, һабағаш, шәбағас* һ.б. < **чәп (~ чип) агачы**, к. диал. (ДС I: 232; ДС II: 216, 218) **чәп, шәп, чеп, чип** < рус. *цеп,* гом. слав. тамырлы сүз (шуннан ук удм., коми *чап,* венг. *csep* id.). Тат. **чәп агачы** тәгъбиренә параллель яки шуннан калькалар күрше телләрдә очрый: чув. (Сергеев 1968: 60) *çапуççи, çапвĕççи, çапвуççи < çап йываççи* ~ мар. *сапонда, сепанды < сэп понда* (*пондо* «таяк») «чабагач».

Элекке төркиләр ашлыкны чабагач белән суктырмаганнар, ә көлтәләр җәеме өстеннән үгез һ.б. таптатканнар яисә махсус таш цилиндр тәгәрәткәннәр, башакларны гына җыю (һәм киледә төю) дә булган һ.б. Чабагач куллану, күрәсең, славяннардан алынган. Хәз. көньяк төркиләрдә дә чабагач куллану булмаган (хәзер, әлбәттә, комбайннар эшли).

Дерив.: **чабагачлы, чабагачсыз; чабагачла-у.**

**ЧАБАК I,** миш., себ. **цабак**, «сорожка; плотва; подлещик, чебак» (вообще «плоская некрупная рыба») < гом. кыпч., чыгт., алт., уйг., үзб. *чабақ* (> башк. – БҺҺ II: 196; БТДҺ: 265 – *сабақ, сабақа,* нуг., каз., к.-калп., шор. *шабақ*) «чабак, ташбаш һ.б.ш.», тув. *чабага, шабага* «вак балык», кр.-тат., к.-балк., ком., госм., бор. төрки (МК I: 381) *čapaq* «яссы балык (төрләре)» ~ чув. *çапак > çупах* «чабак (вак корбан балыгы)» – төрки телләрдән күп күрше телләргә таралган сүз, к. удм., коми., мар. *чабак, чавак* (тат. теленнән), рус., укр. *чабак, чебак, чубак*, венг. *csabak*, фар. *чäбäк* «чабак, төрле вак балык». Корнилов фикеренчә (к. аныкы К этимологии топонима *Čeboksary* // СТ № 2, 1972: 54–62) *чабак ~ чапак* сүзе (балык атамасы) **чап** (к.) тәкълиди сүзеннән, ягъни суда чапылдау, чупырдау һ.б.га мөнәсәбәтле рәвештә ясалган сүз. Бу фикер белән нигездә килешкән хәлдә, башк. һәм тув. вариантларының монг. телләреннән килү ихтималына да игътибар иттерәсебез килә (монг. **чаба-кай* булырга мөмкин); аннары кайбер төрки сөйләшләрдә *чабага* һ.б. чабылган, туралган, гомумән вакланган, вак нәрсәләрне, әйтик, гадәттә ташлана торган вак балыкны да белдерүчән, к. **Чабык.** Будагов I: 451; Räsänen 1969: 99; Фасмер IV: 322; Федотов II: 137 (**чабақ** бор. чув. теленнән таралган димәкче); Аникин: 633 (арытабангы бай әдәбият китерелә).

**ЧАБАК II** (Тумашева 1992: 245; ТТДС I: 469) «чепчик, вид шапочки с наушниками» ~ алт. диал. *чабақ* «биек бүрек» > рус. диал. (Аникин: 633) *чабак, чебак, чибак* «колакчынлы бүрек», як. *дьабака,* (Пекарский: 763) *ǯabakka* «хатын-кызларның колакчынлы эчекле бүреге» М. Рясянен буенча (Räsänen 1969: 187), *йап- ~ җап-* «ябу» фигыленнән. Ләкин тат. телендә *й >> ч* очраклары бик сирәк булганлыктан, китерелгән фаразга шикләнеп карарга ярый.

**ЧАБАК III** (ТТДС I: 469), **чабакай** «оплеуха; удар ладонью (например, при трудовом процессе и т.д.)» ← **чап-у** (к.). К. **Чәбәк**.

Дерив.: **чабакла-у, чабакайла-у.**

**ЧАБАКСАР –** город Чебоксары (столица Чувашии) – К. Насыйри бу топонимны татарча **Чыбыксар** «чыбыклар яисә чабаклар күп булган урын (елга)» дип аңлата (чыннан да шәһәрнең елга исеменнән булуы бик ихтимал), ләкин күпчелек топонимистлар бу аңлатманы куәтләмиләр. Чув. *Шупашкар ~ Шопашкар ~ Шопакшар* топонимын төрлечә аңлаталар: халык телендә бу сүз имеш *Шобксар* дигән кеше исеменнән (к. Спасский. Очерки по родиноведению. СПб., 1912: 157); В.Г. Егоров буенча, *Шупашкар* «чуваш шәһәре» (*-кар* болгарча «шәһәр», имеш). Хәз. чув. телчеләре Г. Корнилов (**чабак** матдәсен к.) һәм М. Федотов шәһәр исеме *сү башы кар* «сү башы (к. **Сү**) шәһәре» дип аңлату ягында. Федотов II: 461 (әдәбият күрсәтелә).

**ЧАБАЛАН-У** «возбуждённо двигаться, метаться» ~ төр. *cabala-* id., *cabalan-* «чәбәләнү».

**ЧАБАН** «чабан, пастух на летовке» – тат. әд. телендә бу сүз рус теленнән булса кирәк; төп тат. к. **Чупан.** Рус. *чабан* (төрки телләрдән) тур. Аникин: 633.

**ЧАБАТА,** диал. **цабит, цубата** һ.б. «лапоть», разные виды кожаной обуви (ЗДС: 704, 715, 721), миш. (ТТДС II: 341) **чабади** «лапоть», «название весёлого музыкального мотива и пляски» > удм. диал., мар. диал. *чабата* ~ чув. *çăпата, çăвата* id., к.-балк. *чыбыт* «башмак» ~ каз., к.-калп. диал. *шабата*, каз. (ҚТДС: 381–382) *шапата, шапаты* «каеш чабата» < фар. (Радлов III: 1930) *чабатан, чабатаи* (хәз. сүзлекләрдә юк) «очлы башлы итек», «читек өстенә киелә торган башмак». Сүзнең мәгънә үзгәрешендә юмор сизелә: борыны өскә таба очлайтылган читекләрне элек асылзатлар киеп йөргән. Гомумән, бу сүз бор. Харәзем. *čapbäda* «итек» сүзеннән килә.

**Чабата** сүзе Евразиядә киң таралган: рус., укр. *чёботь, чеботы, чеботья* «башмак, (бизәкле) итек», ит. *ciabatta*, исп. *zapata*, фр. *sabate* «каеш чабата», литв. *čebatas* «итек, башмак» һ.б. (к. Никольский 1928: 166; Добродомов 1976: 35).

Миш. (ДС III: 177) **чабат** «чабата» һәм себ. (ДС I: 230) **шыпытый** «чүәк» сүзләренең рус теле сөйләшләреннән булуы ихтимал. Фасмер IV: 370–371; Федотов II: 97; Аникин: 649; Тимергалин: 535.

Дерив.: **чабаталы, чабатасыз; чабаталык.** Мәрәкәле рәвештә, фр. *sabot* «агач чабата» сүзеннән **саботаж** «эшкә битараф карау, эш ташлау» сүзе ясалган, к. Kluge: 778.

**ЧАБУ I [чаᵒбы̆w]** «фалд», (Троянский I: 428) «клин в платье» > мар. (Исанбаев 1978: 33) *чаву* id., башк. *сабыу* «клин в платье» < гом. кыпч. *чабу* (> нуг., каз., к.-калп. *шабу*) «чабу, балитәк», кырг., алт. *чабуу* «ян, кабырга; хатын-кыз киеменең ян ягындагы кештәге», ком. *чабу* «кештәк; (өчпочмаклы яки диагональ катланган) тукыма буе» < бор. төрки **чапыг, чапуг,* к. төркм. *чапы* «чабу», чыгт. (Радлов III: 1921) *чабуҡ* id., тув. *шапыг* > *сапыг* «чабу; балта (!)». Л. Будагов (I: 451) бу сүзне **чап-у I** сүзе белән баглый: ул фигыльнең алтайча «чигеш чигү» мәгъ. бар имеш, димәк, *чабу* < *чапыг, чабгу* «чигелгән итәк, кештәк» булып чыга. Төр. *çaput* «кештәк» монг. телләреннән (**чапуут*). Сүзнең төп мәгъ. «өстәп тегү» булса кирәк, к. ЗДС: 722.

Дерив.: **чабулы, чабусыз; чабулык** (әйбер).

**ЧАБУ II [чаᵒбы̆w]** «бег» к. **Чап-у I.**

Дерив.: **чабула-у** «контрольдән чыгып чабу, качу (ат тур.)»; **чабулау** «арлы-бирле йөгереп йөрү».

**ЧАБУК, чапук,** (ЛТ I: 163) **чапаҡ** иск. «быстрый, проворный» ~ төр. *çabuk, çapuq* id. К. **Чап-у I–II.**

**ЧАБЫК** (**чыбык-чабык** парлы сүзендә) «хворост» ← **чап-у II** (к.) «селтәнеп кискәләү» сүзеннән, әлбәттә, к. каз., к.-калп. *шабыҡ* «китмәнләү; утау», кырг. *чабыҡ* «китмәнләү эше; пакус» һ.б.ш.

**ЧАБЫК-У (чабыкты, чабыгу)** (ЛТ I: 163) «прославляться (нехорошей славой)». Бу сүз **Чап** «дан» (к.) сүзенең фигыль коррелянты булганлыгын күрсәтә: **чабык-** < *чапык-* шул фигыльнең интенсивлык формасы.

**ЧАБЫН-У** «хлестать себя веником» ← **чап-у II** фигыленең кайт. юн., әлбәттә; сөйл. телендәге **мунча чабын-у** тәгъбирендә төп грамматик бәйләнышлар өзелгән, онытылган.

Дерив.: **чабыныл-у, чабындыр-у; чабынгыч** (бу сүз сөйләшләрдә «миллек» һәм «мунча» мәгъ. кулланыла).

**ЧАБЫР I** «чабрец, богородская трава» ~ чув. *чапăр* id. < рус. *чабер, чабор, чабрец* id., гом. слав. сүзе, к. Фасмер IV: 309; Федотов II: 390.

Тат. диал. (Ә. Баян; ТТДС I: 470) **чабыр бәйрәме** (1–3 июльдә) «сыра эчү белән баглы бәйрәм» – рус сөйләшләреннән булса кирәк.

**ЧАБЫР II** (XVIII г. ядкәре «Җәмигыль-хикәят» телендә) «плащ», **шабыр** «тупас тукымадан тегелгән чикмән». Бу сүз барча Идел-Урал телләрендә бар. Рус. *шабур, шабор, шубур, чибур* һ.б. (к. Аникин: 682) «тупас тукыма һәм шуннан тегелгән кием» мәгъ. очрый.

Бу сүз фар. *чаппар, чапур* «аркылы буйлыгыннан шактый калынрак булган тукыма» сүзеннән килә. Шундый тукыма, шулай ук һәртөрле үрмәләр аркаулыгы-буйлыгы тиң булган тукыма – **чит**кә каршы куелганнар. Бу каршыкуелыш тукымаларны классификацияләүнең иң тәүге моменты булган, к. рәсемне.


*чапыр*: аркаулыгы шактый калынрак


гади тукыма (чит): аркаулыгы-буйлыгы бер тиң

**Чапар, чапур** сүзе нигезендә татар телендә (һәм, гомумән, төрки төлләрдә) күп кенә яңа нигез сүзләр ясалган. Гомуми картинаны түбәндәгечә ифадәләргә мөмкин.

| | |
|---|---|
| Фар, бор. төрки (?) *чапар*// *чапур* | иске тат. *чабыр* «хатыннар плащы»; тат., удм. *шабур* «кыска чикмән», башк. *шубыр* «сирәк тукыма»; |
| | тат. *чапыр* > *чәпер* > *чәпе, цәпе* «тупас тукыма»; |
| | *чәбер* > *чәбе* «читән; текмә читән»; |
| | бор. төрки *чапурак* > тат. *чапрак* «чүпрәк палас; иске-москы»; |
| | төр. һ.б. *чапрак* «ат ябуы»; |
| | рус. диал. *чепур* «читән», рус. *чепрак, чапрак* id. |

**ЧАБЫР-У** «появляться – о сыпи на теле» ~ башк. *сабыр-*, каз., к.-калп. *шабыр-* id. Ачык түгел. Ихтимал, ниндидер *чабы* ~ *чап* «чуанлы, бөрчекле» (сыйфат) сүзеннәндер.

Дерив.: **чабырыл-у; чабырткы, чабырчык** «кечкенә сыткы».

**ЧАБЫШКЫ** «рысак; скакун» ~ башк. *сабышҡы* id., башк. диал. (БТДҺ: 265) *сабышаҡ* «елдам (ат тур.)» ← **чабыш** ← **чап-у.** Тат.-башк. даирәсендә ясалган сүз.

**ЧАВЫЛ [ча$^{o}$wы̆л]** (Будагов I: 466), диал., (ТТДС II: 256) **саwыл,** себ. (Тумашева 1992: 235) **цауыл** «молодой редкий березняк», диал. (ТТДС II: 342) **чаwыл** «толстый прут, тонкая жердь» ~ башк. (БҺҺ II: 203, 233) *сәүел* «чавыл, яшь каенлык», *сауыл* «каен», алт. (Баскаков 1966: 163; Баскаков 1972: 265) *чаал* «чавыл, яшь агачлык; карагайлык», тат. диал. (Будагов I: 457) **чағал**, (С. Кудаш) **чагыл** «тау битләвендә үскән вак агачлык» белән гомоген булырга тиеш. Арытабан эзләр ачык түгел: охшашрак сүзләрнең я мәгънәсе, я фонетик йөзе төгәл тәңгәлләшми, мәс., к.-балк. *чаўул* «эреле-ваклы ташлар яткан үткесез ташлык», кырг. *чогоол* < **чағаwыл* «чәнечкеле куакчыл үлән төре», үзб. (ЎХШЛ: 295), төркм. *чаалы* «чәнечкеле үләннәрдән корылган киртә» ~ кр.-тат., госм. (Радлов II: 1875, 1879) *чалы* «чәнечкеле куаклык» һ.б. Гомумән, алтаистик мәгълүматлардан чыгып *чаwыл* < *чағыл* < монг. *чағаwыл* «каенлык» > *чагуул* > *чагул* > *чагыл* (ягъни монг. *чаға*$^{н}$ «ак; каен» нигезеннән) дип чамаларга ярый. Чаг. ш. ук **Чагыл I.**

**ЧАВЫШ [ча$^{o}$wы̆ш]** (К. Насыйри һ.б.) «полицейский; распорядитель во время сабантуя, свадьбы и т.п.» < гом. кыпч., к. ком. *чавуш* «ярчы, нидачы; чавыш», кар. *чавуш* «хезмәтчеләр башлыгы» ~ төр. *çavuş* «чавыш; сержант; староста һ.б.» (тарих дәвамында бу сүзнең мәгънәсе бик нык үзгәргән, к. Будагов I: 465–466). Төр. теленнән бу сүз барча Балкан, Кавказ, фар., гар. һ.б. телләренә һәм шивәләренә үтеп кергән (әйтмәкче, танылган румын диктаторы *Чаушеску* фамилиясе румынча *чауш* сүзеннән ясалган). **Чавыш** сүзе Урта Идел регионында борынгыдан килә: бу хакта мар. *савуш, саус, сагуш* «кияү егете», мифологиядә «фәрештә; баш тәңренең хезмәткәре» < болг. **җаwуш* «хезмәткәр». Рона-Таш фикеренчә (к. аныкы Об одном заимствованном среднемонгольском слове в марийском языке // Исследования по восточной филологии. М., 1974: 230–235) бу сүз монг. *ǯabuči* «йөрүче, йөгерүче» (к. **Ябагай**), «эш башкаручы, хадим, гамәлдар» сүзеннән килә. Безнеңчә, бу сүз бор. төрки титул **ябгу ~** *җабгу* → *җабгучы* «катлаулы эш башкару; идарәче» сүзеннән дә килергә мөмкин.

**ЧАГА I**, диал. **цага** (ТТДС I: 466, 470) «детёныш животных (особенно – овец)» < гом. кыпч. (ләкин сүзлекләрдә теркәлми) *чаға,* нуг., каз., к.-калп. *бала-шаға*, кырг. *бала-чаҡа* «бала-чага», каз. *шаға* «кызчык», *шаҡа* «яшь бала, бәби, нәни», чыгт.

(Будагов I: 458) *чāға* «карга баласы», төр. *çağa*, төркм. *чага [чā]*, монг. *чақа* «бала, сабый» – киң таралган мәдәни сүз, к. фин-угор. *čaka* «бәрән, бәти», морд. *сава, сäйä* «кәҗә», кор. *čaga* «бала», бор. ир. *chägä* «кәҗә», *chagah* «тәкә», рус. (< төрки) *чага* «кырнак (кыз)». Joki 1973: 317; Фасмер II: 309.

Дерив.: **чагала-у** «бәрәнләү» (ихтимал **чагалы, чагасыз**, ләкин бу сүзләр теркәлмәгән).

**ЧАГА II** «жало» ~ алт. (Баскаков 1972: 265) *чагак, чагаақ* id. Тат. телендә дә дөресрәге **чагақ** булгандыр. Әлбәттә, **чак-у** сүзеннән.

**ЧАГАЛА** (Арсланов 1988: 111; «Идегәй»дә: *Чагалалы Чалкар күл Чаңсыз булыр дипме иден*), (ЗДС: 723) **чағиқ** «чайка, вид озёрных чаек», (Будагов I: 457) **чагала, чакала** «мартышка (вид морских чаек)» ~ каз., к.-калп. *шагала*, үзб. *чағалай* id., *чақалоқ* «кошчык; малай».

Бу сүзне (кырг.) *чағала-* «куркып чыелдау» сүзеннән дип уйларга мөмкин, ләкин ни өчен кителгән *чағалақ* > *шағалақ* формасы кулланылмый икән? Икенче фараз: *чағал-ақ* «кечкенә шакал» (кошның хәрәкәт-кыланышыннан булса) сүзеннән дип уйласак та шул ук сорауга тап булабыз. Ихтимал, рус. (Фасмер IV: 323) *чеглок* «лачын төре» сүзе дә кыпч. **чағалақ* сүзеннәндер.

Өченче фараз: монг. *загалай* < *җагалай* «хач сыман» ← *загал, җагал* «хач, тәре». Кошның һавадагы сурәтеннән. К. түбәндәгене.

**ЧАГАЛТАЙ, чагалмай** «вид чайки» – беренче вариант монголча «хачсыман» дигән сүз, икенчесе < уйг. *чағалмай* id.

**ЧАГАН** «клён; ясень; кленовый, ясеневый» > мар. (Исанбаев 1978: 22) *чаган*, башк. *саған* id. – Идел-Урал региональ сүзе, төбендә монг. сүзе, к. бур. *сагаан үлтэнэг* «чаган», сүзмә-сүз «ак юкәр»: *сағаан* < монг. *цагаан* < *чағаан* «ак», *үлтэнэг* «юкәр, кайры асты»; чаг. төр. *ak ağaç* «каен».

**Чаган** сүзе тат. сөйләшләренең бер өлешендә генә таралган, күпчелек сөйләшләрдә – **өрәңге** (к.), һәм бу сүз дә «ак» мәгъ. Чаг. ш. ук яз. монг. *čaγan* «ак», *čaγaγan* «ап-ак», эвенк. *чāлбан* < *чағалбан* «каен» һ.б. Монг. халыкларында *цаган эбуген* «ак бабай» – җир химаячесе. К. МНМ II: 611.

Дерив.: **чаганлык.**

**ЧАГАНӘ** «род музыкального инструмента – металлические диски на шнуре» < төр., фар. *çaganak, çegane* id. Бу сүз элекке әд. әсәрләрдә дә очрый. Будагов I: 458; Redhouse: 236; Räsänen 1969: 94 (фарсы сүзе ди).

**ЧАГАРАК** «верхнее отверстие юрты» < гом. кыпч. *чағарақ* (> башк. *сағарақ,* нуг., каз., к.-калп. *шағарақ, шағырақ, шаңғарақ*) ~ калм. *цаграг* id. ир. телләреннән булса кирәк: к. монг. *цағариг, цахриг* «тәгәрмәч, чарык, чагарак»; һ.б. чагт. (Будагов I: 457) *чағдарақ* id. үзенчәлекле вариант. Räsänen 1969: 99 (аз гына әйтелә). Чагарак кигиле тәгәрмәч рәвешендә ясала – аңа авыш уыклар терәтелә, уыкларның икенче башлары тирмә читәненә һәм **түрләмәсенә** терәлә. **Түрләмә** – тирмә тирәли тотылган нык, киң тасма – бөтен конструкциянең чәреген-ныклыгын тәэмин итә. К. Будагов I: 163–165 (**үй** «казак өе» сүзен аңлаткан пассажда). Чаг. ш. ук **Яңгырак.**

**ЧАГДАВЫЛ [ча°ғдаwы̆л]** (Будагов I: 452), **чигдаwыл** «командующий арьергардом; военная и ночная полиция» – монг. телләреннән, асылда монг. *чагда-* < бор. монг. *ǯaγda-* «җайлау, координацияләү» сүзеннән, к. **Яктай.** Räsänen 1969: 94 (*чақ, чағ* «төнге вакыт» сүзеннән ди).

**ЧАГУ [ча°ғы̆w]** (ДС I: 212) «высота, высокое место, видное издалека и служащее ориентиром; яркий» ~ башк. *сағыу* id. – **чагыл II** (к.) сүзе белән бәйле.

**ЧАГУАН [ча°ғы̆wан],** себ. **цағуан,** эчк. (ТТДС I: 466), **цағуwан, цағаwын** «оса; пчела» – **чак-у** (к.) белән бәйле, әмма ясалышы бик үк ачык түгел: *-ан* бетемен гом. төрки *аң* (к. **Аң**) дип фаразларга ярый, тик **чагу-** монда нинди сүз төркеменә карый?

**ЧАГЫЛ I** (ТТДС I: 470–471), **сағыл** (БҺҺ II: 197, 203) «голая круча; голая крутая возвышенность; косогор, голый или поросший скудной растительностью», (Троянский I: 468) «овраг» > удм. *чагыл* «ярлау», чув. *чакăл* «текәлек, текә» < гом. кыпч.: кар. *чағыл* «чакматаш; чакматашлы җир, ташлы текәлек», каз. (> кырг.) *шағыл* «эре кырчынташ; ком өеме, бархан» ~ гаг., төр. (Будагов I: 460) *чағыл, чақыл* «ташлы ком», *чақылташ* «шомарган таш». Ф. Корш (1909: 4) тат. һ.б. *чағыл* «вак таш, кырчынташ» сүзе тәүдә «чакматаш» мәгъ. булган ди һәм *чақ-у* (к.) сүзеннән чыгара (< *чаккыл* булса кирәк) һәм бу фаразны инкяр итеп булмый.

Шул ук вакытта *чағыл* > *чаwыл* (к. **Чавыл**) күчеше дә һәр җәһәттән закончалыклы. Шулай итеп,

мәгънә үсеше: «чакматаш > чакматаш катламы чыгып торган урын – башлыча ярлау, текәлек > гомумән ташлы текәлек > вак каенлык» (ташлы текәлекләрдә башлыча вак каеннар үсүчән) шәкелендә күзаллана. Räsänen 1969: 96.

Дерив.: **чагыллы, чагыллык;** әд. телдә **таучагыл** парлы сүзе кулланыла. К. **Чагыр II.**

**ЧАГЫЛ II** (ЗДС: 723) «яркий < гом. кыпч. *чағыл,* башк. *сағыл*, каз., к.-калп. *шағыл* «ачык аяз (көн тур.)» ~ монг. *чағуул, цағуул* «аязлык, яп-якты, күз чагылырлык көн», гом. алтай күпдериватлы *чағ-, чай-, чақ-* «яп-якты булу, яну, яшьнәү һ.б.ш.» тамырыннан. К. түбәндәгене.

**ЧАГЫЛ-У I** «отражаться (о свете)», күч. «находить отражение (в литературе и т.п.)» ~ башк. *сағыл-* id.– бу сүз әд. телдә рус. *отражаться* сүзенә эквивалент-калька буларак кулланышка кереп киткән, югыйсә аның төп мәгънәсе «очкын чыгарылу» – *чагу* (к. **Чак-у I**) фигыленең төш. юн. (к. фольклорда: *чакма чагыла, утлар ягыла*); к. ш. ук диал. (ТТДС II: 443) **чағыл** «җете, ялтыравык».

Төп мәгъ. *чагыл-* борынгыдан килә: гом. кыпч. *чағыл-* «чакма чагылу, очкынлану» < бор. төрки (ДТС: 140) *čaqïl-* id., ш. ук «сигнал бирелү, хәбәр ителү» (күрәсең, чакма чагу караңгалыкта сигнал бирүнең бер ысулы булган). Төрки телләрдән бу сүз күрше телләргә дә кергән: монг. *чакил-*, бур. *сахил-*, эвенк. һ.б. тунг. *сакалгами* «ялтырау, очкынлану», к. ш. ук кырг., як. *чағылган* ~ бур. *сахилгаан*, эвенк. *сакилган* «яшен», монг. *цахилгаан* «электр» һ.б. К. югарыдагыны.

Дерив.: **чагылдыр-у; чагылыш;** к. **Чаткы.**

**ЧАГЫЛ-У II: күз чагыл-у, теш чагыл-у** «резко ударить в глаза (о ярком свете), вызвать оскомину, боль в зубах (о чём-либо, взятом в рот)» – **чак-у** (к.) сүзенең төш. юн. булырга тиеш, к. башк. *сағыл-* «чагылу (елан-чаяннан)». Асылда **Чагыл-у I** белән бердәй.

**ЧАГЫН-У** диал. «быть осторожным» ~ чыгт. *чағын-* «игътибарга алу», як. *чағый-* «сагаю, хәвефләнү», хак. *сагы-* «көтеп тору; сагалау». Räsänen 1969: 94.

**ЧАГЫР I** (ДС I: 213, 225; ДС II: 212, әд. әсәрләрдә дә очрый), себ. (Тумашева 1992: 248) **шағыр (шагыр күз, шагыр күк)** «глубокий, блестящий из глубины», «пёстрый; бледно-голубой; синий; сверкающий, сверлящий (о глазах, неодобрительно)» > чув. *чакӑр*, удм. *чагыр*, мар. *чакыр* «чагыр, зәңгәр; коңгырт (күз тур.)» < гом. кыпч. *чағыр* (нуг., каз., к.-калп. *шағыр*, каз. *шегір,* башк. *сағыр*) < бор. төрки (ДТС: 140) *čaqïr*, бор. чыгт. (Боровков 1963: 355) *чақыр* «төссез, зәңгәрсу (күз тур.)» ~ төр. *çakır* «ялтыравык зәңгәр (күз, күк, диңгез тур.)», алт. *чаңкыр* «күк, зәңгәр», тув. *чаңгыр, шаңгыр* «зәңгәрсу ак», як. *чақыр* «ап-ак, ялтыравык ак», *чақырыас* «ак күзле», (Пекарский: 3553, 3557) *чäңкир* ~ бур. *цэнкир, сэңкир* «сөзек зәңгәр», яз. монг. *çakir* > хәз. монг. *цахир* «ап-ак», *цаңгир* «аксыл» һ.б. ~ нан. *чақи* «күздәге ак, күзенә ак салган» һ.б. (бик күп тамырдаш сүзләр китерелә, к. ССТМЯ II: 380–382). К. ш. ук аз. (АДДЛ: 553) *сағар,* төр. (YTS: 178) *sakar* «кашка (аттагысы)»; рус. диал. *чанкирая* «аксыл, чуар (ат)», *чанкирый* «чуар». **Чаган, Чал** сүзләре белән гомоген. Räsänen 1969: 96; Федотов II: 387; Аникин: 642.

Бор. төрки һәм монголларга зәңгәр күзләр бик сәер һәм начар тәэсирле булып күренгән, шуның өчен тат. фразеологизмы **чагыр күз** – «усал, шәфкатьсез, оятсыз (кеше)» ~ фар. *äзрäкчашм* «зәңгәр күзле; шәфкатьсез».

**ЧАГЫР II** (ТТДС I: 47) «толстое крепкое лезвие, укреплённое на вилке ветви – орудие выкапывания кореньев и специально для копания могил» ~ башк. (БТДҺ: 267) *салир, салыр* < *чалыр* id., диал. (ЗДС: 726) *чалгыр,* башк. *салгир* < *чалгир* вариантына караганда, алынма сүз, чаг. фар. *чағилгир, чақилгир* «ташлы туфрактан ташлар чыгару өчен махсус корал» – *чақил* «чагыл, катламлы ташлык» + *гир* «алгыч» мәгъ. сүз (чаг. *дистер* < *дäстгир, кипкер* < *кäфкгир*). К. **Чалыр**. Тимергалин: 536.

**ЧАГЫР III** (Радлов III: 2065) «бадан, чагир (растение, употребляемое вместо чая)» ~ башк. (БТДҺ: 265–266) *сағыр* «сары акация; кау, кышлаган үлән», *сағыр-соғыр* «чүп үләннәр» ~ рус. диал. *чагир, чагыр* «эстрагон, иссез әрем, тархун)», к. ш. ук каз. *шағыр* «кура, каракура», шор. *чығыр* «чагырсыман үсемлек» һ.б. (к. Аникин: 635). Ихтимал, **чагыр I** белән бердәйдер (чәчәкләре җете ала, зәңгәрле-кызыллы булганлыктандыр).

**ЧАГЫР IV: чагыр таш, чагырташ** «кремень, мергель» ~ гом. кыпч., к. кырг. *чығыр*, як. (Пекарский: 3557) *чақыр* < бор. монг. *čaqiγur* > бур. *сахуур* «чакматаш, чагырташ» ← *чақ-*, к. **Чак-у.** К. ш. ук иске тат. **утчагыр, утчагар** «мылтык» ~ бор. рус.

*цагри* «утлы корал» – куман теленнән («Көнчыгыш телләреннән булса кирәк», ди Фасмер IV: 288). Тимергалин: 538. К. **Чагыл, Чак-у.**

**ЧАГЫР V** иск. «крепкое вино; хмельное вообще» < гом. кыпч., чыгт. *чағыр* < бор. төрки, төркм., госм. *čaqır* id. > уйг. *чәгир, чәгир* >> рус. *чихир, чихирь* «каты шәраб», *чифир* «исерткеч итеп эчелә торган бик каты чәй»; к. ш. ук венг. *csiger* «шәраб»; Кавказ телләрендә *чигырь* «катылатылган шәраб» һ.б. Чаг. маньч. < кыт. *чаӊ* «корбанлык шәраб». Мухамедова 1973: 187; Gombocz: 60; Фасмер IV: 368.

**ЧАГЫТ,** (Гиганов) **цагыд,** (Старчевский) **цагыд** «ров (нечто копаное)», (ЗДС: 724) **чағыт** «озерцо». Старчевский бу сүзгә синонимнар рәтен яза: *ерынды, ойыр, онэр, оро, уру, ойдук, цункур, аргач.* Будаговта (I: 457) *чағид* «буерак, ров» диелә. **Чағ-, чақ-* «казу» сүзеннән булса кирәк, к. **Чагыр II.** Чаг. чув. *чав-* < (тат.?) *чау-* «казу».

**ЧАГЫШТЫР-У**, «сравнивать» ~ башк. *сағыштыр-* id., ← диал. (ЛТ I: 165; ДС I: 212; ДС II: 212) **чагыш-у** «тәңгәл килү, туры килү; бер яссылыкта булу; охшау, чагыштырыла алу» – тат. әд. телендә шул мәгъ. формалашкан сүзләр. Бүтән төрки телләрдә икенчерәк мәгъ.: каз., к.-калп. *шағыштыр-, шағыстыр-* «үчекләштерү» ← *шағыс-* «үлчәшү; бәхәсләшү» ← *шак-* < кырг. *чақ-* «бер нәрсәнең бәяләмәсен икенче нәрсәгә нисбәтләп бәяләү»; төр. *çakıştır-* «өсте-өстенә куеп үлчәү; терлекне казыкка бәйләп кую». Чаг. **Чагын-у, Чак.** Кырг. *чағыштыр-* «чагыштыру» тат. теленнән булса кирәк. Үзб., уйг. *солиштыр-, салиштир-* id. *сол-*, *сал-* «салу, үлчәү» сүзеннән, әмма **чагыштыру** моделендә.

**ЧАДРА** «чадра; зонтик», (ТТДС I: 477) «детская тележка с крышей» ~ гом. кыпч. *чадра* «чадра, зонтик» < фар. диал. *čāдрä* id. К. **Чаршау, Чатыр, Чатра, Шадра, Шәтер.**

**ЧАЕР** «смола» к. **Чәер.**

**ЧАЖ I** «болотная трава с твердым стеблем» к. **Чаш I.** Ошбу вариант **Чаж II** (к.) тәэсирендә ясалган булса кирәк.

**ЧАЖ II** – имитатив громкому шипению > чув. *чаш*, удм. *чӓж*, мар. *шож* id. К. **Чыж.**

Дерив.: **чажгыр-у** ~ чув. (Сергеев 1971: 146) *чашкӑр-* «шаулап чыжылдау (кызган табага салган су, май тур., ш. ук елан ысылдавы тур.)»; парлы сүз: **чаж-чож** «чалгы белән печән чабу тавышлары тур.»; **чажла-у, чажылда-у.** Удм. телендә дериватлары күп.

**ЧАЙБАН** «тысяченожка» ~ чыгт. *чайбан* «чаян». К. **Чаян.** Räsänen 1969: 94.

**ЧАЙКА-У,** диал. **чәйкә-ү** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «махать, качать (головой); полоскать», диал. «взбалтывать» < гом. кыпч., алт. *чайқа-* (> нуг., каз., к.-калп. *шайқа-*, башк. *сайқа-*), тув. *чайға-, шайға-,* як. *сайға-* һ.б. id. ← **чай-,* к. **Чайпа-у.**

Дерив.: **чайкал-у, чайкат-у.**

**ЧАЙПА-У, чайпы-у** «расплескать; ополаскивать» < гом. кыпч.: кар. *цайпа-, цайпы-*, *чайпа-* «себереп төшерү, җимерү; гайбәтен сөйләү», алт. *чайба-* id., хак. *сайба-* «чайкау; болгату» һ.б. ← себ. *цай-, чай-*, башк. *сай-* «чайкау, юу», алт., хак. диал., тув. *чай-* «чайкау», үзб. *чай-* «чайкау, су кертү», угыз. *чай-* «су белән юдыру» һ.б., к. ш. ук башк. *сайын-* ~ угыз. *чайын-* «су керү, коенү»; к. ш. ук алт. *дьайқа-, йайқа-* «чайкау, чайпу», төр. *calka-* «чайкау». Мисаллардан ук күренгәнчә, *чай// җай* тамыры ономопоэтик характерга ия һәм *чал// җал* тамырына якын тора. Räsänen 1969: 93 (төрле, безнеңчә, шикле сүзләр белән чагыштыра).

Дерив.: **чайпал-у, чайпыл-у** (бүтән юн. формалары кулланылмый), **чайпылыш.**

**ЧАЙРЫ** (ТТДС II: 342) «сосновое бревно; сосновая лучина; сосновая кора; сосновая смола» ~ башк. *сайры*, (БТДҺ: 266) *сайыр*, id. – бу сүздә мәгънә үсеше игътибарга лаеклы. Гомумән, әлбәттә, ул к. **Чәер < чаер** белән бердәй.

**ЧАК I,** диал. **цак, цәк, чәк** «пора, время; момент; определённый период» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг. (к. Радлов III: 1830–1840) *чақ* (> нуг., каз., к.-калп. *шақ*, башк. *сақ*) «чак; иске яз. телләрдә – тәүлекнең уникедән бер өлеше – ике сәгатьлек (вакыт)», ш. ук «унбиш минутлык (вакыт аралыгы)», гомумән «төгәл үлчәм, микъдар; иң кечкенә үлчәм» (тув. *шағ* «заман, замана; борынгы», *шақ* «сәгать, сәгатьләмә; вакыт») < бор. төрки (ДТС: 136, 139) *čaq, čaγ* «чак; нәкъ, төгәл» > госм. һ.б. угыз. (Радлов III: 1842) *чағ, чааг* «билгеләнгән вакыт; астрономик сәгать; уникеллык цикл, бүлҗәл», хак., як. *сах* «вакыт, чак; нәкъ», чув. *чух* < *чох* < болг. **чах* (к. мар. *чоло* «чаклы, чамасындагы» < болг. **чаһлы*) ~ монг. *чаг, цаг* (> бур. *саг*) «ва-

кыт; сәгать; һава торышы» ~ кор. (Ramstedt 1935: 27) *ček* «вакыт», бор. кыт. *чак* «үлчәм; бүленеш; ел башы».

Бор. төрки *чақ* сүзеннән рус. (һ.б. слав.) *час* сүзе килә дигән фикер бар, к. иске рус. (Срезневский III: 1429) *часъ* «вакыт; момент; чак», хәрбиләрнең нәүбәт вакыты (к. рус. *стоять на часах; часовой* «ике сәгать нәүбәттә торучы сакчы») да *чақ* сүзенең бор. мәгъ. бик туры килә. К. ш. ук иске тат. **чақ** – тәүлекнең хайван исемнәре белән аталган унике өлешеннән берсе: **сычқан чағы** – төнге 12 дән 2 гә чаклы аралык, **сығыр чағы** – 2 дән 4 кә чаклы, **барыс чағы** – 4 тән 6 га кадәрге аралык һ.б. (арытабан, бүлҗәлдәге тәртиптә, **тавышкан, ләү, елан, елкы, куй, бичен, тавык, эт, дуңгыз** «чаклары»). К. **Чак II, Чак III.**

**Чак** сүзе, гомумән, гадәттән тыш тармакланган мәгънәле, киң деривацияле сүзләрнең берсе һәм ул барча күрше телләргә дә үтеп кергән. Будагов I: 458–459; Räsänen 1969: 95; Федотов II: 425–426.

Дерив.: **чагында, чакта**. К. **Чакла-у, Чаклы, Чәкле.**

**ЧАК II**, себ. (Тумашева 1992: 233, 236) **цак, цәк** «лучшая пора; в силе» – **Чак I** сүзеннән килеп чыккан булырга тиеш, к. хак. *саа* «көч; чак». Räsänen 1969: 95.

**ЧАК III, чак-чак,** диал. (Тумашева 1992: 233) **цак,** диал. **чәк (чәк кенә), цәк** «едва; едва-едва; еле, еле-еле», себ. «сила; напряжение, предел, предельное напряжение». **Чак I** сүзенә баглы, к. кырг., ком., кар. *чақ* (нуг., каз., к.-калп. *шақ*) «таман; чикләнгән; чигендә торган; соңгы чиктә», алт. (Баскаков 1972: 265) *чақ* «көч, көчергәнеш» һ.б.; «көч» мәгъ. тар ареалда гына (себ. тат., Көньяк Себер төрки) кулланыла. Тат., башк. (ТТДС: 471–472; БҺҺ II: 198) *чақ, сақ* «әле генә», «таманысы» мәгъ. тат.-башк. ареалында гына теркәлгән. К. ш. ук төр. *çak* «нәкъ».

Дерив.: **чаклы (чаклык, чаклым); чак кына (чәк кенә, цәк кенә, берцәк кенә)** тәгъбирендә **чак** сүзенең «кечкенә үлчәм берәмлеге» мәгъ. чагыла. К. **Чак, Чакла-у**. Федотов II: 425–426 (**чак I** сүзе белән бергә карый).

**Чак III** сүзе күрше фин-угор телләренә дә кергән.

**ЧАК IV** (ТТДС I: 471, 500) «плохой, неважный; худой, хилый, тощий», **чәк** (ДС I: 222) «мало, впору» диал. – тат. **чаклы** (к. ТТДС I: 472), башк. (БТДҺ: 267) *сақлы* «уртача, шәп түгел; чамалы» ~ алт. *чак* «начар; сугыш хәле», кар. *чаклы, цаклы* «зыян, зыянлы» сүзеннән эллипсис: *чак* – бу сүзләрнең тамыры буларак – «соңгы чик, чама, үлчәм; үлчәүгә калган»; чув. *чох* > *чух* «чак, шәптән түгел» болг. теленнән; чаг. төр., фар. *çak, çaq* «сәләмә; ярыклы», к. ш. ук мар. (Саваткова: 184) *цӓкын* «начар, чак; ябык». К. **Чак I, Чак II.**

Дерив.: (Остроумов 1972: 132) **чагай-, чаклан-** «начарлану», **чаклык** «начарлык».

**ЧАКЛА-У** «догадываться; замечать», (Г. Бәширов) «что-либо делать осмотрительно, осторожно» > мар. (Иванов, Тужаров: 255; Саваткова: 183) *цакла-, чакла-* id., удм. диал. (Тараканов 1977: 95) *чакла-* «каравыллау, күзәтү» < гом. кыпч. *чақла-* id., к. кырг. *чақта-* > каз. *шақта-*, к.-калп. *шақла-,* төркм. *чақ эт-,* чыгт. уйг. (Радлов III: 1849) *чағла-* > үзб. *чоғла-* һ.б. «таманлау; чамалау; якынча үлчәү» – **чак** «үлчәм» тамырыннан. Чаг. монг. *цагла-* «аңлау, төшенү». К. **Чак I, Чак II.**

**ЧАКЛЫ,** диал. (ТТДС I: 471; Махмутова: 223; Рамазанова 1992: 109) **цаклык, чаклык, цәклек, чаклым**, «до (кого, чего, какого времени)» < гом. кыпч. *чақлы* > башк. *сақлы, сақлық, сақлым,* (БТДҺ: 267) *сақтым*, нуг., к.-калп. *шақлы*, каз. *шақты*, кырг. *чақты* < чыгт. (Будагов I: 459) *чақлық, чақлығ, чағлық* id. ~ төр. *çağlı* id. (зурлык тур. гына); чув. *чул* < *чулĕ, чол* < *чолă* > мар. *чоло* «чаклы, кадәр; чамасында» болг. теленнән, чув. *чухлĕ, чухне* (к. Ашмарин XII: 238, 241) тат. теле тәэсирендә килеп чыга ала. Сүзнең тамыры *чақ* < *чағ* «чама».

**ЧАКМА,** диал. **цакма** «огниво; курок ружья»; неол. «зажигалка» > чув., мар., удм. *чакма*, башк. *сақма* < гом. кыпч., гом. угыз. *чақма* (> нуг., каз. *шақпа*) ~ бор. төрки (ДТС: 140) *čaqtaq* > угыз. *чақмақ,* төр. *çaktak* id.

Чакматашка корыч кисәге белән бәреп ут-очкын чыгару җайланмасы ике өлештән тора: таштан һәм шул ташка бәрә торган тимер, корыч кисәгеннән; шуннан инде ике сүз аерып карала: **чакма** – корыч кисәге, **чакмак**, (Тумашева 1992: 233) **цакмак** – «чакматаш (рус. “кремень”)». Күп кенә төрки телләрдә бу сүзләрнең мәгънәләре бутала, алмаштырыла, к. кар. *цакмак тас [таш]* «чакматаш». Ясалыш буенча да **чакма** һәм **чакмак** – аерым сүзләр: **чакма** төбендә сыйфат (к. К. Нәҗмидә *чакма мылтык*), **чакмак** тәүдән ук исем буларак

ясалган. һәр икесенең уртак тамыры – *чак-* (к. **Чак-у**).

Кырг., уйг. *чақмақ,* үзб. *чақмоқ,* каз., к.-калп. *шақмақ, шақпақ* чакматашны да, ут яндырып җибәрү өчен агач кисәкләрен – шакмакларны да белдерә, к. **Шакмак**. Будагов I: 460–461; Мухамедова 1973: 186; Федотов II: 387.

**ЧАКМАК** «кремень для огнива» ~ төр. *çakmak* id., к. югарыдагыны.

**ЧАКМАТАШ** «кремень» < *чакма таш* (*чакма* – сыйфат); мар. *чакмагүй* id. тат. теленнән ярым калька (мар. *гүй* «таш»).

**ЧАКРЫМ, чакырым,** диал. **цакрым** «верста»; по мнению Н.К. Дмитриева (1962: 499), «расстояние, на котором два человека, максимально удалённые друг от друга, слышат голос третьего, стоящего посередине» (чыннан да, уртача тавышлы кеше бер чакырым ераклыкта торган икенче кешегә ишеттерерлек итеп кычкыра алмый, әлбәттә, уртада тагын бер кеше кирәк) ~ башк. *сақырым* id. < гом. кыпч., алт. *чақырым* (> нуг., каз., к.-калп. *шағырым*), угыз. *чағырым* id., к. ш. ук тат. диал. **кычкырым** > манси. (Kannisto 1925: 118–119) *kaš-karәm* ~ к.-балк. *қычырым* «чакрым», төр. диал. *bağırım* id. (*bağır-* «кычкыру, бакыру»). Семантик параллельләр: мар. *уштыш, үштыш* «кычкырык; чакрым», морд. Э. *вайгельбе* «чакрым», сүзмә-сүз «тавыш очы» (*вайгель* «тавыш бирү», *пе* > *бе* «оч, азак»), белорус. *кликовище* «чакрым» – «иң зур кычкыру» (*кликать* «кычкыру, чакыру»), чыгт. *қыйқырым* «чакрым» (*қыйқыр-* «кыйгыру»), калм. *дуна газр* «чакрым» сүзмә-сүз «тавыш җиткән җир» һ.б. Калм. мисалыннан **чакырым** сүзе асылда сыйфат һәм **чакырым җир** дигәннән эллипсис икәнлеге аңлашыла. Тимергалин: 536.

Дерив.: **чакрымлы; чакрымла-у.**

**ЧАК-У (чакты, чагу),** себ. (Тумашева 1992: 232) **цақ-у,** (ЗДС: 734) **чәк-ү** «высекать огонь кресалом; жалить (о змеях, насекомых и т.п.), жечь (о крапиве и т.п.)», диал. (Радлов IV: 191) «расколоть ударом; рассекать», (ДС III: 123) «разжечь огонь» < гом. кыпч., алт., уйг., угыз. *чақ-* (> башк. *сак-,* нуг., каз., к.-калп., тув. *шақ-*) «ут чагу; елан чагу; бәреп егу; әләкләү» < бор. төрки (ДТС: 140) *čaq-* id. > хак., як. *сах-* ~ монг. *чаки-, цаки-, цахи-* id. Татарларга күрше халыкларда бу сүзнең күч. мәгъ. генә активлашкан: чув. *чух-* < *чох-*, мар. *чок-* < *чак-*, удм. *чак-* [*чагына*] «хакимияткә әләкләү». Гомумән, *чак-* ономопоэтик тамыр булса кирәк, к. тохар. *tsak, tsäk* «ялтырап китү». К. ш. ук **Чагу, Чагыл, Чагыл-у, Чалт, Чаткы, Чәкә-ү**. Будагов I: 460–461; Räsänen 1969: 95; Федотов II: 426; ССТМЯ II: 379.

Кайбер сүзлекләрдә **(чакма) чагу** һәм **(елан, дошман һ.б.) чагу** аерым сүзләр итеп күрсәтелә. Безнеңчә, алай аерырга хаҗәт юк: ут ялтыравына агу-зәһәрнең кискен тәэсире охшатылган.

**ЧАКУЛ** (Нагайбаки: 56–60) «сложное покрывало у кряшенок» к. **Чахул.**

**ЧАКЧА** «охотничья пороховница» ~ башк. *сақса,* к. **Шакша.**

**ЧАКШУР** (миш., ДС I: 213), диал. (ТТДС I: 472, 476, 500, 501) **чапчур, чәкчүр, чәпчүр** «кожаные калоши», диал. (Арсланов 1988: 91) **саксыр** «күн балтырса, ботса» ~ башк. (БТДһ: 267, 269) *саксур, сапсур, сапсауыр* «тиредән тегелгән аяк киеме», нуг., каз. *сақсыр* «йоны белән эчкәре тире ыштан», аз. (АДДЛ: 436) *чахчур,* фар. *čāқшӯр* «сирвәлә, хатын-кыз чалбары», төр. *çakşur, çakşır* «тире ыштан; тире оек» һ.б. < монг. *чакчуур* «тире чалбар» ← **чак-* «урау, төрү», к. эвенк. һ.б. *чак* «урау, төрү».

*Чакчур* сүзе күрше телләргә дә кергән, к. рус. *чакчу́ры, чекчуры*, *чикчиры, чахчуры* «тире бутый, кыска тире итек»; фар. *чакшур* «хатын-кыз чалбары», гар. *җақшир* «тула ыштан», серб.-хорв. *čakšire* «хәрбиләрнең тар, озын ыштаны» һ.б. Räsänen 1969: 96 (госм. *čakšyr* «кальсон» фар. теленнән ди); Фасмер IV: 312; Аникин: 637 (шунда ук әдәбият).

**ЧАКЫ, чакын** (ЗДС: 725) «стебель камыша» ~ алт. (Будагов I: 461) *чаки*, (Баскаков 1965: 337) *чаққы*, каз. *шақы* id. Чаг. **Чәке, Чәкә**.

**ЧАКЫР-У** «громко позвать; призывать; провозглашать; кукарекать» ~ башк. *сақыр-* id. < гом. кыпч., алт. *чақыр-*, уйг., үзб. *чақир-*, төр. *çağır-,* нуг., каз., к.-калп. *шақыр-*, *шағыр-* id., бор. төрки (Боровков 1963: 355) *чағир-, чағур-* «чакыру; баш ору, түбәнчелек белән мөрәҗәгать итү», чув. *çохар-* > *çухăр-* «кычкыру», төр. *çağır-* «чакыру; исемләү; халыкны чакырып җыю; яр салу; җырлау» < *чар-кыр-* < *җар-кыр-* «яр салу» (к. **Җар I**) сүзеннән, к. хак. *чахы-* < *җарқы-* (?) «әмер бирү», *чахыг* <

**жарқығ* «чакыру, өндәү, наказ, тәүсыя». Будагов I: 460; Räsänen 1969: 96.

Дерив.: **чакырыл-у, чакырыш-у, чакырт-у; (кунакка) чакырулы.** К. **Чакырым, Чаң III.** Сөйләшләрдә (ЗДС: 725) **чакыра-у** «туй мөддәте тур. чит кешедә сөйләшү».

**ЧАЛ,** диал. **цал** «седой; седина; седой старик», (ЛТ I: 177) «чёрно-белый» > чув., мар. *чал* «чал, чаллык; яфраклар саргаю» < гом. кыпч., алт., уйг., угыз. *чал* (> башк. *сал*, тув., нуг., каз., к.-калп. *шал*) «чал; саргылт, соры» ~ бор. төрки (ДТС: 137) *čal* «аксыл» ~ яз. монг. *čaγ, ča* «якты, ак, аксыл» тамырыннан; шуннан ясалган бик күп сүзләр тур. ССТМЯ II: 381–388. Рус. *чалый* «чал (ат төсмере)» тур. Аникин: 640–641 (арытабангы әдәбият күрсәтелә). К. **Чаган**.

Дерив.: **чаллы, чалсыз; чалар-у.**

**ЧАЛА, цала** (ЗДС: 705–706) «неполный, неполноценный; еле», себ. (Тумашева 1992: 233) «неполный; недовес; едва, чуть-чуть» к. **Чәлә.**

**ЧАЛАК** «горячий (о лошади)» к. **Чалык.** Чаг. ш. ук фар. *čālāk* «елгыр, өлгер». Төрки телләрдә *чалаҡ* дигән берничә сүз бар, әмма аларның мәгънәләре чагышмый.

**ЧАЛБАР,** диал. (ДС II: 219) **шалавар, шалбар,** трбс. **шалуар** «брюки; шаровары» > мар. (Исанбаев 1978: 32), удм. (Насибуллин: 147) *чалбар, шалабар,* чув. *шалавар, шăлавар* ~ чыгт., үзб. (ЎХШЛ: 293) *чалвар, чалбыр, чалвыр,* нуг., каз., к.-калп. *шалбар,* башк. *салбар* < фар. *šälvār* < бор. фар. *saravara* > гар. *сарбал, сарвала, сäрвäлä* > тат. диал. *сирвәлә* id. (к. **Сирвәлә**). Бу сүз Евразиядә киң таралган. Räsänen 1969: 92; Федотов II: 431; рус. *шальвары, шаровары, чамбары, чембары* «чалбар» тур. Аникин: 641 (махсус әдәбият күрсәтелә); Тимергалин: 536.

Дерив.: **чалбарлы, чалбарсыз; чалбарлык.**

**ЧАЛГЫ** «коса» < гом. кыпч. *чалғы* (> нуг., каз., к.-калп., шор. *шалғы*), угыз. *чалғу, чалғы,* уйг. *чалғи, чалға, чалған,* бор. уйг. *čalγu* id. һәм «урак», угыз телләрендә ш. ук «сызгыч (ук, кәманча)» һәм хәтта «себерке», «скрипка» ~ к.-балк. *чалқы* «чалгы» ← *чал-*, к. **Чал-у.** Безнең *чалгы – чалгы урак* ~ каз. *шалғы орақ* «чала торган урак» дигәннән эллипсис.

Дерив.: **чалгылы, чалгысыз; чалгылык.**

**ЧАЛГЫР** (Зимасов) «специальная лопатка для выкопки корневищ сараны» ~ башк. *салыр* id. монг. телләреннән булса кирәк.

**ЧАЛДУН** (Г. Теләш һ.б. Себер-Урал әдипләре) «чалдон, челдон, вольный переселенец в Сибирь (обычно – беглые солдаты и т.п.)» – рус сүзеннән (аның төрле мәгъ. тур. к. Аникин: 638). Рус сүзе исә, безнеңчә, тат. *чалтаң ~ шалтаң ~ салтаң* «йөксез-мөлкәтсез; иярсез» сүзеннән (ихтимал, *салтаң* сүзең башкортча дип уйлап, татар агайлар *чалтаң* дип бозганнардыр). К. **Салт, Шалтан, Ялтан.**

**ЧАЛКА I** (ТТДС I: 472) «сиво-чалый» ← *чал*. Рус. *чалка* «чал ат» сүзеннән булуы ихтимал. Ләкин рус сүзе үзе татарчадан, к. себ. (Гиганов) **цал** «ала, алмачуар (ат)». Чаг. **Чал.**

**ЧАЛКА II, цалка** диал. «верёвка, аркан с петлей на конце» ~ башк. (БТДҺ: 268) *салқы* < *чалқы* «салның төп бүрәнәләрен беркетә торган бау» ← **чал-у** (башк. *сал-*). К. рус. *ча́лка* «көймә, каек һ.б. ярдагы баганага беркетү арканы, чалкасы» – *чалить* «көймәне һ.б. ярга, салдауга китереп беркетү» сүзеннән, бу сүз исә тат. (арканны) **чал-у** сүзеннән яисә тат., төрки **чал* «чалу бавы» нигезеннән, к. рус. диал. *чал* «чалу бавы» (*чал-у* фигыленең исем коррелянты булу бик тә ихтимал). **Чалка**, әлбәттә, тат. теленең үзендә ясалган (чаг. **бүлкә, тотка** һ.б.ш.). Шулай итеп тат. **чалка́** һәм рус. **ча́лка** уртак тамырдан һәр телнең үзендә үзләренчә ясалган сүзләр. М. Фасмер (IV: 312–313) рус. *чал, чалка, чалить* сүзләренең төрки телләрдән алынма булуын кире кага. Рус. *чёлка* «кечкенә байрак; җиле; чук» сүзе дә **чалка** белән нигездәш булса кирәк.

**ЧАЛКАЙ-У** «откинуться назад» < гом. кыпч., к. кырг., уйг., чыгт. *чалқай-* (нуг., каз., к.-калп. *шалқай-,* башк. *салқай-*) «чалкаю, артка каерылу, чалкан яту; (кырг.) җәйрәп яту» ← иске тат., ком., уйг. *чалқа* «артка каерылып, киерелеп торган хәлдәге (кеше); арканың түбәнге өлеше», иске тат. (ЛТ I: 144) **чалқы** ~ каз. *шалқа,* алт. *чалқуу* һ.б. «чалкан». ***Чал** тамырыннан булса кирәк, чаг. **ар-ка, җил-кә, умырт-ка** һ.б.ш., к. Будагов I: 463 (туб. *чал күтәрә саламын* «чалкан яткырам» тәгъбирен китерә). К. **Чалкак, Чалкан, Чалкатан.**

Дерив.: **чалкаеш-у, чалкайт-у.**

**ЧАЛКАК** «откинутый назад (о шарфах, о косе девушки)» < гом. кыпч., к. башк. *салқаҡ,* кырг. *чалқаҡ*

«киң җәелгән, җәйрәп яткан», ног., каз. *шалқақ* «артка каерылып, киерелеп торган», к.-калп. *шалқақ* «күкрәген киергән (кеше)» ← **чалка-* фигыленнән, чаг. диал. (ЗДС: 726) **чалка, чалкай, чалкый** «чалкан; сөзәк, авыш», к. **Чалкай-у.**

Төрки телләрдә икенче бер *чалқақ* «нервылы, ярсулы» сүзе дә бар, к. **Цалғақ.** К. ш. ук **Чалкак** – Башкортстанда элек бик зур булган авыл һәм тау атамасы (**чалкак тау**, гомумән, «биегәйгән саен текәләнә барган тау»); **чалкулык** «киң үр битләве». Төр. *çalık* «кыек киселгән; кыйшайган» һ.б. Чаг. **Чалыш.**

**ЧАЛКАН** «навзничь» ~ башк. *салҡан,* (БТДҺ: 268) *салҡай* ~ үзб. (ЎХШЛ: 292) *чалақан, чаларкан* id. сүзеннән чыгып, **чал-аркан** дигән парлы сүздән дип уйларга мөмкин. Ләкин сүзнең нигезе шулай да **чалка** «арка, арканың түбән өлеше» булса кирәк; шуннан **чалка-н –** инструменталь килеш формасы, к. ш. ук кырг. *чалка-ла-* «артка каерылу, җәелеп аркага яту» яисә «арка куеп йөзтүбән яту» фигыле дә булган. Шуннан кырг. *чалкар* > каз. *шалқар* «киң җәелгән (дала, күл)». К. **Чалкай-у, Чалкак, Чалкатан.**

**ЧАЛКАТАН** диал. «на спине (о плавании)», себ. (Тумашева 1992: 233) **цалгадан** «артка» – тат. телендә генә. Ихтимал, ***чалкантын** формасыннандыр. Ләкин чаг. **Аркатан.** К. **Чалкай-у.**

**ЧАЛЛЫ** «Набережные Челны (город)» – шул исемдәге елга исеменнән; беренче карашка рус. *чёлны* «көймәләр» сүзеннән кебек, тик русча атамасы – шәһәрнең элекке – төрки атамасының «паронимик аттракциясе» (Г.Е. Корнилов. О судьбе болгарско-чувашского *т'а*$^{o}$*:л, ча*$^{o}$*:л* в топонимике Среднего Поволжья // Вопросы чувашского языкознания. Чебоксары, 1963: 86). Чаллы урынында Казан дәүләте заманында «Челлин город» булганлыгы билгеле (Чернышёв: 3). Тәфсилле нигезләмәсен к. Г.Ф. Саттаров. К этимологии топонима *Набережные Челны* // СТ № 3, 1974: 71–74. К. Гариф Н. 2006: 72–74 (бу китап башлыча Чаллы турында).

Гомумән, **Чаллы** сүзен Корнилов та, Саттаров та болг. **чал < тал* «таш» сүзеннән дип уйлыйлар: **чаллы** «ташлы» (елга атамасы). Тик бу фараз да бәхәссез түгел.

**ЧАЛМА** «чалма», диал. (Арсланов 1988: 98) «лассо», (ДС III: 178) «чал, аркан, канат, которым судно привязывается к столбам на причале» < гом. кыпч., алт., госм. һ.б. угыз. *чалма* (> кар. *цалма*, ног., каз., к.-калп. *шалма*) id. ← **чал-у I**. К. ш. ук кырг., алт. *чалма*, тув. *шалба* «аркан; лассо» > калм. *чалм* id. һ.б. (Будагов I: 464; Радлов III: 1892). Рус. *чалма, челма* тур. Фасмер IV: 313; Федотов II: 389. К. түбәндәгене.

**ЧАЛМАШ-У** (З. Бәшири) «обвиваться с размаху (о конце верёвки, каната, ремня и т.п.)» ← **чал-у** (аның интенсивлык формасы ***чал-ма-** фигыленнән). К. **Чалма.**

**ЧАЛПА,** себ. (Тумашева: 233) **цалба**, «наглый, нахальный; невежественно бесстыдный» ~ башк. *салпа*, каз. *шалпы* id. (барысы да хатыннар тур.), кырг. *чалпоо* «чәмән (ат тур.); тотнаксыз, ярсып, кычкырынып китүчән». Тәкълиди тамырдан булса кирәк.

Дерив. (ТРС II: 558; ЗДС: 726) **чалпай-у** «нык симереп, чалшаю (хатыннар тур.)».

**ЧАЛПАК, чалпа** (Будагов: 462) «высыхающая лужа; остаток мелкого озера в пору засухи» ~ аз. *чалпак, чалбак* «ялангач, аз гына йоннары калган», бор. төрки (ДТС: 137) *čalpaŋ, čalpaq* «былчырак», *calpuš* «ябышкак», чыгт. *чалпуқ* «былчырак». Чаг. чув. *чаплак* «ялангач» (бу сүз тат. сөйләшләрендә дә очрый, шуннан рус. *чаплашка* «кырылган башка киелә торган кәпәч». Монда төрле тамырлар булырга мөмкин, к. **Чалпа, Чалчык I, Чәлпән.**

**ЧАЛПУ** (ТТДС I: 473), **чалпы** (ТТДС II: 344), **чалпук** (без теркәдек. – *Р.Ә.*), **шарпу** (ЗДС: 779) «кусок ткани с написанным на нем и прикрепленным заговором» (**чалпу чалу** «завязывать этой тканью предмет заговаривания») < *чалу бау ~ чалу бағ* (булса кирәк), к. себ. (Тумашева 1992: 233) **цалу < чалу** «курчак-амулет» ~ алт. *чалу* «төңгергә яки баучыкка асылган ритуаль кештәкләр, курчаклар яисә төсле тукыма кисәкләре – алар Өлгән тәңренең «тугыз кызын» сурәтләгәннәр; гомумән, *чалу < чалығ* (> шор. *шалығ*) «сурәт, рәсем» дигән сүз (к. **Чалым**), мәс., шор. *парс чалу* «барыс рәсеме» һ.б. Һәртөрле *чалулар* тур. к. Иванов 1979: 38, 81, 88–89, 100–104, 166–169. Гомумән, **чалпу** сүзе (*-п-* билгесе буенча) тат. телендәге бор. кырг.-хак. яисә бор. уйг. компонентыннан килә. К. ш. ук **Цалу**, **Чабук.**

**ЧАЛТ I** – имитатив резкому удару в щёки (*чалт яңагына* «удар в щёки так, что искры сыплются из глаз»). Чаг. **Шалт.**

**ЧАЛТ II: чалт аяз** «небо без единого облачка (и солнце светит ярко)» < ***чагылт** булса кирәк, к. **Цалу, Чагу.**

**ЧАЛУ I** (ТТДС I: 473) «луг; сенокос» ← **чал-у** («печән чабу» мәгънәсеннән, к. **Чалгы**). Бу сүзнең **чалулык** «печәнлек мәйдан» дериваты киңрәк кулланыла.

**ЧАЛУ II** (ТТДС I: 473) «метла, сделанная из ветвистого сука, деревца» ~ аз. (АДДЛ: 434) *чалғи, чалғу* «зур себерке» (*чалғыламах* «зур себерке белән себерү») – **чал-у** (к.) фигыленең хәтсез күп дериватларыннан берсе булса кирәк. К. ш. ук **Чалыр.**

**ЧАЛУ III,** диал. **салу** «раскат, косой скат (на зимней дороге)» ~ башк. *салу* id. ← **чал-у** «кыек кисү, кыеклау» (к. **Чалыш).**

**ЧАЛ-У I** «обвивать; завернуть; захлёстывать; свалить (на убой); подставить ногу», (ЗДС: 727) «обойти, кружить», себ. (Тумашева 1992: 133–134) **цал-у** «путаться под ногами; привязываться (в агрессивном настроении); искать ссоры»; общее значение глагола *чал-, цал-* (башк. *сал-*) «бросать аркан, веревку и т.п. так, чтобы оно обвивало, обводило концом или совсем завернулось, связалось (концом)» > мар., удм. диал. *чал-* «терлек чалу», башк. *сал-* (мәгънәләре татарчадагыдан таррак) < гом. кыпч., гом. төрки *чал-* (> тув., нуг., каз., к.-калп. *шал-*) «чалу» < бор. төрки «бауның, арканның очын кирәгенчә уралырлык итеп ыргыту» мәгънәсеннән: шундый хәрәкәт бор. күчмә тормышта бик тә актуаль булганлыктан, бу сүзнең күч. мәгънәләре дә күбәйгән; бор. төрки сүзлектә (ДТС: 137) үк инде күч. мәгъ. генә бирелә: «сугу; бәрү; җиргә егу; хәбәр итү (кыллы музыкаль коралны уйнату мәгънәсеннән)». Чув. телендә *çол-* > *çул-,* мар. *с'ол- с'ал-* бер генә мәгънәдә «печән чабу». Аерым төрки телләрдә *чал- ~ сал- ~ шал-* фигыленең мәгъ. һәм дериватлары күп булучан.

Күч. мәгънәләре күп булганлыктан, төрки телләрдә *чал-* иң продуктив нигезләрнең берсе. Будагов I: 463–464; Räsänen 1969: 97; Мухамедова 1973: 187; Федотов II: 132 (бөтенләй нигезсез рәвештә *сол-* «чалу» тамырын *çăл-* «йолу» белән чагыштыра). К. **Чәл-ү**.

Дерив.: (аяк) **чалын-у;** (кыллы музыкаль инструмент) **чалын-у;** (аяк) **чалыштыр-у;** (аяк) **чалыш-у; чалдыр-у;** (аяк) **чалыш;** к. **Чалгы, Чалка II, Чалкын, Чалма, Чалмаш-у, Чалу I–II, Чалык, Чалым, Чалын-у, Чалыш;** себ. (Тумашева 1992: 234) **цалын-у, цалыш-у** «эшсез йөрү, каңгырып йөрү».

**ЧАЛ-У II** (ТТДС I: 473) «очищать зерно метлой во время провеивания» – **чал-у I** нең аерымланган мәгъ.

**ЧАЛ-У III** (ТТДС II: 344) «делать верёвочные узлы, фигуры, контуры, делать секретные узлы (один из способов гадания)» – гом. төрки *чал-* (к. **Чал-у I**) сүзенең күч. мәгънәләреннән берсе. К. **Чалым.**

**ЧАЛЧУТ** – название деревушки близ г. Уфы, диал. **чәлчүт,** (Зимасов: 99) **тьәлтьүет** «легкомысленный, вздорный» ~ башкорт кабиләсе атамасы *һальют, сальют, сальйуғут* < монг. *салҗигут* «сәлҗуклар» сүзеннән. К. **Сәлҗук**. Башк. кабиләсе тур. к. Максютова 1976 (аерым бүлек). Ул *сальютлар* Урал арты төбәгендә яшиләр, әмма элек төрле тарафка таралган булганнар бугай.

Чыңгыз хан яулары белән яисә элегрәк тә Көньяк Урал регионына килгән *сәлҗугут*лар, күрәсең, татарлар составына да кергәннәр.

**ЧАЛЧЫК I** (Будагов I: 462) «лужа, топь», «место, где из-под земли сочится вода» (к. Н. Исәнбәт, I: 492 *Чулман төбе чалчык, Ярлары кызык балчык*), «наледь» (ТТДС: 474), себ. (Тумашева 1992: 233) **цалцык** «лужа, слякоть; наледь» – гом. кыпч., к. башк. *салсыҡ* «былчырак; баткаклык», кырг. *чалчыҡ*, нуг., каз., к.-калп. *шалшық,* үзб. (ЎХШЛ: 297) *чәлчик* id. чаг. бор. төрки (ДТС: 137) *čalpaŋ, čalpaq* «былчырак» > кр.-тат. *чалпа*; к. ш. ук көрд. *calav* «чалчык, былчырак».

**ЧАЛЧЫК II** «навязчивый; шальной» – алт., хак., тув. *чалчыҡ*, хак. *салчых* «бәйләнчек» ← (алт. һ.б.) *чылчы-, салчы-* ~ як. *чалычый-* > эвенк. (ССТМЯ II: 382) *чалчи-* «тыйнаксызлану; бәйләнү, җәнҗаллашу»; к. ш. ук себ. **чалыҡ, цалыҡ** «бәйләнчек; дуамал», бу сүз исә **чалы-* > себ. (Тумашева 1992: 233) *цалы-* «талашырга тору» сүзеннән, ***чалчы-** шуның интенсивлык формасы булса кирәк. Чаг. **Чалчык I, Чалык.**

**ЧАЛЫК, чалак** (Троянский I: 481) «задорный, резвый (о лошади)», себ. (Тумашева 1992: 233–234) **цалыҡ** «назойливый; шальной; диковатый (о нраве)» ~ башк. (БТДһ: 268) *салыҡ* «башын уйнатучан

(ат тур.)», ком. *чалық* «чалык (ат)»; к.-балк. *чалық* «каприз, холыксызлык (бигрәк тә атка карата)», кар. *цылык* «үҗәт», алт. *чалыҡ* «холыксыз» ~ монг. *čalgai* > калм. *tsalgää* «ярсу (ат)», к. ш. ук фар., чыгт. (Будагов I: 462) *чалығ, чалыҡ,* бор. төрки – гар. сүзлекләрдә *čalyq* «артак, холыксыз; каты муенлы (ат)», (к. Zajączkowski 1961: 40) ~ каз. *шалыҡ* «шаян, шук», «эпилептик» һ.б. К. ш. ук чув. *чалак* «ярсу, чалык (ат һ.б.), җитез» һ.б. Төр. телендә *çalâk* «тиз, өлгер, җитез» һәм *çalık* «кыек киселгән; биртек» һ.б. – икесе ике сүз. Беренчесе фар. теленә нисбәт ителә.

Бу сүзләр, әлбәттә, уртак *чал-* «кискен хәрәкәтләр ясау» тамырыннан, к. **Чал-у**. Wichmann Y. Wotjakische chrestomatie. Helsinki, 1901: 116; Räsänen 1922: 75; Федотов II: 388.

**ЧАЛЫМ** «черта (лица)», «характер» ~ төр. *çalım* «кылыч йөзе, кыланыш», нуг., каз. *шалым*, тув. *салым* «учлам; тотыныш» (шуннан нуг. *шалымлы,* каз. *шалымды*, тув. *салымныг* «елгыр») ← *чал-* (аның «эләктерү; күреп алу» мәгънәсеннән). Гомумән, төрки телләрдә *чалым* бик төрле мәгъ. очрый; ихтимал, **чал-у** сүзенең «сурәтләү» мәгъ. булгандыр, к. **Чалпу.**

**ЧАЛЫН-У** «цыпляться (за ноги); бросаться в глаза, привлекать внимание», диал. (ЛТ I: 166) «прикасаться», (Тумашева 1992: 234) **цалын-у** «шататься, ходить зря» ~ к.-калп. *шалын-* «чалыну» ← *шал-* «күреп алу, күзгә элү», ком. *чалын-* «колакка чалыну» һ.б. Монда контаминация бар: (*күзгә) чалын-у* < *чагылын-у* булса кирәк, к. **Чак-у, Чагыл-у.**

Дерив.: **чалыныл-у, чалындыр-у.**

**ЧАЛЫР** (ТТДС II: 344) «мягкая метла для очистки верха вороха зерна» ~ башк. (БТДҺ: 267) *салыр, салир* ~ хак. *салгыр*. id. К. **Чалгыр, Чалу.**

**ЧАЛЫШ** «косой; вкривь, вкось» > чув. *чалăш,* мар. *чалыш* < гом. кыпч., алт. *чалыш* (> башк. *салыш,* нуг., каз., к.-калп. *шалыс*) һ.б. ← гом. төрки *чал-* «кыек чабу, кыеклатып кисү» (*чал-у* «арканлап аудару һ.б.» белән бердәй булса кирәк), к. СС *čalyš* «кыек күзле», төр. *çalık* «чалыш», Räsänen 1969: 97; Федотов II: 388.

Дерив.: **чалышлык; чалшай-у; чалыш-чолыш** (~ гом. кыпч. *чалыш-чулуш*).

**ЧАЛЫШ-У,** диал. **цалыш-у** (Тумашева 1992: 234) «слоняться», иск. «работать» < гом. кыпч., төр., төркм. *чалыш-* (> нуг., каз. *шалыс-*) «тырышу; көч кую, эшләү», тув. *шалыш-* «бер-берсенә ышкылу, эләгешү» һ.б. ← *чал-*, к. **Чалым.** Гомумән, төрки телләрдә *чалыш-* дигән бүтән фигыльләр дә бар (мәс., *аяк чалыш-у* һ.б.ш.), к. себ. (Тумашева 1992: 234) **цалыш-у** «кыйшаю, чалшаю» ← **чал-* «кыек кисү» (к. **Чалыш**).

**ЧАМ** (ЛТ: 167), диал. **шам, шәм** «деловая сосна» < төр. *çam* «Шам, Ливан; Ливан кедры, нарат». К. Будагов I: 662; Eren: 77.

**ЧАМА,** диал. **цама** «приблизительная мера; возможность (кого)» ~ кырг., уйг., чулым. *чама*, нуг., каз., к.-калп. *шама,* башк. *сама* «чама, көчкуәт», төркм. *чеме [чэмэ], цама* «форсат; исәп» бор. төрки **ча-* < кор. (к. Рамстедт 1957: 52, 179) *chai-*, монг. *цай-* «үлчәү» (< бор. кыт. *ča* «фут; табан») сүзеннән шикелле, шуннан ук чагыштыру кушымчасы *-ча//-чә* дә килеп чыккан диләр. Себ. (Тумашева 1992: 234) **цама-у** «үлчәп чыгу; аеру» бор. **ча-* фигыленең интенсивлык формасыннан килә ала. Ләкин, безнеңчә, *чама* сүзе бор. кыт. *чама* «чәй-ат» сүзеннән «чәйне атка алмаштыру нисбәте» мәгънәсеннән килә (Ахметьянов 1989: 160). Räsänen 1969: 98; Федотов II: 389.

**Чама** сүзе тат. теленнән күрше фин-угор телләренә дә кергән; чув. телендә аның дериватлары *чамала-, чамалă* һәм ярымкалька *чамасăр* «чамасыз» кулланыла.

**ЧАМБЫЛ, чамбул** (Будагов I: 465) «киң каеш элмәк» < **чәмбәр** (к.) булуы ихтимал, к. каз. диал. (ҚТДС: 732) *шамбал* «җилкәннәрне тота торган бау, баулар». Чаг. ш. ук рус. *чембур* ~ монг. *цумбуур* «йөгән».

**ЧАН** «чан, большая кадка» > чув., рус., морд. *чан,* мар., удм. *чан, чаҥ,* мар. диал. *цаҥ* < кыт., кор. (Ramstedt 1949: 21; Gabain 1950: 307) *čan* «чиләк, чүлмәк», к. ш. ук яз. монг. (Поппе 1938: 435) *čип* «чан».

Рус этимологиясендә *чан* бор. рус. *дшанъ* «такта кисмәк» сүзеннән дип карала һәм тат., чув. һ.б. *чан*, як. *чаан* «чан» рус. теленнән алынма диелә, к. Федотов II: 389–390. Ләкин бор. төрки (ДТС: 138) *čаn* «чан» < кыт. **čаn*, хәз. кыт. *чжань* «купы». К. ш. ук **Чанак.**

**ЧАНА,** диал. **цана** «сани» ~ башк. *сана* id., ш. ук «чаңгы» < гом. кыпч., уйг. *чана,* үзб. *чона,*

*чана* һ.б. (> ног., каз., к.-калп. *шана*) ~ себ. (Тумашева 1992: 234) **цанак,** алт. *чанак, чанык* (> тув. *шанак*), хак. *саңа* ~ чыгт. (Радлов III: 1855–1857) *санак,* чув. *çона* > *çуна* id., ш. ук «чана табаны» ~ иске монг. *čana* (> монг., бур. *цана, сана*) «чана», укр. *сани, санка* «чана табаны» һ.б. М. Фасмер (III: 556–557) тат. һ.б. *чана* рус. һ.б. *сани* сүзләренең гомогенлыгын кире кага, ләкин күп кенә тикшеренүчеләр монда уртак тамыр булырга тиеш диләр (бу хакта к. Аникин: 482). Безнеңчә, *чана* – бор. мәдәни сүз һәм түбәндә «мамонт теше, яңак, ияк сөяге» мәгъ. булган, к. чех. *saně* «чана; яңак сөяге» (чана табаннары яңак сөягенә охшатылган). К. фин. *sani,* эстон. *saŋ*, венг. *szaŋ* «чана», манси. *sun* id. ~ груз. *čana*, авар. *čanağ,* әрм. *sahnak,* фар. *чанаһ* «чана; ияк – яңак сөяге» (к. Абаев I: 398), монг. *шанаа* «яңак», як. *сыҥаах* «яңак; чана» ~ чыгт. *чаңа* «урт сөяге» (Пекарский: 2470).

Бор. заманнарда кар өстеннән гади такта (ике такта) ярдәмендә сөйрәтеп йөкләр һ.б. күчергәннәр. Алгы ягы нык күтәртелгән чаналар соңрак килеп чыккан һәм, күрәсең, мондый чаналар заманында зур яңалык булган. Бик ихтимал ки, *чана* тамыры фин-угор телләреннән таралгандыр. Шуннан ук **чаңгы** (к.). сүзе дә килеп чыккан. К. ш. ук рус. *рты* «яңаклар; чана төре», *ирты* «чаңгы, чаңгылар». Räsänen 1969: 98; Федотов II: 136–137; Тимергалин: 537–538.

Дерив.: **чаналы, чаналык; чаначы.**

**ЧАНАК, чанач** (Будагов I: 488) «скула, висок» ~ кырг. *чанак,* каз. *шанақ* «баш сөягендә күз оясы», чыгт., аз., кр.-тат. **чәнак, чанак** «баш сөяге, чирәп; купы; чиләк», госм., үзб. (ЎХШЛ: 293) *чанақ,* каз. *шанақ* «кыллы музыкаль әсбап резонаторы; тегермән каушасы», уйг. *чанақ* «кабырчык; тегермән ташы тишеге; баш сөягендә күз чокыры», бор. төрки (ДТС: 138) *čanaq,* (Мухамедова 1973: 187) *чаанақ* «агач купы». К. ш. ук яз. монг. *sinaγa* > хәз. монг., бур. *шанага*[н] «чүмеч, уҗау» ~ эвенк. (ССТМЯ II: 395) *чинака* id. Рус. *ченак, чинак, чанак, шанага* «агач кашык, чүмеч» тур. Аникин: 655, 689 (әдәбият күрсәтелә). К. **Чинак. Яңак** белән бердәй түгел.

«Баш сөяге ~ купы, чүмеч, чүлмәк» мәгъ. күчеше типологик күренеш, чаг. **Чирәп.**

**ЧАНАЧ** диал. «охотничий мешок; спальный мешок» ~ кырг., уйг. *чанач* (> каз., к.-калп. *шанаш*), чыгт. (Будагов I: 616), төркм., үзб. *санач, саноч* «ярмыйча туналган тиредән эшләнгән капчык; су капчыгы». Чаг. бор. төрки (ДТС: 138) *čanač* «арык, чибек». Нұрмағамбетов: 130–131 (каз. *шанаш* сүзен **чанак** (к.) белән чагыштыра). ЭСТЯ VII: 189–190.

**ЧАНДАР** – название реки и населённого пункта в Башкортостане, издавна центра лесозаготовок (лес самотоком сплавляли по названной реке) – ихтимал ки, бор. төрки (ДТС: 139, 149) *čandaru* «сандал агачы», ш. ук *čïndan, čïntan* «сандал агачы; хушбуй». **Чандар** < фар. *чандал* < һинд. *canadana* «кыймматле кызыл (чыннан да кызыл үзагачлы) агач» дравид телләреннән килә. **Кызыл агач** дип кыйммәтле – матур, нык хуш исле агачны атау да шул чандардан күчерелгән булса кирәк.

Гомумән, *чандан ~ чандал ~ чандыр*, ш. ук *сандал, сантал, сандали* (к. **Сандал**) Евразия телләренә гаҗәеп дәрәҗәдә киң таралып, исәпсез күп филиация биргән, к. Räsänen 1969: 400.

Бор. төрки *čïndan at* «җирән ат» тәгъбирендә дә шул ук агач төсе чагылдырылган бугай.

**ЧАНДЫР** «сухощавый; жилистый», диал. (ЗДС: 737) **чәндер, чәндеркә** «худой (о ребёнке)», «голень», (ТТДС I: 474) «безволосое место у паха животных», «жила, сухожилие» < гом. кыпч., к. кырг., ком. *чандыр* «сеңер; бот арасындагы шәрә төш (хайваннарда)» > башк., хак. *сандыр* «касык; чандыр», ног., каз., к.-калп., тув. *шандыр* id., ш. ук «корсак мускулатурасы; сеңерле ит; сеңер», үзб., уйг. *чандир* > фар. *чӓндӓр* «сеңер, тарамыш», үзб. диал., уйг., каз. диал. *чәндĕр* «чандыр (кеше)» < уйг., монг. *чандыр* «киндер буйлыгы; сеңер; калдык». К. **Чәлтер.**

**ЧАҢ I,** диал. **цаң** «колокол; звон колоколов» > чув. *чан*, мар. *чаң, цаң,* удм. диал. *чан* id. < уйг. *чаң* (> башк. *саң*, ног., каз., к.-калп., алт., шор., тув. *шаң*) «чаң, гонг, литавра», төр. *çan* id., як. *чаң, чааң* «бронза төре (чаң өчен яраклы)» ~ монг. *чаң, цаң*, калм. *tsaŋ* «литавра; чаң» кытайчадан булса кирәк, ләкин Рясянен (Räsänen 1969: 99, 104) бу сүзне фар. *чаң* «чаң» һәм *чӓң* «чәң, арфа» сүзләре белән бәйли. Будагов I: 461; Федотов II: 389.

**ЧАҢ II**, диал. (Тумашева 1992: 234) **цаң** «пыль; иней» < гом. кыпч., уйг. *чаң* (> башк. *саң,* ног., каз., к.-калп. *шаң*), үзб. *чанг,* таҗ. *чанк* id. ~ як. *чэҥ,* (Пекарский: 3570) *чаң, чаан* «туңлык; бәс, сыкы» ~ яз. монг. *čang* > монг. *цанг,* бур. *сэнг* «сыкы, бәс» ~ эвенк. (ССТМЯ II: 421) *чэҥ-* «бәсләнү».

**ЧАҢ III** – имитатив громкому звону, «звон» > чув. *чан*, башк. *саң, саңк* id. – гом. төрки характердагы сүз, к. як. *чаң* – металлга металл бәрелү авазына тәкълит. Бу имитативның **чаң I** белән бәйләнешы юк түгел. К. ш. ук **Чың.**

Дерив.: **чаң-чоң, чангыл-чонгыл** (~ төр. *çangıl-çangul*); кайбер кыпч. телләрендәге *чаңкыр-мак* «югары тавыш белән кычкыру» сүзе **чакыр-у** (к.) белән контаминациягә кергән.

**ЧАҢГЫ** «лыжа, лыжи», иск. (Троянский I: 488) **чаңға**, себ. (Тумашева 1992: 234) **цанка, цанкы** ~ кырг. *чаңгы* (> каз. *шаңгы*), алт. *чана, шанаш, шаны* (> шор., тув. *шана*) id. ~ монг. *цана* id. *Чана* һәм *чаңгы* сүзләренең урын алмаштыруы аларның охшашлыгыннан да, тамырдашлыгыннан да килсә кирәк. К. **Чана**. Каз. *шаңғыш* «чаңгы» (һәм *чаңгы* үзе), уйг. *чаңги* «тимераяк», элек **чаң-* «шуу» дигән фикергә этәрә, ләкин бу сүзләр икенчел – халык этимологиясенчә ясалган булса кирәк. Һәрхәлдә **чаңгы** һәм **чана** сүзләрен аертырлык дәлилләр әлегә юк.

Дерив.: **чаңгылы, чаңгысыз; чангычы.**

**ЧАҢГЫРАК, чағарақ** «верхнее (дымовое) отверстие юрты» < гом. кыпч. *чаңырақ, чаңарақ* (> башк., нуг. *сағарақ, шығарақ,* каз. *саңырақ, саңарақ, шаңырақ, шанағарақ,* к.-калп. *шаңырақ, шаңрақ*) id., кырг. *чағарақ* «түгәрәк, тугым, коршау, дүңгәләк» ~ монг. *цагариг, цагарт*, бур. *сахариг* id. һ.б. (к. Rona-Tas. Notes on the Kazak yurt of west Mongolia // Acta Orientalia, XII, 1964), яз. монг. *čaγarıγ* «коршау» ~ маньч. *ǯабархан* id. (к. ССТМЯ I: 239). К. **Чагарак**. Räsänen: 99.

**ЧАҢКА-У** «жаждать» < гом. кыпч., уйг., үзб. *чаңқа-,* башк. *саңқы-* ~ яз. монг. *čangγa-* (хәз. монг. *цанга-,* бур. *саңга-*) id. *Чаң* «тузан; эсселек» сүзеннән булса кирәк. К. **Саңак.**

**ЧАҢКЫЛДА-У, чаңгылда-у** «резко звенеть (о пиле и др.)» ← **чаңкыл, чаңғыл ← чаң** (к. **Чаң III**). Чаг. яз. монг. *čanggilǯa-* > хәз. монг. *цангина-* ~ эвенк. (ССТМЯ II: 375) *чаҮълън-* «чаңгылдау». К. ш. ук тат. **чаңгыл-чоңгыл** ~ гом. төрки (төр. һ.б.) *чаңгыл-чуңгул* «көчле һәм күптөрле чың, металл шалтыравы», тат. һ.б. **чаңгыр-чыңгыр** «бераз тонырак шалтырау».

**ЧАП I** – подражание хлёсткому удару, «шлёп» ~ чув. *чап, çап* id., ләкин чув. сүзе **чәп** (йомшаграк бәрүгә имитатив) вариантына да тәңгәл.

Дерив.: диал. (ДС III: 179) **чапа-у** «бәләкләү», **чапылда-у**, парлы сүз: **чап-чоп** (мәс., былчыракта чабу, йөгерү авазлары тур.); **чапыр-чопыр; чапырдау** һ.б. (бу сүзләрнең параллельләре төрле төрки телләрдә очрый). К. **Чабак III, Чаптыр-чоптыр, Чап-у I.**

**ЧАП II,** себ. (Тумашева 1992: 234) **цап** «молва; слава (сомнительная)» > чув., мар. *чап* (уңай мәгъ.) «дан» ~ алт., уйг. *чап* «дан», чыгт. (Радлов 1915–1916) *чап* «ялган хәбәр; мактану, алдашу»; як., аз., төр. (Будагов I: 453) *чап* «мактану» < бор. төрки (ДТС: 135–136) *čab, čav, čaf* «дан, данлы; билгеле», к. ш. ук чыгт., уйг., төр. *čav* «сүз, хәбәр; дан», шор. *шап*, хак. *саб* «дан» ~ фар. *чаw, чаw* «кычкырык, хәбәр» (к. Будагов I: 465); бу сүзнең фигыль коррелянты чыгт. (Радлов III: 1931–1935) *чав-* «билгеле, атаклы булып китү», шуннан **чабық-, чавуқ-** «начар, дан алу» (к. ЛТ I: 163). Räsänen 1969: 93 (**чап** сүзен монг. *чуу* < *чаву* «эхо, дан» сүзе белән чагыштыра, к. **Шау-шу**); Федотов II: 390.

Дерив.: иске тат. **чаплы** «атаклы», шуннан чув. *чаплă* > мар. *чапле* «данлы, атаклы»; к. бор. төрки (КБ) *čaplıy-külüg* «атаклы-данлы». Хәз. тат. *чап* сүзе **аты-чабы** парлы сүзендә очрый, к. ш. ук себ. **цапла-у** «данлау». К. **Чабык-у.**

*Чап* иң тәүләп фиксацияләнгән төрки сүзләрнең берсе: Кытай чыганакларында атаклы **Күктүрек ханы Шабалио** исеменең мәгънәсе «данлы» булганлыгы әйтелә (к. **Чабавыл**); төрки яңгырашы *чаба-лыг* яисә *шабалыг* дип тә әйтергә мөмкин; бор. яңгырашы *чаба* булса, бу сүз төр. *çaba* «тырышлык; дан сөючәнлек» белән гомоген булуы ихтимал.

**ЧАПАК** диал. (ТТДС I: 171) «находчивый; смышлёный; быстрый, оперативный» ~ төр. *çabuk*, фар. *чабөк, чабок* id., көрд. *çapik* «тере, хәрәкәтчән, елгыр» һ.б. төрки сүз булса кирәк, к. **Чап-у.**

**ЧАПАН** «долгополая верхняя одежда, которую носило духовенство» > чув. *чаппан* < чыгт., уйг., кырг. *чапан* > нуг., каз., к.-калп. *шапан,* башк. *сапан* «халат, чапан», үзб., таҗ. *чаппон* «дәрвишләр киеме, ямаулы халат һ.б.» < фар. *чапан,* асылда гар. диалектларыннан килә һәм **Җөббә** (к.) сүзе белән гомоген. **Чапан** сүз төр. теле даирәсендә сирәк очрый (рус. *чапан, чепан* кыпч. телләреннән, ихтимал, тат. теленнән) һәм фар. телендә дә актив кулланылышта түгел. Шуннан чыгып, бу сүзнең Якын Шәрыктән килүенә шикләнүчеләр дә бар. Ләкин аның төрки тамырлары да күренми (**чабу** белән ча-

гыштыру күп сораулар уята). Будагов I: 452 (**чапан** гомумән иске киемне белдерә ди); Фасмер IV: 315; Федотов II: 390; Аникин: 643–644 (бай әдәбият күрсәтелә, ләкин тат. теле искә алынмый).

Дерив.: **чапанлы, чапансыз; чапанлык.**

**ЧАПКЫ** «тяпка; сечка (орудие); тяжёлый, большой нож» ← **чап-у II.**

**ЧАПКЫН** «скакун; нападение конных воинов или разбойников»; иск. «вестовой» < гом. кыпч., төр. һ.б. *чапқын,* уйг. һ.б. *чапқун* id. > нуг., каз., к.-калп., тув. *шапқын,* башк. *сапқын* «чапкын, чапкыр». Әлбәттә, *чап-у* фигыленнән.

Дерив.: **чапкынчы** «чапкында, чабавылда катнашучы; чабавыл».

**ЧАПРАЗ** (ЛТ) «прошнуровка переднего выреза одежды» < фар. *чäпрāст* «иңбаш каешы, портупея», *чäп-у-рāст* «сулга һәм уңга» (Zenker I: 348; Redhouse: 240); элекке заманнарда һәртөрле киемнәрдә төймә урынына шнурлау кулланылу бөтен дөньяда очраган; соңыннан андый гадәт сирәкләнгән, *чапраз* (функция буенча) төрле мәгънәләр алган, к. нуг. *шапраш, шапыраш* «баскыч; ферма», уйг. *чапрас* «чатлашу, хачлау», гаг. *чабраз, чапраз, чапрас* «чатлаш; пычкы тешләре каермасы (бер теш уңга, бер теш сулга каерылу); чигеш төре; аркылы-торкылы», төркм., төр. *çapraz, capraş* «киемдә күкрәк өстендә параллель кишәрләр (мондый форма XX г. Кызыл Армия шинелендә дә булган); каеш аелы; диагональ; кыек; төймә төре; шахмат тактасындагы шакмаклар» (к. Будагов I: 453; Steuerwald: 168), чув. (< тат.) *чапрас* «кыек-мыек»; Төньяк Кавказ телләрендә *чапраз, чапрас* «кыек, кыеш; каптырма төре һ.б.ш.». К. **Чапрыш.**

**ЧАПРАК** «подстилка под седло из старой стёганной одежды, чепрак» – собственно «грубая ткань с утком, которая значительно толще основы» < **чапур-ак* (к. **Чәпе, Шабыр**) < фар. *чäппар-ак*; рус. *чепрак, чапрак* «эчерге, ияр астында кала торган ат ябуы» төр. теленнән, шуннан ук ним. *Schabracke* id., к. ш. ук нуг., гаг. һ.б. *чапрак, шапрак* «чапрак». Фасмер IV: 315, Räsänen 1969: 99; Аникин: 644 (барча бу авторлар сүзнең этимологиясен ачык калдыралар һәм тат. сүзен искә алмыйлар). К. **Чүпрәк-чапрак.**

**ЧАПРЫШ, чапырыш** (ТТДС I: 474–475) «косой, раскосый; наискось; напротив с отступом» ~ каз. *шапыраш* «кылый», чув. *чапруш* «диагональ бизәкле тукыма» (< тат.) һ.б. **чапраз** (к.) сүзеннән үзгәреп килеп чыккан. Бу сүзнең *чапыр, чаппарак* (Яңавыл, Башкортстан, без теркәдек. – *Р.Ә.*) вариантлары фар. (> үзб.) *чәп, чап* «сул як; кыек; чапрыш» сүзе тәэсирендә пәйда булган бугай. Төр. *чапариз, чапрашик* «буталчык, чапрыш» тур. Будагов I: 468, 469.

**ЧАПТАК** (ДС II: 214) «тренер лошадей» ← **чапта-* «ат өйрәтү; гомумән әзерләү» ~ кырг. *чапта-* «тыгызлау, көпләү; зарядлау», тув. *шаптак, шаптакчы* (< *чаптак, чаптакчы*) «җир идән ясау остасы; себерүче, сылаучы» ← *шапта-* (< *чапта-*) «чыбыркылау; сылау, себерү, тыгызлау, дөмбәсләү (мәс., җир идән ясау өчен)» ← *шап-* < бор. төрки (ДТС: 139) *čap-* «сылау». Тат. атчылык мәдәниятен белдергән бу сүз нишләптер әд. телгә кермәгән. Тат. телендә дә, күрәсең, *чапта-у* «җир идән ясау», шуннан «тырышып, махсус әзерләү» сүзе булган, тик җир идән модадан чыккач, бу сүзнең атчылыкка күчерелгән мәгънәсе генә сакланып калган.

**Чаптак** сүзенең **чаптар** (к.) сүзенә катнашы юк.

**ЧАПТАР,** диал. (Тумашева 1992: 234) **цаптар**, «белоногий», (ДС II: 214) **чаммар** «красный с беловатыми пятнами», «рыжий с белой гривой (все о лошади)» – гомумән, мәгънәсе тат. телендә дә, күрше телләрдә дә төрле урыннарда төрлечәрәк: чув. *чоптар* > *чуптар* (< тат.) «кола; койрыгы һәм ялы аксыл җирән (ат тур.)», мар. *савадар, саватар, цавадар* «кола», удм. *чабдар* «чаптар, ак аяклы», *чукдор* «чаптар» ~ гом. кыпч., алт. *чаптар, чабдар* (> башк. *саптар,* нуг., каз., к.-калп., алт. *шаптар,* каз., тув. *шабдар*) «саргылт җирән; саргылт яллы туры (ат)», хак. *сабдар, чамдар,* шор. *шамдар, шамдыр,* алт. *чавыдар,* тув. *шавыдар* < монг. *чабидар,* бур. *савидар* «аклы җирән, аксыл җирән һ.б.ш.» < бор. монг. *čaγabtar* «аксыл; аклы» ← *čaγa*ⁿ «ак; аклы» (к. **Чал, Чаган**), *ča-ji* «ак булу». К. ш. ук эвенк. (ССТМЯ II: 375) *чабидар* «ак муенлы төлке төрчәсе», маньч. *чабдара* «ак яллы, ак төлке (яки ат)». Нишләптер *чаптар* һ.б. угыз. төркиләрендә сирәк очрый. Räsänen 1969: 92; Федотов II: 424.

Тат. телендә **чаптар** сүзен «чабышкы, чапкын» мәгъ. куллану ялгышлыгы еш очрый.

**ЧАПТЫР** – имитатив бегу по луже, грязи (разбрызгивая воду, грязь): **чаптыр-чаптыр, чаптыр-**

**чоптыр** «с шумом, с брызгами (о беге по воде, грязи)». Гом. кыпч. сүзе булса кирәк.

Дерив.: **чаптырда-у.**

**ЧАПТЫР-У I, чаптырт-у** «обильно мочиться; хлестать струей» ← **чап-у I**. Чаг. ш. ук **Чаптыр** (контаминацион компонент).

**ЧАПТЫР-У II** «случать животных (преимущественно о лошадях)» – бор. фигыль, к. уйг. *чаптир-* id., як. *саптарыы* «чаптыру (исем)» ← кырг., уйг. *чап-* «каплау, аталандыру» (хайваннар тур.).

**ЧАП-У I (чапты, чабу)** «скакать; быстро бегать» > чув. *чоп-, чуп-* < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., төр. һ.б. *чап-* (> башк. *сап-,* нуг., каз., к.-калп., тув. *шап-*) id., чыгт., аз. *чап* «галоп, атта чабу күренеше». Федотов II: 423–424.

Бу сүз төрки телләрдә иң продуктив нигезләрдән: **чабыш-у, чаптыр-у; чапкыр** (ат), к. **Чабавыл, Чабышкы, Чапкын, Чапчан, Чабын-у** һ.б. Кушма сүзләрдә: **атчабар** «кыска юлга йөрүче сыбай», **юлчабар** «озын-озак юлга йөрүче сыбай». К. **Чап-у II.** Будагов I: 451–452.

**ЧАП-У II (чапты, чабу)** «рубить, сечь; ударить махом; хлестать; косить (сено)» < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт. *чап-* (> башк. *сап-,* нуг., каз., к.-калп., тув., шор. *шап-*) id., чув. *çап-* һәм *суп-* id. (бу сүзләрнең мәгъ. аермалыклары да бар) id. К. ш. ук мар. *саваш, соваш,* удм. *чабыны* «сугып, чабып җибәрү» һ.б. (тат. һәм чув. телләреннән).

Иске сүзлекләрдә (Будагов I: 451–452; Радлов III: 1916) һәм хәз. кайбер сүзлекләрдә дә **чап-у I** һәм **чап-у II** икесе бер матдә эчендә, бер сүзнең төрле мәгънәләре итеп биреләләр, ләкин хәз. сүзлекләрнең күпчелегендә алар аерым бирелә, чөнки бу сүзләрнең формалары һәрдаим бердәй булса да, мәгънә бердәйлеге ачык-аян түгел. Räsänen 1969: 104; Федотов II: 85–86.

Абаев (I: 307) **чап-у I** һәм **чап-у II** сүзләренә бик күп бүтән телләрдән параллельләр китерә: фар. *čäpidan* «талау», бор. харәзем. *čäp-* «чабу, чәбәкләү», яз. монг. *čab-* «бәрү, сугу», рус. *цапать* «эләктереп алу», коми., удм. (КЭСК: 249, 302) *сапкыны, чапкыны* «чабу, чәпәү». К. **Чап I, Чәпә-ү** һ.б.

**Чап-у II** продуктив нигез: **чабыл-у, чаптыр-у; чапкы, чапкыч**; **чабылдык, чабым, чабын, чабынты** (печән чабудан соң торып калган үлән); к. **Чабык; Чабын-у; Чапчак.**

**ЧАПУР** (ЗДС: 730, әстр.) «цапля». Чаг. бор. төрки (ДТС: 139) *čap-* «суны чәпелдәтеп йөзү яки йөрү». Тәкълиди сүз, әлбәттә.

**ЧАПЧАК,** диал. (ДС III: 189) **чәпчәк** «кадка, колода (из цельного дерева)» < гом. кыпч., алт. *чапчақ* (> башк. *сапсақ*, нуг., каз., к.-калп. *шапшақ*), шор. *шапчақ* > хак. *сапчах, сапсак* id., як. *чабычах* «туз купы, туз тустаган» < бор. төрки (Ибне Мүһәнна), нан. (ССТМЯ II: 384) *чапчи-,* монг. *цавчи-* «кисү, юну, кыру» сүзеннән булса кирәк. Тат. (ДС II: 213), госм., бор. чыгт. (Рабгузи) *чамчақ* «зур чүмеч, агач тустаган» вариантыннан чыгып, К. Насыйри (ЛТ I: 167) **чамчак** сүзен **чам** «(Ливанда үсә торган) кедр агачы» сүзеннән дип тә аңлата, Х. Әрән исә (1999: 78) төр. *çarçak* < *sapcak* «чапчак» сүзендә *sap* «савыт» сүзен күрә. Чаг. **Чәпче-ү.**

Чув. *çӧнçе* > *çунçе* сүзе иске чув. **çонçа* < болг. **җапжа(ҕ)* вариантыннан булса кирәк (ягъни палатальләшү чув. теленең үзендә булган). Räsänen 1969: 99; Федотов II: 148–149 (чув. сүзен мар. *шавыш* > *шовыш,* удм., коми. *сепыс* «агач савыт, кумта» сүзләре белән чагыштыра, безнеңчә, монда очраклы охшашлык кына).

**ЧАПЧАН,** диал. (Радлов, Образцы... IV: 240; Тумашева 1992: 234) **цапацан, цапцаң** «быстрый, ловкий, проворный; быстро, живо» < гом. кыпч., алт. *чапчаң*, уйг. *чапчан, чапсан* (> үзб. *чопсон*), нуг., каз., к.-калп. *шапшаң,* башк. *сапсан* id. ← *чапчы-* (> каз. *шапшы-*, башк. *сапсы-*) «чабып китәргә тору, ыргылу» ← *чап-* (к. **Чап-у I**). Уйг. *чапсан* сүзендә диссимиляцияме яисә ул аерым *чапсы-* фигыленнәнме икәнлеген әйтү кыен (андый фигыль *чап* «галоп» сүзеннән ясала ала). Будагов I: 451.

**Чапчан** сүзеннән тат. **сапсан** < рус. < башк. *сапсан* «лачынның бер төре» сүзе килә.

**ЧАР I –** «имитатив пронзительному женскому крику (от страха)» – к. **Чәр.**

Дерив.: **чарылда-у**, диал. **чарла-у.**

**ЧАР II** «точило, точильное колесо» > мар., удм., чув. *чар* id. < гом. кыпч. *чар* (> нуг., каз., к.-калп. *шар*, башк. *сар*), уйг. *чарқ* id. < фар. *чäрẋ* «тәгәрмәч», к. **Чарык.**

Дерив.: **чарла-у, чарлан-у.**

**ЧАРА I** (ТТДС I: 476; ТТДС II: 346), себ. (Тумашева 1992: 234) **цара** «большая деревянная чаша

для замешивания теста или формирования хлеба» < гом. кыпч., чув., алт. һ.б. *чара* (> нуг., каз., к.-калп., шор. *шара,* башк. (БҺҺ III: 155) *сара,* хак. *сараа*) «зур агач табак; лакан һ.б.ш.» ~ иске монг. *čara* (> хәз. монг. *цар,* бур. *сара*) ~ маньч. *чара* «сай һәм киң табак», безнеңчә, чув. *чара* «хайваннарның бот арасындагы йонсыз төше» белән бердәй: түбәндә **чара** йоны койдырылган тиредән эшләнмеш җәйпәк табакны, җилпучны һ.б. белдергән (төрки һ.б. күчмә халыкларда тиредән һәртөрле савыт-саба эшләнгәнлеге бик билгеле шәй), шуннан бу сүзнең мәгънәсе һәртөрле агач һәм металл савытларга күчерелгән. К. **Шәрә.** Будагов I: 455; Räsänen 1969: 100; ССТМЯ II: 385; Федотов II: 391–392.

Рус. *чара, чарка, чаруша* «җәйпәк купы, агач тас һ.б.» тур. Фасмер IV: 316; Аникин: 646. Русистларның күпчелеге бу сүзне төрки телләрдән алынган дисә, икенчеләре бор. слав. **čara* сүзеннән дип баралар, к. Шанский: 487; (һәм М.Н. Федотов та шул якка каера). Ләкин бор. слав. сүзенең үзенең бор. төрки телләрдән булуы гаҗәп түгел.

**ЧАРА II** «средство, способ» < гом. кыпч. *чара* (нуг., каз., к.-калп. *шара*, башк. *сара*) id. < фар. *čārä* (> төр. *çare*) «чара» – түбәндә «нәрсәгә, нигә» дигән сүздән. Zenker: 340; Räsänen 1969: 100 һ.б. Чаг. **бичара.**

Дерив.: **чарасыз**.

**ЧАРАЧА** (ТТДС I: 276) «предбанник; сени, павильон перед мечетью (для омовения)» > удм. (Смирнов 1890: 46) *sarači*, (Кельмаков 1977: 57) *мин'чо сарача* id. ~ каз. (Будагов I: 622) *шараша* id. < фар. *сāрāчä* «кечкенә өй; павильон» < *сāрāйчä* «кечкенә сарай, пулат».

**Чарача** сүзе элек «мунча» мәгъ. йөргән.

**ЧАРГӨЛ** (ЛС: 12) «вид декоративного растения – лапчатка белая» < фар. *чäһāргул* «дүртгөл». Бу гөл тире иеләүдә кулланыла, имеш, к. ТТАС 2005: 647.

**ЧАРДАК,** гом. диал. **чарлаҡ** «чердак», диал. (ДС II: 179) **чардак** «могильная ограда» > чув. *чартак,* мар., удм. *чардак, чарлак* ~ гом. кыпч. *чардаҡ* (нуг., каз., к.-калп. *шардаҡ,* башк. *сарлак*) < фар. *чартаҡ* < *чäһāр тāҡ* «дүрт так (ялган тәрәзә, уем)»: төрбәләрнең дүрт ягында так ясала торган булган; кар., төр., кр.-тат. *чардаҡ* «чатыр кыек; каравылчы өйчеге», госм. *чартаҡ* «Монблан» һ.б. Zenker: 340; Будагов I: 455–456. Як. *чардаат* «кабер» һәм бур. *шардааг* «чардак» вариантлары рус теленнән булса кирәк.

Каз. (ҠТАС: 752) *шершек* < *чәртәк* «яссы түбәдә күләгә өчен генә дүрт баганачык өстенә куелган түшәмә, тент» беренчел фарсыча мәгънәгә якын булса кирәк. Рус. *чердак* сүзен фарсычадан түгел дип раслаулар (И.Г. Добродомов һ.б.) тәнкыйть күтәрми. М. Федотов (II: 392–393) чув. *чартак* (*чардак* дип укыла) рус теленнән килә ди, тат. сүзен искә дә алмый. Рус. *чердак, чардакъ* «чардак, каюта, аслык һ.б.» тур. Аникин: 656, 657. К. **Чардуган, Чардук**.

Әд. әсәрләрдә дә еш кына **чарлак** варианты очрый, ләкин, безнеңчә, бу кирәксез кыланыш, чөнки рус. *чердак* вариантын һәркем диярлек белә һәм өстәвенә **чарлак** сүзе (к.) бар. Омонимлаштырудан качарга кирәк.

Дерив.: **чардаклы, чардаксыз.**

**ЧАРДУГАН** «ограда могилы», (Троянский I: 460) «голбец» ~ кар. *шардиван* «баскыч», ком. *шардыван* «парапет, бәләсә» < фар.-таҗ. *чāрдӯгāн* «чардуган» – асылда «дүрт багана» дигән сүз.

**ЧАРДУК** (Троянский I: 463) «рама» < фар. *чāр (чäһāр) дӯҳт* «дүрткел».

**ЧАРКА, чәркә** (к. такмакта: *Байның кызы йорынлы, ике күзе эренле; Ярлы кызы яркадай, ике күзе чаркадай*) «чарка, глубокая чашка» <рус., рус телендә *чара* (к. **Чара**) сүзеннән ясалган.

**ЧАРЛАК** диал. «сибирская чайка» ~ чув. диал. *чарлак*, алт. диал. (Радлов III: 1868) *чарлааҡ* id. ← **чарла-у**. Федотов II: 392 (чув. *чарлан,* мар. *чарлажы* «чеәлән» белән чагыштыра).

**ЧАРПУ** диал. (ЗДС: 731) «сыпь» к. **Чалпу,** ш. ук түбәндәгене.

**ЧАРПЫ-У, чарпа-у, чәрпе-ү** «резко бить небольшим предметом», (ТРС 1931) «хлопать», (ТТДС II: 476) «обжечь брызгами» ~ гом. кыпч., угыз. *чарп-, чарпы-,* төр. *çarp-*, нуг., каз., к.-калп., төркм. *шарып-, шарпы-* «кырыйдан бәрү; бәрдерү; алгы аяктан тибү» – гомумән күп фонетик, морфологик вариантларда һәм мәгънәви конкретлаштыру-тарайтулары белән очрый (ТТАС III: 410): **чарпалан-у** «чәрдәкләнү», **чарпаланыш, чарпылыш, чарпыш** «бәрелешү», **чарпыш-у** «югары

ыргылу (дулкыннар тур.), көрәшү (көрәштә кискен хәрәкәтләр ясау)» һ.б. К. Будагов I: 455. Бу сүзләрнең имитатив нигезе *чари* (> тат. *чәри*), *чар* имитативының *-п* тармагы итеп карала ала. Гомумән, имитатив *ч-* авазы дөньядагы барча телләрдә киң кулланыла (чаг. тат. *чап, чәп, чат, чәк, чык, чуп* һ.б.), чаг. ш. ук рус. *чирк (чирк-ать)* «чытырдатып язып кую», *шарпать* «тартып алу» < *чарпать, черпать* (бу сүзнең нигезе төрки телләрдән алынма дип тә карала), *чёк, чик*. К. **Шырпы.**

**ЧАРСУ** иск. «большой перекрёсток; центральная площадь населённого пункта» < фар. *чāрсӯ* «юл чаты; мәйдан». Бу сүз төрки телләрдә *чаршу* (к. **Чаршу**) сүзе белән контаминацияләнгән.

**ЧАРЧА-У** (Тумашева 1992: 242) «быть усталым (после длительной ходьбы и т.п.)» ~ башк. (БТДҺ: 270) *сарса-* id. к. **Чәрчә-ү.**

**ЧАРШАБ, чәршәб** (Будагов I: 473) «известь для побелки» ~ чаг. төр. *çarpı* id. һәм фар. *шаб* «өслек, өстәр, ябулык, штукатурка һ.б.ш.».

**ЧАРШАУ [чаºршаw]** «плотная занавес» ~ башк., нуг., каз. **шаршау** > чув. *чаршав,* мар. *чарша, чаршау, чаршо,* морд. Э. *чаршав* id. < фар. *чāдыршāб, чāдри-шāб* «кечкенә чатыр, төнге чатыр» сүзеннән (ЛТ I: 124; Радлов III: 1870); чаг. ш. ук кар. гаг. *чарчов, чаршаф,* госм. *чаршаw* «чадра; җәюлек, җәймә; квадрат тукыма кисәге» – төп мәгъ. «дүрткел, дөртпочмак». Федотов II: 393. Диал. **чаршаулы, чаршаусыз.** Башк. телендә *шаршау* – пьесадагы «пәрдә».

**ЧАРШУ,** себ. (Тумашева 1992: 235) **царшу** «рынок» < фар. *чāршӯб* һәм *чāрсӯ* «дүртпочмак; мәйдан; зур базар». К. ш. ук кр.-тат., кар., гаг. һ.б. *чаршы,* төр. *çarcı, çarşı* «зур базар». *Чарсу, чаршаб, чаршуб* сүзләрендә беренче компонент *чар (< чāһāр)* «дүрт», икенче компонентлар аерым, төрле сүзләрдән, ләкин мәзкүр кушма сүзләрнең мәгънәләре фар. телендә дә бутала.

**ЧАРШЫН,** диал. (ТТДС I: 364) **саршин, саршын** «перга» < тат. диал. (Ш. Камал) **сарычын** ~ төр. *sarışın* «якты сары»; **чаршын** сүзе **сарычын балавыз** тәгъбиреннән эллипсис нигезендә фонетик җәһәттән дә үзгәреп формалашкан; *-чын//-чен* аффиксы тат. сөйләшләрендә сыйфатларның кимлек дәрәҗәсе форманты.

**ЧАРЫК I,** диал. (Рәхимова: 95–96; Баязитова 1986: 153–154; Тумашева 1992: 135) **царык, чәрек, чәрик, чаркы, чәрке** – различные (по местностям) виды кожаной одежды – от болотных сапог до лёгких тапочек из сыромятной шкуры; «постолы, поршни, чувяки» < гом. кыпч., гом. угыз. *чарық* (нуг., каз. *шарық,* каз. *шәрке,* башк. *сарық*), чыгт. *чаруқ,* к.-балк. *чуруқ, цуруқ* һ.б. id. ← тат. диал. (Тумашева 1992: 135) **цар-, цары-** < (Будагов I: 457) *чары-,* алт. *чар-,* шор. *шары-* «урап бәйләү, чолгау», к. ш. ук кырг. *чарын,* бор. төрки (ДТС: 14) *čaruq* «аякчу төре», тув. *шарыг* «бәйләү, чолгау, урама, бинт» һ.б.; як. *сарыы* «болан тиресеннән ясалган күн» һ.б. **Чар-, чары-** фигыленең (бор. төрки телләр өчен *ч ~ с* тәңгәллеге закончалыклы булмаса да) *сар-у* (к.) фигыле белән гомоген булуы ихтимал. Гомумән **чарық** иң бор. аякчу төре.

**Чарык** сүзе төрки телләрдән барча күрше телләргә үтеп кергән: рус. *чарык, чарки, чары*; фар., көрд., осет. *чарық,* кабарда. *чырықу* ~ тунг. *чāри* һ.б. Räsänen 1969: 100–101; Фасмер IV: 316–317; Аникин: 646. Себ. (Тумашева 1992: 237) **цәркә** «калуш» русчадан кайткан алынма.

**ЧАРЫК II** «мельничное колесо; прядильная машина; колесо для подъёма воды» > мар. *чарк, чарык* «тәгәрмәч, куласа», удм. *чарк* «куласа калагы», морд. Э. *чары* «тәгәрмәч» < фар. *чāрх* «тәгәрмәч, чар, чарык» < бор. фар. *čaxra*, бор. һинд. *čakra* «тәгәрмәч, түгәрәк» ~ лат. *cyclus* «цикл», рус. *коло (около, колесо),* грек. *πολ(ος)* «полюс, кучәр» сүзләре белән тамырдаш. Абаев I: 288; Kluge: 1023 һ.б.

Күпчелек төрки телләрдә бу сүз фарсычадын артык үзгәрмичә кергән, к. к.-балк., ком. *чарх*, уйг. *чарг,* кр.-тат., госм. *чарқ* һ.б. к. Räsänen 1969: 100. **Чарык** сүзе белән **чыгыр** (к.) гомоген. Фар. *чāрх* «күк гөмбәзе; корыч җәя» тур. Будагов I: 473.

**ЧАРЫС,** диал. (Тумашева 1992: 235; ТТДС I: 477) **царыс, чарыз** «свирепый; чрезмерно бойкий; дерзкий», иск. (Будагов I: 456) **чарыш** «резвый; дикий (о лошади)» > мар. *чорыш, чарыш* «чарыс (ат тур.)», чув. *чорăс* > *чурăс* «чарыс (кеше тур.)», удм. *чарс* «җитез (ат)» ~ кырг. *чарыш* «скандалист»? Күп төрки телләрдә юк, тик үзб. *чарс* «асау, кыргый холыклы (ат)», хак. *сас* < *сарс* id. Чаг. алт. *чарыныч* «аждаһа, ләү» (Баскаков 1972: 266, сүзлекче бу сүзне рус. *Змей Горыныч* сүзеннән димәкче, ләкин бу шикле). К. Насыйри *чарыс* сүзенең **җарыс** вариантын бирә, ләкин моның параллельләре табылмады. Әгәр мәзкүр вари-

ант дөрес булса, **йарыс* вариантыннан **ярсу** (к.) нигезе ясала алган. Федотов II: 425 (материалы фәкыйрь).

**ЧАТ I,** себ. (Тумашева 1992: 235), миш. **цат** «развилина, перекрёсток; место соединения рек и пространство между реками поблизости их слияния» > мар., удм. *чат* id. < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг., үзб. *чат* (> каз. *шат*, башк. *сат*), төр., бор. төрки *čat* «ике елга, ике линия кушылган төш; ботакның кәүсәдән бер якка киткән төше; бот арасы» (чаг. тат. **бот-чат**); кайбер телләрдә бу сүз төп мәгънәләрдән читкә китә, к. башк. *сат* «елганың сай төше», төр. *çat* >> венг. *schat* «аел». Радлов III: 1893–1894; Räsänen 1969: 101.

Дерив.: **чатлык, чатлы, чатсыз** (сирәк); **чатлаш-у.** К. **Чата, Чатай, Чатак, Чатал, Чат-у.**

**ЧАТ II** (ЛТ I: 165) «глубокая яма» << бор. төрки (ДТС: 141) *čat* «кое».

**ЧАТ III** – имитатив звукам резкого удара (мелким предметом, ладонью); «тряс» ~ чув. *çат* id., барча төрки телләрдә бар булса кирәк; шуннан **чат-чот, чатыр-чотыр; чатла-у, чатна-у**. К. **Чатыр I, Чәт, Чәти, Чикләвек, Чыт.**

**ЧАТ IV,** диал. (Махмутова: 240–241, ТТДС I: 468) **цат,** «ясно, точно; точь-в-точь» ~ башк. *сат* id. > чув. *чат* «бөтенләй; нәкъ; тик», мар. (Иванов, Тужаров: 256; Саваткова: 183) *цат* «бик тә, нык, күп», *шат* «бөтенләй, чат». **Чат-у** сүзе белән гомоген булса кирәк, к. диал. (ДС II: 180) **чатябышу** «тоташлый ябышу», **чат яту** «төгәл таман килү».

**ЧАТ V** – название группы сибирских татар (к. Тумашева 1977: 237–238) < алт. һ.б., монг. *чагат* «сагайлар» ← бор. төрки **чагай* > хәз. **сагай** – хакас халкының бер этнографик группасы.

**ЧАТА** (Исәнбәт I: 533) «рогатина (для поднимания застрявшего плуга)» ~ башк. *сата* «чатлы ботак, ике яньле зур сәнәк», нуг. *шата* «ике бот, бот арасы» ← **чат I** сүзеннән, к. түбәндәгене.

**ЧАТАЙ: чатай-ботай** «кривой, искривлённый и ветвистый» ~ башк. *сатай-ботай*, кырг. *чатыбуты* id., ш. ук «буталчык».

*Чатай* сүзе монг. *ачатай* (бур. *асатай*) id. сүзенә бик охшаш; шуннан **чат** сүзе үзе дә монг. **ачат* «ачалар» сүзеннән түгелме икән, дигән фикер туа. К. **Ача.**

**ЧАТАК** «плохо; дрянь», (в парном слове **ботак-чатак** «сросшиеся деревья, ветки») < гом. кыпч., к. башк. *сатаҡ* «начар; хөрти, мөшкел җир тырмалый торган ботаклы агач», (БТДҺ: 271) «елга чаты», ком. *чатаҡ* «аяк чалу (көрәштә)», кырг. *чатаҡ* > каз., к.-калп. *шатаҡ* «конфликт, җәнҗал», уйг. *чатаҡ,* үзб. *чатоҡ* «буталчык, болгавыр, аңлашмаучанлык», аз. *чатаг* «үзара ябышып үскән (кәүсә, ботак)», төр. *çatak* «чытырман; буталчык, чуалчык; чәтертән, чәттә, талашчан» һ.б.; бу сүзне Э.В. Севортян (1962: 43) **чат-у** (к.) фигыленнән дип аңлаткан; шуның белән бергә **чатак чат** исеменнән дә һәм (кырг., ком. һ.б.) *чата-* «чат ясау» фигыленнән дә ясала ала. К. **Чатал, Чатлаш-у, Чатмаш-у.**

**ЧАТАЛ** (Троянский I: 435) «вилка; кол, раздвоенный в одном конце (употребляемый в различных целях)» < гом. кыпч., к. нуг., к.-балк. *шатал,* кар., кр.-тат., төр. *çatal* id., ком. *чатал* «сука; кәҗә (утын кисү өчен аяклы җайланма); көймә сөлтәре (бигрәк тә дугасыман терәк)», алт. *чатан* «чатлы багана» ← **чат I**. К. ш. ук чыгт. (әт-Төхфәт: 39) *чатал* «чатал» ~ төркм. (Мухамедова 1973: 187) *чатал* «бот төбе». **Чатал** сүзе гар. һәм фар. телләренә дә алынган. К. **Чатан.** Добр. *çatal* тур. Dobr. I: 482–483 (Дунай дельтасындагы тармаклар шулай атала икән).

**ЧАТАН** «хромой; кривоногий», диал. (ТТДС I: 477) «косой; наискось» > мар., чув. *чатан*, башк. *сатан* «хромой» ~ госм. (Радлов III: 1895) *чатан* «ике аяк (арасы)», алт. *чадан, чатан* «чатлы багана, чата». **Чатан**, димәк, «ике аягын да аерып атлаучы» сүзеннән һәм «чатлы агач» дигәннән метафора. **Чатан** сүзе татарча мәгънәсендә күпчелек төрки телләрдә кулланылмый. К. **Чатал, Чәтән.**

Дерив.: **чатанлык; чатанла-у.**

**ЧАТКЫ** «искра» > мар. *чаткэ,* морд. *сятко* id. тат. **чагылткы** «чакма чакканда чыккан ут» сүзеннән, к. **Чак-у.**

**ЧАТЛАМА: чатлама суык** «трескучий мороз» > мар. *чатлама* id.; к. **Чатла-у.**

**ЧАТЛА-У I, чатна-у** «трескаться, лопаться (о стекле и пр.); страдать от жажды в жару» > мар. *чатна-* < гом. кыпч., чыгт., госм. (Радлов III: 1900) *чатла-* > *чатна-* (> нуг., каз., к.-калп. *шатла-,*

*шатна-,* башк. *сатна-*), кырг. *чатына-* «чатнау, ватылу», чув. (татарчадан морфологик җәһәттән чувашча үзгәртелеп) *çатлат-* «чатнау» – түбәндә *чартла-у* сүзеннән булса кирәк, к. тат. диал. (ДС II: 215) *чалтлама суык* «чатлама суык». **Чат** имитативы мәгъ. буенча *чатна-у* сүзенең тамыры була алмый. Будагов I: 453.

Дерив.: диал. **чатлаwык**, (Тумашева 1992: 235) **цатлаук** «тимер кыскыч» (~ каз. *шаттауық* id., ш. ук «чикләвек»), үзб. (ЎХШЛ: 294) *чатлавиқ* «теш суыргыч келәшчә».

**ЧАТЛА-У II** диал. «сочетать; составить единое из частей» ← **Чат I.**

**ЧАТЛАШ-У** «сочетаться» – **чатла-у II** «өстеөстенә кую; чат яткыру, чатмаштыру» (сирәк кулланыла торган) фигыленең урт. юн. Чаг. **Чатмаш-у.**

**ЧАТМА** (ЛТ I: 163) «бархат, окаймлённый позументом; дорогой чепрак, украшенный вышивкой, аппликацией; накидка на постель» ~ кар. *чатма* «корама», төр. *çatma* «кобага, кәрниз; кайма» ← **чат-у** (к.); к. ш. ук чыгт. (Будагов I: 453), үзб. (ЎХШЛ: 295) *чатма,* каз. *шатма* «кечкенә тирмә, шалаш» < уйг. *чатма* «тагылмалы; тагылма». **Тирмә** җыелмалы-сүтелмәле булса, *чатма* сүтелмичә генә киң өслекле арбага – каңгыга куеп йөртелә торган киез өй булган.

**ЧАТМАШ** «крестом; крест-накрест» ← ***чатма-у**, к. түбәндәгене.

**ЧАТМАШ-У** «лежать крест-накрест или образуя крест, крестовину» ← **чатма-у* «аркылыторкылы кую» ← *чат-у* «янәшә кую» (к. **Чат-у**).

Дерив.: **чатмаштыр-у** ~ башк. *сатмаштыр-у* төп фигыльләрдән киңрәк таралган.

«Чатмашу» мәгъ. тат. (к. ТТДС II: 347) **чаташ-у** ~ к.-балк., кырг., уйг. *чаташ-у* фигыле дә очрый; бу фигыльнең «адашу, саташу» мәгънәсе дә бар, ләкин **чаташ-у** белән **саташ-у** бөтенләй үзгә тамырлардан киләләр.

**ЧАТНА-У** к. **Чатла-у.**

**ЧАТРА** (ТТДС I: 477) «крытая детская тележка» < фар. *čāдирä* id., к. **Чатыр.**

**ЧАТРАШ** «клетчатый; ограда (из планок с диагональными ячеями)», иск. «шахматы» ~ башк. (БТДҺ: 272) *сатраш* id. < фар. *шäтрäнҗ* «шахмат (тактасы һәм уены)». Будагов I: 668.

**ЧАТ-У** (к. ТТДС I: 477 – *чата-калма ябешү* «нык ябышу») «прицепить» < гом. кыпч., уйг., чыгт., угыз. *чат-* (> каз., к.-калп. *шат-*) «нык ябыштыру, беркетү, үзара берләштерү яки берләшү; эләктерү; тагу», кар. *чат-* «нисбәт итү, япсару», бор. төрки (ДТС: 141) *čat-* «анасына кушу (терлекләр тур.)» Г. Рамстедт буенча, бор. төрки **ча-* ~ маньч. *ча-*, кор. *čha-* «эләктереп алу» фигыленең йөкл. юн. (к. Рамстедт 1957: 148). Һәрхәлдә **Чат IV** (*чат ябышу*) сүзе белән гомоген булса кирәк. К. ш. ук як. *сатас-* «чатлашу; бер-берсенә бап килү». Будагов I: 453–454; Мухамедова 1973: 188.

Дерив.: к. **Чатма;** чаг. **Чатак** һ.б.

**ЧАТЫР I, чатырт** – имитатив однократному треску, **чатыр-чатыр, чатыр-чотыр** – имитатив более или менее продолжительному треску (горящего костра, бегу мелких животных в кустах и т.п.) ~ чув. *çатăр*, мар. *чодыр*, удм. *чатыр-чатыр* id. ← **чат, чарт** тәкълиди тамырыннан. Гом. төрки характерда, к. төр. *çatır-çatır, catır-catur* «чатыр-чотыр». К. Будагов I: 453. Чаг. **Чытыр.**

Дерив.: **чатырда-у, чатырдат-у** (~ чув. *чатартат-*, мар. *чодыртат-* id.); **чатырдавык** һ.б.ш.

**ЧАТЫР II,** иск. **чадыр** «шатёр, палатка, юрта; крытая телега, экипаж» > чув. *чатăр*, мар. диал., удм. *чатыр* < гом. кыпч., угыз. һ.б. *чатыр,* тув., угыз. *чадыр* (> нуг., каз., к.-калп. *шатыр, шадыр*) id., тув. диал., алт. диал. *шадыр* > хак. *садыр* «тирмәнең ябу киезе (ул дүрт данә була)», уйг. *чадир,* үзб. *чотир, чодир* «чатыр, чадра (!)» < бор. төрки (ДТС: 135; Clauson: 403) *čatïr, čačïr, čašïr* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 129) *čadur* «пәрдә», *čačir* «пәрдә; чадра», *čatir* «кулчатыр» < иске фар. *čatar* «чадра», *čätir* «шәтер, зонт», *čatr* «чатыр; шәмсия» < бор. һинд. *chattra* «зонт, күләгәлек» ← *chad-* «күләгәләү» (һинд.-евр. тамырларыннан). Фар. теленнән киң таралган: рус., гом. слав. (к. Фасмер IV: 413) *чаторъ, шатёр, шатро*, венг. *sator*, морд. Э. *шатра* «чатыр». К. **Чадра, Чатра, Чатырык, Шатрун, Шәтер.** Будагов I: 292; Федотов II: 394; Аникин: 635–636 (рус. диал. *чадыр* «бер төрле корылма; чатыр» тур.). К. **Чатыр III.**

**ЧАТЫР III: чатыр чабу** «бегать; скакать в спешке» – ихтимал, **чатыр** «көймәле арба» сүзеннәндер. **Чатыр I** сүзеннән дә ясала ала.

**ЧАТЫРЫК** (ДС I: 214) «ограда», себ. (Тумашева 1992: 235) **цатрық** «сарайчик; могильная ограда» ~ ком. *чатрық,* гаг. *чатырық* «юл чаты; юл чатына (кола далада) корылган шалаш». **Чатыр II** сүзеннән.

**ЧАУКА [чаºwқа]** (ТТДС I: 478), себ. (Тумашева 1992: 235) **цауыл** «молодой березняк» ~ башк. (БҺҺ II: 203) *сауқа* id. К. **Чавыл.**

**ЧАХУЛ** (ЛТ I: 164) «чехол», **чукол, чукул** «сложное головное покрывало у кряшенок» (Нагайбаки: 56–60; ЗДС: 761) ~ рус. *чехол* «букчай, яулык; киңәйтелгән җиң очы». К. Насыйри буенча, фар. *чāх̣* «кын» сүзеннән, М. Фасмер (IV: 354) рус сүзенең гом. слав. параллельләрен таба, ләкин чыгышы ачык түгеллеген таный. Безнеңчә, төп чыганак – чыгт., төр. (Будагов I: 495) *чақул ~ чуқал, чуғал* «ат шайманы, ат көбәсе, броня». К. **Чакул.**

**ЧАЧАК,** диал. (ДС II: 160) **сайчак** «бахрома», себ. (Тумашева 1992: 235) **цацақ** «җеп; бәйләм; чачак, чук» < гом. кыпч. *чачақ* (> нуг., каз., к.-калп. *шашақ,* башк. *сасақ*), чыгт., уйг., госм., бор. төрки (Радлов III: 389–390) *сачақ* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 129) *čačak* (~ хәз. монг. *цацааг*) id.; чув. *çÿçе* > мар. *сӧсӓ* id. палаталь вариант булуы белән үзенчәлекле (к. Федотов II: 151). Бу сүз гом. төрки *чач ~ сач* «чәч; чәчелгән, сибелгән нәрсә» (фигыль коррелянты *чач- ~ сач-* «чәчү, сибү», к. **Чәч, Чәчәк, Чәч-ү**) ~ ономопоэтик *чача* тамырыннан булса кирәк. Бу тамыр хәз. телләрдә дә очрый, к. тат. (Г. Бәширов) **чачар-у** «чуклану, чачакка охшап тузылу», нуг. *шаша < чача* «кылган; бәрчә», башк. *сәсә ~* эвен. *чәчә* «сәкәл; баерка» һ.б., төр. телендә *saçak* «чачак, чук; толым» һ.б. Рамстедт 1957: 187; Иванов 1993: 43–44; Eren: 91–92.

**Чач ~ сач** тамырының дериватлары тармаклану борыннан килгән төрле йолалар белән (к. **Чәчү**) аңлатыла.

Тат. дериватлары: **чачаклы, чачаксыз; чачакла-у, чачаклан-у.**

**ЧАШ I** (ДС II: 246) «жёсткая болотная трава – осока Буксбаума» ~ кр.-тат., төр. (Будагов I: 454) *җаш, чаш* «вак салам». К. **Чаж.**

**ЧАШ II** (ЛТ) «отдых на полевых работах в 9–10 утра (если начали очень рано)» ~ каз. *шаш, сәс* «кәрванның көн уртасында ял итүе» ← фар. *чāшт* id. Будагов I: 457.

**ЧАШТЫР** – имитатив громкому, ясно слышному шороху, шуршанию ~ чув. *чаштăр ← чашт* id.

Дерив.: **чаштырт; чаштыр-чоштыр** (атлау); **чаштырда-у** һ.б.

**ЧАЯ [чаºйа],** диал. (Ф. Сәйфи-Казанлы, «Өч нарат») **чайан** «бойкий; дерзкий», себ. (ДС I: 212, 215; Тумашева 1992: 232, 236) **цайан, чаил, чайа** «грубый, злой; упрямый» ~ иск. (ЛТ I: 127) **чайа**, *чада* (?) «ныклы; шәп» > мар. *чойа* «хәйләкәр», мар. диал. (Саваткова: 190) *чайа* «сизгер, зирәк», башк. диал. (БҺҺ II: 197–198; БТДҺ: 266) *сайа, сайақ, сайан* «чая, үзсүзле, үткер; усал, явыз; үпкәчел», *сайалашыу* «ызгышу» ~ кар. *чайа, цайа* «усал, чая» һ.б., бу сүзнең палаталь варианты – себ. (Тумашева 1992: 236) **цәйӓ** «тупас», миш. (Kecskemeti, Paasonen 1965) **čäjä** «елгыр» > чув. *чее, чейĕе* «хәйләкәр; чая; ялкау» ~ төркм. *чее [чэйэ]* «ныклы; чая». Безнеңчә, бу сүз тув., алт. диал. *чайаан*, алт. *дьайан, дьайаған, йайаған, йайағ* «афәтле үлгәннәрнең һәм шаманнарның тынгысыз рухы», себ. (Будагов II: 400) *чайаған* «яралтучы тәңре» > монг. *дзаячи, дзаян, заян, заячи, дзол-заягачи* (к. **Зая I**) «язмыш тәңресе; терлекчелек химаячесе» һ.б. ← алт. *чайа-* < бор. төрки **йайи-* «бар итү, иҗат итү» ← **йай* «корбанлык» (фигыль дериваты *йай-* «корбан итү») белән баглы, к. ш. ук тув. *чаяа-* «иҗат итү». Корбан булган кешеләрнең рухы тәүдә үч алу белән шөгыльләнә, ләкин ул торган саен яхшыра бара һәм соңыннан иҗади рухка әверелә һ.б. Гомумән, **чаяган** образы бик катлаулы мифологикмәҗүси фикерләүләрне чагылдыра. Имеш, ботарлап ыргытылган тәннән, әгәр ул гөнаһсыз булса, кямил, иҗади җанлы рухлар – *җаян ~ чаян ~ шаян*нар ясала, әгәр гөнаһлы булсалар – ярымтыклар (к. **Ярымтык**) килеп чыга. Гомумән, корбанлык – яңаруның сәбәбе. Бу шаманистик караш бик борынгылыктан килә һәм һинд-иран халыкларында да булган. Төрки халыкларның килеп чыгуы турындагы риваятьләрдә бу кавем **җая** итеп кырга ташланган бер малай һәм аны коткарган ана бүредән туып үрчегәнлеге турында әйтелә.

Татарстан территориясендә табылган бер аяксыз, бер кулсыз, сыңар күзле бакыр, җиз сыбайлар, җайдаклар («Маклашеевский всадник», к. А.Х. Халиков. Отражение космогонических и генеологических легенд волжских булгар в археологических материалах // Из истории ранних булгар. Казань, 1981: 5–20) – **чаяган** ул, тәңреләргә корбан ителеп, бер аягы, бер кулы өздерелеп, бер күзе чыгарылып далага ташланган корбанлык кеше (гадәттә

җинаятьче). *Йайаган* > *җайаган* > *чаяган*нарның «чаялык» символы булулары да күптәннән килә, к. тув. *чаянныг* ~ алт. *чайагач*, як. *сайагас* (-*гач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы) «чая; сәләтле; өлгер, елгыр» һ.б.ш., каз. (ҚТДС: 399) *шаян // жаян // наян* id.

**Саян** таулыгының атамасы да шул «җен рухы, җеннәр өлкәсе» мәгънәсендәге сүздән килә дип язалар.

Татар сүзлекләрендә **чая** сүзен бик теләп рус. *отчаянный* (> тат. сөйл. **атчаенный, этчәянни**) сүзеннән дип язалар һәм М. Федотов та (II: 407) шуны яклый. Ләкин бу фараз морфологик җәһәттән аксый: *отчаян-* нигезенең префиксы нишләп төшеп калсын икән? Рус. *чаян-* нигезе исә бөтенләй капма-каршы мәгънәдә – «өмет ителгән» дигән сүз. Аннары, **чая, чаян** сүзен **шая, шаян** нигезеннән аерып булмый.

Мәсьәләгә киңрәк каралса, безнең сүз ышандырырлык булыр кебек. Барча Себер халыкларында – төрле монголларда, тунгус-маньчжурларда һ.б. үзенең уртак ритуаллары белән шаманизм дине таралган. Шаманизм сүзе шаманнар башкарган әмәлдогаларның уртаклыгын гына чагылдыра. Шаманизмның идеологик нигезе – **заячылык** (к. **Заятүләк**) ул. Сүзнең төп нигезе фонетик җәһәттән бор. монг. ядкәрләрендә сакланган (Поппе 1938: 203) *jaya* «бар итү, яралту», бу хәз. телләрдә (закончалыклы аваз күчешләре белән) сакланган алт., тунг. *йайа*, алт. (төрле сөйләшләрдәге) *ньайа-, найа-*, эвен. *найа-,* хәз. монг. *дзайа-,* бур. *зайа-* (шуннан бер яктан як., *сайа-* > *һайа-* > *айаа-,* икенче як., иске угыз., аз. диал. *сайа-*), хак., шор. *чайа-,* алт. диал. *шайа-* «җинаятьчеләрне корбан итү» һәм тәңре, *кудай* тарафыннан корбан кабул ителүе. Шуннан *заяган // җаяган // йайаган // найаган // чайаган // шайаган* «шәһитнең, корбан ителмешнең тынгысыз рухы» сүзе ясалып килгән. Н.Ф. Катанов мәгълүматлары буенча, баш *чайаан* һәм аңа буйсынган тугыз (бер-бер артлы чиннардагы) *чайаннар ~ шайааннар* бар икән. Аларның исемнәре дә булган, тик кайберләренең атамалары гына сакланып калган. Мәс., *үтерелмәс (үлмәс) чаяан*, *алтын чаяан, көмеш чайаан*. Иң кече *чайаан ~ шайаан* вак шуклыклар белән шөгыльләнә, «шаяра».

Кызганычка каршы, бу *заянизм ~ чайанизм* дине тәфсилләп, азмы-күпме төзек теория рәвешендә язылмаган. Шунлыктан аерым детальләрдә каршылыклар да бар. Катанов 1888: 22, 83; Банзаров 1955; Хангалов 1959 (бөтен китап буенча заяннар тур. сөйләнелә); Антонов 1971: 127–130; Vasilevitc W.M. The Acquisition oj shamanistic Ability among the Evenki // Popular Beliefs: 336–349; Ахметьянов 1981: 24–25; МНМ I: 197–199, 375; II: 247; 623 һ.б. К. **Заятүләк, Наян, Шаян**.

Дерив.: **чаялык; чаялан-у,** диал. **чаяр-у** «шаяру, чаялану».

**ЧАЯН [чаºйан]** «скорпион», диал. (Тумашева 1992: 232) **цайан** «скорпион; ящерица» < гом. кыпч. (Төньяк Кавказ төрки телләрендә теркәлмәгән), чыгт., госм. (Радлов III: 1852) *чайан* «чаян, рак; кәлтә; кыргаяк; шөпшә» < уйг. *чадан* < бор. төрки (ДТС: 135–136, 147) *čadan, čaдan, čïdan, čïjan* «чаян; гакрәп йолдызлыгы». К. ш. ук таҗ., үзб. *чиён* «чаян», төр. *çayan,* төркм. *çiyan, чайаан* «кыргаяк» ~ монг. *цайа* < *чайа* «бөҗәк». К. **Чайбан.** Räsänen 1969: 94.

**ЧӘ́БӘ,** диал. (Зимасов: 112) **чөбә,** (ЗДС: 720) **ча́ба** – междометие, которым прогоняют собак, а также коз, овец (к. ТТДС I: 468) ~ башк. *сә́бә,* чув. *чава,* мар. (Упымарий: 249) *чы̆во, чы̆вӧч, чавач* ~ монг. *sziba* id. Ихтимал, бор. ир. *spa, spaka* «эт» сүзеннәндер. Ләкин к. **Чәбәш.**

**ЧӘБӘК I, чәпәк, чабаҡ, чапаҡ** «шлепок, удар ладонью» ~ башк. *сәбәк, сәпәк* id. – бу вариантларның һәркайсы мәгънә үзенчәлекләренә ия һәм барысы да *чап//чәп* тәкълиди сүзеннән ясалган; к. **Чәпә-ү.**

Дерив.: **чәбәкәй < чабакай** (< *чабакай-кай?*) «алкышлап кул чабу», **чәбәклә-ү, чәпәклә-ү, чабакла-у, чапакла-у** «уч яисә бәләк белән бәрү».

**ЧӘБӘК II, чәбәх** «чепчик» (ЗДС: 734, русчадан диелә, ләкин русчада *-әк* кушымчасы юк, шунлыктан монда русчадан ярымкалька тур. гына сүз булырга мөмкин – *чәп* тамырыннан, к. тат. **чәпәш, чәпе** id., фар. *чäпийә* «гади баш киеме». Халыкара тамыр сүз: **чәп < кәп,** к. **Кәпәч.**

**ЧӘБӘЛӘН-Ү < чабалан-у** «биться руками и ногами от возбуждения» < гом. кыпч. *чабалан-* (нуг., каз., к.-калп. *шабалан-*, башк. *сәбәлән- ~ сабалан-*), угыз. (төр.) *çabalan-* id. ← *cabala* «тиберчենү, тырпылдау» ← *çap-* «чабу; чәбәкләү»; төр. *çabalan-* сүзе *çaba* «тырышлык, хәстәр» сүзеннән дә ясала ала.

Дерив.: **чәбәләндер-ү; чәбәләнчек.**

**ЧӘБӘШ, чәбәч** (ТТДС I: 499) «овца около одного года, ярка» < гом. кыпч. *чебич* (> каз.,

к.-калп. *шибиш*), к.-балк. *чемич,* төркм. *чебиш,* уйг. *чивич,* үзб. (ЎХШЛ: 300–308) *сибич, чибиш, чыбыч,* төр. (Zenker: 348) *čebič, čepič, čepüč* «6–12 айлык бәрән», бор. төрки (ДТС: 144) *čepiš* «алты айлык бәти», төр. телендә бу сүзнең «үгез бозау» мәгъ. бар. Чыгышы-ясалышы ачык түгел. Тат. **чәбеш, чәбеч** булырга тиеш иде, хәлбуки икенче иҗектә *-ә-* килә. Бу хәл борынгылыктан килми. Тат. теленең үзендә килеп чыккан булса кирәк. К. **Чебеш, Чибек.**

**ЧӘБЕ I** (ЛТ I: 168; ЗДС: 734) «чина, ценовая досочка, плоская длинная пластина или палочка, которая прикрепляется между нитченками для того, чтобы основы ниток не запутывались» ~ башк. *шәбе, сәбе,* мар. *сап, сäп* id. Чаг. каз. *сабы, шабы*, кырг. *шап* < *чабы* «кечкенә кылыч».

Бу сүздән рус. *сабля* «кылыч төре» килеп чыккан дигән фараз бар (И.Г. Добродомов).

**ЧӘБЕ II,** диал. (ТТДС I: 468) **чәпе,** (Г. Ахмаров) **шабе** «ветви, сучья, отрубленные от ствола дерева; хворост», диал. (Ш. Маннур) «живая изгородь, плетень», себ. (Тумашева 1992: 225–226) **цәбе** «засека» ~ чув. *çапă,* башк. (БТДҺ: 292) *сәбе* id. ~ мар. *саве*, (Саваткова: 143) *сäвы* «чәбе», *савы вичы (пичы)* «чәбе читән», удм. *чабы, чебы* «читән, тере (үсеп утырган куралык-куаклыктан гыйбарәт) читән» ~ венг. *дуерӱ [җэпү]* id. Бу сүзне (чув. *çапă* id.) чув. телчеләре *çап-* «чабу» сүзеннән диләр (Егоров 1964: 203) һәм тат. (**чыбык-чабык** сүзендәге) **чабык** белән чагыштыралар. Ләкин монда шикләнерлек моментлар бар. К. **Чәпе.**

**ЧӘБЕРЧЕК I** «трязогузка (птица)» ~ башк. *сәпсек*, (БТДҺ: 292) *сәберсек, сәберсәк (< чәберчәк)* id. ← *сәберсе- (< чәберче-)* «тик тормау, туктаусыз хәрәкәттә булу». К. диал. (ТТДС I: 499) **чәберчеклән-ү** «чәбәләнү».

**ЧӘБЕРЧЕК II** диал. «яйцо-болтун» ~ мар. *шувырчык, сувырчык* id. Ачык түгел.

**ЧӘВЕР-Ү [чәwĕр-]** (Г. Исхакый) «окружать, охватывать, крутить» ~ чув. *çавăр-, çар-* > мар. (Иванов, Тужаров: 199; Саваткова: 143) *савыр-, сäр-* < бор. кыпч. (Zajączkowski 1961: 43), бор. төрки (ДТС: 145) *čäwür-, čävür-* ~ СС *čövür-,* үзб. *чӧвур-* «әйләндерү»; к. ш. ук уйг. *чәбир-,* чыгт., госм. (Будагов I: 465) *чевур-, чäwур-* «әйләндерү; кайтару», себ. (Тумашева 1992: 243) **цүүр-ү** «әйләнү». К. **Чүрә.** Räsänen 1969: 102 (тәфсилле); Федотов II: 80–81.

Дерив.: **чәверел-ү**; себ. (Тумашева 1992: 237) **цәүерен-ү** «тыкшыну, тыгылып йөрү».

**ЧӘЕР [чәйĕр],** диал. (ДС I: 179) **чайыр** «смола (древесная); янтарь», «живица; сера» < гом. кыпч. *чайыр* (> башк. *сайыр,* нуг., каз., к.-калп. *шайыр*), уйг. *чайир, шайир* һ.б. «эсселектә агачтан, ш. ук кайбер хайваннар тәненнән чыга торган ярымсөзек куе масса, сагыз»; чув. *чейĕр* id. < тат.; удм. *сир* «сумала, чәер» дә төрки телләрдән булса кирәк. Чаг. **Сагыз.** Räsänen 1969: 95.

Дерив.: **чәерле, чәерлән-ү.** Ылысды агачлар **чайыр**ы элек яктырткыч (чырак) ягулыгы итеп файдаланылган.

**ЧӘЙ,** диал. **цәй**, «чай» > мар. (Иванов, Тужаров: 257; Саваткова: 95) *цäй, чäй* < тат. диал. (Тумашева 1992: 232) **цай, чай***,* гом. кыпч., уйг., госм. һ.б. *чай,* башк. *сәй* ~ яз. монг. (ССТМЯ II: 377) *čai* < кыт. *ča'* id. Рус. *чай* (Фасмер IV: 310) төрки телләрдән (киресенчә түгел!). Рус теле аша бу сүз күп телләргә, шул хисаптан Шәрык телләренә дә таралган. Европа телләренә чәй атамасы кыт. теленнән килә, ләкин яңгырашы бүтәнчәрәк, к. Аникин: 636 (бай әдәбият күрсәтелә); Тимергалин: 539–540.

Дерив.: **чәйле; чәйлә-ү** «чәй эчеп утыру»; **чәйлек** «швейцарга һ.б.ш. бирелә торган вак акча – бәхшиш»; **чәйханә.**

**ЧӘЙГҮН, чәйген** диал., ш. ук **чәйнүк, чәйнек,** себ. (Тумашева 1992: 236) **цәйгүн, цәйгән, цәйген** «чайник» ~ башк. (БТДҺ: 292) **сәйнек, сәйгүш, сәйнүк** – *-гүн* белән беткән вариантлар кыт. *ча'гун* «чәй казаны» сүзенә, калганнары рус. *чайник* сүзенә тоташа; кыт. *гун* «казан, чүлмәк» сүзе **чуен** (к.) сүзендә дә саклана. **Чүйнәк** варианты бу ике вариантның контаминациясе. Хайрутдинова 2000: 56.

**ЧӘЙНӘ-Ү,** себ. (Тумашева 1992: 232) **цайна-у** «жевать, грызть; дурно говорить о ком-либо» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг. (к. Радлов III: 1837–1942) *чайна-* (> нуг., каз., к.-калп. *шайна-,* башк. *сәйнә-*) «чәйнәү; аяктан егу, тибү, кыру, яньчү», госм. *чäiнä-* id. Чаг. ш. ук уйг. (Радлов III: 1954) *чäкнä-* «таптау». Фонетик җәһәттән көтелмәгән вариант – төр. *çiğne-* «чәйнәү». Гомумән, ачык түгел.

Дерив.: **чәйнәл-ү, чәйнән-ү** «кешене сүгеп сукрану», **чәйнәш-ү, чәйнәт-ү; чәйнәм** (*бер чәйнәм*); **чәйнәүгеч** «юк-бардан гаеп табучы», **чәйнәүче.**

***ЧӘЙ-Ү,** себ. (Тумашева 1992: 236) **цәй-ү** «утаить; отказываться». Чаг. төр. *саy-, çay-* «баш тарту, тайпылу; әхвәлне алдаштырып сөйләү».

**ЧӘК, чәңк** – имитатив удару небольшого молотка, а также звукам, издаваемым некоторыми птицами ~ чув. *чак* id.

Дерив.: **чәк-чәк, чәңк-чәңк; чәкелдә-ү, чәңкелдә-ү; чәкелдек, чәңкелдек**. К. **Чәкәт-ү, Чек.**

***ЧӘКӘ** «висок», диал. **цәкә**, к. себ. (Тумашева 1992: 236) **цәкәйтмә < цәкә йәтмә** «калфакның бер төре» – **чикә** сүзенең **чәкә** вариантыннан (ул тат. теле өчен закончалыклы); шуннан гом. диал. **чәкәлә-ү** «чикәгә сугу, яңаклау», **чәкәләш-ү** «сугышу, кыйнашу, тәпәләшү» сүзләре ясалган; к. ком., уйг., кырг. *чеке* (> нуг., к.-калп. *шеке*), *чәке,* үзб. *чакка* «чигә», кырг. *чекеле-* «чәкәләү», *чекелеш-* «чәкәләшү» (нуг., к.-калп. телләрендә *шекеле-* «кыек карау, кырын карау, чикә аша карау»). К. **Чикә.**

**ЧӘКӘЛӘШ-Ү** (ТРС 1931) «резко ссориться, столкнуться» ← **чәкәлә-ү** «чигәгә сугу». К. **Чәкә.**

**ЧӘКӘН I** «початок кукурузы; головка рогозника» > мар. *цәгән, цӓган* «җикән», чув. *чакан* id.; рус. *чакан, чикан, чакон* – төрле чәкәнле үләнчел үсемлекләр. Фасмер IV: 312; Аникин: 627; Федотов II: 387 (тат. *чәкән* сүзен искә дә алмый). К. **Җикән, Зикән.**

Рус вариантлары төрле (башлыча тат.) шивәләрдән алынган; **чакан** вариантын чувашчадан дип карау тарихи җәһәттән акланып бетми; чув. сүзе үзе татарчадан булса кирәк. Ләкин удм. *сякан* «зикән» болг. теленнән (мари теле аша).

Дерив.: **чәкәнле, чәкәнсез; чәкәнлән-ү.**

**ЧӘКӘН II** «молоток (в игре – деревянный) с длинной рукояткой; клюшка; игра с таким молотком – чижики, хоккей и т.п.», диал. (ТТДС I: 500) «бита – кость» ~ башк. *сәкән* id., чыгт., кырг. (хәз. сүзлекләрдә теркәлми) *чаҡан* «сугыш коралы буларак озын саплы чүкеч яки ыргак» ← *чаҡ-* «чагу, кадау, кискен бәрү» сүзеннән исәпләнә; Gombocz: 44 (венг. *csakany* «сугыш ыргагы, сугыш чүкече» сүзен аңлатып) һәм Фасмер (IV: 324–325) бу сүзнең слав. телләрендә киң таралганлыгын күрсәтәләр, к. рус. *чекан* «озын саплы тимер чүкеч, кискеч», слов. *čekan* «хәрби чүкеч», словак. *čakan* «киркә,кәйлә» һ.б. Безнеңчә, бу сүз төр. диалектларыннан таралган, ә төр. диалектларына кыпч. телләреннән кергән. Тат. сүзенең мәгънәсе һәм кулланылышы (уен) фар. *чевкäн, чоуган,* көрд. *çewgan, çogan* «кәшәкә, култаяк; поло уены» мәгънәсенә бик охшаш һәм, ихтимал, тат. сүзе шуннан киләдер. Фар. сүзе үзе төрки (кыпч.) телләреннән булса кирәк. К. Шанский һ.б.: 489; Аникин: 651 (әдәбият күрсәтелә); Федотов II: 367.

**ЧӘКӘН III** (ЗДС: 735) «узоры на ткани, деревянных изделиях и т.п., вышиваемые или насечённые; чекань» ← *чәк-* «чигү, бизәү, бизәкләү» К. ш. ук себ. (ЗДС: 708) **цәгәнле, цәгәнне** «чигүле, бизәкле (төрле киемнәр тур.)». Бу сүзне рус. (Аникин: 650) *чегадак, чегедек, чигидек* «төрле хатынкыз киеме» < алт. һ.б. *čägädäk, čägidäk* ~ яз. монг. *čegedeg,* хәз. монг. *цэгдэг* «күлмәк төрләре» (*-дäк,* әлбәттә, «кием» мәгъ., чаг. тат. диал., башк. *күлдәк* «күлмәк») белән чагыштырырга ярый (Аникин кайберәүләрнең чыгт. *чикин* «җилкә, чикә» белән баглауларын китерә, безнеңчә, ул фаразлар – уңышсыз). К. **Чик-ү.**

**ЧӘКӘТ-Ү** «выбивать щелчком по шашке-бите другие шашки, расставленные в ряд; расстрелять одного за другим» ← **чәкә-ү** (к.).

**ЧӘКӘ-Ү, чәке-ү** «коротко и резко ударить (малым молотком); высекать; стучать (металлическим предметом); бить по гвоздю» ← **чәк** (тәкълиди сүз) «чик». Чаг. ш. ук уйг. *чәк-* «чиртү» ~ бор. төрки (ДТС: 143) *ček-* «нокта кую; кадак кагу», *čeknä-* «тырмалау», *čekin* «тырма». Морд. М. *чакамс-* «чәкү» татарчадан булса кирәк. Интервокаль *-к- чәкә-, чәке-* сүзләренең элекке яңгырашы *чәккә-, чәкке-* икәнлеген күрсәтә, к. көрд., төр. диал. *çek* «бер ыргыту». Максуди телендә *чәк итү* «юк итү».

**Чәкә-, чәке-** продуктив нигез: **чәкәш-ү, чәкеш-ү** «тост әйтеп, шәраб савытларын бәрдерешү», **чәкәштер-ү** id., башк. *сәкәш-еү* «тиргәшеп алу», *сәкеткес* (БТДҺ: 293) «тәте», к. **Чәкәт-ү.**

**ЧӘКЕ I, чике** диал. (ТТДС I: 482, 500) «до (послелог)» – чаг. **тәке, тике.** Кайбер төрки телләрдә бу сүз «үлчәү» мәгъ., к. нуг., каз. (ҚТДС: 391) *шекки* (< *чәкки*), төр. *çeki* «үлчәү; бизмән; кадак; ат йөкләме – 250 кг чамасы һ.б.ш.», кр.-тат., тат. диал. *чәки* «акча үлчәү бизмәне; төрле үлчәү берәмлекләре» (к. Будагов I: 483). *Чак ~ чәк ~ чэк* тамырының бихасап мәгънәләре (төр. *çek, cek-* сүзләренең 50 гә якын мәгънәсе күрсәтелә) һәм бихисап дериватлары арасында **чәке < чәкке** дә бу-

лырга мөмкин. Шулай ук *чәке* < **тәке** дип әйтеп тә була.

**ЧӘКЕ II, чәкә** «палка с рогаткой (у удильщиков); уключина и т.п. палка, деревяшка, доска с крепким сучком» (к. ТРС II: 565) ~ рус. *чакка* «балык аулау коралларының бер казыгы» < селькуп. *чакка* «чатал таяк» (к. Аникин: 637). К. **Чикә**. К. ш. ук Räsänen 1969: 103.

**ЧӘКЕЛДЕК** (ЗДС: 736, кргл.) «йомранның бер төре». Төрки телләрдә фонетик җәһәттән бер-берсенә җиңел күчә алган торган *чәгелдәк* ~ *чәгелдек* ~ *чигелдәк, чәкелдек* ~ *чикелдәк* һ.б. сүзләр еш кына очрый, әмма аларның мәгънәләре бер-берсенә җиңел күчә торганнардан түгел. Бу очракта да ошбу сүзнең тәгаен чагыштырырлык икенче бер сүзне табу кыен. Чаг. **Чигелдәк.**

**ЧӘКРӘ** (ТТДС I: 500) «крутизна, где ничего не растёт» ~ башк. (БТДҺ: 293) *сәкерә* id. Ихтимал, тат. диал. **чәркә** «башның чәчсез калган арт чүмече» сүзеннән метатезадыр: элекке күчмәчелек чорында бәбиләрне такта бишеккә чалкан салып йөрткәннәр һәм аларның баш артында чәчләре кыршылып, ялангач калып килгән (үзбәкләрдә үзем күргәнем бар). К. **Чәркә.**

**ЧӘКҮШКӘ** «чекушка, чека (у оси телеги)» < рус. *чекушка* ← *чека* id., бу сүз исә төрки-монг. телләреннән, к. **Чикә.** Чаг. **Чәке II.**

**ЧӘКЧӘК,** диал. (к. ДС I: 222; ДС III: 188; Хайрутдинова 1993: 44–45) **чәкчәги, чәкчәки, чепчәги** һ.б. > башк. *сәксәк, сәксәгей* «выпечка из скреплённых мёдом мелких круглых или подушкообразных кусочков теста, чакчак» > мар. (Исанбаев 1978: 35) *чäкчäк* id. < фар. *чäкчäки* «тамчылы ашамлык» ← *чäкэчäк* «тамчы-тамчы», *чäкэ* «тамчы». К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 292, 296) *чақчақ* «пестә чикләвеге», *чәкчәк* «катламлы торт». Затлы ашамлык төрләре тат. телендә еш кына фар.-таҗ. даирәсеннән килә; чәкчәкнең «камырдан эшләнгән пестә» булуы да закончалыклы (чаг. **Бавырсак, Бөйрәк**). Ләкин менә, көтелмәгәнчә, тув. телендә *чөкчек* «баллы киндераш орлыгы». Бу мәгълүмат **чәкчәк** сүзенең этимологиясен катлауландырып җибәрә.

**ЧӘЛӘ,** диал. (Будагов I: 462) **чала,** (Тумашева 1992: 233) **цала** «неполный, неисправный, незавершённый; не вполне; не до конца» < гом. кыпч., чыгт., уйг., үзб., алт. *чала* (> нуг., каз., к.-калп., тув. *шала,* башк. *сала*) id., үзб. диал. *чәлә* «ярты» (к. тат. *чала татар* «татар белән казак яисә үзбәк метисы»); чаг. монг. *чалай, чалгай* (халха. *цалгай*) «ялгыш эшләнгән, нормадан читләшкән, аермалы» < яз. монг. *čalaγai* id. ~ маньч. *чала-* «ялгышу; хәрәмләшү» < *ча-ла-*: кыт. *чä* «ялгышу, ялгышлык; җитенкерәмәү, аермалы булу» (к. ССТМЯ I: 380). К. ш. ук тат. **цала-бала** ~ уйг. *чала-пула,* тув. *шала-була* һ.б. «ничек җитте шулай», тат. **цала-қөла** ~ к.-балк. *чала- қола* id. һ.б. К. **Шал III.**

**ЧӘЛӘБИ** иск. «аристократ; дворянин, боярин» ← төр. *celebi, çelebi* id. к. **Җәләп, Челби.**

**ЧӘЛИ** (ТТДС I: 500) «ещё; изрядно» ~ чув. *чылай, чыллай* «күп, күп кенә», *чыли, чылли* (Ашмарин XV: 182–183) id. – рус. *целый* «бөтен» сүзеннән дип карала (к. Федотов II: 428). Безнеңчә, чув. *чылай* (> тат. диал. **чылай**) < тат. диал. һ.б. *талай* «күп кенә, байтак» < бор. төрки, монг. *талай* «океан; зур, өлкән» сүзеннән булырга тиеш (чув. аваз үзгәрешләре тулысынча шуңа килә: *а* > *ы, т* > *ч*). Бу болг. сүзенең тат. **чәләй** варианты да булган булса кирәк. **Чылай** < *целый* дигән фараз мәгънәви җәһәттән дә аксый. Чаг. ш. ук мар. *цила, цӗлӓ, чила, чӗлӓ* «бөтен; барсы да, һәр». К. **Талай.**

**ЧӘЛПӘК** (ТТДС I: 500) «хворост (вид кушанья); лепёшка на масле», себ. (Баязитова 2001: 195–196) **чәлпәк, чәлбәк, цәлбәк** «блюдо для поминок» ~ башк. (БҺҺ II: 229) *сәлпәк* «майда пешкән җәймә», (БТДҺ: 293) «төче кабартма» < уйг. *чәлпәк, чальпәк*, үзб. *чалпак* (> каз., к.-калп. *шелпек*), төркм. *челпек* (> каз. *шелпек*) һ.б. төрле махсус белен төрләре ~ чыгт., монг. (Поппе 1938: 132) *čelbeq, čelpek* «коймак, белен» >> калм. *цельвиг* id. Тат. телчеләре бу сүзне *җәүле икмәк* сүзеннән чыгармакчы, Касыйм татарларында *джяльтмяк* «ата-бабаларны искә алу мәҗүси йоласында пешерелә торган белен» (к. Гордлевский 1927: 15) сүзе дә «җәүле икмәк» сүзеннән кебек. Ләкин Ф. Баязитова материалларында **чәлпәк** – кырык бер тишекле була диелә. Шуннан чыгып, без бу сүзне фар. *чäл (чäһäл) бä йäк* «кырык та бер», ягъни «мәшһүр кырык изгене (кырык беренчесе – вафат булмыш кеше) искә алу» сүзеннән, **чигелдәк** (к.) белән тамырдаш дип карыйбыз. Чаг. башк. (БТДҺ: 214) *қырыҡйәймә* «мәрхүмнең кырыгын уздырганда пешерелә торган тәбикмәкләр» – фар. сүзеннән калька. Рус. *челпак* «эченә берни дә салынмаган бәлеш»

тур. Фасмер IV: 329 (билгесез чыганактан ди); Хайрутдинова 1993: 48–49.

**ЧӘЛПӘН** (ЗДС: 736, себ. ) «горка, пригорок, первым выступающий из-под снега весной» ~ рус. (Аникин: 639–640) *чалпан* сазлыктан чыгып, күренеп торган коры утрау: тайга уртасында калкулык». Аникин моны төп рус сүзе димәкче, чөнки үзәк Россиядә, мәс., Новгород тирәләрендә *Челпаново, Челпино* дигән авыллар һ.б. бар. Ләкин төрки телләрдә охшаш сүзләр юк түгел, мәс., аз. *чалпак* «ялангач, йоны йолкынган», чаг. **Чалпак.**

**ЧӘЛПӘРӘМӘ** к. **Челпәрәмә.**

**ЧӘЛТЕР,** диал. (ЗДС: 736) **чәлдер**, (ТТДС II: 365) **чәндер, чәнтер** «голень; берцовая кость» ~ башк. (БТДҺ: 293) *сәлдер, сәндер* id., ш. ук «бот арасы» (?) < *чандыр* «сөякләч». К. **Чандыр.**

**ЧӘЛ-Ү** (ЛТ I: 166), **чәлдер-ү** «красть, стырнуть, стянуть» ~ кырг. *чел-* >> тув. *шел-* «мөгез белән эләктереп ыргыту», төр. *çel-* «ору, бәрү; чалма чалу; урлау» < гом. төрки *чал-* (к. **Чал-у**), к. гаг. *чал-, чалдыр-* «чәлү, урлау». Төр. *çal-, çaldır-* id.

**ЧӘМ** (ТТДС I: 500) «страсть, горячность», себ. (Тумашева 1992: 234) **цам** «обида; обидчивость» ~ башк. *сәм,* үзб. *чам* > каз. *шам* id. < бор. төрки (ДТС: 137) *čam* «бәхәс, җәдәл (судлашу)» > тув. *чам, шам, цам*, монг. *цам* < бор. монг. (к. ССТМЯ II: 383) *čam* < тибет. *hčam* «явыз рухлар (бигрәк тә **аза,** к.) белән көрәшне гәүдәләндергән мистерия – театраль тамаша» (анда артистлар махсус әзерләнеп җен-шайтаннарга каршы ярсу, ачулану хисләрен белдергәннәр), к. к.-балк. *чам* «тамаша, уен-көлке, кылану». Мәҗүси йола *чам* тур. зур әдәбият бар, к. Дьяконов В.П. *Цам* у тувинцев // Религиозные представления и обряды народов Сибири. Л., 1971: 16; Шастина Н.П. Следы примитивных религий в ламаистской мистерии *цам* // Исследования по восточной филологии. М., 1974 һ.б. **Чәм < чам** спектакленең төп өлеше тәмамлангач, **коғ** «куану» өлеше булган, к. **Куан-у.** Рус. сөйл. *цам* тур. Аникин: 631.

Дерив.: **чәмле; чәмлән-ү; чәмчел.**

**ЧӘМӘН I,** диал. (ТТДС I: 474) **чаман** (Будагов I: 451) **чабан, чубан,** себ. (Тумашева 1992: 232) **цабан «**медлительный, ленивый, норовистый (о лошади)» ~ башк. (БТДҺ: 265, 268) *сабан, сауан* «ялкау; җай; тыңлаусыз», *саман, сабан* «ялкау, үшән (ат тур.)», мар. *чаман, чоман*, чув. *чоман* > *чуман* ~ куман. *чаман*, ком. *чабан* (>> нуг., каз., к.-калп. *шабан*), кырг., алт. *чабал* (> шор. *шабал* > хак. *сабал*) id. ~ чыгт., госм. *чоман, чуман* «ялкау, салак, игътибарсыз» (к. Радлов III: 1929, 1930, 2188); к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 232, 243) **цабал, цыбал** «яшь үсенте; тай». Ачык түгел; *а ~ о* вариантларына караганда, элекке бер өч иҗекле сүздән кыскарган. Интервокаль *-б* – борынгыдан килә. Räsänen 1969: 98; Федотов II: 422 (бик аз сүз әйтелә).

**ЧӘМӘН II, чимән** (ЛТ I: 170; Җантурин 1910: 120) «лужайка; трава (густая); аллея» < фар. *чӓмӓн*, госм. *чимӓн* id., төр. *çemen, çimen* «үлән исеме; кызыл борыч; чәмән» < чыгт. (Котби) *чимгән, чимкән, чүмән* < бор. төрки (ДТС: 158) *čümgän* «үләннең бер төре; чәмән» һ.б. Ачык түгел. Zajączkowski 1961: 44–45 (әдәбият китерелә). Гомумән, төрки сүз, тик фар. теле аша таралган булса кирәк. К. ш. ук **Чим.**

Дерив.: **чәмәнлек, чәмәнзар** «төрле үләннәр күпләп үскән урын; гомумән кыргый чәчәкләр».

**ЧӘМБӘР,** диал. (Тумашева 1992: 236, 239) **цәмпәр, цәмбер, цимгәр** «ободок; ободья бочек» ~ чыгт., уйг., госм. *чәмбәр* ~ каз., к.-калп. *шеңбер,* башк. (БТДҺ: 293) *сәмбәрә* < фар. *чӓнбӓр, чӓмбӓр* id., башк. варианты бор. фар. вариантыннан. Kannisto 1912: 185–186 (манси. *šampər* id. < тат. тур.). Redhouse: 247 (бу сүзнең күптөрле мәгъ. тур.) һ.б.

**ЧӘМКӘ** (Троянский) «голый лоб» к. **Җәмкә.**

**ЧӘМЧӘ** (ТРС 1931), диал. **җәмчә > йәмчә** «вышитые узоры, вензели; вышитая кайма» ~ башк. (БТДҺ II: 229) *сәмсә* id., себ. (Тумашева 1992: 234) **цамца** «күлмәк», уйг. алт. *чамча* < иске монг. *čamča* (хәз. монг. *цамц,* бур. *самса*) «күлмәк, хатын-кыз күлмәге» < тибет. *цхьям-чхэ, җамчхэ* id. (к. Хазуев 1978: 59). П. Поуча (Poucha 1959: 47–48) бу сүзнең вариацияләрен корей теленнән алып (*сам* «киндер») барча Европа телләренә чаклы бик күп телләрдә күрә һәм, анынча, тат. **чәмчә (ч < ц < к) камзул** һәм **камис** сүзләре белән тамырдаш булып чыга (әлеге тибет сүзе дә шул даирәгә керә).

**Чәмчә** сүзенең үзенчәлекле мәгъ. шуның белән аңлатыла: Үзәк Азия төрки-монг. халыкларына күлмәк һәм аякчу кырыйларын вензельләп-каймалап чигеп чыгу хас; димәк, **чәмчә < чамча** «вензель, чигеш» **чамча күлмәк, чамча читек** тәгъбиреннән эллипсис. К. ш. ук Räsänen 1969: 98;

ССТМЯ II: 383 (**чамча** «чигүле тун» тунг.-маньч. телләрендә дә киң билгеле). Рус диал. *самса* «яңа туган бәрән тиресеннән тегелгән күлмәк» тур. Аникин: 481–482.

**ЧӘНӘЧКӘ, чәнәшкә, чәнечкә, сәнәскә** (ТТДС I: 501; БТДҺ: 293) «саночки, саночка, маленькие сани» ~ чулым. *цанига* «чаңгы, чаначык» сүзе белән нигездәш, чаг. ш. ук чув. (Сергеев 1971: 117) *çунашка, шунашка* id. Чаг. ш. ук рус. *салазки* (рус сүзләренең дә, татар сүзләренең дә этимологиясе томанлы. Бор. уртак чыганактан булса кирәк).

**ЧӘНЕЧКЕ, чәнечкәк** (бик күп вариантлар) «шип; колючка; вилочка, вилка (для еды)» ~ башк. *сәнеске*, *сәнескәк*, төркм. *санчқы, санчғы, санчғыч,* чув. *сунӑчкӑ, сунчӑка* id. К. ш. ук (ДС III: 145) **сәнеске,** себ., миш. **цәнецке** «балык тоту сәнәге, салдау» << бор. төрки (ДТС: 484) *sančqaq* «сөңге төре» (шуннан, ахыр чиктә, **санҗак**). Мондый сүзләр күп төрки телләрдә бар һәм һәрбер телдә мөстәкыйль рәвештә ясала ала, к. **Чәнче-ү**. Федотов II: 407.

**ЧӘН-Ү, чәнет-ү** (ТТДС I: 501) «уколоть» < бор. төрки **сан-, *саң-, *сай-* id., к. **Чәнче-ү.**

**ЧӘНЧӘ,** (Будагов I: 488) **чәнәчә, чәнечке, чәнтәй > чәнти** «мизинец» ~ башк. (БТДҺ: 272, 290, 294) *сәнсә, сәнтей, сәтәкәй, сәңгер, сәңгерсәк, сыганак, сыңгарсак, сегәнсәй, сегәнсәк,* кр.-тат. *чыначак,* ком. *чиначай, ченкдей*, алт. *чечен*, чыгт. (Будагов I: 488) *чынчанак,* кырг. *чынчалак,* үзб. (ЎХШЛ: 301–302) *чилдирчибак, чичәлә, чъғәнок, чекәнәк, чекәнтәй, чълъйчир, чъмчәләк, чънақай, чъначақ* һ.б. id. < бор. төрки (ДТС: 197) *čïčalaq, čïčatiq* ~ аз. *чечәлә*, як. (Пекарский: 3569, 3716) *чакчык, чаҥчык, чӓнчӓкӓі, чыкыйа, чымыйа, сӧмӳјӓ* «чәнчә» ~ эвенк. *чимки, чимкэгэн, чимчикэн*, эвен. *чингэн* ~ яз. монг. *sikči* > хәз. монг. *чигчий*, бур. *шэгшэгэй* h.б. (к. ССТМЯ II: 395) id.; ягн. (ЯТ: 238) *čenčilak* төрки телләрдән, к. себ. (Тумашева 1992: 244) **цыкцалык** «чәнчә».

Күренгәнчә, **чәнчә < чәнтәйчә** (к. *Бикчәнтәй* соңгы малайга бик «ныклы» булачагын теләп бирелә торган исем) мәгъ. сүзләр һәр телдә күпвариантлы. Бу вариантлар өч җәһәттән килә: 1) *ч-* авазы күп телләрдә кечкенәлекне белдерә (бигрәк тә балалар телендә), 2) чәнчә бармак атамасы сирәк кулланыла һәм һәркем аны үзенчәрәк үзгәртә, 3) чәнчә бармак атамасы төрле мотивлардан чыгып аталучан (бигрәк тә сабыйларны санарга һ.б. өйрәткәндә). Чаг. удм. *чӧльы*, коми. *чаль*, саам. *чел, челх, челкиш*, эстон. *tsilli* «чәнчә бармак», таҗ. *чилик* id. һ.б. К. ш. ук Räsänen 1969: 108.

Кайбер төрки телләрдә чәнчә бармак бөтенләй бүтәнчә (һәркайда үзенчә) атала, мәс., чув. *кача пурне*, тув. *биче-бөөвей,* төр. *serçe* һ.б.ш. Чаг. ш. ук **Атсыз** (бармак).

**ЧӘНЧЕ-Ү (чәнеч-ү, чәнчи** һәм **чәнчә; чәнчү)**, диал. (ТТДС II: 367) **чәч-ү** < гом. кыпч. *чанч-* (> башк. *сәнсе-, сәнс-,* нуг., каз., к.-калп. *шаншы-, шанш-,* к. ш. ук *шеншi-*) < гом. угыз., уйг. *санч-* < бор. төрки (ДТС: 483–484) *sanč-* id. Гомуми закончалык буенча, төп вариант **санчы: *сан-, *саң-** фигыленең ешайту формасы (*-чы//-че* аффиксы) булса кирәк. К. ш. ук шор. *чач-,* тув. *шаш-,* хак. *сас-* >> як. *ас-* «чәнчү; төртү» Чаг. каз., кырг., уйг. *сай-* «чәнчү». К. **Сәнәк, Чәнечке, Чән-ү**. Будагов I: 616; Räsänen 1969: 400.

Дерив.: **чәнчел-ү** («дөмегү» мәгъ. ешрак кулланыла), **чәнчен-ү, чәнчеш-ү, чәнчет-ү; чәнечкәк, чәнчем.** К. **Чәнечке.**

**ЧӘҢ I** (Котби телендә) «струнный музыкальный инструмент, лира, лютня» ~ үзб. *чанг,* көрд., төр. *čeng*, *çenge* id. фар. теленнән дип исәпләнә (к. Будагов I: 489), ләкин бу сүзгә охшаш музыкаль әсбап атамалары күп телләрдә очрый, к. **Чаң, Чәң II, Чең.** К. ш. ук Räsänen 1969: 105.

**ЧӘҢ II: чәң-чәң** – подражание тонкому дребезжащему звону, тонкому голосу щенка, небольшой собачки, а также женщины или ребёнка ~ кырг. *чиң-чиң,* каз., к.-калп. *шиң-шиң* һ.б. id.

Дерив.: **чәңгел-чәңгел** (к. ш. ук башк. – БТДҺ: 294 – *сәңгел тауыш* «нечкә югары тавыш»); **чәңгелдә-ү** (кырг. *чиңкилте-,* к.-калп. *шиңкилде-* id.); диал. (ТТДС I: 505) **чәңгелдек** «кечкенә кыңгырау», ш. ук кычкыручан хатын-кыз тур. кимсетү сүзе.

**ЧӘҢГӘЛ, чәңгел, чаңгал** (ЛТ I: 175) «пятерня; когти хищника, хищной птицы» ~ кырг. *чеңгел* > каз., к.-калп. *шеңгел* ~ төр. *çengel, çengâl* «чәңгәл; ыргак һ.б.» (к. Redhouse: 247) < фар. *чäңгāл, чäнгул* (ш. ук *чäнгäк*) «чәңгәл, ыргак, чәнечке» ← *чäнг* «биш бармак, тырнаклар, учлам, кыскыч, тәгәрмәч теше». Рясянен буенча, чув. *çаклӑб, çакӑл* «ыргак» сүзе дә шуңа тоташа, к. Räsänen 1969: 99.

Дерив.: **чәңгәлле, чәңгәллә-ү** «тырнаклау (ерткыч кош тур.)».

**ЧӘҢГЕЛДӘК,** (ТТДС II: 356, 368; ЗДС: 751) **чәңгелтәк, чәңгелдек, чәңгелгәк, чиңгелдек** «колыбель, люлька; качели, качалка» ~ башк. *сәңгелдәк* ← **сәңгелдә-ү**, (ЗДС: 709) **цәнгел-ү** «тирбәлү». Морфемикасы буенча тәкълиди сүзгә охшаш: бишек тирбәтү авазы **чәң-чәң** дип имитацияләнгән булса кирәк. Чаг. **Сәленчәк, Чиңгелчек.**

**ЧӘҢГЕЛДӘ-Ү** (ЗДС: 738) «лаять тонким голосом (о щенках и т.п.)», күч. «ругать, ругаться высоким голосом (о женщинах)» – гом. төрки сүз булса кирәк, к. кырг. *чиңкелде-* «чинау». **Чәң ~ чиң** имитативыннан: *чәң-чәң өрә* диләр.

Дерив.: **чәңгелдек** (көчек).

**ЧӘҢКИ: чәңки елан** «змея – дух болезни» ~ башк. *сәңки* id. ~ башк. *сәңке-ү, сеңке-ү* «сызлау» (?). Чаг. төр. *çenk* «тырнак; ыргак».

**ЧӘП** – имитатив плеску звукам удара мелким предметом по воде, луже, жидкой грязи, а также ударам мелких волн о твёрдые края (лодки и т.п.) ~ башк. *сәп*, чув. *чап* id.

Дерив.: **чәп-чәп, чәпел-чәпел, чәпер-чәпер; чәпелт, чәперт; чәпелдә-ү, чәпердә-ү.** К. **Чәпә-ү, Чәпче-ү.** Чаг. **Чап, Чап-у, Чәбәк** һ.б.ш.

**ЧӘПӘ-Ү,** диал. (ДС I: 223) **чәпе-ү** «влепить, влеплять; шлёпать (твёрдым предметом по мягкому; мазать глиной щели», «ставить заплату» ~ башк. *сәпә-, сәпе-* id. ← **чәп** (к.), чаг. морд. *цяпамс* «чәпәү».

Дерив.: **чәпәш-ү, чәпәт-ү, чәпәлә-ү;** диал. (ТТДС I: 501) **чәпәк, чәпәләк** «бәләк», **чәпәмә** «аткы, сага», **чәпәләй, чәпәш** «артсыз туфли, чүәк».

**ЧӘПЕ, чәпер,** диал. (ТТДС I: 468, мәгънә вә яңгырашны без аныкладык. – *Р.Ә.*) **цәпе, цәпер** «грубая ткань, циновка; редина, сеть» (общим признаком является то, что основа толще утка или наоборот») < фар. (к. Будагов I: 469) *чäппäр* «читән, койма, рәшәткә төре» < иске фар. *чаппар* id. К. **Чапрак, Чәбе I, Шабыр I.**

**ЧӘПЧЕ-Ү I** «заартачиться; вдруг рассердиться; горячиться», (ТРС 1931) **çәрçү** «дать рикошет», себ. (Тумашева 1992: 234) **цапцы-у** «ринуться, кидаться сверху вниз» < гом. кыпч. *чапчы-* (> нуг., каз., к.-калп. *шапшы-*, башк. *сәпсе-, сапсы-*) «алгы аяк белән тибү; үрәпчү (ат тур.), өскә сикерү; тибенү, ярсу» ~ алт. *сапсы-* «селкетү, калтырату», як. *сапсый-* «селтәнү, кизәнү» ~ бур. *сабша-*, монг. *цавчих* «балта чабу; тибү, тибешү» һ.б. < **чап-чы-** ← **чап-**, к. **Чап-у II.**

Дерив.: **чәпчен-ү;** диал. **чапчан, цапцан** «елгыр; һөҗүмчән» ~ гом. кыпч. *чапчаң* (> каз. *шапшаң*) id., к. **Сапсан.**

**ЧӘПЧЕ-Ү II** (ТТДС: 501) «биться о берег (о волнах); разбрызгиваться» ~ як. *сэпсий-* «тузгу», асылда **чәпче-ү I** белән гомоген, ләкин *чәп (чәп-чәп, чәпелдә-ү)* тәкълиди сүзе тәэсирендә мәгъ. үзгәргән.

**ЧӘПЧИМ, сафсим** диал. «совсем, окончательно» ~ башк. *сәпсим*, мар., удм., чув. *савсим, совсим,* мар. диал. *сопсим* id. < рус., әлбәттә.

**ЧӘР, чәр-р** – имитатив пронзительному женскому крику, ш. ук *чар, чор* id. Бу сүздән күп дериватлар ясалган: диал. **чарла-у, чәрлә-ү,** әд. **чарылда-у, чәрелдә-ү** (һәм аларның юн. формалары). Барча күрше телләрдә параллельләре күзәтелә. Исем дериваты **чәрелдек,** к. ш. ук **Чарлак.** Чаг. **Чыр I.** К. Ашмарин 1928–1950.

**ЧӘРӘЧӘ** «лачуга» к. **Чарача.**

**ЧӘРДӘК** (ЛТ I: 169), **чәрчәк** «мелкие части разбитого, расколотого» < диал. **чәлтәк** < фар. *чäһлү-тäк* «кырык та бер (кисәк)». Чаг. **Чәрпә, Челпәрәмә.**

Дерив.: **чәрдәклән-ү.**

**ЧӘРЕ** «до (чего)» – тат. сөйләшләрендә күп вариантлары булган сүз, к. **Тәре.** Махмутова 1978: 229; Баязитова 1986: 126.

**ЧӘРЕК** «диагональная доска, брус и т.п., поддерживающий деревянные рамочные конструкции в устойчивости, распорка»; күч. «выдержка, внутренняя крепость» ~ мар. (Иванов, Тужаров: 258; Саваткова: 184) *цäрäк, чäрäк* > чув. *чарак* id. Сүзнең нигезе чув. *чар-* < тат. (ЗДС: 731) **чар-, *чәр-* > мар. *чар-, цäр-, чäр-* «туктату, тыю; терәтү, ныгыту». Бу сүзнең татарчаданлыгын чув. *чару* «тыю, нәһи», мар. *цäрнаш (← чәрен-)* «тыелу» сүзләре дә күрсәтеп тора. К. алт. *чер- [чэр-]* «каршы тору» һ.б. (к. **Чиру**).

М. Федотов (II: 390) чув. *чар-* сүзен тат. *тый-* < бор. төрки *tıδ-* сүзе белән чагыштыра; чыннан да монда тиешле аваз күчешләрен күрергә мөмкин (чув. телендә *т- > ч-, а > ы, б ~ р*), ләкин алт. һ.б.

*чәр-* (< яз. монг. *čeger-* «туктату, тыю»?) сүзеннән дип уйлау табигыйрак.

Дерив.: **чәрекле, чәрексез.**

**ЧӘРЕМ** (ЛТ I: 169), **чирем** (ЗДС: 753) любое кожное изделие; обработанная кожа, ремень и т.п. ~ төр. *çerm,* кр.-тат. *черим* id. < фар. *чäрм* id. К. **Чәрмә**). Ш. ук иске тат. **чәремгәр**, үзб. *чәримкәр* «күнче» < фар. *чäрмгäр* id.

**ЧӘРКӘ I** (ТТДС I: 503) «чарка, сосуд для питья хмельного» > чув. (Сергеев 1971: 147) *черкке, черке,* мар. (Саваткова: 184) *цäркa* «рюмка» < рус., рус. *чарка* исә тат. теленнән алынган **чара** (к.) сүзенең кечерәйткеч формасы, к. Фасмер IV: 316. К. ш. ук түбәндәгене.

**ЧӘРКӘ II** (ТТДС I: 503) «голень», ш. ук «затылок» – вообще «место в теле, где явно выступают кости» – **чара II** (к.) сүзенә тамырдаш булса кирәк.

**ЧӘРМӘ,** (Троянский I: 467) **чирмә,** диал. (Balint: 102) **ширмә** «кожная сумка, ранец», диал. (ТТДС I: 486) **чирмә** «сбор лепты с каждого двора на проведение сабантуя – хождение с сумой» ~ башк. (БҺҺ II: 231; БҺҺ III: 162) *сәрмә ~ сирмә* «күннән яки материядән теккән букча; туй бүләкләре капчыгы; күн намазлык» һ.б. (к. Руденко: 138) ~ төркм. *черим* (>> каз. *шерiм,* к.-калп. *шерим*) «күн» (к. Нұрмағамбетов: 134–135), үзб. *чарм, чарим, чәрим* «күн әшья» < фар. *чäрм* «күн» > иске тат. **чәрем** (к.) «һәртөрле күн әйберләр – тат. һөнәрмәннәренең киң таралган товары». К. **Чәрмәк, Чәрмәтөп, Чирбек.**

**ЧӘРМӘК** (ТТАС III: 470) «широкий ремень; тесьма из кожи или шкуры – широкий сплошной лифчик» < фар. *чäрмäк* «күн кисәге» ← *чäрм* «күн», к. **Чәрем.** К. ш. ук к.-балк., кырг. *чермий* «күн (киң тасма) яки тире лифчик (мондый лифчикны кызлар гына кигән)».

**ЧӘРМӘСӘН, Чирмәсән** – Чермасан, название реки на территории современного Башкортостана – бу сүзне **Чирмешән** – Черемшан – сүзе белән чагыштыру географик закончалыкларга бик туры килә: һәр ике елга көньяк-көнбатыштан төньяк-көнчыгышка сузылганнар, тик капма-каршы юнәлештә агалар (шундыйрак хәл **Сакмар** һәм **Самар** (**Сакмара** һәм **Самара**) елгалары очрагында да күзәтелә: бүтән аналогларны да карталардан күпләп табарга мөмкин; мәс., Башкортстанда капма-каршы ике **Майгашты,** ике **Эстәрле** елгасы бар). Бик ихтимал ки, **Чирмәсән** һәм **Чирмешән** Болгар-Биләр дәүләтенең көньяк-көнч. чикләре булып хезмәт иткәннәрдер. Аларның атамалары бор. тат. **чәр-** (к. **Чәрек**) «тоткарлау, оборона тоту» булырга мөмкин. Кызганычка каршы, бу фаразны төгәл исбатларлык мәгълүматлар юк.

Башк. *Сәрмәсән* варианты (тат. телендә дә кулланыла) икенчел (*ч* > *с*) булса кирәк.

**Чирмәсән** елгасына параллель (бераз көньяк-көнчыгыштарак) **Кармасан** елгасы бар. Саф лингвистик назардан бу елгалар атамаларында бор. **-масан//-мәсән* элементын аерырга мөмкин. Ләкин бу регионда андый компонент бер телдә дә теркәлмәгән. Гомумән, бу ике гидронимның чыгышы тур. риваятьләр һәм фаразлар-юраулар гына бар. Һәм алар безнең фараздан ныграк ышандырырлык түгелләр.

**ЧӘРМӘТӨП** (ТТДС I: 502) «кожаный коврик для намаза – традиционный подарок невестки родителям жениха (мужа), вообще – самый ценный подарок невестки (вынимаемый из сумы для подарков последним)» ~ башк. (БҺҺ II: 231; БТДҺ: 295) *сәрмә төбө* id. (ягъни бүләкләр токчаеның иң төбеннән алынган бүләк).

Бу сүз калькалаштырылып мар. теленә дә кергән. К. **Чәрмә.**

**ЧӘРНӘЙ, чәрней** диал. (трбс.) «сурепка»; «всякие съедобные растения» (ЗДС: 739) – бу сүз, ихтимал, бор. төрки (ДТС: 141) *čarnï, čurnï* (< санск. *čurna*) «дару үләннәреннән ясалган тузгы (порошок)» сүзеннәндер. Ул үләннәрдән берсе *sırınčan* – «кәҗә чәнечкелесе» күрсәтелә, бу үлән чәрнәйгә охшаш. Безнең фараз арадаш (бүтән төрки телләрдә булган) сүзләргә мохтаҗ.

**ЧӘРПӘ, чәрпәк** «одна из частей разбитого, расколотого» – тәкълидидиaf *чәрп* тамырыннан (төп мәгъ. «чәчрәнте» булса кирәк). Чаг. **Чәрдәк.**

Дерив.: **чәрпәлә-ү,** (ТРС 1931) **чәрпәлән-ү ~ чәрпалан-у, чәрпәклә-ү, чәрпәклән-ү.**

**ЧӘРТ** – имитатив слабому треску, потрескиванию. Чаг. **Чәт, Черт.**

Дерив.: **чәрт-чәрт.** К. **Чикләвек.**

**ЧӘРЧӘ** (ТТДС I: 502) «четвероугольный проем – зарубка для оконного косяка» < фар. *чāрчӯбэ,*

*чāһāрчӯбэ* «агач рам» (сүзмә-сүз «дүрт агач»), шуннан төр. *çerçeve* «рам, кыса; дүрт як». Чаг. **Чарача.**

**ЧӘРЧӘ-Ү,** себ. (Тумашева 1992: 246) **чарча-у** «устать, уставать, утомляться», (Старчевский) **чярчя** «удушиться, запирать дыхание» < гом. кыпч., к. алт., кырг., үзб. *чарча-,* к.-балк. *чарчай-* (> нуг., каз., к.-калп. *шарша-,* башк. – БТДҺ: 270 – *сарса-*) id. ~ монг. *чарча-* > *царца-* (бур. *сарса-*) «ару-талу; катып калу; үлү» ~ эвенк. *чарча-* «туңгаклау» ← яз. монг. *čarča-* «туңып хәрәкәтсезләнү» ← *čar* «туңгак» (ССТМЯ I: 385, 387). К. ш. ук алт. *чарча-* «чатнау», каз. (ҚТДС: 368) *черчеу* «ат танавына полип үсеп, тын алалмау».

**ЧӘРШӘМБЕ** «среда (день недели)» < фар. *чāршäнбэ, чäһāршäнбэ* id. («дүртенче көн» мәгъ.)

**ЧӘТ** – имитатив звонкому, но не сильному треску, хлестанию (веником и т.п.), **чат** тәклитенең «йомшаграк» варианты

Дерив.: **чәт-чәт** – әкрен генә чатнау тавышына яки кызу-кызу һәм ачулы сөйләүгә (гадәттә хатын-кыз тур.) тәкълит; **чәтерт** – бер тапкыр чәт итеп алу, **чәтерт-чәтерт** – берничә тапкыр чатнап алуга тәкълит; **чәтер-чәтер** – бертуктаусыз чәрелдәүгә яки тиз (хисле, ачулы) хатын-кыз сөйләменә тәкълит; **чәтләү, чәтнәү** «чәт итеп ярылу (кечкенә әйбер тур.)»; **чәтелдә-ү** (***чәтел** нигезе булмаса да) «кызу һәм эмоцияләр белән сөйләү», арытабан – **чәтелдәвек, чәтелдек** «кызу сөйләүчән (хатын яки кечкенә бала)»; **чәтердә-ү** «чатыр-чотыр килеп яну», «чәрелдәү», **чәтердек** «чәрелдек хатын».

Бу сүзнең сурәтләү нечкәлеге белән тагын да үтемлерәк варианты **чәрт** – бик көчле булмаган чатырдауга имитатив, ләкин **чәт** сүзеннән продуктивсызрак. К. **Чәти, Чет, Чикләвек.**

Гомумән, татар имитативлары Н.И. Ашмарин шулкадәр мактаган чуваш имитативларыннан да төрлерәк, киңрәк, мәгънә нечкәлекләренә дә байрак, чөнки тат. теленең авазлар составы да киңрәк. Шуны ук башкорт имитативларына карата да әйтеп була – башкорт телендә имитативларда еш кулланыла торган *ч* авазы юк. Ошбу факт бор. тат. теленең чув. теленә дә, башк. теленә дә нигез булган дигән фикергә китерә.

**ЧӘТӘ, чиру-чәтә** (Троянский) «военный отряд» ~ төр. (Будагов I: 470) *чете* «юлбасарлар һөҗүме», (Steuerwald) *çete* «партизаннар, төп гаскәргә ярдәм итеп, талаучылык белән дә шөгыльләнүчән ирекле чируләр». Чыгышы ачык түгел. Турбаслыда **чәттә** дип сугышкак малайларны сыйфатлыйлар иде.

**ЧӘТӘН** (ТТДС I: 503) «голень», ләкин диалектологларның аңлатмасы дөрес үк түгел, күрәсе, чөнки **шәрә чәтән** мисалы «оятсыз, җирбит» мәгънәсендә; **чәтән** «бот арасы», к. **Чатан** (аның «бот арасы» дигән мәгъ. бар).

**ЧӘТЕРМӘН** (ТТДС I: 502) «болотистый луг» – **Чатырман** (к. **Чытырман**) сүзеннән палатальләшкән.

**ЧӘТЕРТӘН,** диал. (ТТДС I: 503) **чәтертәк, чәтермәк,** (ТРС 1931) **чәтрәш** һ.б. «бойкий, проворный; непоседливо-деятельный» ~ башк. (БҺҺ II: 232) *сәтерсән* id. ~ диал. (трбс., без теркәдек. – *Р.Ә.*) **чатыртан** – ниндидер кош – урманда яши ~ мар. (Упымарий: 239, 242, 248) *чатыртан* «безкойрык», *чодыртан* «саз шөлдие», *чытыртан* «кыр үрдәге төре», иске мар. (к. Исанбаев 1973: 67) *чадартан* «тургай», к. ш. ук мар. (Саваткова: 214) *шытьыртан* «чәтертән (кеше)». Түбәндә кош исеме. Тат. теленә мари теленнән кергән булса кирәк (кош атамаларында *-тан//-тән* кушымчасы мар. теленә хас), ләкин к. түбәндәгене.

**ЧӘТИ, чәтти, чәтнәби** (ТТДС I: 503) «бойкая, крикливая (женщина); озорница» ~ чув. *çатта* id. – *чәт, чат* тәкълиди сүзеннән ясалганнар, к. **Чәт, Чәтертән, Чәүчәләк.**

**ЧӘҮКӘ [чәwкә],** диал. (миш.) **чаука,** себ. (Тумашева 1992: 235) **цауқа** «галка» – К. Насыйри буенча, «фарсыча чау-чау тавышыннан карап ясалган сүздер» (ЛТ I: 127), татарча ди ул, *чәүкәләр чәкелдиләр*, «*чәкел-чөкел итәләр*». *Чәү-чәү* имитативы татар телендә дә бик булырга мөмкин. Ләкин **чәүкә** сүзе тәкълиди сүздән икәнлеге уйг. *чаңкылда-у* «чәңкелдәү, кискен авазлар белән шау-шу килү» фигыленнән (*чаңк-чаңк, чәңк-чәңк* тәкълиди сүзеннән) беленә; гомумән, бу сүзнең параллельләре киң таралган: башк. *сәүкә,* к.-балк. *чауқа* ~ морд. М., чув., рус. диал. *чавка,* коми. *чавкан*, венг. *csoka* «чәүкә». Фонетик җәһәттән мар. (Саваткова: 184) *цäнгä* < *цäңкä* ~ чув. *чанка, чана*, удм. *чана* id. үзенчәлекле. Федотов II: 386 (бу сүз бор. чув. теленнән димәкче). Чаг. ш. ук тунг.-маньч. *чаука* «гаскәр» < бор. монг. *čiγuγa* «шау-шу; талпа» (к. ССТМЯ II: 402, 410); рус. *галка* ← *галдеть*.

**ЧӘҮЧӘЛӘК [чәwчәләк]** «беспокойно-разговорчивый» ~ башк. *сәүсәләк* id.← ***чәүчәлә-ү** ← ***чәү-чәү** тәкълиди сүзеннән; семантик аналогия: рус. *гал-ка ~ галдеть*. К. ш. ук диал. (ЗДС: 740–741) **чәүчәк, чәчәләк** «тиктормас, хәрәкәтчән; бәйләнчек» ш. ук – кош атамасы (чаг. рус. *чечётка*), ш. ук «кызу бәхәсләшүчән (хатын-кыз)», **чәчәлән-ү** «тиргәшеп бәхәсләшү» һ.б.ш.

**ЧӘҺРӘ** «лицо, физиономия» < фар. *чäһрä, чиһрä* id. К. **Чырай.** Будагов I: 502.

**ЧӘЧ,** себ. (Тумашева 1992: 235) **цац, цәц,** фольк. **сач** «волосы на голове» < гом. кыпч. *чач*, алт. *чач, чаш* (> башк. *сәс,* нуг., каз., к.-калп. *шаш, шәш),* уйг., гом. угыз., бор. төрки (ДТС: 479) *sač* id., тув. *чаш,* хак. *сас,* як. *ас* «чәч; толым» ~ чув. *çүç* < *çүç* < *çoç* < *чач* id. Будагов I: 611; Räsänen 1969: 291; Федотов II: 150; ЭСТЯ VII: 216.

Тат. **сач** варианты Алтын Урда уйгурчасыннан булса кирәк. Гомумән, тат. *чәч-* авазлар комплексы урынына *сач-* килү бүтән кайбер сүзләрдә (башлыча уйг. һәм угыз группаларында) күзәтелә: *чачак ~ сачак, чәч-ү ~ сач-, чәчә-ү ~ сача-* һ.б. Бу хәл барча мүзкүр сүзләр ономопоэтик **сач* «сибелгән, таралган, тузгыган нәмәрсә» мәгънәсендәге тамырдан ясалган дигән фаразга китерә.

Дерив.: **чәчле, чәчсез; чәчлән-ү; чәчби, чәчбикә** «озын, парлак чәчле хатын-кыз», **чәчбай** (үлән атамасы), **чәчкап** (к. ДС I: 223) > мар. (Упымарий: 241) *часькап* «көмеш такыя», башк. *сәскап* «башка киелә торган катлаулы (такыялары, тасмалары, чулпылары-тәңкәләре булган) бизәнеч» (бу сүзнең бүтән төрки телләрдә дә параллельләре бар). Идиомалардан – **чәчең чәчкә бәйләнгән булу** «тәңре тарафыннан өйләнештерергә дип язмышлар китабында язып куелган булу» кызыклы: бор. төрки-монг., кыт. һ.б. Азия халыкларындагы ырым-ышану буенча (к. МНМ II: 473), чәчләрнең күзгә күренмәс дәвамы күккә җитә икән дә, чәч очларын тәңре парлап бәйләп тора икән; шунда төенләнгән чәч ияләре кайда гына йөрсәләр дә, ахыр килеп өйләнешәләр икән. Бу тур. төрле этнографик әдәбият бар.

**Чәчүргеч** дип диал. сөйләмдә атның ял сеңерен атыйлар, чөнки элек атның ял сеңерен киптереп матур, ефәксыман ялтыравык сүс ясаганнар, шуннан **чәчүргеч** үргәннәр.

Себердә **цәц** «бәбинең кәкелен – беренче чәчен кискән кардәш» мәгъ., мәс. (ЗДС: 710–711, 740–740) **цәцәбә, цәцәкә, цәцибаба, цәцимама, цәцинә, чәч апа, чәч әни**.

**ЧӘЧӘК,** диал. **чәчкә,** миш. (ДС II: 160; ДС III: 139) **цәцәк, сачәк, сайчак, цицәк, сичак,** себ. (ДС I: 218) **цицегәй, цицекәй, цицәк** «цветок, цветы; оспа»; в некоторых говорах (гәй.) проводится смысловое различие, к. (ДС I: 218) **чичкә** «цветок», **чичәк** «оспа» – к. ш. ук башк. әд. телендә дә *сәскә* «чәчәк (үсемлек)», *сәсәк* «чәчәк (авыру)», ләкин татар лексикологлары мәгънә аеру принцибын танымыйлар. Идел-Урал союзы телләрендә дә бу сүзнең вариантлары күп кенә: чув. *çeçек* (әд. норма), диал. (Сергеев 1971: 147) *чече, чечче,* ш. ук *çeçке, çeçкĕ,* удм. *сяська* id., *чача* «чәчәк (авыру); тәти» (~ себ. **цәцә, цәцәү** «тәти», к. Тумашева 1992: 237), мар. *сäскä, сеска, саска* «җиләк; игелгән яшелчәнең сабак-яфраклары» ~ кр.-тат., чыгт., уйг., алт. (Радлов III: 1988) *чäчäк,* угыз., кар. *чичäк, чечäк,* ком., к.-балк., кырг., тув. *чечек* (> нуг., каз., к.-калп. *шешек*) < бор. төрки (ДТС: 143) *čečäk* «чәчәк» ~ төркм. *җәәҗек* id. Кайбер төрки телләрдә *чәчәк* авыру мәгъ. генә кулланыла, үсемлек органы мәгъ. бүтән сүзләр кулланыла яисә нигез киңәйтелә (каз. *шешекей* «үсемлек чәчәге», *шешек* – авыру атамасы) һәм болай итүнең мәдәни икәнлеген танырга кирәк. К. ш. ук монг. *цэцэг* (< иске монг. *čečeг*) > бур. *сэсэг* ~ эвенк. *чэчэк* > як. *чэчiк* (к. ССТМЯ II: 422). Төрле фраземалар тур. Будагов I: 470–471; ЗДС: 740–741.

**Чәчәк ~ чичәк, цәцәк ~ цицәк** пары тат. теле өчен характерлы; шунысы кызыклы ки, **цицәк** варианты IX г. ук билгеле: Византия шаһзадәсенә кияүгә бирелгән хәзәр кәникәсенең *Цицак [Цицәк]* исемле булуы һәм бу исемнең «чәчәк» мәгъ. булуы тарихта теркәлгән (күп яз. чыганакларда әйтелә). Гомумән, **чәчәк ~ чичәк** сүзе күп күрше телләргә кергән, аның бер мәгънәсе «түбәсе бизәкле бүрек, тулка (шлем)» булган, к. бор. рус. *чечак, чичак* «баш бизәге» (Фасмер IV: 355) > *шишак* (венгр теле аша) «шлем бизәге». **Чәчәк** – «чир төре» кытайчадан калька, к. кыт. *тяньхуа* «күк авыруы, чәчәк», к. МНМ II: 393.

**Чәчәк** сүзен **чачак** сүзеннән аерып булмый, к. уйг. диал. *сачак* ~ үзб. *сочок* «чәчәк; чачак», (ЎХШЛ: 235) *сәчоғ* «чук, чачак». **Чәчкә** варианты **чәчәкә* < (тунг. телләрендә сакланган) *чачака* «чәчәк, чук» вариантыннан килә. Гомумән, бу сүзләр бәбиләр-балалар теленнән, чаг. рус. морд. *цаца, цеця, чечка,* удм., мар. *чача* «бизәк, чук, чачак» һ.б.ш. Будагов I: 470–471; Абаев I: 285; Räsänen 1969:

102; Мухамедова 1973: 189–196; Федотов II: 104; Аникин II: 659.

**ЧӘЧӘН** ~ башк. *сәсән* «певец, бард» к. **Чичән.**

**ЧӘЧӘ-Ү,** себ. (Тумашева 1992: 235) **цаца-у,** «поперхнуться» < гом. кыпч., к. башк. *сәсә-, саса-,* к.-балк., кырг. *чача-у,* к.-балк. *чачыӄ-, чачыгыр-* ~ төркм. *сачыр-* id., чаг. тат. диал. **чәчергәлән-ү, чәчәлән-ү** «ярсынып, төкрекләр чәчеп тиргәү, тиргәнү». К. **Чәч-ү.**

**ЧӘЧӘҮЧӘ [чәчәwчә], чәчәбичә,** (һ. Такташта) **чичибичә** «чечевица», ш. ук (ЗДС: 741) **чәчәли** «чечевица пищевая (Lens culinaris)», соңгы вариант тат. теленең үзендә ясалган. Рус теленнән килә (*-вица* рус сүзьясагыч кушымчасы).

**ЧӘЧКАП, чәчхап, чәчрәткә** (ЗДС: 741–742) «девичий головной убор с монетами (обычно их было девять штук)» ~ башк. *сәсҡап*, кырг. *чачҡап, чачпак* һ.б.ш. *чәч ~ чач* һәм *кап* яисә *рәткә* сүзләреннән гыйбарәт. *Кап* элекке «янчык» мәгънәсендә, **рәткә** исә (мишәрләрдә) рус. диал. *рядка* «чәчәкле бизәк» (чаг. *наряд* «бизәнеш») сүзеннән. *Чәчкап* кызлык билгесе буларак еш кына кыйммәтле, катлаулы баш киеме булган, к. ЗДС: 742. Чаг. **Чулпы** шул ук функциядә.

**ЧӘЧКӘ** «цветок» к. **Чәчәк.**

**ЧӘЧРӘ-Ү, чәчерә-ү,** себ. (Тумашева 1992: 235) **цацра-у** «брызгать (непереходный)», **цацгыра-у** «накрапывать» < гом. кыпч. *чачыра-* (> нуг., каз., к.-калп. *шашыра-, шашра,* башк *сәсрә-, сәсерә-*), уйг., чыгт., угыз. *сачра-, сачыра-* (төркм. *сычра-*) < бор. төрки (ДТС: 479–480) *sačïra-, sačra-* «чәчрәү, сибелү, челпәрәмә килү» (чаг. тат. *чәчрәп киткере* – сүгенү сүзе) асылда *сачгыра-у ~ сачгыр-у* формаларыннан, *сач- ~ чач-* (к. **Чәч-ү**) тамырыннан. Турыдан-туры *сач- > чәч-* нигезеннән дә ясала ала, чаг. *җәй- → җәйрә-ү, көй- → көйрә-ү, төй- → төйрә-ү* һ.б. Будагов I: 611.

Дерив.: **чәчрәл-ү, чәчрәт-ү; чәчрәткеч, чәчрәтке.**

**ЧӘЧҮ, чәчем, чәчемлек** (Баязитова 1992: 276–277) «раздача милостыни, мелких подарков на похоронах и поминках» < гом. кыпч., к. кр.-тат. *чачу* (> каз. *шашу, шәшу*), кырг. *чачы*, тув. *чажыг,* госм. *сачу* < бор. төрки (ДТС: 479; Zajączkowski 1961: 150) *sačïγ, sačyγ* «корбанлык итеп (утка) шәраб, кымыз һ.б.ш. чәчү» >> як. *ысыах* «җәйге кымыз бәйрәме һәм корбан бирү мәрасиме» (к. Антонов: 134–135), к. ш. ук уйг. *сачқы,* чыгт. *сачыӄ,* төркм. *сачыӄ, сачаӄ* ~ монг. *цацаг* > бур. *сасаг* «корбан бирү, хәер өләшү һ.б.ш.». Бу, күрәсең, бик бор. сүз һәм аны кыт. *ша(р)* «ритуаль эчү; ант эчү» сүзе белән чагыштырулар нигезсез түгел. *Чәчү ~ сачык* һ.б. еш кына бүләкләрнең үзләрен, аларның төрләрен дә белдерә, к. Будагов I: 611–612. Төр. *sacı* «кәләшнең чәченә тары (!), чәчәкләр, тәңкәләр чәчү һәм мактау мәрасиме», «чәч», «чәчү» «чәчәк» сememаларын һәм өстәвенә «чәчән» сүзен дә берләштерә. К. Orhan Kurtoğlu. Klasik türk şiirinde *sacı* geleneği // Milli folklor (Ankara). 2009. № 81: 89–99 (бик тәфсилле, «чәчү» җырлары китерелә). К. түбәндәгене.

**ЧӘЧ-Ү,** миш. **цәц-ү,** себ. (Тумашева 1992: 235) **цац-у** «рассыпать, сеять; разбрызгивать; излучать свет», диал. (ТТДС II: 367) «сажать растения» (бу мәгъ. сүз **чәңчә-ү** фигыленнән дә килеп чыга ала) < гом. кыпч., алт. *чач-* (нуг., каз., к.-калп., тув. *шаш-,* башк. *сәс-*), уйг., гом. угыз., бор. төрки (ДТС: 479) *sač-* ~ як. *ыс-* < *сыч-* id. ~ яз. монг. *čača-* (> хәз. монг. *цаца-* > бур. *саса-*) ~ эвенк., маньч. һ.б. (ССТМЯ II: 386–387) *чачу-* (*-у* монда тамыр составында) «чәчү, сибү». Бор. киң таралган тамырдан, к. **Чәчәк, Чәчә-ү, Чәчрә-ү**. К. **Чәчү.** ЭСТЯ VII: 217–218.

Дерив.: **чәчел-ү, чәчеш-ү, чәчер-ү** («чәчрәтү» мәгъ.), **чәчтер-ү; чәчем** (**явым-чәчем** парлы сүзендә); **чәчкен; чәчмә; чәчүлек** һ.б.

**ЧӘЧҮРӘ,** (ТТДС I: 523) **шәшүрә** «чёрт в образе женщины с распущенными волосами» ~ удм. *чочоро* «азгын (хатын)». Бу сүзне «чәч үрә» (торган рух) дип аңлау-аңлату табигый, чаг. ләкин, **чүчәлә** (к.), көрд. *чурчур* «челән; арык һәм озын буйлы хатын».

**ЧӘШЕ** (ТРС 1931 һ.б.), диал. (ТТДС I: 503) **чәче** «приспособление для сушки снопов на поле; стожар» ~ башк. (БТДҺ: 395) *сәсе*, к. **Шәйше.**

**ЧӘШКЕ I, чәшкә** «блюдце, блюдечко, чашка», күч. «коленная чашка» ~ башк. *шәшке*, чув. *чаша, чашӑк, чашка, чашкӑ,* мар. *чӓшка, чашка, цӓшка,* удм. *чаша, чашка* < рус. *чашка, чаша* id. Рус сүзенең этимологиясе томанлы, ихтимал төрки сүздер (к. **Чара**). Фасмер IV: 320.

**ЧӘШКЕ II, шәшке** «норка» ~ башк. *шәшке* id. < мар. *шашкы, шашкĕ*, чув. *шашкă*, удм. (Насибуллин: 144) *чашкъ* «көзән» һ.б. фин-угор телләреннән, к. Räsänen 1969:105. Рус. *шешок* «ас; көзән» тур. Фасмер IV: 432. Каз. *шешке* «чәшке» татарчадан булса кирәк.

**ЧЕ** – частица утверждения или удивления (ТТДС I: 478; Арсланов 1986: 51; Баязитова 1986: 129 һ.б.) ~ фар. *чи* «нәрсә? ни? нилектән?»; чув. *чи* «иң, бик тә». Гомумән, ачык түгел.

**ЧЕБЕК** «слабенький» к. **Чибек.**

**ЧЕБЕН,** диал. **цебен,** себ. (Тумашева 1992: 237) **цыбин, цыбын** «муха», диал. (ТТДС I: 478) **чебен** «комар; мошка» > мар. (Исанбаев 1978: 22) *чы̆бы̆н,* удм. *чибинь* «чебен, черки» < гом. кыпч., к. кар., к.-балк. *чибинь, цибин* «чебен», кр.-тат., уйг., чыгт. (Радлов III: 2154) *чибин*, төр. *cibin* «чебен; бал корты; москит», кырг., алт. *чымын, чыбын*, бор. кыпч. (Курышжанов: 219) *чыбын* (> нуг., каз., к.-калп. *шыбын,* башк. *себен*), төркм. (Мухамедова 1973: 192) *чыйбын* «чебен», *чыйбвын* «черки», *чыыбын* «шөпшә», үзб. (ЎХШЛ: 301) *чиивин, чъбън, чъвън, чүүн,* бор. төрки (ДТС: 145, 147) *čibin, čibün, čigün, čïbïn, čïbun* «чебен, черки», ком. госм. *җибин* «чебен; ком чебене; сукыр чебен» ~ тув. *шымыл* «нөр (бөҗәк личинкасы)» < иске монг. (Поппе 1938: 390) *šimul* «чебен». Алынма сүз шикелле, әмма, гомумән, чыгышы ачык түгел.

Дерив.: **чебенле, чебенсез; чебенлә-ү; чебенлек** «чебеннән саклану өчен пәрдә»; **чебенче** (бер кош һәм бер төр гөмбә – рус. «мухомор»? – атамасы). К. **Чыбылдык.**

**ЧЕБЕШ I, чебеч** (ТТДС I: 479) «цыплёнок; гусёнок; молодая курица» ~ башк. (БТДҺ: 274) *сепей, сепеш, сипеш* «чеби, чебеш; каз бәпкәсе», (БҺҺ II: 204–207) *себей, себеш, сибеш* «каз бәпкәсе», *сепей тауыҡ* «бер яшьлек тавык» – мәгънәсе буенча тат. **чәбәш** (к.) ~ гом. кыпч. *чәбич* «6–12 айлык бәрән яисә бәти» сүзеннән икәнлеге күренә. Бу сүзне кош-кортка нисбәт итү **чеби** (к.) сүзе тәэсирендә килеп чыккан. Югыйсә *чебеш ~ чәбеш* һәм *чеби* сүзләренең бер тамырдан булуы бик шикле.

**ЧЕБЕШ II, чеби** «цыпки (на ногах), потрескивание кожи на ногах от постоянного хождения босиком по грязи и т.п.» – **Чебеш, Чеби** сүзләре белән баглы, ләкин семантик җәһәттән аңлашылып бетми (чебеш кебек яланаяк йөрүдәнме?). Гом. төрки сүз: тув. *шивишки* «чебешке».

Дерив.: **чебешкә, чебешке** id.; **чебешлә-ү, чебешле.**

**ЧЕБИ,** диал. (Тумашева 1992: 237) **цеби** «цыплёнок» ~ башк. (БТДҺ: 272, 275) *себей, сепей, сибей, сибеш,* удм. *чипы, чипу* id., коми. *чипан* «тавык», мар. *чывы, чиви,* (Иванов, Тужаров: 264) *цĕвĕ,* чув. *чĕп, чĕпĕ* ~ рус. диал. *цыпь*, белорус. *цыпа* «чеби»; к. ш. ук кар. (Радлов III: 2153) *чипчä,* нуг. *шипий*, каз. (ҚТДС: 404) *шыбый* id. ~ венг. *scibe* id. һ.б. имитатив *чип, чып* сүзеннән, к. тат. **чип-чип** ~ рус. *цыпцып* тавык-чебиләрне чакыру ымлыгы. Федотов II: 412–413.

**ЧЕГӘН,** диал. (трбс., шрл. һ.б.) **чиған, чыйған, чиган** «цыган» ~ башк. *сегән, сиган, сыйган*, удм., мар. *чиган, циган, чĕгäн,* чув. *чикан* ~ рус. *цыган,* төр. *çigan* < венг. *čigany* һ.б. id. урта гасыр грек. *ατσίγγανος* id. сүзеннән таралган дип карала, к. Фасмер IV: 305; Европа телләрендә (Kluge: 1012): ним. *zigeuner,* ит. *zingaro,* инг. *tzigane* (ихтимал, русчадан) һ.б. id.

Чегәннәр үзләрен **чегән** һ.б.ш. дип атамыйлар. Һәм аларның атамасын бор. төрки *čïγaj* < бор. төрки (Clauson: 408–409) *čүγай [чыгань]* «ярлы, мескен, фәкыйрь» сүзе белән дә чагыштыралар (к. Räsänen 1969: 104, 107), к. ш. ук чув. *чухăнь* «фәкыйрь». «Мөхәммәдия» телендә *чиған вә кяфер* – «һәртөрле динсезләр».

**Чегән** сүзе иске төрки *чэнгэнэ*, кр.-тат. *чиңгәнә*, госм. *чäңгäнä* «чегән; чәңче» сүзеннән дә килеп чыга ала. Гомумән, *чегән* һәм *чыйган* вариантлары бер-берсеннән чыгарылмый, алар ике чит чыганактан киләләр шикелле. К. **Чыйган.**

**ЧЕГЕТ, чыгыт** (ТРС 1931; Хайрутдинова 1993: 97–98; ЗДС: 718, 769) «чигит, солёный творог, сырок и т.п.» > чув. *чăкăт,* мар. *чыгыт* < гом. кыпч., к. кар. *чыгыт, цыгыт,* осет. (< кыпч.) *чыгт* «чыгыт, пышлак һ.б.ш.» Гомумән, бу сүз монг. булса кирәк, чаг. алт. *чеген, чäгäн* ~ яз. монг. *čegen, čigen,* хәз. монг. *цэгээн* «катык төре, кымыз катыгы» (**чегет** < *чигит, *чигәт* шуның күп. формасы булырга мөмкин). Рус. *чигит* (Фасмер IV: 359) кыпч. телләреннән (М. Фасмер кар. теленнән ди, ләкин бу, безнеңчә, төгәл түгел). Рус. *чегень* «әйрән төре» (монг. теленнән) тур. к. Аникин: 650. К. ш. ук Федотов II: 400 (тат. сүзләрен искә дә алмый). Ф. Баязитова (к. аныкы Гомернең өч туе. Казан, 1992:

129–130) материаллары буенча, **чыгыт** «гомернең өч туенда да» ритуаль ашамлык булган.

**ЧЕКЕР,** (А. Расих) **чекри** «сощуренный (о глазах)» ~ кырг. *чекир* «күз карасындагы тап, ак» ~ яз. монг. *čengkir* «аксыл-зәңгәр, чагыр (күз)» > хәз. монг. *цэнкэр, ценхер, чиңхер* һ.б. id. **Чагыр ~ чакыр** сүзенең палаталь варианты. Чаг. рус. *щур* «чекер»: охшашлык очраклы микән?

Дерив.: **чекерәй-ү** «ачуланып күзләрне кысу» ~ кырг. *чекирей-* ~ эвенк. (ССТМЯ II: 392) *чикирэ-* id. Диал. **чекрән, чекрәнлә-ү** «оялмыйча карап тору», **чекерек** «оялмаучан караш; оялмыйча караучан».

**ЧЕКИ, чики, чикай, чикей** (ТТДС I: 483; ТТДС II: 348, 331) «мелкие орехи» – **чикләвек** (к.) сүзе нигезендә тат. телендә ясалган булса кирәк.

**ЧЕЛ I,** диал. (Тумашева 1992: 237–239, һ.б.) **цел, цилтауык, цил, цыл**, «рябчик; куропатка (птицы, белеющие к зиме)» < гом. кыпч., к. кар., кырг., куман., уйг., гаг., госм. һ.б. *чил* (> каз. *шил, шыл,* башк. *сел*) «чел», ш. ук иске ядкәрләрдә *čil, čiil* «чел; ак фондагы сипкел; ялтыравык аклык символы; өр яңа көмеш акча» (к. Räsänen 1969: 111). Ком. *чыл* «челән», нуг. *шел* «бизгәлдәк» сүзләре дә *чел* < *чил* < *чыл* белән гомоген булса кирәк. Гомумән, бу сүз төрки телләрдән күп күрше телләргә үтеп кергән, к. абаз. *чыль*, рус. диал. (< каз.) *шил* «чел» һ.б. Удм. *сяла*, коми. *сьола* «боҗыр» төрки телләрдән микән – әйтүе кыен. К. ш. ук **Челкә.** Будагов I: 484, 507; Zajączkowski 1961: 43; Мухамедова 1973: 189; Аникин: 700.

Идиомалар: миш. (ТТДС I: 466) **целенце** «вак сәдәф; сәдәф» < **цел енце, чел энҗе**, чаг. госм. *чил акче* «вак көмеш акча »; башк. *сел бүреһе* ~ кырг. *чил бөрү* «шакал».

**ЧЕЛ II** «мездра, слой жира на внутренней стороны шкуры, снятой с животных» к. **Чил.**

**ЧЕЛӘЙ-Ү** «жмурить глаза от удовольствия; отрешённо, недоумённо смотреть во все стороны» ~ хак. *чылай-* id. Чаг. кырг. *челей-* «күз чыгу». Ихтимал, *чел* ~ *чил* белән баглыдыр.

**ЧЕЛӘН,** диал. **чылан,** (ЛТ I: 170) **чалан** «цапля» ~ башк. *селән,* ком. *чилле,* к.-балк. *чиллеаяқ,* алт. *чилэң, чилэн, чилән*, тув. *шилен* ~ маньч. *килахун, сулахун* «торна, челән, ләкләк» (?). Чув. *чарлан* ~ мар. *чарланге, цӓрлӓнге* «челән» бүтән тамырдан. Хак. *сүлен* «челән» сүзенең **челән** сүзенә мөнәсәбәте (Räsänen 1969: 111) ш. ук шикле (фонетик закончалыкларга туры килми). Ә менә хак. *чілең* «җәенке сай күл, күлләвек» сүзенең мәгънәсе, безнеңчә, бик бап килә (*челән* (ягъни күлләвек) *кошы* → эллипсис нәтиҗәсе буларак **челән**).

Идиома: **челәнаяк** рус. «ходули».

**ЧЕЛБИ** (Ф. Хөсни) «вежливый, обходительный; видный собой», **цилбәй, чилбәй, чәлбәй, чәлби, чөлбәй** «милый, возлюбленный» (к. ТТДС I: 466, күпчелек вариантларны без теркәдек. – *Р.Ә.*) ~ угыз. (госм. һ.б.) кр.-тат., кар. *чäлäби, чäлаби, чәлби* «илаһи; әфәнде; асылзат, шаһзадә; мөлаем, инсафлы, игътибарлы, илтифатлы; укымышлы; джентльмен; гашыйк рыцарь», гаг. *челеби* «франт» ← төр. *çeleb, çelâb* «рәхим-шәфкать; мөлаем; йомшак мөгамәләле; кечкентәй» (к. Будагов I: 484), к. ш. ук Steuerwald: 174–175.

*Чәләби* тур. күп язылган, к. Смирнов Н Мнимый турецкий султан, именуемый у европейских писателей XVI века Calepinas Cyriscelebes. СПб., 1907 (70 сәхифәле китап, автор мәзкүр сүзне грек. *каллиепес* «сүзчән; нәфис» сүзеннән чыгара, безнеңчә бу – шикле); Бартольд V, 1963: 611–614 (махсус мәкалә, автор сүзнең чыгышы билгесез ди); Гордлевский I 1960: 171, 497. Ихтимал, тарихка кереп калган Алтын Урда баһадиры **Челубей** (ул Куликово мәйданында рус баһадиры белән бергә-бер сугышкан) исеменең дә безнең сүзгә катнашы булса кирәк.

**Челби** сүзенең **Чәләби** белән гомоген булмавы да ихтимал. Ләкин алай уйлаганда да этимология җиңелләшми. Бор. монг. *чэрби* «гвардия офицеры» (к. Гумилёв 1994: 304) белән чагыштыру өстәмә дәлилләр сорый. Чаг. ш. ук тув. *челби* ~ монг. *целбэнг, цэлбэр* «якты, чиста, ап-ак». Чаг. **Җәләп, Чәләби.**

**ЧЕЛДӘК** (Будагов I: 485), себ. (Тумашева 1992: 237, 239) **целтәк** «кружево, кружевное украшение», **цилтәк** «корзина» ~ бор. төрки (к. Räsänen 1969: 111) *čiltäk* id. фар. теленнән булса кирәк, чаг. **Челтәр.**

**ЧЕЛЕК** «акация (на лесопосадках)»; **чилык** «чилига», себ. (Тумашева 1992: 237) **целек** «маленький чахлый лес посреди болот» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 273) *селек* «акация; яшь наратлык», кырг. *чилик* «куралык, биек үлән ешлыгы, шарлык» (> нуг., к.-калп. *шилик*, каз. *шілік* «куралык, үзеннән кәрзин үрелә торган үләнчел үсемлек»), үзб. (ЎХШЛ: 315) *шълъқ, шилик* «ат кузгалагы (гомумән – кура)», иске

үзб. (Хива сөйләшендә, к. Будагов I: 508) *чилиға,* кырг. *чилиге* «карагана (күпьеллык каты сабаклы үлән төре)» > рус. сөйләшләрендә *чилига* «әрем төре – шифалы үлән», к. Аникин: 661. К. **Чий II.**

**ЧЕЛЕК-Ү (челекте, челегү), челий-ү** (Остроумов 1876: 133; ТРС 1931; ТТДС I: 479) «пересохнуть; проголодаться; сильно похудеть, осунуться» ~ кырг. *чилмий-* id. Гомумән, ачык түгел, морфемалары буенча хөкем йөрткәндә, **чи-у* «корыу» фигыленнән, шуңа *-лек-* кушымчасы ялганып ясалган сүз.

**ЧЕЛЕМ** «трубка, кальян»; диал. «жевательный табак» > чув. *чĕлĕм,* мар. *чылым*, удм. *чильым* < уйг., үзб., чыгт., төркм. һ.б. *чилим,* кырг. *чылым* (> нуг., каз., к.-калп. *шылым*) «трубка, кальян» ~ фар. *чäлäм* (к. Räsänen 1969: 108) яисә *чилим* «челем» һ.б. Сүзнең чыгышы бигүк ачык түгел. К. **Черем.** Федотов I: 410; Аникин: 661–662.

Дерив.: **челемче; челемлә-ү.**

**ЧЕЛЛӘ** «сорок самых холодных (25 декабря – 5 февраля) дней зимы и самых жарких (25 июня – 5 августа) дней лета; самое крутое место, основная часть подъёма в гору» (к. Махмутова: 234) ~ гом. кыпч. *чиллә*, уйг. *чиллә* (башк. *селлә,* кырг. *чилде*, нуг., к.-калп. *шилде*, каз. *шілде*) id. < фар. *чилле, чäлä* id., ш. ук «карантин» < *чиһилә* «кырыклык» (← *чиһил, чәһил* «кырык»); бу сүзнең «бала туганчы кырык көн һәм туганнан соң кырык көн женси мөнәсәбәттән тыелу мөддәте» мәгъ. дә бар. Будагов I: 486; Räsänen 1969: 111.

**Чиллә** сүзе татарчадан күрше телләргә дә кергән, к. мар. (Исанбаев 1978: 28) *чеңла* «июль».

Идиома: **чиллә чебене** («бәйләнчек кеше» мәгъ.).

**ЧЕЛПӘРӘМӘ, чәлпәрәмә** «вздребезги» ~ башк. *сәлпәрәмә* id. > мар. (Гордеев 1973: 48) *чылпара,* удм. *чальпа, чальпара* id., ш. ук «өлтеләр, кыйпылчыклар» < фар. *чäл (чäһäл) пāрä* «кырык парә (кисәк)»; *-мә* тат. телендә өстәлгән; чаг. башк. *селбәрә* «көс (бергә йөргән балык маймычлары); күпсанлы бала-чага». Будагов I: 484. Чаг. **Чәрдәк, Челтәр, Чылбыр.**

**ЧЕЛТ, чәлт, чылт** – имитатив миганию, а также мгновенному движению лёгкого предмета.

Дерив.: **челт-челт (итү)**. Чаг. **Челтер.**

**ЧЕЛТӘР**, миш. **целтәр** «кружево; сетка» > мар., удм. *чильтэр,* чув. *чĕнтĕр* id. ~ башк. *селтәр,* кар. *чильтэр* id. < фар. *чилтāр, чиһилтāр* id. сүзмә-сүз «кырык тишек, кырык ярык». Бу сүз төрки телләрдә тагын күптөрле мәгъ. алган: себ. (Тумашева 1992: 247) **чилтер** ~ кар. *чильтэр,* ком. *челтир*, иске тат. *чылтар* (> мар. *чылдар, чындар*) «рәшәткә, штакет; агачтан уелган, уймырланган бизәк»; тат. диал. **челтәр,** башк. *селтәр* «тишекле чүмеч, чулпы; лампа куыгының патроны, самавыр утлыгы» ~ каз. *шілтер,* к.-калп. *шилтер* id.; к. ш. ук аз. (АДДЛ: 438) *чәлтари* «бәйләмләнгән челтәрле кәпәч» < фар. *чилтāрӣ* «челтәрле нәмәрсә» һ.б. Räsänen 1969: 108, 111.

**ЧЕЛТЕР I, челдер** «выделения из половых органов коровы перед отёлом» > мар. *цĕлдĕр*, чув. (Сергеев 1971: 115) *çĕнтĕр, чĕнтĕр, çилтĕр* id. (< тат. диал. **җилтер** id.)

**ЧЕЛТЕР II** – имитатив лёгкому звону цепочек, а также журчанию ручья ~ башк. *селтер* ← *чĕлт* (к.), чаг. ш. ук **чылтыр, шылт, шылтыр.**

Дерив.: **челтер-челтер; челтерт.** К. **Челтерә-ү.**

**ЧЕЛТЕРӘ-Ү, челтердә-ү** «журчать (о еле заметном ручейке); звенеть (о цепочке)» ~ удм. *җылтыртыны* id. ← **челтер II** (к.).

**ЧЕМ I** «стебелёк листка» ~ башк. *сем* id., башк., кырг., каз., к.-калп. *сым*, төркм., аз. һ.б. *сим, сым,* төр. *sim* «көмеш чыбыкчык (ювелирлык эшендә)» < фар. *сӣм* id. К. **Чемәр.**

**ЧЕМ II** «совершенно, чисто (о масти и т.п.)», например, *чем кара* «совершенно черной масти (о лошади)» ~ башк. *сем,* кырг. *чым* > каз. *шым* id. К. чыгт., төр. (Будагов I: 500) *чум* «чем», бор. төрки (ДТС: 146) *čim* «бөтенләй».

**ЧЕМӘР** «тонкий узор (проволокой)» ~ башк. *семәр* < фар. *сӣмк'āр, сӣмг'āр* «ювелир, ювелирлык; көмешче; көмешчелек» ← *сӣм* «көмеш; көмеш чыбыкча». К. **Чем I.** Д.Г. Тумашева (1992: 239) себ. **цимгәр** сүзен **чәмбәр** сүзенең варианты итеп күрсәтә. Бу дөрес түгел бугай.

**ЧЕМЕТ-Ү** «ущипнуть» > чув. *чĕпĕт-* id. < тат. диал. **чемте-ү** < гом. кыпч. *чымты-,* к. башк. *семет-, семте-,* нуг. *шымты-,* к.-балк. *чимди-,* кар. *чымда-, чымдыр-,* алт. *чымды-, чымты-* (к. Радлов III: 2104) «чеметү; чагып алу» һ.б. Төптә нигез (тамыр) – **чымты-у.** Тат. телендә бу сүз кабаттаркалыш кичергән, гүяки нидидер ***чем-ү** фигыленең

йөкл. юн. итеп каралган. Чаг. ш. ук мар. *чывышт-,* удм. *чепыльт-,* коми. *чепӧльт-* ~ венг. *csipni* «чеметү», рус. *щипать* һәм *щикать* «чеметү». К. **Чемче-ү.** Чаг. **Җентек.** Федотов II: 413.

Дерив.: **чеметеш-ү, чеметтер-ү; чемтек** (→ **чемтекләү** ~ гаг. *чимдик,* төр. *çimdik*) «чеметем», **чеметем.**

**ЧЕМЕЧКЕ** (Будагов I: 497; ДС I: 215) «болячка, пупырёчек» – **чемче-ү** (к.) белән баглы булса кирәк.

**ЧЕМЧЕ-Ү** «взять, брать предельно маленький кусочек, щепотку», диал. «щипнуть» ~ кырг. *чымчы-* (> каз., к.-калп. *шымшы-*) «чемчү» < **чымты-** (к. **Чемет-ү**) id. ономопоэтик яисә тәкълиди тамырдан булса кирәк.

Дерив.: **чемчен-ү**, (Будагов I: 497) **чимсен-ү,** себ. (Тумашева 1992: 237–238) **цемцен-ү** «чеметеп кенә ашау; җирәнү».

**ЧЕҢ** «песня-укор родителям девушки во время свадьбы» ~ башк. *сең,* кырг. *чың* «туй вакытында җырлана торган скабрёз (?) җыр». Ләкин тат., башк. сүзе **чәң I** (к.) белән баглы булса кирәк (кыз **чәң**дә уйнап җырлаган). К. ш. ук төр. *çengi* «кәләш кызны озатканда җырлана торган җыр».

Дерив.: **чеңләү** (башк. *сеңләү, сеңдәү*) «китәсе кызның эти-әниләренә үпкәләп җырлаган җыры» ← **чеңлә-ү. Чеңлә-ү** тәкълиди фигыле («нечкә тавыш белән җырлау») сүзе дә бар, ләкин **чеңләү** (йоласы) шуннан дип кистереп әйтеп булмый.

**ЧЕПИ,** (ТРС 1931) **чепек** «гноящиеся, слипающиеся (глаза)» ~ госм. (Радлов III: 1981) *чäлпiк* id. К. ш. ук башк. *сепек* id., *сепелдә-ү* «чепи күзләрен йомгалау», төр. *çipil* «чепи». Тәкълиди тамырдан (**чәлп, челп, чеп**) булса кирәк: бу сүзләр халык телендә ишетелә (конкрет фиксациясе юк).

Дерив.: **чепилек, чепилән-ү**. Элекке заманнарда чепи (трахомалы) күзләр бик еш очраган.

**ЧЕР** – имитатив чириканию, тонкому визгу ~ башк. *сер* id., чаг. **Чәр, Чыр.**

Дерив.: **чер-чер (итү); черелдә-ү, чер-черлә-ү; черелдек.**

**ЧЕРӘШ-Ү** (Исәнбәт I: 353; ТТДС I: 481) «изо всех сил упорствовать (в своем стремлении), перенапрячься» ~ башк. (БТДҺ: 274) *серәш-,* каз., ком. *сиреш-*, як. *чирэс-* id. К. ш. ук (ЛТ I: 169) **чырашмак** «бар тәкатьне сарыф кылмак» ← **черә-, *чира-,* к. алт. (Баскаков 1966: 165) *чир-* «тартышу, черәшү» ~ монг., бур. *шарга-*, яз. монг. *sirγa-* > маньч. (ССТМЯ II: 399) *чирга-* «көчергәнү; буылу, бөялү». **Черәш-ү** < *чергәш-ү* бугай.

**ЧЕРЕК** «гниль; гнилой, трухлявый» ~ башк. *серек* id. < гом. кыпч., алт. һ.б. *чирик, чириг* id. ← *чер-, чере-,* к. **Чере-ү.**

Дерив.: **черекле, черексез.** Парлы сүз: **черек-чарык** ~ чув. *çĕрĕк-çарăк* id.

**ЧЕРЕМ** «короткий сон; дрёма» > чув. *чĕрĕм*, удм. *чырым* < гом. кыпч., к. кырг., к.-балк. *чырым* (кар. *цырым* нуг., каз., к.-калп. *шырым,* башк. *серем*), төркм. *чирим*, үзб. (ЎХШЛ: 303) *чирм* id. Күпчелек төрки телләрдә бу сүз **ит-ү (эт-)** һәм **ал-у** фигыльләре белән генә кулланыла, тик үзб. сөйләшендә «*бер чирм гинә* йоклау» тур. сүз бара. Бу сүзнең деривациясе дә тар, к. тат. диал. **черемлә-ү** ~ к.-балк. *цырымла-* «йоклап алу», *цырымлан-* «миңгерәү». Безнеңчә, *черем* ~ *чырым* сүзе *челем* ~ *чылым* «төрепкә, тәмәке, наркотик» сүзе белән бердәй: каз. ар. сөйләшләрендә **челем итү** «черем итү» (без теркәдек. – *Р.Ә.*): элекке наркотиклар йокы даруы итеп кулланылган; к. ш. ук иске тат. (Радлов III: 2078) **чырым** «(наркотик) үлән төре» >> рус. *чирим* «паңгы һәм күкҗиләк төнәтмәсе – наркотик эчемлек», к. Аникин: 665.

**ЧЕРЕ-Ү,** диал. **чер-ү (черде, черә** диелә) «гнить, загнивать» < гом. кыпч., к. кар., кырг., алт., уйг., үзб. *чири-* (башк. *сере-,* нуг., каз., к.-калп. *шири-*), кр.-тат., төр., кар. (Радлов III: 2194–2196) *чүрү-*, чыгт., уйг. *чүри-*, төркм. *чүйри-, чүйре-* id. Бу сүзнең себ. (Тумашева 1992: 238) **цыры-у** варианты икенчел булса кирәк. Эвенк. *чири-* «исләнү», кор. *čirida-* «черү» сүзе белән чагыштырыла (Рамстедт), ләкин бу шикле, чөнки сүзнең тамыры **чүй-*. Федотов II: 111–112 (сүзнең дериватлары яктыртыла).

Дерив.: **черет-ү; черетке, черетмә, черемә (чертке, чермә** дип тә әйтелә вә языла); к. **Черек.**

**ЧЕРКИ,** диал. **черкәй** «комар; мошка» > удм. *чьрккэй, чиркэй*, мар. (Исанбаев 1978: 22) *чырки* id. < гом., кыпч., к. кар. *чирки, чиркы,* кырг., төркм. диал. *чиркей*, үзб. (ЎХШЛ: 312) *чьркәй* (> башк. *серекәй, серәкәй, серәгәй,* нуг., каз., к.-калп. *ширкей*) id. < *сиврикәй* ← тат. диал. (ДС II: 171) **сөйре** «черки, озынборын», к. иске тат., диал. (Троянский I: 463, 573) **сиүре чебен, черкәй чебен > черкәйчен** «черки» ~ ком. *чиркев җибин* id. ~ төр. *sivrisinek*,

гаг. *сиври синәк* (*синәк* «чебен») id. – һәр очракта «очлы (борынлы чебен)». Шулай итеп, **черки** < **черкәй ← сиврикей чибин** дигән тәгъбирдән эллипсис.

**ЧЕРТ** – имитатив (едва слышному) хрусту, звукам плевка сквозь зубы, чаг. **Чәрт, Чырт.**

Дерив.: **черт-черт; чертлә-ү → чертләт-ү;** диал. (ТТДС II: 350) **чертли, чертләмә,** ш. ук **чертләк, чертлек** «молния (каптырмада)».

**ЧЕРЧЕК I** к. **Чөрчек.**

**ЧЕРЧЕК II** (ЗДС: 746) «малорослый, слабый (о ребёнке)». Чаг. **черчеклән-ү** «вакчыллану», **черчекле** «җентекле, бик төгәл». Монда берничә (һәрхәлдә ике) сүз контаминациясе бар бугай. Чаг. **Черчет.**

**ЧЕРЧЕТ, черчек** (Г. Толымбай; ТТДС I: 481) «навязчивый, назойливый; мелочный; упорный в своем своеобразном стремлении», себ. (Радлов, Образцы… IV: 146) **чүрчүт** «упорный враг» ~ кырг. *чүрчүт* «кяфер, мәҗүси» асылда бор. төрки (ДТС: 158, 643) *čürčät, čürčit, ǯürǯät, ǯürǯit* «маньчжур халкы» ← *ǯürǯän* «маньчжур, җүрҗән» (русча *чжурчжень, чжурчжени* дип язылa) сүзенең монголча күп. формасы. Тарихи җүрҗәннәр төркиләр белән күп сугышкан маньчжур кабиләсе. Чув. *çĕrçĕn* «ефәк» бор. *җүрҗүн* «маньчжур, кытай» сүзеннән булса кирәк.

Ә. Исхакның «Каракаш батыр» дигән әкиятпоэмасында **черчет** гүяки татарларның бор. бабалары токымы итеп бирелә. Ул аны каян китереп чыгаргандыр – аңлашылмый.

Дерив.: диал. (ЗДС: 746) **черчетлән-ү, черчеклән-ү** «дошманчылыкта үҗәтләнү; чиктән тыш тырышу».

**ЧЕТ** (З. Бәшири), **чит** «тонкий ситец» < үзб., чыгт. *чит,* фар. *чӣт* < һинд. *čit, čint* «сыйфатлы чуар тукыма». Бу сүзгә рус. *ситец* сүзе (Европа телләре аша, к. Фасмер III: 628) тоташа. К. ш. ук **Чит II.**

**ЧЕТЕРЕК, четрек** «спутанный узел, клубок; запутанный; сложность, головоломка» ~ башк. *сетерек* id. – я **чытырык ← чытыр* (к. башк. – БҺҺ II: 227– *сытыр* «чуалган киндер буйлыгы»), я *чәттерек* < (төр.) *чаттырық* «аркылы-торкылы, өсте-өстенә салынган» ← *чаттыр-у ← чат-у* (к.) «өсте-өстенә аркылы-торкылы кую, чатмаштыру» сүзеннән. Тат.-башк. даирәсеннән тыш теркәлмәгән. Чаг. **Чечерекле.**

Дерив.: **четерекле, четерексез; четереклән-ү.**

**ЧЕҮ [чĕw]** (Тумашева 1992: 246–247) «лиственница; кедр». Безгә ачык түгел.

**ЧЕХАРДА** «чехарда, игра, где прыгают друг через дружку» (по определению Даля), ш. ук «шеренга». Будагов (I: 479) буенча, бу сүз аз. *чых арда* «чык артка» диелгән уен атамасыннан. Чаг. тат. әд. **шәкшәкәр** id., ихтимал, аз. диал. *чәкчәкәр* «чигендерелә барыр» сүзеннәндер (бу уенда берәү алдагысы өстеннән сикергәч, үзе артка баса, рәттәгеләр барысы да сикереп беткәч, ул алда кала – аның өстеннән сикерә башлыйлар. **Шәкшәкәр** (к.) фарсыча да ясала ала.

**ЧЕЧЕРЕКЛЕ** (ТТДС II: 482) «назойливый, настырный» – я **черчет** (к.) сүзеннән ясалган, я **четерекле** сүзеннән килә.

**ЧИ I** «сырой (о дровах и т.п.); недоваренный; неспелый» < гом. кыпч., к. кар. *ций, чий, цый, чый,* к.-балк., ком. *чий,* кырг. *чыйки* (> башк. *сей,* нуг. *ши*, каз. *шикі,* к.-калп. *шийки*), тув. *чиг,* төр. *çiğ,* хак. *чiг, сых*, төркм. *чиик* «чи» ~ як. *сиик* «чык; чи» < бор. төрки **чигиг,* к. монг. диал. *чигиг* id. Мисаллардан күренгәнчә, бор. төрки (ДТС: 145) *či* «чык, чи» иң бор. вариант түгел. Морфологик җәһәттән караганда, *чи-//чый-* дигән фигыль булган, шуннан *чиг//чыг* һәм **чигиг//*чыгыг* «чык; чыклы; юеш, чи» дигән сүз ясалган дип уйларга мөмкин. Чаг. эвенк. *чип-* «юешләнү, манчылу; бату». Räsänen 1969: 106; ССТМЯ II: 398.

Дерив.: **чилек, чилән-ү.** Элекке *чи башкорт* «күчмәче башкорт»ка *пишкан (пешкән) башкорт* «утрак башкорт» каршы куелып әйтелгән (к. Будагов I: 503). Бу сүз уйнату гына булдымы икән, әллә мондагы *чи* ~ башк. *сей* сүзенең бүтән мәгъ. булуымы икән – әйтүе кыен. К. **Чий I.**

**ЧИ II** «огрех в поле при вспашке и севе» > мар. (Исанбаев 1978: 38) *чий*, удм. *чип* (?) ~ башк. *сей*, (БТДҺ: 280) *сөй,* каз. (ҚТДС: 395, 402) *ши, шүй* id. Чаг. бор. төрки (ДТС: 583) *tsuj* < кыт. *цзуй* «гөнаһ эш».

**ЧИБӘР** «красивый; красавица», диал. (Будагов I: 467) **чибәр, чибир, цибәр** «чистый, опрятный; хорошо», (ДС I: 216) **чибер** «осторожно, тактично;

тактичный человек» (к. ш. ук: *Дауны чичән бетерми, чибәр бетерә,* Исәнбәт III: 371) > чув. *чипер,* мар. *цәвәр, чевер,* удм. *чебер* «матур; матурлык һ.б.ш.», морд. М. *цебярь* «шәп, уңай, нәфис; сәламәт; файдалы» < гом. кыпч. *чәбәр* «чибәр, матур; сәнгатьчә» (> башк. *сибәр,* нуг., каз., к.-калп. *шебер* id.), алт. *чебер,* хак. *сибер,* тув. *шевер* «җыйнак; сакчыл; илтифатлы», алт., уйг. (Радлов III: 1997) *чäбäр* «чиста; инсафлы», төркм. *чепер* «җыйнак, чисталыклы; оста», бор. төрки (ДТС: 142) *čebür* < бор. монг. *čeber* «матур», (Поппе 1938: 131) «телдәр, телдәрлек» < *čege-ber* «чисталыклы; саф» (*čege* «ак, пакь», *-ber* – аффикс), к. ш. ук як. (Пекарский: 3595) *чäбäр* «җыйнак, пакь», бур. *сэбэр* «матур, чиста, сәламәт» һ.б. Бу сүз төрки телләрдән күп күрше телләргә дә кергән, к. рус. *чебер* «чибәр, җыйнак, пөхтә кеше». Будагов I: 467–468; Räsänen 1969: 101; Аникин: 649; Федотов II: 420 (тагын параллельләр китерә, чув. сүзенең татарчадан икәнлеген әйтми).

**Чибәр** сүзе тат. диал. **Чилбәр** (к.) сүзе белән контаминациягә кергән.

Дерив.: **чибәркәй** (бу сүз аерымрак мәгъ. киң таралган, сыер кушаматы буларак очрый) > чув. *чиперке* id.; **чибәрлек; чибәрлә-ү, чибәрлән-ү.** Диал. (ЗДС: 747) **чибәрәй-ү; чибәрттәй < чибәр түтәй; чибәр җиңги.**

**ЧИБЕК, чебек** (ТТДС II: 348), диал. (З. Мансур) **чебек**, (ТТДС I: 466) **цебе** «тоненький, слабенький; хилый, болезненный (о детях)» ~ башк. (БТДҺ: 292) *сибек, сәбәк, сәбек* id. ~ себ. (Тумашева 1992: 247) **чийбек** «чеби, чебеш». Тавык чебиләренең чирләшкә булуларыннан, күпләп үләреннән чыгып, кешеләрне дә шуларга охшатудан булса кирәк. К. **Чеби.**

**ЧИГӘ I,** диал. (ТТДС I: 482) **чигәчә** «височные украшения, височная часть женской шапки» ~ башк. (БТДҺ: 276) *сикәлек, сикәсүк* id., к. **Чикә.**

**ЧИГӘ II** (Баязитова 1995: 98) «мера длины в два локтя» < чув. *чике* id., к. **Шекә**. Федотов II: 418 (чув. сүзен кырг. һ.б. *чыганак* «терсәк» сүзе белән чагыштыра, ләкин бу дөрес түгел).

**ЧИГӘРӘ** иск. «граница» ~ уйг. *чегәрә, чегирә,* үзб. *чегара* (> каз., к.-калп. *шегара*) id. < *чәк ара* «чик ара».

**ЧИГЕЛДӘК**, диал. (ТТДС I: 482–483; Хайрутдинова 1993: 42) **чикелдәк, чигендәк, цигәлдәк, цилдәк** һ.б. «печенье ромбической формы», себ. (Тумашева 1992: 236) **цәгәлтәк** «род баурсака», кас. сөйл. (к. Гордлевский 1927: 13–14) **чигилди'** «четырёхугольная площадка посреди поля, куда складывались кости жертвенных гусей» ~ үзб. (ЎХШЛ: 299) *чегелдек* «бавырсак» – асылда «чигелгән күмәч» мәгъ. булса кирәк, к. (ЗДС: 713) **цигем** «ритуаль күмәч өстенә ясалган бизәкләр». Гомумән, күрәсең, **чәгәлдәк < чәгәлдәк < чәгәлтәк** мәҗүси ритуаль ашамлык булган. К. **Челдәк, Чик-ү II.**

**ЧИГЕНТЕ** «отступление (от темы); исключение (из правил)» ← **чиген-ү. Чигенте** сүзе 1920 нче елларда ук кулланылган, ләкин онытылу сәбәпле аның урынына русчадан уңышсыз калька – **чыгарма** кулланыла башлаган. Ул **чыгарма** сүзенең математикада бөтенләй бүтән мәгънәсе бар.

Дерив.: **чигентеле, чигентесез.**

**ЧИГЕН-Ү** «отступать, отступить» < гом. кыпч., к. кырг. *чегин-* (> каз. *шегін-,* башк. *сиген-*) ~ уйг. *чекин-,* төр. *çekin* һ.б. id. ← *чәк-,* к. **Чик-ү I.**

Дерив.: **чигенел-ү** «чигенергә туры килү», **чигенеш-ү; чигендер-ү; чигенеш** һ.б. К. **Чигенте.**

**ЧИГЕР-Ү** «уступать в цене; снимать со счёта», диал. «пятить (лошадь)» – **чик-ү I** (к.) сүзенең аерым үзенчәлекле йөкл. юнәлешеннән.

Дерив.: **чигерел-ү, чигерт-ү, чигереш.**

**ЧИЕРТ-Ү [чийёрт-], чирт-ү,** диал. (Тумашева 1992: 239) **цирт-ү** «щёлкнуть, давать щелчок; играть на струнах»; күч. «стырнуть, красть; клюнуть» > чув. *чирт-* «тырнак белән чиртү; теш арасыннан төкерү» < гом. кыпч., алт., уйг. *черт-, чәрт-* (> нуг., каз., к.-калп. *шерт-,* башк. *сирт-*) id. Тат. яңгырашы икенчелме яисә борынгыракмы – ачык түгел. Һәрхәлдә бу фигыль имитатив нигездән булса кирәк, к. **Черт.** К. **Чикләвек.**

Дерив.: **чиертел-ү, чиертеш-ү, чирттер-ү; чиертеш, чиертешле** (уен төре), **чиертлек** («фишка, шашка» – чиертеп, урыныннан тәгәрәтергә тиешле фигура).

***ЧИЙ I [чёй],** себ. (Тумашева 1992: 238) **ций** «самый, что ни есть; точно; настоящий» ~ мар. *ци* ~ чув. *чи* «иң, чий». Г. Рамстедт (1957: 91) бу чув. сүзен бор. төрки *jeg* «яхшырак» сүзеннән дип аңлата, ләкин тат. параллеле бу фаразны шик астына куя. Чаг. ком. *чинк* ~ нуг. *шың* «иң, чий». Федотов II: 417 (тат. сүзен китерми).

**Чи** (башк. *сей*) **башкорт, чи мари, чи чуваш** сүзләрендә ошбу **чий** булса кирәк.

**ЧИЙ II [чӗй]** (Арсланов 1992: 152) «вид камышового растения и циновка из этого камыша» < гом. кыпч., алт., үзб. *чий* (> нуг., каз., к.-калп. *ший*) id. ~ уйг. *чиғ, чиг* id., шуннан *чиғлиқ, чиглик* «чий үскән җир» (к. **Челек**); аз. (АДДЛ: 446, 448) *чыг, чых* «вак камыш, шундый камыштан эшләнгән кипкер, челтәр һ.б.ш.»

**ЧИК,** диал. **цик, цәк**, себ. (Тумашева 1992: 246) **чәк** «рубеж; предел; граница» > чув. *чик, чике, чикĕ,* мар. Б. *чек*, мар. Т. *цик* < гом. кыпч. *чек [чэк]* (> нуг., каз., к.-калп., тув. *шек,* башк. *сик*), кар., уйг. *чәк*, үзб. *чекка*, төркм. *чәәк, чәәг* «чик (төрле мәгъ.)» ~ бур. *сэг* < **чэг* id. Räsänen (1969: 102–103); Федотов II: 419 (материалы аз).

Дерив.: **чикле, чиксез; чикләү, чикләнү**. К. **Чигәрә; Чике.**

**ЧИКӘ, чигә** «виски́, щека» < гом. кыпч. *чеке [чэкэ]*, уйг. *чекә* (> башк. *сикә, сигә,* нуг., каз., к.-калп. *шеке*), кар. *чегя, цэге*, уйг., кырг. (Радлов III: 1947) *чäкä*, үзб. *чакка,* төр. *şakak* id. ~ монг. *чикэ, чике, чихэ* «колак». К. ш. ук як. *чэчэгэй* id. Бу сүз «чәкүшкә» мәгъ. дә кулланыла, шуннан рус. *чека* (М. Фасмер бу сүзнең этимологиясе билгеле түгел ди). К. **Чигә I.**

Дерив.: **чигәчә** «чигә турысына тәңкәләр тезелгән бизәнү әйберләре»; **чикәләү** «яңаклау».

**ЧИКЕ, чикем, чәке, чикле, чәкле** «до, по» ~ диал. (ТТДС I: 521; Садыкова 1985: 96; Хайрутдинова 1985: 97) **чиңке, шәке, шәкле, шикле** һ.б. ~ башк. *сикле* ← **чик, чәк** (к. **Чик**). К. Махмутова: 223, 228. Бу сүзләрдә **тике, тикле** һ.б. белән контаминация сизелә. Гомумән, **чик ~ тик** сүзләре үзләре генә дә **тикле** мәгъ. кулланыла (*шул тикле ~ шул чик*).

**ЧИКЕРТКӘ** «стрекоза; сверчок; саранча; кобылка» ~ башк. *сиңерткә,* кар. *чэгирткэ, цэгирткэ, чегиртκя,* кырг. *чегиртке,* алт. *чäгäртки* (> каз., к.-калп. *шегиртке, шегіртке,* нуг. *шегертки*), үзб. *чигиртка,* чыгт., бор. төрки (ДТС: 143) *čekürgä,* төр. *çekirge*, бор. чыгт. *čeürtke* ~ монг. *čü'ürtken* id. (к. Поппе 1938: 161), иске сүзлекләрдә *чекүркә, җекүртгү* ~ төркм. (Мухамедова 1973: 188) *чекиртге* «саранча» һ.б. (к. Радлов III: 1948, 1950, 1957–1958, 2080–281) – имитатив ясалма, аның төгәл тамырын да билгеләү читен, һәрхәлдә *чең ~ чиң, чың* тамырыннан, **чеңер-чеңер, чиңир-чиңир, чыңыр-чыңыр** «чикерткәләр авазына имитатив» сүзеннән дип чамалап була, к. башк. (БҺҺ II: 209) чикерткә *сырылдап сиңеректәй* (~ *чырылдап чиңерекли*), алт. *сеңирткеш* «чикерткә». Кечкенә хайванат атамаларында *-ртқа//-рткә* аффиксы еш кына очрый, к. **Кәсәртке.** Чикерткәсыман бөҗәк атамаларында *ч* һәм *р* авазлары булу да характерлы, к. тат. (ЗДС: 743) чикерткә **чегерди** ~ рус. *сверчок сверчит,* һинд. *čiraka* «чөрчек».

**ЧИКЛӘВЕК [чикләwӗк]** «орех» < диал. **читләwӗк,** (ДС I: 218) **читлаwык,** (Зимасов: 111) **чәтләүек** ~ башк. *сәтләүек* < куман. (Радлов III: 1984) *чäтлäук* > кар. *цетлявук, четлевик, чэтлэвик, чэтлэвич*, к.-балк. *чертлеўюк* (> нуг. *шетлевик*) «гади урман чикләвеге» ← *чэртлә-* тәкълиди фигыленнән, тәүдә, ихтимал, бу сүз чикләвек ваткычны белдергәндер, к. иске тат. (Троянский I: 435) **чатлаwык** «тиски, эскәнҗә». К. ш. ук төрки чыгт. (Будагов I: 453) *чатлағуч* «пестә» ← *чатла* – «чыртлау, шартлау, чатнау»; каз. (ҚТДС: 368) *чекілдек, чекілдеуік, шекілдәуік* «көнбагыш». Сүзнең тамыры, әлбәттә, *черт ~ чәрт ~ чарт* имитативы. Тат. әд. нормага *чикләвек* (*-к-*) яңгырашы очраклы рәвештә (берәр язучының җирле сөйләшеннән) кереп киткән. Сөйләшләрдә чикләвекне **чики** дип атау да бар.

Дерив.: **чикләвекле, чикләвеклек.**

**ЧИКЛЕ** (ТТДС I: 483) «до». Бу сүз тат. телендә **чик** сүзеннән ясала ала. Ләкин һәрхәлдә **чаклы, тикле** сүзләренең тәэсире юк түгел. Моны **чәкле, чәке ~ чике** (к. ТТДС I: 483, 500) вариантлары дәлилләп тора, чаг. **тәке ~ тике** id. id.

**ЧИКМӘН,** диал. (миш., себ. ) **цикмән, цәкмән** «грубое сукно из верблюжьей шерсти» < гом. кыпч., к. кырг., алт. *чекмен,* үзб., уйг., төркм. диал., чыгт. һ.б. *чәкмән, чәкман, чэкмэн* > башк. *сикмән*, (БҺҺ II: 229) *сәкмән,* нуг., каз., к.-калп., тув. *шекпен*, төр. (Zenker: 319) *čikmen* id. гадәттә гом. төрки (төр. һ.б.) *чәк-* «кию, өстенә тарттыру» фигыленнән ясалган дип исәпләнә, к. Räsänen 1969: 103. Бу фаразны тат. (ТТДС II: 352) **чикмәк** «халат, җилән» сүзе дә раслый кебек. *Чәк-* күпмәгънәле сүз, һәм *чикмән* «чигелгән, каелган кием» булуы да ихтимал. Чаг. себ. (ЗДС: 708) **цәгәнле** «чигелгән (кием)».

**Чикмән** сүзе белән беррәттән тат. диал. (Троянский I: 434; ТТДС I: 485) **чебкән, чипкән** < бор.

кыпч. **чәпкән* ~ к.-балк., ком., кырг., алт. *чепкен* (> тув. *шепкен*), госм., алт. (Радлов буенча) *чäпкäн,* аз. (АДДЛ: 437) *чәпкән, чәвәкән* «хатын-кыз җиләне, ябынчасы» сүзе дә бар һәм аны *чикмән ~ чәкмән* сүзеннән метатезаланып килеп чыккан дип карыйлар. К. ләкин калм. *tsemgn* < иске монг. *čemgen* ~ яз. монг. *čengbe, čengme* ~ маньч. (ССТМЯ II: 420) *чәңму* «чикмәнлек тукыма, тула». К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 143) *ček* «чикмәнлек тукыма», фар., көрд. *çek* «өске кием, хәрби амуниция», *čekbend* «тулы хәрби форма». Өстәвенә тагы к. **Сукман.** Монда, күрәсең, берничә сүз контаминациясе күзәтелә.

**Чикмән** ~ *чәкмән ~ чэкмэн* күп күрше телләргә үтеп кергән: мар. диал., удм. диал. *чикмен,* фар. *чекман* һ.б. Будагов I: 482 (тат.-башк. чикмәне тасвирлана); Федотов II: 22 (*чикмән* һәм *сукман* сүзләрен бердәй дип карый һәм хаклы рәвештә аларның рус-слав. даирәсеннән килү ихтималын кире кага); рус. *чекмень* тур. Аникин: 510, 652–653 (бай әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **чикмәнле, чикмәнсез; чикмәнлек.**

**ЧИКМӘР** (ЗДС: 741) «мешок с ремешком» – чаг. бор. төрки (ДТС: 143) *çek-* «капчык бөрмәсен тарттырып бәйләү».

***ЧИКНӘ-Ү, *чәкнә-ү** ~ себ. (к. Тумашева 1992: 246) **цәкнә-ү** (~ мар. Т. *цäкнä-*) «осаживаться; отступить на шаг или на несколько шагов» > удм. *чигнаны, чигналляны* id., *чигнатыны* «чикнәтү» һичшиксез ← **чик- ~ чәк-** «чигү, тарту һ.б.». Ясалышы ачык түгел, ихтимал, ***чикен < чәккин** дигән исем сүз булгандыр. К. түбәндәгене.

**ЧИК-Ү I (чигү, чикте),** миш. **цик-ү** «отступить; нести тяжелую ношу (күч. мәгъ.), переживать (определённое состояние)», диал., иск. «уступить в цене; потерять ценность, достоинство», диал. (ДС III: 482) «курить» < гом. кыпч. *чек-, чэк-* (> башк. *сик-,* нуг., каз., к.-калп. *шек-,* тув. *шэг-*) ~ кр.-тат., чыгт., уйг., госм., төр., аз. (Радлов III: 1945) *чäк-* «тарту, суыру; чабу, селтәү, төю; дәвам итү, озакка сузылу; буяу, буялу; хисаплау, үлчәү; кичерү; күчерү; түзү; чиертү; өтерге, ышкы һ.б.ш. белән эшләү» – төрки телләрдә иң күп мәгънәле сүзләрнең берсе; гомумән, аның мәгънәләренең күпчелеге **тарт-у** (к.) сүзенекенә тәңгәл (**тарт-у** фигыле исә *чәк-* актив кулланылган телләрдә сирәк кулланыла); тат. әд. телендәге кайбер фразеологизмнарда **тарту ~ чигү** бер-берсен алмаштыра: *азап тарту ~ азап чигү; аһ тарту ~ аһ чигү;* к. ш. ук *тартыну ~ чигену* һ.б. Чув. *чак- (< чәк-)* «кимү, кыскару; чигенү» (~ мар. *цäк-, чäк-, чак-* id.) сүзе дә гом. төрки, угыз. *чәк-* сүзенең аерым мәгънәләрен генә саклый. К. **Чик-ү II**. Будагов I: 482; Räsänen 1969: 102; Федотов II: 386.

Дерив.: **чиктер-ү.** К. **Чиген-ү, Чикнә-ү.** Чаг. **Чик.**

**ЧИК-Ү II (чигү, чикте)** «вышивать» ~ башк. *сик-* id. ← **чик-ү I** фигыленнән аерымланган, к. бор. төрки (ДТС: ) *ček-, čäk-* «пунктирлау, сызым сызу» >> хак. *сиг-* «сызыклау, сызык сызу», *чеек* «чигүнең бер төре» [**чэгэк*], алт. диал. (Радлов III: 2111) *чиик* «сызык, линия» (бу сүз **чый-у** сүзеннән дә була ала). Бу **чигү** сүзе, ихтимал, фар. *кäшӣдäн* «тарту; чигү чигү» сүзеннән калькадыр, чаг. **чәкән**. Räsänen 1969: 102.

Дерив.: **чигел-ү, чигеш-ү, чиктер-ү, чигеш,** диал. **чигем.** К. **Чикнә-ү.**

**ЧИКЫЛ-ЧИКЫЛ, чыкыл-чыкыл** – имитатив визгу мышей и т.п. животных (**чикыл-чикыл, чыйк-чыйк** – полное имитативное «описание» звуков, издаваемых встревоженными мелкими животными) > башк. *сикыл-сикыл* id.

Дерив.: **чикылда-у, чыкылда-у** «чинаган тавыш белән авыр хәлеңне белдерү» → **чикылдаган (чикылдап торган)** «ап-ачык; үтә. бик; отъявленный»; **чикылдык** «һәрвакыт зарланып, шаулап, елап ризасызлыгын күрсәтү – хатын-кыз һәм балачага тур.».

**ЧИКЫТ, чыйкыт** «хворый; жалующийся на боли» ~ башк. (БҺҺ II: 208–209) *сикыт,* диал. *сикырт, секерт* һ.б. id., к. **Сикыт.**

**ЧИЛ,** диал. **чәл, чел** «мездра; белый жир на плеве, грудобрюшной перепонке», себ. (Тумашева 1992: 236, 238) **цәл, цилён** «послед» < гом. кыпч., к. башк. *сил, сел,* кырг. *чел [чэл]* > каз. *шел* id., үзб. *чел, чал* «кипрән, сүрү», төр. диал. *çel,* алт. диал. *чäл* «йомырка һ.б. элпәсе», чыгт. (к. Будагов I: 202) *чäл* «пәрәвез; пәрәвезгә эләккән чебен». Räsänen 1969: 193 (материалы күп очраклардагы кебек безнекеннән азрак).

**ЧИЛӘБЕ** «Челябинск» ~ башк. *Силәбе* – миш. (Ульяновск, без теркәдек. – *Р.Ә.*) **чиләбе, циләбе** «низина, непроточный бассейн (естественный или искусственный), куда стекает вода» < фар. *чäл āби* «су чокыры; буа» (*чäл, чал,* таҗ. *чил* «чокыр; буа»,

*āб* «су»). К. ш. ук каз., к.-калп. (ҠТДС: 392) *шел,* төркм. *чил* «дөге басуы; дөге басуының дүрт ягасыннан өелгән туфрак, бруствер» (дөге берничә ай су эчендә үсә һәм аны үстерү өчен махсус **чиләбе**ләр ясыйлар). Чаг. **Шил.**

**Чиләбе** каласын Котлымөхәммәт Тәфкилев (Тевкелев, «Тәфтиләү») башчылыгындагы йомышлы мишәрләр нигезләгән.

**ЧИЛӘК,** диал. (миш., себ.) **циләк** «цилиндрический сосуд из цельного дерева; ведро» > чув. *чилек*, манси. *čilăx* id. ~ себ. (Дмитриева 1981: 196) **цэләк, цәләк** «чиләк» < гом. кыпч., алт., чыгт., төркм. *челек* (> башк. *силәк,* кар. *целек, целяк,* нуг., каз., к.-калп. *шелек*), үзб. *челак* «чиләк; дадан умарта; тәгәрмәч бүкәне», уйг., чыгт., госм. (к. Радлов III: 1971) *čäläk,* к.-балк. диал. *цäлäк* «чиләк», гаг. *челек* «сөт чиләге; патша бүреге, цилиндр бүрек». Н.А. Томиловның «Этнография тюркоязычного населения Томского Приобья» дигән китабында (Томск, 1980: 191) **чигләк** яңгырашы китерелә.

Сүзнең ясалышы-чыгышы безгә ачык түгел.

**Чиләк ~ чәләк** сүзе төрки телләрдән күп күрше телләргә кергән, к. рус. диал. (Фасмер IV: 326, 362) *челек, чиляк* «чиләк төре», фар.-таҗ. *чäлäк, чалак* «чиләк; зур банка», лезг. (Дагстан телләрендә гомумән) *челег* «чиләк» һ.б. Räsänen 1969: 104. Тат. сөйләшләрендә, **видра ~ бидра ~ бидр**әдән аермалы буларак, **чиләк** – һәрвакыт агач савыт.

Дерив.: **чиләкле, чиләксез; чиләклә-ү** (→ **чиләкләп**), **чиләклек** (төрле мәгъ.), **чиләкче.**

**ЧИЛӘН-Ү** «замучиться» ← **чиялән-ү** (к.) булса кирәк. Төр. *çilelen-* «азаплану, интегү» сүзе белән охшашлыгы очраклы.

**ЧИЛБӘР** (Balint: 96) «красивый, изящный» << монг. *сийлбэр* «орнамент, бизәк» ← *сийлэ-* «агач уеп бизәкләр ясау» (Дондуков: 31) < бор. монг. *seile- ~ seilü-* id. Шулай итеп, тат. телендә мәгъңәләре охшаш ике сүз – **чибәр** һәм **чилбәр** – бар; аларның уртак иҗеге **-бәр** – монгол аффиксы.

**ЧИЛТӘН** «сорок святых, управлющих миром; один из них» < фар., таҗ. һ.б. ир. телләрдә *чилтäн, чилтане* (аны «кырык тән» дип тә, *кырык данә* дип тә аңлаталар) id. *Чилтән*гә охшаш мифологик образлар Кытай халыкларында да, төркиләрдә дә бар (төрки **кырык кыз** диелә). Мөселман мифологиясенә катнашы юк. Ясәвидә (2–3 хикмәтләрдә).

*Өч яшемдә чилтән килеп хәлем сорды,*
*Унсигездә чилтән берлән шәраб эчтем.*

Чилтәннәрне *гаиб ирәннәр* белән тиңләштерәләр.

**ЧИМ** иск., диал. (Тумашева 1992: 244) **цым** «трава (на хлебном поле)» ~ кырг. *чым* > нуг., к.-калп. *шым*, уйг., үзб. *чим* id. Чаг. **Чәмән.**

**ЧИМАЙ,** (Будагов I: 508) **чимәй,** себ. (Тумашева 1992: 238–239) **цимәй,** миш. (ЗДС: 709) **цәмәй** «резьба, насечки (на седле)»; «орнамент (на хлебе)», (ТТДС I: 484, 496) **чима, чыма** «резец; огниво» ~ алт. *чимэ,* кырг. (Будагов I: 450) *җимай* «кискеч; чимәй», кар. *цэмэ-* «күмәч-тәмәч өстен тишекләр, сызыклар белән бизәү», *цэмэвэц* «бизәкләвеч», каз. *шымай* «аркылы-торкылы сызыклар» < кыт. *цзы-ма,* бор. кыт. **цзы мак* «иероглиф язу; бәйрәм ашамлыгы өстенә изге теләкләр белдергән иероглифлар сызу» (*цзы* «иероглиф; язу». К. **Чый-у.**

**ЧИМЕК,** диал. (ТТДС I: 480) **чемек** «семик, христианский праздник воскресения» ~ чув. *çимĕк*, мар. *семык*, удм. (Насибуллин: 139) *с'эмык* id., ш. ук «труйчын; кече сабантуй һ.б.» < рус. *семик* id.

**ЧИН** «чин» < рус.; ләкин рус сүзенең этимологиясе бәхәсле – аны төрки телләрдән диючеләр бар. «Бүзьегет» дастанындагы карчыкка әйтелгән *Хан сәңа, моны үлтерсәң, чин бирәдер* җөмләсендәге *чин* сүзе русчадан булуы сәеррәк.

Дерив.: **чинлы (чинлылык), чинсыз.**

**ЧИНАК** (Тумашева 1992: 247) «круглая чашка» – **Чанак** (к.) белән гомоген булса кирәк.

**ЧИНАР** «чинара» < фар.-таҗ. *чäнар, чинар* >> рус. *чинара.*

**ЧИНА-У** к. **Чыйна-у.**

**ЧИНТ, чент,** себ. (Тумашева 1992: 239) **цинт** «переплёт (книги)» – Л. Будагов (I: 489) фикеренчә, **җилд** (к.) сүзеннән үзгәргән. Бу сүз элекке нәшрият терминологиясендә киң кулланылган. Кызганычка каршы, элекке татар китапчылык терминологиясе онытылган һәм ул өйрәнелми дә.

Дерив.: **чинтче** «китап төпләүче», **чинтлә-ү** «китап төпләү» (бу сүзләр Л. Будаговта бирелә).

**ЧИҢГЕЛЧӘК, чәңгелчәк** (ЗДС: 738) «колыбель, люлька (с холщовым дном)», себ. (Тумашева 1992: 189, 236) **сеңелцәк** «таган», **цәңгелцәк, цәңкелцәк** «колыбель» ~ башк. (БТДҺ: 294) *сәңгелсәк* id. ← **цәңкел-ү < чәңкел-ү** «мәтәлчек атыну», күрәсең, ш. ук «тирбәлү», к. ш. ук диал. (ТТДС II: 272) **сәнсәк** «силлә (пружина) урынына кулланыла торган ныклы колга (шуңа бишек эленә)» < **сәңгелсәк*. Чаг. монг. *цэнгэл* < яз. монг. *čenggel* «күңел ачу, уйнау-көлү». Элекке заманнарда таганда атыну еш кына бердәнбер күңел ачу чарасы булган. К. ш. ук **Сәленчәк.**

**Чиңгелчәк** – **чиңгел* сүзенең кечерәйтүле формасы булса, **чәңгелдәк** (к.) *чәң* имитатив тамырына *-елдәк* кушымчасы ялганып ясалган.

**ЧИПИЧЬЯ, чибичья, чибитья** (Даулей. Святки у крещёных татар // ИОАИЭ, XIX. Казань, 1903: 196–203), миш. **чип-чип** «святочные игры» – рус. диал. *святиться, святья* id. сүзләреннән, миш. вариант рус. попларының шул чорда (яңа ел бәйрәмендә) шайтаннарны куып *свят, свят* дип йөрүләреннән (көлеп әйтелгән). К. ш. ук (ЗДС: 745) **чепчинә** – керәшеннәрдәге сөмбелә бәйрәме < рус. *святынцы* id.

**ЧИР,** (Зимасов: 112) **чире,** миш., себ. **цир** «хворь, болезнь» > чув. *чир,* мар. *цер, чер* id., удм. *чер* «йогышлы авыру» < гом. кыпч. *чер* (башк. *сир,* нуг., каз., к.-калп. *шер*) «чир, кайгы», аз. *чәр* «чир», чыгт. *чир* «чуан, җәрәхәт», бор. төрки, алт. (ДТС: 144) *čer* «кату», төр. *çer, cör* «чир; тикән, чәнечке; шайтан», як. *чэр* «сөял, чуан», хак. *сірле* «калтырау, бизгәк; сарку», алт. (Будагов I: 504) *чеер* «чәчәк чире» һ.б. (уйг., угыз телләрендә сирәк очрый). Räsänen 1969: 105; Федотов I: 420.

Дерив.: **чирле, чирсез; чирлә-ү** (күрше фин-угор һәм күп төрки телләрдә параллельләре бар). К. **Чиркен, Чирләшкә.**

Рус. *чирей, чирий* «чуан» сүзен тат. теленнән диюгә М. Фасмер (IV: 365) каршы.

**ЧИРАК, чыйрак,** себ. (Тумашева 1992: 243) **цыйрак, цыйрау** «крепко сученый, крепко скрученный; выносливый, толковый, терпеливый» < гом. кыпч., к. кырг., алт. *чыйрақ, чыйырақ* (> башк. *сирақ, сиралқы* нуг., к.-калп. *шыйрақ,* каз. *ширақ*), тув. *шыырах* > хак. *сыырах* ~ яз. монг. *čigiraγ* (> бур. *шиираг*) id. ← **чира-у** (к.). К. ш. ук төр. *çire* ~ фар. *чире* «чирак», аз. диал. (АДДЛ: 460) *жыврах* «җитез, өлгер» һ.б.

**ЧИРАТ,** диал. (ТТДС II: 354) **чирут,** себ. (Тумашева 1992: 237) **цәрәт** «очередь, черёд» ~ башк. *сират,* мар. *черот, церот*, удм. *черод*, чув. *черет* id. Рус. теленнән төрле сөйләшләрдә мөстәкыйль рәвештә алынган.

Дерив.: **чиратлы, чиратсыз; чиратла-у, чиратлаш-у; чираттагы.**

**ЧИРА-У, чыйра-у** «затягиваться льдом или плёнкой (о бульоне и т.п.); скручиваться» ~ алт., кырг. *чыйыра-* (> башк. *сира-,* нуг., к.-калп. *шыйра-,* каз. *шира-*) «чирау (башлыча җеп тур.), чирату» – бор. төрки (МК, ДТС: 147) *čïγ-* «бәйләү, төенләү» сүзенең дәвамлы интенсивлык формасы (*чыгра- > чыйра-*). Чаг. к.-калп. *шыйыр- < чыйыр- *чыгыр-* «җеп кату», бор. төрки (ДТС: 148) *čïγïr-* «тыгызлану».

Дерив.: **чирал-у, чират-у** «былчырак туңып ката башлау, су өсте туңу». К. **Чирак.**

**ЧИРАХМАН** (ТТДС I: 486) «стебель лопуха; разветвлённый стебель некоторых высоких травянистых растений», иск. «семисвечник» << төр. (TS: 21) *çıraktan* «тармаклы шәмдәл» ← **чырак** (к.). **Чыракман** < фар. *черāғбани* дип пыяла шарлар тезелгән бизәк-ботакны да атаганнар. Шуннан тат. **чирахман** «(ява торган) боз».

**ЧИРӘМ,** диал. (ТТДС I: 484) **чиләм** «лужайка; дёрн» ~ башк. *сирәм, сиҙәм* id. > чув. (Сергеев 1971: 113) *çерем, çейрем* > мар. *сирем* id. ~ мар. *шерем* «тапталган болын; чабынлык, печәнлек», каз. (ҚТДС: 384, 393) *шәрім* «үләнле җир», *шерем* «басуда сөрелмичә калган җир» ~ төркм. (ТДГДС: 204) *ширәм* «үзән урталыгындагы калкулык (андый урында үлән үскән)», *ширем* «язгы сулар эзе (шунда да үлән үсүчән)» ~ бур. *шэрэм* «язгы үлән» >> як. (Пекарский: 2240) *сірäм, сірäн* «чирәм». К. ш. ук мар. *сäран* «печәнлек җир» (тик бу сүзне бүтән тамырлардан чыгып та аңлатырга була). Безнең материал төзек системага урнашып бетми: төркм. телендә, мәс., сүз *ч-* авазына башланырга тиеш иде һ.б. Чаг. иске төр. (Özön: 142–143) *çera* «үлән», *çeramin, cram* (барысы да фарсы) «чирәм, үлән». Räsänen 1969: 105; Федотов II: 102 (бик кыскача).

Дерив.: **чирәмле, чирәмсез; чирәмлек.**

**ЧИРӘП,** диал. (ТТДС I: 467, 486, 502) **цирәп, чәрәп** «глиняный, керамический; красная глина; черепок; горшок; черепица» ~ башк. *сирәп,* куман. *čirep,* кар. *цэрэп, цäрäп,* гаг. *череп* id. ~ венг. *scerep*

«чүлмәк; чирәп», рус. *череп* «баш сөяге», төп мәгъ. «чүлмәк» (шуннан *черепица, черепок*), чаг. тат. мәкаль: *Беркемнең дә чүлмәге-чирәбе буш түгел* «беркемнең дә башы кайгы-борчулардан азат түгел» мәгъ. Рус-слав. сүзен прус. *kerpetis,* бор. һинд. *karparas* «баш сөяге; чирәп, кабырчык» сүзләре белән чагыштыралар, к. Фасмер IV: 341. К. ш. ук **Керәч, Ташбака, Череп.**

**ЧИРБЕК, чирбик** (Ш. Камал; ТТАС III: 430) «шнурующиеся сапоги» < рус. *черевик, черевички* (гом. слав. параллельләре белән) «күн ката, башмак». Рус этимологиясендә праславян *červi* «тире кисәге» сүзеннән дип аңлатыла, к. Фасмер IV: 336–337.

**ЧИРЕК** «четверть» > чув. *чĕрĕк*, мар. *чырык, чĕрĕк,* удм. *черык* < гом. кыпч. *чэрэк, чэрик* (> башк. *сирек,* кар. *цэрик*, нуг., *шерик*, каз., к.-калп. *шерек*) һ.б., уйг. *чарәк,* үзб. *чойрак*, госм. *чäйрäк* һ.б. < фар. *чāр йәк, чäһāр-у-йäк* «дүрт тә бер, дүрттән бер». Федотов II: 415.

**Чирек** сүзенең конкретлаштырылган мәгъ. бар, мәс. тат. «аршынның, кадакның дүрттән бер өлеше», «бер чиләк (сыеклык үлчәме)» – батманның дүрттән бер өлеше булса кирәк һ.б.

Дерив.: **чирекле** (шешә), **череклек**; **чирекләп** һ.б.

**ЧИРЕП** «крепкий, твердый» к. **Ширеп.**

**ЧИРКАН-У**, (Троянский I: 466 һ.б.) **чиркән-ү** «содрогаться, бояться воды (перед купанием), испытывать омерзение» ← **чыйрка-, *чиркә-* фигыленең кайт. юн., к. башк. *сирҡан-, сиркән-, сикән-* id., к.-балк. *чирки-*, нуг. *шийке-* «бизү; нәфрәтләнү», ком. *чирки-* «өтелү», як. *сиргэн-* «чиркану». К. ш. ук кырг. *ичиркен-* «чиркану». Тәкълиди гом. төрки тамырдан булса кирәк. Будагов I: 473–474) **чиркәнмәк** «гнушаться» сүзен фар. төр. *чирк* «эрен; былчырак, пычыргы» сүзе белән баглый. К. **Чиркен.** Чаг. **Җыер-у** (?), **Ысырган-у, Ытырга-у.** Чаг. ш. ук **Җирән-ү.**

Дерив.: **чирканыл-у, чирканыш-у, чиркандыр-у; чиркангыч, чиркандыргыч; чирканыч; чирканчык** (ш. ук **чиркәнел-ү, чиркәнчек** һ.б. палаталь вариантлары да еш очрый).

**ЧИРКӘҮ [чиркәw],** диал. (ЗДС: 714, 753) **чиркау, циркау** «церковь» ~ башк. *сиркәү,* чув. *чиркү, чиркүү,* мар. *чэркэ, чэркö,* удм. *черк* < рус. *церковь* ← бор. рус. *цьркы* id. – грек теленнән, *κυρικον* «хуҗаныкы, тәгаләнеке» сүзеннән (шуннан рус. *кирха* «католик чиркәве» һ.б.). Фасмер IV: 300; Федотов II: 420–421.

**ЧИРКЕН,** иск. **чиркин** «омерзительный» ~ куман., кр.-тат., кырг., кар., төркм., гаг. *чиркин, чыркын*, төр. *çirkin* (> каз., к.-калп. *ширкин*) ← *чирки-, чыркы-* (к. **Чиркан-у**); арытабан ачык түгел, к. бор. монг. *čegür* «җирәнү хисе, нәфрәт», тув. *чииртен* «чиркәнеч», *ческин-* «чиркәнү», *ческинчек* «чирканучан».

**ЧИРЛӘШКӘ** «болезненный; хилый» ~ башк. *сирләшкә,* чув. *чирлешке*, мар. *черлашка* ← **чирләш-ү* ← **чирлә-ү** (к. **Чир**); ясалышы белән чув. теленә аеруча хас. *-шка, -шке* аффиксына беткән сүзләрне хәтерләтә.

Дерив.: **чирләшкәлек; чирләшкәлән-ү.**

**ЧИРМӘ, черемә** (ТТДС II: 349, 354) «сбор продуктов и вещей для проведения сабантуя» к. **Чәрмә.**

Дерив.: **чирмәче** «сабайтунга әйбер, азык-төлек һ.б.ш. җыючы».

**Черемә** варианты (язгы чәчү вакытында «игеннәр уңсын» дигән мәҗүси магия буенча җиргә йомырка ташлау, күрәсең, җир иясенә корбан бирү) **чирмә ~ чәрмә** «күн букчай» сүзен халык этимологиясенчә *черү* фигыленә нисбәтләүдән килеп чыккан – чөнки ул корбанлык йомыркалар *чери.*

**ЧИРМЕШ** > башк. *сирмеш* «мариец, мари» – Хәзәр ядкәрләрендә X г. бирле билгеле этноним; *цармис* ~ чув. *çармăç,* бор. яңгыраштa *чәрмиш,* рус. *черемисы* вариантына караганда **чәрәмис, чәрәмиш ~ чэрэмиш,* мари галимнәре фикеренчә, *черемось, чэрүмось* дигән варианттан килә һәм бу сүз күрше төркиләр (болгарлар, бор. татарлар) теленнән таралган. Марилар үзләрен *чирмеш ~ чәрмеш* дип атамаганнар диләр. Күптәннән килгән фикер буенча, *чэрү-мось* «гаскәр (чирү) кешесе» дигәннән, имеш. Ләкин әгәр *чере ~ черү* өлеше чыннан да төрки *чирү ~* бор. төрки *чэриг* «гаскәр, солдат; саклану (оборона)» сүзеннән килсә, бу сүзнең тамыры *чэр-, чэрэ-* «фронт тоту» фигыленнән *чэрэмиш* «фронт тотучы» сүзе дә ясала ала. *Чирмеш ~ черемись* сүзенең **Чирмешән ~ Чәрмәсән** дигән елга исемнәренә охшашлыгы да фикер уята. Гомумән, барча мәзкүр фаразларның ышандырырлыгы уртача. Четкарев 1953: 107–131; Фасмер IV: 338–339; Черных 1980: 36–40; Гордеев 1964. Фразеологизм: **чирмеш аты** «ашамыйча эшләүче».

**ЧИРМЕШӘН** «река Черемшан» – бу чагыштырмача зур гына елга бор. заманнарда (һәрхәлдә X г.) Болгарстанның көньяк чикләрен билгеләгән һәм шунлыктан, ихтимал, бор. төрки *чәр-* (к. **Чәрек**) «тезелеп каршы тору, фронт тоту» сүзе белән баглыдыр (ягъни «чик елгасы» мәгънәсендәдер). К. ш. ук югарыдагыны. Чаг. **Чәрмәсән.** Гарипова 1998: 334–337 (**Чирмешән** гидронимын *сармат* этнонимы белән чагыштыру очрагын күрсәтә – безнеңчә, бу артык тәвәккәл фараз).

**ЧИРТ I, цирт** (ТТДС I: 267, 286) «нарезка, пазик», (ЛТ I: 175) **чират** (?) «черта, рез» < *черта* ~ бор. рус. *чьрта* id.

**ЧИРТ II** (ТТДС II: 354) «игра с чёрточками» < рус., әлбәттә.

**ЧИРТМӘ** (ТТДС I: 486), **чертмә, черетмә,** башк. (БТДҺ: 274) *серетмә, сертмә* «целина, вспаханная на второй год; залежь» ~ чув. *çĕртме* «парга калдырылган җир, такыр басу; икенчеләй сөреп чәчү» ← **черет-ү** ← **чер-ү** (к.) сүзеннән булса кирәк. Шуның белән бергә бу **чиртмә ~ чертмә** сүзенең бүтән тамыры булу ихтималы да юк түгел.

**ЧИРТ-Ү I** «дать щелчок; щёлкать, грызть семечки, орехи и т.п.» < гом. кыпч., к. алт., кырг. *черт-* (> башк. *сирт-,* нуг., каз., к.-калп. *шерт-*) «чиртү», к. **Чиерт-ү.**

Дерив.: **чиртел-ү, чиртеш-ү, чирттер-ү** («чәлдерү, урлап алу», ш. ук «кылану» мәгъ. кулланыла); **чиртеш, чиртешле** (уен төре); **чиртке** («уенда таякчык»).

**ЧИРҮ,** (ЗДС: 753) **чиреү** «войско (не свое), полчище; множество людей, масса (в одном месте), сборище», (Троянский I: 467) «поход» < гом. кыпч., кар. *цэрив* «сугыш, көрәш, җәң», башк. *сиреү,* к.-балк., *черив*, кырг., алт. *черу, черүү* «гаскәр, чирү», *черик* «солдат», ком. *черив* «яу», нуг., каз., к.-калп. *шеру, шерү,* тув. *шериг* < алт., чыгт., уйг. (Радлов III: 1967–1968) *чäрү, чäрік* «армия» < бор. төрки (Clauson: 428–429) *čerig* «гаскәр, чирү», төр. *çeri* «гаскәр төре», чув. *çар, çарӑ* ~ мар. *сар* < *сäр* «гаскәр; сугыш» (болг. теленнән), венг. *sereg* «гаскәр» һ.б. (күп телләргә кергән). Бу сүзне кыт. алынмасы диючеләр дә бар.

Бор. төрки *čerig* «гаскәр» сүзен ДТС (: 144) авторлары бор. һинд. *kşatrika* «гаскәри; армия» сүзеннән дип карыйлар, әмма М. Рясянен (Räsänen 1969: 105) бу фикерне куәтләми, Дж. Клоусон да сүзнең (аның «нәрсәнең дә булса кире, тискәре ягы» мәгънәсе дә булган) тамыры бор. төрки *čer-, čär-* «кара-каршы төзелеп тору, йөзмә-йөз каршы тору (тезелгән гаскәрләр тур.)» ди, бу фикергә А. Донук та (Donuk: 97) кушыла, к. М. Кашгарида *çergeştek* «капма-каршы тезелеп сугышмак» (II: 209). Бор. *čer-* сүзенең төп мәгънәсе тат. **чәр-ү* (шуннан к. **Чәрек**) «каршы тору, каршылык күрсәтү» сүзендә сакланган шикелле. Бу мәгълүматлар яктылыгында *чиру* < *чәриг* «хәрби тезем» **җәргә** (к.) сүзен хәтерләтә башлый.

Рус. *шеренга* «бер рәтле хәрби тезем» ниндидер бор. төрки телдән, **чәрәңге* ← **чәр-ән-ги* «тезелешү, тезеленге» ← **чәр-ән* «теземгә басу» – **чәр-* сүзенең кайт. юнәлешеннән килә (безнең фараз). К. ш. ук **Чәрмәсән, Чирмешән.** Будагов I: 475; Фасмер IV: 429; Федотов II: 86; ССТМЯ II: 421; Аникин: 632 (рус. диал. *цыриг* «яугир» < монг., бур. *цэрэг* «гаскәр, гаскәри» тур.)

**ЧИС** (ТТДС I: 487) диал. «ухоженность; качество; порядок» ~ мар. *чес,* чув. *чыс* < рус. *честь.*

Дерив.: **числы** (кием).

**ЧИСЛА** «число месяца» ~ мар., удм. *числа,* удм. *число* id. < рус., әлбәттә.

**ЧИСТА** «чистый; чисто» ~ мар. *чиста* id. < рус. Чаг. ш. ук тат. диал. **чисти, чистый** ~ чув. *чисти* «тәмам, бөтенләй; нәкъ» < рус. сөйл. *чисто, чистый* id.

**ЧИТ I** «край (конкретного предмета); отчуждение; чужбина; чужой», диал. (ТТДС I: 487) «угол» < гом. кыпч., к. кар. *чэт*, кр.-тат., кырг. *чет* (> башк. *сит,* нуг., каз., к.-калп. *шет*) id., кр.-тат., төр. *çit*, чыгт., уйг., алт. (Радлов III: 1982) *чäт* «почмак, кырай, яр», ком. *чет* «аулак (җир); сүзсез, тыйнак (кеше)» һ.б. М. Рясянен (Räsänen 1969: 106) **чит II** (к.) белән чагыштыра; Будагов исә **чик** һәм **чит** сүзләре бердәй дип карый (ләкин бу караш фонетик җәһәттән акланмый: сүз азагында бездә *к ~ т* тәңгәллеге күзәтелми). К. **Читлек.** Л. Будагов (I: 503) **Чит I, II, III** сүзләрен бергә карый.

Дерив.: **читке; читлә-ү, читләт-ү; читтәге.**

**ЧИТ II** диал. (Урал.) «решётка; ограда из камыша» ~ төр. *çit* id.; к. **Чыт II, Читән, Читлек.**

**ЧИТ III** (ЛТ I: 168) «ситец, хлопчатобумажная ткань», диал. (Н. Исәнбәт III: 139, *чирек тиенгә*

*чите дә юк* дигәндә) **чите** ~ чув. (Ашмарин XI: 188) *читĕ* «җәймә, чүпрәк, эскәтер» ~ к.-балк., кырг. *чыты, чыт* > нуг., каз., к.-калп. *шыт* «чите» < бор. төрки (ДТС: 146) *čit* id. < һинд. *čit* (к. Абаев I: 312). **Чит II** белән бердәйлеге семантик һәм тарихи җәһәтләрдән караганда бик шикле, хәлбуки һәр ике сүзнең дә **чит, чыты** варианты бар. Чаг. ш. ук **Чет.**

**ЧИТӘН,** диал. **цитән,** себ. (Дмитриева 1981: 196) **чётäн** «плетень», диал. (*текмә читән*) «тын», (ТТДС I: 488; БҺҺ II: 212) «большая корзина; клетка для кур и т.п.» > мар. (Исанбаев 1978: 30) *четан*, манси. *čitän,* хант. *t'edan* «читән» (төп. мәгъ.) < гом. кыпч., к. кар. *цэтэн,* ком., к.-балк., кырг. *четен [чэтэн]* «чыбыктан үрелгән әйберләр (кәрзин, умарта, арба көймәсе)» > башк. *ситән,* нуг., каз., к.-калп. *шетен* id., уйг. (нәкъ татарча) *читән*, үзб. *четан* «кабык яки камыш читән», алт. *чеден* (Радлов сүзлегендә *чäдäн*) > мар. *шеден,* хак. *сиден, седäн* «читән» (төрле мәгъ.) – читәнлек үсемлек исеменнән (чаг. **Кура I, Күрән I**), к. каз. *шетен, четен*, үзб. *четан,* төркм. *читенек* «тау битләүләрендә үсә торган тикән, кура, камыш һ.б. төрләре», аз. (АДДЛ: 442) *чәтән* «камыш; камыштан үрелгән кипкер, читлек, келәт һ.б.ш.; камыш аркаулы палас, тукыма». Бу сүз үз чиратында бор. төрки (ДТС: 146) *čit* > чыгт., госм., уйг. (к. Радлов III: 2140, 2122) *чит* «камыштан, чәнечкәктән һ.б.ш. үрелгән киртә, шалаш» тамырыннан ясалган булырга тиеш, к. ш. ук алт., үзб. һ.б. *чий* «читән һ.б.ш. үрү өчен кулланыла торган үсемлек» (к. **Чий II**), алт. *чет,* тув. *шет* «ылыслы агач төре».

Чув. *сатан* ~ мар. диал. (Упымарий: 189, 253, 259; Саваткова: 185) *сатан, сäтан, цетен, цецен, чэтан* «читән» болг. теленнән булса кирәк. Гомумән, бу сүз бор. төркилектән килә (барча китерелгән сүзләрнең төрле чыганактан булуы шикле) һәм күрше телләргә дә үтеп кергән, к. калм. *шитн* «читән», осет. (Абаев I: 311) *cetenö* «кәрзин» һ.б. Чаг. **Чит II, Читлек, Чыты**. Будагов I: 503–504; Räsänen 1969: 106; Федотов II: 88 (бик ярлы); Нұрмағамбетов: 135–136 (төрле фаразлар, иске ядкәрләрдән параллельләр китерә); Тимергалин: 543.

Дерив.: **читәнле, читәнсез; читәнлек; читәнлә-ү** (*читәнләп алу* дигәндә). Тотрыклы тезмәләр: **читән арба, читән өй; читән тоту**.

**ЧИТЕК** «мягкие сапоги, гетры из мягкой кожи» ~ башк. *ситек* id. > чув. *читтĕк,* мар. (Исанбаев 1978: 34) *с'етык* «олтансыз итек, читек, пайпак» < тат. (диал.) *эч итек* сүзеннән; бу сүз яңа түгел, к. рус. (Аникин: 227–228) *ичетыги, ичетоги, ичетки,* ш. ук (Срезневский III: 1486) *чедыгь* «читек» (XV г. теркәлгән) ~ госм. (Радлов III: 1985) *чäдік* «читек», уйг. *четәк* id.

Рус. *ичиги* «читек төре» **читек** сүзеннән түгел, (себ. һ.б.) **эчек** < *ичик* «йонлач ягы эчкә каратып тегелгән кием» сүзеннән булырга мөмкин.

Дерив.: **читекле, читексез; читеклек; читекче.**

**ЧИТЕН** «трудный; трудно» < гом. кыпч., к. к.-балк., ком., төркм. *четин [чэтин]*, төр. *çetin* «читен», госм., чыгт. (Радлов III: 1983) *чäтін,* башк. *ситен* id., кырг. *четин киши* «үҗәт кеше» (*четин < чертин* «балан, миләш» һ.б.ш.) > нуг. *шетин,* каз. *шетін* «читен (кеше); усал», гаг. *четин* «каты, каткын; үҗәт»; хак. *сидік* «читен, авыр». Барча бу мәгълүматлардан чыгып, *читен < чәртин* сүзе (төр. һ.б.) *sert, çert* «каты» сүзеннән килә дип уйларга ярый. Будагов I: 470.

Дерив.: **читенлек;** (сирәк) **читенле, читенсез; читенәй-ү, читенлән-ү.**

**ЧИТЛЕК** «клетка; клетушка (для молодняка скота и домашней птицы»)» ~ башк. *ситлек* id. > удм., мар. *четлык* id., чув. *читлĕх* «читлек, сарай чардагы» ← диал. *чит* «почмак» (к. ТТДС II: 354) булса кирәк. **Чит II** (к.) сүзеннән дә ясала ала. Федотов II: 421.

**ЧИТНӘ-Ү** себ., м.-кар. (Рамазанова 2013: 254) «заболеть (о животе); боль в животе» ~ кар. *цэкнэ-, цэтнэ-* id., ш. ук «боегу, хәлсезләнү», төр. (Будагов I: 487) *чекзинмек, чеңзинмек* «баш әйләнү».

**ЧИЧӘ, чәчә** «собственная мать ребёнка в семье, где две и более жён у одного мужчины; непервая (чаще – вторая) жена среди нескольких жён» (отсюда **бичә-чичә, бичә-чәчә** «разные женщины, бабы», собственно «старшая жена и младшие жёны») ~ башк. *сисә, сәсә* (башк. сүзе сүзлекләрдә кертелмәгән) id. Бу сүзнең төрле вариантлары һәм төрчәләре себ. сөйләшләрендә күп (к. Тумашева 1992: 237–239; Баязитова 2001: 10, 203; Рамазанова 1991: 36, 52–57, 65): **цәцәкә < цәцә әкә** «әти яисә әнинең энесенең хатыны, җиңги», **цәцәү баба** «дәвәти», **цәци баба** «абыйларның иң өлкәне», **цицата < цицә ата, цицебаба** «әти яисә әнинең абыйсы», **цицә** «ата; апа; әни яисә әнинең сеңелләренең иң кечкенәсе», **цици** «әби» һ.б. Мондый мәгънә төрлелеге *чичә ~ чәчә* һ.б. сүзенең мәгънәсе

нәсел-нәсәп мөнәсәбәтләрендә түгел, бүтән якынлыктан пәйда булганлыгын күрсәтә, моны себ. **цәц инә, цәцинә, цицинә** «атасыннан яисә анасыннан өлкәнрәк хатын» сүзе белдерә шикелле: сүз «бәбинең чәчен алучы» кеше тур. бара: ул баланың я кече, я иң өлкән абыйсы яисә атасы, дәвәтисе яисә дәвәнисе һ.б. булалган; «икенче хатын» мәгъ. соңрак кына карарлаша башлаган. Себ. татарларында **цац туй** – баланың чәчен тәүләп китәрү йоласы тур. к. Рамазанова 1991: 62–63.

Бүтән төрки телләрдә: кырг. *чече,* каз., к.-калп. *шеше* «күпхатынлы гаиләдә баланың үз анасы», аз. *чичи* «әни», ш. ук (АДДЛ: 459) *чичә* «дәвәни», төр. *çiçe* «түти» (угыз телләрендә бу сүз каян килеп чыккандыр – безгә караңгы). Будагов I: 667 (каз. *шеше* тур. этнографик аңлатма тәҗрибәсе бирелә).

**ЧИЧӘН, чәчән** (әд. телдә һәр ике вариантта очрый), себ. (Тумашева 1992: 239) **цицән** «народный певец, бард; красноречивый» < гом. кыпч., к. кырг. *чечен,* үзб. *чечән,* кр.-тат., алт., чыгт., уйг. һ.б. (Радлов III: 1988) *чäчäн* (> башк. *сәсән,* нуг., каз., к.-калп. *шешен*) id. ~ бор. чыгт., яз. монг. *čečen* «кабилә башлыгы», як. (к. Токарев С.А. Общественный строй якутов. М., 1945: 222–223) *сэсэн* «хөкемдарның киңәшчесе». К. ш. ук чув. *çeçен* «чәчәкле, матур; чичән», *чечен* «матурлык, тәҗрибә», уйг. *чечән*, тув. *чечен* «чибәр; чичән; мәргән», як. *сэһэн* «хикәя, кыйсса» ~ бур. *сэсэн* «акыл, акылдарлык», тунг. (ССТМЯ II: 147–148, 422) *чэчэн, сэчэн* «акылдар, акыл иясе; өлгер, уңган, булдыклы» һ.б., к. Будагов I: 471; Федотов II: 103–104.

Сүзнең тамыры *чэчэ* (редупликатив сүз) булса кирәк, к. тат. (Ф. Бурнаш шигырендә *Курай уйнап чичәрде шунда берсе...*) **чичәр-ү**, кырг. *чечерке-*, алт. (Радлов III: 1989) *чäчäркä-* ~ монг. *чэчэрхэ-*, як. *сэһэр-* «матур сөйләргә тырышу; тырышып күп сөйләү». Гомумән, гом. төрки *чичән* < *чэчэн* > *чәчән* сүзен монг. телләреннән таралган дип уйлыйлар. Төрки телләрдән ул күрше телләргә дә кергән, мәс., мар. *чечен* «матур», удм. *чеченька* «көяз» һ.б. Безнеңчә, *чичән ~ чәчән* нигезен *чәчәк ~ чәчкә* (к.) нигезе белән гомоген дип уйларга ярый. Балалар телендә *чәчә ~ чача* «тәти, матур нәрсә» күп телләрдә очрый (к. Аникин: 659). К. түбәндәгене.

Дерив.: **чичәнлек ~ чәчәнлек; чичәнлән-ү ~ чәчәнлән-ү.**

**ЧИЧИН** (ЗДС: 755) «красивый; украшенный; щеголеватый, щегольской» к. **Чичән.**

**ЧИШМӘ** «родник, ключ» > удм. (Насибуллин: 146) *чэшмэ* ~ кырг. *чечме,* төркм. һ.б. *чешме* (> башк. *шишмә,* каз., к.-калп. *шешме*), госм. *чäшмä* < фар. *чäшмä* id. ← *чäшм, чашм* «күз», к. Будагов I: 476; Platts: 433–434.

Дерив.: **чишмәле, чишмәсез.**

**ЧИШТА** (Төньяк Башкортстан, без теркәдек. – *Р.Ә.*), **шишта** (БТДҺ: 394) «шест для соревнований по влезанию (в праздник сабантуй)» < рус. *шесты* «колгалар». Бу сүз тур. Фасмер IV: 432.

**ЧИШ-Ү**, диал. (Тумашева 1992: 239) **циц-ү** «развязывать, распутывать; разрешать, решить (задачу)» ~ себ. (Тумашева 1992: 212), миш. **тиш-ү** id. < гом. кыпч., к. ком., кырг., алт. *чеч-* (> башк. *сис-*, нуг., каз., к.-калп. *шеш-*), тув. *чеш-,* чыгт., алт., уйг. (Радлов III: 1987) *чäч-* ~ бор. төрки (ДТС: 497) *seš-* (> уйг. *сәш-*) >> як. *эс-* «чишү, сүтү, киемне салдыру, тугару». Бу сүзнең фонетик вариантлылыгы күзгә ташлана: тат. диал. **тиш-** ~ к.-балк. *теш-,* үзб., уйг. *йеч-, йәч-* id.; төр. *çöz-,* иске төр. (к. Гукасян 1978: 30) *čez-* «чишү; хәл итү». К. ш. ук бор. төрки к.-балк. *seč-,* төр. *seç-* «аеру; сайлау, сайлап алу». Будагов I: 505–506. К. **Тиш-ү.**

Дерив.: **чишел-ү, чишен-ү** (тәүдә – төймә урынына кулланылган баучыкларны, ялауларны чишү), **чишеш-ү, чиштер-ү;** диал. **чишек** «чишелгән».

**ЧИШҮЧӘ, чичүнчә** «чесуча (вид ткани)» ~ уйг. *чөчүнчә* id. ~ кыт. *tšoudzy* «киҗе, чи ефәк». Аникин: 659–660 (тәфсилле).

Тат. теленә бу сүз русчадан да, уйгурчадан да алынган була ала.

**ЧИЯ I [чёйә],** себ. (Тумашева 1992: 238) **цийә, цейә** «вишня; ягода (разная)», күч. «вишнёвый» > удм. *чия,* чув., мар. *чие* < гом. кыпч., к. кар. *чийа, цийэ,* кырг. *чие,* үзб. *чийә* (нуг., каз., к.-калп. *шие,* башк. *сейә*), ком. *җие* «чия». Чаг. иске тат. (Будагов I: 507) **чигү, чикү** «чия», тат. диал. (ТТДС I: 483) **чики, чикиш** «чикләвек; экәлә». Ихтимал, **чия II** белән баглыдыр.

Дерив.: **чияле, чиясез; чиялек.** Диал. (ЗДС: 713) **цийәрәң < цийә рәң(ендә)** «шәмәхә, бишни».

**ЧИЯ II [чёйә],** диал. (Тумашева 1992: 237) **цейә** «запутанный узел» ~ кырг. *чие* (> каз. *шие,* к.-калп. *шийе,* башк. – БТДҺ: 273 – *сейә*), үзб. диал. (ЎХШЛ: 300) *чигә,* үзб. *чигал* id. ~ як. *сигэ* «карама, баганаларга ни дә булса бәйләү өчен чыбык» ← *чиг-*

«төйнәү», к. уйг. *чиг-,* (Радлов III: 2113) *чіг-* «төенләү» ~ бор. төрки (ДТС: 147) *čiγ-* «төйнәү, бәйләү». Чаг. **Чия I.**

**Чия II** сүзенең тат. **чиялән-ү, чияллән-ү**, башк. *сейәлән-ү*, тат. диал. (ДС II: 217) **чигәлән-ү < чигәллән-ү** дериваты киңрәк билгеле. К. ш. ук башк. *сейәл-еү* «ябышу; камашү, бәйләнү (күз тур.)», *сейәләш-ү* «карышу, үҗәтләнү».

**ЧОБА,** (ТТДС I: 489, 493) **чуwа, чыба**, (Balint: 93) **čіра** «род халата, верхняя холщовая одежда» ~ башк. *сыба* id., нуг. *шыба,* к.-балк. *чуба* «хатын-кыз җиләне», алт. *чуба,* төркм. (ТДГДС: 200) *чуба, чүvvе*, тув. *шыва* ~ монг. *цува* «хатын-кыз чикмәне», яз. монг. *čiba* (> калм. *tsuwo*) «җиңел плащ», бор. төрки (Räsänen 1969: 128) *ǯuba* «мех; эчек» < фар. < гар. *җүббә* «җөббә, киң итеп тегелгән өске кием» > төр. *cübbe, çübbe* «җөббә, руханилар кия торган кием; сыбайлар плащы» – сем. телләреннән таралган мәдәни сүз, шуннан ук к. **зыбын, чыбын, юбка** (← **юба**). Рус. *шуба* «тун» иске нуг. теленнән булса кирәк (бүтән фаразлар тур. Фасмер IV: 482). Алтай-Саян төркиләрендә *чуба* «тол хатыннар җиләне», үзбәкләрдә (ЎХШЛ: 107) *җүббә* «сабыйлар халаты», к. **Җөббә.** Будагов I: 432; Paasonen 1903: 46–49; Отаров 1978: 25. Чаг. ш. ук **Чува.**

**ЧОГАН** (И. Хәлфин сүзлегендә) «ворон, вид ворона» ~ чув. (Сергеев 1971: 112) *çăхан, çăкан, çахон* «козгын».

**ЧОГЫР I [чŏғŏр], чорок, чрык** (ЗДС: 756, 758, 774) «место соединения костей шеи, а также бедра» (*чорок* < *чогрык*). Ачык түгел. *Чыгыр* ~ *чыгырыҡ* сүзеннән дип фаразлау шик уята.

**ЧОГЫР II [чŏғŏр]** (Ш. Камал) «музыкальный инструмент типа мандолины» ~ төр. *čopur,* аз. *чуңғур, чөңүр* алт. (Будагов I: 496) *чоқур, чуқур* ~ яз. монг. *čiγur* > хәз. монг. *цуур*, маньч. *чоор, чӧрӧн* «курай» > як., эвенк. (ССТМЯ II: 408) *чүөр* «шөлдер», к. ш. ук кырг., алт. *чоор* > тув. *шоор* «курай; сыбызгы». Икенче яктан к. ком. *чёгур,* төр. *cögür,* груз. *чонгури* (һ.б.ш. Кавказ телләрендә) «кыллы музыкаль инструмент», төр. *çoğurcik* «сыерчык». Музыкаль аләт атамалары мәдәни лексикага карый һәм бик киң таралучан, шунлыктан барча китерелгән мисалларны бер уртак чыганактан дип карарга мөмкин. Räsänen 1969: 116 (тагын мисаллар китерә, һәм монг. *çoγu-* «чоку» нигезеннән ди).

**ЧОКЧЫН-У [чŏқчŏн-]** «копаться; дотошно исследовать (употребляется преимущественно в этом, переносном значении)» ~ башк. *соҡсон-* id. ← диал. **чоқчы-у**, башк. *соҡсо-у* ~ кырг., алт. *чукчу-,* хак. *чухчы-, чухчыла-* «интенсив чоку, чуку». К. түбәндәгене.

**ЧОКЫР [чŏқŏр],** (ТТДС II: 356) **чŏгŏр,** миш., себ. **цоқор, цокор,** диал. **соқор,** (Арсланов 1988: 165) **чŏңкыр,** себ. (Тумашева 1992: 240) **цŏңқŏр, цŏңғŏр** «углубление, яма». Бу сүзнең бик күп фонетик вариантлары бар, мәгънәсе исә тат. телендә дә, бүтән төрки телләрдә дә өч юнәлештә үсеш алган: а) «төрле махсус чокырлар»; ә) «төрле савытлар»; б) «тирән» сыйфаты. Арытабан к. 1) (ТТДС I: 489) **чогыр, чŏғŏр** «яшелчә саклау өчен чокыр, мөгрәп» ~ чув. (Сергеев 1968: 61) *çăкăр, çăхăр* «чокыр, ям» < гом. кыпч., алт. диал., үзб., уйг., гаг., госм. һ.б. (Радлов III: 2167), угыз. *чуқур,* төркм. *чукыр* (~ башк. *соҡор*, нуг., к.-калп. *шуқыр,* к.-калп. *шŏқыр*) < ком., к.-балк., кырг., уйг. *чоңқур, чуңқур, чуңғур, чуңур,* төр. *çukur* «чокыр, чокырлык», кр.-тат. *чуңраw* «тирән кое», 2) тат. **чоқыр**, башк. (БТДҺ: 279) *соҡор* «глубокая чашка, кружка» > удм. *чыкыр,* мар. (Исанбаев 1978: 32) *чукыр* id. һ.б.; 3) үзб. (ЎХШЛ: 304) *чуқур, чоңқыр,* чув. *чăхăр,* бор. төрки (ДТС: 156) *çuγurdan* «тирән; текә һәм биек кенә битләүле чокыр» ~ чув. (Сергеев 1971: 146) *чүңкүр* «текә ярлаулы» һ.б., к. ш. ук бор. монг. *čongγur* «чокырлы юл».

**Чонкыр <** *чуңкур* сүзе *чоңгыл* сүзеннән (яки киресенчә) килеп чыга ала; *чуңкур* ~ *чуңкул* нигезен исә беренче караудa төрки (ком.), эвенк. һ.б. *чоңк, чоң* «чокырчык, батынкылык» яисә бор. төрки (< кыт., к. ДТС: 156–157) *čiŋ* «кыңгырау, чаң», шуннан «тирән (савыт)» һәм *ҡур* (к. **Кор**) «түгәрәк» сүзләреннән гыйбарәт дип уйларга мөмкин: *чуңкур* «тирән түгәрәк», ләкин бу фараз бердәнбер түгел: Л. Будагов (I: 496) буенча, *чоқыр* < *чуқур* ← *чоқы-у* < *чуқы-у* (к.); әгәр *чоңгыл* < *чуңгул* беренчел булса, бу сүздә төрки телләрдә *-гыл* < *-гул* аффиксы бар дип уйларга нигез бар һ.б. К. **Чоңгыл, Чокы-у.** Räsänen 1969: 119–120.

Дерив.: **чокырлы, чокырсыз; чокырай-у, чокырла-у, чокырлан-у; чокырлык; чокырчык.** К. **Чокырча, Чоңгырчак.**

**ЧОКЫРЧА [чŏқŏрча]** (ДС III: 185) «чашечка; чашеобразная булочка» ~ башк. (БТДҺ: 279) *соҡорса* id. ← **чоқыр** ~ *соҡор,* к. үзб. *чуқурча* «кечкенә чокыр». К. **Чокыр.**

**ЧОКЫ-У [чŏкŏ-]** «ковырять, копать (палкой, кайлом), долбить, делать углубление» < гом. кыпч., уйг. *чоку-, чуқу-, чуңқу-* (> башк. *соко-,* нуг., каз., к.-калп. *шуқы-*, каз. *шӧқы-*) id. ~ як. *чоқуй-* «чүкү, кагу, бәрү» < бор. төрки *čoq-* «терлек сую; сугу» ~ яз. монг. *çoki-* > хәз. монг. *цохи-* «кагу, бәргәләү, тукмау, тукмаклау» ~ тунг.-маньч. (ССТМЯ II: 403) *чō-, чок-, чоқи-, чоку-* «чуку»; бу фигыльнең исем коррелянты ком. һ.б. *чоңқ* ~ эвен. *чоңг, чоқ,* эвенк. *чоонқ* «чокыр, чокырчык». Бу тамыр ономопоэтик-символик характерга ия һәм төрки һ.б. алтай телләрендә исәпсез күп икенчел тамырлар биргән, к. **Чокчын-у, Чокыр, Чоңгыл, Чукы-у, Чукын-у, Чум-у.**

**Чокы-у** үзе генә дә продуктив фигыль нигезе: **чокыл-у, чокын-у, чокыш-у, чокыт-у** (кайбер сөйләшләрдә **чокы-у** «казу» мәгъ. аңлашыла).

**ЧОЛАН,** (ТТДС I: 489) **чылан** «сени, веранда; чулан; большая комната; чердак», себ. (Тумашева 1992: 240, 247) **цŏлан, чŏлан** «хлев, загон, помещение для скота» ~ башк. *солан* «чолан», алт. *чулан* (> чулым. *цулан,* шор. *шулан*), каз. *шылан* «абзар-кура», чыгт. *чулан* «читлек, аран» һ.б. (күпчелек төрки телләрдә теркәлмәгән) < монг. *чууглан, цулан* > бур. *суглан* «җыелыш урыны; заяннар (к. **Заятүләк**) җыелып суд ясый торган урын» (к. Хангалов II: 215–217), иске монг. *чиғулған, чуғлаған* «сейм» > калм. *цуглаан* «җыелыш, җыен, җыен урыны, каравыл йорты» (монг. телләреннән > алт. *чулаан, чуулан*, тув. *шуулган* мифологиядә «тәңреләр яки шайтаннар җыела торган урын», як. *суғулаан, сулаан* «каравыл йорты; җыелыш»). Сүзнең тамыры бор. төрки *čoү ~ čïү* «төен, төргәк», шуннан бор. төрки (ДТС: 152) *čoүla-* «төргәкләү; гаскәрне бер урынга җыю», *čoүlan-* «төргәкләнү; гаскәр бер урынга җыелу». К. ш. ук эвенк. *суглан, һуглан, чуглан* «җыелыш» һ.б. Чаг. **Чолга-у.**

Рус. *чулан, чюлан* (XVI г. бирле билгеле) тат. теленнән булса кирәк; тәүдә бу сүз театр фойесын, гомумән җыелыш урынын, аннары театраль ложаларны да белдергән (к. Валькова 1971: 97–100); чув. *чăлан,* мар., удм. *чулан,* мар. Т. *цŏлан, цылан* «чолан; амбарның өске каты» татарчадан, ләкин рус теле тәэсирендә ныгытылган. Räsänen 1969: 119; Ахметьянов 1981: 24; Федотов II: 400 (бик накыс); ССТМЯ I: 119; Аникин: 672.

Дерив.: **чоланлы, чолансыз; чоланлык.**

**ЧОЛГАУ [чŏлғаw], чылгау, цолгау** һ.б. вариантлар «обмотка, портки». К. түбәндәгене.

**ЧОЛГА-У,** диал. **чылға-у, цылга-у** «завернуть, обмотать; окружать» > чув. *чăлха-* < гом. кыпч., чыгт., алт. *чулға-* (нуг., к.-калп. *шулға-* > каз. *шӧлға-*), хак. *сулга-* id. Э.В. Севортян (1962: 240) аз., төркм. *чулға-* «чолгау» сүзен аз., төр. *çul*, ком. *чул* «эчерге, чапрак; кылдан тукылган тукыма» сүзеннән ди. Безнеңчә, *чулга-* < бор. төрки (ДТС: 152) *čoүla-* > бор. монг. *čiүla-* > калм. (Номинханов 1975: 137–138) *цугла-* «чолгау» (ягъни монда метатеза: *-үl-* > *-lү-*), һәм сүзнең тамыры бор. төрки *čoү* (к. **Аякчу**, **Шу**). Шул ук вакытта аз. һ.б. *чул-* < бор. **чоғул* булса кирәк, к. тув. *шуглақ* < **шоғул-ақ* «эчерге, чапрак».

Дерив.: **чолгал-у, чолган-у** (→ **чолганыш**), **чолгаш-у, чолгат-у**, диал. (ДС III: 185) **чолгаwыч.** К. **Чолгау**. Räsänen 1969: 119; Федотов II: 40. (**чолгау** һәм **чолка** сүзләрен бутый.

**ЧОЛДЫР [чŏлдŏр]** (ТТДС I: 489) «обноски (которые достигаются младшим от старших детей); голяк, оборванец» ~ кырг., алт. *чулду* «калдыклар», чыгт. (Будагов I: 499) *чулду* «бүләк; ганимәт (?)».

**ЧОЛКА,** диал. (ДС II: 211; ДС III: 183; ТТДС I: 467, 489, 491, 496) **цŏлка, цылка, чолка, чулка, чылка, чөлкә, чилкә** «носки, чулок» ~ чув. *чăлха* id. бор. кыпч. (СС) *čulxa* id. **Чолкы** һәм аның вариантлары башлыча миш. сөйләшләрендә очрый. Мар. *чулка* (Иванов, Тужаров: 262; Саваткова: 187) *цŏлка, цылка,* морд. *цолка, цылка, цюлка* «оек», удм. *чулка* id. урта диалекттан. **Чолка < чулка** үзе бор. **чул-қақ* булса кирәк, бор. төрки **чул-* «киекнең тиресен ярмыйча салдыру», к. тув. *чулгу-* «тирене тулаем салдыру», *шулу* «бөтен килеш».

Рус. *чулок* сүзенә килгәндә, ул **чолка** сүзеннән түгел, себ. (Тумашева 1992: 247), алт. **чулуқ** ~ хак. *чулух* < бор. **чул-гуқ ~ чулгу-к* «оек» (җәнлек тиресен тулаем салдырып, оек итеп киюдән) сүзеннән. Шулай итеп, безнеңчә, **чулка, чулук** сүзләре **чолга-у** белән, гомумән, бер нигездән үк түгел. Хәлбуки Фасмер (IV: 380–381) һәм Федотов (II: 400–401) бу сүзләрне бутыйлар. Әлбәттә, монда төрле контаминацияләр булырга, **чолка** сүзенең вариантлары рус. *чулки* сүзеннән кире кайтырга да мөмкин.

**ЧОЛЫК [чŏлŏқ]** «борть» < гом. кыпч., к. иске тат. (Ногман: 132) «күч», кар. *чолу, чулу, цулу* «бал корты; күч», башк. *солоқ,* башк. диал. (БТДҺ: 281) *сөлөк* ~ «умарта; бал корты», чув. *çăл, çăлă [сչŏлŏ]* «чолык», госм. (Радлов III: 2176) *чолуқ* < бор. төр-

ки (ДТС: 152) *čoluγ* «гаилә, җәвер» сүзе белән бердәй булса кирәк.

Дерив.: **чолыкчы, чолыкчылык.**

**ЧОМБЫРАК [чŏмбŏрак]: чомбыракта йөрү** (Г. Әпсәләмов) «ходить у чёрта на куличках»; чаг. осет., төр., көрд. *çaturak* «саз, былчырак». Ономопоэтик сүз булса кирәк, к. Абаев I: 329.

**ЧОНТЫК [чŏнтŏк]** (Җ. Вәлиди) «куцый; бритоголовый (т.е. без хохолки)», себ. (Тумашева 1992: 242) **цунтык** «криворукий, с культяпкой (отрезанной по локти рукой); косноязычный» < гом. кыпч., к. к.-балк. *чонтуқ,* уйг. *чунтуқ, чонтуқ* (> башк. – БТДҺ: 279 – *сонток, сонтор* «такыр (баш тур.); чонтык», ног., к.-калп. *шӧнтық, шонтый*), үзб. *чўлтоқ* «көдрексез (сарык)», к.-калп. *шонтый-* «койрыксыз булу». Чаг. ш. ук кырг., к.-балк., үзб. *чунақ,* уйг. *чонак* > к.-калп. *шунақ,* каз. *шӧнақ* «киселгән (яки кыска) колаклы ат».

**ЧОҢГЫЛ [чŏңғŏл]**, диал. (халык этимологиясенчә) **чумғыл** «яма, пучина; воронка; углубление на дне реки» ~ иске тат. **чоңгыр**, диал. (ЗДС: 714) **цоңгор** «чокыр» ~ киң таралган гом. алтай сүзе: башк. *соңғол, соғол, сөңғөл* «чоңгыл», як. (Пекарский: 3643–3645, 3671) *чоңкучах, чоңхоі, чоңолох, чохоо, чокобул* «түгәрәк чокыр; тирән түгәрәк күл», *чӧңӧ, чӧңӧрӧ* «тирән», алт. (Радлов III: 2017) *чооң* «тирән» ~ эвенк. һ.б. (ССТМЯ II: 415) *чуңгун* «чоңгыл», эвен. *чуңгун* «тирән» ~ монг. *цунхээл* «елга-күл төбендәге чокыр» һ.б., к. **Чокыр**, **Чөңгел**. Ясалышы җәһәтеннән к. **Туңгыл, Ургыл.**

**ЧОҢГЫРЧЫК [чŏңғŏрчы̆к],** себ. (туб.) **цуңгурцак** «грот» ~ кырг. *чуңгурчак* id. ← *чоңгыр* < *чүңгур*, к. **Чокыр.**

**ЧОР I** (**чир-чор** «всякие хвори» парлы сүзенең икенче компоненты) – какая-то кожная болезнь ~ төркм. *чор* «чеби (тән тиресе яргалану)», к. Мухамедова 1973: 190. Чаг. **Чур.**

**ЧОР II** «время, эпоха, период» < иске тат. **ӧчӧр** > удм. *учыр* «момент» < гом. кыпч., к. кырг., кар., уйг., алт., чыгт. (к. Радлов I: 1726, 1731) *учур,* башк. *осор* «момент; чор; туры килеш, тап килү; сәбәп, мәгънә; тапкыр сүз», тув. *ужур* «аеш, мәгънә» ~ монг. *учир* id. Räsänen 1969: 509; ЭСТЯ I: 615. К. **Очра-у.**

**ЧОРГА-У** «выбросить» к. **Чырга-у.**

**ЧОРМА,** диал. (Balint: 27) **очырма,** (Тимергалин: 544) **чортма, очортма** «подволока, пространство под крышей, мезонин», (ТРС 1931) **corma, ocrma** «дверце, окно с крыши для слёта голубей; голубятня» ~ башк. *осорма,* үзб. *учирма* id. *учир-* «очыру» сүзеннән. Будагов I: 116 (*учрама* дип тә язылган).

**ЧОРНА-У**, (ТТДС I: 490) **чорма-у**, (ТТДС II: 361) **чырға-у, чырма-у, чырна-у,** миш., себ. (Тумашева 1992: 245) **цырма-у** «наматывать, обвивать, сплетать; опутать» > чув. *чăрма-* id. < гом. кыпч., к. кырг., ком. *чырма-* (> башк. *сорна-, сорма-,* ног., каз., к.-калп. *шырма-*), уйг., үзб. *чирма-* «урау, урату, чорнау», бор. төрки (ДТС: 144) *čermäl-* «чорналу» һ.б. *чыр-, чур-* (к. **Чур-у**) фигыленең интенсивлык формасы (*чыр-ма,* чаг. **Көрмә-ү, Тырма-у** һ.б.ш.). Чаг. ш. ук **Чолга-у.** Будагов I: 474 (монг. *чірма-* «буталу» белән чагыштыра).

Дерив.: **чорнал-у, чорнан-у, чорнаш-у, чорнат-у; чормавык; чормавыч, чорнавыч,** диал. **чырнау** «чолгау, ыштыр».

**ЧОС** «проворный, быстрый; расторопный» ~ башк. *сос*, (БТДҺ: 282) *сөс,* удм. *чус*, коми. *чож* ~ маньч. (ССТМЯ II: 409) *чос* ~ фар. *чуст* id., к. «Мөхәммәдия» шигырендә *Нәкадәр гакыл улурса чуст гәрәк*, ягъни «акылы булган кадәр өлгер дә булсын». Күрәсең, киң таралган интернациональ сүз.

Бу сүзгә Урта Уралдагы удм. *Чусо* – рус. *Чусовая* елга атамасы тап килә диләр (А.К. Матвеев): ул зур елга алкынлыгы белән танылган.

**ЧОШ** (К. Нәҗми) «слега, жердина; шест» ~ чув. (Сергеев 1971: 156) *шучă, шочă, шăчă, шуччă, шĕчĕ* id. Ихтимал, рус. *шест* ~ *шост* (к. Фасмер IV: 432–433) сүзеннәндер.

**ЧӨГӘ,** диал. (Троянский I: 475) **чөкә** (иске – XVIII г. чыганакларында *севьюк, сугъя, чүге, чукя*) «стерлядь» ~ чув. *çука, çухе, çĕке, çĕкĕ,* мар. (Исанбаев 1978: 22) *чүгäкол, сүгыкол* (*-кол* «балык»), удм. (Алатырев 1976: 156–157) *чуки, чукы, цюке* ~ башк. *сөгә,* каз. *сүген,* уйг. диал. *чүкә,* төркм. *чӧке,* аз. *чӧкә,* госм. (Радлов III: 2165) *чука,* төр. *çuka, çoka* id. ~ рум. *cegă,* пол. *czeczuga* id. Чаг. ног. *шүйке,* ком., к.-балк. *чюкке* «соса» ← *чюй* «чөй». К. **Чөй.** Федотов II: 105 (материалы аз). Линдберг, Герд: 63.

**ЧӨГЕНДЕР [чөгөндĕр]** «свёкла (белая – **ак чөгендер,** красная – **кызыл чөгендер**)» > чув.

*чĕкĕнтĕр, шĕкĕнтĕр,* мар. (Исанбаев 1978: 38) *чүгүндүр*, удм. *чукиндэр* «чөгендер», кайбер чув. сөйләшләрендә – «кишер» < гом. кыпч., к. к.-балк. *чюгюндюр* < куман. *čügündür,* ком. *чювюндюр,* каз. (ҚТДС: 401) *шуғындыр*, нуг. *шувындыр* «(башлыча кызыл) чөгендер», төркм. *шуғундур,* аз. *чуғундур,* госм. *җүкүндүр* «чөгендер», кайбер шивәләрдә «кишер төре» < фар. *чүгүндүр, чуғундäр, чоғондор* id. (яшелчә атамалары төрки телләргә фар. теленнән керүчән); төрки телләрдә *-л-* варианты аерым даирә тәшкил итә, к. себ. (Тумашева 1992: 241) **цөгөлтөр** > башк. *сөгөлдөр* ~ нуг. диал. *шувылдыр*, калм. *šügldür* «чөгендер». Räsänen 1969: 119; Федотов II: 410.

Дерив.: **чөгендерче, чөгендерчелек.**

**ЧӨГЕРМӘК [чөгөрмәк]** к. **Чүгермәк.**

**ЧӨЕЛДЕРЕК [чөйөлдĕрĕк]**, диал. (Садыкова 2003: 179) **чөгөлдерек** «супонь», диал. (ДС II: 227) ш. ук «ремень цепа» > мар. (Исанбаев 1978: 39) *чӧлдырык* ~ башк. *сөйөлдөрөк* id. тат. << бор. монг. *següldürüg* «койрык бавы; бөлдеркә» ← *segül* «койрык; асылынты»; к. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 505) **чөйлек < чөйөллек**, (ТТДС II: 370) *чүлек* > чув. *чӳлĕк*, мар. (Саваткова: 150) *сүлык, цүлык, сулык* «чөелдерек».

**ЧӨЕР-Ү [чөйөр-],** миш. **чүwер-ү** «повернуть (голову) в сторону, отвернуться» ~ гом. кыпч., к. кырг. *чүюр-,* к.-балк., ком. *чююр-,* башк. *сөйөр-* «бору, әйләндерү, чөерү», угыз.-миш. линиясендә кар., кр.-тат. *чүвүр-, чүwүр-*, аз. *чәвир-*, төр. *çevir-,* бор. чыгт. (Боровков 1963: 357) *čäwip-, čäwyp-* < бор. төрки (ДТС: 145) *čevür-* «әйләндерү, чөерү» (*йөз чөер-ү ~ чәwүр-ү* тәгъбире борынгыдан килә) ← *чөй-, чүw-* < бор. төрки *чүг-* «һавага атып, әйләндереп төшерү» фигыленең йөкл. юн. (к. **Чөй-ү**). **Чәwер-ү** (к.) варианты тат. телендә икенчерәк мәгънә дә алган. К. **Чүрә, Чүрәкәй.**

Дерив.: **чөерел-ү, чөереш-ү, чөерт-ү;** диал. **чөерек.**

**ЧӨЙ I,** диал. **чĕw** «деревянный гвоздь, клин» < гом. кыпч. *чүй* (> нуг., каз., к.-калп. *шүй,* башк. *сөй*), кар. *чүй, чюв*, аз. (АДДЛ: 451) *чив,* төр. *çivi* «чөй; теңгел; элгеч», чыгт. (Мухамедова 1973: 189) *чигәк* «кадак» < бор. төрки **чиг-әг.* Räsänen 1969: 121 (**чөелдерек, чөйлек** сүзләрен дә **чөй**гә нисбәтли, безнеңчә, бу дөрес түгел). Удм. *чӧг* «кадак» бор. төрки телләрдән булса кирәк.

Дерив.: **чөйле; чөйсез.**

**ЧӨЙ II** в связанных выражениях (к. мәкаль: *көйгә килмәсә, чөйгә килер*) «лесть, похвала, восхваление (в угоду)» ~ башк. (БТДҺ: 280) *сөй* id.

Дерив.: **чөйлә-ү** (*көйләү-чөйлә-ү* тәгъбирендә), **чөйләт-ү,** к. **Чөйлән-ү.**

**ЧӨЙ III** (Тумашева 1992: 240, 246–247) **цөй, чеү** «молодой сосняк, кедр; спица (из сосны, кедра?)» – **Чөй I** белән бердәй булса кирәк.

**ЧӨЙГӘЧӨЙ** (ТТДС I: 504) – дөресрәге **чигә чөй** «чека, чекушка (телеги)» ~ ком. *чӧгечюй* id. бу кушма сүзнең борынгылыгын күрсәтә. К. **Чикә** һәм **Чөй.**

Рус. *чека, чекушка* (Фасмер IV: 324 чыгышы билгесез ди) кыпч. (тат.) *чэкә* «чигәчөй» сүзеннән.

**ЧӨЙГЕМАШ** < (ТТДС I: 505) **чөйген аш** «постный суп» (?) – дөреслектә бөтенләй киресенчә, к. каз. *шүйгін* «туклыклы мал азыгы», кырг. *чүйгүн* «туклыклы; көр, тук (терлек)» < бор. төрки (ДТС: 146) *čivgin, čivgün* «туемлы», *čivgin aš* «туемлы аш», *čiväg* «тугайткыч; зимле» ← *čiv* ~ **čüj* тамырыннан. Тат. сөйләшләрендәге «майсыз аш» мәгъ. икенче бер сүздән – **йауган аш** сүзеннән күчкән (мәгънәләре буталган), к. Хайрутдинова 1993: 63. К. **Яуганаш.**

**ЧӨЙКӘЛ-Ү** «внезапно подбрасываться вверх (на ухабах и т.д.); выплёскиваться» ~ төр. *çögün-* id. ← **чөйкә-ү* фигыленнән төш. юн., **Чөй-ү** (к.) сүзе белән тамырдаш.

Дерив.: **чөйкәлт-ү** «өскә чөеп җибәрү, түгеп җибәрү», **чөйкәлчек** (~ төр. *çöğünçek*) «баш-башына ике кеше утырып чөйкәлү өчен уртасы терәккә куелган такта».

**ЧӨЙЛӘН-Ү, чөелән-ү** (трбс.) «возноситься, рисоваться от похвал (о детях)» – **чөй-ү II** фигыле нигезеннән ясалган булса кирәк, к. башк. *сөйлән-еү* «кинәт югары сикерү (куян тур.)». Чаг. алт. (Баскаков 1972: 268–269) *чойлен-, чӧйлен-* «алдашу». Чаг. кырг. *чүйрүй-* «ризасызланып борын җыеру; кыланчыклану». К. **Чөй II.**

**ЧӨЙЛЕК [чөйлөк]** «супонь (часть сбруи)» ~ башк. *сөйлек (сөйлөкбау)* id. > мар. *цүлык, чүлык,* чув. *чӳлĕк* id. К. **Чөелдерек.** Räsänen 1969: 121; Федотов II: 427.

**ЧӨЙЛЕК-Ү (чөйлегү, чөйлекте),** диал. **чүлек-ү, цөйлөк-ү** «подбрасываться, подпрыгнуть (от

потери, снятия портивовеса)» ~ башк. *сөйләк-* id. – **чөй-ү** фигыленең дәвамлы интенсивлык формасы (чаг. *ашык-у ← аш-у, томлык-у ← том-у, язлык-у ← яз-у*).

Дерив.: **чөйлектер-ү; чөйлекмә, чүлекмә** (кое сиртмәсе, к. ТТДС II: 370), себ. (Тумашева 1992: 240) **цөйләкмә** «бер тәгәрмәчле арба (ул җигелмәгән чакта горизонталь хәлдә торалмый)».

**ЧӨЙ-Ү,** диал. (ТТДС I: 507) **чү-ү** «подбросить вверх», (Тумашева 1992: 242) **цү-ү** «взлететь» < гом. кыпч., чыгт. *чүй-* (к.-балк., ком. *чюй-*), нуг., каз. *шүй-* «чөю, чөелү; туп-туры югары менү», сирәгрәк – «төшү, колау», төр. *çöğ-* «югарыга атылган шәй баллистик дуга буенча әйләнеп төшү». ~ тув. *шүг-* «көрәштә күтәреп бәрү». Гомумән, бу сүз әйләнеп төшмәле итеп атуны, ыргытуны белдергән һәм бигрәк тә ау кошларына карата әйтелгән (**кош чөю,** к. Будагов I: 301), к. кырг. *чөөл-* «төшә башлау (ук, пуля тур.)».

Дерив.: **чөер-ү, чөеш-ү, чөйдер-ү; чөйгеч**. К. **Чөй II, Чөйкәл-ү, Чөйлән-ү, Чөйлек-ү.**

**ЧӨК I** (ТРС 1931) «вогнутая сторона альчика, жох» ~ чув. *чĕк, шĕк* «ашык», *чăк, шук* «чөк» ~ гом. кыпч. *чүк, чүкө* (> нуг., каз., к.-калп. *шүк*) ~ калм. *чохо* id. К. ш. ук тув. *чүк*, монг. *цуг* «дөньяның ун тарафы (горизонталь тарафлар – сигез һәм ас вә өс)» > бур. *цуг, зуг* id. Бор. төрки (ДТС: 145) *çik*, төр. *çik* h.б. «чөк». Гомумән, бу сүз Евразиядә киң таралган, к. коми. *цог* «чөк» h.б. Федотов II: 399 (бик аз әйтелә, тат. сүзе искә алынмый).

**ЧӨК II** – вид языческого моления – к. **Чүк.**

**ЧӨКЕР [чөкөр], чөгер** «ритуальный просяной хлеб», диал. (Paasonen) *tčükörі [чөкәри]* «затвердевлый, засохший хлеб (его специально готовили для испытания жениха во время свадьбы)», (ТТДС I: 366) **секере** «целый круглый хлеб, который должен до конца съедать в один присест жених во время свадьбы» (удмуртчадан дип күрсәтелә, ләкин, безнеңчә, бу сүз мари-чуваш даирәсенннән: *җ ~ ч ~ с'*) ~ чув. *çĕкĕр, çăкăр, çăхăр* «икмәк; арыш икмәге», мар. (Упымарий: 196; Иванов, Тужаров: 207–208; Саваткова: 151) *сӧкӧр, сыкыр* > удм. *сукыри* «каравай, түгәрәк ипи», рус. диал. (Даль) *сюкур* «икмәк, ипи», *сюкуры* «мордва көлчәсе» < морд. *сюкоро, сукоро* «икмәк», *сёра* «ашлык», *цюкор* «көлчә» << бор. уйг., чыгт. (Будагов I: 445) *җүгәри,* госм. *чӧкäри,* хәз. үзб. *җугари, җугара, җүңөру* «сорго, гаолян, Бохар тарысы», *жухори*, кырг. *җүгөрү,* каз., уйг. *җугара* «кукуруз; жугара» (к. **Җөгәрә, Кәкери-чөкери**) h.б. фар.-ир. *җау* «арпа, ашлык» тамырыннан булырга тиеш. Егоров 1964: 206; Räsänen 1969: 209–210; Федотов II: 91 (тат. материалы **җөгәрә** сүзе белән чикләнә).

**Җөгәри, җөгәрә** Идел-Урал регионында игелми, бу сүз белән Урта Азия якларыннан килгән илат һәртөрле игенне һәм, аннары, икмәк-ипине атаганнар. Башк. (БТДһ: 284) *сукер* «камыл» тат. диал. **чүкер* id. сүзеннән булса кирәк. Гомумән, *с*-авазына башланган вариантлар болгар игенчелегенең фин-угор халыкларына булган көчле тәэсире тур. сөйли.

**ЧӨКРӘ** (ТРС 1931) «затылок; выемка на задней части шеи». Чаг. башк. *сөйҙә,* нуг., каз., к.-калп. *шүйде* «умырткалыкның иң өске өлеше, атлант» < *чүйдә ~ чүйрә.*

**ЧӨЛДИ, чөлли** (ТТДС I: 505) «четвертинка, четверть литра (спиртного)» ~ башк. (БТДһ: 396) *шүлдей* > мар. (Исанбаев 1978: 14) *чӧлдий, чӧл* id.

**ЧӨЛКӘР, челкәр** (ДС III: 190; ТТДС I: 480) «тёмно-голубой (о лошади); сизый, пёстрый» ~ башк. (БТДһ: 281) *сөлкәр* «чуар» ~ каз. диал. *чөлкәр* «куе зәңгәр» (шуннан рус. *Челкар тенгиз* «Чөлкәр диңгез» – Казакстандагы зур бер күл атамасы) < монг. *цэгүл-кәр* «аклы кир (ат)».

**ЧӨМӘК, чемәк** «кран, носик чайника», диал. (ТТДС I: 506; ТТДС II: 369) «стрелка лука; пятка косы» < гом. кыпч., к. башк. (БТДһ: 281, 375) *сөмөк, сөмәк* «кран», *һемәк* «төтәткеч», ком. *чүмке,* кырг. *чөмөк, чүмөк,* к.-балк. *чюмек,* h.б. (> каз., к.-калп. *шүмек, шүбөк*) «кран, бәбинең сидеге агып чыксын өчен бишек төбенә куелган эче куыш сөяк, төрепкә», уйг. *җүмәк,* госм. *сӳбäк* id. ~ бур. *сэмгэн, сэмэгэн* «эче куыш сөяк, чөмәк; труба, трубка». Асылда *чүмгäк ~ сүмгәк* «җилекле (эче куыш) сөяк» ← *чүм-, сүм-* «җилек суыру». К. түбәндәгене.

**ЧӨМЕР-Ү [чөмөр-]** (ДС III: 190, ләкин күп сөйләшләрдә очрый), **чүмер-ү** «пить с поверхности (жидкости), втягивать, жадно сосать» ~ башк. *сөмөр-, һемер-,* үзб. *симир-*, чыгт., госм., уйг. (Радлов IV: 855) *сүмүр-*, бор. төрки (ДТС: 511) *sömür-* «чөмерү; йоту». Чаг. тунг. (ССТМЯ II: 87) *сими-,* яз. монг. *sime-* «имү, чөмерү». Чаг. ш. ук **Чүмеч**.

**ЧӨ́НКИ,** иск. **чөн** «потому что» < гом. кыпч. *чүнки* (> башк. *сөнки,* нуг., каз., к.-калп. *шүнки*), төр. *çünkü* ~ куман., госм. *чүн ким* < фар. *чӯн ки* id. (*чӯн* < *чи гуна* «шул рәвешле, шул чакта, чөнки»); бу сүзне (Хәсән Гали, Räsänen 1969: 121) *өчен ки (кем)* < *үчин ки (ким)* сүзеннән дип аңлату да бар.

**ЧӨҢГЕЛ [чөңгөл]** (ТТДС I: 507), **чүмгәл** (минз.) «озёрца, оставшиеся после половодья» ~ төр. *çöngül* id. – **чоңгыл** (к.) сүзеннән аерылмый. К. ш. ук алт. (Баскаков 1966: 161) *чӧң-* «бату, батынкыланып тору», гом. тунг. (ССТМЯ II: 407) *чоңдо* «ям, бәләкәй тирән чокыр».

**ЧӨРЧЕК [чөрчөк], черчек** (ТТДС I: 481) «сверчок» – ихтимал, рус теленнәндер, ләкин тат. диал. **чөрелдә-ү** «черелдәгән тавыш чыгару» сүзе дә бар. Һәрхәлдә имитатив тамырдан. К. ш. ук **Шөрчек.**

**ЧУ I, чыw** «плацента» ~ башк. *сыу,* (БТДҺ: 292) *сыуын* < *чыwын* id. – бор. төрки (ДТС: 151) *čoγ* «төргәк». К. **Аякчу.**

**ЧУ II** (К. Насыйри; диал.) «молва, слух», «шум, гвалт» (ш. ук **чыр-чу** сүзендә чагыла) ~ каз. *шу*, нуг. *сув*, кырг. *шуу, чуу*, үзб., фар. *чӯ, чōу* һ.б. Чаг. **Шау II**.

**ЧУ III** «но (понукание мошади)» («Идегәй») ~ кырг. *чу, чү*, каз. *шу* һ.б.ш. К. **Чү.**

**ЧУАК** «ясный, тёплый день (весной или осенью), тёплынь; солнцепёк (в прохладное время)» < гом. кыпч., к. кырг. *чубақ* (*чуwақ*) > башк. (БҺҺ II: 227) *сыуақ,* каз. *шуақ,* нуг., к.-калп. *шувақ,* иске чыгт. (Поппе 1938: 136) *čiγaq* «эссе, кызу көн» ← бор. төрки (МК, ДТС: 151–152) *čoγ* «кояш эссесе; ут ялкыны; куз өстендәге зәңгәр ялкын» ~ монг. *чог, цог,* бур. *соқ, цок* > як. (Пекарский: 3653) *чоқ* id. һ.б. Шул тамырдан угыз. *чоғаш* «кояш», к. **Чуал I.** Номинханов 1976: 150.

Дерив.: **чуаклы, чуаксыз; чуакла-у;** к. **әбиләр чуагы.**

**ЧУАЛ I,** диал. (ТТДС I: 467; Тумашева 1992: 220) **цуwал, цуал, цыуал** «камин», (ЗДС: 760) «летний очаг во дворе; открытый очаг», (Арсланов 1988: 100) **шувал** «дымоход и печная труба, соединённая со стеной (глинобитной или каменной)» ~ башк. (БТДҺ: 292) *сыуал* «йомры тимер мич; гомумән мич», хак. диал. *соол* id. Рус. *чивал, чувал* «чуал, тышкы морҗа» (< тат.) тур. Аникин: 668–669 (бай әдәбият күрсәтелә).

Гомумән *чуwал* < *чуғал* < *чоғғал* булса кирәк, ягъни **чоғ** (к. **Чуак**) тамырына монг. сүзьясагыч *-ғал* кушымчасы яисә *ғал* «ут» сүзе өстәлеп ясалган; чаг. ш. ук төр. диал. *чоғаш* «кояш эссесе, кояш». К. югарыдагыны.

Дерив.: **чуаллы, чуалсыз** (өй).

**ЧУАЛ II,** диал. (Радлов IV: 96) **шуал** «большой дорожный мешок; переметная сума» ~ үзб., төркм., аз. һ.б. *чувал, чуал* (> нуг., каз. *шувал, шуал*) id. < фар. (Будагов I: 490) *җӯwāл, җӯбāл* id., ш. ук «беркетеп тегелгән, җөйле; җөйче, тегүче». К. Нұрмағамбетов: 141 (гар. сүзе димәкче); Аникин: 669. К. ш. ук түбәндәгене.

**ЧУАЛДЫЗ** диал., иск. «длинный мешок для перекладывания на лошадей, верблюдов» < уйг. *чувалдуруз* < фар. *чувāли дӯруз* id. төп. мәгъ. «озын чуал».

**ЧУАЛ-У, чыwал-у,** диал. **чŏwал-у < чŏбал-у** (к. ТТДС I: 488; ТТДС II: 356 һ.б.), диал. (ТТДС I: 491) **чуғал-у** «путаться; спутаться; якшаться» < гом. кыпч., к. кар., кырг. *чубал-* (> нуг., каз., к.-калп. *шубал-,* башк. *сыбал-*) «сөйрәлү, өстерәлү; бер-бер артлы тезелеп бару» ← кар., кырг. һ.б. *чуба-* > себ. (Тумашева 1992: 241) *цуба-* «озынаю; сузылу; бер-бер артлы килү; көн артыннан көн үтү» ~ тат. диал. (к. ТТДС I: 494) **чыбы-у,** уйг. *чуба-, чуға-* хак. *суба-* «йомгак, киләп һ.б. сүтү» ~ бур. *суба-,* монг. *суби-,* яз. монг. (к. ССТМЯ II: 410) *čibu* «бер-бер артлы тезелеп килү; тартып сузу; сузылу» һ.б., безнеңчә, бор. төрки (Радлов III: 2184; ДТС: 39, 156) *чуб* «өлкә; чылбыр бөҗрасы; тезем буыны» сүзеннән (*чуб-а-*) ясалган. Чаг. ш. ук ком., кырг. *чубур-* ~ бур. *чубури-,* як. *субуруй-* «бөртекләп, берәмләп, тамчылап кына төшү (килү, чыгу); бер-бер артлы тезелү». К. **Чыбата**.

Дерив.: **чуалын-у, чуалыш-у, чуалт-у** һәм **чуалдыр-у** (икесе дә очрый). К. түбәндәгеләрне.

**ЧУАЛЧЫК,** диал. **чŏбалчык** «запутанный; путаница; сложный, головоломный» ~ башк. *сыбалсық, сыуалсық* ← **чуал-у** (к.); фигыль нигезенә *-чык* кушымчасы ялганып, әһәмиятсез, җитди булмаган яисә негатив нәрсәләрнең атамалары-сыйфатлары ясалучан, чаг. **бәйләнчек, өстерәлчек, чукынчык** һ.б.

Дерив.: **чуалчыклы, чуалчыксыз; чуалчыклан-у.**

**ЧУАЛЫШ** «замятня; дрязги» ~ башк. *суалыш* id. – «чуалу күренеше» мәгънәсеннән күчерелмә.

**ЧУАН,** диал. (ДС I: 217; ТТДС I: 788, 793, 495, 518; ТТДС II: 356) **цыwан, чŏбан, чипан, чыбан, чыкан** «карбункул, чирей, нарыв» ~ чув. *ҫăпан,* мар. (Упымарий: 196) *сүвäн, сыван, цыван* < гом. төрки сүз, к. кар. *чыбан,* аз., госм. *чибан,* төр. *çıban*, төркм. *чыйбан,* башк. (БТДҺ: 279) *сŏбан* id. < бор. төрки (ДТС: 150, 156) *čipïqan, čïpqan, čïbaqan* «бериш чүл-дала үсемлеге һәм аның бер очы кызарып торган аксыл җимеше, шул җимешкә охшаш шешек» (диелә, әмма киресенчә, ягъни җимеш атамасы шешеккә охшатылган булырга да мөмкин) > иске кыпч., уйг., үзб. *чипқан,* монг. *чипкан* «чуан», яз. ядкәрләрдә (Мухамедова 1973: 191) *чиибан ~ чыбаан* id.

Бу сүзнең икенче – *б* авазы редукцияләнгән бер филиациясе – себ. (Тумашева 1992: 243) **цыйған,** миш. (ТТДС I: 495) **чыкан,** башк. *сиқан, сыйқан,* алт., кырг. *чыйқан, чыйықан* > *чыйыған* ~ иске монг. (Поппе 1938: 435) *čiγan* «чуан, шеш». Бу сүздән *ч* > *ш* күчеше булган телләрдә (нуг., каз., к.-калп., тув. яки бур. диал.) **шыйықан* > **шыйыған* яңгырашы аша каз. *шиған* ~ бур. *шиихан* «далаларда очрый торган түгәрәк очлы тау» > рус. > тат. **шихан** (к.) сүзе килеп чыккан. К. **Чука.** Егоров 1964: 208; Räsänen 1969: 106; Федотов II: 96–97 (материалы ярлы); Аникин: 703 (рус. *шихан* тур., материалы аз).

Дерив.: **чуанлы, чуансыз; чуанла-у; чуанчык.**

**ЧУАР,** диал. (Троянский I: 448, ТТДС I: 488) **чŏбар,** (ЗДС: 768) **чыбар** «пёстрый, чубарый» > чув. *чăпар,* удм. *чипор,* мар. *чувар* < гом. кыпч., чыгт. *чубар* (> нуг., каз., к.-калп. *шубар,* башк. *сыбар*), уйг. *чипар* һ.б. «чуар (башлыча ат тур.)», кырг., тув. ш. ук *чоор, чаар* id.; төркм. *чопур* ~ төр. *çopur* «шадра; сипкелле; кутырлы».

Сүзнең икенче бер вариантлар группасы – -*ғ*- төркеме: үзб. *чавқар, чавқор*, алт. *чоқур* (> хак. *сохыр, чохыр*) < иске монг. (Поппе 1938: 136) *čooqur* < *čipaqur* «чуар, ала» киң таралган сүз, к. яз. монг. *čoиxur* >> як. *чуоғур* ~ эвенк. *човур, чокур, чоγур, чугур*, маньч. *чохоро* һ.б. (ССТМЯ I: 402–403); хәз. монг. *шоохор* (> калм. *цоохр*), бур. *соохор* һ.б. К. **Чупыр**. Räsänen 1969: 118–119; Номинханов 1975: 228; Федотов II: 403.

Ат төсмере буларак *чŏбар* < *чубар* сүзе күп күрше телләргә кергән (төп чыганагы – бор. монг.), мәс., рус. *чебарый, чубарый* (ат), к. неол. *чебурашка* һ.б. Фасмер IV: 375; Аникин: 648.

Дерив.: **чуарлы, чуарлык; чуарла-у, чуарлан-у.** Ш. ук диал. (ЗДС: 756) **чобарай** – бер төрле кош; **чобарқа** «сипкел».

**ЧУБАЛГЫ, чуалгы** диал. «замятня, беспорядки от недопонимания друг друга» ← *чубал-у, чуал-у*, әлбәттә. Алт. (Баскаков 1966: 166; 1972: 269) *чубалғы, чыбалғы* «кырмыска» тат. *чубалгы* белән бердәй (ләкин күч. мәгъ.) нигездән булса кирәк.

**ЧУБИН: чубин ат** фольк. «похоронные носилки». **Чубин** монда фар. *чӯбин* «агачтан ясалган» сүзеннән. Чаг. каз. (ҚТДС: 401) *шубын* «агач – тупас (кеше)».

**ЧУВА** (ЗДС: 760) «длинная женская рубашка» **чоба** (к.) сүзе белән бер микән, әллә кр.-тат. *чуқа*, төр. *čuha* «шинель», *čoha, čoka* «сукно, постау» (> башк. *соға* «сыйфатлы постау»), бор. төрки (КБ) *čüge* «чикмән төре» һ.б. (к. Doerfer III: 110–114) > рус. диал. (Аникин: 669) *чуга, чугай, шугай* «җиңсез тун» белән бердәй микән?

**ЧУВАШ [чуwаш], чуаш** «чуваш; чувашский» ~ мар. (Упымарий: 193, 195; Иванов, Тужаров: 206; Саваткова: 149) *суас, с'уса, суäс,* башк. *сыуаш* – бүтән төрки телләрдә *чуваш* – Идел-Урал регионында иң интригалы этнонимнарның берсе. Хикмәт шунда ки, марилар һәм кайбер бүтән төрки булмаган этник группалар татарларны *суась* дип атыйлар. Ә чувашларның үзләренә исә *суасьла мари* «татар сыман мари» атамасы такканнар. Һәм болай атауга нигезләр дә бар: бик күп лингвистик, этнографик һәм тарихи фактлар күрсәткәнчә, чуваш халкының составында элекке марилар төп өлешне тәшкил итә. Татарларны кайбер русча тарихи документларда «Казанские чуваши» дип атыйлар. Икенче яктан чувашларны «горные татары» (горный – монда Тау ягындагы – «Иделнең уң ягындагы») дип атау да булган. Татарларның бер группасы да үзләрен *чуваш, чуаш* дип атамаган дисәк тә була. Тик бер искәрмә белән: татар теленә күчкән кайбер татар авыллары еш кына элекке гадәт буенча *чуваш* дип атала бирәләр. Мәс., хәз. Башкортстандагы Базгыя авылы кешеләре *чуваш* дип язылып килгән.

*Чуwаш, чоош, човаш, çivaş* дигән этник берәмлекләр себер татарлары (к. ЗДС: 760–761), кыргызлар (к. İnan I: 7) һәм төрекләр арасындада очрый.

*Чуаш* этнонимының чыгышы билгесез. Тарихи җирлектә шуңа охшаш бер генә этноним бар – бор. *чӧш* кабиләсе атамасы. Идел-Урал төрки телләрендә, бигрәк тә чуваш телендә, бор. төрки *о, ӧ* авазлары *уа* һәм *үә*гә әверелә торган булган, мәс., бор. *тӧрт* чув. диал. *тыварт*, әд. *тыват* булып әверелгән, бу яңгыраш исә арадаш *түәрт* яңгырашыннан килеп чыккан. Шуның кебек үк, бор. болгар ташъязмаларындагы *күән* «көн», *уан* «ун» һ.б. Чув. *пыварлы* – борынгыча *борлы* «бурлы»; *кывак* < *кӧк* «күк»; *тывар* «тоз» – борынгыча **тор; хăвар* – борынгыча *хор-* «кую». Шулар үрнәгендә *чываш, чуаш* < *чүәш* < бор. *чӧш* дип уйларга мөмкин (бу версияне чуваш тарихчысы В. Каховский китерә). *Суась* сүзен «курык мари»лар (ягъни «тау ягы марилары») *суәс* дип әйтәләр һәм бу яңгыраш борынгырак дип уйларга нигезләр бар. Ә ник соң марича *ч* түгел – *с*? Хикмәт шунда: мари телендә *с* авазы *сч* кебегрәк, *ч* авазына якын яңгыраштa әйтелә. Русча *чюваш* варианты да шул әйтелешне чагылдырган. Шулай итеп *чуаш* сүзе *чӧш* сүзеннән килеп чыга ала. Болар икесе дә этноним. Тик менә кистереп әйтеп булмый: тарихи мәгълүматлар җитенкерәми. *Чӧш* халкы Көньяк Себердә яшәгән һәм аның теле, яшәү рәвеше, кая киткәнлеге һ.б. турында мәгълүматлар юк диярлек. Һәм Урта Идел-Көньяк Урал регионында *чӧш* дигән сүз яз. ядкәрләрдә теркәлмәгән.

Рус телендә XVI г. азагы, XVII г. башында язылган исәп-хисап, җир үлчәү-җир бүлешү документларында *чюваш, чюваша, чюваше, чувай* дип билгеле бер социаль катлам белдерелә. Аларда «фәлән татарларның чувашлары» мәгънәсендәге тәгъбирләр очрый. Ул «чувашларның» исемнәре татарча-мөселманча. «Чуваш авыллары»ның исемнәре дә чувашча түгел, татарчарак.

Дамир Исхаковның күпсанлы публикацияләрендә *чуваш, чюваш* дип аталган кешеләрнең этник чуваш кына түгел, татар да, мари да, удмурт та булганлыгы исбат ителә. Хәз. Татарстанның төньягы буйлап сузылган *чуваш юлы* Удмуртиягә киткән (**юл** дип Казан дәүләте чорында ям юлын да, шулай ук зур административ өлкәне дә атаганнар).

Чуваш филологлары һәм тарихчылары иске документлардагы «чувашларны» этник, чын чувашлар дип исбатларга тырышалар. Аларның фикеренчә, Казан ханлыгы чорында бу илдәге илатның, һәрхәлдә авыл халкының күпчелеге чувашлар булган һәм алар, имеш, соңыннан татарлашып беткәннәр. Шул ук вакытта чуваш галимнәре бар көчләренчә чувашларның урыс хакимияте астына үз теләкләре белән кергәнлеге, «урыс-чуваш дуслыгы» турында сүз куерталар. Ләкин әлеге документларда сөйләнелгән «чювашлар» – арада иң каһәрләнгән халык: аларның җирләрен талап урысларга, татарларга, бу җирләргә сөрелгән полякларга, латышларга биргәннәр. «Тугрылыклы дус» чувашлар белән рус хакимияте шундый мөгамәләдә булыр иде микән ни?

Аннары Казан тирәсендә «зур күпчелекне» тәшкил иткән «чювашлар» рус хакимияте чорында нишләп бик тиз татарлашканнар соң? Урыс хөкүмәте татарлар санын арттыру белән кызыксынган дип әйтеп буламы? Юк, әлбәттә.

Димәк, XVI–XVII гг. Казан ханлыгы территориясендә яшәгән «чювашлар» этник чувашлар булмаган, ә татарларның, гомумән Казан иле халкының бер социаль катламы – табәкасы (сословие) булган.

Чуваш сүзе шул яки шуңа якын яңгыраштa, чуваш галимнәре билгеләгәнчә, чагыштырмача соң гына 1502 елда гына фиксацияләнә: шул елда чувашлар Казан ханы оештырган фестивальгә чакырылалар. Ләкин һәвәскәр тарихчыбыз Әхмәт ага Булатов (күптән мәрхүм) чуваш сүзенең XV г. ук *чузаськи* формасында фиксацияләнгәнен тапкан (к. Топонимия Поволжья. Ульяновск, 1969: 176–182). *Чузаськиләр чирмешләр* белән беррәттән Казан ханы армиясендә хезмәт иткәннәр. Билгеле, «чузаськи» чуваштан гайре халык була алмый. Көнб. Европа ядкәрләрендә теркәлгән бу сүз, ихтимал, руслардан язып алынгандыр: *чузаськи* ул «чуазьский» яки «чувашский»дән бозылган булса кирәк.

Шунысы игътибарга лаеклы ки, чуваш сүзе бу халыкның төп атамасы түгел. XV г. элегрәк чувашларны *веде, ведене, вяда, ведьке* дип атаганнар: бу атама рус тарихи ядкәрләрендә һәм мордва телләрендә сакланган. XIII г. ядкәре – сәяхәтче венгер монахы Юлиан язмаларында искә алынган *Ведин* дигән Идел буе иле дә чувашларга карый булса кирәк. Көнб. Европада төзелгән карталарның берсендә хәз. Чабаксар тирәләрендә *Веда Суар* шәһәре күрсәтелгән.

Тагын бер кызыклы факт: элекке документларда татарларда, башкортларда һәм мариларда (к. Черных 1980: 86–87) *Чувашай, Чувашбай, Чувашбирде, Сыуашбирде, Акчуаш ~ Аксыуаш, Сывас, Цюваш* дигән исемнәр еш очрый. Нәрсә соң ул **чувашай**? Ай исемеме? Әйтеп булмый: *Солта-*

*най* дигән исем дә булган ич, хәлбуки андый ай юк. *Чувашбай* аңлашыла, әмма *Чувашбирде* исеме *Аллабирде, Ходайбирле, Тәңребирде* кебек исемнәр рәтендә тора. Ихтимал ки, татар-болгар мәҗүсилегендә иген-җөгәрә тәңресе булгандыр (андый тәңре булу – типологик күренеш). Тагын бер фараз: төрек теле ядкәрләрендә *чуваш, чуғаш* дип кояшны атаганнар. Әллә *чуваш* – кояш тәңресеме? Ул вакытта чувашлар – «кояшка табынучылар, чувашчылар» була ала. **Чуваш** дигән тәңре атамасы ислам дине көчәюе белән махсус оныттырылса да бик табигый.

Тарихи җәһәттән **чуваш** сүзен **чураш** (к.) белән тәңгәлләштерү дә бик бап килә, ләкин монда фонетик җәһәттән хилафлыклар бар.

*Суась ~ чуаш* сүзе турында (башлыча чувашларның үзләре тарафыннан) йөзгә якын этимологик мәкалә язылган. Тик аларда да төрле фаразлар гына бәян ителә. Шул фаразлардан иң популяр булганнары:

1) *чуаш* – тат. *җуаш, юаш* «басынкы» сүзеннән (Фасмер IV: 376);

2) *чуаш* – тат. диал. *җуач* «елга арты, аръяк» сүзеннән (Казаннан караганда чувашларның Идел аръягында яшәвеннән);

3) чаг. төр. сөйләшләрендә (к. Eren H. Sirca köşkte // Türk dili, Ankara 1993: 499) *çavaş, çogaş, çogaç, çivaç, çovaş, çoveç, çöveç, cöveş* «кояш» – **ураз** (к.) сүзеннән мәгънәви калька. Ихтимал һәм кызыклы фараз, ләкин чувашларның кояшка табынулары тур. мәгълүмат юк. К. Краснов Ю.А. Проблема происхождения чувашского народа в свете археологических данных // Советская Археология, № 4. 1974: 112–124; Федотов II: 394–399 (*чуваш ~ суась* тур. бәхәсләр юнәлешен күрсәтү җәһәтеннән әһәмиятле); Ахметьянов Р.Г. К значению слова *чюваш* в документах XVI–XVII веков // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань, 1995 (шунда *чуваш* сүзенә даир әдәбият китерелә).

**ЧУЕН [чуйы̆н]**, диал. (ДС II: 227) **чөгән, чөген,** (ТТДС I: 505) **чөгин,** себ. (Тумашева 1992: 240) **цōғын, цōйын** «чугун; чугунный котёл, чугунок» < гом. кыпч., уйг. *чойун, чойын* (> башк. *суйын* – БТДҺ: 280 – *сөгөн,* нуг., каз., к.-калп., шор. *шойун, шойын*), уйг., к.-балк. *чоғун,* төркм. *чойн,* үзб. *чуйан* һ.б. бор. кыт. **чөй гун* «чуен савыт» сүзеннән: бер очракта бу сүз веляр (к. алт. *чойгон*), икенче очракта палаталь (уйг. диал. *чейүн, чөйгүн,* чыгт. *чүйүн*) яңгыраштa чагылыш тапкан (тат.-башк. палаталь – нечкә сузыклы вариантлар шуннан килә); к. ш. ук алт. *чой*, тув. *шой*, алт. диал. (телеут) *чөө* ~ калм. *цөө, цөй* «чуен»; бур. *сой* «ялтырап торган (металл)», бор. төрки (ДТС: 151) *čодип* «бакыр». Гомумән, бу сүз һәр төрки һәм монг. телендә күпвариантлы, чаг. төр. *çoyan, çögen, cöven, çöyken* «чуен». Бор. төркиләр чуен койган.

Бор. кыпч. сүзе төрки-монг. телләреннән күп күрше телләргә кергән, к. Абаев I: 319; Räsänen 1969: 113 (күп мисаллар күрсәтелә, нишләптер тат. *чуйын* сүзе чуваш теленнән дип бара); Номинханов 1975: 263–264. Рус. *чугун, цыгун, чигун,* рус., укр. *чавун, чагун, чаун* һ.б. төрки телләрдәге вариантлылыкны чагылдыра (*чаwын, чаун* варианты тат. телендә дә булган, к. Радлов III: 1831), к. Аникин: 633–634 (бай әдәбият күрсәтелә). К. **Чуй.**

Дерив.: **чуенчы, чуенчылык.**

**ЧУЕР [чуйы̆р],** диал. **суер** «галька» – ихтимал, чуен-тимер рудасы, к. башк. **һуйыр < суйыр**, башк. диал. (БТДҺ: 283) *суйынташ* «чуерташ». Бүтән төрки телләрдә теркәлмәгән. **Чайыр** (к.) сүзеннән үзгәргән булырга мөмкин, ләкин кайда, каян, ничек?

**ЧУЙ: чуй булсын** (ТТДС I: 494) «пожелание невестке» ~ кырг. *чой бол!* «ныклы бул» ← *чой* «каты, ныклы». Иске тат. *чуй* ~ башк. *суй* «крица». Чаг. **Чуен**.

**ЧУК I** «кисть, бахрома» (> башк. *суҡ*) > чув. *чук,* удм. *чук, чок*, мар. *чоко*, морд. М. *чёка* < гом. кыпч., к. кырг. *чоҡ* «бүрек яисә балалар кәпәче түбәсендәге чук; төймә» > нуг., каз., к.-калп. *шоҡ* id.; ономопоэтик сүзгә охшый, к. эвенк., эвен. һ.б. *чоγ* «кыңгырау теле». Башк. *суҡҡа, суҡай* «тау түбәсе; очлы тау» ~ к.-балк. *чокай* «баш түбәсендә төенләнгән чәч; гөмбәз» ~ чув., мар. *тук*, эстон. *tukk,* фин. *tukka* «чәч», коми. *туг* «чук». К. Абаев I: 404; ССТМЯ I: 403.

Дерив.: **чуклы, чуксыз; чукла-у.**

**ЧУК II,** себ. (Тумашева 1992: 241) **цуҡ** «много; очень; все вместе, скопом» < чыгт. *чуҡ* ~ аз., госм., төр. (Будагов I: 495) *чоҡ* id. (*чоғул* «күпчелек») ~ бур. *суг* «бергәләшеп; өлкәр»; бу сүз, ихтимал, кырг. *чоҡ* < бор. төрки (ДТС: 151) *čоγ*, монг. *сюг* «ут, нур; янып торган күмер, учак» сүзе белән бердәйдер («учак тирәли утырган кешеләр > җыен > күп»), к. як. (Пекарский: 3687) *чуоғуі* ~ монг. *чугла-* > бур. *сугла-* «бергә җыелу» (~ себ. **цукла**- «эреләндерү, тыгызла-у»), алт. *чоғул* «тыгыз

урнашкан», *чогул-* «җыелу» һ.б. «Мөхәммәдия» телендә *čōқ* «хаҗга баручылар төркеме» ~ рус диал. (Фасмер IV: 373) *чох* «төркем; күплек», *чохом* «барысын бергә». Каз. сүзлегендә *шоқ* «утлы күмер, туплам; чук (?)» бергә бирелә.

Дерив.: хат нәмунәсендә **чуктин-чук, чук-чук** «күптин-күп, бик күп» (сәлам).

**ЧУКА** (ТТДС II: 357), **чукка, чока** «(острая) вершина горы» ~ кырг. *чоко, чоколоқ,* каз., к.-калп. *шоқа, шоқы* id., башк. (БТДҺ: 273) *суқа, суққа, сукай* id., ш. ук *суқа* «тау башы, түбәсе», к.-балк. *чоқай,* уйг., үзб. *чоққа* «кәкел, баш түбәсенә төйнәлгән чәч; чукай»; чаг. башк. *суқса* «түгәрәк (куак)», *суқсай-ыу* «түгәрәкләнеп калкып тору» ~ уйг. *чохчай-* id.; бур. *согсо* «өем», *согсой-* «күтәрелеп-өелеп тору», монг. *цоги* «зур өем, таучык», *цогцой-* «чукчаю» ← яз. монг. *čoүča* ~ тунг.-маньч. (к. ССТМЯ II: 404) *чокчо, чоко* «(түгәрәк чалымлы) тау башы». Күрәсең, бик бор. топонимик апеллятив. Чаг. **Чуан; Чүкәй-ү.**

**ЧУКМАР** «дубинка (с утолщённой) головкой», себ. (Тумашева 1992: 241) «гиря» > чув. (Сергеев 1971: 148) *чукмар, чотмар,* мар. *чокмар*, удм. *чокмор*, морд. М. *цетмар*, рус. *чекмарь, чукмар, чехмарь* һ.б. < гом. кыпч., чыгт. *чоқмар*, башк. *суқмар,* кырг., төркм. *чоқмор,* төр. *çoktar, çotar* һ.б. id. > каз., к.-калп. *шоқпар* «чукмар, гөрзи; күсәк; мүкләк (сыер)» ~ рус. диал. (Даль) *токмарь* «чукмар; күсәк», тув. *токпар* «мүкләк (сыер башы)», к. ш. ук госм. (Радлов III: 2011) *чоқмақ, чоқман* «чукмар». *Чук I < чоқ* сүзе белән баглы. Федотов II: 421; Аникин: 652 (бай әдәбият күрсәтелә).

Дерив.: **чукмарлы, чукмарсыз; чукмарбаш** «бака баласы»; **чукмарлан-у.**

**ЧУКРАК** «глухонемой; совсем глухой» > мар. *чокрак* id. – асылда (к. ТТДС I: 491) «үзеннән су агып чыкмый торган күлләвек, чокыр» дигән сүз (чукрак кешедән дә сүз чыкмый, чөнки ул тел белми) ~ башк. *суқрақ* id., (Катаринский; БҺҺ III: 159) *суқрақ, суқырақ* «күлләвектән калган былчырак; каткан былчырак» – түбәндә бу сүз даладагы чишмәне белдергән, к. кар. *чоқрак, чоғарақ, цоғарак*, к.-балк. *чоқурақ* «чишмә, чишмә суы», нуг. *шоқырақ* «чишмә», төр. *çokrağan* «зур чишмә» ← төр. *çokra-*, бор. төрки (ДТС: 345) *çoqra-* «шаулап, кайнап дулкынлану» («чукрау») ← *çoq-* «ыргылу, ташлану», имитатив сүз булса кирәк. Räsänen 1969: 114 (аз гына мәгълүмат).

Ком. *чоқрақ,* уйг. *чоқурақ* «тигез түгел» сүзе «каткан чукрак, балчыклык» сүзеннән, шуннан каз., к.-калп. *шоқрақ* «тигезсез йөрүчән; сикерүчән (ат)».

**Чукрак <** *чоқрақ* сүзе төрле мәгъ. күрше телләргә дә кергән, мәс., чирк. *шокурак* < (нуг.) «тозлак, түмгәклек», рус. (Фасмер IV: 325) *чеклак* «елганың (тиз агуыннан) туңмый торган төше».

Дерив.: **чукраклык; чукраклан-у.**

**ЧУКЧАЙ-У** «выделяться острым верхом (о горе на равнине и т.п.)» ~ башк. *суқсай-,* алт. *чоқчой-,* як. *чохчоі-* ~ бур. *согсой-,* яз. монг. *čoүčai* id., ш. ук «чүгәләү» ← алт. *чоқчо,* яз. монг. *čoүča,* эвенк. *чоқчо* «очлы тау, өем», «чум». Будагов I: 496; ССТМЯ II: 404; Räsänen 1969: 114.

**ЧУКЫНМЫШ** «крещёный, крестившийся; окаянный (употребляется как ругательство)» ~ башк. *суқынмыш* id. К. **Чукын-у.**

**ЧУКЫН-У** «креститься, принять крещение»; себ. (Дмитриева 1981: 195) **цоғын-у** «молиться», күч. «пасть, разбиться» > мар. *чокын-*, удм. *чукын-* < гом. кыпч., уйг., төркм. *чоқун-,* үзб. *чуқин-, чоқин-* (> нуг., каз., к.-калп. *шоқын-,* башк. *сукын-*) id. морфологиясе буенча **чукы-у** фигыленең кайт. юн. («үз-үзеңне чуку»), чаг. чув. *сăхсăх-* «чукыну; үз-үзеңне чуку» (к. Ашмарин 1898: 9). К. **Чукы-у.** Будагов I: 495, 496; Räsänen 1969: 114 (тел. *čök-* «суга чуму» белән чагыштыра).

Дерив.: **чукыныш-у, чукындыр-у; чукынган** («мәлгунь»); себ. (Тумашева 1992: 241) **цуғынты** «чукынган», **чукынчык;** к. **Чукынмыш.**

**ЧУКЫР** «клёст (птица)» ~ каз. *шоқыр* «өтерге». **Чукы-у** (к.) сүзеннән булырга тиеш.

**ЧУКЫ-У,** диал. (себ., миш.) **цуқы-у** «клевать» < гом. кыпч., к. ком., кырг., госм., чыгт. *чоқу-*, үзб. *чуқи-*, алт. *чокы-* (> башк. *суқы-у,* нуг., каз., к.-калп. *шоқы-*), хак. *чоқ-* id. ~ яз. монг. *čoqi-* (> хәз. монг. *цохи-*, бур. *сохи-*), як. *чоқуй-* «чуку, җиңелчә (көчсез генә) сугу, тортү» ~ эвенк., нан. һ.б. (ССТМЯ II: 407) *чоңкй-* «чуку; чоку»; сүзнең *чоқ-* варианты да бар. Чаг. **чокы-у.** Räsänen 1969: 114; Федотов II: 35–36 (чув. *сăх-* «чуку, чагу, төртү» сүзе белән **чукы-у** сүзен бергә карый, ләкин чув. сүзе фонетик җәһәттән сораулар уята).

Дерив.: **чукыш-у, чукыт-у;** к. **Чукын-у, Чукыр.**

**ЧУЛА I** «полосатый, полосками (о поверхности); урывками, прерывистый» ~ башк. *сула* «ара, аралык; форсат» < гом. кыпч., к. к.-балк., ком., уйг. *чола,* кырг. *чоло* (> каз. *шола*), уйг., алт. *чол* «аралык, өзеклек; тулмаганлык; буш вакыт», к.-балк. ш. ук «эшкәртелмәгән урын, чи».

**Чула** сүзе гом. кыпч. *болыт ала, җир чула* – «төрле хәлләр була» дигән мәкальдән билгеле; к. ш. ук парлы сүз: **ала-чула**.

**ЧУЛА II** иск. «псевдо-; лже-; одно только название» < яз. монг. *čola* ~ маньч. (ССТМЯ II: 405) *чоло* «титул; кушамат; псевдоним»; к. ш. ук тув. *шола*, хак. *сола*, як. *соло* «дәрәҗә, чин». **Чәлә** (к.), *чала* сүзе белән гомоген дип әйтеп булмый, ләкин ул сүз белән, ш. ук югарыдагы **чула I** белән контаминацияләнә. **Чула**, димәк, «булдыклылыгы рәсми дәрәҗәсенә тәңгәл булмаган зат» дигән мәгъ. Räsänen 1969: 115 (кор. *čol-o* «хәрби чин, атама» белән чагыштыра.

**ЧУЛАК,** диал. (миш., себ. ) **цулак,** миш. (ДС II: 185) **чулан** «однорукий, сухорукий; увечный, калека; неумелый» > мар., удм. *чулак, чолак,* чув. *чулах, чăлах* «чулак; сыңар кул; бармаксыз»; морд. Э. *цолак* «юньсез» < гом. кыпч., уйг., чыгт., үзб., аз., госм. *чолақ* (> башк. *сулақ,* нуг., каз., к.-калп. *шолақ*), кырг. *чолоқ* < бор. төрки (ДТС: 152–153) *čolaq, čoluq* «чулак» ~ яз. монг. (Поппе 1938: 136) *čolaq* id. Чаг. кырг. *чолтой-* «көтек, кисек булу», *чолтоң* (> каз. *шолтоң*) «киселгән, өзелгән нәрсәнең төбе». *Чолақ* һәм *чолтаң* сүзләренең уртак тамыры – кырг. телендә сакланган *чол-* «бер әгъзасы өзелү, чулаклану», бор. дини гадәт буенча «корбанлык кешене, аның бер кулын, бер аягын кисеп, бер күзен чыгарып, далага илтеп ташлау» (к. **Чая, Ярымтык**) һәм шул ук фигыльгә як. *чологор* «бер генә күзле», эвен., эвенк. һ.б. *чулугды, чулокэ, чӧлэкэ* (к. ССТМЯ II: 413) «сыңар куллы, сыңар аяклы, сыңар күзле кешеләр-җеннәр» сүзе дә тоташа. Чаг. тат. сөйл. **чулак-чултый** «һәртөрле кулсызаяксызлар». К. ш. ук кырг. (Будагов I: 498) *чунақ, чонақ* (к. **Чунак)** белән чагыштыра. Räsänen: 115 (уйг. *čoluq* id. *čol-* «тупак итеп кисү» – *verstümmelt verden* – сүзеннән ди. Бу – безнең фаразга су коя). Федотов II: 400; Аникин: 654, 672 (рус. диал. *чулак* «кулсыз» һәм *челюгдеи* «ярымтыклар» сүзләре тур.).

Дерив.: **чулаклык; чулаклан-у.**

**ЧУЛЛЫК** «бекас» < госм. *чуллуқ* id. ~ бор. төрки (ДТС: 156) *čulïq* «большеклювый зуёк» диелә (мондый тәфсиллек каян алынгандыр инде). Гаг. *чоллуқ* «буш җир» сүзенең мәзкүр сүзебезгә катнашы ачык түгел.

**ЧУЛМАН (Чулман иделе),** иске тат. (Из глубины столетий: 185) **Чулыман** «река Кама (чаще – до слияния с Белой)» ~ башк. *Сулман* id. Каманың элекке атамасы буларак, күрше чув., мар., удм. телләрендә дә – *Чолман.* Ләкин бу сүз, һичшиксез, төрки чыгышлы. Бу тур. Себердәге охшаш елга исемнәре булуы сөйли. Якутиянең көньягында *Чульман, Чульмакан* дигән елгалар, Көньяк Себердәге берничә *Чула, Чулакан, Чулышман* һәм, бигрәк тә, *Чулым* елгасы исемнәре бер тамырга тоташса кирәк. Шуны әйтергә кирәк, Обь елгасының ун кушылдыгы булган Чулым озынлыгы-зурлыгы ягыннан безнең Чулманнан калышмый дияргә була. **Чулышман** дигәне исә асылда Обь елгасының төп чыганагы, аның иң югаргы агымы.

Бор. төрки телләрдә *чулыман-* (к. ДТС: 156–157) *čulïman, cülimän* дип сазламык елга үзәнен атаганнар. Чулманның да, бигрәк тә безнең бор. бабалар тәү тапкыр күргән көньяк үзәне сазламыклар, култыклар, дугай күлләр белән бизәлгән. Ошбу факт та Чулман атамасының шул бор. төрки ядкәрләрдә теркәлгән *чүлимән* сүзе белән бер булуы дәлилле шикелле. Гарипова 1998: 337–341 (төрле фикерләр һәм фаразлар китерелә).

**ЧУЛПАН** «планета Венера (особенно – утренняя)» < гом. кыпч., уйг., үзб., төркм., аз., төр. һ.б. *чолпан* (> башк. *сулпан,* нуг., каз., к.-калп. *шолпан*, тув. *шолбан*), алт., як. *чолбон, чолмон, чолпон,* хак., тув. *солбон* id., алт. диал. (Баскаков 1966: 165–166; Баскаков 1972: 272) *чӧлбӧн, шӧлбон* «(гомумән) йолдыз» ~ иске монг. *čolban, čolbun* > бур. *солбанг* «чулпан; нажагай; орден». Яңгырашына караганда, бу сүз кыпч. телләренә уйгурчадан таралган.

**Чулпан** < *чолпан* сүзенә һәм образына баглы төрле легендалар бар: алт. *чолпан* «Диана, аучы кәникә, аучы гүзәл», як. *чолбон* «шайтан (иблис) кызының күзе», бур. *солбаң, солбаң* «Кытай императорының кызы» һ.б. Безнеңчә, **Чулпан** кыт. *Чжу люң ван* «күк ләве; күк аждаһасы – ләүләр патшасы» сүзеннән (к. Ахметьянов 1981: 58): кояш төнен су керә һәм иртән судан чыга башлый, шул чагында дошман ләү – шайтан аның кием киенгән мәлендә тотып йотмакчы була, әмма әлеге *Чжу люң*, бер күзен кысып, җәядән шайтанга ук ата, аның кысылмаган күзе – чулпан! К. **Таң I, Чулпы.**

Мар. *чолпан* ~ *чолган* сүзен *чолга* «якты, нурлы» сүзе белән багланышта аңлаталар; удм. *чулпон*

«чулпан» һәм *Чулмон* «Чулман» сүзләре бердәй дип карала. Тик бу аңлатмалар халык этимологиясенә тартым. Räsänen 1969: 115; Mandoky L. Asiatische Sternnamen // Glaubenswelt und Folklore der sibirischen Völker. Budapest, 1963: 521–532 (бу хезмәттә **Чулпан <** *Чолбан* сүзенең этимологиясе ачык калдырыла); МНМ II: 623.

**ЧУЛПЫ,** диал. (ЗДС: 715, 716, 762) **цолбо, цолпан, цулбы, цулбан** «серебряная бляха; накосник; кисть, бахрома; плетёный ковш – дуршлаг» ~ башк. *сулпы* id. – күпчелек кыпч. телләрендә (ком., к.-балк., кырг. *чолпу* > нуг., к.-калп. ш*олпы*) «сөзгеч, (тишекле чүмеч)» мәгъ.генә сакланган; тик үзб. *чолпа* (>> *шолпы*) сүзендә генә «хатын-кыз киеме яисә чәчләрендә түгәрәк металл бизәк» мәгъ. бар. Себ. (Тумашева 1992: 247) *чолпы* «ат ялы», сары уйг. *чолvап* «ат маңгаена бизәк өчен куелган йолдыз» **чулпан** сүзе белән гомоген.


Бу мәңгелек билгесе, вакытлар, заманалар уза, ләкин бер үк нәрсәләр онытылгач, тагын кабатлана, дигәнне белдерә

**Чулпы** сүзе (сүз уртасындагы *-п-*) иске уйг. теленнән таралган һәм иске монг. *čolbu*$^{n}$ «чулпан; йолдыз; орден» сүзеннән килә (к. ш. ук монг. *цолув* «йолдыз» ~ сары уйг. *чолы* «йолдызга охшатып чыбыктан үрелгән сөзгеч»). Түбәндә кыт. теленнән килә (С.Е. Малов фикере); *чулпан ~ чулпы* дип Кытайда мәңгелек билгесе булган челтәр фигурасын да атаганнар. Шундый мәкаль бар: *Иләк чулпыдан «синең тишегең унау» дип көлгән, ди* (ә үзенеке бихисап!). Чаг. шундый икенче бер мәкаль: *Кәҗә сарыктан синең күтең ачылып китә, дип көлгән, ди* (ә үзенеке һәрвакыт ачык) Нұрмағамбетов: 138–139 (материалы диффуз). К. **Чулпан.**

**ЧУЛЫК** «правнук» ~ үзб. (ЎХШЛ: 357) *чавлық, чувлық, чоовлық* id. (>> нуг., каз., к.-калп. *шаулық*) ~ төр. *čoluk* «зур гаилә, токым». Чаг. **Чолык.**

**ЧУЛЫК-У** (ЗДС: 762) «подтянуться от голода (о животе)» *чул-* ← бор. төрки (ДТС: 192) *čol-, čolsoqul* «бетеренү, суалу» сүзенең интенсивлык формасы (*-ык* кушымчасы, чаг. *ачу → ачык-у, талу → талык-у, үчү → үчек-ү* h.б.).

**ЧУМ** (ТТДС I: 492) «большой кувшин, большой ковш, кастрюля» ~ фар. диал. *чом, чум* ~ рус. *чум* id., к. Фасмер IV: 381, Аникин: 675. Чув. *чăм* «капкачлы зур күкшен» тур. Федотов II: 401 (**җам** сүзеннән ди, безнеңчә, бу дөрес түгел). Чаг. ш. ук **Чүмеч.**

**ЧУМА** «чума» – хәз. кулланышта рус теленнән, ләкин рус теленә Шәрык телләреннән кергән, к. төр. (Будагов I: 500) *чума* «чума, йогыш». Укр. *джума* варианты төр. сөйләшләреннән булса кирәк. Фасмер IV: 381–382.

**ЧУМАК I,** диал. **сумаҡ** «vulva», вообще половой орган, иске тат. (Будагов I: 500) **чумак, чумбал** «ремесленные орудия, инструменты» (вернее «кожаная сумка с инструментами») ~ башк. *сумаҡ* (БТДҺ: 284) «*касык», «кабарып торган» ~ венг. *szomak* «күн шешә, фләгә» < госм. *чомаҡ* «күн сумка, янчык». Чаг. **Чумак II, Чумака.**

**ЧУМАК II** «возница; подвода (на дальнюю дорогу)» < рус., укр. *чумак* id., ш. ук «тоз һәм балык сатучы сәүдәгәр» төр. *чумаҡ, чомаҡ* «күн бидрә, дегет чиләге» сүзеннән дип уйлыйлар, чөнки озынозак юлга йөрүче сәүдәгәрләр h.б. күн дегет савыты тагып йөргәннәр (чаг. тат. мәкаль: *Дегет чиләге дә хаҗга бара*). **Чумак** сүзен З. Вәлиди (Velidi: 51) бор. төрки *čotaq, čötük* дигән төрки кабилә – танылган сәүдәгәр кавеме белән бәйли. Көнч. слав. телләрендә *чумак* сүзе төрле мәгънәләрдә очрый (к. Аникин: 674): «олаучы; кабакчы», «ахмак» (сүгенү сүзе, к. **Чумак I**), «дүртпочмаклы туз савыт» (к. **Чумака**), «агач чүкеч». Соңгысы уйг., кырг. диал., гаг., фар. *чомаҡ,* көрд. *çomax*, госм., төр. (Zenker I: 375; Будагов I: 500) *чумаҡ* «сугыш чукмары; томар (жезл), тимер кисап; зур кашык» (> лезг. h.б. Кавказ телләрендә «шар башлы таяк») сүзләреннән килә. К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 153) *čomaq* «гаса, таяк; томар». Бор. төрки (op. cit) *čomaq* «мөселман» сүзен Дж. Клоусон (Clauson: 422) мөселманнарның күсәк белән кораллануы, ә Ф. Сумер (Sümer 1992: 32) аларның күн капчык тотып йөрүләре белән аңлаталар. Уйг. *чомаҡ* «нык, көчле кеше» төрлечә аңлатыла ала.

**Чумак ~ чомак** сүзенең барча мәгънәләре төрки **чомгаҡ* «текә ярдан су чумырып алу өчен сапка беркетелгән күн савыт» сүзеннән килеп чыга алалар, ләкин моны исбатларга кирәк. К. **Чумака.** Фасмер IV: 382.

**ЧУМАКА,** диал. (Арсланов 1992: 155) **шомака** «ковш, черпак, половник» ~ башк. (БТДҺ: 284)

*сумаҡа* «баш чүмече» ← *чум-у* булса кирәк. К. югарыдагыны.

**ЧУМАН** (ТТДС I: 492) «четырёхугольная корзина (которая ставится на санки) или плетёные санки для катания» ~ башк. (БТДҺ: 284, 395) *суман, шуман* «озынча тагарак; кәрзин; талдан үрелгән каз, үрдәк оясы», чув. *чуман,* мар. *чоман,* мар. Т. *чӧман* id., ш. ук (Упымарий: 244) «каездан эшләнгән чаңгы», удм. *чумон* – төрле кәрзин атамалары, рус. (Даль) *чуман* «туз кызау; соскы, соскыч; улакланган каез кисәге – аны чана шуу һәм печән ташу өчен файдаланалар» диелә. Рус. этимологиясендә бу сүзне остяк (ханты) яисә чуваш теленнән кергән дип исәплиләр, ләкин хәлиткеч дәлилләр юк. Төп мәгъ. «каез (кайнатып эшкәртелгән ныклы юкә кабыгы, кайрысы)» булырга тиеш һәм, безнеңчә, **чуман** сүзе фин-угор телләреннән килә. Фасмер IV: 382; КЭСК: 313; Федотов II: 422; Аникин: 674.

**ЧУМАР,** (ЛТ I: 174) **чумур,** (Будагов I: 500) **чүмүр,** (ТТДС I: 507) **чумӗр,** (Зимасов: 114) **чумир,** (ТТДС I: 492; Г. Толымбай) **чумара** «клёцки» («нечкә озын камыр кисәген турап ашка салынган ашамлык», к. Хайрутдинова 1993: 77–78) ~ башк. (БТДҺ: 284) *сумар* «дүрткел салма» ~ мар. *чомар*, морд. М. *цёмара* «арыш онынннан пешерелгән чумар»; КЭСК (: 394) авторлары фикеренчә, бу сүз удм. *чумер,* коми. *чомӧр* «беренче яңа уңыш ашлыгыннан пешерелгән ритуаль ашамлык – чумар» сүзеннән. Бүтән төрки телләрдә **чумар** сүзе үз мәгъ. юк шикелле, шунлыктан аның фин-угор телләреннән (субстрат телдән) алынган булуы бик ихтимал. **Чумара** варианты «бушлай ашау-эчү, тиген табыш» мәгъ. очрый: бу факт та әлеге фараз файдасына: яңа уңыштан беренче ашны бөтен авыл бергә ашаган (чаг. **күҗә, тахил**).

**ЧУМБАЛ** «мешок с инструментами (у бродячего ремесленника)» (к. Будагов I: 500) – каз. *шомбал* «зур чувал»; к. эвен. *чомпули* «тарбаган (монгол байбагы) тиресеннән эшләнгән капчык, толын, янчык». Ләкин арадаш сүзләрнең юклыгы бу чагыштыруны бик зәгыйфь итә. *Чумбал* фар. диал. *җӯми баҕал* «әйбер капчыгы» сүзеннән булуы ихтималрак (*җӯм* «капчык; сүрү», *баҕал* «әйберләр, мөлкәт»).

**ЧУМГА** (Будагов I: 500), себ. (Тумашева 1992: 242) **цумға,** урта диал. (ТТДС I: 492) **чумгаҡ** «нырок, чомга» ~ башк. (БТДҺ: 284 һ.б. чыганаклар) *сумаса, сумғош, сумғы, сумғыс өйрәк, сумҡа* id. ~ чув. *чăмăш* «күлбога», *чăмкăҫ* «чумга», удм. *чомга*, мар. (Упымарий: 245) *чомга, чонга* «кулик, шөлди» << бор. төрки (ДТС: 152, 153) *čomүuq, čomuq* «чумга» – гом. төрки сүз булырга тиеш (тик сүзлекләрдә еш кына теркәлми); к. тик хак. *сомғы, соңма* «күгәл», бор. төрки (Мухамедова 1973: 190) *чомуқ, чомғуқ, чомғақ* «карга» (?). **Чумга,** әлбәттә, *чум-* < *чом-* фигыленнән. Рус. *чомга, чёмга* «чумга» тур. Аникин: 667. К. түбәндәгене.

**ЧУМГАЛАК** «чомга, нырок» – тат. теленең үзендә **чумгала-у** фигыленнән ясалган һәм тамырдаш **чумга** (к.) сүзе белән контаминацияләнгән.

**ЧУМ-У,** диал. **цум-у,** (ТТДС I: 358) **чумна-у** «нырять; окунаться» > чув. *чăм- [чŏм-]* << бор. төрки (ДТС: 153, 155) *čom-, čӧm-* id. Борынгыдан бирле калын һәм нечкә вариантларда кулланыла: ком., алт., госм. һ.б. *чом-* (> башк. *сум-, сумғы-,* нуг., каз., к.-калп., шор. *шом-* > хак. *сом-*), як. *ум-* (*умус-* «чумышу») ~ к.-балк., кырг., уйг., чыгт. *чӧм-* «чуму; чумдыру», үзб. *чӧм-* «йөзү». Чаг. **Чоңгыл, Чүмеч, Шоңгы-у.** Räsänen 1969: 115; Федотов II: 401 (бик ярды).

Дерив.: **чумыл-у** (христианнардагы бер йоланы да белдерә, к. ТТДС I: 358), **чумын-у, чумыш-у, чумдыр-у.** К. ш. ук **Чумга, Чумыр-у.**

**ЧУМЫР-У** (ТТДС I: 492, гомумән еш очрый) «погружать (и вынимать)» ~ башк. *сумыр-* id. < диал. **чумгыр-у** id. ← **чум-у** (к.). Гомумән, бу сүз төрле юллар белән ясала ала (мәс., **чумдыр-у**дан кыскарырга мөмкин) һәм гом. төрки характерда, к. бор. төрки (ДТС: 153) *čomur-* «чумыру», *čomur-miš* «чүмеч» һ.б. **Чум-у** һәм **Чумыр-у** сүзләре тәкълиди тамырдан булырга тиеш, чаг. тат. **чумп ~ чулт** – суга кечерәк таш төшкәндәге, бака чумгандагы һ.б.ш. авазга тәкълит.

Дерив.: **чумырт-у; чумыргыч** «зур чүмеч; су алгыч бидрә».

**ЧУНАК** диал. «отвергнутый; в отшибе, в стороне от дорог (о селении, доме)» ~ каз. *шұнақ* «колагы киселгән (җәзаланган) кол», кырг. *чунақ* «колаксыз, колагы киселгән; артык шаян бала; шалапай» һ.б. к. Будагов I: 498. Чаг. тат. диал. **чунтык, чонтык** «берәр бармагы яки колагы киселгән һ.б.»

**ЧУНТАЙ, чонтый** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «мошонка, яйца быка; мешочек из мошонки быка», диал. (Арсланов 1988: 99) **чӧнтай** «портмоне» >

мар. *чонтай* «янчык» < гом. кыпч., к. ком. *чонтай* «кисет», үзб. *чонтай*, уйг. *чөнтәк*, кырг. *чонтой, чөнтөй* (> нуг. *шоңтай*, к.-балк., к.-калп. *шонтай*) «чунтай; кесә», төркм. (ТДГДС: 198) *чонтай* «капчык» монг. телләреннән булса кирәк, к. яз. монг. (Поппе 1938: 435) *čип* «сумка» (*čuntaj* «сумкалы»). Рус. *сондой* «чунтай» < монг. тур. Аникин: 504.

**ЧУПАЙ** (ТТДС I: 493; ТТДС II: 358) «ребёнок, который сосёт свой палец; соска, жёвка» – безнеңчә, бу мәгънәләр икенчел, чөнки к. диал. (трбс.) **чупай (чупай ябалагы)** «байгыш; чырайсыз ябалак; сыч», башк. (БТДҺ: 284) *супа йабалаҡ, супай өкөһө, супайҙы (< чупайлы)* «төкле аяклы ябалак», *супай* «чупай; байгыш, ялгыз яшәүче кеше», ш. ук «бүрек (кошларда)». Мисаллардан күренгәнчә, төп мәгънә – «өкеләрнең башында була торган колаксыман каурыйчыклар; кәкел» һәм бу хәл ошбу сүзне рус., укр. һ.б. слав. (Фасмер IV: 375) *чуб* id. ~ ним. *Schopf* id. сүзе белән чагыштырырга мөмкинлек бирә. Ностратик сүз микән?

**ЧУПАН** «чабан, овечий пастух» < уйг. *чопан*, үзб. *чупон* < фар. *чӯпāн, шубāн* < авест. *fšupana* «терлек саклаучы»; к. ш. ук кр.-тат., төр. һ.б. *çoban* >> рус. *чабан* id. Аникин: 633.

**ЧУПТАР,** (ДС III: 187) **чыптар** «тканый узор; техника узорного тканья с разноцветными нитками» ~ башк. *суптар* < фар. *җүфттāр* id., сүзмә-сүз «парлы җеп» (*җүфт* «пар, парлы, икеләтелгән», *тāр* «җеп»). К. **Чүплә-ү III.**

Дерив.: **чуптарлы; чуптарла-у.**

**ЧУПЫР** (ТТДС I: 493) «веснушки, пупыри; веснушчатый» ~ төр. *çopur* id., ш. ук «чуар болан, жираф» << монг. **чупаҡур*, к. **Чуар**. Будагов I: 491.

Дерив.: **чупырчык; чупырлы.**

**ЧУР I** (ТТДС I: 493) «предел; промежуток», «дальше не ходи, остерегайся» ~ рус. (Фасмер IV: 385) *чур* id.; рус сүзенең төгәл генә этимологиясе юк, шунлыктан тат. (миш.) *чур* сүзен рус теленнән дип кистереп әйтеп булмый. К. ш. ук Кондратьева Т.Н. Собственные имена в русском эпосе. Казань, 1967: 117–119, 125.

Дерив.: к. **Чурсыз** (рус. *черезчур* сүзеннән ярымкалька).

**ЧУР II (чуры?)** диал. «рисунок, чертёж; схема; рамка; украшение речи, образность» (миш. **чурла-у** «сәнгать; сәнгатьчә сөйләү»), себ. (Тумашева 1992: 242) **цур** «чана» ← *цурлы цанак* «үрәчәле чана» сүзеннән эллипсис булса кирәк; безнеңчә, бу сүз яз. монг. *ǯiruγ* «сызым; план» > хәз. монг., бур. *зураг* «рәсем, сурәт, сызым», алт. *дьуруҡ*, тув. *чурук* «рәсем, бизәк; фото» ← яз. монг. *ǯiru-* >> тув. *чуру-* «рәсемләү; фотога төшерү» ~ эвенк. һ.б. (ССТМЯ I: 278; 600) *ǯурӯ-* «рәсемләү, сызымлау» һ.б. сүзеннән килә. К. **Йорын, Чурла-у**, **Чур-у.**

**ЧУР III** – имитатив звукам, издаваемым жабами и лягушками, а также урчанию (достойно внимания *чур* ~ **урч*) ~ себ. (Тумашева 1992: 242) **цур** «шум, крики, визг».

Дерив.: **чурла-у, чурылда-у** (> башк. *сурла-у, сурылда-у*); ТТДС I (493 сәхифәдә) күрсәтелгән **чурла-у** «ачыгу» – *эч чурла-у* дигәннән эллипсис; к. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 240) **цорла-у** «чурлау».

**ЧУР IV, чŏр** «опухоль; болезнь, горе» ~ башк. (БТДҺ: 284) *сур* id. < гом. төрки, к. кырг. *чор* «каткан шеш», төр. *çor* «хасталык, авыру, чир», төркм. *чор* «чуан», чаг. ш. ук як. *сор* «афәт; каза», тат. **чир-чор** «һәртөрле (шешле, яралы) чирләр», *чёрный бүсер, чур бүсер...* «бүсер куу ырымындагы такмак» (Н.В. Юсупов); фар., көрд. *çor* «эпидемия; ваба; авыр яра; бәла-каза».

**ЧУРА** «слуга, работник; батыр, служащий хану» позднее (**чура кол**) «крепостной» ~ кр.-тат. *çora,* нуг. *şora* «шәрәфле әсир», «шәрәфле әсир белән гади бер кыздан туган ир бала» < гом. кыпч., к. башк. *сура,* кар. *чора, цора* «хезмәтче, хадим», кырг. *чоро* «би токымы, бинең, ханның гвардия гаскәрие», төркм. *чооры* «кол токымы» > нуг., каз., к.-калп. *шора* «хадим; морза», эпоста – «баһадир углы» (к. Будагов I: 674) ~ кырг., алт., госм. *чор, чөр* > алт., диал. хак. *шор* «шәрәфле кол», бор. чыгт. («Келурнамә»дә) *чөрӓ* «аристократия» ~ калм. *tsora* «гаскәри, алпар» һ.б. < санск. *çūra* id. (Ramstedt 1935: 430); к. ш. ук иске укр. *чура, джура* «кучты, корал йөртүче; хәрби тәрбиягә алынган яшүсмер», уйг., үзб., таҗ. *җура, җора* «дус, иптәш; кияү егете». *Җору, җура, чура* монг. халыкларының төп эпос герое Гэсәрнең тәүге исеме була, к. МНМ I: 284.

**Чура** сүзе Урта Идел регионында борынгыдан билгеле, к. чув. *чура* «хезмәтче әсир яисә әсирә», мар. *цора, чёра* «хезмәтче малай; нииндидер бер изге» (к. Holmberg: 79), удм. *сюр, сьор* «читтән килеп җәмгыятькә алынган кеше». Морд. М. *цёра* «угыл, углан». Федотов 1990: 276; Федотов II: 424–425;

Черных 1980: 39–40; Тимергалин: 545. К. **Чураман, Чураш, Чүре.**

**ЧУРАГАЙ** (к. мәкаль: *Чуртан чурагайны йотмас,* Исәнбәт I: 562), диал. (Тумашева 1992: 240) **цорағай** «щука средней величины» ~ башк. *сурағай,* (БҺҺ II: 219) *сураҡай* > мар. (Исанбаев 1978: 22) *чорагай* «чуртан» ~ каз. *шорағатай*, як. *чорохой* << яз. монг. *čiгiхаj* (> хәз. монг. *цурхай*, бур. *сурхай*) ~ эвен. (ССТМЯ II: 400) *чеерукай* һ.б. «яшь чуртан». К. ш. ук саян. (Рассадин 2008: 191) *шурхай* «чурагай», *шуруш* «чуртан». Рус. *черугайка, чурагай* һ.б. (күп фонетик модификацияләр) тур. к. Аникин: 658. К. **Чуртан.**

**ЧУРАМАН** тар. «начальник над слугами, прислугой» ~ башк. *сураман* ← **Чура** (к.)

**ЧУРАП** иск. «узорчатые цветные носки девушек в старину» ~ добр (Dobr. III: 493) *çorab,* төр. *çorap* < гар. *җураб* < фар. *гураб* id. К. ш. ук рус. (Даль) *джурапки, чурапки* id.

**ЧУРАШ,** диал. **сурас** «внедрившийся в семью, род, народ, инородец; отатарившийся представитель другого народа». Бу сүз норматив сүзлекләрдә (ТТАС һ.б.) теркәлмәгән; диалекталь сүзлекләрдән Д.Г. Тумашева (1992: 194) **сурас** «никахсыз туган бала» сүзен китерә. «Башҡортса-русса һүҙлек»тә (1996: 557) *сураш* «название одного из родов племени **үҫәргән**» диелә, ләкин шул сүзлеккә кушымта итеп бирелгән кабилә-ыру атамаларында *сураш, чураш, шорас* тагын төрле сөйләшләрдә биш-алты урында искә алына.

**Чураш** сүзен уртак мәгънәдә без 1986 елда Иглин районының Бибакты авылында очраттык: *Балхиярлар – чурашлар алар, чуваш нәселеннән... фамилияләрен мөселман исеменә алмаштырганнар,* диде Габитова Хәлимә (1911 елгы әби). Мин ул чагында бу сүзгә әһәмият бирмәдем, берәр төрле кушамат дип уйладым. Ләкин тагын берничә ел үткәч, У.Э. Эрдниевның «Калмыки» (Элиста, 1970: 209) дигән тарихи-этнографик китабында *цорос, чорос* «чужак, окалмычившийся тюрк» дигән сүзләрен укыгач тат. телендә дә **чураш** «татарлашкан чит халык вәкиле» сүзе булганлыгын аңладым. Калмыклар *шаган цорос* «ак чураш», ягъни «калмыклашкан татар», *шара цорос* «сары чураш», ягъни «калмыклашкан башкорт», *хара цорос* «кара чураш» «калмыклашкан казак яисә нугай» төркемнәрен аералар икән. Ихтимал, кайчандыр *цорос, чорос* «гомумән төркиләрне белдергәндер, хәзер исә алай түгел: кыпчак төркиләрен калмыклар *мангыд* < *мангуд* дип атыйлар (шуннан *шаган мангд* – татар, *шара мангд* «башкорт», *хара мангд* «казак»). Гомумән, *цорос, чорас* сүзе калмыкларның борынборыннан килгән ыру-кабиләләренә карата киң кулланыла (Номинханов 1969: 199–203) һәм аның озын тарихы бар. XIV г. монголлар *солгар* «сул кул, көнчыгыш» вә *җуңгар* «уң кул, көнбатыш» төркемнәренә бүленәләр. Җунгарларның легендар беренче ханы баласыз-токымсыз вафат булгач, аның урынына чыгышы билгесез (аны байтирәк төбеннән табып үстергәннәр) егетне – *Чорос*ны чакыралар. Һәм шуның токымнары җунгарларның һәм алардан аерылып чыккан калмыкларның идарәче груһын тәшкил иткәннәр. Бу *Чорос* турында монгол халыкларында исәпсез күп легендалар йөри (МНМ II: 632–633, С.Ю. Неклюдов мәкаләсе).

**Чураш** сүзе, гомумән, татарларга бөтенләй таныш булмаган сүз түгел: *Чураш, Сураш* дигән авыллар Идел-Урал регионында еш кына очрый (к. Башкирская АССР. Административно-территориальное деление. Уфа, 1969: 426; Татарстан республикасының административ-территориаль бүленеше. Казан, 1992: 286); *Чурашев* дигән фамилия билгеле.

Әйтелгәннәрдән чыгып, **чураш** сүзе монгол телләреннән алынган дип уйларга ярамый. Хикмәт шунда: *чураш* < *чораш* сүзе закончалыклы фонетик модификацияләрдә Себер төрки телләрендә дә очрый: Н.Ф. Катанов җыйган фольклор материалларында (Абакан 1963: 20–26, 98–109) *Сурас, Сураз* – ата-анасыз үскән (типологик) батыр образы. Алтайлыларда **Сурас Кыпчак** бор. ыруларның берсе, төбендә, имеш, ялгызын үскән сукыр баланың токымнары (к. Алтай кеп-куучындар: 197–198). Рус сөйләшләрендә, бигрәк тә Себердә, *сураз* «уйнаштан туган яисә иярчен бала» (к. Фасмер II: 806; Словарь русских говоров Новосибирской области. Новосибирск, 1979: 528, 556), хак., алт. телләрендә *суразак* «ятим үскән бала» һ.б.

**Чураш ~ сураш ~ сурас** сүзен С.Ю. Неклюдов (МНМ II: 632–633) төрки-монгол телләрдә киң билгеле *чура* < *чора* (варианты *чур* < *чор*), башк. *сура* «ханга хезмәт итүче батыр, хан кургавылының бер яугире» сүзенең монголча күп. формасы (*чора-с*) дип аңлата. *Чураш* сүзенең *чура* тамырыннан ясалуы бик мөмкин. Ләкин ни өчен монда ауслаутта *-ш* килеп чыккан соң? Монысы аңлашылып бетми. Шунлыктан *чураш* сүзен төркичә **чурағач* < *чорағач* < *чорғач* сүзеннән (*чура ~ чур* сүзенең иркәләү-кечерәйтү формасыннан) килүе

дә бик мөмкин, чөнки төрки телләрдә *-гач* кушымчасының *-гаш* яңгырашын алуы еш кына (нуг., каз., к.-калп. телләрендә генә түгел) очрый, мәс., татарча *тәлгәш* < *тәлгәч, ялгаш* < *ялгач*. Алтай-Саян төркиләрендә *Сурагаш, Суразак* кебек ялгызлык исемнәре бар.

Тарихи җәһәттән *чураш* < **чураҕаш* сүзенә **чуваш** этнонимы бик бап килә, ләкин *-р-* авазы кая югалган, дигән сорауга җавап юк.

**ЧУРГА** (Будагов I: 493) «носок или рыльце сосуда» > мар. (Упымарий: 245) *чорко* id. < гом. кыпч., к. ком., к.-балк. *чорға,* алт., кырг. *чорҕо* (> нуг., шор., тув. *шорға* > хак. *сорҕо*) «улакчык; чөмәк; чурга», як. *сорго* «керәч торба яисә труба» < иске монг. *čoroγa* «труба»; к. ш. ук яз. монг. *čorγu*, хәз. монг. *цорго* > эвенк. һ.б. *сарго,* маньч. *чорхо* «чурга, труба, семәк һ.б.ш.» Räsänen 1969: 116; Номинханов 1975: 160; ССТМЯ II: 65, 409. Рус. *шорга* < шор. *шорга* «агач торба» тур. Аникин: 706.

К. ш. ук **Чүгәтәй, Чүргәт.** Башк. (БТДҺ: 284) *сурҡай* «борылмалы, бөгелгәләгән (агач кәүсәсе)» сүзе дә **чурга** белән баглы булса кирәк («труба сыман»). Чаг. **Чогыр.**

**ЧУРГАК**, себ. (Тумашева 1992: 242) **цурғаҡ** «неумеха; неряха» ~ башк. (БТДҺ: 287) *сурҡаҡ*, кырг. *чорҡоҡ,* каз. *шорҡаҡ,* к.-калп. *шорғаҡ* «булдыксыз; тәҗрибәсез; җубалгы». Чаг. түбәндәгене.

**ЧУРГА-У, чүргә-ү** «наскоро намотать, беспорядочно перевязывать; скручивать», миш. (ТТДС I: 497) **чырга-у** «чорнау» ~ кырг. *чорго-, чөргө-,* тув. *чөрге-*, к.-балк. *чёрге-*, чыгт. (Будагов I: 493) *чүргәмәк* «бөрештерү, чүргәү». Чаг. **Чорна-у, Чырымта, Чүч-ү**.

**ЧУРЛА-У** диал. «изукрасить; витиевато говорить» < *чуры-ла-у*. К. **Чур-у**.

**ЧУРСЫЗ, чорсыз** «беззастенчивый; бестактный; наглый» ~ чув. *чăрсăр* id. Федотов (II: 405) рус теленнән кергән **чур** (к.) нигезеннән тат. һәм чув. телләрендә параллель (дөресрәге – үзара калькалаштырылып) ясалган дип күрсәтә. Безнеңчә, ул хаклы.

Дерив.: **чурсызлык; чурсызлан-у.**

**ЧУРТ** «чёрт» < рус.

Дерив.: **чуртым** (*чуртым да юк, чуртымамы кирәк* һ.б. дигәндә).

**ЧУРТАН**, диал. **цуртан** «щука» > мар. *чортон* < гом. кыпч., төркм., үзб. *чортан,* алт., кырг. *чортон* (> нуг., каз., к.-калп., тув. *шортан*), хак. *сортан,* як. *сордон, сордоң,* чув. *çăрттан* id., госм. *чортан* «еланбалык» ~ бур. *сордон,* эвенк. (ССТМЯ II: 113) *сордоҡ, чордоң* «чуртан». Тат. диал. (Тумашева 1992: 135) *куртан, култан* яңгырашы сәер: ихтимал, ул эвенк теленнән әйләнеп кайткандыр (эвенк сөйләшләрендә *сортон* > *һортон* > *хортон* > тат. *куртан* булуы мөмкин), ләкин к. маньч., ульч. *ҡору*, маньч. (ССТМЯ I: 404) *ҳоро, ҳувара* «чуртан». Башк. телендә (һәм бүтән алтай телләрендә дә) *чуртан* ~ *суртан* сүзенең вариантлары бик күп (к. БТДҺ: 282–287). **Чуртан** < *чортан* һичшиксез **чурагай** (к.) сүзе белән тамырдаш, чаг. каз. *шораҕатай* «чуртан», *-гай* кушымчасы да, *-тан* кушымчасы да монг. телләренә хас һәм, күрәсең, бу сүз монг. телләреннән таралган – тәүдә Амур елгасының урта агымнары тирәсендә яшәгән монголлар балыкчылыкны төркиләрдән яхшырак белгәннәр. К. **Чурыш.** Räsänen 1969: 116; Федотов II: 98–99 (бу авторларда материал бик аз – гади параллельләр генә); рус. *сордонка* «чуртан» (төрки телләрдән) тур. Аникин: 506.

**ЧУР-У** «беспорядочно, наскоро стегать» к. **Чурга-у.**

**ЧУРЫШ** (ТТДС I: 493) «ёрш» – русчадан булуы ихтимал, ләкин к. **Чурагай, Чуртан.**

**ЧУТ I** «счёты (приспособление); число, количество, значимость, разряд, категория (людей)» ~ мар. *чот, шот*, удм. *чот*, чув. *шут* id. (мәгънәләре татарчаныкыннан киңрәк һәм алар ешрак кулланылалар да) < рус. *счёт, счёты.* Бу сүзләр бүтән төрки телләргә дә кергән: башк. *сут*, кырг. *чот*, каз. *шот* һ.б. «чут».

Дерив.: **чутлы, чутсыз; чутла-у, чутлан-у; чутыннан** (рәвешләшкән чыгыш килеш формасы).

***ЧУТ II** (дериватларыннан һәм кушма сүзләр составыннан чыгарыла) «поперечный топор» < кырг., уйг. һ.б. *чот* (> каз. *шот*) id.

Дерив.: **чутла-у** (> чув. *чутла-*, мар. *чотла-* «юну, юнып чыгу (бура бүрәнәсен эчке яктан)».

**ЧУТЫР,** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **чутрай, чутрый** «корявый, рябой; пятнистый, пёстрый; разводы; пятна» < фар. теленнән бор. алынма, к. башк. *сутыр*, кырг. *чотур*, алт. *чодур*, үзб. *чотир*

«чутыр». К. **Шадра. Чупыр** (к.) сүзе белән тамырдаш түгел.

Дерив.: **чутырлы, чутырсыз; чутырла-у.**

**ЧУХРЫЙ** иск. (Г. Камал) «одетый чрезмерно пышно; чересчур франтоватый; щёголь, франт» > мар. *чукри* id. < госм. *чухадари*, халыкча *чухрай* «сарай хадимнәренең сәер дәрәҗәдә купшы (биек үкчәләр, гадәттән тыш биек, мөгезле, җәенке һ.б. калпаклар, чулпылар белән характерлы) киеме» ← *чухадар* «сарай хадиме; яничәриләрнең дәрәҗәләренә тәгаен формаларын киенгән офицерлары» ← *чуха, чоха* «махсус озын кием; кыйммәтле сукно» ~ фар. *чӯх̣ā* id. Бу сүз рус., пол. телләрендә билгеле булган, к. рус. (Фасмер IV: 377) *чуга, чугай, чуха, чоха* «озын кафтан». Безнең якларга бу сүз Кырым татарлары аша килгән булса кирәк.

**Чухрай** «көязлеккә дәгъва итеп, зәвыксыз киенгән кеше» сүзе рус., укр. телләрендә дә очрый.

**ЧУЧКА,** себ. (Тумашева 1992: 242) **цуцка, цуцкы,** «поросёнок; свинья» < гом. кыпч., уйг., үзб. *чочқа* (нуг., каз., к.-калп. *шошқа,* башк. *сусқа*), кырг., алт. *чочқо,* к.-балк., хак. *чочха* id. госм. *чуҗыға, чоҗыға* «бәләкәч чучка», кар. *чочха, цоцқа* «малай, яшь егет», *чочуқ* «имгәк баласы, бәби», чыгт. *чочуқ,* бор. төрки (ДТС: 150) *čočuq* «чучка, дуңгыз баласы» ~ төр. *čocuk* «яшь бала» ~ себ. (Тумашева 1992: 240; Дмитриева 1981: 195) **цо̄цук, цоцык** «имчәк», тат. диал. (ТХИ: Дастаннар 1984: 141) **җожык** id., миш. (ТТДС I: 570) **жежык**, (ЗДС: 717) **цуцык** «әрәмтамак, буйга җитеп тә файда китерми торган егет яисә кыз», каз. (Нұрмағамбетов: 45) *җожық,* төркм. *җоҗуқ* «чучка, дуңгыз баласы» һ.б. бор. төрки **чочуңа* «чучка» > чув. *сысна* (> мар. *сосна, сöсна, сисна, сасна*) «дуңгыз, чучка» ← *чочу-* «чупылдатып имү» тәкълиди сүзеннән, шуннан ук грек. *ςυς* [*сус*], лат. *sūs* «чучка», к. Федотов II: 77.

*Чучык* ~ *Чучка* сүзе күп кенә бүтән телләргә дә кергән: манси. *tšuško* «дуңгыз», көрд. *çuçik* «бәби, имчәк баласы»; рус. *чушка* «чучка, дуңгыз» сүзен дә Л. Будагов (I: 491) татарчадан ди; рус. диал. *чучак* тәгаен татарчадан; рус телендә һәм кайбер кардәш телләрдә *чуча* «чучка, дуңгыз» сүзе бар һәм шунлыктан рус *чушка* сүзен шул (ш. ук тәкълиди) тамырга нисбәт итәләр (төрле карашлар тур. к. Аникин: 679–680).

Дерив.: **чучкачы; чучкачылык** «дуңгызчылык»; диал. **чучкала-у** (сөйләшләрдә *чучка* «дуңгыз баласы», *дуңгыз* «үсеп җиткән хайван» ачык аерымлана); **чучкалык.** Тат. гади сөйләмдә **чучка**, башк. *суска* «юньсез, әдәпсез яшь кеше». **Чучка** «дуңгыз, морҗа терәге» мәгънәсе (ТТДС I: 493) **дуңгыз** сүзеннән калька буларак халык этимологиясе буенча килеп чыккан. К. **Туңгыз.**

**ЧҮ** ы. «чу; цыц» – киң таралган мәдәни сүз: ком. *чув* «тавышсыз-өнсез», коми. *чöв* id. һинд. *čhи* «чү!» һ.б. Рус. *чу* сүзен *чуть* «әз генә» яки *чуять* «сизү» сүзләре белән баглау (Фасмер IV: 375) бигүк дөрес булмас. Чаг. бор. төрки (ДТС: 156, 524–525) *či, čï, šu, šü* «-чы//-че» (үтенү кисәкчәсе).

**ЧҮӘК,** (ТТДС I: 507) **чүwәкәй** «тапочки, сплетённые из грубых ниток, шнурков» ~ диал. (ТТДС I: 507–508) **чөбәк, чүбәк,** (Тумашева 1992: 242) **цүбәк** «пакля, грубые волокна льна, конопли и т.п.; жгутики из пакли, тряпья» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 285) *сүбәк* «чүәк», «чүбек», кырг. *чөпек,* шор. *шӧбäг* « чүбек», үзб. (ЎХШЛ: 306) *чувәй, чувак* «чүәк» ← *чүп, чөп*, к. **Чүп**. Калдык-постык сүсләрне эрләп-борып яки ишеп ясалган киндерәләрдән үрелгән чүбәк ~ чүәкләрне без дә күргәнебез бар. Рус. *чувяк, чувяк* сүзен Фасмер (IV: 323) чеч. *čиаke* «башмак» белән чагыштыра, ләкин ул, күрәсең, тат. сүзен белмәгән. К. түбәндәгене.

**ЧҮБЕК** «очёски; пакля; мусор» ~ башк. *сүбек, сүбәк* > чув. *чүпĕк*, мар. *чӧвык* id. тат., башк. **чүбәк ~ сүбәк** (к. югарыда), **сүбәк бораү** «чүбек чәйнәү, буш сүз сөйләү» – төбендә «чүбектән чүәк ясау өчен калын җепләр, киндерәләр борау, бөтерү». Венг. *scöpü* «чүбек» сүзенә караганда, бор. төрки **чöпүг* сүзе булган һәм шуннан төрле юллар белән тат. **чүбәк** һәм **чүбек** килеп чыккан (турыдан-туры **чүбәк** > **чүбек** яки киресенчә түгелдер). Федотов (II: 427–428) бу сүзне «бор. чуваш сүзе» димәкче.

Дерив.: **чүбекле, чүбексез; чүбеклә-ү** (диал. «чүпләү, чүп барлыкка китерү»).

**ЧҮГӘЛӘ-Ү** «сесть на карточки, приседать» < гом. кыпч., чыгт. (Радлов III: 2028) *чӧгäлä-*, башк. *сүгәлә-* «тезләнү, чүгәләү» ← *чӧк-* «чүгү» (бу фигыльнең ешайту интенсивлык формасы, ягъни тәүдә **чүгәләү** «бер-бер артлы берничә тапкыр чүгү» мәгъ. булган, чаг. «чүгәләп бию»). Чаг. **Чүкәй-ү.**

**ЧҮГӘТӘ, чүгәтәй,** (ТТДС II: 369) **чүбәтә, чүвәтә, чүwәтә,** себ. (Тумашева 1992: 242) **цүгәцәй, цүәцәй** «блюдце (с носиком)» ~ башк. *сеүәтә* < монг. *чӧргäтäй* id., к. **Чүргәт.**

**ЧҮГЕРМӘК, чүгәрмәк** (ТТДС I: 369), диал. (ТТДС I: 504; ТТДС II: 368) **чөгөрмәк, чөкөрмәк** «маленькое глубокое озеро, яма, наполненная водой; провал; подбоина; водоворот над ямой на дне» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 285) *сүгермәк,* кырг. *чөгөрмө* «чүгермәк» ← *чөгүр-* (> каз. *шөгер-,* к.-калп. *шөгир-*), уйг. *чөкүр-, чөкәр-,* төр. *çöker-* «түбәнгә төшерү, түбәнәйтү, чүктерү, чүгерү» ← *чүк-* ~ *чөк-*, к. **Чүк-ү**. Чаг. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 305) *чөгүрмә, чөгирмә* «тирән бүрек»; бур. *сүнхэрэг* «чүгермәк, сулык», *сүнхэ* «иңкүлек» < гомумән **чөңкәг* id. ← *чөңк-* «чүгү».

**ЧҮК, чөк** (Остроумов 1892; Баязитова 1986: 248 һ.б.) «праздник после заговения в Троицын день» ~ чув. *чĕк, чук, чӧк, чүк*, мар. диал. (Иванов, Тужаров: 262; Саваткова: 186 һ.б.) *цӧк, цүк, чок, чокымыш* id., удм. *чук, чеке, цӧк* «үлгәннәрне искә алу (Труйчын) көнендә кычкырык сүзе» ~ алт. *чӧк* > шор. *шӧк,* алт. диал. *шок* – мәҗүси корбан бәйрәмендә кычкырык сүзе. Чув. һәм мар. телләрендә бу сүз күпмәгънәле (к. Ашмарин XV: 261–265) һәм продуктив сүзьясагыч нигез, ләкин объектив тикшеренүчеләр (к. Itkonen: 263) аны тат. теленнән, тат. мәҗүсилегеннән таралган диләр. *Чүк* < *чөк* сүзе һәм йоласы монг. халыкларында X г. бирле билгеле (к. Dioszegi V. Libation songs of the altaic turks // Acta ethnographica. T. XIX, f. 1–2. Budapest 1970: 96). Räsänen 1969: 121; Федотов II: 426–427 (кайбер кызыклы мәгълүматлар китерә).

**ЧҮКӘЙ-Ү, чукай-у** (ЗДС: 760) **чүкәйлә-ү** диал. (трбс.) «сесть на корточки» ~ башк. *сүкәй-* «бөкрәю» ~ тув. *сөгөй-,* як. *өкөй-* «(тезгә таянып) иелү, чүгеп тору» ← *чүк* «чүккән хәлдә булу», к. **Чүк-ү**. Чаг. ш. ук тат. (ТТДС I: 491) **чуқай-у** «бөрешү», башк. (БТДҺ: 216) *суқай-,* каз. *соқай-* «чыгынкы, чыгынты булып тору» (к. **Чука**), бор. төрки (МК II: 21) *söke olturdı* «чүкәеп утырды»; тат. диал. **чуңкай-у, чүнкәй-ү** «чүгеп утыру» һ.б.ш.

**ЧҮКЕЛИ, чүкеләй** (трбс.) «бестолковый; придурок» ~ башк. *сүкелей* < ? бор. монг. *ǯüggüj* «юньсез» (*ǯüg* «юнь», *-гүй* ~ *-сез* – юклык кушымчасы). Чаг. ш. ук венг. *csökönyös* «чүкели, чыгымчы».

**ЧҮКЕР-Ү** (Н. Исәнбәт) «башка суккалау, башына сугып егу» ~ башк. (БТДҺ: 286) *сүкер-* «егу (?); башына сугу» ← **чүке-ү** (к.); ясалышы ачык түгел.

**ЧҮКЕ-Ү** «ковать, работать молотком; коротко ударить молотком или подобным металлическим предметом» > мар. диал. *чӧгы-* id. ~ башк. *сүке-,* калп. *шөк-* (→ *шөккиш* «чүкеч») ~ монг. *чоки-,* як. (Пекарский: 3633) *чокуй-* «сугу, тукмау; чәкәтү»; рус. *чёкать, чокать* id. һ.б. – барысы да тәкълидн тамырдан (тат. диал. **чүңк-чүңк** «чүкү авазлары», к. **Чәк**).

Дерив.: **чүкел-ү**, **чүкен-ү, чүкеш-ү**, к. **Чүкеч.**

**ЧҮКЕЧ,** диал. **чүкеш** «молоток» ~ башк. *сүкеш* > мар. *чӧкыс',* удм. *чекыч* id. < гом. кыпч., к. к.-балк., ком., госм. *чөкүч,* нуг., к.-калп. *шөкиш,* к.-калп. *шөккиш,* аз. *чәкүш,* чыгт. *čeküš* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 132) *čeküč* ~ бор. төрки (ДТС: 143) *čekük* ~ төркм., төр. *çekiç* ~ фар. *çekuš,* авест. *çakuša* id.! Бу сүзнең бор. ир. телдә булуына нигезләнеп, төрки вариантларны да фар. теленнән дип карау бар. Ләкин, мәс., тат. **чүкеч < чүкегеч** булырга да мөмкин. Гомумән, төрки һәм бор. ир. сүзләрнең охшашлыгы бу очракта очраклы. Тик укр. *чекуша* «зур агач чүкеч» төрки телләрдән булса кирәк (авест. теленнән түгел бит инде!). Фасмер IV: 326; Räsänen 1969: 103.

**ЧҮК-Ү (чүкте, чүгү),** себ. **цүк-ү** «приседать; оседать; опуститься, опускаться» < гом. кыпч., алт., чыгт., уйг., госм. (һ.б. угыз) *чөк-* (> башк. *сүк-*, нуг., каз., к.-калп. *шөк-*) id., ш. ук «күчеп утыру, урнашу һ.б.ш.» (к. Радлов III: 2034–2036; Будагов I: 497) ~ чув. *çăх-* «чүгү, чүгәләү», *çак-, çӧк-* «егылу», бор. төрки (ДТС: 153, 155, 510) *čoq-, čök-, sök-* «чүгү, тезләнү; түбәнәю». Бу сүз дөяне чүктерү өчен киң кулланылган. Räsänen 1969: 117; Федотов II: 90–91 (һич нигезсез **йөген-ү** сүзен дә *чүк-* < *чөк-* белән чагыштыра).

Дерив.: **чүгел-ү, чүгеш-ү, чүктер-ү.** К. **Чүгәлә-ү, Чүкәй-ү.** Кайбер төрки телләрдә *чөк-* фигыле дериватларга аеруча бай (мәс., төр. теле).

**ЧҮЛ,** себ. (Дмитриева 1981: 195) **цөл** «пустыня, сухая степь» < гом. кыпч., чыгт., уйг., госм. (һ.б. угыз.) *чөл,* башк. *сүл,* бор. төрки, бор. монг. *čöl,* хәз. монг. *цөл* «чүл» ~ як. *чөл* «тиелмәгән, абрау (җир)», тув. *шөл* «басу, кыр; мәйдан» (рус. *поле* сүзеннән калька) һ.б. > фар. *чөл, чул* id.; к. ш. ук иске калм. (Номинханов 1975: 275) *цөлө* «чүл».

Дерив.: **чүлле, чүлсез; чүллек;** тат. диал. **чүлләү** < уйг. *чөллә-* «сусау, чаңкау» чүлгә катнашы бар микән – ачык түгел.

**ЧҮЛЛИ** «четверть литра (воды)» к. **Чөлди.**

**ЧҮЛМӘК,** диал. **цүлмәк** «глинянный горшок», диал. «керамика» > чув. *чүлмек, чүмлек* id. < гом.

кыпч. *чөлмәк* (> башк. *сүлмәк,* кырг. *чөлмөк*, нуг., каз., к.-калп. *шөлмек*) «чүлмәк, куык». Бу сүзнең *чөмләк* варианты да (госм., аз. һ.б.) еш очрый, к. ш. ук СС *čomlak* id., шунлыктан *чүлмәк* < *чөлмәк* < **чөмләк* дип (Зәйнәп Коркмаз) карау бар. Чыннан да **чүлмәк** сүзенең бүтәнчә уңышлы аңлатылмасы күренми. *Čömlek* сүзен исә (төр.) *çömle-* < *čomla-* суны «чумырып» (к. **Чүмеч**) алу фигыленнән дип фаразлап була. Тик, шулай да, *çölmek* варианты киңрәк таралган, аның модификацияләре дә күбрәк, к. төркм. (ТДГДС: 200) *чөлмек* «шифер»; кар. *цюльмячик, чёльмячик* «кечкенә чүлмәк», аз. диал. (АДДЛ: 450) *чөлмә* «чүлмәк», к. ш. ук **Чүлмәнчек**. Räsänen 1969: 117–118; Федотов II: 427 (бик аз материал бирә). Нұрмағамбетов: 140 (урынсыз чагыштырулары бар).

Дерив.: **чүлмәкче, чүлмәкчелек**.

**ЧҮЛМӘНЧЕК** (ТТДС I: 507), **чүлмәчлеки** (Г. Бәширов) «обливание водой друг-друга во время языческого обряда **яңгыр буткасы** – коллективного моления с пожеланием дождя» – **чүлмәк** сүзе белән бәйле булса кирәк һәм, димәк, ***чүлмән, *чүлмәч** «чүлмәк» сүзе булган.

**ЧҮМӘК, чүмә** диал. «кочка; чурбан; круглая куча, выпуклость» ~ башк. (БТДҺ: 286) *сүмәк,* каз. (ҚТДС: 400) *шөме* «чүмәлә» ~ як. (Пекарский: 3668–3669) *чөмөх* «чүмәлә», *чомчах, чөмчөх* «өем, күбә» ~ бур. *сомоо* «чүмәлә, өем», *сомо-, сомохо-* «чүмәлә өю», *сомсорхо* «өелү, өерелешү», монг. *цомог, чомог* «чүмәлә» һ.б. Бу сүзләр ономопоэтик *чом//чөм* «түгәрәк өем» сүзеннән киләләр. К. ш. ук төр. диал. *çöm-* «өю».

Дерив.: **чүмәкәй, чөмәкәй** (ДС III: 190 һ.б.) «өеп тутырылган, савыт кырыеннан биегәеп торган»; **чүмәлә-ү, чүмә-ү** «чүгәләп, бөрешеп утыру» (соңгы фигыль *чүмә-* дигән фигыль дә булганлыгын күрсәтә); **чүмәләй** «өеп, чүмәкәйләп» (бу сүздән – *чүмәләй өелгән* тәгъбиреннән эллипсис нәтиҗәсендә **чүмәлә** (к.) сүзе дә килеп чыга ала), **чүмәләмә** «өелгән, чүмәкәйләп тутырылган».

**Чүм < чөм** ~ *чом* тамыры икенче *чөм-, чом-* (к. **Чум-у, Чүмеч**) сүзе белән баглы түгел (һәрхәлдә баглылык сизелми). К. **Чүмәш-ү.**

**ЧҮМӘЛӘ,** диал. (ЗДС: 759) **чөмәл** (< чув. *çĕмел* ?) «копна, небольшой стог, стожок» > мар. (Исанбаев 1978: 38) *чӧмäлä,* удм. *чумолё,* коми. (КЭСК: 313) *чумала* id. < гом. кыпч. **чөмäлä*, к. кырг. *чөмөлө, чөмөлөй* (> башк. *сүмәлә*, нуг., каз., к.-калп. *шөмеле, шөмелей*), үзб. диал. (ЎХШЛ: 305) *чөмәләк, чомалай* «кибән, эскерт», *чөмәлә-* «чүмәләләү», уйг. *чүмәли, чөмүлә* «чүмәлә; кырмыска оясы; кырмыска». Әгәр тат. диал. **чүмәлә-ү,** башк. (БҺҺ II: 220) *сүмәлә-,* үзб. диал. *чөмәлә-* «чүмәлә өю» **чүмәләлә-ү** (һ.б.ш.)дан кыскарып кына килеп чыкмаган булса, сүзнең нигезе тат. диал. **чөмә,** башк. *сүмә*, каз. (ҚТДС: 370, 400) *чөме, шөме* «өем; кибәнчек», төр. *çöт-* «чүгү, чүгәләү» һ.б. К. **Чүмәк, Чүмәш-ү**. Федотов II: 108. Рус. *чомуля* (< тат. диал. **чөмүлә**) тур. Аникин: 667. К. түбәндәгене.

**ЧҮМӘЛДЕ,** (ЗДС: 715, 759; Тумашева 1992: 24) **чөмәлте, цөмәлде, цүмөлдү цөмәлде, чөмәлделек** «муравей» ~ алт. (Будагов I: 487) *чүмали*, чыгт. *чүмдү* id., уйг. *чүмәли, чөмүлә* «кырмыска оясы» һ.б., к. ш. ук бор. төрки (ДТС: 155) *čömäli* бор. монг. (Поппе 1939: 136) *čubali* «кырмыска». **Чүмәлә** (к.) белән тамырдаш булса кирәк. К. тат. диал. (ЗДС: 759) **чөмә, чөмәл** «кибән, чүмәлә», шуннан *чөмәлле* > *чөмәлде* формалары җиңел ясала. К. **Чүмәлә, Чубалгы.**

**ЧҮМӘШ-Ү** (ДС III: 191) «присесть на корточки» ← ***чүмә-ү** «түгәрәкләнү, бөрешү» фигыленең урт. юн., чаг. төр. *çömül-, çömel-,* чыгт. (Поппе 1938: 136) *чумала-,* госм. (Радлов III: 288) *чумал-* «чүмәшү» ~ яз. монг. *čomčui-* (хәз. монг. *цомцой-*, бур. *сомсой-*) «бөрешү», маньч. (ССТМЯ II: 414) *чумчу-* «чүмәшү, бөрешү; тезләреңне кочаклап утыру». К. **Чүмәк.**

**ЧҮМЕЧ,** диал. (ЛТ I: 174) **чумча, цүмӗц** «половник, поварёшка; ковшик» < гом. кыпч., уйг. *чөмүч*, куман. *чөмич* (> башк. *сүмес*, нуг., каз., к.-калп. *шөмиш, шөмӗш*), чыгт. (Радлов III: 2050) *чөмүш,* уйг. диал. *чомуч*, төркм. *чөмче*, госм. *чөмүш, чөмчү*, бор. төрки (ДТС: 155) *čömče*, төр. *çömçe, çetse,* чыгт., үзб., таҗ. *чумча* id. һ.б. *чөм, чом* «эчү, чүмерү өчен савыт» дигән мәдәни тамырдан, к. бор. төрки (Räsänen 1969: 117) *čomča* «кечкенә *чом*», чыгт. *чумуш, чумчуқ* > *чумшуқ* id. **Чүмеч** < *чөмүч* варианты *чөмгүч* сүзеннән, ягъни **чөм-* «чүмереп эчү» фигыленнән ясалган (исем сүздән) булса кирәк.

*Чөм, чом* «су, сыеклык эчү савыты» күп кенә телләрдә теркәлгән: яз. монг. *čoти*, монг. *цом* «чәркә, бокал» ~ эвенк. (ССТМЯ II: 406) *чомо, чомко* һ.б. «тустаган, чум (к.), чүмеч»; удм. *чумук* «агач тустаган һ.б.ш.»; рус. *чум*, бор. рус. *чумъ* «ужау, чүмеч», *чумашка* «чулпы, тишекле чүмеч» һ.б. Бу тамыр

*чум-* < *чом-* «чуму» тамыры белән баглы булса кирәк (күчемле һәм күчемсез фигыльләр еш кына алмашына).

Этимологик хезмәтләрдә тат. **чумыч** «чүмеч» сүзе кабатлана; хәз. тат. телендә бу вариант теркәлми. Диал. (ДС III: 191) **чүмич** «тегермән калагы» рус. *чумичка* id. сүзеннән кире алынма; рус. *чумич, чумичка* тат. теленнән (*-у-*!). Гаҗәп рәвештә һинди *čammač, čamča* (төрки телләрдәнме?) «кашык». Räsänen 1969: 117; Фасмер IV: 381; Аникин: 672; Мухамедова 1973: 190.

Дерив.: **чүмечле, чүмечсез; чүмечлә-ү.**

**ЧҮННЕК, чүнник** (Бәширов III: 375) «пасека» ~ мар. (Саваткова: 190) *чельник* id. < рус. *пчельник* id.

**ЧҮҢ: чүң бүкән** (Идегәй, к. 1988: 138) «плаха; высокий суд (?)» – чаг. кырг., уйг. *чоң* «зур, өлкән; дәрәҗәле», каз. *шоң* «зур; эре феодал» < кыт.

**ЧҮП** «сор, мусор; сорняк; кострика; хлам», диал. «послед», (ТТДС I: 508) «клоп» > чув. *çуп, çупĕ* (> мар. *сүво* «чүбек») < гом. кыпч., алт., угыз. *чөп* (> нуг., каз., к.-калп. *шөп*, хак. *сӧп*, башк. *сүп*), алт. диал. (Баскаков 1966: 166) *чөөп* «чүп»; кыпч., угыз., уйг. телләрендә башлыча «корыган үлән, салам калдыклары; вак үлән; чүбек; соңгылык һ.б.ш.», аз. *чөп* «чүп, шырпы» ~ тув. *чөъп*, бор. төрки (ДТС: 155) *čöp* «түп, шәрабның һ.б. төпкә утырган калдыгы, куерыгы; чүп» ~ монг. *цүб, цөб* < бор. монг. *çöb-* id. Бу сүзнең борынгырак яңгырышы *түп* < *төп* булса кирәк (к. **Түп**): *т* > *ч* күчеше төрки телләрдә (чув. теленнән тыш) сирәк очрый, ләкин гомумән (бигрәк тә *т-* авазыннан соң *-и, -ү* авазлары килгәндә) бар, к. **тиш-ү** ~ *чиш-ү*, үзб. *түш-* > *чүш-* «төшү» һ.б. Төрки *чүп* < *чөп* сүзен фар. *чуб, чоб* «агач; таяк» сүзе белән чагыштыру бик шикле. К. Будагов I: 490; Räsänen 1969: 118; Федотов II: 148. Рус. *чуп* «елга төбендәге чүп» < тат. *чүп* тур. Аникин: 677.

Дерив.: **чүпле, чүпсез; чүпче, чүпчел.** К. **Чүәк, Чүбек, Чүпер, Чүплә-ү I, Чүпрә, Чүпрәк, Чүпче-ү, Чүрәк.**

**ЧҮПЕР** (Радлов III: 2202) «выжимки; остатки, выварки, гуща, послед», себ. (Тумашева 1992: 240–241) **цөбөр, цөбĕр,** (ЗДС: 711) **цебер** «рваньё; лохмотья» ~ уйг. *чүпүр* «йондагы кыл, кылчык» ← *чөп, чүп* «чүп»; ясалышы ачык түгел, ихтимал кушма яисә парлы сүздәндер (< **чөп-күр*?, к. бор. төрки **күр* «чүп», к. **Көрә-ү**); яки *чүп-* < *чөп-* дигән фигыль дә булырга мөмкин, шуннан **чүпкĕр* < **чөпкүр* исеме («чүпле») ясала ала. Һәрхәлдә интервокаль *-п-* саклану монда элек уртада ике тартык булганлыгына ишарәли шикелле.

Дерив.: диал. **чүперлә-ү** «бала ташлау (куркудан һ.б. – буаз хайваннар тур.)», күч. «эшне бозу, хурлыклы рәвештә хыянәт итү, тотнаксызлану», себ. (ЗДС: 715) **цөбөрәй-ү, цөпрәй-ү** «телгәләнү, өтәләнү»; диал. **цебердәк, чебертәк** «ярыклы-тишекле (яфрак тур.)». К. **Түбер, Чүпрәк, Чүпрә.**

**ЧҮПЛӘ-Ү I** «засорить, сорить» ~ башк. *сүплә-* ← **чүп** (к.). Гомуми мәгъ. буенча «чүпкә әверелдерү, чүпкә чыгару; чүплеләү».

Дерив.: **чүплән-ү** «чүплеләнү».

**ЧҮПЛӘ-Ү II** «подбирать по штукам (мелкие, рассыпанные предметы)» < гом. кыпч., к. башк. *сүплә-,* кр.-тат., ком., кар. *чөпле-, чёпле-,* к.-калп. *чёбле-,* к.-калп. *шөпле-* «чүпләү, чуку», каз. *шөпте-* «чүп үлән утау». **Чүплә-ү I** сүзе белән **Чүплә-ү II** ике лексик системадан килә. Ихтимал, **чүплә- < чүпелә-** < **чөпүлә-* < монг. *чөбгүйлә-* «чүпсезләү».

Дерив.: **чүплән-ү** «чүпченү»; **чүпләш-ү, чүпләт-ү.**

**ЧҮПЛӘ-Ү III** «ткать с двойными, двухцветными нитками», «считать попарно» ~ башк. *сүплә-* < **җүфтлә-ү:** иске *җүфт* < фар. *жүфт*, *чүфт* «ике, пар (җеп)» (к. **Чуптар**). К. ш. ук (ТТДС I: 308) **чүпләмле** «парлы-парлы бию төре», (ДС II: 228) **чүпәш-ү** «кулалмаш ашлык суктыру». К. **Җепкер, Җефет, Җөп, Өфти, Чыпта, Юкә, Юрган.**

Дерив.: **чүпләм** (башк. *сүпләм*) «чүпләп киндер сугу эше; чүпләп сугу җайланмасы (тактасы)».

**ЧҮПРӘ,** сөйл. **чүперә** «дрожжи», диал. (ЛТ I: 176; ТТДС I: 508) «осадок, гуща на дне сосуда с квасом, пивом и т.п.» < гом. кыпч., к. башк. *сүпрә,* кар. *чёпря, чэпрэ, чопра* «чүпрә», кар. диал. *джибрэ* «сыгылган виноград калдыгы», ком. *чёпюре* «турта, чүпрә; түпрә, чүп», иске каз. *шөбрö,* каз. диал. (ҚТДС: 399) *шөбере* «турта, иерек (тире иеләү боламыгы) төбендә калган куерык» ~ бур. *сүбрэг* «турта, эретелгән май түбе» һ.б. < *чүпер-әг* ~ *чөпүр-äг* (асылда, шуннан ук, к. **Чүпрәк**) ← *чүпер* (к.) < *чөпүр*. К. ш. ук чув. *çĕпре* ~ венг. *söprö* «чүпрә, сыл, мил», бор. төрки (МК I: 318) *čöb* «шәраб туртасы». *Чүпрә* ~ *түпрә* (к.) мәгънәдәшлеге бу сүзләрнең бор. уртак тамырдан килгән-

леген ачык күрсәткән мисал. Чыгт. *чäпрäк, шäбрäк* «чүпрә», нуг. *шапра* «турта» икенчел ясалмалар. Уйг. *чөпүрәнди* «чүп-чар» *чөпүр-* фигыле булганлыгын күрсәтә.

Ошбу сүзнең бүтән мәгънәләре дә кызыклы: иске тат. (Радлов III: 2203) **чүбрә** ~ к.-калп. *шөбире* «балык кылчыклары» ~ кырг. *чөбүрө* «вак-төяк, ыбыр-чыбыр», үзб. *чевара*, каз., к.-калп. *шөбере* «онык-нукаларның балалары». Федотов II: 110 (бик аз мәгълүмат бирә). К. **Чүпрәк.**

Дерив.: **чүпрәле, чүпрәсез; чүпрәлек.**

**ЧҮПРӘК,** сөйл. **чүперәк** «тряпка, тряпьё», диал. «пелёнка»; диал. вариантларны өч группага аерырга була 1) **чибүрөк** «чүпрәк»; 2) **чөпрәк, чеперик, чебрүк** «савыт саба капламасы, тастымал»; 3) **чебрик, чеп-чебүринке** «пәрәмәч; майда пешерелгән күмәч» һ.б. (к. ЗДС: 714, 743, 764) < гом. кыпч., к. башк. *сепрәк*, ком. *чюпюрек*, нуг. *шуберек, шиберек*, каз. (Радлов III: 1113) *шүпөрөк, шөбөрок*, хак. (Радлов IV: 851) *сүбүрäк, сүбäрик*, хәз. хак. *сүбрек, сүрбек* «чүпрәк», куман. *čüprek* «биләүлек, кипке», алт. диал. *чүбрäк* «кульяулык», чыгт. (Радлов III: 1153–1154) *чибäрик, чибүрä, чиприк* «чүпрәк» һ.б. < *чүпер-äк* ~ *чөпүр-äк* < *чопүр-äг* (к. **Чүпрә**) «калдык; туп, турта» *чөпүр* (к. **Чүпер**) сүзенең кечерәйтүле формасы. К. ш. ук **Чүрәк.** Räsänen 1969: 118.

Дерив.: **чүпрәкле, чүпрәксез; чүпрәклек; чүпрәклән-ү; чүпрәкче; чүпрәкчел** (һәртөрле тукыма һәм кием-салым яратучан, шуларны җыючан).

**ЧҮПЧЕ-Ү** (ТТДС I: 508) «полоть сорняк, сор» ~ к.-калп. *шөпше-* id. – *чүп* сүзеннән, тик ясалышы ачык түгел (морфологиясе буенча **чөп-* дигән фигыльнең дәвамлы формасы, тик ул *чөп-* фигыле безгә билгеле түгел).

Дер.: **чүпчен-ү** «юк-бар эш белән йөрү».

**ЧҮРӘ,** диал. **цүрә** (ДС I: 225; ТТДС I: 509; Тумашева 1992: 247), **чөрә** (Гомәр Гали телендә) «обратная сторона (листа, материи, дома), обух; окружность, кругом; наоборот, напротив; около» ~ башк. (БТДҺ: 287) *сүрә* «төрле төскә керә торган юка ефәк» (дөресе – «дәрия, ике ягы ике төрле ефәк» булса кирәк) < гом. кыпч., к. кар. *чювря, чуврэ, чэврэ, циврэ*, к.-балк. *чювре, цюйре*, ком. *чүйре*, кырг. *чөйрө* ~ чыгт., госм. (Радлов III: 1998–2001) *чäврä*, аз. *чеврә*, төр. *çevre*, бор. төрки (Боровков 1963: 361) *чöрä* һ.б. «тирә; тирәлек; әйләнә; тирәли тотылган киртә; урау; чүрә», чув. *çавра* «түгәрәк; әйләнеч, урау» (< бор. тат. **чәүрә*?) ← тат. **чәвер-ү** (к.) ~ бор. төрки (ДТС: 145) *čevur-*,төр. *čevir-* «икенче якка әйләндерү, бору, урау һ.б.» (бик күп мәгънәләрдә чагылучан) фигыленең дериватлары (я бор. **чәwүрәг* «әйләнмә» сүзеннән, я хәл фигыль формасыннан исемләшкән). Räsänen 1969: 102; Федотов II: 80–81.

Дерив.: **чүрәләй, чүрәли**; (*киреле-чүрәле* дигәндә) **чүрәле**; к. **Чүрәкә, Чүргәнче, Шүрәле.**

**ЧҮРӘГӘЙ** к. **Чүрәкәй.**

**ЧҮРӘК** (Будагов II: 493; ТТДС II: 371) «мелкие хлебцы, испечённые из остатков теста после выпечки хлеба» < гом. кыпч., чыгт., төркм. *чөрәк* (> башк. – БҺҺ III: 160 – *сүрәк,* нуг., каз. *шөрек*), төр. *çörek*, бор. төрки (ДТС: 155) *čöräk* «чүрәк, кабартма, коймак (һ.б. вак камыр ашамлыклары)» < **чöврек, чöврäк* < билгесез төрки *чöбүрәк* > рус. *чебурек, чурек* (һәр икесе кыпч. телләреннән, к. Фасмер IV: 386), *чурека* «начар пешкән икмәк» (Аникин: 677–678) һ.б. *Чүрәк*, шулай итеп, морфологик җәһәттән **чүпрәк** (к.) сүзе белән бердәй!

**ЧҮРӘКӘ, чүрәкәй** (ТТАС III: 481; ТТДС I: 509), **сүрәкә** (БҺҺ II: 221) «деревянный шар; вид игры с таким шаром» ~ чув. *çавракa* «түгәрәк; шар» ← **чәвер-** ~ *чавăр-* «әйләндерү», к. **Чәвер-ү.** Чаг. диал. (ЗДС: 767) **чүргәнче(к)** «өермә» < **чәвергәнчек.*

**ЧҮРӘКӘЙ, чүрәгәй,** (ДС III: 190; Тумашева 1992: 241) **цөрәгәй, чөрәккә, чөрги,** (ТТДС I: 509) «чирок, вид (разные виды) диких уток» ~ башк. (БТДҺ : 282, 287) *сөрәк, сөрәкә, сөрөгәй, сүрәкә, сүрәгә, сөрәшкә*, алт. *чүрекей*, хак. *сиргейек,* як. (Пекарский: 3611, 3727) *чäрки, чöркöі, чыркакы, чыркамай, чыркыі* id. Рус. *чирок,* укр. *чирка* сүзен Аникин (2000: 665) аерым «праславян» тамырдан дип, төрки-слав. охшашлыгы имитатив (дөресрәге – ономопоэтик) тамырлар охшашлыгыннан дип күрсәтә, ләкин удм. *чурегей,* мар. (Исанбаев 1978: 21) *чоракай* < тат. Төрки телләрдә **чурагай** (к.) сүзе белән дә контаминацияләнгән. Тат. формалары, ихтимал ки, **чәвер-ү, чүрә** сүзләре тәэсирендә дә ясалгандыр (башын су төбенә тыгып, арты белән әйләнүчән үрдәк).

**ЧҮРГӘТ, чургат** (Троянский I: 465) «сосуд с носиком или с рыльцем для слива жидкости» >

мар. кч. (Исанбаев 1978: 32) *чоргат*, удм. диал. *чурок* «бүрәнкә, бүрәнкә салган савыт», чув. *чурхат* «сөт чиләге» < иске монг. *čorγotaj* > калм. *цоргота* һ.б. «борынлы (чөмәкле, чургалы) савыт» (к. **Чурга**). Шул ук монг. *чоргатай* сүзенә тат. **чүгәтә, чүгәтәй** (к.) сүзе дә тоташа. М. Федотов (II: 145) чув. *çурхат* сүзенең параллельләрен карамастан, аны *çурха ат* «юрга ат» (имеш, «атка охшаш савыт») дип «аңлата».

**ЧҮРГӘ-Ү** «наматывать» к. **Чурга-у.**

**ЧҮРЕ, чүри** тар. «сын или дочь раба; рабыня-пленница» < чыгт. (Радлов III: 2194) *чүрі*, уйг. *чөри*, үзб. *чори*, төркм. *чооры* > каз., к.-калп. *шоры* «чүре». К. **Чура, Чураш.**

**ЧҮРИ, цүри** (ЗДС: 717) «гусёнок», **цүрек** (ш. ук) «вид мелкой дикой утки» ~ аз. *чүрә* «чеби», *чүртә* «үрдәк бәпкәсе», чув. *çура, çури* «бала, бәби, кош баласы». Чаг. ш. ук рус. диал. (СНО: 528) *суразята* «чебиләр». Чаг. **Чүрәкәй**.

**ЧҮСИНКЕ, чүчинке, чучынкы, сачинкә, чусай** (күп вариант, к. ЗДС: 565, 764) < рус. *чёсанки* «югары сортлы йоннан басылган пима» ← *чесать* «тәрәшләү, тетү». **Чусай** варианты тат. теленең үз сүзе, үзендә ясалган.

**ЧҮТ** сөйл. «чуть, чуточки» ~ чув. *чут, чуть,* мар. *чуть, цуц*, удм. *чуть* id. < рус.

**ЧҮТЕКИ** сөйл. «всё-таки, всё же» ~ башк. *сүтеки*, чув. *чуттĕки*, удм. *сётаки, сёжки,* мар. (Саваткова: 147) *содыки* id. < рус.

**ЧҮЧӘЛӘ,** себ. (фольклорда, В.В. Радлов җыентыкларында) **цүцөлө** «сказочная птица» ~ мар. (Упымарий: 237) *цäцäлä* «щегол» ~ алт. *чүчäлиш* ~ калм. *čičali, tsutsali*, маньч. *čočijali* «бер кош исеме» (к. Ramstedt 1935: 445) ~ яз. монг. *čiičali* > мар. *цууцали* «шөлди, чуллык» ~ тунг. (ССТМЯ II: 142), эвенк. *чукчэӈэ,* як. *чöкчöӈö* id. Чаг. ш. ук **Чәчүрә** (к.).

**ЧҮЧ-Ү, чуч-у** (Будагов I: 492) «внезапно испугаться; вздрагивать» ~ башк. *сус-* «куркудан катып калу, дерт итү», (БТДҺ: 285) «көйсезләнү, мыгырдану» < бор. төрки (КБ) *čoč-* ~ кырг., алт. *чочу-, чочула-, чочун-* «курку, куркыну», уйг. *чөчү-, чөчүн-* «куркыну», *чөчүт-* «куркыту», хак., алт. (Баскаков 1972: 269) *чоочы-, чочы-, чочын-, чөч-* «курку, имәнү», каз. *шош-, шошы-*, нуг., к.-калп. *шоршы-* ~ үзб. диал. (ЎХШЛ: 305) *чорчы-* «чучу, сискәнү» (үзб. телендә борынгырак вариант сакланган) бор. **чор-* «курку, сискәнү» фигыленең дәвамлы интенсивлык формасы, ул фигыльнең рефлекслары – себ. (Тумашева 1992: 242) **цурғақ** «куркак, булдыксыз», **цурул-у** «чурылу; бөкрәю; бөрешү». Чаг. **Чургак, Чурга-у, Чур-у** («бөрү»).

«Бөреш-ү > куркын-у» мәгъ. күчеше бер дә гаҗәп түгел.

**ЧЫБАТА** «цуг, запряжка лошадей друг за другом» ~ башк. *сыбата* id. ← башк. *сыбат-у* «бер-бер артлы рәткә тезеп чыгу» (тат. **чыбат-у** булырга тиеш), башк. *сыба-у* ~ тат. диал. (к. ЗДС: 715) **цуба-у** «тезелеп сузылу» ~ кырг. *чуба-, чубал-* «бер-бер артлы бару, сузылу, өстерәлү», нуг. *шубал-* «тезелеп өстерәлү» ~ монг. *цуба, чуба* «тезем», *чубатай* «мичәү, олау». К. ш. ук ком. *чубур-* «бер-бер артлы йөгерү», *чубурув* «тауларда кәҗә сукмагы» һ.б. барысы да төрки-монг. *чуб* «рәт, тезем» тамырыннан. К. **Суалчан, Чуал-у.**

**ЧЫБЫК,** диал. (миш., себ. ) **цыбык** «хворостина, лоза, прутик, розга; проволока» > мар. *цывык*, чув. *çăпăк* id. < гом. төрки, к. гом. кыпч., алт., уйг., госм. һ.б. *чыбық* (> башк. *сыбық*, нуг., каз., к.-калп. *шыбық,* тув. *шывык,* шор. *сымық,* хак. *сымых*), бор. төрки (ДТС: 147, 150, 151, 156) *čïbïq, čubuq* ← *čïp* id. Соңгы вариант башлыча угыз телләре даирәсендә (госм., аз. һ.б.) таралган һәм кр.-тат. *чубуқ,* к.-калп. *шубуқ,* бор. кыпч. (СС: 207) *čibuh* угыз телләреннән алынма булса кирәк. Рус. *чубук, чублук, чубулдук* «чыбык; озын саплы төрепкә» төр. теленнән алынма дип карала (Фасмер IV: 376, күпсанлы әдәбият күрсәтелә); рус теленнән бу сүз күп күрше телләргә таралган.

Китерелгән (һәм китерелмәгән) бай лексик материал күрсәткәнчә, сүзнең тамыры **чып** (*чубук* << *чып-ук,* к. фар. *чыбуқ, чупуқ* «чубук») һәм ул тәүдә «ботакчык, чем» мәгъ. булган, к. себ. (ДС I: 219; Радлов III: 2099) **чыбал, чыбыртак** «тал чыбыгы», себ. **цыбы,** алт. *чыбы* «ак чыршы, пихта» ~ башк. (БТДҺ: 287) **сыбы** «вак куаклык», бор. төрки *čïp* «чыбыкча», себ. *чуқ-чыбуқ* «куба тал, чыпчык талы», *туң-цыбык, цуқ-цыбык* «куаклык» (к. Тумашева 1992: 218, 241, аңлатмалары бүтән чыганакларга туры килми) һ.б. Будагов I: 468; Räsänen 1969: 106; Федотов II: 403–404; Аникин: 668 (бай әдәбият һәм мисаллар күрсәтелә).

Дерив.: **чыбыклы, чыбыксыз** (техник терминологиядә); **чыбыкла-у; чыбыкча.**

**ЧЫБЫЛДЫК,** диал. (ТТДС I: 496, 742 һ.б.) **чымылдык, чебелдек,** себ. (Тумашева 1992: 243) **цыбындык** «занавес; полог», «свадебный занавес, за которым во время свадьбы сидят жених и невеста» < гом. кыпч., к. башк. *сымылдыҡ,* (БТДҺ: 289) *сымылдырыҡ,* ком. *чувулдуруқ, җубулдуруқ, чывылдырыҡ, җибилдирик,* кр.-тат., кырг., үзб. (ЎХШЛ: 302) *чымылдыҡ, чымылдырыҡ,* алт. *чыбылдыҡ* һ.б. (> нуг., каз., к.-калп. *шымылдыҡ*), куман, себ. (Радлов IV: 57) *цыбынныҡ* id.; палаталь вариантлар: чув. (Сергеев 1968: 9) *чĕпĕлтĕк*, чыгт. (Радлов III: 2103–2159, IV: 57) *чiмiлдүрүк*, госм. *җiбiнлiк*, үзб. *чимиллик, чимиллиқ* id. Чув. *шăналăк*, мар. *шыҥгалык, шӹҥӓлӹк, шыҥалык* һ.б. (аерым вариант) «чебеннәрдән саклану өчен бөркәү, чаршау, чыбылдык» (← *шăна* < **сиңгәк* > мар. *шына, шыҥа, шӹҥӓ* «чебен», к. Иванов, Тужаров: 299; Саваткова: 217); гомумән, һәркайда диярлек бу сүз «чебен» мәгъ. сүзләргә (к. **Чебен**) нисбәт ителә, ләкин к. үзб. *җамолиқ* «чыбылдык» *җамо* «озын кием» (ш. ук вакытта үзб., уйг. *чимилдиқ, чимилдих* «чыбылдык» та бар).

**ЧЫБЫЛ-У** (ТТДС I: 494) < **чŏбыл-у** «разматываться; разладиться» ← **чыбы-, *чŏбы-, *чоба-* «рәтне, теземне үз тәртибе белән кире сүтү» фигыленең төш. юн., к. себ. (Тумашева 1992: 241) **цуба-у** «бер-бер артлы тезелү; сузылу, озаю, озару; көн артыннан көн узып, кичектерелү» < уйг. *чуба-*, хак. *суба-* «киләп сүтү», як. *субуй-* ~ бур. *суба-*, монг. *суби-* «теземдә булу, тезелү; тезелеп бару; бер-бер артлы (тартып һ.б.) алу», безнеңчә, бор. төрки *чуб* «өзбе, бер сызыкка тезелгән нәрсәләрнең берсе, буыны» тамырыннан. К. **Чыбыр-у, Чыбыт-у.**

Сөйләшләрдә таралган (минз., трбс., к. ш. ук БТДҺ: 290) **сыпыл-у** «сизрәү (тукымалар тур.), сүтелү» сүзе дә **чыбыл-у** яңгырашыннан килеп чыккан яки шул фигыльнең бер варианты (башкортчасымы) булса кирәк.

Дерив.: **чыбылт-у; чыбылчык.**

**ЧЫБЫРКЫ < чыбырткы,** диал. **цыбырткы** «плеть, кнут» < гом. кыпч., к. кырг., алт. *чыбыртқы* > нуг., каз., к.-калп. *шыбыртқы,* хак. *сымыртқы,* башк. (ш. ук куман., алт. диал., к. Радлов IV: 671) *сыбыртқы* id. ← *чыбыр-, сыбыр-* (хак. *сымыр-*) «ат куу, (атны һ.б.) чыбыклау; сыптыру, сыпыру, себерү» (к. башк. *сыбыртқы* «себерке»). Чаг. **себертке > себерке.** Гомумән, *чып//сып* ономопоэтик тамырдан, ихтимал **чыбык** сүзе белән тамырдаштыр (ләкин бу ачык түгел). К. ш. ук чыгт. *чупчурға* > фар. *чымчырға* «камчы». Федотов II: 404 (чув. *чăпăркка* «чыбыркы» сүзен нәкъ татарча диярлек әйтелүенә карамастан, «төрки телләрдән» дип тәгърифли). Будагов I: 468; Нұрмағамбетов: 141–142 (тәфсилле).

Дерив.: **чыбыркылык; чыбыркыла-у.**

**ЧЫБЫР-У** диал. «собирать, производить сборку; ставить в ряд», себ. (Тумашева 1992: 240) **цŏбыр-у** «(рәткә) сузу; сүтеп ташлау; (вакыт уздырып) авыз ачып йөрү» ~ башк. *сыбыр-* < *сŏбŏр-* «җыю, туплау», як. *субуруй-* «бер-бер артлы сузылу», к. ш. ук башк. *себереү* << **чŏбŏрыw* «биектә очкан кошлар теземе» (палатализация) ← **чыбы-* < **чŏбы-* «тезелү, тезелеп бару, тезелә бару», к. югарыда **Чыбыл-у.** К. **Чыбыт-у**.

**ЧЫБЫТ-У** (ТТДС I: 494) «разобрать по порядку; размотать и снова замотать; включать» ~ башк. *сыбат-* «тәртип белән тезү (яки сүтү)», *сыбата* «мичәүләп (җигү), мичәү» ← **чыбы-* < **чобы-* «(тәртип белән) тезелү (яки сүтелү)» сүзенең йөкл. юн.; **чыбыт-у** ш. ук **чыбылт-у** формасыннан да килеп чыга (*-л-* редукцияләнә) ала. К. югарыдагыларны.

**Чыбыл-у, чыбыр-у, чыбыт-у** сүзләре **чуал- < чобал-у** (к.) белән тамырдаш, әмма соңгысына антонимнар. Ихтимал, бор. телдә үк *чубу-* һәм *чуба-* фигыльләре уртак тамырдан антонимнар булгандыр, тик бу фараз мисаллар белән расланмый. Дөресрәге – ниндидер тел даирәсендә **чобал- < чубал-** «сүтелеп сузылу һәм тезем тәртибен югалту» мәгъ. өстенлек иткәндер. Уңай мәгънәнең киресенә әверелүе *кер* «пычранты» һәм *кер* «юылып эленгән нәрсә» мәгънәсен алуы мисалларында да күзәтелә. К. ш. ук **Чүмәлә.**

**ЧЫГАНАК I,** диал. **чыгынак,** (ТТДС I: 494) **чыгым** «источник, родник (төрле мәгъ.)» < гом. кыпч., к. башк. *сығанаҡ*, каз., к.-калп. *шығанақ* ~ төр. *cığanak* һ.б. (күп сүзлекләрдә теркәлмәгән) ← (кырг.) *чыған* id. ← *чыҡ-* (к. **Чык-у**). Рус. (Фасмер IV: 359) *чиганак* «җәй уртасында кибүчән күл» < кыпч.

**ЧЫГАНАК II, чығыныйк** һ.б. (күп вариантлар), себ. диал. (Тумашева 1992: 243) **цығанаҡ** «күгән; тупса; терсәк» ~ башк. (БТДҺ: 288) *сығанаҡ,* кырг. *чықанақ,* каз., к.-калп. *шығанақ* «чөй,

ишек күгәне; терсәк; чыгынты» сүзе киң таралган. К. Рамазанова: 118–120 (**чәнчә бармак** белән тамырдаш димәкче).

Дерив.: **чыганаклы, чыганаксыз.**

**ЧЫГТАЙ: чыгтай теле** «чагатайский язык» ← монг. *Чеғатай* – ялгызлык исеме (Чыңгыз ханның бер улының исеме), «Үзәк Азия һәм Тибет тауларында яши торган биек кыргый ишәк».

**Чыгтай** (төрки) **теле** – үзендә гарәп хәрефләре кулланылган һәм төрки халыкларда XI–XIX гг. гамәлдә булган яз. төрки тел. Монгол яуларына кадәр үк формалашкан булса да (к. Ә. Ясәви, С. Бакыргани әсәрләре), Чыңгызханның углы Чыгатай улусында (аңа хәз. Урта Азия, Әфганстан, Иран вә күрше тупраклар да кергән) халыкара аралашу теле буларак киң таралганлыктан, шул монгол ханы исеме белән аталган. Бу яз. тел Алтын Урда биләмәләрендә дә киң кулланылган.

Сузыклар өчен нибары өч кенә хәреф булганлыктан, чыгт. телендә аерым төрки телләрнең вокализм үзенчәлекләре нивелирлашкан. Консонантизмда кайбер төрки телләрдә нык үсешкән аваз күчешләре, ассимиляция һәм диссимиляция дә чагылыш тапмаган. Бу хәл гомумтөрки сүзләр һәм формаларның бертөрле язылуына мөмкинлек биргән. Сингармонизм гарәп алфавитындагы кайбер каты һәм йомшак хәрефләрне төркичә куллану юлы белән чагылдырылган.

Чыгт. теленең орфографиясендә, ш. ук грамматика вә лексикасында да төгәллеккә ирешелмәгән. Кайчакта чыгт. теленең «иске үзбәк» һәм «иске татар» вариантларын аералар. Чыгт. телен куллануның соңгы чорларында анда угыз-төрек (госманлы) яз. теленең тәэсире көчәйгән.

Чыгт. теле аерым төрки тел үзенчәлекләрен начар чагылдыргач, XV г. алып аның милли яз. вариантлары формалаша башлаган. XVI г. «татар төрекчәсендә» татар теле үзенчәлекләре беленми диярлек, XVII г. шагыйре М. Колыйда алар шактый, XIX г. башы әдибе Г. Кандалый күпчелек әсәрләрен чын тат. телендә язган (аның аңлы рәвештә чыгтайча язган әсәрләре дә бар). Ләкин, әйтергә кирәк, хәз. тат. әд. теленең формалашуында чыгт. теленең тәэсире көчле булган.

К. Благова Г.Ф. Тюркское *чағатай* – русское *чагатай//джагатай.* Тюркологический сборник, 1971. М., 1972: 167–205.

**ЧЫГЫМ, чыгын** «норов; норовистый (о лошади)» > чув. *чăхăм,* удм., мар. (Упымарий 1928: 249; Насибуллин: 146) *чыгын, чигын, чъгън* id. ~ башк. *сығым, сығын* id., як. (Пекарский: 3709) *чығын* «кырыс, үҗәт» һ.б., ихтимал, *чық-ын-* «тартәдән чыгу» сүзеннәндер. К. гаг. *чықын-* «артаклану, артка тартылу (ат тур.)», *чықынма* «чыгымчылык». Ачык түгел. Федотов II: 406–407 (венг. *csökönyos* «чыгымчы» сүзе белән чагыштыруы безне ышандырмый).

Дерив.: **чыгымчы; чыгымла-у.**

**ЧЫГЫНТЫ** «выступ» ~ башк. *сығынты* id. ← **чык-у.**

**ЧЫГЫР** – общее название для различных механизмов, имеющих вращающиеся части, колёса, колёсики, валы и т.п.: «детская коляска с маленькими колёсами» (к. ДС II: 223; БТДҺ: 288); «ворот колодца, водоподъёмная машина; приспособления для прядения, сучения, витья верёвок; блок ткацкого станка» (к. Будагов I: 477; Сафина 1990, где даётся описание различных **чыгыр: дугызчыгыр, шәмчыгыр** и т.п.) > мар. (Упымарий: 249) **чыгыр,** (Саваткова: 212) *сыгыр* «блок (механизм)», удм. *чыңгыр* «балалар тәгәрәтеп уйный торган коршау» ~ рус. *чигирь* «кое чыгыры» < гом. кыпч., к. башк. *сығыр,* кырг. *чығыр,* каз. *шығыр,* үзб. *чиғир* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 148) *čïγrï* < сугд. *čγr* ~ санск. *čakra* «тәгәрмәч, чыгыр», к. ш. ук бор. чыгт. *чақруқ, җиқриқ* «чыгыр, домкрат» ~ төрки *җықыр* «чыгыр, сү күтәрткеч зур тәгәрмәч» (к. Мухамедова 1973: 186–187). К. **Чагарак, Чыгырык.**

**Чыгыр** < һинд-ир. *čakra,* һинд.-евр. **kwekla* «әйләнә, тәгәрмәч» ← *kwel-* «әйләндерү» сүзләреннән килә. Бу тамырга рус. *коло* (шуннан *около* «тирәли», *колесо* «тәгәрмәч» сүзләре), аннары (грек, лат. телләреннән таралган) **колония, полюс, цикл** сүзләре дә тоташа икән (к. Kluge һ.б. сүзлекләр). Фасмер IV: 359; Федотов II: 399.

**Чыгырыннан чыгу** «рәте китү, юньсезләнү» тәгъбиренә караганда, **чыгыр** сүзенең «күчәр» мәгъ. дә булган.

**ЧЫГЫРЫК, чыгырчык** «вспомогательное колесо (блока и т.п.)» < гом. кыпч., к. башк. *сығырық,* нуг. *шықрық, шықыршық,* кырг. *чығрық, чығырық* «коршау; чагарак, дугыз», төр. *çıkrık* «чыгыр (төрле мәгъ.)» ~ яз. монг. *čaγariγ* (> хәз. монг. *цахариг* > бур. *сахариг*) «коршау, түгәрәк, шайба» << сугд. *čγraγ* id. ← *cγr*, к. **Чыгыр.**

**ЧЫГЫТ** к. **Чегет.**

**ЧЫДА-У,** миш., себ. **цыда-у,** иске тат. (? ЛТ I: 151) **җида-мак** «терпеть, вытереть; переносить» > мар. *чыта-,* мар. Т. *цӹтä-,* морд. *цидя-,* удм. *чида-* < гом. кыпч., уйг., алт. һ.б. *чыда-* (нуг., каз., к.-калп., тув., шор. *шыда-,* башк. *сыҙа-*), уйг., үзб., чыгт., иске монг. *чида-,* хак. *чыда-,* як. *сыта-, сата-* «чыдау, түзү», кайбер телләрдә (к. Радлов III: 2091) «мөмкинлеккә ия булу; хәленнән килү; абруйлы булу», урта монг. (Поппе 1938: 434) *čida-* «дөрес эш итү», төр. *çıda-* «сабыр итү» – М. Рясянен буенча (Räsänen 1969: 107), монг. телләреннән килә, к. монг. диал. *чада-* > бур. *шада-* «кулдан килү». Чув. *чăт-* (Федотов III: 405–406) «чыдау» < *чыт-* id. сәер генә яңгыраш. Кайбер телчеләр *чыда-* < *чыңда-* «нык булу» (к. **Чың II, Чыңкы**) диләр. Чаг. ш. ук авест. *çiδa* «савап, түземлек нәтиҗәсе». Будагов I: 471.

Дерив.: **чыдаш-у, чыдат-у; чыдам.**

**ЧЫЕЛДА-У [чы̆йы̆лда-],** диал. **цыйылда-у** «пищать» > удм. диал. *чийылда-* ~ башк. *сыйылда-* id. ← **чый I** (к.)

**ЧЫЖ, чыш** – имитатив шипению (масла на сковороде, воды на накалённой поверхности) ~ башк. *шыж*, чув. *чăш* id., ш. ук кисәк кенә кыштырдауга имитатив. Бүтән кардәш вә күрше телләрдә дә бар бугай.

Дерив.: **чыж-чыж, чыж-чаж; чыжла-у, чыжгыр-у, чыжылда-у.** К. **Чыш(т), Чыштырт.**

**ЧЫЖ-У** (Будагов I: 476) «жарить на масле» ~ чыгт. *чыж-* id. **Чыж** имитативыннан фигыльләшкән сүз.

Дерив.: **чыжыл-у, чыждыр-у; чыжык** «сызыл, сызык» (к.).

**ЧЫЖЫМ**, **чыҗым** «натянутый шнур, верёвка; телеграфные провода; канаты для поддерживания стеблей хмеля; сетки для ловли птиц» ~ добр. тат. (Akb: 191) *sıcıт* «кое бавы», башк. (БҺҺ II: 304) *шыжым* «җылымның аскы һәм өске бавы», үзб. (ЎХШЛ: 303) *чизим* «нечкә аркан», аз., төр., гаг. *сиҗим*, төр. *sıcıт*, нуг., каз. *шыжым, чыжым* ~ калм. *шиҗм,* бур. *шэжэм,* монг. *шижим,* маньч. *сиӡин* ~ як. *ситим, сэтэп* «чыжым; гомумән озын бау». Чыгышы безгә (гомумән) ачык түгел. Номинханов 1975: 142; ССТМЯ II: 99 (мәгълүматлары аз); ЭСТЯ VII: 253–254.

Язучы Г. Толымбай (әллә чынлап, әллә юри) *чыжым баганасы* «телеграф баганасы» дигәнне «чыжлап торган багана» дип аңлата (ул баганалар еш кына гүләп-чыжлап торучан иде). Халык этимологиясе, әлбәттә.

**ЧЫЙ I, чи** (**чый-чый, чи-чи**) – имитатив громкому писку, плачу; визгу животных. Гом. төрки һәм гом. алт. характерда, к. чыгт. (Будагов I: 506) *чыг,* төр. *çiğ* һ.б. Икенчел формалар. **чыйкчыйк, чыйыл-чыйыл** һ.б., к. **Чикыл-чикыл**.

Дерив.: **чыйна-, чинә-** (гом. алт. сүзе, к. эвенк., (ССТМЯ II: 397) *чиңэ-, чиңә-* «чинау», **чыелда-** (к.), **чыйкылда-у** һ.б. Шулардан тагын сүзләр ясала: **чыелдык, чыйкылдык** һ.б.

**ЧЫЙ II,** диал. (Тумашева 1992: 237–238, 243) **цей, ций, цый** «черта, рез (нанесённый острым предметом)» < кыт. *цзый* «иероглиф» (яисә *чжи* «язу, язып билгеләү»). К. **Чый-у**.

**ЧЫЙГАН** диал. «цыгань» < бор. төрки (ДТС: 148) *çïγап, čïγaj, čıγaǰ* «фәкыйрь» < ? (ДТС: 141) *čïrγuj* «фәкыйрь, ярлы». Әгәр бу сүз бор. монг. сөйләшләреннән булса (*-гуй* ~ төрки *-сыз*), сүзнең нигезе-тамыры *чыр* (к. **Чыр II**) була. Чаг. **Чегән.** Әйтелгәнчә, *чегән* һәм *чыйган* сүзләренең тамырдашлыгы шикле.

**ЧЫЙРАК** «крепкий» к. **Чирақ.**

**ЧЫЙ-У,** диал. (ТТДС I: 483, 495) **чий-ү,** себ. (Тумашева 1992: 238, 243) **ций-ү, цый-у** «писать (острым предметом), чертить, проводить борозду, царапать» ~ башк. *сый-,* (Баскаков 1972: 268, 272) алт. диал., чулым. *чий-, ций-,* (Баскаков 1966: 166) *чүй-*, хак. *сиг-* «язу, чыю» ← *чый, чий* (к. **Чый**) «язма, сызык, сызым» < кыт., к. ш. ук **Чимай. Чый-у** төп мәгъ. «язу» булуы диал. (Зимасов: 39) **йазыу-чыйыу** (синонимик парлы) сүзеннән дә күренә.

Дерив.: **чыйык ~ цыйык** (к. Будагов I: 509) «чыелган сызык, линия» (~ тув. *шыйыг,* алт. *чийик* id.); **чыйдыр-у** (**чый-у** фигыленең бүтән юнәлешләре теркәлмәгән); диал. **чыйгы, чыйгыч** «сызгы, сызгыч» (балтачылык эшендә).

**ЧЫК,** диал. **цық, цык, ысық** «роса» < гом. кыпч. *чық,* уйг., үзб. (ЎХШЛ: 303) *чығ, чиқ* > нуг., каз., к.-калп., тув. *шық* > хак. *сых* «юешлек, чык», төр. *çiğ, çiу* «чык» ~ бор. төрки (ДТС: 150) *čïŋ* «юеш», *čïq-* «юешләнү». Чаг. **Чи.**

Дерив.: **чыклы;** диал. (ДС III: 187) **чыкылма, чыкыллы йевеш** «бөтенләй юеш».

**ЧЫК-У,** миш., себ. **цык-у, цық-у** «выходить, выйти; выступать (бик күп күч. мәгъ.)» < гом. кыпч., алт., уйг., госм. *чық-*, уйг., үзб. *чиқ-* (> нуг., каз., к.-калп. *шық-*, башк. *сық-*) id. ~ чув. *тух-* < *тох-* < **тах* id. *Чық-* < *тшық-* < *тышық-* ~ *ташық-* < **талчық-* ← **талчы-* ← *тал-* > *талық-* > болг. *талқ-* > *тақ-* > чув. *тох-* > *тух-* дип аңлатыла, к. бор. төрки (ДТС: 540; Мухамедова 1973: 163) *tašïq-* «чыгу» ← *taš-* «ташу, чыгу»; яз. монг. *talgı-* «китү, чыгу, ераклашу». Сүзнең исем тамыры төркетчә *таш-* ~ болг. *тал-, талч-* «тыш, эчкә каршы як: өй, йорт эченнән бүтән киңлекләр». Будагов I: 479–480; Федотов II: 257–258 (әдәбият күрсәтелә).

**Чык-** бик продуктив нигезләрдән: **чыгыл-у, чыгыш-у, чыгар-у** (дөрес булмаган йөкл. юн., сирәгрәк **чыктыр-у** да кулланыла), **чыгын-у** (кайт. юн.) сөйләшләрдә «тәртип бозу, әдәпсезләнү һ.б.ш.» мәгъ. кулланыла (чаг. **Чыгым**); **чыгым** («сулык төбендә чишмә; таркау чишмә», к. ТТДС I: 494); ш. ук «хәраҗәт». Икенчел дериватлар бик күп, к. **Чыганак, Чыгынты, Чыкыкчы.**

**ЧЫКЫКЧЫ** (Будагов I: 479) «хирург, извлекающий осколки, обломки костей из ран» ← **чықық, чыққы** «чыгарга, чыгарылырга тиешле нәрсә»; бу сүз бор. төрки хәрби терминологиягә карый. Иске тат. сүзлекләрендәге бу сүз төр. *çıkıkçı* «хәрби фельдшер», *cıkık* «чыгынты; чыгып торган сөяк» сүзләреннән күчерелгән булса кирәк.

**ЧЫЛАЙ** (Баязитова 1986:48) «довольно много; изрядно» < чув. *чылай, чыллай, чылли* «байтак». М. Федотов (II: 428) мар. *цилай* «бөтен бер, тулы, күп» сүзенә карап, чув. сүзен рус. *целый* «бөтен бер» сүзеннән димәкче. Безнеңчә, ошбу китерелгән сүзләр чув. фонетик үзгәреш законнары нигезендә гом. төрки **талай** (к.) сүзеннән дә килеп чыга ала. Без *чылай вакытлар үтте инде* дигәнне ишеткәнебез бар. Чаг. **Чылгый II?** К. **Чәли.**

**ЧЫЛА-У** диал., сирәк «мочить» ~ уйг., үзб. *чила-* id., ш. ук «камыр изү», кырг. *чыла-* «болгату», *чыла* «былчырак», *чылала-* «чылау, чылату». Тат., башк. телләрендә *чыла-* фигыленең юн. формалары **чылан-у** ~ *сылан-у* һәм **чылат-у** ~ *сылат-у* активрак кулланыла. Бор. төрки (ДТС: 146) *čilä-* «чылау», *čilän-* «чылану», *čilät-* «чылату» сүзләренә караганда, *чыла-, чилә-* < *чыгла-, чиглә-*, к. кар. *чый,* алт. *чық, чың* ~ тув., төр. *чиг* «юеш; чык». К. **Чык.** Räsänen 1969: 106.

**ЧЫЛБЫР,** миш., себ. **цылбыр** «цепь; женское украшение; кружева» > мар. (Упымарий: 251) *чылвыр* «чылбыр», удм. *чильпыр* «вуаль, челтәр», чув. *чĕлпĕр* «яка чылбыры; нукта, йөгән» < гом. кыпч., к. кырг., алт. *чылбыр* (> башк. *сылбыр,* нуг., каз., к.-калп., шор. *шылбыр*) «йөгән; чылбыр», чыгт. *чилбур,* уйг., алт. диал. *чулбур,* госм. *җылбыр* «йөгән» ~ монг. *цилбуур,* яз. монг. *čilbuγur, čulbuγur* «йөгән, дилбегә». Гадәттә телчеләр бу сүзне монг. телләреннән алынма дип тәгърифлиләр. Безнеңчә, бу сүз фар. *чилбугур* «кырык бөҗра, чылбыр» дигәннән: *чил, чиил* «кырык», үзб., таҗ. (к. ЎХШЛ: 56) *бугур, буқур* «бөҗра; уенчык шарчык». К. төр. *çılbır* «күптөрле ашамлык». Чаг. **Чәлпәк, Челлә, Челпәрәмә, Челтәр** (бу сүзләр нигезендә дә *чәл* ~ *чел* ~ *чил* «кырык»).

**Чылбыр** < *чилбур* сүзе күп телләргә үтеп кергән, к. рус. *челбур* «бау, аркалык», *чемпур* «тарткы бау», *ченбур, чумбур* «йөгәнчек», *чилбур* «чыбыркы бөлдеркәсе» һ.б. (к. Аникин: 653–654). Будагов I: 484; Räsänen 1969: 108; Фасмер IV: 331; Федотов II: 410–4 (гомумән, бу сүз тур. күп язылган).

Дерив.: **чылбырлы, чылбырсыз; чылбырла-у; чылбырчык.**

**ЧЫЛГЫЙ I,** диал. (Радлов III: 1887) **чалгый** «полы кафтана», себ. (Тумашева 1992: 233) **цалгый** «крапива» < гом. кыпч., к. кырг. *чалғай* «өчкел тукыма кисәге», *чалғы, чалғын* «канат җәеме» ~ нуг., каз., к.-калп. *шалғай* «чабу очы», *шалғы* «канат кагымы», башк. (БТДҺ: 267) *сылғый, салғый* «тау итәге; кавырсын» ← **Чал-у** (к.).

**ЧЫЛГЫЙ II,** себ. (Тумашева 1992: 90, 244, 253) **цылғый, йылғай, ылғай** «всегда; сплошь» ~ башк. (БТДҺ: 128, 405) *йылғый, ылғы*, кырг. *чылғый*, каз. *ылғи* id. Монг. теленнән булса кирәк.

**ЧЫЛТЫР, чылдыр** – имитатив звону цепей, журчанию ручья и т.п. ~ чув. *чăлтăр* id.; чаг. **Челтер II.**

Дерив.: **чылтыр-чылтыр; чылтыра-у; чылтырда-у.**

**ЧЫМЧЫРЫК,** диал. (Зимасов: 98) **тымчырык,** себ. (Тумашева 1992: 244) **цымцырық** «тихонько, очень тихо», миш. (Ахмаров 1905: 19) **цымцырык** «молчаливый» ~ алт. *шымшырык* id. ~ каз. *шым-шытырық* «бөтенләй караңгы, ачык түгел», алт. (Баскаков 1966: 167) *чымчайынан* «тып-

тыныч», башк. (БТДҺ: 289), хак. *сымсырыӄ* «тыптын». Чаг. **Шым.**

**ЧЫМЫР** > башк. *сымыр* – имитатив мурашкам по коже, а также звукам выделения газов из прокисшего молока, пива и т.п. (изредка употребляется и как существительное: «пупырышек») ~ кырг. *чымыр*, уйг., үзб. *чимир*, каз., к.-калп. *шымыр* id.

Дерив.: **чымыр-чымыр; чымырда-у.**

**ЧЫН I,** миш., себ. **цын** «правда; правдивый; истинный; действительный; настоящий» > мар., удм. *чын,* чув. *чăн* id. < гом. кыпч., уйг., чыгт., бор. төрки (ДТС: 148), госм. *čïn* (> башк. *ысын*, нуг., каз., к.-калп., тув., шор. *шын* > хак. *сын*) ~ яз. монг. *čiŋ,* як., гом. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 258) *ǯиң* id. < кыт. *чжэн, чиң* «дөрес, чын; тугры; гадел». Räsänen 1969: 109; Федотов II: 402–403 (тәфсилле).

Дерив.: **чын-чын; чынлы; чынлык; чынла-у; чынлап;** иск. **чынчы** «тәкъва иясе», к. **Чыныкый.**

**ЧЫН II** диал. (Г. Теләш): **чын (ат) –** некая масть лошади. «Ялтырап торган кызгылт» мәгъ. бугай.

**ЧЫН III: чын ефәк, чын энҗе** сүзләрендә (по-видимому) «китайский» к. **Чынаяк.** К. **Цене.**

**ЧЫНАЯК [чы̆найак],** (Хайрутдинова 2000: 50–54) **чинайак,** миш. **цынайак** «фарфоровая и фаянсовая чашка (вообще – посуда)» ~ башк. *сынайаӄ* id. < **чыный аяк** «Кытай савыты > фарфор савыт» (чөнки фарфорны тәүләп кытайлар җитештерә башлаганнар). **Чыный** < фар *чӣнӣ, чыйный,* гар. *çӣнӣ* «кытайныкы» ← **Чин, Чыйн** «Кытай». К. ш. ук кырг. *чыны* > каз. *шыны* «фарфор; чынаяк; көзге», башк. (БТДҺ: 289) *сына* «тәгәч». К. **Цене.**

**Чынаяк** сүзе күрше мар., удм., рус телләренә дә кергән, к. Räsänen 1969: 111.

**ЧЫНДАН** тар. «Синьцзян (западная, уйгурская провинция Китая)» ~ уйг. *Чиндан* id. < кыт.

**ЧЫНЫ, чына** «цен, ценовная досочка» (палочка, лучина, которая вставляется между верхними и нижними нитками основы на ткацком стане для того, чтобы нитки не перепутались и не скомкались) ~ башк. *сыны* id. < рус. *цен (ценъ)* «каждый из двух рядов основы» – «тукыма буйлыгының аскы яки өске теземе», к. Даль IV: 578; Фасмер IV: 298 (Дальдә әйбәтрәк аңлатылган).

**Чыны** сүзе хәз. чорда онытылган диярлек, тик диал. (ЗДС: 772) **чынысыз** «юньсез, рәтсез» сүзендә һәм **чынысы чыгу** (ш. ук **җилесе чыгу**) «рәте китү, рәтсезләнү» идиомасында гына кулланыла; башк. диалектологлары *сыңысы сығыу* дигәндәге *сыны* сүзен «җаны» дип аңлаталар (к. БТДҺ: 289).

Рус. *ценъ* сүзенең ышандырырлык аңлатмасы юк, шунлыктан тат. **чыны** сүзен «рус алынмасы» дип әйтү дә шартлы әле. Гомумән, тат. **чыны** барча сөйләшләрдә дә кулланылмаган, кайбер якларда буйлык җепләре чуалмасын өчен чыра түгел, киндерә – **җиле** кулланганнар.

**ЧЫНЫК-У (чыныкты, чыныгу)** «закаляться; укрепляться (о человеке); приобретать опыт» < гом. кыпч. *чыныӄ-* (> башк. *сыныӄ-,* нуг., каз., к.-калп. *шыныӄ-*) id. – морфологиясе буенча **чыны-, *чын-* фигыленең интенсивлык формасы; ләкин андый фигыль теркәлмәгән, тик. кырг. *чыңа-,* уйг. *чиңа-, чиңай-* «ныгу, чыныгу» ← *чың* «ныклы» сүзләре генә билгеле. Гомумән, *чыныӄ-* нигезе **чың II** (к.) тамырыннан. Чаг. ш. ук бор. төрки (МК II: 117) *söz čïnïqtï* «сүз чынга чыкты, дөрес булып чыкты». Ихтимал, **чынык-у** фигыленең ясалышына шул бор. сүзнең контаминацион тәэсире булгандыр.

**ЧЫНЫКЫЙ,** (ТТДС I: 496) **чыңкый** «истинный, настоящий, самый правильный» ~ кырг. *чыныгы*, тув. *шынныг* id. **Чын** сүзеннән, ясалышы ачык түгел. Чаг. монг. (сол.) *ǯинки*, маньч. *ǯиңкини* «чыныкый», к. ССТМЯ I: 258.

**ЧЫҢ I** – иммитатив звону, «звон, длительный однообразный гул (в голове, в ушах)» ~ гом. төрки *чың*, уйг., үзб. *чиң* id., кырг., кр.-тат һ.б. *чың* > каз. *шың* «чең (туйда кәләш җыры, кайбер чыганакларда “скабрёз җыр” диелә)», як. (Пекарский III: 3686, 3719) *чың* «тимер чыңлавы», *чуң* «чуенга сугу авазы», *чуңи* «кискен аваз», уйг. *чиң* «һәртөрле музыкаль инструмент» һ.б. (гомумән *чың//чиң, чаң//чәң, чуң//чүң* – төрле югары авазларны белдерә торган тәкълиди тамыр) ~ монг. *чиң, циң* – музыкаль инструмент төрләре: к. ш. ук **Чина-у, Чыңгыл, Чыңгыр, Чыңкы.**

Дерив.: **чың-чың, чың-чаң; чыңла-у** һ.б.

**ЧЫҢ II: чың тимер** «род железа (звонкая сталь)», **чың чынаяк** «качественный (звонкий?) фарфор» ~ кырг. *чың,* уйг., тув., *чиң,* бор. төрки *čïŋ* «ныклы, катгый; каты», каз. *шың* «бик каты (җир), таш җирлек»; к. ш. ук тат. диал. («Идегәй») **чуң**

**тимер** «корыч». К. **Чыңка, Чыңкы.** Räsänen 1969: 111–112.

**ЧЫҢ III** (ТХИ: Дастаннар 1984: 291) «представитель завоёванного народа»; к. ш. ук (ЛТ I: 171) **чуаш-чиңки** «яулап алынган халык – табигълар». Чаг. чув. *çын* «кеше, ят кеше» (алт. *дьон,* тув., шор., хак. *чоң* ~ яз. монг. *ǯon* «халык, мир» сүзе белән чагыштырыла, к. Федотов II: 153–154). Гомумән, ачык түгел.

**ЧЫҢГЫ** (миш., ЗДС: 772) «звонок в дверях», ш. ук **чыңгарак** «звонкие крики детей», иск. **чыңгыр** «колокольчик» ~ төр. *čingir* «бертөр музыкаль аләт», иске тат. **чыңгырак,** төр. *çıngırak, cıngırdak* «ишек кыңгыравы» һ.б. (охшаш сүзләр күп төрки телләрдә очрый). К. Будагов I: 481; Räsänen 1969: 109.

**ЧЫҢГЫЗ** «Чингизхан (имя собственное)», татарча яңгыраш сәеррәк, чөнки гом. төрки, монг. *Чиңгиз* (палаталь рәттә) «Чыңгыз хан», гомумән «император» – бор. уйг. *тәңгиз* «диңгез» сүзеннән дип уйланыла, к. ТА XII 1964: 55; Советская историческая энциклопедия, Т. 29. М., 1978: 604 һ.б. абруйлы басмаларда шундый ук аңлатма бирелә. Ләкин Г. Дёрфер бу этимологиягә каршы (к. Doerfer I: 312–315, шунда ук *чиңгиз* сүзенең бүтән этимологияләре китерелә).

Шуны әйтергә кирәк: күпчелек чыганакларда бу исем палаталь янгыраштa, тик татарларда һәм (алардан алып булса кирәк) башкортларда веляр вариантта: *Чыңгыз > Сыңғыз.* Казакларда да *Шыңғыз,* ләкин күп кенә очракларда *Чиңгиз ~ Шиңгиз* дип языла. *Чиңгиз ~ Чиңгис* асылда уйг. теленнән таралган (бу телдә *-ы-* һәрдаим, сүздә каты тартыклар килсә дә, *-и-* белән алмаштырыла, мәс., *қызыл > қизил, қылмақ > қилмақ, чықды [чықты] > чиқди* һ.б.). К. ш. ук төр. *Čengiz*, иске әрм. чыганакларында *Чангиз*, рус. елъязмаларында (История татар, т. III: 778) *Чаногизъ*. Тат *Чыңгыз* беренчел яңгырашка *чингиз* яңгырашыннан якынрак бугай.

Атаклы Чыңгыз ханның асыл исеме *Тэмучин* һәм бу исем Чыңгыз ханның атасы Исүгәй баһадирда хезмәтче булып яшәгән әсир татар *Тэмүрчин* «тимерче» шәрәфенә бирелгән (күрәсең, ул татар әйбәт кеше булган). Тэмучин хан зур уңышларга ирешкәч, 1206 елда корылтай җыя һәм шунда аңарга шаман – баш рухани *Кәкчү Тэб-Тэңри* тәкъдиме белән *Чиңгиз ~ Чыңгыз* дигән шәрәфле исем бирелә. Бу сүз ул корылтайда катнашучыларга таныш булган, тик менә төп мәгънәсе һәм асыл яңгырашы безгәчә килеп җитмәгән. Шунлыктан Э. Хара-Даван (к. На стыке континентов: 125) «бу сүзнең канәгатьләндерерлек аңлатмасы беркайда да очрамый», ди.

XIX г. һәм XX г. башларында татарларда **Чыңгыз** сүзе бик популяр булган, «Чыңгыз баласы» дигән балалар журналы чыгарылган һәм балаларга Чыңгыз исеме бирелгән (безнең шәхсән гомеребездә Чыңгыз исемле ике кешене күргәнебез булды). Төрки халыкларга тарихта иң көчле удар ясаучы Чыңгыз хан монголлары икәнен искә алсак, мәзкүр мавыгулар юккарак диярга кирәк. Әмма төрки һ.б. халыкларда *Чыңгыз ~ Чиңгиз* исеме хәзер дә очраштыргалый.

Безнеңчә, *Чыңгыз* исеменең Себер төркиләрендәге (тува, якут) *чаңгыз* «ялгыз, бердәнбер» яңгырашаннан килүе мөмкин. Себер халыкларында *Чаңгыс* «батырлар башлыгы» тур. эпик әсәрләр очрый.

**ЧЫҢГЫЛ I: чыңгыл-чыңгыл** – имитатив звону (особенно – колокольчиков среднего размера); бу сүз үзе генә исемләшкән: **чыңгыл** (Г. Әпсәләмов) «туй кыңгыравы». К. ш. ук (ТТДС I: 498) **чыңғы** «кыңгырау».

Дерив.: **чыңгылда-у, чыңгылты** һ.б.

**ЧЫҢГЫЛ II** (Будагов I: 483–484), диал. (Тумашева 1992: 244) **цыңгыл** «терновник; колючка» ~ каз. *шыңғыл*. Чаг. як. *чыңкыл* «нык, көчле (каршылык тур.)». К. түбәндәгене.

**ЧЫҢГЫР** – имитатив звону цепей ~ башк. *сыңғыр*, каз., кырг., алт., төр. һ.б. *чыңғыр ~ шыңқыр* id. К. **Чың I.**

Дерив.: **чыңгыр-чыңгыр; чыңгырдау;** диал. **чыңгыра-у < чыңгы-чырау** «яңгыратып кычкыру» (мәс., торна тур.), «чыйна-у» һ.б. (төрки телләрдә дериватлары күп).

**ЧЫҢКА,** (Тумашева 1992: 244) **цыңка** «крепление к двери, на которое навешивается замок» ~ уйг. диал. *чиңка* id. ~ *чиңка-* «көчәйтү; ныгыту». Каз. (ҚТДС: 408) *шың* «келә элү өчен ишеккә беркетелгән божра». К. түбәндәгене.

**ЧЫҢКЫ** (ТТДС I: 498) «крепкий; строгий; злой; решительный» – **чың II** сүзеннән, әлбәттә, к. уйг. *чиңки-* «ныгу; көчергәнү», *чиңк-* «ныгу, тыгызлану һ.б.». К. Räsänen 1969: 111–112 (монг. теленнән ди).

**ЧЫҢРАК, чыңгырак** (мәкальдә: *Чыңрактан үтә киткере*) – «дымовое отверстие чувала». К. **Чаңгырак.**

**ЧЫҢРАУ [чыңраw]: чыңрау торна** «ибис (птица) ~ башк. *сыңрау* «торна», каз. *шыңрау турна* id. *чыңгыра-у* «югары тавыш белән көчле итеп кычкыру» сүзеннән, к. Будагов I 483. Башкортларда *сыңрау торна* тур. легенда бор. һәм шуңа корылган опера иҗат ителгән.

**ЧЫПТА,** (ЛТ I: 168; ТРС 1931) **чөпта** «циновка; рогожа; рогожный куль; плетёнка (саней)» > чув. *чăпта,* мар. (Исанбаев 1978: 33) *чыпта* id. < гом. кыпч. *чыпта* (нуг., каз., к.-калп. *шыпта*), уйг., үзб. *чипта* «чыпта; тупас тукыма; кап, капчык», чыгт. (Радлов III: 2155) *чіфтä,* госм. *чифта* «камыш чыпта; ятак», үзб. диал. (ЎХШЛ: 302) *чипта* «капчык», *чъпта* «камыш кипкер» < фар. *чифте, чүфтэ* «ике катлы (тукыма)», к. кырг. диал. *чүптә* «келәм», Федотов II: 404 (чыгышы күрсәтелми). Рус. *чекта* «үлән чыпта» тур. Аникин: 653. Төр. *чифт, чүфт, чифтä* – төрле парлы нәрсәләр тур. Будагов I: 478. К. **Җефет, Җөп.**

Дерив.: **чыпталы, чыптасыз; чыпталык.**

**ЧЫПЧЫК,** миш., себ. **цыпцык** «воробей; любая мелкая птица, пташка» > чув. *шăпчăк*, мар. *шупшык, шүшпүк* «сандугач», мар., удм. *чибизик* «шәүлегән, сиртмәкойрык һ.б.ш. кош» < гом. кыпч. *чыпчык,* ком. *җымчык,* башк. *сыпсык*, бор. ядкәрләрдә *чыпчык, чыпчук, чыпчак, чупчук* «төрле вак кош, чыпчык», каз. *сыбышык,* кырг. *чымчык,* үзб. *чумчук* «чыпчык», чыгт. (Радлов I: 216) *чімчік* id. һ.б. Бу сүз формаль җәһәттән *чып* тамырыннан, ләкин бу очракта «формаль» этимология (бигүк төгәл) дөрес булмас, ошбу сүздә имитативлык өстенлек итә, чаг. рус. *пичуга, чипчуга* «кошчык», як. *чыычаах* ~ монг. *чечіге,* маньч. *чэчикэ* һ.б. «кошчык, чыпчык» (к. Пекарский: 3731), эвенк. *чипича, чичакун* «кошчык, чыпчык; песнәк» (к. ССТМЯ II: 398, 401, бик күп мисаллар китерелә, алар төрле вак кошларны белдерә), ягн. *siča* ~ сугд. *syč* «чыпчык»; кыт. *чи* < *чиб* «кошчык» һ.б. Рус. *чипчикуй* «тургай төре» << яз. монг. *čipčiγai* «чыпчык» тур. Аникин: 663.

**ЧЫП: чып-чып, чыпыл-чыпыл, чыпылда-у** «плеск; плескать» и т. п. – гом. төрки сүзләр.

**ЧЫПЫР: чупыр: чыпыр-чыпыр, чупыр-чупыр** – имитатив громкому всплеску, всплескам и т.п. ~ башк. *сыпыр-сыпыр, супыр-супыр,* чув. *чăпăр, чăппăр, чаппăр* id. Бүтән төрки телләрдә дә охшаш сүзләр бар. Чаг. югарыда.

Дерив.: **чыпырда-у, чупырда-у; чыпырдык** (балык төре).

**ЧЫР I** – имитатив визгу, а также сверчению, верещанию, свисту, чириканию и т.п. резким голосам ~ чув. *чăр,* гом. кыпч. *чыр* > нуг., каз., к.-калп. *шыр,* башк. *сыр* id. (барча дериватлары белән). Чаг. **Чар, Чәр, Чер** һ.б. Бу төрдәге имитативлар күрше телләрдә дә киң таралган, чаг. рус. *чик-чирик* һ.б.

**Чыр** – күптөрле дериватлар нигезе: **чыр-чыр (килү), чырык-чырык (килү); чыркыл-чыркыл; чырла-у, чырылда-у; чыркылда-у → чырылдык, чыркылдык; чырый; чырый-чырый; чырый-чарый; чырыйла-у** һ.б.

**ЧЫР II** «жир, плёнка на поверхности мясного супа, навар; блеск кожи человека» < гом. кыпч. *чыр* id. (> каз. *шыр: шыр біту* «тазарып матурлану», кар. *цыр* «филтә; лампа мае») ~ бор. төрки (ДТС: 146, 151) *čir* «җәү, эч мае», *čïrγuj* «ярлы, фәкыйрь» < монг. *чиргүй* «чырсыз».

Дерив.: **чырлы** (ТРС 1931) «матур, нурлы йөзле», **чырлан-у** «йөз нурлану, сәламәтлек тәэсире калдыру».

**ЧЫР III** (ТТДС II: 497) «мелкая рыба; вид мелкой рыбы» < рус. *чир*?, к. Аникин: 664 (бу сүзне коми теленнән дип күрсәтә). Тат. сүзе гәй. сөйләшендә – Уралда теркәлгән һәм, ихтимал, удмурт теленнәндер.

**ЧЫРА** «лучина; длинная щепка» > мар. *чыра* id. < гом. кыпч., төркм., госм., чыгт. һ.б. *чира, чыра* (> башк. *сыра,* нуг., каз., к.-калп. *шыра*) id. < фар. *чирāғ* (к. **Чырак**). *Чыра* сүзенең элек чыракны белдергәнлеге *Көн күрмәгән көн күрсә көндез чыра яндырыр* дигән мәкальдән күренә.

Дерив.: **чыралы, чырасыз; чыралык; чырагач** < *чыра агачы* һ.б.

**ЧЫРАЙ,** миш., себ. **цырай** «лицо (как выразитель настроения), облик» > мар. (Упымарий: 252; Иванов, Тужаров: 266; Саваткова: 189) *чырай, цырей, чурий, цыре* «чырай, төс» < гом. кыпч., алт. *чырай* (> нуг., каз., к.-калп. *шырай,* башк. *сырай*), чыгт., уйг. *чирай,* үзб. *чирой* id. ~ яз. монг. *čiraj* > хәз. монг. *цирай,* хак., як. *сырай* «чырай, йөз» < фар. *чäһрä* < авест. *čithra* ~ бор. һинд. *čitra* «якты

(йөз)», к. ш. ук **Чәһрә** (гомумән *чäһрä* > *чайра* > *чирай* күчешләре булган). Platts I: 461; Абаев I: 549; Räsänen 1969: 109.

Дерив.: **чырайлы** (бу сүз «матур» мәгъ. дә кулланыла), **чырайсыз** «төнтек» (к. **чырайсыз ябалак** – өкеләрнең бер төре).

**ЧЫРАК,** иске тат. **чыраг,** миш. **цырак,** себ. **цырак** «светец (железный торшер с рожками, куда вставляются светильники, в крайнем случае – лучины); железное решето, прикреплённое на носу лодки, где горел костер для ночного лова рыбы»; (ДС I: 221) «лучина», иск. шигъ. «свет глаз моих (о любимом человеке)» > мар. (Упымарий: 246) *чрак* «төнлә балык тотуда кулланыла торган чырак», удм. *чаг* «чыра» (*чагкусо, чагпурт* «чыра пычагы, чыра балтасы», *чагкис, чагпис* «чырагач») < гом. кыпч. *чырақ* (> башк. *сырақ*, нуг., каз., к.-калп. *шырақ*), кр.-тат., госм., аз. һ.б. *чыраг, чараг* «яктырткыч» < бор. фар. *raočah* (метатеза яисә бүтән бер сүз ялганган), к. ш. ук сугд. *črγ* «лампа». Абаев I: 374; Будагов I: 472; Räsänen 1969: 109; Мухамедова 1973: 191.

Дерив.: **чыракла-у** «төнлә яктылык ярдәмендә балык тоту»; **чыракчы** (к. Исәнбәт I: 567, *Чыракчыны чуртан күрмәс* мәкалендә). К. **Шәмчырак.**

**ЧЫРГА-У, чыргы-у**, диал. (ТТДС I: 49) **чорға-у, чоргы-у,** себ. (Тумашева 1992: 245) **цырға-у** «кидать вверх» ~ башк. (БТДҺ: 280) *сорға-, сорғо-* < *очырға-* ← **Очыр-у** (к.).

**ЧЫРМА-У, чырна-у** «опутать» к. **Чорна-у.**

**ЧЫРТАН** (ДС I: 221) «костёр» < фар. *чирāгдāн* «яктырткыч учак»?

**ЧЫРШЫ I,** диал. (ТТДС I: 498) **чырыш** «ель, сосна» ~ башк., нуг. *шыршы,* чув. *чăршă, чăрăш*, каз. *шырыш*– искечә **чырышлы** «сумалалы (агач)» сүзеннән эллипсис булса кирәк, к. себ. (Тумашева 1992: 248) **чыршынны < чыршынлы** «сумалалы агач – чыршы, пихта», гом. кыпч. *чырыш*, каз. *шырыш* «сумала, чаршын, шереш». Икенче яктан к. фар. *сäршāһ* «күпботаклы» (бу фаразны к.-калп. *шырша* «чыршы» сүзе куәтли). Федотов II: 404.

**Чыршы** сүзенә рус. (Аникин: 647, 664) **чарыш** «куе вак урманлык», *чирища, чирище* ← *чира* «эчендә йөргесез урман» сүзләре бик охшаш. Ләкин бу сүзләр тува теленнән, Көньяк Себердән алынганнар. Тув. *чыра* ~ алт. *дьыра* «куе әрәмәлек» сүзенең татарча диалектлардагы эквиваленты *җыра* бугай (бу сүзнең ер-удан ясалуы мотлак түгел).

**ЧЫРШЫ II** (миш., ЗДС: 774) «вид рыбы, пескарь». Чаг. рус. *шереш, шершпер?*

**ЧЫРЫМТА, чорымта** «остатки мочала», диал. (ДС III: 192; БТДҺ: 399) **шарамта**, **шырамта** «мочалка» ← *чӧр-у, чур-у* (к. **Чурга-у**). Ясалышы бик үк ачык түгел.

**ЧЫРЫШ-У, чыршай-у** «сморщиться, покрыться морщинами» ← **чыр-у, *чыры-у*, к. алт. диал. (Радлов III: 2079) *чырі-* «бөршәю, бөрешү; чырыш-у», *чырышкан* «чыршаюлар, җыерчыклар», к. Баскаков 1966: 167.

**ЧЫТ I** (Будагов I: 503) «морщины на лбу лошади», диал. **чыт-у** «сморщить лицо» (*йөзен чытты* диелә, моны **сыт-у** белән бутыйлар). Чаг. **Чытлык, Чытык.**

Дерив.: **чытай-у** «чыраен чыту», башк. *сытрай-у* id.

**ЧЫТ, чыты** (ДС I: 215) «плетенье, плетёная корзина», себ. (Тумашева 1992: 223) **цыт** «плетень» < кырг. *чыт*, төр. *çıt,* башк. *сыт* id., бор. төрки (ДТС: 151) *čït* «койма, камыш шалаш». Чаг. **Читән.**

**ЧЫТАН** (Троянский I: 468) «росомаха», диал. (трбс.) «некое лесное животное, рысь (?)» ~ үзб. *чита* «гепард». Фар. теленнән булса кирәк (һинд. телләрендә *чита* «гепард»).

**ЧЫТКЫЗ, чыткыс** «пояс должностных лиц на свадьбе», (ТТДС I: 498) «женский пояс с кистями» – мордва телләреннән булырга тиеш (бу сүз мордва-каратайларда теркәлгән), к. морд. Э. *цёко* «чук» (< тат.), *цёказъ* «чукланган».

**ЧЫТЛЫК, чытлак** (ЛТ I: 168 «бер төрле кызлар» дип аңлатыла) «кокетливый; излишне улыбчивый» – **чыт < чырт** (нинди мәгънәдә?) сүзеннән, к. диал. **чыртлы, чытлы, чытлык** «тиктормас; елгыр; шук» (к. ТТДС I: 498), **чытлан-у** «тик тормау, чытлыклану» (ТТДС II: 362). Тамыры ачык түгел.

**ЧЫТЫ** (ТТДС I: 498) «корзина, плетенье», **чита** (ТТДС II: 354) «ограда» ~ башк. (БТДҺ: 391) *сыт* «читәннән үргән каз оясы; рәшәткә; текмә» < рус. *щит, щиты*? К. ш. ук **Читән.**

**ЧЫТЫК** «угрюмый, неприветливый; сморщенный (о лице)» ← **чыт-у** (к. **Чыт-у I**). Чаг. ш. ук уйг. (Zenker: 378) *чытуқ* «усал йөз; явыз шайтан; Чыңгыз хан кылычының сабындагы бер бизәк».

**ЧЫТЫР** «густая чащоба, заросли, густой кустарник; хворост, сухие сучья на растопку», диал. (ТТАС III: 463) «плетень, плетеный» > мар. (Упымарий: 253) *чытыр* id. ~ башк. *сытыр* id., ш. ук «буйлык җепләрнең кылыч артындагы буталчыгы» (к. БҺҺ II: 227), кырг. *чытыр* «утлавык үләне», ком. *җыдыр* «чытыр», каз. *шытыр* «терлек ашамый торган үлән; эт эчәге» ~ гаг. *чытран* «биек үләннәр», *чытыран* «куе урман» ← **чыт II,** к. чув. *чăтлăх* «чытырман», төр. (YTS: 56) *çitilgi, çitilgu, çitilki, çiturgu* id.

Дерив.: **чытырлы, чытырсыз; чытырлык;** диал. **чытырық, чытырак** «чытыр». К. **Чытырман.**

**ЧЫТЫРМАН,** диал. (Дмитриева 1981: 195) **цатырман** «густые заросли», күч. «нечто непонятное»; «вспыльчивый, горячий (как горящий сухой хворост)» < гом. кыпч., алт. *чытырман* (> башк. *сатырман,* нуг., каз. *шытырман*), шор. *шыдырбан* > хак. *сыдырбан* «чытырман», уйг. *читирман* «бер төр үсемлек; ялган, хәйлә, мәкер» ← *чытыр* сүзеннән, әлбәттә («зур чытырлык» мәгъ.). Бу сүз күрше телләргә дә кергән, к. манси. *чытырман, шытырман* һ.б. (к. Steinitz: 85–100); мар. (Упымарий: 253 һ.б.) *чатыртан, чатыркан* «вак ягулык чытыр» сүзе дә **чытыр, чытырман** сүзләре белән баглы булса кирәк, к. тат. сөйл. **чытыр-чатыр** «чытырманлы».

Дерив.: **чытырманлы, чытырманлык**. Ахметьянов 1989: 49; Федотов II: 406 (чув. *чăтлăх* «чытырлык» тур.).

**ЧЫТЫРТ** – имитатив одноразовому треску ~ башк. *сытырт,* чув. *çăтăр, çатăр* id. (чув. телендә бу имитативтан күп кенә сүзләр ясала). Гом. төрки характерда.

Дерив.: **чытырт-чытырт** (> **чытыр-чытыр**); **чытыр-чатыр, чытыр-чŏтыр** (яну тур.); **чытырда-у; чытырдык. Чытырт, чытыр** сүзенең **Чытыр, Чытырман** сүзләренә контаминацион катнашы бар. К. ш. ук **Чатыр I.**

**ЧЫШ** – имитатив шипению ~ чув. *чăш* id. (бу телдә бик продуктив тамыр).

Дерив.: **чышылда-у; чыш-пыш** (төрле чышылдаулар, ш. ук пышылдап сөйләшүләр тур.); сирәк кенә **чышт (итү)** тәгъбире дә очрый.

**ЧЫЧКАН, чышкан** (ЗДС: 775) «мышь, мышонок» к. **Сычкан, Тычкан.**

**ЧЫШТЫРТ** – имитатив одноразовому шороху, шуршанию ~ чув. *чăштăрт* id.

Дерив.: **чыштарт-чыштырт** (> **чыштыр-чыштыр**); **чыштыр-чаштыр, чыштыр-чоштыр; чыштырда-у.**

# Ш

**Ш** авазы тат. телендә бор. (руник һ.б.) *ш* авазыннан һәм кайбер очракларда прототөрки *л* (*лч*) авазыннан килә. Сирәк кенә булса да гом. төрки *ч* > тат. *ш* очрый.

*Ш-* авазына да күп кенә тәкълиди сүзләр башлана. *Шш* – «чү! тавышланмагыз!» мәгъ. ымлык гом. төрки һәм гом. слав. характерлы сүз. Чаг. рус. *шикать.*

**ШАБ** ист. (Троянский; К. Насыйри) «квасцы (для дубления кож)» < фар. *шāб* < гар. *шāб* id.

**ШАБАЛА** (ТТДС I: 502; БТДҺ: 388), **шапала** (ЗДС: 779) «дуршлаг, разливательная ложка; лопатка для очищения плуга; отвал плуга, предплужник», себ. (Тумашева 1992: 248) **шабала, шәбәлә** «кашык», диал. (ТТДС I: 469, 493) **чабала, чыбала** «дуршлаг» һ.б. > удм. (Насибуллин: 146) *шабала* «сука шабаласы», мар. (Упымарий: 156) *савала, совла* «кашык» < гом. төрки, к. алт., каз. *шабала,* алт. *чабала*, шор. *шабыла,* чув. *çăпала, шăпала* «кашык, уҗау», каз. диал. *шабала* «кипкер, дуршлаг», тув. *шопулаӄ* «кашык», госм. *сапылак* «озын саплы чүмеч», тув. *шамнаӄ, шамлаӄ,* шор., хак. диал. *самнаӄ,* алт. диал. *самалак*, чулым. *чебеле, цебеле, шебеле* «кашык». Чаг. үзб. *сопол, сапал* «чүмеч», уйг. *сапал* «керамик савыт-саба», кырг. *сапал* «керәч, нык яндырылган керамик әшья (савыт-саба гына түгел)» – К.К. Юдахин фикеренчә, ир. телләрдән. Будагов I: 659; Joki 1952: 283; Räsänen 1969: 96; Егоров 1964: 207; Федотов II: 96 (һич нигезсез рәвештә *шабала* сүзен чув. теленнән димәкче). Рус. *шабала* «сука шабаласы» тур. Аникин: 681–682 (болг. теленнән димәкче).

Гомумән, бу сүз рус теле аша да киң таралган. М. Федотов һәм А. Аникин фикере венгер галимнәренең бу сүзне венг. *csobolyo* «агач мичкә, тәпән» сүзен бор. болг. теленә нисбәт итүенә нигезләнә. Ләкин сүзнең таралышы болг. теле тәэсире даирәсеннән күпкә киңрәк. Аннары төрки телләрдә күпчелек очракта *ч-* > *ш-*, киресенчә булган очраклар юк диярлек (аерым шартларда гына мөмкин), шунлыктан тат. диал. **чабала, чыбала** ~ чулым. *цебеле, чебеле* беренчел фонетик вариантка якынрак булырга тиеш.

**ШАБАЛКА, шебалка** (ТТДС I: 509) «лопатка для очищения плуга» < рус.; рус телендә бу сүз **шабала** (ш. ук *шебала, шибало*) сүзенең деминутив формасы, ә төп форма исә татарчадан булса кирәк. **Шибало** варианты – рус. *шибать* «сугып төшерү» сүзенә нисбәт ителгән, бу – халык этимологиясе нәтиҗәсе. К. югарыдагыны.

**ШАБАШ** «ничего не поделаешь, шабаш» < рус. *шабаш* < яһ. *шаббас* «шимбә, яһүди ял көне» – асылда **шимбә** (к.) сүзенә тамырдаш. Фасмер IV: 391.

**ШАБДАР** «растение, похожее на клевер» < фар. *чāвдāр*, төр. *çavdar* «арыш» (*шабдар* арыш арасында үсүчән).

**ШАБРА, шабура** (ТТДС II: 371; ЗДС: 775) «сосед-инородец; друг из представителя другого народа» ~ каз. *шабра* id. < рус. *шабёр* (родительный падеж) «күрше; эштәш, әшнә», рус. диал. *сяберь* id. һ.б. – гом. слав. сүзе (шуннан ук *серб* этнонимы килә) диләр, к. Фасмер IV: 391. Ләкин к. каз. (ҚТДС: 373) *шабыра* «(тиреләрдән ясалган) куыш», ш. ук «күрше».

**ШАБЫР I** (ДС I: 225) «чекмень из домотканного холста» ~ башк. (БҺҺ II: 303) *шубыр* «теш саен бер җеп үткәреп сугылган киндер», чув. *шапăр* > *шопăр* > *шупăр* «җиңелчә ак җилән», удм. *шабур, шобыр,* мар. *шобыр, шовыр,* рус. *шабур, шабура, шабурина, шабурятина, шебур, шибур, шубур* «җиңел чикмән; таушалган шинель; шабыр; җиңсез чикмән һ.б.ш. иске кием» < иске тат. **чабур, чабыр** (к. «Җәмигыль-хикәят»тә: *дөхтәрнең ихтыяр чабырын башына бөркәде* дигәндә **чабыр** – «ябынча, плащ») < фар. *чāпāр, чāппāр* «читән, юан аркаулы тукыма, чәпер» (к. **Чапрак, Чәпе**). Бу сүз Евразиядә киң таралган, к. к.-балк. *чабыр* «каеш чабата», хак. *сабыр* (бу телдә *ч* > *ш* > *с*) «аучы чикмәне, халат», хак. диал. *сүбүр, шубыр* «озын ыштан», кырг. *чабыра* «зур кәрзин» һ.б. уртак нигездән булса кирәк. Фасмер IV: 392; Отаров 1978: 42, 90; Федотов II: 461; Аникин: 682.

**ШАБЫР II, шыбыр** – имитатив обильному стоку, стеканию воды, пота ~ чув. *шапăр*, төркм. *шабыр* id. һ.б. (гом. төрки сүз булырга тиеш). К. **Шылбыр.**

Дерив.: **шабыр-шобыр** (кыектан шаулап аккан яңгыр суы тур.); **шабырда-у.** Идиомалар: *шабыр булу; шабыр тиргә бату.*

**ШАВА [ша$^{o}$wa]** (ТТДС I: 371; ЗДС: 775; Г. Әхмәров әсәрләрендә) «большая (деревянная) чаша, тарелка, чашка» ~ морд. М. *шава,* морд. Э. *ашава* id. Арытабан безгә ачык түгел. Чаг. уйг. *чаwа* «май савыты».

**ШАВЫЛ [ша$^{o}$wы̆л]** (ДС I: 225), алабугат. (Арсланов 1988: 100) *шәвіл* «вид крыс (с очень длинными хвостами)» < төр. *şavul* «шакул», үзб. (ЎХШЛ: 309) *шәвүл* id. **Шакул** (к.) белән гомоген булса кирәк (озын койрыклы күсе шакулга охшатылган).

**ШАГЫ́ЙРАНӘ [ша$^{o}$ғиранә]** «поэтически» < фар. *шā‘ирāнä* id. ← гар. *шā‘ир* «шагыйрь». К. түбәндәгене.

**ШАГЫЙРЬ [ша$^{o}$ғир]** «поэт» < гар. *шā‘ир* id. ← *ш‘р* «хисләнү» тамырыннан, шуннан ук к. **Шигырь.** Бүтән төрки телләрдә *шаир* дип тә әйтелә. Тимергалин: 547.

Дерив.: **шагыйрьле, шагыйрьсез; шагыйрьлек; шагыйрьләрчә.** Искечә **шөгарә** «төрле шагыйрьләр» (**шагыйрь-шөгарә** id.).

**ШАГЫР** (имитатив) к. **Шыгыр.**

**ШАДРА, шадыра,** себ. **шатра** «рябой; рябь на лице», диал. (ДС II: 222) «пёстрый, цветистый», (ТТДС I: 510) «вафельная ткань» ~ башк. *шаҙра, шаҙыра* id. < фар. *чāдир, чāдирä* «чадралык тукыма» < һинд. *čitra* «чуар», к. **Чатыр, Чәһрә, Чутыр, Чырай. Шадра** сүзе нуг.-тат. даирәсеннән күп күрше телләргә таралган: чув. *шатра* «шадра; шадралык; чутыр», мар. *шадра, шадыра, шедра*, удм. (Насибуллин: 149) *шэдра* «чәчәк чире; шадралык», рус. *шадра, шедра* «чутыр; шадралык» (→ *шедровый* «шадра битле») һ.б. К. ш. ук шор. *шадыра* > хак. *садыра* «шадра», себ. (Тумашева 1992: 249) *шатыр* «эре бөртекле». Räsänen 1969: 440; Фасмер IV: 394; Федотов II: 437; Аникин: 684 (**шадра** сүзенең татарчадан таралганлыгын инкяр итмәкче, ләкин тат. теле материалы шелтәсез рәвештә без китергән этимологияне раслый).

Дерив.: **шадралы, шадрасыз; шадралык; шадралан-у.**

**ШАДРИК** «поташ» < ним.; элек Идел-Урал регионында *шадрик* заводлары күп булган һәм крестьяннар шадрик чималы белән шөгыльләнеп акча эшләгәннәр; *шадрик* заводларында нимес осталары эшләгән.

**ШАДЫР** (ТТДС I: 510) «весёлый, развесёлый» ~ кар. *шатыр, сатыр* id. < фар. *шāдх̣$^{w}$āр* «шаталак; исерекләрчә шат». К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 249) **шатрак** «шатлыклы» < фар. *шāдх̣$^{w}$āрäк* id. К. **Шаталак.**

Дерив.: **шадырлык, шадырлан-у.**

**ШАДЫРВАН [ша$^{o}$дырwан], шадирван** иск. (Будагов I: 659–660) «павильон у мечети с ажурными прозрачными стенами» ~ гаг. *шадраван*, төр. *şadırvan* «мәчет янындагы фонтанлы бассейн» < фар. *шāдорвāн* id.

**ШАЙ I, шәй** (ДС I: 226, ДС II: 228; БТДҺ: 389 һ.б., Көньяк Уралда киң таралган) «как будто, вроде» Л. Җәләй буенча, *охшай, ǒшай* сүзеннән, ләкин кайбер урынчылыкларда (мәс. к. Хайрутдинова 1985: 92) **шайы** дип әйтелә һәм бу вариант үзб. *чағи, чоғи* «шай» сүзен хәтерләтә (*чағ* «таман» сүзеннән). К. ш. ук гар. *шā’аи‘* «ишетелә, ишетелгәнчә». Мар. *сäй,* (сирәгрәк) *сай* «бугай» рус. *чай, чать* «-дыр инде» (← *чаять* «дип уйлау, өметләнү») сүзеннән дип хисаплана, ләкин тат. *шай* < рус. *чай* дип исәпләргә тат. сүзенең мәгънәви һәм синтаксик үзенчәлекләре хилаф (рус. сүзе – кереш сүз, тат. сүзе – кисәкчә). Гомумән, **шай, шайы** сүзен **шай II** сүзеннән дә аеруы кыен. Һәрхәлдә **шай I** тат. телендә формалашкан. Федотов II: 430 (урынсызга **җай** сүзе белән чагыштыра).

**ШАЙ II** (м.-кар.; Хайрутдинова 1985: 101–102, к. ш. ук Исәнбәт – I: 425 – «ел белән ел шай түгел») «ровный, ровно; равный, подобный; ногодок» ~ чув. *шай* «тиң, тиңлек, тигезлек; тәңгәл; караш, назар; күз күреме» ~ кырг. *шай* «тиң(лек), таман(лык)» >> каз. *сай* id. Чаг. бор. (ир.) Харәзем телендә *šayi* «охшаш», *šayidan* «охшаш булу» (к. Фрейман: 71).

Дерив.: **шайла-у** «тигезләү; кырлау» («Каратайда яңа амбар салырга шайлаган таш китергәннәр» диелә); хәзерләү» (к. ДС II: 228; БТДҺ: 38); себ. (Тумашева 1992: 248), добр. (Akb: 68, 104) **шайлы** «киенгән, ясанган»; башк. (БҺҺ II: 298) *шаймашай* «күзгә-күз (карап)» ~ кырг. *шайма-шай* «ба-

рысы да әзер», каз., к.-калп. *сайма-сай* «тиңмә-тиң; тап-таман». К. ш. ук **Шәйләү.**

**ШАЙ III** (Будагов I: 663; ДС I: 226; Тумашева 1992: 248) «прибор; убор, комплект; снаряжение» ~ үзб., төркм. *шай* «әсбап; деталь; бизәк», төркм. *шай-сеп* «бирнә комплекты», кырг. *шай* (> каз. *сай*) «тиешле әзерлектә(ге); тулы (көчендәге); көч, кодрәт» < бор. төрки (ДТС: 481) *šaj-jarïq* «панцырь». К. **Шайман.**

Дерив.: **шайла-у** (~ башк. *шайҙа-у, шәйҙә-ү*) «төзәтү, бизәү, рәтләү», себ. (Тумашева 1992: 248) **шайланцык** «көяз, франт; бизәнүчән», **шайлы** «бизәлгән; көйләнгән, әзерләнгән» һ.б.

**ШАЙ IV** (Тумашева 1992: 248) «опасность, беда» ~ ком. *шай* id. К. төр. *şayi* «начар хәбәр».

**ШАЙМАН** диал. «снаряжение; сбруя; латы» ~ кырг. *шайман*, каз., к.-калп., уйг. *сайман*, үзб. (ЎХШЛ: 308) *шайы-шайман* id. ← **шай III.**

**ШАЙТАН, шәйтан** «бес, сатана; шайтан» < гар. *шайṭāн* id. ~ яһ. *сатан* «судта гаепләүче; әләкче, бөһтанчы». Рус. *сатана* грек теле аша килгән.

**Шайтан** сүзе Евразиядә киң таралган һәм мәҗүси халыкларда да «тәңренең дошманы, явыз рух; пот» мәгъ. очрый, к. Аникин: 685 (әдәбият күрсәтелә). К. **Шайтани**.

Дерив.: **шайтанлы, шайтансыз; шайтанлык; шайтанлан-у, шайтанча; шайтанчык; шайтанчылык;** идиомалардан: **шайтан ашыгы** тур. к. **Ашык; шайтан таягы** һ.б. Иске әд. телдә **шаятыйн** «төрле шайтаннар» (**шайтан** сүзенең гар. күп. формасы).

**ШАЙТАНИ** «сатанинский» < гар. *шайṭāнӣ* id. ← **шайтан** (к. югарыда).

**ШАК I** (Тумашева 1992: 249) «грязь; помои» ~ башк. *шаҡ* «шакша ясар өчен эт яки бүре тизәге (к. **Шакша**)» («Башҡортса-русса һүҙлек 1996»да **бүре шагы** «волчий след» диелә, бу аңлатма тулы түгел), кырг. *шаҡ* «буза эшләү өчен төелгән тары»; «куйларның койрыгына ябышып каткан тизәк (аны **шакша** ясау өчен файдаланалар)». К. **Шакмара, Шакшы.**

**ШАК II** «твёрдый; сушёный» (**шак калац** – к. Тумашева 1992: 249 – «крендель, сушки») ~ башк. *шаҡ* «каты, нык» ~ ир. (күп телләрдә, к. ЯТ: 326) *шах,* фар. *шāх̣* «каты; кыя», пушту. *šax* «каты, катрач» һ.б. К. **Шакар-у.**

Идиома: **шак кату** «гаҗәпләнүдән катып калу» – фар. *шāх̣ шудан* «тораташ булып кату» тәгъбиреннән ярымкалька. К. ш. ук үзб. (ЎХШЛ: 313) *шах* «каты». К. **Шакар-у, Шәкелмә.**

**ШАК III** «кран, вентель; стопор, фиксатор (мельничного колеса)», (ТТДС I: 511) «дубинка» ~ кырг., каз., к.-калп. *шаҡ* «мөгез; коры ботак», үзб. *шаҡ, шоҡ, шәҡ* id. < фар. *шāх̣* «мөгез; ботакчык». Чаг. ш. ук чув. *шаҡ* «уен таякчыгы».

**ШАК IV** – имитатив стуку ~ чув. *шак* id. Федотов II: 430–431.

Дерив.: **шак-шак (итү); шакыл-шакыл; шакылда-у, шакылдык; шак-шок** һ.б. Чаг. **Шык.**

**ШАКАЙ, шага(й)** (ТТДС I: 510–511) «бабка, надкопытный сустав (животных)» ~ тув. *шаңай, шанкй* ~ бор. монг. (Поппе 1938: 333) *šiγai* «ашык». Чаг. **Шәмәй.**

**ШАКАЛ** «шакал» – хәз. яңгыраште < рус., рус. исә < төрки, к. иске тат. (ЛТ һ.б.), госм. *чакал*, яз. монг. *čaqal* һ.б. (бөтен дөньяга таралган сүз) < санск. *çrigala* «шакал, сыртлан» (төп мәгънәсендә «улаучы»). *Чакал* > *шаҡал* нуг., каз., к.-калп. телләрендә күзәтелгән күчеш, ләкин фар. телендә дә *шағал, шиғал, шағар* «шакал». К. ш. ук **Чагала, Чагалтай**. Räsänen 1969: 96; Фасмер IV: 395–396; Kluge: 791.

**ШАКАР-У** «крепко привязывать, жёстко прикрепить (в частности – вязом)», диал., башк. (БТДҺ: 389) «сплести плетень», (ТТДС II: 372) «вывернуть, скрутить» ← **шак II**. Чаг. ш. ук (ТТДС II: 372) **шакранна-у** «бозланып кату».

**Шакар-у** сүзеннән тат., башк. сөйләшләрендә **шакарма** «читән, текмә» сүзе ясалган.

**ШАКМАК** «квадратная клетка (на поверхности); чурка (для самовара)» > чув., мар., удм. *шакмак* id. < гом. кыпч., к. кырг. *шаҡмаҡ*, каз. *шаҡпаҡ,* кырг., уйг. *чаҡмаҡ,* үзб. *шаҡмоҡ* «шакмак, кубик, вак утын». Чаг. фар. диал. *шāҡҡу маҡ* «шакмаклы утын» ← гар. *шāҡҡ* «ярка, пүлән, тубырчык» ← *шҡҡ* «яру, яргалау». *Чаҡ-* «чагу, яру, яргалау» төрки телләрдә дә очрый, чаг. **Шакмара.** Федотов II: 430–431.

**Шакмак** сүзе, ихтимал, Урта Азиядә укып кайткан шәкертләр, муллалар теленнән таралгандыр.

Дерив.: **шакмаклы** «шакмаклар рәвешендә»; **шакмакла-у.** Диал. (ТТДС II: 372) **шакы-у** «шакмак ясау» кире сүз ясалышыннан булырга тиеш. Чаг. ш. ук **Чакмак.**

**ШАКМАРА, шакмарай** (ДС III: 191, ТТДС I: 511) «чурка для самовара», (ДС II: 228) «шарик; чурка» ~ кырг. *шакмар* «шак, куйларның койрыгына каткан тизәк» ← **шак I** (к.). Чаг. ш. ук **Шаһмара.**

**ША́КТЫЙ < шактай** «изрядный, значительный; довольно-таки много» ← **шак,* к. чув. *шак* (< иске тат.) «тулысынча; тоташ». Гомумән, ачык түгел.

**ШАКУЛ** «ватерпас; отвес» < гар. *шāқӯл* id. (к. Будагов I: 661). Бу сүз күп телләргә таралган; төр. *şakul, çekül id.* К. **Шавыл.**

**ШАКША** (М. Гафури), **шакча** «рожок для пороха или табака» ~ башк. *сақса,* кырг. *чақча,* каз. *шақша* id. < фар. *шāхчä* «мөгезчек; савыт итеп файдаланыла торган куыш мөгез» ← *шāх* «мөгез, ботак».

**ШАКШЫ** «грязный, поганый; нечистоплотный; гнусный и т.п.» > чув. *шакшă,* мар. *шакше,* удм. *шакшы* id. ← **шак I** (к.) булса кирәк, к. кырг. *шақшақ* «асылынган чүп». Тик рус. *шакша* «сызык, турта; каткан былчырак», ком. *шақша* «сыгылган бәрәңге калдыгы», удм. *шакта* «чүп», морд. М. *sekša* һ.б. фин-угор сүзләре. К. КЭСК: 264; Фасмер IV: 396; Аникин: 685–686 (рус диал. *шакша* «бозкар катыш су һ.б.ш.» тур., тәфсилле, тат.-башк. сүзләре искә алынмый).

**ШАКЫЛДА-У** «стучать (само-собой)» к. **Шак III.**

**ШАКЫР, шыкыр** – подражание стрекотанию сорок.

Дерив.: **шакыр-шыкыр; шакырда-у.**

**ШАЛ I** «кожаная лента, которая вставляется между сшиваемыми краями кож, шкур (иначе нитки будут резать шкуру); тонкая цветная кожа», (БҺҺ II: 299) «краска для кожи» ~ чув., үзб., уйг. *шал*, кырг. *шалы*, алт. *шал* ~ калм. *šal* «шал; яшел төстәге сәхтиян» < фар. *шäл* id. > аз. *шал* «күн билбау». Будагов I: 661; Räsänen 1969: 168; Федотов II: 431. К. **Шәлия.**

**ШАЛ II** (Тумашева 1992: 249) «паралич; паралитик» ~ уйг., кырг. *шал* > каз., к.-калп. *сал* id. Чаг. көрд. *şal* «бәсләнгән, кулга ияләштерелгән (хайван)».

**ШАЛ III** (Тумашева 1992: 249) «сумасшедший; шалый» ~ каз. (Катаринский 1903) *сал* «бәтрәк, чалчык; җилкенчәк; уен-көлкечә; шут». Чаг. рус. *шалый, шалить, шальной* (← **шал*, бу рус сүзенең канәгатьләндерерлек этимологиясе юк). Уйг. *шалақ, шаллақ* «тотнаксыз; чисталыксыз; җавапсыз».

Дерив.: **шалай-у** «котыру, шаяру». К. **Шалагай.**

**ШАЛАВАЙ [ша°лаwай], шалаван [ша°лаwан]** (Троянский; Будагов I: 671; ТТДС I: 511) «простодушный, открытый; легконравный, весёлый» ~ башк. (БҺҺ II: 299) *шалаулай, шәлеүән* id. – **шал** (к.) тамырыннан булса кирәк. Рус. *шалава* бор. монг. яки тат. теленнән, к. түбәндәгеләрне.

**ШАЛАГАЙ** «неисполнительный, необязательный» ~ яз. монг. *čalaγai, čaliγai* (хәз. монг. *цалгай*, калм. *šalγä*) > маньч. *чалахаі* «шалагай; буталчык (кеше), игътибарсыз»; иске монг. *čalai-* > хәз. монг. *цалай-* «төгәллексез булу» һ.б., к. ССТМЯ II: 380 (бу сүзләрне маньч. *чала-* «ялгышу, игътибарсыз кылану» < *ча-ла-* кыт. *чä* «ялгышу, төгәлсезлек; тиешлелектән аерылу» сүзеннән димәкчеләр). Чаг. **Шал II**. Рус. *шалагай* татарчадан булса кирәк (к. Фасмер IV: 397). Чаг. ш. ук **Чәлә.**

Дерив.: **шалагайлык; шалагайлан-у.**

**ШАЛАПАЙ** «шелопай, шалопай» < рус. булса кирәк, ләкин рус сүзе үзе төрки телләрдәндер. Чаг. **Шал, Шалавай, Шалагай, Шалба.**

**ШАЛАМА** «лохматый, с шерстью, висящей клочьями; засорённый (о дворе)» ~ алт. *дьалама, йалама, чалама,* тув. *чалама,* як. *салама* һ.б. Себ. төрки телләреннән «үзенә төрле төстәге тасмалар, кештәкләр тезеп тагылган ритуаль-шаманистик киндерә (ул бик озын булырга да мөмкин)» сүзеннән булса кирәк. Ул *чалама* һ.б. тур. этнографик әдәбиятта күп сөйләнелә, мәс., Потапов 1969: 353.

**ШАЛАШ,** (ДС II: 161) **салаш** (гомумән бу вариант күп сөйләшләрдә очрый), әстр. (Арсланов 1988: 157) **шалаша** «шалаш; настил на ветвях деревьев» ~ аз., госм. *салаш*, төркм., ком. *чалаш*, нуг., каз. *шалаш* һ.б. > рус. *шалаш*, Д. болг.,

серб., рум., чех, пол. һ.б. телләрдә *салаш* «шалаш, палатка; япма; тере агачка terәтелеп ясалган куыш» (бу мәгънә тат. сөйләшләрендә дә бар) һ.б. ← **сала II** (к.) сүзеннән булса кирәк. Мар., удм. һ.б. *шалаш* рус. теленнән, рус сүзе исә төрле төрки шивәләрдән, ди Фасмер (IV: 397); к. ш. ук Клепикова Г.П. Славянская пастушеская терминология, 1974; Мурзаев 1984: 623; Шипова: 408. **Шалаш** сүзен венг. *szallas* «төн куну урыны» сүзеннән дию (к. Этимологические исследования по русскому языку. Вып. IV. 1963) дөрес түгелдер.

**ШАЛБА** (Тумашева 1992: 249), ш. ук (Будагов I: 671) **шалбак,** (ТТДС I: 512) **шалка, шалпык** «неумелый; неряха». **Салак** (к.) белән тамырдаш булса кирәк. Чаг. **Шалапай, Шәлпәй-ү** һ.б. Мондый (күп вариантлы) сүзләрнең тамыры – тәкълиди *шалп* – **җил ~ җәл** һ.б. (к. **Җил**) сүзенең *-п* детерминантына беткән тармагы.

**ШАЛГАМА** (ТТДС I: 512; ТТДС II: 372) «(горизонтальная) жердина, слега, поперечина и т.п., на которую привязывается, кладётся, прикрепляется ряд других предметов» – ниндидер **шалға-* фигыленнән. **Шалгама** дип шәмчыракны да атаганнар. К. **Шәлгәмә.** Чаг. уйг. *шалдама* «бәби күкрәкчәсе».

**ШАЛКАН,** диал. (Арсланов 1988: 99; Тумашева 1992: 249) **шалғам** «репка» < гом. кыпч., к. каз., кырг. *шалкан* ~ *шалқам*, госм., куман., шор., тув. *шалған*, алт. диал., хак. *салған*, к.-балк. *шалхан*, госм., уйг., к.-калп. *шалғам*, үзб. *шолғом*, алт. *чалқан,* котт. (Joki 1952: 281–282) *čalgana* id. бор. **чӓлқана* сүзеннән: **-кана** үсемлек атамалары ясагыч кушымча (к. **Кана-у II**), к. калм. *šalγaγ* «шалкан», себ. (Тумашева 1992: 233) **цалғай,** кырг., алт. *чалқан, чалқанчақ,* чыгт. *шалаған*, алт. диал. (Баскаков 1972: 271) *шалғанақ* «кычыткан» – «кечкенә шалкан» кебегрәк. Кычыткан яфрагы беркадәр шалканныкына охшаш. Ошбу мәгълүматлар яктылыгында *шалкан* сүзен фар. *шӓлгӓм* сүзеннән дип раслау ышандырмый.

Күрше чув., мар., удм. телләрендә *шалкан* сүзенең рефлекслары юклыгы күзгә ташлана: ул телләрдә «шалкан» мәгъ. бүтән сүзләр кулланыла.

Идиома: **шалкан бәясе** «бик арзан». Шалканның Идел-Урал регионында мул уңыш бирүеннән генә булырга тиеш.

**ШАЛМАН** (к. Казан утлары, № 10, 1988: 22) «жулик» ~ башк. (БТДҺ: 390) id., ш. ук «иптәш (каракныкы, бандитныкы)». Ачык түгел. Кеше исемнәрендә **Шалман < Шаһигыйльман** «галимнәрнең шаһы» һәм **шалман** сүзе шуннан (ирония белән) ясала ала. Чаг. ш. ук башк. (БҺҺ II: 299) *шалман* «күсе, ялман».

**ШАЛТ** – имитатив резкому движению и звукам от таких движений, стуку, (к. ш. ук **Шылт**) ~ чув. *шалт* id.; чаг. каз., к.-калп. *шалт* «җитез».

Дерив.: **шалт-шолт** (чут белән эшләү авазларын һ.б.ш. белдерүчән), **шалтыр-шалтыр, шалтыр-шолтыр; шалтыра-у, шалтырда-у; шалтырак; шалтыравык** (уенчык), **шалтырт** (тик торганда бер шалтырау) һ.б. (бу сүзләрнең параллельләре чув. телендә дә бар); к. ш. ук **шалтыр-шалдыр, шалдыр-шолдыр, шалдыра-у** (*-т*лы вариантларыннан мәгъ. аермалары юк диярлек).

**ШАЛТА, шалтак** «затверделый» ← **шалт** (к.)?

Дерив.: (ТТДС I: 512; Тумашева 1992: 249; Будагов I: 662); **шалтай-у, шалтакла-у** «катып китү».

**ШАЛТАЙ-БАЛТАЙ** «шалтай-болтай» < рус.

**ШАЛТАН** (БҺҺ II: 299) «порожний», иске тат. (к. ЛТ I: 165) **салтақ** «хромой; без обязанностей» < уйг. *салтаң* «йөксез ат; буйдак (кеше)» < монг. *шалдаң*, *салдаң* «киемсез, ялангач; хәерче, сукбай» ← *шалт* < *чалт* «болытсыз, ачык (күк)» ~ каз., к.-калп., үзб., кырг. *салт*, төр. *salt* «буш, йөксез; яланат, иярсез генә атланып», төркм. (ТДГДС: 155) *салт* «баласыз (хатын)»; к. ш. ук алт. диал. *чалтаң*, *чалдаң* «ялангач; фәкыйрь, сукбай» > рус. *чалдон, челдон* «Себергә тәүләп күченеп утырган урыс» (к. Аникин: 639, 687) > тат. **чалдун** id. К. **Салт.**

Рус этимологиясендә *чалдон* сүзе монг. теленнән чыгарыла (Фасмер IV: 326; Аникин), ләкин бу дөрес түгел, аның тамырының гына монг. телләреннән булуы ихтимал.

**ШАМА** «спитый чай, выварки» > мар. *шама* < гом. кыпч., үзб., уйг., чыгт. (Радлов III: 991) *шама*, каз. *шама* > *сама, шамба, сәме, сәмбе* id. < кырг. *чама* < кыт. *чамо* «чәй калдыгы» (*ча* «чәй», *мо, ма* «калдык, чүп»), к. ҚТҚЭС: 208. Һинд. *šātä* < санск. *šatak* «каралык; мүк; шама» очраклы охшашлык мисалы.

**ШАМАИЛ, шәмаил** «изображение святых мест с надписями; разукрашенный каллиграфический

текст (молитв) для украшения комнаты» < гар. *шӓмā'ил* «тумыштан килгән холык; шәмаил» *шӓмӣлӓ* сүзенең күп. формасы > иске тат. **шәмилә** «өстенлек, сыйфат; күренеш, охшашлык» < лат. теленнән алынган *шмл ~ смл* «охшаш булу» тамырыннан, к. лат. *simulis* «охшашлык», шуннан *симулянт, симуляция.* Тимергалин: 554. Махсус әд.: Шамсутов 2003.

**ШАМАКАЙ, шамакый** «клоун, циркач», диал. (ЗДС: 778) **шамыкай** «пугало, чучело» < фар. *шӓмāх̣ӓи* «Азәрбайҗандагы Шамахы шәһәре (кешесе)»: бу шәһәрдә циркачлар тәрбияләнгән һәм алар Казан дәүләтенә дә килеп тамашалар күрсәткәннәр. Шул ук шәһәр исеменнән **Шәмәхә** (к.) сүзе дә килә.

**ШАМАН** «шаман» < рус.; рус теленә исә тунг. телләреннән кергән (эвенк. *самаан,* маньч. *сама* id., к. ССТМЯ II: 59). А.Е. Аникин һ.б. кайбер авторлар (к. Аникин: 687–688) бу сүзне шиксез үзтума тунг.-маньч. сүзе дип ныкышалар, гомум таралган фикер буенча исә (Фасмер IV: 401), **шаман** сүзе тохар теле аша бор. һинд. *çramanas* «аскет-буддист» сүзеннән килә. Бу фикерне *шаман, әш-шаманийа* «шаманчылык» сүзләренең гар. һәм фарс. телләрендә IX–XI гг. ук киң таралганлыгы (бу тур. к. Бируни 1995: 544) дәлилли. Хәз. фар. *шӓмӓн* «потпәрәст, мәҗүси».

**ШАМБЫ, жумба** «налим», (ТТДС I: 512) «щука, щурёнок» ~ чув. *шампа* «шамбы; кашыкбаш; күпкәнкорсак», мар. *шамба, шомба* «шамбы» ~ фин. *sampi*, эстон. *samb* «чөгә (һ.б.) балык» фин-угор сүзе. К. LSFU № 56, 1952: 21. **Жумба** вариантының чыгышы ачык түгел.

**ШАН** «громкая слава; честь» – гар. *шāн* «эшлеклелек, мөһимлек; дан» сүзе белән чагыштырыла, к. ш. ук төр. *şen* «гөрләп яшәү» (< гар.). Тик дөресрәге тат., башк. *шан* < кырг., уйг. *шаң* «газамәтлек; бүләк; шан» – кытайчадан: анда *шӑн* «бүләк, мөкяфәт» > яз. монг. *šang* id. (к. ССТМЯ II: 424).

**ШАНДАЛ** «большая лампа», «светильник с двумя, тремя свечами, лампами» (к. Будагов I: 672) к. **Шәмдәл.**

**ШАҢ, шаңк** – имитатив глуховатому звону, стуку ~ чув. *шанк* id.

Дерив.: **шаңда-у, шаңла-у, шаңгылда-у; шаңгыр-шаңгыр; шаңгырда-у** (кипкән бүрәнәләр, яхшылап яндырылган керамика һ.б.ш.ның бер-берсенә бәрелүе тур.).

**ШАП** – имитатив стуку нетвёрдым предметом (в т.ч. доской плашмя) ~ чув., удм. *шап* id., чаг. фар.-таҗ. *шапидан* «бәрү, сугу».

Дерив.: **шап-шап, шап-шоп; шапы-шопы; шапыл-шапыл; шапылда-у, шапылдык; шапалак** «чебен үтергеч». К. **Шапыр.**

**ШАПИ, шыпый, шыпытый** (ЗДС: 779, 793) «пинетка, чувяк» ~ каз. (ҚТДС: 382, 383) *шапата, шапаты* «чарык, үкчәсез, кунычсыз аяк киеме». К. **Чабата.**

**ШАПШАК** (Радлов III: 985) «неряшливый; неряшливо», диал. (ТТДС I: 552) **шәпшәк** «болезненный» ~ чув., мар. *шапшак* id. ~ ком. *шавшақ* «ныгып, катып өлгермәгән»; гаг. *савсақ* «игътибарсызлык, шапшаклык; эшлексез». Гомумән, ачык түгел. Чаг. диал. (ДС II: 228–229) **шава, шапа** «шапшак», төр. *şapşal* «сәләмә, ертык-портык».

**ШАПЫР I** (ТТДС I: 512–513) «метла (большая)», күч. (?) «хвастун, врун» к. **Шапыр II, Шапыр-у.**

Дерив.: **шапырай-у** (> удм. *шапрайа-*) «мактану, масаю».

**ШАПЫР II** – имитатив взбалтыванию вспученной, мутной жидкости (в основном виде употребляется редко); чаг. **Шабыр.**

Дерив.: **шапыр-шапыр, шапыр-шопыр; шапырда-у.** К. **Шапыр-у.** Чаг. **Шопыр-у.**

**ШАПЫР-У** «перебалтывать (закисавший кумыс и т.п.); веять, провеивать (лёгкую массу)» < гом. кыпч., к. к.-балк., ком. *шапыр-* (> нуг., каз., к.-калп., кырг. *сапыр-*) id. ← **шапыр II.** Тат., башк. **шапыр-у** «арттырып сөйләү; мактану» сыеклык шапырылганда күбекләнү, газлар чыгуга охшатылудан.

Дерив.: **шапырыл-у; шапырын-у** «мактану»; **шапырт-у** «арттырып сөйләү»; **шапырай** «мактанчык»; **шапырык** «арттырып сөйләүче» һ.б., к. БТДҺ: 391.

**ШАПЫРЫШЛА-У** (ЗДС: 779) «нарезать вкосую, вдоль и поперёк» < **чапырышла-у,** к. **Чапрыш.**

**ШАР I** «шар», диал. (ТТДС I: 513) **шара** «деревянный шар (для игры)», (ДС I: 227) **шаруķ** id. ~ кырг. *чар* id. Бу сүзләрне русчадан дию җитәрлек түгел, чөнки рус сүзенең үзенең чыгышы ачык түгел, к. Фасмер IV: 406. Чаг. тат. диал. (ТТДС I: 513) **шар** «кәтүк» < **чар** (к.); башк. (БТДҺ: 391) *шар* «груша».

**ШАР II** «известковый раствор; (белая) краска» ~ чув. *шар* id. < (себ., Тумашева 1992: 248) **шағыр** id. < яз. монг. *čaqir* «ап-ак» (к. **Чагыр**). Чаг. иске рус. (Срезневский III: 1583) *шаръчий* < төрки *шарчы* «буяучы». Рус. *шаръ* «буяу» төрки телләрдән, к. Фасмер II: 407; Тимергалин: 548. К. **Акшар.**

**ШАР III** (ТТДС I: 513) диал. «совсем (открытый)» ~ чув. *шар* id. К. **Шыр I.** Гомумән, ачык түгел.

**ШАР IV** (ТТДС I: 513) «лес», (Тумашева 1992: 249) «ивняк, маленький, но густой лес, чащоба» ~ башк. *шар* «сазлыклы чатырман». Чаг. **Шырлык.** К. ш. ук рус. диал. *шигар, шигыр* һ.б. «куе вак урман, шар», к. Аникин: 698–699.

**ШАР V** – имитатив громкому журчанию, громкому говору, смеху ~ алт., төр., чув. *шар* ~ як. *чар* id. К. **Шыр II.** Федотов II: 435–436.

Дерив.: **шарла-у** (шуннан **шарлавык, шарлама** – бу сүзләр чув., мар. телләренә дә кергән); **шарылда-у** (> **шарылдавык, шарылдык**) «үзүзен әдәпсез тоту (хатын-кыз тур.)». Чаг. түбәндәгеләрне.

**ШАРГЫ** (Тумашева 1992: 249) «злой; бойкий; крикливый» ~ башк. (БТДҺ: 270) *сарға* < *чарға* «үткер, усал; кызу; әче тавышлы» ~ *чар?* (к. **Чар I**). Чаг. ш. ук мар. (Иванов, Тужаров: 256–257; Саваткова: 183) *цäргä, царга, царгата, чаргата* «чәрелдек; чыркылдык; тавышчан», *цармак* «чая» һ.б.ш. Чаг. **Шыргыя.**

**ШАРКЫЛДА-У** «кромко и развязно смеяться» < диал. **шаркыл-шаркыл** – тотнаксыз көлүгә имитатив. К. **Шар V.**

**ШАРТ I** «условие, условия» < гар. *шäрṭ*. К. **Ширт.** Тимергалин: 548.

Дерив.: **шартлы, шартсыз; шартнамә** «килешү»; иске тат. **шәраит** «шартлар» турыдан-туры гарәпчәдән.

**ШАРТ II** – имитатив треску (ломающегося дерева, палки и т.п.) ~ чув. *шарт*, гом. кыпч. *чарт, шарт* (> каз. *сарт*) id.

Дерив.: **шартла-у** «шарт итү; челпәрәмә килеп ваклану» (→ **шартлат-у**), **шартлагыч.**

**ШАТ** «весёлый, радостный; весел» ~ гом. көнб. төрки *шат,* чыгт., госм. *шад* (> госм., кр.-тат., нуг. диал. *шаз, шäз*) < фар. *шāд* < авест. *šata,* бор. ир. *čyata* «тыныч күңелле, шат»; тат. диал. (ТТДС I: 513) **шарт** варианты иҗек азагындагы *-д* (*шад*) авазын *-рт* ярдәмендә белдерүдән килеп чыккан булса кирәк. К. **Шадыр, Шатман.** Räsänen 1969: 439; Абаев I: 151, 286.

Дерив.: **шатлык; шатлан-у.**

**ШАТАЛАК** (ТТДС I: 513, БРҺ 1996: 765) «весёлый, озорной; весельчак, озорник» ~ себ. (Тумашева 1992: 249) *шатрак* < фар. *шāдтарак* id. ← *шад* «шат» + *тар* (сыйфатларда көчәйткеч кушымча) + *ак* (исем ясагыч кушымча).

**ШАТМАН, шадыман** «в весёлом настроении» ~ кырг. *шатман*, уйг. *шадман*, чыгт. *шадиман* һ.б. id. < фар. *шāдимāн* «шатлыклы хәлдә» ← *шāд* «шат».

Идиома: **шатман таягы (әләме)** «нәүрүз бәйрәмендә күтәреп йөртелә торган бизәкле-чуклы таяк».

**ШАТРАНЖ, шәтранж** «шахматы», иск. «шашки» < гар. *шäṭранҗ* < фар. *шäтäрäң* < санск. *čatur anga* id., сүзмә-сүз «дүртпочмак» (тәүдә шахмат фигуралары тактаның дүрт почмагына тезелә торган була). Тимергалин: 549–550. К. **Шатрач.**

**ШАТРАЧ** (ТТАС III: 495) «клетчатый (о ткани)» < **шатранҗ** (к.). К. башк. (БТДҺ: 392) *шатраш* «шакмаклы; шашка».

**ШАТРУН** (ТТАС III: 395; БТДҺ: 392) «крыша, покатая с трёх или с четырёх сторон» ~ мар. *шатрон*, чув. *шатрун* id. < рус. *шатрóм* ← *шатёр*. К. **Шәтер.**

**ШАТЫРТ** – имитатив внезапному треску ~ чув. *çатăр* id. К. **Шытырт.**

Дерив.: **шатыр-шотыр; шатырда-у.**

**ШАУ I [шаᵒw]** «всегда, всё время; постоянно; сплошь, полностью» > чув. *шав* id., ш. ук «хәзергәчә» ~ нуг., к.-калп. *сав, саў,* к.-балк. *саў* (< нуг.

булса кирәк) «барчасы, бөтенесе» – табышмаклы сүз. К. ш. ук коми. *чав* «шау» (димәк, бу сүз бор. Идел-Урал регионында да булган) ~ удм. *шал* id. Федотов II: 429 (тат., башк. параллелен китерү белән чикләнә).

Ихтимал, бу сүз ахыр чиктә **шау II** белән бердәйдер, ләкин моны исбатлавы кыен.

**ШАУ II [шаºw]** «шум» > чув. *шав* << бор. **чаг,* к. тат., башк. **шау-шу** «шум-гам» < бор. төрки (ДТС: 136) *čaɣ-čiɣ* id.; к. кр.-тат., кырг., алт. *шуула-,* хак. *соола-* «шаулау»; чаг. бор. кыт. *шао* «сарай музыкасы; оркестр». Бор. кыт. императорлары төрки идарәчеләргә еш кына күп музыкантлы оркестр бүләк иткәләгәннәр. Шул мәгълүматлар нигезендә *шау* сүзе **чаг-шыу* парлы сүзе *шагшуг* яңгырашын алгач килеп чыккан дип уйларга мөмкин. Икенче яктан, *чаг-шыу* парлы сүзе *чаг-чуг* булып аккомодацияләнгәч, шуннан *чуу* >> башк. *сыу* «тавыш, шау-шу» аерымландырылган дип уйларга ярый. Федотов II: 429.

Дерив.: **шаулы, шаусыз; шаула-у, шаулат-у;** парлы сүз: **шау-гөр;** идиома: **шау яру** «бик каты шаулау». К. **Шаукым, Чу.**

**ШАУДАРАЙ [шаºwдарай]** (Будагов I: 662) «просторный; удобный (об одежде)» – **шау I** белән баглы булса кирәк: *-дарай//-тарай* фар. теленнән кергән артыклык дәрәҗәсе кушымчасы, к. **Куптарай, Титарай.**

**ШАУКЫМ [шаºwкы̆м]** «косвенное влияние, отголосок», диал. (Остроумов 1892: 236) «название особого существа – дух самоубийцы» ~ чув. *шалкӑм* id., тат. диал. (Радлов III: 929) **шауқын**, үзб. *шовқин*, чыгт. *шауқун*, каз., к.-калп. *шауқым,* (ҚТДС: 288) *сауқым*, кырг. *шоокум* «шау-шу; атынчабын чыгару, ни турында булса да күп сөйләү, шаулау» (К.К. Юдахин бу сүзне ир. ди), төркм. *шовхун* «шау-шу; рухлану, дәррәү кубу», к.-балк. *шаӯ* «үлек, мәет; начар». Ихтимал, монда ике омоним сүздер. Чаг. **Шау II.**

Дерив.: **шаукымлы, шаукымсыз; шаукымлан-у.**

**ШАШЛЫК** «шашлык» – русчадан кире алынма, русчага нindidер (*шашлик* дип сөйләгән) төрки телдән килгән (гомумән, бу сүз киң таралган). Тамыры *шаш ~ шыш*, к. бор. төрки (ДЗС: 524) *šïš* «шашлыкка дип ит кисәкләре тезү өчен чыбык». К. **Шеш II.**

**ШАҺ** «шах, император Персии, Ирана» < фар. *šāh* < бор. ир. *xšayaθiya* «хөкемдар, биләүче» ← бор. арий. *xšay, kşay* «биләү, хөкем йөртү» (к. **Шәһәр**), к. Platts: 719; Будагов I: 663; Тимергалин: 551–552.

**Шаһ** сүзеннән фар. телендә күп сүзләр ясалган, шулардан **шаһзадә, шаһи, шаһин, шаһиншаһ** сүзләре тат. әд. теленә дә кергән; к. ш. ук **шаһинә** «шаһ хатыны» – гарәпчәдән (гар. телендә ясалган сүз). Кайбер этимологлар элекке төрки телләрдә киң кулланылган *шад* «ханның беренче урынбасары (гадәттә – углы)» сүзен дә *šаһ* белән тамырдаш диләр.

Дерив.: **шаһлык, шаһларча.**

**ШАҺИТ** «свидеталь; очевидец» < гар. *šāhid* id. ← *šhd* «күреп тору, хадисә урынында булу», шуннан ук **шәһадәт** «шаһитлык», **шәһадәтнамә** «таныклык». Будагов I: 663.

Дерив.: **шаһитлы, шаһитсыз; шаһитлык.**

**ШАҺМАРА** фольк. «царь змей» ~ төр. *şahmeran* id. < фар. *šāhe mārān* «еланнар патшасы». К. **Шакмара.**

**ШАШ-У,** диал. (ЗДС:734) **чаш-у** «беситься; сходить с ума; быть в недоумении, растерянности перед неожиданным явлением, событием и т.п.» < гом. кыпч. *шаш-*, ком. *шашы-* (> нуг., каз., к.-калп. *сас-*) «шашу; өлтерәү, кабалану», кр.-тат., госм., гаг. *шаш-* «гаҗәпкә калу, каушау» ~ уйг. диал. *чач-*, үзб. *чаш-* id. ~ бор. төрки (ДТС: 521) *šaš-* «юлдан язу; кабалану, өлтерәү, ашыгу», төр. *şaş-* «шашу, гаҗәпләнеп шак кату» бигрәк тә киң кулланыла һәм мул деривацияле. Чаг. ш. ук төркм. (ТДГДС: 196) *чааш-, чәәш-* «төрле якка китү». Ошбу сүзнең исем коррелянты да бар: гаг. *шаш* «ахмак, юләр». Гомумән, лексема нindidер мифологик зат атамасына охшый.

Дерив.: **шашын-у, шаштыр-у, шашыр-у; шашкын;** диал. (ТТДС I: 478) **чашман** «аптыраган; борчулы, пошаман».

**ШАЯН [шаºйан],** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **шайа** «шаловливый; шустрый» > удм., мар. диал. *шаян* id. Бу сүз Идел-Урал регионында гына очрый, тик нуг. *шая* «чая». Гомумән, *шайан* һәм *шайа* вариантлары булу көнч. төрки, монг. телләрендәге фонетик закончалыкларны хәтерләтә һәм бу сүзләрнең **чая** һәм **чаян II** (к.) сүзләренең фонетик (нугайча) вариантлары булуына өстәмә дәлил. К. **Зая, Наян.** Ахметьянов 1981: 24–25. Каз. (ҚТДС: 401)

*шойан* «белдекле», төр. *şayan* < фар. *шайан* «кыйм-мәтле (кеше)» – бүтән сүз.

Дерив.: **шаянлык, шаянлан-у.** К. **Шаяр-у.**

**ШАЯР-У [шаºйар-]** «шутить» ← диал. **шая** «шаян». Чаг. **Чаяр-у ← чая** (к.).

Дерив.: **шаярын-у, шаярыш-у, шайарт-у** (көтелмәгән «алда-у» мәгъ. дә очрый).

**ШАЯТЬ [шаºйәт]** «авось; быть может» < фар. *шāйäд* id. *шāйäстäн* «җитәрлек булу, файдалы булу» фигыленең аерым формасы. Шул ук фигыльдән иске тат. (к. ГТРС: 699) **шаистә** «достойный» сүзе дә килә. Чаг. **Шәт.**

**ШӘБӘР-Ү** «измокнуть, озябнуть (от сырости); покрыться гусиной кожей» ~ чув. *шапар-* id. Морфемик составына караганда, **шәб(ә)* нигезеннән. Чаг. иске тат. **шәп** «каты кыл, чем» ~ башк. (БТДҺ: 400) *шәбе* «шайтан тырнагы».

**ШӘББУЙ,** (ЛТ I: 210) **шаббуй** «левкой (декоративно-парфюмерное растение)» < фар. *шäббӯй* id., сүзмә-сүз әйткәндә «төнге ис» (бу үсемлекнең чәчәге төнлә генә ачылып характерлы ис тарата).

**ШӘБЕН, шәwен, шәбән** (ДС I: 228–231; ДС II: 233; ТТДС I: 520) «(продолговатая) копна», миш. (Халиков 1995: 78, 79) **шабен** «стожок, небольшая скирда» < рус. булса кирәк. Чаг. рус. *шúбень* «игътибарсыз өелгән печән, салам өеме» ← *шибать* «ыргыту, бәрү». Чаг. ш. ук ним. *Schoben, Schober* «өем; кибән һ.б.ш.» (ләкин тат. сүзенең нимесчәдән алыну ихтималы аз).

**ШӘВЫК [шәwы̆к]** (Ф. Сәйфи-Казанлы) «возбуждение» < гар. *шäwķ* id., ш. ук «мәхәббәт, теләк, омтылыш; дини экзальтация». Будагов I: 675.

Дерив.: **шәвыклан-у;** идиома: **шәвык итү** «нык теләү».

**ШӘЕХ [шәйӗх]** «шейх, старец; глава религиозного объединения» < гар. *шäйх̣* id. ← *шйх̣* «картаю». Будагов I: 678–679 (дини шәехләр тур. бик тәфсилле); Тимергалин: 553.

Дерив.: **мәшаех** (гарәпчәдән үк) «шәехләр; картлар; картлар мәҗлесе (киңәше)».

**ШӘҖӘРӘ** «родословная, схема родословного дерева» < гар. *шäҗäра* id. ← *шҗр* «ботаклану». Тимергалин: 552–553.

**ШӘЙ I** «вещь, предмет» < гар. *шäй';* төрки телләрдә (кар., кр.-тат., төр. һ.б.) киң таралган сүз. **Предмет** сүзе урынына тат. әд. телендә дә кулланылган (һәм хәзер дә сирәкләп кулланыла).

**ШӘЙ II** «видимо» к. **Шай.**

**ШӘЙЛӘ-Ү** «замечать (в темноте, в тумане), смутно помнить; угадывать, догадываться» ~ башк. (БТДҺ: 389) *шайла-* id., чув. *шайла-* id., ш. ук «күзәтү, чамалау, чагыштыру; исәпкә алу; шигырьназым төзү». Чув. мәгънәләре күрсәткәнчә, нигез мәгъ. «охшату, охшаш дип табу». **Шәйлә-ү < шайла-у** фигыле **шай** «охшаш; тиң, тигез» сүзеннән (к. Федотов II: 430) ясалып, аның мәгънәсенә бүтән аваздаш сүзләр дә тәэсир иткән. К. **Шай I. Шәйләү**нең диал. «әзерләү» мәгъ. (ЗДС: 781) икенче бер сүз булса кирәк, к. **Шай II, III.**

Дерив.: **шәйлән-ү;** башк. (БТДҺ: 400) *шәйлек, шәйләк* «күзәтүче; күзәтүчән» (окказиональ сүз булса кирәк).

**ШӘЙШЕ,** диал. (ТТДС I: 503; ТТДС II: 367, 369, 380) **чәрше, чәлче, чәче, чәше,** (Халиков 1995: 73–74) **шәлче, шәлше, чалше, шәше, шәш, шеш** «стожар; колья, поставленные со связанными вверху концами, на которую кладуться снопы, сено и т.п. для просушки, шиш» ~ башк. (БТДҺ: 393) *сәйсе* id., рус. *шиш* id. (мәгънәви вариантлар тур. к. Аникин: 703–704). Табышмаклы һәм бәхәсле сүз. Күрше чув., мар., удм. телләрендә ышандырырлык параллельләре юк, коми. *шодз* «шәйше (җитен киптерү өчен)» сүзе дә очраклы охшашлык булырга мөмкин. Кайбер вариантлардагы *-л-* ~ *-р-* интертеза түгел дисәк, фар. *чäһāрчӯб* > *чäрчуб* – сүзмә-сүз *дүрт агач* – «бура; кыса, рам; шәйше» сүзе искә төшә. Рус сүзе татарчадан булса кирәк (ләкин кайбер рус телчеләренең **шәйше** сүзен *шеш* < *шиш* «кабарган урын» белән чагыштыруы хата). Гомумиләштереп әйтсәк, *шәйше* < *чәрше* < фар. *чäрчӯб* «шәйше» һ.б. – иң ихтимал фараз. К. ш. ук **Әшәлчә.** Авыл хуҗалыгына баглы фар. сүзләре тат. телендә юк түгел, рус телендә дә бар.

**ШӘК** (ТТДС II: 379; БТДҺ: 369) «бита; боёк в игре в бабки; вид игры с битой» – ихтимал, рус. *чик* «мәрәй», *чикать* «бәрү, бәреп төшерү» белән баглыдыр.

**ШӘКӘШӘ** (Тумашева 1992: 250) «большая чаша, большая пиала» < фар. *шäһк'äсä* «шаһ кясә,

табында иң зур кясә». Фар. телендә *шаһ* «иң зур» мәгъ. киң кулланыла, мәс., *шāһбāл* «из зур каурый», *шāһбāз* «иң шәп ау лачыны», күч. мәгъ. «лачын, шәп егет», *шāһрāһ* «магистраль юл» һ.б.

**ШӘКЕЛ,** себ. (Тумашева 1992: 250) **шәгел** «вид; форма; схема», к. **Шикел.**

**ШӘКЕЛМӘ** (ТТДС II: 379) «педаль ткацкого станка», (ТТАС III: 533) «крюк на конце верёвки» ~ чув. *çекĕлме, çекĕлле* id. ← *çекĕл, çеккĕл, çаккăль* «ыргак» ← *çак-* «асу, эләктерү». Чаг. диал. (ТТДС II: 379) **шәкәлмә** ~ башк. (БТДҺ: 389, 400) *шәкәй, шәкәл, шәкәләй, шақалай, шақалақ* «бәкәл (ат тоягының сыйрак сөягенә тоташкан урыны, эләктерелеше)». Күрәсең, Идел-Урал регионында *чәк* ~ *шәк* ~ *шак* «элү, элгеч» фигыле булган. Арытабан ачык түгел. Рус. *щиколотка* сүзеннән дию (ЗДС: 781) морфологик җәһәттән абсурд.

**ШӘКЕРТ,** себ. (Дмитриева 1981: 198) **шäкäрт** «учащийся (религиозного училища); ученик учёного, мастера» > мар. (Исанбаев 1978: 10) *шäгырт* «кара эш эшләми торган» < фар. *шāгирд* «шәкерт; хезмәтче, кучты».

**ШӘКШӘКӘР** «чехарда» < фар. *шäқāққäр* id. – сүзмә-сүз «туңкай итү» (*шäқāқ* «тункаю, туңкаеш», *кäр* «эш; эшләүче» мәгъ. кулланыла).

**ШӘЛ I** «шаль» ~ кр.-тат. *шäлä,* башк. *шәл,* башк. диал. (БТДҺ: 390) *шал* << фар. *шāл* id. Тат. теленә бу сүз рус теленнән дә кергән, ләкин төп чыганагы – фар. теле, шуннан Европа телләренә киң таралган, к. Фасмер IV: 401; Шипова: 409; Kluge: 792; Крачковский: 359.

**ШӘЛ II** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «крюк грузчика» ~ кр.-тат. (Радлов III: 1957) *чäгäл* «каптырма», төр. *çekel* «саплы ыргак»; чаг. ш. ук чув. *çекĕл* > мар. *сагыле* «йөкчеләрнең аркага йөк күтәрү җайланмасы».

**ШӘЛГӘМӘ** (ТТДС II: 372, 380) «шнурок или проволока с нанизанными украшениями (брошками, погремушками, монетами и т.п.)», **шалгама** «поперечина забора, слега; связывающий брус» ~ мар. *шылкама, шолкама* «брошкалар теземе» ~ морд. *сюлгам, сюлгамо* «беришле брошкалар, ялтыркалар яисә шөлдерчекләр теземе» (русча археологик әдәбиятта *сюльгама* дип язылa) фин. *solki* «аел; бәйләм» сүзе белән чагыштырыла, к. КЭСК: 273. **Шәлкем** (к.) белән чагыштыру бик ышандырмый. К. **Шалгама.**

**ШӘЛДЕРӘ-Ү** «греметь (о погремушке)» – **шалтыра-у** (к.) сүзенең палаталь модификациясе.

Дерив.: **шәлдерәвек** (К. Тинчурин), **шәлдермәс, шәлдермәч** «шалтыравык».

**ШӘЛКЕМ,** диал. **шалкым, шәлгем,** «прядь, кисть; гроздь», күч. (М. Җәлил) «сборник (стихов, рассказов)» < гом. кыпч. булырга тиеш, к. кр.-тат., госм., чыгт. (Радлов IV: 363; Боровков 1963: 261) *салқым* «тәлгәш; җыйма һ.б.». Ономопоэтик *салк* тамырыннан, к. **Салкы.**

**ШӘЛПӘЙ-Ү, шалпай-у** «вяло отвисать» < гом. кыпч., к. кырг. *шалпай-*, башк. *шалбай-,* каз. *салпи-* һ.б. ~ бур. *шальпай-* id. ← **шәлпе, *шалпы* «шәлпәйгән» ← *шалп, салп* ономопоэтик тамырыннан, к. **Салпы.** К. түбәндәгене.

**ШӘЛПЕР, шәлбер, сәлбер** «вяло отвислый, отвисающий (и слегка колыхающийся)», башк. (БТДҺ: 390) *шалбыр* «сүлпән, сүрән (кеше тур.)» – **салбыр** (к.) сүзенең модификациясе (*с* ~ *ш* тәңгәллеге гади күчеш түгел, ә мәгънәви нюансларга ия).

Дерив.: **шәлперә-ү** ~ **шәлберә-ү.**

**ШӘЛТӘҮ [шәлтәw]** (Тел ярышы: 47–48) «петля, скоба и т.п. для топора и пр. предметов, прикреплённые к ремню; ремень с петлями, чехлами, кобурами для ношения дорожных принадлежностей» > мар. (Исанбаев 1978: 40) *шалтау, шалтал, шалтар* id. ~ башк. (БҺҺ II: 299; БТДҺ: 390, 400) *шалтау, шәлтеү* id. – бу сүз тарайтылган-күчерелмә мәгънәләрдә дә очрый, к. миш. (Kecskemeti, Paasonen: 196) *šältäw* «терлек тәненә салынган тамга», (ТТДС II: 380) **шәлтәү таяк** «үзенә киләпләр асыла торган махсус таяк», (БҺҺ II: 212) *шәлтәү таягы* «ишек тоткасы» һ.б. << бор. монг. *segülde, segülder* «хәрби каеш, шәлтәү; амуниция» ← *segül* «койрык, чук», к. **Сөлтәр, Шелтә.**

**Шәлтәү** бор. монг. һәм төрки армияләрендә хәрби дәрәҗә билгесе булган, хәрби җәза билгесе итеп гаскәринең шәлтәвен салдырганнар. Шуннан тат., башк. (к. ТТДС I: 521) **шәлтәве төшкән** ~ к.-балк. *сюлдери түшгенди* «бөтенләй кәефсезләнгән, рухы төшкән, авыр рухи хәлдә калган» идиомасы килә. Рус армиясендә дә (электән бирле) гауптвахтага кертелгән солдатның бил каешын алалар.

**ШӘМ,** иск. **шәмгы,** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **шәмĕк** «свеча; лампа, светильник» < гар. *шäм'* «балавыз шәм», *шäм'ат* «шәм, яктырткыч» ← *шм'* «балавызлау» тамырыннан. *Шәм ~ шам* төрки телләрдә киң таралган. К. **Шәмдәл, Шәмлек.**

**ШӘМӘЙ** (ТТДС I: 522, БТДҺ: 401), башк. (БТДҺ: 401) *шәмәк,* тат. (ТРС 1931: 67, 68, ДС II: 225) **чәбәй, чәмәй,** себ. (Тумашева 1992: 245) **чабаи** (!) «бабка; игра в бабки», диал. «игра в подкидывание палочек» – чыгышы ачык түгел. Чаг. **Шакай.**

**ШӘМӘК** диал. «скрытое поселение; притон». Башкортстанда берничә авыл исеме. Ихтимал, фар. *шäмгяһ* «качкыннар торлагы» сүзеннәндер. Шунысы характерлы – ул авылларның рәсми исеме бүтәнчә була, тик күрше авыл кешеләре генә аларны «шәмәк» дип йөртәләр.

**ШӘМӘХӘ,** диал. (ТТДС I: 512; Н. Исәнбәт) **шамаҡы, шамаҡый** «фиолетовый» – асылда шәмәхә төсендә характерлы бизәкләре булган тукыма атамасы: ул фар. *шäмāхäи* дип атала һәм «Шамахыныкы, Азәрбайҗандагы Шамахы шәһәрендә эшләнгән» дигән мәгънәдәге сүз (ул шәһәрдәге ефәкчелек тур. к. Э.А. Керимов. Из истории этнографического изучения Азербайджана в русской науке // Этнографический сборник. Баку, 1964: 199); *шемаханские шелка* «Шәмәхә ефәге» рус илендә дә атаклы булган, к. Фасмер IV: 427. «Ефәк > шәмәхә» мәгъ. күчешенә параллель: иске төрки (< фар.) *ипäкин* «ефәк; шәмәхә» (к. Мелиоранский: 76). **Шәмәхә** шәһәре исеменнән **Шамакай** (к.) сүзе дә килә. Рус әкиятләрендә *шемаханская царица* «тылсымлы гүзәл».

**ШӘМДӘЛ,** иске тат. **шәмғыдан,** диал. (ТТДС I: 522) **шәмгәдән, шәмдәр,** крш. (Balint: 101) **šandel** «подсвечник; светильник» > чув. *шантал*, мар., рус. *шандал* «шәмлек; шәмчырак» < фар. *шäм'дāн* «шәм савыты, шәм аслыгы» һәм *шäм'дāр* «шәмлек» сүзләреннән (контаминация). К. **Шандал.**

**ШӘМЛЕК, шәмнек, шәмдек** (ТТДС II: 380; БТДҺ: 401) «стропила» – асылда «шәм яки чыра утырту өчен өч яки дүрт аяклы тимер җайланма, торшер» (к. күрсәтелгән сүзлекләр); өй кыегы атламасы шуңа охшатылган. Шәмлектәге чыра белән яктыртылу тур. к. ЗДС: 783.

**ШӘМРӘЙ-Ү, шәмәр-ү** «встать и стоять совершенно прямо», к. ш. ук (ДС II: 233) **шәм булу** id. ← **шәм** (к.).

**ШӘМЧЫРАК**, диал. (ТТДС I: 522) **шәм-шыра** «светец, лучинка; свеча с торшером» ~ башк. (БҺҺ II: 307) *шәмсира* id. < *шәм-чыраг*. К. **Шәм** һәм **Чыраг.** Тимергалин: 555.

**Шәмчырак, шәмчыракай** дип яшьләрнең уенлы кич утыруын да атаганнар; бер чая кыз (хуҗабикә) «*шәмчырак, шәмчырак*, янмаганың яхшырак» дип утны сүндергән һәм шунда – караңгыда ишүле тастымал белән селтәнеп утырмачыларны дөмбәсли башлаган һәм егетләр, янәсе кызларны саклап, аларны кочакка алганнар – тастымал төене егетләрне кыйнаган. Кызлар артык кычкырына башласалар, кабаттан ут алганнар.

**Шәмчырак** белән беррәттән әкияттәге **шәбчырак** ~ төр. *şebçirağ* «яктырткыч таш» сүзе дә (ш. ук фарсычадан) билгеле, ул ташны кайбер җәнлекләр, бөҗәкләр күтәреп йөри, имеш.

**ШӘМШИР,** себ. (Тумашева 1992: 188) **сәмсәүр** «вид шпаги» ~ каз. *симсар, самсир* id. < фар. *шäмшūр* id. Будагов I: 672.

**ШӘҢГӘ,** диал. **шәңге,** (ДС I: 232) **шәңкә,** (Хайрутдинова 1993: 39; ЗДС: 783–784) **шәңки** «ватрушка; пельмени, шаньги» > мар. (Исанбаев 1978: 35) *шäнгä* id. ~ башк. (БТДҺ: 390, 401) *шаңга, шәңгә, шәңкә* «шәңгә, эремчек пәрәмәче», удм. (Насибуллин: 147), коми., рус. *шаньга, шаньги* – пәрәмәч төрләре (тәфсилле аңлатмасын к. Аникин: 689–690), бур. *шаанги* «көләчә», як. *һааңки ~ шаңки* «шәңгә» һ.б. А.Е. Аникин буенча, рус теленнән таралган (бу телдә инг. чыганакларында XVII г. башларында теркәлгән) һәм карел. *šanki* «пешерелмә» сүзеннән килә, имеш. Ләкин башк. (БТДҺ: 401) *шәңгә, шәңге* «дүңгәләк, келиндер», үсемлек атамаларында – «яссы чәчәк яисә җимешлек (көнбагыш табагы шикеллесе)». К. ш. ук калм. *шаңгы* «ужау, тәгәч» < фар. *шäңгūр* id., ш. ук «сөзгеч» (*шäн* «киндер сүсе, пәҗе», *-гūр* «алгыч»). Шулай итеп, безнеңчә, мәзкүр сүз, бик күп бүтән ашамлык атамалары шикелле, фар. теленнән таралган һәм бу фараз тарихи мәгълүматларга бап килә. **Шәңге** (шәңге бөккәне) – кайнатып пешерелә һәм кайнар судан сөзгеч белән алына торган бөккән һ.б.

**ШӘҢКӘЙ** (ТТДС I: 522) «жеребёнок» – Сергач мишәрләрендә теркәлгән бу сүз фин-угор

телләреннән килсә кирәк, к. удм. *чуньы* < *чаньы,* коми. (КЭСК: 391) *чань* «колын» >> рус. диал. (Түбән Новгород) *шинька* «колын» (к. Фасмер IV: 440, *шинь* матдәсендә). Тат. телендә, ихтимал, *шән* < бор. фин-угор сөйләшләреннән үк килә. Чаг. ш. ук мар. *чама, чома, цама* «колын».

**ШӘҢКӘЙ-Ү** «вянуть, отвисать (об ушах)» ← чув. *шан-* id. төп мәгъ. «туңу» булса кирәк (туңган колак эрегәч асылынып төшә), к. чув. *шăн-* «туңу». Икенче яктан чув. *шан-* закончалыклы рәвештә тат., башк. **шиң-ү** белән чагыша, к. Федотов II: 438.

**ШӘП** «замечательный; бравый; быстрый; замечательно, браво; быстро» > чув. *шеп*, мар. *шеп, шäп*, удм. *шап* id. < гар. *шäбб, шабб* «яшь, тере, җитез; егет» ← *шбб* «яшь булу». Чаг. төр. *şab, şap* «япь-яшь (егет)».

Дерив.: **шәпле; шәплек; шәбәй-ү, шәплән-ү** (бу сүзләр күрше телләргә дә кергән).

**ШӘПКҮР,** (Тумашева 1992: 250) **шәпкир** «близорукий; больной куриной слепотой» < фар. *шäбкүр* «тавыккүз», сүзмә-сүз «төнен сукыр» (*шäб* «төн, кич», *кур, кӧр* «сукыр», к. **Күрә карау**).

**ШӘР, шәрр** «вредоносное воздействие (чёрта, сатаны)» ~ чув. *шар* (к. Ашмарин XVII: 132–133 һ.б.) «афәт» < гар. *шäрр* «явызлык». М. Федотов (II: 435) бу сүз белән *чир ~ чәр* сүзенең кайбер вариантларын (каз. *шер*, алт. *шäр*) бутый.

**ШӘРАБ, шәрап (шәрабы ~ шәрабе)** «вино» ~ башк. һ.б. кыпч. *шарап* < гар. *шäрāб* id. (шуннан ук – Европа телләре аша – **сироп** «татлы су», к. Kluge: 850) ← *шрб* «эчү» (бу тамырны тикшеренүчеләр тәкълиди характерда дип карыйлар). Шуннан ук к. **Ширбәт**. Будагов I: 665.

Дерив.: **шәрабханә, шәрабче**; иске тат. **шәрабшөреб** парлы сүзенең икенче компоненты да әлеге тамырдан, *шурӯб* «эчемлек эчү» дигән сүз.

**ШӘРӘ I,** диал. (БһҺ II: 308; ТТДС I: 522) **шәре, шәр** «голый; голое место на теле животного» ~ чув. *çара*, (Сергеев 1971: 111) *чара* «ялангач; үсемлексез (мәс., кашлак); тоташ»; *çара-* «ялангачлану; шәрәю» (*çарал-* «ябага кою; йонсызлану, шәрә калу», *çарат-* «ялангачлау; урман төпләү», к. Ашмарин IX: 58–63), мар. *чара, цäрä* «шәрә; (Paasonen 1948: 156) корсакта, бот арасында йонсыз төш» (мәс., этләрдә һ.б. була), *цäр* «бот арасы; бил» – нәкъ шушы мәгънә беренчел булса кирәк, к. чув. *итем çари* ~ мар. *идым чара* «ындыр табагы», димәк *шәрә* < *чара* «тире табак» (к. **Чара II**) белән бердәй; к. ш. ук удм. (Насибуллин: 144) *чап-чара* «шәп-шәрә», каз. *сара* < *шара* «якты; ачык, тигез (юл тур.)». Морфологик җәһәттән *шәр* < **чар* беренчел булырга мөмкин; фонетик җәһәттән *чара* > *чәрә* > *шәрә* закончалыклы (бигрәк тә тат. теле өчен). Тик ошбу тарихи сүзнең чув. телендә киңрәк кулланылуы күзгә ташлана. Федотов II: 86–87 (урынсыз параллельләр китерә).

Дерив.: **шәрелек; шәрәлә-ү, шәрәлән-ү, шәрәй-ү;** идиома: **шәрә батыр** «мәгънәсез рәвештә батыр». Чаг. **Шәре.**

**ШӘРӘ II** (миш., ТТДС I: 522) «орех; узелкование (растения)» ~ монг. *шээр* «чикләвеклек». Гомумән, ачык түгел.

**ШӘРӘКӘ, шүрәкә** (ТТДС I: 523) «уток (короткий), основа (короткая); квадрат на ткани, тканый квадрат, ромб и т.п.», «чурка для самовара (прямоугольной формы)» ~ чув. *çаврака* «түгәрәк, әйләнә; йомарлак» < **чәүрәкә,* к. чув. *çавра* ~ тат. **чәүрә ~ чүрә** «тирә, әйләнә; арткы як», к. **Чүрә.**

«Кыска аркаулык» мәгъ. тукымада квадрат һ.б. ясау өчен шундый аркаулык кулланылудан, әлбәттә.

**ШӘРӘМӘТ** (БТДһ: 401) «жалкое подобие чего-либо (названного)» ~ чув. *шеремет*, мар. *шеремет* «мескенкәй, бахыр; кызганыч ки (кереш сүз)» < фар. *шäрмäнд, шäрмäндä* «оятка калган, оятлы; кыюсыз; мескен».

М.Р. Федотов (II: 454) чув., мар. сүзләрен төр. *şeremet* «кызу холыклы, елгыр» < фар. *шӣр мäрд* «батыр арыслан», күч. «шәп йөрешле менге ат» сүзе белән чагыштыра, ләкин бу – бүтән сүз.

**Шәрәмәт** ~ *шеремет* ниндидер мәҗүси рух мәгъ. кулланылган. Бу сүздән (кайсыдыр мәгънәсеннән) бор. тат. исеме пәйда булып, шул кеше исеменнән рус боярлары фамилиясе – *Шереметьевлар* килә, к. Фасмер II: 429.

**ШӘРӘФ** «почёт, честь» < гар. *шäрäф* id. ← *шрф* «хөрмәтле булу; югары булу», шуннан ук **шәриф** «хөрмәтле, дәрәҗәле, шанлы», иске тат. **әшрәф** «иң хөрмәтле» күч. – «мәр». Инг. телле илләрдәге *шәриф* «баш судья» сүзе дә гарәпчәдән килә бугай. К. ш. ук **Шәрәфә.** Будагов I: 666–667.

Дерив.: **шәрәфле, шәрәфсез.**

**ШӘРӘФӘ, шәрәфәт** «галерея или просто выступ вокруг минарета мечети» < гар. *шäрафäт* «югарылык». К. югарыдагыны.

**ШӘРЕ,** диал. (ТТДС II: 380, БТДҺ: 401) **шәр** «полынья, вода, выступавшая поверх льда зимой; наледь; мокрый снег, мокрая пороша» – ихтимал, **шәре-ү** сүзе белән гомогендыр. Гомумән, ачык түгел.

Дерив.: **шәрлә-ү, шәрел-ү** (ТТДС II: 380) «боз өстенә чыгу – су тур.».

**ШӘРЕ-Ү,** диал. (ТТДС I: 523) **шәрә-ү**, (ТТДС II: 380) **шәрәлә-ү** «испортиться, протухнуть; покрываться плесенью; мокнуть (от глины)», миш. (ор. cit) **шәре-ү** «выходить из игры» ~ башк. (БТДҺ: 401) *шәре-* «картаю» – ачык түгел, ихтимал, **шәре** (к.) сүзе белән баглыдыр. Чаг. тув., монг. *шаар* «черек-чарык; ташландык», тув. *шара* «лайла».

**ШӘРЕХ** «комментарий, объяснение (к сочинению)» < гар. *шäрх* id. Будагов I: 666.

Дерив.: **шәрехле, шәрехсез; шәрехлә-ү.**

**ШӘРИГАТЬ** «шариат, религиозные правила жизни, религиозный закон» < гар. *шäри'ат ← шр'* «юнәлтү, юнәлү». Шуннан ук **шәргыя** «шәригатьчә законлы» (**хәйләи шәрғыя** рус. «благородный обман, святая ложь»).

**ШӘРИК** «товарищ, сотоварищ; одноклассник (особенно – об учащихся медресе)» < гар. *шäрӣк* id., шуннан ук к. **Ширкәт, Мөшрик.**

**Шәриктәш** варианты бер дә кирәксезгә киңәйтелгән.

**ШӘРИТ** «узорчатая или особо крашеная кайма, кромка полы одежды, шали и т.п., тесьма с бахромой» ~ добр., төр. *şerit* «озын челтәр, бизәкле тасма» (гомумән, бу сүз Шәрык телләрендә, Кавказда киң таралган) < гар. *шäрӣṭ* id.

Төр. *şerit* «кәрап бортына, шоссе өстенә сызылган тасмасыман сызыкларны да атыйлар». Тат. әд. телендә *шәрит* сүзен активлаштыру әйбәт булыр иде, чөнки *буй, буй-буй, буйлык, полоса, тасма* кебек сүзләр «шәрит» мәгъ. кулланылганда, ул сүзләрнең төп мәгънәләре искә төшеп, текстны авырлаштыра.

**ШӘРКЫЙ** «восточный; свойственный (Ближнему) Востоку» < гар. *шäрқӣ*, к. **Шәрекъ.**

Дерив.: **шәркыят** «көнчыгышны өйрәнү», **шәркыятчы.**

**ШӘРМӘНДӘ** (Дәрдемәнд һ.б.) «постыдное дело» < фар. *шäрммäндä* «оятка калу»: *шäрм* «оят», *мäндä* «калу; калмыш». *Шарм* < авест. *fšarəma* > слав. *срам* ~ ним. *Harm* «оят». Kluge: 399.

**ШӘРРӘН: шәррән яра** «совершенно открыто, ничуть не скрывая» < гар. *шäррāн йäрā* id., к. ГТРС: 712.

**ШӘРЫК, шәрекъ** «Ближний Восток», ш. ук. «восток; восход» < гар. *шäрқ* id. ← *шрқ* «кояш чыгу; яктыру», шуннан к. **Шәркый, Мәшрикъ.** Тимергалин: 556.

**ШӘТ,** себ. (ДС I: 66) **ишәт** «может быть, возможно» ~ чув. *шет*, морд. М. *шять*, удм., мар. *шат*, (Саваткова: 197) *шаток* id. рус. *чать* id. сүзеннән дип уйларга мөмкин, ләкин к. кар. *шагат, шахад, шаад* «шәт, шаһит» < гар. *шäһāд* «күрәсең». К. **Шаһит, Шәһадәт.** Чаг. **Шаять**.

**ШӘТЕР** «зонт, зонтик» << фар. *чäтр, чäтир* id., к. **Чатыр.** Будагов I: 469–470. Бу сүз бүтән бер юл белән рус теленә дә килеп кергән, к. рус. *шатёр* «зур чатыр, гөмбәз», шуннан *шатром* «зур гөмбәзсыман» > тат. **шатрун** (к). Икенче яктан каз. *шатыр* < *чатыр* «җилкән» сүзе ясалган.

**ШӘТНЕК** (Хайрутдинова 1980: 32) «кадка» ~ чув. *шетник* id. < рус. диал. *шатник* «кәбестә һ.б. тапап тозлау өчен агач тәпән».

**ШӘҮВӘЛ [шәwwәл]** «шавваль – десятый месяц лунного года» – рамазан аеннан соң килә һәм аның тәүге өч көне – рамазан бәйрәме.

**ШӘҮКӘЛ [шәwкәл]** (ТТДС I: 523) «крупнокостный и худой (но здоровый и сильный)» ~ башк. (БТДҺ: 392) *шауҡал* id. << монг. *шобхаал, шобхагал* «сөякләч, сөякләре беленеп торган».

**ШӘҮКӘЛӘ [шәwкәлә]** иск. «высокий головной убор» к. **Шүклә.**

**ШӘҮКӘТ [шәwкәт]** «великолепие, величие» < гар. *шäwкäт* id.

Дерив.: **шәүкәтле** «дан-шөһрәтле».

**ШӘҮЛӘ [шәwлә]** «отражение (на водной поверхности и т.д.); отблеск, зарево; фигура, тень (в полумраке)» > чув. *шевле, шевлев* id. < чыгт.

*шäғлä, шуғлä*, иске тат. **шөгълә**, *шүwлә*, башк. (БТДҺ: 394) *шөгәлә*, төр. *şule* һ.б. id. < гар. *шуʻлä* «факел; шәфәкъ» ← *шʻл* «ут, учак ягу», шуннан ук иске тат. **мәшгаль** «сигнал учагы; факел». Будагов I: 668; Федотов II: 452 (*шевле* сүзенең татарчадан икәнлеген әйтми һәм бөтенләй хата этимология бирә).

Дерив.: **шәүләле, шәүләсез; шәүләлән-ү.**

**ШӘҮЛЕГӘН [шәwлĕгән], шүлегән** «иволга; оляпка», диал. (Ахатов 1977: 57) **шүлгән** «коршун, вид коршуна» – асылда тат. диал., башк. **шүлгән** «су асты патшасы» (к. **Шүлгән**) белән бердәй: шәүлегән суга чумып, су астыннан җим табып көн итә һәм аның бу сәер, гаҗәеп кыланышы барлык халыкларда бу кош тур. төрле мифологемалар барлыкка килүгә сәбәп булган. Татар-башкортларда, димәк, гүяки су асты патшасы кошчыкка әверелеп судан чыга һәм югары күтәрелә; шәүлегәннең җәйге яңгыр алдыннан сайравы аның яшен тәңресе белән багланышы турындагы легендаларга нигез булган (мордва фольклорына хас мотив). **Шәүлегән** – су асты патшасының килене (к. Paasonen 1949: 371–379), рус. фольклорында (к. Симонов И. Охотники за сказками. Ярославль, 1970: 187–196) *шулигун* – суга төшеп үлгән бер Иля дигән кызның инкарнациясе, Тува әкиятләрендә (Тыва тоолдар, V. Кызыл, 1960: 94–120) *Шулуун ~ Шулүгүн ~ Шүлгән* Курбустанның (Һормуздның) ана үрдәккә әверелеп йөри торган сеңлесе һ.б.

**Шәүлегән** сүзе, гомумән, шул кош мәгъ. тат. телендә генә очрый бугай. Бу сүз тур. Г. Рәхимнең (к. Мәгариф, № 9–10, 1923: 35–36) «Төркичә бер сүз төбе турысында төпченү» дигән мәкаләсе бар, анда **шәүлегән** сүзе төр. *үшәү* «текә яр» белән баглы дип расланыла. Безнеңчә, бу аңлатма бик ясалма.

**ШӘФӘГАТЬ [шәфәғәт]** «благосколонная поддержка, помощь; заступничество» < гар. *шäфäʻат* id. Будагов I: 669. Дерив.: **шәфәгатьле; шәфәгатьче, шәфәгатьчел; шәфәгатьчелек.**

**ШӘФӘКЪ** «вечерняя или утренняя заря» < гар. *шäфäķ* id. ← *шфķ* «яктыра башлау; якты караш». К. түбәндәгене.

**ШӘФКАТЬ [шәфкәт]** «милосердие; снисхождение», иск. «помилование» < гар. *шäфķат* id. ← *шфķ*, к. югарыдагыны. Будагов I: 669.

Дерив.: **шәфкатьле, шәфкатьсез; шәфкатьче.**

**ШӘХЕС** «личность, особа» < гар. *шäх̮ç* id. ← *шх̮ç* «килеп чыгу, пәйда булу, йөз бирү». Тимергалин: 557.

Дерив.: **шәхсән, шәхси, шәхсият** (бу сүзләр гар. теленең үзендә үк ясалганнар); **шәхсилек.**

**ШӘҺӘР** «город», иск. «область» < уйг. *шәһәр* < фар. *шäһр* id. < авест. *xšaδra* < бор. ир. *xšatra* «(яулап алынган) биләмә, өлкә» ← *xši-, xšy-* «биләү, идарә итү» (һинд-ир. тамыр сүзе); шуннан ук һинд. *кшатри* «сугышчылар кастасы» һәм *сатрап* (< бор. фар. *xšatrabān* «өлкә башлыгы, өлкә караучы») сүзләре дә килә.

Чув. *шехер* «губерна», *шекер* «губернаның башкаласы» болг. теленнән килсә кирәк: бу сүзләрдә сүзнең борынгырак мәгъ. саклана. Күпчелек төрки телләрдә **шәһәр** сүзе актив кулланылмый. Platts: 738.

Дерив.: **шәһәрле, шәһәрсез; шәһәрлек.**

**ШӘҺВӘТ [шәһwәт]** «половое вожделение, страсть, похоть» < гар. *шäһwäт* id. Тимергалин: 58.

**ШЕКӘ, шөкә** (**шекә пәрие** Н. Исәнбәт һ.б. авторларда) «гном» ~ мар. *чыки* «кәрлә», *шига* «шүрәле», чув. *чике [чигә]* «терсәк; ярты аршынлык озынлык», шуннан *чике сухал* «терсәк буйлыгы мифик зат» («үзе бер карыш, сакалы йөз карыш») М.Р. Федотов (II: 48) буенча, чув. теленнән таралган сүз. Аналогиясе – удм. *кид-мурт* «ярты аршын буйлыгы кеше»: *кид* «кул, терсәк», *мурт* «кеше».

Казан артында **Шекә** дигән авыл да бар, ләкин **шекә** сүзе аннан таралмаган, чөнки бу сүз Тау ягында ешрак очрый. Шекә тур. сөйләкләрдә ул – абзар яисә ташланган өй иясе; кайчакта урманда яши, утын әзерләүчеләрнең балтасын урлый һәм җырлагач, биегәч, әкият сөйләгәч кенә бирә. Аны куар өчен дога укысаң, ул догаларны кирегә укый, әмма догада кирегә укып булмый торган сүз булса, шуңа төртелеп, аның кодрәте бетә һәм ул юкка чыга. Аның урынында күл генә кала, ди.

**ШЕЛЕ,** (ДС I: 231) **шел** «лыко для плетения лаптей» ~ удм. (Насибуллин: 147) *шильы* id. Чаг. алт. (Будагов I: 671) *шiлi* «муен тамыры», тув. *шылы-* «катламнарга аеру, тасмалау», уйг. *шил-* «кабык сую». Ләкин тат. **шеле** сүзе, мөгаен, удм. теленнән алынгандыр (ул Төньяк Башкортстанда очрый). Чаг. ш. ук чув. *чĕлĕ* «телем» ← *чĕл-* «телү».

**ШЕЛТӘ** «порицание, выговор» > мар. *шылта, шелта, шĕлтау* id. < бор. кыпч., к. алт., кырг. *шилте,*

*шилтä* id., госм. (Радлов IV: 1078), фар. *шілтақ* «юкка, яла ягып сугу», бор. монг., чыгт. (Поппе 1938: 270) *šıltaq* «яла, бөһтан» һ.б. **сылта-у** белән тамырдаш ди М. Рясянен (Räsänen 1969: 445, 447). К. **Сылта-у.** Күпчелек (кыпч. һ.б.) төрки телләрдә *шелтә* < *шилтә* сүзе теркәлмәгән. Ним. *schelten* «шелтәләү», әлбәттә, очраклы аваздаш.

Дерив.: **шелтәле, шелтәсез; шелтәлә-ү; шелтәчел.**

**ШЕЛТЕРӘ-Ү** (Ф. Сәйфи-Казанлы) «сильно сохнуть, засыхать (о травах, сене)» – имитатив **шелтер ← шелт** нигезләреннән (ләкин бу сүзләр конкрет телкәлмәгән).

**ШЕПКӘН** «рыжик (вид травы с маслянистыми листьями)» ~ чув. *шӑпкан*, мар. *шыпкан* id. Чаг. бор. төрки (ДТС: 150) *čïpïqan* «унаби, кытай хөрмәсе (кошкунмасчалар ыругыннан куак)» ~ уйг. *чобуган, чубакан*, монг. *чибукан* id. К. **Чуан.** Чаг. ш. ук уйг. (Räsänen 1969: 447) *šipkin* «шәмәхә», урта төрки *jipkin, jipkil* «көрән», бор. төрки *jipin* «шәмәхә; кызгылт» < (безнеңчә) кыт. *žiəpxan, žiəpxun* «кызгылт һ.б.»

**ШЕРЕШ** «клейстер» ~ төр. *çiriş* (> венг. *csiriz*), үзб. *сираж*, кар., ком. *чырыш* > нуг., каз., к.-калп. *шырыш* – җилемнең төрле төрләре. К. ш. ук себ. (Гиганов) *черешен* «известь». Чаг. **Чаршын.** Räsänen 1969: 423 (СС *siriš* «сумала» < фар. *sirišk* «тамчы; сүк» ди).

**ШЕШ I** «опухоль» < гом. кыпч., чыгт., гом. угыз. *шиш*, төркм. *чиш, чыш*, чув. *шӑҫ*, шор. *шыш*, як. *ис* id., ш. ук (күч. мәгъ.) «кибән», к. **Шеш-ү.** Чаг. рус. *шишка* (ләкин рус этимологиясендә бу сүз төрки алынма дип исәпләнми).

**ШЕШ II** «вертел; шиш, стожар (кол, который втыкается вертикально в центр стога)», диал. (Тумашева 1992: 250) «вилка, вилы; палочка, которую надевают на морду телёнку, чтобы не сосал», (Akb: 123) *šiš* «энә, без» < гом. кыпч., алт., госм. һ.б. *шиш*, хак. *сис*, төркм. *чыш*, к.-балк. *тиш* «шеш» < бор. төрки (ДТС: 506) *šiš* ~ *šïš* «шеш», чув. *шӑл* «теш» сүзе белән чагыштырыла, ләкин бу шикле (к. Федотов II: 440). Рус. *шиш* «очлы тау, пик» < төрки *шиш* тур. Аникин: 704.

Дерив.: **шешлек** «тимер үзәккә элеп пешерелгән ит»; рус. *шашлык* < төрки *шишлäк* id. ← *шишлә-* «шешләү». К. **Шашлык.** Чаг. **Шеш-ү.**

**ШЕШӘ,** диал. **шиша, чиша** «бутыль; стеклянный пузырь; стекло» > мар. *шиша* «бутылка» ~ гом. кыпч., к. кырг. *шише,* уйг. *шишә,* каз. (ҚТДС: 402–403) *шүйше*, төркм. *чүйше*, аз. *шүшә*, үзб., госм. *шиша,* к.-балк. *шыша* һ.б. «шешә, пыяла савыт; пыяла; көзге һ.б.ш.» В.С. Соколова буенча (1953: 72, 84, 85), фар. *шӣшā, шӯшā* яңгырашы аша санск. теленнән.

Дерив.: **шешәле** («шешәгә тутырылган» мәгъ. бар), **шешәсез; шешәлек; шешәдәш** (рус. *собутыльник* сүзеннән калька).

**ШЕШӘК** «двухлетний; на втором году (об овце)» ~ башк. (БТДҺ: 393) *шешәк* «икенче яшьтәге сарык, кәҗә; икенче яшьтәге каз» < кырг., төркм., төр. (һ.б. угыз) *шишәк* < уйг. диал. *чишәк* < бор. төрки (ДТС: 563) *tišäk* «шешәк, тешәгән сарык, куй» ← *tiš* (> уйг. *чиш*) «теш» сүзеннән, к. ш. ук башк. (*эт шешәгәндә картаер*, дигәндә, к. БТДҺ: 393) *шешә-ү* «тешәү». Шулай итеп, **шешәк** һәм **тешәк** – икесе бер үк сүзнең төрлечә фонетик үсешләре; кыпч. телләрендә беренче *ш-* югала, к. кырг. диал. *ишшек* > каз., к.-калп. *исек* «шешәк».

**Шешәк** < *шишек* яңгырашы кыпч. телләрендә таралмаган, ул мөгаен уйг. теленнән килә (*т-* > *ч-* > *ш-* уйг. теленә хас). Башк. *шешә-ү* сүзе дә, әлбәттә, башк. теленең үзендә килеп чыкмаган.

*Шишäк* «шешәк» сүзе күп телләргә (фар., Кавказ, Балкан) алынган.

**ШЕШБӘРӘ, шешбүрә, шөшбөрэ** (Будагов I: 675, транскрипциясе бәхәсле), диал. (ДС II: 231; ТТДС I: 514; Хайрутдинова 1933: 109–110) **шешмәрә, шөшпүрә,** себ. (Тумашева 1992: 241, 251) **цөцбәрә, цөцбүрә, цөцмәрә, шөшпәрә, шөшбүрә** «творожный вареник; пельмень» ~ башк. (БТДҺ: 287, 396) *сүспәрә, шүшмәрә,* кырг. *чүчбара, чүчпара*, үзб. *чүчвәрә, чүчвара,* уйг. *чöчүрә, чöчwәрә*, ком. *дюшбере,* аз. *дүшбәрә* һ.б. Кырг. вариантларына караганда – кушма сүз. Сүзне төрлечә аңлатырга була, әмма бертөрле хәлиткеч материал юк. Чаг. *бәрәк ~ бөйрәк ~ бүрәк* «бәлеш».

Л. Будагов сүзләренә караганда, Казан шәһәре *шүшбүрә*ләр белән мәшһүр булган.

**ШЕШМӘН** «пухлый; толстый (о мужчине)» ~ төр. *şişman* id. Төрки *шиш* (к. **Шеш I, Шеш-ү**) сүзе нигезендә фар.-көрд даирәсендә ясалган булса кирәк (*-ман* кушымчасы); тат. **шешмәк** < *шишмәк* варианты төрки телләрнең үзләрендә ясалган.

**ШЕШ-Ү**, диал. **чеш-ү** «вспухать, пухнуть» < гом. кыпч., чыгт., уйг., угыз. *шиш-* < бор. төрки (ДТС: 524) *šiš-* id.; бу сүзнең веляр варианты да киң таралган: тат. диал. (миш., без теркәдек. – *Р.Ә.*) *чыш-у* ~ чув. *шыҫ-*, төркм. *чыш-*, нуг., хак. *сыс-*, як. *ис-* id. һ.б.ш. К. **Шеш.** Федотов I: 467 (арытабангы фаразлар китерелә).

Дерив.: **шешен-ү, шештер-ү; шешек, шешенке, шешкен, шешмән**. Рус. *шиш, шишка,* ш. ук мар. (Исанбаев 1978: 18) *шӹйшӹ* «корчаңгы» сүзләре белән кардәшлеге шикле.

**ШИБЛИТ** «штиблет (вид обуви)» < рус. < ним., к. Фасмер IV: 478.

**ШИГРИН** «шагрень, шагреневая кожа» < рус. *шагрень* (чыгышы төрки, к. **Саурый**).

**ШИГЫЙ, шига** «шиит; шиитский» < гар. *шӣʻӣ* id., гомумән – «группа» (*шӣʻат ʻАли* «Гали сахабә тарафдары» дигәннән эллипсис).

**ШИГЫРЬ** «стих, стихотворение» < гар. *шиʻр* id. К. **Шагыйрь.**

Дерив.: **шигъри; шигърият** (гарәп телендә үк ясалганнар).

**ШИК** «сомнение, подозрение» > чув. *шик,* мар. *шек, шэк* id., удм. (Насибуллин: 149) *шэк* «шиклелек» < фар. *шäк, шэк* id. > гар. *шäкк* «шик, шикләнү». Бу сүз төрки телләргә X–XI г. ук кергән һәм киң таралган (*шэк* > *шик* күчеше дә шуны күрсәтә).

Дерив.: **шикле, шиксез; шикллән-ү** (диал. ш. ук **шигәй-ү**); **шикчел;** себ. (Тумашева 1992: 250) **шик-ү** «шикләнү».

**ШИКАЯТЬ [шикайәт]** «жалоба; обвинение» < гар. *шикāйäт* id. ← *шкw* «зарлану».

Дерив.: **шикаятьче; шикаятьлә-ү.**

**ШИКӘР,** диал. **шәкәр** «сахар» > мар. *шекар* id. < гом. кыпч. *шәкәр*, башк. *шәкәр,* госм., уйг. *шәкәр* < бор. төрки (ДТС: 522) *šäkär, šeker* < фар. *шäкäр* < һинд. *sarkara* «агартылган шикәр» (бөтенләй ук агартылмаган шикәр *Khanda* дип аталган, шуннан к. **Кант**), К. Lippmann E.O. Geschichte des Zuckers. Berlin, 1929. Һинд. сүзе IX–XI гг. ук төрки телләргә һәм бөтен Евразиягә таралган. Kluge: 1017.

Дерив.: **шикәрле, шикәрсез; шикәрләп, шикәрлә-ү; шикәрче, шикәрчелек.**

**ШИКЕЛ** (ДС III: 193, ТТДС I: 513; Balint: 102) «общий вид, лик, лицо», себ. (Тумашева 1992: 250) **шигел, шәгел** «внешность» < кырг., бор. кыпч. *шекил,* төр. *şekil,* уйг. *шәкил, шәкл* ~ к. тат. **шекел** id. < гар. *шäкл* «шәкел» ← *шкл* «гөманлы булу, юралу; ясалу, формалашу», шуннан ук к. **Мөшкил, Тәшкил.** Тат. *шикел – шәкел* тәңгәллеге бу сүзнең бор. заманда язмадан түгел, телдән алынганлыгын күрсәтә. Шуны ук чув. *шкал* «сыман, шикелле» (< *шакл*) кушымчасы да дәлилли. К. **Шәкел.** Чаг. **Шәйлә-ү.**

Дерив.: (Ш. Камал) **шикелсез** «кыяфәтсез, ямьсез», к. түбәндәгене.

**ШИКЕЛЛЕ,** себ. (Дмитриева 1981: 198) **шәгәллү, шәкилли, шәйиллү** «как, словно, точно» – **шикел, шәкел** (к.)., себ. **шәгил** > *шәйил* «шәкел, форма; кыяфәт» сүзеннән тат. теленең үзендә дә ясала алган, ләкин бу сүз күп төрки телләрдә очрый: төркм. *шекилли,* кырг. *шекилди, шекилдүү* > к.-калп. *секилди,* каз. *секiлдi,* нуг. *секинли* «шикелле». Башк. һәм Уралдагы тат. сөйләшләрендә бу сүзнең модификацияләре күплеге күзгә ташлана: *шекелле, шикетте, шикелдеге, шәкте* һ.б. (к. БТДҺ: 393).

**ШИКМӘ** (ТТДС I: 515; БҺһ II: 302, Balint: 102) «обрешётка (крыши); лестницы; мостки; подстропильник; каркас забора» > чув. *шитме* «бурада фасад бүрәнәсе» ~ калм. *шитме* «агач рәшәткә» ~ ? (ЛТ I: 210) *шебкә* «рәшәткә, шикмә». К. ш. ук чув. *чикме, чикмек* «баскыч, күтәрелгеч; шикмә, текмә читән» ← *чик-* «тегү, кадау». Ихтимал, монда төрле тамырлар контаминациясе булгандыр, к. **Тек-ү, Чик-ү.**

**Шикмә** сүзен «озын баскыч» мәгъ. куллану мәслихәт.

**ШИЛ** (ТТДС I: 515) «межень, самая маловодная пора реки» ~ башк. (БТДҺ: 376) *һил* < *сил* «тын, тымызык (һава тур.)». Сүзнең киңрәк таралган кулланылыш формасы **шил булу ~ сил булу** (к. ТТДС I: 369, 515) «бөтенләй тынып калу». К. **Шил-ү.**

**ШИЛМА** (трбс.; БТДҺ: 393) «шельма; бойкий, шустрый и хитрый (о мальчиках и девочках)» < рус.; бу сүз ним. *Schelm* «мут, хәйләче» сүзеннән дип исәпләнә, к. Фасмер IV: 426. Асылда бу сүз «үләксә итен сатучы» дигән сүз икән, к. Kluge: 798.

**ШИЛ-Ү** (ТТДС I: 516; ТТДС II: 375) «уменьшаться, убавляться, опадать (о воде); похудеть»,

**шилкәтлән-ү** «затихать (о дожде и т.п.)» – **шил** (к.) сүзе белән баглы, ләкин формаль мөнәсәбәтләр ачык түгел. Ихтимал *шил* ~ *шил-* фар. *чел* (> каз. *шел* һ.б., к. **Чиләбе**) «дөге басуы; дөге басуыннан суны саркыту һ.б.ш.» сүзе белән баглыдыр.

**ШИМБӘ,** диал., башк. **шәмбе, шәмбә**, (Тумашева 1992: 250) **шәмпе** «суббота» ~ төркм. *шенбе*, госм. *шӓмбӓ*, уйг. диал. *шамби*, кырг. *шемби* > каз. *семби, сембі* һ.б. id. < фар. *шӓнбӓ*, иске фар. *шанбат* (> чув. *шӑмат*, мар. *шумат*, удм. *шумот*) < бор. яһ. *šabbat, šabbata* (>> рус. *суббота*) – ахыр чиктә аккад телендәге **Шаммаш** «кояш тәңресе» сүзенә кайтып калса кирәк. Җидекөнлек атна системасы белән бу сүз рефлекслары бөтен дөньяга таралган. К. ш. ук **Шабаш**. Фасмер III: 792; Федотов II: 442–443; Kluge: 778, 784.

Дерив.: **шимбәлек** (рус. *субботник* сүзеннән калька); **шимбәсез** «шимбә җитмичә».

**ШИМДЕ** иск. «теперь, после этого (сказанного); уже» ~ кар., төр., гаг. *шимди, шинди,* төркм. *шүнди, шүнни* < *шу инди, шу эмди* «шул инде, әлеге дә баягы»; яки уйг. *уш иман* «хәзер генә; шундук». Тат. сүзе < госм. Будагов I: 673; Мухамедова 1973: 192.

**ШИҢ-Ү** «завянуть, блекнуть; стать дряблым» ~ каз. *сең-*, чув. *шан-* < **шәң-* ~ як. *иин-* id. Räsänen 1969: 410; Федотов I: 433 (якут мисалын китермиләр).

Дерив.: **шиңел-ү, шиңдер-ү.**

**ШИРӘ** «закваска; ягодный сок» > мар. *ширӓ* id. < уйг., үзб., төркм. *ширә* < фар. *шӣрӓ* «сироп; эфьюн мәгенең сыгынтысы», төр. *şire, şıra* «әчетергә куелган виноград суты; фильтрланган эфьюн». Тат. телендә эфьюнчылыкка баглы мәгъ. юк.

**ШИРБӘТ** «сладкий напиток (сыта и т.п.); вода, принесённая молодухой в доме мужа в первый раз» (к. Баязитова 1986: 160) > мар. (Исанбаев 1978: 36), чув. *шерпет* ~ башк. *шәрбәт* «татлы эчемлек» < гар. *шӓрбӓт* id., төрки телләрдә киң таралган. К. ш. ук **Шәраб.** Будагов I: 665–666; Федотов II: 455.

**Ширбәт** белән баглы йолалар тур. ТТДС II: 375–376 (тәфсилле).

**ШИРЕ, ширә** («Чура батыр» дастанында) «застолье богатырей; длинный стол» ~ нуг. *сыра,* төр., чыгт. һ.б. *ширә* (> морд. *шира, шра*) «дүртпочмак өстәл», хак. *ширэ, ширээ*, алт. *шире, ширее, ширгее,* тув., монг. *ширээ(н)* < бор. монг. *širege,* эвенк. һ.б. (ССТМЯ II: 426) *siregen* «зур өстәл, тәхет; шыйлык, буддистларның потлары куела торган өстәлчек» > бор. төрки (ДТС: 523) *širä* «ханның аш өстәле» һ.б. Будагов I: 680; Аникин: 702 (рус. *ширетой* < бур. *шэрээтэ* (*лама*) «тәхетле лама»). Кавказ телләрендәге *сире* һ.б.ш. «өстәл» тур. Абаев III: 208.

Дерив.: башк. (БТДҺ: 394) *ширлек* «киштә; кечкенә сәке». Чаг. **Шыйлык**.

**ШИРЕБ** (Остроумов 1892; Balint: 102) «крепкий, твердый; жёсткий», диал. (ТТДС I: 516) **ширеп** «свежий; твёрдый, тугой (о теле животных)» < чув. *çирĕп* «ныклы, точ, каты», мар. *сирып* «көчле, саллы», (Иванов, Тужаров: 202) *сирĕп* «точ, сусыл; хәлле, көр». Бу сүзне М.Р. Федотов (II: 123) бор. төрки (ДТС: 243) *jarp* «нык, каты» сүзе белән чагыштыра һәм без моңа каршы түгел.

**ШИРЛЕК I** диал. (крш., без теркәдек. – *Р.Ә.*) «озорство; баловство» ~ кар. *шэнлик, шэльлик* < *шэрмлик* id. ← *шэрм* < фар. *шӓрм* «оят, хурлык; усал шаяру», шуннан иске тат., үзб. **шәрмәндә** (< *шӓрм мӓндӓ)* «оятка калу».

Икенче яктан к. каз. (ҚТДС: 393) *шерлік*, уйг. *ширлик* «егетлек, батырлык» ← каз., үзб. һ.б. *шер* «арыслан; батыр».

**ШИРЛЕК II** диал. «скамья», башк. id., чаг. тув. *ширә*, монг. *ширээ* «тәхет». К. **Шыйлык.**

**ШИРМӘ** (Остроумов 1872: 137) «сумка» к. **Чәрмә.**

**ШИРТ I** (ТТДС I: 516) «заколдованное место; колдовство, колдование» ~ мар. (Саваткова: 219) *шӹрт* «урман феясы», (Иванов, Тужаров: 300) *шырт* «явыз рух», чув. *шӑрт* «чәчүлек химаячесе (рух)», «ачу, явызлану». Ачык түгел, чаг. рус. *чёрт* «явызлык, шайтан» (гом. слав., к. Фасмер IV: 347).

**ШИРТ II** иск. «присяга» ~ кар., каз., к.-калп., кырг., алт. һ.б. *шерт* (> хак. *сирт* >) рус. *шерть* «бәйгать, ант» < уйг. *шәрт* < гар. *шӓрṭ* «шарт; шартнамә». Бу сүз гар. теленнән бик бор. заманнарда ук кергән (чөнки ул манихей язмаларында да кулланыла). Чаг. ш. ук чув. *шӑрт* > мар. *шырт* «ширт» (к. Федотов II: 450) – болг. теленнән. Каз.,

к.-калп., нуг. *серт* диелә. Рус. *шерть* тур. Аникин: 697 (иске рус документларында *шерть, шертовать* бик тә киң кулланыла).

**ШИТ,** (ТТДС I: 487) **чити** диал. «четверть (десятины, литра)» ~ башк., чув., мар. *шит* «карыш, чирек аршын» < рус. *четь* id. < *четверть* «түтәрәм», к. Фасмер IV: 352. К. ш. ук башк. (БҺҺ II: 212) *ситмиллик* «ун адым (җир киңлеге)» < рус. *четвертник* id.

**ШИФА** «целительное воздействие» < гар. *шифā'* id. ← *шфй* «дәвалау».

Дерив.: **шифалы, шифасыз; шифала-у; шифаханә; шифачы.**

**ШИХАН** (ТТДС I: 516; БҺҺ II: 302) «одинокая гора (в степи)» < рус. *шихан* id., ш. ук «биек көрт, боз өеме; чагыл» (к. Фасмер IV: 444, чыгышы ачык түгел ди), безнеңчә, тат., каз. *шыйған* id. сүзеннән, к. **Чуан**. Ләкин шул ук сүзнең бур., монг. варианты *шиихан* «чуан, очлы тау» сүзе рус вариантына якынрак яңгыраштa. К. ш. ук себ. (ЗДС: 718) *цыйған* «сызлавык», каз. (ҚТДС: 403) *шыған* «көтүнең авангарды». Фар. *шāх̣, шāх̣āн* «текә тау».

Тат. диал., башк. диал. (ТТДС I: 518; БҺҺ III: 21) **шыған** «озын, төз агач; озын, төз буйлы (кеше)» сүзенең *шихан* һ.б. сүзенә катнашы ачык түгел. Аникин: 703 (безнең кебек үк *шихан* «очлы тау < очлы шеш» дип фикер йөрткән А.К. Матвеевка каршы чыга).

**ШИШАРА,** (Хайрутдинова 1993: 43) **шишарат**, (ТТДС I: 488) **чишәрә** «булка, батон с поперечными углублениями или с сужениями; колобок (с радиальными углублениями с одной стороны) и т.п.; мучные изделия (разные в разных местах)» ~ башк. (БТДҺ: 394, 402) *шишара, шәшәрә* id. > мар. (Исанбаев 1978: 35) *шишара* «шишара, өйдә пешерелгән келиндер; ай нуры; радиаль сызыклар» < фар. *шәш шāрāх, шәш шāрхā* «шишара; алты тигез кисәк, алты телем»: *шәш* «алты» + гар. *шāрха*[т]*, шāрха, шāрūхā* «телем, телемнәр; телемләү; бүлемтек һ.б.ш.» ← *шрх* «өлешләргә бүлү, бүлемтекләү», к. **Шәрех.**

Фар. телендә *се шāррах* «өч бүлем» сүзе дә бар. Камыр ашамлыкларын алтыга бүлемтекләү гаиләдә алты җан башы (дәвәни, дәвәти; әни, әти; ике бала) булырга тиеш дип караудан булса кирәк (к. Г. Тукайның «Безнең гаилә» шигырен). Чаг. ш. ук **Шешбәрә.**

**ШОБАГА, шыбага** «жребий; участок (земли, покоса, доставшаяся по жребию); площадь земли, состоящая из восьми единиц надела» (к. Г. Ибраһимов, т. III: 530) > удм. *шыбага, шымана*, мар. *шывага* id. ~ үзб. (ЎХШЛ: 316), уйг. һ.б. *шыбаға* (> нуг., каз., к.-калп. *сыбаға*) «өлеш, тантаналы табында һәр кунакның дәрәҗәсенә күрә бирелгән ит өлеше» (бу хакта к. **Пай, Сөбә**) ~ монг. *шавга*, як. *sibaγa* id., калм. *šawxo* «юрау, шобага салу өчен махсус кубик» ← монг. *шо* < кыт. *шō* «юрау һәм төрле уеннар, ш. ук шобага салу өчен кубик» сүзеннән, к. ССТМЯ II: 388 (эвенк. *чиб-, чииб-* «шобага ташлау» матдәсендә). Тат. (ТТДС I: 518) **шыбага** «җылым калкавычы» сүзендә беренчел мәгъ. саклана булса кирәк.

Чув. *шăпа*, мар. (Упымарий: 281, Саваткова: 214) *шыва, шӹвӓ* «шобага» варианты халык этимологиясенчә **шобага** сүзен **шоба-га** дип аңлаудан килеп чыккан булса кирәк (ягъни бу вариантлар татарчадан алынган). Räsänen 1969: 445; Федотов II: 446–447 (һәр икесенең материалы ярлы).

Дерив.: **шобагалы, шобагасыз; шобагалык; шобагала-у.**

**ШОЛГАН** (ТТАС III: 511) «крот; землеройка» (Остроумов 1892: 239) **шулыган, шыулыган,** (ТРС 1931) **шулган** «суслик, крот» > мар. диал. *шулган, шурган* id. ~ шор. (к. Räsänen 1969: 450) *шүшкāн* «кыр тычканы». Ихтимал, **шүлгән** (к.) белән бердәйдер.

**ШОМ** «безотчётный страх, глубокое опасение», себ. (Тумашева 1992: 251) «недобрый», (Радлов, Образцы..., в сказке *Куш істäгäлі jӱргäн ханның улуу äкujäті*) **шум** «злой дух» ~ кырг., уйг., үзб., аз. диал., төр. диал., бор. төрки (Боровков 1963: 365) һ.б. *шум* «шук; хәйләкәр; жулик» > нуг., к.-калп. *сум*, каз. *сӧм* id., фар.-таҗ. *шум* «шом» ~ гар. *шӯм* «бәхетсезлек китерүче (рух)». Төр. фольклорында *şum bala* «усал шаян, елгыр малай» образы (явыз рух түгел). Кырг. < каз. *сумырай* «кыяфәтсез явыз рух» < фар. *шумируй* «шомлы йөз(ле)» булса кирәк. Чаг. санск. *śітпи, šитпи* «дию». К. ш. ук **Шомбай.**

Дерив.: **шомлы; шомлык; шомлан-у.**

**ШОМА** «гладкий; хорошо, с шиком одетый» ~ башк. *шыма* id. > чув. *шăма*, мар. *шыма* id., ш. ук «иркә, йомшак мөгамәләле» – гом. тат. **шума** «шуып торган, тигез; шырпысыз (мәс., такта)» ← **шу-у** (к.). К. ш. ук тат. **шомакай** «купшы; мөлаем»

> чув. *шăмакай, шăмаккай*, мар. *шымакай* id., каз. *сумақай* «шомакай» сүзе дә татарчадан булса кирәк.

Дерив.: **шомалык; шомалан-у, шамала-у, шомар-у;** фразеологизм: тат., башк. **шома (шыма) көпшә** ~ мар. *шымавуч,* чув. *шăма кĕпçи* «фәрештә уты (үсемлек)». Федотов II: 443.

**ШОМБАЙ** «тихоня, шпик; себе на уме; хитрец, прикидывающийся дурачком» ~ башк. *шымбай* id., чув. *шăмпай* «юньсез», кырг. *шумпай* «жулик, шук; иң яхшы ау карчыгасы» ← *шум* «хәйләкәр; жулик» ~ каз. *сӧмпайы* «сөйкемсез, кыяфәтсез». Бу сүздә төрле контаминацион тәэсирләр бар. К. **Шом.**

**ШОМБИЯ [шŏмбийа]** (ЛС: 12) «заразиха (растение)» ~ кырг. *шумгуя*, үзб. (ЎХШЛ: 318) *шумгия, шумғула* id. ~ фар. теленнән. Чаг. **Шом.**

**ШОМЫРТ [шŏмŏрт],** себ. (Тумашева 1992: 82, 86) **йумрут, йомырт** «черёмуха» ~ алт. *йымырт, йымырыт, дьымырт, йурбут*, хак. *нымырт, ныбырт, мумурт*, төр. диал. *йумурт* «шомырт, миләш». Тат. сүзе чув. *çăмăрт, çĕмĕрт* < болг. **җŏмŏрт* сүзеннән килә; каз. *шомырт,* үзб. *шумурт* «шомырт; тикән, күгән» татарчадан булса кирәк, к. ш. ук себ. **чумурт** «кыргый чия» (Старчевский). Тат. телендә **шомырт – муел** агачының җимешен белдерә. Гомумән, бу сүзнең чыгышы бик үк ачык түгел, тик *йомырка* < *йомыртқы* (к.) белән чагыштырып була. Левитская 1963; Егоров 1964: 211; ЭСТЯ IV: 283–284; Федотов II: 109.

**ШОҢГЫ-У [шŏңғŏ-], шуңғы-у,** себ. (Тумашева 1992: 253) **шыңгы-у** «быстро и глубоко нырнуть; пикировать (о ловчих птицах)» ~ тат. диал., каз. (Будагов I: 648) *сунгу-, сүнгү-* «ловко нырять» (гом. кыпч. сүзе булса кирәк, тик сүзлекләрдә теркәлмәгән) ~ уйг. *шуңғу-,* алт. диал. *шуңу-* «түбәнгә ыргылу» ~ бур., монг. *шунга-*, яз. монг. *sungγu-* > эвенк. (ССТМЯ II: 426) *шиңу-* «чуму, шоңгу» һ.б. id. **Чоңгыл, Чум-у, Шоңкар.**

**ШОҢКАР** «кречет, ловчий сокол» < гом. кыпч., к. кырг., уйг., үзб. һ.б. *шуңқар, шумқар*, кырг. диал. *сумғур,* каз., к.-калп. *суңқар,* СС, төр. *songur,* бор. төрки (ДТС: 508, 525) *sonqur, šunqar* ~ яз. монг. *šingxur, šingxor*, хәз. монг. *сонгуур* ~ маньч. (ССТМЯ II: 477) *шоңкоро* «шоңкар, ак лачын», *онкон часха* (*часха* «кош») «лачын» һ.б. Бу сүзне *оңғы-у,* **шоңгы-у** (к.) сүзеннән ясалган дип уйларга мөмкин, ләкин кайбер фонетик вариантлар бу фаразга хилаф. Ихтимал ки, *шоңкар* бор. һинди *čanikart* «бер әкияти кош» сүзеннән киләдер. Өзён (Özön) сүзлегендә госм. *шүнкар* «шоңкар» фар. сүзе дип бирелә. Чаг. **Соңгыр.** Будагов I: 649; Ögel 1993: 355–356; Тимергалин: 561; Сафина 2006: 28–29.

**ШОПЫР-У[шŏпŏр-], шопырдат-у** «шумно расхлёбывать; шумно пить (чай)» ← *шопыр-шопыр* тәкълиди сүзеннән, чаг. ш. ук **шабыр-шобыр, шупыр-шопыр** һ.б.ш. халыкара киң таралган *шурп* (к. **Шәраб**) «тавышлап эчүгә тәкълит» сүзеннән (*шопыр-у* < **шорпыр-у*?).

**ШОРЫМ-БОРЫМ [шŏрŏм-бŏрŏм]** «разная мелочь (товары)» ~ рус. *шурум-бурум, шурубара, шуры-муры* «ыгы-зыгы» (к. Фасмер IV: 490). Тат. сүзен русчадан дип үк раслап булмый.

Дерив.: (К. Тинчурин) **шорым-борымчы.**

**ШӨГЕР [шөгөр]** диал. – вид рыбы, чаг. венг. *süger* «алабуга». **Шөгер –** Идел-Урал регионында берничә елга атамасы.

**ШӨГЫЛЬ [шөғөл]** «занятие» < гар. *шу‘л* id. ← *ш‘л* «яндыру (чүлмәкне), эшләү».

Дерив.: **шөгыльле, шөгыльсез; шөгыльлән-ү,** диал. **шөгыльчелек.**

**ШӨЙЛӘ**, диал. (ТТДС I: 515–516; БТДҺ: 393) **шилә** «всегда; всё еще; до сих пор, совсем» ~ нуг. *сӧле* «хәзер үк», төркм. *шейле*, төр. *şöyle* «шул рәвешчә, беркөе, шулай итеп» < *шу(л) хилә* (*хил* «төр, хәл»). К. Ашнин 1959: 145. Чаг. **Бөйлә.**

**Шөйлә** сүзе трбс. сөйләшендә киң кулланыла. Нишләп бу типик угыз сүзе Башкортстан үзәгенә эләккәндер инде.

**ШӨКӘТ:** к. диал. (ТТДС I: 523) **шөкәтсез** «безобразный; неприличного вида; нескладный» ~ башк. (БРҺ 1996: 771) *шөкәтһеҙ* id. ~ себ. (Тумашева 1992: 252) **шүләкәтсес** «ялкау; сәләтсез». Чаг. каз. *сӧкет, сӧлекет* «оят», кырг. *сӧлӧкӧт* «фигура, сын». Ачык түгел. Гар. *сāлукāт* «төзеклек» сүзеннәнме?

**ШӨКЕР [шөкөр]** «слава Богу; спасибо» < гар. *шукр* id. Шуннан фар. телендә *шукрана* > тат. **шөкерана** «шөкер итәрәк» сүзе килә.

Дерив.: **шөкерле, шөкерсез.**

**ШӨЛДЕР [шөлдөр],** диал. (ДС II: 227) **чөлдөр,** (ЗДС: 757) **чолдор** «колокольчик» – имитатив нигездән булса кирәк, чаг. **шелтер-шелтер < шылтыр-шылтыр** (к. **Шылт**).

**ШӨЛДИ** (Будагов I: 676) «кулик; ржанка». Ачык түгел.

**ШӨПШӘ**, диал. (ДС III: 195, ТТДС I: 519) **шыпша, шыпшы, шүпшә** «оса; шершень» < чув. *шăвăша, сăвăса, сыпса*, ш. ук (Сергеев 1971: 104–105) *сăвăслан, шăвăшлан, суслан* id. **сагызак** (к.) сүзе белән бердәй булса кирәк. Федотов II: 28 (бик накыс, хәтта чув. сүзләрен дә китереп бетермәгән).

**ШӨР: шөр җибәрү** «сильно испугаться, быть напуганным» к. **Шүрлә-ү.**

**ШӨРЕП [шөрөп]** «винт, шуруп» < рус. < ним. *Schraube* «борау, винт, шөреп» (тәүдә «көпшә»).

Дерив.: **шөрепле, шөрепсез; шөреплә-ү.**

**ШӨРЧЕК [шөрчөк]** (Троянскийдан башлап теркәлгән), **шерчек, ширчек, шырчык** «сверчок, домашний кузнечик» ~ чув. *шăрчăк,* мар. *шырчык, цырцык, цӗрцӗк* һ.б. рус. *сверчок* id. сүзеннән булса кирәк, чөнки русчада *сверчать* «чөрелдәү, чырылдау» фигыле дә бар. М. Федотов (II: 450) бу сүзне төрки параллельләр һәм яз. монг. *čarčaγaj* «чикерткә, саранча» сүзе белән чагыштыра.

**ШӨТИМ, шитәм, шөйтәм, шүтим, шитем диал.** (ТТДС I: 523; БТДҺ: 395) «залежь» < удм. *шӧтэм* «ташландык (җир)» (төп мәгъ. «уңдырышсыз»).

**ШӨҺРӘТ** «громкая слава» < гар. *шуһрат* id. ← *шһр* «билгеле, данлы булу».

Дерив.: **шөһрәтле, шөһрәтсез; шөһрәтлән-ү.**

**ШӨШЛЕ [шөшлө], чөшле** «коточик, кочедык (инструмент для плетения лаптей)» ~ чув. *шӗшле* id. < мар. (Упымарий: 195–196) *сузлӧ, шужлӧ, суслӧ,* (Саваткова: 208) *шужыль* > удм. (Насибуллин: 404) *с'ӳзлӗ* id. Безнеңчә, мар. *шуж* «тишекчә, колакча» сүзеннән. Федотов II: 458 (*шеш* < *шиш* сүзе белән бутый).

Идиома: **шөшле (балык)** ~ чув. *шӗшлӗ пулă* «чуртан» ~ удм. *с'ӱз'лькай* «чурагай». *Чөшле* < мар. *с'ӱзлӧ* сүзенең «penis» мәгъ. дә бар.

**ШУ I (бау-шу** сүзендә) «всякая верёвка, шнур и т.п.» < бор. төрки (ДТС: 151) *čoγ* «бау, бәйләвеч», *baγ-čoγ* «бау-шу».

**ШУ II (шау-шу** сүзендә) «шум» ~ каз., монг. *шуу* id. Күп төрки телләрдә бар булса кирәк, әмма сүзлекләргә кертелмичә кала. Гомумән, типологик тәкълиди сүз. Чаг. **Шау II.**

Дерив. **шула-у, шуылда-у;** (колак, йөрәк) **шу итү** «шомлану».

**ШУБЫР** (Ш. Мөдәррис) «волынка, пузырь (духовой музыкальный инструмент)» ~ чув. *шăпăр*, мар. (Иванов, Тужаров: 292; Саваткова: 214) *шӱвӱр, шӱвыр, шӗвӗр* id. фар. *шāйпӯр* (> аз. *шәйпур*) > гар. *шӱббӯр* «мөгез; быргы» сүзе белән чагыштырыла, к. Федотов II: 447. К. ш. ук алт., тув., бур. һ.б. *шоор* «шубыр, сыбызгы, курай». Бор. яһ. (Тәүратта искә алына) *шофар* «кучкар мөгезеннән эшләнгән быргы».

**ШУК** «бойкий, резвый; шаловливый, шустрый; весёлый» ~ чув. *шух, шухă,* мар. (Саваткова: 208) *шука, шукави* < гом. кыпч., к. кар., кырг., к.-калп., уйг. *шоқ, шох,* төркм. *шоох,* хак. *сох*, чыгт., бор. төрки *шох*, төр. *şuh* һ.б. id. < фар. *шōх̣, шӯх̣* id. (дип исәпләнә); шуның белән бергә якын-чиктәш мәгъ. сүзләр киң таралган: себ. (к. Тумашева 1992: 251) **шук** «ачучан», себ. тат., башк. (БТДҺ: 395) **шуқ** «карак» ~ алт., шор. *шоқ,* тув. *шоғ* «үткен, усал; усаллык» (к. Радлов IV: 1022), *шоқ-* «ироник мактау; явыз көлү»; нуг. *шоқ,* к.-балк. *шох* «якын дус»; монг. *шог* «шуклык» һ.б. Егоров 1964: 340; Räsänen 1969: 449; Федотов II: 463–464 (бу хезмәтләрдә өстәмә мәгълүматлар бирелә).

Дерив.: **шуклык; шуклан-у.**

**ШУЛ,** диал. (ТТДС I: 517; БТДҺ: 395) **шу,** (ТТДС I: 511; Тумашева 1992: 249; БТДҺ: 390) **шал** «тот, то; то-то; вот так, так-то» > мар., удм. *шол* < гом. кыпч. *шол* (> нуг., каз., к.-калп. *сол,* як. *соол*) < бор. төрки (ДТС: 373, 524) *šul* < *ošul, ušul* < *ušu ol.* К. ш. ук башк., тат. диал. (ТТДС I: 330) **ӧшӧ** < чыгт., кырг. *ошу, ошо*, бор. төрки (ДТС: 373) *oš, oši* «менә бу, менә шул».

**Шал** варианты миш. һәм себ. сөйләшләрендә таралган һәм бор. *уш ан* (к. иске тат., угыз һ.б. *ушандақ* «шундый, шулай итеп, шулай ук») сүзеннән килеп чыккан булса кирәк. Шулай ук бор. (к.-балк.) *ошул* > *ушал* (сингармоник чылбыр үзгәреше) буенча да килеп чыга ала.

**Шул** сүзе дә кыек килешләрдә **шун** суппletив нигезендә төрләнә: *шуның* < *шунның, шуны* < *шунны, шуңар* ~ *шуңа* < *шуңга, шуннан, шунда*, к. ш. ук *шундый* < *шундай, шунча*. Шулай итеп *шул* ~ *шал* вариантлары нигезендә *ул* ~ *ан* тәңгәллеге ята. Гомумән, **шул** сүзенең тәшкилләнешендә өч тамыр сүз – *у* < *о, уш* < *ош* һәм *ул* < *ол* катнашкан (к. Щербак 1987: 127–130). Радлов I: 1147–1152; Радлов III: 1102; Будагов I: 137; чув. *сав* «шул» тур. Федотов II: 78–79 (чув. сүзен төрки нигезләрдән аерырга тели шикелле, хәлбуки чув. *ҫав* сүзе *уша у* сүзеннән дип тә карарга мөмкин).

Дерив.: **шулай** (< *шу-лай* яисә *шул-лай* ~ *шун-лай*), **шунлык→шунлыктан** һ.б. К. **Шуңа, Шушы.**

**ШУЛГЫ** (ТТДС II: 376), **шулы** (ТТДС I: 517) «метла для подметания тока», по функции – «вид ночвы, желобка, применяемый на току» ~ чув. *шăлкă* id. ← *шăл-* «себерү, сөртү», к. **Шылан,** ш. ук **Сөлге.**

**Шулы** варианты болг. **шулһы* яңгырашыннан булса кирәк. Бор. аграр термин.

**ШУЛПА,** диал. (ЛС: 229 һ.б. чыганакларда) **шурпа, шурба** «суп; бульон» > мар. (Исанбаев 1978: 36) *шорва* «ширә» < гом. кыпч., уйг., чыгт., госм. һ.б. *чорба,* башк. (БҺҺ II: 304) *шулпа, шурпа, һурпа* id. < фар. *шōрбā* «тозлык»; чув. *шӧрпе, шӳрпе* «өйрә» < тат. булса кирәк. *Шорба* сүзен гарәпчәдән (*шрб* «эчемлек эчү») дигән караш та бар, һәрхәлдә төрки телләрдә киң таралган *ч-* варианты гар. сөйләшләрендә дә килеп чыга ала. Räsänen 1969: 111; Федотов II: 465; Хайрутдинова 1993: 70–71. Рус. *шорпа, шарпа, щерба* «уха, шулпа» тур. Аникин: 692.

Дерив.: **шулпалы, шулпасыз; шулпалык.**

**ШУҢА, шуңарга** «поэтому, оттого» ~ башк. *шуға* id. – асылда **шуңа күрә** тәгъбиреннән эллипсис; бу тәгъбирдәге **күрә** «өчен; тиң» мәгънәсендә аерым хәлдә дә кулланыла. **Шуңа** сүзе һәм бүтән *шун-* нигезеннән ясалган сүз-формалар уйг. телендә дә аеруча актив.

**Шуңа < шу-н-ға** булса кирәк, чаг. **шу-н-да, шу-н-дый (шу-н-дай), шу-н-нан (шу-н-дан), шу-н-ча,** ягъни монда *-н-* интертезик табигатькә ия. Шуның белән бергә, *шуңа* < *шун-га* < *шул-га* дип аңлату да гайре табигый түгел. К. **Шул.**

**ШУПЫР-ШОПЫР** – имитатив торопливой, шумной трапезе – шуннан **шупырда-у, шопырдау** һәм хәтта **шупыр-у, шопыр-у** «ашык-пошык сыек аш ашау».

**ШУР** (Тумашева 1992: 251; БТДҺ: 396) «соль из степных озёр; солонец, солончак; чахлый кустарник у солончаков», иск. (Гиганов) «рассол» < фар. *шōр* > кырг., монг. *шор* «тоз, тозлак» (> нуг., каз., к.-калп. *сор* > рус. диал. *сор* id.), рус. *шор* «Себер һәм Казакстан якларындагы чукрак күлләрдән алынган тоз». К. ш. ук тат. диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *шур* < үзб. *шўр* «тозлы, артыкча тозланган». Фасмер IV: 487; Аникин: 505–506 (бай әдәбият күрсәтелә). К. **Шүр.**

**ШУРА** «совет (как политическое понятие)» < гар. *шӯрā* id. Бу сүз XX г. башларында киң кулланылган (мәс., **Шуралар җөмһүрияте** «Советлар Союзы»).

**ШУ-У** «скользить, кататься на льду, снегу (на коньках, лыжах); ускользать» ~ башк. *шыў-,* чув. *шу-, шăв-* id. Бүтән төрки телләрдә юк шикелле (тув. *сой-, соғ-* «шуу», ләкин монда чагыштыру өчен фонетик кыенлыклар бар), шунлыктан *шу-* нигезе фин-угор телләреннән кергән дип уйлыйлар, к. Räsänen 1969: 449; Федотов II: 459.

Дерив.: **шуыл-у, шуыш-у** (→ **шуышма**), **шудыр-у, шудырт-у, шудыргыч, шудырма; шугалак, шугак** һ.б. К. **Шома.**

**ШУШЫ** «этот (самый), вот этот; данный» ~ нуг., каз. диал. *сосы* id. < гом. кыпч., уйг. һ.б. *шу ушу, шу уша* сүзеннән булса кирәк.

Дерив.: **шушылай, шушындый.**

**ШҮКЛӘ** (Будагов I: 675, шуннан – Тумашева 1992: 251; бу сүз асылда гарәпчә хәрәкәсез язылыштан алынган һәм дөресе **шәүкәлә** булырга тиеш) «мачта, баган» ~ башк. (БТДҺ: 401) *шәукәләй* «бәйләмле баш киеме, хатын-кыз башлыгы», кырг. *шөкүлө*, каз., к.-калп. *сәукеле* «яшь килен-нәрнең бик биек кәпәче» (ул елтыркалар, җилфердәкләр белән бизәлгән булган, к. Будагов I: 648). «Мачта» мәгъ. күчерелемә булса кирәк. Чыгышыясалышы бигүк ачык түгел. Ихтимал, фар.-таҗ. *шāһкāллā* «шаһ баш киеме, патшабикә бүреге», ш. ук «күп әләмле мачта» сүзеннәндер; чаг. **Кәләпүш.**

**ШҮЛГӘН, шүлегән** (башкорт хикәяте буенча В. Даль язылышында *шулюган*) «подводный дух; царь подводного мира» << кыт. *шуй-люң-хуан* «су

ләүләре (аждаһалары) императоры», к. **Шәүлегән**. К. ш. ук як. *сүлүгүн*, рус. диал. (> коми.) *шиликун, шуликон* һ.б. «су асты рухы (рухлары) – алар яңа ел төнендә бәкедән чыгалар, ди». К. Ахметьянов 1981: 58–59; Аникин: 700–701 (безнең этимологияне кире какмакчы булып, бүтән, шактый шикле фаразлар китерә). Алт. диал. (Баскаков 1965: 60) *шүлүгүн йайзан* – әкияттә тиле түрә.

**Шүлгән ~ шүлегән** сүзе башк. мифологиясендә һәм эпосында еш очрый, топонимиядә дә кулланышлы. Мәшһүр «Урал батыр» эпосында ул – Уралның энесе. Урал-тау рухы азакта үлә, ә **Шүлгән** суга чумып исән кала. Һәм хәзер **Шүлгән таш** мәгарәсендә (Көньяк Уралда) яши, ди.

**ШҮР** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) пересоленный; солёный» << фар. *шӯр* id. Диал. (Арсланов 1988: 100) **шор** «каклаган (ит)» сүзе дә шул ук сүздән булса кирәк. К. **Шур, Шүрә.**

**ШҮРӘ,** (Арсланов 1988: 100; Арсланов 1992: 156) **шөрә, шөйрө** «вобла (сушёная рыба)», (Тумашева 1992: 251) **шуру** id. – **шур//шүр** сүзе белән бәйле булса кирәк. Чаг. ш. ук **Сөйре.**

Тат.-башк. *Бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй* дигән мәкальдә **шүре** ошбу **шүрә** түгелме икән?

**ШҮРӘКӘ I** (ТТДС I: 523) «чурка» – рус сүзе белән баглы (ләкин әле рус теленнән дип үк әйтеп булмый). Чаг. ш. ук чув. *шүреке* «шына, өчпочмаклы агач кисәге».

**ШҮРӘКӘ II** (ТТДС I: 523) «вафельная ткань». Чаг. чув. *шүрке* ~ мар. *шӧргӓ* «элмәк, тозак» (шүрәкә тукыманы элмәкләп тукыйлар).

**ШҮРӘЛЕ** «леший» (впервые зафиксировано венгерским учёным Г. Балинтом) > чув. *шүреллӗ, шүрел*, мар., удм., кырг. *шурали* id. ~ каз. (Валиханов 1984: 210–215) *сорель* (русча язалышы, каз. *сөрәл* булса кирәк) «дала шүрәлесе» – тат. фольклорына аеруча хас рух. Бу сүз тур. күп кенә төрле фаразлар әйтелгән (шул хисаптан рус демонологиясендәге *щур, чур, чурилья* дигән рух белән баглау еш очрый).

Безнеңчә, *шүрәле* < *чүрәле аяк* «тискәрегә (артка) караган аяклы» тәгъбиреннән (фонетик җәһәттән дә үзгәргән) эллипсис. Хикмәт шунда, шүрәле шикелле кешегә охшаш, ләкин акылга сайрак җан иясе – аягы артка карау белән билгеле. Мар. һәм башк. сөйләшләрендәге *шурали ~ шүрәле* атка артка карап менеп утыра, чөнки аның аяк табаны артка караган; башкортларда җен-шайтаннарны *тирес (тискәре) аяҡ* дип тә атыйлар (к. БҺҺ II: 249 һ.б.); фар.-таҗ., аз., төр. *гули йабани* > *гүлибани* «чүл шүрәлесе» безнең шүрәлегә бик охшаш: ул төнлә кеше атына атланып йөри, кеше күрсә, көрәшергә яисә кытыклашырга тәкъдим итә һәм аның да аягы артка карый; осетин мифологиясендәге җен-шайтаннырның, урман-тау рухларының үкчәсе кирегә караган (к. МНМ I: 342, II: 266); ханты-манси әкиятләрендәге *менкв, менк-ики* дигән җеннең авызы һәм аяклары артка каерылган (гомумән бу җенне бер егет нәкъ Г. Тукай «Шүрәле»сендәге шикелле алдый: бармакларын бүрәнә ярыгына кыстырта һәм исемен *молтэли* «үткән яз» дип ялганлап китә һ.б., к. Мифы, предания и сказки хантов и манси, М., 1980: 432, 552). Аягы кирегә карау алтайлардагы *албыс,* якутлардагы *абаасы* дигән явыз рухлар өчен дә характерлы. Мәшһүр «*кар кешесе (йэти)»* тур. һәр җирдә диярлек «аның аяк табаны кирегә карый» дип сөйлиләр икән (к. Хиллари Э., Дойч Д. На холодных вершинах. М., 1983: 49–69) һ.б. Аягы артка караган пәри тур. Һиндстанда да сөйлиләр. Шундый пәри кызларының берсе, танылган инглиз язучысы Р. Киплинг «Ким» романында китергән мәгълүматларга караганда, *чурайль* – «бала тапканда үлгән хатын рухы». Аның да аяклары артка караган һәм ул да кешеләрне азаплаган. Ихтимал, бу бөтен Азиядә таралган бер мифологема атамасыдыр.

Чувашча *шүреке (шүрэкэ)* «вак җеннәрнең бер төре» сүзе **шүрәле** сүзенең нигезе *шүрә* < *чүрә* икәнлеген дәлилли кебек. Гомумән, *ч* > *ш* күчеше нуг., каз., к.-калп. телләренә хас: аларда *шөрэ* «чүрә, тискәре як», к. **Чүрә.** К. Әхмәтҗан Р. Тукай әкиятләрендә күчмә сюжетлар // КУ. № 8, 1995: 182–186; Тимергалин 562–567.

**ШҮРЕ** «цевка, шпулька», диал. (ТТДС I: 523) «катушка; папироса», (Радлов IV: 1110) «дудка; веретено», себ. (Тумашева 1992: 242) **цүр < чүр** «шпулька» ~ башк. (БТДҺ: 386) *шүре, сүре* «кәтүк, шүре; сүрү (?)», чув. *ҫӗр, ҫӗрӗ, шүрӗ* «шүре», удм. (КЭСК: 274) *серы,* коми. *сюри* id. – мәдәни сүз, к. монг. (Егоров 1964: 212) *шүүр* «шүре», рус. *чурук, чурюк, тюрик, тюрюк* «шүре кәтүк» (к. Аникин: 577–578, 678). Гадәттә тат. **шүре** сүзен болг. теленнән, хәтта чувашчадан (Федотов II: 112–113) дип күрсәтәләр, ләкин к. **Шүр-ү.**

**ШҮРЕК** (Будагов II: 675), **шүрүк** (Тумашева 1992: 252, Радловтан) «слива», **кара шүрек** «чернослив». Ачык түгел.

**ШҮРЛӘ-Ү,** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **шүберлә-ү, чүпрәлә-ү** «пугаться, трусить, побаиваться» ~ башк. *шөрлә-,* (БТДҺ: 395) *шөртлә-, шөрә-, шөр йөбәр-* ~ (Н. Исәнбәт, *Мырауҗан батыр*) *шүр җибәрү* id. ← *шүр, шүүр* < *шүбер* «кайбер хайваннар (мәс., сасы көзән) саклану максатларында чыгара торган бүленте – сасы исле матдә» сүзеннән, **шүбер, чүпрә** варианты **Чүпрә** (к.) сүзен хәтерләтә, бәлки шуның күч. мәгънәседер. Чаг. **Шөр.**

**ШҮРЛЕК** «полка, кухонный шкафчик, обычно прикреплённый к стене» ~ чув. *шүрлĕх* «өйнең алгы почмагындагы киштә» ← *шүр* < *шĕвĕр* «почмак; очлы» (к. **Сөйре**) сүзеннән шикелле (к. Ашмарин XVII: 262–263, 370). Ләкин тат. **шүрелек** «шүреләр куя торган киштә» сүзеннән дә була ала. К. ш. ук мар., удм. *шöрлĕк* «шүрлек» < тат. булса кирәк (к. Исанбаев 1978: 31). Чаг. каз. *сöре* < *шöре* «шүрлек».

**ШҮР-Ү** (миш.) «наматывать, перематывать» ~ башк. (БҺҺ II: 220–221) *сүр-* **< чүр-ү** id. Чаг. **Чүргә-ү** (к.), к.-балк. *чöрге-*, хак. *сöрге-* «урау, чуру». К. **Чур-у.**

**ШЫБЫН, шобын** «заострённая палка (для сдирания коры)» ~ чув. *шĕпĕл, шүпĕн,* иске чув. (Золотницкий) *шүбүн* id. < мар. (Упымарий: 282) *шувын, шывын, шугыньо* «каергы, рычаг» ~ коми. *сöвин* id. Федотов II: 458.

Чаг. ш. ук. рус. (Даль) *совень* «шыбын».

**ШЫБЫР, шыбырт** – имитатив внезапному падению воды сверху (с крыши, с одежды) ~ чув. *шăпăр, шăпăрт* id.

Дерив.: **шыбыр-шыбыр** (гом. кыпч., төркм., үзб. һ.б. параллельләре бар) – озак вакыт сибәләп кенә яуган яңгыр тавшы тур.; **шыбыр-шабыр; шыбырда-у.** К. **Шабыр.**

**ШЫГРЫМ, шыгырым** «как сельди в бочке – о заполненности чего-либо (комнаты – людьми и т.п.)» ~ чув. *шăкăрин* id. Тәкълиди тамырдан.

Дерив.: **шыгрымла-у,** сөйл. **шыгрымлы.**

**ШЫГЫР, шағыр** – имитатив скрипу; бүтән төрки телләрдә – мәс., чув. *шăкăр,* төркм. *шығыр* һ.б. – бүтән төр авазларны белдерә.

Дерив.: тат. һәм бүтән төрки телләрдә бик киң: **шыгыр-шыгыр, шыгыр-шагыр, шагыр-шыгыр, шыгырт** һ.б.; **шыгырда-у; шыгырдык** һ.б. (икенчел дериватлар да күп).

**ШЫЕК [шы̆йы̆к]** (ТТДС II: 377; БТДҺ: 397) «слабый, хилый», (трбс.) «чрезмерно гибкий (о прутьях и т.д.)» – безнеңчә, **сыек** (к.) сүзеннән (тат.-башк. – чув. *с ~ ш* линиясендә этимологик дублетлар очраштыргалый). Чаг. ш. ук башк. диал., каз. *шайық* «сыек».

**ШЫЕЛДА-У [шы̆йы̆лда-]** – имитатив нерезкому свисту, например – от быстро летящего предмета, крыльев быстро летящей птицы и т.п. ← сөйл. (сирәк очрый) **шый** ~ чув. *шăй-* сызгыруга тәкълит.

**ШЫЕР-У [шы̆йы̆р-],** диал. (ТТДС II: 273) **сыйыр-у** «сдирать, содрать» ~ чув. *шăйăр-* id. ~ алт., төр., каз. һ.б. *сыйыр-* id. **сыдыр-у** (к.) белән чагыштырыла, ләкин к. башк. (БТДҺ: 397) *шый-* «шылу, шуышып төшү яисә чыгу» – **шыйыр-ыу** шуның йөкл. юн. була ала. К. ш. ук башк., тат. **шыйыр-у, шыйырт-у** «кыйнау; бәреп яву (яңгыр тур.); орышу, җәзалау (камчы белән кыйнап)». Федотов II: 439.

**ШЫЙГАН,** (ТТДС II: 518, шул ук сөйләштән БТДҺ: 397) **шыған** «высокое безветвистое дерево; высокая безветвистая часть ствола дерева (растущего в густом лесу»)» ~ башк. *шыйҙа, шыйҙан, шыйҙақ, шыйлан, шыйтық,* ш. ук башк. (БТДҺ: 396–397) *шыбағай* «маш, чишта (сабантуйда менә торган багана)», *шыбай, шыбан* «шыйган», чаг. ш. ук (ТТДС I: 376–377; ТТДС II: 518) **шоған, шыгай, шыған** «гөлҗимеш». К. ш. ук (без теркәдек. – *Р.Ә.*) **шығай** «нәзек-озын һәм арык (кеше)».

Бу сүзләрнең уртак тамыр өлеше **шый (< шŏй?)* «бүрәнә, кәртәлек» булса кирәк; «гөлҗимеш» мәгъ. «киртә» мәгънәсеннән «үсеп чыккан» (чөнки гөлҗимеш «тере койма» итеп файдаланылган). Монголчадан булса кирәк, к. монг. *шугуй* < бор. монг. *siγui* «куе ылыслы урман, куе таллык» (*шуғуй* > *шөгый* > **шый* була ала). **Шихан** (к.) белән чагыштыру дөрес түгел.

**ШЫЙЛЫК, шейлек, шŏльŏк** (к. Матвеев 1910: 24; Баязитова 1997: 166–167) «жертва и жертвенник в честь полевого духа, полевое моление;

торжественное сборище на поле, в лесу (у крещёных татар)» ~ чув. (Сергеев 1971: 156–167) *шыльӑк, шилек, шилик, шилкӗ, ширлӗк, шырлӑк* «туй йолаларының берсе – ихатада, урамда уздырыла торган күп кешелек табын һәм шуның өчен махсус эшләнгән корылма – амфитеатр», мар. (Упымарий: 261; Саваткова: 278; Календарные праздники и обряды марийцев. Йошкар-Ола, 2003: 86–150) *шелык, шилык* «сөрән – *шүрем* бәйрәме һәм туй мәрасимнәре өчен махсус корылма; җиһаз корбанлыклар, потлар – иконалар кую өчен махсус өстәл». Идел-Урал регионында таралган бу дистинктив сүз, безнеңчә, бор. татар мәҗүсилегеннән калган. Элек ислам дине әһелләре шыйлык бәйрәменә каршы көрәш алып барганнар, к. Г. Утыз-Имәни, «*шулук* дигән бидгать» дип, җәмәгать тәртибендә мәчет алдында утырып ашауны искә ала. Шунлыктан бу сүз керәшеннәрдә генә сакланып калган. Шыйлык корып, кырда-яланда дөньяви мәҗлес ясауга Утыз-Имәнидән алты гасыр элек яшәгән Ә. Ясәви дә каршы булган, к. 124 хикмәттә:

*Даме тәзвир куеп, халкны юлдан ордың,*
*Шәйлыҡ кылып, рийа берлә дүкән кордың,*
*Гыйшрәт кылып, шәйтан берлә дәүран сөрдең,*
*Дидарына сәне нә дип рәва итсен.*

**Шыйлык** сүзе мәгънәсе белән чыгт. *шолен* ~ каз. *шуйлан* «хөкемдарларның һәм гамәлдарларның (гадәттә җомга көннәрендә) кара халыкка ачык һавада оештырган сый мәҗлесе» (к. Будагов I: 676), төр. *şölen*, бор. угыз., фар. (Гордлевский I: 215), гар. *šilan* «җиңү хөрмәтенә кабилә башлыклары оештырган тантаналы мәҗлес» (күп чыганакларда искә алына) сүзенә тәңгәл килә, ләкин морфологиясе буенча аермалылык *шилан* ~ *шуйлан* сүзен *шыйлык* ~ **шуйлык* белән тулысынча бер сүз дип карарга мөмкинлеге бирми. Özön: 789.

**Шыйлык ~ шырлык** сүзенә башк. *ширҙек (ширлек)* «туй табыны (һәм шуның өчен махсус келәм)» ~ монг. (к. А. Позднеев 1896: 14) *ширдыкъ* «начальниклар өчен сәке», хәз. монг. *ширдэг* (> тув. *ширтек*) «туй мәҗлесе өчен киез» сүзе дә бик охшаш.

**Шыйлык** сүзен **сыйлык** сүзеннән «үзгәргән» дип (Ф. Баязитова) яисә рус. *сенник* сүзенең чагылышы дип (к. Räsänen 1969: 445) аңлатулар бу сүзнең фонетик вариантларын да (бигрәк тә чув. *ширлӗк* ~ *шырлӑк*ны), мәгъ. үзенчәлекләрен дә (бигрәк тә аның мәҗүси-дини төсмерен) исәпкә алмыйлар. Шулай итеп **шыйлык** сүзе табышмаклы булып кала. Ихтимал, ул контаминация нәтиҗәседер. Денисов 1969: 145–150; Ахметьянов 1981: 100; Федотов II: 466.

**ШЫК I** (Радлов IV: 1041) «образ, вид» ~ төркм. (ТДГДС: 205) *шыҡ* id., башк. (БҺҺ II: 305) *шыҡла-* «тышлау, ышыклау». Чаг. себ. (Тумашева 1992: 252) **шыҡ** «изгеләр каберен караучы» < **шәех** (к.), к. к.-балк., кырг. *шыйыҡ, шайыҡ,* нуг. *ших, шиҡ* «изге, изгеләр кабере». Ихтимал, *шыҡ* гомумән бизәкле-бидәрле корылманы белдерә башлагандыр. К. ш. ук **шыксыз.**

**ШЫК II** – имитатив негромкому глуховатому стуку ~ чув. *шӑк* id.

Дерив.: **шык-шык; шыкы-шыкы; шыкыл-шыкыл; ышык** < төр. *ışık* «нур».

**ШЫКЫРДА-У** «стрекотать» к. **Шакыр.**

**ШЫЛАН** «болотный хвощ (из которого вяжут веники)» ~ мар. (Упымарий: 283) *шылан*, удм. *шилан, шълан* < чув. *шӑлан* id. ← *шӑл-* «себерү» ~ тат. *сөл-* id. булса кирәк.

**ШЫЛБЫР** «сильно размякший» ~ кр.-тат. *чылпыр, шылпыр* «пычранып җебегән, нык йомшарган һәм юеш», нуг. *шылбыр су* «шабыр су», *шылбырак* «былчырак», *шылбырама* «пычранып җебегән хәлдә(ге)» ~ каз. *сылбыр* «җебегән», *сылбыра-у* «шәлперәү, җебеп төшү (кеше тур.)» һ.б. 2007 елгы татарча-русча сүзлектә нәкъ шул каз. варианты (искәрмәсез-нисез) китерелгән; **сылбыра-у** «размякнуть, расписать; робеть». Тәкълиди *шылбыра-* id. кырг., кр.-тат. һ.б. телләрдә дә булгач, төп яңгыраш **шылбыр** дип алырга кирәктер. Бу тәкълиди сүзнең закончалыклы нигезе **шылп,* к. себ. тат. (ЗДС: 792) **шылбыҡ** «шапшак», иске «казанча» (Будагов I: 671) **шылбыҡ** «юньсез яшь егет» (*повеса* диелгән), кырг. *шылпылда-* «былчырактан бару» һ.б. *Шылбыр* яңгырашыннан **шыбыр** (*шыбыр су,* **шыбыр-шыбыр**) килеп чыккан бугай, к. **Шабыр** (тик **шалбыр** яңгырашын без бүтән төрки телләрдән тапмадык).

**ШЫЛТ: шылт итү** (Г. Тукай һ.б.) «внезапно зазвучать в тишине». Киң таралган тәкълиди тамыр, шуннан **шылтыр-шылтыр, шылтырау, шылтырт, шылтыр-шалтыр.** Параллельләре чув. телендә күп.

**ШЫЛ-У** «проскользнуть; улизнуть» ~ чув. *шӑл-* id. < *ышыл-* (к. **Ыш-у**) булса кирәк (чув. сүзенең «шуу, сөртелү» мәгъ. дә бар).

Дерив.: **шылдыр-у** «урыннан урынга күчерү (җиңел әйберләрне)», шуннан тат. **шылдырма** > чув. *шăлтăрма* «күчерелмәле блок».

**ШЫМ** «тишь, тишина» ~ алт. *сым, чым, шым,* хак. *сым* id. (бу телләрдә дә башлыча **шым булу** ~ *чым бол-, сым пол-* тәгъбире кулланыла). К. **Чым-чырык**.

**ШЫМАРТ-У, шымар-у** «прижать уши в гневе (о лошади)» ~ чув. диал. *шăмар-,* мар. (< тат., к. Исанбаев 1978: 19) *шымар-, шӹмӓр-* id. Федотов II: 442.

**ШЫМЧЫ** «шпион» > мар. *шымче* «вор-наводчик» ~ нуг., кар., ком. *сынчы,* уйг., үзб. *синчи* id., ш. ук «сынчы» сүзеннән булса кирәк. Сүзнең мәгънәсенә **шым** тәэсир иткән бугай.

**ШЫМЫТ-У, шымат-у** «погладить (по голове)» ~ мар. *шымат-* id.

**ШЫНА** (Тумашева 1992: 252; Будагов I: 681), диал. (Арсланов 1988: 92) **сына** «клин для раскалывания дров» < гом. кыпч., к. кырг. *шынаа,* уйг. *шина*, үзб., төркм. *шинә,* нуг., каз. *сына,* к.-калп. *сна*, хак. *сыын, сыынчах,* шор. *шыынҗақ,* алт. *шаа,* тув. *шаанак* ~ калм. *шаанцаг,* бур., монг. *шаантаг* < яз. монг. *širantuγ* «шына, чөй»; чаг. ш. ук фар. *шанэ* «шына; кикрик». Чыгышы ачык түгел.Номинханов 1975: 259.

**ШЫҢГЫР-ШЫҢГЫР** – имитатив звону сухихи веток ~ чув. *шăнкăр* «кыңгыраулар чыңлавына тәкълит». К. **Чыңгыр.** Федотов II: 445

Дерив.: (Г. Толымбай хикәяләрендә) **шыңгырдак** ~ себ. (Тумашева 1992: 252) **шыңгыртак, шыңгырцак** id.; **шыңгырда-у** (*шыңгырдап торган бүрәнәләр*).

**ШЫҢШЫ-У** «хныкать; тихо визжать, скулить» ~ к.-балк. *цыңцы-, сынсы-*, як. *сыҥсый-* id., нуг. *шыңшы-* < *чыңчы-* «чеңләү». Чаг. ш. ук **Яңша-у.**

**ШЫПАҢ, шыбаң** (Тумашева 1992: 252), иске тат. (Казан) **шыфаң** «пустомеля, болтун» ~ үзб. дерив. *шипаңда-* «юкны сөйләү». Чаг. фар. *сӯкбāң, сӯкбāнг* «юкка тавыш куптару». Räsänen 1969: 446.

**ШЫР I** «тюк (чая)» < рус. *шира, ширья* «чәй такталары төрелә торган махсус тире» < монг. *шир, шири* «тире, күн», к. Аникин: 702 (тат. сүзен искә алмый). К. ш. ук мар. (Упымарий: 239) *ширэ* «чәй төргәге».

**ШЫР II** «голо; совершенно», чаг. **Шәрә**. К. **Шырсыйрак.**

**ШЫР III: шыр ит-ү, шыр-шыр, шырла-у, шырыл-шырыл, шырылда-у** һ.б. – подражание журчанию и т.п. – гом. кыпч., төр. *şır, şırıl-şırıl, şırılda-* һ.б., к. Dobr. III: 243. Гомумән, киң мәгънәле.

**ШЫРАЗ** (Р. Рәхимова), диал. (ТТДС I: 516) **ширас** «петелька для пуговиц», (Троянский I: 462) **шыраш** «нашивка над фалдами» ~ чув. *шăраç* «билбауга тагылган чук, итәк вә җиң очларына тегелгән челтәр яисә чигелгән бизәк» ~ кырг. *чыраз* «чигеш; аркылы-торкылы билгеләр (гадәттә якада)», үзб. *шираз* «изү бавы (чуклы киндерә)» < иске фар. (Очерки истории культуры средневекового Ирана: 214) *тираз, тыраз* «киемдәге кайма, бизәкле җиңсә», ш. ук «үзендә бизәкле тукымалар эшләнә торган шәһәр атамасы». Чаг. башк. (БҺҺ II: 369) *тыраш үләне* «күк сөтлегән». К. **Сыраҗ.**

**ШЫРГЫЯ [шы̆рғы̆йа]** (трбс.; БТДһ: 399) «шумная кокетка; неприлично озорная, бедовая женщина» ~ кырг. *шуркуя* id., каз. (Катаринский), к.-калп. *сырғыйа* «жулик; хәйләкәр» – фар. сүзе булса кирәк, к. фар. *шӯргӯйā* «күп һәм кискен сүзле, телмәкәр» (*шӯр* «тозлы, тозланган», *гӯйā* «сөйләүче; сүзчән», чаг. *тозлап-борычлап сүгү*). Себер рус сөйләшләрендә *сыркъя* «шүрәле, кыргый кеше» (себ. татарчасыннан булса кирәк), к. Крик мамонта. М., 1991: 189.

**ШЫРДАН** (ТТДС I: 519; Хайрутдинова 1993: 107) «вид колбасы; ливерная колбаса» ~ чув. *шăртан*, мар. *шырдан, шыртан* id. < гом. кыпч., к. кар. *шырдан, ширдан, шердян* «ашказаны; эчәк», ком. *ширдан*, үзб. *ширдон* «карта», төр. (Радлов IV: 1) *шірдӓн* «сарык тәкәсенең эч мае», *şirden* «кече ашказаны; кырыккарта» ~ аз. (АДДЛ: 449) *чортан*, көрд. *çortan*, фар. *чортан, чордан* «шырдан» – төр. теленнән, төр. сүзе үзе фар. *ширдан, ширдаң* «сөт савыты» (*шӣр* «сөт», *дāн* «савыт, сыешлык») сүзеннән үзгәреп килеп чыккан: махсус эшкәртелгән бавырдан сөт савыты ясаганнар.

Кр.-тат. (Dobr. III: 243) *şırdan* «күшәүче хайваннар ашказанының дүртенче бүлеге» дип аңлатыла.

**ШЫРЛЫК** «чащоба, дебри» **шарлык** (к. **Шар IV**) сүзенең фонетик варианты шикелле, ләкин бүтәнчә дә тәшкилләнә ала, к. себ. (Тумашева 1992: 252) **шығыр** «яшь чыршылык» (шуннан *шығырлық > шырлық* булуы ихтимал). Чаг. ш. ук чув. *çăра* «куе, еш» → *çăралăх* «ешлык, куелык, шырлык»; алт. *дьыраа* «куаклар» → *дьыраалық* «куаклык»; тув. *шыргай* «шырлык».

**ШЫРПЫ** «спичка, спички», диал. (ДС III: 187) **чырпы**, (ДС I: 231–232) **шырбы, шырпық** «заноза; деревянный гвоздик; спичка, спички» > чув. *шăрпăк,* удм. *шырпы,* мар. (Саваткова: 218 һ.б.) *шӹрпӹ, шырпӹ* id. ~ себ. (Тумашева 1992: 244–245) **цырбы**, башк. (БТДҺ: 206) *сырпы* «вак чыбык-чабык, нәнечкеле чыбыклар», (ЗДС: 720) «колга, чош, жирда» < куман. (Радлов IV: 206) *цырпы*, к.-балк. *цырпы, чырпы* id., кар. *чырпы,* төр. *çırpı* «вак куаклык; арча, чыршы; чүп-чар; сызгыч, кисү сызыгы», чыгт., көрд. *чирби, чирпи* «коры ботакчык, тикән» ~ кырг. *чырпық* id. Нуг., каз., к.-калп. *шырпы* «шырпы, чыбыкча» татарчадан булса кирәк (үзләренчә **сырпы* булыр иде).

**Шырпы <** *чырпы* < *чырпық,* безнеңчә, *чырпы-, чарпы-* «вак өлтеләргә бүлгәләнү, чәрдәкләнү» фигыленнән, фигыль исә *чарп* тәкълиди сүзеннән килә. Чаг. диал. **чырпы-чарпы** «төрле шырпылар». К. **Чарпы-у.** Räsänen 1969: 119; Федотов II: 449.

Дерив.: **шырпылы** («чәнечкеле, кылчыклы» мәгъ. бар), **шырпысыз; шырпыла-у** (иеләгәндә тирене төрле почмакларына чөйчек, шырпы кагып, тарттырып кую).

**ШЫРСЫЙРАК** (Ф. Хөсни) «босяк; голь перекатная» < *шыр сыйрак* (к. **Шыр I**); чаг. аз. *балдыры ачығ* – «балтыры ачык» – «сукбай, үтә ярлы кеше».

**ШЫРТ I –** имитатив глуховатому треску (слабому в отличие от **шарт**, к.).

Дерив.: **шырт-шырт; шыртла-у.**

**ШЫРТ II** (Остроумов 1872: 130), **шыт** (М. Гали), **ширт** (Тумашева 1992: 251) «щетина; резец плуга», диал. (ТТДС I: 519) «чесалка кудели; гребень с крупными зубьями» ~ чув. *шăрт*, мар. (Упымарий: 286) *шырт*, удм. *шырыт* id. < бор. кыпч. (Курышжанов), бор. төрки (ДТС: 505) *sïrt, sïrït* «дуңгыз шырты», чаг. **Сырт. Сырт** дип (каз. һ.б.) пычакның төйтәсен һәм шуннан очын атыйлар; дуңгызның арка сызыгы пычак төйтәсенә охшатылган һәм дуңгыз сыртында үскән озын кыллар (алар элек киң кулланылган һәм хәтта сәүдә шәе булып исәпләнгән) – *сырт кылы* → **сырт//шырт.** *С > ш* күчеше нигезендә **шырт** сүзен болг. теленнән дип карыйлар, к. Berta: 14–19. К. **Шыт.** Федотов II: 449–450.

**ШЫТ: шыт кебек чыгу** (ТТДС I: 519–520) «всходить ровно (о всходах)» < *шырт кебек.* К. **Шырт II.**

**ШЫТ-У,** диал. (ДС II: 219, 224, 232) **чыт-у, шырт-у** «прорастать; всходить (о хлебах)» ~ башк. (БТДҺ: 400) *шырт-* «борынлау» > мар., удм. диал. *шыт-*, мар. Т. (Саваткова: 219) *шӹт-* id. Идел-Урал дистинктив сүзе, болг. теленнән булса кирәк, к. чув. *шăт-* «тишелү» (**тишелү** сүзенең «шыту» мәгъ. тат. телендә дә киң билгеле).

Дерив.: **шыттыр-у** (бу сүзнең «юкны сөйләү, ялганлау» мәгъ. дә бар); **шытым**; мар. телендәге *шытык, шӹтӹк* «шытым» сүзе дә иске тат. теленнән шикелле, к. ш. ук чув. *шăтăк* «тишек» ~ тат. диал. (ТТДС I: 520) **шытық** «әкәләдән шытып чыккан имәнчекләр». Гомумән, **шыт-у** сүзенең әзәл мәгънәсе «тишелү, тишү» икәнлеге бәхәссез дияргә була һәм В.Г. Егоровның (1964: 336) **шыт-у**ны аз. һ.б. **чатла-у** (к. **Чикләвек**) «ярылып чыгу, чытлау» сүзе белән чагыштыруы юкка түгел. К. **Черт, Шырт II.**

**ШЫТЫР; шытыр-шытыр, шытыр-шатыр** – подражание лёгкому треску, хрусту – гом. кыпч. тәкълиди сүзе: кр.-тат., кырг., к.-балк. *шытыр* id. һ.б. Күп кенә дериватлар: **шытырт; шытырда-у; шытырдык** һ.б.

**ШЫТЫРНАК** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «частокол» ~ чув. *шăтăрнак* id. Чаг. тат. диал. (Арсланов 1988: 100) **шытырык** (рус. «боковые перила, идущие от матицы в крыше землянки» диелгән), башк. (БҺҺ II: 155) *сатраш* «шытырнак». **Чатыр** (к.) сүзе белән баглы булса кирәк, к. фар. *čādornāk* «чатырлы, чатырсыман».

# Ы

**Ы [ы̆]** авазы тат. телендә бор. төрки **ы** (*ı, ï, y* дип тә билгеләнә) авазыннан килә; кайбер очракларда бу аваз *-а-* белән чиратлаша. Кайбер очракларда *ы* > *ŏ* күзәтелә.

**ЫГЫ-ЗЫГЫ** «шум-гам, беготня, переполох» ~ нуг. *ыгы-зыгы*, каз. *шығы-жығы,* к.-калп. *ығын-жығын,* тув. *ыы-сыы* id., аглау-сыктау дигәннән: *ыгы* ~ *агы* «елау (аглау, егълау) күренеше», *сыгы* «сыктау, үлгәннең фазыйләтләрен искә төшереп такмаклау». К. үзб. *йиғи-сиғи* «елау-сыктау». *С* > *з* көчеше тат. телендә күп кенә сүзләрдә очрый (к. **З** мәкаләсен). **Сығы ~ сыwы** > чув. *сăвă* «җыр» ~ һунн, угыз *сагы* «үлгәннәрне мактап җырлау» тур. к. Ахметьянов 1981: 108. *Ыгы* тур. ЭСТЯ I: 79.

**ЫГЫШ** (ТТДС II: 382) «крик, шум, скандал» к. түбәндәгене.

**ЫГЫШ-У** (ТТДС II: 382), **ығыш-ыу, ығын-ыу** (БТДҺ: 402) «настаивать, упорствовать; медлить; копошиться» – күренүенчә, бу фигыльләрнең төп нигезе **ық-у [ыгыу]** – ихтимал, **ык** (к. **Ык-у**) «агым яисә җил уңаена китү», ш. ук «агымга, җилгә каршы тору» (бер сүзнең поляр капма-каршы мәгънәләре булу төрки телләрдә очрый). Шул ук вакытта монда ике тамыр фигыль дә булырга мөмкин. Һәрхәлдә башк. *ығырла-у, ығышла-у* «әкренләү, җайлау» *ык-* «пассив кылану» мәгънәсендә күрсәтәләр.

Әйтергә кирәк, китерелгән тат. **ыгыш, ыгыш-у** сүзләрендә башк. теленнән алынма күрергә мөмкин, чөнки алар Көнч. Башкортстанда, «чи башкортлар» яшәгән төбәкләрдә теркәлгәннәр.

**ЫЕК [ы̆йы̆ķ]** «старая, изможденная лошадь», себ. (Тумашева 1992: 225) **уйук, ыйук** «жертвенная лошадь – лошадь (определённой масти), которую отпускают на волю в жертву божествам» < гом. кыпч. *ыйык,* башк. *ыйык, ийек* id., к. хәз. Төньяк Башкортстанда (Р. Нуретдинов мәгълүматлары) **ыйык җирләр** «махсус рәвештә сөрелми-чабылмый торган мәйданнар» ~ кырг. *ыйык* «изге», к.-балк. *ыйык көн* (гомумән «атна» мәгъ. дә бар), алт. *ийик, ыйык* «ыек»; *ыйык ту* «изге тау» (андый таулар тур махсус к. Алтай кеп-куучындар: 367), хак. *изик, ызык*, сары уйг. *йузуқ, йүзүк* «тәңрегә багышланган, изге» < бор. төрки (ДТС: 217–218) *ïduq, ïδuq* «изге корбанлык» ~ тув., уйг. *ыдық, ыдуқ,* як. *итик, ытық* «ыек; корбан, корбанлык», бор. төрки *ыдуқ* «тәңреләр җибәргән» (*ыдуқ қут* «тәңре җибәргән кот» – уйгурларда монарх титулы) һ.б. бор. төрки *ыд-, ыҙ-* «тарату; җибәрү; азат итү» сүзеннән, к. Rachmati-Arat R. Der Herrscher Titel Iduq-qut // UAJ. T. 35; ЭСТЯ I: 649–650 (тат. диал., башк. *ыйык* искә алынмый).

Күрәсең, *ый-//ыҙ-//ыд-* тамырының *ыр-* варианты да булган, к. чув. *йĕрĕх* «корбан сораучы рух; нәсел-ыру химаячесе; кот» < **йырық* ~ **ырық* (чаг. тат. **ырык:** *ырыкныкы ырыкка, шырыкныкы шырыкка (китә)* мәкалендә «әрәмгә киткән мөлкәт»). Мөселманлык көчәйгәч, **ыйык** төшенчәсе һәм шуның белән баглы йолалар онытылган, ләкин аларның эзләре сакланган, к. Башкортстанда берничә **Ийек** елгасы; куман. *йых өв* ~ кар. *йэг үв* «изге өй, чиркәү, синагога, мәчет». **Ыек** елга-тауларда балык тотмаганнар, ау ауламаганнар, тик корбан бәйрәмнәрен генә уздырганнар һ.б. (к. Мурзаев 1977: 49–50); Якутиядәге берничә *Ытык күөл* ~ Кыргызстандагы *Ысык (< Ызык) көл* (русча *Иссык-Куль*) шундыйлардан. Татар-башкортлардагы зиратларда печән чабарга, агач кисәргә һ.б. ярамау йоласы да элекке «ыек җирләр» калдыру гадәтенең чагылышлары булса кирәк. Räsänen 1969: 164; ЭСТЯ I: 649; Гумилев 1993: 374; Федотов I: 199–200; Инан: 119–123. **Ыек ат** төсмере һәр кабиләдә үзенчә булган, к. Бутанаев 1990: 136. **Ыек ат** җибәрү бор. һинд кабиләләрендә дә, шулай ук гарәпләрдә дә булган, к. Бируни 1995: 147. Коръәндә Салих пәйгамбәрнең сәмуд кавеменә ыек дөя бүләк итүе һәм сәмудиләрнең ул дөяне үтерүе, шуның өчен бу кавемнең һәлак ителүе хакында әйтелә (гар. *ыек* диелми, әлбәттә). Малов: 139 (сары уйг. *jӱзук ат* тур.); МНМ I: 598–599.

**ЫЖ-Ж –** имитатив шуму ветра, метели, бури. Дерив.: **ыжылда-у,** к. **Ыжгыр-у, Ыжла-у.**

**ЫЖГЫР-У** «неистово шуметь, выть (о ветре); грозно, исступлённо кричать» – **ыж** тәкълиди сүзеннән *-гыр* кушымчасы ярдәмендә ясалган, к. **Ажгыр-у.**

**ЫЖЛА-У** сөйл. «реагировать, действовать, как требуют обстоятельства» – «ничектер реакция бирү, хәлне исәпкә алу» – мондагы **ыж** тамырына охшаш сүзләр башк. сөйләшләрендә күп кенә (к. БТДҺ: 403), мәс., **ыж-ыу** «коткы салу».

**ЫЗА** «досада; стыд» ~ нуг., каз., к.-калп., кырг. *ыза* id. К. **Иза.** Будагов I: 192 (гарәпчәдән ди).

**ЫЗАН** (Троянский I: 31) «межа; межрядье, поле между двумя межами» ~ башк. (БҺҺ II: 308) *ыҙан,* нуг., кр.-тат., төркм. диал. (ТДГДС: 206) *ызан* «басу», каз. (ҚТДС: 412) *ыза* «сазламык җирдә ике дренаж канал арасы», тат. диал. (Сембер, к. Радлов I: 560) **азан** «межа» (бәлки язылышы дөрес түгелдер). Бу сүзне Г. Рамстедт (1949: 71) чув. *йăран* ~ кор. *iraŋ* «ызан, басу чите, җир үлчәме» белән чагыштыра, Н.Н. Поппе дә шуны кабатлый; М.Р. Федотов өстәвенә маньч., нан. *ирун, йурун* «түтәл, ызан» сүзен дә китерә (Федотов II: 185). Бу фаразларны юкка чыгармастан, шуны әйтергә кирәк; **ызан** сүзе **Ыз-у** (к.) сүзеннән дә килеп чыга ала. Ахметьянов 1989: 64–65.

Дерив.: **ызанлы, ызансыз** (XX г. 30 нчы елларында *ызансыз кырлар* тур. күп җырлана иде).

**ЫЗБА** «изба, дом (небольшой)» – рус теленнән бор. заманнарда (XIII г. кадәр) алынган, к. куман. *изба* «ызба». Рус. сүзе тур. төрле фикерләр бар, к. Фасмер II: 120–121. Һәвәскәр тарихчы һәм телче Ә. Булатов иске төрек сүзлекләрендә фар. *избә* «көпкә (зимлянке)» сүзе бар дип сөйли иде.

Дерив.: **ызбалы, ызбасыз.**

**ЫЗБЫРУЙ** (гадәттә **збруй** дип кыскартып языла) «сбруя» < рус. *сбруя, збруй* id. Рус сүзенең чыгышы-ясалышы ачык түгел, ихтимал, пол. *zbroja* «корал-ярак, шайман» сүзеннәндер, ди М. Фасмер (I: 518). Чаг. башк. (БТДҺ: 403) *ызбруй, ызбурый* «киндер сугу кирәк-ярагы, киндер урдыны» << фар. диал. *äзбäрāйū* «башлангыч кирәк-ярак» > төркм. *эзбер* «җигемлек». Шулай итеп, **ызбыруй** – төрки телләр аша кергән фар. сүзе булырга мөмкин.

Рус телендә ат җигүгә баглы күп кенә сүзләрнең төрки телләрдән алынганлыгы – мәс., *дуга, лошадь*, *телега*, *чекушка* һ.б. – билгеле һәм шул факт яктылыгында *сбруя* сүзенең дә нииндидер төрки телдән килүе гаҗәп булмас.

**ЫЗГЫР: ызгыр җил** «пронизывающий холодный ветер» ~ башк. *ызгар ~ ызғыр,* кырг. *ызғаар, ызғар* «ызгыр (җил); явыз, каһәрле» башк. (БТДҺ: 403) *ыжғыр, ыжғырақ, ызғырық* «ызгыр» ← ***ызгыр-у**, к. уйг. *изғир-* «үзәккә үтү (суык, җил тур.)», үзб. *изғир* «ызгыр» һ.б. Чаг. **ыжгыр-у, ызгыш-у** һ.б. Ком., каз., к.-калп., төркм., үзб. *ызғар-, изғар-* «су күтәрелү, ташу» икенче бер сүз булса кирәк, тик Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 648) бу сүзне **ызгыр** белән бергә карый (һәм фигыль коррелянтын күрсәтми). К. түбәндәгеләрне.

**ЫЗГЫ-У** «сильно беспокоиться; беситься, нервничать до обессиливания» < гом. кыпч., к. башк. (БТДҺ: 403) *ызғы-* id., нуг., к.-калп., кырг. *ызгы-* «мыжгу, мыж килү», каз. *ызғы-*, үзб. *изғи-* «өерелү; әйләнү (көтү тур.)» һ.б. ← *ыз, ыж* тәкълиди сүз, шуннан ук к. **Ызгыр, Ызгыш.**

**Ызғы-у** фигыленең үзеннән аның дериватлары – **ызгыт-у** (Вәлиди I: 148; ТТДС I: 525; БТДҺ: 403) һәм (башк.) *ызғыр-у* киңрәк кулланыла. **Ызгы-** нигезе бор. заманда ук фин-угор телләренә кергән, к. мар. *ызгэ-*, коми. *ызгы-* «нык тынычсызлану; шаулау», венг. *izgat-* «ызгыштыру». Диал. (ЗДС: 506) **осқот-у, ысқыт-у, ысқырт-у** «азындыру» – бүтән сүздер.

**ЫЗГЫШ** «ссора с бранью» ← **ызғы-у**. К. иске тат. (Будагов I: 36) *азгуш-*, төр. *azgaş-*, каз. *ызғуш-* һ.б. «ызгышу». Чаг. ш. ук чыгт., төр. (Боровков 1963: 42) *ызғаш* «азыну; ызгыш». К. түбендәгене.

**ЫЗМА** «подпруга; петелька; крепление частей сбруи зигзагообразным проведением шнура; прошнуровка», башк. (чынлыкта – тат., к. БТДҺ: 403) **ызма, ызна** «зигзагообразная вышивка» > чув. *ăсма*, (Сергеев 1968: 13) *ăçма* «зигзаглап тегү» > удм. *исма, изма* «бизәк шнур, зигзаглы чигү» < гом. кыпч. *ызма*, к. каз. *ызба* «тукымадан тегелгән бау», уйг. *измә* «элмәк, ләмкә» ← **ыз-у.**

**ЫЗНАЙ** (ЗДС: 796; Зимасов: 121), **iznaj** (Balint: 21) «всегда» ~ мар. удм. *ызнай*, чув. (Сергеев 1968: 13) *ăснай* id., ш. ук «һаман саен» гадәттә рус. «знай (себе)» дип аңлатыла. Хәтта әкият герое **Ызнай батыр** исемен *Знай батыр* дип язгалыйлар. Ләкин Төньяк Кавказ, Дагстан халыкларында аналогик герой исемен *Эзнай (батыр)* дип язалар һәм рус сүзеннән дип аңлатмыйлар. Безнеңчә, *ызнай* сүзе төр. *ez navi* < фарсы *äз нowи* «яңадан; торып-торып» сүзеннән булуы бик ихтимал.

**ЫЗНАЧ** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «старший брат мужа или жены» < рус. диал. *снай, снач* id., бу сүз

исә үз чиратында тат. диал. (миш.) *йезнәй* «җизни» сүзеннән.

**ЫЗ-У** (Вәлиди I: 149; ДС II: 53), диал. **өз-ү** «проводить борозду; пахать» ~ каз. *ыз-* id., ш. ук «ике-өч җөй тегеп, чүпрәк бау ясау» бор. сүз, чаг. **Изү, Ызма.** Чаг. ш. ук бор. чыгт. (Боровков 1963: 123) *ідлӓ-* «өстәмә (аралык) буразна сызу, аралау», димәк *иδ ~ ыδ* исем сүз дә булган? Гомумән, бигүк ачык түгел.

**Из//ыз** тамырын тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 323–324, 328) *иру, ирун* «түтәл, буразна» һәм, арытабан, *ир-* «сөйрәү, сөйрәтү» тамыры белән чагыштырырга мөмкин (к. **Ызан**). ЗДСта (: 677) **уз-у, уза-у** вариантлары китерелә, ләкин алар шикле.

**ЫК I** (Тумашева 1992: 253; Арсланов 1988: 157) «течение; движение сплошной массы», «укрытие; направление по ветру», диал. (Арсланов 1976: 66) «согласие, благосклонное внимание» ~ башк. (БҺҺ II: 309) *ыҡ* «уңай», башк. (БТДҺ: 404), нуг., каз., кырг. *ык* «җил уңае; ышык», төркм. id., ш. ук «сарык көтүе». К. ш. ук диал. (ТТДС I: 525) **ыкка килмәү** «килешмәү», (Зимасов: 121) **ыкка килү** «килешү, күнү». К. **Ык II, Ык-у, Ычкын-у.**

Дерив.: **ыклы** «агымлы», диал. (ТТДС II: 383) **ыкла-у** «ышыклау».

**ЫК II** – река Ик, в Сибири – река Обь; на Южном Урале и Приуралье имеется ещё несколько небольших рек с тем же названием. Бу сүзнең «кугын, бүрәнә агызу» мәгънәсеннән (к. югарыда) килеп чыгуы бик ихтимал.

**ЫК-МЫК, ыкы-мыкы** – имитатив невнятному затруднительному ответу, звукам *ы-ы, э-э,* издаваемым при этом ~ удм. *ык-мык*, чув. (Ашмарин III: 36) *ӑк-мӑк* ~ нуг. *ык-мык,* төр. *ık, ıkıl-ıkıl* id. Чаг. рус. *икать, заикаться* һ.б. Сүзнең *-мык* өлеше төрки телләргә хас *м-* авазы өстәп сүзгә пардаш ясаудан килә (чаг. *аз-маз, тиле-миле*).

Дерив.: **ыкылда-у, ыкылдау-мыкылдау** һ.б.

**ЫКТЫМАТ** «собранный, подтянутый, в меру» < гар. *иʻтимāд* «ышаныч; ышанычлы». Башк. *ыҡсымат* варианты *ыҡсым* «ыкчам» сүзе тәэсирендә барлыкка килгән. Хәлбуки *ыкчам* – бөтенләй үзгә сүз.

**ЫКТЫРМА** (БТДҺ: 404) «суслон, шалаш из снопов» < гом. кыпч., к. каз., кырг. *ыктырма,* кар., к.-балк. *ыхтырма* «җилдән саклану өчен куыш, шалаш, вакытлы абзар һ.б.ш» ← *ыктыр-* «җилдән саклау» ← *ык-* (к. **Ык-у**). **Ыктырма** даими юнәлешле җил (пассат) булган чагында (яисә шундый җилле урында) җил «шуып» кына үтеп китәрлек итеп ясала. К. ш. ук **Ытырга-у**. К. түбәндәгене.

**ЫК-У** (Будагов I: 70; Тумашева 1992: 253) «плыть по течению, идти по ветру» ~ башк. (БТДҺ: 402) *ыгыу (ыҡ-)* id., ш. ук «ялкаулану; сыену; агым, җил көченнән кыйшаю» – **Ык I** сүзенең фигыль коррелянты. К. **Ылык-у, Ычкын-у**. К. югарыдагыны.

**ЫКЧАМ,** диал. **ыкцам** «аккуратный, собранный; подтянутый» ~ башк. *ыҡсам, ыҡсым,* кырг. *ыкчам*, нуг., каз. *ыкшам*, төркм. *ыкҗам*, үзб. *ихчам*, уйг. *ихчәм* «ыкчам; уңайлы», кырг. ш. ук «җитез, өлгер» < гар. *ихҗāм* «пөхтәлек, җыйнаклык» ← *хҗм* «эчкә алу; төренү, яшерү» тамырыннан, Шуннан ук иске тат. **хәҗем** «сыешлык, савыт, капчык күләме», **хәҗем итү** «эченә (эчеңә) сыйдыру». Кырг. телендә *ык* – «әзер, тайяр; елгыр», *ыкчый-* «әзер тору».

**ЫЛАК, олак** «козлёнок (особенно диких коз, антилопы)» ~ башк. (БҺҺ II: 309; БҺҺ III: 214) *ылаҡ, лаҡ* «язын туган кәҗә яки сарык бәрәне» < гом. кыпч. *ылак* < гом. төрки (ЭСТЯ I: 412) *оглак, огул-ак* «малай; бәти» сүзеннән, к. алт. *уулак,* хак. *оолак* «малай» һ.б. Махсус әдәбият: Талипов Т.Г. К вопросу о возможной интерпретации фонетической модификации слова *oɣlaq ~ laq* «козлёнок» // Языки народов Сибири. Кемерово, 1980: 96–108. К. түбәндәгене.

**ЫЛАНШАК** (ЗДС: 797) «детвора, детишки» < иске тат. *углан-ушак* ~ төр. *oğlan-uşak* «угланнар һәм ушаклар (ваклар)», парлы сүз. Моннан тыш, иске тат. **угланчак** < гом. төрки *огланчак* «кечкенә угыл» сүзе дә бар, шуннан, безнеңчә, рус. *лончак* «бераз үскән (бер яшьлек) колын» сүзе килеп чыккан. Будагов I: 141. К. **Олан, Углан, Угыл, Ул, Ушак II.**

**ЫЛАШ** (ЗДС: 797) «сооружение на столбах и с крышей для сушения курута» ~ башк. *ылаш* id. ~ чув. *лаҫб лаҫӑ, ӑлаҫ* id. гадәттә **алачык** сүзе белән чагыштырыла. Ләкин бу аерым бер сүз булса кирәк. Башкортстанда теркәлгән **ылаш** сүзенең чув. теленнән алынган булуы да шикле.

**ЫЛГА-У, олга-у** (Радлов I: 1376; Тумашева 1992: 160, 253) «выбирать, отбирать» ~ каз. (ҠТДС: 413), кырг., тув., алт. диал. (Баскаков 1972: 273), як. *ылға-* «сайлау, кеше аеру», уйг. *илға-*, үзб. (к. ЎХШЛ: 119) *ълға-* «сайлап алу, сортлау» ~ монг. *ялга-*, бур. *илга-* < (яз. монг.) *ilγa-* ~ маньч. (ССТМЯ I: 307) *илға-* «аеру, аерып алу, билгеләү». *Ылға-, илға-* фигыле аеруча тув. һәм уйг. телләрендә киң кулланышлы вә продуктив сүзьясагыч нигез. ЭСТЯ I: 652 (материалы безнекеннән азрак). Чаг. **Чылгый II.**

**ЫЛЫК-У (ылыкты, ылыгу)** «вовлекаться (в течение, движение)», диал. «уноситься течением» < гом. кыпч., к. каз. (ҠТДС: 414), үзб. диал. (ЎХШЛ: 122) *ылық-* id., ш. ук «иярү; сүзенә, өндәвенә карау» < *ығлық-* < *ығылық-* «агым уңаена китү» – *ық- (ығу)* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе (чаг. *атлык-у, җитлек-ү, өзлек-ү, сөрлек-ү, язлык-у*). Чаг. башк. (БТДҺ: 404), себ. (Тумашева 1992: 253), кырг. *ықла-* > каз. *ықта-* «ылыгу; бер якка китү». К. **Ык, Ык-у.**

Дерив.: **ылыктыр-у; ылыктыргыч.**

Диал. **олоқ-у** (к. ЗДС: 503) «ияләшү» икенче бер сүз булса кирәк (шулай да *ы* > *ŏ* очраклары булгалый).

**ЫЛЫС** «хвоя, хвоинка» ~ башк. *ылыҫ* id., башк. диал. (БТДҺ: 405) *лыс* «мүк», мар. *лус, лус* «ылыс», чув. (Ашмарин VIII: 124–126) *лăс* «ылыслы агач ботагы; ылыс». Анлаут *ы-* – протеза (чөнки сүз башында *л-* килү төрки телләргә хас түгел). КЭСК: 164; Федотов I: 336.

Дерив.: **ылыслы** (агач төре), **ылыссыз.**

**ЫМ** «знак рукой, мимикой и т.п.» < гом. кыпч. *ым* id., бор. төрки (ДТС: 209; МК I: 38) *ет, im* «пароль» (М. Кашгари сүзләренә караганда, үз кабилә *им*ен белмәгән кешене үтергәннәр). Чаг. ш. ук үзб. *имо,* госм. *има* < гар. *ӣмā'* «ым».

Дерив.: **ымлы, ымсыз; ымла-у; ымлык;** диал. (ДС I: 234) **ымал-у** «ымлау». К. **Ымсын-у.**

**ЫМАК** (себ., ЗДС: 797) «приятный; соглашающийся» ~ уйг. *имақ* id. чаг. каз. *ымыра* «килешү», кырг. *ымыла* «фикер бердәмлеге» ← **ым*, **ымы.* Чаг. ш. ук тат. диал. **ымылҗы, ымылчы** «артык ярамсак, юха».

**ЫМЗЫ, ымызы** (Будагов I: 204) «утренний просвет, утренние сумерки» ~ башк. (БТДҺ: 406) *ымыҙ* «өмет; яктылык» ~ төр. *ımızgan-* «лампаны, шәмне һ.б. кысып, яктысын кечерәйтеп кую; черем итү, ярым йокыда булу» ~ каз. *ымырт* «эңгер». Арытабан ачык түгел. Бор. төрки сүз булырга тиеш (*р ~ з*). Чаг. төркм. (ТДГДС: 207) *ымлық* «эңгер».

**ЫМСЫН-У** «непроизвольно выражать мимикой потаённое желание; очень хотеть и остаться ни с чем» ← **ымсы-у** (бу сүз сирәк очрый) ~ башк. *ымһын-* id., чув. *ăмсан-* «көнләшү», як. *ымсыы-* «комсызлану». Сүзнең тамыры **ым** (к.) булса кирәк.

Төрки телләрдә шуңа бик охшаш икенче сүз бар: тат. **омсын-у ~ өмсен-ү,** башк. *омһон-*, каз. *ŏмсын-*, кар., каз., чыгт. *умсун-*, алт., тув. *умзан-,* төр. диал. *умсан-* (> башк. диал. – к. БТДҺ: 405–406 – *омтан-, ымтын-, ымшан-*) һ.б. «ымсыну, ымсынып калу»; бу сүз төр., бор. төрки (ДТС: 611) *ит-* «өметләнү» сүзенә тоташа, к. ЭСТЯ I: 595–596. Шулай итеп, **ымсын-у** һәм **омсын-у** тамырдан ике сүз. Федотов I: 83 (*ымсын-* һәм *омсын-* сүзләрен аермый).

Дерив.: **ымсыныш-у, ымсындыр-у**; диал. **ымсык** «ымсынучан» ~ як. *ымсыы* «комсыз».

**ЫНДЫР,** диал. (ТТДС I: 178) **йындыр,** себ. (Тумашева 1992: 254) **ыртын,** (Радлов I: 1470) *ірtін*, «гумно; часть крестьянской усадьбы, где располагалось гумно, стога соломы, куча навоза и т.п.» – бу этногенез мәсьәләләре өчен әһәмиятле сүз (игенчелек термины) спорадик рәвештә төрле төрки телләрдә очрый: башк. (БТДҺ: 251) *ŏндŏр*, башк. *ырдын, ырҙын,* ком. *инныр,* к.-балк. *андыр*, *ындыр,* төр. диал. (татарчадан булса кирәк) *ындыр,* шор. *ыртын*, манси. (тат. сөйләшләреннән) *artyn* << бор. төрки (ДТС: 390) *örtgün, örtkün* «ындыр; ашлык суктыру» > хак., алт. (Вербицкий: 414) *үртүн, үрдүн* id. Бу сүз алт. *үрдүн, ӧрдин*, чулым. *үртүң* «сандал; балта тотәсе» сүзе белән бердәй булса, тамыры – (алт.) *орт-, ӧрт-, үрт-* «сугып тыгызлау». Шулай итеп, бор. төрки **ортуң, уртуң* > тат. *ŏртын-* > *ыртым, ырдын* > *ындыр* (метатеза).

Бор. **ортуң* ~ **ӧртүң* сүзенең икенче бер филиациясе – чув. *йăтам, итем [идэм]* > мар. *идём, йидём*, удм. *итым*, мар. диал. (Kecskemeti, Paasonen сүзлегендә) *idäm* «ындыр; идән» (тәүдә дөмбәсләп тыгызландырылган җир идән – ындыр табагы да шулай эшләнгән) ~ тат. диал. **идәм** (к. **Идән**). Бу филиация *урдуң* > *ырдаң* (икенче-өченче иҗекләрдә *у ~ а* төрки телләр тарихында типик күренеш) > *ыйдаң* һәм параллель *үрдүң* > *эрдäң* > **эйдәң* күчешләрен чагылдыра, к. морд. *утон*

«ындыр» (бор. төрки теллəрдəн үк килə), нуг. («Шора батыр» дастанында) *ыдан* «əвен; баз, зиндан», алт. *эдирен ~ эриден* «ындыр».

**Ындыр** һəм **идəн** сүзлəренең этимологик бердəйлегенə М. Рясянен игътибар иткəн, тик ул тат. сүзен чув. теленнəн дип күрсəтə. Əмма себ. (ЗДС: 220) **итан, итəн** «идəн» варианты чув. теленнəн килə алмый. Димəк, **идəн** бор. тат. теленнəн үк килə. Һəм бор. татарлар (дип əйтергə мөмкин) Идел-Урал регионында болгарлар килгəнче үк яшəгəннəр (к. ш. ук **Басу**). Räsänen 1969: 167; ЭСТЯ I: 656–657 (Э.В. Севортян материал китерү белəн чиклəнə); Федотов I: 201 (ш. ук бик аз).

Дерив.: **ындырлы, ындырсыз; ындырчы** (кеше ындырыннан көлтə урлаучы, к. такмаза: *Ындырчы, ындырчы, кулын сугып сындырчы*).

**ЫНШЫРТ** (трбс.) «болезнь от встречи с разгневанным человеком» < чув. *ăншăрт* id., *ăнсăрт* (Ашмарин IV: 51, 53) «куркып авыру» ~ мар. *аңшырт, оңшырт* «рахит». Мар. *шырт, шёрт, сырт* «пəри, пəрəгəн (явыз, яман яисə яхшы-хикмəтле рух)» сүзе белəн баглы булса кирəк. К. Марийский фольклор. Мифы, легенды, предания: 101–107 (*шырт, ширт* «авыру рухы»). М.Р. Федотов (I: 85) чув. *ăншăрт* сүзен (тат. һəм мар. сүзлəре искə алынмый) төр., төркм. һ.б. *инҗит, ынҗат* «интектерү» сүзлəре белəн багламакчы.

**ЫҢГЫРАШ-У** «стонать; бредить во сне» > чув. *ăнăраш-* id., ш. ук «лыгырдау, яңшау» ~ башк., каз. *ыңыран-у,* каз. *ыңырас-* «иңрəү, ыңгырашу, мөңрəү (сыерлар тур.)» ← тат. диал. **ыңгыра-у**, (Dobr. II: 118–119) *ıŋgırau, ıŋgırdamaq,* башк. (БТДҺ: 406) *ыңырла-у* «авызны ачмыйча гына авазлар чыгару» ~ ком. *иңгыра-,* к.-балк. *ыңгырда-,* каз.. кырг., як. һ.б. *ыңгыра-, ыңыра-, ыңра-* id. *ың ~ иңъ* ымлыгыннан, к. төр. *ınıltı* «ыңгырап алу» авазы, *intin* «нинди дə булса зəгыйфь аваз» һ.б. Пекарский: 3801, 3803. Чаг. **Иңрə-ү, Ык-мык, Ыңгырчак.**

**ЫҢГЫРЧАК,** диал. (себ., миш.) **ыңгырцак** «седёлка» > мар. (Исанбаев 1978: 39) *ыңгырчак* < гом. кыпч., алт. *ыңгырчақ, ыңырчақ,* тув. *ыңгырҗақ,* куман., чыгт. *йыңгырчақ,* башк. *ыңғарсақ,* һ.б. id. кырг., як. *ыжгыр, ыжыыр, ыгыр* «ияр, зур (ишəккə, мөгезле эре терлеккə менгəндə кулланыла торган) ияр» сүзеннəн кечерəйткеч нигез дип уйланыла. Лəкин **ыңгырчак** сүзенең кайбер вариантлары төрле юнəлештə аңлашыла, к. тат. диал. (ТТДС I: 156–157) **иңылчак, иңёлчəк**, чув. *йĕнерчĕк ~* удм. *эңэрчак* (< төрки) «ыңгырчак» ← чув. *йĕнер ~* удм. *эңэр* «ияр». К. ш. ук к.-балк. *аңңырчақ ~* урта монг. (Поппе 1938: 408) *yangirčaq* ~ иске рус. *арчак, аарчак* (к. Фасмер I: 92, тат. теленнəн диелə, лəкин хəз. тат. бу сүз теркəлми) «ыңгырчак; каңга, ияр тактасы», себ. рус (Аникин: 88) *аңгарычак* «йөклəү ияре». Төп вариант, безнеңчə, *арт-, аарт-* < **аңырт* (чаг. **арт-у II**, як. *ырт-, ыырт-, ыңырт-*) «аркага төяү» сүзеннəн ясалган исем булган, шуны халык этимологиясенчə төрле бүтəн сүзлəргə нисбəт итү нəтиҗəсендə сүзнең күп вариантлылыгы килеп чыккан. **Ыңгыр > ыңгырчак** сүзен *ыңгыр ~ ыгыр* (к. **Ыңгыраш-у**) сүзенə нисбəтлəү дə халык этимологиясенчə. Räsänen 1969: 116; Федотов I: 195; ЭСТЯ I: 658–659; Иванов 1993: 247–248.

**ЫРАВАН [ы̌раwан]** «очень хорошо, замечательно» (*эшлəр ыраwан, дөнья кəраван* мəкалендə) ~ башк. (к. БТДҺ: 100, 101) *ирауан, ирəуəн* «рəхəтлек; иркенлек» ~ тув. *ириван, эриван* < бор. һинд. *nirvan, nirvana* «нирвана, мəңге рəхəтлек (вечное блаженство)» (Н. Исəнбəт этимологиясе).

Бу сүзне икенче **ыраван ~ ырауан** «тиз генə, җəһəт» < *раван [раwан]* id. (к. **Раван**) сүзе белəн бутарга ярамый.

**ЫРАЙ** (*Ыраена күрə чырае* мəкалендə һ.б.) «настроение; мнение (о ком), отношение (к кому)» ~ кырг., каз. *ырай*, үзб. (ЎХШЛ: 224) *рай, райа, ырайа,* төр. *ıra, ra, ray* < фар. *рай, рäй* id. < гар. *ра'й* «яхшы мөнəсəбəт, буйсынучанлык» (к. Özön: 702) ← *р'й* «буйсыну; хөрмəтлəү», шуннан ук к. **Рəгыять, Ригая.** Башк. (БТДҺ: 407) *ырайа* «телəр-телəмəс» < гар. *ра'йä* «буйсыну хəле» (ягъни башк. сүзе «буйсынып кына» мəгъ.). ЭСТЯ I: 659 (Севортян бу сүзнең этимологиясен белмəгəн).

**ЫРА-У** «спориться (о работе), успешно развиваться» ~ башк. *ыра-* (БТДҺ: 407) «төзəлү», «арту, күбəю» (*ырамалы* «бик күп») > удм. *ыра-* «ырау», ш. ук «җил уңайга өрү», мар. *воран-* «ырау; төзəлү». Идел-Урал сүзе. Алт., тув., хак. *ыра-* «ераклашу» сүзе белəн чагыштыру бəхəсле. Тат. *ыра-у* < *ōра-у* булуы ихтимал (к. **Орга-у**).

Дерив.: **ырат-у; ырам, ырамлы;** башк. *ырамтал* «ырамлы».

**ЫРБАЙ-У** (ЗДС: 799) «возгордиться; вести себя гордо и нагло», (шунда ук) **ырпай-у** «тупас кылану, кычкырыну» ← **ырба, *ырпа* «тəкəббер һəм тупас». К. кр.-тат. *ırbaŋ-ırbaŋ* «тупас рəвештə;

кычкырынып-җикеренеп; шәпләнеп», *ırbaŋke* «кискен сүзләр әйтүчән», каз. *ырбаң* «урынсыз (сүз, кыланыш)», *ырбаңда-* (*ырбаңла-*) «тотнаксызлану; кыланчыклану», кырг. *ырба-* «азу, көчәю (тискәре күренешләр тур.)», *ырбаақ* «азгын (яра һ.б.ш.)» ← **ырп*. Чаг. бор. төрки (ДТС: 243) *jarp* «нык, көчле; тупас, рәхимсез» (к. **Ярпай-у**).

Рус. *рыпаться* сүзе искә төшә.

**ЫРГАЙ I** «ирга; жимолость» < гом. төрки, нуг., каз., к.-калп., алт., тув., хак. *ырғай* id. ~ монг. *ирғай, ньиргай* id. Бор. төрки сүз булса кирәк. Рус. *ирга, ярга* тур. Аникин: 223, 729 (төрки-монг. сүзе ди).

**ЫРГАЙ II** «вид рыбы» к. **Арган.**

**ЫРГАК** «крюк» > чув. *ăрхах, йăрхах*, мар. *ырғақ* < гом. кыпч., хак. *ырғақ* id. ~ тув. *ырғақ* «кәкре», *ырғай-* «бөгелү, кәкрәю», бор. төрки (МК, ДТС: 51, 220) *arγaγ, ïrγaγ* «ыргак, багур, керәшә (балык аулау коралы)» ← **ыр-у.** Егоров 1964: 76.

Дерив.: сугышта, көрәштә **ырғакла-у** тур. Dobr. II: 119–120.

**ЫРГА-У** (Тумашева 1992: 254) «качать, раскачивать» < гом. кыпч., алт., уйг., госм. *ырға-* < бор. төрки (ДТС: 220) *ïrγa-* «селкетү, хәрәкәткә китерү». К. ЭСТЯ I: 260–261.

**ЫРГЫТ-У**, миш. (ДС III: 46) **выргыт-у** «бросать, бросить; кидать, швырять» ~ чув. *вăркăт-*, удм., мар. *выргыт-* id. < гом. кыпч. *ырғыт-,* уйг., үзб. *ирғит-* id. ← **ырғы-у** (к.). Федотов I: 107–110 (чув. *вăркăт-* «ыргыту» сүзен *вăр-* «ору» сүзеннән димәкче, бу, әлбәттә, дөрес түгел).

Дерив.: **ыргытыл-у, ыргытын-у, ыргытыш-у, ыргыттыр-у.**

**ЫРГЫ-У** «прыгнуть (вперед), броситься (рывком)» < гом. кыпч., к. нуг., каз., к.-калп., төркм. (ТДГДС: 207) *ырғы-*, ком. *иргы-*, үзб., уйг. *ирғи-* id. Бу сүзне М. Рясянен (Räsänen 1969: 166) **ырга-у** (к.) сүзе белән бердәй дип карый, Э.В. Севортян исә (ЭСТЯ I: 662–663) аерым карый. Без соңгы фикер яклы. *Ырғы-* < **ыр-ық-* булса, бу нигез ниндидер *ыр-* фигыленең интенсивлык формасы булса кирәк.

Дерив.: **ыргыл-у, ыргыт-у** (к. югарыда); **ыргылыш, ыргым** һ.б.; башк. телендә (БТДҺ: 403) *ырғымыш* – уен атамасы, *ырғымбай* «кайнар холыклы кеше, юләр», *ырғындақ* «сикереп чабучан» һ.б.

**ЫРЖА** (ТТДС I: 527; БТДҺ: 408), **ыража, ыраша, ыраса, ырайы** «ржа; рьдя, сухой туман; зарница» < рус., әлбәттә.

**ЫРЖАЙ-У,** себ. (Тумашева 1992: 254) **ырцай-у** «осклабиться, скалить зубы» < гом. кыпч., добр. *ırcaу-,* як. *ыржай-,* ком., үзб. *иржай-,* уйг. *ирҗай-* ~ монг. *иржай-, аржай-,* бур. *ирзай-* > тув. *ырзай-* > хак. *ырсай-,* алт. *ырсай-, ырчай-* һ.б. ← төрки **ырыж-ай* id. К. ш. ук эвенк. (ССТМЯ I: 327) *ирǯарга* «ырылдап теш күрсәтү (эт тур.)» – күрәсең, тәкълиди **ырыж* сүзеннән (чаг. **ырылда-у**). К. **Ыржык.**

Дерив.: **ыржаеш-у, ыржайт-у** (*теш ыржайту* диләр) ← кр.-тат. (Dobr. II: 119–120), кырг. һ.б. телләрдә **ырыж ~ ыржы* тамырыннан ясалган сүзләр бездәгедән күбрәк; мәс., кырг. *ыржақ* «авызны киң ачып елмаю, көлеш», *ыржаке* ~ кр.-тат. *ırcanke* «ыржаючан, мәгънәсез яисә артыкча көлүчән», кырг. *ыржаңда-, ыржаңда-* «ямьсез кычкырып көлү» ~ кр.-тат *ırcaй – ırcaй gülmek* һ.б. Рус. *ржать* «(атлар тур.) яңгыратып аваз салу» сүзе дә төрки сүзгә баглы түгелме икән?

**ЫРЖЫК** (ДС III: 198; БТДҺ: 408 һ.б. ), себ. (Тумашева 1992: 254) **ыршық** «с выступающими (неровными) зубами; зубоскал; бессмысленно улыбающийся» ~ башк., нуг. *ыржан*, алт. *ырсаң* һ.б. id. **ыржы-, *ыржа-* «ыржаю» фигыленнән (бу фигыльнең аерым паронимы). К. **Ыржай-у.**

**ЫРЗАЙ** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «благочестие, благочестивый» ~ башк. (Максютова: 99) *ыржа* id., чув. (М.И. Скворцов телдән әйткәнчә) *ăрсай*, мар. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) *ырса* «изге» < бор. төрки (ДТС: 212, 213) *arši, rši, irši, irzi, irži* «изге карт; заһид» < санск. *rsi* id., ш. ук «изге шагыйрь». К. ш. ук каз. (ҚТДС: 101) *ersi* «җайлы»?

Безнеңчә, хәз. Башкортстандагы **Ырзай ~ Ырсай** дигән авыл исеме дә шул сүздән (гомумән, шул исемдәге кеше булган диләр).

**ЫРМАУ [ы̆рмаw],** диал. (Ә. Фәйзи) **ырнау** «паз» – **ырма-у** фигыленнән исемләшкән, к. түбәндәгене. К. **Ыры-у.**

Дерив.: **ырмаулы, ырмаусыз; ырмаула-у.**

**ЫРМА-У** «делать пазы, пазить» ← **ыр-у** (бу фигыльнең интенсивлык дәрәҗәсе булса кирәк).

**Ырым-а-у** дип тә карарга мөмкин. К. югарыдагыны.

**ЫРУ, ору** «род, родня; широкий круг родственников» (к. Кузеев Р. Очерки исторической этнографии башкир. Уфа, 1957: 44), «фертильность» (**ырудан калу** «потерять способность рожать») > чув. *ăру, ăрăв* < гом. кыпч., к. башк. *ырыу,* нуг. *ырув*, кар. *урув*, к.-балк., ком., каз., як. *ру ~ уру,* кырг., эвенк. *уруу,* уйг., үзб., чыгт., госм., монг. һ.б. *уруғ* < бор. төрки (ДТС: 615) *uruγ* «ыру; орлык» > тув. *уруғ* «орлык», төр. *uruk* «ыру». Монг. һәм тунг.-маньч. сүзләре, әлбәттә, төрки телләрдән кергән. Сүзнең тамыры *ур ~ үр* «тудыру; токым» ~ бор. төрки (ДТС: 614) *urï* «ир бала». Монг. *ураг* «ыру» нигезе **ур*-яисә **ура-* дигән фигыль дә булганлыгын күрсәтә шикелле. Будагов I: 128 (тат. *оруғ* сүзе «волость» мәгънәсендә дә булган ди); Егоров 1964: 42, 49; Räsänen 1969: 516; ЭСТЯ I: 604–606; Федотов I: 88.

Дерив.: **ырулы, ырусыз; ырудаш;** диал. **ырулаш-у.** К. ш. ук **Орга-у, Орлык, Өрет, Үрче-ү; Ыруг.**

**ЫРУГ, оруғ** «род (как таксономическая категория)» < иске тат., чыгт., уйг. һ.б. *уруғ* «ыру, ыруг», чыгт. (Радлов I: 1658–1659) *уруғ* «кардәшлек» һ.б. К. **Ыру.**

Дерив.: **ыруглык, ыругчылык; ыругдаш.**

**ЫРЫК** (к. мәкаль: *Ырыкныкы ырыкка, шырыкныкы шырыкка китә*) «(хороший) род, (хорошая) порода» ~ нуг. *ырқ* «нәсел традициясе; мәел; кәеф», кырг. *ырқ* «яхшы тормыш, яши белү», төркм. *ырқ,* төр. *ırk* «токым, тамыр; кан тамыры, темперамент; нәселдән килгән характер», бор. төрки (ДТС: 220) *ïrq* «юрау; язмыш» ~ бор. монг. *ıru, ıruwa* «язмыш билгесе; юралыш». Добр. сүзлегендә бу сүз гарәпчәдән диелә. ЭСТЯ I: 665 (Э.В. Севортян **ырым** сүзе белән баглы ди). К. **Ырым.**

**ЫРЫМ** «мелкие предзнаменования магического характера; колдование, ворожба; суеверие» > чув. (Сергеев 1968: 54) *ăрăм, ĕрĕм* «әмәл; ырым», мар. *ырым* «хорафат» < гом. кыпч., алт., тув., төркм. *ырым*, чыгт., үзб. *иримъ* «галәмәт, әшкәртү, билге; юрау» һ.б., бор. төрки (ДТС: 212, 220) *irü, ïru* «хикмәтле билге» < ***ыр-** фигыль тамырыннан (ди Э.В. Севортян, ЭСТЯ I: 665–666), к. ш. ук як. (Пекарский: 3808–3811) *ыра, ыраа* «сизенү, әшкәртелү» << монг. *ірywa* id., к. **Ырық.** Федотов I: 86–87.

Дерив.: **ырымла-у; ырымчы.**

**ЫРЫС, ырыз** «счастье, доля» > чув. *ăрăс*, мар. *рыз* < гом. кыпч. *ырыс* каз. *рыс,* нуг. *ырыз* id. – бу сүзне себ. (Тумашева 1992: 254) **ырыск, рыск, ырсых** «язмыш; ризык», нуг. *ырызкы,* кырг. *ырысқы* «көндәлек ризык», төркм. *ырызығ* «яшәү хәле, яшәү рәвеше» сүзләреннән аерып булмый, шунлыктан Э.В. Севортянның (ЭСТЯ I: 666–667) **ырыс** сүзен **ырык, ырым** сүзләре белән баглавына без каршы. К. ш. ук кар. *ырыз*, төр. *ırz* «намус, вөждан; гыйффәт», үзб. *ырс* «бәхет, уңыш». Бу сүзләр гар. *ризқ* «ризык» < пәһл., бор. ир. *rōčik* «көнлек ризык» һәм шул ук тамырдан булган фар. *руз* «көн; бәхет» сүзләренең төрлечә рефлексларыннан гыйбарәт. Добр. сүзлеге *ırz* «намус, гыйффәт» сүзен гарәпчәдән ди. К. Räsänen 1969: 389. К. **Ырыскал.**

Дерив.: **ырыслы, ырыссыз.**

**ЫРЫСКАЛ, рыскал** «бәхет, дөньялыктагы өлешең» > чув. *ăрăскал*, мар. *рыскал* < бор. кыпч., к. кр.-тат. *ырыскал* һ.б. < фар. *рӯзг'āр* «вакыт, чор; гомер; язмыш»; бу сүз үзе генә дә күп төрки телләргә алынган һәм төрле мәгъ. кулланыла: үзб. *рузгар* «әйберләр, мал-туар. мөлкәт», төр. *rüzgâr* «җил», көрд. *rizgari* [*рызгари*] «язмыш; иркенлек; тынычлык», сүзнең тамыры фар. *рӯз* «көн; яктылык; ризык». К. **Ураз, Ырыс.** Федотов I: 87–88.

Дерив.: **ырыскаллы, ырыскалсыз.**

**ЫРЫ-У** (к. Троянский I: 30 – **ыру-мак** дип язылган) «пазить, стругать» ~ чув. (Ашмарин III: 65) *ыр-, ыра-,* башк. *ыра-, ыр-, ыры-* (*ырыды* диелә), алт., хак. *ыр-, ар-,* як. *ор-* id. К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 28) **ар-** «багананы һ.б. киртү». К. **Ырма-у.** Räsänen 1969: 128; Федотов I: 472–473 (бик шикле параллельләр китерә).

Дерив.: башк. *ырғы* «балтасыман очлы лом», башк., себ. **ырма** «кирт, бәҗ» (→ **ырмала-у**), *ырык, ырым* (к. БТДҺ: 407–409). К. ш. ук **Ыргак**. Чаг. **Ындыр < Ырдын**.

**ЫС I,** себ. (Тумашева 1992: 254–255) **ыш** «чад; дым; копоть» < гом. кыпч., хак. *ыс,* як. *ыыс,* алт., тув. *ыш* id. ~ чув. *йăс* «төтрә; ыс» – бор. гом. төрки сүз, тәүдә ул «тире ыслау өчен махсус төтен» мәгъ. булган.

Дерив.: **ыслы, ыссыз; ысла-у, ыслык.** К. **Ыслак.**

**ЫС II, ысс** – подражание шипению (змей, гусей), ш. ук күч. мәгъ. күрәсең – подражание мед-

ленной злобной речи. Күп төрки телләрдә бар бугай, ләкин сүзлекләрдә сирәк күренә.

Дерив.: **ысылда-у** һ.б., к. Dobr. II: 182.

**ЫСЛАК** «камера для копчения кожи» ~ башк. диал., каз. *ыстақ,* тув. *ыштық* һ.б. id. Шуның белән бергә тат. диал., кр.-тат., госм. *ыслақ* «юеш» сүзе дә бар: ул мәгънә тиреләрне парландырып төтәсләүдән килеп чыккан. Сүзнең ясагыч нигезе **ысла-у ← ыс** (к.).

**ЫСНАЧ, ычнач** (ТТДС I: 528–529; Тумашева 1992: 254) «принадлежности труда (особенно ткача)» < рус., укр. *снасть* id. Бу сүзнең гом. слав. параллельләре, тамырлары билгеле түгел, к. Фасмер III: 697.

**ЫСПАЙ,** (гәй.) **ыспайы**, себ. (Радлов IV: 250; Тумашева 1961: 230–231; Тумашева 1992: 251) **сыпайы, ысбайы, ысфай** «аккуратно, красиво и модно одетый» > чув. *ăспай,* мар. *ыспай,* удм. *ис-пай* ~ нуг. *ыспай,* ком. *ысбайы,* төркм. *сыпайы* һ.б. «ыспай; әдәпле» < иске тат., чыгт. *сипаhи* «атлы гаскәри; хәрби формадагы кеше; офицер» < фар. *сипāhӣ* id. (к. **Сыбай**) ~ иске фар. *ăспhāӣ* «(ике) атлы гаскәри» ← *ăсп* «ат». Атлы гаскәри һәр ордада диярлек югары хәрби катламны тәшкил иткән, шуннан гомумиләштерелеп «көяз, ыспай» мәгъ. алган, чаг. **кавалер** «көяз егет» – түбәндә «атлы» (шуннан – **кавалерия**), **рыцарь** << ним. *рейтер* «атта йөрүче» һ.б. Будагов I: 39, 619–620.

Дерив.: **ыспайлы** (!, чаг. **сыбайлы**); **ыспайлык; ыспайла-у; ыспайлан-у**. Тат. әд. телендә **сипай** (< инг. < һинд. < фар. *сипāh*) «Һиндстанда инглиз хезмәтендә булган җирле гаскәри» сүзе дә кулланыла.

**ЫСПАС** «начало осени; пора мелких дождей» < рус. *спас, спасов день* (М. Фасмер буенча, 6 август). Рус сүзе *спаситель* (*Христос* сүзенең тәрҗемәсе) дигәннән.

**Ыспас** сүзе тат. телендә киң таралган һәм аның мәгънәсе рус. мәгънәсенә бигүк тәңгәл килми. **Өч ыспас** – беренче, икенче, өченче ыспасларның тәртибе кирегә – өченче ыспас хронологик җәһәттән беренче. Мар., удм. телләрендә *спас* дип төрле дини бәйрәмнәр атала.

**ЫСТРАМ, ыстырам** (ТТДС I: 529, киң таралган) «срам, позор, стыд» ~ чув. *ăстăрам,* мар. *страм,* удм. *странь* id. < рус. *срам* (яки *стыд и срам* тәгъбиреннән). *Страм* дип рус сөйләшләрендә әйтелә һәм *-т-* рус телендә пәйда булган.

**ЫСУЛ, осул** «способ, приём; стиль, форма» < гом. кыпч. *усул* < гар. *усӯл'* id. – *асыл* сүзенең күп. формасы. **Өслүб** (к.) сүзе белән тамырдаш түгел. К. Будагов I: 54.

Дерив.: **ысулы җәдит** «яңача укыту методы», **ысулы кадим** «искечә укыту» – XIX г. икенче яртысы, XX г. башларында киң таралган педагогик-иҗтимагый хәрәкәтләр атамалары.

**ЫСЫРГАН-У** иск. «испытывать прилив жары от стыда, волнения досады» и т.п. ← иске тат. *ысы, ыссы* «эссе». Будагов I: 47–48. Чаг. **ытырга-у.** К. **Сырха-у.**

**ЫТЫРГА-У, ытыргалан-у** (ТТДС I: 529; БҺҺ II: 312) «передёрнуться от внезапных сильных чувств, смутиться, стесняться; невольно обороняться» < *ықтырға-у* ← башк., гом. кыпч. *ықтыр-* «ышыклау; ышыклану», к.-балк., кар. *ыхтыр-* «дошманны чигендерү; саклану, яклану», кырг. *ықтыр-, ықта-* «ышык эзләү; оялу, ытыргау» ← гом. кыпч. *ық* «ышык» < «агым уңае». К. **Ык, Ыктырма.**

**ЫЧКЫН-У,** диал. («Кәлилә вә Димнә» тәрҗемәсендә) **очкын-у** «вырваться» < гом. кыпч., к. к.-балк. *ычқын-, ыцқын-,* нуг., каз., к.-калп. *ышқын-,* башк. *ысқыны-,* хак. *ысығын-,* төр. диал. *ıcgın-, ıkcın-* < алт. (Радлов I: 355) *ықчын-* id. ← **ыкчы-** «агып, җилләнеп, җилгә очарга әзер тору» ← *ық-* «агу, җил уңаена очу һ.б.» (к. **Ык-у**). К. чув. (Ашмарин IV: 75) *ăçкăт-* «ычкындыру, бәйдән җибәрү», кырг. *ычкый-* «көчергәнешле хәлдә, ычкынырга әзер тору»; *ычкын-* < *ыкчын-* сүзенең күчемле мәгъ. дә бар: тув. *ышкын-,* як. *ытыгын-,* бор. төрки (ДТС: 216) *ïсуïп-* «җибәрү, ычкындыру, төшерү», Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 672–673) **ычкын-** нигезенә «юкка чыгу» мәгънәсен бирә һәм сүзнең этимологиясен, безнеңчә, ялгыш юнәлештә эзли (кайбер яңгырашларны ул китермәгән – белми).

Дерив.: **ычкындыр-у** – киң кулланыла.

**ЫЧКЫР** «гачник, поясок, очкур» < гом. кыпч., кырг., алт. *ычқыр,* алт. диал. *ычкар* > нуг., каз., к.-калп. *ышқыр*, кр.-тат., госм. *учқур*, чыгт., бор. төрки һ.б. *ичқур,* башк. *ысқыр* «эчке билбау» сүзеннән. Радлов I: 1730; Räsänen 1969: 162. Рус. *очкур, ичкур* < төрки *ичкур* тур. Аникин: 434 (бай әдәбият күрсәтелә). К. **Эч, Кор.**

**ЫШАН-У,** диал. (ДС II: 90; без теркәдек. – *Р.Ә.*) **ишан-у, ŏшан-у, шан-у** «верить, доверять» > чув. *шан-*, мар. *шан-*, *ушэн-, ишан-* < гом. кыпч. *ышан-, ишан-* (> кар., нуг., каз., к.-калп. *ысан-*), чыгт., уйг., үзб. *ишан-* < *иш (эш) ан-* «иш дип белү (исәпләү)», шуннан закончалыклы рәвештә, уйг. *ишән-*, бор. төрки (ДТС: 214) *išän-* > алт. *ижен-*, хак. *ĕзен-, ĕзäн-* id. Угыз телләрендә бу сүз электән булмаган, күрәсең (төр., тув., як. телләре материалы шуны күрсәтә), төркм. (ТДГДС: 208) *ышан-* кыпч. телләреннән (Ставрополь төрекмәннәрендә < тат.), Räsänen 1969: 174; ЭСТЯ I: 673–674; Федотов II: 433 (яз. монг. *iča-* «ышану» сүзен китерә һәм *иша-* дигән фигыль бар дип чамалый).

Дерив.: **ышаныл-у, ышандыр-у; ышаныч** (бу сүзләрдән күп кенә икенчел дериватлар ясала), диал. (ТТДС I: 529; ТТДС II: 373, 387) **шандык, ышандык** «ышаныч»; чув. *шанчăк* «ышаныч» тат. ***ышанчык** булса кирәк; сөйләшләрдә **ышангыч, ышанчак** «ышанучан».

**ЫШКЫ** «фуганок; скобель» > мар. (Исанбаев 1978: 40) *ышке* id. ← **ыш-у** (к.).

**ЫШКЫ-У** «тереть» ~ гом. кыпч., к. кырг. *ышкы-* > нуг., каз., к.-калп. *ыскы-* id. ← **ыш-у** (чаг. **йол-у → йолкы-у, кыр-у → кырк-у**).

Дерив.: **ышкыл-у, ышкын-у, ышкыш-у, ышкыт-у.**

**ЫШЛАПЫР** (ТТДС I: 529; ТТДС II: 387), **ышлапур** (БТДҺ: 411) «воланчик вокруг шеи, пришиваемый на грудь платья» < рус. *шлáфор* id. ← иске рус. *шлафрок* < ним. *Schlafrock* «йокы күлмәге (аның XVIII–XIX гг. формасы: аңа бик киң яка яисә хәтта башлык тагылган булган)». Фасмер IV: 452.

Хәз. рус сүзлекләрендә бу сүз күренми.

**ЫШНА** «чищоба, росчисть (участок, где лес вырублен и выкорчеван для превращения в поле); поляна» ~ чув. *ĕшне, ишнэ, шна,* нуг. *ысна* id. ← *ыш-у* (к.) булса кирәк (чаг. *әвер-ү → әвернә* һ.б.ш.). Федотов I: 160 (тамырын күрсәтми).

**ЫШТАН** «штаны» > чув. *ăштан,* мар. *ыштан*, удм. *иштон,* рус. *штан, штаны* < чыгт. *иштан* id. < бор. төрки (ДТС: 201) *ič ton* «эчке кием; кальсон». Кырг. *ыштан*, нуг., каз. *ыстан* «ыштан» рус яки тат. теленнән кергән булса кирәк, чөнки *ыштан* сүзе күп төрки телләрдә электән теркәлмәгән. Рус. *штаны* < төрки тур. к. Аникин: 707 (әдәбият күрсәтелә).

**ЫШТЫР** «онучи, портянки» ~ мар. *ыштыр*, мар. Т. (к. Саваткова: 228) *ĕштĕр*, удм. *штыр* id. М. Рясянен (Räsänen 1969: 168) бу сүзне фин-угор сүзе дип бара һәм фин. *hattara* «ыштыр» сүзе белән чагыштыра. Әмма безнеңчә, **ыштыр** чув. *ăш тир* «эчке тире» сүзеннән дә була ала: тире ыштыр элек-электән билгеле.

Дерив.: **ыштырлы, ыштырсыз.**

**ЫШ-У, ышы-у,** диал. (ДС I: 57) **йыш-у** «тереть; соскабливать неровности» ~ нуг., каз., к.-калп. *ыс-*, кырг. *жыш-*, башк., алт. *йыш-*, алт. *дьыш-*, хак. *йыс-* id. К. **Ышкы, Ышкы-у.**

**ЫШЫК** «место, защищённое от ветра или от горячего солнца», иске тат. (Троянский I: 41) **ышык, ашык** (?) «яшертен, уртын» > мар. *ышык, ĕшĕк, ушĕк*, удм. *ышык, ышыгъ, ъшък* «ышык, күләгә» ~ к.-балк. *ышык*, тув. *ыжык* id.; к. чув. *ăшăх* «сайлык; сай (агымсыз төш?)», (Ашмарин III: 359) *ыш* «салкын». Угыз телләрендә (аз., госм. һ.б.) *ышык,* бездәге мәгънәгә кире – «нур, яктылык» мәгъ. һәм *ышы-* «утны дөрләтү» фигыленнән килә. Гомумән, «безнең» *ышык* сүзе дә нининдидер *ыш-, ышы-* фигыленнән, ләкин тиешле фигыль безгә билгеле түгел.

Дерив.: **ышыклы, ышыксыз; ышыкла-у, ышыклан-у**. Чаг. **Шыксыз.**

# Э

**Э [ĕ]** авазы тат. телендә башлыча гом. төрки *и* авазыннан һәм еш кына *ы* авазыннан килә. Бик күп тарафларда (миш., себ. диалектларында һ.б.) *ĕ* < *ө*; ш. ук *ĕ* > *ө* очраклары да булгалый.

**ЭБЕР-ЧЕБЕР,** (ДС II: 234) **ыбыр-чыбыр** «всякая мелочь, мелкота» ~ бор. төрки (МК I: 362) *ewer-çübür* «кәҗә кылы», *çübür, çüpür* «кыл, кылчык».

**ЭЗ** «след» < гом. кыпч., гом. угыз. *из* < бор. төрки (ДТС: 221) *jiz* ~ кар. *йыз*, к.-балк., нуг. *ыз*, төркм. *ыйз, ыыз, ииз* «эз, билге; кыланыш» ~ чув. *йĕр* «эз» – бор. гом. төрки сүз. ЭСТЯ I: 383–385, 646–647; Федотов I: 198; Мухамедова 1973: 93.

Дерив.: **эзле, эзсез**. К. **Эзәк, Эзәр II, Эзәрлә-ү, Эзлә-ү. Эз ~ ыз** гомумән катлаулы тарихка ия булган сүз; тормышта киң кулланышлы төшенчәләрне белдергәнлектән, аның беренчел мәгънәсен билгеләү дә кыен; һәрхәлдә **ызан** (к.) сүзе белән чагыштыруларга без каршы, чөнки монда кискен мәгънә аермалары килеп чыга. Чыгт. һ.б. (Будагов I: 191–192) *иҙ-* «җибәрү, юнәлтү» белән чагыштыру да бәхәсле.

**ЭЗӘК** (Троянский һ.б., диал.) «маленькая, еле заметная тропинка» ← **эз** (бу сүзнең кечерәйтү формасы) шикелле, ләкин **эзә-ү** дигән фигыль бар бугай).

**ЭЗӘР I** «широкий пояс (должностного лица)» к. **Зәр.**

**ЭЗӘР II** диал. (трбс.) «хождение по следу; преследование» ← **эз** (к.). Ясалышы ачык түгел. Ихтимал, **эзәр-ү** яисә **эзәрлә-ү** (к.) сүзеннән кире сүзьясалышы нигезендә килеп чыккандыр. Бүтән төрки телләрдә теркәлмәгән.

Дерив.: **эзәрле; эзәрлек** (→ **эзәрлеклә-ү**); **эзәрче** «эзләр буенча киек аулаучы аучы, эзәрләүче; эзләр белгече».

**ЭЗӘРЛӘ-Ү** «преследовать, гнаться по следам; идти по следам кого-либо» – бу сүз тат. һәм алт. телендә генә бугай. Ясалышы – гомуми закончалыклар буенча хөкем йөрткәндә – бор. төрки *из-* < **ирг-* «эз буенча бару» фигыленнән (ул сүз – *эз* < *из* < **ирг* сүзенең фигыль коррелянтыннан) дәвамлы интенсивлык формасы (*-арла*//*-әрлә* кушма аффиксы белән ясала, чаг. *бөгү – бөгәрләү, йому – йомарлау* һ.б.). Беренче карашка **эзәрлә-ү** фигыле **эзәр** (к.) сүзеннән, әмма бу сүзнең үзенең этимологиясе бик томанлы.

Бор. төрки телләрдә (Боровков 1963: 122) *ідäр- ~ idär-* «эзәрләү» сүзе булган, шуннан *ідärü* «эзәрләп, эзәрлекләп» сүзе (хәл фигыль) ясалган. Бүтән төрки телдән кереп дөрес аңланылмаган тәкъдирдә, **эзәрү** сүзе исем ителеп, шуннан **эзәрүлә- > эзәрлә-** сүзе ясала ала.

Дерив.: **эзәрлән-ү, эзәрләт-ү** (сирәк кулланылалар).

**ЭЗЛӘ-Ү** «искать (по следам)» < гом. кыпч. *изле-* (> башк. *эҙлә-ү, эҙҙә-ү, эҙҙә-ү,* кырг., каз. *изде-,* каз. *ĕзде-*) id., ләкин бор. чыгт. (Боровков 1963: 173) *ідлä-* «эз калдыру» ← *эз* < *из* (к. **Эз**).

Дерив.: **эзлән-ү, эзләш-ү, эзләт-ү.**

**ЭЛӘЙ** (ТТДС I: 532; Тумашева 1992: 49–50) «опечек; передняя часть нар; скамья (у дверей)» < хак. диал., чыгт. (Радлов I: 1478) *iläi* «алгы як, йөзлек» < *ил-äй*: *ил* «алгы як, алдан, элек» (к. **Элек**) + **äй* «як; ас» булса кирәк. К. ЭСТЯ I: 349 (*илк* матдәсендә; Э.В. Севортян тат. сүзен искә алмый).

**ЭЛӘКӘ, эл'ака,** (ТТДС I: 289, 294) **лака, ләкә** «часть посевного участка; часть земли, которая вспахивается, но оставляется незасеянной; борозда, граница участка, которая обозначается остатками костра (углём и золой); участок поля (в любом состоянии), который дарится девушке, выходящей замуж, в качестве **инче** (к.)» < гар. *läkä, läkkä* «тап, билге; билге казык», к. төр. *leke* «тап»; чаг. ш. ук аз. (АДДЛ: 297) *ләкәр* «буразна». Гомумән, бу (миш. сөйләшләрендә шактый киң таралган) сүзнең тарихы бигүк ачык түгел. К. Ахметьянов 1968.

**ЭЛӘК-Ү (эләкте, эләгү),** сөйл. **ләк-ү** «зацепиться, застрять; попасться, попасть; достаться (төрле мәгъ.)» > чув. *лек-,* (Ашмарин VIII: 74) *ленк-,* мар. *ләк-, лак-* id. **Эләк-** нигезе тат.-башк. телләрендә генә бугай һәм ул **элек-ү** яңгырашыннан, ягъни **эл-ү** фигыленең интенсивлык дәрәҗәсеннән (*ĕ* > *ә* күчеше тат. теленең күп кенә сүзләрендә очрый, к. **Шәүлә**). Федотов I: 336 (бор. төрки этимон эзли). К. **Эл-ү.**

Дерив.: **эләгел-ү; эләгеш-ү** («конфликтка керү» мәгъ. актив кулланыла); **эләктер-ү** (шуннан **эләктергеч**).

**ЭЛӘН** (ТТДС I: 532; БТДҺ: 435 – асылда тат. сөйләшләреннән) «лён; льняная ткань» < рус. *лён*, әлбәттә (бу сүзнең һинд.-евр. тамырлары бар, к. Фасмер II: 481).

**ЭЛӘҢКЕТ** (ТТДС II: 389), **эләңгет, эләгет** (БТДҺ: 414) «измученный, усталый; обессиленный; старая собака; хитрый», **ләгет** (ТТДС I: 293) «скотина-обуза (старая, бесполезная)» – чаг. рус. (Фасмер II: 483) *леньгуз, леньгас* «ялкау». К. ш. ук фар. > үзб. (ЎХШЛ: 170, 171) *ләвәң, ләң* «хәлсез, ялкау, чирле» (**ләң эт > эләңгет** була ала).

Дерив.: **эләгетлән-ү** «түбән, лаек булмаган кеше белән булашу (әрләшү)».

**ЭЛӘ-ТАНАК,** (ТТДС I: 533, 545) **энәталак, энә-танак** диал. «общий нормальный вид»: *энә* < бор. төрки (ДТС: 46) *aпаүи, аңаүи* «образ, кыяфәт, сурәт», **танак* > чув. *тонак* > *тунак, тона* > *туна* «кәүсә, сөяк, күчән» (монда **эләк-ү** сүзенең тәэсире күренә).

**ЭЛГӘК** (трбс., ТТДС II: 388) «закреплённый крючок, крюк» ← **эл-ү**, әлбәттә. К. уйг., үзб. (ЎХШЛ: 115) *илгәк* «төймә, тияк» (тун ялавын эләктерү өчен таякчык).

**ЭЛГӘР** «предшественник» < чыгт., уйг., үзб., госм. һ.б. *илгар* «алдынгы отряд, авангард; тиз генә ясалган баскын, һөҗүм» < (безнеңчә) монг. *илгар* «алдыңгы отряд», сүзмә-сүз «алдагы кул» (*ил, эл* «ал як, алдынгы», *гар* «кул»). К. Будагов I: 84.

Дерив.: **элгәрче** «алдан хәбәр бирүче». К. **Элгәре, Элек.**

**ЭЛГӘРЕ** «предварительно; заранее» < гом. кыпч., к. кар. *илькэри,* куман., гом. кыпч., алт., чыгт., урта төрки *илгäри* > гом. угыз. *илэри,* уйг. *илгәрү* < бор. төрки (ДТС: 208) *ilgärü* «алга; алда; көнчыгышка» ← бор. төрки *ил, эл* «алгы як; көнчыгыш (тирмәләрнең ишеге көнчыгышка каратылган), ишек төбе» + *гäру* (юнәлеш кушымчасы). Шулай итеп, **элгәр** белән **элгәре** – өлешчә генә тамырдаш. **Элгәре** < **элеккәре** сүзе дә бар. К. **Элек.** ЭСТЯ I: 347.

Дерив.: **элгәрге < элгәреге; элгәртен < элгәретен** (чаг. *югары → югартын*); **элгәр-ү (< элеккәр-ү)** сүзе дә килеп чыга ала. К. түбәндәгене.

**ЭЛГӘРТ-Ү** диал. «упредить, опередить; предотвратить, принимать превентивные меры» – морфологиясенә караганда, ***элгәр-** фигыленең йөкл. юн., ләкин андый фигыль теркәлмәгән шикелле; ихтимал, **элгәр-ү < элгер-ү**дер: **элгер-ү** фигыле булса, ул тат. (ТТДС I: 531; ТТДС II: 389) **элке,** себ. (Тумашева 1992: 54) **илки** ~ каз., төркм., төр., бор. төрки (ДТС: 208) *ilki, ilkin* «тәүләп, беренчеләй, элекке буларак» ← *ilk* «элек» (к. **Элек**) сүзеннән киләчәк (чаг. *соң → соңар-у: соңару – элгеру* антонимнар булган). *Элгеру* > *элгәру* күчеше **искәрү** сүзенә аналогия буларак килеп чыга ала. Икенче яктан, монда **элгәр** сүзенең дә тәэсире булган, әлбәттә. Räsänen 1969: 170. Чаг. ш. ук **Эл-ү II.**

Дерив.: **элгәртел-ү, элгәрттер-ү. Элгәрт-ү** бик кирәкле фигыль булса да, әдәбиятта сирәк кулланыла, аның урынына **алдан алу** тәгъбире очрый (ләкин бу бик уңышлы түгел).

**ЭЛЕК,** себ. (Дмитриева 1981: 131) **äлик [әлик]** «раньше, прежде; прежде чем», (ТТДС I: 531) **элек** «рано» > чув. *ĕлĕк* «элек» < куман., кар., каз., госм. (һ.б. угыз) *илк* «беренче», уйг., чыгт. *илк, илик* «башлангыч чор, тәүдә» < бор. төрки (ДТС: 208) *ilik, ilk, ilki* «элек, тәүдә» > як. *илик* «беренче, беренчел». Будагов I: 85; ЭСТЯ I: 348–350 (бай әдәбият китерелә), Федотов I: 147. Чаг. **Эл-ү II, Элке.**

Дерив.: **элекке; электән → электәнге.**

**ЭЛЕП, элип, әләп** (ТТДС I: 531, 543) «начиная с» ← себ. (Тумашева 1992: 50) **эл-ү** «җиту; барып җитү». Чаг. **Элгәрт-ү.** Тат. әд. *алып* «әлеп» сүзенең монда катнашы бармы икән – әйтүе кыен.

**ЭЛҖЕН (көне)** «Ильин день (христианский праздник)» – август башы < рус., әлбәттә. К. ш. ук **Илҗә көне.**

**ЭЛКЕ, элкен** (ЗДС: 805) диал. «прежде, сначала» ~ бор. төрки (ДТС: 208) *ilki, ilkin* id., к. **Элгәрт-ү, Элек.**

**ЭЛКЕ-САЛКЫ, элке-селке** (ЗДС: 805) «вяло, не торопясь» ~ кырг. һ.б. *илки-* «әкрен эш итү», төр. *ilik-* «агым тукталу», *ilgü* «тоткар».

**ЭЛМӘ** «ильма» ~ чув. *йĕлме* id. < рус. *и́льма, и́лем* id. (к. Фасмер IV: 126–127) ~ ним. *Elm, Ulme*, лат. *ilmus, ulmus* һ.б. id. Pokorny: 302; Федотов I: 194. Kluge: 940.

Дерив.: **элмәле, элмәлек.**

**ЭЛПӘ I**, диал. (ТТДС I: 542) **әлпә** «тонкий слой, плёнка, перепонка; зубная эмаль» > мар. (Гордеев I: 91) *äлпä, ĕлпä* id. Чаг. **Элперә-ү.**

**ЭЛПӘ II** «хитрость, обман» << монг. *илбе* ~ калм. *ilwə dzilwə* id. Ramstedt 1935: 207 (тат. сүзе белән чагыштыру аныкы).

Дерив.: (Остроумов 1872: 139) *элпяля-* «хәйләләп серен белү», (Balint 1988) *elpačen* «хәйләкәр».

**ЭЛПЕРӘ-Ү** (ТТДС I: 532) «износившись, утончаться» ~ к.-калп. *илбире-,* як. *илбирии-,* эвенк. *илбилэ-* id., к. ССТМЯ I: 306–307. Морфологиясенә караганда, *элпер* < *илпир* «юкарган катлам» нигезеннән. Тат. *элпер канат* «юка, нәфис канат» сүзен ЗДС (: 805) нишләптер «йөнтәс канат»дип аңлата.

**ЭЛҮ** «подарки невесты в пору свадьбы» – **эл-ү I** сүзеннән, әлбәттә. каз. (ҚТДС: 418) *iлуге салу* яшь киленнең бүләкләре.

**ЭЛ-Ү I** «повесить, зацеплять; прицепить, схватить (быстро)» < гом. төрки, бор. төрки *ил-* < *иил-* «элү (һәм аерым телләрдә бүтәнчәрәк мәгъ.)» ~ уйг., төр. диал. *ыл-* id., төрки телләрдә иң продуктив нигезләрнең берсе: тат. телендә **элен-ү, элеш-ү, элдер-ү** («тиз генә качып, йөгереп китү» мәгъ. активрак); **элгәк, элмәк, элге, элгеч; эленке-салынкы > элке-салкы;** диал. (ТТДС I: 530–533; Тумашева 1992: 50) **элдек, элгет, элгецә** һ.б. «элгеч, эләктергеч». Күрсәтелгән дериватлар күрше мар. (к. Гордеев 1973: 49), удм. һ.б. телләргә кергән. К. ш. ук **Эләк-ү.** Räsänen 1969: 170; ЭСТЯ I: 343–346; ССТМЯ II: 259.

**ЭЛ-Ү II** (Тумашева 1992: 50) «успеть к месту». Чаг. **Элек.**

**ЭМБЕР, имбир** «имбирь» < рус. булса кирәк; бу сүз Европа телләреннән килә, к. Фасмер II: 129; Kluge: 440 (ахыр чиктә дравид телләреннән диелә).

**ЭМЕҖЕ,** (БТДҺ: 415) **өмөжө** «малина; малиновое варенье», диал. (ТТДС I: 533) **энежи** «малина» < удм. *элгезь,* мар. *ыҥгыжҫ, ĕҥĕz,* морд. *индзей* һ.б. К. Toivonen: 165.

**ЭМИ** диал. к. **Ими.**

**ЭНӘ, инә,** диал. (ТТДС I: 530; ЗДС: 205, 681, 691, 802, 803) **ивнә, инйә, ийнә ~ ийенә, үнә, эзнә, эҗнә**, себ. (Тумашева 1992: 50–53) **игнә, иңнә,** (ДС III: 199) **ёйни** «игла, иголка» < гом. кыпч. *йинэ, инэ*, алт., тув., як. *ине*, як. *инйа,* алт. *иине*, үзб., уйг. *игнә, нинә,* уйг. диал. *йигнә, җигнә*, төркм., як. *иңне, иңңе, икне, инне*, СС, төр., аз. *игинә* ~ бор. төрки (ДТС: 261–262) *jignä, jiŋnä* һ.б. күп вариантлар (к. ЭСТЯ I: 367–368, әле анда кайбер тат.-башк. вариантлар кермәгән) < бор. төрки *йигинэ, йииңинэ* ~ эвенк. *инмэ*, иске монг. *ǯegün* < *jegüne* id. ← бор. **йэг* «энә, үткен оч». Бик ихтимал, бу тамыр, бор. *jig* «җөй» (к. **Җөй**) сүзе белән гомогендыр. Морфемикасы буенча хөкем йөрткәндә, бор. **йэги-* «тегү» фигыле булган, шуннан **йэги-нэ* «теккеч; энә» сүзе ясалган (*-нә* кушымчасы *әвернә, бирнә, тәртнә* һ.б. кайбер сүзләрдә дә күренә). Бу *-нә ~ -на* бор. *~нәң* «әйбер, шәй» түгелме икән? Будагов I: 202; Räsänen 1969: 200; ССТМЯ I: 316; Мухамедова 1973: 92–93.

**ЭНӘКАРАК** «стрекоза» < *энә карагы*, к. түбәндәгене.

**ЭНӘЛЕК**, себ. (Тумашева 1992: 50, 57) **иңнәлек** «стрекоза» ~ каз. *инелік* id. Чаг. тат. **энәкарак, энә карагы, энәче** id.; сулыклар елга-күлләр тирәсендә булынучан бу бөҗәк энәсыман бер органын «күтәреп» оча – гүяки энә урлап качкан шикелле күренә. Чаг. як. *инйэлик* «бал корты, шөпшә һ.б. чаккысы, угы», үзб. *ниначи* «энәкарак, энәче».

**ЭНДӘШ-Ү** «обратиться (со словом), замолвить» < диал. (ДС I: 254) **өндәш-ү** id. ~ алт. (Радлов I: 1822) *үндäш-* < бор. төрки (ДТС: 626) *ündäš-* «эндәшү, чакырышу», асылда – **өнләшү ← өн** < *үн* (к. **Өн**).

**ЭНЕ,** себ. (Радлов I: 733) **äнi** «младший брат» < гом. кыпч., гом. угыз., уйг., үзб., як. *ини,* төр. диал. *enі*, сары уйг. *ыны,* чыгт. *инäчä,* алт. *иин,* бор. төрки (ДТС: 210) *ini* id., төркм. диал. *ини* «җиян» ~ тунг.-маньч. *ина, инан* «җиян» һ.б. Покровская: 36–38; Räsänen 1969: 172; ЭСТЯ I: 362–363; Рамазанова 1991: 55, 114, 166; Кормушин: 81.

**ЭНҖЕ,** диал. (ЗДС: 809) **энзе,** себ. (Тумашева 1992: 50, 78) **енце ~ йенце**, «жемчуг; бисер; ожерелье» > удм. *инзи* «энҗе», мар. (Упымарий: 248) *чинчи, чинчэ, чынчэ* «сәйлән, сәдәф», (Иванов, Тужаров: 261, 266) *цинци, цĕнцĕ* «ялтырка», чув. *ĕнчĕ* (нәкъ тат. әйтелә) «энҗе» < гом. кыпч., үзб., тәрм., төр. һ.б. *инҗи, инҗү,* башк. *ынйы* < бор. төрки (ДТС: 642 һ.б.) *ǯenčü, jenčü, junču, ünǯü* «энҗе» < кыт. *ǯen-ǯu*

«чын энҗе». Бу сүз Евразия телләрендә бик күп ятрак вариантларда да очрый, мәс., төркм. *һүнҗи*, к.-калп. *хинҗи*, хак. *нěнчě* һ.б. Räsänen 1969: 203; Менгес: 94–100; Федотов I: 155; рус. *жемчуг, земчуг* «энҗе» тур. Фасмер II: 46. К. түбәндәгене.

**ЭНҖЕЛЕ: энҗеле тәкә, энҗеле үрдәк** – в сказках – животные (козёл, утка), в которых превращены царственные особы, букв. «жемчужный, с жемчугом» – энҗе асылзатлык билгесе булып исәпләнгән; к. ш. ук чыгт. (к. Радлов III: 334) *Йäнҗү öгÿзÿ* «Сыр-дәрья елгасы», элек – Хуанхэ шулай аталган. Бор. болгар чорыннан калган археологик табылдыкларда авызына энҗе капкан үрдәк фигурасы еш кына очрый; алар бор. көнч. славян колтларында да сурәтләнә (Рыбаков 1988: 587–588). Семантик җәһәттән болар бөтен Азиягә таралган – к. кор. (МНМ I: 435) *ёыйподжу* ~ бор. төрки (ДТС: 146) *čintamani* < санск. *cintämani* «һәр теләгеңне үти торган энҗе» образына тоташа. Ул энҗене бер үрдәк су төбеннән тапкан да югалткан, һәм үрдәкләр һаман шуны эзлиләр, ди.

**ЭҢГЕР,** диал. (Ф. Йосыпов материалларыннан) **өңгөр, үңгүр**, сөйл. **эңгер-меңгер** «сумерки» < гом. кыпч. *иңгир, иңир*, уйг., бор. төрки (ДТС: 211) *iŋir* ~ кар., чулым. *äңир, äңгир,* алт. диал. *ěнер* «кичәгенәк», башк. (БТДҺ: 415) *эңер* «кич». Гомумән, бу сүзнең фонетик вариантлары хәтсез – аларны Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 354–356) дүрт типка аерып карый: 1) *иңгир//ыңгыр,* 2) *ыгыржын// иқыржын,* 3) *иңрик//ыгрық,* 4) *иңирт//ыңгырт* һ.б.; соңгы типка себ. (ДС I: 235, 238) **ымырт, эңěрт** ~ каз. *имирт//ымырт* «эңгер» керә. К. ш. ук Räsänen 1969: 172; Федотов I: 52 (чув. *ěнер* < **еңәр* сүзенә параллель як. *үнүр* «күптән түгел» сүзен китерә).

*Эңгер ~ ыңгыр ~ ымырт* (һ.б.) сүзен Будагов бик хаклы рәвештә **ымызы** (к.) сүзе белән чагыштыра (*ыңгырғы > ымызы*!).

Дерив.: **эңгерге; эңгерлә-ү** «эңгергә калып йөрү».

**ЭҢЕР,** (ТТДС I: 609) **эмбер** (к. **Эмбер** «имбир, зәнҗәбил» белән бутау!) «жеруха (многолетнее лекарственное растение)» ~ каз. *иир* < бор. төрки (Clauson 1972: 112) *egir* ~ фар. *айгар* < грек. *акороη* id. (Бактрия грек теленнән таралган булса кирәк). Дж. Клоусонның бу чагыштыруы, гомумән, шиклерәк.

**ЭРӘЕШ [ěрәйěш]** (Вәлиди I: 147), (БТДҺ: 407, тат. сөйләшләреннән) **ырайыш** «приличный вид» ← **рәеш.**

**ЭРӘЙБӘК** (ЗДС: 806) «белая фата невесты на свадьбе» < фар. *рӯи пāк* «пакь йөз», ягъни «намусы пакь, гыйффәтле» мәгъ.

**ЭРӘФ** (ТТДС I: 535) «красивость; отделка», себ. **рәф** «карниз» ~ төр. *raf* «киштә» ~ фар., көрд. *рäф* «рәт, группа».

**ЭРБЕТ, эрбет чикләвеге** «кедровые орехи» – сүзмә-сүз «Эрбет шәһәреннән китерелә торган чикләвек (бу шәһәр XVIII–XX гг. сәүдә үзәге булган)». **Эрбет** атамасы үзе **Иргәел** (к.) сүзеннән килә. К. ш. ук **Ирмәк.**

**ЭРГӘ** (ТТДС I: 533–534; БТДҺ: 416; Тумашева 1992: 50) «завалинка; основа, фундамент; длина, вдоль; окольность» (**эргәсендә** «около, рядом»), (Ахмаров, Арсланов 1988: 100) **иргә** «фундамент», (Ш. Мөдәррис әсәрләрендә) **эргә** «авторитет; моральная основа», (М. Җәдил) «цитадель» < гом. кыпч., к. нуг., каз., к.-калп. *ирге* «тирмәнең аскы өлеше, фундамент», алт., кырг. *ирге, иреге* «бусага тирәсе», хак. *иркěн*, тув. *эргин* «бусага, ишек яңагы». Безнеңчә, **Җәргә, Ниргә** (к.) сүзләре белән бердәй. К. **Иргәнәк.** Будагов I: 189 (Тубылда **ирңә** дип яза, ләкин бу яңгыраш үзгә җирдә очрамады).

**ЭРГӘЗЕМБАЙ,** диал. (ТТДС I: 527; БТДҺ: 407, 416) **ырғазимбай, ырғазымбай, эргәзимбай, арғазымбай** «сон-трава», «подснежник», «горицвет» < **эргәзембай чәчәк < иргәҗел байчәчәк** (кабаттаркалыш үрнәге!); соңыннан **чәчәк** сүзе төшерелгән, к. **иргәел < иргәҗел.** К. **байчәчәк, пайчәчәк** «бәхет (өлеш) юрау чәчәге». Ахметьянов 1981: 27.

**ЭРЕ,** диал. (М. Гафури һ.б., гомумән төрле сөйләшләрдә еш очрый) **ирě,** миш. (ДС III: 66) **йěрě** «крупный», күч. «гордый, надменный; надменно» < гом. кыпч., гом. угыз. *ири,* төркм. *иири* ~ себ. (Радлов I: 761; Тумашева 1992: 38) **эри**, иске тат. (Котби һ.б.) **эрик**, чыгт. (Будагов I: 91) *ириг,* уйг., бор. төрки (ДТС: 165, 177, 211) *erig, irig*, уйг., үзб. *йирик* «эре». Бу сүзне иске тат., чыгт. һ.б. *эрик, ирик, ириг* < бор. төрки (ДТС: 177) *erik* «тупас» сүзе белән чагыштыру ышандырырлык түгел. Морфологик җәһәттән *эре* < *ире* < **эйириг* (к. чыгт. *иййрик*) сүзе ниндидер **иир-* ~ **эйир-* фигыленнән дип уйларга мөмкин, ләкин конкрет мәгълүматлар җитәрлек түгел, к. ЭСТЯ I: 371–372. Гомумән, төрки телләрдә *ир ~ иир* дигән омоним тамырлар күп һәм аларның берничәсен **эре** сүзенә таба «борып» була. К. ш. ук Мухамедова 1973: 94.

**Ире > эре** сүзе белән тат. диал., башк. диал. (ТТДС I: 150; БТДҺ: 101) **ирәбә, ирәбе** «эре сөякле; зур, эре; елгыр, җитез; уңган, егәрле» сүзе баглы булуы бик ихтимал. Тик бу сүзнең дә чыгышы-ясалышы ачык түгел (ул бүтән төрки телләрдә юк та шикелле).

Дерив.: **ереле (ереле-ваклы); эрелек; эрелән-ү.**

**ЭРЕМЧЕК,** диал. **эремцек**, (ТТДС I: 534; БҺҺ III: 220–221) **эрек, эремек > эрмек, эретке** һ.б., себ. (Тумашева 1992: 58) **иремцек** «творог». Төп һәм иң киң таралган вариант **эремчек** > чув. *эрĕмчĕк*, мар. *ырымчык* һ.б. < гом. кыпч. *иримчик* (> нуг., каз., к.-калп. *иримшик,* каз. *ірімшік,* башк. *эремсек*) id. ихтимал, **иримчәк* вариантыннандыр. Сүзнең нигезе *ирим* «эрү хәле» ← *ири-* «эрү». Хайрутдинова 1993: 94.

**ЭРЕН,** себ. (Тумашева 1992: 58) **үрүн** «гной» – гом. төрки сүз: нуг., ком., к.-балк. *ирин,* кырг., каз., алт., тув. *ириң,* хак. *іриң,* каз. *іріӊ, ірін* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 213, 258, 263) *iriŋ, jerin, jiriŋ* ~ як. *ириҥэ,* хак. диал. (Радлов I: 1766) *ірäн, ірäӊ,* чыгт., госм. *äрін* һ.б. ← гом. төрки *ири-, äри-* «эрү, череп эрү». ЭСТЯ I: 273–375; Рамазанова 2013: 305. себ. варианты **эрүң* яңгырашыннан булса кирәк. Чаг. ш. ук бор. төрки (ДТС: 257) *jer-* «тәнне кисү».

Дерив.: **эренле, эренсез; эренлә-ү.**

**ЭРЕ-Ү I,** диал. (ТТДС I: 172) **йĕрĕ-ү** «прокисать; творожиться» < гом. кыпч., алт., тув., уйг., үзб., гом. угыз., як. *ири-* һ.б. бор. төрки (ДТС: 263) *jirü-* «эрү; черү». ЭСТЯ I: 289–290. К. түбәндәрәк.

Дерив.: **эрет-ү; эремсү;** к. **Эремчек, Эрен, Эркет.**

**ЭРЕ-Ү II,** диал. **ире-ү** «таять, растаять; расплавиться, растворяться» < нуг., кар., ком. *ири-,* кырг., к.-балк., каз., к.-калп., тув. *эри-*, уйг., чыгт., аз. *әри-,* төркм. *эри-, эрэ-,* гаг. *йери-*, башк. *ире-,* як. *ри-* < бор. төрки (ДТС: 177, 182) *eri-, erü-* id. Шулай итеп, тат. әд. телендә, ш. ук нуг., кар., ком. телләрендә **эре-ү I** һәм **эре-ү II** буталган, контаминацияләнгән. Чув. *ир-* «эретү» күчемле фигыльгә әверелгән (шуннан *ирĕл-* «эрү»). ЭСТЯ I: 289–290, 372–374.

Дерив.: **эрет-ү; эреткеч; эретмә.** К. **Эрмәк**. К. ш. ук диал. **эрү** «эри төшкән» (бу сүз борынгыдан килә, к. тув. *эриг* id.).

**ЭРКЕЛ-Ү** «стягиваться, собираться (в одно место); скапливаться», к. каз., к.-калп., кырг., үзб., чыгт., госм. *иркил-* «тукталу, җыелу; гаҗәпләнеп калу; өерелү, өергә җыелу», төркм. *иркил-* «изрәү, өю, калгу, тынычлану», төр. *irik-, erik-* id. < бор. төрки (ДТС: 212) *irkil-* «бергә җыелу (гаскәр тур.)» ← кырг., чыгт., госм. (Радлов I: 1464, 1467) *irk-* «курку, дертләү; бергә җыелу, өер хасил итү» < бор. төрки *irk-* «җыю» > к.-калп. *ирк-* «тоткарлау, бөяү», чаг. ш. ук ком. *ирки-* «бөреп тегү». ЭСТЯ I: 378–379.

Дерив.: **эркелеш-ү**; башк. (БТДҺ: 417) *эркем* «күлләвек», *эркеү* «өер, җыен», *эркенде, эркенте* «җыелган сыеклык» һ.б.

**ЭРКЕТ,** себ. (Тумашева 1992: 50) **эргет** «жидкость, выцеженная из простокваши; пахта, сыворотка ~ башк. *эккет*, кырг., уйг. һ.б. (Будагов I: 189) *иркит* id. **Эрке-ү** (к. югарыдагыны) сүзеннән ясалган («эчке тартылыш белән бергә җыелган нәрсә»). Хайрутдинова 1993: 98.

**ЭРЛӘ-Ү,** диал. (ТТДС I: 569–570; ТТДС II: 112–113 һ.б.) **йөрлә-ү < йегерлә-ү, җерлә-ү < җегерлә-ү** «прясть» ~ башк. (БТДҺ: 94, 101) *ирлә-* < *игерлә-* ~ чув. *арла-* < *авăрла-* < болг. **әwерлә-* id. Бу фигыль нигезе ике төрле юлдан килеп чыга ала: 1) диал. (ТТДС II: 112) **йегер** «эрләм (пряжа)» сүзеннән (һәм аның бор. яңгырашларыннан), 2) диал. (ДС I: 64, 261) **йегер-ү** ~ себ. (Тумашева 1992: 51, 59, 231) **ĕwĕр-ү > ир-ү, өйөр-ү < үгер-ү** «эрләү» фигыленең интенсивлык формасыннан (чаг. *куу* → *куалау*, *өтү* → *өтәләү, чабу* → *чабалау* һ.б.). **Йĕгĕр-, җĕгĕр-** нигезе күп төрки телләрдә очрый: гом. кыпч., алт. *ийир-,* үзб., уйг. *йигир-,* аз., госм. (Радлов I: 700) *äйр-*, ком., госм. *äгір-* < бор. төрки (ДТС: 16) *egir-* «әйләндерү, бөтерү, эрләү» ~ бор. монг. *egere-, egeri-* (хәз. монг. *ээрэ-*) > эвенк. (ССТМЯ I: 466) *ēрэ-* id.

**Йегер- <** *йигир-* фигылен бик мантыйклы рәвештә бор. төрки (ДТС: 203) *ig, jig* > үзб. (ЎХШЛ: 111) *ийк,* каз., алт., төркм. *иик*, төркм. диал. *ыық* «орчык, күчәр» сүзеннән ясалган дип карыйлар (чаг. ш. ук **эвер-ү** < *эгир-*). Егоров 1964: 20; ЭСТЯ I: 227–231; Федотов I: 27; Мухамедова 1973: 93–94.

Дерив.: **эрлән-ү, эрләш-ү; эрләт-ү; эрләм.** Чаг. **Эрчәк.**

**ЭРЛИГАН: эрлигандай (ирләр)** (ТТДС I: 534) «богатырского роста», ш. ук **өрлектәй** (ир, егет һ.б.) id. ***Өрлегәндәй** «бор. баһадирдай» сүзеннән булса кирәк, чөнки кешене өрлек белән чагыштыру сәеррәк.

**Эрлиган** сүзе көнч. төрки (алт. һ.б.) *Эрлик хан* «дию, җир асты патшасы» сүзеннән булырга мөмкин.

**ЭРМӘК** (Г. Толымбай) «исчезающий остаток таявшего, растворяющегося вещества» < **эремәк** ← **эр-ү II.** Чаг. төр. *irmik* > рус. *ирмик, эрмик* «эремчек төре».

**ЭРЧӘК** (ЗДС: 808) «рычаг». Рус теленнән шикелле, ләкин рус сүзенең этимологиясе бәхәсле. **Эрчәк**нең тат. **иерчәк** «әйләндергеч» сүзеннән килүе дә ихтимал. К. **Иер-ү I.**

**ЭРШЕ, эрәше** (ТТДС I: 532) «мрачный, нелюдимый» ~ ком., к.-балк. *ирши, эрши* «ямьсез» < бор. төрки (ДТС: 212) *irši (irši-qaršï)* «көнчел, дошманлыклы» < санск. *īrşyä* id.

**ЭСКӘК** «пинцет» ← диал. (себ. к. Радлов I: 1528) *іскä-* «тарту, тетү, өтү»; гом. кыпч. *искек,* каз. *іскек ~ искäх,* тув. *испик* «эскәк», бор. төрки (ДТС: 214) *iskä* «эләктереп тартып алу; тетү, йолку», (МК I: 255) *isken-* «кыска үлән ашау, кыска йон (төк) йолку» ~ гом. тунг. (ССТМЯ I: 330) *ис-* «чәч, йон, төк йолку». Бор. төрки-монголларның чәч-сакалларын эскәкләп алулары тур. кытай чыганакларында әйтелә.

Дерив.: **эскәклә-ү.**

**ЭСКӘМИЯ,** (Троянский I: 36) **эскәмлә,** (ЗДС: 808–809) **эскәмбийә, эскәми** «скамья, скамейка». Бу сүзләрнең **эскәмлә** варианты төрекчәдән, калганнары русчадан алынган. Һәр икесе грек. *ςκαμνια* «эскәмияләр» сүзенә тоташа, ә бу сүз исә лат. *scamnum* «эскәмия, юнып эшләнгән нәрсә» сүзеннән. Фасмер III: 632.

**ЭСКӘНҖӘ** «пресс; пытка» < төр., аз. (Радлов I: 1529) *іскäнҗä* id. < фар. *шäкäнҗä* «газаплау, җәфа».

**ЭСКЕРТ** «скирда» < рус. (күп телләргә кергән); рус. теленә бу сүз Балтыйк телләреннән алынган; гомумән, бу сүз белорус теле аша таралган булса кирәк. Фасмер III: 640.

**ЭССЕ,** (ТТДС I: 535) **эсте,** себ. (Тумашева 1992: 50, 61) **ессеү, исү,** иске себ. (Радлов I: 890) **äзү** «горячий; жаркий» < гом. кыпч., к. нуг., ком., к.-балк., кар., кр.-тат., аз., госм. һ.б. *исси*, каз., к.-калп., төркм. *ыссы*, каз. *ыстық,* кырг., төр. *ыссық, ысы, ысық,* уйг. *иссиқ* < бор. төрки (ДТС: 213–220) *isi, isig, ïsïγ* > тув. *изиг,* уйг. диал. (Радлов I: 1539) *ізік*, алт. *изи* > хак. *ĕзĕ*, як. *итии* «эссе» ~ чув. *ăшă* «җылы» – төп яңгыраш **изсиг* булса кирәк, к. **Эссе-ү.**

Дерив.: **эсселе, эссесез; эсселек; эсселән-ү, эссер-ү, эсселә-ү** «эсседән авыру», диал. **сычак** < *ыссычак* «көн эсселеге», **эссен-ү** «җылыну; субъектив эссе дип хис итү», **эссет-ү; эсетмә** (гом. төрки параллельләре бар, к. Будагов I: 47–48) «малярия, бизгәк» һ.б. **Эссе** ним. *Esse* ~ хетт. *hašša* ~ ним. *Asche* «тимерче уты; эсселек; көл» (к. Kluge: 259) һ.б.ш. сүзләргә бик охшаш, ләкин бу очраклы охшашлык булса кирәк. К. **Ысырган-у.**

**ЭССЕ-Ү** диал. (Тумашева 1992: 50) «становиться горячим, жарким» < гом. кыпч., к. нуг., ком. *исы-*, кырг., каз., к.-калп. *ысы-* id. (фигыльләрдә бер генә *-с-*), уйг. *исси-* «эссеү» < бор. төрки (ДТС: 213–220) *isi-, ïsï-* id. > алт., хак., тув. *изи-*, як. *итий-* id., чув. *ăш-* «яну» һ.б. (к. ЭСТЯ I: 668–671).

Геминатсыз *-с-* очраклары икенчел булса кирәк (чөнки һәрдаим *эссе* < *исси* һ.б., к. **Эссе**). **Эссе-** < *исси-* ике төрле аңлатыла ала: 1) *ис, ыс* исем сүзеннән ясалган фигыль дип: *ис-си-, ыс-сы-* ← *ис//ыс* дип исәпләү (Э.В. Севортян шул фикердәрәк), 2) бор. *ирси-, ырсы-* ← *ир//ыр* дип исәпләү, к. бор. төрки (ДТС: 211) *ir* «тауның кояшка караган ягы». Räsänen 1969: 173–174; Федотов I: 95.

**ЭСТ** диал. (ЗДС: 809) «собака». *Эт* сүзенең мондый яңгырашлары бүтән төрки телләрдә дә очраштыргалый. К. **Эт.**

**ЭСТӘ-Ү,** диал. (ДС I: 64) **ситә-ү** «хотеть, желать, просить, добиваться», (ДС I: 238) **эстә-ү** «искать» ~ үзб. *ĕстә-* < кр.-тат., кар., алт., хак., бор. уйг., чыгт., аз., госм. *истä-, истә-* < бор. төрки (ДТС: 214 һ.б. күп ядкәрләрдә) *iste-, издә-, издә-* «эстәү» Э.В. Севортян һ.б. буенча (ЭСТЯ I: 383–385), *излә-* «эзләү» белән бердәй. Безнеңчә, бу бик шикле. Ихтимал, элек **эз-* < **из-* «эзләү» фигыленнән **эзет* < **изит* «эзләү хәле, шөгыле» сүзеннән *изит-э-* фигыле булгандыр. К. **Эт**.

Дерив.: **эстәк** < (кар., уйг.) *истәк*, бор. төрки *istäk* «конкрет теләк, максат».

**ЭСТИП** (м.-кар.) «степь; луг» < рус. булса кирәк. Рус. сүзенең чыгышы ачык түгел; бу сүз гомумән күп телләрдә очрый: төр. *step,* ним. *Steppe* һ.б. (тик гадәттә рус теленнән дип аңлатыла).

**ЭТ,** диал. (ДС III: 64) **ит, ийт**, (ТТДС II: 35, м.-кар. сөйләшендә) **эст, эзт** «собака», диал. «щенок» < гом. кыпч., гом. төрки *ит, ийт*, тув., як. *ыт*, чув. *йытă* ~ тунг. (нан.) *инда*, (ульч.) *иңда*, чжурч-

жень (бор. маньч.) *yintahhung*, чукот. *ыттъын*, коряк. *чытгын*, яп. *инд* (к. ССТМЯ I: 661–662). Э.В. Севортян (ЭСТЯ I: 385) уйг. диал. һ.б. *ишт* вариантын икенчел дип карый, ләкин тат. диал. *эст* ~ бор. монг. *išit* «эт» бу вариантның да бик борынгылыгын күрсәтә. К. ш. ук Räsänen 1969: 174; Федотов I: 187–188; Pritsak 1955: 60.

Ихтимал, чукот, коряк һәм япон сүзләре очраклы охшашлыктандыр.

Дерив.: **этле, этсез; этлек** (күч. мәгъ. «усал юньсезлек»), **этләч** «әрсез», **этлә-ү; этлән-ү; этләш-ү** (бу юн. формаларының мәгънәләре бер-берсеннән чыгарылмый). К. **Этәлә, Етекә, Этләй.**

**ЭТӘЛӘ** (ДС I: 238): **этәлә каз** «вид степного гуся, который гнездится в норах, оставленных грызунами» < каз. *ит ала каз*, кырг. *ит аалы* id., ш. ук төрле мифик хайваннар атамасы. К. Диваев А. Ит-ала-каз (поверье) // Этнографическое обозрение. СПб., 1908, № 1–2.

**ЭТӘР-Ү** «подталкивать» ← **эт-ү** (к.).

**ЭТЕКӘ, этәкә, этәнәй** «пескарь, вьюн, ёрш» ~ башк. (БТДҺ: 420) *этекәй, этеш* id. **Эт** сүзеннән, ясалышлары ачык түгел. К. **Этләй.**

**ЭТЛӘЙ,** (ТТДС I: 536) **этәй** – название малоценной рыбы, обитающей в самых незначительных ручьях ~ башк. (БТДҺ: 421) *этмей, этней* id. **Эт** сүзеннән. Ясалышы ачык түгел.

**ЭТ-Ү** «толкать» < гом. кыпч., алт., гом. угыз., чыгт., уйг. диал., үзб. диал. һ.б. (ЭСТЯ I: 386–387) *ит, ийт* < бор. төрки (ДТС: 215) *it-*, нуг., кр.-тат., чыгт., төр. һ.б. *итә-, ийтә-* id. Шуннан **этәр-** (< гом. кыпч., уйг. *итәр-*), ясалыш моделе буенча к. *тип-ү – тибәр-ү*.

Дерив.: **этел-ү, этеш-ү; этеш** һ.б. бор. телдән үк киләләр.

**ЭЧ,** миш., себ. **эц,** себ. (Тумашева 1992: 62) **иц** «внутренность, живот; внутренняя часть (любого предмета)», себ. (Радлов I: 868) **äц** «подклад» < гом. кыпч., алт., уйг., чыгт., угыз., бор. төрки *ич* (> нуг., каз., к.-калп., тув. *иш*, каз. *ĕш*, чув. *ăш*, башк. *эс*, хак. *ĕс*, як. *ис*), үзб. диал. (Э.В. Севортянда) *иич* id. Чаг. **Эч-ү.** Räsänen 1969: 168; ЭСТЯ I: 388–391; Федотов I: 93–94.

*Эч* < *ич*, бор. төрки (ДТС: 201) *ič* төрки телләрдә иң киң деривацияле сүзләрнең берсе; тат. **эчке, эчлә-ү, эчле** (төрле мәгъ.), **эчсез; эчлек**. К. **Эчәге, Эчәк, Эчек, Эчерге, Эчкәре, Эчкен, Эчмәк, Ычкыр, Ыштан, Ыштыр.** Кулланышта *эч* сүзенең антонимы **тыш** (к.). Шуның өчен **эч** сүзенең беренчел мәгънәсе «корсак» дип карау ялгыш фикер.

**ЭЧӘГЕ** «внутренность (животных), кишки» < гом. кыпч., к. кырг., к.-балк. *ичеги*, алт. (Радловта) *ичäгä, ичеге,* уйг., чыгт. *ичәгү*, (Радлов I: 1520) *иҗагу,* чыгт. (Будагов I: 181) *ичаку,* бор. һәм урта төрки (ДТС: 201; Поппе 1938: 171) *ičägü, ičegü* id. **Эчәк**тән аерырга кирәк. Ясалышы ачык түгел, ихтимал, **эчәге <** *иччәгү* < *ичтәгү*дер, к. фигыльләрдән **-чт- > -чч- > -ч-:** *кичтеру* > *киччеру* > *кичеру, очтыру* > *оччыру* > *очыру; эчтеру* > *эччеру* > *эчеру* һ.б.ш. К. **Эч, Эчәк.** ЭСТЯ I: 392–393.

**ЭЧӘК** «кишки» < гом. кыпч., алт. *ичек, ичäк* (> нуг., каз., к.-калп. *ишек*, каз. *iшек,* башк. *эсәк*), уйг. *ичәк*, үзб. *ичак* һ.б. ← *ич* «эч», ихтимал, деминутив **ич-чäк* яисә (*қуруғсақ, бағырсақ* сүзләре рәтендә) **ичсäк* булгандыр. ЭСТЯ I: 392–393.

Дерив.: **эчәкле, эчәксез** (хайваннар); **эчәклек.**

**ЭЧЕК, чек** (Будагов I: 181) «мех; меховая подкладка» < гом. кыпч., к. кырг. *ичик* > каз. *iшiк* id., бор. төрки (МК) *ičük* «вак җәнлек тиресе» ← *эч* < *ич*; ясалышы ачык түгел. ЭСТЯ I: 393.

**ЭЧЕРГЕ**, диал. (Ахмаров 1910: 19; ТТДС I: 481, 537; Тумашева 1992: 51) **эцерге, черге, чер'и** «подстилка под седло, грубый чепрак; матрац» < гом. төрки (кайбер телләрдә теркәлмәгән), к. уйг. диал., төркм. *ичирги*, чыгт. *iчäргу,* к.-балк., үзб. *чирги*, кар. *чыргы* һ.б. id., башк. *эсерге*, (БТДҺ: 274) *серге* id., ш. ук «курҗын» ← *эч* < *ич*; ясалышы ачык түгел. ЭСТЯ I: 394.

**ЭЧКӘРЕ** «вовнутрь, вглубь» < гом. кыпч. *ичкери, ичкäри*, уйг. *ичкәру,* башк. *эскәре* < бор. төрки (ДТС: 202) *ičkärü* id. һ.б. ЭСТЯ I: 340. *Эчкәре* ← *эч*, чаг. *тышкары, югары, элгәре* һ.б. монда *-қары* аффиксы бар шикелле; бор. төрки *ičkär-* «эчкә керту» сүзенә мөнәсәбәте бик үк ачык түгел.

**ЭЧКЕН** – название этнографической группы татар (на Урале) ~ Алтын Урда һәм Казан дәүләтләрендә اچكين (ничек әйтелгәндер инде) «сарай гвардиясе; эчке сакчылар» (к. Сборник материалов... 1941: 177) – фар. *даруни* сүзеннән калька. Бор. төрки (ДТС: 201–202) *ičkin* «дошман ягыннан

килеп, үз ихтыяры белән бирелгән зат» ← *ičik-* «бирелү, буйсыну» сүзеннән: *ičik-kin* > *ičkin*. Әлбәттә, *ič-* «эчү; эчкә керү» фигыленнән. «Сарай сакчысы» мәгъ. тагы бор. *ičiki, ičräki, ičrägi, ičräk* сүзләре дә кулланылган, к. Мукминова Р.Г. Среднеазиатские термины *тагджа, сукнияр* и *ички* // Письменные памятники Востока. М., 1970: 127–134.

Эчкеннәрнең (һәрхәлдә) бер өлешенең элек христиан булганлыгы мәгълүм.

**ЭЧКЕРЛЕ** «внутренне недоброжелательный (несмотря на внешнюю лояльность)» < *эче керле* дип тә, *эчкереле* дип тә таркатыла ала (соңгы очракта **эч кере** тезмәсеннән). М. Гафуридә: *тышлары керле, вәләкин юк аларда эч кере.*

**ЭЧМӘК** (ТРС 1931; ДС I: 238 һ.б.), диал. (Тумашева 1992: 51) **эцмәк** «варежки мехом вовнутрь; внутренние варежки; внутренняя одежда, жилет» > удм. *исьмек* id. < гом. кыпч., к. башк. *эсмәк*, кырг., төркм., төр. *ичмек*, үзб. (ЎХШЛ: 18) *ичмак* >> нуг., каз., к.-калп. *ишмек* > *ишбек* > *iшпек* «эчмәк, эчке кием», «атка иң аскы ябулык» < бор. төрки (ДТС: 202) *ičmek* «кучкар тиресе; эчерге, чапрак» ← *эч* < *ич*; **-мәк** «кием» мәгъ. икенчел кушымча, чаг. *күлмәк* < *көңүлмäк*; себ. сөйләшләрендә **тышмак** «тышкы бияләй; плащ»; **башмак** «аяк башы киеме»?

**ЭЧРӘ** иск. – послелог «в, во, внутри (чего), внутрь (чего)» < чыгт., бор. уйг., бор. төрки (ДТС: 202) *ičrä* id. ← *ič* «эч»; чаг. *соңра, тышра, үзрә* һ.б.ш. мондый сүзләрдә *-ра//-рә* форманты чув. урын-вакыт килеше форманты *-ра//-ре* белән бердәй булса кирәк. Җәләй 2000: 20–22.

**ЭЧ-Ү,** миш., себ. **эц-ү** «пить, выпивать» < гом. кыпч., уйг., алт., чыгт., гом. угыз. *ич-* (> нуг., к.-калп., тув. *иш-*, каз. *ĕш-*, як. *ис-*, башк. *эс-*, хак. *ĕс-*, чув. *ĕç-*) id., *эч* < *ич* (к. **Эч**) сүзенең фигыль коррелянты дип карала (ягъни *эчү* ул «эчкә алу» дигән сүз, к. төр. *iç-* «эчү; тәмәке тарту»). Räsänen 1969: 163; ЭСТЯ I: 391; Федотов I: 159.

Дерив.: **эчел-ү, эчеш-ү, эчер-ү** (< *ичир-* < *иччир-* < *ичтир-* «эчтерү» формасыннан), **эчтер-ү** яңгырашы хәз. телдә үзенчәлекле мәгъ. алган: *эссе көн су эчтерә,* диелә; **эчем** (**ашам-эчем** дигәндә), **эчемлек, эчке** «эчүчелек, эчкечелек»; парлы сүзләрдә исем фигыль формасында: **ашау-эчү, эчү-косу.**

**ЭШ** «работа, занятие, дело» < гом. кыпч., уйг., үзб., алт., тув., гом. угыз. *иш* (> нуг., каз., хак. диал. *ис*, каз. *ĕс*), төркм. *ииш*, чув. *ĕç (*ĕж?)* – арытабан бик үк ачык түгел; телчеләр бер яктан бор. монг. *üile* > як. *үлэ* «эш» һәм хәтта кор. *iл* «эш» белән, икенче яктан (к. Баскаков 1978: 72) кыт. *shi, šhih* «эш» сүзе белән чагыштыруны алга сөрәләр. Будагов I: 194–196; Räsänen 1969: 174; ЭСТЯ I: 395–396; Федотов I: 158–159.

Дерив.: **эшле, эшсез; эшлә-ү, эшлән-ү; эшлек** (шуннан – **эшлекле, эшлексез); эшчән**, диал., сөйл. **эшмән.** К. **Эшмәкәр.**

**ЭШЕР-Ү,** диал. (м.-кар. һ.б.) **ышыр-у** «протолкнуть, толкать кучу, массу» ~ башк. (БТДҺ: 411) *ышыр-* id. < **ишер-ү** (к. **Иш-ү**); **эшер-ү ~ ышыр-у** сүзе норматив булмаган мәгъ. дә кулланыла. Үзб. (ЎХШЛ: 123) *иширмақ, ышырмак* «эшерү», ихтимал, тат. теленнәндер. Бу сүзләр белән беррәттән чаг. ш. ук **өшер-ү, өшәлә-ү.** Монда контаминация бар.

Дерив.: **эшерел-ү, эшерен-ү** (бусы сүгенү сүзе буларак та актив кулланыла), **эшерт-ү.**

**ЭШЛӘКИ, эшләкәй** «вид певчей птицы»; фольклорда еш кына очрый торган бу сүзнең нинди сайрар кошны белдергәнлеге ачык түгел. Сүзлекләрдә **эшләки** «песнәк» диелгәнгә без бик шикләнеп карыйбыз.

**ЭШЛИЯ [ĕшлĕйә]**, диал. **шелийә** «шлея (часть упряжи)» ~ каз. *шiлия,* ком. *ишлия* ~ тув. *шылыяа* һ.б. рус. *шлея* сүзеннән булса кирәк; бу сүзне **шеле** (к.) белән чагыштыру уңышсыз, чөнки рус сүзенең ышандырырлык һинд.-евр. тамырлары билгеле, к. Фасмер IV: 454.

**Эшлия** тат. һ.б. төрки телләрдә **күтлек** дип атала – бу сүзнең «тәүфикъсызлыгы» **эшлия** сүзен кулланырга мәҗбүр иткән. Рус. *шлея* һәм төрки *шилийә ~ шылыйа* очраклы охшашлыкта да була ала, к. як. *сыалда* «кыска ыштан», *ат сыалдата* «эшлия». К. ш. ук **Шеле.**

**ЭШЛӘПӘ** «шляпа» < рус. < ним., к. Фасмер IV: 456.

**ЭШМӘКӘР** «деловой человек; трудяга» – эш сүзе нигезеннән *-мәкәр* кушымчасы ярдәмендә ясалган; *-мәкәр* кушымчасы тагы (ЗДС: 250, 587) *йиймәкәр* «(җиләк-гөмбә) җыярга әвәсле», *сүзмәкәр, телмәкәр* «сөйләшергә яратучан» сүзләрендә һ.б. очрый. Ихтимал, бу кушымча тат. телендә ясалгандыр; к. **Кәр, кяр**.

Дерив.: **эшмәкәрлек**.

# Ю

**Ю** хәрефе тат. әд. яз. телендә *йу* һәм *йү* дигән авазлар комплексын белдерә. Бу хәреф рус язуыннан алынган һәм рус язуы үсешендә барлыкка килгән. Чаг. ш. ук **Е, Я.**

**ЮА [йуа],** диал. **җуа** «дикий чеснок; дикий лук», «перо лука» (Тумашева 1992: 85) > мар., удм. *юа* < нуг., төркм. *юва*, төркм. диал. (ТДГДС: 14) *аҗуvа,* куман. *yova* «юа, кыргый суган; суган», каз., к.-калп. *жуа*, кырг. *җуа*, төр. *yuya, yuva* «юа яки суган кыягы», бор. төрки (ДТС: 248) *java, jafa* «юа», чаг. уйг. *йаwа* «кыргый» (Радлов I: 15) – бигрәк тә үсемлекләр тур., чаг. фар. *йāwwāū* id.? к. **Ябай.**

**ЮАК** (себ., ЗДС: 256) «веселье, успокоение» ~ каз. диал. *жубак* id. Гомумән, бу сүзгә «үз-үзеңне алдабрак тынычлану, үзеңне тынычландыру» мәгъ. бирелә. Будагов II: 369. К. **Юан-у, Юат-у.**

**ЮАН [йуан, йы̆wан],** диал. **җуан, җыwан** (ЛТ: 157) «толстый (в диаметре)»; диал. «крупный (о телосложении)» ~ нуг. *юван*, каз., к.-калп. *жуан, җуан*, кырг. *җоон,* алт. *дьоон,* хак. *чоон,* як. *суон* «юан, калын»; тоф. *н'оон* id.; интерденталь *-ғ-* сакланган яңгырашларның мәгънәләре төрлерәк: бор. чыгт. (Боровков 1963: 158) *йоғун* «юан; калын (тавыш)», бор. төрки (ДТС: 269) *joγan* «юан», куман., уйг. (Радлов IV: 409–411, 540) *joған* «нәкәс, килбәтсез», чыгт., госм., аз. *jоғун,* төркм. *йоғын* «тупас; авыр гәүдәле», *jуған* «зур буйлы, бәдәнле; югары биек; тупас» һ.б. (ЭСТЯ IV: 208–209).

*Юан* < *йоған, йоғун* «юан (гәүдә тур.)» **югары** сүзе белән тамырдаш һәм (госм., Рабгузи) *йуғ, йоғ* «юан, тулымса, зур гәүдәле; бөек» тамырыннан: шуннан *йоғ-а-* «юанаю, бәдәнгә үсү», *йоған* < *йоға-ған* «юан; үскән» һәм уйг. *йоғ-ар-* «юан, дәү булып китү» → *йоғ-ар-ығ* «үскән, югары»; бор. *йоғ* тамырының фигыль коррелянты да булган, к. бор. угыз. *yoγul-* «үсү, юанаю» («Коркыт ата» эпосы телендә). Чаг. ш. ук яз. монг. *ǯиǯаn, ǯиǯаγаn* «юан; калын (тавыш)» (к. Поппе 1938: 181, 210) < бор. төрки **җуғҗа-ған* < **йоғ-чу-ған*; бор. төрки *joq* «биек урын» (ДТС: 273) һ.б. К. **Юантык, Югары.**

Дерив.: **юанлык; юанай-у** һ.б.

**ЮАНТЫК [йуанты̆ķ],** диал. **җуантык** «короткий и толстый (преимущественно о человеке)» – *-тык* кушымчасы ярдәмендә ясалган (чаг. *култык* < *куңылтык, куентык, муентык, янтык*).

**ЮАН-У [йуан-]**, диал. **җуан-у < йŏван-у < йŏбан-у < йубан-у** (к. Тумашева 1992: 85) һәм **җŏван-у < җŏбан-у** «утешаться, утешиться»; диал. (безотносительно к звучанию) «замешкаться, медлить (отвлекаясь на что-либо); забавляться» > чув. *йăпан- [йăбан-],* мар. (сирәк) *йыван-,* удм. *йываны (< йованыны)* «юану; тынычлану, килешү» < нуг. *йубан-,* ком. *йыбан-,* к.-балк. *җубан-*, кар. *йуван-, йубан-, йувун-,* каз., к.-калп. *жубан-, жөбан-,* кырг. *җубан-*, уйг., үзб. *йупан-* «юану; мавыгу», к.-балк. *джобан-, джубан-* «ашап алу» (һичшиксез күч. мәгъ.) < гом. төрки **йуба-* «тыныч булу; тыныч уйлану» фигыленнән, к. себ. (Тумашева 1992: 81, 85) **йŏбау** «арык, арыклану» – дөресе «хәлсезлектән аз хәрәкәтләнә башлау» ~ ком. *йыбав (йыбаw)* «шатлык» – дөресрәге «тынычлану» (мәгънә күчешләре бер үк сүздән антонимнар ясый), шуннан: **юат-у** < *йобату;* **юаш** < *йобаш* һәм к. **Юбал-у.** К. ЭСТЯ IV: 232, 240–241 (бу сүзлектә **Юаш** сүзе *йуба-* фигыленең дериваты дип каралмый). К. **Юак.**

Дерив.: **юаныч** (күп төрки телләрдә бар).

**ЮАТ-У [йуат-],** диал. **җуат-у < җоват-у < җобат-у** «утешать» > чув. *йăпат- [йŏбат-]* id., ш. ук «игътибарны читкә юнәлтү», удм. *йыват-* «юату, тынычландыру, килештерү» ~ гом. кыпч. *йубат-,* каз., к.-калп. *жубат-, җөбат-,* кырг. *җубат-,* кар. *йувут-,* уйг., үзб. *йупат-,* кар. *йувут-* id. бор. *йуба-* «тыныч уйлану» фигыленең йөкл. юн., к. **Юан-у, Юаш-у, Юба-у.**

**ЮАЧ [йуач]** диал. (нокр., к. ТТДС I: 175) «заречье» << бор. төрки (ДТС: 277) *juwač* id. Ачык түгел.

**ЮАЧА [йуача]** «ритуальная лепёшка с маслом во время свадьбы» ~ чув. *йăва, йăвача* id. (рус. «колобок» диелгән), удм. *юача,* мар. *ювацa* id. (к. Саваткова: 229) ~ көнч. төрки *jawa* «майлы икмәк» (Zenker: 657), бор. төрки *juva* «катлама, катламалы ашамлык» (ш. ук *jujqa, jurqa, juqa,*

*juvγa*, к. ДТС: 227) сүзеннән булса кирәк. В.Т. Егоров буенча, чув. *йăвача* «кош оясы сыман ясалган камыр ашамлык» чув. *йăва* «оя, кош оясы» сүзенән (Егоров 1964: 73), бу сүз исә күп кенә төрки (башлыча угыз) телләрдә очрый һәм *оя [ойа]* сүзе белән тәңгәлләштерелә (к. ЭСТЯ IV: 239). *Юача* белән сөннәтче бабаны сыйлаганнар (Воробьев: 250). Мордваларда да туй ашамлыгы оя сыман итеп пешерелә (бу, күрәсең, «оя коруга» ишарә); татарларда *юача* ритуаль бәйрәм ашамлыгы (к. Хайрутдинова 1993: 45–46), бигрәк тә туйда пешерелә һәм майлы булырга тиеш (к. сатирик җыр: *Камыр баскан кодачаның Кулы ябешә микән; Сезнең якта юачалар Майсыз да пешә икән*); мар. *уйалча, уйача* «юача төре» сүзен *уй* «май» сүзеннән дип карыйлар (Сепеев: 219). *Май*ның изге рухлар белән баглылыгы тур. к. **Май.**

**Юача** бор. *juvγača* «юкамыш» сүзеннән дә була ала. К. **Юкәр.**

**ЮАШ [йуаш], җуаш** «кроткий, тихий, скромный, забитый» > чув. *йăваш* (мар. һәм удм. телләрендә юк, чөнки бу телләрдә шуңа охшаш яңгырашта бүтән сүзләр бар) id. ~ кр.-тат. *yuwaş, cuwaş,* чыгт., төркм. *йуваш*, нуг. *ювас,* каз., к.-калп. *җуас, жуас,* кырг. *җоош, җубаш,* уйг. (Радлов III: 445) *җуаш, җубаш, йобаш,* алт. *дьобош, йобош,* шор. *чобаш,* хак. *чыбас* һ.б. id. бор. *йуба-* «тыныч, тын булу (калу)», уйга талу; семәю, арыганлыктан тынып калу» фигыленнән ясалган исем (*йуба-ш*). К. **Юба-у.**

Бу сүзнең беренче иҗектә *-а-* варианты киң таралган: тат. диал. (ЗДС: 224) **йаваш-йаваш** «әкренләп, әкрен генә», төр., добр. *javaş, jawaş* «әкрен, йомшак холыклы», уйг. *йаваш, йабаш* «юаш» < бор. төрки (Радлов III: 278, 290; ДТС: 248–249) *javaş* «әкрен, йомшак» һ.б. Күрәсең, сүзнең бор, нигезе **qav-//jaw-//jap-* фигыле булган, шуннан, **йау-аш* исем нигезе ясалган, шуңа омоним (бердәй түгел) к. **Юаш-у, Юбал-у** һ.б. Гомумән, монда җентекләп тикшеренәсе бар. ЭСТЯ IV: 51–53.

Дерив.: **юашай-у, юашлан-у; юашлык;** диал. **юашлат-у, юаш-у** һ.б. к. Будагов II: 369; ЗДС: 256; әлбәттә, барча бу сүзләрнең *җ-* вариантлары да бар.

**ЮАШ-У [йуаш-]** (М. Гафури; БҺҺ II: 96) «затихнуть, усмириться» ~ каз. *жуас-* ~ чыгт. *йуваш-, йаваш-,* төр. (Zenker II: 970) *javaš-* id. бор. *йауба-* «семәю» фигыленең урт. юн. булырга тиеш (бу юн. формасы еш кына төп фигыль була һәм бер субъектка гына карый). Күп кенә яңгыраш һәм формаларның уртаклыгы **юаш-у** һәм **юан-у** һ.б. сүзләрнең тамыры уртаклыгын күрсәтә. К. **Юан-у, Юаш, Юбал-у, Юба-у.**

**ЮБАЛ-У, йобал-у** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «ухудшаться; пойти на разлад» ~ як. *субара-* «ябыгу, кечерәю, начарлану», бор. төрки *jubal-* «рәтсезләнү», *juba-* «рәтсез эшләү», *juban* «эштән качу», *jubat* «адаштыру; теләсә ничек эшләтү» (к. ДТС: 277, аерым тәгъбирләрдән чыгып бирелгән бу аңлатмалар бик субъектив булырга мөмкин, ягъни бу сүзләрнең төп мәгънәләре бүтәнрәк булуы ихтимал), к. тат. (эчк.) **йŏбау** «арык» (ТТДС I: 174) < **йоба-у* «арыклану, йончу». К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 248) *javal-* «тынычлану; семәю».

*Юбал-, йобал-* фигыленең киң таралган дериваты **йŏбалғы, җŏбалғы, җубалгы** (ТТДС I: 173, 575–576) «шапшак, җыйнаксыз, будыксыз» – төп мәгъ. «начар, рәтсез эш, рәтсезләнү» ~ бур. *ǯоболонтой < ǯоболонтай* id. Мар. *йуалгы* «сүрән (көн), салкынча» тат. сөйләшләреннән. К. **Юан-у, Юат-у, Юаш, Юба-у.**

**ЮБА-У** (Тумашева 1992: 85) «страдать, мучиться; изнемогать» ~ алт. (Баскаков 1972: 213) *дьобо-* «чирләү», тув. *чова-* «талчыгу; кайгыру» ~ монг. *зово- < җово- <* яз. монг. *ǯoba-* ~ гом. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 260–261) *ǯobo-* «азаплану». Бу гом. алтай фигыле чув. *йăп* «тыныч, тын» тәкълиди сүзе белән чагыштырыла (Егоров 1964: 73), әмма монда тикшеренәсе бар. К. **Юан-у, Юат-у, Юаш-у, Юбалгы.**

**ЮВАРИ [йуwари], җувари** (болгар ташъязмаларында) тар. «представитель определённого сословия в Волжской Булгарии XIV века» – Х. Фәезхан буенча, *йаw әри* «яу ире», ягъни «офицер» – әлбәттә, фараз гына; күренекле галим О. Прицак бу сүзне бор. хәзәр кабиләсе *кабар* белән чагыштырып зур мәкалә язды, к. *Йуар* und kaβar // UAJ, 36, f. 3–4, 1965. Ләкин бу мәкалә дә юраудан артык шәй түгел. Безнеңчә, **җүәри* «крестьян», к. к.-калп. *җүйери* «чөгер, җөгәрә; җөгәрәче». К. ш. ук Гукасян 1978: 26.

**ЮГАЛ-У,** диал. **җугал** «исчезнуть; потеряться» ~ төркм. *йогал-*, каз., к.-калп. *җоғал-*, кырг. *җоголо-*, алт. *дьогол-* < уйг., бор. төрки (ДТС: 273; Боровков 1963 ; 159) *joqal-* id. Күп телләрдә юк. Бу сүз тат. диал. **йуга-у** < уйг., госм., чыгт. (Радлов III: 400–402) *йоқа-* «юкка чыгу» фигыленең төш. юн.,

к. ш. ук тат. диал. (ТТДС I: 176; Тумашева 1992: 86) **йуғат-у** < бор. төрки *joqat-* «югалту» әлеге фигыльнең йөкл. юн. **Юк < йоқ** сүзеннән, әлбәттә.

**ЮГАРЫ [йуғары̆],** диал. **җугары** «вверх; верховой, верховный; вверху; почётное место в комнате» (*югары уз* «проходи на почётное место») < гом. кыпч. *йоғары*, каз. *жоғары, жогары* < төркм., уйг., бор. төрки *joqaru* (ДТС: 273; Боровков 1963: 159) һ.б. (фонетик вариантлары к. ЭСТЯ IV: 213–214) – безнеңчә, борынгырак вариант – чыгт. (Радлов III: 403) *йоққари* – бор. төрки (ДТС: 273) *joq* «биек җир» сүзенең бор. юн. килеш формасы. К. ш. ук төр. *yokuş* «калкулык, текәлек». К. **Юан.**

Бор. төрки (ДТС: 284) *jügürü* «югары, югарыча» сүзе, безнеңчә, аерым сүз (аның «хәзер, хәзерге көндә, иң соңгы моментта» мәгъ. дә бар) һәм бор. **йү* «күтәрелеш, күтәренке төш» (шуннан **йөк, йүксә-**) сүзенең бор. юн. килеш формасы.

**ЮГЫЙСӘ [йуғисә],** диал. **җуғисә;** затланышлы: **югыйсәм, югыйсәң** «иначе, в противном случае; а то» < *юқ исә* < бор. төрки *joq ersä* (ДТС: 272). Чаг. **Юкса.**

**ЮДАК [йудак]** диал. (миш., к. ТТДС I: 116) «долговые проценты» – дөресрәге *ютак [йүтак]* булса кирәк, к. үзб., уйг., төр. *jut-* «йоту; отып алу, үзенә алып калу», үзб. *йутуғ, йутуқ* «отыш; файда, керем». Рус. диал. *юдак* id. төрки телләрдән.

**ЮДЕ [йүдĕ]** (ТТДС I: 185), диал. **йуды** (ДС III: 67), **җүде** «иод, раствор иодистого кальция» < рус.

**ЮЕШ [йүĕш],** диал. **җүвĕш** «мокрый, влажный» ~ башк. диал. *йĕwĕш*, кар. *йивис, йүвюш, йүвүш* < *йивиш* < *йибиш* id. «җебеш» *йиби-* «җебү» сүзеннән. Бор. *йибиш* «юеш; җебү» сүзе белән беррәттән *йибиш-* «җебешү» фигыле дә булган (мондагы *-ш* – **җебеш**тәге *-ш* түгел), шуннан *йибишик* > **Җепшек** (к.).

Дерив.: **юешлек; юешлән-ү** һ.б.

**ЮЖ [йуж]** диал. (ТТДС I: 176) «корка льда поверх снега; наст» < удм. *юж* id. Чаг. рус. *юз* «бозлавыкта тайгак төш; (автомашина) тайгаклау».

**ЮЗӘЙ [йүзәй], йөзәй, йөзөй** диал. (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «добрый дух (у кряшенов)» – *Иисус* сүзеннән булса кирәк (аны католиклар *Йезу* дип әйтәләр); чаг. ш. ук як. *дьөсөгөй, дьөһөгөй* «изге рух – атлар химаячесе; байтирәк сакчысы». **Юзәй, Йөзи** элек кеше исеме буларак киң кулланылган (шуннан *Юзиев*лар).

**Юзәй** сүзе керәшеннәрнең бер өлеше бор. төрки христианнардан (X г. ук) килгәнлеген күрсәтә.

**ЮК [йуқ],** диал. **җуқ** «нет, не (редко)» ~ чув. *çук*, гом. төрки *йоқ*, бор. төрки *jōq* id. (нуг. *йоқ*, каз., к.-калп. *жоқ, җоқ,* кырг. *җоқ,* тув. *чоқ,* хак. *чох,* як. *суох* һ.б., барча тикшеренүчеләр фикеренчә, **җуй-у** «юк итү» сүзе белән бәйле, ягъни *йуқ* < *йоқ* < **йоуқ//йоуғ* «югалган, юк булмыш, *йуык». *Юк// җук* һәм *җуй-у* сүзләренең уртак тамыры ***йо-** дип исәпләнә (*йоқ* сүзенең «ярлы, ярлылык» мәгънәсе исәпкә алына). К. Räsänen 1969: 204–205; ЭСТЯ IV: 211–213).

**Юк** тат. телендә продуктив нигез, шуннан: к. **югал- (югат-), юкла-у, юкса, юксын-у, юклык, юксыл.**

**ЮКА [йуқа],** диал. **җуқа, йо̆қа, йо̆қақ, җо̆қа, йо̆қақ** (в диалектологических словарях плохо отмечены), себ. (Тумашева 1992: 85; ТТДС I: 174) **йуға, йобка** «тонкий, худощавый, слоёный; слойка (мучное изделие)» > чув. *çухе* «юка», *çуху* «юкамыш», мар. *йуку* «юкамыш» (Исанбаев 1978: 35) < нуг., уйг. *йуқа,* ком. *йуққа,* к.-балк., кырг. *җуқа, җупка,* каз., к.-калп. *жо̆қа,* тув., хак. *чога,* уйг. диал. *йуқақ,* кар., алт. *йувқа, йуфқа* «юка», госм. *йуфка*, бор. төрки *jupqa, jujqa, juqa, juvɣa, juvqa* «юкамыш», салар. *йукä,* аз. диал. *йуха* һ.б. (ЭСТЯ IV: 241–242) «юка» < бор. фар. *җӯфт к'āһ* «ике катлы, катлаулы; катлама» сүзеннән, шуннан ук к. **Юкә.** Бор. төрки *juɣa, juvɣa* сүзенең төп мәгъ. «катлы-катлы, катлаулы» икәнлеген М. Кашгари күрсәткән булса да, тюркологлар (шул исәптән ЭСТЯ IV авторлары да) бу сүзнең этимологиясен томанда калдыралар. К. **Юкамыш, Юкә.**

**ЮКАГАЧ [йуқағач]** «молодая липа (ободранная)» < *йүкә агачы*; чаг. удм. *нинпу* id. (*нин* «юкә», *пу* «агач»).

**ЮКАМЫШ [йуқамы̆ш],** диал. **җоқамыш, йықамыш, җықамыш** (ТТДС I: 177, 575, 578) «лепёшка, которая при печении образует два слоя, между которыми остается пространство, заполненное газом, слойка» – **юка** сүзеннән, әлбәттә (бор. төрки *juvqa* «юкамыш», к. ДТС: 283), ләкин *-мыш* кушымчасы биредә аңлашылып бетми: ул гадәттә фигыль нигезләргә ялгана. Күрәсең, *-мыш* биредә

бүтән кайбер ашамлык атамаларыннан күрмәкче генә (*катмыш, җимеш*) ялганган.

**ЮКӘ [йүкә],** диал. **җүкә** «мочало», себ. (Тумашева 1992: 87) **йүгә** «юкә; тастымал», диал. **йөкә [җөкә] агачы** «липа» > мар. диал. *йүкӓ* «липа», чув. *çӑка* id. ~ нуг. *йӧке,* к.-балк. *җӧгә,* ком. *йӧге*, каз., к.-калп. *жӧке*, үзб. *җука* «юкә; юкә агачы», балк. *зӧwге,* төркм. *чӧке* һ.б. «юкә; юкә агачы», кар. *эвкә* «юкә агачы», *йэвкә* «каен», шор. *чуға* «юка; юкә» << фар. *җӯфт к'āһ* «ике катлы, күп катлы, ике кат кабыклы» (*җӯфт* «парлы, сыңарлы», *к'āһ* «кабык»). К. ш. ук калм. *дзӧке* «карама». К. **Юка, Юкагач, Юкамыш, Юкәр.** Егоров 1964: 35; Räsänen 1969: 207; ЭСТЯ IV: 32 (бу авторлар барысы да сүзнең этимологиясен томанда калдыралар).

**ЮКӘР [йүкәр], юкәре [йүкәрĕ]** «луб; внутренний слой коры липы» (тат. телендә генә) << фар. *җӯфт к'āһ рӯй* «ике кат кабыкның йөзе». Шулай итеп, **юка**, **юкә** һәм **юкәр** сүзләре этимологиясенең ачкычы тат телендә: *җӯфт к'āһ > җукак, йукак > йука, йүкә; җӯфт к'āһ рӯ(й) > җүкәре > юкәр.*

Мәзкүр фар. сүзләре бор. Күктүрек дәүләте заманында, һәрхәлдә б.э. I меңьеллыгында үзләштерелгәннәр. Һәм аларның иң тулы составы тат. телендә булу татарларның да борынгылыгына дәлил. **Юкә агачы** башлыча Көньяк-Көнч. Европада үсә, дала-чүлләр өчен дә, Себер киңлекләре өчен дә ул хас түгел. Һәм, димәк, мәзкүр сүзләр Көньяк-Көнч. Европада б.э. I меңьеллыкта күпсанлы фар. телле илат яшәгән һәм ул илат татарлар составына кергән булып чыга.

**ЮКЛА-У [йуқла-], җуқла-у** «переживать отсутствие кого (когда он очень нужен)» ~ башк. диал. *йуқта- – юк* сүзеннән, параллельләре гом. кыпч. һәм угыз телләрендә; кайбер тикшеренүчеләр бу сүзне бор. төрки *joyla-* «мәрхүмне искә алу» (*joy* «дәфен») (к. ДТС: 270) сүзе белән дә чагыштыралар, к. ЭСТЯ IV: 212.

**Ю́КСА [йуқса]** «иначе; если нет, то …» < гом. төрки характерда, к. төр. *yoksa*, кар. *йохса* һ.б.; бу сүзне *юк исә < йок эрсӓ* сүзеннән дип уйлау табигый, ләкин бор. **йок-* дигән фигыльнең шарт формасы дип тә уйларга мөмкин.

**ЮКСӘК [йүксәк],** миш. (без теркәдек. *Р.Ә.*) **йүксүк** «высокий, возвышенный» ~ кр.-тат., төр. *yüksek,* чыгт. *jöksäk,* йүксек id. ← бор. төрки (КБ) *jöksä-* «күтәрелү» ~ як. *ӧксӧй-* «агымга каршы йөзү» ~ монг. *ögse-* id. ← *ög* «югарылык, биеклек», к. Räsänen 1969: 207.

*Йүксәк* «биек (бигрәк тә абстракт мәгъ.)», *йүксәл-* «күтәрелү» уйг., үзб. һ.б. яз. телләрдә дә кулланыла. **Йүксүк** варианты тат. сөйләшләрендә генә бугай.

Дерив.: **юксәлеш** «гомуми күтәрелеш, үсеш». Безнеңчә, *юксә-* сүзе дә булган: ... *ул безне йүксәде* дигәнне ишеткәнем бар.

**ЮКСЫЛ [йуқсы̌л],** иске тат. **йуқсул** «бедняк, пролетарий» < (кар.) *йоқсыл,* төр., уйг., чыгт. *йоқсул* id. (ЭСТЯ IV: 214–215), бор. чыгт. (Боровков 1963: 160) *йоқсул-* «ярлылану»; телчеләр бу сүзне **юк** сүзе белән бәйләргә тырышалар. Безнеңчә, бу сүзнең тамыры *йоқ* «йок, җыелган мөлкәт»; чаг. кырг. *жуқсуғ* «ихтыярдан тыш, ирексездән» < (ДТС: 274) *joksuz* «нәтиҗәсез», *йоқсуз* «мөлкәтсез», к. үзб. *йоққ* «йок» (ЎХШЛ: 135), ягъни «әкренләп җыелган мал-мөлкәт». *Йуксыл < йоқсул* «ярлы» бор. *йоқсу-, йоқса-* «мөлкәткә мохтаҗ булу» (чаг. *җирсе-, суса-*) фигыленнән монг. телләрендә ясалган (*-л* аффиксы). К. **Йок.**

**ЮЛ [йул],** диал. **җул** «дорога, путь; полоса; способ» ~ чув. *çул, çол* < болг. **җол* < гом. төрки *йол* (каз., к.-калп. *жол*, кырг. *җол*, алт. *дьол*, хак. *чол, чул,* тув. *чул,* як. *суол*) < бор. төрки (ДТС: 270–271), төркм. *jool* ~ монг., бур. *зол*, бор. монг., гом. тунг.-маньч. (ССТМЯ I: 262) *ǯол* «юл; уңыш, мач, бәхет» – алтай телләре өчен иң характерлы сүзләрнең берсе; як. *суол* «юл» белән беррәттән *дьол* «бәхет, мач» сүзе дә бар, тик бу гади этимологик дублет кына булса кирәк, гом. төрки *йоол* сүзен «юл» һәм «мач» мәгънәле ике сүз дип карарга нигез юк.

Безнеңчә, *йоол* бүтән алтай телләренә төрки телләрдән таралган һәм тәүдә үк «сәүдә сәфәре» мәгъ. булган һәм, ихтимал, кыт. яки сугд. теленнән кергән берәр тамырдандыр. Үзәк Азия халыкларыннан сәүдә белән башлыча төркиләр шөгыльләнгән. *Юл* «тапталган яки махсус ясалган җир буе, киң сукмак» мәгъ. – икенчел. Будагов III: 381–382.

Әйтелгәнне ошбу сүзнең барлык мәгънәләре раслап тора: бүтән телләрдә – «юнәлеш, барып кайту, сәфәр, күчтәнәч, язмыш», тат. һ.б. юлда очраган кешегә *юл булсын* дип тәбрикләү, бор. төрки *jola-* «озату». К. ш. ук **Юлла-у, Юлык-у, Юлы.**

**ЮЛА [йула]** диал. «рай», «лампа, светильник; свет» (м.-кар. сыгытларында мәрхүм тур. «Юлада булсаң иде», «Юлада күрешербез» кебек тәгъбирләрдән чыгып әйтәбез) ~ чаг. уйг., бор. төрки (ДТС: 278) *jula*, чув. *чула* «нур, яктылык (сакраль мәгънәдә)», бор. монг. *ǯula* «шәм» < кыт. *чжу ла* «лампада (икона алдында изге шәм яки шәмнәр җөмләсе)». Мәгънәсе белән **юла** христианнарның *Елисей болыннары* «кыяматтә гөнаһсыз кешеләрнең оҗмах көтеп яшәгән урыны» сүзенә охшаш. К. ССТМЯ I: 279; Räsänen 1969: 210.

**ЮЛАК [йулак̡]** «полоса, дорожка; старица; сухое русло» < *йул-ак̡* (*-ак̡* кечерәйтү кушымчасы) < гом. кыпч. *йолак̡* (каз., к.-калп. *жолак̡*) < бор. төрки (ДТС: 271) *jolaq* «сукмак, юлчык; юлюллы» – *юл* < *йол* сүзеннән, әлбәттә. К. ЭСТЯ IV: 219.

**ЮЛАКАЙ [йулак̡ай], юлагай** «попутно, попутный» – ачык түгел. **Юл** сүзеннән булса кирәк. Монг. сүзенә охшаган (*-гай* аффиксы). Чаг. **Юлык-у.** Чаг. каз. *жолай, жолшыбай* id. һәм **Юлай** исеме.

**ЮЛАМАН [йуламан]** «попутчик; сотоварищ» – гадәттә [аның белән] **юл аман** дип аңлатыла.

**ЮЛА-У [йула-]** «подходить, подойти» – **юл** сүзеннән дип уйларга мөмкин, ләкин дөресрәге < **юы-ла-у** (к. диал. **йуы** «якын», к. **Якын**).

Дерив.: **юлат-у** «рөхсәт итү, мөмкинлек бирү», **юлатма-у** «якынлаштырмау».

**ЮЛАУЧЫ [йулаwчы̆]** «путник» < **юллау-чы.**

**ЮЛӘР [йүләр],** диал. **җүләр** «дурачок, сумасшедший» > чув., мар. *йӱлер,* удм. диал. *жулер* id. ← ***җүлә-** «шашыну, акылдан язу» фигыленнән, к. уйг. *җөлә-, җөли-* «төштә, йокыда сөйләнү, күп сөйләү». Кырг. *жөөлү-,* алт. *дьүлү-, дьүүл-, йүүл-* id., як. *сүүл* «җенси ярсыну чоры», *сүүле-* «җенси ярсыну» < калм. *зүүл-* «саташу, шашыну, ярсыну» < бор. монг. **ǯegüle-* id. (Ramstedt 1935: 485) **ǯegü* нигезеннән, чаг. тунг.-маньч. *ǯэгдэ-* «яну; кызу», бор. монг. *ǯegün* «көнчыгыш; сул». К. ЭСТЯ IV: 33 (**юләр** сүзе китерелми).

**ЮЛӘ-Ү I [йүлә-]** диал. «соединить, соединять швом; пришивать, пришить» < миш. *йүлә-ү* «җөйләү» сүзеннән, к. **Җөй.**

**ЮЛӘ-Ү II [йүлә-]** < себ. (брб.) **йөлө-ү** id. (Тумашева 1992: 88) «поддержать, падающий предмет; помогать в нужный момент». ~ кырг. *җөлө-,* алт. *дьөлө-, йөлө-, йөле-,* хак., тув. *чөле-* «терәтеп кую; ярдәм итү; исәпләү» һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 32–33). Чаг. **Йөлен.**

**ЮЛБАРЫС [йулбары̆с]** «тигр» < гом. кыпч. *йолбарс* (кырг. *җолбарс,* каз., к.-калп. *жолбарыс*) «юлбарыс; каплан; арыслан» < *йоллы барс (барыс)* сүзеннән булса кирәк, төрле фикерләр тур. к. ЭСТЯ IV: 219.

**ЮЛЛА-У [йулла-]** «ходить с претензией; ходатайствовать; направлять; выискивать» ← **юл** әлбәттә.

Дериваты: **юллан-у** «юнәлү, юл тоту».

**ЮЛЛЫ [йуллы̆]** (регуляр. мәгънәләрен исәпләмәгәндә) «толковый» – **юл** сүзенең «уңыш, мач» мәгънәсеннән.

**ЮЛЛЫК [йуллы̆к̡]** «проход (дыма в печи)» – тат. телендә ясалган булса кирәк. Әлбәттә, **юл** сүзеннән.

**ЮЛТЫЙ [йулты̆й]** диал. (к. мәкаль: *Юлтый юлламыйча торалмый*) «искатель удачи, авантюрист», чаг. себ. (Тумашева 1992: 85) **йулта-у** «эздән бару». Чаг. монг. *золтай* < *ǯoltaj* «бәхетле, уңышлы; юллы». К. **Юл.**

**ЮЛЫ [йулы̆],** диал. **җулы** «раз; заодно», диал. **йусы < йулсы, йулысы** id. < бор. төрки (ДТС: 271) *jolï* id. *юл* < *йол* сүзенең 3 зат тартым формасыннан дип уйларга мөмкин, әмма бүтәнчә булуы да ихтимал.

**ЮЛЫК [йулы̆к̡]** «праправнук» ~ үзб. *җавлык̡* id. Ачык түгел.

**ЮЛЫК-У (юлык, юлыгу),** диал. **җулык-у** «попасть на …; встретить (неожиданно)» ~ чув. *ҫулăх* < гом. кыпч. *йолык̡-, йолук̡-,* төркм. *йолук̡-,* каз., к.-калп. *жолык,* к.-балк., кырг. *жолук̡-,* аз. *jолух-* < бор. төрки *joluq-* (ДТС: 272) «очрашу» – бор. **jol-* яки **jolu-* «юлга чыгу, юлда йөрү» фигыленнән (интенсивлык формасы).

**ЮМА [йума], җума** «плоская верёвка из трёх, пяти, семи и пр. нечётных прядей (с чётными

прядями вить плоскую ремнеобразную верёвку практически невозможно)», күч. (ЗДС: 193) «льстивый» ~ төр. *yoma* id. ← **yo-* ~ чув. *яв-* «яссы бау ишү». **Юма** сүзенең дериватлары билгелерәк: **юмакай, йомакай** (> чув. *йămакай*) «оста телле ялагай» (теле **юма**га охшаш), **юмала-у, җумалау-җүкәләү** «төрлечә ялагайлану».

**ЮМАЛ [йумал]** диал. (ТТДС I: 117) «пресный; слащавый; поверхностно, поверхностный, недостаточный (в чём-либо)» ~ чув. *çăмăл* «җиңел, җиңелчә (уй, фикер), өстән-өстән» ~ удм. *зумал* «төче» болг. теленнән булса кирәк. Чаг. **Җиңел.**

**ЮМАРТ [йумарт],** диал. **йөмарт, җомарт** id. «щедро, щедрый, тароватый» > чув. *юмарт* id., удм. *ӟомарт* «алчак, илгәзәк», мар. *йомарт* id. < фар. *җăвāнмăрд* (к. ЛТ I: 156) «яшь кеше, егет». Күп төрки телләрдә очрый (мәс., кырг. *жоомарт,* төр. *cömert* id.).

Дерив.: **юмартлык, юмартлан-у** һ.б.ш.

**ЮМАР-У [йумар-]** «мять в кулаке, захватить в кулак и мять» – **йомарла-у** (к.) белән бер нигездән.

**ЮН-У [йун-],** диал. **җун-у** «обтёсывать, тесать» ~ чув. *çун-* < гом. төрки *йон-* (кырг., к.-балк. *җон-,* каз., к.-калп. *жон-,* алт. *дьон-,* тув., хак. *чом-*) id. ~ як. *суон-* id. бор. гом. төрки **йо-* тамырыннан (ЭСТЯ IV: 221–222) исәпләнә, чаг. ш. ук бур. *зула-* < *зуӊла-* «юну»; кар. *йон* «уелма бизәк» (исем) һәм *йон-* «юну», *йонцу* «скульптор».

**ЮНЬ I [йүн],** диал. **җүн** «направление; толк» > чув. *йӳн*, мар. *йӧн* «юнь, рәт, чара, чыгу юлы», удм. *йӧн* «яхшырак» (*йӧн-йӧн* «җитди»), *ӟӧн* «чара, рәт», морд. Э. *ён, ёнь* «юнь (юнәлеш, акыл)», морд. М. *ён* «юнәлеш», *ёнь* «акыл, хәтер» < гом. кыпч. *йӧн* (кырг., к.-балк. *җӧн,* каз., к.-калп. *жӧн*) «юнәлеш, як, рәт; гади, гадәти, арзан», госм., төр. *yön* «як, юнәлеш; эчтәлек; караш», к.-балк. *җӧн* «диафрагма (аергыч)». Гомумән, бу тамыр сүз кыпч. телләрендә һәм төрекчәдә иң продуктив нигезләрнең берсе: тат. **юнәй-ү, юнәл-ү, юнәлт-ү, юнәт-ү, юньле, юньсез, юньчел**, диал. **юнән-ү, юнәү** һ.б.

**Юнь** < *йӧӧн* сүзенең чыгышы бигүк ачык түгел; бор. төрки сүзлектә һәм Себер төрки телләрендә ул юк (к. ЭСТЯ IV: 232–234), Федотов (I: 203–204) *йӧн* > *йӳн* сүзен бор. монг. *ӡаŋ* (к. **Заң**) «холык, кагыйдә, закон» белән чагыштыра, ләкин бу чагыштыру нигезсез. Ахметьянов 1989: 109–110.

**ЮНЬ II [йүн],** диал. **җүн** «недорогой» > чув. *йӳн*, үзб. уйг. *жун, җун* «юнь, сыйфатсыз» Г. Рамстедт фикеренчә, бор. монголчадан (к. JSFU XXXVIII, Helsinki, 1922–23: 9). М.Р. Федотов та (I: 204–205) шул фикердә, к. бор. монг. *йпе* > тув. *үне* «бәя». Чаг. ш. ук **Юнь I.**

**ЮНЬЛЕ-БАШЛЫ [йүнлĕ-башлы̆]** сөйл. «приличный; терпимый», **юне-башы юк** «не на что смотреть». Боларда *юнь* «халык», *баш* «идарә», к. алт. (Баскаков 1965: 299) *дьюнын-бажын билген* «халкын һәм идарәсен белгән».

**ЮРА-У [йура-],** диал. **җура-у,** (Тумашева 1992: 86) **йуры-у** «гадать; толковать (знамения, сны); приписывать, решить заключить (по некоторым признакам)» < гом. кыпч. *йора-, йоры-* (кырг. *җоро-,* үзб. (ЎХШЛ: 135) *йоры-,* башк. (БТДҺ: 127) *йуры-,* ком. *ёра-*, каз., к.-калп. *жоры, җоры*) id., к.-балк. *җора,* төрки *yora* «фараз, тәгъбир», *йорала-* «юрау» ~ иске яз. төрки телләрдә; төр. *yor-* < бор. төр. (к. ДТС: 276) *jor-, jör-* «юрау, сүтү, чишү», як. *сүӧр-*, аз. *йоз-* һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 223–225) ~ калм. *йор* «ырым», бур. *ёро* «начар галәмәт» сүзе белән чагыштырыла. Галимнәр тәүге мәгъ. «чишү, чишелеш» дип уйлыйлар. Кыпч. формаларыннан чыгып фикерләгәндә, сүзнең тамыры *йор* > *йӧр* исем булган. К. **Юргә-ү.**

*Йура-* < *йора-* бор. **йойра-* ~ *йойру-* сүзеннән дә килеп чыга ала, к. тат. диал. *җуй* (*уй-җуй* дигәндә) ~ кырг. *җой*, үзб. *йой* һ.б. «ният, фараз, эш планы, әмәл, хәйлә».

**Юра-** продуктив сүзьясагыч нигез, к. **Юри.**

**ЮРГА [йурға],** диал. **җурга** «иноходец; иноходь; игривый, проворный, много ходячий» > чув. *çăрха,* мар. *йорга*, удм. *йурго* id. < гом. төрки *йорға* (к.-балк. *җорга,* кырг. *җорго,* каз., к.-калп. *жорға,* алт. *дьорго, йорго,* хак. *чорга* һ.б.) < бор. төрки *jorïya* (ДТС: 274) ~ бор. монг. *ӡiruya* > эвенк. *ӡирээ,* тув. *чыра,* хәз. бур. *җороо* «юрга». Ясалышы бәхәсле сүз (к. ЭСТЯ IV: 225–226). Чув. *йăрка-, йăркка-* «юырту» ~ себ. **йурға-у** id. (Тумашева 1992: 86) үзенчәлекле. Һичшиксез **юыр-у** (к. **Юырту**) < *йугыр-у* сүзләре белән тамырдаш (*юрга* < *йугырга !*). Чаг. ш. ук як. *дьорогой* «юрга, җитез, елгыр», *дьоруо* «юрга (ат)».

Дерив.: **юргала-у.**

**ЮРГАН [йурған],** диал. **җурган,** отличается обилием фонетических вариантов (что характерно

для заимствованных слов): **йуырган** (ДС I: 122), **йуртқан** (Тумашева 1992: 86), **җөбырган** (ДС II: 260), **җеборган, җыбырган** (ТТДС I: 569, 577), **йурқан** (БТДҺ: 126) «стёганое одеяло» > чув. *юркан,* мар. *йорган,* удм. диал. *ӟурган* id. < гом. кыпч., угыз. *йорған, йоорган,* к. каз., к.-калп. *жорган,* үзб. *җурган* < кар. *йувурган,* нуг. *йувыркан,* кырг. *җууркан,* алт. *дьууркан,* каз. диал. *жуырқан* < бор. чыгт. (Поппе 1938: 200) *yawurqan*, бор. төрки *joɣurqan*, тув. *чоорган*, як. *суорган* һ.б. (ЭСТЯ IV: 225–226), к.-балк. *җув урган* (бу вариантлар дөрес булса) үзенчәлекле; чаг. ш. ук эвенк. *ӡибин* «кабатланган, катланган» → *ӡибгэхун* «юрган» (ССТМЯ I: 259). Безнеңчә, бу сүзнең ачкычы тат. диал. **җеборган** < *җөб орган* < бор. фар. (сугд.) **җүф(т) опрақан* «ике кат (кат-кат) иске кием» сүзеннән, к. фар. *жүфт* «катлы», бор. төрки (ДТС: 368) *opra-* «искерү (кием тур.)», шуннан **opraqan; opraq* «кием-салым, иске кием, ятак әйберләре» – юрган итеп гадәттә иске өске кием файдаланылган, ул гадәттә тишек-ярык булганлыктан, аны ике кат итеп аерым кисәкләрен беркетеп йөрткәннәр. Байларча юрган бәрән тиресеннән эшләнгән һәм *көрпә* (чаг. *көрпә юрган*) «бәрән» дип аталган. Әле 1930–1940 нчы елларда да юрган гадәттә корама була иде.

**ЮРГӘК [йүргәк]**, диал. **җүргәк, йөргәк, йүргә, йүргө** (Тумашева 1992: 89; ТТДС I: 184) «пелёнка» << бор. төрки *jörgäk, jörkäk* (ДТС: 276) > чув. *чӧргек* id. Тат. диал. **йүргә-, җүргә-, җүрмә-ү** «уратып җөйләү», «җеп урау», гомумән «урау, чорнау, чолгау, биләү» < бор. төрки **йӧрге-* id. Бу фигыльләр исә бор. төрки *jör-* < алт. *дьӧр-* >> як. *сӧрӧ-* «бөтерелү, уралгалау, чорналу, чолгану» фигыленең ешайтылу формасы. К. ш. ук рус диал. (Аникин: 182) *дёрге* «тутырма (колбаса төре)» < алт. *дёргем* id. < бор. төрки *jörgä-* «урау, төрү», диелә. К. **Юрьгәмеш.**

**ЮРЕЛГЕ [йүрӗлгӗ]** (себ., ЗДС: 260) «тетива». Ачык түгел.

**ЮРИ [йүри]** «нарочно» – к. ш. ук **юрамалый, юрамалы**, башк. *юрамал*, к.-калп. *жорамал* id. – **юра-у** сүзеннән (*юрый* «юрап» > *юри*) шикелле; бу сүзнең ерак параллельләре бар, к. эвенк. *ӡор'е, ӡори* < яз. монг. *ӡoriyuda,* монг. *зориуд* >> як. *соруйан* id. (ССТМЯ I: 265).

**ЮРТАВЫЛ [йуртаwы̆л]** тар. «конный отряд, посылаемый для угона скота» ~ чыгт. *йуртаул, йуртағул,* кырг. *җуртуул, жортуул,* к.-балк. *жортаwул* id. *юырт-* < *йӧрт-* «табыш эзләп «юырту» сүзеннән, к. кырг. *жорт-* id. (к. **Юырт-у**). Рус. *ертаул, ертул, уртоул, юртаульный полк* «авангард һәм разведка чәсте», к. Будагов II: 371; Фасмер I: 28; 1996 елгы башкортча-русча сүзлектә *юртауыл* «авангард» дип аңлатылган, хәлбуки Л. Будагов сүзлегендә башк. *йуртуыл* «талау сәфәре».

**ЮРТАК [йуртақ]** «рысак» > мар. *йорток,* чув. диал. *юртах* < гом. кыпч. *йортақ* (кырг. *җортақ* «гади ат», каз., к.-калп. *жортақ* «юртак») id. гом. кыпч. *йорт-* «юырту» сүзеннән. Чаг. ш. ук түбәндәгене.

**Юртан** «җитез, тере», чув. *юрккӑн, юрткӑн* < тат. **йурткын* «тик тормаучан, артык хәрәкәтчән, елгыр»; чаг. рус. *юркий?* К. **Юырт-у.**

Дерив.: **юртакла-у ~ юртанла-у.**

**ЮРТЛА-У [йуртла-]** «жить (оседло)» (к. Тумашева 1992: 86) ~ каз. диал. *жортта-у* (ҚТДС: 129) тув., хак. *чуртта-, чурта-* id. «йортла-у».

**ЮРЫК [йуры̆қ], йоруқ** (Тумашева 1992: 83, 87) «хождение по делу», «лад, способ; приличие; благонравие; прилично», **журық** (к. ЗДС: 193) «продолжение (хорошего)» > морд. Э. *ёрык* «мәгънә» ~ башк. *йурық* «уңай; юнәлеш», ком. *ёрық* «система, тәртип», к.-балк. *җоруқ* «формулировка, норма, норматив», кырг. *җоруқ* «йөреш-торыш; тәртип, кыланыш», каз., к.-калп. *жорық,* үзб. (ЎХШЛ: 138) *йуруқ, йуръқ* «церемония, юсык», алт. *дьорык* «юл, сәфәр; юырту», тув. *чоруқ,* хак. *чорых* «сәфәр; юырту», бор. төрки (ДТС: 274) *jorïq* «гадәт, яшәү рәвеше; йөреш», (Боровков 1963: 162) *йорық* «гамәлдәге; абруйлы» һ.б. бор. *йоор-* «йөрү, гамәлдә булу» сүзеннән булырга тиеш (чаг. тат. *акча йөрү, закон йөртү*).

**ЮРЬГӘМЕШ [йүргәмӗш]** (ЗДС: 260) «репейник (?)», **йүргәмец, йөрмәwец** «паук; паутина» (Тумашева 1992: 89; ЗДС: 266) ~ кырг. *җӧргӧмүш* id., бор. төрки *jörgäj* «чорналчык үсемлек», *jörgänč* «үрмәгөл» – барысы да *йүргә-* < *йӧрге-* «чорнау» фигыленнән, к. ш. ук алт. (Будагов II: 372) *йоргомыш* «үрмәкүч», хәз. алт. *дьӧргӧнӧк, дьӧргӧмӧш* id. (төп мәгъ. «пәрәвез» булса кирәк). Чув. диал. *энкрамӗш,* мар. *ӓнгырымшы, энкремыш* «үрмәкүч» ← *аңгыр* «ау, кармак» (тат. сөйләшләреннән булса кирәк, чөнки *-мыш//-меш* аффиксы чувашныкы түгел). К. **Юргәк, юрмә-ү ~ җурмә-ү.**

**ЮСЫК [йусы̆к]**, диал. **җусык, йо̆сук** «общий порядок (распорядок), устав», диал. (ТТДС I: 177) «порядочный» ~ башк. *йуҫық, йуһық* id., ш. ук «кирәгенчә; уңай (белән); бөтенләй», кырг. диал. *җосок*, каз. *жосақ, жосык*, алт. диал. *дьозок* «үз-үзеңне тотыш үрнәге» һ.б. **Юсын** (к.) сүзе белән бәйле, к. ЭСТЯ IV: 31–32.

**ЮСЫН [йусы̆н]** «закон общего поведения, вежливость; порядочный, вежливый» ~ үзб. *йосун*, кырг. *җосун, җошун*, каз. *жосын* «гореф-гадәт, борынгыдан килгән әдәп-тәрбия кагыйдәләре» (к. ҠТДС: 126–127) < бор. төрки (ДТС: 275), бор. монг. *josun* «гадәт, традиция», маньч. *йоңсу* «әдәп; гореф-гадәт» < кыт. *йун-су* «гадәт, гадәттәге» (к. ССТМЯ I: 347). Чаг. монг. *йаса* < *йоса* «традицион закон, Чыңгыз хан кануннары» (**Яса-у** белән бер түгел!). Будагов II: 376–377; Гаврилов 1929; Räsänen 1969: 103.

**ЮТАЗЫ [йутазы̆]** «название крупного села и реки в Татарстане», чаг. уйг. *йотаза, җотаза, җотта* «мантый (ашамлык)». Икенче яктан, чаг. к. **Талбазы, Туймазы** һ.б.ш. авыл һәм елга атамалары.

**ЮТӘЛ [йүтәл],** диал. **җүтәл** «кашель» < гом. кыпч. *йөтел* (кырг. *җөтел, җөтөл,* каз., к.-калп. *жөтел, жөтөл*), уйг. *йотал, йөтәл* < бор. төрки (ДТС: 277) *jotül* id. < (алт.) *дьөдүл, дьөтүл* > алт. диал., тув. *чөдүл,* хак. *чидил,* як. *сөтөл* (к. ЭСТЯ I: 227) – *йөт* < *дьөт* тамырыннан (к. **Йөткер-ү**). Сүзнең ясалышы бигүк ачык түгел, ихтимал бор. **йөте-* фигыленнәндер. К. кырг. *жөтөл-*, үзб. *йўтал-* «ютәлләү», тув. *чөдүр-* id.

**Ю-У [йу-],** диал. **җу-у, җыw-у** «мыть, стирать» < гом. кыпч., куман., уйг. *йу-* (к.-балк., кырг. *җу-*, нуг., каз., к.-калп. *жу-*) ~ чув. *ҫу-, ҫӑв-,* хак. *чу-*, тув. *чуг,* алт. диал. *дьуг-,* угыз. *йуй-,* як. *суй-* «бәләкләү; юу» һ.б., к. ЭСТЯ IV: 238–239.

Бу бер иҗекле сүзнең төрки булмаган телләрдәге параллельләрен чамалау кыен.

Тат. *йу-* < *йо̆w-* продуктив нигез, к. регуляр ясалышлар: **югыч, юдырт-у, юдыр-у** һ.б., иске тат. (Троянский II: 336) **йуык** «юылган».

**ЮХА [йуха],** диал. **җуха** «льстец, подхалим (имеющий злой умысел); льстивый» > чув. *ҫука, юхха, ҫухха*, мар. (Исанбаев 1978: 10) *йука,* удм. *юхо* id.; **юха елан** миф. «чибәр хатын-кыз кыяфәтенә кергән елан (бәкедән чыга һәм кеше йоклаганда канын суыра)»; мифологемага күрә, елан мең ел яшәсә аждаһага, аждаһа мең ел яшәсә юхага әверелә; төрекмән фольклорында: елан (озак яшәсә) *ювха* дигән жанварга, *ювха* (озак яшәп) *ювдарха*га, *ювдарха* исә *аждарха*га әверелә (к. Каррыев: 43–51). Бу сүзләр (һәм мифологема) бор. кыт. (б.э. башлары, «Шуцзин» китабында әйтелгән) *люңхуа* «аждаһа гүзәл» (*люң* «аждаһа, ләү», *хуа* «гүзәл кыз, чәчәк»), *люң дар хуа* «аждаһа – зур гүзәл» (*дар* «зур, бөек») сүзләреннән килә. Чаг. себ. тат.: **«әштәһә йылан** мең йәшәсә **әштәр** болыр, әштәр мең яшәсә **әшкәр** булыр» (Радлов, Образцы … IV, 1882: 246). К. ш. ук к.-калп. *җуwһа* «ялагай». Юха образына һиндуистик мифологиядә *нача, начини* (елан кыз) охшаш. К. МНМ II: 195.

Тат., башк. *йуха* сүзендә *-х-* авазы булу аның чагыштырмача соң гына берәр чыганактан (монголчадан яисә иске бор. төрки китаптан) алынма булуын күрсәтә. Ләкин сүзнең таралышын билгеләргә материал юк: хәз. сүзлекләрдә мондый (иске мифологиягә караган) сүзләр гадәттә күрсәтелми.

**ЮЧЕН [йүчӗн]** (Габдессәлам, к. Мирас № 9, 2000: 14) «аристократка, холёная дочь» < монг. *җүшин* < кыт. *фу-җин* id. (Будагов I: 790), к. тув. *дүштүк* «кәләш».

**ЮШ [йуш]** (**юравы юш килү** «сон в руку»), диал. **җуш** «соответствует, соответствующий» (к. *Ефәк пута билгә буш, сатин казакигә җуш*, к. М. Фәйзи җыйган җырлар). Ачык түгел. Чаг. нуг. *йош*, каз. *жош*, к.-калп. *йош*, төркм. *йоош* «илһам», уйг. *йуш, йус* «(начар) галәмәт» ~ фар. *җош* «дәрт, илһам; теләк, шатлык».

**ЮША [йуша],** диал. **йоша** (ТТДС I: 175; БҺҺ III: 73), **йөшә** (Тумашева 1992: 128) «олень; лось» (болан белән пошыйны бутау тат. һәм башк. сөйләшләренә гомумән хас) ~ рус. *юшак, юший, вьюшак* «пошый үгез бозавы (ике яшьтәге)», *юшак, южан* «ике яшьлек урман боланы» (к. Матвеева 1962: 39), билгесез (бор.) фин-угор теленнән дип уйланыла. Ләкин к. монг. *ǯusaγ* «ике яшьлек кучкар» ← *ǯusa-* «җәйләү, бер җәйне тулысынча яшәп үткәрү (*ǯuⁿ* «җәй»). К. Владимирцов: 174. Мәзкүр хезмәтләрдә тат., башк. **йуша** (һ.б.ш.) искә алынмый. Чаг. **Җуша** («охра, охра төсендәге»; *җуша болан* > *юша*?)

**ЮШӘ-Ү [йүшә-],** диал. **йуша-, җуша-** «пребывать в покое (пережёвывая) – о животных» ~

кырг. *җуша-, җууша-, җокша-*, каз. *жууса-, жувса-*, нуг. *йувса-* «күшәп тик тору» (Г. Рамстедт буенча) бор. монг. *ǯoγsa-,* хәз. монг. *зогсо-* (> тув. *соқса-*) «тукталу; тик тору», к. ЭСТЯ IV: 34–35 (тат., башк. сүзләре юк!). Чаг. **Юшатыр** Башкортстанда зур гына елга (мал көтүләрен шунда юшатканнар).

**ЮШКЫН I [йушқы̆н]** «накипь; осадок, наносы; полынья» > чув. *юшкăн* «юшкын; ләм», мар. *йошкын,* удм. *ǯушкын* «юшкын» < себ. (туб.) *йуушқŏн*, башк. (БТДҺ: 130) *йыушқын* «юшкын», безнеңчә, иске тат. *йуыш-* «кайнау, кайнап чыгу, күбекләнеп алу» сүзеннән, к. үзб. *җошқын* «кайнар, кызгын, кызу канлы», *җуш урмақ* «ташып кайнау», госм. (Радлов III: 173) *җуш-* «ташып чыгу; кайнашу», төр. *coşku* «кайнарлану, шашу күренеше», *coşkun* «кайнар, кызу; әсәрләнгән, дулкынланган», *çoşmak* «кайнап чыгу, ташып чыгу; ярсу», төркм. *жошгун* «ташкын», *җошмак* «ташып чыгу», кырг. *җошы-,* каз., к.-калп. *жосы-* «шаулап агу» һ.б. ~ фар. *җӯш, җӧш* «кайнау, порху; дәртләнү (күренеше)». Чаг. **Явышкын.** ЭСТЯ IV: 232.

**ЮШКЫН II [йушқы̆н]** (ЗДС: 259), «плесень типа водоросли» **юшкын I** белән гомоген булса кирәк. К. **Явышкын.**

**ЮЫК [йуwы̆қ]** (Тумашева 1992: 87) «близко, близкий» ~ госм., кыпч. *йуwық* (кырг., к.-балк. *җуwық,* каз., к.-калп. *жуwық*) id. бор. төрки *jaγ-u-q* «якынайган» (*jaγ-u-* «якынаю») сүзеннән, к. **Явык.**

**ЮЫРТ-У [йуы̆рт-],** диал. **җуырт-у, юрт-у** «бежать рысью» < «заставлять бежать рысью» ← диал. *йуыр-, йŏwор-* «йөгерү, чабу». к. кар. *йувур-*, нуг. *йувыр-*, каз., к.-калп. *җуwыр-* «йөгерү; чабышу» < бор. төрки **йоғур-* > тат. диал. (миш.) **йŏгŏр-у, йыгыр-у** «йөгерү, чабу». Нишләптер төрки телләрдә *йорт-* «юырту» варианты бик киң таралган һәм хәтта төп вариант шул дип санала (ЭСТЯ IV: 226–227). Хәлбуки, *йорт* < **йоғурт-* (**йоғур-* сүзенең йөкл. юн.) дип исәпләү бернинди дә кыенлыкка терәтми. Шул ук *йоғур-* нигезенә **йөгер-ү** < гом. төрки *йүгүр-* һәм *йөр-, йөре-* < гом. төрки *йоры-* сүзләре дә тоташса кирәк. Кайбер тюркологлар, монгол материалы белән мавыгып, *йүгүр-* һәм *йоры-* нигезләрен гетероген сүзләр дип карыйлар. Хәлбуки сүзара мөнәсәбәтләрне тәүдә төрки телләр эчендә ачыкларга кирәк.

Гомумән, **йөгер-ү, йөре-ү** һәм **йуыр-у** сүзләренең гомогенлыгы мөмкин түгел дияргә сәбәп юк, ләкин алар арасында бәйләнешләрнең ничеклеген күрсәтеп бирү дә тәвәккәл адым, чөнки фонетик, семантик һәм морфологик закончалыклар һәртөрле фаразларга юл куя.

**Йөре-** < *йүрү-* һәм *йүрә-* вариантларыннан чыгып, тәүге аффикс *-ра//-ру* (*-рä//-рү*) булган дип уйлау мантыйклы (бу аффикс һәм аның шундый вариантлылыгы яхшы билгеле), *йүгүр-* варианты *йүгрү-*дән килеп чыга ала. Шул тәкъдирдә сүзнең тамыры **йоғ* < **йоғу* «тиз хәрәкәтләнү, чабу, йөгерү» булып чыга; **йөрү** мәгънәсе (һәм сүзе) икенчел (моңа аналог: немесләр *gehen* «йөрү» сүзен сирәк кулланалар, аның урынына, хәтта әкрен атлау тур. сүз барса да, *laufen* «йөгерү» сүзе кулланыла). Шулай итеп

бор. → *йоры-* → *йорға-* > тат. диал. *йурға-у,*
*йоғу-ру* → *йүрү-* > тат. *йөре-*,
*(-ра)* → *йүгүр-* > тат. *йөгер-*.

Чынлыкта бу схема катлаулырак булырга мөмкин, әлбәттә. Ахметьянов 1989: 80.

**ЮШЬКӘ [йүшкә],** диал. **җүшкә** «заслонка, задвижка, вьюшка» > мар. *йушка*, чув. *юшкĕ, йӱшке* < рус. *вьюшка* (*вей-* «җил исү» тамырыннан).

# Я

**Я** хәрефе элекке *йа* һәм *йә* урынына тат. язуына рус алфавитын куллануга керткәч килеп кергән. Бу хәреф үзе дә рус язуы үсешендә килеп чыккан.

**Я** хәрефен куллану, язуны кыскарту белән бергә, тат. телендә кайбер уңайсызлыклар да тудыра һәм кайчакта язма сүзнең укылышын махсус аңлатырга туры килә (к. «Мәдәни җомга», 2004 ел, 29 август саны, проф. Ф. Хатипов мәкаләсе). Шунысы кызыклы ки, иң элекке төрки руник алфавитта да *я = йа* хәрефе очрый һәм кайбер тикшеренүчеләр, *я* хәрефен руслар бор. төрки алфавиттан алмадылармы икән, дип тә сорау куялар. Без бу хакта «Ялкын» журналында бер мәкаләчек бастырган идек. Руслар кириллицага күчкәнче ниндидер бер алфавит кулланганнар, ул алфавит хәзәрләрдән яки болгарлардан алынган бор. төрки руник алфавит булган бугай диләр. *Я* руник язуыбызда ук очрагач, *я* хәрефе «үзебезнеке» булып чыга…

Татар әдәби *я- [йа-//йә-]* комплексына урта диалект сөйләшләрендә бик еш кына *җа-//җә-* комплексы тәңгәл килә (охшаш тәңгәллекләрнең барысын да чагылдырып бетермәдек). *Йа, йә* комплексына башланган сүзләрдә төрле контаминацияләр, радиацияләр, дублетлар ешрак очрый.

**Я I [йа°]** ы. – выражает восхищение и удивление, а также недовольство: «до чего же», мәс., *я, бу нихәл; я, бу кадәр түземсез булырсың икән* һ.б.ш. Гом. көнб. төрки сүз. Гар. телендә дә бар.

**Я II [йа°]** иск., кит. – слово почтителного обращения: «о!». *Я Гали* «о Али (сказал пророк)», *я Хода*. Төр. (Özön: 901) *ya,* фар. *йā* < гар., гар. эндәш кисәкчәсе.

**Ярабби** (к.) сүзендә дә шул ук ымлык: *йа Рабби* дип язылып, әйтелеп килгән, соңрак кына кушып яза башлаганнар. ДТС: 221.

**Я III [йә],** диал. **җә** «да-да, ладно; ну, ну-ну» ~ гом. кыпч. *җә, йә,* каз., к.-калп. *жә* ~ монг. *че, дже, зэ* id.; тат. **ягез, җәгез** ~ ком. *җәгиз* «әйдәгез, башлыйк, керешик». Чаг. **Яме.** К. Dobr. III: 463 (фар. теленнән диелгән).

**Я IV [йә],** диал. **җә** – препозитивная частица принуждения: «ну, давай; согласен; ну и что» ~ чув. *йе,* мар., удм. *йа, йä, йе,* удм. диал. *ӟä, зä* (Насибуллин: 115) < гом. төрки *йэ, җэ,* алт. *че, чее, тье, дье, нье,* кр.-тат., төр. *ya* (Dobr. III: 463), як. *чä, ччä, чiä* (Пекарский: 3594) ~ монг. *жэ, зэ, дзэ, че* (төрле диалектларда төрлечә).

Постпозитив *йә* «ярый, яхшы, хуш», шул ук сүз булса кирәк. Түбәндә – фигыль нигезе (к. *йәгез!*), «әйдә, башла» мәгъ.; шуннан *я инде* < *я инде* үкенүне, түземсезлекне белдерә торган модаль сүз – борынгыдан килә (к. тув. *җä амды* id.); *яле* < *йә әле* (> удм., мар. *яле*), *яме* (> мар., удм. *йамĕ, йäмĕ, ӟамĕ*) тат. телендә ясалганнар. Гомумән, бу сүз киң таралган, хәтта рус сөйл. (Аникин: 183) *дже, де, дьэ* «ну, вот». ЭСТЯ IV: 44–45.

**Я V [йә],** диал. **җә** – частица определительная и разделительная «или; или … или, то ли … то ли» ~ чув. *е ... е,* мар. *йа ... йа, йэ ... йэ,* удм. *йа ... йа, ӟä ... ӟä* < гом. көнб. төрки *йа ... йа* (к. Радлов III: 2) ~ фар. *йā ... йā* id. Кавказ телләрендә дә киң кулланыла (Абаев I: 563). Бу сүзне фар. теленнән таралган дип кистереп әйтмәс идек. К. **Яисә, Яки.** ЭСТЯ IV: 44–45.

**ЯБ [йа°п]** (себ., ЗДС: 223) «возвышенность, повышенное место» (которое заслоняет или прикрывает что-либо). Сүзлектә *-б* белән язылган бу сүз **җап** (к.) «борт, кырый» белән бердәй түгелме икән?

Дерив.: **йаб асты** «ышык җир».

**ЯБА I [йа°ба]** (себ., ЗДС: 223) «крытый ток» ~ каз. *жаба* «кош тоту өчен корыла торган сыңар кыеклы куыш».

**ЯБА II [йа°ба]** «специальная рогатина, вилы с двумя широкими зубьями (при веянии на ветру» ~ тат. диал., кр.-тат. *җаба,* (Dobr. III; 464) *уава,* каз. *жаба,* үзб. *йаба,* төркм. *йааба,* чыгт., госм. *йапа* «тишекле көрәк, сәнәк». К. Räsänen: 187; ЭСТЯ IV: 45 (*япь* ~ *җәп* сүзе белән бердәй дип карала, безнеңчә, бу шикле).

Дерив.: **ябала-у** «ашлыкны җилгәрү өчен яба белән һавага ату».

**ЯБАГА [йа°баға],** диал. **җабаға, җабағы** (ДС I: 260) «линяющий; линяющий (однолетний)

жеребёнок; шерсть-линька» > мар. (Саваткова: 235) *явага* «ике яшьлек бия», удм. *ябалга* «икенче яшьтәге колын; ябага», чув. (< кр.-тат. яки нуг.) *йопах, йупах* «ябага йон», *йупах тыйха* «ябага тай» < гом. кыпч. **йабаға,* ком., нуг. *ябағы,* каз., к.-калп. *жабаға*, кырг. *җабаға*, к.-балк. *җабағы*, аз. *йапағы*, *йапаги* һ.б. < бор. төрки (ДТС: 221) *japaγu, jabaqu* id., к. ш. ук кар. *йапаға* «кыркылган йон», гаг. *йапаа* «йон, сүс», бор. төрки *yapaγu qoj* «куе йонлы сарык» (к. Clauson: 874–875); сүзлекләрдә бор. төрки *jap* «йон» сүзеннән иканлеге күрсәтелә, әмма ясалышы аңлатылмый. Безнеңчә, сүзнең бор. яңгырашы удм. телендә сакланган *йабалга* сүзендә: *йаб-а-л-ға*; *йап* → *йапа-* «йонлау, йон үсү» (шуннан аз., төр. *йапақ, yapak* > тат. диал. **йапак** «ябага») → *йапал-* «йонлану, үзендә куе йон үсү» → *йапалки* (төркичә) > **йабалгы* яки **йапалга(й)* (монголча) > *ябагы, ябага-*. Монг. *дагаки* «ябага» < *ǯawaқи* < алт. *дьябақы.* Рус. *ябага, ебага, джабага, чибага, джибага* «язгы сарык йоны; ябага тай» тур. Аникин: 182, 195, 720; Räsänen 1969: 188; ЭСТЯ IV: 125–126; Ахметьянов 1989: 79. К. **Ябык I.**

**ЯБАГАЙ [йаᵒбағай]** (Ф. Бурнаш), диал. **җабағай** «бедный, захудалый» (к. ш. ук **ярлы-ябагай** «беднота») < бор. монг. *jabuγaj, jabuγar* «җәяүле» ← *jabu-* «җәяүләү», чаг. алт. *јокту-јойу ≈ юклы-җәяү* «ярлы-ябага» (к. Маадай-Кара 1973: 151, 464). Тат. диал. **йабағай** «үткен сүзле; чәчән» (к. Тумашева 1992: 63) < бор. монг. *jabuγan (jabuγaj) üliger* «әкият, әкиятче» = «җәяүле дастанчы» сүзеннән (к. ССТМЯ I: 337). Дастанчылар гадәттә **җәяү йөргәннәр** (чаг. башк. *йәйәүле Мәхмүт* – мәшһүр дастанчы исеме).

**ЯБАЙ [йаᵒбай]** диал. «дикий; одинокий; дикорастущий» – себ. (Тумашева 1992: 63) **йабайы** «кыргый иген», башк. *йабай* «кыргый, садә; кечкенә буйлы ат токымы», каз. *жап, жаба, жабайы, жэбэ,* ком. *йабу,* нуг. *йэбэ* «кечкенә ат токымы; кыргыйлашкан ат, кыргый ат». Бор. кыпчак далаларындагы кыргый атлар, күрәсең, кечкенә буйлы, кечкенә колаклы (к. **Ябалак**), бик зур яллы, көлтә койрыклы булганнар (к. ш. ук **Җәбә: җәбә хәере**). Чыгышы белән *йабай, йабайы* – фар. *йāwāū* «кыргый» сүзеннән; к. кырг. *җапайы, җабай* «кыргый, кыргыйлашкан». К. **Юа, Япан.** К. Ахметьянов, 1975: 73; ЭСТЯ IV: 46.

**Ябай** һәм **җәбә** сүзләренең бердәйлеге шуннан да күренә: нуг. *Ял-қуйрык тез битәр деп Йәбәдән айғыр қоймаңыз – Явға минмеге ат тувмас* (Ноғай халық йырлары: 97) ~ башк. *Ял-ҡойроғо тулы тип, Ябайҙан айғыр алмағыз; Ҡойон-дауыл уйнатып, Урал һыртын сыңлатып Яуға сабыр ат тумас* (Башҡорт халыҡ ижады. Эпос 1982: 178, 170).

**ЯБАЛАК I [йаᵒбалақ],** диал. **җабалак** «сова; сыч, филин» < гом. кыпч. *йабалақ* (каз., к.-калп. *жабалак, җапалак,* кырг. *җапалак*), иске тат. **йафалак** < уйг. *йапалақ, йапилақ,* чыгт., угыз. *йапалақ* < бор. төрки *jabalaq, jaba qulaq* > алт. *йаба қулақ, йабы қулақ*, себ. (Тумашева 1992: 69) *йапқолақ,* хак. *чаба (чабаң) хулах* һ.б. id. (к. ЭСТЯ IV: 129–130). Этимологик сүзлекләрдә *ябага, япак* сүзләре белән бағланышлы дип аңлатыла (Räsänen 1969: 187; Clauson 1972: 875); безнеңчә, каз. диал. (к. Аманжолов: 375, 377) *жебе қулақ* «колагы кыргый ат – җәбәнеке шикелле» сүзеннән, к. **Ябай, Җәбә.** Чаг. **Өке.** Сафина 2006: 38–40.

Ябалакларның кечкенә каурый колагын язгы йон-ябагага охшату гайре табигый кебек.

**ЯБАЛАК II [йаᵒбалақ]: ябалак кар** «снег хлопьями»; без бу сүзне элек (Әхмәтьянов 2001: 260) гом. төрки характердагы (к. ЭСТЯ IV: 130) *йапалак* < *йалпалак* «яссы, ялбыр» сүзеннән дип аңлаткан идек. Ләкин к. уйг. *ләгләк кары* «ләкләк кары – язгы кар (ләкләк килгәндә яуган кар)», к.-балк. *жебалак кар* «язгы кар»; к. ш. ук тат. *карга кары (бураны)* «март аенда яуган кар (буран)». Тат. **ябалак кар** – көзге кар, ябалаклар төньяктан килгәндә яуган кар – **Ябалак I** сүзеннән булып чыга.

**ЯБАЛДАШ [йаᵒбалдаш]** (Троянский II: 271) «крона», диал. (Остроумов 1892: 64; ДС III: 217) **җабалдаш** «кругловетвистый; раскидистый», (Avьl xuçalьƣь həm urmancьlьq atamalarь: 31) **йәбәлдәш** «крона дерева», **җабалдаш** «приземистый» ~ башк. (БҺҺ II: 97) *йәбәлдәш,* кырг. *чапалдаш, җапалдаш, жапелдеш* id. К. ш. ук **ябалдак** (Г. Әпсәләмов) «ябалдашлы; ябалдаш», **ябалгы** (без теркәдек. – *Р.Ә.*) «ябалдаш», чаг. алт. диал. *сарбагалду* «ябалдаш, ябалдашлы», алт. чулым. *сарбақ* id., *сарбай-, шарбай* «киңәю, ялпаю» ~ монг. *сарбайи-* id., *сарбагар* «киң ябалдашлы», калм. *сарвә-* «як-якка ботаклану» (Joki 1952: 285) < алт., тув. *чарба-* id., ш. ук «ялы ике якка киткән (ат)» < **җарба*.

Сүзнең ясалышы катлаулы: *йабалдаш* һәм *йабалдак* бор. **йабалда-* < *йабалла-* < «һәр якка киң итеп ботаклану» фигыленнән, фигыль исә *йабал* <

диал. *йалбал-, йарбал-* < монг. *йарбағал* (*-гал* аффиксы) «киңәйгән нәрсә» сүзеннән, бу сүз төрки **йарба, йарпа* (тәкълиди сүз) «җәенке, киң» нигезеннән, к. **Җарпай-у, Ялпай-у.**

**ЯБАНҖЫ** к. **Япанчы.**

**ЯБӘЛӘ [йәбәлә]** (ЗДС: 239) «толк, порядочность», иск. «подарок, дар» (к. мәкаль: *Эндәшмәгәнгә ябәлә юк.* Исәнбәт III: 495), **җәбәлә, җәбелкә** «спортивный интерес» (*Кәҗәсе кыйммәт түгел, җәбелкәсе кыйммәт*, сабантуй бүләге тур., к. Исәнбәт III: 133) ~ чув. *йапала,* мар. *явала* «җиһаз; әйбер» (< тат. булса кирәк), каз. (ҚТДС: 118) *җебелек* «чәчәк кушып үрелгән ял», кырг. *җебилге* «атның парад дирбиясе – баш өстенә беркетелгән чук-чачак», төр. *cebeli, cebelkü* «матур шайманлы (сбруйлы) ат»; чыгт. *җәбәлкәр* «шайманлы ат», Г. Нәваи әйткәнчә, монг. теленнән, к. монг., маньч. (ССТМЯ I: 280–281) *ǯәбәлә* «уң як; уңга асыла торган ук савыты» (шуннан Г. Исхакый телендәге *җәбәлә як «*уң як»). К. ш. ук **Җәбәләй, Җибәләй**. Doerfer I: 283; Sumer 1983: 98–99.

**ЯБГУ [йабғу], җабғу** – титул верховного правителя, фактического властителя (но не хана) во многих тюркских государствах древности (особенно до монгольских завоеваний). Яз. вариантлары: *jafγu*, *javγγu* (*javγuγu)* иң бор. теркәлешләрдә (VII г.) *dabγuγa,* гар., әрм. чыганакларында *джебу*, соңгыракларында *yakvu, yakju, yaquy* һ.б. id. Тат. диал. (ЗДС: 223) **йабугай** «үткен сүзле», ихтимал, бор. титулның чагылышыдыр. Гомумән, бу титулны фар. яки кыт. теленнән килә дип уйлыйлар, Гумилёв исә гом. төрки *йап-* «башкару; хисап бирү» сүзеннән ди. Бернштам А. О древнейших следах джекания в тюркских языках Средней Азии // Памяти акад. Н.Я. Марра. М.–Л., 1938: 18–20; ДТС: 222–223, 249; Баскаков 1987: 72; Ögel: 226. Чаг. **Ябдаш, Яп-у II.**

**ЯБДАШ, йабдәш, йәптәш, җәптәш** (ЗДС: 184; 223, 242) «ловкий, дельный, способный; живой, общительный (о характере) – *яп-* «эшләү, башкару» һ.б. (к. **Яп-у II**) сүзенең исем коррелянты **йап* «эш, башкарыш» сүзеннән шикелле. Чаг. **Җап, Яп** «канау, сугару каналы»? **Япташ** бер каналдан су алучы».

**ЯБЕШ-Ү [йәбеш-],** диал. **җәбеш-ү** «прилипать; рьяно приниматься за дело; накинуться (с бранью)» – *йабыш-* нигезеннән палатальләшеп килеп чыккан. К. **Яп-у.**

**Ябеш-** нигезеннән ясалган сүзләр **ябыш-** нигезеннән параллель ясалганнарыннан мәгънәләре җәһәтеннән аерылып торалар; *ябештерү* «җилемләп тоташтыру», *ябыштыр-у* «ябу, каплау»; **ябешке** «бәйләнчек», **ябышкы** сүзе кулланылмый да; **ябешмә, ябештермә** дигән ашамлык төре бар (ЗДС: 240), **ябышма** дигән сүз икенче мәгънәдә һ.б.; **ябеш-** һәм **ябыш-** сүзләрен «унификацияләү» телне ярлыландыруга китерә. Чаг. *җанкай – җәнкәй, янчык – җәнчек; ятыш – ятеш* очракларында да шундый хәл.

**ЯБУ [йа$^{o}$бы̆w],** диал. **җабу** «попона, накидка; навес; кровля» < гом. кыпч. *йабу* (к.-балк. *җабыw*, кырг. *җабуу*, каз., к.-калп. *жабу*), үзб. диал. (ЎХШЛ: 127) *йапу,* алт. (Баскаков 1972: 209) *дьабу* id., як. *сабыы* id. бу сүзнең борынгылыгын күрсәтә, хәлбуки ул *яп-у* фигыленең исемләшкән формасы буларак тат. телендә дә ясала ала; чаг. төр. *yapı* «төзелеп яткан корылма; конструкция». К. **Яп-у II.**

**ЯБУГАЙ** диал. «бойкий, речистый; распорядительный» к. **Ябгу.**

**ЯБЫЗ, йаwыс: йаwыс әйлән** (ЗДС: 222–223) «низкая трава (которую трудно косить)» к. **Ябыс.**

**ЯБЫК I [йа$^{o}$бы̆қ],** диал. **җабык** «худой, тощий; бедственный» (к. җырда: *Заманалар авыр, еллар ябык…*) > чув. *йапăх* «начар, ташландык, шапшак», мар. *йавық, йавыгэ*, удм. диал. (Насибуллин: 115) *ǯабък* id. < гом. кыпч. *йабык* (күп телләрдә сакланмаган, тик к. *җабық,* каз., к.-калп. *жабық*) id. ~ алт. диал. *йабы, йаабы* «арык, ябык; усал; комсыз, начар; ялган» (к. Радлов III: 279). К. **Ябык-у.** Сөйләшләрдә (ЗДС: 223) **йабыгач** «күңелсез» сүзе бар.

**ЯБЫК II [йабык]**, диал. **җабык** «закрытый» < гом. кыпч. *йабық* (к.-балк. кырг. *җабық,* каз., к.-калп. *жабық*) id. ← **Яп-у.**

**ЯБЫК-У (ябыкты, ябыгу),** диал. **җабык-у** «худеть, тощать», диал. (Радлов III: 279; ТТДС I: 158; Тумашева 1992: 63) «скучать (по ком); иметь отвращение (к своему положению), быть в подавленном настроении» > чув. *йапăх* id. < гом. кыпч. *йабық-* > кырг. *җабық-,* каз., к.-калп. *жабық-* id.

бор. **йап-* яки **йабы-* «начар, түбән хәлдә булу» фигыленең интенсивлык формасы (*йап-ыķ-*), ә *ябык* «арык» шул ук фигыльдән ясалган сыйфат (икесендә ике төрле кушымча). *Йап-* «начарлану, түбәнәю» **йап** (к. **Җап**) «начар, түбән» сүзенең фигыль коррелянты.

Бор. **йап- (йапы-)* сүзенең тамыр багланышларын билгеләү кыен (бу тур. к. ЭСТЯ IV: 9–10). **Явыз** сүзе белән баглау (Егоров, Рясянен) юраулы. **Ябык, ябык-у** сүзләренең мәгъ. структурасы күбрәк *йоба-у* сүзенекен хәтерләтә (к. **Йобау, Юаш**). К. **Ябырыл-у.**

**ЯБЫНЧА [йаᵒбы̑нча]** «плащ; женское покрывало», диал. (Тумашева 1992: 63) **йабындзы** «вуаль», **йабынцы** «юрган» > чув. *юпăнчă* «ябынча; дүрткел киез» < гом. кыпч. *йабынча, йабынчаķ, йабыңчыķ,* угыз. *йапынҗа, йапынҗы,* төр. *yapıncak,* ком. диал. *йамунчу,* алт. *йамынчы,* хак. *чабынҗах* id., тув. *чабынчак* «эчерге, ат ябуы» һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 128). Иске тат. **йапанча** «ябынча» сүзендә *йапан* «кыр-ялан» сүзенең тәэсире сизелә (*йапанча* «кырда киелә торган кием»).

*Ябынча,* бигрәк тә *япанча* сүзе рус һәм үзгә слав. телләрендә киң таралыш тапкан, к. рус. *епанча, япанча, япончица* «ябу, ябынча», серб. *japundže*, Д. болг. *јапунче, јапынче,* пол. *opońča* һ.б., к. Юналеева 1982: 38–42; Аникин: 200 (Р.Ю. Юналееваның китабын искә алмаган).

**ЯБЫРЫЛ-У [йаᵒбы̑ры̑л-],** диал. **җабырыл-у** «навалиться, нападать массой» (**ябырылу** «нашествие») ~ нуг., ком. *йабырыл-* id., кар. *йапырыл-* «бастырылу (кузгалыш, фетнә тур.)», урта. төрки *jabrul-* id., ~ бор. төрки *jabrıl-, javrıl-* «зәгыйфьләнү» (*jabrıt, javrıt* «зәгыйфьләтү») ← *jabır-, jabru-, javrı-* «көчсезләнү» ← *jab-* «көчсез, көчсезләнү». Ләкин бу схеманың тат. *ябырыл-у* сүзенә турыдантуры катнашы юк, тат. сүзе гом. кыпч. **йабыр-*, кырг. *җабыр-* «басу, түбәнәйтү яу булып килү» (ш. ук. *җабыл-*), каз., к.-калп. *жабыр-*, *җапыр-* «үләнне (җил) аудару; дошманны масса белән кысу» ~ иске тат. *җабыр-,* (Радлов III: 280) *йабыр-* «караңгылык басу», хак., төркм. *йапшыр-*, тув. *чабыр-* «басу, бастыру» (тув. *чавырыл-* «ябырылу; төшү, түбәнәю, юашлану») нигезеннән килә. Кырг. *җабыр-* һәм *җабыл-* һичшиксез **җап-* яки *җабы-* «егылу, тәбәнәкләнү; төшү; юашаю» фигыленнән юн. формалары (*жабы-р-* яисә *җап-ыр-* йөкл. юн.); шул ук фигыльдән, ихтимал, к. **Ябык** һәм **Ябык-у,** алт. диал. *йабыр-* «тәбәнәкләнү, төшү», башк. диал. (БҺҺ II: 82) *йабрый* < *йабырыг* «салбыр, салынкы», иске төрки (Räsänen 1969: 176) *jabur-* «яшерү» һ.б.

Үз чиратында *жап-* яисә *җабы-* (бусы ихтималрак) гом. төрки, монг. *җап* (к. **Җап**) «түбән» сүзеннән аерылмаска тиеш, к. к.-балк. *жабалан-* «ябырылу»; чаг. ш. ук к.-калп. *жабырла-* «шау-гөр килү», кырг. *жабуу* – калмык һәм җунгарларның ораны, «ура!», шуннан *жабулла-* «ура кычкырып һөҗүмгә ташлану».

*Ябыр-у* нигезе белән тат. диал. **йабыз,** кырг. *йапыз* «тәбәнәк» сүзе тамырдаш булырга тиеш (*r ~ z*), к. алт. *дьабыза-* «түбәнәю, чүгү, шилү (су тур.)», әмма **явыз** (к.) сүзенең моңа катнашы шикле (к. ЭСТЯ IV: 48).

Гомумән, *ябырыл-* ← **ябыр-* икәнлеге шөбһәсез, ачык, әмма безнең бүтән кайбер тәңгәлләүләр вә чагыштырулар арытабангы тикшерүләргә, ачыклауларга, төгәлләүләргә мохтаҗ. Мәс., удм. *җабыр-* «эләктерү, тотып алу» тат. сүзенә мөнәсәбәтле микән? К. ш. ук түбәндәгене.

**ЯБЫС [йаᵒбы̑с], йаус, уаwыс** (Тумашева 1992: 64, 65, 73), **йабыз, йаwыз, йабзак** (ЗДС: 223–224) «низкий, низенький» (**йауза**- «түбәнәйтү») ~ уйг. *йапиз,* кырг. *йапыз*, алт. *дьабыс,* хак. *чабыс,* тув. *чавыс* id. ~ иске төрки (Räsänen 1969: 176) *jabru* «тыныч; сүлпән». Бор. төрки сүзлектә (ДТС: 222) *jabız*ның «вакытның вагы (ничтожный)» мәгъ. генә күрсәтелә. Бор. **йап-, *йапы-* «түбәнәйтү» сүзеннән. К. **Ябыз, Ябырылу, Явыз.**

**ЯБЫШ-У [йаᵒбы̑ш-],** диал. **җабыш-у, йәбеш-ү, җәбеш-ү** (күп төбәкләрдә **ябеш-ү** сүзе **ябыш-у**дан мәгънәви җәһәттән бераз аерыла) «прилипать» < гом. кыпч. *йабыш-* (нуг. *ябыс-*, к.-балк. *җабыш-* > каз., к.-калп. *жабыс-*), гом. угыз. *йапыш-*, уйг. *йепиш-* id. һ.б. Бу фигыль гомумән *яп-у* фигыленең урт. юнәлешеннән килә, ләкин үзенчәлекле мәгънәләре белән аерылып тора: «бергәләп тотыну, ярсып һөҗүм итү, башлау һ.б.» Тат. веляр вариант гом. кыпч. линиясен дәвам итсә, *йәбеш-, җәбеш-* < уйг. *йепиш-* булса кирәк; «(эшкә) тотыну» мәгъ. башлыча шушы вариантка хас. К. **Яп-у I.** ЭСТЯ (IV: 132–134) *йабыш-у*ның *йабу*дан икәнлегенә шик белдерә. Бор. төрки (ДТС: 235–236) *japïš-* ~ чув. *çыпăç-* «ябешү» тур. Егоров 1964: 225.

Безнеңчә, *йабыш-у* «ябарга ярдәм итү» (**яп-у** фигыленең регуляр мәгънәдәге урт. юн.) сүзеннән аеру өчен тат. әд. телендә **ябеш-ү** вариантын активлаштыру хәерле.

Дерив.: **ябештерү** һәм **ябыштыру; ябешкән** «бәйләнүчән», **ябышкак** (балчык һ.б. тур.), **ябешкәк** «бет серкәсе».

**ЯВЕР [йәwӗр], җәwер** (ЗДС: 182, 240) «род, племя; стадо гусей, уток». Бу сүзне Рясянен (Räsänen: 176) чув. *çури, çӳри* «яшь бала; бәпкә» белән чагыштыра һәм *ябыр-у* «каплау, яшерү» (к. **ябырыл-у**) фигыленнән димәкче. К. **Җәвер.**

**ЯВЫЗ,** диал. **җаwыз** «злобный, злой» – кыпч. сүзе түгел (нуг., ком., кырг. телләрендә теркәлмәгән шикелле) ~ каз., к.-калп. *жаwуз, йаwыз, йоwуз*, үзб. диал. *жоwуз*, кар. *йувуз*, бор. уйг. *йабус*, бор. төрки (ДТС: 222–223, 249–250) *jabïz, javuz, javïz, jafuz* «явыз; яман, әшәке»; төр. «кырыс, гайрәтле һәм усал» (к. ЭСТЯ IV: 47–48) татар этимологиясендә (Л. Җәләй) бор. **йағыз* id. *йағы* «дошман» сүзеннән дип карала. Чыннан да к. төркм. (Мухамедова 1973: 100) *йаувузрақ* «явызрак» дигәндә *йау* < *йағы;* ул чакта в *вуз* ~ *уз*. Телчеләр бор. *йабуз* сүзен бор. *jablaq, javlaq* «начар, әшәке, кырыс» сүзе белән тамырдаш дип карыйлар (к. бор. төрки *jabïz-jablaq, javïz-artaq, javuz-junčïү* «яман, әшәке»). **Явыз** сүзен тат. диал. **йабыс** (к.) «түбән» сүзе белән чагыштыру конкрет материаллар белән расланмый: беренчедән «түбән > начар» мәгъ. күчеше төрки телләр өчен хас түгел, икенчедән *явыз//явуз* сүзенең «яман чир» һ.б. мәгънәләре «түбән» мәгънәсенә якынлашмый. Ә. Булатовның *йавуз* < *йәк уз* «шайтан (кебек) оста» яки «шайтан чире» дигән фаразы да фонетик җәһәттән аксый. Гомумән, *-з* бор. *-р*дан килеп чыкканлыктан, архетип – *javurg* булырга тиеш. чаг. **Ябырыл-у.**

Дерив.: **явызлык; явызлан-у; явызларча.**

**ЯВЫК [йа°wы̆к],** диал. (Тумашева 1992: 73, 87) **йуык, йыwык** (ЗДС: 194) **җыwы'** (ТТДС I: 577) «близко, близок, близкий» ~ чув. *çывӑх, çӑвӑх, çух*, *çук* ← тат. диал. (Гиганов) *явуй-*, *йыw-у* «якынаю» фигыленнән; *йыwуқ* «якын» һәм *йыwы-* «якынаю» иске тат. яз. ядкәрләрендә еш кына очрыйлар, к. ш. ук бор. төрки *jawuq, javuq* < *jaүuq* «якын» ← *javu-, jawu-, jaү-, jaq-* «якынаю» (ДТС: 224–225, 237, 249–250). Гом. төрки характердагы сүз (к. як. *суок* «явык»). **Як** сүзе белән тамырдаш (к. ЭСТЯ IV: 62–63; күп телләрдән мисаллар бирелә, тат. мисаллары өлешчә генә китерелә). К. **Юык, Якын.** Räsänen 1969: 178, 180; Мухамедова 1973: 100–101; Федотов II: 152.

**ЯВЫЛ [йа°wы̆л]** «к дьяволу» > чув. *явӑл,* мар. *йавыл* «шайтан, наян» (к. Саваткова: 230), иске тат. (Утыз-Имәни һ.б.) *иблис-йағул* id. ~ к.-балк. *жабыл* id. грек. *διαβολος* сүзеннән бор. алынма (рус теленнән түгел). Чаг. ш. ук. **Иблис.**

**ЯВЫМ [йа°wы̆м],** диал. **җаwым** «осадки» (*йаwымлы* «ненастный») ~ гом. кыпч. *йаwым* id.; *йаwын* варианты да еш очрый: каз., к.-калп. *жаwын*, үзб. *йағин,* уйг. *йеғин* һ.б. «явым». **Яwым** ← *йаwым,* ә **явын** < **йаwғын*. К. **Яу-у.**

**ЯВЫР [йа°wы̆р],** диал. (ТТДС I: 563) **җаwыр, җаwырнабаш** (ДС II: 257–258), **җаwырна башы,** миш. (ТТДС II: 158) **йаwрын, йаwырна, йаwырны** «ключица» – әд. телдә дә **яурын, яwырын** < гом. кыпч. *йаwырын* (к.-балк. *җаурун, заурун,* кырг. *жоорун*, каз., к.-калп. *жаwырын*), башк. (БҺҺ II: 87) *йаwырын, йаwырыннау,* алт. *йарын, йаарын*, хак. *чарын, чаарын,* як. *сарын,* чув. *çорӑм* > *çурӑм* – күпчелек телләрдә (тат. сөйләшләрендә дә) бу сүз калак сөяген һәм җилкә сөяген (умыртка башын) белдерә. Сүзнең нигезе – бор. төрки (ДТС: 224), чыгт. *jaүïr,* уйг. *йеғир* (> кырг. *җоор*, каз., к.-калп. *җабыр, жаwыр*) «атның ияр яисә камыт тигән (тия торган) урыны; камыт йарасы» һәм **йаwырны, йаwырна** < (төркм.) *йаwыр (йағыр-ы) урыны* дигәннән, к. ш. ук госм. *йағры* (*йағыр-ы*) > куман., себ. (брб.) *йаwру* «атның сөяк чыгып торган урыны; калак сөяге», төркм. *йағыр* «хайванның арка пычыргысы; пычыргылы терлек» ~ яз. монг. *daүari* «иңбаш» (< төрки **дьағарын* сүзеннән булса кирәк). Гомумән, формаль җәһәттән *йавырын* (< **йағур-ғун*) – **йаwыр-* < **йағыр* «чиләнү, пычыргылану» сүзеннән фигыленнән, к. каз (ҚТДС: 116) *жауыр-,* кырг. *җоору-,* аз. *jaғыр-* «чиләнү», ә *йаwыр* < *йагыр* (исем) шуннан килеп чыккан (киресенчә түгел), к. **Яурыл-у.** Бор. *йағыр-* фигыле **йағ* яки **йағы* дигән сыйфаттан була ала. Räsänen 1969: 178; Мухамедова 1973: 101; ЭСТЯ IV: 65–67. К. **Яурынчы.**

Күп гасырлар дәвамында ат чирләре төрки халыклар өчен иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булган.

**ЯВЫШ [йа°wы̆ш]** иск. «подарок» < бор. төрки *jaүïš* «жертвенное приношение» ← *jaү-* «корбан китерү» (МК, ДТС: 224). Шуннан киң таралган *Йаwыш* – кеше исеме (мәшһүр *Яушевлар*). **Яу-у** белән тамырдаш (чаг. **чәчү** «явыз рухлардан саклану өчен корбан»).

**ЯВЫШКЫН [йа$^{o}$wы̆шқы̆н], йашкын, йуышкын** (Радлов III: 173; Тумашева 1992: 73, 87) «плесень; заплесневелая вода» ~ чыгт. *йошқун,* ком. *йошгун* «мүк, мәре». *Юшкын* (к.) белән гомоген кебек.

**ЯГА [йа$^{o}$ға],** диал. **җага, жаға** «окраина, опушка, берег, край, у края» (ТТАС III: 621; Тумашева 1992: 64; ТТДС I: 159, 593; (БТДҺ: 105) < гом. кыпч., чыгт., бор. уйг. *йаға* (к.-балк. *җаға,* каз., к.-калп. *жаға*), алт. *йаға, дьаға, дьака,* хак. *чаға,* як. *саға* ~ бор. монг. *jaγa* > бур. *заха* id. (ш. ук «яка»), болг. **җаға* > мар. *сага* «янында».

Тат. телендә *яга (йаға, йага, җаға, жага)* һәм *яка* сүзләре аермачык аерыла (этимологик дублет), башк. телендә мондый полярлашу сизелми. ЭСТЯ (IV: 82–83) сүзләрендә **яка** һәм *яга* бер матдәдә бирелә һәм Дж. Клоусонның фикере китерелгән: *яга, яка* – **яқ-, яғ-** (к. **Явык**) «якынлашу» фигыленнән. Без моңа нигездә каршы түгел, ләкин **як, яг** исеме дә булырга мөмкин, шунлыктан башк. диал. (БТДҺ: 105) *йағақ* «янәшә» сүзнең борынгырак яңгырашын чагылдыра булса кирәк (*йағақ* < *йақақ*); чув. телендә *çоха, çуха* «яка» мәгъ. генә булып, мар. телендә *саха* киңрәк мәгънәдә булуы бу сүзнең чув. теленнән түгел, болг. теленнән турыдан-туры алынуына дәлил (мар. < тат. *йака* «яка» сүзе дә бар).

**Яга** сүзеннән **ягалау**- «тирәли йөрү; эш башларга җыену», шуннан **ягалый** «тирәли» сүзе ясалган (бу сүзләрнең параллельләре бүтән кыпч. телләрендә дә очрый). К. **Яка, Ят.**

**Яга**ның **яка**, **җака** варианты да очрый (*кабер якасында* «кабер янында»), шундый варианттан рус. *якут//джакут* (халкы) < монг. *җакаут* «ягадагылар, читләр, ерактагылар» сүзе дә килә (к. Аникин: 722–723), чаг. рус. *украин* «чит, ягадагы, украин». Рус. *яга* «колын тиресе» < төрки *йага* тур. Фасмер IV: 543.

**ЯГАН [йа$^{o}$ған]** (Котби) «слон» < бор. төрки (МК һ.б., к. ДТС: 224, 233) *jaŋan, jaγan* > алт. (Вербицкий) *jаан,* тув. *чаан,* монг. *дзаган* «фил; мифик бер хайван», уйг. *янге* «фил» < бор. кыт. *xiang-an*. К. Крюков М.В. Хуан Шу-ин. Древнекитайский язык. М., 1978: 36. Тик монда кайбер төгәллекләр кертергә кирәк. Чыгт. (Будагов II: 332) *йаған, йаан* «зур, дәү, олы, хөрмәтле», тик *йаган аң* гына «фил»! Димәк, *йаган* сүзенең төп мәгъ. нәкъ фил түгел. Чаг. ш. ук *йаған ижик* «бик зур капка», *йаған улу* «өлкән угыл» һ.б. Кыскасы, монда төпченергә кирәклек вә мөмкинлек тә бар.

Диал. (ЗДС: 225) **йаған** «хайван сыйрагы», «мамонт сыйрагы» микән?

**ЯГМА [йа$^{o}$ғма]** тар. «грабительский подход; нашествие» ~ кр.-тат., төр. *yağma* id. Сүзлекләрдә (Özön, Räsänen һ.б.) һәрдаим фар. сүзе дип күрсәтелә. Фар. телендә ул чыннан да актив кулланыла. Бор. төрки (ДТС: 225) *jaγma* «бер төрки, кабилә» диелгән.

**ЯГЪНИ [йәғни]** «то есть, иначе говоря» < гар. *йә‘нӣ* «бу белдерә ки» сүзеннән.

**ЯГЫ I [йа$^{o}$ғы̆]** «враг» < бор. төрки (ДТС: 221) *jaγï* id. Бу сүз тат. тарихи әсәрләрдә бор. телләрдән алынып стилизация өчен кулланыла. Диал. (ЗДС: 225) **йағы** «сугыш, җәң». К. **Яу.** Будагов II: 332–333 (**йагы** сүзенең дериватлары күрсәтелә).

**ЯГЫ II [йа$^{o}$ғы̆]** (ЗДС: 225) «шуба с мехом как снаружи, так и изнутри» ~ алт., тел. *йаққы* id. < бор. төрки (ДТС: 225, 238) *jaγqu, jaqu* «доха», *яга, ягушка* «йоны тышкары ненец туны»; рус. < як. *санаяк, сангаяк* «йоны тышкары болан тун» тур. күп язылган, к. Аникин: 195, 481–482, 721–722 (ишле әдәбият күрсәтелә).

Йоны тышкары булган тире кием яңгырдан, юеш кардан әйбәт саклый, чөнки табигый шартларда хайван тиресе шундый шартларга да исәпләнгән була.

**Яга, ягы** сүзе белән *доха* (к.) бер нигездән, әмма соңгысы монг. телләреннән (аларда *й-* < *дй-* > *д-* күзәтелә).

**ЯГЫЛ-У [йа$^{o}$ғы̆л-]** (ЗДС: 225) «прикасаться; дотрагиваться; завязывать близкие отношения» ← бор. төрки *jaγul-* ← *jaγu-* «якын килү» фигыленең төш. юн. К. **Як-у, Яхшы.** Чаг. **йагыл-у** (*май ягылу, ут ягылу* һ.б.) ← *йақ-* «өстенә кую, тидерү һ.б.»

**ЯГЫМЛЫ [йа$^{o}$ғы̆млы̆],** диал. **җагымлы** «приятный» ← сөйл. *ягым* (*йагым, җагым*) «күңелгә хуш килү» ← *йак-* (*җак-*) «сылау» (*май ягу*), к. **Як-у.** *Йагым* сүзе гом. кыпч. теленнән үк килә, к. нуг., ком. *ягым – ягымлы*, к.-балк. *җағым* → *җағымлы,* кырг. *җағым* → *җағымдуу*, каз. *жағым* → *җағымды*, к.-калп. *жағым* → *жағымлы* һ.б. **Ягымсыз** (вариантлары белән) сүзе дә еш очрый.

**ЯГЫТ [йа$^{o}$ғы̆т]** (Гиганов) «валежник, сучья, оставляемые после заготовки леса и стандартных

дров» ← *ягу, яқ-у*. **Ягыт** оригиналь ясалмыш сүз. Хәз. тех. термин **ягулык** сүзенә бик тәңгәл килә. Чаг. төр. *yakıt* – «ягулык».

**ЯД: яд итү [йа°д ит-]** «благоговейно поминать» – фар. *йāд* «хәтер» сүзеннән (к. **Ядкәр**). К. диал. шуннан ук (миш., себ. ДС III: 204) *йат, йәт* «хәтер», *йәтле* «хәтерле». К. **Ятла-у.**

**ЯДАУ [йа°даw],** диал. (ЗДС: 177–178, 226, 238) **җадаw**, **йазау,** себ. **йатаw** «изнурённый, захудалый, тощий» < гом. кыпч. > төркм. *йадаw* (к.-балк. *җадаw*, кырг. *жадоо*, каз., к.-калп. *жадаw*) < чыгт. *йадаг*, уйг. *йадаң, йадаңгу* «ядау», хак. *чадан* «көчкә», тув. *чадаг* «көчсез, бәләкәй (ат)», як. *дьадаҥы* (> эвенк. *дяданг*) «ярлы, хәлсез, мескенчәк» һ.б. ← тат. диал. (себ., к .Тумашева 1992: 72) **йата-у, йада** ~ гом. кыпч., уйг., чыгт. *йада-,* төркм. *йаада-* ~ монг. *йада-* «хәлсезләнү, азаплану, аптырау», тув., хак. *чада-* «гаҗиз калу», як. *сатаа* «тырышутырмашу, булдыру (!)» фигыленнән килә (к. ш. ук як. *дьадай* «фәкыйрьләнү, бөлү»). ЭСТЯ (IV: 67–68) бу сүзне монг. телләреннән димәкче (ЭСТЯда тат. *ядау ~ җадау* искә дә алынмый). Тат. диал. (ЗДС: 226) **йазар-у** «хәлсезләнү» **йады ~ *йазы* дигән сыйфат нигез булганлыгына күрсәтә шикелле.

**ЯДӘЧ [йәдәч],** диал. **йәтәч, җәдәч, җәтәч, зәдәс** (ДС II: 84), **җәдәз** «дужка у птиц (с которым играют в игру «беру да помню» или «Иван-дурак»)» > чув. (Сергеев 1971: 68) *йетес, йӗтес, итес, йетек* һ.б., мар. (Саваткова: 38, 43) *йатас, йäтäс, йӗдас*, удм. (Насибуллин: 15) *ǯатес* id. – башк. *сәтәш, сәҙәш*, нуг. *ябдесин,* кар. *йаддэс*, төр., кр.-тат., нуг. (TS 5: 141–142; Dobr. III: 465) *yades, lades* < фар. *йāд äст* «исемдә» яки *yäd dašt* «хәтердә калачак шәй» (TS 4: 1451–1452), к. ш. ук Егоров 1964: 80; Федотов I: 201.

**Ядәч сындыру, ядәч аеру** гадәте уен гына булмаган – чувашлар (к. Ашмарин I: 61) һәм мордвалар (Евсевьев: 29) *труйчын* – җәйге нардуганда зиратка барып үлгәннәрне искә алу көннәрендә кем ничә елдан үлә дип бәхәсләшү өчен дә ядәч аерганнар. **Җәдәчләшү** гадәте Кавказ халыкларында (к. абаз. *сандис,* кабарда. *кандис* «ядәч»), Балкан илләрендә (к. рум. *lades*) һәм комиларда (*чэгсь*) һ.б. күзәтелә.

**ЯДКӘР [йәткәр]** (совершенно неверно: **ядкарь**), **ядкяр,** иск. **йадигәр, йадикәр** «память (кого-чего), вещь в память; в памяти» > чув. (Сергеев 1968: 16–17) *еткер, еккер* «мирас; таныш урыннар» < фар. *йāд кäр(д)* «искә алу, йад итү» (*йāд* «хәтер», *кäрдäн* «итү») сүзеннән. К. **Яд, Ятла-у, Яттан.**

**ЯДРӘ [йәдрә],** диал. **җәдрә**, башк. *йәҙрә* «дробь для ружья; ядро (пушки); снаряд». XVI г. ук *йäдрä* формасында теркәлгән (Кол Шәриф, «Зафәрнамә…») < рус. *ядро*.

**ЯДУ, ядулык** «колдовство» к. **Җаду; Яйчы.**

**ЯДЫГАН [йа°дыған],** бар. (Тумашева 1992: 64) **йатыган** «гусли; арфа» ~ рус. (яз. һәм диал.) *джитаган, jättaga, джатыган* һ.б. (Аникин: 185, 640) < чыгт., яз. монг. *jatuyan, jattuya* «ундүрт кыллы гөслә» (хәз. монг. *ятга* «сигез кыллы арфа»), алт. диал. *йадаган*, хак. *чадыган, чатхан* һ.б. (к. Цинциус 1984: 40) маньч. *фитухан* «бандура, думбыра» белән чагыштырыла. Гөслә яткан хәлендә уйналгач, бу сүзне *йат-у*дан дип уйлау табигый (чаг. тат. диал. **йадаған** «өйдә ятучан», Тумашева 1992: 72), к. Räsänen 1969: 192–193. Ләкин бу фараз өстәмә дәлилләргә мохтаҗ. Ихтимал, *йадыган* < *йәттиқаң* «җиде кыл» дигән сүздәндер (*каң* кыл чыңлавына тәкълид монг., алт һ.б. телләрдә очрый).Номинханов 1975: 175; ЭСТЯ IV: 156–157 һ.б.

Төр. һ.б. *йатаган* «кәкре кылыч» сүзе дә, ихтимал, **атыган** сүзеннәндер.

**ЯЗ I [йа°з]** «весна» (диал. **җаз** хәзер кулланылмый диярлек) < гом. кыпч. *йаз* (кырг., к.-балк. *җаз*, каз., к.-калп. *жаз*), угыз. *йаз, йааз*, алт. *дьас, дьаз,* тув., хак., шор. *час,* як. *чаас* «яз», кайбер көньяк телләрдә (төр., гаг., нуг., каз., к.-калп., үзб. һ.б.) «җәй», ә «яз» мәгъ. бүтән сүзләр белән белдерелә, мәс., миш., тат. (Г. Ибраһимов, ТТДС I: 160) *җәй* «яз», к. үзб. *йоз* «җәй», ә «яз» – *бәһар, баһор,* төр. *ilkbahar*. Бу хәл календарь алмаштырулар белән баглы булса кирәк, чөнки бор. төрки телләрдә *йаз, җәй, көз, қыш* сүзләре (фонетик вариацияләре белән) күптәннән килгәне күренә. Чув. *çур < çор <* болг. **җар* «яз» һәм төркм. *йааз*, як. *саас* «яз» сүзләреннән чыгып, тәүге варианты *йаар < дьаар* дип билгелиләр һәм еш кына маньч. *ньар-*, монг. *нярай* «яңа туган; яшел» сүзләре белән чагыштыралар (Цинциус 1971: 79–80; Poppe 1972: 49); саф лингвистик җәһәттән бу чагыштыру хатасыз (к. ЭСТЯ IV: 69–70), ләкин тарихи-семантик принциптан караганда, ул шикле: хәз. *-з* урынына *-р* килү – саф төрки күренеш, мәгънәви җәһәттән монг.-маньч.

варианты борынграк: яз – балалау һәм яшеллек фасылы. Шунлыктан мәзкүр чагыштыруны кире кагучылар да бар. Гомумән, мәсьәлә юраулы кала. К. ш. ук **Яз-у I.** Егоров 1964: 219, Räsänen 1969: 196.

**Яз** продуктив нигез: **язгы, язгылык, язла-у, язлый, язын; язлак, язлау** «язлый торган урының» сүзе дә булган.

**ЯЗ II [йа$^{о}$з]** себ. (к ЗДС: 228) «дикий», мәс., *яз үрдәк* һ.б. К. **Язы** «дала».

**ЯЗЛА-У [йа$^{о}$зла-у]** (киң таралаган, к. ЗДС: 228) ярдәмче фигыль «чуть не…» (о том, что выражено в основном глаголе) < **йазыла-у < йазула-у ←** **язу.** К. түбәндәгеләрне.

**ЯЗЛЫК-У (язлыкты, язлыгу)** «промахнуться» – **Яз-у III** фигыленән (интенсивлык формасы).

**ЯЗМЫШ [йа$^{о}$змы̆ш]** «судьба» ~ чыгт., иске тат. *йазмыш* id. китаби телдән, к. **Язу, Яз-у II.** Төбендә «тәкъдир» мәгъ. **Алла язмыш(ы)** дигән тәгъбирдән. Чаг. *Алланың язганы* ш. ук мәгъ.

**ЯЗУ [йа$^{о}$зы̆у]** (ЗДС: 226) «грех; насчастье, глубокая ошибка от греха» ~ кр.-тат. (Dobr. III: 501) *yazγı, yazı alın* (*маңгай*) *yazısı* «(бәхетсез) язмыш». К. **Язмыш, Язык.**

Дерив.: **язулы: язулы башым** «гөнаһлы башым». Бу тәгъбир миш. җырларында очрый.

**ЯЗ-У I [йа$^{о}$з-]** «развязывать, разложить сметану на пахту и масло, разогнуть, распрямлять, распускать, пушить, трепать, теребить (шерсть); расстилать, писать» (тат. диал. **җазыw** хәзер кулланылмый диярлек) < гом. кыпч. *йаз-* (башк., төркм. *йаҙ-,* к.-балк., кырг. *җаз-,* каз., к.-калп. *жаз-*), угыз. *йаз-,* төркм. *йааз-,* алт. *дьас-, йас-,* тув. *чаз*//*час,* бор. төрки *jat-, jad-, jaδ-, jaz-, jaj-* (к. ДТС: 250 һ.б.) id. Безнең карашка, *йаз-у* «кәгазь һ.б.ш. өстенә ниндидер билгеләр төшерү» сүзе асылда «сүзне авазларга таркату» «сүзне җәеп салу» кебегрәк мәгънәдән үсеш алган; гадәттә (күп телләрдә) «язу» мәгъ. сүз «сызу, чыю» мәгъ. сүздән үсеп чыга, ләкин бу үсеш мотлакан түгел бит! Гомумән, *язу I, язу II* һәм *җәю* сүзләре генә түгел, *яз* һәм *җәй* сүзләре барысы да уртак бер тамырга – **т'äр* «яз», «язга чыгу» > *д'äр-* > *йааз* сүзенә кайтып кала (шуннан ук *агач яфрак* **яр-у,** ягъни – «язу, җәелдерү»); *йаз-у* һәм *йаз, җәй-ү* һәм *җәй* (гом. төрки *жаймаķ* һәм *җай*) сүзләре исем-фигыль корреляциясе «синкретизм» парлары алар. Хикмәт шунда: күп гасырлар буенча бор. төркиләр үзәннәрдә кышлап, тауларда язлап һәм җәйләп яшәгәннәр, күп гасырлар буенча берүк процесслар кабатланган: кышлаудан язлауга (җәйләүгә) җиткәч, төеннәр *язылган* һәм киезләр *җәелгән.* Билгеле, мондый тормышта яшәгәндә *яз* тамырының метаморфик, метонимик һ.б. күч. мәгънәләре аерым сүзләргә нигез була торган. К. **Яз-у II.** ЭСТЯ IV: 69–70 (*йаз- I*), 70–71 (*йаз- II*).

**Яз-у I** сүзеннән диал. **йазма** «гөбе әйрәне», **йазым** «бер порция язылган май» сүзләре ясалган (ТТДС I: 161). Кайбер кыпч. телләрендә (к.-балк., каз., к.-калп.) бу сүзнең «кашу, дәвалау» мәгънәсе бар. Идиома: **тел яздыру** «җәзалап серләрне сөйләтү». Добр. *cazıq, yazıq* «җәенке» сүзе бар.

**ЯЗ-У II [йа$^{о}$з-],** диал. **җаз-** «писать» < гом. кыпч. *йаз-* (к.-балк., кырг. *җаз-,* каз., к.-калп. *жаз-*), гом. көнб. төрки *йаз-,* башк. *йаҙ-* id. ~ чув. *çыр* (> мар. *сир-*) id. Еш кына бор. монг. *ǯiru-,* тунг. *н'иру-* «язу» бор. монг. *ǯur-* «рәсемләү» сүзләре белән чагыштырыла, әмма, безнеңчә, бу шикле: чув. *çыр-* < болг. – *җыйр-* > венг. *ir-* «язу», әлбәттә, бор. гом. төрки **йар-* < *т'ар-* «язу; таркату» сүзеннән, ләкин *а* > *ы* болг. (чув.) телендә соңрак килеп чыккан булырга тиеш, ягъни бу күренеш монг. һәм тунг. телләрендәге төрки алынмаларда чагылыш табарга тиеш түгел. Безнеңчә, монг. һәм тунг. сүзләре бөтән аерым бер сүздән килә.

Гом. төрки *йаз-* «язу» бор. төрки *йааз-* «җәелдерү, сөйләмне сүзләргә, сүзләрне хәрефләргә таркату» сүзеннән булса кирәк (чаг. тат. *май язу* «каймакны майга һәм әйрәнгә таркату», *йон язу* «тетү»). К. **Язу I.**

**Яз-** продуктив нигез: **язма́, язмачы, язмачылык, яздыр-у, яздырт-у** (газет-журналны), **язгыч** (неол.), **язмыш** (← Алланың язмышы – «язганы») һ.б. **Язу** «язылган нәрсә; документ» барча кыпч. телләренә хас. **Язучы** «әдип» – рус теленнән калька. Будагов II: 322–329.

**ЯЗ-У III [йа$^{о}$з-],** диал. **җаз-** «чуть не попасть (в цель); сойти с пути, лишиться чего, ошибиться» әд. телдә ярдәмлек-актионсарт фигыль буларак киң кулланыла (мәс., *егыла язу*), к. ш. ук диал. *яза* «ялгашып» (*яза басу* «аяк белән ялгыш басу»).

Төрки сүзлекләрдә *йаз-у III*, кайчакта *йаз-у II* «җәю» белән бер матдәдә бирелә, ләкин тат. диал. (ЗДС: 226) **йазла-у** «язу» – кырг. *җаз-, жазда-* «ялгышу, гаепле булу» бу сүзнең мөстәкыйльлеген

бик ачык күрсәтеп тора; к. ш. ук нуг. *йаз-*, к.-балк. *жаз-*, каз., к.-калп. *жаз-* «ялгышу һ.б.». К. **Язык.**

*Йаз-* тамырының этимологиясе юраулы: бор. төрки *ol kejikni yazdï* (ДТС: 250) «ул киеккә атып тидермәде» сүзе кызыклы: бәлки бор. форма **jazï-* «языга җибәрү» мәгъ. булгандыр. К. **Язы.** Räsänen: 193 («язлыгу» һәм «аз гына булмый калу» мәгънәләрен ике фигыльгә бүлеп бирә).

**ЯЗЫ [йа$^о$зы],** диал. (ЗДС: 178) **җаз, җазы** «равнина; ровное дно балки, ровная пойма реки» ~ башк., төркм. *йаҙы,* кырг. *җазы* (каз., к.-калп. *жазы*), чыгт. *йазый, йаз,* госм. *йазу* (төр. *yazı*), кр.-тат. (Dobr. I: 420–421) *cazıq* «язы». К. ш. ук уйг. *йези*, алт. *дьазы*, хак., тув. *чазы*, як. *сыһыы* id. һ.б. Тат. диал. (ТТДС I: 160) **йажу** ~ хак. диал *чажы* id. үзенчәлекле. Барысы да *йаз-* «җәю»дән, к. бор. төрки (ДТС: 251) *jazï* «дала; ачык, ачыклык» < **йазыг, *йазгу.* Добр. *cazıq [җазык]* id. бор. бер яңгырашны чагылдыра бугай.

*Язы* сүзе хәз. әд. телдә сирәк кулланыла, әмма топонимикада еш очрый (мәс., *Бозаяз < бозау язысы* һ.б.ш.). К. **Яз II, Яз-у I.**

*Язы* белән беррәттән төрки телләрдә башк. *йаҙық* «тигез юл» (к. БҺҺ II: 82) ~ кырг. *җазық*, каз., к.-калп. *жазық* «язы, тигезлек, тигез җир» сүзе дә очрый. Бу сүз *йазы* белән турыдан-туры баглы түгел; әмма, әлбәттә, *язы* да, *язык* та *йаз-* «җәелдерү» фигыле нигезендә ясалганнар. К. **Яссы.**

**ЯЗЫК [йа$^о$зык̆],** диал. **җазык** «грех, проступок» < гом. кыпч. *йазык* (к.-балк., кырг. *җазык,* каз., к.-калп. *жазық*) < бор. төрки (Поппе 1938: 165; Боровков 1963: 135; ДТС: 251 һ.б.) *jazuq* > алт. *дьазык*, төркм. *йаазык, йаазук*, аз. *йазыг,* тув. *чазыг,* хак. *чазых* «язык, гөнаһ; хата, язлыгу» – *йаз-у* «ялгышу, гаепле булу» (к. **Язу III**) сүзеннән, к. Исхаков 1961: 198–199. Тат. һ.б. телләрдә *йазыклык* «язык» сүзе дә бар.

Тат. диал. **йазу** «бәхетсез язмыш» (ТТДС I: 161) ~ ком. *йазыw*, төркм. *йāзу,* к.-балк. *жазыw* «язмыш» < бор. төрки *jazıγ* > төр., гаг. *йазық* «югалган; әрәм; җәл», ком. *йазық,* к.-балк. *жазық* «кызганыч; бәхетсез» сүзе дә бор. гом. төрки **jazıγ < *jazγuγ < *jarγuγ*. К. **Ярлы.**

Бу сүзләр күрше телләргә күп тапкырлар кергән, к. мар., удм. *йазық* «гөнаһ». Чув. *çылăх < çырлăх* «язык, гөнаһ» бор. **җарг-лык* «языклык» сүзеннән, к. удм. *сирлык,* мар. *сулык* «язык, гөнаһ» < болг. **җарылык, *җаргылык* id.

**Я́ИСӘ [йәисә]** «или же» < *йә исә (ирсә)*, к. **Я V** һәм **Ирсә.**

**ЯЙ [йа$^о$й]** себ. (ЗДС: 227) «достаток, богатство; лад, взаимопонимание» ~ каз. *жай* «аң, белем; төзеклек». **Җай** (к.) белән бердәй микән – өзеп әйтеп булмый. Räsänen 1969: 179.

Дерив.: **яйлу** «мул, таза тормышлы».

**ЯЙБЫ [йа$^о$йбы̆]** себ. (ЗДС: 227) «широко разлившаяся вода» < **йайбық* булса кирәк, к. (шунда ук) **йайбы-** «ташылып җәелү» ~ кырг. *җайпа-* id., гомумән «киң җәелү». **Җәй-ү** белән тамырдаш.

Дерив.: **йайбак, йайпак** «киң җәелгән (күлләвек)» ~ гом. кыпч. (к. Räsänen 1969: 179) *jajpaq* id.

**ЯЙГЫР [йа$^о$йгы̆р]** диал. «радуга» к. **Җәйгор.**

**ЯЙКА-У [йа$^о$йқа-]** (себ., Будагов I: 346; ЗДС: 227) «трясти, вытряхивать; полоскать; качать на качелях» ~ алт. *дьайқа-, йайқа-* «баш кагу, селтәү, селкү» << бор. төрки (ДТС: 226–227) *jaaqa-* «чайкау; селкетү»; *jajqal-, jajqan-* «селкенү; тетрәү, дулкынлану», ш. ук *jajtur-* «керләр чайкату (чайкарга бирү яисә кушу)» > себ. (ЗДС: 236) **йайға-** «селтәү», **йайғал-** «тиз һәм дулкынлатып хәрәкәтләнү, айкалу (болытлар тур.)». Күренгәнчә, бор. төрки сүзләр себ. татарчасында бөтен парадигмасы белән сакланган. Төр. *yayka-* «керләр чайкау» диал. сөйләмдә генә, әд. телдә *yıka-* (нык кыскартылган вариант). К. ш. ук к.-калп., кырг., каз. *җайқа- > жайқа-* «селкетү, чайкалдыру» һ.б.

Себ. (ЗДС: 227) **йайқы-у** «чеби чыгару» дип аңлатылган сүз шул ук *йайка-у*дан, аның «бишектә тирбәтеп йоклату» кебек мәгънәсеннәндер.

**ЯЙКӘР [йәйкәр], җәйкәр** (ЗДС: 183, 241) «общительный и добрый; пропагандирующий доброту» ~ каз. *жайқор* «очень добрый». Чаг. фар. (искечә) *чāйкäр, чāкäр* «укымышлы хезмәтче, кол».

**ЯЙНАМАЗ [йайнамаз]**, диал. (Тумашева 1992: 74) **йәйнамаз, нәйнамаз**, (ЗДС: 492) **намазҗәй** «молитвенный коврик» ~ каз., к.-калп. *жайнамаз*, үзб. *җойнамаз*, уйг. *җайнимаз* id. < фар. *җāй нä-мāз* «намаз урыны».

**ЯЙЧЫ [йа$^о$йчы̆],** (себ., Будагов II: 246; ЗДС: 226–227) **йайцы, йадацы** «колдун, колдунья» ~ кырг. *җайчы, җайчын,* каз. *жайшы* id. < *жай, җай* «сихер». К. **Җаду.**

**ЯК [йаᵒк]**, диал. **җак** «сторона; край, область» < гом. кыпч., уйг., үзб., чыгт. *йаҡ* (к.-балк., кырг. *җаҡ*), төркм. *йааг, йааҡ,* үзб. диал., куман. *йааҡ* «як; кавем-кардәш» бор. төрки (ДТС: 237) *jaq* «як, ян», «якынлашу» – кайбер төрки телләрдә (Себер, угыз) юк.

Бу сүзне күп кенә бүтән сүзләр белән чагыштырырга мөмкин: *яга, ягы, ян, яңак*; Räsänen (1969: 180) хәтта *йаҡ-* «сылау» фигылен дә *йак* белән бердәй дип карый, ләкин барысы да юраулы. Әмма *як* һәм *якын* сүзләренең тамырдашлыгы бәхәссез, ләкин *якын* сүзе турыдан-туры *як* сүзеннән түгел, ә *йаукын* < *йагуҡ* (к. **Явык**) сүзеннән – шуның инструменталь килеш формасы, *йагуҡ* исә бор. *йаг-* «якынлашу» (шуннан бор. *йаҡ-*) ← *йа* «юнәлеш; юнәлү» сүзеннән булса кирәк. Гомумән бор. *jaq* < **jaγaq* булырга тиеш.

*Йак* сүзен эвенк. һ.б. тунг. *ǯапка* «яр, кыр, ике якның берсе, тараф», *ǯапкун* «сигез (сигез як)» белән чагыштыру шикле, ә чув. *аяк* «ян, як» белән чагыштыру (Егоров 1964: 35) бөтенләй нигезсез (чув. сүзе бор. төрки *äjägü* «кабырга» сүзеннән).

*Йак* шактый продуктив нигез: әд. **йакла-у** «кемнедер канат астына алу», **йаклы** «берәүнең тарафдары булу», **йакташ,** иске тат. **йакчы** «тарафдар» (бу сүзләр бүтән төрки телләрдә дә бар) белән беррәттән диал. (к. ЗДС: 227) **йаклан-у** «кемнең дә булса ярдәменә ышанып үз-үзеңне иркен тоту» һ.б. сүзләр бар. К. **Якын, Якыр-у**. Будагов II: 333.

**ЯКА [йаᵒҡа]**, диал. **җаҡа** «ворот, воротник; нашейное украшение – нагрудник с монетами» > мар. (Исанбаев 1978: 33) *йаҡа*, удм. (Насибуллин: 115) *ǯага,* чув. *çуха, çоха* id. (шул исәптән әлеге бизәнгеч мәгъ. дә) < гом. кыпч. *йаҡа* (к.-балк., кырг. *җаҡа*, каз., к.-калп. *жаҡа*), уйг., чыгт., госм. *йаҡа* «яка, яга», кр.-тат., алт., *йага*, алт. *дьаҡа* «яка; як, кырый» ~ хак., тув. *чага* id., як. *җага, сага* «яка, як, кырый» ~ бор. монг. (Поппе 1938: 201) *ǯaqa, ǯаха* (хәз. монг. *заха*) > эвенк. *ǯаҡа* «яка» (ССТМЯ I: 243). «Яка»ны Максуди (XVI г. тат.) һәрдаим *янка* дип яза! Һичшиксез *яга* сүзе белән бәйле; **як** (к.) сүзе белән баглылыгы ихтимал.

Көрд. *уах [йах], уахе, уехе* «яка, муенса, камыт» бор. ир. *jax* > фар. *җуг* «камыт» белән дә чагыштырыла (соңгысы рус. *иго* белән тамырдаш). Будагов II: 333–336; Räsänen 1969: 180; Федотов II: 141–142.

**ЯКӘ, йәккә** (себ., ТТДС: 241) «отдельно, обособленно; в одиночку» < фар. *йäккä* id. ← *йäк* «бер». К. **Яктә.**

**Я́КИ [йәки]** «если; иначе» < фар. *йā кū* id. (к. **Ки**).

**ЯКТАЙ [йаҡтай]** (ДС I: 243; Тумашева 1992: 65) «удобный; удобный случай» ~ нуг. *ягдай* «файда, уңайлылык; әхвәл, шартлар», кырг. *җагдай*, каз., к.-калп. *жагдай* < урта. монг. *ǯaγdaj* id. К. ш. ук башк. *яҡта-у* «тирмә детальләрен алыштырып беркетү» ~ тув. *чагда-* «җайлаштыру». К. **Чагдавыл.**

**ЯКТӘ [йәктә], йектә** (к. ЗДС: 241, 246) «халат, кофта и. т.п. лёгкое одеяние» ~ төр. *yekta* «тик бер» «бер генә катлы», каз. (ҚТДС: 118) *жегде* «ирләр күлмәге, бер кат күлмәкчән» һ.б. Будагов (II: 359) бу сүзне фарсы *йäк та* «бер генә (катлы)» сүзеннән дип аңлата.

Гомумән, ошбу сүздән рус < фр. *жакет* сүзе килә диләр.

**ЯКТЫ [йаᵒҡты̆],** диал. **җаҡты** «светлый; свет» < чыгт. *йаҡты, йаҡту, йагту, йаглу,* бәҗ. *йаwту* (Радлов III: 35, 53), төр. диал. *йакту,* к.-калп. *жаҡты*, төркм. *йагты* id. (ЭСТЯ IV: 62) ~ чув. *çутă* < *çотă* < болг. **җаты* < бор. төрки *йагыт-ыг* «яктыртылган» сүзеннән ← *йагыт-* «яндыру, яктыртү» ← *йагы-* «яну; яктырткычта май яну» сүзеннән, *йаг* «эч мае» тамырыннан. К. **Яры-у II** сүзендәге схеманы.

**Йакты** сүзе күп кенә төрки телләрдә юк (аның урына *йаруг* сүзе һәм аның фонетик вариантлары кулланыла), **йактыр-у** дериваты исә ешрак очрый. Тат. телендә дә бу сүз бор. уйг. теленнән кергән булуы ихтимал. К. **Яу II, Як-у, Ян-у.** Федотов II: 146.

**ЯК-У (якты, ягу),** диал. **җак-у** «прикладывать; приписывать; мазать (что на что); подходить, быть приятным, зажечь (прикладывать огонь к дровам); топить» – *ут йагу* «утны утынга кую», *утка ягу* «янучан нәрсәне утка кую» > *йагу* «сылау» – «янучан нәрсәне яндырып җылыту» < гом. кыпч. *йаҡ-* (кырг., к.-балк. *җаҡ-,* каз., к.-калп. *жаҡ-*), угыз. *йаҡ-* < бор. төрки **йаг-ыҡ-* ← *йагы* «май яндыру» ← **йа* «яну» тамырыннан > *йаг* «яна торган нәрсә, май».

*Йагы* нигезеннән: *йаг-ыл-* > *йал-* (ДТС: 227) «яну» → *ялҡы-н* «ялкын»; *йаг-ын-* > *йан-* «яну», *йагыт-* «яндыру, яктырту» (> болг. *җат-* > чув. *çот-, çут-* «ягу, яндыру») → *йагытыг* > **якты** (к.); *йагыр-* «май яндырып яктырту» → *йагыр-ыг* > *йаруг* «якты, нур»; шуннан *йагры* «яры, яндыру өчен май» > *йары*; шуннан бор. *йагрыт-* > *йарыт-*

«яктырту» → тат. диал. **йартақ** «чырак, май яндырып яктырта торган җайланма» >> болг. **җарта* > чув. *çорта, çурта* «шәм» һ.б. (к. **Яры-у II** сүзендәге схеманы). К. ш. ук **Ягымлы, Якты, Яртак, Яры, Яу II, Яу-у, Яхшы**. Будагов II: 334–335; ЭСТЯ IV: 58–59.

**ЯКУТ I [йа$^о$қут]** «яхонт» < гар. *йāқӯт* < грек. *hyakinthos* > лат. *hyacinthus* гөл төре (шуннан ук рус. *гиацинт* – «сөмбел гөл»), грек-рус кеше исеме *Йакинф* та шуннан. К. Фасмер IV: 575; Kluge: 429. Грек сүзе билгесез бер телдән алынма.

**ЯКУТ II [йа$^о$қут]** «якут». Татарлар *йақут* дип әйтәләр. Якутларның үзатамасы *саха,* ләкин бу яңгыраш *җақа* «кырый, ята» сүзеннән бугай. Бу сүздән бурятча күп. формасы *җакаут ~ якаут* була. К. ш. ук Аникин: 722–723.

**ЯКҮН [йәкүн]** иск. «итог вычислений, сумма; итог (вообще)» < гар. *йӓкӯн* «булсын». К. ш. ук иске канатлы сүз: **күн фә йӓкүн** «шундук бар да булсын сиңа». XX г. беренче яртысында бу сүз киң кулланыла иде.

**ЯКЫН [йа$^о$қы̆н],** диал. **җақын** «близкий, близок, близко» > чув. *яхӑн* < гом. кыпч. *йақын* (кырг. *җақын,* каз., к.-калп. *жақын*), уйг., чыгт., госм. *йақын,* төркм. *йақыын* id. бор. **ja-*, к. бор. төрки ДТС: 224) *jayu-, jaq-, javu-* «якынлашу» фигыленнән, төрлечә ясала ала: бер яктан – *йау-ык* > *йаwык* «якын» (к. **Явык**) сүзенең инструменталь килеше буларак – *йаwык-ын* > *йаwкын* > *йақын;* икенче яктан (төркм. яңгырашы) урта. төрки *йақығ* «якын (кардәш)» сүзенең шул ук килеше буларак – *йақығын* > *йақыын* > *йақын;* ниһаять, бор. *йақ-* фигыленнән турыдан-туры: *йаққын* (*-қын* фигыльләрдән сыйфат ясагыч кушымча). **Як** сүзенең инструменталь килеше булуы да ихтимал, чаг. монг. *зах* «як, кырый; яка» → *захин* «якын» К. **Юла-у, Юык, Явык, Якыр-у, Ян.** Ихтимал, тамырдашлары: тунг.-маньч. *daya* «якын» ~ кор. *taya* id. ССТМЯ I: 188–189.

**Якын** тат. телендә бик продуктив нигез: **якынлык, якынча: якынай-у, якынлаш-у** һ.б.

**ЯКЫР-У [йа$^о$қы̆р-]** «приблизить» – иске сүзлекләрдә «Казан (теле)» (Будагов II: 334) искәрмәсе белән бирелгән бу сүз хәзер очрамый; к. алт. *йақы-, йақыр-, дьақар-* «заказлау; әмерләү» ~ монг. *дзака-, дзакир-* id. (Будагов II: 336) < бор. төрки *jaqur-* «якын китерү (түрәгә – атны)», (к. ДТС: 238) – бор. *jaq-* «якынлашу» фигыленең йөкл. юн. (< *йақкыр-*). К. **Якын.**

**ЯЛ I [йа$^о$л],** диал. **җал** «грива», диал. «сухожилие под гривой на шее лошади; недокошенная трава» (ТТДС I: 162) < гом. кыпч. *йал* (к.-балк., кырг. *җал,* каз., к.-калп. *жал*), угыз, чыгт., уйг. *йал* (үзб. *йол*), уйг. диал. *йәл, йайла,* (Радлов III: 11, 153) *йаил, йаал*, төркм. *йаал*, кр.-тат. *yalın, calın*, алт. *дьал,* тув. *чал* «ял», як. *саал* ~ башк. *йал* «атның җилкә мае» id. Як. *сиэл* (> эвенк. *сиэл, һиэл*) ~ тув. *чел, чӓл*, төр. *yele* (*йәлә*), чулым. *йӓлӓк*, алт. диал. *йӓлӓн, йӓлин*, хак. *чилiн* һ.б. «ял», алт. диал. (Баскаков 1972: 212) *дьелеги, дьелтек* «шырт, дуңгыз ялы» бу сүзне монг. *дел, деленг ~* эвенк. *дэлин, дээлин, далин* «ял» сүзе белән чагыштырырга мөмкинлек бирә (к. ССТМЯ I: 235). К. ш. ук кар. *йала,* к.-балк. *җалқа* «ял» – һичшиксез, *җилкә* (к.) сүзе белән бердәй, к. чув. *çилхе* «ял» < болг. **җилгә* «ял; җилкә» (к. Räsänen 1969: 181), – бор. төрки (ДТС: 228) *jalïy* «кикрик; ял, ияр кашы», төр. *yal* «ял; җилкә».

Шулай да *ял ~ җилкә* сүзенең барча мәгъ. вә формаларын бер уртак нигезгә кайтару кыен. К. **Җилкә, Ял II, Ялда-у.** Будагов II: 337; ЭСТЯ IV: 85–87; Федотов II: 118–119. К. түбәндәгене.

**ЯЛ II [йа$^о$л],** диал. **җал** «отдых; наём; плата за работу, вознаграждение» > чув. *йол* > *йул,* мар., удм. *ял* «отдых» – сүзлекләрдә ике сүз итеп бирелә (к. ЭСТЯ IV: 84–85), ләкин гаг., төр. *yal* [*йал*] «көч, хәл; май» ш. ук «эткә бирелә торган боламык (эт боламыгы)» сүзләре һәр ике мәгънәнең уртак семантик нигезе булып тора. Гом. кыпч. *йал* (к.-балк., кырг. *җал,* каз., к.-калп. *жал*), алт. *дьал,* хак., тув. *чал* «эш хакы», себ. тат. **йал** «әҗер»: *Якшы ишкә бер ял пәрдинбә*? (к. Радлов, Образцы … IV: 27). Бу сүз үз чиратынла *йал I* сүзеннән (аның «ял асты мае; калын сеңер» мәгънәсеннән) килеп чыккан булса кирәк: ерак юлга йөрергә атка *ял бирергә* кирәк; бу фаразны төркм. *йаал*, алт. диал. *йӓлӓ* «ат ялы; ял (эш хакы)» сүзләре дә раслый. Рус. *ял* «тук ат», *ялы наедать* «ял итү; тик яту» (Аникин: 724) төрки телләрдән ярымкалька; к. ш. ук чув. *йӑл, йул, йол* «көч, хәл» (к. Ашмарин IV: 55, 316), тат. диал. **йал** «пакус арасында калган үлән», нуг. *йал* «тиешенчә сөрелми калган буразна арасы, чи» – турыдан-туры *ял* сүзеннән метафора. *Йал-* күрәсең фигыль мәгъ. дә йөргән, к. диал. **ялык-у** «артык ял итү», **ялын-у** «ял, имтияз». Гомумән, *йал*

тамырында төрле бор. тәэсирләр сизелә; *йал* продуктив нигез: **ялла-у, ялчы.**

Кайбер сүзлекләрдә (мәс., Redhouse:1238) **ял, җилкә** һәм **ял** «көч, ял, эш хакы» бер тамырдан дип карала. Бу раслама җентекләп исбатлауны сорый.

*Йал* сүзе (төрле мәгъ.) күрше (фар., Кавказ) телләргә дә кергән (к. Räsänen 1969: 181). Мар. *йалдар* «эш хакы» < *йал-тăр* парлы сүзеннән (к. чув. *тар, тăр* < болг. **тәр* «тир хакы, эш хакы; тир»). К. **Ялчы.**

**Йал** һәм **йыл** сүзләрен чагыштыру (Алпаров 1945: 320), безнеңчә, дөрес түгел.

**ЯЛА [йа$^{о}$ла],** диал. **җала** «поклёп, клевета» > чув. *йула* > *йола,* мар. *йола, йала* < гом. кыпч. *йала* (кырг. *җалаа,* каз., к.-калп. *жала*), уйг. *йала* id. < бор. төрки *jala* (ДТС: 227) «гаеп, ифтира, яла», *jala-* «гаепле дип күрү», алт. *дьала,* тув., бур. *йала,* монг. *жала, йола* > рус. диал. *яла* «штраф, пеня» (Радлов III: 154; Räsänen 1969: 181; ЭСТЯ IV: 87; Аникин: 724).

**ЯЛАВАЧ [йа$^{о}$лаwач],** иск., сөйл. **йалаwыч** «посол, посланник; пророк» < бор. төрки *jalabaç, jalbaç,* күп яз. ядкәрләрдә *йалавачы* (халык этимологиясе буенча гына *-чы*) – чыгышы юраулы сүз, к. ЭСТЯ IV: 89. Безнеңчә (яңа фараз), **яла** сүзе белән бәйле, чаг. як. *салаӯ-* < **җала-* «идарә итү, юнәлтү», *саланыччы* «идарәче, оештыручы мөдир». К. ш. ук мар. *салаус* «илче фәрештә» (< болг.).

**ЯЛАГАЙ [йа$^{о}$лағай],** диал. **җалағай** «льстец, подлиза» > чув. *йулахай, йолахай,* мар. *ялахай* «ялкау, ялагай» ~ нуг., ком. *йолағай,* каз., к.-калп. *жалағай,* алт., шор. *йалаққай* id., хак., бур. *чалахай* «ярамсак, ягымлы», кырг. *җалакай* «ялкау, сәлкәү», як. *дьалағай* «игътибарсыз» – тат. диал. (ДС I: 260) **йалқа, җалақ,** госм., алт. *йалақ* < *йалғақ* «ялкау – ялагай», як. *дьалах* «игътибарсыз» нигезеннән, к. үзб. *йалхақ* «гамьсез алчак», *йал* «тик яту» тамырыннан (к. **Ял II**), к. себ. **йалағай-у** (Тумашева 1992: 66) «ялагайлану» < *йалақ-ай-у* «*йалақ* булу». К. ш. ук маньч. *залхай,* иске монг. *zalingxaj* «хәйләкәр ялкау; хәйләкәр, наян» ← *zali* «хәйлә-мәкер». ЭСТЯ (IV: 89) *йалағай* дигән нигезне мәгънәләре бер-берсенә якын өч омоним дип күрсәтә. Без ике генә дибез: икенчесе **йала-у** сүзеннән – «ялаучан» булырга мөмкин. Гомумән *ялагай* һәм *ялак* бер-берсенә керешкән һәм мөгаен тамырдаш сүзләр.

**ЯЛАК [йа$^{о}$лақ], җалақ** диал., кр.-тат. *calaq, yalaq* «корыто для скота» к. **Ялгаш.**

**ЯЛАМАЧ [йа$^{о}$ламач]** (Г. Әпсәләмов) «сырки из картофельного пюре» < *йағлы-мач* «майлы күмәч» сүзеннән (*-мач* аффиксы).

**ЯЛАМЧА [йа$^{о}$ламча]** «вид травы с длинным тонким стеблем» < *йаламача* «кечкенә ялама – үзенә кештәкләр бәйләнгән изге бау» сүзеннән, к. **Ялау.**

**ЯЛАН I [йа$^{о}$лан],** диал. **җалан, йалаң** (ДС II: 246) «поле; открытое место, равнина; степь», диал. «голый», диал. «мелкий лес на пойме» > чув. *йалам* «луговая сторона реки» (к. Ашмарин V: 57), мар. диал. (Исанбаев 1978: 25) *йалан* ~ алт. *йалан, йалаң, дьалан*, шор., хак. диал. *чалан* «ялан», уйг., үзб. *йалаң* (диал. сөйләмдә, сирәк кулланыла), к.-балк., кырг., каз. *җалаң, жалан* «ялангач», үзб. диал. (Харәзем) *йалақ йер* «ялан җир» (икенчел булса кирәк) < бор. төрки (ДТС: 227) *jalaŋ, jalïŋ* «ялангач». *Елань, ялан* «ялан» (Аникин: 197, 724) рус сөйләшләрендә киң таралган сүз һәм эвенк. һ.б. *ялан* «ялан» рус теленнән булса кирәк.

ЭСТЯ (IV: 91–94, 95) авторлары нишләптер *йалан, йалаң* сүзеннән төр., бор. уйг., чыгт. (берничә генә телдә) *йалың* «ялан, ялангач» сүзен аералар; без алай аеруга нигез күрмибез. Төрки телләрдә рельеф объектларын тән әгъзалары белән чагыштырып атау – киң таралган күренеш, к. **азак, арка, култык, сырт, тамак** һ.б. Кайбер телчеләр рус *ялан* сүзенең төрки булуына шикләнәләр. к. Фасмер IV: 554.

*Йалан, йалаң* сүзе *алан* (ш. ук *аклан*) белән контаминацион нигездә генә баглы. *Йалан* сүзе *йал* < *йала* тамырыннан (шуның инструменталь килеш формасы), төп мәгънәсе «ялангач». К. **Ялан II.**

**ЯЛАН [йа$^{о}$лан] II,** диал. **җалан** «всегда, всё время» > чув. диал. *ялан*, мар. *ялан, йалан*, удм. *ялон*, морд. Э. *яла* id. < гом. кыпч. **йалаң* id., к. к.-балк. *җалаң* «тик, әмма; шулай да», каз., к.-калп. *жалаң* «гадәти», төркм. (кыпч. телләренән) *йалаң* «һәмишә, һәрвакыт» **Ялан I** сүзеннән: бор. кыпч. төркиләр өчен гел бериш дала (киңлек) һәм гел бериш тормыш, кабатланучан очраклар (озынлык) багланышы (метафора) бик аңлаешлы һәм актуаль булган. К. ш. ук куман, бор. төрки, уйг., чыгт. *йалаң* «фәкать, бары тик» ~ тув. *далаң* (< алт. **дьалаң*) «өйләнмәгән» (Joki 1952: 117).

**ЯЛАНГАЧ [йа$^{o}$лаңғач]**, диал. **җаланғач, йалангац, йаланац** «голый» < гом. кыпч., чыгт. **йаланғач* (кар. *йаланғац,* к.-балк. *җаланңач*, нуг. *йалаңаш*, каз., к.-калп. *жалаңаш,* башк. *йаланғас*), үзб. диал. *җалаңач*, *җалаңғач*, уйг. *җалаңач, җалиңач*, кырг. *җыланач, җыланғач* ~ алт. *дьылаңаш, йаланқач,* төркм., бор. төрки *йаланчак* id., безнеңчә, *йалан* сүзенә *-қач* иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып ясалган (≈ рус. *голенький*). ЭСТЯ IV: 104.

**ЯЛАУ [йа$^{o}$law],** диал. **җалау** (Троянский I: 405), диал. **йала** сүзенең ике мәгънә линиясе бар:

1) (ДС I: 243) «байрак»; (Арсланов 1988: 101) «гаскәри аерма билгесе – кечкенә әләм (баш киемендә)», к. себ. (әкият) *Кӧчӗм хан ... һәйбәтләп киенгән: яуга кия торган җалалы бүреген, көбә куягын киеп йибәргән.* Хак. (Чирем тамырлары: 38), урта төрки (Боровков 1961: 255) *йалаw* «бунчук, тулгага (шлемга) беркетелгән әләм» > чув. *ялав,* удм. *ялау* «сөңге очына бәйләнгән кечкенә байрак, байрак», *яла* «элмәк», мар. (Упымарий 300, 305; Иванов, Тужаров: 56; Саваткова: 39) *йалва, йолва, йалавав* «чук, тасмачык», *ялава* «чук, чачак; сырга», *йола* «әләм (кечкенә байрак), флюгер», рус. *яловец, еловец* «рус яугирләренең шлем түбәсендәге трубкага тыгып куела торган тукыма» (Аракин: 31–32);

2) «кием элмәге (төймәләрне төймәләр өчен, аруча эчтәгеләрне)» (Остроумов 1892: 67).

Гомумән, бу сүз нинди булса билге итеп йөртелгән тасма чукны белдергән һәм бик киң таралган, к. ком., нуг. *йалаw* «камчы очына беркетелгән каеш; элмәк», кырг. диал. *жалоо*, каз., к.-калп. *жалаw* «тасма, байрак, әләм», чыгт. *йалаw* «флаг; шлем тышыннан уратыла торган ефәк кисәге» (Радлов III: 155), «байрак тукымасы» (Будагов II: 338) ~ бор. монг. *ǯalaγa* > монг. *залаа* «бүрек түбәсендәге чук, түбә чәче – какул, бантик, кикрик, байрак», эвенк. (ССТМЯ I: 245) *ǯалаγан* «бүрек түбәсендәге кечкенә чук» < бор. төрки **йалаға*, к. алт. *йалаға*, *дьалаға* «бантик, әләм; шырт (дуңгызның сырт кыллары)» һ.б.

ЭСТЯ (IV: 99–100) авторлары бик хаклы рәвештә *ялау* сүзенең паронимы итеп алт. *йалама, йалаба, дьалама,* хак., тув. *чалама*, хак. диал. *чалаңма*, як. *салама* «үзенә егерме кештәк беркетелгән бау (һәртөрле мәҗүси йолаларда кулланыла, этнографик әдәбиятта җитәрлек яктыртыла)» сүзен китерәләр һәм боларның уртак нигезе бор. **йала-* сүзе дип күрсәтәләр: аны исә *йалга-у* фигыле белән чагыштыралар. Безнеңчә, *йала*-ның турыдан-туры *ялга-у*га бәйләнешы юк, *йала- < йала-* бор. **йа-* «бәйләү, бәй» сүзеннән һәм бу фигыль *җиле* сүзе белән тамырдаш. К. **Җиле, Саламат, Яламча.**

Егоров (1964: 353) чув. *ялав* сүзен чыгт. *ялав* һ.б. белән чагыштырып, чувашчага бу сүзнең тат. теленнән кергәнлеген әйтми (гомумән, бу автор өчен тат. теле материалын күрмәмешкә салышу хас). Ахметьянов 1989: 146. Рус. *яловец, елов* «шлем түбәсенә беркетелгән чук, чачак» (< төрки) тур. Аникин: 724.

**ЯЛА-У [йа$^{o}$ла-],** диал. **җала-у** «лизать» ~ чув. *çула- < çола-* < болг. **җала-* < гом. төрки *йала-* (кырг., к.-балк. *җала,* каз., к.-калп. *жала-,* алт. *дьала,* хак. *чалға-,* тув. диал. *чылға-,* як. *сала-* id. «ялау, чүмерү; ашап бетерү» төрлечә аңлатыла (к. ЭСТЯ IV: 87–89), безнеңчә, *йағла-* «майлау» сүзе белән бердәй (к. төр., кырг., тат. диал. *йала-* «ялагайлану») булса кирәк.

**Яла-** продуктив сүзьясагыч нигез: шуның интенсивлык формасы **ялман-у** төрки телләрдә киң таралган фигыль, к. ш. ук **ялмавыз.**

**ЯЛБЫР [йа$^{o}$лбы̆р],** диал. **җалбыр** «лохматый, кудлатый, патлатый; лохмотья» < гом. кыпч. *йалбыр* id., к. кырг. *җалбыр,* каз. *жалбыр* «ялкын дөрләве» һ.б. параллельләре күп ~ бур. *дальбагар* «асылынкы; ялбыр» һ.б. *йалп* тәкълиди тамырыннан (к. **Җил**), к. кырг. *җалба, жалба-жулба,* к. диал. *жалба-жулба* – жалбырдауга тәкълит, алт. *дьалбыш* «ялкын» һ.б. Чаг. як. *дьалбый-* «ялп-ялп итү, селтәнү, ялпылдату», «камчы селтәп, каргау, каргышлар уку»; *дьалбыыр* «шаман кылычы» (аңа һәртөрле чүпрәкләр, чуклар асылган була). *Жалбыр* һәм *жалбырдау*ның тат. «йомшак» вариантлары *жәлбер, җилбер* һәм *җәлбердәү, җилбердәү (> җилфердәү).* К. түбәндәгеләрне.

**ЯЛБЫРА-У [йа$^{o}$лбы̆р-]** «колыхаться, (тяжело) развеваться», «висеть лохмотьями и шевелиться» һ.б., ш. ук *йалбырда-, җалбырда-* id. ~ нуг. *ялбыра,* каз., к.-калп. *жалбыра-,* каз. диал. *йалбырда,* алт. (Радлов III: 188–189) *йалбра-*, *дьалбыра-* «ялкынлану, киң итеп җилфердәү» һ.б. ахыр чиктә *йалп//җалп//дйалп* һ.б. тәкълиди тамырыннан. Чаг. **Җилфердә-ү, Ялпы** һ.б.

Дерив.: **ялбыран-у, ялбырат-у** (бүрек колакчыннарын ялбыратып йөрү һ.б.; ***ялбырак** сүзенә **яфрак** (к.) тоташа.

**ЯЛБЫР-ЙОЛБЫР [йа$^{о}$лбы̆р-йө̆лбө̆р], җалбыр-җолбыр** – подражание колыханию, развеванию (изодранной одежды и т.п.). Чаг. югарыдагыларны.

**ЯЛВАР-У [йа$^{о}$лwар-], диал., ялбар-у, җалбар-у, җалвар-у** «умолять, убедительно просить» > чув. *чалвар-,* чув. диал. *çолвар-, çулвар-,* мар. *ялвар-, сарвал-, сӧрвӓл-*, удм. *сюльвор-, ялбар-* (шулай итеп, бу сүз Урта Идел регионында болг. теленнән дә, татарчадан да таралган) < гом. төрки, чыгт. *йалбар-* (к.-балк., кырг. *җалбар-,* каз., к.-калп. *жалбар-,* алт. *дьалбар* һ.б.) id. ~ бор. монг. *ǯalbari-* > бур. *зальбар-* һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 92–93). Безнеңчә, этимологиясенең ачкычы уйг. *йалбәр-* < **йали бэр* id. бор. *йалы-* «гыйбадәт кылу; ялыну» сүзенең бор. хәл фигыль формасына (**йалый-*) *бэр-* «бирү» яки **бар-** «бару > дәвам итү» актионсарт фигыле кушылып ясалган. К. Ә. Ясәвидә (103 хикмәт): *Курkгыл имде, курkгыл имде, Ходага ялы барып…*

Бор. **йалы-** фигыле бор. төрки **йал* «корбан», *йа-* «корбан бирү» сүзеннән, к. сол. (маньч. диал.) *ǯalbara*, маньч. *ǯalbari, ǯalbarila-, ǯandu-, ǯanǯi-, ǯanu-, ǯa-* «гыйбадәт кылу; дошман күрү (!) < каргау» (ССТМЯ I: 246). К. **Ялын-у.**

**ЯЛГАН [йа$^{о}$лған],** диал. **җалган** «ложь; ложный» < гом. кыпч. *йалған* (к.-балк., кырг. *җалған*, каз., к.-калп. *жалған*), чыгт., уйг. *йалған* < бор. төрки *jalγan* (ДТС: 228) > угыз. (төр. һ.б.) *йалан* id.

Бу сүзнең көнб. төрки телләрдә генә булуы күзгә ташлана: димәк, ул чагыштырмача яңа. Тат. диал. **йалдаk** «алдакчы» (ТТДС I: 162) сүзенең *ялган* сүзенә нисбәте ачык түгел. Себ. тат. (Тумашева 1992: 62) **йалан** «ялган» – угыз телләреннән килеп кергән булса кирәк (*җалан, жалан* id. каз. телендә дә очрый). ЭСТЯ (IV: 92) бу сүзне **яла** белән бәглы дип күрсәтә. Безнеңчә, тат. сөйл. киң таралган (ДС III: 208; ТТДС I: 169 һ.б.) **йаңгал, җангал** «ялган» (*йаңгалак, җаңгалчык* «ялганчы, алдакчы», *йаңлага-у* «ялганлау») беренчел вариантны чагылдыра һәм ул бор. **йаң-* «ялгышлык, ялгышу» сүзеннән (ихтимал, монг. *-kал* аффиксы ярдәмендә ясалган) булырга мөмкин. Һәрхәлдә *ялган* һәм *ялгыш* сүзләренең охшашлыгы очраклы түгелдер (*ялгыш* < *яңылыш* булган кебек, *ялган* < *яңылган: *йаңылга-* «ялгыштыру» фигыле була ала).

Дерив.: **ялганлы, ялгансыз; ялганлык; ялганла-у; ялганчы** һ.б.

**ЯЛГА-У [йа$^{о}$лға-],** диал. **җалга-у** «приставить, наставлять, приделывать» < гом. кыпч., уйг., төркм. *йалға-* (кырг., к.-балк. *җалға-*, каз., к.-калп. *жалға-*), госм. *йалkа*, як. *салғаа-* (Пекарский: 2046) ~ бор. монг. (Поппе 1938: 200), маньч. (ССТМЯ I: 246) *ǯалүа-* «ялгау, ямау, ябыштыру»; тат. **ялгау** «ялгана торган өлеш, кисәк» (башк. *ялғау* «кушымча; постфикс») > чув. *юлхав* «кендек бавы, соңгылык». Чаг. як. *салғы-* «бер-бер артлы килү» < бор. төрки **йал-гы-*.

ЭСТЯ (IV: 12–14) авторлары бу сүзне бик чәлә һәм таркау яктырталар (тат. *ялга-у* монголчадан алынма диелә, к. монг. *зал* < *җал* «дәвам; әкренәю, ял итү»). Г. Рамстедт (1957: 137) *ялга-у* сүзен тунг. *ǯalu-* «тулы булу» сүзе белән бәйли. Гомумән – этимологиясе юраулы сүз.

Дерив.: **ялгаулы, ялгаусыз; ялгаулык; ялган-у, ялгаш-у, ялгат-у; ялгама, ялганма** һ.б.

**ЯЛГАШ [йа$^{о}$лғаш],** диал. **җалгаш** «деревянное корыто (в котором дают корм скотине)» < бор. *ялkач* кечкенә **йал* сүзеннән шикелле, к. нуг. *йалғас,* уйг., аз., гаг., төр. *йалак* «ялгаш» < *йал-аk,* к. ЭСТЯ IV: 90–91. Төр. һ.б. угыз телләрендә *йал* «терлек боламыгы» (һәм шул боламык салына торган савыт).

Төньяк Кавказ телләрендәге – ком. *йалғаw,* к.-балк. *жалғауч,* даргин. *яглав,* авар. *ялғаз,* осет. *залғавинзэ* «тоткалы таба» сүзенең **ялгаш** сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел. Бу сүзне *йалга-у* фигыленнән ясалган дип уйлыйлар (Отаров 1987: 64–65). Бу фараз дөрес булса, *йалгаш* тәүдә су агызгыч улакны белдергән (андый улаклар бер-берсенә ялганып озын су юлы хасил итәләр). Һәм *йалгаш* < *йалга-ш* булып чыга. К. ш. ук халаҗ. *йалғаk* «ялгаш».

Шул ук вакытта аерым үзб. диал. *йағлаw,* уйг. *йағлаk, йағлиғу* > тат. диал. (ТТДС I: 581) **җәйләү** «таба, табак» сүзе дә билгеле, һәм ул *йағла-* «майлау» сүзеннән булырга тиеш. Угыз. *йалаk* сүзе *йағлаk* сүзеннән дә барлыкка килә ала. Шулай итеп тат. *йалғаш* һәм угыз. *йалаk* сүзләренең бердәйлеге шик астында кала.

**ЯЛГЫЗ [йа$^{о}$лғы̆з],** диал. **жалғыз, җаңғыз,** себ. (ЗДС: 233) **йанғус, йаңыс** «одинокий, одиноко» > удм. *йылдыш* < гом. кыпч. *йалғыз* (кырг. *җалғыз,* к.-балк. *җаңғыз,* каз., к.-калп. *жалғыз, жалғуз,* башк. *йанғыҙ*), чыгт., уйг. *йалғуз*, төркм. *йалңыз,* бор. төрки (ДТС: 229) *jalïŋus, jalïŋuz, jalaŋus, jalŋuz, jaŋus, šalγuz* id., төр. *yalnız* id. Бу сүзнең фигыль коррелянты да бар бугай, к. чыгт. (Будагов I: 340) *йалғузмаk* «качып китү». Күпчелек

төрки телләрдә исем (яки фигыль) нигезеннән тат. **йалгызак**, *җаңғызаķ* (> мар. *йалгыжак, йалзак*, к. Ўпымарий: 300) ~ кар. һ.б. кыпч. *йалғызаķ, йалгызов,* каз., к.-калп. *жалķызаķ,* алт. *дьанғызаķ*, алт. диал., тув. *чаңызаķ* «ялгыз яшәүче (төрле көч. мәгъ. белән)», як. *соғотох* «ялгыз батыр» һ.б. сүзе ясала.

**Ялгыз, ялгызак** сүзләренең төрки фольклорда «героик» мәгънәсе игътибарны җәлеп итә: башк. *Яңғыз батыр*, чув. (Ашмарин IV: 195–197) *Йанкас, Йанкăс*, алт. *Дьаныз, Дьеңиз,* тув. *Эр-Чаңысах,* як. *Эр-Соготох* «дөньяда иң беренче кеше, бөек герой», якутларда ш. ук «ярымтык (сыңар күзле, сыңар аяклы кеше)». Кайбер лингвистлар бу сүзләр белән монг., бур. *Җаңгар, Җаңгыр* – монгол халыкларында иң популяр эпик герой исемен чагыштыралар, к. МНМ I: 372–373.

Безнеңчә, *ялгыз* < *йалынгуз* сүзе белән бор. төрки (ДТС: 227–229) *jalaŋuq, jalïŋyq, jalnuq* «беренче кеше – Адәм галәйһиссәлам; сөекле җария» (М. Кашгари аңлатмасы шундый) >> мар. *йоңгок* «ялгызак» сүзе тамырдаш. К. төркм. *йалңыыз*, нуг. *йалķы,* кырг. *җалķы,* каз. *жалķы,* аз. (АДДЛ: 240) *йалхы,* калм. *йалңы* «берләч (гадәттә икешәр бала таба торган терлекләрдә ялгыз бала)», монг. *ялың* «берүзе». **Ялгыз** сүзе белән бүтән сүзләрне чагыштырулар гипотетик фараз хөкемендә кала.

Кызыклы дериваты: **япа-ялгыз, япан-ялгыз.** К. түбәндәгене.

**ЯЛГЫЗЫН [йа$^{о}$лғы̆зы̆н],** диал. **йаңғызын** һ.б. «одиноко, в одиночку» – **ялгыз** сүзенең инструменталь килеш формасы.

**ЯЛГЫШ [йа$^{о}$лғы̆ш],** диал. **җалгыш, җаңгыш, җаңылыш, җаңылыш, җаңгыш, йаңлыш, йаңыш** «ошибочно; ошибка»; чув. *йăнăш*, удм. *янгыш* (*йаңгыш*) «ялгыш, хата», мар. *йоңылыш, йонķыш* «ялгышып» (*самынь* < болг. **жаңгыл* «ялгыш») < гом. кыпч. *йаңылыш* (нуг. *йаңылыс,* кырг. *җаңылыш,* к.-балк. *җаңылыч, җаңылыш,* каз., к.-калп. *жаңылыс*), төркм. *йалңыш* «ялгыш», төр. *yanlış* «ялгыш, хәтәр, куркыныч» (оригиналь мәгънә!) һ.б. ← тат. диал., гом. төрки *йаңыл-* «юлдан язу (бер янга китү?)». К. **Ялгыш-у.**

Дерив.: **ялгышлы, ялгышсыз; ялгышлык; ялгышлан-у;** диал. **ялгышча** һ.б.

**ЯЛГЫШ-У [йа$^{о}$лғы̆ш-],** диал. **йаңгыш-у, йаңгылыш-у,** ш. ук. **җаңгыш-у, җаңгылыш-у** һ.б. (әйтергә кирәк, нәкъ диал. формалар этимологик җәһәттән дөресрәк) «ошибиться, ошибаться» > чув. *йăнăш-* id. < гом. төрки *йаңылыш-у*, асылда, «бергәләп яки үзара **йаңыл-у**», к. тат. диал. (Тумашева 1992: 69) < гом. кыпч. *йаңыл-* (кырг., к.-балк. *җаңыл-*, каз., к.-калп. *жаңыл-*), гом. көнб. төрки *йаңыл-* (уйг. *йеңил-*, *йаңил-*), төр. *yanıl-* «ялгышу, адашу, алдану» сүзеннән (ЭСТЯ IV: 120), бу фигыль исә **йаң-, *йаңы-* «ялгышлык булу; ялган булу» фигыленнән (ихтимал тат. диал., башк. **йаңыш** вариантлары турыдан-туры шул фигыльдәндер). К. **Ялгыш.**

Гипотетик **йаң-* фигыле төрле бүтән нигезләрнең тамыры булырга мөмкин. Һәрхәлдә *ялган* < *яңгал* (к. *ялган*) **йаңылган* яки **йаңгылан* һ.б. сүзләреннән килеп чыкса, аның тамыры шул ук *йаң* булуы ихтимал.

*Йаң* фигыле үз чиратында *йан-у* «бер янга китү» фигыленнән килеп чыгарга мөмкин (**йангы-, йаңķы-, йаныķ-* кебек ясалмалар була ала). К. Ә. Ясәвидә (59 хикмәт):

> *Чыраг булып, үчмәгән, дин юлыдың янмаган,*
> *Нахак эшне итмәгән гадәләтлек Гомәрдер.*

Монда *йан-* «төп юлдан читкә китү; ялгыш юлга керү» кебек мәгънәдә. Әйтмәкче, тат. сөйләшләрендә дә **йаныķ юл** «төп юлдан аерылып киткән юл, сукмак» сүзе бар (сүзлекләрдә теркәлмәгән).

Дерив.: **ялгыштыр-у, ялгышыл-у, ялгышын-у** һ.б.

Шуны да ачыклап үтик: **ялгыш** < *йаңылыш* **йаңыл-у** фигыленнән ясалган исем (-*ш*$^{1}$ аффиксы), ә **ялгыш-у** < *йаңылыш-у* **йаңыл-у** фигыленең урт. юн. (-*ш*$^{2}$ аффиксы), ягъни монда ике очракта аффикслар ике төрле (омоним кушымчалар).

**ЯЛДА-У [йа$^{о}$лда-]** (ТРС 1966), (Akb: 122) *calda-* «купать, искупать лошадь (скот)», (Будагов I: 339) «(медленно) плавать», «быть на плаву» ~ себ. тат., башк. **йалда-у** «елга кичү» < гом. кыпч. *йалда-*, каз. *жалда-,* к.-калп. *йалла-* «ат ялына тотынып зур елгалар кичү» (нуг. *ялда-* «йөзү», «махсус ишкәксез агып бару») сүзеннән (ЭСТЯ I: 93–94); башк. *йалдау* **йалда-у** фигыленнән исемләшкән һәм «атны су кертерлек урын» мәгъ. алган. К. себ. *йалдап цыгу* «йөзеп чыгу» (терлекләр тур., к. Тумашева 1992: 67). Сүзнең тамыры – **йал**, к. **Ял I.** Чаг. монг. *залах* «кимәне юнәлтү».

Элекке заманнарда күчмән төркиләр тирән елгаларны башлыча ялдап кичкәннәр; хатыннар һәм бала-чагалар **күпергә** утырып кичкән. Утрак

тормышта **ялдау**ның «атны су кертү» мәгъ. үсеп чыккан, чөнки утрак илат гадәттә кимәләр, күперләр ясый.

**ЯЛЕ** «ну-ка» к. **Я IV.**

**ЯЛКАУ [йа°лқаw],** диал. **җалқаw** «лентяй; лень» («*ялкавы килгән*» дип сөйлиләр), себ. (Тумашева 1992: 66) **йалгаw** «ленивый; недосоленный» > чув. *йолхав* > *йулхав,* мар. диал. *йолко*, удм. диал. *ǯалкау* (Насибуллин: 115) < гом. кыпч. *йалқаw* (кырг. *җалкоо*, к.-балк. *җалқаw*, каз., к.-калп. *жалкаw*), уйг. *йалқаw*, үзб. *йалқоw*, тув. *чалғо* id. ~ бор. монг. *ǯalqaγu* > хәз. монг., калм. *залхуу* id., *залхай* «ашыкмаучан» һ.б.ш. сүзләр. К. ш. ук алт. *йалку, дьалку* «ялкау, ялкаулык».

*Ялкау* сүзенең үзеннән чыгып **ялқа-у* дигән фигыльнең исемләшкән исем фигыль формасы дип уйларга мөмкин. Ләкин *йалқа-* дигән фигыль нигезе билгеле түгел, әмма *йалқы-* дигән фигыль бар: башк. *йалкы-,* алт. *йалқы-, дьалқы-* (ЭСТЯ IV: 14); бу сүз бик җиңел генә *йалык-* сүзеннән килеп чыга ала: ләкин бу метаморфоза булды микән? Гомумән, **ялкау** һәм **ялык-у** сүзләренең үзара мөнәсәбәте башваткыч мәсьәлә: ЭСТЯ IV авторлары монда ике-өч аерым нигезнең контаминациясен күрәләр. Хикмәт бу нигезләрнең уртак морфологик формулага кермәве. Мәгънә җәһәтеннән дә кыенлыклар бар. К. **Ялык-у.**

Дерив.: **ялкаулык, ялкаулан-у.**

**ЯЛКЫЛДА-У [йа°лқы̆лда-]** (ТТАС III: 34; Тумашева 1992: 67), диал. **җалқылда-у** «сверкать, ярко блестеть (широкими полосками); пламенеть; полыхать»; күч. «быть блестящим (о человеке, доме)»; переносные значения не относятся к основам **йалк** *(итү)* «полыхнуть», **йалк-йалк** *(итү)* «повторно и однообразно полыхать», **йалк-йолк** *(итү)* «разнообразно полыхать», **йылк** *(итү)* «полыхнуть не очень ярко», **йылк-йылк** *(итү)* «полыхать не очень ярко, матовато блестеть, сверкать полосками (о ткани и т.п.)» (к. **елкылда-у**), которые всегда в конкретном образном значении.

Бу сүзләрнең бүтән төрки телләрдәге тәңгәлләрен табу кыен, чөнки андый (тәкълиди) сүзләр сүзлекләрдә саран биреләләр; чув. *йалкӑш-* «яну, ялкылдау, елкылдау» тат. сөйләшләреннән (саф чув. *ҫалккӑш-* булырга тиеш), к. ш. ук мар. *йолгыж-, йылгыж-* «ялкылдау, ялтырау» < тат., ләкин әлегәчә тат. *йалкыш-у* фигыле сүзлекләрдә теркәлмәгән. Хәлбуки *ялкылдау – балкылдау* парына тәңгәл *ялкыш – балкыш* пары да булырга тиеш. Гомумән, *ялкылдау* тәкълиди сүзьясалышы калыбында *йалқ* тәкълитеннән ясалган. *Йалк* нигезе исә *йал (> җал)//йыл* тамырыннан *-қ* детерминанты ярдәмендә ясала (чаг. *йылк, җилк, жилп, йалт* һ.б.). К. **Ялкын**.

**ЯЛКЫМ [йа°лқы̆м], йалғым, йалқын** (ЗДС: 229) «боковая часть чего-либо; крыло» нуг., ком. *ялқын*, кырг. *жалқын*, тув. *чалғын*, каз. *желқом* id.

**ЯЛКЫН [йа°лқы̆н],** диал. **җалкын** «пламя» > удм. диал. (Насибуллин: 195) *ǯалкын* ~ уйг. *йалқун,* алт. *дьалкын,* каз. *жалқын, жалқум,* төркм., госм. *йалқым, йалғым* id. тат. диал. **йалкы-,** (Будагов II: 340; ТТДС I: 162), *җалқы-* (Остроумов 1892: 68) «ялкынлану, дөрләп яну» фигыленнән (< *йалқы-ын*), сүзнең тамыры *йалқ-* ялкынлануга имитатив, к. ш. ук алт. диал. (Радлов III: 153) *дал,* хак. *чал* «ялкын, яшен», алт. *ялы*, ком. *ялла-* «яну» һ.б. К. **Ялт.**

Төрки телләрнең күпчелегендә **ялкын** урынына себ. тат. (Тумашева 1992: 67) **йа°лын** ~ нуг., ком. *йалын,* кырг. *җалын,* к.-калп. *жалын,* үзб. диал. *йалиң,* угыз. *йалың* «ялкын» сүзе кулланыла, ә *йалқын* исә *чалгый* мәгъ. йөри. К. ш. ук алт. *дьалкын* «яшен», хак., тув. *чалын* «ялкын; дулкын, очкын», *чалгың* «дөрләү, дулкынлану», монг. *заль* < *жали* «ялкын; ялт итү». ЭСТЯ IV: 106.

*Йалын, йалың* варианты *йалкын* сүзеннән килеп чыккан, ягъни ул яңарак булса кирәк, шулай да ул бик бор., к. чув. *ҫулӑм* < *ҫолӑм* < болг. **йалым* > мар. Т. *салым* (Саваткова: 141) «ялкын».

**Ялкын** сүзеннән тат. **ялкынсын-у** «кызарып шешү» фигыле ясалган. К. **Ялкылда-у.**

**ЯЛМАВЫЗ [йа°лмаwы̆з]** «чудовище, Баба-Яга», диал. (ДС I: 244; Тумашева 1992: 67, 90) **җалмаwыз,** себ. **йалмавыц, йылмаус, йалмағус** > чув. *йелмӗвӗс* id. ~ нуг., ком. *йелмаwыз,* кырг. *җалмооз, җелмогуз*, каз., к.-калп. *жалмаwуз*, үзб. *йалмавуз, йалмағиз* id. бор. *йәл-маңыз* «шайтан Маңыз (Мангуз)» сүзеннән, к. уйг. *йәл муңуч* id., кырг. диал. *Йәлмогуз* «диюләрнең анасы, су анасы». Чаг. *Җилбегән* < *Йәл Бәгән.* ЭСТЯ IV: 95–96. К. **Җил** һәм **Мус.** Төрки һәм күрше халыкларда *чулмус, шулбус, шимнус* һ.б. (күп вариантлар) «ялмавыз» төрлечә аңлатыла.

Тат. диал., себ. **йалмаwыц ~ йалмаwыр** «себерке», ихтимал, бу сүзнең борынгырак *-г*

вариантыннан киләдер: Ялмавыз карчыкның себеркегә утырып очучан булуы бөтен дөньяга билгеле мифологема. Ögel: 543; МНМ II: 647 һ.б.

**ЯЛМАН I [йа$^{о}$лман]**, диал. **җалман** «крыса»; диал. (независимо от фонетического варианта) «тушканчик; крот», к. ш. ук **ялмак** «тавышкан» (ТРС 1966), себ. **йалман** «суслик» (Тумашева 1992: 67) ~ каз. диал. *атжалман* «күсе», нуг. *йалман* «тозлакта үсүчән үлән төре» ← *йалман қулақ,* к. үзб. *йалман кулоқ* ~ каз. *жалмаң кулақ* «ялманколак», төркм. *йалман қуйруқ* – үлән атамалары, калм. *йалмң* «ялман»; бүтән чыганакларда төгәллек юк: алт. *ялбан*, алт. диал. (Радлов III: 190) *дьалман* «кечкенә бер хайван», «күсе төре», бор. кыпч. (Мелиоранский һ.б.) *йӓлман* «җир тычканы». ЭСТЯ (IV: 97) авторлары бу сүзне *йалма-у* сүзеннән дип аңлаталар, ләкин к. чыгт. (Боровков 1961: 46, 264) *йалман, йӓлмӓн* «җитез, елгыр», төркм. (Будагов II: 362) *йәлтан, йәлман* < фар.-төрки *йәлманаnд* «җилдәй җигез», бор. төрки (ДТС: 231) *jamlan* «күсе төре» ← *jam* «чүп, тирес»? Тат. *йалмак* варианты экспрессив ясалма булырга да мөмкин. Чаг. түбәндәгене.

**ЯЛМАН II [йа$^{о}$лман]: йалман кылыч, йәлмән** «сабля, меч» (фольклорда: *Йаныл-йаныл чабарга йалман кылыч йанда йук*, к. Тумашева 1992: 67) ~ кырг. *җалман* «кылычның, хәнҗәрнең очы», госм. (Радлов III: 358; Будагов II: 364) *йӓлман* «кылыч очы», төр. (Redhouse: 1239; Tarama sözlügü. 1983: 232) *yaltan* id., ш. ук «тау башында торган таш кыя» ← төр. *yalım, jalıŋ, jalčın* id. ~ тув., хак. *чалым* «таш кыя». ЭСТЯ (IV: 103) авторлары «таудан чыгып торган таш кыя» һәм «кылыч очы» мәгънәләре бердәйлеген таныйлар, ләкин ике матдәдә, Редһоуз һәм Штойервальд (Steuerwald: 1003) бер матдәдә бирәләр. ЭСТЯ тат. мисалын китерми. Бу сүз элек кып. телләрендә киң таралган булган, к. рус. *елман, елмань* «кылыч йөзе (бигрәк тә аның очы)» (к. Фасмер II: 16), *елбан, елбань* «яр буендагы таш кыя; текә тау; пик» (Аникин: 198; автор **ялман** белән чагыштыруны кире кага). Безнеңчә, «туфрактан чыгып торган кыя > кылыч очы» бик мөмкин (чаг. ним. *Pick* «пик – чыгып торган тау башы» һәм «усаллык, кискенлек»). К. ш. ук каз. (ҚТДС: 106) *жалман* «хәнҗәр сабы», төр. *yaltan* «текәлек», «кыек үскән теш».

**ЯЛМА-У [йа$^{о}$лма-]** «глотнуть, вылизнув языком», диал. **җалма-у** < гом. кыпч. *йалма-* (кырг. *җалма-*, каз., к.-калп. *жалма-*) id. бор. *йал-* «ялау» сүзенең интенсивлык формасы; **ялма-** фигыленең кайт. юн. **йалман-** «ясану» үзеннән киңрәк таралган. К. ЭСТЯ IV: 95.

**ЯЛПАЙ-У [йа$^{о}$лпай-],** диал. **җалпай-у, җәлпәй-ү** «уплощиться, сплющиться, широко и низко оседать» < гом. кыпч., үзб. *йалпай-* (кырг. *җалпай-*, каз., к.-калп. *жалпай-*), як. *налбай-* id. ← *йалпы//йалпа* (к. **Ялпы**). Чаг. ш. ук **җәлпәлән-ү, йәлпәлән-ү** «яньчелү» (ДС III: 223); чаг. монг. *йалба-, далба-* «югары, ялпаю». Бор. кыпч. **йалмал-* (төркм., башк. *йалпар-*) варианты да булган (к. **Ябалдаш**). К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 66) **йалбырсак, йалпырсак** «киң, киңчә» ← **йалпы-р-у* «ялпаю; ялпы булып китү». К. түбәндәгене.

**ЯЛПАК [йа$^{о}$лпак]**, диал. (ДС I: 241–243; ДС II: 258; Тумашева 1992: 66) **йәлпәк, җалпак, җәлпәк, йалбақ, йалвақ, зәлпәк** (БҺҺ III: 61, асылда мишәрдә) «плоский, сплюснутый, уплощённый; очень пологий» < гом. кыпч., уйг. *йалпақ,* үзб. *йалпоқ* (кырг., к.-балк. *җалпақ, җалпаң*) id., к.-балк. ш. ук «яссы тау түбәсе – көтүлек», алт. *дьалбақ* «ялпак, киң», *дьалбаң* «сөзәк», хак. *налпах, чалбах, чалбах* «ялпак» (бу сүзнең бер күч. мәгънәсе характерлы: гаг., башк., госм. *йалпақ* «ахмакларча илгәзәк, гадәттән тыш беркатлы») ← *йалпы//йалпа*. К. **Ялпы.**

**ЯЛПЫ [йа$^{о}$лпы̆],** диал. **жалпу** (ЗДС: 179), **җалпы** (БҺҺ III: 55, асылда тат.) «плоский; плоская долина, низина с невысокими краями» ~ гаг. *йалпы* id., уйг. (Радлов III: 186) *йалба, йалпа*, бор. төрки (DLT III: 30) *yalbı* «яссы»; бу сүзнең күч. мәгъ. киң таралган: тат. **йалпы** «гомуми, конкрет түгел» (*ялпы сүздән ялыктым,* диләр), башк. *йалпы* «ишле, бердәм, гомуми», каз., к.-калп. *жалпы* «уртак; гомуми» (бу семантик үзгәреш шуннан: бор. заманнарда табигый чикләре булмаган киң көтүлекләр ыру-кабиләләр өчен уртак булган), уйг. (Радлов III: 186) *йалпа* «ялпы; ахмак».

*Йалпы* < (төр.) *йалпыг* > *цалпык* бор. *йалп-* яссы күренүгә, ялбырдауга тәкълит сүзеннән (к. ЭСТЯ IV: 100–101). Параллельләре монг.-тунг. телләрендә дә бар.

**Йалпы//йалпа** продуктив нигез: шуннан **ялпак, ялпы,** башк., үзб. диал. (ЎХШЛ: 126) **йалпаш**, **йәлпәш** «ялпаксыман» һәм киң таралган **йалпай-у** (**йалпар-у** варианты да бар).

**ЯЛПЫКОЛАК [йа°лпы̆қолақ]** (**ялпы колак** дип аерым да языла) «собака с отвислым ухом, порода таких собак», күч. «непостоянный в решениях мальчик» – бик бор. тәгъбир, к. бор. төрки (ДТС: 236) *japrï qulaq* «салпы колак». **Йапры** < **йалпырыг* булса кирәк. Чаг. **Ялпы.**

**ЯЛПЫЛДА-У [йа°лпы̆лда-]** диал. «качаться из стороны в сторону» (об отвислых ушах собаки, о навешанных тканях на ветру и т.п.).

Дерив.: **ялпылдат-у** (мәс., *бүрек колакчынын ялпылдатып йөрү,* диләр); **ялпылдак** сүзе дә бар бугай.

**ЯЛТ [йа°лт],** диал. **җалт** – подражание блеску, сверканию («сверк!»), а также очень быстрому взгляду: **йалт кына** «быстро, мгновенно», **йалт-йалт** подражание однообразному поблёскиванию, **йалт-йолт** подражание поблёскиванию разнообразному ~ чув., гом. кыпч., уйг. *йалт* (кырг. *җалт,* каз., к.-калп. *жалт*) id. Тәкълиди регуляр сүзьясалышы: **йалтырт, йалтыр-йалтыр, йалтыр-йолтыр**, шуннан **йалтыра-у** «ялт-йолт итү», **йалтырак** «ялтыр-йолтыр килеп торган», **йалтырка** «ялтыравык (исем)» һ.б.; кыпч. телләрендә боларның параллельләре бар. К. Исхаков 1951: 103–111. К. **Ялтан, Ялтар-у, Ялтыр.**

**ЯЛТАГАЙ [йа°лтағай], ялтакай, җалтагай, җәлтәгәй** (тат. диал.; БТДҺ; 109) «юркий, изворотливый», «трусливый хитрюга» < монг. *жалтагай, залтагай* id. чаг. чув. *яштакай* id. К. түбәндәгеләрне.

**ЯЛТАЙ [йа°лтай]** (ЗДС: 230) «сполохи; молния вдалеке» ~ уйг. *йалтай* id., күч. «җитез, елгыр; яшен тизлегендәге». К. ш. ук тат., башк. **ялтай-у** «бик тиз карарын, фикерен үзгәртү». Мондый сүзләр төрки телләрдә күп кенә булырга тиеш. К. түбәндәгене.

**ЯЛТАК [йа°лтак], ялтакай,** (Dobr. III: 474) **yaltaq** «быстро меняющий ориентировку», «лицемерный, льстец» ~ чыгт. (Будагов II: 339) *ялтақ,* төр. *yaltak* id. К. **Ялтагай.**

**ЯЛТАН [йа°лтан], җалтан, йалтан-йөлтан, җәлтән** – барысы да диал. (к. ТТДС I: 581) «быстро; быстро реагируя; быстродействующий» ~ кырг. *жалтаң* «курыккан, өреккән» < бор. кыпч. **йалтаң* «куркынып, тизгер булыр киткән», шуннан: тат. (Тумашева 1992: 67) **йалтаңла-у** «әрлебирле чайкалу», башк. (БТДҺ: 108) *йалтаңда-у,* кырг. *жалтаңда-у* «куркынып алан-ялан карану». К. ш. ук себ. **йалтайла-у** «шүрләү», кар. *йалтай*, башк. *йалтай, йалтан, йалтаң* «ялкау» ~ гом. кыпч., үзб., чыгт., төр. һ.б. *йалтақ,* кырг. *җалтақ,* каз., к.-калп. *жалтақ,* шор. *чалтақ* «ялагай, тиз бирешүчән, чәрексез» – бор. **йалта-* «ялт итеп карану яисә тайпылу» сүзеннән. Чаг. уйг. *йалдан-,* хак., тув. *чалтан-*, алт. *дьалтан-* «ялтанлау, куркып тайпылу; эштән тайчыну» һ.б. (бу рәттәге бүтән кайбер сүзләр тур. к. ЭСТЯ IV: 101–102, тик анда тат. теле материалы һәм *йалтан-у* фигыле китерелми). К. **Чалдун, Ялтан-у, Ялтар-у** һ.б. түбәндәгеләрне.

**ЯЛТАН-У [йа°лтан-], җалтан-у, йылтан-у** «увильнуть, отскочить (от удара); кинуться назад, в сторону», күч. «прикидываться, прикинуться кем или каким» < гом. кыпч. *йалтан-, җалтан-* id., конкрет мәгъ. кырг., каз. (Будагов I: 399) *җалтан-* «ат тур. – башын бирмәү; башын болгау» ← *ялта-жалта-* «ялт итү, ялт хәрәкәтләнү» һ.б. К. **Ялт, Ялтагай, Ялтай, Ялтак, Ялтар-у.**

**ЯЛТАР-У [йа°лтар-]** «быстро повернуться, чтобы сбросить седока (о лошади)» (Н. Арсланов), «быстро отстранить, отклонить от себя» (Будагов II: 339) – бор. **йалта-* «ялт борылу, ялт тайпылу» сүзенең йөкл. юн. булса кирәк. К. **Ялтан.**

**ЯЛТӘГӘ [йәлтәгә]** себ. (ЗДС: 241) «флюгер» ~ төр. *yeltek* id. ← *yelte-* «җилләндерү, җилләнү; гайрәтләнгән булу». К. түбәндәгене.

**ЯЛТӘН [йәлтән]** диал. (ЗДС: 183) **җәлтән**, сирәгрәк **йәлтәк, йәлтәгәй** «с порывистыми движениями и решениями» ← **җәлт** (к. **Җәлт**). К. **Ялтагай.** Чаг. **Ялтәгә.**

**ЯЛТЫР [йа°лты̆р],** диал. **җалтыр,** сирәгрәк диал. **йәлтер, җәлтер** «блестящий; блеск; бегающий (о глазах) ~ башк., нуг. *йалтыр*, кырг. *җалтыр* һ.б. (барча төрки телләрдә рефлекслары бар) id. Бор. төрки охшаш исем яки сыйфат юк, тик (ДТС: 230) *jaltïr-, jaldra-, jaltrï-, jïltïr-, joldra-* фигыльләре бирелгән. Әлбәттә барысы да *jalt* тәкълиди сүзеннән, к. **Елт, Ялкын, Ялт** һ.б.

**Ялтыр** тат. телендә киң дериватлы: **ялтыра-, ялтырак, ялтырка** (болар да деривацияле сүзләр).

**ЯЛЧЫ [йаºлчы̆],** диал. **җалчы** «наёмный работник, батрак» > мар. (Исанбаев 1978: 15) *йалче,* удм. *ляльчи* id. < гом. кыпч. *йалчы* (нуг. *йалшы*, башк. *йалсы,* к.-балк., кырг. *җалчы*, каз., к.-калп. *жалшы*) id. *йал* (к. **Ял II**) сүзеннән; бу модельдә ясалган сүзләр: чув. *тарҫӑ*, монг. *зарч, зарча* < бор. монг. *ǯarči ~ йарычы* id. (к. Боровков 1963: 142–145) – *йары* «ярдәм» сүзеннән. Алтайларда **ялчы** «ял ите (каты ит) ашаучы» дигән халык этимологиясе бар.

**ЯЛЧЫ-У [йаºлчы̆-],** диал. **жалчы-w,** (ЗДС: 241) **йәлче-ү** «достигнуть желаемого; иметь развитие, успех; загореться; воспламенеться, обращаться, говорить с сияющим лицом», (*Бай хатыны ялчыга ялчымас* дигән мәкальдә **ялчыма-у** «не быть довольным; не улыбаться») < гом. кыпч. *йалчы-* (башк. – БТДҺ: 109 – *йалсы-у, йәлсе-ү,* к.-балк., кырг. *җалчы-*, каз., к.-калп. *жалшы-*), уйг., үзб. *йалчи-* id., ш. ук «шатлану, шатландыру; тәэмин ителү» һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 102) – чыгышы юраулы; безнеңчә, бор. (ДТС: 227) *jalčït-* «кызыктыру» *jal-* «янып китү, ялкынлану» сүзеннән *-чы* аффиксы ярдәмендә ясалган (чаг. *кыр – кырчы-, үр – үрче-*). Төп мәгъ. тат. телендә сакланган. Бу сүз, безнеңчә, бор. төрки *jalčïq* «ай нуры; ай», *jašïq* «кояш, кояш нуры», арытабан *яшен* (к.) сүзләре белән тамырдаш.

Дерив.: **ялчык-у** «чамадан тыш шатлану» (ТТАС III тә дөрес аңлатылмаган – «талчыгу» диелгән), **алчын-у** «шатлык кичерү, куану» к. төр. *yalčin* «такыр тау битләве», **ялчыт-у** «үлгәнче көлдерү» ~ бор. төрки (ДТС: 228). *jalčït-* «рухландыру; аздыру». Барысы да ахыр чиктә *ял ~ ялт* тамырыннан.

**ЯЛЫК-У (ялыккан, ялкыта, йалыгу),** диал. **җалығ-ыw** «почувствовать скуку (от чего), отвращение; томиться от однообразия» – бу гом. кыпч. сүзнең нигезе (тат. телендә үк күренгәнчә) бик тотрыксыз; уйг. *йалиқ-,* нуг. *йалық-*, каз., к.-калп. *жалиқ-*, башк. диал., ком., бор. төрки (МК, ДТС: 230) *jalq-* > кырг. *җалқ* id. яңгырашыннан, бу яңгыраш исә к.-балк. *җалкы-,* алт. *дьалкы-,* тув. *чалға-* ~ бор. монг. *ǯalγa-* «ялыгу» вариантыннан. Шулай итеп, **ялык-у** сүзен бор. *йал-* фигыленең интенсивлык дәрәҗәсе дип тәгърифләп булмый шикелле. Әмма, ихтимал ки, иң беренчел яңгыраш тат.-нуг.-каз. телләрендә сакланган булса кирәк (?) **Йалык-** < *йаллык- (йал-лык-у)* булырга мөмкин.

ЭСТЯ (IV: 14–15) авторлары **ялык ~ җалык** сүзе хакындагы озын матдәдә аны *ялкау//җалкау* сүзнең дериватларның берсе итеп күрсәтәләр. Ләкин, безнеңчә, **ялык-** белән *ялка-* нигезләре арасында шактый аерма бар. Әгәр *йалық-* «артык ял итү» булса, *йалка-* «ял теләү, ялга омтылу» (*-ка* аффиксы), димәк болар тамырдаш, ләкин аерым, бербер сенә турыдан-туры баглы булмаган нигезләр. Хәз. монг. *залх-* «ялыгу» һәм *залха-* «җиксендерү, җәзалау; жобану» – икесе ике нигез.

Һәр ике фигыль үз чиратында бор. бер *йāл-* < *дьаал-* фигыленнән. Азактагы *-л* авазына карап фикер йөрткәндә, бу сүз үзе бор. **дьаа-* фигыленең төш. юн. Як. *дьаал* «теләмичә, теләс-теләмәс» шул ук фигыльдән ясалган исем һәм аның *йаал-* фигыленә турыдан-туры мөнәсәбәте юк.

Як. *салт-* һәм *салгыт-* (икесе дә «ялкыту») фигыльләренең дә аерым саклануы юкка түгел. *Салт-* < **йалт* < **йалыт* бор. *йал-* фигыленең йөкл. юн. К. ш. ук як. *салғы* «ял итү урыны (киек-кошларга карый)». К. **Ял.**

Дерив.: **ялкыт-у** һәм **ялыктыр-у** (икесе бер мәгъ.).

**ЯЛЫН-У [йаºлы̆н-],** диал. **җалын-у** «умолять, упрашивать, просить пощады, прощения, нижайше просить» > чув. *йолӑн-, йулӑн-, йӑлӑн-* (Сергеев 1971: 66), мар. *ялын-*, удм. *ялын-, җалын-* id. < гом. кыпч. *йалын-* (кырг., к.-балк. *җалын-*, каз., к.-калп. *жалын-*), чыгт., төркм. *йалын-*, үзб. *йалин-*, уйг. *йелин-* id., алт. *дьалын-*, тув. *чалын-* «ялыну, буйсыну, үтенеп мөрәҗәгать итү» ~ як. *салын-* «шүрләү; хөрмәт итү». К. ш. ук себ. (Тумашева 1992: 67) **йалыр-** «гафу үтенү», **йалырға-у** «игелек эшләү». Барысы да бор. **йал-* «хатасын төзәтү; рәтләү; юнәлдерү» сүзеннән, к. бор. монг. *ǯala-* > бур. *зала-* «идарә итү; төзәтү». К. **Яла.**

**Ялын-** нигезенең аеруча кулланышлы дериватлары: **ялындыр-у, ялыныч** (барча кыпч. телләрендә барлар); диал. **җалынчак** ~ төркм. *йалынҗа*, төр. диал. *yalıncak* «ялынучан, сорanuчан».

**ЯМ I [йаºм]**, диал. **җам** «яма» > чув. *йам* «тирән тарлавык» (к. Ашмарин VII: 69), мар. (Иванов, Тужаров: 59; Саваткова: 37) *йăм, йăмĕ,* удм. диал. *җам* «ям» < рус. *яма* дип әйтеп бетереп булмый, чөнки рус сүзенең үзенең этимологиясе ачык түгел (к. Фасмер IV: 555–556). Тат. үзенчәлекле сүзләр: **күмер җамы** – «күмер яндыру базы», **йам утыру** «күмер яндыру (махсус базда туфракка күмеп агач яндыру һәм күмер хасил иттерү)». К. **Ямбикәр.**

**ЯМ II [йа$^{o}$м]** тар. «почтовая станция; ям» к. **Ямыл.**

**ЯМАК I [йа$^{o}$мак]** «плохой человек» (Утыз-Имәни) ~ башк. *йамаҡ, йамаҡай* «начар, ямьсез», мар. диал. *ямак* – әкият герое, тискәре тип id. Төр. *yatak* «урынбасар; чик сакчысы» сүзен телчеләр *яма-у* белән баглыйлар, к. Будагов II: 365. Ачык түгел. Чаг. **Яматай.**

**ЯМАК II [йа$^{o}$мак]: ямаҡ мае** (ЗДС: 230) «горчица». Ачык түгел. Бер мәлне тат.-башк. телчесе Т. Гарипов бу сүзне **ямәк** халкы исеменнән бугай дигән иде, ләкин бу фараз расланылмый.

**ЯМАН [йа$^{o}$ман],** диал. **җаман** «плохой, скверный» < гом. төрки, бор. төрки (Радлов III: 301) *йаман,* кырг. *җаман,* каз., к.-калп. *жаман* һ.б. ~ алт. *дьаман, дьабал,* хак. *чабал* id. ш. ук «явыз рух». Бу сүзнең сингармонизмга буйсынмаган вариантлары бар, к. уйг. диал., үзб. (ЭСТЯ IV: 109–110) *йәман, җәман* һәм кайбер телләрдә (төр., төркм.) бу сүз «сугышчан» мәгънәсендә, к. ш. ук көрд. *йӓман* «сугышчан, үткер, кыю; явыз». Дж. Клоусон фикеренчә, бу сүз XI г. элек очрамый (Clauson: 937), Г. Рамстедт буенча, бу сүз көньяк кор. *jäтап* «варвар; кыргый, асау (ат тур.)» сүзеннән (Ramstedt 1952: 75). Чыннан да, бу сүз тәүдә атка мөнәсәбәтле булган булса кирәк, к. **Чәмән. Яман** сүзе күп Евразия телләренә үтеп кергән. Рус сөйләшләрендәге (фономорфологик вариантлары бик күп булган) *яман*, бурят һәм калм. *ямаан* «тәкә, кыр кәҗәсе төре» сүзен, *куку яман* «исе яман» дип тә аталгач, «безнең» **яманнан** килә дип уйларга мөмкин.

**ЯМАТАЙ [йа$^{o}$матай],** диал. (ДС I: 244; ДС II: 243; ДС III: 218) **җаматай** «неважный, некрасивый, дурной» – тат.-башк. телләрендә генә; монголчадан булса кирәк, к. бор. монг. *ǯатаүtai,* хәз. монг. *замагтай* «былчырак, пычрак» (*-тай* - төрки *-лы*). Ихтимал, бу сүз *ямак, яман* кебек үк **ягы** (к.) «дошман» тамырыннандыр.

**ЯМА-У [йа$^{o}$ма-]**, диал. **җама-у** «наложить заплату, латать, чинить прореху» > гом. кыпч., бор. төрки *jата-* (ДТС: 281), к.-балк., кырг. *җама-,* каз., к.-калп. *жама-,* алт. *дьама-,* хак. *нама-,* тув. *чама-*, як. *сама-* һ.б. (ЭСТЯ IV: 108) тунг.-маньч. *наму, нама* «ямау» белән чагыштырыла. Бор. монг. *ǯата-* «ямау, ишләү» төрки телләрдән булса кирәк.

Тат. **йамау**, **җамау** (исем) < гом. кыпч. *йамаw* (кырг. *йамоо*) < уйг. һ.б. *йамағ* сүзеннән. Тат. диал. **йамачкы**, **йамацку** (ДС I: 244; Тумашева 1992: 67), ш. ук **йамачла-у** «ямаштыру» **йама-у** сүзеннән, ләкин ясалышлары аңлашылмый. **Яман-у** «үз киемеңне ямау» актив кулланылган.

*Йама-* нигезендә *-а* яисә *-ма* фигыль ясагыч кушымчалар эзләп карарга мөмкин (*йам-а-?, йа-ма-?*).

**ЯМӘК [йәмәк]** – название древнего племени, имеющего отношение к истории татар (возможно – предки домонгольских татар Среднего Поволжья) – *кимәк* сүзе белән бердәй дип карала (**кимәк** сүзе үзе < **ике йәмәк** дигән фикер дә бар). ДТС: 255; Velidi-Togan: 162–163 (һ.б. битләр).

**ЯМБИКӘР [йа$^{o}$мбикәр],** диал. (ТТДС I: 565) **җамбикәр** «яма, куда бросают падаль, мусор» < фар. **ямибӣк'āр* «файдасыз (бикяр) ям»?

**ЯМБЫЗ [йа$^{o}$мбы̆з],** диал. (ТТДС I: 163, 565; Тумашева: 68; ЗДС: 179, 230) **җамбыз, җамыз, йамуз, йамыс, йанбуз** «пах, внутренняя сторона бедра», (ДС II 244) «талия; валёк с углублением посередине» ~ нуг., төркм. *йамыз*, чыгт. (Радлов III: 99) *йанбуз*, уйг. *йамыз, йомуз*, к.-балк. *җамыз, заммыз*, бор. төрки *jamïz*, як. *сымыс* «касык тирәсе һ.б.» Бу сүз белән иске төрки (Räsänen 1969: 184) *jamdu, jamdy* «касык» сүзе чагыштырыла. Будагов (II: 342) себ. *йанбуз* «касык» сүзен *йан* «тараф» матдәсендә бирә. К. ш. ук ЭСТЯ 1989: 110–111 (ачык кына этимология китерелми). Әгәр *йамбуз* һәм *йамду* бердәй икән, монда өч серле тамыр *йам, буз* һәм *ду* шәйләнә.

Дерив.: диал. (ЗДС: 230) **йампасла-у** «күтенә сугу (мәс., баланың)» ← **йампас* («янбаш» түгелдер инде!).

**ЯМЫЛ [йа$^{o}$мы̆л]** «ямская служба; почта», диал. (гәй, к. ТТДС I: 162) **йал** (*йал куу*) < **йамил* id. ~ кырг. *җамыл*, уйг. *йамул, йамин* «канцелярия» < кыт. *ямэнь* id. сүзеннән; к. яз. монг. *jamun* id. > тунг. *јамун* «почта; олау» (ССТМЯ I: 340–341). Бу сүз түбәндә иске тат. (Троянский) *җам* < гом. төрки, бор. төрки *jam* < кыт. *t'am* «почта станцасы» белән бердәй түгел, тик контаминациягә генә кергән (һәрхәлдә һәр икесе дә кытайчадан). Бор. төрки *йам, җам* (монг. *җам* > *зам*) «ат алмаштыру пунктлары теземе булган юл» фар., рус. һ.б. телләргә

алынып, бай деривация биргән, к. Даль; Будагов II: 341; Фасмер IV: 555, Аникин: 725; Тимергалин: 569–570.

Дерив.: **ямылчы, ямылчылык**; *ямыл чабу ~ ям чабу* «почта йөртү».

**ЯМЬ [йәм],** диал. **җәм, ийәм** (ДС II: 92) «красота; благолепие», диал. (ЗДС: 241) **йәм** «красиво» ~ башк. *эйәм* > удм., мар. (к. Смирнов 1890: 46) *йам, йӓм* «матур, җәзибәле; матурлык; шатлык; хакимлек, хакимият»; иске (яз.) тат. (Будагов I: 176) *йәм, эйәм, иләм, илам, әйлам* «ямь»; бу сүзнең *эйәми* варианты да булганлыгы шул ук Будагов сүзлегендә китерелгән *эйамилү* «ямьле» сүзеннән һ.б. текстлардан күренә (> тат. диал. *ийәмле* «кызыклы; матур, чибәр» к. ТТДС I: 181). А. Троянский сүзлегендә *аййам* «сәләтле, булдыклы», *әййам* «язгы каникул < гар. *аййāм, āл-аййāм* «матур көннәр, бәхетле чаклар» (гомумән **«көннәр»**, ләкин моңа махсус мәгънә бирелә, к. бор. гар. *аййāм-ул-‘араб* «гарәпләрнең шанлы чаклары» дигән атаклы әсәр; *әййам* дип патшаның патшалык чорынмөддәтен атаганнар). К. ш. ук гар. *әййам-ул-бахур* – елның иң җылы чагы – июльнең икенче яртысы, ул чагында кояш **игәр** йолдызлыгында була һәм латинча **каникул** (эт көннәре) сүзе дә шуның белән бәйле (иң эссе көннәрдә укымаганнар һәм эшләмәгәннәр дә). Ләкин безнең якларда ул көннәр бик тә **ямьле** – игеннәр өлгереп, урак башланган, табигать байлыклары тулып ташкан чак. Чаг. уйг. (гар. диелә) *айәм* «бәйрәм», төркм. *эййәм* «матур, ямьле».

Дерив.: **ямьле** (добр. *yatlı*), **ямьсез; ямьлә-ү, ямьлән-ү** һ.б.

Бор. төрки эпитафияләрдә (к. Кормушин 1997: 196) *jämlig* «ашамлык бирүче» сүзе (← *jäm* «җим, ашамлык») бар, ләкин бу сүздән **ямьле** килеп чыгуы, гомумән мөмкин булса да, ачык-аян күрелми.

**ЯМЬШӘЙ-Ү [йәмшәй-]** «деформироваться, сплющиваться; стаптываться», **ямьшек** «плоский; сплющенный». Бу сүзләрнең төп нигезләре **йәмеш* «формасы бозылган» һәм *йәмеш-* «формасы бозылу» икәнлеге һәм **йәм-* тамырыннан икәнлеге күренә. Ләкин бүтән бер тамырга бәйләнышы ачык кына күренми. Чаг. **Яньче-ү** (ләкин бу чагыштыруда да сораулар туа). К. **Яньшек.**

**Ямьшәй-** һәм **ямьшек** (ш. ук **җәмшәй-** һәм **җәмшек**) нигезләре деривацияле: **ямьшәйт-ү, ямьшеклән-ү** һ.б.

**ЯМЬ-ЯШЕЛ [йәм-йәшел]** «презелёный; зелёненький». Аномаль ясалыш – ** япь-яшел** булырга тиеш иде.

**ЯН I [йа°н],** диал. **җан** «бок; сторона, место вблизи кого-чего» ~ чув. телендә бу сүз этимологик дублет бирә: *çум < çом* < болг. **жам* һәм *ен [йэн]* икесе дә уртак төп мәгъ., ләкин соңгысы абстракт «җәһәт, як» мәгънәсендә дә кулланыла һәм тат. диал. **йән* сүзеннән (к. **Янчык**) килә; гом. кыпч., чыгт., уйг., бор. төрки *jan* > к.-балк., кырг. *җан*, каз., к.-калп. *жан*, алт. *дьан*, тув., хак. *чан*, хак. диал. *нан* < тоф. *ньан* һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 113–114) «ян; кыек» (Радлов III: 78). **Йан, йан-у** «кайту» һәм **йак**, **йакын** сүзләре бер тамырдан булса кирәк (к. Будагов II: 342, тик автор бу тамырга карамаган кайбер сүзләрне дә кертә). Мухамедова (1973: 98) төркм. *йаан* «ян» нигезе *ян-у* «көю» нигезеннән озын сузык белән аерыла ди.

*Ян* бик продуктив сүзьясагыч нигез: ул бер төркем бәйлекләр ясауда (**янына, янында, яннарында** һ.б.) кулланыла; к. ш. ук регуляр ясалмалар: **яндаш, яндагы, яннан,** кушма сүзләр составында: **янбаш, янтерәк, янага(й), янапа, яңҗиңгә** (һ.б. нәсел-нәсеп атамаларында). К. **Янак, Яна-у, Янәшә, Яндавыр, Яндавыл, Янтай-у, Янтау//Яндау, Янтак//Янтык, Янчык.** К. ш. ук **Як, Ят.**

**ЯН II [йа°н]** диал. «лук (для метания стрел)», к. Тумашева 1992: 68. К. **Җәя, Янкылыч.**

**ЯНАК [йа°нак]**, диал. **җанак** «косяк (двери)», мар., чув. *йанак*, чув. *йанак*, удм. *йанак, ǯанак,* безнеңчә, **ян** сүзеннән (**йан-ак**), **-ак** – сүзьясагыч кушымча. **Янак** һәм **яңак** сүзләрен берләштерү (ТТАС III: 665–666) дөрес түгел. Чаг. диал. **янта-у** «яннан (янын) юнып шомарту», **янтау** «ишек янагы».

**ЯНАРАЛ [йа°нарал]** иск. «генерал» < иск. рус. сөйл. *енарал* id.

**ЯНА-У [йа°на-],** диал. **җана-у, йаны-у, җаны-у** «угрожать, порываться ударить» > мар., удм. *йана-,* чув. *йона- > йуна-* id. < нуг. *йана-, йаны-,* куман., бор. кыпч. *йана-,* төркм. *йаана-* id., башк. диал., гом. кыпч. *йаны-* (к.-балк., кырг. *җаны-,* каз., к.-калп. *жаны-*) «кизәнү, янау» < бор. төрки (ДТС: 233) *jani-* id. ~ монг. *зана-,* бур. *занга-,* бор. монг. (Поппе 1938: 201) *ǯani-* id., үзб., гаг. *йан-*, к.-балк. *җан-, җаң-* >> як. *сан-* id. һ.б. ЭСТЯ IV: 114.

**Я́НӘ [йанә],** диал. **җәнә** «еще, снова», диал. **йәнәгә** «яренгә, киләсе елга», **җәнәтәдән** «яңадан» (ДС I: 245, 263) > удм. *ӟӓнӓ* «аерым», *сяна* << болг. **җәнә* «тагын да, шуннан тыш» < гом. кыпч. *йэнӓ-, йине* һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 114–115) id. *йан-* «кайту» сүзенең хәз. заман һәм хәл фигыль формасыннан, к. бор. төрки (ДТС: 231) *jana, jana-evrä* «янып-әвереп», тат. *йәнә килеп* «кайтадан, кайтып», ләкин палаталь вариантның киң таралыш алуы аңлашылып бетми (ихтимал, бу вариант бор. уйг. телендә пәйда булып, шуннан әд. телләр аша таралгандыр). ЭСТЯда *йәнә* белән бергә бор. *кәнә* сүзе тур. да хөкем йөртелә. Безнеңчә, *кәнә* сүзе *кән-* «ял итү»дән ясалган һәм саф этимологик җәһәттән *йәнә* сүзенә мөнәсәбәтле түгел. К. **Янәсе.**

**ЯНӘСЕ [йәнәсе],** (ЗДС: 242) **йәнәмәсе, йәнәпәсе** «дескать, якобы» > башк. *йәнәһе*, тат. диал. (ТТДС I: 182) **йәнәсәк** (< *йәнә әйтсәк*) id., удм., мар., чув. сөйләм телендә дә очрый; **йәнә** сүзеннән булса кирәк (*йәнә-се* «**йәнә** дип әйткәне»). Гомумән, ачык түгел.

**ЯНӘШӘ [йәнәшә],** диал. **җәнәшә, йанаша,** себ. (Тумашева 1992: 68), башк. (БҺҺ II: 84) **йанаш** «рядом (с кем)» диал. **йәнәш-ү < йанаш-у** «рәттән, яннан утыру» (КБтә *janaš* «рәттән бару») сүзенең хәл фигыль формасы, к. чув. *юнашар* «янәшә». К. гом. көнб. төрки *йанаш-у* (нуг. *йанас-*, кырг., к.-балк. *җанас-*, каз., к.-калп. *жанас-*) «рәттән утырышу». К. ш. ук кр.-тат., кар., ком. *йанаша* «параллель; якын», алт. *дьанаш* «параллель», гом. төрки *йандаш* «янәшә» һ.б. К. **Ян.**

**ЯНБАШ [йа$^{о}$нбаш],** диал. **җанбаш** «бок таза; верхний конец бедреной кости» > мар. *янбаш* id. < гом. кыпч., уйг. *йанбаш* (нуг. *йанбас*, кырг., к.-балк. *җамбаш, җанбаш,* каз., к.-калп. *жанбас*) id. *йан башы* дигәннән. К.-балк. *җанбаш* «кыек, кыеш» – күч. мәгъ.

**ЯНДАВЫЛ [йа$^{о}$ндаwы̆л]** тар. «боковое охранение войск; личная охрана знатного лица» – **янда-у** сүзеннән гом. төрки (< монг.) хәрби терминнар ясалу моделе (*-wул < -гул*) буенча ясалган. К. **Яндавыр.**

**ЯНДАВЫР [йа$^{о}$ндаwы̆р],** диал. (БҺҺ III: 67) «боковые стойки, рёбра (телеги для сена)» < гом. көнб. кыпч. *йандаwур*; к. ком. *яндавур* «яннан», нуг. *яндавыр* «мичәү», к.-балк. *җандаўур* «ярдәм» **йандаwыл** сүзеннән (*-л > -р*). К. түбәндәгене.

**ЯНДА-У [йа$^{о}$нда-],** диал. **йанта-у, җанда-у,** (Тумашева 1992: 68) **йанта-у** «обтесать, обрабатывать с боку; охранять со стороны; скосить, делать косым» ~ алт. *дьанда-* id. һ.б. – кыпч. телләрендә бу сүз (үзе һәм исемләшкән формалары) бик төрле мәгънәләр алган, к. кырг. *жандоо* «тау битләве», башк. (БТДҺ: 110) *йандау* «чикә; сәндерә». **Ян I** сүзеннән, әлбәттә. К. ш. ук **Янтау, Янтык, Яны-у.**

**ЯНКЫЛЫЧ [йа$^{о}$нкы̆лы̆ч]** иск. «радуга < лук со стрелой» > мар. *йангеж, йоҥеж* «җәя; ук; куян», к.-балк. *җанқылыч* «салават күпере» < гом. көнб. кыпч. **йан-кылыч:** *йан* (себ. тат., башк. *йан*, алт. диал. *ньан*) «җәя», *кылыч* «корал, кылыч».

Бу сүз миш. фамилиясе **Янгалычев, Янглычев** сүзендә күренә, Төмән (Темников) мишәре *Янглыч* исеме иске рус документларында сакланган (к. Гераклитов А.А. Хрестоматия для чтения по истории мордовского народа. Саратов, 1928 һ.б.), *Янгалычева Марьюшка* дигән татар юлбасар хатыны тур. мордва тарихи җыры М. Горькийның «Балачак» повестендә китерелә. Соңрак **Янгалычевлар** рус кенәзләре токымы буларак билгеле.

**ЯНТАЙ-У [йа$^{о}$нтай-],** диал. **җантай-** «накрениться, покоситься» < гом. кыпч., уйг. *йантай-* (к.-балк., кырг. *җантай-, җантый-*) id., тув. *чамдый-* «янтаю, чатанлау» бу сүзнең борынгылыгын сөйли; сүзнең нигезе *йант* < *йаныт* яки **йанта* булырга тиеш, к. иске тат. *җантай* (Будагов II: 343) «кыек, авыш». Һәрхәлдә **йан I** сүзеннән (ЭСТЯ IV: 118), ихтимал, аның фигыль коррелянтыннандыр.

**ЯНТАК I [йа$^{о}$нтак],** диал. **йантаw** (к. ЛС: 12) «волчец (трава)» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *йантақ* «ак тигәнәк, дөя тигәнәге», бор. төрки (МК) *йандақ,* төркм. (Мухамедова 1973: 103) *йаннақ* һ.б.; бу үләннең төтене ак корым бирә, аны чүлмәк-чирәп яндыруда кулланалар һәм шунлыктан бу сүзне *ян-* «яну» сүзеннән дигән фараз дөрескә охшаш. Будагов I: 430, II: 343; Радлов III: 91; ЭСТЯ IV: 117.

**ЯНТАК II [йа$^{о}$нтак]** к. **Янтык.**

**ЯНТАУ [йа$^{о}$нтаw]** диал. (ТТДС I: 161; ЗДС: 232, өч омоним **йантау** китерелә) «бок, боковая сторона; окраина» ~ себ. (Тумашева 1992: 67)

«авыл янындагы урман» ~ башк. (БТДҺ: 111) «агач кәүсәсенең үзәге алынып ясалган чиләк», к.-балк. *җантау* «ян якларында терәкләре булган арба (к. **Яндавыр**); кибән (бер арба); каеш арбага бәйләү өчен» һ.б. К. **Янда-у.**

**ЯНТЫК [йа$^{о}$нты̆к], җантык** (ЗДС: 180, 232; миш. сөйл. бик кулланышлы; ТТДС I: 165) «бок; сторона; край; наклонный; криво, косо», (Тумашева 1992: 68) «пологий» < гом. кыпч., алт. *йантық* (к.-балк., кырг. *җантық,* каз., к.-калп. *жантық*), уйг. *йантуқ* «кыек, авыш», алт. диал. *дьантык*, тув. *чамдық* «чит; бүтән», тув. *чамдығар* «кыеш», хак. *нандық* «янъйөзәр (кысла төре)» һ.б.; бу сүзнең иске тат. *җантақ* (~ к.-балк., кырг. *җантақ*) варианты да булган; бор. **йантағ//йантуғ* «кыек; чит» сүзеннән, *йан* тамырыннан. К. **Янда-у, Янтай-у.** ЭСТЯ IV: 118 (**йантай-** белән бергә бирелә).

**ЯН-У I [йа$^{о}$н-],** диал. **җан-у** «гореть» ~ чув. *çон-* > *çун-* < гом. төрки *йан-* (кырг., к.-балк. *җан-*, каз., к.-калп. *жан-*, алт. *дьан-*, тув., хак. *чан-*, хак. диал. *нан-, ньан*) id., безнеңчә, бор. төрки *йағ-ын-* id. *йақ-* < *йағ-* «май ягу, яну ~ яндыру» фигыленнән кайт. юн. ЭСТЯ IV: 112–113. *Йан-* сүзенең бор. **йа-* фигыленнән икәнлеген Егоров (1964: 218) та әйткән.

**Яну** фигыленең дериватларыннан тат. **йанык, җанык, җанак** (ДС III: 218) ~ чув. *çонăх, çунăх*, төр., төркм., гаг. *йаныk*, уйг. *йаниқ* «янган урын, яндырылган урман (басу)» һ.б. киң таралган. К. ш. ук себ. **йаңы-у** (Тумашева 1992: 69), **йаңга-у** «ялчыту, кабызу» < *йан-қа-* (*-қа* аффиксы).

**ЯН-У II [йа$^{о}$н-]** иск. «вернуться, возвращаться» < уйг., бор. төрки (ДТС: 231–239) *јап*, алт. *дьан-,* тув. *чан-* һ.б. (к. ЭСТЯ IV: 111–112), **ян** сүзе белән тамырдаш булса кирәк. К. **Янә.**

Иске тат. **ян- II** бик продуктив сүзьясагыч нигез булган, к. Будагов I: 341–343.

**ЯНУТ [йа$^{о}$нут]** «енот» < рус. *енот* < фр. *genette* < исп. *gineta* < гар. *җӓрнӓйç* < *гӓрнӓиç* «генетта (мәчесыман хайван)» сүзеннән, чаг. **Кернә.**

**ЯНЦАК** иск. «боковая броня, дымка, бранина для лошадей» (Будагов II: 342) ~ госм. *йанҗақ,* төр. *yan, jancık* id. К. **Янчык.** Радлов III: 96.

**ЯНЧЫК [йа$^{о}$нчы̆к],** диал. **җанчык, йәнчек, йәнцек, җәнчек** «холщовый или кожаный кошель; кошелёк, кисет» > удм. *янчик, ǯäнчук,* мар. *янчык, ǯäнчĕк,* чув. *енчĕк [йэнчĕк]* id., мар. Т. *йäнзык* «умал, чунтай» (Саваткова: 37); бу мәгъ. тат. гади сөйләмендә дә очрый < гом. көнб. кыпч. *йанчық* (кар. *йанцық, йанчығ,* кырг. *җанчық,* башк. *йансық*), үзб., уйг. *йанчуқ,* госм. *йанҗық,* алт. *йанчуқ, дьанчық,* тув. *чанчық,* шор., хак. *нанҗық* < бор. төрки (ДТС: 232) *јапčïq, јапčиq* «янчык» *ян (йан)* сүзеннән, аның «янда йөртелә торган кесә, чунтай һ.б.ш.» мәгънәсеннән. Чаг. төркм., бор. угыз. (Мухамедова 1973: 98–99) *йаанлық* «тире янчык». К. ЭСТЯ IV: 118. К. **Янцак.**

**ЯНЫ-У [йа$^{о}$ны̆-]** «править, точить» ~ к.-балк., кырг. *җаны-*, алт. *дьаны-* «яннан сыйпау, яныу» ← *ян.* Һәр телдә *яна-у* белән бутала, ләкин ДТСта *јап-* «янау», *јапи-* «яныу» аерым сүзләр итеп бирелә.

**Яны-у** сүзенең дериваты – тат. **йанаw, йану, йанаwыч, йануч, җанаwыч, җануыч** «үткерләгеч корал – агач сапка катырылган комташ измәсе» > мар. *яно, янаус*; бүтән төрки телләрдә сирәк очрый.

**ЯНЬЧЕ-Ү [йәнчĕ-],** диал. **җәнче-, йәнце-** «сплющивать, сплющить; придавить» ~ бор. төрки (ДТС: 231–232, 251) *јепčі-, јепč-, јапč-* > төркм., кар., үзб. диал., чыгт., аз. диал. *йәнч-,* к.-калп. *женш-,* уйг. *йенҗи-,* бор. уйг. *йанчы-,* кырг. *җанчы-,* алт. диал. *дьанчы-,* башк. *йәнсе-* id. (һ.б. күп охшаш мәгънәләрдә, к. ЭСТЯ IV: 184–186). К. чыгт. (Будагов II: 99–100) *йәнчи-* «юкарту», *йингил-, йäнчил-* «юкару, нәзегәю» нигезләреннән *йәнчик* «яньчелгән, юкартылган», арытабан *нечкә* < *йәнчикӓк* «яньчелгән, юкартылган, нәзегәйтелгән» сүзләре ясалган (моңа Будагов тәүләп игътибар иткән). **Яньче-** нигезенең веляр варианты бор. төрки (ДТС: 231–232) *јапč-* «басылдыру, изү, ватылдыру» хәз. телләрдә сирәк очрый бугай. Күренеп тора ки, *йәнче- ~ йанчы-* нигезе *-чи//-чы* кушымчасы ярдәмендә *йән-//йан-* нигезеннән ясалган (чаг. *борчы- ← бор-, күпче- ← күп-, үрче- ← үр-* һ.б.). К. **Нечкә, Яньчерә-ү.**

Дерив.: **яньчел-ү, яньчет-ү**; диал. (ЗДС: 242), **йәнчелү** «картаю», диал. **йәнчек** «кыек»; (ЗДС: 184) **җәнчем** «бер талкырлык тотам» (димәк **җәнче-** «талку» сүзе бар). Чаг. **Яньшәй-ү.**

**ЯНЬЧЕРӘ-Ү [йәнчĕрә-]** (ДС II: 244) «сплющиваться» ~ кырг. *җанчыра-* id. *йәнче- ~ йанчы-* нигезенең ешайтулы формасы ← **йанчы-ра-*. К. югарыдагыны.

**ЯНЬШЕК [йәншĕк]** «сплющенный» < **йәнше-, йәмше- < йәнче-** булырга тиеш.

**ЯҢ [йа$^{о}$ң]** «тиф; эпидемия» (ДС I: 242; Тумашева 1992: 68) ~ куман., нуг., алт. *йаң*, алт., як. *дьаң* «кизү чире» < бор. монг. *ǯanү ǯara* «сифилис ← чит ил чире (ярасы)»: *ǯanү* < кыт. *ǯaŋ* «чит ил», к. ЭСТЯ IV: 122.

**ЯҢА [йа$^{о}$ңа],** диал. (ТТДС I: 170) **җаңа, йаңы, җаңы** «новый; только что» ~ чув. *çĕн, çĕнĕ* < гом. кыпч., төркм., башк. *йаңы* (к.-балк., кырг. *җаңы*), үзб. *йаңги* id. *Йаңа* вариантына параллельләр – каз., к.-калп. *җаңа,* як. *саңа*, тув. *чаа*, хак. *наа* «ява». Уйг. һәм угыз телләрендә *йеңи, йәңи, йәңки* «яңа» варианты киң таралган һәм чув. *çĕнĕ* < болг. **җәнĕ* шуннан.

*Яңа//йаңы* сүзеннән монг. *ǯaŋgi, занги* «яңалык» (калм. *зәңги* «яңалыклар») сүзе килә (ЭСТЯ IV: 125) һәм, безнеңчә, монг. сүзе төп мәгънәгә якын: бор. *йаңгы* асылда «яңгыравык, кайтаваз» дигән сүз (к. тув. *чаңгы* «эхо», як. *саңа* «тавыш, сөйләм; җавап») һәм бор. *йаң* «яңгырау» (исем һәм фигыль) сүзеннән, ягъни *йаңгы*ның паронимы (уртак нигездән, ләкин бүтәнчәрәк ясалган варианты). К. **Яңгыра-у.** Чаг. **Ян-у** «кайту».

**Яңа** сүзе тәүдә сүзгә, хәбәргә генә караган (чаг. әйтем: *иске авыздан яңа сүз*), тора-бара аның мәгъ. киңәйгән, ул һәрнәрсәгә карый башлаган. **Яңалык** «яңа хәбәр» борыннан килә; бу сүзнең «яңа булу» мәгъ. – соңгырагы. Алт. *дьангы* «кайту күренеше» (*дьангыла-* «кайту») *йаң* тәкълитеннән дә, *дьан-* «яну, кайту» сүзеннән дә ясала ала.

**ЯҢАК [йа$^{о}$ңаķ],** диал. **җаңаķ, йанак** «щека; челюсть, скула» > мар. (Упымарий: 301) *йанак,* чув. (Сергеев 1971: 67) *йанах, йанаха* «яңак, яңак сөяге»; төрки телләрдә бу сүзнең биш төп фонетик варианты һәм «ияк, чигә» белән керешүе күзәтелә: 1) гом. кыпч., уйг., төркм., госм. *йаңак*, чыгт. *йаңкак* (каз., к.-калп. *җаңаķ*), тув. *чаңаķ,* хак. диал. *наңак* id.; 2) алт. *дьааķ,* кырг. *җааķ,* тув. *чааķ,* шор., хак. диал. *нааķ* id.; 3) тат. диал. (ДС I: 248, миш.) *йайак* «ияк» ~ ком., кар. *йайаķ,* к.-балк. *җайаķ* «яңак», 4) тат. диал. (ДС III: 224, миш.) *җәйәк, дзәйәк* ~ балкар. *зийек* «яңак», 5) иске тат. (Троянский I: 490) *чынаķ* «чигә» ~ як. *сынаах* «яңак». К. ш. ук **Ияк**.

Этимологлар (к. ЭСТЯ IV: 123–124), бор. төрки *jaŋ, jaŋaq, jaŋүaq* «як, ян, яңак» (ДТС: 233; DLT I: 40 һ.б. чыганаклар) сүзеннән чыгап, *йаңаķ* нигезен *йан* (к. **Ян**) сүзенә нисбәт итәләр. Ләкин бу этимологиядә *-ң-* аңлатылмый. Һәм бик күп телләрдә *йаңак* сүзенә охшаш сүзләр күзәтелә: фар. *зäнäх, зенех* ~ авест. *zanva*, бор. һинд. *hanuh*, тохар. *ǯanv* «яңак», гар. *җäнāх* «канат», *җāних* «ян» һ.б. (к. **Чана**). Бу хәл очраклы микән? Һәрхәлдә **яңак** һәм **ияк** сүзләренең гомогенлыгы шиксез.

**ЯҢГЫР [йа$^{о}$ңғы̌р],** диал. **җаңгыр,** себ. (Тумашева 1992: 68) **йамғыр < йамғур** «дождь» ~ чув. *çумăр* < *çомăр* < бор. төрки (ДТС: 225) *jaүmur* ← *jaү-* «яву» сүзеннән (к. **Яу-у**), **йағмур** сүзенең күпсанлы вариантлары һәм рефлекслары ЭСТЯда китерелә (IV: 57): *-мур* кушымчасы **тамыр** сүзендә дә күзәтелә.

Тат. вариант ком. *йаңгур,* к.-балк. *җаңур, җаңгур* id. белән бергә аерым үзенчәлекле группа тәшкил итә (көнб. кыпч. группасы).

Дерив.: **яңгырлы, яңгырсыз; яңгырла-у.**

**ЯҢГЫРАК [йа$^{о}$ңғы̌раķ],** диал. **йаңгырык** «предгорье, мелкие складки гор перед большой горой, отроги; ответвления ствола дерева у основания; ствол с ответвлениями внизу; пень, на котором рубят дрова» (Тумашева 1992: 69), **йаңрыķ** «скелет» (шунда ук) ~ башк. (БТДҺ: 111) *йаңķырыķ* «бүкән, ястык (арбанықы); ян терәк (арбада); сәке йөзлеге; шикмә», нуг., ком. *йаңғырыķ* «бүкән», к.-калп. *җаңғырыķ* «сандал бүкәне», алт. (Баскаков 1966: 113) *дьангыршыķ* «аслык такта», бор. төрки (ДТС: 234) *jaŋraq* «тау итәгендә катланмалар» ← тат. (ТТДС I: 170) **йаңыр-у** «(як-якка) тамыр җибәрү». Ягъни бу киң таралган сүзнең ясагыч нигезе тат. телендә сакланган. Чаг. **Чагарак.**

**ЯҢГЫРА-У [йаңғы̌ра-],** диал. **җаңгыра-у** «звенеть, звучать, раздаваться (об эхе)» > чув. *йанăра-*, *йанкăра-*, *йанра-, йантра-* һ.б. (к. Сергеев 1971: 65), удм. *ǯангърат-* (< тат. диал. *җаңгырат-*, к. Насибуллин: 115), мар. *йанра-, йантра-, йынтра-, йынтыртат-* id. ~ уйг. *яңра-,* бор. төрки *jaŋra-* id.; бу сүзнең киңрәк таралган варианты тат. диал., иске тат. (Будагов II: 336) *йаңгыр-мак* ~ ком. *йаңгыр-,* каз. *җаңғыр-*, алт. *дьаңғыр-* ~ бор. төрки (ДТС: 233–234) *jaŋүïr-, janqur-* «яңгырау, яңгы булу» ← уйг. *йаңгу,* төр. *janki, janku,* алт. *дьаңу,* тув. *чаңгы* «яңгырык, кайтаваз» (ягъни *йаңгы-р-* «яңгыга әверелү» кебек); эвенк. һ.б. *йангир-* «металл авазы яңгырату» (ССТМЯ I: 342–345) төрки телләрдән, сүзнең тамыры (хак.) *йаң* «яңгырау (исем һәм фигыль)». Шуннан *йанғу* «кайтаваз» белән

беррәттән (бур.) *яңги-* «яңгырау» фигыле дә ясалган, менә шуннан, тәкълиди сүзләр калыбына кереп, (ЗДС: 180) *йаңгыр* «кайтаваз» һәм *яңгы-ра-* фигыле ясала. К. ш. ук чув. *йан, йанк* «яңгырап кую», *йанкла-, йанклат-* «яңгырау» һ.б. (Ашмарин IV: 188–194). Нуг. *заң* «мәктәп кыңгыравы», *заңыра-* «зыңгырау, зыңгылдау». Формаль алганда, *йангу* бор. *йан-* «кайту» сүзеннән дә ясала ала, к. **Яңа.**

*Яңгыра-* продуктив нигез, шуннан диал. **йаңгырак** (ш. ук **йангырык**, к. Balint 1988: 74), **йаңгыравык** «кайтаваз», **йаңгыраш, йаңгырау** (фонетика термины) һ.б. сүзләр ясала.

**ЯҢЛЫ [йаºңлы̊]** иск. «подобный (чему)» < бор. тат. әд. (Мөхәммәдьярда бик еш очрый) *йаңлыг* < урта төрки *jaŋlïγ* id. *jaŋïl-* «охшау» *jaŋ* (кыт.) «образ, кыяфәт; характер» сүзеннән, к. ш. ук бор. уйг. (КБ) *jaŋza-* «охшау; ияру». ЭСТЯ IV: 121–122. К. **Заң.**

**ЯҢША-У [йаºңша-]** (Гиганов) «ворчать, жаловаться» (*яңгыз кеше яңшамас*, диләр), диал. **җанша-у** «беспрерывно говорить (дома, в семье)», **йанкыш-ыw** (Арсланов 1988: 79) «лаять» ~ башк. *йаңыша-* «еш елау; кычкырып зар елау; кычкырып күп сөйләү» > мар. (Упымарий: 302; Иванов, Тужаров: 60; Саваткова: 44) *йаңыса-, йӗҥӗсӓ-* «иңрәү, сыкрау, чыелдау (эт тур.)», *йыныса* «елак», *йаңыша-, йанча-, йонча-, йыча-* «туктаусыз сорау, үтенү, ялвару» < чыгт., госм. *йаңша-* «лыгырдау; әрләү», к.-балк. *җанша-*, кырг. *җаңча-* «күп сөйләү», кырг. *җаңша-* «кубылгы тавыш белән җырлау», як. *дьаҥсай-, ньаҥсай-, ньаҥсайыы* «үгетләп һ.б. күп сөйләү», *ньаҥый-* «ләңгелдәү», *ньаҥ* «ләң», *ньаҥ-ньеҥ* «ләң-ләң (кечкенә этнең туктаусыз өрүенә тәкълит)». К. ш. ук салар. (Тенишев 1964, күп очраклар) *jaŋşa-, jaşa-* «сөйләү, әйтү», тув. *чаңча-* «тиргәү», як. *саҥа-* «күп сөйләү», Г. Нәваи телендә (Боровков 1961: 47) *jaң-* «юкны сөйләү, лыгырдау», КБ телендә *йаңзат-* «яраштыру, охшату», бор. төрки *йаңлыг* «сурәтле, кебек» *йаң* «образ, сурәт» – асылда *йаң* рәсеме? (к. югарыда).

**Яңша-у** фигыленең дериватларыннан үзеннән дә киң таралганы тат. диал. **җаңгышак** «өйдә акыл биреп, өйрәтеп торучы», себ. **йаңышак, йанҗак** «күп сөйләүчән, бәйләнчек», башк. *йаңышаҡ, йаңышаҡан* «кирәксезгә нотык сөйләүчән яки илереп елаучан, күп сүзле, тавышчан кеше» (к. ТТДС I: 569; Тумашева 1992: 68–69; БТДҺ: 112) > мар. *яңышак* «теләнче» < гом. кыпч. **йаңышаҡ* «яңшак», к. к.-балк. *джаншаҡ* «лыгырдык», госм., бор. төрки (КБ) *йаңшаҡ*, аз. (АДДЛ: 240) *јаншаг* «лыгырдык» һ.б. Төр. (Будагов II: 359) *яңаз, яназ* «тиргәүчән, сукранучан» аерым оригиналь дериват.

Төрки телләрдән тыш, *йаңша-* нигезе бор. монг. *jaŋgsi-* «өрү, тиргәү» (*jaŋgsija* «яңшак») сүзе белән (Räsänen 1969: 187), арытабан нан. *йэңсэчи-* «сулкылдау», маньч. *йаңшанту* «мифик хайван – улаучы рух», кыт. *йан* id. сүзләре белән чагыштырыла (ССТМЯ I: 343, 355). Чаг. ш. ук **Шыңыгы-у.**

**ЯП [йаºп], япа** «совершенно (только об одиночестве); одиноко, одинокий» (к. ЗДС: 233) ~ нуг., уйг. *йаппа* (*ялгыз*) фар. *йӓкпā* «сыңараяк» («ялгыз» мәгъ.) яки *йӓкбӓйӓк* «бердәнбер» кебек тәгъбирләрдән булса кирәк. К. ш. ук түбәндәгене.

**ЯПАН [йаºпан]** (ЗДС: 223, 233; иске тат. китапларында еш очрый) «голая степь; безлюдное пространство» < уйг. *йапан* id., бүтән төрки телләрдә бу сүз *-б-* белән әйтелә: гом. кыпч. *йабан* (кырг. *җабан, җапан*, каз. *жабан*), төр. *yaban* һ.б. «япан», ш. ук «чит ил, чит җир» һ.б. < фар. *бейāбāн* «кешесез, кеше яшәмәгән җир, дала». Будагов II: 314. К. түбәндәгене.

Дерив.: иск. **япаны ~ ябани** һ.б. к. **Ябай.**

**ЯПАНЧЫ [йаºпанчы̊], ябанчы** иск. «волк», «имя собственное, возможно – название любого храброго воина» ~ кр.-тат. *yabançı* ~ төр. *yabancı* «ят, чит; чит илнеке; таныш түгел» һ.б., к. Dobr. III: 465.

Төр., чыгт. *йабанчы, йапанчы* төрле мәгъ. актив кулланыла.

**Япанчы** сүзе **ябынча** белән тамырдаш түгел, к. **Ябынча.**

**ЯПМА [йаºпма]**, диал. **җапма** «крыша на столбах (без стен)»; сөйләшләрдә төрле мәгъ. очрый (к. ЗДС: 180, 234): «кулинар әйбер төрләре; җәймә; кием детальләре төрләре» – бүтән төрки телләрдә дә шул ук хәл: *япма ~ яппа ~ җаппа* ← *яп-, җап-* һ.б. төрле мәгъ. К. **Яп-у I.**

**ЯПСАР-У [йаºпсар-]**, диал. **җапсар-у, җапсарла-у** «наложить край одного плоского предмета на край другого такого», күч. «приписывать вину и т. п. на кого-либо другого» (башк. *япһар-*, киресенчә, «гаебен яшерү») – гом. кыпч. *йапсар-, җапсар-*, каз., к.-калп. *жапсар-* id., монг. *жабсар-* > хәз. монг. *завсар-* «ярыкны, аралыкны яшерү» ← *җап* > *зав* «аралык, ярык», к. **Җап**. Бу сүзләрнең

төбендә монголныкымы, төркиме икәнлеген әйтү читен. К. ш. ук нуг., уйг. *йапсармақ* «фронт тоту».

Китерелгән фигыльнең исем коррелянты да бар, к. (ЗДС: 180, 239) **йафсарлы** «өсте-өстенә ябулы; бөрмәле», **җапсар** «куыш», дөресе (без теркәдек. – *Р.Ә.*) – «куыш сөлтәренә, шикмәләр өстенә салынган түшәмә – печән, кабык» һ.б., **җапсарла-у** «шикмәләр өстенә җәю; ярык-тишекләрне каплау; җөйне яшерү» һ.б. Будагов I: 426 (каз. сүзе тур. гына). К. ш. ук нуг., уйг. *йапсар* «чигәрә, ызан, межа».

Тат. телендә **япсар** нигезенә тамырдаш бүтән сүзләр дә бар бугай. **Яп-у I** фигыленә бәйланышы бәхәсле.

**ЯПТАК [йаᵒптақ], йапкат, йапкыт** (ЗДС: 234–235) «верх крытых саней, каркас кибитки», **җаптак** «естественное укрытие от ветра (под скалой и т.п.)» ~ бор. төрки (ДТС: 135, 235) *tabγut, japγut* «утыргыч мендәре, мендәрле урындык» ← **Яп-у I**. Кырг. (Будагов II: 435) *җабдуқ* «хәстәр», уйг. *җабдусун* (монг.), монг. *дзабдуху* «әзерләнү». Тамыры (**яп-у II**), ясалышлары безгә ачык түгел.

**ЯП-У I (япты, ябу),** диал. **җабы-w** «крыть, закрывать, затворить, заключить (в тюрьму)» < гом. көнб. төрки (Радлов III: 259) *йап-,* (кырг., к.-балк. *җап-,* каз., к.-калп. *жап-*), алт. *дьап-,* тув., хак. *чап-,* як. диал. *сап-,* чув. *çып-* id. ЭСТЯ (IV: 127–128) бу сүзне бик хаклы рәвештә тат. диал. һ.б. *йап-* (к. **Яп-у II**) «эшләү, ясау, башкару» сүзеннән аерып куя. К. **Ябеш-ү, Ябыш-у.** ДТС: 235.

**Яп-** нигезеннән регуляр рәвештә дә бик күп сүзләр ясалган: **ябу** (исем), **япкыч, япма** (күп мәгъ.), **япсар-у, яптыр-у, ябык-у** (?), **ябык, ябыл-у, ябын-у**, **ябыш-у** («ябарга ярдәм итү») һәм шулардан (барча төрки телләрдә дә) тагын исәпсез күп дериватлар ясалып килә һәм актив кулланыла. ЗДСта (: 180, 234, 242) тагы **җапкан, җапкыч, йапкак, йапкы, йапкыт, йапмач, йапшер, йапыр-у, йәптертәк, йәпшен-ү** күрсәтелә.

**ЯП-У II (япты, ябу)** миш. (ТТДС I: 157) «испечь; зарабатывать (деньги)» < гом. көнб. төрки, угыз. *йап-* «ясау, әзерләү, тәртипкә китерү, оештыру» ~ хак. *чап-* id, ~ кр.-тат. (Dobr. III: 482) *yaptak* «ясау; ремонтлау; башкару». Бор. төрки *йабғу (йафғу)* «фактик хөкемдар (рәсми хан булмаса да) барча идарә эшләрен башкаручы» сүзе дә ошбу фигыльдән дигән фикер бар.

**Яп-у II** сүзен сүзлекләрдә (нан пешергәндә кәбәрәне тандыр яндауларына ябып-ябыштырып, чәпәп пешерүне күз алдында тотып) **яп-у I** белән берләштерү очраклары күзәтелә. Ләкин «идарә итү» мәгънәсен «көлчә чәпәү»дән чыгару кыен. К. **Ябгу**, **Япь II.** Радлов III: 260, 271; Räsänen 1969: 187; ДТС: 235–236; ЭСТЯ IV: 126–127.

**ЯПЫРТМА [йаᵒпы̊ртма]** диал. (прм., ЗДС: 234) «тесьма, волан» ← бор. төрки (ДТС: 236–237) *japur-* «тигезләү, шомарту». Чаг. түбәндәгене.

**ЯПЫР-У [йаᵒпы̊р-]** диал. (әстр., ЗДС: 234) «есть с жадностью», добр. *сарıг-* «җимерү, бәргәләү, таркату, шыеру» ~ нуг. *япыр-* «бәргәләү, җыеру, җимерү; комсызланып ашау», каз. *жапыр-,* кырг. *җапыр-* «аудару, өстенә аву, ташкынланып килү-каплау; комсызланып ашау» ← **йарп-?* К. **Ярпай-у?** Кыпч. телләрендә дә интервокаль *-п-* саклана. Тат. диал. сүзе күрше төрки телләрдән (ком., нуг.) алынган булса кирәк. Чаг. **Ябырыл-у.**

**ЯПЬ I [йәп],** диал. **җәп** «развилина; развилка; разветвление; прядь в верёвке» ~ башк. *йәп,* башк. диал. (БТДҺ: 105) *йаб*, мар. (Иванов, Тужаров: 199; Саваткова: 143) *сäп, сап* «дилбегә; япь», чув. *йуп, йупа, йӳп* << **йап, *йäп* «япь». Мар. сүзе *җәп* сүзеннән килеп чыга алса (*ǯ- > s'-*), чув. сүзендәге *й-* бу сүз өчен характерлы түгел; өстәвенә чув. телендә *йуп- < йап-* «бер якка борып җибәрү» фигыле дә бар. *Япь*нең чув. параллеле *çап* булырга тиеш иде. Бәлки чув. сүзләре тат. теленнән (миш. диалектыннан) соңрак алынгандыр; к. ш. ук тат. диал. **җәпләкә, җәпләшкә, җәпләшке** «япьле урын, чатлы агач, чата» ~ чув. *йӳплешке [йүпләшкә]* id.; *җәп < җап* сүзе, ихтимал, каз. диал. *жап* ~ чыгт. (Радлов III: 259) *йап* «зур арыкның басуга киткән тармагы» белән тамырдаштыр. Бу *йап ~ җап* исә тат. диал. *жап* «тау астындагы тигез җир» сүзе белән бәйле булса кирәк, к. **Җап, Җәптәш.** Икенче яктан к. чыгт., үзб. *йап*, каз., к.-калп. *жап* «арык, канал тармагы» – бор. Харәзем теленнән, к. ЭСТЯ IV: 129. Чаг. ш. ук **Яба II.**

Дерив.: **япьле, япьсез; япьлекә.**

**ЯПЬ II [йәп]** (к. мәкаль: *Ибе килсә йәбе килми; япьтәш* «эштәш») – *ип* белән тамырдаш булса кирәк, к. каз. *еплě* «сәләтле», башк. (БТДҺ: 132) *йәп* «рәт, юнь», *йәптәш-ěw* «охшашу», *йәпһеҙ* «кырыс».

**ЯР I [йаᵒр],** диал. **җар** «берег; крутой берег; побережье» > чув. (Сергеев 1968: 95), удм., мар., рус. һ.б. *яр*, удм. диал. *ǯар* (Насибуллин: 115) id.

< гом. көнб. төрки *йар, йāр* (Радлов III: 99–100) > кырг., к.-балк. *җар*, каз., к.-калп. *жар* id. *Яр-у* сүзе белән чагыштырыла (ЭСТЯ IV: 17–18), к. алт. *јарат, јарыт,* як. *сыр*, чув. *çыр* «текә яр». Рус. *яр* тур. Аникин: 728. Гомумән, *яр* сүзе барча күрше телләргә кергән (к. фар.-таҗ. *җäр,* тунг.-маньч. *йāри, ēран* id., ССТМЯ I: 291).

Тат. гомумхалык телендә *йар//җар* «гомумән су кырые, кыргак» һәм **йарлау**, **йарлаwык** (к. ДС I: 246; БҺҺ II: 86) «текә яр» аерымлана шикелле. К. ш. ук мар. диал. *йарлан-* «яр умырылу» (Упымарий: 302) < тат. **йарлан**- id. К. **Ер-у, Ярлау, Яр-у.**

**ЯР II [йаºр]**, диал. (ДС II: 262) **җар, йәр, җәр** (*сөйгән җәр,* к. Татар җырлары 1995: 301) «возлюбленный, милый друг», иск. «ближайший друг» < фар. *йāр, йāрū* id., к. **Яран, Ярдәм.** К. Будагов II: 323.

**ЯРА [йаºра],** диал. **җара** «рана; нарыв» < гом. көнб. төрки *йара* (кырг., к.-балк. *җара*, каз., к.-калп. *жара*) id. Бу сүзне этимологлар (к. Радлов III: 104; ЭСТЯ IV: 139–140) **йар-у** сүзе белән бәйлиләр, ләкин, беренчедән, ясалыш моделе ачык түгел, икенчедән, төрки телләрдә *йарә* һәм *йәра* (сингармоник булмаган) вариантлары бар, бу исә алынмаларга хас. Иске фар. *jara* «киң беләзек, муенса; көчлек; яра» сүзеннән булырга да мөмкин (тәүдә *йара* «богау эзе»).

**Яра** продуктив нигез: **яралан-у, ярала-у, яралы** һ.б.

**ЯРАБАЙ [йаºрабай]** (Иванова: 46) «зверобой (трава)» < рус. *зверобой* (терлек күп ашаса, агулана, шуңа күрә «җәнлек үтергеч» мәгъ. сүз). Бу үлән тат. **был** дип тә атала.

**Я́РАББИ** «о боже! Ах!» < *йа рабби* күп телләрдә очрый һәм гар. теленнән таралган.

**ЯРАК I [йаºрак],** диал. **җарак** «пригодность» – **яра-у** фигыленнән.

Дерив.: **яраклы, яраксыз** (бу сүзләр төп сүздән киңрәк кулланыла); **яракла-у, яраклан-у, яраклаш-у** һ.б.

**ЯРАК II [йаºрак],** диал. (ДС I: 246; Тумашева 1992: 69) **җарак, йараӻ** «оружие; снаряжение; принадлежность» < гом. кыпч., уйг., чыгт. *йарак* (кырг. *җарак,* каз., к.-калп. *жарак*) < бор. төрки (ДТС: 239) *jaraq, jarïq*, куман. *jarov* «корал, шайман» – **яра-у** фигыле белән бәйле, к. ЭСТЯ IV: 139. Шуның белән бергә «корал» мәгънәсенең тәшкиле аңлашылып бетми.

Дерив.: тар. **ракчы.**

**ЯРАЛ-У [йаºрал-],** диал. **җарал-у** «сотвориться, быть зачатым» ~ чув. *çурал-, çорал-* < болг. **җарал-* < бор. төрки **йарал-* id. > ком., уйг. *йарал-*, кырг. *җарал-* id. (күп кенә төрки телләрдә юк) id. бор. **йара-* фигыленең төш. юнәлешеннән, әлеге фигыль исә, безнеңчә, тат. диал. **йаура-, йауры-** «аталану, кушылу; орлыклану; туу» фигыленнән, к. себ. фольклорында *Ай мынан күн йаурылып, ике нур йалгашып ... пайда булган мырзамын* (Тумашева 1992: 73; автор ни өчендер *йаурыл-у* сүзен «ослабевать» дип тәрҗемәли; төр. *yavrul-* «арууталу» сүзе бар, ләкин ул бу текстта урынсыз); шул ук фигыльдән к. тат. *җәwĕр* < *җәwре* «зат» < бор. **йаwрыӷ* > төрки *yavru* «яшь бала» ~ чув. *сура, çурă, çăвăр, çÿрĕ* (Сергеев 1971: 118) «җәнлек-җанвар баласы, токым, җәвер», чыгт. *йаwрук* id. (Радлов III: 18). К. ш. ук **Ярат-у II, Җәвер.**

**Йаwры-, йаwра-** фигыленең ясалышы-тамыры ачык түгел. ЭСТЯда (IV: 53) *йавры, йавру,* кр.-тат. *йäвру* сүзе *йарал-у, йарат-у* фигыльләренә бәйләнештә күрелми, тат. материалы искә алынмый.

**Ярал-у** продуктив нигез, шуннан **яралгы, ялалткы.**

**ЯРАН I [йаºран]**, диал. **җаран, җәрән** «адепт, клеврет, дружок; дружка (товарищ нехорошего человека)» < гом. көнб. төрки < фар. *йāрāн* «дуслар» (**яр** сүзенең күп. формасы).

**ЯРАН II [йаºран]** «герань» < рус. сөйл. *еран, иран* < *герань* < лат. *geranium* id., түбәндә «торна гөле» дигән сүз (Преображенский I: 122). Чөнки аның җимешлегенең торна борынына охшаш үсентесе була, к. Kluge: 348.

**ЯРАСӘ [йаºрасә]** (К. Насыйри, «ярканат төре»), **йарыскы** (Тумашева 1992: 71) «летучая мышь» < төр., госм. *йараса, йарасе, йарасык, йäрäсä, yelemse,* аз. *йәләсән,* салар. *jeresen* (ЭСТЯ IV: 140) id. К. ш. ук тув. *ча'скы* «ярканат». **Ярканат < Ярыканат** белән тамырдаш булса кирәк.

**ЯРАТ-У I [йаºрат-],** диал. **җарат-у** «любить» > чув. *йорат- > йурат- (юрат-)*, мар. *йарат-* (кырг., к.-балк. *җарат-*, каз., к.-калп. *жарат-*) «ярый дип исәпләү, хуплау, тәбрикләү» ← «ярый торган итү»

сүзеннән (монда төп үзенчәлекле момент – мәгъ. күчеше: «сөю, мәхәббәт баглау» мәгъ. уйг. яисә тат. телендә килеп чыккан булса кирәк), ягъни **яра-у** сүзенең йөкл. юнәлешеннән, чаг. *ачкыч ярату.* К. **Яра-у.**

Дерив.: **яратыш-у, яраттыр-у; яраткан.**

**ЯРАТ-У II [йа°рат-],** диал. **җарат-** «сотворить, создать, создавать (в религиозном стиле)» < гом. кыпч., чыгт., уйг., бор. төрки (ДТС: 239), төр. һ.б. *йарат-* (к.-балк., кырг. *җарат-*, каз., к.-калп. *жарат-*) id. Бор. *йара-* < **йаwра-* яисә **ярал-у** фигыленең (**ярат-у < یралт-у**) йөкл. юнәлешеннән. **Ярат-у I** белән омонимлыктан качу өчен **яралт-у** вариантын активлаштырырга мөмкин.

Дерив.: **яратыл-у < яралтыл-у.**

**ЯРАУ [йа°раw],** диал. (ТРС 1966; ТТДС I: 166, 566; ЗДС: 180) **җарау** «пригодный к скачкам или к походу (о лошади); полнотелый, мощный; пригожая, здоровая (пригодная для замужней жизни – о девушке, женщине); весёлый» ~ кырг. *жароо* «физик җәһәттән тиешлечә торышта; артык симез түгел», *җара-* «ябыгу» > каз., к.-калп. *жара-* id., к.-балк. *жарау* «күнекмә, тренировка»; тат. **җараулы** «чабышка әзер (әзерләнгән)» >> мар. *саралы* «матур һәм сәламәт (бигрәк тә атлар тур.)» – җырларда очрый. **Ярау** сүзе мәгънәсе белән **яра-у** фигыленә тоташа, ләкин аның ул фигыльдән килеп чыкмый торган мәгънәсе бар һәм ул мәгъ. тарихи-этимологик аңлатмага мохтаҗ. Фин этимологлары бу сүзне як. *дьарай-* «ябыгу», тув. *чарыг* «ябык; маен сарыф иткән» һәм арытабан уйг. *йағра-* «әйбәтләнгән, матурланган» (*йағ-* «ягу, ягымлы булу») сүзләре белән бәйлиләр (Kannisto 1912: 95–96; Räsänen 1969: 198). Ахметьянов 1989: 79–80.

Дерив.: **ЯРАУЛА-У, ЯРАУЛАН-У, ЯРАУЛАТ-У** һ.б., башлыча атчылыкта.

**ЯРА-У [йа°ра-],** диал. **җара-у** «подходить, быть годным, пригодным, соответствовать; угодить, угождать» > чув. *йора-* > *йура-*, мар. *йорӓ-, йӧрэ-* «ярау» (шул ук вакытта чув. *çораç-* > *çураç-* «ярашу; ярәшү», мар. *сарас-, сорас-* «ярәшү» < болг. **җараш-* id.) < гом. көнб. төрки *йара-* (кырг., к.-балк. *җара-*, каз., к.-калп. *жара-*), алт. *дьара-*, тув., хак. *чара-* «ярау, ярашу; өлешкә тию; хәлле булу һ.б.ш.», бор. төрки *jara-* «ярау; уңай булу, мач килү» (ДТС: 239) < **jaγ-ra-* (фигыль ясагыч *-ра* аффиксы) булса кирәк. К. **Ярау, Ярәшү.** ЭСТЯ IV: 137–138.

**Яра-** продуктив нигез, шуннан **Ярак I, Ярамсак, Ярат-у, Яраш-у** (бу нигезләр үзләре дә бик продуктив) һ.б., к. **Ярый, Ярәш-ү** һ.б. бик күп, к. Будагов II: 324. К. түбәндәгеләрне**.**

**ЯРӘКӘ [йәрәкә]** (минз., ТТДС I: 182) «очень большая речная лодка, почти корабль» < төр. *gereke, karaka* << ит. *кракка* – «җилкәнле кәрап төре».

**ЯРӘШ-Ү [йәрәш-],** диал. **җәрәш-ү, җәрәштер-ү** «просватать (девушку)» диал. (БТДҺ: 113) **йараш-у, җирашу** > удм. *яраш-* ~ мар. *сарас-, сорас-, сӧрӓс-* < болг. **җараш-* > чув. *çораç-* > *çураç-* id. гом. кыпч., уйг. һ.б. *йараш-* «ярашу, бер-береңә ярау; килешү, солых төзү» фигыленнән, к. ш. ук каз. *жарас-* «кыз ярәшү». Тәүдә күчемсез фигыль күчемлегә әверелгән. К. **Яра-у.**

**ЯРГАК [йа°рғак],** диал. **җарғақ** «шкура без шерсти, облезлая шкура; одежда из (недублёной) кожи» – в частности «верхние рукавицы» (Тумашева 1992: 70), «кожан» (ТРС 1966) ~ чув. *çорхах* > *çурхах* «яры; сәләмә кием, ертык-портык» < болг. **җарғақ* < гом. кыпч., төркм., чыгт., уйг. *йарғақ* (> к.-балк., кырг. *җарғақ,* каз., к.-калп. *жарғақ*), алт. *дьарғақ* «яры; яргак; кием тегү өчен эшкәртелгән тире» (соңгы мәгъ. «кием тегү өчен әзерләнгән тире» мәгънәсеннән), тәүге мәгъ. исә – «начар тире», к. к.-балк. *җарғақ* «түбән сортлы сарык тиресе». Бу сүздән төрле тарафка күч. мәгънәләр үсешкән: иске тат. *йарғақ* «яхшы күн, замша» (к. Будагов II: 325), кырг. диал. *жарғақ, йарғақ* «чыр (шулпа өстенә чыгып, ката төшкән май катламы)» > чув. *йалхах* «элпә»; каз., к.-калп. *жарғақтай,* ком. *йарғақ* «арык, ябык» >> мар. (Упымарий: 302) *йаргақ* «ярлы, пролетарий»; як. *дьарға* «кайма, чигеш; тире кием чигеше; бизәкле тире кием», хак. *чарғах* «тире калкан» (к. Субракова О.В. Этимология некоторых архаичных слов хакасского языка // Лексикология и словообразование хакасского языка. Абакан, 1987: 40–41).

*Йарғақ* ← *йарға-* «йоны коелу», к. тув. *чарғаш* «йоны коелган». *Йарға-* фигыле, үз чиратында, бор. **йар-, *йару-* фигыленнән. К. **Яры, Чара, Шәрә.** Zenker: 948; Räsänen 1969: 190; ЭСТЯ IV: 141–142; рус. *ергак, яргак, ергач* «тышкы йонлы тун» тур. Аникин: 201.

**ЯРГЫ [йа°рғы]** тар. «суд» (русча XV–XVI г. сүзлекчәсендә *йаргы йарадыр* «суды судит», к. Ковтун Л.С. Русская лексикография эпохи

средневековья. М., 1963: 321–324), к. себ. **йарғу** «хөкем карары», **йарғузақ** «судлашучан», **йарғула-у** «хөкем итү» (брб., к. Тумашева 1992: 70) ~ чыгт., төр. *йарғу*, алт. *дьаргы*, хак., тув. *чарғы* «суд; хөкем» > бор. монг. *ǯarɣu* > хәз. монг. *зарга* «суд эшләре; суд хөкем» ~ як. (Антонов: 121) *сорғу, сарғы* «язмыш». Сүзнең фигыль тамыры тик тат. (*яргы яр-у*) һәм монг. (XIX г. сүзлегендә *дзар-, дзарғу*) телләрендә генә сакланган. Будагов II: 325–326; Бутанаев 1990: 151.

**Йар-** тамыры *җар* «игълан» сүзе белән бердәй булса кирәк. Шул ук вакытта *яр-* тамыры *яр-у* фигыленә дә баглы булырга мөмкин: бор. гадәт буенча үлемгә хөкем ителгән кешене урталай *ярганнар* (к. ш. ук тат. *яру* «җәзалау; кыйнау»: *Без үзебез ярлылар, элек безне ярдылар; Безнең үчне буржуйлардан большевиклар алдылар,* дип жырлыйлар иде XX г. 30 нчы елларында). Тат. *ярма яру* «күп сөйләү, төрлечә сөйләү» тәгъбирендәге **ярма** сүзе дә *яр-* «хөкем йөртү» фигыленнән шикелле. К. ш. ук бор. төрки (ДТС: 240) *jarɣan* «суд хөкемен җиренә җиткерүче; палач», себ. **йарғақ** «күп сөйләүчән» һ.б. Рус. (< монг., маньч.) *йаргучей* «җирле судья, администратор» тур. Аникин: 779. К. **Җар I, Ярлык, Ярлыка-у.**

**ЯРДӘМ [йәрдәм],** диал. **йардәм, жардәм, җәрдәм,** «помощь, содействие» < гом. кыпч., уйг. *йардем* (башк. *йарҙам,* кырг. *җардам*, каз., к.-калп. *жардам*) id. фар. *йāри-у-дāм* «дуслык һәм ярдәм» сүзеннән, шуннан төр. *yardım* «ярдәм», бор. алынма (хәз. фар. *йардāм* сүзе юк, *йардум* сүзе генә бар һәм ул төрекчәдән дип әйтелә). ЭСТЯ (IV: 142–143) бу сүзнең этимологиясе юраулы дип билдерә. К. калм. *dam, dem* ~ алт. *tem, täm* «ярдәм» (Ramstedt 1935). К. **Дәм.**

Дерив. киң: **ярдәмле, ярдәмсез; ярдәмләш-ү; ярдәмчел** һ.б.; **ярдәм итү** киң кулланыла.

**ЯРЕК [йәрĕк]**: (себ., ЗДС: 67–71) **йәрек аш** «еда, яства которые хочет беременная женщина» ~ төр. (Будагов II: 355) *йәрик* ~ кырг. *җерик* id. К. түбәндәгене.

**ЯРЕК-Ү [йәрĕк-]** (себ., ЗДС: 343) «хотеть какую-либо конкретную пищу (чаще о беременной женщине)» ~ төркм. (Мухамедова 1973: 106) *йергинмәк*, төр. (Будагов II: 255, гарәп хәрефләрендә генә язылган, транскрипция безнеке) *йәринмәк* нәрсәнедер (билгеле бер шәйне) ашарга теләү (көмәнлеләр тур.)», төр. ш. ук «гомумән нәрсәнедер бик теләү» ← **йәр-* «теләү» < бор. төрки **йәгәр-* < **йәг эр-* «яхшы күрү», к. бор. төрки *jeg* «яхшы», *jegäd-* «яхшыру», *jegät-* «яхшырту» һ.б. һәм *er-* «теләү, артыннан куу» булса кирәк, к. ДТС: 174, 252.

Күп телләрдә *йәргин-* «җирәнү» сүзе бар һәм аны кайчак *йәрик-* «ярегү» сүзе белән бутыйлар. Ләкин боларда төптән үзгә-үзгә тамырлар, к. **Җир II.**

**ЯРЕН [йәрĕн],** диал. **җәрен, йәрин,** иске тат. (С. Хәлфин сүзлегендә) **йарын** «будущий год, в будущем году», диал. ш. ук «завтра» ~ башк. *йәрен* id., каз. диал. (Нұрмағамбетов: 40–42) *жарын*, чыгт., кар., кр.-тат., уйг., госм. *йарын* «иртәгә», гаг. *йаарын* id. < **йағырғын* «таң, яктырыш» сүзеннән, к. алт. *йарғын* ~ чув. *çурăн, çорăн, çурăм* «таң», кырг. *җарқын* «якты», чаг. ш. ук чув. *ыран [ыйран]* «иртәгә».

Сүзнең фономорфологик үсеше: *йағ-, йақ-* «май яну» (к. **Яу II**) → *йағ-ыр-* «яндыру, яктырту» → *йағырғын* «яктыртылыш» > *йарғын* > *йарын* > *йәрен, җәрен.* К. алт., уйг., госм. *йары-* (хак. *чары-*, як. *сары-*) «яктыру», бор. төрки. *jaruɣ* «яктылык, нур», як. *сараа-* «яктыру», *сарсын* «иртәгә» һ.б. К. **Якты.**

Мәгъ. үсеше «яктыру > таң > иртәгә > киләсе елга». «Таң > иртәгә» мәгъ. күчеше күп телләрдә очрый (к. к.-балк. *тангбла* ~ тат. диал. **таң белән** «иртәгә»), «иртәгә > киләсе елга» тат., каз., к.-калп. һәм үзб. телләрендә (үзб. *йарын* ~ каз., к.-калп. *жарын, җарын* id.). ЭСТЯ I: 146; Федотов II: 142; Ахметьянов 1989: 16–17.

**ЯРИЧӘ [йәричә],** диал. (Будагов II: 434), себ. **ярча, ярца** «ярица, яровая рожь» ~ башк. *йәрисә, йәрсә* ~ удм. *ярича,* мар. *йăрца* id., ш. ук «эре ярма» < рус. *ярица* – бор. рус. *яра* «яз» сүзеннән (Фасмер I: 559–560).

**ЯРКА [йа$^{о}$рқа],** диал. **җарқа** (ТТДС I: 567), **йарға** (Тумашева 1992: 70) «половина сколотого бревна; плаха», **йарғанақ** (И. Гази) «полено» ~ чув. *çуркам*, к.-балк. *җарқа* id. **Яр-у** сүзеннән, әлбәттә.

**ЯРКАНАТ [йа$^{о}$рқанат],** диал. **жарканат**, себ. **йаруқанат** (Тумашева 1992: 71) «летучая мышь» > мар. *йарканат* < гом. кыпч. *йарқанат* (кырг. *җарқанат*, к.-балк. *җерқанат;* каз. *жарқанат*, к.-калп. *җарғанат*), башк., төркм. *йарғанат*, алт. *дьарқанат,* хак. *чарханат*, як. (ДСЯЯ: 204) *сарыы*

*кынат, сарыкынат* һ.б. id. *йары қанат* (к. **Яры**) сүзеннән, чаг. төркм. диал. *дериканат* «тире канат», төр. диал. *каньшканат*, хак. *хырнаканат* (*хырна* «карындык») һ.б. ЭСТЯ IV: 140–141.

**ЯРКӘ [йәркә]** диал. (ТТДС I: 182) «любовник; человек, хвастающий любовными успехами» ~ чув. *еркĕн (йэркĕн), ерешке* id. Чаг. тат. диал. (ТТДС I: 574, 582) **җәрәкәү//җирәкәү,** ком. *яревке* «ялагай, юха». Ачык түгел.

**ЯРКЫН [йа$^{o}$ркы̆н],** диал. **җаркын, йарғын** (к. Тумашева 1992: 70–71) «яркий; блестящий» < гом. кыпч. *йарқын* (кырг. *җарқын,* каз., к.-калп. *жарқын*), үзб. *ярқын* id. < *йарықын* ← себ. тат. **йарық,** гом. кыпч. *йарық,* төркм. *йаарық* (кырг. *җарық*, каз. *жарық*) < бор. төрки (ДТС: 244) *jaruγ* «нур, яктылык, якты» сүзенең инструменталь килеш формасы. К. **Яры-у.**

**ЯРЛАУ [йа$^{o}$рлаw]** «обрыв, крутой берег; подводная яма (и воронка, бурун над ней)», шуннан **йарлаwық** «чоңгыл; убылган ярлау» (ДС I: 246; БҺҺ II: 86; Тумашева 1992: 70) – тат. һәм башк. телләрендә генә очрый, **яр** сүзеннән үзенчәлекле модельдә ясалган (чаг. *Бозлавык, Чикләвек* < *Чәртләwек* һ.б.).

**ЯРЛЫ [йа$^{o}$рлы̆]**, диал. **җарлы** «бедный; бедняк», диал., иск. «бедняга» (к. «Йосыф китабында»: *Ярлы Яғқуб бу тәдбиргә рази улды*), «плохой, неважный» (без теркәдек. – *Р.Ә.*), «надо, надобно» (Старчевский) > мар. диал., удм. диал. *ярлы, ярло* «ярлы, бедняк», чув. *йурлă* < *йорлă* < гом. кыпч. *йарлы* (к.-балк., кырг. *җарлы,* каз., к.-калп. *жарлы,* кырг. диал. *жарды*) < бор. төрки *jarlïγ* «ярлы, бәхетсез» (к. ДТС: 242). Бу сүзнең тат. диал. (Тумашева 1992: 71) **йарылу** (< **йарылуғ*), алт. *йарылы*, чулым. *йарылығ,* кырг. *җарылы* вариантлы игътибарга лаек: димәк, сүзнең нигезе *йары* > чув. *йорă* > *йурă*, ш. ук *йор* > *йур* «ярлылык; авырлык» (к. Ашмарин V: 3, 6–7); к. як. *сарғы-сатыы* «җәяүле», *сарғы-сатаған* «үтә ярлы», манси. *йаарло* (< төрки) «ярлы». Бу фактлардан чыгып, *йары* < **йаарғы* дигән нәтиҗәгә киленә, ләкин бу сүзнең төп мәгъ. ачыкланмый. ***Йары-** фигыле дә булган, к. (ЗДС: 236) **йарлык-у,** каз. *жары-л-у* «ярлылану». М. Рясянен буенча, бор. **йар-* «буш» (Räsänen 1969: 190), ләкин бу фараз гына. Шулай ук Ж. Киекбаевның *йары* монда «яры, йонсыз тире» дигәне дә фараздан артык түгел. Брб. (Дмитриева 1981: 142) *йарлур-* «ярлылану» **ярлы** сүзеннән һәм нигез этимологиясенә берни дә бирми. **Ярлы** сүзе уйг. һәм угыз телләрендә юк (шикелле), ләкин венг. (Gombocz: 76) *gyarlo* «ярлы». ЭСТЯ IV: 142–143.

Деривациясе регуляр.

**ЯРЛЫК [йа$^{o}$рлы̆қ]** «извещение, указ, ярлык; удостоверительная записка» > чув. *йорлăк* id. (Ашмарин V: 8) – бу тат. халык телендә дә (әкиятләрдә), яз. ядкәрләрендә дә еш кына очрый торган сүз бүтән кыпч. телләрдә сирәк кулланыла һәм яз. телдән килә (мәс., кырг. *җарлық,* каз., к.-калп. *жарлық*) < бор. төрки (ДТС: 141, 242–243, 641) *čarlïγ, čarluγ, ǯarlïγ, ǯarluγ, jarlïγ*, уйг. *йарлиқ, йарлиғ* (үзб. *йорлиқ*), алт. *йарлык,* төр. *yarlığ* «ярлык, әмернамә, указ», төр. «рөхсәтнамә». Барча тикшеренүчеләр бу сүзне **йар//җар//чар** «бөтен халыкка игълан» (к. **Җар I**) сүзенә баглыйлар. Рус. **ярлык** «товарга ябыштырылган белешмәлек» < төр. «тамгаханә рөхсәтнамәсе» мәгъ. булса кирәк. Гомумән, бу сүз төрки телләрдән күрше (монг., ир., Кавказ һ.б.) телләргә дә үтеп кергән (к. Аникин: 729).

Себ. **йарылык** (Тумашева 1992: 71) «ярлык, боерык» – **йарлык** сүзеннән «киңәйгән» булса кирәк, ләкин бор. *йар-ығ* яки *йарғы* «игълан» сүзеннән дә (*йарлық* < *йарылық* < *йарығлық, йарғылық*) булуы ихтимал (**йар, җар** сүзенең фигыль мәгънәсе булганлыгы тат. **йарып салу, йарып әйтү** тәгъбирләреннән күренә шикелле), к. ш. ук удм. *ялон* «игълан», *ялись* «сөрәнче, нидачы» ← бор. удм. **йалы-* < **йары-* яисә *йарла-*.

**Ярлык** сүзе тур. күп язылган, тик ЭСТЯ (IV: 18) биргән мәгълүмат бик ярлы. К. **Ярчы, Ярлыка-у, Ярлыкаш.**

**ЯРЛЫКА-У [йа$^{o}$рлы̆қа-],** диал. **җарлыка-у** «прощать (грехи)», иск. «помочь; быть милостивым» < гом. кыпч., чыгт. *йарлықа-* (кырг. *җарлықа-*, каз., к.-калп. *жарлықа-*), төр. *yarlıqa-*, *yarlıqqa-* id., бор. төрки (ДТС: 242–243) *jarlïqa-* «яхшы әмер бирү» *йарлық* сүзеннән (*йарлық-а-*), к. ш. ук төрки-манихей. *yırlıγ* «әмер», *yırlıqa-* «әмер бирү» (Zieme P. Ein manichäisch-türkisches fragment // Acta Orientalia, XXIII. 1970); мәгънәви мөнәсәбәтләр бор. төрки хөкем гадәтләрен чагылдыра: суд хөкеме уңай, кичерүле булса гына кычкырып һәм язмача игълан ителгән, югыйсә үлем җәзасы тур. күп сөйләп тормаганнар. Чаг. алт. *йарлық, йарлықчы, дьарлықчы* «бурханизм динендә – дин башлыгы»

(к. Сагалаев: 87–97), чыгт. *йарлықачы* «гөнаһларны кичертүче» һ.б

Бор. татар-болгар мәҗүсилегендә дә *йарлыкачы, җарлыкачы* «гөнаһларны ярлыкатучы» булган, күрәсең, к. чув. *çырлахса* «ярлыкаучы, кабул итүче, килештерүче, кичертүче фәрештә» ← *çырлах, çырлаху* «ярлыкау (исем), гыйбадәт»; мар. *серлагаш* «кичерүчән тәңре, рәхим-шәфкать фәрештәсе» ~ себ. тат. (Тумашева 1992: 70; Будагов II: 323) **йарлықаш** «хезмәт хакы, мәгаш» ~ алт. *йарлықаш*, каз. *жарылғас* «патша бүләге».

**ЯРМА [йа$^{о}$рма],** диал. **җарма** «крупа» < гом. төрки *йарма* (кырг., к.-балк. *җарма*, каз., к.-калп. *жарма*, алт. *дьарма*, тув. *чарба* һ.б.) < бор. төрки *jarma* (ДТС: 242) – **яр-у** фигыленнән.

**ЯРМАК [йа$^{о}$рмақ]** диал. (И. Туктаров) «деньги, денежки» > морд. М. *ярмақ* «тәңкә» < төркм., уйг. һ.б. *йармақ* (яз. ядкәрләрдә еш очрый, к. ЭСТЯ IV: 143–144), урта төрки *jarmaq, jartmaq* «уртасы ярыклы Кытай тәңкәсе» – *йар-у* сүзеннән булса кирәк, к. Räsänen 1969: 190; Clauson: 969; к. ш. ук Добродомов 1978: 46–51 (хант. *ермак*, манси. *ярмак* «ефәк» сүзенең төрки *йармақ* «тәңкә» сүзеннән чыкканлыгын исбатлый); Тимергалин: 572.

**ЯРМИНКӘ [йәрмиңкә],** диал. **җәрминкә** «ярмарка» ~ мар. *йӓрмӗнкӗ,* удм. *ярмонька*, чув. *ярмӑнкка* id. < рус. сөйл. *ярмонька* id. < *ярмарка* < ним. *Jahrmarkt* «еллык чаршу (зур базар)» сүзеннән.

**ЯРПАЙ-У [йа$^{о}$рпай-]** «вести себя разнузданно (но не нагло, не преступно)», диал. **җарпай-у, йалпай-у** «көрәю, тазару, яхшыру» (ТТДС I: 162, 567), «шәпле, абруйлы булып китү» (Радлов III: 149), **йалбай-у** «киңәю, симерү, тулу» (Тумашева 1992: 66) һ.б. > чув. *йарпай-* «киңәю, җәелү; тиген, эшсез йөрү» < гом. кыпч. **йарпай-*, к. кырг. *җарбай-* «эчтән кинәнү», башк. *йарпай-у, йалпай-у* «тулыру, тулымсалану» (БТДҺ: 109, 113) ~ як. *дьарбай-* «сәйран кылу, саф һавада йөреп кайту» һ.б. **йарпа* «җәелеп, тузгыган, киңәйгән» сүзеннән, к. бор. төрки (ДТС: 243) *jarp* «ныклы, каты» → *jarpaб, jarpat-* «ныгу», чаг. ш. ук мар. *йырпа//йӗрпӓ* «җилбәгәй», кырг., як. *җарбаң, дьарбаң* «бик иркенәеп йөрү (хәле)», алт. *дьалбаң* «һавада пәрвәз итү (хәле)», нуг. *ярбаң*, каз., к.-калп. *жарбаң* «ялагайлык» һ.б. (боларның уртак мәгънәсе – мораль яктан да «киңәю»). К. **Ярпач.**

Максудидә «ярпай-у» мәгъ. *яркай-у* сүзе кулланыла.

*Йарпа* нигезе тәкълиди сүз булса кирәк. К. **Ябалдаш.**

**ЯРПАЧ [йа$^{о}$рпач], җарпач** (ЗДС: 181, 236) «фамильярный хвастун (иногда невыносимый)» ~ каз. (Катаринский) *жарба-, жарбай-* «фамильяр кочаклау». Чаг. алт., төр. һ.б. *ярдак* «ачык, илгәзәк, ярдәмчел». К. **Ярпай-у.**

**ЯРСЫ-У [йа$^{о}$рсы-],** диал. (ЛТ I: 151) **җарсы-** «разъяриться, (сильно) возбуждаться», диал. «устать» (ДС II: 245), **йарсу [йа$^{о}$рсы̆w]** «страстный» > мар. кч. *йарсу* «кызу канлы» (Исанбаев 1978: 10) < гом. кыпч. **йарсы-* (к.-балк. *җарсы-*, *зарсы-*, кырг., каз., к.-калп. телләрендә теркәлмәгән) «ярсу, җирәнү; чиктән чыгу», уйг., алт., бор. төрки *jarsı-* «җиксенү», бор. төрки *jarsïγ-* «ярсып китү», *jarsuб-* «төкеренү», (ДТС: 243) *jarsï-* «җирәнү», алт. диал. *дьарсы, йаарсы-* «җирәнеч булу», *йаaруу* «бурсык исе, шөр», хак. *чарсы-, нарсы-* «җирәнү»; к. ш. ук төркм. *йарс-* «бозылу, үзгәрү», як. *дьаар*, *чаар* «сасы (ис)». Телчеләрнең күпчелеге бу сүзне күп кенә кадим ядкәрләрдә очрый торган *йар* «селәгәй» сүзеннән дип карый (ЭСТЯ IV: 134, 144–145), ләкин сүз ясалышы тәфсилле аңлатылмый (к. ш. ук Joki 1952: 118–119; Räsänen 1969: 191).

Әлбәттә, «төкеренү > җирәнү, ярсу» мәгъ. күчеше бик аңлаешлы, ләкин *йарсы-* нигезе *-сы* кушымчасы ярдәмендә ясалган булса, сыйфат тамырдан ясала, шуның өчен сүзнең тамырына алт. диал. һәм як. сүзләре якынрак шикелле, гомумән, *йарсы-*, димәк, «сасы дип исәпләү» була, бу мәгънә «төкеренү» мәгънәсен дә үз эченә ала. Чаг. ш. ук бор. монг. *jarši-, jari-* «күп һәм ярсып, төкерек чәчеп сөйләү». Монда *-сы* кушымчасы барлыгына **ярсын-** һәм **ярсыт-** (юн.) формаларының таралганлыгы да дәлил.

**ЯРТЫ [йа$^{о}$рты̆],** диал. **җарты** «половина; половинный», себ. тат. (Дмитриева 1981: 142) **йартық** < гом. кыпч. *йарты* (к.-балк., кырг. *җарты*, каз., к.-калп. *жарты*), алт. *дьарты,* тув., хак. *чарты, чартығ, чартық* id., бор. *йарт-ығ* * «ярылган, ярулы, ярдырылган» (*йарт-* «ярдыру»). К. **Яр-у.**

**ЯРТЫЛАШ [йа$^{о}$рты̆лаш]** «наполовину» < *йартылач*; ләкин **яртыла-у** дигән фигыльдән дә ясала ала.

Дерив.: **яртылы; яртыла-у.**

**ЯР-У I [йа$^{o}$р-],** диал. **җар-у** «расколоть (надвое), расщепить; бить, наказать» ~ чув. *ҫор-* > *ҫур-* < гом. төрки *йар-* (к.-балк., кырг. *җар-*, каз., к.-калп. *жар-*), тув., хак. *чар-* id. < бор. төрки (төркм.) *йаар-* id., ихтимал, **йак-ар-* «як-якка аеру» сүзеннәндер.

Барча тикшеренүчеләр (Радлов III: 102–103; Räsänen 1969: 189; ЭСТЯ IV: 135–137) тат., төр. диал. *йар-*, тув. *чар-* «хөкем итү, хәл итү; аеру, ачыклау» сүзен **яр-у** белән бердәй, шуның күч. мәгънәсе дип карыйлар. Бу караш «икегә яру > хәл итү > хөкем итү» һәм ш. ук «җәзалау» (к. **Яргы**) мәгънә күчешләренең типологик характерда булуы белән дә куәтләнә.

*Яр-* нигезе төрки телләрдә иң продуктивлардан берсе, к. **Яра (?), Яргы, Ярка, Ярма, Ярты, Ярчык, Ярык, Ярым, Ярымтык, Ярыш-у (?).**

**ЯР-У II [йа$^{o}$р-]** (ЗДС: 236) «засветить, светлеть, светать» ~ алт. *йар- дьар-,* уйг., чыгт. *йары-, йару-* id., ком. *йар-* «(күмер) көйрәп яну» һ.б. К. **Яры-у.** Räsänen 1969: 189.

**ЯР-У III [йа$^{o}$р-]** (ЗДС: 236) «много болтать» ~ чув. *яр-* id., гомумән «җибәрү; ычкындыру». Чаг. *ярма яру* «күп сөйләү, мәгънәсезгә сөйләү».

**ЯР-У IV [йа$^{o}$р-]: яфрак яр-у,** диал. **чәчәк яр-у** «распускать листья (лепестки)»; хәз. телебездә әчке семантик багланышлары бигүк аңлашылмаган бу тәгъбирдә **яр-** бор. төрки **йар-* «җибәрү, җәелдерү» сүзеннән һәм бор. (ДТС: 222, 223, 245 һ.б.) *jad-, jaδ-, jaj-, jat-, jaz-, jas-* «җәелдерү, язу» (к. **Җәй-ү**) фигыльләре рәтендәге берсе булса кирәк. Ул **йар-* варианты омоним *jar-* «(икегә) яру» сүзе булганга төшерелеп калган. *Йар- ~ йаз-* дигәннән, иҗек азагында *r ~ z* һәм *r ~ t ~ d ~ δ ~ j ~ z ~ s* чиратлашуы күп кенә бор. төрки тамырларда чагыла.

**ЯРУТ [йа$^{o}$рут], җарут** «ярутка; подорожник; мать-и-мачеха» ~ ком. *яра от* «песи бочагы», *яр уты* дип тә *яра уты* дип тә аңлатыла ала (чөнки яраларга ябу, дәвалар өчен кулланыла). Рус. *ярут, ярутка* < тат.

**ЯРЧЫ [йа$^{o}$рчы̆]** диал. (Н. Арслан) «защитник». Бор. текстта *Аргын ятып калса да, ярчы булган ил өчен.* К. **Яр I.**

**ЯРЧЫК [йа$^{o}$рчы̆к]** «осколок» < (кар., гаг.) *йарычыкъ < йары-чыкъ* id. себ. тат., кар., гаг., төркм. *йары (йаары),* чыгт. *йари,* бор. уйг. *йару,* кырг. *җары,* каз., к.-калп. *жары* ~ чув. *ҫорă* > *ҫурă* < болг. **җары* > удм. *с'ур (сюр)* «ярым, яртылаш» (бу сүз үзенчәлекле рәвештә удм. телендә «үги» мәгъ. кулланыла: *сюранай* «үги анай», *сюратай* «үги атай», *сюрпи* «үги угыл», *сюрныл* «үги кыз» һ.б.), к. ЭСТЯ IV: 146–147. Чаг. ш. ук хак. *чарчых* «ярчык, пүләһ», себ. тат. (Тумашева 1992: 71) *йарцы, йарца* «пүләһ, ярчык», каз. *жарқынчақ* «ярчык» һ.б. К. **Яр-у.**

**ЯРЫ I [йа$^{o}$ры̆],** диал. **җары** «плевра, кожица, перепонка», (ТТДС I: 167) «брезент», иск. «шкура без шерсти» (к. **тире-яры** «кожное сырье») < гом. кыпч., төркм. *йары,* алт. *йаруу, йарыг,* шор. *чарыг,* як. *сары* id. (ЭСТЯ IV: 146). Беренчел мәгънәсе «плевра, карындык, карын ярысы» булган, к. тат., башк. **йары май** «терлекнең эченә җыелган май, яу» (БТДҺ: 114).

**Йары**, безнеңчә, бор. *йағры < йағыр-ығ* «бор. яктырткыч өчен эч мае» (**йағыр* «җәү яндыру») сүзеннән, к. бор. төрки (ДТС: 238) *jaqrï*. К. **Яу II.**

**ЯРЫ II [йары̆],** диал. **җары** (к. ш. ук *йарыга//җарыга* – плеонастик ясалма), күбесенчә *бер йары//җары* тәгъбирендә кулланыла «в сторону кого-чего» < гом. кыпч. **йары,* к. кар. *йары*, к.-балк. *җары*, чыгт. *йару*, алт. *дьаар*, алт. диал. *тьаар* (к. Баскаков 1972: 259) id., безнеңчә, бор. төрки *jaγru, jaγuru, jaqru* «янында, якынында» сүзе белән (ДТС: 225) бәйле, бу сүз исә *jaγur-* «якынлаштыру» нигезеннән хәл фигыль *jaγuru* (*-у = -а*); *jaγur-* үзе бор. *jaγu-* «якынлашу» сүзенең йөкл. юн., к. тат. диал. *йуық < jaγuq* «якын». к. **Якын.** Төрле фикерләр тур. к. ЭСТЯ IV: 145–146.

**ЯРЫЙ [йа$^{o}$ры̆й], йарар,** диал. **җарар, җарый** «ладно, хорошо» > мар. *йара, йарä, йоро, йӧрӧ,* удм. *йара*, чув. *юрĕ, юрать*, удм. диал. *ǯарам* < тат. *җарармы, җарaймы* (Насибуллин: 115) «хорошо, ладно». К. **Яра-у.**

**ЯРЫК [йа$^{o}$ры̆к],** диал. **җарық** «трещина; щель; с трещиной» ~ чув. *ҫурăқ* < *ҫорык* < болг. **җарық* id. < гом. кыпч. *йарық* (к.-балк., кырг. *җарық* > каз., к.-калп. *жарық*), угыз. *йарық,* уйг. *йариқ, йоруқ,* чыгт. *йаруқ, йаруг,* алт. *дьарық,* тув., хак. *чарық* > хак. *чарых* id. *йар-* фигыленнән. ЭСТЯ IV: 136–137.

**ЯРЫМ [йа$^{o}$ры̆м],** диал. **җарым** «пол-, полу-»; сирәк «половина» ~ чув. *ҫурма-* < *ҫорма-* < болг.

**жарма* (?) < гом. кыпч., угыз. *йарым* (Радлов III: 128–129), к.-балк., кырг. *җарым* > каз., к.-калп. *жарым,* уйг. *йерим,* чыгт. *йарум,* алт. *дьарым,* алт. диал. *тьарым*, хак. *чарым*, монг., бур. *зарим* «ярты; өлеш» ЭСТЯ IV: 137. Чаг. мар. (Упымарий: 303–304; Саваткова: 30) *йарым, йäрым* «җиде аршынлы киндер» сүзенең **ярым** сүзенә мөнәсәбәте ачык түгел.

**ЯРЫМБИШ [йаºры̆мбиш],** диал. **җарымбиш** (к. ТТДС I: 168, 567) «треть десятины; две единицы **түтәрәм**» ~ чув. *çур пилĕк* id. **Биш** дигән җир үлчәү берәмлегенең яртысы булса кирәк. Ул *биш җәриб (чәриб)* дигәннән кыскартылма була ала: **җәриб** ≈ 14 сутый; **биш җәриб** 70 сутый, шуның яртысы ≈ 35 сутый, ягъни якынча өчтән бер дисәтинә. Чув. *çур пилĕк* татарчадан калька. Рус. диал. < тат. *ярым* үзе ⅛ дисәтинә.

Сергеев (1970: 221–222) рус. *ярым* сүзен чув. сүзе – *йар-* «җибәрү» фигыленнән дип расламакчы: *йарым* «җибәрем» рус. *загон* «ярты дисәтинә» сүзеннән калька ди. Ләкин *ярăм* сүзе чувашчада гомумән юк, аннары И.Т. Сергеев гипотезасын кабул иткән очракта да **ярымбиш** = *çур пилĕк* сүзенең мәгънәви структурасы аңлашылмый кала (**биш** = **пилĕк** бу очракта нәрсәне белдерә?).

**Ярымбиш**тән башка миш. (ЗДС: 237) **йарымцыбык** «¼ дисәтинә» бар. К. **Чыбык II.**

**ЯРЫМТЫК [йаºры̆мты̆к],** диал. **җарымтак** (ТТДС I: 567) «половинник – полчеловека – мифический образ», буквально – «результат деления пополам; половина» (*-мтык* кушымчасы) ~ алт. *дьарымтык, йамыртык,* хак. *чарымдых,* монг. *ǯarimduq* «ярымтык – яру нәтиҗәсе»; бу сүзнең мифик «ярты кеше» мәгъ. тат. телендә барлыкка килгән булса кирәк (башк. *йарымтык* дигәне тат. сөйләшләреннән), к. ш. ук себ. *йартук* (Радлов III: 63) «ярты кеше, шүрәле», мар. (Упымарий: 48, Исанбаев 1978: 10), удм. *йарымдык* «наян рух; шелтәләп сүгү сүзе».

**Ярты кеше** мифик образы бик күп халыкларда, бигрәк тә Урал-Алтай халыкларында киң таралган: чувашларда *çури* (*ар çури* «ир ярымтыгы», *ама çури* «хатын ярымтыгы»); фар. *нниснас, наснас* (тат. фольклорына да кергән), гар. *шäкк* (тат. фольклорында да очрый), удм. *палэс мурт,* мар. *шурлочо*, мансиларда *хумпал,* ненецларда *парнээ*, якутларда *сучунаа, абаасы, абааhы*, энецларда һәм долганнарда *сихио* (Мифологические сказки энцев. М., 1961: 27–32), монголларда *терен* (< тибет. *тһеурен*), *Ороло-бэетэн, Орголи,* эвенкларда *чулугды, чулурэ, чулокэ*, нганасаннарда *баруси, сигэ,* Себер русларында *альбин, оплетай* (к. Аникин: 84–85), белорусларда *половинник* һ.б. Бор. төрки һ.б. халыкларда да ярымтыклар тур. мифлар сөйләгәннәр (Карпини: 26). Кытайда *бицзяньминь* «ярымтык» – төньяк рухы.

К. Рамазанова 1968: 435–436; Ахметьянов 1981: 48–49.

**ЯРЫТМА [йаºры̆тма] > ярымта** «светильник для лучения рыбы» (**йарытмалау** сүзендә, к. Тумашева 1992: 71), «плошка светильника» > чув. *çатма* «таба»; чув. сүзендә хәтта *а > о > у* күчеше дә булмавы бу сүзнең тат. теленнән чагыштырмача яңарак алынганлыгы һәм тат. телендә *җартма < җарытма* сүзе урта диалектта да булуы тур. сөйли. К. **Яры-у.**

**ЯРЫТ-У [йаºры̆т-]** «осветить» к. **Яры-у II.**

Себ. сөйләшләрендә бу сүз актив сүзьясагыч нигез: **йарыткы, йарыткуц, йарытма** һ.б. – төрле яктырткычлар.

**ЯРЫ-У I [йаºры-]** (Исәнбәт III: 295) «иметь вдоволь; быть довольным» < гом. төрки *йары-*, халаҗ. *йару-* (кырг. *җары-* > каз., к.-калп. *жары-*) id. (к. ЭСТЯ IV: 146). Чаг. тат. диал. *йарыл-у* «шат, көләч кыяфәттә булу». К. **Яры-у II.**

**ЯРЫ-У II [йаºры̆-]** (Тумашева 1992: 71) «светить, светиться, рассветать» (**таң ярылу//җарылу** тәгъбире һәр якта бар) < гом. төрки *йары-,* төркм. *йаары-,* уйг. *йари-,* алт. *дьары-,* кырг. *жары-,* хак. *чары-,* тув. *чыры-* id. < бор. төрки *jaru-* «яктырту, балку» (ДТС: 244), безнеңчә, бор. төрки *йагри-* «(яктырткычка) май ягылу» сүзеннән, һәрхәлдә бу сүз **як-у, ян-у** сүзләре белән бәйле (к. ЭСТЯ IV: 134–135), к. ш. ук **Яу II.**

**Яры-у** фигыленең дериватлары үзеннән күбрәк билгеле: 1) диал. (себ. һ.б.) *йарык* << бор. төрки *йаруг* id. (к. **Яркын**); 2) гом. төрки *йарын* «иртә», к. **Ярен;** 3) диал. *йарыт-у//җарыт-у* > удм. *ǯардънъ* «таң ярылу» < гом. кыпч. *йарыт-* (кырг. *җарыт-* > каз., к.-калп. *жарыт-*) > болг. **җарыт-, җарт-* > чув. *çот-* > *çут-,* мар. *сат-, сот-* «ярыту, яктырту», шуннан мар., удм. *сорта* < мар. *сарта* < болг. **җарта* < -**җарыт-ак* > чув. *çорта* > *çурта* «шәм», алт. *йарта* «балыкчы чырагы» > венг. *gyartya, gyorta* «шәм» (к. Gombocz: 78–79), к. ш. ук як. *сырдыа-* «яктыру, ярылу», *сырдык* < *йарытыг* «якты, яктылык». К. ш. ук **Ярытма.**

Гомумән, **яры-у** сүзенең чыгышы түбәндәге шәкелдән күренә (схеманы к.).




**ЯРЫШ [йа$^{о}$рӹш],** диал. **җарыш** «соревнование», **йарыш-у, җарыш-у** «соревноваться (в беге)» < гом. төрки *йарыш* һәм *йарыш-,* төркм. *йаарыш* һәм *йаарыш-* (нуг. *йарыс,* к.-балк., кырг. *җарыс-* > каз., к.-калп. *жарыс-*), алт. *д'арыс,* тув. *чарыш-* > хак. *чарыс,* як. *сырыс-* һәр ике мәгънәдә id. ЭСТЯ (IV: 148–149) бу сүзнең чыгышы тур. Дж. Клоусонның *йар-* «яру» фигыленнән дигән фикерен китерә. «Яру > бәхәсләшү» мәгъ. күчеше бөтен дөньяда билгеле булса да, төрки *йарыш* һәм *йарыш-* башлыча йөгерү тур. әйтелә һәм бу сүзләрнең нигезе һичшиксез **йар-* (шуннан *йар-ыш* исем фигыль формасы, ә *йар-ыш-* урт. юн.). Безнеңчә, *йарыш* < *ыйар-ыш* вә *йарыш-* < *ыйар-ыш-* һәм *йар-* < *ыйар-* «җибәрү» гом. төрки *ый-* < *ыӡ-* «этәрү, җибәрү» сүзенең йөкл. юн., шуннан (иске татарчадан) чув. *яр-* «җибәрү, күндерү, куу (?)», чаг. *ҡуыш-у* «ярышу». К. **Ий-ү.**

**ЯС [йа$^{о}$с]** «траур» – гомумхалык телендә (себ. һәм миш. диалектларында: ТТДС I: 168; Тумашева 1992: 71–72) киң генә таралган. Шуңа да карамастан Н.И. Ашмарин һәм аңа ияреп М. Рясянен да мар. *йасы, йăсĕ, йŏсы̄* «авыру; яс, кайгы, боеклык» сүзен иске чувашчадан дип карыйлар. Гом. төрки *йас* (хәер, кырг., к.-балк., каз., к.-калп. юк бугай) сүзен гадәттә гар. *йа'с* «траур» (Будагов II: 329) яки гар. *йа'ç* «өметсезлек» сүзеннән дип карыйлар (ЭСТЯ IV: 150), ләкин төркм., үзб. диал. *йаас* (ЎХШЛ: 128), венг. *gyasz*, бор. төрки (ДТС: 244) *yas* «зыян-зәүрәт; үлем», төр. диал. *yıs* «яс, траур» бер дә гар. алынмасына якынлашмыйлар. Безнеңчә, *йас* < монг. *йас (йасун)* «сөяк, закон, йола» белән гомоген, к. тат. *йас тŏт-у (тыт-у)*, бор. төрки *jas tut-* ~ монг. *яс барих* «сөяген тоту, җирләү, күмү, яс тоту». Гар.-фар. *йас* белән өлешчә охшашлык – очраклы күренеш.

**Яс** продуктив нигез: сөйләшләрдә (к. ДС I: 227; ТТДС I: 168; Радлов III: 221) **йасла-у** «сыктау; чеңләү», **йаслату** «кыз чеңләтү (туенда кайгылы җыр җырлату)», **йаслы** (кар., госм. **йаслы**) «күптән түгел якыны, кардәше үлгән (кеше)», **йаслаwык** «елак бала» һ.б. Әмма бу сүзләр әд. телдә бик сирәк очрый.

**ЯСАВЫЛ [йа$^{о}$саwӹл],** диал. **җасаwыл**, «судебный пристав» < гом. төрки *йасаwул* (кырг. *жасаwыл, җасоол*, каз., к.-калп. *җасаwыл,* башк. *йаһаwыл*), төр. *yasavul* һ.б. – хәрби-административ чин (төрле мәгъ. тур. ЭСТЯ IV: 151–153) < бор. монг. *jasaɣul* > *ǯasaɣul* «командир ярдәмчесе», *ǯasa-* «оештыру» сүзеннән (к. **Яса-у**). К. ш. ук як. *дьаһабыл, д'асабыл* «әмер, күрсәтмә; җитәкче». Як. формасы бор. төрки (V г.) *Дизабул* – Византиягә төрки каганлыктан илче булып барган кешенең исеме (ялгызлык исем) түгел, ә *ясавыл* – «ханның ярдәмчесе» булган дигән фикергә китерә. Хак. *чазоол* «ясак җыючы» тур. Бутанаев 1990: 148. К. **Ясак, Ясал.**

**Ясавыл** сүзе (бигрәк тә Чыңгыз империясе чорында) күп телләргә таралган. Рус. *есаул* тур. к. Аникин: 203.

**ЯСАК [йа$^{о}$сак],** диал. **җасак** «налог, сборы; ясак (подать натурой)» > мар. *йозак*, чув. (< рус.)

*ясак* < гом. төрки *йасақ* > к.-балк., кырг. *җасақ* > каз., к.-калп. *жасақ* «ясак». Гомумән, бу сүз бик төрле мәгъ. очрый, тат. мәгъ. бор. төрки *jasaq* (*alban-jasaq*, ДТС: 34) «салым, ясак» мәгъ. дәвам итә. Бүтән төрки телләрдә: башк. *йаһақ* «ясак; мылтык ясавы (заряд); кабиләләр килешүе», кырг. *җасақ* «хәрби берек – хөкүмәт (хан) гаскәре» > каз. *жасақ* «кабилә гаскәре», чыгт., госм. (Радлов III: 216) *йасақ* «тыю; низам; низамнамә; хәрәҗ; штраф; ясал», хәз. төр. *yasak* «тыелу; штраф» ~ бор. монг. *ǯasaγ* «хакимият; хөкүмәт; идарә; идарәче» > хәз. монг. *засах* (тув. *чазак*) «хөкүмәт; хөкүмәт башлыгы», маньч. *ǯасақ* «идарәче»; монг. *йаса* «закон». Идарәви терминнар уртак бер чыганактан килсәләр, уйг. *йасақ* «мебель», төр. диал. *йасак* «кәртә, йорт» бөтенләй бүтән чыганактан. Һәр очракта *йасақ*, әлбәттә, *йаса-у* фигыленнән; к. ш. ук хак. диал. *йазоғ* «матур!» (чаг. **ясан-у**). Будагов II: 230–231; ЭСТЯ IV: 151–152; ССТМЯ I: 253.

**Ясак** сүзе бик күп күрше телләргә, еш кына мәгънәви үзгәрешләр кичереп кергән, мәс., күрд. *yasaq, yazaq* «кайтарма, кайтарып бирелгән акча». Рус. *ясак* тур. к. Даль; Аникин: 730–731. К. **Ясавыл, Ясак, Ясаклы, Ясал, Яса-у.** К. түбәндәгене.

**ЯСАКЛЫ [йа$^{o}$сақлы̆],** диал. **жасаклы** «ясачный» ~ башк. *йаһақлы* id. – «башлыча натуралата салым түләүче», ш. ук себ. татарларының аерым бер группасы (этноним булып киткән). Бу сүз русча *ясачный, ясатчик* id. сүзләреннән калькамы, яисә киресенчә, рус сүзе татарчадан калькамы – әйтүе кыен. Һәрхәлдә рус хакимияте чорында *ясачный* сүзе 1612 елдан бирле билгеле (Аникин: 731). Чув. *ясаклӑ* < тат. *йасаклы* «ясак түләүче».

**ЯСАЛ [йа$^{o}$сал]** тар. «боевой порядок, строй; подразделение» (Сборник материалов… 1941: 149, 168) < чыгт. (Будагов II: 330) *йасал* id., төр. *yasal* «закон, законлы» < бор. монг. *ǯasal* «төзем; төзәтү» > эвенк. *ǯаһал, ǯасал* «әхвәл, вазгыять», як. (ДСЯЯ: 96) *дьаһал, дьасал* id.

Монг. *ǯasal* беренче карашка *ǯasa-* «ясау» сүзеннән шикелле, ләкин В.Я. Владимирцов (: 235) бу сүз бор. монг. *ǯiysaγal* «төзем, тәртип, шеренга, парад, ясал» (> хәз. монг. *загсал*) сүзеннән ди. Ләкин **ясал**ны **ясау**-дан да аерып булмый. Димәк, *йаса-* < бор. төрки **йағса-, йығса-?*

**ЯСАН-У [йа$^{o}$сан-],** диал. **җасан-** «наряжаться» ~ башк. *йаһан-* > чув. *йосан-* > *йусан-* «төзәтенү, төзелү, сәламәтләнү» < гом. кыпч., уйг. *йасан-* (> к.-балк., кырг. *җасан-* > каз., к.-калп. *жасан-*) «ясану; хәзерләнү», *яса-у* фигыленнән.

**ЯСАУ [йасаw],** диал. **җасау** «украшение; наряды; заряд ружья» ~ башк. *йаһау* > чув. *йосо, йосу, йосо* «нәфис, күркәм» (Ашмарин V: 14) – **яса-у** фигыленең исемләшкән формасы.

**ЯСА-У [йа$^{o}$са-],** диал. **җаса-у** «делать, сделать, смастерить; строить», диал. «украшать; заряжать (ружье)», себ. (Тумашева 1992: 72) «принять за кого» ~ башк. *йаһа-у,* чув. *йоса* > *йуса-* (ш. ук *йосав* > *йусав*), мар. *йаса-* < гом. кыпч., уйг., угыз. *йаса* (кырг., к.-балк. *җаса-* > каз., к.-калп. *жаса-*), алт. *дьаза-,* тув., хак. *чаза-* id., төп мәгъ. «тәртипкә китерү, төзәтү, төзекләндерү» ~ бор. монг. *ǯasa-* (хәз. монг. *заса-*, бур. *заһа-*) > эвенк., маньч. һ.б. *ǯаса-* «төзәтү, ясау» (ССТМЯ I: 253); бу сүзне маньч. *даса-* «идарә итү» белән дә чагыштыралар. Гомумән, *йаса-* бәхәсле сүз, кайбер төрки телләрдә бу сүз әзәл лексикада юк, шуннан чыгып аны монг. телләреннән алынма дип тә карыйлар (ЭСТЯ IV: 150–151), һәрхәлдә бу сүзнең дериватлары **ясавыл, ясак, ясал** (к.) тәгаен монгол теленнән. К. ш. ук Будагов II: 329–330 (күп материал бирә); Räsänen 1969: 91.

**Яса-** нигезенең күпсанлы дериватларыннан *ясалма сүз* дигәндәге **ясалма**ның мантыйксызлыгы күзгә ташлана. Соң бит халык телендә **ясалма** «табигый түгел» дигән мәгънәдә! Тат. телендә ул **ясалмыш** сүзләр табигый түгел мени? **Ясалмалы, ясалгыч** һ.б.ш. нигезләр дә кулайрак булыр иде.

**ЯСИН [йа$^{o}$син]** – название 36-й суры Корана, которую обычно читают по усопшим. Бу сүзнең конкрет мәгънәсе юк, ул ике – *йā* һәм *сӣн* дигән хәреф атамаларыннан гыйбарәт. Коръәндә мондый бер яки берничә гарәп хәрефеннән башланып киткән сүрәләр аз түгел: «Сад», «Таһа», «Әлифләммим» һ.б.ш.

Тат. телендә **ясин** күч. мәгъ. киң кулланылган. XX г. башларында *пролетариат капитализмның ясинчысы* кебек тәгъбирләр, *большевиклар царизмга ясин укыды* кебек җөмләләр язылып-басылып килгән.

**ЯСИПКӘ [йа$^{o}$сипкә]** (С. Рафиков), диал. (ТТДС I: 567) **җасипкә, йасипкәче** «помощник мельника; гарнец» < рус. *засыпка, засыпщик* id.

Татарларга берзаман хәтта тегермән ясарга да тыелган, шунлыктан кайбер тегермәнчелек

терминнары тат. теленә русчадан кереп калган, к. **Куласа, Мөшкә** һ.б.

**ЯСКЫ-У [йаᵒскы̆-]** диал. (ТТДС II: 110–111) «возбуждённо протестовать», (М. Гафури) «нападать, расправив когти (о хищных птицах), угрожать» ~ башк. (БТДҺ: 114) *йасқа-, йасқы-* id., нуг. *йасқа-,* кырг. *җасқа-,* каз., к.-калп. *жасқа-* «кизәнү», шуннан тат. (ТТДС I: 168) **йаскан-** «һөҗүм итү, гайрәт чәчү» > мар. (Упымарий: 303) *йаскын-* «кизәнү», нуг. *йаскан-,* кырг. *җаскан-,* каз., к.-калп. *жасқан-* «ялтарыну, бәрүдән тайпылу», төркм. *йасғын-* «куркыну» ~ калм. *zasxa-* «кисәтү». Монг. телләреннән булса кирәк (к. Räsänen 1969: 191; автор тат., башк., мар. мисалларын белми).

Дерив.: **яскыш-у** «әрләшеп бәхәсләшү».

**ЯСЛЕ [йәслě],** диал. **җәсле** «детские ясли (учреждение)» ~ мар. *йәшла,* чув., удм. *ясли* id. < рус. (*ясли* < *ядьсли* «утлык»).

**ЯСМАН [йаᵒсман],** диал. **җасман** (ТТДС I: 567) «тонкая лепёшка (раздваивающаяся при готовке)» > чув. *йосман* > *йусман* id. ~ нуг. *йаспан,* бор. төрки (ДТС: 245) *jasïman* «яссы шешә, тире капчык» ~ кар., СС *yastan* «күн шәраб капчыгы» – *яссы* (к.) сүзеннән булса кирәк; к. ш. ук бор. рус. *усмен* «тиредән эшләнгән», *усма* «күн» һ.б. **Яссы** сүзеннән булса кирәк: **ман** «савыт», чаг. **Батман.** Фасмер IV: 171.

**ЯСМИН [йаᵒсмин]** «жасмин (растение) < госм. *йасмин* id. < гар. *йāсмӣн* < фар. *йāсӓмӓн* дип исәпләнә, к. Kluge: 450. Рус. *жасмин* фр. теле аша шул ук чыганактан килә. Гомумән, халыкара билгеле сүз. **Чын ясмин** тур. Закиров: 108. К. ш. ук Будагов II: 330; Räsänen: 191 (беркайда да тирәнтен этимологиясе бирелми).

**ЯСМЫК [йаᵒсмы̆к],** диал. (ТТДС I: 593) **йасмак, җасмык, җасмак** «чечевица; фасоль; любое растение с мелким горохом» > чув. *йасмăк,* мар. *йасмық,* удм. *яснық* «ясмык» < гом. кыпч. *йасмық* (нуг. *йасмақ,* кырг. *җасмық,* каз., к.-калп. *жасмық*), чыгт., уйг. *йасмуқ,* үзб. *йасмиқ* id.; бу сүзнең бор. төрки (ДТС: 245) *jasïmuq* > уйг. *йесимуқ,* кырг. *җасымық,* каз. *жасымық* яңгырашлары һәм бик төрле үсемлекләрне (тары, бодай, кукуруз һ.б., к. ЭСТЯ I: 154) белдергән очраклары бар. **Йассы** (к. **Яссы**) сүзеннән; *йассы-мук* «яссыланып гарипләнгән» (*-мук* чир., авыру атамаларын белдерә торган сүзләр ясагыч кушымча): бу сүз тәүдә ашлыктагы гарип бөртекләрне белдергән булса кирәк.

**ЯССУ [йаᵒссы̆w],** диал. **йастуw, җастыw, йасты** (Радлов III: 228), **җастык** (ТТДС I: 568) «плоскость; разложенное на плоскость состояние», **кул яссуы** «ширина руки в наложенном на плоскость состоянии» (гомумән, **яссу//яссы** үзе генә дә озынлык, ара берәмлеге ≈ 9 см, к. *Мылтыгымны бер яссы чамасы борып куйдым*... ТХИ: Әкиятләр III: 288). **Яссы** (к.) белән бәйле.

**ЯССЫ [йаᵒссы̆],** диал. **йасты** (ДС III: 219), **йатсы, җассы, җасты** «плоский» ~ ком., куман., төркм., чыгт., госм. *йассы,* үзб. *йасси,* к.-балк. *җассы,* угыз. *йасы,* аз. *йасты* «яссы; киңчә», төр. *yatsı* «җәенке-тигез», К. Насыйри буенча (ЛТ I: 92), *йатсы* сүзеннән (*йат-у* тамырыннан) *йат* сүзенең исем-сыйфат коррелянтына *-су* < *-сығ* кушымчасы ялганып ясалган булып чыга, чаг. **уйсу;** К. Насыйри гипотезасы **яссы** сүзендәге геминатны да әйбәт аңлата: *йатсы* > *йассы* бик табигый; ләкин *йат* дигән сыйфат (бирегә ярашлы мәгънәдә) билгесез, ә исем төр. телендә генә теркәлгән (*jat* «ятак», к. ш. ук төркм. *йатла-* «куну», ТДГДС: 99) һәм бу гына җитми. Шуңа күрә без бу сүзне *йаз-* «җәю» (һәм шуның белән баглы төр. *йас-* «яссы булу») фигыленә кагылышлы дип карау яклы. Безнеңчә, *йассы* < *йассығ* > *йассу* (к. **Яссу**), *йассиғ* үзе исә *йатсығ* < *йастығ* < **йазыт-ығ,* ягъни сүзнең бор. нигезе **йаз-ыт* «язу, җәю (эше)». Шуннан ук *йазыт-а-* > *йаста-* «урын, ятак җәю» (к. **Ястау**), *йазыт-ығ* > *йастығ* «яту урыны» (к. **Ястык**) яки яту вакыты (к. **Ясту**). Шулай итеп, бор. закончалыклы *йазыт* «җәю, җәелгән нәрсә» нигезе булган дип фаразлау уртак нигездән ясалганлыгы күренгән, ләкин ничек ясалганлыгы аңлашылмаган бер төркем сүзләрнең этимологиясен хәл итә (бу сүзләр тур. ЭСТЯ IV: 154–156), к. ш. ук **Ястаң**. Чаг. **Язы.**

**ЯСТАҢ [йаᵒстаң],** диал. **җастаң** «подход; лесть» (**йастаңла-** «угодничать») ~ хак. *частаң,* як. *сыстаң* id. – **яста-у** фигыленнән.

**ЯСТАУ [йаᵒстаw]** «мягкий подход (к человеку), деликатность» > чув. *йостав, йустав* id., ш. ук «атның, юрганың йомшак йөреше» **яста-у** фигыленнән (аның күч. мәгънәсеннән). К. ш. ук тат. **ястаулы** «йомшак мөгамәлә таләп итүчән; түбәнчелекле». К. **Ястаң.**

**Ястау** сүзе барында рус. *подход* сүзен *якын килү* дип тәрҗемәләү – ярамас.

**ЯСТА-У [йа$^{о}$ста-]**«положить подушку (для сидения) кому-либо; обхаживать кого-либо; деликатно ухаживать за кем-либо; бегать, как бы специально не причиняя неудобств седоку (о лошади-иноходи)» > чув. *йоста-, йуста-* (соңгы мәгъ.) ~ башк. (БТДҺ: 114) *йаçта-,* төр. *yasta-, yasla-* «ястау; терәү», кырг. *җаста-, җазда-,* алт. *дьаста*, як. *сытаа-* id. < бор. **йазыт-а-* > *йаст-а-* һәм *йазыт-ла* > *йастла-,* ш. ук *йазытла-* > *йазтла-* > *йатла-* вариантларыннан. К. **Яссы, Ястаң, Ястык, Яштакай.**

**Яста-у** фигыленең кайт. юн. тат. **йастан-у** (к. мәкаль: *Торыр торагы, ястаныр ястыгы юк*), кырг. *җаздан-* > *җастан-,* чыгт. *йастан-,* төр. *yastan-, yaslan-,* як. *сыстаң-* «үзенә ястык-мендәр салу; үз фикереңне-сүзеңне нигезләү, мәсьәләгә нигезләнеп тотыну» төп фигыльдән киңрәк кулланыла.

**ЯСТЫК [йа$^{о}$стык],** диал. **җастык** «широкая подушка; подстилка» < гом. төрки *йастық,* ком., уйг., бор. төрки (ДТС: 245) *jastuk*, төркм. *йассық,* к.-балк., кырг. *җастық* > каз., к.-калп. *жастық* id. аз. диал. *йасдуғ, йасдығ* (АДДЛ: 241) «ястык; камыт бөяте» (*йастык* сүзенең күп кенә бүтән күч. мәгънәләре дә бар, к. ЭСТЯ IV: 154–155) < бор. төрки **йазыт-ық* «(өскә) җәелгән нәрсә» сүзеннән. К. **Яссы.**

**ЯСТҮ [йәстү]** «ночной намаз (последний из пяти ежедневных намазов)» < госм. (бор. угыз) *йасту, йатсу* «йокыга яту вакыты» (к. Будагов II: 321) сүзеннән, к. нуг., ком. *йасы* «төн, кич», к.-балк. (> абаз.) *җассы, җасы* «төнгә каршы вакыт; ястү» – *яссы* (к.) сүзе белән нигездәш («ятак җәер вакыт»). Тат. сүзенең кайда һәм ни өчен палатальләшүе ачык түгел.

**ЯТ [йа$^{о}$т]**, диал. **җат** «чужой, незнакомый; чужак; посторонний; чужд» > мар. *йат* > *йот*, чув. *йот* > *йут*, удм., мар. *ят* id. < гом. төрки *йат* (кырг. *җат* > каз., к.-калп. *жат*), алт. *дьат*, хак., тув. *чат* id. Төр., аз. *йад*, монг. *җад, зад*, төркм. *йаат* id., үзб. *йот, йат*, төр. диал. (ДС III: 1492) *jat* «ят чит; жаһил, надан» элек-электән брб. диалектындагы **йагыт** «дошман, чит, дошманнар» – *йағы* сүзенең бор. күп. формасыннан дип тәгърифләнә. Räsänen 1969: 192; ЭСТЯ IV: 158–159.

**Ят** продуктив нигез: **ятлык, ятсын-у.** К. **Ятырга-у.**

**ЯТАГАН I [йа$^{о}$таған]** диал. (ЗДС: 238) «домосед» – «үз өеннән чыгып йөрмәүчән (кеше)» ← *йат-* «яту», чаг. *қабаған, қачаған* һ.б. (тамыр сүз + *аған*), бу модель төрле телләрдә очрый. К. түбәндәгене.

**ЯТАГАН II [йа$^{о}$таған]** «ятаган (вид оружия)» (в русских словарях толкуется как «короткая шашка», однако в турецких словарях как «охотничий нож») ~ кр.-тат. (Dobr. I: 412; III: 496) *catayan, yatayan* «очы бераз бөгелгән, йөзенең (кискесенең) ике ягы да үткен аучы пычагы»; аны гадәттә ятык-горизонталь хәлдә махсус савытта йөрткәннәр. К. төр. *yatagan,* фар. *йатаған, йатақан,* госм. (Радлов III: 190) *йатаған* «авыр ау пычагы» һ.б. (күп телләргә таралган). Чаг. **Ядыган, Ятаган I.**

**ЯТАК [йа$^{о}$тақ]** «постель; кровать; (временное, скромное) жилье» ~ гом. кыпч., уйг. *йатақ* (кырг. *җатақ* > каз., к.-калп. *жатақ*) – **ят-у** сүзеннән. К. ш. ук **ятакханә** «тулай торак; кунып чыгу йорты» (бу сүз каз., үзб. һ.б. телләрдә дә бар).

**ЯТЕШ [йәтеш], җәтеш** (ТТДС I: 182) «удобный; склонный; наготове» < *йатыш* id., **ят-у** фигыленнән («мәелле булу» мәгънәсеннән). Тат.-башк. (*а* > *ә*, *ы* > *ĕ*) палатальләшүе буенча ясалган.

Бу сүзнең беренчел формасы **йатышлы** иқенчерәк мәгъ. кулланыла.

**ЯТИМ [йәтим],** диал. **җәтим** «сирый; сирота» < гар. *йӓтӣм* id., ш. ук **ятимә** «девочка-сирота» < гар. *йӓтимӓ* id. Тат. диал. *җәтим-җистер* «үксез-ятимнәр» (к. **Җистер**).

**ЯТЛА-У [йа$^{о}$тла-],** диал. **җатла-у** «выучить наизусть» – иске тат. *йад,* диал. *йат* «хәтер» < фар. *йӓд* id. сүзеннән ясалган (*йад-ла-*), к. **Яд, Ядәч, Ядкәр.**

**ЯТ-У [йа$^{о}$т-],** диал. **җат-у** «лежать, лечь; обитать; иметь склонность; быть удобным, приемлимым» < гом. төрки *йат-* (к.-балк., кырг. *җат-* > каз., к.-калп. *жат-*), алт. *дьат-,* хак. *чат-,* тув. *чыт-,* як. *сыт-* id., к. ш. ук халаҗ. *йаат-* id. Бор. **йа-* фигыленең йөкл. юн. дигән фикер бар (ЭСТЯ IV: 156–157). *Ят* бик тә продуктив нигез: **яткылык, яткын, ятма, яту** (балык ятуы), **ятулык, ятык, ятым, ятынкы, ятыш, ятышлы, ятышсыз** һ.б., фигыльнең йөкл. юн. вариантлары **яткыз-у** һәм **яткыр-у** аерым мәгънә төсмерләренә ия. К. ш. ук **Ятаган, Ятак, Ятеш.**

**ЯТЫРГА-У [йа$^{o}$ты̆рға-]** (ЗДС: 239) «нуждаться; стесняться выдавать себя среди чужих» ~ кр.-тат., төр. *yadırγamaq* id. < *yat-ırγa-* ← *yat* «ят». Мәзкүр *-ırγa*//*-irgä* кушымчасы күп төрки телләрдә, әмма сирәк кулланыла.

**ЯТЬМӘ [йәтмә],** диал. **җәтмә** «нахлёстка, веревочная сеть» (к. ЛТ I: 154), «сетка для ловли птиц, горностая, рыбы; бредень; решётка» (Радлов III: 367), «тесьма для платья; перепонка; силок, силки» (БТДҺ: 133), «плавательная перепонка у птиц» (Balint 1988: 99) – шул ук мәгънәләр диал. *әймә*, башк. *әймәк* сүзендә дә бар (ТТДС I: 518; БҺҺ II: 98, 324) ~ мар. *ӓтмӓ, атма* «бүрәнкәсыман челтәр капчык, сөзгеч, сөкә; су кошларының аягындагы йөзү ярысы», чув. *атма* id., *ятма* «изү, ызма» (к. Сергеев 1968: 96), морд. *алтыма* «ятьмә» – Идел-Урал лингвистик ареалы сүзе, *-мә* кушымчасына караганда – төрки фигыльдән. Чаг. **Ялда-у** «йөзү». К. **Әтмәллә-ү.**

**ЯТЬРӘК [йәтрәк],** диал. **ятерәк, җәтрәк** «быстрее, живее» (ДС II: 262; ТТДС I: 182; БҺҺ II: 98) диал. *йәт, җәт* > *җәһәт* < гар. *җӓһд* «тырыш, тырышлык» сүзеннән (**иҗтиһат** сүзе белән тамырдаш).

**ЯУ I [йа$^{o}$w],** диал. **җаw** «войско; война; враг» (*кара яу* «полчище») < гом. кыпч. *йаw* (к.-балк. *җаw*, кырг. *җоо*, каз., к.-калп. *жаw*), төркм., үзб. *йоw*, алт. *дьуу*, хак., тув. *чаа* id. < бор. төрки (> уйг., үзб. диал., төркм., төр.) *jaγı*, уйг. *йәғи, йәғи* id., к. Будагов II: 332–333; Räsänen 1969: 178; ЭСТЯ IV: 55–57.

Уйг. һәм иске тат. *йаw* һәм *йағы* семантик һәм стилистик җәһәтләрдән аерымланалар: *йағы* һәрвакыт дошманны гына белдерә. *Йағы-, йағык-* «дошманлашу» фигыле дә билгеле.

*Йаw* < *йағы* сүзе белән чув. *çӑв, çу* «ят, чит» сүзе, аннары чув. *çуй* < *çой* > мар. *сӧй* «гауга; сугыш» сүзләре чагыштырыла, ләкин бу чагыштырулар юраулы. *Йағы* < *йа-ғы* дип уйлау ышанычлырак. Гомумән, *йаw, йағы* сүзләре бик күп күрше (гар.-фар., Кавказ һ.б.) телләргә кергән.

**Яу** продуктив нигез: **яулы, яусыз;** к. **Яугир, Яула-у, Яучы.**

**ЯУ II [йа$^{o}$w],** диал. **йәү, җау, җәү,** башк. *йәү* «жир, масло; блеск на поверхности», «мёд» (ЛТ I: 154) – везде употребляется редко и в устойчивых выражениях: *күз йавы* «блеск глаз», *бит җавы* «здоровый цвет лица» (Ф. Сәйфи-Казанлы), *җәүле*//*җаулы икмәк* «хлеб с маслом, лепёшка на масле», *бал җавы* «медовая падь»; гом. кыпч. *йау, җау* < бор. төрки *jāγ* «терлек мае, эч мае»; чув. *çу, çӑв* «май» < кыпч., к. ш. ук алт. *дьуу, дьүү* «яу, сагыз». ЭСТЯ IV: 58–59; Федотов II: 127.

Гом. төрки *jāγ* тур. к. Räsänen 1969: 177. Бу сүз бик күп һәм киң кулланышлы сүзләр ясалуга нигез булган, к. **Ярен, Як-у, Якты, Ян-у, Яртак, Яры, Яу-у** (боларның тагы күпсанлы дериватлары бар).

Дерив.: диал. (ТТДС I: 583, дөрес бирелмәгән) **җәүчә** «сарымай».

**ЯУГАНАШ [йа$^{o}$wғанаш]** (ТТДС I: 169) «постный суп» < *йаwған аш,* к. себ. (Тумашева 1992: 73) *йауған* ~ үзб. *ёвғон* < бор. төрки (ДТС: 248–249) *javγan* «майсыз-итсез» ← *java* «буш». К. **Чөйгемаш.**

**ЯУГИР [йа$^{o}$wгир]** иск. «воин, солдат» < бор. чыгт. *йаwкӓр* id. төрки *йаw* «яу» һәм фар. *кӓр* «эш, эшләүче» сүзләреннән гыйбарәт, к. үзб., таҗ. *ёвкор* > кырг. *җоокер,* каз., к.-калп. *жаукер* «яугир»; удм. телендә кызыклы ярымкалька: *ожгар, ожгарчи* (ш. ук *ожчи*) (Алатырев 1976: 35–36).

**ЯУЛА-У [йа$^{o}$wла-],** диал. **җаула-у** «завоевать» – бу сүзнең бу мәгънәсе тат.-башк. телләрендә генә, югыйсә каз., к.-калп. *жаула*, кырг. *җоола-* «яу булып бару; дошман күрү» < бор. төрки (ДТС: 224) *jaγïla-* id. ← *jaγï-* «дошман».

**ЯУЛЫК [йа$^{o}$wлы̆қ],** диал. **җаwлык** «платок» > удм. *ӟалық,* мар. *йолык*, мар., чув. *йалық* id.; чув. *çулӑк* < болг. **җоwлық* > мар. *солық,* удм. *сюлық* id. < гом. кыпч. *йаwлық* (к.-балк. *җаулуқ,* кырг. *җоолуқ* > каз., к.-калп. *жаwлық*) < (төркм.) *йағлық* «яулык», кр.-тат., госм. *йағлық* «кулъяулык», уйг. *йағлиқ* «тастымал» һ.б. *йағ* «май» сүзеннән; тат. мәгънәсенә **ябулык** сүзе тәэсир иткән. К. ш. ук гаг. *йаалық* «яулык». Егоров 1964: 217; Мухамедова 1973: 101; Рамазанова 2008: 113–117.

**ЯУРЫЛ-У [йа$^{o}$wры̆л-], йурыл-у** (Тумашева 1992: 73, 87) «обессиливаться, ослабеть» < **йаwыр-* «арыту; аркасын чиләндергәнче эшләү» фигыленең төш. юн., к. **Явыр.** Тат. яңгырашы чагыштырмача иң тәүге, бүтән телләрдә (кар., ком., төркм., төр., аз.) *йорул-* «ару, талчыгу» ← *йор-* «арыту, йончыту» < **йаwур-*, к. бор. төрки (ДТС: 249) *javre-, javru-* «зәгыйфьләнү», «хәлсезләндерү».

ЭСТЯ IV: 223 (бу сүзлек авторлары тат. мисалын белмиләр).

**ЯУРЫН [йаᵒwры̆н],** диал. **җаwрын, җаwырын** «загорбок, верхняя часть спины между плечами», «ключица» < *йавыр-ын,* ш. ук диал. (ТТДС I: 158, 563) *йавырна, җаwырна* «киемнең иңбашы» ~ гом. кыпч. *йаwрын, йаwрун,* каз. *жаурун,* балкар. *заурун,* шор., тув. *чарын,* як. *сарын* «яурын» ~ чув. *çурăм* «арт як, җилкә». К. **Явыр.**

**ЯУРЫНЧЫ [йаᵒwры̆нчы̆],** диал. **җаwрын, җаwырынчы** «гадальщик по лопатке животных» ~ кырг. *җоорунчу,* каз., к.-калп. *жаwырыншы* id.; терлекнең яурынын – калак сөяген учакта кыздыралар, шунда яурын өстендә төрле сызыклар пәйда була, аларны теге яки бу иероглифка охшатып юраганнар. Бу төр күрәзәлек бор. Кытайдан килә. Шуңа охшаш юраулар – *гаруспик* – антик дөньяда да булган.

**ЯУТИРӘК [йаᵒwтирәк]** (Тумашева 1992: 73) «чёрный тополь» ~ алт. *йутерек* id. (Будагов I: 414) «*йау* (сагыз) тирәге», ягъни «кара тирәк» сүзеннән, к. **Туйра.** Тирәк сагызы элекке тире эшкәртү эшендә кирәк булган; чаг. башк. *йаw сабагы (чабагы)* үзеннән җилем, сагыз алына торган чабак балыгы. К. Kannisto 1912: 99 (манси. *ieβtə räxiiβ* «сагызлы тирәк» сүзе татарчадан калька икән). К. **Яу II.**

**ЯУ-У [йаᵒw-],** диал. **җаw-у** «падать сверху (о дожде и снеге)», күч. «свалиться с неба и т.п.» < гом. кыпч. *йаw-* (к.-балк. *җаw-,* кырг. *җоо-,* каз., к.-калп. *жаw-*) < гом. төрки *йаг-,* чув. *çу-, çăв-* < болг. **җыw-* id., к. ш. ук чулым. *йäw-* id. К. **яңгыр <** *йагмур.*

Безнеңчә, *йаw- < йаг-* «яву», гом. төрки *йак-* «ягу (*май ягу*), былчырату; пычрату (*бәла ягу*)» (ЭСТЯ IV: 57–58) һәм арытабан *йаг > йау > җәү* сүзе белән бердәй: *ягъмур явды (йагды)* тәүдә «яңгыр былчыратты» мәгъ. булган, соңыннан гына бу мәгънә үзгәргән, абстрактлашкан (к. **Яры-у II** сүзендәге схеманы). Барлык бу сүзләрнең чыгыш нигезе *йаг* «май, җәү», ихтимал, бор. *йа-* тамырыннандыр (ЭСТЯ IV: 59). К. **Явым, Явын, Як-у, Яу II.** Räsänen 1969: 177.

**ЯУЧЫ [йаᵒwчы̆],** диал. **җаwчы, йаwцы, цауцы** (Радлов IV: 190) «сват, сводник» > чув. *евчĕ* [*йэвчĕ*] id. < гом. кыпч. *йаучы* (кырг. *җоочу, җуучу,* нуг. *йаwшы*, каз., к.-калп. *жаушы*), алт. *дьуучы, йуучы* id. – бәхәсле этимологиягә ия: гади генә *йаучы* < «(кәләш) яулаучы» дип уйлау, бор. төрки *йупчы* (Радлов III: 568) сүзенең фонетик йөзе белән килешми, шуңа күрә бу сүзне яз. монг. *ǯabulči, ǯaγuči, ǯiγulčin* «арадашчы; кунак» сүзеннән дип исәплиләр (Владимирцов: 247; Räsänen 1969: 176; ЭСТЯ IV: 34). А. Рона-Таш исә *яучы* һәм *чавыш* сүзләрен бердәй дип исәпли. К. **Чавыш.**

**ЯУШАН [йаᵒwшан],** диал. **җаушан, йәwшән** «вероника (растение)» ~ башк. (БТДҺ: 126) *йушан* «камыр агачы» < гом. кыпч., чыгт. *йаwшан* (нуг. *йувсан,* кырг. *җуушан,* каз., к.-калп. *җӧвсан*), куман. *juvšan,* төр. *yavušan,* аз. *йовшан, йойшан,* уйг. *йапшан* «әрем, яушан; кылган һ.б. (төрле җирдә төрлечә)». Рясянен *йабышган* сүзеннән ди (к. **Ябыш-у**) һәм ЭСТЯ (IV: 54–55) шуңа кушыла, ләкин рус. *евшан, емшан* «әрем төре» сүзе бу фаразны шикле итә (гомумән, бу сүз күп күрше телләргә кергән; рус. диал. *чашпан* < тув. *чашпан* «каракура» тур. к. Аникин: 647–648). К. ш. ук бор. төрки *jarčan, javčan* (ДТС: 235, 248) «чәнечкеле чүп үләне; яушан», тат. диал. **йаwшак** (ЛС: 12), **йушыр** (Тумашева 1992: 87) – үлән исемнәре. Безнеңчә, *йаwшан* төбендә бер төрле дару – им үләне һәм аның этимологиясен шул даирәдән эзләргә кирәк.

**ЯФРАК [йаᵒфрак],** диал. **җафрак, йафырак, җапрак, җапырак, йабрак** (Гиганов) «лист дерева», диал. «веник» < гом. кыпч. *йапрак, йапырак* (башк. *йапрак,* к.-балк. *чапрак,* кырг. *җапырак,* каз., к.-калп. *жапырак*), угыз. *йапрак* һ.б. (бу сүзнең фонетик вариантлары бик күп) id. < бор. яз. төрки *йапыргак < йалпыргак, йалбыргак* id. *йалбыр-* «ялбырдау» нигезеннән. ЭСТЯ (IV: 130–132) артык вакланып бүтән этимологияләргә дә туктала. Тәүдә *япрак < йалбыргак* терлек ашату өчен (печән урынына) ясалган миллекләрне белдергән булса кирәк (андый бәйләмнәрнең күп яфраклы булганы яхшы). Тат. *йафрак* варианты Алтын Урда уйг. теленнән килә (*п > ф*, чаг. *зифа, туфрак, фәрдә*). К. ш. ук алт. *дьалбырак,* к.-балк. *чапрак, чапырак,* як. *себирдэх* «яфрак». Чув. *çулçа < çолçа < çавăлçа* «яфрак» болг. **җалбырча* сүзеннән булса кирәк, к. себ. **йалбыршак** «киң, ялпак» (Дмитриева – 1981: 141 – **йалбырсак** дип бирә). Räsänen 1969: 188 (күп кенә вариантлар күрсәтә, ләкин барысы да теркәлмәгән, әлбәттә).

**ЯХШЫ [йаᵒхшы̆],** диал. **җахшы, жакшы, йакшы** «хорошо; хороший, добрый (о человеке)»

< гом. кыпч., башк. *йакшы* (кар. *йаксы,* к.-балк. *ахшы,* кырг. *җакшы,* каз., к.-калп. *жаксы*), угыз. *йагшы,* алт. *дьакшы,* бор. төрки (ДТС: 238) *jaqšï, jaxšï* id. < бор. төрки *йагышыг, йакыш-ыг* «ягымлы» сүзеннән (ЭСТЯ IV: 63–64), *як-, яг-* «күңелгә йагу» тамырыннан исәпләнә. Ләкин *йахшы* вариантының (*-х*) киң таралуы очраклы микән? Чаг. бор. Харәзем (ир.) *ja xūš* «яхшы». Рус. *якши* тур. Аникин: 723.

**ЯШӘҢ [йәшәң], йәшән,** себ. **йәҗәң** (ЗДС: 240, 243–244) «молодая пышная трава» ~ кырг. *җашаң,* каз. *җасаң* «юеш үлән» *йәш ~ йаш* «тамырыннан», к. бор. төрки (ДТС: 245) *jaš* «яшел, яшь, сәрин».

**ЯШӘР-Ү [йәшәр-],** диал. **җәшәр-ү** «позеленеть; увлажиться (о глазах); помолодеть» < гом. төрки *йашар-* id. (күп телләрдә юк) – бор. *йаш* «яңгырлар чоры, яшеллек, юешлек; яшь» сүзеннән. К. **Яшь I.**

**ЯШӘ-Ү [йәшә-]**, диал. **җәшә-ү** «жить, проживать» < гом. төрки, бор. төрки *йаша-* «яшәү, яшь (яз) уздыру» сүзеннән; к. ш. ук нуг. *йаса-,* кырг., к.-балк. *җаша-* > каз., к.-калп. *жаса-,* алт. *дьажа-,* тув., хак. *чаза-, назы-* «яшәү» (тув. сүзе бор. төрки *йашы-* варианты да булганлыгын күрсәтә).

**Яшә-** нигезенең дериватларыннан регуляр булмаган **яшәеш** төр. *jaşajiş* id. сүзеннән, к. ш. ук кр.-тат., кар. *йашайыш* id. К. **Яшел, Яшь I.**

**ЯШЕЛ [йәшĕл]**, диал. **җәшел** «зелёный» > чув. *йешĕл* [*йәшел*] id. < гом. кыпч. *йашыл* (нуг. *йасыл,* к.-балк., кырг. *җашыл,* каз., к.-калп. *жасыл*), алт. *йажыл, дьажыл,* шор. *чазыл,* хак. *чазыл* id. як. *саһыл* «сары» һ.б. < бор. төрки *йашгыл* id. к. алт. *йашкыл* id. бор. *йаш, йааш* «яшь, яшел» тамырыннан, ихтимал *йыл//йал* белән тамырдаштыр (ЭСТЯ IV: 164). К. **Яшәр-ү.**

**Яшел** продуктив нигез: **яшеллек; яшеллән-ү;** к. **Яшелчә** һ.б.

**ЯШЕЛЗӘҢГӘР [йәшĕлзәңгәр]** «ярь-медянка (лекарство от кожных и глазных болезней)»: **зәңгәр** монда фар. төп мәгънәсендә бакыр тутыгы. Рус. атамасы төрки (тат.) атамадан калька.

**ЯШЕЛЧӘ [йәшĕлчә],** диал. **җәшелчә** «овощ, овощи» – собственно «зелень» < **яшел-чә** культуралы үсемлек атамалары моделе буенча ясалган (чаг. диал. **кызылча** «чөгендер») < гом. кыпч. *йашылча* (кырг. *җашылча,* каз., к.-калп. *жасылша*) id.

**ЯШЕН [йәшĕн]**, диал. **җәшен** «молния» < гом. кыпч. *йашын* (нуг. *йасын*, кырг., к.-балк. *җашын*, каз., к.-калп. *жасын*), алт. *дьажын, ньажын*, шор. *чажын*, хак. *газын*, чув. *çиçĕм* id., к. ш. ук иске тат. **йашым,** чыгт. *йашим*, кар. *йашим* «яшен» (*йашым ташы* «яшма», чөнки бу ташны яшен ясый, ул яшеннән саклый дип исәпләгәннәр – Будагов I: 355 – һәм югары бәяләгәннәр). *Йәшен* < *йашын* < *йашгын* < *йашкын* һәм *йашым* сүзләре бор. *йаш-* (шор. *чаш-*), *jašu-* (ДТС: 230) «яшьнәү, ялтырау, балку» сүзеннән ясалганнар, шул ук фигыльдән чыгт. *йашук* «кояш». *Йаш-, йашу-* фигыле бор. **йалч-, *йалчу-* «ялтырап тору» фигыленнән, *ял(т)* тамырыннан. ЭСТЯ IV: 150. К. **Ялкын**, **Яшьнә-ү.** Чаг. чув. *çиçĕм, çилçĕм* < **җәлҗим* < **йалчын* ~ монг. *залин* < *жалин* «яшен». **Ялчы-у** «көлеп карау, үз итү» сүзе дә шушы рәттән булса кирәк. Барча бу сүзләрдә төрки телләргә хас *-лч* > *-ш* аваз күчеше күзәтелә.

**ЯШЕНЧӘК [йәшĕнчәк], яшенцәк, йәжембек, йәженпәк** (Тумашева: 74, 76; ЗДС: 240, 244) «игра в прятки; прячущиеся» ~ каз. *жасырыңбақ,* кырг. *жашынбак, җашымпак, шынмак* id. ← *жашын-* «яшеренү». Бу сүздә *-бәк ~ -пәк* кушымчасы, *-чәк ~ -цәк* кебек үк, аерым аффикс булса кирәк (*-мәк* белән бердәй түгел).

ЗДСта **йәшенцәк** сүзенә «яңа гына чыккан бет» дигән сәер аңлатма да бирелгән. Гомуми мантыйк буенча, асылда себ. **йәшенцәк** «куе үлән арасында яшеренеп яткан кыргый хайван баласы, мәс., кузый-күрпә, бәрән-бәти, дүдәк бәпкәләре» турында әйтелә бугай. Бет серкәсенә карата бу сүз күч. мәгъ. әйтелгән. К. **Яшер-ү.**

**ЯШЕР-Ү [йәшер-]**, диал. **җәшер-ү** «скрывать, скрыть, прятать» < гом. кыпч. *йашыр-* (кырг., к.-балк. *җашыр-,* нуг. *йасыр-,* каз., к.-калп. *жасыр-*), алт. *дьажыр-,* хак., тув. *чазыр-* id. гом. төрки *йаш-* < бор. төрки (ДТС: 246–247) *jaš* «яшеренү; качу», як. *сас-* «яшеренү»; чыгт. (Радлов III: 243) *йаш* «яшертен» фигыленең йөкл. юн., тәүдә, ихтимал, *йаштыр-* яисә *йашгыр-* формасында булгандыр, к. алт. *йашыт* «сер».

Тат. диал. (ТТДС I: 183) **йәшен-ү** «яшеренү» < гом. төрки *йашын-* id. турыдан-туры *йаш-* фигыленнән (шуның кайт. юн., *йәшеренү*дән кыскармаган), к. ЭСТЯ (IV: 16–161).

**Яшер-** продуктив нигез: **яшерел-ү, яшерен-ү, яшереш-ү,** диал. **йәшерек** «яшерелгән, яшеренгән хәлдәге» (к. Balint: 77); **яшерен < йәшерген;**

**йәшертен < йәшёрткён** «яшеренгән хәлдә» (к. ком. *йашыртгын* «яшертен»), диал. **җәшери, җәшерей < *җәшриғ** «әйбер яшерү уены». Крш. (Будагов II: 331) **йашерек** «(христианнардагы) таинство» – русчадан калька. К. ш. ук **Нашмак.**

**ЯШМА [йа°шма], яшьмә [йәшмә], яшым [йа°шы̆м]** «яшма» электән килгән төп тат. сүзләре (к. Насыйри II: 140), диал. (ЗДС: 237) **ясма** «яссы таш» дип аңлатканнар, ләкин **яшма** булырга тиеш, (ЗДС: 244) **йәшмә** «яшел» дигәне дә шул ук шәй. Рус *яшма* < тат. (ул шулай дип аңлатыла да). Элек яшманы «яшен ташы» дип атаганнар. Гомумән, *яшма, яшел, яшен* сүзләре үзара баглы, тик монда бүтән тамырларның контаминациясе булырга мөмкин. Кытайда яшьмә ташы элек-электән аеруча кыйммәтле дип саналган, яңа туган баланың авызына яшьмә каптырганнар. Монг. *Яшил Саган тэңри* (к. МНМ II: 609) «яшма яшен тәңре» дип тәрҗемәләнә. Гомумән, яшьмәнең бор. төп мәгънәсе – «яшел метеорит», аны күктән Алла иңдерә дип исәпләгәннәр.

**ЯШМАК [йа°шмак], яшьмәк [йәшмәк]** иск., диал. «головной платок, закрывающий и плечи» < гом. төрки (к. Будагов II: 330) *йашмақ* id. ← *йаш-* «яшерү». К. аз. (АДДЛ: 242) *јашмах* «алачык түбәсен ябу өчен камыш чыпта». *Яшмак* сүзе, гомумән, *-мақ* аффиксы ярдәмендә фигыль тамыры *йаш*-тан да, *мақ* «кием» сүзе кушылып исем нигезе *йаш*тан да ясала ала. «Мөхәммәдия»дә:

> *Чүн аны Гаишә ана ишетте,*
> *Яшанып яшмагын, дышын бикетте.*

Димәк *яшан-* фигыле дә булган, ул исә *йаша-* фигыль нигезеннән, анысы *йаш* исеменнән ясалган. *Яшер-ү < йашыр-у* сүзендә инде тамыры *йаш-* – тәгаен фигыль. К. **Нашмак.** Этнографик әдәбиятта **яшмак** рус телендә дә очрый.

**ЯШТАКАЙ [йа°штақай]** (ЗДС: 238) «угодливый, льстивый» ~ мар. *йаштагай,* чув. *яштакай* id. ***Яста-у** (к. **Ястау**) фигыленнән ясалган булса кирәк. Тат. **йастағай* > чув. яки мар. *йаштакай* > тат. *яштакай* (*с > ш* мар. һәм чув. телләренә хас).

**ЯШЬ I [йәш]**, диал. **җәш** «молодой; год жизни» < гом. төрки *йаш* (төркм. *йааш*, як. *саас*) > к.-балк., кырг. *җаш,* нуг. *йас,* каз., к.-калп. *җас,* алт. *дьас, ньас,* хак. *чаш, чеш, час* id., ш. ук «юеш, чи». Чаг. бор. монг. *ǯalayu* «яшь егет, яшь».

Безнеңчә, мәгънәви үсеш: «яңгырлы фасыл, юеш чак > үләннәр үскән чак, җәй > яшел чак > яшь (чак)» һәм ш. ук «яшь, кичерелгән җәйләр саны» бик аңлашыла һәм типологик характерга ия (чаг. *кары-у* «кар кичерү», рус. *лето* «җәй, яшь»). Кытай илчесе Сюй Тин (XIII г.) язганча, «яшен сораганда, татар ничә тапкыр җир яшәргәнен бармагында санап җавап бирә» К. В глубине столетий…: 144. Һәм *йәш < йаш* белән бор. *йал* (чув. *çул < çол* < болг. **җал < дьал < тьал*) «ел» сүзе төптә икесе бер сүз. Ләкин ЭСТЯ (IV: 161–164) *йаш* һәм **йал* сүзләре бердәйлеген танымый бугай.

**Яшь** продуктив нигез: **яшәр-ү, яшә-ү, яшьле, яшьлек** һ.б.

**ЯШЬ II [йәш],** диал. **җәш** «слеза» – гадәттә *күз яше* ~ чув. *куç çулĕ* дип тә әйтелә – гом. төрки *йаш* (закончалыклы фонетик вариантлар белән) id. ЭСТЯ (IV: 161–164) **яшь I** белән бердәй дип карый, ләкин, безнеңчә, күз **яше** икенче бер тамырдан булырга тиеш (типологик семантика буенча күз яше яңгыр юешлеге белән тәңгәлләштерелми).

**ЯШЬЛӘВЕК [йәшләwĕк], йәшәwек, җәшләwек, җәшәwек** (ЗДС: 185, 243, 243) «молодая густая трава; густая листва» ← *йәшнә-ү, җәшнә-ү* «шаулап үсеп утыру», *йәшлә-ү* «яшь үләндә утлап йөрү» < бор. төрки (МК, ДТС: 247) *jašla-* «яшь үләндә утлау» ← *jaš* «яшь, яшел», к. **Яшь I.** К. ш. ук түбәндәгене.

**ЯШЬНӘ-Ү I [йәшнә-]** «буйно разрастаться (о растительности всех видов)» ← **йәшлә-ү** ← *йәш* < бор. төрки (ДТС: 245) *jaš* «сәрин яшеллек».

**ЯШЬНӘ-Ү II [йәшнә-],** диал. **җәшнә-ү** «сверкать (о молнии)» – гади генә *яшеннә-ү < яшенлә-ү* сүзеннән булмаска да мөмкин: *йәш* «яшен» тамырыннан турыдан-туры ясалган булуы ихтимал.

**ЯШЬТИ [йәшти],** диал. **җәшти** «ровесник» < бор. **йашыт-ыг,* к. тув. *чажыт* > хак. *чазыт* «яшьти»; *карт < карыт* моделендә ясалган бор. нигездән. Күп телләрдә юк.

**ЯЭҖҮҖ-МӘЭҖҮҖ [йә'җүҗ-мә'җүҗ], Яәҗүҗ вә Мәәҗүҗ** «название мифического народа на далёком от арабов востоке, которого Искандер Зулькарнайн запер за железной стеной» – Сәддел-Искәндәр артына куылып биклэнгән һәм ахырзаманга кадәр шунда торасы ике халык атамасы.

Мөселманнар өчен бу риваять Кытай тур. әйтелгән кебек булган. Чынлыкта мәзкүр сүзләр – яһ. (Библиядәгечә) *Гог вә Магог,* тәүдә бор. еврейләрдән төньяктарак яшәгән һәм аларга дошман булган Магог иле һәм аның идарәчесе Гог. Бу сүзләр конкрет алганда нинди халыкны һәм нинди патшаны белдергәнлеге билгеле түгел (бик күп субъектив фаразлар әйтелгән), Византиялеләр берзаман Гог-Магог дип русларны атаса, руслар шул ук сүзләр белән монголларны атаганнар һ.б. МНМ I: 307, 596.

**Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ** Коръәндә махсус искә алына. Татарлар төрле чорларда Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ дип монголларны, русларны, кытайларны атаганнар. Бу сүзләр хәзер дә төрле ишле дошманнарга карата кулланыла.

**ЯЯЛА-У**: (ЗДС: 227) **йайала-у** «мучиться, страдать». Бу сүз брб. диалектына күрше халыклар – алтайлылардан яисә үзләренең элгәрләре – уйгурлардан, уйгур диалектларыннан килсә кирәк. Аларда *йайа-* «азаплану; корбан ителү» сүзе бар. Кытайның безнең эрадан күп элек языла башлаган тарихи язмаларында төркиләрнең килеп чыгышы турында күп тапкырлар бер үк риваять китерелә: иң бор. төркиләр (Кытайдан) көнбатышта, «Көнбатыш диңгез»дән көньяктарак яшәгәннәр. Берзаман аларга бик көчле дошман һөҗүм иткән һәм кырып ташлаган. Төркиләрдән бер аягы, бер кулы киселгән бер малай гына торып калган. Ул малайны бер бүре асрап үстергән. Төрки халыклар шул малайның токымнары.

Әкият шәкелендә булса да, бу риваять тирән дөреслекне чагылдырса кирәк.

Төрки һәм монгол халыкларында бик бор. заманнардан алып XIX г. кадәр бик үзенчәлекле һәм рәхимсез бер гадәт яшәп килгән: нинди дә булса бер ярамаган кыланышы өчен кешенең бер аягын, бер кулын кисеп, бер күзен чыгарып, кешесез далага илтеп ташлаганнар. Шул юл белән тәңрегә корбан ителгән кемсә, әгәр ул чыннан да гөнаһлы булса, **ярымтыкка** – шүрәле сыман рухка әйләнгән. Әгәренки ул гөнаһлы булмаса, корбанның җаны **җаян**га – күзгә күренмәс изге рухка әверелгән (ул **җаян** сүзенә тат. **наян, чая, чаян** һәм **шаян** сүзләре тоташа һәм шуннан ук **Зая-Түләк** образы килә).

Ярымтыклар һәм җаяннар турында төрки, монгол, тунгус вә бүтән Төньяк Азия халыкларында исәпсез күп риваятьләр, әкиятләр, сөйләкләр сакланган. Бу *җайан* сүзе – монг. *җайачи, дзаячи, заян, заяши, заяаша, заягыч* > *заяч* (к. МНМ I: 375; МНМ II: 247 һ.б.) – *җай-, җайа-* «корбан итү» сүзеннән килә.

Һиндстан галимнәре фикере буенча, бу сүз бор. һинд телендәге *җай* – кешене урталай ярып корбан итү сүзеннән таралган. Шуңа охшаш гадәтләр Америка индианнарында да бик билгеле. К. **Зая II, Наян, Чая, Шаян.**

Справочное издание

**Ахметьянов** Рифкать Газизянович

**ЭТИМОЛОГИЧЕСКИЙ СЛОВАРЬ
ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**

**В двух томах
Том II (М–Я)**

Казань. Издательство «Магариф — Вакыт». 2015

Белешмә басма

**Әхмәтьянов** Рифкать Газизҗан улы

**ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ
ЭТИМОЛОГИК СҮЗЛЕГЕ**

**Ике томда
II том (М–Я)**

Редакторы
Бизәлеш редакторы
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*
Корректоры

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.04.2015.
Форматы 84 x 108 1/16. Офсет кәгазе. «Times New Roman» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 35,5. Тиражы 1000 д. Заказ

«Мәгариф – Вакыт» нәшрияты
E-mail: valeevmx@mail.ru
http://magarif-vakyt.ru

Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленного
электронного оригинал-макета в типографии филиала ОАО «ТАТМЕДИА»
«Пик «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.
E-mail: idelpress@mail.ru